ТАТАР

ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

# ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР Ә.М.МАЗҺАРОВ

4

М–П

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ИНСТИТУТЫ
2014

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ҖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

## Баш гыйльми мөхәрририят

Ә.М.Мазһаров (рәис), Р.М.Вәлиев (рәис урынбасары), Р.К.Абдуллин, С.С.Айдаров, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, Г.С.Сабирҗанов (җаваплы мөхәррир), К.М.Салихов, М.Х.Сәлахов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Җ.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

© ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2014.
«Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында»гы РФ Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институтының язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

ISBN 978-5-902375-10-1

# М

**МА́ВРИН** Михаил Иванович (1.12.1929, Урта Идел өлкәсенең Иске Майна р-ны Кокрять а.), хирург, мед. фән. д-ры (1981). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Әлмәт шәһәре хастаханәсендә хирург булып эшли. 1959 елдан Казан мед. ун-тының 1 нче хирургия авырулары кафедрасында (1983 тән 12 нче шәһәр хастаханәсе, 2002 дән Респ-ка клиник хастаханәсе җирлегендә). Хезмәтләре гепатопанкреатодуоденаль зона патологиясе хирургиясе, ашказаны асты бизе хирургиясенә (панкреонекроз, киста, эренле тирән яра, хроник панкреатит), бөер, сидек юллары һәм сидек куыгы физиологиясе һәм патологиясенә карый.

Х е з м.: Нервная регуляция функции почек. К., 1980; Острый панкреатит. К., 1982; Атлас операции на поджелудочной железе. К., 1997 (автордаш).

**МА́ВРИН** Савва Иванович (1744, Новгород губ. — 1809, шул ук губернаның Тихвин ш.), дәүләт эшлеклесе, генерал-поручик (1791), сенатор (1791), яшерен советник (1797). Дворяннар нәселеннән. 1756 елдан хәрби хезмәттә. 1773–74 тә Пугачёв кузгалышы нәтиҗәләрен тикшерү буенча Казан һәм Оренбург яшерен комиссияләре әгъзасы. Император Екатерина II гә җибәргән хәбәрләрендә халыкның массакүләм рәвештә азатлык хәрәкәтенә күтәрелүенә сәбәп булган адм., алпавытлар һәм завод хуҗалары башбаштаклыгын гаепләп чыга. 1774 тә Е.И.Пугачёвның үз көрәштәшләре тарафыннан тотып бирелүенә ирешә һәм баш фетнәчедән иң беренче булып сорау ала (М. беркетмәләре 1858 дә басылып чыга, соңрак әһәмиятле тарихи чыганак булып хезмәт итә). «Пугачёв фетнәсе алдыннан Җаектагы чуалышлар» («Волнения на Яике перед пугачёвским бунтом», СПб., 1872) язмасында казакларның 18 йөз уртасында хөкүмәткә каршы чыгышлары турында җентекләп сөйли һәм әлеге вакыйгаларга объектив бәя бирә. 1776–86 да С.-Петербург икмәк кибетләре башлыгы. Шул ук вакытта С.-Петербург вице-губернаторы (1782–83), коры җир гаскәрләрендә генерал-провиантмейстер (1783–90). 1791–97 дә (бүленеп) Сенат департаментында хезмәт итә. 1795 тә Вятка, 1796 да, бер үк вакытта, Казан генерал-губернаторы. Губерна идарә органнарына ревизия үткәргәндә, М. хакимият органнарында эшләүчеләрнең үз урыннарыннан явызларча файдалану очракларын ачыклый. Ревизия нәтиҗәсендә җирле чиновниклар урыннарыннан алынып, эшләре судка тапшырыла. *Казан постаучылары чуалышлары* вакытында М. ташламаларга бара, постау мануфактураларында эшләүчеләр хезмәт хакларын арттыруга ирешәләр һәм җан башыннан түләнә торган салымнан азат ителәләр. М. Г.Р.Державин б-н хат алыша.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003. *Е.Б.Долгов.*

**МАВРО́ВСКАЯ** Магдалина Константиновна (23.2.1914, хәзер Свердловск өлкәсенең Каменский р-ны Маминское а. — 24.5.2012, Казан), график, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). 1934 елда Татарстан сынлы сәнгать техникумын (хәзер Казан сынлы сәнгать уч-щесе) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1986). М. иҗаты күпкырлы. Аның әсәрләре арасында — пейзажлар, портретлар, натюрмортлар, ш.у. акварель, рәсем, эстамп (офорт, литография, монотипия) техникаларындагы жанр композицияләре.



М.К. М а в р о в с к а я. «Казан Император университеты». Офорт, кәгазь, тушь, каләм, карандаш. 1976. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

1940–50 елларда М. рәсемнәренең графика серияләрендә станлы циклларының китап иллюстрацияләренә якынлыгы тоемлана: «Шагыйрь Тукайның балачагы» (1947, карандаш), «Пушкин Казан Кремлендә» (1950, төсле карандаш), М.Горькийның «Минем университетларым» әсәренә (1946–47, карандаш,



М.К. М а в р о в с к а я. «Танкердан Зөя утравы күренеше». Кәгазь, төс йөгертелгән литография. 1987. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

күмер), «М.Горький әсәрләрендә татарлар образы» (1958–59, кара акварель; 1962 дә акватинта б-н офорт техникасында башкара) иллюстрацияләр циклы.

1977–79 да Казанда М. тырышлыгы б-н ТАССР Сәнгать фонды каршында офорт остаханәсе оештырыла. 1970 еллар башында, рәссам-график буларак, М. иҗатының үзенчәлеген офорт билгели, әлеге стильдә «Кокушкино авылы — В.И.Ульянов-Ленинның беренче сөрген урыны» (1967–68), «Болгарлар» (1968–69), «Казанда Горький урыннары» (1976–79), «Казан Кремле манаралары» (1976–78), «Якын үткәндәге Казан», «Борынгы Казан» (икесе дә — 1987–89) әсәрләре иҗат ителә. Казанның йөзен саклап калу теләге башкала турында офорт серияләре иҗат итүгә этәрә.

Респ-ка (1942 дән) һәм зона — «Зур Идел» (Волгоград, 1967; Ульянов, 1969) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1981 (Казан), 1982 (Казан янындагы Васильево пос.), 1984, 1994, 2001, 2004 (Казан) елларда уза.

*Әд.:* Ч е р к а с о в а Н.В. Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; И л ь и н а М.Е. Шесть десятилетий вдохновенного труда // Казань. 1998. № 4; Магдалина Мавровская. Графика: Каталог выставки. К., 2001. *О.Г.Вербина.*

**МАГА́НОВ** Наил Өлфәт улы (28.7.1958, Әлмәт ш.), сәнәгать җитештерүен оештыручы, ТРның атказ. нефтьчесе (2001). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1983). 1976 елдан «Татнефть» АҖдә эшли: скважиналарны тикшерүче оператор, технолог, нефть һәм газ чыгару буенча мастер; «Елховнефть» НГДУында өлкән инженер – нефть һәм газ чыгару цехы башлыгы урынбасары, цех башлыгы; 1991 дән «Зәйнефть» НГДУы башлыгының капиталь төзелеш буенча урынбасары, 1993 тән АҖнең нефть һәм нефть продуктларын сату бүлеге башлыгы, 1994 тән ген. директорның җитештерү буенча урынбасары, 1998 дән урынбасары, 2000 нән беренче урынбасары – нефть һәм нефть продуктларын реализацияләү идарәсе башлыгы. Нефтьне читкә чыгаруның нәтиҗәле схемаларын эшләү һәм гамәлгә кертүгә, Түбән Кама шәһәрендә яңа нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары комплексының беренче чиратын төзү һәм файдалануга тапшыруга зур өлеш кертә. 2013 тән «Татнефть» АҖ ген. директоры, «ТАНЕКО» АҖ Директорлар советы рәисе. «Ел җитәкчесе-2010» респ-ка конкурсының «Актив инвестицион эшчәнлек өчен» номинациясе лауреаты. Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**МАГА́НОВ** Равил Өлфәт улы (25.9.1954, Әлмәт ш.), нефтьче, «ЛУКОЙЛ-Оверсиз» АҖнең директорлар советы рәисе (1997 елдан). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1977). 1977–88 елларда «Сөләйнефть» (1981–82 дә нефть промыселы башлыгы), «Ямашнефть» (1984–85 тә идарә башлыгы урынбасары), «Урьевнефть» (1985–88 дә идарә башлыгы) нефть-газ чыгару идарәләрендә эшли. 1988–93 тә «ЛУКОЙЛ-Лангепаснефтегаз» АҖдә (Лангепас ш., Төмән өлкәсе), ген. директор (1991 дән); 1993 тән «ЛУКОЙЛ» нефть компаниясе» АҖдә (Мәскәү), аңа нигез салучыларның берсе, вице-президент. Хезмәтләре нефть чыгару өлкәсенә карый. Нефть һәм су үткәргечләрен тутыгудан саклау, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру, эретеп ябыштырылган корыч торбалар һәм торба үткәргечләр эшләү, ремонт эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча яңа алымнар эшләүдә катнаша. Уйлап табуга 10 лап авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1989). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Как повысить нефтеотдачу пластов // Нефть России. 1995. № 12; И экономно, и экологично // Нефть России. 1998. № 1.

**МАГИСТРА́Т** (лат. magistratus — башлык), 1718 — 1869 елларда Россиядәге социаль катлауларга бүленешле шәһәр идарәсе органы. Баш М. регламенты (1721) буенча шәһәрләрдәге земство йортларына алмашка шәһәр М.лары кертелә. Шәһәр М.лары Баш М.ка (1727 гә кадәр), губернаторга һәм воеводага (1775 кә кадәр), Губерна М.ына (1869 га кадәр) буйсынулы була. М. башында бургомистр тора. 1724 тән ратман вазифасы өстәлә. М.тагы барлык вазифалар мәҗбүри хезмәт дип карала. М.ка сайлаулар воевода һәм губернатор җитәкчелегендәге органнар аша үткәрелә. Сайланганнар, С.-Петербургка барып, Баш М.та расланалар. Баштарак Көнбатыш үрнәгендә гомерлек хезмәт срогы билгеләнә. 1729 да М.ларны воевода каршындагы башкарма органнарга әверелдереп, исемен ратушага алмаштыралар, бургомистрның хезмәт срогы бер елга калдырыла, 1731 дән өч елга кадәр озайтыла. 1747 дә М.лар кабат торгызыла. Шәһәрнекеннән тыш провинция М.лары булдырыла. Шәһәр М.ы провинция М.ына, провинциянеке — губернаныкына, губернаныкы Баш М.ка буйсына. Провинция М.лары — президент һәм ратманнардан, шәһәр М.лары бургомистр һәм ратманнардан тора. М.лар адм.-мәхкәмә, полиция һәм салым салу-җыю функцияләрен башкаралар; сәүдәгәрләр һәм мещаннарның җинаять һәм гражданлык эшләрен карыйлар; дәүләткә төрле түләүләр түләтү һәм хезмәт йөкләмәсе үтәтүгә күзәтчелек итәләр; 1754 тән башлап таможня салымы һәм кибет, амбар, тимерчелек, ашханә, түләүле мунча, юлаучылар йорты тотудан, олау йөртү, ат сату, камыт тамгалау кебек хезмәтләрдән кергән керемнән акчалата салым җыялар. М.ларга дәүләт монополиясендәге товарлар (тоз, шәраб, тәмәке һ.б.) сату, казна тегермәннәре тоту кебек эшләр йөкләтелә. Алар карамагындагы таможнялар, ваклап эчемлек сату йортлары, кибетләр һәм складлар, ат базарлары, елга кичүләре, юлаучы йортлары, түләүле мунчалар, казна тегермәннәренә посад кешеләре арасыннан сайлап куелган бурмистрлар, целовальниклар күзәтчелек итә. Полиция күзәтчелеген старосталар, йөзлек, унлык башлыклары башкара. Гади халык арасыннан төнге каравылчылар билгеләнә. Сенатның 1754 ел 5 май фәрманы б-н М.лар каршында, иң түбәнге мәхкәмә инстанциясе буларак, сату-алу, ярминкә тәртипләре, вексельләргә кагылышлы эшләрне карау өчен гапләшү мәхкәмәсе булдырыла. Аңа судьялар сәүдәгәрләр арасыннан сайлана. 1720 елларга М.лар Казан губернасының барлык шәһәрләрендә диярлек булдырыла: Казанда шәһәр М.ына президент җитәкчелек итә, аның карамагында 2 бургомистр, 4 ратман эшли; Чабаксар М.ы 2 бургомистр, 3 ратманнан; Курмыш, Зөя, Алатыр, Уржум, Козмодемьянск, Васильсурск М.лары 1 бургомистр һәм 2 ратман; Царёвококшайск, Ядринск, Малмыж, Цивильск, Кокшайск, Яранск М.лары 1 бургомистр һәм 1 ратманнан тора. 1721 ел Регламенты буенча М. әгъзаларының саны шәһәрнең разрядына карап билгеләнә, сайлану хокукына беренче йөзлеккә кергән бай сәүдәгәрләр, югары дәрәҗәле гражданнар ия була. 1731 ел Фәрманы б-н бургомистр урынына югары һәм уртача дәрәҗәле, целовальник, хисапчы һ.б.ш. урыннарга түбәнрәк дәрәҗәле кешеләр — урта кул сәүдәгәрләр һәм кибет тотучылар дәгъва итә ала. Мондый бүленеш М.та хезмәт куючыларның мөлкәти җаваплылыгы б-н бәйле була. М.ка сайланган кешедән катгый рәвештә үз эшләрен калдырып тору таләп ителә. Бу еш кына бөлү куркынычы китереп чыгара. Шәһәр нигезләмәсе буенча 1745 тән М.ның адм.-хуҗалык функцияләре *шәһәр думасына* тапшырыла. 1782 дән, Баш М. бетерелеп, губерна М.ы гамәлгә керә. Шәһәр М.ы карары б-н килешмәгән кеше губерна М.ына мөрәҗәгать итә ала. Шәһәр М.ы өч елга сайланган 2 бургомистр һәм 4 ратманнан тора; шәһәр халкының саны 500 дән ким икән, ратушада 1 бургомистр һәм 2 ратман, 500 дән артык булса, 2 бургомистр һәм 2 ратман хезмәт куя. М.лар каршында опекунлык эшләре б-н шөгыльләнүче ятимнәр мәхкәмәсе эшли. 1775 нең 7 ноябре Манифесты нигезендә М. хезмәткәрләренең чиннары түбәндәге чикләрдә билгеләнә: губерна М.ы рәисе — 7 нче, прокуроры — 8 нче, утырышчылары — 10 нчы, 1 нче һәм 2 нче бургомистрлары — 11 нче класс; шәһәр М.ының 1 нче һәм 2 нче бургомистрлары, губерна М.ы ратманнары — 12 нче, шәһәр М.ы ратманнары һәм посад бургомистрлары — 13 нче, староста, гапләшү мәхкәмәсе судьялары һәм посад ратманнары — 14 нче класс. 1793 тә Чистайда М. булдырыла. Екатерина II чорында халык аз яшәгән шәһәрләрдә М.лар урынына ратушалар кертелә. Думалы шәһәрләрдә ратуша мәхкәмә эшләрен генә карый. 1824 тән кечерәк шәһәр һәм посадларда адм.-хуҗалык учреждениеләрен мәхкәмә учреждениеләре б-н куша башлыйлар, шәһәр идарәсе, шәһәр думалары һәм М.лардан алынып, ратушаларга тапшырыла. 1839 нең гыйнварында Казан губернасының биш шәһәрендә дума һәм М.лар ратуша б-н алыштырыла. 1869 да, яңа төр мәхкәмә учреждениеләре кертелү сәбәпле, М.лар бетерелә.

*Әд.:* Д и т я т и н И.И. Устройство и управление городов России. СПб., 1875; ш у л  у к. Городское самоуправление в России. Ярославль, 1877; З о р и н А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МАГНИ́Т ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ**, К а з а н  у н - т ы  к а р ш ы н д а. Казаннан 40 *км* көнбатыштарак, Горький тимер юлының Васильево станциясеннән 18 *км* төньяктарак урнашкан. 6 павильоннан: 4 се магнит үзлегенә нигезләнмәгән махсус (2 се вариацион, абс. күзәтүләр, приборларны көйләү һәм тикшерү), приборлар б-н дистанцион идарә итү һәм күзәтү материалларын эшкәртү павильоннарыннан тора.

1825 елда А.Я.*Купфер* университет бакчасында М.о. төзү һәм махсус приборлар сатып алу үтенече б-н Казан ун-ты идарәсенә мөрәҗәгать итә. Шул ук елда Казанда И.М.*Симонов* һәм Парижда француз академигы Д.Араго бер үк вакытта магнит күзәтүләре үткәрәләр һәм Европаның барлык терр-ясендә магнит давыллары барлыкка килүнең синхронлык фактын билгелиләр. 1828 дә ботаника бакчасы терр-ясендә, ун-тның Иске клиникасы ишегалдында ике магнит павильоны һәм таш беседка (тимер кулланмыйча) төзү башлана.

1829 да Казанда (шул ук елда Петербургта) Европада беренче М.о. төзелә (приборларның байлыгы буенча дөньяда иң яхшы биш обсерваториянең берсе), биредә беренче булып магнит угы үзгәрешләрен даими күзәтүләр үткәрелә башлый, һәм немец математигы К.Гаусстан 2 ел алдан, 1835 тә И.М.Симонов җир магнетизмы өлкәсендә мөһим ачыш ясый. 1840 та университет ишегалдында агач павильон төзелә, 1842 дәге янгынга кадәр даими магнит күзәтүләре үткәрелә. 1844 нең башына М.о.нең яңа таш бинасын төзиләр. 1872–78 дә М.о. директоры И.М.Смирнов тарафыннан Россиянең Европа өлешенең магнитлы манзарасы эшләнә, нәтиҗәдә иң зур тимер рудасы чыганагы — Курск магнит аномалиясе ачыклана. 1893 тә ун-т ишегалдында таш җир асты павильоны төзелә. 1904–09 да М.о. Займище тимер юлы станциясе тирәсенә күчерелә, биредә исә 1909 дан даими күзәтүләр үткәрелә башлый.

1965–66 да М.о. һәм Казан ун-тының файдалы казылмаларны эзләү һәм разведкалау каф. җирлегендә палеомагнит обсерваториясе (к. *Палеомагнетизм*) оештырыла. 1972–74 тә Раифа посёлогыннан (Яшел Үзән р-ны) ерак түгел М.о. өчен биналар төзелә, биредә 1980 гә кадәр иске М.о. б-н параллель рәвештә магнит күзәтүләре үткәрелә. Соңыннан тикшеренүләр Раифа янындагы яңа обсерваториядә генә алып барыла.

20 йөздә М.о. төрле оешмаларга — 1923–31 дә һәм 1957 дән Казан ун-тына, 1931–41 һәм 1942–48 дә («Магнит-метеорология обсерваториясе» исеме астында) СССР Гидрометеорология хезмәтенә, 1941–42 һәм

1948–56 да Җир магнетизмы фәнни-тикшеренү ин-тына буйсына.

М.о. тикшеренүләре Җирнең төп магнит кырын һәм аның гасырлардан килгән вариацияләрен өйрәнүдә зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман тикшеренүләре «В2» халыкара мәгълүматлар үзәгенә (Мәскәү) керә. Обсерватория төрле фәнни һәм җитештерү берләшмәләренең заказларын үти. М.о. 1 нче (1883) һәм 2 нче (1931–32) Поляр ел, Геофизик ел һәм Тыныч Кояш елы (1961–65) халыкара программаларында катнаша.

*Әд.:* Ульянин В.А. Новая загородная магнитная обсерватория Императорского Казанского университета и магнитные наблюдения за 1898 по 1912. К., 1914. *М.П.Черзор.*

**«МАГНИ́Т ЭШЧЕСЕ́»**, атналык иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Магнитогорск округ ком-ты, округ башкарма ком-ты һәм округ профсоюзлар советы органы. 1931 елның 6 июленнән 1935 нең августына кадәр Чиләбе өлкәсе Магнитогорск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 490 саны чыга. Мөхәррирләре — А.Гыйсмәтуллин, Әсәнов. СССРдагы иң эре кара металлургия пр-тиесе — Магнитогорск металлургия комб-ты төзелешендә эшләүче татар эшчеләре коллективына атап чыгарыла. Газета СССРда индустрияләштерү барышын яктырта, комб-тны торгызуга аеруча көч куйган татар эшчеләре турында очерклар (фотолар б-н), алдынгы тәҗрибә турында чыгышлар бастыра. Газета битләрендә еш кына эшче хәбәрчеләрнең мәкаләләре дә урын ала.

*Әд.:* Челябинская область: Энцикл. Челябинск, 2005. Т. 4. *Т.М.Насыйров.*

**МАГНИТОГО́РСК** шәһәре, *Чиләбе өлкәсендә* урнашкан. Халкы — 411860 кеше (2013), татарлар — 20433 кеше (2010). Татарлар ш.у. шәһәр эчендәге Яңа Северный һәм Новостройка эшчеләр посёлокларында яшиләр. 1929–32 елларда татар-башкорт мәктәбе була, 1931–35 тә М.да «*Магнит эшчесе*» г-тасы нәшер ителә, 1971–96 да «Яшьлек» татар-башкорт җыр һәм бию ансамбле эшли. 1991–2000 дә Татар мәдәни үзәге, 1996 дан «Милли мәдәниятләрнең Магнитогорск үзәге» муниципаль учреждениесе каршында татар бүлеге (җитәкчесе К.Р.Исхакова), 1998 дән «Иман» матди ярдәм күрсәтү фонды, 2000 нән «Төп йорт» татар социаль-мәдәни үзәге җәмәгать оешмасы эшли. 2004 тә җамигъ мәчет ачыла. 43 нче мәктәп каршында — татар сыйныфы, 22 һәм 135 нче балалар бакчаларында татар төркемнәре бар. Татар җәмәгать китапханәсендә 6000 нән артык исемдәге татар китабы, аудио- һәм видеоматериаллар саклана (2002). 1991 дән татар телендә «Ватан» радио тапшырулары чыга, 2000 нән айга 1 тапкыр «Төп йорт» г-тасы нәшер ителә. 1936–93 тә М.да татар-башкорт театры (1997 дә Татар халык театры буларак яңадан эшли башлый) була. Татар социаль-мәдәни үзәге каршында «Тамчылар» бию ансамбле, «Юлдаш» вокаль-инструменталь ансамбле, татар телен өйрәнү түгәрәге, ислам динен тотучы балалар лагерьлары (2004 тән) эшли. Ел саен Сабан туе (1974 тән), Нәүрүз (1991 дән), «Уйнагыз, гармуннар» (1997 дән), «Татар театры көне» (2000 нән) һ.б. үткәрелә. 2002 дә «Татар җаны» муз. конкурсы, 2001/02 дә Татарстаннан күчеп килүчеләр очрашуы («Якташлар очрашуы») оештырыла. М.да РФнең атказ. металлурглары Ш.А.Әгъләмҗанов, Ф.Г.Тимершин, техник фән. канд. Р.Т.Латыйпов, техник фән. канд., РФнең атказ. металлургы, РФ хөкүмәте бүләге лауреаты Р.С.Тәхәветдинов, РФнең атказ. транспорт хезмәткәре Ф.Г.Шәйдуллин туган. РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе Г.М.*Бигиев*, техник фән. д-ры Д.Х.*Девятов*, корыч коючы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты М.*Зиннуров*, РСФСРның атказ. артисты, Урал консерваториясе профессоры Ш.С.*Әмиров*, композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Р.М.Бакиров, сынчы, РФ Рәссамнары берлеге әгъзасы Н.С.Гайфуллин, арх., РФ Архитекторлар берлеге әгъзасы Н.Т.Сәяхов, РФнең атказ. энергетигы Р.А.Ганиев, РФнең атказ. төзүчеләре М.М.Мозаффаров һәм Ф.А.Мөхәммәтҗанов, Сов. Союзы Герое Х.Ә.*Ниатбәков*, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Дан ордены кавалеры Ф.М.Шәмсетдинов, шагыйрьләр Г.Г.*Афзал* һәм Б.Ш.*Рәфыйков*, язучылар Р.Х.*Фәизов* һәм М.М.*Хәбибуллин*, ТРның халык артисты Г.М.*Рәхимкулов*, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәрләре Р.Г.Рәхмәтуллин һәм А.Ш.Шакировның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М. шәһәре б-н бәйле.

**МАГНИ́ЦКИЙ** Василий Константинович (3.3.1839, Казан губ., Ядринск өязе Ядрин ш. — 4.3.1901, Ядринск өязенең Шуматово а.), педагог, тарихчы, этнограф. Чабаксар руханилар уч-щесен (1854), Казан руханилар семинариясен (1857), Казан ун-тын (1858–62) тәмамлый. 1862 елдан Казан җинаятьчелек палатасы канцеляриясендә хезмәт итә, 1863 тән Казан губернасының Казан һәм Чабаксар өязләрендә мәхкәмә тикшерүчесе. 1877–94 тә Вятка губернасының Уржум, Алабуга өязләре, Казан губернасының Лаеш, Спас, Тәтеш, Зөя, Чабаксар өязләре халык уч-щеләрендә инспектор. М. тырышлыгы б-н уч-щеләрнең саны арта (1884–85 тә генә дә 14 уч-ще яңадан ачыла), пед. курслар эшли, съездлар уздырыла, Казан губернасындагы укытучыларга үзара ярдәм күрсәтү җәмгыяте оештырыла. Үзенең эшчәнлегендә рус булмаган халыклар мәгарифенә зур игътибар бирә, туган телдә укыту кирәклегенә басым ясый. Отставкага киткәннән соң (1894), Шуматово земство уч-щесендә попечитель була, Беренче бөтенроссия халык санын алу вакытында хисапчы вазифасын башкара. Удмуртларны «*Мултан эше*»ндә актив яклый. Пед. һәм иҗтимагый эшчәнлеген фәнни-тикшеренү эше б-н бергә алып бара, Идел буе халыкларының, башлыча, чуашларның икътисади һәм рухи (дини) мәдәниятләрен өйрәнү һәм тасвирлау б-н шөгыльләнә. Фольклор һәм диалектология буенча материаллар җыя, археол. истәлекләрне, алар турындагы мәгълүматларны таба һәм архив документларын бастыра, Идел-Кама буе халыкларының килеп чыгышын һәм этник тарихын, йолаларын һәм дини ышануларын, ш.и. христианлыкка кадәрге мәҗүсилекне өйрәнә. М.ның берничә басма хезмәте Казан татарларына багышлана: «Казан шәһәре татарларының көнкүрешеннән фактлар» («Факт из быта татар г. Казани», 1882), «Тамбов һәм Казан татарлары турындагы мәсьәләләргә карата» («К вопросу о тамбовских и казанских татарах», 1895), «Мишәрләр (мещера, мещеряклар) һәм аларның Казан һәм Сембер губерналарында урнашулары турында берничә белешмә» («Несколько данных о мишарях (мещера, мещеряки) и селениях их в Казанской и Симбирской губерниях», 1898).

1877 дә Казанда уздырылган 6 нчы Бөтенроссия археология съездында катнаша. Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте әгъза-хезмәткәре (1874 тән), Археол. комиссиясе әгъзасы (1877 дән), Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыятендә мөхбир әгъза (1881 дән), хакыйкый әгъза (1885 тән). Җәмгыятьләргә археол. табылдыкларны һәм этнография әйберләрен, үзенең хезмәтләре һәм фоторәсемнәрен бүләк итә. Н.Я.*Агафонов*, Н.И.Золотницкий, Рус география җәмгыятенең этнография бүлеге секретаре В.Н.Майнов, башка тарихчы һәм этнография белгечләре б-н языша. П.Г.Осокин, Н.И.Золотницкий, В.А.Сбоев, чуаш этнографы С.М.Михайлов хакында биографик материаллар бастыра.

«Казанские губернские ведомости» (1861–84), «Русские ведомости» (1867–73), «Судебный вестник» (1873), «Известия по Казанской епархии» (1876), «Учёные записки Казанского университета» (1877–82), «Волжско-Камское слово» (1881–82), «Волжский вестник» (1883–87), «Известия Общества археологии, истории и этнографии при Казанском Императорском университете» (1884–1901), «Этнографическое обозрение» (1895), «Сборник статей, сообщений, описей и документов Нижегородской губернской учёной архивной комиссии» (1898–1901) һ.б. вакытлы матбугат басмалары б-н хезмәттәшлек итә. Чабаксарда бер урам М. исеме б-н атала.

Хезм.: Материалы к объяснению старой чувашской веры. К., 1881; Нравы и обычаи в Чебоксарском уезде: Этногр. сб. К., 1888; Чувашские языческие имена. К., 1905.

*Әд.:* Износков И.А. Василий Константинович Магницкий // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1901. Т. 17, вып. 5/6; Агафонов Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Вып. 1; Никольский Н.В. Биография В.К.Магницкого // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1919. Т. 30, вып. 2; Корбут М.К. Василий Константинович Магницкий и его труды. Чебоксары, 1929; Василий Константинович Магницкий — исследователь культуры и быта чувашей. Чебоксары, 1989.

*Е.П.Ключевская.*

**МАГНИ́ЦКИЙ** Михаил Леонтьевич (23.4.1778, Мәскәү ш. — 21.10.1844, Одесса ш.), дәүләт эшлеклесе, шагыйрь, публицист, хакыйкый статский советник (1810). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-ты каршындагы зыялы затлар пансионын тәмамлый (1795). 1795 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1798 дән Тышкы эшләр коллегиясендә, 1803–10 да Эчке эшләр министрлыгының дәүләт эшләрен җайга салу экспедициясендә бүлек башлыгы. 1810–12 дә Россия Дәүләт Советының Законнар чыгару депар-



М.Л.Магницкий.

таментында статс-секретарь. Шул ук вакытта 1810–12 дә Хәрби министрлык каршындагы Хәрби уставлар һәм кулланмалар эшләү комиссиясе директоры. 1812–16 да М.М.Сперанский эше буенча сөргендә була (Вологда ш.). 1816–17 дә Воронеж вице-губернаторы. 1817–19 да Сембер гражданнар губернаторы. 1819 дан Дин эшләре һәм халык мәгарифе министрлыгының Училищелар баш идарәсе әгъзасы. 1819 ның февраль-апрелендә Казан ун-тына ревизия үткәрә; ун-т эшчәнлегенә тискәре бәя бирә (укытучылар һәм студентларның белем һәм әхлак дәрәҗәсе түбән булу, динне санга сукмау, «хөр фикерлелек» б-н мавыгу). 1819–26 да Казан уку-укыту округы попечителе. Идел буенда мәгариф эшен үзгәртеп корырга омтыла: губернадан җыелган салымнар хисабына уку йортларын өстәмә финанслауга ирешә; рус булмаган халыклар өчен авыл мәктәпләре ачтыра; Әстерхан шәһәрендә көнчыгыш телләре ин-ты булдырырга тәкъдим итә; православие һәм самодержавиегә нигезләнгән «халык тәрбиясе» планын төзи. Казан ун-тында Изге Союз идеяләре рухындагы реформа уздыра: күп кенә фәнни предметлар фундаменталь дини тәгълиматка ярашлы итеп үзгәртелә. М. 25 профессорның 11 ен эштән җибәрә, китапханәдән «хөр фикер» таратучы китапларны алдыра, хезмәткәрләр һәм студентлар өстеннән адм. күзәтчелеген көчәйтә (шул максаттан 1820 дә ун-т директоры вазифасын гамәлгә кертә), укыту планнарын үзгәртә, башка дисциплиналар хисабына дини тәгълимат өйрәтүне киңәйтә. Аның тәкъдиме б-н 1821 дә «Казанские известия» г-тасы урынына «Казанский вестник» ж-лы чыга башлый. М. ун-тта һәм укытучы кадрлар әзерләүне яхшырту буенча аерым чаралар күрә, ун-тны шәркыять фәннәре үзәгенә әверелдерергә омтыла. 1820–23 тә сүз ирекен чикләгән цензура уставын эшләүдә катнаша. Либераль дворяннар арасында реакционер һәм обскурант атамасы ала, хөкүмәт даирәсендә дә дошманнары була. 1826 да Казан ун-тына генерал-майор П.Ф.Желтухин уздырган ревизиядән соң, адм. һәм финанс гаепләре табылу сәбәбе б-н, вазифасыннан азат ителә, Ревель шәһәренә сөрелә. 1823–33 тә шунда «Радуга» ж-лы нәшер итеп, рус тарихына багышланган, ш.и. Европа мәгарифен тәнкыйтьләгән мәкаләләр бастыра. 1833–39 да һәм 1841 дән соң Одесса шәһәрендә, 1839–41 дә Херсон шәһәрендә яши. «Одесский вестник» һәм «Одесский альманах» ж-лларында хезмәттәшлек итә. «Приятное и полезное препровождение времени» ж-лында (М., 1794) һәм Н.М.Карамзинның «Аониды» альманахында (М., 1796–99) сентименталь шигырьләре б-н катнаша. «Грузинода күргән төш» («Сон в Грузино», 1825; 1863 тә С.-Петербургта басылган) шигыре А.А.Аракчеевка багышлана. «Россия язмышы» («Судьба России», Ревель, 1832) мәкаләсендә М. татарлар Рус дәүләтен Европа йогынтысыннан коткарган һәм православие диненең сакланып калуына булышкан дигән фикер үткәрә. Аның «Җиһанга бер караш» («Взгляд на мироздание», М., 1843) брошюрасы — галәмгә христианлык карашыннан чыгып, лирик уйланулар формасында язылган чәчмә әсәр. «Хезмәт юлын башлаучы чиновниклар өчен эшлекле һәм дәүләти сөйләшүләр теле буенча кыскача кулланма» («Краткое руководство к деловой и государственной словесности для чиновников, вступающих в службу», М., 1835) китабында М. үзен чыганаклар белгече һәм талантлы стилист итеп таныта. Бу хезмәт «эшлекле тел»не катгый кысаларда, шул ук вакытта шагыйранә югарылыкта тасвирлавы б-н үзенчәлекле. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1821).

Чыг.: Два мнения попечителя Казанского учебного округа // Русский архив. 1864. Кн. 1; Показания М.Л.Магницкого // Девятнадцатый век: Ист. сб. М., 1872. Кн. 1.

Х е з м.: Печальная песнь на кончину П.И.Милиссино. М., 1795; Ода на случай постановления бюста её императорского величества. М., 1796; Поэзия // Собр. образцовых русских сочинений и переводов в стихах. СПб., 1821. Ч. 1; Дума при гробе Сперанского // Русская старина. 1893. Т. 80; Стихотворения // Сб. любовной лирики XVIII в. СПб., 1910.

*Әд.:* Ф е о к т и с т о в Е.М. Магницкий. Материалы для истории просвещения в России. СПб., 1865; Л а ж е ч н и к о в И.И. Как я знал М.Л.Магницкого // Рус. вестн. 1866. № 1; З а г о с к и н Н.П. Из времен Магницкого: Страничка из истории Казанского университета 20-х годов. К., 1894; ш у л у к. История Императорского Казанского университета за первые сто лет его существования. 1804–1904: В 4 т. К., 1902–04.

*Е.Б.Долгов.*

**МАДА́НОВ** Павел Васильевич (27.2.1903, Казан губ., Зөя өязе Морат а. — 23.9.1977, Казан), туфрак белгече, биол. фән. д-ры (1954), проф. (1954). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда ук эшли, читтән торып уку бүлеге ф-лы директоры (1932 елга кадәр). 1935 тән Казан ун-тында, туфрак белеме каф. мөдире (1957 дән). Хезмәтләре туфраклар эволюциясен һәм составын өйрәнүгә карый. М., беренчеләрдән булып, Көнчыгыш Европа тигезлегенең оборона корылмалары (16–17 йөзләр Рус дәүләте, Идел-Чулман буе Болгары) һәм бронза гасыр курганнары астында калган туфракларын әзлекле өйрәнә башлый. М. туфракта органик фосфатларны билгеләү методикасын эшли. Татарстан туфракларында молибден, кобальт, йод микроэлементларының күләме, таралу һәм хәрәкәтчәнлек үзенчәлекләрен билгели. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биологическая аккумуляция марганца в почвах Волжско-Камской лесостепи и его доступность сельскохозяйственным растениям // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн. 2, вып. 2; Вопросы палеопочвоведения и эволюции почв Русской равнины в голоцене. К., 1967 (автордаш); Микроэлементы и микроудобрения в подзолистой зоне Русской равнины. К., 1972 (автордаш).

*Әд.:* Павел Васильевич Маданов // Почвоведение. 1978. № 3. *А.А.Шинкарёв.*

**МАДЫ́К** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 99 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 68 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Клуб. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Мадык, Мандык исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, камыт ясау, агач материаллары хәзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та миссионерлык мәктәбе, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 180,1 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1811 дә — 39 ир-ат; 1834 тә — 133, 1859 да — 217, 1887 дә — 330, 1905 тә — 379, 1920 дә — 326 (Яңа Мадык авылы халкын да кертеп), 1926 да — 274, 1938 дә — 327, 1949 да — 258, 1958 дә — 249, 1970 тә — 226, 1989 да — 112, 2002 дә — 90 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф. Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**МАДЬЯ́Р** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 72 *км* көньяктарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 9 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда Салагыш авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Алабуга (1928 дән — Чаллы) кантоны Салагыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 99, 1938 дә — 524, 1949 да — 150, 1958 дә — 130, 1970 тә — 122, 1989 да — 49, 2002 дә — 25 кеше.

**МАДЬЯ́РОВ** Нәҗип Гәрәй улы (3.3.1928, хәзер Әтнә р-ны Кызыл Утар а. — 15.4.2002, Чаллы ш., туган авылында җирләнә), шагыйрь, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1962). 1960 елдан журналистлык эшендә, Арча р-ны «Коммунизмга» г-тасы редакциясендә бүлек мөдире (1960–63), Лениногорск телевидениесендә мөхәррир (1964–65), Балтач р-ны «Хезмәт» г-тасында мөхәррир урынбасары (1966–78). 1979 дан Чаллы шәһәрендә яши. 1979–88 дә 67 нче һөнәри уч-щедә директор урынбасары. Авыл хезмәтчәннәренә, туган як табигате, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә багышланган «Син генә уйларымда» (1962), «Җәйге яңгыр» (1970), «Мең төрле уй» (1976), «Рәшәле офыкларым» (1979) исемле шигырь җыентыклары авторы. Юмор-сатира әсәрләре «Кызыклы шигырьләр» (1990), «Хикмәтле хәлләр» (1995), «Көлке көлтәсе» (2000) җыентыкларына тупланган. Балаларга атап язылган «Ялкын яллы

кара айгыр» (1966), «Ямьле кыш» (1971), «Утлы кыя» (1978), «Салават күпере» (1988) кебек китаплары, нигездә, маҗаралы сюжетка корылган, шигырьләре фантазиягә, юморга, нечкә лирикага, табигать күренешләрен сурәтләгәндә төсмерләргә бай булулары б-н аерылып торалар. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Галиев Ш. Нәҗип Мадьяров // Казан утлары. 1979. № 10.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАДЬЯ́РОВ** Нәкыйп Әхмәди улы (6.9.1959, Арча р-ны Яңавыл а. — 9.11.1988, Казан), спортчы (самбо, дзюдо көрәше), СССРның спорт остасы (1977, дзюдо), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1983, самбо). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). 1981 елда, Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлаганнан соң, Казан «Органик синтез» ЖБдә эшли. Самбо буенча дөнья чемпионы (1983), «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең Үзәк советы беренчелегендә (1979, дзюдо; 1980–83), А.А.Харлампиев истәлегенә халыкара турнирда (1983), спорт осталары арасында 2 нче дөнья чемпионатында (1983) җиңүче. СССР Кубогы иясе (1982), Маршал В.К.Блюхер истәлегенә Бөтенсоюз турнирында (1977), Россия чемпионатында (1979) көмеш медальләр; самбо буенча РСФСР халыклары спартакиадаларында (Идел буе зонасы, 1978, 1982), СССР чемпионатында (1981), очучы-космонавт П.И.Беляев истәлегенә Бөтенсоюз ярышларында (1976) бронза медальләр ала. 1990 нан Казанда М. истәлегенә самбо буенча Бөтенроссия турнирлары уздырыла.

*Әд.:* Илдарханов И.Г. Алты егет булганнар... Бертуган Мадьяровлар турында кыйсса = Богатырского рода-племени ... Быль о братьях Мадьяровых. К., 2005.

**МАДЬЯ́РОВ** Нәфыйк Әхмәди улы (1.8.1956, Арча р-ны Яңавыл а.), спортчы (самбо, дзюдо көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1977, дзюдо), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1980, самбо). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1979). ТАССР (1975, 1977–83, самбо; 1978, 1980, дзюдо), РСФСР (1977, самбо), ТАССР кубогы ярышлары (1977, самбо; 1980, дзюдо), СССР (1982, самбо) чемпионы. Самбо буенча ТАССР (1976, көмеш), СССР (1978, көмеш; 1982, бронза), РСФСР (1981, көмеш; 1979, бронза) чемпионатларында, яшьләр арасында СССР беренчелегендә (1975, көмеш), Дөнья Кубогы ярышларында (1983, көмеш), СССР (1983, бронза), РСФСР (1983, бронза) чемпионатларында, РСФСР халыклары спартакиадаларында (1982, бронза) медальләр ала. 1980–85 тә Казан «Органик синтез» ЖБнең Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы. 1987–99 да ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгы системасында эшли, 1999 дан «Ак Барс-Питрәч» агрофирмасы директоры.

*Әд.:* к. *Мадьяров* Нәкыйп Ә. мәкаләсен.

**МАДЬЯ́РОВ** Рәфыйк Әхмәди улы (27.11.1953, Арча р-ны Яңавыл а.) спортчы (самбо, дзюдо көрәше), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1978, самбо), халыкара категорияле судья (1996). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1979). ТАССР (1972, 1974–78, 1981–83, 1978, 1980, дзюдо), «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең Үзәк советы (1973), «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Үзәк советы (1978), «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятенең Россия советы (1977), РСФСР халыклары спартакиадасы (Идел буе зонасы, 1982), СССР (1982), дөнья, спорт осталары арасында (1983), Сов. Союзы Герое Н.Липатов исем. Бөтенсоюз турнирында (1974, самбо) чемпион. Самбо буенча ТАССР (1971, 1975, көмеш), РСФСР (1982, көмеш; 1977, бронза), дөнья (1982, көмеш) чемпионатларында, СССР Кубогы ярышларында (1982, көмеш), РСФСР халыклары спартакиадасында (Идел буе зонасы, 1978, бронза) медальләр ала. 1979–83 тә Казан «Органик синтез» ЖБнең Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы. 1983–88 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгы системасында. 1988 дән Казанның төрле оешмаларында адм.-хуҗалык эшендә.

*Әд.:* к. *Мадьяров* Нәкыйп Ә. мәкаләсен.

**МАДЬЯ́РОВ** Фәрит Әхмәди улы (10.8.1944, Арча р-ны Яңавыл а.), спортчы, тренер (самбо, дзюдо көрәше), СССРның спорт остасы (1967, самбо; 1971, дзюдо), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (2004), РСФСРның атказ. тренеры (1978), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1973). Самбо буенча ТАССР чемпионатларында (1964–72, 1974–77), «Труд» ирекле спорт җәмгыяте Үзәк советы (1969–77), ВЦСПС (1973) беренчелекләрендә, Бөтенсоюз турнирларында (1972, 1975), РСФСР халыклары спартакиадаларында (Идел буе зонасы, 1978) җиңүче; дзюдо көрәше буенча Россия, ветераннар арасында Европа чемпионатларында җиңүче (2004). ТАССР чемпионатында (1963, самбо; 1968, ирекле көрәш), СССР (1965, самбо), ВЦСПС (1970, самбо) яшьләр беренчелегендә көмеш медаль; Россия (1973, самбо; 1968, көрәш), дөнья (2004, дзюдо, ветераннар арасында) чемпионатларында, ВЦСПС беренчелегендә (1971, самбо) бронза медаль иясе. 1975–77 дә ТАССРның иң яхшы тренеры булып таныла. 1976–88 дә «Синтез» спорт клубында тренерлык эшендә, бер үк вакытта РСФСР, СССР (1979–84) җыелма командалары тренеры, Аргентина җыелма командасы тренер-консультанты (1983). Самбо көрәше һәм дзюдо буенча СССРның 58 спорт остасын, ш.и. халыкара класслы спорт осталарын әзерли (Э.А.Водяшев, В.А.*Волков*, А.Ф.Зәйнетдинов, Ф.Идиятуллин, Рәфыйк, Нәкыйп һәм Нәфыйк Мадьяровлар, З.В.*Сәгъдиев*, И.В.Сәләхов). 1988 дән «Синтез» физик культура йорты (1991 дән Казан «Органик синтез» АҖнең чит ил белгечләре йорты) директоры.

*Әд.:* к. *Мадьяров* Нәкыйп Ә. мәкаләсен.

**МАДЯ́КИН** Фёдор Павлович (25.12.1929, Мордва АССРның хәзерге Краснослободск р-ны Каймар а. — 6.9.2012, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1975), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1980, 1996), СССРның атказ. уйлап табучысы (1979). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (2001 гә кадәр), проф. (1977), гетероген системалар химиясе һәм технологиясе каф. мөдире (1985–99), инженерлык химия-технологиясе ф-ты деканы (1977–85, 1990–92). Хезмәтләре махсус химиягә карый. М. пиротехника буенча фәнни юнәлеш булдыра. Гетероген янучан системаларның яну һәм нурландыру механизмын тикшерә. Аның җитәкчелегендә төрле кулланылыш өчен пиротехник составлар, пиротехник типтагы каты ягулыклар (ш.и. эластомерлар нигезендә, пластизоль нигездә) булдырыла; аларны әзерләү һәм алардан эшләнмәләр ясау технологияләре эшләнә. Үтәли пресслау алымы б-н катлаулы кисемле пироэлементлар алына, алар авиация техникасын җылылык ярдәмендә үзлегеннән төзәүле сугыш кирәк-яракларын саклау өчен җылылык бүлеп чыгаручы ясалма объектлар сыйфатында кулланыла (Әфганстанда, Чечен Респ-касында). М. периодик нурландыручы гетероген системаларны ача һәм аларның януын тикшерә; ак һәм төсле ялкыннар составларын тәкъдим итә («Салют» тибындагы эшләнмәләрдә кулланыла, йолдызлар җемелдәве кебек матур манзара тудыралар һәм фейерверкларны бизиләр, эз калдыру һәм сигнал бирү эшләнмәләрендә кулланыла ала); целлюлоза нитратлары нигезендә пиродары составларын (төсле утлар, очкынлы-ялкынлы һәм очкынлы-форслы, аэрозоль хасил итүче һ.б. составлар) һәм утиль дарылар нигезендә пиродарылар эшли. Фәнни эшкәртмәләре (эшләнмәләр, составлар) пиротехника з-дларында, ш.и. Эстәрлетамакның «Авангард» з-дында, В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесендә җитештерүгә кабул ителә, барлык заманча фейерверк эшләнмәләрендә кулланыла. 900 дән артык фәнни хезмәт, ш.и. 3 монография авторы. Уйлап табуга 200 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1975). Дуслык ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.



Ф.П.Мадякин.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000; Создатель школы пиротехников // Науч. Татарстан. 2004. № 4.

**МАЁВКА** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 154 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1910–20 елларда Зур Ключи авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан

өязе Ильинка волостенда. 1920 дән ТАССР-ның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 295, 1926 да — 427, 1938 дә — 313, 1949 да — 300, 1958 дә — 187, 1970 тә — 110, 1979 да — 48, 1989 да — 80, 2002 дә — 78 кеше.

**МАЖА́Р**, урта гасырларда (13–14 йөзләр) Алтын Урданың Төньяк Кавказдагы шәһәре. 14 йөздә Кавказ аръягыннан Кара диңгез алды терр-яләренә һәм Идел буена сузылган транзит сәүдә юлларының кисешү үзәге, ш.у. Кавказ алдының мөһим сәяси һәм икътисади үзәге буларак таныла. 1310–11 елларда М.да акча сугыла. 1395 тә шәһәрне Урта Азия әмире Аксак Тимер гаскәрләре җимерә. М.дагы таш биналарның археол. калдыклары 18 йөз ахырында Кума елгасы ярында, Святой Крест шәһәре (хәзер Ставрополь краеның Будёновск ш.) янында табыла. 1907 дә В.А.Городцов торак, төрбә, һөнәрче остаханәләре, шәһәр сууткәргече системасы калдыкларын ачыклый. 1960 елларда археол. казу эшләрен Э.В.Ртвеладзе, 1980–90 елларда — Э.В.Зивилинская алып бара.

*Әд.:* Городцов В.А. Результаты археологических исследований на месте развалин г.Маджара в 1907 году // Тр. 14 Археол. съезда. 1911. Т. 3; Ртвеладзе Э.В. Надпись Джанибек-хана на плите из Маджара // Советская археология. 1970. № 3; шул ук. Мавзолей Маджара // Советская археология. 1973. № 1; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII — XIV вв. М., 1985; Фёдоров-Давыдов Г.А. Золотоордынские города Поволжья. М., 1994.

*И.Л.Измайлов, Л.Ф.Недашковский.*

**МАЖА́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Солонка елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 3 кеше яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Мозяр исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, балта эше, өс һәм аяк киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 4 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 748,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 412, 1897 дә — 641, 1908 дә — 703, 1920 дә — 743, 1926 да — 684, 1938 дә — 524, 1949 да — 308, 1958 дә — 205, 1970 тә — 108, 1989 да — 7, 2002 дә — 5 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**МАЖАРАЛЫ́ ӘДӘБИЯ́Т**, мавыктыргыч сюжетка, кискен конфликтларга, төрле табышмак һәм серләргә корылган әсәр; эчтәлеге б-н «авантюр» әдәбиятка, детектив, фәнни фантастика, юлъязмага (сәяхәтнамәгә) якын. Татар әдәбиятында М.ә. урта гасырларда формалаша башлый. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен», Сәйядинең «Дастаны Бабахан» дастан-поэмаларын мажаралы мәхәббәт поэмалары рәтенә кертәләр. Урта гасырлар әдәби традицияләре 19 йөздә дә дәвам итә: К.Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы», «Әфсанәи Гөлрөх вә Камәрҗан», Ф.Халидинең «Әсфе сәхәр вә сәхәр, ягъни мең дә бер сәхәр», «Әлфе ләйлә вә ләйлә», Г.Фәезхановның «Тутыйнамә», Ш.Рәхмәтуллинның «Кылаф берлә Диләрә», «Кылаф берлә Турандык», «Малик», «Сәйфелмөлек» һ.б. күп кенә әсәрләр укучыга Шәрекъ илләре, мәхәббәт мажаралары, каһарманлык, тәхет өчен көрәш турында сөйли. Вакытлар узу б-н, М.ә. формасы үзгәрә төшә. 18 йөздә сәяхәтнамә жанры һәм аның бер төре — хаҗнамә формалаша башлый. Билгесез авторның «Исмәгыйль агай сәяхәтнамәсе», Гали Чокрыйның «Хаҗнамә»се, Ф.Кәримнең «Рихләт әл-Мәрҗани»е, «Аурупа сәяхәтнамәсе», С.Максудиның «Англиягә сәяхәт»е һ.б. ерак җирләр, башка халыкларның тормышы һәм көнкүреше турында сөйли. М.ә.ның бу төре татар әдәбиятының дидактик традицияләрен дәвам итә. 20 йөз ахыры прозаиклары М.Юныс («Юлда уйланулар», «Җиде могҗиза»), М.Мәһдиев («Җир йөзендә алты кыйтга»), Т.Әйди («Оҗмах утравы», «Кардәшләр кочагында») һ.б.ның юлъязмаларында сәнгати һәм документаль, лирик һәм аналитик башлангычлар берләшә.

19 йөзнең 2 нче яртысында М.ә.ның яңа — детектив төре барлыкка килә. З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы татар әдәбиятында беренче детектив әсәр санала. 1920–30 елларда яхшы б-н яман арасындагы конфликт сыйныфлар каршылыгы (Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы) кысаларында карала торган совет детективының аерым бер төре оеша; тора-бара ул өстенлек итүче идеологик юнәлеш басымында социаль һәм антисоциаль конфликтка әверелә (А.Расихның «Бәхет орлыклары», «Урланган хәзинә»). Сугыштан соңгы еллар татар әдәбиятында Р.Ишморатова («Милиция лейтенанты», «Тормыш дәвам итә»), Т.Әйди («Божра» детектив повесте, «Елан угы», «Иблискә ришвәт» мажаралы романнары) һ.б.ның әсәрләре танылa. М.Насыйбуллин («Телсез шаһитлар», «Яшерен касса», «Капкын»), Ф.Галиев («Урман йорты серләре», «Өрәк эзеннән», «Следователь Сомов хикәяләре»), Р.Сәгъдинең («Каргыш») психологик әсәрләрендә «милиция» детективы традицияләре социаль-әхлакый проблемалар б-н үрелеп бара. З.Фәтхетдинов иҗатына («Гомергә тиң сер» — «Тайна стоит жизни», «Унынчы мәет» — «Десятый мертвец», «Кыйммәтле шартнамә» — «Ценный договор») тарихи ретроспекция хас. Социаль, психол., әхлакый мәсьәләләр күтәрелгән детектив әсәрләр сериясен М.Маликова иҗат итә («Хөкем», «Августның беренче кичендә», «Утлар моңы», «Югалган якутлар», «Чәчкә балы» повестьлары, «Өермә» романы).

М.ә.ның тагын бер тармагы — фәнни фантастиканың барлыкка килүе 20 йөз башына карый (Ф.Әмирхан, «Фәтхулла хәзрәт»). Бөек Ватан сугышы елларында әлеге жанр Г.Кутуй әсәрләрендә чагылыш таба («Рөстәм мажаралары»). 1960–70 елларда А.Тимергалинның уйлап чыгарылган галәмнәр турындагы хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары («Пәһлеван кабере», «Космостан кунаклар»), 1990 елларда реалистик хикәяләүгә мистика элементлары килеп кергән романтик фантастика әсәрләре (Ф.Латыйфиның Р.Якушев б-н берлектә язылган «Тамга», «Игезәкләр», «Соңгы кисәтү» повестьлары) басылып чыга.

Хәзерге көндә М.ә. детектив, «фэнтези» (Г.Гыйльманов, «Албастылар», «Оча торган кешеләр»), авантюр-мажаралы повесть (Н.Гыйматдинова, «Елан»), «хатын-кыз романнары» (М.Маликова, «Шәфкать», «Фидая»), әдәби әкиятләр (Р.Батулла, «Елантау»), «массачыл әдәбият»ка якыная. 20–21 йөзләр киселешендә мажара җирлеге бүгенге заман кешесенә (Н.Гыйматдинованың «Таң ата да, кич була», «Аргы якта, бирге якта» повестьлары), хәзерге вазгыятькә (Ф.Латыйфиның «Бәйсез этләрне атарга» повесте) тәнкыйди карашны кискенләштерү һәм уен алымын (З.Хәкимнең «Агымсуда ни булмас...» романы) көчәйтү, ш.у. «автор үлеме» концепциясен куллану өчен (Т.Миңнуллинның «Минһаҗ мажаралары» романы; А.Фәлахнең «Татлы газап» повесте) файдаланыла.

*Әд.:* Бәширов Ф.К. XX йөз башы татар прозасы. К., 2002; История татарской литературы Нового времени (XIX — начало XX века). К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**МАЖАРЛА́Р** (maggari; кайвакыт мадьяр, бәҗгәрд, паскатирлар), Көньяк Урал алдында 10–14 йөзләрдә яшәгән угор чыгышлы ярымкүчмә кабиләләр төркеме. 10–14 йөзләр гарәп-фарсы тарихи-геогр. чыганакларында (Ибне Рустә, әл-Бәкри. «Ходуд әл-Галәм», әл-Гардизи, әл-Димәшки, әл-Гомәри һ.б.) искә алына. Хәзәр каганлыгы чигендә, әсәгел һәм бәҗәнәк кабиләләре арасындагы җирләрдә яшиләр. 10 йөз башында бәҗәнәкләрдән җиңелеп, М.ның бер өлеше венгрлар б-н бергә Дунай елгасы бассейнына күченә, икенче өлеше Идел һәм Урал буенда кала. 11–13 йөзләрдә М. Идел буе Болгар дәүләтенең көнчыгыш чикләрендә, аның мәдәни һәм сәяси йогынтысында яшиләр, 1223–32 елларда болгарлар ягыннан монгол гаскәрләренә каршы сугышалар. М. 14–15 йөзләрдә Алтын Урда составына кергән җирләрдә урнашалар, акрынлап мөселманлаша һәм төркиләшә баралар. М.ны тарихи яктан Постпетрогром (10–12 йөзләр) һәм Чиялек (13–14 йөзләр) археол. культуралары б-н бәйләп карыйлар. Этнологлар фикеренчә, бу кабиләләр иштәк һәм өлешчә татар-типтәр этнотерр. төркемнәренә якын тора.

*Әд.:* Заходер Б.Н. Каспийский свод сведений о Восточной Европе. М., 1967. Т. 2; Казаков Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; Левицкий Т. «Мадьяры» у средневековых арабских и персидских географов // Восточная Европа в древности и средневековье. М., 1978; Исхаков Д.М. Из этнической истории татар восточных районов Татарской АССР до начала XX в. // К вопросам этнической истории татарского народа. К., 1985; шул ук. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998; Измайлов И.Л. Средневеко-

вые памятники Альметьевского региона // Проблемы изучения истории заселения и образования населённых пунктов Альметьевского региона. К., 2000.
*И.Л.Измайлов.*


**МАҖЫ́Н** елгасы, Кама аръягының көнчыгыш өлешендә, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,2 *км*, бассейнының мәйданы 56,6 *км²*. Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Иске Маҗын авылыннан 4 *км* көньяктарак, тамагы Салкын Чишмә посёлогыннан 1,5 *км*. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. М.ның 2,6 һәм 5,6 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 80 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 300–400 *мг/л*. Елгада су күләме 0,49 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МАҖЫ́Н** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 13 *км* көньяктарак, Мәләкәс елгасы бассейнында. 2010 елда 8 кеше (татарлар) яши. 1719–22 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М. да су һәм җил тегермәне, әвен эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 860,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәткe волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 352, 1913 тә — 580, 1920 дә — 539, 1926 да — 292, 1938 дә — 290, 1949 да — 215, 1958 дә — 193, 1970 тә — 222, 1979 да — 62, 1989 да — 26, 2002 дә — 12 кеше.

**МАЗУ́НИНО КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), якынча 3–5 йөзләрдә Чулман алдында, Агыйделнең түбән агымында хөкем сөргән археол. культура. Беренче тапкыр 1958 елда В.Ф.Генинг тарафыннан тасвирлана. Атамасы Удмурт Респ-касының Сарапул р-ны Мазунино авылы янындагы каберлеккә нисбәтле. М.к. истәлекләре 19 йөздән мәгълүм. Алар А.А.Спицын (1887–88, 1898), Ф.Д.Нефёдов (1893–94), В.Ф.Генинг (1954–56), Р.Д.Голдина, В.А.Иванов, Т.И.Останина һ.б. тарафыннан өйрәнелә. М.к. халкы игенчелек (арпа, борай, солы, бодай игү), терлекчелек (мөгезле эре һәм вак терлек, ат, дуңгыз асрау), аучылык (төп объектлар — кондыз, поши, аю, кабан, куян, төлке, сусар) б-н шөгыльләнә, тимер (ураклар, кәкре чалгылар һ.б. табыла) һәм бакыр (бизәнү әйберләре) металлургиясе б-н таныш була. Балчык савыт-саба (йомры төпле, кабартылган кырынлы, муеннары тышка ачылган касә сыман савытлар) — кечкенә чокырлар, киртләнгән рәвештәге бизәкләр сырланган. М.к. кабиләләре шәһәр һәм авылларда яшәгәннәр (124 шәһәрлек һәм 265 авыллык мәгълүм). Торакларкүбесенчә җир өстендә агачтан төзелгән; учак калдыклары, кирәк-яраклар салу өчен казылган чокырлар сакланган. Мәетләр үзенчәлекле корбан чалу комплекслары булган каберләрдә җирләнгән (29 каберлек табыла). Мазунино каберлегендә — 69, Тарасовка каберлегендә (Удмурт Респ-касы) 1879 кабер тикшерелгән. Каберләрдә күмәк җәсәдләр, табут калдыклары очрый. Гадәттә, аларда мәет янәшәсенә әйберләр салынган туз тырыслар куелган. Аеруча еш очраучы эшләнмәләр — аскы өлешләрендә бөҗра беркетелгән чыбыксыман асылмалар, күбәләк рәвешендәге күкрәк каптырмалары, бил каешына беркетелгән тупыпочмаклык, ромб, түгәрәк формадагы, кайбер очракларда аскы өлешләренә вак бөҗралар өстәлгән бизәкләр, кабырчыклардан эшләнгән бизәнү әйберләре (бил каешы аеллары, асылмалар, муенсалар, бизәкләр), чылбыр рәвешендәге асылмалар, ш.и. түгәрәк калку төпле савыт-саба.

М.к. Пьянобор һәм Кара Абыз археол. культураларының мәдәни-тарихи комплексларына охшаш. Фаразланганча, фин-угор кабиләләренең Пермь төркеменнән калган. Т.И.Останина фикеренчә, М.к.ның формалашу процессы 2–3 йөзләр — 5 йөзнең 1 нче яртысы чикләрен колачлый. 3 йөзнең 2 нче яртысында М.к. кабиләләре яңа терр-яләрне, ш.и. хәзерге Татарстан җирләрен үзләштерә башлыйлар. 5 йөздә алар халыкның башка төркемнәре б-н кушылалар (Татарстанда — Турай, Пермь өлкәсендә — Кудаш, Башкортстанда Иске Луштино каберлекләре). Азелино культурасының Чулманның түбән агымы буендагы каберлекләрендә М.к.на караган предметларга охшаш әйберләр очрый, мәс., Рождествено V каберлегендә (Лаеш р-ны) Азелино бронза тагылмалары табылган каберләр өйрәнелә.

Татарстанның төньяк-көнчыгыш р-ннары терр-ясендә (Агыйдел, Ык елгаларының һәм Кама елгасының киктәш өлешләренең түбәнге агымнары буенда), ш.и. Менделеев р-нының Турай авылы янында М.к.ның 41 истәлеге табыла.



Турай каберлегеннән табылган Мазунино культурасына нисбәтле материаллар: 1. Каберлекнең курганлы булмаган өлеше планы; 2. Кабер планы; 3. Әйберләр (бронза, пыяла, балчык, тимер).

*Әд.:* Генинг В.Ф. Мазунинский могильник // Вопр. археологии Урала. 1967. Вып. 4; шул ук. Ижевский могильник IV–V вв. н. э. // Вопр. археологии Урала. 1967. Вып. 7; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989; Останина Т.И. Население Нижнего Прикамья в III–V вв. Ижевск, 1997; Голдина Р.Д. Древняя и средневековая история удмуртского народа. Ижевск, 1999.

**МАЗУНО́В** Мөнир Хәсән улы (1.4.1918, хәзер Пенза өлкәсенең Лопатин р-ны Иске Карлыган а. — 31.3.1987, Казан), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1949). Бөек Ватан сугышында катнаша, Ерак Көнчыгыш фронтының «Тревога» г-тасында хәрби хәбәрче. 1946–59 елларда (бүленеп) Татарстан радиоком-тында мөхәррир, соңрак башлык урынбасары. 1949–53 тә совет гаскәрләренең Төньяк төркеме составындагы «Вольность» г-тасында өлкән әдәби хезмәткәр. 1960–63 тә Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир, 1967–71 дә «Кооператор Татарстана» г-тасында җаваплы мөхәррир. «Йөрәк җырлый» (1959), «Күңелем аккошы» (1966), «Ул кайтмады» (1968), «Ак күгәрченнәр» (1972), «Туган як» (1975), «Офыклар» (1988) исемле шигырь җыентыклары авторы. М.ның шигырьләренә нечкә лиризм хас, аларда туган як табигатенең матурлыгы чагыла. Композиторлар Б.Мөлеков, М.Мозаффаров, Р.Яхин, Ә.Бакиров, З.Хәбибуллин, А.Ключарёв көйгә салган «Туган як», «Язгы хисләр», «Яшьләр җыры», «Әниемнең җылы кочагы» кебек җырлары халык арасында киң популярлык казана. Балалар өчен «Энесенә ул апа»

(1960), «Урал улы» (1962), «Нәни төзүчеләр» (1967),«Уйнагыз, балалар» (1985) исемле китаплары бар. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, С.Я.Маршак, Н.Хикмәт, П.Хузангай шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Ихлас күңелдән. К., 1980.

**МА́ЗУР** Берк Литманович (Борис Львович) (8.10.1896, Гродно губ., Бельск өязе Орли а. — 20.12.1987, Казан), фтизиатр, аллерголог, медицина д-ры (1935), проф. (1937), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1923), туберкулёз диспансеры (Казан) табибе. 1930 елдан Казан мед. ин-тында: факультет клиникасының рентген кабинеты мөдире (1930–71); туберкулёз курсы җитәкчесе, факультет терапиясе каф. киңәшчесе (1971–85). Бер үк вакытта Туберкулёз ин-тында рентген кабинеты мөдире (1926–32); эксперименталь лаб. мөдире (1927–1942); 1935 тән тире авырулары һәм венерик авырулар клиникасында эксперименталь лаб. мөдире.

Хезмәтләре туберкулёз авыруын китереп чыгаручы туберкулёз таякчыгы биологиясенә, чир вакытындагы аллергиягә, патологик материалдан микобактерия культураларын аерып алу ысулларына, авыруларны дәвалау өчен туберкулёз фагы һәм вируска каршы атуберкулин куллануга карый. 1928 дә М. туберкулёз таякчыкларының чиста культурасын аерып алу ысулын тәкъдим итә («Мазур ысулы»). 1940 та олылар һәм балаларда бронхиаль астма һәм хроник үпкә ялкынсынуын (пневмония) дәвалау өчен «зәңгәр таякчыклар» препаратын кулланып карыйлар. Бөек Ватан сугышы елларында эренле яраларны дәвалау өчен бактериофаг эшләнә. 1962 дә М. беренче булып үпкә туберкулёзының хроник формаларын дәвалау максатында туберкулёз бактериофагын һәм туберкулёз бациллаларының кислотага чыдамсыз төрләреннән туберкулин сыйфатларын җуйган, микробларга каршы көрәшү сыйфатларына ия фильтрат алуга ирешә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О диссоциации туберкулёзных бацилл. К., 1932; Кожная аллергия и полиморфизм возбудителя туберкулёза // Казан. мед. журн. 1934. № 9 (автордаш); Клиника и дифференциальная диагностика туберкулёза // Казан. мед. журн. 1959, № 6.

*Әд.:* Г у р ы л ё в а М.Э., В и з е л ь А.А., К р а с н о п ё р о в Ф.Т. К истории преподавания фтизиатрии в Казанском медицинском университете // Проблемы туберкулёза. 2001. № 5.

**МАЗҺА́РОВ** Әхмәт Мазһар улы (1.1.1943, Балтач р-ны Сасна а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1983), ТР ФА академигы (1992), ТАССРның атказ. химигы (1990), РФнең мактаулы нефтехимигы (2002). 1964 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Куйбышев синтетик спирт з-дында (1967 гә кадәр), Бөтенсоюз үсемлекләрне химик саклау чаралары фәнни-тикшеренү ин-тының Щёлково ф-лында (1970 тән) эшли. 1972 дән Бөтенроссия (Волга) углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. мөдире, директор урынбасары (1977 дән), директор (1981 дән), проф. (1990); ТР ФА президенты (2006–2014). Хезмәтләре күкерторганик кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә, нефть һәм газ эшкәртү технологиясенә карый. М. күкертле кушылмаларның металл-фтал-цианинлы катализаторлар катнашындагы оксидлашу реакцияләре кинетикасын һәм катализын тикшерүгә зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә нефть, авиакеросин, җиңел углеводород чималын меркаптаннан аеру технологияләре; газ конденсатын һәм авыр нефтьләрне — күкертле водородтан һәм меркаптаннардан, агып җыела торган суларны күкертле кушылмалардан чистарту технологияләре; бу процесслар өчен катализаторлар (гомоген һәм гетероген) эшләнә. Дөньяда беренче булып, нефтьне селектив демеркаптанлаштыру технологиясен эшләгәне өчен (Американың «Шеврон» компаниясе тарафыннан Тенгиз чыганагында (Казакъстан Респ-касы) гамәлгә ашырыла), ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1998). М. эшләгән технологияләр буенча Россиядә — 32, Болгариядә 1 сәнәгать җайланмасы төзелә һәм файдаланыла, Иранда 20 җайланма төзелә (2004). Уйлап табуга 112 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2005). «Почёт билгесе», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.



Ә.М. Мазһаров.

Х е з м.: Новые катализаторы и процессы для очистки нефтей и нефтепродуктов от меркаптанов // Нефтехимия. 1999. Т. 39, № 5 (автордаш); Ресурсы меркаптансодержащих нефтей и газоконденсатов и особенности их переработки // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4 (автордаш); Selective desulfurization crudes and gas condensates containing low molecular mercaptans and hydrogen sulfide // The Journal of the Iranian Petroleum Institute. 1999. № 51 (автордаш).

*Әд.:* Выпускники — гордость технологического университета. КХТИ — КГТУ (1931–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МАЙ КОҢГЫЗЛАРЫ́** (Melolontha), пластинкамыеклылар семьялыгыннан коңгызлар ыругы. 36 төре билгеле, Россиянең Европа өлешендә 2, Татарстанда 1 төре бар: көнчыгыш май коңгызы (M. hippocastani F.). Гәүдә озынлыгы 20,5–29 *мм*, киңлеге 10,6–14,6 *мм*, таза, соргылт куныклы коңгырт төстә, авырлыгы 0,6–1,1 *г*. Аркасының алгы өлеше кара, сирәк кенә кызыл. Түше һәм корсагы аксыл кыска төкчәләр б-н капланган. Башы, мыеклары, аяклары һәм канат өслекләре кызыл-көрән, канат өслекләре тар кара каймалы. Мыеклары 10 буынлы, кара, җилпәзә булып җыелучы пластинкалы. Ата затның мыегында — 7 озын, ана затларда — 6 кыска пластинка. Корсагының арткы очы канатлар б-н капланмаган һәм кисәк тараючы үсенте б-н тәмамлана. Коңгызларның канатлары яхшы үсеш алган һәм шунлыктан иркен очалар. Казырга җайлашкан аяклары ярдәмендә җиргә җиңел күмеләләр. Олы личинкалар зур (65 *мм*), чагыштырмача таза С-сыман гәүдәле, сирәк төкчәләр б-н капланган, башы зур, шома, сары-көрән төстә, нык казналыклы. Каеннар яфрак чыгара башлагач, апрель ахыры–майда (исеме шуннан) очалар. Очкан вакытта каен, тал, имән, усак, алмагач һ.б.ның яфраклары б-н туена. Карагай ылысына һәм нарат чәчәк төркемнәренә зыян китерергә мөмкин. Эңгер-меңгердә һәм кич б-н очалар; иртән һәм көндез, катып калган халәттә агачларда утыралар. Коңгызлар 3–6 атнага сузылган очу чорында парлашалар һәм 30–50 *см* тирәнлектә туфракка йомырка (30 га, кайвакыт 70 кә кадәр) салалар. Ана затлар, йомырка салганнан соң, гадәттә, туфрактан да чыгып тормыйча үләләр, ата затлар берникадәр иртәрәк үлә. Личинкалары 4–6 атнадан соң чыга һәм туфракта 3 ел дәвамында үсә. Башта нәзек тамырчыклар һәм гумус б-н туена, үсү б-н калынрак тамырларга күчә, агачларга һәм питомник үсентеләренә зур зыян китерә.

*Әд.:* П р и с я ж н ю к А.А. Вредители и болезни лесных насаждений. Минск, 1960; Т р о ш а н и н П.Г. Хрущи и борьба с ними. М., 1966; В о р о н ц о в А.И. Лесная энтомология. М., 1975.

*А.К.Жеребцов.*

**МАЙ ЧӘЧӘГЕ́** (Maianthemum), ландышчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 3 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — ике яфраклы М.ч. (M. bifolium), ара-тирә барлык районнарда очрый. Күләгәле ылыслы һәм катнаш урманнарда, ш.у. урман сазлыклары буйларында үсә. 8–20 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы туры, нәзек, кабыргалы. Яфраклары чиратлашкан, йөрәксыман, кыска саплы, яфрак сеңерләре белеп тора. Чәчәк ата торганнары ике, чәчәк атмаучылары бер яфраклы. Чәчәкләре вак, ак төстә, хуш исле, сабак очындагы күпереп торган чәчәк төркемендә. Җимеше — кызыл төстә, вак, шарсыман, 1–2 орлыклы, төчкелтем ят тәмле. Май ахыры–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Тамырчаның тиз үсүе сәбәпле, үсемлекләр куе булып үсә. Яфракларында гликозидлар, органик к-талар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе суык тигәндә, бөер авырулары вакытында кулланыла. Җимешләре миләш чипчыклары, божырлар өчен азык булып тора. Декоратив үсемлек.

**МА́ЙКАЛАР** (Meloë), чуанчылар (майкалылар) семьялыгыннан коңгызлар ыругы. Гәүдәсе зур (7–50 *мм* озынлыкта), ачык чуар төстә. Канатлары юк, канат өслекләре кыска, кабарынкы озын корсагының ян-ягына сыланып тормыйлар, башы кинәт кысып буылган. Гемолимфа составында агулы матдә — кантаридин бар, шуңа күрә аларны ерткычлар ашый алмый. 130 төре билгеле; киң таралганнар: Россиянең Европа өлешендә — 16, Татарстан терр-ясендә 6–7 төре билгеләнгән. Аеруча чуар майка (M. Variegatus Donov) күп. Коңгызлар ачык урыннарда язын күренә башлыйлар, яфраклар, чәчәкләр, нек-

тар б-н туеналар, чәчү культуралары шытымнарына зыян китерергә мөмкиннәр. Күкәйләрен (берничә меңгә кадәр) җиргә салалар. Чыккан личинкалар хәрәкәтчел, чәчәкләргә менәләр, умарта кортларына һәм башка элпәканатлыларга ябышалар, алар исә личинкаларны үз ояларына алып кайталар. Кабык салганнан соң, личинкалар аз хәрәкәтләнә, бал һәм башка запаслар б-н туена; умарта кортларының күпләп үлүенә китерергә мөмкиннәр. М.ның саны кимү сәбәпле, зәңгәр М. (M. Violaccus March) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*А.К.Жеребцов.*

**МАЙЛИ́Н** Баимбәт Җармагамбәт улы (1896, хәзер Казакъстан Респ-касы, Кустанай өлкәсе Таран а. — 25.2.1937), казакъ язучысы. Казакъ совет әдәбияты башында торучыларның берсе. 1913–15 елларда «Галия» мәдрәсәсендә белем ала. Анда булачак татар язучылары Ш.Бабич, Ф.Бурнаш, Х.Туфан, С.Кудаш б-н таныша; Г.Ибраһимовтан дәресләр ала. Аның җитәкчелегендә әдәби иҗат б-н шөгыльләнә башлый. 1915 тә Уфада казакъ авылы кызының фаҗигале мәхәббәте турында «Шұғаның белгісі» повестен бастыра (нигезен Г.Ибраһимов биреме буенча ирекле темага язылган инша тәшкил итә).

Окт. рев-циясеннән соң М. әсәрләренең төп герое — социализм төзүче шәхес. «Раушан-коммунист» (Кызыл Урда, 1929) исемле повестенда гади казакъ хатынының актив җәмгыять тормышына күтәрелүе тасвирлана. Казакъстандагы социаль үзгәрешләр «Азамат Азаматыч» (Кызыл Урда, 1934) романында чагыла. Аерым пьесалары милли азатлык өчен баш күтәрү (1916) һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларына багышлана. М.ның аерым сюжет линияләре, сәнгати фикерләү рәвешләре, проза стиле Г.Ибраһимов һ.б. татар язучылары иҗаты стилен хәтерләтә. Мәкаләләрендә үзенең иҗат тамырлары татар мәдәниятенә барып тоташканын әйтеп үтә. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Ә с ә р.: Толык жинак: 4 томда. Алматы, 1933–36; Повести и рассказы. М., 1958.

*Әд.:* Ж а р м а г а м б е т о в К. Б.Майлин: Жизнь и творчество. А.-А., 1962; Түркістан: Халакаралык энцикл. Алматы, 2000.

*Р.К.Ганиева.*

**МАЙЛЫ́ ГӨМБӘЛӘ́Р** (Suillus), болетачалар семьялыгыннан көпшәле гөмбәләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле. Төньяк ярымшарның урта өлкәләрендә таралган. ТР терр-ясендә 3 төре бар: көзге яки сары М.г. (S. luteus), ярмалы яки җәйге М.г. (S. granulatus), борычлы М.г. (S. piperatus). Урман буйларында, аланнарда, кашлакларда үсә. Ылыслы (күбесенчә нарат) һәм бик сирәк очракта яфраклы агачлар б-н микориза хасил итәләр. Июнь–сентябрьдә төркем булып үсәләр. Эшләпәсенең диаметры 10 *см* га кадәр, башта ярымшарсыман, кайвакыт читләре өскә күтәрелеп тора, сары, көрән, саргылт, шома, гадәттә лайлалы, ябышкак, күбесенең тиречел капламы җиңел куба, дымлы көннәрдә ялтыравык майлы (исеме шуннан) төсмер ала. Споралы порошогы аксыл сары. Сабы цилиндрик, озынлыгы 10 *см* га кадәр, юанлыгы 1–2 *см*. Көзге М.г. ярмалы М.г.дән сабындагы бөҗра һәм сары-көрән эшләпәсе б-н аерыла. Йомшагының тәме үтә борычлы булган борычлы гөмбәдән кала, барлык төрләре дә ашарга яраклы.

**МА́ЙНА** елгасы, Идел елгасының сул кушылдыгы, Көнбатыш Кама аръягында. Озынлыгы 55,7 *км*, ТРда — 14,4 *км* (югары агымы). Бассейнының мәйданы 1202 *км²*, Татарстан чикләрендә — 308,6 *км²*. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Спас р-ны Иске Рәҗәп авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, тамагы Ульянов өлкәсе терр-ясендә. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган һәм киң култык хасил иткән. Елга башының абс. биеклеге 130 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 26%. М.ның 8 кушылдыгы бар, иң зур сул кушылдыклары — Тинәр (15 *км*), Кандалка (20 *км*), Кызылсу (28,3 *км*) ТР терр-ясеннән читтә агалар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,13 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 84 *мм*, ташу вакытында су катламы 64 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,068 *м³/с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. М. бассейнында суның күләме 0,46 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МАЙО́РОВ** Борис Иванович (2.10.1931, Ижевск ш. — 27.6.1991, Казан), нәкышьче, педагог, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). 1947–49 елларда Ижевскида һөнәри-сәнгать уч-щесендә укый, Рәссамнар берлегенең удмурт бүлеге каршындагы сынлы сәнгать студиясендә М.В.Балагушин һәм В.А.Жарскийда шөгыльләнә. 1949–50 елларда Удмурт драма театрында декорацияләр эшләүче рәссам. Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1952), И.Е.Репин исем. Нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын тәмамлый (1958), Ю.М.Непринцев җитәкчелегендәге станлы нәкышь бүлегендә белгечлек ала. 1958 дән



Б.И. М а й о р о в. «Шуклык». 1954. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Казанда яши һәм эшли, Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968).

Киң иҗат диапазонлы рәссам М. рәсем сәнгатенең төрле жанрларында: көнкүреш, пейзаж, натюрморт өлкәләрендә эшли. Аның иҗатында портрет жанры аерым урын алып тора. М.ның «Виолончелист портреты» (1967), «Угыл» (1969) һ.б. әсәрләре геройларының рухи дөньясына тирән үтеп керә



Б.И. М а й о р о в. «Виолончелист портреты». 1967. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

алуын күрсәтә. Пейзажлары («Идел ага», 1979 һ.б.) хисле булулары, төсләрнең тыйнаклыгы б-н җәлеп итә. «Тәрәзә йөзлеге белән натюрморт» (1976), «Кашкарыйлар белән натюрморт» (1982) картиналарының төс-буяулар затлылыгы сокландыра. М. рәсем остасы да була («Хатын-кыз портреты», «Ир-ат портреты» — икесе дә карандаш б-н, 1962).

Респ-ка (1959 дан), зона — «Зур Идел» (1964 тән 1991 гә кадәр); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1970); «РСФСР автономияле республикалар рәссамнары әсәрләре» (Мәскәү, 1971); РСФСР сәнгать уч-щеләре укытучыларының хезмәтләре (Мәскәү, 1974) күргәзмәләрендә катнаша. М.ның шәхси күргәзмәсе 1991 дә (Казан) уза (вафатыннан соң).

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975; ш у л у к. Живопись автономных республик РСФСР (1917–1977). М., 1978; В а л е е в а Д.К. Всё богатство палитры // Цвети, мой Татарстан. К., 1980; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

**МАЙО́РОВ** Геннадий Дмитриевич (26.8.1927, Баку, Әзәрбайҗан ССР — 22.12.2001, Казан), хакимият эшлеклесе, ТАССРның атказ. икътисадчысы (1988). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1964). 1944–52 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1954–55 тә КПССның Тәтеш райкомы инструкторы. 1959–61 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында: инструктор, 1961–67 дә 1 нче секретарь ярдәмчесе. 1967–87 дә ТАССР Стат. идарәсе, 1987–88 дә Татарстан Респ-ка стат. идарәсе башлыгы.

1992–96 да Стат. буенча ТР Дәүләт ком-ты киңәшчесе. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**МАЙО́РОВ** Илья Андреевич (1891, Казан губ., Зөя өязе Гордеево а. — 11.9.1941, Орёл ш. янындагы Медведево урманы), Сул эсерлар партиясе җитәкчеләреннән берсе. Крәстияннәр нәселеннән. Казан ун-тының юридик ф-тында укый. 1905–07 еллардагы Рев-ция чорында Социалист-революционерлар партиясенең Казан бүлегенә керә, шуның өчен 1914 тә кулга алынып, 3 елга Енисей губернасына сөрелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанга кайта. Казан крәстиян депутатлары Советына сайлана. 1917 нең июнь–ноябрендә — Зөя өяз җир эшләре ком-ты һәм өяз Земство идарәсе рәисе, 16 июньдә җир эшләре ком-тының алпавыт җирләрен, терлекләрен, инвентарьларын крәстияннәргә бүлеп бирү турындагы карарына кул куя. Өяз, волость һәм авыл советлары оештырырга, изүчеләргә каршы көрәштә крәстияннәрне һәм эшчеләрне берләштерергә өнди. Большевиклар б-н хезмәттәшлек итә. Сул эсерлар партиясендә зур абруй казана, А.Л.*Колегаевның* ярдәмчесе була, ул эшче һәм солдат депутатларының 2 нче Бөтенроссия съездында вакытта сул эсерлар партиясенең губерна ком-ты рәисе һәм Крәстиян депутатларының губерна Советы рәисе вазифаларын үти. Окт. рев-циясе көннәрендә совет хакимиятен урнаштыруны яклап чыга. Учредительләр җыены әгъзасы. Сул эсерларның 1 нче съездында (Петроград, 1917 нең 19–28 ноябре) ҮК әгъзалыгына кандидат итеп сайлана. Крәстиян депутатларының 3 нче Бөтенроссия съезды (Петроград, 1918 нең 13 гыйнвары) депутаты. Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының берләштерелгән 3 нче Бөтенроссия съездында (Петроград, 1918 нең 13–18 гыйнвары) БҮБК әгъзасы итеп сайлана, БҮБКның крәстияннәр секциясе составына кертелә. «Җирләрне социальләштерү турындагы закон» авторларыннан берсе. Берләштерелгән съезд делегатлары, законны кабул итеп, аның «Гомуми нигезләмәләр»ен раслыйлар. 1818 нең гыйнвары–июнендә М. РСФСРның Җир эшләре халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, БҮБКның крәстияннәр секциясе секретаре. Сул эсерлар партиясенең 2 нче съездында (Мәскәү, 1918 нең 17–25 апреле) аграр сәясәт турында доклад ясый. Крәстияннәр арасында хосусый ихтыяҗлар өстенлек итү сәбәпле, җирләрне социальләштерү турындагы законны тормышка ашыра башлауның хәзергә мөмкин түгеллеген, аның большевиклар басымы астында кабул ителүен, шуңа күрә законны комиссиядә яңадан тикшереп, төзәтмәләр кертү зарурлыгын дәлилли. ҮКка әгъза итеп сайлана. 1918 нең маенда Казанга кайта, сул эсерларның губерна конференциясендә катнаша, губерна ком-тына сайлана. Сул эсерлар партиясенең 3 нче съездында (Мәскәү, 1918 нең 28 июне – 1 июле) большевикларга күндәм мөнәсәбәттәге эсерлар б-н арасын өзә, большевикларның хезмәтчел крәстияннәрне әзәрлекләвен гаепләп чыга, ярлылар ком-тлары эшчәнлегенә, үзгәрми торган бәяләр кертүгә, үлем җәзасына, большевиклар террорына протест белдерә. Сул эсерлар партиясенең Брест солыхын өзүгә, Германия хөкүмәтенең күренекле вәкилләренә карата террорлык актлары әзерләүгә юнәлдерелгән гамәли чараларында катнаша. Сул эсерлар фетнәсен оештыручыларның берсе була (1918 нең 6–7 июле). 1918 нең июле ахырында яшерен рәвештә Казанга кайта. Сул эсерлар партиясенең 4 нче съездында (Мәскәү, 1918 нең 2–7 октябре) катнаша, катгый рәвештә РКП(б) һәм совет хөкүмәте алып барган сәясәт б-н килешмәвен белдерә. Казанда кулга алынып (ноябрь), Мәскәүгә озатыла. 1918 нең 27 ноябрендә БҮБК каршындагы Революцион трибунал тарафыннан рев-циягә каршы фетнәдә катнашканы өчен, 3 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Сәламәтлеге какшау сәбәпле (туберкулёз), амнистиягә эләгә. 1919 да кабат кулга алына. 1923 тән сөргендә: икътисадчы булып эшли, М.А.Спиридоновага өйләнә. 1937 дә кабат кулга алына. 1938 дә 25 елга ирегеннән мәхрүм ителә, 1941 нең 8 сентябрендә үлем җәзасына хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Практическое проведение социализации земли. Саратов, 1918; Политика правительства коммунистов (большевиков) в земельном вопросе. Од., 1919.

*Әд.:* Красная книга ВЧК. М., 1989. Т. 1; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993; Казанский университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Л.И.Майоров.*

**«МА́ЙСКАЯ»**, диплоидлы карабодай сорты. 1968 елда Я.Я.Петелина, Г.В.Савинова, Ф.З.Шәкүрова тарафыннан Бөтенроссия бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары фәнни-тикшеренү ин-ты (Орёл ш.) һәм Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясе б-н берлектә «Краснострелецкая» сортыннан чыгарыла. Уртача өлгерешле, салкынга чыдам. Югары уңышлы (15–20% ка), эре бөртекле, чиста ярма чыгышы югары булуы, сөрлегүгә, коелуга һәм шытуга бирешмәве бу сортның үзенчәлеге булып тора. Уңышы буенча стандарт «Богатырь» һәм «Шаталовская-4» сортларыннан 1 *га* дан 2–4 *ц* га югары. Татарстанның Кама алды һәм Идел алды зоналарында (1973), Украина ССРның Полтава өлкәсендә (1978) районлаштырылган. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә (1976). ТРда 1990 елдан игелми.

**МА́ЙСКАЯ ГО́РКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 19 кеше яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Иске Чишмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 169, 1949 да — 148, 1958 дә — 126, 1970 тә — 112, 1979 да — 26, 1989 да — 13, 2002 дә — 3 кеше.

**«МА́ЙСКИЙ»**, Яшел Үзән р-нындагы хуҗалык. 1974 елда оештырыла. Үзәк утары — Осиново авылы. Төп җитештерү юнәлеше — ябык грунтта яшелчәчелек. Эшләүчеләр саны — 1660 кеше. Җир фонды 471 *га*, ш.и. 49 *га* дан артыграгы — кышкы теплицалар. Төп продукциясе — томат, кыяр, борыч, баклажан, яшел тәмләткеч культуралар, гөмбә. Чәчәк цехында ел саен 150 мең данә канәфер, роза, тюльпан, алтын чәчәк үстерелә. Егәрлеге 3 млн. шартлы банка булган консервлау цехы 24 исемдә җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен эшкәртә. Яшелчә җитештерү 1980 дә — 8,6, 1990 да — 12,8, 2000 дә — 14,7, 2005 тә — 20,4, 2012 дә 26,1 мең *т* тәшкил итә.



«Майский» теплица комбинаты.

Яшелчә җитештерүдә энергия саклаулы иң яңа технологияләр үзләштерелә. 1986 да яшелчә культураларын үстерүнең аз күләмле, ш.и. цеолитта — экологик чиста грунтта үстерү технологиясе гамәлгә кертелә. 1993 тән — тамчылап сугару системасы, 1997 дән озайтылган циклда яктырту культурасы, яктылык кайтаргыч плёнкалар һ.б. кулланыла. Икътисади һәм социаль үсеш планнарын уңышлы үтәгәне өчен хуҗалыкка КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының (1976, 1979, 1983, 1984, 1985, 1989), РСФСР МС һәм ВЦСПСның (1977, 1980, 1982, 1987, 1989), РФ Азык-төлек һәм а.х. министрлыгының (1989, 1994) күчмә Кызыл байраклары; «Алтын башак» (1996), «Алтын клише» (1997); «Алтын Меркурий» (1997) халыкара сертификатлары һәм призлары бирелә; ул СССР ВДНХсы лауреаты була (1980, 1987), «Казан ярминкәсе», «Интерагро», «Фермер», «Анимед», «Агрокомплекс» һәм «Энергия саклаулы технологик җиһазлар һәм материаллар» АҖләренең халыкара күргәзмәләре (1999, 2001) дипломнары б-н бүләкләнә. 2000 дә «М.» с-зында «Яшелчәчелек тармагының ябык грунтында энергия саклаулы алдынгы технологияләрне гамәлгә кертү» дигән Бөтенроссия семинары уздырыла. Эшчеләр дәүләт бүләкләренә, ш.и. СССР, РФ, ТРның мактаулы исемнәренә — 34 кеше; Хезмәт Кызыл Байрагы орденына — 2, «Почёт билгесе» орденына — 1, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденына — 1, алтын медальгә — 4, ш.и. СССР ВДНХсы медаленә 1 кеше лаек була.

2000 дә «М.» с-зы «М.» агрокомбинаты» дәүләт унитар пр-тиесе итеп үзгәртелә, аның җирлегендә (8–9 нчы цехлар) «Прогресс» ҖЧҖ төзелә, 2004 тә «М.» теплица комбинаты» ҖЧҖ итеп үзгәртеп оештырыла.

Җитәкчеләре: В.В.Карпов (1974–89), И.Г.*Ганиев* (1989 дан).

*Әд.:* Карпов В., Савельева Е. Свежие овощи круглый год. К., 1980; Лидеры АП России. М., 2000; Архипов В. Осиновские страницы. К., 2002. *В.А.Архипов.*

**МА́ЙСКИЙ** (Мәхүбгалиев) Сәхип Нурлыгаян улы (17.1.1901, хәзер БРның Борай р-ны Бигәнәй а. — 24.1.1942), Сов. Союзы Герое (7.4.1940), подполковник. Татар-башкорт хәрби мәктәбен тәмамлый (Казан, 1925). Гражданнар сугышында катнаша. Туган авылында колхозда эшли. Совет-фин сугышы вакытында 674 нче укчы полкның батальон командиры (13 нче армиянең 150 нче укчы дивизиясе). 1939 елның декабрендә Коуккуниеми (Ленинград өлкәсе Приозёрский р-ны) авылы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: сугышчыларны 8 тапкыр атакага күтәрә; торак пункт алынганнан соң, батальон һөҗүмне дәвам итә; М. каты яралана, әмма сафта кала. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышында катнаша, механикалаштырылган бригада командиры урынбасары. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. М.нең туган авылы мәктәбенә мемориаль такта куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Зайцев А.Д., Рощин И.И., Соловьев В.Н. Зачислен навечно. М., 1990. Кн. 2. *М.З.Хәбибуллин.*

**МАКА́ЕВ** Әнвәр Әхмәт улы (28.5.1916, Мәскәү — 30.3.2004, шунда ук), тел галиме, филол. фән. д-ры (1964). РФАнең Тел белеме ин-тында эшли. Гомуми тел гыйлеме, германистика (герман телләре тарихы, морфологиясе, рун язуы), индология (борынгы ведалар теле), арменистика, һинд-европа ареаль лингвистикасы мәсьәләләренә караган хезмәтләр авторы. Париж лингвистика җәмгыяте һәм Швециядәге Рунология җәмгыяте әгъзасы.

Хезм.: Язык древнейших рунических надписей (лингвистический и историко-филологический анализ). М., 2002; Общая теория сравнительного языкознания. М., 2004.

**МАКА́ЕВ** Харис Нуретдин улы (27.11.1941, Чүпрәле р-ны Иске Шәйморза а.), ветеринар-микробиолог, эпизоотолог, иммунолог, вет. фән. д-ры (1996), проф. (2002). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (2011). 1969 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшкә калдырыла. 1983 тән Бөтенроссия фәнни-тикшеренү вет. ин-тында, биопрепаратларны тикшерү һәм стандартизацияләү секторы мөдире (1998 дән). Хезмәтләре яшь терлекләрдә респиратор һәм ашказаны-эчәк авырулары, мөгезле эре терлекләрдә некробактериоз, бозауларда сальмонеллёз очракларында куллану өчен нәтиҗәле химик дәвалау препаратлары уйлап табуга карый. А.х. терлекләрен йогышлы авырулардан (листериоз, некробактериоз, сальмонеллёз, гадәти дуңгыз чумасы) дәвалау өчен М. уйлап тапкан вакциналар хуҗалыкларда киң кулланыла. Терлекләрдәге йогышлы авыруларны дәвалау һәм кисәтү максатыннан ул эшләгән 25 рекомендация һәм норматив-техник документ вет. өлкәсендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы һәм 4 патенты бар.

Хезм.: К вопросу специфической профилактики листериоза свиней // Ветеринария. 1974. № 10; Динамика иммуноморфологических изменений у поросят после аэрозольной иммунизации вакциной из штамма листерий АУФ // Ветеринария. 1984. № 7; Принципы лабораторной диагностики некробактериоза // Ветеринарный врач. 2010. № 3.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**МАКА́РИЙ МОНАСТЫРЕ́**, 17 йөз уртасы — 20 йөз комплекслы архит-ра истәлеге. Югары Ослан р-ны терр-ясендәге Идел елгасының уң ярында, «Рудник» пристане янында, Зөя утравыннан 1,5 *км* да урнашкан. Монастырьга Макарий Желтоводский-Унженскийның эшен дәвам иттергән монах Исая нигез сала. Монастырьның төп бинасы — Вознесение Господня чиркәве — 17 йөз уртасында агачтан төзелә. Исая аның төньяк дивары янында җирләнә. 18 йөз башында чиркәү таштан яңартып салына. 19 йөз башыннан монастырьда яңа кирпеч биналар төзелә башлый.

1835–39 елларда хәйрияче Н.И.Саврасова иганәсенә «Вознесение Господня» чиркәве классицизм стилендә үзгәртеп корыла. Композициясе сузынкы үзәкле. Квадрат рәвешендәге үзәк гыйбадәт залы түбәсенә нечкә муентыклы кечерәк кенә шарсыман гөмбәз



Макарий монастыре. Гомуми күренеше. Н.Дмитриев рәсеме. 20 йөз башы.

корылган. Аның югары өлешендә — өчпочмаклы фронтоннар, ә фасадларында зур булмаган турыпочмаклы тәрәзәләре бар. Аңа көнчыгыш яктан — апсида рәвешендәге ярымтүгәрәк конструкция, көнбатыштан бер катлы, уксыман гөмбәзле зур подваллы ашханә һәм 21 метр биеклектәге өч ярусле чаң манарасы тоташкан (Казан бае Е.Н.Лебедев акчасына төзелә). Чаң манарасындагы икенче ярусның түбәнге өлеше фасадларын ярымтүгәрәк уемнар, югары өлешенең ян-яклары уемнар һәм пилястралар бизи, цилиндр формасындагы өченче ярус шарсыман гөмбәз б-н тәгәлләнгән. 1907 дә храм төзәттерелә. Аның зыян күргән гөмбәзләре 2000 дә арх. К.И.Мусина проекты буенча яңадан торгызыла.


1866 да Вознесение Господне баш храмының төньяк-көнчыгыш тарафында кирпечтән изге Афанасий Александрийский һәм Барлык изгеләр хөрмәтенә багышланган янкормалары булган «Барлык хәсрәт чигүчеләр юанычы» Мәрьям Ана иконасы чиркәве төзелә. Ике катлы, квадрат рәвешендәге апсидасыз храм 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-расының типик үрнәге булып тора. Фасадлары штукатурланган һәм агартылган. Бинаның



С.Н.Майский.

беренче катын — турыпочмаклы, икенчесен а́ркалы зур тәрәзәләр яктырта. Түгәрәк җиллек уемнары уелган көньяк һәм төньяк фасадлар ике кыеклы итеп эшләнгән, көнбатыш як өчпочмаклы фронтон б-н камалган. Ишек чиркәүнең көнбатыш ягында урнашкан; биредә чиркәү монастырь башлыгы корпусы б-н тоташкан, корпусның аскы катында хөҗрәләр һәм кунакханә урнашкан. Фасадларның архитектур-декоратив бизәлеше соңгы классицизм стилендә башкарылган.

1892 дә Вознесение Господня чиркәвенең көнбатыш ягында эклектика стилендә кирпечтән 12 хөҗрәле, ашханәсе һәм аш-су әзерләү бүлмәсе булган ике катлы, коридорлы монахлар корпусы төзелә. Аның фасадларының беренче катын гөмбәзсыман тәрәзә уемнары, икенче катын кокошник рәвешендәге а́ркалы тәрәзә йөзлекләре тигезләп бүлгәләгән. Фасадның өч өлештән торуын пилястралар, буйга киселешен борыслар һәм профильле кәрниз күрсәтеп тора. Торак корпусның көньягында, чишмә өстендә, ишеге төньякка уелган, агартылган квадрат кирпеч бина — 19 йөз ахырында псевдорус стилендә төзелгән кәшәнә урнашкан. Портал буйга сузылган а́рка б-н бизәлгән, профильле киртләч кәрнизе бар. Түшәме әвернәле гөмбәз рәвешендә ябылган, идәнгә ак таш түшәлгән. Элек кәшәнә эчендә ике борынгы икона — Смоленск Мәрьям Ана һәм Макарий Желтоводский-Унженский иконалары торган. Чишмәнең төньягында байрак, хач һәм иконалар күтәреп тантаналы йөрүләр оештырылган.



Макарий монастыре. Вознесение чиркәве. 17 йөз уртасы. Реконструкция. 1835–39.



Г.А. Макаров.

1892–98 дә тотылган койма комплексны берләштерүче элемент булып тора, ул төньяк дивар буйлап сузыла. Монастырь комплексы терраса читендә урнашкан. Терраса күп терәкләр б-н ныгытылган. Койма кирпечтән, металл кушып тотылган. Комплексның көнбатыш һәм көнчыгыш тарафларында тешле кәрниз, ачык профильле, филёнкалы руст б-н бизәлгән а́ркалы таш капка бар. А́рка уемында архивольт алымы кулланылган. Капка а́ркаларына гөмбәзләр беркетелгән. Койманың озынлыгы 110 метр.

1797 дә М.м.нда император Павел I була. Ул комплексның табигать кочагында урнашуына игътибар итә. Аның тарихы б-н кызыксынганнан соң, 1798 дән казна исәбеннән ел саен 300 әр сум акча бирергә боера, ш.у. монастырь милке итеп җир кишәрлекләрен, балык тоту урыннарын, тегермән һ.б.ны теркәп куярга куша.

Совет чорында, 1930 елларда, М.м.ның ике чиркәве, чаң манарасы һәм кәшәнә гөмбәзләре юк ителә; кайбер тәрәзәләр томалана, биналар үзгәртеп корыла; монастырьда 1937 дән Идел известьташ чыгаручы рудник конторасы, тулай торак һәм складлар, Бөек Ватан сугышы чорында — госпиталь, 1985 кә кадәр балалар туберкулёз санаторие урнаша. 1997 дән монастырь биналары комплексы Казан епархиясенә тапшырыла.

*Әд.:* З о г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; М а л о в Е.А. Свияжская подгородная Макарьева пустынь. К., 1897.

*Л.М.Мортазина, Г.И.Середа.*

**МАКА́РОВ** Александр Степанович (1904, Казан губ., Спас өязе Рус Йорткүле а. — 9.9.1970, Казан), ветеринар-хирург, вет. фән. д-ры (1963), проф. (1965). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1929). 1929–34 елларда Урал өлкәсенең Ишим шәһәрендә район вет. табибе булып эшли, 1934–40 та Куйбышев районара вет. бактериология лаб-ясендә вет. табиб-консультанты, 1940–41 дә Кукмара р-нында вет. табибе. 1941–45 тә фронтта, вет. лазаретының хирургия бүлеге башлыгы. 1945–50 дә Львов а.х. ин-тының хирургия каф. мөдире вазифасын башкаручы. 1950 дән Казан вет. ин-тының гомуми һәм махсус хирургия кафедрасында, 1961 дән — каф. мөдире. Хезмәтләре терлекләрнең нерв системасы эшчәнлеге үзенчәлекләре б-н бәйле резистентлыгын һәм реактивлыгын, яраланган терлекләрнең типологик реактивлыгын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: К методике исследования особенностей типов высшей нервной деятельности крупного рогатого скота // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1961. Т. 82; Коэффициент частоты пульса и дыхания как клинический показатель процессов саморегулирования // Уч. зап. Казан. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1967. Т. 98.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**МАКА́РОВ** Алексей Сергеевич (21.4.1949, Юдино р-ны Красная Горка а. — 25.11.1998, Казан), физик, техник фән. д-ры (1998). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлый, «ГИПО» Федераль ФҖБдә эшли, директор урынбасары (1983 тән), директор (1987 дән), ген. директор (1991 дән). Хезмәтләре атм. оптикасына һәм оптик приборлар төзелешенә карый. М. кыр шартларында атмосфераның оптик-физик параметрларын үлчәү өчен приборлар комплексын булдыра. Ирекле ориентлашкан трассадагы тепловизион приборларның атмосфера каналында энергия югалтуларны бәяләүнең инженерлык методикасын, ш.у. әйләнә-тирәнең экологик мониторингы өчен махсус приборлар комплексын: «Луч-ДПР» лазер станциясен, «Квант-2П», «Квант-3П » аэрозоль счётчикларын эшли. М. җитәкчелегендә 1987–98 дә оборона заказлары үтәлә, танкларга каршы комплекслар өчен тепловизион төзәгечләрне серияләп җитештерү оештырыла. СССР МС (1990), ТРның Дәүләт (1998, үлгәннән соң) бүләкләре лауреаты. 1991–96 да ТР ЮС депутаты. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальные данные о прозрачности приземных атмосферных трасс различной протяжённости в видимом диапазоне длин волн 0,6–25,0 мкм. М., 1979 (автордаш); Оптическая погода в нижней тропосфере. К., 1998 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**МАКА́РОВ** Анатолий Николаевич (29.4.1962, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2009), проф. (2010), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), Кама политехник ин-тында эшли. 1997 елдан Казан ун-тының Чаллы ф-лында: директор урынбасары, бер үк вакытта икътисад каф. мөдире (2003 тән); директор (2004–12), бер үк вакытта икътисад ф-ты деканы (2012 дән). Хезмәтләре базар мөнәсәбәтләре шартларында югары белем бирү, җир милке һәм аның икътисади яктан гамәлгә ашыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Реализация земельной собственности: системный и институционально-эволюционный подходы. К., 2007; Экономические проблемы инновационного развития. М., 2009 (автордаш); О земельной собственности и экономической безопасности регионов // Землеустройство, кадастр и мониторинг земель. 2012. № 10; Проблемы управления собственностью в системе воспроизводственного потенциала регионов. Уфа, 2012.

**МАКА́РОВ** Василий Тимофеевич (28.7.1900, Сембер губ., Сембер өязе Крюковка а. — 23.1.1978, Мәскәү), агрохимик-туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1948), проф. (1948). Казан а.х. һәм урман хуҗалыгы ин-тын тәмамлый (1927). 1933–37 елларда Татарстан югары коммунистик а.х. мәктәбендә игенчелек каф. мөдире. 1937–38 дә Казан ун-тында агрохимия каф. мөдире, 1938–41, 1946–48 дә проректор. 1947–48 дә М. Албаниягә командировкага җибәрелә, анда аның җитәкчелегендә Тирана шәһәрендә университет ачыла. 1948–54 тә Томск ун-ты ректоры. 1954–76 да Мәскәү ун-тында игенчелек каф. мөдире. Хезмәтләре Татарстанда туфракны известьләү юлы б-н бөртекле культураларның уңышын күтәрү мәсьәләләренә карый. М. известь запасларын тикшерә, аларны куллану ысулларын эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Потребность серых лесостепных почв в извести // Тр. Томского ун-та. 1949. Т. 107; О прохождении стадии яровизации в летнее время одноукосным красным клевером в условиях таёжной зоны Сибири // Вопр. географии Сибири. Томск, 1952. Вып. 3; Пути повышения урожайности озимой ржи в Томской области // Тр. Томского ун-та. 1954. Т. 130.

*Әд.:* Профессор В.Т.Макаров (к 75-летию со дня рождения) // Вестн. Моск. ун-та. Сер. 17. Почвоведение. 1975. № 3; Учреждения и деятели сельскохозяйственной науки Сибири и Дальнего Востока: Биогр.-библиогр. справ. Новосиб., 1997.

**МАКА́РОВ** Владимир Николаевич (14.8.1924, Казан — 3.3.1985, шунда ук), хакимият эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1969). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1949). 1948–50 елларда Казанда ВЛКСМның Совет райкомы 1 нче секретаре. 1950–53 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1954–57 дә «Казэнергострой» трестында, бүлек башлыгы (1956 га кадәр). 1957–61 дә Казан химия-технол. ин-ты проректоры. 1961–63 тә Казан хезмәт ияләре депутатларының Совет район советы башкарма ком-ты рәисе. 1963–67 дә ТАССР мәдәният министры урынбасары. 1967–79 да ТАССР МСның Кинофикация идарәсе башлыгы. 1979–84 тә ТАССР Кинофикация буенча Дәүләт ком-ты рәисе. Бу елларда респ-када торак пунктларны тоташ кинофикацияләү гамәлгә ашырыла, фильмнарны прокатка алу буенча иң югары күрсәткечләргә ирешелә. 1951–55, 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МАКА́РОВ** Георгий Андриянович (4.4.1897, Казан губ., Зөя өязе Карагуҗа а. — 19.3.1978, Украина ССР, Одесса ш.), генерал-лейтенант (1944). 1 нче Мәскәү артиллерия командирлары составы курсларын (1920), артиллерия командирлары составы белемен күтәрү курсларын (Пушкино ш., 1926), Хәрби техник академия каршындагы техник белем күтәрү академик курсларын (Ленинград, 1931), Хәрби техник академия каршындагы югары командирлар составы белемен күтәрү курсларын (Ленинград, 1939) тәмамлый. 1908 елдан Казанда, 1910–16 да тукучы, икмәк пешерүдә ярдәмче булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша; 1916 да 2 нче запастагы артиллерия бригадасы рядовое, 1916–18 дә Көньяк-Көнбатыш фронтның 8 нче артиллерия бригадасы фейерверкер-разведчигы. Гражданнар сугышы елларында, 1918–19 да, 27 нче укчы дивизиянең Сульяк яр төркеме (Иделдә) 1 нче Тверь полкы кызылармиячесе, Чех-словак корпусы

һәм КОМУЧның Халык армиясе частьларыннан Лаеш, Чистай, Бөгелмә, Уфаны азат итүдә, адмирал А.В.Колчакның Ак армиясенә каршы Көнчыгыш фронттагы сугышларда катнаша. 1920–21 дә генерал П.Н.Врангель Ак армиясенә каршы Көньяк фронтта сугыша. 1921–22 дә 52 нче укчы дивизиянең 2 нче җиңел артиллерия дивизионында взвод командиры, Н.И.Махно җитәкчелегендәге баш күтәргән крәстияннәр армиясенә каршы көрәшә. 1922–37 дә Украина Хәрби округында: 1923–28 дә 15 нче Сиваш укчы дивизиясенең 44 нче укчы полкында взвод, батарея, дивизион командиры, 1928–32 дә 7 нче укчы корпусының 7 нче авыр артиллерия полкында дивизион командиры, 1933–37 дә 100 нче укчы дивизиядә 100 нче артиллерия полкы командиры. 1937–40 та Киев Хәрби округында: 1937–38 дә штабның артиллерия бүлегендә артиллерия буенча тәэминат башлыгы, 1938–40 та 46 нчы укчы дивизиядә артиллерия башлыгы. Бөек Ватан сугышында катнаша: 1941–42 дә Балтыйк буе фронтында 8 нче армиянең 10 нчы укчы корпусы артиллерия командиры, Ленинград фронтында Нева оператив төркеменең артиллерия башлыгы, 1942–43 тә Төньяк-Көнбатыш фронтта 1 нче удар армия гаскәрләре командиры урынбасары, 1943–45 тә 2 нче Балтыйк буе фронтында 6 нчы гв. армиясе гаскәрләре командиры урынбасары. 1945 елның августыннан япон армиясенә каршы сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1946–47 дә Одесса Хәрби округында артиллерия командиры урынбасары. 1947 дән запаста. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, ике 2 нче дәрәҗә Суворов, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАКА́РОВ** Марс Андреевич (28.10.1939, Биләр р-ны, хәзер Нурлат р-ны Чура Батыр а.), баянчы, композитор, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). Казан музыка уч-щесен тәмамлый (1962). 1962–68 елларда Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамблендә баянчы, соңрак оркестр җитәкчесе, 1968–77 дә филармониянең лекторий бүлегендә аккомпаниатор, 1977–78 дә Уфа дәүләт филармониясендә концертмейстер. 1978–81 дә Татар опера һәм балет театрының концерт төркемендә баянчы, 1982–2004 тә Казанның 18 нче номерлы сәнгать мәктәбендә укытучы. Халык һәм татар композиторларының көйләрен эшкәртә. «Каз канаты», «Кошлар кебек», «Минзәлә», «Тәфтиләү» (халык көйләре); «Җиз кыңгырау моңнары» (В.Хәбисламов муз.), «Бәрәңге» (И.Хисамов муз.), «Ямьле Чирмешән буйлары» (И.Шәмсетдинов муз.), «Студентлар маршы» (А.Ключарёв муз.), «Гаянә» (А.Хачатурян муз.) һ.б. шундыйлардан. М. сихри моңга ия күп җырлар авторы. 60 нчы еллардан аның шагыйрь Хәсән Туфан б-н иҗади дуслыгы башлана. Композитор шагыйрьнең «Киек казлар», «Агыла да болыт агыла», «Юксындырсаң, нишләрмен», «Ай чыга Арча кырыннан» һ.б. шигырьләрен көйгә сала. Аның иҗатының үзенчәлеге — муз. аһәңгә бай булуы «Ни сөйли урман» (С.Хәким шигыре), «Ак самавыр» (Г.Зәйнашева), «Төнбоеклар» (И.Юзеев), «Мәк чәчәге» (А.Абдуллин), «Тормыштан суынма син» (Ф.Яруллин), «Дөнья матур, дөнья киң» (Г.Афзал), «Иң кадерлем син генә» (М.Хөсәен), «Уралым» (А.Игебаев) һ.б. романсларында һәм лирик җырларында ачык күренә. Аналарга олы хөрмәт композитор күңелендә аеруча мөһим урын алып тора, ана образы аның «Бала йоклату» (үз шигыре), «Кара шәле килә сөйрәлеп» (З.Насыйбуллин) һ.б. тәэсирле бирелә. Композиторның яраткан темалары бихисап бай һәм күптөрле. Г.Тукайның «Кырлай», «Су анасы», «Таз малай», «Кызыклы шәкерт», «Мәзәк бию» һ.б.ның мәшһүр әсәрләреннән муз. күренешләр иҗат итә.

М.ның әсәрләре ТРның танылган коллективлары һәм күренекле җырчылар репертуарына кертелә. Инструменталь әсәрләрен Р.Үтәй, А.Шутиков, Р.Халитов, Р.Мостафин, Х.Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге халык музыка уен кораллары оркестрлары башкара.

М., баянчы һәм композитор буларак, актив концерт эшчәнлеге алып бара. СССР һәм Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә (Польша, Монголия, Финляндия, Чехословакия) гастрольләрдә була. Радио, телевидение фондларында инструменталь әсәрләреннән язмалар, хор әсәрләре, йөзләп җыры саклана.

Ә с ә р.: Баян өчен пьесалар. К., 1969; Биергә өйрән! К., 1984 (автордаш); Йөз татар биюе. К., 1989 (автордаш); Еллар һәм җырлар. К., 2003; Сәнгатебез йолдызлары. К., 2011.

**МАКА́РОВ** Пётр Ильич (23.1.1948, Питрәч р-ны Кавал а.), авыл хуҗалыгы җитештерүен механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2002), ТРның атказ. а.х. механизаторы (2002). 1971 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татсельхозтехпроект» проектлау конторасында эшли, 1973–77 дә — ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгында. 1977 дән Казан а.х. академиясендә, читтән торып уку ф-ты деканы (1990–95). Хезмәтләре туфрак эшкәртү техникасын төзүгә карый. М. интенсив игенчелек шартларында туфрак эшкәртүнең энергия саклаулы, эрозиягә каршы һәм тигез (тирән бură... бразналарсыз) алымнарын тәкъдим итә. Туфракның төрле типларын тигезләп сөрү өчен сукалар, туфракны чәчүгә кадәр эшкәртү һәм аерым урыннарга минераль ашламалар кертү эшләрен берләштергән агрегатлар (ТРның 12 хуҗалыгында файдаланыла), чәчүлекле культураларның рәт араларын тәбенә өеп эшкәртү культиваторы, орлыклык суганнарны туфрак төерләреннән аерып, бер фазалы җыеп алу машинасын эшли. Уйлап табуга 26 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ВДНХсының ике көмеш медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологии и техника для гладкой вспашки почв. К., 2000; Подготовка и настройка машин к полевым работам. К., 2002 (автордаш); Регулировка и настройка машин для заготовки кормов. К., 2003 (автордаш).

**МАКА́РОВ** Юрий (Георгий) Васильевич (29.8.1894, Казан — 22.7.1980, шунда ук), педиатр, мед. фән. д-ры (1936), проф. (1935). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1921), ваба, аннары тимгелле тиф госпитальләре табибе, бер үк вакытта Казан ГИДУВының педиатрия кафедрасында һәм балалар клиникасында эшли. 1935 елдан Архангельск мед. ин-тының балалар авырулары каф. мөдире. 1943 тән СССР һәм РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тлары каршындагы Балалар авыруларын дәвалау һәм кисәтү советлары әгъзасы. 1946–68 дә Казан мед. ин-тының балалар авырулары каф. мөдире. Татарстанның Балалар табибләре җәмгыяте рәисе (1946 дан). Хезмәтләре педиатрия мәсьәләләренә, кече яшьтәге балалар авыруларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: О безбелковых отёках у детей // Казан мед. журн. 1923. № 4; Роль яслей в профилактике детского туберкулёза // Казан мед. журн. 1933. № 7 (автордаш); Ревматизм у детей // Казан. мед. журн. 1934. № 11–12; Острые желудочные заболевания у детей. К., 1945.

*Әд.:* Профессор Юрий Васильевич Макаров: Некролог // Казан. мед. журн. 1980. № 5.

**МАКА́РОВА** Тамара Петровна (17.7.1951, Чүпрәле р-ны Матак а.), педиатр, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук факультет педиатриясе кафедрасында эшли. 1983 елдан — клиник фармакол. һәм 3 нче терапия, 1996 дан 2 нче балалар авырулары кафедраларында. Хезмәтләре балаларда соматик авырулар вакытында иммун статусын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Скрининг артериального давления и ЭКГ у детей дошкольного возраста // Казан. мед. журн. 2010. № 1 (автордаш); Иммунные нарушения и содержание селена при хроническом пиелонефрите у детей // Казан. мед. журн. 2011. № 1 (автордаш).

**МАКА́РОВА-ХАЙН** Герма Адольфовна (24.10.1899, Түбән Новгород ш. — 1984, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1955), проф. (1961). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1923), Архангельск мед. ин-тының балалар клиникасында эшли. 1946 елдан Казан мед. ин-тының госпиталь педиатриясе кафедрасында, 1956–67 дә балалар авырулары пропедевтикасы каф. мөдире. Хезмәтләре туклану тиешенчә булмаган очракта скелет үсешен тикшерүгә, рахит авыруы барышында кандагы неорганик фосфор микъдарын билгеләүгә, фосфатларның эчәклектән канга сеңүен һәм бәвелдәге аскорбин к-тасы микъдарын ачыклауга карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О некоторых неспецифических влияниях на туберкулиновую реакцию // Вопр. туберкулёза. 1928. Т. 6, № 7–8; О трофаллергии // Казан. мед. журн. 1934. № 3–4; О терапевтическом действии альгиновой кислоты и альгината при желудочно-кишечных заболеваниях у детей // Вопр. педиатрии. 1941. № 6.

*Әд.:* Профессор Герма Адольфовна Макарова // Казан мед. журн. 1985. № 2.

**МАКА́РОВКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 15 *км* көнбатыштарак, Солонка елгасы буенда. 2010 елда 21 кеше (руслар) яши. 1653 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мич чыгару, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә.

20 йөз башында М.да земство мәктәбе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 711 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Каймар волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 33 ир-ат; 1859 да — 139, 1897 дә — 322, 1908 дә — 358, 1920 дә — 383, 1926 да — 479, 1938 дә — 397, 1949 да — 400, 1958 дә — 260, 1970 тә — 131, 1989 да — 33, 2002 дә — 58 кеше.

**МАКА́РОВКА** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 58 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 149 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да тимерчелек, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 407 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Саралан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 43 ир-ат; 1859 да — 267, 1897 дә — 349, 1908 дә — 392, 1920 дә — 494, 1926 да — 561, 1938 дә — 578, 1949 да — 412, 1958 дә — 340, 1970 тә — 271, 1979 да — 200, 1989 да — 147, 2002 дә — 164 кеше.

**МАКА́РОВКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 47 *км* көньяктарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 48 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, М.да 2 су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1793,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Токмак волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1858 дә — 447, 1870 тә — 556, 1897 дә — 961, 1913 тә — 1190, 1920 дә — 1224, 1926 да — 759, 1938 дә — 646, 1949 да — 398, 1958 дә — 172, 1970 тә — 212, 1979 да — 119, 1989 да — 68, 2002 дә — 54 кеше.

**МАКА́ШЕВ** Мәхмүт Хаҗи улы (17.5.1913, Вятка губ. Турай а. — 1980, Ленинград), электротехник, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Ленинград энергетика техникумын (1934), Ленинград электротехник ин-тын (1955) тәмамлый. 1938 елдан Бөтенсоюз метрология фәнни-тикшеренү ин-тында (Ленинград), сектор башлыгы (1955–70), әйдәп баручы инженер (1970–73). Дәүләт бүләге ешлык берәмлеген яңадан торгызучы Дәүләт эталонының яңа конструкциясен эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша.

**МАКА́ШЕВА** Рауза Һади кызы (10.5.1917, Вятка губ. Турай а. — 24.6.2002, С.-Петербург), үсемлекләр генетикасы белгече, селекционер, а.х. фән. д-ры (1974). Ленинград ун-тын тәмамлый (1939). 1940–45 елларда туган авылы мәктәбендә рус теле укыта, колхозда хисапчы булып эшли. 1945 тән Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тында (Ленинград), бөртекле-кузаклы культуралар бүлегендә өлкән фәнни хезмәткәр (1954 тән). 1979–2002 дә бөртекле-кузаклы культураларның генетик ресурслары б-н бәйле мәсьәләләр буенча консультант. Хезмәтләре борчак биологиясе, систематикасы, селекциясе һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. M. Pisum ыругында 2 төрне аерып чыгара: P. fulvum Sibth. et Smith — кызыл-сары борчак һәм P. sativum L. — астөрләре б-н игүле борчак, төрләрнең ареалларын, аларның экологик характеристикасын һәм эволюцион статусын ачыклый. Аның тарафыннан борчакның 10 яңа сорты чыгарыла. «Борчак» («Горох», Л., 1973) монографиясе 1983 тә инглиз теленә тәрҗемә ителә һәм Һиндстанда нәшер ителә. М. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Вишнякова М.А., Петрова М.В., Булынцев С.В. Доктор сельскохозяйственных наук Рауза Хадиевна Макашева. СПб., 2002.

**МАКЛАКО́В** Александр Иванович (8.9.1929, Чистай ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1971), проф. (1972), Казан ун-тының атказ. профессоры (2004), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1952), шунда ук эшли, 1967–94 тә молекуляр физика каф. мөдире, 1994 тән шул ук каф. профессоры. Хезмәтләре полимерларда һәм гетероген системаларда ТМРны өйрәнүгә карый. М. ТМР-релаксация вакытлары буенча полимерларның пластификациясе тибын һәм эремәләрдә кристаллашуын бәяләү алымнарын эшли. Иярмә бәйләнешләре булган полимерларны өйрәнү өчен ТМР техникасын тәкъдим итә. Үздиффузияләнү коэффициентының эремәдәге полимерлар концентрациясенә универсаль гомумиләштерелгән бәйлелеген таба, үткәргечләрнең полиэтилен изоляциясенең озакка чыдамлылыгын фаразлау алымнарын тәкъдим итә, күзәнәкле тирәлекләрдә сыеклыкның тизләтелгән үздиффузиясен ачыклый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Изучение пластификации полимеров методом ЯМР // Успехи химии. 1979. Т. 48, № 4 (автордаш); Изучение пластифицированных систем методом ЯМР // Высокомолекулярные соединения. 1983. Т. 25, № 9; Самодиффузия в растворах и расплавах полимеров. К., 1987 (автордаш); Encyclopedia Fluid Mechanics. Houston–L.–P., 1990. V. 9 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**МАКЛАКО́В** Дмитрий Владимирович (15.2.1951, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүленеп, 1996–2009 елларда Казан архит-ра-төзелеш ун-тының югары матем. каф. профессоры). Хезмәтләре аэрогидромеханикага карый. Авырлык көчен исәпкә алып, агымнар һәм кавитацияләр теориясенең нәсызыкча мәсьәләләрен чишү алымнарын һәм Бернулли константалары төрле булган агымнарның тәэсир итешүләре мәсьәләләрен тикшерү юлларын, гидропрофильләр өчен кавитацион диаграммалар теориясен (бергәләп), комачаулыкларны дулкынга ялгап агуның нәсызыкча теориясен эшли. Агымнар һәм кавитация теориясенең экстремаль мәсьәләләрен тикшерә.

Хезм.: Нелинейные задачи гидродинамики потенциальных течений со свободными границами. М.-К., 1997; Задачи оптимизации формы в аэрогидродинамике. М., 2008 (автордаш); A note on the optimum profile of a sprayless planing surface // Journal of Fluid Mechanics. 1999. V. 384.

**МАКЛАКО́В** Лев Иванович (23.6.1937, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында эшли (1963–68), 1968 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында физика каф. мөдире. Хезмәтләре түбән молекуляр уретаннар кристаллашуын, олигомер һәм полиуретан системаларны спектраль тикшерүгә карый. М. микрофазалы бүленү хас булган полиуретаннарны (сегментлашкан полиуретаннар) тикшерә, уретанлы олигомер системаларда үзлелек арту механизмын ачыклый. Уретаннарның ерак инфракызыл спектрларын һәм водород күперчекләре тирбәнүләрен өйрәнү нәтиҗәсендә олигомер һәм полиуретан продуктларның физик үзлекләрен билгеләүдә макромолекулаларның молекулаара водород бәйләгеченең әһәмиятле ролен күрсәтә. Полимерларның комбинацион чәчелүе спектрын тикшерү буенча беренче хезмәтләр авторларының берсе. РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001).

Хезм.: Курс физики: В 3 т. К., 1995–98 (автордаш); Низкочастотная колебательная спектроскопия амидных и уретановых соединений // Успехи химии. 1997. Т. 66, № 5 (автордаш); Far-infrared spectra of some segmented polyurethanes // Journal of Molecular Structure. 1996. V.375 (автордаш).

**МАКЛАКО́ВА** Людмила Васильевна (24.2.1930, Ленинград — 5.2.2002, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1980). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын (1953), Казан Зур драма театры каршындагы студияне (1961) тәмамлый. Университетның Б.Э.Ниренбург һәм Г.П.Ардаров җитәкчелегендәге театр коллективында катнаша, Казан химия-технол. техникумында әдәбият курсы укыта. Студияне тәмамлаганнан соң, Казан Зур драма театрына эшкә килә. Аның сәхнәсендә 100 гә якын роль башкара, хатын-кыз характерын төрле яклап ачып, классик һәм заманча драматургиядә тулы бер образлар галереясын тудыра. Инна («Хезмәттәшләр», В.П.Аксёнов повесте буенча), Нюра («Туй көнендә», В.С.Розов), Авдотья Ро-

мановна («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Павла («Без туган йорт», П.Когоут) кебек беренче рольләрендә үк актрисаның сәхнә таланты ачыла. Бу тышкы сурәтнең нәзакәтлелегендә, хисчәнлек, тәэсирлелек, зыялылыкта, героиняларының рухи дөньясын бөтен тирәнлеге б-н яктыртырга, психол. халәтне бар нечкәлекләре б-н бирергә омтылуда чагыла. Бер үк вакытта аның героинялары нык рухлы көчле шәхесләр буларак аерылып тора. М. башкарган Лушка («Күтәрелгән чирәм», М.А.Шолохов романы буенча), Надя («Бервакыт Яңа ел кичендә», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов), Наталья Петровна



Л.В.Маклакова.



Л.В.Маклакова княгиня Вяземская ролендә («Барлыгы 13 ай», Ю.З.Дынов; сулда – Раевский ролендә Е.А.Кузин).

(«Искитәрлек бүләк», Е.И.Габрилович), Горчакова, Светлана Николаевна («Озату», «Урманда веранда», И.М.Дворецкий), Лиза («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов) образлары 1970 еллар героинясының иң матур сыйфатларын үзендә туплаган заманча хатын-кыз тибын гәүдәләндерә. 1978 елда «Әни килде» (Ш.Хөсәенов) пьесасындагы М. иҗат иткән Ана образы театр тормышында зур бер вакыйга буларак кабул ителә, тамашачыларның көчле алкышларына һәм уңай бәяләренә лаек була. Хатын («Барысы да бетте», Э.Олби) образында актриса аз һәм төгәл сәнгатьчә чаралар ярдәмендә әхлакый газаплар тирәнлеген ачып бирә. М. рус классикасының күп кенә зур образларын иҗат итә: Настя («Урманнарда», П.И.Мельников-А.Печерский романы буенча), Надежда Монахова, Софья («Варварлар», «Соңгылар», М.Горький), Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский).



Л.В.Маклакова Надежда Монахова ролендә («Варварлар», М.Горький).

*Әд.:* Илялова И., Ингвар И. Русский театр в Казани. К., 1991; Благов Ю. Сердцем и разумом // Идель. 2000. № 5.


*Ю.А.Благов.*

**МАКЛАУ́Ш** елгасы, Идел алдында, Олы Яклы (Сура елгасы бассейны) елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 17,1 *км*, ТР чикләрендә 4 *км* (түбән агымында). Бассейнының мәйданы 112,5 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Ульянов өлкәсе терр-ясендә, тамагы Чүпрәле р-ны Түбән Чәке авылыннан 1,4 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 205 *м*, тамагыныкы — 133 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. М.ның 1,5 тән алып 8,7 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар, иң зурлары — Руссалимовка (сул). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең өченче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,125 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. М. елгасы үзәненең уңъяк сөзәклегендә Кирәмәт (Яңа Чәке урман даласы) табигать истәлеге урнашкан.

**МАКЛАШЕ́ЕВКА ҖАЙДАКЛАРЫ́**, болгар бронза асылма йозаклары (якынча 11–12 йөзләр), Куйбышев (хәзерге Спас) р-нының элеккеге Маклашеевка авылы янында А.Х.Халиков (1967) һәм П.Н.Старостин (1983) тарафыннан табыла. Котсыз кешеләр (бер йозакта — ир-ат, икенчесендә — хатын-кыз) атланган әкияти хайваннар (А.Х.Халиков фаразлавынча — «мөгезле барслар») рәвешендә эшләнгәннәр. Сыннар аларның аскы өлешендәге, йозакның бикләү тоткасы куелган тишек аша беркетелгән. Зурлыкларыннан күренгәнчә (биеклеге — 13 һәм киңлеге 9 *см*), алар кечкенә сандык яки тартмаларны бикләү өчен кулланылган. Кайбер тикшеренүчеләр М.җ. семантикасын борынгы төркиләрнең (болгарларның) килеп чыгышы турындагы легендалар б-н бәйлиләр, бу — йозакларның берсендә чагыла (балалы хатын-кыз сыны). Фаразланганча, әлеге йозакларның кечкенә сандыклардагы әйберне саклаучы бөти хезмәтен башкаруы ихтимал.

*Әд.:* Халиков А.Х. Отражение космогонических и генеалогических легенд волжских булгар в археологических материалах // Из истории булгар. К., 1981; Археологическая карта Татарской АССР. Западное Закамье. К., 1986.

*Е.П.Казаков.*



Маклашеевка каберлеге табылдыклары:
1. Имәнкискә культурасы;
2. Болгар культурасы.

**МАКЛАШЕ́ЕВКА КО́МПЛЕКСЫ** (археол.) Утка елгасының (Идел елгасының сул кушылдыгы) түбән агымы буенда, Спас р-ның элеккеге Маклашеевка авылы янында урнашкан. М.к. истәлекләре хакындагы беренче мәгълүматлар 19 йөздә тарала башлый. Истәлекләр П.А.Пономарёв (1882, 1897), А.А.Спицын (1898), А.В.Збруева (1939), А.Х.Халиков (1961–62), Е.А.Халикова, Р.Г.Фәхретдинов, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин (1960–80 еллар) һ.б. тарафыннан өйрәнелә. М.к.на бронза һәм тимер гасырларга нисбәтле 20 дән артык археол. истәлек керә. Маклашеевка I шәһәрлегендә болгар чоры урла-



Маклашеевка җайдаклары.

ры һәм чокырлары (10 йөз ахыры — 13 йөзнең 1 нче яртысы), Маклашеевка II шәһәрлегендә бронза гасырның соңгы этабына һәм элгәреге тимер гасырга, Имәнкискә һәм Болгар культураларына караган культура катламнары ачыклана. Шәһәрлек янында 1960 һәм 1990 елларда бронза сынлы йозаклар (к. *Маклашеевка җайдаклары*), 1990 еллар ахырында 6 йөзнең 2 нче яртысы — 7 йөзгә караган көмеш әйберләр (аеллар, бил каешы бизәмәләре, тагылмалар) хәзинәсе табыла. Имәнкискә культурасының Маклашеевка IV һәм V каберлекләрендә 170 тән артык кабер тикшерелә. Аларда яндырылган кеше сөякләре, балчык савыт-саба ватыклары, янган бизәнү әйберләре, кием детальләре табыла. Каберлекләрнең берсендә йолалар башкару чокыры була, анда атның баш сөяге һ.б. сөякләре күмелүе ачыклана.

*Әд.:* Невоструев К.И. О городищах древнего волжско-булгарского и Казанского уезда в нынешних губерниях Казанской, Симбирской и Вятской // Тр. Первого археол. съезда. М., 1871. Т. 1; Шпилевский С.М. Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии. К., 1877; Спицын А.А. Заметки из поездки 1898 года // Изв. археол. комиссии. СПб., 1916. Вып. 60; Старостин П.Н. Памятники именьковской культуры // Свод археол. источников. 1967. Вып. 32; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975.

*П.Н.Старостин.*

**МАКЛАШЕ́ЕВКА КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), бронза гасырның соңгы чорында (якынча б.э.к. 11 йөз — 9 йөзнең 1 нче яртысы) Чулман, Агыйдел, Ветлуга, Олы Чирмешән, Сок елгалары бассейннарында хөкем сөргән археол. культура. М.к. каберлеге беренче тапкыр 1897 елда П.Я.Пономарёв тарафыннан тасвирлана. 1955 тә аны А.Х.Халиков — Казан яны археол. культурасының этабы, 1996 да В.Н.Марков һ.б. галимнәр мөстәкыйль археол. культура буларак аерып чыгаралар; атамасы элеккеге Маклашеевка авылы (Спас р-ны) янындагы каберлеккә нисбәтле. 1960–70 елларда М.к. истәлекләре А.Х.Халиков, 1980–90 елларда В.Н.Марков, Е.П.Казаков, А.А.Чижевский һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Фаразланганча, борынгы фин (фин-пермь) кабиләләре тарафыннан калдырылган. М.к. халкы терлекчелек (мөгезле эре һәм вак терлек, дуңгыз, ат), аучылык (торулыкларда һәм каберлекләрдә аю, төлке, поши, кондыз һ.б. сөякләре табыла), балыкчылык (мәрсин балыклар сөякләре очрый) б-н шөгыльләнә. Игенчелек билгеләре сизелми, бронза металлургиясе югары үсеш ала. Мышьяк һәм аккургаш катнашмалы бронза җитештерү өчен җирле һәм читтән китерелгән чимал файдаланыла. Маклашеевка бронза сугыш кораллары юка катламлы кою технологиясе б-н эшләнә. М.к. кабиләләрендә сөякне кисеп уемлау киң тарала, чимал буларак поши мөгезләре һәм сөякләре кулланыла. Әлеге археол. культураны калдыручылар йон һәм киндер тукымалардан киемнәр тегәләр, аларны, гадәттә, минераль буяуларга маналар. Мурзиха II каберлегендә табылган тимер тишкеч М.к. үсешенең соңгы этабында тимер эшләнмәләр барлыкка килүен күрсәтә. Фаразланганча, тимер эшләнмәләр җитештерү технологиясе Кавказ халыкларыннан үзләштерелә. Балчык савыт-сабалар муены һәм өске өлешләре чокырлы һәм тараксыман бизәкләр төшерелгән түгәрәк калку төпле, башлыча, цилиндр муенлы чүлмәкләрдән гыйбарәт. Баштарак Маклашеевка торулыклары болынлы үзәнлекләрдә, соңрак туфрактан өелгән урлар б-н әйләндереп алынган биек борыннарда урнашкан. Торулыклар мәйданының уртача зурлыгы 3,6 мең $м^2$, кайберләре 15 мең $м^2$га кадәр терр-яне биләгән. Гадәттә бер торулыкта 4–5 торак булган, 9–12 торaклы торулыклар да очрый (Курган шәһәрлеге). Күбесенчә сай чокырлы каберләр өстенә курганнар өелгән, аларга әйберләр куелган. Нигездә, мәетләр башлары б-н көнчыгышка каратып җирләнгән. Татарстан терр-ясендә М.к. истәлекләре Олы Утар авылы (хәзерге вакытта Казанның көньяк-көнбатыш чите; Балым туктаулыгы), Алабуга шәһәре (Луговский курганлы каберлеге), элеккеге Яңа Мордово (Спас р-ны), Яңа Мор (Спас р-ны; Яңа Мор V һәм VIII каберлекләр), Ильичёвский посёлогы (Тукай р-ны; каберлек), элеккеге Мурзиха авылы (Алексеев р-ны; Мурзиха II каберлеге) янында һ.б. урыннарда табыла. Ш.у.к. *Маклашеевка җайдаклары.*

*Әд.:* Халиков А.Х. Приказанская культура // Свод археол. источников. М., 1980. Вып. 1–24; Марков В.Н. К постановке проблемы происхождения памятников маклашеевского типа // Эпоха бронзы Нижнего Прикамья: Тез. науч. конф. К., 1996; Обыдённов М.Ф. Археологические культуры конца бронзового века Прикамья. Уфа, 1998; Чижевский А.А. Е.А.Халикова и проблемы хронологии маклашеевского этапа приказанской культуры // Вопросы историко-культурного наследия Волго-Камья. К., 2002.

*А.А.Чижевский.*

**МАКЛЫ́ГИН** Александр Львович (22.10.1954, Киров өлкәсенең Санчурский р-ны Кунер а.), музыка белгече, педагог, ТР, Мари Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе (1994, 2004), РФ Югары мәктәбенең атказ. хезмәткәре (2010), сәнгать фән. д-ры (2001), проф. (2005). 1982 елдан Казан консерваториясендә укыта (1988–99 да музыка белеме; музыка теориясе; музыка теориясе һәм композиция, 2001 дән композиция кафедралары мөдире; 2007 дән проректор). Бер үк вакытта, 2002 дән, ТР Мәдәният министрлыгының өстәмә һөнәри белем бирү Ин-тында музыка педагогикасы кафедрасын җитәкли. 1999 дан ТР Композиторлар берлеге җитәкчесе урынбасары. М. теоретик музыка белеме мәсьәләләре, ш.и. сонорика б-н шөгыльләнә; Урта Идел халыклары муз. культурасында профессионализм формалашу процессын җентекләп тикшерә, өйрәнә. Музыка педагогикасы мәсьәләләренә зур игътибар бирә. М. музыканы импровизация аша үзләштерүнең методикасын эшли, әлеге методика Россиянең бик күп шәһәрләрендәге музыка уку йортларында кулланылышка кертелә. Аның бөтенроссия һәм төбәк дәрәҗәсендәге семинарлары һәм мастер-класслары Мәскәүдә, Түбән Новгород, Кострома, Пенза, Чабаксар, Йошкар-Ола һ.б. шәһәрләрдә уза (төбәкара «Ел фасыллары» мәктәбе, «Күчмә иҗат күргәзмәләре академиясе» һ.б.). М. — ТРда «Музыка белеме бирү программалары»н эшләүчеләрнең берсе. Аның музыка өлкәсендәге һәм иҗтимагый эшчәнлеге гаять киң: халыкара «Европа-Азия» хәзерге заман музыкасы фестиваленең сәнгать җитәкчесе; респ-ка дәрәҗәсендәге «Джаз тамчысы» («Джазовая капель»), «Студентлар дебюты» («Студенческий дебют»), С.Сәйдәшев исем. композиция һәм импровизация конкурсы (ТР), «Палантай көннәре» («Палантаевские дни»), «Джаз-пайрем» (Марий-Эл) фестиваль-конкурсларының рәисе һәм жюри әгъзасы. Муз. әсәрләр авторы: орган өчен «Шувыр» (1993) пьесасы, татар халык уен кораллары оркестры өчен «Татар рэгтаймы» (2003), Казан Зур драма театры спектакльләренә музыка, фортепиано өчен пьесалар һ.б.

Әсәр.: Сонорно-колористическая тенденция в гармонии русских и советских композиторов // Проблемы стилевого обновления в русской классической и советской музыке. М., 1983; Пентатоновые модальные принципы в музыке марийских композиторов // Традиционное и современное в музыке народов Поволжья. Йошкар-Ола, 1988; О формообразовании в вокальной музыке эпохи Возрождения. К., 1990; Музыкальные культуры Среднего Поволжья: Становление профессионализма. М., 2000.

*Әд.:* Капуль Л. Импровизации все возрасты покорны // Музыкальная жизнь. 1997. № 11; Сокольская А. Рондо в стиле Маклыгина // Казань. 2005. № 5.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МАКОВЕ́ЛЬСКИЙ** Александр Осипович (10.7.1884, Гродно ш. — 16.12.1969, Баку), философ, филос. фән. д-ры (1921), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1946), Әзәрбайҗан ССР ФА академигы (1949), Әзәрбайҗан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1930). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1907), шунда ук эшли, проф. (1918). Бер үк вакытта, 1909–20 елларда, Казан югары хатын-кызлар курсларында укыта. 1920–60 та — Әзәрбайҗан ун-тында (Баку). Бер үк вакытта, 1944 тән, Әзәрбайҗан ССРның Филос. һәм хокук ин-тында: 1944–45 тә филос. һәм хокук секторы мөдире, 1945–50 дә — директор. Хезмәтләре антик филос. тарихына, Якын Көнчыгыш халыклары философиясенә, мантыйк һәм психологиягә карый. Антик философлар хезмәтләрен тәрҗемә итә.

*Әд.:* В поисках за абсолютной достоверностью. К., 1912; Введение в философию: В 2 ч. К., 1912–16; Досократики: В 3 ч. К., 1914–19; Псевдо-Демокрит в его фрагментах и свидетельствах древности. М., 1925; Древнегреческие атомисты. Баку, 1946; Авеста. Баку, 1960; История логики. М., 1967.

**МАКО́ВСКИЙ** Стефан Игнатьевич (1904, Грозный ш. — ?, шунда ук), бораулау мастеры, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). 1914–21 елларда Грозныйда каеш дирбиялар остаханәсендә эшли. 1922–36 да «Грознефть» берләшмәсендә эшче, бораулаучы, бораулау мастеры. 1931 дә бораулау техниклары курсын тәмамлый. 1936–42 дә Мәскәү геол. трестының геол. партиясендә өлкән бораулаучы. 1942–58 дә «Татнефтеразведка» трестында: өлкән бораулау мастеры, участок башлыгы, Шөгер нефть разведкасының бораулау конторасы башлыгы, 3 нче Әлмәт тик-

шерү-бораулау конторасы директоры (1981 дән). Татарстанда зур нефть чыганакларын: Ромашкино, Акташ, Азнакай һ.б.ны ачуда катнаша. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге Ромашкино нефть чыганагын ачканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**МАКСА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында. Кече Мишә елгасының (Мишә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,1 *км*, бассейнының мәйданы 112,9 *км*$^2$. Теләче р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Максабаш авылыннан 4,4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Ачы авылыннан 1,4 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. М.ның 0,4 тән алып 4,7 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 138 *мм*, ташу вакытында су катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,15 *м*$^3$*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суның гомуми күләме 1,66 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**МАКСАБА́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Макса елгасы буенда. 2010 елда 299 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та 2 мәчет (1867 һәм 1870 тә төзелә), 2 мәдрәсә, су тегермәне, 3 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1854 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир-ат; 1859 да — 961, 1897 дә — 1107, 1908 дә — 1398, 1920 дә — 1208, 1926 да — 955, 1938 дә — 811, 1949 да — 692, 1958 дә — 574, 1970 тә — 535, 1979 да — 577, 1989 да — 318, 2002 дә — 330 кеше.

**МАКСИ́М ПҮЧИНКӘСЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 48 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1652 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү-мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.П.ндә Вознесение чиркәве (1905–15 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), тегермән, 2 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2546,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красногорск волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 227 ир-ат; 1859 да — 919, 1897 дә — 965, 1908 дә — 907, 1920 дә — 897, 1926 да — 889, 1938 дә — 617, 1949 да — 392, 1958 дә — 278, 1970 тә — 346, 1979 да — 191, 1989 да — 130, 2002 дә — 52 кеше.

**МАКСИ́МКОВО** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Туйма елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 26 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 19 йөз башында Иске Гришкино авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Акполян, Починок Андреев исемнәре б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле эшкә яллана. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, монда ашлык саклау-сату кибете эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 316,2 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 25 ир-ат; 1859 да — 124, 1887 дә — 180, 1905 тә — 272, 1920 дә — 299, 1926 да — 340, 1938 дә — 315, 1949 да — 275, 1958 дә — 270, 1970 тә — 240, 1979 да — 136, 1989 да — 54, 2002 дә — 26 кеше.

**МАКСИ́МОВ** Александр Александрович (3.8.1891, Оренбург губ., Троицкий өязе Түбән Увельский станицасы — 28.6.1976, Мәскәү), җәмәгать-сәясәт һәм халык мәгарифе эшлеклесе, философ, филос. фән. д-ры (1934), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1943). 1910 елда Казан ун-тының мед. ф-тына укырга керә, 1911 дә физика-матем. ф-тына күчә. Революцион эшчәнлектә актив катнаша, эсерлар партиясе әгъзасы була, Беренче бөтендөнья сугышында интернационалистик позициядә тора, сугышка каршы юнәлдерелгән листовкалар тарата. Университетны тәмамлаганнан соң (1916), химия буенча профессорлык дәрәҗәсенә әзерләнү өчен шунда калдырыла. 1918 дән РКП(б)да, 1918 нең февраленнән Казан губернасының халык мәгарифе комиссары. 1918 нең августында КОМУЧ органнары тарафыннан кулга алына, атарга хөкем чыгарыла, Кызыл Армия гаскәрләре тарафыннан азат ителә. Казан өчен барган сугышларда катнаша. 1918 нең 10 сентябреннән яңадан губерна халык мәгарифе комиссары, бер үк вакытта, 1918 нең ноябреннән Казан югары уку йортлары комиссары. М. җитәкчелегендә совет хакимияте органнары декретларына яраклаштырып, мәгариф системасы үзгәртеп корыла: мәдрәсәләр һәм православие руханилары уку йортлары ябыла, наданлыкны бетерү, земство һәм шәһәр мәктәпләрен 1 нче, югары башлангыч уч-щеләрен 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә совет мәктәпләре итеп үзгәртү компаниясе башлана; югары уку йортларында эшчеләр ф-тлары ачыла. Сәнәгать, коммерция һәм а.х. уч-щеләре җирлегендә Казан политехник ин-ты оештырыла, Казан укытучылар ин-ты Югары халык мәгарифе ин-ты итеп үзгәртелә. 1919 ның октябреннән Кызыл Армиядә, полк, дивизия комиссары. 1920 нең ноябреннән РСФСР Халык мәгарифе комис-тының эшчеләр ф-ты бүлеге мөдире. 1922 дән Мәскәү ун-тының филос. каф. мөдире, бер үк вакытта Кызыл профессорлар ин-тында (1924–34) һәм Коммунистик академиядә (1931–36). 1934–54 тә СССР ФАнең Филос. ин-тында, 1944–49 да Мәскәү ун-тының филос. ф-тында. Хезмәтләре табигыять белемнәренең филос. мәсьәләләренә карый. Казан урамнарының берсе М. исемен йөртә.


Х е з м.: Ленин и естествознание. М., 1933; Введение в современное учение о материи и движении. М., 1941; Очерки по истории борьбы в русском естествознании. М., 1947.

*Әд.:* К о р б у т М.К. Казанский государственный университет имени В.И.Ульянова-Ленина за 125 лет. 1804/05 — 1929/30. К., 1930. Т. 2; С у л т а н б е к о в Б.Ф. Максимов Александр Александрович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**МАКСИ́МОВ** Валерий Архипович (1.5.1940, Мамадыш р-ны Колышчы а. — 14.9.2012, Казан), машиналар төзү һәм механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1983), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2005). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, компрессор машиналары һәм җайланмалары каф. мөдире (1982–86, 1989 дан), бер үк вакытта суыткыч һәм компрессор машиналары ф-ты деканы (1982–86, 1989–92), проф. (1984). 1969–77 дә компрессорлар төзү махсус КБсында (хәзер «НИИтурбокомпрессор» АҖ) бүлек башлыгы, 1986–89 да фәнни эшләр буенча директор урынбасары, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998 дән), бер үк вакытта «Казанкомпрессормаш» ФҖБ ген. директорының фән буенча 1 нче урынбасары. 1997 дән «Идея» инновацион-җитештерү технопаркы» АҖнең металл эшкәртү һәм транспорт буенча баш эксперты. Хезмәтләре сыеклык һәм газ механикасына, вакуум һәм компрессор техникасына карый. М. майлауның термодинамик теориясен тәкъдим итә. Гидродинамик ышкылу узеллары системаларын исәпләү һәм проектлаштыру алымнарын эшли. Уйлап табуга 49 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР машина төзүчеләре фәнни-техник җәмгыяте идарәсе рәисе (1982 дән). Медальләр, ш. и. СССР ВДНХсы-



И.Т. Максимов.



К.Е. Максимов.

ның көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Трибология подшипников и уплотнений жидкостного трения высокоскоростных турбомашин. К., 1998 (автордаш); Двухроторные винтовые и прямозубые компрессоры: Теория, расчёт и проектирование. К., 2000 (автордаш); Газовая смазка: Перспективы применения в турбомашиностроении. К., 2002; Высокоскоростные опоры скольжения гидродинамического трения. К., 2004 (автордаш).

**МАКСИ́МОВ** Владимир Ильич (5.11.1947, Әлмәт р-ны Ямаш а.), физиолог, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2001). 1970 елда Казан вет. ин-тын тәмамлап, шунда ук физиол. кафедрасында эшли. 2000 нән Мәскәү вет. медицинасы академиясенең физиол. каф. профессоры, бер үк вакытта, 2003 тән — баш гыйльми секретарь. Хезмәтләре терлек органнарының гармональ статусын туганнан соңгы онтогенезда тикшерүгә карый.

Х е з м.: Основы физиологии и этиологии животных. М., 2004 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**МАКСИ́МОВ** Владимир Петрович (25.12.1909, Ташкент — 7.9.2007, Казан), инженер-механик, Казандагы 387 нче завод директоры (1948–61). Мәскәү авиация ин-тын тәмамлый (1937). 1929–41 елларда Мәскәүдәге 22 нче авиация з-дында эшли, завод эвакуацияләнгәннән соң (1941), Казандагы 22 нче авиация з-дында (1948 гә кадәр): техник, әйдәп баручы инженер, цех башлыгы, баш технолог, директор урынбасары. 1948–61 дә 387 нче заводта. М. җитәкчелегендә пр-тиедә үзйөрешле С-4 комбайннарын җитештерү җайга салына, вертолётлар җитештерү буенча реконструкция уздырыла, Ми-1, Ми-4 вертолётларын һәм аларның модификацияләрен эшләп чыгару үзләштерелә. 1961–71 дә Производствоны оештыру технологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында лаб. башлыгы, баш инженер урынбасары. 1971–86 да Казан авиация техникумы укытучысы. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, ике Кызыл Йолдыз ордены, башка орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанские вертолёты: Полёт продолжается. К., 2000.

**МАКСИ́МОВ** Вячеслав Васильевич (9.3.1908, Сембер губ. Сембер ш. — 30.4.1975, Казан), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, физика-матем. фән. канд. (1946), проф. (1967). 1934 елда Казан авиация ин-тын (1 нче диплом иясе) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, самолётлар конструкцияләү һәм проектлаштыру (1937–41, 1942–44, 1947–51), самолёт җиһазлары (1951–54), гироскопик приборлар һәм җайланмалар (1954–71) кафедралары мөдире; бер үк вакытта самолётлар төзү (1949–51), радиотехника (1952–53) ф-тлары деканы; приборлар һәм автоматлар ф-тын оештыручы һәм аның деканы (1952–58). Хезмәтләре гироскопик техникага, самолётларны ныклыкка исәпләүгә карый. М. реактив «катюша» миномётларын җитештерүне оештыру (1941–42), тәҗрибә очкыч аппаратларын проектлаштыру һәм төзү эшләре б-н җитәкчелек итә. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә..

Х е з м.: Расчёт касательных напряжений в стыковых узлах деревянных лонжеронов // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1946. Вып. 17; Поведение гировертикали с шариковой коррекцией вблизи истинной вертикали // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1960. Вып. 59; Расчёт параметров гирополукомпаса. К., 1964.

**МАКСИ́МОВ** Иван Тихонович (5.8.1924, Мамадыш кантоны Албай а. — 11.11.1987, Казан), Сов. Союзы Герое (29.6.1945), полковник. Милләте буенча татар. Смоленск хәрби пехота уч-щесен (1943), офицерлар составын камилләштерү курсларын (1947) тәмамлый. Сугышка кадәр туган авылында колхозда хисапчы булып эшли. 1942 елның августыннан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 358 нче укчы полкның рота командиры (70 нче армиянең 136 нчы укчы дивизиясе). Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Полесье, Люблин-Брест (икесе дә — 1944), Көнчыгыш Померания һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. М. 1945 нең 30 мартында Данциг (хәзер Гданьск, Польша) шәһәре янында Висла елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: аның җитәкчелегендә сугышчылар дошманның 6 танк контрһөҗүмен кире кайтара. 1954–77 дә Казанда хәрби комиссар. 1977 дән запаста. 1978–87 дә Мәскәү авиация технологиясе һәм җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында кадрлар һәм режим буенча директор урынбасары. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Геройга Казанда Яңа Савин хәрби комис-ты бинасына мемориаль такта һәм Мамадыш шәһәрендә бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Есть на Вятке городок: Ист.-краевед. очерки. К., 1981; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2. *М.З.Хәбибуллин.*

**МАКСИ́МОВ** Кондрат Евдокимович (12.3.1894, Вятка губ., Уржум өязе Шишкино а. — 1.10.1981, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957), ТАССРның халык рәссамы (1960), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1974). Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укый (1914–17, бүленеп). 1917–27 елларда туган авылында сал агызучы булып эшли. 1927–29 да Ленинград рәссамы М.М.Гужавин җитәкчелегендә яңадан нәкышь б-н шөгыльләнә башлый. 1930–35 тә Казанда сал агызу тәҗрибә станциясендә эшли, сал агызу хезмәтен механикалаштыруны камилләштерү б-н шөгыльләнә, уйлап табуга 27 авторлык таныклыгы ала. 1930 еллар уртасыннан нәкышь сәнгате өлкәсендә актив эшли башлый. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан р-ннарында йөри, миниатюр этюдлар циклын яза (100 гә якын әсәр), шулар нигезендә тыл хезмәтчәннәренә багышланган «Салларда» (1943), «Урман кисүчеләрнең төн куну урыны», «Орлык фондына ашлык тапшыру» (икесе дә — 1944) исемле зур картиналар иҗат итә. 1940 еллар уртасында рәссам соңрак үз иҗатында үзәк урынны алган пейзаж жанрына мөрәҗәгать итә. М.ның зур мирасында Кавказ, Кырым, Украина, рус Төньягы пейзажлары да аз түгел, урта рус пейзажы темасы аңа аеруча якын. Ул картиналарында Татарстанның Идел-Кама киңлекләрен, Вятка урманнарын тасвирлый. М. И.И.Шишкин нигез салган рус реалистик пейзажы традицияләрен дәвам итә, үстерә: «Кама» (1945), «Камага юл» (1953), «Арыш» (1953), «Урманлы офыклар» (1953),



К.Е. М а к с и м о в. «Вагоннарга утын төяү». 1945. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

«Куйбышев диңгезе» (1957), «Ак мүк түшәлгән нарат урманы» (1965), «Вятка киңлекләре» (1969), «Чыршы урманында көн уртасы» (1973) һ.б. М. иҗатының күпчелеге камера-лирик һәм әкияти-романтик характерда: «Абага чәчәк аткан төн» (1946), «Алёнушка», «Кащей патшалыгы» (икесе дә — 1950 еллар), «Тыелган урман» (1959). «Урмандагы янгын», «Урман шаулаган якларда» (икесе дә — 1950 еллар), «Алабуга. 1918 елда кызыл партизаннарны аткан урын» (1967) пейзажларында тирән сагыш чагыла. М. ш.у. табигатьне, күптөрле чәчәкләр һәм җиләк-җимешләр дөньясын тасвирлаучы натюрморт жанрында да уңышлы эшли: «Урман чәчәкләре» (1945), «Чалма чәчәкләр һәм бәллүр» (1946), «Йөзем» (1956), «Шәфталулар» (1965), «Ак карлыган сабагы» (1969) һ.б. 1970 елларда ул Идел пейзажларына кабат әйләнеп кайта («Куйбышев сусаклагычында», 1973; «Идел өстендә», 1976).

Ә с ә р.: Не пожалею сил // Мы из Советской Татарии. К., 1960.

*Әд.:* Кондрат Евдокимович Максимов. Выставка произведений художника К.Е.Максимова: 60 лет со дня рождения, 25 лет творческой деятельности.

К., 1954; Кондрат Евдокимович Максимов // Искусство Советской Татарии. Народные художники: Буклет. К., 1980; Народный художник ТАССР Кондрат Евдокимович Максимов: 75 лет со дня рождения, 40 лет творческой деятельности: Каталог выставки. К., 1980; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Г о л у б ц о в а Т.В. Кондрат Евдокимович Максимов. К., 2004.
*М.Е.Ильина.*

**МАКСИ́МОВ** Николай Валентинович (14.12.1956, Питрәч р-ны Керәшен Сәрдәсе а.), тел галиме, филол. фән. канд. (1991). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казанның 90 нчы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1991 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1992 дән ТР Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-тында татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы каф. мөдире. 1997 дән Казан технол. ун-тында (2003 кә кадәр икетеллелек нигезендә белем бирү укыту-методик үзәге директоры), 2007 дән Казан ун-тында. Татар телен укыту методикасына караган хезмәтләр, урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре һәм уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Татар теленнән дидактик материаллар: 5–7 сыйныф. К., 2000; Татар теле: Урта махсус уку йортлары студентлары өчен дәреслек. К., 2005; Урта мәктәптә татар теле: Кушма җөмлә синтаксисы. К., 2005; Синтаксиста серләр бар. Башваткычлар. Уеннар. Тестлар. К., 2010 (автордаш).

**МАКСИ́МОВ** Николай Иванович (19.5.1911, Пенза губ., Саранск өязе Олы Семилей а. — 5.5.1967, Казан), инженер-механик, Казан авиация з-ды директоры (1960–67), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1961), Соц. Хезмәт Герое (1966). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), шунда ук эшли. 1939–67 елларда Казан авиация з-дында: инженер, әйдәп баручы инженер, цех башлыгы урынбасары, цехның техник контроль бүлеге башлыгы (1943 тән), производство башлыгы (1945 тән), баш инженер (1950 дән), завод директоры (1960 тан). М. җитәкчелегендә пр-тиедә Ту-104, Ил-62, Ту-22 самолётларын һәм аларның модификацияләрен эшләп чыгару үзләштерелә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1949; 1971, вафатыннан соң). 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Казан урамнарының берсенә М. исеме бирелә.

*Әд.:* Завод стратегического назначения. К., 2002.
*Д.С.Фәхретдинов.*

**МАКСИ́МОВ** Юрий Александрович (31.3.1927, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1978). Казан Зур драма театры каршындагы студияне тәмамлый (1947). Студиядә уку дәверендә Казан Зур драма театры спектакльләрендә Петька («Учак», П.Г.Маляревский), Николай Сумской («Яшь гвардия», А.А.Фадеев романы буенча) рольләрен башкара. 1947 елдан Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) труппасында. Яшь геройлар рольләрен уйнап, актёр һәр образны индивидуальләштерергә омтыла. М. башкарган Серёжа («Корыч ничек чыныкты», Н.А.Островский романы буенча), Дэви («Бер йомарлам кар», В.А.Любимова), Аркаша («Воробьёв таулары», А.Д.Симуков), Володя Чернышёв («Аның дуслары», В.С.Розов), Лёня Жарков («Өлгергәнлек аттестаты», Л.Б.Гераскина), Мариус («Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча) образлары романтик хис-тойгылар байлыгы, хәрәкәт активлыгы б-н аерылып тора. Тишка («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский), Кутейкин («Җитлекмәгән егет», Д.И.Фонвизин), Вадим Розвалов («Хәерле сәгатьтә!», В.С.Розов) рольләре актёрның теге яки бу образны тәэсирле сурәтләүдә тиешле чаралардан файдалана белү, герой күңелендәге эчке конфликтны табу һәм ачып бирү осталыгын күрсәтә. М.Сәлимҗанов куйган спектакльләрдә М. иҗат иткән Карандышев («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Яков («Бер төн», Б.Л.Горбатов) рольләре психологик яктан тирән ачылулары б-н зур әһәмияткә ия. Майор Дейтмар («Аксыл чәчле алдакчы», Ю.Клеманов), Габделбәр Сатиев («Муллануp Вахитов», Н.Исәнбәт), Лещ («Соңгылар», М.Горький), Масленников («Казан университеты», Д.Н.Вәлиев) образлары социаль характеристикаларының үткенлеге б-н аерылып тора. Эчке каршылыкның төп чыганагын ачып, актёр образны күләмлерәк итә һәм, үз геройларына карата гаепләүче ролендә чыгып, социаль образга масштаб бирә. Сарафанов («Бистәдә көрәшү», А.В.Вампилов), Никулин («Сөйгәннәрегез белән аерылышмагыз», А.М.Володин), Бессольцев («Бойкот», В.Железников) образлары рухи сыйфатларны җиткерүдә нәзакәтлелекләре б-н аерылып тора; бакырчы Рыло («Җәйге төндә кергән төш», У.Шекспир) образы рәхимле юморы, эчкерсезлеге б-н үзенә җәлеп итә. М. Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә Ивась («Анюта күзләре», Т.Г.Ян), Ибраһим бай («Тапкыр егет», Д.Аппакова), Аю («Ике өрәңге», Е.Л.Шварц), лорд Сент-Джон («Принц






Ю.А.М а к с и м о в. 1. Карандышев («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский); 2. Ивась («Анюта күзләре», Т.Г.Ян) рольләрендә.



Н.И.Максимов.



Ю.А.Максимов.

һәм теләнче», М.Твен повесте буенча), Премьер-министр («Король Матиуш Беренче», Я.Корчак) кебек әкият геройлары галереясын иҗат итә. Алар, сәхнәдәге яшәешләре б-н гадәти булмасалар да, тормыш чынбарлыгына тугрылыклары б-н ышандыралар.

*Әд.:* Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986. *Ю.А.Благов.*

**МАКСИ́МОВ** Яков Яковлевич (7.11.1941, Түбән Кама р-ны Олы Афанас а. — 18.12.1997, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д. -ры (1991), проф. (1992), ТАССРның атказ. икътисадчысы (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан. а.х. ин-тын тәмамлый (1967). Хезмәт эшчәнлеген 1957 елда Түбән Кама р-нының «Красный Ключ» с-зында башлый. 1965–67 дә «Нижнекамский» с-зы икътисадчысы. 1967 дән Казан аграр ун-тында, 1984 тән икътисад теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. хезмәте б-н матди кызыксындыру һәм аңа тарту мәсьәләләренә карый. М. ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгының фәнни советы, Республика хосусыйлаштыру ком-ты эшендә, Татарстанда АПКны үстерү программаларын һәм концепциясен эшләүдә катнаша.

Х е з м.: Семейный труд на селе. К., 1989; АПК Татарии: Проблемы и пути решения. К., 1990; Реализация стимулов к труду в агропромышленном комплексе. К., 1990.
*Ф.С.Зыятдинов.*

**МАКСИ́МОВ-КО́ШКИНСКИЙ** Иоаким Степанович (19.9.1893, Сембер губ., Буа өязе Кошки-Яңа Тимбай а. — 30.8.1975, Мәскәү), драма актёры, режиссёр, драматург, Чуаш АССРның халык артисты (1933), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968). Чуаш театрына нигез салучыларның берсе. Сембер чуаш укытучылар мәктәбен тәмамлый, 1913–17 елларда Казан сәнгать мәктәбендә укый. 1918 дә, Көнчыгыш фронт штабы сәяси бүлегенең чуаш секциясен җитәкләгән дәвердә, Казанда чуаш телендә чыгыш ясаучы актёрлар төркемен оештыра. А.Н.Островский пьесасы буенча «Үзең теләгәнчә яшәмә» («Не так живи, как хочется») исемле беренче спектакль 1918 нең 14 гыйнварында Хатын-кызлар мед. ин-ты бинасында (Вознесенский (хәзер Островский) урамындагы элекке Клячкин хастаханәсе) күрсәтелә. 1919 да төркем Чуаш совет күчмә театры статусы ала. Сезон 9 октябрьдә хәзерге Зур Кызыл һәм Тельман урамнары чатындагы Интернациональ театр бинасында (элекке «Ампир» кинотеатры) С.Белая пьесасы буенча «Крәстияннәр» («Крестья-

не») спектакле б-н ачыла. Театр Казан һәм Сембер губерналары терр- яләрендәге чуаш авылларында спектакльләр күрсәтә. 1920 дән Чабаксар шәһәрендә. Бу театр сәхнәсендә М.-К. рус һәм дөнья классикасы, шул чор чуаш драматурглары әсәрләре буенча шактый гына спектакльләр куя. 1922 дән бер үк вакытта драматургия эшчәнлеге б-н дә шөгыльләнә, 30 дан артык пьеса һәм сценарий яза, рус һәм чит ил авторларының әсәрләрен чуашчага тәрҗемә итә. 1925–32 елларда «Чуашкино» актёры, режиссёры һәм сценарийлары авторы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Театральная энциклопедия. М., 1964. Т. 3; Краткая Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001; Чуваши Татарстана. Чебоксары, 2006.

*Ю.А.Благов.*

**МАКСИ́МОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 31 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1920 дә — 165, 1926 да — 193, 1938 дә — 205, 1949 да — 150, 1958 дә — 160, 1970 тә — 105, 1979 да — 69, 1989 да — 54, 2002 дә — 44 кеше.

**МАКСУ́Д** (Максудов) Мәхмүд Гыйсаметдин улы (15.1.1900, Казан губ., Лаеш өязе Югары Кибәхуҗа а. — 10.11.1962, Мәскәү), язучы, тәрҗемәче. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1934). 1918 елдан Мәскәүдә яши, «Чулпан» г-тасы редакциясендә тәрҗемәче, «Яшь эшче» г-тасында мөхәррир (1921–26), «Нәшрият»та баш мөхәррир (1926–28); «Центриздат»ның татар әдәбияты секциясен (1928–31) һәм «Профиздат»ның милли әдәбиятлар секторын җитәкли (1932–33). 1933–34 тә «Коммунист» г-тасында әдәби хезмәткәр. 1918 дә Окт. рев-циясенең берьеллыгы уңаеннан «Бәйрәм җитә» исемле беренче очеркын бастыра. Очеркларында социализм казанышлары, халыклар бердәмлеге темалары яктыртыла («Яңа шәһәр һәм аның кешеләре», 1949; «Тынычлык вахтасында», 1955). Бөек Ватан сугышы елларында политрук, батальон комиссары, сәяси бүлек агитаторы, «Советский воин» г-тасы мөхәррире урынбасары вазифаларын башкара. «Яз җыры» (1929; 2 басма 1990), «Канлы боҗралар» (1929), «Изге көрәшкә» (1941), «Яңа тормыш язында» (1980) кебек хикәяләр җыентыклары; «Үч һәм нәләт җыры» (1944), «Гөлҗамал апа Мәскәүдә» (1948) исемле лирик-публицистик характердагы шигырь җыентыклары; М.Җәлил турында «Сагынган минутларда» (1963) исемле истәлекләр китабы, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Гафури, К.Нәҗми, Һ.Такташ, М.Әмир, Ф.Кәрим иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. Татар теленә А.С.Пушкинның «Дубровский» (1934) һәм «Скупой рыцарь» («Саран рыцарь», 1948), М.Горькийның «Мать» («Ана», 1951), Л.Н.Толстойның «Война и мир» («Сугыш һәм солых», 1–4 т., 1954–57) һәм «Анна Каренина» (1960), И.С.Тургеневның «Рудин» (1959) әсәрләрен, Көнчыгыш әдәбияты классикларыннан Низами, Абай поэмаларын, «Поэты Прибалтики» («Балтыйк буе шагыйрьләре»; Литва ССР ЮСның Мактау грамотасы, 1948) җыентыгын тәрҗемә итә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Әсәрләр. К., 1934; Сайланма әсәрләр. К., 1952; Әсәрләр (1919–1959). К., 1960.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Мәхмүд Максуд иҗаты // Татар совет әдәбиятында реализм мәсьәләләре. К., 1960; Ш а м о в А. Зур тормыш // Казан утлары. 1980. № 1.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАКСУ́Д СӨНДЕКЛЕ́** (псевд., чын фамилиясе һәм исеме Максудов Садыйк Мөбин улы) (15.9.1904, Сембер губ., Буа өязе Сөндек (Сөендек) а. — декабрь 1981), шагыйрь. Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. 1924 елда Донбасс шахталарына китә; совет-партия мәктәбен тәмамлагач (Артёмовск ш., 1927), Щербиновка рудникларында татар һәм башкорт шахтёрларын укырга-язарга өйрәтә. 1931–35 тә «Донбасс эшчесе» татар г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр. 1935 тән Башкортстанда яши: Башглавлитта, Язучылар оешмасында, радио ком-тында, «Әдәби Башкортстан» ж-лында эшли. Әдәбиятка прозаик буларак килеп керә («Күмер тауышы», Уфа, 1930), ләкин алга таба күбрәк поэзия җанрында иҗат итә. Аның беренче язмалары 1930 елларда Мәскәүдә чыккан «Эшче», «Игенчеләр» г-таларында һәм «Яшь эшче» ж-лында дөнья күрә. Татар һәм башкорт поэзиясендә, беренчеләрдән булып, эшчеләр, шахтёрлар темасын күтәреп чыга («Донбасс ударниклары», 1931; «Стаханов турыһында йыр», Уфа, 1938; «Мәхәббәт», 1938 җыентыклары). «Урал шигырьләре» (1948), «Хезмәткә дан» (1950), «Тормыш шатлыгы» (1960) җыентыкларына кергән шигырьләрендә дә производство темасы үзәктә тора; аларда Куйбышев ГЭСын төзүчеләргә, геологлар, нефтьчеләр хезмәтенә мәдхия җырлана. Мариуполь шәһәре оккупацияләнгән вакытта немец фашистлары тарафыннан газаплап үтерелгән атаклы стахановчының батырлыгы турында «Макар Мазай» (Уфа, 1950) һәм революционер «Иван Якутов» (Уфа, 1959) поэмалары — М.С.нең иҗат уңышлары. Соңгы елларында бик яратып лирик миниатюралар һәм сигезьюллыклар яза («Беҙ ҡабыҙған уттар», Уфа, 1974; «Кемдең ҡулы матур?», Уфа, 1977). Балалар өчен «Һуңгы хат» (Уфа, 1934), «Буяусы малайзар» (Уфа, 1957) җыентыклары авторы; А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, М.В.Исаковскийларның кайбер әсәрләрен башкорт теленә тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Шигырьләр, поэмалар. К., 1941; Сайланма әсәрләр. К., 1955; Бессмертие. Уфа, 1972.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАКСУДИ́** (псевд., чын исеме билгесез) (15 йөзнең 2 нче яртысы — 16 йөзнең 1 нче яртысы), төрки-татар шагыйре. Дини-дидактик шигъри хикәятләрдән торган «Һәза китабу фи бәйани могъҗизаи бин-нәби» («Пәйгамбәр кылган могҗизаларны аңлата торган китаб», 1515; 1848 дә басыла) исемле китап авторы. Күләме — 6150 бәйт. М. укучыларны диннең сафлыгын сакларга, ислам идеаллары өчен көрәшкә әзер булырга, куркыныч янау ихтималы булганда, бердәмлеккә чакыра. Сүзләренең ихласлыгын, ислам диненең бөеклеген исбатлау өчен, ул пәйгамбәр кылган могҗизалар, җиңүләр, аның кяферләр б-н көрәше турында яза. Хикәяләр үзләренең бай, образлы теле б-н аерылып торалар, аларда татар халык лексикасы элементлары бар. Җыентык татарлар арасында кулъязма рәвешендә тарала.

Ә с ә р.: Могҗизнамә. К., 2002.

**МАКСУДИ́** Әхмәтһади (Һади) Низаметдин улы (28.9.1868, Казан губ., Казан өязе Ташсу а. — 28.6.1941, Казан), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Татар морзалары *Сөендековлар* нәселеннән. Мулла гаиләсеннән. Садри *Максуди*ның абыйсы. 1881 елдан Казанда яши. «Касыймия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, шунда укыта башлый. Г.*Баруди* эшен дәвам итүче буларак, укытуда, беренчеләрдән булып, яңа ысул куллана. 1894 тә Төркиягә китә, анда яңа ысуллы мәдрәсәләрнең укыту тәртипләрен өйрәнә, алдынгы карашлы зыялылар, ш.и. Ә.Мидхәт, А.Дәүләт идеяләре б-н таныша. И.*Гаспринский* чакыруы б-н Кырымга килә, андагы «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә шәкертләргә мантыйк фәнен һәм гарәп телен укыта. «*Тәрҗеман*» г-тасында языша. 1896 да Казанга кайта. Казан татар укытучылар мәктәбенә экстерн тәртибендә имтиханнар тапшырып, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта. 1890 еллар башында бертуган Юнысовларның Мөселман балалар ятимханәсе мәктәбендә, 1 нче шәһәр башлангыч уч-щесендә татар теле, тарих, география укыта. 1903–05 тә Казан ун-тында ирекле тыңлаучы.

1892 дә М. иҗекләп укырга өйрәтүче «Мөгаллим әүвәл» («Беренче дәреслек») әлифбасын бастырып чыгара, гарәп графикасы нигезендә татарча уку һәм язуны тиз үзләштерү өчен иң яхшы ярдәмлек буларак, бу дәреслек 30 дан артык басма кичерә («*Әлифба*» мәкаләсенә илл.не к.). Анда тән өлешләре, эш кораллары, йорт кирәк-ярагы, хайваннар дөньясы, кием-салым, савыт-саба, азык-төлек турында аерым сүзләр, җөмләләр һәм кыска хикәяләр, татарча ялгызлык исемнәр, антонимнар һәм синонимнар бирелә. «Мөгаллим сани» («Икенче дәреслек» — соңгы баскыч укыту өчен, 1902) — беренчесенең дәвамы, гарәпчә укырга-язарга өйрәтә. Әлифбаларның икесе дә казакълар, үзбәкләр, кыргызлар һәм башкортлар тарафыннан да кулланыла. 1906 ның августында М. татар мөгаллимнәре җыенында катнаша, җыенда башлангыч сыйныфлар өчен уртак уку-укыту программасы кабул ителә. 1910 да ул «Төрки сарыфы» («Татар теле морфологиясе»), «Төрки имля кагыйдәләре» («Татар теленең орфография кагыйдәләре»), «Төрки нәхүе» («Татар теле синтаксисы») дәреслекләре әзерләп чыгара, грамматика һәм дөрес язу кагыйдәләрен бердәм нормага кертергә омтыла. М. язган гарәп теле дәреслеге «Әд-Дөрүс әш-шифаһия» («Гарәп телен өйрәнү буенча йөз дә-

рес», СПб., 1898) берничә тапкыр нәшер ителә, аны хәзерге мәдрәсә шәкертләре дә файдалана. М. ш.у. «Русистан. Россия мөселманнары өчен рус телен үзлегеңнән өйрәнү буенча гамәли дәреслек...» («Русистан. Практический учебник-самоучитель русского языка для мусульман России...», 1911), «Французча «Мөгаллим әүвәл» (1913) һ.б. кулланмалар төзеп бастыра.

М. мәдрәсә шәкертләре өчен ислам нигезләрен аңлаткан популяр ярдәмлекләр серияләрен эшли. «Гыйбадәте исламия» (1898) китабы тулысынча һәм өлешләп кабат-кабат нәшер ителә. 1898 дә М. «Тәквими дивари» — татарча беренче дивар календаре бастыра. Төркиядә газета чыгару эше һәм «Тәрҗеман» г-тасы эшчәнлеге б-н танышканнан соң, М.да татар телендә газета нәшер итү фикере туа. 1903–05 тә «Йолдыз», «Көндез», «Казан» г-таларын бастыруга рөхсәт алу өчен берничә омтылыш ясый. 1906 да «Йолдыз» г-тасын ачып (Казандагы икенче татар газетасы), хыялын тормышка ашыра. Бу газета рев-циягә кадәрге татар вакытлы матбугатының иң абруйлы һәм танылган басмаларыннан санала. Казан шәһәр думасы гласные буларак, М. 1906 да Казанда беренче татар китапханәсе — «Көтебханәи исламия» ачтыруга ирешә һәм 1923 кә кадәр аңа үзе җитәкчелек итә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында яралыларга һәм сугышта һәлак булганнарның туганнарына ярдәм итү максатыннан мөселман ком-ты оештыруда һәм аның эшчәнлегендә катнаша. М. һәм энесе С.Максуди, «*Иттифакъ әл-мөслимин*» мөселман либераль-демократик партиясе лидерларыннан булып, аның Үзәк идарәсе составына кертеләләр. Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаенда (Түбән Новгород, 1906 ның августы) М. партия ҮК һәм Үзәк Бюросы әгъзасы, Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтаенда (Петроград, 1914 нең декабре) Россия мөселман җәмәгать оешмалары ҮК әгъзасы итеп сайлана. Бөтенроссия мөселманнарының беренче (Мәскәү, 1917, май) һәм икенче (Казан, 1917, июль–август) корылтайларында катнаша; икенче корылтайда *Милләт Мәҗлесенә* депутат итеп сайлана, *Милли Идарәнең* халык мәгарифе комиссиясе составына кертелә, төркичеләр (Эчке Россия һәм Себер төрки татарларының милли-мәдәни мохтарияты тарафдарлары) фракциясендә тора.


1) Философия
2) Математика
3) Физика
4) Химия
5) Анорганология
6) Фитология (Ботаника)
7) Зоология
8) Антропология

Ә. Максудиның «Фәнни камус» сүзлеге бите.

Татар теле шрифты һәм орфографиясенә багышланган бөтенроссия конференциясендә (Казан, 1919 ның гыйнвары) катнаша. 1925–30 да Шәрекъ пед. ин-тында гарәп теле укыта. 1927–28 дә М. башлыча фәнни һәм иҗтимагый-сәяси терминнарны туплаган зур хезмәтен — «Фәнни камус» (аңлатмалы сүзлеген) нәшер итү эшенә керешә. 1 нче томның 2300 сүз һәм төшенчәне эченә алган дүрт өлеше басылып чыга (барысы 4 том, 10 мең термин күздә тотыла). Сүзлектә термин-төшенчәләр фәннең аерым тармакларына нисбәтле рәвештә бүлекләргә бүлеп, параграф эчендә мәгънә ягыннан төркемләп урнаштырыла.

1930 елларда М. гарәпчә язылган «Мизани әл-әфкяр» («Фикерләр төгәллеге», 1903) мантыйк дәреслеге б-н башланган хезмәтен дәвам итә, аны бастыру өчен, фәлсәфи хезмәтенең рус телендәге кульязмасын әзерли (сәяси әзәрлекләүгә дучар булуы сәбәпле бастыра алмый). Бу хезмәт берничә кисәктән тора: 1. «Шәрекъ (төрки-гарәп) мантыйгы. Татарча төп нөсхәдән тәрҗемә» ике төп өлешне эченә ала — «Мантыйкның асылы» һәм «Мантыйкның бүлекләре»: категориология, этнология, гносеология, аргументология. 2. «Шәрекъ мөселман мантыйгы», гарәпчә төп нөсхәдән өстәмәләр кертелгән тәрҗемә. 3. «Төрки-гарәп фәлсәфәсе». 4. «Шәрекъ фәлсәфәсе конспекты». 5. «Шәрекъ фәлсәфәсе квинтэссенциясе». 6. «Фәлсәфә терминологиясе».

1933 тә М., «Бөтенсоюз социал-фашистлар партиясе» оештыруда ялган гаеп тагылып (к. «*Контрреволюцион фетнәчеләр оешмасы*» эше), Вятка шәһәренә сөрелә. 1937 нең гыйнварында Казанга кайтырга рөхсәт бирелә, ләкин 1937 ел ахырында кабат кулга алына. Сәламәтлеге какшау сәбәпле, 1939 да төрмәдән чыгарыла.

М. бөтен гомерен татар халкының мәгарифе һәм мәдәниятен үстерүгә багышлый. Уртачыл карашлы либерал буларак, революцион нигилизм һәм консерватив схоластика чикләренә ташланмый, татар милләтен мөстәкыйль үсеш юлына этәрү максатыннан аны дөнья мәдәнияте казанышлары б-н бәйләргә омтыла. М. — татарлар арасында гына түгел, бөтен төрки-мөселман дөньясында танылган шәхес.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М.И. Максудилар шәҗәрәсе // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999; Зәбиров Г.Г. Максуд баба һәм Максудилар. К., 2000; Гаффарова Ф.Ю. Әхмәтһади Максуди. К., 2002; шул ук. «Йолдыз» кабызган Максуди. К., 2006; Рахимов С. «Я ближе всех был связан с И.Гаспринским» (Ахмет-Хади Максуди) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1995, май; Баттал-Таймас Г.Г. Два брата Максуди: Жизнь, творчество и труды. К., 1999; Тазиева Л.К. Лексика букварей Ахметхади Максуди // Бодуэновские чтения. Бодуэн де Куртенэ и современная лингвистика: Междунар. науч. конф. К., 2001. Т.2; Сабирзянов Г. «Фәнни камус» А.Н.Максудова // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2002. № 1.

*Р.А.Айнетдинов.*



Ә. Максуди.

**МАКСУДИ́** (Максудов) Садри (Садретдин) Низаметдин улы (эмиграциядә Садри Максуди Арсал) (23.7.1878, Казан губ., Казан өязе Ташсу а. — 20.2.1957, Истанбул), татарларның милли азатлык хәрәкәте җитәкчеләреннән берсе, Төркиянең дәүләт эшлеклесе, тюрколог, хокук белгече. Татар морзалары *Сөендековлар* нәселеннән. Мулла гаиләсеннән. Әхмәтһади *Максудиның* энесе, Адилә (Гадилә) *Айданың* этисе. 1888 елдан «Касыймия» (Казан) мәдрәсәсендә укый. Аны тәмамлаганнан соң (1894), абыйсы б-н «*Зынҗырлы» мәдрәсәсенә* (Бакчасарай ш.) китә, шунда И.*Гаспринский* б-н таныша (соңрак аны үзенең рухи атасы дип атый). 1896–1901 дә Казан татар укытучылар мәктәбендә укый; уку чорында «Мәгыйшәт» (1898) романын яза. 1901 нең җәендә, киләчәк юлын билгеләү алдыннан, М., Ясная Полянада Л.Н.Толстой б-н очрашып, озаклап әңгәмә кора, Кырымда И.Гаспринский, Истанбулда төрек язучысы Ә.Мидхәт янында булып, алар йогынтысы б-н Парижга китәргә карар итә.

1902–06 да Париж ун-тының юридик ф-тында укый, социология һәм фәлсәфә буенча Э.Дюркгейм һәм Л.Леви-Брюльләрнең лекцияләренә йөри. Шул ук вакытта Сәясәт фәннәре шәхси мәктәбенә укырга керә, Коллеж де Франс ун-тына йөреп, социолог Г.Тард лекцияләрен тыңлый.


1906 да ватанга кайтып, Россиянең сәяси тормышына актив катнашып китә. Либераль-демократик юнәлешле «*Иттифакъ әл-мөслимин*» («Мөселманнар берлеге») партиясе җитәкчеләреннән берсе; Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаенда (Түбән Новгород ш., 1906 ның августы) «Иттифакъ әл-мөслимин»нең ҮКна сайлана. Кадетлар партиясе исемлеге буенча Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907); секретарь урынбасары һәм кадетлар фракциясе әгъзасы; 3 нче Дәүләт Думасы депутаты, мөселманнар фракциясе җитәкчесе (1907–12). М. Думаны мөселманнар, Россия халыклары, ш.и. татарларның сәяси, мәдәни һәм дини хокукларын яклау трибунасы итеп файдалана. Парламентара берлекнең Берлин конференциясендә катнаша (1908), Дәүләт Думасы делегациясе составында Англиядә

булып, король Эдуард VII һәм премьер-министр Асквит тарафыннан кабул ителә. Англиядә алган тәэсирләрен «Англиягә сәяхәт» (1914) китабында тасвирлый. Дәүләт Думасы депутаты буларак, 1910 ның сентябрендә Төркестанга сәяхәт кыла: Ашхабад, Сәмәрканд, Бохара, Коканд, Ташкент шәһәрләрендә Россия мөселманнарын үз мәнфәгатьләрен яклау максатыннан берләштерү идеясен пропагандалый. М. 1910 да алтын приисклары хуҗасы М.Рәмиев кызы Камиләгә өйләнә.

4 нче Дәүләт Думасына сайлауларда үз кандидатурасын куя, ләкин үтми, Казанга кайта. 1913 тә Мәскәү ун-тында юридик дисциплиналар буенча экстерн тәртибендә имтиханнар тапшыра. 1913–17 дә Казан мәхкәмә палатасында антлы вәкил ярдәмчесе, адвокат, Казан шәһәр идарәсендә юридик комиссия әгъзасы. Бөтенроссия мөселманнарының дүртенче корылтаенда (1914 нең июне, С.-Петербург) мөселман дини учреждениеләрен үзгәртеп кору турында доклад ясый.

1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң кабат актив сәяси эшчәнлеккә кайта. Казан мөселманнар ком-ты, ш.у. Бөтенроссия мөселманнары корылтаен җыюны оештыру максатыннан төзелгән Россия мөселманнары Вакытлы Үзәк бюросы әгъзасы. Кадетларның 7 нче съездында (1917, март) ясаган чыгышында Россия мөселманнарының халыкларга киң үзбилгеләнү хокукы бирәчәк демократик респ-ка яклы булуын белдерә. 1917 нең апрелендә Вакытлы хөкүмәт М.ны Төркестан ком-ты әгъзасы итеп билгели. Ташкентта булуы сәбәпле, ул Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (1917 нең мае, Мәскәү) катнаша алмый, әмма читтән торып *Милли Шура* башкарма ком-ты әгъзасы итеп сайлана. Милли Шурада Учредительләр җыенына сайлаулар вакытында мөселманнар тотачак тактиканы эшләү һәм Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаен җыю комиссияләре составына кертелә. 1917 нең 28 июнендә булган Милли Шура утырышында мөселманнарның үзбилгеләнүе турында доклад ясый; бу мәсьәлә булачак корылтайның көн тәртибенә кертелә. М. Икенче корылтай өчен мөселманнарның милли-мәдәни мохтарияты конституциясе текстын әзерли. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаенда (1917, июль–авг., Казан) доклад ясый, шуның нигезендә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли-мәдәни мохтариятын (автономиясен) төзү турында М. эшләгән Декларация кабул ителә. Декларацияне тормышка ашыру өчен, М. җитәкчелегендә Мохтарият коллегиясе сайлана. Дәүләт киңәшмәсендә катнаша (1917 нең августы, Мәскәү). Милли парламент ачылышында (1917 нең ноябре, Казан) *Милләт Мәҗлесе* рәисе һәм милли хөкүмәт — *Милли Идарә* рәисе итеп сайлана. М.ның Россиядәге сәяси эшчәнлегендә бу иң югары нокта була.

М. Окт. рев-циясен кабул итми, кулга алыну куркынычы тугач, 1918 дә Финляндия аша Франциягә китә. 1919 да, Милләт Мәҗлесе вәкиле буларак, Париж Халыкара конференциясендә Идел буе төркиләренең хокукларын яклау мәсьәләсен күтәрә. 1920 нең декабрендә Г.Исхакый һәм Ф.Туктаров б-н берлектә Франция матбугатында «Эчке Россия татар-мөселманнарның чит илдәге вәкиллеге мөрәҗәгате»н бастырып чыгара. 1921 нең гыйнварында Учредительләр җыены әгъзалары киңәшмәсендә (Париж) катнашып, татар вәкилләре Декларациясен игълан итә. 1922–23 тә Хельсинкида һәм Берлинда яши, төрки халыклар тарихы буенча материаллар туплый. 1923 нең августында Франциягә әйләнеп кайта; Париж ун-ты профессоры. 1919 дан Азия фәнни җәмгыяте әгъзасы, Парижда чыга торган «Le Temps» («Вакыт») г-тасында һәм «Journal Asiatique» («Азия журналы») ж-лында язмалар бастыра.



С. Максуди.

Төркиянең мәгариф министры Х.Сөбхи чакыруы буенча М. 1925 тә Төркиягә күчә; Юридик мәктәп һәм Әнкара ун-тының юридик ф-ты профессоры. 1931–1938 дә — Республика халык партиясеннән, 1950–54 тә — Демократик партиядән Төркиянең Бөек Милләт Мәҗлесе депутаты. 1943 тән Истанбул ун-тының юридик ф-ты профессоры, хокук тарихы белгече. Төркия вәкиле буларак, 1936–37 дә Милләтләр лигасы конгресслары эшендә, Төркия парламенты делегациясе составында 1950 дә Европа Советы киңәшмәләрендә катнаша. «Төрек учагы» җәмгыятенең актив әгъзасы, Төркия тарих җәмгыятен оештыручыларның берсе. Төркия вакытлы матбугатында: «*Төрек юрду*», «Milliyet» («Милләт»), «Tasvir» («Тасфир»), «Cumhuriyet» («Җөмһүрият») газета-журналларында хезмәттәшлек итә.

Төркия чоры М.ның фәнни эшчәнлегендә иң уңышлысы. Аның төрек телен үз нигезендә үстерүгә багышланган, кереш сүзен Төркия президенты Ататөрек язган «Türk dili için» («Төрек теле өчен», Әнкара, 1930) китабы илдә тел реформасы уздыру җәһәтеннән аерым әһәмияткә ия. «Искитлар-сакалар» («İskitler-sakalar», Әнкара, 1933) хезмәтендә дә лингвистика темасы дәвам итә, анда М., төрки халыкларның борынгылыгына басым ясап, скифлар һәм саклар этногенезы нигезендә төрки элементлар ятуын исбатлый. М.ның төп фәнни эшчәнлеге хокук теориясе һәм тарихы өлкәсенә карый, күпсанлы монографияләре шушы проблематиканы күтәрә: «Хокук тарихы дәресләре» («Hukuk tarihi dersleri», Әнкара, 1927), «Хокукның гомуми принциплары» («Hukukun umumi esasları», Әнкара, 1937), «Гомуми хокук тарихы» («Umumi hukuk tarihi», Әнкара, 1941), «Хокук фәлсәфәсе» («Hukuk felsefesi», Истанбул, 1946), «Төркия хокукы тарихы» («Türk hukuku tarihi», Әнкара, 1928; өстәмә басма «Төркиләр тарихы һәм хокук» — «Türk tarihi ve hukuk», Истанбул, 1947; русчага тәрҗемәсе 2002) хезмәтендә М. исламга кадәрге төрки дөньяда хокук нигезләре, төрки халыкларда дәүләт төзелеше, милек, мирас итү, уллыкка алу, хатын-кызның тоткан урыны мәсьәләләренә караган тикшеренүләрен туплап бирә. «Урта Азия төрки дәүләтләре», («Orta Asya türk devletleri», Әнкара, 1934) китабындагы кебек үк, монысында да төрки цивилизациянең төрле тарихи дәверләрдәге үсешен һәм үзенчәлекләрен күрсәтергә омтыла.



С. Максуди Казан губернасының Дәүләт Думасы әгъзалары арасында (баскан, уңнан икенче).

1955 тә М. сәясәттән китә; шул ук елда җәмгыятьнең социаль, сәяси һәм рухи үсешендә милли үзаңның әйдәүче көч булуын раслаган, милләтләрнең мөстәкыйль үсешкә хокукы кагылгысызлыгын исбатлаган «Миллият тойгысының социологик әсаслары» («Milliyet duygusunum sosyologik esasları». Истанбул, 1999) монографиясен бастырып чыгара. М. фикеренчә, бу хокук дәүләт законнары һәм турыдан-туры дәүләтнең федератив-демократик төзелеше б-н беркетелергә тиеш. Әлеге хезмәтне аның татарлар һәм башка төрки-мөселман халыклары милли хәрәкәтенә идея һәм оештыру ягыннан зур йогынты ясаган эшчәнлегенә нәтиҗә дип карарга мөмкин. Тормышының кискен борылышларына карамастан, сәясәтче һәм галим буларак, М. үз инануларына тугры кала. Ш.у.к. Г.*Исхакый* турындагы мәкалә илл-ясен.

Чыг.: Мусульманские депутаты Государственной думы России 1906–1917 гг.: Сб. док. / Сост. Л.А.Ямаева. Уфа, 1998.

*Әд.:* Гаффарова Ф.Ю. «Мин милләтемнең баласымын» (Олуг милләтпәрвәребез Садри Максуди сәяси-иҗтимагый эшчәнлеге). К., 1997; шул ук. Садри Максуди (1906 — 1924 еллар). К., 2001; Зәбиров Г.Г. Максуд баба һәм Максудилар. К., 2000; Садри Максуди: тарих һәм хәзерге заман. К., 2004; Ахметзянов М.И. Максудилар шәҗәрәсе // Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993; Исхаков С.М. Конституция культурно-национальной автономии татарского народа // Идель. 1995. № 5/6; Айда А. Садри Максуди Арсал. М., 1996; Садри Максуди. К., 1996; Баттал-Таймас Г.Г. Два брата Максуди: Жизнь, творчество и труды. К., 1999; Садри Максуди: Наследие и современность: Материалы междунар. науч. конф. К., 1999; Мухаметдинов Р.Ф. Нация и революция. К., 2000; Хабутдинов А.Ю. Лидеры Нации. К., 2003; Carra de Vaux B. Le Penseurs de L'Islam. P., 1926. V. 5; Raevuori Y. Sadri Maksudi ve Fin-Türk münasebetleri. Ankara, 1968; Halen H.Sadri Maksudi Arsal. Hels., 1970.

*Р.А.Айнетдинов.*

**МАКСУДИ́ ӘХМӘТҺАДИ́ ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. 18 йөз башыннан мөселман дин әһелләре, морза Сөендековлар нәселеннән чыккан күренекле җәмәгать эшлеклесе, тел белгече, нашир һәм журналист Ә.Н.*Максуди* китапханәсе. Аның шәхси китапханәсендә татар, гарәп, фарсы телләрендә кульязма һәм басма китаплар, татар мәдәнияте тарихына караган документлар туплана.

Максуди китапханәсендә төп урынны Гайнетдин мулла улы Низаметдиннең кульязмалар тупланмасы били. Максудиның кызлары сөйләвенчә, китапханәдә берничә мең китап һәм кульязма исәпләнә, аларның шактые 1950–60 елларда күченеп йөрүләр вакытында югала. 1989 ның ноябрендә гаилә китапханәсенең сакланган өлеше туганнары тарафыннан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тына (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) тапшырыла, ин-т каршындагы сирәк кульязмалар бүлегендә Ә.Максудиның шәхси фонды оештырыла (барлыгы 140 ка якын саклау берәмлеге, кульязмалар — 20 дән артык берәмлек, татар һ.б. телләрдә басылган китаплар, «Йолдыз» г-тасы төпләмәсе, документлар). 15 тән артык кульязма (18–19 йөзләрдә Идел буенда фикъһ мәсьәләләренә караган, дин кануннары, мантыйк буенча чыккан популяр хезмәтләрнең, нигездә, иң яхшылары) Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә, китапларның бер өлеше Ә.Максуди варисларында саклана. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында булган кульязмалар арасында: «Сахих әл-Бохари» (Мөхәммәд әл-Бохари төзегән *хәдисләр* җыентыгы, 1203) китабы күчермәсе; Әбү Габдулла әл-Хөсәен ибне Әхмәд әз-Зузаниның (1093 тә вафат) «Таҗәл-масадир» («Масдарлар китабы», 12 йөз ахыры күчермәсе); «Тәҗвид» («Гарәп теленең фонетикасы», 12 йөз күчермәсе); Муса хаҗи улы Гали хаҗиның хәдисләргә аңлатмасы (фикъһ, 17 йөз күчермәсе); «Китабе фараиз» (матем., 19 йөз) һ.б.; ш.у. Ә.Максудинең этисе күчереп язган кульязмалар да бар.

19 йөзнең 2 нче яртысында Казанда, Петербург, Истанбул, Бәйрут, Каһирәдә басылып чыккан китаплар арасында Җамал Вәлидинең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»; Ибраһим Хаккыйкиның Төркия тарихы буенча «Мәгърифәтнамә» исемле уку ярдәмлеге һ.б. бар. Ә.Максуди үзе мөхәррире һәм нашире булган «*Йолдыз*» г-тасы төпләмәләре аеруча кыйммәтле санала. Тупланмада Г.Камал, танылган татар хәйриячесе миллионер Садри Нәзиров хатлары саклана. «*Йолдыз*» г-тасы редакциясе каршында ш.у. Ә.Максуди китапханәсе оеша («Һилал» — «Ай» һ.б. гарәп журналлары төпләнмәләре сакланган); ул Казанда «*Көтебханәи Исламия*»*не* оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе була.


*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МАКСУ́ДОВ** Гази Барый улы (24.1.1931, Казан), рентгенолог, хәрби табиб, мед. фән. д-ры (1969). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Куйбышев мед. ин-тының хәрби мед. ф-ты тыңлаучысы (1954–56). 1956 елдан Казан ГИДУВының рентгенология кафедрасында. 1958–61 елларда Мәскәү рентген-радиология ин-тында. 1961–66, 1970–76 да Алжир һәм Малида эшли. 1963 тә француз табибе Д.Раги б-н берлектә, беренче буларак, Бамако шәһәрендә (Мали) яшәүчеләргә, үпкә туберкулёзын кисәтү максатыннан, тоташтан флюорография тикшерүе уздыра. 1966–70 тә СССР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы 4 нче Баш идарәнең рентгенология бүлеге мөдире. 1976–97 дә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Педиатрия һәм балалар хирургиясе фәнни-тикшеренү ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хирургларның Бөтендөнья Халыкара конгрессында (Сидней, 1987), табибләр хәрәкәтенең «Атом-төш коралыннан азат дөнья өчен» халыкара конгрессларында (Монреаль, 1988; Хиросима, 1989) катнаша. Хезмәтләре лепра һәм рентген сурәтләре буенча шуңа охшаш башка авырулар вакытында сөяк үзгәрешләрен диагнозлауга карый.

**МАКСУ́ДОВ** (Максуд) Гаяз Гыйсаметдин улы (16.1.1891, Казан губ., Лаеш өязе Югары Кибәхуҗа а. — 1942), җәмәгать эшлеклесе, журналист, математик, физика-матем. фән. канд. (1933). Кышкар (1905), «Хөсәения» (1906–08) һәм «Буби» (1908–10) мәдрәсәләрендә белем ала. 1910–12 елларда Салоники шәһәрендәге төрек лицеенда укый, аннан, иң яхшы укучы буларак, Льеж ун-тының физика-матем. ф-тына (Бельгия, 1913–14) җибәрелә. Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, Төркиягә күчеп китәргә мәҗбүр була, анда Сарай һәм Бурса шәһәрләре лицейларында матем. фәнен укыта. 1919 да Истанбул ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый. Шул ук елда Россиягә кайта, 1 нче татар хезмәт мәктәбе (Одесса ш.) мөдире. 1920–21 дә ТАССР Дәүләт музеенда фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта Гыйльми үзәк хезмәткәре, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең матбугат бюросы әгъзасы. 1922–24 тә Гыйльми үзәк рәисе, Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, татар теленең фәнни терминологиясе комиссиясе эшләрендә катнаша. *Латин язуын* кертүне беренчеләрдән буларак хуплап каршы ала. Бер үк вакытта «Мәгариф» ж-лы мөхәррире, «Кызыл Армия», «Татарстан» г-талары хезмәткәре. Татар укытучылар җәмгыятен оештыручыларның берсе, аның *яңалиф* буенча методик бюросы рәисе. 1925–26 да ТАССР Мәгариф халык комис-тының Баш сәяси агарту идарәсе рәисе. 1926 дан Шәрекъ пед. ин-ты хезмәткәре. 1930 да, «уң төркем»дә катнашканы һәм «*Унбиш җитәкче хаты*» б-н «*Утыз тугыз җитәкче хаты*»на кул куйганы өчен, ВКП(б) әгъзалыгыннан чыгарыла. 1930–36 да Казан ун-тының физика-матем. ф-тында дифференциаль тигезләмәләрне якынча интеграллаштыру буенча тикшеренү алып бара. Татар мәктәпләре һәм техникумнары өчен матем. дәреслекләре («Кыскача җәбер дәресләре», 1923; «Турысызыклы тригонометрия», 1926; «Җәбер дәресләре», 1929) авторы; татар телендә матем. терминнарын эшли. 1936–37 дә Сәмәрканд ун-тында укыта. Репрессияләр чорының корбаны, үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Возвращённые имена. К., 1990; Б е р к у т о в В.М. Развитие математического образования булгаро-татар. К., 1997; В а л е е в Р., С у л и м а Л. Трагедия сторонника «латинизации» (Дело Гаяза Максудова) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1998. № 1/2.

*Р.А.Айнетдинов.*



Г.Г. Максудов.


**МАКСУ́ДОВ** Сәхипзадә Дәүләтша улы (1873, Уфа губ., Бөре өязе Әсән волосте — 1942), җәмәгать эшлеклесе. Мәдрәсәдән соң Казанда дүрт сыйныфлы рус-татар мәктәбен тәмамлый. Бөре өязенең эре җирбиләүчесе һәм сәүдәгәре, икмәк һәм кун б-н сәүдә итә. Бөре өязе земство җыены гласные (1902 елдан), берничә земство мәктәбенең попечителе. Уфа губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906), Мөселманнар фракциясе һәм «Народная свобода» партиясе әгъзасы. «Нур» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. Кулак-муллалар төркемендә торуда гаепләнеп, 1931 нең августында ОГПУның Татарстан бүлеге тарафыннан кулга алына, дәлилләр җитмәү сәбәпле, шул ук елның октябрендә азат ителә.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998. *Д.М.Госманова.*

**МАКСУ́ДОВА** Зәйнәп Габделҗәмил кызы (28.3.1897, Вятка губ., Алабуга өязе Уразай а. — 3.2.1980, Казан), археограф. 1904–11 елларда «Буби» мәдрәсәсенең кызлар сыйныфында укый. 1912 дә икееллык пед. курслар тәмамлый, рус телен өйрәнә, экстерн рәвешендә имтиханнар тапшырып, Атбасар пед. көллиятен тәмамлый (Казакъстан), урта мәктәпләрдә укыта. 1920 дән Ташкентта: Үзбәк хатын-кызлар ин-тында укыта, Урта Азия ун-тында укый. 1922 дән Казанда. Ликбез курсларында, Совет сәүдә техникумында, урта мәктәптә, 1957–67 дә Казан пед. ин-тында гарәп теле укыта. Шәрекъ телләрен яхшы белә, татар мәктәпләрендә рус телен укыту методикасы б-н шөгыльләнә. Борынгы татар әдәбияты ядкәрләрен өйрәнә. Әсәрләре татар халкының рухи мәдәниятенә зур йогынты ясаган күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләре турында биобиблиографик каталог төзи (ТР Милли музеенда саклана; 7 меңнән артык шәрекъ авторын, 30 меңгә якын әсәр исемен үз эченә ала). Методик әсбаплар һәм фәнни мәкаләләр авторы.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МАКСУ́ДОВА** Шәһидә Габдрахман кызы (29.11.1926, Алабуга кантоны Уразай а. — 7.2.2009, Казан), тәрҗемәче, язучы. Казан. ун-тын тәмамлый (1952). 1954–57 елларда ТАССР Китап палатасында, 1959–68 дә Әлмәт Техника йортында, 1969–83 тә ТАССР Язучылар берлегендә китапханәче булып эшли. Рус теленнән татар теленә Л.Н.Толстой-



Д.Д.Максутов.



С.П.Максютов.

ның «Булька» (1953) исемле хикәяләр җыентыгын, В.А.Чивилихинның «Ёлки-моталки» («Урман-чытырман», 1977) повестен, Д.Н.Вәлиевнең «День икс» («Шартлы көн», 1982) пьесасын, казакъ һәм каракалпак язучыларының әсәрләрен тәрҗемә итә. Яшүсмерләр өчен язылган «Минем кала алуым» (1972; рус телендә «Я и город белокаменный», 1976), «Асылбикәне җирләгәндә» (1996) повестьлары авторы.

Ә с ә р.: Минем кала алуым. К., 2006.

*Әд.:* Шәһидә Максудовага 80 яшь // Казан утлары. 2006. № 11.

**МАКСУ́ТОВ** Дмитрий Дмитриевич (11.4.1896, Херсон губ. Николаев ш. — 12.8.1964, Ленинград), оптик һәм уйлап табучы, СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1946). Чыгышы б-н Касыйм морзалары нәселеннән. 1913 елда Одесса кадетлар корпусын тәмамлый һәм Петербургтагы Хәрби инженерлар уч-щесенә укырга керә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Кавказ фронтына җибәрелә, сугышчан батырлыклары өчен поручик чинына һәм медальләргә лаек була. 1916 да М. Тифлистагы хәрби очучылар мәктәбенә күчә. Имтихан очышында аның очкычы, һавада һәлакәткә тарып, 90 *м* биеклектән егылып төшә, М. имгәнә. Дәвалангannan соң, 1918 дә Кытай аша АКШка китеп, зур астрономик оптика җиһазларын төзүче танылган белгеч Г.В.Ричи янында эшләргә карар кыла, тик Харбинга гына барып җитә ала. 1919 да Томск технол. ин-тына укырга керә. 1920 дән Оптика ин-тында (Петроград) эшли, бирегә ул ин-тны оештыручы һәм аның беренче директоры Д.С.Рождественский чакыруы буенча килә. 1921–30 да Одесса шәһәре пр-тиеләрендә (1927 дән Дәүләт физика ин-тында) астрономик оптика буенча эшләрен дәвам итә. 1930–52 дә Оптика ин-тында (Ленинград), бирева ул соңыннан СССРда астрономик приборлар төзү үзәгенә әверелгән астрономик оптика лаб-ясен төзи һәм аны җитәкли; проф. (1944). 1952 дән СССР ФАнең Төп астрономия обсерваториясендә (Пулково) бүлек башлыгы. Хезмәтләре күләгәле һ.б. оптик тикшеренү алымнарына, зур оптик приборлар төзү технологиясенә, асферик өслекләр әзерләү теориясенә һәм практикасына карый. М., беренче булып, күзгеләрне компенсацияле тикшерү алымын тәкъдим итә (1924), менисклы оптик приборлар системаларын уйлап таба (1941); яңа типтагы — күп кенә өстенлекләре булу өстенә, гади төзелеше б-н дә аерылып торучы *менисклы телескоп* төзи; күпсанлы уникаль астрономик инструментларның оптик өлешләрен эшли. Төрле телескоплар системаларын проектлау һәм исәпләү б-н җитәкчелек итә. Дөньяда иң зур М. телескоплары (мениск диаметры 700 *мм*) Абистумани астрофизика обсерваториясендә (Грузия), Серро-Робле обсерваториясендә (Чили) куела. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1941, 1946). Ике Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены; медальләр, ш.и. Брюссель Бөтендөнья күргәзмәсенең «Grand Prix», СССР ВДНХсының алтын медальләре б-н бүләкләнә. М. исеме ай картасына кертелә һәм бер астероидка (№ 2568) бирелә.

Х е з м.: Астрономическая оптика. Л., 1946; Изготовление и исследование астрономической оптики. М., 1948.

*Әд.:* С е л е ш н и к о в С.И. Юбилеи отечественной и мировой астрономии в 1971 г. // Астрономический календарь на 1971 г. М., 1970; С и к о р у к Л.Л. Д.Д.Максутов и его менисковые системы // Земля и Вселенная. 1992. № 1.

*Р.Г.Усманов.*

**МАКСУ́ТОВ М.А. БАСМАХАНӘСЕ́**, Петроградта. 1914 елда Р.Ибраһимовның Петроградта ябылган басмаханәсе нигезендә ачыла. 1914–16 еллар арасында гомуми тиражы 84113 данә булган 24 татар китабы дөнья күрә. Әлеге басмаларның күбесе — һәлак булган сугышчыларның гаиләләренә акчалата ярдәм күрсәтү турындагы законнарның тәрҗемәләре; Кырым һәм Оренбург татарларына кагылышлы законнар, мөселман хәйрия җәмгыятьләре уставлары, дәреслекләр, хрестоматияләр. Окт. рев-циясеннән соң «Чулпан» г-тасын, совет хакимиятенең татар телендәге декретларын бастыра.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**МАКСУ́ТОВ** Рәфкат (Рәфхәт) Әхмәт улы (23.8.1930, Мөслим р-ны Мөслим а.), нефтьче, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974), СССРның мактаулы нефтьчесе (1980), СССРның уйлап табучысы (1970), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1980). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Татарстан фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, директор урынбасары (1967 дән). 1976 елдан Нефть-газ сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) бүлеге башлыгы, 1982 дән Бөтенсоюз континенталь шельфның нефть һәм газ ресурсларын үзләштерү фәнни-тикшеренү һәм проект-конструкторлык ин-ты директоры. 1995 тән «Нефтеотдача» фәнни-техник компаниясе президенты киңәшчесе. 2000 нән Россия җылылык-энергетика инновацион компаниясендә, Фәнни-техник үсеш департаментының директор-координаторы (2002 дән). М. торбаларда парафин утырмаларын булдырмау буенча теоретик һәм экспериментal эшләр үткәрә, углеводородлар чыгару технологияләрен эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 200 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. (1982), СССР Дәүләт (1989) бүләкләре лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теория и практика газлифта. М., 1987 (автордаш).

*Әд.:* М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России. М.-СПб., 2000.

**МАКСУ́ТОВ** Сафиулла Таҗетдин улы (1858, Казан губ., Казан өязе Олы Күлбаш авылы — 1920 дән соң), җәмәгать эшлеклесе. Крәстияннәр нәселеннән. Мәдрәсә тәмамлап, Олы Күлбаш авылында мулла булып тора. Бер үк вакытта сәүдә эше б-н шөгыльләнә. Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), Мөселманнар фракциясе әгъзасы.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998. *Д.М.Госманова.*

**МАКСУ́ТОВ ТЕЛЕСКОБЫ́**, к. *Менисклы телескоп.*

**МАКСУ́ТОВА** Мәхфүзә Кәрим кызы (31.10.1921, Петроград — 29.05.2009, Казан), энергетика машиналары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1977), проф. (1978), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981). 1946 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, моторлар төзү ф-ты деканы (1958–62), проф.-консультант (1986 дан). Хезмәтләре турбомашиналар теориясенә һәм аларны проектлаштыру, гидрогазодинамик исәпләү алымнарына карый. М. турбиналар һәм компрессорлар характеристикаларына режимлы параметрларның йогынтысын тикшерә. «Труды КАИ» җыентыгындагы «Двигатели летательных аппаратов» сериясенең җаваплы редакторы (1966–76). ТАССР ЮС депутаты (1955–63). «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Газовые турбины авиационных двигателей. М., 1963 (автордаш); Газодинамический расчёт активных турбин. К., 1968; Газовые турбины двигателей летательных аппаратов. М., 1991 (автордаш).

**МАКСУ́ТОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Нәсел башында Уфа өязе Усы даругасының мишәрләр старшинасы Максут Атикеев тора (18 йөзнең 1 нче яртысы). 18 йөздә М.га дворянлык дәрәҗәсе бирелә: Оренбург дворян депутатлары җыенының 1816 ел 20 сентябрь һәм 1853 ел 18 декабрь карарлары б-н Оренбург губернасы дворян нәселләре китабының 2 нче һәм 3 нче кисәкләренә 4 нче мишәр кантонының кантон башлыгы майор Абдулкадыйр Абдулкәрим улы Максутов хатыны Маһитап Мөхәммәтгәрәй кызы (чыгышы б-н княгиня Беркович-Черкасская) һәм уллары Шаһморат, Солтангәрәй, йөзбашлар Солтанмөхәммәт һәм Арслангали, оныклары Сәхибгәрәй, Батыргәрәй, Сәетгәрәй, Сәлимгәрәй, Тимербулат, Абдулмаһан Солтангәрәевләр, Арслангали, Нургали, Шаһимәрдан, Шәйхимәрдан, Шаһимoratовлар, Бибимәликә, Кәримә һәм Нәфисә Шаһиморатовалар б-н бергә теркәлеп куела. 19 йөздә морза М. Уфа губернасы Бөре өязенең Себергән авылында яшиләр. Крепостной крәстияннәр тоталар. 1839 да Уфа өязе Агарды авылының 33 хуҗалыгы — ир-ат һәм хатын-кыз җенесеннән булган 173 җан татар — княгиня Маһитап Максутова исемендә була.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов по истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Г а б -

д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МАКСЮ́ТОВ** Сергей Павлович (10.4.1925, хәзер Пенза өлкәсенең Вадинск р-ны Вадинск а. — 3.2.1945, Польшаның Бжег шәһәре янында җирләнә), Сов. Союзы Герое (10.4.1945, үлгәннән соң), рядовой. 1930 елларда Чаллы р-нында яши. 1943 тән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 18 нче аерым моторлаштырылган понтон күпер салу бригадасы понтончысы (13 нче армия). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Украинаның Уңъяк яры җирләрен (1944) һәм Польшаны (1945) азат итүдә катнаша. 1945 нең 3 февралендә Бриг (Бжег) шәһәре янында Одер елгасы аша салынган күперне саклаганда батырлык күрсәтә: күперне шартлаттырмый, үзе һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои и подвиги. Саратов, 1976. Кн. 2; Х л ю п и н В.И. Сыны России. М., 1985.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАКСЮ́ТОВА** Наилә Нәҗиб кызы (14.8.1946, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1998), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1975 елдан РФА КГҮнең Казан Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли, көйләгеч аксымнарны өйрәнү төркеме җитәкчесе (1981 дән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998 дән). 2010 нан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында. Хезмәтләре биоген һәм абиоген факторлар тәэсирендә үсемлекләрдә аксым метоболизмын җайлауга карый. М. беренче булып үсешне тизләтүче, фунгицид һәм стресска каршы үзенчәлекләргә ия афропротеиннарны (күбекле бөҗәкләр Aphrophora Costalis mats — цикада личинкалары эшчәнлеге продуктларыннан физиол. актив аксымнар) аерып чыгара һәм сыйфатлый. Татарстанда төрле а.х. үсемлекләренең продуктивлылыгын күтәрүче гәрәбә к-тасы препаратын күпләп кертүдә катнаша. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Ферментативная активность афропротеинов // Биохимия. 1999. Т. 64, вып. 7 (автордаш); Янтарная кислота-миметик салициловой кислоты // Физиология растений. 1999. Т. 46, № 1 (автордаш); Сравнительное исследование действия абсцизовой кислоты и с АМР на синтез белков зерновок пшеницы в условиях засухи // Биохимия. 2003. Т. 68, вып. 4 (автордаш).

**МАКТАМА́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,5 *км*, бассейнының мәйданы 40,5 *км²*. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы урман массивында, Югары Мактама авылыннан 4,3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. М.ның 1,4 тән алып 2,9 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,88 *км/км²*. Туенуы катнаш, яртысыннан аз гына артыгы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–0,3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су мулլыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. М. ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–100 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**МАКУ́ЛОВЛАР** (Мокуловлар), татар бәкләре нәселе, 15 йөздән мәгълүм. Бәкләр Бибарсовлар һәм Дәүләткилдиевлар б-н кардәшләр. Нәселне нигезләүче — Тимофей Макулов бәк, башка мәгълүматлар буенча Макыл бәк, 16 йөздә аның җирләре Зөя елгасы буенда булып, Макыл авылы (хәзер Югары Ослан р-нының Татар Макылы авылы) да шунда урнашкан. Казан ханлыгы яулангач, 1556 елда Макыл бәк православие диненә күчеп, Зөя каласында хезмәт итә. 18 йөздә бәкләр М. Чембар өязенең Качкару (хәзер Пенза өлкәсенә карый) һәм Краснослободск өязенең Чекаево (хәзер Мордва Респ-касына керә) авылларында яшиләр. 18 йөзнең 1 нче чирегендә Чекаевода Николай һәм Бәхтияр М.ның ир затыннан 3 крепостной крәстияне була. М. нәселенең бер тармагы 17 йөздә Уфа өязенә күчеп китә. 1726 да Макулов улы морза Әхмәт Котлымәмәтов гаиләсе Уфа өязендә, Нугай даругасының Балтач авылында яши. Атасының утар-биләмәсе (45 чирек) — Сембер өязенең Кече Чынлы авылында. 1814 тә Макулов балалары морза Хансуар Мостаев һәм Байбәк Юсупов гаиләләре б-н Чекаеводан Иске Калмаш (хәзер Башкортстан Респ-касының Чакмагыш р-нына керә) күченә. Бу нәсел вәкилләре ш.у. Эстәрлетамак өязенә дә барып урнаша. М. дәүләт крәстияннәре катлавында калалар.

*Әд.:* Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МАКУШО́К** Маркелл Емельянович (1.1.1881, Киев губ., Умань өязе Вернячка а. — 18.1.1952, Минск), зоолог, биол. фән. д-ры (1937), Белоруссия ССР ФА академигы (1950; 1947 елдан хакыйкый әгъза), Белоруссия ССРның атказ. фән эшлеклесе (1944). Киев ун-тының Чагыштырма анатомия ин-тында эшли, ихтиология профессоры (1918 дән). 1927–31 дә Казан ун-тында, умырткалылар зоологиясе каф. һәм зоол. музее мөдире. 1931–37 дә Мурманск Балык хуҗалыгы океанография фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), 1937 дән Белоруссия ун-тында; умырткасызлар зоологиясе, дарвинизм һәм генетика каф. мөдире (1937–41, 1943–52), бер үк вакытта проректор (1950 дән). Хезмәтләре ихтиологиягә, герпетологиягә һ.б.га карый. Казанда эшләү чорында М. гидробиол. һәм җир өсте имезүчеләрен рациональ файдалану мәсьәләләрен тикшерә. Байкал һәм Баренц диңгезе болытсыманнары систематикасын, умырткалыларның баш үсешен, үпкә һәм йөзү куыгының килеп чыгышын өйрәнә. Мурманск сельдь балыгының таксономик һәм экологик мөстәкыйльлеген билгели, кәсәбәчелек юлы б-н тотуның чимал базасы турында гамәли нәтиҗәләр ясый.

Х е з м.: Лягушка. М., 1926; К вопросу об ареале обитания мурманской сельди и о центре этого ареала // Тр. Гос. океанограф. ин-та. 1932. Т. 1, вып. 4; Кошельковый невод. Архангельск, 1932; Карликовый сомик, его хозяйственное значение и биологические особенности. Минск, 1951.

*В.И.Гаранин.*

**МАКША́КОВ** Станислав Борисович (21.7.1954, Казан), приборлар төзүче инженер, ТРның атказ. уйлап табучысы (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Элекон заводы» АҖдә эшли: инженер, тәҗрибә КБсында инженер-конструктор, цех башлыгы урынбасары, заводның җитештерү башлыгы, лазер техникасы һәм электроника конструкторлык бүлегендә әйдәп баручы инженер, яңа техника бүлеге башлыгы урынбасары. М. катнашында югары сыйфатлы электрон тавыш чыгару аппаратурасы, акустик системалар, лазер мед. техникасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 13 патенты бар. Дәүләт бүләге көндәшлеккә сәләтле күп функцияле яңа лазер мед. техникасын эшләгәне, җитештерүне оештырганы һәм Татарстан мед. учреждениеләрендә гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Усовершенствование громкоговорителей 20 АС-2 // Радио. 1981. № 12; Усовершенствование головок 3 ГФ-31–1300 // Радио. 1982. № 4; Расчёт диапазона и точности коррекции сопротивлений плёночных резисторов, подгоняемых группированием // Электронное приборостроение. 2002. Вып. 6.

**МАКША́НЦЕВ** Борис Григорьевич (7.6.1923, Чуаш автономияле өлкәсенең Урмар а. — 4.3.1990, Казан), педагог, РСФСРның атказ. һөнәри-техник белем бирү укытучысы (1971), СССРның халык укытучысы (1983). 1940–42 елларда Чуаш АССРның Ибреси посёлогында урта мәктәп укытучысы. 1949 да Чуаш пед. ин-тын тәмамлаганнан соң Чуаш АССРның Эчке эшләр министрлыгы балалар бүлегенең өлкән инспекторы, 1950 дән Чуаш АССРның Шөмерлә шәһәрендә 6 нчы һөнәри уч-ще директоры, 1960 тан Чуаш һөнәри-техник белем бирү идарәсендә укыту-тәрбия эшләре буенча башлык урынбасары. 1963 тән Казанның 33 нче урта һөнәри-техник уч-щесендә (хәзер М.исем. 33 нче һөнәри лицей) директор. М. җитәкчелегендә уч-щенең биналар комплексы төзелә, укыту-тәрбия эшләре югары дәрәҗәдә оештырыла, профориентация системасы эшләнә. 1980 дә уч-ще Ленин комсомолы бүләгенә лаек була. 1987 дән Бөтенсоюз һөнәри белем бирү белгечләре һәм хезмәткәрләре квалификациясен күтәрү ин-тының яңадан оештырылган Казан ф-лы директоры. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Я к о в л е в Ю.А. Города на память: Из опыта работы СПТУ № 33 г.Казани. М., 1987.

**МАЛА́ЕВКА** (Торна) авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы по-

сёлогыннан 15 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 10 кеше (руслар) яши. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Зур Кляри, Малавкино, Малавка, Кляри исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 җил тегермәне, 1 казна шәраб, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1128,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 166 ир-ат; 1859 да — 407, 1897 дә — 647, 1908 дә — 700, 1920 дә — 653, 1926 да — 455, 1938 дә — 286, 1949 да — 190, 1958 дә — 121, 1970 тә — 57, 1979 да — 31, 1989 да — 6, 2002 дә — 12 кеше.

**МАЛАЛЛА́** посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 25 *км* көнчыгыштарак, Зөя елгасыннан 2,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 50 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1926 да — 60, 1938 дә — 132, 1949 да — 113, 1958 дә — 89, 1970 тә — 79, 1979 да — 69, 1989 да — 61, 2002 дә — 60 кеше.

**МАЛА́НИЧЕВА** Татьяна Геннадьевна (20.1.1967, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2006). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1990), шунда ук, балалар йогышлы авырулары, 1992 елдан балалар авырулары кафедраларында. Хезмәтләре балаларда бронхиаль астма барлыкка килү механизмнарын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 8 патенты бар.

Х е з м.: Атопический дерматит у детей, осложнённый вторичной инфекцией. К., 2007 (автордаш); Современные особенности атопического дерматита и бронхиальной астмы у детей. К., 2010 (автордаш); Атопический дерматит у детей — современные особенности течения и диагностики // Рос. вестн. перинатологии и педиатрии. 2012. № 2 (автордаш).

**МАЛАХИ́Т** (грек. maláchē — мальва, яфрак төсенә охшаш булуына карап), карбонатлар классындагы минерал, $Cu\,CO_3Cu(OH)_2$. *Бакыр рудаларының* төп минералларыннан берсе. М.та Cu 57,4% тәшкил итә. Моноклиналь сингониядә кристаллаша. Радиаль-нур төзелешле ачык яшел төстәге куник, сыланма (примазки), кабыкча, микроконкрецияләр барлыкка китерә, кайвакыт зур тупланмалар рәвешендә очрый (Уралда 40 *т* га якын авырлыктагы кисәк табыла). М. бакырсыман комташларда цемент булып тора. Бөресыман агрегатлар киселешендә үлән төсеннән һәм фирәзә-яшелдән кара яшелгә кадәр төсмердәге төрле бизәкләр хасил итә. Ялтыравыгы пыяла- яки ефәксыман. Катылыгы 3,5–4, уалучан. HCl да чыжылдап эри һәм $CO_2$ бүлеп чыгара. Бакыр һәм бакыр катнаш сульфид чыганакларындагы окисьлашу зоналарында барлыкка килә. Иң эре чыганаклар — Заирда, Замбиядә, АКШта, Казакъстанда, Уралда.

ТР терр-ясендә югары Пермь утырмаларының бакыр рудаларында радиаль-нур төзелешле микроконкрецияләр рәвешендә, конкрецияләр (кабыкчалар рәвешендә) өслегендә, бакырсыман комташларда (цемент буларак) һәм балчыкларда (сыланма һәм ачык куныклар рәвешендә), шахта һәм штольня өемнәре токымнарында (17–19 йөз) очрый. Бакыр рудасы буларак, зәңгәр буяу ясау өчен, декоратив таш һәм зәркән материалы сыйфатында кулланыла. Илл. к. *Геология музее*.

*Әд.:* Проблемы геологии твёрдых полезных ископаемых. К., 1997.

**МАЛАХО́ВСКИЙ** Григорий Викторович (1904 — ?), суднолар төзүче инженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). 1941–48 елларда Зеленодольск суднолар төзү з-дында баш металлург, анда аның җитәкчелегендә металл җиһазда якорь чылбырларын тоташ кою технологиясе эшләнә. 1948 дән Ленинградта: СССР Суднолар төзү сәнәгате министрлыгының Үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында кою бүлеге башлыгы, шул ук министрлыкның Техник идарәсе башлыгы урынбасары (1951–56), Ленинград ХХСда баш металлург (1957–65). Дәүләт бүләге югары ныклыкка ия коелма якорь чылбырларын житештерүне агымга куйганы өчен бирелә.

**МА́ЛИКОВ** Александр Иванович (14.10.1950, Омск өлкәсенең Саргат р-ны Баженово а.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1999), проф. (2000). 1976 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Себер бүлегендә эшли (Иркутск ш.): Себер энергетика ин-тында (1976–80), Иркутск хисаплау үзәгендә (1980–88), системаларның ышанычлылыгы һәм эшләү сәләте секторы мөдире (1985–86). 1988 дән Казан техник ун-тында, автоматика һәм идарә итү каф. профессоры (1999 дан). Хезмәтләре идарә ителүле нәсызыкча системаларның динамик анализына карый. М. идарә ителүле күп бәйләнешле нәсызыкча системаларның абс. тотрыклылыгын һәм көчеш процессларының сыйфатын тикшерә. «Квадратик форма плюс нәсызыкчалыктан интеграл» рәвешендәге компонентлары булган Ляпунов вектор-функцияләрен төзүнең алымнарын һәм алгоритмнарын, ш.у. күчеш процесслары һәм тартылу өлкәләрен чагыштыру, бәяләү системаларын төзү алымнарын эшли. Күп машиналы электроэнергетик системаларның динамик тотрыклылыгын һәм эшләү сәләтен динамик анализлауга кулланылыш таба. Структур үзгәрешләре булган идарә ителүле нәсызыкча системаларны динамик анализлау һәм бәяләү өчен Ляпунов вектор-функцияләре алымын һәм матрицалы чагыштыру системаларын эшли.

Х е з м.: Метод векторных функций Ляпунова в теории устойчивости. М., 1987 (автордаш); Абсолютная устойчивость нелинейных регулируемых систем со случайными изменениями структуры // Изв. РАН. Теория и системы управления. 1996. № 3; Матричные системы сравнения в исследовании динамики нелинейных систем управления со структурными изменениями // Изв. РАН. Теория и системы управления. 1999. № 3.

**МАЛИ́КОВ** Әдип Малик улы (16.8.1921, хәзер БРның Яңавыл р-ны Иске Чат а. — 23.4.2009, Әлмәт ш.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1979). М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1940–46 елларда Төньяк Сахалинда: разведчиклар отделениесе командиры, «Тревога», «За Советскую власть» исемле фронт г-талары хәбәрчесе. Көньяк Сахалинны азат итү сугышларында катнаша (1945). 1946–49 да Татарстан радиоком-тында башта балалар тапшырулары, соңрак әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире. 1951–60 та «Яшь сталинчы» г-тасы үз хәбәрчесе. 1955 тән Әлмәт шәһәрендә яши. 1965–67, 1972–82 дә ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркәтибе. М. «Совет әдәбияты» ж-лында басылып чыккан «Атаудагы хисләр» (1945) поэмасы аша әдәбиятка кереп китә. Сугыш хатирәләре аның иҗатында төп урынны били. Әсәрләрендәге икенче төп тема — Татарстанның җир асты байлыклары, шул өлкәдә эшләүче респ-ка нефтьчеләренең көнкүрешен сурәтләү. «Шигырьләр һәм поэмалар» (1964), «Салкын Алан» (1969), «Шигырьләр, поэмалар» (1971), «Нефтьче турында баллада» (1967; русчага тәрҗемәсе «Баллада о нефтянике», 1974), «Туган як җиле» (1981; русчага тәрҗемәсе «Сквозь годы», 1987), «Җуелмас хәтер» (2004) җыентыклары, ш.и. «Ташчы» (1956), «Фәрдәнә» (1958), «Гайшә апа» (1959), «Чигүле кулъяулык» (1968) поэмалары шушы һөнәр кешеләренең хезмәтенә багышлана. «Яшьлек утравым» (1974; русчага тәрҗемәсе «Остров моей юности», 1976), «Кембрига юл салучылар» (1965; русчага тәрҗемәсе «Кембрийские фонтаны», 1970), «Гомер мизгелләре» (2001) повестьларында тормышчан образлар реаль вакыйгаларга нигезләнеп сурәтләнә. Аның балалар өчен язылган «Су ташучы аю» хикәясе (1963), «Без кояшны юлда каршылыйбыз» документаль повесте (1964; русчага тәрҗемәсе «Мы солнце встречаем в пути», 1965) турында да шуны ук әйтергә мөмкин. 1960 та М.ның «Таңбатыр» әкият-поэмасы буенча Казан курчак театрында «Бирнәле кыз» спектакле куела. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Бергә яккан учаклар: Сайланма шигырьләр, җырлар, поэмалар. К., 1991.

*Әд.:* С а д р и М. Көчле ихтыяр җырчысы // Казан утлары. 1971. № 7; Б и к ч у р и н Ш. Озын юллар, ерак еллар арасы // Казан утлары. 1981. № 10. *Г.М.Габделхакова.*

**МАЛИ́КОВ** Васил Малик улы (19.10.1924, хәзер Актаныш р-ны Иске Кормаш а. — 11.10.1992, Казан), сынчы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970), ТАССРның халык рәссамы (1974), РСФСРның атказ. рәссамы (1982). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1953), уку елларында С.С.Ахун җитәкчелегендә скульптура б-н шөгыльләнә. В.И.Мухи-

на исем. югары сәнгать-сәнәгать уч-щесенең проф. Р.К.Таурит җитәкчелегендәге монументаль-декоратив скульптура бүлегендә укый. 1959 елдан Казанда яши. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968). Казанда монументаль сәнгать үсешен башлап җибәрүчеләрнең берсе: «Казан — биш диңгез каласы» һәм «Идел буе халыклары» темаларына «Волга» кунакханәсе фасадын бизи (1961–63, сграффито, Р.Ә.Килдебәков, С.М.Бубеннов б-н авторлыкта), «Казан» рестораны интерьерында «Яңа Казан» һәм «Иске Казан» исемле рельефлы-мозаик панно (1963, С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков б-н берлектә), Восстание



В.М. М а л и к о в. Совет хакимияте өчен көрәштә һәлак булганнарга һәйкәл. Казан. Аммонит. 1967. Архитекторлар А.А.Спориус, Г.М.Пичуев.

мәйданында М.Җәлил истәлегенә стела иҗат итә (1965, сграффито, тирән рельеф, Р.Ә.Килдебәков б-н авторлыкта). 1950–60 елларда М., башлыча, станлы портрет жанрына мөрәҗәгать итә: «Властимила Свобода» (гипс, тон, 1958), «Нефтьче М.М.Гыймазов» (гипс, тон, 1959), «Унынчы класс укучысы Володя» (гипс, 1962), «Студент кыз портреты» (гипс, 1963). «Исеңдәме, иптәш ...» композициясе сугыш хатирәләре б-н өретелгән (мәрмәр, 1965). Башкару характеры буенча әлеге композициягә Һади Такташ портреты якын тора (мәрмәр, 1962). М.Җәлил портретында (алюминий, 1967–71) М. башка иҗат ысулын күрсәтә: модельнең һәр детале зур төгәллек б-н почмаклар хасил итүче һәм төрле ачыклыктагы төсләр, яктылык һәм күләгәләрнең үзенчәлекле балкышын барлыкка китерүче яссы кырларда төзелгән. М. иҗатында батырлык



В.М. М а л и к о в. «Тукай». Гипс. 1976.

темасы зур урын били. М.ның Казандагы Горький исем. Үзәк мәдәният һәм ял паркы янындагы ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек булган (1980) Совет хакимияте өчен көрәштә һәлак булганнарга монументы (архитекторлары А.А.Спориус, Г.М.Пичуев) Татарстанда 1960 еллардагы монументаль скульптура өлкәсендә идея һәм сәнгать ягыннан зур әһәмияткә ия әсәр булып тора. Шәһәр архит-расында һәйкәлнең новаторлыгы оригиналь чишелеше, зурлыгы, стелага көчле вертикаль акцент ясалуы, сугышчы фигурасының тирән образлы символга ия булуы, яңа материаллар (алюминий, титан) кулланылуы б-н билгеләнде. «Шуклык» (керәч, 1961) жанрлы композициясе, «КамАЗ үсә» сюжетлы тематик композициясе (гипс, тон, 1973), ш.у. наз һәм гүзәллек тулы «Ялангач кыз» (агач, 1973), «Хатын-кыз сыны» (агач, 1994), «Яшүсмер кыз» (известьташ, 1978), «Актаныш кызы» (мәрмәр, 1990) лирик образлары останың бай иҗат мирасына ямь өсти. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1968). Респ-ка (1953 тән); зона — «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Ульянов ш., 1969; Казан, 1980); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1975, 1980); бөтенсоюз — «60 батырлык елы» (Мәскәү, 1978); чит ил — СССРның фәнни техник һәм мәдәни казанышлар (Прага, 1960) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1968 (Казан, Р.Ә.Килдебәков б-н берлектә), 1974–75, 1984 (Казан) елларда уза. Кызыл Йолдыз, 1 нче һәм 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Ростов-Дон шәһәрендәге Сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт, Тверь шәһәрләре картиналар галереясында саклана.


*Әд.:* Василий Маликович Маликов: Буклет. К., 1980; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*


**МАЛИ́КОВ** Габдуллаҗан Габделхак улы (21.11.1907, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Карамалы а. — 18.9.1981, Чечен-Ингуш АССРның Грозный ш.), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1966). Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты каршындагы а.х. техникумын тәмамлаганнан соң (1926), «Тәмте» с-зында агроном булып эшли. 1927–40 елларда Кыргызстан ССРның Ош өлкәсе авыл хуҗалыгында. 1940–41 дә «Дәүләт орлык фонды» конторасында идарәче, 1946–78 дә Чечен-Ингуш АССРның 3 нче Ленин исем. с-зында директор. Герой исеме М. җитәкләгән совхозның яшелчә-җимеш җитештерүдәге уңышлары өчен бирелә. 1957–77 дә Чечен-Ингуш АССРның ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х ә м и т о в а Р., Б ә д р е т д и н о в Х. Туган якка якыная алмыйча // Гүзәл Кама Тамагы — Камское Устье — жемчужина природы. К., 2006; П а в л о в В. Абдулла Маликов // Блокнот агитатора. Грозный. 1966. № 12.

**МАЛИ́КОВ** Марат Фәйзелкадыйр улы (2.2.1937, БАССРның Илеш р-ны Түбән Яркәй а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры



В.М. Маликов.



Г.Г. Маликов.


(1992), проф. (1992), Башкортстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1965–70 елларда БАССРның Калтасы, 1970–75 тә Тәтешле район мәхкәмәләренең халык судьясы. 1975–78 дә — Удмурт, 1978–95 тә Башкорт ун-тларында укыта. 1995–2000 дә Башкорт ун-тының Эстәрлетамак юридик ф-ты деканы. 2000 нән Башкорт ун-тының Эстәрлетамак ф-лы директоры. 2011 дән Башкорт социаль технологияләр ин-тының дәүләт теориясе һәм тарихы, хокук һәм конституцион хокук каф. мөдире. Хезмәтләре дәүләт хокукы, җинаять-процессуаль, конституцион хокук мәсьәләләрен, Башкортстанда, Удмуртиядә дәүләт һәм суд учреждениеләре барлыкка килү тарихын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Эффективность приговора в современном уголовном процессе. Уфа, 1980; Оценка доказательств в правоприменительной деятельности. Уфа, 1984; Проблемы реализации права. Иркутск, 1988. *Е.Б.Долгов.*


**МАЛИ́КОВ** Марсель Малик улы (10.10.1933, Арча р-ны Каратай а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2005), ТАССРның атказ. агрономы (1983). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Кызыл Юл р-ның (хәзерге Арча р-ны) Тельман исем., Сталин исем., Яшел Үзән р-ның Ленин исем. к-зларында агроном булып эшли. 1967–70 елларда Киров өлкәсендә: Болын-сазлык тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр, Оричевский р-ның «Луговой» с-зында директор (1969 дан). 1970 тән Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, терлек азыгы җитештерү бүлеге мөдире (1976 дан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2006 дан), терлек азыгы җитештерү бүлеге консультанты (2007 дән). Хезмәтләре терлек азыгы җитештерү җирләрен яхшырту, сугарыла торган культуралы көтүлекләр булдыру һәм алардан рациональ файдалану мәсьәләләренә карый. ТРда терлек азыгы җитештерү системасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (2004).

Х е з м.: Кормопроизводство в системе адаптивно-ландшафтного земледелия // Кормопроизводство. 2000. № 12; Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002; Травопольные севообороты — основа биологизации земледелия и производства экологически чистых продуктов растениеводства // Агроэкологические проблемы сельскохозяйственного производства в условиях техногенного загрязнения агроэкосистем. К., 2002.

**МАЛИ́КОВ** Рөстәм Гали улы (20.7.1949, Минзәлә р-ны Бикбау а.), җырчы (лирик-драматик тенор), БАССРның атказ. (1984), ТР-



Р.Г.Маликов.



Һ.К.Маликов.

ның халык артисты (1994). 1980 елда Казан консерваториясен (З.Хисмәтуллина классы) тәмамлый. 1980–88 елларда Башкорт, 1988–2010 да Татар филармонияләре солисты. Җырчының репертуары киң һәм күптөрле булуы б-н аерылып тора, камера вокаль музыкасын, Көнбатыш Европа һәм рус классик операларыннан арияләрне, хәзерге Россия һәм чит ил композиторларының вокаль әсәрләрен колачлый. Алар арасында: Альфред («Травиата», Дж.Верди), Рудольф («Богема», Дж.Пуччини), Ленский, Германн («Евгений Онегин», «Пики дамасы» («Пиковая дама», П.Чайковский), Левко («Май төне» («Майская ночь», Н.Римский-Корсаков), Җәлил («Җәлил», Н.Җиһанов), Салават («Салават Юлаев», З.Исмәгыйлев) арияләре; М.Глинка, П.Чайковский, С.Рахманинов романслары; рус, украин, итальян халык җырлары; рус һәм татар композиторлары җырлары һ.б. Репертуарының үзәген татар («Туган тел», «Рәйхан», «Кара урман») һәм башкорт («Азамат», «Кара юрга», «Урал» һ.б.) халык җырлары тәшкил итә. Җырчы татар композиторлары С.Сәйдәшев, Җ.Фәйзи, М.Мозаффаров, Р.Яхин, Ә.Бакиров, С.Садыйкова, Р.Еникиев, Р.Ахиярова, М.Маликов һ.б.ның вокаль музыкасын актив пропагандалый.

Табигый вокаль мөмкинлекләргә (сирәк очрый торган көчле, матур тембрлы моңлы тавыш) ия җырчы югары проф. башкару осталыгы б-н аерылып тора. М. актив концерт эшчәнлеге алып бара, Россиядә һәм чит илләрдә (Монголия, Дания, Германия, Перу, Финляндия, Франция, Кытай һ.б.) чыгышлар ясый.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МАЛИ́КОВ** Рөстәм Шәйдулла улы (27.2.1961, Биектау р-ны Ташлы Кавал а.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, 1985–87 елларда һәм 1990 нан Казан урта мәктәпләрендә эшли, 1987–90 да РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында. 1992–96 да Казандагы 3 нче гимназия директоры. 1997 дән Казан пед. ун-тында (2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты, 2010 нан Казан (Идел буе) федераль ун-ты), 2002 дән гуманитар ф-тларның пед. кафедрасында. Хезмәтләре татар пед. фикер тарихы мәсьәләләренә карый.

*Әд.:* Тюрко-татарская гуманистическая педагогическая мысль средневековья. К., 1999; Педагогическая мысль татарских просветителей конца XVIII — начала XIX века. К., 2007 (автордаш).

**МАЛИ́КОВ** Һади (Ади) Кәрим улы (22.2.1897, Казан губ., Тәтеш өязе Кече Кариле а. — 6.1.1973, Мәскәү), разведчик, полковник. Казан сәүдә мәктәбен (1914), 2 нче Казан прапорщиклар мәктәбен (1917), Хәрби академия (1924) тәмамлый. 1914–15 елларда Хан Станы авылында (Әстерхан губ.) һәм Казанда контора хезмәткәре. 1916–17 дә Россия армиясендә хезмәт итә, Казан, Симферополь, Оргеев шәһәрләрендәге запас пехота полкларында рядовой, взвод офицеры. Беренче бөтендөнья сугышында Румыния фронтының 56 нчы Житомир пехота полкында рота командиры. 1918 дән Кызыл Армиядә, Петроград мөселман полкы комиссары. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы. Казанда «Болак арты республикасы»н юк итүдә, Гражданнар сугышында катнаша. 1919–20 дә Казан ныгытылган районы штабының разведка бүлеге, 2 нче аерым Идел буе татар укчы бригадасы штабы башлыгы. 1921–23 тә СССРның Төркиядәге вәкаләтле вәкиллеге хәрби атташесы секретаре. 1924–27 дә Кызыл байраклы Кавказ армиясе штабының разведка бүлеге башлыгы. 1927–31 дә СССРның Ирандагы вәкаләтле вәкиллеге хәрби атташесы. 1931–33 тә 1 нче татар укчы полкы командиры һәм комиссары (Казан). 1934–36 да Кытайда (Шөнҗан) баш хәрби киңәшче. 1936 да Кызыл Армиянең Разведка идарәсендә бүлек башлыгы. 1936–37 дә СССР дан Кытайга йөк ташуны оештыру буенча махсус хәрби экспедиция башлыгы. 1938 дә Рязань пехота хәрби уч-ще укытучысы. Шул ук елда «татар хәрби-фашистлар оешмасы» эше буенча гаепләнеп кулга алына, репрессияләнә; үлгәннән соң аклана. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Разведка и контрразведка в лицах: Энцикл. словарь российских спецслужб. М., 2002.

**МАЛИ́КОВА** (Шәфигуллина) Әминә Малик кызы (13.9.1930, Апас р-ны Кормаш а.), пресслаучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1954 елда пресслаучылар курсын тәмамлый. 1955–89 да «Элекон» ФҖБдә эшли: пресслаучы, пластмасса эшләнмәләрне эшкәртүче, контролёр. Герой исеме җидееллык планны (1959–65) үтәүгә зур өлеш кертkәнә һәм яңа техника үзләштергәнә өчен бирелә. Заводта, беренчеләрдән булып, «Коммунистик хезмәт ударнигы» исеме ала. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Завод музеенда М.га бюст куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МАЛИ́КОВА** Мәдинә Габделхак кызы (5.8.1935, Сарман р-ны Мортыш Тамак а.), журналист, язучы, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976, 1985). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1959–64 елларда «Чаян», 1964–87 дә «Азат хатын» (1978 дән җаваплы сәркәтип) ж-ллары редакциясендә. 1989–90 да ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары. 1993 тән Бөтентатар Кызыл Хач җәмгыяте президенты. М.ның әдәп-әхлак мәсьәләләренә караган язмалары респ-када һәм үзәк матбугатта еш басылып килә. «Юлдашлар» (1967) дигән беренче хикәяләр җыентыгы ук әхлак мәсьәләләренең кискен куелышы б-н үзенә җәлеп итә. «Казан каласы — таш кала» (1971; русчага тәрҗемәсе «Свет улыбки Моны Лизы», 1985), «Егетлеккә бер адым» (1978), «Янар таулар яктысында» (1980) повестьлары, «Шәфкать» (1984; русчага тәрҗемәсе «Милосердие», М., 1988), «Басып сайрар тавы бар» (1987), «Фидая» (1991), «Алтын ятьмә» (2001), «Кызыл гөл» (2005) романнары иҗат интеллигенциясе тормышыннан алып язылган. Үзенең геройлары — актёрлар, режиссёрлар, рәссамнар, музыкантлар, табибләр, галимнәр образлары аша М. кешелек кыйммәтләренең асылын ача, ялагайлык, икейөзлелек, миһербансызлык кебек сыйфатларны фаш итә. М. иҗатына нечкә лиризм, образларны сурәтләүдә тирән һәм төгәл психол. алымнар хас. Бигрәк тә хатын-кыз образлары уңышлы. «Хөкем» (1969), «Адашканга юл кайда» (1971; русчага тәрҗемәсе «Мелодия огней», М., 1986), «Югалган якутлар» (2004) повестьлары, «Өермә» романы (2003) детектив жанрына карый. М. драматургия өлкәсендә дә актив эшли. «Йөрәк ничек түзсен» (1989 да сәхнәләштерелә), «Оҗмах балалары» (1990 да сәхнәләштерелә), «Моңнар төште башыма» (1992 дә сәхнәләштерелә), «Синең өчен үзем үләрмен» (1994 тә сәхнәләштерелә) пьесалары Минзәлә, Әлмәт татар драма театрларында куела. Х.Ямашев исем. респ-ка бүләге лауреаты (1980).

*Әд.:* Хантемирева Г. Тәсләр балкышы // Казан утлары. 1981. № 8; Галимуллин Ф. Халатың ак, күңелең пакь булса // Казан утлары. 1983. № 9.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАЛИ́НОВКА** посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Уруссу посёлогыннан 23 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 36 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Кырымсарай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 46, 1938 дә — 162, 1949 да — 121, 1958 дә — 76, 1970 тә — 110, 1979 да — 87, 1989 да — 33, 2002 дә — 55 кеше.

**МАЛИНО́ВСКИЙ** Лев Александрович (22.12.1854, Тверь губ. Старица ш. — ?), хирург, медицина д-ры (1882). Мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (С.-Петербург, 1877), хәрби мед. хезмәтендә. 1878 елда Хәрби мед. академиясе клиникаларында (С.-Петербург). 1879 да 89 нчы Ак диңгез пехота полкында хәрби табиб. 1881 дә Гельсингфорс хәрби госпиталенә күчерелә һәм фәнни максаттан Хәрби мед. академиясе клиникаларына беркетелә. 1883 тән Могилёв үзәк фельдшерлар мәктәбе директоры ярдәмчесе һәм Могилёв җәмәгать тәрбиясе приказы хастаханәсе ординаторы. 1887 дән Могилёвтагы дин йортларының өлкән табибе, бер үк вакытта (1888) фельдшерлар мәктәбе директоры. 1888 дән Киев ун-тының хирургик патология кафедрасында. 1889–90 да чит илдә фәнни командировкада була. 1891 дән

Казан ун-тының оператив хирургия кафедрасында ординар проф. Казан хирургия мәктәбенә нигез салучыларның берсе (1890 нчы еллар). 1893 тән Киев ун-тының факультет каршындагы хирургия клиникасы кафедрасында ординар проф. Хезмәтләре нерв системасы авыруларын хирургия юлы б-н дәвалауга карый.

Х е з м.: О нарывах головного мозга. СПб., 1891; Периферический паралич лицевого и тройничного нервов при гнойном страдании среднего уха и хирургическое лечение его // Мед. обозрение. 1893. Т. 40, № 17.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**МАЛИНО́ВСКИЙ** Михаил Сергеевич (4.10.1880, Сембер губ. Неклюдово а. — 1976, Мәскәү), акушер-гинеколог, СССР МФА академигы. (1944), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934), Соц. Хезмәт Герое (1971). В.С.*Груздев* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1907), шунда ук акушерлык һәм гинекология кафедрасында калдырыла. Бер үк вакытта Казан земство хастаханәсендә һәм Лихачёв бала тудыру йортында баш табиб (1912–16), гинекология бүлеге мөдире (1917–19) булып эшли. Гражданнар сугышы елларында Казан госпиталенең баш табибе. 1919 елдан Иркутск мед. ун-тында. 1923 тән Мәскәүдә: 1 нче Мәскәү мед. ин-тында акушерлык һәм гинекология каф. мөдире (1948 гә кадәр), бер үк вакытта Бауман р-ны бала тудыру йорты баш табибе (1923–26), Мәскәү ГИДУВының акушерлык һәм гинекология каф. мөдире (1931–35). 1936–47 дә Бөтенсоюз эксперименталь мед. ин-тының (1943 тән — Акушерлык-гинекология фәнни-тикшеренү ин-ты) акушерлык-гинекология клиникасы директоры. 1947–59 елларда Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тында (ЦИУВ, Мәскәү). СССР МФАнең вице-президенты (1944–46). Хезмәтләре акушерлык-гинекология авыруларын кисәтү һәм дәвалауга, бала табу акты физиологиясе һәм патологиясенә, бала тапканда авыртуны басу һәм хирургия юлы б-н ярдәм итү мәсьәләләренә карый.

М. акушерлык һәм гинекология өлкәсендә физиол. юнәлешне нигезли. Атопик кан китүне туктату, плацента канын күчерү ысулларын, бала табудан соңгы сепсисны дәвалау юлларын тәкъдим итә. Акушер-гинекологларның Бөтенсоюз һәм Мәскәү җәмгыятьләре рәисе. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об искусственном раннем разрыве плодного пузыря при нормальных родах. К., 1915; Обезболивание родов: Практ. рук. для врачей и студентов. М., 1937 (автордаш); Неоперативная гинекология. М., 1957 (автордаш).

*Әд.:* Памяти академика АМН СССР Михаила Сергеевича Малиновского // Акушерство и гинекология. 1976. № 8.


**МАЛИНО́ВСКИЙ** Фёдор Николаевич (1864, Одесса ш. — 1911 дән соң), архитектор. 1881 елда Одесса уч-щесен тәмамлаганнан соң, С.-Петербургтагы Гражданлык инженерлары ин-тына укырга керә. 6 елдан гражданлык инженеры дәрәҗәсе ала һәм техник-төзелеш ком-тына кабул ителә. 1887 дә Ломжа губернасының Остров шәһәрендә казармалар төзү өчен оештырылган гаскәри төзелеш комиссиясе составында. 1889 дан Тверь губернасы идарәсендә: төзелеш бүлегендә кече инженер, 1892 дән — кече архитектор, соңрак Тверь губернасы архитекторы итеп билгеләнә. 1893–1907 дә Казан губернасы архитекторы, бер үк вакытта, 1895–1907 дә, епархия архитекторы, 1902–07 дә Казан сәнгать уч-щесе укытучысы. 1907–11 дә — Казан губернасы инженеры. 1911 дә — Ковно шәһәрендә (хәзер Каунас ш., Литва) губерна инженеры.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында Казан губернасында дини архит-ра биналарын бизи (башлыча, эклектика стилендә). Храмнар проектлаштыра: Ташкирмән авылындагы Гурий чиркәве (хәзер Лаеш р-ны, 1895), Ачы авылындагы Духосошествие чиркәве (хәзер Теләче р-ны, 1896), Малмыж авылындагы



Ф.Н. М а л и н о в с к и й. Раифа монастыреның Троица соборы. 1904–07. Көньяк-көнчыгыш яктан күренеше.

чаңлы Сергий Радонежский чиркәве (хәзер Мамадыш р-ны, 1896), Танкеевка авылындагы Троица чиркәве (хәзер Спас р-ны, 1897), Иоанн Предтеча хатын-кызлар монастырендагы (Зөя шәһәре) «Барлык хәсрәт чигүчеләр юанычы» Мәрьям Ана иконасы соборы (1898–1906), Богдашкино авылындагы Никола чиркәве (хәзер Тәтеш р-ны, 1899), Апак авылындагы Покров чиркәве (хәзер Әлки р-ны, 1899), Чарлы авылындагы Никола чир-



Ф.Н. М а л и н о в с к и й. Иоанн Предтеча хатын-кызлар монастыреның «Барлык хәсрәт чигүчеләр юанычы» Мәрьям Ана иконасы соборы. Зөя. 1898–1906. Көнбатыш яктан күренеше.



Ә.М. Маликова.



М.С. Малиновский.

кәве (хәзер Кукмара р-ны, 1901–02), Раифа монастыреның Троица соборы (1904–07). 1897 дә Раифа монастырендагы «Синай һәм Раифада шәһит киткән изге аталар» чиркәвен, 1911 дә Лаеш шәһәрендәге Троица (хәзер София) чиркәвен һ.б.ның үзгәртеп кора. Гыйбадәт йортлары б-н бергә аның проектлары буенча уку һәм җәмәгать биналары: 1895 тә — Казан Богородица монастырендa чиркәү-приход мәктәбе, 1899 да — Казан епархиясе уч-щесе, 1901 дә — Энгельгардт обсерваториясе, 1903 тә — Казан ун-ты студентлары тулай торагы, 1904 тә Казан руханилар уч-щесенең ике катлы яңа корпусы төзелә.

М. иҗат эшчәнлеге б-н бергә җәмәгать эшләре б-н дә шөгыльләнә. 1888 дән Ятим һәм зәгыйфь балаларны тәрбия кылу җәмгыятенең идарә әгъзасы булып тора (хастаханә бинасын бушлай проектлаштыра). 1902 дә, ятимнәр йортларын «аеруча кайгырткaны өчен», император Николай II нең рәхмәтенә лаек була. 1907 дән Казан тарих-археол. җәмгыяте әгъзасы.

*Әд.:* Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. К., 1993; М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**МАЛИЯ́ НӘЗАРӘТЕ́**, к. *Милли идарә.*

**МА́ЛКИН** Борис Залманович (6.6.1939, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1985), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1961), шунда ук эшли, теоретик физика каф. мөдире (2000–05). Хезмәтләре күчеш металлары һәм сирәк мәгъдән элементларының парамагнитик ионнары булган кристалларның теоретик спектроскопиясенә карый. М. кристаллик кыр теориясендә алмаш корылмалар моделен, оптик спектрларда һәм ТМР кристаллар спектрларында изотопик эффектлар теориясен, куертылгын нәметалл сирәк мәгъдән кушылмалар магнитострикциясе һәм магнитоакустик үзлекләре теориясен эшли. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006).

Х е з м.: Кристаллическое поле в высокотемпературных сверхпроводниках // Физика твёрдого тела. 1994. Т. 36, № 6 (автордаш); Crystal Field and Electron-Phonon Interaction in Rare-Earth Ionic Paramagnets // Spectroscopy of Solids Containing Rare — Earth Ions. Amst., 1987; Ion-phonon interaction // Spectroscopic properties of Rare — Earths in Optical Materials. B., 2004.

*Р.Г.Усманов.*

**МА́ЛКИН** Залман Израилевич (9.4.1897, Витебск губ. Сураж ш. — 2.12.1980, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1926), проф. (1935),

ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). М.Н.*Чебоксаров* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1921), факультет каршындагы терапия клиникасында директор вазифасын башкаручы итеп калдырыла (1932–35). Бер үк вакытта ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тында социаль авырулар бүлеге мөдире. 1935 елдан Казан мед. ин-тының факультет терапиясе каф. мөдире, 1969 дан шунда ук проф.-киңәшче. Бер үк вакытта, 1938–44 тә, Казан стоматология ин-тының терапия каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы елларында эвакогоспитальләрдә киңәшче. 1947–48 дә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш терапевты. Хезмәтләре эчке авыруларга диагноз кую, аларны дәвалау һәм кисәтүгә; витаминнарны, ревматизм, ашказаны ялкынсынуы, үпкә патологиясе, бавыр циррозларын өйрәнүгә карый. М., беренче булып, никотин к-тасының дәвалау үзлеген (катехоламиннар эшләп чыгаруга этәргеч булу һәм холестерин алмашын көйләү) исбатлый (1948). Бөек Ватан сугышы елларындагы берничә хезмәте септик ангинаны өйрәнү өлкәсенә карый. Ревматизм авырулары вакытында десенсибилизацияләүче терапия ысуллары авторы; ревматизм һәм коллагенозларны комплексны дәвалаганда, беренчеләрдән булып, пенициллин куллана башлый. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Терапевтические очерки. К., 1952; Методика применения лечебного питания при болезнях печени. К., 1956; О лечении язвенной болезни желудка и двенадцатиперстной кишки в условиях сельской больницы. К., 1956.

*Әд.:* А н и с и м о в В.Е., К р а с н о п ё р о в Ф.Г. Профессор З.И.Малкин. К., 1987.

**МА́ЛКИН** Иосиф Ильич (16.1.1907, Казан — 14.11.1992, шунда ук), педагог, Татарстанда пионерлар хәрәкәтен оештыручыларның берсе, ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1966). Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый (Казан, 1927). 1923 елда, 8 нче сыйныфта укыганда, РКСМның Казан шәһәр ком-ты кушуы буенча Казанда беренче «Рабис» пионер отрядын оештыра һәм җитәкли. 1924 тән — Тәҗрибә-үрнәк пионерлар коммунасы (балалар йорты), 1928 дән Казандагы 19 нчы урта мәктәп директоры. Бер үк вакытта, 1924–41 дә ВЛКСМның респ-ка һәм шәһәр ком-тлары әгъзасы, пионерлар хәрәкәтен, балалар спорт һәм хезмәт лагерьларын оештыру, республикада пионервожатый кадрлар әзерләү б-н шөгыльләнә. 1941 дән Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–60 та ТАССР Мәгариф министрлыгының Укытучыларның белемен күтәрү ин-ты директоры.

1960–89 да Казан пед. ин-тының пед. кафедрасында. Хезмәтләре пионерлар хәрәкәте тарихы, тәрбия эшләре методикасы мәсьәләләренә карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Очерки истории пионерского движения Татарской АССР. К., 1973 (автордаш); Первые галстуки. К., 1984.

**МА́ЛКИН** Пётр Иванович (30.9.1918, Тәтеш ш. — 13.1.1980, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (4.5.1944, 8.8.1944, 15.5.1946), кече сержант. Тәтеш зоотехниклар техникумын тәмамлый (1938). Район элемтә конторасында эшли. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында: 367 нче танкка каршы аерым истребительләр дивизионында туп төзәүче (47 нче армиянең 260 нчы укчы дивизиясе), 100 нче гаубица артиллерия бригадасында туп төзәүче (3 нче удар армиянең 5 нче артиллерия дивизиясе). Төньяк Кавказ, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Кавказ өчен сугышта (1942–43), Белгород-Харьков (1943), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 27 мартында Ковель шәһәренә керү юлларындагы сугышта совет гаскәрләренә алга баруны тәэмин итә (дошманның 3 пулемётын сафтан чыгара). 1944 нең 5, 8–9 июлендә Ковель шәһәре өчен барган сугышта (дошманның 3 пулемётын, 7 ут ноктасын бастыра, дзотын юкка чыгара); 1945 нең 16–26 апрелендә Берлин өчен сугышларда (дошманның зур күләмдәге сугыш техникасын, 2 миномёт батареясын һәм 3 каршылык күрсәтү үзәген сафтан чыгара) батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Тәтеш элемтә үзәгендә эшли. Медаль б-н бүләкләнә.



П.И. Малкин.

*Әд.:* Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды Славы. К., 1969; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАЛКО́В** Виктор Павлович (8.10.1931, Вотяк автономияле өлкәсенең Можга р-ны Биләр а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1975), проф. (1978), ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1981, 1998). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1956–62 елларда Куйбышев шәһәренең (хәзер Самара ш.) Самара р-ны эчке эшләр бүлегендә тикшерүче, тикшерү бүлеге башлыгы, Октябрь р-ны эчке эшләр бүлеге башлыгы. 1962–98 дә Казан ун-тында: җинаять процессы һәм криминалистика (1975–82), җинаять эшләре хокукы (1982 елдан) кафедралары мөдире; юридик ф-т деканы (1972–83). 1998–2001 дә Мари ун-тының Россия һәм чит илләр җәмәгать хокукы, 2001 дән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тының (Казан) җинаять эшләре һәм процессы кафедралары мөдире. Хезмәтләре җинаять эшләре хокукын һәм процессын өйрәнүгә, җинаятьләрнең ишәю проблемаларына, мәхкәмә процессы формаларын камилләштерү мәсьәләләренә карый. Уку ярдәмлекләре һәм дәреслекләр авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Повторность преступлений: Понятие и уголовно-правовое значение. К., 1970; Совокупность преступлений: Вопросы квалификации и назначения наказаний. К., 1974; Множественность преступлений и её формы по советскому уголовному праву. К., 1982; Совокупность приговоров и назначений наказания. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**МАЛКО́В** Игорь Сергеевич (11.10.1953, Вологда өлкәсенең Харьков р-ны Красная Горка а.), хирург, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан. мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), Казан ГИДУВында (бүленеп: 1979 елда 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә, 1980 дә — Казан шәһәренең 7 нче клиник хастаханәсендә). 2009 дан Казан ГИДУВының хирургия каф. мөдире, профессоры. Хезмәтләре эчәклек үткәрмәүчәнлеге, гастродуоденаль кан китү, корсак куышлыгы җәрәхәтләре очракларында диагноз кую һәм авыруларны дәвалауга карый. Уйлап табуга 7 патенты бар. Гастроэнтерограф җайланмасы өчен М. Брюссель халыкара күргәзмәсендә көмеш медальгә лаек була (2001). ТРның уйлап табу һәм рационализация отличнигы (2005), РФнең сәламәтлек саклау отличнигы (2006).

Х е з м.: Острая кишечная непроходимость: методы диагностики и лечения. Практическое руководство для врачей. К., 2009 (автордаш); Лечебно-диагностические аспекты острой спаечной тонкокишечной непроходимости // Казан. мед. журн. 2009. № 2 (автордаш); Профилактика и лечение гнойных осложнений у больных деструктивным панкреатитом // Казан. мед. журн. 2009. № 6 (автордаш).

**МАЛМА́ТИН** Григорий Иванович (17.4.1917, Казан губ. Күтәмә а. — 6.7.1988, Ташкент), геолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983), Үзбәкстан Респ-касының атказ. геологы (1967). Урта Азия индустриаль ин-тын тәмамлый (Ташкент, 1946). Таҗикстан һәм Үзбәкстан ССР җитештерү оешмаларында геол.-разведкалау партияләре һәм экспедицияләре башлыгы. 1960 елдан Үзбәкстан ССР Геол. министрлыгы идарәсе башлыгы. М. металл (СССР Дәүләт бүләге), металлургия һәм керамик чимал чыганакларын ачуда катнаша. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МАЛМЫ́Ж** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 14 *км* төньяктарак, Комазан елгасы бассейнында. 2010 елда 97 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — крычылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. Сергий Радонежский чиркәве булган (1896 да төзелә; сакланмаган). 1780 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Уса исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да волость идарәсе урнаша; чиркәү, земство мәктәбе, тимерче алачыгы, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1696,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Комазан волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 68 ир-ат; 1859 да — 605, 1897 дә — 1032, 1908 дә — 1262, 1920 дә — 1222, 1926 да —





1182, 1938 дә — 953, 1949 да — 602, 1958 дә — 376, 1970 тә — 379, 1979 да — 310, 1989 да — 168, 2002 дә — 126 кеше.

**МАЛМЫ́Ж ӨЯЗЕ́**, 1780–1929 елларда Вятка губернасында. Үзәге — Малмыж шәһәре. 1708 дә Малмыж җир-су биләмәләре б-н бергә Казанга беркетелә, шәһәр яны бистәсе статусы ала (1764). 1780 дә Вятка наместниклыгы составында Малмыж өязе оештырыла, 1796 да бетерелә, 1802 дә торгызыла һәм кабат бетерелә. 1817 дә Вятка губернасының Алабуга, Уржум, Сарапул һәм Глазов өязләренең 15 волостен эченә алган М.ө. төзелә. Ул көнбатышта Вятка губернасының Нолинск, төньякта — Глазов, көнчыгышта — Сарапул, көньяк-көнчыгышта — Алабуга өязләре, көньякта Казан губернасының Мамадыш өязе б-н чикләшә. Төньяк-көнбатыштан көньяк-көнчыгышка таба өязне Нократ елгасы кисеп үтә һәм урманлы Нократ аръягы (терр-ясенең 5/6 өлеше) б-н Нократ алды тигезлеге өлешләренә бүлә. М.ө. Порек, Милэт, Арык, Зур Шабан, Пижман, Люга, Аджим, Төшке, Кужинерка, Зур һәм Кече Гоньба, Шушма, Малмыж, Буртек, Бөре, Тойма, Көлмез һ.б. елга сулары б-н юыла. Мәйданы 14064 кв. чакрым. Халкы 284,1 мең кеше, ш.и. руслар — 50,7%, удмуртлар — 24,7%, татарлар — 20,7%, марилар — 3,9%. 18–19 йөзләрдә өязнең адм. бүленеше берничә мәртәбә үзгәртелә. 1796 да М.ө. 19 волостьтан тора. Өяз бетерелгәннән соң, Арбор, Вяткогорский (Вятка Тавы), Мукикаксинский, Түбән Чутай, Порек, Урта Көшкәт, Яңгул волостьлары Уржум өязенә; Олы Уча, Водзимон, Кизнер, Китәк, Купка (өлешчә), Малмыж, Полян, Иске Омга, Сосновка волостьлары Алабуга өязенә; Купка (өлешчә) һәм Селты волостьлары Глазов өязенә; Николаев волосте Сарапул өязенә кертелә. 1817–32 дә М.ө. 15 волостьны берләштерә. 1860 та волостьлар саны — 24 (Арбор, Кече Рожки, Түбән Чутай, Чавал, Сизнер, Шода, Яңгул, Бубый, Кукшел, Меринов, Усад, Сәрдекбаш, Зур Порек, Олы Уча, Зур Шабан, Вавож, Волипельга, Иске Торык, Вихарево, Рыбная Ватага, Кырчым-Купка, Селты, Сюмси, Уватукля); 1873 тә — 26 (Көлмез, Үҗәл волостьлары өстәлә); 1895 тә — 28 (Бубый волосте бетерелә, Иске Бөре, Малмыж, Мултан волостьлары оештырыла); 1898 дә — 29 (Сизнерь волосте бетерелә, Носла волосте оештырыла. Усад волосте Вятка Аланы волосте дип үзгәртелә); 1904 тә — 30 (Уватукля һәм Сюмси волостьларын кушып, Сям-Можга волосте оештырыла); 1911 дә — 31 (Христорождественский волосте оештырыла); 1915–16 да — 32 (Аджим волосте өстәлә); Малмыж өязенең Сюмси волосте авылларын Глазов өязенең Шмыков, Рожки, Порез волостьлары б-н кушып, Гура волосте оештыру нияте дә була. 1867 гә кадәр М.ө. — 3, 1873 тән — 5, 1906 дан — 6 станга бүленә. 1 нче станга (үзәге — Малмыж шәһәре) Аджим, Зур Порек, Зур Шабан, Малмыж, Кече Рожки, Чавал волостьлары; 2 нче станга (үзәге — Чепья авылы) Арбор, Түбән Чутай, Носла, Сәрдекбаш, Чепья, Шода, Яңгул волостьлары; 3 нче станга (үзәге — Вятка Аланы авылы) Вятка Аланы, Күкшел, Меринов, Иске Бөре, Иске Торык волостьлары; 4 нче станга (үзәге — Вавож авылы) Олы Уча, Вавож, Волипельга, Уватукля волостьлары; 5 нче станга (үзәге — Көлмез авылы) Вихарево, Көлмез, Рыбная Ватага, Сюмси волостьлары; 6 нчы станга (үзәге — Селты авылы) Купка, Мултан, Селты, Сям-Можга, Үҗәл, Христорождественский волостьлары карый. М.ө. халкы игенчелек, балык тоту, умартачылык, сунарчылык, кош аулау, колмак үстерү, урман кисү-ташу, сал агызу, төрле кәсәбәчелек (өс һәм аяк киемнәре тегү, тире эшкәртү, киндерману, тимерчелек эше, йорт җиһазлары, тәгәрмәч-чана һәм мичкә ясау, чүлмәк ясау-яндыру һ.б.), ш.у. читкә чыгып эшләү (бурлак хезмәте, олау йөртү, урман эше) б-н шөгыльләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында өяздә аракы куу, сыра кайнату, кирпеч сугу, тире эшкәртү, тимер эретү, чуен кою, патока (бәрәңге балы) сыгу, пыяла, сумала-дегет, балавыз-шәм, поташ ясау һәм химия з-длары, киҗе-мамык, кытай тукымасы һәм комач, аркан, кәгазь ф-калары була. Өяздә 13 ярминкә, 275 сәүдә йорты, 844 базар эшли. Иделнең түбән агымына ашлык һәм агач, Казанга — бал һәм тире, Пермьгә — колмак, Мәскәүгә киек-кош озатыла. 19 йөз ахырында Малмыж өязендә 1 өяз һәм 2 мәхәллә уч-щесе, 23 земство һәм 22 чиркәү-приход мәктәбе, 50 укырга-язарга өйрәтү мәктәбе, кайбер мәгълүматлар буенча, 200 татар мәктәп-мәдрәсәсе була. 1920 дә өязнең кайбер волостьлары ТАССР һәм Вятка автономияле өлкәсе составына кертелә. М.ө. 1929 да бетерелә.

Чыг.: Столетие Вятской губернии: Сб. материалов и истории Вятского края. Вятка, 1880. Т. 1; Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1895 год. Вятка, 1894; Проект общих оснований оценки усадебных, пахотных, сенокосных и выгонных земель по 10 участкам Вятской губернии за исключением Слободского. Вятка, 1895; Материалы по статистике Вятской губернии. Т. 12. Общая сводка по губернии. Ч. 1. Подворная опись. Вятка, 1898.

*Д.Г.Мостафина.*

**МАЛМЫ́Ж РАЙОНЫ́**, *Киров өлкәсенең* көньягында урнашкан. Мәйданы — 2196,38 *км*². Үзәге — Малмыж шәһәре (Киров ш.ннән 294 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 25398 кеше (2012), ш.и. 8751 татар (2010). Районда 13 татар авылы бар, 8 торак пунктта татарлар башка халыклар б-н бергә яши. Иң зур татар авыллары (2003): Иске Йөрек (924 кеше), Татар Югары Гоньбасы (779), Яңа Смәел (582), Яңа Йөрек (495), Таң (493). Татарларның күбесе район үзәгендә яши (2010 да — 2842 кеше). М.р. терр-ясендә татарлар Казан ханлыгын Рус хөкүмәте яулап алгач барлыкка килә. Аларның шуннан соңгы күпләп күченүләре 1930 еллардагы күмәкләштерү һәм сәяси репрессияләр, ш.у. сугыштан соңгы чорда районда урман сәнәгате пр-тиеләренең үсеше б-н бәйле. 1917 елга кадәр Иске Йөрек, Татар Югары Гоньбасы, Яңа Смәел авылларында — мәчетләр, алар каршында мәдрәсәләр була. Мәчетләр совет чорында да эшли. М.р.да күптәннән килгән татар мәгърифәтчелеге традицияләре яшәп килә: 1893 тә Малмыж шәһәрендә, 1915 тә Иске Йөрек авылында — ир балалар өчен, 1916 да кыз балалар өчен татар мәктәпләре, 1920 еллар башында Иске Йөрек, Татар Югары Гоньбасы һәм Яңа Смәел авылларында татар мәктәпләре ачыла, 1960–86 да



С.Е.Малов.



А.П.Малышев.

алар рус мәктәбе итеп үзгәртелә. 2002/03 уку елында М.р.ның 3 мәктәбендә укыту татар телендә бара, 3 сендә татар теле фән буларак укытыла. 1997 дән Малмыж шәһәренең Балалар иҗат йортында татар телен өйрәнү дәресләре үткәрелә. Совет чорында районда «Авыл тормышы», 1990 нан «Дуслык» г-тасы нәшер ителә. 1991 дә М.р.да Татар милли-мәдәни үзәге оештырыла, аның каршында үзешчән коллектив эшли. Язучы Э.С.*Касыймов*, вице-адмирал М.Җ.*Искәндәров*, физика-матем. фән. д-ры Н.С.*Гарифҗанов*, тарихчы М.Г.*Худяковларның* тормышы М.р. б-н бәйле. Тарихи-мәдәни истәлекләр — Яңа Смәел, Иске Йөрек һәм Татар Югары Гоньбасы авылларындагы агач мәчетләр. Малмыж шәһәрендәге Төбәкне өйрәнү музеенда М.Г.Худяковның кульязмалары саклана.

**МАЛО́В** Евфимий Александрович (23.1.1835, Сембер губ., Сөнгәләй өязе Тирәнкүл а. — 25.2.1918, Казан), миссионер, дин галиме, ислам дине белгече, илаһият д-ры (1901). Г.С.*Саблуков* шәкерте. 1862 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1910 га кадәр, бүленеп: 1862–63 елларда Казан руханилар семинариясендә укыта), 1865 тән — яһүд теле каф., 1884–1910 да мөселманлыкка каршы предметлар каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1883–95 тә, «Известия по Казанской епархии» ж-лы мөхәррире. 1869 дан Казан Богоявление чиркәвендә рухани, протоиерей (1881). 1886 дан Благовещение кафедраль соборында. Мөселман илаһияте, Идел буенда православие миссионерлыгы тарихына, татарларның этнографиясенә караган хезмәтләр авторы. М.ның христиан археологиясенә, Казандагы һәм Казан губернасындагы монастырьлар һәм храмнар тарихына багышланган хезмәтләре зур әһәмияткә ия. Ислам догматикасын, гарәп һәм татар телләрен яхшы белгән М. мөселман-татарлар һәм яһүдләр арасында актив миссионерлык эшчәнлеге алып бара: православие динен актив пропагандалау, мөселман руханилары һәм җирле халык б-н ачык бәхәс алып баруны беренче планга куя. Миссионерлык эшчәнлегенең төп алымы мөдәррисләр, шәкертләр, гади диндарлар б-н аралашудан, ислам илаһияте нигезләрен тикшереп, тыңлаучыларны христианлыкның өстенлегенә ышандырудан гыйбарәт була. Изге Гурий борадәрлегенең миссионерлык эшчәнлегендә әйдәп баручы руханиларның берсе. П.*Әхмәров* б-н берлектә татар телендә мөселманлыкка каршы «Библия һәм Коръән тәгълиматлары Адәм турында» (1885), «Библия һәм Коръән тәгълиматларында Моисей кануны» (1889), «Ахырзаман турында Мөхәммәд тәгълиматы» (1897) исемле хезмәтләр бастыра. М.ның миссионерлык эшчәнлеген шәкертләре А.А.*Воскресенский*, Я.Д.*Коблов*, М.А.*Машанов* дәвам итterә. М.ның басылмаган миссионерлык көндәлекләре Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә, шәхси архивларда саклана.

Х е з м.: О новокрещенской конторе. К., 1878; Исторические исследования церквей г. Казани: В 2 вып. К., 1884–91; Сведения о мишарях: Этногр.очерк. К., 1885; Миссионерство среди мухаммедан и крещённых татар. К., 1892; О превосходстве Моисея перед всеми пророками. К., 1895.

**МАЛО́В** Камил Миңлегәрәй улы (29.8.1933, Актаныш р-ны Кәзкәй а. — 20.7.2003, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1996). 1954 елда Казан. пед. ин-тын тәмамлый. 1960–67 елларда Алабуга (декан, проректор), 1967–70 тә Башкорт (каф. мөдире, декан) пед. ин-тларында, 1970–76 да Хисаплау техникасын халык хуҗалыгына кертү ин-тында матем. тәэмин ителеш бүлеге башлыгы (Казан). 1976 дан Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында (хәзер Казан энергетика ун-ты), югары матем. каф. мөдире (1976–88). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләргә һәм дискрет системаларга карый. М. даими коэффициентлы сызыкча дифференциаль тигезләмәләр чишү шартларын таба; соңга калучан аргументлы сызыкча дифференциаль тигезләмәне тривиаль чишүнең асимптотик тотрыклылыгы өчен кирәкле һәм җитәрлек шартлар билгели; дискрет системаларны күпбуыннар рәвешендә күрсәтә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: М-преобразования. Сцепления. Квантоpизация. Инварианты изоморфизма // Кибернетика. 1982. № 4; Гипердействительные числа и введение в дискретный аналог операторного исчисления Микусинского // Межвуз. темат. сб. науч. трудов. Электроэнергетика. К., 1998.

**МАЛО́В** Сергей Ефимович (4.1.1880, Казан — 6.9.1957, Ленинград), төрки телләр белгече, тел белеме д-ры (1935), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Казан руханилар академиясен (1904), Петербург ун-ты Көнчыгыш телләре ф-тының гарәп-фарсы-төрек-татар бүлеген (1909) тәмамлый. Кытайда экспедицияләрдә була (1909–11, 1913–15), анда ул уйгыр, лобнор, салар телләренә һәм фольклорына караган бай мәгълүмат туплый. Аннан кайткач, төрек теле һәм әдәбияты магистры була (1916). 1917–22 елларда Казан ун-тында, Шәрекъ пед. ин-тында укыта, Казан ун-тының нумизматика музее мөдире була. 1922 елдан Петроградта: Тере шәрекъ телләре, Төньяк халыклары ин-тларында, Ленинград ун-тында укыта, СССР ФАнең Тел белеме ин-тында эшли. 1943–45 тә Алма-Ата шәһәрендә: Казакъ ун-тында һәм пед. ин-тында төрки телләр секторы җитәкчесе. М. борынгы төрки язмаларны өйрәнә. Кытайга беренче сәяхәте вакытында 10 йөз борынгы уйгыр язма истәлекләреннән «Алтын йаруг» текстын таба һәм В.В.Радлов б-н берлектә бастырып чыгара (1–8 чыг., СПб., 1917). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Уйгурский язык. Хамийское наречие: Тексты, переводы, словарь. М.–Л., 1954; Уйгурские наречия Синьцзяна: Тексты, переводы, словарь. М., 1961; Язык жёлтых уйгуров: Тексты и переводы. М., 1967.

*Әд.:* Т е н и ш е в Э.Р. Сергей Ефимович Малов (к 100-летию со дня рождения) // Советская тюркология. 1980. № 6.

**МАЛОРЕ́ЧИНСКИЙ** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Танай елгасы бассейнында. 2010 елда 296 кеше (руслар — 76%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына, 1960 елларга кадәр рәсми документларда «Алабуга» с-зының икенче бүлекчәсе посёлогы буларак очрый. Оештырылган көннән ТАССРның Алабуга кантоны Алабуга волостенда, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1926 да — 62, 1938 дә — 160, 1949 да — 184, 1958 дә — 262, 1970 тә — 315, 1979 да — 239, 1989 да — 225, 2002 дә — 295 кеше.

**МАЛТАБА́Р** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 33 *км* көнчыгыштарак, Игәт елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 174 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1710 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кривошеина авылы буларак та билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 3 ярма яргыч, 3 әвен базы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1864,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1816 да — 272, 1859 да — 625, 1870 тә — 696, 1884 тә — 852, 1897 дә — 969, 1906 да — 1181, 1913 тә — 1125, 1920 дә — 1149, 1926 да — 823, 1949 да — 525, 1958 дә — 362, 1970 тә — 394, 1979 да — 335, 1989 да — 191, 2002 дә — 200 кеше.

**МА́ЛЫШЕВ** Алексей Петрович (8.10.1926, Лаеш кантоны Панау а. — 24.11.1998, Сочи шәһәренең Лазаревский р-ны Лазаревский пос.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), полковник. Һөнәр уч-щесен (Казан, 1942), Пермь хәрби пехота уч-щесен (1943) тәмамлый. Казанда хәрби з-дта токарь булып эшли. 1943 елның ноябреннән Кызыл Армия сафларында. 1944 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 696 нчы укчы полкның отделение командиры (33 нче армиянең 383 нче укчы дивизиясе). 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 5 февра-

ләндә Фюрстенберг (Германия) шәһәре янында Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга; елга кичкәндә, рота командирының гомерен саклап кала; сугышта, плацдармны киңәйтү өчен, дошман тылына үтеп керә, полк һөҗүмен тоткарлап торучы дзотны шартлата. Сугыштан соң — хәрби комиссар, Сочи шәһәрендә Лазаревский р-нының ветераннар советы рәисе. 1985 тән запаста. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Лазаревский посёлогында 75 нче урта мәктәп һәм Лаеш р-ның Столбище авылындагы мәктәп аның исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1993.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МА́ЛЫШЕВ** Вадим Геннадьевич (14.8.1950, Казан), сан. табибе, мед. фән. д-ры (1992). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Арча эшчеләр посёлогы сан.-эпидемиол. станциясендә сан. табибе булып эшли. 1976 елдан Казан ГИДУВының Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә, 1992 дән Ульянов ун-тының кеше патологиясе каф. мөдире, «Россия университетлары» программасы эксперты, Иммунореабилитация буенча халыкара ассоциация әгъзасы. Хезмәтләре җәрәхәтләрне дәвалауга карый. М. тарафыннан баш сөяге-баш мие җәрәхәтләре очракларында симпатик-адренал һәм адренокортикаль системаларның функциональ халәте өйрәнелә.

Х е з м.: Актуальные проблемы развития ADHD-синдрома. М., 2009; Глицифоновая мазь как средство лечения базалиомы и плоскоклеточного рака кожи. М, 2009.

**МА́ЛЫШЕВ** Василий Алексеевич (14.6.1949, Владимир өлкәсенең Меленки р-ны Южный пос.), салкын штамплау җайланмаларын көйләүче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Бөтенсоюз машина төзелеше читтән торып уку техникумын (Мәскәү, 1980) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1966 елда Меленки урман сәнәгате хуҗалыгында юл эшчесе булып башлый. 1971–73 тә Горький фрезер станоклары з-дында, 1973–97 дә «КамАЗ» АҖнең Пресслау-ремонтлау з-дында эшли. Күп кенә цехларның технол. җайланмаларын монтажлау һәм көйләү-җибәрү эшләрендә катнаша. 1976 ның февралендә беренче «КАМАЗ» автомобилен җыюда катнашу хокукына лаек була. 1990 да ул җитәкләгән комплекслы бригада, беренчеләрдән булып, аренда подрядына күчә. 1997–2004 тә «Начало» ҖЧҖ тә (Чаллы ш.) эшли. Дәүләт бүләге югары нәтиҗәле катлаулы һәм уникаль күп функцияле прессларның зур номенклатурасын, автомат линияләр һәм алар нигезендәге комплексларны булдырганы һәм җитештерүгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К а з а к о в Б. Так нам сердце велело. Наб.Челны, 1996.

**МА́ЛЫШЕВ** Сергей Владимирович (27.9.1950, Казан — 7.6.2007, шунда ук), шагыйрь, тәрҗемәче, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый (1972). 1991 елдан «Идел» («Идель») ж-лында әдәби мөхәррир. «Хәтер яфраклары» («Листья памяти», 1984), «Төнге сөйләшү» («Ночной разговор», 1993), «Кирегә санау» («Обратный отсчёт», 2000) лирик җыентыклары, балалар өчен язылган «Дөньяда бар нәрсә дә кызыклы» («Всё на свете интересно», 1986), «Буйлы-буйлы бер нәрсә» («Что-то полосатое», 2003) китаплары авторы. М.ның поэзиясе — ясалма пафостан принципиаль ерак торган «тыныч лирика»; балалар өчен язган шигырьләренә йомшак юмор хас. Рус теленә Г.Кандалый, Дәрдемәнд, Ф.Кәрим, Х.Туфан, З.Нури, Ш.Галиев, И.Юзеев, Х.Халиков, Ә.Гадел, Р.Мингалим, Ф.Яруллин, Р.Миңнуллин, Г.Зәйнашева, Р.Вәлиева, М.Фәйзуллина әсәрләрен, мөнәҗәтләр тәрҗемә итә.

*Әд.:* С т р а ш н о в С. Возраст ответов (о молодой волжской поэзии) // Молодые о молодых. М., 1988.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МА́ЛЫШЕВ** Юрий Валентинович (2.12.1932, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1992). 1955 елда Казан. ун-тын тәмамлаганнан соң, Ижевск механика ин-тында эшли. 1959 дан Казан технол. ун-тында, югары матем. каф. профессоры (1991 дән). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләр теориясен тикшерүгә, хәрәкәт тотрыклылыгы теориясенә, символик исәпләүләргә карый. М. дифференциаль тигезләмәләр системасын сыйфат ягыннан тикшерү алымын булдыра һәм аларның механика мәсьәләләрендә кулланылышын күрсәтә. Ул ике үлчәнешле системаларның чик цикллары булу шартларын таба, үзгәрешле коэффициентлы нәсызыкча дифференциаль тигезләмәләрне тикшерүнең символик алымын тәкъдим итә. Софус Линың орынма рәвешүзгәртүләр теориясе б-н бәйле бликлар теориясен эшли.

Х е з м.: Дальнейшее развитие теоремы Н.Г.Четаева о неустойчивости движения // Дифференциальные уравнения. 1977. Т. 13, № 5 (автордаш); Об устойчивости и топологической классификации инвариантных множеств // Дифференциальные уравнения. 1978. Т. 14, № 8; Кольцевые области, содержащие предельные циклы // Дифференциальные уравнения. 1984. Т. 20, № 3 (автордаш).

**МА́ЛЫШЕВА** Клавдия Филипповна (2.7.1936, Ширәмәт р-ны Красный Ключ пос.), кош караучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1949–60 елларда бозау караучы, 1960–96 да Түбән Кама р-нының «Красный Ключ» кошчылык ф-касында кош караучы. «ТАССРның иң яхшы бозау караучысы» (1959), «ТАССРның иң яхшы кош караучысы» (1986) исемнәренә лаек була. Герой исеме терлекчелекне үстерүдәге уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МА́ЛЫШЕВА** Светлана Юрьевна (14.11.1965, Казан ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлагач (1988), шунда ук историография, тарихи чыганаклар һәм тарихи тикшеренү



К.Ф. Малышева.

алымнары кафедрасында (2010 едан ун-тның Тарих ин-ты составында, 2013 тән Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү ин-тының историография һәм тарихи чыганаклар каф.) эшли. Хезмәтләре Россиядә 1917 елгы рев-цияләр, Гражданнар сугышы, Россия эмиграциясе тарихына, шул чорны чагылдырган тарихи чыганакларны барлауга, ш.у. мәдәният һәм көнкүреш тарихына карый. «Архив эше нигезләре» («Основы архивоведения», 2002) уку-укыту кулланмасы авторы.


Х е з м.: Российское Временное правительство 1917 года. Отечественная историография 20-х — середины 60-х гг. К., 1999; Временное правительство России. Современная отечественная историография. К., 2000; Советская праздничная культура в провинции: Пространство, символы, исторические мифы (1917–1927). К., 2005; Terra Universitatis: Два века университетской культуры в Казани. К., 2005 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804 — 2004): Библиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**МАЛЬГИ́Н** Виктор Андреевич (6.12.1940, Мордовия АССРның Дубёнки р-ны Кайбичево а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1991), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). 1966 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң, ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында студентлар бүлеге мөдире булып эшли. 1968 дән Казан ун-тында. 1975 тән Казан ракета гаскәрләре һәм артиллерия югары хәрби команда-инженерлар уч-щесендә марксизм-ленинизм каф. профессоры. 1989 дан Казан финанс-икътисад ин-тында: икътисад теориясе каф. мөдире (1989–93), проректор (1993–95), бер үк вакытта, 1994–2004 тә, Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында икътисад теориясе каф. мөдире, кафедраның профессоры (2004 тән). Хезмәтләре милекчелек һәм эшмәкәрлек мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә карый. Медаль һәм ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Совершенствование основного хозяйственного звена в современных условиях. К., 1987; Рыночная экономика и малый бизнес. К., 1997; Экономическая свобода и устойчивость предприятия. К., 2000 (автордаш); Преобразование государственной собственности в условиях институциональных преобразований. К., 2001 (автордаш); Государственное регулирование экономики. К., 2004 (автордаш).

**МА́ЛЬМБЕРГ** Владимир Константинович (1.12.1860, Мәскәү — 9.12.1921, шунда ук), сәнгать белгече, археолог, сәнгать теориясе һәм тарихы д-ры (1905), Германия археол. ин-ты мөхбир әгъзасы. Казандагы өченче



Н.Д. Мальнёв.

гимназияне (1880), Казан ун-тын (1884) тәмамлый. 1885 елдан, проф. дәрәҗәсенә әзерләнү өчен, Петербург ун-тына командировкага җибәрелә. 1888 дән Казан ун-тының нәфис сәнгать теориясе һәм тарихы каф. приват-доценты. 1890 нан Дерпт ун-тының классик филол. һәм археол. каф. профессоры. 1907 дән Мәскәү ун-тының сәнгать теориясе һәм тарихы каф. профессоры, 1913 тән Александр III исем. Император нәфис сәнгать музее директоры. Рус археол. җәмгыяте (1891), Император археол. комиссиясе (1895) әгъзасы. М. тикшеренүләре антик (архит-ра, скульптура, нәкышь, керәч, торевтика) һәм Борынгы Шәрекъ сәнгатенә (Мисыр сәнгате) карый. 70 кә якын фәнни хезмәт (шуларның 20 дән артыгы басылмыйча кала: «Антик пластинадан кыска курслар», «Лукиан биографиясе», «Грекларда вазалар бизәү», «Антик сәнгатьтә Афродита образы» һ.б.) авторы.

Х е з м.: Древнегреческие фронтонные композиции: Исследование в области декоративной скульптуры. СПб., 1904; Портреты Дюрера. М., 1912; Старый предрассудок: К вопросу об изображении человеческой фигуры в египетском рельефе. М., 1915.

*Әд.:* Сборник Московского общества по исследованию памятников древности. Вып. 2: В честь профессора Владимира Константиновича Мальмберга. М., 1917.

**МАЛЬНЁВ** Николай Дмитриевич (9.5.1926, Курск өлкәсенең хәзерге Солнцево р-ны Выползово а. — 16.8.2012, Чаллы ш.), көйләүче, Соц. Хезмәт Герое (1981). 1942 елда Болохов тау-һөнәр уч-щесен тәмамлаганнан соң, «Красногвардейскуголь» шахтасында (хәзер Тула өлкәсе) электромонтажчы булып эшли. 1958–72 дә Камышлы текстиль комб-тында (Сталинград өлкәсе) электрослесарь. 1972–89 да «КамАЗ» ҖБнең Агрегат з-дында көйләүче, кардан валлары җыю бригадасы бригадиры (1974 тән). М. җитәкчелегендәге коллектив берничә тапкыр заводта, берләшмәдә «Иң яхшы бригада» исеменә лаек була. 1976 да М. «КамАЗның иң яхшы эшчесе» исеменә лаек була. Герой исеме зур йөк автомобильләрен җитештерүче Кама берләшмәсенең 2 нче чираты төзелешендә ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МА́ЛЬЦЕВ** Михаил Васильевич (10.7.1910, Ростов өлкәсенең Сальск ш. — 19.10.1972, шунда ук), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1946, 1965), геол.-минерал. фән. канд. (1956). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), «Прикамнефть» трестында (Пермь ш.) эшли. 1940 елдан «Туймазынефть» трестының геол. бүлеге башлыгы. 1949 дан «Татнефть» трестында баш геолог, 1957 дән «ТатНИПИнефть»тә директор урынбасары. 1960 тан Оренбург геол. идарәсе директоры. Урал-Идел буендагы Баулы, Туймазы (Дәүләт бүләге), Серафимово, Оренбург (Дәүләт бүләге) һ.б. девон чоры нефть һәм газ чыганакларын ачучыларның берсе.

Х е з м.: Геологическое строение нефтяных месторождений ТАССР. К., 1956.

*Әд.:* Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996.

**МА́ЛЬЦЕВ** Станислав Викторович (28.9.1941, Чуаш АССРның Канаш ш.), педиатр, мед. фән. д-ры (1981), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Ижевск шәһәрендәге 3 нче балалар хастаханәсе табибе. 1966 елдан Казан мед. ин-тының педиатрия кафедрасында, 1976 дан Казан ГИДУВының педиатрия каф. мөдире, проф. (1982). 1991 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка аналар һәм балаларны саклау үзәге директоры. Хезмәтләре аналар һәм балалар сәламәтлеген саклауга һәм шуңа кагылышлы социаль мәсьәләләргә карый. М. рахитка бәйле авыруларга дифференциаль диагноз кую һәм аларны дәвалау ысулларын ачыклый, балаларда пиелонефрит авыруын дәвалау юлын тәкъдим итә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. 1990–93 тә РФ Халык депутаты.

Х е з м.: Дифференциальная диагностика различных форм рахита // Казан. мед. журн. 1983. № 3; Младенческая смертность в Республике Татарстан. К., 1995 (автордаш); Неотложная помощь в практике семейного врача. К., 2004 (автордаш); Диагностика, профилактика и лечение рахита у детей. К., 2005 (автордаш); Принцип диагностики, профилактики и лечения железодефицитных анемий у детей. Учебное пособие. К., 2009.

**МА́ЛЬЦЕВА** Лариса Ивановна (14.5.1945, Украина ССР, Винница өлкәсенең Крыжополь р-ны Жабокрич а.), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Кемерово өлкәсенең Белово авылы мед. уч-щесендә укыта. 1969 елдан Казандагы 2 нче бала тудыру йорты гинекологы. 1974 тән Казан мед. академиясенең акушерлык һәм гинекология кафедрасында, 1996 дан каф. мөдире. Хезмәтләре йөклелек чорында килеп чыккан катлаулылыкларның көчәю механизмын һәм карындагы инфекцияләрнең яралгыга зарарлы йогынтысын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Иммунотерапия больных хроническим неспецифическим сальпингоофоритом // Казан. мед. журн. 1983. № 1; Беременность и железодефицитные состояния. Учебное пособие. К., 2007 (автордаш); Антифосполипидный синдром. К., 2008; Современные подходы к диагностике и ведению родов при анатомически и клинически узком тазе. Учебное пособие. К., 2012.

**МА́ЛЬЦЕВО** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 7 *км* көнчыгыштарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 126 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1652 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле эшкә яллана. 20 йөз башында М.да тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 748 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятский волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 359, 1887 дә — 528, 1905 тә — 681, 1920 дә — 519, 1926 да — 569, 1938 дә — 670, 1949 да — 481, 1958 дә — 288, 1970 тә — 254, 1979 да — 188, 1989 да — 113, 2002 дә — 115 кеше.

**МАЛЮ́ТИН** Дмитрий Петрович (1890–1938), партия, хуҗалык эшлеклесе. 1917–18 елларда РСФСРның Азык-төлек халык комис-ты коллегиясе әгъзасы, Казан губернасының Азык-төлек ком-ты рәисе. 1918–19 да РКП(б)ның Казан губерна ком-ты һәм губерна башкарма ком-ты рәисе. 1920–21 дә Башкортстан АССР һәм Төркестан азык-төлек халык комиссары. 1922 дән Мәскәүдә Г.В.Плеханов исем. Халык хуҗалыгы ин-ты ректоры, Мәскәү инженерлык-икътисад ин-ты директоры. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

**МАМАДЫ́Ш**, район карамагындагы шәһәр, Мамадыш р-ны үзәге. ТРның төньягында, Казан-Екатеринбург тимер юлындагы Кукмара станциясеннән 80 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казаннан 167 *км* ераклыкта урнашкан. Вятка елгасы буендагы пристань.

Мәйданы — 12,6 *км*². 2010 елда 14435 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 66,7%, руслар — 31,1%) яши. Агач эшкәртү, сыр-май комб-тлары; кирпеч, балык, спирт-аракы з-длары, «Мамадыш нефтепродукт» АҖ, «Спартак» һәм Алабуга киҗе-мамык җитештерү берләшмәләре ф-лары, икмәк кабул итү пр-тиесе, Казан архитектура-төзелеш ун-ты ф-лы, һөнәр лицее, 4 урта, 2 башлангыч мәктәп, музыка һәм спорт мәктәпләре, 2 мәдәният йорты, 3 китапханә. Район тарихы музее. Мәчет, чиркәү.

14 йөз ахырында Мамадышка (беренче күчеп килүче исеме б-н бәйле) татар авылы булларак нигез салына. 17 йөз башында хәзерге М. шәһәре тирәсендәге җирләр Зөя Успение монастырена бирелә, һәм монда рус крәстияннәре килеп урнаша. 1617 дә монастырь, биләмәләрен нугайлар һөҗүменнән саклау өчен, шәһәргә ныгытма төзетә. Җирле чиркәү исеме б-н авыл да Троицкий дип йөртелә башлый, ләкин иске атамасы да саклана. 1764 тә халкы экономик крәстияннәр катлавына күчерелә; иген игү, терлекчелек, балык тоту һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнә, юлаучылар йорты тота. 1774 нең июлендә җирле халык Казанга һөҗүм б-н килгән Е.И.*Пугачёв* отрядларын чаң кагып каршылый, халыкның күбесе Пугачёв ягына чыга. 1781 дә Троицкий авылы Казан наместниклыгының (1796 дан — губернасының) өяз шәһәре итеп үзгәртелә һәм хәзерге исемен ала. Яңа статус М.та адм. идарә органнары (шәһәр башлыгы идарәсе, казначылык, игелек кылу идарәсе,







Мамадыш шәһәре. 1. Гомуми күренеше; 2. Шәһәр ратушасы бинасы. 1785; 3. Бөек Ватан сугышында җиңүгә багышланган һәйкәл.

өяз мәхкәмәсе, дворяннар опекунлыгы һ.б.) булдыруга сәбәп була, шәһәрнең икътисади үсешенә һәм халык саны артуга китерә. 1896 ның май–июнендә М.та атаклы «Мултан эше» буенча мәхкәмә утырышлары үткәрелә. 20 йөз башында шәһәрдә Троица соборы, Петропавел һәм Ксения зират чиркәүләре, мәчет, шәһәр уч-щесе, 4 мәктәп (земство (2), Халык мәгарифе министрлыгы, чиркәү-приход мәктәпләре), почта-телеграф конторы, телефон, земство даруханәсе, хастаханәсе һәм вет. шифаханәсе, су тегермәне, аракы з-ды, 3 әвен, пароходлар һәм агач материаллары пристане, 3 казна шәрабханәсе, 7 зур һәм 49 вак-төякләр кибете, 9 сыраханә, трактир, чәйханә, 22 юлаучылар йорты була; пәнҗешәмбе көннәрендә базар эшли. 1920 дә ТАССР төзелгәч, М. — Мамадыш кантоны, 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш р-ны үзәге. Шәһәрдә 20 гә якын 18 йөз ахыры — 20 йөз башы гражданнар һәм гыйбадәт кылу йортлары архит-расы истәлекләре саклана, алар арасында шәһәр ратушасы (1785), Ксения чиркәве (1876–82; хәзерге көндә дә эшли), дворян П.А.Тырышкин һәм сәүдәгәр Н.И.Щербаков йортлары (19 йөзнең 2 нче яртысы), хәрби казармалар комплексы (19 йөз ахыры) һ.б. бар. М.та В.Г.*Короленко*, М.Е.Салтыков-Щедрин, Сов. Союзы маршалы В.И.*Чуйков* була. Халык саны: 1782 дә — 1272 ир-ат; 1859 да — 3619, 1897 дә — 4195, 1910 да — 5100, 1917 дә — 5188, 1920 дә — 3069, 1926 да — 2972, 1938 дә — 7847 кеше, 1959 да — 9, 1970 тә — 9,7, 1979 да — 10,1, 1989 да — 11,6, 2002 дә — 13,5 мең кеше.


**«МАМАДЫ́Ш»**, Мамадыш р-нындагы нәсел үрчетү з-ды. 1918 елда совхоз буларак оештырыла. 1949 да совхозга «Агробаза» хуҗалыгы, 1957 дә «Красная Горка», «Победа», Сталин исем. к-злар кушыла. 1990 да — нәсел үрчетү с-зы, 1997 дә нәсел үрчетү з-ды итеп үзгәртеп оештырыла. Аның составына: Красная Горка авылы (1 нче ферма) — үзәк утар, Максим Пучинкәсе а., Ташлы а., Беляев Пучинкәсе посёлогы керә. 2008 дән «Омар» агрофирмасы» ЯАҖ составында. 2003 тә хуҗалыклар саны — 607, эшләүчеләр — 340 кеше. А.х. файдалану җирләре 6973 *га*, ш.и. сөрү җирләре — 5180 *га*. Мөгезле эре терлек 2172 баш (ш.и. 590 баш сыер), 4827 баш дуңгыз (шулардан 404 ана дуңгыз). Совхозда дуңгызларның эре ак токымы үрчетелә. 1951 дән аутбридинг ысулы б-н эре кара токымлы дуңгыз көтүләре булдыру буенча эш алып барыла. 1992 дән хуҗалык дуңгыз үрчетүнең линияле ысулына күчә. 2003 тә 1 *га* дан 52,4 *ц* уңыш алынып, 11 мең *т* бөртекле ашлык, 546 *т* ит (тере үлчәм), 2744 *т* сөт җитештерелә. 200 фатир, ашханә, ыслау цехы, мунча, спорт-сәламәтләндерү комплексы, 5 кибет, көнкүреш хезмәте күрсәтү йорты, фельдшер-акушерлык пункты, профилакторий һ.б. мәдәният-көнкүреш объектлары төзелә; җитештерү объектлары һәм торак фондлар газлаштырыла. Хуҗалык КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының күчмә Кызыл байраклары (1983, 1989), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКларының Мактау грамоталары (1984, 1985), СССР ВДНХсының дипломы (1989) б-н бүләкләнә. 1985 тә «М.» нәсел үрчетү з-дында дуңгызчылык буенча Бөтенроссия семинары уздырыла. Дуңгыз караучы М.Г.*Хәйруллина* Соц. Хезмәт Герое исеменә лаек була, 6 кешегә ТАССР, РСФСРның атказ. хезмәткәре исеме бирелә. Җитәкчеләре: М.Ш.*Насыйров* (1980–95), Ф.И.Сәлахов (2005 –08).

*И.Н.Афанасьев.*

**«МАМАДЫ́Ш»** совхозы посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 2 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2010 елда 1998 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, Мамадыш һөнәр лицее ф-лы, мәдәният йорты, китапханә. 1927 дә нигез салына. Беренче исеме — «Агробаза» с-зы (1949 га кадәр). Оештырылган көннән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 438, 1949 да — 392, 1958 дә — 495, 1970 тә — 781, 1979 да — 1018, 1989 да — 1428, 2002 дә — 2015 кеше.

**«МАМАДЫ́Ш»** совхозының 2 нче фермасы посёлогы, Мамадыш шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Пакшин елгасы буенда. 2010 елда 234 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 59%, руслар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 346, 1949 да — 500, 1958 дә — 601, 1970 тә — 518, 1979 да — 332, 1989 да — 236, 2002 дә — 266 кеше.

**МАМАДЫ́Ш КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. *Мамадыш өязенең* 19 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — Мамадыш шәһәре. Мәйданы — 4838 $км^2$. Халкы 170669 кеше, ш.и. татарлар — 68,5%, руслар — 26,1%, удмуртлар — 4,4% (1926). Шәһәрдә яшәүчеләр — 6197, авылда яшәүчеләр — 164472 кеше. Бер $км^2$ га уртача 35,3, авыл җирләрендә 34 кеше туры килә. М.к. 12 волостьтан (Әбде, Вахит, Кукмара, Мамадыш, Мамалай, Омар, Саба, Сәрдек, Тәкәнеш, Үсәли (Өчиле), Шәмәрдән, Яңгул) тора. 196 мәктәп эшли. М.к.нда металл һәм агач эшкәртү, киез-тула басу, җитен эрләү, азык-төлек һәм химия пр-тиеләре була. Һөнәри кәсепчелек өлкәсендә эшләүчеләр саны 3,3 мең кешедән арта (1926). 38647 крәстиян хуҗалыгы (1928), 24 а.х. кооперативы (1925) теркәлгән. 1928 дә сөрү җирләре мәйданы 273276 *га*, ш.и. арыш — 88110, солы —



56379, карабодай — 11171, борай — 3922, бодай — 2219, тары — 894, бәрәңге — 1704, техник культуралар — 5131 *га*. 270669 баш терлек, ш.и. 53872 мөгезле эре терлек, 31546 ат, 173475 сарык була. ТАССРны районлаштыру барышында М.к. Кукмара, Мамадыш, Саба, Тәкәнеш районнарына бүленә.

*Әд.:* Статистический справочник по промышленности ТАССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3, 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике: В 5 вып. К., 1928–29; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МАМАДЫ́Ш КИҖЕ́-МАМЫ́К ФА́БРИКАСЫ**, к. *Кижә-мамык җитештерү сәнәгате*.

**МАМАДЫ́Ш ӨЯЗЕ́**, 1781–1920 елларда Казан губернасында. Үзәге — Мамадыш шәһәре. Мамадыш җир-су биләмәләре б-н бергә Казан өязе составында була, 1708 дә Казанга беркетелә. 1719 да Казан губернасының Казан провинциясенә кертелә. 1781 дә М.ө. Казан наместниклыгы составында (Мамадыш өяз шәһәре статусы ала). 1796, 1801, 1803 еллардагы адм.-терр. үзгәртүләр вакытында Казан губернасы составында калдырыла. Губернаның төньяк-көнчыгышында урнашкан. М.ө. төньякта — Вятка губернасының Малмыж өязе, көньякта — Казан губернасының Чистай өязе, көньяк-көнбатыш һәм көнбатышта — Казан губернасының Лаеш һәм Казан өязләре, көньяк-көнчыгышта — Уфа губернасының Минзәлә өязе, көнчыгышта Вятка губернасының Алабуга өязе б-н чикләшә. Терр-ясе уңъяк (таулы) һәм сульяк (яр буе, тигезлек) өлешләргә бүленә. Өяз Нократ елгасы кушылдыклары: Ушма, Оча кушылдыгы б-н Шыя, Норма, Ерыкса, Комазан һ.б. елгалар; Чулман елгасы кушылдыклары: Чөкәнеш кушылдыгы б-н Омар, Сон кушылдыгы б-н Бөрсет, Олы һәм Кече Мишә, Казкаш елгалары; Казансу елгасының кушылдыгы Кесмәс сулары б-н юыла. Мәйданы 4,9 мең кв. чакрым чамасы. Халкы 189,8 мең кеше, ш.и. татарлар — 69,4%, руслар — 25,1%, удмуртлар — 4,4% (1897). 1904 елга 2 стан һәм 19 волостьтан тора; 1904 тән 3 станга бүленә. 1 нче станга (үзәге — Мамадыш, Тау Иле авылы) Кабык Күпер, Красная Горка, Кече Кирмән, Түбән Сон, Иске Комазан, Троица-Сәкинәс, Благовещенск-Омар волостьлары; 2 нче станга (үзәге — Нырты, Красная Горка авыллары) — Әбде, Бөкмеш, Елыш, Яңа Чүриле, Сатыш, Шомырбаш волостьлары; 3 нче станга (үзәге — Кукмара авылы) — Әсән-Елга, Иске Юмья, Ядегәр, Лыябаш-Келәүш, Җөри, Петропавел волостьлары карый. 1818–20 дә Елыш волостеннан Олы Саурыш волосте, Әбде һәм Петропавел волостьларыннан Завод-Нырты волосте аерылып чыга һәм волостьлар саны 21 гә җитә. М.ө. халкы игенчелек (арыш, солы, карабодай һ.б.), бакчачылык, умартачылык, кәсәбәчелек (тире иләү, тире эшкәртү, киез-тула һәм итек басу, ману, урман кисү һәм агач эшкәртү, тимерчелек һ.б.), ш.и. читкә чыгып эшләү (тегүчелек, җир һәм балта эше, алтын приискларында һәм тимер юлда эшләү) б-н шөгыльләнә. 18–19 йөзләрдә Кукмара, Нырты һәм Бөрсет авылларында бакыр кою з-длары була. Мамадышта һәм өяз авылларында, башлыча, киез-тула һәм итек басу, ману, тире эшкәртү, аракы, тегермән тарту, кирпеч сугу, сабын кайнату, шырпы, балавыз, скипидар, поташ, ат дирбияләре ясау пр-тиеләре эшли; ат питомнигы була. 1914 елга өяздә 25 эре, 293 вак завод-фабрика исәптә тора. 20 йөз башында Мамадышта өч сыйныфлы шәһәр уч-щесе, башлангыч кыз балалар уч-щесе, өяздә 48 башлангыч халык уч-щесе, 41 чиркәү-приход һәм 53 миссионерлык мәктәбе, 226 татар мәктәп-мәдрәсәсе булган. М.ө. 1920 дә бетерелә, волостьларның күпчелеге *Мамадыш кантонына* кертелә.




Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861. Т. 8; Памятная книга Казанской губернии на 1863 год. К., 1862; Списки населённых мест Российской империи: Казанская губерния. СПб., 1866. Т. 14; Волости и важнейшие селения Европейской России: Губернии Нижне-Волжской области. СПб., 1883. Вып. 4; Материалы для сравнительной оценки земельных угодий в уездах Казанской губернии: Уезд Мамадышский. К., 1888. Вып. 6; Казанская губерния // Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. СПб., 1904. Т. 14; Список сёл Казанской губернии. СПб., 1908.

*Д.Г.Мостафина.*




**МАМАДЫ́Ш РАЙОНЫ́**, ТРның төньягында урнашкан. Кама алды икътисади р-нына керә. Мәйданы — 2599,7 *км*². 33 авыл җирлеген (җирле үзидарә советын), 129 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — *Мамадыш* шәһәре. 2012 елда 44,4 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 75,4%, руслар — 20,9%, марилар — 1,4%, удмуртлар — 1,4%) яши. Шәһәр халкы — 14,7 мең, авылларда 29,7 мең кеше яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 17,1 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязенә керә, 1920–30 елларда ТАССРның Мамадыш кантонында. Оешкан вакытында М.р.на 1 шәһәр һәм 54 авыл советы, 86 торак пункт керә, аларда 67971 кеше (татарлар — 37778, руслар — 29400, башка халыклар — 793 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә М.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Кызыл Йолдыз районына* бирелә. 1940 та районның мәйданы — 1459 мең *км*², халык саны — 45,8 мең кеше, 30 авыл советы, 72 торак пункт була. Таркатылган (1959 ның 26 марты) Кызыл Йолдыз р-нының берничә авыл советы М.р.на күчерелгәч, район 1868,3 *км*² җир били, составында 22 авыл советы, 107 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февраленда М.р.на Балык Бистәсе һәм Тәкәнеш р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3834 *км*², халык саны — 109,2 мең кеше, 40 авыл советы була, торак пунктлар саны 201 гә җитә. 1965 нең 12 гыйнварында ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, районның терр-ясе кими — мәйданы 2598 *км*², халык саны — 73,6 мең кеше, 29 авыл советы һәм 152 торак пункт кала. М.р.ның рельефы — елга үзәннәре, ерым һәм сызалар б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлек (биеклеге 180–200 *м*). Кама һәм аның кушылдыклары Шыя, Ушма елгалары ага. Көрән-соры һәм кәсле көлсу, аксыл-соры һәм соры урман туфраклы җирләр өстенлек итә. Терр-ясенең 29,7% ын урманнар алып тора. Балчык, ком, известьташ, көрән ташкүмер, бакыр рудасы, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: Бөрсет елгасы, *Бөрсет акчыршылыклары*, *Мишә аучылык тыюлыгы*, *Порфирьев акчыршылыгы*, «*Соколка урманы*». Район терр-ясендә неолит дәвереннән һәм бронза гасырдан Болгар һәм Алтын Ур-

да чорына кадәрге булган 34 археол. истәлек табыла. М.р. — нигездә а.х. районы. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, җәнлек асрау тармаклары үскән. А.х. җирләре 131,9 мең *га* били, ш.и. 88,8 мең *га* сөрүлек җир (2010). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак, җитен игелә; бәрәңге үстерелә. 2010 да М.р.да 23 а.х. пр-тиесе эшли. Сәнәгать пр-тиеләренең күбесе Мамадыш шәһәрендә тупланган; район үзәгеннән читтә — мебель ф-касы (Келәүш а.), яшелчә киптерү з-ды (Тәкәнеш а.). Районда Кама, Мамадыш урманчылыклары эшли. М.р. җиреннән Казан — Уфа, Мамадыш — Кукмара автомобиль юллары уза. Вятка елгасында — Мамадыш, Кама елгасында Бөрсет һәм Соколка пристаньнары урнашкан. 61 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 40 башлангыч, 13 тулы булмаган урта, 29 урта һәм балалар сәнгать мәктәбе; а.х. лицее, һөнәр көллияте, 54 китапханә, 43 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 76 клуб, хастаханә. Татар һәм рус телләрендә «Нократ», «Вятка» район г-талары нәшер ителә.

**МАМАДЫ́Ш ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, Мамадыш шәһәрендә. 1981 елда җәмәгатьчелек тәртибендә ачыла, 1991 дән ТР Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. Элеккеге сәүдәгәр И.Ф.Захаров йортында урнашкан (19 йөзнең 2 нче яртысы; архит-ра истәлеге). Экспозиция мәйданы — 195 $м^2$, музей фондында 3 мең саклау берәмлеге бар. Экспозиция өч залда урнашкан. «Төбәкнең борынгы заманнардан алып 20 йөз башына кадәрге тарихы» бүлегендә күргәзмәгә археол. һәм нумизматика коллекцияләре,



Мамадыш шәһәрендә төбәк тарихы музее.

көнкүреш әйберләре, татар, рус халыкларының өс киемнәре куелган. Бөек Ватан сугышы тарихы фоторәсемнәрдә, документларда, ш.у. Сов. Союзы Геройлары И.Т.*Максимов*, М.К.*Москвин*, Г.Я.*Нигъмәтуллин*, М.А.*Просвирнин* фотосурәтләрендә чагыла. Күргәзмә залында ел саен музей фонды һәм шәхси коллекцияләрдән берничә күргәзмә оештырыла. Музей фондында якташлар: язучы Ш.*Маннур*, композиторлар М.З.*Яруллин* һәм Ф.З.*Яруллин* турында материаллар тупланган. Иң кыйммәтле әйберләр арасында — сәүдәгәр Н.И.Щербаков өстәле (20 йөз башы), палеонтологик экспонатлар, милли костюмнар. Ел саен Җиңү көне (9 май), Халыкара музейлар көне (18 май) үткәрелә.

**МАМАДЫ́Ш УРМАНЧЫЛЫГЫ́** Мамадыш һәм Кукмара р-ннары терр-ясендә урманнарны файдалану, саклау, ышыклау һәм яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1932 елда оештырыла (1991 гә кадәр берничә тапкыр шул ук исемдәге урман сәнәгате хуҗалыгына үзгәртелә). 2007 дән хәзерге исемендә. М.у.ның гомуми мәйданы 47772 *га*. 4 урманчылык: Келәүш (12693 *га*), Комазан (14979 *га*), Соколка (9061 *га*), Норма (11021 *га*) участокларыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан 45440 *га*, ш.и. ылыслы токымнар барлык мәйданның 34,7%, каты яфраклылар — 21,5%, йомшак яфраклылар — 38,9%, куаклылар — 4,9% ын тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар булып нарат (10024 *га*), чыршы (4964 *га*), биек кәүсәле имән (8204 *га*), өрәңге (1009 *га*), каен (5829 *га*), усак (4565 *га*), юкә (5472 *га*) һ.б. тора. Өстенлек итүче урман типлары: өрәңге-юкәле яшь имәнлекләр, катнаш нараталыклар, имәнле һәм катнаш чыршылыклар, алар исә урман б-н капланган мәйданның 40% ын тәшкил итәләр. Яшь урманнар — 37%, урта яшьтәгеләр — 38,9%, өлгереп килүчеләре — 13,1%, өлгергәннәре — 9,7%, картайганнары 1,3% урман мәйданын алып тора. Гомуми агач запасы 6073,3 мең $м^3$, ш.и. өлгергәннәрнең — 511 мең $м^3$, картайганнарның — 134,4 мең $м^3$. 2012 дә урман торгызу эшләре 57 *га* мәйданда алып барыла, 7 *га* мәйданда саклаучы утыртмалар булдырыла. Гомуми мәйданы 10 *га* булган урман питомникларында ел саен агач һәм куак токымнарының (гади нарат, гади чыршы, Себер карагае, сабакчалы имән, иенке каен, вак яфраклы юкә һ.б.) якынча 1,5 млн. данә утырту материалы үстерелә. М.у. терр-ясендә Кама һәм Вятканың биек ярларында 3914 *га* мәйдан биләүче, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясына бай булган нарат һәм катнаш урманнардан торган «Соколка урманы» табигать истәлеге урнашкан. М.у.н үстерүдә һәм урман хуҗалыгы эшләрен алып бару дәрәҗәсен күтәрүдә респ-каның атказ. урманчылары А.Д.Арсентьев (1962–90 да урман хуҗалыгы директоры), М.С.Хәсәнов (1990–2011 дә урман хуҗалыгы директоры), И.Г.Мөхәммәтшин, ТРның атказ. икътисадчысы А.Л.Хәйруллин зур өлеш кертәләр.

*Ф.К.Хәлиуллин.*

**МАМАДЫ́Ш-ӘКИ́Л** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 47 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 430 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.-Ә.дә мәчет, су тегермәне, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1395 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 феврленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 610, 1897 дә — 1151, 1908 дә — 1341, 1920 дә — 1416, 1926 да — 935, 1938 дә — 1153, 1949 да — 1017, 1958 дә — 867, 1970 тә — 794, 1979 да — 685, 1989 да — 581, 2002 дә — 522 кеше.

**МАМА́Й** (1330 тирәсе — 1381, Кафа ш.), Алтын Урда бәкләр бәге, 1360 елдан, асылда, Алтын Урданың Көнбатыш олысы идарәчесе. Кыят ыруыннан, Ак Урдада ыру башы булган дип фаразлана. Җанибәк хан заманында күтәрелә, аның кызына өйләнә, бәкләр бәге дәрәҗәсенә ия була. Бирдебәк хан идарә иткәндә Кырымда олыс бәге булып тора. Тәхет чуалышлары чорында хан сараенда зур абруйга ирешә (1361). Үз йогынтысыннан файдаланып, хан тәхетенә *Абдуллаһны* утырттыра (1361, яз-көз). Күк Урда ханы Мөрид гаскәрләре тарафыннан Сарай әл-Җәдидтән куылгач, Кырымга кача, бәйсезлек сәясәте алып бара, Адбуллаһ һәм *Мөхәммәдбуләк ханнар* исеменнән акчалар суктыра (1369–80). Күк Урда ханнары һәм сарай аксөякләре б-н көрәшә, Ак Урдада йогынтысын киңәйтергә омтыла, Сарай әл-Җәдидне берничә тапкыр кулына төшерә (1363, 1368, 1372, 1375). 1370 елларда М., Русь җирләре һәм Идел буе Болгарын да кертеп, Алтын Урданың Түбән Иделдән башка барлык көнбатыш олысларын үз карамагында тота. 1370 еллар уртасында Мәскәү кенәзе Дмитрий Иванович, М. хакимиятен танудан баш тартып, Алтын Урдага буйсынмау сәясәте үткәрә башлый. Моңа җавап итеп, М. Рязань (1373, 1378), Түбән Новгород (1378) кенәзлекләренә һөҗүм итә. Әмма Мәскәүне буйсындыра алмый, Болгарда (1376), Вожа елгасы буенда (1378) җиңелүләргә дучар була. Йогынтысын ныгыту максатында 1380 дә Мәскәүгә зур яу оештыра, тарихка *Куликово кыры сугышы* дип кергән бәрелештә җиңелә. Гаскәренең исән калган өлеше б-н Дон тамагына кача. *Туктамыш хан* гаскәре аны Калка елгасы буенда куып җитә. М. гаскәре Туктамыш хан ягына чыга. М. үзе, сыену эзләп, Кафа шәһәренә юнәлә, Туктамыш б-н низагка керергә теләмәгән генуялылар тарафыннан шунда үтерелә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Прохоров Г.М. Повесть о Митяе. М., 1978; Куликовская битва. М., 1980; Сказания и повести о Куликовской битве. М., 1982; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Назаров В.Д. Свержение ордынского ига на Руси. М., 1983; Клосс Б.М. Избранные труды. М., 1998. Т. 1; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2000; Григорьев А.П. Сборник ханских ярлыков русским митрополитам. СПб., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МАМА́КОВ** Георгий Фёдорович (2.12.1926, Лаеш кантоны Керәшен Казысы а. — 3.2.2007, Казан), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, галим агроном, икътисад фән. канд. (1970), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1987). Казанда авиация техникумын (1944), Югары партия мәктәбен (1958), а.х. ин-тын (1967) тәмамлый. 1941–43 елларда Балык Бистәсе р-нының «Гигант» к-зында хисапчы булып эшли. 1947–54 тә Корноухово р-нында: «Гигант» к-зы рәисе (1947–49), ВЛКСМ район ком-тының 2 нче, 1 нче секретаре (1949–53),

КПСС район ком-ты инструкторы (1954 тән). 1958–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында партия органнары бүлеге инструкторы. 1959–65 тә КПССның Буа район ком-ты 1 нче секретаре. 1965–67 дә ТАССРның а.х. министры. 1967 дә Казан вет. ин-тында, 1967–94 тә Казан а.х. ин-ты проректоры. 1959–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, ике көмеш медале; РСФСР ЮС, ТАССР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МАМАЛА́Й** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* көньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 227 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да мәчет, тимерче алачыгы, ярма яргыч, 4 вак тәүкләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1069,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 447, 1897 дә — 842, 1908 дә — 950, 1920 дә — 859, 1926 да — 765, 1938 дә — 728, 1949 да — 494, 1970 тә — 409, 1979 да — 439, 1989 да — 288, 2002 дә — 223 кеше.

**МАМЕ́ДОВ** Вахит Абдулла оглы (1.7.1959, Әзәрбайҗан ССРның Закатала р-ны Лагич а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1999), проф. (2007). 1981 елда Әзәрбайҗан ун-тын тәмамлаганнан соң, Әзәрбайҗан ССР ФА Физика ин-тының Биоэнергетиканың молекуляр нигезләре үзәгендә, 1982–83 тә Молекуляр биол. ин-тында, 1985 тә Нефть химиясе процесслары ин-тында эшли. 1985 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2001 дән), гетероциклик кушылмалар химиясе лаб-ясе мөдире (2002 дән). Хезмәтләре стереохимиягә, мезоүлчәнешле тотрыклы карбанионнарның электрофиль реагентлар б-н реакциясе механизмнарына, поликонденсат карбо- һәм гетероциклик системалар синтезына, табигый һәм дару препаратларын хемоэнзиматик синтезлауга карый. М. гетероцикллаштыру һәм гетеромакроцикллаштыру закончалыкларын төрле типтагы модельле азотлы, күкертле һәм кислородлы гетероциклик системалар катнашында тикшерә; тәэсир итү мөмкинлекләре зур булган биологик актив матдәләр сыйфатында кулланулырга яраклы гетероциклик системаларны фармакоформ фрагментлар һәм төрле рәвешле азоло[*a*]хиноксалиннар катнашында синтезлау алымнарын эшли; табигый алкалоидлар синтезына юл ачучы югары функциональ стереоизомер индианнар, тетралиннар, бензоциклогептаннар таба.

Хезм.: 1-Имино-3-арил-4-оксо-4,5-дигидротиазоло [3,4-a] хиноксалины. Ретросинтетический подход // Химия гетероциклических соединений. 1999. № 12 (автордаш); Неожиданное сужение цикла в реакциях 3-бензоилхиноксалинов с 1,2-фенилендиаминами. Хиноксалино-бензимидазольная перегруппировка // Изв. РАН. Сер. хим. 2004. № 1 (автордаш); Nucleophilic addition reaction of aromatic compounds with α-chloroglycidates in the presence of Lewisb acid // Tetrahedron. 2000. V.59 (автордаш).

**МА́МИН** Мөхәммәтша Гомәр улы (1905, хәзер Мордва Респ-касының Зубово-Полян р-ны Горенка а. — август, 1943), әдәбият галиме. Пензада укытучылар курсларын тәмамлый (1921). 1924–30 елларда авыл мәктәбендә эшли. 1933 тә Шәрекъ пед. ин-тын тәмамлый, 1936 дан шунда укыта. Мәкаләләрен, рецензияләрен студент елларында ук бастыра башлый. Һ.Такташның тормышын һәм иҗатын өйрәнә («Такташ поэзиясе», 1941). Бөек Ватан сугышында катнаша. Воронеж тирәсендәге Воробьёвка авылы янында һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

**МА́МИННАР**, татар бәкләре нәселе. Нәселне нигезләүче — Янбулат морза Мамин (17 йөзнең 1 нче яртысы). 1634–35 еллар грамотасында кенәз Мамин — Уразай Кормәмәтов исеменә Кадом өязе Мокша аръягы станының Екшеево (Чёрный Починок) авылындагы биләмә теркәлгән. Казанның 1648–51 еллар писцовый кенәгәләреннән күренгәнчә, М. нәселе вәкилләре Богдан, Ишәй, Алмакай морза Янбулатовларга аталарының Екшеево авылындагы биләмәсе күчә. Морза Богдан Маминның вафатыннан соң 1685 тә анның Кадом өязендәге Екшеево һәм Чермных авылларындагы, Керенский өязендәге Лундан авылындагы биләмәләре уллары Ибраһим, Кормаш, Сөенбай, Исәк, оныклары Давыт һәм Мәрдәш Дусаев, Илмай Сүнчәләевләргә бүлеп бирелә. 1713 тә кенәз Мамин улы морза Семён Аюкаевның Сембер өязендәге Зөябаш (Тимошкино) авылында бер крепостной крәстиян утары була. 18 йөз ахырында морза М. Бузат (хәзер Башкортстан Респ-касының Эстәрлебаш р-нында), Абзан (хәзер Башкортстан Респ-касының Благовар р-нында) һәм Богырыслан өязенең Давыт (Давыткино) авылларына урнашалар. Давыт авылында яшәгән Мамин улы Кодрәк Ишәевкә хезмәтләре өчен 1694 тә 564 чирек җир һәм 33 сум акчалата бүләк бирелгән. Давытта яшәгән морза М.ның дворянлык дәрәҗәсе 1796 ның 1 декабрь, Бузатта яшәгәннәренеке 1797 нең 19 ноябрь фәрманнары б-н раслана. Саратов һәм Пенза губерналарындагы морза М. ш.у. дворян дәрәҗәсе алганнар. Сенатның 1840 ел 17 октябрь, 1855 ел 2 август, 1861 ел 28 ноябрь һәм 1862 ел 29 май күрсәтмәләре буенча, бу нәсел вәкилләре дворян дәрәҗәсендә үзләрен татар кенәзләре дип атау хокукы б-н расланалар. М.ның Абзан авылында яшәгән тармагы дәүләт крәстияннәре катлавында кала. Карамалы авылының 1 нче җамигъ мәчете имам-хатибы һәм мөдәррисе, М. нәселеннән булган Әхсән Хәмзин 1884 тә ахун дәрәҗәсе ала. 19 йөздә М. Керенский өязенең Кочетовка һәм Никольское, Саратов губернасы Хвалын өязенең Иске Мастек, Сембер губернасы Сызрань өязенең Әхмәтле авылларында да яшиләр.

*Әд.:* Списки дворянских родов, внесённых в родословную книгу Пензенской губернии. Пенза, 1908; Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МА́МИНОВ** Олег Владимирович (12.1.1925, Петрозаводск ш.), химия технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1971), проф. (1972), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989). 1950 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан. технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, химия технологиясе процесслары һәм аппаратлары каф. мөдире (1966–83). Хезмәтләре ике фазалы агымнарда гидродинамикага, җылылык һәм масса алмашуга, химик кинетикага карый. М. тарафыннан химия һәм нефть-газ сәнәгате өчен реакторлар, аппаратлар һәм җайланмалар буенча теоретик тикшеренүләр үткәрелә, аларның матем. модельләре, исәпләү методикалары эшләнә, конструкцияләре төзелә. Үзәктән куулы инжекцион катнаштыргыч эшләгәне өчен 43 нче Бөтендөнья уйлап табулар, фәнни-тикшеренү һәм сәнәгый яңалыклар күргәзмәсе дипломына һәм бронза медаленә лаек була (Брюссель, 1994). М. хезмәтләре ТР һәм РФнең нефть-газ чыгару тармагында, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 76 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Югары уку йортлары чыгарган «Массообменные процессы и аппараты химической технологии» җыентыгының җаваплы редакторы (1981–2004). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Гидродинамика и массообмен в пенном слое // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1991. Т. 34, № 9 (автордаш); Моделирование технологических процессов в полимерных гетерогенных системах // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1999. Т. 42, № 3 (автордаш); Центробежные аппараты смешения для получения эмульсий, микроэмульсий и растворов // Хим. и нефтегазовое машиностроение. 1999. № 6 (автордаш).

**МА́МИШЕВ** Якуб (19 йөз ахыры, Казан губ., Казан өязе Орнашбаш а. дип фаразлана — 20 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. 1917 дән Казанда Мөселман социалистлар ком-тында, приказчиклар бюросында эшли. «Минем дә бар язганнарым» (1910) җыентыгы авторы. М.нең «әл-Ислах», «Кызыл байрак», «Кызыл Армия» г-таларында басылган шигырьләре «Татарча уку» җыентыгына (1915) керә. М. иҗатына лиризм хас, шагыйрь вазгыять, тормыш мәгънәсе турында уйлана.

*Әд.:* Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

**МАМЛИ́ЕВА** Светлана Әхмәт кызы (7.12.1947, Казакъстан ССР, Алма-Ата), архитектор-реставрацияләүче. Казан төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Татгипросельхозстрой» ин-тында эшли. 1974 елдан Татарстан «Росреставрация» бер-

ләшмәсе архитекторы. 1988 дән «Мастер» архит-ра-төзелеш ширкәтен оештыра. 1989 дан «Гелиос» иҗат-җитештерү үзәгендә реставрация бүлеген җитәкли. 1995 тә шәхси остаханәсен («С.Ә.Козлованың шәхси иҗади остаханәсе») оештыра. 1997 дән Казан Архит-ра һәм шәһәр төзелеше баш идарәсе каршындагы тарихи һәм мәдәни истәлекләрне реставрацияләү сыйфатын тикшерүче Госархконтроль ком-тында бүлек башлыгы һәм әйдәп баручы белгеч. 2002–03 тә «Мамлиева остаханәсе» ҖЧҖ директоры. 2003 тән «Татинвестгражданпроект» реставрация фирмасы директоры урынбасары. М. — ТР тарихи-мәдәни истәлекләрен фәнни консервацияләү һәм реставрацияләү өлкәсендә танылган белгеч. Татарстан терр-ясендә аның тарафыннан 10 нан артык дини, җәмәгать һәм торак биналарын, ш.и. Казанда Богоявление чиркәвенең чаң манарасын (1974), Дәүләт банкын (1974), сәүдәгәр Чернояров йортын (1985), Лютераннар чиркәвен (1996), Богоявление чиркәвен (1998), ТР Мөселманнар Диния нәзарәтен (1999), Чистай шәһәрендә — Никола соборын (1982), Питрәч р-нында Богородица чиркәвен (1984–86) реставрацияләү проектлары эшләнә.

*Л.М.Мортазина.*

**МАМЛИ́ЕВЛАР**, татар бәкләре нәселе. Нәселне нигезләүче — Чекаш морза. 17 йөздә Чекаш морзаның биләмәсе Темников өязенең Ефаево авылында була. Соңрак морза М. Кадом өязенең Ирсит һәм Торопово авылларында да җир билиләр. 1713 елда М.дан Битәй Гомәров һәм Ислан Үтәкәев иске Княжево һәм Аюкай (Аюкаево) авылларында 3 крәстиян хуҗалыгы тота. 18 йөздә М. нәселләре б-н Пенза губернасы, Краснослободский өязе Тархан (Енаково) авылында яшиләр. Петр I Фәрманы б-н М. дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. 18 йөз ахырында нәселнең бер өлеше Оренбург губернасына: Бүздәк, Ышланкүл, Каргалы (хәзер Башкортстан Респ-касының Благовар р-нында), Бакай, Мәүлет (хәзер Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-нында), Яңа Мортаза (хәзер Башкортстан Респ-касының Чакмагыш р-нында) авылларына күченә. Сенатның 1797 ел 19 ноябрь фәрманы б-н М. нәселенең Уфа тармагының дворян дәрәҗәсе раслана. Пенза дворяннар җыенының 1793 һәм 1836 елгы карарлары буенча, М. Пенза губернасы дворяннар шәҗәрәсе китабының 5 нче кисәгенә кертеләләр. Пенза губернасының Краснослободский өязендә яшәгән морза М. (Ханбәк Нәдершин, Әбүбәкер Абдуллин, Рамазан Сәетов) Пенза губернасы дворяннар шәҗәрәсе китабының 2 нче, 5 нче һәм 6 нчы кисәгенә кертелә.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Списки дворянских родов, внесённых в родословную книгу Пензенской губернии. Пенза, 1908; Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3; Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МАМО́НИНО**, к. *Аяз иле*.

**МАМЫ́К** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1381 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 64%, чуашлар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды, урманчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Никола чиркәве. А.А.Шульцның утар-йорты — 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Успенский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Успение чиркәве, земство мәктәбе, 2 ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете була; сишәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 417 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мукшы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман р-ны үзәге, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 204 ир-ат; 1859 да — 994, 1897 дә — 1464, 1908 дә — 1618, 1920 дә — 1935, 1926 да — 1429, 1938 дә — 1894, 1949 да — 1936, 1958 дә — 1304, 1970 тә — 1637, 1879 да — 1319, 1989 да — 1180, 2002 дә — 1427 кеше.

**МАМЫ́К** (? — 1498/99), Себер ханзадәсе, Казан ханы (1495–96). *Ибакъ* ханның энесе. Ибакъ үтерелгәннән соң, Төмән ханлыгыннан куыла. Төмән олысы сугышчылары һәм нугайлар гаскәре, ш.у. Колмөхәммәд җитәкчелегендәге Казан карачыбәкләре ярдәмендә Мөхәммәдәминне куып, Казан тәхетенә утыра. Нугайларга таянып, карачыбәкләрнең ирeген чикләмәкче була. Хәрби фетнә нәтиҗәсендә казанлылар тарафыннан куыла. 1498 елда бертуганы Агалак б-н Казанга яу оештыра. Үзара көрәш-бәрелешләр вакытында һәлак була.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Казан ханнары. К., 1995; Сибирские летописи. СПб., 1907; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; А л и ш е в С.Х. Казань и Москва: Межгосударственные отношения XV–XVI вв. К., 1995; И с х а к о в Д.М., И з м а й л о в И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**МАМЫ́К БЕТЛӘРЕ́** (Mallophage), бөҗәкләр отряды. Озынлыгы 1–11 *мм*, куе төкләр б-н капланган. Канатсызлар. Авыз аппараты кимерүгә җайлашкан. Мыекчалары кыска, тыныч халәттә башының аерым чокырчыкларына яшеренгән. Кайбер М.б.нең күзләре үсеш алмаган, аяклары йөгерүгә җайлашкан. 2,5 меңгә якын төре билгеле, РФдә — 400 гә якын, нигездә, кошлар паразиты, ш.у. имезүчеләрдә дә (йон ашаучылар) очрыйлар. Татарстан терр-ясендә М.б.нең кошларда паразитлык итүче 300 гә якын төре билгеле, эпидермик, каурый һәм йон кисәкләре, кан, тире бүлендекләре б-н туеналар. Тулы булмаган әверелешле үсеш узалар. Күкәйләрен каурыйга яки йонга салалар; үсешләре 3–4 атна дәвам итә. Күпчелек очракта М.б. аерым бер хайван төренә яки охшаш төрләр төркеменә катгый туры килә: тавык М.б. (Menopon gallinae), күгәрчен М.б. (Columbicola columbae), эт йон ашаучысы (Trichodectes canis) һ.б. Күпләп паразитлык итеп хайваннарда көчле кычыту барлыкка китерәләр, нәтиҗәдә, даими тынычсызлыктан алар ябыга.

**МАМЫ́К ҮЛӘ́Н**, к а р л ы г а ч к о й р ы г ы (Asclepias), мамыкбашчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр яки ярымкуаклар ыругы. 200 дән артык төре билгеле, күбесенчә Евразия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР да 2 төре бар. Дарулы М.ү. (A. officinale) — барлык районнарда да, дала М.ү. (A. step-posum) күбесенчә Кама аръягында очрый. Ылыслы урманнарда, куаклар арасында, елга һәм күл ярларында, далаланган тау битләрендә үсә. 30–120 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Сабагы туры, өске өлешендә тармаклы. Яфраклары гади, йомыркасыман, очлы. Чәчәкләре вак, ике җенесле, саргылт-ак төстә, куентылы чатыр яки чук чәчәк төркемендә урнашкан. Җимеше — кубоколыклы ике табакча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Тамырча һәм орлыкларында гликозидлар, органик к-талар бар. Халык медицинасында тамырча һәм орлыкларыннан ясалган төнәтмә диабет, йөрәк һәм бөер авыруларыннан кулланыла. Агулы, баллы үсемлекләр.

**МАМЫКБА́Ш** (Eriophorum), күрәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача поясларында таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар: киң яфраклы М. (E. latifolium), нечкә М. (E. gracile), күп башаклы М. (E. polystachion), җиңсәле М. (E. vaginatum). Сазлыкларда һәм йөзмә «үлән-утрауларда» үсә. 15–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, нечкә. Яфраклары тар, озын, өч кырлы яки цилиндрсыман. Чәчәкләре ике җенесле, күп чәчәкле башакчыкларда, чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеш бирү чорында барлыкка килүче мамык кебек йомшак ак башчалар — М.га хас үзенчәлек. Җимеше — озынча орлыкча. Җиңсәле М.ның яфраклары яшел килеш кышлый. Апрельдән майга кадәр чәчәк ата. Җимешләре җәй башында өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамырчалардан) б-н үрчи. Киң яфраклы М. — дару үләне. Сабаклары су кошлары өчен азык булып тора. Барлык төрләре дә — торф барлыкка китерүчеләр. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

**МАМЫ́ЛОВКА** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 206,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красногорск волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабу-



П.З. Манаков.

га, 1935 нең 10 февраленнән — Мамадыш, 1958 нең 19 июленнән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 34, 1897 дә — 89, 1908 дә — 126, 1920 дә — 121, 1926 да — 120, 1938 дә — 126, 1949 да — 170, 1958 дә — 89, 1970 тә — 51, 1979 да — 20, 1989 да — 11, 2002 дә — 9 кеше.

**МАМЫ́Ш** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 17 *км* төньяктарак, Шашы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 64 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Шашы исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл (Яңа Шашы авылын да кертеп) җәмәгатенең имана җире 1199 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 6 ир-ат; 1859 да — 72, 1897 дә — 268, 1908 дә — 260, 1920 дә — 298, 1926 да — 327, 1938 дә — 235, 1949 да — 166, 1958 дә — 123, 1970 тә — 127, 1979 да — 98, 1989 да — 73, 2002 дә — 73 кеше.

**МАМЫШБИРДЕ́** (Мәмешбирде) (? — ?), марилар йөзбашы, бәк, *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56)* вакытында бәйсезлек хәрәкәтен оештыручыларның берсе. *Болын ягында* көрәш башлаган М. турындагы беренче мәгълүматлар 1554 елга карый. Рус елъязмаларында М. кул астындагы баш күтәрүчеләрнең Иделдәге судноларга һөҗүмнәре турында әйтелә. 1555 тә М. Олы Нугай Урдасы идарәчесе Йосыф бәк улын, рус елъязмаларына «патша улы Ахполбей» дип кергән *Гали Әкрамны* аркадашы итеп, хан тәхетенә чакыра. Соңрак Ахполбейның рус гаскәрләренә каршы көрәшү урынына гади халыкны талау б-н шөгыльләнүен күреп, аны юк итә. 1556 ның мартында баш күтәрүчеләрнең М. җитәкчелегендәге 2 мең кешелек төркеме җирле халыкны яуга күтәрү максатыннан *Тау ягына* чыга. Чуашлар йөзбашы, рус хакимиятенә карата күндәм Алтыш, М.не мәҗлескә дәшә. Мәҗлес вакытында марилар йөзбашының 200 көрәштәше үтерелә, аның үзен тотып Мәскәүгә озаталар. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Б а х т и н А.Г. XV – XVI века в истории Марийского края. Йошкар-Ола, 1998; А л и ш е в С.Х. Тернистый путь борьбы за свободу (Социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. II половина XVI – XIX вв.). К., 1999.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МА́МЫШЕВ** Хәмзә (1768 яки 1770 — 1840 тан да иртәрәк түгел), хәреф басучы, яшерен советник. 1789 елда хәрби хезмәткә алына, 7 нче Кронштадт батальонында хезмәт итә. 1788–91 дә рус-швед сугышында катнаша, медаль б-н бүләкләнә. 1791 дән И.К.Шнорның Петербург басмаханәсендә хәреф җыючы, 1800 дән — Казан гимназиясенә тапшырылган Азия басмаханәсендә, 1829 дан Казан ун-ты басмаханәсендә корректор. 1805–11 дә *Казан әсасый халык училищесендә* татар теле укытучысы. 1831 дән отставкада.

*Әд.:* О высочайше пожалованных пенсиях Мамышеву и Маркову // Казан. вестн. 1832. Ч. 34, кн. 3; Указатель города Казани, или памятная книжка для жителей Казанской губернии на 1841 год. К., 1840; К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги: От начала возникновения до 60-х гг. XIX в. К., 1992.

**МАНА́КОВ** Пётр Захарович (29.5.1915, Самара губ., Бөгелмә өязе Павловка а. — 8.11.1987, Ленинград), Сов. Союзы Герое (28.4.1943), капитан. Казан танк уч-щесен тәмамлый (1944). Сугышка кадәр Вахитов исем. с-зда: Бөгелмә МТСы тракторчысы, механик, бригадир булып эшли. 1937–40 елларда һәм 1941 нең ноябреннән Кызыл Армия сафларында. Совет гаскәрләренең Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия походында катнаша (1939). 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 392 нче батальонның «КВ» танкы өлкән механик-йөртүчесе (38 нче армиянең 180 нче танк бригадасы). Воронеж фронты гаскәрләре составында Курск сугышында (1943) катнаша. 1943 нең 1 февралендә Касторный авылы (Курск өлкәсе) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: М. танкы экипажы разведка вакытында дошманның танк колоннасын тар-мар итә; сафтан чыккан машинасында сугышуын дәвам итә, яралана. 1948 дән запаста. Ленинград заводында механик булып эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәрендә М.ка бюст куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1993.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАНАРА́** (гарәп. منارة), мөселманнарны намазга чакырып *азан* әйтү өчен хезмәт итүче махсус биек корылма (мәчет М.сы түгәрәк, квадрат формасында яки күпкырлы булырга мөмкин). Алтын Урда чорына кадәрге Идел буе Болгар дәүләте шәһәрләрендәге зур мәчетләрдә М. төньяк фасад каршында — ишек янында була. Яруслы композицияле М.ның куб рәвешендәге нигезе тромплар аша азан әйтергә менү өчен әчтәге борылмалы баскычлы цилиндрга тоташа. Төп ярус өстендә цилиндр рәвешендәге кечерәк диаметрлы, азанчы өчен түгәрәк мөәзәнә — балконлы югары ярус урнаша. Түбә, гадәттә, конус рәвешендә була. Казан ханлыгы чорындагы М.лар юкка чыгарыла. Болгар шәһәрлегендә Алтын Урда заманында төзелгән *Кече манара* сакланып калган. Касыйм шәһәрендә 16 йөз башында корылган таш М.лы *Касыйм хан мәчете* бар. Татар мәчетләрендә М. түбә уртасында, почмакларда яки бинадан аерым, ишек өстенә дә урнаштырыла. Эчендә яктылык тәрәзәсенә яки балконга алып менүче баскычлы М. үзенең формасы б-н түгәрәк, квадрат рәвешендә яки күпкырлы була. М. конус, чатыр, гөмбәз б-н тәгәлләнә һәм очына ай куела.

*Н.Г.Надыйрова.*

**МАНАССЕ́ЙН** Вячеслав Авксентьевич (3.3.1841, Казан губ., Лаеш өязе Девлезери а. — 13.2.1901, С.-Петербург), терапевт, медицина д-ры (1869), җәмәгать эшлеклесе. С.-Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (1866), шунда ук, гомуми патология, гомуми терапия һәм диагностика кафедрасында, 1876–92 елларда клиник патология һәм эчке авырулар терапиясе каф. мөдире, проф.; бер үк вакытта (1872–79) С.П.Боткин клиникасында эшли. Хәрби мед. академиясендә (С.-Петербург) китапханәче вазифасын башкара, китап саклау эшен башлап җибәрүгә зур өлеш кертә. 1880–1901 дә чыккан атналык «Врач» г-тасына нигез сала һәм аңа мөхәррирлек итә. М. ярдәмгә мохтаҗ табибләр өчен махсус фонд оештыра. Хезмәтләре ач тору вакытында тән тукымаларында бара торган катлаулы матдәләр алмашын өйрәнүгә, туберкулёзны башлангыч чорында ачыклауга карый. М. С.-Петербургта эчәргә яраклы дип табылган суларның күп авырулар китереп чыгаручы фактор булуын тикшереп исбатлый. «Бактерияләрнең яшел кистовикка йогынтысы турында» («Об отношении бактерий к зелёному кистовику», 1871) хезмәтендә М. беренче булып, пенициллин табылудан күпкә элгәрерәк, Penicillium glaucum күгәрек гөмбәсенең бактерияләргә каршы көрәшү сыйфатларын ачыклый.

Х е з м.: Материалы для вопроса о голодании: Дис. ... СПб., 1869.

*Әд.:* Ж б а н к о в а Д. Памяти Вячеслава Авксентьевича Манассейна // Врачебное дело. 1926. № 1; Ч и с т о в и ч Н.Я. Из воспоминаний о Вячеславе Авксентьевиче Манассейне // Казан. мед. журн. 1926. № 2; А р с е н ь е в Г.И. В.А.Манассейн: Жизнь и деятельность. 1841–1901. М., 1951.

**МАНА́ТОВ** Шәриф Әхмәт улы (20.10.1887, башка мәгълүматлар буенча 1892, Оренбург губ., Чиләбе өязе (хәзер Курган өлкәсе Әлмән р-ны) Манат а. — 1936, Чиләбе өлкәсе Смородиновка а., хәзерге БРның Учалы р-ны Көчек авылында җирләнә), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист. Петербург психоневрология ин-тында укый (шунда М.М.Вахитов б-н дуслаша); 1914 елдан Истанбулда. Цюрих шәһәрендә (Швейцария) В.И.Ленин б-н очраша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, Оренбургка кайта, РСДРП әгъзасы (меньшевик-интернационалист), 1918 нең маеннан — РКП(б) әгъзасы. Башкорт Милли Шурасын оештыручыларның берсе һәм җитәк-

чесе (1917–18). Оренбург губернасының башкорт федералистлары исемлеге буенча Учредительләр җыенында әгъза булып катнаша. Башкорт Милли Шурасы вәкиле буларак, ХКС б-н Башкортстан автономиясе турында сөйләшүләр алып бара, 1918 нең гыйнварында Ленин б-н очраша. 1918 дән Башкортстан хөкүмәте әгъзасы. Совет хакимияте б-н хезмәттәшлек иткәне өчен Милли Шура җитәкчелегеннән читләштерелә. М.Вахитов һәм Г.Ибраһимов б-н бергә РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршында Эчке Россия Үзәк мөселман комис-тын оештыруда катнаша; комис-т рәисе урынбасары һәм мәгариф бүлеге җитәкчесе (1918–19). И.В.Сталин һәм башкалар б-н бергә «Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы турында нигезләмә»гә кул куя. «Чулпан» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1919 да коммунистлар партиясе оештыруга булышлык итү өчен Төркиягә җибәрелә. 1920 нең октябреннән РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының Башкортстан АССР дагы тулы вәкаләтле вәкиле, Фрунзеда дәүләт, партия эшләрендә, пед. эшчәнлектә. 1935 тә ВКП(б)дан чыгарыла, эшеннән алына. Үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Насыйров Р. От имени башкир // Возвращённые имена. Уфа, 1991; Политические деятели России 1917: Биогр. словарь М., 1993.

**МА́НГУШЕВ** Габдрахман Габделкәрим улы (1887, Оренбург ш. — 1919), драма актёры. Сәхнә эшчәнлеген 1910 елда «Сәйяр» труппасында башлый, 1915 тән «Ширкәт» труппасында, Гражданнар сугышы елларында фронт театр труппаларында. Бәдри («Галиябану», М.Фәйзи), Юныс хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Рәхимҗан («Яшьләр», Ф.Әмирхан) рольләрен башкаручы буларак билгеле. «Мөхәррир» (1914), «Бәхет эзләүчеләр» (1918) һ.б. пьесалар авторы. 1918–19 елларда «Кызыл Армия» г-тасының җаваплы сәркәтибе.

**МАНГЫ́Т**, 1) Үзәк Азиядән чыккан, соңрак «нугай» дигән үзатама алган төрки кабилә. 14 йөз ахырында Алтын Урда әмире *Идегәй* Җаек һәм Җембе елгалары арасында ярыммөстәкыйль *Мангыт йорты* олысына нигез сала. 1430–50 елларда Мангыт йорты Әбелхәер ханның кучмә дәүләтенә керә. Бу дәүләт таркалганнан соң, М. кабиләсе аерым дәүләт булып оеша. 15 йөзнең 2 нче яртысында М. бәкләренә һәм морзаларына буйсынган кабиләләрнең күпчелеге «нугай» дигән гомуми атама б-н атала башлый. Мангыт йорты *Нугай Урдасы* булып таныла. 2) 14–17 йөзләрдә Олы һәм Кече Нугай Урдаларында, Казан, Кырым һәм Әстерхан ханлыкларында идарә иткән ыругларның берсе. М. ыругы татар ханлыклары сәясәтендә әһәмиятле урын биләгән. Аның йогынтысы арту Нугай Урдасы көчәю б-н бәйле була. Мәс., Кырым ханлыгында М. ыругы Барын ыругын тәхеттән читләштерә, шуннан соң ханлыктагы дүрт карачыбәкнең берсе урынын М. ыругы башы били. 3) Бохара әмирләре нәселе (1753–1920). Тәхеткә Бохарада Аштарханилар нәселен бәреп төшереп утыралар. М.лар ана ягыннан Чыңгыз хан нәселе санала: нәселне нигезләүче Аштарханилар ыругы ханының кызына өйләнгән була.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Т. 2; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998; шул ук. Тюрко-татарские государства XV–XVI вв. К., 2004; Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; Manz B.F. The clans of Crimean khanate, 1466–1532 // Harvard Ukranian studies. 1978. Vol.2; Inalcik H. The khan and tribal aristocracy: The Crimean khanate under Sahib Giray I // Harvard Ukranian studies. 1980. Vol. 3–4.

*И.Л.Измайлов.*

**МАНГЫ́Т ЙОРТЫ́**, к. *Нугай Урдасы.*

**МАНДОЛИ́НА** (итал. mandolino), чыгышы б-н Италиядән, плектор б-н чиртеп уйный торган кыллы музыка уен коралы. Башлангычы лютня (кыллы чиртмә) уен коралыннан килә. Тулысынча М. 17 йөздә формалаша, дүрт кыллы уен коралы буларак e, a, b, g квинталарына көйләнә. М.ның урталай киселгән груша рәвешендәге агач корпусы аерым нәзек буынтыклардан (сегментлардан) ябыштырылган. Тавыш көчәйтү хезмәтен үти торган аскы һәм өске тактасы (яссы өслеге) нараттан эшләнә. Түгәрәк яки озынча түгәрәк «розетка»сы яисә «голоснигы» бар. М.ның «кузовы» гриф һәм тешсыман металл боргычлары булган яссы башлы муентык б-н тоташтырыла. Уен коралының гомуми озынлыгы якынча 635 *мм.* Грифта кара агачтан яисә эбен агачыннан эшләнгән яссы пластинка була, анда ладлар урнаша. Уйнарга уңайлы булсын өчен ладлар кайбер уен коралларында перламутр бөҗралы юка металл бусагалар б-н бүлгәләнә. Аларның саны тигезсез: гадәттә, бер яки беренче ике кыл өчен күбрәк һәм алдагы икесе яки өчесе өчен азрак (түбән кыллар өчен 19, югарылары өчен 28 яки 30). Авазлар кылларны чирткеч ярдәмендә калтыратып чыгарыла. Соло (ялгыз) башкару, ансамбль һәм оркестр уен коралы буларак кулланыла. 19 йөздә көчле, ачык тавышлы яссы, озынча түгәрәк формадагы башка төрле М.лар барлыкка килә. Татарлар арасында М. 19 йөзнең соңгы чирегендә, башта һәвәскәрләр уен коралы буларак, соңыннан концертларда башкару өчен киң таралыш ала. 20 йөз башында беренче милли уен кораллары ансамбльләре составына керә. Хәзерге вакытта да М. татарларда популярлыгын югалтмый һәм гармун б-н соло, ш.у. башкаручыга кушылып уйнау өчен кулланыла, төрле традицион татар музыка уен кораллары б-н ансамбльдә киң файдаланыла.



Мандолина (М.Җәлилнең шәхси әйберләреннән). ТР Милли музее.

*Р.Ф.Халитов.*


**МАНЕ́НКОВ** Павел Васильевич (20.6.1897, Могилёв губ., Горецкий өязе Маслаки а. — 27.1.1974, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1964). В.С.*Груздев* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1921), шунда ук, оператив хирургия кафедрасында эшли, 1926 елдан — акушерлык һәм гинекология кафедрасында. 1932 дән Казан мед. ин-тының акушерлык һәм гинекология каф. һәм клиникасы мөдире, 1963 тән проф.-киңәшче. Хезмәтләре хатын-кызларны балага уза алмаудан дәвалау, гинекология хирургиясе, акушерлык-гинекология практикасында аерым урынны анестезияләүгә карый. Ялкынсыну продуктлары һәм шеш күзәнәкләре тукымаларга үтеп кергән очракта (инфильтрация) аерым урынны анестезияләү өчен махсус шприц уйлап таба. 1946 дан Бөтенроссия акушер-гинекологлар җәмгыятенең Казан ф-лы рәисе. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К вопросу о заживлении операционных ран под местной, послойной, инфильтрационной анестезией // Вестн. хирургии. 1928. Т. 14, кн. 40; Paroophoron, его топография и судьба в различные возрасты внутри- и внеутробной жизни женщины // Уч. зап. Казан. ун-та. 1928. Т. 88, кн. 3; К вопросу о радикальном лечении фибромиом матки // Казан. мед. журн. 1936. № 5; Итоги клинического опыта. К., 1968.

*Әд.:* П.В.Маненков (к 70-летию со дня рождения) // Акушерство и гинекология. 1967. № 11.

**МАНЗАРА́С** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы буенда. 2010 елда 864 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Катнаш мал азыгы з-ды. Мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 856 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 264, 1897 дә — 490, 1908 дә — 517, 1920 дә — 516, 1926 да — 484, 1938 дә — 517, 1949 да — 380, 1958 дә — 438, 1970 тә — 464, 1979 да — 471, 1989 да — 478, 2002 дә — 802 кеше.

**МАННА́НОВ** Илдар Маннан улы (10.3.1921, Минзәлә кантоны Бүләк а. — 18.5.2010, Чаллы ш.) Сов. Союзы Герое (17.12.1941), өлкән сержант. Совет сәүдәсе техникумын тәмамлый (Кострома ш., 1959). Мөслим р-ны-



И.М. Маннанов.



Ш.Ф. Маннанов.

ның Яңа Сәфәр авылы МТСында өлкән комбайнчы булып эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 127 нче артиллерия полкында 2 нче батарея расчёты туп коручысы (4 нче аерым армиянең 65 нче укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, Карелия һәм Ленинград фронтлары гаскәрләре составында Тихвин оборона һәм һөҗүм операцияләрендә (1941), Волхов елгасы буендагы сугышта оборона сызыгын саклауда катнаша (1943). 1941 нең ноябрендә Тихвин шәһәре (Ленинград өлкәсе) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: яралана, әмма сугышуын дәвам итә; дошманның берничә танкын сафтан чыгара. 1945–57 дә Калинин (хәзер Актаныш) р-ны кулланучылар берлегендә сәүдә мөдире, 1959–63 тә Ворошилов (хәзер Сарман) р-ны кулланучылар берлеге рәисе булып эшли. 1963 тән Чаллы шәһәрендә яши. 1963–70 тә шәһәр план ком-ты рәисе, 1970–81 дә ТАССР МС Тәэминат һәм сату идарәсенең районара сәүдә базасы директоры. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. М. — Тихвин шәһәре (1961), ТРның Мөслим р-ны һәм Чаллы шәһәренең (2005) мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Буров А.В. Твои Герои, Ленинград. Л., 1970; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1993.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАННА́НОВ** Фәнис Нурмөхәммәт улы (2.11.1951, Азнакай р-ны Татар Шуганы а.), тау инженеры, ТРның атказ. нефтьчесе (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1979). 1973–76 елларда «Татнефтегеофизика» тресты промысел-геофизика конторасының газ-каротаж партиясендә эшли. 1976 елдан (бүленеп) «Татнефть» АҖдә: хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы бүлеге инженеры, «Актүбәнефть» НГДУының нефть һәм газ чыгару цехы мастеры (1980 гә кадәр), 1983–97 дә катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау Азнакай идарәсендә баш инженер урынбасары, баш инженер, бер үк вакытта (1992 дән) башлык урынбасары, 2001 дән — Әлмәт идарәсендә башлык. 1980–82 дә СССР Госгортехнадзорының Татарстан округы идарәсендә Лениногорск район тау техникасы инспекциясенең участок тау-техника инспекторы. 1982–83 тә Казакъстан ССР «Актүбәнефть» берләшмәсенең «Октябрьскнефть» НГДУында хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча баш инженер урынбасары. 1997–2001 дә «Катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау буенча Татнефть-Азнакай идарәсе» ҖЧҖдә баш инженер, бер үк вакытта директорның 1 нче урынбасары. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар. Дәүләт бүләге Татарстан нефть чыганакларындагы авыр чыгарыла торган нефть запаслары ятмаларының нефть бирүчәнлеген күтәрү технологияләре комплексын эшләгәне һәм сәнәгатьтә киң кулланугa керткәне өчен бирелә.

**МАННА́НОВ** Шакир Фатих улы (1.10.1917, БАССРның Ишембай р-ны Кыяуык а. — 23.4.1973, БАССРның Эстәрлетамак р-нында җирләнә), Дан орденының тулы кавалеры (6.12.1943, 5.9.1944, 22.2.1945), сержант. Туган авылында киномеханик булып эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1030 нчы укчы полкының 76 *мм* лы туп расчёты командиры (11 һәм 47 нче армияләрнең 260 нчы укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, Брянск, Белоруссия һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Демянск (1942–43), Орёл, Брянск (икесе дә — 1943), Люблин-Брест (1944), Варшава-Познань, Көнчыгыш Померания һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1945) катнаша. 1943 нең декабрь башында Белоруссия ССРның Гомель өлкәсендә Золотой Рог авылы өчен сугышта (дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда 2 пулемётын юк итә), 1944 нең июле башында Ковель шәһәре (Украина ССР Волынь өлкәсе) өчен (дошман дзотын җимерә һәм 2 пулемёт ноктасын юк итә); 1944 нең 21 сентябрендә Щамоцин (Польша) торак пункты өчен (2 пулемётны һәм дзотны юк итә, пехота һөҗүмендә катнаша) сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң демобилизацияләнә. Туган ягында элемтә үзәгендә эшли. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Не ради славы. М., 1969; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 4; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАННА́НОВА** Флора Фатих кызы (19.9.1946, Германия, Галле ш.), ортопед-стоматолог, мед. фән. д-ры (1997), Башкортстан Респ-касының атказ. табибе (1998). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), Уфа шәһәрендә стоматолог-ортопед булып эшли. 1979 елдан Казан мед. ун-тының ортопедик стоматология кафедрасында. 1981 дән Башкорт мед. ун-тында, 1984 тән ортопедик стоматология каф. мөдире. Хезмәтләре балалар һәм олыларда теш-казна аномалияләре һәм деформацияләрен ортопедик дәвалауга, авыруларны ортопедик реабилитацияләүгә карый.

Хезм.: Моделирование напряженного состояния опорных тканей зубов при нормальном и аномальном их положении // Стоматология. 2001. Т. 80, № 6 (автордаш); Лечение сужения верхней челюсти // Ортопедия. 2003. № 2 (автордаш); Ортопедическое лечение больных при полной потере зубов. Уфа, 2003.

**МАННА́ПОВ** Фәхри Садретдин улы (6.2.1897, Оренбург ш. — 9.2.1956, Казан), җырчы (баритон), драма артисты. 1927 елга кадәр Оренбург, Әстерхан, Урта Азия шәһәрләренең татар театрларында чыгышлар ясый. 1927–33 тә Татар акад. театрында эшли. Музыкаль драма репертуарындагы рольләрне аеруча уңышлы башкара. 1938 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый. 1938–48 дә Татар опера һәм балет театры солисты, 1948–56 да ТАССР Җыр һәм бию ансамбле солисты. Концерт программаларын оештыручы һәм сәнгать җитәкчесе булып эшли. Булат, Солдат («Качкын», «Ирек», Н.Җиһанов), Вафа («Башмагым», Ж.Фәйзи) һ.б. опера партияләрен һәм татар, башкорт халык көйләрен, татар композиторлары (С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, Ж.Фәйзи, З.Хәбибуллин, Ф.Яруллин һ.б.) җырларын башкара. Көчле, матур тавышка ия М.ның иҗади эшчәнлегенә драматик һәм вокаль сәләтнең табигый берләшүе хас. СССР шәһәрләрендә гастрольләрдә була.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МАННА́ПОВ** Шамил Мәгыйз улы (1.1.1938, Әлки р-ны Татар Мулла Иле а. — 6.10.2012, Казан), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1965), «Татарстан яшьләре», «Социалистик Татарстан» г-талары редакцияләрендә хәбәрче булып эшли (1977–86). 1986–89 елларда Татарстан китап нәшриятында, 1989 дан «Казан утлары» ж-лының проза бүлегендә мөхәррир. М. татар поэзиясенә 1960 еллар башында солдат хезмәтенә багышланган, студентлар тормышын, яшьләр проблемаларын күтәргән шигырь һәм поэмалары белән килеп керә. «Яшьтәшләрем» (1967), «Хәят көндәлеге» (1970), «Тамырлар» (1972), «Тугрылык алиһәсе» (1976), «Кайту» (1981; русчага тәрҗемәсе «Возвращение», М., 1982), «Апрель авазы» (1987), «Җиргә сыенам» (1990), «Өндәге төшләр» (1997) исемле шигъри җыентыклар һәм «Әти урманы» (1979), «Ачы какылар» (1992), «Мәңгелек елмаю» (2001) исемле хикәя җыентыклары авторы. М. үзенең лирик-публицистик яңгырашлы, оптимистик рухлы әсәрләрендә тормыш-яшәешне замандашларының уй-кичерешләре аша чагылдырырга тырыша. Матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре еш басыла. Җыр текстлары авторы.

Әсәр.: Тормыш сиратлары. К., 2008.

*Әд.:* Баянов Ә. Даһилык дәгъваламыйча гына // Казан утлары. 1997. № 12; Вәли М. Янган саен өмет яңара // Мирас. 1998. № 1.

*Г.М.Габделхакова.*

**МАННУ́Р** (Маннуров) Шәйхи (Шәйхелислам) Фәрхулла улы (15.1.1905, Казан губ., Мамадыш өязе Тулбай а. — 11.6.1980, Казан, туган авылында җирләнә), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1937). 1921 елдан Себердә: шахтёр, Андреевка руднигы каршында ачылган татар мәктәбендә укытучы. Свердловск шәһәрендә совет-партия мәктәбен тәмамлагач (1924), Тобол округы Тукыз авылында уку йорты мөдире, Тобол шәһәрендә



Ш. Маннур.

балалар йорты мөдире, округ комсомол ком-ты инструкторы. 1929 дан Донбасс металлургия з-дында прокатчы, Днепрогэс төзелешендә бетон салучы. 1932–33 елларда Мәскәүдә яши, «Эшче» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1937–38 дә «Совет әдәбияты» ж-лында җаваплы сәркәтип. Бөек Ватан сугышы елларында «Сугышчан чакыру», «Алга, дошман өстенә!», «Ватан бәхете өчен» кебек фронт г-талары хәбәрчесе. 1946–48 дә Татар опера һәм балет театрында әдәби бүлек мөдире. М.ның беренче шигырьләре 1923–24 тә Себердә, Уралда чыккан газета-журналларда басыла башлый. Язучы «Чуен ташкыннар» (1930) поэмасында беренче бишьеллык эшче-ударниклары образларын тудыра. Авыл хуҗалыгын күмәкләштерү темасы «Гайҗан бабай» (1934) һәм «Меңнән бер кичә» (1935) поэмаларында чагылыш таба. Татар әдипләре арасында Бөек Ватан сугышы темасын яктыртуда «Казан кызы» (1946) поэмасы күренекле урын алып тора. 1960–70 тә М., нигездә, проза жанрында гына иҗат итә. М.Җәлилгә багышлап «Муса» (1968; 2 нче басма 1975; русчага тәрҗемәсе М., 1983) романын бастыра. Үзенең, авылдашларының, балачак дусларының тормышыннан алып «Агымсуларга карап» (1974; русчага тәрҗемәсе «Глядя на текучие воды», 1991) автобиографик повестен яза. Балаларга багышланган шигырь һәм поэмалары тупланган «Нәниләргә, дәүләргә» (1965), «Кызларга һәм малайларга» (1984) җыентыклары бала психологиясенең нечкәлекләрен, аларның әйләнә-тирәдәге тормышны кабул итү үзенчәлекләрен аңлап иҗат итүе б-н аерылып тора. М. халыкчан тел бизәкләренә бай хикәяләү стиленә ия каләм остасы буларак танылa. Ул А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, Т.Г.Шевченко, Ш.Руставели, Җамбул әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1951; Күңел йомгагы: 2 китапта. К., 1968–71; Уткүз. К., 1986.

*Әд.:* З а к и р М. Туган як һәм әдип кадере // Казан утлары. 2005. № 1; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МАННУ́Р ШӘЙХИ́ МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕ́Й-КИТАПХАНӘСЕ́**, Мамадыш р-ны Тулбай авылында. 1995 елның 24 гыйнварында ТР Берләштерелгән дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2007 дән муниципаль музей. Экспозиция мәйданы — 83 *м*². Коллекциядә 4600 дән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Язучы, тәрҗемәче, фольклор туплаучы Ш.Маннур 1957 дә үз хисабына авылда китапханә төзетә, музей шуның нигезендә ачыла. Экспозициядә төп урынны язучының мемориаль әйберләре, кулъязмалары, китаплары һәм шәхси китапханәсе алып тора. Музейда Ш.Маннурның «Муса» романын язу һәм авыл китапханәсен салдыру тарихына караган материалларга киң урын бирелгән. Экспозициядә ш.у. авыл тарихын чагылдырган материаллар һәм документлар, татарларның көнкүреш әйберләре, эш кораллары, ш.и. 20 йөз башында Россия шахталарында эшләгән авылдашларының шахта лампалары коллекциясе бар. Музей ел саен Ш.Маннурның туган көнен (15 гыйнвар), М.Җәлилнең туган көнен (15 февраль), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә.





Тулбай авылында Шәйхи Маннурның мемориаль музей-китапханәсе. 1. Музей йорты; 2. Экспозиция фрагментлары: Ш. Маннурның шәхси әйберләре.

**МАНСУ́Р** (? – 1426/27), мангыт бәге (1420–26/27). Идегәй әмирнең улы. Атасының вафатыннан соң, Мангыт ыруглы идарәчесе (бәк) булып кала. Күк Урда тәхетенә Хаҗимөхәммәд ханны, соңрак Барак ханны утырта, соңгысының бәкләр бәге (диван башлыгы) була. М. идарә иткәндә Мангыт олысы җирләрендә тынычлык урнаша, шуның нәтиҗәсе буларак, аның Күк Урдага йогынтысы көчәя. М. Барак хан б-н бергә Алтын Урда тәхете өчен Олуг Мөхәммәд ханга каршы көрәшә. 1426 елда аларның гаскәре, җиңелеп, Идел аръягына чигенә. Мангыт ыругы башы буларак, М.ның Барак хан б-н аралары бозыла, берлек таркала. М. Барак б-н ике арада тәхет өчен барган сугышта һәлак була.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; I s c h b o l d i n B. Essays on Tatar history. New Dehli, 1973.

*И.Л.Измайлов.*

**МАНСУ́Р** (15 йөзнең 2 нче яртысы — 16 йөз уртасы), дин һәм дәүләт эшлеклесе. 1545 елда Әстерханнан Казанга килә, Казан ханлыгы мөселманнарының башлыгы (сәет) итеп сайлана. Шул ук елда Сафагәрәй хан б-н бергә шәһәрне ташлап китә.

*Әд.:* И с х а к о в Д.М. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. К., 1997; Ислам в Среднем Поволжье. К., 2001.

**МАНСУ́Р** (Мансуров) Зыя Мансур улы (17.12.1916, хәзер БРның Дүртөйле р-ны Җитембәк а. — 11.11.1965, Казан), шагыйрь.1937 елдан Дүртөйле р-нының «Ярыш» г-тасы редакциясендә корректор. 1946 дан Дүртөйле район үзәгендә радиотапшырулар дикторы, 1948 дән Илеш р-ны мәдәният йорты директоры булып эшли. 1949 дан Казанда яши: Татарстан радиоком-тында әдәби тапшырулар мөхәррире (1952–53), «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр (1953–55). «Язгы ташкыннар» (1950), «Ак розалар» (1963), «Этаплар китабы» (1966), «Үрләргә күңелем гашыйк» (1968) исемле шигъри җыентыклар авторы. Шигырьләренә тәэсирлелек, халыкчан гадилек һәм нечкә лиризм хас. Шагыйрь туган як табигатен, аның кешеләренең күңел дөньясын, яшьлек, мәхәббәт романтикасын яратып тасвирлый. Юмор-сатира — М. иҗатының көчле якларыннан берсе. Сатира жанрының төрле формаларына мөрәҗәгать итеп, ул карьерист, бюрократ кебек типларны тәнкыйтьли. «Омтылу» (1951), «Озын Колак баласы Елак-Мылак» (1958) кебек поэма-әкиятләре балалар өчен язылган. Рецензияләр, әдәби-тәнкыйть һәм әдәбият белеменә караган мәкаләләре «Шигъри осталык турында» (1965) җыентыгына тупланган. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма шигырьләр. К., 1959; Сайланма әсәрләр. К., 1972; Лейсан — весенний дождь. М., 1972.

*Әд.:* Х у җ и е в Г. Үрләргә күзем текәлгән // Казан утлары. 1966. № 3; М ә җ и т о в З. Шагыйрь җаны // Казан утлары. 1973. № 5.

**МАНСУ́Р әл-БОРЫНДЫКЫ́Й** (18 йөзнең 1 нче яртысы), дин эшлеклесе. *Мортаза әс-Симети* шәкерте. Сембер губернасының Буа өязе Борындык авылында мәдрәсә тота. Фарсы телендәге «Тәрәкыйбе Мансурия» китабы авторы (1726).

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н о в Р. Асар. К., 2006.

**МАНСУ́РОВ** Алексей Алексеевич (15.3.1900, Рязань губ. Касыйм ш. — 1941), археолог, этнограф, библиограф, музей белгече. Мәскәү ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1918). 1918 елдан Касыйм өяз халык мәгарифе бүлеге инструкторы, аннары мөдире. 1922 дә М. җитәкчелегендә Касыйм җирле төбәк музее (хәзер Касыйм төбәкне өйрәнү музее) оештырыла. 1924–33 елларда Үзәк сәнәгать өлкәсенең Рязань музеенда эшли: өлкән фәнни хезмәткәр, гыйльми секретарь, директор вазифаларын башкаручы; бер үк вакытта Губплан каршындагы Җитештерүче көчләрне өйрәнү буенча Рязань ком-ты секретаре һәм Рязань төбәге тикшеренүчеләр җәмгыяте гыйльми секретаре. М. музей төзү эшенә зур өлеш кертә: археол. коллекцияләрне системага сала, аның җитәкчелегендә Рязань төбәге библиографиясе төзелә (30 чыгарылыш, аларның 17 се басылып чыга), Үзәк сәнәгать өлкәсенең музей хезмәткәрләре кон-



А.А. Мансуров.



Б.Х. Мансуров.

ференциясе уздырыла (1925). Археол. экспедицияләрдә тупланган материаллар буенча (В.А.Городцов, Б.А.Куфтин, О.Н.Бадер б-н берлектә) М. Рязань төбәгенең җыелма археол. картасын төзи башлый. Төбәкне этнографик яктан өйрәнүдә катнаша (Б.А.Куфтин һәм Н.И.Лебедева б-н берлектә). Аның Касыйм татарларына нисбәтле (матди материал, тарих, көнкүреш һәм рухи мәдәният хакында язмалар) тикшеренүләренең нәтиҗәсе аеруча зур әһәмияткә ия. 1933 тән Мәскәүдә: Мәскәү өлкәсе төбәкне өйрәнү музеенда, Үзәк һәм өлкә төбәкне өйрәнү бюросында, Бөтенсоюз Китап палатасында, Уенчыклар музеенда эшли, Югары музей курсларында укыта. Бөек Ватан сугышы башлангач, ополчение сафларына баса һәм Мәскәү янындагы сугышларда һәлак була. Хезмәтләре Рязань төбәге археологиясе һәм этнографиясенә, музейлар эшенә карый.

Х е з м.: Этнографические работы по Рязанской губернии в 1926–1927 гг. // Этнография. 1927. № 1; 1930. № 3; Описание рукописей этнологического архива // Тр. Об-ва исследователей Рязанского края. 1928. Вып. 15; 1929. Вып. 22; Техника музейного дела: Учёт и хранение коллекций. М., 1931; Библиография литературы по музейной технике // Советский музей. 1934. № 1, 3–4; 1935. № 2, 4–6; Методика составления археологической карты. М., 1939.

*Әд.:* М а м о н т о в А. Выдающийся советский библиограф-краевед А.А.Мансуров // Советская библиография. 1965. № 3; Б а д е р О.Н., В а г н е р Г.К., К р и г е р Н.И. Роль А.А.Мансурова в изучении Рязанского края // Археология Рязанской земли. М., 1974; Материалы Свода памятников истории и культуры РСФСР: Рязанская область. М., 1980; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 1.

*Ф.Л.Шәрифуллина.*

**МАНСУ́РОВ** Борис Александрович (20.2.1754, Казанда дип фаразлана — 16.10.1814, Казан), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1801). Дворяннар нәселеннән. 1768 елдан хәрби, 1801 дән гражданлык хезмәтендә. 1787–91 дә рус-төрек сугышында, 1799 да Италиягә һәм Швейцариягә яуларда катнаша. 1803 тән Казанда гражданнар губернаторы. Губерна идарәсе һәм полиция эшен җайга сала, дәүләт җыемнары һәм йөкләмәләрен үтәтүгә тәртип кертә, Казан губернасында юллар төзү һәм запас икмәк кибетләре салдыруны оештыра. Казанда губерна басмаханәсе (1804), хәрби госпиталь (1809), туп кою з-ды (1812) М. катнашы һәм булышлыгы б-н булдырыла. Аның дәверендә Казан ун-тына нигез салына (1804), Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте оеша (1806), «Казанские известия» г-тасы чыга башлый (1811). 1812 дә Ватан сугышына *Казан ополчениесен* оештыруга һәм 1812 нең декабре — 1814 нең гыйнварында Казанда Мәскәүдән эвакуацияләнгән үзәк архив идарәсе органнарын, төрле хәйрия учреждениеләрен урнаштыруга җитәкчелек итә. П.П.Есипов театрына химая ярдәме күрсәтә.

*Әд.:* Л о б а н о в - Р о с т о в с к и й А.Б. Русская родословная книга. СПб., 1895. Т. 1; А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Ч. 1; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**МАНСУ́РОВ** Борһан Хөснетдин улы (24.6.1889, Саратов губ., Хвалынск өязе Иске Зелёное а. — 1942 нең августы, Мәскәү ш.), дәүләт эшлеклесе. 1906 елда Әстерхан шәһәрендә «Уйгату» яшерен революцион г-тасын чыгаруда катнаша. 1907 дә Казандагы «Мәрҗания» мәдрәсәсендә укый башлый, шул ук елда революцион эшчәнлеге өчен аннан чыгарыла. Х.Ямашев б-н бергә татар эшчеләре арасында хөкүмәткә каршы пропаганда алып бара. 1908–15 елларда Әстерхан, Саратов, Тобол, Петроград губерналарында укыта. 1915–17 дә Архангельск шәһәрендә торып, Мурманск тимер юлы төзелешендә катнаша. 1917 нең февралендә Архангельскида мөселман эшчеләре ком-тын оештыручыларның берсе. Окт. рев-циясеннән соң Петроградта Үзәк мөселман комис-тының хезмәт бүлегенә җитәкчелек итә. 1918–20 дә Россия Мөселман коммунистлар партиясе ҮК әгъзасы, «Хөррият», «*Кызыл Шималь*» г-талары мөхәррире, Үзәк мөселман комис-ты рәисе урынбасары (Мәскәү), «Эшче» г-тасы мөхәррире, Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросының нәшрият бүлеге мөдире. ТАССР төзүдә актив катнашучыларның берсе, 1920 дә ТАССР ҮБК Президиумы рәисе итеп сайлана. 1921 дән Мәскәүдә хуҗалык эшендә, 1934–37 дә «*Сугышчан алласыз*» ж-лының җаваплы мөхәррире. РСФСР БҮБК әгъзасы.

*Әд.:* С а й д а ш е в а М.А. Мансуров Бурхан Хуснутдинович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**МАНСУ́РОВ** Булат Баһаветдин улы (7.7.1937, Төрекмән ССР, Чарджоу ш.), кино режиссёры, сценарийлар авторы, педагог, Төрекмәнстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978). Бөтенсоюз кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тын тәмамлаганнан соң (1963, С.А.Герасимов остаханәсе), М. — 1964 елда «Төрекмәнфильм» киностудиясендә «Ярыш» («Шукур-Бакши») фильмының режиссёры һәм сценарий авторы. «Сусауны басу» («Утоление жажды», Ю.В.Трифонов әсәре буенча, 1966), «Кол хатын» («Рабыня», А.П.Платоновның «Такыр» новелласы буенча, 1968), «Үлем юк, егетләр!» («Смерти нет, ребята!», 1970), «Тризна» (1972), «Мәхәббәт хикәясе» («Притча о любви», 1976), «Монда акчарлаклар очып килмәде» (В.П.Астафьевның «Үткел» («Перевал») повесте буенча, 1977), «Гаҗәеп дөнья» («Блистающий мир», А.Грин әсәре буенча, 1984), «Җырлар яклаучысының кайтуы» («Возвращение покровителя песен», 1984), «Солтан Бәйбарс» («Султан Бейбарс», 1989) фильмнарын төшерә. Барлык үз фильмнарының, ш.у. «Бәхеттән аерылган Фраги», «Сары үгез төне» фильмнарының сценарий авторы. Бөтенроссия кинематография ин-тында укыта, продюсерлык итә, С.М.Эйзенштейн исем. халыкара киномәктәпләрне үстерү фонды президенты.

*Әд.:* Кино: Энцикл. словарь. М., 1986.

*Е.П.Алексеева.*

**МАНСУ́РОВ** Гасыйм Гата улы (1894, Вятка губ., Сарапул өязе Кирсә а. — 1955, Муром ш.), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог. 1915–16 елларда Пермь губернасының Оса, Вятка губернасының Сарапул өязләре мәктәпләрендә, 1916–17 дә Ижевск рус-татар уч-щесендә укыта. 1917–20 дә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Мамадыш өяз башкарма ком-ты рәисе, Советларның 7 нче Бөтенроссия съездында БҮБК әгъзасы итеп сайлана. 1920–21 дә Төркестан АССР Эчке эшләр халык комис-ты әгъзасы, җинаятьчеләрне эзләү идарәсе башлыгы. 1922–24 тә ТАССР ХКС рәисе урынбасары, «Коммунистический путь» ж-лының редколлегия әгъзасы. 1924 тән Мәскәүдә: Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-тында, Мәскәү ун-тында укыта, Шәрекъ халыклары этник мәдәнияте ин-ты проректоры. Хезмәтләре татарларның милли хәрәкәтенә карый. 1931 дә репрессияләнә (тоткынлыктан 1941 дә азат ителә); үлгәннән соң аклана. Бөек Ватан сугышы елларында санитар поездында эшли.

Х е з м.: Татар провокаторлары. М., 1925; Татары в годы первой революции. М., 1926.

*Әд.:* Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990.

**МАНСУ́РОВ** Зиннур Мөҗип улы (15.7.1949, Мамадыш р-ны Түбән Ушма а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2009). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1974–83 тә «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, 1983–86 да «Казан утлары» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1986–90 да ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында баш мөхәррир, 1990–95 тә ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары, 1995 тән «Мәдәни җомга» г-тасының баш мөхәррире. «Кул бирәм» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1979 да басылып чыга. М.ның поэзиясе хисләренең ихласлыгы, тормыш-яшәешне фәлсәфи мәгънәдә аңлатуы белән аерылып тора. Намуска, мәхәббәткә тугры калу турында публицистик яңгырашлы, көндәлек тормыш вазгыятенә караган шигырьләре «Йөз суы» (1983), «Тысячелистник» (М., 1983), «Ваем» (1988), «Душицы белый запах» (1991), «Яшәү үзәне» (1998), «Күңел сәфәре» (1999), «Җәрәхәтле йөрәк җылырак» (2003) җыентыкларын тәшкил итә. «Юлын белгән арымас» (1989), «Күңелдә фидаи яшәсә» (2006) исемле публицистик мәкаләләр җыентыклары төрле буын шагыйрьләре иҗатына, әдәбият, сәнгать мәсьәләләренә, четерекле иҗтимагый-сәяси тормыш темаларын яктыртуга багышланган. Аның күп кенә шигырьләре рус, инглиз, тө-

рек, казакъ телләренә тәрҗемә ителгән. ТР-ның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Галиуллин Т. Яшәү мәгънәсе // Гомер учагы. К., 1991; Гаташ Р. Сәфәрләргә чыксаң белерсең // Казан утлары. 2000. № 4; Гафиятуллина Н. Хәтер сызлануы // Казан утлары. 2004. № 1. *Г.М.Габделхакова.*


**МАНСУ́РОВ** Павел Андреевич (2.3.1896, Петербург — 2.2.1983, Ницца ш.), нәкышьче, график, сәхнә бизәлеше остасы, тукымалар рәссамы. Рус авангардының күренекле вәкилләреннән. 1909–15 елларда С.-Петербургта барон А.Штиглицның Үзәк техник рәсем төшерү уч-щесендә һәм Сәнгать әсәрләренә кызыксындыру җәмгыятенең Рәсем мәктәбендә укый. 1915 елда армиягә алына, 1 нче авиация полкында һәм Хәри-һава флоты идарәсендә хезмәт итә. Окт. рев-циясеннән соң сәнгать авангардының төп эшлеклеләре — П.Н.Филонов, К.С.Малевич, М.В.Матюшин, В.Е.Татлин б-н даими элемтәдә тора. 1918 дә Царское Селодагы Кытай театрында куелган «Упман» балетына (А.Лурье музыкасы) декорация һәм костюмнар эшли; Сәнгать әсәрләренең 1 нче Дәүләт ирекле күргәзмәсен оештыручыларның берсе була (Петроград, 1919). 1919 да Казанга килә, гадәттән тыш Комиссия тарафыннан кулга алына, Казан сәнгать мәктәбендә укыту шарты б-н 1920 дә азат ителә. 1920 дә уч-щенең нәкышь ф-ты остаханәсе б-н җитәкчелек итә, саф пластик форма һәм предметсыз конструкция законнарына өйрәтә. 1924–25 тә Ленинград сәнгать-сәнәгать техникумында укыта. 1926 да М. совет сәнгате тәнкыйте һөҗүмнәренә дучар ителә һәм Италиягә китәргә мәҗбүр була. 1928 дән Парижда яши. 1930–39 да, предметсыз сәнгать танылмау сәбәпле, гамәли-бизәлеш сәнгатенә мөрәҗәгать итә, тукыма бизәү б-н шөгыльләнә, Париждагы Пату, Шанель, Ланвэн кебек югары мода йортларына эшли. 1940–83 тә реставрация б-н шөгыльләнә. 1957 дә кабат предметсыз нәкышькә, 1920 еллардагы пластик концепцияләргә мөрәҗәгать итә, шушы жанрда үз стилен булдыра. Сәнгатьтә табигый форма йогынтысында пластик форма тудыру проблемасын тирәнтен өйрәнә, соңрак бионика өлкәсенә кергән теоретик мәсьәләләргә кагылып үтә.

Әсәрләре: «Композиция» (агач, майлы буяу, 1918), «Предметсыз композиция» (1918–1920 еллар), «3 нче номерлы модель» (кәгазь, тушь, гуашь, 1920), «Суперматик композиция» (катыргы, гуашь, сызым кораллары, 1920–21), «Нәкышь формуласы» (такта, майлы буяу, 1927) һ.б. Әсәрләре Третьяков галереясында, Нью-Йорктагы Заманча сәнгать музеенда, Кёльн шәһәренең Гмуржа галереясында, Берлиндагы Милли галереяда, Киров һәм Омск өлкә сәнгать музейларында, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

Сәнгать әсәрләренең 1 нче Дәүләт ирекле күргәзмәсендә (Петроград, 1919), 1 нче рус сәнгать күргәзмәсендә (Берлин, 1923), Барлык юнәлешләрдә иҗат итүче Петроград рәссамнары картиналары күргәзмәсендә (Петроград, 1923), 16 нчы Халыкара сәнгать биенналесендә (Венеция, 1924), Сынлы сәнгатьнең юбилей күргәзмәсендә (Ленинград, 1927), «Абстракт сәнгатькә 50 ел» күргәзмәсендә (Париж, 1957), Сәнгать һәм сәнәгать музеендагы «1910–1939 еллардагы беренче буыннарның абстракт сәнгате» (Сен-Этьен ш., Франция), Заманча сәнгать милли музеендагы (Париж, 1972) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәсе 1929 да (Рим) уза.

*Әд.:* Неизвестный русский авангард в музеях и частных собраниях: Альбом. М., 1992; Великая Утопия. Русский и советский авангард 1915–1932: Каталог выставки. М., 1993; Павел Мансуров. Петроградский авангард: Каталог выставки. СПб., 1995. *Г.Р.Фәйзрахманова.*

**МАНСУ́РОВ** Ринат Нәҗип улы (29.9.1959, Бохара ш., Үзбәкстан ССР), нәкышьче. П.П.Беньков исем. Ташкент сәнгать уч-щесен (1980), Ташкент театр-сәнгать ин-тының нәкышь бүлеген тәмамлый (1988). 1988 елдан Ташкенттагы Респ-ка сынлы һәм гамәли сәнгать интернат-лицеенда укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1996). М. иҗатына реализм, авангард, сюрреализм кебек төрле стиль юнәлешләре хас. Аларда рәссам метафора һәм кинаяләр шигъриятенә мөрәҗәгать итә, пластик формаларның хисси чагылышын колорит



Р. Н. Мансуров. «Су анасы». 1993.


һәм үзенчәлекле композицион чишелеш берлегендә ачып, образлар тудыра. Жанрлы рәсемнәр, ландшафт һәм архитектура пейзажлары авторы. Төп әсәрләре: «Дуэт», «Нәүрүз» (икесе дә — 1990), «Феникссологиягә кереш, яки С.Дали истәлегенә» (1991), «Су анасы» (1993), «Бохара көйләре», «Бохара циклы» һ.б. Үзбәкстан рәссамнарының Япония (1989), Мәскәү (1990), АКШ (Лас-Вегас ш., 1994) күргәзмәләрендә, Үзбәкстандагы «Ил» татар рәссамнары берләшмәсе күргәзмәләрендә (Ташкент, 1995, 1996), 1991 дән — Үзбәкстанның Бәйсезлек көненә, «Нәүрүз» бәйрәменә багышлап ел саен үткәрелә торган респ-ка күргәзмәләрендә, «Рәссам һәм табигать» һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Әсәрләре АКШ, Англия, Германия, Көньяк Корея, Россия, Франция һ.б. илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МАНСУ́РОВ** Фәнил Хәбибулла улы (3.12.1931, хәзер БРның Чакмагыш р-ны Чакмагыш а. — 30.5.1995, Уфа ш.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1957), Башкортстанның Бүздәк район газетасында бүлек мөдире (1957–60), Чакмагыш р-ның Калмашбаш сигезьеллык мәктәбендә укытучы (1960–63), «Агыйдел» (Уфа) ж-лында әдәби хезмәткәр (1963–67) булып эшли. 1968 елдан Казанда: Татарстан китап нәшриятында мөхәррир (1968–71), «Социалистик Татарстан» г-тасы хәбәрчесе (1972–76). 1983 тән кабат Уфада: «Өмет» г-тасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире (1991–94). «Юл башы» исемле беренче повесте 1961 дә «Агыйдел» ж-лында басыла. Давыллы рев-ция вакыйгаларын һәм Бөек Ватан сугышы елларын, сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтләгән повесть һәм хикәяләре «Хәерле юл» (1969), «Яктытауда бүз тургайлар» (1973), «Ак буран» (1977), «Юл чатында көмеш әрем» (1978) «Агыйделкәй алкын» (1991) җыентыкларына тупланган. «Айгалаш кыйссасы» повесте шагыйрь Шамун Фидаиның гражданнар сугышы елларындагы тормышына багышланган. Гомеренең соңгы елларында иҗат иткән «Солтан Кирәмәт» (1993) романы тоталитар җәмгыять шартларында фаҗигале шәхес язмышы турында сөйли.

*Әд.:* Тимерғалина Р. Башҡортстан яҙыусылары. Өфө, 1968.

**МАНСУ́РОВ** Фуат Шакир улы (10.1.1928, Алма-Ата ш., Казакъстан ССР — 12.6.2010, Мәскәү), дирижёр, педагог, Казакъстан ССР, ТАССР, РФнең халык артисты (1967, 1975, 1998), РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1995), проф. (1980). 1950 елда Алма-Ата ун-тының физика-матем. ф-тын, 1951 дә виолончель классы буенча Алма-Ата консерваториясен тәмамлый. Мәскәү консерваториясе аспирантурасында дирижёрлык осталыгына өйрәнә (Л.Гинзбург шәкерте), 1963 тә И.Маркович җитәкчелегендә югары дирижёрлык осталыгы курслары үтә. М. иҗатына И.Зак зур йогынты ясый. 1949–67 дә М. Казакъ халык уен кораллары оркестры баш дирижёры, Казакъстан ССРның Дәүләт симф. оркестрын оештыручы һәм беренче баш дирижёры, Казакъстан акад. опера һәм балет театры, Казакъстан радиосы симф. оркестры баш дирижёры. Казакъстан музыка мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертә. Казакъстан опера һәм балет театрында, классик репертуарга караган спектакльләрдән тыш, Е.Брусиловскийның «Варислар», С. Мөхәммәтҗановның «Айсылу» һ.б. милли музыка әсәрләрен сәхнәләштерә. 1967 дән Зур театрда (Мәскәү) стажёр, 1969 дан — дирижёр, бер үк вакытта Казандагы Татар опера һәм балет театры баш дирижёры (1968–70), Татарстан Дәүләт симф. оркестры баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе (1986 дан). Иҗат эшчәнлеге дәверендә, башлыча, дөнья классикасын тәшкил итүче Көнбатыш Европа һәм рус опера һәм балет репертуарына караган әсәрләрнең барысын да диярлек: Дж.Вердиның «Трубадур», «Аида», Дж.Пуччининың «Тоска», Ж.Бизеның «Кармен», А.Даргомыжскийның «Су кызы», «Таш кунак», П.Чайковскийның «Евгений Онегин», «Мазепа», Н.Рим-

ский-Корсаковның «Патша кәләше»н, хәзерге чит ил һәм рус композиторлары әсәрләрен куя; Зур театрда К.Молчановның «Макбет», В.Гаврилинның «Анюта» һ.б. балетларының беренче куелышында катнаша. Симф. дирижёр буларак, М.ның репертуарын тулаем диярлек дөнья классикасы һәм хәзерге заман репертуары: Л.Бетховен, Ф.Шуберт, С.Прокофьев, Д.Шостакович симфонияләре, К.Сен-Санс, А.Дворжак, К.Дебюсси, Р.Штраус, И.Стравинскийның симф. әсәрләре һ.б. тәшкил итә. М. ТРның симф. культурасы һәм театр музыкасы үсешенә аеруча зур өлеш кертә. Татар опера һәм балет театрында милли опера һәм балет үрнәкләреннән иң танылганнарын: Н.Җиһановның «Алтынчәч», «Җәлил» операларын, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетын һ.б. яңа редакциядә сәхнәгә күтәрә. М. татар симф. музыкасын актив пропагандалый. Татарстан композиторлары Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Ф.Әхмәтов, А.Миргородский, А.Луппов һ.б.ның күпсанлы симф. әсәрләрен беренче башкаручы. Чит илләрдә актив иҗади эшчәнлек алып бара, атаклы симф. оркестрларның концерт программалары б-н чыгышлар ясый. Чит илләрнең опера һәм балет театрларында: Аргентина һәм Төркиядә — П.Чайковскийның «Пики дамасы»н, Финляндиядә И.Рауттаварның «Винсент Ван Гог»ын; Аргентинада П.Чайковскийның «Аккош күле» һәм А.Хачатурянның «Спартак» һ.б. балет спектакльләрен сәхнәгә куя. ТР Дәүләт симф. оркестры б-н Көнбатыш Европа илләрендә (ГФР, Франция, Италия һ.б.) гастрольләрдә була. 1951 дән укытучылык эшчәнлеге алып бара, ш.и. Мәскәү (1971–82), Казан консерваторияләрендә укыта. Студентларның симф. оркестры чыгышлары һәм опера спектакльләре М.ның пед. эшчәнлегенә лаеклы бәя булып тора. Музыкаль әсәрләр авторы (симф., Ф.Яруллинның «Шүрәле» балеты темаларына симф. сюита һ.б.). Дирижёрларның бөтенсоюз конкурсы (1966), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.


Ф.Ш. Мансуров.


ТРның Дәүләт симфоник оркестры. Дирижёры Ф.Ш. Мансуров.

*Әд.:* Б и к ч у р и н а Ф. Высокая цель // Татарстан. 1997. № 12; Э й з е н А. Он во всём — маэстро // Идель. 2003. № 2.

*Ф.Ш.Бикчурина.*

**МАНТЕ́ЛЬ** Александр Фердинандович (7.3.1880, С.-Петербург — 24.11.1935, Мәскәү), сәнгать тәнкыйтьчесе, нашир, коллекционер, рәссам. САдә укый (тәмамламый). 1905 елдан Казан өязендәге хуторында, 1920 дән Иваново-Вознесенск губернасында яши. 1908–13 тә Казандагы вакытлы матбугат б-н хезмәттәшлек итә («Волжское утро», «Волжские дали», «Казань» һ.б.), аларга Казан сәнгать мәктәбе укучыларын җәлеп итә. 1990 да «Яшьлек әкияте» исемле китабы дөнья күрә, аны бизәүдә танылган рус рәссамнары Е.Е.Лансере (тышлык) һәм Б.М.Кустодиев (иллюстрация) катнаша; 1910 да «На рассвете» нәшриятын оештыра һәм үз мөхәррирлегендә «На рассвете» (1910) һәм «Зилант» (1913) әдәби-нәфис альманахлары, 20 йөз башы Казан китап продукциясе арасында сәнгатьле итеп махсус иллюстрацияләнгән беренче басмалардан «Д.И.Митрохин» (1912), «Н.К.Рерих» (1912) китапларын чыгара. 1912 дә нәшриятын Н.Н.Андреевка тапшыра. М. зәвык һәм сәнгать проблемаларын яктырткан эссе, кыска язмалар, редакция мәкаләләре, хикәя, нәсер, драма әсәрләре бастыра, аерым мәкаләләре декадентлыкка, кубизм, футуризмга багышлана; К.Гамсун, Э.По, И.И.Левитан, Я.Ф.Циоглинский иҗатлары турында яза, үзенең рәсем һәм шаржларын бастыра. 1910 да М. Казандагы Дворяннар җыены залларында «Мир искусства» сәнгать берләшмәсе әгъзаларының һәм аңа якын рәссамнар А.Н.Бенуа, Б.М.Кустодиев, И.С.Петров-Водкин, Н.К.Рерих, Е.Е.Лансере һ.б. әсәрләреннән 1 нче күргәзмә оештыра. 1913 тән М.ның сәнгати карашлары кискен үзгәрә. «Нео-футуризм» исемле җыентыгы басылып чыгу Д.Д.Бурлюк, В.В.Маяковский, В.И.Каменскийның Казандагы гастрольләре вакытына туры килә; М. алар б-н җыентык битләрендә бәхәс алып бара. Басма провинциаль квазифутуризмның үзенә бертөрле үрнәге була һәм матбугатта кискен тәнкыйть кузгата, аерым алганда, П.П.Драверт үткен чыгыш ясый; шуңа карамастан, М. җыентыкның 2 нче басмасын чыгарып өлгерә.

М.ның сәнгать коллекциясендә «Сәнгать дөньясы» рәссамнары һәм аңа иҗат юнәлеше буенча якын торган рәссамнар: Б.И.Анисфельд, А.Н.Бенуа, А.Ф.Гауш, Б.М.Кустодиев, Е.Е.Лансере, Г.К.Лукомский, Н.К.Рерих һ.б. графикасыннан, ш.у. С.Ю.Жуковский, А.М.Кокорев, С.Ф.Колесниковның нәкышь картиналарыннан торган Казанда бердәнбер тупланма формалаша. М. тупланмасындагы аерым әсәрләр «Рус рәссамнары берлеге», «Сәнгать дөньясы» күргәзмәләренә куела, «Аппелон», «Сатирикон», «Весы» ж-лларында күчереп басыла, М.ның үз басмаларында дөнья күрә. 1919 да, П.М.Дульский үтенече буенча, М. тупланмасы ТАССР Халык мәгариф комиссариатының музейлар һәм борынгы һәйкәлләрне саклау эшләре бүлеге карамагына алына һәм Тәтеш, Козьмодемьянск, Казан губерна музейлары арасында бүленә (әсәрләрнең бер өлеше ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Козьмодемьянск тарих-сәнгать музей-тыюлыгында саклана). 1920 дә М. тупланмасындагы әсәрләрнең бер өлеше «Казан губерна музее сәнгать бүлегенең яңа табышлары» күргәзмәсенә куела. 1919–20 дә М. Тәтеш өязе буенча агент сыйфатында музейлар һәм борынгы ядкәрләрне саклау бүлегенә эшкә җәлеп ителә. 1920–30 да туку ф-калары өчен рәсемнәр иҗат итә, Иваново өлкәсендәге Плёс шәһәре картиналар галереясында эшли.

М. — «Утарда кояш байый», «Л.Н.Толстой вафат булган урын», «Балыклар», «Пейзаж» (барысы да — 1910 еллар), «Чиркәү», «Кич», «Шәһәр», «Совет бизәлеш үрнәге» (барысы да — 1920) нәкышь әсәрләре, «Сәнгать академиясе профессорлары күргәзмәдә көндәшләрнең картиналарын карыйлар һәм аларга рәссам исеме бирәләр», «Депрейс һәм ирләр», «Евгений Геркен», «Парижда Бастилия колоннасы» шаржлары (барысы да — «Жизнь» ж-лы, 1912, № 2) авторы.

Казандагы 1 нче дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә (1920), Россия САнең Иваново-Вознесенск ф-лындагы 3 нче картиналар күргәзмәсендә (Иваново-Вознесенск, 1930) катнаша.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

Х е з м.: В наши дни: Драма // Волжские дали. 1908. Вып. 11; Заметки о новом искусстве // Волжское утро. 1908. № 1; И.И.Левитан // Волжские дали. 1908. Вып. 13; Популярность искусства // На рассвете. К., 1910. Кн. 1; О кубизме // Жизнь. 1913. № 4; Рисунки для тканей. М.–Л., 1930.

*Әд.:* Десятилетие служения искусству. А.Ф.Мантель, К., 1912; Первая государственная выставка искусства и науки в Казани. К., 1920; К о р н и л о в П.Е. Художественное собрание Тетюшского музея // Зап. Тетюшского музея. 1927. № 1; К л ю ч е в с к а я Е.П. А.Ф.Мантель и его коллекция // Музей в системе ценностей евразийской культуры. К., 2000; З н а м е н с к а я Е.Н. Драматические коллизии А.Мантеля // Мир музея. 2006. № 3.

*Е.П.Ключевская, А.А.Виноградова.*

**МАНУФАКТУ́РА** (лат. manus — кул һәм factura — эшләү, ясау), хезмәт бүленешенә һәм кул көче б-н хәрәкәткә китерелүче техникага нигезләнгән пр-тие. Россиядә М. башлангычы булган сәнәгать пр-тиеләре 16 йөздә күренә башлый. М. барлыкка килүнең алшартлары: һөнәрчелек һәм товар җитештерүнең алга китүе, хезмәт бүленешенең тирәнәя баруы. Милек формасына карап, М. — казна (дәүләт) һәм хосусый; эшне оештыру рәвешенә карап — үзәкләштерелгән (бер остаханәдә эшләүчеләрне берләштерә), катнаш (кайбер эшләр үзәкләштерелгән остаханәдә, кайберләре өйдә башкарыла), таркау (эш бирүче мөстәкыйль эш башкаручыны чимал һәм эш кораллары б-н тәэмин итә, соңыннан алардан әзер продукцияне сатып ала һәм сата) төрләргә бүленә. М.да ялланып эшләүчеләр һәм крепостной крәстияннәр хезмәте кулланыла. 17 йөздә Россиядә М.лар санаулы гына була

(белгечләр 30 дан 60 ка кадәр дип исәпли), 18 йөздә, дәүләтнең максатчан чаралары нәтиҗәсендә, М. җитештерүе сизелерлек үсә. Император Пётр I меркантилизм сәясәте уздыра. 1720 еллар башында сәнәгатьне үстерү максатыннан үзәк дәүләт учреждениесе — Мануфактур-коллегия төзелә (өзеклекләр б-н 1804 кә кадәр эшли). Ул барлык төр (казнаныкы һәм хосусый) М.лар б-н идарә итү эшен оештыра: М. хуҗаларына техника б-н булыша һәм финанс ярдәме күрсәтә, М.ларның эшче көч һәм белгечләр б-н тәэмин ителешен, фабрикантларга тиешле ташламалар ясалуны, пр-тиеләр эшен һәм әзер товарны сату тәртипләре үтәлешен контрольдә тота. М. җитештерүен үстерү ш.у. Баш магистрат вазифасы да булып санала. Эшче куллар җитешмәү мәсьәләсе М.га «бәйле эшчеләр» беркетү юлы б-н хәл ителә. 1721 ел Фәрманы буенча дворяннарга да, сәүдәгәрләргә дә М. өчен авыллар сатып алу рөхсәт ителә, тик сәүдәгәрләр, дворяннардан аермалы буларак, крәстияннәрне бары тик М. б-н бергә генә сата ала. М.га ревизия үткәргәндә андагы барлык паспортсыз крәстияннәр М.га беркетелә. Сәнәгать җитештерүенең крепостнойлыкка нигезләнүе технол. артталыкка, җитештерү күләменең түбән темплар б-н үсүенә, җитештерелгән продукциянең көндәшлек дәрәҗәсе төшүгә китерә. М.лар җитештергән товарның төп кулланучысы дәүләт үзе була. Пётр I, казна М.лары эшеннән канәгатьсезлек белдереп, аларның шактыен хосусый милек иясләренә тапшыра. Шул ук вакытта дәүләт өчен мөһим җитештерү төрләре аерым игътибарга алына. Казан төбәгендә беренче М.лар 1640 елларда барлыкка килә: Казанда һәм Кукмара авылында беренче бакыр кою пр-тиеләре ачыла, аларда 100 дән артык кеше эшли; Спас авылы янындагы алпавыт селитра җитештерү пр-тиесендә 200 крепостной крәстиян эшли; Кама елгасы буендагы Морза бистәсендә Тумашевның домна миче була. 18 йөздә М. җитештерүе Казан губернасында сәнәгать үсешендә әйдәүче урын били. 18 йөз башында төбәктәге барлык эре М.лар дәүләт тарафыннан төзелә һәм аларда беркетелгән крәстияннәр хезмәте файдаланыла: 1714 тә — Казан постау М.сы (1724 тә сәүдәгәр И.А.*Михляевка* бирелә), 1718 дә — *Казан адмиралтействосы*, 1719 да — *помпа каеш-куннәре заводы* ачыла. Төрле урыннарда *бакыр кою заводлары* уңышлы эшли (Кукмара, Шилнә, Мишә, Иштирәк һ.б.). Хосусый М.лар, башлыча, җитештерүнең төбәк өчен традицион туку, тире-күн эше, сабын кайнату, аракы куу кебек тармакларына карый. Туку М.лары (киндер, комач, яулык тукымасы) күбрәк татар эшмәкәрләре кулында була. Эшчеләр авыр хезмәт шартларында эшлиләр, еш кына канәгатьсезлекләрен белдерәләр. Казанда постаучылар берничә тапкыр күтәрелеп чыга (к. *Казан постаучылары чуалышлары*), М.ларга, заводларга беркетелгән эшчеләр Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге *Крәстияннәр кузгалышында (1773–75)* һ.б.да катнашалар. 19 йөздә, төбәктә *капитализм* үсү, буржуазия барлыкка килү, машина көченә көйләнгән җитештерү алга китү шартларында, посессион һәм крепостной крәстияннәр хезмәтен кулланып көн итүче М.ларның күбесе көндәшлекне күтәрә алмый һәм эшләүдән туктый. Казан губернасындагы барлык бакыр кою з-длары, соңрак Казан постау М.сы ябыла. Алпавыт пр-тиеләре бөлгенлеккә төшә. Капиталистик М.лар, киресенчә, үсеш кичерә. 19 йөз башында Казан губернасындагы М.ларның шактые сәүдәгәрләрнеке һәм мещаннарныкы булып, аларда яллы эшчеләр хезмәте кулланыла. 1812 дә Казан губернасында 3 постау М.сы эшли: Казанда алпавыт Осокин М.сы (349 крепостной эшче), Лаеш өязе Алексеев авылында Сахаров варислары М.сы (561 крепостной крәстиян) һәм Казандагы Җәмәгать тәрбиясе приказы М.сы (36 — беркетелгән, 25 яллы эшче). 94 күн М.сы, башлыча, сәүдәгәр һәм мещан катлавыныкы була, аларда яллы эшчеләр эшли: 32 се — Казанда (24 е — сәүдәгәрләрнеке, 8 е — мещаннарныкы; эшләүчеләр саны — уртача 6–7 кеше; иң эреләренең хуҗалары: Муса Апанаев — 26 эшче, Якуб Аитов — 26, Салих Аитов — 31); 17 се — Чабаксарда (1 се — сәүдәгәрнеке һәм 16 сы — мещаннарныкы); 24 е — Казан өязендә (19 ы — сәүдәгәрләрнеке; иң эреләрнең хуҗалары: Ягодное авылында Иван Котелов — 55 эшче, шунда ук Пётр Котелов — 54; 5 е — мещаннарныкы); 11 е — Мамадыш өязендә (5 е — сәүдәгәрләрнеке, 6 сы — мещаннарныкы). Крәстиян М.лары да була: 2 се — Казанда, 5 е — Мамадыш өязендә, 2 се — Чабаксарда; 1 се Адмиралтейство конторасына карый (17 яллы эшче). Күн М.ларында барлыгы 802 кеше эшли. 23 сабын кайнату, шәм һәм балавыз ясау М.сыннан (174 кеше эшли) иң эреләренең хуҗалары — сәүдәгәрләр И.Жарков (11 кеше), Ю.Китаев (13), Я.Шатунов (11), П.Евреинов (11), А.Квасников (9), 1 М. — мещанныкы (3) һәм 2 се — татарларныкы. Лаеш өязе Алексеев авылында хакыйкый статский советник Сахаров варисларының 1 киндер М.сы (24 кеше), ш.у. 9 яулык һәм киҗе-мамык М.сы (шулардан 4 е — Казан, 5 е — Царёвококшайск өязләрендә: иң эре пр-тиеләр хуҗалары — Муса Хуҗасәитов, Ор авылы, 68 эшче; Сөләйман Хуҗасәитов, шунда ук, 81; Мәхмүт Хуҗасәитов, шунда ук, 63; Нәзир Хуҗасәитов, шунда ук, 81). Бу тармакта барлыгы 534 кеше эшли. Казан сәүдәгәре А.Блюденевның 1 аркан, 1 эрләү М.сы (26 кеше), Лаеш өязендә 2 алпавыт поташ М.сы (крепостнойлар хезмәте кулланыла), Казанда 1 серкә һәм 1 аракы з-длары (3 кеше), Казанда 1 тимер з-ды (3 кеше), Казанда һәм Мамадыш өязендә 2 бакыр һәм сәдәф М.сы исәптә була. 1812 дә Казандагы 3 эре сабын кайнату М.сы 11,5–13 мең пот сабын, 8 комач М.сы 514 мең аршын (476 мең сумлык) товар җитештерә. 1842 елга комач һәм кытай тукымасы М.ларының саны 23 кә җитә. Казан ун-ты профессоры К.Ф.Фукс Казан губернасы М.лары буенча үз исәбен тәкъдим итә (1828–29). Ул 61 эшләп килүче, 5 эшләп туктаган күн М.сына (иң күп җитештерү — 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре Л.Ф.Крупениковныкы), 13 сабын кайнату М.сына (иң эресе — 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре Х.Юнысовныкы), 4 постау М.сына (иң эресе — сәүдәгәр Г.И.Осокинныкы), 6 туң май-шәм һәм 8 туң май эретү М.сына бәяләмә бирә (ахыргача язып тәмамланмаган). Казан губернасы М.ларының байтагы татар сәүдәгәрләренеке була. «Мануфактура и торговля» ж-лында (1830) 1767–99 да хуҗалары татар сәүдәгәрләре булган М.лар турында мәгълүмат бирелә, анда күрсәтелгән 9 М.ның 6 сында комач җитештерелә: 1 се Кышкар авылында (1 нче гильдия Арча сәүдәгәре М.Усмановныкы, 1767 дә төзелә), 1 се Бәрәскә авылында (3 нче гильдия Арча сәүдәгәре К.Борнаевныкы, 1775), 2 се Орнашбаш авылында (3 нче гильдия Арча сәүдәгәре К.Мәмәшевныкы, 1776 һәм Арча сәүдәгәре М.Мәмәшевныкы, 1778), 2 се Царёвококшайск өязе Оры авылында (2 нче гильдия Арча сәүдәгәре С.Сәетовныкы, 1798 һәм 1799); 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре Х.Апанаев М.сында (1778) тире эшкәртелә, 3 нче гильдия Казан сәүдәгәре Х.Апанаев М.сында (1778) сабын кайнатыла, йомышлы татар М.Кәримовның Царёвококшайск өязендәге М.сында (1795) поташ ясала. Бу мәгълүматлар тулы түгел, чөнки «Татар ратушасы» беркетмәләре һәм журналларындагы мәгълүматларга караганда, Казанның Иске татар бистәсендә генә дә 24 М. эшли (11 сабын кайнату, 10 күн, 3 кәҗә тиресе эшкәртү М.сы). «Ведомости 1812» язганча, Казан губернасы буенча исемлектәге 129 М.ның 45 е (35 %) татарларныкы була, барлыгы 4823 кешедән аларда 1509 ы (31,4 %) эшли. 1846 ел мәгълүматлары буенча, Казан губернасында 245 завод һәм фабрика исәпләнә, ш.и. 166 сы — Казанда. Араларында, бик аз санда булса да, машина көченә көйләнгәннәре дә була. Шул чор чыганакларындагы М.ларга кагылышлы мәгълүматлар төгәл түгел, чөнки җитештерүчеләрнең барысы да үз пр-тиеләре турында төгәл мәгълүмат җиткереп бармый. Казан губернасындагы сәнәгать үсешенә бәя биреп, 1845 тә губернатор: «Чимал эшкәртү ысуллары иске һәм камил түгел, шуңа күрә сәнәгатьтә көтелгән үзгәрешләр юк», — дип яза. Җитештерү, нигездә, кул көченә көйләнгән була. Пар двигателе уйлап табылып, сәнәгатьтә кискен борылыш ясалганнан соң, капиталистик юл б-н баручы М.лар да, завод һәм фабрикалар б-н көндәшлеккә сәләтен югалтып, ябыла башлыйлар. Шул ук вакытта, 20 йөз башында Казан губернасында әле кул көченә корылган җитештерү өстенлек итә. Пр-тиеләрнең күбесендә механик җайланмалар булмый, эшләүчеләр саны — уртача 5 кеше.

Ш.у.к. *Индустрияләштерү*.

Чыг.: История Татарии в материалах и документах. М., 1937.

*Әд.:* Бурнашев В. Очерки истории мануфактур в России. СПб., 1883; Обзор различных отраслей мануфактурной промышленности России. СПб., 1862. Т. 1–2; Туган-Барановский М.И. Избранное. Русская фабрика в прошлом и настоящем. М., 1997; Карл Фукс о Казани, Казанском крае. К., 2005.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МАҢГА́Й ТӘҢКӘСЕ́**, хатын-кыз киеме элементы — Урал алды (Уфа һәм Пермь губерналары) татарларында 20 йөз башына кадәр яшәп килгән чәч япмасы. Өсте ачык итеп ту-

кымадан эшләнгән түгәрәк башлыктан гыйбарәт. М.т.нең иң гади төре — маңгайга бәйләнә торган киндер тасма, башлык рәвешенә китерү өчен аның өске кырыен шнур б-н җыеп тарттырганнар. Баш киеменең маңгайга туры килгән өлеше чуклар тагылган укалы тасма яки тәңкәләр б-н бизәлгән. М.т.н яулык астыннан, элекке заманнарда өчпочмаклы зур баш япмасы — кыекча астыннан кигәннәр.

*Әд.:* Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000. *Ф.Ф.Гулова.*

**МАҢГЫ́Ш** (Мангыс, Мангас, Мангус), «Ак Күбек» дастанының Себер татарлары варианты персонажы. Кидан ханның улы. Эпик геройның иң куркыныч дошманы. Төрки-монгол мифологиясе һәм героик эпосындагы шул ук исемдәге персонаж кебек, кеше ашаучы зат. «Джангар» калмык героик эпосы б-н дә охшашлыклар бар. М. бик көчле, хәтта йоклаган килеш тә аны кеше тиресеннән тегелгән каешлар б-н генә бәйләп куеп була. М. — явыз рух, аның б-н көрәшү бик кыен. Шуңа да эпик геройның аны җиңүе аеруча әһәмияткә ия.

*Әд.:* Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4; Пекарский Э.К. Словарь якутского языка. П., 1917. Т. 1; Фалев П.А. Ногайская сказка об Ак Кобеке // Сб. Музея антропологии и этнографии. 1918. Т. 5; вып. 1; Героический эпос народов СССР. М., 1975. Т. 1; Урманчеев Ф. Героическое сказание «Ак Кубек» // Советская тюркология. 1977. № 3. *Ф.И.Урманчеев.*

**МАРА́Ш** (Maraş) Ибраһим (23.8.1967, Төркиянең Киршәһәр провинциясе Каман р-ны), тарихчы, ислам дине белгече, теология д-ры (2000). Әнкара ун-тын тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук эшли. Бер үк вакытта, 1995–96 елларда, Татарстанда һәм Башкортстанда тарихи-социол. тикшеренүләрдә катнаша, Казан пед. ун-тында; 2001–02 дә ТРдагы социомәдәни хәлне тикшерү б-н җитәкчелек итә; 2003–04 тә Казан ун-тының Көнчыгышны өйрәнү ин-тында укыта. Бер үк вакытта, 2002–03 тә, Хартум ун-тында (Судан) эшли. Хезмәтләре ислам динен өйрәнү, төрки халыкларда дини хәрәкәтләр тарихы, Татарстанда ислам диненең торышы мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Религиозное обновление в Тюркском мире. К., 2005; Традиционное понимание ислама в Волго-Уральском регионе // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2006. № 1; Günümüz Tatarstan'inin Sosyal ve Kültürel Yapisi (Kazan Örneği). Ankara, 2003; Islam Felsefe Geleneğinde Nur Metafiziği. Ankara, 2007.

**МАРЕНАЧАЛА́Р** (Rubiaceae), гентианачалар рәтеннән ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Бер- һәм күпьеллык үләннәр, куак, ярымкуак, агачлар һәм лианалар. 500 дән артык ыруг һәм 6,5 меңнән артык төре билгеле, ике ярымшарда да, башлыча, тропик һәм субтропикларда киң таралганнар. ТР терр-ясендә 4 ыруглан (жерардия, сырмавык, йогырт, буяу үләне) 24 төре билгеле. Яфраклары каршыдаш яки сабакка бөҗрасыман урнашканнар, гади, бөтен, төпчек яфраклары бар. Чәчәкләре берле, 4–5 буынлы, еш кына ике җенесле, дөрес формада, өске чәчәк төркеменә җыйналган. Чәчәге, касәсе җимшән б-н кушылып үсү нәтиҗәсендә, тулысы б-н диярлек редукцияләнә яки җимшән очында кечкенә тешчекләр рәвешен ала. Таҗ тоташ яфракчыклы, көпчәксыманнан көпшәле-бүрәнкәсыманга кадәр. Чәчәк баганачыгы төбендә нектар түгәрәге урнашкан. Гадәттә, җимшәне түбән һәм ике оялы. Чәчәкләренең ачык төстә, хуш исле булулары б-н берләттән, кайбер М.да аксыл үзәкле чәчәк төркеме яки ак төстәге эре чәчәк яны яфраклары бар. Җимеше — тартмачык, җиләк, икеле чикләвекчек. Орлыклары бик вак. М. җимешләре б-н күгәрченнәр, миләш чыпчыклары туклана. Сырмавык, йогырт, декоратив; йогыртның кайбер төрләре — баллы үсемлекләр. Кытыршы сырмавык, өч чәчәкле йогырт, татар буяу үләне ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**МАРИ́** Осип (Иосиф) Антонович (1755, Италия, Мантуя ш. — 10.3.1819, Казан), архитектор, классицизм вәкиле. Италиядә инженер дәрәҗәсе ала. 1784 елда Г.А.Потёмкин тарафыннан Россиягә чакырыла. Смоленск драгун полкында исәпләнә, бер үк вакытта Севостополь шәһәрендә ныгытмалар салу б-н шөгыльләнә, 1796 дан — отставкада. 1798 дән Казан гимназиясе архитекторы һәм архит-ра укытучысы, 1801 дән Казан адмиралтейство архитекторы, 1818 дән — Казан ун-ты архитекторы. 1815 тә Казандагы янгыннан соң шәһәрнең ген. планын камилләштерә. Казандагы күп кенә торак йортларның проектлары авторы.

*Әд.:* Дульский П.М. Классицизм в Казани. К., 1920.

**МАРИ́ БҮЛӘ́Р** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 28 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы буенда. 2010 елда 276 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1747 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.Б. дә земство мәктәбе, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1156,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 669, 1926 да — 756, 1938 дә — 590, 1949 да — 536, 1958 дә — 381, 1970 тә — 440, 1979 да — 360, 1989 да — 265, 2002 дә — 288 кеше.

**МАРИ́ РЕСПУ́БЛИКАСЫ** (Марий Эл Республикасы), РФнең Европа өлешендә, Идел бассейнының урта өлешендә урнашкан. Идел буе федераль округына керә. 1920 елның 4 ноябрендә Мари автономияле өлкәсе буларак оештырыла, 1936 ның 5 декабрендә Мари АССР итеп үзгәртелә, 1990 ның 22 октябреннән — Мари Совет Социалистик Респ-касы, 1992 нең 8 июленнән — Мари Респ-касы. Мәйданы — 23,2 мең *км*². Башкаласы — Йошкар-Ола шәһәре (Мәскәүдән 862 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 690349 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 да — 38821, 1970 тә — 40280, 1979 да — 40917, 1989 да — 43747, 2002 дә — 43377, 2010 да — 38,4 мең кеше. М.Р. терр-ясе *Идел буе Болгар дәүләте*, *Алтын Урда* һәм *Казан ханлыгының* тарихи йогынтысында була. Мари якларында татарлар 15–16 йөзләрдә күренә башлый. 17–18 йөзләрдә хәзерге М.Р.ның көньягында, башлыча, йомышлы татарлар нигез салган беренче татар авыллары (кайберләре хәзерге көндә дә яши) төзелә. Татарларның традицион шөгыле — игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, урманчылык һ.б. 1920–30 елларга кадәр татарлар тупланып яшәгән авылларда мәчетләр эшли: Алашайка (Мазарбашы) (2), Алмаметьево (Кышна), Ирнур, Күлбаш, Купай, Куян (2), Кече Исмаил, Поле-Кугунур, Портчара, Портанур (2), Починок Портанур (хәзер Кызыл Байрак), Починок Чекманур, Татар Чодраялы (Мари Комыргуҗасы) (2), Таштоял (Иске Авыл), Хәбибуллин, Хәсән һ.б. Совет чорында укытуны татар телендә алып баручы мәктәпләр һәм сыйныфлар була. Бәрәңге р-нында 1932 дән — «Удар колхозчы», 1940–91 дә «Коммунизмга» г-талары чыга. М.Р.да татарлар 1930 елларда һәм сугыштан соңгы чорда яңа сәнәгать объектлары төзелү б-н бәйле рәвештә шактый күбәя. Хәзерге вакытта татарлар тупланып Йошкар-Ола (2002; 12858 кеше) һәм Волжск (8231) шәһәрләрендә, Бәрәңге (8825), Мари-Төрек (4860), Морки (3177), Звенигово (2239), Медведев (1454) р-ннарында; сирәгрәк Козьмодемьянск шәһәрендә (235), Советский (529), Сернур (240), Волжск (182), Килемары (188), Куженер (114), Оршанка (109), Таулы Мари (58), Яңа Торьял (56) һәм Юрино (52) р-ннарында яшиләр. М.Р. татарларының төбәк милли-мәдәни автономиясе (Йошкар-Ола), Йошкар-Ола татарларының милли-мәдәни автономиясе, Медведев р-ны татарларының «Дуслык» автономиясе, Морки р-ны татарларының милли-мәдәни автономиясе, «Туган тел», «Мирас» җәмгыятьләре, «Дуслар» татар яшьләре иҗтимагый оешмасы эшли. 1997 дән Йошкар-Олада «Республика татар мәдәнияте үзәге» мәдәният дәүләт учреждениесе эшли, аның каршында татар телен, тарихын һәм әдәбиятын, гарәп телен һәм Коръән нигезләрен өйрәнү курслары; «Сандугач» татар җыры, «Болгар» халык биюләре, «Рәйхан» фольклор төркеме; ветераннар өчен «Хыял», «Тургай» гармунчылар, «Мөслимә» хатын-кызлар, «Очрашу» яшьләр клублары һ.б. эшли. Республика татар мәдәнияте үзәге Сабан туе, Нәүрүз бәйрәмнәрен, Каз өмәсе, Корбан, Нардуган, Рамазан кебек дини һәм йола бәйрәмнәрен; татар әдәбияты көннәрен; татар поэзиясен сәнгатьле уку (М.Җәлил һәм М.Р.да туган Г.Кормашев истәлегенә багышлап), «Сылукай», «Уйнагыз, гармуннар!», татар телендә КВН һ.б. конкурсларны; «Чулпан» татар балалар иҗаты фестивален; татар-башкорт көрәше буенча респ-ка беренчелегенә ярышлар үткәрә. Татар мәдәнияте үзәкләре Волжск шәһәрендә, шәһәр тибындагы Бәрәңге посёлогында эшли; Мари-Төрек р-нының Дружино авылында Татар мәдәнияте йорты ачылган. М.Р.нда респ-ка дәрәҗәсендә «Татар җыры»

конкурсы (1993, 1995, 1997, 2001), «Сөембикә — 2001» татар үзешчән сәнгать, М.Р.ның кече татар театрлары (2007, 2008) фестивальләре уздырыла. Бәрәңге р-нында — 58 (ш.и. 29 балалар төркеме), Морки р-нында 17 (ш.и. 3 балалар төркеме) үзешчән сәнгать коллективы эшли; иң популярлары — «Яшьлек» һәм «Ялкын» ансамбльләре. Бәрәңге р-ның Портанур авылы мәдәният йорты каршында татар халык театры эшли. 1993 тән респ-ка телевидениесендә ай саен «Туган тел», 1998 дән атнага 2 тапкыр — сишәмбе һәм шимбә көннәрендә — «Бүләккә җыр», радиода 1995 тән айга бер тапкыр «Туган як» информацион-муз. тапшыруы чыга. 1992 дән Бәрәңге р-нында «Безнең тормыш» татар район г-тасына кушымта чыгарыла. 2007/08 уку елында Мари-Төрек р-нының 4 мәктәбендә (238 укучы), Морки р-нының 3 мәктәбендә (153), Бәрәңге р-нының 4 мәктәбендә (773) татар теле укытыла. Красногорский посёлогы урта мәктәбендә татар сыйныфы (26 укучы) ачылган. 1998 дә М.Р.да Төбәк мөселман дини нәзарәте оештырыла.



Мари Республикасы.
Йошкар-Ола шәһәрендәге мәчет.

2006 да 23 мәчет эшли, ш.и. Йошкар-Оладa — 2, Волжск шәһәрендә — 1, Звенигово р-нының Красногорский посёлогында — 1, Советский р-нының Советский посёлогында — 1, Морки р-нында — 5 (Морки, Октябрьский, Күлбаш, Кышна пос., Татар Чодраялы), Мари-Төрек р-нында — 5 (Мари-Төрек, Мариец пос., Татар Кетнәсе, Пыжмара, Шишинер а.), Бәрәңге р-нында — 8 (Бәрәңге штп (2), Мазарбашы, Портанур, Ирнур, Куян, Портчара, Хәсән а.); Медведев р-нының Медведево посёлогында һәм Бәрәңге р-ның Поле-Кугунур авылында мәчетләр салына. 2007 дән Мазарбашы авылында мәдрәсә эшли. ТР Мәдәният министрлыгы б-н М.Р.ның Мәдәният, матбугат һәм милләтләр эше министрлыгы арасында мәдәни хезмәттәшлек турында килешү төзелә. Татарлар яшәгән р-ннарда (Бәрәңге р-ны һ.б.) Татар мәдәнияте көннәре, татар язучылары һәм мәдәният эшлеклеләре б-н очрашулар, Казаннан, Татарстанның башка шәһәр һәм районнарыннан килгән артистлар һәм иҗат коллективлары гастрольләре үтә. Сов. Союзы Геройлары Х.Х.*Хәсәнов*, Т.К.*Кержнев*, Ә.Г.*Гайсин*, фашистларга каршы яшерен оешма (к. «*Җәлилчеләр төркеме*») җитәкчесе Г.Н.*Кормашев*, Соц. Хезмәт Герое И.М.Мортазин, очучы-сынаучы, РФ Герое Р.А.Бариев, техник фән. д-рлары Г.С.Юнысов, М.Г.Салихов, биол. фән. д-ры Р.И.Винокурова, икътисад фән. д-ры М.М.Әхмәдиева, а.х. фән. д-рлары Ф.В.*Әһлиуллин*, Ә.Һ.*Газизуллин*, Л.Р.*Шәрифуллин*, композитор А.Б.*Луппов*, цирк артисты Г.Г.*Гыйбадуллин*, җиңел (Ф.Ш.Гаптуллин) һәм авыр (И.М.Нигъмәтуллин) атлетика буенча Россия чемпионнарының тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М.Р. б-н бәйле.

*Әд.:* Национальные проблемы татар, проживающих в Республике Марий Эл: Материалы науч.-практ. конф. Йошкар-Ола — Параньга, 1996; Муравьёв А.В. Этнокультурная мозаика Республики Марий Эл. Йошкар-Ола, 2006.

*Р.З.Юлдашев, Э.В.Габдрәхимова.*

**МАРИ́ СУЫКСУЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 29 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 497 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1722 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черемисские Суксы исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, аучылык б-н шөгыльләнә. *Крәстияннәр кузгалышында* (1773–75) халкы Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, 4 җил тегермәне, 1896 дан әвен эшли. 20 йөз башында кредит ширкәте була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1200,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 261, 1859 да — 425, 1870 тә — 445, 1884 тә — 500, 1906 да — 669, 1913 тә — 623, 1920 дә — 628, 1926 да — 658, 1938 дә — 628, 1949 да — 546, 1958 дә — 559, 1970 тә — 653, 1979 да — 591, 1989 да — 498, 2002 дә — 511 кеше.

**МАРИ́ ТӘКӘШЕ́** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 21 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — умартачылык. 18 йөз ахырында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле әштә эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 434,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 58, 1887 дә — 47, 1905 тә — 72, 1920 дә — 333, 1926 да — 336, 1938 дә — 100, 1949 да — 90, 1958 дә — 105, 1970 тә — 108, 1979 да — 60, 1989 да — 27, 2002 дә — 26 кеше (1920, 1926 елгы мәгълүматлар Татар Тәкәше авылын да кертеп бирелә).

**МАРИ́ ТЕЛЕ́**, мари халкының теле, фин-угор телләре семьялыгына керә (Идел буе-фин телләре төркемчәсе). Мари телендә сөйләшүчеләр (к. *Марилар*) Мари, Башкортстан, Татарстан, Удмурт Респ-каларында, Киров, Свердловск, Түбән Новгород өлкәләрендә, Пермь краенда һәм РФнең башка төбәкләрендә тыгыз урнашып яши. Аларның гомуми саны 604 мең кеше, ш.и. ТРда — 18,8 мең (2002). М.т. тау мари, болын мари, көнчыгыш мари һәм төньяк-көнбатыш мари диалектларына бүленә; төп фин-угор үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, төрки (8 йөздән) һәм рус (13 йөздән) телләре йогынтысында үсеш ала. Тартык авазлар — 22, сузык авазлар — 8 дән алып 12 гә кадәр (җирле сөйләшләргә карап). Грамматик мөнәсәбәтләр башка *агглютинатив телләрдәге* кебек, нигездә, кушымчалар ярдәмендә белдерелә. Язу рус графикасы нигезендә үсеш ала (19 йөз). Әдәби тел 20 йөз башында формалаша. Аңа беренче мари язучыларының (С.Г.Чавайн, М.С.Герасимов-Микай, Н.С.Мухин һ.б.) әсәрләре басылып килгән «Мари календарьлары»ның («Марийские календари», 1907–13) йогынтысы зур була. Мари әдәби теленең 2 төре бар: болын-көнчыгыш мари һәм тау мари. М.т. Мари Респ-касының дәүләт теле санала (рус теле б-н беррәттән). Башлангыч мәктәпләрдә укыту М.т.ндә алып барыла, бу телдә дәреслекләр, әдәби һәм публицистик әдәбият басыла, газета һәм журналлар чыга, теле- һәм радиотапшырулар алып барыла, спектакльләр куела. М.т. мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында өйрәнелә; Мари теле, әдәбияты һәм тарихы фәнни-тикшеренү ин-ты, Мари ун-ты, Мари пед. ин-ты фәнни тикшеренүләр үзәге булып тора.

*Әд.:* Марийско-русский словарь. М., 1956; Современный марийский язык: В 2 ч. Йошкар-Ола, 1960–61; Русско-марийский словарь. М., 1966; Национальный состав и владение языками, гражданство: Итоги Всероссийской переписи населения 2002 года. М., 2004. Т. 4.

**МАРИ́-ТӨРЕ́К РАЙОНЫ́**, *Мари Республикасының* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 1,5 мең *км*$^2$. Үзәге — Мари-Төрек посёлогы (Йошкар-Оладан 125 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 21588 (2012), татарлар — 4231 кеше (2010). Татарлар, башлыча (2002), Мари-Төрек (1760 кеше), Мариец (558), Яңа Павловский (148) посёлокларында, Татар Кетнәсе (1042), Кече Шишинер (1451), Дружино (129), Ведерники (114), Кече Исмаил (103), Яңа Пыжмара (98), Кече Түнтәр (74), Татар Шолкеры (70), Болгарлар (69), Яңа Мир (60), Кече Носа (40), Яхин (32), Югары Мир (22) авылларында яшиләр. М.-Т.р.да татарлар 16 йөздә Казан ханлыгы рус гаскәрләре тарафыннан яулап алынгач (1552) һәм Рус хөкүмәтенең халыкны көчләп христианлаштыру сәясәте нәтиҗәсендә барлыкка килә. Татар миграциясенең көчле дулкыны (башлыча, Кукмара, Балтач, Арча р-ннарыннан) 1930 еллардагы күмәкләштерү чорында теркәлә.



Марилар. 1. Тәүге мари галимнәренең берсе В.М.Васильев мари авылында яшәүчеләр б-н. 1926. «Мари халык сәнгате» («Марийское народное искусство», 1985) китабыннан; 2. Таулы Мари фольклор ансамбле. Мари Респ-касы. 2010; 3. Мари хатын-кызлары костюмы. 19 йөз. РФАнең Бөек Пётр исем. Антропология һәм этнография музее. С.-Петербург.

1917 гә кадәр Татар Кетнәсендә кәгазь һәм комач-кытай ф-калары, 3 мәчет; Татар Шолкерында кәгазь җитештерү ф-касы, су тегермәннәре, мәдрәсә; Кече Исмаилда мәчет (1930 елларга кадәр) эшли. Татар мәктәпләре Яхин (1931–61), Яңа Пыжмара (1933–75), Яңа Мир (1931), Кече Носа (1950 елларда), Дружино (1950 елларда) авылларында эшли. Хәзерге вакытта мәчетләр Татар Кетнәсе (1999 дан), Яңа Пыжмара (1996 дан), Кече Шишинер (2003 тән) авылларында, Мари-Төрек посёлогында (2006 дан) эшләп килә. Татар Кетнәсе, Дружино, Болгарлар, Яңа Мир авыллары, Мариец, Яңа Павловский посёлоклары мәктәпләрендә татар теле фән буларак укытыла. Татар Кетнәсе, Дружино авыллары мәдәният йортлары каршында драма түгәрәкләре һәм вокаль ансамбльләр (1990 еллардан) эшли. М.-Т.р.да Татар мәдәнияте көннәре, Сабан туе, Нәүрүз, Корбан һ.б. бәйрәмнәр үткәрелә. ТР б-н М.-Т.р. арасында тыгыз мәдәни бәйләнешләр (Арча, Балтач р-ннары коллективларының концерт программалары б-н алмашу) урнашкан. Районда Соц. Хезмәт Герое И.М.Мортазин, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре Н.К.Камилов, ТАССРның атказ. артисты Г.Г.Гыйбадуллин туган.

**МАРИИ́НСК РАЙОНЫ́**, *Кемерево өлкәсенең* төньяк-көнчыгышында урнашкан. Мәйданы — 5,6 мең *км*$^2$. 1976 елда оештырыла. Үзәге — Мариинск шәһәре (Кемерово ш.ннән 367 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 56832 кеше (2012). Татарлар — 898 кеше (2010), башлыча, Туйлы (166 кеше), Куркули (156) һәм Тундинка (146) авылларында яши. М.р.на татарлар 20 йөз башында, Столыпинның аграр реформасы нәтиҗәсендә килә. Бу чорда Куркули һәм Тундинка авылларына нигез салына (1912 еллар тирәсе). 1920 дә Туйлы авылы төзелә, 1925–31 дә мәчет, мәктәп була, анда гарәп теле, ислам нигезләре өйрәнелә; хәзерге вакытта Татар милли-мәдәни үзәге (2003 тән), музей, китапханә, «Безнең динебез» түгәрәге, «Туйлы кызы» үзешчән коллективы эшли. Куркули авылы урта мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла, милли традицияләрне өйрәнү буенча факультатив дәрес кертелгән, «Мирас» фольклор берләшмәсе эшли (1975 тән). М.р.ның татарлар яши торган торак пунктларында ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә. М.р.да Соц. Хезмәт Герое Е.Г.Хәбибуллина туган, РСФСРның атказ. укытучысы Р.М.Миңнебаеваның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге шушы район б-н бәйле.

**МАРИЛА́Р** (үзатамалары — мари, марий; иске рус язмаларында — черемис, татар халкында — чирмеш), фин-угор халыклары төркеменнән, Мари Респ-касының (1920–36 елларда Мари автономияле өлкәсе, 1936–90 да Мари АССР) төп халкы. РФ дә М.ның гомуми саны — 547605 (2010), ш.и. Мари Респ-касында — 290863 кеше. Түбән Новгород (6415 кеше), Свердловск (23801 кеше), Пермь (5395 кеше) өлкәләрендә, ш.у. Башкортстан Респ-касында (103658 кеше), Удмурт Респ-касында (8067 кеше) тупланып яшиләр; ТРда — 18848 кеше, башлыча Әгерҗе, Актаныш, Алабуга, Кукмара, Менделеев, Минзәлә, Мөслим р-ннарында гомер итәләр. 3 этнографик төркемгә бүленәләр: тау ягы М.ның күпчелеге Иделнең уңъяк ярында һәм Ветлуга буенда яши, болын ягы М.ы — Ветлуга-Вятка елгалары аралыгының калган өлешен, көнчыгыш тараф М.ы Вяткадан көнчыгыштагы терр-яне, Кама һәм Урал алдындагы җирләрне билиләр (алар анда 16–18 йөзләрдә килеп урнашалар). Мари телендә (к. *Мари теле*) сөйләшәләр, язулары — рус алфавиты нигезендә. Башлыча, православие динен тоталар (массачыл христианлаштыру 18–19 йөзләрдә уздырыла), ш.у. христианлык һәм традицион инанулар катнашмасыннан гыйбарәт «мари дине» («марла вера») тарафдарлары да бар. Б.э.ның 1 нче меңьеллыгында формалашкан борынгы мари этносының үзәген фин-угор кабиләләре тәшкил итә. М. оешуы һәм үсешендә *болгарлар*, соңрак *татарлар* (болын ягы М.ның көнчыгыш төркемнәренә төрки күршеләренең йогынтысы зуррак була: аларның бер өлеше ислам динен кабул итә), яңа дәвердә *руслар* б-н (бигрәк тә төньяк-көнбатыш һәм тау ягы М.да сизелерлек чагыла) этномәдәни багланышлар зур роль уйный. Аеруча *чуаш* мәдәнияте һәм көнкүреше б-н охшашлыклар бар (беренче чиратта, тау ягы М.да һәм болын ягы М.ның көньяк төркемнәрендә).

Элек, сирәк очракларны исәпкә алмаганда, М. авылларда яшиләр, хәзерге вакытта М.ның 60% тан артыгы авыл тормышы алып бара. Җәмәгать җир биләве һәм патриархаль тәртиптә җирдән файдалану 1930 елларга кадәр саклана; катлаулы авыл җәмәгате өстенлек итә (к. *Авыл җәмәгате*). Төп шөгыльләре — сөрүле игенчелек. Туфрак сука (шогавуй), сабан (агавуй, сабан), тырма (тырма, шүре), китмән (кәтмән) б-н эшкәртелә. Төп басу культуралары — арыш, солы, арпа, тары, карабодай, бәрәңге; техник культуралар — киндер, җитен, колмак; яшелчәләр — суган, кәбестә, торма, кишер. 19 йөздә тау ягы М.да бакчачылык үсеш ала. М. атлар, мөгезле эре терлек, сарыклар, йорт кошлары асрыйлар; дуңгыз һәм кәҗәләр сирәк очрый, чөнки алар «хәрам», корбанга яраксыз санала. Сунарчылык, балыкчылык, чолыкчылык (соңрак — умартачылык), кыргый җиләк-җимеш, гөмбә җыю икенчел роль уйный. Агач, үсемлек сүсе, йон, күн эшкәртү б-н бәйле кәсепләр (күмер яндыру, сумала кайнату, кап сугу, үрелгән әйберләр җитештерү һ.б.) шәхси хуҗалыкта әһәмиятле санала, әмма капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше чорында аларның продукциясе инде товар булып китә. Үсешкә ирешкән сәнгать һөнәрләре: зәргәрчелек (көмештән хатын-кыз бизәнү әйберләре эшләү), агачны кисеп бизәкләү, тукучылык, чигү.

М. элек-электән елга-ерым буйларында таралып яшиләр. 19 йөзнең 2 нче яртысында авылларда йортларның таркау урнашуы урамнарга бүленү тәртибе б-н алышына башлый: урнашуның төньяк-рус төре өстенлек итә. Тораклары — ике бүлемле (өй-өйалды) яки өч бүлемле (өй-өйалды-өй һәм руслардан кергән өй-өйалды-келәт), ике яклы түбәле буралган йорт. Мари төбәгенең төньягында һәм көнбатышында рус традицияләре йогынтысында бүлеп алынган аш-су әзерләү урыны, рус миче һәм сәндерәләре булган йортлар өстенлек итә. Көнчыгышта, бигрәк тә Кама

алдында, мари өенең эчке күренеше татар интерьерын хәтерләтә — казаны сылап ябыштырылган мич, түр дивар буенда киң сәке, бүлеп алу өчен чаршаулар элү һ.б. Гадәти утар корылмаларына амбар яки еш кына ике катлы, икенче катында галерея булган бина рәвешендәге келәт, баз, сарай керә, бай утарларда әвенле ындыр табагы да була. Җәйге чорда файдаланыла торган торак-кухня (кудо) борынгы корылма булып исәпләнә — ул җир идәнле, түшәмсез итеп җиңелчә бурадан эшләнә; казан асылган ачык учактан төтен чыксын өчен түбәсе ярык калдырып ябыла. Элекке вакытта кудо ш.у. гаилә-нәсәп вәкилләренең җыелып гыйбадәт кылу һәм йолалар башкару урыны булып та хезмәт иткән. Мунча, гадәттә, ындыр артында, су чыганагына якынрак җирдә салынган.

М.ның традицион кием үзенчәлекләре, аның аерым вариантлары хатын-кызлар киемендә ачыграк чагылыш таба. 19 йөздә — 20 йөз башында аның төп элементлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт була: туника сыман өлгеле күлмәк (тувыр), ыштан (йолаш), туры арттакталы ачык чабулы яисә кисеп бөрмәләнгән кафтан (шовыр), алъяпкыч (ончылсакыш), бил тастымалы (солык), пута (юштә); көнчыгыш мари хатын-кызларында төрки халыклар үрнәгендәге чуар күлмәк таралыш ала, аны, татар һәм башкорт хатын-кызлары гадәтенчә, путасыз кияләр. Көндәлек киемнәрне дә тегеп, чигеп, аппликация юлы б-н бизәклиләр, әмма бәйрәм һәм туй киемнәре аеруча купшы бизәлә, аларга өстәмә рәвештә күпсанлы зәркән бизәмәләр кулланыла — бил, күкрәк, муен, колак бизәмәләре сәйләннәрдән, кабырчык, ялтыравык, тәңкәләрдән эшләнә, ш.у. төрле көмеш беләзек һәм йөзекләр кию гадәте яшәп килә. Кияүдәге хатын-кыз баш киеменең 3 төре киң таралган була: баш чүмечена куела торган яссы калаклы конус рәвешендәге калфак (шымакш), баш сөлгесе (шарпан), руслардан кергән каты өсле турыпочмаклы тәкыя (сорока). Шурка — мордва һәм удмурт хатын-кызларыныкы кебек үк, каен тузыннан ясалган борынгы биек баш киеме, 19 йөз ахырына кулланылыштан төшеп кала. Өске кием булып ак яисә кара постаудан туры итеп һәм киселеп, бөрмәләп тегелгән кафтаннар (мыжер), кайры һәм манылган киндер яки фабрикада эшләнгән тукыма б-н тышланган туннар (ужга) хезмәт итә. Аяк киеме — чабата (йыңдал), күн итек (кем), киез итек (межгем). Мари хатын-кызларында элек-электән аяк балтырларын кара постау ыштырлар б-н чолгап кую гадәте яшәп килгән, шуңа күрә күрше татарлар аларны «кара аяклар» дигәннәр.

М.ның традицион ризыклары — чумарлы аш (лашка), ит яки эремчек пилмәне (подкогыльо), ит, терлек мае яки каннан ярма кушып пешереп әзерләнгән казылык (сокта), какланган ат казылыгы (каж), катлы белен (команмелна), көлчә (эгерче), төче солы икмәге (шергинде). М.га гына хас кайбер ашларны әзерләгәндә тиен, керпе, тузбаш, зәһәр елан ите, балык оны, киндер орлыгы кулланылган. Карчыга, байгыш кебек киек кошлар итеннән аерым ризыклар әзерләнгән, шул ук вакытта кыр казлары, торна, аккош һәм күгәрченнәрне аулау тыелган. Киң таралган эчемлекләр — сыра (пура), каты бал (пуро), пахта (эран).

М.да зур булмаган моногамик гаиләләр өстенлек итә, әмма бүленеп чыкмаган, 3–4 буын якын туганнарны берләштергән зур гаиләләр дә була. Патрилокаль никах хөкем сөрә; никах килешүе төзегәндә кәләшнең ата-анасына калым (олно) түлиләр, ә алар кызларына мал-мөлкәт (пого) һәм мал-туардан (кузык) бирнә бирәләр. Катнаш никахлар ешрак руслар һәм чуашлар б-н очрый. Туй йоласы музыка, җыр, биюләр б-н уза торган күп этаплы катлаулы ритуалдан гыйбарәт. Хуҗалык эшләре б-н тыгыз бәйләнгән бөтенхалык бәйрәмнәре дә шамакайларның театрлаштырылган тамашалары, уеннар, музыка (киң таралган уен кораллары — барабан, сорнай, сыбызгы, гөслә, агач трубалар, 19 йөзнең 2 нче яртысыннан — гармун), үзенчәлекле җырлар (муро), биюләр б-н уза. Булачак игеннәр уңышы, терлек үрчеме, кияүләр турында багулар урын алган Яңа ел бәйрәме, «шорык йол», руслардагы май чабуга охшаш «уйарня» бәйрәме, «ага пайрем» — бергәләшеп гыйбадәт кылу һәм корбанга иген бирү йоласы башкарыла торган язгы сабан бәйрәме, җәйдә «явыз рухлар»ны куу йоласы (М. шакылдавык һәм торба тавышлары астында йорт-каралты диварларына камчылар, чыбыклар б-н сугалар) уздырылган «сурем» бәйрәме, яңа уңыш ашлыгыннан йола ризыклары пешереп һәм гаилә гыйбадәтләре кылып, көзге «угинде пайрем» билгеләп үтелгән. Христиан календаре бәйрәмнәренә дә мәҗүси йола элементлары өстәлгән. башкортлар, татарлар б-н якын күршеләр булып яшәгән төбәкләрдә М. *Җыен*, *Сабан туе* бәйрәмнәрендә катнашканнар. Галәмдәге тормыш көче, аллалар ихтыяры, явыз рухлар, бозым, күз тию, мәрхүмнәр җаны турындагы карашларга нигезләнгән, традицион булмаган медицина үсеш алган. Им-томчылар һәм сихерчеләрне гаять яшерен шартларда остазлар укыткannar.

Мәрхүмне кышкы киемнәр кидереп җирләү, җәйге чорда мәетне зиратка чанага салып алып бару — бабалар культының борынгыдан килгән үзенчәлекләре. Традицион җирләү йоласында ахирәттәге дөнья (кыямәт) турындагы карашлар чагылыш тапкан: кабергә киндер кисәге (мәрхүмнең җаны күпердән чыккандай упкын аша ахирәткә күчсен өчен); гөләп ботаклары (үлеләр патшалыгы капкасын саклаучы еланнарны һәм этләрне куу өчен); мәрхүмнең гомер буе җыелган тырнаклары (алар ярдәмендә, имеш, ул ахирәткә күчкәндә тау-кыялар аша үтеп чыга) куелган.

19 йөз ахырында – 20 йөз башында милли үзаң үсеше күзәтелә;. 1907 дә мари телендә беренче вакытлы басма — еллык «Марла календарь» («Мари календаре») басыла, 1915 тә беренче мари газетасы нәшер ителә башлый. 19 йөз ахырында аз санлы милли интеллигенция, башлыча, укытучылардан тора; аларның агарту эшчәнлеге һәм төбәкне өйрәнү юнәлешендәге беренче тикшеренүләре — мари халкының тарихы, этнографиясе, теле һәм фольклоры буенча материаллар җыю һәм бастырып чыгару — этнос үсешендә зур роль уйный. Әмма М.ның икътисадын һәм мәдәниятен күтәрүдә, милли эшчеләр сыйныфы, интеллигенция, колхоз крәстияннәре кадрлары формалашуда совет хакимияте чорындагы үзгәртеп корулар хәлиткеч әһәмияткә ия була. Хәзерге вакытта М.ның милли һәм сәяси активлыгы үсешенә Бөтенмари Советы (Марий Мер Канаш, 1992 дән), «Марий Ушем» мари милли җәмәгать оешмасы (1917–18 дә, 1990 нан) булышлык итә. 1998 дән ТРда М.ның милли-мәдәни автономиясе эшли, аның төп бурычы — ТРда яшәүче мари халкының мәдәни традицияләрен саклау һәм яңарту. 2011 дә Казанда ТР М.ының Беренче съезды уздырыла. Ш.у.к. *Мари Республикасы*.

*Әд.:* Ф у к с А. Записки о чувашах и черемисах Казанской губернии. К., 1840; С м и р н о в И.Н. Черемисы: Ист.-этногр. очерк. К., 1889; Е в с е в ь е в Т.Е. Обычаи, верованья и суеверия марийцев // Марий Эл. 1927. № 10; К р ю к о в а Т.А. Марийская вышивка. Л., 1951; ш у л у к. Материальная культура марийцев XIX века. Йошкар-Ола, 1956; Х а л и к о в А.Х. Об этнических основах марийского народа // Древние и современные этнокультурные процессы в Марийском крае. Йошкар-Ола, 1976; К о з л о в а К.И. Очерки этнической истории марийского народа. М., 1978; С е п е е в Г.А. Марийцы // Народы Приволжья и Приуралья. М., 1985; П е т р о в В.Н. Марийцы // Народы России. М., 1994; М о л о т о в а Т.Л. Современная материальная культура сельских марийцев // Историко-культурный комплекс Республики Марий Эл. Йошкар-Ола, 1996; Современная этническая культура финно-угров Поволжья и Приуралья. Йошкар-Ола, 2002.

*Ф.Ф.Гулова.*



В.И.Маринин.

**МАРИ́НИН** Виктор Иванович (5.8.1923, Чистай ш. — 20.2.1943, Украина ССР, Донецк өлкәсе Сергеевка а.), Сов. Союзы Герое (31.3.1943, үлгәннән соң), сержант. Автогараж җиһазлары з-дында токарь булып эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 50 нче танк батальоны мотоциклчысы (3 нче танк корпусының 50 нче танк бригадасы). Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында Украинаны азат итүдә катнаша (1943). 1943 нең февралендә Краматорск шәһәре һәм Сергеевка авылы янындагы сугышта батырлык күрсәтә: 3 тапкыр разведкага барып кыйммәтле мәгълүматлар алып кайта; 20 февральдә дошман танкларына каршы сугышка керә, 2 танкны сафтан чыгара, авыр яралана, ләкин сугышуын дәвам итә һәм шунда һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Т р о к а е в А.А. Подвиг на шахтёрской земле. До-

нецк, 1983; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАРИНО́ВИЧ** Андрей Петрович (4.9.1912, Витебск губ. Витебск ш. — 29.12.1996, Казан), биолог-аучылык белгече. Бөтенсоюз мех чималы хуҗалыгы ин-тын (Мәскәү, 1937) тәмамлый, Владимир өлкәсендә, Карелия һәм Якутия АССРларда аучылык һәм мех белгече булып эшли; шул төбәкләрдә нутрия һәм ондатра хуҗалыкларын оештыра. 1954 елдан СССР дәүләт саклаулыклары системасында. 1961–76 да Идел-Кама саклаулыгы директоры. Хезмәтләре саклаулыклар табигатен саклауга һәм фәнни саклаулык фондын булдыруга карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Орден, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Волжско-Камский государственный заповедник // Тр. Волжско-Камского заповедника. 1968. Вып. 1; Опыт учёта лосей с самолёта в Волжско-Камском заповеднике // Волжско-Камский заповедник. К., 1980 (автордаш).

*Ю.А.Горшков.*

**МАРКАРЬЯ́Н** Наполеон Антонович (6.8.1925, Ровно ш., Украина ССР), баллистика өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1981), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), ТАССРның атказ. машина төзүчесе һәм атказ. уйлап табучысы (1985, 1990). Львов ун-тын (1952), Кораблар төзү һәм кораллану хәрби-диңгез академиясен (Ленинград, 1953) тәмамлаганнан соң, В.И.Ленин исем. Казан химия з-дында заказчы (СССР Хәрби-диңгез флоты) вәкиле булып эшли. 1957–2005 елларда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. башлыгы (1961 дән). Хезмәтләре ыргытылма зарядларның эчке баллистикасына, ялкынлану һәм яну процессларына, аларны күпшәле системаларга проектлау һәм конструкцияләүгә карый. М. җитәкчелегендә баллистик характеристикаларга температура сизгерлеге зур булмаган ыргыту зарядлары төзелә, 30 дан артык ыргыту зарядын серияләп җитештерү үзләштерелә. Дәүләт бүләге махсус аппаратлар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 135 авторлык таныклыгы һәм патенты бар, шуларның 41 е җитештерүгә кертелгән. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

**МАРКЕ́ЛОВ** Виктор Фёдорович (30.3.1944, Казан), спортчы (ирекле көрәш), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1967), халыкара категорияле судья (1990), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). 1971 елда Югары тренерлар мәктәбен (Мәскәү өлкәсенең Малаховка ш.), 1980 дә Казан пед. ин-тын тәмамлый. Спорт б-н 1960 тан «Динамо» спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый; тренерлары — В.В.Нелюбин (1960–61), Р.А.Азизов (1961–63), А.Ш.Шәйхетдинов, С.А.Преображенский (1963–75). 1975 тән М.Н.Чистяков исем. Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә укыта. «Динамо»ның Россия советы (1961), СССР (1968, 1970, 1972), РСФСР халыклары спартакиадалары (1967), Дус халыклар армияләре ком-тлары спартакиадалары (1967, 1969, 1971, 1973) чемпионы, Дөнья кубогы (1973) иясе. СССР (1961, яшүсмерләр), Европа (1970) чемпионатларында көмеш медальләр ала. «РФдә Олимпия хәрәкәтен үстерүдәге казанышлары өчен» билгесе б-н бүләкләнә (2004).

**«МАРКИ́З» УТРАВЫ́** («Маркиз», «Комлы утрау», «Гостиный остров»), Идел елгасында, Югары Ослан авылы турысында була. Мәйданы якынча 15 *км²*. 14 йөздә — 16 йөз башында утрауда кунаклар җыены (сезонлы ярминкәләр) уздырыла. 15 йөзнең 2 нче яртысыннан Казан ханлыгының рус кенәзлекләре, Кавказ, Кырым, Себер һәм Урта Азия б-н транзит сәүдәсе (тире-күн, мех, балавыз, тукыма, металл эшләнмәләр, аш тәмләткечләр h.б.) үзәге. Чит ил сәүдәгәрләре — «кунаклар» да (утрауның русча исеме шуннан) күпләп килә. Рус һәм Европа чыганакларында «М.»у. Казан ханлыгына каршы оештырылган яуларда (1524, 1551, 1552) рус гаскәрләре тукталган һәм илчелекләр очрашкан (1523) урын буларак искә алына. Түбән Новгород янында Мәкәрҗә ярминкәсе эшли башлаганнан соң (1524), рус сәүдәгәрләренә «М.»у.на килү тыела. 1552 елдан соң ярминкәләр уздырылмый. 16 йөзнең 2 нче яртысында утрау теркәү кенәгәләрендә Троица-Сергий монастыре (Зөя ш.) биләмәләренең бер кисәге буларак теркәлә. 19 йөздән «Маркиз» исеме б-н танылa, Казан халкының ял итү урынына әверелә. Совет чорында «Комлы утрау» дигән яңа топоним кертү омтылышы була. 1956 да утрауның күпчелек өлеше Куйбышев сусаклагычы астында кала.

Чыг.: Список с писцевой и межевой книги г. Свияжска и уезда 1565–1567 гг. К., 1909; Летописец начала царства царя и великого князя Васильевича // Полное собрание русских летописей. М., 1965. Т. 29; Г е р б е р ш т е й н С. Записки о Московии. М., 1988; История о Казанском Царстве (Казанский летописец) // Полное собрание русских летописей. М., 1903. Т. 19.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

*С.Ю.Измайлова.*

**МА́РКИН** Николай Григорьевич (9.5.1893, Пенза губ. Рус. Сыромяс а. — 1.10.1918, Әгерҗе р-ны Пьяный Бор, хәзер Красный Бор а.), хәрби эшлекле. Гражданнар сугышында катнаша. 1914 елдан Балтыйк флотында. 1917 дә Петроград Советы әгъзасы, Советларның 1 нче Бөтенроссия съезды делегаты, 1 нче чакырылыш БҮБК әгъзасы, «Центрофлот» әгъзасы. Окт. рев-циясе вакыйгаларында катнаша (Петроград). 1917 ел башында Россия Тышкы эшләр халык комис-ты секретаре, соңрак контролеры итеп билгеләнә. РСДРП ҮК күрсәтмәсе б-н элекке Тышкы эшләр министрлыгы архивларының яшерен документларын бастырып чыгару эшен оештыра. 1918 нең июнендә *Идел буе хәрби флотилиясен* оештыру буенча комиссар итеп билгеләнә. 1918 нең августыннан Идел буе хәрби флотилиясе комиссары һәм командир ярдәмчесе. 10 сентябрьдә «Ваня» канонер көймәсеннән десант төшерүгә җитәкчелек итә (к. *Казанны азат итү операциясе*). Сентябрь ахырыннан хәрби суднолар отряды командиры, Кама елгасында барган сугышларда катнаша. 1 октябрьдә Пьяный Бор янындагы бәрелештә һәлак була.

*Әд.:* В а р г и н Н.Ф. Комиссар Волжской флотилии. М., 1961; Н а з а р о в А.В. Николай Маркин. Саратов, 1971.

**МА́РКИН** Юрий Сергеевич (8.9.1938, Рязань өлкәсенең Каверино р-ны Каверино а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002), проф. (1993), ТРның атказ. уйлап табучысы (2005). 1962 елда Рязань а.х. ин-тын тәмамлый. 1961–63 тә Рязань совнархозының махсус КБсында эшли. 1963–84 тә Казан а.х. ин-тында, машина детальләре һәм графикасы каф. мөдире вазифаларын башкаручы (1977–80). 1984–2001 дә Рязань а.-х. академиясендә, теоретик механика каф. мөдире (1984–89). 2001 дән Казан энергетика ун-тында, бер үк вакытта Казан аграр ун-тында (2002 дән) һәм «1 нче номерлы Казан автотранспорт предприятиесе» АҖдә яңа техника буенча киңәшче (2002–06). Хезмәтләре күп массалы системаларның ышанычлылыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре мәсьәләләренә карый. М. тешләр деформациясенең туры тешле цилиндрик тапшыргычлар әйләнеше тигезлегенә тәэсирен тикшерә (тикшерү нәтиҗәләре Рязань станоклар төзү һәм Рязань комбайн машиналары төзү з-дларында гамәлгә кертелгән). Механика буенча укыту-лаб. җиһазлары, югары уку йортларында фәннәрне укыту өчен практикумнар әзерли. Уйлап табуга 115 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Неравномерность вращения и вибрационный контроль зубчатых передач. К., 1982; Восстановление зубчатых передач сельскохозяйственной техники. Рязань, 2001; Учебное и лабораторное оборудование по механике. К., 2004 (автордаш).

**МА́РКОВ** Виталий Михайлович (29.3.1927, Казан — 18.10.2010, шунда ук), тел галиме, филол. фән. д-ры (1965), проф. (1966), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1949). 1951–74 елларда (бүленеп) шунда ук эшли, рус теле каф. мөдире (1964 тән). 1960–61 дә Барнаул пед. ин-тында, 1961–63 тә Горький ун-тында. 1967–68 дә Вроцлав ун-тына (Польша) командировкага җибәрелә. 1974–94 тә Удмурт ун-тының (Ижевск ш.) рус теле каф. мөдире. 1995 тән кабат Казан ун-тында. Хезмәтләре рус теле тарихына карый. М. тарафыннан фәннең яңа тармагы — грамматик лексикология эшләнә. 11 йөз язма чыганакларында теркәлеп калган рус телендәге кыскарган сузыкларның төшеп калу сәбәпләрен ул беренче булып күрсәтә. Аның исем төрләнеше концепциясе тарихи морфологиягә кертеп өлеше булып санала. М.ның күп кенә хезмәтләре сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш сүз төркемнәре тарихына; семантик ысул б-н сүз ясалышы мәсьәләләренә, рус теленең тарихи стилистикасына карый.

Х е з м.: К истории редуцированных гласных в русском языке. К., 1964; Историческая грамматика русского языка: Именное склонение. М., 1974; О семантическом способе словообразования в русском языке. Ижевск, 1981.

*Әд.:* Н и к о л а е в Г.А. Профессор Виталий Михайлович Марков // История русского языка: Словообразование и формообразование. К., 1997.

*Г.А.Николаев.*

**МА́РКОВ** Михаил Васильевич (14.11.1900, Царицын ш. — 15.9.1981, Казан), ботаник, биол. фән. д-ры (1939), проф. (1940), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Казан геоботаника мәктәбе вәкиле (1931–75 елларда җитәкчесе), А.Я.*Гордягин* укучысы. Агрофитоценологиягә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тын һәм бер үк вакытта Казан а.х. һәм урманчылык ин-тын тәмамлый (1924). 1924 тән Казан ун-тында, ботаника (1945–74, 1965 кә кадәр — геоботаника) каф.сы мөдире, проректор (1952–58). Бер үк вакытта, (1925 тән), Казан а.х. ин-тында эшли, ботаника каф. мөдире (1928–47). Хезмәтләре геоботаникага, болынчылык һәм урманчылык белеменә, агрофитоценологиягә карый. М. туфракта һава запасын билгеләүнең кыр ысулын эшли, туфракның тыгызлык дәрәҗәсен үлчәү приборы уйлап таба. Чистай кантоны терр-ясенең агач-куак һәм дала үсемлекләрен өйрәнә, далалану факторларын ачыклый, ТАССРның Кама аръягы терр-ясендә урман һәм даланың үзара бәйлелеген тикшерә, 1936–37 дә киң колачлы стационар тикшеренүләр үткәрә, тикшеренүләр барышында исә «экологик урыннар», «урнашу һәм яшәү тәрәлеге», «үсемлекләрнең экологик һәм фитоценоз оптимумнары», «әйдәп баручы факторлар» һ.б. проблемаларга кагылган теоретик мәсьәләләргә игътибар итә. Татарстан болыннарына тасвирлама бирә, Куйбышев ГЭСы һәм Куйбышев сусаклагычы төзелү нәтиҗәсендә, үсемлекләр капламының үзгәрешен фаразлый (1944–48). 1:200000 (1941) һәм 1:500000 (1943) масштабында ТАССРның геоботаника карталарын төзи. «Татарстан АССР үсемлекләре белешмәсе»н («Определитель растений Татарской АССР», 1979) төзүчеләрнең берсе, «Казан университетында 175 ел дәвамында ботаника» («Ботаника в Казанском университете за 175 лет», 1980) хезмәте авторы. Казан ун-ты каршында оешкан Бөтенсоюз табигыятьчеләр җәмгыяте (1948–74), Бөтенсоюз ботаника җәмгыяте (1959–74) рәисе, аның шәрәфле әгъзасы (1978 дән). Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хез.: Луга Татарской АССР // Уч. зап. Казан. ун-та. 1946. Т. 106, кн. 1, вып. 6; Растительность Татарии. К., 1948; Флора и растительность поймы рек Волги и Камы в пределах Татарской АССР // Уч. зап. Казан. ун-та. 1955. Т. 115, кн. 1, 5 (автордаш); Общая геоботаника. М., 1962; Агрофитоценология. К., 1972; Избр. труды. К., 2000.

*Әд.:* Тематическая подборка, посвящённая деятельности ботаника Михаила Васильевича Маркова // Казань. 2000. № 10.

*Е.Л.Любарский.*

**МА́РКОВ СӨЗӘКЛЕГЕ́**, к. *Урдалы тау.*


**МА́РКОВА** Надежда Григорьевна (23.9.1960, Балык Бистәсе р-ны Рус Әшнәге а.), педагог, пед. фән. д-ры (2010). Чаллы пед. ин-тын (1992), Түбән Кама муниципаль ин-тын (2011) тәмамлый. 1980 елдан Казан һәм Түбән Кама мәктәпләрендә башлангыч сыйныфларда укыта. 2002 дән Түбән Кама муниципаль ин-тында пед., гомуми гуманитар һәм социаль фәннәр кафедрасында (2011 дән проф.), 2003–08 дә пед. фәннәре ф-ты деканы. Хезмәтләре студентлар арасында милләтара мөнәсәбәтләр культурасын, яшьләр арасында толерантлык мәсьәләләренә карый. Югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Культура мира как индикатор бесконфликтных межнациональных отношений. М., 2010; Толерантная культура как индикатор межнациональных отношений. М., 2010.

**МАРКО́ВНИКОВ** Владимир Васильевич (13.12.1837, Түбән Новгород өлкәсенең Княгинин ш. — 29.1.1904, Мәскәү), химик-органик, Мәскәү химия мәктәбенә нигез салучы, химия д-ры (1869), проф. (1870). А.М.Бутлеров шәкерте. 1860 елда Казан ун-тын тәмамлый, Бутлеров тәкъдиме б-н химия лаб-ясендә, «химия б-н шөгыльләнүен дәвам иттерү өчен», лаборант итеп калдырыла. 1865–67 дә профессорлык эшчәнлегенә әзерләнү максатында Германиягә командировкага җибәрелә (Гейдельберг һәм Берлин ун-тларында лекцияләр тыңлый, немец галимнәре А.Байер, Е.Эрленмейер, Г.Кольбе лаб-яләрендә эшли). 1869 дан Казан ун-тында лаб. мөдире. 1871 дә алдынгы фикерле галимнәр төркеме б-н бергә, П.Ф.*Лесгафтның* ун-ттан гаделсез куылуына каршылык йөзеннән, эшеннән китә, шул ук елда Новороссийск ун-тына (Одесса ш.) проф. вазифасына чакырыла. 1873 тән Мәскәү ун-тында, аналитик һәм органик химия каф. мөдире (1893 кә кадәр). Хезмәтләре теоретик органик химиягә, органик синтезга, нефть химиясенә карый. М. тикшеренүләре Бутлеровның органик кушылмалар төзелеше теориясен раслауга һәм тирәнәйтүгә багышланган. Май к-талары арасында изомерия булуны исбатлый, май к-тасы изомерларының галогенлы һәм оксидлы кушылмаларын синтезлый, күп кенә олефин углеводородлар оксидларын ача. Бутлеров карашларына һәм тәҗрибә нәтиҗәләренә нигезләнеп, химик кушылмаларда атомнарның үзара тәэсир итешүе турында тәгълимат төзи, шуның б-н химик төзелеш теориясен тулыландыра, икеле бәйләнешләр буенча алыштыру, аерылып чыгу, кушылу реакцияләренең юнәлеше турындагы кагыйдәне (аерым алганда, *Марковников кагыйдәсе*) формалаштыра. М. нәтиҗәләре атомнарның үзара тәэсир итешүе теориясен электрон күзаллаулар нигезендә тагын да үстерүдә мөһим роль уйныйлар. Ул химик төзелеш теориясе фаразлаган һәм гомуми формуласы $C_3H_6(COOH)_2$ булган барлык ике нигезле изомер к-таларны, ш.у. дүрт буынлы циклның беренче кушылмасын — циклобутандикарбон к-тасын таба. 1880 еллардан башлап, Кавказ нефте составын өйрәнүгә керешә һәм шуның б-н нефть химиясен мөстәкыйль фән буларак нигезли. Углеводородларның яңа классларын ача (үзе аларга нафтеннар исемен бирә, 1883), Кавказ нефтеннән ароматик углеводородлар таба, аларның башка класс углеводородлары б-н азеотроп (аерым кайнамый торган) катнашмалар ясый алу сәләтен ачыклый. Беренче булып, нафтиленнарны (циклоалкеннарны) өйрәнә, нафтеннардан (циклоалканнардан) исле углеводородларга күчүне гамәлгә ашыра, индивидуаль нафтеннар һәм тармакланган углерод чылбырлы парафиннар синтезлый. Углерод атомы саннары 3 тән 8 гә кадәрле цикллар барлыгын исбатлый, циклик углеводородларны циклны киметә барып изомерлау реакциясен ача. Этерификация реакциясе механизмын, алыштырылган циклик кетоннарны оксидлауны өйрәнә, суберон таба. Углеводородларның чагыштырма авырлыгының темп-рага бәйлелеген тикшерә, углеводородның туңу ноктасының аның беришлеге һәм сафлыгы критерие була алуын күрсәтә. Органик матдәләрне анализлау һәм синтезлауның яңа экспериментал алымнарын кертә. Минералогик химия һәм геол. мәсьәләләре б-н шөгыльләнә, Көньяк Россиянең тоз күлләрендә күләмле тикшеренүләр уздыра. Рус-төрек сугышы вакытында (1877–78) хәрәкәттәге армиягә сан. ярдәме оештыруда актив катнаша. «Ветлянка чумасы» көчәйгән чорда «Дезинфекциягә практик җитәкчелек» («Практическое руководство к дезинфекции», М., 1878) кулланмасын төзи. М. тырышлыгы б-н Россия химиясе тарихына багышланган «Ломоносов җыентыгы» («Ломоносовский сборник», М., 1901) басылып чыга. Рус химия җәмгыятен гамәлгә куючыларның берсе (1868), Мәскәү табигать, антропология һәм этнография сөючеләр җәмгыятенең химия бүлеген оештыручы һәм аның рәисе. Илнең химия сәнәгатен үстерүгә, фәнни белемнәрне таратуга ярдәм итә, фән б-н җитештерүнең тыгыз бәйләнештә булу зарурлыгын күрсәтә. Кавказ нефтьләрен өйрәнү буенча хезмәтләре өчен Халыкара нефть конгрессының алтын медале б-н бүләкләнә (1900). М.ның шәкертләре арасында бик күп танылган галимнәр: проф. М.И.Коновалов, СССР ФАнең шәрәфле әгъзасы Н.М.Кижнер, И.А.Каблуков һ.б. бар. М. — Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1901), университет терр-ясендәге элекке химия лаб-ясе бинасына аның хөрмәтенә мемориаль такта урнаштырылган.



М.В.Марков.



В.В.Марковников.

Х е з м.: Избр. труды. М., 1955.

*Әд.:* А р б у з о в А.Е. Казанская школа химиков. К., 1971; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**МАРКО́ВНИКОВ КАГЫЙДӘСЕ́**, нәсимметрик алкеннарга яки алкиннарга протонлы к-талар яки су кушылуның закончалыкларын билгели. М.к. буенча водород атомы во-

дород б-н иң күп туенган углерод атомына килеп кушыла, мәс.:

$$CH_3\text{-}CH{=}CH_2 + HX \rightarrow CH_3\text{-}CHX\text{-}CH_3$$

Гомуми очракта галогенводород элементларының кушылу тәртибен күрше алкил төркемнәр тәэсирендә нәсимметрик төзелгән олефинның икеле бәйләнеше полярлашуы билгели. Олефин молекуласына кушылучы катион углеродның — күбрәк водородлы (тискәре корылган), ә анион әзрәк водородлы (уңай корылган) атомына тартыла. Аерым очракларда М.к. бозыла, чөнки кушылу тәртибе алмаштыргычларның тибына (кайбер атом төркемнәре икеле бәйләнешнең кире полярлашуына китерә) һәм реакция механизмына бәйле. 1869 елда Казанда В.В.*Марковников* тарафыннан бәян ителә.

*Әд.:* Краткая химическая энциклопедия. М., 1964. Т. 3.

**МАРТАЗИ́НОВА** Вәзирә Фәйзулла кызы (29.7.1946, Саратов ш.), метеоролог, физика-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2003). Саратов ун-тын тәмамлый (1969). 1971–74 елларда СССР Гидрометеорология фәнни-тикшеренү үзәгендә. 1975 тән Украина Гидрометеорология фәнни-тикшеренү ин-тында климатик тикшеренүләр һәм һава торышын озак вакытка фаразлау бүлеге мөдире. Хезмәтләре озак вакытка климат үзгәрешләрен һәм һава торышын фаразлау ысулларын эшләүгә карый. М. тарафыннан зур масштаблы атм. күренешләре (җылылык күчешләре, атм. циркуляциясе һ.б.) өйрәнелә һәм аларның вакыт-вакыт ике айлык кабатланучанлыгы ачыла. Айлык, сезонлык һава торышын фаразлауның нигезен тәшкил иткән «йөзүче аналог» алымын эшли. Бөтендөнья метеорология оешмасы эксперты (1997 дән).

Х е з м.: Крупномасштабная атмосферная циркуляция ХХ столетия, её изменения и современное состояние // Тр. Укр. науч.-исслед. гидрометеорол. ин-та. 1998. Вып. 246 (автордаш); Влияние возмущённости геомагнитного поля на процессы атмосферной циркуляции в Северном полушарии // Тр. Укр. науч.-исслед. гидрометеорол. ин-та. 2000. Вып. 248 (автордаш).

**МАРТЫ́НОВ**, кече планета (№ 2376), 1977 елда Кырым астрофизика обсерваториясендә астроном Н.С.Черных тарафыннан ачыла, Д.Я.*Мартынов* исеме б-н атала. Кояштан ераклыгы 2,9 дан 3,5 а.б.кә кадәр. Кояш тирәли 5,8 ел эчендә әйләнеп чыга.

**МАРТЫ́НОВ** Борис Павлович (5.7.1928, Чуаш АССРның Цивильск р-ны Рындино а. — 26.5.1994, Мәскәү), галим-агроном, а.х. җитештерүен оештыручы, а.х. фән. канд. (1968). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1952). 1952–54 елларда Чепья р-нының Димитровский МТСында баш агроном, 1954–58 дә директор. 1958 дә Балтач р-ны а.х. инспекциясе башлыгы, бер үк вакытта район башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1958–60 та КПССның Биектау район ком-ты 2 нче секретаре. 1961–63 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты а.х. бүлеге мөдире, 1963–73 тә ТАССР МС рәисенең беренче урынбасары, бер үк вакытта (1965 кә кадәр) а.х. продуктлары җитештерү һәм әзерләү министры. 1973–85 тә РСФСР а.х. министры урынбасары, 1985–90 да РСФСР Дәүләт агросәнәгать ком-ты рәисе урынбасары, бер үк вакытта Җирдән файдалану, җир төзү, урман хуҗалыгы һәм хезмәтне саклау идарәсе б-н үсемлекчелек продукциясен җитештерү һәм эшкәртү буенча Баш идарә (1988–89) һәм Үсемлекчелек продукциясен эшкәртү һәм тәэмин итү, җитештерүне интенсивлаштыру буенча Баш идарә башлыгы (1989–90). 1990–94 тә Американың «Пионер» фирмасында координатор-консультант (Мәскәү).

М. үсемлекчелек продукциясе җитештерү һәм эшкәртү системасын камилләштерүгә, җитештерүгә фәнни нигезләнгән игенчелек системасын, заманча ашламаларны, эрозиягә каршы һәм башка чараларны гамәлгә кертүне оештыруга, интенсив технологияләр буенча а.х. культураларын игүне үзләштерүгә, бөртекле ашлык, май культуралары, терлек азыгы аксымы, күпьеллык үләннәр, кукуруз, җитен һ.б. җитештерү буенча максатлы комплекслар булдыруга һәм гамәлгә куюга, орлыкчылык, терлек азыгы җитештерү проблемаларын хәл итүгә зур өлеш кертә.

1963–67 дә ТАССР ЮС, 1963–71 дә РСФСР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МАРТЫ́НОВ** Дмитрий Яковлевич (25.3.1906, хәзер Краснодар краеның Темрюк ш. — 22.10.1989, Мәскәү), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1943), проф. (1935), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945, 1966). 1925 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе директоры (1931–51), астрофизика каф. профессоры (1932–39), мөдире (1939–47), ун-т ректоры (1951–54). 1954 тән Мәскәү ун-тында, астрофизика каф. мөдире (1955 тән), бер үк вакытта П.К.Штернберг исем. Астрономия ин-ты директоры (1956–76, Мәскәү). Хезмәтләре планеталар астрономиясенә һәм куш йолдызларга карый. М. — астрофизикада яңа юнәлешкә — куш йолдызларны физик тикшерү алымнарына нигез салучыларның берсе; бу алымнар аларның эчке төзелешен һәм йолдызлар эволюциясен өйрәнгәндә кулланыла. Беренчеләрдән булып, тотылышлы куш йолдызларның эллиптик орбиталары әйләнешен тикшерә башлый, бу хезмәтләре йолдызлар төзелеше һәм эволюциясенең хәзерге теориясе нигезен тәшкил итә. «Гамәли астрофизика курсы» («Курс практической астрофизики», М., 1960), «Гомуми астрофизика курсы» («Курс общей астрофизики», М., 1965) дәреслекләре авторы. Уйлап табуга 2 патенты бар. Бөтенсоюз астрономия-геодезия җәмгыятенең президенты (1960–65, 1970–75), СССР ФА Астрономия советының Астрономик хәбәрләр бюросы рәисе (1941 дән), Халыкара астрономнар берлегенең № 5 «Документация» комиссиясе президенты (1955–61), Король астрономнар җәмгыяте әгъзасы (Лондон, 1969 дан), СССР ФАнең Космик топономика комиссиясе рәисе (1977), СССР ФА Астрономия советының «Кояш системасы» секциясе рәисе (1980–85). «Астрономический циркуляр»



Д.Я. Мартынов.

ж-лының баш мөхәррире (1941–62), «Земля и вселенная» ж-лына нигез салучы һәм аның баш мөхәррире (1965–88). СССР ФАнең Ф.А. Бредихин бүләге лауреаты (1986). Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, «Яңа астрономик объектларны ачкан өчен» медале һәм СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. 1977 дә ачылган астероидка (№ 2376) М. исеме бирелә.

Х е з м.: Затменные переменные звезды. М.–Л., 1939; Планеты: Решённые и нерешённые проблемы. М., 1970; Звёзды и звёздные системы. М., 1981 (автордаш).

*Әд.:* Ч е р е п а ш у к А.М. Жизнь и деятельность Д.Я.Мартынова // Развитие методов астрономических исследований. М.–Л., 1979; Дмитрий Яковлевич Мартынов (1906–1989) // Астрон. журн. 1990. Т. 67, вып. 2.

*Р.Г.Усманов.*

**МАРТЫ́НОВ** Евгений Васильевич (31.3.1953, Удмурт АССР, Сарапул ш.), мәгълүмати технологияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1996), проф. (2002), ТРның атказ. энергетигы (2008). Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук, тармак фәнни-тикшеренү лаб-се мөдире (1983–96), автоматика һәм идарә каф. профессоры (1996 елдан). Бер үк вакытта, 1999 дан, ТР МК каршындагы ТР Энергия саклаучы технологияләр үзәге директоры, 2004–05 тә ТР Икътисад һәм сәнәгать министры урынбасары. Хезмәтләре адаптив мәгълүмат-идарә комплексларын һәм системалары булдыру; акустик агым тәэсиренә корылган мәгълүмат-энергия эвереелдергечләрен эшләү мәсьәләләренә карый. М. җитәкчелегендә сыеклык һәм газларның тотылыш күләмен билгеләү өчен агымга һәм күмелүгә көйләнгән өермәле «интеллектуаль» үлчәгечләр уйлап табу буенча тикшеренүләр үткәрелә. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ хөкүмәте бүләге бирелә (2009), ТР Мактау грамотасы (2003), медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Концепция построения датчиков угловой ориентации малоразмерных ЛА // Вопр. оборонной техники. Сер. 14. 1991. Вып. 1 (автордаш); Экспериментальное и численное исследование акустических течений около объёмных резонаторов // Прикладная механика и техн. физика. 1997. Т. 38, № 6 (автордаш).

**МАРТЫ́НОВ** Иван Васильевич (26.12.1919, Казан губ., Лаеш өязе Тонеево а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1966), РФА мөхбир әгъзасы (1991; 1981 дән СССР ФА мөхбир әгъзасы), Соц. Хезмәт Герое (1974), СССРның мактаулы химигы (1978). Хәрби химик саклану академиясен тәмамлый (1951). 1938–58 елларда хәрби хезмәттә. 1958–78 дә Органик химия һәм технол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), директор (1961 дән), проф. (1968). 1978–89 да РФАнең Физиол. актив матдәләр ин-ты директоры (Мәскәү

өлкәсенең Черноголовка ш.). Хезмәтләре физиол. актив фтор- һәм фосфорорганик кушылмаларга карый. М. полигалогенолефиннарны нитрирлауның гомуми алымнарын эшли, α-нитрокарбон кислоталар, α-аминокислоталар һәм аларның кушылмаларын, галогеннитроалканнар һәм галогеннитрозоалканнар синтезлау ысулын булдыра. Алты координацияле фосфор кушылмаларын — нейтраль тетрафторфосфоратларны тикшерә. 100 дән артык фосфорилланган оксим синтезлый һәм аларның үзлекләрен өйрәнә. Төрле биологик актив матдәләр — үсемлекләрне эффектив саклау чаралары, түбән молекуляр биорегуляторлар, махсус тәэсир итү матдәләре ала; махсус куллану матдәләренең технологияләрен эшли һәм җитештерүгә кертә. М.ның күп кенә эшләре химик кушылмаларны рефрактометрик тикшерүгә, рефрактометрик константалар үзгәрүнең гомуми закончалыкларын билгеләүгә багышланган. Уйлап табуга 150 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Ленин бүләге лауреаты (1972). Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорилированные оксимы // Итоги науки и техники. Сер. Органич. химия. 1989. № 10 (автордаш); Бициклические ортоэфиры кислот фосфора // Итоги науки и техники. Сер. Органич. химия. 1989. № 11 (автордаш); Phosphorus — contaning N-trifluoromethylcarbodiimides and N-trifluoromethylfluoroformamidines in reactions with nucliophilic reagents // Phosphorus, Sulfur and Silicon. 1990. № 49/50 (автордаш).

*Әд.:* О в ч и н н и к о в Ю.А. Биоорганическая химия. М., 1987; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**МАРТЫ́НОВ** Равил Әнвәр улы (16.6.1946, Ленинград ш. — 9.11.2004, Ростов-Дон ш., С.-Петербургта җирләнә), дирижёр, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977), РФнең халык артисты (2000), проф. (1992). Ленинград (1965) һәм Мәскәү (1975) консерваторияләрен тәмамлый. 1975 елдан Татар филармониясе симф. оркестры дирижёры. 1978 дән С.-Петербургта (1984–85 тә В.В.Андреев исем. рус халык оркестры баш дирижёры), 1986 дан С.-Петербург акад. симф. оркестры баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе, бер үк вакытта, 1992 дән, Ростов-Дон шәһәре филармониясенең акад. симф. оркестры җитәкчесе. М.ның репертуарында классик һәм ш.у. хәзерге заман музыкасы зур урын тота. Әсәрләре аның тарафыннан башкарылган композиторлар М.ны иҗатларының сизгер һәм күтәренке рухтагы интерпретаторы буларак бәялиләр. Дирижёрларның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты (1983).

**МАРТЫ́НОВ** Сергей Алексеевич (30.5.1962, Әлмәт ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Әлмәт нефть техникумын (1981), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1990) тәмамлый. 1980–2012 елларда «Татнефть» АҖдә эшли: «Әлмәтнефть» НГДУында механик-җыю эшләре слесаре, Әлмәт бораулау эшләре идарәсе механигы, Әлмәт геол.-эзләү конторасы баш механигы, Әлмәт нефть промыселы җиһазларын ремонтлау буенча җитештерү хезмәте күрсәтү үзәк базасында баш инженер, Бөгелмә механика з-ды директоры (2005 тән). Уйлап табуга 10 нан артык патенты бар. Дәүләт бүләге авыр табыла торган нефть запасларын чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрү өчен яңа технологияләр комплексын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**МАРТЫ́Ш** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Аулаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 143 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1678 дән Бачкеев (Бекчюров) Пустошы исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мартышбаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, арба һәм чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 601,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән — Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 241, 1920 дә — 555, 1926 да — 565, 1938 дә — 548, 1949 да — 369, 1958 дә — 380, 1970 тә — 343, 1979 да — 149, 1989 да — 70, 2002 дә — 76 кеше.

**МАРТЫ́Ш КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама аръягында. Спас р-ны Порфировка авылыннан 1,1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,24 *га*. Су күләме якынча 1000 $м^3$. Озынлыгы 80 *м*, иң зур киңлеге 40 *м*. Уртача тирәнлеге 0,59 *м*, иң зур тирәнлеге 1 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы озынча. Суы бик йомшак (0,78 *мг-экв/л*), җиңелчә минеральләшкән (64 *мг/л*), гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 10 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.

**МАРТЫША́ЧИЙ** посёлогы, Спас р-нында, Болгар — Базарлы Матак автомобиль юлы буенда. 2010 елда 42 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1925 тә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Спас кантоны Спас волостенда. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 66, 1949 да — 107, 1958 дә — 228, 1970 тә — 132, 1979 да — 87, 1989 да — 58, 2002 дә — 53 кеше.

**МАРТЬЯ́НОВ** Анатолий Петрович (21.3.1935, Чуаш АССРның Порецк р-ны Никулино а. — 13.10.2011, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004), проф. (1991), ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1990). 1962 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1965–67 дә Мәскәү төзелеш инженерлары, 1967–72 дә Караганда политехник ин-тларында. 1972 дән Казан аграр ун-тында, материаллар технологиясе һәм материаллар белеме каф. мөдире (1977 дән), бер үк вакытта проректоры (1986–93). Хезмәтләре көчәрле системаларның ышанычлылыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләре мәсьәләсенә карый. М. машина детальләрен, узелларын һәм агрегатларын исәпләү теориясен эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Неконсервативные задачи и методы расчёта стержней, стержневых систем и оболочек. К., 1976; Устойчивость и колебания стержневых систем с граничными условиями в неглавных плоскостях изгиба. К., 1983; О плоских формах потери устойчивости стержней при изгибе со сжатием // Изв. вузов. Строительство и архитектура. 1990. № 5.

**МА́РЧЕНКО** Герман Николаевич (1.4.1939, Ленинград өлкәсенең Парголово р-ны Капитолово а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1976), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Полимер материаллар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Пермь ш.). 1975–93 елларда Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, проф. (1977). 1997 дән Казан энергетика ун-тында икътисад һәм җитештерүне оештыру каф. мөдире. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә һәм физик химиясенә карый. М. җитәкчелегендә азот к-талы целлюлоза эфирлары җитештерүнең күкерт к-тасыз экологик чиста процесслары, целлюлоза нитратлары җитештерүендә эшләнелгән к-талы калдыкларның электрохимик регенерациясе, эффектив нитратлаучы системалар синтезлауның электрохимик ысулы булдырыла. Аның җитәкчелегендә яңу һәм шартлау буенча үткәрелгән фундаменталь тикшеренүләр яңу һәм шартлау чыганакларын (ш.и. зур нефть химиясе һәм энергетика комплексларында, нефть һәм газ промыселларында) киңәйтмәүнең югары эффектив технологияләрен булдырырга ярдәм итә; кайбер төр артиллерия атышлары һәм якыннан торып сугышу системаларына зарядлар ясауны тәэмин итә. Уйлап табуга 163 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биосинтез и структура целлюлозы. М., 1985; Физическая химия неводных растворов целлюлозы и её производных. М., 1991.

*Әд.:* Современный интеллектуальный потенциал России. М., 1997. Т. 1.

**МА́РЬИНО** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 16 *км* көнчыгыштарак, Үләмә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да Покров чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе, җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 372,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның



Г.Д. Маслов.



П.С. Маслов.

10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1859 да — 248, 1897 дә — 341, 1908 дә — 420, 1920 дә — 331, 1926 да — 345, 1938 дә — 296, 1949 да — 160, 1958 дә — 184, 1970 тә — 147, 1979 да — 86, 1989 да — 44, 2002 дә — 24 кеше.

**МАРЬЯ́НОВКА** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 8 *км* көньяктарак, Бор елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 13 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 102, 1938 дә — 79, 1949 да — 96, 1958 дә — 59, 1970 тә — 29, 1979 да — 12, 1989 да — 5, 2002 дә — 12 кеше.

**МА́СЛЕННИКОВА** Валерия Шамильевна (2.7.1940, Казан), педагог; пед. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Казанның 35 нче мәктәбендә инглиз теле укыта. 1967 елдан ВЛКСМның Идел буе район ком-ты 2 нче, 1 нче секретаре, Чаллы шәһәренең «Камгэсэнергострой» төзелеше идарәсендә партия ком-ты секретаре урынбасары (1971). 1973 тән КПССның Казан шәһәре Идел буе район ком-тында идеология бүлеге мөдире. 1977 дән КПССның Татарстан өлкә ком-тының Марксизм-ленинизм ун-ты ректоры, Сәяси агарту йорты мөдире урынбасары. 1991 дән Татарстан укытучыларның белемен күтәрү ин-тында мәдәният тарихы һәм теориясе каф. мөдире. 1992 дән РМАнең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-тында һөнәри тәрбия һәм социаль педагогика лаб-ясе мөдире. Бер үк вакытта, 1994 тән, Казан социаль-юридик ин-тының социаль эшләр кафедрасында, 2003 тән Татар гуманитар-пед. ун-тының (2010 нан *Казан (Идел буе) федераль университеты*) башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү ф-тында һөнәри белем бирү кафедрасында. Хезмәтләре шәхес культурасын формалаштыру, һөнәри белем бирү, тәрбияви тирәлектә социомәдәният тудыру, шәхесне социальләштерү мәсьәләләренә карый. РФ хөкүмәте бүләге лауреаты (2005). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретические аспекты подготовки социального педагога в системе среднего специального образования. К., 1995; Современная идеология воспитания социально ориентированной личности. К., 2004; Психолого-педагогическая модель социально ориентированной личности студента среднего специального учебного заведения. К., 2007.

**МА́СЛОВ** Аркадий Павлович (14.1.1924, Зөя кантоны Фёдоровское а. — 26.9.1966, Казан), гистолог, мед. фән. д-ры (1956), проф. (1958). А.Н.*Миславский* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда ук, гистология кафедрасында эшли, 1958 дән проф. Кемерово мед. ин-тына нигез салучыларның берсе. 1956–60 елларда шунда гистология каф. мөдире, бер үк вакытта ф-т деканы (1957). Хезмәтләре сизгер нерв очларының химик төзелешенә, эчке органнарның афферент иннервация микроморфологиясе законлыкларын һәм рецептор аппаратының оч өлеше үзенчәлекләрен ачыклауга карый.

Х е з м.: К вопросу о взаимоотношениях между чувствительными нервными окончаниями и кровеносными капиллярами // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1957. Т. 34, № 3; Применение новых отечественных красителей в микроскопической технике // Казан. мед. журн. 1959. № 4; Проблемы морфологии, патоморфологии и реактивности периферических отделов нервной системы // Сб. работ кафедры гистологии. К., 1961.

*Әд.:* З а б у с о в Г.И., Ш в а л е в В.Н. Памяти Аркадия Павловича Маслова (14.1.1924 — 26.9.1966) // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1967. Т. 52, № 6.

**МА́СЛОВ** Геннадий Семёнович (20.1.1952, Казан), спортчы, тренер (алкалы хоккей), СССРның спорт остасы (1975), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1997), Россиянең атказ. тренеры (2000). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1983). Спорт б-н 1964 елдан «Стрела» (Казан) спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый. СССР (1975, «Крылья Советов» командасы составында, Мәскәү), ветераннар арасында дөнья (2002–04, «Ак Барс» командасы составында, Казан) чемпионатларында көмеш медальләр ала. 1968–71, 1973–74, 1976–85 тә Урицкий исем. СК командасында (Казан), 1971–72 дә Армия СК да (Куйбышев ш.), 1972–73 тә Армия СК да (Ленинград), 1974–76 да «Крылья Советов» (Мәскәү) командасында уйный. 1975 тә Канада профессионаллары б-н суперсерияләр очрашуларында катнаша («Крылья Советов» командасы составында, Мәскәү). Иң яхшы һөҗүмче (спорт осталары командалары уеннарында 687 алка кертә). 1985 тән «Урицкий» исем. СК, 1991 дән «Итиль», 1995 тән «Ак Барс-2» (Казан) командалары тренеры.

**МА́СЛОВ** Георгий Дмитриевич (28.8.1915, Уфа губ., Минзәлә өязе Сухарево а. — 7.9.1968, Норильск ш.), геолог, Соц. Хезмәт Герое (1963). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1939), Куйбышев гидроузелында эшли. 1940 елда Главгидростройның проектлар секторында, 1941–42 дә Оборона эшләре идарәсендә (Мәскәү). 1942–68 дә Норильск тау-металлургия комб-тының геол. идарәсендә: күмер чыгару төркеме башлыгы, руда булмаган казылмалар буенча өлкән инженер, башлык, руда булмаган казылмалар (1951–54), стратиграфик (1958–64), эзләнү һәм картага төшерү (1964–68) партияләрендә баш инженер. М. Норильск р-нының стратиграфиясен, геологиясен, рудалы файдалы казылмаларының урнашу закончалыкларын тикшерүгә зур өлеш кертә. Геология, металлогения һәм никельне фаразлау карталарын, ордовик, силур, девон һәм Пермь-триас вулканик ятмаларының стратиграфик схемаларын төзи. Талнах һәм Хараелах елгалары үзәннәрендә Норильск рудалы тирән киселешләрен аерып күрсәтә. Герой исеме Талнах бакыр-никель рудалары чыганакларын ачу һәм тикшерү эшендә (1960) ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Талнах шәһәрендә бер урам һәм мәктәп М. исеме б-н атала. Норильск сәнәгать р-нын үзләштерү һәм үстерү тарихы музеенда М.га багышланган экспозиция бар.

Х е з м.: Тектоника Игарско-Норильского района и рудоконтролирующие структуры // Тектоника Сибири. Новосиб., 1963. Т. 2.

*Әд.:* Георгий Дмитриевич Маслов // Недра Таймыра. Норильск, 1997; М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России: Энцикл. М.-СПб., 2000. Т. 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*М.Я.Гаитов.*

**МА́СЛОВ** Пётр Семёнович (24.8.1918, Казан губ., Зөя өязе Тәмте а. — 24.9.1993, Казан), драма актёры, педагог, ТАССРның халык артисты (1975), РСФСРның атказ. артисты (1984). Мәскәү тимер юл транспорты инженерлары ин-тын (1941), Хәрби-транспорт академиясен (1945), Мәскәү Художество акад. театры каршындагы студияне (1949) тәмамлый. 1949–55, 1956–59 елларда — Ярославль драма театрында, 1955–56 да Австриядә Совет Армиясе Үзәк йорты театрында





П.С. М а с л о в: 1. Мармеладов («Җинаять һәм җәза», Ф.М. Достоевский романы буенча); 2. Зәйнетдин («Җилкәнсезләр», К. Тинчурин) рольләрендә.

актёр. 1959 дан Казан Зур драма театрында, бер үк вакытта, 1978 дән, Казан театр уч-щесендә педагог. Казанга тәмам формалашып җиткән оста буларак килә. Аның репертуарында бу вакытта Алёшка («Тормыш төбендә», М.Горький), Медведенко («Акчарлак», А.П.Чехов), Бальзаминов, Шмага, Дормедонт («Бальзаминовның өйләнүе», «Гаепсездән гаеплеләр», «Кичеккән мәхәббәт», А.Н.Островский) кебек рольләр була; ул тиз арада труппаның әйдәп баручы актёрлары исемлегенә керә. Епиходов («Чия бакчасы», А.П.Чехов), Афанасий («Иркутск вакыйгасы», А.Н.Арбузов), Задорнов («Океан», А.П.Штейн), Левон («Левониха орбитада», А.Ё.Макаёнок) кебек беренче рольләрендә үк актёр МХАТ мәктәбе осталыгына ия булуын, рольне төгәл һәм җентекле башкара белүен күрсәтә. Көчле характерлы актёр буларак, М. Скворец («Ленинград проспекты», И.В.Шток), Петрович («Чит ярда», Б.Н.Полевой романы буенча), Егор, Григорий Фёдорович («Безнең бурычлар», «Иң бәхетле», Э.Я.Володарский), Солдатенков («Ил гизүләр», А.Н.Арбузов), Еремеев («Узган җәйдә Чулимда», А.В.Вампилов), Фрязин («Имеш-мимешләр», А.Д.Салынский), Чмутин («Сагыш», А.М.Галин) кебек социаль геройлар рольләрен аеруча ышандырырлык итеп башкара; аларның һәрберсе билгеле бер категория кешеләрен, билгеле бер тормыш позициясен гәүдәләндерә. Рус классикасында М. иҗаты драматургия материалына тирәнтен үтеп керүе, тышкы тәэсирлелеге ягыннан аерылып тора: Ширинкин («Төшемле урында», Д.Н.Мамин-Сибиряк), Мармеладов («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Тараканов, Головастиков («Зыковлар», «Варварлар», М.Горький), Муромский («Эш», А.В.Сухово-Кобылин), Курюков («Фёдор патша», А.К.Толстой) рольләре шундыйлардан. Образны бөтен нечкәлекләре б-н җентекле гәүдәләндерү, игътибарны шәхеснең генә түгел, аны чолгап алган тормыш күренешләрен дә тулы ачарга мөмкинлек биргән характер үзенчәлекләренә юнәлдерү актёр тудырган образларны масштаблы һәм иҗтимагый әһәмиятле итә. М.ның иҗат палитрасына ш.у. комик һәм сатирик чаралар да хас. Ночкин («Мунча», В.В.Маяковский), Создатель («Илаһи комедия», И.В.Шток), Зәйнетдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Вислухин («Мәхәббәт һәм күгәрченнәр», В.П.Гуркин) образлары актёр тарафыннан кыю һәм рәхимсез рәвештә фаш итеп тудырыла. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Илялова И., Ингвар И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**МА́СЛОВА** Инга Владимировна (23.7.1969, Череповец ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2011). Алабуга пед. ин-тын тәмамлый (1991). 1991 елдан Казан ун-тының Алабуга ин-тында тарих һәм хокук белеме ф-ты укытучысы, 2008 дән деканы. Хезмәтләре 19–20 йөз башында Вятка губернасында сәүдәгәрлек тарихына, Россия шәһәрләренең тарихи-мәдәни үсешен өйрәнү методологиясенә багышлана.

Х е з м.: Купеческая династия Стахеевых. Елабуга, 2007; Менталитет купечества уездных городов Вятской губернии XIX — начала XX вв. (монография). М., 2010; История Елабуги в документах и материалах (с древнейших времён до начала XX века). К., 2012 (автордаш).

**МА́СЛОВА** Лариса Владимировна (25.10.1951, Саратов өлкәсенең Вольск ш.), виолончелист, педагог, ТРның халык артисты (1996). 1975 елда Казан консерваториясен (А.Хәйретдинов классы) тәмамлый. 1975–77 дә ТАССР Дәүләт симф. оркестры артисткасы, 1979–2008 дә Татар филармониясе солисткасы. Бер үк вакытта Казан музыка уч-щесендә (1978–87 һәм 1998–99), 18 нче музыка (1993–96) һәм 6 нчы (1999 дан) балалар музыка мәктәпләрендә укыта. Сәхнәдә ТАССР Дәүләт симф. оркестры (җитәкчесе Н.Рахлин) б-н П.Чайковскийның «Рококо темасына вариацияләр» («Вариации на тему рококо») әсәрен башкара. М.ның репертуары, башлыча, барлык виолончель репертуарын, ш.и. оркестр



Л.В. Маслова.

б-н виолончель өчен концертларны (Н.Рахлин, Ф.Мансуров, Р.Мартынов, Р.Салаватов һ.б. җитәкчелегендәге оркестрлар б-н башкара), Г.Ф.Гендель, Л.Бетховен, Ф.Шуберт, И.Брамс, С.Прокофьевларның виолончель сонаталарын; виолончель өчен К.Сен-Санс, К.Дебюсси, С.Рахманинов, А.Глазунов, Д.Шостакович, С.Гобәйдуллина һ.б.ның әсәрләрен колачлый. 1980–90 елларда М. Татарстан музыкант-инструменталистлары арасында иң актив концерт эшчәнлеге алып баручылардан берсе. Киң күләмле (ш.и. монографик) соло концерт программалары, ш.у. ТР һәм РФнең әйдәп баручы башкаручылары б-н ансамбльдә (1991 дән «Кантилена» кыллы квартет составында) чыгышлар ясый. Концерт, соната кебек күләмле әсәрләр һәм төрле характердагы миниатюралар М. башкаруында бер үк дәрәҗәдә уңышлы чыга. Артистка үз репертуарын төрле чорга караган, төрле жанр һәм стильдәге әсәрләр б-н һәрдаим баетып тора. Анда татар музыкасы аерым урын тота. М. — ТР композиторларының аның өчен махсус язылган күп кенә әсәрләренең беренче башкаручысы. Беренче тапкыр татар виолончель музыкасы антологиясен — дүрт концерттан торган «Татарстан композиторларының виолончель музыкасы» циклын туплап башкара (1989). Әлеге концерт программаларына элек башкарылмаган һәм ш.у. антологияне төзүче тарафыннан яңадан торгызылган әсәрләр дә керә. М. Россиянең күпләгән шәһәрләрендә, радио һәм телевидениедән чыгышлар ясый. Аның уенына — тәэсирлелек, җитезлек, осталык, йомшаклык, тирәнлек, тембр байлыгы, характер, стиль төгәллеге, бай эчтәлек, башкарган әсәрләренә форма бөтенлеге хас. Музыкант-башкаручыларның 5 нче Бөтенроссия конкурсы дипломанты (1977). «Әнвәр Шәрәфиев. Виолончель һәм фортепиано өчен пьесалар» («Анвар Шарафеев. Пьесы для виолончели и фортепиано», 1986) җыентыгының төзүчесе һәм мөхәррире. М.ның виолончель өчен язылган дөнья классикасы һәм милли классик музыка әсәрләренә аранжировкалары уку-укыту һәм концерт репертуарларына кертелгән.

*Әд.:* Альмеева Н. Женщина с виолончелью // Идель. 1991. № 8–9; Гурьянова Р. Мелодия судьбы в переложении для виолончели // Татарстан. 1993. № 11; Салманова Г. Виолончель — моё второе я // Идель. 2000. № 1; Кутуй Р. По бархатной дорожке звука // Казань. 2001. № 7; Шамсутдинова Ф. Подвижница // шунда ук. С. 111–113.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МА́СЛОВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 35 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шкимер елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 235 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Рождество-Богородица чиркәве (1813 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе, 5 җил һәм 1 пар тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3661 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ромодан волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 902, 1897 дә — 1276, 1908 дә — 1455, 1920 дә — 1508, 1926 да — 1280, 1938 дә — 702, 1949 да — 498, 1958 дә — 445, 1970 тә — 462, 1979 да — 358, 1989 да — 243, 2002 дә — 254 кеше.

**МА́СЛОВКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 15 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 677 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50%, руслар — 48%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, бакчачылык. Җиләк-җимеш эшкәртү з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысында Казан ханлыгы чоры авылы

урынында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богословский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Иоанн Богослов чиркәве (1753 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), 3 тимерчелек, кредит ширкәте, 3 вак-төякләр һәм 1 казна шәраб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Дмитриевка авылын да кертеп) 2016,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 281 ир-ат; 1859 да — 889, 1897 дә — 1147, 1908 дә — 1450, 1920 дә — 1395, 1926 да — 1478, 1949 да — 672, 1958 дә — 576, 1970 тә — 522, 1989 да — 791, 2002 дә — 801 кеше.

**МАСОННА́Р**, франкмасоннар (фр. franc-maçon — ирекле ташчы), дини-әхлакый хәрәкәт. Урта гасырларда инглиз ташчылары корпорацияләрендә (цехларда) барлыкка килә. 17 йөздә яшәгән Бэкон, Бокль, Ян Каменский, Лейбниц — М. оешмасы әгъзалары. Англиядә 1688 елгы рев-ция М. тарафыннан тормышка ашырыла. Тәхеткә утырган Вильгельм Оранский М. язган конституцияне тотып ант итә. 17 йөз ахырында М. хәрәкәтендә реформа уздырыла, 4 ложа кушыла һәм Англиядә бөек ложа хасил була (1717). Хәзерге М. хәрәкәте шуннан башлангыч ала. Англиядән Көнбатыш Европага, Азиягә (Һиндстан), Америкага (АКШ) һәм Россиягә үтеп керә. Ирекле ташчылар ордены үзенең структурасын (ложа — җирле оешма, бөек ложа — ил күләмендәге ложалар тупланмасы), иерархиясен (өйрәнчек, оста ярдәмчесе, оста, бөек оста), символикасын һ.б. үзенчәлекләрен урта гасырлардагы ташчы-төзүчеләр цехлары (борадәрлекләре), рыцарьлык орденнары һәм тамплиерлар, иоаннитлар, розенкрейцерлар кебек төрле мистик орденнардан ук килгән тәртиптә саклый. М. үз эшчәнлекләренең максатын шәхесне камилләштерүдә, «кешеләрне туганлык, мәхәббәт, тигезлек һәм үзара ярдәм аркылы берләштерүдә» күрәләр. М.ның төп принциплары — Югары (Бөек) Башлангычка, җанның үлемсезлегенә ышану — масонлык хәрәкәте өчен уртак була; соңрак ул берничә: «шотланд», «француз», «швед», «немец» һ.б. системаларга бүленә (алар бер-берсеннән ритуаллар, ложа әгъзаларының кайсы социаль катлауга каравы, фәлсәфи карашлары, символлары, масонлык дәрәҗәләренең саны б-н аерыла).

Россиядә М. хәрәкәте таралу турындагы беренче документаль мәгълүматлар 1730 елларга карый. 18 йөз уртасында Россиядә М. күп түгел: графлардан З.Г. һәм И.Г.Чернышёвлар, Р.И.Воронцов, А.П.Сумароков, И.П.Елагин, кенәз М.М.Щербатов һәм бөек кенәз Пётр Федорович (булачак император Пётр III, ул Ораниенбаумда үз ложасын ача). И.П.Елагин масон ложасына 1750 елда керә. Император Елизавета Петровна, Елагинның бөек княгиня Екатерина Алексеевна яклылар фетнәсендә катнашуыннан шикләнеп, канцлер А.П.Бестужев-Рюмин эше буенча аны 1759 да Казан губернасына сөрдерә. И.П.Елагин үзенең Казан янындагы утарында яши, Екатерина II тәхеткә утыргач, 1762 дә башкалага чакыртып алына, әмма Казан б-н элемтәсен өзми. 1770 еллар башында ул, Россиядәге масон ложаларын берләштереп, аларга җитәкчелек итә, үз системасын булдыра. 1772 дә ул Рус провинция ложасының Бөек остасы дәрәҗәсенә ия була, Р.И.Воронцов — шул ук ложада җирле оста, С.В.Перфильев (Г.Р.Державинның дусты) провинция хәзинәләренең бөек сакчысы вазифасын үтиләр (Г.Р.Державин ш.у. масон булгандыр дип фараз ителә; соңрак, Павел I чорында, ул масон ордены б-н бүләкләнә). 1774 тә Елагин С.-Петербургта «Тугыз Муза», «Урания», «Беллона» ложаларын, Мәскәүдә «Клио» ложасын ача. А.И.Бибиков, кенәз А.И.Мещерский, А.Н.Радищев «Урания» ложасына керәләр. 1770 елларда Елагин карамагындагы ложалар арасында 1776 да Казанда ачылган «Таң Кояшы» ложасы да була (әгъзалары һәм эшчәнлеге турында мәгълүматлар юк). Башкалада яшәгән Казан дворяны В.И.Полянскийның масон булганлыгы билгеле. Екатерина II аны өметле күренгән башка яшьләр б-н, философия һәм сәнгать белемен өйрәнү өчен, Италиягә һәм Франциягә җибәрә, Полянский анда, Вольтер б-н танышып, үзе турында уңай фикер тудыра. Россиягә кайтканнан соң, 1772–78 дә СА секретаре һәм масон ложасы әгъзасы. Тискәре гамәлләре (кеше хатынын тартып ала, жандармнарга каршы кылыч күтәрә) өчен аны Петербургтан сөрәләр. Граф З.Г.Чернышёв тәкъдиме б-н ул Могилёв наместниклыгына киңәшче итеп билгеләнә. 1778–79 да Могилёвта В.И.Полянский ложасы эшли. 1780 дә отставкага чыгып, Казанга кайта, әмма масонлык эшчәнлеген ташламый. 1770 еллар ахырыннан Россия М.ы хәрәкәте үзәге Мәскәүгә күчә.

Даими рәвештә Казанда үз утарларында яшәгән М.ның берсе — А.Л.Лихачёв. 1773 тә ул Семёнов полкы лейб-гвардиясеннән отставкага чыга һәм Спас өязенең Полянки авылында яши башлый. «Новиковның мистика тулы китапларыннан» китапханә туплый, бу китаплар аны масон буларак кызыксындыра. Тикшеренүчеләр Лихачёвны «Таң Кояшы» ложасы эшчәнлегендә күренекле урын тоткан, дип исәплиләр, Ложаны да ул үзе яки Панаев нигезләгән, дип фаразлыйлар. Лихачёв китапханәсендә масон ложалары әгъзалары, Казан алпавытлары И.И.Панаев, И.И.Завалишин (к. *Завалишиннар*) һәм П.Н.Ивашев (к. *Ивашевлар*) язып бүләк иткән китаплар шактый була. Өлкәннәр сөйләвенә караганда, Полянкида «масон киемнәре, тамгалары, крепостной малярлар ясаган нииндидер декорацияләр» озак вакытлар саклана әле (соңыннан алар барысы да диярлек А.Л.Лихачёв оныгы Фёдор Семёновичның тол хатыны — И.И.Панаев кызы тарафыннан юк ителә). А.Л.Лихачёв үз заманы өчен укымышлы кеше була, 1791 дә ул — Казанда Н.М.Карамзинның «Московский журнал»ын алдыручы бердәнбер кеше. 1787–1803 тә Казан дворяннар җыены депутаты, дворян нәселләре шәҗәрәләре китапларын төзүдә катнаша, 1798–1804 тә Казан халык уч-щесе директоры. С.А.Москотильников түгәрәге әгъзалары б-н тыгыз элемтәдә тора.

Эшчәнлеге б-н Н.И.Новиковка теләктәш И.И.Панаев (Петербург масоны, 1780–81 дә «Горус» ложасында һәм Мәскәүнең «Өч Байрак» ложасында урын остасы) 1783 тә Пермьдә «Алтын Ачкыч» ложасын ача, шул ук ел ахырында Казандагы «Таң Кояшы» ложасында урын остасы булып сайлана. Казан алпавыты Н.В.Страховага өйләнгәннән соң, ул берничә ел Казанда яши, 1786 да Пермьгә губерна прокуроры итеп билгеләнә. Казан ложасы утырышларында В.И.Полянский да катнашкан булырга тиеш (1784 нең 23 ноябрендә аның масонлыкта кабат торгызылуы турында кабер ташына язылган). 1783–86 да Казандагы «Таң Кояшы» ложасы И.И.Панаев җитәкчелегендә эшли. Бу ложа мөһеренең уң ягында кояш «йөзе» сурәтләнгән, сулда — балта һәм чүкеч, түбәнге өлештә — рәшәткәле чардуган һәм баш сөяге сурәте төшерелгән кабер ташы; аста русча «Көчнең карасы кача» («Убегает силы тьма»), дип язылган, өстә шул ук сүзләр латин телендә кабатланган.

Казан төбәге б-н бәйләнешле атаклы Мәскәү М.ыннан берсе — П.А.Татищев. 1783 тә ул «Таҗлы Байрак» ложасында префект, 8 нче провинция приоры һәм директория әгъзасы булып тора. Казанда аны яхшы беләләр: энисе Анастасия Нефёдовнадан аңа Кудрявцевларның нәсел утарлары мирас булып күчә, еш кына Казанда һәм Каймарда булгалый, Казан М.ы б-н элемтәдә тора.

1784 тә Мәскәү М.ы Ирекле ташчылар орденында оешкан розенкрейцерлар берлегенә кушылалар. 20 ләп масонга Алтын-Алсу Хачның иң югары дәрәҗәсе бирелә. Орден директорлары урынын Н.И.Новиков, кенәз И.В.Лопухин, С.И.Гамалея һәм И.А.Поздднеев били (И.Г.Шварц вафат булганнан соң, Россия орденнары башлыгы). Алар иҗтимагый-агарту эшчәнлекләре б-н танылалар, «Дустанә гыйльми җәмгыять», Басмаханә компаниясе, Филол. һәм Тәрҗемә семинарияләре, китапханә оештыралар, берничә мәктәп ачалар. Тәрҗемә семинариясенә Казаннан да берничә укучы чакыртыла (анда бушлай укыталар).

Н.И.Новиков исәпләвенчә, 1782–86 да Мәскәү идарәсенә 19 ложа керә (13 е — Мәскәүдә; Казан, Вологда, Кременчуг, Могилёв, Орёл, Харьковта — 1 әр ложа).

18 йөз ахырында Казанда С.А.Москотильниковның әдәби түгәрәге оеша, аның әгъзалары М. була. Савва Андреевич Казанга 1793 тә Ярославльдән килә. Ул шул вакытта ук масон булгандыр дип фараз ителә, чөнки 1794 тә Казандагы М. башлыгы булып китә. Тәрҗемәче С.А.Москотильников, шагыйрь Г.П.Каменев, укытучы И.И.Чернявский, тарихчы Н.С.Арцыбашев, актёр В.Р.Бобровскийны уртак кызыксынулар — масонлык һәм әдәби-

ят берләштерә. Түгәрәк 18 йөз ахыры — 19 йөз башында Казан шәһәренең мәдәни тормышында әһәмиятле роль уйный, танылган публицист, берничә масон ложасы һәм Новиковның «Дустанә гыйльми җәмгыяте» әгъзасы, «барлык рус туганнарның күзәтчесе» И.В.Лопухин б-н даими элемтәдә тора. 1797 дә, Лопухин Казанга килеп киткәннән соң, багланышлар тагын да ныгый. 19 йөзнең беренче елларында Казан М.ы, үз хезмәтләреннән альманах рәвешендә җыентык бастырып, аны И.В.Лопухинга багышларга ниятлиләр, ләкин басма дөнья күрми кала. Төбәк тарихчысы П.А.Пономарёв язганча, «бу зыялы түгәрәк Казанда алты ел буе уңышлы эшли» һәм «18 йөзнең иң гүзәл башлангычлары б-н рухланган» түгәрәк әгъзалары «шул чор Казан җәмәгатьчелегендә мәдәният пионерлары» вазифасын башкара. Философия һәм табигыять фәннәре гыйлемнәренә, күркәм рухи-әхлакый сыйфатларга ия Москотильников тиз арада әлеге түгәрәкнең үзәк фигурасына әверелә. Аны М.ның Казандагы соңгы вәкиле дип атыйлар. Москотильниковның масонлыкка нисбәтле кәгазьләре сакланмаган диярлек, ул үләр алдыннан аларны яндыра. Нибары 2 масон җыры, 1 шигырь, 1 чыгыш тексты (барысы да — сирәк документ) һәм үзе язган «Котылу эзләүчегә нәсихәт» («Наставление ищущему спасения») кулъязмасы сакланып калган. Бу масон оешмасының исеме һәм эшчәнлеге тукталу датасы мәгълүм түгел.

1798 дә Казанда Павел I булып китә. 1796 да ул Н.И.Новиковны ирекә чыгара, А.Н.Радищевны сөргеннән кайтарта. Новиков эше буенча җәбер күргән И.И.Панаев язмышы б-н аерым кызыксына (аңа Панаевның 1796 ның октябрендә Пермьдә үлүе турында әйтәләр). 1798 дә Павел I Мальта ордены гроссмейстеры дәрәҗәсе ала һәм Россиянең Бөек Приорлыгына нигез салынуны раслый. Аның Казан М.ы б-н очрашуы яки очрашмавы мәгълүм түгел, чөнки Павел I нең ирекле ташчылар идеалларына карата мөнәсәбәте суынганнан соң (бу идеаллар полиция дәүләте чынбарлыгы б-н яраша алмый), патшаның М.га карашына кагылышлы документларының күпчелеге юк ителә. Фәкать Казанда императорның уллары өчен масон В.И.Чемесов йорты әзерләнеп куелу турында гына билгеле. Аның бакчасында М.ның җыелышлары уза торган мәгарә була. Императорның Казан гимназиясенә карата кайгыртучанлык күрсәтүе В.И.Полянскийны гимназиягә шәхси китапханәсен бүләк итү ниятенә этәрә (соңрак китапханә университетка тапшырыла).

Павел I патшалык иткән чорда ложаларның кабат торгызылуы Россиядә иҗтимагый аңның 19 йөз башында масонлык «фәненнән» алгарак китеп, ложалардан яңа, сәяси эчтәлек эзләвен күрсәтә.

1817 дә «Астрея» ложасы Казан губернаторы М.П.Баратаевка Казан һәм Себер губерналарында М.га өч төрле дәрәҗә бирү хокукы, ысуллары һәм вәкаләте тапшыра. 1818 дә М.П.Баратаев Сембердә «Игелек Ачкычы» ложасы ача. Бу ложага 1818 нең 11 февралендә М.П.Баратаев тарафыннан Казан ун-ты профессоры К.Ф.Фукс кабул ителә; 1821 дә Сембердә аңа 1 нче дәрәҗә бирелә. Казан ун-ты профессорлары арасыннан М.: А.И.Арнольд («Игелек Ачкычы», Сембер, 1822), В.Р.Берви («Өч Айбалта», Ревель, 1820), И.А.Литтров («Берләшкән Дуслар», Петербург, 1816), Ф.И.Эрдман, («Берләшкән Дуслар», 1816), Ф.Х.Эрдман («Аполлон», Лейпциг, 1809).

19 йөзнең 1 нче яртысында масон ложалары дворяннарның хөкүмәт сәясәтенә карата оппозициясе буларак карала, масон идеяләренең киң колачлылыгы төрле иҗтимагый даирә вәкилләрен масонлык хәрәкәтенә тарта. Александр I хөкүмәте масон ложалары эшчәнлеген үз мәнфәгатьләрендә кулланырга омтыла. Әмма бу өметләр акланмый; «иң югары дәрәҗәдәге» конспиратив ложалар оеша башлый, М.ның декабристлар б-н тыгыз бәйләнештә булуы ачыклана. 1822 дә масон ложалары тыела, 1826 да Николай I бу тыюны раслый.

М. алга таба Россиянең иҗтимагый тормышында актив катнашмыйлар, шулай да 20 йөз башында Дәүләт Думасында алар күпчелекне тәшкил итәләр (араларында И.В.*Годнев* та була), М. 1917 елгы Февраль рев-циясенең җиңеп чыгуында хәлиткеч роль уйныйлар, Вакытлы хөкүмәтне алар төзи. 1920–30 елларда рус эмигрантлары арасында М. байтак була. 1992 дә РФ Президенты Б.Н.Ельцин Россиянең Мальта ордены б-н мөнәсәбәтләрен кабат торгыза. 2007 нең апрелендә Көнчыгыш Европаның 20 масон ложасы вәкилләре, Прага шәһәренә җыелып, алдагы эшчәнлекнең юнәлешләрен билгелиләр, Көнчыгыш Европа масон оешмаларының максатларын ачыклыйлар.

*Әд.:* Лонгинов М.Н. Новиков и масонские мартинисты. М., 1867; Пыпин А.Н. Хронологический указатель русских лож от первого введения масонства до запрещения его: 1731–1822. СПб., 1873; шулук. Русское масонство XVIII и первой четверти XIX в. П., 1916; Аврех А.Я. Масоны и революция. М., 1990.

*А.В.Гарзавина.*

**МА́ССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМА́Т ЧАРАЛАРЫ́**. к. *Татарстан Республикасы* .

**МАСТБА́УМ** Михаил Ильич (24.8.1892, Казан — 28.2.1961, Таллин) фтизиатр, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1932), Эстония ССРның атказ. табибе (1948). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлый (1915). Казан ГИДУВына нигез салучыларның берсе, 1920–39 елларда шунда фтизиатрия каф. мөдире. Бер үк вакытта Казан мед. ин-ты терапия клиникасында эшли (1929–32). 1939 дан Сталинград мед. ин-тының госпиталь терапиясе кафедрасында. 1941–45 тә Тын океан, Балтыйк хәрби-диңгез флотларының баш терапевты. 1945 тән Эстония ССР ФАнең клиника бүлегендә һәм Таллинның дәвалау учреждениеләрендә. «Казанский медицинский журнал»ның баш мөхәррире урынбасары (1932–35), баш мөхәррире (1935–38). Терапевтларның Таллин фәнни җәмгыяте рәисе (1947–59). Хезмәтләре туберкулёз симптоматологиясе һәм иммунологиясенә, үпкә авыруларына, гастроэнтерологиягә, витаминнарны өйрәнүгә карый.

Хезм.: Ошибки диагностики лёгочного туберкулёза. М.–Л., 1930 (автордаш); Схема клинических форм лёгочного туберкулёза // Борьба с туберкулёзом. 1932. № 8; Симптоматология и амбулаторная практика. К., 1941.

*Әд.:* М.И.Мастбаум: Некролог // Клиническая медицина. 1961. № 9.

**МАТА́К** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасы (Сураның уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 614 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, урман материаллары әзерләү, балта эше б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, М.та чиркәү, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1653 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Шемуршы волостенда, 1920 дән Чуаш автономияле өлкәсендә. 1921 нең 17 ноябреннән (башка мәгълүматлар буенча, 1921 нең 22 сентябреннән) ТАССРның Буа кантонында. 1930ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 феврленнән — Буа, 1966ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 595, 1897 дә — 1045, 1910 да — 1450, 1920 дә — 1704, 1926 да — 1592, 1938 дә — 1474, 1949 да — 1579, 1958 дә — 1382, 1970 тә — 1734, 1979 да — 1194, 1989 да — 736, 2002 дә — 692 кеше.

**«МАТБАГА́Й КӘРИМИЯ́»**, к. *Кәримовлар басмаханәсе.*

**«МАТБАГА́Й ШӘРӘ́Ф»**, к. *«Мәгариф» басмаханәсе.*

**МАТБУГА́Т ЙОРТЫ́**, Казанда архит-ра истәлеге. Конструктивизм стилен аеруча ачык чагылдырган корылмаларның берсе. 1933–35 елларда Мәскәү архитекторы С.С.Пэнның конкурс проекты буенча төзелә. М.й. комплексы эчке ишегалды тирәли урнашкан һәм житештерү, сәүдә, адм., хуҗалык-склад биналары кергән 4 комплекстан тора. Сузынкы фасады б-н Бауман урамына чыгып торган төп корпусы конструктивизмның төп стилистик билгеләрен чагылдыра: яссы түбәләр, колонналы портикның эченә тайпылган беренче кат, ярымтүгәрәк баскыч җәмбеле вертикале, тасма сыман тәрәзәләр. М.й.ның төп корпусы Муса Җәлил урамын кисеп тора, шуның өчен 1 нче кат аша үтеп китү юлы төзелгән. Реконструкцияләү өчен ябылганга кадәр (2007) комплекста Татарстан китап нәшрияты, «Полиграфия-нәшрияты комбинаты» ДУП, «Матбугат йорты» ҖЧҖ, «Мәгариф» нәшрияты, Китап палатасы, «Мәдәни җомга» г-тасы редакциясе һ.б. эшли. Илл. *Конструктивизм* мәкаләсеннән кара.

*Әд.:* Остроумов В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978.

*Т.Р.Закирова.*

**«МАТБУГА́Т УДА́РНИГЫ»**, журнал. ВКП(б)ның Уфа шәһәр ком-ты органы. 1936 елда Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррирләре — И.Насыйри, Г.*Әми-*



И.С. Матвеев.

*ри*, А.Дәүләтшин. Актив авторлары арасында — Р.Нигъмәти. Уфа нәшриятлары эшен яктырта, соц. ярыш алдынгылары турында яза.

*Әд.:* Башкортостандың милли матбугат альбомы // Ватандаш. 2000. № 4.

**МАТБУГА́Т ЭШЛӘРЕ́ БУЕНЧА́ КАЗА́Н ВАКЫТЛЫ́ КОМИТЕТЫ́**, беренчел цензураның бетерелүе сәбәпле, татар һәм чуаш телләрендә күпләп басылган китапларны тикшерү, с.-д. һәм социал-революционерлар йогынтысына каршы тору максатыннан цензор М.Н.Пинегин тәкъдиме б-н 1907 елның 1 гыйнварында оеша. Ком-тның беренче рәисе дә М.Н.Пинегин була. Ком-т әгъзалары — Н.Ф.Катанов (татар китаплары буенча), А.В.Фролов һәм Н.И.Ашмарин (татар вакытлы матбугаты буенча). 1908 нең 9 гыйнварыннан Уфа, Пермь, Самара, Сембер,Әстерхан, Акмулла губерналарының матбугат оешмалары да әлеге ком-т карамагына күчә. Ком-тка килгән басмаларның саны елдан-ел арта: 1907 дә — 1551, 1908 дә — 1890, 1909 да — 2055, 1911 дә — 2438, 1912 дә — 3084, 1913 тә — 3023 данә; гомуми күләме буенча беренче урынны матур әдәбият алып тора, аннары дәреслекләр, дини китаплар, балалар әдәбияты һәм фәнни хезмәтләр чиратлаша. Ком-т эшчәнлеге җәза, репрессияләр б-н (мөхәррирләрне кулга алу, басмаларны тыю һ.б.) үрелеп бара. Аның эшчәнлегендә патша хөкүмәтенең реакцион сәясәте чагыла. Ком-т Вакытлы хөкүмәт күрсәтмәсе нигезендә 1917 нең 16 маенда ябыла. Вазифалары матбугат эшләре буенча губерна комиссарына тапшырыла.

*Әд.:* Ч е р н ы ш ё в Е.И. Восточная печать в эпоху реакции XX века // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1925. Т. 33, вып. 1; К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

**МАТВЕ́ЕВ** Владимир Иванович (14.12.1910, Тамбов губ., Тамбов өязе Хитрово а. — ?), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Мәскәү машиналар төзү ин-тын тәмамлый (1935). 1932–34 елларда Үзәк авиация машиналары төзү з-ды (Мәскәү) конструкторы, технологы. 1935–55 тә 22 нче Казан авиация з-дында: тикшерүче мастер (1936 га кадәр), 1936–38 дә цехларны тикшерү бюросы башлыгы урынбасары, 1938–45 тә башлыгы, 1945–46 да техник тикшерү бүлеге башлыгы урынбасары, 1946–53 тә продукция сыйфаты буенча баш контролёр, 1953 тән КПСС ҮК парторгы — партия ком-ты секретаре. 1955–62 дә КПССның Казан шәһәр ком-ты секретаре. 1962–63 тә ТАССР ХХСның авиация сәнәгате идарәсе башлыгы. 1963–66 да ТАССР азык-төлек товарлары сәнәгате, 1966–68 дә ТАССР азык-төлек сәнәгате министры. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МАТВЕ́ЕВ** Владимир Фёдорович (23.4.1881, С.-Петербург — 4.12.1919, Петроград), хокук белгече, полиция хокукы д-ры (1915), статский советник (1916). Дворяннар нәселеннән. Петербург ун-тын тәмамлый (1903); шунда ук эшли: 1904–08 елларда проф. стипендиаты, 1908–10 да приват-доцент, 1917 дән полиция хокукы каф. ординар профессоры. 1910–15 тә Казан ун-тының полиция хокукы кафедрасында экстраординар проф., 1915–17 дә ординар проф. Хезмәтләре дәүләт хокукын өйрәнүгә, җәмәгать җыеннары проблемаларына һәм Көнбатыш Европа илләрендә җирле үзидарә өстеннән дәүләт күзәтүе мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Право публичных собраний: Очерк развития и современной постановки права публичных собраний во Франции, Германии и Англии. СПб., 1909; Государственный надзор за общинным самоуправлением во Франции и Пруссии. К., 1915.

*Әд.:* Биобиблиографический словарь профессоров и преподавателей Казанского университета. 1905–1917. К., 1986.

*Е.Б.Долгов.*

**МАТВЕ́ЕВ** Иван Степанович (19.9.1907, Казан губ., Лаеш өязе Егорьево а. — 22.6.1968, Украина ССРның Харьков ш.), Сов. Союзы Герое (27.2.1945), полковник. «Выстрел» курсларын (1946), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1952) тәмамлый. 1929 елдан Кызыл Армия сафларында. Сугышка кадәр Егорьево авыл советы рәисе булып эшли. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1086 нчы укчы полк командиры (33 нче армиянең 323 нче укчы дивизиясе). Көнбатыш, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү янындагы сугышта (1941–42), Смоленск (1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 14–16 гыйнварында Гнездкув, Немирычув (Зволень шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Польша) торак пунктлары тирәсендәге сугышта батырлык күрсәтә: дошманның оборона ныгытмаларын өзүне оештыра; чолганышта кала һәм сугышып алган позициясен тәүлек буе саклап тора. 1955 тән запаста. Харьков Автоматика тәҗрибә КБда эшли. Өч Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАТВЕ́ЕВА** Татьяна Всеволодовна (28.4.1940, Ленинград), невропатолог, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Казан шәһәренең 9 нчы хастаханәсендә невропатолог булып эшли. 1968 елдан Казан ГИДУВының неврология клиникасында, клиника каршында иммунология лабораториясен оештыручы (1972). 1994 тән Казан мед. ин-тының нерв авырулары кафедрасында. Хезмәтләре таркау склероз патогенезына карый.

Х е з м.: Состояние тимуса при рассеянном склерозе по пневмомедиастинографии // Казан. мед. журн. 1975. № 2; О механизме формирования активных Т-РОК у больных // Журн. невропатологии и психиатрии. 1981. № 4; Состояние вегетативной нервной системы у больных рассеянным склерозом // Неврол. вестн. 1994. № 1–2; Семиотика поражения черепных нервов с методикой их обследования. К., 2006.

**МАТВЕ́ЕВКА РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә Минзәлә һәм Калинин р-ннарының бер өлешендә оештырыла. 1948 дә районда 18 авыл советы, 53 торак пункт исәпләнә. 1954 нең 19 ноябрендә, район терр-ясе Минзәлә һәм Калинин р-ннарына кайтарылу сәбәпле, район таркатыла.

**МАТВЕ́ЕВКА РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 1,8 мең *км*². Үзәге — Матвеевка авылы (Оренбургтан 600 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 11755 (2012), татарлар — 3944 кеше (2010). М.р.да 7 татар авылы бар: Азамат, Югары Котлымбәт, Түбән Котлымбәт, Яңа Әшер, Иске Әшер, Иске Котлымбәт, Иске Якуп. Матвеевкадагы татарлар саны — 839 (2010). 1917 гә кадәр Иске Әшер һәм Иске Якуп авылларында 2 шәр, Югары Котлымбәт, Азамат, Иске Котлымбәттә берәр мәчет эшли. 1917 дән соң Иске Котлымбәт авылында татар мәктәбе ачыла. 2002/03 уку елында М.р.ның 5 мәктәбендә татар теле — фән, 2 мәктәптә факультатив дәрес буларак укытыла. 2001 дә Иске Әшер мәдәният йорты каршында «Якташлар» ансамбле (2002 дә халык ансамбле исеме бирелә) оештырыла. Районда татар мәдәнияте декадалары үткәрелә. М.р.да Сов. Союзы Герое Ә.Б.*Шамкаев* туган.

**МАТВЕЙЧУ́К** Марьян Степанович (р. 3.10.1947, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Сосновка а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук матем. анализ кафедрасында (1975–96), Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының ихтималлылык теориясе бүлегендә (1996–2001) эшли; бер үк вакытта, 1996 елдан, Ульянов пед. ун-тында, матем. анализ каф. мөдире (1999 дан). 2001 дән Кубань ун-тының Новороссийск ф-лы профессоры Хезмәтләре функциональ анализга карый. М. Нейман алгебрасының ортогональ проекторларында бирелгән үлчәнешләр өчен Глисон проблемасын чишә.

Х е з м.: Одна теорема о состояниях на квантовых логиках // Теорет. и мат. физика. 1980. Т. 45, № 2; Описание полуконечных мер в полуконечных алгебрах // Функциональный анализ и его приложения. 1981. Т. 15, вып. 3; Measures on Effects and on Projections in Space with Indefinite Metric // Fields Institute Communications. 2000. V.25.

**МАТВИЕ́ВСКИЙ** Лаврентий Арефьевич (1841, Мариинск Посады ш. — 1917 дән соң), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан, җәмәгать эшлеклесе. 1863 елда этисеннән сәүдә пр-тиесен мирас

итеп ала, Царицын, Казан, Әстерхан шәһәрләрендә агач материаллары б-н сәүдә итә. 1870 еллар уртасыннан Казанда. 1908 дә «Уллары белән Л.А.Матвиевский һәм П.Т.Набоковның сәүдә йорты» фирмасын ача. 20 йөз башында Казанның иң бай кешеләреннән санала: Казан, Түбән Новгород һәм Кострома губерналарында тулай бәясе 450 мең сумлык 22 мең дисәтинә, башлыча, урманлы җир биләмәләре, Казанда кирпеч йорты була. Туган шәһәрендә актив җәмәгать эшчәнлеге алып бара: Чабаксар земствосы гласные (1867), төрмә ком-ты директоры (1868), Мариинск Посадында шәһәр башлыгы. 1879–1917 дә Казандагы Владимир соборында ктитор (староста), Император кешелеклелек җәмгыятенең Казан ярлыларга ярдәм итү ком-ты әгъзасы (1874 тән), попечителе (1896 дан), император Мария ведомствосы карамагындагы Казан балалар приюты попечительлегенең шәрәфле әгъзасы (1888 дән), Казан сәүдәгәрләр банкы советы рәисе. Император кешелеклелек җәмгыятенең гыйбадәт йортын, Владимир соборы каршындагы уч-ще, Мариинск Посадында һәм Казандагы укытучылар семинариясе каршында чиркәүләр төзетү, Кызыл Хач җәмгыятенең Казан бүлеге өчен йорт сатып алу һәм аның каршында чиркәү төзетү, Казанның мәхбүсләрне тәрбияләү бүлекчәсе биналарын киңәйтү һәм үзгәртеп төзү максатларында иганә ярдәме күрсәтә. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары, Станислав тасмасына беркетелгән «Тырышлык өчен» алтын медале б-н бүләкләнә.

**МАТЕМА́ТИК АНА́ЛИЗ**, математиканың бер бүлеге, анда функцияләр чик күчеш операциясе ярдәмендә өйрәнелә. Чик күчеш процессы (чиксез кечкенә зурлык төшенчәсе) б.э.к. 4–3 йөзләрдә Борынгы Греция галимнәре (Евдокс, Архимед) һәм урта гасырларда Европа галимнәре тарафыннан күбесенчә геом. фигураларның мәйданнарын һәм күләмнәрен исәпләү өчен кулланылган. Математиканың бүлеге буларак, М.а. 17–18 йөзләрдә И.Ньютон, Г.Лейбниц, Л.Эйлер хезмәтләрендә формалаша, чикләмәләр теориясе 19 йөз башында француз математигы О.Коши хезмәтләрендә төгәл бәян ителә. Казан ун-тында М.а., фәнни юнәлеш буларак, Н.И.Лобачевский хезмәтләре нигезендә барлыкка килә, 1834 елда ул санлы функциягә беренче фәнни билгеләмә бирә: теориянең киң мөмкинлекләре бер-берсе б-н бәйләнгән саннарны бергә караганда гына бәйләнеш барлыгын таный, ди ул. Саф матем. кафедрасында аның дәвамчысы А.Ф.Попов аналитик алымнарны гидродинамика тигезләмәләрен тикшерү б-н бәйли. В.Г.Имшенецкийның аерым чыгарылмалардагы тигезләмәләрне интеграллау буенча хезмәтләре (1865, 1868) күп еллар буе бу өлкәдә төп чыганак була һәм чит телләргә дә тәрҗемә ителә. 1930 еллар башында Казанда М.а. буенча тикшеренүләр Б.М.Гагаев җитәкчелегендә үткәрелә. Ул дифференцирлауга тотрыклы ортогональ функцияләр системаларын яңадан исәпләү турында Н.Н.Лузин проблемасын чишә (1927). Аның күп кенә шәкертләре Казанда һәм Россиянең башка фәнни үзәкләрендә әһәмиятле фәнни юнәлешләрне җитәклиләр (Ю.Г.Борисович, Б.Г.Габделхаев, Ф.Д.Гахов, А.Д.Ляшко, В.Н.Монахов, Һ.С.Салихов һ.б.). 1950 елларның икенче яртысыннан Казан ун-тында аналитик функцияләр теориясендә яңа юнәлеш-кайтма кырый мәсьәләләр теориясе үсеш ала. Аналитик функцияләр теориясе кысаларында аның гомуми куелышын М.Т.Нужин эшли. Туры кырый мәсьәләләр һәм сингуляр интеграль тигезләмәләр өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләр Ф.Д.Гахов һәм аның шәкертләре тарафыннан үткәрелә. Ул Б.Риманның атаклы проблемасының (аналитик функция өчен сызыкча иярешлелек мәсьәләсе) тулы чишелешен таба. Риманча өслекләрдә һәм автоморф функцияләр классында Б.Риманның кырый мәсьәләсе (Л.И.Чибрикова, И.А.Бикчәнтәев), шул ук мәсьәлә тураймый торган кәкреләрдә (Б.А.Кац) тикшерелә, Гильберт мәсьәләсе тибындагы чик мәсьәләләр (Е.П.Аксентьева, Ю.В.Обносов), катнаш типтагы тигезләмәләр өчен кырый мәсьәләләр (В.И.Жегалов) өйрәнелә. Л.А.Аксентьев һәм аның шәкертләре тарафыннан аналитик функцияләр өчен бер- һәм күпбитлелекнең җитәрлек шартлары алына. Риманча өслекләрнең тармакланган капламаларын төзү мәсьәләсе тикшерелә (Ф.Г.Әүхәдиев, С.Р.Насыйров, И.Р.Нәҗметдинов, Е.А.Широкова). Казан пед. ин-тында М.И.Әлмөхәммәтов җитәкчелегендә дифференциаль тигезләмәләрнең сыйфатча теориясе өлкәсендә уңышлы тикшеренүләр алып барыла. 1970 елларда Казан ун-тында А.Н.Шерстнёв тарафыннан оештырылган «Операторлар алгебралары һәм аларның кулланылышы» семинары базасында функциональ анализ өлкәсендәге тикшеренүләр җәелдереп җибәрелә. Үзәк булмаган функционалларга карата нәкоммутатив интеграллау һәм топологик алгебраларда проекторлардагы үлчәнешләрне төзү (С.В.Дорофеев, Г.Д.Луговая, М.С.Матвейчук, П.Г.Овчинников, О.Е.Тихонов, Н.В.Трунов), ш.у. сигма-аддитивлыкның топологик критерийларын һәм цилиндрик ихтималлылыкларның аз кушылучанлыгын (Д.Х.Мөштәри) өйрәнү буенча өстенлекле фәнни тикшеренүләр башкарыла. Функцияләрнең конструктив теориясе өлкәсендә Б.Г.Габделхаев һәм аның шәкертләре операторлары тигезләмәләрнең зур классын якынча чишү алымнарын эшлиләр, ә ул санлы алымнарны оптимальләштерүнең гомуми теориясен үстерү мөмкинлеген бирә.

*Әд.:* Г а х о в Ф.Д. Краевые задачи. М., 1977; Ч и б р и к о в а Л.И. Основные граничные задачи для аналитических функций. К., 1977; Т р у н о в Н.В., Ш е р с т н ё в А.Н. Введение в теорию некоммутативного интегрирования // Современные проблемы математики. Новейшие достижения. М., 1985. Т. 27; А в х а д и е в Ф.Г., А к с е н т ь е в Л.А., Е л и з а р о в А.М. Достаточные условия конечнолистности аналитических функций и их приложения / ВИНИТИ // Итоги науки и техники. Сер. Матем. анализ. М., 1987. Т. 25; M u s h t a r i D.H. Probabilities and Topologies on Linear Spaces // Kazan Math. Found. 1996.

*А.Н.Шерстнёв.*

**МАТЕМА́ТИК ЛО́ГИКА**, гомуми (фәлсәфи) логиканың кануннарын һәм фикерләү формаларын матем. алымнар ярдәмендә өйрәнүче фән. М.л.ның төп мәсьәләләреннән берсе — фикер йөртүләрнең матем. исбатлануын өйрәнү. Шул ук вакытта башлангыч, исбатлауларсыз кабул ителгән нигезләмәләр дә (аксиомалар) бар, алардан билгеле бер фикерләү принциплары ярдәмендә нәтиҗәләр чыгарыла. Нәтиҗәнең дөреслеге башлангыч нигезләмәләргә һәм исбатлау барышында кулланылган фикерләү принципларына бәйле. Шул рәвешле үстерелгән матем. теорияләр аксиоматик дип аталалар; М.л.ның аксиомалар бәйсезлегенә һәм теорияләрнең капма-каршы булмаучанлыгына караган мөһим бүлекләре шулар б-н бәйләнгән.

М.л.ның аксиоматик теориясенә нигез салучы — Россия математигы, Казан ун-ты профессоры Н.И.*Лобачевский*. Бу теориянең классик үрнәге булып Евклидның берничә постулатына, ш.и. турыларның параллельлеге турындагы 5 нче постулатка нигезләнеп төзелгән Евклид геометриясе тора. 5 нче постулатны бу геометриянең башка постулатларыннан чыгарып булмасына инану Лобачевскийны бу постулат Евклид геометриясенең башка аксиомаларына бәйле түгел дигән фикергә китерә. Ул 1826 елда соңыннан *Лобачевский геометриясе* дип йөртелүче яңа геометрияне төзи һәм анда әлеге постулат капма-каршысы б-н алыштырыла. Аннан соң итальян математигы Е.Бельтрами Лобачевский аксиомалары үтәлә торган геометриянең моделен төзи (1868), немец математигы Ф.Клейн Лобачевский геометриясенең капма-каршы булмаганлыгын катгый исбатлый (1872). Шулай итеп, 5 нче постулатның Евклид геометриясенең башка аксиомаларына бәйле түгеллеге дәлилләнә.

20 йөздә күплекләр теориясендә М.л.ның мөһим нәтиҗәләре алына: Австрия математигы К.Гедель континуум сайлау һәм аның проблемасы аксиомасының күплекләр теориясе аксиомалары б-н капма-каршы булмавын исбатлый (1934), Америка математигы П.Коэн аларның күплекләр теориясе аксиомаларына бәйле түгеллеген билгели (1963).

М.л.да тикшеренүләр үткәргәндә карала торган матем. теория б-н билгеле дәрәҗәдә бәйләнгән формаль системалар төзелә. Бу алымның авторы — немец математигы Д.Гильберт. Аңа кадәр бу өлкәдә инглиз мантыйкчысы Дж.Буль, немец математиклары Э.Шредер һәм Г.Фреге, итальян математигы Дж. Пеано, Казан ун-ты профессоры, астроном П.С.*Порецкий* хезмәтләрендә логика алгебрасы эшкәртмәләре урын ала. Порецкийның «Логик нигезләмәләрне чишү юллары һәм математик логиканың кире ысулы турында» («О способах решения логических равенств и об обратном способе математической логики», 1884) дигән хезмәте логика алгебрасы үсешендә зур роль уйный. Галим Россиядә беренче тапкыр Казан ун-тында үзенең әлеге хезмәте нигезендә М.л. курсыннан лекцияләр укый (1887).

Формаль системаларның логика өлеше үз эченә формальләштерелгән аксиомаларны

һәм формаль чыгару кагыйдәләрен ала; аларны ничек сайлап алуга һәм фикерләүләр мәгънәсен дөреслек ягыннан ничек кабул итүгә карап, интуицион, конструктив, күп мәгънәле, модаль һ.б. логикаларны аерып өйрәнәләр.

Казан ун-ты профессоры Н.А.*Васильев* хезмәтләрендә урын алган идеяләр күп мәгънәле, ш.у. интуицион һәм конструктив логикаларның төп нигезләмәләре чагылышы буларак бәяләнә.

1960 еллардан башлап Казан ун-тында Н.К.*Замов* җитәкчелегендә исбатлаулар теориясе, гамәли М.л., ясалма интеллект теориясе, программалар синтезы һәм программалаштыруны укыту методикасы өлкәләрендә тикшеренүләр алып барыла. Резолюцияләр алымында терминнарны тәртипкә салу стратегиясе эшләнә, һәм ул предикатлар исәпләүнең бик күп формулалары өчен хәлиткеч процедура булып тора. Шул ук алым нигезендә теоремаларны исбатлау программасы төзелә, аның ярдәмендә модаль логикалар һәм күплекләр теориясенең күпчелек теоремаларын автоматик режимга исбатларга мөмкин (В.Ю.Базылев, В.Ю.Михайлов).

М.л. алгоритмнар теориясе б-н принципиаль бәйләнгән. 20 йөзнең урталарында инглиз математигы А.Тьюринг һәм Америка математигы А.Черч хезмәтләрендә алгоритмик чишелүчән функция төшенчәсе аныклана, ә бу элегрәк чишелеш алгоритмы табылмый килгән күп кенә матем. проблемаларның алгоритмик чишелмәүчәнлеген исбатларга мөмкинлек бирә. 1970 елларда Казан ун-ты галимнәре М.М.*Арсланов* җитәкчелегендә алгоритмик чишелмәүчән теорияләрне чишелмәүчәнлек дәрәҗәләре буенча классификацияләр; матем. проблемаларның әлеге класслар иерархиясендәге конкрет баскычка керүе критерийларын табалар, чишелмәүчәнлек дәрәҗәләрен төп җыелучанлыклары буенча тәртипкә салуның алгебраик структурасын төзүгә зур өлеш кертәләр.

*Әд.:* К л и н и С.К. Математическая логика. М., 1973; А р с л а н о в М.М. Рекурсивное перечисление множества и степени неразрешимости. К., 1986; Resolution methods for the decision problem. B.–N.Y., 1993.

*М.М.Арсланов.*

**МАТЕМА́ТИК МОДЕЛЬЛӘШТЕРҮ́**, процессларны һәм күренешләрне экспериментлар мөмкин, кирәк булмаган һәм кыен булган очракларда аларның матем. модельләрендә тикшереп өйрәнү алымы. Табигать күренешләрен сурәтләгән универсаль модельләр кулланла, җәмгыятьне һәм фәнни-техник алгарышны мәгълүматлаштыруның мөһим бер өлешен тәшкил итә. М.м. элементлары борынгы чорларда ук кулланылган; фән буларак 20 йөздә галимнәрне чиксез күп вак эшләреннән азат иткән электрон-хисаплау машиналары үсеше б-н бәйле рәвештә формалаша. М.м. санлы алымнарны эшләү (аларның кайберләре танылган галимнәр: И.Ньютон, К.Гаусс, И.Эйлер, Н.И.Лобачевский, П.Л.Чебышев исемнәрен йөртә) б-н тыгыз бәйләнгән, ә бу исә матем. алымнарның төрле белем даирәләренә һәм гамәли эшчәнлеккә үтеп керүенә ярдәм итә.

Илдә М.м.нең киң таралуы акад. А.А.Самарский исеме б-н бәйле. Аның тырышлыгы б-н РФА Матем. модельләштерү ин-ты төзелә (1991), М.м. буенча фәнни конференцияләр һәм мәктәпләр эшләп килә (Казанда яшь галимнәрнең беренче мәктәпләре 1974 һәм 1976 елларда үткәрелә), «Математическое моделирование» ж-лы нәшер ителә.

Казанда М.м. буенча тикшеренүләр 1950 елларда башланып китә, Казан ун-ты галимнәре тарафыннан сүрүләр һәм фильтрлаштыру теорияләренең нәсызыкча мәсьәләләре өчен матем. модельләр төзелә, аларны чишүнең челтәрле алымнары эшләнә (Б.М.Гагаев, В.В.Морозов, А.В.Сульдин, Г.Г.Тумашев, В.Я.Булыгин һ.б.). М.м. буенча эшләр РФА КГҮ ин-тларында (Матем. һәм машиналар төзү ин-тында, Казан физика-техника ин-тында), Казан техник һәм Казан технол. ун-тларында, Казан архит-ра-төзелеш ун-тында дәвам иттерелә. Шуышучанлык һәм пластиклык теориясендәге нәсызыкча мәсьәләләр өлкәсендә, композит материаллар механикасында, күппараметрлы кайтма булмаган процессларны һәм тоташ тирәлекләр механикасында билгеләгеч нисбәтләрне модельләштерүдә, физика, химия һәм термодинамикада (И.Г.Терегулов) нәтиҗәле эшләр үткәрелә. 1989 да Динамика һәм ныклык проблемалары фәнни-техник үзәге оештырыла (җитәкчесе В.П.Паймушин), анда 1996 дан башлап катлаулы конструкцияләрнең механик торышын М.м. һәм ТРда уникаль объектлар проектлаштыру эшләре (Кама һәм Казансу елгалары аша күпер корылмалары, метрополитен һ.б.) алып барыла. Торак-корылмаларның зур тизлекле җилләр вакытындагы динамик торышын тикшерү, куркыныч формадагы тирбәнүләрне һәм флаттер күренешләрен булдырмый калу максатында, аларның критик кыйммәтләрен билгеләү өчен, аналитик-эксперименталь алымнар эшләнә (В.А.Иванов, А.И.Голованов, И.Х.Сәитов). Бериш һәм күпкатламлы композит материаллардан эшләнгән конструкцияләрнең киеренке деформацияләнгән халәтен тикшерү өчен, нәтиҗәле санлы алымнар төзелә (А.И.Голованов), реаль объектлар исәпләнелә (турбина балдаклары, автомобильләрнең көч бирү элементлары, вертолётларда хәрәкәт бирү системалары, балчык нигезләр һ.б.), контурның төрле рәвештәге сүрүләре һәм пластиналары бөгелешен исәпләү өчен, чик элементлар алымы эшләнә, контактлы мәсьәләләрне чишү алымы тәкъдим ителә (Ю.П.Артюхин, А.П.Грибов). М.м. сыеклык һәм газлар механикасы өлкәсендә, аерым алганда, майлауның термоэластик һәм гидродинамик теориясе бүлегендә гамәли әһәмияткә ия, шуның б-н ул югары тизлекле турбомашиналарны, калаклы һәм үзәктән куулы компрессорларны камилләштерүдә зур роль уйный (В.А.Максимов). аныксызлык шартларында катлаулы динамик системалар б-н идарә итү алымнары аэрокосмик өлкәдә киң куллану таба (Г.Л.Дегтярёв).

Күпрежимлы һәм күпмаксатлы аппаратларны оптимальләштерү алгоритмнары, ш.у. авиация двигательләре б-н автоматлаштырылган идарә итү системаларын һәм компьютерлаштырылган өйрәнү комплексларын матем., программ һәм мәгълүмати тәэмин итү булдырыла (Ю.В.Кожевников); үсешне фаразлау һәм идарәне оештыру өчен икътисади объектлар системасын М.м. тәкъдим ителә (Т.К.Сираҗетдинов).

*Әд.:* М о и с е е в Н.П. Математика ставит эксперимент. М., 1979; Т и х о н о в А.Н., К о с т о м а р о в Д.П. Вводные лекции по прикладной математике. М., 1984; П е т р о в А.А. Экономика. Модели. Вычислительный эксперимент. М., 1996; С а м а р с к и й А.А., М и х а й л о в А.П. Математическое моделирование. М., 1997; Математика: Большой энцикл. словарь. М., 2000.

*А.Д.Ляшко.*

**МАТЕМА́ТИКА** (грек. mathēmatikḗ, máthēma — фән сүзеннән), логик фикерләүләргә нигезләнгән структуралар, тәртип һәм нисбәтләр турындагы фән; объектларның формаларын хисаплау, үлчәү һәм сурәтләү гамәле үсү барышында барлыкка килгән. М. кешенең фәнни һәм гамәли эшчәнлегенең барлык даирәләрендә диярлек кулланыла; иң мөһим уку фәннәренең берсе булып тора, интеллектуаль мөмкинлекләрне һәм логик фикерли белүне үстерергә ярдәм итә.

М. буенча беренче танылган хезмәт булып Евклидның аксиоматик алымны нигезләгән «Башлангычлар» хезмәте (б.э.к. 3 йөз) санала, биредә геометрия үз алымнары, мәсьәләләре, дөреслек критерийлары булган системалы тикшеренү объектын тәшкил итә. Хезмәтнең нигезенә беренчел, төп аксиомалар (ачыктан-ачык, исбатлауны таләп итми торган расламалар) һәм алардан логик фикерләү ярдәмендә чыгарыла торган, чикләнмәгән сандагы теоремалар системасы ята.

М.ның үсешенә гамәли мәсьәләләр генә түгел, фәннең үз ихтыяҗлары да йогынты ясый, һәм бу матем. белемнәрнең шактый ук артуына китерә. Гарәп илләрендә һәм Һиндстанда сан төшенчәсе киңәйтелә, унайлы позицион исәп системасы эшләнә. М.ның үсеше өйрәнелә торган төшенчәләрнең абстрактлашу дәрәҗәсен дә югары күтәрә. Мәс., М.да аның яңа баскычы белемнәрнең яңа өлкәсен — *алгебраны* барлыкка китерә. Җәмгыять ихтыяҗлары, икътисадның һәм диңгезчелекнең үсеше заманча алгебраик нотацияләр һәм яңа алымнар туугa сәбәп була. 16 йөздә 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә алгебраик тигезләмәләрне чишү алымнары уйлап табыла. Координаталар алымы, дифференциаль һәм интеграль исәпләүләр күп кенә мөһим мәсьәләләрне бердәм алым б-н хәл итәргә мөмкинлек бирә. Матем. белемнәргә яңа гамәли фән — *механикада* күпләп ихтыяҗ туа. Борынгы заман М.сы үсешендә эшләнгән коник кисемнәр теориясе кәтмәгәндә генә планеталар хәрәкәтен тасвирлауда файдалану таба. М.ның шуннан соңгы үсешен аның төп башлангычлары б-н тирәнтен кызыксыну, төрле ихтыяҗлардан чыгып, М.ның аерым өлкәләрен үстерү, «сан» һәм «фәза» төшенчәләренең гомумиләштерелүе билгели. Яңа төр саннар баштарак гадәти санлы мәсьәләләр чишүне уңайлаштыру өчен кулланылса, соңрак кайвакыт яңа гомумиләштерүләр дә тудыра торган мөстәкыйль тикшеренү объекты буларак бар-

лыкка киләләр. Өч үлчәнешле Евклид фәзасы төшенчәсен гомумиләштерү күп үлчәнешле һәм чиксез фәзалар, нәевклид геометрияләр, функциональ һәм топологик фәзалар туута китерә. Әйтик, хәзерге М.да фәза дип өстәмә алгебраик, топологик, тәртипчә һ.б. структуралар б-н тәэмин ителгән нинди дә булса объектлар (нокталар дип йөртелүче) күплеген атыйлар. М. һәм аның иң абстракт өлкәләре күп кенә башка фәннәрдә кулланыла башлый. Компьютерлар уйлап табылу заманча алгебраны, саннар теориясен һәм функциональ анализны кулланган кибернетика, матем. модельләштерү, дискрет М., якынча исәпләүләр теориясе кебек яңа матем. фәннәр барлыкка килү һәм үсү б-н бәйле.

Казан губернасында М.ның үсеше Казан ун-ты тарихы б-н аерылгысыз бәйләнгән, биредә М. фәнен күп кенә ачышлар һәм фундаменталь гомумиләштерүләр б-н баеткан галимнәр эшли. Беренче М. профессорлары 1808 елда университетка укытырга чакырылган М.*Бартельс* — күпкырлы математик һәм талантлы педагог-галим йогынтысында дөньяга чыга. М. фәне үсешенә Евклид аксиомалары системасыннан үзгә системалы яңа *геометрия* төзегән Н.И.*Лобачевский* зур өлеш кертә. Лобачевский теориясе геометриянең чикләрен киңәйтеп кенә калмый, М.ның максатларын яңача төшенүдә зур роль уйный. Лобачевскийның ачышы, революцион характерда булганлыктан, галимнең вафатыннан соң гына танылуга ирешә. Әйтик, аның тригонометрик рәтләрне үз куелышлары буенча тикшерүләре үз чорыннан берничә унъеллыкка узып китә. Ул гамма-функцияләр теориясенең оригиналь төзелешен эшли, аларның кайбер билгесез үзлекләрен ача, алгебрада югары дәрәҗә тигезләмәләрнең тамырларын якынча исәпләүнең камилрәк алымын тәкъдим итә. Талантлы педагог һәм лектор буларак, Лобачевский төрле белгечлекләр буенча галимнәргә зур йогынты ясый һәм ярдәм итә (химиклар Н.Н.Зинин һәм А.М.Бутлеров үзләренең фәнни эшчәнлекләрен Лобачевский җитәкчелегендә М. буенча башлап җибәрәләр). 19 йөзнең 2 нче яртысында Лобачевскийның шәкерте А.Ф.Попов гидромеханикадан тикшеренүләр үткәрә. Поповның укучысы В.Г.Имшенецкий аерым чыгарылмалардагы тигезләмәләрне интеграллаштыру мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. Аның хезмәтләре француз һәм немец телләренә тәрҗемә ителә, 19 йөз ахырының иң зур математикларыннан берсе булган норвег Софус Ли тарафыннан югары бәяләнә. В.П.Максимовичның магистрлык диссертациясендә 2 нче тәртип гомуми сызыкча дифференциаль тигезләмәне квадратураларда интеграллауның мөмкин түгеллеге дәлилләнә. Ф.М.Суворов хезмәтләрендә өч үлчәнешле риманча фәзаларның дифференциаль инвариантлары табыла. *Казан физика-математика җәмгыятен* 20 ел буе җитәкләгән А.В.Васильев автоморф функцияләрне ачуга бик якын килә. Аның «Алгебраик тигезләмәләр системаларының тамырларын аерып чыгару теориясе» дигән диссертациясе тикшеренүләрнең иң күп төр алымнарын куллануы б-н аерылып тора. Васильев *Лобачевский Н.И. исемендәге халыкара премия* булдыруда, бөек галимнең хезмәтләрен һәм беренче фәнни биографиясен бастырып чыгаруда зур роль уйный. А.П.Котельников, гомумиләштерелгән комплекслы саннарны кулланып, векторлыга охшаган винтлы исәпләүләр аппаратын үстерә. Аерым алганда, ул махсус ихтималлылык теориясендә тизлекләр фәзасының Лобачевский фәзасы икәнлеген исбат итә. Д.Н.Зейлигер сызыкчалы фәзаларның комплекслы теориясен төзи. Д.М.Синцов, Россиядә беренче булып, нәголоном геом. тикшеренүләре уздыра. П.С.Порецкий (белгечлеге буенча астроном) Казан ун-тында, Россиядә беренче булып, матем. логика курсларын укый.

Республикада матем. тикшеренүләр үсешенең яңа чоры 1920 елларда башлана. Университетның киңәйтелүе, М. кафедралары булган башка югары уку йортлары ачылу М. б-н шөгыльләнүче галимнәрнең саны шактый артуга китерә. Күп еллар Казан физика-матем. җәмгыятенең башында торган Н.Н.Парфентьев фәнни потенциалны формалаштыруда зур роль уйный. Ул, шәхсән үзе механика фәне өлкәсендә күбрәк эшләсә дә, матем. тикшеренүләргә күп кенә яшь галимнәрне тарта, аларның хезмәтләре исә яңа фәнни юнәлешләргә нигез сала.

Казан ун-тында геометриянең үсеше П.А.Широков исеме б-н тыгыз бәйләнгән. Аның симметрик фәзалар теориясе буенча тикшеренүләре зур әһәмияткә ия. П.А.Широков, илебез геометрларыннан беренче булып, тензорлы анализ алымнарын өйрәнә һәм аларны Риман геометриясенең күп кенә мөһим мәсьәләләрен чишүдә куллана. Соңрак Казанда геом. мәктәбен проектив фәза өслекләре теориясендә нормальләштерү алымын төзүче А.П.Норден җитәкли. А.П.Котельников, П.А.Широков, А.П.Норден тикшеренүләре А.П.Широковка *Казан геометрия фәнни мәктәбенең* фәнни юнәлешен — алгебралар өстендә геометрияне формалаштырырга мөмкинлек бирә. А.З.Петровның Эйнштейнның гомуми ихтималлылык теориясендә геом. проблемаларына караган хезмәтләре дөньякүләм танылу ала. Б.Л.Лаптев, беренчеләрдән булып, катламланган фәзаларның дифференциаль геометриясе буенча тикшеренүләрне башлап җибәрә.

1927 дә Казанга Н.Г.Чеботарёвны чакыру һәм 1934 тә аның тырышлыгы б-н Казан ун-ты каршында *Математика һәм механика институты* ачылу зур әһәмияткә ия була. М.ның төрле өлкәләрендә Чеботарёвның алгебраик тикшеренүләре — Галуа теориясе, Ли төркемнәре теориясе, полиномнар һәм бөтен функцияләрнең дәвамлылыгы проблемасы, резольвентлар проблемасы — дөньякүләм танылу ала. Аның шәкерте И.Д.Адо — Ли алгебраларын күрсәтү турындагы атаклы теореманы, В.В.Морозов ярымгади Ли алгебраларының максималь асалгебралары регулярлыгы теоремасын исбатлыйлар. Функцияләр теориясе буенча тикшеренүләрне Б.М.Гагаев дәвам итә, ул Н.Н.Лузинның бер проблемасын чишә. Аның шәкерте Һ.С.Салихов Коши-Ковалевская теориясе өлкәсендә фундаменталь нәтиҗәләргә ирешә. М.И.Әлмөхәммәтов француз математигы А.Пуанкаре хезмәтләре б-н бәйле дифференциаль тигезләмәләр теориясеннән күп кенә теоремаларны исбатлый. Ф.Д.Гахов кырый мәсьәләләр буенча тикшеренүләрен башлап җибәрә, ул ирешкән нәтиҗәләр аерым чыгарылмалардагы тигезләмәләр һәм комплекслы үзгәрешленең функцияләре теориясе буенча дәреслекләргә кертелгән.

Хәзерге заман М. әдәбиятында ш.у. Казан механиклары тарафыннан кертелгән матем. объектлар (Громека–Бельтрами тигезләмәсе, Громека–Лэмб формасы, Четаев алымы, Пуанкаре–Четаев тигезләмәсе, Донелл–Мөштәри теориясе, Каменков критерие һ.б.) билгеләп үтелә. Казан математикларының хәзерге тикшеренүләре Г.Г.Тумашев һәм М.Т.Нужин тарафыннан аэрогидромеханика мәсьәләләренә бәйле рәвештә үстерелгән кайтма кырый мәсьәләләр теориясенә карый.

20 йөзнең 2 нче яртысында тикшеренүләр Казан математиклары өчен традицион өлкәләрдә — алгебра (В.В.Морозов, Ю.Б.Ермолаев, И.И.Сахаев, С.М.Скрябин), геом. (А.П.Норден, Б.Л.Лаптев, В.В.Вишневский, Б.Н.Шапухов, А.П.Широков, В.В.Шурыгин), *математик анализ* (Б.М.Гагаев һәм аның шәкертләре), дифференциаль тигезләмәләр (М.И.Әлмөхәммәтов; Һ.С.Салихов, В.Р. Фридлендер, Л.Д.Эскин, М.Д.Бронштейн), кырый мәсьәләләр (Ф.Д.Гахов, Л.И.Чибрикова, И.А.Бикчәнтәев, В.И.Жегалов, Ю.Г.Обносов) буенча дәвам иттерелә. Шушы өлкәләр кысаларында яңа юнәлешләр — ихтималлылык теориясенең матем. проблемалары (А.З.Петров, А.В.Әминова, В.Р.Кайгородов һ.б.), комплекслы үзгәрешле функцияләренең геометрик теориясе (Л.А.Аксентьев, Ф.Г.Әүхәдиев, Б.А.Кац, А.М.Елизаров, С.Р.Насыйров һ.б.), хисаплау алымнары (А.Д.Ляшко, М.М.Карчевский, А.В.Лапин, И.Б.Бәдриев, Р.З.Даутов һ.б.), оптимальләштерү алымнары (Я.И.Заботин, И.В.Коннов һ.б.), *якынчалык теориясе* (Б.Г.Габделхәев, Н.С.Габбасов һ.б.) буенча тикшеренүләр башлана. Математиканың Казан өчен яңа өлкәләре: *кибернетика* һәм дискрет матем. (Р.Г.Бухараев, Ф.М.Аблаев, Ю.В.Голунков, Р.Х.Латыйпов, Р.Г.Нигъмәтуллин һ.б.), *ихтималлылык теориясе һәм математик статистика* (А.В.Сульдин, И.Н.Володин, В.И.Ладохин, Д.Х.Мөштәри, А.Н.Чупрунов һ.б.), функциональ анализ (А.Н.Шерстнёв, С.А.Григорян, М.С.Матвейчук, О.Е.Тихонов, Н.В.Трунов һ.б.), саннар теориясе (Г.А.Фрейман, Е.В.Новосёлов, Д.А.Москвин), *математик логика* (М.М.Арсланов, В.Д.Соловьев һ.б.), программалаштыруның матем. проблемалары (Н.К.Замов), матем. физика (М.Җ.Миассаров), сызыкча топологик фәзалар (Ю.И.Грибанов, Н.М.Зобин) үсеш ала.

М.буенча тикшеренүләр Казанның югары уку йортларында, акад. һәм фәнни-тикшеренү институтларында алып барыла. М. белгечләрен әзерләү өчен, Казан ун-тының физика-матем. ф-ты нигезендә 1960 та механика-матем. ф-ты, 1979 да хисаплау математи-

касы һәм кибернетика ф-ты ачыла. Казан ун-тында М.ның төрле проблемалары буенча даими үткәрелә торган фәнни семинарлар М. галимнәренең нәформаль берләшмәләренә әверелә. 1936 дан башлап укучылар өчен матем. олимпиадалар үткәрелә, 1961 дә Казан ун-ты каршында махсус физика-матем. мәктәбе булдырыла. 1891–1949 да «*Известия физико-математического общества при Казанском университете*» ж-лы, 1957 дән «*Известия высших учебных заведений. Математика*» фәнни-теоретик ж-лы чыгарыла. 1895 тә, башлыча, нәевклид геом. өлкәсендәге зур фәнни казанышлар өчен Н.И.Лобачевский исем. халыкара премия, 1991 дә Н.И.Лобачевский исем. медаль гамәлгә куела.

*Әд.:* История отечественной математики: В 4 т. Киев, 1966–70; Юшкевич А.П. История математики в России до 1917 года. М., 1968; Казанский университет. 1804–1979: Очерки истории. К., 1979; Шакирова Л.Р. Казанская математическая школа. К., 2002; Изотов Г.Е. Казанское физико-математическое общество. К., 2003; The New Encyclopaedia Britannica. 15 The Edition. Chi., 1999. V. 7.

*Р.Г.Бохараев, Д.Х.Мөштәри, Б.Н.Шапуков, А.Н.Шерстнёв.*

**МАТЕМА́ТИКА ҺӘМ МЕХА́НИКА ИНСТИТУТЫ́**, Казан ун-ты каршындагы Н.Г.Чеботарёв исем. фәнни-тикшеренү ин-ты (НИИММ), илдә югары уку йортлары каршындагы фәнни-тикшеренү ин-тларының берсе. 1934 елда университет профессоры Н.Г.Чеботарёв тырышлыгы б-н төзелә (1947 гә кадәр аның директоры була); 1947 дән Н.Г.Чеботарёв исемендә.

НИИММда үсеш алган фәнни проблемалар теоретик характерда була һәм матем. б-н механиканың актуаль өлкәләренә карый: 1) алгебрада — револьвентлар проблемасы һәм өзлексез төркемнәр (Н.Г.Чеботарёв, И.Д.Адо); дәвам ителүчән поминомнар (Л.И.Гаврилов, Н.Н.Мейман); Ли төркемнәре теориясе, Галуа теориясе, алгебра һәм тензорлы анализ (Н.Г.Чеботарёв); 2) анализда — ортогональ полиномнар (Б.М.Гагаев); дифференциаль тигезләмәләр системаларының аерымланган ноктлары (М.И.Әлмөхәммәтов); *n* нчы тәртип сызыкча дифференциаль тигезләмәләрдә Чаплыгин алымын куллану (Г.Х.Максудов); аналитик функцияләр өчен сызыкча кырый мәсьәләләр (Ф.Д.Гахов); зур саннар законын гомумиләштерү (К.П.Персидский); 3) геометриядә — винтсыман сызыкча функцияләр; аныксыз метрикалы симметрик фәзалар; тензорлы анализ (П.А.Широков); нуль системаларда иярешлелек (В.А.Яблоков); Финслер фәзалары (Б.Л.Лаптев); 4) механикада — динамика траекторияләренең тотрыклылыгы, Кронекер характеристикалары һәм аларны хәрәкәт тотрыклылыгы мәсьәләләренә карата куллану (Н.Г.Четаев); тотрыклылык теориясенең гомуми проблемалары (К.П.Персидский, И.Г.Малкин); вибрация теориясенең кайбер мәсьәләләре (Н.Н.Парфентьев).

1936 ның мае — 1937 нең октябрендә теоретик физика бүлеге эшли (җитәкчесе — поляк физигы М.Г.Матиссон (Ж.С.Адамар шәкерте), хезмәткәрләр — С.А.Альтшулер һәм И.А.Щербаков). НИИММда аспирантларның зур төркеме эшләп килә, соңыннан аларның күбесе зур галимнәр булып таныла.

Бөек Ватан сугышы елларында институт галимнәре, Казанга эвокуацияләнгән Мәскәү һәм Ленинград ин-тлары хезмәткәрләре б-н берлектә, оборонага кагылышлы темалар буенча эшли.

Сугыштан соңгы елларда институтта В.В.Морозов, Ф.Д.Гахов, А.П.Норден, С.Н.Андрианов, М.Т.Нужин, Г.Г.Тумашев, Б.Л.Лаптев, А.З.Петров, П.И.Петров, С.Ф.Сайкин нәтиҗәле эшлиләр.

1950–60 елларда институтта нефть тематикасы буенча тикшеренүләр җәелдерелә, яңа бүлекләр һәм лаб-яләр ачыла. НИИММ илнең югары уку йортына караган әйдәп баручы фәнни үзәкләренең берсе буларак таныла. 1978 дә институт һәм Казан ун-тының механика-матем. ф-ты нигезендә хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты ачыла. 1990 еллар башында институтта 15 фән д-ры һәм 50 канд-ты эшли. 1992 дә ул РФАнең Матем. бүлеге составына керә; институтта элеккеге б-н бергә яңа перспектив юнәлешләр дә үсеш ала. Аспирантура һәм докторантура эшләп килә, аларда күп кенә танылган галимнәр — зур фәнни юнәлешләргә нигез салучылар, ш.и. Казан ун-ты ректоры булып эшләгән М.Т.Нужин һәм Чуаш ун-ты ректоры С.Ф.Сайкин әзерлек үтәләр. Институтның җитәкчеләре: В.В.Морозов (1947–54), Г.Г.Тумашев (1954–61), Б.М.Лаптев (1961–80), Н.Б.Ильинский (1980–90), А.В.Костерин (1990–94), А.М.Елизаров (1994 тән).

*Әд.:* Очерки истории НИИ математики и механики имени Н.Г.Чеботарёва. К., 1989; Научно-исследовательский институт математики и механики имени Н.Г.Чеботарёва. 1993–1997. К., 1998. Елизаров А.М. Сохранение и развитие вузовских НИИ: иллюзии и реальность // Развитие стратегического подхода к управлению в российских университетах. К., 2001.

*А.М.Елизаров.*

**МАТКА́УШ** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Брустан елгасы буенда. 2010 елда 16 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1704 тән татар авылы буларак билгеле, 1740 елларда авылда беренче рус кешеләре теркәлә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ебалаково исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә; 18 йөзнең 2 нче яртысында Авзяно-Петровск һәм Воткинск тимер кою з-дында эшли. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында М. Е.И.Пугачёв отрядлары туплану үзәкләренең берсе була. 20 йөз башында Богородица чиркәве (1878 дә төзелә), земство мәктәбе, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1952,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Мәлкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 168, 1859 да — 605, 1870 тә — 598, 1884 тә — 655, 1897 дә — 950, 1906 да — 1028, 1913 тә — 1030, 1920 дә — 938, 1926 да — 917, 1938 дә — 603, 1958 дә — 333, 1970 тә — 224, 1979 да — 127, 1989 да — 52, 2002 дә — 38 кеше.

**МАТМЫ́Р** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 44 *км* төньяктарак, Илләт елгасыннан 4 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — умартачылык. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 214 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 26 ир-ат; 1859 да — 78, 1897 дә — 149, 1908 дә — 220, 1920 дә — 197, 1926 да — 225, 1938 дә — 265, 1949 да — 341, 1958 дә — 324, 1970 тә — 269, 1989 да — 89, 2002 дә — 50 кеше.

**МАТРО́СОВ** Александр Матвеевич (чын исем-фамилиясе Мөхәммәтҗанов Шакирҗан Юныс улы) (5.2.1923/24, БАССРның Тамьян-Катай кантоны Кунакбай а., хәзер БРның Учалы р-ны, башка чыганаклар буенча — Екатеринослав ш., хәзер Днепропетровск ш. — 23 яки 27.2.1943, Псков өлкәсе, Локня р-ны Чернушки а., Великие Луки шәһәрендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (19.6.1943, үлгәннән соң), гв. рядовое. Краснохолмск хәрби-пехота уч-щесен (Оренбург ш. янында, 1942) тәмамлый. 1932 елда әнисе үлеп, гарип әтисе б-н генә кала. 1934–39 да Мәләкәс (хәзер Димитровград ш.) һәм Ивановка авылы (хәзер Ульянов өлкәсе) балалар йортында тәрбияләнә. Куйбышев шәһәренең вагон ремонтлау з-дында эшли. 1942 нең сентябреннән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 254 нче гв. укчы полкның укчы-автоматчысы (22 нче армиянең 56 нчы гв. укчы дивизиясе). 1943 нең 23 яки 27 февралендә Калинин фронты гаскәрләре составында Чернушки авылы өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: дошманның пулемёт дзоты амбразурасын гәүдәсе б-н каплый һәм подразделениенең алга уңышлы хәрәкәтен тәэмин итә, һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Уфа, Ульянов, Великие Луки шәһәрләрендә М.ка һәйкәлләр куела. Балалар хезмәт колониясе, Уфа шәһәрендә кинотеатр, Казанда бер урам аның исемен йөртә. Россия Эчке эшләр министрлыгының Уфа югары мәктәбендә (1966), Кунакбай авылында мемориаль музей ачыла (1993).

*Әд.:* Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Т. 1; Орёл умирает на лету. Уфа, 1966; Насиров Р. Откуда ты, Матросов? Уфа, 1994; Подвиги их бессмертны. Уфа, 2000; Файзуллин А. Кем ты был, Александр Матросов? // Новая Вечёрка. 2003.

29 янв.; Неизвестный Матросов // Восточный экспресс. 2004. 27 февр.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МАТРО́СОВ** Владимир Мефодьевич (8.5.1932, Алтай краеның Шипуново р-ны Шипуново а. — 17.4.2011, Мәскәү), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1967), РФА академигы (1991; 1987 елдан СССР ФА академигы, 1976 дан мөхбир әгъза). 1956 да Казан. авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, проф. (1968), махсус матем. (1968–72), кибернетика (1972–75) кафедралары мөдире. 1975 тән СССР ФАнең Себер бүлегендә (Иркутск ш.): Себер энергетика ин-тында директор урынбасары, системалар теориясе һәм кибернетика бүлеге мөдире (1975–80); Хисаплау үзәген оештыручы һәм директоры (1980–91). 1991–96 да РФА Транспорт проблемалары ин-тының (С.-Петербург) Мәскәү ф-лы директоры. 1996 дан Мәскәүдә: Машиналар төзү ин-ты каршындагы Тотрыклылыкны һәм нәсызыкча динамиканы тикшерү үзәге директоры, 2000 нән Мәскәү авиация ин-тының матем. кибернетика каф. мөдире. Хезмәтләре теоретик механикага, хәрәкәт тотрыклылыгы теориясенә, аналитик һәм нәсызыкча динамикага, социаль-икътисади һәм экол. системаларны глобаль модельләштерүгә карый. М. тотрыклылык теориясендә һәм динамик системалар б-н идарә итүдә Ляпуновның вектор-функцияләр алымын эшли; системаларның матем. теориясендә теоремалар чыгару өчен, чагыштыру принцибын формалаштыра. Ясалма интеллект өлкәсендә фәнни юнәлеш — теоремалар чыгару һәм исбатлауны автоматлаштыру өчен, алгоритмлы якын килүне төзи. М. үстергән фәнни алымнар реаль техник объектларның динамикасы һәм алар б-н идарә итү проблемаларын хәл итәргә мөмкинлек бирә (стратосфера обсерваторияләре, озак сроклы орбиталь станцияләр, элемтә спутниклары һ.б. өчен). Бөтендөнья һәм төбәкләр үсешен тикшерү, матем. модельләштерү һәм анализлау буенча халыкара һәм Россия проектлары җитәкчесе. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан техник ун-тының шәрәфле профессоры, К.Э.Циолковский исем. Космонавтика академиясенең шәрәфле әгъзасы.

Х е з м.: Метод сравнения в математической теории систем. Новосиб., 1980 (автордаш); Алгоритмы вывода теории метода векторных функций Ляпунова. Новосиб., 1981 (автордаш); Метод векторных функций Ляпунова: Анализ динамических свойств нелинейных систем. М., 2001; Моделирование и управление процессами регионального развития. М., 2001 (автордаш).

**МАТУ́Р КОҢГЫЗЛА́Р**, ч и б ә р  к о ң г ы з л а р (Calosoma), *бызылдавыклар* семьялыгыннан коңгызлар ыругы. Зур гәүдәле (25–31 *мм*). Канатлары яхшы үсеш алган. Личинкалары кара төстә. Түшәлмәдә һәм туфракның өске катламында яшиләр. Олы коңгызлар һәм личинкалары — актив ерткычлар. Корбанын тотканнан соң, М.к. югары казналыктагы аерым каналлардан аңа ашкайнату согы сиптерә, ул исә корбанының эчке органнарын сыек боткага әйләндерә, соцыннан ерткыч аны суыра. 40 ка якын төре билгеле, Россиянең Европа өлешендә — 6; Татарстан терр-ясендә 5 төре билгеләнгән. Исле М.к. (C. sycophanta) һәм матур бронза коңгыз (C. inguisitar) киң яфраклы һәм катнаш урманнарда яши; туфрак өстендә һәм ш.у. агачларда күп кенә парсыз имән ефәк күбәләкләре гусеницаларын, алтын корсак, карышлавыклар һ.б. күбәләк гусеницаларын юк итәләр. Исле М.к. Кама аръягы урман-далаларының көньяк районнарында таралган (парсыз ефәк күбәләгенең таралу урынында бик күп була). Идел буе калкулыгында бик сирәк очрый. Матур бронза коңгыз бөтен респ-ка терр-ясендә бар, әмма саны күп түгел. Алтынсу ноктал М.к. (C. auropunctatum Herbst), дала М.к.ы (C. denticolle) һәм басу М.к.ы ачык биоценозларда (болын, аланнарда) яшиләр. Ябалакчыклар, ак күбәләк гусеницалары б-н туена. Басу М.к.ы шактый күп, аеруча басу агроценозларында, тугай болыннарында һәм күпьеллык үләннәр астында очрый. Тәңкә канатлыларның санын төп көйләүчеләр булып торалар. Исле М.к., бронза М.к., алтынсу ноктал М.к. ТРның, исле М.к. РФнең дә Кызыл китабына кертелгән.


*А.К.Жеребцов.*

**МАТУ́ХИН** Вадим Леонидович (8.9.1946, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. 1996 дан Казан энергетика ун-тында: электрон техника һәм автоматлаштыру ф-ты деканы (1996–2003), бер үк вакытта физика каф. мөдире (1998 дән), Электроэнергетика һәм электроника ин-ты директоры (2004 тән). Хезмәтләре магнит күренешләре һәм каты җисем физикасына карый. М., беренче булып, үтә үткәрүчән кушылмаларның электрон структурасын өйрәнү өчен, төшнең квадруполь резонансы спектроскопиясе алымнарын куллана.

Х е з м.: Спектры ЯКР[93] Nb в соединениях со структурой A-15 // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1978. Т. 42, № 10 (автордаш); Ядерный квадрупольный резонанс в интерметаллидах // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1981. Т. 45, № 9 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**МАТУ́ХИН** Евгений Леонидович (17.11.1948, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2000). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1974 тән Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, сектор башлыгы (1985 тән), бүлек башлыгы (1995 тән), баш фәнни хезмәткәр (2000 нән). Хезмәтләре махсус химиягә карый. М. җитәкчелегендә матдә составын һәм үзлекләрен аналитик тикшерүнең экспресс алымнары комплексы, сынау алымнарына ГОСТ комплекслары һәм төрле кулланылыштагы техник материаллар эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. М. үтә түбән үзлеккә ия булган химик продуктлар алу технологиясен, полимер материаллар модификацияләүнең электрофизик алымнарын һәм технологияләрен тәкъдим итә, югары вольтлы электрон тизләткечләр куллануга нигезләнеп, тәҗрибә-сәнәгать полимер деструкциясе җайланмасын төзи. Целлюлоза этерификациясе кинетикасы һәм механизмы өлкәсендәге тикшеренүләре, целлюлоза һәм нитроцеллюлоза җитештерүдәге алдынгы алымнарның фәнни нигезләрен эшләгәне өчен СССР МС бүләгенә лаек була (1987). 180 мәкалә авторы. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар.

А.М. Матросов. В.М. Матросов.

Х е з м.: Исследования радиационно-химических процессов деструкции целлюлозы ускоренными электронами методом ЭПР // Журн. прикладной химии. 1990. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Лучшие сыны России. М., 2004.

**МАТУША́НСКИЙ** Григорий Ушерович (13.3.1946, Казан), педагог, физика-матем. фән. канд. (1974), пед. фән. д-ры (2003), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук радиофизика кафедрасында эшли. 1977 елдан Казан технол. ун-тында, югары уку йортлары укытучыларының белемен күтәрү ф-ты деканы (1986–2002), укытуда информацион технологияләр каф. мөдире (1996–2002). 2002 дән Казан энергетика ун-тында, проректор (2002–03), һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре пед. системаларны проектлаштыру, белгечләрне һөнәри эшчәнлеккә әзерләү, югары уку йортын тәмамлаганнан соң белем бирү тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Проектирование системы непрерывного профессионального образования преподавателей высшей школы. К., 1999; Дополнительное профессиональное образование преподавателя высшей школы (история, модели, перспективы). К., 2003; Становление и развитие системы послевузовской подготовки научно-педагогических кадров в России. К., 2006 (автордаш).

**МАТФЕ́Й** (? — 31.1.1646, Казан), дин эшлеклесе. 1606 елдан Кирилл-Белозерский монастыре игумены, 1610 да аны поляклардан саклауны оештыра. 1613 тә Земский собора катнаша. 1615 тән Казан һәм Зөя митрополиты. М. эшләгән чорда Казандагы *Архиерей йортының* вотчиналар б-н идарә итүче учреждениеләренең икътисади эшчәнлеге нык үсеш ала, Раифа Богородица, Седмиозёрный һ.б. монастырьларына нигез салына. М. мөселманнарга һәм мәҗүсиләргә карата көч куллануга каршы чыга, бу, үз чиратында, халыклар арасында дустанә мөнәсәбәтләрне саклап калуга ярдәм итә. Акча яки дәүләт милкен үзләштерүдә гаепләнгән берничә Казан воеводасы М. йогынтысы б-н эш урыннарыннан алына.

*Е.В.Липаков.*

**МАТЧА́ МАЕ́**, татар халкында борынгыдан килгән, йорт салганда матча күтәрү б-н бәйле йола. Татар авылларында хәзер дә саклана. Гадәттә, матча урнаштырылганнан соң, хуҗалар балта осталарына сөлге һәм яңа пешкән икмәк бирәләр, аларны атланмай (йола атамасы шуннан), корбанга чалынган тавык шулпасы б-н сыйлыйлар; бу корбан б-н яңа йорт изгеләштерелә, ул гаилә әгъзаларына саулык һәм озын гомер китерә, дип исәпләнә.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977; шулук. Типы сельских жилищ (конца XIX — начала XX вв.) // Пермские татары. К., 1983.

*Ф.Ф.Гулова.*

**МАТЮ́ШИНО** (Боровое Матюшино) авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 27 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 139 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1648–50 еллардан Матюшин Починок исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Матышкино буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 18 йөздә агач Илья чиркәве, 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 611,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Воскресенский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 53 ир-ат; 1859 да — 154, 1897 дә — 204, 1908 дә — 272, 1920 дә — 435, 1926 да — 401, 1949 да — 350, 1958 дә — 542, 1979 да — 181, 1989 да — 185, 2002 дә — 142 кеше.

**МАТЮ́ШИНО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 22 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 62 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында сарай җирләрендә нигез салына. Беренче исеме — Починок Матюшкин. 17 йөз ахырында дворян Нарышкиннарга шәхси милек буларак бирелә. Халкы игенчелек, терлекчелек, таш чыгару һәм эшкәртү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да земство мәктәбе (1887 дә ачыла), җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 684 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 245 ир-ат; 1859 да — 392, 1897 дә — 459, 1908 дә — 488, 1920 дә — 523, 1926 да — 503, 1938 дә — 549, 1949 да — 496, 1958 дә — 513, 1970 тә — 305, 1979 да — 271, 1989 да — 149, 2002 дә — 109 кеше.

**МАТЮ́ШКО** Борис Николаевич (17.8.1946, Казан), инженер-технолог, техник фән. канд. (1978), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1968), Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, сектор мөдире (1981 дән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1986 дан), массалар алмашу процессларын исәпләү һәм тикшерү лаб-ясе мөдире (2000 нән). Хезмәтләре күп компонентлы катнашмалар ректификациясе, абсорбциясе һәм сепарациясе процессларында җылылык-масса алмашуга, җылылык-масса алмашу кинетикасына карый. М. нефть һәм газ эшкәртү җайланмалары өчен колонналы җиһазларны исәпләү программаларын, газ конденсатын кабат эшкәртүнең технол. схемасын төзи. Дәүләт бүләге углеводород чималын җитештерү һәм аны күкертле кушылмалардан чистарту технологияләрен һәм катализаторларын эшләгәне өчен бирелә. Фәнни эшкәртмәләре «Татнефть» ҖБдә, Россия-Америка уртак «Тенгизшевройл» пр-тиесендә (Казакъстан Респ-касы), РФнең газ һәм нефть эшкәртү, нефть химиясе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә.

**МАТЯ́ШИН** Юрий Иванович (29.7.1939, Столбище р-ны Столбище а. — 23.2.2012, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1961 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясендә эшли. 1965–70 тә Бөтенсоюз терлек азыгы фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе Лобня ш.), әйдәп баручы инженер (1968 дән). 1982–86 да Бөтенсоюз сыек ашламалар фәнни-тикшеренү ин-тында механикалаштыру бүлеге мөдире (Мәскәү өлкәсе Клин ш.). 1986–87 дә Бөтенсоюз а.х.н механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсе Луговая ст.). 1970–82 дә һәм 1987 дән Казан аграр ун-тында хезмәтне саклау һәм производствога өйрәтү (1972–80), мелиорация (1980–82), машина-трактор паркын эксплуатацияләү (1996 дан) кафедралары мөдире. Хезмәтләре ротацион туфрак эшкәртү машиналарын проектлаштыру һәм эшләп чыгаруның фәнни нигезләренә карый. М. коник барабанлы һәм спираль эшче органлы, кучергечсез эшли торган машиналарның (үсемлекчелек комплексы өчен) компьютерлы технологияләрен һәм исәпләү системаларын тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә туфрак өслеген эшкәртү өчен экономияле ротацион механизмнар комплексы булдырыла. М. ТР машина-трактор паркының оптималь структурасын һәм составын нигезли. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы», «РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре» билгеләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт и проектирование ротационных почвообрабатывающих машин. М., 1988 (автордаш); Повышение экономичности работы машинно-тракторных агрегатов при совмещении технологических операций обработки почвы. К., 1994; Теория и расчёт ротационных почвообрабатывающих машин. К., 1999 (автордаш).

**МАУ́Н**, к. *Валериана.*

**МАХАО́Н** (Papilio machaon L.), җилкәнканатлылар семьялыгыннан күбәләк. Европа һәм Азиядә иң күп таралган күбәләкләрнең берсе. Канат җәеме 56–85 *мм*, кара бизәкле сары төстә, арткы канатларында зәңгәр чокырчык һәм берәр кызыл тап бар. Елга 2 тапкыр: май–июнь (язгы буын), июль–август (җәйге буын) айларында оча. Кышны курчак стадиясендә үткәрә. Гусеницалары зур, яшел төстә, аркылы кара буйлы һәм кызыл нокталы; чатыр чәчәклеләр семьялыгындагы үсемлекләрдә яшиләр. Башы артында, тыныч халәттә күренми һәм ярсулганда көчле исле агулы сыекча бүлеп хәрәкәтләнүче чәнечкесыман бизе бар. РФнең һәм ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*С.Г.Гордиенко.*

**МАХО́ТИН** Александр Анатольевич (30.1.1962, Пермь өлкәсенең Кизел ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан химия-технол. ин-тын (1982), Мәскәү икътисад-хокук ин-тын (2003) тәмамлый. 1979–1991 елларда, 1997 дән «Татнефть-Нефтехим» АҖнең идарәче компаниясендә эшли: маркетинг идарәсе башлыгы (1998 дән), «Кама» сәүдә йорты директоры (2001 дән), «Кама» фәнни-техник үзәгендә технологияләр һәм тәҗрибә-конструкторлык фәнни-тикшеренү эшләре буенча директор урынбасары (2003 тән). Уйлап табуга 10 нан артык патенты бар. Дәүләт бүләге «Түбәнкамашин» АҖдә көндәшлеккә сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү максатында яңа төр материалларны эшләү һәм үзләштерүдә катнашканы өчен бирелә.

**МАХО́ТКИН** Алексей Феофилактович (3.9.1941, Казакъстан ССРның Гурьев ш.), химия технологиясе процесслары һәм аппаратлары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бөгелмә механика з-дында эшли. 1970 тән Казан технол. ун-тында перспектив технол. процесслар җиһазлары (1979–81), химия з-длары җиһазлары (1994 тән) кафедралары мөдире, бер үк вакытта Казан «Яңа технологияләр» вузара инженерлык үзәге директоры (1982 дән). Хезмәтләре химия технологияләренә һәм инженерлык экологиясенә карый. М. химия җитештерүен интенсивлаштыру һәм сәнәгать пр-тиеләреннән чыгарылган ташландык газны азот к-тасы пары һәм томаны катнашмаларыннан чистарту өчен өермәле аппаратлар һәм катализаторлар эшли (ТР һәм РФнең 25 шәһәрендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 50 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретические основы очистки газовых выбросов в производстве нитратов целлюлозы. К., 2004.

**МАХО́ТКИНА** Лилия Юрьевна (14.1.1969, Казан), җиңел сәнәгать өлкәсе технологы, техник фән. д-ры (2006). 1992 елда Россия

текстиль һәм җиңел сәнәгать ин-тын (Мәскәү) тәмамлый, Казан технол. ун-тында эшли, өс һәм аяк киемнәре конструкцияләү каф. мөдире (2007 дән). Хезмәтләре җиңел сәнәгатьтә яңа технологияләрне тикшерү өлкәсенә (кием проектлаштыру; мех, аяк киеме, күн-галантерея әйберләре) карый. Уйлап табуга 8 патенты бар.

Х е з м.: Высокочастотная плазменная обработка в производстве обуви. К., 2006 (автордаш); Состояние и перспективы развития обувной промышленности // Кожевенно-обувная пром-сть. 2010. № 3 (автордаш); Влияние факторов окружающей среды на материалы лёгкой промышленности. К., 2011 (автордаш).

**МАХСУ́С УРТА́ МУ́ЗЫКА МӘКТӘБЕ́**, Казан консерваториясе каршындагы гомуми һәм проф. белем бирү уку йорты (көллият). 1960 елда Татарстаннан һәм Идел буеның башка төбәкләреннән сәләтле балаларны укыту һәм иҗади югары уку йортларына әзерләү максатыннан ачыла. Укучылар беренче сыйныфтан алып, барлык башка сыйныфларга кабул ителә; уку срогы гади урта мәктәпләргә караганда 1 елга артык. Мәктәп каршында башка шәһәр укучылары өчен интернат эшли. Укыту фортепиано, оркестр өчен кыллы уен кораллары, тынлы һәм бәрмә уен кораллары белгечлекләре буенча алып барыла. Мәктәпне тәмамлаучылар урта белем турында аттестат алалар һәм аларга белемнәрен консерваториядә дәвам иттерү хокукы бирелә; 2004 тән, программага пед. фәннәр кертелгәннән соң, уен коралларында уйнарга өйрәтүче укытучы, ш.у. концертмейстер (пианистлар өчен), оркестр артисты (кыллы һәм тынлы музыка уен кораллары белгечлекләре өчен) квалификациясе алалар. Мәктәптә: В.Г.*Апресов*, М.Б.Арбузова, И.С.*Дубинина*, Е.И.*Карпухин*, Э.А.*Монасзон*, Ш.Г.*Низаметдинов*, А.Н.*Хәйретдинов*, Ш.Х.*Монасыйпов*, В.Г.*Лукьянов*, А.Л.*Маклыгин* һ.б. укыталар. Тәмамлаучылар арасында танылган музыкантлар, педагоглар һәм музыка белгечләре: Р.К.*Абдуллин*, Р.Ю.*Абязов*, А.Ә.*Әсәдуллин*, А.Г.*Гыйльфанов*, С.М.Гуляк, Ю.А.*Егоров*, К.Х.*Монасыйпов*, М.В.Плетнёв, М.Ф.*Сираҗетдинов*, Д.И.Сөләйманова, Р.Г.Урасин һ.б. бар. Мәктәптә 200 бала укый (2009); пед. коллектив составында 72 — музыка һәм 23 гомуми белем бирү укытучысы исәпләнә, алар арасында — 13 профессор, 23 Казан консерваториясе укытучысы, ш.и. А.Ә.Әсәдуллин, М.Г.*Әхмәтов*, Э.К.*Әхмәтова*, Ә.В.*Бурнашева*, В.Р.*Дулат-Алиев*, Ф.И.*Хәсәнова*, һ.б. бар. 33 укытучы РФ һәм ТРның атказ. укытучысы, атказ. мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре, атказ. артист исемнәрен йөртә. 2007–09 да 40 укучы халыкара, бөтенроссия һәм төбәк музыка конкурслары лауреатлары була. Мәктәп директорлары: Г.Х.Ходжаев (1959–64), В.А.*Афанасьев* (1964–69), Ж.К.*Айдаров* (1969–73), И.Г.*Халитов* (1973–77), Р.Ш.Болгарская (1977–86), Р.Ю.*Абязов* (1986–96), А.А.Михайлов (1996 дан).

*В.М.Спиридонова.*

**МАХТЕ́ЕВ** Леонид Миронович (21.4.1927, Донецк өлкәсенең Макеевка ш., Украина ССР — 24.4.1992, Казан), радиоинженер, Ленин бүләге лауреаты (1978), СССРның мактаулы радисты (1980). Бөек Ватан сугышында катнаша. Кара диңгез флотының һава һөҗүменнән саклану белгечләре мәктәбен (1947), Казан авиация ин-тын (1958) тәмамлый. 1951 елда демобилизацияләнә һәм Казан ун-тының физика кафедрасында эшли. 1952 дән Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. (1960–61), бүлек (1961–62) башлыгы, баш инженер урынбасары (1962–69), баш инженер — директор урынбасары (1969–87). М. җитәкчелегендә тану аппаратурасы булдырыла (сериялэп җитештерүгә алына, коралланугa кертелә). Ленин бүләге радиолокация системасын төзегәне өчен бирелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МАЧАКЛЫБА́Ш** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 6 *км* төньяктарак, Вәрҗәде елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 39 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Азнакай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 118, 1949 да — 119, 1958 дә — 140, 1970 тә — 102, 1979 да — 60, 1989 да — 16, 2002 дә — 40 кеше.

**МАША́НИН** Григорий Михайлович (13.2.1919, Казан губ., Спас өязе Болгар а. — 26.5.1988, Ялта ш.), Сов. Союзы Герое (29.6.1945), гв. майоры. Омск очучылар хәрби авиация мәктәбен (1942), офицерлар составының очу-тактик әзерлеген камилләштерү курсларын тәмамлый (1946). Сугышка кадәр елга портында электрик булып, Әстерханда суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 6 нчы гв. авиация-штурм полкында звено командиры (3 нче гв. армиясе). 3 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Балтыйк буенда (1945), Көнчыгыш Пруссиядә барган һава сугышларында (1945) катнаша. 1945 нең маена кадәр 120 сугышчан очыш ясый, шуларның 100 ендә дошман ныгытмаларын һәм гаскәрләре тупланган урыннарны штурмлый. Өч тапкыр яралана. 1969 дан отставкада. Ялтада ДОСААФ ком-тында эшли. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; В созвездии славы. Волгоград, 1976; Я г о д и н с к и й Е.А. Золотые Звёзды речников. М., 1979. Вып. 3.

*М.З.Хәбибуллин.*



Г.М.Машанин.

**МАША́НОВ** Михаил Александрович (11.5.1852, Тобол губ. Петропавловск ш., хәзер Казакъстан Респ-касы — 1924, Казан), миссионер, шәркыятьче галим, җәмәгать эшлеклесе. Тобол руханилар семинариясен (1872), Казан руханилар академиясен (1876) тәмамлый. Н.П.*Остроумов* һәм В.Т.*Тимофеев* шәкерте. 1874–76 елларда, студент чагында, «Мөхәммәд динендәге кимчелекләргә искәрмәләр б-н христиан диненә кыскача аңлатма» буенча Казан үзәк керәшен татарлар мәктәбендә лекцияләр укый, 1874 тә миссионерлык эше б-н керәшен татарлар яшәгән җирләргә — Казан губернасы Мамадыш өязенә җибәрелә. Бу сәфәре, башлыча, аның киләчәктәге фәнни тикшеренүләренең асылын билгели, «Казан губернасы Мамадыш өязендәге керәшен татарларның дини-әхлакый хәле турында язма» («Заметка о религиозно-нравственном состоянии крещёных татар Казанской губернии Мамадышского уезда», 1875) хезмәте өчен мәгълүматлар туплау мөмкинлеге бирә. 1876 дан Казан руханилар академиясендә: инспектор ярдәмчесе, 1877 дән приват-доцент, 1885 тән доцент, 1887 дән экстраординар проф., 1906 дан атказ. экстраординар проф., 1911 дән миссионерлык мөселманнарга каршы фәннәр каф. штаттан тыш профессоры. 1878 дә Изге Гурий борадәрлеге советы составына һәм Борадәрлекнең эш кәгазьләрен алып баручы вазифасына сайлана. 1899–1914 тә (1885–86 да һәм 1904–06 да бүленеп) Борадәрлек сәркәтибе. Бу оешма вәкиле буларак, православиене пропагандалау һәм ислам йогынтысын киметү максатында, М. Казан губернасының барлык өязләрендә булып чыга. 1882 дән «Исламга каршы миссионерлык җыентыгы»ның («Миссионерский противомусульманский сборник»; 1892–1915 тә комиссиясенең казначее һәм эшләр идарәчесе, 1915 тән цензор) редакция комиссиясе әгъзасы. 1885–87 дә Сүриядә, Палестинада, Мисырда, Гарәбстанда командировкада була, гарәп телен һәм мөселман илаһият әдәбиятын өйрәнә. М. Казан руханилар академиясе китапханәсенә 80 ләп китап һәм кульязма җибәрә. Сәфәрдән кайткач, «Европа христианнары мөселман Шәрегында» («Европейские христиане на мусульманском Востоке», 1889) дигән китабын бастыра. 1889–1916 да *Казан миссионерлык курсларында* «илаһият энциклопедиясе», «Мөхәммәд кануны тарихы һәм аны фаш итү», гарәп теле буенча лекцияләр укый. 1892 дән Изге Гурий борадәрлегенең тәрҗемә комиссиясе рәисе. Бер үк вакытта, 1900–16 да, Казан губерна статистика ком-тының хакыйкый әгъзасы. 1905 нең мае-июнендә С.-Петербургта узган шәркый әҗнәбиләр мәгарифе мәсьәләләре буенча махсус киңәшмәдә М. «Изге Гурий борадәрлеге мәктәпләренең бүгенге хәле» дигән доклад б-н чыгыш ясый, Н.И.Ильинский программасын киләчәктә дә куллануны, мәктәпләрнең санын арттыруны, укытучыларның белем дәрәҗәсен күтәрүне хуплый. 1905–06 да «Церковно-общественная жизнь» ж-лы мөхәр-

рирләренең берсе. 1910 да миссионерлар съезды эшендә (Казан, 13–26 июнь) катнаша, «Мөхәммәд динендәге татарларның бүгенге хәле һәм аларның башка әҗнәбиләргә карата мөнәсәбәте» дигән доклад б-н чыгыш ясый, анда исламның рус булмаган халыкларга зур йогынты ясавын билгеләп үтә. М., акрынлап, мөселман татарлар арасында алга таба да актив миссионерлык эшчәнлеге алып баруның нигезсез булуы турындагы фикергә килә. 1912 дә «Инородческое обозрение» ж-лы мөхәррире. 1919–20 дә Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография ин-тында Көнчыгыш Россиядә ислам тарихы, ислам гыйлеме һәм гарәп теле буенча курслар укый, проф. (1920). 1921 нең 18 мартында, Казан руханилар академиясенең законсыз нигездә эшләве турындагы эш кузгатылып, 19 профессорның берсе буларак кулга алына. Шартлы рәвештә бер елга концлагерьда тотылуга хөкем ителә, соңрак иреккә чыгарыла.

Хәзерге Шәрекъны өйрәнү фәнендә М. гарәпләрнең исламга кадәрге инануларын өйрәнгән төп галимнәрнең берсе булып санала. Үзенең хезмәтләрендә ислам хөкем сөрүенең төрле аспектларын, Мөхәммәд пәйгамбәрнең эшчәнлеге, исламда никах, хатын-кызның тоткан урыны, исламның дин буларак үсешендә гарәпләрнең роле һ.б. мәсьәләләрне тикшерә. 1887–1924 тә Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте советы әгъзасы. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мухammеданский брак в сравнении с христианским браком в отношении их влияния на семейную и общественную жизнь человека. К., 1876; Очерк быта арабов в эпоху Мухаммеда как введение в изучению ислама. Ч. 1. Очерк религиозного быта арабов-язычников в эпоху Мухаммеда. К., 1885; Европейские христиане на мусульманском Востоке. К., 1889.

*Әд.:* Б е р д н и к о в И.А. Краткий очерк учебной и учёной деятельности Казанской духовной академии за пятьдесят лет её существования. 1842–1892 гг. К., 1892; М а з и т о в а Н.А. М.А.Машанов и проблемы исследования ислама в Казани в конце XIX — начале XX вв. // Историография Ирана нового и новейшего времени. М., 1989; Х а б и б у л л и н М.З. Михаил Александрович Машанов — профессор Казанской духовной академии, миссионер и исламовед. К., 2006.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МА́ШИН** Сергей Викторович (22.4.1944, Казан — 21.10.2001, шунда ук), генерал-лейтенант (1996). Казан ун-тын (1996), СССР Дәүләт иминлеге ком-ты югары мәктәбен (Мәскәү, 1982) тәмамлый. 1970–92 елларда ТР Дәүләт иминлеге ком-ты органнарында. 1992 дән ТРның Салым буенча тикшерүләр идарәсе башлыгы, 1993 тән ТРның Салым полициясе департаменты директоры, 1995 тән РФнең ТР буенча Салым полициясе Федераль хезмәте идарәсе башлыгы. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**МАШИНАЛА́Р ТӨЗҮ́ ҺӘМ МЕТА́ЛЛ ЭШКӘРТҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, авыр сәнәгатьнең хезмәт кораллары, куллану әйберләре, оборона продукциясе җитештерү һәм машиналар, җиһазлар ремонтлау б-н мәшгуль тармаклары комплексы.

М.т.һ.м.э.с.нең төп тармаклары: автомобильләр төзү (*«КамАЗ»*, элеккеге *«Гаро» заводы*, *«Алабуга автомобильләр заводы»* ҖБ, Лениногорск «Автоспецоборудование» заводы АҖ һ.б.), авиация төзелеше (*«Казан авиация җитештерү берләшмәсе»* АҖ, *«Казан вертолёт заводы»*, *Казан моторлар төзү берләшмәсе* АҖ һ.б.), приборлар төзү һәм радиоэлектроника (*«Теплоконтроль»*, *«Электроприбор»*, *«Элекон* заводы», *«Радиоприбор»*, *«Казан оптика-механика заводы»*, *«Чистай «Восток» сәгать заводы»* АҖләре һ.б.), суднолар төзү һәм суднолар ремонтлау (*«Яшел Үзән А.М.Горький исем. заводы»*, *«Чистай суднолар төзү һәм ремонтлау заводы»* АҖләре һ.б.). Насос-компрессорлар, вакуум һәм суыту җиһазлары («Казанькомпрессормаш», *«Вакуммаш»*, *«Әлнас»* АҖләре, *«Серго исемендәге завод»* ҖБ» федераль ДУП һ.б.), электротехник җиһазлар (*«Татэлектромаш»*, «Казан электротехника заводы» АҖләре һ.б.), мед. инструментлары һәм аппаратурасы (*«Казан медицина инструментлары заводы»*, *«Микрон»*, «Казан медицина аппаратурасы заводы» АҖ, «Медфизприбор» ФҖБ һ.б.), ягулык һәм нефть химиясе сәнәгате өчен җиһазлар (*«Әлмәт торбалар заводы»*, *«Нефтемаш»*, *«Нефтеавтоматика»* АҖләре), коммуналь, сан.-техник җиһазлар (*Казан газ аппаратлары заводы – Веста»*, *«Сантехприбор»* АҖләре һ.б.) җитештерү үсеш алган. Металл эшкәртү юнәлешендә *«Түбән Кама механика заводы»* АҖ, «КамАЗ», «АлАЗ» ҖБ АҖләре бүлекчәләре һ.б. зур күләмле эшләр башкаралар. 2012 елда Татарстанда 2647 М.т.һ.м.э.с. пр-тиесе (ш.и. 199 эре һәм уртача зурлыктагы, 2111 кече) исәпләнә, шуларның 2%ы — дәүләт милкендә, 5%ы — катнаш, 93%ы — хосусый милектә. Аларда якынча 149 мең кеше эшли. ТР сәнәгатендә М.т.һ.и.э.с.нең өлеше пр-тиеләр саны, төп фондлар, продукция, табыш күләме буенча тиңдәшле рәвештә (%ларда) 37,7; 11,6; 21,5; 8,8 тәшкил итә; шушы тармакта эшләүчеләр — 38,8%.

М.т.һ.м.э.с. продукциясенең күп кенә төрләрен эшләп чыгару буенча Татарстан РФдә иң алдынгы урыннарны били. РФ буенча гомуми күләмнән чыгып исәпләгәндә, респ-када газ турбиналарының 95% чамасы, йөк автомобильләре һәм үзәктән куулы эл.насосларының — 50 шәр % ы, көнкүреш суыткычлары һәм сәгатьләрнең 30 ар %ы, газ плитәләренең, приборларның, хисаплау техникасы, автоматлаштыру чаралары һәм аларга кирәкле запас частьларның 20 шәр %ы, медицина техникасының, аңа кирәкле запас частьларның, нефть һәм химия җиһазларының 15 әр %ы җитештерелә.

М.т.һ.м.э.с. пр-тиеләре, башлыча, Казанда, Чаллы, Яшел Үзән, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Чистай, Түбән Кама, Лениногорск шәһәрләрендә урнашкан. Кечерәк пр-тиеләр Азнакай, Нурлат, Буа, Арча шәһәрләрендә, Биектау тимер юл станциясендә, Хуҗамәт авылында (Минзәлә р-ны) эшли.

Казан губернасында беренче М.т.һ.м.э.с. пр-тиеләре 19 йөз башыннан мәгълүм. 1812 дә 5 завод була (аларда 481 крепостной һәм 282 ирекле ялланган эшче эшли; тимердән 5307 пот авырлыкта төрле әйберләр, чаңнар, бакыр савыт-саба, төймәләр җитештерелә). Пр-тиеләрнең иң зурлары Мамадыш өязендә урнашкан була, алар прапорщик Осокин (4 мич; 154 крепостной һәм 150 ирекле ялланган эшче; 2103 потлык продукция), сәүдәгәрләр Иноземцев һәм Үтәмишев (5 мич; 327 крепостной һәм 118 ирекле ялланган эшче; 1413 потлык продукция) милкендә булганнар. 19 йөзнең 2 нче яртысында чагыштырмача эрерәк заводлар: А.Н.Свешниковның чуен-бакыр коюю, тимерчелек-котельный һәм механика (Казан, 1851), А.М.Провотровның механика һәм чуен кою (Чистай ш., 1852), М.Я.Рамның механика (Казан, 1877), Л.Х.Либихтның (А.Н.Сапожковның) һәм И.М.Сенниковның чуен-бакыр кою (Казан, 1880, 1890), корыч кою (Паратский Затон а., 1898) з-длары; *«Кавказ вә Меркурий»* АҖнең суднолар ремонтлау остаханәләре, Тимер юллар министрлыгының Казан округы пр-тиеләре һ.б. барлыкка килә. Аларда бакыр коелмалар, пар казаннары, тимерчелек әйберләре, янгын сүндерү торбалары җитештерелә.

1913–14 тә Казан губернасында 16 металл эшкәртү һәм машиналар төзү пр-тиесе (аларда 2 меңнән артык кеше эшли) исәпләнә, араларында а.х. хезмәте кораллары һәм машиналары җитештерүчеләр, автомобильләр ре-

1960–2011 елларда ТР машиналар төзү һәм металл эшкәртү сәнәгате продукциясенең төп төрләрен җитештерү

| Продукция төре | 1960 | 1980 | 1990 | 2000 | 2011 |
|---|---|---|---|---|---|
| Металл кисү станоклары, данә | 377,0 | 218,0 | 156,0 | 12,0 | – |
| Приборлар, автоматлаштыру чаралары һәм алар өчен кирәкле запас частьлар (хисаплау техникасы чараларыннан һәм көнкүреш сәгатьләреннән тыш), млн. сум | 19,9 | 137,2 | 153,8 | 424,7 | 913,5 |
| Насослар, вакуумлы һәм югары вакуумлы агрегатлар, мең данә | 1,8 | 21,8 | 23 | 2,1 | 4,0 |
| Һава һәм газ компрессорлары, һава яки вакуумлы насослар, данә | 727 | 1248 | 1157 | 166 | 231,0 |
| Химик җиһазлар һәм алар өчен кирәкле запас частьлар, мең сум | 1912 | 2777 | 5787 | 4518 | 7772 |
| Йөк автомобильләре, данә | – | 23331 | 75983 | 23494 | 57416 |
| Җиңел автомобильләр, данә | – | – | 1962 | 33671 | 19839 |
| Медицина техникасы һәм аның өчен кирәкле запас частьлар, млн. сум | 4,9 | 25,6 | 45,1 | 235,0 | 1203 |
| Санитар-техник арматура, мең данә | 668 | 1520 | 1256 | 1213,8 | 1021,8 |

монтлаучылар да була. Аларның продукциясе губернадагы гомуми сәнәгать җитештерүе күләменең 5%ын тәшкил итә. 1918–19 да тармак пр-тиеләре национализацияләнә. Гражданнар сугышы елларында аларның күбесе ябыла, *яңа икътисади сәясәткә* күчкән пр-тиеләр Татметаллтрестка берләштерелә (1922). 1930 елларда гомумдәүләт *индустрияләштерү* сәясәтенә бәйле рәвештә яңа эре машиналар төзү пр-тиеләре оештырыла башлый. Бу чорда Казанда язу машиналары з-ды (1931), авиакомб-т — самолётлар, двигательләр җитештерү заводлары комплексы (1932), оптика приборлары чыгаручы 237 нче завод (1940) һ.б. нигезләнә. Суднолар төзү, суднолар ремонтлау з-длары һ.б. киңәйтелә һәм реконструкцияләнә. 1913 ел б-н чагыштырганда 1940 та М.т.һ.м.э.с. продукциясенең күләме 71 тапкыр арта. ТАССР илдә машиналар төзү һәм металл эшкәртүче эре үзәкләрнең берсенә әверелә. Бу елларда *Казан–Яшел Үзән сәнәгать төйнәлеше* формалаша. 1941–42 дә респ-кага машиналар төзүче һәм металл эшкәртүче 20 дән артык эре һәм уртача зурлыктагы пр-тие (76 мең хезмәткәр), ш.и. Мәскәүнең 22 нче авиация, 230 нчы авиация үлчәү приборлары, 2 нче сәгать, электромеханика з-длары, Ленинградның 387 нче авиация, 379 нчы эл. техникасы, оптика-механика, машиналар төзү з-длары, Воронежның 16 нчы моторлар з-ды, Киевның теш дәвалау борлары ф-касы, Бежецкийның автогараж җиһазлары з-ды (Калинин өлкәсе) һ.б. эвакуацияләнә. Респ-ка терр-ясендә яңа җитештерү төрләре — мед. инструментлары, оптика-механика, үлчәү, навигация приборлары, сәгать производстволары һ.б. барлыкка килә. Авиация төзелеше респ-када машиналар төзелешенең төп тармагына әверелә, аның өлеше төп сәнәгать-җитештерү фондлары бәясенең 80% тирәсен тәшкил итә. 1941–45 тә ТАССРда машиналар төзү продукциясе күләме 6,8 тапкыр, эшчеләр саны 2 тапкыр арта; тармакка барлык эшләүчеләрнең 70% тан артык өлеше, респ-када сәнәгый җитештерү күләменең 60% тан артык өлеше туры килә.

Сугыштан соңгы елларда М.т.һ.м.э.с. үсешен дәвам итә. Казанда компрессорлар, «Теплоконтроль», матем. машиналары, «Сантехизделия», «Сантехприбор» механика, «Лесхозмаш» з-длары, ш.у. Нурлат машиналар төзү з-ды, Лениногорск, Чистай махсус автомобиль җиһазлары з-длары һ.б. төзелә. ТАССРның көньяк-көнчыгыш р-ннарында *нефть-газ чыгару сәнәгате* үсеше нәтиҗәсендә *нефть-газ машиналары төзү сәнәгате* барлыкка килә. 10 нан артык завод (Бөгелмәдә һәм Лениногорск шәһәрендә — «Нефтеавтоматика», Әлмәт һәм Азнакай шәһәрләрендә — «Нефтемаш», Лениногорск шәһәрендә — «Газспецмашремонт», автоматлаштыру һәм агрегатлар-механика, Әлмәт шәһәрендә — насослар, торбалар, инструментлар, Әлмәт һәм Лениногорск шәһәрләрендә — приборлар төзү, Бөгелмә шәһәрендә — механика һәм электротехник җиһазлар з-длары һ.б.) төзелә; *Әлмәт–Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше* формалаша. 1950–70 елларда самолётлар, вертолётлар, кече корабльләр, приборлар һ.б. хәрби техника җитештерүче оборона комплексы пр-тиеләре кызу темплар б-н үсә. 1940 ел нәтиҗәләре б-н чагыштырганда, тармак продукциясенең күләме 1960 елга — 57,6, 1970 елга 178,9 тапкыр арта. 1970 елларда, КамАЗ (1969 да нигез салына) төзелешенә бәйле рәвештә, автомобильләр төзү үсеш ала. Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Зәй, Менделеев шәһәрләренең һәм шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогының сәнәгать пр-тиеләре җирлегендә Татарстан машиналар төзү сәнәгатенең яңа үзәге — *Түбән Кама территориаль-җитештерү комплексы* оеша. 1970–80 елларда М.т.һ.м.э.с. фәнни-техник алгарыш казанышларын: автомат, конвейерлы һәм өзлексез агымлы линияләрне, автоматлаштыру приборларын һәм чараларын, санлы программалар б-н идарә ителүле станокларны гамәлгә кертү, пластмассалар һәм композит материаллар куллану, технол. процесс б-н идарә итүне камилләштерү, производствоны туплау һәм специальләштерү һ.б. нигезендә интенсив рәвештә үсә. Ел саен эшләнмәләрнең 100 дән артык яңа төрләрен серияләп җитештерү үзләштерелә. 1970–80 елларда тармакта продукция чыгару 4,4, 1980–1990 елларда 1,8 тапкыр үсә һәм 1940 елгы күрсәткечтән 1402 тапкыр артып китә (1990). Респ-ка сәнәгать продукциясенең гомуми күләмендә М.т.һ.м.э.с.нең өлеше 40% тан күбрәк күрсәткечкә ирешә.

1990 елларда җитештерүнең күләме шактый кими: 1997 дә ул 1990 дагы күрсәткечнең 37% ын, ТР сәнәгать продукциясендә 14,9% ны тәшкил итә. Кайбер пр-тиеләрнең (Казан «Терминал» хисаплау техникасы чаралары ЖБ, Татарстан «Свияга» ЖБ, «Лесхозмаш», Нурлат машиналар төзү з-длары һ.б.) эшчәнлеге туктала. Оборона сәнәгате пр-тиеләрендә продукция чыгару күләме кискен кими (1998 дә 1990 дагы күрсәткечнең 10% ы җитештерелә), бу респ-ка икътисадында тискәре чагыла, чөнки җитештерү куәтләренең 60% ы әлеге пр-тиеләр карамагында була, ТР сәнәгатендә эшләүчеләрнең 40%ы аларга туры килә. Соңрак оборона сәнәгате пр-тиеләре конверсиягә күчерелә, аларга автомобиль транспорты, нефть һәм нефть химиясе, газ сәнәгате, төзелеш индустриясе, а.х. өчен детальләр һәм аерым әйберләр эшләп чыгару буенча дәүләт заказлары бирелә башлый (җитештерү күләменең 20% ы чамасы). 1999 дан М.т.һ.м.э.с. җитештергән продукциянең күләме арта бара һәм 2003 тә 1990 дагы күрсәткечнең 71% ын тәшкил итә. 1998–2012 дә тармакның җитештерү күләме 16,5 тапкыр арта (ТР М.т.һ.м.э.с. продукциясенең төп төрләрен җитештерү динамикасы таблицада бирелгән).

М.т.һ.м.э.с.нең күп кенә пр-тиеләре актив инновацион эшчәнлек алып баралар, көндәшлеккә сәләтле продукция чыгаралар. 30 дан артык пр-тиедә җитештерелүче продукция сыйфаты б-н ИСО-9000 халыкара стандартларына туры китереп идарә итү системасы гамәлгә кертелгән. М.т.һ.м.э.с.нең шактый пр-тиеләре («КамАЗ», «Казан вертолёт заводы», «Электроприбор», «Элекон заводы», «Казан медицина инструментлары заводы», «Микрон-холдинг», «Әлнас», «Яшел Үзән А.М.Горький исем. заводы», «Чистай «Восток» сәгать заводы» АҖләре, «Серго исемендәге завод» ҖБ федераль ДУП һ.б.) актив сәүдә-икътисад эшчәнлеге б-н шөгыльләнәләр.

Тармак продукциясе РФнең төрле төбәкләренә, 50 дән артык якын һәм ерак чит илләргә җибәрелә. ТРның экспорт структурасында машиналар төзү продукциясе 6,4% чамасы тәшкил итә (2012). Татарстанда чит илләр (АКШ, ГФР, Франция, Италия һ.б.) компанияләре б-н берлектә оештырылган 32 пр-тие, ш.и. «Камминз Кама» АҖ, «ZF-Кама» ҖЧҖ (икесе дә Чаллыда), «Кремер-нефтехим» АҖ (Түбән Кама), «Эка» АҖ (Казан), «Агро-Идея» ҖЧҖ (Лениногорск) һ.б. тотрыклы эшлиләр.

ТР М.т.һ.м.э.с. пр-тиеләренең күпчелеге читтән китерелгән чималны куллана. Төп чимал (кара металлар прокаты, тимер, төсле металлар, чуен) җибәрүчеләр — Урал, Үзәк, Идел-Вятка төбәкләре һәм Украина металлургия пр-тиеләре. Шул ук төбәкләрдән һәм РФнең Төньяк-Көнбатыш икътисади р-нынан комплектлаучы эшләнмәләр дә кайтарыла. Машиналар төзүче эре пр-тиеләр каршында 9 фәнни-тикшеренү ин-ты һәм 5 КБ эшли. М.т.һ.м.э.с. алдындагы мәсьәләләрне һәм бурычларны хәл итүдә югары уку йортларының тармак проблема лаб-яләре дә катнаша. Белгечләр Казан техник һәм Казан технол. ун-тларында, Кама икътисади инженерлык академиясендә, 6 техникумда һәм 10 лицейда әзерләнә. М.т.һ.м.э.с. пр-тиеләре Казан, Чаллы, Яшел Үзән, Чистай, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләренең социаль инфраструктурасын һәм шәһәр хуҗалыгы объектларын формалаштыруда актив катнашалар. Алар тораклар, халык мәгарифе һәм сәламәтлек саклау объектлары, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, клублар һәм мәдәният йортлары, стадионнар, спорт мәктәпләре һ.б. төзелешен финанслыйлар.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

*Әд.:* Абрамов В.П., Кладиев Н.Х., Шагимухаметов Ф.Г. Наш край Татарстан. К., 1970; Табеев Ф.А. На новых рубежах. К., 1976; Мустафин М.Р., Хузеев Р.Г. Всё о Татарстане. К., 1994; Фасхутдинов К.Ф. Промышленность Республики Татарстан в 50–90 годы XX в. // Историк и время. К., 2003.

*К.Ф.Фәсхетдинов, М.Ж.Гаитов, Г.Я.Мәүлетова, С.Г.Белов.*

**МАШИНА́-ТРА́КТОР СТА́НЦИЯСЕ** (МТС), СССРда җир эшкәртү һәм уңыш җыю өчен махсус техника б-н җиһазландырылган дәүләт а.х. пр-тиесе. МТСлар 1928 елдан колхозларга аграр хезмәт һәм оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә ярдәм күрсәтү өчен төзелә башлыйлар. А.х. җитештерүенең төп кораллары (трактор, чәчкеч, культиватор, комбайннар) б-н тәэмин ителәләр һәм а.х. җитештерүе өлкәсендә дәүләт сәясәтен уздыруда мөһим урын тоталар. Беренче МТС Одесса өлкәсенең Берёзовский р-нында Шевченко исем. С-39 трактор колоннасы җирлегендә оештырыла (1928). МТСлар булдырылганчы, барлык өлкәләрдә дә дәүләт машина-прокат пунктлары, трактор отрядлары,



Б.В. Машковцев.

машина һәм машина-ат станцияләре, трактор колонналары оештырылган була. Шуларның беренчеләре Татар Кандызы, Әмәкәй, Мөслим, Нөркәй, Норлат, Базарлы Матак, Буа, Тәтеш, Кукмара волостьларында (аларда 160 трактор исәпләнә) төзелә. «Мөслим» дигән беренче трактор колоннасы (Чистай кантоны) 1928 дә «Татхлебсоюз» системасында булдырыла (1929 да исеме Татарстанның 10 еллыгы исем. МТС дип үзгәртелә; анда 29 трактор исәпләнә); 1930 да язгы чәчүгә Тымытык, Теләнче Тамак, Норлат һәм Базарлы Матак МТСлары оештырыла (һәр станциядә — 20 дән 30 га кадәр трактор була). 1932 дә респ-када 45 МТС эшли (919 трактор); алар 1 млн. 480 мең *га* чәчүлекләре булган 1616 колхозга хезмәт күрсәтә. Аннан соң ел саен якынча 10 МТС булдырыла, 1936 га барлык районнарда да оештырыла. 1939 да станцияләр саны 103 кә җитә (5444 трактор), 1957 дә 115 МТС була. 1932 дән МТСларга бөртекле ашлык җыю комбайннары кайтарыла башлый. 1937 дә аларның саны 1717 гә җитә. МТСның төп җитештерү берәмлеге трактор бригадасы була. МТС утарында остаханә, гараж, ягулык-майлау материаллары базасы, машиналар өчен ышыклау түбәләре, складлар һ.б. хуҗалык объектлары, ш.у. торак һәм мәдәният-көнкүреш биналары урнаша. МТС башкарган эшләр өчен колхозларда җитештерелгән а.х. продукциясе яисә билгеләнгән бәя б-н акчалата түләнә, 1958 дән бары тик акчалата гына түләнә. 1950 еллар ахырыннан, агросәнәгать интеграциясе шартларында, а.х. пр-тиеләрен квалификацияле белгеч кадрлар б-н тәэмин итү даими яхшыртыла барганда, МТСларның җитештерү-техник хезмәт күрсәтү формасы хуҗалыклар ихтыяҗына туры килми башлый, аларның җитештерүне оештыру функциясе үсүдән туктый, шул сәбәпле колхозларның үз җитештерү резервларыннан файдалану инициативасы тоткарлана. 1958 дә МТСлар ремонт-техник станцияләр (РТС) итеп үзгәртелә (барлыгы 58), аларның техникасы колхозларга сатыла (133 мең трактор, 5 мең комбайн һ.б. техника). Соңрак РТСлар «*Татсельхозтехника*»ның район бүлекләре итеп үзгәртелә.

Авыл җитештерүчеләрен, игенчелектә һәм терлекчелектә фән-техника казанышларыннан файдаланып, заманча ысуллар б-н эшләүгә тартуда, авылның гомуми культурасын күтәрүдә МТСлар әһәмиятле роль уйный.

*Әд.:* Байрамов К.Л. Тракторные колонны и первая МТС в Татарии // Сб. науч. работ Казан. мед. ин-та. К., 1957. Вып. 3; Залялов А.М., Устюжанин Е.И. Коллективизация сельского хозяйства ТАССР 1927–1937 гг. К., 1968; Залялов А.М. Социалистическое преобразование сельского хозяйства Татарии. К., 1974.

*И.Н.Афанасьев.*

**МА́ШКИН** Константин Павлович (1895, Вятка губ. Уржум ш. — 1937, Мәскәү), профсоюз, хуҗалык эшлеклесе. 1915–16 елларда Казанда студентларның с.-д. түгәрәкләрен оештыручыларның берсе. 1917–20 дә Казан губерна башкарма ком-ты Президиумы әгъзасы һәм секретаре, ХХС рәисе, РКП(б)ның Казан губерна ком-ты секретаре. 1920 еллар башыннан профсоюз эшендә, Иваново-Вознесенск ком-ты рәисе, бер үк вакытта Мәскәү губерна профсоюз советларының оештыру бүлеге мөдире, ВЦСПС Президиумы әгъзасы. 1932 дән С.М.Киров исем. «Динамо» з-дында электр цехы башлыгы. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Мирсияпов Т.А., Фомин А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995). К., 1995.

**МАШКО́ВЦЕВ** Борис Вячеславович (9.7.1922, Пятигорск ш. — 23.11.1973, Казан), Сов. Союзы Герое (22.7.1966), полковник, атказ. очучы-сынаучы (1972). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. Энгельс хәрби очучылар мәктәбендә очуга әзерлек уза. 1956 да Казанның С.П.Горбунов исем. авиация з-дына очучы-сынаучы итеп билгеләнә. 1964 тә 1 нче класслы очучы-сынаучы квалификациясен ала. Герой исеме 1966 ның 22 июлендә хезмәт бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлыгы һәм яңа хәрби техниканы үзләштерүгә өчен бирелә. 1973 нең 23 ноябрендә сынау очышы вакытында авиация фаҗигасендә һәлак була. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1988. Т. 2. *М.З.Хәбибуллин.*

**МАШКО́ВЦЕВ** Николай Михайлович (1.11.1935, Удмурт АССРның Сюмси р-ны Ходыри а.), биохимик, вет. фән. д-ры (2001). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1959). 1959–63 елларда Ижевск респ-ка вет. бактериология лаб-ясенең паразитар авырулар бүлеге табибе булып эшли; бер үк вакытта, 1960 тан, йогышлы авырулар бүлегенә җитәкчелек итә. 1963 тән Казан вет. ин-тында (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе), нәорганик һәм органик химия каф. мөдире (1968–90), шул ук кафедрада доцент (1990–2008). Хезмәтләре а.х. терлекләренең тереклек эшчәнлегенә микроэлементлар һәм витаминнар тәэсирен өйрәнүгә карый. М. туфракта, үләндә, терлекләрнең тән тукымасы һәм органнарында селен булу-булмавын анализ ясап тикшерә. Удмурт Респ-касы Дәүләт бүләге лауреаты (2002).

Хезм.: Использование хелатных форм микроэлементов в животноводстве. К., 2005 (автордаш); Профилактика и терапия селеновой недостаточности у сельскохозяйственных животных. К., 2005.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**МАШО́НКИНА** Людмила Ивановна (3.4.1952, Приморье краеның Лазо р-ны Преображение бухтасы), астроном, физика-матем. фән. д-ры (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук астрономия кафедрасында эшли. 2004 тән РФА Астрономия ин-тының (Мәскәү) әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре йолдызлар атмосферасында спектраль сызыклар формалашуны өйрәнүгә, йолдызларда химик элементлар барлыгын билгеләүгә, Галактиканың химик эволюциясенә карый. М., беренче булып, Галактиканың калын һәм юка дискларының төрле химик тарихларын күзәтү юлы б-н раслый (нейтроннар эләктереп алу процессында синтезлана торган авыр элементлар барлыгын анализлау ярдәмендә); кайбер салкын йолдызларда барий, европий, стронций, неодий күләмен югары төгәллек б-н билгели; Галактиканың химик эволюциясе моделенә күзәтү чикләрен таба. Европа астрономнар җәмгыяте (1995 тән), Халыкара астрономнар берлеге (1998 дән) әгъзасы.

Хезм.: Не — ЛТР анализ формирования линий EuII в атмосферах звезд солнечного типа // Астрон. журн. 2000. Т. 77; The Accurate Collisional Cross Sections as Important Input Data in NonLTE Calculations // Model Armospheres and Spectrum Synthesis. ASP Conf. Ser. 1996. V. 108. Barium and europium abundances in cool dwarf stars and nucleosynthesis of heavy elements // Astronomy and Astrophysics. 2000. V. 364 (автордаш).

**«МАЯ́К»**, иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. Эчке Россия һәм Себер мөселман төрки-татарларның Милли идарәсе органы. 1918 елның 7 декабреннән 1919 ның 21 апреленә кадәр Петропавловск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 30 саны чыга. Мөхәррире — Г.*Исхакый*. Газетаны нәшер итүдә башлап йөрүчеләрнең берсе Ф.*Туктаров* Самара шәһәре Милли идарәсенең урындагы бүлегеннән татар хәрефләрен сатып ала. Г.Терегулов, Г.Баттал, З.Кадыйри «М.» б-н хезмәттәшлек итә. Газетада Уфа шәһәрендә оештырылган Эчке Россия һәм Себер мөселман төрки-татарларның Милли идарәсе, ш.у. Парижда үткән Версаль тынычлык конференциясе эшендә катнашу өчен сайланган Милләт Мәҗлесе комиссиясе эшчәнлегенә зур игътибар бирелә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Исхакый Г. Гәзитчелек эшендә 25 ел // Әдәби җомга. 1992. 24 апр.; Насыйров Т. Гражданнар сугышы чорындагы большевистик булмаган татар матбугаты // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4.

*Т.М. Насыйров.*

**МАЯКО́ВСКИЙ** Владимир Владимирович (7.7.1893, Грузия, Багдади а. — 14.4.1930, Мәскәү), шагыйрь, драматург. «Штанлы болыт» («Облако в штанах», 1915), «Владимир Ильич Ленин» (1924), «Яхшы!» («Хорошо!», 1927), «Бөтен тавышка» («Во весь голос», 1930) һ.б. поэмалар, «Кандала» («Клоп», 1928), «Мунча» («Баня», 1929) һ.б. пьесалар, шигырьләр авторы. Казанда өч тапкыр була. Беренче килүендә, 1914 елның февралендә, Дворяннар җыены залында үзенең матурлыкны ничек аңлавы турында лекция укый. Икенче килүендә, 1927 нең гыйнварында, Казан ун-тында лекция б-н чыгыш

ясый, «Владимир Ильич Ленин» поэмасыннан өзекләр укый. Алган тәэсирләрен «Яңа туган башкалалар» («Рождённые столицы», 1927) мәкаләсендә чагылдыра: Казан һ.б. шәһәрләр «... революция нәтиҗәсендә башкалалар булып киткән шәһәрләр үсәләр, төзеләләр һәм, иң мөһиме, азатлыкка ирешкән илләрнең мөстәкыйль мәдәнияте б-н сулыйлар», дип яза. «Союз шәһәрләре буйлап» («По городам Союза», 1927) шигырендәге «Университет — Казанның горурлыгы» («Университет — горделивость Казани») дигән гыйбарәсе канатлы сүз булып китә. 1928 нең башында М. кабат Казанга килә: 20 гыйнварда «Колос» кинотеатрында язучының эшчеләр алдындагы җаваплылыгы турында чыгыш ясый, 21 гыйнварда Казан ун-тының актлар залында «Владимир Ильич Ленин» поэмасыннан өзекләр укый, 23 гыйнварда «Яхшы!» («Хорошо») поэмасын, әдәбият турында доклад укый, «Казанское подворье» кунакханәсендә җирле шагыйрьләр б-н очраша. Бу очрашуда өч тапкыр — чуаш, татар һәм мари телләрендә М.ның «Сул марш» («Левый марш») шигыре яңгырый (1927 дә Г.Кутуй тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителә). Бу очракны М. «Казан» («Казань», 1928) шигырендә искә ала. «Өч мең һәм өч сеңел» («Три тысячи и три сестры», 1928) шигырендә М.: «Дастан булып / күтәрелә Казан, / Кызыл Татарстанның / башкаласы», — дип яза. Казан театрлары сәхнәләрендә аның 1923 тә — «Мистерия Буфф» пьесасы, «150000000» поэмасы буенча, 1967 дә «Мунча» пьесасы буенча спектакльләр куела.

Ә с ә р.: Сочинения: В 2 т. М., 1987.

*Әд.:* Л а в у т П.И. Маяковский едет по Союзу. М., 1969; Бушканец Е.Г Маяковский в Казани // Литературный Татарстан. К., 1950.

*Л.Е.Бушканец.*

**МАЯ́НСКАЯ** Ксения Александровна (13.1.1907, Иркутск ш. — 1997, Казан), терапевт, рентгенолог, мед. фән. д-ры (1952), проф. (1956), ТАССРның атказ. табибе (1964). Ә.Б.Терегулов шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), Яшел Үзән шәһәрендә терапевт булып эшли. 1932–33 елларда Урта Идел краеның Ульянов р-ны Ишеевка авылы участок хастаханәсе мөдире. 1933–35 тә Ульянов шәһәренең совхоз-колхоз поликлиникасында терапевт һәм рентгенолог. 1935 тән Казанда: өлкә хастаханәсендә рентгенология кабинеты мөдире. 1936 дан Казан мед. ин-тының терапия клиникасында, 1960 тан 1 нче госпиталь терапиясе каф. мөдире, 1970 тән проф.-киңәшче. Бөек Ватан сугышы елларында эвакогоспитальләрдә эшли. Хезмәтләре ашкайнату органнары авыруларын ачыклау һәм дәвалауга карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О рентгенодиагностике хронических аппендицитов // Казан. мед. журн. 1938. № 8/9; Клинико-рентгенологические наблюдения при дискинезиях толстого кишечника // Казан. мед. журн. 1949. № 2; Функциональные взаимосвязи органов пищеварения. Л., 1970.

**МАЯ́НСКАЯ** Светлана Дмитриевна (19.5.1963, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), Новосибирск клиник һәм экогенталь мед. ин-тында эшли. 1992–2000 елларда Новосибирск дипломнан соң белем бирү мед. академиясенең факультет терапиясе кафедрасында; 2001–02 дә клиник патофизиол. курсы мөдире; 2002–08 дә поликлиника терапиясе һәм гомуми дәвалау практикасы, 2008 дән кардиология һәм ангиология кафедралары мөдире. Фәнни-тикшеренү эшләре ишемия авыруы очракларында ялкынсынулар ролен, артериаль гипертензия һәм атеросклероз очракларында эндотелиаль дисфункция көчәю механизмнарын өйрәнүгә багышлана.


Х е з м.: Функциональное состояние эндотелия сосудов в динамике развития артериальной гипертонии у лиц молодого возраста// Медицина и образование в Сибири. 2009. № 6 (автордаш); Ранние маркеры дисфункции эндотелия в динамике развития артериальной гипертонии у лиц молодого возраста // Казан. мед. журн. 2009. Т.90, № 1 (автордаш)..

**МАЯ́НСКИЙ** Андрей Николаевич (27.11.1940, Казан), иммунолог, аллерголог, мед. фән. д-ры (1977), проф. (1981). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1977 дән иммунология һәм биохимия фәнни-җитештерү бүлеге мөдире. 1981 дән Түбән Новгород мед. ин-тының микробиол. каф. мөдире. Хезмәтләре аллергология, иммунология һәм организмның иммун саклануучанлыгын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Реактивность нейтрофила. К., 1984 (автордаш); Очерки о нейтрофиле и макрофаге. Новосиб., 1989 (автордаш); Моделирование и клиническая характеристика фагоцитарных реакций. Горький, 1989; Введение в медицинскую микологию. Учебно-метод. пособие. Н.Новгород, 2000.

**МӘГА́ЗОВ** Риза Шәехҗан улы (10.3.1932, БАССРның Миякә р-ны Яңа Ишле а.), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1986), БР ФА академигы (1992), БАССРның атказ. табибе (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Миякә р-ны хастаханәсендә окулист, хирург (1962 гә кадәр), Әлшәй р-нында баш табиб (1963–64), Г.Г.Куватов исем. Респ-ка хастаханәсендә баш табиб (1965–78, Уфа). 1978 дән И.И.Мечников исем. Вакцина һәм сыркынды фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (Мәскәү). 1988 дән «Иммунопрепарат» ФҖБ ген. директоры (Уфа), проф. (1992). Хезмәтләре авыруны вакцина кулланып кисәтү теориясе һәм практикасына карый. М. анаэроб һәм шартлы-патоген микроблар китереп чыгарган авыруларны кисәтү һәм дәвалау өчен яңа вакцина препараты — полианатоксин уйлап таба. Вакцина кулланудан соң организмның функциональ халәтен комплексы бәяләү ысулларын тәкъдим итә. СССР МС бүләге (1985) бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: 100 лет на страже здоровья. Уфа, 1976; Вакцины, поствакцинальные реакции и функциональное состояние организма привитых. Уфа, 1985 (автордаш); Поствакцинальные реакции: Механизм развития и профилактика. Уфа, 1991.



Р.Ш. Мәгазов.

**МӘГАРӘЛӘ́Р** (гарәп. — مغارة),җир кабыгының өске катламында җир өстенә бер яки берничә чыгу урыны булган куышлар. Җир асты сулары тәэсирендә сульфатлы һәм карбонатлы (гипс, известьташ, доломитлар) токымнарның эрүе (карст процессы) нәтиҗәсендә хасил булалар. М., гадәттә, бер яки күп яруслы озын галерея булып сузылалар, алар буенча еш кына җир асты елгалары ага. Киңәйгән вакытта галереялар берничә метр биеклектәге заллар хасил итә, аларны еш кына күлләр били. Кальций һәм углекислый газ б-н туенган тамып торучы суларның парга әйләнүеннән мәгарә түбәсеннән боз сөңгеләре рәвешендә асылынып торучы сталактитлар хасил була. Идәнендә 20–25 *м* га кадәр биеклектәге конус рәвешле сталагмитлар үсеп чыга. Сулар туңудан боз капламнары барлыкка килә. Тауларда М. аеруча күп. АКШтагы Мамонт мәгарәсе (озынлыгы 240 *км*) — дөньяда иң зурысы. Россиядәге зур мәгарәләрнең берсе — Көнгер мәгарәсе — Уралда урнашкан. Зур булмаган мәгарәләр бәрмә дулкын, суффозия (вак минераль кисәкчекләрнең су б-н аска юылуы), дефляция (өрдерү) нәтиҗәсендә барлыкка килә. Татарстанда Идел елгасының уңъяк сөзәклегендә Пермь системасы Казан ярусы гипслары катламнарында карстлы М. системасы билгеле (к. *Кама Тамагы спелеология системасы*). Урта Идел буендагы *Юрьев мәгарәсе* алар арасында иң зурысы (озынлыгы 410 *м*).

*Әд.:* С т у п и ш и н А.В., М у х и т д и н о в а Д.Х. Сюкеевские пещеры. К., 1950; С т у п и ш и н А.В. Равнинный карст и закономерности его развития на примере Среднего Поволжья. К., 1967; Г в о з д е ц к и й Н.А. Проблемы изучения карста и практика. М., 1972.

*А.П.Дедков.*

**«МӘГАРИ́Ф»** («مه‌عاريف»), Казандагы нәшрият һәм китап сату ширкәте. 1906 ел ахырында бертуган *Шәрәфләр*, Г.Камал, М.Корбангалиев тарафыннан оештырыла. 1907 нең июненнән аны М.М.Мостафин җитәкли. «М.» редакциясе Х.Ямашев, Г.Тукай б-н тыгыз бәйләнештә була. Бу с.-д. юнәлешендәге татарча әдәбият басмаларында да, Г.Тукайның үзе исән чагында басылган әсәрләр җыентыгында да чагыла.

Окт. рев-циясеннән соң нәшрият б-н Г.Шәрәф җитәкчелек итә. Нәшрияттә китаплар, брошюралар, дәүләт оешмаларының, ш.и. РКП(б) мөселман оешмаларының үзәк бюросы заказлары буенча листовкалар, мәс., «Коммунистик манифест» (1918) басыла. Татар мәктәпләре өчен арифметика, физика, геом., гарәп теле буенча дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре нәшер ителә. «Балалар китапханәсе»

сериясендә Г.Рәхим, Җ.Шәрәф, Ф.Әмирхан, Н.Исәнбәт һ.б.ның (30 дан артык исемдә), Г.Тукайның (22 исемдә) әсәрләре бирелә. Балалар өчен «Шигырьләр китапханәсе» сериясе, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, Е.И.Чириков, Һ.К.Андерсен һ.б.ның тәрҗемә әсәрләре, татар язучыларының хикәяләре басыла. Мәгърифәтчелек эшчәнлеге совет хакимияте вакытында да дәвам итә. Барлыгы 120 басма (аларның 51е — балалар өчен әдәби әсәрләр) дөнья күрә: 1917 дә — 18, 1918 дә — 21, 1919 да — 39, 1920 дә — 7, 1921 дә — 2 исемдә китаплар чыга. Балалар әдәбияты, дәреслекләр 20–40 мең данә, кайберләре 60 мең данә тираж б-н нәшер ителә. Каталоглар (1909, 1911, 1913, 1914) басыла.

1919 ел уртасына кадәр китапларын үз басмаханәсендә, ә национализацияләнгәннән соң, төрле дәүләт басмаханәләрендә бастыра.

*Әд.:* Кәримуллин Ә.Г. Китап дөньясына сәяхәт: татар басма сүзенең сәхифәләреннән. К., 1979; шул ук. Татарская книга начала ХХ века. К., 1974; шул ук. Становление и развитие татарской советской книги: 1917–1932. К., 1989.

**«МӘГАРИ́Ф»**, ТР милли нәшрияты. 1991–2010 елларда эшли. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар телендә дәреслекләр, уку ярдәмлекләре нәшер итә. Татар мәктәпләре өчен рус теле, рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслекләрен әзерли. Югары уку йортлары өчен татар телендә дәреслекләр, ике телле мәктәп дәреслекләре, фразеология, химия, биол., мед. буенча русча-татарча сүзлекләр, орфография, матем. һәм техник терминнар сүзлекләрен бастыра. 1991 дән 2006 ның 1 маена кадәр гомуми тиражы 20 млн. данә тәшкил иткән 1800 гә якын басма дөнья күрә. Һәр елда 1,5 млн. данә гомуми тираж б-н 100 гә якын исемдә китап басыла. Басылган китапларның 30% ка якыны Россиядә һәм аннан читтә татарлар күпләп яшәгән өлкәләрдә тарала. 2010 да Татарстан китап нәшриятына кушыла.

*Әд.:* Кто есть кто: Авторы издательства «Магариф». К., 2002; Книги — крылья души = Китап — күңел канаты: Книги издательства «Магариф» (1991–2006): Библиогр. справ. К., 2006.

**«МӘГАРИ́Ф»**, Казандагы басмаханә. 1906–13 елларда төрле исемдә эшли: *Шәрәфләр басмаханәсе*, *«Үрнәк»*, Казаков В.Е., *Антонов Л.П. ташбасмаханәсе*. 1906 елның 1 ноябрендә галим һәм мәгърифәтче Г.Шәрәф тырышлыгы б-н *«Мәгариф»* нәшриятының техник базасы буларак ачыла һәм *«Матбагаи Шәрәф»* дип атала башлый. Беренче басмасы — М.Гафуриның «Яшь гомерем» исемле шигырьләр җыентыгы. М.Гафуриның дүрт җыентыгы, Г.Тукайның өч җыентыгы, рус шагыйрьләренең бер җыентыгы кергән «Шигырьләр мәҗмугасы» сериясе; татар халык җырлары, фәнни-популяр әсәрләр җыентыклары, тарих, медицина, татар теле грамматикасы буенча китаплар, сәяхәт очерклары һ.б. басыла. Басмаханә, нигездә, «Мәгариф», «Сабах» (Казан), «Хезмәт» (Троицк) нәшриятлары, Х.Әбүзәров, Ә.Исхаков, Н.Сөләйманов, бертуган Шәрәфләр заказлары буенча эшли. Г.Шәрәф басмаханәсендә чыккан 106 басманың 20 гә якыны хөкүмәткә каршы юнәлештә булганы өчен эзәрлекләнә. Монда татар демократик матбугаты — «Әхбар» г-тасы, «Тәрбия», «Казан мөхбире» ж-лары басыла. 1906 ның ноябрь–декабрь айларында гына да тиражы 37280 данә булган сәяси тема буенча 13 исемдә китаплар нәшер ителә. Басмаханәне 1908 нең уртасында ябалар (сәбәбе — цензура фикеренчә, баш күтәрүгә чакырган «Форъядлар» шигыре басылуда), 1908 нең ноябрендә аның җирлегендә Г.Ю.Саинов тарафыннан «Үрнәк» басмаханәсе ачыла. Шул елның декабрендә 13 китап басыла: А.С.Пушкинның «Таш кунак» («Каменный гость»), Л.Н.Толстой хикәяләре, И.Богдановның «Зөләйха һәм Фатыйма» пьесасы, география һәм татар теле дәреслекләре. Татар телендә гомуми тиражы 480665 данә булган 152 исемдә китап нәшер ителә: аларның 79 исемдәгесе — Ф.Әмирхан әсәрләре, Г.Камал драмалары, 9 ы — Г.Тукай шигырьләре. Н.В.Гоголь, М.Горький, Д.Дефо һ.б.ның тәрҗемә әсәрләре дә басыла. География, математика буенча дәреслекләр, фәнни-популяр әсәрләр, календарьлар, рус, фарсы һ.б. телләр үзөйрәткечләре нәшер ителә. Продукциянең яртысын басмаханәнең үз хисабына басылган китаплар тәшкил итә. 1911 дә нибары 11 китап басыла. 1911 нең 18 гыйнварында басмаханә ябыла. 1911 нең 20 апрелендә Г.Шәрәф аны рәсми рәвештә В.Е.Казаковка сата. Әмма Г.Ю.Саинов вакытындагы кебек үк аның чын җитәкчесе булып кала. Басмаханәдә 163 исемдә җиһаз, ш.и. 1 тиз баса торган машина, 1 «Американка» басу машинасы, 9 мең сумлык 112 поттан артык хәреф була. Басмаханәдә 8 кеше, ш.и. 3 хәреф басучы, 4 хәреф җыючы эшли. Татар телендә 1,5 ай эчендә гомуми тиражы 49,5 мең данә булган 14 китап басыла (Байронның С.Сүнчәләй тәрҗемәсендәге «Шильон тоткыны», З.Бәшири хикәяләре, дәреслекләр һ.б.). 1911 нең 26 ноябрендә «Төрле-төрле җырлар» дигән татар халык җырлары җыентыгына арест салына, цензура фикеренчә, әлеге җырлар «дошманга каршы сүз б-н генә түгел, туры мәгънәсендә корал б-н дә көрәшергә» чакыралар. Килеп туган хәлләр «Үрнәк» басмаханәсенең ябылуына китерә.

1911 нең ахырында ул Л.П.Антонов ташбасмаханәсе составына керә. 1912 дә, татар хәрефләре сатып алынганнан соң, 106,5 мең данә тираж б-н 26 исемдәге татар китабы басыла. 1911–13 елларда татар телендә гомуми тиражы 295 мең данә булган (нигездә, «Мәгариф» нәшрияты заказлары) 76 китап нәшер ителә. Балалар өчен китаплар, календарьлар, шигырьләр, фәнни хезмәтләр басыла. 1913 нең ноябрендә «Мәгариф» нәшриятының бер үк исемдәге үз басмаханәсе ачыла, ул М.М.Мостафин исеменә рәсмиләштерелә. Пайчылары — Г.Камал, М.Корбангалиев һәм Г.Шәрәф; соңгысы оештыручы һәм җитәкче булып кала. Басмаханәдә 2 тиз баса торган машина, 100 пот рус һәм 700 пот татар шрифты була. Анда 10–15 кеше хезмәт куя. 1917 гә кадәр гомуми тиражы 530350 данә тәшкил иткән 147 исемдәге китап басыла. Төрле исемнәрдә эшләп килгән «Мәгариф» басмаханәсе 1906 дан 1917 гә кадәр гомуми тиражы 1,4 млн. данәдән артып киткән 419 китап бастыра. Окт. рев-циясеннән соң балалар өчен китаплар, милли мәктәпләр өчен дәреслекләр нәшер ителә, РКП(б) каршындагы мөселман оешмаларының үзәк бюросы заказларын — «Коммунистик манифест» (1918), «Икмәк монополиясе» (1918) брошюралары, листовкалар һ.б. басыла. 1919 ның июнендә, бертуган Кәримовлар басмаханәсе б-н берләшкәннән соң, ул 6 нчы дәүләт басмаханәсе исемен ала, 1922 дән — К.Якуб исем. басмаханә.

*Әд.:* Кәримуллин Ә.Г. Беренче татар китаплары // Историко-культурное наследие = Тарихи-мәдәни мирас. К., 2009; шул ук. Татарская книга начала ХХ века. К., 1974; Здравствуй, Книга! К., 1989.

**«МӘГАРИ́Ф»** («معارف»), газета. Оренбург губернасы халык мәгарифе бүлеге органы. 1923 елда Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, 1 нче саны 1923 нең 10 февралендә чыга. «Иптәшләр, яхшы тормыш өчен аң-белем таратуга булышлык итик!» дигән девиз б-н басыла. Актив авторлары — Н.Баймурзин, Н.Надиев. Төп темалары: халык мәгарифе проблемалары; наданлыкны бетерү юллары; коммунистик идеология нигезендә мәктәптә белем бирүне реформалаштыру; ачлык һәм җимереклек б-н көрәш; халык хуҗалыгын аякка бастыру; эчке һәм тышкы сәясәттәге яңалыклар. Фән һәм техника өлкәсендәге яңалыклар турында хәбәрләр, икътисади язмалар басыла.

*Әд.:* Гайнанов Р.Р., Марданов Р.Ф., Шакуров Ф.Н. Татарская периодическая печать (1905–1924): Библиогр. указ. К., 1999.

*А.Ә.Хәсәвнех.*


**«МӘГАРИ́Ф»** («معارف»), дини, әдәби журнал. 1909 елның 16 гыйнварыннан 1910 ның 13 августына кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә аена 2 тапкыр, барлыгы 14 саны нәшер ителә. Нашире — Габдрахман Галиев, мөхәррире — М.Рахманкулов. «Мөселман туганнар, берләшеп, мәгариф юлына басыйк!» девизы б-н чыга. Актив авторлары арасында — И.Әбдрәшитов, Ахунзадә, А.Биктимеров, С.Исхакый, Б.Мансуров, М.Хәлил, З.Шәрифуллин, Г.Янап була. Басманың максаты — Россия мөселманнарының интеллектуаль дәрәҗәсен күтәрү һәм әхлакый аңын үстерү. Журналның тематик юнәлеше редакциянең «дин һәм әдәбият — милләтләрне якынайту һәм алар арасында мөнәсәбәтләрне ныгытуда ике көч» дигән фикерендә чагыла. Шәригать нигезендә «иҗтимагый тормыш төзү» турында чыгыш ясаганда «М» ш.у. дини тормыштагы рухи торгынлыкны тәнкыйтьли, иске карашлы мөселманнарга каршы чыга. «Коръән тәфсире турында» рубрикасында *сүрәләрнең* тәрҗемәләре, аларның имам Газали шәрехләвендәге мәгънәләре, М.Бигиевнең Коръәнне татар теленә тәрҗемә иткәндә килеп чыккан проблемалар турындагы тикшеренүләре басыла. «Җәмгыяте исламия» һәм «Дар әл-могаллимин» эшчәнлеге яктыртыла. «Фән һәм мәгариф» бүлегендә мәктәпләрдә яңа ысул б-н белем бирү, бала тәрбияләү, хатын-кызның бала тәрбияләүдәге роле, физика, химия, астрономия, геогр. өлкәсендәге фәнни ачышлар турында мәкаләләр басыла. «Төркиләр тарихы» рубрикасында Төрки каганлык тарихы,

төрки кабиләләрнең үзара мөнәсәбәте, аларның этнографиясе һәм мәдәнияте турындагы мәкаләләре урын ала. Журнал Габбасыйлар идарәсе чорындагы Гарәп хәлифәлеге тарихы б-н таныштыра. Гарәп шагыйре Г.Шәүкинең дини эчтәлекле шигырьләреннән өзекләр, мөнәҗәтләр, хикәяләр басыла. 1910 ның февраленнән журнал сирәгрәк, өзеклекләр б-н чыга, күләме кыскара.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МӘГАРИ́Ф»**, иҗтимагый-пед., фәнни-әдәби айлык журнал. Оештыручысы — «Татмедиа» ААҖ. «Мәктәп» ж-лының дәвамчысы. 1918 елның 7 ноябреннән Казанда татар телендә нәшер ителә. Эчке Россия мөселман эшләре комис-тының Гыйльми һәйәт органы буларак чыга башлый. 1918 нең ноябреннән 1919 ның мартына кадәр 3 саны дөнья күрә, аннары чыгудан туктый. 1921 нең апрелендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты тарафыннан яңадан басыла башлый. Төрле елларда-гы исеме: 1918–36 да «М.», 1936–37 дә «Башлангыч мәктәп», 1938–41, 1949–90 да «Совет мәктәбе», 1990 нан «М». Журналны оештыручылар: беренче мөхәррире Г.*Ибраһимов* һәм Казан губерна мәгариф халык комиссары Ш.*Әхмәдиев*. Мөхәррирләре: В.*Шәфигуллин* (1921–22), Г.*Максудов* (1923–24), М.*Таһиров* (1925), Н.*Мөхетдинов* (1927), Г.*Ходаяров* (1931–32), Г.Биктаһиров (1933–34), Ш.*Башкиров* (1934–1937), И.Әбдрәшитов (1937), Г.Бакиров (1937), М.*Вәлитова* (1938–41), Х.Хәйри (1949), Г.Гайфуллин (1950–51), Ф.Махиянов (1952–60), Ш.Ногманов (1960), Ф.*Ибраһимов* (1960–77), В.*Зыятдинов* (1977–89), Ф.*Шәрифуллин* (1989–2003), Г.*Шәмсетдинов* (2004–2013), И.Миргалимов (2013 тән).
















Журналлар: 1-2, 6. «Мәгариф»; 3. «Башлангыч мәктәп»; 4, 5. «Совет мәктәбе».

1920 елларның 1 нче яртысында гомумсәясиһәм тарихи темаларга багышланган мәкаләләр күп басыла, 2 нче яртысыннан журналда игътибар пед. мәсьәләләргә бирелә. Төп темалар арасында: педагогикада яңа юнәлеш — педологияне үстерү, сәяси-агарту эшчәнлеге, һөнәри белем бирү, мәктәпкәчә тәрбия, педагоглар арасында профсоюз эше, мәктәптә пионер һәм төбәкне өйрәнү эше, дингә каршы пропаганда алып бару проблемалары һ.б. Бу елларда журналның иң актив авторлары — Г.Алпаров, Х.Бәдигый, А.Вәлитов, В.Горохов, М.Корбангалиев, Н.Надиев, Г.Ногайбәк, Ш.Рамазанов, Г.Рәхим, И.Рәхмәтуллин, Г.Сәгъди, Д.Сафин, Ф.Хәмидуллин, Г.Шәрәф, Л.Яфаровның мәкаләләре басыла. 1930 елларда журнал сәхифәләрендә *яңалифкә* күчү, наданлыкка каршы көрәш, тәрбия эшенең сыйфатын яхшырту, мәктәпләрнең матди нигезен ныгыту мәсьәләләренә күп урын бирелә. 1936 ның сентябрендә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы утырышына «Мәгариф» ж-лының төп җитешсезлекләре һәм тупас бозып аңлатулары» турында мәсьәлә куела; аның карары нигезендә мәгариф халык комиссары, журналның баш мөхәррире Ш.Г.Башкиров вазифасыннан азат ителә. Педология б-н көрәш кампаниясе аркасында редакция таратыла, журнал «Башлангыч мәктәп» дип үзгәртелә, тематикасы башлангыч белем бирү мәсьәләләренә кадәр тарая. 1941–48 дә журнал басылмый. Бөек Ватан сугышы тәмамлангач, ТАССР Мәгариф халык комис-ты тарафыннан «Халык мәгарифе буенча җитәкче һәм педагогик-методик материаллар җыентыгы» (1945), «Педагогик-методик җыентык» (1–2 чыг., 1946–47) чыгарыла.

1949 да ТАССР җитәкчелеге башлангычы б-н журнал яңадан басыла башлый: башта ике айга бер тапкыр, 1956 дан ай саен чыга. СССРда «Мәктәпнең тормыш белән бәйләнешен ныгыту турында» Законы (1958) кабул ителгәннән соң, журналда мәктәпне реформалаштыру, укытуны производство б-н бәйләү мәсьәләләренә зур игътибар юнәлтелә. 1951 дән журналның «Татар мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты» бүлегендә мәкаләләр рус телендә басыла башлый. 1960 елларның 2 нче яртысында журналда укыту-тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү, укучыларның танып белү активлыгын арттыру, татар теле һәм әдәбиятын укытуны камилләштерү, укытуда технологик чаралар куллану мәсьәләләренә багышланган конференция материаллары басыла.

Алга таба журнал редакциясе респ-ка галимнәрен һәм укытучыларын заманча тикшеренүләргә, бигрәк тә проблемалы укыту методикасына багышланган мәкаләләр бастыруга җәлеп итә.

90 елларда журналның тематикасы үзгәрә. Аның битләрендә милли мәктәпләрнең максатын һәм бурычларын билгеләүдә яңа юллар, ТР халыклары телләре турындагы Законны тормышка ашыру, укыту-тәрбия эшен оештыру мәсьәләләре чагылыш таба. Журнал үзенең эшчәнлеге дәверендә иң атаклы татар вакытлы матбугаты басмаларының берсе булып кала. Ул татар милли мәктәбе үсешенә һәм пед. кадрларның квалификациясен күтәрүгә үзеннән зур өлеш кертә.

*Әд.:* Ш ә р и ф у л л и н Ф. Узган юлга күз салсак... // Мәгариф. 2003. № 3; Н а д и е в Н. О татарском педагогическом журнале «Магариф» // Просвещение и жизнь. 1929. № 1; Как разгромили журнал «Магариф» // Султанбеков Б.Ф. Татарстан. XX век. Личности, события, документы. К., 2003. Кн. 2.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«МӘГАРИ́Ф ҖИТӘКЧЕСЕ́»**, айлык фәнни-пед. журнал. Оренбург губернасы халык мәгарифе бүлегенең губерна методик бюросы каршындагы азчылык милләтләрнең методик секциясе органы. 1927–28 елларда Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 7 саны чыга. Мөхәррире — М.Рәфыйков.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989; К а р и м у л л и н А. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

**МӘГАРИ́Ф НӘЗАРӘТЕ́**, к. *Милли Идарә.*

**«МӘГАРИ́Ф ЭШЛӘРЕ́»**, айлык пед. журнал. БАССРның Мәгариф халык комис-ты органы. 1920 елда Эстәрлетамак шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. Мөхәррире — Х.Таһририя. Актив авторлары арасында — Әбүбәкеров, Ажанов, Бикмаев, Мирзанов, Мөслими, Г.Фәхретдинов. «Гомуми бүлек»тә иҗтимагый-пед. проблемаларга, урта мәктәп укучыларын һөнәри-пед. әзерләү, класстан тыш тәрбия һәм балаларның мәктәптән тыш ялларына, балалар, ятимнәр йортларына һ.б. проблемаларга багышланган мәкаләләр басыла. «Махсус бүлек» авыл җирлегендәге наданлыкны бетерү буенча оешкан комиссия эшчәнлеген яктырта (курслар, түгәрәкләр, китапханәләр, лекцияләр уку һ.б.). Атаклы фән эшлеклеләре, педагоглар, публицистларның мәкаләләре басыла (А.В. Луначарский һ.б.). «Яңалыклар» бүлегендә 1 нче Бөтенбашкорт съезды һәм БАССРның Мәгариф халык комис-ты эшчәнлеге турында хәбәрләр, мәктәпкәчә оешма тәрбиячеләре һәм урта мәктәп укытучылары өчен уку ярдәмлекләре һәм китаплар исемлеге бирелә.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МӘГАРИ́Ф ЭШЧЕСЕ́»**, айлык иҗтимагый-пед., фәнни журнал. РСФСР Мәгариф халык комис-тының социаль тәрбия бүлеге органы. 1926 елның гыйнварыннан 1931 нең гыйнварына кадәр Мәскәүдә татар телендә 52 саны нәшер ителә. 1928 нең февраленә кадәр «Нәшрият»та, соңрак СССР халыклары Үзәк нәшриятында басыла. Төрле елларда мөхәррирләре: И.Юманкулов, И.Агишев. Актив авторлары арасында — Г.Алпаров, Н.Әюпов, Г.Баимбәтов, Г.Ибраһимов, Г.Салаватов, Ш.Саттаров, Г.Хәбиб, Н.Хәйри, С.Шакулова. Журналның максаты — милли мәктәпләрдә укыту-тәрбия бирү процессын оештыру һәм алдынгы педагоглар, методистлар тәҗрибәсен тарату. Төп бүлекләре: гомуми, педагогика һәм методика, сәяси агарту, мәктәпкәчә тәрбия, укытучылар һәм укучылар тормышы, тел һәм орфография, әдәбият, фән яңалыклары, урыннардан хәбәрләр, китаплар дөньясында, тәнкыйть һәм библиография. Ш.у. к. «*Культура революциясе*».

*Т.М.Насыйров.*

**әл-МӘГАРРИ́** (المعري) Әбүл-Галә (973, Мәгаррәт ән-Нөмән ш., хәзерге Сүрия — 1057 яки 1058, шунда ук), гарәп шагыйре һәм фикер иясе. Тумыштан сукыр. Белемне атасыннан, Багдад һәм Хәләб шәһәрләре дин белгечләреннән ала. Фәнни трактатлар, фәлсәфи-гуманистик эчтәлекле шигырьләр, тезмә әсәрләр авторы. Танылган шигъри җыентыклары — «Рисаләт әл-гофран» («Гафу итү хакында юллама», 1623 яки 1624), «Сикт әз-зәнд» («Чакма таш очкыны», Каһирә, 1869 яки 1870), «Әл-лөзумийят-лөзум мә лә ялзам» («Мәҗбүриятлек», Каһирә, 1891 яки 1892). Аның иҗатында пантеистик, материалистик һәм атеистик күзаллаулары, дөньяга карашының каршылыклары чагыла. Шагыйрь яшәү һәм үлем, адәм баласы һәм Аллаһ, яшәү мәгънәсе кебек мәңгелек проблемалар хакында уйлана. Гуманист буларак, танып белүнең нигезен тәшкил иткән кеше акылына мәдхия җырлый, ләкин шул ук вакытта хакыйкатьне танып белеп булмый, дип саный. Социаль гаделсезлекне тәнкыйтьли, үзе аны яшәү рәвешенә Аллаһ тарафыннан салынган хакыйкать, дип исәпли. Һәрбер дингә карата түземле булырга өнди, руханиларның кимчелекләрен, юк-барга ышануны, абруйлы кешегә табынуны тәнкыйтьли. Югары әхлаклы кеше буларак, яшәү мәгънәсен халыкка хезмәт итүдә күрә, һәр эштә чама хисен белергә һәм тыелырга чакыра. Чәчмә әсәрләренә фикер һәм хис сафлыгы хас. «Мәҗбүриятлек» әсәрендә үзен гуманист, социаль гаделсезлекне тәнкыйтьләүче буларак таныта. Теле катлаулы, ләкин шул ук вакытта камил, аерым очракларда сүз уйнатып ала. М.нең иҗаты гарәп, фарсы һәм төрки, ш.и. татар әдәбиятларына (Хисам Кятиб, Сәйф Сараи, Ш.Зәки, Дәрдемәнд, Н.Думави) зур йогынты ясый. 20 йөз башында шагыйрь идеяләре аеруча популяр булып китә. Аның турында Р.Фәхретдин, Н.Думави яза, әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә. 1907 елда Казанда М.Бигиевнең искәрмәле тәрҗемәсендә «Әл-лөзумийят» басыла. 1908 дә М.Бигиев «Әдәбият гарәбия илә гыйльме исламия» («Гарәп әдәбияты һәм ислам гыйлеме») исемле китабында М.нең тормышы һәм иҗаты турында мәгълүматлар бирә.

Ә с ә р.: Әл-лөзумийят: 2 кис. К., 1907; Стихотворения. М., 1971.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Әбүл-Галя әл-Мәгарри. Оренбург, 1908; Ш и р о я н С.Г. Великий арабский поэт и мыслитель Абу-ль-Аля аль-Маарри. М., 1957; Ш и д ф а р Б.Я. Абу-ль-Аля аль-Маарри. М., 1985.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘГЪЛҮМА́Т ТЕХНОЛО́ГИЯЛӘРЕ**, хисаплау техникасы, бирелгән мәгълүматны саклау һәм элемтә линияләре, телевидение ярдәмендә тапшыру б-н бәйле аспектларны үз эченә алган төшенчә. М.т. социаль бурычларны хәл итү, оборона сәләтен ныгыту, җитештерүне, чимал һәм материалларны читкә чыгаруны оптимальләштерү өчен дөнья базарында көндәшлеккә сәләтле фәнни продукция булдыруга ярдәм итә. Технологик җиһазны яңарту компьютерлаштыруның эшләнмә яшәешенең барлык этапларында (уйлап табу, инженер анализы, эшләп чыгару һәм контрольдә тоту, гамәли куллану, төзәтү, модернизация һәм үтилләштерү) аның тулы электрон билгеләмәсен (EPD — Electronic Product Definition) тәэмин итүче барлык программа һәм аппарат чараларын гамәлгә кертү б-н бергә бара.

Компьютерлаштыруның программалы чаралары: проектлау өчен (CAD — Computer Aided), эшләп чыгару (CAM — Computer Aided Manufacturing), контрольдә тоту өчен (CAC — Computer Aided Control). Бер үк яки төрле географик терр-яләрдә эшләүче белгечләрнең үзара аралашуы җитештерү мәгълүматы б-н программалы идарә итү чаралары (PDM — Production Data Management) ярдәмендә тормышка ашырыла. Эшләнмәләрне җитештерүдә һәм алардан файдалануны тәэмин итүдә катнашучы пр-тиеләрнең килешенеп эшләве эшләнмәнең эшләү чорында Интернет алымнар, ягъни Web-технологияләр кулланып өзлексез мәгълүмат алышу формасында тормышка ашырыла (CALS — Continuous Acquisition and Life Cycle Support). Пр-тие ресурслары (финанс һәм материаллар бухгалтериясе, планлаштыру, тәэминат, персонал, сыйфат системасы, складлар һ.б.) б-н идарә итү өчен ресурслар б-н идарә итүче программа чаралары (ERP — Enterprise Resource Planning) кулланыла. Web — технологияләр файдаланылган очракта, ERP программаларын географик торышына бәйсез рәвештә аралашучы пр-тиеләр дә куллана алалар. Фәнни дәрәҗәсе югары булган эшләнмәләрнең эш циклын мәгълүматлаштыруның корпоротив системаларын формалаштыруга CAD, CAE, CAM, PDM, ERP программа чараларын комплекслы куллану ярдәмендә ирешелә.

Компьютерлаштыруның аппарат чаралары: программа чаралары куелган компьютерлар; эш урынының күмәк челтәрен формалаштыру өчен кирәкле челтәр җайланмалары; текстлы яки график мәгълүматны кәгазьгә яки башка җайланмага чыгару җайланмалары. Татарстанда М.т. 1960 еллардан башлап үсеш алган (Р.Г.Бохараев, Ю.В.Кожевников һ.б.). Казан ун-тында теоретик механика кафедрасы (мөдире Ю.Г.Коноплёв) хезмәткәрләре тырышлыгы б-н фәнни һәм укыту практикасында инженер анализының программа чаралары кулланыла. Казан техник ун-тында машиналар төзелешендә мәгълүмат технологияләре кафедрасы (мөдире И.Х.Сәетов) оештырыла. Машиналар төзелешенең М.т. «КамАЗ», «Казан вертолётлар заводы», «Казан моторлар төзү ҖБ», Казан авиация ҖБ, Казанның «Союз» тәҗрибә-конструкторлык бюросы АҖләрендә һ.б.да гамәлгә кертелгән (1990 еллар). Ту-214, Ту-324 самолётларын, АИ-22 турбореактив моторын һәм НК-38СТ газтурбиналы кучергечле моторын җитештерүне үзләштергәндә, «Ансат» һәм «Актай» вертолётларын төзегәндә М.т.нең заманча алымнары кулланыла. «Татнефть» һәм «Казаноргсинтез» АҖ пр-тиеләрендә ERP программа чаралары кертелгән. Компьютерлаштыруның программа һәм аппарат чараларын тәкъдим итүләр һәм семинарлар Сәүдә-сәнәгать палатасында, Икътисад һәм сәнәгать министрлыгында, РФА КГҮдә, ТРның югары уку йортларында һәм сәнәгать пр-тиеләрендә үткәрелә.

*Әд.:* Б е с п а л о в В., К л и ш и н В., К р а ю ш к и н В. Развитие системы PDM: вчера, сегодня, завтра ... // САПР и графика. 2000. № 11; Г а л ь п е р и н Д.М. Корпоративная система информационных технологий жизненного цикла наукоёмких изделий // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2003. № 2; С и н к л е р А. Большой толковый словарь компьютерных терминов. М., 1998.

*Д.М.Гальперин.*

**«МӘГЪЛҮМАТЕ́ ҖӘДИДӘ́»** (جديده معلومات — «Яңа мәгълүмат»), атналык дини журнал. «*Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия*» ж-лының дәвамчысы. 1911 елның 10 мартыннан 1912 нең 15 гыйнварына кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 16 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Я.Канзафаров. Журнал мөселман руханилары мәнфәгатен яклый. Максаты — «татар милләте бәхетле булсын һәм алга бар-



«Мәгълүмате җәдидә» журналы.

сын өчен, исламны пропагандалау». Актив авторлары арасында — Җ.Абызгилдин, М.Акимов, А.Бикмиев, А.Хәбир, М.Хәсәнов. Төп бүлекләре: «Ислам һәм аның башка диннәргә мөнәсәбәте», «Мөселманнарның җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге роле, бурычлары», «Исламда хатын-кыз», «Имам вәгазе һәм үгет-нәсыйхәтләре», «Балаларны мөселман кануннары буенча тәрбияләү», «Ислам: сораулар һәм җаваплар». «М.җ.»дә фән һәм техника, медицина, бакчачылык, терлекчелек өлкәсендәге яңа ачышлар, эчке һәм тышкы сәясәттәге яңалыклар хакында, ш.у. сәяси һәм дини эшлеклеләрнең (И.Гаспралы, М.Бигиев һ.б.) тормышы һәм эшчәнлеге турында мәкаләләр басыла; алдынгы татар газеталары — «Тәрҗеман», «Вакыт»ка күзәтү ясала. «Әдәбият яңалыклары» рубрикасы була. *А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МӘГЪЛҮМАТЕ́ МӘХКӘМӘИ́ ШӘРГЫЯИ́ ЫРЫНБУРГИЯ́»** («معلومات محكمهء شرعيهء اورنبورغيه») — «Оренбург Диния нәзарәте хәбәрләре»), дини журнал. Шул ук исемдәге оешма органы. 1908 елның гыйнвар аеннан 1910 ның ноябренә һәм 1916 ның гыйнварыннан 1917 нең сентябренә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 95 саны чыга. 1910 да, *«Идел буе төбәгендәге мөселман татарлар йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә»* күрсәтмәсенә нигезләнеп, хакимият тарафыннан ябыла, Беренче бөтендөнья сугышы елларында «хәрби цензура рөхсәте» б-н яңадан басыла башлый. Беренче 18 санын имам М.Хәсәни редакцияли, составында казый Г.Капкаев, Н.Мамлиев, Х.*Габәши* булган редколлегия 19–61 нче саннарын чыгара; яңадан Г.Капкаев, Н.Мамлиев, С.Урманов составында бастыру дәвам ителә. Актив авторлары арасында — Җ.Абызгилдин, Г.Исинбирдин, Һ.Килдебәк, Һ.Мәхмүдов, С.Сүнчәләй, Н.Түнтәри, Г.Чокалый. Максатлары һәм эчтәлеге 2 нче санда басылган «Журнал программасы»нда бирелә. Рәсми бүлектә Оренбург Мөселман Диния нәзарәте, Россия хөкүмәте, губерна идарәсе карарлары, яңа мәхәлләләр ачуга рөхсәт алыну, имам һәм мөәзиннәр билгеләнү турындагы хәбәрләр басыла.

Рәсми булмаган бүлектәге мәкаләләрдә кешенең рухи тормышына кагылышлы мәсьәләләр, дини бәйрәмнәр турында языла, Корьән сүрәләренә аңлатмалар бирелә. Әлеге бүлектә мәгариф, мәдрәсә тормышы, шәкертләрне әхлакый тәрбияләү мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр дә урын ала. Журналда мед., сәламәтлек саклауны үстерү, төрле авыруларга каршы көрәшү проблемаларын күтәргән, тәмәке тарту, аракы эчү, комарлы уеннар уйнауның зарары турындагы мәкаләләр дә басыла. Әхлакый проблемаларны күтәргәндә гаиләне ныгытуга аерым урын бирелә. Күп кенә мәкаләләр тарихи темага багышлана, ш.и. С.Акбирдинның «Китап нәшер итү тарихы», Х.Габәшинең «Тарих һәм аның мәгънәсе», А.Вамбериның «Аксак Тимернең холкы һәм үз-үзен тотышы» һ.б. була. Журнал җир эшкәртү, терлекчелек, бакчачылык, умартачылык буенча киңәшләр дә бастыра.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926; Миңнуллин Р. «Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыя Оренбургия» журналы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4. *Т.М.Насыйров.*

**«МӘГЪРИФӘ́Т»**, атналык газета. 1925 елның 16 гыйнварыннан 12 апреленә кадәр Кеми шәһәрендә (Финляндия) татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Х.Хәмидулла.

**«МӘГЪРИФӘ́Т»**, мәгариф хезмәткәрләре һәм укучы яшьләрнең атналык газетасы. 1991 елның февраленнән Казанда татар телендә нәшер ителә. 1 нче саны Казан ун-тының партия ВЛКСМ ком-тлары, ректораты, профсоюз ком-ты органы буларак «Ленинчы» исеме б-н басыла. 2 нче саннан хәзерге исемдә. Мөхәррире — Р.Ә.*Фәттахов.* Оештыручылары — Казан, Чаллы, Алабуга югары уку йортлары; «Азатлык» татар яшьләре берлеге; редакция коллективы. Алга таба оештыручысы — «Татмедиа» ААҖ. 1998 дән мөхәррире — Х.Х.Вәлиәхмәтов. «М.» ТРда мәгарифне үстерү мәсьәләләрен яктырта, татар яшьләре һәм студентлары тормышы, татар телен һәм мәдәниятен үстерү проблемаларын күтәрә, яшь татар язучылары әсәрләреннән өзекләр бастыра. 2013 нең августыннан «М.» газетасы чыгудан туктый. *Р.А.Айнетдинов.*

**МӘГЪСУ́МОВ** Тәлгать Мәгъсүм улы (11.3.1942, Арча р-ны Шушмабаш а.), җылылык физикасы галиме, техник фән. д-ры (1998), ТРның атказ. машина төзүчесе (2002). 1964 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, термодинамик һәм термофизик тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (1971 дән). Хезмәтләре очкыч аппаратлар двигательләрендәге эш процессларын өйрәнүгә, түбән энергетикалы техника чараларын төзүгә карый. М. табигый битумнар һәм аеруча үзле нефтьләрне җылылык б-н тәэсир итеп чыгару өчен пар-газ генераторы, катлам эчендә януны имитацияләү өчен җылылык-газ генераторы, катнаштыргыч һәм рекуператив һава җылыткычлар, карусель тибындагы ашлык киптерү җайланмалары эшли. М.нең эшкәртмәләре нефть-газ чыгару сәнәгатендә, магистраль газ кудыру станцияләрендә, РФ һәм ТРның башка сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрендә файдаланыла. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә..

Хезм.: Исследования по созданию парогазогенераторов для воздействия на нефтяной пласт // Глубинные теплогенераторы для повышения нефтеотдачи. М., 1983 (автордаш); Термодинамический метод определения расхода воды для получения парогаза заданной температуры // Нефтяное хоз-во. 1986. № 8 (автордаш); Эффективность использования энергии при различных методах теплового воздействия на пласт // Нефтяное хоз-во. 1992. № 8 (автордаш).

**«МӘДӘНИ́ ҖОМГА́»**, атналык әдәби-нәфис газета. Оештыручылары — ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, ТР Мәдәният министрлыгы. «*Татарстан хәбәрләре*» г-тасы җирлегендә оеша. 2005 елдан «Татмедиа» ААҖ ф-лы. 1995 нең июленнән Казанда татар телендә нәшер ителә. Баш мөхәррире — З.М.*Мансуров.* Газетада татар мәдәнияте, әдәбияты һәм теле мәсьәләләренә,





«Мәдәни җомга» газетасы.

респ-каның күренекле мәдәният эшлеклеләренең эксперт бәяләмәләренә зур урын бирелә; социаль мәсьәләләр яктыртыла, мәгариф һәм тәрбия системасының торышы хакында материаллар урнаштырыла. Даими рәвештә танылган һәм башлап язучы авторларның әсәрләренә, китапларга һәм спектакльләргә рецензияләр басыла. Ай саен «И туган тел...» кушымтасы чыгарыла, анда фән, мәдәният, мәгариф эшлеклеләренең фикерләре, ш.у. татар теле тарихы һәм үсеше актуаль мәсьәләләренә багышланган материаллар урын ала. *Р.Р.Мөхәммәтова.*

**«МӘДӘНИ́ КӨРӘШКӘ́ ТАБА́»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты, ТАССР Мәгариф халык комис-ты, Татарстан профсоюзлар өлкә советының Наданлыкны бетерү җәмгыяте органы. Газета 1928 елның октябрендә Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 1 саны чыга. Наданлыкка, эчүчелеккә каршы көрәшкә чакыра; татар графикасын латинлаштыруны яклап чыга. И.В.Сталин һәм М.И.Калинин чыгышларыннан өзекләр бастыра. Авторлар арасында М.Агишев, Г.Зарипов, Г.Кашшаф, Б.Корбанов, З.Мәһдиев, Г.Минский, Г.Нигъмәти, И.Рәхмәтуллин, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Толымбай, Г.Кутуй, Д.Фәтхи, Р.Хәмиди һ.б. бар. *А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МӘДИНӘ́»** мәчете, Казанда татар халык архит-расы традицияләрендә төзелгән хәзерге заман мөселман дини корылмасы. Бина



«Мәдинә» мәчете. Казан. 1996–97.
Арх. Р.В.Билалов, инженер М.Х.Шәймәрданов.
Көнбатыш фасад.

1996–97 елларда архитектор Р.В.Билалов проекты буенча салына, инженеры — М.Х.Шәймәрданов. Мәчет Идел буе р-нындагы скверда урнашкан. Ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен ике заллы итеп эшләнеп, манарасы түбәгә куелган мәчетләр төренә карый. Ишеге төньякка чыга. Мәчетнең Т рәвешле бурасына ир-атлар залы һәм хуҗалык бүлмәләрен берләштергән вестибюль керә. Вестибюльнең сулъяк өлешендә эргә катындагы хатын-кызлар залына алып төшүче баскычы бар. Вестибюльнең уңъяк өлешендәге авыш түбә үзәгеннән күтәрелгән дүрт ярусы, сигез кырлы манарага тар баскыч илтә. Манара икенче һәм дүртенче ярусларындагы сигез кырлы ике мөәзәнә-балконы б-н үзенчәлекле. Бинаның бура диварлары тышкы һәм эчке яктан такта б-н тышланган. Фасадларына уеп эшләнгән бизәкләр төшерелгән.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МӘДРӘСӘ́** (гарәп. مدرسة — мәктәп), руханилар һәм дини белемле мөселманнар әзерләүче мөселман уку йорты. Идел буе Болгар дәүләтендә М.ләр 10 йөздә барлыкка килгәләр, Алтын Урдада һәм Казан ханлыгы чорларында эшлиләр. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан — 18 йөзнең 1 нче яртысында Идел-Урал төбәгеннән чыгучылар Урта Азия, башлыча, Бохара шәһәре М.ләрендә белем алалар. 18 йөзнең 2 нче яртысында, Сенатның «Казан, Түбән Новгород, Әстерхан һәм Себер губерналарындагы аерым авылларда яшәүче Мөхәммәд кануныңдагы татарларга мәчетләр төзергә рөхсәт һәм яңа чукындырылган татарларны башка авылларга күчереп утырту турында» 1756 ел 26 август фәрманы басылганнан соң, М.ләр Россия империясендә дә ачыла башлый; аларда Урта Азия укыту системасы өстенлек ала; 19 йөзнең уртасына кадәр танылган мөдәррисләрнең зур күпчелеге Бохарада белем ала (Г.*Курсави*, Г.*Утыз Имәни*, Ш.*Мәрҗани* һ.б.) Башка мөселман илләреннән аермалы буларак, Россиядә барлык М.ләр мәхәллә мәчетләрендә эшли. Уку йортлары законда да, гамәли эшчәнлектә дә барлык мәхәллә балалары өчен булган башлангыч дини мәктәпләргә (к. *Мәктәп*) яки проф. дин белгечләре һәм пед. хезмәткәрләр әзерләүче М.ләргә бүленми. М. оештыру өчен мәхәлләне зур белемле дин эшлеклесе җитәкләргә тиеш була һәм иганәчеләр ярдәме сорала. Казан, Уфа, Оренбург һ.б. зур шәһәрләрдә М.ләр, башлыча, мәхәлләләр каршында эшли. Гадәти М.дә укыту стандарт дини хезмәтләрне, ш.у. мантыйк, фикъһ, матем. буенча трактатларны өйрәнүгә корылган була. Гарәп һәм фарсы телләре фән буларак укытылмый, ә китапларны өйрәнү барышында үзләштерелә. Дөньяви уку йортларындагы кебек сыйныфларга, дәрес һәм уку елына бүлү булмый, әмма укытуның актив формасы — лекцияләр уку, моназаралар (диспутлар) уздыру кулланыла. Каллиграфиягә әһәмиятле урын бирелә. Укыту эшчәнлеген, М.нең җитәкчесе мөдәрристән тыш, аның ярдәмчеләре — хәлфәләр алып бара. Уку еллары саны билгесез була (шәкертләр, үзләрен имам-хатип итеп сайлап куясы мәхәллә халкын канәгатьләндерерлек дәрәҗәгә җиткәнче, укуларын дәвам итәләр) һәм Оренбург Мөхәммәд Дини Мәҗлесендә имтихан тапшыру б-н тәмамлана. Сәләтле шәкертләр укуларын Бохарада, Якын Көнчыгыш илләрендә дәвам итәләр, һәм үзләре мөдәррисләр дәрәҗәсенә ирешәләр. М.ләр мәхәллә халкының хәйрия, иганә һәм зәкяте хисабына яши, кагыйдә буларак, үз биналарында урнашалар, шәкертләрнең яшәве түләүсез була. М.нең эшчәнлеге Россия империясе законнары тарафыннан көйләнми, Халык мәгарифе министрлыгы оешмаларының һәм хокук саклау органнарының хисап алу һәм күзәтү астына алырга тырышулары барып чыкмый. 1870 елдан хөкүмәт М.дә рус телен мәҗбүри укытуны кертергә тырыша, ләкин гадәти М.ләр аны кабул итмиләр. Иске ысуллы М.ләр 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында татар халкының мәгарифен үстерүдә, милли зыялылар формалашуда әйдәп баручы рольне уйный.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, җәдитчелек үсеш алу нәтиҗәсендә, М.дә белем бирү характеры үзгәрә. Уку-язуга өйрәтүдә аваз алымы, гарәп һәм фарсы телләрен дәреслекләр һәм сүзлекләр буенча өйрәнү, аерым фән буларак дин фәннәре, фикъһ, мантыйк кертелә. Иң алдынгы М.ләрдә («*Мөхәммәдия*», «*Буби*», «*Хөсәения*», «*Галия*») 8–12 еллык уку вакыты б-н дәрес сыйныф-дәрес системасы урнаша. Акрынлап белем бирүнең эчтәлеге үзгәрә, дөньяви фәннәр: табигать фәннәре, матем., татар (төрки) теле, Россия һәм татар халкы тарихы кертелә. Яңа ысуллы М.ләрдә рус телен укыту хуплана, күпчелек М.ләрнең шәкертләре аны 1870 еллардан М.ләрнең мөстәкыйль уку йортына әверелгән рус сыйныфларында өйрәнәләр, калганнарында үз укытучылары була. Яңа ысуллы М.ләр гомуми белем бирүче уку йортларына әверелә, аны тәмамлаучыларга, рус урта мәктәбе курсы буенча имтихан тапшырып, югары уку йортларына керү мөмкинлеге бирелә. Яңа ысуллы М.ләрнең эшчәнлеге нәтиҗәсендә, шул мәдрәсәне тәмамлаучы мөгаллимнәр, соңрак мулла гына түгел, бәлки яңа ысуллы мәктәп укытучылары да булып, татар мәгарифе һәм мәдәнияте үсешендә мөһим роль уйныйлар. Ләкин күп кенә М.ләр 1917 гә кадәр иске ысулны саклыйлар. 1920 еллар ахырында М.ләрнең эшчәнлеге туктала. 1945 тән СССРда бердәнбер М. — «Мир Араб» — Бохарада (Үзбәкстан ССР) эшли. 1990 елларда РФ һәм ТРда М.ләр яңадан ачыла башлый. Хәзерге М.ләр мөселманнарның җирле Дини идарәләре — мөхтәсибәтләр карамагында, алар — имам-хатиплар, ислам нигезләре, гарәп теле укытучыларын әзерләүче махсус урта дини уку йортлары; М.ләрнең кайберләрендә кыз балалар бүлеге эшли. 2013 тә ТР терр-ясендә 8 М., ш.и. 2 се Казанда эшли.

*Әд.:* Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: Мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан. К., 1992; Кобылов Я.Д. Конфессиональные школы Казанских татар. К., 1916; Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. К., 1941; Махмутова А.Х. Становление светского образования у татар: Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917. К., 1982; Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. К., 1992; Валиди Д. Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). К., 1998; Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: Очерки. К., 2001.

**МӘДХИЯ́** (гарәп. مديحة — панегирик, мактау җыры, ода), Шәрекъ поэзиясе жанры; тантаналы мөһим вакыйгаларны яки күренекле кешеләрнең эш-гамәлләрен данлау йөзеннән язылган лирик шигырь. М. борынгы чорлардан килә. Аңа объектны идеаллаштыру, гиперболизация, күтәренке рух, купшы стиль хас. М.нең күбесе — шигъри (бәйт, дүртьюллыклар), сирәгрәк — катнаш (проза һәм шигырь) формада, ә кайберләре рифмалы проза б-н (Кадыйр-Гали-бәкнең «Тәгърифе Борис»ы — «Борисны мактау») язылган. Эчтәлеге һәм формасы б-н *касыйдә* һәм *мәрсиягә* якын тора.

М. — татар әдәбиятында киң таралган жанр; Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Мөхәммәдьярның «Нуры содур» әсәрләренең багышлаулары, Хөсәен бине Локманның «Мәдхе Мөхәммәдҗан», Гали Чокрыйның «Мәдхе Казан», Р.Фәйзуллинның «Төнге мәдхия» исемле шигырьләре — моңа мисал.

*Әд.:* Миңнегулов Х.. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘЕ́Т БИТЛЕГЕ́** (археол.), мәрхүмнең битен каплаган махсус япма. Татарстан терр-ясендә М.б. 9 йөз-10 йөз башы мәҗүси болгар каберлекләрендә (мәс., *Танкеевка каберлегендәге* 40 кабердә) табыла. Мәрхүмнең башы яшел кытай ефәге б-н төрелеп, бит ягы-



Танкеевка каберлегеннән табылган көмеш мәет битлеге. ТР ФА Тарих институты фондлары.

на күзләр һәм авыз өчен тишекләр ясалган көмеш, кайбер очракта алтынланган битлек тегелгән. Битлекләрнең берсендә кысып-батырып кашлар, борын, мыек урыннары эшләнгән.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. О назначении погребальных лицевых покрытий Танкеевского могильника // Уч. зап. Перм. гос. ун-та. 1968. № 191; ш у л у к. Культура ранней Волжской Булгарии (Этапы этнокультурной истории). М., 1992.

*Е.П.Казаков.*


**МӘЕ́Т ҖИРЛӘ́Ү ҺӘМ МӘРХҮМНЕ́ ИСКӘ́ АЛУ́ ЙОЛАЛАРЫ́**. Мөселман татарларда җеназа-мәет җирләү йоласы *ислам* дине кагыйдәләренә нигезләнә. Мәетне, гадәттә, үлгән көнендә яки икенче көнне җирлиләр. Мөселманнарда кеше үлгәннән соң күз яше күрсәтү гадәте хупланмый; якыннары догалар укыйлар, мәрхүмнең кылган яхшылыкларын искә төшерәләр. Кабер казылып бетү хәбәреннән соң гына мәетне юу башкарыла. Юылган, ахирәт күлмәге кидерелгән, кәфенгә төрелгән мәетне, махсус кабыкка салып, ирләр зиратка күтәреп алып баралар (авыл җирендә). Мәрхүмнең гәүдәсен алып чыгып китәр алдыннан мулла дога укый, хушлашырга килүчеләрнең һәммәсенә дә хәер — *сәдака* (акча, кульяулык, сабын һ.б.) таратыла. Мәетне алып чыккач, хатын-кызлар өйне җыештыралар, мәрхүмнең урын-җирләрен һ.б. әйберләрен юалар. Элегрәк мәет чыккан йортта ашарга әзерләү өч көн буе рөхсәт ителмәгән; хәзерге вакытта шәһәрләрдә бер көн б-н генә чикләнәләр. Җирләүдә, кагыйдә буларак, ирләр генә катнаша. Мәетне өйдән чыгару б-н яисә зиратка керер алдыннан җеназа намазы укыла. *Кыйблага* каратып казылган кабердә махсус куыш уела — ләхет алына, мәет шунда урнаштырыла. Мөселманнарны, гадәттә, табутсыз, кайчак капкачсыз табутта күмәләр, әгәр табут капкачлы булса, аны кадакламыйлар. Ләхет такталар яки кирпеч б-н каплана. Каберне күмгәннән соң, мулла Коръән *сүрәләре* укый, укып бетергәч, мәрхүмнең туганнары сәдака тараталар. Муллага гүр сәдакасы бирелә: элек — сарык, хәзер исә мөселман җәмәгате ихтыяҗлары өчен ешрак акча тапшырыла. Мәрхүмне искә алу йолалары берничә искә алу мәҗлесен — өчесен, җидесен, кырыгын, 51 нче көнен һәм елын уздырудан тора, аларга я ирләр генә яки хатын-кызлар гына чакырыла (шәһәрдә кайчак берләштереп тә үткәрелә). Искә алу мәҗлесләрендә Коръән укыла, сәдака өләшенә, 40 нчы көнендә мәрхүмнең әйберләре таратыла. Искә алу мәҗлесенең төп ризыгы булып әлбә — он, май, бал яки шикәр кушып әзерләнгән ризык санала, аны җирләгән көнне дә, искә алу мәҗлесенә дә әзерлиләр; Себер татарларында ш.у. сөткә-майга изелгән ризык — кәпкер пешерәләр. Иң элек итле токмачлы аш, икенчегә пешкән ит б-н бәрәңге бирелә, аннары тәмле-баллы ризыклар б-н чәй эчү оештырыла. Мөселман татарларның җеназа-мәет җирләү йоласында исламга кадәрге чордан калган элементлар да күзәтелә: кеше үлү б-н, аның күкрәгенә пычак яки кайчы куялар; кәфен теккәндә, җепне төенләмиләр, инәне «үзеңнән читкә» алып тегәләр; мәетне алып чыкканда, ишек яңагына кагылмаска тырышалар һ.б. *Керәшен татарларда* мәет җирләү-искә алу йолалары православие традицияләренә туры килә: мәетне үлү б-н үк юалар, чиркәүдә җеназа укыйлар, өченче көнне табутка салып күмәләр. Шул ук вакытта керәшеннәрнең йолаларында аларның этномәдәни үсеш үзенчәлекләре нәтиҗәсендә христианлыкка кадәр үк барлыкка килгән күп кенә элементлар күзәтелә: үлгән кешенең авызына су салу, аның урын-җире тирәли пычак б-н үтү (исәннәрдән «аеру»), 40 нчы көнне искә алу мәҗлесенә мәрхүмне «чакырып», аның өчен ризык кую йоласы һ.б. Керәшен татарларда искә алу мәҗлесләре 3,9,20 һәм 40 нчы көннәрдә, аннары ярты ел һәм бер ел узгач үткәрелә. Элегрәк 40 нчы көндә мәрхүм хөрмәтенә сарык, алданрак үлгән туганнары хөрмәтенә тавык, барча үлгәннәр хөрмәтенә балык корбан итү, 40 күмәч (гердә) пешерү йоласы булган. Дини бәйрәмнәрдә — мөселман татарларда *Корбан бәйрәме* һәм *Ураза бәйрәмендә*, керәшен татарларда Пасха һәм Покров алдыннан гомуми искә алулар уздырыла, алар бергәләп зиратларга барып, әрвахлар рухына догалар уку б-н үтә. Мөселман каберенә мәрхүмнең исеме, туган һәм үлгән еллары язылган, ярым ай төшерелгән таш (керәшеннәрдә хач б-н) куела, кабер өстенә чәчәкләр, агачлар, куаклар утыртыла. Совет хакимияте чорында татарларда дини бәйрәмнәр рәсми идеология тарафыннан көнкүрештән кысрыклап чыгарыла, әмма татарларның күпчелеге традицион күмү йолаларын башкаруны дәвам итә; алар советлардан соңгы чорда кабат торгызыла.

*Әд.:* К о б л о в Я.Д. Религиозные обряды и обычаи татар-магометан // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1909. Т. 24; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; У р а з м а н о в а Ф.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; Х а л и к о в а Е.А. Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X — начала XIII в. К., 1986; Татары. М., 2001; Китаб аль-джаназа ва-ль-истифада мин хаза. Н.Новгород, 2007.

**МӘҖИ́ТОВ** Әмир Нуриәхмәт улы (11.12.1928, Алабуга кантоны Бондюг пос., хәзер Менделеев ш. — 23.3.1992, Казан), нәкышьче, РСФСРның атказ. рәссамы (1970). Казан сәнгать уч-щесен (1949), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлый (1955), шунда Д.К.Мочальский җитәкчелегендә станлы нәкышь бүлегендә белгечлек ала. Ин-тны тәмамлаганнан соң, Ярославль шәһәренә җибәрелә, сәнгать мәктәбендә укыта (1955–59); Рәссамнар берлеге әгъзасы (1958), РСФСР Рәссамнар берлегенең Ярославль оешмасы идарә рәисе (1964–77). 1979 елдан Казанда. ТАССР Рәссамнар берлеге рәисе (1982–91). Нәкышьче буларак, күбрәк көнкүреш жанрында эшли: «Туристлар» (1955), «Балыкчылар» (1956), «Финишта» (1957), «Ятьмә ялгаганда» (1959), «Су коенучы кызлар», «Балалар» (икесе дә — 1963). М.ның тарихи жанрда иҗат иткән картиналары: «Барабанчы» (1967, 1968 дә Ленин комсомолы исем. бүләк бирелә), «Сигнал» (1969), «Брест каһарманнарына» (1972); ш.у. портретлар б-н киң танылa: «Акчарлак» (1964, В.Н.Терешковага багышланган), «Сынчы С.Т.Коненков портреты» (1974), «Партия ветераны Н.Т.Мәҗитов оныгы Карина б-н» (темпера, 1976), «Кар бөртеге» (пастель, 1976), «Карина» (темпера, 1977). Рәссамның таланты Казандагы иҗат чорында киң ачыла. Нәкышь техникасында зур осталык б-н эш итүче М. буяу катламының сыйфатына зур игътибар бирә, буяуларны ирекле, мул, куе итеп куллана, катлаулы, күп фигуралы композицияләрне оста төзи. Ул нәкышь сәнгатенең барлык жанрларында нәтиҗәле эшли — «Казан» милли мәдәният үзәгендәге «Дастан булып күтәрелә Казан» (1997) исемле монументаль нәкышь панносы, сюжетлы-тематик, портрет, пейзаж әсәрләреннән «Апрель. Алабуга» (1990), «Бәйрәм» (темпера, 1991) һ.б.



Ә.Н. Мәҗитов.



Ә.Н.М ә җ и т о в. «Салават күпере». Киндер, темпера, пастель. 1963. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.





Ә.Н.М ә җ и т о в. 1. «Ятьмә ялгаганда». 1956. Рыбинск тарих һәм сәнгать музей-саклаулыгы; 2. «Барабанчы». Киндер, майлы буяу. 1967. Ярославль сәнгать музее.



Г.Ә. Мәҗитов.

Зона — Идел буе рәссамнары әсәрләре (Ярославль ш., 1958); «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1967; Горький ш., 1974; Казан, 1980, 1991; Чабаксар, 1985); бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1960, 1965, 1967, 1970) һ.б.; бөтенсоюз — «Тынычлык сагында» (Мәскәү, 1965), «Совет хакимиятенә 50 ел» (Мәскәү, 1967), «Ватан сагында» (Мәскәү, 1968, 1973, 1983) һ.б.; халыкара — 6 нчы (Мәскәү, 1957) һәм 7 нче (Вена, 1959) бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивальләре уңаеннан оештырылган халыкара, ш.у. Болгария, Германия, Монголия, АКШ, Төркия, Финляндия, Япониядә совет рәссамнары күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1968 (Мәскәү) һәм 1988 (Казан) елларда уза. Әсәрләре Ярославль сәнгать музеенда, Ростов-Ярославль сәнгать музей-тыюлыгында, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Менделеев шәһәрендәге туган якны өйрәнү музеенда, Ленинград һәм Әлмәт шәһәрләре картиналар галереясында саклана. 2005 тә Казандагы иҗат остаханәсе җирлегендә М. музее ачыла («Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее составында).

Х е з м.: Сенежские этюды // Коненков С.Т. Встречи. Воспоминания современников о скульпторе. М., 1980.

*Әд.:* А.Н.Мазитов: Буклет. Волгоград, 1967; Художники Ярославля: А.Н.Мазитов, В.В.Шепелев, А.И.Соловьёв: Каталог. М., 1968; Лауреаты Ленинского комсомола. М., 1970; П а р а м о н о в А.В., Ч е р в о н н а я С.М. Советская живопись. М., 1981. *М.Е.Ильина.*

**МӘҖИ́ТОВ** Әсгать Гариф улы (24.8.1900, Самара губ., Ставрополь өязе Татар Урайкиносы а. — 29.7.1946, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССРның атказ. артисты (1944). Авыл мәдрәсәсендә, 1911 елдан Мәләкәс мәдрәсәсендә укый, соңгысыннан шәкертләрнең хокукларын яклап чыккан студентлар хәрәкәтендә катнашканы өчен куыла. 1917 дә пед. курсларын тәмамлаганнан соң, Мәләкәс мәктәбендә укытучы һәм шәһәр большевикларының «Мәләкәс тавышы» г-тасында хәреф җыючы-корректор булып эшли, бер үк вакытта һәвәскәр театрлар куйган спектакльләрдә катнаша. 1919 да үз теләге б-н Кызыл Армия сафларына баса, Төркестан фронты сәяси бүлегенең татар театры төркеменә җибәрелә. 1920 дә Самара татар драма студиясендә укый, аны тәмамлаганнан соң, Оренбург шәһәрендә Г.Кариев исем. театрда актёр булып эшли. 1921–22 дә Урта Азиядә басмачыларга каршы көрәштә катнаша. 1922–24 тә Казанда Татар дәүләт театрында Җиһанша («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Иманкол («Наёмщик», Т.Гыйззәт), Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш) рольләрен башкара, бер үк вакытта совет партия мәктәбе, Татар коммунистлар ун-ты, милиция мәктәбе каршындагы драма түгәрәкләре б-н җитәкчелек итә. 1924 тә Мәскәү кинематография техникумына укырга җибәрелә. Мәскәүдә укыган вакытта Х.Ямашев исем. Мәскәү эшчеләр клубының театр коллективы б-н җитәкчелек итә. Казанда Татар театр техникумы каршында оештырылган «Бомба» агитколлективы өчен инсценировкалар яза. Соңрак Әстерхан шәһәрендә «Совкино» бүлегендә эшли, 1927 дә Казанда режиссёр ассистенты сыйфатында «Булат батыр» фильмын төшерүдә катнаша. 1928 дә — Мәскәү үзәк татар эшче, 1929–30 да — Әстерхан татар, 1930–31 дә Татар акад. театрларында эшли, бер үк вакытта Татар театр техникумында укыта. 1931–37 дә М. — Казанда *Татар сәнгать эшче театрын* (*«Эшче»*) оештыручы, аның директоры һәм сәнгать җитәкчесе. 1938 елдан Балтач колхоз-совхоз театрының (элекке Татар акад. театрының колхоз ф-лы, хәзер Татар драма һәм комедия театры) директоры һәм сәнгать җитәкчесе; анда ул «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Партизаннар» (Г.Садри), «Серле хәзинә» (Т.Гыйззәт), «Кунак егет» (Ә.Шамил), «Агай-эне — ак мыек» («Свои люди, сочтёмся», А.Н.Островский) спектакльләрен куя; үзе язган «Яраткан кешеләр», «Шул ук кешеләр» пьесаларын сәхнәләштерә. Драматург, театр теоретигы, театр сәнгате мәсьәләләренә караган мәкаләләр, ш.и. «Яңа тормышка», «Зәңгәр блуза», «Кызыл байрак» һ.б. мәкаләләр авторы.

Ә с ә р.: Бәйрәм бүләге. М., 1927; Пар чиләк. М., 1928; Авыл — күмәк хуҗалыкка таба алга. К., 1930; Еллар йомгагын сүткәндә. К., 1930; Җиңүчеләр. К., 1930; Ударниклар. К., 1931.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МӘҖИ́ТОВ** Борһан Сәләхетдин улы (1921, Төркестан АССР, хәзерге Үзбәкстан Респ-касы Коканд ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1983), проф. (1984). 1945 елда Ленинград политехник ин-тын тәмамлый. 1958 дән Үзбәкстан ССРның Атом-төш физикасы ин-тында (хәзер Үзбәкстан Респ-касы ФАнең Атом-төш физикасы ин-ты, Ташкент ш.), директор урынбасары (1960–75). Хезмәтләре протоннарның җиңел төшләр б-н үзара тәэсиренә карый.

Х е з м.: Ядерные реакции и изомерные переходы. Таш., 1973; Позиционно-чувствительные детекторы ядерных излучений. Таш., 1979; Статистические методы в ядерных реакциях. Таш., 1985.

**МӘҖИ́ТОВ** Гали Әхмәт улы (14.9.1912, хәзер БРның Ярмәкәй р-ны Яңа Шах а. — 30.1.1993, Украина, Ялта ш.), Сов. Союзы Герое (19.8.1944), гв. подполковнигы. Казан хәрби пехота уч-щесен (1936) тәмамлый. 1933 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет гаскәрләренең Көнбатыш Украина походында (1939), совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче гв. авиация дивизиясендә өлкән штурман (еракка очучы 3 нче гв. авиация корпусы). 1944 нең мартына дошманның һәм тупланган гаскәрләрен һәм ерак тылындагы хәрби-сәнәгать үзәкләрен бомбага тоту максаты б-н 183 сугышчан очыш ясый. 1954 тән отставкада. «Белем» җәмгыятендә эшли, ДОСААФ оешмасы рәисе, автомәктәптә укыту-тәрбия эшләре буенча рәис урынбасары (Ялта ш.) булып эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Ялта шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; Герои Советского Союза: Краткий биогр. словарь. М., 1988. Т. 2. *М.З.Хәбибуллин.*

**МӘҖИ́ТОВ** Зәет Мәҗит улы (25.8.1927, Минзәлә кантоны Иске Айман а. — 13.5.2000, Казан), шагыйрь, әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1955), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1951). 1954–57 елларда «Совет Татарстаны» г-тасы редакциясендә эшли, 1957–89 да Казан ун-тында укыта. Шагыйрь Ф.Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында күпсанлы мәкаләләре һәм монографиясе бар. Хезмәтләре Бөек Ватан сугышы чоры татар поэзиясен өйрәнүгә багышлана. «Таңгы җыр» (1953), «Чәчәк бирәм сиңа» (1959), «Ярсу Ык» (1967), «Күңел җыры» (1972), «Рәхмәт яусын» (1977), «Теләк» (1984), «Кер бакчама» (1999) исемле шигырь җыентыклары авторы. М.ның лирикасы аһәңле яңгырашлы. Лирик герое — һәр эшкә җаваплы караучы ватанпәрвәр шәхес. М. үзенең иҗаты б-н татар әдәбиятында лиро-эпик жанрны үстерүгә сизелерлек өлеш кертә, үзен әдәби пейзаж остасы итеп таныта.

Х е з м.: Фатих Кәрим: Тормыш һәм иҗат юлы турында очерк. К., 1963; Заман сулышын тоеп: Бүгенге әдәбият турында. К., 1967 (автордаш); Татар поэзиясе Бөек Ватан сугышы елларында. К., 1989.

*Әд.:* Г а т а ш Р. Ир җанында ни булмас! // Казан утлары. 1997. № 8.

*Р.Ф.Харрасова.*

**МӘҖИ́ТОВ** Илгиз Габидулла улы (20.8.1932, Казан — 14.6.2004, шунда ук), режиссёр, педагог, музыка-җәмәгать эшлеклесе, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978, 1983). ТР Концерт эшлекләре берлеге рәисе (1991). Иҗат эшчәнлеген 1964 елда Татар филармониясендә вокалчы солист буларак башлый. 1967 дә Дәүләт театр сәнгате ин-тына (Мәскәү) укырга керә. 1973–75 тә Татар опера һәм балет театрының баш режиссёры, 1975–92 дә Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе. Татар опера һәм балет театрында В.А.Моцартның «Дон Жуан», Г.Доницеттиның «Сөйдергеч эчемлек» («Любовный напиток»), Дж.Вердиның «Риголетто», Л.Хәйретдинованың «Мәкерле песи» һ.б. операларын, ш.у. оперетталар һәм муз. комедияләр куя. Татар башкару сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. Каракалпак, Чуаш, Башкортстан Респ-калары мәдәнияте көннәрен уздыру эшенә җитәкчелек итә. Күренекле татар әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләре Б.Урманче, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Г.Бәширов, Т.Гыйззәт, М.Җәлил, С.Хәким һ.б.га, илебез һәм респ-кабыз тарихындагы зур вакыйгаларга: Бөек Ватан сугышында җиңүнең 40 еллыгына, Окт. рев-циясенең 70 еллыгына, ТАССР оешуның 60 еллыгына, 1 нче

Бөтендөнья татар конгрессына, Татарстан Респ-касы көнен бәйрәм итүгә багышланган театральләштерелгән концерт программаларын сәхнәгә куя. Татар композиторларының иҗатын пропагандалауга зур игътибар бирә, Ф.Әхмәтов, Н.Җиһанов, А.Ключарёв һ.б.ның әсәрләреннән симф. музыка кичәләрен оештыра. Якты моңы, үзенчәлеге б-н аерылып торган «Урман юлында», «Их, дускаем, кил әле!», «Ак каеннар шаулый», «Көнче күбәләк», «Алтын аланда», «Яшьлек урамы» һ.б. җырлар авторы. Казан консерваториясендә күп еллар дәвамында опера классын алып бара. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МӘҖИ́ТОВ** Нәҗип Каюм улы (8.7.1940, Ютазы р-ны Иске Урыссу а.), механика өлкәсе галиме, а.х. фән. д-ры (1990), Россия А.х. фәннәре академиясе мөхбир әгъзасы (2005), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996), ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1988), ТР ФАнең шәрәфле акад. (2008). 1965 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, 3 нче урта һөнәри-техник уч-щедә (Ульянов өлкәсенең Кузоватово пос.), Казан а.х. ин-тында (1966–79), Мари ун-тында (1979–80) эшли. 1980 нән Татарстан Авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тында, авыл хуҗалыгын механикалаштыру бүлеге мөдире (1989–92), баш фәнни хезмәткәр (1992 дән), а.х. машиналары буенча директор урынбасары (2004 тән), бер үк вакытта Казан а.х. академиясе (хәзер Казан аграр ун-ты) профессоры (1994 тән), ТР Агросәнәгать комплексының механикалаштыру буенча баш эксперты (1995 тән), «ТР инвестиция-финанс корпорациясе» АҖнең а.х. машиналары секторы башлыгы (1995 тән), проф. (1996). Хезмәтләре а.х. машиналарын төзүгә карый. М. күпьеллык үләннәрне аэрацион эшкәртү технологиясен һәм шул максаттагы механика чараларын тәкъдим итә. Авыл хуҗалыгы культураларын эшкәртүнең дымлылык, энергия һәм ресурс саклаулы алымнарын, бәрәңге эшкәртүнең универсаль технологиясен, рәт араларын эшкәртү машинасын, катлаулы һава шартларында кулланыла торган бәрәңге казыгыч машина эшли. Унификацияләнгән блоклы-модульле культиваторлар комплексын эшләп чыгарганы өчен (РФнең барлык климатик туфрак зоналарында кулланыла) «Алтын көз–2003» (Мәскәү) Халыкара агросәнәгать күргәзмәсенең 1 нче дәрәҗәле дипломына һәм алтын медаленә лаек була. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РСФСР, ТРның Дәүләт бүләкләре (1990,1999), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге (2001) лауреаты. Медальләр, ш. и. СССР ВДНХсының өч алтын, өч көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Комбинированные почвообрабатывающие агрегаты. К., 1984; Машины почвоохранного земледелия. М., 1987; Ресурсосберегающие почвообрабатывающие машины. К., 2003.

**МӘҖИ́ТОВ** Ришад Кәшфелмаһан улы (25.5.1937, Казан — 25.11.2003, Мәскәү), физик, физика-матем. фән. д-ры (2000). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1965 тән Мәскәүдә: Физика проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тында, лаб. башлыгы (1968 дән); РФАнең Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында (1971 дән), сыеклыклар микродинамикасы секторы мөдире (1990 нан). Хезмәтләре конденсатлашкан тирәлекләрдә затлы газлар төшләренең магнит резонансына карый. М. тозларның судагы эремәләрендә төшләрнең магнит резонансын тикшерә, бу эремәләрдә су молекулалары һәм протоннарның динамикасын билгели. Суда селтеле металл ионнарының төш релаксациясе үзенчәлекләрен ачыклый. Зур булмаган басым астында инерт газлар б-н тутырылган сыеклыкларны югары сизгерлектә тикшерү методикасын эшли. Конденсатлашкан тирәлекләрдә (сыеклыкларда һәм каты җисемнәрдә) эретелгән инерт газларның төш релаксациясен үлчи, молекуляр хәрәкәтнең фундаменталь закончалыкларын билгели.

Х е з м.: Релаксация ядер $^{131}$Xe атомов ксенона, растворённого в жидкостях // Докл. АН СССР. 1983. Т. 273, № 1 (автордаш); ЯМР $^{129}$Xe ксенона, растворённого в тканях животных in vitro: Влияние поражения ткани раком // Докл. РАН. 1999. Т. 365, № 3 (автордаш); Nuclear relaxation of atomic neone-21 liquid solution // Journal of Magnetic Resonanse. 1992. V. 96, № 1 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**МӘҖИ́ТОВ** Шакир Хафиз улы (1907, Оренбург ш. — 1968, Казан), драма актёры, композитор. 1927–39 елларда Оренбург һәм Әстерхан татар театрларында эшли, 1939–48 дә — Татар акад. театрында, башлыча, характерлы рольләр башкара. 1949–60 та Татарстан радиосында муз. тапшырулар мөхәррире. М. татар халык музыка иҗатын тирәнтен белә, спектакльләргә музыка яза. Күбрәк җырлар авторы буларак танылa. Басылып чыккан әсәрләре «Яңа җырлар» (1954), «Юл җыры» (1965), «Туган як җырлары» (1972) һ.б. җыентыкларда тупланган.

*Әд.:* Композиторы Советского Татарстана. К., 1957. *Ф.Ш.Салитова.*

**МӘҖИ́ТОВ** Шамил Сәләхетдин улы (1914, хәзер Үзбәкстан Респ-касының Коканд ш. — 1991), машиналар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1982), проф. (1983). Ленинград политехник ин-тын тәмамлый. 1953–91 елларда Таҗикстан ССРның Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре а.х. машиналарының терәк конструкцияләре ныклыгы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Методы и оценки повышения прочности, долговечности, надёжности машин. Душ., 1989.

**МӘҖИ́ТОВА** Мәдинә Ирек кызы (31.8.1968, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (2011). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1992), шунда ук, 2 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында эшли. ТРда хатын-кызлар сәламәтлеге торышын (ш.и. аналыктан тыш йөклелек эпидемиологиясен, операциядән соң хатын-кызларның репродуктив потенциалын) өйрәнә. Операциядән соңгы катлаулану очракларын кисәтү ысулларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Безгазовая лапароскопия в гинекологии как альтернатива классической эндоскопии // Казан. мед. журн. 2008. № 4 (автордаш); Некоторые аспекты применения внутриматочной системы с левоноргегстрелом (в помощь практикующему врачу). К., 2012 (автордаш); Инновационная технология эндовидеохирургии в гинекологии // Казан. мед. журн. 2013. № 3 (автордаш).

**МӘҖИ́ТОВА** Роза Кадыйр кызы (8.3.1927, Үзбәкстан ССРның Кирмән ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). 1950 елда Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң, Эстәрлетамак пед. ин-тында эшли. 1960 тан Казан техник ун-тының икътисад һәм хокук теориясе кафедрасында. Бер үк вакытта (1994 тән), Петербург ун-тының Россия укытучыларны кабат укыту һәм квалификациясен күтәрү гуманитар ин-ты Казан ф-лының икътисад теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре бүлү мөнәсәбәтләренә, хезмәт хакы һәм икътисади мәнфәгатьләр бәйләнешенә, хуҗалык алып бару алымнарын камилләштерүгә карый. Аерым хезмәтләре СССР ВДНХсына һәм Халыкара күргәзмәләргә куела. «Бүлү мөнәсәбәтләре һәм аларны камилләштерү» («Распределительные отношения и их совершенствование», 1970) монографиясе СССР ВДНХсы билгесе б-н бәяләнә (1971), «Хезмәт хакы һәм аның икътисади мәнфәгатьләр б-н бәйләнеше проблемалары» («Заработная плата и проблемы её взаимосвязи с экономическими интересами», 1983) дигән хезмәте Болгариядә узган Халыкара күргәзмә дипломына лаек була (1984). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Заработная плата и проблемы её взаимосвязи с хозяйственным механизмом социалистического общества. М., 1990; Интеллектуальный труд: Сущность, особенности, содержание и проблемы измерения его результатов // Актуальные проблемы совершенствования учебной и научной деятельности в высшей школе. К., 2003.

*Әд.:* Г о р т ы ш е в Ю.Р., Ш а р а п о в С.И., Х а й р у л л о в Д.С. Полвека в высшей школе // Науч. Татарстан. 2001. № 2.

**МӘҖЛИСИ́** (15 йөз ахыры — 16 йөз башы), төрки шагыйрь, татарлар арасында киң таралган 4 мең шигъри юлдан торган «Кыйсса-и Сәйфелмөлек» исемле мәхәббәт дастаны авторы. Сюжеты «Мең дә бер кичә» җыентыгының шул исемдәге әкиятенә барып тоташа. Беренче тапкыр 1807 елда Казанда басыла, соңыннан да күп тапкыр нәшер ителә. М. дастанына нигезләнеп, татар шагыйре *Баһави* («*Буз егет*»), казакъ шагыйре Йосыфбәк Шәйхелислам («Кыйсса-и Сәйфелмөлек-Бәдигыльҗамал», 1876) әсәрләрен язалар.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том.

**МӘҖМУГА́** (гарәп. مجموعة — җыентык), төрки әдәбиятларда җыентык, альманах, сайланма әсәрләр җыелмасы. Күп очракларда М. дип хәзерге «хрестоматия» атамасына якын булган, чәчмә һәм тезмә әсәрләрдән төзелгән китапларны яки фәнни хезмәтләр җыентыкларын атаганнар (мәс., «Мәрҗани мәҗмугасы»). Аерым очракларда «М.» атамасы «журнал» мәгънәсендә кулланылган.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«МӘҖМУГЫ́ЛЬ-ХИКАЙӘ́Т»** («مجموع الحكايات» — «Хикәятләр җыентыгы»), татар әдәбияты ядкәре. 18 йөздә Көнбатыш Себердә

яшәгән, чыгышы б-н Казан арты кешесе Мөхәммәтрәхим ибне Рәфыйкъ әл-Казаный тарафыннан төзелә (1775). Романтика, фантастика, мәхәббәт-романтика һәм нәсыйхәт характерындагы әкият һәм хикәятләр җыентыгын тәшкил итә. Алар сюжетның (фарсы телендәге язма чыганакларга барып тоташа) катлаулылыгы һәм төрлелеге, композициянең төзеклеге, күпсанлы персонажлары, теленең байлыгы һәм нәфислеге б-н аерылып тора. Беренче тапкыр Казанда 1994 елда басыла.

*Әд.:* И с м а г и л о в Н.Ф. Сборник «Маджмугал-хикаят» как проявление литературных связей с Востоком // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999.

*Н.Ф.Исмәгыйлев.*

**МӘҖҮСИЛЕ́К** (гарәп. مجوسى), бердәм тәгълиматы булмаган диннәрнең теизмга каршы куелган традицион атамасы (политеизм, яки күпаллалык); табигать көчләрен гәүдәләндерүче аллаларга, илаһи көчләргә, рухларга табыну. Борынгы җәмгыятьтә барлыкка килә. Анимизм, магия, тотемизм, фетишизм, шаманизм кебек төшенчәләргә туры килә. Мәҗүси табынуларның асылы — табигатькә магик көч, сихер б-н тәэсир ясау. Мәҗүсиләр коллективның (ыру, кабилә, җәмгыять) биол. һәм хуҗалык тормышы өзлексез яңарып тору цикллары б-н үзара бәйләнгән дип күзаллыйлар. Шуның өчен ел дәвамында билгеләп үтелгән бәйрәмнәргә гаилә тантаналарын — туй йолаларын, мул сый мәҗлесләрен һ.б.ны да өстәгәннәр. Татарларның борынгы бабаларына утка, Кояш, су, борынгы бабалар, тотемнар (хайваннар) рухына һ.б.га табыну хас булган. Алар карашынча, дөнья өске (күк), урта (кешеләр һәм рухлар яшәгән җир) һәм түбән (җир астындагы дөнья) өлешләргә бүленгән.

Күпаллалыкның иң югары дәрәҗәсе күктәге баш алла *Тәңре* б-н төгәлләнә. Тәңре халыклар һәм дәүләт хакимнәренең язмышлары б-н идарә итүче һәм ирлек башлангычына ия булган иң югары көч итеп күзалланган; Евразиядәге борынгы төрки дәүләтләрдә Тәңре — каганның яклаучысы, аңа зирәклек һәм хакимлек сәләте бирүче. Идел буенда яшәгән төрки халыкларда Тәңре ш.у. агачка табыну культы («тормыш агачы», «галәм агачы», татарларда — «яфан агачы»), Күк һәм Җир, Тәңре һәм аңа табынучы кешеләр арасын бәйләүче чылбыр булып торган. Алар күзаллавынча, изге агачның һәр ботагында алла урнашкан, ул агач янында кешеләр корбан чалганнар, борчу-мәшәкатьләр турында сөйләшкәннәр, ярдәм сораганнар. «Тормыш агачы» өлгеләре болгар сынлы сәнгатендә дә киң таныла. «Тормыш агачы» б-н бәйле аллаларга ышану Алтай төркиләрендә дә була. Болгарлар каен, имән, зирек, артыш һ.б. агачларны саклаучы-сихри сыйфатларга ия дип санаганнар. Соңрак чорлардагы ышануларда да агачлар рухларның вакытлыча тукталу урыны булып исәпләнгән. Бу хатыннарның изге каеннарга дога б-н бала сорап мөрәҗәгать итү йоласында да чагылыш тапкан. Каен корыган булса да изге саналган; аңа кагылырга ярамаган, чөнки каенда үлгәннәрнең рухы урнашкан, каен — зират агачы, кайгы һәм хәсрәт агачы дип уйланылган, шуңа күрә аны йорт тирәсенә утыртмаганнар (к. *Ак каен*). Татар фольклорында Ак тирәк, Күк тирәк, Бай тирәк, туган җир, нәсел агачы образлары еш очрый. Кояш системасындагы планеталарның Рух-Кояшка карап урнашуына бәйле рәвештә торак йортларның Кояшка юнәлтеп төзелүе, Кояшка табыну йоласы, айга карап дәвалану ысуллары болгарларда Кояшка һәм Айга табыну йоласы булуын чагылдыра. Суны тормыш һәм уңдырышлылык чыганагы итеп кабул итү суга табыну б-н бәйле. Им-том итүчеләр өшкерү өчен, гадәттә, чишмә суын файдаланганнар, дәвалау өчен ш.у. аңа көмеш акча яки миләш ботаклары ташлаганнар. Изге каберләр тирәсеннән, елгалар янындагы мәгарәләрдән агып чыгучы чишмә сулары могҗизалы дәвалау үзенчәлекләренә ия дип исәпләнгән. Биләр шәһәрлеге янәшәсендәге Балынгуз тавы итәгендә урнашкан «изге чишмә» янында корбан чалу йоласы хәзерге көнгә кадәр сакланган. Суның саклау үзенчәлегенә ышану *Шүрәле* турындагы мифта да чагылыш тапкан. Анда әсәрнең геройлары Шүрәледән елга аръягына чыгып котылалар. Идел болгарларының шактый зур катламында хайваннар культы яшәп килгән. Ат, барс, бүре һәм эткә табыну б-н бәйле рәвештә үсеш алган йолалар системасы шуны дәлилли. Чүлмәк-савытларның стильләшкән поши, болан, ат, аю башлары яки башка өлешләре рәвешендәге тоткалары саклау көчен чагылдырган. Идел болгарларының мәҗүси карашларының шактые борынгы төрки һәм болгарларга кадәрге чорларга карый. Урта Идел һәм Кама буйларына болгарлар килгәч, аларның элекке ышанулары җирле фин-угор мифлары б-н үрелгән. Идел һәм Кама буе халыкларындагы күп кенә легендаларның, мифологик карашларның охшашлыгы һәм еш кына тулаем тәңгәл килүе аларның үзара бәйләнештә булуларының чагылышы. Шул ук вакытта төрки компонент өстен булып кала бирә.

Мәҗүси ышанулар 922 елда болгарлар ислам дине кабул иткәннән соң да юкка чыкмый, еш кына яңа дини формаларда үсә, камилләшә, үзгәреш кичерә. Аларның кайбер элементлары күптәнге, мөселманлык билгесе буларак кабул ителә, башкалары рәсми дин тарафыннан кысрыклап чыгарыла. 1990 еллар башыннан Урта Идел буенда яшәүче кайбер халыкларда М.не яңадан торгызу тенденциясе күзәтелә. Хәзерге заманда татарларда мәҗүси ышануларның һәм йолаларның элементлары *Сабан туе, Җыен, Карга боткасы, Әмәл, Нәүрүз* бәйрәмнәрендә сакланып калган. Алар ш.у. татар фольклорында (эпос, йола шигърияте, мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар) да чагылыш тапкан. Ул жанрлар аша безгә тарихтан мифологиянең мәҗүси персонажлары килеп җиткән (*Дию, Аждаһа, Елан, Шүрәле, Убыр, Су анасы, Су бабасы, Су иясе* һ.б.). Хәзерге татарларда йолдызлар б-н бәйле мәҗүси күзаллаулар да сакланып калган. Алар Борынгы Вавилонның мифологик системаларына карый. Галәмдәге тотрыклы яшәешне яки аның юкка чыгу ихтималын билгеләүче мәгънәсе бирелгән Казык йолдыз, ш.у. Галәм язмышында мөһим роль уйнавына инанылган Җидегән йолдыз, Кече Җидегән йолдыз б-н бәйле карашлар аеруча популяр. Әлеге күзаллаулар бер үк вакытта башка эпик баһадирлар (к. *Алып*), аларның атлары яки асыл гамәлләре б-н үзара бәйләнештә тора. Монотеистик динне чагыштырмача соңрак кабул итүләре б-н бәйле буларак (16 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), Татарстанда яшәүче башка халыкларның (башлыча, фин-угорларның) рухи мәдәниятләрендәге мәҗүсилек катламы, татарларга караганда, шактый зур.

*Әд.:* Б а к и р о в М.Х. Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. К., 2008; Татар мифологиясе: Энциклопедик сүзлек. К., 2009; Д а в л е т ш и н Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (Истоки, становление и развитие). К., 2004; Этнография татарского народа. К., 2007.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**МӘЗӘ́К** (гарәп. مزاح — шаярту, көлке), л а т ы й ф ә, х и к ә я т, татар фольклоры жанры; көтелмәгән борылыш, үткен тел б-н төгәлләнә торган кечерәк күләмле юмористик-сатирик чәчмә әсәр. Анекдотның милли вариантлы. М.ләр социаль һәм тормыш-көнкүреш төрләренә бүленә. Социаль М.ләрдә гади халыкның ханнар, вәзир, бәк, казый, мулла, сәүдәгәрләр б-н каршылыклары һәм низаглары тасвирлана, явыз, мәрхәмәтсез, гаделсез, әхлаксыз хөкемдарлар, мәхкәмә, сәүдә, укыту өлкәсендәге кимчелекләр көлеп тәнкыйтьләнә, ә тормыш-көнкүреш М.ләрендә аерым кешеләрнең кимчелекләре: ялкаулык, наданлык, саранлык, шапшаклык, ялганчылык, холыксызлык көлкегә калдырыла. М.ләрдәге көлү җиңелчә, кайвакыт, бигрәк тә хөкемдарларның кимчелекләреннән көлгәндә, ачы да булырга мөмкин. М.ләрнең уртак персонажлары булган тулы цикллары бар — такылдык Әкмәли, надан Мокый б-н Мәнди, ялкау Әшти б-н Мәшти һ.б. Кайбер М.ләрнең реаль прототиплары да була (мәс., мәгърифәтче, тәрҗемәче һәм нашир Р.*Әмирханов* — М.ләр циклы герое Р.Тылмачның прототибы). М.ләрдә комик ситуация тудыру өчен тел чаралары (полисемия, омонимия һ.б.), стилистик фигуралар (гипербола, каламбур һ.б.) кулланыла. М.ләрнең барлыкка килү вакыты билгесез, аерым үрнәкләр борынгы Шәрекъ әдәбияты әсәрләрендә, 14 йөзнең кульязма җыентыкларында очрый. Әлеге традиция борынгы төрки әдәбиятка тәрҗемә һәм калька аша үтеп керә. М.ләрнең беренче басма җыентыгы — төрек теленнән тәрҗемә ителгән «Ләтаиф Хуҗа Насретдин әфәнде» (1845). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында М.ләрнең берничә җыентыгы басыла; ш.у. М.ләр матбугатта да дөнья күрә. 1960–80 елларда М.ләрнең Г.Бәширов тарафыннан әзерләнгән 2 җыентыгы чыга. «*Татар халык иҗаты*» фәнни басмасында бу жанрга «Мәзәкләр» исемле аерым том (1979) багышланган.

*Әд.:* Б ә ш и р о в Г. Туксан тугыз мәзәк. К., 1960; ш у л у к. Мең дә бер мәзәк. К., 1963; М а х м у т о в Х.Ш. Комичность в татарских мэзэках // Типология татарского фольклора. К., 1999.

*Х.Ш.Мәхмүтов.*

**МӘЗГУ́ТОВ** Вили Замир улы (2.4.1934, Үзбәкстан ССР, Бохара өлкәсенең Шафиркан

р-ны), фармаколог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1990). Ташкент мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук, фармакология кафедрасында калдырыла. 1972–92 елларда Ташкент педиатрия мед. ин-тында клиник фармакология каф. мөдире, 1989 дан 1 нче педиатрия ф-ты деканы. Хезмәтләре Үзбәкстан Респ-касында балалар авырулары һәм үлемена, ш.у. витилиго проблемаларына карый. 8 рационализаторлык тәкъдиме бар.

Х е з м.: Материалы к фармакологии препарата псорален, применяемого для лечения витилиго. Ташкент, 1967.


**МӘЗҺӘ́Б** (гарәп. مذهب — юл), исламдагы дини-хокукый мәктәп. 7–8 йөзләрдә төрле хокукый гыйлемнәр «М.» атамасы б-н билгеләнгән. 8–9 йөзләрдән башлап гомуми танылган 5 мәктәп бар: сөнниләрдә — хәнәфи, малики, шәфигый, хәнбәли М.; шигыйләрдә — имами-җәгъфәриләр М. ТРда мөселманнар, барлык М.ләр өчен уртак булган Коръән һәм Сөннәне ихтирам итү б-н бергә, *гореф-гадәт*кә нигезләнгән традицион хокукларны да таныган хәнәфиләр юлын тоталар. Бу исә өммәне бергә тупларга, ш.у. мөселманнарга башка дин вәкилләренә карата толерант мөнәсәбәттә булырга ярдәм итә.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**МӘЙДА́Н** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 46 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 347 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Сәүдәгәр И.Г.Сироткин йорты, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге — Спас-Преображение чиркәве манарасы. Казан ханлыгы чорында нигез салына, 1550–60 елларда Рус крәстияннәре килеп урнаша. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Спасское исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да Спас-Преображение чиркәве, земство (1867 дән бирле эшләүче авыл приход мәктәбе җирлегендә 1875 тә ачыла) һәм чиркәү-приход (1905 тә ачыла) мәктәпләре, 19 җил һәм 2 су тегермәне, 5 тимерчелек, 1 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли; дүшәмбе саен базар, елга 2 тапкыр (15 май, 14 сент.) ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5047 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 557 ир-ат; 1859 да — 2348, 1897 дә — 3016, 1908 дә — 3762, 1920 дә — 3329, 1926 да — 2750, 1938 дә — 2074, 1949 да — 1302, 1958 дә — 1211, 1970 тә — 1106, 1979 да — 797, 1989 да — 586, 2002 дә — 493 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**«МӘЙДА́Н»**, әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал. Оештыручылары: Чаллы шәһәре хакимияте, ТР Язучылар берлеге. 2001 елның октябреннән Чаллыда татар телендә нәшер ителә. Баш мөхәррире — В.Ш.Имамов (2005 тән).




«Мәйдан» журналының беренче саны.

**МӘК** (Papaver), мәк чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның салкын, уртача һәм субтропик поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә коелучан М. (кыргый М.) (P. rhoeas) үсә, чәчүлекләрдә, юл буйларында очрый. 1980 елларга кадәр Көнбатыш Кама арьягында йокы яки әфьюн мәге (P. somniferum) үстерелә. Үзәк тамырлы. Сабагы туры, 30–120 *см* биеклектә. Яфраклары чиратлашкан, күгелҗем төстә, каурыйсыман бүленмә, дулкынсыман тешле читле. Чәчәкләре берле, зур, ачык яки ак төстә, озын чәчәк сабында урнашкан. Җимеше — зәңгәрсу-кара төстәге бик күп вак орлыклы, төрле формада һәм зурлыктагы эре тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Әфьюн мәге азык һәм дару үсемлеге булып тора. Май һәм аксымга бай орлыклары — азык, тартмачыклары дару (онга тарттырылганнан соң һәм орлыкларыннан аергач) буларак кулланыла, морфин алкалоидлары, кодеин, папаверин алалар.



Йокы мәге.

**МӘКА́ЛЬ** (гарәп. — مقالة), афористик кыска, сурәтле, грамматик һәм логик яктан төгәлләнгән, оешкан ритмлы, хикмәтле үгет-нәсыйхәтләрдән гыйбарәт фольклор жанры. Соңгы билгеләмә М.не *әйтемнән* аера. Тел бизәү чарасы буларак М.гә төрки шагыйрь Й.Баласагуни игътибар итә. «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1069–70) поэмасында ул аны «абышка сүзе» («олылар сүзе») дип атый. Татар әдәбиятында М. «борынгылар сүзе», «ата-баба сүзе», «халык сүзе», «гыйбрәтле сүз» дип тә аталган. «Мәкаль» дигән яңа термин беренче тапкыр М.Ивановның «Татар хрестоматиясе»ндә кулланыла (1842). Татар М.ләрен фәнни яктан өйрәнү К.Насыйринең «Фәвакиһелҗөләса фил әдәбият» («Әдәби мәҗлес йомгаклары», 1884) китабы б-н бәйле. М.ләрне җыю б-н Н.Исәнбәт, Х.Ш.Мәхмутов һәм венгр шәркыятьчесе Д.Мессарош шөгыльләнә. Татар халык авыз иҗатында М.ләрнең тематик бүленеше кабул ителгән: табигать күренешләре, кеше сыйфатлары, иҗтимагый тормыш, Ватан һәм чит илләр, мәхәббәт һәм дуслык, гаилә-көнкүреш һ.б. турындагы төркемнәр аерып карала. Кайбер М.ләр халык теленә татар әдәбияты классиклары М.Акмулла, Г.Тукай, М.Җәлил һ.б. әсәрләреннән кергән.

*Әд.:* И с ә н б ә т Н. Татар халык мәкальләре: 3 томда. К., 1959–67; Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Мәкальләр // Татар халык иҗаты: Хрестоматия. К., 2005; М е с с а р о ш Д. Среди чувашей и татар Поволжья // Этнография. 1909. № 9.

*Ф.И.Урманчеев.*

**МӘКА́М** (гарәп. مقام — баскыч, дәрәҗә), мөселман мәдәниятында бернечә төрле мәгънә белдерү өчен кулланыла торган төшенчә: 1) суфичылыкта рухи камилләшү юлындагы баскыч, дәрәҗә; 2) Шәрекънең мөселман халыкларында традицион музыка (мөгамнар, мәкамнар, мөкамнар) нигезләре. Урта гасырлар әдәбияты ядкәрләре (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е һ.б.) татар мәдәниятендә ш.у. проф. музыкантлар һәм җырчылар тарафыннан М. композицияләре башкару традицияләре булган дип уйларга нигез бирә. Хан сарайларында, югары катлау даирәләрендә М. еш яңгырый. Аксөякләр арасында әлеге традиция юкка чыгу б-н (16 йөзнең 2 нче яртысы), «М». термины фәкать дини тормышта Коръәнне көйләп укуны аңлату өчен генә кулланыла башлый. М. атаклы татар мәдрәсәләренең һәм ш.у. танылган кари һәм хафизларның Коръән укуда муз. таныкнамәсе була. Һәрбер М. кайда киң таралган (Кизләү М.е, Шәйморза М.е, Казан М.е) — шул җирлек яисә башкаручы кари исеме б-н атала. Татар мохитенә читтән кергән Мисыр М.е, Шам М.е, Ливан М.е дә шул рәвешчә исемләнә. Совет хакимияте елларында күп кенә билгеле М.нәр онытылып юкка чыга, әмма М. сәнгате халык традицияләрендә Коръән уку осталыгының иң мөһим үрнәк күрсәткечләренең берсе булып кала; 20–21 йөзләрдә ул яңа үсеш ала.

*Әд.:* В а л и д о в Дж. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 года). М.-П., 1923; Профессиональная музыка устной традиции народов Ближнего и Среднего Востока и современность. Таш., 1981; С а й ф у л л и н а Г.Р. Музыка Священного Слова: чтение Корана в традиционной татаро-мусульманской культуре. К., 1999.

*Г.Р.Сәйфуллина.*

**МӘКАМӘ́** (гарәп. مقامة — әңгәмә), урта гасырлар гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларында шаян новеллалар жанры. 10 йөздә Гарәп хәлифәлегендә барлыкка килә. Әлеге жанрдагы әсәрләрдә, гадәттә, сәүдәгәрләрдән, байлардан көлүче хәйләкәр егет һәм хикәяләүче — шул вакыйгаларның шаһиты катнаша. М. ритмга салынган проза б-н катлаулы телдә языла, рифмалаша, кагыйдә буларак, сүз уйнату киң кулланыла. Циклларга (мәкамәт) берләшәләр. М. иҗаты б-н аеруча гарәп-фарсы шагыйре Әхмәд әл-Хәмәдани танылa (52 дән артык новелла, 990). Әлеге циклның герое — шагыйрь, галим Әбүл-Фәтх Искәндәри үзенең талантын өркетү һәм алдалау өчен файдалана. Гарәп шагыйре Ибне әл-Харириенең М. циклы (50 гә якын новелла, 12 йөз башы) герое Әбү Зәйд үзенең тапкыр

телен һәм шигъри талантын ш.у. алдау, ялган өчен куллана. М. дә герой сөйләменең һәм шигырьләренең сәнгать дәрәҗәсе һәм фикер үткенлеге, сүз иҗаты һәм рифмалар камиллек дәрәҗәсенә җитә.

*Әд.:* К р ы м с к и й А. Арабская поэзия в очерках и образцах. М., 1906; Бади аз-Заман Абу-л-Фадл Ахмад ибн ал-Хусейн ал-Хамадани: Макамы. СПб., 1999.

*А.М.Ахунов.*

**МӘКӘ́** (Pimpinella), чатыр чәчәкләр семьялыгыннан күп-, сирәк кенә бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 гә якын төре билгеле, Азиядә, Европаның тропик, субтропик һәм урта өлкәләрендә, берничә төре Америкада таралган. 15–60 *см* биеклектә. Яфраклары парсыз каурыйсыман. Чәчәкләре вак, ак төстә, катлаулы чатырда урнашкан. Җимеше — ике орлыкча. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Ташъяргыч М. (P. saxifraga) — күпьеллык үсемлек, барлык районнарда да очрый, болыннарда, тау битләрендә, куаклар арасында үсә. Июнь ахырыннан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Орлыктан үрчи. Үсемлектә органик к-талар, эфир майлары, шикәр, сумалалар бар. М.төнәтмәсе — какырык куптару чарасы, ашказаны-эчәк тракты эшчәнлеген көйли. Яшь яфраклары салатлар ясаганда, тамырчасы һәм җимешләре тәмләткеч буларак кулланыла. Терлек азыгы һәм баллы үсемлекләр. Известь М.се (P. titanophila) — күпьеллык үсемлек. Бик сирәк төр. Югары Ослан, Азнакай, Баулы р-ннары терр-ясендә ташлы, мергельле тау битләрендә очрый. Июнь–июльдә чәчәк ата. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**МӘКӘРҖӘ́ ЯРМИНКӘСЕ́**, Россиянең иң эре ярминкәсе. Идел елгасының сулъяк ярында, Макарьев монастыре янында уздырылган (хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Макарьево бистәсе, Түбән Новгородтан 88 *км* ераклыкта). 1524 елда бөек кенәз Василий III рус сәүдәгәрләренә Казанга барып сәүдә итүне тыйганнан соң оеша. 16 йөз уртасыннан 1816 га кадәр ел саен июль–август айларында эшли. М.я.нә Россиянең 200 дән артык шәһәр һәм авылыннан сәүдә итүчеләр җыела, руслар һәм татарлардан тыш, Урта Азия, Кавказ арты илләре, Һиндстан, Ираннан сәүдәгәрләр килә. Ярминкә Россия һәм Европа товарларын Себер һәм Кытай товарларына алмашу үзәге була, багланышлар Кама елгасы һәм кушылдыклары, *Эрбет ярминкәсе* аша алып барыла; Свенск ярминкәсе аркылы Украина, Белоруссия, Речь Посполита, Кара диңгез алды терр-яләре б-н элемтә тотыла. Көнбатыш Европа товарлары, башлыча, Архангельск шәһәре аша кертелә. Башта ярминкә б-н монастырь хакимияте идарә итә, тәртип саклый, сәүдәгәрләр арасындагы низагларны көйли, сәүдә җыемы җыя. 1700 дән М.я. дәүләт органнары идарәсенә күчә (баштарак Зур казна приказы һәм Казан сарае идарәханәсе, 1718 дән — Коммерц-коллегия), барлык җыемнар казнага туплана. 1720 дә ярминкәнең товар әйләнеше 220 мең сум тәшкил итә: 81 мең сумлык товар (ефәк, сафьян, сарык тиресе, дөге, хөрмә җимеше һ.б.) — Әстерханнан, 27 мең сумлык товар (кытай тукымалары, затлы җәнлек тиресе, тимер һ.б.) — Себердән, 30 мең сумлык товар (тукымалар, әзер кием-салым, галантерея, буяулар һ.б.) — Мәскәүдән, 12 мең сумлык товар (мех, ефәк, күн һ.б.) — Казаннан килә. 1730–40 та М.я.нә ел саен 400 мең сумнан артык, мәс., 1785 тә якынча 6,5 млн. сумлык товар китерелә. Сату-алу 20 ләп рәттән торган «Гостиный двор»да бара, берсе «Казан (татар) рәте» дип йөртелә, аның сәүдә әйләнеше елына якынча 103 мең сум була. Ярминкә әйләнәсендә балаганнар эшли. 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөздә М.я. сату-алу күләме ягыннан башка ярминкәләрдән 20–25% ка өстен тора (1790 да товар әйләнеше 30 млн. сум тәшкил итә). 18 йөзнең 1 нче яртысында Казан сәүдәгәрләре ярминкәдә катнашучыларның иң эшлекле беренче унлыгына керә. 1720 дә Казан сәүдәгәрләре М.я.нә 54 партия товар китерәләр, иң эре партия хуҗалары И.Михляев (2106 сум) һәм Я.Пушников (1795 сум) була. Казан сәүдәгәрләре, башлыча, сарык, куян, төлке, тиен, чәшке тиреләре, а.х. продуктлары, ш.и. ашлык, ш.у. җирле пр-тиеләр һәм һөнәрчелек товарлары б-н сату итә. 1802 дә М.я. б-н идарә итү өчен махсус контора булдырыла. Ярминкә эшчәнлеге киңәйгән саен аның урнашуына бәйле уңайсызлыклар: су басу куркынычы тудыручы тәбәнәк ярлар, яңа корылмалар төзү өчен урын җитмәү, товарларны күпләп саклау мөмкинлеге булмау һ.б. үзләрен ныграк сиздерә. 19 йөз башында М.я.н башка урынга күчерү мәсьәләсе берничә мәртәбә күтәрелә һәм ул, 1816 ның 18 августында булган янгында сәүдә комплексы тулысынча юкка чыкканнан соң, хәл ителә: 1817 ел 15 февраль фәрманы б-н М.я. Түбән Новгородка күчерелә.

*Әд.:* В о л к о в М.Я. Центры ярмарочной торговли в Европейской России в 1-й четверти XVIII в. // Проблемы социально-экономической истории феодальной России: Сб. статей. М., 1984; С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991. Отечественная история: История России с древнейших времён до 1917 года: Энцикл. М., 2000. Т. 3.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МӘККӘ́** (гарәп. مكة), Согуд Гарәбстанында (Кызыл диңгездән 70 *км* ераклыкта); мөселманнар өчен изге шәһәр — аларның хаҗ кылу урыны; Хиҗаз провинциясенең адм. үзәге. Халкы 2 млн. кеше (2013). 2 йөздән Макарәбә буларак билгеле. Гарәпләрнең борынгы табыну үзәге. Халык фаразлары буенча, М.дә кайчандыр *Адәм* белән *Хаува*, *Ибраһим*, *Исмәгыйль* пәйгамбәрләр, Исмәгыйльнең әнисе Һаҗәр яшәгән; *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең туган җире, 630 елда ул М. шәһәрен беренче мөселман җәмгыяте б-н сугышсыз яулап ала. Өммәвиләр династиясе хакимлек иткән чорда (661–750) М.нең шәһәр инфраструктурасы яхшыртыла: күпкатлы йортлар, суүткәргечләр төзелә, бакчалар утыртыла һ.б. 1802 дә М.не ваһһабчылар басып алалар һәм берничә ел кулда тоталар. 19 йөз башына кадәр Көнбатыш Гарәбстанны биләгән дәүләтләрнең хәлифәләре тарафыннан идарә ителә, әмма шәһәрнең эчке тормышы шәһәр хакимияте (шәрифләр) кулында була. 1924 тә ваһһабчылар Гарәбстанны берләштерү өчен барган көрәштә М.не үз кулларына алалар, 1926 да анда ваһһабчы дин башлыгы Ибн Согуд тәхеткә утыра (1932 дә М. Согуд Гарәбстаны корольлеге составына керә). Шәһәрдә *Кәгъбә* б-н исламның баш мәчете «Мәсҗид әл-Хәрам», ислам ун-ты урнашкан. Халыкның төп шөгыле хаҗиларга хезмәт күрсәтү, гыйбадәт кылу әйберләре җитештерү. М.гә керергә мөселманнарга гына рөхсәт ителә. Хаҗ вакытында шәһәргә ел саен 2 млн.га якын хаҗ кылучы килә. 2012–13 тә М.дә ТРдан 2500 гә якын кеше хаҗ кыла.

**МӘКТӘ́П** (гарәп. مكتب — язу урыны). 1. Башлангыч мөселман уку йорты. М.ләр гарәп илләрендә 7–8 йөзләрдә барлыкка килә, соңрак барлык мөселман илләрендә тарала. Идел буе Болгар дәүләтендә 10 йөздән билгеле, Алтын Урда, Казан ханлыгы вакытында да булалар. 18 йөзнең 2 нче яртысында Россия составында Идел-Урал төбәкләрендә ярым тыелган була. 1773 елда «Теләсә нинди дин тоту ирекен тану» фәрманын кертү б-н, мөселман руханиларына балаларга дини белем бирү бурычы йөкләнә, һәрбер указлы мулла бер үк вакытта М. укытучысы да була. Рәсми мәгълүматлар буенча, 19 йөз уртасында Казан губернасында 430 М., 1905 тә — 845, 1907 дә — 877, 1913 тә 967 М. эшли, барысы 79 мең укучы укый. Чынлыкта, М.ләр күбрәк була, чөнки алар һәр мәхәлләдә эшли. М.ләр мәхәллә халкы акчасына тотыла. Аларның күбесендә мәхәллә муллаларыннан тыш, башка мөгаллимнәр дә укыта, кече яшьтәге укучыларга указлы мөәзиннәр дәрес бирә. 19 йөздә — 20 йөз башында М.ләрдә татар ир балалары белем ала. 19 йөзнең 2 нче яртысында кыз балалар өчен дә М.ләр барлыкка килә, аларда руханилар гаиләсеннән булган хатын-кызлар укыта, соңрак имам-хатиплар үзләре дә укыта башлый. Хөкүмәтнең күп тапкырлар М.ләрне күзәтүгә яисә аларның исәбен алырга тырышулары уңышсызлыкка очрый. 19 йөзнең соңгы чирегенә кадәр М.ләр укыту дини характерда була: укучылар уку, язу, арифметика, гарәп теле, догалар, мөселманнарга фарыз гамәлләрне өйрәнә, әхлакый-догматик эчтәлекле китаплар укый, Һәфтиякне (Коръәннең 7 нче өлеше) ятлыйлар. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында җәдитчелек үсеше нәтиҗәсендә күп М.ләр аның принципларына туры китереп үзгәртеләләр. Укырга-язарга өйрәтүдә аваз алымы, сыйныф-дәрес системасы б-н укыту кертелә. Татар, гарәп телләре, арифметика өйрәнелә, табигать, тарих, геогр. фәннәре буенча башлангыч мәгълүмат җиткерелә, күп М.ләрдә рус теленнән башлангыч белем бирелә. Яңа ысуллы М.ләрдә бары Ходай кануннарын гына укытучы муллалар түгел, ә яңа ысуллы мәдрәсәләрдә («Мөхәммәдия», «Буби» һ.б.) белем алган мөгаллимнәр зуррак роль уйный. М.ләрнең эшчәнлеге совет хөкүмәте вакытында да туктатылмый, 1926 да 800 М.тә 30 мең бала укый. 1929 га кадәр мөселман руханиларына балаларны укытырга рөхсәт ителә; совет мәктәпләре булмаган төбәкләрдә муллалар балаларны укыткан өчен дәүләттән матди ярдәм алалар. М.ләр, күпчелек мөселман мәхәлләләре б-н бергә, 1930 еллар

башында ябылалар. 1990 еллар башыннан, балалар һәм өлкәннәр өчен якшәмбе мәктәпләре буларак, яңадан ачылалар (күпчелек мөселман мәхәлләләрендә эшлиләр), анда гарәп теле һәм графикасы, ислам дине нигезләре өйрәнелә. М.ләр өчен дәреслекләр бастыру яңартыла.

*Әд.:* к. *Мәдрәсә.*

2. Гомуми белем бирә торган уку йорты. Совет хакимияте урнашканнан соң, чиркәүне дәүләттән һәм мәктәпне чиркәүдән аеру турындагы Декрет (1918) б-н дөньяви белем бирү принцибы кертелә. Халык мәгарифе системасында тамырдан үзгәрешләр була: гимназия б-н реаль уч-щеләр бердәм урта мәктәп итеп үзгәртеләләр, 1920 елдан респ-када халык арасында наданлыкны бетерү буенча планлы программа гамәлгә ашырыла. 1920–30 елларда беренче тапкыр татар телендә гомуми белем бирү дәүләт системасы булдырыла: ана телен һәм әдәбиятын, рус телен өйрәнү методикасы буенча программалар һәм уку ярдәмлекләре, гуманитар һәм табигать фәннәре буенча дәреслекләрнең рус теленнән тәрҗемәсенең тулы комплекты әзерләнә. 1933/34 уку елында СССРда гомуми башлангыч белем бирү кертелә. Урта мәктәпләр челтәре тиз үсеш ала, яңа укытучы кадрлар әзерләү башлана, яңа дәреслекләр булдырыла. 1936/37 уку елында шәһәрләрдә җидееллык белем бирү мәҗбүри була. ТАССРда милли мәктәпләр үсешендә татар теле алфавиты алмашу (10 ел эчендә ике тапкыр: 1927, 1939) җитди каршылыклар тудыра. 1950 елларның 2 нче яртысында халык мәгарифе үсешендә мөһим бурычларның берсе хәл ителә: 1955/56 уку елында гомуми мәҗбүри җидееллык, 1959/60 та — гомуми сигезьеллык белем бирү кертелә. Халык мәгарифен квалификацияле пед. кадрлар б-н тәэмин итү буенча зур эш башкарыла, 1955–60 та ТАССРда 550 дән артык яңа мәктәп биналары төзелә. 1970 елларда мәктәп яшендәге барлык балаларны гомуми мәҗбүри урта белем бирүгә күчерү гамәлгә ашырыла. Совет җитәкчелегенең совет халкының яңа җәмгыятен формалаштыруга юнәлтелгән рәсми курсы б-н тәңгәл рәвештә 1950 еллар ахырыннан Татарстанда татар телендә укытуны бетерү сәясәте уздырыла, шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә барлык милли мәктәпләр рус телендә укытуга күчерелә, рус мәктәпләрендә укучы татар балалары өчен ана телен өйрәнү кыскартыла. 1980 еллар башына Казанда нибары 1 татар мәктәбе кала. 1990 елларда милли мәдәниятне тергезү, милли мәктәпләр эшләрен яңарту, балаларның ана телен өйрәнүен оештыру эшчәнлеге башлана. 1990–2000 елларда татар гимназияләре челтәре булдырыла, күп мәктәпләрдә татар сыйныфлары эшли башлый, гомуми белем бирү мәктәпләре программаларына татар телен укыту кертелә. Махсуслаштырылган мәктәп, гимназия, лицейларның саны шактый арта, дәүләтнеке булмаган мәктәпләр барлыкка килә.

2009 да Татарстанда 2300 ләп гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. татар телендә белем бирә торган 1138 мәктәп эшли. 2000 еллар ахырында гомуми белем бирү учреждениеләрен җан башыннан финанслауга күчү «оптимальләштерү»гә, ягъни аз комплектлы авыл мәктәпләрен ябуга, бу исә гомуми белем бирү мәктәпләре санының кискен кыскаруына, милли мәктәпләрнең кимүенә китерә: 2012 дә Татарстанда 1589 гомуми белем бирү уку йорты (якынча 375 мең бала), ш.и. 852 татар телендә белем бирүче мәктәп (якынча 72 мең бала), 69 татар гимназиясе (26,5 мең бала) эшли.

*Әд.:* Туишев Ю.А. Развитие народного образования в Татарской АССР: к 30 летию Татарской АССР. К., 1950; Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). К., 1975; Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). К., 2001.

Ш.у.к. «Татарстан Республикасы» мәкаләсендәге «Халык мәгарифе» бүлеген.

**«МӘКТӘ́П»**, татар халкында беренче фәнни-пед. журнал. 1913 елның 21 февраленнән 1914 нең 17 октябренә кадәр Казанда айга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 25 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Ш.Ш.*Әхмәров*; ул үз тирәсенә атаклы татар зыялыларын, Казан һәм Петербург ун-тын тәмамлаучыларны: укытучылар, әдәбиятчылар, галимнәр, журналистларны җыя. Журналда Х.Әбүәлхан, Ф.Агиев, Һ.Атласи, Ш.Әхмәров, И.Бикколов, С.Җәлал, Г.Ибраһимов,




«Мәктәп» журналы.

Р.Ибраһимов, Г.Исхакый, Г.Кариев, М.Корбангалиев, Ә.Максуди, Г.Мостафин, К.Мотыйгый, Ф.Сәйфи, С.Сүнчәләй, М.Фуат, Г.Шәрәф һ.б.ның мәкаләләре басыла. Журналның оешуына Ш.Әхмәровның Г.Тукай б-н якыннан аралашуы да йогынты ясый. Беренче саны Тукай шигыре б-н ачыла, өченчесе шагыйрьнең үлеменә багышлана. «М.» белем һәм тәрбия бирү проблемаларын бик югары иҗтимагый дәрәҗәгә күтәрә, татар мәктәбенең үткәнен, бүгенгесен һәм киләчәген киң күләмдә һәрьяклап яктырта. Журнал битләрендә уку программалары, уку процессы б-н бәйле мәсьәләләр тикшерелә, пед. темаларга, татар милләтен белемле итүгә багышланган бәхәсләр алып барыла. Милли тәрбиягә зур игътибар бирелә, туган телне үстерү мәсьәләләре күтәрелә. «М.» ш.у. укучыларны чит илләрдә белем бирү системасы б-н дә таныштыра. Казанның алдынгы мәктәпләренә багышланган мәкаләләр циклында атаклы укытучылар эшчәнлеге яктыртыла; мәктәп укытучылары үзләренең эш алымнары б-н уртаклаша, укыту һәм тәрбия бирү мәсьәләләре буенча фикерләр алыша. Ш.у.к. «*Мәгариф*» (иҗтимагый-пед., фәнни-әдәби айлык журнал).

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**МӘКТӘПКӘ́ЧӘ БАЛАЛА́Р УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ́**. 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башларында М.б.у. Россиядә ике юл б-н үсеш ала. Беренчедән, мәктәпкәчә тәрбия теориясенә нигез салучы немец педагогы Г.Фребель (1782–1852) системасы буенча булдырылган М.б.у. челтәре үсеш ала. Алар каршында Фребель җәмгыятьләре һәм балалар бакчалары булдырыла башлый, беренчесе 1870 елда С.-Петербургта ачыла. Пед. кадрлар җәмгыять каршындагы курсларда һәм Берлинда өч еллык Фребель курсларында әзерләнә. 1917 елга Россиядә якынча 150 Фребель балалар бакчасы була. Казанда беренче балалар бакчасын 1907 дә А.А.Самойлова оештыра, ул Берлинда үзенең әтисе — проф.-физиолог А.Ф.Самойлов җитәкчелегендә Фребель курсларын тәмамлый. Икенче балалар бакчасын 1909 да Гаилә-пед. түгәрәге ача. 1917 гә шәһәрдә 3 түләүле Фребель балалар бакчасы була. Икенчедән, 1880 еллардан хәйрия җәмгыятьләре, эшләүче хатын-кызларның балалары өчен түләүсез һәм арзанлы балалар ясләре һәм бакчалары оештыра башлый. Бу балалар бакчалары, нигездә, пед. түгел, ә социаль статуста була. 1900 дән Александра ятимханәсе каршында ясләләр, 1906 дан — Ярлы һәм авыру балаларны кайгырту җәмгыяте каршында, 1911 дән Ярлы яһүдләргә ярдәм җәмгыяте каршында балалар бакчалары эшли. Хатын-кызларның ирләр б-н тигез хокуклылыгын яклаучы, хатын-кызларны җәмгыятькә файдалы хезмәткә тартуны алга сөрүче марксистик идеологиягә ярашлы рәвештә, ш.у. традицион гаиләнең тиздән бетәчәге турындагы 1930 елларга кадәр хөкем сөргән карашлар нигезендә дәүләт хакимияте органнары 1918 дә үк М.б.у. проблемасы б-н актив шөгыльләнә башлый, Совет хакимиятенең беренче елларында ук бик күп санда балалар бакчалары ачыла. 1918 нең көзендә Казанда — 9, 1919 ның язында — 40, ш.и. 7 татар (Иске татар, Яңа татар һәм Пороховой бистәләрендә) балалар бакчасы була; М.б.у. өяз шәһәрләрендә дә ачыла. 1920 дә ТАССРда 200 балалар бакчасы эшли. НЭП елларында аларның саны, финанслау туктатылу сәбәпле, бик нык кими. 1926 елга түләүле яисә зур пр-тиеләр каршында барлыгы 45 балалар бакчасы кала. Ләкин индустрияләштерү башлану б-н М.б.у. саны яңадан тизлек б-н арта; 1927 гә ТАССРда 73, 1929 да 200 балалар бакчасы була. Күмәкләштерү башлану б-н М.б.у. авылларда да ачыла башлый.

1940 елга респ-када 549 балалар бакчасы (шулардан 194 е колхозларда) исәпләнә, аларда 27 мең бала тәрбияләнә; 64 мең балага исәпләнгән 1563 балалар мәйданчыгы булдырыла (колхоз һәм совхозлардагы сезонлы М.б.у.).

Бөек Ватан сугышы елларында М.б.у.нең саны кимеми, чөнки хатын-кызларның җитештерү өлкәсендә эшләве арта. Сугыштан соңгы елларда да М.б.у. саны арту дәвам итә, 1980 еллар башына ТАССРда 260 мең урынга исәпләнгән 1940 балалар бакчасы эшли. Балаларның 70% ы М.б.у.ндә тәрбияләнә. 1980 елларның 2 нче яртысына халыкның М.б.у.нә ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндерелә. 1980 елларда М.б.у. челтәре кыскара башлый (яңа төзелеш барган районнардан тыш), кайбер балалар бакчалары балалар аз туу сәбәпле ябылалар. 1991 дә 1860 М.б.у. эшли. 1990 еллар башыннан М.б.у. финанс ягыннан авыр хәлдә була, күп пр-тиеләр үз М.б.у.н тота алмыйлар. Демографик кризис та дәвам итә, шул сәбәпле М.б.у.нең саны кими. Аларны саклап калу өчен, барлык ведомство М.б.у. җирле бюджет балансына күчерелә. 1992 гә 53% ы ведомство учреждениесе булса, 2003 кә алар 2,4% кына кала. 2003 нең башына ТРда 1611 М.б.у. эшли, аларда 147 мең бала тәрбияләнә (67% мәктәпкәчә яшьтәге бала).

Совет хакимияте елларында М.б.у. өчен пед. кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирелә. 1919 дан Казанда М.б.у. хезмәткәрләрен әзерләүче курслар эшли, 1925 тән аларның җитәкче һәм тәрбиячеләренең белемен күтәрү Татарстан укытучыларның квалификациясен күтәрү ин-тында алып барыла (хәзер Мәгарифне үстерү ин-ты). 1927 дән М.б.у. тәрбиячеләрен урта пед. уку йортларында әзерлиләр. М.б.у. эшчәнлеге б-н җитәкчелек итү өчен 1932 дән респ-ка, өлкә халык мәгарифе органнарында тиешле бүлекләр булдырыла, җирле халык мәгарифе органнарында мәктәпкәчә тәрбия буенча инспектор һәм методист вазифалары кертелә. Аларның эшчәнлеге М.б.у.нең тәрбия һәм белем бирү ролен күтәрүгә юнәлтелгән була. 2003 нең башына ТРда 93% М.б.у. аттестация һәм дәүләт аккредитациясен үтә, шуларның 42% ына беренче яисә икенче категория бирелә, аларның белем бирү программаларының дәрәҗәсе шул типтагы дәүләт стандартларыннан югары була. Балаларны ана телләрендә тәрбияләү һәм белем бирү үсеш ала. 1996 да ТРда 896 татар М.б.у. эшли, 593 рус телле М.б.у.ндә 796 татар, 53 чуаш, 16 удмурт, 11 мари төркеме була. 2003 тә М.б.у.ндә 67,3% татар баласы исәпләнә. 2012дә 1930 М.б.у.ндә 188 мең бала тәрбияләнә.

*Әд.:* Якубовская М. Из прошлого детских садов г.Казани // Вестн. просвещения. 1923. № 9/10; Колосовская З.М. Двадцатипятилетие детских садов Татарской АССР // Дошкольное воспитание. 1945. № 8/9; Корнеева М.С. Из истории развития общественного дошкольного воспитания в Татарской АССР (1917–1941 гг.) // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1958. Т. 13.

*Е.В.Липаков.*

**МӘКЧӘ́**, мәк үләне (Glaucium), мәк чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре бар: мөгезле М. (G. corniculatum) Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Басуларда, ачык сөзәклекләрдә, юл буйларында үсә. 15–40 *см* биеклектәге берьеллык соргылт-яшел үсемлек. Яфраклары күгелҗем, каурыйсыман теленмә, озынча тар өлешле. Чәчәкләре берле, эре, ботак очларында һәм яфрак куентыларында урнашкан, төбендә кара тимгелле. Җимеше — ачылучан ике капкачлы, күп орлыклы, туры яки аз гына бөгелгән кузаксыман тартмачык. Тамырларында сөтчел сыекча бар. Май–июньдә чәчәк ата, җимешләре июньнән көзгә кадәр өлгерә. Декоратив үсемлек.

**МӘЛӘВЕ́З РАЙОНЫ́**, *Башкортстан Республикасының* көньягында урнашкан. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 3254 *км²*. Үзәге — Мәләвез шәһәре (Уфадан 205 *км* көньяктарак). Халкы — 86557, ш.и. Мәләвездә 60475 кеше яши (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 7118, 1979 да — 9232, 1989 да — 12492, 2002 дә — 12624, 2010 да — 13019 кеше. Районда 94 торак пункт, ш.и. 8 башкорт-татар, 2 башкорт-рус-татар, 1 татар-рус-чуаш авылы исәпләнә. Иң борынгы торак пункт — шәһәр тибындагы Җергән посёлогы (1771 дә нигез салына), монда төрле милләт халкы б-н бергә татарлар да яши. 2 мәктәптә (Мәләвез ш. һәм Җергән штп) татар теле фән буларак укытыла (2007).

**МӘЛӘКӘ́С** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чаллы елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 21,4 *км*, бассейнының мәйданы 152,1 *км²*. Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Җирекле авылы янында, тамагы Чаллы шәһәре эчендә. Елганың түбән агымы Түбән Кама сусаклагычы суы астында калган. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. М.нең 1 дән алып 12,5 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Алар арасында иң зурысы — Куады елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,44 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу вакытында су катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. М. бассейнында суның гомуми күләме 2,9 млн. *м³* булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘЛӘКӘ́С** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаллы — Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 903 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710–11 дән Сендюкова Пустошь исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Вознесение чиркәве, «министрлык мәктәбе», 2 су һәм 2 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2559,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 931, 1897 дә — 1529, 1913 тә — 1859, 1920 дә — 1855, 1926 да — 1162, 1938 дә — 1013, 1949 да — 821, 1958 дә — 686, 1970 тә — 763, 1979 да — 627, 1989 да — 845, 2002 дә — 808 кеше.

**МӘЛӘКӘ́С БАТЫНКЫЛЫГЫ́**, Татар, Токмов һәм Жигули-Пугачёв гөмбәзләре арасында урнашкан тектоник структура. Үлчәме 200×250 *км*, төрле горизонтлар буенча амплитудасы 300–600 *м*. М.б. чикләрендә кристаллик нигез түбәсе буенча күмелгән Серноводск-Абдуллино рифей авлакогенының көнбатыш өлешен һәм Әлки-Пичкас убылмасын билгелиләр. Авлакоген зонасында нигез 3000–3500 *м* һәм аннан да зуррак тирәнлектә ята.

М.б.ның борт өлешләре баскычсыман төшә торган (тирәндәге җимерелүләр буенча) һәм локаль чыгынтылардан тора, төньяк-көнбатыштагы төшеп торган участок башка рифей утырмалары б-н тулган. М.б. югары горизонтларда (терригенлы девон түбәсе буенча) сөзәкләнә. Аның төзелеше карбонның турней ярусы өслеге буенча *Кама-Кинель бөгелешләр системасы* һәм аның бортындагы риф комплекслары йогынтысында катлаулана. М.б. чикләрендә югары карбон һәм түбән Пермь түбәсе буенча геологик киселештән өскә таба 3 тектоник элементны аералар — структур баскычсыман зоналар, валлар һәм локаль күтәрелешләр б-н катлауланган көнчыгыш һәм көнбатыш бортлар, үзәк өлеш. Төшеп торган үзәк зона дүртенчел чорда көнбатышка таба Идел елгасының хәзерге үзәненә күчә.

М.б.ның көнчыгыш бортында, нигездә девон һәм сирәк кенә ташкүмер утырмаларында, уннарча нефть чыганагы табылган (иң эреләре — Нурлат һәм Енорускино). Өстәрәк ятучы утырмаларда күпсанлы руда булмаган файдалы казылмалар билгеләнгән: гипс, мәрмәр оникс, битумнар, бентонит, кирпеч һәм керамзит балчыклары, известьташлар, доломит, күмер һ.б.

*Әд.:* Геология Татарстана. М., 2003.

*Н.С.Исхакова.*

**МӘЛӘКӘ́С РАЙОНЫ́**, *Ульянов өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 3472 *км²*. 1928 елда оештырыла. Үзәге — Димитровград шәһәре (1972 гә кадәр — Мәләкәс, Ульянов шәһәреннән 80 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 36202 кеше (2012). 2002 елгы халык исәбе буенча, 13,3 мең татар. Татарлар, башлыча, Димитровград шәһәрендә (6,8 мең кеше), Яңа Аллагол, Парау, Мукшы Күле, Филипповка, Сабакай, Мөси авылларында яшиләр. 1917 гә кадәр Мәләкәстә мәчет (1896 да төзелә, 1992 дә яңадан ачыла) эшли, 1918 дә — татар телендә «Мәләкәс тавышы», 1923–25 тә «Яңа авыл» г-тасы нәшер ителә. М.р.да комп., ТАССРның халык артисты, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ф.К.*Туишев*, Дан ор-

денының тулы кавалеры А.В.Вильданов, әдәбият белгече И.З.Нуруллин, шагыйрь Г.Ш.Сәгыйров туган.

**«МӘЛӘКӘ́С ТАВЫШЫ́»**, газета, к. *«Урак-чукеч»*.

**МӘЛӘНЧЕ́К**, керәшен татарларда хатын-кызларның өйдә сугылган киндердән яки сатып алынган ситсыдан тегелгән чәч япмасы, традицион баш киеме комплексының 20 йөз башына кадәр тотрыклы кулланылган мәҗбүри элементы. *Маңгай тәңкәсеннән* аермалы буларак, М. каен тузыннан яки юка тактадан (калак) ясалган маңгай бәйләвече б-н бергә тегелгән; калакның формасы төрле төбәкләрдә төрлечә булган: Кама алдының көнбатышында — озынча турыпочмаклык, Кама аръягының көнчыгышында — тояк, Казан губернасының Чистай өязе керәшен хатын-кызларында квадрат рәвешендәге калаклар кулланылган. Гадәти көннәрдә М.не яулык астыннан, бәйрәмнәрдә күп катламлы баш киеме *сурәкә* б-н бергә кигәннәр.

*Әд.:* к. *Маңгай тәңкәсе.*

*Ф.Ф.Гулова.*

**МӘЛБАГЫ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 6,6 *км*, бассейнының мәйданы 40,9 *км²*. Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы шәһәр тибындагы Актүбә посёлогыннан 2 *км* төньяктарак, тамагы Мәлбагыш авылында. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагынықы — 160 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. М.ның 2,2 һәм 3,8 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,095 *м³*/с. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**МӘЛБАГЫ́Ш** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 544 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният сарае, китапханә. Мәчет. 18 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Яке исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 2 су тегермәне була; сишәмбе саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2028 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССР ның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 622, 1889 да — 1200, 1910 да — 1649, 1920 дә — 1672, 1926 да — 1683, 1938 дә — 1204, 1949 да — 868, 1958 дә — 861, 1970 тә — 855, 1979 да — 746, 1989 да — 594, 2002 дә — 582 кеше.

**МӘЛЕ́М** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Урман Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,5 *км*, бассейнының мәйданы 96,5 *км²*. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Мәлем авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Мәлем авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 222 *м*, тамагынықы — 84 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. М.нең 0,8 дән алып 10,3 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Алар арасында иң зурысы — Баса инеше. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км²*. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 96 *мм*, ташу вакытында су катламы 73 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,076 *м³/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**МӘЛЕ́М** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 34 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мәлем елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровское исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чана, агач савыт-саба, тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 Покров чиркәве (1735 һәм 1893–97 дә төзелә), земство мәктәбе, су тегермәне, әвен була; сишәмбе көннәрендә — базар, 1–4 октябрьдә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1312 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 331, 1870 тә — 489, 1913 тә — 694, 1920 дә — 698, 1926 да — 475, 1938 дә — 497, 1958 дә — 344, 1970 тә — 367, 1979 да — 243, 1989 да — 145, 2002 дә — 119 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**МӘЛКИ́** (Кырбаш) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 31 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ырым елгасы буенда. 2010 елда 567 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә Чудотворец чиркәве, Халык мәгарифе министрлыгы һәм башлангыч мәктәпләр, 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1011,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Иске Тәрбит волостенда, 1920 дән Чуаш автономияле өлкәсенә керә. 1921 дән ТАССРның — Буа, 1922 дән Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 353, 1897 дә — 656, 1908 дә — 789, 1920 дә — 889, 1926 да — 870, 1938 дә — 1015, 1949 да — 641, 1958 дә — 599, 1970 тә — 873, 1979 да — 817, 1989 да — 648, 2002 дә — 609 кеше.

**МӘЛЛӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 71,66 *км*, бассейнының мәйданы 1018,1 *км²*. Елга башы Азнакай р-ны Мәлбагыш авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, берникадәр өлеше Сарман р-ны терр-ясенә керә, тамагы Мөслим р-ны Мәлләтамак авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагынықы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. М.нең 0,6–19,1 *км* озынлыктагы 29 кушылдыгы бар; алар арасында аеруча зурлары: Нөгеш (7,7 *км*), Буралы (9,8 *км*), Карамалы (13 *км*), Рангазар



Мәллә елгасының түбән агымы.

(11,6 *км*), Кәүҗияк (19,1 *км*) — сул; Кәкре елга (14,9 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,1 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә (өчтән ике өлеше). Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга режимын күзәтү Мөслим р-ны Михайловка авылы янындагы гидрологик постта алып барыла (1962 дән). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга өсте тигезлегенең уртача еллык тирбәнешләре 2,5 *м*. М. ноябрь уртасында туңа. Кыш ахырында бозның калынлыгы 98 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,055 *м³/с* . Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. М. бассейнында суның гомуми күләме 11,7 млн. *м³* булган 9 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘЛЛӘТАМА́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 8 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 579 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та волость идарәсе, 2 мәчет, 3 мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 әвен эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3938,38 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирехтин волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 609, 1897 дә — 796, 1913 тә — 1128, 1920 дә — 1184, 1926 да — 854, 1938 дә — 1325, 1949 да — 963, 1958 дә — 832, 1970 тә — 865, 1979 да — 734, 1989 да — 667, 2002 дә — 602 кеше. М. янында *Мәлләтамак комплексы* урнашкан.

**МӘЛЛӘТАМА́К КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Мөслим р-ны Мәлләтамак авылы янында урнашкан. 1971 елда П.Н.Старостин, 1970–80 елларда Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан тикшерелә. Таш, бронза гасырлар торулыкларын һәм каберлекләрен, Пьянобор, Кушнаренко, Чиялек, Болгар һ.б. археол. культуралар авыллыкларын һәм каберлекләрен үз эченә ала (барлыгы 25 ядкәр). Мәлләтамак III каберлегендә 6 кабер тикшерелә, аларда чакматаштан эшләнгән хезмәт кораллары очрый. V каберлектә төрле археол. культураларга нисбәтле каберләр өйрәнелә, таш гасырга караган 15 кабердә күп күләмдә чакматаштан ясалган ук һәм сөңге очлыклары, хәнҗәрләр, чакматаш беркетелгән сөяк эш кораллары, сланецтан эшләнгән аркылы балталар, кабырчыклы муенсалар һ.б. табыла. Алар янында янган агач багана калдыклары сакланган 4 корбан чалу чокыры ачыла. Неолит һәм энеолит чорлары туктаулыкларында балчык савыт-саба ватыклары һ.б. табыла. Постпетрогром һәм Чиялек археол. культуралары торулыклары урынында учак калдыклары, балчык савыт-саба ватыклары, таш түшәлгән дини йолалар мәйданчыгы һ.б. тикшерелә. Алтын Урда чоры болгар авыллыкларында йорт калдыклары, һөнәрче түгәрәгендә һәм әвәләп эшләнгән савыт-саба ватыклары, тимер җитештерү эзләре, кара һәм төсле металлдан эшләнгән әйберләр теркәлә. М.к. терр-ясендә Урта Идел төбәгендә мөгездән ясалган һәм кремний кисәкләре беркетелгән, урак рәвешендәге иң борынгы хезмәт кораллары табыла.



Мәлләтамак комплексы. V каберлек. Пыяла кубок. ТР ФА Тарих институтының Археологик тикшеренүләр милли үзәге.



Мәлләтамак комплексы. V каберлек.
1. Чакматаштан эшләнгән табылдыклар; 2. Сөяк кашык һәм мөгездән эшләнгән хезмәт кораллары кисәкләре. ТР ФА Тарих институты фондлары.

*Әд.:* Казаков Е.П. Работы в Татарии // Археологические открытия 1975 года. М., 1976; Шулук. Памятники меллятамакского типа на востоке Татарстана // Контактные зоны Евразии на рубеже эпох. Самара, 2003; Старостин П.Н.Первый меллятамакский могильник // Древности Икско-Бельского междуречья. К., 1978; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989.

*Е.П.Казаков.*

**«МӘЛХӘМӘ»** (гарәп. ملحمة), шигъри формада юрау китабы. «М.»нең эчтәлегеннән чыгып караганда, аның авторы Искәндәрпаша исемле кеше булырга тиеш. Китапта һәр айга карата 14–25 юрау, төрле табигать күренешләрен, аларның җәмгыять тормышына ясалган тәэсирләрен (ачлык, сугыш һ.б.) тасвирлау урын ала. Татарлар арасында 16 йөзнең 1 нче яртысыннан кульязма рәвешендә тарала башлый. Казанда беренче тапкыр 1891 елда басыла.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Татар кульязма китабы. К., 2000. *М.И.Әхмәтҗанов.*

**МӘМӘ́Й** посёлогы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 184, 1958 дә — 102, 1970 тә — 70, 1979 да — 39, 2002 дә — 1 кеше.

**МӘМӘКТА́Й бине ҖӘГЪФӘ́Р** (? — 10 йөз уртасы), болгар идарәчесе. *Алмыш* илтәбәр улы дип фаразлана. Болгар акчалары (921/22) буенча мәгълүм.

**МӘМӘ́Т** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чупай елгасы буенда. 2010 елда 722 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 чирегендә Яшел Үзән р-нының Олы һәм Кече Шырдан авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында халкы типтәрләр, дәүләт крәстияннәре катлавына керә, бер өлеше (элеккеге йомышлы татарлар) лашманчы хезмәтен үти. Игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сәүдә, сандык ясау б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында М.тә 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2076 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варварино (1918 дән — Кичү) волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 67, 1762 дә — 78, 1782 дә — 99, 1811 дә — 154 ир-ат; 1834 тә — 375, 1859 да — 770, 1889 да — 983, 1910 да — 1460, 1920 дә — 1579, 1926 да — 1294, 1938 дә — 1416, 1949 да — 1161, 1958 дә — 933, 1970 тә — 996, 1979 да — 851, 1989 да — 702, 2002 дә — 753 кеше.

**МӘМӘ́Т** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бырыс елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына, 1557 дән соң — рус авылы. Рус чыганакларында беренче исеме — Икимень (Искимень). 18 йөз башыннан хәзерге исемен йөртә. 17–19 йөзләрдә М. крәстияннәре бер үк вакытта берничә дворян нәселенә карый, алар арасында атаклы химик А.М.*Бутлеровның* ата-бабалары да була. Алар игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.тә җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 344,05 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 208, 1782 дә — 233 ир-ат, 1859 да — 139, 1897 дә — 212, 1908 дә — 231, 1920 дә — 157, 1926 да — 180, 1938 дә — 186, 1949 да — 182, 1958 дә — 102, 1970 тә — 94, 1979 да — 38, 1989 да — 17, 2002 дә — 1 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**МӘМӘТКУ́ЗИННАР-САКА́ЕВЛАР** (Мәмәтхуҗиннар-Сакаевлар), татар бәкләре нәселе. Морза Сакаевлар б-н кардәшләр. Нәсел

башында 1561 елның 7 мартында Иван Грозный тарафыннан патша сараеның Мещера өязе Мукша аръягы станындагы Будаево һәм Кучюсово авыллары бүләк итеп бирелгән Атказ (Атназ) Җофарбирде улы Мәмәткузин тора. Атказ Мәмәткузинның улы — Дусай, Дусайның уллары — Адарали һәм Ураз Мәмәткузиннар. Ураз 1688 нең сентябрендә Кадом һәм Керенский өязләрендәге кайбер биләмәләрен туганы Адарали уллары Сәфәр б-н Чернакайга тапшыра. Документларда Сәфәр һәм Чернакай Адаралиевлар — морзалар, ә Ураз Мәмәткузин кенәз дип теркәлгән. 1773 тә морза М.-С. Бәләбәй өязенең Абзан авылына (хәзер Башкортстан Респ-касының Благовар р-нына керә) барып урнашалар. М.-С. нәселенә дворянлык дәрәҗәсе Сенат фәрманы б-н 1796 ның 1 декабрендә бирелә. 1678 елгы халык санын алу мәгълүматларында морза-бәк Чапкын, Келәш, Котлымәмәт М.-С.ның Темников өязе Тенсюпино авылында 14 крәстиян утары тотулары теркәлгән. Керенский өяздә яшәүче М.-С. Пенза губернасы дворяннар шәҗәрәсе китабының 2 нче кисәгенә кертелә. Тенсюпино авылында әле дә М.-С. фамилиясен йөртүчеләр яши.

*Әд.:* Списки дворянских родов, внесённых в родословную книгу Пензенской губернии. Пенза, 1908; Дворянские роды Российской империи. М., 1996. Т. 3; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МӘМӘ́ТОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Касыйм татарларыннан. Нәсел башында Кадом морзасы Елизарий Мәмәт бәк улы Акмәмәтов тора. Рус дәүләтенә хезмәткә 16 йөз уртасында күчәләр. 1686 елда морза Биктимер Мәмәт улы Елизарьев искә алына. 18 йөз башында морза М. Кадом өязе Торопово авылында яшиләр, 18 йөз ахырында крепостной крәстияннәре б-н бергә Бәләбәй өязенең Бүздәк авылына күченәләр. 19 йөзнең 2 нче яртысында Мәмәтовлар нәселенең Уфа тармагы дворян катлавына кертелә.

*Әд.:* Новиков В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Каратеев М.Д. Княжеские роды // Арабески истории. М., 1994. Кн. 1.; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МӘМӘШИ́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 32 *км* төньяктарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 792 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1827,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1873 тә — 902, 1884 тә — 1231, 1905 тә — 1650, 1920 дә — 1818, 1926 да — 1627, 1938 дә — 1729, 1949 да — 1200, 1958 дә — 1237, 1970 тә — 1100, 1979 да — 1067, 1989 да — 860, 2002 дә — 872 кеше.

**МӘМДӘ́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 31 *км* төньяк-көнбатыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 508 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1602–03 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, тегү, тимерчелек, йон-тукыма ману, йон тетү, арба һәм көпчәк ясау, итек тегү, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә 2 мәчет, мәдрәсә, мәктәп, фельдшерлык пункты, 3 җил тегермәне, тимерчелек, 2 шырпы ясау остаханәсе, 10 вак-төякләр кибете була; сишәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2522,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 275 ир-ат; 1859 да — 1114, 1897 дә — 1199, 1908 дә — 1435, 1920 дә — 1356, 1926 да — 1589, 1938 дә — 1188, 1949 да — 1016, 1958 дә — 861, 1970 тә — 813, 1989 да — 528, 2002 дә — 505 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**МӘМИ́** (Олы күл), күл, Идел алдында, элеккеге су юлында сакланып калган. Зөя елгасының сулъяк тугаенда, Кайбыч р-ны Кече Мәми авылыннан 1 *км* төньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 10,16 *га*. Озынлыгы 1610 *м*, иң зур киңлеге 110 *м*. Формасы озынча. Ярлары сөзәк.

**МӘМИ́** елгасы, Идел алдында, Коры Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 14 *км*, бассейнының мәйданы 139,8 *км*². Елга башы Югары Ослан р-ны Олы Мәми авылыннан 4 *км* төньяктарак, тамагы Кама Тамагы р-ны Иске Барыш авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 66 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. М.нең 1,4 тән алып 13,1 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар, алар арасында иң зурысы — Мәми инеше (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 120 *мм*, ташу вакытында су катламы 108 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**МӘМИ́** инеше, Идел алдында, Мәми елгасының (Коры Үләмә, Зөя елгалары бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,1 *км*, бассейнының мәйданы 34,1 *км*². Югары Ослан р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Олы Мәми авылыннан 5 *км* төньяктарак, тамагы Канаш авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. М.нең 2,3 һәм 4,3 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,62 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н суену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 72 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**МӘМЛИ́ КАЗА́К ЧАЛЛЫСЫ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, Балык Бистәсе посёлогыннан 46 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 231 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1652 дән Яңа Мәзлә авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 520,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 410, 1897 дә — 656, 1908 дә — 819, 1920 дә — 819, 1926 да — 702, 1938 дә — 1077, 1949 да — 530, 1958 дә — 454, 1970 тә — 524, 1989 да — 268, 2002 дә — 257 кеше.

**МӘМСӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 35 *км* төньяктарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 371 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Байчура Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1878–79 да М. крәстияннәр кузгалышы үзәкләренең (к. *Татар крәстияннәре кузгалышлары*) берсе була. 20 йөз башында 4 мәчет, 5 җил тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 3 зур һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Шинер-Кинер авылын да кертеп) 4122,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 авгус-

тыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да 1503, 1897 дә — 2030, 1908 дә — 2428, 1920 дә — 2228, 1926 да — 1027, 1938 дә — 928, 1949 да — 534, 1958 дә — 511, 1970 тә — 557, 1979 да — 467, 1989 да — 347, 2002 дә — 368 кеше.

**МӘМСӘВИ́** Ихсан Гомәр углы (1821, Казан губ., Казан өязе Мәмсә а. дип фаразлана — 1871), дин эшлеклесе, шагыйрь. Гарәп һәм татар телләрендә язган. 1845 елдан Нократ губернасы Бөрбаш авылы мәчете имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе булып тора. Ш.*Мәрҗани* дини-фәлсәфи карашлары тарафдары. 1868 дә «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»ның 1 нче том кушымтасында Ш.Мәрҗани әсәрләренә карата шигъри комментарийлар бастыра. Танылган замандашларына мәдхияләр һәм элегияләр багышлый.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Ф ә х р е т д и н Р. Асар: Кыскача конспект-аннотация. К., 2003. *А.М.Ахунов.*

**МӘНӘВЕ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Эстәрле елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*, бассейнының мәйданы 57,7 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Мәнәвез авылыннан 3,6 *км* көнбатыштарак, тамагы Азнакай шәһәренең көнчыгыш читендә. Елга башының абс. биеклеге 280 *м*, тамагыныкы — 130 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. М.нең 0,7 һәм 1,7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә аз гына күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 05–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *м*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,083 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада суның гомуми күләме 0,008 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘНӘВЕ́З** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Эстәрле елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,6 *км*, бассейнының мәйданы 54,8 *км*². Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Әгерҗе авылыннан 6 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Туйкә авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 150 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. М.нең 1 дән алып 5,2 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан аз гына артыграгы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,085 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. М. бассейнында суның гомуми күләме 1,8 млн. *м³* булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘНӘВЕ́З** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 5 *км* көнбатыштарак, Сыза елгасы буенда. 2010 елда 641 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; нефть-газ чыгару. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1927 дә Азнакайдан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Азнакай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 369, 1949 да — 359, 1958 дә — 353, 1970 тә — 337, 1979 да — 339, 1989 да — 310, 2002 дә — 474 кеше.

**МӘНГУ́ ТИМЕ́Р ХАН** (? — 1282), Алтын Урда ханы (1266 дан). *Батый хан* оныгы. Бәркә хан вафатыннан соң (1266) Алтын Урдада хакимиятне үз кулына төшерә. Бәркә сәясәтен дәвам иттерә; Алтын Урданың бөек монгол каганыннан бәйсезлеген ныгыту өчен көрәшә. М.Т.х. заманында Җүчиләр нәселе тамгасы б-н акча суга башлыйлар. Аның тарафыннан бөек монгол каганы рөхсәтеннән башка бирелгән ярлыклар (Ярослав Ярославичка бөек кенәзлек итүгә (1266), Генуя сәүдәгәрләренә Кафа шәһәрендә (Кырым) колония оештыру хокукын раслау, рус руханиларына өстенлекләр бирелүне тану (1267) һ.б.) сакланган. Урда эчендә хакимиятне ныгыту нәтиҗәсендә М.Т.х. актив тышкы сәясәт алып бару мөмкинлегенә ирешә. 1268–69 да ул Урта Азиядәге үзара низагларга катнаша, Баракъ ханга каршы чыга, Хайду ханга бөек каган тәхете өчен Хубилайга каршы көрәшенә ярдәм итә. Талас елгасы буенда корылтай уздыра (1269), анда Җүчи, Һулагу һәм Чагатай олысларының бөек каган хакимиятеннән бәйсезлеге законлаштырыла. М.Т.х.ның Нугай җитәкчелегендәге гаскәрләре рус отрядлары б-н бергә Литваның көнчыгыш өлешен (1274–75), Сандомирның тирә-ягын (1280) бөлдерәләр. М.Т.х. заманында Идел буенда, бигрәк тә мөһим икътисади һәм сәяси үзәккә әверелгән Сарай әл-Мәхрусәдә шәһәр төзелеше алга китә. 1280 елларда М.Т.х. хакимияте какшый башлый, аксөякләр арасында аерымлану омтылышлары көчәя, ярымбәйсез олыслар күбәя. Тамагында эренле шеш ачылудан вафат була.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983. *И.Л.Измайлов.*

**МӘНДӘ́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 43 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 193 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дүсем исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, әвен эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1432,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 317, 1897 дә — 581, 1913 тә — 768, 1920 дә — 740, 1926 да — 523, 1938 дә — 605, 1949 да — 499, 1958 дә — 441, 1970 тә — 508, 1989 да — 177, 2002 дә — 217 кеше.

**МӘНДИ́ КОТЫ́Ш** (тулы исеме Мәнди бине Котыш бине Туеш бине Тәганаш) (1761, хәзер Башкортстан Респ-касы Көергәзе р-ны Кинҗәбай а. дип фаразлана — 9.4.1849, шунда ук), шагыйрь, хаттат. Гарәп һәм татар телләрендә язган. Берничә мәдрәсәдә, ш.и. Казанда белем ала. Мал асрау, кымыз ясау б-н шөгыльләнә. Нәкышбәндийә суфичылык тәрикате тарафдары. Суфи эчтәлекле тезмә һәм чәчмә формада язылган дини-дидактик трактатлар (кульязма рәвешендә) авторы. Танылган әсәре — «Вакты сәхәр...». *Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘНЗУМӘ́** (гарәп. منظومة— тәртипкә кителгән сөйләм; тезмә дастан), гарәп, фарсы һәм төрки-татар поэзиясендә — поэтик әсәр, поэма, эпик яки лироэпик әсәр. Шигъри җыентыкларны да «мәнзумә» дигән күпчелек формасы б-н атыйлар. Хәзерге фарсы әдәбиятында балладаны М. диләр. Татар әдәбиятында бу атама беренче тапкыр «Китабе Гөлстан бит-төрки»дә искә алына. Әсәрдәге 5 хикәятне автор «хикаяте мәнзумә» дип атый. *Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘННӘ́Н** Ринат (чын исеме Архипов Ринат Николаевич) (6.2.1946, Чистай ш.), шагыйрь. Татар һәм рус телләрендә яза. Казан мед. ин-тын тәмамлый (1974). 1978 елдан Казанда, табиб булып эшли. Беренче китаплары 1998 дә басыла башлый. Күбесенчә пародияләр, сатирик-юмористик шигырьләр яза («Үртәмешләр», 2009; «Очрашу», 2010). Балалар өчен ике дистәгә якын китап иҗат итә, алар арасында: «Табиб әлифбасы» (2001), «Каян килә туңдырма?» (2003), «Микроб» (2005), «Армиягә барабыз» (2009), «Шүрәле әлифбасы» (2011) һ.б. «Яңарыш хәбәрчесе» (2009) китабы Г.Исхакыйга багышланган.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МӘҢГӘ́Р** Әхмәтвәли Ибраһим улы (8.12.1891, Петропавловск ш., хәзер Казакъстан Респ-касы — 10.10.1978, Истанбул ш.), эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, нашир. Петропавловскида мәдрәсә тәмамлый, агасы кибетендә өйрәнчек була. 1911 елда Монголиягә бара, анда немецларның «Штукен» фирмасы б-н бергә Россия һәм Кытай б-н йөн сәүдәсе

үзәкләре оештыруда катнаша. 1925 тән Тяньцзинь шәһәрендә (Кытай) сәүдә б-н шөгыльләнә (Кытайда аның 40 сәүдә үзәге була). Төрек-татар җәмгыяте оештыра һәм аның б-н җитәкчелек итә (1925). М. акчасына мәктәп төзелә. *Мукден конгрессында* (1935) рәис булып сайлана. Аның хисабына «Милли байрак» г-тасы нәшер ителә, анда М.нең Кытайдагы, Япониядәге һәм Кореядәге татарлар проблемаларына багышланган мәкаләләре басыла. 1939 дан Истанбулда яши. Швейцариянең «Ульрих Мейер» фирмасы б-н хезмәттәшлек итә, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң немецларның Төркиядәге «Мерседес-Бенц» һәм «Роберт Бош» автомобиль фирмалары вәкиллекләрен җитәкли. Төрек автомобиль сәнәгатен нигезләүчеләрнең берсе (Истанбулдагы автомобиль сәүдә фирмасына аның исеме бирелә). 1950 елларда «культура революциясе» җәелгән Кытайдан качкан татарларга ярдәм күрсәтә: Төркиядә аларны торак һәм эш б-н тәэмин итү өчен зур күләмдә акча бирә (Силибри шәһәре янында алар өчен ферма сатып ала). 1970–80 елларда М. акчасына *«Казан»* ж-лы нәшер ителә. Татар халкының 20 йөз башындагы күренекле эшлеклеләре турында мәкаләләр авторы. М. хисабына татар яшьләренең Истанбулдагы, Әнкарадагы мәдәни оешмалары өчен биналар арендага алына, фәнни-популяр һәм дини китаплар бастырыла. Үзенең гаять бай китапханәсен Төркия тарихын өйрәнү ин-тына (Әнкара) бүләк итә. Төркия һәм Татарстан арасында багланышлар булдыру өчен мәдәни-хәйрия фондын оештыруга омтылыш ясый. 1995 тә кызы Сафия Имре Истанбулда М. исемендәге фондны нигезли.

*Әд.:* Әхмәтвәли Мәңгәр: Хатирәләр. К., 1997; Татарстан-Төркия: Мәдәни багланышлар. 1992–2003. К., 2004; Татарский век глазами национальной элиты: 100 выдающихся татар. К., 2005.


*И.Н.Надыйров.*

**МӘҢГӘРИ́ ШАҺИӘХМӘ́Т**, к. *Шаһиәхмәт бине Мөхәммәт әл-Мәңгәри.*

**МӘРДИ́ЕВ** Хуҗи Шәймәрдан улы (25.2.1895, Уфа губ., Минзәлә өязе Бикләнә а. — 1.2.1978, Тукай р-ны Бакчасарай а.), колхоз җитештерүен оештыручы. 1920 елдан Бикләнә авылы крәстияне. 1927–31 дә мелиорация ширкәте (аңа Бикләнәнең 12, соңрак барлык крәстиян хуҗалыгы керә) рәисе, бер үк вакытта Бөтенсоюз трактор төзелеше өчен акча җыю хәрәкәте кысаларында бу эшне авылда җитәкли. 1931–41 дә «Бакчасарай» к-зы рәисе (бүленеп), 1941–58 дә Чаллы р-ның Молотов исем. (1957 дән Чкалов исем.) к-зы рәисе. Бөек Ватан сугышы елларында оборона фондына акча җыюны оештыра. М. җитәкчелегендә хуҗалыкның матди-техник базасы ныгытыла. 1954 тә хуҗалык респ-када беренчеләрдән булып 1 млн. сумнан артыкка продукция сата. 1958 дә тулай керем 2,28 млн. сум тәшкил итә. Беренче бөтендөнья (1914–18), Гражданнар (1918–20), совет-фин (1939–40) сугышларында катнаша. 1946–54 тә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Заслуженные люди Тукаевского района. Наб.Челны, 2003. *Б.А.Канеев.*

**МӘРДИХА́НОВ** Рәшит Мәрдихан улы (8.4.1930, Минзәлә р-ны Чулпан а. — 16.12.1996, Минзәлә ш.), драма актёры, ТР-ның халык артисты (1991). 1951–90 елларда Минзәлә татар драма театры актёры. Проф. белеме булмаса да, героен нечкә тоемлап, аның рухи халәтен бөтен нечкәлекләре б-н төгәл җиткерә алу сәләтенә ия була; ул тудырган образлар психологик бөтенлек, сәнгатьчә камиллек, тормышчанлык, әчкерсезлек һәм рухи бәйсезлекләре б-н аерылып торалар. 1957 дә Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәрендә М.ның Шәйхенур («Язылмаган законнар», Ю.Әминев) ролен башкаруы уңай бәяләнә. Ул уйнаган Җиһанша, Тимуш, Җантимер («Зәңгәр шәл», «Ил», К.Тинчурин), Балаш («Сәвил», Д.Җаббарлы), Гыйлемдар («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Тимербулат («Икәүдән-икәү»,




Р.М.Мәрдиханов Җантимер ролендә («Ил», К.Тинчурин).

Г.Ахунов), Гапсаттар («Гапсаттарның Кырымга сәяхәте», С.Шәкүров), Заһит («Хыянәт», Х.Вахит), Шатун («Гарасат», Г.Сабитов), Илшат, Зиннәт («Гөлчәчәк», Ю.Әминев), Андро («Андро һәм Сандро,» Г.Хугаев), партоешма секретаре («Платон Кречет», А.Корнейчук), Миронов («Мария», А.Салынский), Суиндон («Шайтан шәкерте», Б.Шоу) рольләре аеруча игътибарга лаек. М. иҗатында фикер ачыклыгы һәм төгәлле-



Р.М.Мәрдиханов Генерал ролендә («Сызылып таңнар атканда», Ә.Гаффар; сулда — Ф.Бәдриев).



Р.М.Мәрдиханов.



Ш.Мәрҗани.

ге нечкә сәнгати тоемлау һәм образның тирән психологик чишелеше б-н бергә үрелеп бара.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МӘРҖАНИ́** Шиһабетдин (13.1.1818, Казан губ., Казан өязе Ябынчы а. — 15.4.1889, Казан), илаһият галиме, тарихчы, мәгърифәтче. М.нең бабасы имам һәм мөдәррис була, әтисе Бохара мәдрәсәсендә укый, Казан өязенең Ябынчы һәм Ташкичү мәдрәсәләрендә мөдәррислек итә. Башлангыч белемне М. гаиләдә һәм Ташкичү мәдрәсәсендә ала. Мәдрәсәне тәмамлагач (1835), шунда укыта. 1838–49 елларда «Күгелдаш» һәм «Мир-Араб» (Бохара), «Ширдар» (Сәмәрканд) мәдрәсәләрендә укый; бер үк вакытта абруйлы илаһият галимнәреннән дәресләр ала; китапханәләрдә күренекле гарәп-мөселман фәне һәм әдәбияты вәкилләре: Ибне Сина (Әбүгалисина), *Ибне әл-Гарәби, Ибне Рөшд*, әс-Сүйүти, *әл-Газали* Әбү-Хәмид, әш-Шәхәстани, *Ибне Халдун* һ.б.ның хезмәтләрен өйрәнә. Берничә гыйльми әсәр, ш.и. әл-Кәтибинең мантыйк буенча «Әш-Шәмсийә» трактатының керешенә аңлатма (басылмый), мантыйк һәм фикъһ нигезләре буенча «Әт-тарикат әл-мөсла вә әл-гакидәт әл-хөсна» («Үрнәк ысул һәм иң камил иман», 1890) әсәренә шәрехләмә, Бохарада табигыять фәннәре укыту ысуллары турында «Әгъляме әбнаи-д-дәһр би әхвәли әһли Мавәраэннәһер» («Мавәраэннәһер әһелләренең хәле турында дәвер улларының белдерү хаты»; кулъязмасы сакланмаган) тәнкыйди хезмәтен яза. Борынгы тарихи кулъязмалар, документлар җыю һәм күчерү б-н шөгыльләнә, соңрак аларның бер өлеше М.нең хезмәтләрендә урын ала. Ихтимал, Сәмәркандтагы остазы казый Әбү Сәед карашлары йогынтысында, М.дә дини ислахчылык идеяләре туа. Бохарада ул исламдагы мистик-аскетик агым — *суфичылык* б-н таныша, Нәкышбәндийә борадәрлегенең өч шәех-остазының — Г. ибне Ниязколый, Ә. әл-Фарукый әл-Һинди, М. ибне Әхмәд әл-Һиндинең шәкерте була, рухани остазлык хокукы — иҗазәт алуга ирешә. Ватанына кайткач (1850), 1 нче Казан мәчетенә имам-хатип һәм мөдәррис итеп билгеләнә (Оренбург Диния нәзарәте мөфтие С.Тәфкилев һәм татар хәйриячесе — сәүдәгәр И.Юнысов б-н фикер каршылыклары булу сәбәпле, 1854 тә һәм 1874 тә бүленеп эшли). Бер үк вакытта, 1860 тан, М. *Корьәннең* Казан басмалары текстының тулылыгына һәм төгәллегенә күзәтчелек итә. Соңыннан, Россиядә Коръән бастыру тарихына багышланган «Фаваид әл-мөһиммә» («Файдалы һәм

мөһим») дигән китап чыгара. 1862 дә М. кандидатурасы мөфти вазифасына — Мөселманнарның Диния нәзарәте башлыгына тәкъдим ителә, ләкин Изге Синод обер-прокуроры К.П.Победоносцевның хуплавын тапмый.

1867–68 дә Казан ахуны һәм мөхтәсибе була. 1876–84 тә мөселман руханилары вәкилләреннән беренче буларак, *Казан татар укытучылар мәктәбендә* дин гыйлеме укыта. 1876 да Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* әгъзасы итеп сайлана. 1877 дә *Дүртенче археология съездында* татар галимнәреннән беренче булып Болгар һәм Казан тарихы буенча доклад ясый (1878 дә «Гилаләт аз-заман фи тарихи Болгар вә Казан — «Болгар һәм Казан тарихын каплап торучы заман пәрдәсе» исеме б-н басыла). М.нең фәнни хезмәтләре Казан ун-тында Көнчыгышны өйрәнүче галимнәр В.В.*Радлов*, И.Ф.*Готвальд*, Мирза Мөхәммәтгали, А.К.*Казимбәк* тарафыннан югары бәяләнә. 1880 дә М. Мәскәүгә, Мәккәгә сәфәр чыга, юл уңаеннан Киев, Одесса, Истанбул, Каһирә һ.б. шәһәрләрдә була, күренекле мөселман галимнәре һәм сәяси эшлеклеләр б-н очраша. М.нең шәкерте һәм аның эшен дәвам иттерүче Р.Фәхретдин 1897 дә аның «Рихләт әл-Мәрҗани» («Мәрҗанинең сәяхәте») исемле юлъязмаларын шәрехли һәм бастырып чыгара. Үзенең мәдрәсәсендә М. дәресләрне укучыларда мөстәкыйль фикер йөртү сәләтен үстерүне төп максат итеп куйган шәхси пед. концепциясе принциплары буенча алып бара.

Табигыять фәннәрен, рус телен татар мәктәпләре программаларына кертүне яклап чыгышлар ясый. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы җәдитчеләренең тулы бер буыны М.не бөек остаз буларак хөрмәтлиләр. Үзенең дини-фәлсәфи хезмәтләрендә һәм мәгърифәтчелек эшчәнлегендә ул *ислам* динен үзгәрүчән чынбарлыкка карата үзенчәлекле яраклаштырырга, татар халкының милли үзаңын формалаштырырга омтыла. М. шигыйләрнең дә шундый ук мөселман булуларын ассызыклап, татарларга кызларын иранлы шигыйләргә кияүгә бирергә рөхсәт итүче *фәтва* чыгара (Казан мөселманнары аларны диндәш итеп танымыйлар). Ул мөселман хокук белеме фикъһның кайбер кагыйдәләрен яңадан карап чыгарга кирәклеген әйтә. М.нең «*Нәзурат әл-хак фи фәдийәт әл-гашаи вә ин ләм йагаб әш-шафәкъ*» («Эңгер-меңгер төшүгә бәйсез рәвештә кичке намазның кирәклеге турында хакыйкатькә бер караш») исемле 1870 тә басылган полемик трактаты зур яңгыраш ала һәм авторга мөселман Шәрегында танылу китерә. М. фикеренчә, төньяк киңлекләрдә көн һәм төн озынлыгының үзгәреп торуы тәүлеккә биш вакыт намазның фарызлыгын кире кага алмый. Ул үзенең тезисын Коръән, хәдисләр, фикъһ һәм аеруча абруйлы мөселман голямаларының гамәлләре б-н нигезли. М., Г.*Курсави* кебек үк, һәр мөселман өчен «*иҗтиһад* капкаларының ачыклыгы» һәм исламны яңарту идеяләрендә (тәҗдид) нык тора. *Тәкълид* — традицияләргә иярү — бары тик Коръәнгә, *Сөннәгә* һәм абруйлы илаһият галимнәренә иярүне күз алдында тота дип саный. М. исламны бидгатьтән, соңгы яңалыклардан арындырырга, Коръәнгә, Сөннәгә һәм әүвәлге гадел остазларның (сәләфи) гамәлләренә әйләнеп кайтырга өнди. «Назурат әл-хак ...» хезмәте ислам *мәзһәбе* (дини-хокукый мәктәпләр) феномены турында тирәнтен фикерләүгә нигезләнә. Бер мәзһәбтән икенчесенә икенчел дәрәҗәдәге проблемалар буенча күчү мәсьәләсендә М. мондый күчешнең тыелмавына һәм иманны саклап калуда хәтта мәҗбүри булуына басым ясый. Ләкин, ислам диненең гомуми кагыйдәләре турында сүз барганда, ул катгый рәвештә хәнәфи мәзһәбе юлыннан барырга чакыра (к. *Хәнәфиләр*). Ислахчылык нәтиҗәсендә М. шикаятьләр һәм аноним мәкаләләрдә төрле хурлауларга, бәла ягуларга дучар була. Г. ән-Нәсави мулла «Нәзурат әл-хак...»ны кире кагып, «Мөзһир әл-кәлимәт әл-җаруда әл-ләти хийа фи-н-назура» («Назурадәге куркыныч сүзләрне фаш итү», 1874) исемле мәкаләсен яза. Моңа каршы галим «Хакк әл-мәгърифә вә хөсн әл-идрак» («Хакны тану һәм иң яхшы төшенү», 1880) һәм «Баркил-вәмид фи радд галәл-бәгыйзил-мөсәммә биннәкыйзи» («Тискәре исеме б-н аталган дошманнарның фикерләрен кире кагып яндыручы яшен», 1888) исемле яңа китаплар б-н җавап бирә. Үзенең догматик-илаһият һәм фикъһ мәсьәләләре буенча карашларын ш.у. «Хикмәт әл-балигат әл-җәннияти фи шәрх әл-гакаид әл-хәнәфияти» («Хәнәфиләрнең дини ышанулары турында өлгереп җиткән дөрес карашлар китабы», 1888) китабында бәян итә. Альтернатива сыйфатында бөтен мөселман дөньясына билгеле 14 йөз илаһият галиме әт-Тафтазаниның «Газб әл-фурат вәл-мәгез-золәл ән-нәкыйгли-әсрах-шәрхе әл-Җәләл» («Җәләл шәрехләвен ачыклауга карата бик нык эчәсе килгәндә сусауны басу өчен бирелгән саф һәм татлы су кебек дөрес фикерләр», 1875) исемле шәрехләвен тәкъдим итә. «Хизәмәт әл-хәвәши ли-идәхәт әл-гавәми» («Гаделлекне томалаучы пәрдәне алу өчен шәрехләүләр җыентыгы», 1889) китабында хәнәфи мәзһәбендәге фикъһ мәсьәләләре тикшерелә. М. дини спекуляциягә нигезләнгән *кәлям* гыйлеменә каршы чыга, илаһият галимнәренең кайбер фәлсәфи төшенчәләрне урынлы кулланмауларын күрсәтә, дини догмалар б-н филос. арасында катгый бүленеш барлыгын яклап чыга.

М. тарих фәнендә тирән эз калдыра. Шундый хезмәтләренең берсе, 10–12 йөз Урта Азия төрки халыклары тарихына багышланган «Гыйрфәт әл-хәвакин ли-ирфәт әл-хәвакин» («Хаканнарны танып белү турында аз-маз гыйлем», 1864) хезмәте. Ул мәшһүр мөселман эшлеклеләренең тормышын тасвирлаган «*Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф*» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре»; кулъязмада) исемле 6 томлы җыентык әзерли. Бу хезмәткә өстәп, М. Мөхәммәд пәйгамбәрнең биографиясен, башлангыч чор ислам тарихын, мөселман илаһияты фәненә күзәтүләр туплаган «Мөкаддимә китаб Вафийәт әл-әсляф вә тәхийәт әл-әхляф» («Элгәреләр һәм аларның киләчәк буынга сәламнәре» китабына кереш», 1883) китабын яза. М. анда, гарәп тарихчысы Ибне Халдунга ияреп, фәннәрне «гадәти» һәм «акыл б-н төшенә торган»га бүлеп төркемли. Әлеге хезмәтенең икенче томында М. ислам диненең Идел буе төбәгенә керүе тарихын, төбәктә ислам мәдәниятенә зур өлеш керткән аеруча күренекле мөселманнарның эшчәнлеген яктырта. 17 йөзнең 2 нче яртысыннан 19 йөзнең 3 нче чирегенә кадәрге чорны колачлаган алтынчы томда мәгърифәтче Россия дәүләте составындагы Идел буе мөселманнарының тарихын ача. Татар халкының рухи йөзен формалаштыруда әһәмиятле роль уйнаган мөселман зыялыларына аеруча зур игътибар бирелә, ә Пётр I, Наполеон кебек төрле сәяси фигураларның эшчәнлегенә бәя биргәндә, галим аларның ислам диненә мөнәсәбәтеннән һәм аның таралуыннан чыгып фикер йөртә. М.нең икенче тарихи хезмәте — «*Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар*» («Казан вә Болгар хәлләре турында файдалы хәбәрләр») әсәрендә гарәп, фарсы һәм төрки чыганаклардан алынган күп кенә династияләр һәм шәхесләр турында тарихи-биографик белешмәләр, эпиграфика һәм нумизматика мәгълүматлары, телдән әйтелгән хәбәрләр, халык әкиятләре тупланган. Анда беренче тапкыр татар халкы тарихына караган хезмәт иҗат итү омтылышы ясала. «Татар» этнонимының законлылыгын нигезләп, М. Идел болгарлары (Алтын Урда һәм Казан ханлыгы буыннары аша) һәм үз чорының Идел-Урал буе татарлары арасында тарихи варислык барлыгын раслый. Илаһият белеме хезмәтләрендә дә М. еш кына үзен тарихчы итеп таныта, кеше акылы ирекен, шәхеснең иҗади активлыгы хокукын һәм үз-үзен раслау мөмкинлеген яклап чыга. Һ.*Атласи* М.нең реформаторлык карашлары мәсьәләсендә аны христиан дине реформаторы М.Лютер б-н чагыштыра. М. Идел һәм Урал буе мөселман халыклары арасында җәдитчелек идеяләре үсешенә зур йогынты ясый.

*Әд.:* Мәрҗани. К., 1915; Ю з е е в А.И. Шихаб ад-дин Марджани — мыслитель, религиозный реформатор, просветитель (к 180-летию со дня рождения). К., 1997; Ш.Марджани: Наследие и современность: Материалы междунар. науч. конф. К., 1998; Ю с у п о в М.Х. Шигабутдин Марджани. К., 2006; K e m p e r M. Cufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789–1889: der Islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. B., 1998.

*Д.А.Шаһавиев.*

**МӘРҖАНИ́ МӘЧЕТЕ́** («Беренче җамигъ мәчет», «Юнысов мәчете»), татар дини архит-расы истәлеге. 1552 елдан соң Казандагы беренче таш мәчетләрнең берсе. 1766–70 тә Екатерина II рөхсәте б-н Иске татар бистәсендә мәхәллә халкы акчасына төзелә (арх. В.И.Кафтырев проекты дип фаразлана). Манарасы дүрт кыеклы түбә уртасында торгызылган ике катлы, бер заллы мәчет була. 1861 дә коммерция советнигы И.Г.Юнысов акчасына мәчет әйләнәсенә элеккеге агач койма урынына кирпеч койма тотыла, бинаның төньягында баскычлы кирпеч янкорма төзелә; вестибюль озынайтылып икенче зал итеп үзгәртелә. 1863 тә михраб киңәйтелә, тирәнәйтелә, тәрәзә уела. 1885 тә Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре З.Госманов акчасына манара үзгәртеп корыла, 1887 дә манарага сәү-



Мәрҗани мәчете. Казан. 1766–70.
Арх. В.И. Кафтырев (фаразлауларча).

дәгәрләр В.Гыйззәтуллин һәм М.Вәлишин акчасына металлдан челтәр култыксалы түгәрәк мәэзәнә — балкон куела.

Хәзерге вакытта М.м. төньягында Т рәвешле янкормасы булган ике катлы бинадан гыйбарәт; ишеге урам якта. Вазифалары буенча мәчет хуҗалык (1 нче) һәм намаз уку өчен анфиладалы заллар (2 нче) катларына бүленгән. Мәчет бүленмәләренең түшәме гөмбәзсыман. 2 нче кат залларының гөмбәзләренә купшы, үсемлек шәкелендәге барокко орнаментын татар гамәли-бизәлеш сәнгате үрнәкләре б-н аралаштырып әвәләп ясалган һәм алтын йөгертелгән бизәк төшерелгән. Дивардардагы әвәләп ясалган бизәкләр зәңгәр, яшел һәм алтынсу төсләргә буялган. Залларны урталай бүлүче диварның уң ягында манараның эчке баскыч ишеге урнашкан. Манара эчендәге бормалы баскыч мөәзинне түгәрәк мәэзәнәгә — балконга алып менә. 3 яруслы манарада бизәкләр юк диярлек. 2 нче каттагы а́ркалы биек тәрәзә уемнары барокко стилендәге йөзлекләр б-н каймаланган. Тәрәзә араларындагы диварлар парлы һәм так пилястрлар б-н аерылган, ионик капительләргә стильләшкән татар бизәге элементлары да кертелгән. 1850–89 да мәчетнең имам-хатибы күренекле дин һәм җәмәгать эшлеклесе, тарихчы, педагог һәм вәгазьче Ш.*Мәрҗани* була. М.м. Татарстанда совет чорында эшләгән бик аз санлы мәчетләрнең берсе.

*Әд.:* Остроумов В.П. Казань. Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; Халитов Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991.

**МӘРҖАНИ́ ШИҺАБЕТДИ́Н МУЗЕЕ́**, Әтнә р-ны Комыргуҗа авылында. 2000 елның 2 октябрендә ачыла. Урта мәктәп каршында урнашкан. 82 $м^2$ га якын мәйданны биләгән ике экспозиция залыннан гыйбарәт. Коллекциядә 150 саклау берәмлеге исәпләнә. 1992 дән материалларны рус теле һәм әдәбияты укытучысы Г.Б.Вәлиева туплый. Экспозиция авторлары — А.Д.Хәйруллина, ТР Милли музее фәнни хезмәткәре рәссам Ф.А.Зыязов. Экспозиция Ш.*Мәрҗанинең* тормышын һәм эшчәнлеген хронологик эзлеклелектә яктырта. Беренче бүлек Ш.Мәрҗани һәм аның туганнары тормышы б-н бәйле авылларга, ш.у. атаклы мәгърифәтченең уку елларына багышлана. Экспозициядә 19 йөз татар йортының интерьер фрагментлары торгызылган, күргәзмәгә 19 йөзгә караган мулла киеме, йорт кирәк-яраклары куелган. Икенче залдагы экспозиция Мәрҗанинең



Комыргуҗа авылында Шиһабетдин Мәрҗани музее. Экспозиция фрагменты.



Комыргуҗа авылында Шиһабетдин Мәрҗани музее. Татар йорты интерьеры. 19 йөз.

Казандагы эшчәнлеге һәм аның дәвамчылары («Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкертләре һәм варислары») б-н таныштыра. Анда галимнең оныгы Суфия Мостафина тарафыннан музейга тапшырылган шәхси әйберләре: көмеш чәнечке-пычаклар, 4 чәй тәлинкәсе һ.б. куелган. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында мемориаль әйберләр коллекциясе, китаплар, Ш.Мәрҗани әсәрләре басмалары бар. Музей җирлегендә «Туган төбәкне өйрәнәбез» дигән мәктәп түгәрәге эшли. Ел саен Халыкара музейлар көне (18 май), Белем көне (1 сент.) үткәрелә.

**МӘРҖАНИ́ ШИҺАБЕТДИ́Н ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. Дин белгече, фәлсәфәче һәм тарихчы Ш.*Мәрҗанинең* китап тупланмасын үз эченә ала. Китапханәдә 4 меңнән артык китап һәм кульъязма исәпләнә. Китапханәнең төп өлешен ул Урта Азиянең Бохара, Сәмәрканд һәм Хива шәһәрләрендә укыган чагында туплый. Аның вафатыннан соң, васыяте буенча, китапханәне балалары — улы Борһанетдин һәм кызлары Галия б-н Һава үзара бүлешәләр. Борһанетдин һәм Һава кулына күчкән китап һәм кулъязмаларның язмышы билгесез. Галиягә мирас булып калган китаплар тупланмасының бер өлеше аның кызы Нәгыймә һәм оныгы Нәҗия тарафыннан 1937 елда 1250 берәмлектә Казан ун-тының Фәнни китапханәсенә тапшырыла; 74 томы 1983–86 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият, сәнгать ин-ты) архивына күчерелә. Китапларның бер өлеше Г.Баруди китапханәсенә эләгә, соңрак шушы китапханә б-н бергә Казан ун-тының Фәнни китапханәсе фондына тапшырыла.

Китапханәдә Шәрекъ авторларының тарих, фәлсәфә, дин тәгълиматы, мөселман хокукы, математикага караган кыйммәтле кульъязмалары, ш.у. әдәби-дини әдәбият, календарьлар, шәҗәрәләр саклана. Ш.Мәрҗани аларны тарихи һәм дини хезмәтләрендә куллана, бу үз чиратында галим хезмәтләрен чыганакларга бәета, мәгълүмати кыйммәтен арттыра. Китапханә фонды ш.у. Ш.Мәрҗани кушуы буенча аның укучылары күчергән кыйммәтле китаплар һәм кулъязмалар күчермәләре хисабына да байый. Мәрҗанинең чордашлары һәм аның мирасын өйрәнүчеләр раславынча, китапханәдә әл-Фараби, Ибне Фазлан, Ибне Сина, әл-Казвини, әл-Газали, Ибне Халдун, Ибне әл-Әсир, әл-Чәләби, әс-Саксини, Г.Нәвои, З.Бабур һ.б.ның кульъязмалары саклана. Анда ш.у. танылган татар дин белгечләре һәм язучыларының, ш.и. Ш.Мәрҗани татар халкы тарихын язганда киң кулланган чордашларының бик күп әсәрләре урын алган.

*Әд.:* Мәрҗани. К., 1915; Юсупов М.Х. Шигабутдин Марджани как историк. К., 1981; Ахметзянов М.И. Фонд Шигабутдина Марджани в Институте языка, литературы и искусства им. Г.Ибраһимова // Марджани: учёный, мыслитель, просветитель. К., 1990.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**«МӘРҖАНИЯ́»**, Казандагы мәдрәсә. 1770 елларда Казанның 1 нче мәхәллә мәчете каршында ачыла (к. *Мәрҗани мәчете*). 1870 еллардан шунда укыткан Ш.*Мәрҗани* исеме б-н атала; аңа кадәр Ахун, Юныс мәдрәсәсе буларак билгеле. Беренче мөдәррисе А.Ибраһимов була (1793 тә вафат). Ибраһим бине Хуҗаш әл-Казани (1825 тә вафат) мәдрәсәне Идел-Урал төбәгендә иң танылган уку йортларының берсенә әверелдерә (фәлсәфә укытуның югары сыйфаты б-н аерылып тора).

19 йөзнең 2 нче яртысында укыту дәрәҗәсе түбәнәя. Ш.Мәрҗани җитәкләгән 1850–89 елларда мәдрәсә эре мөселман уку йортына әверелә, анда, гадәти фәннәрдән тыш, матем., астрономия, тарих укытыла; якынча 140 шәкерт укый. Ш.Мәрҗани б-н И.Юнысов арасындагы каршылык нәтиҗәсендә, 1860 еллар ахырыннан 1870 еллар ахырына кадәр 1 нче мәхәлләдә 2 мәдрәсә эшли; берсе б-н Мәрҗани җитәкчелек итә, ул күпчелек бай шәһәр кешеләре акчасына тотыла;



«Мәрҗания» мәдрәсәсе. 1881.
Арх. П.И. Романов. Хәзерге күренеше.

икенчесе рәсми рәвештә 1 нче мәхәллә мәдрәсәсе санала, И.Юнысов акчасына тотыла, ләкин аның карашлары мөселман җәмгатьчелеге тарафыннан тәнкыйть ителгәнлектән, ябыла. 1889–1908 дә мәчетнең имам-хатибы Б.Баһаветдинов (Ш.Мәрҗанинең улы) мөдәррис була; аның авыруы сәбәпле, 1899 га кадәр чынлыкта мәдрәсә б-н мөәзин Х.Ихсанов җитәкчелек итә һәм бу чорда мәдрәсә үз дәрәҗәсен югалта. 1899 да аны имам С.*Абдуллин* алыштыра; ул эшләгәндә яңа ысулга нигезләнеп укыту кертелә һәм аның сыйфаты яңадан югары дәрәҗәгә ирешә. 20 йөз башында якынча 100 шәкерт укый. 1918 дә мәдрәсә рәсми рәвештә ябыла, ләкин 1923 кә кадәр С.Абдуллин шәкертләрне укытуын дәвам итә. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында Х.*Фәезханов*, Г.*Фәезханов*, Г.*Гомәри*, Ш.*Рәмзи*, Г.*Апанаев*, К.*Тәрҗемани*, Х.М.*Ямашев*, С.Х.*Айдаров*, С.Ж.*Сәйдәшев* бар.

1820 дән мәдрәсә Кабан күле буендагы үзенә аталган агач бинага урнаша. 1837 дә аның урынына Г.Юнысов акчасына Икенче Аркылы урамда (хәзерге Ф.Кәрим урамы) яртылаш таш бина төзелә. Ш.Мәрҗани һәм И.Юнысов каршылыгы вакытында алар һәркайсы үз мәдрәсәләре өчен бина төзиләр: И.Юнысов 1873 тә — элеккесе урынында, Ш.Мәрҗани 1871 дә — Беренче Аркылы урамда (хәзерге З.Солтан урамы). Мәдрәсәсе ябылгач, Юнысов ул бинаны мәхәлләгә кайтармый; 1887 дә варислары аны *Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыятенә* тапшыралар. Ш.Мәрҗани төзеткән бина 1875 тә яна; 1881 дә яңадан төзетелә (архит-ра истәлеге). 2003 тә биредә яңадан «М.» мәдрәсәсе ачыла. 2004 тә ул Казан ислам көллияте итеп үзгәртелә.

*Әд.:* М ә р җ а н и Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1990. Т. 2; Х а й р у т д и н о в Р.Р., С а л и х о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

**МӘРҖӘ́Н** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 8 *км* көньяктарак, Шәмәк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 110 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Юлба, Көек исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 4 җил тегермәне, ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 816,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 130 ир-ат; 1859 да — 448, 1897 дә — 631, 1908 дә — 625, 1920 дә — 548, 1926 да — 810, 1949 да — 328, 1958 дә — 234, 1970 тә — 198, 1979 да — 162, 1989 да — 114 кеше.

**МӘРМӘ́Р О́НИКС**, тау токымы, кальциттан, сирәк кенә арагониттан тора, катламлы, нечкә, дулкынсыман сызыклы, вак бөртекле, радиаль-нурлы. Кайвакыт бормалы ак сызыклы, төрле төсмердәге көрән, яшькелт, алсу төстә. Төсе органик матдәләрнең яки тимер оксидларының кушылмаларына бәйле. Кайбер төрчәләрнең үтә күренмәлелеге 1–1,5 *см*. Катылыгы 3–3,5. Пыяласыман ялтыравыклы. М.о. җиңел киселә, яхшы шомартыла һәм ялтыратыла. М.о. чыганакларының шактый өлеше яшь вулканнар районнарына туры килә һәм $CaCO_3$ утыру нәтиҗәсендә кайнар сулардан барлыкка килә. М.о. карбонат токымнарына күзәнәкләр һәм ярыклар аша салкын суларның инфильтрациясе вакытында алардан да утырырга мөмкин. М.о.ның катламсыман, саркымлы (мәгарә) һәм тамырлы (ярыклы) чыганакларын аерып йөртәләр. Чыганаклары Алжирда, Пакъстанда һ.б. урыннарда билгеле. Россиядә М.о. чыганаклары Иркутск өлкәсендә, Саха Респ-касында, Красноярск краенда үзләштерелә. М.о.ның иң зур чыганагы — *Пичкас мәрмәр ониксы чыганагы*



Мәрмәр оникс.

Татарстан терр-ясендә урнашкан (Спас р-ны). Шулай ук Кама Тамагы, Биектау һ.б. р-ннарда 20 дән артык вак ятмалар бар. М.о. ятмалары Пермь системасы Казан ярусының карбонатлы, сирәк кенә комсу токымнарында билгеләнә. Алар гиперген (җир өслегенә якын) токымнарга карый һәм төп 3 морфогенетик типта билгеләнә: мәгарә-карст, ярыклы-шуышма һәм цементлашу зонасында инфильтрацион-ярыклы. М.о.ның Пичкас чыганагы мәгарә-карст тибына карый һәм югары декоратив үзлекләре б-н характерлана. Декоратив-сәнгати сыйфатлама төсләрнең ачыклыгы, аларның капма-каршылыгы, рәсем тибы һәм кимчелекләрнең булу-булмавы б-н билгеләнә. Кимчелекләргә күзәнәкләр, ярыклар, чит кушылмалар, тонык рәсемнәр керә. М.о. көнкүреш һәм сәнгать эшләнмәләре — ваза, шкатулка, шәмдәлләр, муенса, кулоннар һ.б. ясау өчен, ш.у. декоратив тышлау материалы буларак кулланыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*А.В.Шишкин.*

**МӘРСИ́Н БАЛЫКЛА́Р**, о с ё т р б а л ы к л а р (Acipenseridae), мәрсинсыманнар отрядыннан балыклар семьялыгы. Хәзерге ихтиофауна арасында аеруча борынгы төркемнәрнең берсе. Дөньякүләм фаунада 23 төр; Россиядә — 11, Татарстан терр-ясендә 5 төре билгеле. Алар арасында: кереп йөрүчеләр — кырпы (Huso huso), мәрсин (Acipenser gueldenstaedti) һәм гадәти төче су төре — чөгә балык (A. ruthenus). Каспий, Кара һәм Азов диңгезләре бассейннарында таралган кырпы М.б. арасында аеруча зур балык, авырлыгы 1 *т* га җитә һәм 80 елга кадәр яши. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнче, елга режимы шартларында үрчү өчен, Урта Иделгә һәм Камага күтәрелә (1983 елда Кама тамагында 207 *кг* авырлыктагы ата кырпы эләгә). Идел ГЭС плотинасы төзелгәннән соң (к. *Куйбышев сусаклагычы*), уылдык чәчү миграциясе туктый, әмма беренче елларда сусаклагычта әле яшь балыклар тотыла. Кырпы — соң өлгерүче төр, җенси яктан ата затлар 10–12, ана затлар 14–16 яшьтә өлгерә. Үрчемлелеге — 200 меңнән 8 млн.га кадәр уылдык бөртеге. Көчле агымлы чуерташлы урыннарда үрчи. Яшь балыклар бентос б-н туклана, олыгайгач ерткычка әвереләләр. Мәрсин Каспий, Кара һәм Азов диңгезе бассейннарында очрый. 1982 дә Идел-Кама саклаулыгының Саралан участогы янында мәрсин б-н чөгә балык гибриды тотыла. Урта Идел шартларында мәрсин 12–15 яшендә җитлегә. Елганың тиз агымлы ташлы урыннарында үрчи. Уылдык чәчкәннән соң, яшь мәрсиннәр Каспий диңгезенә китәләр һәм шунда үсәләр. Куйбышев сусаклагычы төзелгәнче, Каспийдан Урта Иделгә орчыкбалык (A. stellatus) һәм бик сирәк кенә укборын (A. nudiventris) керә. Чөгә балык Балтыйк, Ак, Баренц, Карск, Каспий, Кара һәм Азов диңгезләре бассейнында таралган, шулай да Идел һәм Камада аеруча күп. Елгаларның көйләнгән агымы шартларында, нигездә, Куйбышев сусаклагычының Идел һәм Кама плёсларында кәсәбәчелек әһәмияте саклана, биредә, агымлы һәм ташлы грунтта, аларга үрчү өчен уңай. Чөгә балыкның иң зур озынлыгы 1 *м* дан артык, авырлыгы 16 *кг* га кадәр, 24 яшькә кадәр яши. Чөгә балыкның гадәти литофил һәм сусаклагыч шартларында аерым бер уылдык чәчү урыны юк диярлек. Казан ун-тының умырткалылар зоологиясе каф. хезмәткәрләре тарафыннан чөгә балык личинкалары 1970 елларда Пустые Моркваши авылыннан өстәрәк, Идел буе плёсында табыла, бу исә анда аларның уылдык чәчү урыннары булуын күрсәтә. 2006 да уылдык бөртекләре һәм личинкалары Вятка тамагыннан астарак Кама плёсында табыла. Чөгә балыкның җенси җитлегүе төрлечә. Ата затларның бер өлеше яшәүнең 3 нче, ана балыклар 4–5 нче елларында җитлегә башлый. Сусаклагыч шартларында чөгә балыкның беренче елларда үсеше елга режимы б-н чагыштырганда шактый яхшыра, әмма 1980 еллар уртасыннан үсеш күрсәткечләре кими, бу сулыкларда экологик торышның начар булуы б-н аңлатыла. Әлеге төрнең абс. үрчемлелеге 8,7 меңнән 40,8 мең уылдык бөртегенә кадәр тирбәлә. Чөгә балыкның азык спектры чагыштырмача киң, 49 га кадәр компонентны үз эченә ала, яшь балыклар сусаклагыч шартларында — зоопланктон, олы затлар хирономид личинкалары һәм моллюсклар б-н туклана. Чөгә балык — кыйммәтле кәсәбәчелек төре. 1989 да Татарстанда 40,5 *т* га кадәр тотыла, аннан соң кими һәм 2006 да 0,59 *т* тәшкил итә. Шул сәбәпле уылдык чәчү урыннарын саклау, тотуны чикләү һәм ясалма үрчетү кирәк. Кырпы һәм мәрсин ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Атлас пресноводных рыб России. М., 2003. Т. 1; К у з н е ц о в В.А. Рыбы Волжско-Камского края. К., 2005.

*В.А.Кузнецов.*

**МӘРСИЯ́** (гарәп. مرثيـــة — елау-сыктау, некролог), Шәрекъ поэзиясе жанры, гүр иясе булган танылган галимнәргә, әдипләр, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре, остазларга һ.б. багышланган элегик әсәр. М.дә аларның әхлакый сыйфатлары, кылган гамәлләре искә алына. Бу жанр әсәрләренә кайгылы элегик аһәң хас. М. мәдхия жанрына якын тора: берсенең дә катгый структурасы, төгәл билгеләмәсе юк, икесенә дә макталган персонажларның яхшылыкларын күпертеп күрсәтү хас. Аерым үрнәкләре борынгы төрки әдәбиятта (кабер ташлары язмаларында), фольклорда очрый. Татар әдәбиятында М. жанрында Г.Утыз Имәни, Акмулла, Г.Тукай, Н.Думави, Ш.Бабич һ.б. язган.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.


*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘРТЕ́Н** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 44 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. 1678 дән мәгълүм. 1930 елларга кадәр Ташлы Елга исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, тегермән, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1238,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 348, 1897 дә — 428, 1908 дә — 533, 1920 дә — 598, 1926 да — 511, 1938 дә — 478, 1949 да — 475, 1970 тә — 279, 1979 да — 182, 1989 да — 94, 2002 дә — 44 кеше.

**МӘРЬЯ́М**, Коръән персонажы, изге хатын-кыз, татарларда Мәрьям ана; христианнардагы Дева Марияга туры килә; Гайсә пәйгамбәрнең (Библиядә Иисус Христос) әнисе. Коръәннең 19 нчы сүрәсе аның исеме б-н аталган; анда М. тормышы турында, Җәбраил фәрештәнең аңа Аллаһның бүләге — киләчәктә кешеләр өчен символ булачак угыл — изге сабый хакында сөйләве бәян ителә. Аллаһның ихтыяры б-н М. балага уза һәм аны тудыра, улы б-н халкы янына бара. Сабый аларга үзенең Аллаһ колы булуын, Ходайның аңа вәхи иңдерүен һәм пәйгамбәр итеп билгеләвен әйтә. Мөхәммәд пәйгамбәр турындагы риваятьләрдә — *хәдисләрдә* М. тәкъва мөслимәләрдән исәпләнә, аеруча ихтирам ителгән хатын-кызлардан санала.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**МӘСӘГУ́ТОВ** Рафаэль Зәйнур улы (21.12.1934, Сталинград өлкәсенең Кече Чапур а.), график, нәкышьче, монументчы-рәссам, җәмәгать эшлеклесе, Украинаның атказ. (1984) һәм халык (1993) рәссамы. М.ның әнисе — Й.*Акчура* нәселеннән. Казан сәнгать уч-щесендә В.Подгурскийда (1954), Киев сәнгать ин-тында (1960) укый. 1954 елдан Киевта. 1960–64 тә Республика реклама идарәсендә, 1965–67 дә «Днипро» нәшриятында, 1976–78 дә Украина ССР Дәүләт нәшрият ком-ты каршындагы Халыкара китап күргәзмәләре һәм ярминкәләр дирекциясендә баш рәссам булып эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Украинадагы төрки телле халыкларның респ-ка үзәге рәисе (1989–92), «Украина–Төркия» Халыкара җәмгыяте президенты (1993 тән), Украинаның Милләтләр советы рәистәше (1992). Украина МК каршындагы милләтләр хокукы һәм миграция буенча консультатив совет рәисе (1994). 12 нче Бөтендөнья




Р.З.Мәсәгутов.




Р.З.М ә с ә г у т о в. 12 нче Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале эмблемасы. Мәскәү. 1985.

яшьләр һәм студентлар фестиваленең (Мәскәү, 1985) эмблемасы авторы буларак халыкара танылу ала, моның өчен «Тынычлык елы — 1987» алтын медаленә лаек була (Париж, ЮНЕСКО).



Р.З.М ә с ә г у т о в. «Кырым. Авылда кыш». Төсле графика. Катнаш техника. 2003.

М. — китап һәм станлы графика өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Украина язучыларының 400 дән артык китабын (Б.Олейник, М.Божан, И.Драч, Б.Чалый, П.Мовчан, Д.Павлычко, Ю.Буряк, П.Загребельный һ.б.); 1967–87 еллар шигърияте альманахларын, «Украина шигърияте» антологиясен, «Украинаның яшь шигърияте» җыентыгының 10 томын, «Грузия шигърияте» җыентыгының 12 томын, «Борынгы Греция мифлары» җыентыгының 5 томын; А.Блок, В.Маяковский, И.Тургенев, Е.Евтушенко һ.б.; украин һәм татар телләрендә «Муса Җәлил» (Киев, 1988), «Габдулла Тукай» (Казан, 1990) юбилей бүләк басмаларын, «Шан кызы турында риваять» (Әнкара, 1991) һ.б. бизи һәм иллюстрация ясый. Плакатлар, рәсемле открыткалар һ.б. полиграфия продукцияләре авторы. М.ның сәнгать теле иҗади индивидуальлеккә ия, аның әсәрләренә стильләр төрлелеге (реализм традицияләре, классик рәсем, нәкышь авангарды) хас. Евразия халыкларының тарихы, мәдәнияте һәм фольклорына мөрәҗәгать итә («Кыпчак даласы», «Роксолана», «Умай алиһә һәм Мамай», «Кенәз Могыт»; «Дала шаманы Чурай»; «Кыпчак кенәзе кызы Туран» һ.б.), пейзаж (графика серияләре — «Украина пейзажы», «Төрек пейзажы», «Парижда бер атна», «Алтын гөмбәзле Киев») һәм портрет жанрларында эшли. М. әсәрләренә Казан графика мәктәбе традицияләренә нигезләнгән тирән автор стилистикасы (Н.И.*Фешин*, И.Н.*Плещинский*ның рәсем осталыгы мирасы), иҗат иреге, бер үк вакытта композициянең конструктив төгәллеге, сәнгать теленең җанлылыгы хас. Монументаль сәнгать, бизәү сәнгате, дизайн өлкәсендә уңышлы эшли (Бакчасарай шәһәре Сәүдә үзәгеn бизәү; Керчьта Олимпия спорт сарае бизәлеше һ.б.). Волгоградта Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 60 ел тулуга багышланган «Патриот» сәнгать мемориалы проекты авторы, 2005 тән аны төзү эшләрен җитәкли.

1 нче Халыкара китап күргәзмә-ярминкәсендә катнаша (Мәскәү, 1977). Шәхси күргәзмәләре: 1977 (Мәскәү), 1978 (Нью-Йорк, Берлин), 1992 (Истанбул), 1995, 2000, 2001 (Киев). Әсәрләре Украина музейларында, Нью-Йоркта Украинаның хәзерге заман сәнгате музеенда, Төркия, Англия, Франция, АКШта шәхси коллекцияләрдә саклана. Украинаның Н.Островский (1981), В.Касиян (1989), Т.Шевченко (1992) исем. республика бүләкләре лауреаты. «Халыклар дуслыгы» ордены б-н бүләкләнә (1985).

*Әд.:* Художники Советской Украины: Энцикл. словарь. Киев, 1981; Ч о в н о в а В. Заслуженный художник Украины Р.Масаутов. Киев, 1984; Л е м ы ш А. Масаутов Р. // Зеркало недели. 1996. 5–12 июня; С л у ц к и й Е. Киев златоглавый (Киев в картинах народного художника Украины Р.Масаутова). Киев, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӘСӘГУ́ТОВ** Хәбибрахман Ситдыйк улы (1862, Вятка губ., Малмыж өязе Морт а. — 1930 дан соң), җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Вятка губернасы Малмыж өязенең Түнтәр авылы мәдрәсәсендә укый, Алабуга шәһәрендәге өяз уч-щесен тәмамлый. Морт мәчете

имамы, соңрак Алабугада ахун була. Вятка губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты булып сайлана (1907), мөселман хезмәт таифәсе әгъзасы. «Дума» г-тасын оештыручыларның берсе. 1917 елдан соң Семипалатинск шәһәренә күчеп килә, сәүдә эшчәнлеге б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Госманова.*

**МӘСӘДЕ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 23 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасы буенда. 2010 елда 321 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Нефть суыртып агызу станциясе. Башлангыч мәктәп, клуб. 1927 дә Такталачык авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Актаныш волостенда. 1930ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1958 дә — 115, 1970 тә — 243, 1979 да — 205, 1989 да — 251, 2002 дә — 290 кеше.

**МӘСӘ́Л** (гарәп. مثل — әдәп, әхлак өйрәтү өчен читләтеп сөйләнгән хикәя), әдәби жанр: 1) персонажлары хайваннар, кошлар яки җансыз предметлар булган кыска чәчмә, тезмә яки кушма формадагы читләтеп әйтүгә, кинаягә корылган хикәя; 2) мәкаль, әйтем. М.нең ахырында, гадәттә, өстенлек итүче нәсыйхәт, мораль (әхлакый нәтиҗә) бирелә. Жанрның барлыкка килүе санскрит әдәбияты ядкәре «Панчатантра»ның «Кәлилә вә Димнә» исеме б-н гарәп теленә тәрҗемә ителүе б-н бәйле. Урта гасырлар татар әдәбиятында аеруча киң тарала. К.Насыйри, Т.Яхин, Г.Тукай, М.Гафури, С.Рәмиев, Ә.Исхак, Г.Шамуков иҗатларында урын ала.

*Әд.:* Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990. *Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘСӘЛИ́МОВ** Тәлгать Хәсән улы (27.1.1958, БАССРның Миякә р-ны Шатмантамак а.), график. 1982 елда Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый, шунда ук эшли, ф-т деканы (1993 тән), сынлы сәнгать каф. доценты (1994 тән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1991). Басма графика өлкәсендә эшләүче әйдәп баручы рәссамнарның берсе (офорт, линогравюра), катнаш техника һәм пастель техникасында эшләнгән станлы әсәрләр авторы. М. иҗатында төп урынны татар халкы тарихына, мифологиясенә, фольклорына, тормыш-көнкүреш сюжетларына багышланган тематик серияләр һәм цикллар; пейзажлар һәм натюрмортлар алып тора. Алар арасында: «Тукайга багышлау» (пыяла, химик чаралар б-н бизәк төшерү, 1985), «Тукай сәхифәләрен ачканда» (офорт, 1985–86), «Габдулла Тукай» диптихы (пастель, 1987); төсле карандаш техникасындагы әсәрләре — «Без кемнәр?» (1988), «Халык җырлары үрнәгендә», «Балачак хатирәләре» (икесе дә — 1989) серияләре; катнаш техникада — «Уйланулар» (1990) сериясе, «Чагылыш» (1997), «Төш» (2000); графитта — «Җырлы көйләр» сериясе, «Мәңгелек җир авазы» триптихы





Т.Х.Мәсәлимов. 1. «Балачак сукмаклары». Кәгазь, пастель. 1995. «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музее; 2. «Намаз. Иртә». Кәгазь, пастель. 1997.

(барысы да — 1990), «Яраткан чәчәкләрем» сериясе (1996); пастель стилендә — «Капкачы малай» (1991), «Сагыш» сериясе (1992), «Каз өмәсе» (1995), «Дала» (1996–97), «Ай мөгезле күк сыер» (2000) һ.б.

Республика (1978 дән), зона («Социалистик Урал», Курган ш., 1991; «Урал VIII», Уфа ш., 1997), бөтенроссия (станлы графика, Мәскәү, 1996), бөтенсоюз («Илнең яшьлеге», Мәскәү, 1987; «Рәсем күргәзмәсе», Мәскәү, 1991), «Татарт» төбәкара бөтентатар күргәзмәләрендә (С.-Петербург-Казан, 1991) һ.б. катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1990, 1998 (икесе дә — Уфа ш.). Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда һ.б. саклана. БРның Г.Сәләм исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1992).

*Әд.:* Рахимкулов Ю. На языке жизни и бессмертия // Рампа. 1992. № 1; Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӘСГУ́Д әл-БОЛГАРИ́**, болгар астрономы (14 йөз). Астрономик инструментлар ярдәмендә гыйбадәт вакытын билгели.

**әл-МӘСГУДИ́** (المسعودي) Әбү-л Хәсән Гали ибне әл-Хөсәен (әл-Багдади) (896 тирәсе, Багдад — 956 яки 957, Фустат ш., Мисыр), гарәп тарихчысы, географы, сәяхәтчесе. Мисырда һәм Сүриядә яши. Гомеренең күпчелек өлешен сәфәрләрдә уздыра, мөселман илләрендә (Иран, Палестина, Йәмән), Һиндстанда, Кавказ арьягында һ.б. җирләрдә була. 930 елларның 2 нче яртысында Хәзәр (хәзерге Каспий) диңгезе буйларында булып китә, анда Җаек (Урал), Итил (Идел), Кура һ.б. елгалар тамакларында яшәгән халыкларның тормышы, традицияләре һәм гореф-гадәтләре, Баку, Дербент, Бардау шәһәрләре һ.б. хакында мәгълүматлар җыя. әл-М. ш.у. Хәзәр каганлыгы башкаласы Итил шәһәрендә дә булган дип фаразлана. Аның хезмәтләрендә Хәзәр каганлыгының сәяси системасы тасвирлана: әл-М. анда, башлыча, болгар аксөякләре вәкилләре идарә итә, халыкның зур күпчелеге мөселманнар, бары тик мөселман гына вәзир була ала дип яза. Әл-М. ш.у. Дунай буе болгарлары хакында да искә ала. Аның 7 тарихи-геогр. хезмәте арасында иң зур күләмлеләре — «Әхбар аз-заман» («Заман хәбәрләре») һәм «Китаб әл-әүсат» («Уртанчы китап») югала, алардагы кайбер мәгълүматлар башка чыганакларда сакланган. Сакланмаган хезмәтләренең кыска кисәкләре әл-М.нең «Муруҗ әз-зәһаб вә мәгадин әл-җәваһир» («Алтын һәм асылташлар мәгъдәннәрен юу урыннары», 943) дигән әсәрендә урнаштырылган. Анда грекларның, римлыларның, гарәпләрнең җирләре турындагы гомуми географик мәгълүматлар һәм, аерым алганда, Көнчыгыш Европа халыкларына нисбәтле тарихи-этнографик тасвирлама бирелә. Безнең көннәргә килеп җиткән башка кулъязма хезмәтендә — «Китаб әт-әтбиһ вә-л-ишраф»та («Кисәтү һәм яңадан тикшерү китабы», 956) төзәтүләр һәм өстәмәләр б-н элегрәк язылган әсәрләрен тасвирлый. Чит илләрдә әл-М. хезмәтләре 18 йөздән басыла башлый. Француз тикшеренүчесе М.д'Оссон әл-М.не гарәп Геродоты дип атый. Россиядә әл-М. әсәрләре Б.А.Дорн, Х.Д.Френ, А.Я.Гаркави, И.Ю.Крачковский, В.В. Бартольд, А.П.Ковалевский, Б.Н.Заходер, В.М.Бейлис һ.б. тарафыннан өйрәнелә һәм шәрехләнә.

*Әд.:* Бартольд В.В. Арабские известия о русах // Советское востоковедение. 1940. № 1; Бейлис В.М. Ал-Масуди о русско-византийских отношениях в 50-х годах X в. // Международные связи России до XVII в. М., 1961; Микульский Д.В. Арабский Геродот. М., 1998.

*Л.Х.Хәмидуллин.*


**МӘСГУ́Т** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 355 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М. тә волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, мәдрәсә, земство станциясе була; җомга көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 6645 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 ок-

тябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 381, 1889 да — 773, 1910 да — 1074, 1920 дә — 1283, 1926 да — 872, 1938 дә — 815, 1949 да — 482, 1958 дә — 593, 1970 тә — 726, 1979 да — 594, 1989 да — 478, 2002 дә — 492 кеше.

**МӘСГУ́ТОВ** Миңнехан Мәсгут улы (1895, Казан губ., Чистай өязе Зирекле а. — 24.4.1945, Германиядә җирләнә), Дан орденының тулы кавалеры (27.7.1944, 29.3.1945, 15.5.1946, үлгәннән соң), Георгий кавалеры (1914), рядовой. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Туган авылында балта остасы булып эшли. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 504 нче аерым пулемёт-артиллерия батальоны сапёры (3 нче удар һәм 33 нче армияләрнең 115 нче ныгытылган районы). Калинин, 2 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск (1943) сугышында, Невель (1943), Режицк-Двина, Рига (икесе дә — 1944), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 24 июнендә Рогачёв шәһәре (Белоруссия ССР) янындагы сугышта (миналы кырларда 6 үтү юлы ясый); 1945 нең 27–28 февралендә Каллис шәһәре (хәзер Калиш ш., Польша) янындагы сугышта (батальон сапёрлары б-н кузәтү пунктын җиһазлый, 3 күперне минадан арындыра, 80 гә якын мина чыгара); 1945 нең 22 апрелендә Губин шәһәреннән (Польша) төньяктарак Нейсе елгасын кичкәндә (миналы кырларда 3 үтү юлы ясый, танкка каршы куелган 18 мина чыгара) батырлык күрсәтә. Берлин янында һәлак була. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



М.М. Мәсгутов.

**МӘСКӘ́Ү** шәһәре, РФ башкаласы, *Мәскәү өлкәсе* үзәге, дөньяның иң зур мәдәни-сәяси үзәкләренең берсе. Халкы — 11979529 кеше (2012). Татарлар саны: 1926 да — 11262, 1939 да — 57687, 1959 да — 80489 (Кырым татарларын да кертеп), 1979 да — 131328, 1989 да — 157376, 2002 дә — 166083, 2010 да — 149043 кеше. М.гә татарлар (башлыча, хан наместниклары, илчеләр һәм хезмәткәрләр) 14–15 йөздә Алтын Урда чорында килә. 15–16 йөздә күп кенә татар феодаллары, имана җирләре алып, шәһәр читенә урнаша. Алар арасында, Казан татарларыннан тыш, Кырым һәм нугай татарлары да (ш.и. әсирләр) күп була, аларның бер өлеше шәһәрдә торып кала; ш.у. Касыйм, Себер, Кадом татарлары һ.б. яши. 17 йөз башында М.дә татарлар тупланып яши торган 3 үзәк була: Кырым утары (Казан ханлыгының дипломатик һәм сәүдә вәкиллеге; 1530 еллардан мәгълүм, 1785 кә кадәр эшли), Касыйм ханнары йорты, *Мәскәүдә татар бистәсе*. 17 йөздә татар халкының төп эшчәнлеге — сарай, хәрби һәм дипломатик хезмәт (тылмач һәм тәрҗемәчеләр сыйфатында). 1612 дә татар отрядлары шәһәрне поляк интервентларыннан азат итүдә актив катнаша. 18 йөздә башкаланың С.-Петербургка күчүе һәм дәүләт аппаратын үзгәртүләр нәтиҗәсендә М.дә татарлар саны кими. 1730–40 елларда Татар (Татарская) урамында (элеккеге Татар бистәсе) хосусый биләмәдәге 80 татар хуҗалыгы булса, 1793 тә шәһәрдә бары 7 йортның гына хуҗасы татар була. 1744 елгы чыганакларга караганда, Зур Калуга урамында татар зираты (17 йөз башларына кадәр барлыкка килә) һәм Татар урамында мәчет (18 йөз ахыры — 19 йөз башында икесе дә юкка чыгарыла) була. 19 йөзнең 1 нче яртысында М.дәге татар халкының күпчелеген Касыйм, Казан, Түбән Новгород, Пенза һ.б. губерна шәһәрләреннән килгән сәүдәгәр һәм мещаннар тәшкил итә. Реформалардан соңгы чорда хуҗалык эшчәнлегенең игенчелек б-н бәйле булмаган төрләренең әһәмияте үсү, Урал һәм Идел буе татарларының читкә китеп эшләве нәтиҗәсендә шәһәрдә татарлар шактый күбәя. 1866 да М.дә мөселман динендәге 493 кеше (күпчелеге татарлар) исәпләнә, 1871 дә алар 663 кә (511 ир-ат һәм 152 хатын-кыз), 1882 дә 1831 кешегә (1548 ир-ат, 283 хатын-кыз) җитә. Татарларның 38% ы сәүдә өлкәсендә эшли, 31,4% ы — хәрби һәм дәүләт хезмәткәрләре, ирекле һөнәр ияләре; калганнары — олаучылар, тимер юлчылар, ашханә тотучылар һ.б. 1897 елгы халык исәбе буенча, шәһәрнең Сретенка (945 кеше), Тверской (605), Пятницкий (531) һәм Мясницкий (201) өлешләрендә татарлар аеруча күп яши. Аларның 41,6%ы сәүдә б-н шөгыльләнә. Татар сәүдәгәрләре кибетләренең күбесе шәһәрнең тарихи үзәгендә (Сретенка, Ильинка, Зур Татар урамнарында, Сумников, Колокольников һәм Зур Черкасский тыкрыкларында, София яр буе урамында, Неглинка проездында) урнаша. Төп товарлар: мех (башлыча, илтер һәм каракүл), эшкәртелгән күн, аяк киеме, мануфактура товарлары. Күн эшләнмәләрнең бер өлеше М.нең үзендә (татарларның сарык тиресен иләү һәмману урыннарында) эшкәртелә. Татарлар ш.у. юлаучылар йорты, рестораннар (иң танылганы Цветной бульвардагы «Кече Эрмитаж») һәм кунакханәләр (Сретенкада — «Казан», Рождественский бульварында — «Кырым») тота. 1917 гә кадәр шәһәрдә 2 таш мәчет эшли — Татар бистәсендә (иң беренче мәчет 1816 — 1819 да агачтан төзелә, таш мәчеткә 1823 тә нигез салына, 1858 һәм 1882 дә реконструкцияләнә; хәзерге *Тарихи мәчет*) һәм Выползов тыкрыгында (1904; Мәскәү Җамигъ мәчете, 2012 дә сүтелә); мәдрәсә (1871 дә ачыла), Данилов мөселман зираты (1771 дән) эшли. М.дә яшәүче татарлар туган телне һәм рус телен яхшы белүләре б-н аерылып тора. 1913 тә Баку нефть сәнәгатьчесе А.Ш.Асадуллаев иганәсенә Кече Татар тыкрыгында мөселман мәдәни үзәгенә әйләнгән йорт төзелә, анда татар мәктәбе, балалар бакчасы, китапханә, театр, клуб, басмаханә урнаша; «*Ил*» (1914–15) «*Сүз*» (1915–16), «*Безнең ил*» (1916–17) г-талары (мөхәррирләре Г.*Исхакый* һәм Н.*Гасрый*) нәшер ителә; татар драматурглары пьесалары буенча спектакльләр куела. Совет чорында монда татар вакытлы матбугаты редакцияләре урнашкан, С.*Садыйкова*, Ф.*Яруллин*, Р.*Ваһапов* һ.б. мәдәният эшлеклеләренең иҗат кичәләре һәм концертлары үткәрелгән. М.*Җәлил* тормышы һәм иҗатының Мәскәү чоры Асадуллаев йорты б-н тыгыз бәйле.



Казан вокзалы. Арх. А.В.Щусев. 1914–26.

Окт. рев-циясеннән соң М.дә совет һәм милли оешмалар «*Кызыл байрак*» (1917–18; Мөселман соц. ком-ты, мөхәррире М.*Вахитов*), «*Кызыл Армия*» (1918–19; Үзәк мөселман хәрби коллегиясе), «*Чулпан*» (1918–19; РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты, мөхәррире Г.Ибраһимов), «*Эшче*» (1918–19, 1921–31; Шәрекъ халыкларының РКП(б) ҮК каршындагы коммунистик оешмалары Үзәк бюросы) һ.б. газеталар нәшер ителә. Татар телендә журналлар да чыга: «*Кызыл Шәрекъ*» (1918–20, 1922–23; Шәрекъ халыкларының коммунистик оешмалары Үзәк бюросы һәм РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты), «*Яшь эшче*» (1921–22; Россия Коммунистик Яшьләр Союзы ҮК каршындагы татар-башкорт бюросы), «*Кечкенә иптәшләр*» (1924–28; ВЛКСМ ҮК каршындагы татар-башкорт бюросы балалар журналы, 1927–28 дә мөхәррире М.Җәлил) һ.б. 1922–28 дә «Нәшрият» нәшрияты эшли, ул татар телендә уку әсбаплары, иҗтимагый-сәяси, а.х., мед., техник һәм матур әдәбият чыгара. 1920–30 елларда М.гә шактый күп татарлар күчеп килә. Аларның күбесе «Динамо», «Красный богатырь», Сокольники вагон ремонтлау, В.В.Куйбышев исем. электр з-дларында, метрополитен төзелешендә, «Правда» нәшрият-полиграфия комб-тында эшли. Сугыш алды елларында татарлар Замоскворечье, Измайлово, Сокольникида тупланып яши. Гуманитар һәм техник өлкә-

ләрдә татар интеллигенциясе кадрларын формалаштыруда М.зур роль уйный. Меңләгән татар егетләре һәм кызлары шәһәрнең югары һ.б. уку йортларында белем ала. 1934 тә *Татар опера студиясе* ачыла, аны тәмамлаучылар Татар опера һәм балет театрында беренче труппаны оештыра. 1941 дә меңләгән татарлар һәм татарстанлылар шәһәрне немец-фашист гаскәрләре һөҗүменнән саклауда катнаша.

1944–49 да Театр сәнгате дәүләт ин-ты каршында О.И.Пыжова җитәкчелегендәге Татар студиясе эшли. 1957–61 һәм 1984–88 дә М.С.Щепкин исем. театр уч-щесендә татар студияләре оештырыла. Аны тәмамлаучылар арасында күренекле шәхесләр: Ф.*Әхтәмова*, Н.*Дунаев*, Н.*Ихсанова*, Г.*Исәнгулова*, Т.*Миңнуллин*, Р.*Таҗетдинов*, М.*Харисов*, Ф.Хәмитова, Ә.*Шакиров*, Р.*Шәрәфиев* һ.б. М.дә ш.у. шагыйрь һәм язучылар Ә.*Ерикәй*, Г.*Әпсәләмов*, М.*Львов*, Р.*Вәлиев*, Р.*Гәрәй* һ.б. укый. 1960 ка кадәр шәһәрдә 2 татар урта гомуми белем бирү мәктәбе эшли. М. татар телендә тарихи әһәмиятле чаралар үткәрү урынына әйләнә. 1917 дә *Бөтенроссия мөселманнарының беренче съезды* була, 1957 дә *Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы* уздырыла, «Семёновская» метро станциясе тирәсендәге бер урамга Шәймәрдан Ибраһимов исеме бирелә.

2012 гә шәһәрдә «Туган тел» (1989 дан) татар мәдәни җәмгыяте, «Мирас» Татар яшьләре үзәге (1991 дән; 1999 га кадәр «Ак Барс» исемен йөртә), «Интеллектуал» клубы (1992 дән), Бөтенроссия ислам мәдәни үзәге бүлекчәсе, Гомуммәскәү татар милли-мәдәни төбәк автономиясе (1997 дән), Мәскәү ФА татар җәмгыяте (1997 дән), «Ватаным» коммерцияле булмаган партнёрлык җәмгыяте, Татар милли мәгърифәт үзәге (2002 дән), «Берлек» төбәкара бизнес һәм мәдәният берләшмәсе (2004 тән) һ.б. иҗтимагый, мәдәни һәм икътисади оешмалар эшли. М.дә 4 мәчет бар. Дини оешмалар: «Бәйт-Аллаһ» мөселман җәмгыяте, РФ Ислам мәдәни үзәге (1991 дән), РФнең Европа өлеше мөселманнары дини идарәсе вәкиллеге (1998 дән), Ислам халыкара миссиясе, РФнең Мөселман оешмалары координацион үзәге, «Ярдәм» дини берләшмәсе; ш.у. «Хәләл» татар дини мирасын үстерү фонды, «Фатыйха», «Файда», «Ихлас» матди ярдәм фондлары. 1994 тән Җамигъ мәчет каршында Югары ислам көллияте, 1999 дан Мәскәү ислам ун-ты эшли. «Татарские новости» (1993 тән), «Ислам мөнбәре» (1995 тән), «Мусульманский курьер» (1998 дән), «Современная мысль» (1999 дан), «Татар доньясы» (2002 дән) г-талары, «Мусульмане» ж-лы (1992 дән) нәшер ителә. «Туган тел» татар мәдәни җәмгыяте каршында «Диләфрүз» милли театры, «Рината» балалар студиясе, «Уен» сатира театры, «Чишмә» һәм «Ләйлә» ансамбльләре эшли. М.нең 2 балалар бакчасында һәм 2 урта мәктәптә (№959, 1186) этнокультуралы татар компоненты б-н укытыла. 1986 дан Сабан туе бәйрәме үткәрелә. 1991 дән Ш.С.Сафин истәлегенә Бөтенроссия татар-мишәр көрәше уздырыла. М. б-н Татарстан арасында тыгыз икътисади һәм мәдәни элемтәләр урнашкан. Аларны координацияләү б-н *Татарстан Республикасының РСФСРдагы вәкаләтле вәкиллеге* (1994) шөгыльләнә. Татар акад. театры, *Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле* һ.б. иҗат коллективлары һәм аерым башкаручыларның гастрольләре даими уздырыла, респ-ка рәссамнары күргәзмәләре оештырыла. Шәһәрдә Муса Җәлилгә — 2 (2008, 2012), Г.Тукайга (2011) һәйкәл куелган. СССР ФА һәм РФАнең хакыйкый әгъзалары К.Ә.*Вәлиев*, Р.Ф.*Ганиев*, Х.М.*Миначев*, Р.И.*Нигъмәтуллин*, Р.З.*Сәгъдиев*, Р.Г.*Сюняев*; дәүләт эшлеклесе Ф.Ә.*Табиев*; Россия Мөфтиләр шурасы рәисе шәех Р.Гайнетдин; армия генералы М.Ә.*Гәрәев*; генерал-полковниклар Р.С.*Акчурин* һәм М.С.*Хәкимов*; язучы М.*Галәү*; хирург Р.С.*Акчурин*; халыкара журналист Ф.М.*Сәйфелмөлеков*; тарихчылар А.Г.*Әхтәмҗан* һәм Ә.Х.*Борһанов*; философлар Н.Б.*Биккинин*, Э.С.Кульпин-Губәйдуллин, А.В.Сагадеев; инженер-конструктор Р.И.*Утәмишев*; төзүче инженер А.Б.Беляев; СССР (РФ)ның атказ. спорт осталары А.Д.*Әлмәтов*, З.Х.*Билалетдинов*, И.Ф.*Гыймаев*, Р.Ф.*Дасаев*, А.М.*Кабаева*, Ш.С.*Сафин*, Ш.Ә.*Тарпищев*, В.Н.*Һидиятуллин*, Ш.Ш.*Хисаметдинов*, Г.С.*Хөсәенов*; халыкара гроссмейстерлар Е.И.*Бариев* һәм А.М.*Йосыпов*; дирижёр Ф.Ш.*Мансуров*; актриса Ч.*Хамматова*; балет артисты И.Җ.*Мөхәммәтов*; җырчы Р.И.*Ибраһимов* һ.б.ның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М. б-н бәйле.



Асадуллаев йорты.

*Әд.:* Р о з е н б е р г Л.И. Татары в Москве XVII — середины XIX века // Этнические группы в городах европейской части СССР (формирование, расселение, динамика культуры). М., 1987; С а д у р В.Г. Татарское население Москвы (1860 — 1905 гг.) // шунда ук. С. 26–39; А х т а м з я н А.А. Как зарождалась татарская община в Москве // Этносфера. 2001. № 10; Х а й р е т д и н о в Д.З. Мусульманская община Москвы в XIV — начале XX века. Н.Новгород, 2002; Х а к и м о в М.С., С а ф а р о в М.А. Татары: Воины. Труженики. Патриоты. М., 2006.

*А.И.Ногманов, А.И.Хәбибуллина.*

**«МӘСКӘ́Ү КОЧЕГА́РКАСЫ»**, атналык эшчеләр газетасы. ВКП(б)ның Мәскәү ком-ты Мәскәү өлкәсе бюросы, күмер чыгаручылар профсоюзы өлкә ком-ты һәм «Мәскәү-күмер» берләшмәсе органы. 1932 елның 16 сентябреннән 1933 нең 24 июненә кадәр Мәскәү өлкәсенең Донской эшчеләр посёлогында татар телендә нәшер ителә, барысы 38 саны чыга. Беренче 4 саны 1932 дә «Московская кочегарка» г-тасы битләрендә рус телендә басыла. Мәскәү өлкәсе күмер бассейнында эшләүче татар эшчеләренә атап чыгарыла. *Т.М.Насыйров.*

**МӘСКӘ́Ү МӘЧЕТЛӘРЕ́**, *Мәскәүдә Татар бистәсе* мөселманнар гыйбадәтханәсе 16 йөздән мәгълүм. Патша боерыгы б-н, 1649 елда православиедән башка дин гыйбадәтханәләре ябыла, Татар бистәсендә яшәүчеләрнең күпчелеге шәһәр яны бистәләренә күчә. 19 йөз уртасында Кунцево бистәсендәге 16–17 йөзләр мәчетенең археол. калдыклары һәм мөселман зираты табыла. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында манарасыз агач мәчет эшли (1812 елгы Ватан сугышы вакытында яна). 1816 да татарлар тарафыннан Тарихи мәчет төзелә, 20 йөз башына кадәр ул Мәскәүдә бердәнбер була, 1936 да ябыла, 1994 тә кабат мөселман җәмәгатенә кайтарыла. 1904 тә Җамигъ мәчет төзелә, 1930 да ябыла һәм Бөек Ватан сугышы чорында мөселман җәмәгатенә кайтарып бирелә, 2012 дә сүтелә. «Поклонная гора»дагы мемориаль мәчет Бөек Ватан сугышында һәлак булган мөселман сугышчылар истәлегенә Россиядәге төп диннәрнең гыйбадәт кылу биналары комплексында (1993 тә) төзелә (арх. И.Таҗиев). Күпкырлы биек манаралы, кырлы гөмбәзле, монументаль порталлы мәчет мөселман Шәрегының төрле архит-ра мәктәпләре элементларын чагылдыра. «Ярдәм» мәчете 1997 дә Отрадный бистәсендә «Һилял» татар рухи мирасын үстерү фонды башлангычы б-н һәм аның акчасына салына. Ике манаралы, гөмбәзле мәчет Россиядәге өч төп дин корылмалары комплексына керә.

**МӘСКӘ́Ү МӨСЕЛМА́Н ХАТЫ́Н-КЫЗЛАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать оешмасы. 1913 елның мартында Мәскәүдә оештырыла. Оештыручылары — М.П.Асадуллаева, Г.Тагиева, М.Б.Ширинская, М.Х.Шәмсетдинова, М.Бабишева һ.б. Төп максаты — мөселман хатын-кызлары уку йортлары һәм мәдәният учаклары эшчәнлеген җанландыру, мохтаҗларга ярдәм оештыру. Беренче бөтендөнья сугышы елларында яралы сугышчыларга һәм качак мөселманнарга ярдәм күрсәтә. Окт. рев-циясеннән соң эшчәнлеге туктала.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**МӘСКӘ́Ү ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Мәйданы — 47 мең *км²*. Үзәге — *Мәскәү* шәһәре. Халкы — 7048084 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 да — 52520 (Кырым татарларын да кертеп), 1989 да — 51059, 2002 дә — 52851, 2010 да — 56202 кеше. Татарлар, башлыча, Балашиха (1702 кеше), Воскресенск (1267), Дмитров (1084), Домодедово (1013), Ленин (1217), Люберцы (2607), Мытищи (1848), Наро-Фоминск (1619), Ногинск (2233), Одинцово (2350), Орехово-Зуево (2550), Пушкино (1942), Раменский (1633), Сергиев-Посад (1740), Щёлково (2016 кеше) р-ннарында (2002) яшиләр. 1999 да Төбәк татар милли-мәдәни автономиясе оештырыла, аның җирлегендә Сергиев-Посад, Орехово-Зуево, Одинцово, Наро-Фоминск, Люберцы, Пушкино р-ннарында, Дубна, Коломна, Электросталь, Подольск шәһәрләрендә, Молодёж-

ный посёлогында милли-мәдәни автономияләр төзелә. М.ө.ндә физика-матем. фән. д-ры, проф. Ф.А.Гәрәев, а.х. фән. д-ры, проф. М.К.*Каюмов*, техник фән. д-ры Р.М.Гатауллин туган; а.х. фән. д-ры К.Җ.*Мөхәммәтшин*, РФнең атказ. химигы М.Г.Бәдриевнең тормышы һәм хезмәте эшчәнлеге М.ө. б-н бәйле.

**МӘСКӘ́Ү ПРОТЕКТОРАТЫ́**, 1487–1521 елларда Казан ханлыгының Мәскәү кенәзлегенә сәяси буйсынып яшәү чоры. 1487 нең июлендә Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III гаскәре тарафыннан Казан яулап алынганнан һәм Илһам хан тәхеттән төшерелеп, гаиләсе б-н Вологда шәһәренә сөргенгә җибәрелгәннән соң урнаша. Иван III «Болгар кенәзе» титулы ала. М.п. шартлары буенча, ханнар барлык мөһим эш-гамәлләрен рус воевода-наместниклары б-н килештерергә тиеш булалар. Алар Мәскәүгә Нугай Урдасындагы хәлләрне хәбәр итеп торалар, Рус дәүләтенең Нократ җирләрен яулау сугышларында Казан ханлыгы отрядлары да катнаша. 1487 дән бөек Мәскәү кенәзлегенең Казан ханлыгы б-н ясак мөнәсәбәтләре туктатыла. Бу чорда Мәскәү б-н Казан арасындагы килешүләрдә гадәттә өч шарт куела: Казан хөкүмәте Мәскәү дәүләтенә яу чапмаска; Мәскәүнең бөек кенәзе рөхсәтеннән башка яңа хан сайламаска; ханлыкта яшәүче рус кешеләре мәнфәгатен кайгыртырга тиеш була. Рус хөкүмәте ш.у. рус сәүдәгәрләренә табыш китерерлек икътисади таләпләр дә куя. Шушы вакыттан башланган рус баскынчылыгы җирле феодаль аксөякләрдә ризасызлык көчәюгә китерә. 1490 еллар уртасына рус йогынтысындагы хөкүмәткә каршылар бердәм көч булып оешa, оппозиция башында карачыбәк *Колмөхәммәд*, Казан аксөякләре Урак, Садыр һәм Апиш тора. 1495 тә алар, тәхеткә Себер ханзадәсе Мамыкны утыртып, М.п.на чик куярга омтылыш ясыйлар. Ләкин яңа хан дәүләт б-н идарә итәргә сәләтсез булып чыга һәм шәһәрдән куып җибәрелә. 1496 да Нурсолтан ханбикәнең улы — Кырымда үскән, рус йогынтысына каршы булган Габделлатыйф хан дип игълан ителә. Ул бөек Мәскәү кенәзлегеннән котылу сәясәте алып бара. Шул сәбәпле 1502 дә тәхеттән төшерелә. Аны абыйсы Мөхәммәдәмин алыштыра. Ул хан тәхетендә утырган чорда Казанда рус воеводалары йогынтысы сизелерлек кими. 1505–06 дагы сугышта Казан гаскәре уңышка ирешкәннән соң, 1507 нең мартында Мәскәү б-н Казан арасында солых килешүе төзелә; 1520 гә кадәр тыныч мөнәсәбәтләр саклана. Шаһгали идарә иткән чорда (1519–21) рус киңәшчеләре йогынтысы кабат көчәя, алар ханлыкның эчке тормышы мәсьәләләрен хәл итүгә тыкшына башлыйлар; бу хәлләр Шаһгалинең тәхеттән куылуына һәм ханлык башына Кырым ханзадәсе Сәхибгәрәйне чакырып утыртуга китерә. 1521 нең язында тәхеткә менгән Сәхибгәрәй чоры Казанда русларга каршы һәртөрле һөҗүм-бәрелешләрдән башлана, аннары ул, гаскәр туплап Кырымнан Коломнага таба килүче бертуганы, Кырым ханы Мөхәммәдгәрәй б-н берләштә, Мәскәүгә яу чаба. 1521 нең җәендә Василий III солых килешүе төзергә һәм Мәскәүнең Кырым ханына буйсынуын танырга мәҗбүр була, аңа ясак түләп торырга вәгъдә бирә; Казан М.п.ннан тулысынча котыла.

*Әд.:* А т л а с и Һ. Казан ханлыгы. К., 1913; Г а з и з Г. Татар тарихы. К., 1922; В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1; Х у д я к о в М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923;

**МӘСКӘ́Ү ҮЗӘ́К ТАТА́Р ЭШЧЕ́ ТЕА́ТРЫ**, проф. театр. Мәскәүнең Коммуналь эшчеләр клубы каршындагы һәвәскәр театр түгәрәге җирлегендә Эшче театры исеме б-н оеша. Ул, нигездә, Донбасс, Кузбасс, Мәскәү яны, ш.у. Урал һәм Себер татар эшчеләренә хезмәт күрсәтә. 1926 елда Мәскәү татар драма труппасы дип үзгәртелә. Анда проф. актёрлар чакырыла; 1928 дән РСФСР Мәгариф халык комис-ты карары б-н М.ү.т.э.т. 1933 кә кадәр эшли. Коллективны оештыручы һәм аның җитәкчесе — Г.И.*Айдарский*. Труппаны Мәскәүдәге сәнгать югары уку йортлары студентлары, ш.и. М.Мәһдиев, Г.Саттаров, С.Садыйкова, А.Измайлова, Г.Ильясов, Г.Девишев, К.Поздняков, С.Булатов, Ә.Мәҗитов тәшкил итә. Коллектив Мәскәү коммуналь эшчеләр клубында урнаша. Спектакльләргә музыканы М.Мозаффаров, А.Ключарёв, Н.Җиһанов, З.Хәбибуллин яза, спектакльләрне рәссам П.П.Троицкий бизи. Театр репертуарын М.Фәйзинең «Галиябану», С.Батталның «Организатор», Г.Ильясиның «Тормыш көлә» («Бичара кыз»), Н.Исәнбәтнең «Качаклар», «Культур Шәңгәрәй», Ш.Камалның «Козгыннар оясында», «Ут», «Таулар», К.Тинчуринның «Кандыр буе», «Ил», «Зәңгәр шәл», Ф.Бурнашның «Хатирә апа», Г.Кутуйның «Балдызкай», «Директор Җәмилев», Д.И.Курдинның «Давыл арасында» пьесалары тәшкил итә. М.ү.т.э.т. Мәскәү Художество театры реализмы, ш.у. Мейерхольд исем. театр һәм Пролеткульт эшчеләр театрының формалистик эзләнүләре кебек сәнгать юнәлешләре йогынтысында була. Алар театрның иҗат стиле үзенчәлеген билгели. Этнографик башлангычка өстенлек бирүдән баш тартып, М.ү.т.э.т. драматургик конфликтны, аның социаль аспектларын ачарга омтыла. Спектакльләр вакыйгаларның кискенлеге һәм киеренкелеге, көтелмәгән чишелешләре б-н җәлеп итә. Бу театр сәхнәсендә беренче тапкыр шул заманның эшче образы тудырыла. Иҗади эзләнүләр атмосферасы күп кенә актёрларны үзенә тарта. Биредә Г.Камская, Р.Фәйзи, Г.Капкаев, Г.Булатова, Х.Уразиков, М.Мутин, М.Рәхмәтуллина, Г.Донской, Т.Капкаева, Г.Галиуллина, Г.Гыйматов, Х.Кәтиев, Г.Зыятдинов, Х.Ихсанова, З.Агишева, З.Сафин, Ф.Насретдинов, А.Кайбицкий, Т.Гыйззәт, С.Өметбаев, Х.Сәлимова, Г.Хисамов, Г.Сәгыйтов, Г.Ибраһимова, И.Гафуров, Ш.Сарымсаков, Ф.Халитов һ.б. эшли. Театрның иҗат ысулы 1930 еллар башында көчәеп киткән идеологик көрәш кысаларына туры килми. 1933 елның июнендә Бөтенроссия ҮБК карары б-н коллектив таратыла, актёрларның бер өлеше Татар акад. театрының колхоз ф-лы труппасы составына керә.

*Әд.:* А й д а р с к и й Г. Театр сәнгате. К., 1931; Татар совет театры. К., 1975.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МӘСКӘҮДӘ́ ТАТА́Р ӘДӘБИЯТЫ́ ҺӘМ СӘНГАТЕ́ ДЕКА́ДАСЫ** (1957 ел, 24 май — 2 июнь), СССР башкаласында ТАССРның мәдәни казанышларын беренче тапкыр күрсәтү бәйрәме. Декадада *Татар академия театры, Татар опера һәм балет театры, Казан Зур драма театры, Минзәлә татар драма театры, Татар филармониясе* коллективлары, иҗади берлекләр — язучылар, композиторлар, рәссамнар; 300 дән артык үзешчән артист катнаша. Республиканың театр коллективлары тарафыннан К.С.Станиславский һәм В.И.Немирович-Данченко исем., Кече, Үзәк балалар, Ленин комсомолы исем. Мәскәү театрлары сәхнәләрендә 50 ләп спектакль, ш.и. Н.Җиһановның «Алтынчәч», Х.Вәлиуллинның «Самат» опералары, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балеты (Татар опера һәм балет театры); Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», М.Әмирнең «Миңлекамал», Н.Исәнбәтнең «Зифа», «Хуҗа Насретдин», У.Шекспирның «Король лир» (Татар акад. театры); А.К.Толстойның «Фёдор патша», М.Горькийның «Карт», А.Н.Афиногеновның «Үз балаларының әнисе», Р.Ишморатның «Үлемсез җыр», М.Н.Елизарованың «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» (Казан Зур драма театры); М.Фәйзинең «Галиябану», Ю.Әминевнең «Язылмаган законнар» (Минзәлә татар драма театры) әсәрләре буенча спектакльләр куела. П.И.Чайковский исем. Концертлар залында Татар филармониясенең җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясый (к. *Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле*). Союзлар йортының Колонналы залында Татарстан язучыларының чыгышлары була, СССР СА залларында ТАССР сынлы сәнгать әсәрләре күргәзмәләре оештырыла. Башкаланың мәдәни җәмәгатьчелеге тарафыннан республика язучылары, рәссамнары һәм театр коллективлары иҗатына карата фикер алышулар уздырыла. Декаданың Зур театрда узган йомгаклау концертында СССРның партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре, Мәскәүдәге илчелек һәм дипломатия башлыклары була.

*И.И.Илялова.*

**МӘСКӘҮДӘ́ ТАТА́Р БИСТӘСЕ́**, Зур Татар урамы (Большая Татарская) тирәсендә татарлар электән тупланып яшәгән бистә. Чыганакларда беренче тапкыр 1619 елда телгә алына, ләкин аңа элгәрерәк нигез салынгандыр дип фаразлана (тарихчы М.Н.Тихомиров фикеренчә, М.т.б. 16 йөздә үк булган). Тарихи атамасы б-н бергә, бистәнең «Татар урамы» дигән икенче исеме дә бар. *Мәскәүдә тылмачлар бистәсе* кебек үк, Татар бистәсе башкалада «чит кавем» бистәсе санала; анда яшәүчеләр гомуми законнарга буйсынсалар да, беркадәр үзидарәгә ия булалар; Пётр I чорында әлеге бистәләр автономия элементларын югалталар. 17 йөздә Татар бистәсендә Илчелек приказында тылмач вазифасын башкаручы татарлар яши; соңрак бирегә татар сәүдәгәрләре урнаша башлый. Чыганакларда бистә халкының катнаш булуы әйтелә: 1669 да — 18 хуҗалыкның 9 ында, 1730–40 елларда — 80 нән 12 сендә, 1826 да — 35 тән 8 ендә татарлар яши. 20 йөз башында элекке-

ге Татар бистәсе урнашкан район һәм аның тирәсендәге терр-яләр мөселманнарның тупланып яшәү урынына әверелә. М.т.б.нең үз мәчете була (беренче тапкыр 1744 тә телгә алына, к. *Тарихи мәчет*, *Мәскәү* ш.).

*Әд.:* Р о з е н б е р г Л.И. Татары в Москве XVII — середины XIX века // Этнические группы в городах европейской части СССР (формирование, расселение, динамика культуры). М., 1987; Х а й р е т д и н о в Д.З. Мусульманская община Москвы в XIV — начале XX вв. Н.Новгород, 2002.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МӘСКӘҮДӘ́ ТЫЛМАЧЛА́Р БИСТӘСЕ́**, 15–17 йөзләрдә татарлар аерымланып яшәгән бистә, Мәскәүнең хәзерге Зур һәм Кече Тылмач тыкрыклары тирәсендә урнашкан була, башкаланың «чит кавем» бистәләреннән санала. Тылмачлар бистәсендә, башлыча, Илчелек приказында тылмач вазифаларын үтәгән Касыйм һәм Романов (Кострома) татарлары яши. Бистәдә яшәүчеләр гомуми закон-тәртипләргә буйсынсалар да, беркадәр үзидарәгә ия булалар. Пётр I чорында әлеге бистәләр автономия элементларын югалталар.

*Әд.:* Имена московских улиц: Топоним. словарь. М., 2007.


**МӘСНӘВИ́** (гарәп. مثنوى — икеләтелгән, янәшә куелган, кушылган), Шәрекъ поэтик атамасы: 1) шигырь юллары бердәй үлчәмле, үзара рифмалашкан, интонацион һәм мәгънәви яктан чагыштырмача бөтен һәм мөстәкыйль бәйт; 2) аа, бб, вв рәвешендә рифмалашучы бәйтләрдән төзелгән фәлсәфи-дидактик, романтик-героик әсәр. М. формасы эпик поэзиягә хас; лирик шигырьләрдә монорим (бөтен шигырьгә бер рифма) кулланыла. Бу форма урта гасырлар фарсы әдәбиятында барлыкка килеп, төрки халыклар әдәбиятларында киң тарала. Урта һәм зур күләмле эпик һәм лироэпик әсәрләрдә (Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Нәвоинең «Хәмсә»се) еш очрый. М. формасында Баласагуниның «Котадгу белег» поэмасы, Котб, Хисам Кятиб, Мөхәммәдъяр поэмалары, Г.Утыз Имәни, Ә.Каргалый, Г.Чокрый, Г.Тукай, Н.Думави шигырьләре язылды.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; К в я т к о в с к и й А. Поэтический словарь. М., 1966.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘТӘСКӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Тәмте елгасының (Мишә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,1 *км*, бассейнының мәйданы 58,6 *км²*. Теләче р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Лесной посёлогыннан 1 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Тәмте-Мәтәскә авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 96 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%, М.нең 1 дән алып 3,2 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәре тыгызлыгы 0,4 *км/км²*. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен лык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 125 *мм*, ташу вакытында су катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м³/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. М. бассейнында суның гомуми күләме 1,8 млн. *м³* булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘТРҮШКӘ́** (Origanum), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 дән артык төре билгеле, Европа һәм Азиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади М. (O. vulgare) бар. Урман аланнарында, тау битләрендә үсә, респ-каның барлык терр-ясендә таралган. 30–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы шуышма. Сабагы туры, җете төстә, төкчәле. Яфраклары йомыркасыман озынча, өсте куе яшел төстә, асты кара нокталы соргылт яшел. Чәчәкләре вак, җете алсу, калкансыман-себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган. Җимешләре 4 чикләвекчеккә таркала. Июльдән сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре август башында өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Җир өсте өлешләрендә эфир майлары, дуплау матдәләре, аскорбин к-талары бар. Тынычландыру чарасы, бронхларны, ашкайнату системасы бизләренең секрецияләрен куәтләндерә. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе какырык чыгару һәм бәвел кудыру өчен кулланыла. Күп кенә дару җыелмалары составына керә. М.не тәмләткеч буларак кулланалар. Баллы үсемлек, татар халкы чәйгә салып эчәргә ярата. М.нең эфир мае парфюмериядә кулланыла.



Гади мәтрүшкә.

**МӘҮЛА́ КАЗЫ́Й МӨХСИ́Н** (14 йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. *«Китабе Гөлестан бит-төрки»* кульязма җыентыгында урын алган газәл жанрындагы шигыре б-н мәгълүм. Анда лирик геройның сөйгәне, аның «адәмиләр җаны» булуы тасвирлана; кызның чибәрлеге «ай б-н кояшны» таң калдыра, аның алдында зифа буйлы кипарислар баш ия.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛА́ КОЛЫ́Й** (Меллагол, Бәйрәмгали Колыев, Бимкә суфи) (1630 нчы еллар, Казан өязе Чыты а., башка мәгълүматларга караганда, Колай а. — 18 йөз башы, хәзер Лениногорск р-ны Иске Иштирәк а. дип фаразлана), суфи шагыйрь, дин эшлеклесе. Казан арты мәдрәсәләренең берсендә белем ала. 1670 елларда Болгар шәһәре тирәсендә яши, дини-агарту эшләре б-н шөгыльләнә. Шуның өчен рәсми хакимият тарафыннан эзәрлекләнә. 1699 да гаиләсе б-н Иске Иштирәк авылына күчә һәм, кайбер мәгълүматларга караганда, вафатына кадәр шунда яши.

М.К. — төрки суфи шагыйрьләр Ә.Ясәви һәм С.Бакыргани традицияләренең дәвамчысы. М.К.ның бөтен иҗаты аларның идеяләре б-н сугарылган. 20 йөз ахырында табылган «Береккәннәр сыйфаты» һәм «Хәләл нәфкъә эстәгәнләр сыйфаты» («Хәләл ризык эстәүчеләр») поэмаларының авторы. Әсәрләрнең икесе дә безнең көннәргә тулаем рәвештә килеп җитмәгән: беренчесенең бернечә бите юк, икенчесенең баштагы өлеше генә сакланган.

М.К.ның 100 дән артык шигыре (3800 юлга якын) мәгълүм. Алар биш күчермәсе сакланган «Хикмәтләр» исемле кульязма җыентыкка кертелгән (1669–70; бүтән мәгълүматларга караганда, 1678–79). Җыентыкны 1925 тә фольклорчы Ф.Туйкин таба һәм бу хәбәрне «Кызыл Татарстан» г-тасында бастыра (1926 ның 26 октябре). Күчермәләрне өйрәнгән әдәбият галиме Г.Сәгъди шигырьләрнең бер өлешен (400 строфа чамасы) «Вестник Научного общества татароведения» ж-лында бастырып чыгара (1927, № 7). 1950–60 елларда кайбер шигырьләре татар һәм рус телләрендә дөнья күрә. Тулырак басмалар К.С.Дәүләтшин һәм М.В.Гайнуллин тарафыннан әзерләп бастырыла.

М.К. шигырьләрен тирә-як һәм анда яшәгән кеше, яшәү һәм үлем турындагы уйланулар тәшкил итә. Шагыйрь фикерләвенчә, дөньяда һәр нәрсәнең башында Аллаһ тора. Дөньяны ул тирән мәгънәгә ия булган китап рәвешендә күзаллый. Кешенең максаты — шул китапны өйрәнү: «Күр ислямны, ни гаҗәп — Мәгънә тулук бер китап; Бак галәмгә кыл хисап, Гыйбрәт тулуг галәми». М.К. кешенең әхлакый йөзен ислам нигезләреннән чыгып бәяли һәм аңа зур әһәмият бирә. Аныңча иң мөһим сыйфатлар арасында — ата-анага хөрмәт, балаларны кайгырту, мескеннәргә карата мәрхәмәтле булу һәм, билгеле, яшәү чыганагы — хезмәт. Җәннәткә керү өчен Аллаһның хуплавына лаеклы эш — игенчелек дип фаразлана:

Игенчелек — галәмада изге аты,
Нигъмәт йийләр мөэмин, кяфир — юктыр каты.
Игенчене көйдермәгәй тәмуг уты,
Игенчелек — гали эшдер — кыйлыр булсаң.

М.К.ның игелекләр турында уйланулары суфилар турындагы фикерләре б-н аваздаш. Аның карашынча суфи — югары әхлаклы, тирән уйлый торган, белемгә ия булган идеаль кеше. Күңел бушлыгын суфи битлеге белән каплаучы, икейөзле, үз-үзен генә яратучыларны шагыйрь тәнкыйтьли. Дөньяга дан җырлап, игелекле тормышка өндәп, ул тормыш-яшәешнең «мәңгелек дөньяга» таба юлда кыска гына бер тукталыш икәнен, фани икәнлеген дә онытмый:

Үлем эше катигъ эшдер, белгел аны
Бу дөнъйа барчаларга ирер фани
Терек куймаз, илтәр барча — сәне, мәне,
Җефетләрне тол кыйлгусы ушбу үлем.

Шигырьләренең күбесе 4 юллык строфа б-н язылган. Гадәттә, алар аааб, вввб схемасы буенча рифмалаштырыла; кайвакытта һәр строфаның соңгы юлы кабатлана. Сурәтләү чараларыннан М.К. антитезаны, риторик мө-

рәҗәгатьне, символларны яратып куллана. Әсәрләренең теле гади, аңлаешлы. М.К.ның тормышы һәм иҗаты Ф.К.Туйкин, Г.Г.Сәгъди, К.С.Дәүләтшин, Ш.Ш.Абилов, Х.Й.Миңнегулов, М.И.Әхмәтҗанов һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

Ә с ә р.: Хикмәтләр. К., 2001.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. Т. 1; Д ә ү л ә т ш и н К. Борынгы татар әдәби мирасы. Мәүлә Колый хикмәтләре. Эстәрлетамак, 2002; Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. К., 1999; К а д и р о в а Э.Х. Язык хикметов татарского поэта XVII в. М.Кулыя. К., 2003.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛӘНА́ ГЫЙМА́Д МӘҮЛӘВИ́** (14 йөз), төрки-татар шагыйре. «Мәүләна» тәхәллүсе (гарәп. иябез, хуҗабыз — мөхтәрәм затларга, дин эшлеклеләренә мөрәҗәгать итү формасы) б-н мәгълүм. «Китабе Гөлестан бит-төрки» кулъязма җыентыгыгына кергән үзенең бер шигыре (6 бәйт) б-н билгеле. Шигырьдә лирик геройның мәхәббәт газаплары кичерүе тасвирлана. Бу шигырьгә Сәйф Сараи назыйрә яза.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛӘНА́ ИСХА́К** (Хуҗа Исхак, Мәүлана Исхак Харәзми) (14 йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. «Харәзми» тәхәллүсенә караганда, чыгышы б-н Харәземнән булса кирәк. «Китабе Гөлестан бит-төрки» җыентыгына кергән ике газәл (биш һәм җиде бәйттән торалар) һәм Алтын Урда шагыйрьләре әсәрләре тупланмасы булган «Ядкярнамә»гә кергән бер фәрд авторы буларак билгеле. Ике газәле дә мәхәббәткә багышлана: лирик герой сөйгәнен сагына, аның б-н очрашырга омтыла; икесендә дә төрки-мөселман мифологиясенең танылган персонажлары (Искәндәр, Нух, Хозыр) бар. Газәленең берсенә Сәйф Сараи назыйрә яза. Фәрдендә М.И. яшәү һәм үлем турында уйлана: «Җиһан сәүгән кешенең күзләрен канәгать тулдырыр, үлсә — тупрак». Әсәрләре образлы, бай тел б-н язылган.

*Әд.:* М и ң н е г у л о в Х. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛӘ́ТШИН** Минзөфәр Мәүлет улы (24.11.1934, Түбән Новгород крае, Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн а.), хокук белгече, югары квалификацияле судья (1996), ТРның, РФнең атказ. хокук белгече (1994, 1995). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1962). ТР Югары мәхкәмәсендә: 1963–75 елларда әгъза, 1975–93 тә рәис урынбасары, 1993–2005 тә рәиснең 1 нче урынбасары. Хезмәтләре гражданлык, хезмәт хокукы, мәхкәмә корылышы һәм мәхкәмә эшләрен башкару мәсьәләләренә карый.


Х е з м.: История Верховного суда и судебной системы Республики Татарстан (конец XIX — начало XXI в.). К., 2011.

**МӘҮЛЕБЕ́РДИН** Солтан Фәррах улы (2.3.1937, Ленинград — 8.11.2001, С.-Петербург), театр рәссамы, нәкышьче, график. А.Н.Островский исем. Ленинград театр ин-тының театр куелышы ф-тын (Н.П.Акимов остаханәсе) тәмамлый (1961). Новосибирскидагы «Красный факел» театрында сәхнәгә куючы рәссам (1961–64), Воронеж Яшь тамашачылар театрында баш рәссам (1964–66), РСФСР Сәнгать фондының Воронеж бүлегендә бизәүче рәссам (1966–73), бер үк вакытта өлкә нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. 1973 тән — Ленинградта, Ленсовет исем. театрда рәссам, Ленинград телевидениесендә сәхнәгә куючы рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1975). М. бизәгән спектакльләр арасында — А.Н.Арбузов пьесасы буенча «Шәһәрдә таң» («Город на заре»), Дж.Родари әкияте буенча «Джельсомино алдакчылар илендә» («Джельсомино в стране лжецов»), А.Гайдар повесте буенча «Барабанчы язмышы» («Судьба барабанщика»), А.Вампилов пьесасы буенча «Өлкән ул» («Старший сын»), М.Горький пьесасы буенча «Залимнәр» («Варвары») һ.б.лар бар (1962–66).




С.Ф.М ә ү л е б е р д и н. «Пляжда». 1980.

М.ның сценография, нәкышь һәм графика әсәрләренә образларның югары дәрәҗәдә гомумиләштерелүе, кыска, ачык пластик форма, сәнгать теленең кырыс тыйнаклыгы хас. М. монументаль һәм аеруча станлы нәкышьтә уңышлы эшли, нәкышь (май, темпера) һәм график натюрморт (офорт, литография, линогравюра, гуашь) остасы булып танылa, пейзаж һәм портретка мөрәҗәгать итә; еш кына образны билге яки символ буларак сурәтли (офорт — «Натюрморт», 1978; нәкышь — «Шешә һәм рюмка белән натюрморт», 1978; «Көзге каршында 1», «Көзге каршында 2», гуашь, 1980 еллар; «Төсләр натюрморты», 1990; «Кызыл урындыкта», 1991; «Натюрморт 5», 1997; «Баш сөяге һәм китап», 1990 еллар; «Авылда төн», «Дачада», «Җәйге бакчада», «Сусанна», 1980 еллар; «Малай портреты», 1985 һ.б.).



С.Ф.М ә ү л е б е р д и н. «Малай портреты». 1985.



М.М.Мәүлиев.

«Кара туфраклы төбәк» исемле зона (1960 еллар), Ленинград рәссамнарының шәһәр (1975 елдан), нонконформист рәссамнар (Ленинград, 1982–83), «Татарт» төбәкара бөтентатар (С.-Петербург-Казан, 1991) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1991, 2002, 2004 елларда уза (С.-Петербург).

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Б.М.Кустодиев исем. Әстерхан картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Мавлюбердин Султан Фаррахович. Живопись. Графика: Буклет. СПб., 2004.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӘҮЛИ́Д КИЧӘСЕ́** (гарәп. مولد — мәүлид ән-нәби, сүзгә-сүз — пәйгамбәрнең тууы), 1) *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең туган көне уңаеннан үткәрелүче бәйрәм. Мөселман ай календаренең 3 нче ае — рабигыль-әүвәлнең 12 нче көнендә билгеләп үтелә. Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне төгәл билгеле булмаганлыктан, М.к. аның үлгән көненә туры китереп үткәрелә. Элегрәк бәйрәм сөнни илаһиятчеләр тарафыннан тыелган яңалык итеп игълан ителә (*бидгать*), ләкин соңрак мөселман хокук белгечләренең килешенгән карары (иҗма) б-н, «хупланган яңалык» дип беркетелә. Коръән укыганнан һәм сәдака өләшкәннән соң, кычкырып мөнәҗәтләр (мәүлид) укыла, мәчетләрдә вәгазь сөйләнә. Кайбер илләрдә мөселманнар факеллы, тантаналы йөреш оештыралар, пәйгамбәрнең анисе — тәкъва Әминә сурәтен күтәреп баралар, мәчетләрдә аның хөрмәтенә гыйбадәт кылына. Пакъстанда М.к. — дәүләт бәйрәме. 2) Мөселман изгеләренең туган һәм үлгән көннәрен бәйрәм итү (к. *Әулия*).

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**МӘҮЛИ́ЕВ** Мисбах Мәүли улы (10.2.1929, Минзәлә кантоны Чулпан а.) тау технигы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1961 елда Кизел тау техникумын тәмамлый (Пермь өлкәсе). 1952–74 тә «Кизелуголь» комб-тының (Пермь өлкәсенең Губаха ш.) «Ключевская» шахтасында проходчик (казучы), тау мастеры (1966 дан). Герой исеме күмер һәм сланец сәнәгатен үстерү буенча җидееллык планны (1959–65) үтәгәндәге уңышлары һәм хезмәттә югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. 1974–2000 дә «Түбәнкаманефтехим» АҖдә компрессорлар машинисты, обходчик, слесарь-ремонтлаучы. КПССның 22 нче съезды делегаты (1961). Ленин ордены, медальләр, «Шахтёр даны» билгесе б-н бүләкләнә.



В.С.Мәүликов.

*Әд.:* Герои Труда. Пермь, 1975; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МӘҮЛИ́КОВ** Васил Салих улы (30.10.1943, Кукмара р-ны Югары Шәмәрдән а.), ташчы, Соц. Хезмәт Герое (1981), ТАССРның атказ. төзүчесе (1976). 1 нче уч-щене тәмамлаганнан соң (Юдино пос., 1961), Горький тимер юлының 5 нче юл-төзелеш трестында ташчы булып эшли. 1965–69 елларда Казан органик синтез з-дында аппаратчы. 1969–99 да «Камгэсэнергострой» АҖДә (Чаллы ш.) ташчы, ташчылар бригадиры (1970 тән). 1971–75 тә, 1976–80 дә М. җитәкчелегендәге бригада йөкләмәләрне даими рәвештә 190–200% ка җиткереп үти. Герой исеме Кама зур йөк автомобильләре җитештерү берләшмәсе куәтләренең 2 нче чираты төзелешендә һәм берләшмәнең куәтләрен үзләштергәндә ирешелгән уңышлары өчен бирелә. ВЛКСМның 16, 17, 18 нче съездлары делегаты. Франция һәм СССР яшьләр берләшмәләре конференциясендә катнаша (Париж, 1972), 10 нчы Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале делегаты (Берлин, 1973). М.Җәлил исем. ТАССР комсомолы бүләге (1974), Ленин комсомолы исем. бүләк (1975) лауреаты. 1984–89 да СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Паушкин Г. Батыр на Каме. К., 1971; Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МӘҮЛИ́Н** Габделхак Мәүлә улы (15.8.1934, Кукмара р-ны Өркеш а. — 7.1.1996, Яшел Үзән р-ны Осиново а.), галим-агроном, а.х. производствосын оештыручы, РСФСР, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986, 1992). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Кукмара р-нының «Нырты» с-зында агроном, 1960–65 елларда «Яңа тормыш» к-зында рәис булып эшли. 1965–79 да Саба р-нында: а.х. җитештерү идарәсендә башлык, район башкарма ком-ты рәисе (1972 дән). 1979–84 тә ТАССР а.х. министрының беренче урынбасары, «Татарское» кошчылык ҖБдә ген. директор (1984–95). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бер алтын, алты көмеш медале б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МӘҮЛИХА́НОВ** Үмәр Абдулла улы (24.9.1937, Мәскәү), спортчы, тренер (фехтование), СССРның атказ. спорт остасы (1964), РСФСРның атказ. тренеры (1975). Шәхси һәм команда беренчелегендә СССР чемпионы (1963, 1967–68), дөнья чемпионы (1965, 1967, 1969), команда беренчелегендә Олимпия уеннары чемпионы (1964, 1968), шәхси беренчелектә Олимпия уеннарында бронза медаль ала (1964). Медальләр б-н бүләкләнә. Мәскәүдә яши.

**МӘҮЛҮ́ТОВ** Мидхәт Рәхмәтулла улы (16.2.1928, БАССРның Бәләбәй р-ны Шланлыкүл а. — 8.12.2000, Уфа ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1973), БР ФА мөхбир әгъзасы (1995), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988), БАССРның атказ. нефтьчесе (1973), СССРның мактаулы нефтьчесе (1978). 1950 елда Уфа нефть ин-тын (хәзер Уфа нефть техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1953–56 да Мәскәү нефть ин-тында), нефть-тау токымнары ф-ты деканы (1958–62), нефть-газ скважиналары каф. мөдире (1964 тән), бер үк вакытта проректор (1965–70), проф. (1974); директоры (1989–91) һәм «Азимут» конструкторлык-технол. бюросының фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре бораулау һәм углеводородлар чыгару технологияләренә карый. М. забойга дулкын табигатьле тәэсир итүнең техник чараларын һәм технологияләрен эшли, бораулау тизлеген арттыру өчен майлагычлар уйлап таба. Аның җитәкчелегендә нефть катламнарын икенчел эшкәртү һәм скважиналарны ремонтлау алдыннан сүндерү технологияләре эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 105 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге (1983, 1987), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге (2000) лауреаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Разрушение горных пород при бурении. М., 1978 (автордаш); Смазочное действие сред в буровой технологии. М., 1993 (автордаш).

*Әд.:* Башкирская энциклопедия. Уфа, 2008. Т. 4.

**МӘҮЛҮ́ТОВ** Рифат Рәхмәтулла улы (20.3.1926, БАССРның Бәләбәй р-ны Шланлыкүл а.- 25.7.2000, Уфа ш.), машиналар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1975), РФА мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972, 1990). 1949 елда Уфа авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү авиация-технол. ин-тында эшли. 1953–92 дә Уфа авиация ин-тында, проректор (1960–61), ректор (1961 дән), бер үк вакытта материаллар каршылыгы каф. мөдире (1973 тән), проф. (1975). 1992 дән РФА Уфа гыйльми үзәгенең Механика ин-тында: директор, деформацияләнүче каты җисем механикасы лаб-ясе мөдире, 2000 нән өлкән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре деформацияләнүче каты җисем механикасына һәм авиация конструкцияләре элементларының ныклыгы мәсьәләләренә карый. М. каты җисемнәрне нәстационар үзле-сыгылмалы- пластик деформацияләү процессларының физик-матем. модельләрен һәм санлы алымнарын эшли. Киеренке деформацияләнгән халәтне исәпләүнең нәсызыкча мәсьәләләрен чишә, сыгылмалы-пластик деформация шартларында көчәнешләр тупланышы һәм материалның төрле йөкләнешләр алгандагы шуышучанлыгы мәсьәләләрен тикшерә. Авиация конструкцияләрендәге җылылык йөкләтелгән элементларны аларның йөкләнеше характерын исәпкә алып исәпләү, проектлаштыру һәм ышанычлы ныклыгын тәэмин итүне, ш.у. конструкцион материалларның нәсызыкча торышларын яңача нигезли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. «Белем» җәмгыятенең Башкортстан бүлеге идарәсе рәисе (1976–84). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре; БАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Повышение прочности и надёжности резьбовых соединений. М., 1979; Высшая школа глазами ректора. М., 1992; Сопротивление материалов. М., 1994; Концентрация напряжений в элементах авиационных конструкций. М., 1996.

*Әд.:* Башкирская энциклопедия. Уфа, 2008. Т. 4.

**МӘҮЛҮ́ТОВ** Хөсәен Бәһаветдин улы (август 1893, Чистай ш. — 1937), Кызыл Армия командиры, полковник (1935). Казан татар укытучылар мәктәбен (1915), Чугуевск хәрби уч-щесен (1916), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү, 1926) тәмамлый. 1900 елда Мәүлүтовлар гаиләсе Пермь шәһәренә күченә, 1911 дән М. — Казанда. 1915 тә Россия армиясенә алына. Көньяк-Көнбатыш фронтта, 74 нче дивизиянең 295 нче Свирск пехота полкында рота командиры булып хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң рота мәхкәмәсе рәисе, полкның солдат ком-ты әгъзасы. 1917 нең көзендә, авыр яраланып, дәвалану өчен Пермьгә җибәрелә. 1918 дә Мөселманнар эшләре буенча Пермь округы комис-ты рәисе. Пермьдә Кызыл Армиянең татар-башкорт берләшмәләрен оештыручыларның берсе. Вятка губерна башкарма ком-ты әгъзасы, Вятка губернасы Милләтләр эшләре буенча комис-т рәисе (1919). Гражданнар сугышында катнаша. 1919 дан Кызыл Армиядә — Идел буе 1 нче аерым татар укчы бригадасында 3 нче полк командиры. Оренбург фронтында сугыша, 1920 елгы Бохара операциясендә һәм Фирганә үзәнендәге сугышларда катнаша. Хәрби академия тәмамлаганнан соң, Эшче-крәстиян Кызыл Армиясенең Разведка идарәсенә җибәрелә. Кайбер мәгълүматлар буенча, 1926–31 дә Иранда дипломатия эшендә була. Соңрак Кызыл Армиянең Разведка идарәсендә бүлек башлыгы ярдәмчесе, Кызыл байраклы Кавказ армиясе штабының разведка бүлеге башлыгы. Ике Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Гришин Я.Я., Шарафутдинов Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

**МӘХӘЛЛӘ́** (гарәп. محلة — урын алу, урнашу), шәһәрнең берничә кварталын яки зур авылның бер өлешен берләштергән, кайбер адм. һәм дини үзидарә элементлары булган мөселман җәмгыяте (өммәт). Шәһәрләрдә М. җитештерү-һөнәрчелек яки катлау һәм нәсел-ыру билгеләре буенча оешкан, кайвакыт исемнәре дә шуңа туры килгән. Җәмәгать

карамагындагы мәчет М. үзәге булып торган. Элек авыл М.сендә үзидарә башлыгы вазифасы старостага (аксакал) йөкләнгән, сайлау вакытында аны тәкъдим итү хокукы еш кына имам-хатип кулында булган. Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада, Казан ханлыгында М.нең социаль-сәяси формасы башка мөселман дәүләтләрендәге җәмгыятьләрдән бер ягы б-н дә аерылмаган. Татарларда М.нең роле Казан ханлыгы яуланганнан соң үзгәрә (1552); мөселман җәмәгате 16 йөзнең уртасыннан 18 йөзнең ахырына кадәр ябык конфессиональ җәмгыять төзелү аркасында гына исән кала. Мөселман халкының рухи ихтыяҗлары тулысынча читкә кагылган шартларда мәдәни һәм дини традицияләрне саклап калуда аның әһәмияте чиксез зур була. Татар М.се башка конфессиональ тирәлекнең (православие) турыдан-туры тәэсире нәтиҗәсендә үзенчәлекле сыйфатлар ала. Аерым алганда, берләштерүче адм. хакимият структураларының булмавы нәтиҗәсендә, татар М.сен җитәкләгән *мөселман руханиларының* йогынтысы арта. Руханилар өстен хокуклы катлау булмый, ләкин, элек-электән килгәнчә, мөселманнарның гаилә-көнкүреш һәм мирас мөнәсәбәтләренә зур йогынты ясый. Үз бурычларын башкару б-н бергә, җәмгыятькә шактый акча китергән мәхәллә *мәктәпләре* яки *мәдрәсәләре* М.нең мөһим институтларыннан санала. Берләшмә әгъзалары яңа М. оештыру, руханилар сайлау, мәчет төзү (төзелеш уставына үзгәрешләр алдан килешеп кертелә) хокукына ия булган: моның өчен кимендә 200 ир-атның ризалыгы җиткән, мәчетләрне христиан дине корылмалары һәм яшәү урыннары h.б. б-н янәшә төзү тыелган. Татар буржуазиясе барлыкка килү һәм үсеш алу нәтиҗәсендә җирле мөселман җәмгыятьләре тотрыклылана, адм.-хуҗалык аппараты функцияләре үзгәрә: руханилардан тыш, аеруча абруйлы кешеләр арасыннан кайгыртучы — мөтәвәлли (кагыйдә буларак, эшләре алга киткән сәүдәгәр, авыл бае) җитәкчелегендәге мөтәвәллият сайлана. Сайлау М.нең барлык әгъзалары катнашында, ачыктан-ачык үткәрелә; аннары нәтиҗәсе нотариуста һәм Уфа шәһәрендәге Оренбург мөселман диния мәҗлесендә раслана. Мөселман җәмгыятьләренең финанс мөстәкыйльлекләрен тәэмин итүдә хәйриячелек эше (18 йөздә — 20 йөз башында иганәчеләр акчасына 17 мәчет төзелә), вакыф (к. *Вакыф*) милке (мәчет карамагына мәңгегә тапшырылган күчемле һәм күчемсез милек) зур әһәмияткә ия була. Окт. рев-циясенә кадәр Казандагы барлык мәчетләрнең дә вакыф милке (табыш йортлары, кибетләр, җир кишәрлекләре рәвешендә h.б.) була, алардан кергән табыш М. ихтыяҗларына тотыла. Совет чорында М. ин-ты гамәлдән чыга һәм 1990 елларда, СССР таркалганнан соң, мәчетләр тергезергә һәм төзергә керешкәч, М. яңадан оеша башлый. 2013 ел ахырына Татарстанда 1400 ләп М. эшли.

*Әд.:* К о б л о в Я.Д. О магометанских муллах. К., 1998; М у х а м е т ш и н Р.М. Ислам в общественной и политической жизни татар и Татарстана в XX веке. К., 2005; Х а й р у т д и н о в Р.Р., С а л и х о в Р.Р. Исторические мечети Казани. К., 2005.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**«МӘХӘЛЛӘ́ ХӘБӘРЛӘРЕ́»**, рәсемле бюллетень-җыентык. *Ислам җәмгыяте* (Финляндиядә) органы. 1949–63 елларда Хельсинкида елга 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 60 саны чыга. Мөхәррирләре — О.Али, А.Али, З.Таһир h.б. Иҗтимагый-сәяси, дини темаларга багышланган мәкаләләр басыла. Балаларга багышланган рубрикада татар халык әкиятләре, Г.Тукай шигырьләре бирелә. Җыентык Финляндиядә яшәүче татарлар тарихын өйрәнү буенча әһәмиятле чыганак булып тора. «М.х.» 2000 нән яңадан нәшер ителә башлый.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**МӘХКӘМӘ́ СИСТЕ́МАСЫ**, ТРда мәхкәмә хакимиятен гамәлгә ашыручы барлык мәхкәмәләр системасы. М.с.ның һәр буыны бертөрле мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле мәхкәмәләр җыелмасыннан гыйбарәт. Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада, Казан ханлыгында мәхкәмә хакимияттән аерылмый: хакимиятнең һәм идарәнең барлык органнары мәхкәмә вәкаләтләренә ия була. Моннан тыш, урыннарда *шәригать* кануннарына таянып казыйлар һәм иргәчеләр мәхкәмәләре эш йөртә. Казан Рус дәүләте тарафыннан буйсындырылганнан соң, төбәктә мәхкәмә вазифаларын наместниклар (17 йөзгә кадәр), воеводалар (1613–1708), земство старосталары һәм ярдәмчеләр — целовальниклар (18 йөзгә кадәр), губа старосталары (җинаять эшләре буенча) һәм целовальниклар (1702 елга кадәр) башкара; крепостной крәстияннәрне аларның хуҗалары хөкем итә (ш.у. к. *Татар мәхкәмәсе йорты*). Чиркәү эшләре Казан архиепискобы (митрополиты) мәхкәмәсендә һәм 1722–44 тә рухани идарәдә, 1744–1917 дә консисториядә карала. Шул ук вакытта, 1789–1917 дә, Идел буе, Себер һәм Урал алды мөселманнары арасында туган милек бәхәсләре, *вакыфлар* h.б. гражданлык-хокук мәсьәләләре Уфа (1796 дан — Оренбург) мөселман Диния нәзарәте карамагында була. 18 йөз башында, Пётр I идарә иткән чорда, мәхкәмәне оештыру өлкәсендә «даими формалар» эзләү бара һәм уңышсыз рәвештә мәхкәмәне хакимияттән аеру омтылышы ясала. Казан губернасында мәхкәмә вәкаләтләре 1708–09 дан губернаторга, обер-комендантка (Казанда), провинцияләрдә комендантларга һәм воеводаларга, ш.у. 1713–19 да ландрихтерга (губерна земство судьясына) һәм ландратларга (губернатор каршындагы советникларга), 1719–27 дә түбән (1722–27) мәхкәмәләр буйсынулы *Казан надворный мәхкәмәсенә* тапшырыла. 1727 дә Пётр I заманында оештырылган барлык гомуми җирле мәхкәмәләр бетерелә, аларның вазифалары губернаторга һәм воеводаларга күчә. Хәрби частьларда һәм гарнизоннарда хәрби мәхкәмәләр эшли. Шәһәрләрдә мәхкәмә хакимияте 1699–1718 дә — сайлаулы бургомистрлар, 1718–28 дә — шәһәр *магистраты*, 1728–43 тә — ратушалар, 1743 тән кабат магистратлар (1754–1869 да алар каршында *гәпләшү мәхкәмәләре* эшли) тарафыннан гамәлгә ашырыла. 1775 тәге Мәхкәмә реформасы нәтиҗәсендә илнең М.с. үзгәртеп корыла. Екатерина II хөкүмәте мәхкәмә һәм хакимиятләрне бер-берсеннән аеру юнәлешендә чираттагы омтылышны ясый, әмма мәхкәмә органнарының югарыдагы мәхкәмәләргә һәм идарә органнарына буйсынуы үзгәрешсез калдырыла. 1781–82 дән Казан губернасында түбәндәге мәхкәмә учреждениеләре тәгаенләнә: түбән инстанция — дворяннар өчен *өяз мәхкәмәләре*, шәһәр кешеләре өчен шәһәр магистратлары һәм ратушалары (к. *Казан шәһәре татар бистәләре ратушасы*), крәстияннәр өчен кече расправа; урта инстанция — Земство югары мәхкәмәсе (к. *Земство мәхкәмәләре*), *Казан губернасы магистраты*, Югары расправа; югары инстанция — *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы, Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы*. Гомуми мәхкәмә органнары б-н бергә *Казан вөҗдан хөкеме мәхкәмәсе, ятимнәр мәхкәмәсе* оештырыла. Крәстияннәргә хөкем чыгару хокукына (авыр җинаять очракларыннан тыш) алпавытлар ия була. Генерал-губернатор (1796 га кадәр) һәм губернатор мәхкәмә тикшерүенә һәм мәхкәмәләрдә эшләр каралуга күзәтчелек итәләр, җинаять эшләре буенча чыгарылган хөкем карарларын раслыйлар. 1796 да урта мәхкәмә инстанциясе мәхкәмәләре бетерелә, гражданлык һәм җинаять эшләре палаталары Губерна мәхкәмәсе палатасына һәм расправаларга (1801 дә торгызылалар) берләштерелә. 1864 тәге Мәхкәмә реформасын уздыру нәтиҗәсендә Россиядә мәхкәмәнең хакимияттән аерымлануы, барлык социаль катлаулар өчен уртаклык, барлык кешеләрнең дә мәхкәмә каршында тигез хокуклылыгы h.б. принципларга нигезләнгән яңа М.с. формалаша. Казан губернасында җирле (волость мәхкәмәләре, җәмәгать мәхкәмәләре һәм мировой судьялар съездлары) һәм гомуми (*Казан округ мәхкәмәсе, Казан мәхкәмә палатасы*) мәхкәмәләр, *адвокатура* оештырыла, антлы утырышчылар мәхкәмәсе гамәлгә кертелә. 1889 да — 20 йөз башында ш.у. *земство башлыклары* һәм шәһәр судьялары да мәхкәмә вәкаләтләрен башкаралар. Хәрби юстиция саклана (к. *Казан хәрби округ мәхкәмәсе*). 1917–18 дәге «Мәхкәмә турында» декретлары б-н рев-циягә кадәрге М.с. бетерелеп, яңасы оештырыла. Окт. рев-циясеннән соң мәхкәмә органнары эшчәнлеге халык мәхкәмәләре һәм 1922 гә кадәр революцион трибуналлар, 1922 дән ТАССР Өлкә мәхкәмәсе, 1923 тән ТАССР Баш мәхкәмәсе, 1937 дән ТАССР (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) Югары мәхкәмәсе; респ-ка кантоннарындагы (1930 га кадәр), районнарындагы (1930 дан) һәм шәһәрләрендәге халык мәхкәмәләре; махсус мәхкәмәләр (хәрби трибуналлар, хәрби-транспорт трибуналлары h.б.) тарафыннан гамәлгә ашырыла. 1997 дән ТРның М.с.н уртак карамактагы федераль мәхкәмәләр (*Татарстан Республикасы Югары мәхкәмәсе, район мәхкәмәләре*), *Идел буе округының Федераль арбитраж суды, Татарстан Республикасының арбитраж мәхкәмәсе, Татарстан Республикасы Конституцион мәхкәмәсе*, җәмәгать мәхкәмәләре тәшкил итә. Мәхкәмәләр бердәм демократик принципларда оеша-

лар һәм эшлиләр, мәхкәмә хакимиятен мөстәкыйль, бәйсез рәвештә, фәкать закон нигезендә генә гамәлгә ашыралар.

*Әд.:* Троцина К. История судебных учреждений в России. М., 1851; Хафизов Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Виленский Б.В. Судебная реформа и контрреформа в России. Саратов, 1969; Ефремова Н.Н. Судоустройство России в XVIII — первой половине XIX вв.: Ист.-правовое исслед. М., 1993.

*Е.Б.Долгов.*

**МӘХМҮ́Д** (? — 1465), Себер ханы (1430–65). Шәйбанилар нәселеннән, Себер ханлыгын нигезләүче *Хаҗимөхәммәд хан* улы. Атасы һәлак булып, Әбелхәер хан Урта Азиягә киткәннән соң, җирле ыруглар фетнәсен җитәкли, аксөякләр тарафыннан хан итеп куела. Әбелхәер б-н сугышта җиңелгәч, Әстерханга кача. Соңрак Төмәнгә (Чыңгы Тора) әйләнеп кайта, анда үз исеменнән акча суктыра. Җирле ыругларга таянып, Әбелхәергә каршы сугыш алып бара.

Чыг.: Сибирские летописи. СПб., 1907.

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ахмедов Б.А. Государство кочевых узбеков. М., 1965; Нестеров А.Г. Монеты сибирских Шейбанидов // Восток-Запад: Диалог культур Евразии. К., 2001. Вып. 2; Исхаков Д.М. Введение в историю Сибирского ханства. К., 2006.

*И.Л.Измайлов.*

**МӘХМҮ́Д БОЛГАРИ́** (Мәхмүд бине Гали бине Гомәр әл-Болгари әс-Сараи) (1297 тирәсе — 22.3.1360, Алтын Урда, Сарай әл-Җәдид), язучы, дин белгече. Гомеренең күп өлешен Сарай әл-Җәдидтә уздыра. Шәригать белгече, Коръән шәрехләүчесе булып таныла. Татар әдәбиятының проза жанры үсешенә көчле йогынты ясый, дини-дидактик «Нәһҗел-фәрадис» («Оҗмах юлы», 1358; Казан, 2002) әсәре авторы. Әсәр 40 фасылга бүленгән дүрт бүлектән (бабтан) тора. Беренче ике бүлектә Мөхәммәд пәйгамбәр, беренче хәлифәләр (Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Гали), ислам таралган беренче гасырларның күренекле мөселман эшлеклеләре турында хикәяләнә. Өченче бүлектә Аллаһка якынайткан фарызлар (намаз, ураза, хаҗ, зәкят, ата-анага ихтирам, түземлек һ.б.) тасвирлана, ахыргы бүлектә кешене Аллаһтан ерагайтучы эшләр (уйнаш кылу, ялган, үч саклау һ.б.) турында бәян ителә. Ясаган нәтиҗәләрен дәлилләп, автор Коръәнгә сылтама ясый, танылган мөселман әһелләренең сүзләрен китерә.

Әсәр.: Нәһҗел-фәрадис. К., 2002.

*Әд.:* Миңнегулов Х. Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты. К., 1998; Абилов Ш. Нахдж ал-фарадис // Средневековая татарская литература (VIII–XVIII вв.). К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘХМҮ́Д КАШГАРИ́** (Мәхмүд бине әл-Хөсәен бине Мөхәммәд) (1028, Кашгар шәһәре янындагы Азык а. — 1126, Опал ш.), Урта Азия галим-филологы, төрки телләр белгече. Барсхан шәһәре әмире Хөсәен бине Мөхәммәднең улы, Мавәраәннәһерне яулаган караханилар идарәчесе Богра хан оныгының баласы. Багдад һәм Кашгар мәдрәсәләрендә белем алган дип фаразлана. Күп сәяхәт итә, легендалар, риваятьләр, тарихи хикәяләр язып ала; телләр һәм төрки кабиләләрнең диалектларын өйрәнә. Аның тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып гарәп телендә язылган «Диване лөгать әт-төрк» (1072–74) сүзлеге тора. Ул — безнең көннәргә кадәр килеп җиткән бердәнбер иң борынгы төрки диалектология ядкәре. Анда 9 меңнән артык сүз һәм сүзтезмә теркәлгән, фонетик һәм морфологик үзлекләре буенча төрки телләрнең классификациясе бирелгән, Урта Азия, Көнчыгыш Төркестан, Идел һәм Урал буе халыклары һәм төрки кабиләләре турында киң лингвистик, тарихи-мәдәни һәм этнографик мәгълүматлар туплап гомумиләштерелгән. Сүзлектә ш.у. Римнан Кытайга кадәр таралган төрки кабиләләрнең атамалары китерелгән, М.К. тарафыннан төзелгән дөнья картасында аларның геогр. урыннары күрсәтелгән; анда ш.у. лирик һәм йола җырлары, төрки-мөселманнарның будда динендәге уйгырларга каршы сугышлары турында героик эпостан өзекләр, А.Македонский походлары турында тарихи риваятьләр һәм легендалар, 400 дән артык мәкаль һәм әйтемнәр урын алган.

М.К. иҗат мирасын өйрәнүгә С.Е.Малов, А.Н.Кононов, Җ.Вәлиди, С.Ахаллы, А.Курышҗанов, Х.Мәхмүтов, К.Броккельман, Әхмәдзәки Вәлиди Тоган һ.б. ватандаш һәм чит ил төрки телләр белгечләре зур өлеш кертә. Сүзлек В.Аталай тарафыннан төрекчәгә — «Divanü Lûgat it-türk tercümesi» (1–3 т., Әнкара, 1939–41), С.М.Моталлибов тарафыннан үзбәкчәгә — «Туркий сўзлар девони» (1–3 т., Ташк., 1960–63) тәрҗемә ителә.

*Әд.:* Мәхмүтов Х. Мәңгелек ядкәр. К., 2002; шул ук. Борынгылар әйткән сүзләр: VIII–XVII йөз төрки-татар ядкәрләрендә афоризмнар. К., 2002; Әхмәтҗанов М. Халкыбызның олуг зыялысы // Мирас. 2006. № 3; Бәширова И. «Диване лөгатет-түрк» һәм татар теле лексикасы // Мәдәни җомга. 2009. 30 гыйн. (№ 4); Валидов Дж. О словаре турецких языков Махмуда Кашгарского // Вестн. науч. об-ва татароведения. 1927. № 7; Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Кононов А.Н. Махмуд Кашгарский и его «Дивану лугат ат-тюрк» // Советская тюркология. 1972. № 1; Умаров Э. Махмуд Кашгарский о согласном «ч» // Вопросы языкознания. 2003. № 4.

*В.Х.Хаков.*

**МӘХМҮ́Д ХАН** (Мәхмүтәк) (?-1462), Казан ханы (1445–62). *Олуг Мөхәммәд ханның* олы улы. Атасы Алтын Урда тәхетеннән төшерелгәннән соң качып яшәгәндә, *Биләү* (*Белёв*) *янындагы сугышта* (1437), кабат Казан тәхетен биләгәндә (1438) һәрдаим аның янында була. 1445 елда *Суздаль янындагы сугышта* Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II гаскәрләрен тар-мар итә. Шул ук елда энесе Якуб б-н бергә Василий II ягыннан Русь дошманнарына каршы сугыша. 1445 тә, Олуг Мөхәммәднең үлеменнән соң (яки ул фетнәдә үтерелгәч), Мәхмүд Казан ханы дип игълан ителә. Рус чыганакларында беренче «Казан патшасы» буларак искә алына. М.х. идарә иткәндә аның энеләре Якуб һәм Касыйм Василий II гә хезмәткә күчәләр (Касыймга аерым биләмә — Касыйм ханлыгы бирелә). М.х. вакытында Казан ханлыгының адм., хәрби-сәяси һәм аксөяк нәселләр структурасы формалаша. Казан сәяси, икътисади һәм мәдәни үзәккә әверелә, сәүдә һәм һөнәрчелек үсә. М.х. Мәскәү кенәзлеге эшләренә катнашмау сәясәте алып бара.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Казан ханнары. К., 1995; Фукс К. Краткая история города Казани. К., 1805; Баженов Н.К. Казанская история. К., 1847; Перетяткович Г.И. Поволжье в XV и XVI вв.: Очерки из истории края и его колонизации. М., 1877; Пинегин М. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; Герберштейн С. Записки о Московии. М., 1998; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**МӘХМҮ́Д ХАН** (? — 1476 дан соңрак), Олы Урда ханы (1460 еллар), Әстерхан ханлыгын нигезләүче. *Кече Мөхәммәд* ханның улы. 1460 елларда Олы Урда тәхете өчен Әхмәд хан б-н барган көрәш-бәрелешләрдән соң, Олы Урдага каршы торырлык ханлык торгызу максатыннан, Хаҗитарханга кача. 1466–70 елларда, Нугай Урдасы бәкләренә таянып, бәйсезлек сәясәте алып бара, үз исеменнән акча суктыра. Хәзерге фәндә М.х. Олы Урда ханы булып калган, Әстерхан ханлыгы Олы Урданың соңгы ханнары тар-мар ителгәннән соң, 1502 елда аерылып чыккан дигән фикер яши. Ш.у. к. *Мәхмүд хан хаты.*

*Әд.:* Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Литвин М. О нравах татар, литовцев и московитян. М., 1994; Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; Зайцев И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МӘХМҮ́Д ХАН ХАТЫ́**, 15 йөз төрки-татар язма истәлеге (1466 елның 10 апреле б-н тамгаланган). Хат Олы Урда ханы Мәхмүд әмере б-н язылган (Мәхмүд 1460 елларда Әхмәд хан б-н тәхет өчен көрәштә катнаша), Төркия солтаны Фатих Мехмедкә юлланган. Документның үлчәме — 141x27 *см.* Текст кара төстәге каләм карасы б-н язылган. Хат 21 юлдан тора. Текстның өч урынына уртасына хан исеме уелган дүртпочмаклы мөһер (6×6 *см*) сугылган. Хат гарәп графикасында, гарәп сүзләре мул кулланылган әдәби төрки телдә язылган. Хатта ике дәүләт хакимнәренең ата-бабалары арасында дустанә мөнәсәбәт саклана килгәнлеге (исәнлек-саулык белешү, бүләкләр бирешү, илчеләр алмашу, сәүдә арадашлыгы һ.б.), ике дәүләт арасында дипломатик мөнәсәбәтләрне яңарту зарурлыгы һәм Истанбулга илчеләр җибәрелгәнлеге бәян ителә. Аның төп нөхсәсе Истанбулдагы Төпкапы музее архивында саклана. Фәнни әйләнешкә 1940 та хатның фотокүчермәсен, транскрипциясен, төрек теленә тәрҗемәсен комментарийлар б-н әзерләп бастырган Ә.Н.Курат тарафыннан кертелә.

*Әд.:* Письмо хана Золотой Орды Махмуда в Стамбул (1466) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4.

**МӘХМҮДИ́** (Мәхмүтов) Заһид Борис улы (4.7.1960, Кукмара р-ны Кукмара пос.), язучы. Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1982). 1989–2005 елларда (бүленеп) «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниесендә: «Агыла да болыт агыла», «Нурлы Казан», балалар өчен фәнни-популяр «Һәр тарафта сер яши» дигән

радиотапшыруларның мөхәррире һәм алып баручысы. 1991–97 дә «Шәһри Казан», «Мәдәни җомга», «Әдәби җомга» г-таларында, «Татарстан» ж-лында әдәби хезмәткәр булып эшли. 2006 дан «Мәгърифәт» г-тасында. Балалар өчен «Профессор Мияугәл» (1991), «Тәмуг чәчәге» (1996), «Ак болыт» (1999) исемле фантастик һәм маҗаралы повесть, хикәяләр, «Әче балан» (2002) исемле детектив хикәяләр җыентыклары, «Һәркемнең үз юлы» романы (2005), «Ахырзаман шаукымы» повесте (2006) авторы. Әсәрләре үзенчәлекле стильдә, милли рухта язылган. М. ш.у. радиоспектакльләргә сценарийлар язучы һәм аларның режиссёры буларак та билгеле: «Калканлы Идел», 2000; «Сары каеш — сары сагыш», 2001; «Бүре», 2002 тапшырулары.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Г.М. Габделхакова.*

**МӘХМҮ́ДОВ** Әмир Гобәй улы (28.6.1947, БАССРның Әлшәй р-ны Әбдрәшит а.), шагыйрь, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе, филол. фән. д-ры (1999). 1969 елда Бөре пед. ин-тын тәмамлый. 1974–81 дә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1981–92 дә Казан пед. ин-тында, 1998–2002 дә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли. «Суверенитет» г-тасында баш мөхәррир (1991–95), бер үк вакытта ТРның «Суверенитет» ком-ты координацион советы рәисе. «Муса Җәлил иҗатында эстетик идеал» («Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля», 1980) исемле хезмәт, «Матурлык тантанасы» (1983), «Мәңгелек моң» (1987) шигырь китаплары авторы.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МӘХМҮ́ДОВ** Гали (1855, Чистай ш. — ?), шагыйрь. 1870 елдан Казанда, 1890 елларда Павлодар шәһәрендә яши. «Кыйссаи ике игез бала», «Кыйссаи Сәмруг», «Кыйссаи Адәм», «Кыйссаи Бәхтияр», «Кыйссаи Робинзон» исемле матбугатка чыкмаган дини-мифологик, фольклор сюжетларына нигезләнеп язылган шигъри әсәрләр авторы. Кульязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты фондында саклана.


**МӘХМҮ́ДОВ** Камил Әхмәт улы (27.5.1941, Дагстан АССР, Буйнак ш.), авиация генерал-майоры (1989). Армавир югары хәрби авиация очучылары уч-щесен (1964), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү өлкәсенең Монино пос., 1972) тәмамлый. 1974–79 елларда истребительләр авиациясе часте командиры урынбасары, командиры. 1979–85 тә СССР Һава һөҗүменнән саклану берләшмәсе авиациясе башлыгы. 1985–86 да СССР Һава һөҗүменнән саклану берләшмәсе авиациясе башлыгы урынбасары. 1986 дан СССР Һава һөҗүменнән саклану берләшмәсе командующиенең авиация урынбасары — авиация башлыгы. Орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

**МӘХМҮ́ДОВ** Малик (19 йөз ахыры — 20 йөз башы), хаттат. 1849 елда *Вечеслав* (*Вячеслав*) *Г.М. ташбасмаханәсендә* һәм 1901 дә *Казан университеты басмаханәсендә* басылган, сәнгати стилистикасы һәм нәфис композициясе б-н аерылып торган «Бина әл-Ислам» төсле литографик *шәмаиле* авторы. Аның зурлыгы 55×33 *см*. Исламның биш баганасын символлаштыручы биш гөмбәз б-н очланган, бер-берсенә камалган җиде квадраттан торган кирмәннең стильләшкән-шартлы сурәтен тасвирлый. Суфичылык эстетикасының рухи-мистик символы булган кирмән образы «нәсех» стилендә язылган дүртенче хак халифә Гали исеменең көзгедәге чагылышы б-н тулыландырыла, вертикаль хәрефләр бер үк вакытта манара архит-расы һәм кылыч очлары формасын тасвирлыйлар. Шәмаилнең төсле чишелеше ак төснең кызыл, көрән төсләрдәге капма-каршы булган төрле төсмерләр б-н аралашып килүенә һәм зәңгәр, яшел, сары төсләрнең кушылуына корылган.

Фаразлаулар буенча, М. ш.у. дүрт манаралы — җиде катлы квадрат формасындагы ераклаша баручы кирмән рәсеме ясалган «Ислам-иман сакчысы» (1909) дигән литографик шәмаил авторы да. Беренче шәмаилдәгечә, аскы өлештәге квадратның «Йә, илаһи» дип, зур хәрефләр б-н язылган каймалы өслеге композициянең архитектоник өлеше булып тора. Рәсемнең эчтәлеге мөселманнар өчен җиде тәртип кагыйдәсе турындагы аңлатмалы язуда ачыла. Ике шәмаил дә ТРның Милли музеенда саклана.


*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӘХМҮ́ДОВ** Мөхәммәдгали әс-Сөләнгери (1824, Казан губ., Казан өязе, хәзерге Биектау р-ның Сөләнгер а. — 31.1.1891, Казан), рәссам-хаттат, миниатюр китаплар остасы, педагог, статский советник (1870). Зәңгәр мәчет каршындагы мәдрәсәдә мөдәррис Хәбибулла Рахманкуловта укый (Казан). Камил дәрәҗәдә гарәп каллиграфиясен үзләштерә. А.К.Казимбәк юлламасы б-н 1842 елда Казан ун-тының Шәрекъ бүлегендә һәм Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә гарәп, фарсы һәм төрек-татар каллиграфиясен укытырга рөхсәт ала. М. дәресләрендә гарәп язуының классик стильләре — нәсех, тәгълик,



М. М ә х м ү д о в. «Хилйә». Төсле литография. 1851. Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе.

шикәстә, дивани, рикъа, рәйхани (М. һәм аның шәкертләре тарафыннан башкарылган хезмәтләрнең үрнәкләре ТР Милли архивында саклана) өйрәтелә. 1844 тә хезмәтендә раслана. 1849 да крәстиян катлавыннан чыгарыла. 1854 тә, Шәрекъ бүлеге Петербург ун-тына күчерелгәндә күчеп китүдән баш тартуы сәбәпле, Казан ун-тындагы эшеннән азат ителә һәм, каллиграфия укытучысы вазифасы да калдырылып, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә татар теле укытучы



М. М ә х м ү д о в. Кульязма китап унваны. Кәгазь, алтын. Акварель. 19 йөз уртасы. ТР Милли архивы.

итеп билгеләнә. Бер үк вакытта, 1846–48 дә Казан руханилар академиясендә татар теле укыта, 1850–54 тә гимназия каршындагы пансионга назир итеп билгеләнә. 1876 да яңа ачылган *Казан татар укытучылар мәктәбендә* инспектор (директор) була, 1881 дә ялга китә.

М. гарәп графикасындагы кульязма китапларны күчереп яза, текстларны алдан ук унван — декоратив заставкалар б-н бүлә, каймага ала, бүлек исемнәрен төсле, бизәкле үрмә хәрефләр б-н аерып куя; еш кына җөмлә азагына нокта урынына чәчәк үрнәкләре ясый. Тушь һәм акварель б-н эшли. *Шәмаил*, *кыйтга*, хилйә, гарәп язуының сәнгати стиль үрнәкләре авторы (тәгълик, нәсех, шикәстә, дивани һ.б.). Каллиграфия дәресләрендә шәкертләрне язу өчен камыш, шома кәгазь, тушь һәм буяулар б-н үзе тәэмин итә.

1849 да Мартиниан Ивановның 1842 дә басылган һәм күпчелек өлеше университет типографиясендәге янгын вакытында юкка чыккан «Татар хрестоматиясе»нең («Татарская хрестоматия») кульязмасын гарәп графикасында күчереп яза (кульязманың исән калган өлешләре Мәскәү ун-ты китапханәсенең Кульязмалар бүлегендә, РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Петербург ф-лында саклана). М.ның хезмәте нәстәгълик стилендә башкарылган, баш исемнәре кызыл кара (мистара б-н сызылган эзләр сакланган), текстлар Кытай карасы б-н башкарылган. М. сәнгате үрнәген 1842 унванга бүленгән бәетләр табагыннан һәм Камалетдин Әбделгатат Мәхмүд Кирмәни Диванындагы 59 газәлдән күрергә мөмкин (ТР Милли ар-

хивы фондларында саклана). 1840 еллар башында Ф.И.Эрдман җыентыгыннан 2 фарсы кульязмасын күчереп яза (тәгълик стиле б-н унваннар, текстлар әзерли) һәм ахырда: «фәкыйрегез Мөхәммәдгали Мәхмүд мулла улы әс-Сөләнгери күчереп язды», — дип кул куя (Россия Милли китапханәсендә саклана, С.-Петербург ш.).

Ш.Мәрҗанинең «Болгар һәм Казан тарихы» китабын күчерә (автор кульязмасы варианты Казан ун-ты фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана.

М. — шәркыятьче галим И.Н.*Березин* тарафыннан югары бәя алган «Татар телен өйрәнү өчен гамәли кулланма» («Практическое руководство к изучению татарского языка», 1857) авторы (әлеге китап студентлар һәм гимназистларның берничә буынына кулланма була). 1870 еллар башында татарларның рус телен өйрәнү проблемаларына мөрәҗәгать итә. В.В.Радлов исеме б-н басылган «Татар укучылары өчен рус грамматикасы» («Грамматика русского языка, составленная для татар восточной России», 1873) дәреслегенең автордашы була. Казан татар укытучылар мәктәбендә педагогика һәм дидактикадан укыта, татарлардан рус теле укытучылары әзерләү системасын булдыруда мөһим роль уйный. Губернатор күрсәтмәсе б-н гигиена буенча: «Мәетләрне җирләгәндә саклану чаралары турында» («О предохранении при погребении умерших», 1851), «Ваба чире таралу ихтималыннан киңәшләр» («Наставления по случаю появления холеры», 1864) брошюраларын татар теленә тәрҗемә итә; кабулханәләрдә мөселманнар өчен ант текстын төзи. Казан ун-ты басмаханәсендә Шәрекъ телләрендә басылган китапларның корректоры була. Анна тасмасындагы алтын медаль (христиан динендә булмаган затлар өчен 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены тиңдәше) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Траубенберг П.В. Татарская учительская школа в Казани. К., 1890; шул ук. Мухамет-Галей Махмудов: Некролог // Казанские вести. 1891. 10 февр.; Дульский П.М. Казанский каллиграф Али Махмудов. К., 1930; Михайлова С.М. Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья. К., 1972; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: Истоки и развитие (XIX в. — 20-е гг. XX в.). К., 1998; Исхакова Р.Р. Казанская татарская учительская школа и её роль в формировании и становлении национального образования. К., 2002; Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003; Зайцев И.В. Казанский каллиграф Мухаммед-Гали Махмудов — Мухаммед-Али б. мулла Махмуд ас-Салангури // Источники и исследования по истории татарского народа. К., 2006.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Е.В.Липаков, И.А.Новицкая.*

**МӘХМҮ́ДОВ** Рафаэль Хәбир улы (20.2.1947, Чистай р-ны Каргалы а.), инженер-механик, нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), техник фән. канд. (1993), СССРның уйлап табучысы (1998). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1970), ТатНИПИнефтьтә эшли (бүленеп: 1974–80 дә — РФнең Төньяк-Көнбатыш магистраль нефтьүткәргечләре идарәсендә, Казан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993 тән). М. углеводородлы резервуарлардан парларны тотып алу, рециркуляция нәтиҗәсендә углеводородларның югалуын киметү, нефть күбеген таркату, нефть скважиналарына су килүне туктату, нефть һәм газны бергә транспортлау технологияләрен эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнаша. РФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1994). Дәүләт бүләге аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүче яңа термоимплозион һәм перфорацион-имплозион экспресс-технологияләр эшләгәне һәм киң күләмдә гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**МӘХМҮ́ДОВ** Хәйрулла Хәбибулла улы (8.5.1909, хәзерге Оренбург өлкәсенең Ташлы р-ны Бәшир а. — 23.10.1983, Алма-Ата), тел галиме, филол. фән. д-ры (1971), Казакъстан ССРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1975). 1940–83 елларда Казакъ ун-тында, рус теле (1967 дән — рус филологиясе) каф. мөдире. М. рус һәм төрки (казакъ, уйгыр) телләр арасындагы бәйләнешләрне, 11–16 йөзләрдәге рус китап ядкәрләре телендәге төрки әзләрне тикшерә. Рус-казакъ һәм казакъ-рус сүзлекләрен төзүчеләрнең берсе. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые вопросы теоретической стилистики // Филологический сборник. А.-А., 1965. Вып. 4; Русско-казахские лингвостилистические взаимосвязи. А.-А., 1970.

**МӘХМҮ́ДОВ** Шәрәфетдин Җәләлетдин улы (1853–?), җәмәгать эшлеклесе. Эстәрлебаш авылы (Уфа губ.) мәдрәсәсендә, 1872 елдан Татар-башкорт укытучылар мәктәбендә (Уфа ш.) укый. 1876 дан — Эстәрлебаш, 1902 дән Эстәрлетамак мәдрәсәләрендә рус теле укыта. Уфа губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907–12), мөселманнар фракциясе әгъзасы, керем һәм чыгымнарга дәүләт теркәве уздыру, халык мәгарифе, эшчеләр мәсьәләсе, икмәк сәүдәсе комиссияләре әгъзасы. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Мусульманские депутаты государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. документов и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Госманова.*

**МӘХМҮТӘ́К**, к. *Мәхмүд хан.*

**МӘХМҮ́ТОВ** Мирза Исмәгыйль улы (1.5.1926, Пенза губ. Саранск өязе, хәзерге Мордва Респ-касының Ләмбрә р-ны Алтар а. — 25.3.2008, Казан), педагог, филолог, шәркыять, дин гыйлеме белгече, халык мәгарифе эшлеклесе, филол. фән. канд. (1966), пед. фән. д-ры (1972), СССР ПФА, РМА, ТР ФА академигы (1978, 1991, 1991), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1991, 1996). Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң (1940), авыл китапханәсендә эшли; 1942 елның ноябреннән Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд өлкәсе Знаменск МТСында тракторчы, комбайнчы. 1944–46 да Семищенск (Фиргана ш.), аннан соң Әстерхан авиамеханиклар мәктәбендә; 1947–48 дә хәрби очучыларның Кировобад авиация уч-щесендә авиамеханик (Әзәрбайҗан ССР); 1948–49 да Иркутск хәрби уч-щесе курсанты; 1949–50 дә Әзәрбайҗан ССРның Шамхор шәһәре хәрби частендә авиатехник, бер үк вакытта эшче яшьләр урта мәктәбе укучысы.


М.И.Мәхмүтов.

1950–55 тә Мәскәү чит телләр хәрби ин-тында тыңлаучы, гарәп һәм инглиз телләрен өйрәнә; 1955 нең көзеннән Балтыйк буе Хәрби округында (Рига ш.) инглиз теленнән тәрҗемәче. 1955 нең декабрендә Совет Армиясеннән демобилизацияләнә, Казанга күчеп килә; Казан ун-тында гарәп теле укыта.

1958–76 да ТАССР мәгариф министры. Бу чорда респ-када гомуми сигезьеллык (1962) һәм мәҗбүри урта белем (1976) бирүне гамәлгә кертү мәсьәләләре уңышлы хәл ителә, мәктәпләрнең матди-техник базаларын ныгыту планнары тормышка ашырыла, мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре челтәре киңәйтелә. ТАССР халык мәгарифе системасы җитәкчесе буларак, М. урта мәктәп укытучыларын фәнни-тикшеренү эшенә җәлеп итәргә тырыша, укытуның яңа форма һәм алымнарын, укыту процессына эксперименталь программалар һәм дәреслекләр кертүгә булышлык итә. 1960–70 елларда ТАССРның мәктәп системасы, аеруча Казан шәһәре мәктәпләре, илдәге башка төбәк укытучылары өчен алдынгы пед. тәҗрибәнең төп базасы булып тора.

М. инициативасы б-н 1976 да СССР ПФАнең Һөнәри-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-ты төзелә (хәзер Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе институты), 1992 гә кадәр шул институтның җитәкчесе була. Тиздән институт илдәге һөнәри-техник белем бирү педагогикасы проблемаларын өйрәнүче, укытуның яңа технологияләрен эшләүче зур үзәкләрнең берсенә әверелә. 1992 дә М. яңа фәнни белем бирү учреждениесе — Татарстан-Америка региональ ин-тын оештыра. 1995 тән ТР ФАнең Социаль-икътисади проблемалар ин-ты баш фәнни хезмәткәре; бер үк вакытта, 1996–2006 да, ТР ФАнең Социаль-икътисади һәм хокук фәннәре бүлеге акад.-секретаре, Россия ислам ун-тының (Казан) филол. һәм илләр өйрәнү каф. мөдире.

М.нең төп фәнни казанышлары алгарышлы проблемалы укыту теориясен һәм алымнарын эшләү б-н бәйле (к. *Проблемалы укыту*), шушы нигездә ул укучыларның фикерләү эшчәнлеген камилләштерүгә булышлык итүче пед. технологияләр концепциясен төзи. М.нең «Проблемалы укыту. Теориянең төп мәсьәләләре» («Проблемное обучение. Основные вопросы теории», М., 1975) һәм «Заманча дәрес» («Современный урок», М., 1985) монографияләре СССРның союздаш респ-калары халыклары телләренә, ш.у. испан, кытай, немец һәм чех телләренә тәрҗемә ителә. Һөнәри-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында М. җитәкчелегендә укытуның

политехнизм, һөнәри юнәлтү, проблемалылык, мотивацияләр, күчүчәнлек принциплары концепцияләре буенча тикшеренүләр оештырыла, гомуми һәм һөнәри белем бирүнең үзара бәйләнешләре эшләнә. 1993 тә М. редакциясендә Коръәннең татар теленә тәрҗемәсе басыла.

Бөтендөнья тынычлык советы әгъзасы (1965–70), ЮНЕСКО каршындагы Наданлыкны бетерү буенча халыкара консультатив ком-т эксперты (1965–72). СССР ПФАнең Н.К.Крупская исем. бүләге (1986), ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге (1996) лауреаты. 1959–79 да ТАССР ЮС депутаты.

Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл байрагы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: 2 томда. К., 1993 (автордаш); Теория и практика проблемного обучения. К., 1972; Организация проблемного обучения в школе. М., 1977; Школьный русско-татарский словарь. К., 1989; Пророк Мухаммед. М., 1996; Мир ислама: Прошлое и настоящее. К., 2006.

*Әд.:* К р а ш е в с к и й Е. Портрет активного человека. М., 1975; М и л и б а н д С.Д. Библиографический словарь советских востоковедов. М., 1975; С а ф и у л л и н а И.А., З а к и р о в Г.С. Теория проблемного обучения М.И.Махмутова. К., 2002.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**МӘХМҮ́ТОВ** Хәлил Зәки улы (10.3.1939, Мамадыш р-ны Катмыш а. — 28.9.2012, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1989). Казан театр уч-щесен (1966), Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын (1975) тәмамлый. 1966 елда Татарстан респ-ка күчмә театры труппасына эшкә килә. Р.Бикчәнтәев, Р.Тумашев, П.Исәнбәт, М.Сәлимҗанов кебек режиссёрлар җитәкчелегендә эшләү М.ка зур сәхнә остасы дәрәҗәсенә күтәрелергә мөмкинлек бирә. Максут («Умырзая чәчәкләре», Ю.Әминев) һәм Хәлил («Сары чәчәк ата көнбагыш...», А.Гыйләҗев) кебек революционерлар, гашыйк егет Хәйретдин («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), газап чигүче Хафиз («Шәмсекамәр», М.Әблиев), юләр Тархан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), шат Юлдыбай («Күктән төшкән бәхет», Н.Асанбаев), үз-үзеннән бик канәгать Ислам («Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде»), Ш.Хөсәенов) образларын, У.Шекспир (Бенедикт — «Юктан чыккан тавыш») һәм К.Гольдониның (Флориндо — «Ике хуҗаның хезмәтчесе») классик комедияләрендәге геройларны гәүдәләндергән актёр жанр табигатен нечкә тоемлап эш итә, пластик нәзакәтлелеккә, һәр характерны индивидуальләштерүгә омтыла. М.Горькийның «Мещаннар» (1967) пьесасындагы Нил роле өчен М. Бөтенроссия театр конкурсы лауреаты исеменә лаек була. Биктимер («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) һәм Малик Бикташев («Кыр казлары артыннан», И.Юзеев) образлары б-н актёр зур уңыш казана. Алар аша ул тормышта катлаулы хәлләргә юлыккан геройларының тирән эчке драматизмын ачып бирә. Тормышчан сыйфатларны гадәттән тыш гомумиләштереп, Малик образында актёр үзенә бер төрле социаль битлек тудыра, үз рәхәтен генә кайгыртып яшәүне хуплаган мещанлык карашларын аяусыз фаш итә. Т.Миңнуллинның «Без бит авыл малае» пьесасындагы ул тудырган Иртуган образы — алда әйтелгән геройның капма-каршысы. Иртуган — милли характер үзенчәлекләрен, татар крәстияненең туган җиренә тугрылыгын гәүдәләндерүе, тормыш сөючәнлеге һәм күтәренке рухлы булуы б-н аерылып тора. Р.Заһидуллин куйган спектакльләрдә М. тирән эчтәлекле шактый гына рольләр башкара: Күрән би («Идел суы ака торур», Н.Фәттах), Борис («Минем сөекле картларым», Р.Солнцев), Ислам Фоатович («Игълан буенча өйләнү», Б.М.Рацер, В.К.Константинов), Кәрим бай («Башмагым», Т.Гыйззәт). 1997–2001 дә Казан театр уч-щесендә укыта.

*Д.Ә.Гыйммранова.*



Х.З.Мәхмүтов.



Х.З. М ә х м ү т о в Хәлил ролендә («Сары чәчәк ата көнбагыш...», А. Гыйләҗев; сулда – И.Мәхмүтова).



Х.З. М ә х м ү т о в Нил ролендә («Мещаннар», М. Горький).

**МӘХМҮ́ТОВ** Хуҗиәхмәт Шаһиәхмәт улы (15.2.1933, хәзер Мамадыш р-ны Түбән Ушма а.), фольклорчы, филол. фән. д-ры (1996), ТАССР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1983, 1993). Казан ун-тын тәмамлый (1958). 1960–66 елларда Буа шәһәрендә «Яңа юл» г-тасында җаваплы сәркәтип, бүлек мөдире. 1966 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар фольклорының афористик жанрларына карый. Татар табышмакларына багышланган «Кечкенә дә төш кенә» (1980) монографиясе авторы. Хезмәттә табышмакларның тематик һәм сәнгать үзенчәлекләре, генезисы һәм функцияләре, жанрның хәзерге торышы яктыртыла. Татар халкының йола һәм бәйрәмнәре, 8–17 йөз әдәби ядкәрләрендә очраган борынгы төрки афоризмнар турында китаплары, төрки-татар һәм ислам мифологиясенә, татар фольклористикасы тарихына багышланган хезмәтләре бар. М. татар фольклоры жанрларының классификациясен (табышмак, мәкаль, әйтем, сынамыш, ант, яхшы теләк, каргыш, ышану, канатлы сүзләр) бирә һәм аларны фәнни яктан (кайберләрен беренче тапкыр) тасвирлый. «*Татар халык иҗаты*» җыентыгын төзүчеләрнең берсе, «Табышмаклар» (1977), «Мәзәкләр» (1979), «Мәкаль һәм әйтемнәр» (1987) китапларының фәнни мөхәррире. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1989).

Х е з м.: Канатлы сүз — хикмәтле сүз. К., 1999; Борынгылар әйткән сүзләр. К., 2002; Афористические жанры татарского фольклора. К., 1995.

*Әд.:* Х и с а м о в Н., У р м а н ч е Ф. Җәүһәрче // Фәнни Татарстан. 2002. № 1; Я р у л л и н а Л. Гадилектә галилек // Мәйдан. 2003. № 1; Берлекнең яңа әгъзасы: Хуҗи Мәхмүтов // Казан утлары. 2004. № 2.

**МӘХМҮ́ТОВ** Һәнүз Котдус улы (15.7.1933, БАССРның Яңавыл р-ны Таш Елга а. — 17.12.1996, Казан), театр белгече. Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1963). М.ның «Татар драматургиясендә трагедия жанры» дип исемләнгән диплом эше ун-тның гыйльми советы тарафыннан матбугатка тәкъдим ителә һәм 1965 елда басылып чыга. 1963 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында фәнни хезмәткәр. Г.Исхакыйның рухи мирасына караган документаль материаллар бастырып чыгаруга зур өлеш кертә (ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге, 1996). «Мирас» ж-лы (1991–96), күп кенә фәнни җыентыклар мөхәррире.

Х е з м.: Татар совет театры. К., 1975 (автордаш); Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988 (автордаш); Әстерханда татар театры // Мирас. 1994. № 1–3, 7–12; 1995. № 1–8; Исхакый эзләреннән // Мирас. 1997. № 2.

*Д.Ә.Гыйммранова.*

**МӘХМҮ́ТОВА** Альта Хаҗи кызы (9.6.1937, Алабуга р-ны Бәзәкә а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1971). Алабуга пед. уч-щесен (1955); Казан ун-тын (1965) тәмамлый, шунда ук: СССР тарихы (1968 елдан), совет чорына кадәрге СССР тарихы (1976 дан), татар халкы тарихы (1989 дан) кафедраларында эшли. Хезмәтләре рев-циягә кадәрге татар мәктәпләре, *җәдитчелек*, *хатын-кызлар хәрәкәте*, патша хөкүмәтенең милли сәясәте тарихы мәсьәләләренә карый. Гаилә–милләт нигезе сериясе басмаларының 1 томындагы, Габдулла Бубиның 20 йөз башында мөселман хатын-кызларының гаиләдә һәм җәмгыятьтә тоткан урынына багышланган фәлсәфи һәм социаль трактаты анализланган «Г.Бубый. Хатыннар» (К., 2013) китабының төзүчесе-авторы.

Х е з м.: Вакыт инде: без дә торыйк... (Җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу). Очерклар. К., 2012; Милләт аналары. К., 2012; Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917). К., 1982; Лишь тебе, народ, служенье! (История татарского

просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби). К., 2003; Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). К., 2006.

**МӘХМҮ́ТОВА** Исламия Һидият кызы (1.12.1943, Әлки р-ны Югары Әлки а.), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1981), РСФСРның атказ. артисты (1987). Хезмәт эшчәнлеген 1963 елда Татар респ-ка күчмә театрында бутафор булып башлый. А.Гыйләҗевнең «Кара күзле кызлар» пьесасы буенча куелган спектакльдә Гөлләр ролен уңышлы башкарып, 1964 тә әлеге театрның актрисасы булып китә. Махсус театр белеме булмаса да, бергә эшләгән өлкән актёрларның тәҗрибәләрен уңышлы үзләштереп, К.Тумашева, Р.Тумашев кебек режиссёрлар җитәкчелегендә М. үзенә генә хас сәхнә почеркы булган оста актриса булып җитешә.



И.Һ. М ә х м ү т о в а авыл советы секретаре ролендә («Кайтыр идем», Р.Хәмид; унда – Х.Мәхмүтов).

Тормыш дөреслегенә туры килә торган төгәллек, тирән психол. анализ аның Ясминә («Кыр казлары артыннан», И.Юзеев), Гөлбану («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Шамилә («Без бит авыл малае», Т.Миңнуллин), Оптубхан («Соңгы атыш», У. Умәрбәков), Шәмсекамәр (М.Әблиевнең шул исем. пьесасы), Ганна («Сагышларым — гомер агышларым», А.А.Дударев), Мария («Гөнаһлы хатын», М.Сторожева) рольләрендә ачык чагылыш таба. Смеральдина («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Беатриче («Шау-шулы көн», У.Шекспир), Почтальон хатын («Алтын көз», Ш.Фәрхетдинов) образларын иҗат иткәндә актрисаның комедия остасы, импровизациягә сәләтле икәнлеге күренә. М. тудырган характерлар һәрвакыт үсеш-үзгәрештә бирелә, алар тамашачыны күпкырлы булулары, сәхнә тормышында көтелмәгәнчә гәүдәләнеш табулары б-н җәлеп итә. М. һәрбер образда милли характер үзенчәлекләрен ассызыклап, аның иң күркәм сыйфатларын аерып күрсәтә, татар хатын-кызы идеалын гәүдәләндерә белә. Аның Анна («Сары чәчәк ата көнбагыш», А.Гыйләҗев), Ана («Әниемнең ак күлмәге» («Әни килде»), Ш.Хөсәенов), Койтымбикә («Ител суы ака торур», Н.Фәттах), Кураж ана («Кураж ана һәм аның балалары», Б.Брехт) рольләре аерым урын били, театр тормышында зур бер вакыйгага әйләнә. Зур осталыгы, яшәү мәгънәсе турында масштаблы фикер йөртә белүе, сәхнә тормышының үтә чынлыгы актрисага эпик югарылыктагы, психол. тирән, социаль гомумиләштерелгән образлар иҗат итәргә мөмкинлек тудыра.



И.Һ. Мәхмүтова.



И.Һ. М ә х м ү т о в а Кураж ана ролендә («Кураж ана һәм аның балалары», Б.Брехт; сәхнәдә Ш.Фәрхетдинов белән).

М. үзен ш.у. талантлы оештыручы, режиссёр, драматург һәм тәрҗемәче буларак та таныта. 1991–93 тә сәнгать җитәкчесе сыйфатында театр коллективы б-н Д.Салиховның «Яшьлек хатам — йөрәк ярам», И.Юзеевнең «Резидәкәй», Н.Гаетбайның «Аты барның — дәрте бар», Р.Сәгъдинең «Сынган беләзек» пьесалары буенча спектакльләрне сәхнәгә куя. «Син бит минем бергенәм», «Мәхәббәт чишмәсе», «Күрәсем килгән иде» пьесаларын язып сәхнәләштерә, Б.Брехтның «Кураж ана һәм аның балалары» пьесасын татарчага тәрҗемә итә. М.ның үзенчәлекле, күпкырлы иҗаты татар театр сәнгатенең казанышы, татар милли характерының җанлы гәүдәләнеше булып тора.

*Әд.:* Г ы й л ь м е т д и н о в а З. Мәхмүтовларда — Мәхмүтовларча // Сәхнә. 2003. № 5.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МӘХМҮ́ТОВА** Ләйлә Таһир кызы (25.8.1925, хәзер Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Мөси а. — 20.2.2002, Казан, туган авылында җирләнә), тел галиме, филол. фән. канд. (1952). Ленинград ун-тының Көнчыгыш ф-тын тәмамлый (1948). 1952–86 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1961 дән тел белеме секторы мөдире). Татар диалектологиясе һәм лексикография тармаклары буенча эшли. М. җитәкчелегендә *Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы* төзелә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең (1–3 т, 1977–81) фәнни җитәкчесе һәм мөхәррирләреннән берсе; рус-татар, диалектологик, фразеологик сүзлекләр төзүче. Хезмәтләре татар теле тарихы, татар лексикологиясе, фонетика, татар-рус, татар-башкорт һәм татар-мордва икетеллелеге мәсьәләләренә карый. «Хәзерге татар әдәби теле» («Современный татарский литературный язык», 1–2 т., М., 1969–71) китабының авторларыннан һәм мөхәррирләреннән берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт исследования тюркских диалектов: Мишарский диалект татарского языка. М., 1978; О некоторых татарско-куманских параллелях (по материалам фонетики и грамматики) // Исследования по исторической диалектологии татарского языка. К., 1985. Вып. 3.

*Әд.:* Р а м а з а н о в а Д.Б. Во имя науки // Актуальные вопросы татарского языкознания. К., 2002.

*Д.Б.Рамазанова.*

**МӘХТҮМКОЛЫ́Й** (псевд., Фраги) (якынча 1730 — 1780 еллар), төрекмән шагыйре, төрекмән әдәбиятының реалистик юнәлешенә нигез салучы. Танылган төрекмән шагыйре һәм дини фикер иясе Дәүләт-Мәмәд-Әзадиның улы (1700–60). Ширгази (Хива ш.) мәдрәсәсендә белем ала. Күп җирләргә сәяхәт кыла, иранлыларда әсирлектә була. Сакланган әдәби мирасы 10 мең бәйт чамасы. М.ның лирикасы күбесенчә гошма строфик формасында язылган (дүрт унбер иҗекле юлдан тора). Иҗатында М. яшәешнең төп мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә: яшьлек һәм картлык, гомернең тиз үтүе һәм ыгы-зыгылыгы булуы, яхшылык һәм яманлык, гаделлек һәм әхлакый камилләшү. Ил язмышы турында уйлана, төрки кабиләләрне берләшергә чакыра. М. поэзиясе халык иҗаты б-н нык бәйле. Ул төрекмән поэтик телен халык теленә якынайта. Әсәрләре кульязма рәвешендә Идел буенда киң таралган була, күп тапкыр татар теленә тәрҗемә ителә. Татар журналларында һәм шигъри җыентыкларда (Ф.Туктамышев, Ә.Исхак тәрҗемәләрендә) 1917 елдан соң күренә башлый.

Ә с ә р.: Избранное. М., 1960.

*Әд.:* Махтумкули (Юбилейный сборник, посвящённый 225-летию со дня рождения великого туркменского поэта). Аш., 1961; К о р - О г л ы Х. Туркменская литература. М., 1972.

*Р.К.Ганиева.*

**МӘҺӘ́Р** (гарәп. مهر — бирнә, калым), мөселман халыкларында никахлашканда кияү тарафыннан кәләшкә түләнә торган калым. Хатын милке булып санала һәм, кайбер очраклардан тыш, кире кайтарып бирелми. Татарларда М.гә, икътисади шартларга һәм гореф-гадәтләргә карап, билгеле күләмдә акча, кием-салым, йорт кирәк-ярагы, хуҗалык төзелеше әйберләре, терлек-туар керә. М.нең микъдары һәм күләме якларның килешүе буенча билгеләнә. 19 йөздә ярлылар өчен М.нең хакы 30–500 сум чикләрендә үзгәреп тора, бай тормышлы татарларда 1 мең сумга кадәр җитә. Совет чорында М. үзенең беренчел мәгънәсен югалта һәм, башлыча, йола буларак саклана.

*Әд.:* Семейный быт и праздники // Татары. М., 2001.

**МӘҺДИ́** (гарәп. مهدى — дөрес юлдан баручы), ахырзаман якынлашуын алдан хәбәр итүче, *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең эшен соңгы дәвам иттерүче, афәттән коткаручы зат. М. Коръәндә искә алынмый, ләкин аның хакында *хәдисләрдә* киң аңлатма бирелә. Элегрәк *Гайсә* б-н тиңләштерелә, соңрак иманны яңартучы мөстәкыйль образ буларак кабул ителә. М., *исламның* әүвәлге чисталыгын тергезү өчен,

кыямәт көне җитәр алдыннан кайтачак. Шигыйлърдә (к. *Шигыйлър мәзһәбе*) киң таралган төп догмаларның берсе — «яшерен имам»ның кайтуына ышану.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**МӘҺДИ́ЕВ** Мәкәрим Әдһәм улы (23.12.1901, Самара губ., Бөгелмә өязе Түбән Ока а. — 10.7.1938, Мәскәү), драма актёры, режиссёр, педагог. Казан татар укытучылар мәктәбендә укый, анда һәвәскәрләр театрына тартыла. Проф. сәхнә эшчәнлеген 1918 елда Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясенең сәяси бүлеге каршындагы фронт театры труппасында башлый, соңрак Г.Казанский җитәкчелегендә «Үрнәк» (Уфа ш.) татар театр труппасында эшли. Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, 1925) тәмамлый, Мәскәү үзәк татар эшче театры спектакльләрендә катнаша. 1925–26 да Татар акад. театрында актёр һәм режиссёр, бер үк вакытта Татар театр техникумы директоры. 1926 да В.Мортазин-Иманский чакыруы б-н Уфага кайта, Башкорт сәнгать техникумында педагог һәм уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли,



М.Ә.Мәһдиев (уңнан икенче) Татар театр техникумы педагоглары белән (сулдан уңга – К.К.Чеботарёв, Р.Ф.Ишморат, И.Г.Ингвар, Б.Н.Симолин).

1930 дан 1937 нең 5 сентябрендә кулга алынганга кадәр — актёр, режиссёр, 1933 тән — Башкорт акад. драма театрының сәнгать җитәкчесе. К.С.Станиславский системасын эзлекле пропагандалаучы новатор, аны башкорт сәхнәсенең реформаторы дип йөртәләр. Дөнья классикасына һәм заманча репертуарга мөрәҗәгать иткән вакытта, аңа автор сүзенә сакчыл мөнәсәбәт, характер һәм хәлләрне җентекле эшкәртү, төп уй-фикерне җиткергәндә, актёрның хис-тойгыларын тиешле юнәлешкә бора белү, сәнгатьчә сурәтләү чаралары эзләү хас. М. иҗаты Башкорт драма театрында аеруча тулы ачыла. Анда аның тарафыннан С.Мифтахов («Паннар илендә», «Һакмар», «Зимагурлар»), Д.Юлтый («Карагол», «Салават»), А.Таһиров («Алатау», «Себердә яшәүче Гыйльман»), Г.Идрисов («Яз җыры») кебек башкорт яшь драматургларының пьесалары буенча спектакльләр куела. Ул ш.у. татар драматурглары пьесалары: «Кандыр бүе» (К.Тинчурин), «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), «Галиябану» (М.Фәйзи); чит ил классиклары әсәрләре: «Юлбасарлар», «Мәкер вә мәхәббәт» («Разбойники», «Коварство и любовь», Ф.Шиллер), «Сарык чишмәсе» («Овечий источник», Лопе де Вега); рус драматурглары пьесалары: «Борис Годунов» (А.С.Пушкин), «Ревизор» (Н.В.Гоголь; Хлестаков ролен уңышлы башкара) буенча да спектакльләр куя. Мәскәү үзәк татар эшче театрында («Һиҗрәт», «Культур Шәңгәрәй», Н.Исәнбәт; «Боз астында дулкын», «Упкын», Ә.Т.Рахманкулов), Татар акад. театрында («Казан кызы», К.Әмири; «Камали карт», Ф.Бурнаш) спектакльләр күрсәтә. М. башкарган рольләр арасында Отелло образы (У.Шекспирның шул исем. әсәре буенча) аеруча игътибарга лаек. Бу образның тышкы тотнаклылыгы артында характерның эчке күәте сизелә. М. театр сәнгате теоретигы буларак та хезмәт куя, башкорт вакытлы матбугатында аның башкорт милли театры тарихына караган мәкаләләре басыла. Репрессияләнә һәм атып үтерелә; үлгәннән соң аклана (1957).

Ә с ә р.: Театр тураһында: Мәкәләләр йыйынтығы. Өфе, 1962.

*Әд.:* Башкирский государственный академический театр драмы. Уфа, 1969; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992. *И.И.Илялова.*

**МӘҺДИ́ЕВ** Мөхәммәт Сөнгат улы (1.12.1930, Арча р-ны Гөберчәк а. — 12.6.1995, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, әдәбият галиме, филол. фән. канд. (1964), ТРның халык язучысы (1993). Мулла гаиләсеннән. 1930 еллар башында гаиләләре репрессиягә дучар була һәм өйләреннән куып чыгарыла. Әтисе НКВД лагерьларында һәлак була. М. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1954–59 да Арча р-ны мәктәпләрендә татар әдәбияты һәм тарих фәннәрен укыта. 1960 тан Казан ун-тында, 1963–91 дә татар әдәбияты каф. доценты. М.нең фәнни эзләнүләренең төп юнәлеше — 1920 еллар башындагы иҗтимагый-мәдәни мохит. 1960 елларда М. вакытлы матбугатта татар халкының рухи мирасына, 1920 еллар татар әдәбиятының күренекле вәкилләренә (Г.Сәгъди, Г.Рәхим, Г.Гали, Г.Нигъмәти, Ф.Сәйфи-Казанлы) багышланган мәкаләләр бастыра, 1967–70 тә «Галия» һәм «Буби» мәдрәсәләре, татар мәгърифәтчеләре бертуган Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар, Р.Фәхретдин, З.Камали, Г.Баруди, Ф.Кәрими турында язып чыга. 1960 елларда М. татар укучысына С.Рахманколый исемен кайтара: хикәяләрен туплап «Мәлиха куаклыгы» (1979) җыентыгын басмага әзерли. М. ш.у. Ф.Агиев, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Ә.Хәсәни һ.б.ның тормышы һәм иҗаты турында мәкаләләр, «Халык иҗаты әсәрләрен системалы итеп тикшерү тәҗрибәсе» (1982, автордаш), «Әдәбият һәм чынбарлык» (1987), «Реализмга таба: 20 йөз башы татар әдәбиятында чынбарлыкның чагылышы мәсьәләләре» (1989), «Талантның социаль тамырлары: яңа революцион күтәрелеш һәм беренче империалистик сугыш еллары татар әдәбияты тарихыннан» («Социальные корни таланта: из истории татарской литературы в годы нового революционного подъёма и первой империалистической войны», 1990) монографияләре авторы. М. «Без — кырык беренче ел балалары» («Казан утлары» ж-лы, 1968, № 5; рус теленә тәрҗемәсе «Мальчишки сорок первого», 1974) исемле беренче повесте б-н үк үзен үзенчәлекле иҗат стиле булган язучы итеп таныта. Аңа лиризм, нечкә юмор, үзенчәлекле тел-бизәкләү чаралары хас. Гадәти булмаган сюжет корылышы, үзәк



М. Мәһдиев.

урынны алып торучы лейтмотивлар әсәрләренең төзелешенә дә үзгәлек бирә. «Кеше китә — җыры кала» (1979) повесте геройлары — авыл кешеләре, вакыйгалар Бөек Ватан сугышы чорында бара. Тылдагы фидакарь хезмәт һәм яу кырындагы батырлыклар, кайгы һәм шатлык, хыянәт һәм ныклык кебек кыйммәтләрне күрсәтеп, автор әсәр геройларының берсеннән төп фикерне әйттерә: «Туган ил өчен мондый авыр вакытларда йомшаклык күрсәтү ярамый, кеше булып, ир булып калырга кирәк. Шул чакта нәсел-нәсәбең, туган җирең, туган авылың да исән-сау булыр». Аның «Фронтовиклар» (1973; русчага тәрҗемәсе «Большая земля под крылом», М., 1974), «Каз канатлары» (1975), «Мәңгелек яз» (1982) романнары, «Ут чәчәге» (1980) повесте татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Әдәби тәнкыйть М.не «туган як җырчысы» дип атый, язучы авыл, аның кешеләре турында аеруча җылы итеп, яратып яза, аларның җитешсезлекләрен, кимчелекләрен дә читләтеп үтми, кайчак көлеп тә ала. Еллар үтү белән, язучының иҗат стиле бераз үзгәрә. Юмордан тыш, әсәрләрендә ачы сатирик штрихлар да күренә башлый, лиризм — хискә бирелү, сагыш б-н бeррәттән үткәннәрне сагыну да көчәя. М. иҗатында «үз» күңел дөньясы гәүдәләнеше сыйфатында үткәннәр тора, язучы һәм аның геройлары гына түгел, халык та үзенә шуннан көч ала, терәк таба. «Торналар төшкән җирдә» (1983) повестенда һәм «Бәхилләшү» (1990) романында үткәннәр мотивына инвариант булып, кешеләрнең бу дөньядан мәңгегә китү, гореф-гадәтләр, бәйрәмнәр, көнкүреш детальләренең юкка чыга баруы мотивлары кебек мәңгелек кыйммәтләр тора. 1980 еллардагы актуаль сәяси һәм иҗтимагый-көнкүреш проблемаларын чагылдырган «Тынгысыз өч көн» исемле бердәнбер пьесасы 1983 тә Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела. Чит илләргә сәяхәте тәэсирендә дөнья күргән «Җир йөзендә алты кыйтга» әсәре (1992) юлъязма жанрында язылган; чит илдәге тормышны үзенеке б-н чагыштырып, әдип үз халкының рухи кыйммәтләренең мәгънәсен эзли. Гомеренең соңгы елларында М. «Ачы тәҗрибә» (1993) исеме куеп мемуарлар яза, ләкин беренче китабын гына чыгарып өлгерә. Аның әсәрләре күп тапкырлар кабаттан басылып чыга, күбесе рус теленә тәрҗемә ителә. 1990 да М.кә «Бәхилләшү» романы һәм «Торналар төшкән җирдә» повесте өчен ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге бирелә. 2000 дә Гөберчәк авылында язучының музее ачыла.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1995–96.

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Р. Гадиләр, гадәтиләр // Якутлар табыладыр вакыт белән. К., 1983; М и ң н у л л и н Ф. Яшьлекне сагыну // Балта явызлар кулында. К., 1994; М.Мәһдиев: язучы турында замандашлары. К., 2004.

*Д.Ф.Заһидуллина, Р.Ә.Мостафин.*

**МӘҺДИ́ЕВ МӨХӘММӘ́Т МУЗЕЕ́**, Арча р-ны Гөберчәк авылында. 2000 елның 6 июлендә ачыла. 2006 дан «Казан арты» әдәби-музей берләшмәсе ф-лы. ТР халык язучысы, әдәбият галиме М.С.*Мәһдиевнең* тормышы һәм эшчәнлегенә багышлана. Мәһдиевләрнең йорты урынында махсус төзелгән бинада урнаштырылган. Экспозиция өч залдан гыйбарәт, мәйданы — 93 *м²*. Музей коллекцияләрендә 1000 гә якын саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция авторлары — ТР Милли музее фәнни хезмәткәре А.Д.Хәйруллина, Ф.К.Дәминова, рәссам Ф.А.Зыязов. Экспозициянең беренче бүлеге Мәһдиевнең туган





1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты: язучының Казан фатирындагы бүлмә интерьеры.

җиренә багышлана, күргәзмәгә борынгы китаплар, көндәлек йорт кирәк-яраклары, ш.у. табигать күренешләре сурәтләнгән фоторәсемнәр куелган. Икенче залдагы экспозиция җирле халыкның мәдәнияте һәм көнкүреше б-н таныштыра, биредә татар йорты интерьеры торгызылган, язучының 1937 дә репрессияләнгән әтисенә кагылышлы архив документлары куелган. Бөек Ватан сугышына багышланган өченче залда язучының Бөек Ватан сугышында катнашкан Рәшит абыйсы турында материаллар, ш.у. әдипнең шәхси әйберләре урын алган. М.С.Мәһдиевнең Казан фатирындагы эш бүлмәсе интерьеры торгызылган. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында язучының өстәле, урындыгы, кием-салымнары, ш.и. СССР Хәрби диңгез флоты формасы, шәхси әйберләре, дусларының аның турында язган мәкаләләре бар.

Музей ел саен Белем көнен (1 сентябрь), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә, язучының туган көнен (1 декабрь) үткәрә.

**МӘҺДИ́ЕВ** Наил Гамбәр улы (12.10.1959, Бөгелмә ш.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре. ТРның атказ. торак-коммуналь хуҗалык хезмәткәре (2001). Ленинград урман техник академиясен тәмамлый (1982). 1982–84 елларда «Татнефтегеофизика» трестында (Бөгелмә ш.) инженер, 1984–86 да ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1986–90 да КПССның Бөгелмә шәһәр ком-тында бүлек мөдире. 1990–92 дә Халык депутатларының Бөгелмә шәһәре Советы башкарма ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1992–95 тә Бөгелмә р-ны һәм Бөгелмә шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары, 1996 дан — башлыгы. Бер үк вакытта, 1996 дан, Бөгелмә Халык депутатларының берләштерелгән советы рәисе. 2006–10 елларда «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы. 2010 нан ТР урман хуҗалыгы министры. 1995–2004 тә ТРның Халык депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МӘҺДИ́ЕВ** Усман Хәсән улы (10.1.1940, Иркутск өлкәсенең Бодайбо р-ны Артёмовск приискы), бетон эшләнмәләрнең ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), Россия Архит-ра һәм төзелеш фәннәре академиясе хакыйкый әгъзасы (2006), РФнең атказ. төзүчесе (2000). Ташкент тимер юл транспорты инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Днепропетровск тимер юл транспорты инженерлары ин-тында эшли. 1975–80 елларда Мәскәүнең «Главмоспромстройматериалы» трестында бүлек башлыгы, «Мосоргстройматериалы» конструкторлык-технол. бюросында фәнни эшләр буенча директор урынбасары. 1980 нән фәнни-тикшеренү һәм проект-технол. ин-тында. Хезмәтләре эффектив төзелеш материаллары технологияләре булдыру һәм гамәлгә кертүгә карый. Сөзәк авышлыкларның тотрыклылыгы турындагы фәзаи мәсьәләне вариатив чишү алымын тәкъдим итә. М. җитәкчелегендә катламлы-монолит эшләнмәләр һәм конструкцияләр төзүнең төп нигезләмәләре эшләнә, деформацияләнгән киеренке халәтнең темп-рага һәм механик тәэсирләргә бәйлелеге ачыклана, катламнар калынлыгы б-н аларның деформатив характеристикалары арасындагы иң кулай нисбәтләр табыла. Уйлап табуга 41 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының өч алтын, өч көмеш медале б-н бүләкләнә. СССР МС һәм РФ Хөкүмәте (ике тапкыр) бүләкләре лауреаты.

Х е з м.: Слоистые защитно-декоративные композиты. М., 1997; Мини-заводы по производству изделий для строительства малоэтажных зданий // Строит. материалы, оборудование, технологии XXI века. 2006. № 5; Экология, научные достижения и инновации в производстве строительных материалов на основе и с применением техногенного сырья // Строит. материалы, оборудование, технологии XXI в. 2009. № 12 (автордаш).

**МӘҺЛИ́ЕВ** Рамил Рафаэль улы (12.5.1960, Уфа ш.), график, педагог. Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика бүлеген тәмамлый (1983). 1984 елдан Уфа сәнгать уч-щесендә укытучы, мөдир (1986 дан). Рәссамнар берлеге (1996), ЮНЕСКО каршындагы Халыкара сынлы сәнгать ассоциациясе әгъзасы (1996). Аклы-каралы һәм төсле литография өлкәсендә әйдәп баручы рәссамнарның берсе, ш.у. катнаш техника б-н дә эшли (монотипия, ретушь, меццо-тинто, акварель). М. әсәрләре автор стилистикасының үзенчәлеге, татар авылы, ш.у. мифология һәм фольклор сюжетларына караган шәһәр пейзажлары темасын ачучы образларның хисләргә байлыгы б-н аерылып тора. Төп әсәрләре: «Интерьер» (1987), «Дача моңы» (1990), «Мәчет» (1991), «Кызыл курчак белән композиция» (1992), «Кырыктартмачы» (1992), «Ишегалды» (1993), «Тулган ай» (1994), «Малай һәм ат» (1995), «Борынгы Уфа» сериясе (1996, 4 кисәк), «Әңгәмә», «Онар», «Галахан», «Тувыртуш» (барысы да — 1997), «Кайту» (2003).

Респ-ка (1984 тән), зона («Социалистик Урал», Курган ш., 1991; «Урал VIII», Уфа ш., 1997) күргәзмәләрендә, станлы басма графиканың Урал триенналесендә (Уфа, 1995, 1998), халыкара («Кече формалар графикасы» биенналесе, Сент-Никлаас ш., Бельгия 1991–99; «Төрки дөнья», Испарта, Әнкара шәһәрләре, Төркия, 2000) күргәзмәләрдә, экслибрис конкурсларында (Маастрихт ш., Нидерланд, 1993; Медон ш., Франция, 1994) катнаша. 2 нче Урал станлы басма графика триенналесе (Уфа ш., 1998), «Тугызынчы Зур Идел» зона күргәзмәсе (Саранск ш., 2004) дипломанты. Шәхси күргәзмәсе 1996 да уза (Уфа ш.).

Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан сәнгать музеенда, «Урал» галереясында (Уфа ш.), Брунек шәһәре Графика музеенда (Италия), Эрбет сәнгать музеенда, чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә (Германия, Төркия һ.б.) саклана.





Р.Р. М ә һ л и е в. 1. «Сезон тәмам». Төсле литография. 1995; 2. «Малай һәм ат». Төсле литография. 1995.

*Әд.:* Рамиль Маглиев. Графика. Уфа, 1997; Художники Башкортостана. XX век: Справ. Уфа, 2002; Luc van Den Briele «Nieuwe namen in de hedendaagse exlibriskunst» // Grafica. 1993. № 3.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*


**МӘЦКӘ́Й-МӘЧКӘ́Й**, к у п к ы н, Себер татарлары мифологиясе һәм фольклорында үлгән сихерче рухы. Борынгы ышануларда кешеләр арасында яши, тышкы кыяфәте б-н алардан аерылмый. М.-м. төннәрен утлы шар булып очып йөри, кешеләрнең канын эчә, аларга чир-авырулар йоктыра. Ул *Убырны* һәм *Убырлы карчыкны* хәтерләтә. М.-м.дән кешене, догалар ярдәмендә, мулла гына коткара ала. Башкорт мифологиясендә М.-м. явыз зат буларак та, күрәзәче уңай зат буларак та билгеле. («*Кузы Күрпәч белән Баянсылу*» дастанының башкорт версиясе).

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Башҡорт халык ижады: Әкиәттәр. Өфө, 1976. 1 кит; К и р е е в А.Н. Башкирский народный героический эпос. Уфа, 1970.

**МӘЧЕ́ БОРЧАГЫ́**, д ө я с е ң е р е, а с т р а г а л (Astragalus), кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләннәр, ярымкуаклар, сирәк кенә куакчыклар һәм зур булмаган куаклар ыругы. 2200 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм субтропик поясларында, Көньяк Американың таулы районнарында һәм Африканың көньяк көнчыгышында таралган. 10–120 *см* биеклектәге үсемлекләр. Яфраклары катлаулы, парсыз каурыйсыман. Чәчәкләре куе кызыл, алсу, шәмәхә, тонык сары яки ак төстә, төрле формадагы чук чәчәк төркемендә. Җимеше — 6–7 орлыклы кузак. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи. ТРда 17 төре бар. Дания М.б. (тургай борчагы) (A. danicus), нут М.б. (A. cicer), буркынсыман М.б. (A. onobrichis), Австрия М.б. (A. austricus), нигездә, ташлы һәм ялангач тау битләрендә, корылыклы болыннарда, ерымнарда үсә. Ураксыман җимешле М.б. (A. falcatus) һәм буркынсыман М.б. культурага кертелгән. 100 *кг* яшел массада 28 азык берәмлеге һәм 20% ка якын эшкәртелмәгән протеин (коры матдә) була, печәндә тиңдәшле рәвештә 73 азык берәмлеге һәм 15%. Печән уңышы 1 *га* дан 30–60 *ц*. Халык медицинасында татлы тамыр яфраклы М.б.ның (A. glycyphyllus) сабагы төче авыруы (золотуха) һәм тире тимгеле вакытында тынычландыру чарасы буларак кулланыла. 12 төре: Идел буе мәче борчагы (A. wolgensis), җыерчыклы мәче борчагы (A. sulcatus), Цингер мәче борчагы (A. zingere) һ.б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель растений Татарской АССР. К., 1979.

**МӘЧЕ́ БӨТНЕГЕ́**, к ү к с ы р г а (Nepeta), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 250 гә якын төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америка, Африкада очрыйлар. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Гади М.б. (N. cataria), венгр М.б. (N. pannonica) республиканың барлык терр-ясендә таралган; украин М.б. (N. ucranica) көньяк-көнчыгыш Кама аръягында очрый. Далаланган тау битләрендә, елга ярлары буенда, куаклар арасында, болыннарда үсәләр. 25–100 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамыры тармаклы. Сабагы туры, вак төкчәләр б-н капланган. Яфраклары өчпочмаклы-йөрәксыман, очлы, кырыйлары тешәүле. Чәчәкләре вак, ак яисә алсу төстә, тыгыз башаклы чәчәк төркемендә. Җимеше — вак чикләвекчекләр. Июнь–сентябрьдә чәчәк аталар. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Үсемлекләрдән бөтнек исе килә. Җир өсте өлешләрендә гликозидлар, май, органик к-талар, дуплау матдәләре бар. Халык медицинасында гади М.б. һәм венгр М.б. аппетитны ачу, баш, бавыр авырулары вакытында кулланыла. Баллы үсемлекләр. Украин М.б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Менделеев шәһәрендәге «Таң» мәчете. 1995.

**МӘЧЕ́Т** (гарәп. مسجد — табыну урыны), мөселман дини корылмасы. Урта Идел терр-ясендә беренче мәчетләр Идел буе Болгар дәүләтендә 10 йөздә барлыкка килә. Биләр шәһәрлегендә гарәп архит-расы тибындагы күп колонналы 10 йөз бинасы — җамигъ М.нең археол. калдыклары сакланып калган. 14 йөздә Алтын Урданың Болгар олысы башкаласы Болгар шәһәрендә күп колонналы М. төзелә (хәзер *Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы*; ш.у.к. *Болгар җамигъ мәчете*, *Кече манара*). Әлеге чорның мөселман дини архит-расында сәлҗүкләр архит-расының йогынтысы нык сизелә. Алтын Урда таркалганнан соң, мөселман дини төзелеш традицияләре Казан ханлыгы архит-расында дәвам итә. Ханлыкның монументаль М.ләре госманлылар стилендә төзелгән дип фаразлана. Авыл М.енең җирле традицион төре агачтан буралган, манарасы ике яки дүрт кыеклы түбәгә урнаштырылган бинадан гыйбарәт була. Казан төбәгендә М.нең 5 төре: квартал яки «мәхәллә М.е»; бәйрәм намазлары өчен җамигъ яки «җомга М.е»; үзәк башкала «кәбирәсе»; гомуми шәһәр мосалласы; зиратта гыйбадәт кылу М.е булуы мәгълүм. 16 йөздән башлап мәхәллә һәм җамигъ М.ләре генә төзелә. Казан ханлыгын Рус дәүләте яулаганнан соң (1552), татар монументаль дини архит-расы үсүдән туктый, Казанда М.ләр төзү тыела. 1593 елгы патша боерыгында Казан воеводаларына катгый рәвештә: «Һәм сез барлык татар мәчетләрен сибереп түгегез, алга таба татарларга һич тә М. төзергә рөхсәт бирмәгез», — диелә. Сенатның «Казан губернасында мәчетләр төзергә рөхсәт бирмәү турында»гы 1742 елгы фәрманы да ш.у. мөселманнарга һәм татарларга катгый каршы юнәлештә була, 1744 кә Казан һәм Зөя провинцияләрендәге 536 М.нең 418 е җимертелә. Екатерина II хакимлеге чорында Россия мөселманнарына карата дини сәясәт шактый үзгәрә. 1760 елларның 2 нче яртысыннан Казан төбәгендә таш мәчетләр салына башлый. Рус проф. архитекторлары, заллы, манаралары түбәгә урнаштырылган традицион М. тибыннан файдаланып, аларны гомумроссия стилендә төзергә керешәләр. Башлыча бер яки ике заллы, хуҗалык бүлмәләре беренче катта яки келәт астында, манаралары түбәгә урнаштырылган М.ләр калкып чыга. Манаралар, кагыйдә буларак, ярусллы итеп төзелә. Яруслар формалары һәм зурлыклары буенча аерылып торган, кечкенә түбәле кәрнизләр б-н бүленгән. Беренче типтагы М.не бизәгәндә (мәс., *Кышкар мәчете* һәм *Мәчкәрә мәчете*),



Болгар шәһәрендәге Ак мәчет комплексы. Арх. С.П.Шакиров. 2012.

барокко стиле архит-расы һәм татар бизәлеш сәнгате элементларын аралаштыру алымы кулланыла. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында шәһәр архит-расы йогынтысында түбәнең кадаксыз төре (бүрәнә фронтон) — атламалы түбәгә, манараның буралы конструкциясе каркасына алыштырыла. Бүрәнә диварларның чыгынтыларын лопатка яки пилястрлар б-н бизәп, такта б-н тышлый башлыйлар. Шушы ук чорда М. биналарында такта кәрнизләр, көньяк һәм төньяк фронтоннарда чорма тәрәзәләре, түбә асты куышлары, ике колонна өстендә ике кыеклы түбәле өйалды баскычы һ.б. барлыкка килә. Татар мәчетләрендә ислам дине билгесе — ярымай (манарада, гөмбәз очларында һәм михраб өстендә) чагыштырмача 18 йөз ахырында күренә башлый. *Әсән-Елга мәчете* — Татарстанда безнең көннәргә кадәр сакланып калган бердәнбер татар агач дини архит-ра истәлекләреннән берсе (18 йөз ахыры). 18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче чирегендә манарасы түбәгә урнашкан бер яки ике заллы гадәти М. катгый классицизм формаларында төзелә (*Ташкичу мәчете* һәм Байлар Сабасы авылындагы М.). Ләкин бу чорда М.ләрнең күпчелеге агачтан салына. Шәһәрдә яки авылларда агач М. фасадларын һәм интерьерларын бизәгәндә классицизм архит-расы элементлары кулланыла: киң кәрниз, тоскан ордерындагы лопаткалар һәм пилястрлар, капительле агач колонналар рәвешендәге ордер элементлары, баскыч һәм балкон култыксаларындагы балясиналар. 19 йөз башында Россиядә архит-рага һәм төзелешкә, ш.и. мөселман дини корылмаларына билгеле кагыйдәләр кертелә. Кануни актлар авыл М.ләрен якындагы йорт-каралтылардан 10 сажиннан да ким булмаган ераклыктагы мәйданнарга яки үзәк урамнарга салуны күздә тота (гадәттә, авыл М.е авыл үзәгендәге елга буена яки тыкрыкка салына). 2–3 мең халкы булган зур татар авылларында берничә М. эшли. Төзелеш өчен рөхсәт алына һәм проект ясала. 1829 да беренче проект басылып чыга (Казан губернасында яклау тапмый), 1844 тә гөмбәзле манарасы төньякка һәм ишеге аның аскы ярусына урнашкан татар М.е проектының яңа үрнәге раслана. 19 йөзнең 2 нче яртысында күп кенә М.ләр, мәс., Мамадыш өязендәге Кәчимир һәм Казиле авылларындагы М.ләр, *Чистай шәһәренең беренче мәчете* төрле архитектур формалар катнашкан үрнәк проект буенча төзелә. 1863 тә моңарчы катгый кысаларда булган М. проектлары үрнәкләренең композициясен һәм планын ирекле сайлау рөхсәт ителә. 1920–30 елларда күп кенә М.ләрнең эшчәнлеге туктатыла, биналары төрле учреждениеләр тарафыннан яки хуҗалык максатларында файдаланыла башлый. 1980 еллар ахырында үзгәртеп кору башлангач, мөселман мәхәлләләре кабат оеша, тарихи М. биналары мөселманнарга кайтарыла, яңалары төзелә башлый. Яңа оешкан мөселман мәхәлләләре тормышында хатын-кызларның актив катнашуы мәчетләрнең функцияләре киңәюгә китерә. М. төзүдә рев-циягә кадәрге үрнәкләргә ияру, гадәти күләмле-планлаштырылган чишелешләрдән файдалану әкренләп яңа композицияле карарлар эзләү һәм куллану б-н алыштырыла башлый. М.нең функциясен оештыру 2 төргә бүлеп карала: гыйбадәт заллары анфилада рәвешендә ир-атлар өчен төп катта һәм хатын-кызлар өчен ниргәдә яки беренче катта була, ишекләре аерым куела. М. әче вестибюль һәм холлдан башка тагын арулану һәм тәһарәт алу, ял итү һәм укучыларга дәрес бирү бүлмәләрен, китапханәгә бүлене. Икенче юнәлеш Казандагы һәм респ-каның зур шәһәрләрендәге дини биналарга хас. Залы гөмбәзле, үзәк манарасы төньякта, ишек өстендә урнашкан М. тибы киң тарала башлый. Казандагы *«Печән базары мәчетенең»* («Нурулла») композициясе дә шуңа охшаган. Татар М.е образын шәркый-мөселман, болгар һәм татар халык архит-расы үрнәкләрен чагылдырган яңа формаларда иҗат итәргә омтылу Менделеев шәһәрендәге *«Таң» мәчете*, Чаллыдагы *«Әбузәр»* биналарында сизелә. Чаллы шәһәрендәге *«Тәүбә» мәчете* гөмбәзсез ике кыеклы түбә б-н ябылган. Теләче авылындагы М. заллары соңгы елларда киң таралган диагональ рәвештә урнашуы б-н үзенчәлекле. Кайвакыт М.нең гомуми композициясе һәм зал түбәсе диагональ үзәк буенча төзелә (Казандагы *«Болгар» мәчете*; Югары Ослан р-нының Кызыл Байрак авылындагы М., 1997, архитекторлар Т.М.Агишев, И.Н.Агишева һ.б.). Күпманаралы *Түбән Кама җамигъ мәчетенең* залы диагональ рәвештә оештырылган М. тибына керә, монда дини ихтыяҗлар дини-агарту бурычлары б-н бергә башкарыла. М. композициясен катлауландыру, аны нәфис архитектур алымнар б-н баету күренеше Чаллыдагы *«Ихлас»*, Алабугадагы *«Җамигъ»* мәчетләрендә, Р.Г.Галиев исем. *Әлмәт мөселман дини мәгърифәт үзәгендә* һ.б.да гәүдәләнеш таба. 2013 ел башына Татарстанда 1325 М. исәпләнә. Ш.у. к. *Казан мәчетләре, Мәскәү мәчетләре, Манара, Михраб.*

*Әд.:* Халитов Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МӘЧЕТЛЕ́ РАЙОНЫ́**, БРның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 1557 *км*². Үзәге — Олы Ыктамак авылы (Уфадан 283 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 24440 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 8702, 1979 да — 7372, 1989 да — 6983, 2002 дә — 6052, 2010 да — 5886 кеше. Районда 50 торак пункт, ш.и. 4 татар, 6 татар-башкорт, ш.у. 2 татар-рус һәм татар-рус-башкорт авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009) — Олы Ака (1239 кеше) һәм Яңа Мөслим (1085). 2004/05 уку елында М.р.ның 6 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 6 сында татар теле фән буларак өйрәнелә.

**МӘЧКӘРӘ́**, Мошкара елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 15 *км*, бассейнының мәйданы 55,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Лениногорск р-нында. Елга башы Яңа Чыршылы посёлогы янында, тамагы Александровка посёлогыннан 3,5 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 320 *м*, тамагыныкы — 128 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. М.нең 1 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 км/км². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–10 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,075 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. М. бассейнында суның гомуми күләме 1,9 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӘЧКӘРӘ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 25 *км* төньяктарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 229 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб. Сәүдәгәр Үтәмишевләр йорты — 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ишменево исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөздә М. зур мөселман мәгарифе үзәкләреннән берсе була.



Мәчкәрә авылы. Сәүдәгәр Үтәмишевләр йорты. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

2 җирле мәчеттә һәм авыл мәдрәсәсендә атаклы дин галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре белем ала һәм эшли, алар арасында Г.*Курсави*, Х.*Әмирханов* була. 20 йөз башында 1 кирпеч-мамык һәм 2 китайка тукымасы өчен җеп эрләү биналары, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1552,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Күкшел волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1873 тә — 677, 1884 тә — 802, 1905 тә — 993, 1920 дә — 933, 1926 да — 797, 1938 дә — 663, 1949 да — 579, 1958 дә — 544, 1970 тә — 458, 1979 да — 440, 1989 да — 307, 2002 дә — 240 кеше. Ш.у. к. *«Мәчкәрә» мәдрәсәсе, Мәчкәрә мәчете.*

**«МӘЧКӘРӘ́»**, мәдрәсә. Вятка губернасының Малмыж өязе Мәчкәрә авылында ур-

нашкан була (хәзер ТРның Кукмара р-ны), авылның беренче мәхәлләсе каршында эшли. 1750 елларда Габделхәмид бине Үтәгән әл-Түнтәри тарафыннан нигез салына. Үзенең үсеше б-н мәдрәсә укучыларының берсе — Г.Г.Үтәмишевкә бурычлы (к.*Үтәмишевләр*), әлеге эре эшмәкәр «М.» мәдрәсәсенә зур ярдәм күрсәтә. Икенче мөдәррисе Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти була (1818 дә вафат); аның вакытында «М.» Идел-Урал төбәгендә иң билгеле мәдрәсәләрнең берсенә әверелә, үзенең бу статусын Габдулла бине Яхъя әл-Чиртуши (1858 дә вафат) вакытында да саклап кала. А.Сөбханкулов (1886 да вафат) һәм А.Абдулбәширов мөдәррислек иткәндә, мәдрәсә үзенең алдынгылык ролен югалта, иске ысуллы гадәти уку йортына әверелә. Мәдрәсәне тәмамлаучылар — Г.*Курсави,* Х.*Әмирханов*, С.Мәрҗани (Ш.Мәрҗанинең әтисе), М.Тукаев (Эстәрлебаш мәдрәсәсен нигезләүче), Х.Госманов («Госмания» мәдрәсәсен нигезләүче), И.М.Үтәмишев (Кышкар мәдрәсәсе мөдәррисе).

*Әд.:* Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1890. Т. 2; Хайрутдинов Р.Р., Салихов Р.Р. Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

**МӘЧКӘРӘ́ МӘЧЕТЕ́**, татар дини архит-расы истәлеге. Кукмара р-ны Мәчкәрә авылы үзәгендә урнашкан. 1791 елда 1 нче гильдия Малмыж сәүдәгәре Габдулла ибне Габдессәлам ибне Үтәмиш әл-Мәчкәрәви акчасына төзелә. Түбәсенә манара урнаштырылган ике катлы, ике заллы мәчет. Беренче кат хуҗалык әйберләре куйю өчен билгеләнгән. Анфиладалы гыйбадәт залының түшәме гөмбәзсыман. Гөмбәз өслеге барокко һәм татар бизәлеш сәнгате үрнәгендәге филёнкалар, катырып ясалган розеткалар б-н бизәлгән. Мәчет фасадларында Петербург бароккосы стилендәге классицизм элементлары булган әүвәлге



Мәчкәрә авылы мәчете. 1791.

бизәлеш сакланып калган. Мәчеттә татар галим-теологлары һәм вәгазьчеләре ахун Мөхәммәдрәхим бине Йосыф әл-Ашыти һәм Габдулла бине Яхьякәл-Чиртуши имам хезмәтен башкаралар. 2011 дә М.м.нең манарасы торгызыла.

*Әд.:* Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МЕБИКА́Р** (лат. mebicar), дару, көндез кулланыла торган транквилизатор (2,4,6,8-тетраметил-2,4,6,8-тетраазобицикло (3,3,0) октадион-3,7). Тәме ачы булган төссез порошок, суда һәм күп кенә органик эретмәләрдә җиңел эри; химик яктан инерт: кислота, селте, оксидлаштыручы, яңадан кайтаручы матдәләр, дарулар һәм азык компонентлары йогынтысына бирелми; яхшы саклана, стерильләштерү ысулларына чыдам, эрү темп-расы 224–228 °С. РФАнең Органик химия ин-тында (Мәскәү) эшләнә, фармакологик активлыгы Казан мед. ин-тында (И.В.*Заиконникова*, И.Е.*Зимакова* һ.б.) өйрәнелә. Клиник тикшерүләр М.ның дәвалау активлыгы югары булуны раслый. 1979 елда препаратка патент бирелә һәм ул гамәлдә кулланыла башлый; 1986 да фенозепам һәм седуксен б-н бергә СССРда кулланылучы өч төп транквилизатор исемлегенә кертелә. Мускуллар көчсезлеге, сүлпәнлек, йокымсырату эффектлары уятмый, кан күрсәткечләренең нормальләшүенә этәргеч бирә. М. матдәләр алмашына йогынты ясамый, организмнан тулысынча, үзгәрешсез чыгарыла, токсинлылыгы аз, организмның гадәти метаболитларына (мочевина һ.б.) якын. Психиатрия, наркология, невропатология, стоматологиядә, ш.у. көндәлек тормышта неврозларны кисәтү өчен кулланыла. «Татхимфармпрепаратлар» АҖдә җитештерелә (2001 дән).

*Әд.:* Зимакова И.Е. Фармакологические эффекты нового психотропного препарата мебикара // Фармакология и токсикология. 1977. Т. 40, № 6.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МЕГДЯ́ТОВ** Рәшит Салих улы (15.8.1951, Мәскәү), невропатолог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1995). Н.А.Семашко исем. Мәскәү стоматология ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда эшкә калдырыла. Хезмәтләре бит нервы зарарланган очракта вегетатив-кан тамырларындагы һәм трофик тайпылышларны, деафферентация синдромын өйрәнүгә карый. М. тарафыннан Россолимо-Мельнерсон-Розенталь синдромын, өч япьле бит невралгиясен, алгы баскычсыман мускул синдромын, гепатоцеребраль дистрофияне, биттәге авырту синдромнарын, умыртка сөягенә функциональ блокада ясагандагы авырту синдромын, бит нервы невропатиясен, муен остеохондрозы вакытындагы скаленус-синдромны дәвалау ысуллары тәкъдим ителә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Невралгия тройничного нерва. М., 1999.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Александр Владимирович (20.6.1935, Кама Тамагы р-ны Варварино а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), проф. (1994), РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1993). Казан а.х. ин-тын (1963), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1967) тәмамлый. 1961–65 елларда ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында, Октябрь, Алексеев р-ннарында комсомол һәм партия эшендә, 1967–69 да Кама Тамагы р-ны башкарма ком-ты рәисе, 1970–71 дә ТАССРның сыйфат буенча баш инспекторы урынбасары, 1971–76 да ТАССР а.х. министры урынбасары, 1976–78 дә «Россемкартофель» ФҖБнең бәрәңге орлыкчылыгы бүлеге башлыгы һәм ген. директоры урынбасары. 1978–2000 дә (бүленеп) РФ А.х. һәм азык-төлек министрлыгында: партком секретаре (1978–89), баш кадрлар идарәсе башлыгы (1989–96), кадрлар сәясәте һәм персонал б-н эшләү бүлеге рәисе (1999–2000). 1996–99 да Россия менеджмент һәм агробизнес инженерлары академиясе проректоры. 2000 нән Россия агросәнәгать комплексын кадрлар б-н тәэмин итү академиясе проректоры.

Хезмәтләре агросәнәгать комплексында аграр реформалар һәм дәүләтнең кадрлар сәясәте мәсьәләләренә карый. М. тырышлыгы б-н Россиядә беренче Агросәнәгать комплексында социаль һәм кадрлар мәсьәләләре буенча фәнни-тикшеренү ин-ты, Агросәнәгать комплексының кадрлар һәм социаль сәясәт академиясе булдырыла. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. Россия Табигыять фәннәре академиясенең В.И.Вернадский исем. медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Аграрная реформа АПК: Кадровая политика на переходном этапе к рынку. СПб., 1993; Кадровый потенциал российского села. М., 1994; Природно-экологические проблемы сельского хозяйства. М., 2000 (автордаш); Оценка персонала. М., 2001; Сельское хозяйство России в свете экологических проблем. М., 2004 (автордаш).

*Әд.:* А.В.Медведеву — 70 лет // Вестн. кадровой политики, аграрного образования и инноваций. 2005. № 6.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Анатолий Михайлович (13.8.1944, Казан), гидрогеолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1970), Куйбышев геол. идарәсендә геол.-разведкалау идарәсе экспедицияләрендә эшли. 1977 елдан «Татмелиоводстрой», 1980 нән «Сельхозводстрой» трестларында. 1985 тән «Росводэксплуатация» АҖдә, 1989 дан Казан геол. экспедициясендә. 1994–2002 дә «Татнефть» АҖ идарәсенең геол.-разведкалау идарәсендә баш гидрогеолог. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыгару районнарында җир асты сулары чыганакларын тикшерү методикасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Борис Яковлевич (10.3.1938, Казан — 18.6.2008, Казан), слесарь-инструментчы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). 1961–79 елларда Казан төгәл машиналар төзү з-дында эшли. Дәүләт бүләге махсус приборлар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены б-н бүләкләнә.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Владимир Иванович (25.12.1928, Саратов өлкәсенең хәзерге Ивантеево р-ны Сёстры а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1977), проф. (1979), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1989), Чуаш АССРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1977). 1952 елда Саратов а.х.н механикалаштыру ин-тын тәмамлаганнан соң, ТАССР А.х. министрлыгының Казан өлкә идарәсендә, 1953 тән Казан а.х. ин-тында укыта. 1963 тән Чуаш а.х. академиясендә, тракторлар һәм автомобильләр каф. мөдире (1963–2001), а.х.н механикалаштыру ф-ты деканы (1965–69). Хезмәтләре машина агрегатлары энергетикасына, аларның параметрларын исәпләү методикасына карый. М. катнаш машина агрегатларында двигательнең егәрлеген күп юнәлештә бүлә торган тракторларны эшләүдә һәм җитештерүгә кертүдә катнаша (Минск һәм Липецк

трактор з-дларының махсус КБ коллективлары б-н берлектә). Уйлап табуга 50 авторлык таныклыгы бар. Чуаш АССР ЮС депутаты. (1985–90). «СССРның уйлап табучысы», «РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре» билгеләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Энергетика машинных агрегатов с рабочими органами-движителями. Чебоксары, 1972; Выбор оптимальных параметров почвообрабатывающей техники с использованием методов вибреологии и многокритериальной оценки. Чебоксары, 2000; Ротационные рабочие органы-движители. М., 2004 (автордаш).

**МЕДВЕ́ДЕВ** Вячеслав Николаевич (30.12.1940, Казан — 30.8.1999, шунда ук), хирург, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1987). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук эшли (бүленеп: 1973–76 елларда Кения Респ-касында госпиталь хирургы), 1981 дән 2 нче хирургик авырулар каф. мөдире. Хезмәтләре йөрәк һәм кан тамырлары авыруларын хирургик дәвалауга карый. М. тарафыннан ясалма кан әйләнеше кичергән авырулар халәте, кардиохирургиягә нисбәтле авыруларның вегетатив статусы халәте һәм ясалма кан әйләнеше кулланылганда миокардтагы матдәләр алмашы үзгәрешләре өйрәнелә. М. җитәкчелегендә Татарстанның Казан һәм башка шәһәрләрендә беренче аортокоронар шунтлау операцияләре ясала. Ул аяклардагы облитерацион эндартериитны периартериаль симпатэктомия юлы б-н хирургик дәвалау ысулларын гамәлгә кертә, тумыштан килгән яки авыру китереп чыгарган йөрәк зәгыйфьлеген, уртача гипотермия һәм ясалма кан әйләнеше шартларында беренче булып, хирургик дәвалый, йөрәк клапаннарына протезлар куя, катнаш цианотоник йөрәк зәгыйфьлеген көйли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар (аяктагы кан тамырларына операция ясау ысулы; зарарланган артерияне саклау өчен авыруның үз венасы өлешен әзерләү). Йөрәк хирургиясенә кирәкле мед. инструментлары уйлап тапканы өчен СССР ВДНХсы медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Клиника, диагностика и хирургическое лечение пороков сердца. К., 1995 (автордаш); Динамика изменений люминолзависимой хемилюминесценции крови больных с пороком сердца, оперированных в условиях искусственного кровообращения // Казан. мед. журн. 1998. № 4.

*Әд.:* Профессор Вячеслав Николаевич Медведев // Казан. мед. журн. 1999. № 5.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Григорий Антонович (1868, Терек өлкәсенең Кура станицасы — 4.2.1944, Мәскәү өлкәсенең Абрамцево пос.), нәкышьче, график, педагог. Владикавказда реаль уч-ще, классы рәссам дәрәҗәсендә СА тәмамлый (1894). Казан сәнгать мәктәбен оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе, рәсем һәм нәкышь классларында укытучы (1895–1917), мөдир (1901–04, 1907–14) булып эшли. «Казан сәнгать мәктәбендә махсус белгечлекләр буенча программалар», «Реформалаштырылган Казан сәнгать мәктәбенең нәкышь класслары программалары» авторы. Күп тапкырлар СА уздырган сәнгать мәктәпләре укытучылары съездларында катнаша. 1920 еллар башында Татарстан дәүләт нәшриятына плакатлар эшли. ТатАХРР (1923), Рәссамнар берлеге (1935) әгъзасы.





Г.А. М е д в е д е в. 1. «Сабанда». 1924; 2. «Ахирәтләр». 1924. Икесе дә – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

1918–25 тә — Мари АССРда, 1930–32 дә Мордовия АССРда эшләп ала. Мари һәм мордва халыкларының тормыш-көнкүреше темаларына картиналар яза. 1932 дә Мәскәүгә күчә, Абрамцево посёлогында яши һәм эшли. М. пейзажлар, Идел буенда яшәүче татар, мари, мордва, башкорт халыкларының хезмәте һәм көнкүреше темаларына жанрлы картиналар иҗат итә; Идел йөкчеләре, кызылармиячеләр, рев-ция юлбашчыларының зур портрет галереяларын төзи.

Төп әсәрләре: «Борынгы җырлар» (1900), «К.Л.Мюфке портреты» (1900 еллар башы), «Баржа төяүчеләр» (1912), «Авылда ачлык» (1917), тау мариларының авыллары һәм кешеләре сериясе (1918–25), «Ахирәтләр», «Татарларның сөрү җире», «Сабанда (Кичке күләгәләр)» (барысы да — 1924), «1905 елда шәһәр думасы янында Казан эшчеләренең кораллануы» (1925), «Казанны яклау: 16 йөз», «Борынгы Казан», «Күчмән далаларында», «Чапкын», «1918 елда Казан янында десант төшерү», «Вахитовны ату», «Мордва туе», «Мордва халык җырларын җыючы, мордва халык җырларын, көнкүрешен һәм телен тикшерүче М.Е.Евсевьев эш вакытында» (барысы да — 1926), «Йөкчеләр Иделдә» (1929), «Ленин исемендәге туку фабрикасында. Казан», «Бакыр кою. Вахитов заводы», «Чуен кою. «Кызыл юл» заводы. Казан» (барысы да — 1920 еллар). М. портретын Н.И.Фешин иҗат итә.

Казан рәссамнары күргәзмәләрендә (1896), Казан сәнгать мәктәбенең вакытлы күргәзмәләрендә (1911–16), Картиналарның 1 нче бушлай күргәзмәсендә (Казан, 1918), Казандагы 1 нче Дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә (1920), Картиналар, этюдлар, эскизлар, рәсемнәрнең 1 нче Козьмодемьянск күргәзмәсендә (1920), 2 нче Дәүләт нәкышь, скульптура һәм архит-ра күргәзмәсендә (Казан, 1921), АХРР (Мәскәү, 1922 елдан), ТатАХРР (Казан, 1923 тән) күргәзмәләрендә, «Казан плакаты» күргәзмәсендә (Казан, 1929) катнаша.

Әсәрләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.В.Григорьев исем. Козьмодемьянск сәнгать-тарих музеенда, Т.Е.Евсеев исем. Мари милли музеенда (Йошкар-Ола ш.), Мордва Респ-касының берләштерелгән туган як музеенда (Саранск ш.), Рев-ция музеенда (Мәскәү) саклана.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии: Биогр. справ. К., 1975.

*Е.П.Ключевская.*

**МЕДВЕ́ДЕВ** Дмитрий Анатольевич (14.9.1965, Ленинград), дәүләт эшлеклесе. Ленинград ун-тын тәмамлый (1987), шунда ук гражданлык хокукы кафедрасында эшли (1990–99); юридик фән. канд. (1990). Бер үк вакытта, 1990–99 елларда, Ленинград шәһәре халык депутатлары Советында, С.-Петербург мэриясендә. 1999–2000 дә РФ Президенты администрациясе җитәкчесе урынбасары, 2000–03 тә 1 нче урынбасары, 2003–05 тә



Д.А.Медведев.

җитәкчесе. 2005–08 дә РФ Хөкүмәте Рәисенең 1 нче урынбасары; 2008–12 дә РФ Президенты, 2012 нең маеннан РФ Хөкүмәте Рәисе. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Респ-касы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» шартнамә (2007) әзерләүдә катнаша, аның РФнең Федераль законы сыйфатында кабул ителүенә булышлык күрсәтә. Күп тапкырлар ТРда була, респ-када социаль-икътисади һәм мәдәни үсешнең барышы, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы б-н

таныша. 2007 нең ноябрендә Казандагы Россия ислам ун-тында булганда М. «Россиядә мөселманнар дәүләт һәм җәмгыять тормышында, мәдәнияттә һәрвакыт актив роль уйнадылар, Ватанга фидакарь хезмәт иттеләр, гражданлык бурычларын тулысынча үтәделәр», дип билгеләп уза. 2011 нең июнендә аның башлангычында Казанда Әзәрбайҗан Респ-касы президенты И.Алиев һәм Әрмәнстан Респ-касы президенты С.Саргсян катнашында Таулы Карабах мәсьәләсен хәл итү буенча саммит булып уза. 2013 тә М. Казанның 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарын уздыруга әзерлеге барышы б-н таныша, татарларның милли Сабан туе бәйрәмендә һәм 27 нче Универсиаданы ябу тантанасында катнаша. «Казанның 1000 еллыгы истәлеге» медале б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов, Г.С.Сабирҗанов.*

**МЕДВЕ́ДЕВ** Ефрем Игнатьевич (1903, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Мертовщина а. — 1982, Куйбышев ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1960), проф. (1962), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970). Шәрекъ пед. ин-тын (Казан, 1929), Казан ун-тын (1931) тәмамлый. 1919 елда Бөгелмә шәһәре тимер юлында эшче. 1929–35 тә Үзәк дәүләт архивы управляющие, ТАССРның Үзәк музее директоры. 1936–76 да Куйбышев пед. ин-тында, 1962 дән СССР тарихы каф. мөдире. 1977 дән Куйбышев ун-тында рев-циягә кадәрге Россия тарихы каф. мөдире. СССР ФАнең «Бөек Октябрь социалистик революциясе» проблемасы буенча Фәнни советының Идел буе секциясен җитәкли. Хезмәтләре Урта Идел буендагы аграр хәрәкәт, Гражданнар сугышы һәм Окт. рев-циясе тарихына карый. М. җитәкчелегендә «Беренче бөтендөнья сугышы һәм Февраль революциясе чорында патша армиясе» («Царская армия в период первой мировой войны и февральской революции», 1932) документлар җыентыгы нәшер ителә.

Х е з м.: Октябрьская революция в Самарской губернии. Куйбышев, 1957; Установление и упрочение Советской власти в Среднем Поволжье. Куйбышев, 1974.

*С.И.Ионенко.*

**МЕДВЕ́ДЕВ** Михаил Михайлович (22.9.1945, Луганск ш.), фотожурналист. 1969–71 елларда кино операторы ассистенты, Воркута телевидение студиясендә фотохәбәрче. 1971–73 тә Ростов фотокомб-тында кино операторы. 1974 тән «КамАЗ» ҖБдә: баш конструктор идарәсе кинофотолаб-ясе башлыгы, кино операторы, 1985 тән «Рабочий КамАЗа» г-тасы редакциясендә кино операторы. 1986 дан ТАССР буенча ТАСС фотохәбәрчесе, 1990 нан «Фото ИТАР-ТАСС» агентлыгының ТР буенча үзхәбәрчесе, ТР, Удмурт Респ-касы, Мари Респ-касы буенча фотохәбәрчесе. 2003 тән «Фото АРТ» ҖЧҖ директоры (Казан). «Татар ашлары» («Татарская кулинария», 2004), «Татарстан манзарасы» («Татарстан с высоты птичьего полёта»), «Портфолио-Казань» (2005) фотоальбомнары авторы. «КамАЗ-мастер» дизайн-системасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен РФнең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт бүләге бирелә (2001).

**МЕДВЕ́ДЕВ** Николай Петрович (20.7.1916, Сембер губ. Каменские Выселки а. — 23.2.1995, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1960), проф. (1962), ТАССРның атказ. табибе (1947), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1967, 1975). А.В.*Вишневский* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), Казандагы эвакогоспитальдә эйдәп баручы хирург. 1945 елдан Казан мед. ин-тында, 2 нче хирургик авырулар каф. мөдире (1961–1981), проф.-киңәшче (1981–95). Татарстанда йөрәк-кан тамырлары хирургиясенә нигез салучы. 1974 тә М. Казанның 6 нчы хастаханәсе каршында кардиохирургия үзәге оештыра (1996 дан М. исем.). Татарстан хирурглары җәмгыяте рәисе (1979–95). Хезмәтләре йөрәк-кан тамырлары авыруларын, йөрәк-кан тамырлары патологиясе вакытында биохимих үзгәрешләрне өйрәнүгә карый. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы, Н.И.Пирогов исем. медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биохимические нарушения при хирургических операциях и их коррекция. К., 1967; Биохимические аспекты клинической хирургии. К., 1973; Нарушения гемиостаза у хирургических больных и возможности их коррекции. К., 1982 (автордаш); Путь к сердцу: Записки хирурга. К., 1993.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**МЕДВЕ́ДЕВ** Пётр Михайлович (15.1.1837, Мәскәү — 30.1.1906, С.-Петербург), драма актёры, режиссёр, антрепренёр. Мәскәү театр уч-щесендә укый. Проф. сәхнә эшчәнлеген 1853 елда Тула шәһәрендә И.М.Никулин труппасында башлап җибәрә. 1854–61 дә Кострома, Тверь, Саратов, Воронеж, Курск, Әстерхан шәһәр театрларында уйный. 1861 дә Пенза шәһәрендә актёрлар ширкәте б-н җитәкчелек итә, 1863–67 дә Самара шәһәрендә антреприза тота. 1866 ның җәендә труппасын беренче тапкыр Казанга гастрольләргә алып килә. Зур уңыш б-н узган гастрольләрдән соң, ул Казанга дәвамлы эшкә чакыру ала. 1867–72, 1874–80, 1884–88 дә Казан шәһәр театрының антрепренёры була, бер үк вакытта актёр һәм режиссёр буларак та эшен дәвам итә. М. Казан театрын Россия провинцияләренең иң алдынгы театры дәрәҗәсенә күтәрә. Нигездә, рус һәм дөнья классикасы, заманча драматургия пьесаларына (У.Шекспир, Ф.Шиллер, А.С.Грибоедов, Н.В.Гоголь, А.В.Сухово-Кобылин, А.Ф.Писемский, А.Н.Островский) таянып, М. актёрлардан башкаруда ансамбльлелеккә ирешүне, психол. төгәллек һәм тәэсирлелек, үз-үзеңне тотуда югары зәвыклылык; костюмнар, аксессуарлар сайлауда төгәллек, бар нәрсәдә тормыш чынлыгы таләп итә. М. ш.у. театр сәнгате реформаторы, К.С.Станиславский, В.И.Немирович-Данченко, А.П.Ленский принципларын башлап җибәрүче буларак билгеле. Спектакльләренең куелыш сыйфатына зур игътибар бирә. М., башка театрларда куелуы тыелган күп кенә спектакльләрне сәхнәгә менгерү өчен, цензура ком-тыннан аерым хокуклар алуга ирешә. 1868 дә Казан сәхнәсендә беренче тапкыр А.К.Толстойның «Иоанн Грозныйның үлеме» («Смерть Иоанна Грозного»), 1869 да Н.В.Гогольнең «Ревизор» пьесалары буенча спектакльләр цензура тарафыннан сызу-бозуларга дучар ителми генә куела; биредә ш.у. А.Н.Островский пьесалары буенча күп кенә спектакльләр Петербург һәм Мәскәүдән алдарак дөнья күрә. М. талантларны күрә һәм ача белгән искиткеч педагог, яшь актёрлар



П.М.Медведев.

тәрбияләүче була. Төрле елларда М.ның Казан труппасында А.А.Рассказов, М.А.Решимов, А.А.Немирова-Ральф, А.П.Ленский, В.А.Макшеев, В.Н.Давыдов, К.А.Варламов, М.Г.Савина, П.А.Стрепетова, М.И.Писарев, А.И.Шуберт, М.В.Лентовский, М.Т.Иванов-Козельский, Н.В.Пальчикова эшли, статист сыйфатында Ф.И.Шаляпин сәхнә эшчәнлеген башлый.

М. Казан сәхнәсендә балалар өчен спектакльләр (әкияти феерияләр, балалар әдәбияты әсәрләре буенча спектакльләр) куючы беренче антрепренёр була; истә калырлык күңелле тамашалар оештыра. 1874 тә М., драма труппасы эшен дәвам иттергән хәлдә, Казанда опера спектакльләре куюга нигез салып, опера труппасы да оештыра. Башкаручылардан Ф.К.Львов, З.И.Эйбоженко, Д.А.Усатов, А.П.Ухтомская-Баронелли, Ю.Ф.Закржевский, О.К.Ильяшевич, Н.В.Унковскийны, дирижёрлардан У.И.Авранек, А.А.Орлов-Соколовскийны чакыра. М.җитәкчелегендәге опера спектакльләре югары башкару культурасы б-н аерылып тора. Ул, рус музыка-вокал мәктәбе үсешенең киләчәк юнәлешен алдан тоеп, җырчылардан вокаль техниканың драматик уен б-н бергә табигый үрелеп баруын таләп итә. Тормыш дөреслеген тирәнтен яктыртучы актёр буларак, М., үзе иҗат иткән характер тибын иҗтимагый күренеш дәрәҗәсенә җиткереп, башкарган рольләренә киң социаль гомумиләштерүләр бирә белә. Аның Казанда уйнаган аеруча әһәмияткә ия булган тирән эчтәлекле рольләре — Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь), Расплюев («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Фамусов («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Крутицкий («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский). Труппасындагы актёрларга карата гаделлеге, театр эшен тирәнтен белүе, искиткеч администраторлык сәләте М.ны рус театры тарихында сизелерлек эз калдырган иң эре антрепренёрларның берсе дәрәҗәсенә күтәрә. 1890 да ул С.-Петербургтагы Александра театрына баш режиссёр итеп чакырыла.

Х е з м.: Автобиография. К., 1886; Воспоминания. Л., 1929.

*Әд.:* Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Д а в ы д о в В.Н. Рассказ о прошлом. Л.-М., 1962; Б л а г о в Ю. «... Получил прозвище Казанский» (Пётр Медведев и Казанский театр во второй половине XIX века). К., 2001.

*Ю.А.Благов.*

**МЕДВЕ́ДЕВ** Семён Ноевич (24.11.1928, Кырым өлкәсенең Азов р-ны Колай а., хәзер

Азовское пос.), радиофизик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Мәскәү механика ин-тын тәмамлый (1951), Казан радиоэлектроника ин-тында эшли, әйдәп баручы инженер (1956–62), бүлек башлыгы (1962–81), бүлекчә башлыгы (1981–93), башкаручы директор (1993- 95), әйдәп баручы инженер-конструктор (1995 тән). М. актив сорау һәм җавап режимында эшли торган радиолокацион системалар төзүдә катнаша (РФ армиясе һәм флотын коралландыру өчен җитештерүгә кертелә ). Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге радиолокация өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МЕДВЕ́ДЕВ П.М.ның ТЕА́ТР КИТАПХАНӘСЕ́.** П.М.*Медведевның* Казандагы антреприза репертуарын тәшкил иткән пьесалар җыелмасыннан тора. Театр китапханәсен ул 1857–58 елларда Динабург (хәзерге Даугавпилс, Латвия) шәһәре сәхнәсендә уйнаган вакыттан ук җыя башлый, әмма төп өлешен Казанда антреприза тоткан чорда җыелган пьеса текстлары тәшкил итә. С.-Петербургка киткәндә, П.М.Медведев китапханәсен театрга калдыра, аннан ул башка антрепренёрлар тарафыннан тулыландырыла. Окт. рев-циясеннән соң ТАССР Фәнни китапханәсенә күчерелә, ә 1934 тә Казан ун-ты Фәнни китапханәсенә тапшырыла.

Китапханәдә 2 мең чамасы китап, ш.и. 1850–60 елларда киң таралган рус һәм чит ил авторларының басмалары, ташбасма һәм кулъязмалары була (А.С.Пушкин, А.Н.Островский, У.Шекспир, Ж.Б.Мольер һ.б.). Барлык пьесаларның өчтән бер өлешен комедияләр һәм водевильләр тәшкил итә, опера һәм оперетта либреттолары да саклана. П.М.Медведев антрепризасы вакытында Казан театры сәхнәсендә Казан драматурглары пьесалары да куела, мәс., К.К.Бродовскийның «Яшенле яңгыр читләтеп үтте» («Гроза прошла мимо», 1883), элекке Казан тормышыннан А.П.Славинның «Гаврил Иванович Михляев, Казан сәүдәгәре һәм фабриканты» пьесасы («Гаврил Иванович Михляев, Казанский купец и фабрикант», 1876), билгесез авторның «Черек күл вакыйгасы Поп тавында ачылды» («На Чёрном озере случилось, на Поповой горе объяснилось»). Пьеса текстларыннан тыш, китапханәдә рус театры, артистлар тормышы һ.б. турында төрле басмаларда чыккан язмалар да урын алган (48 данә).

Исәпкә алу кенәгәсе буенча карточкалар каталогы төзелә, хәзер ул Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Медведев китапханәсе аерым бер тәртиптә төзелә: һәр нөсхә тышлыгына П.М.Медведев театры китапханәсендәге китапның номеры язып ябыштырыла. Бу китапханәнең Казанда театр тарихын һәм П.М.Медведев шәхесен өйрәнү өчен әһәмияте зур.

*Әд.:* М е д в е д е в П.М. Воспоминания. Л., 1929; Н е д о р е з о в а И.А. К вопросу об изучении частных библиотек: театральная библиотека П.М.Медведева // Рукописная и старопечатная книга: Проблема сбора, сохранения и изучения. К., 1995.

*И.А.Новицкая.*

**МЕДВЕ́ДЕВ РАЙОНЫ́**, *Мари Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 2796,6 *км²*. Үзәге — Медведево посёлогы (Йошкар-Оладан 8 *км* көнбатыштарак). Халкы — 68075 (2012), татарлар — 2160 кеше (2010). Татарлар, башлыча, район үзәгендә яшиләр. Хәзерге вакытта 3 нче Медведево урта мәктәбендә татар-башкорт көрәш секциясе эшли (1990 нан). 2003 тән М.р.нда Татар милли-мәдәни автономиясе яшәп килә, аның ярдәме б-н ел саен татар милли бәйрәмнәре үткәрелә. ТР б-н М.р. арасында тыгыз мәдәни һәм икътисади бәйләнешләр урнашкан, а.х., сәнәгать, мәдәният өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу буенча делегацияләр оештырыла. М.р. б-н ТАССРның атказ. артисты Г.Г.*Гыйбадуллинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге бәйле.

**МЕДВЕ́ДЕВА** Нина Павловна (6.2.1939, Новосибирск өлкәсе Ленинск-Кузнецкий ш.), гидрогеолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004). Томск политехник ин-тын тәмамлый (1962), Казан геол. экспедициясендә эшли. 1995–97 елларда «Татнефть» АҖнең Татарстан геол.-разведкалау идарәсендә гидрогеолог. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыга торган р-ннарында җир асты сулары чыганакларын разведкалау методикасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**МЕДВЕ́ДЕВКА** посёлогы, Буа шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Тоша елгасы (Зөянең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1 кеше яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның — Тәтеш, 1957 нең 30 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1938 дә — 94, 1958 дә — 74, 1970 тә — 64, 1979 да — 34, 1989 да — 23, 2002 дә — 7 кеше.

**МЕДВЕ́ДКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 17 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 13 кеше (руслар) яши. 1732 дә отставкадагы солдатлар авылы буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Бөгелмә, Кече Бөгелмә исемнәре б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1717 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 473, 1889 да — 771, 1910 да — 929, 1920 дә — 1062, 1926 да — 929, 1938 дә — 422, 1949 да — 293, 1958 дә — 205, 1970 тә — 143, 1879 да — 83, 1989 да — 33, 2002 дә — 28 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**МЕДВЕ́ДКОВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 23 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасы тамагы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. 17 йөздә Успение монастыре (Зөя шәһәре) җирләрендә нигез салына. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, урман материаллары б-н сату итә. 20 йөз башында М.да 4 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 582 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир-ат; 1859 да — 202, 1908 дә — 284, 1926 да — 371, 1938 дә — 270, 1949 да — 145, 1958 дә — 171, 1970 тә — 96, 1979 да — 48, 1989 да — 8, 2002 дә — 1 кеше.

**МЕДИЕВИ́СТИКА** (лат. medius — урта һәм aevum — гасыр, чор) тарих фәнендә Көнбатыш Европаның урта гасырлардагы тарихын өйрәнүче бүлек. Беренче булып урта гасырлар тарихын аерым чорга 15 йөз гуманист тарихчылары бүлеп чыгаралар; алар бу чор Көнбатыш Рим империясе җимерелгәннән соң башланган дип саныйлар. 17 йөздә тарихны борынгы, урта, яңа дәверләргә бүлеп өйрәнә башлыйлар. 18 йөз мәгърифәтче тарихчылары урта гасырларны феодализм чоры б-н тәңгәлләштерәләр. Шул заманда феодализм барлыкка килүнең «герман» һәм «роман» теорияләре туа. 19 йөздә М.да милли фәнни мәктәпләр оеша. 19 йөзнең 1 нче яртысында, тарихи мәгърифәтчелек тәгълиматы кризис кичергән һәм герман историографиясендә романтизм таралыш алган шартларда тарихи хокук мәктәбе (К.Ф.Эйхгорн, Ф.Савиньи һ.б.), Л.Ранке мәктәбе, Гейдельберггтагы мәктәп (Г.Г.Гервинус, В.Циммерман һ.б.), француз историографиясендә либераль мәктәп (О.Тьерри, Ф.Гизо, Ф.Минье, А.Тьер, Ж.Мишлё) әһәмиятле роль уйныйлар. Беренчеләре М.ның чыганаклар базасын киңәйтүләре, тикшеренүләрдә тәнкыйди ысуллар кулланулары, икенчеләре дворяннар һәм «өченче катлау» арасындагы сыйнфый көрәш теориясен күтәреп чыгулары б-н мәгълүм. 19 йөзнең 2 нче яртысында Европа М.сында берничә юнәлеш: сәяси, тарихи-хокукый (Германиядә Г.Маурер, Г.Вайц, П.Рот һ.б.; Англиядә У.Стебс, Г.Мэн һ.б.), тарихи-икътисади (Германиядә К.Т.Инама-Штернегг, К.Лампрохт һ.б.; Англиядә Т.Роджерс; Франциядә Н.Д.Фюстель де Куланж), мәдәни-тарихи синтез юнәлешләрендә үсүче позитивистик М. барлыкка килә һәм үсеш ала. К.Маркс һәм Ф.Энгельсның тарихи хезмәтләре марксистик М.га нигез сала. 19–20 йөзләрдә, позитивистик историография кризис кичергәндә, неокантианство йогынтысында тәнкыйди агым туа (Германиядә Г.Белов, Г.Зелигер һ.б.; Англиядә Ф.Мейтленд; Франциядә Ж.Флак, Ш.Пти-Дютайи һ.б.). 20 йөздә М.да «Анналы» ж-лы тирәсендә тупланып, үз юнәлешләрен булдырган француз тарих фәне вәкилләре аерым урын били. 20 йөзнең икенче яртысында М. яңа социаль тарих, тарихи антропология, ментальлекләр тарихы, микротарих, «яңа локаль тарих», гендерлы тарих, интеллектуаль тарих һ.б. юнәлешләр йогынтысында үсә. Хәзерге М.да ур-

та гасырларны чорларга бүлүдә төрле карашлар бар. 19 йөздә ныгып урнашкан һәм чит илләрдә хәзер дә өстенлек итүче традицион караш буенча, М.ның предметы — 5 йөздән алып (Көнбатыш Рим империясенең җимерелүе) 15 йөз уртасына яки ахырына кадәрге чор (китап басу уйлап табылу, төрекләрнең Константинопольне алуы, европалыларның Американы ачуы, Бөек географик ачышлар һәм колониаль яулап алулар дәвере). Кайбер тарихчылар (мәс., хәзерге заман француз тарихчысы Ж.Ле Гофф һ.б.) Рим империясе кризисын да эченә алган 2–3 йөзләрдә башланып, урта гасырларның матди һәм интеллектуаль эзләре югалган 18 йөз ахыры — 19 йөз башы б-н йомгакланган «озын урта гасырлар» версиясен яклый. Россия М.сы (рев-циягә кадәргесе һәм марксистик М.) 20 йөз урталарына кадәр урта гасырлар б-н яңа заман чиген 18 йөз ахырына, Француз буржуаз рев-циясе чорына билгеләп килде. Марксистик историографиядә кабул ителгән бүленеш нигезендә урта гасырлар 5 йөздән 17 йөз урталарына кадәр дәвам итә һәм феодаль җитештерү ысуллары барлыкка килү һәм ныгып урнашу кысаларын били. Урта гасырларны өйрәнү үзенчәлекләре чорларга бүлү һәм тикшерү үзенчәлекләренә карап билгеләнә. Кайбер галимнәр (Л.И.Мечников, локаль цивилизацияләр теорияләре тарафдарлары О.Шпенглер, А.Тойнби һ.б.) тарихны «борынгы чор–урта гасыр–яңа заман» яки «колбиләүчелек–феодолизм–капитализм–социализм» схемалары буенча бүлүне кабул итмиләр.

Россиядә М., тарих фәненең аерым бер өлеше буларак, 1830–40 елларда барлыкка килә. Аны рәсми рәвештә өйрәнү үзәкләре — Мәскәү, Казан, Харьков, С.-Петербург, Киев ун-тлары. Мәскәү ун-тында М.га Т.Н.Грановский тарафыннан нигез салына. Россия М.сының 19 йөз — 20 йөз башындагы үсеше сәяси (Т.Н.Грановский, П.Н.Кудрявцев, С.В.Ешевский, В.И.Герье, М.М.Стасюлевич, Н.А.*Осокин* һ.б.), социаль-икътисади (И.В.Лучицкий, М.М.Ковалевский, Н.И.Кареев, П.Г.Виноградов, А.Н.Савин, В.К.*Пискорский*, Р.Ю.Виппер һ.б.), мәдәни-тарихи (Л.П.Карсавин, О.А.Добиаш-Рождественская, И.М.Гревс һ.б.) юнәлешләрдә бара; аңа үзара аралашу нигезендә («рус тарихчылары мәктәбе») Мәскәү (Т.Н.Грановский, В.И.Герье һәм аларның шәкертләре), С.-Петербург (М.С.Куторга, М.М.Стасюлевич) ун-тларында һ.б. университетларда, фәнни лидерлар тирәсендә (В.И.Герье, П.Г.Виноградов, И.В.Лучицкий һ.б.ның мәктәпләре) оешкан фәнни мәктәпләр йогынтысы зур була. Совет чорында марксистик М. бердәнбер юнәлеш булып тора. Аның тарафдарлары феодолизм генезисын (А.Р.Корсунский, А.И.*Данилов*, А.Я.Гуревич, Л.Т.Мильская һ.б.), урта гасырлардагы социаль-икътисади проблемаларны (Н.П.*Грацианский*, А.И.Неусыхин, М.А.Барг, Е.А.Косминский, В.Ф.Семёнов, С.Д.Сказкин, А.Д.Люблинская һ.б.), урта гасырлар дәүләте тарихы, социаль һәм сәяси каршылыклар, урта гасырлар идеологиясе мәсьәләләрен (Е.В.Гутнова, А.Н.Чистозвонов, М.М.Смирин һ.б.) өйрәнүгә зур өлеш кертә. Хәзерге чор теоретик плюрализм, цивилизацияләр тарихына таба борылу, тарихи антропология һ.б. б-н характерлана.

Татарстанда М. барлыкка килү һәм аның үсеш алуы югары белем бирүче уку йортлары: Казан ун-ты, Казан руханилар академиясе, пед. ин-тлар (Көнчыгыш пед. ин-ты һ.б.) барлыкка килү һәм үсү б-н бергә бара. Казан ун-тында урта гасырлар тарихын башлап укытучылар — немец профессорлары П.Ф.Цеплин, И.Е.Миллер, И.Г.Томас; ун-тны тәмамлаучылар — Н.А.Кондырев, Н.А.Иванов һ.б. 1850–60 елларда ун-тта урта гасырлар тарихы буенча лекцияләрне М.И.Славянский, В.Ведров, Н.А.Фирсов укый. Фән буларак Казанда М.га нигез салучылар — Н.А.Осокин, А.И.*Смирнов*, И.Н.*Смирнов*. Аларның хезмәтләре Россия М.сында еретиклык хәрәкәте тарихы проблемаларын, урта гасырлар шәһәрләрен өйрәнүгә юл ача. Проф.-юристлар С.М.*Шпилевский*, Н.К.*Нелидов* (хезмәтләре борынгы германнарга һәм славяннарга карый), Н.П.*Иванов* (халыкара мөнәсәбәтләр һәм хокук), С.А.*Егиазаров* (урта гасырларда шәһәр тормышының чагыштырма тарихы), ш.у. урта гасырлар тарихына мөрәҗәгать итәләр. Казан руханилар академиясе укытучыларыннан проф. С.А.Предтеченскийның магистрлык диссертациясе «IX йөз ахырына кадәр Көнбатыш чиркәүләре эшчәнлегенә папа тәхете йогынтысы арту» («Развитие влияния папского престола на дела западных церквей до конца IX в.») дип атала, Д.Беликов «Готларда христианлык» («Христианство у готов»), А.Потехин «Англиканнар һәм пуританнарның көрәш тарихыннан очерклар» («Очерки из истории борьбы англиканства с пуританством»), Е.А.*Будрин* «XVI йөз антитринитарийлары» («Антитринитарии XVI в.») хезмәтләрен язалар. 20 йөз башында Казан руханилар семинариясендә М.ны Казан ун-тының чиркәү тарихы каф. приват-доценты К.В.*Харлампович* укыта. Казан ун-тында Византия темасы буенча Д.Ф.*Беляев*, Д.В.*Айналов*, С.П.*Шестаков*, Казан руханилар академиясендә И.М.Добровольский, проф. Ф.А.*Курганов* эшлиләр. Чиркәү һәм мәдәният тарихы проблемалары аларның игътибар үзәгендә була. 1906–10 да ун-тның гомуми тарих кафедрасында Испания тарихы буенча танылган белгеч, И.В.Лучицкий шәкерте проф. В.К.Пискорский эшли. Казан ун-тында «Салика законы»ның (Lex Salica) беренче русча тексты (тәрҗемәчеләре — В.К.Пискорский шәкертләре Н.П.Грацианский һәм А.Г.Муравьёв) нәшер ителә (1913). Н.П.Грацианскийның «XIII–XIV йөзләрдә Париж һөнәрчелек цехлары» («Парижские ремесленные цехи в XIII–XVI столетиях», 1911) хезмәте — рус әдәбиятында урта гасырлар цехларына нисбәтле беренче аерым тикшеренү эше. Казанда ш.у. борынгы германнарга, франк крәстияннәре тормышына, аббат Ирминон сәясәтенә, Бөек Карлның «Утарлар турында капитулярий» («Капитулярий о поместьях») фәрманына багышланган хезмәтләр языла. 1913–22 дә проф. М.В.*Бречкевич* М. буенча лекцияләр курсы укый һәм гамәли дәресләр алып бара. 1921 дә ил күләмендә югары уку йортларының тарих-филол. ф-тлары ябылу проф. тарихчылар әзерләүдә һәм, гомумән, тарих фәне үсешендә өзеклеккә китерә. 1920 елларда галимнәр чит илләрдәге архивларда, китапханәләрдә эшләүдән, алардан чыганаклар һәм фәнни әдәбият соратып алудан һ.б. мөмкинлекләрдән мәхрүм ителәләр. Казан ун-тында тарих-филол. ф-ты фәкать 1939 да гына торгызыла. Бөек Ватан сугышы елларында Казанга эвакуацияләнгән галимнәр арасында күренекле медиевистлар да була: акад. Д.М.Петрушевский (1942 нең 12 декабрендә Казанда вафат), СССР ФА мөхбир әгъзасы, соңрак акад. Е.А.Косминский, проф. М.В.Левченко, проф. Б.Ф.Поршнев, яшь галимнәр Н.А.Сидорова, А.Е.Рогинская, Л.Е.Кертман һ.б. 1950–90 елларда М.ны доц. М.Д.Бушмакин (Казан пед. ин-тында, Казан ун-тында, 1943–58), проф. А.И.Данилов, доц. А.В.Сергеев (Казан ун-тында, 1950–88), проф. Г.П.*Мягков*, А.З.Ханина (Казан ун-тында, 1963–88), соңрак чорда М.М.Базина (1976–2005), Т.А.Смолова (1988–96), И.Х.Гарифҗанов (1996–2001), А.Г.Суприянович (1996–2000) укыта. А.И.Даниловның шәкертләре (В.А.Гавриличев, Г.К.Садретдинов, Н.И.Смоленский, И.И.*Шәрифҗанов* һ.б.) М. һәм гомуми тарих историографиясе өлкәсендә абруйлы белгечләр булып танылалар. 20 йөзнең 2 нче яртысында Казан медиевистлары фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше булып чит илләр һәм Россия М.сы һәм славистикасы тарихын өйрәнү тора; 20–21 йөзләр чигендә урта гасырлар тарихына багышланган хезмәтләр дөнья күрә.

*Әд.:* Бушмакин М.Д. Профессор Н.А.Осокин — первый Казанский медиевист // Средние века. 1960. Вып. 17; Ханина А.З. В.К.Пискорский // Вопросы историографии всеобщей истории. К., 1968. Вып. 3; Ягудин Б.М. Н.А.Осокин и становление Казанской школы всеобщей истории. К., 1998. Мильская Л.Т. Николай Павлович Грацианский // Портреты историков: Время и судьбы. М., 2000. Т. 2; Сыченкова Л.А. Культура Западной Европы: Российский опыт историографического осмысления (2-я половина XIX — 30-е гг. XX вв.). К., 2000; Историки в поиске смыслов. К., 2003; Мягков Г.П. Медиевистика в Казанском университете // История и историки в Казанском университете: К 125-летию Общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете. К., 2005. Ч. 2.

*Г.П.Мягков.*

**МЕДИЦИ́НА** (лат. medicina, medicus — табиблек, дәвалау), фән өлкәсе һәм гамәли эшчәнлек, максаты — авыруларны кисәтү һәм дәвалау, кешенең сәламәтлеген ныгыту һәм саклау, гомерен озайту.

Фән буларак, М. фундаменталь мед., биол. мед., социаль мед. төркемнәрен туплаган фәнни дисциплиналар комплексын тәшкил итә. Биол. мед. дисциплиналары кеше тәне төзелешен (морфология) төрле бүленештә: организм (анатомия), органнар (топографик анатомия), тукымалар (гистология), күзәнәкләр (цитология) һәм ш.у. молекула дәрәҗәсендә (молекуляр биол.) өйрәнә. М. организмның функциональ эшчәнлеген (физи-

ол., биохимия), авыруларның килеп чыгышы, көчәюе һәм барышы закончалыкларын (патологик анатомия һәм патофизиол.), иммунология, аллергология, микробиол., паразитология, мед. биохимиясе һәм биофизикасы аша аларның махсус аспектларын ачыклый, организмга дарулар тәэсирен (фармакология) тикшерә. Авыруга диагноз кую һәм авыру кешене дәвалау (терапия, хирургия, педиатрия), бала таптыру б-н бәйле мед. ярдәме (акушерлык һәм гинекология) кебек клиник дисциплиналар аерым төркем хасил итә. Гигиена, социаль мед. б-н бәйле дисциплиналар (эпидемиология, җәмгыяви сәламәтлек һәм сәламәтлекне саклау, мед. демографиясе, биомедэтика, мед. хокукы, мед. социологиясе һ.б.) тормыш шартларының кеше сәламәтлегенә йогынтысын өйрәнә, сәламәтлек саклау һәм авыруларны кисәтүгә, сәламәтлек саклауны оештыру мәсьәләләренә юнәлдерелгән чаралар тәкъдим итә. М. әйләнә-тирә дөньяга тәэсир итүнең фәнни (исбатлауга нигезләнгән мед.) һәм сәнгатькә хас (табиб интуициясе, диагноз кую сәләте, пациентка психологик йогынты ясау) ысулларын, ш.у. дәвалау манипуляцияләре вакытында мануаль күнекмәләр куллана.

М. — кешелек туплаган гыйлемнәрнең иң борынгы тармагы. Бик борынгы заманнарда ук, ялгышулар аша, халык медицинасы — дәвалауның эмпирик алымнары (кан алдыру, банка салу, шин кую, яра бәйләү һәм ш.у. гигиена чаралары) системасы формалаша, халык тәҗрибәсенең күп гамәлләре хәзер дә кулланылышта. Табиблек гыйлеме формалашуда Шәрекъ М., ш.и. Идел буе Болгар дәүләте табибләренең йогынтысы зур була. Болгар табибләре пульсны тыңлауга аерым әһәмият бирәләр, кан алдыруны киң кулланалар. Борынгы болгар табибләре язган хезмәтләр Шәрекътә танылу ала. Гарәп табибе Серапион (кече Ибне Сераби) үзенең «Дару матдәләре турында гыйлемнәр» (12 йөз) китабында болгар табибләре тәҗрибәсен телгә ала. Алар турында атаклы гарәп галиме Ибне әл-Бейтар Дхъя Хуҗа Хәлфә дә яза. «Энциклопедия лөгатьлеге»ндә («Энциклопедический лексикон», т. 1–17, 1835–41) Болгардан чыккан галим-табиб *Борһанеддин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари* (?–1204) хакында мәгълүмат бар. Аның фармакология өлкәсенә караган «Гади дарулар» табиблек трактаты мөселман дөньясына билгеле була. Болгар галим-табибләре, бертуган Таҗетдин һәм Хәсән бине Юныс әл-Болгариларның хезмәтләре ш.у. киң таныла. Өлкәне — табиб-фармаколог Таҗетдин — Гыйракның Мосул шәһәрендә укый һәм гомер итә, фармакология буенча «Агуланулардан көчле дәва», «Дару үләннәренең мөмкинлекләре» хезмәтләрен яза. Энесе Хәсән «Агуланулардан көчле дәва»ны гарәп теленә тәрҗемә итә (12–13 йөз), трактатның гарәпчә күчермәсе Иранда, Мәҗлес китапханәсендә саклана (1997 елда Казанда тәрҗемәсе басылып чыга). М. тарихында Идел буе Болгар дәүләтеннән чыккан Хаҗи Әбүбәкер Бәлхи әл-Болгари һәм Хаҗи Әскәр исемнәре дә билгеле.

Халык сәламәтлеген саклауда көндәлек санитария культурасы зур роль уйный, ислам дине аңа (тән, кием, торак гигиенасы, намаз алдыннан тәһарәт алу һ.б.) аерым игътибар бирә.

Идел буе Болгар дәүләтендә халык медицинасы тора-бара фәнни, проф. юнәлеш ала; 13 йөздә хастаханәләр барлыкка килә (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында әйтелә). Гарәп язуы болгарларга Шәрекъ табибләренең хезмәтләре б-н танышу мөмкинлеге бирә. Цивилизацияләр үсеше кысаларында җәмгыяви М.га нигез салына, чагыштырмача стандартлаштырылган белем бирү — мед. мәктәпләрендә, соңрак университетларда (Салерно — 9 йөз; Болонья — 12 йөз; Оксфорд, Кембридж, Париж, Падуя — 13 йөз; Прага, Краков, Вена — 14 йөз) тормышка ашырыла. Мед. ярдәменә мохтаҗларга ярдәм күрсәтү учреждениеләре барлыкка килүдә дини оешмаларның роле аеруча зур була. Рус дәүләтендә беренче хастаханә Киевтагы Печера монастыре каршында ачыла (1070). 12 йөздә Русьнең Новгород һәм башка шәһәрләрендә хастаханәләр була. Патша Иван Грозный заманында кабул ителгән «Стоглав» җыентыгы (1545) Россиядә хастаханәләр эшчәнлегенең дәүләт күзәтчелегендә торуын раслый, җыентыкта хастаханәләрнең корылыш тәртибе һәм авыруларны карау-дәвалау кагыйдәләре җентекләп тасвирлана. Мәскәү Русенда М.ның дәүләт системасына кертелүе 1581 дә Даруханәләр приказы оештырыудан башлана (к. *Даруханәләр*). Пётр I чорында медицинага кагылышлы иң әһәмиятле казанышлар: хәрби госпитальләр (ш.и. Казанда — 1722) төзелү, мед. белеме бирү системасы булдырылу (1707 дә госпиталь мәктәпләре ачылу). Екатерина II патшалык иткәндә Мед. коллегиясе оештырыла, мед. белеме бирү җәелдерелә: Мәскәү ун-тында мед. ф-ты ачыла, госпиталь мәктәпләре мед.-хирургия академияләре итеп үзгәртелә; *җәмәгать тәрбиясе приказлары* (1775) төзелә. Приказлар эшчәнлеге нәтиҗәсе буларак, 1775–1865 тә Казан губернасында 519 хастаханә (17,4 мең ятак-урын) ачыла. Приказлар оештырылу б-н бергә, өяз табибләре вазифасы кертелә, 1797 дән табиблек идарәләре булдырыла. «Губерна һәм өяз земство учреждениеләре турында нигезләмә» («Положение о губернских и уездных земских учреждениях», 1864) раслана; «приказ медицинасы»на алмашка киң халык катламнарына участокларга бүленешле тәртип буенча бушлай хезмәт күрсәтүче *земство медицинасы* килә. Урта һәм югары мед. белеме бирү системасы нигездә 19 йөздә формалаша. М., галим-медикларның эзләнүләренә һәм хезмәтләренә карап, төрле юнәлештә үсә: физиол. (К.М.*Быков*, Н.О.*Ковалевский*), патология (В.В.*Пашутин*, А.В.*Петров*); хирургиядә уңышлар, анатомия-хирургия киселешендә булып, топографияне үзләштерүгә нигезләнә (А.-Л.А.*Китер*, Ф.О.*Елачич*, Н.И.*Боголюбов*), иммунология һәм бактериология өлкәсендә И.Г.*Савченко* эшли (к. *Медицина белеме бирү*). Россиянең үз терапия мәктәбе традицияләре ныгып урнаша (А.Л.Мясников, В.П.Образцов, М.П.Кончаловский, Д.Д.Плетнёв, Н.Д.Стражеско, Г.Ф.Ланг, Н.А.*Виноградов*, Н.И.*Котовщиков*, К.Ф.*Фукс*, М.А.*Хомяков*, Ә.Б.*Терегулов*, Н.К.*Горяев* һ.б.); нейрохирургия (В.М.*Бехтерев*, Н.Н.Бурденко, А.Л.Поленов, С.П.Фёдоров), пластик хирургия (С.С.Юдин, В.А.*Гусынин*), йөрәк-кан тамырлары хирургиясе (А.Н.Бакулев, В.С.Савельев, В.И.Бураковский, Н.П.*Медведев*), онкология (П.А.Герцен, Н.Н.Петров, Н.Н.Блохин), офтальмология (В.П.Филатов, Е.В.*Адамюк*) фәнни мәктәпләре барлыкка килә. Гигиена, фән буларак, Россиядә киң таралыш ала, уртак җәмгыяви максатка хезмәт итүче, ләкин һәркайсы үзенчәлекле өч үзәк — Петербург мәктәбе (А.П.Доброславин), Мәскәү мәктәбе (Ф.Ф.Эрисман), Казан мәктәбе (А.И.*Якобий*) — тәшкил итә.

Окт. рев-циясеннән соң М. аеруча зур күтәрелеш кичерә. Совет хөкүмәте каршында төзелгән Табибләр коллегияләре советы (1918) илнең сәламәтлек саклау системасын үзгәртеп кору эшенә керешә. 1918 нең 11 июлендә Н.А.Семашко һәм З.П.Соловьёв (икесе дә Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаган) җитәкчелегендә РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-ты оештырыла; совет сәламәтлек саклау системасының төп принциплары (дәүләт җитәкчелеге, авыруларны кисәтү чаралары күрелү, фән һәм практика бергәлеге, авыруларны булдырмау мәсьәләләрен халык катнашында хәл итү) алар тарафыннан нигезләнә. 1918 нең апрелендә Казан губерна сәламәтлек саклау бүлеге булдырыла, 1920 нең сентябрендә ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты (к. *Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы*) төзелә. Ил өчен катлаулы чорда яңа сәламәтлек саклау системасы, аз күләмдәге ресурсны иң кыен мәсьәләләрне хәл итүгә — йогышлы һәм социаль авыруларны дәвалауга, ана һәм балалар сәламәтлеген саклауга юнәлтеп (к. *Казанда фәнни медицина җәмгыятьләре*), эпидемияләрне туктатып калуга ирешә. Совет М.сының авыруларны кисәтү һәм социаль мед. юнәлешендәге эшчәнлегенең ачык мисалы — киң таралган социаль авырулар: туберкулёз, венерик чирләр, трахомага каршы көрәшү өчен махсус хезмәтләр булдыру (к. *Диспансерлар*, *«Каменка»*). Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан илдә һәр кеше өчен бушлай табиб ярдәме күрсәтү системасы, нигездә, оешып бетә. Бөек Ватан сугышы елларында сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт җитәкчелегенең өстенлекләре раслана: хәрби мобилизация мед.-санитария хезмәте б-н тәэмин ителә, эвакогоспитальләр һәм яралыларны дәвалау оештырыла, тылда уңай сан.-эпид. халәт саклана, оборона заводларында эшләүчеләргә югары сыйфатлы мед. ярдәме күрсәтүдә өстенлекләр билгеләнә, халыкка мед. ярдәме күрсәтү сугышка кадәрге дәрәҗәдә саклана, эпидемияләр башлануга юл куелмый. Мед. фәнендә һәм практикада зур алга китеш күзәтелә. Матди база һәм кадрлар потенциалы булдырыла (к. *Эвакуация госпитальләре*).

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында сәламәтлек саклау системасы, мед.

фәнни мәктәпләре барлыкка килә. Казан М. үсешенең иң эре үзәкләреннән берсе булып кала (к. *Казан медицина фәнни мәктәбе*, *Сәламәтлек саклау*). Хәзерге чорда Казан мед. фәнни мәктәбе традицияләре Казан мед. ун-тында, Казан мед. академиясендә һәм аларның клиник уку-укыту базаларында, Казан эпид. һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында дәвам ителә. 20–21 йөзләр чигендә М.ның хезмәт күрсәтүгә караган тармагы (косметология, пластик хирургия, ортодонтия һ.б.) барлыкка килә, шулай итеп, тормыш һәм сәламәтлекне саклау янәшәсенә тагын бер кайгырту объекты — кеше матурлыгы куела.

21 йөз башыннан М.ның фәнни тикшеренүләр таләп итә торган мед. генетикасы (ген инженериясе ысулларын куллану), иммунология (организмда бара торган патологик процессларны биофизик җайланмалар ярдәмендә визуальләштерү ысулларын эшләү), күзәнәк медицинасы кебек юнәлешләре көчле күтәрелеш кичерә.

*Әд.:* Амиров Н.Х. 180 лет высшего медицинского образования // Казанский медицинский институт (1814–1989). К., 1989. Ч. 1; Павлухин Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; Зыятдинов К.Ш., Павлухин Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана (до 1917 г.). К., 2005.

*Н.Х.Әмиров, А.С.Созинов, Р.Г.Исхакова.*

**МЕДИЦИ́НА БЕЛЕМЕ́ БИРҮ́**, мед. кадрлары әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү системасы; табиб һәм урта мед. персоналының проф. эшчәнлеге өчен кирәкле белем һәм гамәли күнекмәләр тупланмасы. М.б.б. мед. фәне һәм сәламәтлек саклау практикасы б-н тыгыз бәйләнгән, аның урта, югары һәм өстәмә белем төрләре бар. Өзлексез М.б.б. стратегиясе кабул ителгән. Император Александр I идарә иткәндә уздырылган мәгариф реформасы кысаларында дәүләти М.б.б. системасы төзелә; 19 йөзнең 1 нче яртысында урта мед. хезмәткәрләре әзерләү башлана. 1837 елда Казанда губерна земство хастаханәсе базасында 50 укучыга исәпләнгән өчьеллык фельдшерлар мәктәбе ачыла, анда акушерлар, фельдшерлар, ш.и. Казан һәм күрше губерналар өчен санитарлар әзерләнә. 1884 тә Лихачёв бала тудыруга булышлык итү йортында (сәүдәгәр И.Т.Лихачёв акчасына төзелә) крәстиян хатын-кызлар арасыннан акушерлар әзерләү курслары эшли башлый (берьюлы 2 укучы кабул ителә, уку-укыту чыгымнарын өяз ведомстволары түли); 1899 һәм 1908 дә теш табибләре мәктәпләре ачыла. 1922 дә урта мед. уку йортлары РСФСР Мәгариф халык комис-ты карамагына тапшырыла, 1936 да — фельдшерлар мәктәбе, 1954 тә киң профильле белгечләр: шәфкать туташлары, акушерлар, сан. фельдшерлары, фельдшер-лаборантлар, балаларны дәвалау-профилактика учреждениеләре өчен шәфкать туташлары, ш.у. теш техниклары, мед. җиһазларына хезмәт күрсәтүче техниклар һ.б.ны әзерләүче мед. уч-щеләре (фармацевтлар өчен — фарм. уч-щеләре) итеп үзгәртелә. Уч-щеләр СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының (1991 дән — РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының) Уку йортлары баш идарәсенә карый. 1950 еллардан урта мед. хезмәткәрләренең белемен күтәрү Казан мед. көллияте һәм Казан мед. ун-ты каршындагы дипломнан соңгы әзерлек системасы аша тормышка ашырыла.

19 йөз башында Халык мәгарифе министрлыгы карамагына 6: Мәскәү, Вильно, Дерпт, Казан, Петербург, Харьков уку-укыту округлары карый. 1755 тә Мәскәүдә, 1802 дә Дерптта, 1803 тә Вильнода, 1804 тә Казанда, 1805 тә Харьковта, 1819 да Петербургта ачылган университетлар югары белем үзәкләренә әверелә.

Казанда югары М.б.б. системасына Казан ун-тында мед. бүлеге һәм ординатура, Бактериология, Акушерлык (Повивальный), Чәчәк салу ин-тлары, Югары хатын-кызлар курслары һәм, дипломнан соңгы әзерлек учреждениесе буларак, күз клиникасы ачылу аша нигез салына.

Казан ун-тының 1804 тә кабул ителгән Уставы буенча уку йортында табиблек яки мед. фәннәре укытыла торган мед. ф-ты булдыру карала. 1811 дә булачак табибләр — беренче өч студент укый башлый; 1814 нең 2 маенда мед. ф-ты ачыла; анатомия, физиол. һәм мәхкәмә табиблеге фәне, патология, терапия һәм клиника, табиб терминологиясе, хирургия, акушерлык күнекмәләре, терлекләрне дәвалау кафедралары оеша. Казан ун-тының беренче мед. профессорлары: И.П.*Каменский* (акушерлык), И.О.*Браун* (анатомия һәм физиол.), Ф.Х.*Эрдман* (терапия), А.И.*Арнгольд* (хирургия), Х.Ренард (фармация). Казанда клиник белем бирү барлыкка килү Ф.Х.Эрдман исеме б-н бәйле : 1811 дә ул Клиник ин-т проектын тәкъдим итә; университетта вакытлыча 4 ятак-урынлы бүлмә булдырыла, гимназия каршындагы хастаханәдә пациентларга амбулатор ярдәм күрсәтү җәелдерелә. К.Ф.Фукс тарафыннан клиника ординаторы вазифасы кертелә, ординатор клиникада шөгыльләнүче һәр студентка аерым дәваланучы беркетеп, студентның үзенә беркетелгән дәваланучының авыру барышын һәм дәвалау ысулларын көн саен теркәп баруына җитәкчелек итә; чыгарылыш имтиханнарында студентлар үзләренең авыруны дәвалый белүләрен исбатларга тиеш булалар. Г.И.Сокольский һәм Н.А.*Скандовский* студентларга авыруларны диагнозлауның иң яңа ысулларын (перкуссия һәм аускультация) өйрәтү тәкъдиме кертәләр.

Казан ун-тының беренче укытучы-медиклары — чит илләрдән: 4 немец һәм 1 итальян. Казан ун-тын тәмамлаганнардан мед. ф-тында беренче проф. А.Е.*Лентовский*, мед. ф-тын тәмамлап, беренче булып мед. д-ры дәрәҗәсенә ирешүче — Д.И.*Протопопов*. Н.А.Скандовский Казан мед. мәктәбе тарихында Россиянең беренче клиницисты (терапевт) буларак лаеклы урын ала.

1835 тән ф-тта 5 еллык уку тәртибе кертелә, курсларга бүленешле уку процессы закон б-н раслана, һәр ярты ел эчендә укытыларга тиешле дисциплиналар катгый рәвештә билгеләнә. Н.И.Лобачевский тәкъдиме б-н университет терр-ясендә Анатомия театры төзелә (1837), 1836 да Казанда булып киткән император Николай I хуплавы б-н 60 ятак-урынга (22 — терапиягә, 24 — хирургиягә, 14 — акушерлыкка) исәпләнгән университет клиникасы (соңрак «Иске клиника» буларак билгеле) сафка баса (1840). Шулай итеп, табибләр әзерләү өчен иң яхшылардан булган уку-укыту базасы булдырыла.

Студентлар үз хисабыннан укучы һәм казна хисабыннан укучы ике төркемгә бүленә. Беренче төркемдәгеләр өйләрендә торып укый, укуга гадәти киемнән йөри, укулары тәмамлаганнан соң, алар үзләре теләгән урында хезмәт итә алалар; икенче төркемдәгеләр ун-тта торып укыйлар, тулысынча казна тәэминатында яшиләр, шуның бәрабәренә, диплом алганнан соң, билгеләнгән урыннарда 6 ел эшләргә тиеш булалар. 19 йөзнең 1 нче яртысында чыгарылышлар аз санлы була (3–8 кеше), 1860 еллардан соң мед. ф-ты ел саен 25–30 табиб әзерләп чыгара башлый.

Россиядә беренче булып ясалган операцияләр: ташларны вату һәм ринопластика, эфирлы наркоз б-н ясалган аналык экстирпациясе — аналык җиңсәсе аша аналыкны алу (1835, 1847) — Казан мед. ф-тына танылу китерә. Ун-т ш.у. фәнни эшчәнлектә һәм мед. кадрлары әзерләүдә гигиенага йөз тотуы (мед. полициясе, сан. күзәтчелеге, шәхси гигиена һәм җәмәгать гигиенасы, дәвалау эшен һәм сәламәтлек саклауны оештыру, табибнең адм. вазифалары һ.б. мәсьәләләрне күтәрү) б-н дә аерылып тора. 1813 тә гигиена адъюнкты, штаб-лекарь Ф.Д.Калайдович җәмәгать тәрбиясе дисциплинасын укыта башлый. 1869 да аерым гигиена каф. (мөдире — проф. А.И.*Якобий*) барлыкка килә; санология, валеология, мед. экологиясе төп фәнни юнәлешләре итеп билгеләнгән бу каф. тиешенчә җиһазландырыла. 19 йөздә дөньякүләм танылу алган *Казан медицина фәнни мәктәбе* оеша.

Н.А.*Виноградов* клиник белем бирүдә реформа уздыра: предметны өйрәтү теория (лекцияләр) һәм гамәли (авыру ятагы янында) юнәлешләрдә алып барыла; Россиядә беренчеләрдән клиник лаб-я (1863) булдыра, термометрияне авыруның хәлен ачыклау ысулы буларак куллану кертә, үлем б-н тәмамланган клиник очракларда патологоанатом тикшерүен мәҗбүри итеп куя.

19 йөз ахырында мед. ф-тында 23 каф. була, 360 студент укый. 1890 да университет терр-ясендә теоретик дисциплиналар укыту өчен махсус бина (физиология корпусы) төзелә. 1899 да Арча кырында хирургия, акушерлык-гинекология, педиатрия, офтальмология һәм тире-венерология юнәлешендәге «яңа клиникалар» (4 корпус) сафка баса.

1896 да Россия университетлары, ш.и. Казан ун-ты каршында һәм клиникаларда гражданлык табибләре һәм хәрби табибләрнең квалификациясен күтәрү системасы кертелә. Терапия буенча 3 еллык ординатурада лекцияләр тыңлап, имтихан тапшырганнан соң, шул нигездә табибкә аерым исем бирелә (земство табибе һ.б.). 1880 елларда Казан Россиянең эре офтальмология үзәкләреннән берсенә әверелә. Идел буе, Себер, Көнчыгыш Россия өчен табиб-офтальмологлар әзерләү һәм аларга дипломнан соңгы өстәмә белем бирү заманы өчен яхшы җиһазландырылган

күз клиникасында (ун-тның күз авырулары каф. мөдире Е.В.*Адамюк*) тормышка ашырыла.

1856 да ун-тның акушерлык клиникасы профессоры А.И.*Козлов* (1856–70 тә директор) тәкъдиме б-н, акушерлар әзерләү өчен, 1 еллык бушлай курслы Акушерлык ин-ты ачыла; 1865 тән уку-укыту 2 курслы итеп үзгәртелә, булачак акушерларга земство мед. практикасында зарур булачак кайбер фельдшерлык күнекмәләре бирелә.

Мед. ф-тының яшь профессорлары, киләчәктә атаклы галим һәм җәмәгать эшлеклесе булып танылачак Н.О.*Ковалевский*, П.Ф.*Лесгафт*, А.В.*Петров*, А.И.Якобий, Акушерлык ин-тында укытканда, акушерлар әзерләү программасын төзиләр (1869). Ул төпле мед. белеме алган акушерны, табибләр җитешмәгән очракта, табибне алыштырырлык һәм төбәктә гигиена һәм табиб ярдәме күрсәтә алырлык итеп әзерләүгә юнәлдерелгән була. Программада анатомия буенча гамәли күнекмәләр, физиол. һәм акушерлык буенча лекцияләр, хатын-кыз авырулары һәм гигиенасы курсы уздыру карала. Укучылар мөстәкыйль рәвештә бала таптыралар, бала тапкан хатын-кызны һәм яңа туган баланы карау, тернәкләндерү күнекмәләре алалар. 1873 тән «кызлар прогимназиясе курсының мәҗбүри предметларын» белү ин-тка кабул ителү өчен шарт итеп куела. Акушерлык клиникасының (директоры В.С.*Груздев*) 1900 дә төзелгән яңа бинасында акушерлар әзерләү өчен барлык мөмкинлекләр тудырыла, курстан курска йомгаклау аңгәмәсе аша күчү тәртибе кертелә, чыгарылыш имтиханнарының тәгаен көне билгеләнә (елына 2 тапкыр). В.С.Груздев акушерларның фельдшерлык вазифасын мәҗбүри рәвештә үзләштерүгенә ирешә. 1902 дән профессорлар Н.А.*Геркен* һәм А.Н.*Казимбәк* тәкъдиме б-н институт укучылары Александр земство хастаханәсенең хирургия һәм терапия бүлекләрендә, Кызыл Хач җәмгыяте дәваханәсендә шөгыльләнәләр. 1918 дә Акушерлык ин-тында акушерларның соңгы чыгарылышы була. Факультет клиникалары б-н бер үк вакытта Казан ун-ты каршында Бактериология ин-ты (беренче директоры — Н.Ф.Высоцкий) төзелә, И.Г.Савченко тарафыннан шул ин-т базасында гомуми патология һәм бактериологияне студент-медикларга мәҗбүри предмет буларак өйрәтү кертелә (1903). Казан губернасының земство Чәчәк салу ин-ты чәчәк салучылар әзерләп чыгара, аларга «закон нигезендә («Россия империясенең законнар җыелмасы») бозауларга һәм кешеләргә чәчәк сала алу турында» таныклык бирелә. Казанда 1 нче теш табибләре мәктәбе — 1899 да (курс 2,5 ел тәшкил итә), 2 нче мәктәп 1908 дә ачыла. 1912 гә кадәр Идел-Кама төбәгендә теш табибләре әзерли торган башка уку йортлары булмый. 1918 дә СССР Халык комиссарлары советы боерыгы б-н Петроград, Мәскәү, Казан, Саратов шәһәрләрендәге теш табибләре әзерләүче уку йортлары мед. ф-тлары каршындагы онтологик юнәлешле ярдәмче уку-укыту учреждениеләре итеп үзгәртелә. 1920 дән Казандагы 2 нче теш табибләре мәктәбе, яхшырак җиһазландырылуы сәбәпле, Казан ун-ты структурасына кертелеп, одонтология бүлеге-кафедрасы дип атала башлый.

1920–30 елларда Казан югары фәнни потенциалга ия эре М.б.б. үзәге буларак таныла; табибләр белемен күтәрү ин-ты (ГИДУВ), Казан мед. ин-ты, стоматология, кан салу, туберкулёз, соц. сәламәтлек саклау һәм гигиена ин-тлары, Татарстан эксперим. мед. ин-ты ачыла. 1922 дә дөньяда беренче Трахоматоз ин-ты (Е.В.Адамюк исем.) булдырыла (Казан губернасында һәр дүрт кешенең берсе трахома б-н авырый).

Илдә стоматологлар җитешмәү сәбәпле, 1936 да СССР Халык Комиссарлары Советы илнең 11 шәһәрендә стоматология ин-тлары булдыру турында карар кабул итә. Казан стоматология ин-ты 1938 дә ачыла (директоры — И.М.Утробин), 1950 дә ин-т Караганда шәһәренә күчерелә. 1950–54 тә Казанда стоматологлар әзерләнми. 1954 тә Казан мед. ин-тында стоматология ф-ты кабат ачыла. 1930 да Казан ун-тының мед. ф-ты нигезендә Казан дәүләт мед. ин-ты оештырыла. 1994 тән ул *Казан медицина университеты* статусын ала (РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында); 2005 тән — Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш федераль агентлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» дәүләт югары һөнәри белем бирү уку йорты. КДМУ (8 ф-т) Татарстан, Мари, Мордва, Ингуш, Калмык, Чуаш һәм Чечен Респ-калары, Самара, Пенза, Ульянов, Саратов өлкәләре өчен 9 белгечлек буенча табибләр әзерли. Барлык ф-тларда 5500 студент укый. 1991 дән ун-тта дөньяның 46 иленнән килгән студент, ординатор һәм аспирант (2013 тә 400 дән артык кеше) белем ала. М.б.б. түбәндәге белгечлекләр буенча тормышка ашырыла: дәвалау, педиатрия, мед.-профилактика (уку — 6 ел), стоматология, фармацевтика, социаль эш (5 ел), мед. биохимиясе, мед. биофизикасы һәм югары белемле шәфкать туташлары әзерләү (4 ел — бакалавр дәрәҗәсе). Мед. һәм фармацевтика буенча югары белем бирүче уку-укыту программаларын үзләштергән һәр кеше мәҗбүри рәвештә дипломнан соңгы башлангыч әзерлек уза (интернатура һәм ординатура). Интернатура — 28, ординатура 41 белгечлек буенча табибләр әзерли. Фәнни эш һәм югары мед. уку йортлары өчен пед. кадрлар әзерләү аспирантура аркылы тормышка ашырыла. Медицина кадрлары әзерләү өзлексез белем бирүне тәэмин итүче күпкатлы уку-укыту системасы буенча алып барыла: югары уку йортына әзерлек (мәктәп-лицей, мәктәпләрдәге махсус сыйныфлар, консультация-һөнәри юнәлеш бирү үзәкләре), әзерлек курслары (көндезге, кичке, көндезге-читтән торып уку), дипломнан соңгы һөнәри әзерлек (интернатура, ординатура, аспирантура), яңадан укыту һәм белгечләрнең белемен күтәрү.

Россия мед. югары уку йортлары ф-тларының иң өлкән һәм зурларыннан берсе булган дәвалау ф-ты 1814 елда оеша, авыруларны дәвалау белгечләре әзерли. Мед.-профилактика ф-ты 1930 да барлыкка килә, гигиена табибләре һәм эпидемиологлар әзерләп чыгара.

Педиатрия ф-ты 1932 дә, дәвалау ф-тыннан аналар һәм балалар сәламәтлеген саклау бүлеге аерылып чыкканнан соң барлыкка килә, табиб-педиатрлар әзерли. 1993 тә өч ф-т студентларына дипломнан соңгы әзерлек чорында өч юнәлешнең: дәвалау, педиатрия, мед.-профилактика — берсен сайлап алырга мөмкинлек бирерлек итеп бердәйләштерелгән уку-укыту планы кабул ителә. Югары стоматологик белем бирүгә Казан ун-тының мед. ф-тында 1920 дә ачылган одонтология һәм стоматология каф. аша нигез салына; ф-т 1950 гә кадәр гамәлдә була, 1954 тән кабат ачыла. Фармацевтика ф-ты 1975 тә оештырыла, дару матдәләре ясау, җитештерү, куллану өлкәсе белгечләре әзерли. 1994 тә ачылган менеджмент һәм югары белемле шәфкать туташлары әзерләү ф-ты дәвалау-профилактика учреждениеләрендә шәфкать туташлары эшен оештыру белгечләре әзерли (урта махсус мед. белеме базасында, бакалавриат). 1991 дә ачылган социаль эш ф-ты югары белем базасында социаль хезмәткәрләр әзерләп чыгара, социаль хезмәткәрләрне яңадан укыту бүлегенә шул тармак буенча белгечләр әзерләү б-н шөгыльләнә (200 дән артык студент). Университетның башка ф-тлары студентлары, өстәмә укып, «табиб-психолог» белгечлеге ала алалар. 1994 тә ачылган өстәмә белем ф-тында табиб һәм провизорлар әзерлекнең түбәндәге төрләрен уза: беренчел белгечлек — клиник интернатура (400 кеше), һөнәри әзерлек — клиник ординатура (300 кеше), стажлы белгечләр өчен гомуми һәм тематик өстәмә белем (2000 кеше), мед. уч-щеләре укытучыларының белемен күтәрү (50 дән артык кеше). Табибләр белемен күтәрү тематик курс — гомуми практика табибе (гаилә медицинасы), балалар хирургиясе, фармацевтика, мед. профилактикасы һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә идарә итү курслары базасында тормышка ашырыла; гомуми, тематик, белгечлек буенча цикллар формасында уза. Ун-тның 34 клиник кафедрасы һәм 3 курсының дәвалау-пед. эшчәнлеге ТР сәламәтлек саклау системасына караган 46 клиник мед. учреждениеесе җирлегендә: Казан мед. ун-ты клиникаларында, киң профильле хастаханәләр һәм район хастаханәләрендә, тар профильле дәвалау-диагностика берләшмәләре үзәкләре, диспансерларында, бала тудыру йортларында, киң профильле поликлиникаларда һәм стоматология поликлиникаларында, хатын-кызлар консультацияләрендә, хастаханәләр һәм ашыгыч мед. ярдәме станцияләрендә алып барыла. Роспотребсоюзның респ-ка һәм шәһәр хезмәте үзәкләре дәвалау-профилактика юнәлешендәге табибләр әзерләүдә уку-укыту базасы, Татарстан, Мари, Чуаш Респ-каларының аптека системасы фармацевтлар өчен уку-хезмәт күнекмәләре алу базасы булып тора. Казан мед. ун-тының җиде уку корпусы, үз стоматология клиникасы бар (мәйданы 41490 $м^2$). 65 кафедрада һәм 10 курста 1500 дән артык укытучы, ш.и. 150 проф. һәм фән д-ры, 300 дән артык доцент һәм фән канд.

белем бирә. Алар арасында РМФА, ТР ФА акад. — 6, мөхбир әгъза — 5, РФнең атказ. фән эшлеклесе — 6, ТРның атказ. фән эшлеклесе — 10, РФнең атказ. табибе — 6, ТРның атказ. табибе — 24, РФ сан.-эпид. хезмәте мактаулы хезмәткәре — 7. Тугыз белгечлек буенча 3 махсус диссертация яклау гыйльми советы эшли. Студентларның үз фәнни җәмгыяте бар, укуда, фәнни эшчәнлектә, җәмәгать эшләрендә уңышка ирешкән студентларга, гыйльми совет карары нигезендә, Казан мед. фәнни мәктәбе данын тудырган атаклы галимнәр исемендәге махсус стипендияләр бирелә. Студентлар өчен халыкара стажировка системасы булдырылган. Казан мед. ун-ты Студентларның халыкара мед. ассоциацияләре федерациясендә һәм Европа студент-медиклар ассоциациясендә әгъза булып тора.

Табибләрнең һөнәри квалификациясен күтәрү максаты б-н 1920 дә Клиник ин-т оештырыла (идарәдә — В.И.Иорданский, Р.А.*Лурия* һәм В.П.Первушин, ин-т РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тының фәнни учреждениеләре исемлегенә кертелә); 1925 тә В.И.Ленин исем. Дәүләт табибләр белемен күтәрү ин-ты (ГИДУВ) эшли башлый. 1926–27 дә табибләр 11 белгечлек буенча әзерләнә. Идел буендагы барлык респ-ка һәм өлкә табибләре дипломнан соңгы әзерлек уза. 1978 дән Казан ГИДУВы — беренчел звено табибләр әзерләү буенча Идел буе төбәгенең баш учреждениесе; 1995 тән — Казан дәүләт медицина академиясе өстәмә һөнәри белем бирү учрежениесе (2003 тән — Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш федераль агентлыгының «Казан дәүләт медицина академиясе» дәүләт өстәмә белем бирү учреждениесе). Өч ф-тта (сан.-гигиена, терапия, хирургия) ел саен Россиянең төрле төбәкләреннән килгән табибләр 100 дән артык белгечлек буенча квалификация күтәрә. Мед. учреждениеләренә һәр елны 2 еллык клиник ординатура узган югары әзерлекле 100 дән артык белгеч әзерләп җибәрелә. Мед. академиясе докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклауга кабул итү хокукына ия.

*Әд.:* Зыятдинов К.Ш., Павлухин Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана (до 1917 г.). К., 2005.

*Н.Х.Әмиров, А.С.Созинов, М.Ю.Абросимова.*

**МЕДИЦИ́НА ИМИНИЯТЕ́**, к. *Иминиятләштерү.*

**МЕДИЦИ́НА МӘГЪЛҮМА́Т-АНА́ЛИЗ ҮЗӘГЕ́**, ТР Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы карамагында, «Медсоцэконом» дәүләт учреждениесе дәвамчысы. 1993 елда оештырыла. М.м.-а.ү. стат. мәгълүмат җыю, эшкәртү, саклау һәм анализлау; халыкның сәламәтлек дәрәҗәсен, динамикасын өйрәнү; пациентларның авырулары һәм аларны дәвалау ысуллары турындагы мәгълүматларны эшкәртү һәм анализлау; фәнни тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшчәнлек, халык сәламәтлеген саклау һәм респ-ка сәламәтлек саклау системасында идарә эше проблемаларына карата рекомендацияләр бирү; методологик эшләнмәләр һәм программа системаларын гамәлгә кертү, укыту-өйрәтү материаллары тарату, консультация һәм методик ярдәм оештыру б-н шөгыльләнә.

М.м.-а.ү. ТР МКның халык сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә кагылышлы карар һ.б. норматив документлар проектларын әзерләүдә катнаша; Татарстан халкына бушлай мед. ярдәме күрсәтүдә Дәүләт гарантиясе программаларын төзи, ТР һәм Россиянең башка төбәкләре арасында сәламәтлек саклау өлкәсенә караган мәгълүмат алмашу һәм тәҗрибә уртаклашуны координацияли; РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы, Мәҗбүри мед. иминияте федераль фонды һәм ТР МК арасында халыкка мед. ярдәме күрсәтү буенча өч яклы килешүне әзерли. 1993 тән «Татарстан Республикасында халыкның сәламәтлеге һәм сәламәтлек саклау статистикасы» («Статистика здоровья населения и здравоохранения Республики Татарстан») һ.б. җыентыклар нәшер итә. Ел саен респ-ка сәламәтлек саклау өлкәсе өчен 5 күрсәтмә-җыентык чыгара. Сәламәтлек саклаудагы көнүзәк мәсьәләләр (ТР инвалидларына мед.-социаль ярдәм күрсәтү, читтән килгәннәрне госпитализацияләү, Татарстан мед. учреждениеләрендә хезмәт күрсәтү сыйфаты һ.б.) буенча мед.-социологик тикшеренүләр уздыра; респ-ка мед. статистлары өчен квалификация күтәрү һәм Казан мед. ун-ты студентлары өчен социол. тикшеренүләр теориясен өйрәнү һәм практика узу базасы булып тора.

М.м.-а.ү.ндә 96 хезмәткәр, ш.и. 7 мед. фән. д-ры һәм канд., 1 атказ. табиб эшли.

*В.Г.Шерпутовский.*

**МЕДИЦИ́НА СӘНӘГАТЕ́**, сәламәтлек саклау системасының дәвалау-профилактика учреждениеләре һәм халык ихтыяҗлары өчен дарулар һәм мед. техникасы җитештерүче халык хуҗалыгы тармагы.

Казан губернасында 19 йөзнең 2 нче яртысында формалаша башлый. Беренче пр-тиеләр провизорлар һәм фармацевтлар, күмәртәле аптекарьлык кибетләре хуҗалары тарафыннан оештырыла. 1890 елда Девриенг һәм Зуль Казанда желатин ф-касы ачалар, анда 1893 тә 18 кеше эшли, 7 мең сумлык продукция җитештерелә. 19 йөз ахырында Ф.Х.Грахенең — ясалма минераль сулар һәм пилюляләр өчен желатин капсулалар, А.Ф.Кешнерның альбумин-эчәк з-длары эшли башлый. 1916 да гариплэнгән сугышчылар өчен протез остаханәсе булдырыла, Стеарин-сабын кайнату, глицерин һәм химия з-дында (Казан) А.Е.Арбузов салицил препаратлар: аспирин, салицил к-тасы, ачы салицил натры, салол һ.б. җитештерүне оештыра. 1918–21 дә тармак пр-тиеләре национализацияләнә, аларның күбесе ябыла. Индустрияләштерү елларында Казанда мөгезле вак терлек эчәкләреннән хирургик тегү материалы җитештерүче илдәге бердәнбер кетгут з-ды төзелә (1931), химия-фармацевтика ф-касы (1931), сан. автомобильләре өчен кузовлар эшләп чыгаручы автокузов з-ды (1938) оештырыла.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Казанга Киевтан илнең иң эре заводлары (Ломоносов исем. химия-фарм. һәм теш-табиблык борлары з-длары), ш.у. Мәскәү һәм Ленинградтагы кайбер фарм. производстволары эвакуацияләнә. Кызыл Армиянең Сан. идарәсе заказлары буенча пр-тиеләр госпитальләр һәм фронт өчен кирәкле препаратлар, инструментлар, яра бәйләү материаллары, пешү һәм өшү очракларында кулланыла торган майлар, шәхси аптечкалар, рентген экраннары эшләп чыгаруны үзләштерәләр. Автокузовлар з-дында дезинфекция һәм автоформалин камералары, яралыларны күчереп йөртү өчен носилкалар һәм көймәләр, Дитерехс шинналары җитештерү җайга салына. Сугыш елларында Татарстанда М.с.нең җитештерү күләме 10 тапкыр диярлек арта.

Алдагы чорда гамәлдәге пр-тиеләрдә реконструкция, техник яктан яңадан коралланy, яңа сәнәгать мәйданчыклары төзү җәелдерелә. 1950 еллардан М.с.нең фәнни-тикшеренү һәм проектлау-конструкторлык юнәлеше үсә: Казанда Бөтенсоюз экспериментал хирургия аппаратлары һәм инструментлары фәнни-тикшеренү ин-ты ф-лы (1960, 1977 дән — Бөтенсоюз мед. инструментлары фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-ты), яңа мед. инструментларының һәм аппаратурасының аерым төрләрен, ш.у. М.с. өчен технологияләр һәм технол. җиһазлар эшләү һәм җитештерүгә кертү буенча специальләшкән КБлар һәм тәҗрибә з-длары оештырыла. 1970–80 елларда алар җирлегендә «Медфизприбор» һәм «Мединструмент» ФҖБләре, 1976 да кетгут һәм химия-фарм. з-длары җирлегендә *«Татхимфармпрепаратлар»* ҖБ төзелә. Бу чорда, медицина галимнәре б-н хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә, тармак югары фәнни дәрәҗәгә һәм яхшы сыйфатлы продукция чыгаруга ирешә. СССРда һәм чит илләрдә җирле пр-тиеләр тарафыннан проектланган һәм җитештерелә торган «ясалма бөер» һәм үпкәне тегү аппаратлары, күз, вак кан тамырлары, йөрәк микрохирургиясе, нейрохирургия һәм гинекология инструментлары, мед. газ анализаторлары, ясалма тегү-җөй материаллары, *фосфорорганик дару кушылмалары* һ.б. киң таныла.

1990 елларда пр-тиеләрне һәм фәнни проектларны үзәкләштерелгән дәүләт финанславы тулысынча диярлек туктала. Демпинг бәяләре һәм югары рентабельлек аркасында ил базарында чит ил продукциясенең өлеше күпкә арта, нәтиҗәдә, ТРда М.с. продукциясен җитештерү һәм сату күләме азая. Җитештерүдә эшләүчеләрнең саны ике тапкыр диярлек кими. Күп кенә пр-тиеләр технол. яктан шактый артка кала бара. 2000 гә М.с.нең эре һәм урта пр-тиеләренең төп фондлары тузу дәрәҗәсе 54,4% ка җитә.

2000 еллар башында Татарстан М.с. пр-тиеләре тарафыннан һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, Россия стоматология ассоциациясе һ.б. катнашында гомуми һәм махсус хирургиядә, микрохирургия, стоматология, травматология, ортопедия, гинекология, мед. диагностикасы һәм функциональ диагностика өлкәсендә заманча мед. техникасы, лаб. җиһазлары, кетгут һәм ясалма тегү материаллары һ.б.ны булдыруга юнәлтелгән үсеш программалары эшләнә һәм гамәлгә кертелә баш-



В.А.Медноногов.



И.И.Межлаук.

лый. Программалар пр-тиеләрнең төп җитештерү фондларын күпкә яңартуны, җитештерелүче продукциянең сыйфатын яхшырту, эчке һәм тышкы базарларда аның көндәшлек дәрәҗәсен күтәрү чараларын, җитештерү б-н идарә итүдә халыкара идарә хисабы һәм анализы нормаларын, сыйфат б-н идарә итүдә халыкара стандартларга (ИСО 9000, 14000, MRP II, GMP) туры килгән системаларны гамәлгә кертүне, илдәге һәм чит илләрдәге фирмалар б-н тыгыз хезмәттәшлекне күздә тота.

Хәзерге М.с. химия-фарм. сәнәгатен (ясалма чималдан һәм үләннәрдән дозаларга бүленгән дарулар, антибиотиклар, витаминнар, бактериологик препаратлар, кан алмаштыру матдәләре һәм орган-препаратлар, майлар, яра бәйләү материаллары һ.б. дәвалау-профилактика чаралары җитештерә), мед. инструментлары сәнәгатен (мед. инструментлары, аппаратлары һәм җиһазлары), пыяладан, фарфордан һәм пластик массадан мед. эшләнмәләре (аптека савыт-сабасы, ясалма тешләр, теш-табиблек һәм протез материаллары) җитештерүне үз эченә ала.

Структур үзгәрешләр нәтиҗәсендә хосусый һәм катнаш милекле оешмалар барлыкка килә, аларга Татарстан М.с.ндә эшләүчеләрнең 90% ы, тармак продукциясенең 90% ы туры килә. 1990–2011 дә пр-тиеләрнең гомуми саны 5 тән 47 гә кадәр арта, шуларның 30 ы — химия-фармацевтика, 17 се — мед. техникасы пр-тиеләре. Эшләүчеләрнең гомуми саны 2,6 мең кешедән артык. 23 кече пр-тие исәпләнә (680 кеше эшли). Пр-тиеләрнең күбесе Казанда тупланган. Иң эреләре: «Татхимфармпрепаратлар», *Казан медицина инструментлары заводы*, «*Микрон*», *Казан протез-ортопедия предприятиесе*, Казан мед. аппаратлары з-ды (лаб., киптерү-стерилизация, саклану-радиология җиһазлары; вакуум, кондиционер һәм һаваны чистарту, үзәктән газ кудыру җайланмалары; термостатлар, химик активаторлар һ.б.), «Медфизприбор» (газ анализаторлары, тышкы сулыш функцияләре анализаторлары, балалар инкубаторлары, биопробалар өчен контейнерлар һ.б.), Казан фарм. ф-касы (дару препаратлары), Казан бактерия препаратлары җитештерү пр-тиесе (йогышлы авыруларга каршы иммунобиол. препаратлар). Төп продукциясе б-н бергә медицинага караган эшләнмәләрне «*Тасма*» (флюорография, мед., теш плёнкалары) «*Элекон заводы*» (терапия, гинекология, урология өчен диагностика һәм хирургия лазер аппаратлары), «*Серго исемендәге завод*» (суыткыч мед. җиһазлары), «*Васильево пыяла заводы*» һ.б. пр-тиеләр җитештерә. М.с. өчен җиһазлар «Серго исемендәге завод»та (төймә дарулар эшләү өчен роторлы пресслар) һәм «Васильево пыяла заводы»нда (химия лаб-ясе савыт-сабасы) чыгарыла. Бөтенроссия мед. инструментлары фәнни-тикшеренү ин-ты, Казан эпидемиология һәм микробиол. ин-ты мед. техникасы һәм препаратлары өлкәсендә тикшеренүләр алып баралар, проектлар әзерлиләр.

2011 дә ТРда 1,2 млрд. сумлык мед. техникасы һәм аңа запас частьлар, 1,86 млрд. сумлык дарулар (антибиотиклар, йөрәк-кан тамырлары авыруларын дәвалау препаратлары, авыртуны басучы, темп-ра төшерүче һәм ялкынсынуга каршы дарулар, витамин-препаратлар, күз авыруларын дәвалау препаратлары һ.б.) җитештерелә.

ТРда М.с. өчен белгечләрне Казан мед. («фармация» белгечлеге буенча), Казан техник («биотехник һәм медицина аппаратлары һәм системалары»), Казан технол. («медицина-биология практикасында инженерлык эше») һәм Казан энергетика («медицина электроникасы») ун-тлары әзерли. Ш.у.к. *Даруханәләр*.

*Әд.:* На службе здоровья и долголетия. К., 1981.

*С.Г.Белов.*

**МЕДНОГО́РСК ШӘҺӘРЕ́**, *Оренбург өлкәсендә*, Оренбург шәһәреннән 233 *км* читтә урнашкан. 1939 да нигез салына. Халкы — 28364 (2012), татарлар — 1180 кеше (2010). Соц. Хезмәт Герое З.С.*Рахмангулов*, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре К.Х.Тугушевларның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М. шәһәре б-н бәйле.

**МЕДНОНО́ГОВ** Вячеслав Александрович (7.1.1924, Бөгелмә кантоны Зәй а. — 5.2.1997, С.-Петербург ш.), Сов. Союзы Герое (18.8.1945), полковник. Тамбов хәрби очучылар авиация мәктәбен (1944), Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (Мәскәү, 1954) тәмамлый. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 783 нче штурмлау авиация полкы очучысы (4 нче һава армиясенең 4 нче штурмлау авиация корпусында 199 нчы штурмлау авиация дивизиясе). 2 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында 1945 нең маена кадәр дошманның оборона чикләренә 93 сугышчан очыш ясый, 5 бронетехникасын, 22 тимер юл вагонын, 48 автомашинасын, 7 дзотын, 5 артиллерия батареясын юк итә. 1961 дән запаста. Ленинград шәһәрендә яши. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәрендә Геройга бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — казахстанцы. А.-А., 1968. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МЕДЯ́НКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Сөлчә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 62 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Көтеш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 142, 1949 да — 163, 1958 дә — 198, 1970 тә — 212, 1979 да — 187, 1989 да — 109, 2002 дә — 68 кеше.

**МЕДЯ́НЦЕВА** Эльвина Павловна (8.7.1949, Киров өлкәсенең Көлмез р-ны Көлмез пос.), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1995), проф. (1996). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1995 тән аналитик химия каф. профессоры. Хезмәтләре биологик актив кушылмаларның электроаналитик химиясенә карый. М. фермент-субстрат, антитәнчек-антиген, металл-лиганд системаларын вольт-ампер үлчәнешле детектирлауның гомуми юлларын һәм принципларын тәкъдим итә һәм нигезли. Төрле табигатьле (ш.и. биосенсорлы) иммобильләшкән катализаторлар б-н ампер үлчәнешле сенсорлар, иммунофермент сенсорлар, ш.у. иммунохимик һәм иммунофермент анализның яңа вариантларын эшли. Төрле факторларның иммобильләшкән ферментларның каталитик активлыгына тәэсире барлыгын ачыклый. Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Основы электроаналитической химии. К., 1986 (автордаш); Амперометрические датчики на основе иммобилизованных ферментов // Успехи химии. 1991. Т. 60, № 4 (автордаш); Ионы металлов как эффекторы ферментов // Успехи химии. 1998. Т. 67, № 3 (автордаш).

**МЕЖЛА́УКЛАР**, дәүләт һәм партия эшлекләре, бертуганнар. **Иван Иванович** (30.9.1891, Харьков ш. — 26.4.1938). Харьков ун-тының тарих-филол., юридик ф-тларын тәмамлый (1912, 1916). 1911 елдан революцион хәрәкәттә катнаша. 1918 дә Казан эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советы секретаре; июньнән губерна хәрби комиссары; август–декабрьдә Идел буе хәрби округы командующие. Казан губернасында Кызыл Армия частьләрен оештыруны җитәкли, Казан өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1918 нең декабрендә — 1919 да Кызыл Армиянең тәэминат бүлеге башлыгы. 1921 дән Урта Азиядә һәм Тамбов шәһәрендә хакимият-хуҗалык һәм партия эшендә. 1931–36 да Хезмәт һәм Оборона Советы секретаре һәм СССР ХКСның Эшләр идарәсе башлыгы урынбасары. 1936–37 дә СССР ХКС каршындагы югары мәктәп эшләре Бөтенсоюз ком-ты рәисе. СССР ҮБК әгъзасы. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

**Валерий Иванович** (7.2.1893, Харьков ш. — 29.7.1938), Харьков ун-тының тарих-филол., юридик ф-тларын тәмамлый (1914, 1917). 1907 елдан революцион хәрәкәттә катнаша. 1918–20 дә сәясәт хезмәткәре, Көнчыгыш фронтның 5 нче һәм Көньяк фронтның 10 нчы, 14 нче, 2 нче армияләренең Революцион Хәрби Советлары әгъзасы, Украинада хәрби эшләр халык комиссары. 1918 нең сен-

тябрендә Казан өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә. 1920 дән хакимият-хуҗалык эшендә. 1924–31 дә СССР Халык Хуҗалыгы Югары Советы Президиумы әгъзасы, рәисе урынбасары. 1934 тән СССР ХКС, Хезмәт һәм Оборона Советы рәисе урынбасары, СССР ХКС каршындагы Дәүләт план комиссиясе рәисе (бүленеп: 1937 дә СССР авыр сәнәгать халык комиссары). 1927 дән ВКП(б) ҮК әгъзалыгына канд., 1934 тән әгъзасы. СССР ҮБК әгъзасы. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләр корбаны; үлгәннән соң аклана.

**Мартын Иванович** (1895, Харьков ш. — 7.8.1918, Казан) Харьков ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1917). Украинада Гражданнар сугышында катнаша. 1918 нең маенда Казан губернасы юстиция комиссары. Губернаның мәхкәмә органнарын (революцион-тикшерү комиссиясен, округ халык мәхкәмәсен оештыра), революцион трибуналлар эшчәнлеген үзгәртеп коруны җитәкли. Акгвардиячеләр тарафыннан атып үтерелә.

*Әд.:* С м ы к о в Ю.И. Братья Межлауки // Борцы за счастье народное. К., 1967; Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1983.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕЖРАБПРО́М**, к. *Халыкара эшчеләр хәйрия оешмасы.*

**МЕЗОЗО́Й ЭРАТЕ́МАСЫ (Э́РАСЫ)**, м е з о з о й (грек. mésos — урта, арадаш һәм zōē яшәү), җир кабыгы катламнарының гомуми стратиграфик шкаласында фанерозой эонотемасының уртача группасы һәм Җирнең геол. тарихында шуңа туры килә торган эра. 1841 елда инглиз геологы Дж.Филлипс тарафыннан билгеләнгән. 251±0,4 ел элек башлана һәм 65,5±0,3 млн. ел элек тәмамлана. Триас, *юра системасы* (*чоры*) һәм *акбур системасына* (*чорына*) бүленә. М.э.(э.)нда интенсив рәвештә җыерчыклану, тау барлыкка килү, вулканик эшчәнлек, диңгез биеклегенең еш тирбәнешләре һәм климатик үзгәрешләр билгеләнә. Материклар яңа чикләр һәм үләмнәр ала. Атлантик, Һинд, Арктик һәм Көньяк океаннар формалаша. М.э.(э.) өчен 25 *м* һәм тагын да озынрак эре сөйрәлүчеләр (динозаврлар, ихтиозаврлар, птерозаврлар һ.б.) хас. Бик күп санда бөҗәкләр, беренче чын кошлар, имезүчеләр барлыкка килә. Диңгез умырткасызлары арасында эра ахырында динозаврлар б-н беррәттән үлеп беткән аммонитлар һәм белемнитлар (аларның ташка әйләнгән калдыклары ТР терр-ясенең көньяк-көнбатышында Идел яры буендагы ишелмәләрдә очрый) өстенлек итә. Флораның яңаруы бара, наратбаш һәм абагасыманнар ылыслылар һәм яфраклылар б-н алмашына, үләннәр һәм чәчәкләр үсеп чыга. М.э.(э.) утырмаларына дөньякүләм нефть һәм газ запасының аеруча зур күләме (Фарсы култыгы, Көнбатыш Себер), ташкүмернең өчтән бер өлеше (АКШ, Себер), янучан сланецлар, тозлар һ.б. файдалы казылмалар туры килә. ТР чикләрендә М.э.(э.)нда палеозой эрасы ахырында башланган континенталь чор дәвам итә, шунлыктан биредә триас һәм юра чорының күпчелек утырмалары юк. Юра чоры уртасында гына Идел буеның көньяк өлешенә акбур чорында да булган диңгез үтеп керә (Татарстан терр-ясенең көньяк-көнбатыш өлешен дә били). М.э.(э.) ахырында диңгез сулыгы юкка чыга, һәм 50 млн. елдан артыкка сузылган континенталь чор башлана. ТР терр-ясендәге цеолитлы, кремний-карбонатлы, балчыксыл токымнар, янучан сланец, фосфорит һ.б. ятмалар, язу акбуры чыганаклары М.э.(э.) утырмалары б-н бәйле.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Геология Татарстана. М., 2003.

*С.О.Зорина, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**МЕЗОЛИ́Т** (грек. mésos — урта, ике арадагы һәм líthos — таш), урта таш гасыр, *палеолиттан неолитка* күчү дәвере (якынча б.э.к. 10–5 нче меңьеллыклар). Бу чорда борынгы кешеләр тормышында зур үзгәрешләр була. М. климатның кисәк җылынуы һәм боз катлавының Европаның ерак төньяк-көнбатышына таба чигенүе сәбәпле башлана, бу дүртенчел геол. дәвернең — *голоценның* башлангычы була. Голоценның элгәрге этапларында (пребореал, бореал) рус тигезлеге терр-ясендә бозлык янындагы салкынга яраклашкан флора һәм фауна юкка чыга, хәзерге табигый зоналар урнаша. Борынгы аучылар кәсәбәчелек объектларын һәм тормыш рәвешен үзгәртергә мәҗбүр булалар. Күчү булып яшәүче һәм күчү булып яшәми торган бик зур булмаган хайваннарны аулау өстенлек итә башлый (язгы-көзге яшәү урыннарында ау һәм урманда индивидуаль сунарчылык). Ау кораллары, кирәк-яраклары һәм алымнары камилләшә. Соңгы палеолит чорында уйлап табылган ук төп коралга әйләнә. Көймә, ятьмә, мурдалар һәм башка җайланмалар ярдәмендә балык тоту зур үсеш ала. Мезолит чоры общиналары сан ягыннан зур булмый һәм соңгы палеолит чорындагыга караганда урыннан урынга ешрак күчә. Торулыклар елга ярларында, биек булмаган калкулыклар һәм террасаларда барлыкка килә. Тораклар, гадәттә, җиңелчә корылышлы һәм кечкенә була. Җәен — кыска чорга исәпләнгән вакытлы (сезонлы) туктаулыклар һәм лагерьлар, кышын эрерәк даими торулыклар корылган, дип фаразлана. М. дәвере матди мәдәнияте чакматаштан пычаксыман пластиналар, аеруча микропластиналар эшләү технологиясенең югары үсеш дәрәҗәсенә ия булуы б-н аерылып тора; микропластиналар ясау өчен, бәрүгенә түгел, кысу ысулы да кулланыла. Пластиналар тире, агач, сөяк эшкәртүдә, ш.у. пычакларның кискеч өлеше һәм очлыклар буларак файдаланыла.



Косякау туктаулыгында табылган чакматаш әйберләр. ТР ФА Тарих институты фондлары.

Татарстан терр-ясендә берничә археол. культура истәлекләре мәгълүм. *Чулман тамагы культурасы* халкы Кама тамагы төбәгендә соңгы бозлык чорында ук, ягъни палеолит һәм мезолит дәверләре чигендә яшәгән: Иделнең уң ярында Сөйке Кичүе һәм Кама Тамагы посёлоклары янында, ш.у. Актай елгасы (Иделнең сул кушылдыгы) тамагында туктаулыклар булуы билгеле. Тәтеш III, Косякау, Любава, Семёнов туктаулыклары һ.б. бу культураның иң югары үсеш алган этабын чагылдыра. Чулман тамагы археол. истәлекләренә, ихтимал, ук очлары буларак кулланылган, китеп эшкәртелгән батынкы кырыйлы трапеция рәвешендәге кораллар хас. Агыйдел елгасы тамагындагы элеккеге Татар Әҗбие тирәсендәге, ш.у. Ык елгасының түбән агымы буендагы (Юртау, Аккүл) туктаулыклар Чулман буе культурасына нисбәтле. Чулман тамагы культурасындагы чакматаш индустриясенә караганда пластиналарны кысу ысулы б-н эшләү югарырак үсешкә ирешә. Ләкин Чулман буе культурасының кораллар җыелмасы бертөрлерәк булган. Төрле чакматаш һәм сөяк кораллар табылган, Ык елгасының түбән агымы буенда Минзәлә р-ны Дәвек авылы янындагы М. дәвере туктаулыгы бу яктан аерылып тора. Ашыт елгасының түбән агымы буенда Биектау р-ның Алан Бәксәр, Кече Битаман, Бикнарат авыллары янындагы туктаулыклар, Зөя елгасының урта агымы буенда Апас р-ның Кабык Күпер авылы янындагы торулык соңгы М. чорына (фаразланганча, б.э.к. 6 нчы меңьеллык) карый. М. дәверенең таштан эшләнгән әйберләренә кечерәк очлыклы пластиналар эшләгәндә микропластиналар ясау ысулы куллану, ш.у. неолит дәверендә киң таралган шомартылган өслекле кискеч кораллар хас.

*Әд.:* К о с м е н к о М.Г. Мезолит Среднего Поволжья // Краткие сообщения Ин-та археологии. 1977. Вып. 149. Памятники эпохи мезолита; ш у л у к. О некоторых мезолитических памятниках Икско-Бельского междуречья // Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; Г а л и м о в а М.Ш. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье реки Камы. М.-К., 2001; ш у л у к. Новые материалы по мезолиту Марийского края // Тверской археол. сборник. 2003. Вып. 5.

*М.Ш.Галимова.*

**МЕ́ЙЕН** Сергей Викторович (17.12.1935, Мәскәү, — 20.3.1987, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1972), проф. (1973). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1960), СССР ФАнең Геол. ин-тында (Мәскәү) эшли, лаб. мөдире (1972 дән). Хезмәтләре Урал алды, Урта Идел буе (ш.и. Татарстан терр-ясе) палеозой утырмалары палеоботаникасына, биостратиграфия, эволюция теориясенә, палеонтологиядә электрон-хисаплау машиналары куллануга карый. СССР Дәүләт бүләге палеоботаника буенча монографиясе өчен бирелә (1989).

Х е з м.: Основы палеоботаники. М., 1987.

**МЕ́ЙЕР** Дмитрий Иванович (1.9.1819, С.-Петербург — 18.1.1856, шунда ук), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1848), коллегия

советнигы (1853). Баш пед. ин-тын тәмамлый (С.-Петербург, 1841). 1844–55 елларда Казан ун-тында: гражданлык законнары кафедрасында адъюнкт (1848), 1848–52 дә экстраординар проф., 1852 дән ординар проф; бер үк вакытта, 1853 тән, юридик ф-т деканы. 1855 тән Петербург ун-ты һәм Хокук белеме уч-щесе ординар профессоры. Казанда «юридик клиника» — хокук мәсьәләләре буенча түләүсез консультация оештыра. Катлауларга нисбәттә һәм дин тотудагы төрлелеккә нигезләнгән хокукый тигезсезлеккә һәм крепостнойлыкка каршы чыгышлары б-н танылa. Л.Н.Толстойның карашлары формалашуга зур йогынты ясый, Толстой үзенең көндәлекләрендә М. хакында җылы фикерләр язып калдыра. Казан цивилистика мәктәбенә нигез сала. Россиядә халыкара хосусый хокук фәнен нигезләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре гражданлык, вексельләр, сәүдә хокукын өйрәнүгә карый. «Борынгы рус залог хокукы» («Древнее русское право залога», 1848) монографиясендә Борынгы Русьтагы кредит бирү шартларын һәм кредит мөнәсәбәтләре формаларын ачып бирә. «Юридик уйдырма һәм фаразлар, астыртын һәм ясалма гамәлләр турында» («О юридических вымыслах и предположениях, о скрытных и притворных действиях», 1854) хезмәтендә юридик фикцияләр һәм презумпцияләр проблемасын тирәнтен тикшерә. «Одессаның сәүдә көнкүрешенә карата юридик тикшеренүләр» («Юридические исследования относительно торгового быта Одессы», 1855) әсәре җирле сәүдә тәртипләре һәм корабльләрне иминиятләштерү буенча килешүләр барлыкка килүне өйрәнүгә багышлана. Университетларда гражданлык хокукын укытуга зур әһәмият бирә, әлеге мәсьәлә турында махсус хезмәт яза. «Рус гражданлык хокукы» лекцияләр курсында («Русское гражданское право», 1–2 бүлек, 1858–59; 10 басма, 1915) фәннең әлеге тармагына системалы тулы тасвирлама бирә, юридик анализның нечкәлекләрен ача. Милек, гаилә хокукы турында мөстәкыйль фәннәрне аерып чыгару хакында фикер әйтә.

Х е з м.: О значении практики в системе современного юридического образования. К., 1855; Очерк русского вексельного права. К., 1857; Общая теория гражданских обязательств по русскому праву. СПб., 1861.

*Әд.:* П е к а р с к и й П.П. Студенческие воспоминания о Д.И.Мейере, профессоре Казанского университета // Братчина. СПб., 1859. Ч. 1; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Л а н д к о ф С.А. Д.И.Мейер (1819–1856) // Уч.зап. Казан. ун-та. 1954. Т. 114, кн. 9; П е в з н е р Г.С. Д.И.Мейер — выдающийся русский цивилист // Уч.зап. Казан. ун-та 1956. Т. 116, кн. 13.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕ́ЙЕР** Эдуард Андреевич (Карлович) (20.2.1859, С.-Петербург — июнь 1928, Краснодар ш.), зоолог, зоол. д-ры (1898). Петербург ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1881), шунда ук эшли. 1883–88 елларда Италиядә Неаполь зоол. станциясендә. 1889 дан Варшава, 1891 дән Казан ун-тларында, проф. (1902 дән). 1913 тән Югары хатын-кызлар курсларында (Тифлис ш.), 1918 дән Кырым ун-тында (Симферополь ш.), 1927 дән Краснодар пед. ин-тында. Хезмәтләре диңгез фаунасын, боҗралы суалчаннарны өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Организация трубчатых червей семейства Serpulidae и Hermellidae как результат их сидячего образа жизни // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1893. Т. 30, вып. 1; Исследования над развитием кольчатых червей // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1897. Т. 31, вып. 4; Можно ли объяснить возникновение вторичной полости тела на основании экскреторной деятельности животных? // Тр. Санкт-Петербургского об-ва естествоиспытателей. 1900. Т. 30, вып. 1.

*В.И.Гаранин.*

**МЕ́ЙКЛЯР** Павел Владимирович (11.4.1914, Одесса ш. — 1998, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1963), проф. (1965). 1939 елда Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң, Оптика ин-тында эшли (Ленинград ш.). 1951 дән Пермь пед. ин-тының гомуми физика каф. мөдире, 1955 тән Пермь ун-тының эксперим. физика каф. мөдире. 1957–90 да «Тасма» ҖБнең Казан химия-фотография сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тында, фотография процесслары лаб-ясе мөдире (1957–84). Бер үк вакытта, 1957–71 дә, Казан ун-тында, гомуми физика каф. мөдире (1965–67). Хезмәтләре фотография процесслары физикасына карый. М. фотография катламнары люминесценциясе һәм фотоүткәрүчәнлеге алымы ярдәмендә яшерен фотографик сурәт барлыкка килү механизмын ачыклый. Электр кыры тәэсирендә фотокатламнарның сизгерлеген арттыру алымын эшли. Астрономия, фототелеграфия өчен фотография тасмалары эшли һәм җитештерүгә кертә. СССР МС бүләге лауреаты (1950). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физические процессы при образовании скрытого фотографического изображения. М., 1972.

*Р.Г.Усманов.*

**МЕ́ЙКОВ** Оттомар Фридрихович (7.1.1823, Лифляндия губ. Днепр ш. — 5.2.1894, шунда ук), хокук белгече, хокук д-ры (1850), яшерен советник (1883). Мещаннар катлавыннан. Дерпт ун-тын тәмамлый (1845). 1847–51 елларда Юстиция министрлыгында бүлек башлыгы ярдәмчесе, 1851–55 тә Сенатның 4 нче департаменты секретаре (С.-Петербург). 1855–58 дә Казан ун-тының Рим хокукы кафедрасында экстраординар проф. 1858–92 дә Дерпт ун-тында: Рим һәм герман хокукы кафедралары, гомуми хокук белеме (1865 кә кадәр), Рим хокукы (1865–85, 1887–92) кафедралары ординар профессоры; 1872–76 да юридик ф-т деканы, 1876–81, 1890–92 дә ректор. Җирле законнарны кодлаштыруда, Балтыйк буе илләрендә 1864 елгы Мәхкәмә реформасын уздыруда катнаша. Хезмәтләре Рим хосусый хокукы тарихы һәм догмасын, гомуми гражданлык суды процессын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Die Diction der romischen Brautgabe. Дерпт, 1850; Grundriss des Pandektenrechts. Дерпт, 1866; Grundriss der Institutionen des romischen Rechts. Дерпт, 1880; Imperatoris Justiniani institutiones. Дерпт, 1887.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Юрьевского, бывшего Дерптского, ун-та (1802–1902). Юрьев, 1902. Ч. 1; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕ́ЙМАН** Наум Натанович (Нохим Санелевич) (28.4.1912, Волынь губ. Базар Овручский өязе — 31.3.2001, Израиль), математик, физик-теоретик, физика-матем. фән. д-ры (1937), проф. (1939). Н.Г.*Чеботарёв* шәкерте. 1932 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: алгебра кафедрасында (1932–34), Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1934–47). 1947–75 тә Мәскәүдә: Физик проблемалар ин-тында (1954 кә кадәр), СССР ФАнең Теоретик һәм эксперим. физика ин-тында (1954 тән). Хезмәтләре реаль үзгәрешленең функцияләре теориясенә, аерым чыгарылмаларның дифференциаль тигезләмәләренә, якынча һәм санлы исәпләү алымнарына, теоретик физикага карый. Төп хезмәтләре бөтен (санлы) функцияләрне — нульләрнең бүленеше, бөтен һәм аналитик функцияләрне чагыштыру мәсьәләләрен өйрәнү б-н бәйле. М. дифференциаль тигезләмәләр системаларын, аерым алганда, сызыкча параболик тигезләмәләр системаларын чишүдә рәшәткәләр алымын куллана. Рәшәткәләр алымында тотрыклылыкны һәм җыелучанлыкны өйрәнү юлларын тәкъдим итә, матем. физика һәм гидродинамиканың нәсызыкча мәсьәләләрен чишү нәтиҗәләрен ала (Л.Д.Ландау б-н берлектә). СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1953). Тель-Авив ун-тының шәрәфле профессоры (1989, Израиль).

Х е з м.: Проблема Рауса–Гурвица для полиномов и целых функций. М.–Л., 1949 (автордаш); Принцип причинности и асимптотическое поведение амплитуды рассеяния // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1964. Т. 47, вып. 5.

*Әд.:* Математика в СССР за сорок лет. 1917–57. Т. 1. Обзорные статьи. М., 1959.

**МЕ́ЙСНЕР** Валериан Иванович (20.6.1879, Саратов ш. — 1938), зоолог, ихтиолог, балык хуҗалыгын оештыручы. Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1902), шунда ук зоол. кафедрасында (1911 елга кадәр) эшли: карачкы ясаучы (таксидермист), Зоол. музеенда саклаучы хезмәткәр. Бер үк вакытта (1906 дан) Идел буе биол. станциясе б-н җитәкчелек итә. 1911–14 тә Тула, бер үк вакытта С.-Петербург балыкчылык һәм диңгез промыселлары буенча җир һәм дәүләт милке идарәсендә өлкән белгеч. Окт. рев-циясеннән соң (1930 га кадәр) Балык хуҗалыгы фәнни-тикшеренү ин-тының (Мәскәү) 1 нче директоры, бер үк вакытта Баш балыкчылык идарәсендә башлык, соңрак — СССР балык хуҗалыгының 1 нче халык комиссары. Идел дельтасын, Каспий диңгезен һ.б.ны өйрәнү буенча оештырылган күп кенә экспедицияләр җитәкчесе. Төрекмәнстан балык хуҗалыгы станциясен оештыручы (1928). Хезмәтләре музей эшенә, балык үрчетү һәм балык хуҗалыгы буенча укыту-методик ярдәмлекләр эшләүгә карый. Казан ун-ты Зоол. музееның беренче балыклар каталогы (1909) авторы.

Х е з м.: Очерк зимней фауны озера Кабана // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1904. Т. 39, вып. 3; Систематический каталог позвоночных животных зоологического музея Императорского Казанского университета. Ч. 4. Pisces. К., 1907; Искусственное рыборазведение, его смысл, значение для человека и приёмы. П., 1920; Промысловая ихтиология. М.–Л., 1933.

*В.И.Гаранин.*

**МЕЛИОРА́ЦИЯ** (латин. melioratio — яхшырту), җирләрне а.х.нда файдалану өчен киптерү, сугару, туфракның структурасын үзгәртү (юдыру, гипс б-н ашлау, известьләү һ.б.), сөрү мәйданын тирәнәйтү, махсус үсемлекләр (сидератлар), ышыклаучы урман утыртмалары утырту һ.б. ысуллар б-н тамырдан яхшыртуга юнәлтелгән оештыру-хуҗалык һәм техник чаралар җыелмасы. А.х. файдалану җирләренең продуктлылыгын арттыру һәм мәйданнарын киңәйтү өчен аларны яхшырту б-н халык элекке заманнардан ук шөгыльләнгән. Россиядә бу чаралар «кырларны төзәтү», «җирләрне чистарту», «җирләрне яхшырту» дип аталган. М. төшенчәсенең мәгънәсе киң, табигый байлыклардан файдалану елдан-ел интенсивлаша барган саен, аның эчтәлеге тулылана бара. М.нең барлык төрләренә агротехник алымнар өстәлә, алар мелиорацияләнүче җирләрне а.х.нда файдалану һәм культуралаштыру эшләре составына керә. Совет хакимияте елларында М.не оештыруга дәүләт зур әһәмият бирә, эшләрнең күләме сизелерлек арта, фән һәм техника казанышларыннан файдалану шактый үсә. Бу тармакны гамәлгә кертү өчен урыннарда махсус идарә органнары булдырыла. Татарстанда 1922 елда ТАССР Җир эшләре халык комис-ты каршында Җир төзү һәм мелиорация идарәсе оештырыла (1961 дә ТАССР МС каршындагы Су хуҗалыгы идарәсе итеп үзгәртелә), аның карамагында «Мелиоводстрой» конторасы оештырыла (1962 дә «Водстрой» төзү-монтаж идарәсе итеп үзгәртелә, 1965 тә ТАССР МС каршында Мелиорация һәм су хуҗалыгы идарәсе, 1966 да «Мелиоводхоз» тресты, 1968 дә *Татарстан АССР Мелиорация һәм су хуҗалыгы министрлыгы* оештырыла, 1970 тә — «Мелиоводстрой» тресты, 1989 да «Татводмелиорация» төзелеш-эксплуатация җитештерү берләшмәсе (1993 тән «Татмелиорация» ЖБ, 1996 дан «Татмелиорация» траст компаниясе» АҖ). ТРда М. төрле юнәлешләрдә алып барыла. *Гидротехник мелиорация* киң үсеш ала, ул сугару, плотина, сусаклагычлар, киптерү каналлары төзү юллары б-н җирләрнең су режимын тамырдан үзгәртүне тәэмин итә. Химик М. гамәлгә ашырыла, ул, известь (к. *Туфракны известьләү*), гипс, фосфорит һәм доломит оннары, туфрак структурасын барлыкка китерүче сополимер һ.б. мелиорантлар кертеп, туфракны яхшырта. Культуралы-техник М. яткын җирләрне үзләштерү һәм яхшырту, аларны культуралы басуларга әйләндерү эшләре комплексын үз эченә ала. Туфрак саклау М.сенә җирләрне юылудан, су юып ашалудан саклау чаралары керә. Туфрак саклаулы игенчелектә эрозиягә каршы комплекслы эшләр үрнәге булып Биектау р-нының «Чулпан» күмәк хуҗалыгында кулланылучы система санала, анда 6 мең *га* мәйданда эрозиягә чыдам, продукция потенциалы югары булган игенчелек алып барыла (к. *Адаптив агроландшафтлы игенчелек системасы*). *Агроурман мелиорациясе* урман полосалары утырту һ.б. агротехник чаралар үткәрә, әлеге чаралар туфрак һәм һава корылыгы, коры җилләр, туфрак эрозиясе һәм тышкы тирәлекнең башка уңайсыз шартлары б-н көрәшкә юнәлтелә. Фитомелиорация — мелиоратив культуралар (борчак, вика, донник, люпин, рапс һ.б.), болын мелиорациясе күпьеллык үләннәр чәчү юлы б-н гамәлгә ашырыла. Биомелиорация туфрак структурасын файдалы микроорганизмнар, яңгыр суалчаннары кертеп яхшыртудан гыйбарәт. Хәзерге вакытта ТРда «2006–2013 елларда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә җирләрне тамырдан яхшырту буенча мелиорация эшләре» һәм «2012–2014 елларда Татарстан Респ-касында гидротехник корылмаларны яңадан торгызу буенча мелиорация эшләре» максатчан респ-ка программалары гамәлгә ашырыла. М.нең төрле төрләре б-н ТРда ш.у. «Татмелиорация идарәсе» Федератив бюджет дәүләт учреждениесе, «Татагрохим» АҖ, «Татагрохимсервис» АҖ һ.б. шөгыльләнә.

*Әд.:* К о л п а к о в В.В., С у х а р е в И.П. Сельскохозяйственные мелиорации. М., 1988.

*Ф.Н.Сафиуллин, Р.М.Низамов.*


**МЕЛИ́ССА** (Melissa), иренчәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 3–4 төре билгеле, Евразиядә киң таралган. Россиядә бер төре — дару М.сы яисә лимон исле бөтнек үсә. Татарстан терр-ясендә бакча участокларында үстерелә. Уртача 60–80 *см* биеклектәге үсемлек, туры, 4 кырлы, тармакланган сабаклы, үрмәле ян үрентеләре һәм җир асты тамырчалары бар. Яфраклары эре, саплы, йомыркасыман, каяу-тешәүле. Сабакларда капма-каршы урнашканнар. Сабаклары һәм яфракларының аскы өлеше бераз төкле. Дару М.сы, җәй башыннан алып, озак вакытка чәчәк ата. Чәчәкләре алсу, ак яисә саргылт, ике җенесле; өске яфраклар куентыгында урнашалар һәм ялган такыя барлыкка китерәләр. Җимеше 4 чикләвекчектән тора. Бу үсемлектә лимон исе бик көчле, аңарда эфир майлары, С витамины, каротин, дуплау матдәләре, сумала бар. М.ны орлыктан һәм үсемлекне аерып утырту ысулы б-н үрчетәләр. Орлыкларны иртә язда салкын парникларга чәчәләр. Аерып утыртканда 3–5 еллык үсемлекне һәрберсендә 3–5 бөре булган өлешләргә бүләләр. М. үстергәндә туфракны йомшартып, чүпләрдән чистартып, өстәмә сыек ашлама кертеп торалар. Яфраклары һәм үсентеләре бер сезонга 2–3 тапкыр җыела. Дару М.сы медицинада тынычландыра, авыртуны баса, азык эшкәртүне яхшырта торган дару буларак кулланыла. Яңа өлгергән һәм киптерелгән яфраклары кулинария, парфюмерия һәм косметикада файдаланыла.



Мелисса.

*Л.Д.Полякова.*

**«МЕЛИ́ТА»**, Казандагы мех сәүдә-сәнәгать пр-тиесе, РФдә иң эреләрдән санала. Эшләүчеләр саны — 1 мең чамасы кеше (2013). 1928 елда Казанның 1 нче мех ф-касы буларак нигезләнә. Соңрак чимал эшкәртү-ману, тире иләү, бүрек тегү ф-калары төзелә, 1930 да алар мех ф-касы б-н СССР Тышкы сәүдә халык комис-ты Мех синдикатының Казан мех комб-тына берләштерелә. Хезмәт коллективы Яңа Татар бистәсенең мехчы һөнәрчеләреннән формалаша. Беренче продукция сарык, йорт куяны, мәче, эт, куян һәм йомран тиреләреннән затлы мехларга охшатып манылган мех ярымфабрикатыннан гыйбарәт була, ул халыкара аукционнарда сатыла. Түбән сыйфатлы тиреләрдән бүрекләр тегелә. Комб-тта, илдә беренче буларак, мехны берьюлы эшкәртү һәм ману ысулы эшләнә һәм гамәлгә кертелә (1932), ул эшкәртү циклын һәм эшләүчеләр санын шактый кыскартырга мөмкинлек бирә. Комб-т әйдәп баручы механикалаштырылган мех пр-тиесенә әверелә, 1930 елларның 2 нче яртысында СССРдагы тулай мех продукциясенең 50% тан артыгын җитештерә. Бөек Ватан сугышы чорында, җылы киемнәр һәм парашют-десант кирәк-яраклары эшләп чыгаруны үзләштереп, пр-тие фронт өчен эшләнмәләр җитештерүгә күчә; беренче тапкыр Казан «Спартак» күн аяк киемнәре комб-ты б-н берлектә сәнә-



«Мелита» мех сәүдә-сәнәгать предприятиесе.
1. Тегү цехы; 2. Продукция үрнәкләре.

гый нигездә унталар һәм мех итекләр җитештерү оештырыла (1941). Дәүләт йөкләмәләрен вакытында һәм сыйфатлы үтәгәне өчен, комб-т Ленин орденына лаек була (1944). Алдагы елларда, СССР мех сәнәгатендә әйдәп баручы буларак, комб-т күп яклап аның үсеш профилен билгеләде. Илнең шундый ук пр-тиеләрендә комб-тта эшләнгән һәм беренче тапкыр гамәлгә кертелгән казанышлар: эшләнмәләрнең сыйфатын һәм тышкы рәвешен күпкә яхшырткан термохимик технология кулланып, сарык тиресен нәфисләндерү (СССР Дәүләт бүләге, 1951); тигезләү, иләү һәм охшатып ману алымнары; тиреләрне маркалау автоматлары киң тарала. 1963 тә комб-т җирлегендә Казанда, Зөядә һәм Кукмарада урнашкан 9 фабрикадан Татарстан мех берләшмәсе оештырыла (1972 дән — Х.Ямашев исем.). 1960–70 елларда респ-када җәнлекчелекнең интенсив үсеше б-н бергә берләшмәдә затлы мехлар (көмешсыман кара төлке, чәшке, ак төлке), ш.у. диңгез җәнлеге тиреләрен эшкәртү үзләштерелә. Пр-тие белгечләре Г.З.*Афанасьев* җитәкчелегендә читлектә асралган җәнлекләрдән табигый сыйфатлы мех алу технологияләрен эшлиләр. Җитештерү күләме арта, массачыл ихтыяҗга ия эшләнмәләрнең (баш киемнәре, пальто, якалар һ.б.) ассортименты киңәя. Аларның зур өлеше һәм мех ярымфабрикатының иң яхшы үрнәкләре халыкара аукционнарда сатыла. 1990 еллар башына кадәр продукциянең төп өлешен сарык тиресеннән махсус тегелгән эшләнмәләр тәшкил итә. 1992 дә хәзерге исемдәге Татарстан мех сәүдә-сәнәгать АҖ оештырыла (2010 нан — ҖЧҖ). Хәзерге вакытта аның составына кергән ф-каларда төрле тиреләр (сарык тиресе, каракүл, чәшке, көзән, ак төлке, котик, эт, бүре һ.б.) эшкәртелә, массакүләм ихтыяҗга исәпләнгән киемнәр (туннар, пальто, якалар, баш киемнәре, оекләр, оекбашлар һ.б.), махсус кием (куртка, ярымпальто, бияләй, мех итекләр, унталар), автомобиль утыргычлары тышлыклары тегелә, юылган йон, аяк киемнәре өчен сарык тиресеннән ярымфабрикат чыгарыла. 2008 дә заманча ману җиһазлары урнаштырыла, көннән әйберләр тегү үзләштерелә. 2011 дә эшләнмәләрнең төп төрләре түбәндәге күләмдә җитештерелә (мең данә): пальто, ярымпальто, хатын-кызлар һәм ир-атлар курткалары — 11,9; балалар пальтолары, ярымпальтолары һәм курткалары — 0,3; баш киемнәре — 41,5. Россиядә чыгарыла торган барлык мех эшләнмәләрнең 25% ы «М.» өлешенә туры килә. «М.» конструкторлары Россиянең танылган модельеры, Россия Сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы И.В.Крутикова б-н хезмәттәшлектә продукция ассортиментын даими рәвештә яңарталар, мех киемнәрнең эксклюзив коллекцияләрен эшлиләр. Җитештерүдә Россия, ГФР, Италия, Швейцария мех фирмаларының химик продуктлары һәм иң яңа технологияләре кулланыла. «М.» сәүдә йорты продукциясе үзенең фирма салоннары челтәре, РФ шәһәрләрендәге, ш.и. Мәскәү, С.-Петербург һәм Новосибирскидагы вәкиллекләре, РФ һәм Белоруссия Респ-касының 17 шәһәрен колачлаган дилерлар челтәре аша сата; РФнең 30 дан артык шәһәрендә күчмә сәүдә оештырыла. Пр-тие продукциясе 12 алтын, 16 көмеш, 5 бронза медаль; Мәскәү, Лейпциг, Париж, Лондон, Нью-Йорк, Копенгаген, Франкфурт-на-Майне, Прага, Алма-Ата, Улан-Батор халыкара күргәзмәләре, ярминкәләре, конгресслары һәм аукционнарының 14 дипломы б-н билгеләп үтелә. Халыкара сәнәгать күргәзмәсендә (Брюссель, 1958) төрле имитацияләрдә нәфисләндерелгән сарык тиресе үрнәкләре — 1 нче алтын медальгә, махсус эшкәртелгән сарык тиресеннән тегелгән балалар пальтосы «Гран-при»га лаек була. Башка халыкара бүләкләр арасында көндәшлеккә сәләтле һәм сыйфатлы продукция өчен — «Сыйфат өчен алтын йолдыз» (1993), «Алтын глобус» (1994), социаль-икътисади кризис шартларында икътисади яшәеш һәм үсеш өчен «Бирмингем факелы» (1996) бар. Сарык тиресен һәм кондыз мехын эшкәртүдә уникаль технологияне гамәлгә керткәне өчен 2005 тә пр-тие РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләген ала. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. Сов. Союзы Герое — 3, Соц. Хезмәт Герое — 1, СССР Дәүләт бүләге лауреаты — 6, РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты — 2 кеше; Ленин ордены — 15, Октябрь Революциясе ордены — 3, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 61, Халыклар дуслыгы ордены — 2, «Почёт билгесе» ордены — 86, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнары 41 кешегә бирелә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — И.М.Полонский (1930–31), А.М.Манько (1931–32), А.Г.Барышников (1933–34, 1937–40), М.Б.Эйдельнант (1940–43), Ю.С.*Комиссаренко* (1943–61, 1963–71), Р.Х.Халитов (1961–63), Н.В.Невзоров (1971–74), Н.С.Рәхимов (1974–88), А.М.*Пахомов* (1988–2002), В.А.Васильев (2002–03, 2003 тән директорлар советы рәисе), Р.Х.Гомәров (2003 тән).

*Әд.:* Сказ о Казанских меховщиках. К., 1974; Комиссаренко Ю.С. Овчинка стоит выделки. К., 1978.

*С.Г.Белов.*

**МЕЛКУМЯ́НЦ** Герман Тигранович (5.5.1932, хәзерге Вологда өлкәсенең Кубено-Озёрский р-ны Карабаново а.), галим агроном, а.х. производствосын оештыручы, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Куйбышев р-ны а.х. идарәсе башлыгы (бүленеп, 1967–71); Алабуга р-нының «Волна революции» һәм «Алабуга» с-зларында баш агроном (1962–67) һәм директор (1971–77, 1977–86) булып эшли. 1986–87 елларда Алабуга р-ны һәм Алабуга шәһәрендә район башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1987–92 дә ит комб-ты директоры, 1992–93 тә хакимият башлыгы. 1995–2000 дә ТР Халык депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр; ТАССР һәм ТР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Алабуга шәһәренең мактаулы гражданы (1986).

*И.Н.Афанасьев.*

**МЕЛОДРА́МА** (грек. melos — җыр һәм drama — хәрәкәт), 1) драматургия жанры; үткен интригалы, гадәттән тыш эмоциональ, яхшылык б-н явызлык кискен каршы куелган пьеса. Анда катнашучылар катлаулы язмышлар, гадәттән тыш көчле хисләр б-н аерылып торалар, чынга охшамаган четерекле хәлләргә тап булалар. Язмыш сынауларына карамастан, уңай геройлар һәрвакыт җиңүгә ирешә. М.да музыка киң кулланыла (соңрак аның роле сизелерлек кими төшә). Франциядә 1790 еллар ахырында, Россиядә 1820 еллар ахырында барлыкка килә. Татар драматургиясендә М. жанрына, беренчеләрдән булып, М.Фәйзи мөрәҗәгать итә. Аның «Кызганыч» романтик М.сында (1914) гашыйк геройлар гадәттән тыш хәлләргә юлыгалар. Алар бер-берсен бик яраталар, милләткә хезмәт итү теләге б-н яшиләр. Мәхәббәтнең тирәнлеге, трагик коллизияләр, сагышлы җыр-музыка тамашачыга эмоциональ яктан көчле тәэсир ясый. М.Фәйзинең «Тәкъдирнең шаяруы» (1913), «Асылъяр» (1920), «Адашкан күңел» (1923), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» (1926) һ.б. пьесалары М. жанрына карый. 1960–80 елларда М. жанрының җанлануы Х.Вахит, Ш.Хөсәенов, Т.Миңнуллин, И.Юзеев һ.б. иҗатында күзәтелә. 20 йөз ахыры — 21 йөз башы татар драматургиясендә Р.Сәгъди («Сынган беләзек», 1997), И.Мәхмүтова («Син бит минем бергенәм», 1997), Т.Миңнуллин («Эзләдем, бәгърем, сине», 2001) һ.б. иҗатында үстерелә.

2) Катнашучыларның сөйләме (диалог һәм монолог) б-н кушылып бара торган муз.-драматик сәхнә әсәре. Европада 18 йөздә — 19 йөз башында киң тарала. Татар драматургиясендә беренче муз. пьеса — М.Фәйзинең «Галиябану» (1917) әсәре. Тора-бара андый әсәрләр муз. драмага карый башлый (К.Тинчуринның «Кандыр буе», 1932 һ.б.).

*Әд.:* Татар совет театры: Очерклар. К., 1975; Әхмәдуллин А. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. К., 1982; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*Ә.М.Закирҗанов.*

**МЕЛУ́ЗНИКОВ** Анатолий Александрович (2.4.1909, хәзер Иваново өлкәсенең Кинешма ш. — 5.11.1958, Казан), язучы. 1932 елдан Казанда яши. 1933 тән «Красная Татария» г-тасы редакциясендә, 1947 дән башка газеталарда, «Чаян» ж-лында эшли. Балалар өчен язылган «Без шулай яшибез» («Так мы живём», 1952), «Полкан белән Васька» («Полкан и Васька», 1952), «Кошлар, хайваннар һәм җәнлекләр хакында» («Про птиц, животных и зверей», 1959) шигъри җыентыклары, «Өч әкият» («Три сказки», 1957), «Мәсәлләр һәм фельетоннар» («Басни и фельетоны», 1958) китаплары авторы. Рус теленә К.Нәҗми, Г.Кутуй, Ә.Исхак, С.Баттал, Б.Рәхмәт, Җ.Тәрҗеманов, З.Нури, Н.Арсланов һ.б.ның шигырьләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша.

*Әд.:* Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**МЕ́ЛЬНИК** Александр Николаевич (21.8.1957, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1996), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). 1979 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тының (хәзер Казан тех-

ник ун-ты) сәнәгать икътисады һәм җитештерүне оештыру кафедрасында эшли. 1995 тән Казан энергетика ун-тының икътисад һәм җитештерүне оештыру каф. мөдире, 2001 дән проф. ТР ФАнең соц.-икътисади фәннәр бүлегендә икътисад буенча фәнни совет рәисе. Хезмәтләре базар мөнәсәбәтләренә күчү шартларында стратегик планлаштыру һәм пр-тиеләр эшчәнлеген реструктуризацияләү мәсьәләләренә, ТРның энергетика комплексын реформалаштыруга карый. М. тарафыннан реструктуризацияләүнең нәтиҗәлелеген икътисади бәяләүнең күпбаскычлы моделе, яңа техника, технологияләрне гамәлгә кертү һәм башка төрле капитал салу юнәлешләренең сайлап алынган вариантларын икътисади нигезләү алгоритмнары булдырыла.

Х е з м.: Стратегическое управление деятельностью предприятий в условиях развития рыночных отношений. К., 1995; Стратегическое планирование деятельности фирмы на этапе перехода к рыночным отношениям. СПб., 1996; Реструктуризация электроэнергетики в условиях становления рыночных отношений. К., 2004; Управление инвестиционной деятельностью фирмы. К., 2004; Экономическая оценка инвестиций. К., 2004.

**МЕ́ЛЬНИКОВ** Александр Михайлович (31.8.1908. Чистай ш. — 12.6.1972, Казан), геолог-нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950), геол.-минерал. фән. канд. (1964), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1964). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), СССР ФАнең Башкортстан экспедициясендә геол. партияләр башлыгы булып эшли. 1932 елдан Татгеолбюрода, 1937 дән «Востокнефть» трестында, 1939 дан «Сызраньнефть»тә, 1940 тан «Татнефтегазразведка»да, баш геолог (1944–70). М. Татарстан терр-ясе һәм аңа чиктәш төбәкләр өчен утырма тышлыкның стратиграфик шкаласын, тектоник схеманы, углеводородларны эзләү һәм тикшерү алымнарын, эзләү-разведкалау максатыннан бораулау эшләренең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча тәкъдимнәр эшләүдә катнаша. Нефть ятмаларының урнашу үзенчәлекләрен билгели. М. җитәкчелегендә Татарстан терр-ясендә 100 гә якын нефть чыганагы ачыла. Дәүләт бүләге Ромашкино нефть чыганагын ачкан өчен бирелә. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геологическое строение и нефтеносность ТАССР. К., 1948 (автордаш); Геология нефтяных и газовых месторождений Волго-Уральской нефтегазоносной провинции. М., 1970 (автордаш).

**МЕ́ЛЬНИКОВ** Леонид Николаевич (13.3.1947, Югары Ослан р-ны Печищи а.), спортчы (парашют спорты), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1976). Спорт б-н 1968 елда Казан аэроклубында (тренер О.Н.Рущупкин) шөгыльләнә башлый. Молдавия ССР (1973), СССР һава-десант гаскәрләре (1973), СССР һава һөҗүменә каршы гаскәрләр (1976, 1978, 1982–83), СССР Кораллы көчләре (1978), дуслык армияләре спорт клублары Кубоклары беренчелекләре (1977–78, команда беренчелегенә), РСФСР (1987, Ветераннар арасында һава акробатикасы буенча) чемпионы. Дус армияләр спорт клублары кубогына ярышларда медальләр ала (1977, көмеш — һава акробатикасы буенча, бронза — шәхси беренчелектә). М. һава акробатикасы һәм җиргә төгәл төшү буенча (көндезге һәм төнге) 8 меңнән артык сикереш ясый. Дөнья рекордсмены (1977, 1980). 1983–86 да Новосибирск шәһәре һава һөҗүменә каршы гаскәрләр командасы тренеры, 1986–98 дә ТР Эчке эшләр министрлыгы органнарында хезмәт итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МЕ́ЛЬНИКОВ** Николай Александрович (15.10.1872 — 1951), җәмәгать эшлеклесе. Нәселдән килгән дворян, проф. М.И.Мельниковның оныгы. Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен һәм Мәскәү а.х. ин-тының тулы булмаган курсын тәмамлый. Козьмодемьянск өязе земство җыены гласные (1898 елдан), идарә рәисе. Казан губернасы земство идарәсе рәисе. Казан губернасыннан 3 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907–12), октябристлар фракциясе әгъзасы, Казанга вакытыннан алда әйләнеп кайта. Беренче бөтендөнья сугышы елларында авыруларга, яралы сугышчыларга һәм фронтка җибәрелгәннәрнең гаиләләренә ярдәм итү буенча Земство берлегенең Казан губерна ком-ты рәисе (1914 тән), яралыларга ярдәм күрсәтүче җәмәгать оешмаларының берләштерелгән ком-ты рәисе. 1916 дан игенчелек министры каршындагы Совет әгъзасы, хәрәкәттәге армия өчен азык-төлек хәзерләү буенча баш вәкаләтле вәкил. Окт. рев-циясеннән соң Аклар хәрәкәтендә катнаша, А.В.Колчак хөкүмәтендә армия өчен азык-төлек хәзерләү буенча вәкил вазифасын башкара. Аклар армиясе җиңелгәннән соң, Харбинга (Кытай), 1920 еллар башында аннан Ле-Ман шәһәренә (Франция) китә. Париж янындагы Сент-Женевьев-де-Буа зиратында җирләнә.

Х е з м.: 19 лет на земской службе (1898–1916) // Звезда. 2002. № 7.

*Әд.:* С о л д а т о в Я.В. Казанское земство в период первой мировой войны: историко-политический анализ: Дис. ... К., 2004.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МЕ́ЛЬНИКОВ** Николай Михайлович (14.7.1840, Казан — 30.12.1900, шунда ук), зоолог, зоол. д-ры (1869), атказ. проф. (1894). Э.А.*Эверсман* шәкерте. Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1861). 1862–64 елларда чит илләрдә фәнни командировкада. 1865–97 дә Казан ун-тында, Зоол. музее мөдире (1871 дән). Физика-матем. ф-ты каршында физиол. кафедрасын оештыручыларның берсе. Бер үк вакытта Казан вет. ин-тында зоол. каф. (1882–1900), зоол. музее мөдире, аны исә Неаполь һ.б. зоол. станцияләрендә тупланган яңа экспонатлар б-н баета. Хезмәтләре гомуми зоологиягә, паразитология, энтомологиягә карый. 1873–75 тә Казан ун-ты каршында оешкан Табигыятьчеләр җәмгыятенең президенты һәм хакыйкый әгъзасы. Казан губернасы терр-ясендә очрый торган зарарлы бөҗәкләрне өйрәнү һәм аларга каршы көрәш оештыру максаты б-н 1880 елларда шушы җәмгыятьнең энтомология комиссиясен җитәкли.

Х е з м.: О саранче в Малмыжском уезде и о мерах к предупреждению её развития и распространения // Протоколы заседания Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те, 1879–80. К., 1880; О фауне восточного берега Каспийского моря и острова Челекена // Протоколы заседания Об-ва естествоиспытателей при Имп. Казан. ун-те, 1880–81. К., 1881.

*Әд.:* Н.М.Мельников // Казан. телеграф. 1901. 1 янв.; Материалы к истории ветеринарного образования в СССР // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та. М., 1956. Т. 63.

*В.И.Гаранин.*

**МЕ́ЛЬНИКОВ** (Мельников-Печерский) Павел Иванович (псевд. Андрей Печерский) (25.10.1818, Түбән Новгород ш. — 1.11.1883, Түбән Новгород губ. Ляхово а.), язучы. 1837 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1839 дан Түбән Новгородта яши, дини раскол тарихын өйрәнә. 1841 дә Мәгариф министрлыгы (С.-Петербург) каршындагы Археографик комиссиянең мөхбир әгъзасы исемен ала. 1845–50 дә «Нижегородские губернские ведомости» г-тасында эшли. 1847 дән Түбән Новгород генерал-губернаторы каршындагы махсус вазифалар үтәүче чиновник, 1850 дән Эчке эшләр министрлыгында эшли. Раскольникларның скитларын кансызлык б-н җимерүче булып танылa. 1866 да отставкага чыга, «Северная пчела» ж-лында эшли, «Московские ведомости» г-тасында, «Русский вестник» ж-лында языша. Тарихи хезмәтләр, тарихи-этнографик очерклар, хикәяләр авторы. Төп хезмәте — «Урманнарда» («В лесах») һәм «Тауларда» («На горах») (1871–74, 1875–81 дә «Русский вестник» ж-лында басылалар) дилогиясендә 19 йөз уртасы Идел аръягы һәм Тау ягы тормышы, кәсепләр, иске дин тарафдарларыннан сәүдәгәрләрнең көнкүреше, җирле халыкның гореф-гадәтләре, раскольниклар скитлары һәм яшерен секталар турында яза.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 8 *т.* М., 1976.

**МЕ́ЛЬНИКОВ** Фёдор Кузьмич (20.9.1918, Чистай ш. — 3.7.2001, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1953) тәмамлый. 1946 елда ВКП(б)ның Чистай шәһәр ком-тында лектор, 1947–50 дә бүлек мөдире урынбасары, 1950–54 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары. 1954–62 дә КПССның Зеленодольск шәһәр ком-тының 1 нче секретаре. 1963–64 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында: хакимият һәм сәүдә-финанс органнары бүлеге, 1964–66 да җиңел, азык-төлек сәнәгате һәм сәүдә бүлеге мөдире. 1966–78 дә ТАССР МС Рәисе урынбасары. Әлеге елларда, азык-төлек һәм сәнәгать товарлары, җиңел һәм азык-төлек сәнәгате өчен чимал кытлыгы хөкем сөргән шартларда, аның респ-ка икътисадына һәм халык тормышына тискәре тәэсирен бетерү буенча оператив чаралар күрә. 1955–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕ́ЛЬНИКОВ ЙОРТЫ́**, Чистайдагы архит-ра истәлеге. 1860–79 елларда модерн элементлары б-н эклектик формаларда сәүдә-



Чистай шәһәрендәге Мельников йорты. 1860–79.

гәр М.Л.Мельников өчен төзелә. Беренче катында кибетләр, контора һәм келәтләр булган ике катлы утар-йорт; икенче катта торак бүлмәләре урнашкан. «Г» хәрефе рәвешендәге йорт юллар кисешендәге почмакны чаң сыман гөмбәзле, купшы почмаклы ризалит б-н бизәп тора. Гөмбәзнең балконлы цилиндрик барабанының очы барокко стилендәге бизәкләр б-н төгәлләнгән. Икенче һәм аттик катлардагы ярымтүгәрәк балконнар бинаның почмагына аерым төс биреп тора. Бинаның төрле күләмле ике канаты ризалитлар б-н тәмамланган. Сул яктагы кыскарак канат аттик каттагы ике пирамидалы яссы ризалит б-н ныгытылган. Шундый ук ризалит уң яктагы озын канатның аттик барабанлы гөмбәз астындагы ярымтүгәрәк ризалит б-н төгәлләнгән урта өлешенә урнашкан. Почмак ризалиты бинаның төп бизәге булып тора. Беренче каттагы кибет ишекләре ризалитлардан аерылып тора. Урам фасадларын бизәгәндә катлаулы ордерлы парлы ярымколонналар, төрле биеклектәге терәкләр б-н нытытылган кәрнизләр, модерн стилендәге тәрәзә йөзлекләре һ.б. кулланылган. 1988 гә кадәр бинада ВЛКСМның шәһәр ком-ты урнашкан була, хәзер биредә дәүләт учреждениеләре эшли.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МЕ́ЛЬНИЧНЫЙ** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 24 *км* төньяктарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 215 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1770 елларда Иске Торҗа һәм Иске Көшкәт авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Юбикименленка исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тегермән эшли. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Урта Көшкәт волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1795 тә — 11 ир-ат; 1859 да — 116, 1897 дә — 264, 1905 тә — 276, 1910 да — 309, 1920 дә — 295, 1926 да — 258, 1938 дә — 340, 1949 да — 252, 1958 дә — 213, 1970 тә — 190, 1979 да — 178, 1989 да — 184, 2002 дә — 216 кеше.

**МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЙЛА́Р**, тарихи вакыйгаларны, күренекле дәүләт, җәмәгать, фән, мәдәният, сәнгать эшлеклеләре турындагы истәлекләрне мәңгеләштерү максаты б-н мемориаль әйберләрне туплауны, саклау, өйрәнү һәм күргәзмәгә куюны тормышка ашыручы музейлар төркеме. Музей ниндидер вакыйга булган яки атаклы шәхес яшәгән, эшләгән истәлекле урыннарда яисә биналарда, аларны яңадан җиһазландырып (тулысынча яки өлешчә) оештырыла. 2013 елда ТРда М.м. саны — 22, шуларның 7 се Казанда, калганнары респ-ка авылларында һәм шәһәрләрендә урнашкан. М.м.ның 8 е ТРның Милли музее ф-лы статусына ия, 1 се «Казан» милли мәдәният үзәгенә карый. Оештырылу вакыты буенча Г.Р.*Державинның* шәһәр музеендагы (1895 тән, хәзер ТР Милли музее) мемориаль әйберләр комплексы иң беренчеләрдән санала. ТРдагы иң өлкән М.м. — *Ленин В.И. музей-йорты* (1937), *Горький А.М. әдәби-мемориаль музее* (1938), *Камал Шәриф музей-фатиры* (1950). М.м.ның күтәрелеше 1980–90 елларга туры килә, музейлар бигрәк тә әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре эшчәнлегеен күздә тотып төзелә. Кагыйдә буларак, тарихи-биографик һәм мемориаль-көнкүреш комплексларны эченә алган экспозицияләрдә авторлык принцибы өстенлек итә. Аларга күп мәгънәле эчтәлек һәм визуаль образлылык хас.

ТРдагы барлык М.м. үзләре урнашкан биналарның мемориальлеге һәм андагы әйберләр коллекциясе буенча аерып карала. Төп мемориаль җиһазлар б-н тулысынча сакланган мемориаль биналарда (йортларда) урнашкан М.м.: *Арбузовлар А.Е. һәм Б.А. музей-йорты*, Татар әдәбияты тарихы һәм Ш.Камалның мемориаль музей-фатиры, *Җиһанов Нәҗип музей-фатиры*. Шул чордагы әйберләр б-н тулыландырылган, өлешчә сакланган мемориаль җиһазлар б-н төп биналарда (йортларда) урнашкан М.м.: *Гашек Ярослав әдәби-мемориаль музее, Васильев Константин мемориаль музее, Маннур Шәйхи мемориаль музей-китапханәсе, Пастернак Борис мемориаль музее, Җәлил Муса музей-фатиры*. Интерьеры реконструкцияләнгән биналарда урнашкан һәм аерым мемориаль әйберләр коллекцияләре булган М.м.: Ленин В.И. музей-йорты, *Боратынский Е.А. әдәби музее, Дурова Н.А. музей-утары, Шишкин И.И. музей-йорты, Купала Янка музей-фатиры*. Мемориаль әйберләр комплексы тулысынча яисә өлешчә сакланган, сакланмаган мемориаль бина урынында күчермәсе торгызылган бинага урнашкан М.м.: Горький А.М. әдәби-мемориаль музее, *Җәлил Муса мемориаль музее, Насыйри Каюм музее, Туфан Хәсән музее, Фәйзи Мирхәйдәр музей-утары, Тукаевлар музей-йорты, Фәхретдин Ризаэтдин мемориаль музее*. ТРда бер яки берничә генә мемориаль әйбере булган, аерым шәхескә багышланган музейлар бар: *Тукай Габдулла әдәби музее, Тукай Габдулла музей-комплексы, Кайбицкая Галия музее, Мәрҗани Шиһабетдин музее, Яковлев И.Я. музее, Насыйри Каюм исемендәге архитектура-этнография комплексы, Исхакый Гаяз тарихи-мемориаль һәм этнография комплексы, Цветаева М.И. мемориаль комплексы*. Мемориаль әйберләргә ия, әмма мемориаль булмаган биналарда урнашкан музейлар: *Мәндиев М.С. музее, Хәким Сибгат мемориаль музее, Горький А.М. музее, Кариев Габдулла музее, Урманче Бакый музее һ.б. Арча әдәбият һәм сәнгать* музее, *Казан университеты тарихы музее, Казан химия мәктәбе музеенда* ш.у. мемориаль әйберләр комплексы бар. М.м.ны этник мәдәният традицияләре буенча да төркемнәргә аерырга мөмкин: 13 е татар мәдәнияте, 7 се рус мәдәнияте, 2 се башка милләт мәдәнияте эшлеклеләренә багышлана.

*Г.Г.Нуретдинова.*

**МЕМУАРЛА́Р** (франц. mémoires — истәлекләр), авторның замандашлары булган билгеле шәхесләр һәм үзе катнашкан яки күргән вакыйгалар турындагы истәлекләренә нигезләнеп язылган документаль әдәбиятның бер төре. М.ны түбәндәге үзенчәлекләр аерып тора: фактларга таяну (авторның үзе күргән-белгән реаль шәхесләр һәм вакыйгалар турында язуы), материалның ретроспективлыгы (күбесенчә үткән вакыйгалар турында языла, авторның тормышы һәм иҗатына нәтиҗә ясала). Татар әдәбиятында М.ның барлыкка килүе 20 йөз башына карый. Беренче мемуар итеп Р.Фәхретдиннең «*Асар*»ын атарга мөмкин. Сәяхәтнамә жанрында язылган әсәрләрдә М. элементларын табарга мөмкин; мәс., Р.Фәхретдиннең «Исмәгыйль сәяхәте», З.Бигиевнең «Мавәраәннәһердә сәяхәт» («Ике елга арасында сәяхәт»), Ф.Кәриминең «Истанбул мәктүбләре». 1930 елларда Г.Камал «Минем персональный пенсионер булуым тарихы» һәм «Яза башлавым тарихы» әсәрләрен яза. Татар мемуаристикасының чәчәк аткан чоры сугыштан соңгы елларга туры килә: М.Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», «Хатирәләр урманы», Ф.Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Р.Ишморатның «Сайрасын тургайлар», «Гомер сукмаклары», А.Расихның «Яшьлек эзләрем», Х.Мөҗәйнең «Сугыш язмалары» һ.б. Фактларның төгәллеге, дөреслеге буенча М. документлар һәм фәнни язмалардан калыша, ләкин субъективлык элементлары һәм фактларның тулы булмавы авторның көчле индивидуаль «мин»е, сүз остасының тасвирланган вакыйгаларга карата мөнәсәбәте б-н тулылана. Ә.Еникинең «Соңгы китабы» моңа мисал булып тора. Аерым очракларда М.ны автобиографик роман яки повестьтан аеру да кыен. Ләкин М.ның чикләре билгесез тоелса да, аны жанр буларак авторның ниятеннән чыгып билгеләп була. Мәс., М.Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» китабын, М.га шактый якын булса да, автобиографик повесть дип санарга кирәк, чөнки автор өчен иң мөһиме — үз тормышын хикәяләү түгел, ә үз буынының күмәк портретын иҗат итү. Автобиографик повестьлар рәтенә ш.у. Г.Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» әсәрен кертергә мөмкин. М. матур әдәбият, публицистика һәм фәнни әдәбият киселешендә тора. Татар әдәбияты һәм мәдәнияте эшлеклеләре (Г.Тукай, М.Җәлил, Һ.Такташ, С.Сәйдәшев һ.б.) турындагы күптөрле истәлекләр ба-

рыннан да элек аларда китерелгән фактларның яңалыгы һәм әһәмияте б-н аерылып торалар, шуңа күрә андый китаплар фәнни-публицистик әдәбиятка карый. М. жанрында күп кенә башка авторлар да яза (Ш.Галиев, Б.Камалов, Ә.Галиев, Ш.Маннапов, Р.Батулла һ.б.).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

*Р.Ә.Мостафин.*

**МЕ́НГДЕН** фон (Фамендин) Иван Алексеевич (1679, Мәскәү — 18.11.1731, Әстерхан ш.), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1726), яшерен советник (1730). Дворяннар нәселеннән. 1695 елдан хәрби хезмәттә. 1700–21 дәге Төньяк сугышында катнаша. 1722 дән лашманнар эшләренә күзәтчелек итә, Казан һәм Әстерхан губерналарында җан исәбен алу буенча 1 нче ревизия нәтиҗәләрен тикшерү б-н шөгыльләнә. Җирле халык санын алу вакытында законга каршы кылынган гамәлләрне ача. 1725 тән Казан, 1726 дан Әстерхан губернаторы. Губерна халкына һәм калмыкларга карата күзәтчелекне арттырып, башкортларның баш күтәрүен булдырмаска тырыша. Әстерханда үләт чире эпидемиясе чорында (1728), карантин постлары һәм кизүләре оештырып, Идел буенда авыру таралуга чик куя.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕ́НДЕ** Герхард фон (von Mende) (25.12.1904, Рига ш. — 16.12.1963, Дюссельдорф, ГФР), немец тарихчысы, тюрколог, проф. (1936). 1919 елда әтисен большевиклар атып үтергәннән соң, Германиягә күчеп китә. 1923–27 дә Любек шәһәрендә эшмәкәр. Берлин ун-тын тәмамлый. 1933 тә «Советлар Союзында колонизация тарихыннан очерклар» («Очерки по истории колонизации в Советском Союзе») темасына магистрлык диссертациясе яклый. 1934–36 да академик алмашулар хезмәткәре булып эшли.

1935 тә «Россия төркиләренең милли көрәше. Советлар Союзында милли сәясәтне өйрәнү» («Национальная борьба российских тюрков. Исследование национальной политики в Советском Союзе») темасына докторлык диссертациясе яклый. Ул Көнбатыш тарих белемендә СССРдагы милли мәсьәләләргә, Россия империясе һәм Советлар Союзы шартларында төрки халыкларның милли азатлык хәрәкәте тарихы һәм үсешенә багышланган беренче хезмәт була. М. Германия б-н төрки дөнья арасында хезмәттәшлек урнаштыру мөмкин, дип саный. 1936 дан Берлинда Чит илләрне өйрәнү югары мәктәбе каршында оешкан Россияне өйрәнү ин-тында (Russland Institut). 1937 дә институт каршында төрки-татар китапханәсе оештыра. 1940 тан Берлин ун-тында (төрки-татар халыклары телләрен һәм яшәгән илләрен өйрәнү каф. мөдире), 1941 дән, бер үк вакытта, Познань ун-тында. «Шәрекъ фәне бурычлары» конференциясендә (Берлин, март 1942) катнашып, «Шәрекъ халыклары проблемалары» темасына доклад б-н чыгыш ясый. Әлеге докладында М. СССРга каршы алып барылган сугышның Германия фәне алдына өр-яңа мәсьәләләр куюын билгеләп үтә, чөнки армия һәм Германиянең гражданнар хакимияте сугышка кадәр дошман дип каралган, абстракт рәвештә генә кабул ителгән СССР халыклары б-н турыдан-туры очраша; М. фикеренчә, немецлар тормыш-көнкүрешләре, рухи омтылышлары, сәяси максатлары турында берни белмәгән һәм моңарчы бернинди элемтәдә булмаган халыклар б-н сугыш башлыйлар. М. хезмәттәшләрен Шәрекъ халыкларының тарихи үсешен җитдирәк һәм тирәнрәк өйрәнүгә өнди. 1941 дән «Кавказ» бүлеге җитәкчесе (СССРдагы төрки-мөселман халыкларына бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен җавап бирә). 1943 тә Германия тарафыннан оккупацияләнгән көнчыгыш терр-яләр эшләре министрлыгының «Чит халыклар» бүлеген җитәкли. «*Идел-Урал» легионын* туплауда, *Төрки-татарларның «Идел-Урал» көрәш берлеген* оештыруда катнаша, төрле халыклар б-н эш алып баручы министрлык каршында оештырылган милли арадашлыклар эшчәнлеген күзәтә (ш.и. «*Татар арадашлыгы*»). Икенче бөтендөнья сугышыннан соң Швейцариягә күчеп китә, анда ул, СССРга үз теләге б-н кире әйләнеп кайтучы сугышчыларның депортациясен тоткарларга тырышып, Кызыл Хач халыкара җәмгыяте б-н хезмәттәшлек итә. 1950 еллар башында Дюссельдорф шәһәрендә советология б-н шөгыльләнүче «Көнчыгыш Европа» тикшеренү хезмәте үзәге» оешмасын җитәкли. Кёльн шәһәрендә Марксизм-ленинизмны өйрәнү федераль ин-тын оештыручыларның берсе (хәзер Шәрекъ һәм халыкара мәсьәләләрне өйрәнү федераль ин-ты). Хезмәтләре Көнчыгыш Европа төрки халыклары, ш.и. татарлар тарихына карый.

Х е з м.: Der nationale Kampf der Ruslandturken. Ein Beitrag zur nationalen Fragen in der Sowjetunion. B., 1936; Volkstumfragen im Osten, in: Ostaufgaben der Wissenschaften. Vortrage auf der Osttagung deutscher Wissenschaftler. Munch., 1943. S. 80–91.

*И.А.Гыйләҗев.*

**МЕНДЕЛЕ́ВИЧ** Владимир Давыдович (5.12.1956, Казан), психиатр, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Казан шәһәренең В.М.Бехтеров исем. хастаханәсе каршындагы психоневрология диспансерында психиатр, 1982 елдан Казан мед. ун-тында, 1997 дән мед. психологиясе һәм гомуми психол. курсы мөдире. Хезмәтләре психиатрия, мед. психологиясе, неврозология, психосоматикага карый. М. педагоглар, медиклар һәм социаль хезмәткәрләр өчен инвалид балаларга мед., психол., пед. ярдәм күрсәтү буенча методик күрсәтмәләр эшли. Алкоголизм, наркомания б-н авыручылар һәм аларның гаилә әгъзаларына психол. ярдәм күрсәтү, психиатрия диагнозы кую принципларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Как предупредить невроз: Записки психотерапевта. К., 1988; Наркозависимость и коморбидные расстройства поведения (психологические и психопатологические аспекты). М., 2003; Клиническая и медицинская психология. М., 2008; Психический инфантилизм при невротических и соматоформных расстройствах. К., 2009.

**МЕНДЕЛЕ́ВИЧ** Давыд Моисеевич (16.2.1932, Урта Идел краеның Каменка а., хәзер Пенза өлкәсенең Каменка ш.), психиатр, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1984), ТРның атказ. табибе (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000), РФнең атказ. югары уку йорты хезмәткәре (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Киров өлкәсендәге Ашлан психиатрия хастаханәсе баш табибе. 1959 елдан Казан мед. ин-тында, 1980 нән психиатрия каф. мөдире. Хезмәтләре профессиягә бәйле авыруларны кисәтү өлкәсенә, психик тайпылышларның церебраль механизмнарын өйрәнүгә карый. «Намуслы хезмәт өчен» медале б-н бүләкләнә (2011).


Х е з м.: Основные принципы и методы изучения центральной нервной системы при психических заболеваниях. К., 1979 (автордаш); Вербальный галлюциноз. К., 1980; Трезво об алкоголе. К., 1988 (автордаш); Основы детской психологии. К., 1995; Психические расстройства при нарушении голоса // Архив психиатрии. 2002. № 3; В.М.Бехтерев и современные Казанские медицинские школы. К., 2007 (автордаш).

**МЕНДЕЛЕ́ВИЧ** Елена Геннадьевна (23.6.1960, Горький өлкәсенең Заволжье ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. табибе (2010). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Казан шәһәренең 6 нчы хастаханәсендә терапевт, 1986 елдан невропатолог, бер үк вакытта, 1985 тән, Казан ГИДУВының нерв авырулары клиникасында, 1989 дан нерв авырулары кафедрасында невропатолог. 1991 дән Казан мед. ун-тының неврология һәм реабилитация кафедрасында. Хезмәтләре вертеброневрологиягә, остеохондрозны кисәтү һәм дәвалауга карый.

Х е з м.: Психиатрия и наркология. М., 2005 (автордаш); Психические болезни с курсом наркологии. М., 2008 (автордаш).

**МЕНДЕЛЕ́ЕВ** Дмитрий Иванович (27.1.1834,Тобольск ш. — 20.1.1907, С.-Петербург), химик, галим-энциклопедист, җәмәгать эшлеклесе, химия д-ры (1865), Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1876). 1855 елда Баш пед. ин-тын (С.-Петербург) тәмамлаганнан соң, Ришелье лицее каршындагы гимназиядә укыта (Одесса ш.). 1857–90 да Петербург ун-тында (1865 тән проф.), бер үк вакытта, 1864–72 дә, Петербург практик технол. ин-ты профессоры. 1890–95 тә Диңгезчелек министрлыгының Фәнни-техник лаб-ясе киңәшчесе (Мәскәү). 1892 дән Үрнәк герләр һәм үлчәүләр депосының галим-саклаучысы (депо соңыннан аның тырышлыгы б-н Баш үлчәүләр палатасы итеп үзгәтелә, хәзер Д.И.Менделеев исем. Бөтенроссия метрология фәнни-тикшеренү ин-ты), 1893 тән аның управляющие (директоры). Фундаменталь хезмәтләре гомуми химиягә, химия технологиясенә, физикага, гидродинамика, метрология, һавада очуга, метеорология, геол., а.х., икътисадка, халык мәгарифенә һ.б.га карый. Изоморфлыкка һәм чагыштырмача күләмнәргә багышланган беренче хезмәтләрендә үк ул химик элементларны кушылмаларның кристаллик формалары буенча классификацияләргә тырыша; химик элементларның активлыгы аларның атом күләмнәренә бәйле булуын ачыклый. Гейдельберг шәһәрендә

(Германия, 1859–61) командировкада вакытта лаб. төзи, һәм анда сыеклыкларның максималь кайнау темп-ралары булуы ачыла (1860). Россиядә чыккан беренче «Органик химия» («Органическая химия», СПб., 1861; Петербург ФАнең Демидов бүләге) дәреслеге авторы. «Химия нигезләре» курсын әзерләгән вакытта химик элементларның үзлекләре аларның атом авырлыкларына периодик бәйле булуы турындагы фикергә килә. 1869–71 дә периодиклык турындагы тәгълимат нигезләрен бәян итә, периодиклык законын ача, химик элементларның периодик системасын эшли, аның берничә вариантын төзи. Периодик системага нигезләнеп, кайбер билгеле элементларның атом авырлыкларын төзәтә, әлегәчә фәндә билгеле булмаган элементларның, ш.и. экаалюминий — галлий, экабор — скандий, экасилиций — германийның (тиңдәшле рәвештә 1876, 1879, 1886 елларда ачылалар) барлыгын һәм үзлекләрен фаразлый (1870). Бу элементларның ачылуы периодик законга танылу китерә. Соңрак элементның М. периодик системасындагы тәртип номерының реаль физик мәгънәгә ия булуы һәм атом төше корылмасына, ягъни төштәге протоннар санына һәм нейтраль атом сүрүендәге электроннар санына туры килгәне беленә. Атом төше корылмалары арткан саен, тиңдәшле рәвештә 2 ($s$), 6 ($p$), 10 ($d$) һәм 14 ($f$) элементлар аша элемент үзлекләренең периодик кабатлана баруы ачыкланган. Химик элементларның периодик системасының күп вариантлы график сурәтләре арасыннан 1990 елларга кадәр вертикаль урнашкан төркемнәре саны (8 — кыска һәм 18 — озын) б-н аерылып торучы 2 формасы таралган була. Күрсәтелгән саннар атомның төш корылмасы (протоннар саны) арта барган саен, аның ике тышкы энергетик дәрәҗәсенең электроннар б-н максималь тулуы периодлы икәнен чагылдыралар. Таблицаның кыска формасында, озынындагы кебек үк, 7 период, төркемнәр төп ($a$) һәм ярдәмче ($b$) астөркемнәргә бүленәләр. Химик элементлар периодик системасының төркемнәрне 1 дән алып 18 гә кадәр гарәп цифрлары б-н номерлаган озын формасы 1989 елда Халыкара теоретик (саф) һәм гамәли химия берлеге тарафыннан кабул ителә һәм гомуми куллану өчен тәкъдим ителә. Әлеге форма кабул ителү б-н «астөркем», «типик элементлар», «семьялыклар» төшенчәләре юкка чыга. Ике зур семьялыкның — лантаноидлар һәм актиноидларның урыны үзгәрешсез кала. 18 төркемнең һәрберсенә (1 нче периодның системада аерым урын тоткан H һәм He элементларыннан башка) вертикаль буенча бер рәт итеп, ике тышкы («валентлык») электрон катламнары бер үк электрон структуралы ($s$-, $s$- + $p$- яки s- + d-) элементлар кертелә. Периодик закон М.ның фундаменталь «Химия нигезләре» («Основы химии», 1–2 кисәкләр, СПб., 1869–71) хезмәтен язу өчен нигез булып тора. Автор үзе исән чагында китап 8 тапкыр басыла, инглиз, немец һәм француз телләренә тәрҗемә ителеп чыгарыла; химияне үстерүгә һәм аны укытуга йогынтысы буенча дөньякүләм химия әдәбиятында бу хезмәткә тиңнәр булмый. Гаять күп эксперименталь материалга таянып, М. хәзерге заман эремәләр гыйлеме нигезләренең берсе булган эремәләрнең гидратлар теориясен төзи. Клапейрон тигезләмәсен (Клапейрон–Менделеев тигезләмәсе) гомумиләштереп, идеаль газның бер моле өчен гомуми халәт тигезләмәсен чыгара. Метеорология һәм һавада йөзү буенча тикшеренүләр үткәрә, гамәли нивелирлау өчен сизгер дифференциаль барометр уйлап таба. Фәнни тикшеренүләрне илнең икътисади үсеше ихтыяҗлары б-н тыгыз бәйләнештә алып бару — М. эшчәнлегенең төп билгесе. Ул нефть, күмер чыгару, металлургия һәм химия сәнәгатьләренә аеруча игътибар итә. Нефть үткәргечләре төзү, нефтьне химик чимал итеп куллану инициаторы була; нефтьнең авыр металлар карбидларыннан нәорганик килеп чыгышлы булуын фаразлый; нефтьләрне эшкәртүдә ваклап кудыру принцибын тәкъдим итә. Күмерләрне җир астында газландыру идеясе б-н чыга, сода, күкерт к-тасы, ясалма минер. ашламалар җитештерүне илнең үз чималына нигезләнеп арттыру — беренче чираттагы бурыч дип исәпли. Төтенсез дарының бер төрен уйлап таба, һәм аның беренче партиясе Бондюг (хәзер Менделеев) шәһәре химия з-дында әзерләнә, биредә М. химия технологиясе мәсьәләләре буенча фәнни киңәшче була. А.х.на караган хезмәтләрендә ачы туфракларны известьләү, вакланган фосфоритлар, суперфосфат, азотлы һәм калийлы ашламалар куллану, минераль һәм органик ашламаларны бергә кертү зарурлыгын күрсәтә. Баш үлчәүләр палатасында эшләгәндә, М. Россиядә метрика эшен үстерүгә ярдәм итә. Төгәл үлчәнешләр теориясен төзи, көянтә һәм арретирның иң яхшы конструкцияләрен эшли, үтә төгәл үлчәү алу ысулларын тәкъдим итә. М. җитәкчелегендә фунт (кадак) һәм аршинның прототиплары кабат яңартыла, рус үлчәү эталоннары б-н инглиз үлчәмнәре һәм метрик үлчәмнәр чагыштырыла. Ул Россиядә метрик үлчәүләр системасын кертү кирәк дип саный һәм аның факультатив кулланылышына рөхсәт алуга ирешә (1899, 1918 дән мәҗбүри). М.ның «Аңлатмалы тариф» («Толковый тариф», СПб., 1891) китабы озак вакытлар рус таможня сәясәтенең нигезен тәшкил итә. Ф.А.Брокгауз һәм И.А.Ефронның «Энциклопедик сүзлеген» төзегәндә химия-техника һәм фабрика-заводлар бүлеге мөхәррире, ш.у. бу басманы бизәгән күп кенә мәкаләләр авторы сыйфатында актив катнаша. Рус химия җәмгыятен гамәлгә куюда (1868, хәзер Д.И.Менделеев исем. Россия химия җәмгыяте) башлап йөрүчеләрнең берсе. Дөньяның төрле илләренең 90 нан артык фәннәр академиясе, фәнни җәмгыятьләре, университетлары, институтлары әгъзасы һәм мактаулы әгъзасы. 101 нче химик элемент (менделевий), минерал (менделеевит), Айдагы кратер, Курил утрауларындагы вулкан, Төньяк Боз океанындагы су асты сырты М. исеме б-н аталган. М. исеме дөньяның иң бөек галимнәре б-н беррәттән Бриджпорт ун-ты (Коннектикут штаты, АКШ) Фән мактау тактасына кертелгән. Бөекбритания ФА медальләре б-н бүләкләнә. Россиядә М. истәлегенә саф һәм гамәли химия буенча Менделеев съездлары үткәрелә (1907–2005 тә 17 съезд үтә). СССР ФА химия һәм химия технологиясе буенча иң яхшы хезмәтләр өчен Д.И.Менделеев исем. бүләк һәм Алтын медаль билгели (1962).



Д.И.Менделеев.

Химик элементларның хәзерге периодик системасының рус телендәге варианты Казан галимнәре Р.С.Сәйфуллин һәм А.Р.Сәйфуллин тарафыннан тәкъдим ителә (1999). Элементлар исемнәре рус һәм инглиз телләрендә бирелә, элементның латин телендәге исеме инглизчәсе б-н туры килмәгән очракларда курсив б-н өстәп языла. Һәр элемент өчен 2 электр тискәрелек зурлыгы, гади матдәләрнең физик параметрлары кертелгән. 101–111 нче элементлар ИЮПАК раслаган һәм аныклаган исемнәре һәм атом (моляр) массалары б-н (1997–2005, 1999) язылганнар. Кыска таблицаның төркемнәренә һәм үзләренең өстәмә $a$ һәм $b$ индекслары б-н астөркемнәренә сылтамалар, ш.у. лантаноидлар һәм актиноидлар өчен «күчеш элементлары» төшенчәсе сакланган, соңгылары элеккечә аерым рәтләргә (төркемнәрдән тыш) аерып чыгарылганнар һәм 3 нче (элекке III$b$) төркемгә карыйлар.


Х е з м.: Сочинения: В 25 т. М.–Л., 1934–54; Избранные лекции по химии. М., 1968.

*Лит.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира. М., 1991; С а м и н Д.К. Сто великих учёных. М., 2002; С а й ф у л л и н Р.С., С а й ф у л л и н А.Р. Универсальный лексикон: химия, физика и технология. М., 2002; ш у л у к. Современная форма таблицы Менделеева // Наука и жизнь. 2004. № 7; У ш а к о в а Г.Г. Современная периодическая система химических элементов Д.И.Менделеева. К.,2006.


*В.Г.Абзалова, Р.С.Сәйфуллин.*

**МЕНДЕЛЕ́ЕВ**, район карамагындагы шәһәр, Менделеев р-ны үзәге. Татарстанның төньяк-көнчыгышында, Әгерҗе — Акбаш тимер юлындагы Тихоново станциясеннән 8 *км* төньяктарак, Кама елгасының уңъяк ярында (Казаннан 238 *км* ераклыкта) урнашкан. Мәйданы — 14,1 *км*². 2010 елда 22075 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 55,1%, руслар — 36,1%, удмуртлар — 2,4%, марилар — 2,4%) яши. Л.Я.Карпов исем. *химия заводы*, «Менделеевсказот» ЖЧҖ (к. *«Татазот»*), икмәк з-ды, мебель ф-касы, 2 һөнәр уч-щесе, 4 урта мәктәп, 3 гимназия, балалар сәнгать мәктәбе. Мәдәният сарае, төбәк тарихы музее, 3 китапханә. Мәчет, чиркәү. Хәзерге М. 1967 дә шәһәр тибындагы Бондюг посёлогы, Ленино (1920 еллар башына кадәр — Мирное Пристанище, Камашево а.), Тихие Горы, Бондюга авыллары кушылу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Тихие Горы һәм Бондюга авыллары 17 йөзнең 2 нче яртысында *Седмиозёрный пустыне* биләмәләрендә төзелә башлый; Мирное Пристанище авылына 1801 дә алпавыт И.Н.Камашев нигез сала, анда Мәскәү, Владимир, Казан губерна-

# Modern version of Mendeleev's Periodic Table of the Elements
# Химик элементларның Д.И.Менделеев периодик таблицасы

| Атом массасы, чагыштырма | 186.207 | Atomic mass, relative |
|---|---|---|
| Атом номеры. Билгеләнеше | **75 Re** | Atomic No. Symbol |
| Электроннар бүленеше | [Xe] $4f^{14}5d^{5}6s^{2}$ | Electron configuration |
| Эрү температурасы (°C) | 3180 | Melting point (°C) |
| Кайнау температурасы (°C) | 5627 | Boiling point (°C) |
| Электртискәрелек (Полинг/Олпред һәм Рошоу буенча) | 1.9/1.46 | Electronegativity (Pauling/Allred & Rochov) |
| Атамасы | Rhenium<br>Рений | Name |
| Латинча атамасы | *Rhenium* | Latin name |

Groups 1...18 IUPAC 1989
Groups IA...VIII...0 IUPAC 1970
Төркемнәр 1...18 ИЮПАК, 1989
Төркемнәр IA...VIII...0 ИЮПАК, 1970

© Р.С.Сәйфуллин, А.Р.Сәйфуллин, 2007
© R.S.Sayfullin, A.R.Sayfullin, 2007
January 2007

| Период / Period | Group 1 Төркем<br>Ia | 2<br>IIa | 3<br>IIIb | 4<br>IVb | 5<br>Vb | 6<br>VIb | 7<br>VIIb | 8<br>VIII | 9<br>VIII | 10<br>VIII | 11<br>Ib | 12<br>IIb | 13<br>IIIa | 14<br>IVa | 15<br>Va | 16<br>VIa | 17<br>VIIa | 18<br>0 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1.00794<br>**1 H**<br>$1s^1$<br>-259.14<br>-252.87<br>2.02/-<br>Hydrogen<br>Водород<br>*Hydrogenium* | | | | | | | | | | | | | | | | | 4.002602<br>**2 He**<br>$1s^2$<br><-272.2<br>-268.93<br>12.3 eV<br>Helium<br>Гелий |
| 2 | 6.941<br>**3 Li**<br>$[He]2s^1$<br>180.54<br>1347<br>0.98/0.97<br>Lithium<br>Литий | 9.012182<br>**4 Be**<br>$2s^2$<br>1278<br>2970<br>1.57/1.47<br>Beryllium<br>Бериллий | | | | | | | | | | | 10.811<br>**5 B**<br>$2s^12p^1$<br>2210<br>~2600<br>2.04/2.01<br>Boron<br>Бор<br>*Borum* | 12.011<br>**6 C**<br>$2s^22p^2$<br>~3550<br>4827<br>2.55/2.50<br>Carbon<br>Углерод<br>*Carboneum* | 14.00674<br>**7 N**<br>$2s^22p^3$<br>-209.86<br>-195.8<br>3.04/3.07<br>Nitrogen<br>Азот<br>*Nitrogenium* | 15.9994<br>**8 O**<br>$2s^22p^4$<br>-218.4<br>-182.96<br>3.44/3.50<br>Oxygen<br>Кислород<br>*Oxygenium* | 18.9984032<br>**9 F**<br>$2s^22p^5$<br>-219.62<br>-188.11<br>3.98/4.10<br>Fluorine<br>Фтор<br>*Fluorum* | 20.1797<br>**10 Ne**<br>$2s^22p^6$<br>-248.7<br>-246.05<br>10.6 eV<br>Neon<br>Неон |
| 3 | 22.989770<br>**11 Na**<br>$[Ne]3s^1$<br>97.86<br>883.15<br>0.93/1.01<br>Sodium<br>Натрий<br>*(Natrium)* | 24.3050<br>**12 Mg**<br>$3s^2$<br>648.8<br>1107<br>1.31/1.23<br>Magnesium<br>Магний | | | | | | | | | | | 26.981538<br>**13 Al**<br>$3s^23p^1$<br>660.37<br>2467<br>1.61/1.47<br>Aluminium<br>[Aluminum]<br>Алюминий | 28.0855<br>**14 Si**<br>$3s^23p^2$<br>1412<br>2355<br>1.90/1.74<br>Silicon<br>Кремний<br>*Silicium* | 30.973761<br>**15 P**<br>$3s^23p^3$<br>44.14<br>280<br>2.19/2.06<br>Phosphorus<br>Фосфор | 32.066<br>**16 S**<br>$3s^23p^4$<br>112.8<br>444.674<br>2.58/2.44<br>Sulphur<br>Күкерт<br>*[Sulfur]* | 35.453<br>**17 Cl**<br>$3s^23p^5$<br>-100.98<br>-34.6<br>3.16/2.83<br>Chlorine<br>Хлор<br>*Chlorum* | 39.948<br>**18 Ar**<br>$3s^23p^6$<br>-189.2<br>-185.7<br>7.7 eV<br>Argon<br>Аргон |
| 4 | 39.0983<br>**19 K**<br>$[Ar]4s^1$<br>63.65<br>774<br>0.82/0.91<br>Potassium<br>Калий<br>*(Kalium)* | 40.078<br>**20 Ca**<br>$4s^2$<br>839<br>1487<br>1.00/1.04<br>Calcium<br>Кальций | 44.955910<br>**21 Sc**<br>$3d^14s^2$<br>1541<br>2831<br>1.36/1.20<br>Scandium<br>Скандий | 47.867<br>**22 Ti**<br>$3d^24s^2$<br>1670<br>3287<br>1.54/1.32<br>Titanium<br>Титан | 50.9415<br>**23 V**<br>$3d^34s^2$<br>1890<br>3380<br>1.63/14.5<br>Vanadium<br>Ванадий | 51.9961<br>**24 Cr**<br>$3d^54s^1$<br>1857<br>2672<br>1.66/1.56<br>Chromium<br>Хром | 54.938046<br>**25 Mn**<br>$3d^54s^2$<br>1244<br>1962<br>1.55/1.60<br>Manganese<br>Марганец<br>*Manganum* | 55.845<br>**26 Fe**<br>$3d^64s^2$<br>1535<br>2750<br>1.83/1.64<br>Iron<br>Тимер<br>*Ferrum* | 58.933200<br>**27 Co**<br>$3d^74s^2$<br>1495<br>2870<br>1.88/1.70<br>Cobalt<br>Кобальт<br>*Cobaltum* | 58.6934<br>**28 Ni**<br>$3d^84s^2$<br>1453<br>2732<br>1.91/1.75<br>Nickel<br>Никель<br>*Niccolum* | 63.546<br>**29 Cu**<br>$3d^{10}4s^1$<br>1083.4<br>2567<br>1.901.75<br>Copper<br>Бакыр<br>*Cuprum* | 65.39<br>**30 Zn**<br>$3d^{10}4s^2$<br>419.88<br>907<br>1.65/1.66<br>Zinc<br>Цинк<br>*Zincum* | 69.723<br>**31 Ga**<br>$3d^{10}4s^24p^1$<br>29.78<br>2403<br>1.81/1.82<br>Gallium<br>Галлий | 72.64<br>**32 Ge**<br>$3d^{10}4s^24p^2$<br>937.4<br>2830<br>2.01/2.02<br>Germanium<br>Германий | 74.92160<br>**33 As**<br>$3d^{10}4s^24p^3$<br>817<br>(3,7MPa)<br>субл.615<br>2.18/220<br>Arsenic<br>Мышьяк<br>*Arsenicum* | 78.96<br>**34 Se**<br>$3d^{10}4s^24p^4$<br>217<br>684.9<br>2.55/2.48<br>Selenium<br>Селен | 79.904<br>**35 Br**<br>$3d^{10}4s^24p^5$<br>-7.25<br>58.78<br>2.96/2.74<br>Bromine<br>Бром<br>*Bromum* | 83.80<br>**36 Kr**<br>$3d^{10}4s^24p^6$<br>-156.6<br>-152.3<br>6.8 eV<br>Krypton<br>Криптон |
| 5 | 85.4678<br>**37 Rb**<br>$[Kr]5s^1$<br>38.89<br>687.2<br>0.82/0.89<br>Rubidium<br>Рубидий | 87.62<br>**38 Sr**<br>$5s^2$<br>769<br>1384<br>0.95/0.99<br>Strontium<br>Стронций | 88.90585<br>**39 Y**<br>$4d^15s^2$<br>1522<br>3337<br>1.22/1.11<br>Yttrium<br>Иттрий | 91.224<br>**40 Zr**<br>$4d^25s^2$<br>1852<br>4377<br>1.33/1.22<br>Zirconium<br>Цирконий | 92.90638<br>**41 Nb**<br>$4d^45s^1$<br>2468<br>4742<br>1.6/1.23<br>Niobium<br>Ниобий | 95.94<br>**42 Mo**<br>$4d^55s^1$<br>2617<br>4612<br>2.16/1.30<br>Molybdenum<br>Молибден<br>*Molybdaenum* | (97)<br>**43 Tc***<br>$4d^65s^1$<br>2172<br>4877<br>1.9/1.36<br>Technetium<br>Технеций | 101.07<br>**44 Ru**<br>$4d^75s^1$<br>2310<br>(~3900)<br>2.2/1.42<br>Ruthenium<br>Рутений | 102.90550<br>**45 Rh**<br>$4d^85s^1$<br>1966<br>3727<br>2.2/1.5<br>Rhodium<br>Родий | 106.42<br>**46 Pd**<br>$4d^{10}$<br>1552<br>3140<br>2.2/1.4<br>Palladium<br>Палладий | 107.8682<br>**47 Ag**<br>$4d^{10}5s^1$<br>961.93<br>2212<br>1.9/1.4<br>Silver<br>Көмеш<br>*(Argentum)* | 112.411<br>**48 Cd**<br>$4d^{10}5s^2$<br>320.9<br>765<br>1.7/1.5<br>Cadmium<br>Кадмий | 114.818<br>**49 In**<br>$4d^{10}5s^25p^1$<br>156.78<br>2080<br>1.78/1.5<br>Indium<br>Индий | 118.710<br>**50 Sn**<br>$4d^{10}5s^25p^2$<br>231.88<br>2270<br>1.96/1.7<br>Tin<br>Аккургаш<br>*Stannum* | 121.760<br>**51 Sb**<br>$4d^{10}5s^25p^3$<br>630.5<br>1750<br>2.05/1.8<br>Antimony<br>Сөрмә<br>*(Stibium)* | 127.60<br>**52 Te**<br>$4d^{10}5s^25p^4$<br>449.5<br>989.8<br>2.1/ 2.0<br>Tellurium<br>Теллур | 126.90447<br>**53 I**<br>$4d^{10}5s^25p^5$<br>113.5<br>184.35<br>2.66/2.2<br>Iodine<br>Иод<br>*Iodum* | 131.293<br>**54 Xe**<br>$4d^{10}5s^25p^6$<br>-111.9<br>-107.1<br>5.85 eV<br>Xenon<br>Ксенон |
| 6 | 132.90545<br>**55 Cs**<br>$[Xe]6s^1$<br>28.5<br>678.4<br>0.79/0.86<br>Caesium<br>Цезий<br>*[Cesium]* | 137.327<br>**56 Ba**<br>$6s^2$<br>725<br>1640<br>089/0,97<br>Barium<br>Барий | 138.9055<br>**57 La**<br>$5d^16s^2$<br>920<br>3454<br>1.10/1.08<br>Lanthanum<br>Лантан | 178.46<br>**72 Hf**<br>$4f^{14}5d^26s^2$<br>2227<br>4602<br>1.3/1.23<br>Hafnium<br>Гафний | 180.9479<br>**73 Ta**<br>$4f^{14}5d^36s^2$<br>2996<br>5425<br>1.5/1.33<br>Tantalum<br>Тантал | 183.84<br>**74 W**<br>$4f^{14}5d^46s^2$<br>3410<br>5660<br>1.7/1.40<br>Tungsten<br>(Wolfram)<br>Вольфрам<br>*Wolframium* | 186.207<br>**75 Re**<br>$4f^{14}5d^56s^2$<br>3180<br>5627<br>1.9/1,46<br>Rhenium<br>Рений | 190.23<br>**76 Os**<br>$4f^{14}5d^66s^2$<br>3045<br>5027<br>2.2/1.52<br>Osmium<br>Осмий | 192.217<br>**77 Ir**<br>$4f^{14}5d^76s^2$<br>2410<br>4130<br>2.2/1.6<br>Iridium<br>Иридий | 195.078<br>**78 Pt**<br>$4f^{14}5d^96s^1$<br>1773.5<br>3830<br>2.2/1.4<br>Platinum<br>Агалтын | 196.96655<br>**79 Au**<br>$4f^{14}5d^{10}6s^1$<br>1064.43<br>2807<br>2.54/1.42<br>Gold<br>Алтын<br>*Aurum* | 200.59<br>**80 Hg**<br>$4f^{14}5d^{10}6s^2$<br>-38.86<br>356.6<br>1.9/1.5<br>Mercury<br>Терекөмеш<br>*(Hydrargyrum)* | 204.3833<br>**81 Tl**<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^1$<br>303.5<br>1457<br>1.62/1.44<br>Thallium<br>Таллий | 207.2<br>**82 Pb**<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^2$<br>327.5<br>1740<br>2.33/1.55<br>Lead<br>Кургаш<br>*(Plumbum)* | 208.98038<br>**83 Bi**<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^3$<br>271.3<br>1564<br>2.02/1.67<br>Bismuth<br>Висмут<br>*Bismuthum* | (210)<br>**84 Po***<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^4$<br>254<br>962<br>2.0/1.76<br>Polonium<br>Полоний | (210)<br>**85 At***<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^5$<br>302<br>337<br>2.2/1.86<br>Astatine<br>Астат<br>*Astatium* | (222)<br>**86 Rn***<br>$4f^{14}5d^{10}6s^26p^6$<br>-71.0<br>-61.8<br>5.1 eV<br>Radon<br>Радон |
| 7 | (223)<br>**87 Fr***<br>$[Rn]7s^1$<br>27<br>677<br>0.7/0.86<br>Francium<br>Франций | (226)<br>**88 Ra***<br>$7s^2$<br>970<br>1140<br>0.89/0.97<br>Radium<br>Радий | (227)<br>**89 Ac***<br>$6d^17s^2$<br>1050<br>(~3250)<br>1.1/1.0<br>Actinium<br>Актиний | (261)<br>**104 Rf***<br>$5f^{14}6d^27s^2$<br>Rutherfordium<br>Резерфордий | (262)<br>**105 Db***<br>$5f^{14}6d^37s^2$<br>Dubnium<br>Дубний | (263)<br>**106 Sg***<br>$5f^{14}6d^47s^2$<br>Seaborgium<br>Сиборгий | (264)<br>**107 Bh***<br>$5f^{14}6d^57s^2$<br>Bohrium<br>Борий | (265)<br>**108 Hs***<br>$5f^{14}6d^67s^2$<br>Hassium<br>Хассий | (268)<br>**109 Mt***<br>$5f^{14}6d^77s^2$<br>Meitnerium<br>Мейтнерий | (281)<br>**110 Ds***<br>$5f^{14}6d^87s^2$<br>Darmstadtium<br>Дармштадтий | (280)<br>**111 Rg***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^1$<br>Roentgenium<br>Рентгений | (277)<br>**112 Uub***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^2$<br>Ununbium<br>Унунбий | ( )<br>**113 Uut***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^1$<br>Ununtrium<br>Унунтрий | (289)<br>**114 Uuq***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^2$<br>Ununquadium<br>Унунквадий | ( )<br>**115 Uup***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^3$<br>Ununpentium<br>Унунпентий | (289)<br>**116 Uuh***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^4$<br>Ununhexium<br>Унунгексий | ( )<br>**117 Uus***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^5$<br>Ununseptium<br>Унунсептий | (293)<br>**118 Uuo***<br>$5f^{14}6d^{10}7s^27p^6$<br>Ununoctium<br>Унуноктий |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 140.116<br>**58 Ce**<br>$4f^26s^2$<br>798<br>3426<br>~1.2/1.1<br>Cerium<br>Церий | 140.90765<br>**59 Pr**<br>$4f^36s^2$<br>931<br>3512<br>~1.2/1.1<br>Praseodymium<br>Празеодим | 144.24<br>**60 Nd**<br>$4f^46s^2$<br>1021<br>3068<br>~1.2/1.1<br>Neodymium<br>Неодим | (145)<br>**61 Pm***<br>$4f^56s^2$<br>1168<br>2460<br>1.2/1.1<br>Promethium<br>Прометий | 150.36<br>**62 Sm**<br>$4f^66s^2$<br>1077<br>1791<br>~1.2/1.1<br>Samarium<br>Самарий | 151.964<br>**63 Eu**<br>$4f^76s^2$<br>822<br>1597<br>~1.2/1.0<br>Europium<br>Европий | 157.25<br>**64 Gd**<br>$4f^75d^16s^2$<br>1312<br>3250<br>~1.2/1.1<br>Gadolinium<br>Гадолиний | 158.92534<br>**65 Tb**<br>$4f^96s^2$<br>1356<br>3123<br>~1.2/1.1<br>Terbium<br>Тербий | 162.50<br>**66 Dy**<br>$4f^{10}6s^2$<br>1409<br>2562<br>~1.2/1.1<br>Dysprosium<br>Диспрозий | 164.93032<br>**67 Ho**<br>$4f^{11}6s^2$<br>1474<br>2695<br>~1.2/1.1<br>Holmium<br>Гольмий | 167.259<br>**68 Er**<br>$4f^{12}6s^2$<br>1529<br>2863<br>~1.2/1.1<br>Erbium<br>Эрбий | 168.93421<br>**69 Tm**<br>$4f^{13}6s^2$<br>1545<br>1947<br>~1.2 /1.1<br>Thulium<br>Тулий | 173.04<br>**70 Yb**<br>$4f^{14}6s^2$<br>819<br>1193<br>~1.2 /1.1<br>Ytterbium<br>Иттербий | 174.967<br>**71 Lu**<br>$4f^{14}5d^16s^2$<br>1663<br>3302<br>~1.2 /1.1<br>Lutetium<br>Лютеций |
| 232.038<br>**90 Th***<br>$6d^27s^2$<br>1750<br>(~3800)<br>1.11/1.1<br>Thorium<br>Торий | 231.03588<br>**91 Pa***<br>$5f^26d^17s^2$<br>1572<br>4230-4500<br>1.14/1.1<br>Protactinium<br>Протактиний | 238.0289<br>**92 U***<br>$5f^36d^17s^2$<br>1132<br>3818<br>~1.2/1.2<br>Uranium<br>Уран | (237)<br>**93 Np***<br>$5f^46d^17s^2$<br>639<br>3902<br>1.36/1.2<br>Neptunium<br>Нептуний | (244)<br>**94 Pu***<br>$5f^67s^2$<br>641<br>3340<br>1.2/1.2<br>Plutonium<br>Плутоний | (243)<br>**95 Am***<br>$5f^77s^2$<br>996<br>2607<br>~1.1/1.2<br>Americium<br>Америций | (247)<br>**96 Cm***<br>$5f^76d^17s^2$<br>1340<br>3110<br>1.2/1.2<br>Curium<br>Кюрий | (247)<br>**97 Bk***<br>$5f^97s^2$<br>1050<br>2630<br>~1.1/1.2<br>Berkelium<br>Берклий | (249)<br>**98 Cf***<br>$5f^{10}7s^2$<br>900<br>1227<br>1.2/1.2<br>Californium<br>Калифорний | (254)<br>**99 Es***<br>$5f^{11}7s^2$<br>860<br>-<br>1.3/-<br>Einsteinium<br>Эйнштейний | (257)<br>**100 Fm***<br>$5f^{12}7s^2$<br>-<br>-<br>1.3/1.2<br>Fermium<br>Фермий | (258)<br>**101 Md***<br>$5f^{13}7s^2$<br>-<br>-<br>1.2/1.2<br>Mendelevium<br>Менделевий | (259)<br>**102 No***<br>$5f^{14}7s^2$<br>-<br>-<br>1.3/-<br>Nobelium<br>Нобелий | (260)<br>**103 Lr***<br>$5f^{14}6d^17s^2$<br>-<br>-<br>1.3/-<br>Lawrencium<br>Лоуренсий |

* Element has no stable nuclides. For radioactive elements the value in parentheses refers to the number of nucleons (mass number) of the most stable isotope (IUPAC, 1999)
* Элементның тотрыклы изотоплары юк. Аның өчен җәялләрдә иң озак яшәүче изотопның масса саны (төштәге нуклоннар саны) кыйммәте бирелә (ИЮПАК, 1999).
( ) Alternative english name
[ ] American spelling of the element's name
( ) Инглизчә альтернатив атамасы
[ ] Элемент исеменең америкалыларча язылышы.

ларыннан күчерелгән крәстияннәр килеп урнаша. 1834 елгы мәгълүматларга караганда, Бондюгада — 420, Мирное Пристанищеда — 373, Тихие Горы авылында 766 ир-ат исәпләнә. 1867 дә завод хуҗасы П.К.*Ушков* Камашев утарын сатып ала һәм 1868 дә химия з-ды һәм посёлокка нигез сала. Бу чордан башлап, тирә-як авылларда яшәүче күп кенә крәстияннәр өчен заводта эшләү — яшәү чыганагы, ә торак пунктлар үзләре пр-тие инфраструктурасының бер өлеше (Тихие Горы авылы пристане аша йөкләр китертелә һәм кирәк җиргә озатыла, Мирное Пристанище авылында Ушков утары, директорлар һәм инженерлар фатирлары була) булып китә. Шул чор өчен зур торак пунктка әйләнгән завод посёлогы (1897 дә — 3001 кеше) 20 йөз башында Бондюг исемен ала. 1896 да монда рус-татар уч-щесе, 1898 дә заводта эшләүчеләр өчен рус мәктәбе ачыла. 1906 да завод исәбенә мәчет төзелә. Православие динен тотучы Бондюг һ.б. авыл кешеләре Тихие Горы авылындагы Богоявление чиркәве приходына карый. 1868 дән авылда земство мәктәбе эшли, шундый ук уку йорты Бондюга авылында да була (1896 дан). 1897 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, Тихие Горы авылында — 789, Бондюгада — 473, Мирное Пристанищеда 373 кеше яши. 19–20 йөзләрдә П.К.Ушков з-ды Россиядә химия өлкәсендәге алдынгы пр-тиеләрнең берсенә әверелә. Заводның фәнни киңәшчесе Д.И.*Менделеев* була. Ул 1893 нең июнь–августында төтенсез дары җитештерүне җайга сала. Рев-циягә кадәрге чорда пр-тие җитәкчеләре арасында атаклы химик-технологлар Б.И.*Збарский*, Л.Я.*Карпов* була. 1916–17 дә заводның хәрби хисап бүлегендә язучы Б.Л.*Пастернак* эшли. 1921 гә кадәр Бондюг посёлогы (һәм аның б-н бәйле авыллар) Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1921–25 тә Бондюг посёлогында СССРда беренче радий з-ды эшли, һәм ул илебез атом-төш физикасы үсешендә мөһим роль уйный. 1928 нең 21 маенда Бондюг шәһәр тибындагы эшчеләр посёлогы (штп) статусын ала, 1930 ның 10 августыннан яңадан оештырылган *Бондюг районының* үзәге булып китә. Район таркатылгач (20.1.1931), посёлок Алабуга р-ны составында. 1935 нең 10 февраленнән — яңадан район үзәге. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне берләштерү сәбәпле, яңадан Алабуга р-ны карамагына күчерелә. 1967 нең 11 августында М. шәһәре итеп үзгәртелә, 1985 нең 15 августыннан — Менделеев р-ны үзәге. М.та 19 йөз — 20 йөз башы сәнәгать, дини һәм гражданлык архит-расы (ш.и. Богоявление чиркәве — 1818–35 тә, Бондюг з-ды контора бинасы 1870 тә төзелә һ.б.) саклана. Шәһәрнең истәлекле урыны — 4 нче урта мәктәп (элек Бондюг штп.ның 1 нче урта мәктәбе), аны тәмамлаучылар арасында 6 Сов. Союзы Герое (В.И.Белоусов, В.И.Бурмистров, В.Г.Пискунов, П.С.Сафронов, М.В.Суднишников, М.С.Фомин) бар. Халык саны (1967 гә кадәр — Бондюг, 1967 дән — М.): 1920 дә — 3,7 мең, 1926 да — 5,2, 1938 дә — 8,7, 1970 тә — 13,6, 1979 да — 13,8, 1989 да — 18,2, 2002 дә — 22 мең кеше.

*Әд.:* С а б и р о в Р.М. По городам Татарии. К., 1976; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.



Менделеев шәһәре. Шәһәрнең үзәк өлеше күренеше.




Менделеев шәһәре. Бөек Ватан сугышында җиңүгә багышланган монумент.

**МЕНДЕЛЕ́ЕВ Д.И. ИСЕМЕНДӘГЕ́ РЕСПУ́БЛИКА ХИ́МИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Татарстанда, ирекле иҗтимагый оешма. Д.И. Менделеев исем. Химия җәмгыятьләре федерациясенә керә. Казан ун-ты каршындагы химия җәмгыятенең (1869 елда нигезләнә, 1 нче президенты — Н.П.Вагнер, шәрәфле әгъзасы — А.М.Бутлеров) дәвамчысы, соңрак Рус физика-химия җәмгыяте составында. 1934 тә Д.И. Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Казан бүлеге төзелә (оештыручылары — А.Е.Арбузов, А.Я.Богородский, В.В.Евлампиев, Г.Х.Камай); 1991 дән Татарстан бүлеге. 1992 дән хәзерге исемендә. Галимнәрне, укытучыларны, химия сәнәгатендә һәм халык хуҗалыгының эргәдәш тармакларында эшләүче инженер-техник хезмәткәрләрне, студентлар һәм махсус урта уку йортлары укучыларын берләштерә. Респ-ка югары уку йортларында, фәнни-тикшеренү ин-тларында, сәнәгать пр-тиеләрендә (Казан ун-ты, Казан технол. ин-ты, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты, Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты, «Түбәнкаманефтехим», «Казаноргсинтез», «Казан ясалма каучук заводы» АҖләре һ.б.) 17 башлангыч оешмасы бар. Җәмгыять химия һәм химия технологиясенең төрле мәсьәләләренә караган фәнни конгресслар, конференция, киңәшмә, симпозиумнар оештыра (Казанда Гомуми һәм гамәли химия буенча Менделеев җыеннарының 1928 дә — 5 нчесе, 2003 тә 17 нчесе үткәрелә), әгъзалары укучы яшьләр арасында конкурс, викторина, олимпиадалар үткәрүдә, химик белемнәрне, ш.у. илдә һәм дөньяда ирешелгән фән һәм техника казанышларын таратуда катнашалар, Казан химия мәктәбе традицияләрен саклау һәм үстерү буенча тарихи-мемориаль эш алып баралар. Җәмгыятьнең мөһим бурычы — респ-каның фәнни-җитештерү мөмкинлекләрен ныгыту һәм үстерү программасын үтәүдә химия җәмәгатьчелегенең катнашуына ирешү. Респ-када химия җәмгыятен төрле елларда А.Е.Арбузов (1934–54), Г.М.Синайский (1955), А.Ф.Богоявленский (1956–62), А.Н.Пудовик (1962–70), Н.С.Әхмәтов (1971–73), П.А.Кирпичников (1973–87), В.П.Барабанов (1987 дән) җитәкли.

*Әд.:* К о з л о в В.В. Всесоюзное химическое общество им. Д.И.Менделеева, 1868–1968. М., 1971; Б а р а б а н о в В.П. Республиканское химическое общество им. Д.И.Менделеева // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4; Российское химическое общество им. Д.И.Менделеева. М., 2007.

*В.П.Барабанов.*

**МЕНДЕЛЕ́ЕВ РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнчыгышында, Удмурт Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади районына керә. Мәйданы — 744,9 $км^2$. 14 авыл җирлеген (җирле үзидарә советын), 36 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Менделеев шәһәре. 2012 елда 30,4 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,6%, руслар — 31,4%, удмуртлар — 3,9%, марилар — 3,7%) яши. Шәһәр халкы — 22 мең, авылларда 8,3 мең кеше яши. Халкының урнашу тыгызлыгы — 1 $км^2$ га 41 кеше. Район 1930 ның 10 августында Бондюг р-ны (үзәге — Бондюг штп) буларак оештырыла. 1921 гә кадәр терр-ясе Вятка губернасына, 1921 дән — ТАССРның Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонына керә. 1931 нең 20 гыйнварында район таркатыла, терр-ясе Алабуга р-нына бирелә. 1935 нең 10 февралендә район кабат торгызыла. 1940 та Бондюг р-нының мәйданы — 730 $км^2$, халык саны — 40,3 мең кеше, 25 авыл советы, 58 торак пункт була. 1960 та район 741,8 $км^2$ җир били, аңа




10 авыл советы, 59 торак пункт керә. ТАССР-да адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Бондюг р-ны таркатыла, биләмәсе Алабуга р-нына бирелә. 1967 нең 11 августында шәһәр тибындагы Бондюг посёлогы район карамагындагы шәһәр итеп үзгәртелә һәм Менделеев исемен ала. Ул 1985 нең 15 августында Алабуга р-nынnан бүленеп чыккан Менделеев р-ның адм. үзәге булып китә. Бу чорда районның мәйданы — 850 *км*², халык саны — 22,9 мең кеше, 11 авыл советы, 40 торак пункт исәпләнә.

М.р.ның рельефы — киртләчле, эрозияләнгән дулкынсыман тигезлек (биеклеге 62–200 *м*). Кама (Түбән Кама сусаклагычы) һәм аның кушылдыгы Туйма (саклаулы табигать истәлеге) елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры, көрән соры, соры урман туфраклы. Терр-ясенең 6,2% ы — урманлык. Нефть, доломит, мергель, минераль су ятмалары бар. Район терр-ясендә археол. истәлекләр табыла. М.р. — нигездә, индустриаль-а.х. р-ны. Сәнәгать пр-тиеләренең күбесе Менделеев шәһәрендә урнашкан; Ижевка авылында минераль суны савытларга тутыру пр-тиесе эшли. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, җәнлек үрчетү нык үскән. А.х. җирләре 38,9 мең *га* били, ш.и. 32,7 мең *га* сөрүлек җир (2010). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә; бәрәңге үстерелә. 2010 да районда 11 а.х. пр-тиесе эшли. М.р. җиреннән Әгерҗе–Акбаш тимер юлы, Алабуга–Можга автомобиль юлы уза. 20 гомуми урта белем бирү мәктәбе (2011/12 уку елында 3120 укучы), балалар сәнгать мәктәбе, һөнәр уч-щесе, 22 китапханә, төбәкне өйрәнү музее, 21 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 22 клуб; 2 хастаханә, «Ижминводы санаторие» (к. *Иж минераль сулары*). Татар һәм рус телләрендә «Менделеев хәбәрләре», «Новое время» район г-талары нәшер ителә.

**МЕНДЕЛЕ́ЕВ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Менделеев шәһәрендә, ТР Милли музее ф-лы. 1991 елда ачыла. «П.К.Ушков вә шөрәкясе химия заводы»ның (1870, архит-ра истәлеге) элеккеге контора бинасында урнашкан. Төрле елларда биредә заводка нигез салучы һәм хуҗасы П.К.*Ушков*, күренекле галимнәр Б.И.*Збарский*, Д.И.*Менделеев*, Л.Я.*Карпов* эшли. Бинага Д.И.Менделеев (1953) һәм Л.Я.Карпов (1979) истәлегенә ике мемориаль такта урнаштырылган. Музей мәйданы — 331,2 *м*², парк зонасы — 5,1 *га*; музей коллекцияләре 9 меңгә якын саклау берәмлеге тәшкил итә. «Кокшан-Бондюг-Менделеев» экспозициясе төбәктә 1850 дән башланган химия сәнәгате тарихын бәян итә. Ушковлар химия сәнәгатен төзегән чорда шунда фәнни консультант булып эшләгән Менделеев эшчәнлеге турындагы материаллар, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы эшчеләренең хезмәт һәм көнкүреш әйберләре, Д.И.Менделеев һәм австрияле инженер А.Бетгер җитәкчелеге һәм киңәше б-н төбәктә 1893 тә төзелгән чүлмәк производствосы әйберләре коллекцияләре тәкъдим ителә. 20 йөз тарихына багышланган экспозиция бүлегендә совет чоры химия сәнәгатен оештыручы Л.Я.Карпов эшчәнлеге турындагы документлар, ш.у. илдә бердәнбер хлорлы радий җитештерү сәнәгатенең башлангычы турында сөйләүче материаллар аерым кызыксыну уята. Экспозиция бүлекләренең берсе экология проблемасына багышлана. Анда радиоактив зарарлануның нәтиҗәләрен һәм зарарлы производство төзелешләрен (1988 дәге полиуретан з-ды) юкка чыгару турындагы документлар бар. Музейның аеруча кызыклы экспонатлары арасында — «П.К.Ушков вә шөрәкясе химия заводы, Кама буендагы Алабуга» келәймәсе, «АИУ» (П.К.Ушков



Менделеев шәһәрендә төбәк тарихы музее.

хатыны, Александра Ивановна Ушкова) барельефлы вензеле б-н парк вазасы (1897); Тихие Горы авылыннан Е.В.Тихонов заказы буенча коеп ясалган өрелмәле шөлдер (1817, оста В.Макушкин); Европа дәрәҗәсендәге сыйфатлы продукциясе өчен «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» АҖ делегациясенә «Химия — 2000» күргәзмәсенең алтын медален тапшыру уңаеннан, ГФРга визиты вакытында Менделеев шәһәре хакимияте башлыгына Вернхайм шәһәре бургомистры бүләк иткән бизәкле тәлинкә (1996, Германия) бар.

Музей каршында ТР тарихчы-архивчылары җәмгыятенең Менделеев бүлеге, Менделеев р-ны керәшеннәренең мәдәни-агарту җәмгыяте, «Менделәй» әдәби берләшмәсе, музейның попечительләр советы эшләп килә. Ел саен Төбәкне өйрәнү укулары (12 февраль), Халыкара музейлар көне (18 май) үткәрелә. Менделеев музее хәбәрләре басыла (1–3 чыг., 2002–04). Музей директорлары — В.Н.Соловьёв (1991–2011), А.А.Андриянов (2011 дән).

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1.

**«МЕНДЕЛЕЕВАЗО́Т»**, химия сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 843 кеше (2013). 1983 елда Яңа Менделеев химия з-ды буларак нигезләнә. 1988 дән «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» ҖБ составында. Файдалануга 1989 да тапшырыла. 1992 дән мөстәкыйль дәүләт пр-тиесе. 2002 дә «Татазот» унитар пр-тиесе итеп үзгәртелә, 2003 тән АҖ, 2004 тән хәзерге исемдәге ҖЧҖ. «М» структурасында — 3 төп җитештерү цехы: елга 380 мең *т* продукция чыгаруга сәләтле АС-72М агрегаты урнаштырылган аммиак селитрасы җитештерү; гомуми куәтләре елга 300 мең *т* га (100% $HNO_3$ кә карата исәпләгәндә) исәпләнгән өч УКЛ 7–76 агрегаты булган куертылмаган азот к-тасы эшләү; АК-1,5 блоклы (елга 900 мең *м*³ кислород чыгаруга сәләтле) һава аеру цехлары эшли; 10 ярдәмче цех, сыек аммиак цехы бар. 2005 тә куертылмаган азот к-тасы цехында 2 нче УКЛ 7–76 агрегаты реконструкцияләнә. Ахыргы газларны азот оксидларыннан югары темп-рада каталитик чистарту алымы — түбән темп-рада сайлап чистартуга, кыйммәтле алюмо-палладийлы катализатор арзанлы алюмо-ванадийлы катализаторга алмаштырыла. Нәтиҗәдә, 1 *т* азот к-тасы җитештерү өчен табигый газ чыгымы 25 *м*³ га, атмосферага чыгарылучы газларда углерод оксидының күләме 0,08% тан 0,03% ка кадәр кими. Төп продукция — магнезиаль өстәмәле аммиак селитрасы (балластсыз азотлы ашлама). Шулай ук куертылмаган азот к-тасы һәм техник кислород (сыек һәм газ хәлендә) җитештерелә. Продукцияне кулланучылар: РФ һәм чит илләр сәнәгатенең а.х., химия, файдалы казылмалар чыгару һәм тау эшләре, башка төрле тармаклар пр-тиеләре. Чимал җибәрүче төп пр-тиеләр: аммиак — «Инвестимпекс» ҖЧҖ (Казан), зәһәр натр — «Идел-Вятка химия компаниясе» ҖЧҖ (Түбән Новгород өлкәсе Дзержинск шәһәре), магнезит — «Магнезит» төркеме» ҖЧҖ (Чиләбе өлкәсе Сатка авылы), күкерт к-тасы — «Уралимпекс» АҖ (Свердловск өлкәсе Полевской шәһәре). 1990 да 165,8 мең *т* аммиак селитрасы, 81,4 мең *м*³ кислород, 1991 дә, тиңдәшле рәвештә, 273,8 мең *т* һәм 151,6 мең *м*³ җитештерелә. Алдагы елларда продукция җитештерү кими: 1998 дә аммиак селитрасы — 24,4 мең *т*, азот к-тасы — 102,6 *т*, кислород 107,2 мең *м*³ тәшкил итә. 1999 дан җитештерү күләмнәре арта башлый, 2005 тә аммиак селитрасы — 207,8 мең *т*, азот к-тасы — 1240,3 *т*, кислород газ халәтендә — 332,5 мең *м*³, сыек хәлдә 168,1 *т* (327,7 мең *м*³) эшләп чыгарыла. 625,6 млн. сумлык продукция (ш.и. 616,9 млн. сумлык аммиак селитрасы) сатыла, 5,7 млн. сумлык табыш алына. Сатуның гомуми күләмендә экспорт 1992–93 тә — 30% чамасы (Чехословакиягә һәм Германиягә җибәрелгән продукция), 2003–04 тә — 2% (Әзәрбайҗан), 2005 тә 11% тан күбрәк (Украина, Әзәрбайҗан, Сербия, Черногория, Казакъстан, Сүрия) тәшкил итә. Пр-тие халыкара технол. һәм сыйфат өчен призы б-н бүләкләнә (1995, Италия). «Б» маркалы аммиак селитрасы Россиянең иң яхшы 100 товары исемлегенә керә (2007). Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була: 2 кешегә


ТРның атказ. химигы исеме бирелә, 26 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында: Д.П.Иванов (1983–87), Х.В.Мостафин (1988–92), Р.А.Галиуллин (1993–99), Г.А.Мирибян (1999–2004), А.М.Мөхәммәтшин (2004–07), Ф.А.Абдрахманов (2007 дән).

*Әд.:* ООО «Менделеевсказот» // Экспортная продукция предприятий Республики Татарстан. К., 2005.

*М.Ж.Гаитов.*

**МЕНИ́СКЛЫ ТЕЛЕСКО́П**, М а к с у т о в т е л е с к о б ы, көзгеле-линзалы телескоп, батынкы сферик көзгесе алдына мениск (кабарынкы-батынкы линза) куела. 1941 елда Д.Д.Максутов тарафыннан уйлап табыла. М.т. әзерләп чыгару өчен гади һәм компактлы, сурәтләр кыры зур (аберрацияләр б-н бозылмаган диярлек), чагыштырмача тишем 1:3 булганда, 5° ка кадәр күрү кырында югары сыйфатлы сурәтләр алуны тәэмин итә.




Иң гади менисклы системаның оптик схемасы (F – системаның фокусы).

1950–60 елларда М.т. схемасы буенча гади һәм уңайлы мәктәп телескоплары эшләп чыгарыла, зур телескоп-астрографлар (йолдызларны фотога төшерү өчен) Пулково (Россия), Алма-Ата (Казакъстан), Абастумани (Грузия), Бюракан (Әрмәнстан) обсерваторияләрендә урнаштырыла. Казан оптика-механика з-дында эшләнгән мениск диаметры 35 *см* лы М.т. инде күп еллар В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә хезмәт итә. М.т. бик күп илләрнең һәвәскәр астрономнары арасында киң таралу тапкан.

*Әд.:* М а к с у т о в Д.Д. Астрономическая оптика. М.–Л., 1946; Современный телескоп. М., 1968.

*Р.Г.Усманов.*

**МЕ́НЬЧИКОВ** Геннадий Павлович (7.1.1940, Барнаул ш.), философ, филос. фән. д-ры (2000), проф. (2001). Хәрби-сәяси академия тәмамлый (Мәскәү, 1969). 1958–65 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1969–90 да төрле хәрби уч-щеләрдә филос. укыта. 1990–2003 тә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында. 2003 тән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тының (Казан) филос. кафедрасында. Хезмәтләре аңны онтологик анализлауга карый.

Х е з м.: Виртуальная реальность: понятия, новации, применения // Философские науки. 1998. № 3–4; Духовная реальность человека (анализ философско-онтологических основ). К., 1999.

**МЕНЬШЕВИКЛА́Р**, Россия с.-д. эшчеләр партиясе (РСДРП) составындагы сәяси агым (фракция), 1917 елдан мөстәкыйль партия. Фракция РСДРПның 2 нче съездындагы (1903) фикер каршылыклары нәтиҗәсендә оеша, исемен партиянең үзәк органнарына сайлауларда азчылык тәшкил иткән төркем буларак ала. Күренекле вәкилләре – Ю.О.Мартов, П.Б.Аксельрод, Ф.И.Дан, Г.В.Плеханов, А.Н.Потресов, Н.Н.Жордания, И.Г.Церетели, Н.С.Чхеидзе. Фракциядә оештыручы үзәк һәм аерым җитәкчегә катгый буйсыну булмый. М. арасында төрле сәяси фикердә торган төрле төркемнәр хасил була. РСДРПның Казандагы оешмасында М. фракциясе 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында барлыкка килә (600 ләп кеше). 1905 нең 1 нче яртысында Казан социал-демократлары, РСДРПның 2 нче съездындагы большевиклар һәм М. аерымлануына игътибар итмичә, бергә эшлиләр. Киресенчә, партиянең гади әгъзалары, аерымлануның асылын аңламыйча, берләшүне яклап чыгалар. Казан жандармериясе мәгълүматларына караганда, М. большевиклардан 1905 нең җәендә аерылып чыга. Казанга «Искра» г-тасы даими кайтартыла (бу чорда ул М. г-тасы). М. төркеме кулында гектограф була, алар гомумпартия әдәбиятыннан файдаланалар. Оешманың рев-ция елларындагы актив эшлеклеләре – В.П.Южанинов, В.Залежский, П.Жеребин. Нигездә, студент һәм укучы яшьләрдән торган оешма әгъзалары сәяси чыгышларда катнашалар, карагруһчыларга каршы көрәшү өчен кораллы отрядлар төзиләр. 1905 елгы октябрь вакыйгаларыннан соң М. үз оешмаларын таркаталар: кайберләре (ш.и. В.П.Южанинов) Казаннан китә, кайберәүләр большевикларга кушыла. Рев-ция тәмамланганнан соң, 1907–08 дә, РСДРПның Казан ком-тында М. йогынтысы көчәя: бу елларда Б.Н.Нелидов (легаль рәвештә чыгарылган «Дневник Казани» басмасы мөхәррире), А.М.Войдинова һ.б. актив эшли. Меньшевик С.Гертик шәһәр профсоюзларының үзәк бюросына җитәкчелек итә. 1907–16 да, эзәрлекләүләр нәтиҗәсе буларак, Казан губернасында М. саны кискен кими. Беренче бөтендөнья сугышы елларында М. саклану тактикасына күчәләр: солых төзү һәм бөтен халык катнашында учредительләр җыены чакыру таләбе куялар. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң РСДРПның Казан бюросына берләшәләр (әгъзалары – А.П.Рясенцев, Ю.П.Денике, М.М.Брук, Б.Н.Нелидов, Г.Ф.Никитин, К.М.Остров, М.И.Шергов, А.М.Войдинова һ.б.), Вакытлы хөкүмәтне яклап чыгалар, хакимиятнең губерна структураларына, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан Советы, җәмәгать куркынычсызлыгы ком-тлары, Ватанны һәм рев-цияне коткару ком-тлары һ.б. составына кертеләләр. М., Окт. рев-циясе нәтиҗәләрен танымыйча, яңа хакимияткә буйсынмау (саботаж) хәрәкәтендә, Совет хөкүмәтенә каршы көрәшүче рәсми оешмалар (КОМУЧ һ.б.) эшендә актив катнашалар. 1917 нең октябрендә уң эсерлар б-н большевикларга каршы бердәм социалистик блок төзиләр. 1919 да М.ның Казан бюросы таркала, 1923 тә М. партиясенең эшчәнлеге тыела. Басма органнары – «Казанская рабочая газета», «Казанское слово», «Рабочее дело», «Рабочая воля» г-талары.

*Әд.:* Л и в ш и ц С. Очерки истории социал-демократических организаций в Казани (1888–1916 гг.) // Пути революции. 1922. № 2; ш у л у к. Казанская социал-демократическая организация в 1905 году // Пролетарская революция. 1923. Т. 2 (14); Т ю т ю к и н С.В. Меньшевизм: Страницы истории. М., 2002; Л и т в и н А.А. Общественно-политическое движение в Поволжье. Конец XIX – начало XX в.: Российская историография. К., 2003.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МЕ́НЬШИКОВ** Виктор Константинович (30.12.1874, Казан губ., Лаеш өязе Пановка а. – 22.2.1945, Казан), педиатр, медицина д-ры (1906), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Профессорлар П.М.Аргутинский-Долгорукий һәм И.Г.Савченко шәкерте. Казан педиатрлар мәктәбенә нигез салучы. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1898), ун-т каршындагы балалар клиникасында эшли, 1911 елдан клиниканың мөдире. 1918–20 дә Кызыл Хач җәмгыятенең Томск һәм Иркутскидагы хәрби госпитальләрендә. Иркутск ун-тында мед. ф-тын оештыручыларның берсе. 1920 дән Казан ун-тының мед. ф-тында балалар авырулары каф. профессоры, 1921–22 дә мед. ф-ты деканы урынбасары. Хезмәтләре кече яшьтәгеләр физиологиясен һәм патологияләрен өйрәнүгә, ашкайнату системасы авыруларын, диатез вакытында матдәләр алмашы бозылуны дәвалауга карый. Йогышлы авыруларны өйрәнә, дәвалау ысуллары тәкъдим итә. Бордә таякчыкларының аерымлык билгеләре барлыгын раслый, дипло-стрептококкның үзгә төрен ачыклый, кызамык б-н авырганда аңа аерым игътибар ителергә тиешлеке кисәтә. Балаларны дәвалаганда, беренче булып, бума ютәлгә каршы вакцина терапиясе куллана, анемия һәм башка авырулар вакытында кан салуны гамәлгә кертә. Скарлатинага каршы сыркынды ясап куллануны оештыручы һәм башлап кулланучыларның берсе. Татарстан балалар табибләре җәмгыятен (Бөтенсоюз җәмгыяте бүлеге, 1935) һәм Казанда балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыятен (1909–17) оештыручы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1945 тә Казан мед. ун-тының балалар клиникасына М. исеме бирелә.

Х е з м.: К бактериологии кори. К., 1906; О возбудителе коклюша // Русский врач. 1909. № 31; Новые достижения в области профилактики и серотерапии скарлатины // Казан. мед. журн. 1929. № 1.

*Әд.:* Профессор Виктор Константинович Меньшиков. К., 1989.

*В.Ф.Богоявленский.*

**«МЕҢ ДӘ БЕР КИЧӘ́»**, урта гасырлар гарәп әдәбияты ядкәре; һинд, фарсы һәм гарәп фольклоры мотивларына таянып, 8–9 йөзләрдә язылган *хикәйәтләр* җыелмасы. Аның барлыкка килүе озак еллар дәвамында фәнни дискуссия темасы була. Күпчелек белгечләр фикеренчә, җыентыкның нигезен якынча 9 йөздә гарәпчәдән фарсы (пәхләви) теленә тәрҗемә ителгән «Хәзар әф-санә» җыентыгы тәшкил итә. Ә ул, үз чиратында, һинд оригиналларына барып тоташа дип фаразлана (пәхләви телендәге текст бүгенге көннәргә кадәр килеп җитмәгән). Сюжет кысасын Шәһрияр хөкемдар һәм аның вәзиренең Шәһрезадә исемле зирәк кызы турындагы гарәп әкияте тәшкил итә. Үлемгә хөкем ителгән бу кыз 1001 кичә дәвамында Шәһриярга мавыктыргыч әкиятләр сөйли, әмма аларны иң кызыклы урынында бүлеп, туктап кала торган була. «М.д.б.к.»нең гарәп кулъязмаларының күбесе 17–19 йөзләргә, берничәсе ге-

нә 15 йөзгә карый (җыентык тулысынча төзелгән вакыт). Җыентыкка кергән хикәятләр әчтәлеге б-н 3 төргә бүленә: 1) тылсымлы әкиятләр һәм чыгышы б-н һинд яки фарсы әдәбиятына караган фантастик характердагы повестьлар; 2) янәсе Багдадта Һарун әр-Рәшид һәм аның вәзире Җафар б-н бәйле булган вакыйгалар (күбесенчә грекларның мәхәббәт темасына багышланган романтик хикәяләре); 3) мәмлүкләр заманында Каһирәдә булган вакыйгалар турындагы «шәһәр» әкиятләре. Җыелмага ш.у. аерым барлыкка килгән һәм мөстәкыйль әсәр булып танылган аерым әсәрләр дә кергән (мәс., диңгезче Синдбад, зирәк Хәйкәр турындагы әкиятләр һ.б.). 1987 елда «М.д.б.к.» әкиятләре Мәскәүдә 3 томда басылып чыга. «М.д.б.к.» әкиятләре бөтен дөньяга танылa, күпчелек халыкларның, ш.и. татарларның да фольклорына һәм әдәбиятына зур йогынты ясый. Төп сюжет һәм мотивлары татар әкиятләрендә, Мәҗлиси, Мөхәммәдъяр, К.Насыйри, Г.Тукай әсәрләрендә чагылыш таба. Татарчага төрек теленнән Ф.Халиди тарафыннан тәрҗемә ителә, беренче тапкыр 1897–99 да басыла.

Ә с ә р.: Мең дә бер кичә. К., 1958; 2004; Тысяча и одна ночь: В 3 т. М., 1987.

*Әд.:* Г о с т е р А., К р ы м с к и й А. К литературной истории «Тысячи и одной ночи». М., 1900; Э с т р у п И. Исследование о «1001 ночи», её составе, возникновении и развитии. М., 1904; М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993.

**«МЕҢ ДӘ БЕР КӨН»**, мажаралы *хикәйәтләр* җыентыгы; урта гасырлар фарсы әдәбияты ядкәре. Төзелеше б-н «Мең дә бер кичә»не хәтерләтә: «кысалы» композиция, төрле дәрәҗәдәге хикәяләрне каймалап алган кысалы кыйсса. Ике җыентыкта да бер үк яки охшаш геройлар катнаша, бердәй сәнгати чаралар файдаланыла, шуңа карамастан, «М.д.б.к.» мөстәкыйль идея-эстетик әһәмияткә ия. Аерым хикәйәтләре — «Кылаф берлә Диләрә», «Кылаф берлә Турандык», «Малик» — татарчага Ш.Рәхмәтуллин тарафыннан тәрҗемә ителә һәм XX йөзнең 1 нче чирегендә Казанда басылып чыга.

*Әд.:* М и н н е г у л о в Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993.

**МЕҢАЯКЛА́Р**, ике пар аяклы күбаяклыларның өч отрядының җыелма атамасы. Тропик, субтропик һәм уртача өлкәләрдә яшәүче 30 дан артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 11 төре бар. М. — трахея ярдәмендә сулаучы җир өсте буынтыгаяклылары. Гәүдә озынлыгы 1–30 *см*, һәркайсы (бишенчедән башлап) күпсанлы сегментлардан торучы гәүдә һәм баш өлешләргә бүленгән. Күкәйдән тудыручылар. Үсешләре, гадәттә, анаморфоз (личинкалары күкәйдән җитлеккән хайванга охшап чыга; кабык салган саен, аяклары һәм сегментлары арта бара) рәвештә бара. Җир өсте түшәлмәсендә яшиләр, үсемлек калдыклары б-н туеналар. Сирәк кенә үсемлек тамырларын зарарлыйлар. Киң яфраклы урманнарда, нигездә, болыннарда яшиләр. Тышчаларында кальций туплап, туфрак ясалу процессында катнашалар. Урта полосада соры меңаяк (Rossiulus kessleri) һәм ком меңаягы (Schizophyllum sabulosum) таралган.

*Әд.:* А л е й н и к о в а М.М. Почвенная фауна Среднего Поволжья. М., 1964; Л о к ш и н а И.Е. Определитель двупарноногих многоножек (Diplopoda) равнинной части Европейской территории СССР. М., 1969.

**МЕҢБА́Ш** (Vaccaria), канәферчәләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Европа, Урта диңгез буенда, Азиянең уртача поясларында үсә; ТРда бер төре — испан М.ы (V. hispanica), ул ш.у. чәчүле М. (V. segetalis) дип атала. Яфраклары күгелҗем-яшел, тоташ, кара-каршы урнашкан, сабагы туры, ботаклы, 30–60 *см* биеклектә. Чәчәкләре калкансыман көпшәк чәчәк төркемендә урнашкан. 5 канатлы кабыргалы касәсыман. Таҗлары тешле кайтарылма, алсу төстә. Июнь–июль айларында чәчәк ата. Бер үсемлеге 7,6 мең орлык бирә. Дару үләне буларак кулланыла (үләне — ялкынсынуга каршы, орлыклары — авыртуны туктата). Үләнен июнь–июль айларында, орлыгын августта җыялар. Тамыры агулы. М. язгы чәчүлекләрне чүпли (бигрәк тә тары һәм җитен); орлыклары культуралы үсемлекләр б-н бер вакытта өлгерә, тары һәм җитен орлыгыннан аеруы кыен.

*Әд.:* Б а к и н О.В., Р о г о в а Т.В., С и т н и к о в А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

**МЕҢБАШЫ́**, төрки-татар һәм монгол гаскәрләрендә хәрби дәрәҗә, *төмәннең* (10 мең) уннан бер өлеше булган гаскәри берәмлек башлыгы. Хәрби хезмәттә торган халәттә җир биләмәләренә ия була. Яу вакытында мең кешелек атлы гаскәр туплый һәм шуңа җитәкчелек итә. Шулай ук йөкләмәләр (гаскәрне азык-төлек, атлар, ат дирбияләре, кирәк-ярак б-н тәэмин итү) үти.

**МЕҢНӘ́Р** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 20 *км* көньяктарак, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 267 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, аучылык, күн аяк киеме җитештерү, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстиәннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында М.дә мәчет (1836 дан мәгълүм) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1936 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 175, 1859 да — 440, 1870 тә — 505, 1884 тә — 551, 1897 дә — 699, 1906 да — 761, 1913 тә — 821, 1920 дә — 818, 1926 да — 692, 1938 дә — 624, 1949 да — 380, 1958 дә — 367, 1970 тә — 516, 1979 да — 434, 1989 да — 279, 2002 дә — 270 кеше. М. янында *Меңнәр комплексы* урнашкан.

**МЕҢНӘ́Р КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Актаныш р-ны Меңнәр авылы янында Сөн елгасының (Агыйделнең сул кушылдыгы) сул кушылдыгында урнашкан. 1960–80 елларда Е.П.Казаков тарафыннан тикшерелә. Таш гасыр, Буралы курган, Чиркәскүл, Кушнаренко, Постпетрогром һ.б. археол. культуралар туктаулыкларын, торулыкларын һәм каберлекләрен үз эченә ала. М.к. терр-ясендә Урта Идел төбәгендә мезолит чорына караган иң борынгы кабер табыла. Фаразланганча, анда аучы җирләнгән; кабердән чакматаштан ясалган ук очлыклары, кыргыч, сөяк сөңге очлыгы, ерткыч хайваннарның казык тешләреннән җыелган асылмалар һ.б. чыга.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. Неолитические погребения в восточных районах Татарии // Советская археология. 1978. № 2; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989.

*Е.П.Казаков.*

**МЕҢЧЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,9 *км*, бассейнының мәйданы 42,4 *км*². Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Үрнәк авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Рус Мәнҗесе авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 70%. М.нең 0,7 дән алып 6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 94 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. М. ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*³/с. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**МЕҢЬЯФРА́К** (Achillea), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел һәм ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. 100 дән артык төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Калкулык М.ы (A. collina), гади М. (A. millefolium), ярмабашлы М. (A. nobilis), чәнечкеле М. (A. setacea) ара-тирә барлык районнарда очрый, тугай М.ы (A. inundata) һәм дала М.ы (A. stepposa) — респ-ка өчен сирәк төрләр. Болыннарда, аланнарда, урман буйларында, куаклар арасында, тау битләрендә, тораклар янында, юл буйларында үсәләр. 10–100 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлекләр. Тамырчасы нәзек, шуышма. Сабагы туры, күтәрелмә. Яфраклары гади, ланцетсыман, кыяк, бик күп сегментларга каурыйсы-



Гади меңьяфрак.

ман теленмә. Чәчәк кәрзиннәре вак, калкансыман чәчәк төркемендә: кырыйдагы чәчәкләре ялган телле, җимшәнле чәчәкләр — ак, сирәк кенә алсу, уртадагылары көпшәсыман, сары төстә. Җимеше — озынча орлыкча. Июнь–сентябрь башында чәчәк аталар. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамырчалардан) б-н үрчиләр. Җир өсте өлешләрендә ахиллеин алкалоиды, гликозидлар, эфир мае, органик к-талар, микроэлементлар бар. Барлык төрләре дә халык медицинасында кулланыла. Үлән төнәтмәсе кан туктату, тир чыгару һәм гомумныгыту чарасы буларак кулланыла. М. ашказаны һәм «аппетитны ачучы» чәйләр составына керә. Баллы, исле, инсектицид үсемлекләр.

**МЕРӘЛӘ́Р**, 1 нче — 2 нче меңьеллык урталарында Идел б-н Ука елгалары арасында яшәгән фин-угор кабиләсе. Византия тарихчысы Иордан (6 йөз), Көнбатыш Европа һәм рус чыганакларында (11–12 йөзләр) телгә алына. Төп шөгыльләре — игенчелек, терлекчелек, сунарчылык, 9 йөздән — Идел буйлап сәүдә итү. 10 йөз ахырында М. яшәгән җирләргә славяннар үтеп керә башлый һәм җирле халык акрынлап үз мәдәниятен югалта. М. 14–16 йөзләрдә, колонияләштерү һәм көчләп чукындырылу нәтиҗәсендә, руслар б-н кушылып, йотылып бетәләр. «Мерә» этнонимы Югары Идел топонимикасында сакланып кала. Иделнең югары агымы тирәсендәге терр-яләрдә М. б-н бәйле 100 дән артык археол. истәлек: торулыклар, шәһәрлекләр, каберлекләр бар. М.нең бизәнү әйберләре (калын һәм киң чигә алкалары, хайван һәм кош сурәтләре төшерелгән асылмалар, чәчкаплар) күрше кабиләләрнекеннән аерылып тора. 1 нче меңьеллыкта җирләү йоласы махсус корылмаларда — җир өстенә урнаштырылган «мәрхүмнәр йортлары»нда башкарыла, 10 йөздән мәетләрне бизәнү һәм көнкүреш әйберләре б-н бергә күмә яки яндыра башлыйлар. Мәетнең кабергә куелышы төрлечә.

*Әд.:* Корсаков Д.А. Меря и Ростовское княжество. К., 1872; Смирнов А.П. Очерки древней и средневековой истории народов Среднего Поволжья и Прикамья. М., 1952; Ярославское Поволжье в X–XI вв. М., 1963; Финны-угры и балты в эпоху средневековья. М., 1987; Рябинин Е.А. Финно-угорские племена в составе Древней Руси. СПБ., 1997; Леонтьев А.Е. Меря // Финно-угры Поволжья и Приуралья в средние века. Ижевск, 1999.

*И.Л.Измайлов.*

**МЕРӘ́С** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 12 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 71 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1738 елдан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында М.тә мәчет (1806 дан билгеле), мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 987 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1816 да — 144 ир-ат; 1859 да — 318, 1870 тә — 321, 1884 тә — 402, 1897 дә — 527, 1906 да — 520, 1913 тә — 508, 1920 дә — 411, 1926 да — 429, 1938 дә — 435, 1949 да — 321, 1958 дә — 262, 1970 тә — 226, 1979 да — 199, 1989 да — 138, 2002 дә — 90 кеше.

**МЕРӘ́С** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 261 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1731 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 ярма яргыч, әвен эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 964,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1870 тә — 367, 1897 дә — 527, 1913 тә — 645, 1920 дә 623, 1926 да — 452, 1938 дә — 452, 1949 да — 263, 1958 дә — 289, 1970 тә — 322, 1979 да — 247, 1989 да — 178, 2002 дә — 251 кеше.


**МЕРГА́СОВ ЙОРТЫ́**, Казандагы тарих һәм архит-ра истәлеге, 20 йөзнең 1 нче яртысындагы совет чоры архит-расы үрнәге. Шәһәр үзәгендәге Кремль урамыннан Черек күлгә илтүче калкулык битендә урнашкан. 1928 елда арх. Д.М.Фёдоров проекты буенча полковник Мергасовның элеккеге җир кишәрлегендә (Мергасов тыкрыгында) төзелгән 4 катлы, эргә каты да булган кирпеч йорт, исеме шушы шәхес фамилиясе б-н бәйле; Дзержинский урамы буенда. Йорт формасы П-рәвешендә, турыпочмаклы, баскычлы ишегалды хасил итә, Черек күл ягыннан таш баганаларга беркетелгән тимер рәшәткә б-н уратып алынган. Ишегалдына Дзержинский урамы ягындагы капка аша керелә. Күп фатирлы 7 подъездлы йорт 1930 еллар башындагы совет чоры архит-расы стилендә төзелгән. Һәр катта 2–3 бүлмәле берничә коммуналь фатир бар. Фасадлар штукатурланган, ритмлы тезелгән турыпочмаклы тәрәзәләр һәм озынча балконнар б-н тыйнак кына бизәлгән. Үзәк өлештәге төньяк фасад кыскыч рәвешендәге бизәкләр б-н төгәлләнгән бишенче катка үзенчәлек бирә, флангларда баскычлы блоклар б-н бүленеп алынган ике ризалитлы тар тәрәзә уемнары аерылып тора.

М.й.нда 1931–52 дә — татар язучысы, публицист, тәрҗемәче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты К.*Нәҗми*, 1938–41 дә — татар балалар язучысы А.Алиш яши. Илл. *Конструктивизм* мәкаләсеннән кара.

*Әд.:* Остроумов В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры. К., 1993.

*Л.М.Мортазина.*

**МЕ́РГЕЛЬ** (лат. marga — энҗеле), балчык һәм карбонатлы утырма тау токымы, балчык б-н охшаш, ләкин пластик сыйфатка ия түгел, тыгыз, җирсыман; 50–75% $CaCO_3$ һәм $MgCO_3$ (кальцит, сирәк кенә доломит) һәм 10% тан 70% ка кадәр балчыксыл кисәкчекләрдән тора. Минераль составы буенча М.не известьле һәм доломитлы, кушылмаларга бәйле рәвештә кремнезёмлы, глауконитлы, комташлы һ.б.га бүләләр. Төрле төстә, ешрак аксыл. Сай сулыкларда $CaCO_3$ ның утырымга төшүе нәтиҗәсендә хасил була. Пластсыман ятмалар хасил итеп, барлык яшьтәге утырмаларда очрый. Татарстан терр-ясендә мезозой һәм палеозой утырмаларында һәр җирдә таралган. 1970 елда Чүпрәле р-нында соңгы акбур



Шомартылган өслекле мергель (Татарстанның югары Пермь утырмаларыннан).

яшендәге цеолитлы мергель-кремнийлы токымнар билгеләнә, 1990 да биредә ТРда беренче цеолитлы токымнар чыганагы ачыла. М. цемент һәм вакташ җитештерүдә, эчәргә яраклы һәм агынты суларны чистарту, газны, һаваны киптерү һ.б. максатларда кулланыла.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

**МЕРЕЖИ́НСКИЙ** Михаил Фёдорович (9.6.1906, Таврия губ. Бакчасарай ш. — 31.7.1970, Минск), биохимик, мед. фән. д-ры (1943), СССР МФАнең мөхбир әгъзасы (1960). Одесса мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1930), шунда ук, биохимия кафедрасында эшли. 1934 елдан Украина ССР ФАнең Биохимия ин-тында. 1938 дән Молотов (хәзер Пермь) мед. ин-тында биохимия каф. мөдире, проф. (1943). 1944 тән СССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының Үзәк туклану фәнни-тикшеренү ин-ты директоры һәм биохимия каф. мөдире. 1945 тән Казан мед. ин-ты директоры (1947 гә кадәр) һәм биохимия каф. мөдире (1949 га кадәр). 1950 дән Минск мед. ин-тында. Хезмәтләре витаминнарны өйрәнүгә, майлар һәм липидлар алмашына карый. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Витамины и их участие в осуществлении процессов обмена веществ. Минск, 1954; Нарушение углеводного обмена при заболеваниях человека. Минск, 1967; Основы эндокринологии. Минск, 1967.

*Әд.:* Амиров И.Х., Саркин В.Г., Красильников С.Н. Десятый директор. Михаил Фёдорович Мережинский (1906–1970) // Ректоры Казанского медицинского института. К., 1994.

**МЕРЕЖКО́ВСКИЙ** Константин Сергеевич (23.7.1855, С.-Петербург — 10.1.1921, Жене-

ва ш.), ботаник, ботаника д-ры (1906). Петербург ун-тын тәмамлый (1880). 1902–14 елларда Казан ун-тында эшли, проф. (1906 дан). Хезмәтләре зоологиягә, антропологиягә, кремнийлы суүсемнәр һәм лишайникларны өйрәнүгә, үсемлек күзәнәгенең килеп чыгуы теориясенә карый. Ак диңгезгә, Балтыйк буе, Кырым, Калифорния, Италия, Полинезиягә (Гаити утравы һәм Гавай утраулары) һ.б.га оештырылган күп кенә экспедицияләрдә катнаша. М. тарафыннан 1909–13 тә Казан һәм аның тирәсеннән җыйналган лишайниклар коллекциясе Казан ун-тының Ботаника музеенда саклана. Симбиогенез теориясенә нигез салучыларның берсе, органик дөньяны 3 патшалыкка: микодалар (бактерияләр, зәңгәрсу-яшел суүсемнәр, гөмбәләр), үсемлекләр, хайваннарга бүлеп, үзенчәлекле система тәкъдим итә. Неотения һәм органнар олигомерлашуның эволюцион әһәмиятен күрсәтә. 1914 тән эмиграциядә.

Х е з м.: К познанию лишайников окрестностей Ревеля. К., 1909; Теория двух плазм как основа симбиогенеза — нового учения о происхождении организмов // Уч. зап. Казан. ун-та. 1909. Т. 76, кн. 12; Определитель главнейших лишаёв Средней России для студентов и начинающих. К., 1910; Конспективный курс общей ботаники. К., 1910. Ч. 1.

*Әд.:* Волков В.А., Куликова М.В. Российская профессура XVIII — нач. XX вв. Биологические и медико-биологические науки: Биогр. словарь. СПб., 2003.

*Э.И.Байбаков, А.П.Ситников.*

**МЕРЕТӘ́К** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Бырыс елгасыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 57 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1910 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1920 дә — 242, 1926 да — 250, 1938 дә — 229, 1949 да — 218, 1958 дә — 252, 1970 тә — 210, 1979 да — 123, 1989 да — 66, 2002 дә — 77 кеше.

**МЕРИ́НГИЯ** (Moehringia), канәферчәләр семьялыгыннан бер-, ике- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар: ян чәчәкле М. (M. lateriflora) һәм өч сеңерчәле М. (M. trinervia). Ара-тирә барлык районнарда да очрый. Дымлы урманнарда, куаклар арасында, елга тугайларында үсә. 10–30 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары йомыркасыман, очлы, өскеләре — утырма, астагылары саплы. Чәчәкләре ак, куентылы чәчәк төркемендә. Ян чәчәкле М.дә таҗ яфраклары касә яфракларыннан 2 тапкыр озынрак, өч сеңерчәле М.дә — кыскарак. Җимеше — күп орлыклы ачылучан капкачлы тартмачык. Май–июльдә чәчәк ата. Орлыклары июль–августта өлгерә. Ян чәчәкле М.нең тамыры, сабагы һәм яфракларында сапониннар бар. Тибет медицинасында сөяк авыруларын дәвалауда кулланыла.

**МЕРКУ́ШЕВ** Александр Максимович (14.11.1918, Казан губ., Лаеш өязе Рус Әшнәге а. — 1.5.1991, Белоруссия Респ-касы, Минск өлкәсенең Логой р-ны Плещеницы штп.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), майор. Командирлар составын камилләштерү (1942), Үзәк офицерлар составын камилләштерү (1956) курсларын тәмамлый. Сугышка кадәр Котлас (Архангельск өлкәсе) шәһәренең суднолар ремонтлау з-дында эшли. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 457 нче укчы полкта рота командиры (3 нче армиянең 129 нчы укчы дивизиясе). Брянск, Үзәк, 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Орёл, Брянск (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 28–29 июнендә Шатково авылы (Могилёв өлкәсе Бобруйск р-ны) һәм Бобруйск–Минск автомагистрале янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: чолганыштан чыгарга омтылган дошманның 13 һөҗүмен кире кайтара. 1959 дан запаста. Шәһәр тибындагы Плещеницы посёлогында яши. Ленин ордены, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Котлас шәһәренең мактаулы гражданы. Герой хөрмәтенә суднолар ремонтлау з-ды бинасына мемориаль такта куела.


*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Самый памятный день войны. М., 1970; Я г о д и н с к и й Е.А. Золотые Звёзды речников. М., 1981. Вып. 4; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МЕРКУ́ШИН** Михаил Алексеевич (18.12.1961, Горький өлкәсенең Городец р-ны Заволжье ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (2005). 1982 елда Горький театр уч-щесен тәмамлый. 1982–89, 1991–96 һәм 1997 дән — Казан, 1989–91 дә — Киров, 1996–97 дә Чиләбе яшь тамашачылар театрлары (ТЮЗ) актёры. Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә башкарган беренче рольләреннән үк (Шафиров — «Гуманоид күктә оча», А.Г.Хмелик; Цыганок — «Алёша Пешков», И.А.Груздев, О.Д.Форш; Гамир — «Китәм инде», Р.Хәмид; Лысенков — «Рядовойлар», А.А.Дударев) актёр-



М.А.М е р к у ш и н Ефимов ролендә («Неточка», Ф.М. Достоевскийның «Неточка Незванова» повесте буенча; сулда – Е.Крайняя).



А.М. Меркушев.



М.А. Меркушин.

ның яхшы проф. әзерлеге, актёрлык техникасын төгәл үзләштерүе, көчле темпераментка ия булуы күренә. М.га жанр табигатен нечкә тоемлау, төрле пландагы рольләрне башкаруда табигыйлек хас. Иҗат алымындагы үзирония ул тудырган образларга индивидуальлек, үзенчәлек бирә. Актёрның аеруча зур әһәмияткә ия булган тирән эчтәлекле рольләре — Сергей Белобрыков («Җимерү», Б.Л.Васильев повесте буенча), Несчастливцев («Урман», А.Н.Островский), принц Фердинанд («Давыл», У.Шекспир), герцог де Барблё («Төнге йола», М.Бартенев), Дуглас Макбейн («Пыяла читлек», Д.Б. Пристли), Розенкранц («Розенкранц һәм Гильденстернның үлеме», Т.Стоппард), Астров («Ваня абзый», А.П.Чехов). М. катнашкан «Давыл» спектакле «Алтын битлек» Милли бүләгенә лаек була (1996), ул ш.у. Финляндиядә (Хельсинки, 1995), Голландиядә (Амстердам, 1997) уздырылган халыкара театр фестивальләрендә катнаша.

**МЕ́РЛИН** Вольф Соломонович (22.1.1898, Могилёв ш. — 24.1.1982, Пермь ш.), психолог, психол. фән. д-ры (1950), проф. (1951). Петроград пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1924), А.И.Герцен исем. Ленинград пед. ин-тында эшли. 1932 елдан Саратов, 1938 дән Свердловск пед. ин-тларында, 1948 дән Казан ун-тында, 1954–82 дә Пермь пед. ин-тында, психол. каф. мөдире (1979 га кадәр). Хезмәтләре темперамент психологиясе, шәхеснең эксперим. психологиясе мәсьәләләренә, эшчәнлектә шәхси стиль проблемаларына карый. М. психик күренешләрнең физиол. күренешләргә «күпмәгънәле бәйләнеш»е принцибын аерып күрсәтә; бу принцип шәхеснең индивидуаль үзенчәлекләре оешмасының төрле — нейродинамик, психодинамик һәм шәхси дәрәҗәләре арасындагы бәйләнешләрнең катлаулы характерын ачарга ярдәм итә. Әлеге өлкәдәге тикшеренүләр кеше темпераменты концепциясен булдыруга китерә.

Х е з м.: Очерк психологии личности. Пермь, 1959; Очерк теории темперамента. М., 1964; Проблемы экспериментальной психологии личности. Пермь, 1970; Очерк интегрального исследования индивидуальности. М. 1986.

*Әд.:* К л и м о в Е.А. Штрихи к портрету В.С.Мерлина // Вопр. психологии. 1998. № 1.

**МЕСЕ́ТНИКОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре. **Анисим Кириллович** (1789, Казан өязе Мишаевка а. — 7.2.1858, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан, сәүдә киңәшчесе (1849). Крәстияннәрдән. Баш-

та сәүдәгәр В.А.Савиновта приказчик була. 1822 елда үз эшен башлый (агач савыт-саба б-н сәүдә итә). 1825 тә Казанда һәм Түбән Новгородта уен карталары сатарга рөхсәт ала. Кужерда пыяла ф-касы һәм Казан губернасының Царёвококшайск өязендә аракы з-ды сатып ала. 1849 да аның көмеш акча әйләнеше 300 мең сумга җитә (ипи, балык, май, шәраб, бакалея һәм киҗе-мамык, тимердән ясалган товарлар сәүдәсе). Казанда 6 таш йорты, Царёвококшайск өязендә 2 дачасы, 2600 дис. җире була. 1848–50 дә, 1857 дә Казан шәһәре башлыгы, бер үк вакытта Казан шәһәр җәмәгать банкы директоры. Ложкиннарның картлар йорты попечителе, төрмәләргә күзәтчелек һәм ярдәм җәмгыяте әгъзасы (1834 тән директоры).



А.К.Месетников.
Фоторәсем. ТР Милли музее фонды.

Ложкиннарның картлар йортына бина алырга көмеш б-н 25167 сум акча иганә итә (йорт аның акчасына тотыла). Император Казан икътисадчылар җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1841 дән). Өч алтын һәм бер көмеш медаль б-н бүләкләнә. **Пётр Анисимович** (1828, Казан — 23.1.1884) — 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан. Пыяла ф-касы, селте һәм аракы з-длары, Казанда 6 таш йорт һәм Царёвококшайск өязендә 2470 дис. урман хуҗасы. Идел буенда табаклы пыяла һәм пыяла савыт-саба җитештереп сатучы эре эшмәкәр. 1863–66 да Казан шәһәр магистраты бургомистры, 1865 тән Казан өязе һәм губерна земство җыеннары, 1871–84 тә Казан шәһәр думасы гласные. Казан шәһәр җәмәгать банкы, Идел-Кама һәм Дәүләт банкларының Казан бүлекчәләре идарәсе әгъзасы. Мария кыз балалар гимназиясе попечительләр советының идарә әгъзасы. Император Казан икътисад җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы. 2 «Тырышлык өчен» алтын медале б-н бүләкләнә.

Чыг.: Достойны памяти потомков (Городские головы Казани 1767–1917 гг.): Сб. док. и материалов. К., 2002.

*Әд.:* Агафонов Н.Я. Из Казанской истории. К., 1906; шул ук. Казань и казанцы. К., 1906. Вып. 1; Свердлова Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**МЕССА́РОШ** Дьюла (Meszaros Dyula) (1883–1957), венгр шәркыятьчесе, тюрколог, филол. фән. д-ры (1909). Чуаш халкының теле һәм ышанулары б-н кызыксына. 1906 елда татар телен өйрәнү максаты б-н Казанга килә, татар сөйләм һәм әдәби телләрен тикшерә. 1907 дә *Бәдигый Хуҗа* б-н бергә Түбән Курса авылында татар халык шигърияте, ышанулары, әфсен үрнәкләрен җыя, Урта Идел буена экспедициядә алар татар һәм чуаш халыкларының фольклорын, ышануларын һәм этнографиясен өйрәнәләр (1908 гә кадәр). Җыйган мәгълүматларга нигезләнеп, чуаш һәм татар телләренең һәм фольклорының үзара бәйләнешен тикшерә, ислам диненең чуаш ышануларына тәэсирен өйрәнә. Экспедиция һәм М. тикшеренүләренең нәтиҗәләре 20 йөз башында рус, чуаш һәм венгр телләрендә басыла.

Хезм.: Среди чувашей и татар Поволжья // Этнография. 1909. № 9; Сборник чувашского фольклора. Т. 1. Памятники старой чувашской веры. Чебоксары, 2000; Csuvas nepkoltesi gyüjtemeny. II. Kozmondasok, talalosmondasok, dalok, mesek. Bdpst., 1912.

*Әд.:* Бәдигый Хуҗа. Халык әдәбияты. 1 бүлек: Мәкальләр. К., 1912; шул ук. Сайланма хезмәтләр. Татар халык иҗаты әсәрләре. К., 2001.

*И.Н.Надыйров.*

**МЕСТЕ́ЧКО РАЙ́ФА** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Раифа күле буенда. 2010 елда 484 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 73%, татарлар — 23%) яши. 1920 елларда нигез салына. Халык саны: 1926 да — 171, 1949 да — 350, 1958 дә — 482, 1970 тә — 622, 1989 да — 674, 2002 дә — 593 кеше. Посёлок янында *Богородица пустыне* корылма ансамбле бар.

**МЕТАЛЛНЫ́ НӘФИ́С ЭШКӘРТҮ́ СӘНГАТЕ́**, металллардан һәм аларның эретмәләреннән — алтын, көмеш, бакыр, җиз, бронза һ.б.дан *уеплау*, чүкү, кою (к. *Кою сәнгате*), басып бизәк төшерү (к. *Басма*), *чүкеп бизәк төшерү*, калыплау юллары б-н әйберләр эшкәртү. Торевтика (антик сәнгатьтә еш кулланыла) — металлны чүкү, чүкеп бизәк төшерү, басып бизәк төшерү алымнары б-н рельефлы эшкәртү әлеге өлкәгә карый. М.н.э.с. киң мәгънәсендә *зәргәрчелек сәнгатен* дә үз эченә ала. Татар М.н.э.с.нең һөнәрчелектә югары үсеш алган борынгы традицияләре бар һәм алар корал, ат дирбиясе, көнкүреш җиһазлары, кием бизәкләре һ.б.ны әзерләгәндә киң кулланыла. Бизәк төшерелгән металл йорт җиһазы өй интерьерының бер өлеше булып тора, бәйрәмнәр һәм дини йолалар үткәргәндә кулланыла.

Татарстан терр-ясендә иң борынгы металл әйберләр *бронза гасырга* карый. Алар арасында Буралы курган, Чиркәскүл, Казан яны археол. культураларының борынгы кабиләләренә хас гади орнаментлы бизәнү әйберләре (беләзекләр, түгәрәк формалы аеллар, чигә асылмалары һ.б.) бар. М.н.э.с.нең аеруча үсеш алган формаларына Ананьино каберлегендәге табылдыклар арасыннан «җәнлек стилендәге» бронза бизәнү әйберләре, көзгеләр һәм кораллар, төрле җәнлекләрнең бизәлгән скульптур һәм рельефлы сурәтләре (поши, ат, бөркет, лачын һ.б.), Пьянобор һәм Азелино культуралары каберлекләреннән геом. һәм зооморф бизәкле өс киемнәре әйберләре (каптырмалар, күкрәк бизәкләре, акчалар, чигә асылмалары, алкалар һ.б.) керә. Кою техникасы б-н эшләнгән, уеплау, бөртекләү алымы б-н бизәлгән аз санлы бронза һәм көмеш бизәнү әйберләрен, корал һәм ат дирбияләрен Имәнкискә культурасы кабиләләре калдырган. Татар гамәли-бизәлеш сәнгатендә М.н.э.с. генезисы Евразиянең борынгы дала кабиләләре культурасына (Иссык, Ноин-Ула, Пазырык һ.б. курганнардан басма, уеплау, бөртекләү, җепкыр техникаларында бизәлгән «җәнлек стилендәге» сак-скиф әсәрләре), торевтика эшләнмәләренә, һуннар һәм болгарларга кадәрге археол. истәлекләрдә казу эшләре вакытында табылган бизәнү әйберләренә барып тоташа (Перещепин, Сентмиклош һ.б.). Олы Тархан, Танкеевка, Кайбыч һ.б. каберлекләрдән табылган төрле әйберләрдә «болгар җәнлек стиле», мифологик образлылык, геом. һәм үсемлек орнаментларының символик үрнәкләре (җәнлек һәм кош сурәтләре, «тормыш агачы», ике башлы кошлар һ.б.) Салтау-Маяк культурасы стилендә үсеш ала.


Идел буе Болгар дәүләтендә М.н.э.с. югары дәрәҗәгә җиткән металл эшкәртү кысаларында үсеш кичерә (тимерчелек, бронза кою, торевтика, зәргәрчелек, 14 йөздән — чуен эретү, к. *Болгар сәнгате*). Осталар Төньяк Европа, рус кенәзлекләренә, Урал һәм Себер халыкларына, Үзәк Азия илләренә җибәрү өчен үсемлек, җәнлек сурәтләре һәм эпиграфик орнаментлар б-н бизәлгән (басма, штамповка, чүкелгән бизәк, уеплау, сырлау, корлау һ.б.) тиңдәшсез эшләнмәләр (кечкенә йозаклар, көзгеләр, сувенир балталар, комганнар, бизәнү әйберләре, савыт-сабалар, шәмдәлләр) ясау өчен җиз, бронза, көмеш, сирәк кенә алтын, кургаш һәм аккургаш, тимер, ш.у. эретмәләр (алтын һәм көмеш) кулланалар. Җирле бакыр һәм тимер ятмалары, читтән кергән төсле металлар М.н.э.с. үсешенә этәргеч бирә. Алтын Урда чорында М.н.э.с. күчмә дала һәм утрак игенчелек культуралары традицияләрен берләштерү нәтиҗәсендә тулы үсешкә ирешә (к. *Алтын Урда сәнгате*). Аксөякләр өчен ясалган алтын һәм көмеш эшләнмәләр популярлык казана; шәһәр халкы арасында җиз һәм бронза савыт-саба киң тарала. Йорт кирәк-яракларының яңа төрләре — нәфис пропорцияле һәм силуэтлы, бай бизәкле ярымшарсыман савыт-саба, кубоклар, кувшиннар, шарсыман төпле савытлар, шәмдәлләр, асылмалы яктырткычлар һ.б. барлыкка килә. М.н.э.с. эшләнмәләрнең бизәгендә уеплау, рельефлы чүкеп ясау һәм басма ысуллары бик еш кулланыла. Чәчәк-үсемлек бизәкләре б-н бергә эпиграфик орнаментлар, яхшы теләкле язулар (аеруча көзгеләрдә), арабескалар киң файдаланыла. Казан ханлыгында М.н.э.с.нең үсеше турында рус елъязмалары («Казан тарихы») мәгълүматлары буенча фикер йөртергә мөмкин. Казан яулангачннан соң, Мәскәүгә гаять күп байлык, алтын-көмеш озатыла. Калган тиңдәшсез сәнгать әсәрләре музейлар фондларында сакланалар (Мәскәү Кремленең Кораллар палатасы, С.-Петербургтагы Россия халыкла-







































**Металлны нәфис эшкәртү сәнгате.** 1. Амфорасыман савыт. Көмеш. Чүкү, алтын йөгертү. Перещепино хәзинәсе (Кубрат хан хәзинәсе). 6 йөзнең 1 нче яртысы. Эрмитаж; 2. Билбау аелы. Бронза. Кою, уеплау. Пьянобор культурасы. Б.э.к. 3 йөз – б.э. 3 йөзе. ТР Милли музее; 3. Аждаһа сурәте төшерелгән аел. Бронза. Кою. Идел буе Болгар дәүләте. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 4. Асылма йозаклар. Бронза. Биләр ш. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 5. Мөһерләр. Бронза. Кою. Болгар ш. 12 йөз. ТР Милли музее; 6. Савыт. Бронза. Чүкеп ясалган бизәк, уеплау, каралту. 13 йөз. ТР Милли музее; 7. Савыт капкачы. Бронза. Чүкеп ясалган бизәк, уеплау. 14 йөз. ТР Милли музее; 8. Муенса асылмасы. Алтын. Чүкеп ясалган бизәк, уеплау, каралту. 14 йөз. Эрмитаж; 9. Кувшин. Бакыр. Чүкеп ясалган бизәк, уеплау. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Казандагы Ушкова йорты бинасындагы балкон рәшәткәсе фрагменты. Чуен. Кою, чүкү. Чабакса тимерчелек кәсепчелеге. 1908; 11. Р.Ә. К и л д е б ә к о в, Ю.В. Е ф р е м о в, В.В. К и с е л ё в. Казандагы «Татарстан» кунакханәсенең (банкет залындагы) дивар панносы фрагменты. Алюминий. Чүкеп ясалган бизәк, каюлы күн. 1970; 12. Г.Н. Б о г о р о д с к а я. «Николай Лобачевский» плакеткасы. Бронза. Кою. 2004; 13. И.Н. Б а ш м а к о в. Казанның Г.Тукай мәйданындагы сәгать. Чуен. Кою. 1999; 14. Ирләр бил каешы аелы. Көмеш. Басма, уеплау, кою. 16 йөзнең 1 нче яртысы. «Казан» милли мәдәният үзәге; 15. И.Н. Б а ш м а к о в «Казан» бүләк җыелмасы. Бакыр, җиз. Чүкү, кою. 2003.

ры этнография музее, ТРның Милли музее һ.б.). Бу, башлыча, уеплау, басма, җепкыр, каралту, челтәрле бизәк, асылташ б-н корлау техникасында купшы итеп бизәлгән татар аксөякләренең алтын һәм көмеш эшләнмәләре (к. *Казан ханлыгы сәнгате*), Казан ханнары тәхете, *Казан таҗы*, бил каптырмалары, бизәкле төймәләр һ.б. Казан ханлыгы яулангannan соң, патша боерыгы б-н, корал ясаудан саклану максатында татарларга һәм рус булмаган башка милләт кешеләренә кайнар ысул б-н металл эшләнмәләр ясау тыела. Казан губернасында һәр җирдә диярлек тимерчелек һөнәренең җирле традицияләре өзелә, һәм бу эш әкренләп рус осталары кулына күчә. М.н.э.с. халык нәфис кәсепчелеге рәвешендә Чабакса (к. *Чабакса һөнәр-сәнгать остаханәсе*) һәм Балык Бистәсе (к. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе*) авылларында үсеш ала. Йорт кирәк-яраклары (люстралар, фонарьлар һ.б.) һәм савыт-саба (су савытлары — гугумнар, комганнар, каһвә савытлары, каһвә тарткычлар, тәлинкәләр һ.б.) ясау б-н беррәттән, металлны ут б-н эшкәртү һәм корал, ш.и. салкын корал (кылычлар, хәнҗәрләр, пычаклар) эшләү Кырым татарлары көнкүрешендә 1944 елда алар Кырымнан сөрелгәнче саклана. М.н.э.с. эшләнмәләре чүкү, уеплау, җепкыр, сырлау һәм каралту ысуллары б-н еш кына кош, балык, кипарис һәм чәчәкләр, кайвакыт билге-бөтиләр үрнәгендәге (борынгы төрки Алласы Һомай) сюжетлы орнаменталь композицияләр б-н бизәлә. 17 йөз төрек сәяхәтчесе Әүлия Чәләби Бәлх, Бохара, Сәмәрканд, Луристан кебек шәрекъ һөнәрчелеге үрнәкләрен кабатлап атаклы коелма тимер казаннар эшләүче Чуенчы авылы (Кырым) турында яза. 19 йөздә тимерчелек һөнәре әкренләп Идел буе, Урал алды һәм Себер ягы татар авылларында һәм шәһәр бистәләрендә, ш.и. хәзерге Биектау р-нындагы *Тимерче* авылында, ш.у. Яшел Үзән, Апас һәм Тәтеш р-ннарындагы авылларда яңарыш ала. 19–20 йөз башының бакырчы, тимерче осталар көнкүреш әйберләрен, савыт-саба, ат дирбиясе бизәкләрен һ.б. чүкеп бизәк төшерү, уеплау, басма һәм сырлау техникасында эшлиләр (комганнар, кувшиннар, ләгәннәр, табагачлар, самоварлар, чәйнекләр, поднослар, чүмечләр, чиләкләр, тимер б-н тышланган сандыклар, күмер кыскычлар, капка һәм ишек тоткалары һ.б.), көмешчеләр һәм алтынчылар (к. *Зәргәр*) бизәнү әйберләре ясыйлар (чулпы, бил каптырмалары, тагылма бизәк, аеллар һ.б.). Бакыр, тимер һәм аның эретмәләре б-н беррәттән — җиз, 20 йөзнең 2 нче яртысыннан калай кулланыла. М.н.э.с.нең нәселдән килгән осталары, гадәттә, гаилә б-н эшлиләр; һәр авыл янындагы елга буенда 1–2 тимерчелек булган. 1920 елларда осталар артельләргә берләшәләр (1925 тә комган җитештерүче 32 артель оеша), ләкин күпләр аерым эшләүләрен дәвам итәләр. Бакырның кыйммәтлеге һәм фабрикада җитештерелгән металл йорт кирәк-яракларының таралуы бакыр сәнгать эшләнмәләренең әкренләп юкка чыгуына китерә. Аеруча калай һәм чуен эшләнмәләр киң тарала. 1940 еллардан соң, бакыр эшләнмәләр ясау яки төзәтү өчен борынгы акчаларны эретә башлыйлар. 1960 еллардан калай һәм чуеннан эшләнгән йорт кирәк-яраклары тарала башлый (мәс., комганнар). Осталар тимердән һәм калайдан ш.у. музыка уен кораллары — *кубызлар* һ.б.ны эшли башлыйлар. Металл б-н эшләүче халык осталары хәзерге вакытта, башлыча, комганнар, көнкүреш һәм хуҗалык кирәк-яраклары ясыйлар. Алар арасында — Татарстанның Балтач р-ны Салавыч Сәрдегәне авылыннан Шәйхетдин бабай, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль авылыннан Сәхап һәм Нуретдин Нәфыйковлар, Самара өлкәсе Иске Ярмәк авылыннан Салих Шакиров, Түмән өлкәсенең Яркәү р-ны Яңа Каешкүл авылыннан Газиз Мөхәммәтшин һ.б. таныла. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли музее тупланмаларында, районнарның туган якны өйрәнү һәм мәктәп музейларында җиздән, чуеннан, тимер һәм аның эретмәләреннән коеп, чүкеп ясалган һәм чүкеп бизәк төшерелгән борынгы әйберләр саклана. Араларында М.н.э.с. үрнәкләре дә бар.

М.н.э.с. өлкәсендә, башлыча, рәссамнар (*Ә.Бәширов*, *И.Башмаков*, Г.Богородская, И.Васильева, М.Зерзизов, В.Киселёв, *Е.Киселёва* һ.б.) эшли. 1960 еллардан башлап, җәмәгать һәм торак биналарының интерьерлары, кайвакыт экстерьерлары өчен дивар паннолары, композицион өстәлмәләр, тышлаулар (мәс., колонналарга), фәзаи конструкцияләр (бизәүле рәшәткәләр, киртәләр) һәм гамәли-бизәү юнәлешендәге предметлар (дивар тәлинкәләре, идән вазалары һ.б.) эшләгәндә чүкеп бизәк төшерү сәнгате киң кулланыла башлый. 1960 елларда җиздән чүкеп бизәк төшерү б-н Казан рәссамы А.Сысоев (станлы жанр характерындагы 70 тән артык әсәр иҗат итә), 1970–80 елларда рәссамнар Г.Арчуашвили (Түбән Кама ш.), Я.Зиннәтуллин (Лениногорск ш.), М.Шәйдуллин (Чаллы ш.), М.Мостафин (Әлмәт ш.) һ.б. шөгыльләнә. Казан сувенирлар ф-касы һәм Халык сәнгате кәсепчелегенең өйдә эшләүчеләр комбинаты үзешчән рәссамнары иҗатында чүкеп бизәк төшерелгән сувенирлар җитештерү киң кулланылыш таба (татар фольклоры үрнәкләре, тарихи сюжетлар һ.б.).

1980 еллар башында рәссамнар И.Башмаков, Г.Богородская иҗатында (Нефтьчеләр мәдәният йорты интерьерлары һәм Әлмәттәге «Татнефть» идарәсенең конференцияләр залы ишекләре, Арча р-ны Яңа Кырлай авылы рестораны, югары уку йортлары студентларының ашханәсе, «ЦУМ» Сәүдә үзәге рестораны, «Золотой бегемот» бары, Казандагы Сәнгать фонды фасады эмблемасы һ.б.) монументаль-бизәлешле М.н.э.с. үсеш ала (кече скульптура, рельеф, яктырткычлар, фонарьлар, идәнгә куела торган бакыр вазалар — җиз, бронза, алюминий, корыч). Рәссамнар чүкү, эретеп ябыштыру, штамплау һәм кою технологиясен актив куллананалар, төрле металларны, металлны агач һәм пыяла б-н аралаштырып, композициягә тематик сюжетлар кушалар. М.н.э.с.ннән вак пластик эшләнмәләр, декоратив кирәк-яраклар (тәлинкәләр, вазалар, шәмдәлләр, шкатулкалар), Коръән тышлыклары, дивар паннолары, сувенирлар (И.Васильев, С.Евдокимов, И.Фазылҗанов, З.Хөсәенов һ.б.) эшләнә. Казанда М.н.э.с. 2000 нән Казан сәнгать уч-щесендә укытыла.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Фёдоров-Давыдов Г.А. Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Гарифуллин И. Из истории хозяйственной жизни татарского населения Тюменской области. Тюмень, 1996; Руденко К.А. Металлическая посуда Поволжья и Прикамья в XIII–XIV вв. К., 2000; Заатов И. Крымско-татарское декоративно-прикладное и изобразительное искусство. Симферополь, 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МЕТА́Н**, саз газы, рудник газы, $CH_4$, янучан табигый газ. Җир кабыгында ирекле тупланмалар (ятмалар), эрегән (нефтьтә, пластларда һәм җир өсте суларында), сибелгән, бөртексыман (токымнар, органик матдәләр) һәм каты (газлы гидратлы) халәттә очрыйлар. Җир астында метаносфера хасил итә (1982 дә Казан галиме Б.М.Йосыпов тарафыннан билгеләнә). Һава буенча тыгызлыгы 0,555 (20 °С та). Эрү темп-расы 182,5 °С, кайнау — 164,56 °С, критик — 82,4 °С, кабыну — 187,8 °С, ялкынсыну — 837,8 °С, таркалу темп-расы 600 °С. Нефтьтә эрүчәнлеге суга караганда 10 тапкыр күбрәк. Чагыштырмача яну җылылыгы ташкүмергә караганда 2,5 тапкыр зуррак (50,5 *МДж/кг*). Һава б-н бергә (5–16% булганда) шартлаучан катнашмалар хасил итә, бу исә шахталарда һәм казылмаларны баета торган комбинатларда шартлауга китерә. М.ның төп массасы сибелгән органик матдәне, күмер һәм нефтьне микроорганизмнар таркатуы вакытында, ш.у. Җирнең тирәндәге зоналарында барлыкка килә.

Татарстан терр-ясендә янучан газ ($CH_4$) чыгышлары 19 йөз башыннан билгеле: Зөя р-ны терр-ясендә газ кабынып китә, 2 ел дәвамында сүндерә алмыйлар, һәм авыл башка урынга күчерелә. 19 йөздә Пермь утырмаларында бораулау вакытында һавага М. чыгу күзәтелә. 20 йөздә М. катнашмалары палеозойның борынгы утырмаларында һәм кристаллик нигезнең чатнаган токымнарында билгеләнә. М. химия сәнәгате продуктлары: хлороформ, ацетилен, формальдегид, корым һ.б. алу өчен чимал һәм ягулык буларак кулланыла. Ш.у.к. *Янучан табигый газлар*.

*Әд.:* Юсупов Б.М., Веселов Г.С. Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1973.

**«МЕТЕО́Р»**, сәяси, әдәби-нәфис һәм сатирик журнал. 1906 елның сентябреннән 1907 нең июненә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 7 саны чыга. Даими басылмый: 1906 да — 3, 1907 дә 4 саны дөнья күрә. Нашир-мөхәррире булып Н.А.Скворцов исәпләнә, чынында мөхәррирләре Н.Е.Воронцов, А.Ф.Ярославцев була. Авторлары арасында — сатириклар А.С.Бухов, Е.Пяткин, шагыйрь Н.С.Охотин (псевд. Изгнан-

ник). Мәкаләләренең күбесе псевд. б-н чыга. Цензура журналны «артык сул» дип бәяли, 2 нче санның тышында «Яшәсен ирек!» дип аваз салучы эшче сурәтләнә. 1906 ның октябрендә, 3 нче сан чыкканнан соң, редакция хезмәткәрләре кулга алына. Соңгы саны 1907 нең маенда чыга. Журнал төсле рәсемнәр һәм карикатуралар б-н бизәлә. Рәсемнәрнең авторлары арасында — танылган рәссам А.И.Трапицын.

*Әд.:* Б е й с о в П.С. Свободное слово бессмертно: Из истории революционной литературы в старом Симбирске, 1905–1912 гг. Саратов, 1966; А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. Всё началось с путеводителя... К., 1975.


*Р.А.Айнетдинов.*

**МЕТЕОРИТЛА́Р** (грек. meteо́ra — атм. күренешләре), а э р о л и т л а р, кояш системасының космик җисемнәре — Җиргә, Айга төшүче астероид, планетаара бушлыктагы башка планеталар һәм аларның иярченнәренең кисәкләре. Тәүлек саен Җиргә 1 дән 10 меңгә кадәр планетаара матдә төшә, шуларның 75% ының диаметры 0,1 *мм* дан кечерәк. 3 меңнән артык зур М. билгеле, иң зурлары — авырлыгы 60 *т*, күләме 9 $м^3$ булган Хоба (көньяк-көнбатыш Африка) һәм Тунгус (Себер) М.ы. Җирнең тирән токымнарында нинди химик элементлар булса, М. составында да шулар бар, Fe һәм Ni өстенлек итә. Составы һәм төзелеше буенча тимер, таш, тимер-таш, пыяласыман һәм күмерле М.га аерыла, соңгыларында 30 төрдәге аминокислота (алардан исә Җирдә тере организмнар барлыкка килергә мөмкин) һәм ароматик углеводородлар бар. ТР терр-ясендә 4 М. (барысы да таш) табыла: «*Каенсаз*» (иң зурысы), «Мөслим» (10,9 *кг*, 1964 тә Мөслим р-нында табыла), «Ивановка» (9 *кг*, 1983, Тәтеш р-ны), «Чуаш Кисасы» (5,5 *кг*, 1899, Аксубай р-ны). Бу М.ның төп массасы РФАнең М. буенча ком-ты коллекциясендә, кисәкләре Казан ун-тының геология музеенда саклана.

*Әд.:* Каталог метеоритов коллекций Советского Союза. М., 1986.

*Е.С.Шуликов, Е.О.Смышлявкина.*







Метеоритлар. 1. «Чуаш Кисасы»; 2. «Мөслим»; 3. «Ивановка».

**МЕТЕОРОЛО́ГИЯ** (грек. metēōra — атм. күренешләре һәм ...*логия*), Җир атмосферасы, анда барган физик процесслар һәм күренешләр турындагы фән. Атм.ның составын һәм төзелешен, анда һәм җир өслегендә җылылык әйләнешен һәм режимын, дымлылык әйләнешен һәм суның фаза әверелешләрен, һава массалары хәрәкәтен, атм.да электрик, оптик һәм акустик күренешләрне өйрәнә. М.нең төп бүлекләре: атм. физикасы (атм. күренешләренең гомуми закончалыкларын өйрәнә), синоптик М. (һава торышы һәм аны фаразлау алымнары), *климатология* (Җир шары климаты) мөстәкыйль фәннәр буларак өйрәнелә. Гамәли М. фәннәренә авиация М.се, космик М., хәрби М., мед. М.се, агрометеорология һ.б. керә.

Татарстанда М.нең үсеш тарихы Казан ун-ты б-н бәйле. 1805 елда метеорология станциясе (И.И.Запольский, Ф.К.Броннер) эшли башлый. 1812 дә аның җирлегендә Казан ун-тының *Метеорология обсерваториясе* оештырыла. Бер үк вакытта Казан уку-укыту округының метеорология челтәре булдырыла (Н.И.Лобачевский, А.С.Савельев). *Казан метеорология фәнни мәктәбенә* нигез салына. 1828 дән башлап даими геомагнитик күзәтүләр алып барыла (А.Я.Купфер, И.М.Симонов, Э.А.Кнорр, В.А.Ульянин). 19 йөзнең 2 нче яртысыннан аэрологик (И.А.Больцани), синоптик (И.Н.Смирнов) М.гә нигез салына. 1920–50 дә Татарстан климатының үзенчәлекләре өйрәнелә (П.Т.Смоляков, О.А.Дроздов һ.б.). 1950–60 елларда сусаклагычларның метеорологик һәм гидрологик режимы, респ-каның агроклиматик ресурслары тикшерелә. 1960–2000 елларда глобаль һәм региональ климат, зур масштаблы атм. күренешләренең динамикасы һәм энергетикасы, яңара алучан энергия чыганаклары һәм атм. экологиясе буенча мәсьәләләр гомумиләштерелә (Н.В.Колобов, Ю.П.Переведенцев һ.б.).

*Әд.:* М а т в е е в Л.Т. Физика атмосферы. СПб., 2000; П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Метеорология в Казанском университете: Становление, развитие, основные достижения. К., 2001.

*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**МЕТЕОРОЛО́ГИЯ ОБСЕРВАТО́РИЯСЕ** К а з а н у н и в е р с и т е т ы к а р ш ы н д а, ун-тның физика кабинеты каршында 1805 елда И.И.Запольский тарафыннан оештырылган метеорология станциясе җирлегендә 1812 елның 1 гыйнварында булдырыла.Өзлексез күзәтүләр алып барылу (1828 дән) буенча, С.-Петербург (1743 тән) һәм Мәскәү (1779 дан) обсерваторияләреннән соң, Россиядә алдынгы урыннарны алып тора. Беренче күзәтүләрне студентлар — булачак физика һәм матем. укытучылары үткәрә. 1811 нең августыннан проф. Ф.К.Броннер (М.о.н 1812–17 дә җитәкли) инициативасы б-н күзәтү материаллары «Казанские известия» г-тасында басыла башлый. Обсерваториянең формалашуы А.Я.Купфер (1821 дә тукталган метеорологик күзәтүләрне 1827 дә кабат башлап җибәрә), Н.И.Лобачевский (күзәтүләр программасын киңәйтә, биметалл туфрак термометрын уйлап таба), Э.А.Кнорр (Казан укыту округы терр-ясендә метеорология станцияләре челтәрен оештыруга һәм үткәрелгән күзәтүләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштерүгә беренче омтылышларны ясый) эшчәнлеге б-н бәйле. Соңыннан А.Я.Купфер дөньяда һәм Россиядә беренче регуляр геофизика челтәрен һәм метеорология хезмәтен (1834) оештыра, Баш физика обсерваториясенә (1849) нигез сала һәм аның беренче директоры була. 1830 еллардан М.о. Россиянең көнчыгыш өлешендә метеорологик өйрәнүләрнең фәнни-методик һәм оештыру үзәгенә әйләнә. 1846–55 тә М.о.не А.С.Савельев җитәкли, аның вакытында исә метеорологик үлчәүләр тәүлеккә 5 тапкыр (3 урынына) үткәрелә башлый. Оешып килүче метеочелтәрне ныгытуга И.А.Больцани (1855–76) һәм И.Н.Смирнов (1864–80) зур өлеш кертә. 1870 тән күзәтүләр бөтен Россия өчен бердәм инструкция буенча үткәрелә башлый, ә М.о.нең күзәтү материаллары Баш физика обсерваториясе тарафыннан чыгарыла торган «Летопись»та («Елъязма») нәшер ителә. М.о. мәгълүматлары Россиянең танылган климатологлары Г.И.Вильд, К.С.Веселовский, А.И.Воейков хезмәтләрендә чагылыш таба. Р.А.Колли инициативасы б-н кояш энергиясе ташкынын күзәтүләр башлана. М.о. б-н Ф.М.Цомакин җитәкчелек иткән елларда (1881–91) туфрак темп-расын һәм парга әйләнүне күзәтүләр дә өстәлә. 1885 тә «Казан университетының магнит-метеорология обсерваториясе күзәтүләре» («Наблюдения магнитно-метеорологической обсерватории Казанского университета») комплекслы җыентыгы нәшер ителә башлый: 1882–83 тә М.о. Халыкара поляр ел чараларында катнаша. 1891 дә Н.П.Слугинов вакытында Россиядә ун-т обсерваторияләре арасында иң яхшысы булган яңа обсерватория төзелә. 19 йөз ахырында Д.А.Гольдгаммер тарафыннан Казан губернасында 23 метеостанция оештырыла. 1897 дән «Россиянең Көнчыгыш челтәренең айлык бюллетене» («Ежемесячный бюллетень сети Востока России») һәм «Россиянең Көнчыгыш метеорология челтәре хезмәтләре» («Труды метеорологической сети Востока России») нәшер ителә, чит илләр б-н басмалар алмашу башлана. М.о. 1923 тә университетта оештырылган геофизика кафедрасы (хәзер метеорология, климатология һәм экология кафедрасы) составына керә. 20 йөздә М.о. үсешенә өлеш кертүчеләр: В.А.Ульянин (М.о.н 1897–1931 дә җитәкли), П.Т.Смоляков (1933–34 һәм 1936–52), Н.В.Колобов (1952–78), Ю.П.Переведенцев (1978 дән). Казан ун-тының М.о. Идел буеның 15 губернасы, Кавказ, Урал һәм Себер терр-яләрендә метеочелтәрләр оештыру-

да, ш.у. Рус тигезлегенең көнчыгышында табигать күренешләрен һәм климатын тикшерүдә әһәмиятле роль уйный. Хәзерге вакытта М.о. материаллары Казан шәһәре климатын, табигый һәм антропоген факторлар йогынтысы астында аның үзгәрешләрен өйрәнүдә киң кулланыла. Обсерватория студентлар өчен уку практикасы базасы булып тора. Ш.у.к. *Казан метеорология фәнни мәктәбе.*

*Әд.:* Смоляков П.Т. К 125-летию Метеорологической обсерватории Казанского государственного университета им. В.И.Ульянова-Ленина // Уч. зап. Каз. ун-та. 1936. Т. 96, кн. 1; 150 лет Метеорологической обсерватории Казанского университета. К., 1963; Переведенцев Ю.П., Наумов Э.П. К 190-летию Метеорологической обсерватории Казанского университета // Метеорология и гидрология. 2002. № 5.

*Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.*

**«МЕТО́ДИК ҖЫЕНТЫ́К»**, пед. журнал. Урта Идел буе төбәге халык мәгарифе бүлеге органы. 1930 елда — Мәскәүдә, 1931–33 тә Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. 1931 дә «*Методика юл күрсәткече*» исеме б-н чыга. Мөхәррире — А.М.Вәлитов. Мәгариф эше, алдынгы мәктәп укытучылары һәм башка мәгариф хезмәткәрләренең тәҗрибәсе һәм эш нәтиҗәләре б-н таныштыруны максат итеп куя. Актив авторлар арасында — А.Вәлитов, Ф.Давыдов, К.Чигурин. «М.җ.»та коллективлаштыру һәм аның укыту процессындагы ролена, мәктәпләрдә дингә каршы тәрбиянең куелышына, мәдәни төзелешләр өлкәсендә соц. ярышлар үткәрүгә һ.б.га багышланган мәкаләләр дөнья күрә.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МЕТО́ДИК ҖЫЕНТЫ́К»**, пед. журнал. Свердловск фәнни-тикшеренү пед. ин-ты органы. 1933–34 елларда Свердловск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Насыйров Т. Утызынчы елларда татар матбугатын буу // Идел. 2002. № 7.

**«МЕТО́ДИК ЮЛ КҮРСӘТКЕЧЕ́»**, журнал. К. «*Методик җыентык*».

**МЕТРӘ́Й** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Казанчы елгасы буенда. 2010 елда 607 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә 2 мәчет, 2 мәктәп, мәдрәсә, 3 су тегермәне, 5 ярма яргыч, 2 постау басу бинасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5529,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 509, 1897 дә — 949, 1913 тә — 1317, 1920 дә — 1298, 1926 да — 1248, 1938 дә — 1460, 1958 дә — 750, 1970 тә — 864, 1979 да — 703, 1989 да — 653, 2002 дә — 612 кеше.

**МЕТРОЛО́ГИЯ** (грек. métron — үлчәм һәм ...*логия*), үлчәүләр, аларның бердәмлегенә һәм таләп ителгән төгәллегенә ирешү юллары турындагы фән. Үлчәүләр турында борынгы рус язма истәлекләрендә, елъязмаларда, рус кенәзләренең грамоталарында искә алына. Борынгы Русьта үлчәүләрнең дөреслеген күзәтү эше руханиларга йөкләнгән була. 15 йөздә, үзәкләштерелгән Рус дәүләте оешу б-н, үзәк хакимият органнары барлыкка килә, яңа кушылган шәһәрләр хисабына дәүләт акчалары әйләнеше арта, таможня пошлиналарыннан керем күбрәк керә; үлчәүләрнең дөреслеген күзәтү эше акрынлап дөньяви хакимияткә күчә. Иван IV заманында (16 йөз) язмача кабул ителгән үлчәүләр, камил үрнәкләр булмаса да, илдә бердәм үлчәү системасын урнаштырырга ярдәм итә. Россиядә үлчәүләрне оешкан дәүләт күзәтчелегенә алу омтылышы Пётр I заманына (18 йөз башы) карый, бу чорда үлчәүләр системасы Англия системасы б-н яраклаштырыла. Европаның башка дәүләтләре Англияне Россия б-н монополистик сәүдә итүдән кысрыклый барган саен, Россиядә үлчәүләр системасын Европа кабул иткән системага тәңгәлләштерү зарурлыгы туа. 1875 елда Парижда Метрика конвенциясе кабул ителүгә һәм халыкара үлчәүләр бюросы оештырылу хәлиткеч вакыйга була. Россиянең бөтен терр-ясе буйлап үлчәүләрнең җирле тикшерү палаткалары, ә Мәскәүдә Баш үлчәүләр тикшерү палатасы оештырыла (хәзер Д.И. Менделеев исем. Бөтенроссия метрология фәнни-тикшеренү ин-ты). Д.И.*Менделеев* дәүләт үлчәүләр хезмәте үсешенә зур йогынты ясый. Аның тырышлыгы б-н 1902 дә Казанда 16 нчы номерлы Казан үлчәүләр тикшерү палаткасы төзелә, палатканың эшчәнлеге дәүләт хезмәте рангына күтәрелә һәм Казан, Сембер, Вятка, Самара губерналарына җәелдерелә. Соңыннан бу палатка үлчәү техникасы буенча Татарстан дәүләт контроль лаб-ясе итеп үзгәртелә, 1966 да аның җирлегендә Бөтенсоюз физик-техник һәм радиотехник үлчәүләр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лы (к. *Бөтенроссия чыгым үлчәү институты*), ш.у. Стандартлар һәм техника өстеннән дәүләт күзәтчелеге идарәсе (1975 тән — Урта Идел стандартлаштыру һәм метрология үзәге (оештыру-техник һәм метрологик җитәкчелек функцияләре б-н), 1995 тән — Татарстан стандартлаштыру, метрология һәм сертификация үзәге) төзелә. 1966 дан — «Эталон» Казан тәҗрибә з-ды, 1989 дан «Россертифико» Нефть продукциясен сынау һәм сертификацияләү үзәге эшли башлый. Тарихи, законлы, теоретик һәм гамәли М.ләр аерып өйрәнелә. Тарихи М. төрле илләрдә кулланыла торган озынлык, мәйдан, күләм, масса һ.б.ның берәмлекләрен аларның тарихи үсешендә өйрәнә, алар арасындагы нисбәтләрне ачыклый, хәзерге берәмлекләргә китерә, атамаларның килеп чыгышын өйрәнә. Законлы М. үлчәүләрнең бердәмлегенә, дәүләт билгеләгән һәм күзәтүдә торган үлчәү чараларының бертөрлелегенә ирешү б-н бәйле мәсьәләләрне карый. Теоретик М.нең бурычлары: үлчәү техникасының берәмлекләр системасының, үлчәү чаралары эталоннары һәм үрнәкләренең теоретик нигезләрен булдыру һәм камилләштерү; үлчәү берәмлегенең үлчәмен эталоннан эшче үлчәү чараларына күчерүнең фәнни нигезләрен булдыру; үлчәүләрдәге хаталар теориясен вакыт эчендә үзгәрүләрен исәпкә алып үстерү. Теоретик М.дә фәнни юнәлешләрнең берсе — куплап үлчәүләр өчен җитештерүчәнлекне һәм төгәллекне күтәрү максатында автоматлаштырылган үлчәү чаралары булдыру; шул ук вакытта үлчәү чараларының ышанычлылыгы (күрсәтүләрнең дөреслеге) теориясе дә үстерелә. Үлчәүләрнең электрик алымнары һәм мәгълүматны автоматик җыю-эшкәртү системаларының үсеше яңа фәнни юнәлеш — автометрия барлыкка килүгә сәбәп була. Автометриянең бурычлары: мәгълүмат-үлчәү системаларының алымнарын һәм бәяләү критерийларын төгәллек, тизлек, ышанычлылык һ.б. яктан чыгып эшләү; үлчәү, тикшерү һәм диагностика өчен оптималь алгоритмнар булдыру. Очраклы һәм системалы хаталар б-н көрәшү алымнары да шактый үстерелә. Гамәли М. конкрет үлчәүләр һәм үлчәү системаларының төгәллеген гарантияләү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә; технол. процессларның тотрыклылыгын, җитештерүчәнлеген һәм нәтиҗәлелеген тәэмин итә, бу исә тикшерү параметрларын дөрес сайлап алуга, тиешле үлчәү-тикшерү аппаратурасы б-н җиһазландыруга бәйләнгән. Болары газ турбиналы двигательләрнең стенд сынауларында, принципиаль яңа технол. процессларның (плазма һәм лазер б-н эшкәртү, плёнкалы технология, үтә югары басым астында, вакуумда эшкәртү һ.б.) параметрларын тикшергәндә аеруча мөһим. Казан авиация технологияләре ин-тында Г.М.Заһретдинов җитәкчелегендә нәсызыкчалык хаталарын төзәтеп күчмә уртачалаштыру; экспоненциаль тигезләү (соңгы нәтиҗә таләп иткән төгәллекне канәгатьләндерүче оптималь тигезләү параметрлары б-н) алымнары эшләнә; газ турбиналы двигательләрнең дроссель характеристикаларын автоматик исәпләгәндә һәм төзегәндә үлчәүләрнең аномаль нәтиҗәләрен төшереп калдыру алымнары тәкъдим ителә; үлчәү нәтиҗәләрен эшкәртүдә мажоритар логика һәм үлчәүләр санын нәтиҗәләрнең чынбарлыкка иң якын торырга тиешлегеннән чыгып оптимальләштерү алымнары булдырыла. Бу алымнарны гамәлгә кертү үлчәү нәтиҗәләренең төгәллеген 20 % ка, тикшерүләр дөреслеген 10 % күтәрергә мөмкинлек бирә. Автоматлаштырылган метрологик аттестация һәм газ турбиналы двигательләрнең стенд сынаулары өчен үлчәү каналларын дөресләү системасы эшләнә, һәм ул метрологик аттестация вакытын 50 тапкырдан артыкка кыскарту мөмкинлеге бирә, үлчәүләрнең төгәллеген һәм дөреслеген күпкә күтәрә. Бу хезмәтләр Татарстанның сәнәгать пр-тиеләрендә, ш.и. Казан моторлар төзү җитештерү берләшмәсендә, Казан компрессор машиналары төзү з-дында гамәлгә кертелгән. Ш.у.к. *Нәметрик үлчәү системасы.*

*Әд.:* Коротков В.П., Тайц Б.А. Основы метрологии и точности механизмов приборов. М., 1961; Агекян Т.А. Основы теории ошибок для

астрономов и физиков. М., 1972; Бугдун Г.Д., Марков Б.Н. Основы метрологии. М., 1972; Иванов А.И. Основы теории точности измерительных устройств. М., 1972; Орнатский П.П. Теоретические основы информационно-измерительной техники. Киев, 1976; Тойберт П. Оценка точности результатов измерений. М., 1988; Пиотровский Я. Теория измерений для инженеров. М., 1989; Новицкий П.В., Зограф И.А. Оценка погрешностей результатов измерений. Л., 1991.

**МЕТРОПОЛИТЕ́Н**, метро (фр. metropolitain, сүзгә-сүз — башкаланыкы, грек. mе́tropolis — төп шәһәр, башкала сүзеннән), урамга кертелмәгән рельслы пассажирлар транспорты. М. линияләре җир астыннан, өстеннән һәм эстакадалардан уздырыла. Россиядә М.нар Мәскәүдә, С.-Петербургта, Екатеринбург, Самара, Казан, Түбән Новгород, Новосибирскида эшли һәм төзелеш дәвам итә. Яңа М.нар Красноярск, Омск, Чиләбе, Уфа шәһәрләрендә төзелә.

Казанда метро төзелеше 1983 елда, Шәһәрнең комплекслы транспорт схемасы («ГИПРОкоммундортранс» ин-ты тарафыннан эшләнә) кабул ителгәннән соң башлангыч ала. 1984 тә уйланылган төзелеш трассасында — беренчел, 1988 дә комплекслы тикшеренүләр уздырыла. 1987 дә, СССР Аралашу юллары министрлыгы Казанда М. төзүнең техник-икътисади нигезләмәсен («МетроГИПРОтранс» ин-ты тарафыннан эшләнә) раслаганнан соң, «Горьковметропроект» ин-ты М.ның беренче линиясен проектлауга керешә. СССР МСның финанслауны һәм илнең төзелешен туктату турындагы карары нигезендә 1989–95 тә эшләр туктатылып тора. 1996 да проект эшләнеп бетә һәм раслана, шул ук елның декабрендә 1997–2023 тә Казанда М. төзү турында хөкүмәт Программасы кабул ителә. М.ның ген. проектлаучысы итеп «Казгражданпроект» ин-ты билгеләнә.

1997 дә «Казметрострой» пр-тиесе оештырыла. Төзелеш зонасындагы инженерлык һәм транспорт коммуникацияләрен күчерү буенча беренче чираттагы эшләр, метро трассасын билгеләү буенча геодезия-маркшейдерлык эшләре башкарылып, станцияләрдә чокырлар казылганнан соң, 2000 нең 22 маенда «Сукно бистәсе» станциясеннән «Тукай мәйданы» станциясе ягына туннель казу башлана. Эшләтә башлау участогын казыганда 5 туннель казу комплексы (ТКК) һәм 3 казу калканы файдаланыла. 2004 тә, туннельләрне казуны төгәлләү б-н бергә, эшләтә башлау участогы төзелешенең архит-ра-төзелеш эшләрен, юллар сузуны, туннельләрне һәм станцияләрне технол. җайланмалар, автоматлаштырылган идарә, сигналлар һәм элемтә, үткәрү һәм контроль системалары б-н тәэмин итүне үз эченә алган икенче этабы башлана. Казан М.ының беренче линиясенең эшләтә башлау участогы төзелешендә «Казтрансстрой» пр-тиеләре (депо төзү), «Волгомост» АҖнең 3 нче Мостоотряд ф-лы («Әмәт» станциясен төзү), «Татэлектромонтаж» (электр б-н тәэмин итү линияләрен сузу һәм электр җиһазларын урнаштыру), ш.у. РФ (Мәскәү, Самара, Түбән Новгород, Пермь, Сочи), Казакъстан, Төркия пр-тиеләре һ.б. катнаша.





Метро станцияләренең перрон заллары. 1. «Кремль»; 2. «Тукай мәйданы».

Казандагы туннельләр һәм станцияләр күбесенчә сай тирәнлектә (12–32 *м*) урнашкан, аларны катлаулы инженерлык-геол. шартларда (юеш юшкынлы катлаулар, сулы грунтлар) төзегәндә махсус ысуллар — су куләмен киметү һәм грунтны химик чаралар б-н ныгыту кулланыла. Станцияләр — ачык, туннельләр ябык ысул б-н төзелә. Туннельләрнең даими тотрыклы конструкцияләре кыршаулар рәвешендә тоташкан тимер-бетон тюбинглардан, станцияләрнеке монолит тимер-бетоннан корыла. Автоматлашкан ТККлардан, ш.и. Казандагы үзенчәлекле грунтларны исәпкә алып махсус заказ буенча эшләнгән комплекслардан файдалану казу эшләрен тизләтү, шул ук вакытта су суырту өчен өстәмә җиһазлар кирәк булмаган тюбинглар урнаштыру, янәшәдәге биналарга һәм корылмаларга зыян китермәү мөмкинлеге бирә. Туннельләрнең эчке ягын түшәгәндә РФдә һәм БДБдә беренче тапкыр өстәмә гидроизоляция таләп ителмәгән, 25 *см* калынлыктагы тюбинглар кулланыла. Комплектлаучы башка материаллар кебек үк, алар «Казметрострой»ның чит илләрдән кайтартылган җиһазлар куелган төзелеш конструкцияләре з-дында җитештерелә. Казан М.ында тимер-бетон нигезле, Р-65 рельслары урнаштырылган, ныклы һәм озак вакытка исәпләнгән, шау-шуны һәм вибрацияне киметүче вибрациядән саклаулы юл файдаланыла. Метроны эшләтү һәм файдалану өчен, «Казан метрополитены» (2006 дан — «Метроэлектротранс») пр-тиесе төзелә. М.ның беренче линиясенең эшләтү участогы (2 юлны кушып исәпләгәндә, файдаланулы озынлыгы 7,01 *км*) 2005 нең 27 августында ачыла. Аның составына 5 станция («Кремль», «Тукай мәйданы», «Сукно бистәсе», «Әмәт», «Горки», башта аларның 3 се — күчеп утырулы, 2 се — «Кремль», «Горки» станцияләре — кире юнәлештәге тупикны була), алар арасындагы 4 юл, депо, инженерлык корпусы керә. 2008 нең 29 декабрендә «Җиңү проспекты» станциясе һәм 1,1 *км* озынлыктагы юл, 2010 ның 30 декабрендә «Кәҗә бистәсе» станциясе, 2013 нең 9 маенда «Яшьлек», «Төньяк вокзал», «Авиатөзелеш» станцияләре ачыла. «Кремль» һәм «Кәҗә бистәсе» станцияләрен Казансу елгасы астыннан казылган туннель тоташтыра. Хәрәкәт составында «Казан» һәм «Русич» тибындагы ике секцияле вагоннар файдаланыла. 2012 дә М.нан 26,9 млн. пассажир файдалана.

Казан М.ының дизайнында уңайлыкларга зур игътибар бирелгән. Илдәге М.нар арасында беренче тапкыр инвалидлар өчен пандуслар куелган, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен платформа кырыйлары өскә күтәртелеп эшләнгән. «Горки» станциясенең үзенчәлеге — перрон залы түшәменең гөмбәзе эллипс рәвешендә эшләнүе, терәү колонналарының булмавы. «Әмәт» станциясе астан узучы автомобиль юлы өстендә «хайтек» стилендә төзелгән күпер конструкциясеннән гыйбарәт. Бу станция вестибюльләренең берсеннән тимер юл платформасына чыгу юлы бар; Россиядә андый система беренче тапкыр кулланыла. «Сукно бистәсе» станциясенең дизайны 19 йөз шәһәр архит-расы традицияләрендә эшләнгән. «Тукай мәйданы» станциясе бизәлешендә татар халык шагыйре иҗаты б-н бәйле тарихи-әдәби мотивлар файдаланылган. «Кремль» станциясе урта гасырлар Шәрекъ кирмәне рухында стильләштерелгән. «Җиңү проспекты» станциясе бизәле-



«Әмәт» метро станциясе.



И.Р. Метшин.

шендә совет халкының 1941–45 еллардагы Бөек Ватан сугышында җиңүе темасы чагылдырылган. «Кәҗә бистәсе» һәм «Төньяк вокзал» станцияләре дизайны — «хайтек», «Яшьлек» станциясенеке минимализм стилендә эшләнгән. «Авиатөзелеш» интерьерында авиалайнер салоны темасы чагылыш тапкан.

2013 ел башына Казан М.ының файдаланулы юллары озынлыгы, ике юлны кушып исәпләгәндә, 15,8 *км* тәшкил итә. Метродан көн саен 100 меңнән артык пассажир файдалана. *С.Г.Белов.*

**МЕ́ТШИН** Илсур Рәис улы (24.4.1969, Түбән Кама ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, юридик фән. канд. (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1992). 1993–95 елларда хосусыйлаштыру агентлыгы мөдире, 1995–97 дә Казанның Совет р-ны хакимияте башлыгының аппарат җитәкчесе, 1997–98 дә Вахитов р-ны хакимияте башлыгының 1 нче урынбасары. 1998–2005 тә Түбән Кама р-ны һәм Түбән Кама шәһәре хакимияте башлыгы. Бер үк вакытта халык депутатларының Түбән Кама берләштерелгән Советы рәисе. М. Түбән Кама шәһәренең социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә өлеш кертә, нәтиҗәдә, шәһәр берничә тапкыр «Россиянең иң төзек шәһәре» бөтенроссия конкурсында җиңеп чыга, 2002 дә «Идел буеның мәдәни башкаласы» дип таныла. 2005 нең ноябреннән Казан хакимияте башлыгы; 2005 нең декабреннән «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма ком-ты рәисе. М. җитәкчелегендә транспорт инфраструктурасын һәм шәһәр халкына хезмәт күрсәтүне үзгәртеп кору буенча зур проект гамәлгә ашырыла, капиталь төзелеш һәм торак йортларны төзекләндерү планнары үтәлә. 2006 дан «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы, шул ук вакытта Казан шәһәр думасы рәисе. Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасы вице-президенты, Бөтендөнья «Берләшкән шәһәрләр һәм җирле хакимиятләр» оешмасы вице-президенты, БМОның җирле үзидарә буенча консультатив советы әгъзасы. Казанга 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарын (2013) уздыру хокукы бирелүгә, әлеге чараларны әзерләү һәм уздыруга зур өлеш кертә. Хезмәтләре төбәкнең хокук нигезләрен эшләү мәсьәләләренә карый. 1999–2004 тә ТР халык депутаты. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Почёт» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Правовая система республики в составе Российской Федерации. М., 2002.

**МЕХА́НИКА** (грек. mēchanikḗ — машиналар төзү сәнгате), матди җисемнәрнең фәзада һәм вакыт эчендә хәрәкәте һәм аларның үзара тәэсир итешүләре турындагы фән. Тигезләнеш (М.ның бүлеге) турында иң гади белешмәләр б.э.к. берничә мең ел элек билгеле була. М. буенча безгә беренче булып ирешкән трактатлар — Аристотельнең натураль фәлсәфи язмалары (б.э.к. 4 йөз), «М.» терминын фәнгә ул кертә. Архимед статиканың фәнни нигезләрен эшли. Птолемей, оптик күзәтүләргә таянып, дөньяның геоцентрик системасын төзи. Статиканың кинематик вариантлы гарәп галимнәре тарафыннан тасвирлана. Яңарыш чорында М. кануннарын өйрәнүгә архит-ра техникасының үсүе зур йогынты ясый. Һөнәрләр, диңгезгә чыгу, хәрби хезмәтнең кискен үсеше динамиканың фәнни нигезләре тууга этәргеч бирә. Н.Коперник планеталар хәрәкәтенең гелиоцентрик системасын тәкъдим итә, И.Кеплер — аларның хәрәкәт законнарын, Г.Галилей — классик М.ның чагыштырмалылык принцибын һәм инерция, Р.Декарт хәрәкәт микъдары саклану законын чыгара. Голландия механигы Х.Гюйгенс инерция моменты, үзәктән куучы һәм үзәккә куулы көчләр төшенчәләрен кертә. И.Ньютон классик М. законнарын ахыргача эшләп бетерә. 18 йөздә техник М. киң үсеш ала: А.К.Нартов — токарь-күчерү станогын, И.И.Ползунов һәм инглиз уйлап табучысы Дж.Уатт пар машинасын уйлап таба, И.П.Кулибин уникаль механизмнар конструкцияли. 19 йөздә М.ның интеграль һәм дифференциаль принциплары формалаштырыла, механизмнар кинематикасы, деформацияләнгән тоташ тирәлекләр М.сы, кече тирбәнүләр һәм хәрәкәтнең тотрыклылыгы, махсус механик фәннәр, каты җисемнең хәрәкәте кебек бүлекләр үсеш ала. Җисемнең деформацияләре теориясендә, корабль теориясендә, теоретик гидромеханикада (турбулент агымнар, чик катлам теориясе, майлау теориясе, канатны ягалап агу теориясе, газлар динамикасы) фундаменталь нәтиҗәләр алына; реактив хәрәкәт М.сына нигез салына. 20 йөздә М.ның үсешенә суднолар һәм авиация төзелешләре, космонавтика, энергетика, тирәлекләрне фильтрлау, җитештерү технологияләре, гидрокорылмалар төзелешенең гамәли проблемалары этәргеч ясый.

Татарстанда М.ның фән буларак торгызылуы Казан ун-ты галимнәре — профессорлар Г.И.Карташевский, И.И.Запольский, Г.Б.Никольский, К.Ф.Реннер, М.Ф.Бартельс һ.б.ның хезмәтләре б-н бәйле. 1825–33 елларда Н.И.Лобачевский М. буенча (ш.и. гидростатика һәм гидравлика) лекцияләр укый; соңрак аның лекция конспектлары буенча М.ны Н.Д.Брашман һәм П.И.Котельников укыта. Лобачевскийның шәкерте А.Ф.Попов өслектәге дулкыннар, эластиклык һәм тавыш теорияләрен үстерә. И.С.Громека капиллярлык күренешләре һәм үзле сыеклык хәрәкәте теориясен эшли (Громека–Ламба тигезләмәсе гидромеханика буенча барлык дәреслекләргә кертелә). Г.Н.Шебуев җылылык һәм гидродинамика кырларын заманча өйрәнүгә зур өлеш кертә. Д.Н.Зейлигер охшаш үзгәрүчән җисем М.сы торгызылуы һәм винтлы исәпләүләрнең җисем кулланылышы буенча тикшеренүләр үткәрә. Гаусс принцибын гомумиләштергән Е.А.Болотов ышкылулар теориясе һәм аналитик М. буенча саллы нәтиҗәләргә ирешә. Н.Н.Парфентьев Казанда, беренче булып, көчәнешләрне анализлауның оптик алымнары лаб-ясен булдыра, М. тарихы мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1930 елларда Н.Г.Четаев хәрәкәтнең тотрыклылыгы теориясе буенча яңа фәнни юнәлешкә нигез сала, тотрыклылыкның Казан мәктәбен җитәкли (И.Г.Малкин, К.П.Персидский, М.Ш.Әминов, П.А.Кузьмин, В.М.Матросов, Г.С.Галиуллин, В.Н.Скимель-Оше һ.б.). Авиация сәнәгате һәм ракеталар төзүнең үсеше канат аэродинамикасы буенча тикшеренүләргә (С.Г.Нужин, В.А.Павлов, Н.Г.Куршев), пластиналар һәм сөрүләрнең деформацияләнгән киеренке халәтен өйрәнүгә (Х.М.Мөштәри, К.З.Галимов, М.С.Корнишин, А.В.Саченков, И.Г.Терегулов, Ю.Г.Коноплёв һ.б.) этәрә. Самолёт һәм вертолёт конструкцияләре М.сы, аларның ныклыгы һәм тотрыклылыгы буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр үткәрелә (Ю.Г.Одиноков, В.А.Павлов, М.Б.Вахитов, В.Г.Шатаев, Ю.А.Радциг, А.В.Болгарский, А.Ю.Лисс, Г.Л.Дегтярёв һ.б.). Казанда аэродинамиканың *кайтма кырый мәсьәләләре* буенча фәнни мәктәпкә нигез салына, һәм ул үсеш ала; канатның һәм гидротехник корылмаларның профилен проектлау буенча тикшеренүләр дәвам иттерелә (Г.В.Каменков, Г.Г.Тумашев, М.Т.Нужин, Т.К.Сиражетдинов, Н.Б.Ильинский һ.б.). Ныклы үсеш алган бүлекләрнең берсе — авиация турбомашиналары һәм компрессорлар (Г.С.Жирицкий, В.И.Локай, А.В.Щукин, В.А.Максимов һ.б.), реактив һава двигательләре (В.П.Глушко, С.В.Румянцев, А.В.Талантов һ.б.) төзүнең техник һәм технол. процесслары механикасы. Татарстанда нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү *җир асты гидромеханикасын* һәм фильтрлау теориясен үстерүгә нигез сала. Галимнәрнең нефтьле катламнар гидромеханикасы һәм чыганакларны рациональ эшкәртү теориясе (Һ.С.Салихов, В.Я.Булыгин, В.Д.Чугунов, Г.Г.Вахитов, А.Ш.Газизов, Р.Х.Мөслимов һ.б.), күзәнәкчел тирәлекләрдә җылылык һәм масса күчеше (М.А.Пудовкин һ.б.), релаксацион нәсызыкча фильтрлау (С.Ф.Сайкин, Ю.М.Молокович һ.б.) буенча хезмәтләре киң танылу таба. М.ның төрле бүлекләре: аэрогидрототрыклылык; фильтрацион консолидация; сөрүләрнең грунт б-н тәэсир итешүе; тоташ һәм кавитацион агымнар; металларны газодинамика, лазер б-н эшкәртү технологиясе; биомеханика, композитлар һәм реология, дисперс тирәлекләр һ.б. киселешендә тикшеренүләр үткәрелә (М.А.Илһамов, А.В.Костерин, В.Н.Паймушин, А.В.Кузнецов, О.М.Киселёв, И.Х.Фәхретдинов, С.Б.Черевацкий, Ф.А.Гарифуллин, Д.А.Гобәйдуллин һ.б.). Казан галимнәренең М. өлкәсендәге фәнни һәм гамәли эшчәнлеге Казан циркы төзелешендә конструкцияләрне пластиналар һәм сөрүләр теориясе нигезендә исәпләүдә, Кама елгасы

аша күпер төзелешендә, Казан метрополитены туннелен салу барышында, ш.у. Татарстан пр-тиеләрендә (Казан вертолёт з-ды, Казан моторлар төзү ЖБ, Яшел Үзән суднолар төзү з-ды) технол. процессларны исәпләүдә гамәлгә ашырыла. Казан ун-ты җирлегендә — «*Известия высших учебных заведений. Математика*» (1957 дән), Казан техник ун-ты базасында «*Известия высших учебных заведений. Авиационная техника*» (1958 дән) ж-ллары нәшер ителә. М. буенча тикшеренүләр ТРның техник югары уку йортларында, сәнәгать пр-тиеләренең махсус бүлекләре һәм КБларында алып барыла. Бик күп Казан галимнәре илнең башка шәһәрләрендә кафедра һәм лаб-ялэрнең, институтлар, әйдәп баручы фәнни үзәкләр, югары уку йортларының оештыручылары һәм җитәкчеләре булалар. Казанда туып үскән М.А.Лаврентьев — СССР ФАнең Себер бүлеген оештыручы һәм аның беренче рәисе (Новосибирск ш.), К.П.Персидский — Казакъстан ССР ФАнең Матем. һәм механика ин-ты директоры, Н.Г.Четаев — СССР ФАнең Механика ин-ты директоры (Мәскәү), В.М.Матросов — РФАнең Машиналар төзелеше ин-ты каршындагы Тотрыклылык һәм нәсызыкча динамика тикшеренүләре үзәге директоры, В.М.Фомин — РФА Себер бүлегенең Теоретик һәм гамәли механика ин-ты директоры, В.Н.Монахов — РФА Себер бүлегенең Гидродинамика ин-тында лаб. мөдире.

*Әд.:* Моисеев Н.Д. Очерки развития механики. М., 1961; Казанский авиационный институт. М., 1986; Переломное десятилетие. Казанский государственный технологический университет. К., 2000; История Казанского университета. 1804–2004. К., 2004.

*В.В.Клоков.*

**МЕХА́НИКА һӘМ МАШИНА́ ТӨЗЕЛЕШЕ́ ИНСТИТУТЫ́**, РФА КГҮнең фәнни-тикшеренү ин-ты; 1991 елда СССР ФА Казан ф-лының Е.К.Завойский исем. Физика-техника ин-тының төп фәнни юнәлешләре фильтрлау теориясе (матем. секторы, Н.Г.Чеботарёв тарафыннан нигез салынган) һәм сыгылмалар теориясе (бүлек башлыгы Х.М.Мөштәри) булган механика бүлекчәләре җирлегендә оештырыла. Институтта теоретик һәм эксперименталь тикшеренүләрнең төп юнәлешләре: юка тышчалы конструкцияләрнең, гидроаэросыгылмалы һәм дулкынлы системаларның нәсызыкча механикасы; күзәнәкле структураларда һәм технол. җайланмаларда күп компонентлы күпфазалы тирәлекләр динамикасы; үзгәрүчән структуралы идарә системаларының нәсызыкча тотрыклылык теориясе.

1970–90 елларда, контактлы өслекнең зур күчешләрен исәпкә алып, юка тышчалы конструкцияләрнең сыеклык һәм газ б-н тәэсир итешүе теориясе үстерелә; үткәргеч торбалар, моторлар, үтә үткәрүчән кабель, парашютлар, биотышчалар һ.б.ның модельләрен тәшкил итүче системалар тәкъдим ителә (М.Ә.Илһамов, Ә.Н.Гыйльманов, Җ.М.Сәхәбетдинов, В.В.Ридель, Р.Ш.Гыймадиев). Торбаларда газ һәм аэрозольнең көчле нәсызыкча тирбәнешләре эксперименталь һәм нисбәти тикшерелә; дулкыннарның ярым дисперсияле пар-газ тамчылы катышмаларда таралуы теориясе һәм газ куыкчыгының сыеклыктагы динамикасын тикшерү өчен матем. модель эшләнә (М.Ә.Илһамов, Д.Ә.Гобәйдуллин, Р.Г.Зарипов, А.А.Аганин). Катлаулы геометрияле сүрүләрнең көчле җылылык йөкләнешләре тәэсиренә ныклыгы теориясе һәм аны исәпләү алгоритмнары тәкъдим ителә; структуралары бериш булмаган элпәләр һәм мембраналарның механик үзлекләрен билгеләүнең эксперименталь-теоретик алымы үстерелә (М.С.Корнишин, М.С.Ганиева, Н.М.Якупов).

1990–2000 елларда нефть, газ һәм су катламнарын фильтрлау параметрларын идентификацияләү алымнары эшләнә; полимер-дисперс системалар кулланып, нефть катламнарына су кертүнең матем. модельләре төзелә (М.Х.Хәйруллин, П.А.Мазуров, А.И.Никифоров). Технологик җайланмаларда һәм җылылык алмаштыргычларда җылылык һәм масса күчерүнең матем. модельләре, суыту системалары, җилләткечләр конструкцияләре, градирлау корпусларын көчәйтү өчен терәк системалар тәкъдим ителә (В.Л.Федяев, А.Б.Мазо, Н.М.Якупов).

Институтта тупланган үзгәрешле тигезләнеш массасының релятивистик динамикасына (У.Н.Закиров) караган мәсьәләләр, нәсызыкча идарә системаларының һәм очраклы структур үзгәрешләре булган системаларның тотрыклылыгын тикшерү өчен Ляпунов вектор функцияләр алымы (А.И.Маликов) үсеш ала.

Институт составында (2013) — 7 лаб. (тоташ тирәлек механикасы; тоташ тирәлекнең хисаплау динамикасы; сүрүләрнең нәсызыкча механикасы; фильтрлау процессларын матем. модельләштерү; җир асты гидродинамикасы; технол. процессларны модельләштерү, тотрыклылык һәм идарә итү, гидрогеол. процессларны матем. модельләштерү төркеме) һәм аспирантура бүлеге. Штатта 65 фәнни хезмәткәр, ш.и. 13 фән д-ры һәм 25 фән канд-ты. Тәҗрибә базасына 8 эксперименталь җайланма, күппроцессорлы хисаплау системасы МВС-1000/16К керә. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре «Татнефть», «Түбәнкаманефтехим» АҖләрендә һәм ТРның башка пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. Ш.У.Галиев, К.З.Галимов, М.С.Ганиева, Б.В.Гулин, В.Л.Данилов, В.А.Иванов, М.Ә.Илһамов, М.С.Корнишин, В.М.Матросов, Р.Г.Нигъмәтуллин, Һ.С.Салихов, И.В.Свирский, В.В.Скворцов, И.Г.Терегулов, В.Д.Чугунов һ.б. ин-тта механика буенча тикшеренүләргә зур өлеш кертәләр. Институтның күп кенә хезмәткәрләре ТРның атказ. фән эшлеклесе, ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе исемнәренә лаек була, орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә. Институтның җитәкчеләре — М.Ә.Илһамов (1991–96), В.Л.Федяев (директор вазифаларын башкаручы, 1996–98), Д.Ә.Гобәйдуллин (1998 дән).



РФА КГҮнең Механика һәм машина төзелеше институты тарафыннан эшләнгән терәк системасындагы СК-1200 градирнясы. Түбән Кама ш.

*Әд.:* Обзоры исследований по механике сплошной среды: К 50-летию КазНЦ РАН. К., 1995; Институт механики и машиностроения // Проблемы нелинейного анализа в инженерных системах: Междунар. сб. 1998. Вып. 1(7); Актуальные проблемы механики сплошной среды: К 10-летию ИММ КазНЦ РАН. К., 2001; Российская академия наук. 1991–2001. М., 2002.

*З.В.Скворцова.*

**«МЕШӘ́К-АЛЫ́П»**, Бараба татарларының әкияти-мифологик дастаны. Баш каһарман исеме б-н аталган. Сюжеты батырларның каһарманлыклары, яучылап (димләп) йөрү мотивларына нигезләнгән. Кара хан боерыгы б-н каһарман төрле батырлыклар кыла: могҗизалы балык Яанның алтын яңагын, Чүчеле кошының (башка исеме — Алып Каракош) алтын каурыен алып кайта. Батырлыкларның иң авыры ханга кәләш — Тәбәнә Кугаханышны алып кайту була. Тәбәнә Кугаханыш төрле кыяфәтләргә керә белә: ул балыкка әверелә яки орлык булып идәнгә чәчелә. Каһарман, бөтен авырлыкларны җиңеп, кәләшне ханга алып кайтып бирә. Хан зур туй мәҗлесе оештырырга уйлый. Тәбәнә Кугаханыш, Мешәк-алыпның батырлыкларын бәяләмәвен белгәч, ханны кара тукрангa әверелдерә, ә үзе Мешәк-алыпка кияүгә чыга. Кияү хан була. Алар бергә озак еллар тату һәм бәхетле яшиләр.

«М.-а.» 1860 елларда хәзерге Новосибирск өлкәсенең Колыванский р-ны Тәрәнә авылында В.В.Радлов тарафыннан язып алына.

*Әд.:* Радлов В.В. Образцы народной литературы тюркских племён, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. СПб., 1872. Ч. 4.

*Ф.И.Урманчеев.*

**МЕЩАННА́Р** (поляк. mieszczane — шәһәрдә яшәүчеләр), Россия империясендә салым түләп торган шәһәр халкы. Элек Русьның Речь Посполита терр-ясенә кергән Көньяк һәм Көнбатыш шәһәрләрендә яшәүчеләрне, 17 йөздә — чыгышлары б-н Польшадан булган, Илчелек приказында хезмәттә торып, 1671–72 елларда Мәскәү янында Мещаннар бистәсе төзеп яшәгән кешеләрне М. дип йөрткәннәр. 18 йөзнең соңгы утыз елында Россия шәһәрләрендәге барлык посад халкы М. дип аталган: Госманлылар империясе б-н солых төзелү уңаеннан кабул ителгән 1775 ел 17 март Манифесты буенча, капиталы 500 сумнан ким булмаган посад кешеләре сәүдәгәрләр катлавыннан М. катлавына күчәргә тиеш була. Капиталын үстергән М. ка-

бат сәүдәгәр катлавына кайта һәм яңадан кире күчә ала. «Шәһәрләргә өстенлекләр грамотасы»нда (1785) шәһәрләрнең барлык «урта тормышлы кешеләре» М. дип күрсәтелгән («гомумән М.»), бу исем «хезмәт сөю һәм яхшы холык нәтиҗәсе» итеп каралган, ягъни шәһәрдә күчемсез милке булган «цех гражданнары», «чит шәһәр һәм чит ил кунаклары», «посад кешеләре» М. катлавына кертелгән. М. вак сәүдә һәм вак һөнәрчелек б-н тоткарлыксыз шөгыльләнү хокукына ия була; мещан катлавы статусы нәселдән тапшырыла. Шуннан соңгы чорларда М. дип аталырга хокуклы яки тиешле затлар исемлеге киңәя бара. Ул, башлыча, элекке крәстияннәр хисабына арта. Һәр шәһәрдә М. җәмгыяте оештырыла, җәмгыять *мещаннар идарәсен* сайлап куя. М. катлавына теркәү губерна казна палаталары тарафыннан, кабул итү килешүе аша һәм яңа әгъза кабул итүче М. җәмгыятенең 6 «ышанычлы» әгъзасы тәкъдиме б-н башкарыла. М. катлавына караган зат, башка җиргә китәр алдыннан, кайтканына кадәрге вакыт өчен салымнарын алдан түләп куя (бу турыда паспортына тамга салына). Мещан балаларын гимназиягә бирү өчен, М. җәмгыятенең ризалыгы таләп ителә. Мещан гаиләсендәге бүленеш яки башка чыгу очракларында ш.у. җәмгыять ризалыгы таләп ителә. «Казан губернасының геометрик картасы» мәгълүматлары буенча, 1796 да Казан губернасы шәһәрләрендәге М. саны (ир-атлар): Чабаксар — 1193, Чистай — 474, Зөя — 339, Козьмодемьянск — 314, Ядрин — 273, Цивильск — 259, Царёвококшайск — 160, Лаеш — 129, Тәтеш — 91, Спас — 34, Мамадыш — 33 кеше. 19 йөздә Казан губернасы шәһәрләренең социаль составында М. өлеше 50–80% ка җитә. 1860 та Казан губернасындагы салым түләп торган шәһәр халкыннан 61174 кешенең 49020 се М. була; 1897 дә М. саны — 88399 кеше, шуларның 62818 е шәһәрләрдә яши. М. зур күләмле акчалата җыемнар һәм натуралата түләүләрне күтәрә, ш.у. рекрут бирә. 1863 тә җан башыннан түләнә торган салым азрак күләмле сәүдә-һөнәрчелек җыемы б-н алыштырыла. Һөнәрчелек салымы турындагы закон (1898) чыкканнан соң (ул М.га да кагыла), М.ның хуҗалык эшчәнлеге б-н социаль катлау арасындагы бәйлелек юкка чыгарыла. «М.» төшенчәсе социаль чыгышны күрсәтү өчен генә кулланыла башлый (соңрак тискәре мәгънә дә ала: ягъни тар карашлы, вак омтылышлы кешеләр). ХКСның 1917 нең 10 ноябрендә кабул ителгән «Социаль катлауларны һәм гражданлык чиннарын бетерү турында»гы Декреты б-н М. катлавы бетерелә.

*Әд.:* Сборник материалов по истории Казанского края в XVII в. К., 1908; Гончаренко Л.Н. Города Среднего и Нижнего Поволжья во второй половине XIX века (Социально-экономические исследования). Чебоксары, 1994; Зорин А.Н. Города и посады дореволюционного Поволжья. К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МЕЩАННА́Р ИДАРӘСЕ́**, Россиядә мещаннар катлавы үзидарәсе. М.и. Россия империясе шәһәрләренә хокук һәм өстенлекләр бирү грамотасы (1785 нең 21 апреле) нигезендә оештырыла. М.и. мещаннар җәмгыяте (алар һәр шәһәрдә була) әгъзалары тарафыннан сайлана, губернатор тарафыннан раслана. Идарә 3 елга сайлана, староста, аның ярдәмчесе һәм берничә десятниктан тора. Староста мещаннар җәмгыятендә торучыларның исемлеген төзи-яңарта, җәмгыять әгъзасы каядыр китәсе булса, паспорт бирә, салым исәбен билгели һәм җыемнар җыя. Идарәдә *мещаннар* исемлеге һәм мещан гаиләләре исемлеге, туу, үлү, өйләнешү һ.б. теркәүләр алып барыла. Бөтенроссия ҮБК һәм ХКСның 1917 ел 10 ноябрь Декреты нигезендә М.и. бетерелә.

*Әд.:* к. Мещаннар.

**МЕЩА́НОВ** Василий Николаевич (3.1.1923, Чаллы кантоны Түбән Маврино а. — 6.8.2011, Казан), галим агроном, агрохимик, а.х. фән. канд. (1972), РСФСРның атказ. агрономы (1982). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1957). 1957–65 елларда респ-кадагы иң зур «Акташ» с-зында баш агроном, 1965–69 да Әлмәт зональ агрохимия лаб-ясе мөдире, 1969–71 дә ТАССР а.х. министры урынбасары. 1971–89 да Бөтенроссия а.х.н химияләштерү фәнни-тикшеренү һәм проектлау-технол. ин-тының Идел-Вятка ф-лында директор урынбасары. «Акташ» с-зында эшләү чорында М., респ-када беренчеләрдән булып, берьюлы түләнә торган премия системасын производствога кертә, бу исә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә һәм эшчеләрнең матди кызыксынуы артуга китерә. Татарстанда агрохимия хезмәтен оештыручыларның берсе. Әче туфракларны известьләү, җир эшкәртүдә ашламаларны нәтиҗәле куллануның фәнни нигезләрен һәм гамәли ысулларын эшли. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Применение удобрений на выщелоченных чернозёмах Татарской АССР. К., 1978; Известкование кислых почв. М., 1982; Рекомендации по известкованию кислых почв. К., 1986; Молодому агроному. К., 1987.

**МЕЩЕ́РА**, 1 нче меңьеллыкта — 2 нче меңьеллык уртасында Идел-Ука елгалары арасындагы җирләрдә яшәгән, фин-угор төркеменә караган кабиләләр. 10–16 йөзләр чыганакларында Ука буе халкы буларак күрсәтелә. Чыгышлары *мерәләргә* бәйле дип фаразлана. Мерәләрнең бер өлеше ш.у. балт кабиләләренең этномәдәни йогынтысын кичерә. Бердәм кабилә булмаулары ихтимал. Төп шөгыльләре — ышна ачып иген игү, терлекчелек, сунарчылык. 11 йөздән М. төбәгенә славян халыклары үтеп керә һәм җирле халык ассимиляциягә дучар ителә. 12–13 йөзләрдә, русларның колонияләштерүе һәм христианлаштыруның массачыл төс алуы нәтиҗәсендә, бу процесс аеруча тиз бара. 14–16 йөзләрдә М. төбәгенә *Мухша олысыннан* чыккан татарлар күчеп утыра. 2 нче меңьеллык уртасыннан башлап, М. чыганакларда аерым халык буларак телгә алынмый. «М.» этнонимы Югары Идел буе топонимикасында сакланып калган. 15 йөздән рус рәсми чыганакларында М. (М. төбәге) адм.-терр. төшенчә буларак кулланыла. 15–17 йөзләрдә чыгышлары б-н шушы төбәктән булган йомышлы татарларга кагылышлы атамалар әлеге термин б-н бәйле: «йомышлы М. татарлары», «мещеряклар», ш.у. йомышлы татар бәкләре — Мещерскийлар фамилиясе. М.ның берничә археол. истәлеге — башлыча 11–13 йөзләргә караган гадәти һәм курганлы каберлекләре билгеле. 11–12 йөзләргә нисбәтле гадәти каберләрдә мәетләр чокылган агачка яки табутка (кабык табут та очрый) салып, көнбатышка каратып җирләнгән. Курганлы каберлекләр, башлыча, 12–13 йөзләргә карый. М. төркемен хасил иткән халыкларның хатын-кызларына яссы, айсыман алкалар, нечкә металл чыбыклардан үрелгән балдаклар, төрле чылтыравыклар кушып ясалган чәч асмалары хас булган.

*Әд.:* Финно-угры и балты в эпоху средневековья. М., 1987; Рябинин Е.А. Финно-угорские племена в составе Древней Руси. СПб., 1997; шулук. Мещера // Финно-угры Поволжья и Приуралья в средние века. Ижевск, 1999.

*И.Л.Измайлов.*

**МЕЩЕ́РА ТӨБӘГЕ́**, к. *Мишәр йорты.*

**МЕЩЕ́РОВ** Әнвәр Таһир улы (20.4.1920, Пенза губ., Краснослободский өязе Акчеево а. — 14.1.1986, Ленинград), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1970), проф. (1972). Казакъстан а.х. ин-тын тәмамланган соң (1950), Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тында (Ленинград) эшли; Пушкино лаб-яләрендә яшелчә культуралары фәнни төркеме җитәкчесе (1951–55). 1955 елдан Майкоп тәҗрибә станциясенең (Краснодар крае) яшелчә культуралары лаб-ясе мөдире. 1958 дән Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тында: директор урынбасары һәм бакча культуралары лаб-ясе мөдире (1958–65), интродукция һәм яңа культуралар бүлеге җитәкчесе (1965–75). Дөньядагы кыярлар коллекциясе эше б-н җитәкчелек итә (1952 дән), бер үк вакытта бакча культуралары (карбыз, кавын) буенча тикшеренүләр уздыра. Кыярлар коллекциясе һ.б. культуралар б-н эшләгәндә чәчәк ату биологиясе, эволюция һәм җенес генетикасы, селекциядә гетерозисны өйрәнү һәм куллану, авыруларга чыдамлык мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Огурцы. М., 1963 (автордаш).

**МЕЩЕ́РОВ** Зариф Ибраһим улы (15.6.1919, Пенза губ., Краснослободский өязе Акчеево а. — 25.7.1964, Горький ш.), Дан орденының тулы кавалеры (16.9.1944, 3.11.1944, 19.4.1945), старшина. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 479 нчы аерым сапёрлар батальонында отделение командиры (5 нче һәм 39 нчы армияләрнең 338 нче укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, Көнбатыш һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Киев оборона операциясендә (1941), Мәскәү сугышында (1941–42), Ржев-Вязьма, Смоленск (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 15 августында Кудиркос-Науместис (Литва ССР) шәһәреннән төньяк-көнчыгыштарак (сапёрлар төркеме б-н дошман-

ның тимерчыбыклы тоткарлык сызыгы аша юл ясап, укчыларның көтелмәгән һөҗүмен тәэмин итә); 1944 нең 5–6 октябрендә Расейняй (Литва ССР) шәһәреннән көньяктарак (сапёрлар төркеме составында миналы кыр аша бернечә үтү юлы ясый); 1945 нең 16 гыйнвар төненә каршы Шилямнен (Көнчыгыш Пруссия) пункты янындагы (сапёрлар төркеме б-н, укчылар подразделениесен уздыру өчен, дошманның тимерчыбыклы тоткарлык сызыгы аша үтү юлы ясый) сугышларда батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Горький автомобиль з-дында мастер булып эшли. Ике Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней. Саранск, 1973; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МЕЩЕ́РОВ** Хөсәен Хәким улы (14.1.1895, Пенза губ., Краснослободский өязе Акчеево а. — 24.9.1977, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1939), проф. (1954), ТАССРның атказ. табибе (1945), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1964). Проф. В.С.*Груздев* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1926), шунда эшкә калдырыла, 1927 елдан акушерлык-гинекология клиникасында. 1930 дан Казан мед. ин-тында, акушерлык һәм гинекология каф. мөдире (1954–68), проф.-киңәшче. Хезмәтләре гинекологиягә, эндокринология һәм генетикага, яралгыны антенаталь саклау, йөклелекнең соңгы чоры токсикозы, гениталийдагы яман шеш радиотерапиясенә карый. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К изучению этиологии и патогенеза дегтярного рака // Тр. Казан мед. ин-та. 1935. № 1/2 (автордаш); Радиотерапия рака женской половой сферы в гематологическом освещении. К., 1952; Проблема радиотерапии рака шейки матки в гематологическом освещении (сообщение 1): Гематологическая характеристика больных раком шейки матки // Казан. мед. журн. 1960. № 2; Гематологическая характеристика действия радиолучей в эксперименте // Казан. мед. журн. 1966. № 1.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**МЕЩЕ́РОВ** Шамил Кадим улы (7.1.1957, Мордва АССР, Ельники р-ны Чурино а.), психотерапевт, мед. фән. д-ры (2004), проф. (2006). 1986 елда Ленинград сан.-гигиена ин-тын тәмамлый. 1990–92 дә Ленинград өлкә мед. наркология диспансерының бүлек мөдире, 1992–97 дә башлыгы. 1997 дән Хәрби-мед. академиясендә (С.-Петербург) укыта. Хезмәтләре социаль изоляция нәтиҗәләрен фармакологик юл б-н коррекцияләүгә карый.

Х е з м.: Дофамин и подкрепляющие системы мозга. СПб., 2002 (автордаш); Способ моделирования синдрома алкогольной зависимости у крыс // Усовершенствование методов и аппаратуры, применяемых в учебном процессе, медико-биологических исследованиях и клинической практике. СПб., 2002. Чыг. 33 (автордаш); Синдром социальной изоляции. СПб., 2004 (автордаш).

**МЕЩЕ́РСКИЙ** Платон Степанович (8.11.1713, Мәскәү губ. — 23.12.1799, Кострома губ., Нерехтин өязе Михеевский а.), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-аншеф (1784), инфантерия генералы (1796). Дворяннар нәселеннән. 1729 елдан хәрби, 1764 тән гражданлык хезмәтендә. Кырым татарларына каршы яуда (1732), рус-швед (1741–43) һәм Җидееллык (1756–62) сугышларда катнаша. 1764 тән Малороссия коллегиясе әгъзасы, 1769–74 тә Малороссия идарәчесе.

1774–80 дә Казан губернаторы. Пугачёв көрәштәшләре зыян китергән Казанны яңадан торгызуга җитәкчелек итә: яңа план буенча урамнар һәм тыкрыклар тигезләнә, су канаулары казыла, фонарьлы ут баганалары куела, Покровский, Воскресенский һәм Черек Күл буендагы урамнар ачыла; йортлар салу өчен халыкка акчалата ссуда бирелә. 1774–75 тә ачлыкны булдырмау максатыннан генерал П.И.Панин б-н берлектә азык-төлек бәяләрен контрольдә тота, җәмәгать эшләре оештыра, бу елларда губернада казна ипи кибетләре төзелә. 1775 елгы Губерна реформасын эшләүдә катнаша. 1781 дә Казан наместниклыгын булдыруга җитәкчелек итә. Реформа барышында губерна җирләре киметелә һәм 13 өязгә бүленә (ш.и. Мамадыш, Спас, Чистай өязләре оештырыла; Мамадыш, Спас, Чистай өяз шәһәрләренә әверелә). 1780–81 дә Казан һәм Сембер, 1781–83 тә Казан һәм Пенза, 1783–92 дә Казан һәм Вятка генерал-губернаторы (наместник).

Хезмәт урыннарындагы җинаятьләр б-н көрәшә, губернаторларның, Казан наместниклыгының адм., мәхкәмә һәм төрле катлам оешмаларын күзәтеп тора. М. заманында Казанда 1786 да Әсасый халык уч-щесе, Дары з-ды салына, 1797 дә руханилар семинариясе руханилар академиясе дип үзгәртелә. 1796–97 дә Казан хәрби губернаторы. 1798 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясен яңадан торгызуга ирешә. Изге Андрей Первозванный, Изге Александр Невский орденнары б-н бүләкләнә.

М.га Н.Струйскийның «Син безнең арада булганда» («Когда ты между нами был», М., 1780), Д.Зиновьевның «Казанда Әсасый халык училищесе ачылуга мәдхия» («Ода на случай открытия в Казани Главного народного училища», СПб., 1786) һәм «Барлык эшләрдән азат ителүгә бәйле мактау сүзе» («Похвальное слово на случай увольнения от всех дел», СПб., 1793) шигырьләре багышлана.


*Әд.:* Д о л г о р у к о в П.В. Российская родословная книга. СПб., 1855. Ч. 2; Р у м м е л ь В.В., Г о л у б ц о в В.В. Родословный сборник русских дворянских фамилий. СПб., 1887. Т. 2; П е т р о в П.Н. История родов русского дворянства. М., 1991. Кн. 1; Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**МЕЩЕРЯКО́В** Адриан Матвеевич (7.9.1896, Пенза губ. Парцы а. — 1970, Чиләбе ш.), хирург, анатом, мед. фән. д-ры (1951). Проф. В.Н.*Мурат* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1929), Буа кантонының Шонгат хастаханәсе мөдире булып эшли. 1930 елдан Казан мед. ин-тының анатомия кафедрасында. 1932 дән Чуаш АССРның Балабаш-Баишево, 1933 тән Мари АССРның Кожласолинский хастаханәләрендә мөдир. 1939–40 та, совет-фин сугышы чорында, Казан хәрби госпиталендә. 1941 дән Кызыл Армиядә, 13 нче армиянең 611 нче кыр госпитале ординаторы. 1942 дә тоткынлыкта. 1943 тән Үзәк фронт сәяси идарәсе карамагында (тикшерү уза). 1943–46 да 1095 нче сортировка эвакогоспиталенең хирургия бүлеге башлыгы. 1947 дән Казан мед. ин-тының анатомия кафедрасында, бер үк вакытта, 1949 дан, фельдшер-акушерлык мәктәбендә укыта. 1950 дән Чиләбе мед. ин-тының анатомия каф. мөдире, 1969 дан проф.-киңәшче. Хезмәтләре эксперименталь морфологиягә, гистология, эмбриологиягә карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



З.И.Мещеров.



П.С.Мещерский.

Х е з м.: К морфологии парасимпатического отдела вегетативной нервной системы тазового сплетения человека и некоторых животных // Тр. Казан. мед. ин-та. 1937. Т. 2; Результаты экспериментального морфологического изучения иннервации женских половых органов // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1938. Т. 19, вып. 3; К вопросу об иннервации прямой кишки // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1939. Т. 20, вып. 2.

*Әд.:* А л а е в А.Н., С п е р а н с к и й В.С. Зарубежные и отечественные анатомы. Саратов, 1977.

**МИА́СС** шәһәре, Чиләбе өлкәсендә урнашкан. Халкы — 166231 (2012), татарлар — 5,5 мең кеше (2002). М.терр-ясенә татарлар 19 йөзнең 2 нче яртысында урнаша башлый, бакыр эретү з-дында эшли, һөнәрчелек һәм сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та татарлар кибет тоталар; мәчет һәм мәдрәсә, татар типографиясе була. Хәзерге вакытта Шәһәр үзәк китапханәсе каршында милли әдәбият бүлеге эшли (1996 дан), татар телендәге китаплар фонды бар. М.тан ТРга «Урал» автомобильләре китерелә. Шагыйрь М.Х.Шаһиевның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М. шәһәре б-н бәйле.

**МИГАЧЁВ** Станислав Александрович (19.8.1947, Баулы р-ны Еновка а.), физик, физика-матем. фән. канд. (1982), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре каты җисем акустикасына, оптио- һәм радиоспектроскопиягә карый. 10 *МГц*–10 *ГГц* диапазон ешлыгындагы өзлексез һәм импульслы акустик нурланыш кулланылган спектрометрлар комплексын эшли. Акустикада һәм акустооптикада көчле магнетиклар-



М.П. Мизинов.

ны кире ферромагнитик тәртипкә салуның роле турындагы төп теоретик нигезләмәне раслаучы нәтиҗәләрне тәҗрибә юлы б-н таба һәм тикшерә. Дәүләт бүләге акустик дулкыннарның кристалларда квант системалары б-н үзара тәэсире күренешләрен тикшерүгә һәм гамәли куллануга караган хезмәтләре өчен бирелә.

Х е з м.: Исследование кристаллов ИАГ: Cr, Fe методом акустического электронного парамагнитного резонанса // Физика твёрдого тела. 1991. Т. 33, № 9 (автордаш); Акустооптическая дифракция в гематите, обусловленная магнитоупругой модуляцией поляризации оптических мод // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2008. Т. 88, вып. 1 (автордаш).

**МИГУНО́ВА** Елена Сергеевна (4.1.1984, Казан), спортчы (җиңел атлетика), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (2005), ТРның атказ. спорт остасы (2006). Татар гуманитар-пед. ун-тының юриспруденция ф-тын тәмамлый (Казан, 2006). Спорт б-н 1994 елда Олимпия резервы «Тасма» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый, тренерлары — Р.Р.Шурыгина, 2001 дән О.И.Павлова. 2003 (яшүсмер кызлар арасында), 2005 (яшьләр арасында), 2006 да Европа чемпионатларында, Бөтендөнья универсиадасында (2005, барысы да 4×400 *м* лы эстафетада узышуда), Россия беренчелекләрендә (2006, яшьләр арасында), хатын-кызлар арасында Бөтендөнья ислам уеннарында (2005, 400 *м* да узышуда), Идел буе Федераль округы спартакиадаларында (2006, яшьләр арасында, 200 *м* да узышуда) җиңүче. Европа кубогы (2006, 4×400 *м* лы эстафетада) иясе. Яшүсмерләр арасында Россия беренчелекләрендә (2002, 4×400 *м* лы эстафетада узышуда), яшьләр арасында (2005, 400 *м* лы узышуда) көмеш медальләр ала. Яшүсмерләр арасында дөнья (2003, 4×400 *м* лы эстафетада узышуда), яшьләр арасында Европа (400 *м* лы узышуда) чемпионатларында бронза медальләр иясе. 2002 дән ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы Үзәк спорт ком-тының Дәүләт өстәмә белем бирү учреждениесендә спортчы-инструктор, бер үк вакытта ТР буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәре.

**МИГЪРАЖ** (гарәп. المعراج — югарыга күтәрелү, күккә ашу), Мөхәммәд пәйгамбәрнең 621 елда, Рәҗәб аеның 27 нче кичендә Иерусалимга могҗизаи сәяхәте һәм аның *Аллаһ* катына күккә ашуы. Мөселман риваятьләре буенча, пәйгамбәр Мәккә мәчете янында йокыга талгач, аның янына Буран исемле канатлы җан иясе б-н *Җәбраил* фәрештә килә. Мөхәммәд алар ярдәме б-н мизгел эчендә Бәйтелмөкатдәс (Иерусалим) шәһәренә сәяхәт кыла һәм Әкъса мәчете янында җиде кат күккә аша, анда Адәм, Яхъя, *Гайсә*, *Йосыф*, Идрис, Һарун, Муса, *Ибраһим* пәйгамбәрләр б-н очраша. Шуннан соң Аллаһ катында аның б-н сөйләшә. Аннары яшен тизлегендә Мәккәгә кайтарыла. Бу кичне мөселманнар намаз, *Корьән* укып үткәрәләр.

**«МИЗА́Н»** («ميزان»), газета. 1908 ел ахыры — 1909 ел башында Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 24 саны чыга. «*Хәмият*» г-тасының дәвамчысы. Нашире һәм мөхәррире — М.*Исмәгыйлев-Ширванский*.

*Әд.:* Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1926. К., 1926; Затымызга мөнасиб сыйфатларымыз // Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. К., 1989. Т. 3.

**МИЗИ́НОВ** Михаил Петрович (18.11.1918, хәзер Ульянов өлкәсенең Инза р-ны Пятино а. — 22.10.1969, Казан), Сов. Союзы Герое (24.8.1943), полковник. Чкалов хәрби авиация уч-щесен (1940), офицерлар составын камилләштерүче Югары очу тактик курсларын, Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава инженерлар академиясен (Мәскәү, 1955) тәмамлый. 1937 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 128 нче бомбардировщиклар полкы звеносы командиры (16 нчы һава көчләре армиясенең 3 нче бомбардировщиклар корпусы 241 нче бомбардировщиклар дивизиясе). Үзәк фронт авиациясе составында 1943 нең апреленә дошманның тупланган хәрби техникасын һәм тимер юл үзәгендәге хәрби эшелоннарын бомбага тоту максаты б-н 210 сугышчан очыш ясый. Сугыштан соң СССР Хәрби һава көчләре сафларында хезмәт итә (1959 га кадәр), Казанда яши. Ике Ленин ордены, Кызыл Байрак, Александр Невский, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ф ё д о р о в А.Г. В небе — «петляковы». М., 1976; Честь, отвага, мужество. Саратов, 1979; Герои огненных лет. М., 1980. Кн. 4.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИЗИ́НОВО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 11 *км* көньяктарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 166 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да чиркәү-приход мәктәбе (1894 тә ачыла), 4 тегермән, салат ясау йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 684 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 598, 1897 дә — 728, 1908 дә — 600, 1920 дә — 599, 1926 да — 687, 1938 дә — 584, 1949 да — 562, 1958 дә — 602, 1970 тә — 531, 1979 да — 359, 1989 да — 204, 2002 дә — 148 кеше.

**МИКАЙ́Л бине́ ҖӘГЪФӘ́Р** (10 йөз уртасы), болгар идарәчесе. *Алмыш* ханның улы дип фараз ителә. Исеме 918–20 елларда сугылган болгар акчаларыннан мәгълүм. Идел буе Болгар дәүләте илтәбәре (идарәчесе) (930 нчы елларга кадәр). М.б.Ж.нең вафатыннан соң дәүләт үзәкләре Болгар һәм Сувар шәһәрләрендә булган 2 биләмәгә бүленә, дип уйланыла.

*Әд.:* М у х а м а д и е в А.Г. Древние монеты Поволжья. К., 1990.

**МИКРОАШЛАМАЛА́Р**, составында микроэлементлар (бор, бакыр, марганец, молибден, кобальт, цинк һ.б.) булган минераль ашламалар. Аз күләмдә кулланылалар. М.ны борлы (бор кислотасы, борлы концентрат, борлы суперфосфат, бор ферритлары, бор хелатлары, кайбер вак төелгән борлы рудалар һ.б.), бакырлы (бакыр купоросы, бакыр ферритлары, бакыр хелатлары, пиритлы огарок һәм бакырның башка тозлары), марганецлы (әче күкертле марганец сульфаты һ.б.), молибденлы (молибденлы-әче аммоний, натрий аммоний молибдаты һ.б.) кобальтлы, цинклы (әче күкертле цинк һ.б.), күкертле (гипс һ.б.) төрләргә, ш.у. составында 2 һәм күбрәк микроэлемент булган полимикроашламаларга аералар. А.х. культураларының М.га ихтыяҗы үсемлекләрнең биол. үзенчәлекләренә һәм туфракта микроэлементлар булуга карап билгеләнә. ТР туфракларының микроэлементлар б-н тәэмин ителеше таблицада бирелә.

Т Р туфракларында микроэлементлар (2012 нең 1 гыйнварына)

| Микроэлементлар | Тикшерелгән мәйдан мең *га* | Тәэмин ителеш дәрәҗәсе | | |
|---|---|---|---|---|
| | | түбән | уртача | югары |
| Бор | 3249,4 | 6,8 | 20,1 | 73,4 |
| Бакыр | 2523,5 | 34,9 | 8,7 | 56,4 |
| Марганец | 1463,6 | 1,8 | 34,1 | 64,0 |
| Молибден | 3249,4 | 52,1 | 39,8 | 8,1 |
| Кобальт | 2523,5 | 10,5 | 44,6 | 44,9 |
| Цинк | 2523,5 | 58,6 | 17,2 | 24,2 |
| Күкерт | 3249,4 | 51,9 | 39,1 | 9,1 |

Кәсле-көлсу туфракта микроэлементлар күпчелек иллювиаль горизонтта, кара туфракта — черемәдә, соры урман туфрагында арадаш урында туплана. Микроэлементларның концентрация дәрәҗәсе туфракның черемә катламында туфрак барлыкка китерүче токымнар, үсемлекләр, механик составы үзенчәлекләренә, черемә булуга һәм хуҗалыкның туфрактан ничек файдалануына бәйле. Карбонатлы туфракларда молибден һәм борның артыклыгы күренә, ул балчыксыл кисәкчәләр һәм хәрәкәтчән цинк булуга бәйле. Авыр механик составлы туфраклар бор, кобальт, бакыр б-н яхшырак тәэмин ителгән. Җиңел механик составлы туфракларда молибден, цинк, күкерт, бакыр азрак. Торфлы туфраклар бакырга бигрәк тә ярлы.

Борлы М. куллану үсемлекләрне тышкы мохитнең уңайсыз шартларына тотрыклырак итә. Молибден әһәмиятле ферментларны, аерым алганда, нитратредуктазаларны (2,3 тапкыр) активлаштыра, үсемлекләрнең молекуляр азот туплау процессында мөһим роль уйный, үсемлек яфракларында хлорофилл һәм аскорбин к-тасын арттыра, үсеш

процессларын һәм пигментлар туплануны көчәйтә. Кәсле-көлсу туфракларда аны куллану туфрактагы азотның минеральләшүе артуга һәм үсемлекләрнең «экстра-азотны» яхшы үзләштерүенә китерә: азот б-н туклану яхшыра, бу көчле фотосинтез аппараты формалашуын, тамыр системасының сеңдерү-йоту сәләте артуын тәэмин итә. Марганец шактый дәрәҗәдә оксидлаштыру-кайтару ферментларының активлыгын билгели, ДНК һәм РНК, органик к-талар, витаминнар синтезына, фосфор, күкерт, азот һәм ауксиннар алмашына тәэсир итә, туклыклы матдәләр һәм ионнарны сеңдерүгә булыша, углекислый газның ($CO_2$) йотылу һәм кояш радиациясен файдалануның нәтиҗәлелеген көчәйтә, вегетациянең 1 нче яртысында фотосинтезның продуктлылыгын арттыра, 2 нче яртысында үсешне акрынайта. Бакыр чагыштырмача кыска вегетация чорында тамыр системасының сеңдерү сәләтенә, $CO_2$ ассимиляциясенә, кояш радиациясен файдалануга, пигментлар активлыгына, азот һәм ауксин алмашына, фотосинтезның интенсивлыгына уңай тәэсир итә. Күкерт сулау, фотосинтез, азот һәм углевод алмашы, ферментлар, витаминнар, хлорофилл, эфир, майлар һ.б. синтезы процессларында катнаша. А.х.да 100 дән артык М. һәм микроэлементлар өстәлгән минераль ашламалар куллану рөхсәт ителгән.

М.ны куллануның төп ысуллары — чәчүгә кадәр аларны орлыклар б-н рәтләргә кертү (1 *га* га 0,5–5 *кг* тәэсир итүче матдә), тамырдан тыш өстәмә тукландыру (0,1–0,05 % лы микроэлементлар сыекчасын сиптерү) һәм чәчү алдыннан орлыкларны эшкәртү (чылату). Татарстанда «ЖУСС» маркалы органик (хелатлы): бакыр-бор препараты (ЖУСС-1) һәм бакыр-молибденлы (ЖУСС-2) М. кулланыла, аларны «ТОРС» фирмасы җитештерә. Беренчесе бөртекле культураларның орлыкларын, орлыклык бәрәңгене эшкәртү өчен (1 *т* га 2–3 *л*), икенчесе — бөртекле-кузаклы культураларның орлыкларын (1 *т* га 3 *л*) һәм бәрәңге чәчүлекләрен (1 *га* га 1 *л*) эшкәртү өчен кулланыла.

М.дан файдалану икътисади яктан нәтиҗәле, аз чыгымнар б-н уңыш 15–25% ка арта. Табышлылык дәрәҗәсе М.ның нәорганик формаларын кулланганда — уртача 25–87%, органик формаларын кулланганда 57–156% тәшкил итә, үсемлекләрнең авыруларга чыдамлыгы арта, агроценозга каршы пестицидлар куллану кими.

*Әд.:* Гайсин И.А. Микро-, макроудобрения в интенсивном земледелии. К., 1989.

*И.Н.Афанасьев, М.М.Ильясов, Р.И.Сафин.*

**МИКРОБИОЛО́ГИЯ** (грек. mikrós — кечкенә һәм *биология*), микроорганизмнарны, аларның морфология, физиол., биохимия, систематика, генетикасын һәм үзгәрүчәнлеген; таралышын, табигатьтәге һәм кеше тормышындагы ролен; микроорганизмнарны ачыклау, аерып алу, аларга тәэсир итү ысулларын өйрәнүче фән. Башлап өйрәнүче галимнәр: Л.Пастер (Франция), Р.Кох (Германия), И.И.Мечников (Россия) һ.б. М. фәне бернichә мөстәкыйль бүлек тәшкил итә. Гомуми М. микроорганизмнар биологиясенең фундаменталь закончалыкларын өйрәнә; микроорганизмнарның яшәү тирәлегенә карап, туфрак һәм су М.се, геол. М. аерып карала. Мед. М.се патоген һәм шартлы патоген микроорганизмнарны, аларның аерымлык сыйфатларын, авыру китереп чыгару механизмнарын һәм токсиннар тәэсирен; инфекция процесслары закончалыкларын өйрәнү б-н бергә микробиол. диагностика ысулларын эшли. Клиник М. бүлекләре аерым өйрәнелә, антибиотиклар һәм гөмбәләрне өйрәнү, вакцина профилактикасы мөстәкыйль вирусология һәм иммунология фәне объекты булып тора. Вет. М.се шушы ук мәсьәләләрне а.х. терлекләре һәм кыргый хайваннарга кагылышлы рәвештә карый. Технол. М. яки биотехнология, биопрепаратлар эшләүдә (терлек азыгы аксымы, чүпрә, липидлар һ.б.), ш.у. антибиотиклар, ферментлар, витаминнар, аминокислоталар синтезында катнашучы микробиол. процессларны, азык-төлек микробиологиясен һ.б. өйрәнү б-н шөгыльләнә. Биотехнол. өлкәсендәге уңышлар М. һәм азык-төлек сәнәгате үсешенә этәргеч бирә. А.х. М.се табигатьтәге матдәләр әйләнешендә, туфрак составын, аның структурасын формалаштыруда һәм уңдырышлылыгын арттыруда микроорганизмнарның ролен, үсемлек авыруларын һәм аларга каршы көрәш чараларын өйрәнә. Санитария М.се әйләнә-тирә мохит микрофлорасын, аның кеше сәламәтлегенә йогынтысын тикшерә, аны контрольдә тоту ысулларын тәкъдим итә, гигиена нормативларын эшли, аларны саклау һәм яхшырту чараларын билгели. Санитария М.се санитария-азык-төлек М.се тармагын да үз эченә ала. Аерым тармак тәшкил итүче радиацион М. ионлаштыручы нурларның микроорганизмнарга тәэсирен тикшерә. Космик М. космик корабль яки станция шартларында кеше һәм тирәлекнең бер-берсенә йогынтысын өйрәнә, галәмдә микроорганизмнарның яшәешен һәм үрчүен тәэмин итәрлек шартларны ачыклый. М. фәннең биол., микология, иммунология, эпидемиология кебек тармаклары б-н тыгыз элемтәдә тора.

Татарстанда М.нең фән буларак үсеше Бактериология ин-ты ачылу (1900), Казан клиник ин-тында (хәзер Казан мед. академиясе; 1920), Казан ун-тында (1930), Казан вет. ин-тында (1917) М. кафедралары, соңгысында фәнни-тикшеренү лаб-ясе барлыкка килү б-н бәйле. Мед. М.се үсешенә И.Г.*Савченко* (иммунитетны физика-химия юнәлешендә өйрәнү), В.М.*Аристовский*, Р.Р.*Гельтцер* (спирохетозларны өйрәнү, 1930–38), М.В.*Рево* (туберкулёзга каршы көрәш проблемаларын тикшерү, 1938–44) зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышы елларында яра инфекцияләренең стафилококклы, стрептококклы, анаэроблы төрләрен диагнозлау, дәвалау һәм кисәтү (Казан ГИДУВы, Н.Н.*Спасский*, К.Ф.*Фирсова*, 1940–50) мәсьәләләре алга чыга. Сифилис авыруын пенициллин кулланып дәвалау тәҗрибәсе кертелә (ГИДУВ, С.М.*Вяселева*, 1956–64). 1960–80 елларда яра инфекциясе очракларында фагоцитоз күренеше, бактериаль аллергеннар (И.Е.*Алатырцева*), Идел буе респ-каларында липтоспирозлар (З.Х.*Кәримова*, Г.З.Хәбирова), Урта Идел буенда бөер синдромлы геморрагик бизгәк (В.А.Бойко, Т.А.*Башкирёв*) өйрәнелә, беренче буларак төссез трепонема формасы аерып алына (Л.М.Устименко). Казан мед. ин-ты микробиологларының эзләнүләре фосфорорганик һәм табигый кушылмалардан торган яңа дару матдәләре табу һәм сынау юнәлешендә алып барыла (М.Г.Берим, К.Б.Брудная, Е.К.Наумова, Ш.З.Туктарова, Р.Г.Исхакова, Т.Ә.Кәримова һ.б.), үт юллары авырулары очрагында геликобактерның ролен (О.К.*Поздеев*, Ю.В.Вәлиева), РФ терр-ясендә таралыш алган стафилококкларның дарууларга бирешмәүчәнлеген (Л.Т.Мусина) өйрәнүгә аерым игътибар бирелә. Микробиологлар, инфекционистлар һәм эпидемиологлар (Д.К.Бәширова, А.С.*Созинов*, И.И.Мамкеев һ.б.) вируслы гепатит патогенезын һәм авыруны дәвалау ысулларын төрле яклап, тирәнтен тикшерәләр. Дисбактериозның төрле төрләре б-н озаклап авыручы балаларның система һәм органнары микрофлорасы өйрәнелә, авыруны дәвалау ысуллары тәкъдим ителә. 1990 еллардан фосфор һәм күкертле органик кушылмалардан торган препаратлар б-н бергә вирусларга каршы яңа төр дарулар уйлап табуга зур әһәмият бирелә (О.К.Поздеев). Фәнни тикшеренү материаллары Казан мед. ин-ты (1994 тән Казан мед. ун-ты) чыгарган фәнни хезмәтләр җыентыкларында басыла (1964, 1974,1984, 1994, 2004).

Казан ун-тында М. буенча беренче фәнни тикшеренүләр 1830 елларда башлана һәм алар йогышлы авыруларны өйрәнүгә багышлана. Терлекләрне дәвалау каф. профессоры Ф.Брауэль (1806–82) ратологик процесста түләмә бацилласының ролен ачыклый. М.нең башлангыч үсешенә «Кеше һәм хайваннардагы йогышлы авыруларның сәбәбе буларак үсемлек паразитлары» («Растительные паразиты как причина заразных болезней человека и животных»; т. 1–4, СПб., 1882–86) дигән фундаменталь хезмәт авторы Н.В.Сорокин (1846–1909) зур өлеш кертә. Университетта М. үсешенә этәргеч биргән М. кафедрасына танылган спирохетолог В.М.Аристовский җитәкчелек итә. 1930 елларда ботаника, аннары М. лаб-яләрендә сулыкларның микрофлорасы тикшерелә. М.И.*Беляева* (1940–76) җитәкчелегендә Бөек Ватан сугышы елларында киң кулланылган ампула кетгутын стерильләштерүнең яңа ысулы уйлап табыла. 1951 дә, беренче буларак, нуклеодеполимераза бактерияләре һәм аларның шешләр үсешенә йогынтысы өйрәнелә башлый, шуның б-н молекуляр биологиягә нигез салына. 1963 тә шешләрне дәвалау өчен микроблардан алына торган препаратлар синтезлый торган махсус лаб. оештырыла, ул соңрак бактерияләрнең күзәнәктән тыш гидролитик ферментларын өйрәнүче эре тикшеренү үзәгенә әверелә (җитәкчесе — И.Б.*Лещинская*, 1976–2003). 1980 елларда актив рәвештә нуклеодеполимеразалар бүлеп чыгаручы микроорганизмнар аерып алына, продуцентлар үстерү технологияләре һәм ферментларны

югары дәрәҗәдә чистарту ысуллары эшләнә, аларның төп физик һәм химик, ш.у. каталитик үзлекләре, биосинтез үзенчәлекләре өйрәнелә. Bacillus intermedius (биназа) рибонуклеазасын (РНКаза) һәм Serratia marcescens эндонуклеазасын сәнәгатьтә житештерү җайга салына; бу ферментларның мед.-биол. үзлекләре, вирусларга каршы тору, иммунитетны яхшырту, шешләр б-н көрәшү кебек сыйфатлары тикшерелә. Генетик инженерия, биотехнол. һәм мед. максатларында микроб нуклеазалары препаратлары һәм охшаш ферментлар уйлап тапкан өчен М.И. Беляева, Д.В.Йосыпова, Б.М.Куриненко, Н.П.Балабан СССР МС бүләгенә лаек булалар (1987). Шул ук елда махсус лаб. биохимия һәм ферментлар биоинженериясе фәнни-тикшеренү лаб-ясе дип үзгәртелә. 1990 елларда бактерияләрнең күзәнәктән тыш гидролазаларын өйрәнү эшенә Д.В.Йосыпова, Ф.Г.Куприянова-Ашина, Б.М.Куриненко, Н.П.Балабан, Л.В.Знаменская, М.Н.Филимонова, В.И.Вершинина, М.Р.Шәрипова, Ә.М.Мәрданова һ.б. зур өлеш кертә: биназа һәм S. marcescens эндонуклеазасы геннары клонлаштырыла, әүвәл өйрәнелмәгән бацилла протеиназалары, фосфатлары һәм РНКазаларына тасвирлама бирелә, Serratia төркеме бактерияләренең хитиназа комплексы өйрәнелә, S.marcescens эндонуклеазасының ферментатив катализы механизмы турында яңа мәгълүматлар алына. «Бактериаль ферментлар...» («Бактериальные ферменты...») хезмәте өчен И.Б.Лещинская, Л.В.Знаменская, С.Ю.Егоровка ТР ФАнең В.А.Энгельгард исем. бүләге бирелә (1996). 1960 еллар башында Казан ун-тының М. лаб-ясендә Р.П.*Наумова* җитәкчелегендә нефтьнең экологик куркынычлы ксенобиотиклары һәм углеводородларында микроб метаболизмының физиол.-биохимик аспектлары өйрәнелә. Микроб деградациясе, эшкәртелмәгән нефть һәм нефть шламнары, нитроароматик һәм кремний-органик кушылмалар, арилполикарбонлы һәм өске катлам актив матдәләр таркалуының метаболик юллары тикшерелә. Ксенобиотиклар катаболизмында катнашучы ферментлар өйрәнелә, аерым ферментларның плазмида регуляциясендә катнашу үзенчәлекләре ачыклана (Н.Г.Захарова, С.Ю.Селивановская, С.К.Зарипова, А.Н.Фәттахова, И.М.Скипина һ.б.). 1970 еллардан башлап генетик токсикология өлкәсендә тикшеренүләр алып барыла: эволюциянең төрле дәрәҗәсендә торган организмнардагы (прокариотлардан башлап, күзәнәк культуралары һәм хайваннарның аерым органнарына кадәр) токсиннар һәм мутагеннарны тиз арада бәяләү өчен тест-системалар тәкъдим ителә. 1990 еллардан эукариот модельләрдә биназаның гено- һәм цитотоксинлык сыйфатлары тикшерелә, in vitro биназасының аерым төр онкогеннар экспрессияләүче рак күзәнәкләренең кайбер линияләренә карата югары цитотоксинлык һәм апоптогенлыкта булуы ачыклана. Биназаның аксым төзелешен өйрәнү бу фермент һәм шеш күзәнәкләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең нечкә механизмын аңларга мөмкинлек бирә (И.Е.Черепнёва, О.Н.Ильинская).

Татарстанда вет. М.се И.Н.*Ланге*, Н.Д.Степанов, М.П.*Тушнов*, Н.П.*Руфимский*, М.В.Рево, Х.Х.*Абдуллин*, В.П.*Кивалкина*, Р.Г.*Госманов* хезмәтләре б-н билгеләнә. А.х. терлекләренең йогышлы авырулары өйрәнелә, диагноз кую һәм авыруны кисәтүнең махсус чаралары тәкъдим ителә (М.В.Рево, Ш.Х.Харисов, В.С.Сухорецкий, Х.Х.Абдуллин, В.П.Кивалкина), И.Н.Ланге вакцинасы нигезендә түләмәгә каршы вакцина (Казан вакцинасы) уйлап табыла; гистолизатлар аерып алынып, аларның кеше һәм терлекләр организмына тәэсире өйрәнелә (Е.К.Боль, В.В.Никольский, А.П.Тушнов, Н.Р.Руфимский, Х.Х.Абдуллин, Ш.Х.Харисов һ.б.). Бруцеллёз проблемалары өйрәнелеп, бруцеллёзга каршы нәтиҗәле вакциналар тәкъдим ителә (С.К.Салмаков, штамм 82), ш.у. местериоз (О.А.Котылев, АУФ), колибактериозга каршы вакциналар, яңа дезинфекция препаратлары (феносмолин) эшләнә. Авыру тудыручы микроорганизмнарга эфир майлары тәэсире тирәнтен өйрәнелә (Х.Х.Абдуллин, 1950 еллар). В.П.Кивалкина һәм З.Х.Кәримова җитәкчелегендә прополистан ясалган препаратларны тикшерү нәтиҗәсендә аларның иммунитет булдыруга уңай йогынтысы ачыклана; препаратлар мед. һәм вет. практикасына кертелә (С.Г.Покровский, А.А.Барсков, В.А.Балалыкин, Ә.И.Ибраһимова, Э.Л.Бударкова һ.б., 1960–80 еллар). Р.Г.Госманов Ку бизгәге очрагында риккетсиозга диагноз кую юлларын һәм авыруны кисәтү чараларын тәкъдим итә.

1970 елларда Казан ун-тында а.х. М.сенә кагылышлы яңа төр тикшеренүләр башлана: үсемлекләрне гөмбә инфекцияләреннән саклый торган препарат — триходермин биопестициды уйлап табыла, аны җитештерү технологиясе эшләнә; үсемлекләрнең туклануын яхшырта һәм кырыс шартларга каршы торучанлыгын арттыра торган киң кулланышлы бактериаль препаратлар булдырыла (Р.А.Сайманова, Н.Г.Захарова, Ф.К.Алимова, С.Ю.Егоров, Н.К.Мочалова). Бу препаратлар Татарстанның «Казанский тепличный», «Майский», «Новая жизнь» теплица хуҗалыкларында кулланыла. 1980 елларның 2 нче яртысыннан Т.В.Багаева җитәкчелегендә сульфат редуцияләүче бактерияләр тикшерелә, беренче буларак, анаэроб бактерияләрнең Desulfovibrio, Desulfotomaculum, Desulfobakterium төрләренә караган чиста культуралары тарафыннан углеводородлар синтезлану һ.б. өйрәнелә. Казан микробиологларының казанышлары Ф.Г.Куприянова-Ашинаның «Экзогенлы дезоксирибонуклеазаларның ДНК синтезына тәэсире, микроорганизмнар күзәнәкләренең үсеше һәм бүленүе» («Влияние экзогенных дезоксирибонуклеаз на синтез ДНК, рост и деление клеток микроорганизмов», 1990), И.Б.Лещинская, В.П.Варламова, Б.М.Куриненконың «Бактерия нуклеазалары» («Нуклеазы бактерий», 1992), С.Ю.Егоровның «Үсемлекләр үсеше регуляторларының — микроорганизмнарның тереклек эшчәнлеген көйләү» («Регуляция жизнедеятельности микроорганизмов — регуляторов роста растений», 2003), Ф.К.Алимованың «Trichoderma / Hypocrea (Fungi, Ascomycetes, Hypocreales): таксономия һәм таралыш» («Trichoderma/Hypocrea (Fungi, Ascomycetes, Hypocreales): таксономия и распространение», 2005) монографияләрендә бәян ителә. Ш.у. к. *Казан медицина фәнни мәктәбе, Казан эпидемиология һәм микробиология институты, Казан медицина университеты.*

*Д.Р.Нуретдинова, Г.Н.Лапшина, О.Н.Ильинская, Р.Г.Исхакова, Ә.И.Ибраһимова.*

**МИКРОДУЛКЫННА́Р ТЕХНОЛО́ГИЯЛӘРЕ** (МДТ), ультраюгары, үтә югары һәм бик югары ешлыклы электромагнитик кырлар энергиясе б-н матдәләргә, материалларга һәм биол. объектларга аларның үзлекләрен үзгәртү максатында тәэсир итүнең алымнары, юллары һәм чаралары күплеге. МДТнең төп үзенчәлекләре материалларны электромагнитик кырлар б-н кыздырудан, ш.у. бу кырның, ешлыклары диапазонына, тәэсир итү вакытына һәм модуляция параметрларына бәйле рәвештә, бик күп төрле тәэсирләреннән гыйбарәт. Микродулкыннар техникасында материалларны җылыту эшкәртелә торган материалдан җылылык бүленеп чыгу б-н бара; инерциясез процесс (электромагнитик тәэсир туктатылганнан соң, җылылык бүленеп чыгу да туктый). Җылыту процессы б-н идарә итәргә мөмкин: бу тирбәнүләр ешлыгын үзгәртү юлы б-н, эшче камераларның параметрларын үзгәртү хисабына, ш.у. бериш булмаган материалга селектив тәэсир итү, ягъни чагыштырма йотылуы зуррак өлешләрне көчлерәк җылыту юлы б-н эшләнә. Кагыйдә буларак, электромагнитик кырның тәэсире шушы ук объектны гадәти чаралар б-н шул ук темп-рага кадәр җылыту нәтиҗәләреннән аерыла. Электромагнитик кыр артык көчле булганда, биол. объектларның талчыгуы, хәтта һәлакәте дә күзәтелә, көч уртача һәм түбән булганда, стимуллаштыру характерындагы (үсүне тизләтү, организмнарның иммун функцияләре күтәрелү һ.б.) нәтиҗәләр алына.

Тәэсирнең дәвам итү вакытына һәм көченә карап, югары һәм түбән интенсив МДТне аерып өйрәнәләр. 1 нче класс процесслары (киптерү, җылыту, эретү, материалны кыздырып эшкәртү һ.б.) электромагнитик кырның югары көче һәм озак вакытлы булуы б-н характерлана, нәтиҗәдә, материал шактый җылына һәм тирәлек б-н җылылык алмашу зур була, эшкәртелә торган матдәләрнең фаза халәте һәм массасы үзгәрә. Эшкәртү бертөрле шартларда барсын өчен, вакыт аралыгында үзгәрә торган электромагнитик кырлар тудырырга кирәк. Мондый процессларны анализлау һәм аларны оптимальләштерү электродинамик һәм җылылык физикасы (җылылык һәм масса алмашуны да кертеп) аспектлары б-н берлектә алып барыла. 2 нче класс процессларына (бик югары ешлыклар диапазонындагы электромагнитик кыр б-н биол. объектларга стимуллаштыргыч тәэсир ясау) электромагнитик тәэсирләрнең түбәнрәк дәрәҗәдәге, артык җылытуны китереп чыгармый торганнары хас. Түбән интенсив

МДТ файдаланыла торган электромагнитик кырларның бериш булуына катгый таләпләре б-н аерылалар. Тирәлек б-н җылылык алмашу процесслары зур роль уйнамый, ә электрофизик параметрлар эшкәртү процессында даими кала.

1950 еллардан башлап, Россиядә МДТ үстерү үзәкләре Мәскәү, Фрязино, Ленинград, Саратов, Чиләбе, Новосибирскида туплана. 1980 еллар уртасыннан фәнни һәм хуҗалык эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә МДТ б-н кызыксыну шактый арта. ТРда МДТ өлкәсендәге тикшеренүләр Казан техник ун-тының Гамәли электродинамика фәнни-тикшеренү үзәгендә (НИЦ ПРЭ) үткәрелә. Эшчәнлек өч юнәлештә алып барыла: үтә югары һәм бик югары ешлыклы электромагнитик кырлар тәэсирендә матем. һәм физик модельләштерү процесслары алымнары; шул ук кырларның төрле характердагы матди тирәлекләргә тәэсир итү нәтиҗәләре; технол. җайланмалар һәм комплекслар проектлаштыру һәм эшләү алымнары. Казан галимнәре тарафыннан а.х. һәм нефть тармаклары өчен МДТ алымнары һәм техник чаралары тәкъдим ителә (Г.А.Морозов, Ю.Е.Седельников, Н.Г.Воробьёв, Н.Е.Стахова һ.б.); түбән интенсив МДТдә үтә югары һәм артык югары ешлыклар диапазонындагы электромагнитик кырлар кулланунның теоретик нигезләре эшләнә; үтә югары ешлыкларның энергия чыгымын минимальләштерү принцибына нигезләнеп, эшкәртү режимнарын сайлап алу мәсьәләсе хәл ителә; җайланмаларның эшче камераларында электромагнитик кырларның күп элементлы ярсынуын анализлау һәм оптимальләштерү методикасы, тикшерүнең махсус, ш.и. радиометрия принципларына нигезләнгән алымнары тәкъдим ителә. РФдә һәм БДБ илләрендә беренче булып, НИЦ ПРЭ галимнәре микродулкын процессорлар һәм комплекслар гамәлендә системология, статистик анализ һәм синтез, фокусланган апертурлар, когерент чыганаклардан нурландыручы системаларны оптимальләштерү алымнарын кулланалар; бу алымнар нефть һәм газ чыгару, ш.у. башка сәнәгый тармаклар өчен икътисади яктан уңай бәяләнгән микродулкын технологиясе комплексларын булдырырга мөмкинлек бирә. Казан вет. медицинасы академиясе (Ф.М.Шәкүрова, М.Н.Корнишина) һәм ТР МКның Баш ветеринария идарәсе лаб-ясе хезмәткәрләре б-н берлектә төрле тирәлекләрне (терлек торакларыннан чыккан агынтылар, теплицаларда беренчел һәм икенчел грунтлар, он, транспортлау та́расы) паразитар микрофлорадан арындыру буенча тикшеренүләр үткәрелә. Терлек торакларыннан чыккан агынтыларны гельментсызландыру һәм йогышсызландыру, ш.у. бөртекле культура һәм күпьеллык үлән орлыкларын аларның шыту сәләтен, авыруларга тотрыклылыгын күтәрү максатында эшкәртү җайланмалары тәкъдим ителә; борчактагы үлән ашаучы коңгыз личинкаларын юк итү режимнары, терлекләрне, «Луч», «Явь» тибындагы аппаратлар кулланып, даруларсыз дәвалау алымнары эшләнә (Г.А.Морозов, М.Ш.Шәкүров, А.Г.Макаров). Чыршы һәм нарат орлыкларын чәчү алдыннан эшкәртү МДТ (ТРның барлык урман хуҗалыкларында гамәлгә кертелә) булдырыла; орлыкчылык-тәҗрибә станцияләре өчен «Шытым» тибындагы җайланмалар төзелә (Яшел Үзән р-нының Васильево посёлогында һәм Арча урман хуҗалыгында), алар шытучанлыкны, шытылу энергиясен, авыруларга каршы торучанлыкны күтәрергә, орлык фонды чыгымнарын 30% ка киметергә ярдәм итә (Татарстан урман-тәҗрибә станциясе һәм ТР урман хуҗалыгы министрлыгы хезмәткәрләре б-н берлектә). Экология мониторингы максатында зур шәһәрләрдә электромагнитик кыр дәрәҗәсен тикшерү өчен программа-аппаратура комплексы эшләнә (Г.А.Морозов, Ю.Е.Седельников, В.Н.Лаврушев һ.б.). Нефть чыгару тармагы өчен җайланма һәм комплекслар: нефть скважиналары торбаларындагы асфальт-парафин утырымнарын эретү өчен микродулкын технологияле тәҗрибә комплексы, су-нефть эмульсиясен эшкәртү һәм аның кушылмалары составын анализлау өчен «ПМВК-400» модуле һәм микродулкынлы «ДОН» җайланмасы. НИЦ ПРЭ эшләнмәләре нефть чыгаруга әзерләү комплексларында гамәлгә кертелә («Лениногорскнефть» НГДУы).

*Г.А.Морозов.*

**МИКРОКЛИ́МАТ** (грек. mikrós — кечкенә һәм *климат*), зур булмаган терр-янең җир өслегендәге бер-берсенә охшамаган үзенчәлекләргә (рельеф, үсемлекләр, туфрак, сулыклар, корылмалар һ.б.) бәйле һава климаты. Микро- һәм макроклимат арасындагы арадаш халәтне билгеләүче җирле климат — мезоклиматның бер өлеше. Мәс., урман массивы мезоклиматында урман буйлары, аланнары, ызаннары һ.б. М.ны аералар; шәһәр яки аның районнары мезоклиматында — мәйдан, урам, сквер, ишегалды һ.б. М. үзенчәлекләренең үзгәреше (туфрак һәм һава темп-расы, дымлылык, җил тизлеге һ.б.) климатик зоналар арасындагы кучеш үзгәрешләреннән дә көчлерәк булырга мөмкин. Мәс., текәлек 5-8° булганда, төньяк һәм көньяк сөзәклекләр арасында туфрак өслегенең темп-ра аермасы, көньяк сөзәклекләрдә кояш радиациясе күләме зур булганлыктан, язын һәм җәен 10–15 °С ка җитәргә мөмкин. Рельефның батынкы урыннарында язгы-көзге *кыраулар* ихтималы зур. Күлләрдә бозның озак эремәве сәбәпле, яр буендагы агачларда вегетация чоры тоткарлана. Үсемлекләр үсеше өчен уңай тәэсир ясап, язын калкулыкларның ышык сөзәкләрендәге кар туфракта дымны җилләнә торган сөзәклекләр б-н чагыштырганда озаграк саклый. Шәһәрнең читенә караганда аның үзәк өлеше һәрвакыт җылырак. Яр буе зонасы мезоклиматына һәм М.ка Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларының йогынтысы күпьяклы. Язын һәм көзен сусаклагычлар янында һаваның уртача айлык темп-расы 3-5 °С ка югары, җәен 1-2 °С ка түбән. Аяз, җилсез көндә М. үзгәрешләре арта, болытлы һәм җилле көндә тигезләшә; биеклек арту б-н, туктала. М. үзенчәлекләрен исәпкә алу а.х. культураларын үстерү, мелиорация үткәрү, сәнәгать объектларын һәм торак пунктларны урнаштыруда зур әһәмияткә ия.

*М.А.Верещагин, Э.П.Наумов.*

**МИКРОЛИТРАЖЛЫ́ АВТОМОБИЛЬ-ЛӘ́Р ЗАВОДЫ́**, к. *КАМАЗ*.

**«МИКРО́Н»**, мед. сәнәгате фәнни-җитештерү пр-тиесе. 1997 елда Казанда элек «Мединструмент» фәнни-җитештерү берләшмәсе составына кергән «Микрон» тәҗрибә з-ды җирлегендә оештырыла; 2000 нән АҖ, 2013 тән «Микрон-холдинг» ҖЧҖ. Аның составына 6 ҖЧҖ керә. Эшләүчеләр саны — 60 кеше (2013). Медицина, беренче чиратта стоматология өчен җиһазлар, инструментлар һәм препаратлар эшләү, җитештерү, сату, аларга хезмәт күрсәтү өлкәсендә специальләшә. Төп продукциясе: бормашиналарга куелучы асылма инструментлар (турбина очлыклары, микромоторлар, скейлерлар, «һава-һава» пистолетлары, шланглар), бормашиналар, стоматология комплекслары, спираль мед. компрессорлары һәм һава чистарту системалары. Хезмәт күрсәтүләр исәбендә — җитештерелгән стоматология җиһазларын файдалану урынында монтажлау һәм урнаштыру; сатып алынган инструментка һ.б. төрле мед. техникасы эшләнмәләренә гарантияле һәм гарантиядән тыш хезмәт күрсәтү.

1990 елларда «Энҗе» сериясенә кергән НТС-300–4, НТС-300–05, НТКС-300, НТСБК-300 турбина очлыкларын, НУ-40 почмак очлыкларын, НП-40 туры очлыкларын, МП-30, МП-40 микромоторларын, БПС-300/40 бормашиналарын, КМП-60 компрессорын җитештерү үзләштерелә. 2000 нән спиральле майсыз КМС-01, КМС-02 кучмә компрессорлары, спиральле КМСП-01 — «Микрон», КМСП-02 — «Микрон» (майлаусыз) мед. кучмә компрессорлары эшләнә. Стоматология җиһазларын модернизацияләү юнәлешендә «Икенче тормыш» программалары (1,2) гамәлгә ашырыла. 2002 дән «М.» Россия стоматология ассоциациясе б-н тыгыз элемтәдә эшли; илнең стоматология челтәрен халыкара стандартларга туры килгән инструментлар һәм җиһазлар б-н яңадан коралланд



«Микрон» предприятиесе продукциясе.
Стоматология өчен җиһазлар комплекты.



«Микрон» предприятиесе продукциясе. Бормашиналар өчен асылма инструментлар.

дыру максатында башка пр-тиеләр һәм оешмалар б-н берлектә «Россиядә нәтиҗәле стоматология» программасын тормышка ашыра. Пр-тие ISO 9001 стандарты сертификатына ия (2000), Австрия, ГФР, АКШ, Швейцариянең әйдәп баручы фирмалары б-н хезмәттәшлек итә. Продукциясе РФнең күп кенә төбәкләренә җибәрелә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Иран, Италия, Румыния, АКШ, Төркия, БДБ илләренә чыгарыла. Заманча стоматология инструментларын, материалларын, алдынгы технологияләрне күпләп гамәлгә кертүе өчен пр-тие Россия төбәк күргәзмәләрендә 2 дипломга лаек була (2004). Уйлап табуга 6 патент бирелә. Пр-тие хезмәткәрләреннән 1 кеше — «Почёт билгесе» ордены, 2 кеше ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчесе — В.П.Сидоренков (1997 дән).

*Р.З.Мансуров, М.Ж.Гаитов.*

**МИКРОЭЛЕМЕНТЛА́Р**, терлекчелектә продуктлылыкны арттыру максатыннан һәм матдәләр алмашы бозылуны кисәтү өчен аз микъдарда азыкка өстәп бирелә торган химик элементлар (йод, кобальт, бакыр, цинк, селен, марганец һ.б.). Рационда М. артык булу яки җитешмәү терлекләргә зыян сала, аларның үсешен тоткарлый, продуктлылыгын, үрчемлелеген киметә, авырулар китереп чыгара, үлемгә китерә, продукциянең сыйфатын төшерә. Казан вет. медицинасы академиясе галимнәренең (А.П.Онегов, Р.Ә.Әхмәтов, Л.П.Зарипова, Ю.Н.Кәлимуллин, Н.М.Машковцев һ.б.) тикшеренүләре нәтиҗәсендә аерым М. җитешмәгәндә матдәләр алмашы бозылу, продуктлылык кимү һәм терлекләрдә аерым төр («энзоотик») авырулар барлыкка килү раслана. ТРда туфракның кобальт, йод, бакыр, селен һәм цинкка чагыштырмача ярлы булуы мәгълүм (к. *Микроашламалар*). Буаз терлек рационында йод дефициты зоб барлыкка килүгә, зәгыйфь токым тууга яки терлекнең үле яралгы салуына сәбәп булырга мөмкин (Г.В.Домрачев, Н.Җ.Хаҗипов, Л.Г.Замарин, Р.Җ.Корбанов). Хайваннар ана сөте б-н тиешле күләмдәге тимернең 10–15 процентын гына алалар, шуның нәтиҗәсе буларак, яңа туган терлекләр анемиягә дучар була, селен җитешмәү мускуллар авыруы тудыра. М. нормада булсын өчен терлек азыгына төрле минераль премикслар (биол. актив матдәләр кушылмасы) өстәү тимер дефицитын кисәтә һәм организмның тулай резистентлыгын — төрле зарарлы факторларга каршы тора алучанлыгын арттыра. М. организм тарафыннан үзләштерелсен өчен, аларның хелат формаларын аминокислоталар, пептидлар, аксымнар һ.б. биолигандалар б-н куллану отышлы (Х.Ш.Казаков, Э.В.Тен, Р.Г.Бинеев, Г.Ф.Кәбиров, М.Ю.Метлякова, Г.П.Логинов һ.б.).

*Әд.:* О н е г о в А.П., А х м е т о в Р.М. Применение микроэлементов в животноводстве Татарской АССР. К., 1974; К а б и р о в Г.Ф., Л о г и н о в Г.П., Х а з и п о в Н.З. Хелатные формы биогенных металлов в животноводстве. К., 2004.

*Г.П.Логинов.*

**МИКУ́ЛИН** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ямаш елгасы (Дала Зәе бассейны) буенда. 2010 елда 379 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 61%, татарлар — 25%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөз уртасында Чернигов губернасыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Лизуновка, Түбән Микулин исемнәре б-н дә билгеле. 20 йөз башында волость идарәсе, земство башлыгы урнаша; 2 чиркәү, земство мәктәбе (1871 дә ачыла), земство станциясе, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 512 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1889 да — 298, 1910 да — 303, 1920 дә — 417, 1926 да — 446, 1938 дә — 572, 1949 да — 415, 1958 дә — 430, 1970 тә — 345, 1979 да — 283, 1989 да — 339, 2002 дә — 453 кеше.

**МИ́КУСЕВ** Иван Егорович (11.10.1937, Подберезье, хәзер Кайбыч р-ны Камыл а.), хирург, травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның, РФнең атказ. табибе (1998, 2007). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Губаха шәһәренең (Пермь өлкәсе) 3 нче хастаханәсендә хирург, 1963 елдан хирургия бүлеге мөдире. 1965 тән Казан шәһәрендәге 5 нче хастаханәнең кичектергесез хирургия бүлегендә, бер үк вакытта, (1965–77), Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре кул чугы имгәнүләре һәм кул чугы авырулары этиологиясе, патогенезы һәм аларны хирургия юлы б-н дәвалауга, кул чугының тумыштан килгән кимчелекләрен һәм табан авыруларын дәвалауга, тире пластикасына карый. М., беренче булып, уч төбе апоневрозының нерв аппаратын аутогенезда тикшерә, Дюпюитрен контрактурасы (мускулның озакка сузылган тотрыклы кыскаруы) схемасын эшли һәм аны операция юлы б-н дәвалау юлын тәкъдим итә (1975 тән гамәлдә), мед. практикасына 30 дан артык яңа төр операция кертә (барысы да авторлык таныклыгы һәм патент б-н расланган, ТРның мед. учреждениеләрендә кулланыла). Дәүләт бүләге «Кул чугы авырулары булган яки кул чугы имгәнгән авыруларны яңача дәвалау» дигән хезмәте өчен бирелә (1999).

Х е з м.: Тендогенные сгибательные контрактуры пальцев кисти // Вестн. хирургии. 1983. № 1; Контрактура Дюпюитрена (вопросы этиологии, патогенеза и оперативного лечения). К., 2001.

**МИ́КУСЕВ** Юрий Егорович (27.7.1944, Подберезье, хәзер Кайбыч р-ны Камыл а.), невролог-реабилитолог, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1994). Проф. М.М.Миңлебаев шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының 12 нче дәвалау-профилактика берләшмәсе терапевты. 1971 елдан Казан мед. ун-тында, физиотерапия, дәвалау физкультурасы һәм табиб контроле каф. мөдире (1974–91), 1991 дән неврология һәм реабилитация каф. профессоры. Хезмәтләре лимфа системасы физиологиясе һәм патологиясенә, авырулар һәм инвалидларны физик ысуллар б-н реабилитацияләүгә карый. М. физик йөкләнеш бирелгәндә лимфа системасы эшчәнлеген һәм лимфа системасы патологиясен өйрәнә, авыруларны тернәкләндерү мәсьәләләрен тикшерә.

Х е з м.: Способ длительного получения лимфы в эксперименте // Патол. физиология и эксперим. терапия. 1982. № 1 (автордаш); Динамика лимфоциркуляции при физической нагрузке // Теория и практика физической культуры. 1985. № 1; Восстановительное лечение больных с рефлекторными и корешковыми проявлениями остеохондроза // Вертеброневрология. 2002. Т. 9, № 1–2; Организация и опыт работы гигиенического воспитания населения РТ. К., 2004.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский университет (1804–2004): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**МИКШЕ́ВИЧ** Юлий Октавиан (Антонович) (24.10.1824, Ковно губ., Поневежье өязе Швабишки а. — 11.3.1878, Казан), хокук белгече, икътисадчы, тарих фән. һәм сәяси икътисад д-ры (1856), хокукый статский советник (1873). Дворяннар нәселеннән. Дерпт ун-тын тәмамлый (1848); шунда ук эшли, 1853–55 елларда геогр., этнография һәм статистика каф. приват-доценты. 1857 дән Казан ун-тының сәяси икътисад һәм статистика каф. ординар профессоры, 1863–73 тә юридик ф-т деканы. Рауның индивидуалистик һәм тарихи-физиол. мәктәпләре икътисадчылары карашларының тарафдары. Төп хезмәтләре халык хуҗалыгында «шәхси файда һәм чикләнмәгән ирек хакимлегенең мөмкинлеге һәм файдасы хакында»гы проблемаларны өйрәнүгә, сәүдә һәм сәнәгать кризислары турындагы мәсьәләләргә багышлана. Кредит, сәүдә ширкәтләре һ.б. турында тәгълимат эшли. 1861 елгы Крәстиян реформасы алдыннан дәүләт милкен торгларда сату юлы б-н Россияне финанс ягыннан савыктыру проектын алга сөрә. Казан икътисадчылар җәмгыяте эшчәнлеге өлкәсен киңәйтүне яклый, әлеге җәмгыятьне үзгәртеп кору планын төзи. 1869 да Россия хайваннарны саклау җәмгыятенең Казан бүлеген оештыра.


Х е з м.: Продажа государственных имуществ как одно из средств для удовлетворения современных финансовых потребностей России. К., 1859; Несколько слов о новой основе доверия: По поводу трудов Комиссии для устройства земских банков. К., 1862; Записка о воспитательном значении кроткого обращения с животными. К., 1869; Uber das Verhaltniss der Consumtion zur Production. Дерпт, 1856.

*Әд.:* Степанов Я.С. Памяти Ю.А.Микшевича. К., 1878; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**МИЛӘҮШӘ́** (Viola), миләүшәчәләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында, башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 22 төре бар. Басу М.се (V. arvensis), эт М.се (V. canina), төкле М. (V. hirta), тау М.се (V. montana), өч төсле М. (V. tricolor) һ.б. барлык районнарда очрый; шикле М. (V. ambigua), калкулык М.се (V. collina), яр буе М.се (V. litoralis) һ.б. — респ-ка өчен сирәк төрләр. Урманнарда, куаклыкларда, чәчүлекләр, болыннар, сазлыкларда, яр буйларында үсәләр. 5–50 *см* биеклектәге бер- һәм күпьеллык үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, каяу читле. Чәчәкләре берле, өске өлеше бөгелеп торучан озын чәчәк сабында, зәңгәр, аксыл-шәмәхә, кайвакыт ак яки саргылт, сирәк кенә ике яки өч төстә. Җимеше — озынча тартмачык, кипкәч ачыла һәм орлыкларын тышка ата. Апрель–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июньнән өлгерә башлый. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамырчалардан) үрчи. Халык медицинасында өч төсле М., төкле М., басу М.се һ.б.ның җир өсте өлешләре файдаланыла, аларда флавоноидлар, сапониннар, органик к-талар, каротин, эфир майлары бар. Үлән төнәтмәсе тамак йомшарту, бәвел кудыру чарасы, ш.у. матдәләр алмашын көйләүче буларак кулланыла. Басу М.се, күрексез М. (V. contempta), өч төсле М. — декоратив, баллы үсемлекләр. Төрле төстәге эре чәчәкле Виттрок М.се яки ала М. (V. wittrockiana) культуралы үсемлек буларак үстерелә. Төксез М. (V. epipsila), сазлык М.се (V. palustris) һәм күләгә М.се (V. selkirkii) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**МИЛӘ́Ш** (Sorbus), роза чәчәклеләр семьялыгыннан яфрак коючан агачлар яки куаклар ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: гади М. (S. aucuparia) һәм аю баланы яфраклы М. (S. sambucifolia). Гади М. барлык районнарда, аеруча ылыслы агачлар үскән урманнарда очрый. Биеклеге 4–15 *м*. Кайрысы шома, соры. Ябалдашы җыйнак. Яфраклары чиратлашкан, парсыз каурыйсыман, очлы пычкы читле. Чәчәкләре ике җенесле, ак, аксыл сары, хуш исле, калкан чәчәк төркемендә. Җимешләре — вак, шарсыман, кызыл яки кызгылт-сары. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре сентябрьдә өлгерә, агачта хәтта кыш көне дә саклана, беренче кыраулардан соң ачы тәме бетә. М. орлыктан һәм тамыр үрентеләреннән үрчи. Суыкка һәм корылыкка чыдам. Җимешләре шикәргә, органик к-таларга, пектин матдәләргә бай. Фәнни медицинада авитаминоз вакытында сәламәтләндерү чарасы буларак кулланыла; витаминлы җыелмалар составына керә; халык медицинасында бәвел кудыру һәм тонусны күтәрү чарасы буларак файдаланыла. Җимешләре кошлар (боҗыр, суерлар, көртлекләр, күкшә-



Гади миләш.

ләр һ.б.) өчен азык булып тора. Декоратив үсемлек буларак, бакча һәм паркларда үстерелә. Үзагачы каты, нык, кызгылт төстә; төрле әйберләр ясаганда кулланыла. Саклагыч урманнар үстерүдә файдаланыла. Баллы үсемлек. Аю баланы яфраклы М. — респ-ка өчен сирәк төр, Куйбышев сусаклагычы терр-ясендә очрый. 1–2 *м* биеклектәге куак, ялтырап торган ачык яшел яфраклы һәм кызгылт сары — кызыл җимешле. Культурада таралган кара миләш арония ыругына карый (к. *Кара миләш*).

**МИЛӘ́Ш ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Turdus), чебенче кошлар семьялыгына караган миләш чыпчыгысыманнар ассемьялыгыннан сайрар кошлар ыругы. 62 төрне үз эченә ала. Европа, Азия, Америкада таралганнар; Яңа Зеландиягә китерелгәннәр. ТРда 5 төре оя кора: миләш чыпчыгы (T. pilaris), сайрар миләш чыпчыгы (T. ericetorum), кара миләш чыпчыгы (T. merula), деряба (T. viscivorus), ак кашлы миләш чыпчыгы (T. musicus). Озынча тәз гәүдәле (20–27 *см* озынлыкта), хәрәкәтчән, шау-шулы, аерылып торучан кошлар, көчле туры томшыклы, биек аяклы, озын койрыклы. Каурый капламы тыгыз, чуар. М.ч. үзләренең сайраулары б-н билгеле. Аеруча миләш чыпчыгы киң таралган. Канаты һәм койрыгы кара көрән, аркасы кара коңгырт, башы һәм муены зәңгәрсу-соры, асты ак, түше һәм ян-яклары кара чуар төстәге зур кош. Сайравы яңгыравыклы. Колония булып, урманнарда, шәһәр бакчаларында, паркларда оялый. Төркем хасил итә. Ояларын агач ботакларында, түмгәкләрдә, кайвакыт




Миләш чыпчыклары. 1. Миләш чыпчыгы; 2. Сайрар миләш чыпчыгы.

куаклыкларда кора. Сайрар миләш чыпчыгы берникадәр кечерәк, коңгырт, гәүдәсенең аскы ягы тамчысыман кара тимгелле. Куаксыз чиста нарат урманнарыннан кала барлык төр урманнарда яши. Кичен һәм таңда сайрый, сайравы ике тапкыр кабатланучы сызгырудан гыйбарәт. Кара миләш чыпчыгының каурый капламы кара төстә, томшыгы ачык кызыл-сары, күз тирәсе ак боҗралы. Куаклар күпләп үскән ылыслы һәм яфраклы урманнарда яши, җиргә якын оялый. Сайравы буенча сайрар миләш чыпчыгыннан гына калыша, әмма башка кошларның тавышын кабатлау буенча аннан өстен тора. Тышкы кыяфәте б-н сайрар миләш чыпчыгына охшаш, тик зуррак. Катнаш урманнарда һәм наратлыкларда очрый. Сайравы флейта тавышын хәтерләтә. Шулай ук ак кашлы миләш чыпчыгы сайрар миләш чыпчыгына охшаш, әмма, аннан аермалы буларак, ян-яклары кызыл-сары, күз өстендә киң кызыл-ак «кашлары» бар. Елга тугайларында куаклар (тал, шомырт) арасына оялый.

М.ч. — күчмә кошлар, гадәттә, Көньяк Европада кышлыйлар. Язның беренче билгеләре б-н оялау урыннарында күренә башлыйлар. Ояларын кипкән үлән, нәзек чыбык, тамырлардан, лишайник, мүктән коралар. 4–7 йомырка салалар. Ояда 13–14 көн утыралар. Бер сезонда 2 оя бала чыгаралар. Аеруча балаларын ашату чорында зарарлы бөҗәкләрне күпләп юк итәләр. Җимеш һәм җиләкләр б-н тукланып, агач һәм куак орлыкларының таралуына булышалар.

*Әд.:* Птицы Волжско-Камского края. Воробьиные. М., 1978; Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988; Аськеев И.В., Аськеев О.В. Орнитофауна Республики Татарстан. К., 1999.

**МИЛИ́ЦИЯ**, җәмәгать тәртибен, гражданнарның, пр-тие, оешма, учреждениеләрнең милкен, хокукларын һәм хокукый мәнфәгатьләрен җинаятьчел үзләштерүдән һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрдән саклаучы орган. Казан губернасында Вакытлы хөкүмәтнең 1917 елның 11 мартында һәм 17 апрелендә чыгарылган карарларына туры китереп, *полициягә* алмашка «халык милициясе» буларак төзелә. Әмма составына элеккеге *полиция идарәләренең* эзләү бүлекчәләре кертелгән «вакытлы милиция» оештырылмый кала. Окт. рев-циясеннән соң М. РСФСР Эчке эшләр халык комис-тының 1918 ел 20 октябрь карары нигезендә булдырыла. Татарстанда җирле Советлар һәм аларның башкарма ком-тлары карамагында булып, ТАССР Эчке эшләр халык комис-тына (1920–30, 1937–46), ТАССР ХКСна (1931–37), ТАССР Эчке эшләр министрлыгына (1946–49, 1953 тән), ТАССР Дәүләт иминлеге министрлыгына (1949–53) буйсына. 1918 нең 20 октябрендә Казан губерна эшче-крәстияннәр милициясе идарәсе оештырыла; ул РСФСР БҮБК һәм ХКСның 1920 ел 27 май Декреты, ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н — ТАССР Эчке эшләр халык комис-тының Баш милиция идарәсе, ТАССР ҮБК һәм ТАССР ХКСның 1930

ел 20 декабрь карары б-н ТАССР ХКС каршындагы Милиция һәм җинаятьчеләрне эзләү идарәсе итеп үзгәртелә. 1937 дән ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты (1946 дан — Эчке эшләр министрлыгы) составында сәяси һәм җинаятьчеләрне эзләү, соц. милекне урлау һәм спекуляция б-н көрәш бүлекләре, сугышчан әзерлек, паспорт-виза, дәүләт автоинспекциясе хезмәтләре һ.б. ачыла. 1949 дан М. җирле бүлекчәләр б-н җитәкчелек итүдә төбәк принцибыннан җинаять төрләре буенча җитәкләү принцибына күчә. Респ-ка М.сенең оештырылу һәм эшчәнлек нигезләре РСФСРның 1991 ел 18 апрель Законы б-н билгеләнә. Ул ТР Эчке эшләр министрлыгы составындагы криминаль М.гә һәм җирле (җәмәгать куркынычсызлыгы) М.гә бүленә. Криминаль М.гә җинаятьчеләрне эзләү, икътисади җинаятьләргә, оешкан җинаятьчелеккә, наркотикларның законсыз әйләнешенә, алкогольле продукциянең законсыз әйләнешенә каршы көрәш идарәләре, кинологлар хезмәте, Интерпол милли үзәк бюросы ф-лы керә. Башлангыч тикшерү эшләре мәҗбүри булган җинаятьләрне искәртү, булдырмау һәм ачу, ш.у. сорау алу, тикшерү һәм мәхкәмә органнарыннан яшеренүче, җинаять җәзасыннан качучыларны, хәбәрсез югалган затларны эзләүне оештыру, табу һ.б. б-н шөгыльләнә. Җәмәгать куркынычсызлыгы М.сенә җәмәгать тәртибен, М. участок уполномоченныйлары, балигъ булмаганнар эшләре һәм лицензия-рөхсәт бирү бүлекчәләре эшчәнлеген тәэмин итү, паспорт-виза хезмәте, сорау алуларны оештыру, ведомстводан тыш сак, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәләре керә. Гражданнарның шәхси иминлеген, җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү, башлангыч тикшерү эшләре мәҗбүри булмаган җинаять гамәлләрен һәм адм. хокук бозуларны искәртү һәм булдырмау, ш.у. гражданнарга, вазифаи затларга һәм оешмаларга ярдәм күрсәтү б-н шөгыльләнә. 2011 дә полиция итеп үзгәртелә.

*Әд.:* На пороге третьего тысячелетия. К., 1997; На страже порядка. К., 1997.

*Е.Б.Долгов.*

**«МИЛИ́ЦИЯ. ЗАКО́ННОСТЬ. ПРАВОПОРЯ́ДОК»** («Милиция. Законлылык. Хокукый тәртип»), ТР хокук саклау органының атналык газетасы. 1933 елның октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. Оештыручылары — ТР Эчке эшләр министрлыгы, газета редакциясе коллективы. Мөхәррирләре — В.Сәлимгәрәев, С.Дәүләтбаев (1997 дән). Газета хокук саклау өлкәсенә кагылышлы рәсми документлар бастыра. ТРда милиция хезмәтен, мәхкәмә органнары; прокуратура, адвокатура, таможня, арбитраж эшләрен яктырта; криминаль хәбәрләр басыла. 2009 дан «Особый менталитет» исеме б-н чыга.

**МИЛЛӘ́Т** (гарәп. ملة), индустриаль җәмгыятьнең үсеш процессында барлыкка килгән этник берлек формасы. Үз-үзләренә исем бирү, кардәшлекләрен, тарих-мәдәният (әдәби тел, дин, гореф-гадәтләр) уртаклыгын аңлавы нигезендә берләшкән кешеләрнең тотрыклы социаль-тарихи, этник бергәлеге. «М.»нең этник һәм сәяси мәгънәсе төрлечә — этник бергәлек (этномилләт) һәм ватандаш (этник аерымлыкларына карамастан, илнең барлык яки күпчелек гражданнары — «америкалылар», «россиялеләр») буларак аңлатыла. Хәзерге заман фәнендә «этномилләт» төшенчәсенә нисбәтле берничә теория яшәп килә: примордиалистик (эссенциалистик), инструменталистик һәм конструктив теорияләр. Примордиалистик теория социобиологик һәм эволюцион-тарихи юнәлешләргә бүленә. Беренче юнәлеш тарафдарлары (Ван ден Берг, Л.Н.Гумилёв, К.Хюбнер) этниклыкны кешеләрнең борынгыдан ук теге яки бу төркемгә хас объектив чынбарлык буларак тикшерәләр. Моны аңлату өчен еш кына «М.» килеп чыгуын өйрәнүче расачыл һәм эволюцион-генетик теорияләрдән файдаланалар. Эволюцион-тарихи юнәлеш тарафдарлары (Ю.В.Бромлей, Н.Н.Чебоксаров, В.И.Козлов, А.Х.Халиков, С.А.Арутюнов, Э.Смит һ.б.) М.не биол. бергәлек дип түгел, ә бәлки этник җәмгыятьнең социаль-тарихи үсеше б-н борынгыдан бәйләнеше булган социаль бергәлек итеп карыйлар. М. турында мондый караш дөньяви фәндә 1960–70 елларга кадәр өстенлек итә, илебез фәнендә исә 1990 елларда да бердәнбер була. Инструменталистик караш этник төркемнәрнең саклануы кешеләрнең гаммәви мәдәниятле прагматик җәмгыятькә хас читләшүләрен җиңеп чыгу ихтыяҗына туры килә дип аңлата. Ә М. үзе алар тарафыннан сәяси көрәштә төркем мәнфәгатьләренә ирешү максатында туплау чарасы булып карала. Конструктив карашлар буенча (Б.Андерсон, Э.Геллнер, Э.Хобсбаум, В.А.Тишков, С.В.Соколовский һ.б.) М. — электән үк этник берлек булып та яшәмәгән, этносның табигый үсеше нәтиҗәсендә дә оешмаган, бәлки этномәдәни карашлар һәм «этник хисләр» рәвешендәге социаль-сәяси доктриналарны эшләү, оештыру һәм халык аңына кертүдә зыялы төркемнәр яки милли лидерлар тарафыннан әзерләнгән социаль продукт. Моңа аң-белемнең киң таралуы һәм гаммәви мәгълүмат чараларының йогынтысы да шактый булышлык итә. 20–21 йөзләр чикләрендә кайбер этнологлар, тарихчылар, социологлар (Л.М.Дробижева, Д.М.Исхаков, И.Л.Измайлов һ.б.), әлеге карашларның бер мәгънәлелегеннән читләшергә теләп, гомуми дифракцион теория тәкъдим итәләр. Аның буенча, этник берлек буларак, М., һәр тарихи чорда мәдәният, тел, көнкүреш гадәтләренең яңа элементларын даими үзләштереп, элеккеләрен югалту, тарихи үткәннәргә яңача караш процессында үскән, үз-үзләренә биргән исемнең, тел һәм мәдәниятнең ачык аңлаешлы бердәмлеген күрсәтә. Әлгәреге урта гасырлар берлекләреннән М. булып формалашуның мөһим факторы — сәяси икътисад. Базар мөнәсәбәтләренең киңәюе һәм тирәнәюе, җәмгыятьнең демократияләшүе, гаммәви элемтә чараларының камилләшүе йогынтысында аерым дәүләт кысаларында халыкның тагын да тыгызрак һәм ныклырак бердәмлеге хасил була, урта гасырлар партикуляризмы, социаль һәм мәдәни-дини таркаулык җиңелә. Мәдәният һәм тел өлкәсендәге тирән кузгалышлар б-н янәшә баручы мондый процесслар этностан өстен мәдәни һәм этносәяси гореф-гадәтләр тәрбияләүгә, ш.у. бердәм әдәби тел һәм тиешле мәгариф системасын төзүгә (кайвакыт ясалма юл б-н) китерә. Нәтиҗәдә, анык сыйфатларын (гомуми аталыш, тарихи вакыйгалар, әдәби тел нормалары һ.б.) зыялы милли элита формалаштырган яңа этносәяси берлек барлыкка килә. Теге яки бу М.нең барлыкка килүе төрлечә булырга мөмкин: урта гасырлардан ук этник үсеш линиясенең турыдан-туры дәвам итүе (инглизләр, руслар, поляклар, кытайлар); ике яки берничә этносәяси берлекнең этник якынаюы нигезендә барлыкка килгән М. (немецлар, испаннар, французлар); урта гасырлардан килгән бер этник берлекнең дивергенцияләнүе (аерылуы) нәтиҗәсендә ике яки берничә М. барлыкка килү (словениялеләр, хорватлар, босниялеләр һәм серблар; руслар, белоруслар һәм украиннар). Дәүләт М.нең барлыкка килүе һәм үсешендә мөһим фактор булып тора, халыкның үз милли дәүләтен төзергә омтылуы һәрвакытта халык хәрәкәтенең мөһим юнәлешеннән санала. М. булып җитешүдә *татарлар* үзенчәлекле юл үтә. Яңа дәүләтчелек барлыкка килгән *Алтын Урда* чоры аларның этник тарихында мөһим урын алып тора. Яңа гореф-гадәтләр, мәдәният, әдәби тел һәм этносәяси үзаң, беренче чиратта, хәрби-түрә катлау мохитендә формалаша, ә «татар» атамасы дәүләт аксөякләре этносоциаль берлегенең дә политонимы буларак кулланышка керә. Җүчиләр империясе берничә бәйсез дәүләткә (ханлык) таркалгач, татар этносәяси берлеге дә өлешләргә бүленә, андагы төркемнәр мөстәкыйль һәм билгеле бер чикләрдә үсеш ала, ләкин барлык дәүләтләрдәге югары катлау үзен татар дип атавын дәвам итә. Урта гасырларда «татар» атамасы, чит этноним буларак, Русьта, Европа һәм мөселман илләрендә Монгол империясенең бөтен халкын билгеләү сыйфатында кулланыла. 16–17 йөзләрдә Идел һәм Урал буе татар ханлыкларын Рус дәүләтенә кушканнан һәм аларның этносәяси системасы җимерелгәннән соң, бердәм мәдәният таркала, милли югары катлауның сыйнфый төсе югала һәм төп өлеше христианлаштырыла. Болар «татар» төшенчәсенең киң халык мохитенә таралуына сәбәп була. Бу чорда, аеруча татар ханлыкларын руслар яулап алганнан соң, дини (мөселман) үзаңның роле зур була. 19 йөзнең 2 нче яртысында буржуаз социаль-икътисади мөнәсәбәтләрнең үсеше (Идел-Урал төбәгендә яшәүче татарлар мохитендә аеруча күзгә ташлана) һәм милли мәдәниятнең күтәрелеше чорында татар этносының тарихи-мәдәни бердәмлеген аңлау яңа нигездә барлыкка килә, «татар» атамасы аңа бәйле күзаллау һәм риваятьләр нигезендә яңартылган милли үзаң формалашу процессы башлана һәм гомумтатар идеологиясе формасындагы яңа тарихи традицияләр туа (Ш.*Мәрҗани*, И.*Гаспринский*, Р.*Фәхретдин*, Һ.*Атласи*, Г.*Исхакый* һ.б.). *Җәдитчелек* һәм гомуми мәгариф системасы, әдәби тел, китап басу һәм вакытлы матбугатның үрнәк нормалары нигезендә алга киткән «югары» мәдәният формалашу процессында Ка-

зан татарлары этносы Россиядәге төрки-мөселман халыкларының тартылу үзәге һәм татар М. үсешенең нигезе булып әверелә. Мәдәни-интеграль процесслар нәтиҗәсендә хәзерге заман М.е барлыкка килә, бу бердәм татар милли үзаңы формалашуга һәм «татарлар» дигән гомуми үзатама расланyга китерә. Татар М.нең алга таба ныгый баруы һәм үсеше совет иҗтимагый-сәяси, соц.-икътисади һәм этномәдәни камилләшү шартларында бара.

Хәзерге заманда аермаларны тигезләүче гаммәви мәдәният йогынтысында М.нең этномәдәни һәм иҗтимагый тормышы глобальләшә һәм камилләшә бара. Мәгълүмати-технологик цивилизация һәм халыкларның үзара йогынтысы үсә барган шартларда үзенең этномилли үзенчәлеген саклау, супер- һәм мегамилләтләр, үзенчәлекле, эшлекле милли бердәмлекләр даирәсендә үз урынын билгеләү ихтыяҗы туа.

*Әд.:* Хасанов Х.Х. Формирование татарской буржуазной нации. К., 1977; Бромлей Ю.В. Очерки теории этноса. М., 1983; Национализм и формирование нации: Теории, модели, концепции. М., 1994; Тишков В.А. Очерки теории и политики этничности в России. М., 1997; Козлов В.И. Этнос. Нация. Национализм: Сущность и проблематика. М., 1999; Единство татарской нации: Материалы науч. конф. АН РТ «Цивилизационные, этнокультурные и политические аспекты единства татарской нации». К., 2002; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Введение в этногенез и этническую историю татарского народа. К., 2007.
*И.Л.Измайлов.*

**«МИЛЛӘ́Т»**, Казандагы басмаханә. 1908 елның сентябрендә «Идриси, Галиев вә шөрәкясе» китап сәүдәсе ширкәте нигезендә ачыла. 1908 нең 25 ноябреннән мөстәкыйль («М.» фирмасы буларак) эшли башлый. Иң беренче басылган китап — Р.Фәхретдиннең «Шәкертлек әдәбе». 1908 дән 1917 гә кадәр гомуми тиражы 1376015 данә булган 256 китап нәшер ителә. 1909 ел иң уңышлы ел була: 303800 данә тираж б-н 53 китап чыга. Басылган китапларның күбесе (218) басмаханәнең үз исәбенә нәшер ителә. Басмалар арасында мәктәп һәм мәдрәсә дәреслекләре зур урын алып тора. Р.Фәхретдиннең дидактик хикәяләре (16 басма), Россия халыклары тарихы, мед., гарәп фәлсәфәсе китаплары, календарьлар, нәшрият каталоглары, җәмгыять уставлары һ.б. басыла. «М.» — Х.Исхаков, Г.Рамазанов, З.Бәшири, К.Сәгыйтов, Г.Мусин һ.б. язучыларның 18 матур әдәбият әсәрен чыгара. 74 басма (гомуми тиражы 478800 данә) — дини эчтәлектә, аларның 47 се — Г.Галиев (Г.Баруди) әсәрләре, 3 басма — «Һәфтияк», 1 се — Коръән аятьләре. Аз гына күләмдә чит заказлар да (Г.Тукай шигырьләренең 3 басмасы, М.С.Иманкулованың «Тәрҗемәче»се, кулинария китаплары) басыла.

Басмаханәдәге татар хәрефләренең яңа запаслары, төрле башланма, төгәлләү үрнәкләре һ.б. бизәмәләрне Татполиграф 1940 ка кадәр файдалана. М.*Идрисовның* Мәскәү, С.-Петербургның иң яхшы басмаханәләрендә һәм Германиядә, Төркиядә өйрәнүе нәтиҗәсендә яңалыклар кертелә, күптөсле басма кулланыла. Полиграфиянең югары дәрәҗәсе дәреслекләр, портрет, открыткаларны иң яхшы Европа стандартларына туры китереп эшләргә, күптөсле географик карталар бастырып чыгарырга мөмкинлек бирә. 1916 да нибары 4 китап нәшер ителә, 1917 дә исә бер китап та басылмый. Бу — сугыш һәм рев-ция елларындагы авырлыклар б-н бәйле була. Югары дәрәҗәдәге полиграфия эшләнеше зур капитал салулар таләп итә. Бу елларда басмаханәдә 52 эшче һәм хезмәткәр эшли, «Американка», «Бостонка» машиналары, стереотип станок була. 1921 нең 1 гыйнварында «М.» басмаханәсе национализацияләнә, Сигезенче дәүләт басмаханәсе дип атала башлый. Республика Революцион Хәрби Советы сәяси идарәсенең Көнчыгыш бүлеге заказларын үти. 1921 дә Кыргызстан өчен «Әлифба» (1 нче кисәк), брошюралар («Демобилизация турында», «Кызыл армия», «Иҗади театр») һ.б. басыла, «Кызыл яшьләр» г-тасы, хосусый китап нәшриятларының дәреслекләре чыга. «М.» басмаханәсе каршында китап кибете эшли (1897 дән), Уфа (1900), Минзәлә (1909), Әстерхан (1910), Чаллы шәһәрләрендә ф-лары ачыла. Бу кибетләрдә, үз басмалары б-н беррәттән, Казан, Уфа, Оренбург басмаханәләрендә дөнья күргән шәрекъ телләрендәге, Каһирә, Бәйрут, Истанбулда басылган китаплар да сатыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Здравствуй, Книга! К., 1989.

**«МИЛЛӘ́Т»** («ملت»), көндәлек иҗтимагый-сәяси, икътисади газета. 4 нче Дәүләт Думасының мөселманнар фракциясе органы. 1913 елның 28 декабреннән 1915 нең 7 февраленә кадәр Петроградта нәшер ителә, барысы 19 саны чыга. Текстлар татар һәм рус телләрендә басыла. Наширләре — Б.Әхмәтов һәм С.Җантурин, мөхәррире — И.Леманов. «Мөселман фракциясе», «Мөселман басмасы», «Безнең хәбәрләр» һ.б. рубрикаларда илдәге сәяси вазгыять, Дәүләт Думасында мөселманнар эшчәнлеге, Мөселман иҗтимагый оешмалары съезды эше, халык мәгарифе, яралы хәрбиләр һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү һ.б. мәсьәләләр яктыртыла.
*Җ.С.Миңнуллин.*

**МИЛЛӘ́Т МӘҖЛЕСЕ́** (Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының Милләт Мәҗлесе), төрки-татарлар милли парламенты. Эчке Россия һәм Себер мөселманнары эшчәнлеге б-н идарә итү максатыннан, Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае (1917 елның 21 июле — 2 августы, Казан) карары б-н җыела. 1917 нең 20 ноябреннән 1918 нең 11 гыйнварына кадәр Уфа шәһәрендә эшли. М.М. эшчәнлегендә, Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының милли-мәдәни мохтарияте нигезләрен эшләү комиссиясе тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр буенча һәр ике җенескә караган 50 мең кешедән 1 депутат исәбеннән, 110 депутат катнаша. 20 яшькә җиткән төрки-татар мөселман кешесе (җенесенә карамастан) сайлый һәм сайлана ала. Рәис итеп С.*Максуди*, рәис урынбасары итеп Ибн. *Әхтәмов*, секретарь итеп Г.*Фәхретдинов* сайлана. Югары башкарма орган — *Милли Идарә*. Закон проектын әзерләү, мандат, мәгариф, финанс, дин эшләре, терр. автономияләр, «милли өлкәләр» комиссияләре эшли. М.М. эшчәнлеген матди яктан тәэмин итү өчен махсус фонд оештырыла, теләгән һәр кеше М.М.нә матди ярдәм күрсәтә ала. С.Максудиның мөселманнарга мөрәҗәгатеннән соң, фондта байтак сумма туплана; бу акчага М.М. җыеннары уза торган бина (Уфадагы С.Шәмгулов кибете) җиһазландырыла. Мәҗлес барышында ике фракция барлыкка килә: төркичеләр — Эчке Россия һәм Себер төркиләренең милли-мәдәни мохтарияте яклылар (С. һәм Ә. Максудилар, З.Кадыйри, Г.*Терегулов* һ.б. — барысы 50 ләп кеше) һәм туфракчылар (территориячеләр) — Идел-Урал Штаты формасындагы автономия яклылар (И.*Алкин*, С.*Атнагулов*, Һ.*Атласов*, Г.*Баттал*, С.*Җантурин*, С.*Енгалычев* һ.б. — барысы 37 кеше). М.М. утырышларында милли-мәдәни мохтарият законнарын эшләү һәм Милли Идарә сайлау кебек төп мәсьәләләр б-н беррәттән, советлар режимына мөнәсәбәт, диннең дәүләттән аерымлануы, Идел-Урал терр. автономиясе оештыру, яңа оешкан хөкүмәткә урнашыр өчен төбәк сайлау кебек мәсьәләләр дә карала. М.М. Совет хөкүмәтен рәсми танымый һәм Идел-Урал Штаты төзү турында карар кабул итә; шул максатка ирешү өчен *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәте* сайлана. Диннең дәүләттән аерымлануы мәсьәләсендә, озак барган дискуссиядән соң, күпчелек каршы тавыш бирә. Депутатлар юстиция, мәгариф, финанс эшләрен, хәрби эшне оештыру мәсьәләләре; төрки-татарлар (татар, мишәр, типтәр, нугай, башкорт һ.б. төркемнәрнең милли бергәлеген ассызыклау максатыннан, депутатлар әлеге төркемнәрнең һәркайсы өчен ярашлы төрки-татар атамасын куллана) яши торган җирләрне терр-яләргә бүлү буенча комиссияләрдә эшләнгән төп нигезләмәләрне кабул итәләр. Шул көннәрдә Уфада булган 10 мең хәрби мөселман М.М.нә тугрылык анты бирә. 1918 нең февралендә Идел-Урал Штаты төзү инициативасын Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең Казанда барган икенче корылтае лидерлары үз кулларына алалар. Совет хакимияте һәм милли хәрәкәт җитәкчеләре арасындагы мөнәсәбәт кискенләшә. 28 февральгә каршы төндә корылтайның кайбер җитәкчеләре кулга алына (к. *Болак арты республикасы*). 1918 нең 25 апрелендә И.Сталин һәм М.*Вахитовның* уртак карары нигезендә, Мәскәү Милли Шурасы б-н бәйле барлык оешмаларның эшчәнлеге туктатыла, аларның мөлкәте, акчасы, документлары һәм урнашкан биналары Үзәк татар-башкорт комис-тына тапшырыла. Шул ук көнне Г.Баембәтов әлеге карар турында Уфага җибәрелгән телеграмманы идарә рәисе С.Максудига тапшыра. Милли Идарә җыелышында таләпләргә буйсынырга карар чыгарыла. М.М. депутатларының бер өлеше большевикларга каршы көрәшүчеләр кулында булган терр-яләргә китә.

М.М. делегатларының сайланган төбәге, кайсы фракциягә керүе һәм кайсы комиссиядә эшләве күрсәтелгән исемлеге: С.Абдуллин (Пермь ш.; туфракчы; дин эшләре, законнар чыгару, регламент, мандат, милли өлкәләр комиссияләре); Г.Абызов (Рос-

тов-Дон ш.; туфракчы; законнар чыгару, терр. автономияләр, милли өлкәләр комиссияләре); С.Агафурова (Пермь ш.); А.*Акчурин* (Акмулла ш.; туфракчы; М.М. секретаре урынбасары; мәгариф, милли өлкәләр комиссияләре); Х.Акчурин (милли өлкәләр комиссиясе); И.Алкин (Казан; туфракчы; М.М. рәисе урынбасары; законнар чыгару, регламент, терр. автономияләр комиссияләре); Ш.*Алкин* (Уфа ш.; төркиче; финанс комиссиясе рәисе; *Малия нәзарәте* рәисе); Г.Әлмөхәммәдов (Уфа ш.; мандат комиссиясе); Г.*Алпаров* (Уфа ш.; төркиче); Г.Әмиров (Румын фронты; туфракчы; финанс, терр. автономияләр комиссияләре); Г.Арсланов (Казан); Һ.Атласов (Самара ш.; төркиче; законнар чыгару, терр. автономияләр комиссияләре); С.Атнагулов (Уфа ш.; туфракчы; терр. автономияләр комиссиясе); Ш.*Әхмәдиев* (Казан; туфракчы; мәгариф, мандат, финанс, законнар чыгару, терр. автономияләр комиссияләре); Ф.Әхмәдуллин (Уфа ш.; туфракчы; финанс, законнар чыгару комиссияләре); Г.Әхмәдов (Әстерхан ш.; төркиче, финанс комиссиясе); Ш.Әхмәдов (милли өлкәләр комиссиясе); М.Әхмәров (Уфа ш.); Ибн. Әхтәмов (Уфа ш.; төркиче; М.М. рәисе урынбасары, законнар чыгару комиссиясе); Г.Әюпов (1 нче армия; катнашмый); З.Аюханов (Самара, Мәләкәс шәһәрләре; туфракчы; дин эшләре, мәгариф комиссияләре); Г.Баһаветдинов (Казан; туфракчы; дин эшләре, мандат комиссияләре); Х.Баһаветдинов (Самара, Богырыслан шәһәрләре); М.Багдани (Казан; килми); Х.Байбиков (Касыйм ш.); Х.Бакыев (Сембер ш.; төркиче; мәгариф комиссиясе); Г.Балтанов (Алабуга ш.); Г.Баниев (милли өлкәләр комиссиясе); Д.Баталиев (төркиче; мәгариф комиссиясе); Г.Баттал (Казан; төркиче; регламент, мандат, терр. автономияләр комиссияләре); И. *Бикколов* (Сембер; төркиче; мәгариф, финанс, мандат комиссияләре); Г.*Буби* (Вятка ш.; туфракчы); Х.Борнашев (Румын фронты; туфракчы; регламент комиссиясе); Ә.*Вәлиди* (Уфа); М.Вахитов (Казан; килми); С.*Вахидов* (Казан; туфракчы; милли автономияләр комиссиясе); Б.Габбасов (Оренбург ш.); Г.Габделбаниев (Оренбург ш.); И.Габделбариев (Оренбург ш.; төркиче; дин эшләре комиссиясе); Г.Габдрахманов; Габдрәшитов (Верхнеуральск ш.); С.Габидов (милли өлкәләр комиссиясе); И.*Габитов* (Казан; төркиче; регламент комиссиясе); М.Габидуллин (Бөгелмә ш.; милли өлкәләр комиссиясе); Г.Гайсин (Оренбург ш.; килми); Ш.Гайфи (Әстерхан ш.; төркиче; мәгариф, терр. автономияләр, милли өлкәләр комиссияләре); Д.Галиев (10 нчы армия); В.Галләмов (Оренбург ш.; туфракчы; регламент, мандат комиссияләре); Г.Даукаев (Уфа ш.; мандат комиссиясе); Г.Дивиев (Харьков ш., төркиче; регламент, законнар чыгару, милли өлкәләр комиссияләре); Г.Дивишев (Төньяк Россия); С.Җантурин (Уфа ш.; төркиче; финанс, милли өлкәләр, терр. автономияләр комиссияләре); Д.Еналиев (Пенза ш.; төркиче; милли өлкәләр, мәгариф комиссияләре); С.Енгалычев (Саратов ш.; туфракчы; законнар чыгару, терр. автономияләр комиссияләре); Х.Ермиев (2 нче армия; төркиче; финанс комиссиясе); Х.Зәйнуллин (3 нче армия; төркиче; терр. автономияләр комиссиясе); А.Зиннәтуллин (Самара ш.); Х.Зөфәров (5 нче армия); Г.*Ибраһимов* (Уфа ш.; туфракчы; финанс, законнар чыгару комиссияләре); И.Исламголов (Уфа ш.); М.Исмаков (Уфа ш.); Г.Исхаков (Мәскәү; төркиче; законнар чыгару, милли өлкәләр комиссияләре); С.Исхаков (Уфа ш.); З.Кадыйри (Уфа ш.; төркиче; мәгариф, терр. автономияләр комиссияләре); З.*Камали* (Уфа ш.; туфракчы; мәгариф, дин эшләре комиссияләре); Ф.Камалова (Оренбург ш.; килми); К.Кәримов; Г.Касыймов (Уфа ш.; туфракчы; финанс, мандат комиссияләре); Г.Китабов (Оренбург ш.; туфракчы); М.*Корбангалиев* (Казан; килми); Н.Корбангалиев (Оренбург, Троицк шәһәрләре; төркиче; регламент, законнар чыгару, терр. автономияләр комиссияләре); И.Кадерлиев (12 нче армия); С.Максуди (Казан); Ә.*Максуди* (Казан; төркиче); З.Маликов (12 нче армия); М.Мозаффаров; Х.Мозаффаров (Казан; төркиче; дин эшләре комиссиясе); Й.*Мозаффаров* (Румын фронты; килми); Г.Мортазин (Оренбург ш.; туфракчы; дин эшләре, мандат комиссияләре); Ф.*Мөхәммәдьяров* (туфракчы; М.М. рәисе урынбасары); А.Мөхәммәддинов (Уфа ш.); М.Мөхәммәдов (Уфа ш.; килми); Ә.*Мостафин* (Казан); М.Нугаев (Уфа ш.; килми); Ниязголов (Верхнеуральск ш.; килми); Г.Рәхимкулов (мандат, милли өлкәләр комиссияләре); Г.Рахманкулов (Кавказ фронты; туфракчы; регламент комиссиясе); Г.Рахманкулов (Пермь, төркиче; дин эшләре комиссиясе); Рафиков; К.Сәгыйдов (Петроград; милли өлкәләр комиссиясе); А.*Сәйфи* (Уфа ш.; туфракчы; мәгариф комиссиясе); Ф.*Сәйфи-Казанлы* (Уфа ш.; туфракчы; финанс, законнар чыгару, мандат, терр. автономияләр комиссияләре); К.Салихов (Казан); Х.Сафиуллин (Казан; туфракчы; регламент, мандат комиссияләре); Г.Сөләймани (Түбән Новгород ш.; төркиче; законнар чыгару, милли өлкәләр комиссияләре); М.Сөендеков (Верхнеуральск ш.); Х.Таначева (Казан; килми); Х.Таһиров (Тамбов ш.; милли өлкәләр комиссиясе); Г.Терегулов (Уфа ш.; төркиче; регламент, мәгариф комиссияләре); М.Усманов (Уфа ш.; туфракчы; дин эшләре комиссиясе); С.Урманов (Уфа ш.; төркиче; дин эшләре, терр. автономияләр комиссияләре); Г.Фәйзрахманов; Г.Фәхретдинов (Румын фронты; төркиче; регламент комиссиясе); Р.*Фәхретдин* (Уфа ш.; килми); Г.Хәйдәров (милли өлкәләр комиссиясе); Ш.Хәмиди (Уфа ш.; катнашмый); М.Халиков (Уфа ш.; туфракчы; мәгариф комиссиясе); З.Ходҗаши (Казан; катнашмый); Ж.*Хурамшин* (Уфа ш.; төркиче; финанс, мандат комиссияләре); М.Хәнәфи (Уфа ш.; туфракчы; дин эшләре комиссиясе); Х.Шаһидуллин (Самара, Богырыслан шәһәрләре); Г.Шәһиди (төркиче; дин эшләре комиссиясе); Ә.Ширванов (Уральск ш.); Г.Якубов (Уфа ш.); Х.Яһудин.

*Әд.:* Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; Исхаков С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 г. — лето 1918 г.). М., 2004; Давлетшин Т. Советский Татарстан. К., 2005.

*И.Р.Таһиров.*

**«МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң КОНТРРЕВОЛЮЦИО́Н-ФЕТНӘЧЕ́Л ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́** («Крәстияннар иттифагы»), 1933 елда ОГПУ тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Бер төркем кеше совет хакимиятен бәреп төшерү өчен коралны фетнә әзерләүдә, буржуаз-демократик респ-ка төзергә омтылуда гаепләнә. Мәсәлән, Б.Борнаев контрреволюцион оешма эшендә катнашуда, авылның совет хакимиятенә каршы «элементларын» барлауда һәм көрәшкә әзерләүдә, Арча р-ны колхозларында «таркату эше» алып баруда, кулак дип табылган крәстияннәрне оештыруда гаепләнә. Оешма үзәге Мәскәүдә, бүлекчәләре Татарстан АССРда, Башкортстан АССРда һ.б. милли республикаларда тупланган дип белдерелә. Татарстан бүлекчәсе буенча 34 (башка мәгълүматлар буенча — 36) кеше, ш.и. М.Алиев, Г.Әминов, Ф.Әхмәтов, Г.*Баембәтов*, К.Бикчәнтәев, И.*Галиев*, Д.Н.Грачёв, В.И.Гришин, В.Д.Егоров, М.Җиһаншин, Г.*Измайлов*, А.Козлов, И.Кулиев, Х.А.Миңнуллин, А.Нугаев, З.Нуркин, А.Савельев, Г.Сәгъдиев, М.*Сәгыйдуллин*, Г.Сәлимҗанов, Р.Шәрәфетдинов хөкемгә тартыла. Мәхкәмә утырышы 1933 нең 10 июлендә Казанда була. Гаепләнүчеләрнең күпчелеге төрле елларга хезмәт б-н төзәтү лагерьларына җибәрелүгә хөкем ителә, кайберләре, хөкемгә кадәр ябылуда тотылу сроклары исәпкә алынып, ирекккә чыгарыла. ТАССР Югары мәхкәмәсе президиумы, җинаять составы булмау сәбәпле, 1957 елның 15 сентябрендә әлеге карарны юкка чыгара, хөкемгә тартылучылар аклана (М.Мөхәммәтшин эше буенча аклау карары 1958 нең 14 июнендә чыгарыла).

**«МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң КОНТРРЕВОЛЮЦИО́Н-ФЕТНӘЧЕ́Л ЯШЕРЕ́Н МӘГЪЛҮМА́Т ТУПЛА́У ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́** (*Атласов эше*), 1937 елда Татарстан Эчке эшләр халык коми-ты тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Бер төркем кеше, чит дәүләтләр вәкилләре кушуы буенча, сов. хөкүмәтен корал кулланып бәреп төшерү һәм СССР терр-ясендә «мөстәкыйль төрки-татар буржуаз-демократик дәүләте» төзү максаты б-н контрреволюцион оешмага туплануда гаепләнә. Оештыручысы һәм җитәкчесе Һади Атласи дип табылган яшерен оешма эше буенча 24 кеше мәхкәмә җаваплылыгына тартыла. Мәхкәмә процессы 1937 нең 23–28 октябрендә Казанда уза. Г.А.Алтынбаев, Һ.М.Атласов, К.Л.Исхаков, К.К.*Туйкин*, Ф.К.*Туйкин*, С.Ш.Уразманов, Б.Фәттахов, З.Б.Фәттахов, Р.Я.Яруллин атарга хөкем ителә (1938 нең 15 февралендә үлем җәзасы тормышка ашырыла). Х.Б.Бастанов, У.А.Гомәров, Ф.Ш.Даутов, И.Идрисов, К.С.Ильясов, Х.Х.Надыйров, С.М.Туктарига 10 еллык төрмә срогы һәм 5 елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителү җәзасы бирелә. Ф.Бакиров, К.Г.Бикбов, Р.Д.Вилданов, Г.Исмәгыйлевкә карата әлеге җәза чаралары — 8 һәм 3; М.Әбделханов, А.С.Ермаковка карата — 7 һәм 3; С.Х.Халитовага кара-

та — 5 һәм 2 нисбәтендә билгеләнә. СССР Югары мәхкәмәсе Хәрби коллегиясе, җинаять составы булмау сәбәпле, 1953 нең 27 маенда әлеге карарны юкка чыгара, хөкемгә тартылучылар аклана.

**«МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң СОВЕ́Т ХАКИМИЯТЕНӘ́ КАРШЫ́ ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́**, 1937–39 елларда РСФСР Эчке эшләр халык комис-ты тарафыннан оештырылган гаепләү эше. Бу эш буенча, Мәскәүдәге уң троцкийчыларының террорчыл үзәге җитәкчелегендә Казан уң троцкийчылары блогы б-н берлектә СССРда совет хөкүмәтен юк итү һәм капитализмны кире кайтару максатыннан җинаятьчел оешма төзүдә гаепләнеп, 4 кеше хөкемгә тартыла. Мәхкәмә утырышы 1940 елның 2 июлендә Мәскәүдә була. М.Ю.*Борындыков*, М.Г.*Бәдәйли*, М.Тюменев 8 елга, И.Х.Бобров 5 елга хезмәт б-н төзәтү лагерена җибәрелүгә хөкем ителә. ТАССР Югары мәхкәмәсе президиумы, җинаять составы булмау сәбәпле, 1955 нең 27 октябрендә әлеге карарны юкка чыгара, хөкем ителүчеләр аклана.

**МИЛЛӘТЧЕЛЕ́К**, төп принципы милләтнең иң югары кыйммәт булуы, социаль-сәяси процессларда беренчеллеге турындагы тезистан торган теория, идеология һәм сәясәт. М. кешеләрнең теге яки бу милләткә нисбәтлелеге турындагы карашлар җыелмасына, милли факторны хакимияткә дәгъва кылуда төп дәлил сыйфатында алга куюга нигезләнә. М. идеологияләренең шовинистик, экстремистик, агрессив юнәлешләрдән алып (сугыш һәм басып алу юлы б-н илләр һәм халыкларны коллыкка төшерү, милли җәберләү, расачылык, «этник чистарту», башка халыкларны күралмау, үзенең этник җәмгыятен башка милләтләрдән өстен кую һ.б.) либераль-реформачы агымга кадәрге киң спектры яши. Сәяси планда М.не 2 төргә: бөек державачыл шовинизм һәм аз санлы халыкларның чиктән ашкан милләтчелегенә бүлеп карыйлар. М. идеологлары еш кына башка милләт һәм халык вәкилләренә карата дошманлык һәм күралмау хисе тоюдан ерак торалар, ә бәлки сәяси бәйсезлеккә омтылуларын игълан итәләр, үз халыкларының мул, иркен тормышта яшәүләрен кайгыртуны беренче чираттыгы эш дип карыйлар.

М. 17 йөз ахырында барлыкка килә һәм этник яки тел бердәмлеге нигезендә дәүләт төзү идеясен монархка, хуҗага, дингә феодалларча бирелгәнлеккә каршы куя. Әлеге идеологиянең алга таба таралуы милли азатлык хәрәкәтенә нык бәйле була. Элек Англиядә, аннары (18 йөз ахырында) Америка һәм Франция дәүләтләренең сәяси төзелешләрендә гомумхалык казанышы дип кабул ителгән шактый зур үзгәрешләр була. Бу милләтләрнең һәркайсы үзен азатлык идеясен иң хак йөртүче, беренчел чыганак һәм милли үзбилгеләнешләрендә хәзергә кадәр мөһим элемент дип саный. Бу җәһәттән М. либеральлек карашлары үсешендә мөһим роль уйный. Әгәр 18 йөз ахырында ил халкының холкына хас социомәдәни һәм сәяси бердәмлегенә басым ясалса, 19 йөздә исә этник М. тәэсире көчәя. Аның тарафдарлары милли бердәмлек гомум этник килеп чыгуга нигезләнә, һәм башка этнос вәкилләре әлеге мәдәниятнең төп вәкилләре була алмый дип саный. Вакытлар узу б-н әлеге агым ксенофобия һәм расачылыкның күп элементларын үз эченә ала. 20 йөз башында этник бериш милләт базасында дәүләт төзү идеясе киң тарала. Бу, үз чиратында, Европадагы Габсбурглар, Госманлылар, Романовлар империяләре кебек, күп кенә мультимилли дәүләтләрнең таркалуына китергән сәбәпләрнең берсенә әверелә. Башка социаль факторлар һәм иҗтимагый-сәяси агымнар б-н бәйләнгән әлеге идея шәхесне үз-үзен күрсәтү омтылышыннан мәхрүм иткән һәм үз мәнфәгатьләрен милләт мәнфәгатьләренә тулысынча буйсындырган җәмгыять төзергә өндәүче фашизмны барлыкка китерә. Фашизмга (нацизм) ш.у. расизм хас. Нацизмның Икенче бөтендөнья сугышында җиңелүе һәм Советлар Союзының сәясәте М.нең гадәттән тыш формаларының дәрәҗәсен төшерүгә, Азия һәм Африка илләрендәге милли азатлык хәрәкәтенең кискен көчәюенә, бөтендөнья колониаль системасының һәлакәтенә һәм яңа дәүләтләр төзелүгә этәрә. Әлеге процесс еш кына җирле М. үсешенә һәм хәтта трайбализм (кабилә эченә бикләнү) килеп чыгуга, аз санлы милләтләрнең бәйсезлеккә омтылу җирлегендә күп кенә яңа дәүләтләрнең җимерелүенә яки таркалу куркынычына китерә. Либераль-демократик режимлы илләрдә төп каршылыклар тирәнәя: гражданлык М. («милләтләр-илдәшләр») идеясе нигезендә гражданлык хокуклары, законнар чыгару дәрәҗәсендә мөстәкыйльлекне тәэмин итү, дәүләт мәдәниятен, динен, телен саклау раслана. Бер үк вакытта милләт булуларын аңлаган аз санлы милләтләр үзләренең тел, мәдәни, дини һәм сәяси хокукларын таләп итәләр. Кагыйдә буларак, радикаль милләтчеләр глобальләштерүгә каршы чыгалар һәм милли аерманы юкка чыгаручы гаммәви мәдәният басымына каршы ачыктан-ачык көрәшкә чакыралар. 20 йөз башыннан Россия фәнендә һәм сәясәтендә «М.» сүзен «шовинизм» һәм «ксенофобия» төшенчәләренең синонимы сыйфатында куллану гадәткә керә. Шуның б-н «М.» төшенчәсенең тискәре төсмере алгы планга чыга һәм эчтәлеге үз милләтенең өстенлегенә кайтып кала. Бу, бер яктан, Россиянең гамәлдә М. идеологиясе төшенчәсе һәм аның заманча теорияләре б-н таныш булмавы, икенче яктан – дөньяда кабул ителгән әлеге терминның патша һәм совет режимнары тарафыннан аңлы рәвештә бозып күрсәтелгән мәгънәсенең тарихи яктан ныгып калуы б-н бәйле.

Татар милли идеологиясе һәм этносәяси М. 19 йөзнең 2 нче яртысында аермачык чагыла башлый. Әлеге идеяләр беренче тапкыр Ш.*Мәрҗани* хезмәтләрендә формалаша. Галим аларда татар милләтенең мәдәни-тарихи бердәмлеге мәсьәләсен алга куя, тарихи юлының төп этапларын билгели. Мәрҗани хезмәтләрендә төрки-болгар (төркиләр, хәзәрләр, болгарлар, кыпчаклар) һәм Алтын Урда татарларының тарихи варислыгын ачыклау зур әһәмияткә ия. Бер үк вакытта ул татарлар һәм аларның борынгы бабалары тарихын гомуммөселман тарихына терки һәм асылда беренче булып татар милли идеясен формалаштыра. Мәрҗани эшен дәвам иттерүчеләр (Һ.Атласи, М.*Бигиев*, И.*Гаспринский*, Г.Исхакый, Р.*Фәхретдинов* һ.б.) аның концепциясенең төрле аспектларын үстерәләр. Болар 20 йөз башында Россиядә яшәүче мөселман халыкларының сәяси максатларын формалаштыру өчен нигез була («Иттифак әл-мөслимин» партиясенең программ документлары), 19 йөз ахырында — 20 йөз башында татар милли үзаңы формалашу, «татарлар» гомуми үзатамасының рәсмиләшүе милли-интеграция процессларының һәм татар М. идеяләренең тирәнәюе нәтиҗәсе булып тора, хәзерге заман татар милләтенең формалашуына китерә (к. *Татарлар*). Ш.у. к. *Милләт*.

*Әд.:* С т а л и н И.В. Марксизм и национальный вопрос // Сочинения. М., 1946. Т. 2; Б р о м л е й Ю.В. Очерки теории этноса. М., 1983; Демократизация и образцы национализма в Российской Федерации 90-х годов. М., 1996; Национализм и формирование нации: Теории, модели, концепции. М., 1997; Т и ш к о в В.А. Очерки теории и политики этничности в России. М., 1997; К о з л о в В.И. Этнос. Нация. Национализм: Сущность и проблематика. М., 1999; А л ь т е р м а т т У. Этнонационализм в Европе. М., 2000; М а л а х о в В.С. Национализм как политическая идеология. М., 2005; Национальная идея в Западной Европе в Новое время. М., 2005; H r o c h M. Social Preconditions of Nationi Revival in Europe. Camb., 1985; H o b s b a u m E. Nations and Nationalism since 1780: Programme, Myth, Reality. Camb., 1990; Eriksen Th. H. Ethnicity and Nationalism: Anthropological Perspective. Boulder, 1993; S m i t h A.D. Nationalism and Modernism. L., 1998.

*И.Л.Измайлов.*

**МИ́ЛЛЕР** Герард Фридрих (Фёдор Иванович) (18.10.1705, Герфорд ш., Вестфалия — 11.10.1783, Мәскәү), тарихчы, археограф, Петербург ФА әгъзасы (1730). 1722–25 елларда Ринтельн һәм Лейпциг ун-тларында укый. 1725 тә Петербургка килә. 1725 тән Петербург ФА адъюнкты, 1730 дан профессоры. Камчатканы өйрәнү өчен оештырылган 2 нче экспедициядә катнаша (1733–43). 1748 дә историограф буларак Россия гражданлыгы ала. 1754 тән Петербург ФА конференц-секретаре. 1766 дан Тышкы эшләр коллегиясенең Мәскәү архивында хезмәт итә. Экспедиция вакытында «барлык йөргән юлларымны» җентекләп тасвирлап бардым, дип яза. Хезмәтләре арасында «Кайбер истәлекле урыннарны тасвирлап, Казаннан Екатеринбург, Сарапул, Оса, Көнгер шәһәрләре аша Тоболга юл» («Путь от Казани через Сарапул, Осу, Кунгур и Екатеринбург в Тобольск с описанием некоторых достопримечательностей») да бар. Себергә экспедициягә барганда Казан губернасы халыклары турында мәгълүматлар туплый, «Казан губернасында яшәүче мәҗүси халыкларны, ягъни чирмешләрне, чуашларны һәм вотякларны тасвирлау» («Описание живущих в Казанской губернии языческих народов, яко то черемис, чуваш и вотяков») хезмәтен яза. Хезмәттә татарлар турында да мәгълүматлар бар (1791 дә С.-Петербургта аерым китап булып нәшер ителә), китапка рус теленә тәрҗемә ителгән «Рос-

сиячә тәрҗемә белән татар, чирмеш, чуаш, вотяк, мордва, пермь, зырян телләрендә сүзлек»тә («Словарь на татарском, черемисском, чувашском, вотяцком, мордовском, пермском и зырянском языках с российским переводом») өстәлә. Себер төбәген өйрәнү дәверендә М. «анда яшәүче башка халыкларның гореф-гадәтләре, көнкүреше, канунннары» б-н дә кызыксына. Галим татар шәһәрлекләрен (Искәр, Бигеш һ.б.) өйрәнә, җирле татарларның риваятьләрен (мәс., Күчем ханның ислам динен кертүе һ.б.) язып ала, алардан татар елъязмалары, Төмән татарларыннан шәһәрнең борынгы исеме хакында сораштыра; Себер төбәге татарларының этнографиясен өйрәнә (Тобол шәһәрендә татар туенда була, сөннәткә утырту йоласында катнаша). Җыйган мәгълүматлары нигезендә М. «Себер тарихы»н яза («История Сибири»; 1 нче томы 1750 дә рус телендә «Себер ханлыгын тасвирлау» — «Описание Сибирского царства ...» исеме б-н нәшер ителә). «Борынгы заманнардан алып руслар хакимлегенә кадәрге» вакыйгаларны бәян итеп, «Себер төбәгенең төп халкы — татарлар» дигән фикергә килә һәм «татар тарихы»ннан үзе ачыклаган мәгълүматларны китерә. 1732 дә немец телендә «Sammlung Russischer Geschichte» тарихи ж-л чыгара башлый. «Ежемесячные сочинения, к пользе и увеселению служащие» ж-лы мөхәррире (1755–64). 1767 дә *Яңа кануннар эшләү комиссиясе* депутаты итеп сайлана.

Х е з м.: Сочинения по истории России: Избранное. М., 1996; Сибирь XVIII в. в путевых описаниях Г.Ф.Миллера. Новосиб., 1996; История Сибири: В 2 т. М., 1999–2000.

*Әд.:* Б е л к о в е ц Л.П. Россия в немецкой исторической журналистике XVIII в.: Г.Ф.Миллер и А.Ф.Бюшинг. Томск, 1988; Э л е р т А.Х. Экспедиционные материалы Г.Ф.Миллера как источник по истории Сибири. Новосиб., 1990; И л и з а р о в С.С. Герард Фридрих Миллер (1705–1783). М., 2005.

*И.Р.Вәлиуллин.*



Татар ашлары йортында әзерләнгән ризыклар: 1. Токмачлы аш; 2. Итле бәлеш; 3. Бөккән, вак бәлеш, пәрәмәч, өлеш, өчпочмак; 4. Казылык; 5. Кыстыбый; 6. Кош теле; 7. Талкыш кәләвә; 8. Чәкчәк; 9. Гөбәдия; 10. Юка; уртада чәй ашлары.

**МИЛЛИ́ АШ-СУ**, татар халкының традицион ашлары җыелмасы. Татарларда ризыклар ярмалар (карабодай, тары, борай, арпа), он (арыш, бодай, борчак һ.б.), яңа чалынган терлек ите (сарык, сыер, ат, йорт кошлары) кулланып әзерләнә. Сөткә, сөт продуктларына зур урын бирелә. Сыер сөте кайнатмаган, кайнатылган, әчетелгән килеш кулланыла. Аны чәйгә салалар, тәмләткеч сыйфатында боткаларга һәм сыек ризыкларга өстиләр. Өсте алынган яки сепараторда аертылган сөт әчетелгән сөт продуктлары — *катык, әйрән*, эремчек һәм аның төрләрен (сөзмә) әзерләү өчен файдаланыла. Балык (Себер һәм Әстерхан татарларыннан кала), гөмбә һәм яшелчәләр элек сирәгрәк кулланылган. 19 йөз ахырыннан бәрәңгенең әһәмияте арта бара, ул камырлы һәм ярмалы ризыкларны алмаштыра; ш.у. җиләк-җимешләр, җирле һәм читтән китерелгән тәмләткечләр (йөзем, өрек, кара борыч, канәфер һ.б.) кулланыла. Йорт кошлары (башлыча тавык) йомыркалары популяр була. Традицион М.а.-с.да терлек мае (дуңгыз маеннан гайре) һәм атланмай киң файдаланыла, атланмай табынга чәй янына, кайбер чакта *корт* б-н (кортлы май) бирелә. Үсемлек майларыннан җитен һәм көнбагыш майлары кулланыла. М.а.-с.дан көндәлек табынга һәм бәйрәмнәрдә барлык төрки халыкларга мәгълүм, элек-электән килгән ризыклар да куела. М.а.-с. үсеше үзенең этник традиция кысалары б-н генә чикләнми, күрше халыклар, ш.у. Себер, Урта Азия, Кавказ халыклары мәдәнияте дә аңа билгеле бер йогынты ясый (пылау, хәлвә). Беренче ашлардан татарлар бигрәк тә кулдан баскан *токмачлы* шулпага, икенче ашлардан пешкән ит б-н бәрәңгегә өстенлек бирәләр. Ашны күбесенчә тавык һәм сарык итеннән әзерлиләр, гадәттә, икенче аш сыйфатында табынга пешерелгән тавык һәм бәрәңге чыгаралар. Бәйрәмнәрдә эченә сөт һәм тәмләткечләр кушып, йомырка тутырылган тавык әзерлиләр. Татар аш-суының үзенчәлеге — аның камыр ризыкларына гаять бай булуы. Алар күптөрле: икмәк, кабартма, коймак, белен, ләвәш, бәлеш, гөбәдия, бөккән, кыстыбый, сумса, пәрәмәч, өчпочмак һ.б.; тәм-томнар һәм чәй ашларыннан бавырсак, кош теле, юка һ.б.. Йола ризыкларына бәбиләгән хатыннар өчен майда оннан әзерләнә торган баллы ботка — әлбә (керәшен татарлар аны мәрхүмне искә алу йоласы өчен пешерәләр), ш.у. туй сыйлары — чәкчәк, кияү пилмәне, кияү коймагы, кияү сумсасы керә. Ислам дине йогынтысында татарларда исерткеч эчемлексез табын әзерләү гамәлдә була. Аңа кадәр җиңелчә исерткечле эчемлекләр — буза, кымыз, сыра кулланылган. Киң таралган эчемлекләр — ширбәт (җиләк-җимештән һәм балдан әзерләнә), чәй, каен суы, әйрән.

20 йөздә, башлыча, М.а.-с. традицияләре сакланган хәлдә, татарларның тукланууы сизелерлек үзгәрешләр кичерә. Халыкның тормыш муллыгы арту нәтиҗәсендә, күп кенә яңа ашлар һәм ризыклар барлыкка килә, гөмбә һәм тозлы ризыклар кулланышка керә. Татарлар борщ, щи, уха, котлет, гуляш пешерә башлыйлар. Яшелчә һәм җиләк-җимешләр дә табында зур урын ала, балык ризыкларының төрләре арта.

*Әд.:* Ф у к с К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татарская кухня. К., 1985; М у х а м е д о в а Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. М., 2001.

*Р.Р.Батыршин.*

**«МИЛЛИ́ АЯК КИЕМЕ»**, татар халык сәнгати һөнәрчелеге пр-тиесе. 1972 елда Арча һәм Дөбъяз (1960 та Татарстан сәнәгать советы һөнәрчелек артельләре җирлегендә нигезләнә) сәнгать ф-каларын берләштерү юлы б-н Арча «М.а.к.» ҖБ буларак оештырыла. Якынча 180 кеше эшли (2005). ҖБ составында Арчадагы төп производство (аяк киемнәре җитештерү, чимал-материалны механик тарттыру), Арча, Биектау р-ннарының тирә-яктагы 16 авылында һәм Түбән Кама шәһәрендә урнашкан 11 филиал (чүәкләр, читекләр өчен милли бизәкләр чигү һ.б.) була. 1980–90 елларда пр-тиедә төрле белгечлекләр буенча 1300 гә якын оста һәм 500 (кышкы айларда 700 гә кадәр) өйләрдә читек тегүчеләр эшли. 1988 дә аяк киемнәре җитештерү елга 1 млн. 200 мең парга җитә (елга 20–30 исемдәге эшләнмә), шулардан 650–680 мең пар бизәкле күн яки чигелгән орнаментлар б-н чыгарыла. Ел саен аяк киеме төрләре 18–20% ка яңартыла. Шулай ук хатын-кызлар өчен җылы итекләр һәм мокасин тибындагы үкчәсез йомшак аяк киемнәре җитештерелә. 1980 дә Лейпцигта узган көзге ярминкәдә читекләр дипломга һәм алтын медальгә лаек була. 1985 тә борынгы «Казан җөе» алымы (милли аяк киеме тегүдә кадерләп саклана) нигезендә процессны гадиләштергән һәм читек чигүчеләр хезмәтен җиңеләйтүче җайланма булдырыла (авторлары — И.Х.Гайнетдинов, З.З.Зиннәтуллин,

Ф.К.Кадыйров). Күннән милли аяк киемнәре (алтынсыман җепләр, төсле ефәк һәм мамык, оригиналь каюлы күн техникасы кулланып читекләр, чүәкләр, вояжиркалар), түбәтәйләр, милли киемнәр, мылтык тышлыклары, сувенирлар эшләп чыгарыла. Традицион продукция б-н беррәттән, модельле, көндәлек һәм махсус аяк киемнәре җитештерелә. Нәфис эшләнмәләр кечерәк серияләр рәвешендә һәм индивидуаль заказлар буенча чыгарыла. 1990 елларда пр-тиедә җитештерү күләмнәре кими, банкротлык процедурасы уздырыла. 2002 дә фабрика хосусый милеккә күчерелә (җитәкчесе — И.М.Минхәеров). 2006 да ябыла. Пр-тие җитәкчеләре арасында — В.С.Уваев (1972–77), М.Х.Хәкимов (1977–86), И.Х.Гайнетдинов (1986–97). Ш.у.к. *Халык нәфис кәсепчелеге*.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; Гулова Ф.Ф. Татарская национальная обувь: Искусство кожаной мозаики. К., 1983; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995; Саттарова Л.И. Казанская узорная кожа. М., 2004.

*Г.Я.Мәүлетова, Л.И.Саттарова.*

**МИЛЛИ́ АЯ́К КИЕМЕ́** (традицион). Татарларның борынгы бабалары — терлекчелектә зур үсешкә ирешкән Идел болгарлары, гадәттә, күн аяк киеме — *юфть* (*йомшак күн*) һәм *сафьяннан* эшләнгән итекләр, башмаклар, галошлар киеп йөргәннәр. 10–13 йөзләргә караган күн аяк киеменең сакланып калган кисәкләре Болгар һөнәрчеләренең югары дәрәҗәдәге осталыгы хакында сөйли. Алар еш кына үз эшләнмәләрен күнгә басып бизәк төшерү, чигү ысуллары б-н бизиләр, ш.у. төрле төстәге күннән аппликация, фигуралы металл бизәкләр дә кулланалар. Казан татарларында күн аяк киеме киез аяк киеме шикелле үк традицион булып тора: кышта — киез итекләр, барлык ел фасыллары өчен киез каталар файдаланылган. Эшкә *чабата* кигәннәр. Ул тула оек, бәйләгән оек, киндер оек, киндер ыштыр, тула ыштыр, җитен тукымадан тез бәйләвече (аяк чолгавы, аякчу) б-н киелгән. 19–20 йөзләр чигендә Казан һәм Казан арты итекчеләренең күптөсле бизәкле мозаика ысулы б-н җитештергән эшләнмәләре киң таныла. 20 йөздә *Арча милли аяк киеме җитештерү берләшмәсе* эшләп чыгарган һәм авыл осталары тарафыннан җитештерелгән бизәкле читекләр, башмаклар, кәвеш, каталарга ихтыяҗ аеруча зур була. Ш.у.к. *Аяк киемнәре тегү кәсепчелеге*, *Аяк киеме җитештерү сәнәгате*.

*Әд.:* Гулова Ф.Ф.Татарская национальная обувь: Искусство кожаной мозаики. К., 1983; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000; Саттарова Л.И. Казанская узорная кожа. М., 2004.

**«МИЛЛИ́ БАЙРА́К»**, иҗтимагый-сәяси газета. «*Ерак Шәрекъ төрки -татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе*» органы. 1935 елның 1 ноябреннән 1945 нең август башына кадәр Мукден шәһәрендә (Кытай) татар телендә нәшер ителә, барысы 440 саны чыга. Нашире — С.Аити. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире — Г.*Исхакый*; газетаның исеме Берлинда нәшер ителгән «*Яңа милли юл*» ж-лы б-н аваздаш. Аннан соң мөхәррирләре И.Дәүләткилдиев һәм аның хатыны Рокыя Мөхәммәдиш. Редакциядә М.Арслан, А.Гыйззәтулла, Ш.Илдар эшли; актив авторлар арасында — А.Аги, Х.Болгари, Х.Габдүш, Ф.Гыйльман, К.Салиәхмәт, Х.Сөләев. Татар эшмәкәрләре Ә.Мәңгәр һәм Я.Ибраһим матди ярдәм күрсәтәләр. Татар эмигрантлары матбугаты арасында газета үзенең басылу дәвамлылыгы, мәкаләләрнең күптөрле булуы һәм укучылар арасында киң таралуы б-н аерылып тора. Газета битләрендә Г.Исхакыйның татар милләтен, аның мәдәниятен һәм азатлыгын яклап көрәш рухы б-н сугарылган уннарча мәкаләләре дөнья күрә (беренче санда — «Безнең максатлар», алдагы саннарда — «Ерак Шәрекътә милли матбугат», «Милли Мәҗлеснең 20 еллыгы», «Финляндия татарлары», «Советларның руслаштыру сәясәте», «Большевикларның безнең дингә каршы басымы», «Безнең киләчәгебезнең нигезләре» һ.б.). Газета мәкаләләрендә татар эмиграциясе тормышы: аның тарихы, иҗтимагый эшчәнлеге, мәдәнияте, әдәбияты, икътисади хәле һәрьяклап яктыртыла. «М.б» 1945 нең августында Маньчжурия терр-ясенә совет гаскәрләре кергәннән соң чыгудан туктый. Басма хезмәткәрләренең бер өлеше совет контрразведкасы органнары тарафыннан кулга алына һәм озак вакыт төрмәдә ябылып тотыла.


ملی بایراق
Far East

«Милли байрак» газетасы.

*Әд.:* Мәхмүт Т. Чит илләрдәге татар вакытлы матбугаты // Казан утлары. 1990. № 10; Исхакый Г. Япония — Токио // Мирас. 1995. № 2; Насыйров Т. Татар мөһаҗирләре матбугаты // Казан утлары. 2001. № 7; Гайнетдинов Б. Тюрко-татарская эмиграция: начало XX века — 1930-е годы. Наб.Челны, 1997.

*Т.М.Насыйров.*

**МИЛЛИ́ БАНК** (Россия банкының Татарстан Респ-касы Милли банкы), 1918 елда Казанда губернаның национализацияләнгән банклары җирлегендә РСФСР Халык банкының Казан бүлекчәсе буларак төзелә. 1922 дән СССР Дәүләт банкының Казан өлкә конторасы, 1937 дән СССР Дәүләт банкының Татарстан респ-ка конторасы, 1987 дә СССР Дәүләт банкының Татарстан респ-ка идарәсе; 1990 нан РСФСР Дәүләт банкының ТАССР буенча Баш идарәсе, 1991 дән РСФСР Үзәк банкының ТССР буенча тер. Баш идарәсе, 1992 дән хәзерге исемдә. М.б.та 1 мең чамасы кеше эшли (2012).

1994 нең 15 февралендә РФ һәм ТР арасында «*Россия Федерациясенең дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында*» *Шартнамә* төзелә. Әлеге документны кабул итү барышында банк эшчәнлеге турында килешүгә кул куела, аның нигезендә ТР М.б.ының хокуклары шактый киңәя, аңа өстәмә вәкаләтләр, ш.и. халыкара сөйләшүләрдә Россия банкы вәкиле буларак эш итү хокукы бирелә. ТР банкы эшчәнлеген киңәйтү нәтиҗәсендә, аның структурасы да шактый үзгәрә. Хәзерге вакытта М.б. — бүлекләр, идарәләр һәм бүлекчәләрдән торган катлаулы, нәтиҗәле эшләүче организм. Методология, кредит-исәпләү мөнәсәбәтләре һәм кредит ресурслары бүлеге ТР икътисадын үстерергә ярдәм итә торган акча-кредит сәясәтен эшли һәм оештыра; коммерция банклары һ.б. учреждениеләр б-н кредит килешүләре төзи, шушы юнәлешне методологик яктан җитәкли. Респ-ка, төбәк һәм тармак программаларының барлык проектлары, кредитлардан файдалануның нәтиҗәләлеген анализлау өчен, әлеге бүлеккә кертелә. Бухгалтерлык исәбе, хисаплар һәм исәпләүләр бүлеге



ТР Милли банкы. Хәзерге күренеше.

хисап-касса үзәкләренең һәм коммерциячел банкларның эшен банкара исәпләүләр, төрле дәрәҗәдәге бюджет средстволары һәм бюджеттан тыш фондлар исәп-хисабы буенча көйли. Акча әйләнешен көйләү һәм эмиссия-касса хезмәте бүлеге эмиссия операцияләре үткәрүне тәэмин итә, респ-када һәм аның төбәкләрендә акча әйләнеше торышын анализлый, аны ныгыту буенча тәкъдимнәр эшли. Бүлек әйләнештәге гомуми акча массасын — аның структурасын билгели, бу даирәдәге үзгәрешләрне һәм тенденцияләрне анализлый. Анализлар нигезендә ТР буенча акча әйләнешенә фаразлар төзелә. Валюта әйләнешен көйләү һәм аңа контрольлек итү идарәсе (1994 тә төзелә) 18 вәкиллек банкының, аларның Татарстаннан читтәге 7 ф-лының, респ-каның тышкы икътисади эшчәнлек б-н шөгыльләнүче барлык пр-тиеләре һәм оешмаларының диярлек валюта операцияләрен контрольдә тота. ТР банкларында валюта операцияләренең гомуми күләме — 500 млрд. сум тирәсе, бу сан М.б.ның барлык активлары суммасының 4% тан артык

өлешен тәшкил итә. Экспорт һәм импорт әйләнешләре ТРның вәкиллек банклары аша рәсмиләштерелә. Пр-тиеләргә тышкы икътисади эшчәнлек алып бару өчен бирелгән валюта кредитлары 42 млн. доллар — респ-кадагы барлык кредит кертемнәренең якынча 9% ын тәшкил итә. Ай саен вәкиллек банклары кассалары аша уртача 25 млн. доллардан артык валюта уза. Чит ил валютасындагы акча кереме һәм чыгымының төп юнәлеше булып халыкка хезмәт күрсәтүнең валюта алмаштыру операцияләре тора. Идарә 200 дән артык валюта алмаштыру пунктын тикшерүдә тота. Кыйммәтле кәгазьләр бүлеге (1991 дә төзелә) акцияләр, вексельләр, облигацияләр һ.б. кыйммәтле кәгазьләр чыгаруны тикшерә. Фондлар базарында пр-тиеләр һәм оешмаларның акция һәм облигацияләреннән тыш, дәүләтнең дә кыйммәтле кәгазьләре әйләнештә йөри. 1995 нең уртасыннан, ТР Президенты Указы нигезендә, ТР Финанс министрлыгы чыгарган кыска вакытлы облигацияләр дә әйләнешкә кертелә. М.б. облигацияләр чыгару күләмен арттыру, аларны чыгару шартларын үзгәртү, дилерлар челтәрен киңәйтү һ.б. буенча конструктив тәкъдимнәр б-н чыга. Беренче чыгарылыштан башлап, рәсми дилерлар саны 8 дән 20 гә җитә, шуларның 10 сы — ТРның коммерция банклары. Инспекция идарәсе (1995 тә төзелә) коммерция банкларының эшчәнлеген, гамәлдәге законнарның дөрес үтәлешен контрольдә тота. Касса хезмәтен оештыру бүлеге сыйфатлы касса хезмәте күрсәтү һәм дәүләт байлыгының сакланышы өчен җавап бирә. Банкта, интеграллаштырылган банк системалары булдыруның иң яңа чараларын кулланып, аның бүлекчәләрен комплекслы автоматлаштыру гамәлгә кертелгән. Иминлек һәм мәгълүматны саклау идарәсендә (1994 дә төзелә) ш.у. махсус мәгълүмат саклау бүлеге бар. Региональ мәгълүмат үзәге (РМҮ) респ-каның 169 исәпләү-касса үзәгеннән һәм коммерция банкларыннан, ш.у. аларның филиалларыннан килгән мәгълүматны эшкәртә. Бер көн эчендә РМҮ аша 1 трлн. га кадәр сумманы эченә алган уртача 25 меңнән артык акча документы уза. Заманча яңа җиһазлар б-н тәэмин ителеш буенча ТРның М.б.ы Россиядә иң алдынгы урыннарның берсен алып тора.

М.б.ның үз матбугат үзәге бар, ул актуаль банк мәгълүматын респ-ка матбугатында, радио һәм телевидениедә чыгарып бара; «Банковская газета» басмасын нәшер итә. Коммерция банклары б-н эшләү бүлеге респ-каның коммерция банклары эшчәнлеген контрольдә тота. Татарстанда 26 коммерция банкы һәм 192 ф-лы эшләп килә. Аларның гомуми устав капиталы — 300 млрд. сум тирәсе.

Банкның җитәкчеләре арасында — И.А.Тихенко (1918), П.А.Марвин (1918), И.В.Наконечный (1918–19), Н.Р.Мышко (1919–20), Н.Н.Анциферов-Михайлов (1922–24), И.А.Яковлев (1924–26), А.Д.Тацолаев (1926–27), Э.И.Вейнбаум (1927–29), Н.М.Прасолов (1929–33), А.Г.Граник (1933), Ю.Я.Чеботарёв (1933–34), С.М.Харин (1934–35), И.П.Калманович (1935–37), И.Я.Морозов (1937–41), П.И.Балаханов (1941–47), П.П.Хорьков (1947–65), С.А.Штыркина (1965–76), М.И.Галимов (1976–93), Е.Б.Богачёв (1993 тән).

*Әд.:* Б о г а ч ё в Е.Б. Проблемы совершенствования банковской системы и её информационное обеспечение. М., 1998; Российские банки: рождение империй. Ч. 2: Банковские альянсы: спрут расправляет щупальца // Эксперт. 1998. № 11.

*В.Г.Федулов, И.Н.Вәлиуллин, Ф.С.Зыятдинов.*

**МИЛЛИ́ ҖЫЕЛЫ́Ш**, к. *Милли Мәҗлес*.

**МИЛЛИ́ ИДАРӘ́** (Эчке Россия һәм Себер төрки-татар милли-мәдәни мохтариятенең югары башкарма идарәсе), 1918 елның гыйнварында *Милләт Мәҗлесе* депутатлары тарафыннан сайлана, Уфа шәһәрендә эшли. Рәисе С.Н.*Максуди*, рәис урынбасары И.Ә.*Әхтәмов*. Министрлыкларны: Малия (финанс, рәисе Ш.С.Алкин, әгъзалары — З.Агафуров, Г.Буби, С.С.Җантурин, Г.Кәрими, Г.Курмай, Л.Яушев), Мәгариф (рәисе Н.Корбангалиев, әгъзалары — И.Бикколов, Г.Еникиев, З.Кадыйри, Г.Терегулов, И.Үтәмешев, К.Хәсәнов), Диния (рәисе мөфти Г.Баруди, әгъзалары — М.Буби, Г.Курмаши, К.Тәрҗеманов, С.Урманов, Р.Фәхретдин) нәзарәтләрен берләштерә. 1918 нең 21 апрелендә РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты һәм Татар-башкорт комис-ты карары б-н, Диния нәзарәтеннән тыш, М.и. таратыла, акчалары тартып алына. Себердә совет хакимияте урнаштырылганчы М.и. әгъзалары үз эшчәнлекләрен Петропавловск шәһәрендә (Көнбатыш Себер) дәвам итәләр. С.Н.Максуди киткәннән соң рәис вазифаларын — И.Ә.Әхтәмов, урынбасарныкын — С.Урманов, сәркәтип вазифаларын И.Бикколов башкара.

*Әд.:* И с х а к о в С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 г. — лето 1918 г.). М., 2004; Д а в л е т ш и н Т. Советский Татарстан. К., 2005. *Д.М.Госманова.*

**МИЛЛИ́ КЕРЕ́М**, к. *Региональ эчке продукт*).

**МИЛЛИ́ КИЕ́М**, татарларның көнкүрештә, бәйрәмнәрдә һәм йолалар башкарганда киелә торган өс, баш, аяк киемнәре предметларының, бизәмәләр һәм өстәмә әйберләрнең (сумкалар һ.б.) гармонияле яраштырылган бербөтен җыелмасы; татар *гамәли бизәлеш сәнгатенең* киң таралган төрләренең берсе. М.к.нең сәнгати-образлы структурасына материал, өлге, силуэт, төс, орнамент, кием детальләрен комплектлау һәм аны киеп йөрү ысуллары керә. Татар М.к.е ансамблен иҗат итүдә *сәнгати туку, чигү, каюлы күн, укалап чигү, зәргәрчелек сәнгате, аппликация* кулланыла. Татарларның М.к.е этнографик типлар (алар төбәк һәм җирле аермаларга ия, социаль, җенес-яшь, гаилә статусы һ.б. б-н яраштырыла) буенча классификацияләнә, ул кием функцияләренең күптөрлелеге, аның файдалану һәм йолалар башкарудагы әһәмияте б-н бәйле. Татар традицион М.к. нигезен борынгы төрки ир-ат һәм хатын-кыз эчке киеменең туника рәвешендәге өлгеле, аерым детальләренә силуэтлы һәм декоратив үзгәлекләр хас күлмәге һәм киң балаклы чалбар тәшкил итә. Традицион татар М.к. комплексына җиңсез яки кыска җиңле *камзул*, озын җиңле *казаки*, чикмән, бишмәт, җилән, чоба, толып һәм үзгә өлгеле (билле яисә тоташ арттакталы) җилбәгәй киелә торган башка өс киемнәре; очлы яки түгәрәк түбәле киез, мех һәм тукыма баш киемнәре; күн һәм киез аяк киемнәре; түшлекләр (*изү*, күкрәкчә); *чулпы* һәм *тезмә*; кием бизәмәләре: *хәситә*, яка чылбыры, *каптырма* һ.б. керә. Археол. казу эшләре нәтиҗәсендә Идел буе болгарларының 8–12 йөзләргә караган М.к. детальләре ачыклана: киемгә тагыла торган металл бизәкләр, аеллар һ.б.; баш киемнәре; күн бил каешлары; бизәмәләрнең төрле төрләре (*чигә асылмалары*, муенсалар, чулпылар һ.б.); басып төшерелгән бизәк һәм фигуралы металл бизәкләр беркетелгән күн аяк киеме калдыклары һ.б. Әлеге табылдыклар, тасвирлама һәм язма чыганаклар Идел буе болгарлары киемендә үзләре үк җитештергән тукыма, күн һәм мех, ш.у. Шәрекътән китерелгән тукымалар һәм киемнәр кулланылуы турында сөйли. Әл-Бәлхи (10 йөз) хәзәрләр һәм болгарларның озын өске киеме һәм җиңнәре терсәккә җиткән «куртка»лар (татар камзулының прототибы) киеп йөрүе турында яза. Күкрәк турысы ике кайтармалы кафтан буларак билгеле әлеге курткалар. ш.у. ике бил каешы (аларның берсе бизәкләр тагып ясала), йомшак итекләр һәм баш бәйләвече йөртү гадәтләренең Көнчыгыш Европа далаларында, Иранда һәм Кавказ артында киң таралыш алуы, тикшеренүчеләр фикере буенча, болгарлардан килә. Алтын Урда ханнары һәм аксөякләренең М.к. комплексы, хәрби кием һәм кирәк-яраклар турында мәгълүматлар гарәп һәм Европа сәяхәтчеләре хезмәтләрендә телгә алына. Уникаль раритетлар арасында — «*Мономах бүреге*» — Алтын Урда татар аксөякләренең бәйрәм баш киеме, зәркән бизәмәләре — хатын-кыз баш киемнәре детальләре, бил каешлары, *беләзекләр, алкалар*, чулпылар, *Корьән савытлары* һ.б. (к. *Зәргәрчелек сәнгате*). Казан ханлыгы яулангannan соң морзалар һәм татар хәрби аксөякләренең зиннәтле М.к.е юкка чыга. Рус елъязмаларында Казаннан алып кителгән «күптөрле патша киемнәре» һәм алтын б-н бизәлгән «ятаклар» (тукымалар), ш.у. кыйммәтле «чүпрәк-чапрак» тутырылган хисапсыз «әрҗәләр» (тартмалар) искә алына. Татар аксөякләре М.к.е турында өске киемнең (казаки, бишмәт, ябынча), баш киемнәренең (нәүрүз, тафья, башлык) һәм аяк киемнәренең (читек, чабата, башмак) исемнәрен һәм формаларын саклаган 16–17 йөзләр рус боярлары киеме буенча фикер йөртергә мөмкин; Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында татар ханнарының алтын таҗы — «*Казан таҗы*», авыр алтын бил каешы каптырмалары (к. *Җепкыр*), бәйрәм киемнәренең буй уемына тагыла торган декоратив төймәләре саклана.

16 йөзнең 2 нче яртысы — 18 йөз башындагы М.к. ансамблен борынгы рәсемнәр һәм Европа сәяхәтчеләре гравюралары ярдәмендә күзалларга мөмкин: ирләр һәм хатын-кызлар арасында җилбәгәй өске кием, сары, ал, кызгылт-сары, аксыл-шәмәхә, зәңгәр, яшел, сирәк кенә кызыл төстәге тукымалардан те-




**Милли кием мәкаләсенә.** 1. Казан ханы киеме. 15–16 йөзләр. Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова реконструкциясе. Рәссам А.А.Гайнетдинова. 2005; 2. Казан татары. С.Е. Герберштейнның «Мәскәү хәлләре турында язмалар» китабыннан алынган рәсем. 1549. Вена ш.; 3. Казан татарлары. Х.-Г.-Г.Гейслер гравюрасы. 1799-1801. Дәүләт Тарих музее. Мәскәү; 4. «Казан татарлары кызы». А. Мартынов гравюрасы. 1808. Дәүләт Рус музее. С.-Петербург; 5. Казан татарлары. Г.-Ф.Паулиның «Россия халыклары» альбомыннан гравюра. 1862. С.-Петербург; 6. Казан сәүдәгәре гаиләсе. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. Н.И. Воробьёв фондыннан алынган фоторәсем. ТР ФА Тарих институтының этнография бүлеге; 7. Шәһәрдә яшәүче татар гаиләсе. 20 йөз башы фоторәсеме. Казан; 8. Татар студенты. «Татар халык киеме» циклыннан. Рәссам Ч.М. Саттарова. 2003; 9. Авылда яшәүче татар кызы киеме. Әлмәт районы Бишмунча авылы музее; 10. Көтүче малай киеме. Әлмәт районы Кама-Исмәгыйль авылы музее; 11. Татар ир-аты һәм хатын-кызының стильләштерелгән бәйрәм киемнәре. «Карина» ательесы. 2004. Чаллы ш.

гелгән, муены ярымтүгәрәк уемлы һәм ябык якалы күлмәкләр киң тарала. М.к. ансамблендә укалап чигү детальләре (укалар, укалы тасмалар, чигешләр), полихром асылташлар мулдан куелган зәркән бизәмәләр (к. *Корлау*): күкрәкчәләр, чулпылар, алкалар, беләзекләр, йөзекләр, Коръән савытлары һ.б. кулланыла. М.к. комплексына ш.у. каты һәм йомшак табанлы, күн, киез яисә постаудан тегелгән бизәкле итекләр, үкчәле һәм үкчәсез артсыз күн башмаклар; биек конус рәвешендәге металл тәңкәчекләр, тәңкәләр һәм ярымасылташлар б-н бизәлгән баш киеме һәм тәкыя — җирлеге тукымадан эшләнеп, мех б-н каймаланган яки аннан башка гына, укалап чигелгән һәм кыйммәтле ташлар б-н бизәлгән ярымтүгәрәк башлык керә. Япма рәвешендә иңсәгә салына торган кием — «ябынча» (ул русларда «епанча»га әйләнгән) турында мәгълүматлар сакланып калган.

18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөз уртасында татар халкының классик М.к.е формалашып җитә, аның үрнәге итеп Казан татарларының шәһәр М.к.е алына. Ул өйдә сугылган буйлы чуар тукымадан (куе зәңгәр, күк, сары, яшел, ал, соры, кызыл һәм ак төстәге тар һәм киң буйлар чиратлаша) яисә бер төстәге сатып алынган тукымалардан (атлас, ефәк, парча яки сатин) тегелгән утыртма якалы һәм күкрәк өлеше уемлы, аска таба киңәеп киткән иркен күлмәктән тора. Күлмәк өстеннән камзул — озын (казаки) яисә кыска җиңле, яки җиңсез, билгә кадәр өлеше гәүдәгә сыланып, итәкләре аска таба киңәеп торучы озынча жилет киелә. Хатын-кызларның күлмәк итәкләре киң бала итәкләр, укалы тасма, мех, кош мамыгы һ.б. б-н бизәлә. Хатын-кыз күлмәгенең күкрәк уемы алтын һәм көмеш зәргәр тәңкәләр, акчалар, ярымасылташлар тезелгән күкрәк бизәме (изү) б-н каплана; күлмәк эченнән чигүле тукымадан эшләнгән күкрәкчә киеп калдырыла. М.к. ансамбленә бизәкле күн, кайчак алтынлап чигелгән итекләр, бәрхет туфлиләр керә, башка М.к.нең үзәк бизәү элементы булган укалы бәрхет яисә бәйләнгән (киҗе-мамык һәм йон) *калфаклар* киелә. Хатын-кыз М.к.е ансамбленә калфаклардагы бәрхет җирлеккә төшерелгән укалы бизәкләр мәһабәтлек һәм төгәллек бирә, кайчак алар чуклары маңгайга төшеп торучы укалы тасма, энҗеләп чигү һәм аппликация б-н тулыландырыла. Зур баш япмалары (тастар, өрпәк һ.б.) һәм яулыклар М.к.нең мәҗбүри элементлары булып тора. Ирләр М.к.е ш.у. иркен һәм озын (тезгә җиткән) күлмәктән, өйдә тукылган алачадан һәм җиңел киҗе-мамык тукымалардан тегелгән ыштаннан гыйбарәт була. Күлмәк өстеннән камзул яки казаки, киселеше, озынлыгы, яка формасы һ.б. б-н аерылып торган, җилбәгәй киелә торган өске киемнең төрле төрләре киелгән. Күптөрле ирләр баш киеме арасында — киез эшләпәләр, тукыма тышлы киң мех кырпулы бүрекләр (камчат бүрек), өскә таба түбәсе тарая барган кайтармалы һәм колакчынлы бүрекләр (колакчын), түбәсе конус рәвешендәге (такыя) һәм яссы түбәле (кәләпүш) *түбәтәйләр*. Кәләпүшләр караңгы төстәге бәрхеттән тегелә һәм ука, энҗе, сәйлән б-н бизәлә. Ирләр аяк киеме күн һәм киез итекләрнең төрле төрләре, башмаклар, тула оеклар, чолгаулар, аякчулар һ.б.дан тора, еш кына алар төрле төстә һәм бизәкле була. М.к.нең сәнгати тәэсирлелеген тудыруда төп принцип — нәфислелек: анда фактурасы, төсе, бизәлеше төрле булган материаллар һәм предметлар берләштерелә. Шуның б-н бергә киемнең эре формалары, биеклеккә карап тезеп кую һәм арттыра бару принцибы буенча төзелгән ачык детальләр хисабына тудырылган күпсанлы бизәү эффектлары М.к.гә феодаль чор М.к.енә хас тантаналы монументальлек, беркадәр авырлык һәм катлаулылык өсти.

Авыл М.к.е дә шул ук өлешләрдән тора, әмма анда декоратив детальләр, кыйммәтле зәркән бизәмәләр азрак була, күбрәк чигү һәм туку кулланыла. Моннан тыш, авыл М.к.е этнографик, этнотөбәк (Мишәр татарлар, Урал буе, Себер, Әстерхан татарлары М.к.е) һәм этноконфессиональ (керәшен татарлар М.к.е) төрлелекне саклый.

19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында татар гомуммилли киеме барлыкка килә, ул гомумевропа модасы юнәлешләренә туры килә торган яңа үсеш тенденцияләренә ия була: силуэты буенча җиңелчәрәк, билгеле бер фасон һәм модалы детальләр кертеп тегелгән хатын-кыз күлмәкләре, кыскарак һәм гәүдәгә ятып тора торган итеп тегелгән камзуллар, декоратив кадама рәвешендәге кечкенә калфаклар, баш япмаларын, өс киемнәрен «авырайтучы» декоратив детальләр һәм зәргәр бизәмәләрне (күкрәкчәләр, хәситәләр һ.б.) кире кагу, тыенкы төсләр җыелмасы. М.к. күпкатлылыктан, укалап чигү фрагментларыннан, чәмчә һ.б. детальләрдән арына бара, эшлеклерәк төсмер ала. Аңарда этник, социаль һәм яшь үзенчәлекләре җуела. М.к.дә милли үзгәлекләр ролен баш киемнәре — калфак, түбәтәйләр, ш.у. аяк киемнәре — каюлы читекләр һәм туфлиләр, өлешчә зәргәр бизәмәләр — алкалар, беләзекләр, муенсалар һ.б. башкара. 1920–30 елларда традицион халык М.к.е асылда юкка чыга, ул эстрада-фольклор, театральләшкән тамаша кысаларында яшәп килә. М.к.нең аерым чагылышлары халык көнкүрешендә — яулык бәйләү, күлмәк өлгеләре рәвешләрендә, үзенчәлекле төсләр җыелмасында, бигрәк тә авыл халкы киемнәрендә саклана. Проф. сәнгать төре буларак, М.к. хәзерге киемне модельләштерү формасында үсеш кичерә, уникаль һәм серияле үрнәкләрдә эшләнә. Бу процесс төп ике юнәлештә бара: киемдә традицион үзенчәлекләрне (халык традицияләре яки тарихи стильләр) саклау, үстерү һәм моданың яңа агымнары тарафыннан тудырылган авангард стиле.

Модельер рәссамнар иҗатында татар М.к.енең чалбар, иркен күлмәк, жилет-камзул кебек стильләштерелгән формалары һәм күлмәк күкрәкчәләре, бала итәкләр, бөрмәләр, ш.у. укалап чигелгән баш киемнәре һәм путалар, зәргәр бизәмәләре кулланыла (Т.Смирнова, Т.*Рөстәмова*, З.*Мөхәммәтҗанова*, С.Гарбузова, Л.Чубукова, Р.Камалова һ.б.). Милли көнкүреш, бәйрәм һәм сәхнә киемнәре халык осталары һәм һәвәскәрләр (С.Ислаева, Ф.Калмурзина, О.Мамина, Н.Мостафина, М.Сәлиева, А.Юсупова һ.б.), «Туран» милли-мәдәни фонды, Казан өйдә эшләүчеләр комб-ты, «Илдан» фирмасы, «Эбиволь» АҖ («Алтын ай» остаханәсе), «Карина» ательесы (Чаллы ш.) тарафыннан җитештерелә, милли сувенир уенчыклар рәвешендә модельләштерелә (А.Глебова, А.Гришвина, А.Галәвиева, Т.Волкова һ.б.). Белгечләр 2000 нән Казан технол. ун-тының җиңел сәнәгать ин-ты дизайн һәм конструкцияләү ф-тында әзерләнә (к. *Дизайн*).

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Гаген-Торн Н. Женская одежда народов Поволжья. Чебоксары, 1960; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х гг.). К., 1995; Завьялова М.К. Татарский костюм. К., 1996; Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 2000; Татары. М., 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МИЛЛИ́ МӘҖЛЕ́С** (Милли парламент), татар иҗтимагый оешмасы, 1990 елларда татар халкының экстерр. вәкиллекле органы булуга дәгъва итә. М.М.не оештыру һәм эштәлеге концепциясенең төп нигезләмәләре *Бөтентатар иҗтимагый үзәгенең* (БТИҮ) 2 нче корылтаенда (1991 нең 15–16 феврале) кабул ителгән 2 нче программасында җентекләп аңлатыла. Концепция авторлары *Милләт Мәҗлесенең* (1917 нең 20 ноябре — 1918 нең 11 гыйнвары, Уфа шәһәре) тарихи тәҗрибәсенә таяна. Алар фикеренчә, 1990 еллар башында татар халкының милли вәкилләрдән сайланган органы булмау, Татарстан парламентының (1995 елга кадәр — Югары Совет, аннары — ТРның Дәүләт Советы), этник як исәпкә алынмыйча, респ-када яшәүче барлык гражданнар вәкилләре органы буларак, милли мәнфәгатьләрне тиешенчә чагылдыра алмавы Милли парламент төзү зарурлыгын китереп чыгара. М.М. бөтен татар халкының вәкиллекле органы булыр, татар милли суверенлыгының һәр ике төрен: «дәүләти-терр.» һәм экстерр. милли-мәдәни мохтарият төрләрен тәшкил итәр дип уйланыла. Дәүләт хакимиятенең респ-ка органнары б-н каршылыклар килеп чыкмасын өчен М.М. дәвамлы вакыт арасында төзелергә тиеш була. Ләкин 1991–92 еллар чигендә респ-када сәяси вазгыять кискенләшү сәбәпле, татар милли хәрәкәтенең радикаль канаты вәкилләре М.М. булдыруны тизләтергә карар итәләр. 1991 нең ноябрендә алар оештыру ком-ты төзиләр (рәисе — З.Л.*Зәйнуллин*). 1992 нең 1–2 февралендә Казанда 1 нче Бөтентатар корылтае була, анда Татарстаннан һәм элеккеге СССРның төрле төбәкләреннән 877 делегат катнаша. Корылтайда берничә нигезләмә кабул ителә, кайберләренә «закон» статусы бирелә (мәс., «Татарстан республикасының дәүләт бәйсезлеге турында», «Бөтента-

тар халык корылтае һәм Милли Мәҗлес турында», «Халык җыеннары һәм Милли Мәҗлеснең җирле органнары турында»). Шушы документлар нигезендә, корылтайлар арасында милли парламент эшчәнлеген алып бару өчен М.М.нең беренче составы төзелә (79 депутат). Рәисе итеп Т.М.Абдуллин, рәис урынбасарлары итеп Ә.Г.Мәхмүдов һәм З.Л.Зәйнуллин сайлана. Барлыгы 4 корылтай җыела (барысы да Казанда): 2 нчесе — 1994 нең 19 февралендә, 3 нчесе — 1997 нең 15 мартында, 4 нчесе 2004 нең 17 апрелендә уздырыла. М.М. сессияләрендә рәис һәм аның урынбасарлары җитәкчелегендә президиум, секретариат һәм тармак комиссияләре (мандат, диаспора б-н эшләү, халыкара, икътисад, финанс һ.б.) сайлана. 1992 дә М.М.нең 1 нче сессиясендә башкарма орган — Милли Идарә оештырыла, 2 нче корылтайда ул бетерелә; 4 нче корылтайда «Татар халкының Милли Мәҗлесе» иҗтимагый оешмасы Уставы кабул ителә. Шушы вакыттан М.М.нең җитәкче органнарын съезд (4 елга бер чакырыла), совет һәм президиум тәшкил итә. Съездда катнашучылар президиум һәм ревизия комиссиясен, президиум — М.М. рәисен, аның урынбасарларын, секретарен сайлый. Совет президиум әгъзалары һәм М.М.нең җирле бүлекләре вәкилләре составында оеша. М.М. рәисләре: Т.М.Абдуллин (1992–94), Ф.Ә.*Бәйрәмова* (1994–97), А.*Хәлим* (1997–2001), Г.С.Галиуллин (2004 тән).

М.М., эшчәнлеге иҗтимагый берләшмәләр турындагы законнарга туры килмәү сәбәпле, республиканың юстиция органнарында теркәлми. 1990 елларда М.М. үз эшчәнлеген идеологик характердагы программ документларга — И.Г.Әмирханов җитәкчелегендә эшләнгән һәм 1996 да кабул ителгән «Татар халкы Кануны (Конституциясе)» һәм «Гаилә кодексы»на нигезләнеп алып бара. Әлеге документларның беренчесе татар милләтен күтәрү татар милләтчелеге, төркичелек һәм исламчылык принципларын милли аңга сеңдерү һәм тормыш рәвешенә әверелдерү аша гына мөмкин булачак дип раслый. М.М. идеологлары конфессиональ хокукның (шәригать) милли (конституцион) хокуктан өстенлеген шарт итеп куючы мөселман тәртипләрен татарлар яшәгән һәр җирдә гамәлгә кертүне зарури дип саныйлар. Шуның б-н бергә алар исламга консерватив-саклагыч функция үтәргә тиешле дини тәгълимат итеп карыйлар. М.М.нең сәяси активлыгы эшчәнлегенең башлангыч чорында югары була. 1992 нең февралендә 1 нче Бөтентатар корылтаен җыю идеясе хакимиятнең дәүләт органнары функцияләренең кайберләрен М.М. карамагына тапшыруны кирәк санаучы радикаль милли агым тарафдарлары һәм аларга каршылар арасында респ-ка күләмендә кискен сәяси бәхәс китереп чыгара. Урталыктагылар (Д.М.Исхаков, Р.С.Хәкимов) радикалларны дәүләт хакимиятенә омтылулары б-н М.М. идеясенең асылын бозу, абруен какшатуда гаепләләр. Корылтай узганнан соң, аның кайбер карарлары ТР ЮС депутатлары тарафыннан тәнкыйть ителә. М.М. җитәкчелек, респ-ка хакимиятенең рәсми органнары һәм җәмәгатьчелек б-н конструктив хезмәттәшлеккә ирешә алмый. Шушы шартларда сәяси инициатива акрынлап респ-каның рәсми җитәкчелегенә күчә һәм җитәкчелек карары б-н 1992 нең июнендә, М.М. җыйган корылтайга альтернатива буларак, Бөтендөнья татар конгрессы (БТК) уздырыла, анда татар милли хәрәкәтенең радикализмга каршы активистларының күпчелеге катнаша. *Татар милли бәйсезлек партиясе «Иттифакъ»* (М.М. сәясәтен башлыча шушы партия билгели) җитәкчелеге 1992 нең 21 июлендә татар халкының милли хәрәкәтләре һәм фиркаләре исеменнән сәяси мөрәҗәгать бастырып чыгара, анда М.М. «татар халкы мәнфәгатьләрен чагылдыручы бердәнбер» сәяси көч буларак игълан ителә. М.М. әгъзалары ТР Конституциясен, «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Респ-касы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамәне тәнкыйть итәләр, Татарстанның бәйсезлеге мәсьәләсен күтәрәләр, Россия б-н мөнәсәбәтләрдә респ-каның ассоциацияле статусына, ш.у. ТР да ике дәүләт теле — татар һәм рус телләре булу, ягъни Конституция б-н беркетелгән икетеллелек принцибына каршы чыгалар. 1990 еллар уртасында М.М. җитәкчелеге төп игътибарны татар халкының рухи тормышында дин йогынтысын көчәйтүгә юнәлтә. 1990 елларның 2 нче яртысыннан респ-кадагы сәяси процессларда М.М.нең роле әллә ни сизелми. 2004 тә яңа җитәкчелек М.М. эшчәнлеген тергезерга омтылыш ясый, әмма үз башлангычларында теләктәшлек тапмый.

*Әд.:* Т е р е н т ь е в а И.В., Б е л я к о в Р.Ю., С а ф а р о в М.Ф. Республика Татарстан: Политические партии, движения, лидеры. К., 2001.

*М.Ф.Сәфәров.*

**МИЛЛИ́ МӘКТӘПЛӘ́Р ФӘННИ́-ТИКШЕРЕНҮ́ ИНСТИТУТЫНЫ́Ң ТАТАРСТА́Н ФИЛИАЛЫ́.** 1960 елның 21 июнендә ПФАнең милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-ты бүлекчәсе буларак РСФСР МС һәм РСФСР буенча КПСС ҮК бюросы карары б-н ачыла (1968 дән РСФСР Мәгариф министрлыгы карамагында), 1991 дә төп институт Мәгарифнең милли проблемалары ин-ты итеп үзгәртелә. 1995 тә филиалны федераль бюджеттан финанслау туктатыла, аның җирлегендә ТР ФАнең Мәгарифнең милли проблемалары ин-тын булдыру карары кабул ителә, ләкин ул гамәлгә ашмый кала. 1996 ның ноябрендә филиал җирлегендә ТР ФАнең Тарих ин-ты составында Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге булдырыла. 1960–80 дә Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында 10–15 кеше эшли. Татар мәгарифе тарихы һәм теориясе, татар теле һәм әдәбияты укыту, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыту методикасы проблемалары өйрәнелә, укытучылар өчен уку ярдәмлекләре һәм әдәбият булдырыла, табигыять фәннәре буенча дәреслекләр татар теленә тәрҗемә ителә. Филиал мөдирләре: Л.З.Шакирова (1960–63), Г.А.Жданова (1963–84), Ф.Ю.Йосыпов (1984–93), Ф.М.Солтанов (1993–96).

*М.М.Гыйбатдинов.*

**МИЛЛИ́ ОРКЕ́СТР**, 19 йөз ахырында — 20 йөз башында уйнаучылар саны һәм составы катнаш, башлыча Европа, ш.у. көнкүрештә таралган традицион рус һәм күбесенчә шәһәр татарлары арасында кулланылган татар милли уен коралларында (скрипка, мандолина, гитара, фортепиано, думбра, гармун, курай, гөслә, кубыз һ.б.лар) башкаручыларның зур булмаган коллективлары. М.о.да катнашучылар саны 20–30 кешегә җитә; гадәттә, җитәкчеләре — милли сәнгать, традицион проф. музыка иҗаты вәкилләре була. М.о.лар 1905–07 елгы рев-циядән соң иҗтимагый тормышны демократияләштерү һәм дин йогынтысыннан арындыру уңаеннан күпләгән шәһәр һәм авылларда татар мәдәни-агарту оешмалары каршында, ш.у. театр һәм музыка сөючеләр түгәрәкләрендә киң үсеш ала. Казанда В.Апанаев, И.Галиәкбәров, Г.Зайпин җитәкчелегендә, ш.и. *Шәрекъ клубы* һәм «*Сәйяр*» драма труппалары каршында беренчә инструменталь коллектив эшли. Кыллы зур оркестрлар Уфа (җитәкчесе Г.Ижбулдин), Троицк (Г.Булатов), Ташкент («Чишмә» җәмгыяте каршында М.Мансуров җитәкчелегендәге халык уен кораллары оркестры), Оренбург (И.Иялов җитәкчелегендәге мандолина һәм гитаралардан торган «неаполитан оркестры») һ.б. шәһәрләрдә була. Зур М.о.лар Мәскәүдә, Петербург, Әстерхан, Самара, Саратов, Төмәндә һәм Россиянең татарлар яшәгән башка шәһәрләрендә оештырыла. Оркестрлар репертуары нигезен татар халык көйләре, концерт бирүче татар музыкантлары иҗат иткән оригиналь пьесалар, Европа һәм рус көнкүреш музыкасы (маршлар, биюләр һ.б.) тәшкил итә. М.о.лар әдәби-муз. һәм бию кичәләрендә, концертларда актив катнашалар, чыгышлары граммофон пластинкаларына яздырыла. Колоритлы һәм масштаблы яңгырашлары б-н тыңлаучылар алдында зур популярлык казаналар. М.о.лар,



Шәрекъ клубының кыллы оркестры. Казан. 1910.

проф., һәвәскәр һәм милли драма труппалары б-н хезмәттәшлек итеп, спектакльләр алдыннан һәм антрактларда чыгышлар ясыйлар. Милли аудиторияне музыка сәнгатенең яңа формаларын үзләштерүгә әзерлиләр, инструменталь ансамбльнең башкару сәнгатен үстерүгә булышлык итәләр һәм хәзерге татар проф. музыка сәнгате формалашуга сизелерлек йогынты ясыйлар. Оркестрантлар арасыннан С.Габәши, С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров кебек күп кенә танылган татар композиторлары һәм музыкантлары үсеп чыга.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**МИЛЛИ́ ШУРА́**, к. *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы.*

**«МИЛЛИ́ ЮЛ»**, журнал, к. *«Яңа милли юл».*

**МИЛЛИ́-МӘДӘНИ́ МОХТАРИЯ́Т**, күпмилләтле дәүләт составында «кече» халыклар тоткан урын турындагы тәгълимат. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында барлыкка килә. Австрия социал-демократлары К.Реннер һәм О.Бауэр хезмәтләрендә мәдәният, тел, мәгариф өлкәләрендә мөстәкыйльлеккә ирешү милли мәсьәләләрне хәл итү буларак карала. О.Бауэрның «Милли мәсьәлә һәм социал-демократлар» хезмәте 1909 елда рус теленә тәрҗемә ителә һәм җәмәгатьчелектә киң кызыксыну уята.

Татарларда М.-м.м. идеясе 19 йөздә — 20 йөз башында, татар иҗтимагый фикерендә татар җәмгыятенең киләчәк сәясәтендә тотачак ролен фаразлау өстенлек иткән чорда, мәгърифәтчеләр (К.*Насыйри*, Ш.*Мәрҗани*, Р.*Фәхретдин*) эшчәнлеге һәм исламдагы либераль-реформаторлык агымы (җәдитчелек) йогынтысында туа. Халыкларның империя составындагы урыны мәсьәләсен иң беренче булып үзенең диплом эшендә («Госманлы империясенең дәүләт институтлары тарихы буенча тикшеренү» — «Исследование по истории государственных институтов Османской империи». Париж, 1903) Й.Акчура күтәреп чыга; ул Төркия мисалында төрле этник төркемнәрне берләштерү һәм шул нигездә бердәм милләт төзү мөмкин булмавын күрсәтә. Акчура төп игътибарны, әгәр халыкларга мохтарият бирелмәсә, аларның тулы мөстәкыйльлек максатыннан колларына корал алып, империядән аерылып чыкканчы көрәшәчәгенә юнәлтә. Аның фикеренчә, Госманлылар империясен федерация принципларында үзгәртеп корып кына саклап калырга мөмкин. Ул үз идеяләрен «Сәясәтнең өч төре» (1904) хезмәтендә киңрәк һәм тирәнрәк итеп тасвирлый. Әлеге хезмәтне татар халкының милли үзаңы үсүгә зур йогынты ясаган иҗтимагый-сәяси хәрәкәт — *пантюркизм* манифесты дияргә мөмкин. 1903 тә «Тәрҗеман» г-тасының 20 еллыгы уңаеннан Бакчасарай шәһәренә татар зыялыларының күп кенә күренекле вәкилләре җыела, шунда милли мәсьәләләр беренче тапкыр гомумроссия күләмендә карала, Россия империясендә милли мәдәниятне саклап калу юллары тикшерелә. Россия төрки-мөселман җитәкчелеге вәкилләренең күбесе, уртак тел һәм уртак дин нигезендә, илдәге төрки-мөселманнарны уртак сәяси милләткә берләштерү фикерен күтәреп чыгалар, дәүләт оештырачак этнос итеп, алар фикеренчә икътисади, сәяси һәм мәдәни үсеш ягыннан югарырак дәрәҗәгә ирешкән Идел буе татарлары күрсәтелә. Бу идея, ил икътисадының кызу темплар б-н үсеп китүенә бәйле рәвештә, милләт булып оешу процессы тизләнү сәбәпле, Россиянең төрки халыклары арасында тормышка ашмый кала. Россия хөкүмәте ш.у., империядәге барлык төркиләрнең татарлашуыннан һәм илдә көчле сәяси агым барлыкка килүдән куркып, әлеге идеянең таралуына һәртөрле киртәләр куя. Пантюркизм тарафдары булуыннан шикләнелгән һәр кеше полициянең яшерен күзәтүенә алына һәм эзәрлекләнүгә дучар ителә. Й.Акчураның 1908 дә Россиядән китүенә төп сәбәп шул була. Татар милләтенең күренекле вәкилләре 1905–07 еллар рев-циясе чорында М.-м.м. идеясенә мөнәсәбәтләрен тагын да ачыграк күрсәтәләр. Россия мөселманнарының либерал-демократик юнәлешле «*Иттифакъ әл-мөслимин*» («Мөселманнар берлеге») партиясе оештырыла, Бөтенроссия мөселманнарының өч корылтае (1905 нең 15 августы; 1906 ның 13–23 гыйнвары; 1906 ның 16–21 августы) җыела, аларда Россия мөселманнары иҗтимагый-сәяси оешмасының беренче программасы эшләнә һәм кабул ителә. Мөселманнарның М.-м.м. таләбе куелу б-н бергә, аның эчтәлеге дә ачыклана: дин эшләрендә мөстәкыйльлек, төбәкләрдә киң үзидарә, милли мәгарифнең ана телендә булуы, милли югары уку йортлары ачу һәм Россия ун-тларына каршылыксыз кереп уку мөмкинлеге. Болар һәммәсе конституцион парламент монархиясе буларак идарә ителүче бердәм Россия составында тормышка ашырылырга тиеш дип күзаллана (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). М.-м.м.нең эчтәлеген күбесенчә иттифакъчыларның идея-тактик союзнигы *Конституцион демократлар партиясе* программасы тәшкил итә. Бу партия программасында М.-м.м. төшенчәсенә беренче мәртәбә аңлатма бирү омтылышы ясала: «Россия империясенең Төп законы, Империядә яшәүче халыкларның тулы гражданлык һәм сәяси тигезлегеннән тыш, аларга җәмгыяви тормышта төрле тел һәм сөйләм куллану ирекен, белем бирү йортлары төзү һәм тоту, ш.у. һәр халыкның телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү максатыннан җыеннар, берлекләр, учреждениеләр булдыру ирекен эченә алган ирекле мәдәни үзбилгеләнү хокукын гарантияләргә тиеш», — диелә. Кадетлардан аермалы буларак, иттифакчылар халык таләп иткән өлкәләрдә өлкә мохтариаты түгел, ә киң демократик башлангычлар нигезендә оешкан милли өлкә мохтарияте булдыру һәм ш.у. җирле эшләрне хәл иткәндә закон чыгару хокукына ия булу тәкъдиме б-н чыгалар. Ләкин болар программаның дәүләт төзелеше турындагы пунктларына түгел, үзидарә турындагы пунктларына кертелә. Милли мәсьәләне чишү юлларын башка сәяси партияләр дә тәкъдим итә. Социалист-революционерлар (эсерлар) һәм с.-д. халыкларга, аерылып чыгу мөмкинлеген дә кертеп, үзбилгеләнү хокукы бирүче федератив Россия яклы була. РСДРП 1913 тә бу лозунгны вакытлы тактик манёвр буларак игълан итә. В.И.*Ленин* таныганча, лозунг карагруһ бөек рус милләтчелеге б-н көрәш шартларында күтәрелә, ул: «Без чынлыкта федерациягә каршы — ул икътисади элемтәләрне какшата, бер дәүләт өчен яраксыз түгел» — дип белдерә. Эсерлар 1906 елгы программаларында, халыкларның этнографик тупланышы чикләрендә терр.-милли мохтарият төзелү һәм халыклар катнаш яшәгән терр-яләрдә азчылыкның хокуклары саклану шарты үтәлгән очракта, Россия өчен федератив-демократик респ-ка формасын яклыйлар. 1905–07 еллар рев-циясе чорында татар зыялылары, революцион партияләр программалары нигезләмәләре б-н чагыштырганда, уртачыл карашта торалар, с.-д.ны да, эсерларны да якламыйлар. Социалист-революционерлар идеяләре татар зыялылары арасында 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң гына популярлаша.

Татар милләтпәрвәр җитәкчелеге, әзләнү халәтендә булып, мохтариятнең асылын, Россия дәүләтчелеге кысаларында аның нинди булырга тиешлеген ачыкларга омтыла. 1906 да Р.*Ибраһимовның* «Автономия нәрсә ул? Ничек була?» мәкаләсе басылып чыга. Автор М.-м.м.нең асылын руслар б-н тигез хокуклылык, аерым земство идарәләре оештыру, мөселман хәрби корпусы төзү һәм тыныч вакытта аны мөселманнар күпчелекне тәшкил иткән губерналарга урнаштыру, дин эшләрен алып бару өчен мөселманнарга ассигнацияләр бүлеп бирү, әхлакый чисталыкны саклау максатыннан руслардан аерым мәктәпләр булдыруга кайтарып калдыра. Күпләрне татарларга, гомумән, М.-м.м. кирәкме соң дигән уй борчый. Беренче бөтендөнья сугышына кадәр зыялылар арасында пантюркизм идеяләре бик популяр була, моңа татарларның Россия буйлап географик яктан киң сибелгәнлеге дә йогынты ясый.

М.-м.м. мәсьәләсе 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, Россия империясендә дәүләт строен үзгәртүнең күренеп торган мөмкинлекләре ачылуга бәйле рәвештә кискенләшә. 1917 дә татарлар милли мәсьәләнең чишелешен диннәр тигезлеге һәм дини үсеш өчен юллар ачылуда; милли чикләүләр бетерелү һәм Россиядә яшәүче халыкларның тигез дип игълан ителүендә, алар арасында хокуклары кысылган халыкларның тормышы һәм эшчәнлегеннән юридик киртәләрнең рәсми рәвештә алып ташлануында, аларны илнең тигез хокуклы гражданнары итеп танылуында; һәр халыкның фәкать үзенә генә кагылышлы милли эш-гамәлләре даирәсендәге (дин, мәгариф, мәдәният) эшчәнлекнең дәүләт тарафыннан шул халыкның үзенә тапшырылуында күрә.

1917–18 елларда Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында М.-м.м. мәсьәләсе тикшерелә, дискуссияләр була. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда «Федератив халык республикасы» тарафдарлары (Ә.Вәлиди, Г.Тупчыбашев, А.Букәйханов һ.б.) һәм Россия төрки-мөселманнарын бердәм сәяси милләт итеп туплау һәм шул нигездә дини-мәдәни мохтарият төзү фикерендәге

унитаристлар (Ә.Цаликов, Г.Исхакый һ.б.) арасында бәхәс бара. Унитаристлар Россия дәүләтенең бөтенлеген саклау зарурлыгына басым ясыйлар, бу чорда федерализм татарларны хәтта милли-мәдәни эшчәнлектәге җитәкчелектән дә читләштерергә мөмкин, дип саныйлар. Ә.Вәлиди, корылтайда «Россия мөселманнарының кабилә составы турында» дигән доклад б-н чыгыш ясап, бердәм мөселман милләте юклыгын, шунлыктан мөселман халыкларын тел һәм мәдәният ягыннан берләштерергә омтылуларның гайре табигый хәл булуын һәм моның адм. юл б-н тормышка ашырыла алмаячагын исбатлый. Озакка сузылган бәхәсләрдән соң, резолюция кабул ителә. Россиядә бергә тупланып яшәүче мөселманнар мәнфәгатенә терр. мохтариятләргә нигезләнгән федератив халык республикасы рәвешендәге дәүләт төзелеше җавап бирә, ә билгеле бер терр-яләре булмаган милләтләр М.-м.м. төзелешеннән файдаланырга тиеш дигән карарны 446 делегат хуплый, 271 делегат каршы тавыш бирә. 1917 нең 22 июнендә Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае (Кавказ, Төркестан, Кырым, Казакъстан вәкилләре катнашмый), Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае һәм Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае делегатларының уртак утырышында Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының М.-м.м.н төзү турында декларация кабул ителә һәм Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының М.-м.м. нигезләрен эшләү комиссиясе оештырыла. Комиссия эшчәнлегенең башлануы Россия терр-ясендә М.-м.м. төзелешенең фактта танылуын аңлата. «Эчке Россия мөселманнары милли-мәдәни мохтарияте органнарына сайлаулар турындагы Нигезләмә»дә, беренче милли парламент милли губерналарны раслаганга кадәр, мохтарият кысаларындагы татарлар күпләп яши торган Казан, Уфа, Оренбург, Самара, Әстерхан, Пермь, Түбән Новгород, Тамбов, Тобол, Томск губерналары һәм Уральск өлкәсе — үзәге губерна шәһәре булган мөстәкыйль милли округлар санала, диелә. Төбәкләрдә бер-бер артлы М.-м.м.нең иң беренче хакимият органнары — милли шуралар оеша; 1917 нең сентябрендә исемнәре үк Эчке Россия мөселманнарының яңа статусын күрсәтеп торган «Җөмһүрият» һәм «Мохтарият» г-талары чыга башлый. Август аеннан кайбер авылларның халкы милли волостьлар оештырырга керешә. 1917 нең көзендә М.-м.м. органнары, нигездә, оешып бетә, губерна, шәһәр, өяз шураларыннан торган милли шуралар һәм аларның башкарма ком-тлары системасы барлыкка килә. 1917 нең 4–6 октябрендә Томск шәһәрендә уздырылган Гомумсебер мөселманнарының беренче корылтае Себердә М.-м.м. төзелешенә йомгак ясый. Себер мөселманнары мохтарият төшенчәсенә киң мәгънә бирәләр, мохтарият мәдәни мәсьәләләрне генә түгел, икътисади, хәрби, һөнәри һ.б. мәсьәләләрне дә хәл итәргә тиеш, дип саныйлар. Корылтай Себер мөселманнарының М.-м.м. хокукларын гарантияләячәк мохтарият төзелешен яклап чыга. Эчке Россия һәм Себер мөселманнары М.-м.м.нең С.Максуди эшләгән Конституциясе, 1917 нең октябрь башларында рус теленә тәрҗемә ителеп, раслау өчен Вакытлы хөкүмәткә җибәрелә.

Игълан ителгән мохтариятнең югары органы — *Милләт Мәҗлесе* (1917 нең 20 ноябре — 1918 нең 11 гыйнвары) эшчәнлеге делегатлар арасында мохтариятнең нинди булырга тиешлеге хакында уртак фикер булмавын күрсәтә. Беренче утырышларда ук берничә төркем (фракция) барлыкка килә. Экс-терр. М.-м.м. тарафдарлары — *төркичеләр* (С.Максуди, Ибн. *Әхтәмов*, Г.Исхакый, Г.*Терегулов* һ.б.) б-н терр. милли мохтарият тарафдарлары — *туфракчылар* (И.*Алкин*, Г.*Ибраһимов* һ.б.) арасында аеруча көчле бәхәс бара. Төркичеләр, Россиядәге төрки-татар халыкларының күбесенә хас арталык терр. милли мохтарият төзүгә киртә булачагын сәбәп итеп, милли дәүләт төзелешенең башлангыч чорында киң вәкаләтләргә ия, халыкны мәдәни һәм мәгариф ягыннан үстерүгә булышачак, ш.у. милли дәүләтчелеккә тыныч юллар б-н ирешүгә китерәчәк М.-м.м. төзү идеясен яклыйлар. Алар фикеренчә, татар халкы әлегә милләт булып оешмаган, милли дәүләтчелек төзүгә алшартлар юк. Ахырда беркадәр М.-м.м. элементлары да сакланган терр. милли мохтарият идеясе, ягъни туфракчылар җиңеп чыга. Моңа ш.у. илдә иҗтимагый-сәяси вазгыять үзгәрү дә сәбәп була: хакимияткә большевиклар килә, милләтләрнең, хәтта аерылып чыгу һәм аерым дәүләтләр төзү мөмкинлеге дә кертелеп, үзбилгеләнү хокукы игълан ителгән Солых турында декрет чыга.

Идел-Урал Штаты төзү идеясенә каршы большевиклар *Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы* төзү идеясен тәкъдим итәләр. Булачак республиканың Оештыру съездын җыю буенча беренче утырыш уздырыла (1918 нең 10 мае), И.В.Сталин, шунда чыгыш ясап, алга мохтариятнең чикләрен һәм вәкаләтләрен билгеләү мәсьәләсен куя. Башкортстан АССР (1919) һәм Татарстан АССР (1920) төзелгәннән соң, М.-м.м. идеясе үзеннән-үзе төшеп кала.

1990 елларда М.-м.м. идеясе кабат күтәрелә, бу юлы ул ТР дан читтә яшәүче татарларның М.-м.м.н күздә тота. 1996 да РФнең Милли-мәдәни мохтарият турында законы кабул ителә. Ш.у.к. *Автономия*.

*Әд.:* Усманова Д.М. Вопросы национально-государственного самоопределения на страницах татарской периодической печати (1917 — апр. 1918 гг.): Дис. ... К., 1994; Мухаметдинов Р.Ф. Зарождение и эволюция тюркизма. К., 1996; История национальных политических партий России: Материалы междунар. конф. М., 1997; Фахрутдинов Р.Р. Татарский либерализм в конце XIX — начале XX века (очерки политической истории). К., 1998; Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000; Ямаева Л.А. Мусульманский либерализм начала XX века как общественно-политическое движение (по материалам Уфимской и Оренбургской губерний). Уфа, 2002; Исхаков С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 — лето 1918 г.). М., 2004.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МИЛЛИ́-МӘДӘНИ́ МОХТАРИЯ́Т НИГЕЗЛӘРЕ́Н ЭШЛӘ́Ү КОМИ́ССИЯСЕ**, 1917 елның 22 июлендә Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтае, Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтае, Бөтенроссия мөселман руханилары корылтае делегатларының (1 меңнән артык кеше) берләштерелгән утырышында Эчке Россия һәм Себер төрки-татарларының милли-мәдәни мохтарият кануннары караламасын (проектын) эшләү өчен оештырыла (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Беренче состав: комиссия рәисе — С.*Максуди*, рәис урынбасары — Ибн. *Әхтәмов*; әгъзалар — Г.*Шәрәф*, Ә.*Мөхетдинова*, Ф.Кәримов, К.Кәримов, Н.Хәлфин, Һ.*Атласов*; кандидатлар — Н.Корбангалиев, Г.*Исхакый*, Г.Абызов, Г.*Терегулов*. 1917 нең августыннан эшен Уфада дәвам итә. Яңартылган состав: С.Максуди (рәис), Ибн.Әхтәмов (урынбасар); әгъзалар — Г.Шәрәф, Ә.Мөхетдинова, Һ.Атласов, Н.Корбангалиев, Г.Терегулов, С.Мамлиев, С.Урманов, Ш.*Алкин*, Г.Шинаси. Комиссия Идел-Урал төбәгендәге мөселман халкы турында мәгълүмат җыю, Милләт Мәҗлесенә әзерлек һәм аны уздыру, сайлауларны оештыру кебек эшләр б-н шөгыльләнә. Булачак мохтариятнең төп принциплары һәм структурасы бәян ителгән «Милли-мәдәни мохтарият нигезләре» проектын матбугатта бастырып чыгара. 1917 нең декабрендә эшчәнлеге туктатыла.

*Әд.:* Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.


**МИЛМӨХӘММӘ́ТОВ** Әүхәди Әхмәди улы (6.4.1913, Томск губ. Новониколаевск ш., хәзер Новосибирск ш. — 21.1.1987, Казан), комсомол һәм профсоюзлар эшлеклесе. ВКП(б) ҮК каршындагы Партия-оештыручылар югары мәктәбен (Мәскәү, 1939), КПСС ҮК каршындагы Партия югары мәктәбен (Мәскәү, 1952) тәмамлый. 1932 елда Көньяк Урал тимер юлының Златоуст станциясе депосы каршындагы фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбендә инструктор. 1933 тән комсомол эшендә. 1936–37 дә «Сажерез» з-дында (Куйбышев ш.) комсомол ком-ты секретаре, 1939–44 тә ВЛКСМның Приморье крае ком-ты, 1944–49 да Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1952–53 тә КПССның Чистай өлкә ком-ты идеология буенча секретаре. 1953–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире. 1959–65 тә ТАССР МС рәисе урынбасары, 1965–72 дә Профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. ТАССР ЮС депутаты (1947–51, 1959–75). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Мирсияпов Т.А., Фомин А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995 гг.). К., 1995; Мильмухаметов И.А. Помним и любим. К., 2005.

**МИЛО́ВА** (чын фамилиясе Лебедева) Людмила Прокофьевна (21.6.1904, Владикавказ ш. — 9.2.1949, Казан), драма актрисасы, ТАССРның атказ. артисты (1944). Владикавказ гимназиясен тәмамлаганнан соң, Грозный шәһәр театрында, аннары Ашхабад, Пенза, Горький, Краснодар, Калуга, Владимир,



Л.П.Милова.



Н.К.Милославский.

Ленинград, Архангельск шәһәрләрендәге театрларда эшли. 1931–32, 1935–36, 1937–39, 1943–48 елларда Казан Зур драма театры актрисасы. Кабатланмас мөлаемлыкка ия булганга, тамашачы М.га битараф кала алмый: ул сәхнәгә чыккан саен алкышлап каршы ала. Тоемлау көченә таянып, актриса рольнең тышкы күренешенең катгый партитурасын төзи, аның героиняларының һәр хәрәкәтенә эчке бөтенлек хас, тирән мәгънә салынган. Бөек Ватан сугышы елларына һәм сугыштан соңгы беренче елларга туры килгән иҗатының соңгы чорында М. башкарган Нина («Маскарад», М.Ю.Лермонтов), Лиза Калитина («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев),



Л.П. М и л о в а Нина ролендә («Маскарад», М.Ю.Лермонтов).

Юлия Тугина, Негина («Соңгы корбан», «Талантлар һәм баш иючеләр», А.Н.Островский), Даша, Марья Темрюковна («Михнәтле заман», «Иван Грозный», А.Н.Толстой), Шурочка Азарова («Бик күптәннән», А.К.Гладков), Дездемона («Отелло», У.Шекспир), Юдифь («Уриэль Акоста», К.Гуцков) рольләре халыкның әхлакый пакьлек идеалына ихтыяҗын, игелек һәм гаделлек хакына үз-үзеңне корбан итәргә әзер булу, фидакарьлек кебек сыйфатларны гәүдәләндерә. Ул ш.у. Нина («Давыл арасында», Д.И.Курдин), Галина («Солдатлар», Б.С.Ромашов), Елена («Дан», В.М.Гусев), Божена, Джесси («Прага кәстәнәләре астында», «Рус мәсьәләсе», К.М.Симонов) рольләрендә замандашларының уңай образларын тудыра. М. иҗатында гәүдәләнеш тапкан эмоциональ байлык, башкарудагы самимилек, һәр образны яктыртканда чагылыш тапкан ышандыру көче Казанның 1930–40 еллар театр тормышында әһәмиятле бер күренеш булып тора. Актриса Казан тамашачыларының мәхәббәтен яулый.

*Әд.:* И л я л о в а И., И н г в а р И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**МИЛОСЛА́ВСКИЙ** Валериан Владимирович (19.1.1880, Тверь губ. Зубцово ш. — 16.1.1961, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1920), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940, 1955). Казан гигиена белгечләре фәнни мәктәбен оештыручыларның берсе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1907), Себер тимер юлының Нижнеудинск участогында һәм Дон өлкәсе Кагальчи авылында табиб булып эшли. 1909 елда Елена клиник ин-тында (С.-Петербург). 1910–61 дә Казан мед. ин-тында, проф., гомуми гигиена каф. мөдире (1923 тән), бер үк вакытта Казан чәчәк салу ин-ты мөдире (1910–26), гигиена лаб-ясе мөдире (1924 тән) һәм ВЦСПСның Хезмәтне саклау ин-ты директоры урынбасары (1936 дан). 1939 дан ТАССРның сан.-эпид. хезмәте киңәшчесе. Казан мед. ин-тында санитария-гигиена ф-тын оештыручыларның берсе. Хезмәтләре эндемик зоб этиологиясе һәм патогенезында микроэлементларның ролен тикшерүгә, су гигиенасы һәм су б-н тәэмин итү гигиенасы мәсьәләләренә карый. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К методике определения азотистой кислоты в сточной воде. К., 1911; Кладбища г. Казани в санитарном отношении // Тр. Казан. мед. ин-та. 1936. Т. 1 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Валериан Владимирович Милославский: Некролог // Казан. мед. журн. 1961. № 3; К а м ч а т н о в В.П. Профессор Валериан Владимирович Милославский. К., 1969.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МИЛОСЛА́ВСКИЙ** Иван Богданович (1625 тирәсе, Мәскәү — 1681, Киев), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, окольничий (1665), бояр (1671). Патша Алексей Михайловичның беренче хатыны М.И.Милославскаяның туганнан туганы. 1649 елдан патша сараенда хезмәт итә, 1653 тән стольник. 1654–67 еллардагы рус-поляк, 1656–58 дәге рус-швед сугышларында катнаша. 1654 тә — Смоленск шәһәренә һөҗүм вакытында отряд башлыгы, 1656 да Динабург шәһәрен ала, Ригага һөҗүм итүдә катнаша. 1659–63 тә — Холмогор шәһәрендә воевода. 1665–68 дә — Челобитный приказ судьясы. 1670–71 дә — Сембер шәһәрендә 1 нче воевода, С.Т.*Разин* җитәкчелегендәге *Крәстияннәр кузгалышы (1670–71)* вакытында шәһәрне саклый. Ю.Н.Барятинский б-н бергә Урта Идел буендагы крәстияннәр күтәрелешен бастыра; әлеге күтәрелеш вакытында күп халык җәзалана, Әстерхан шәһәре алына. 1676–77 дә Казанда 1 нче воевода. 1679 да Курск шәһәрендә воевода. 1680 нән Киевта 2 нче воевода, П.В.Шереметьев б-н берлектә шундагы армия б-н идарә итә. Әлеге армия Госманлылар империясе һәм Кырым ханлыгы гаскәрләре һөҗүмен кире кайтару максаты б-н оештырыла.

*Әд.:* к. *Крәстияннәр кузгалышы (1670–71).*

*Е.В.Липаков.*

**МИЛОСЛА́ВСКИЙ** (чын фамилиясе Фридебург) Николай Карлович (7.5.1811 — 14.1.1882, Одесса), драма актёры, антрепренёр. Кавалерия офицеры, 1837 елда театрга эшкә урнаша. Кубесенчә провинция театрларында эшли. Укымышлы кеше, драматик әдәбият белгече буларак, еш кына режиссёр, спектакльләрнең сәнгать җитәкчесе вазифаларын башкара. 1852–58 елларда Казан шәһәр театрының антрепренёры һәм сәнгать җитәкчесе. Дөнья классикасын һәм рус авторларының иң яхшы пьесаларын нигез итеп алып, репертуарны тәртипкә китерә. 1853 тә, рәсми рәвештә тыелган булуга карамастан, М. Казан театры сәхнәсендә А.С.Грибоедов пьесасы буенча «Акыллылык бәласе» («Горе от ума» спектаклен куя, Чацкий ролен башкара. Ел саен Н.В.Гогольнең «Ревизор» һәм «Өйләнү» («Женитьба») пьесалары буенча спектакльләр куела, Мәскәү театры б-н бер үк вакытта ул чакта әле яшь драматург А.Н.Островскийның «Кеше чанасына утырма» («Не в свои сани не садись»), «Төшемле урын» («Доходное место»), «Ярлы кәләш» («Бедная невеста»), А.В.Сухово-Кобылинның «Кречинскийның туе» («Свадьба Кречинского») пьесалары буенча спектакльләр дөнья күрә. Соңгысында М. уйнаган баш герой роле иң уңышлылардан санала. Казанда чит ил һәм рус авторларының пьесалары буенча куйган спектакльләрендә ул Гамлет (У.Шекспирның шул исем. әсәре буенча), Кин (А.Дюманың шул исем. әсәре буенча), дон Сезар де Базан («Испан дворяны», Дюмануар һәм А.Деннери), Жорж Мориц («Графиня Клара д'Обервиль», О.Анисе-Буржуа һәм А.Деннери), Жорж де Жермани («30 ел, яки Уенчы тормышы», В.Дюканж), Прокопий Ляпунов («Ляпуновның үлеме», С.А.Гедеонов) рольләрен башкара. М., формага тирән мәгънә салып, һәр хәрәкәтне камилләштереп, рольнең тышкы күренешен җентекле итеп кора; бер үк вакытта образның эчке дөньясына да зур игътибар бирә, персонаж хәрәкәтләрен психологик яктан дәлилләргә омтыла. Аның башкаруында мелодрама геройлары романтик характер ала, ирек сөючәнлек, хөр фикерлелек идеяләрен алга сөрә. Теге яки бу спектакльне сәхнәгә куйганда, М. партнёрлардан башкаруда ансамбльлелеккә ирешүләрен, һәр рольне, икенче дәрәҗәдәге рольләрне дә, яхшылап уйлап башкаруларын таләп итә. Александра театры һәм Кече театр труппаларында лаеклы урын тоткан А.И.Стрелкова, Х.И.Таланова, Е.Б.Пиунова-Шмидгоф, В.И.Виноградов кебек актёрлар тәрбияли. М. эшчәнлеге б-н, И.А.Крути билгеләп үткәнчә, Казан театрының «алтын гасыр»ы башлана. 1867–71 дә актёр Казанда П.М.Медведев труппасында эшли, бу елларда ул Грозный («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой, «Василиса Мелентьева», А.Н.Островский), Вырин («Станция күзәтчесе», А.С.Пушкин повесте буенча), Ихарев («Уенчылар», Н.В.Гоголь), Дадли («Мария Стюарт», Ф.Шиллер) рольләрен башкара.

*Әд.:* М е д в е д е в П.М. Воспоминания. Л., 1929; К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958.

*Ю.А.Благов.*

**МИЛОСЛА́ВСКИЙ** Яков Михайлович (20.2.1926, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1966). СССР МФА академи-

гы А.Л.Мясников шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Мари АССРда участок табибе булып эшли. 1949 елдан СССР МФАнең Терапия ин-ты ординаторы. 1952 дән 1 нче Мәскәү мед. ин-тының факультет терапиясе кафедрасында. 1955 тән Рязань мед. ин-тының факультет терапиясе кафедрасында. 1962 дән Владивосток, 1967 дән Казан мед. ин-тларының эчке авырулар пропедевтикасы каф. мөдире. Хезмәтләре миокард инфаркты һәм йөрәк эшчәнлеге җитешсезлеге вакытында метаболик терапия өлкәсенә карый. М. гипертония авыруы патогенезында бөер өсте бизләре тышчасының ролен өйрәнә.

Х е з м.: Надпочечники и артериальная гипертония. М., 1971 (автордаш); Функциональные методы исследования сердечно-сосудистой системы. Чебоксары, 1976 (автордаш); Основные инструментальные методы исследования сердца. К., 1983 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Яков Михайлович Милославский // Казанский мед. журн. 1986. № 2; Яков Михайлович Милославский (к 60-летию со дня рождения) // Кардиология. 1986. № 7.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МИЛУ́ШЕВ** Александр Константинович (19.12.1933, Үзәк кара туфраклы өлкәнең Рассказово р-ны Татарщино а. — 3.11.1996, Мәскәү), генерал-майор (1985). Милләте буенча татар. Хәрби-юллар уч-щесен (1955), Хәрби тыл һәм транспорт академиясен (Ленинград, 1971) тәмамлый. 1973–79 елларда Балтыйк буе хәрби округында: автотранспорт хезмәте өлкән офицеры, 1975–79 да гомумгаскәри берләшмәнең автотранспорт хезмәте башлыгы (Калининград ш.). 1979–88 дә Байкал аръягы хәрби округында: автотранспорт хезмәте башлыгы урынбасары, 1980–88 дә кораллану идарәсенең автомобиль хезмәте башлыгы (Чита ш.). 1989 дан СССР Оборона министрлыгының Үзәк юл төзелеше идарәсе башлыгы. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИЛЬШТА́Т** (Milstadt) (Мюллер) Эрих (1904, Ростов-Дон ш. — 1970, Берлин), немец драматургы, тәрҗемәче. 1921 елдан Германиядә яши. Банкта клерк, матбугатта мөхәррир булып эшли. 1930 да немец эшчеләре делегациясе б-н Советлар Союзында булып китә. Фашистлар хакимияткә килгәч, эмиграциягә (Чехословакия, Англия) китәргә мәҗбүр була. 1947 дә Германиягә кайта. М.Җәлилгә багышланган «Кызыл ромашка» исемле телефильмга (1959) һәм шул ук исемдәге нәфис фильмга (1963, режиссёры Латар Беллач) сценарий яза. Сценарий язганда СССРга килә, шагыйрьнең туганнары һәм якыннары б-н очраша. Немец теленә М.Җәлил, М.Е.Салтыков-Щедрин, казакъ фольклоры әсәрләрен тәрҗемә итә.

*Р.Ә.Мостафин.*

**МИЛЮКО́В** Павел Николаевич (15.1.1859, Мәскәү — 31.3.1943, Экс-ле-Бен, Франция), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тарихчы, публицист, рус тарихы магистры (1892). Дворяннар нәселеннән. 1882 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1886–94 елларда рус тарихы каф. приват-доценты. 1905 тә «Коткару Берлеге» («Союз Освобождения») сәяси берләшмәсе эшлеклесе, конституцион демократлар партиясен оештыручыларның берсе һәм җитәкчесе (1907–18 дә ҮК рәисе). 3 нче, 4 нче Дәүләт Думалары депутаты (1907–17). 1917 нең февраль-май айларында Вакытлы хөкүмәтнең тышкы эшләр министры. Окт. рев-циясеннән соң, Аклар хәрәкәте вәкилләре б-н хезмәттәшлек итә. 1919 дан эмиграциядә. 1921–40 та «Последние новости» (Париж) г-тасы мөхәррире. Тарихи үсешкә позитивистик карашларда тора, рус историографиясендәге дәүләт юнәлеше һәм «икътисади материализм» йогынтысын кичерә. Хезмәтләре Россия тарихы, әдәбияты, сәясәте, икътисадына һәм рус рев-циясе мәсьәләләренә карый. «XVIII йөзнең 1 нче чирегендә Россиядә дәүләт хуҗалыгы һәм Бөек Пётр реформасы» («Государственное хозяйство России в первой четверти XVIII столетия и реформа Петра Великого». М., 1892) монографиясе — Пётр I керткән үзгәрешләрне тикшергән беренче хезмәт. Хезмәт бай архив материалларына таянып язылган һәм Казан губернасы үрнәгендә Россия оешмалары һәм финансларының Пётр I чорындагы дәүләт икътисады б-н бәйләнешен ачып бирә. «Рус мәдәнияте тарихы очерклары» («Очерки истории русской культуры», ч.1–3, М., 1896–1903) хезмәтендә М., рус җәмгыяте оешуда дәүләт төп рольне уйный, дип күрсәтә, ш.у. Рус мәдәниятенә Шәрекъ халыкларының мирасы йогынтысын билгеләп уза. «Күчмә тормыш алып барган» төрки халыклар мисалында М. борынгы заманнардан алып урта гасырларга кадәр игенчелек һәм күчмә культураларның үзара бәйләнешен тикшерә, Россия дәүләтчелеге оешуда монгол яуларының хәрби төзелештә, идарә һәм финанс өлкәләрендәге ролен күрсәтә. Казан либералларын тасвирлаган «Хатирәләр (1859–1917)» («Воспоминания (1859–1917)», т. 1–2, Нью-Йорк, 1955) авторы. Әлеге хезмәт — 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Россиядәге иҗтимагый хәрәкәт тарихына кагылышлы әһәмиятле чыганак.

Х е з м.: Из истории русской интеллигенции. СПб., 1903; История второй русской революции: В 3 вып. София, 1921–24; Россия на переломе. Большевистский период русской революции: В 2 т. Париж, 1927.

*Әд.:* П.Н.Милюков: Сборник материалов по чествованию его 70-летия, 1859–1929. Париж, 1929; Историки России XVIII — начала XX вв. М., 1996.

*Е.Б.Долгов.*

**МИЛЯШО́В** Николай Фёдорович (13.9.1956, Краснодар крае Лабинск ш. — 7.6.2005, Казан), электр энергетикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2001). Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Казан технол. ун-тында эшли, электр күчергечләре һәм электротехника каф. мөдире (2000 елдан). Хезмәтләре электр энергетикасына һәм автогенераторлы идарә системалы көч үзгәртү техникасына, идарә системаларындагы һәм алмаш ток күчергечләрендәге динамик процессларны компьютерда модельләштерүгә карый. М. катлаулы көнкүреш техникасы җайланмаларында, ш.у. кеч- кенә һәм уртача егәрлектәге вентилятор җайланмаларында кулланыла торган асинхрон һәм вентиль-индукторлы двигательләр б-н механотрон системалар эшли. М. җитәкчелегендә көнкүреш һәм махсус техника, очкыч аппаратлар, металл эшкәртү станоклары өчен ешлык б-н идарә ителүле, югары тизлекле асинхрон электр күчергечләр сериясе булдырыла. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Эшкәртмәләре Татарстан һәм элекке СССР респ-калары пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә.



П.Н.Милюков.



Г.М.Минаев

Х е з м.: Электромеханотронная система с высокоскоростным асинхронным двигателем // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 1999. № 7/8; Асинхронная электромеханотронная система с автогенераторным управлением // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 1999. № 9/10; Бытовой электропривод: Благополучная экология или дешевизна // Энерго. 2001. № 1/2.

**МИНА́ЕВ** Гатаулла Мирзаһит улы (тәрбиягә алган гаилә фамилиясе буенча — Орлов Николай Сергеевич) (29.12.1919, Уфа губ., Минзәлә өязе, хәзер Актаныш р-ны Зөбәер а. — 29.9.1982, Ровно ш.), Сов. Союзы Герое (2.5.1945). Мәктәпне тәмамлаганнан соң, ата-аналары б-н Колпино шәһәренә (Ленинград өлкәсе) китә. Яшьли ятим кала, Орловлар гаиләсендә тәрбияләнә. Ижора з-дында слесарь булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында. Киев янында әсирлеккә эләгә, концлагерьдан кача. 1942 нең февраленнән «Ватан өчен» (Сумы өлкәсе) исемле партизан отрядында. 1943 тән партизаннар берләшмәсенең шартлату төркеме командиры (Ровно өлкәсе). М. җитәкчелегендәге отряд 20 сугышчан һәм диверсион операция үткәрә, дошманның йөзләгән эшелонын юк итә, 4 тимер юл күперен шартлата. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р а к и п о в Ш.З. Хранить вечно. К., 1980; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2; Подвигом прославленные. Киев, 1985.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИНАЧЁВ** Хәбиб Минач улы (11.12.1908, Сембер губ., Буа өязе Яңа Бикшек а. — 25.3.2002, Мәскәү), химик-органик, химия фән. д-ры (1954), РФА академигы (1991; 1979 елдан СССР ФА академигы; 1972 дән мөхбир әгъза). 1939 да Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, РФАнең Органик химия ин-тында эшли, директор урынбасары (1955–77), Сирәк һәм сибелгән элементларда катализ лаб-ясе мөдире (1963–90), проф. (1970), 1989 дан төркем җитәкчесе, дирекциядә киңәшче. СССР ФАнең Катализ буенча фәнни советы


Х.М. Миначёв.


Р. Мингалим.

рәисе (1982–89), Гомуми һәм техник химия бүлекчәсенең акад. секретаре урынбасары (1985–90), СССР МКның Фән һәм техника Дәүләт ком-тында «катализ һәм аны сәнәгатьтә куллану» проблемасы буенча фәнни совет рәисе урынбасары (1985–92). М.ның фундаменталь тикшеренүләре катализның теоретик нигезләрен үстерүгә, төрле классны органик кушылмалар синтезлауның яңа алымнарын эшләүгә, нәтиҗәле каталитик системалар булдыруга карый. М. углеводородларны 8 нче төркем металлар тупланган җисемнәрдә гидрирлау, дегидрирлау, изомерлаштыру, бензин фракцияләре риформингы реакцияләрен тикшерә. Аз күләмдә затлы металлар катнашкан катализаторларның югары активлыгын һәм тотрыклылыгын ачыклый, аларны югары нәтиҗәле сәнәгый риформинг катализаторлары сыйфатында тәкъдим итә. Сирәк мәгъдән элементлары (СМЭ) оксидларының каталитик активлыгы аларның электрон төзелешенә бәйле булуын ача һәм бу бәйлелекне формалаштыра. СМЭның берьярым оксидларының олефиннарны гидрирлау реакцияләрендә түбән темп-ралы каталитик активлыгын һәм аларның С=С-бәйлелегендәге көчешен, ш.у. үз составларында күчеш элементлары булмаган цеолитларның уникаль үзлеген — төрле классны органик кушылмалар гидрирлауда катализатор була алуын ача. Углеводородларны әйләнә-тирәне пычратмыйча изомерлаштырырга һәм алкилларга мөмкинлек бирә торган, составларына СМЭ һәм 8 нче төркем металлар кергән нәтиҗәле цеолит катализаторлар уйлап таба. Рений оксидлары, сульфидлары, галогенидлары һ.б. кушылмаларын төрле органик реакцияләр катализаторлары буларак куллануның киң мөмкинлекләрен ачыклый. М. җитәкчелегендә матдәләрне бер стадияле синтезлау алымы эшләнә, бу матдәләр югары сыйфатлы ягулык һәм майлау матдәләренең компонентлары, каучук һәм пластмассалар эшләгәндә мономерлар, кыйммәтле реактивлар һ.б. булып тора. Уйлап табуга 100 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Фәнни эшкәртмәләре Россия һәм башка илләрнең химия пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән. 1970–80 елларда М. «цеолитлар б-н катализ» темасы буенча СССРның милли координаторы, СССР һәм АКШ, Германия, Чехословакия, Бөекбритания, Һиндстан, Болгария, Вьетнам галимнәре б-н күпьяклы хезмәттәшлекнең шеф-координаторы була. ГДР ФАнең чит ил әгъзасы (1983). «Химия твёрдого топлива» (1982 дән), «Нефтехимия» (1988–99) ж-лларының баш мөхәррире. СССР МС (1976), СССР Дәүләт (1977), СССР ФАнең Н.Д.Зелинский исем. (1972, 1987), А.А.Баландин исем. (1993) һәм ГДР ФА (1989) бүләкләре лауреаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын һәм бер көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Редкие земли в катализе. М., 1972 (автордаш); Фотоэлектронная спектроскопия и её применение в катализе. М., 1981 (автордаш); Рений и его соединения в гетерогенном катализе. М., 1983 (автордаш); Окислительно-восстановительный катализ на цеолитах. М., 1990 (автордаш).

*Әд.:* Хабиб Миначевич Миначёв / АН СССР // Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1993. Вып. 94; Памяти академика Х.М.Миначёва // Нефтехимия. 2002. Т. 42, № 3; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**МИНӘЧЕТДИ́НОВ** Марат Канәфи улы (24.4.1961, Чүпрәле р-ны Югары Каракитә а.), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1990). Арча р-нында эшли: «Коммунист» к-зында (1983–86), «Северный» с-зында (1986–97) баш агроном, «Уңыш» күмәк пр-тиесе җитәкчесе (1997–98), Мәрҗани исем. а.х. җитештерү кооперативы рәисе (1998 дән). Дәүләт бүләге ТРда сәламәтләндерелгән нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МИНГАЛИ́ЕВ** Газиз Фуат улы (7.8.1961, Казан), инженер-физик, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1983 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, идарә, икътисад, финанс һәм эшмәкәрлек ф-ты деканы (2002 дән), пр-тиеләр икътисады каф. мөдире (2004 тән). Хезмәтләре энергияне саклау нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә карый. М. тарафыннан энергия саклауны максатчыл программалы планлаштыру методологиясе, энергия саклау программасын финанслау механизмын формалаштыру һәм аның нәтиҗәлелеген бәяләүнең методик базасы булдырыла, ул исә финанслауның иң кулай алымнарын сайлап алырга, финанслау алымының энергия саклау программасына йогынтысын бәяләргә, финанс чараларының рациональ составын һәм структурасын билгеләргә мөмкинлек бирә. 2001–06 елларга Казанның Энергия саклау программасы, ТР Транспорт һәм юллар хуҗалыгы министрлыгының Энергия саклау программасы (2003) авторларының берсе. ТР МКның Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре фонды эксперт советы әгъзасы.

Х е з м.: Экономические методы и модели управления процессом энергосбережения в регионе. К., 1998; Управление потенциалом энергосбережения. К., 1999; Экономическое обоснование ресурсосбережения на предприятии и в народном хозяйстве. К., 2002.

**МИНГАЛИ́ЕВ** Равил Касыйм улы (23.1.1940, Яшел Үзән р-ны Норлат а.), радиоинженер, «Элекон заводы» АҖнең башкаручы директоры (2003 елдан), РФнең атказ. машина төзүчесе (1996), икътисад фән. канд. (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1966). 1958 дән «Элекон заводы» АҖдә: җыючы слесарь, радиоаппаратура монтажчысы, өлкән инженер, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, ген. директор урынбасары (1979 дан). М. җитәкчелегендә 80 нән артык төрдә махсус эшләнмә проектлары башкарыла һәм гамәлгә кертелә; «Юниор» мәктәп з-ды оештырыла. Хезмәтләре электрон приборлар төзү өлкәсенә карый. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Почёт ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**МИНГАЛИ́М** (Мингалимов) Рөстәм Гали улы (15.9.1937, Куйбышев өлкәсенең Камышлы р-ны Йолдыз а. — 1.6.2014, Казан), шагыйрь, драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987), ТРның халык шагыйре (2010). Казан ун-тын (1967), СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби (Мәскәү, 1978) һәм Дәүләт театр сәнгате ин-ты каршындагы театр курсларын (Мәскәү, 1980) тәмамлый. 1954 елда Казакъстан ССРның Көкчәтау өлкәсендә чирәм җирләрне үзләштерүдә катнаша. Ташкент шәһәре заводларында слесарь һәм станоклар көйләүче (1956–58), Минзәләдә геофизик кыр экспедициясендә электр җиһазлары буенча слесарь булып эшли (1959–62). 1967–75 елларда «Яшь ленинчы» г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркәтип вазифаларын башкара. 1975–77, 1989–97 дә ТР Язучылар берлегендә әдәби консультант. М. балаларга атап язган «Әйт, Кояшым!» (1966) һәм өлкәннәр өчен «Эзләр» (1967) исемле беренче шигырь җыентыклары б-н үк татар поэзиясендә тормыш күренешләрен үзенә генә хас образлы фикерләү һәм форма чаралары ярдәмендә гәүдәләндерергә тырышучы, масштаблылыкка, ассоциатив фикер һәм хис бердәмлегенә омтылучы, метафораларга бай, ирекле ритмикага корылган шигырьләр остасы буларак мәйданга чыга. «Күперләр» (1969), «Алкын су» (1971), «Күз карасы» (1974) җыентыкларына кергән шигырьләргә үзара сөйләшү интонациясе, фән һәм техника дөньясы образларын актив куллану хас. 1980 еллардан М. иҗаты тагын да тирәнрәк һәм фәлсәфирәк була бара. «Иртәгә» (1975), «Ике авыл арасы» (1979) поэмаларында шагыйрь илләр, халыклар, милләтләрне борчыган дөньякүләм проблемалар турында уйлана. «Нәкъ унбиш ел үткәч» (1972), «Уздылар» (1972), «Борчулы минутларда» (1975) кебек шигырьләрендә сагышлы уй-хисләр, лирик кичерешләр динамикасын ачып бирү омтылышы өстенлек ала. М. балалар өчен күп иҗат итә: «Ә сәгать келт-келт итә» (1968), «Төнге әкият» (1973), «Бәхетле исем» (1977), «Галстуклы кәҗә» (1992), «Эх, Самара яклары» (1998), «Өч үрдәк» (2013) җыентыклары. Драматургия өлкәсендә дә күп эшли. Аның «Урман улы — Зурмөгез» (Мәскәү үзәк курчак театрында «Длиннорогий — сын ле-

са» исемендә сәхнәләштерелә, 1978), «Сихерләнгән урман» («Заколдованный лес» исемендә шул ук театрда, 1979), «Шүрәлеләр үч алмый» (Чаллы татар драма театры, 1982) әкият-пьесалары буенча спектакльләр куела. «Кайда сез, ирләр?» (Татар акад. театры, 1982), «Өченче бүлмәдә эт яши» (Әлмәт татар драма театры, 1983), «Кунак кызы гел килмәс» (шул ук театрда, 1985), «Кире уйларга соң инде» (Татар драма һәм комедия театры, 1987) пьесаларында әхлак, мәхәббәт, тәрбия, гаилә проблемалары күтәрелә. Соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре күбрәк милләт язмышына багышлана: «Татар түбәтәе» (1992–2000) шигырьләр циклы, «Дәрт чүлмәге» (2003), «Кем кулларына калдырыйм» (2007) җыентыклары. ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге (1997) һәм ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2005).

Ә с ә р.: Тау астында илле бүре: Пьесалар. К., 1990; Зелёный сон. М., 1978; Жемчуг на ладони. Стихи. Уфа, 1995; Сайланма әсәрләр. 4 томда. К., 2012.

*Әд.:* Мәйдан. 2005. № 2 (махсус сан); Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009.

*Г.М. Габделхакова.*

**МИНГӘРӘ́ЕВ** Рәфкать Шаһимәрдан улы (1917–1990), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1962). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1940), «Татнефть» трестында эшли, баш инженер (1957 дән). 1963 елдан ТАССР ХХСның нефть сәнәгате идарәсе башлыгы. 1965 тән СССР нефть сәнәгате министры урынбасары. 1970 тән Бөтенсоюз нефть һәм газ чыгаруны икътисади оештыру фәнни-тикшеренү ин-ты (Мәскәү) директоры. М. җитәкчелегендә Татарстанның күп кенә нефть чыганаклары ачыла. Дәүләт бүләге нефть ятмаларын контур эченә су кудырып эшкәртүнең яңа системасын эшләгәне һәм аны Ромашкино нефть чыганагында куллануны өчен бирелә. 1959–67 дә ТАССР ЮС депутаты.

**МИНДУБА́ЕВ** Әдип Сәхип улы (17.4.1929, Спас кантоны Күлбай Мораса а. — 22.5.1998, Казан), мәдәният эшлеклесе, тарих фән. канд. (1970). Казан ун-тын (1960), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1970). 1953–54 елларда ВЛКСМның Биләр райкомында бүлек мөдире. 1954 тән Казанда: ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы (1957 гә кадәр), 1957–59 да ВЛКСМның Киров райкомы секретаре, 1959–60 та урта мәктәп директоры, 1960–63 тә КПССның Киров райкомы секретаре, 1963–68 дә КПССның шәһәр ком-тында бүлек мөдире, 1970–73 тә Совет райкомының 1 нче секретаре. 1973–76 да ТАССР мәдәният министры. 1976–85 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1985–89 да ТАССРның Нәшриятлар, полиграфия эшләре һәм китап сәүдәсе дәүләт ком-ты рәисе. 1992–94 тә Алабуга җиңел автомобильләр з-дының Казан вәкиллеге баш икътисадчысы. Хезмәтләре социализм дәверендә сәнәгый җитештерүне камилләштерүдә инженер-техник интеллигенциянең роле мәсьәләләренә карый. 1971–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МИНДУБА́ЕВ** Фәйзулла-Котдус Миндубай улы (1869-?), җәмәгать эшлеклесе. Мәдрәсәдә укый. Казан губернасының Тәтеш өязендә мулла. Казан губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906), мөселманнар фракциясе һәм «Халык азатлыгы партиясе» әгъзасы. Аннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Госманова.*

**МИНДУБА́ЕВ** Юрий Хәниф улы (7.7.1929, Үзбәкстан ССР, Фирганә ш. — 20.7.1966, Казан), ветеринар-анатом, биол. фән. д-ры (1962), проф. (1965). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли. 1959–61 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-тында а.х. бүлеге башлыгы урынбасары, 1961–63 тә ТАССР а.х. министры урынбасары, бер үк вакытта Татарстан Респ-касы а.х. тәҗрибә станциясе директоры, 1963–66 да Казан вет. ин-тының анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре йорт хайваннарының эчке органнары иннервациясен тәэмин итүче вегетатив нервларның макро- һәм микроморфологиясенә карый.

Х е з м.: Морфология симпатических стволов и некоторых их ветвей у лошади // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1957. Т. 67; Нервы сердца и лёгких домашних животных // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1961. Т. 80.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Р.И.Ситдыйков.*

**МИНДУБА́ЕВА** Фәридә Әнвәр кызы (1.12.1951, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (2000). Караганда мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шәһәр хастаханәсендә (Караганда ш.) терапевт. 1975 елдан Караганда мед. ин-тында, 1999 дан нормаль физиол. каф. мөдире. Хезмәтләре физик факторларның үзәк нерв һәм йөрәк-кан тамырлары системаларына йогынтысын өйрәнүгә, организмның хезмәт шартлары һәм экология факторларына җайлашу закончалыкларын ачыклауга карый.

**МИНЕ́ЕВ** Константин Елизарович (27.5.1912, Казан — 20.7.1987, шунда ук), Казан электрон-хисаплау машиналары з-ды директоры (1954–66). Казан ун-тын (1941), Бөтенсоюз тышкы сәүдә академиясен (1948, Мәскәү) тәмамлый. 1930–34, 1941–45 елларда Казан пр-тиеләрендә эшли. 1934–37 дә Кызыл Армия сафларында. 1945–54 тә СССР МС каршындагы Совет мөлкәте баш идарәсенең ГДРдагы вәкиле. 1966–79 да совет сәүдәсенең чит илләрдәге (Польша, Болгария) вәкиллекләре хезмәткәре, Икътисади ярдәмләшү илләре б-н хезмәттәшлек итү идарәсе эксперты (Мәскәү). М. җитәкчелегендә завод үсешенә нигез салына, төп җитештерү куәтләре булдырыла, инфратүбән ешлыктагы приборлар, илдә чыгарылучы 1 нче буын (М-20) һәм 2 нче буын (М-220, «Сетунь», «Наири», «Гранит», «Урал-11») электрон-хисаплау машиналарын, алфавитлы-санлы басу җайланмаларын җитештерү гамәлгә керелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.Ш.Бәдретдинова.*

**МИНЕРАЛЛА́Р** (лат. minera — руда), химик составы һәм физик үзенчәлекләре якынча бертөрле, үзләренә генә хас кристаллик структуралары булган табигый, ясалма һәм техноген җисемнәр. Акад. В.И.Вернадский М.га ш.у. кайбер аморф (опал, аллофан), сыек (саф терекөмеш, амальгама) һәм газсыман токымнарны да кертә. М. — тау токымнары һәм рудаларның состав өлеше. Төрле мохиттә, Җир һәм планеталарның каты һәм газсыман өслегендә һәм җир астында, тере организмнарда һәм микроорганизмнар эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ясалма М. лаборатор һәм сәнәгый шартларда алына. Составы буенча М.ның күпчелеге — нәорганик кушылмалар, әмма органиклар да бар: органик к-таларның тозлары, фосфатлар, оксалатлар, казылма тозлар h.б. Минераль төрләргә (индивидуаль табигый химик матдәләр) һәм төрле төрчәләргә (бер минераль төрнең төсле һәм морфологик вариацияләре) аерып йөртәләр. 3 меңгә якын М. билгеле, ел



Тау токымындагы минераллар.

саен 20 дән 100 гә кадәр М. ачыла. Тере организмнарда 40 ка якын М. булуы ачыкланган, ш.и. апатит һәм кальций карбонаты, алар — скелет һәм тешләр составына, опал (ак ахак) б-н бергә $CaCO_3$ болытсыманнар һәм үсемлекләрнең төп тукымаларына керә. М.ның үлчәмнәре *мм* өлешләреннән алып 10 *м* га кадәр һәм аннан озынрак күрсәткечләргә (пегматитларда сподумен кристаллары), авырлыгы берничә тоннага кадәр (кварц, кыр шпаты) җитә. М.га атама беренче табылган урыны, теге яки бу кеше хөрмәтенә, физик үзлекләренең характеры һәм химик составы буенча бирелә.

Татарстан терр-ясендә барлык класслардагы М. булуы ачыкланган: саф элементлар — бакыр, күкерт, алтын, көмеш, платиналы металлар; инерт газлар; оксидлар — кварц, *лимонит*, гётит (к. *Минераль буяулар*), ак ахак h.б.; сульфидлар — пирит-марказит, халькопирит h.б.; карбонатлар — *кальцит, доломит, сидерит* h.б.; сульфатлар — ангидрит, *гипс, целестин* h.б.; галоид кушылмалар — *аш тозы*; фосфатлар — *фосфоритлар*; силикатлар — плагиоклазлар, слюдалар (биолит, *глауконит*, мусковит), каолинит (*балчык*), *цеолитлар* h.б. Төрле төстәге: шәмәхә (аметист), зәңгәр (*азурит*), индиго-зәңгәр (*ковеллин*), яшел (*малахит*), көрән (лимонит), сары-җизсыман (халькопирит); төрле катылыктагы —

гипстан (2) кварцка (7) һәм алмазга (10) кадәр М. табылган. ТР терр-ясендә утырма, магматик, метаморфик, өске һәм тирәндәге М. очрый. Барлык билгеле М.ның 15% ка якыны абразив һәм антиабразив, кыйммәтле һәм ясалма ташлар һ.б. сыйфатында металлар һәм химик элементлар алу өчен кулланыла. Ш.у. к. *Минералогия.*

*Әд.:* Прогноз нефтегазоносности фундамента молодых и древних платформ. К., 2001.

**МИНЕРАЛЛА́Р ФИ́ЗИКАСЫ**, минералогиядә фәнни юнәлеш, минералларның (ш.и. ясалма) һәм тау токымнарының үзлекләрен физик алымнар б-н өйрәнә. Каты җисемнәр физикасы (С.А.*Альтшулер*) һәм Җир турындагы фәннәр (минералогия һәм геохимия, В.М.*Винокуров*) кушылганда, 1960 елларда Казан ун-тында барлыкка килә. Е.К.*Завойскийның электрон парамагнит резонансы* ачышы (1944) М.ф.ның формалашуында төп рольне уйный. Күп кенә минералларның барлыкка килү һәм үзгәреш процесслары аларның электрон төзелеше нечкәлекләренә бәйле булуы б-н билгеләнә, фаза күчешләре өлкәсендә матдәләрнең хемосорбцияләре һәм аномаль реакция сәләтләре ачыла. Тау токымнарының төп коллектор үзенчәлекләрен билгеләүнең экспресс ысулы; зәркән ташларын затлыландыру ысулы эшләнә. Нефть-газлылыкның геотермик критерийлары, күзәнәкле мохиттә авыр нефть һәм битумнарның молекуляр халәте үзенчәлекләре, тау токымнарының һәм катлам суларының җылылык үзенчәлекләре һ.б. билгеләнә.

**МИНЕРАЛО́ГИЯ** (*минерал* һәм *...логия*), минераллар, аларның килеп чыгышы, составы, төзелеше, үзлекләре, төр үзгәрешләре һәм гамәли кулланылышы турындагы фән. Минералларны тикшерү вакытында химия, кристаллография, физика һәм геол. мәгълүматлары кулланыла. Россиядә минераллар турында беренче мәгълүматлар 1798 елда В.М.Севергин тарафыннан басыла. Татарстанда минералларны тикшерү Казан ун-ты ачылганнан соң башлана: 1806 дан проф. К.Ф.*Фукс* студентлар б-н Казан тирәсенә экскурсияләр үткәрә, Уралга экспедицияләр оештыра, табигыять тарихы кабинеты өчен минераллар җыя, кабинет 1826 да минерал. кабинеты, соңыннан ун-тның *Геология музее* итеп үзгәртелә. 1840 та М. һәм геогнозия каф. (мөдире П.И.*Вагнер*) оештырыла, 1865 тән минералларны микроскопик һәм химик ысуллар б-н тикшерүләр М. кафедрасында үткәрелә (аны Ф.Ф.*Розен* җитәкли). Ул альбитның оптик үзлекләре аның химик составына бәйлелеген билгели, корунд буенча слюда (пыялаташ) псевдоморфозасын ачыклый һ.б. 19 йөз ахыры һәм 20 йөз башында Идел һәм Кама буеның — утырма, Урта Урал һәм Себернең — магматик (А.М.Зайцев һәм А.В.Лаврский), Вятка һәм Казан губерналарының — фосфорит һәм волконскоит (П.И.Кротов), Казан тирәсенең целестин (П.Л.Драверт) токымнары; Идел, Урал буе һәм Уралның (Б.П.Кротов) барлык токымнары М.се өйрәнелә. 1920–30 елларда доломит барлыкка килү теориясе эшләнә, галит, флюрит, Уралдагы тимер рудасы чыганаклары минералларының үзенчәлекләре ачыклана (Б.П.Кротов). 1930 да Казан ун-тының М. кафедрасын Идел буенда минерал. тикшеренүләрне башлап җибәрүче Л.М.Миропольский җитәкли. В.А.Полянин, В.А.Тимесков һ.б. б-н берлектә Идел буе (башлыча, Пермь), Урал утырмаларында минералларның бүленеш закончалыклары, Урал һәм Себернең тимер рудалары һәм бокситларның минераль составы билгеләнә, аларны өйрәнүнең яңа алымнары эшләнә. Акад. А.Е.Ферсман Миропольскийны СССР ФАнең өлкән минералогы итеп билгеләргә тәкъдим итә.

1960 елларның уртасыннан Татарстанда М.дә яңа фәнни юнәлеш — *минераллар физикасы* үсеш ала, минералларны (ш.и. ясалма) тикшерүнең яңа алымнары — радиоспектроскопия, рентгенография, термография, люминесценция, электрон оптик спектроскопия (В.М.Винокуров, И.Н.Пеньков, А.И.Бахтин, Г.Р.Булка, Г.А.Кринари, В.В.Власов, В.Ф.Крутиков, Е.Н.Шляпкина һ.б.) киң кулланыла. Күп кенә минераллар өчен рентген типлаштыруы үткәрелә, детальләрнең электрон төзелеше б-н барлыкка килү һәм үзгәреш процесслары арасындагы бәйлелек ачыклана, күчеш фазалары өлкәсендә матдәнең аномаль релаксация мөмкинлеге һәм хемосорбция күренеше ачыла һ.б. Мёссбауэр эффектын куллану (Ш.Ш.Башкиров, В.Г.Изотов һ.б.) төрле минералларның кристаллохимик типоморфизмын урнаштыруга китерә. Нефть һ.б. файдалы казылмаларны эзләү эшләренең киңәюе б-н ТРда токымнарның, нефть коллекторлары, фосфорит, цеолит һ.б.ның минераль составы һәм физик үзлекләре киң өйрәнелә башлый. 20 йөз ахырында Татарстанда (Казан ун-ты, ЦНИИгеолнеруд) технол. М. шактый үсеш ала. Чернобыль АЭС авариясе нәтиҗәләрен бетерүдә катнашкан ЦНИИгеолнеруд галимнәре В.А.Копейкин, У.Г.Дистанов, И.А.Зәйнуллин һ.б. тарафыннан радионуклидлар күчешен булдырмауга булышлык итүче минераллар (бентонитлар, палыгорскит һ.б.) табыла.

*Әд.:* Винокуров В.М., Бахтин А.И. История кафедры минералогии и петрографии Казанского университета. К., 2005.

*В.М.Винокуров, В.А.Тимесков, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**МИНЕРА́ЛЬ АШЛАМАЛА́Р**, минераль туклар, нәорганик матдәләр, башлыча үсемлекләр туклануы өчен кирәкле матдәләре булган тозлар. А.х. культураларының уңдырышлылыгын һәм а.х. продукциясенең сыйфатын күтәрүдә нәтиҗәле чара. Уңышның гомуми артымының яртысы ашламалар б-н тәэмин ителә. ТР шартларында 1 *кг* азот-фосфор-калийлы М.а. кулланганда, өстәмә уртача 4,4 *кг* бөртекле ашлык, 21,5 *кг* бәрәңге, 20 *кг* шикәр чөгендере һәм 38 *кг* яшелчә уңышы алына.

М.а. туфрак аша тәэсир итүче ашламаларга яисә химик мелиорантларга (известьле, гипслы) — туклыклы матдәләрне туфракның үзеннән туплау юлы б-н үсемлекләрнең туклануын читтән яхшыртучыларга (к. *Туфракны известьләү, Гипс*) һәм үсемлекләр туклануына уңай йогынты ясый торган, турыдан-туры тәэсир итүче ашламаларга бүленә. Соңгыларын гади (бер компонентлы), бер туклыклы элементы булган ашламаларга: *азотлы ашламалар* (аммиаклы, натрий һәм кальций селитралары, аммоний сульфаты, мочевина һ.б.), *фосфорлы ашламалар* (суперфосфат, фосфорит оны, преципитат һ.б.), *калийлы ашламалар* (калий хлориды, калий тозы, калий сульфаты һ.б.) һәм 2 яисә күбрәк туклыклы матдәләре булган *комплекслы* (икеләтелгән, өчләтелгән) *ашламаларга* (нитрофос, аммофос, нитрофоска, азофоска, нитроаммофоска, нитроаммофосфат, диаммофоска һ.б.га) бүләләр. Комплекслы ашламалар катлаулы һәм катлаулы-катнаш (кушма һәм катнаш) ашламаларга аерыла. Кушма ашламалар — берничә химик кушылманың завод шартларында эшләнә торган катнашмасы: гранулллы ашлама, һәр грануласында ике яисә күбрәк туклыклы матдә була; сыек ашлама, ике яисә күбрәк матдә эремәләре катнашмасы. Катнаш ашламаларны, кагыйдә буларак, а.х. пр-тиеләрендә төрле каты ашламаларны механик юл б-н катнаштырып алалар. М.а.га ш.у. составында микроэлементлар булган (B, Mo, Mn, Cu, Zn, G һ.б.) *микроашламалар* да керә. Каты (порошок сыман һәм гранулллы) һәм сыек ашламалар җитештерелә. Туфрак тирәлеге реакциясенә тәэсир итүенә карап, физиол. әче (тоз катионнары туфрак эремәсен әчетә торган анионнарга караганда яхшырак сеңә), физиол. селтеле (анионнар үсемлекләр тарафыннан үзләштерелә, катионнар туфракта туплана һәм аны селтеләндерә), физиол. нейтраль (туфрак реакциясен үзгәртмиләр) ашламаларга аерылалар. М.а. (органик ашламалар кебек үк) чәчү әйләнешендә аерым билгеләнгән система буенча кулланыла (к. *Ашламалар системасы*). М.а.ның нәтиҗәлелеге аларны органик ашламалар б-н бергә керткәндә, үсемлекләр ихтыяҗын, туфрак һәм ашлама үзенчәлекләрен исәпкә алып, оптималь микъдарда кулланганда шактый арта. М.а.ны дөрес кулланмау (артык микъдарда, начар эшкәрткәндә һәм үз вакытында кертелмәгәндә) уңышның, туфрак уңдырышлылыгы һәм продукция сыйфатының түбәнәюенә; авыруларга, үсемлекләр һәм терлекләр үлеменә, елга һәм сулыкларның пычрануына китерә.

Татарстанда 1 *га* чәчү мәйданына 1 *кг* тәэсир итүче матдә исәбеннән кертелгән М.а.: 1996 да — 94, 1997 дә — 105, 1998 дә — 74, 1999 да — 55, 2000 һәм 2005 тә — 76; 2011 — 60; ш.и. азотлы ашламалар — 41,9, фосфорлы — 13,5, калийлы — 13,6. Респ-ка а.х. пр-тиеләре кулланган М.а.ның гомуми күләмендә аммиак селитрасы («Менделеевсказот» ҖЧҖ җитештерә, Менделеев ш.), азофоска, аммиак суы, хлорлы калий, калий сульфаты, нитроаммофоска күпчелек урынны алып тора. Ш.у.к. *Ашламалар, Авыл хуҗалыгын химияләштерү.*

*М.Ю.Гыйләҗев, И.Н.Афанасьев.*

**МИНЕРА́ЛЬ БУЯУЛА́Р**, минераль пигментлар, башлыча, лак-буяу материаллары алу һәм төзелеш әйберләрен буяу өчен кулланылучы табигый пигментлар (куе сары (охра), сары кызыл (сары сурик), кызыл (мумия), киноварь, акбур, азурит һ.б.). РФ-

дә 70 кә якын чыганак билгеле, аларның балчыксыл һәм тимер оксиды тибындагылары зур әһәмияткә ия. Россиядә 20 йөз ахырында елына 150–160 мең *т* чимал чыгарылучы 10–12 чыганак эшкәртелә. Татарстан терр-ясендә М.б. алырга яраклы 50 дән артык чыганак (2002) һәм ятма булуы билгеле: тимер оксиды тибындагы сурик, мумия, охра (Лаеш, Алабуга, Актаныш һ.б. р-ннарда), балчыклы (Казан тирәсендә, Тәтеш р-нында һ.б. урыннарда), карбонатлы (Лаеш, Алабуга, Тукай һ.б. р-ннарда), сульфатлы (Кама Тамагы гипс чыганагы). Аеруча тимер оксиды пигментлары гамәли әһәмияткә ия, алар хәзерге Татарстан терр-ясендә 18 йөзнең 2 нче яртысыннан ук биналар буяу, тире иләү, тукыма ману өчен киң кулланылган. Җирле ихтыяҗлар өчен сазлык тимер рудалары Буа, Чирмешән, Әгерҗе һ.б. р-ннарда табыла. 20 йөзнең 2 нче яртысында ТРның 11 районында 20 дән артык чыганак һәм перспективалы тимер оксидының 40 ка якын пигментлы чагылмалары ачыклана, алар исә дүртенчел система (голоценлы) яшендәге сазлыклы-торфлы утырмаларда киң таралган. М.б.ның $C_1$ һәм $C_2$ категорияле запаслары һәм $P_1$ категорияле ресурслары түбәндәге чыганакларда билгеләнгән: Иске Кормаш (Актаныш р-ны) — 24,6 һәм 11,2 мең *т*, Бурцевск (Тәтеш р-ны) — 6,7 һәм 5,8 мең *т*, Яковлево (Алабуга) — 3,4 һәм 1,8 мең *т*. Тимер оксидының пигментлы 24 чыганагы запасы һәм 21 сәнәгати-перспективалы чагылманың фаразланган ресурслары 85–90 мең *т* тәшкил итә.

Чыганаклар геоморфологик локальләшү шартлары буенча түбәндәге төркемнәргә бүленә: тугай, терраса (Берёзовка, Яковлево һ.б.); сыза, ерым (Бикләң, Калинино һ.б.); елга үзәннәренең авыш сөзәклекләре (Городище, Иләксаз һ.б.). Объектларның мәйданы 0,5–0,6 дан 8–13 мең *м*² га кадәр, руда җисемнәренең калынлыгы 0,07–1,2 *м* (уртача 0,15–0,2 *м*). Чыганаклар 0,03–0,05 тән 1,2–1,5 *м* га кадәр (күбесенчә 0,1–0,3 *м*) калынлыктагы туфрак катламы һәм аллювиаль комсыл балчык астында яталар. Чимал коңгырт сары, кызгылт сары, кызыл, көрән һәм коңгырт көрән төстәге, буяу нәтиҗәсе яхшы булган, порошоксыман көпшәк массадан тора. Рудаларның минераль составы: тимер гидрооксиды (20–30 дан 80–90% ка кадәр), балчыклы (5–10 нан 40–50% ка кадәр), карбонатлы (1–5 тән 40% ка кадәр) һәм органик (5–10 нан 40–45% ка кадәр) матдәләр. Тимер оксиды 12 дән 81,3% ка кадәр тәшкил итә. Еш кына гётитка кристаллашкан аморф гидрогётит пигмент хасил итүче булып тора. Термик эшкәртүдән соң, сазлык рудалары пигмент сыйфатында куллануга яраклы. Яндыру нәтиҗәсендә ГОСТка һәм техник шартларга туры килүче көрән, кызыл һәм кара төстәге пигментлар алалар. ТРда елына 1,8–2 мең *т* тимер оксиды пигментларын җитештерә торган пигмент з-ды төзелә.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых РТ: В 3 т. К., 1999–2001.

*И.В.Дьячков.*

**МИНЕРА́ЛЬ СУЛА́Р**, составында кайбер биол. актив матдәләр ($CO_2$, $H_2S$, Fe, Br, J, сирәк кенә Ra, Fe, Li, As, B һ.б.) күп булган, гомуми минеральләшүе 1 *г/л* дан артык, гадәттә, югары темп-ралы һәм газлы җир асты һәм сирәк кенә җир өсте сулары. М.с.га ш.у. термаль (энергетика максатларында кулланылучы) һәм J, Br, B һ.б. элементлар алына торган табигый сәнәгать сулары керә. Темп-ра (°С) буенча — салкын (20 гә кадәр), җылы (20–37), термаль (37–42) һәм кайнарга (42 дән артык); минеральләшү буенча (*г/л*) — тозлырак (10 га кадәр), тозлы (10–35), тозлаклар (35 тән артык); химик составы буенча — хлоридлы, гидрокарбонатлы, сульфатлы һ.б.; медицина тәэсире буенча — эчәргә яраклы һәм сәламәтләндерү (эчәргә яраклы һәм тышкы кулланылыш өчен); урнашуы буенча — Альп җыерчыклыгы өлкәсендә, вулканик районнарда, интрузияләр б-н тишелгән башка кристаллик токымнарда; геол. тектоник-шартлар буенча — платформалы, геосинклиналь һәм арадаш типларга бүләләр. М.с. чыгынакларын пычранудан саклау максатларында санитар саклау зоналары билгеләнә. СССР терр-ясендә М.с.ның 3,5 меңнән артык чыганагы билгеле була. Татарстанда зур ресурслы М.с. өч төркемдә билгеләнгән: сульфат гидрокарбонатлы һәм хлоридлы; сульфидлы; бром хлоридлы һәм кальций-натрийлы тозлаклар. Сульфатлы М.с. 4 асгруппага бүленә: минеральләшү 5 *г/л* га кадәр булган сульфатлы — «Васильево» (Яшел Үзән р-ны), «Ливадия» (Казан) шифаханәләре, «Зәңгәр күл» (Биектау р-ны) чыганагы; минеральләшүе 2 *г/л* га кадәр гидрокарбонат-сульфатлы һәм сульфат-гидрокарбонатлы; хлорид-сульфатлы һәм сульфат-хлоридлы — «Ижминводы» курорты (Менделеев р-ны; «Шифалы су», «Тазалык» М.с.ы), «Иволга» шифаханә-профилакторие (Баулы р-ны), «Жемчужина», «Чаллы» шифаханәләре (Чаллы ш.; «Яр Чаллы» суы), «Ромашкино» (Зәй р-ны); гидрокарбонат һәм хлорид-гидрокарбонатлы. Сульфидлы М.с. («Мацеста» тибындагы) «Бәкер» шифаханәсендә (Лениногорск р-ны) кулланыла; алар $H_2S$, Br һәм B б-н баетылган. 3 нче группа М.с. ТРның бөтен терр-ясендә таралган.

*М.Е.Королёв, С.И.Поляков.*

**МИНЕРА́ЛЬ ТЕРЛЕ́К АЗЫКЛАРЫ́**, минераллар составы буенча терлек рационнарын балансл ау өчен өстәмә азык сыйфатында кулланылучы табигый һәм ясалма продуктлар. Үсемлек продуктларының күп өлешендә натрий һәм хлор җитешми, шуның өчен а.х. терлекләрен аш тозы б-н өстәмә тукландыралар. Татарстан туфраклары һәм шул сәбәпле терлек азыгы да кальций, фосфор һ.б. *микроэлементларга* ярлы, шуңа күрә азыкка акбур, известьташ, сапропель, сөяк оны, агач көле һәм күмер, гипс, азык фосфатлары, магний карбонаты, глаубер тозы, тимер, бакыр, марганец һ.б. М.т.а. өстиләр. Респ-када известьташның 30–37% ын кальций тәшкил иткән 10 нан артык чыганак бар. Карбонатлы агроминералларда (кальцит, доломит, магнезит) кальций 48% ка җитә, аларда шулай ук магний, селенит, тимер, күкерт һ.б. микроэлементлар бар. Кальцийлы һәм фосфорлы-кальцийлы өстәмә азык сыйфатында: карбонатлы сапропельләр, алар составында 47% кальций, 5 әр % тимер һәм селен, 2–3 әр % фосфор һәм күкерт, агач көле (22% ка кадәр кальций һәм күп кенә микроэлементлар); сөяк оны (24,5% кальций, 11,8 % фосфор, 0,2 шәр % калий һәм натрий); преципитат (30% ка кадәр кальций һәм 15 % фосфор); зарарсызландырылган кабырчыклар һәм йомырка кабыгы (35–37 % ка кадәр кальций) һ.б. кулланыла.

М.т.а. — *катнаш азыкта* булырга тиешле компонент, аларны концентратлар, силос, вакланган тамыразыклар б-н катнаштыралар. Тозлы катнашмалар, брикет-ялагычлар һәм таблеткалар формасында әзерләнәләр. Татарстанда өстәмә азыкны (витаминлы-минераль премикслар, ферментлар, катнаш азык, аксымлы-витаминлы минераль өстәмәләр) һәм вет. препаратларын (даруларны) фәнни яктан өйрәнү, эшләп чыгару, сынау һәм терлекчелектә гамәлгә кертү ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгының Өстәмә азык фәнни-тикшеренү үзәге дәүләт унитар пр-тиесе тарафыннан башкарыла, ул мөгезле эре терлек, ат, дуңгыз, сарык, кәҗә һәм кошлар өчен витаминлы-минераль премикс ларның 25 тән артык төрен җитештерә. Аларның составы Татарстан терр-ясендә терлекчелектә кулланыла торган азыкта М.т.а. һәм витаминнарның җитешмәвен исәпкә алып эшләнә. Тулыландыргыч сыйфатында табигый сорбентлар — цеолит, бетонит, глауконит, карбонатлар, торф файдаланыла. Бу — премиксларның технол. характеристикасын яхшырта һәм аларны 30 дан артык биогенлы макро- һәм микроэлемент б-н баета, шулай ук терлек организмыннан агулы продуктларны, пестицид калдыкларын, хлорорганик кушылмаларны, авыр металларны чыгаруга булыша, бу, үз чиратында, экол. чиста продукт алуга ярдәм итә.

Витаминлы-минераль премикслар җитештерү күләме (*т*): 2001 дә — 80, 2002 дә — 250, 2003 тә — 400, 2011 дә — 200.

*Әд.:* С о л н ц е в К.М. Производство и использование премиксов. Л., 1980; Корма Республики Татарстан. К., 1999; Цеолитсодержащие породы Татарстана и их применение. К., 2001; Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

*И.Н.Афанасьев, Ә.Х.Җаббаров.*

**МИНЕРА́ЛЬ ТӨЗЕЛЕ́Ш МАТЕРИАЛЛАРЫ́**, сәнәгать һәм гражданлык төзелешендә һәм төзелеш материаллары җитештерүдә кулланылучы тау токымнары һәм минераллар, ш.у. ясалма материаллар һәм техноген калдыклар. М.т.м. арасында карбонат токымнары — төзелеш ташы, вакланган таш, известь һәм известьле мелиорантлар җитештерү, цемент сәнәгатендә һ.б. кулланылучы *известьташлар, доломитлар, акбур, известьле туф*; балчыклы — керамик кирпеч, керамзит, санитар-техник әйберләр, керамика, плитә, чирәп, дренаж торбалары һ.б. җитештерү өчен *комсыл балчык* һәм бетонит, утка чыдам, форма ясау, *кирпеч сугу балчыклары*; а.х., цемент җитештерү һ.б. өчен *мергель; ком-вак*

*чуерташ кушылмасы*, төзелеш эшләре өчен җиңелчә цементлашкан ком һәм *комташ* (бетон кушылмалары, төзелеш ташы буларак комташларның каты калдыклары); пыяла һәм металл кою тармаклары өчен бут, кварц комнары (к. *Пыяла комы*); төзелеш эшләре, цемент сәнәгате өчен *гипс*; тышлау ташы һәм ясалма таш буларак *мәрмәр оникс*; беркеткеч М.т.м.на, ашламаларга, сәнәгать агынты суларын, газларны чистартуга һ.б. актив минераль кушылмалар алу өчен цеолитлы токымнар (к. *Цеолитлар*); автомобиль юллары төзелеше һәм ремонты өчен битумлы токымнар, карбонатлылар һәм комташлар (к. *Битумнар*) һ.б. аерыла. Табигый хәлдә кулланылучы М.т.м.: ком һәм вак чуерташ кушылмасы, бут ташы, ком, балчык, комташлар; сәнәгый эшкәртүдән соң: фракцияләшкән вак чуерташ, баетылган ком һәм вак чуерташ кушылмасы, фракцияләшкән һәм вакланган ком, алебастр, керамзит һ.б. 2007 елның 1 гыйнварына ТРда файдалы каты казылмаларның 1000 гә якын чыганагы исәпләнә, ш.и. фаразланган һәм ачыкланган запаслары (440 млн. *м*³) б-н карбонат токымнарының 350 гә якын чыганагы; 260 тан артык кирпеч-чирәп балчыклары (530 млн. *м*³), ш.и. РФнең барлык запасының 15% ка якынын тәшкил итүче бентонит балчыклары запасы; 150 дән артык ком һәм вак чуерташ материаллары (42 нче чыганакның балансында), ш.и. ком һәм вак чуерташ запаслары 300 млн. *м*³ дан артык, төзелеш комнары — 60 *м*³ ка якын; гипсның 2 зур чыганагы (100 млн. *т* дан артык), 1 — мәрмәр оникс (1200 млн. *т* га якын), 3 — цеолитлы токымнар (140 млн. *т* дан артык). Татарстан төзелеш комнары, ком һәм вак чуерташ кушылмасы, түбән һәм уртача маркалы вакланган таш җитештерү өчен карбонат токымнары, известьле мелиорантлар, кирпеч-чирәп балчыклары, бентонит, гипс, битум токымнары, вак-төяк әйберләр ясауга китүче таш (оникс) б-н тәэмин ителгән. Респ-када ком-вак чуерташ катнашмасы, вак чуерташ (чикләнгән күләмдә), гипс һәм гипс ташы, бентонит балчыклары, битум, силикат кирпеч чыгарыла. Югары маркалы вакланган таш, цемент, акбур, төзелеш известе, пыяла һәм форма комы, утка чыдам һәм тышлау кирпече, тышлау плитәсе, төзелеш һәм тышлау ташы респ-кага кертелә.

*Әд.:* Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых РТ. К., 1999. Ч. 1.

*Г.Н.Бирюлёв, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**МИНЕРА́ЛЬ ТӨЗЕЛЕ́Ш ЧИМАЛЫ́**, к. *Минераль төзелеш материаллары.*

**МИНЗАРИ́ПОВ** Нигъмәтҗан (1909, Казан губ. Яңа Дума а. — ?), бораулаучы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1947). 1936–63 елларда Төньяк Урал боксит руднигында эшли: төзүче, төрле эштә эшләүче, руда төяүче, бораулаучы, катлам казучы, катлам казучылар бригадиры (1943 тән). М. тау рудасын эшкәртүнең тизләтелгән алымнарын эшли һәм гамәлгә кертә. Катнаш белгечлекләрне үзләштерү, эш режимын үзгәртү, 4 циклы графикка күчүне, хезмәт җитештерүчәнлеген артыруны тәкъдим итә. Дәүләт бүләге казу эшләренә тизләтелгән алымнар керткәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Североуральск шәһәренең бер урамы М. исеме б-н атала (Свердловск өлкәсе).

Х е з м.: На бокситных рудниках. Свердловск, 1947; Идите к нам, на шахту. Свердловск, 1961.

*Әд.:* Металлурги Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001.

**МИНЗАРИ́ПОВ** Рияз Гатаулла улы (25.9.1951, Әлки р-ны Түбән Әлморза а.), социолог, филос. фән. канд. (1985), социол. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук ВЛКСМ ком-ты секретаре урынбасары, секретаре булып эшли. 1981 елдан журналистика һәм социология ф-тында, бер үк вакытта, 1994 тән, ун-тның укыту бүлеге башлыгы урынбасары, 1995–99 дан — укыту бүлеге башлыгы, 2001–03 — тә Казан ун-тының 200 еллыгына әзерлек буенча оештыру ком-ты рәисе урынбасары. 2003 тән — проректор. Хезмәтләре социаль ин-т буларак мәгариф проблемалары, пед. һәм тәрбия мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Концептуальные основы воспитательного процесса в условиях гуманитарной среды классического университета. К., 2005; Воспитание в российских университетах: Исторический опыт и перспективы: На примере Казанского университета. К., 2006.

**МИНЗӘЛӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 123 *км*, бассейнының мәйданы 2120 *км*². Елга башы Сарман р-ны Яңа Минзәләбаш авылыннан 3 *км* көнбатыштарак. Элек тамагы Минзәлә шәһәре янында була, хәзер елганың түбән агымы Түбән Кама сусаклагычы сулары астында калган һәм киң култыкка әйләнгән. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданы асимметрияле, төньяк-көнбатышка таба авыш калкулыклы тигезлектән тора. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Үзәне киң, уңъяк сөзәклекләр текәрәк. Елга юлы бормалы, киңлеге 15–20 *м*, тирәнлеге 0,5–1 *м* (плёсларда — 2 *м* га кадәр), түбәнге агымында тагын да бормалы. Тугае ике яклы, түбән агымында элекке елга юлында сакланып калган күлләр күп. М.нең 34 кушылдыгы бар, алар арасында иң зурлары: Салкынсу (14,3 *км*), Камышлы (14,6 *км*), Игәнә (50,7 *км*), Ургыды (31 *км*), Ашбула (13,2 *км*) - сул; Саклаусу (15 *км*), Вязовка (6,9 *км*), Маҗын (10,2 *км*) уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км*/*км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–3 *л*/*с*·*км*². Елга режимын күзәтүләр Сарман авылы янындагы гидрологик постта алып барыла (1948–87). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу вакытында су катламы 78 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана һәм уртача 27 көн дәвам итә. Елга өсте тигезлегенең уртача еллык тирбәнешләре 2,7 *м*. М. ноябрь уртасында туңа. Кыш ахырында бозның калынлыгы 82 *см* га җитә. Суының иң аз вакытындагы уртача күпъеллык чыгымы Сарман авылы янында 0,23 *м*³/*с*, тамагында — 1,83 *м*³/*с*. Иң зур чыгымы 215 *м*³/*с* (1969). Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийле типта, урта агымының аерым урыннарында гидрокарбонат-хлорид-натрийлы, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–1000 *мг/л*. М. бассейнында суының гомуми күләме 23,4 млн. *м*³ булган 25 буа бар. Елга ТРның табигать истәлеге (1978). Аның бассейнында «Сөлек урманы» табигать истәлеге урнашкан.



Минзәлә елгасы Минзәлә р-ны Наратлы Кичү авылы янында.

*О.Н.Урбанова.*

**МИНЗӘЛӘ́**, район карамагындагы шәһәр, Минзәлә р-ны үзәге. ТРның көнчыгышында (Казаннан 292 *км*), Әгерҗе–Акбаш тимер юлындагы Круглое Поле станциясеннән 65 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасының Камага кушылган урынында урнашкан. Мәйданы — 7,4 *км*². Халкы — 16476 кеше (2010), 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50,9%, руслар — 45,2%. Аракы-шәраб, икмәк з-длары, төзү материаллары комб-ты. Пед. көллияте, мед. уч-щесе, а.х. техникумы, һөнәр уч-щесе, татар гимназиясе һәм прогимназия, 3 урта мәктәп. Татар драма театры, төбәк тарихы музее һәм *Җәлил Муса мемориаль музее*, Балалар сәнгать мәктәбе, спорт мәктәбе. 3 китапханә (ш.и. 1 — балалар өчен). Район хастаханәсе, шифаханә. 2 православие храмы, мәчет эшли. Татар һәм рус телләрендә «Минзәлә»–«Мензеля» район г-тасы нәшер ителә.

1584–86 да Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чоры авыллары урынында рус кальгасы буларак нигез салына. Иң беренче булып стрелецлар килеп урнаша. 17 йөз уртасында кальга шактый зурая, *Кама аръягы иске чик сызыгы* иң зур кальга булып китә. 1655 тә Смоленск шляхталарыннан гаиләләре б-н кучерелгән 124 кеше исәбенә гарнизон зурая. Геогр. торышы үзенчәлекле булу сәбәпле, М. еш кына *башкорт-татар кузгалышлары* үзәгендә була, хөкүмәт гаскәрләренең туплану урынына әйләнә. *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)* чорында баш күтәрүчеләр берничә тапкыр һөҗүм итә, ләкин М. бирешми. 1781 нең 23 октябрендә Уфа наместниклыгының, 1796 дан — Оренбург, 1865 тән Уфа губерналарында (к. *Минзәлә өязе*) өяз шәһәре статусын ала. Халкы сәүдә, игенчелек һ.б. б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә 6 чиркәү, Покров хатын-кызлар монастыре, түбән кат-

лау аграр мәктәбе (1891 дән), кызлар прогимназиясе, 4 сыйныфлы шәһәр һәм приход уч-щесе, монастырь каршындагы кыз балалар мәктәбе, 60 урынлы земство хастаханәсе, земство аптекасы, китапханә; сыра-бал ясау, спирт чистарту, патока, шырпы һәм кирпеч з-длары була. Шәһәрдә 3 ярминкә эшли, шуларның берсе — Рождественский ярминкәсе (26 дек. — 11 гыйн.) Уфа губернасыннан читтә дә билгеле. 1893 тә 4264628 сумлык товар китерелә, 3282496 сумлык сатыла. Оештырылган көннән (1920, ТАССР) М. — Минзәлә кантоны, 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-ны үзәге. М.дә 15 кә якын 19 йөз — 20 йөз башы сәнәгать, дини һәм гражданлык архит-расы истәлекләре саклана, алар арасында җамигъ мәчет (1910), *Никола соборы* (1813), тимер юл күпере (20 йөз башы) бар. Шагыйрь М.Җәлил һәм Сов.Союзы Маршалы В.И.*Чуйковның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге шәһәр б-н бәйле. Халык саны: 1782 дә — 1111, 1795 тә — 2211, 1816 да — 3235, 1848 дә — 4151, 1870 тә — 4940, 1897 дә — 7539, 1916 да — 8204, 1920 дә — 8780, 1926 да 7642 кеше, 1938 дә — 10,9 мең, 1958 дә — 11,8 мең, 1970 тә — 15,9 мең, 1979 да — 17,4 мең, 1989 да — 15,5 мең, 2002 дә 16,7 мең кеше.

*Әд.:* Сабиров Р.М. По городам Татарии. К., 1976; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.





**«МИНЗӘЛӘ́»**, чия сорты. 1945 елда Тәмте җиләк-җимеш станциясендә А.М.Тверитинов, А.С.Вологдина, Г.И.Розанова тарафыннан чыгарыла. «Владимирская» һәм «Поздняя розовая» сортларының гибриды. Бу сорт югары уңыш бирә, корылыкка һәм салкынга чыдам. Кимчелеге — коккомикоз б-н көчле зарарлана. Куагы уртача биеклектә, киң таралып торган ябалдашлы. Ботаклары озын, нәзек, салынкы. Җимешне, башлыча, алдагы елгы үсентеләре бирә. Үрентеләре нәзек, аксыл-көрән төстә, дугасыман бөгелгән. Яфраклары вак яисә уртача зурлыкта, аз гына ялтыравыклы, озынча түгәрәк. Яфрак читләре ике ягы каяулы. Чәчәкләре уртача зурлыкта, ак, бик күп чәчәк ата. Җимешләре уртача зурлыкта (3,2 *г*), түгәрәк, алсу-кызыл төстә, ялтырап тора. Җимеш йомшагы аксыл-алсу төстә, сусыл, әчкелтем-баллы. Төше эре. Июль ахырында өлгерә. Югары уңыш бирә — 1 куактан 25–30 *кг*. Нигездә җирле сортларның чәчкеннәренә бөре ялгау ысулы б-н үрчетәләр. Җимешләре яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. Татарстанда 1956 дан районлаштырылган, 1970 елларда республикадагы барлык чия утыртмаларының өчтән бер өлешен тәшкил итә.

*Л.Н.Севастьянова.*

**МИНЗӘЛӘ́ АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТЕ́ХНИКУМЫ**, РФ А.-х. һәм азык-төлек министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1891 елда Минзәлә өяз земствосының а.х. мәктәбе буларак ачыла, 1910 нан Игенчелек һәм дәүләт милке министрлыгының а.х. уч-щесе (урта махсус уку йорты), 1919 да совхоз-техникум итеп үзгәртелә, 1921 дән зоотехникум, 1935 тән яңадан совхоз-техникум, 1991 дән хәзерге исемдә. 2001 гә кадәр 8 мең *га* файдалану җирләре, а.х. машиналары паркы, шактый санда терлекләре булган зур, күп профильле а.х. пр-тиесе була; хәзерге вакытта — уку йорты (тәҗрибә кырлары, фермалары,



Минзәлә шәһәре. 1. Үзәк урам; 2. Гимназия бинасы. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 3. Гомуми күренеше.



Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумы. Төп бина. 20 йөз башы.

остаханәләре, умарталыклары бар). 30 меңнән артык белгеч әзерләнә. Укыту агрономия, зоотехния, ветеринария, умартачылык, а.х.да икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, электр җайланмаларын монтажлау һәм файдалануга тапшыру, хокук белгечлекләре буенча алып барыла. 2006 да көндезге бүлектә — 710, читтән торып уку бүлегендә 1051 студент, шуларның 566 сы түләүле нигездә укый. Пед. коллективта 48 кеше эшли, ш.и. ТРның атказ. мәктәп укытучысы — 1, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре — 1 кеше. 1979 дан Әлмәт шәһәрендә филиалы эшли, анда 5 меңнән артык белгеч әзерләнә; 2006 да читтән торып уку бүлегендә (агрономия, зоотехния, бухгалтерлык исәбе) якынча 200 кеше укый.

**МИНЗӘЛӘ́ КАНТОНЫ́**, 1920–30 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Уфа губернасы *Минзәлә өязе* җирлегендә оеша. 1922 дә М.к.ннан *Чаллы кантоны* аерылып чыгарыла. Мәйданы 5621 *км*². Халкы 167116 кеше, шулардан 74,6% татарлар, 23,4% руслар, 1,9% марилар (1926). Шәһәр халкы — 7545 кеше, авыл халкы — 159571 кеше. Халкының урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 29,7 кеше, авыл җирендә — 28,4 кеше. М.к. 356 торак пунктны эченә алган 9 волостьны берләштерә: Актаныш, Әмәкәй, Байсар, Күзкәй, Минзәлә, Мөслим, Яңа Мажын, Пучы, Семиостров волостьлары. 171 мәктәп эшли. Сәнәгать тармагын тире, мех, металл һәм агач эшкәртү, азык-төлек җитештерү пр-тиеләре тәшкил итә. 1926 да 2 мең кеше һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 36114 крәстиян хуҗалыгы (1928), 49 авыл хуҗалыгы кооперативы (1925) исәптә тора. 1928 елда чәчүлек җирләр (*га*) — 288841, ш.и. арыш — 85398, солы — 36233, борай — 19030, карабодай — 9950, тары — 9819, бодай — 1221, бәрәңге — 893, техник культуралар — 2276. Барлык төр терлекләрнең баш саны — 353107, ш.и. мөгезле эре терлек — 86305, ат — 44380, сарык — 205873. ТАССРны районнарга бүлгәндә, М.к. җирлегендә Актаныш, Минзәлә, Мөслим районнары барлыкка килә.

*Әд.:* Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике. К.,

1928–29. Вып. 1–5; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МИНЗӘЛӘ́ МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1936 елда шәфкать туташлары мәктәбе буларак оештырыла, 1939 дан фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1954 тән хәзерге исемдә. Эшләү елларында 3 меңнән артык белгеч әзерләнә. 2012 дә дәвалау эше, шәфкать туташлары белгечлекләре укытыла (269 студент); пед. коллективта барлыгы — 41, 16 штатлы укытучы, 4 табиб (ш.и. 1 ТРның атказ. табибе) эшли.

**МИНЗӘЛӘ́ МӨСЕЛМАННАРЫНЫ́Ң ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, 1915 елның декабрендә оештырыла. Гамәлгә куючылары — Ш.Корбангалин, А.А.Латыйпов, А.Мөхәррәмов, Б.Хәсәнов. Төп максаты — мөселман мәгариф һәм мәдәният оешмаларына, мохтаҗ диндәшләргә матди ярдәм күрсәтү. Минзәлә шәһәре һәм Минзәлә өязе халкына хезмәт итә. 1917 дән соң эшчәнлеге туктатыла.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**МИНЗӘЛӘ́ ӨЯЗЕ́**, 1781–96 елларда Уфа наместниклыгы, 1796–1864 тә Оренбург, 1865–1920 дә Уфа губерналары составында. Үзәге — Минзәлә елгасы буена урнашкан Минзәлә шәһәре (1584–86 елларда *Кама аръягы иске чик сызыгында* ныгытма буларак төзелә). 1708 елда Казанга кушып теркәлә, 1719 да Уфа провинциясенә кертелә (Уфа провинциясе, 1728 дә Казан губернасыннан чыгарылып, Сенат карамагына тапшырыла). Оренбург губернасы оештырылганнан соң (1744), Минзәлә һәм аның тирә-ягы Оренбург губернаторы карамагына күчә, һәртөрле җыем-салым мәсьәләләре буенча Казан губернаторына буйсына. 1781 дә Минзәлә өяз шәһәре статусы ала һәм тирә-як төбәкләре б-н бергә Уфа наместниклыгының Уфа өлкәсенә кертелә, 1796 дан Оренбург губернасы составына алына, 1865 тән Уфа губернасының өяз шәһәре. М.ө. губернаның төньяк-көнбатыш өлешендә урнаша. Ул төньяк-көнбатышта Вятка губернасының Мамадыш һәм Алабуга өязләре, төньякта Вятка губернасының Сарапул өязе, көнчыгышта Уфа губернасының Бөре, көньяк-көнчыгышта Бәләбәй өязләре, көньяк һәм көньяк-көнбатышта Самара губернасының Бөгелмә, көнбатышта Казан губернасының Чистай өязе б-н чикләшә. Мәйданы ягыннан Уфа губернасының 6 өязеннән иң кечкенәсе була: 11329,53 кв. чакрым, яки 1174019,82 дис. Халкы 380 мең кеше; милли яктан һәм катлаулар нисбәтендә: руслар, украиннар, белоруслар — 32,6%, асабалар, татарлар, мишәрләр һәм типтәрләр — 64,5%, мордвалар, марилар, чуашлар — 2,8% (1897). М.ө.нең чикләре төньякта Кама, төньяк-көнчыгышта Агыйдел елгалары буйлап сузыла. Өяз терр-ясе Каманың сул кушылдыклары: Агыйдел бассейнының Сөн (кушылдыклары Карамалы, Сикияз, Калмыя, Сикия, Сарашлы, Терпеле б-н) һәм Шәбез (кушылдыклары Олы һәм Кече Шәбез б-н) елгалары, Ык бассейнының Мәллә, Минзәлә, Игәнә, Вәрәш, Мөшеге, Ташъелга, Камышлы, Табын, Бәҗәнә елгалары, Чишмә




бассейнының Кичү елгасы, Дала Зәе бассейнының Урман Зәе, Сәрәпәле, Зичә, Сәвәләй, Борды, Аулаш, Ерыклы, Баграж һ.б. елгалары, ш.у. Тиргәвеш, Уратма, Мәләкәс, Бикләнь, Бәтке, Туйма һ.б. елгалар б-н юыла. 1798–1865 тә өяз кантон системасы аша идарә ителә: ул 11 нче кантонга кертелә, 11 йорт яки командадан тора. 1802 дә командалар саны 16 га җитә (Сарапул һәм Алабуга өязләренең кайбер өлешләре кушыла), 1834 тә — 25 команда. 1870–94 тә М.ө. — 5, соңрак 6 станга бүленә. 1886 га кадәр — 32, соңрак 31 волостьны берләштерә (1887 дә Казанчы яки Ногайбәк волосте Бәләбәй өязенә күчә), 1906–07 дә — 30 волость. 1890 еллар уртасында 1 нче станга (үзәге — Пучы һәм Матвеевка авыллары) Актаныш (1887 гә кадәр — Илеш), Әмәкәй, Байсар, Пучы, Семиостров, Шәрип (20 йөз башыннан Такталачык дип атала башлый) волостьлары; 2 нче станга (үзәге — Александровка, Карамалы авыллары) Александр-Карамалы, Богодаровка (элек 5 нче станда), Иректе, Яңа Спас, Иске Кәшер волостьлары; 3 нче станга (үзәге — Зәй шәһәр яны бистәсе) Акташ (элек 2 нче станда), Ерсубай, Зәй, Тәкмәк, Троицк-Йосып волостьлары; 4 нче станга (үзәге — Чаллы авылы) Афанас, Бәтке, Макарьевский, (элек 5 нче станда), Яр Чаллы, Сухарево (элек 3 нче станда) волостьлары; 5 нче станга (үзәге — Кузкәй, Хуҗамәт авыллары) Әлмәтмулла (элек 2 нче станда), Әхмәт (элек 4 нче станда), Бишенде-Останково, Нөркәй (элек 2 нче станда), Язикәү (элек 4 нче станда) волость-



лары; 6 нчы станга (үзәге Иске Мәҗын авылы) Балтай (1896 дан — Яңа Шуган; элек 5 нче станда) Күзкәй (элек 5 нче станда), Матвеевка (элек 1 нче станда), Иске Мәҗын (1896 дан — Минзәлә; элек 5 нче станда), Иске Мәлкән (элек 1 нче станда) волостьлары керә. М.ө. халкы иген игү, мал-туар һәм кош-корт асрау, яшелчә үстерү, умартачылык, балык тоту б-н көн күрә; туку, ману, чыпта сугу, киез һәм итек басу, сарык тиресе эшкәртү, аяк киеме тегү, мунчала төшерү, мич чыгару, арба-тарантас, җиһаз, савыт-саба ясау, йон язу кебек һөнәрчелек төрләре б-н шөгыльләнә, бурлаклар, вак-төяк сатучылар, сату эшендә арадашлык итүчеләр, йөк ташучылар да була. Май язу, прәннек, патока, шәраб ясау, аракы куу, терлек мае эретү, шәм, сабын, балавыз ясау, тире эшкәртү, ш.у. киҗе-мамык, постау, селитра, поташ, дегет, кирпеч, ширпы, бакыр һәм чуен кою, тимер эретү, пыяла з-длары эшли; М.ө. тегермәннәр саны буенча губернада беренче урын тота: 356 су, 111 җил тегермәне була. 1910 елга өяздә һәм шәһәрдә 211 бер сыйныфлы, 4 ике сыйныфлы башлангыч уч-ще, 1 дүрт сыйныфлы, 2 урта һәм 2 махсус уку йорты, 411 татар мәктәбе исәпләнә. Автономияле респ-калар төзегәндә өяз ТАССР составына кертелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 4. № 2218; Т. 5. № 3380; Т. 8. № 5248, 5316; Т. 12. № 8901; Т. 21. № 15307; Т. 24. № 17634, 17702; Т. 28. № 21404; Списки населённых мест Российской империи ... по сведениям 1870. Т. 45. Уфимская губерния. СПб., 1877; Сборник статистических сведений по Уфимской губернии. Т. 3. Мензелинский уезд. Уфа, 1899; Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. Т. 45. Уфимская губерния. СПб., 1901. Тетр. 1; 1904. Тетр. 2; Материалы по истории Башкирской АССР. М.–Л., 1949. Т. 3.

*Әд.:* Памятная книжка Уфимской губернии на 1891 год. Уфа, 1891; Кустарные промыслы Уфимской губернии. Уфа, 1912; Обухов М.И. Мектебы Уфимской губернии: Статистический очерк татарских и башкирских школ (мектебов) Уфимской губернии по данным исследования Уфимской губернской земской управы 1912–1913 года. Уфа, 1915; Белокопытов В.И., Остроумов Я.Ф., Сафин М.М. Мензелинская быль: Ист.-док. очерк. К., 1970.

*Д.Г.Мостафина.*

**МИНЗӘЛӘ́ ПЕДАГО́ГИЯ КӨЛЛИЯТЕ́**, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1932 елның сентябрендә пед. техникумы буларак ачыла, 1945 тән пед. уч-ще, 1995 тән хәзерге исемдә. Эшләү елларында Татарстанның көнчыгыш районнарындагы башлангыч һәм урта уку йортлары өчен 10 меңнән артык белгеч әзерләнә. Тәмамлаучылар арасында язучылар Г.Х.Зәйнашева, Р.Гәрәй, М.Г.Маликова, җырчы А.Ә.Вәлиев, халык мәгарифе эшлеклесе В.Г.Гайфуллин бар. Белгечлекләр: башлангыч сыйныфларда укыту, татар теле һәм әдәбияты, чит телләр, технология, информатика; көндезге бүлектә 664, читтән торып уку бүлегендә (2004 тә оештырыла) 171 студент укый. Пед. коллективта 60 кеше эшли, ш.и. фәннәр кандидатлары — 2, ТРның атказ. мәктәп укытучысы — 3. М.п.к. элеккеге реаль уч-ще (1914; архит-ра истәлеге) бинасын били. 1941 дә анда М.Җәлил укыган хәрби-сәяси уч-ще урнашкан була.

**МИНЗӘЛӘ́ РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Төньяк-көнчыгыш Кама буе икътисади р-ны на керә. Мәйданы — 1919,7 *км*². 19 авыл җирлеген (җирле үзидарә советын), 70 торак пунктын берләштерә. Үзәге — *Минзәлә* шәһәре. 2012 елда 29,2 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 62,1%, руслар — 33,6%, марилар — 2,7%) яши. Шәһәр халкы — 16,6 мең, авылларда 12,6 мең кеше яши. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 15,2 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла, 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязенә, 1920–30 елларда ТАССРның Минзәлә кантонына керә. Оештырылган көненнән М.р.да 1 шәһәр һәм 64 авыл советы, 126 торак пункт исәпләнә, аларда 73944 кеше (ш.и. татарлар — 41522, руслар — 31494, башка халыклар 928 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә М.р.ның бер өлеше яңа оештырылган *Калинин районына* бирелә. 1940 та районның мәйданы — 1886 *км*², халык саны — 57,6 мең кеше, 1 посёлок советы, 37 авыл советы, 103 торак пункт була. 1944 нең 19 февралендә М.р.ның берничә авыл советы Матвеевка р-нына күчерелә (1954 нең 19 ноябрендә кире кайтарыла). 1960 та район 2146 *км*² җир били, аңа 1 посёлок һәм 20 авыл советы, 122 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә М.р.на Актаныш р-ны һәм Мөслим р-ның бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 4314 *км*², халык саны — 108 мең кеше, 2 посёлок советы, 50 авыл советы, 251 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, 1965 нең 12 гыйнварыннан район биләмәсе 2295 *км*² га кала, халык саны — 57,3 мең кеше, 25 авыл советы, 126 торак пункт була. 1984 нең 4 июнендә Боерган, Калмыя, Күзкәй, Сәмәкәй, Иске Абдул авыл советлары Тукай р-нына тапшырылганнан соң, М.р.ның чикләре башка үзгәрми.

Районның рельефы — иңкү, сөзәк тигезлек (биеклеге 80–160 *м*). Кама (Түбән Кама сусаклагычы) һәм аның кушылдыклары Ык, *Минзәлә* елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, типик һәм көлсуланган кара, соры урман туфраклы. Терр-ясенең 12,7%ы — урманлык. Нефть, ташкүмер һәм көрән күмер, торф, балчык, чуерташ ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: Ык, Минзәлә елгалары, *Игим наратлыгы*, *Кама-Ык аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә археол. истәлекләр табыла. М.р. — нигездә, а.х. р-ны. Мөгезле эре терлек, сарык асрау алга киткән. А.х. җирләре 97,7 мең *га* били, ш.и. 85,2 мең *га* сөрүлек җир (2010). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, тары, карабодай, борчак игелә. 2010 да М.р.да 10 а.х. пр-тиесе исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре Минзәлә шәһәрендә тупланган; Хуҗамәт авылында ремонт-механика з-ды эшли. Урман хуҗалыгы. М.р. җиреннән Казан–Уфа автомобиль юлы уза. 25 гомуми белем бирү мәктәбе, кадетлар




мәктәбе, коррекция интернат-мәктәбе, мәктәптән тыш эшләр үзәге, педагогия көллияте, а.х. техникумы, мед. уч-щесе, һөнәр уч-щесе, 312 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 49 клуб, 31 китапханә, 2 хастаханә эшли. Татар һәм рус телләрендә «Минзәлә» — «Мензеля» район г-тасы нәшер ителә.

**МИНЗӘЛӘ́ ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ**, Сабир Өметбаев исем. 1935 елда 1 нче Чистай районара колхоз-совхоз театрыннан үзгәртеп корыла, 1922 дән бирле эшләп килгән һәвәскәр коллектив җирлегендә ТАССР Мәгариф халык комис-ты карары б-н 1934 нең 15 октябрендә оеша. Директоры — С.Г.Өметбаев, администраторы — Ю.С.Фарсин. Труппада 16 кеше (Х.Сәлимова, Г.Шәрифҗанов, М.Зәйнуллин, Г.Мөхәммәдиев, Ф.Юнысов, Г.Фәхретдинова, К.Халәпов, Н.Гыйззәтуллина, Г.Казанский, И.Максутов, Н.Яһүдин, Р.Терегулова, Г.Ибраһимов һ.б.) була. Беренче спектакль — «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) — 1935 нең 30 июнендә куела. Репертуарда ш.у. М.Фәйзинең «Галиябану», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», К.Әмиринең «Кара тай», Ш.Камалның «Томан арты», «Козгыннар оясында» пьесалары һәм концерт программасы да була. 1936 да труппа, яңа актёрлар (Р.Шакирова, Г.Калинин, М.Кичүбаев, Г.Сәетова, Х.Шонкаров, Р.Токанаева, М.Рафиков, Г.Бикмуллин һ.б.) б-н тулыланып, Минзәлә шәһәренә күчеп килә. Театрда классик әсәрләр буенча спектакльләр куела: «Банкрот», «Бүләк өчен», «Каениш», «Уйнаш» (Г.Камал); «Гаепсездән гаеплеләр», «Бирнәсез кыз», «Кичеккән мә-



Минзәлә татар драма театры.

хәббәт» («Без вины виноватые», «Бесприданница», «Поздняя любовь»; А.Н.Островский); «Мещаннар» («Мещане», «Васса Железнова» (М.Горький); «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь», И.Ф.Шиллер). Тормышчан дөреслеге, көнкүрештәгечә тәгәллеге, характерларның эчке бөтенлеге б-н аерылып торган спектакльләре б-н 1939 да Мәскәүдә уздырылган 1 нче Бөтенсоюз колхоз-совхоз театрлары фестивалендә катнашып, театр призлы урын яулый һәм 1 нче дәрәҗә диплом б-н бүләкләнә. Бөек Ватан сугышы елларында да эшчәнлеген туктатмый. Коллективтан 34 ир армиягә алына (12 се яу кырында һәлак була), ирләр ролен Х.Сәлимова, Н.Гыйззәтуллина, Р.Шакирова, Н.Гайнетдинова, Г.Юнысова, С.Досаева, З.Сәлимова кебек актрисалар башкара. Сугыштан соңгы елларда труппага Ә.Авзалов, Г.Әхмәтов, Г.Вәлиева, Н.Маннурова, Ш.Сабиров, Р.Мәрдиханов, М.Нигъмәтҗанова һ.б. актёрлар килә. Театр еш кына шул чор авторларының әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Ул чорда аеруча игътибар үзәгендә булган спектакльләр: «Бишек җыры» (Д.Аппакова), «Рәйхан» (Н.Исәнбәт), «Акчарлаклар» (Ә.Фәйзи), «Идел буенда», «Туган авылым» (Г.Насрый), «Йолдызлар балкый» (С.Кальметов), «Мөнирә», «Вәгъдә» (Г.Сәгыйдуллин), «Язылмаган законнар», «Гөлчәчәк» (Ю.Әминев), «Профессор кияве» (Ш.Хөсәенов) һ.б. Фронттан кайткан С.Г.*Өметбаев* театрның сәнгать җитәкчесе итеп билгеләнә. Ул талантлы актёрлар һәм режиссёрлар тәрбияләүгә, аларның проф. осталыкларын үстерүгә зур игътибар бирә. 1957 дә театр (ТАССР шәһәр театрлары арасында бердәнбер) Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты





Минзәлә татар драма театры: 1. Х.Хамматуллин һәм Э.Гәрәева Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» спектакленнән күренештә; 2. Г.Баһаветдиновның «Соңгы бөркет» спектакленнән күренеш (Суфия ролендә – Ф.Зәйнетдинова).



Минзәлә татар драма театры.
Труппа театр бинасы каршында. 2006.

һәм сәнгате декадасында катнаша; аның тарафыннан башкала сәхнәсендә күрсәтелгән спектакльләр (М.Фәйзинең «Галиябану» һәм Ю.Әминевнең «Язылмаган законнар» пьесалары буенча) театр тәнкыйтьчеләренең югары бәясенә лаек була. Күп кенә актёрларга мактаулы исемнәр бирелә, хөкүмәт бүләкләре тапшырыла, театр дәүләт статусы ала. Декадада катнашу театр тормышына зур үзгәрешләр алып килә. Спектакльләрне сәхнәгә кую өчен С.Булатов, К.Тумашева, Х.Сәлимҗанов, П.Исәнбәт кебек танылган режиссёрларны чакыра башлыйлар. Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС) тәмамлаган реж. М.Мостафин да уңышлы гына эшли. 1960–70 тә театр труппасында Р.Әхмәров, И.Фәхретдинов, Т.Хәлиуллин, Г.Галләмов, Ф.Бәдриев, И.Саттарова, А.Фәттахова, А.Богатырёв, М.Нурмөхәммәтова, Ф.Зәйнетдинова, Р.Юзикеев, С.Әхмәтшәрипова, ш.у. Казан театр уч-щесен, Алабуга мәдәният уч-щесен, Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тын тәмамлаучылар эшли. Спектакльләрне бизәү б-н К.Камалетдинов, А.Садыйков, И.Мифтахов, А.Яһүдин һ.б. рәссамнар шөгыльләнә. Репертуарда төп урынны шул чор татар драматургиясе әсәрләре алып тора. Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, С.Шәкүров, Г.Насрый, Х.Вахит, Г.Зәйнашева, Ю.Әминев, Г.Сәгыйдуллин, Т.Миңнуллин, Ш.Зәйни, А.Гыйләҗев, Ә.Баян, Г.Ахунов, И.Юзеев, Ә.Гаффар, Р.Батулла, Р.Кәрами, Ф.Бәйрәмова, Ю.Сафиуллин пьесалары буенча куелган спектакльләр коллектив иҗатының сәнгати юнәлешен билгели. З.Шаһиморатның «Хәят», С.Шәкүровның «Уракчы кыз», М.Кәримнең «Айгөл иле», Ә.Баянның «Һәйкәл», Г.Сабитовның «Ураган», А.Д.Салынскийның «Мария», Н.П.Анкиловның «Мин — солдат хатыны» (барысын да сәхнәгә куючы М.Мостафин), Р.Батулланың «Каерылмасын канатың», Г.Хугаевның «Андро һәм Сандро», Ю.Сафиуллинның «Пар канат», Г.Ахуновның «Икәүдән-икәү», Ф.Бәйрәмованың «Һәркемгә бер кояш», Ә.Гаффарның «Бер картлыкта — бер яшьлектә» (барысын да сәхнәгә куючы Л.Садриев), К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», А.Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», И.Юзеевнең «Сөйгәнемнең туган көне» (барысын да сәхнәгә куючы Ф.Ибраһимов) пьесалары буенча куелган спектакльләр республиканың мәдәни тормышында зур вакыйга булып тора. 1985–90 елларда, театрның сәнгать җитәкчесе итеп Ф.Ибраһимов билгеләнгәч, театрның эстетикасы үзгәрә башлый. Тормыш-көнкүрештәге натуралистик тәгәллектән читкәрәк китеп, ул чынбарлыкны матуррак итеп күрсәтергә, тормыш күренешләрен яктыртуда фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтыла. Спектакльләрдә демонстратив шартлылык, жанр ачыклыгы, актёр уенының күптөрлелеге, сәхнә бизәлешендә метафорик алымнар күренә башлый. Спектакльләрен респ-каның а.х. районнарында күрсәтүенә карамастан, театр сезонның шактый өлешен шәһәрдә эшләп уздыра, шул рәвешчә Минзәлә мәдәни тормышының аерылгысыз бер өлешен тәшкил итә; Мәскәү, Петербург, Уфа, Пермь, Әстерхан, Оренбург, Ижевск, Ульянов, Төмән, Ташкент һ.б. шәһәрләргә гастрольләр б-н бара. 1990–2009 да театрда Л.Садриев, Р.Әюпов, Б.Бәдриев кебек режиссёрлар эшли; 2009 дан театрның баш режиссёры — Д.Сәмерханов. Репертуарын халык ихтирамын яулаган «Сихерче» (Н.Гыйматдинова), «Кызлар нигә елый» (Ф.Бүләков), «Яратылыш» (М.Гыйләҗев), «Өзелгән йөзем» (Д.Салихов), «Мөһаҗирләр» (М.Галәү), «Яр» (Б.Сәлахов), «Гашыйклар кәмите» (Р.Батулла), «Мулла» (Т.Миңнуллин), «Акча? Акча... Акча!» («Пять миллионов долларов», Л.Ворон), «Күзләреңнән үбеп» (Р.Харис), «Ташкын» (Т.Җүҗәноглы), «Остазбикә» һәм «Сөннәтче бабай» (Г.Исхакый) һ.б. спектакльләр тәшкил итә; соңгы икесе өчен 2006 да театр М.Җәлил исем. Респ-ка бүләгенә лаек була. 2007 дә Мәскәүдә уздырылган Россиянең кече шәһәрләрендәге театрлар смотрында М.т.д.т. призлы урын яулый. Г.Исхакыйның әдәби мирасын актив рәвештә пропагандалаган өчен, 2011 дә театр ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләгенә лаек була. Театр труппасында ТРның халык артистлары Р.Муллин, Р.Муллина, В.Нигъмәтуллина, Х.Хамматуллин, ТРның атказ. артистлары И.Насыйбуллин, Г.Сәлахова, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәрләре Ә.Теряева, Н.Хөсәенов, әйдәп баручы актёрлар Э.Гәрәева, Р.Галиуллина, Г.Хисмәтуллина, актёрлар Ә.Исрафилов, Р.Әхмәтҗанов, Э. Әхмәтханова, Р.Бәдретдинов һ.б. эшли.

Театрның директоры — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре Р.Шәймәрданов (1992 дән).

*Әд.:* Шәкүров С. Минзәлә театры // Совет әдәбияты. 1956. № 11; Татар совет театры. К., 1975; Гыйманова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт театры. К., 2007; Золотарёв Е. Золотое двадцатилетие. К., 1989.

*Д.Ә.Гыйманова.*

**МИНЗӘЛӘ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕ́Е**, Минзәлә шәһәрендә, ТР Милли музее ф-лы. 1994 елда ачыла. 19 йөз ахыры истәлеге — элеккеге сәүдәгәр йорты бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 180 *м*$^2$, коллекцияләр 10 меңгә якын саклау берәмлеген тәшкил итә. Өч залдан гыйбарәт экспозиция төбәк табигатен, шәһәр һәм төбәк тарихын чагылдыра. Археол. бүлегендә Ананьино, Буралы курган, Пьянобор культураларына караган табылдыклар (кораллар, бизәнү һәм көнкүреш әйберләре) урнаштырылган. Кыйммәтле коллекцияләр арасында б.э.к.





1. Минзәлә шәһәрендә төбәк тарихы музее; 2. «Минзәлә ярминкәсе» экспозициясе фрагменты.

6–5 йөзләргә нисбәтле биметалл сөңге, б.э.к. 6 йөз — б.э. 16 йөзгә караган кистәннәр коллекциясе бар. Табигыять бүлеге күргәзмәсенә палеонтологик табылдыклар (мамонт сөякләре, кыргый үгез мөгезе һ.б.), төбәкнең хайваннар һәм үсемлекләр дөньясы үрнәкләре, Уралның кыйммәтле ярымасылташлары коллекциясе һ.б. куелган. Этнография бүлегендә 19 йөз уртасында — 20 йөз башында төбәктә яшәгән татар, рус, мари халыкларының кием-салымнары һәм көнкүреш әйберләре үрнәкләре күрсәтелә.

Тарих бүлегендә шәһәрнең төзелә башлаган вакытыннан алып бүгенгесенә кадәрге тарихы чагылдырыла. Күргәзмәдә Кама аръягы иске чик сызыгындагы ахыргы пункт булган Минзәлә кальгасы төшерелгән макет куелган. «Ярминкә һәм сәүдәгәрләр» бүлегендәге экспозициядә 19 йөз ахыры сәүдәгәр йорты интерьер комплексы фрагментлары торгызылган, ш.у. документаль материаллар (вексельләр, банк документлары, Минзәлә ярминкәсенә килгән сәүдәгәрләр исемлеге һ.б.), товар үрнәкләре (тукылган әйберләр, савыт-саба, Иран, Кытай, Төркиядән китерелгән әйберләр) бар. «Минзәлә бөек тетрәнүләр чорында» дип аталган бүлек 1905–07 еллардагы рев-ция вакыйгаларына, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышына, 1920 елгы *«Сәнәкчеләр» фетнәсенә* (документлар, фотосурәтләр, сугыш кораллары һ.б. әйберләр) багышлана. Экспозициянең махсус бүлеге *Минзәлә татар драма театры* тарихын яктырта.

Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — 18 йөз ядкәре, иске славян телендәге агач тышлы кульязма китап; гарәп телендә 1911 дә басылган кануннар белеме китабы; 19 йөз ахырына караган ядкәр, сәүдәгәр *Стахеевларның* кабинет кәнәфие; Минзәлә кешесе В.П.Павловка маршал Г.К.Жуков тапшырган портсигар; В.И.Аксёновның маркетри һәм төбәктә яшәүче рәссамнарның рәсем коллекцияләре. Архив һәм фәнни китапханә бар. Ел саен Ачык ишекләр көне (18 май), бүләкләр кабул итү (10 июнь), Белем көне (1 сентябрь), Минзәлә ярминкәсе көннәре (1–10 дек.) уздырыла.

**МИНЗӘЛӘ́ УРМАНЧЫЛЫГЫ́**, Минзәлә, Актаныш, Мөслим һәм Тукай р-ннары терр-ясендә урманнарны файдалану, саклау, ышыклау һәм яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1935 елда Минзәлә урман хуҗалыгы буларак оештырыла. 1945 тә, ш.у. 1935 тә оештырылган Мөслим урман хуҗалыгы б-н берләшә. 2007 дән — М.у. Урманчылыкның гомуми мәйданы 70941 *га*. 6 урманчылык: Юртау (9463 *га*), Минзәлә (13507 *га*), Актаныш (16278 *га*), Калинин (9975 *га*), Мөслим (9691 *га*), Усы (12027 *га*) участогыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан 62792 *га*, ш.и. ылыслы токымнар — 12122 *га*, каты яфраклылар — 8832 *га*, йомшак яфраклылар — 38098 *га*, куаклыклар 2053 *га* тәшкил итә. Яшь урманнар — 26%, урта яшьтәгеләр — 28%, өлгереп килүчеләре — 18%, өлгергәннәре — 28% урман мәйданын били. Урман культураларын җитештерү үрнәге буларак, М.у.ның югары җитештерүчәнлеккә ия нарат утыртмалары урман культуралары истәлеге булып тора һәм аеруча саклanулы табигать терр-яләре (*Игим наратлыгы, Наратасты урманы*) буларак билгеләнә. 1918–2012 еллар эчендә урманчылыкта нарат утыртмалары 19640 *га* мәйданда булдырыла. 2012 дә урман торгызу эшләре 138 *га* мәйданда алып барыла, текә сөзәклекләрдә 47 *га* мәйданда урман утырту эшләре үткәрелә. Гомуми мәйданы 26,1 *га* булган 3 урман питомнигында елына 1 млн. данәгә кадәр үстерелгән утырту материалы торак пунктларны яшелләндерү һәм төзекләндерү, урман утырту өчен кулланыла. Урман хуҗалыгын үстерүдә респ-каның атказ. урманчылары В.М.Кульков (1961–77 дә урман хуҗалыгы директоры), Ә.Г.Гаянов (1961–71 дә урман хуҗалыгының баш урманчысы), Ә.В.Гущин (1986–98 дә урман хуҗалыгы директоры), М.Ш.Гыйлаев (1963–2003 тә Актаныш урманчылыгы урманчысы), М.М.Минһаҗев (2001 дән урман хуҗалыгы директоры, 2007–10 да бүленеп), Р.И.Гарифуллин (Усы урманчылыгы урманчысы) һ.б. зур өлеш керттеләр.

*М.М.Минһаҗев.*

**МИНЗӘЛӘ́ ЯРМИНКӘСЕ́**, Россиядә иң эреләрдән санала. Уфа губернасының Минзәлә шәһәрендә уздырыла. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына, әмма әлгәрәк тә эшләгәндер дип фаразлана. Рус сәяхәтчесе Н.П.Рычков сурәтләгәнчә, М.я. иркен мәйданга урнашкан була, анда агачтан күп кенә кибетләр төзелә. Җәйге ярминкә («Җәйге Илья ярминкәсе») — 3–5 августта, көзге ярминкә — 3–17 октябрьдә, кышкы ярминкә («Кышкы Раштуа ярминкәсе») 26 декабрь — 11 гыйнварда (1906 елдан — 28 декабрь — 9 гыйнварда, совет хакимияте елларында — 7–21 гыйнварда) үткәрелә. Җәйге ярминкәдә вак һөнәрчелек товарлары: тәгәрмәчләр, мичкәләр, савыт-саба, йорт кирәк-яраклары, бал, балавыз, умартачылык кирәк-ярагы һ.б.; көзге ярминкәдә ш.у. һөнәрчелек эшләнмәләре, киез итек (Кукмара авылыннан), күн аяк киеме (Сарапул шәһәреннән), мех, төрле чимал (кышкы ярминкәдәгедән кимрәк күләмдә) һ.б. б-н сату итәләр. Кышкы ярминкә товар әйләнешенең зуррак, ассортиментның киңрәк, сәүдәгәрләрнең күбрәк булуы б-н аерылып тора. Төп товарлар: мех, чимал, ат (1883–84 тә 1405, 1888–89 да 1200 баш ат китерелә). М.я.ндә чәй, шикәр, балык, кием-салым, тукыма, агач материаллары, буяу б-н дә сату итәләр. 1868 елда ярминкәнең товар әйләнеше 3 млн. сум була. 1879–80 дә ярминкәгә 12,2 млн. сумлык товар китерелә, 10,2 млн. сумлык сатыла; 1880–81 дә бу саннар нисбәтә 13,6 млн. сум һәм 10,2 млн. сум тәшкил итә. 1855 тә М.я.нә сәүдә эшләре б-н — 1900, 1860 елда 2200 дән артык кеше килә. Сәүдә Мытный дворда (сатучыдан йолым алу урыны), Ат һәм Балык рәтләрендә, Гостиный дворда (анда сәүдә, күңел ачу, терлек-туар ябу урыннары була) алып барыла. Себер һәм Самара-Златоуст тимер юллары ачылу М.я.нең әһәмиятен киметә. 1913 тә аның товар әйләнеше 1,6 млн. сум тәшкил итә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында ярминкәгә товар китерү кискен кими. 1920 елларга М.я. әһәмиятен тәмам югалта.

*Әд.:* Ярмарки: К истории ярмарок вообще и к статистике ярмарок в Уфимской губернии. Уфа, 1884; Фридлянд Л.О. Экономика торговли Мензелинского кантона ТССР // Тр. Об-ва изучения Татарстана. 1930. Т. 22.

*Ю.Й.Йосыпов.*

**МИНЗӘЛӘВИ́** Габдеррәфигъ бине Габделгаффар (18 йөз ахыры, Уфа губ., Минзәлә өязе Яхшыбай а. — 19 йөз башы), шагыйрь. Уфа губернасының Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укый. 19 йөзнең 1 нче яртысы мөселман тормышын яктырткан, дидактик эчтәлекле «Ихванларә васыять» («Кардәшләргә васыять», 1843) исемле кульязма поэма авторы.

*М.В.Гайнетдинов.*

**МИНЗӘЛӘВИ́** Кәшшафетдин Шаһимәрдан улы (1864, Уфа губ., Минзәлә өязе Сөлек а. — 1920 елдан соң), шагыйрь, мөгаллим. Татар һәм казакъ телләрендә яза. Сөлек мәдрәсәсендә һәм Шыгай авылы «Мәрҗания» мәдрәсәсендә (1883–92) белем ала. 1892 дән Каркаралы шәһәре (хәзер Казакъстан Респ-касы) мәчетендә мулла һәм мөдәррис вазифаларын башкара. 19 йөз ахырында яза башлый. Дастаннар, фольклор һәм әдәби сюжетларга ияреп язган мажаралар, шигъри кыйссалар авторы (барысы 100 ләп әсәр, башка мәгълүматларга караганда, 80 тирәсе). Аеруча танылган әсәрләре: «Кыйссаи хәким», «Кыйссаи Әбелхарис», «Кыйссаи кимпер», «Кыйссаи Бәдәр» һ.б. М. иҗатында яшь буынны тәрбияләүдәге әхлакый һәм рухи мәсьәләләр, дини һәм дөньяви белем бирү, дини-этик проблемалар чагылыш таба. Акын булып танылa: казакъ телендә Шәрекъ әдәбиятында танылган сюжетларга нигезләнгән дастаннар башкара. Идел, Урал буе, Казакъстанда яшәүче төрки-татар халкында популярлык казана. Утыз Имәни шигырьләрен җыеп, «Китабе



В.Е. Минкина.

мөһиммәт әз-заман» (1898) исемле җыентык бастыра.

*Әд.:* Гарифуллин Д. Якташыбыз — казах акыны // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1995. Май; Әхмәтҗанов М.И. Дастаннар ватаны: Кама аръягының көнчыгыш төбәкләре һәм татар әдәбияты тарихы. К., 1999.

*А.М.Ахунов.*

**МИ́НКИН** Владимир Самуилович (7.7.1947, Киров ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2003). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ун-тында эшли, 1978–87 дә әзерлек бүлеге деканы. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмаларның физик химиясенә карый. ТМР алымнарын кулланып, М. полисульфид олигомерлар табу, аларны вулканлаштыру һәм модификацияләү процесслары, вулканлаштыру челтәренең төзелеше турындагы күзаллауларны фәнни нигезли; олигомерлар төзелешенең алар нигезендә эшләнгән герметиклаучы композицион материаллар үзлекләренә бәйлелеген күрсәтә; модификацияләнгән композицияләрне катыру процессларының гомуми законлылыкларын, формалашучы челтәрнең гетерочылбырлы олигомер композицияләр төзелү механизмына тәэсирен билгели. Сәнәгый сыек тиоколларның төзелешен һәм реакция сәләтен аларны синтезлау алымына бәйле рәвештә тикшерә, ш.у., катыру процесслары механизмнарын һәм кинетик законлылыкларын исәпкә алып, алар нигезендә герметиклар табу процессларын ачыклый. Төрле төзелешле сәнәгый сыек тиоколларны синтезлау һәм катыру процессларын бәяләү юлларын эшли. Машиналар, приборлар төзелеше, нефть һәм газ сәнәгате җиһазларын, төзелеш конструкцияләрен һәм детальләрен герметиклау һәм коррозиядән саклау өчен материаллар тәкъдим итә. Эшкәртмәләре РФнең күп кенә пр-тиеләрендә, ш.и. «Казан ясалма каучук заводы» ФҖБдә, «Кварт», «Казан моторлар төзү заводы», «Ямбург газ чыгару» АҖләрендә һ.б.да гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Югары мәктәп отличнигы», «СССРның уйлап табучысы» билгеләре иясе.

Хезм.: Модификация герметиков на основе полисульфидных олигомеров // Высокомолекулярные соединения. 1989. Т. 31А, № 2 (автордаш); ЯМР в промышленных полисульфидных олигомерах. К., 1997; Vulcanisation of Liquid Thiokol Based Sealants by Manganese Dioxide // Inter. J. Polym. Mater. 2000. V.474.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МИ́НКИН** Тихон Савельевич (8.6.1898, Казан губ., Чистай өязе Бахта а. — 1980, Алма-Ата ш.), ветеринар-хирург, вет. фән. д-ры (1940), проф. (1941), ТАССР, Казакъстан ССРның атказ. фән. эшлеклесе (1950, 1968). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1922), Минзәлә кантонында вет. табибе булып эшли. 1929–34 елларда һәм 1936–56 да Казан вет. ин-тында, гомуми һәм махсус хирургия каф. мөдире (1939 дан) һәм вет. ф-ты деканы (1938–40). 1934–36 да Киров вет. ин-да оператив хирургия каф. мөдире, 1956–62 дә Семипалатинск вет. ин-тында, 1962–80 дә Алма-Ата зоовет. ин-тында хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре айгырларны печтерү технологиясе, а.х. терлекләрендә туры эчәк төшү һәм сөякләр сыну мәсьәләләренә карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Новый метод асептической кастрации жеребцов // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1933. Т. 32.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*М.Ш.Шәкуров.*

**МИ́НКИНА** Вера Егоровна (9.9.1918, Казан губ., Чистай өязе Бахта а. — 20.09.2011, Казан), драма актрисасы, ТАССР, РСФСРның халык артисты (1968, 1977). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң (1938), Татар акад. театрының колхоз ф-лына (соңрак Татарстан Респ-ка күчмә театры) эшкә килә, 1952 елдан Татар акад. театры актрисасы. М.Әблиев пьесасы буенча куелган «Шәмсекамәр» спектаклендә Разия ролен М. ышандырырлык һәм истә калырлык итеп башкара. Зур осталык б-н Галия («Урманда», Ф.Хөсни), Гөлзадә (Р.Ишморатның шул исем. әсәре буенча), Людмила («Соңарган мәхәббәт», А.Н.Островский), Мәфтуха («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Фатыйма, Миңлекамал («Тормыш җыры», «Миңлекамал», М.Әмир) образларын иҗат итә. М. башкаруында Миңлекамал образы түзем, кыю, фидакарь, нык ихтыяр көченә ия булган һәм, бөек җиңүгә зур ышаныч б-н яшәп, тылда тырыш хезмәт куйган хатын-кызларга гимн булып яңгырый; бу образ, респ-ка авылларына гастрольләр б-н баргач, актрисага очрашып күрешергә туры килгән күп кенә реаль шәхесләрнең (прототипларның) сыйфат үзенчәлекләрен туплаган. Татар акад. театры сәхнәсендә М.ның иҗат биографиясе травести (яшүсмер егетләр) рольләрне уйнаудан башлана; аның беренче роле — К.Тинчурин пьесасы буенча куелган «Зәңгәр шәл» спектаклендәге Малай образы. М. башкаруында тыңгысыз, кызыксынучан, шул ук вакытта бераз мәгънәсезрәк тә бу малай тамашачының игътибарын тышкы детальләрнең сәнгатьчә байлыгы, кичерешләр ихласлыгы, тормышчан булуы б-н җәлеп итә. М., Гыйльмениса («Чаткылар», Т.Гыйззәт), Биби, Туганым («Бәхетсез егет», «Банкрот», Г.Камал), Сәрвәр («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин), Екатерина («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Фәтхия («Татар хатыны нишләр күрми», Г.Ибраһимов), Хәмдебану, Рәхимә, Зәйтүнә («Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Әниләр һәм бәбиләр», Т.Миңнуллин), Зилә («Ләйсән ире Хәсән», Ю.Сафиуллин), Әби («Бәхетлеме син?», М.Садыйкова) кебек характерлы рольләр башкарып, милли театр сәнгатенә аеруча зур өлеш кертә. Г.Болгарская, Ф.Ильская, Г.Камская традицияләрен дәвам иткән М. иҗаты үтә дә заманча. Милли характерлар иҗат итеп, аларга таныш төсмерләр биреп, актриса киң гомумиләштерүләргә һәм бер үк вакытта аларның символик яңгыраш алуына омтыла. Ул тудырган образлар асылы б-н халыкчан һәм милли фольклорга якын. М. кинога да төшә (Г.Ахуновның «Хәзинә» романы буенча төшерелгән фильмда — Мәгыйшә; «Зифа оныгы Ришат» фильмында — Зифа).

*Әд.:* Иљялова И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; Иљялова И. Театр имени Камала. К., 1986.

*Д.Ә.Гыймранова.*



В.Е. Минкина Җәүһәрия ролендә («Зөбәйдә – адәм баласы», Ш.Хөсәенов; сулда – Кәримә ролендә Н.Ихсанова).



В.Е. Минкина:
1. Хәерниса («Ике килен-килендәш», Х.Вахит);
2. Гыйльмениса («Чаткылар», Т.Гыйззәт) рольләрендә.

**МИННЕГУ́ЛОВ** (Миңнегулов) Рушан Рөстәм улы (27.11.1992, Байлар Сабасы штп), спортчы (чаңгыда узышу, терәк-хәрәкәт аппараты зәгыйфьләнгән затлар арасында биатлон), Россиянең атказ. спорт остасы (2014). Саба аграр колледжын тәмамлый (2009). Спорт б-н 2007 елда шөгыльләнә башлый (тренеры Р.Х.Миннегулов). 2009 дан РФ җыелма командасы әгъзасы (тренерлары Ә.Ә.Гомәров, И.А.Громова). Россия (2008–09, 2012–13), дөнья чемпионатларында җиңүче һәм дөнья кубогы иясе (2013), Параолимпия уеннарында ике тапкыр чемпион була һәм көмеш медаль ала (Сочи ш., 2014) һ.б. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**МИ́НСКЕР** Карл Самойлович (14.6.1929, Киев ш. — 23.5.2003, Уфа ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1967), БР ФА академигы (1991), Башкортстан АССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1977, 1987). 1952 елда Мәскәү нәзек химия технологиясе ин-тын тәмамлаганнан соң, хәзерге Түбән Новгород өлкәсенең Дзержинск шәһәрендә химия з-дында эшли, 1953 тән Дзержинск тармак фәнни-тикшеренү ин-тында. 1968 дән Башкорт ун-тында, югары молекуляр кушылмалар һәм коллоид химиясе каф. мөдире, 1978 дән галоидлы полимерлар деструкциясе һәм тотрыклылыгы буенча проблемалы фәнни-тикшеренү лаб-ясен оештыручы һәм аның җитәкчесе. Бер үк вакытта, 1968–83 тә, СССР ФА Башкортстан ф-лының Химия ин-тында ионлы полимерлаштыру лаб-ясе мөдире, 1993 тән Транспорт һәм энергия ресурслары проблемалары ин-тында химия һәм биохимия проблемалары бүлеге мөдире. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә, нефть химиясенә һәм техник химиягә карый. Химик физика һәм теоретик технологиянең яңа — турбулент агымнарда кыска вакытлы процесслар узуы бүлеген эшли, шуның б-н сәнәгать җитештерүенә кечкенә үлчәнешле көпшәсыман турбулент реакторлар нигезендә (А.А.Берлин б-н бергәләп) энергия һәм ресурс саклаулы югары җитештерүчән технологияләр кертү мөмкинлеге туа (РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге (2004), ТР галимнәре Р.Я.Дебердеев, Г.С.Дьяконов, Ә.М.Мазһаров һ.б. б-н бергә). М. бутилкаучук (эремәле алым), яңа полимер материаллар, полимер композицияләргә өстәмә химикатлар алу юлларын тәкъдим итә. Россиядә беренче зур тоннажлы унификацияләнгән этиленпропилен каучуклар производствосын эшләгәне һәм гамәлгә кертүгә өчен ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек була (2001, Р.Я.Дебердеев, Г.С.Дьяконов һ.б. б-н бергә). Уйлап табуга 375 авторлык таныклыгы һәм патенты (ш.и. 25 чит илләр патенты) бар. РФАнең акад. В.А.Каргин исем. бүләге лауреаты (1999). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы һәм Бөтенроссия күргәзмәләр үзәге медальләре б-н бүләкләнә

Х е з м.: Деструкция и стабилизация поливинилхлорида. М., 1972 (автордаш); Изобутилен и его полимеры. М., 1986 (автордаш); Квантово-химический аспект электрофильной полимеризации олефинов. Уфа, 1996 (автордаш).

*В.Г.Абзалова.*

**МИ́НСКИЙ** (псевд., чын фам. Аллаһбирдиев) Габдрахман Мөхәммәт улы (29.9.1906, Әстерхан ш. — 26.3.1983, Казан), язучы. Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1938). 1924–25 елларда Әстерханда башта — уку йорты, соңрак «Кызыл Шәрекъ» исемле татар яшьләре клубы мөдире булып эшли. Шунда эшләгәндә, «Татар мәдрәсәсендә бер көн һәм бер төн», «Наданлык», «Ачлык корбаннары» дигән беренче пьесаларын яза. 1926 да Татар театр техникумында укый. 1930 еллар башында «җидегәнчелек»тә гаепләнеп җавапка тартыла. Тикшерү нәтиҗәсендә гаепсез табылса да, матбугаттан, әдәбияттан читләштерелә. 1932–35 тә Чиләбе шәһәрендә яши: «Төзү ударнигы» г-тасының җаваплы сәркәтибе вазифасын башкара. 1938–41 елларда Баку шәһәре (Әзәрбайҗан) киностудиясенең сценарийлар бүлегендә консультант булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1947–51 дә ТАССның Әзәрбайҗан бүлегендә мөхәррир һәм хәбәрче. 1952 дән Казанда: «Чаян» ж-лында әдәбият һәм сәнгать бүлеген җитәкли (1952–57), Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары (1957–60). М. әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Аның Бөек Ватан сугышы турындагы хикәяләре чынбарлыктагы вакыйгаларга һәм үзе кичергәннәргә нигезләнеп язылган («Хикәяләр», 1954; «Батырлар сукмагы», 1958). «Мәхәббәт хикәяләре» (1958), «Язның беренче көне» (1963) кебек хикәяләр җыентыкларында яшьләр тематикасы үзәктә тора. Әстерханда рев-ция алды вакыйгалары «Яшенле яңгыр» (1966; рус теленә тәрҗемәсе «Грозовой дождь», 1974) повестенда чагылыш таба. Драматург буларак, М., нигездә, әхлак-этика проблемаларына багышланган әсәрләре б-н билгеле. Аның «Мансуровлар гаиләсе» (1928 дә куела), «Шлем» (1930 да куела), «Гөлчәчәк» (1940 та куела), «Бөдрә тал» (1957 дә куела), «Лачыннар» (1965 тә куела) пьесалары Татар акад. театры, Татар драма һәм комедия театры, Башкорт драма театры сәхнәләрендә уңыш б-н бара. М. — Г.Ибраһимов, Һ.Такташ, Г.Кутуй турында истәлек язмалары б-н дә таныла («Замандашларым», 1964; «Онытылмас очрашулар», 1973 җыентыклары). Әзәрбайҗан язучылары Җафар Җабарлы һәм Мәһди Хөсәен әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Синең җырың: пьесалар. К., 1981; Повестьлар һәм хикәяләр. К., 1986; Первая симфония: Рассказы. М., 1974.

*Әд.:* Х ә й р и Х. Язучы һәм журналист // Язучы һәм тормыш. К., 1979; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МИНУ́ЛЛИН** Садрислам Минулла улы (24.8.1937, Чуаш АССРның Комсомол р-ны Урмай а. — 29.4.2006, Казан), гамәли механика өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1971), проф. (1994). 1960 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Канаш автозапчастьлар з-дында эшли. 1962–65 тә Мәскәү энергетика ин-тының Волжск ф-лында(Чабаксар ш.), 1965–83 тә Чуаш а.х. һәм Чуаш пед. ин-тларында. 1983 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында эшли. Хезмәтләре гамәли геометриягә һәм инженерлык графикасына карый. М. механика һәм оптиканың фәзаи мәсьәләләрен чишү өчен сызма геометрия буенча ярдәмче модельләштерү алымын эшли. Тәгәрмәчле транспортның идарә системасында сферик шарнирларсыз руль күчергечләрен булдыра. Югары уку йортлары өчен татар телендә «Сызма геометрия» дәреслеге авторы (1995). Уйлап табуга 16 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пространственные четырёхзвенные механизмы с вращательными парами. М., 1970; Рулевой привод. К., 1989; Основы создания рулевого привода без шаровых шарниров // Тракторы и СХМ. 1990. № 10.

**МИНУСИ́НСК РАЙОНЫ́**, Красноярск краеның көньягында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 3,192 мең *км*². Үзәге — Минусинск шәһәре (Красноярскидан 661 *км* көньяктарак). Халкы — 98265 (2012), татарлар — 1052 кеше (2010). Татарлар, башлыча, Минусинск шәһәрендә (938 кеше) һәм Восточное авылында (147) яши. М.р.нда татарлар 19 йөз башында күренә башлый. 1917 гә кадәр Восточное авылында мәчет (1903 тә нигез салына) һәм мәдрәсә, Минусинск шәһәрендә мәчет эшли. Хәзерге вакытта Минусинскида мөселман дини оешмасы (1990 нан), мәчет (1997 дән) эшли. 1990 еллардан Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

**МИНУ́ШЕВ** Фатыйх Хәлил улы (30.11.1928, Буа кантоны Үтәмеш а.), галим агроном, а.х. фән. канд. (1975), а.х. җитештерүен оештыручы. Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Тукай р-нында эшли: Ашытбаш МТСда (1956–57), «Северный» с-зында баш агроном, а.х. буенча район инспекциясе башлыгы (1958), район башкарма ком-ты рәисе (1959–63). 1963–71 елларда ТАССР а.х. министрлыгында: игенчелек һәм орлыкчылык бүлеге башлыгы (1965 кә кадәр), министр урынбасары (1965–67), министр (1967 дән). 1971–83 тә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, 2002 дән җитештерү бүлеге баш агрономы. 1983–99 да ТР Дәүләт орлык инспекциясе җитәкчесе. 1967–77 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, бер көмеш һәм ике бронза медале, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МИНХА́НОВ** Рамил Гаяз улы (23.12.1961, Иркутск ш.), драма актёры, ТРның халык артисты (2012). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1987), Әлмәт татар драма театры труппасына кабул ителә; анда ул яшь замандаш геройларны уйный. Дивана ролендә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), гадәти булмаган, үзенчәлекле характер тудырып, игътибарны үзенә җәлеп итә. М.ның Бакый («Ак калфак», М.Фәйзи), Яппар («Кодача», З.Исмәгыйлев), Флорид («Узып барышлый», Д.Салихов), Җиһангир («Оҗмах капкасы», М.Гыйләҗев), Илдар («Исәнмесез!», Т.Миңнуллин) рольләрендә актёрлык осталыгы



Р.Г.Минханов.



С.Г.Минханова.

чарлана, төрледән-төрле жанрлар үзләштерелә, иҗат диапазоны киңәя. Сәхнәдәге мөлаемлыгы, образга керү сәләте, образның асылын ачып бирү өчен сәнгатьле деталь таба белүе актёрның һәр эшен ышандырырлык итә, тамашачыда кызыксыну уята. М.ның аеруча уңышлы рольләре — Ирек, Сәяр («Балакаем», «Туган-тумача», И.Зәйниев), Гаян



Р.Г.Минханов Илдар ролендә («Исәнмесез», Т.Миннуллин), сулда — Шәүкәт ролендә Р.Таһиров).

ага, Арыслан, Дию («Гашыйк Кәриб», М.Ю.Лермонтов), Дерамо («Болан патша», К.Гоцци), Ир («Туй», Б.Брехт). 2008 дә ТР Мәдәният министрлыгы һәм «Җыен» фондының Д.Сираҗиев исем. бүләгенә лаек була.

**МИНХА́НОВА** Сәкинә Габдрахман кызы (4.2.1958, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2006). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1981), Әлмәт татар драма театрына чакырып алына. 1983–87 елларда Казанда балалар бакчасында тәрбияче булып эшли; 1987 дән яңадан Әлмәт театрында. Лирик пландагы актриса буларак, М. беренче елларда Рәхимә («Мәхәббәт калды адашып», И.Йомагылов), Марфа («Айсылуның айлы кичләре», И.Абдуллин) рольләрен башкара. Ул иҗат иткән Әнисә («Гөнаһсыз гөнаһлылар», Т.Миңнуллинның «Сөяркә» әсәре буенча), Мәстүрә («Җырланмаган җыр», М.Кәрим), Дилбәр («Гүргә керер сер иде», Р.Кинҗәбаев), леди Мильфорд («Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), Рузия («Сагынуларга ни чара», И.Зәйниевнең «Әрем исе» әсәре буенча) образлары темпераментлы, хис-кичерешләргә бай, тирән драматизмга ия булулары б-н аерылып тора. Актриса комедия планындагы Мәхмүзә («Кодача», З.Исмәгыйлев), Лотфия («Туй күлмәге», М.Гыйләҗев), Лира («Эт чаба дип...», Э.Яһудин), Фәния («Узып барышлый», Д.Салихов) рольләрендә кеше холкының төрледән-төрле чагылышын оста гәүдәләндерә. М., нәфис сүз остасы буларак, концертларда катнаша.

*И.И.Илялова.*



С.Г.Минханова Сөмбел ролендә («Безнең гомер язлары», Ф.Садриев), Азат — Р.Минханов.

**МИНҺА́ҖЕВ** Әкрам Алим улы (12.9.1946, Чиләбе өлкәсенең Сатка р-ны Сулея ст.), автомат линияләр һәм агрегат станоклар көйләүче, бригадир (1980 нән), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). Усть-Катав машиналар төзү техникумын тәмамлаганнан соң (1965), Усть-Катав машиналар төзү з-дында эшли. 1970–72 елларда Йөрүзән механика з-дында (Чиләбе өлкәсе). 1972 дән «КамАЗ» АҖдә. Дәүләт бүләге хезмәттәге алдынгы казанышлары һәм җитештерүне арттыруга, автомобильләрнең сыйфатын күтәрүгә зур өлеш керткәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**МИНҺА́ҖЕВ** Билал Галәветдин улы (3.6.1946, Саба р-ны Аккүл-Бигәнәй а.), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1969 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1999 дан реактив-һава двигательләре каф. мөдире (хәзер авиация двигательләре һәм энергетика җайланмалары каф.). Хезмәтләре газ турбиналы двигательләрнең яну камераларындагы физик-химик процессларны тикшерүгә карый. М. җитәкчелегендә турбулент яну теориясе базасында яну камераларын исәпләү һәм проектлаштыру нигезләре эшләнә. Яну камераларының характеристикаларын яхшыртырга һәм яну продуктларындагы агулы матдәләр эмиссиясен киметергә мөмкинлек бирә торган тикшеренүләр үткәрелә. «Таттрансгаз» пр-тиесе газ үткәргечләренә урнаштырылган газ кудыру агрегатларын исәпләү алымнары һәм аларның характеристикаларын яхшырту буенча тәкъдимнәр, «Ансат» һәм «Ми-17» вертолётлары өчен көч җайланмаларының техник характеристикаларын исәпләү алымнары эшләнә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Внутрикамерные процессы и автоматизированная доводка камер сгорания газотурбинных двигателей. К., 2000; Камеры сгорания газотурбинных двигателей. К., 2004; Основы эксплуатации газотурбинных двигателей. К., 2007 (автордаш).

**МИНҺА́ҖЕВ** Вагыйз Васил улы (11.12.1955, Арча р-ны Хәсәншәех а.), адм.-хуҗалык хезмәткәре, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), вет. фән. канд. (1997), ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1992, 1995). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1978). 1978–98 елларда Арча р-нында эшли: «Ватан» с-зының баш зоотехнигы, директоры (1979–83), «Северный» с-зы директоры (1984–85), район а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (1985–87), КПСС райкомының 1 нче секретаре (1988–90), халык депутатларының р-н Советы рәисе (1990 нан), район хакимияте башлыгы (1992 дән). 1998–2011 дә «Татарстан сөте» АҖ (2006 дан — «ВАМИН-Татарстан» холдингы) ген. директоры. Дәүләт бүләге җитештерүдә киң күләмдә фән һәм техника казанышларын куллану нәтиҗәсендә бөртекле культуралардан югары уңыш алганы өчен бирелә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2011 дә ТР халык депутаты, 2011–14 тә РФ Федераль Җыенының Федерация Советында ТР Дәүләт Советы вәкиле. Медаль б-н бүләкләнә.

**МИНҺА́ҖЕВ** Ленарис Харис улы (7.10.1940, Ютазы р-ны Акбаш а.), хокук белгече, хокук фән. д-ры (2000), проф. (2000), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1967–69 елларда Әлмәт шәһәрендә халык судьясы. 1969 елдан Казан ун-тында дәүләт хокукы һәм халыкара хокук кафедрасында (бүленеп: 1975–77, 1985–88 дә Үзәк Африка Респ-касында, Мадагаскар Респ-касында фәнни һәм пед. эштә), 2006 дан конституцион хокук һәм кеше хокуклары каф. мөдире. Бер үк вакытта, 2001 дән, ТРның Сәүдә-сәнәгать палатасы каршындагы өченче як мәхкәмәсе (третейский суд) рәисе. Хезмәтләре халыкара хокук, хокук теориясе, халыкара мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен өйрәнүгә карый.

Хезм.: Методология исследования теоретических проблем международного права. К., 1986; Эффективность норм международного права. К., 1990.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**МИНҺА́ҖЕВ** Минтаһир Нургата улы (10.3.1959, Чирмешән р-ны Лашман а.), геол.-минерал. фән. канд. (2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), ТатНИПИнефтьтә, нефть чыганакларын эшкәрткәндә экология куркынычсызлыгы бүлеге башлыгы (2006 дан). Дәүләт бүләге «Гидрогеологиядә һәм ТРның нефть чыганакларын эшкәртүне күзәтүдә индикатор тикшеренүләрнең аппаратура-методик комплексын булдыру һәм киң кулланышка кертү» хезмәтендә катнашуы өчен бирелә.

**МИНҺА́ҖЕВ** Рамил Хәернас улы (30.1.1960, Мөслим р-ны Мөслим а.), педагог, пед. фән. д-ры (2001), проф. (2002). Казан пед. ин-тын (1981), Казан ун-тын (2005) тәмамлый, 1981 елдан Мөслим р-нының һөнә-

ри-техник уч-щеләрендә һәм мәктәпләрендә физика укыта. 1990 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тының — гомуми физика, 1994 тән физика укыту методикасы кафедраларында. Бер үк вакытта, 2002–05 тә, Татар гуманитар-пед. ун-тында пед. каф. мөдире. 2005–06 да укыту-тәрбия эшләре буенча проректор. 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-тының физика һәм информатика укыту буенча теория һәм методика каф. мөдире. Хезмәтләре физика укыту методикасы һәм укытуда техник чаралар куллану, татар халкының табигыять-фәнни белеме һәм педагогика тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Активизация познавательной деятельности на уроках физики. К., 1993 (автордаш); Становление и развитие системы естественнонаучного образования в татарской национальной педагогике: В 2 кн. К., 2001; Президент М.Ш.Шаймиев: Социально-психологический портрет. К. 2002 (автордаш).

**МИНҺА́ҖЕВ** Фидарис Фәләх улы (25.1.1942, Балтач р-ны Чапшар а.), ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (1999), ТАССРның атказ. агрономы (1985). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Казакъстан ССР Кустанай өлкәсе Аркалык р-нының «Сары Үзән» с-зы бүлекчәсендә агроном булып эшли. 1968–76 елларда Кама Тамагы р-ның а.х. идарәсендә баш агроном, 1976–79 да Әлки р-нының а.х. идарәсе башлыгы, 1979–83 тә «Татарсортсемпром» трестында баш агроном, 1983–86 да ТАССР А.х. министрлыгының бөртекле ашлык җитештерү һәм гомуми игенчелек бүлегендә баш агроном, 1988–90 да ТАССР Дәүләт аграр сәнәгате ком-ты рәисе урынбасары вазифаларын башкаручы, 1990–91 дә ТАССР Аграр сәнәгать комплексының игенчелек һәм үсемлекчелектә, эшкәртү тармакларында алдынгы технологияләр кертү бүлеге башлыгы урынбасары. 1991–2003 тә ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгында: ашлык хуҗалыгын интенсивлаштыру бүлеге башлыгы урынбасары, җир эшкәртү һәм үсемлекчелектә алдынгы технологияләр кертү бүлеге башлыгы урынбасары (1992), башлыгы (1993 тән). 2003 тән «Колос-Агро» фәнни-җитештерү компаниясе» ҖЧҖнең башкаручы директоры. Дәүләт бүләге Биектау р-нының «Чулпан» һәм Арча р-нының «Игенче» күмәк пр-тиеләре үрнәгендә игенчелекнең агроландшафтлы адаптив системасының теоретик нигезләрен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МИНҺА́ҖЕВ** Хәниф Хәйдәр улы (20.7.1942, БАССРның Нуриман р-ны Яңа Субай а.), инженер, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), проф. (1996), РФнең атказ. машина төзүчесе (1994). 1965 елда Чиләбе политехник ин-тын тәмамлый. 1966 дан В.И.Ленин исем. Чиләбе трактор з-дында: 2 нче цехның өлкән мастеры (1968 гә кадәр), куәтле тракторлар корпусы башлыгы (1976–77), моторлар з-ды директоры (1982–87). 1987–95 тә Чабаксар сәнәгать тракторлары з-ды ген. директоры. 1995–98 дә Чуаш ун-тында икътисад каф. профессоры. 1998 дән «Чиләбе трактор заводы» АҖнең техник директоры. Хезмәтләре тракторлар һәм моторлар төзелеше икътисады мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар. Россия сәүдә-сәнәгать палатасы президиумы әгъзасы (1998 дән). 1987–92 дә Чуаш АССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономика электротехнического производства. Чебоксары, 1989; Организация и планирование производства. Чебоксары, 1990; Современные организационно-хозяйственные структуры в промышленности. Чебоксары, 1993; Тракторы ЧТЗ — мощная база строительно-дорожной техники // Строительные и дорожные машины. 2003. № 5.

**МИНҺА́ҖЕВА** (Шәмгунова) Гөлсем Мифтах кызы (30.11.1934, Чирмешән р-ны Якты Тау а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1960). 1952–67 елларда Чирмешән р-нының Тукай исем. к-зында сыер савучы. 1967–89 да Бөгелмә р-нының «Подлесный» с-зында терлекче. 1960 та М. «ТАССРның иң яхшы сыер савучысы» исеменә лаек була. Герой исеме терлекчелек продукциясе җитештерү һәм әзерләүдә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медаль; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Р у м я н ц е в Е. Мингазова Гульсум Мифтаховна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. № 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МИНҺА́ҖЕВА** Ләйлә Ихсан кызы (20.11.1969, Балтач р-ны Борбаш а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2011). Казан. пед. ин-тын (1992) тәмамлаганнан соң, шунда ук (2011 елдан Казан. ун-ты) эшли. Хезмәтләре татар балалар әдәбияты, XX йөз татар әдәбияты, Идел һәм Урал буе әдәбиятлары тарихына карый. «Балалар фольклоры» (2009, автордаш) җыентыгы, «Татар балалар әдәбияты» (1–2 т., 2010) хрестоматиясен төзүче, югары уку йортлары өчен методик әсбаплар авторы.

Х е з м.: XX гасыр татар балалар әдәбияты: үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре. К., 2011; Прошедшие сквозь века... История развития татарской детской литературы. Germany (Германия): Palmarium Academic Publishing, 2011.

*Әд.:* Минһаҗева Ләйлә Ихсан кызы // Балтач энциклопедиясе. К., 2006.

**МИНҺА́ҖЕВА** Нәфисә Мансур кызы (9.9.1956, Казан), эколог, биол. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1980 елдан Казан ун-тында, гамәли экология каф. профессоры, бер үк вакытта су системалары лаб-ясе мөдире (1991 дән). 2010 нан Казан архит-ра-төзелеш ун-тының шәһәр төзелеше каф. профессоры. 2011 дән су экосистемаларын оптимальләштерү лаб-ясе мөдире. КФУның Идарә һәм терр. үсеш ин-тының баш фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре Урта Идел буе, ш.и. Татарстан күлләрен өйрәнүгә карый. М. кече күлләрнең экологиясен яхшырту концепциясен һәм методологиясен эшли. Экологик белем бирүдәге уңышлары һәм экологик укыту уеннары эшләгәне өчен, СССР ВДНХсының ике бронза медале б-н бүләкләнә.



Г.М. Минһаҗева.


Х е з м.: Казанские озёра. К., 1989; Уникальные экосистемы солоноватоводных карстовых озёр Среднего Поволжья. К., 2001 (автордаш); Экология города Казани. К., 2005.

**МИНҺА́ҖЕВА** Эльмира Нурисламовна (23.6.1961, Баку ш.), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Казан шәһәренең җәмәгать туклануы комб-тында сан. табибе булып эшли. 1986 елдан Казан мед. ин-тының — балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы, 2002 дән хезмәт гигиенасы һәм медицинасы кафедрасында, 2007 дән проф. Хезмәтләре яшүсмер кыз балаларның репродуктив сәламәтлеге мәсьәләләрен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Современные особенности распространенности болезней глаз и его придатков среди детей и подростков Республики Татарстан // Современные проблемы науки и образования. 2012. № 2 (автордаш); Распространенность нарушений со стороны органа зрения среди учащихся школы-гимназии с интенсивными зрительными нагрузками // Материалы 16 конгресса педиатров России «Актуальные проблемы педиатрии». М., 2012 (автордаш).

**МИНҺАҖЕТДИ́Н** бине Фәхретдин (1843, Самара губ., Бөгелмә өязе Кичүчат а. — 1931), ташка уеп кисүче, хаттат. Ризаэтдин *Фәхретдиннең* абыйсы. 1865–1931 елларда Мәмәт авылындагы беренче мәхәллә мәчете имам-хатибы (хәзер Әлмәт р-ны). М. эшләгән кабер ташлары Әлмәт р-нының Кичүчат авылы зиратында сакланган. Известьташ плитәләрнең өске өлеше ярымтүгәрәк формада, алгы ягында уеп киселгән язулар урнашкан, бизәкләре юк. Яссы рельефка уеп кисү ысу-





М и н һ а җ е т д и н б и н е Ф ә х р е т д и н. Кабер ташлары: 1. Р. Фәхретдиннең әнисе каберендә. 1873; 2. Р. Фәхретдиннең әтисе каберендә. Уеп кисү. 1891.

лы б-н төшерелгән 7–8 юллык текст гарәп графикасында һәм гарәпчә «сөлес» стилендә башкарылган; рельефлы тар каймалар һәм юл аралары сызыклар б-н бизәлгән. Рәхимкул әл-Иштирәки кызы Мәгубә (Р.Фәхретдиннең әнисе; 1873), Фәхретдин бине Сәйфетдин (Р.Фәхретдиннең әтисе, 1891) һәм башкаларның каберләренә куелган ташларда уелган «Кятәбә Минһаҗетдин вәляде мулла Фәхреддин әл-Кичүчатый» («Кичүчаттан Фәхретдин мулла улы Минһаҗетдин язды») дигән автор язуы бар.

*Әд.:* Ә х м ә т ж а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел: Әлмәт төбәге эпиграфик истәлекләре. К., 2000.
*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МИНҺАҖЕТДИ́НОВА** Лира Нәбиулла кызы (23.8.1935, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1983), проф. (1984), Башкортстан Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1990). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшкә калдырыла, 1984 елдан госпиталь терапиясе каф. мөдире. Хезмәтләре йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары таралышына, бу авыруларга иртә диагноз куюга һәм реабилитация чараларын өйрәнүгә карый. БДБ илләре кардиологлары ассоциациясе президиумы әгъзасы (1990).

Х е з м.: Профилактика артериальной гипертонии. Уфа, 1987.

**МИ́НШИН** Мидхәт (Миңлеәхәт) Мөхәммәтша улы (26.9.1936, Балык Бистәсе р-ны Олы Солтан а. — 25.12.2009. Казан. ш.), журналист, язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977), Казан ун-тын тәмамлый (1959). 1959–60 елларда «Яңа юл» (Буа ш.) район г-тасында эшли. 1960–98 дә «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә, 1998 дән мәгълүмати-публицистик редакциянең баш мөхәррире. 1999–2001 дә ТР Юстиция министрлыгында әйдәп баручы белгеч, бер үк вакытта «Хокук вә хәят» ж-лының баш мөхәррире. 2002 дән «Правосудие в Татарстане» ж-лында. «Васыять» (1979), «Башаклар җырлый» (1982), «Каргыш: Поэмалар» (2003) җыентыклары, җыр текстлары авторы. Респ-ка Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге лауреаты (1977).

*Әд.:* С т о л я р о в Н. Наш корреспондент // Советское радио и телевидение. 1967. № 3.

**МИНЬЯ́Р** шәһәре, *Чиләбе өлкәсендә.* Халкы — 9940 (2012), татарлар — 1410 кеше (2010), Татарларның монда күпләп күченүләре М. метиз-металлургия з-дында җитештерүне киңәйтү (1940 еллар) б-н бәйле. 1990 елдан шәһәрдә Сабан туе бәйрәме үткәрелә, «Дуслык» татар-башкорт мәдәни клубы һәм шул ук исем. ансамбль эшли, 1991 дә мәчет ачыла. М.дан ТРга вак таш китерелә. «Миньяр карьеры» АҖ директоры С.А.Шәгъдәмовның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М. б-н бәйле.

**МИҢГӘ́Р** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 8 *км* көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 213 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез җитештерү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә мәчет, мәктәп, тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1187,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 139 ир-ат; 1859 да — 526, 1897 дә — 783, 1908 дә — 890, 1920 дә — 982, 1926 да — 918, 1938 дә — 945, 1949 да — 589, 1970 тә — 487, 1979 да — 441, 1989 да — 279, 2002 дә 249 кеше. М.дә актёр Ш.Х.*Биктимеров* туган.

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Кыям (Кыяметдин) Сәләхетдин улы (25.6.1929, Буа кантоны Кече Чынлы а. — 3.9.2005, Казан), тәрҗемәче, язучы, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). 1953 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1955–89 елларда Татарстан китап нәшриятында (1955–58 дә — мөхәррир, 1958–66 да — балалар әдәбияты редакциясе мөдире, 1967 дән матур әдәбият редакциясендә), бер үк вакытта, 1966 дан (бүленеп), Казан ун-тында тәрҗемә теориясе һәм практикасын укыта, 1997–2003 тә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында энциклопедик басмаларны татар телендә әзерләү бүлегендә эшли. Рус теленнән татар теленә Л.Н.Толстойның «Детство. Отрочество. Юность» («Балачак. Үсмерчак. Егетчак», 1955–57) трилогиясен, «Казаки» («Казаклар», 1974) повестен, В.Я.Шишковның «Угрюм-река» («Хәсрәт дәрьясы», 1963) романын, В.П.Катаевның «Белеет парус одинокий» («Ялгыз җилкән», 1965) повестен, А.Н.Толстойның «Гиперболоид инженера Гарина» («Инженер Гаринның гиперболоиды», 1972) романын, «Хождение по мукам» («Михнәтле заман», 1976–79) трилогиясен, «Аэлита» (1983) романын, Э.Войничның «Овод» («Кигәвен», 1981) романын, Г.Маркесның «Сто лет одиночества» («Ялгызлык», 1987), Ж.Амадуның «Габриэла, корица и гвоздика» («Габриэланың гыйшкы», 1999) романын, балалар өчен Н.Н.Носовның «Приключения Незнайки» («Белмәмеш мажаралары», 2003) китабын тәрҗемә итә. «Бакый» (1997), «Акыллы атын мактар...» (2004) романнары, әдәби тәрҗемә теориясе, сынлы сәнгатькә багышланган мәкаләләр авторы. Б.Урманче, Л.Фәттахов, И.Зарипов әсәрләре альбомнарын төзи.

Ә с ә р.: Перевод — это искусство. К., 2004.

*Әд.:* Кыйблага тугрылык. К., 2004; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Марсель Миргаяз улы (24.6.1941, Әгерҗе р-ны Барҗы-Умга а.), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1977), проф. (1978), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1990). Проф. М.А.Ерзин шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда эшкә калдырыла, проректор (1979–85), фармакотерапия курсында патология каф. мөдире (1983 тән), патофизиол. каф. мөдире (1993 елдан). Хезмәтләре лимфа системасы патофизиологиясенә карый. Мед. терминнарының русча-татарча кыскача аңлатмалы сүзлеге авторы (1994). Казан патофизиологлар фәнни-методик җәмгыяте рәисе (1995 тән).

Х е з м.: Роль лимфатической системы в патологии поджелудочной железы // Клиническая медицина. 1972. № 6; Лимфообращение при шоковых состояниях // Казан. мед. журн. 1975. № 4 (автордаш); Роль лимфатической системы в нарушениях гомеостаза и в их коррекции // Казан. мед. журн. 1983. № 2; Клиническая патофизиология сосудистого тонуса. К., 2006; Краткий русско-татарско-английский толковый словарь медицинских терминов. К., 2009 (автордаш).

*Әд.:* Профессор Марсель Миргаязович Миннебаев // Казан. мед. журн. 2001. № 4.

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Ринат Ягъфәр улы (24.1.1964, Уфа ш.), график. БРның атказ. рәссамы (2006). Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1986). 1988 елдан Уфа сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге (1995), Халыкара графика академиясе (2004) әгъзасы. М. иҗатында, бигрәк тә аның беренче әсәрләрендә, 20 йөзнең төрки мәҗүси культура элементлары катнашкан, абстракт һәм фигуралы төрле модернистик агымнарның стилистик принциплары кушылмасы булуы б-н аерылып торган хәзерге заман сынлы сәнгать тенденцияләре чагыла: «Күк аты», «Пектораль энарея», «Томирис көзгесе» (барысы да 1994). Соңрак рәссам коллаж техникасын куллана башлый (әсәрләргә аеруча матур чагылыш һәм ягымлылык бирүче кәгазь нигез булып тора): «Намаз», «Сукмак», «Төньяк җиле» (барысы да 2003). М. әсәрләрендә төп тема — борынгы төрки дөнья тарихы һәм мәдәнияте. Күбрәк офорт, литография, акватинта техникасында





Р.Я.М и ң л е б а е в. 1. «Герой». «Мифның туу» сериясеннән. Автор тарафыннан төс йөгертелгән кәгазь. 1998; 2. «Чудь». «Ибне Фазлан сәяхәте» сериясеннән. Автор тарафыннан төс йөгертелгән кәгазь. Үреп ясау, шпон, тимер. 2004.

эшли. Графика серияләре: «Әманәт» (1991), «Урман ияләре» (1992), «Гипербореяләр» (1994), «Алла битлекләре» (1995), «Арийлар фәзасы» (1997), «Миф туу» (1998), «Петроглифлар» (2000), «Мегалитлар», «Архаика» (икесе дә — 2002), «Ибне Фазланның Итил елгасына сәяхәте», «Иртә тимер гасыры» (икесе дә — 2003), «Эзләр», «Гәүдәләнеш» (икесе дә — 2004); «Төрки дөнья» монументаль панносы (В.Г.Шәйхетдинов б-н бергә, 2002).

Урал басма графикасы триенналесендә (Уфа, 1995, 1998, 2001), 1 нче Бөтендөнья кече басма формалар һәм экслибрис (Пекин, Кытай, 1998), Израиль дәүләтенең оешуына 50 ел тулуга багышланган халыкара экслибрис (Буэнос-Айрес, Аргентина, 1998), «Күчмә сәхифәләр — habar» (Мәскәү, 2006; Казан, 2007) күргәзмәләрендә, халыкара «Алтын каләм» иллюстрацияләр (Белград, Югославия, 1999, 2001), «Lilla Europa» нәкышь һәм графика (Хальсберг ш., Швеция, 2000), басма графика (Пекин, Кытай, 2003) биенналесендә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре Уфа (1994, 1997), Мәскәү (1994), Огайо ш., АКШ (1996), Казан (1996), Нижневартовск (1998), Абакан (2000), Новосибирск (2000), С.-Петербург (2005) шәһәрләрендә уза. Башкорстанның әдәбият, сәнгать һәм архит-ра өлкәсендәге Ш.Бабич исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1998), Халыкара экслибрис биенналесе дипломанты (Альбенга ш., Италия, 1997); Урал халыкара басма графика триенналесенең 2 нче (көмеш медаль), 3 нче (бронза медаль), 1 нче (алтын медаль) бүләкләре (Уфа ш., 1998, 2001, 2004); халыкара графика биенналесенең 3 нче (бронза медаль) һәм 1 нче (алтын медаль) бүләкләре (Новосибирск ш., 1999; С.-Петербург, 2004; Любляна ш., Словения, 2005) лауреаты.

М. әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан Дәүләт сәнгать музеенда (Уфа ш.), «Казан» милли мәдәният үзәгендә (Казан), «АӘ» хәзерге заман сәнгате галереясында (Курск ш.), Хәзерге заман сәнгате музеенда (Мәскәү), Кече график формалар галереясында (Пекин, Кытай), Кече график формалар сәнгате галереясында (Альбенга ш., Италия), Картиналар галереясында (Новосибирск ш.), Россиядәге һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Ә х м ә т д и н о в а И. Рәссам сере // Тамаша. 2001. № 3; Ф ё д о р о в В. Этнография Рината Миннебаева // Рампа. 1994. № 7–8; М а х м у т о в М. Созвездие курая // Тулпар. 1998. № 4; Х у с а и н о в А. Я человек полевой // Уфа, 2002. № 11; Миннебаев Р. Фарсах. Графика: Каталог. Уфа, 2006.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Руфил Гаффар улы (18.9.1931, БАССРның Яңавыл р-ны Айбүләк а.), ботаник, эколог, биол. фән. д-ры (1969), проф. (1971), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1977), БР ФАнең шәрәфле академигы (1998). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли. 1963 елдан Башкорт ун-тында ботаника каф. мөдире. Хезмәтләре чүп үләннәрне өйрәнүгә, туфрак альгологиясенә, гомуми экологиягә карый. М. Татарстан кырларындагы чүп үләннәрне тасвирлый һәм аларга каршы көрәш чараларын тәкъдим итә. Флораны экологик-геогр. яктан анализлый, Башкортстан суүсемнәренең экологиясен өйрәнүгә өлеш кертә. «Башкортстан АССРның югары төзелешле үсемлекләре турында белешмә» («Определитель высших растений Башкирской АССР», М., 1988), «Башкортстан суүсемнәре турында кыскача белешмә» («Краткий определитель водорослей Башкортостана», Уфа, 1996), «Ботаникадан русча-башкортча-татарча терминологик сүзлек» («Русско-башкирско-татарский терминологический словарь по ботанике». Уфа, 1996) төзүчеләрнең берсе. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1998). Бөтенсоюз ботаника җәмгыятенең Башкортстан бүлеге рәисе (1970).

Х е з м.: Сорные растения Татарии и борьба с ними. К., 1963 (автордаш); Влияние нефти на почвенные водоросли // Почвоведение. 1989. № 1; Эколого-географический анализ флоры Республики Башкортостан. Уфа, 1995 (автордаш).

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Фәрит Нурмөхәммәт улы (18.11.1949, Зәй р-ны Аксар а.), тракторчы-машинист, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Чаллыда 8 нче а.х. җитештерү-техник уч-щесен тәмамлый (1966). 1965 елдан Зәй р-нының «Нур» а.х. җитештерү кооперативында эшли, шикәр чөгендере үстерү звеносы җитәкчесе (1978–2002). М. җитәкчелегендә звено һәр елны шикәр чөгендереннән югары уңыш ала (1 *га* дан 350 *ц* га кадәр). Аның тәкъдиме б-н колхоз остаханәсендә тамыразыкларны чистартып бетерә торган ике валлы җайланма эшләнә, ул шикәр чөгендерен кул хезмәтеннән башка җыеп алу мөмкинлеге бирә. Дәүләт бүләге хезмәттәге алдынгы казанышлары өчен бирелә. ТАССР ЮС депутаты (1985–90). 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены, СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МИҢЛЕБА́ЕВ** Шамил Хәмит улы (22.10.1947, Башкортстан АССРның Әлшәй р-ны Раевка пос.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1972). 1972–81 елларда Татнефть ҖБнең Лениногорск катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе, мастер, техник бүлек башлыгы, 1981–93 тә Минзәлә нефть эзләү, бораулау идарәсендә цех башлыгы. 1993–2002 дә «Силен» фирмасы ҖЧҖтә баш инженер. Уйлап табуга 12 патенты бар. Дәүләт бүләге аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүдә яңа термоимплозион һәм тишекле-имплозион экспресс-технологияләр эшләгәне һәм киң кулланышка керткәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспресс-технологии добычи нефти // Науч. Татарстан. 1997. № 2 (автордаш).

**МИҢЛЕБА́ЕВА** (ире ягыннан Халитова) Мәрзия Галимбай кызы (12.8.1911, Вятка губ. Ижевск Заводы ш. — 20.8.2000, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1970). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлый (1931). М.ның сәхнә эшчәнлеге Казан мехчылар клубы агитбригадасында башлана, аннан соң ул Татар сәнгать эшче театрына (Казан эшче яшьләр театры) кабул ителә, 1936 елдан Татар акад. театры актрисасы. М.ның күпкырлы иҗат сәләте драма, комедия, муз. драма жанрларының барысында да бертигез дәрәҗәдә ышандырырлык рәвештә ачыла. Актрисаның Галиябану (М.Фәйзинең шул исем. әсәре буенча), беркатлы сукыр ятимә кыз Рәйсә («Күзләр», А.Фәтхуллин), көчле рухлы Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), ягымлы, йомшак күңелле Зөбәрҗәт («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Дорина («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Фаншетта («Фигароның өйләнүе», П.О.Бомарше), хәйләкәр, курку белмәс Варвара («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский) рольләре аеруча зур уңыш казана. М. олы яшьтәге, характерлы хатын-кыз рольләрен дә оста башкара: Дилбәр, Бибиәсма, Сылу («Соңгы хат», «Кайда соң син?», «Рәхим итегез», Х.Вахит), Саймә («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Хәтирә («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Аграфена Кондратьевна («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский), Демидьевна («Ябырылу», Л.М.Леонов); аларга табигыйлек һәм гадилек, тотнаклылык, тыйнаклык хас.



М.Г.Миңлебаева.



М.Г. М и ң л е б а е в а Миңкамал ролендә («Чикләвек төше», Г.Ахунов; сулда – Гыйбадулла ролендә Г.Шамуков һәм Рокыя ролендә Н.Ихсанова).

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары: Биогр. белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; И л я л о в а И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**МИҢЛЕБА́ЕВА** Фәридә Вил кызы (21.8.1961, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1984). РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2005 тән). 2008 елдан оксидлашу-кайтарылу метаболизмы лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре үсемлек күзәнәгенең энергия алмашу закончалыклары һәм үзенчәлекләренә, үсемлекләрнең төрле стресс-ларга чыдамлык механизмнарын һәм адаптация юлларын табуга карый. М. үсемлекләр-

нең стресс тәэсиренә иң беренче реакцияләрен билгеләүдә күзәнәк өслегендә баручы оксидлашу процессларының әһәмиятен күрсәтә.

Хезм.: Особенности действия ионов кальция и кальциевого ионофора A23187 на мембранный потенциал и дыхание клеток корня пшеницы // Физиология и биохимия культурных растений. 1990. Т. 22, № 3 (автордаш); Роль супероксида в формировании неспецифического адаптационного синдрома корневых клеток // Докл. РАН. 1997. Т. 355, № 4 (автордаш); Продукция супероксида и активность внеклеточной пероксидазы в растительных клетках при стрессе // Физиология растений. 2003. Т. 50, № 3 (автордаш).

**МИҢЛЕБА́Й** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 1001 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә. Мәчет. 1735 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кичүбаш-Миңлебай исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, аларның бер өлеше (элеккеге йомышлы татарлар) лашманчы хезмәтен үти. Игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1799 елгы мәгълүматларга караганда, монда ашлык саклау-сату кибете була. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2304 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва-Иваново волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1795 тә — 266, 1859 да — 762, 1889 да — 1065, 1910 да — 1384, 1920 дә — 1499, 1926 да — 1160, 1938 дә — 1232, 1949 да — 1053, 1958 дә — 1079, 1970 тә — 1162, 1979 да — 931, 1989 да — 795, 2002 дә 1004 кеше. М.да язучы Ф.Г.*Кәрими* туган.

**МИҢЛЕБА́Й ГАЗ ЭШКӘРТҮ́ ЗАВОДЫ́** (МГПЗ), РФ нефть сәнәгате газ эшкәртү тармагының беренче пр-тиеләреннән. Әлмәт р-нының шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогында урнашкан. 2 төп һәм 8 ярдәмче цехы бар. Эшләүчеләр саны — якынча 2000 кеше (2012). Иярчен нефть газын, җиңел углеводородларның киң фракциясен кабул итү һәм эшкәртү б-н шөгыльләнә. Төп продукциясе: этан, пропан, изобутан, нормаль бутан фракцияләре; стабиль газ бензины; янучан углеводород, табигый газлар; техник күкерт, техник газсыман кислород, газсыман азот, пентан (изопентан фракциясе). «Казаноргсинтез» АҖ һәм Түбән Кама нефть химиясе комб-тын чимал б-н тәэмин итә. ТР һәм РФ төбәкләре коммуналь-көнкүреш хуҗалыгы пр-тиеләренә сыек һәм ягулык газлары җибәрә. Завод продукциясе Венгрия, Германия, Польша, Финляндиягә һ.б. илләргә чыгарыла. МГПЗ 1953 елда Миңлебай газолин з-ды буларак нигезләнә, 1956 да Миңлебай газ-бензин з-ды итеп үзгәртелә. Шул ук елда пр-тиенең 1 нче чираты файдалануга тапшырыла һәм беренче продукция — сыек углеводородлар эшләп чыгарыла. Еллык җитештерү күләме 438 млн. $м^3$ газ һәм 64 мең *т* сыек продуктлар тәшкил итә. 1958 ел ахырында заводның 2 нче чираты төзелеп беткәннән соң, нефть газын эшкәртү куәтләре ике тапкыр арта (елга 880 млн. $м^3$). 1964 тә һәм 1966 да һәрберсе елга 1100 млн. $м^3$ газ эшкәртә торган 3 нче һәм 4 нче чиратлар сафка баса. 1968 дә пр-тие Миңлебай газ эшкәртү з-ды итеп үзгәртелә, шул ук елда яңа продукт — гелий эшләп чыгарыла, 1975 тә, нефть газыннан сыек углеводородларны аерып алуны тирәнәйтү һәм елга 500 мең *т* га кадәр этан фракциясе җитештерү максатында, заводның 5 нче чираты файдалануга тапшырыла. Еллык проект куәте нефть газын эшкәртүдә — 3630 млн. $м^3$, газларны фракцияләүдә — 1862 мең *т*, гелий җитештерүдә — 1035 мең $м^3$, этан җитештерүдә 498 мең *т* тәшкил итә. 1974 тә нефть газын эшкәртү һәм сыек углеводородлар эшләп чыгару буенча макс. күрсәткечләргә ирешелә: 3,5 млрд. $м^3$ һәм 1,5 млн. *т*. 1979 дан нефть газы күкертле водородтан чистартыла һәм шул нигездә гади күкерт җитештерелә. 1994 тә завод — АҖ, 2002 дә ҖЧҖ итеп үзгәртелә, 2002 дә «Татнефть» АҖнең яңа оештырылган «Татнефтегазпереработка» идарәсе составына керә.

СССР ЮС Президиумының 1971 ел 6 гыйнвар Указы б-н завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Пр-тиенең 200 дән артык хезмәткәре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кешегә Соц. Хезмәт Герое, 22 кешегә халык хуҗалыгы тармакларының атказ. хезмәткәрләре исемнәре бирелә, 72 кеше орден б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: К.Б.Блондек (1954–56), М.А.Регельман (1956–60), В.В.Тимофеев (1960–62), Н.П.Волков (1962–65), Ф.Г.Гайнуллин (1965–74), Х.С.Камалов (1974–96), М.Х.Әминов (1996–2001), Ф.Ә.Зәкиев (2001–02).

*К.Ф.Фәсхетдинов, Г.М.Әхмәтҗанов.*

**МИҢЛЕБА́Й ҮТӘ́ ТИРӘ́Н СКВАЖИНАСЫ́ № 20000**, Татарстан терр-ясендә 4 мең *м* дан артык тирәнлектәге 1 нче скважина. Кристаллик нигездә нефть-газны ачыклау максаты б-н 1973–75 тә *Ромашкино нефть чыганагында* (Әлмәт шәһәреннән көньяк-көнбатыштарак) бораулана. Проект тирәнлеге 4,3 мең *м*, чынбарлыктагысы — 5 мең *м* дан артык. Нигезнең калын катламында токымнарның көчле чатнау һәм ватылуы беленә, тирәнлек арту б-н бу үткәрүчән зоналарның күләме һәм продуктлылыгы арта баруы ачыклана. Тыгызлыгы кимегән тирән зоналардан шактый күләмдә югары минеральләшкән, газлар (гелий, углеводлар һ.б.) б-н туендырылган кайнар су (дебиты тәүлеккә 80 $м^3$ ка кадәр) алына. Алынган мәгълүматлар Татар гөмбәзе кристаллик нигезенең эчке төзелеше турындагы күзаллауны төптән үзгәртә.

*Әд.:* Глубинные исследования архейского фундамента востока Русской платформы в Миннибаевской скважине 20000. К., 1976; Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1997.

**МИҢЛЕБА́Й** тимер юл станциясе посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Әгерҗе–Акбаш тимер юлы буенда. 2010 елда 769 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 63%) яши. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1950 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1958 дә — 628, 1970 тә — 574, 1979 да — 511, 1989 да — 341, 2002 дә — 657 кеше.

**МИҢЛЕГАЛИ́ЕВ** Минһаҗетдин Галиәсгар улы (1857–?, Самара губ., Бөгелмә өязе Кәкре Елга а.), җәмәгать эшлеклесе. Мәдрәсәдә укый. 117 дис. җире була, сәүдә б-н шөгыльләнә. Бөгелмә өязендә земство җыены гласные (1897 дән), волость мәхкәмәсе рәисе (1898 дән), сугышка яраклы атларны исәпкә алу бүлеге мөдире (1905 тән). Самара губернасыннан 4 нче Дәүләт Думасы депутаты (1912–17), мөселманнар фракциясе әгъзасы. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Д.М.Усманова.*

**МИҢЛЕГӘРӘ́Й ХАН** (? — 15.1.1515), Кырым ханы (1478/79 — 1515). *Хаҗигәрәй ханның* улы. Госманлылар империясе идарәчеләре һәм Ширин ыругы җитәкчелегендәге җирле аксөякләр ярдәмендә хакимияткә килә. М.х. идарә иткәндә Кырым дәүләт булып оеша, татар ыруглары һәм карачыбәкләр б-н мөнәсәбәтләр җайга салына, Төркия б-н вассаллык мөнәсәбәтләре ныгытыла, тәхетнең нәсел буенча күчү тәртибе билгеләнә. Көнчыгыш Европадагы тышкы сәясәттә Төркия б-н берлектә Балкан һәм Кара диңгез буеның көнбатышындагы илләргә (1504 елда Молдавиягә) яуларда катнаша, Польша-Литва һәм Рус дәүләтләре арасындагы мөнәсәбәтләрдә «өченче көч» ролен башкара. 1480–90 елларда Олы Урда һәм Речь Посполитага каршы берләшер өчен, әзлекле рәвештә Мәскәү б-н якынлашу сәясәтен тота. Нәтиҗәдә Польшага һөҗүмнәр оештыра (1480, 1482). Олы Урда тәхетенә хуҗа булыр өчен көчле көрәш алып бара; Әхмәд ханны тәхетеннән төшерүгә, аның үтерелүенә (1502), варисларының җиңелүенә булышлык итә; Дон буена һәм Төньяк Кавказга яулар оештыра (1502–10). Олы Урда таркала барган саен М.х. сәясәте Мәскәүгә каршы Речь Посполита б-н берләшүгә юнәлеш ала. М. идарә иткән чакта Рус дәүләтенең Кырымга каршы 16–17 йөзләрдә үткәрелгән сәясәтенә нигез салына.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Казан ханнары. К., 1995; Некрасов А.М. Возникновение и эволюция Крымского государства в XV–XVI веках // Отечественная история. 1999. № 2; Хорошкевич А.Л. Русь и Крым: От союза к противостоянию. Конец XV — начало XVI вв. М., 2001; Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; Зайцев И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МИҢЛЕГӨ́Л** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Томбарлы елгасы буенда. 2010 елда 50 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1885 еллар тирәсендә Татар Томбарлысы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 150 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волос-

тенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1889 да — 62, 1910 да — 139, 1920 дә — 131, 1926 да — 211, 1938 дә — 141, 1949 да — 151, 1958 дә — 139, 1970 тә — 113, 1979 да — 90, 1989 да — 51, 2002 дә 54 кеше.

**МИҢЛЕКӘ́ЕВ** Мәсгут Габдрахман улы (11.4.1930, Бөгелмә кантоны Яңа Елховой а.), техник-механик, Соц. Хезмәт Герое (1966). Лениногорск нефть техникумын тәмамлый (1967). 1946–52 елларда Лениногорск р-ның «Техника» к-зында тракторчы, кырчылык бригадасы бригадиры. 1956–89 да Миңлебай газ эшкәртү з-дында оператор, өлкән оператор (1958), газны күкерт кушылмаларыннан чистарту һәм газ фракцияләрен туплау җайланмасы башлыгы. М. җитәкчелегендәге газ эшкәртүчеләр бригадасы смена йөкләмәләрен 110–145% ка үти. Герой исеме СССР халык хуҗалыгын үстерүнең җидееллык планын (1959–65) үтәгәндә газ сәнәгате үсешенә зур өлеш керткәне һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Н о в и к о в В. Минекаев Масгут Габдрахманович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МИҢЛЕКӘ́Й** (Миңлекәев) Сәхау (Сәхаветдин) Кашафетдин улы (7.12.1895, Самара губ., Бөгелмә өязе Акбаш а. — 17.1.1954, Уфа ш.), шагыйрь. 1906–13 елларда Бәйрәкә авылының «Гобәйдия» мәдрәсәсендә белем ала, 1913–15 тә Добрино авылындагы (хәзер Самара өлкәсе Кләүле р-нына керә) икееллык рус мәктәбендә укый. 1915 тән армия сафларында. 1917 дә полкның солдат ком-тына, соңыннан 12 нче армиянең мөселман ком-тына сайлана. 1917 дән соң уку-укыту оешмаларында эшли. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Тарихи үзгәрешләр чорында татар халкының язмышына, мәхәббәткә, табигатькә багышланган беренче шигырьләрен мәдрәсәдә укыганда ук яза башлый. Соңыннан бу шигырьләр «Солдат моңнары» (1918), «Күңелле шигырьләр» (1921), «Кош-кортлар арасында» (1921), «Кызыл гөлләр»(1923) исемле күмәк шигъри җыентыкларга керә. М. балалар өчен дә яза («Балалар өчен җырлы уеннар», 1921; «Җырлы уеннар», 1923; «Тезмә сүзләр», 1931). 1930 елларда иҗаттан читләшә. «Качкыннар», «Гөлгенә» һ.б. поэмалары матбугатта басылмый кала.

Ә с ә р.: Шигырьләр һәм поэмалар. Бөгелмә, 1998; Сабанда. К., 2001.

*С.Г.Сафуанов.*


**МИҢНӘХМӘ́ТОВ** Зиннур Миңнәхмәт улы (3.6.1947, Алабуга р-ны Каенлык а.), нәкыщьче, график, педагог. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1972), Алабугада яши. И.И.Шишкин исем. балалар сәнгать мәктәбенә нигез салучыларның берсе һәм беренче директоры (1972–82), укытучысы (1990 га кадәр). 1990 елдан Сәнгать фондының иҗади-житештерү остаханәләрендә. Рәссамнар берлеге (1994), «Тамга» иҗат төркеме (2000 нән) әгъзасы. М. — авангард юнәлеше (модернизм, абстракционизм) вәкиле, вакытның рухи һәм социаль каршылыклары турында тәнкыйди һәм фәлсәфи фикер йөртә. Форма һәм төсләр контрастларына, масштаблы һәм ритмлы бәйләнешләргә нигезләнгән экспрессив иҗат алымнарына ия. График (гуашь, акварель, пастель) һәм нәкышь («Күләгәләр», «Кара урман», «Шәп» (барысы да — 1980 еллар), «Марина Цветаева — Алабуга» (1990–96), «Кичке көннәр» (1990–96), «Ак күргәзмә» (1996), «Мин яшәгән җирдә» (1999–2000), «Саф һавада йөрү» (2000–02) серияләре авторы. «Вакыт кыланышы» (2007–12), «Яшәеш бәхете» (2010–12) серияләре б-н «Шәп» (2005–12) картиналар циклы, «Кеше» (1994), «Ана һәм бала» (1998), «Сабан туе», «Бию» (икесе дә — 1997), «Казан» (1998) һ.б. күп кенә картиналар авторы. «Тамга» төркеме күргәзмәләрендә (2000 елдан), «Хәбәр» (2007, Мәскәү, Казан, Истанбул), «Урман арты» (2009, Яңа Кырлай а., ТР) артпроектларында, Г.Тукай шигъриятенә 125 иллюстрация (2011, Казан, Мәскәү), «KAMWA» этнофутуристик фестиваль (2011, Пермь) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1991, 1998, 2006, 2008, 2011 дә — Алабугада, 1991 дә — Мәскәүдә, 1994, 1998, 2008, 2010 да — Казанда, 2006 да Владимир өлкәсенең Александров шәһәрендә уза.

Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Чаллыдагы Картиналар галереясында, Алабуга дәүләт музей-саклаулыгында, Александровтагы М. һәм А.Цветаевларның әдәбият-сәнгать музеенда, «Туран-Арт» фондында, чит илләрдәге шәхси тупланмаларда (Швейцария, Германия, АКШ) саклана. 2006 да Алабугада узган «Хәзерге заман нәкышенең иҗат симпозиумы»нда Гран-при иясе.

*Әд.:* Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. Запоздалый модернизм в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; ш у л ук. Татавангард и современный цивилизованный процесс. К., 2011; Ш а г е е в а Р. Прозрение художника // Казань. 2010. № 7.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*





З.М.М и ң н ә х м ә т о в. 1. «Мин яшәгән җирдә» сериясеннән. 2005; 2. «Яшәеш бәхете» сериясеннән. 2011.



М.Г.Миңлекәев.



Н.М.Миңнеәхмәтов.

**МИҢНЕӘХМӘ́ТОВ** Нурлы Миңнеәхмәт улы (15.6.1914, хәзер БРның Караидел р-ны Аскыш а. — 9.9.1989, шул р-нның Тигермән а.), Сов. Союзы Герое (15.1.1944), гв. старшинасы. Туган авылында умартачы булып эшли. 1936–39 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 39 нчы гв. аерым сапёр батальонының отделение командиры (65 нче армиянең 37 нче гв. укчы дивизиясе). Ленинград, Дон, Үзәк, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында, Гомель-Речица (1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 12 сентябрендә Десна елгасын кичкәндә Собич авылыннан (Сумы өлкәсенең Шостка р-ны) көнбатыштарак барган сугышта батырлык күрсәтә: көймә б-н 35 рейс ясап, 370 сугышчыны, сугыш кораллары һәм орудиеләрне елга аша дошман кулындагы көнбатыш ярга чыгара. Демобилизацияләнгәннән соң, «Үрнәк» к-зында рәис һәм туган авылында умартачы булып эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1965. Кн. 1; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1985. Кн. 3.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИҢНЕГУ́ЛОВ** Госан (15.5.1898, Казан губ., Мамадыш өязе Кече Кирмән а. — 1974, Свердловск өлкәсенең Артёмовск р-ны Буланаш пос.; Артёмовск шәһәрендә җирләнә), забойчы, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1913–18 елларда Богословск киселешендә (Свердловск өлкәсенең хәзерге Карпинск ш.) олаучы, забойчы. 1918–21 дә Кызыл Армиядә. 1921–58 дә Свердловск өлкәсе «Егоршинуголь» трестының 2 нче шахтасында забойчы. Герой исеме күмер чыгаруда, күмер шахталары төзү һәм яңартуда ирешкән уңышлары, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне



Г. Миңнегулов.



Х.М. Миңнекәев.

тәэмин иткән алдынгы эш алымнары керткәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Туган авылында М.ка бюст куелган.

*Әд.:* Брылин А.И., Коверда П.Т. Города нашего края. Свердловск, 1983.

**МИҢНЕГУ́ЛОВ** Хатыйп Йосыф улы (12.5.1939, Зәй р-ны Апач а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994, 2005). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1967 дән шунда ук эшли, 1999–2009 да татар әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре урта гасырлар, 19 йөз татар әдәбиятына, аның гарәп, фарсы һәм төрки телле әдәбиятлар б-н багланышларына, чит илләрдәге татар әдәбияты һәм матбугатына, Г.Исхакый, Г.Тукай иҗатларына карый; әдәби жанрларны да өйрәнә. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен язылган дәреслекләр һәм методик кулланмалар авторы, хрестоматияләр төзүче. С.Сараи, Котб, Т.Ялчыгол, Ш.Зәки һ.б.ның әсәрләрен матбугатка әзерли (кереш сүз, тәрҗемә, транслитерация, комментарийлар авторы). 1995 тә «Татар әдәбияты һәм Шәрекъ классикасы» («Татарская литература и Восточная классика», 1993) монографиясе ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2005). ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Дөньяда сүземез бар. К., 1999; Гасырлар өнен тыңлап. К., 2003; Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. К., 2004; Чит илләрдәге татар әдәбияты. К., 2007; Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). К., 2010.

*Әд.:* Хатыйп Миңнегулов турында — О профессоре Х.Миннегулове. К., 2009.

**МИҢНЕКӘ́ЕВ** Хаҗи Миңнекәй улы (5.3.1918, хәзер Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Сосмак а. — 17.11.1992, Киров өлкәсенең Сосновка ш.), Дан орденының тулы кавалеры (18.10.1944, 8.3.1945, 31.5.1945), гв. кече сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 275 нче гв. танкка каршы истребительләр артиллерия полкында туп расчёты командиры (69 нчы һәм 5 нче удар армияләр). Воронеж, Дала һәм 1 нче Белорусcия фронтлары гаскәрләре составында Харьков оборона һәм һөҗүм операцияләрендә (1943), Курск дугасындагы һәм Днепр елгасы өчен сугышларда (икесе дә — 1943), Люблин-Брест (1944), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 26 августында Кликово һәм Гура-Пулавы (Пулавы шәһәреннән көнбатыштарак, Польша) торак пунктлары янында дошман контрһөҗүмен кайтарганда (сафтан чыккан төзәүчене алмаштырып, дошман танкын юк итә); 1945 нең 14 гыйнварында Анелин-Паёнкув (Польша) торак пункты янында (орудиедән дошманның танкка каршы тубын, күзәтү пунктын юк итә); 1945 нең 20–22 мартында Кюстрин шәһәреннән (хәзер Костшин ш. Польша) төньяк-көнбатыштарак Одер елгасын кичкәндә (расчёт сугышчылары һәм орудие б-н беренчеләрдән булып елга аша чыга, дошманның 2 пулемётын һәм күзәтү пунктын юк итә, миномёт батареясы утын бастыра) батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Сосновкада яши. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Звёзды Славы. Киров, 1970; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

**МИҢНЕХА́НОВ** Нургали Миңнехан улы (24.3.1930, Мамадыш кантоны Игенче а. — 17.2.2001, Саба р-ны Лесхоз пос.), урман белгече, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003, вафатыннан соң), ТАССР һәм РСФСРның атказ. урманчысы (1978, 1991). Лубян урман хуҗалыгы техникумын (1950), Казан а.х. ин-тын (1977) тәмамлый. 1954 елдан Кызыл Йолдыз урман хуҗалыгының Теләче һәм Яңа Арыш урманчылыкларында урманчы ярдәмчесе, урманчы булып эшли. 1962 дән Саба урман эшкәртү хуҗалыгы директоры. 1990 нан Саба р-ны Мишә җирле үзидарә советы рәисе. Саба урман сәнәгате хуҗалыгының формалашуы һәм ныгуына, Татарстан урман хуҗалыгы үсешенә зур өлеш кертә. Бөтенсоюз соц. ярышларда М. җитәкләгән хезмәт коллективы берничә тапкыр призлы урыннар ала, КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның күчмә Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә (1983–88). Дәүләт бүләге урман кискәндә алдынгы, ресурс саклаулы ысуллар эшләгәне һәм куллануга керткәне, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агачларны тирәнтен эшкәртүне оештырганы, Саба урман хуҗалыгында чыршы үстерүнең тизләтелгән ысулларын кулланганы өчен бирелә. Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. Лесхоз посёлогында М.ка бюст куелган (2002).

*А.Х.Газизуллин.*

**МИҢНЕХА́НОВ** Рәис Нургали улы (8.6.1961, Саба р-ны Борчаклы Яз а.), урман белгече, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), ТРның атказ. урманчысы (1997), а.х. фән. канд. (2001). Мари политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Саба урман эшкәртү хуҗалыгында эшли. 1984–85 елларда Кукмара р-нында Лубян экспериментал урман кисү һәм агач эшкәртү з-ды директоры, 1985–86 да Саба урман сәнәгате хуҗалыгының Лубян урман пункты башлыгы. 1986 дан Саба урман хуҗалыгында, Мишәбаш урманчылыгы урманчысы (1986–90), урман хуҗалыгы директоры (1990–99). 1999 дан Саба р-ны хакимияте башлыгы, бер үк вакытта Саба р-ны халык депутатлары советы рәисе. Хезмәтләре урман хуҗалыгына карый. Дәүләт бүләге урман кискәндә алдынгы, ресурс саклаулы ысуллар эшләгәне һәм куллануга керткәне, йомшак яфраклы һәм вак товарлыклы агачларны тирәнтен эшкәртүне оештырганы, Саба урман хуҗалыгында чыршы үстерүнең тизләтелгән ысулларын кулланганы өчен бирелә. 1999–2004 тә ТР халык депутаты.

Хезм.: Пихта сибирская в лесах Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 2000 (автордаш); Ведение комплексного, многоцелевого лесного хозяйства в малолесных регионах. К., 2003.

**МИҢНЕХА́НОВ** Рифкат Нургали улы (1.6.1955, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а.), ТРның Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы баш дәүләт инспекторы, идарә итү системалары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2004), милиция полковнигы (1995), ТРның атказ. эчке эшләр органнары хезмәткәре (2003). 1977 елда Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесен тәмамлаганнан соң, Совет гаскәрләренең Германиядәге төркемендә хезмәт итә. 1982–92 дә ракета гаскәрләренең Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесендә. 1992 дән ТР Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы инспекциясе идарәсендә: башлык урынбасары, башлык (1997 дән). Бер үк вакытта Казан техник ун-тында укыта (2000 нән). Хезмәтләре махсус мәгълүмат системаларын төзүгә һәм алардан файдалануга, юлларда балалар иминлеген тәэмин итүгә карый. М. балаларны юл хәрәкәте кагыйдәләренә өйрәтүнең региональ стандартын эшли (ТРның мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләрендә һәм мәктәпләрендә гамәлгә кертелгән). Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. Дуслык, Батырлык орденнары, медаль, «ТР Эчке эшләр министрлыгының мактаулы хезмәткәре», «Россия Эчке эшләр министрлыгының мактаулы хезмәткәре» һ.б. билгеләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Защита от несанкционированного доступа в специализированных информационных системах. К., 1999; Создание корпоративных информационных систем: От теории к практике. К., 2001; Повышение безопасности дорожного движения в Республике Татарстан. К., 2002 (автордаш).

**МИҢНЕХА́НОВ** Рөстәм Нургали улы (1.3.1957, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а.), дәүләт эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (2003), Россиянең атказ. спорт остасы (2003). Казан а.х. ин-тын (1978), Мәскәү совет сәүдәсе ин-тын (1986) тәмамлый. 1978–85 елларда Саба р-нында: район «Сельхозхимия» берләшмәсендә инженер (1980 гә кадәр), 1980–83 тә Саба урман сәнәгате хуҗалыгында өлкән инженер, баш энергетик, 1983 тән район кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары. 1985–93 тә Арча р-нында: район кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары (1990 га кадәр), 1990–92 дә халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе. 1992 дән Биектау р-ны хакимияте башлыгының 1 нче урынбасары, 1993–96 да Биектау р-ны хакимияте башлы-

гы. 1996–98 дә ТР финанс министры. 1998–2010 да ТР Премьер-министры. 2010 нан ТР Президенты. Респ-ка хөкүмәтен Россиядә икътисади кризис — халык хуҗалыгында, ш.у. социаль-сәяси, милли-мәдәни проблемалар комплексын тудырган 1998 нең август дефолты башланган чордан җитәкли. Ул вакытта сәнәгатьнең эшчәнлек нәтиҗәсе тискәре балансլы була, халыкның тормыш дәрәҗәсе күпкә түбәнәя. М. икътисадны дәүләт тарафыннан җайга салуга, яңа структуралы финанс-сәнәгать төркемнәре оештыруга, кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итүгә, ТР сәнәгатенең Россия төбәкләрендәге һәм чит илләрдәге пр-тиеләр б-н элемтәләрен булдыруга һәм үстерүгә басым ясый. Респ-ка хөкүмәте тарафыннан пр-тиеләрнең финанс хәлен яхшырту, җитештерүчеләрнең салым бурычларын реструктуризацияләү механизмнарын тәртипкә салу, бюджет планын үтәүдә казначейлык системасына күчү буенча зур эш башкарыла. М. җитәкчелегендә ТР МК тузган торакны бетерү, торак пунктларны газлаштыру, нефть-газ комплексын үстерү һәм энергия саклау, инновация-җитештерү технопарклары төзү, кече һәм урта эшмәкәрлек үсешенә ярдәм итү, Татарстан халкын адреслы яклау программаларын гамәлгә ашыра. Әлеге чаралар нәтиҗәсендә ТРда финанс-икътисади хәл тотрыклылана, 2000 еллар башыннан социаль-икътисади үсеш тизләнә. М.ның турыдан-туры катнашы б-н соңгы елларда респ-када алдынгы технологияләрне булдыру һәм гамәлгә ашыру, инновацияләргә инвестицияләр кертүне арттыру буенча киң колачлы эш алып барыла. 2011 дә эре «ТАНЕКО» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләре комплексының беренче чираты сафка баса, аның икенче чиратын төзү дәвам итә. Казанда «Универсиада-2013»кә әзерләнү һәм аны уздыру буенча планнар уңышлы рәвештә тормышка ашырыла. М. катнашында «Алабуга» аерым икътисади зонасында — Алабуга һәм Чаллы шәһәрләрендә «Форд Соллерс Холдинг» компаниясе б-н бергә Ford автомобильләренең төрле модельләрен эшләп чыгару, Менделеев шәһәрендә интеграцияләнгән аммиак, метанол һәм гранулалы карбамидны интеграцияле җитештерү, ш.у. «СМАРТ-сити Казан» халыкара инвестицион технополисын булдыру һ.б. буенча яңа зур проектлар гамәлгә ашырыла башлый. М. ярдәме б-н Казанның тарихи үзәгендә тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклау һәм торгызу юнәлешендә планлы эш башлана. Казанда һәм республиканың башка шәһәрләрендә торакларны капиталь төзекләндерү планнарын үтәүдә җитди уңышларга ирешелә. М. РФ Халыкара сәүдә оешмасына кергән шартларда ТРның аграр сәнәгать комплексы пр-тиеләре эшчәнлеген тиешенчә оештыру һәм яраклаштыру



Р.Н. Миңнеханов.

мәсьәләләренә зур игътибар бирә. Хәзерге вакытта респ-ка дәүләт органнарының оештыру эшчәнлегендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе — авылларны каты өслекле юллар б-н тоташтыру, гомуми белем бирү мәктәпләрен, мәктәпкәчә балалар учреждениеләрен («Бәләкәч» программасы буенча) төзү, реконструкцияләү һәм төзекләндерү. «Электрон Татарстан» проекты — ТР дәүләт структураларында документлар әйләнешен уңышлы рәвештә электрон технологияләргә күчерү тәҗрибәсе илдә зур танылу алды.

2012 дә М. максатлы инновацияләр үсеше өчен уңайлы хокукый, икътисади, социаль һәм иҗади мохит тудыру буенча тәҗрибә уртаклашуны стимуллаштырудан гыйбарәт РФнең Инновацияле төбәкләре ассоциациясе советы рәисе булып сайлана. Хезмәтләре икътисад, агросәнәгать комплексында базар реформалары мәсьәләләренә карый. А.х. кооперациясе, а.х. комплексында инновацияләр менеджменты буенча уку ярдәмлекләре авторы. 1995–96 да һәм 1999–2004 тә ТР халык депутаты. «Супер-Шипы» кышкы трек автоузышында Россия (2000), Д2 автокроссында Европа чемпионы (2004, 2005). Йөк автомобильләре арасында уздырылган «Дезерт-Челендж» ралли-марафоннарында җиңүче (2000–02). РФ хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге лауреаты (2009). 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Дуслык, Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен», Казакъстан Республикасының Достык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



РФ Президенты В.В.Путин, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, ТР Дәүләт киңәшчесе М.Ш.Шәймиев Болгар шәһәрендә. 2012.

Х е з м.: Рекомендации по совершенствованию кормовой базы пригородных хозяйств в условиях рынка. К., 1996 (автордаш); Аграрный сектор Татарстана в условиях развития рыночной экономики. К., 1997 (автордаш); Организационно-экономические основы развития инновационных процессов в АПК. М., 2000; Инновационный менеджмент. М., 2002 (автордаш). *Г.С.Сабирҗанов.*

**МИҢНУ́ЛЛИН** Илгиз Марс улы (22.5.1953, Казан), полиция генерал-лейтенанты (2007), ТРның атказ. хокук белгече (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук радиофизика кафедрасында инженер булып эшли. 1976 елдан ТР Дәүләт иминлеге ком-тында, РФ Федераль иминлек хезмәтенең ТР буенча идарәсендә. 2003–05 тә РФ Наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе башлыгының 1 нче урынбасары, 2005 тән — башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МИҢНУ́ЛЛИН** Ким Мөгаллим улы (4.1.1959, БАССРның Илеш р-ны Нәҗәде а.), әдәбият белгече, фольклорчы, филол. фән. д-ры (2002), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). 1985 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1988–96 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында; 1996–2006 да ТР МК Аппаратында, 1996 дан ТРның «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы Законын гамәлгә кертү ком-ты сәркәтибе, 1999 дан ТР халыклары телләрен үстерү бүлеге мөдире. 2006 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты директоры. Хезмәтләре фольклористика (татар җыр поэзиясе тарихы һәм теориясе), социолингвистикага (ТРда тел сәясәте мәсьәләләре) карый.

Х е з м.: Шигърият һәм җыр. К., 1998; Басма сүз һәм татар җырлары. К., 2000; Һәр чорның үз җыры. К., 2003; Тел язмышы — халык язмышы. К., 2008 (автордаш.); Современные этнокультурные процессы в молодёжной среде Татарстана: Язык, религия, этничность. К., 2000 (автордаш); Песенное творчество татарского народа. К., 2006.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2008. Т. 4.

**МИҢНУ́ЛЛИН** Раил Барый улы (11.1944, Казан), журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1967–73 елларда Казан «Элекон» з-дында эшли. 1973–79 да 1 нче Казан төзелеш трестының күптиражлы «На стройке» г-тасы хәбәрчесе. 1979–99 да «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясендә: радиотапшыруларның яшьләр редакциясе мөхәррире, 1983 тән сәнәгать тапшырулары редакциясенең баш мөхәррире. 1989 дан «Идел б-н Урал арасында» радиожурналы мөхәррире. 2000 нән «Татэнерго» ҖБнең «Энергосбыт» пр-тиесендә җәмәгатьчелек б-н багланышлар буенча әйдәп баручы белгеч. Татарстанда сәнәгать үсеше, ш.и. эре пр-тиеләр: «Татнефть», «Түбәнкаманефтехим», «КамАЗ», «Түбәнкамашин» һ.б. турындагы



Р.М. Миңнуллин.



Т.Г. Миңнуллин.

репортажлар, мәкаләләр һәм төрле язмалар авторы. Иҗатының төп темасы — халыклар дуслыгын ныгыту. Респ-ка Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге (1986), Россия Журналистлар берлеге бүләге (1998) лауреаты.

*Ю.М.Ханжин.*

**МИҢНУ́ЛЛИН** Ринат Гыйззәтулла улы (28.7.1935, Актаныш р-ны Актаныш а.), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан ун-тында эшли, радиофизика кафедрасының өлкән фәнни хезмәткәре (1989 дан). 1995 тән Казан энергетика ун-тында, электроэнергетика системалары һәм челтәрләре каф. мөдире (1997–2001), проф. (2001 дән). Хезмәтләре ярымүткәрүчән һәм үткәрүчән тирәлекләрне локация алымнары б-н радиофизик тикшерүләргә карый. М. спорадик ионосфера катламы Es параметрлары вариацияләренең закончалыкларын билгели, әлеге катламның фаразланган эмпирик моделен төзи. Бу модель Халыкара радиоешлыклар ком-ты тарафыннан Es катламының кыска дулкынлы радиоэлемтәгә тәэсирен фаразлауда кулланыла. Электр линияләре диагностикасы өчен төрле радиоэлектрон үлчәү комплекслары, цифрлы ионозондлар һәм стендлар әзерләүдә катнаша. М. тарафыннан эшләнгән ионозонд «Циклон-9» РФдә күпләп чыгаруга кабул ителә (1993). М. Казанның беренче электромагнитик картасын төзүдә катнаша (1993), аның нигезендә электромагнит кырларының көчәнешлелеге күпкә югары булган зоналары ачыклана. «Гранит» телемеханика комплексы өчен диагностика системасын, электр тапшыру линияләренә ерактан торып диагностика ясау технологиясен эшли, бу хезмәтләре «Татэнерго» АҖнең Идел буе электр челтәрләрендә гамәлгә кертелә (1995–99). Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1986), СССР Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы бүләге (1987) лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Прогностическая радиофизическая модель среднеширотного спорадического слоя Es // Ионосферные исследования. 1997. № 50; Методы и аппаратура определения мест повреждений в электросетях. К., 2002; Методы и средства высокочастотной связи в энергосистемах. К., 2004.

*Р.Г.Усманов.*

**МИҢНУ́ЛЛИН** Роберт Мөгаллим улы (1.8.1948, БАССРның Илеш р-ны Нәҗәде а.), шагыйрь, журналист, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), БРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1998), ТРның халык шагыйре (2005). 1966–68 дә Илеш р-ны «Маяк» г-тасында әдәби хезмәткәр. Казан ун-тын тәмамлагач (1973), «Яшь ленинчы» (1990 нан «Сабантуй») г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1977–83 елларда «Казан утлары» ж-лында өлкән мөхәррир, соңрак җаваплы сәркәтип. 1983–86 да ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-тында әдәби-нәфис тапшырулар редакциясенең баш мөхәррире. 1986–95 тә «Яшь ленинчы» г-тасының баш мөхәррире. «Татарстан» телеканалында «Шигъри тәлгәшләр» (1976–83), «Ихлас» (1993–95), «Китап» (2008 дән) тапшыруларын алып бара. 1995 тән ТР Дәүләт Советында: Мәдәни һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссия рәисе, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары (2000–04), 2004 тән ТР законнары текстларын тәңгәлләштерү комиссиясе рәисе. Баштагы чор иҗатында дөньяга, табигатькә яңача карашлы лирик шигырьләре «Идел» альманахында, «Казан утлары» ж-лында, «Беренче карлыгачлар» (1970), «Безнең бәйрәмнәр» (1974) исемле күмәк җыентыкларда урын ала; аларның герое — шаян-шук фантазёр, кызыксынучан малай. Шагыйрь балалар сөйләменә хас лексиканы, ятышлы гыйбарәләрне бик оста куллана, аларның интонациясен, күңел халәтен ачып бирә («Акбай цирк карый», 1978; «Айга очтык!», 1982; «Глядит в окошко человек», М., 1986 җыентыклары). Күп кенә әсәрләрендә көндәлек мәшәкатьләрне, өлкәннәр б-н балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне, сабыйлар дөньясын калку сурәтли («Энекәш кирәк миңа», 1990; «Дөньядагы иң зур алма», 1992 — Һ.К.Андерсен исем. халыкара Мактаулы диплом, 1994; «Ох, уж эти взрослые!», 1993; «Кучтәнәч», 1995; «Алма бабай», 1997; «Возвращение», 2000; «Балачакка ешрак кайтыгыз», 2002; «Сөенсеннәр әле сабыйлар», 2002; «Мальчик, каких еще мир не видал», 2003 — җыентыклары). М. иҗаты балалар тематикасы б-н генә чикләнми. Аның шигырьләрендә мәхәббәт лирикасы, туган җир б-н бәйле әнкәйләр темасы да зур урын алып тора («Бәхетле булыгыз!», 1976; «Мәңгелек сәфәр», 1983; «Әнкәйнең ак чәчләре», 1986; «Сандугачның туган көне», 1990; «Талбишек»,1995; «Әнкәй безне Сөннән алып кайткан», 2002; «Күңелләр нечкәргәндә», 2004; «Татарларым», 2012 җыентыклары). М.ның лирикасы тирән фәлсәфәгә корылган, милли мотивлар б-н сугарылган. Шигъри теле юмор б-н баетылган. Шигырьләре гади, аңлаешлы, төгәл, ачык детальләр хас. М. поэзиясенең музыкальлеге күп кенә композиторларның да игътибарын җәлеп итә. Аның шигырьләренә композиторлар Р.Яхин, С.Садыйкова, Р.Ахиярова, М.Шәмсетдинова, Р.Хәсәнов, Р.Абдуллин, Ф.Әбүбәкеров, И.Закиров, О.Усманов язган җырлар аеруча популярлык казана. Публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре «Шагыйрь генә булып калалмадым» (1998), «Мин — нечкә күңелле сәясәтче» = «Я — сентиментальный политик» (1999) җыентыкларына тупланган. Әсәрләре рус, башкорт, украин, белорус, чуаш, әзәрбайҗан, удмурт, мари, каракалпак, инглиз, поляк, төрек телләренә тәрҗемә ителә. ТР Балалар фонды рәисе (1988–94), 2012 дән «Татар гаиләсе» бөтенроссия иҗтимагый фонды рәисе. 1990–95 тә ТР халык депутаты, 1995 тән ТР Дәүләт советы депутаты. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1982), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. (1997), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре (1998), ТР Фән һәм мәгариф министрлыгының К.Насыйри исем. (2011) бүләге лауреаты.

Ә с ә р.: Уфа-Казан юллары. К., 1998; Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2004; Әсәрләр: 7 томда. К., 2008; Ещё не вечер. К., 2008.

*Әд.:* У р м а н ч е Ф. Роберт Миңнуллин: Шигъри осталык серләре. К., 2005; Хәзерге татар әдәбияты һәм Роберт Миңнуллин. К., 2008; А р - С е р ш В. Путешествие с поэтом Р.Миннуллиным из Казани в Уфу и обратно. К., 2008; С а р ч и н Р. Лирика Роберта Миннуллина. К., 2012.

*Г.М.Габделхакова.*

**МИҢНУ́ЛЛИН** Туфан Габдулла улы (25.8.1935, Кама Тамагы р-ны Олы Мәрәтхуҗа а. — 2.05.2012, Казан), драматург, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РСФСР, БРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978, 1984, 1995), ТРның халык язучысы (2005). М.С.Щепкин исем. театр уч-щесен (Мәскәү, 1961), М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1977) тәмамлый. Уку елларында рус һәм Европа театр сәнгатенең иң яхшы үрнәкләре б-н якыннан таныша. Минзәлә драма театрында (1961–62), Татар акад. театрында (1962–63) актёр, ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында өлкән мөхәррир (1963–64), «Чаян» ж-лында әдәби хезмәткәр (1964–68). 1984–89 да ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе, 1994 тән татар ПЕН-үзәге президенты. Беренче әдәби тәҗрибәләре — бер пәрдәле пьесалар, скетчлар, шаян хикәяләр. М.ны драматург итеп танытკан пьесалары: иҗади яшьләр тормышыннан алып язылган «Миләүшәнең туган көне» драмасы (1968 дә сәхнәгә куела) һәм гаиләдәге әхлак проблемаларын үз эченә алган «Нигез ташлары» комедиясе (1968 дә сәхнәгә куела). Язучы, драматургиянең төрле жанрларында актив иҗат итеп, күбесе Татарстан, Башкортстан, Казакъстан, Үзбәкстан, Чуаш, Мари респ-каларының театр сәхнәләрендә уйналган уңышлы әсәрләр яза, кайберләре республика һәм үзәк телевидение аша күп тапкырлар күрсәтелә, театр өлкәсенә караган үзәк журналларда басылып чыга. М.ның драматургиясе жанрлар, жанр формалары төрлелеге, халыкчан образлы, җор телдә язылган диалогларның җанлы, табигый яңгыравы, композицион яктан җыйнак-төгәл булуы б-н җәлеп итә. пьесаларының күбесендә хәзерге заманның катлаулы проблемалары чагылыш таба. М. драматургиясендә стиль һәм идея юнәлешләренең берсе — шәхес формалашуга багышланган пьесалар: «Китәр юлың еракмы?» (1975 тә куела), «Адәм баласына ял кирәк» (1980 дә куела), «Монда тудык, монда үстек» (1982 дә

куела). Бу юнәлеш бигрәк тә «Миләүшәнең туган көне» (1968 дә куела), «Дуслар җыелган җирдә» (1976 да куела), «Хушыгыз!» (2000 дә куела) трилогиясендә гәүдәләнеш таба. Бу драмаларда тулы буын татар иҗади интеллигенциясенең катлаулы язмышы күзәтелә, җәмгыятьнең кеше алдында җаваплылыгы проблемасы күтәрелә. Икенче бер юнәлеш пьесаларында инде шәхес буларак формалашкан персонажлар үзәккә алына. «Ир-егетләр» (1971 дә куела), «Үзебез сайлаган язмыш» (1973 тә куела), «Ай булмаса, йолдыз бар» (1977 дә куела), «Әниләр һәм бәбиләр» (1983 тә куела) пьесаларының геройлары тормышта үз кыйбласын тапкан, тормыш авырлыкларына каршы торырлык, максатчан шәхесләр. Идея-эчтәлек ягыннан аеруча игътибарга лаек әсәре — «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976 да куела) фәлсәфи комедиясе. Монда кешенең рухи көченең тамырлары ачып күрсәтелә, яшәүнең үлемнән көчлерәк булуына басым ясала. Тагын бер юнәлешне тарихи вакыйгаларга һәм тарихи шәхесләргә багышланган пьесалар тәшкил итә. «Ат карагы» (1972) драмасының прототибы — хакимият тарафыннан тудырылган һәртөрле ирексезләүләргә каршы чыгыш ясап, шәхси азатлыгын яклаучы тарихи шәхес; «Моңлы бер җыр» (1981 дә сәхнәгә куела) романтик трагедиясенең геройлары — М.Җәлил һәм аның көрәштәшләре; «Без китәбез, сез каласыз» (1986 да куела) драмасының төп герое — халык шагыйре Г.Тукай; «Агыла да болыт агыла» (2001 дә куела) пьесасыныкы — шагыйрь Х.Туфан; «Канкай угылы Бәхтияр» (1974 тә куела) драмасыныкы — Е.Пугачёв көрәштәшләренең берсе. 1990 елларда М. ның драматургиясе яңа темалар һәм образлар б-н баетыла. «Вөҗдан газабы» (1987 дә куела) пьесасында автор җәмгыять төзелеше алмашынуның кеше аңында нинди үзгәрешләргә китерүен күрсәтә; «Илгизәр + Вера» (1994 тә куела) драмасы катнаш никахлар мәсьәләсенә карый; «Шәҗәрә» (1998 дә куела) пьесасы буыннар күчеше проблемаларын чагылдыра. М. татар халкының язмышы, тел, мәдәният мәсьәләләренә еш мөрәҗәгать итә. Илдә барган үзгәрешләрнең асылына төшенергә, ничә гасырлар яшәп килгән халык традицияләренең, рухи байлыгыбызның югала бару сәбәпләрен ачарга тырыша. «Сөяркә» (2001 дә куела) драмасында мәхәббәт һәм бурыч кебек әхлак проблемалары үзәккә алына. «Эзләдем, бәгърем, сине» (2001 дә куела), «Шулай булды шул» (2003 тә куела), «Алты кызга бер кияү» (2006 да куела) пьесаларының геройлары — яшәү мәгънәсен эзләүче персонажлар. М. ш.у. Г.Камал, К.Тинчурин традицияләрен дәвам итүче үзенчәлекле комедиограф та. Комедияләре форма төрлелеге б-н аерылып тора: «Әлдермештән Әлмәндәр» — характерлар комедиясе булса, «Яшьлегем — җүләрлегем» (1978 дә куела) һәм «Йөрәк маем» (1997 дә куела) — вакыйгалар комедиясе, «Диләфрүзгә дүрт кияү» (1972 дә куела) — водевиль, «Бәйләнчек» (1982 дә куела) һәм «Бәҗә мал түгел, кәҗә туган түгел» (1992 дә куела) — сатирик комедияләр, «Гармун белән скрипкә» (1987 дә куела) һәм «Гөргөри кияүләре» (1995 тә куела) — музыкаль комедияләр. Балалар өчен 20 ләп пьеса, ш.и. Акбай турында 7 пьеса иҗат итеп («Авыл эте Акбай», «Акбай нигә күңелсез?» һ.б.), язучы балалар драматургиясенә дә өлешен кертә. М. — җор телле хикәяче, туры сүзле публицист һәм тәнкыйтьче дә. Ул «Дуслык хакына» (1965), «Чишмә җыры» (1968; рус теленә тәрҗемәдә «Милые мои», 1979) хикәя җыентыклары, тормыш вакыйгалары турында фәлсәфи уйланулар б-н баетылган «Утырып уйлар уйладым» (1–3 кит., 1997–2005), «Татарның бер баласы» (2003) көндәлек язмалары авторы. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты, 1989–92 дә СССР халык депутаты, 1995 тән ТР халык депутаты. Ленин бүләге һәм СССР Дәүләт бүләге буенча ком-т әгъзасы (1990–92), Азия һәм Африка илләре тынычлык ком-ты әгъзасы (1985–92). Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1974), ТАССРның Г.Тукай исем. (1979), РСФСРның К.Станиславский исем. (1979) Дәүләт бүләкләре лауреаты. «Почёт билгесе», «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә. Шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогында М. музее эшли.

Ә с ә р.: Ир-егетләр: Пьесалар. К., 1974; Монда тудык, монда үстек.: Пьесалар. К., 1985; Ай булмаса, йолдыз бар: Пьесалар. К., 1996; Робагыйлар. К., 1999; Сайланма әсәрләр: 10 томда. К., 2002.

*Әд.:* Ә х м ә д у л л и н А. Халыкчан характерларга омтылганда // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; ш у л   у к. Үзе сайлаган язмыш // Дөреслеккә ирешү юлында. К., 1993; М о л ч а н о в Ю. Драматург и режиссёр // Дружба народов. 1983. № 11.

*А.Г.Әхмәдуллин.*

**МИҢНУ́ЛЛИН** Фәрваз Мөхәммәдулла улы (5.8.1934, Арча р-ны Ишнарат а. — 11.12.1994, Казан, туган авылында җирләнә), әдәбият тәнкыйтьчесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1959–61, 1965–76 да «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире, 1977–84 тә ТАССР Язучылар берлегендә, 1984 тән Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөдире, баш мөхәррир (1992–94). «Якты юллар» (1975), «Прозаның гражданлык йөзе» (1983), «Затлылык» (1989), «Балта явызлар кулында» (1994) җыентыклары авторы. Аларда агымдагы әдәби процесска анализ ясала, Ә.Еники, Ф.Хөсни, Г.Әпсәләмов, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев, Р.Төхфәтуллин һ.б. язучыларның иҗади портретлары тасвирлана. М. иҗатына гражданлык хисе, язучы осталыгының үзенчәлеген күрсәтә белү хас. Рус теленнән татар теленә Г.Уэллсның «Человек-невидимка» («Күренмәс кеше», 1979), Дж.Лондонның «Мартин Иден» (1982) әсәрләрен һ.б.ны тәрҗемә итә.

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т.Н. Тәнкыйть күгендәге йолдыз // Казан утлары. 2004. № 5; Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*Т.Н.Галиуллин.*

**МИҢНУ́ЛЛИНА** Асия Минвәли кызы (26.11.1952, Ленинград), сынчы, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2006). Казан сәнгать уч-щесен (1971), В.И.Мухина исем. югары сәнгать-сәнәгать уч-щесен (1984) тәмамлый.



А.М.М и ң н у л л и н а. «Су ташучы». Бронза. 2006. Казан.

1984–89 елларда ТАССР Сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). 2001 дән Казан сәнгать уч-щесенең скульптура бүлегендә укыта. Әйдәп баручы сынчы буларак, М. вак һәм декоратив пластикада, көнкүреш һәм портрет жанрларында, монументаль скульптурада уңышлы эшли. Аның иҗатына эмоциональ-психологик уй-ниятләрнең, сәнгать теленең ачыклыгы хас: «Бусага янында» (үзле балчык, 1989), «Карт һәм эт» (җиз, 1989), «Төш» (кызыл агач, 1999), «Сөембикә улы белән» (үзле балчык, 2002), «Агач» сериясе (үзле балчык, 2003). М. — татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләренең портретлары авторы: «Муса Җәлил» (бюст, җиз, 2006), Нәҗип Җиһанов (бюст, җиз, 2006). Аның иҗаты шәһәр архит-ра-фәза мохитендәге монументаль-декоратив скульптура үсешенә йогынты ясый: Казандагы «Күгәрченнәр» фонтаны (җиз, 1996), «Су ташучы» һәйкәле (җиз, 2006) һ.б. М. ш.у. татар фольклоры һәм шигърияте сюжетларына әсәрләр иҗат итә: «Алтынчәч» (җиз, 1995), «Су анасы» (җиз, 1995), «Гөлчәчәк» (җиз, 1996). Сынчы үзенең монументаль хезмәтләрендә акад. традицияләргә иярә, гомумиләштерү һәм архитектоник ачыклыкка омтыла: «Әфганстанда һәлак булган сугышчы-интернационалистларга һәйкәл» (җиз, 1998, Ка-



А.М.М и ң н у л л и н а. «Күгәрченнәр». Бронза. 1996. Казан.



Л.Р. Миңнуллина.

зан), Казанның 1000 еллыгы паркында Кол Гали һәйкәле (җиз, 2005, А.В.Балашов б-н авторлыкта), В.И.Качалов исем. Казан драма театры атриумындагы В.И.Качалов һәйкәле (җиз, 2005).

Респ-ка (1984 тән) һәм бөтенроссия (Тверь ш., 1989, 2 нче премия; Мәскәү, 2001) күргәзмәләрендә, Халыкара скульптура симпозиумында (Алей ш., Ливан, 2000) катнаша. Шәхси күргәзмәсе 1996 да уза (Казан). Бакый Урманче исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Брауншвейг шәһәре муниципалитетының сәнгать тупланмасында (Германия), шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Саттарова Л. Скульптор и город // Дизайн и новая архитектура. 1999. № 2; Кривошеева Т. Сокровенная поэзия творений Аси Минулиной // Казань. 2006. № 8–9.

*Л.Н.Донина.*

**МИҢНУ́ЛЛИНА** Ләлә Рафил кызы (21.8.1952, Казан), драма актрисасы, ТРның халык артисты (1999). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, 1974 елда Татар. респ-ка күчмә театрында (хәзер Татар драма һәм комедия театры) эшли башлый. М.ның Галимә («Кара йөзләр», М.Гафури повесте буенча) ролендәге дебюты талантының аеруча истә калырлык якларын ача: сәхнә тормышының психологик чынлыгы, героинясының эмоциональ халәтен яктыртканда күренгән эчкерсезлек, нечкә тоемлау, импульсивлык; драматургия материалының поэтик тукымасын тирән тоеп, аны тиешле дәрәҗәдә җиткерә белү. Актриса, Мөнәвәрә («Хәзинә», Г.Ахунов романы буенча), Мөслимә («Нигез ташлары», Т.Миңнуллин) кебек замандашлары образларын гәүдәләндереп, игътибарын аларның рухи дөньясына юнәлтә, үз-үзләрен тотышының, ягъни берәүнең кыю, икенче берсенең кыюсыз, йомшак булуының төп чыганагын эзли, шул рәвешчә тамашачыны кешенең үз язмышы өчен җаваплы булуы турында уйланырга мәҗбүр итә. Логик эзлеклелек, сәхнәдә үз-үзен тотуының гадилеге һәм табигыйлеге, башкарудагы төгәллеге һәм эчкерсезлеге актрисаның Динә («Үзебез сайлаган язмыш», Т.Миңнуллин), Лена («Зарыгып көткәнем», А.Д.Салынский), Зөбәрҗәт («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Тәлли («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Гөләндәм («Яшьлек хатам — йөрәк ярам», Д.Салихов), Алинә («Мәхәббәт турында куркыныч әкият», Р.Х.Солнцев), Ана («Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Хәлимә («Резидәкәй», Ш.Мәҗитов), Фәйрүзә («Исәнлеккә-саулыкка», Р.Хәмид), Зәкия («Гайфи бабай, өйлән давай!», Г.Зәйнәшева), Нурия («Сакла сөюне — ташлама берүк!», Х.Төхфәтуллов), Карчык («Алтын көз», Ш.Фәхретдинов) рольләрендә аеруча күзгә ташлана. Образның асылына тирәнтен үтеп кереп, М. драматургия материалының чикләрен киңәйтә, үзе башкарган рольгә тирән мәгънә, зур әһәмият һәм масштаблылык өсти. И.Грекова повесте буенча куелган «Тол хатыннар көймәсе» спектаклендә ул тудырган Әнисә образы аның зур казанышы булып тора. М., теге яки бу образда хатын-кыз фидакарьлеген гәүдәләндереп, үз героинясының рухи кичерешләрен бөтен нечкәлекләре б-н җиткерә белә.



Л.Р. Миңнуллина Галимә ролендә («Кара йөзләр», М.Гафури; Закир ролендә – И.Әхмәтҗанов).

*Д.Ә.Гыймранова.*

**«МИР БИ́ЗНЕСА»** («Бизнес дөньясы»), эшлекле даирәләр өчен рәсемле мәгълүмати журнал. 1997 елның гыйнвар аеннан Казанда рус телендә нәшер ителә. Мөхәррире — А.С.Бикбаева. Эшмәкәрлек һәм сәүдә үсеше, ТРның якын һәм ерак чит илләр б-н икътисади бәйләнешләрен ныгыту мәсьәләләре яктыртыла; Татарстандагы товар җитештерүчеләрнең игъланнары урнаштырыла, аларның иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышы турында хәбәрләр басыла; ТРда эшмәкәрлек үсешен яктырткан мәкаләләр бирелә.


**«МИР ИСЛА́МА»** («Ислам дөньясы»), Россиядә исламияткә багышланган беренче махсус журнал. Император карамагындагы Шәрекъне өйрәнү җәмгыяте органы. 1912–13 елларда Петербургта рус телендә нәшер ителә, барысы 16 саны чыга. Беренче саны 1912 нең мартында дөнья күрә. 1912 дә — квартал саен (4 сан), 1913 тә ай саен (12 сан) басыла. Россия Эчке эшләр министрлыгы башлангычында мөселманнар тормышын яктырту, ил эчендәге мөселман халыкларының милли хәрәкәтен контрольдә тоту һәм аларга чит илләрдәге диндәшләренең йогынтысын күзәтеп тору максатында нәшер ителә. Мөхәррире итеп атаклы шәркыятьче В.В.*Бартольд* билгеләнә, редакция коллегиясе составына күренекле галимнәр И.Б.Крачковский, А.Н.Самойлович, А.Ф.Хащаб, А.Э.Шмидт керә. Журналда, редколлегия әгъзаларыннан кала, Шәрекъне өйрәнүчеләр: В.А.Гордлевский, Н.Н.Мартинович, А.А.Семёнов, А.Г.Туманский h.б.ның мәкаләләре басыла. Эчке эшләр министрлыгы куйган максаттан аермалы буларак, Бартольд Россиядә исламны өйрәнүне Европа фәне дәрәҗәсенә күтәрергә тырыша. Академик характердагы, Россия мөселманнары проблемаларыннан ерак булган мәкаләләр дә (Шмидтның «Дин буларак ислам турында очерклар» («Очерки ислама как религии»), С.Смогоржевскийның «Алжирдагы әдәбият факультетының фәнни эшчәнлеге хакында» («Из научной деятельности словесного факультета в Алжире»), Хащабның «Хәзерге Персиянең икътисади хәле һәм аның башка илләр б-н сәүдәсе» («Экономическое положение современной Персии и её торговля с прочими странами»), Бартольдның «Хәлифә һәм солтан» («Халиф и султан»), шәркыятьчеләрнең Афинада үткән XVI Халыкара конгрессы турында хисап, ш.у. Европада исламны өйрәнүчеләрнең эшләренә рецензияләр, ш.и. венгр галиме Г.Вамбериның 20 йөз башында татарлар арасындагы мәдәни яңарышны хуплаган «Русия татарлары арасында мәдәни хәрәкәт» («Культурное движение среди русских татар», 1912, № 2) мәкаләсенә җавап басыла. 1912 дә редакция исламны өйрәнүне яктыртуга багышланган басмаларга — немецчә «Der Islam» («Ислам»), инглизчә «The Moslem World» («Мөселман дөньясы»), французча «Revue du Monde Musulman» («Мөселман дөньясына күзәтү») журналларына күзәтү ясый. Журналның артык фәнни булуы Эчке эшләр министрлыгы җитәкчелегенә ошамый, шул сәбәпле 1913 тә Гамәли Шәрекъ академиясе (Петербург) укытучылары тарафыннан Д.М.Позднеев җитәкчелегендә яңа редакция оеша. Мәкаләләрнең күбесен авторын күрсәтмичә баса башлыйлар. Төп игътибар мөселман дөньясындагы иҗтимагый-сәяси процессларга, аларның төп юнәлешләренә һәм шәхесләренә юнәлтелә. «Панисламизм мәсьәләсенә карата» («К вопросу о панисламизме»), «Панисламизм һәм пантюркизм» («Панисламизм и пантюркизм»), «Россиядә пантюркизм» («Пантюркизм в России»), «Ике агым» («Два течения») мәкаләләрендә татар милли хәрәкәтенең либераль өлеше лидерлары буларак — Ш.Мәрҗани, Г.Баруди, З.Камали, Р.Ибраһимов, М.Бигиев, консерватив өлеше буларак «Дин вә мәгыйшәт» г-тасы редакциясе күрсәтелә. Мәкаләләрдә Җ.Вәлиди, Й.Акчура, Г.Ибраһимовның пантюркизмга үзенчәлекле карашлары яктыртыла. Татарлар арасында исламдагы реформаторлык хәрәкәтенең идеологлары буларак М.Бигиев, З.Камали исемнәре атала. Реформаторлык тенденциясе татар матур әдәбиятында да күзәтелә. «Мөселман вакытлы матбугаты» бүлегендә Россия, Төркия, Мисыр матбугатына күзәтү дә ясала. Төп игътибар татар вакытлы матбугатына бирелә («Ак юл», «Бәянелхак», «Вакыт», «Дин вә мәгыйшәт», «Идел», «Кояш», «Мәктәп», «Нур», «Сибирия», «Хокук вә хәят», «Шура», «Йолдыз»), алардагы мәкаләләр Россия мөселманнары тормышын өйрәнүдә төп чыга-

нак булып тора. Редакция Россия Эчке эшләр министрлыгының мөселман дини оешмаларын үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча киңәшмә уздырырга җыену хәбәренә карата татар матбугатының фикерләрен анализлый. Саннан-санга Россия мөселман уку йортларындагы вазгыятькә күзәтү рәвешендә «Русия мөселманнарында мәктәп мәсьәләсе» мәкаләләр сериясе басылып бара. Татар матбугатындагы мәкаләләрне тикшерү нигезендә журналда мөселман җәмгыятендә хатын-кызларның хәле үзгәрү, аларның тигез хокуклылыкка, белемгә, иреккә омтылу тенденциясе билгеләп үтелә. Чит ил тематикасында үзәк урынны Россия мөселманнарына йогынтысы үсү һәм Балкан мәсьәләсенең киеренкеләнә баруына бәйле рәвештә Төркия алып тора. 1913 тә «Мөселман китап елъязмасы» рубрикасында гарәп, авар, казакъ, кумык, кыргыз, татар һ.б. телләрдә басылган яңа китаплар турында Матбугат эшләре буенча баш идарә нәшер иткән «Китап елъязмасы» өзекләр биреп бара. Журнал, акча б-н тәэмин ителмәү сәбәпле, басылудан туктый.

*Әд.:* Х а й р у т д и н о в Р.Р. «Мир ислама»: Из истории создания журнала // Мир ислама. 1999. № 1/2.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«МИРАС»**, айлык иҗтимагый-сәяси, фәнни-популяр һәм әдәби-нәфис журнал. Оештыручылары: «Мирас» ж-лы редакциясе, «Мирас» фондының фәнни советы, ТР Мәдәният министрлыгы. 1991 елдан Казанда татар телендә, 2008 дән рус, төрек, инглиз телләрендә дә нәшер ителә. Баш мөхәррире — М.Җ.*Сәхапов*. Даими рубрикалары:



«Мирас» журналы.

«Милли мәгариф», «Халык иҗаты», «Шигърият», «Тарихи мирас», «Сәяси мирас», «Археологик мирас», «Сәнгать белеме мирасы», «Борынгы бабаларыбыз тарихы», «Алтын Урда тарихы», «Казан ханлыгы тарихы», «Төрки халыклар дөньясы», «Мирас» энциклопедиясе, «Мирас» почтасы» һ.б. Журнал битләрендә татар халкының тарихи-мәдәни мирасы истәлекләре басыла, аларны саклау һәм өйрәнүнең мөһим мәсьәләләре тикшерелә. Журнал татар халкының, Россиянең башка халыкларының мәдәни мирасын пропагандалау буенча зур эш башкара, җәмгыятьнең рухи-әхлакый нигезен булдыру һәм үстерүдә катнаша. «Мирас»та атаклы язучы һәм публицистларның мәкаләләре басыла, журнал б-н Татарстан, РФ һәм чит илләр галимнәре, мәдәният эшлеклеләре хезмәттәшлек итә. 1992 дә редакция Кол Гали исем. Халыкара бүләк булдыра. 2010 да чыгудан туктый. 2012 дән «Чын мирас», 2014 тән «Безнең мирас» булып чыга башлый. Баш мөхәррире — Л.Лерон.

**МИРБУЛА́Т** (Хәйр Булат, Пулат, Мирбулат) (?–1363), Алтын Урда ханы (1362 дән). Җүчи нәселеннән булмаган дип фараз ителә. Алтын Урдадагы тәхет чуалышлары чорында идарә иткән хан. Аксөякләр ярдәмендә *Мөрид* ханны Сарай әл-Җәдид тәхетеннән куа. 1362–63 елларда үз исеменнән акча суктыра. 1363 нең көзендә Сарай әл-Җәдид әмир Мамай тарафыннан басып алынгач, М. тәхеттән төшерелә, үтерелүе ихтимал.

*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Куликовская битва. М., 1980; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

*И.Л.Измайлов.*

**МИРГАЗИ́ЗОВ** Марсель Зәки улы (1.1.1935, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1980), проф. (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Проф. И.М.Оксман шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук ортопедик стоматология кафедрасында эшли. 1961 елдан Кемерово мед. ин-тының ортопедик стоматология кафедрасында, бер үк вакытта (1968 дән) стоматология ф-ты деканы. 1991 дән Казан мед. ун-тының ортопедик стоматология каф. мөдире. Хезмәтләре стоматологиядә форма саклау эффектына ия кушылмалардан үтә сыгылмалы имплантатлар һәм конструкцияләр куллануга карый.

Х е з м.: Применение сплавов с эффектом памяти формы в стоматологии. М., 1991; Сверхпластичные имплантаты и конструкции из сплавов с памятью формы в стоматологии. М., 1993; Аттагмены в зубных протезах. Метод. пособие. К., 2000; Ортопедическое лечение поражений твёрдых тканей зубов чешуйчатыми коронками. К., 2000.

*Әд.:* А н д р е е в И.М., К р а с и л ь н и к о в С.Н. Миргазизов Марсель Закиевич // Стоматологический факультет: История в биографиях. К., 1986.

**МИРГАЛИ́МОВ** Илгизәр Миргасыйм улы (5.8.1942, Сарман р-ны Сарман а.), дирижёр, педагог, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991), пед. фән. д-ры (2001), проф. (2002). 1967 елда Мәскәү мәдәният ин-тының оркестр бүлеген тәмамлый. 1967–75 тә Алабуга сәнгать уч-щесендә, 1975 тән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Халык музыка уен кораллары оркестрларының бөтенроссия һәм респ-ка конкурслары һәм фестивальләре лауреаты. Мәдәни-агарту өлкәсендә эшләячәк белгечләрнең һөнәри юнәлешләре мәсьәләләренә караган фәнни хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Социально-педагогические проблемы профессиональной направленности вузов культуры. К., 1984; Социально-педагогическое моделирование профессиональной направленности в вузах культуры: содержательный аспект. К., 2000; Педагогическое, аксеологическое моделирование профессиональной направленности в вузах культуры. К., 2001.

**МИРГОРО́ДСКИЙ** Александр Сергеевич (12.9.1944, Рязань өлкәсенең Скопин ш. — 23.11.1994, Казан), композитор, пианист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1988). 1973 елда Казан консерваториясен фортепиано (Н.Фомина классы) һәм композиция (А.Леман, А.Монасыйпов, Б.Трубин класслары) буенча тәмамлый. 1963 тән Тува АССРның Чадан шәһәре музыка мәктәбендә, Тула музыка уч-щесендә укыта, Новосибирск консерваториясендә концертмейстер булып эшли. 1971–78 дә, 1982–84, 1991–94 тә Казан консерваториясендә укыта. 1978–82 дә Казан кинохроника студиясе, Казан (Зур драма, Татар акад. театрлары), Киров, Мурманск, Архангельск шәһәрләренең драма театрлары б-н документаль фильмнарга һәм спектакльләргә муз. бизәлеш авторы буларак хезмәттәшлек итә, 1984–91 дә Түбән Кама, Чаллы шәһәрләрендә укыта һәм музыка-агарту эшләре алып бара. Төрле жанрда зур күләмле әсәрләр, бигрәк тә инструменталь музыка: симфонияләр, инструменталь концертлар, аерым музыка уен кораллары һәм музыка уен кораллары коллективлары өчен камера әсәрләре иҗат итә. Композитор М. стиленә интеллектуальлек һәм романтик экспрессия берлеге, муз. тәэсирлелекнең заманча чаралары б-н дә, традицион чаралары б-н дә иркен эш итү хас. Аның музыкасы эмоциональ киеренкелек, рациональлек, форма оригинальлеге, муз. фикер тапкырлыгы б-н аерылып тора. М.ның аеруча еш башкарылган, ш.у. респ-ка үзәк басмаларында басылып чыккан әсәрләре арасында орган өчен язылган полифоник сюиталар, инструменталь концертлар, фортепиано әсәрләре, симф. оркестр өчен «С.Сәйдәшевка музыкаль бүләк», Икенче (А.Ключарёв истәлегенә) һәм Дүртенче «Романтик» (С.Рахманинов истәлегенә) симфонияләре һ.б. бар. М. әсәрләре танылган музыкантлар (Р.Абдуллин, Н.Фомина, М.Сираҗетдинов, А.Әсәдуллин, Д.Антонов, А.Гыйльфанов) һәм музыка коллективлары (ТРның Дәүләт симф.оркестры һ.б.) репертуарына керә. Пианист буларак чыгышлар ясый, А.Монасыйпов С.Гобәйдуллина һ.б.ның иҗади портретларын, рецензияләр, музыка сәнгатенә караган мәкаләләр бастырып чыгара. 1974 тән, СССР, Россия, Татарстан Композиторлар берлекләре әгъзасы буларак, иҗтимагый музыка эшчәнлеге алып бара.

Төп әсәрләре: 5 симфония (1973, 1974, 1975, 1980, 1987); Паганини темаларына симф. вариацияләр (1975); оркестр б-н фортепиано өчен 1 нче (1974) һәм 2 нче (1979) концертлар; соло уйнаучы төрле музыка уен кораллары (фортепиано, флейта, скрипка, виолончель, кларнет, фагот, тромбон) өчен сонаталар; камера инструменталь ансамбльләре өчен әсәрләр (сонаталар, сюиталар, квартет, квинтет); орган өчен полифоник сюиталар; 2 хор кантатасы; вокаль әсәрләр (А.Ахматова шигырьләренә язылган цикл, җырлар һәм романслар); документаль фильмнар һәм драма спектакльләренә музыка һ.б.

*Әд.:* Федотова Л.А. Александр Миргородский // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

*Л.А.Федотова.*

**МИРҖӘ́М** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 42 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 237 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Беренче исеме — Мәңгәр. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, М.дә мәчет була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 848,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 325, 1884 тә — 395, 1905 тә — 268, 1920 дә — 564, 1926 да — 554, 1938 дә — 543, 1949 да — 425, 1958 дә — 433, 1970 тә — 438, 1979 да — 332, 1989 да — 252, 2002 дә 278 кеше.

**МИРЗА́**, к. *Морза*.

**МИРЗА́НОВ** Бәхтияр Гомәр улы (10.11.1892, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Юрактау а. — 17.7.1941, Уфа ш.), шагыйрь. 1910–14 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укый, 1935 тә Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый. 1914 тә Казанга килә, «Сөембикә» ж-лы редакциясендә эшли. 1915–17 дә Оренбургта яши, 1917–18 дә — Сәмәркандта, татар-үзбәк мәктәбендә укыта. 1920 дә Оренбургта сәясәт хезмәткәрләре курсларын тәмамлаганнан соң, Эстәрлетамакта БАССР халык мәгарифе комис-ты инспекторы булып эшли. 1922 дән туган авылында балалар укыта, җир үлчәүче, зоотехник булып эшли. 1937 дән Уфада яши. Беренче шигырьләрен һәм тәрҗемәләрен 1914–17 дә «Аң», «Шура», «Сөембикә» ж-лларында, «Вакыт», «Тормыш», «Кояш» г-таларында бастыра. М. иҗатына романтик мотивлар хас, М. төрле социаль һәм фәлсәфи мәсьәләләр күтәрә («Бәйрәм таңы», 1914; «Хөррият көннәрендә», 1917). «Җен туе», «Илче», «Инкыйлаб», «Исмәгыйль» поэмаларында шагыйрь шул заман җәмгыятенең кимчелекләрен тәнкыйтьли, хатын-кыз хокукларын яклый. «Кызыл чәчәкләр» (Эстәрлебаш, 1921) исемле шигъри җыентык, балаларга багышланган «Ак патша» (1921), «Кечкенә революционер» китаплары авторы.

*Әд.:* Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004; Башкорт әҙәбияте: XX быуат башы. Поэзия. Өфө, 1983. 1 кит.

*З.З.Рәмиев.*

**МИРЗАЯ́НОВ** Вил Солтан улы (9.3.1935, БАССРның Дүртөйле р-ны Иске Кангыш а.), химик, җәмәгать эшлеклесе, химия фән. д-ры (1985), проф. (1985). 1958 елда Мәскәү нечкә химия технологиясе ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона сәнәгате пр-тиесендә, 1963–65 тә Бөтенсоюз нефть һәм газ сәнәгатен комплекслы автоматлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында, 1965 тән Дәүләт органик химия һәм технол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү) эшли. 1992 дә «Московские новости» (№ 38, 20 сентябрь) г-тасында (химия фән. д-ры Л.Фёдоров б-н бергә) «Агуланган сәясәт» («Отравленная политика») мәкаләсен бастыра, анда ул илдә химик корал эшләп чыгару һәм сынауның дәвам итүенә каршы чыгыш ясый; дәүләт серен таратуда гаепләнеп, тикшерү астында була (1992–94); җинаять составы табылмау сәбәпле, эше туктатыла. 1995 тән АКШта яши. Хезмәтләре физик химиягә (адсорбция, хроматография) карый. М. углеродлы, катализатор һ.б. адсорбентларның кинетик сыйфатларын, ш.у. противогаз фильтрларының кинетик үзлекләрен тикшерә. Төрле тирәлекләрдә (һавада, сыеклыкта) физиол. актив матдәләрне аз күләмдә туплау алымнарын эшли һәм бу кушылмаларның микротупланышларын хроматографик табу юлларын тәкъдим итә. 150 дән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Үзенең хокук яклау эшчәнлеге турында М. «Каршылык» («Вызов») дигән мемуарларында язып чыга (2002). Аның тырышлыгы һәм турыдан-туры катнашы б-н инглиз теленнән Б.Ижболдинның «Татарлар тарихыннан очерклар» хезмәте — татар һәм рус телләренә (2003, 2005), Э.Паркерның «Татарлар тарихыннан мең ел» китабы рус теленә (2003) тәрҗемә ителә. Маенхен-Хелфенның «Һуннар дөньясы» («Мир гуннов», инглиз телендә), Рәне Гроссеның «Далалар империясе» («Империя степей», француз телендә) китаплары рус теленә тәрҗемә ителә һәм Интернетка куела.

*Әд.:* Мингазов Р. Вил Мирзаянов: Никогда не изменяйте себе // Татарстан. 2002. № 10.

*В.Г.Абзалова.*

**МИРЗО́ЕВ** Камил Мамед улы (17.2.1939, Төрекмәнстан ССР, Керки ш.), геофизик-сейсмолог, физика-матем. фән. д-ры (1988), Таҗикстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1901). Таҗикстан Респ-касы ФАнең Сейсмик тотрыклы төзелеш һәм сейсмология ин-тында эшли, директор урынбасары (1971–94). Сейсмология буенча БМОның эксперт-консультанты, Әфганстанда биек плотиналар, Кубада атом электростанциясе төзелешен нигезләү буенча сейсмологик тикшеренүләрнең фәнни җитәкчесе була. АКШ, Һиндстан, Мисыр һ.б. чит илләрдә хөкүмәтара фәнни килешүләр буенча эшли. 1994 елдан «Татнефть» АҖнең Татарстан геол.-разведкалау идарәсе «Геодинамика» җитештерү үзәге әйдәп баручы геологы, 1995 тән — башлыгы, 2005 тән РФАнең Җир физикасы ин-ты (Мәскәү) баш фәнни хезмәткәре. Җир өслегенең даими булмаган микротирбәнешләре б-н бәйле кристаллик (Йоффе, Эренфест эффектлары) һәм аморф структураларында киеренке мохитнең пластик деформацияләре сикереше сәбәпләрен билгели. Җирнең зәгыйфь табигый механик вибройогынтыларыннан (микросейсмик) изоляцияләү шартларында коррозиягә чыдам металларны эретү, катламнарның нефть бирүчәнлеген һәм нефть чыгаруны арттыру алымнарын (акад. М.А.Садовский б-н берлектә) эшли, Ромашкино чыганагында скважиналарга су тутыру күләмен көйләү алымнарын тәкъдим итә, бу исә Татарстан терр-ясендә, 1998 дән алып, техноген җир тетрәүләрнең энергиясен һәм санын күпләп киметү мөмкинлеген бирә. Таҗикстан ССРны (Таҗикстан ССРның Әбүгалисина Дәүләт бүләге лауреаты, 1977), СССР, Сантьяго де Куба шәһәрен (Куба Респ-касының Андреас Пой бүләге лауреаты, 1989), Россия, Татарстан һәм Казанны сейсмик районлаштыру, Татарстан һәм Казанның карст куркынычы норматив карталарын эшләүдә катнаша. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сейсмическое районирование территории СССР. М., 1980 (автордаш); Целевая программа сейсмологических исследований территории Татарстана // Мониторинг общественного мнения. 1997. № 3 (автордаш).

**МИРИХА́НОВ** Назиф Мөзаһид улы (24.8.1952, Азнакай р-ны Урсай а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, сәясәт фән. д-ры (2003). Казан төзүче инженерлар ин-тын (1974), СССР МС каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (Мәскәү, 1987) тәмамлый. 1974–85 елларда «Татнефтегазстрой» ҖБдә (Әлмәт ш.) эшли: 1977–78 дә төзелеш-монтаж идарәсе баш инженеры, 1978–80 дә — башлыгы, 1980–81 дә трестның баш инженеры, 1981 дән управляющие. 1985 тән Мәскәүдә: 1987–91 дә СССР Нефть һәм газ сәнәгате пр-тиеләре төзелеше министрлыгының Баш фәнни-техник идарәсе башлыгы урынбасары, 1991–93 тә «Внештрубопроводстрой» тышкы икътисади ассоциациясенең төзелеш фирмасы директоры, 1993–98 дә «Нефтепродукт» коммерция банкы идарәсе рәисенең урынбасары. 1998–99 да ТРның РФдәге тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары, 1999 да тулы вәкаләтле вәкиле. 2010 нан ТР Премьер-министры киңәшчесе. Хезмәтләре төзелешнең оештыру структурасын камилләштерү проблемаларына, икътисад, политология, федерализмны үстерү мәсьәләләренә карый. Медальләр, шул исәптән 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә.

**МИРОЛЮ́БОВ** Леонид Михайлович (5.9.1956, Казан), балалар кардиохирургы, мед. фән. д-ры (2005). Проф. Н.П.Медведев шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан шәһәренең 6 нчы хастаханәсендә хирург. 1986 елдан Казан мед. ун-тының 2 нче хирургия кафедрасында, бер үк вакытта (1995 тән) ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә кече яшьтәге балалар кардиохирургиясе бүлеге мөдире. Хезмәтләре йөрәк зәгыйфьлегенә диагноз кую һәм хирургия юлы б-н дәвалауга карый. М. артерияләр аутовеноз пластикасының яңа ысулларын, яңа туган балаларда тумыштан килгән йөрәк зәгыйфьлегенә тиз арада диагноз кую алгоритмын тәкъдим итә һәм гамәлгә кертә. Артерияләр аутовеноз пластикасының яңа ысулын уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Клиника, диагностика и хирургическое лечение пороков сердца. К., 1995 (автордаш); По-

роки у новорожденных. К., 2002 (автордаш); Врождённые пороки сердца у новорождённых и детей первого года жизни. К., 2008; Врождённый порок сердца. Трагедия на всю жизнь или временные трудности. К., 2011 (автордаш).

**МИРОЛЮ́БОВ** Михаил Григорьевич (29.5.1931, Мәскәү — 17.2.2007, Казан), ветеринар-акушер, вет. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Удмурт АССРның Богатырка МТСы баш вет. табибе (1955–56), Ува р-ны баш вет. табибе (1957–58) булып эшли. 1959–60 елларда Казан зооботаника бакчасында зоол. бүлеге мөдире. 1960 тан Казан вет. ин-тында, акушерлык һәм гинекология каф. мөдире (1989–99), каф. профессоры (1999 дан). хезмәтләре сыерларда җилен шешү авыруына диагноз кую, авыруны дәвалау һәм кисәтү, төрле төр хайваннарда ана зат кысырлыгы һәм ата зат импотенциясе симптоматикасы, сыер яралгысын трансплантацияләү, а.х. терлекләренең үрчем бирүенә әйләнә-тирә мохит тәэсире мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Резервы повышения молочной продуктивности у коров. К., 1983; Лошадь. К., 1997; Ветеринарное акушерство, гинекология и биотехника размножения. М., 1999 (автордаш); Записки ветеринарного врача. К., 2003.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**МИРО́НОВ** Алексей Максимович (15.2.1866, Харьков ш. — 1929 дан соң), сәнгать тарихчысы, педагог, музей хезмәткәре, коллекционер. Харьков ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлый (1888). 1891 елдан Мәскәү ун-тының сәнгать теориясе һәм тарихы каф. приват-доценты, бер үк вакытта Мәскәү Румянцев җәмәгать музееның уку залы мөдире (1901 дән). 1892–94, 1895 тә чит илләрдә стажировка уза, Римдагы Германия археол. ин-тында докладлар б-н чыгышлар ясый (1894). Фәндә үзенең остазлары дип И.В.Цветаев һәм Ф.И.Буслаевны саный. 1906 дан Казан ун-тында, сәнгать теориясе һәм тарихы кафедрасында проф. (1914), атказ. проф. (1916), эстетика тәгълиматлары тарихы, антик дәвер, христиан, Яңарыш чоры сәнгате буенча курслар укый. Бер үк вакытта, 1907 дән, *Казан университетының нәфис сәнгать һәм борынгы истәлекләр музее* мөдире, 1909 дан университетның драма һәм әдәбият түгәрәкләре җитәкчесе. Шәкертләре арасында Б.П.Денике, П.А.Радимов, П.М.Дульский, Н.А.Щербаков, А.А.Фёдоров-Давыдов бар. Шулай ук Югары хатын-кызлар курсларында (1906–17), музыка уч-щесендә укыта, Казан сынлы сәнгать мәктәбенең Попечительләр ком-ты әгъзасы булып тора (1908–17). 1919 ның февралендә бөтенроссия конкурсында Казан ун-ты профессорлары составына сайлана. 1922 дән иҗтимагый фәннәр каф. деканы вазифаларын башкара. Бер үк вакытта Казан дәүләт архит-ра-сынлы сәнгать остаханәләрендә сәнгатьләрнең гомуми тарихын укыта (1918–26). Музейлар төзелешендә актив катнаша: 1919 дан ТАССР Мәгариф халык комис-тының музейлар һәм борынгы ядкәрләрне саклау эшләре бүлеге әгъзасы, рәис (Б.Ф.Адлер) урынбасары. 1926 дан Ташкентта, Урта Азия ун-ты профессоры, университетның Шәрекъ музейлары эшләре буенча музейлар секциясе мөдире.

М. тормышының Казан чоры фәнни тикшеренү, музей, күргәзмәләр оештыру, җыю эшчәнлеген колачлый. Аның тикшеренүләр өлкәсе антик һәм элгәреге христиан дәвере сәнгатен, Яңарыш чоры сәнгатен, аерым алганда, А.Дюрер иҗатын, 17–18 йөзләр рус сәнгатен үз эченә ала. М.ның шәхси коллекциясендә, башлыча, Европа — Италия, фламанд, Голландия, Франция мәктәпләре, ш.у. 19 йөз рус сәнгате әсәрләре (шул заман атрибуциясе буенча) була. Казан ун-тының нәфис сәнгать һәм борынгы истәлекләр музее мөдире буларак, китапханә һәм предметлар коллекцияләрен туплау б-н шөгыльләнә, төп игътибарын сынлы һәм декоратив-гамәли сәнгатьнең асыл әсәрләрен алдыруга юнәлтә, ун-тның төп бинасында музей экспозициясе оештыра. Берничә тапкыр музейга үз тупланмасыннан сәнгать әсәрләре бүләк итә. Казан сынлы сәнгать мәктәбенең Попечительләр ком-ты әгъзасы буларак, шәхси тупланмалардан рев-циягә кадәрге чорда иң зур күргәзмә булып танылган «Казанның сәнгать хәзинәләре» күргәзмәсен оештыра һәм уздыра (1916). 1920 елларда М. ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршындагы музейлар һәм тарих, сәнгать ядкәрләрен саклау эшләре бүлекчәсенең эшчәнлегендә актив катнаша. Музей фондын тулыландыру максатында реквизицияләнгән мөлкәтнең тарихи-сәнгати әһәмиятен ачыклау эшенә җитәкчелек итә. 1924 тә сәнгать эксперты сыйфатында чиркәү, монастырь һ.б. учреждениеләрдән конфискацияләнгән затлы әйберләрне ачларга ярдәм итү өчен сату максатында махсус фәнни-сәнгать комиссиясе составында эшли. *Казандагы беренче Дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсен*, «*Шәрекъ халыклары мәдәнияте күргәзмәсен*» (китаплар бүлеге), Бөек француз рев-циясе тарихы күргәзмәсен оештыруда катнаша. «Красная Татария» г-тасы, «Казанский музейный вестник», «Вестник просвещения ТАССР» ж-лларында сәнгать һәм тарих ядкәрләрен саклау, хәзерге заман сынлы сәнгате гамәлияте, татар нәфис һөнәрчелеге мәсьәләләренә кагылышлы мәкаләләр бастыра; беренчеләрдән булып Казанда татар сәнгате музеен оештыру зарурлыгы мәсьәләсен күтәрә. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Московский публичный и Румянцевский музей как художественно-воспитательное учреждение. М., 1898; Альбрехт Дюрер, его жизнь и художественная деятельность. К характеристике эпохи Возрождения в немецком искусстве // Уч. зап. Моск. ун-та. Отд. историко-филолог. 1901. Вып. 31; Фальсификации, подражания и копии произведений Альбрехта Дюрера в русских художественных собраниях // Уч. зап. Казан. ун-та. 1908. Т. 75, кн. 10; Изображение богини Победы в греческой пластике // Уч. зап. Казан. ун-та. 1911. Т. 78. Кн: 1–4; Музейный фонд как источник для выставок // Первая государственная выставка искусства и науки в Казани: Каталог. К., 1920; Татарский музей в Казани // Вестн. просвещения. К., 1923. № 6; Художественные ремёсла у татар // Причал. 1925. № 6.

*Әд.:* К л ю ч е в с к а я Е. Из истории искусствознания в Татарстане // Татарстан. 1996. № 10; С ы ч е н к о в а Л. Алексей Максимович Миронов. Попытка научной реабилитации // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 1; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.П.Ключевская.*

**МИРО́НОВ** Анатолий Владимирович (23.3.1945, Горький өлкәсенең Лукоянов р-ны Кудеярово а.), педагог, географ, геогр. фән. канд. (1977), пед. фән. д-ры (1995), проф. (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1974–86 елларда Алабуга пед. ин-тында, башлангыч белем бирү методикасы һәм педагогикасы ф-ты деканы (1983 тән). 1986 дан Чаллы пед. ин-тының башлангыч белем бирү методикасы һәм педагогикасы каф. мөдире. 2011 дән Чаллы социаль-пед. технологияләр һәм ресурслар ин-тында. Хезмәтләре Татарстанның физик географиясе, педагогларны укыту һәм экологик тәрбия проблемаларына карый.

Х е з м.: Сельскохозяйственные ландшафты лесостепи Поволжской возвышенности. К., 1984; Содержание экологического образования будущего учителя. К., 1989; Преподавание экологии в школе. М., 2004.

**МИРО́НОВ** Виталий Григорьевич (10.1.1933, Мәскәү өлкәсенең Ивантеевка эшчеләр пос. — 16.3.2001, Казан), кино операторы, кино режиссёры, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Югары хәрби-диңгез уч-щесен (1957), Бөтенсоюз кинематография ин-тының операторлар ф-тын (Мәскәү, 1971) тәмамлый. 1958 елда һәвәскәрләр киностудиясендә «Уралга походка» («В поход на Урал») дип аталган беренче фильмын төшерә. 1958–95 елларда Казан телестудиясендә: баш оператор, 1964 тән оператор һәм кино төркеме режиссёры. Казан һәм респ-ка тормышындагы аеруча әһәмиятле вакыйгалар турында кинохроника сюжетларын төшерүдә актив катнаша, Татарстанда «Казаным» («Моя Казань», 1972) дип аталган беренче төсле документаль фильм төшерә. М.ның 55 фильмы ил күләмендә тарату һәм Үзәк телевидениедән күрсәтү өчен кабул ителә. Алар арасында «Күңелдә яз» («В душе весна», 1964), «Яңадан туган риваять» («Возрождённая легенда», 1966), «Галина Калашникова бии» («Танцует Галина Калашникова», 1967), «Салих Сәйдәшев көйләре» («Мелодии Салиха Сайдашева», 1968), «Иделдән көйләр» («Мелодии с Волги», 1970), «Татар опералары сәхифәләре буенча» («По страницам татарских опер», 1972), «Гали Ильясов җырлый» («Поёт Гали Ильясов», 1974), «Татар гармуннары» («Татарские гармошки», 1974), «Рөстәм Яхин көйләре» («Мелодии Рустема Яхина», 1981), «Чуаш бизәкләре» («Чувашские узоры», 1983) муз. фильмнары, фильм-концертлары, ш.у. Б.Урманче иҗаты турында «Сагыш» фильмы, композитор Л.Батыр-Болгарига багышланган «Кайту» («Возвращение», 1992) фильм-портретлары, Н.И.Якушенко, В.В.Кешнер, Ю.С.Федотов һ.б. актёрлар иҗаты турында телевизион фильмнары аеруча әһәмияткә ия. Казан те-



П.А.Миронов.



Л.М.Миропольский.

лестудиясе тарихына багышланган күп серияле «Җиде кич» («Семь вечеров») документаль фильмын төшерүдә катнаша. Бер үк вакытта күп кенә фильмнарның операторы һәм режиссёры була. М. иҗатына кадрны салмак монтажлау, эре планнарның күплеге, материалны нечкә тоемлау, геройларының рухи дөньясын тирән тоя һәм аны тәэсирле итеп яктырта белү хас.

*Е.П.Алексеева.*

**МИРО́НОВ** Владимир Фёдорович (12.9.1957, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1995), проф. (2000), ТРның атказ фән. эшлеклесе (2005). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм 1995 кә кадәр шунда ук эшли (бүленеп: 1983–86 да Казан химия-фотография сәнәгате технол. һәм проектлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында). 1995 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, табигый кушылмаларның фосфорлы аналоглары химиясе лаб-ясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, 2000 нән мөдире, бер үк вакытта Казан ун-тының органик химия каф. профессоры. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. М. α-фосфориллы триалкилфосфитларны һәм перфторкарбон к-таларының фосфориллы кушылмаларын синтезлый һәм реакциягә сәләтен тикшерә. Пластификация, инсектоакарицид һәм вирусларга актив каршылык үзлекләренә ия булган кушылмаларны ача. Органик синтезда (ш.и. фосфорорганик кушылмалар синтезында) табигый кушылмаларны фосфориллау өчен югары нәтиҗәле реагентлар табу максатында фторалкилфосфитлар куллану юлларын тәкъдим итә. Органик кушылмаларга галогенфосфораннар кулланып галогеннар кертү алымнарын, ш.у. бензо[e]-1,2-оксафосфорининнар — табигый биоактив кушылмаларның фосфорлы аналогларын — кумариннар һәм α-хроменнар синтезлауның оригиналь ысулын эшли, нәтиҗәдә, табигый полифеноллы кушылмаларны яңа гетероциклларга модификацияләү мөмкинлеге туа. Сөт, салицил, миндаль һ.б. гидроксикарбон к-таларның фосфориллы кушылмалары химиясенә; җиде буынлы фосфорлы гетероцикллар — физиол. актив кушылмаларның табигый аналогларын синтезлау алымнарына караган хезмәтләрнең автордашы. Табигый чыганаклардан — амарант, люпиннан пектиннар һәм аксым алу технологиясен эшләүдә, аларның төзелешен, биологик активлыгын һәм аларны югары туклыклы азык һәм терлек азыгы өстәмәләре сыйфатында куллануны тикшерүдә, ш.у. анемиягә каршы тәэсирле пектин полиметаллкомплексларын уйлап табуда катнаша. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР ФАнең Г.Х.Камай исем. бүләге лауреаты (2003).

Х е з м.: Фторалкоксипроизводные трёхвалентного фосфора: Синтез и реакционная способность // Успехи химии. 1996. Т. 65, вып. 11 (автордаш); Р-функционализированные фосфораны в реакциях присоединения // Журн. общей химии. 1996. Т. 66, вып. 3 (автордаш); Успехи в развитии химии гетероциклических производных фосфора в работах Казанской химической школы // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3–4 (автордаш).

**МИРО́НОВ** Павел Андреевич (12.11.1919, Казан губ., Чистай өязе Рус Сарсазы а. — 26.4.1945, Чехословакия, Брно ш. янында җирләнә), Сов. Союзы Герое (15.5.1946, үлгәннән соң), гв. кече лейтенанты. Кама елга пароходчылыгында механик ярдәмчесе булып эшли (Чистай ш.). 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 33 нче гв. кавалерия полкы танкка каршы батареясының утка тоту взводы командиры (6 нчы гв. кавалерия корпусының 8 нче гв. кавалерия дивизиясе). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Венгрия, Чехословакияне азат итүдә катнаша. 1945 нең 26 апрелендә Брно шәһәреннән төньяк-көнбатыштарак барган сугышларда батырлык күрсәтә: 1 танк, 4 БТРны юк итә һәм 2 тупны сафтан чыгара; шул сугышта һәлак була. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медаль б-н бүләкләнә. Чистай шәһәренең бер урамы М. исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Я г о д и н с к и й Е.А. Золотые Звёзды речников. М., 1981. Вып. 4; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИРО́НЧЕНКО** Валерий Николаевич (26.9.1950, Төньяк Осетия АССР, Орджоникидзе ш.) генерал-майор (1996), пед. фән. канд. (2000). Югары хәрби гомумгаскәри командирлар уч-щесен (Орджоникидзе ш., 1971), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1988) тәмамлый. 1971 елдан Идел буе хәрби округында: мотоукчылар взводы командиры, 1976 дан рота командиры, 1978–83 тә штаб башлыгы, батальон командиры. 1983–85 тә Төркестан хәрби округының мотоукчылар командиры урынбасары. 1988 дән полк командиры, 1990 нан Идел буе хәрби округының мотоукчылар дивизиясе штабы башлыгы. 1995 тән Казан югары хәрби командирлар уч-щесе башлыгы, бер үк вакытта Казан хәрби гарнизоны башлыгы. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, «Шәхси батырлык өчен», Почёт, Әфганстан Респ-касының Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 1996.

**МИРОПО́ЛЬСКИЙ** Леонид Михайлович (16.6.1896, Казан губ. Спас Затоны а. — 27.6.1965, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1936), проф. (1934). ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1945, 1947). Казан ун-тын тәмамлый (1919), шунда ук эшли, Геол.-минерал. ин-ты директоры (1931), минерал. һәм петрография каф. мөдире (1931–65), проректор (1944–46). Бер үк вакытта Казан пед. (1923–32), Казан химия-технол. (1930–31) ин-тларында укыта. 1945 елдан СССР ФАнең Казан ф-лында: Геол. ин-ты директоры (1945–64), Президиум рәисе урынбасары (1945–49). Хезмәтләре Урал-Идел буе төбәгенең минералогиясе, литологиясе, минераллар геохимиясенә, тау токымнары һәм файдалы казылмаларына карый. М. Урта Идел буеның төп минералларының барлыкка килү шартларын һәм аларны файдалану юлларын тасвирлый, химик элементларның (V, Ni, Cu, Ba, Ca h.б.) геохимик үзенчәлекләрен һәм Татарстан терр-ясендә палеозой утырмаларының топогеохимик үзлекләрен ачыклый. Файдалы казылмаларның экзоген чыганаклары классификациясен эшли, Идел-Кама төбәгенең палеозой катламнарында утырма формацияләр бүленеп чыгуын, Пермь төсле (кызыл) токымнарына төс бирүчәнлек сәбәпләрен нигезли. Татарстанда нефть эзләү-разведкалау планын төзүдә катнаша, көрән күмер, бакыр рудалары һ.б. файдалы казылма ятмаларын эшкәртү мөмкинлеген бәяли, төзелеш өчен җылылык һәм тавыш изоляцияләү материалларын, сорбентлар, җирле чималдан минераль йон җитештерү буенча күрсәтмәләр нигезли.

СССР ФАнең Җитештерүче көчләр советы каршындагы минераль чимал секциясе рәисе (1941–44), ТАССР Дәүләт план ком-ты каршындагы Фәнни-техник совет рәисе урынбасары (1941–45). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, Татарстан ҮБКның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Медные руды в пермских отложениях ТАССР и их генезис // Уч. зап. Казан. ун-та. 1938. Т. 98, кн. 1, вып. 10; Топогеохимическое исследование пермских отложений в Татарии. М., 1956.

*Әд.:* В и н о к у р о в В.М. Л.М.Миропольский. К., 2003.

**МИРОТВО́РЦЕВ** Василий Васильевич (1839, Иркутск губ. — 22.9.1891, Казан), монгол теле, әдәбияты, мәдәнияте, будда дине белгече, тарихчы, тәрҗемәче, теология магистры (1869). Петербург руханилар академиясен һәм бер үк вакытта Петербург ун-тының Шәрекъ бүлеген тәмамлаганнан соң (1863), Казан руханилар академиясендә: будда диненә каршы миссионерлык предметлары кафедрасында, 1872–91 елларда рус гражданнар тарихы кафедрасында укыта; бер үк вакытта, 1880–84 тә, акад. инспекторы, 1884 тән яңа ачылган миссионерлык бүлегендә будда дине тарихын һәм монгол телен укыта, проф. (1870). 1877 дән Изге Гурий борадәрлегенең тәрҗемә комиссиясе әгъзасы: бурят теленә «Иске һәм Яңа Гаһеднең изге тарихы» («Священная история Ветхого и Нового Завета», 1878), «Догалык» («Молитвослов», 1882) h.б. китапларны тәрҗемә итә. Хезмәтләре монгол теле белеме, будда дине догматикасына карый.

Х е з м.: Изложение и критический разбор основных начал буддизма. К., 1873; К биографии

о.Иакинфа Бичурина // Православный собеседник. 1886. Ч. 2; Материалы для истории Пекинской миссии // Православный собеседник. 1888. Ч. 3.

*Әд.:* Знаменский П.В. История Казанской Духовной Академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы): В 3 ч. К., 1891–92: Василий Васильевич Миротворцев: Некролог. К., 1891.

*Е.В.Липаков.*

**МИРОШНИЧЕ́НКО** Григорий Кузьмич (1895, Чернигов өлкәсенең Ичня р-ны Ичня а. — 1959, Ульянов ш.), гв. генерал-майоры. 1920 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 41 нче аерым укчы бригада, 260 нчы укчы һәм 16 нчы запас укчы дивизияләр командиры. 1946 дан Казан суворовчылар хәрби уч-щесе башлыгы, 1951 дән Ульянов пед. ин-ты профессоры. Ленин, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Белов А.А. Мы — из Казанского суворовского. М., 1999.

*Р.Р.Сәлахиев.*

**МИРСӘЯ́ПОВ** Илизәр Тәлгат улы (1.1.1954, Әлмәт р-ны Колшәрип а.), төзелеш конструкцияләренең ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1994).1976 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1999 дан нигезләр һәм фундаментлар, корылмалар динамикасы һәм инженерлык геологиясе каф. мөдире (бүленеп, 1984-95 тә Иваново төзүче инженерлар ин-тында). Хезмәтләре сәнәгать һәм гражданлык корылмаларының нигез һәм фундаментларын проектлаштыруга, тимер-бетон конструкцияләрнең ныклыгын исәпләүгә карый. Төрле режимдагы циклик йөкләнеш астында җыелма-монолит элементларның чыдамлыгын бәяләү алымнарын эшли (тикшеренү нәтиҗәләре тимер-бетон конструкцияләр проектлаштырудагы норматив документларның нигезен тәшкил итә). Медальләр, ш.и. Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең алтын медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Экспериментальные исследования физико-механических свойств глинистых грунтов при длительном трёхосном сжатии // Инженерная геология. 2010, №1 (автордаш); Прогнозирование деформаций оснований фундаментов с учётом длительного нелинейного деформирования грунтов // Основания, фундаменты и механика грунтов. 2011, № 4 (автордаш); Экспериментальные исследования податливости контакта слоёв сталежелезобетонных конструкций при малоцикловых нагружениях // Вестн. МГСУ. 2011. № 2 (автордаш).

**МИРУМЯ́НЦ** Сурен Осипович (1.11.1925, Үзбәкстан ССР, Сәмәрканд ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2001). Бөек Ватан сугышында катнаша. Үзбәкстан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), Оптика ин-тында (Ленинград) эшли. 1959 елдан Оптика ин-тының ф-лында (Казан, хәзер ДУП ФФҖҮ «ГИПО»): 1963–86 да директор, бер үк вакытта, 1965–86 да, молекуляр спектроскопия һәм атм. оптикасы бүлеге башлыгы, 1986 дан молекуляр спектроскопия, интеграль һәм җепселле оптика бүлеге башлыгы, 1996 дан гыйльми секретарь. Хезмәтләре молекуляр спектроскопиягә, атм. оптикасына, интеграль һәм җепселле оптикага карый. М. электрон-ярсынулы катлаулы молекуланың чит газ молекулалары б-н бәрелешү барышында эффектив энергия тапшыруы закончалыкларын билгели; оборона тармагында гамәли куллану өчен, спектрның 1 дән 25 *мкм* га кадәр аралыгында атмосфераның үтә күренмәлелеген исәпләү алымнарын эшли; оптик-җепселле элемтә линияләре өчен мәгълүмат агымының оптик-спектраль тыгызлагыч-сирәгәйткечләрен тикшерә һәм эшли; ташкүмер шахталарында, нефть химиясе сәнәгатенең җитештерү цехларында, канализация коеларында, туннельләр, подваллар, цистерналар һ.б.да шартлаучан метан газын табу һәм концентрациясен үлчәү өчен оптик-җепселле система һәм оптик-электрон прибор уйлап таба. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Атлас спектров прозрачности по произвольно ориентированным трассам атмосферы. М., 1977 (автордаш); Экспериментальные данные о прозрачности приземных атмосферных трасс различной протяжённости в диапазоне 1–25 мкм. М., 1979 (автордаш); Исследуя тайны оптических явлений // Науч. Татарстан. 1997. № 1 (автордаш); Научно-производственное объединение «Государственный институт прикладной оптики»: В 2 ч. К., 1997 (автордаш).

*Әд.:* Сурен Осипович Мирумянц // Оптический журн. 2000. № 11.

*Р.Г.Усманов.*

**МИРХӘЙДӘ́РОВ** Рауль Мирсәет улы (17.11.1941, хәзер Казакъстан Респ-касы, Актүбә өлкәсенең Мартук пос.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Рус телендә яза. Ташкент политехник ин-тын тәмамлый (1968). 1961–80 елларда төзелеш оешмаларында прораб, инженер булып эшли. 1990 нан Мәскәүдә яши. Беренче «Самсон тукталышы» («Полустанок Самсона») хикәясе «Родники» (М., 1971) альманахында басылып чыга. М. иҗатын ике чорга бүлергә мөмкин. 1970–85 тә ул кечкенә формаларда (хикәя, повесть) яза (Мәскәүдә басылып чыккан «Бәхет кошы» — «Жар-птица», 1971; «Оренбург шәле» — «Оренбургский платок», 1978; «Безне онытмагыз» — «Не забывайте нас», 1980 һ.б. җыентыклар). Шуннан соңгы елларда ул күләмлерәк әсәрләр иҗат итә. М. — үткен сюжетка корылган, детектив интригага нигезләнгән социаль-сәяси романнар авторы. Әсәрләренең геройлары — төрле дәрәҗәдәге сәясәтчеләр, хакимияткә менеп утырып, ришвәтчелеккә бирелгән чиновниклар, «күләгә»дә яшәүчеләр. Криминаль структуралар турындагы күпкырлы фактик материалны анализлау нәтиҗәсендә язылган «Җәяүле сәйран» («Пешие прогулки», М, 1988), «Кытай императорының сыңары» («Двойник китайского императора», М., 1989), «Кара аксөякләр» («Масть пиковая», М., 1990), «Мин хөкем итәм» («Судить буду я», М., 1992) романнары совет чорыннан соңгы болганчык еллар хроникасын тәшкил иткән тетралогиягә әверелә. Мәхәббәткә багышланган «Иртәләгән сагыш» («Ранняя печаль», Днепропетровск, 1991) романында язучының беренче иҗади эшчәнлек еллары чагылыш таба, төп темалары үсеш ала. «Һәр нәрсәгә — акчалата» («За всё наличными», М., 1997) романы «яңа руслар» тормышын бәян итә, хәзерге көннең зур афёралары турында сөйли. М. прозасына архитектониканың күпкатлылыгы, жанрлар синтезы хас. Әсәрләре татар, инглиз, немец, француз, испан, венгр, чех, поляк, грузин, казакъ, үзбәк телләренә тәрҗемә ителә. 1997 дә Мартук шәһәрендә язучының музее ачыла.

Әсәр.: Собрание сочинений. В 4 т. М., 1992–93; Собрание сочинений. В 4 т. Днепропетровск, 1996.

*Әд.:* Мустафин Ш.С. Культуру восстановить труднее, чем экономику (Беседы с писателем Раулем Мир-Хайдаровым). К., 2007.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**«МИРЪА́Т»** («مرآة» — «Көзге»), журнал тибындагы брошюралар сериясе. 1900–1903 һәм 1907–1909 елларда С.-Петербургта (16 китап) һәм Казанда (6 китап) татар телендә нәшер ителә. Нашире — Рәшит *Ибраһимов.* Басма татар иҗтимагый фикере барлыкка килүдә зур роль уйный. Аңарда татар җәмгыятенең дини һәм иҗтимагый-мәдәни тормышы мәсьәләләре яктыртыла. Төп игътибар халык мәгарифе, хәйриячелекне үстерү мәсьәләләренә юнәлтелә. Мәкаләләрне Р.Ибраһимов үзе яза. Шулай ук укучылар хатлары да басыла. Брошюралар бигрәк тә җәдиди мәдрәсәләрдә укучы алдынгы шәкертләр арасында яратып укыла.


*Ж.С.Миңнуллин.*

**МИСЛА́ВСКИЙ** Александр Андреевич (11.12.1828, Воткинск з-дының Каменск пос. — 28.11.1914, Екатеринбург ш.), хирург, офтальмолог, медицина д-ры (1894). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1851), Богословский тау округының (Төньяк Урал) Тура бакыр рудникларында табиб булып эшли. 1856 елдан Екатеринбургта: Түбән Исеть (Әчет), 1859 дан Югары Исеть (Әчет) з-д госпитальләрендә баш табиб (госпиталь каршында анатомия музее оештыра). М., дөньяда беренче булып, катаракта (1853) һәм зобны (1862) кисеп алу операцияләре ясый. Казан галимнәре династиясен (Н.А.*Миславский*, А.Н.*Миславский*, А.Д.*Адо*) башлап җибәрүче. 1881 дә А.А.Миславский исем. стипендия булдырыла. Екатеринбургтагы күз хастаханәсенә (1906 да төзелә) аның исеме бирелә.

*Әд.:* Зарипов И. Династия Миславских // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МИСЛА́ВСКИЙ** Александр Николаевич (17.2.1880, Казан — 14.12.1958, шунда ук), гистолог, медицина д-ры (1909), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1939). Н.А.*Миславскийның* улы, А.А.*Миславскийның* оныгы, проф. К.А.Арнштейн шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1904), шунда ук, гистология кафедрасында эшли. Франциядә фәнни командировкада була (1910–12). 1914–17 елларда Кызыл Хачның яра бәйләү отрядлары табибе. 1918 дән Казан ун-тында гистология лаб-ясе мөдире, 1921 дән гистология каф. мөдире, мед. ф-ты деканы, уку-укыту һәм фән бүлеге мөдире (1930 дан Казан мед. ин-тының гистология каф. мөдире). Хезмәтләре периферик нерв



Н.А. Миславский.

системасы һәм аның вегетатив бүлеге морфологиясенә, секреция морфологиясенә карый. Нерв системасының вегетатив бүлеге нейрогистология өлкәсен өйрәнә. «Имезүчеләр тиресендәге катлаулы көпшәсыман (мерокрин) бизләр гистологиясенә караган материаллар» («Материалы к гистологии сложнотрубчатых (мерокриновых) желёз кожи млекопитающих», 1909) монографиясе авторы. Имезүчеләрнең тире катламындагы кайбер бизләрнең аның тарафыннан өйрәнеп тасвирланган секрет бүлеп чыгару процессы секрециянең «апокрин» тибы дип атала башлый. М. Бөтенсоюз анатом, гистолог һәм эмбриологлар җәмгыятенең Татарстан респ-ка бүлеге идарәсе әгъзасы (1930 дан). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл байрагы ордены, медальләр, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К морфологии железистой клетки. Некоторые детали строения клеток почечного эпителия лягушки // Казан. мед. журн. 1913. № 4; Вопросы морфологии чувствительной иннервации. К., 1958.

*Әд.:* З а б у с о в Г.И. Проф. А.Н.Миславский и его школа // Казан мед. журн. 1959. № 2; Проблемы морфологии, патоморфологии и реактивности периферических отделов нервной системы. К., 1961.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МИСЛА́ВСКИЙ** Николай Александрович (17.4.1854, Урал, Тура рудниклары — 25.12.1928, Казан), физиолог, медицина д-ры (1885), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1927), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1926). А.А.*Миславскийның* улы. Казан физиол. мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1876), шунда ук эшли: 1891–1910 һәм 1919–28 елларда физиол. каф. мөдире, 1895 тән проф., 1918 дә ректор, бер үк вакытта, 1907–10, 1915–19, 1924–26 да, мед. ф-ты деканы. 1886 да фәнни командировкада була (Лейпциг, Париж). Хезмәтләре вегетатив нерв системасы физиологиясе һәм морфологиясенә карый. М. нерв регуляциясе механизмын өйрәнә, имезүчеләрнең озынча миендә сулыш үзәге урнашкан урынны билгели, баш мие зур ярымшарлары кабыгының эчке органнарга, шома мускулатураның хәрәкәтләнү һәм тукталу иннервацияләренә, бизләрнең тышкы һәм эчке секрециясенә тәэсирен ачыклый. Сидек куыгының хәрәкәт үзәкләре, үзәк нерв системасының селәгәй бизләре, ашказаны бизе, аналык җиңсәсе бизе, мәни бизе (простата), күз карасы бизендәге нерв аппараты б-н элемтәсен тирәнтен тикшерә. М. тарафыннан (М.Н.Чебоксаров җитәкчелегендә) бөер өсте бизләренең секреция нервы ачыклана, галимнең турыдан-туры катнашында бугазның өске нервының калкансыман биз секрециясенә тәэсире турында ачыш ясала.

Х е з м.: О дыхательном центре. К., 1885; К гистологии продолговатого мозга // Архив психиатрии. 1888. Т. 6; О влиянии мозговой коры на отделение слюны // Медицинское обозрение. 1888. № 13 (автордаш); К изучению о влиянии мозговой коры на расширение зрачка // Неврологический вестн. 1903. Т. 11; Избранные произведения. М., 1952.

*Әд.:* К и б я к о в А.В., Л е б е д е в К.В. Н.А.Миславский. М., 1951.

*В.Ф.Богоявленский.*

**МИССА́РОВ** Мөкаддәс Җиммөхтәсиб улы (9.9.1955, Кыргызстан ССР, Ош өлкәсенең Сулюкта ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1999), проф. (2001). 1977 елда Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1980 нән Казан ун-тында эшли, икътисади кибернетика каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре матем. физикага һәм ихтималлык теориясенә карый. М. Евклид модельләрендә ренормальләшкән төркемне сурәтләү өчен проекцион гамильтонианнар формализмын эшли. Кырның квант теориясенә *p*-адик модельләрнең яңа классын кертә, аларның үзлекләрен өйрәнә, *p*-адик модельләрдә кабаттан нормальләштерү теориясен төзи. Иерархик фермион модельнең төгәл чишелешен таба, бу модельдә ренормальләшкән төркемнең динамикасын тикшерә, критик күренешләрне һәм симметриядәрне сурәтли.

Х е з м.: Критические явления в фермионной иерархической модели // Теорет. и мат. физика. 1998. Т. 117, № 3. Renormalization group solution of fermionic Dyson model // Asympt. Comb. with Appl. to Math. Phys. Netherlands, 2002.

**МИСТАКИ́** Сергей Андреевич (1779, Греция — 24.1.1853, Казан), антик телләр белгече. Бухарестта (Румыния) белем ала. 1821 елдан Россиядә. 1823–39 да Казан ун-ты профессоры. Гимназияләр өчен борынгы грек әдәбияты хрестоматиясе авторы.

**МИ́ТИН** Анатолий Владимирович (26.2.1938, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1986), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Казан авиация ин-тында эшли. 1965–87 елларда СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, 1987 дән Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында физика каф. мөдире. 1998 дән Казан технол. ун-ты профессоры. Хезмәтләре каты җисемнәрдә Мёссбауэр спектроскопиясенә, квант акустикасына һәм магнит күренешләре физикасына карый. М., беренче булып, ферромагнетикларда гамма-магнитик резонанс (ГМР) эффектын күзәтү мөмкинлеген күрсәтә; гамма-нурланышның ультратавыш модуляциясе теориясендә төп чишелешләрне таба; ГМР ярсынуы китереп чыгарган интерференция күренешләрен: гамма-нурланышның магнит-квант тибешләрен, төштәге изомер дәрәҗәләрнең квазиэнергетик магнит халәтләре арасындагы интерференцияне, Мёссбауэр йоткычының индукцияләнгән резонанслы үтә күренмәлелеген теоретик яктан фаразлый.

Х е з м.: Гамма-магнитный резонанс // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1967. Т. 52; Гамма-резонансная спектроскопия твёрдого тела в условиях высокочастотного возбуждения // Успехи физ. наук. 1976. Т. 120 (автордаш); Аморфные магнитные сплавы // Электротехника. 1996. № 7 (автордаш); Нелинейная гамма-резонансная спектроскопия // Изв. РАН. Сер. физ. 1998. Т. 62.

**МИТРӘ́Й** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 358 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Митрәй, Енаулова исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы ясаклар, дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2437 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 785, 1889 да — 862, 1910 да — 1109, 1920 дә — 1433, 1926 да — 1460, 1938 дә — 1268, 1949 да — 826, 1958 дә — 599, 1970 тә — 571, 1979 да — 463, 1989 да — 289, 2002 дә — 361 кеше.

**МИТРОПОЛИ́Т** (грек. — mētropolítēs — башкала), христиан динендә архиерейларның югары руханилык дәрәҗәләренең берсе. Эре епархия башлыгы, патриархка яки нинди дә булса автономияле православие чиркәвенә буйсына. *Казан епархиясе* 1589–1724, 1727–31, 1775–82, 1917–22 елларда һәм 2012 дән М. тарафыннан идарә ителә (к. *Гермоген, Ефрем, Анастасий*).

**МИТРОФА́НОВ** Петр Митрофанович (2.12.1934, хәзер Чуаш Респ-касының Красноармейский р-ны Янгасы а.), ветеринар-микробиолог, вет. фән. д-ры (1983), проф. (1988). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1962). 1962–63 елларда Красноармейский р-нында ит һәм азык-төлек сыйфатын тикшерү станциясе мөдире, районның баш вет. табибе. 1963–75 тә Казан вет. ин-тының патологик анатомия кафедрасында. 1975–90 да ВАСХНИЛның Себер бүлеге Ерак Көнчыгыш һәм Себер вет. эксперименталь ин-тында лаб. мөдире (Новосибирск ш.). 1990 нан Мордва ун-тында вет. каф. мөдире. Хезмәтләре патоморфологиягә, терлекләрдә хламидия һәм микоплазмага бәйле йогышлы авыруларны дәвалауга карый.

Х е з м.: Орнитозная пневмония телят // Профилактика заболеваний молодняка сельскохозяйственных животных. М., 1968 (автордаш); Микоплазмозный мастит у коров // Уч. зап. Казан. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1971. Т. 110 (автордаш).

*Әд.:* Школа ветеринарных патологоанатомов // Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

**МИТРОФА́НОВКА** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 19–20 йөзләр чигендә

нигез салына. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1005 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1913 тә — 447, 1920 дә — 439, 1926 да — 347, 1938 дә — 390, 1949 да — 250, 1958 дә — 191, 1970 тә — 93, 1979 да — 49, 1989 да — 34, 2002 дә — 13 кеше.

**МИТРЯ́ЙКИН** Виктор Иванович (14.6.1952, Мордва АССРның Зубова-Поляна р-ны Известь пос.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1998), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1999). 1974 елда Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесен тәмамлый, 1981 дән шунда ук эшли (1974–81 дә Киев хәрби округында хезмәт итә), отделение башлыгы (1983 кә кадәр). 2011 дән Казан техник ун-тында. Хезмәтләре юка тышлы конструкцияләрнең статик һәм динамик тотрыклылыгына, авиация һәм космос техникасында композицион материаллар механикасына карый. М. модельдә һәм натурадагы ракета двигательләренең тавыш тизлегеннән зуррак агымнары тудырган акустик пульсацияләрне үлчәү методикасын һәм тәҗрибә комплексын тәкъдим итә; комплекс Капустин Яр полигонында (Әстерхан өлкәсе) яңа ракета техникасын сынаганда файдаланыла. Тикшеренү нәтиҗәләре ТР һәм РФнең югары уку йортларында, КБ, ЖБ, заводларында кулланыла. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, «СССРның рационализация һәм уйлап табулар отличнигы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение характеристик шума и оценка его воздействия на экипаж самоходной пусковой установки // Оборонная техника. 1989. № 5 (автордаш); Применение метода возмущений при теоретико-экспериментальном исследовании механики оболочек и пластин, имеющих сложный контур // Изв. АН СССР. Механика твёрдого тела. 1990. № 4 (автордаш); Неразрушающий контроль композиционных конструкций компьютерным томографом. К., 2011 (автордаш).

**МИТЮКО́В** Анатолий Павлович (15.1.1951, Рязань ш.), валторначы, ТРның халык артисты (1995). 1970 елдан Татар филармониясе симф. оркестрының валторначылар төркеме артисты. 1976 да Казан консерваториясен тәмамлый. 2007 дән Татарстан Респ-касының Зур концерт залында валторначылар төркеме концертмейстеры, 2011 дән ТР Дәүләт симф. оркестрының валторначылар төркеме концертмейстеры.

**МИФЛА́Р**, к. *Мифология*.

**МИФОЛО́ГИЯ** (грек. mýthos — риваять, хикәят һәм *...логия*), 1) борынгы ыруглык җәмгыяте һәм урта гасырлар башында яшәгән кешеләрнең җиһан, табигать, кешелек дөньясы, яшәеш-көнкүреш турындагы хыялый күзаллауларын чагылдырган мифлар (аллалар, батырлар, рухлар-ияләр һ.б. турындагы), риваятьләр җыелмасы. Татар халкында түбән мифология персонажлары: урман иясе — *Шүрәле*, су ияләре — *су анасы, су бабасы*, су кызы, йорт һәм абзар-кура ияләре — *ия, абзар иясе, өй иясе*, явыз рух *Албасты*, явыз затлар — *аждаһа, дию* һ.б.; кешеләрне аера торган, Күк дөньясы аллаларына дошманлык кылган, җир асты дөньясы иясе Әрклиг (Орхон-Енисей язма истәлекләрендә аның б-н бергә үлем алласы Бүрт хан да искә алына) турында мифологик хикәятләр сакланган. Татар халкының борынгы бабаларының Күк дөньясы аллалары, Җиһан һәм кешенең барлыкка килүе, беренче бабаларыбыз турындагы мифологик күзаллаулары халык авыз иҗатында тылсымлы һәм тотемистик *әкиятләр, дастаннар, мәкаль-әйтемнәрнең* кайтавазы, мотив һәм образлары рәвешендә сакланган һәм бары тик реконструкцияләү юлы б-н генә яңадан торгызыла алалар. Мәс., «Ак Бүре», «Ак елан» һәм кайбер башка әкиятләрдә аерым кабиләләрнең ак бүредән, ак еланнан, аккоштан һ.б. беренчел хайваннардан барлыкка килүләре турында сөйләнә. Орхон-Енисей язма истәлекләрендә (6–8 йөзләр), «Фал китабы»нда (9 йөз), Ибне Фадлан (10 йөз), М.Кашгари, Й.Баласагуни (11 йөз) хезмәтләрендә төрки-татарларның «югары аллалар» пантеоны, андагы Баш (Югары) Алла — *Тәңре* турындагы күзаллаулары чагылыш тапкан. Ул дөньядагы бөтен нәрсә б-н, ш.и. кеше язмышлары б-н дә идарә итә: Тәңре кешеләрнең гомер озынлыгын билгели, каһаннарга хакимлек бирә, гөнаһлыларны җәзалый, дәүләт һәм хәрби эшләр б-н идарә итә. Тәңре — антроморф (кешеләштерелгән) зат. Ул кешедәге кайбер сыйфатларга ия, хисләрен сүз б-н белдерә. Себер татарлары фольклорында кешенең эчендә яшәүче рухи башлангычны белдерүче *Умай* алиһә еш телгә алына. *Җир-су* — урта дөнья алласы. Тәңре һәм Умай б-н бергә төркиләрне үз канаты, үз яклавы астына алган ике өлкән алланың берсе. Ислам динен кабул итү Югары аллалар турындагы карашлар үзгәрүгә, мөселман дине б-н бәйле яңа мифологик персонажлар һәм атрибутлар туруга китерә; 2) мифларны, аларның килеп чыгуын, эчтәлеген, милли үзенчәлекләрен, таралуын өйрәнә торган фән. Татар мифологиясе фән буларак 19 йөз ахырында — 20 йөз башында барлыкка килә һәм К.Насыйри, Я.Д.Коблов, Н.Исәнбәт исемнәре б-н бәйле. 1980 еллар ахырыннан чыганаклар һәм материаллар эзләкләрәк өйрәнелә башлый, махсус җыентыклар барлыкка килә, фәнни мәкаләләр басыла. Татар энциклопедиясендә М.гә багышланган шактый материал тупланган.

*Әд.:* Н а с ы й р и К. Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр. К., 1975. Т. 2; Татар мифлары: 2 кит. К., 1996–99; У р м а н ч е Ф. Татар мифологиясе // Фәнни эзләнүләр юлында. К., 2000; ш у л у к. Татар мифологиясе аңлатмалы сүзлеген төзүнең төп принциплары // Фольклор теле — шигърият теле. К., 2001; ш у л у к. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь; К о б л о в Я.Д. Мифология Казанских татар. К., 1910; С т е б л и н - К а м е н с к и й М.И. Миф. Л., 1976; Мифы народов мира; Энцикл.: В 2 т. М., 1980–82.

*Ф.И.Урманчеев.*

**МИФТАХЕТДИ́НОВ** Альберт Вәли улы (11.5.1937, Уфа ш. — 9.11.1991, Мәскәү, Магадан ш.ндә җирләнә), язучы. Рус телендә яза. 1959 елда Киев ун-тын тәмамлаганнан соң, Чукоткага килә, 1966 тан Магаданда яши, телевидение студиясендә, «Советская Чукотка», «Магаданская правда» г-талары редакцияләрендә эшли. 1973 тән Магадан язучылары оешмасының җаваплы сәркәтибе. «Чукотка белән очрашу» («Встреча с Чукоткой»), «Үткел» («Перевал»), «Дәшмәү яры» («Берег молчания») телефильмнарының сценарий авторы. «Одиссей турында сөйлә» («Расскажи про Одиссея», Магадан, 1967), «Бик бәләкәй Җир шары» («Очень маленький земной шар», М., 1972), «Кит турындагы серле бер эш» («Совершенно секретное дело о ките», Магадан, 1983), «Котыптагы сәяхәтләр законы» («Закон полярных путешествий», Магадан, 1986), «Кит турында эш» («Дело о ките», М., 1994) хикәяләр җыентыклары авторы. М. Чукотка турында яза, аның геройлары — геологлар, каюрлар, сунарчылар. Хикәя һәм повестьларында язучы яшәешнең катлаулы мәсьәләләре турында уйлана: кем ул кеше, нәрсә ул яшәү, үлем? Аның китаплары эстон, поляк, болгар, испан, инглиз, француз телләренә тәрҗемә ителә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МИФТА́ХОВ** Альберт Габдрахман улы (7.11.1932, Лаеш р-ны Агайбаш а. — 7.10.2008, Казан), компрессорлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1997), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2001), Казан технол. ун-тының атказ. проф. (2006). 1956 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан компрессорлар з-дында эшли, турбомашиналар КБ башлыгы (1958–60), үзәктән куулы һәм суыткыч компрессор машиналары буенча баш конструктор урынбасары (1961–65). 1966–68 дә Ленинград политехник ин-тында. 1968 дән Казан технол. ун-тында, суыту техникасы һәм технологиясе каф. мөдире (1974–2001), бер үк вакытта компрессор машиналарын һәм җитештерү процессларын автоматлаштыру ф-ты деканы (1970–79). «Казанькомпрессормаш» һәм «НИИТурбокомпрессор» АҖләрнең фәнни киңәшчесе (2000 нән). Хезмәтләре үзәктән куулы компрессорларның аэродинамикасына карый. М. үзәктән куулы компрессорларның кертү һәм чыгару җайланмаларын исәпләү һәм оптималь проектлаштыру алымын эшли (ТР һәм РФнең компрессорлар һәм суыткыч машиналар төзү з-дларында гамәлгә кертелә). Компрессорларда югары һәм үтә югары басымлы өлешләрнең оптималь төзелеш вариантларын тәкъдим итә («НИИТурбокомпрессор» һәм «ВНИИХолодмашХолдинг» проект оешмаларында файдаланыла). Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм алтын ме-

дальләре, 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале; ТРның Мактау грамотасы, «РФнең мактаулы югары һөнәри белем хезмәткәре» билгесе б-н бүләкләнә. Таудан шуу спорты буенча СССРның спорт остасы (1953), ТАССР җыелма командасы әгъзасы (1948–56), Казан җыелма командасы тренеры (1952–56).


Х е з м.: Исследование, расчёт и проектирование выходных устройств центробежных компрессоров. К., 1980; Выходные устройства центробежных компрессоров. К., 1987; Входные и выходные устройства центробежных компрессоров. К., 1996; Аэродинамика выходных устройств центробежных компрессоров. М., 1999.

**МИФТА́ХОВ** Илмас Нуретдин улы (25.3.1942, Кайбыч р-ны Мөрәле а.), генерал-майор (1987). СССР һава һөҗүменнән саклану гаскәрләре хәрби-техник уч-щесен (Энгельс ш., 1962), Сов. Союзы Маршалы Г.К.Жуков исем. һава һөҗүменнән саклану командирлары академиясен (Тверь ш., 1969), А.Ф.Можайский исем. хәрби-космик академияне (1973) тәмамлый. 1975–83 елларда СССР һава һөҗүменнән саклану берләшмәсендә хәрби часть командиры урынбасары, командиры. 1983–87 дә СССР һава һөҗүменнән саклану берләшмәсе командиры урынбасары, 1987–88 дә командиры. 1988 дән СССР һава һөҗүменнән саклану берләшмәсе командирының 1 нче урынбасары — штаб башлыгы. Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МИФТА́ХОВ** Нариман Габдрахман улы (26.9.1929, Лаеш р-ны Агайбаш а. — 2.8.1971, Казан), хирург, мед. фән. канд. (1964). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Урыссу, 1957 елдан Ютазы район хастаханәләрендә хирург, баш табиб булып эшли. 1960 тан Казан мед. ин-тының балалар хирургиясе кафедрасында, 1970 тән педиатрия ф-ты деканы. 1968 дән ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар хирургы. Хезмәтләре үт юлларының бавыр эче архитектоникасына һәм аның клиник әһәмиятенә, ашказаны авыруларын хирургия юлы б-н дәвалауга карый. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Резекция желудка по материалам Урусинской районной больницы ТАССР // Казан. мед. журн. 1960. № 1; Опыт неотложной хирургической помощи при острых процессах брюшной полости в условиях районной больницы // Казан мед. журн. 1965. № 5.

**МИФТА́ХОВ** Ринат Низам улы (5.1.1937, Кама Тамагы р-ны Чаллы а.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1988). Сәхнә эшчәнлеген Казанда төзүчеләр клубы каршындагы драма түгәрәгендә башлый, 1957 елда Татарстан Респ-ка күчмә театры (хәзер Татар драма һәм комедия театры) труппасына чакырыла, анда ул 1991 гә кадәр эшли; 1999–2002 дә Казан татар яшь тамашачылар театрында актёр. И.Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы буенча Ш.Мәҗитовның «Резидәкәй» спектаклендәге Зөфәр роле яшь актёрга уңыш китерә. Лирик тәэсирлелек, заман рухына яраешлы романтик күтәренкелек, сәхнәдәге мөлаемлык, яхшы тавыш һәм музыка уен коралында уйный белү М.ка киң танылу алып килә. Актёр тарафыннан иҗат ителгән, аның талантының күпкырлылыгын, ул файдаланган чаралар байлыгын гәүдәләндергән сәхнә образлары — Хаҗи («Хаҗи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Җиһангир хан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Тайфур («Уеннан уймак», З.Шаһиморат), Салих («Урман егете», Т.Закиров), Әндәрҗан («Шомырт чәчәк атканда», А.Гыйләҗев), Яз («Тынгысыз төн», Г.Мөхәммәтшин), Ядкәр («Кыр казлары артыннан», И.Юзеев), Әпсәләм («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Сәйфулла («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Туктаров («Үзебез сайлаган язмыш», Т.Миңнуллин), деля Котри («Кызыклы очрак», К.Гольдони).


Р.Н.Мифтахов.


Р.Н. М и ф т а х о в Җиһангир хан ролендә («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт).

Ансамбльнең саклануын, спектакльнең бөтенлеген кайгыртып, М. һәр ролен, ш.и. эпизодик рольләрен дә гадәттән тыш җаваплы карый. Ул иҗат иткән Дәүләтбай («Караком фаҗигасе», А.Бодыгов), Солтанбәк («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Мөхәммәтҗан («Хәйләсез — дөнья файдасыз», К.Тинчурин), Зариф («Шәмсекамәр», М.Әблиев) образлары сәнгатьчә сурәтләү чараларының контрастлылыгы, игътибарны җәлеп итүе б-н аерылып тора.


Р.Н. М и ф т а х о в Мозаффар ролендә («Гармун уйный беләсеңме?», Т. Миңнуллин; сулда — З.И. Досаева).

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МИФТА́ХОВ** Рөстәм Нариман улы (5.4.1957, Баулы р-ны Урыссу пос.), биомеханик, техник фән. д-ры (1989), Казан мед. ин-тын (1980) һәм Казан ун-тын (1981) тәмамлый. 1981–88 елларда СССР ФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. 1988 дән Казан ун-тының өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре биол. тирәлектә нәсызыкча дулкын процессларын матем. модельләштерүгә, йомшак биол. тышчалар биомеханикасына карый. Медальләр б-н бүләкләнә. АКШта яши.

**МИФТА́ХОВА** Наилә Хөсәен кызы (28.4.1934, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1965), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955), Казан технол. ун-тында эшли, 1970 елдан чит телләр каф. мөдире. Химия-технол. профилендәге югары уку йортлары өчен инглиз теле дәреслекләре авторы. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Английский язык для химико-технологических вузов: Учеб. для I–II курсов: В 3 ч. М., 1981. Ч. 1; К., 2001. Ч. 2–3; Практический курс грамматики английского языка: Пособие для самообразования. К., 1995; Англо-русский химический словарь. К., 2005 (автордаш).

**МИФТА́ХОВА** Рәхилә Хәйдәр кызы (7.10.1940, Үзбәкстан ССР, Каракалпак АССРның Ходжейли ш., — 8.1.2000, Казан), җырчы (сопрано), педагог, РСФСРның атказ. (1981), ТРның халык артисты (1993). 1968 елда Казан консерваториясен (Н.Лучинина классы) тәмамлый. 1968–99 да Татар опера һәм балет театрында солистка, бер үк вакытта, 1971–78 дә, Казан музыка уч-щесендә, 1985–99 да Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә укыта. Опера сәхнәсендә М. Көнбатыш Европа, рус һәм татар композиторлары әсәрләрендәге төп партияләрне башкара. Алар арасында — Джильда («Риголетто», Дж. Верди), Аида (шул исем. әсәр, Дж. Верди), Маргарита («Фауст», Ш.Гуно), Мими («Богема», Дж. Пуччини), Чио-Чио-сан (шул исем. әсәр, Дж.Пуччини), Ярославна («Князь Игорь», А.Бородин), Татьяна, Лиза («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Сәрвәр («Башмагым», Җ.Фәйзи), Әлфия («Самат», Х.Вәлиуллин), Бибисара («Җиһангир», Р.Гобәйдуллин). Җырчының киң концерт репертуары И.С.Бах, Г.Ф.Гендель, В.А.Моцарт, Р.Шуман, Ф.Лист, П.Чайковский һ.б.ның вокаль әсәрләрен колачлый. М. — А.Ключарёв, Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, Р.Яхин, С.Садыйкова, З.Хәбибуллин, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтов, Р.Еникиев һ.б.ның җырларын, романсларын пропагандалауга аеруча игътибар бирә. Җырчы актив концерт эшчәнлеге алып бара, радио һәм телевидение фондларында язмаларын булдыра. М.ның иҗаты затлылыгы, нечкә зәвыгы, сәхнә хәрәкәте нәфислеге, башкару нәзакәтлелеге б-н аерылып тора. Педагог буларак, укучыларын тавыш б-н идарә итә белергә, вокаль осталык ярдәмендә образларны ма-

тур итеп ачарга өйрәтә. Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә ялгыз җырлау кафедрасын оештыручы (1997). М.ның укучылары арасында Р.Ибраһимова, Л.Муллагалиева, С.Рангулова, Р.Миңнегалиев, С.Вахитова, Т.Гордеева, Г.Бабаева бар.

*М.П.Фәйзуллаева.*

**МИХАЙЛ** (Воскресенский Михаил Дмитриевич) (27.12.1897, Курск губ., Путивль өязе Николаевка а. — 21.10.1976, Мәскәү), дин эшлеклесе. 1937 елда атып үтерелгән (2000 дә канунлаштырылган) епископ Дамианның (Воскресенский) улы. 1915 елда Смоленск руханилар семинариясен тәмамлаганнан соң, Петербург ун-тында укый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1916 дан Россия армиясендә, артиллерия офицерлары курсларын тәмамлый (Мәскәү). 1918–19 да Киев ун-тында укый. 1919–22 дә — Кызыл Армиядә, Гражданнар сугышында катнаша. 1923 тән Мәскәүдәге совет оешмаларында хезмәт итә. 1941–46 да — Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 дан — рухани, 1953–60 та Чкалов (Оренбург ш.) һәм Бозаулык епископы. 1960–75 тә Казан һәм Мари епископы (1963 тән — архиепископ). М.ның Казан епархиясе б-н идарә итүе чиркәүне кысрыклау чорына туры килә, ләкин М. ТАССРдагы барлык храмнарны саклап калуга ирешә, моңа аның Бөек Ватан сугышы ветераны булуы ярдәм итә. М.ның шәхси йогынтысы нәтиҗәсендә Казан епархиясе храмнарына яңа рухани кадрлар җәлеп ителә. 1960–70 елларда М. вәгазьләре «Журнал Московской патриархии» басмасының һәр санында диярлек дөнья күрә. Кызыл Байрак, Александр Невский, Ватан сугышы, өч Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Игумен Анастасий (Меткин), Павлов С. Архиепископ Михаил (Воскресенский), бывший Казанский и Марийский: Некролог // Журн. Моск. патриархии. 1977. № 2.

*Е.В.Липаков.*

**МИХА́ЙЛОВ** Александр Семёнович (24.6.1924, хәзер Кемерово өлкәсенең Тисульск р-ны Кунда руднигы — 10.10.1997, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1972), РСФСРның атказ. геологы (1989). Томск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Үзәк Казакъстан геофизик экспедициясендә (Караганда ш.), баш инженер (1953–59). 1960 елдан Себер геол., геофизика һәм минераль чимал фәнни-тикшеренү ин-тында (Новосибирск ш.). 1968 дән ЦНИИгеолнерудта, баш фәнни хезмәткәр (1988 дән). М. җитәкчелегендә молибден (Казакъстан, 1955), фосфорит (Красноярск крае, 1967), цеолит (Төрекмәнстан, 1980; СССР терр-ясендә беренче) чыганаклары билгеләнә. Цеолит чыганакларын эзләүнең теоретик нигезләрен эшләүдә катнаша, аларны эзләү критерийларын, сәнәгый төрләрен билгели. Татарстан терр-ясендә беренче тапкыр цеолит очравын ачыклый (1970). СССР терр-ясендә цеолитларның минераль-чимал базасын тудыруны фәнни яктан нигезли, физик-химик үзенчәлекләрен тикшерә, аларны халык хуҗалыгында файдалану юнәлешләрен билгели. «Фосфорит рудалары чыганакларын фаразлау һәм эзләү буенча методик куллanма» («Методическое руководство по прогнозированию и поискам месторождений фосфоритовых руд». М., 1982) һәм «СССРның фосфатлы чыганакларына минерагеник карта» («Минерагеническая карта на фосфатное сырьё СССР». М., 1983) авторы. СССР МС бүләге лауреаты (1990). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, «Мактаулы җир асты байлыкларын эзләүче» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Неметаллические полезные ископаемые СССР. Фосфориты. М., 1984 (автордаш); Поиски, разведка и оценка месторождений цеолитсодержащих пород. М., 1989.

*Әд.:* Памяти А.С.Михайлова // Отечественная геология. 1997. № 12.

**МИХА́ЙЛОВ** Борис Михайлович (21.3.1906, Иркутск губ., Киренск өязе Знаменка а. — 17.3.1984, Мәскәү), химик-органик, химия фән. д-ры (1948), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1968). А.Е.*Арбузов* шәкерте. 1929 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1930 дан Мәскәүдә: СССР ФАнең анализ һәм синтез лаб-ясендә, Мәскәү ун-тында (1932 дән), Бөтенсоюз эксперименталь мед. ин-тында (1937–41); 1943 тән СССР ФАнең Органик химия ин-тында, карбоциклик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1953–84), проф. (1963). СССР ФАнең Элементорганик химия буенча фәнни советында борның химик кушылмалары секциясе рәисе. Хезмәтләре гетероциклик, полициклик углеводородларга, селтеле металларның органик кушылмаларына, физиол. актив (канцероген, шешләргә каршы) кушылмаларга карый. Төп тикшеренүләре борорганик кушылмалар химиясе б-н бәйләнгән. М. аларны алкилтиобораннар кулланып синтезлауның гомуми алымнарын эшли. Аллилбораннарда перманент аллиль яңадан төркемләнү күренешен ачыклый. Аллилборанның ацетиленнар һәм алленнар б-н реакцияләрен ача, шулар нигезендә борлы полиэдрик уникаль системалар (1-борадамантан, 1-боргомоадамантан һ.б.) синтезлый. Борорганик кушылмалар кулланып синтезлауның нәтиҗәле ысулларын тәкъдим итә, кайбер типтагы синтезланган матдәләрнең вирусларга, ялкынсынуга, көзән җыеруга каршы, гербицид буларак һ.б. физиол. активлыгын билгели. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия бороводородов. М., 1967; Борорганические соединения в органическом синтезе. М., 1977; Полиэдрические соединения бора. 1-бороадамантан // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1984. № 1.

*Әд.:* Памяти Б.М.Михайлова // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1984. № 7; Волков В.А., Вонский Е.В., Кузнецова Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**МИХА́ЙЛОВ** Василий Николаевич (3.2.1910, Казан — 6.7.1943, Курск ш.), Сов. Союзы Герое (10.2.1943), майор. Хәрби пехота мәктәбен (1929), Оренбург хәрби очучы-күзәтчеләр мәктәбен (1934) тәмамлый. 1928 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет гаскәрләренең Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия (1939) походында катнаша. 1941 елның июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 125 нче бомбардировщиклар полкы штурманы (23 нче армиянең 5 нче катнаш авиация дивизиясе). Ленинград фронты авиациясе составында 1941 нең декабренә 75 сугышчан очыш ясый, дошман гаскәрләрен һәм дошман тылындагы мөһим хәрби объектларны бомбага тота. 1943 нең 6 июлендә Ленинград янында сугышчан буруч үтәгәндә батырларча һәлак була. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



В.Н.Михайлов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Буров А.В. Твои Герои, Ленинград. Л., 1970; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИХА́ЙЛОВ** Владимир Никифорович (28.1.1949, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974). 1974–78 елларда «Сельхозтехника»ның Казан бүлекчәсендә цех башлыгы, управляющий урынбасары, 1978–79 да Идел буе бүлекчәсе управляющие урынбасары, 1979–86 да махсус үзәк бүлекчәләр управляющие. 1986–88 дә элемтә чараларының «Центральремтехпред» Үзәк ремонт-техник пр-тиесе директоры. 1988–90 да Бөтенроссия «Росагропроминформ» берләшмәсе башлыгы урынбасары, «Связькомпьютерсервис» пр-тиесе директоры. 1990–92 дә «Внештрейдинвест» уртак пр-тиесе ген. директорының 1 нче урынбасары — Казан «Связькомпьютерсервис» җитештерү ф-лы директоры. 1992–95 тә ТР тышкы багланышлар министрының 1 нче урынбасары. 1995–2001 дә ТРның Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт ком-ты рәисе. 2001 дән ТР сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрының, 2007 дән сәнәгать һәм сәүдә министрының 1 нче урынбасары. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

**МИХА́ЙЛОВ** Евгений Владимирович (7.2.1973, Ижевск ш.), пианист, педагог, ТРның — халык (2004), Удмурт Респ-касы, РФнең атказ. артисты (2004, 2010). 1996 елда Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң (Э.Бурнашева классы), шунда укыта (2011 дән проф.), бер үк вакытта, 1997–2007 дә, Мәскәү дәүләт акад. филармониясендә солист. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Танылган симф. оркестрлар: Deutsche Symphonie-Orchester Berlin (Нем. симф. оркестры, Берлин), Belgium National orchestra (Милли оркестр, Бельгия), Buenos Aires Philharmonic (Буэнос-Айрес филармония оркестры, Аргентина), Mexico-City Philharmonic (Мехико филармония оркестры, Мексика) оркестрларында, Россия милли оркестрында, Санкт-Петербург филармониясе симф. ор-



М.К.Михайлов.

кестрында соло концертлары б-н чыгышлар ясый һәм атаклы дирижёрлар (В.Ашкенази, М.Плетнёв, С.Сондецкис, Ж.Кабалье-Доменеш, М.Палмер, Х.Местер, К.Кальмар, М.Горенштейн, Д.Лисс һ.б.) б-н хезмәттәшлек итә. М. концертлары Россиянең күп шәһәрләрендә, Европа илләрендә, Латин Америкасында, Көньяк-Көнчыгыш Азиядә, Төньяк Америка, АКШта уза. Пианист Швейцариядә (Internationale Musikfestwochen Luzern), Германиядә («Берлин–Мәскәү»), Норвегиядә (Э.Григ исем., Берген), АКШта (Bellingham music festival), Россиядә («Музыкаль Кремль») үткәрелеп килгән халыкара фестивальләрдә һ.б.да катнаша. М. репертуарын рус, Көнбатыш Европа классиклары, хәзерге заман композиторларының әсәрләре һәм пианистның дискографиясенә кергән күп кенә әсәрләр тәшкил итә. Тематик концерт программалары арасында: «Фортепиано әсәрләре транскрипциясе», «Француз клавир музыкасы тарихы», «Сюита: барокко стиленнән импрессионизмга кадәр», «Рус музыкасында әкият» һ.б. бар. М. бигрәк тә А.Скрябин сонаталарын башкаручы буларак танылa. Пианистның уены техник һәм сәнгати камиллеге, яңгырау көченең байлыгы, тавыш тәэсирлелеге, югары лиризм, төрле стильдәге төрле чор әсәрләрен иҗади башкаруы б-н аерылып тора. М. илебездә һәм чит илләрдә мастер-класслар, семинарлар һәм ачык дәресләр үткәрә, пианистлар конкурсларында жюри эшендә катнаша. Укучылары арасында бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреатлары, концерт бирүче пианистлар һәм педагоглар Е.Лось, В.Сидинкова, О.Карпухова, В.Лобарева, Е.Кротов, Т.Камалетдинова һ.б. бар. А.Скрябин исем. (1995, Түбән Новгород), Г.Эриксон исем. (1996, Швеция), Э.Поццоли исем. (1999, Италия), С.Рахманинов исем. (2002, АКШ) һ.б. халыкара конкурслар лауреаты.

**МИХА́ЙЛОВ** Максим Дормидонтович (13.8.1893, хәзер Чуаш Респ-касы, Вурнар р-ны Кольцовка а. — 30.3.1971, Мәскәү), җырчы (бас), СССРның халык артисты (1940). Бала чагыннан чиркәү хорында җырлый башлый. 1918–21 елларда Омск шәһәре чиркәвендә протодьякон, 1922–23 тә Казанда (Варвара чиркәвендә, бер үк вакытта Ф.*Ошустовича* дәресләр ала), 1924–30 да Мәскәүдә (бер үк вакытта Зур театр артисты В.Осиповтан җыр дәресләре ала). 1930–31 дә — Бөтенсоюз радио ком-ты (Мәскәү), 1932–56 да Зур театр солисты. Төп партияләре: Сусанин («Иван Сусанин», М.Глинка), Кончак («Князь Игорь», А.Бородин), Пимен, Варлаам («Борис Годунов», М.Мусоргский), Гремин, Чуб («Евгений Онегин», «Черевички», П.Чайковский) һ.б. Рус халык җырларын иң оста башкаручыларның берсе. Зур диапазонлы көчле тавышка ия. СССРда һәм чит илләрдә гастрольләрдә (Италия, Кытай, Норвегия, Һиндстан, Корея һ.б.) була. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1941, 1942). Туган ягында М. мемориаль музее ачыла.

*Әд.:* Е н д р ж е е в с к и й В.Е., О с и п о в Э.О. М.Михайлов. М.–Л., 1951; К у з н е ц о в а А.С. Повесть о народном артисте. М., 1964; Русские певцы. М., 1965.

**МИХА́ЙЛОВ** Марс Константинович (17.6.1938, Зәй р-ны Түбән Биш а.), нейрорентгенолог, нур диагностикасы белгече, мед. фән. д-ры (1978), ТР ФА академигы (1991), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1978, 1995). Проф. М.Х.Фәйзуллин шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Зәй район хастаханәсендә хирург. 1964 елдан Казан ГИДУВында, проф. (1980), ректор (1980–2007), нур диагностикасы каф. мөдире (1982 дән). Бер үк вакытта, 1992 дән, ТР ФАнең Мед. һәм биол. фәннәре бүлеге академик-секретаре. ТРның Нур диагностикасы белгечләре ассоциациясе президенты (1982 дән). ТР ЮСның Сәламәтлек саклау комиссиясе рәисе (1990–93), шәрәфле ректор (2007 дән). Аның актив катнашы б-н, РФдә беренчеләрдән булып, Казан ГИДУВында гаилә медицинасы каф. һәм интервенцион радиология лаб-ясе оештырыла. Хезмәтләре балалар нейрорентгенологиясенә карый. М., беренче булып, балаларның туганда имгәнгән умыртка баганасы һәм арка мие зәгыйфьлеген тикшерү өчен рентген диагностикасы принципларын эшли; баш мие, умыртка баганасы, бавыр, ашкайнату тракты авыруларына диагноз кую ысулларын камилләштерә һәм яңа мед. технологияләрен гамәлгә куя. Спрингомиелиягә диагноз куйганда, ш.у. яралгының үзәк нерв системасы һәм йөзендәге аномалияләрне тикшергәндә магнит-резонанс томографиясен куллану мөмкинлеген өйрәнә. Бил остеохондрозы очрагында умыртка сөягенең паравертебраль мускулларындагы патологик үзгәрешләрне өйрәнүнең М. тарафыннан гомумиләштерелгән ысулы умыртка-хәрәкәтләнү сегментының халәтен ачыкларга мөмкинлек бирә. Ул хатын-кызлардагы кайбер нейроэндокрин тайпылышларда эндокраниозның патогенетик роле барлыгын исбатлый; гиперпластик процесслар һәм эндометрийдагы яман шешкә башлангыч чорында диагноз кую критерийларын, ашказанындагы яман шеш таралышын нур ысулы б-н ачыклау алгоритмын эшли. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. Белград ун-тының шәрәфле профессоры (Югославия, 1990). ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2005). «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рентгенодиагностика родовых повреждений позвоночника. К., 1983; Нейрорентгенология детского возраста. К., 1986; Дифференциальная рентгенодиагностика заболеваний позвоночника. К., 1993 (автордаш); Онкогинекология. М., 2002 (автордаш); Эхография в диагностике цирроза печени. М., 2003 (автордаш); Рентгенодиагностика родовых повреждений позвоночника у детей. Учебное пособие для врачей. К., 2009; Туберкулёз органов дыхания. Учебно-методическое пособие. К., 2011.

*Әд.:* Академия наук Татарстана. К., 2002.

**МИХА́ЙЛОВ** Николай Вячеславович (19.4.1919, Уфа ш. — 9.7.2010, Казан), ветеринар-анатом, биол. фән. д-ры (1965), проф. (1967). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1941). 1945–48 елларда Сов. Армиясендә (вет. табибе). 1948 дән Казан вет. ин-тында, анатомия каф. мөдире (1966–86), бер үк вакытта (1966–71) вет. ф-ты деканы. Хезмәтләре, эволюцион морфология һәм организм биоэнергетикасы позицияләреннән чыгып, терлекләрнең нерв системасы макро- һәм микроморфологиясен һәм биомеханикасын өйрәнүгә карый. М. ветеринариядә, беренче буларак, перитонит һәм бронх ялкынсынуын лазер б-н дәвалау ысулын нигезли. Вузлар өчен язылган «Авыл хуҗалыгы терлекләре анатомиясе» («Анатомия сельскохозяйственных животных»; берничә тапкыр кабат басыла) дәреслеге авторларының берсе. Уйлап табуга патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Клиническая нейрология (Морфо-функциональный анализ). К., 1976; Механизм лечебно-стимулирующего действия луча лазера на организм животных и повышения их продуктивности. К., 1985.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**МИХА́ЙЛОВ** Олег Васильевич (7.4.1950, Харьков ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1993), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1976–88 дә Казан химия-фотография сәнәгате технол. һәм проектлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында. 1988 дән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре координацион химиягә, фотохимиягә, иммобильләшкән системалар химиясенә карый. М. комплекслар ясау процессларында желатин иммобильләшкән металл катыш матрицалы системаларның реакциягә сәләтен тикшерү һәм аларны гамәли куллану буенча фәнни юнәлеш булдыра. Төрле d- һәм f-металлар катыш желатин иммобильләшкән матрицалы системаларда комплекслар ясау һәм темплат синтезы процессларының гомуми закончалыкларын ачыклый, югары сыйфатлы көмеш булмаган моно- һәм полихром фотосурәтләр, юка оптик катламнар һәм иммобильләшкән сорбентлар алуның фәнни нигезләрен һәм технологияләрен эшли. Фәнни эшкәртмәләре «Тасма» ҖБдә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 125 тән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Комплексы d-элементов с хелатными и макроциклическими лигандами как перспективные компоненты несеребряных фотографических систем // Успехи химии. 1997. Т. 66, № 8; MHF-GIM Complexing: Novel Synthetic and Applied Horizons // Reviews in Inorganic Chemistry. 1997. V.17, № 4; Coordination Compounds as Components of Silverless Photographic Images // Journal of Coordination Chemistry. 1999. V.47, № 1.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МИХА́ЙЛОВ** Сергей Анатольевич (10.2.1956, Горький ш.), очкыч аппаратларның ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (2003), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2012). 1979 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Авиация техникасы һәм технологияләре ин-ты директоры (2003–12), проректоры (2012 дән). Хезмәтләре вертолётта төп терәк системаларның ныклыгына һәм аэросыгылмалылыгына карый. М. һава агымының тотрыксыз тәэсире шартларында вертолётның төп винты калаклары якынаюның санлы анализын тәкъдим итә. Калаклары шарнирсыз беркетелгән төп винтның йөкләнешләрен, ныклыгын һәм аэросыгылмалылыгын исәпли. Вертолётның төп системасы агрегатлары өчен катламлы полимер композицион материаллардан эшләнгән конструкцияләрне тикшерә (тикшерү нәтиҗәләре Казан вертолёт з-дында «Ансат» вертолётын төзегәндә файдаланыла).

Х е з м.: Динамика и прочность несущего винта. К., 1986 (автордаш); Расчёт распределения индуктивных скоростей по диску несущего винта при малых скоростях вращения в косом потоке // Изв. вузов. Авиац. техника. 1993. № 3 (автордаш).

**МИХА́ЙЛОВ** Сергей Михайлович (13.1.1955, Казан), архитектор-дизайнер, сәнгать фән. д-ры (2011), проф. (2001). 1977 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлый, 1982 дән шунда ук архитектур проектлаштыру кафедрасында эшли, 1991 дән архитектур мохит дизайны каф. мөдире, бер үк вакытта, 2001 дән, дизайн ф-ты деканы. Лениногорск (1996–98), Әлмәт (2000–02), Яшел Үзән (2006–07) һ.б. шәһәр үзәкләрен төзекләндерү буенча проект эшләре авторы. РФ Дизайнерлар берлеге әгъзасы (1994 тән, 1997 дән — вице-президенты, 1994–2005 тә — Татарстан бүлеге рәисе). 1995 тән — «Дизайн Ревю» ж-лының җаваплы, 2005 тән баш мөхәррире. РФ Дәүләт премиясе (2003), ТР Дәүләт премиясе (2004) лауреаты. Пушкин исем. Алтын медаль (1999), Россия САнең зур көмеш медале б-н (2004) бүләкләнә, дизайн өлкәсендә «Виктория» милли призы лауреаты (1996, 1998–2004).

Х е з м.: История дизайна. Краткий курс. К., 2004 (автордаш); Основы дизайна. К., 2008 (автордаш).

**МИХА́ЙЛОВ** Фёдор Кириллович (5.5.1898, Сембер губ., Буа өязе Атяшкино а. — 15.2.1986, Казан), техник-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Казан мех техникумын тәмамлый (1938). 1915–17 елларда Лукоянов (Сембер губ.), Гликин (Казан) мех з-дларында сарык тиресе эшкәртүче. 1922–26 да игенче (Атяшкино а.). 1926–28 дә «Красный пахарь» («Кызыл сабанчы») кулланучылар җәмгыятендә сатучы, «Коопмех» (Казан) артелендә сарык тиресе эшкәртүче. 1928–34, 1938–61 дә Казан мех комб-тында: тире эшкәртүче, 1 нче мех ф-касында мастер, 2 нче мех ф-касында бүлек, цех, производство башлыгы, техник җитәкче, цех башлыгы. Дәүләт бүләге сарык тиресенең өске ягын яхшыртып эшкәртүнең яңа алымын эшләгәне һәм кулланышка керткәне өчен бирелә. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сказ о Казанских меховщиках. К., 1974; Овчинка стоит выделки. К., 1978.

**МИХА́ЙЛОВА** Елена Александровна (28.1.1957, Әстерхан ш.), җырчы (лирик-драматик сопрано), педагог, ТРның халык артисты (1993). 1984 елда Мәскәү консерваториясен (И.Архипова классы) тәмамлый. 1984–86 да Әстерхан консерваториясендә иллюстратор булып эшли. 1986–87 дә Чиләбе опера һәм балет театрында, 1987–2001 дә Татар опера һәм балет театрында солистка



Е.А. М и х а й л о в а Сента ролендә («Очучы голланд», Р.Вагнер; Мэри ролендә – Г.Т.Ластовка).

(бер үк вакытта Казан консерваториясендә укытучы). Җырчы репертуарында — бөтендөнья опера репертуарыннан төп партияләр: Графиня («Фигароның өйләнүе», В.А.Моцарт), Ульрика («Бал-маскарад», Дж.Верди), Сента («Очучы голланд», Р.Вагнер), Кармен (шул исем. опера, Дж.Бизе), Тоска (шул исем. опера, Дж.Пуччини), Наташа («Су кызы», А.Даргомыжский), Ярославна («Князь Игорь», А.Бородин), Марина Мнишек («Борис Годунов», М.Мусоргский), Татьяна, Лиза («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Тамара («Демон», А.Рубинштейн), Земфира («Алеко», С.Рахманинов). Матур тембрлы яңгыравыклы көчле тавышка, югары проф. осталыкка ия җырчы. Россиядә һәм чит илләрдә гастрольләрдә була, Аргентина, АКШ, ГФР һ.б. илләр театрларының опера спектакльләрендә төп партияләрне башкара. 2001 елдан Әстерхан консерваториясендә укыта.



Е.А. М и х а й л о в а Лиза ролендә («Пики дамасы», П.И. Чайковский; Графиня ролендә – И.Архипова).

*Ф.Ш.Салитова.*

**МИХА́ЙЛОВА** Зинаида Евменовна (23.10.1923, Алтай губ. «Заря» коммунасы — 12.12.1992, Казан), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. канд. (1975), ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1966, 1973). Бөек Ватан сугышында катнаша: 1942–43 елларда Интендантлык уч-щесе курсанты (Омск ш.), 1943–44 тә хәрәкәттәге армиядә (Көнчыгыш фронт) ашерен эшләр бүлеге мөдире. Томск пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Барнаул, Томск шәһәрләрендә СССР Тимер юллар министрлыгы мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Томск тимер юлы уку йортлары бүлегендә 1951 дән методист, 1955 тән пед. кабинеты башлыгы; 1959 дан Казан тимер юлы уку йортлары бүлеге инспекторы. 1961–67 дә ТАССР Мәгариф министрлыгының мәктәпләр бүлеге өлкән инспекторы, башлыгы, 1967–79 да министр урынбасары. Бу елларда М. респ-када гомуми сигезьеллык һәм урта белем бирүгә күчү планнарын үтәүне тәэмин итү, *проблемалы укыту ысулларын* гамәлгә кертү буенча актив оештыручыларның берсе була. 1979–87 дә СССР ПФАнең Һөнәри-техник пед. фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре пед. фәннәре казанышларын гамәлгә кертү проблемаларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: От идеи — до внедрения (Вопросы внедрения достижений педагогической науки и передового опыта в практику массовой школы). К., 1977 (автордаш); Организация изучения, обобщения и внедрения передового опыта в учебно-воспитательный процесс. М., 1985.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**МИХА́ЙЛОВА** Регина Ипполитовна (10.5.1957, Казан), радиобиолог, а.х. терлекләрен тукландыру буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (2005). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук эшли: радиобиол. бүлегендә һәм вет.-сан. экспертизасы кафедрасында (1988 елга кадәр), терлекчелек технологиясе кафедрасының кафедраара лаб-ясе мөдире (1988–2002), зоол. каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре җәнлек үрчетүгә һәм радиобиологиягә карый. М. азык сыйфатын тикшерә, биол. актив матдәләр куллануның җәнлекләр организмына, алардан алына торган продукт сыйфатына тәэсирен өйрәнә.

Х е з м.: Качество кормосмесей после замораживания // Кролиководство и звероводство. 1989, № 3 (автордаш); Применение биологически активных веществ в рационе норок. Рекомендации. М., 1990 (автордаш); О стабилизации кормосмесей для зверей // Кролиководство и звероводство. 2004. № 5; Использование рапсового масла в кормлении норок // Зоотехния. 2004. № 9; Проблема ка-

чества кормов и питьевой воды в звероводстве // Уч. зап. Казан. гос. академии вет. медицины им. Н.Э.Баумана. 2004. Т. 174 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**МИХА́ЙЛОВА** Сәвия Мөхәммәтдин кызы (21.9.1942, Саба р-ны Туктамыш а. — 1.3.2007, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1986), проф. (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Казан ун-тын тәмамлый (1965), 1969–2007 елларда шунда эшли, 1995 тән сәяси тарих каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1990 нан, Казан техник ун-ты каршындагы Укытучыларның квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-тында тарих каф. мөдире. Хезмәтләре Казан ун-ты тарихына һәм аның Идел буе, Урал алды халыкларының белемен, мәдәниятен үстерүдәге әһәмиятен барлауга, шәркыять белеменә, хәзерге заман милли мөнәсәбәтләр мәсьәләләренә һәм милли мәдәниятләрнең үзара йогынтысына карый. «Культурология» уку ярдәмлеге авторларының берсе (1998). Медаль, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (2002).

Х е з м.: Формирование и развитие просветительства среди татар Поволжья (1800–1861). К., 1972; Казанский университет и просвещение народов Поволжья и Приуралья (XIX в.). К., 1979; Казанский университет в духовной культуре народов востока России (XIX в.). К., 1991; Культура многонациональной провинции: Поволжье и Приуралье. К., 2001 (автордаш).

*Әд.:* Тюркологи современного Татарстана: Справ. М., 1997; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Библиогр. словарь. К., 1999.

**МИХА́ЙЛОВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 175 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1812 дә Пенза губернасының Кызыл Бистә өязеннән күчеп килүчеләр нигез сала. 1860 елларда халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да волость идарәсе, земство станциясе урнаша; чиркәү (1863 тә төзелә), чиркәү-приход һәм земство мәктәбе, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3141 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 845, 1889 да — 1626, 1910 да — 1439, 1920 дә — 1614, 1926 да — 1419, 1938 дә — 1053, 1949 да — 877, 1958 дә — 645, 1970 тә — 474, 1979 да — 306, 1989 да — 84, 2002 дә — 188 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**МИХА́ЙЛОВКА** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 515 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 48%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, орлыкчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1856 да нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дубровка, Языково исемнәре б-н дә билгеле. Халкы игенчелек, терлекчелек, балта эше, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җил тегермәне була; дүшәмбе көннәрендә базар эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1073 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 480, 1897 дә — 715, 1913 тә — 625, 1920 дә — 650, 1926 да — 520, 1938 дә — 527, 1949 да — 411, 1958 дә — 291, 1970 тә — 350, 1979 да — 286, 1989 да — 652, 2002 дә — 554 кеше.

**МИХА́ЙЛОВКА** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Каргалы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 104 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче чирегендә отставкадагы солдатлар авылы булarak нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Солдатлар Каргалысы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч белем мәктәбе (1902 дә ачыла), җил тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 315 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 288, 1908 дә — 314, 1920 дә — 382, 1926 да — 305, 1938 дә — 186, 1949 да — 227, 1958 дә — 285, 1970 тә — 201, 1979 да — 165, 1989 да — 117, 2002 дә — 128 кеше.

**МИХА́ЙЛОВКА** посёлогы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 21 *км* көньяктарак, Терпеле елгасы буенда. 2010 елда 77 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Михайловка исеме б-н дә билгеле. 20 йөз башында тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 280 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1897 дә — 63, 1906 да — 115, 1913 тә — 131, 1920 дә — 145, 1926 да — 156, 1938 дә — 151, 1949 да — 142, 1958 дә — 72, 1970 тә — 208, 1979 да — 119, 1989 да — 67, 2002 дә — 70 кеше.

**МИХА́ЙЛОВКА** посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 19 *км* көньяктарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы ) буенда. 2010 елда 49 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да ашлык саклау-сату һәм вак-төякләр кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 203,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 25 гыйнварыннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 143, 1897 дә — 210, 1908 дә — 203, 1920 дә — 209, 1926 да — 253, 1938 дә — 106, 1949 да — 83, 1958 дә — 60, 1970 тә — 89, 1979 да — 62, 1989 да — 59, 2002 дә — 44 кеше.

**МИХА́ЙЛОВКА** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 17 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1927 дә Урта Камышлы авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан 1997 гә кадәр — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1949 да — 183, 1958 дә — 122, 1970 тә — 98, 1979 да — 70, 1989 да — 17, 2002 дә — 22 кеше.

**МИХЕ́ЕВ** Виталий Васильевич (9.1.1939, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1961 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона сәнәгате пр-тиесендә (Казан) эшли. 1964 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре азотның органик кушылмалары химиясенә һәм югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. М., органик карбонатларның аминнар б-н реакциясен кулланып, полиуретаннар һәм алар нигезендә капламнар алу ысулларын эшли, бу көчле агулы изоцианатлар куллануны туктатырга мөмкинлек бирә. Су б-н сыеклана торган һәм порошоклы буяу-лак материаллары җитештерү өчен, полиуретан олигомерлар синтезлый. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Безизоцианатные методы получения полиуретанов // Лакокрасочные материалы и их применение. 1981. № 5 (автордаш); Полиуретановые покрытия из полиаминов и олигомеров с карбонатными группами // Лакокрасочные материалы и их применение. 1982. № 4 (автордаш); Взаимодействие органических карбонатов с аминами // Журн. органич. химии. 1982. Т. 18, № 10 (автордаш).

**МИХЕ́ЕВ** Иван Степанович (19.7.1876, Казан губ., Мамадыш өязе Ошторма-Юмья а. — 17.9.1937, Йошкар-Ола), удмурт һәм керәшен татар мәгърифәтчесе, педагог, язучы, тәрҗемәче. Казан үзәк керәшен татар мәктәбен (1894), Казан укытучылар семинариясен (1896) тәмамлый, 1897–1913 елларда Казан укытучылар семинариясе каршындагы үрнәк башлангыч вотяк мәктәбендә укыта; сәяси яктан ышанычсыз дип эштән җибәрелә, либераль карашлы була, кадетлар партиясе әгъзасы, чиркәүләр реформасын яклый, 1917 гә кадәр Казанның сәүдә фирмаларында хезмәт итә. 1917 дән Казанда РСФСРның Милләтләр эшләре буенча Халык ко-

мис-ты каршындагы удмурт басмалары мөхәррире, 1924–26 да Шәрекъ пед. ин-тында, бер үк вакытта, 1918 дән, Казан керәшен пед. техникумында удмурт теле укыта. 1917–18 дә барлык керәшен татар конференция һәм съездларында, үзәк керәшен татар мәктәбен дөньяви уку йорты итеп үзгәртү эшендә катнаша. 1926 да Урта Азиядә: Ходжент, Сталинабад (Дүшәнбе ш.), Сәмәрканд шәһәрләренең югары уку йортларында укыта. 1936 дан Мари пед. ин-тында. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Библияне, дини әдәбиятны удмурт теленә тәрҗемә итүдә катнаша, Евангелиене (Инҗилне) тәрҗемә итә (1904). Милли мәктәпләр өчен удмурт һәм рус телләре буенча 20 ләп дәреслек һәм методик ярдәмлекләр, ш.и. рус булмаган мәктәпләр өчен рус телендә 4 үрнәк уку китабын бастыра, алар совет чорында да киң кулланылышта була. Оригиналь методикалы «Рәсемнәр буенча иншалар», текстлар һәм иллюстрацияләр авторы, алар Россиядә 17 тапкыр басыла, төрек, кытай, япон телләренә тәрҗемә ителә. Удмурт телендә 4 пьеса яза, 1904–10 елларда удмурт календарен нәшер итә.

Х е з м.: Грамматические упражнения в начальной школе. К., 1903; Букварь на вотском языке. К., 1907; Первая книга для чтения на вотском языке. К., 1907; Наглядный арифметический задачник для начальных школ. К., 1907; Материалы для составления предложений: Справ. К., 1929; Методика преподавания русской грамоты в школах нацмен. К., 1929.

*Әд.:* С у в о р о в а З.В. Педагогические идеи удмуртского просветителя И.С.Михеева. Ижевск, 1990.

**МИХЕ́ЕВ** Николай Антонович (1902 нең феврале, Әстерхан ш. — 21.8.1941, Казан), фармаколог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1938). Әстерхан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1927), шунда ук, фармакология кафедрасында эшли. 1931 дән Ерак Көнчыгыш (Хабаровск шәһәре) мед. ин-тының фармакология каф. мөдире. 1939 дан Казан мед. ин-тының фармакология каф. мөдире һәм педиатрия ф-ты деканы. Хезмәтләре даруларның йөрәк-кан тамырлары системасына тәэсирен өйрәнүгә карый.

*Әд.:* Деканы Казанского медицинского университета. К., 1997.

**МИХЕ́ЕВ** Павел Егорович (20.12.1912, Казан губ. Чистай өязе, хәзер Нурлат р-ны Егоркино а. — 22.5.1978, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (21.1.1944, 4.2.1945, 15.5.1946), гв. старшинасы. Туган авылы совхозында тракторчы булып эшли. 1934–36 елларда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 65 нче танк полкында танк механик-йөртүчесе (8 нче гв. армиясе). Сталинград, Көньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Изюм-Барвенково, Донбасс (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1943 нең 16–23 декабрендә Запорожье шәһәре (Украина ССР) янындагы (экипаж составында танкка каршы тупны, 2 пулемётны, 4 блиндажны юк итә); 1945 нең 15 гыйнварында Бервце (Польша) тимер юл станциясе тирәсендәге (экипаж составында дошманның 3 тубын, 2 миномётын сафтан чыгара); 1945 нең 1–5 маенда Берлин урамнарындагы һәм шәһәр читендәге (дошман уты астында үзенең танкын ремонтлап, дошманның 2 танкын, 7 тубын һәм берничә автомашинасын юкка чыгара) сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Туган авылында эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.



П.Е.Михеев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды Славы. К., 1969; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИХЛЯ́ЕВ** Иван Афанасьевич (1667–1728), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре. 18 йөзнең беренче чирегендә Казанның иң бай сәүдәгәрләреннән берсе. Мәскәүдә, С-Петербургта, Эрбет, Мәкәрҗә һ.б. ярминкәләрдә сәүдә итә. *Казан постау мануфактурасы*, тире иләү-эшкәртү, спирт з-длары, туң май эретү йорты, 34 вак-төякләр кибете, берничә торак йорт хуҗасы; Мәскәү тукыма з-дының милектәше. М. милкендә җир һәм крепостной крәстияннәр була. Җәнлек тиресе б-н тәэмин итеп торучыларның берсе (1720 елда Мәкәрҗә ярминкәсенә 12740 җәнлек тиресе җибәрә). 1714 тә Казанда, Кремльдән ерак түгел, шәхси постау мануфактурасы төзи, 1722 дә аны император Пётр I килеп күрә. Казна һәм М. мануфактураларында җитештерелгән әйберләрне сыйфат ягыннан тикшереп, Пётр I казна мануфактурасын М.ка тапшырырга карар кыла. Кайбер мәгълүматларга караганда, Пётр I М. йортында туктала. Легендада М. Пётр I гә алтын һәм көмеш тәңкәләр тутырылган, алтын бизәкләр б-н зиннәтләнгән көмеш поднос бүләк итә диелә. М. акчасына Казанда Пятницкий чиркәве, *Петропавел соборы*, Казан губернасы Казан өязенең Потаниха авылында Иоанн-Предтеча чиркәве, Алат авылында Успение чиркәве, Спас өязе Болгар авылында Успение чиркәве төзелә. М.ның тол хатыны Авдотья Ивановна кушуы буенча 1731–56 да — Казанда Богоявление чиркәве, 1735 тә Евдокия чиркәве төзелә. Ш.у.к. *Михляев йорты.*

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: Дела и люди. К., 1998.

**МИХЛЯ́ЕВ ЙОРТЫ́** (Дряблов йорты), Казанда 17 йөз ахыры — 18 йөз башында «Нарышкин бароккосы» стилендә төзелгән һәм сакланып калган бердәнбер рус гражданлык архит-расы истәлеге. Тукыма мануфактурасы хуҗасы И.А.Михляев өчен төзелә, ул үлгәннән соң, тол калган хатынының туганы Дрябловка мирас буенча күчә. 60x17 *м* зурлыктагы турыпочмаклы, ике катлы кирпеч бинаның гөмбәзсыман түшәмле беренче каты хуҗалык ихтыяҗларында файдаланыла, өске катында торак бүлмәләр урнаша. Торак бүлмәләргә төп фасадның үзәгендә төзелгән өйалды баскычы күтәрелә. Сузынкы фасад лопаткалары асимметрияле 3 өлешкә бүленгән. Беренче кат бүлмәләрен йөзлексез кечкенә тәрәзәләр яктырта. Беренче катның шома диварларын өске катның бизәкле кәрнизе аерып тора. Икенче катның тәрәзә йөзлекләре берничә төрле: ярымколонкалы «әтәч кикрикләре», ярымколонкасыз җилпәзә сыман кечкенә фронтоннар һәм ярымколонкалы өчпочмаклы кечкенә фронтоннар б-н купшылап каймаланган. «Нарышкин бароккосы» стилендәге йорт нәфис бизәкле кәрниз б-н төгәлләнә. Интерьерлары сакланган. 20 йөздә көньяк фасад ягына янкорма төзелә. 1770 елда Дряблов йортны гарипләрне асрау ихтыяҗына тапшыра, 1816 дан анда — ашханә, 1833 тән — кунакханә, 1840 тан трактир һәм чәйханә урнаша. Хәзерге вакытта йорт Петропавел соборы карамагында.



Казандагы И.А.Михляев йорты.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МИХО́ВКА**, к. *Мүкле күл.*

**МИХРА́Б** (гарәп. محراب. — изге урын), *мәчет* түрендә *Мәккә* юнәлешендәге (*кыйбла*) куыш. Намаз укучы мөселманнар М.ка йөз б-н басалар, *мөнбәр* М. б-н янәшә була. Татар мәчетләре архит-расында тышкы яктан М. — җир өстеннән яки дивардан чыгып торучы түгәрәк, турыпочмаклы яки бишпочмаклы өске өлеше конуссыман, дүрт, ике кыеклы, ярымгөмбәзле түбә б-н ябылган янкорма рәвешендә төзелә. М.ның интерьерын ярымтүгәрәк яки уксыман а́рка, уеп ясалган орнаментлар, каллиграфик язулар, полихром бизәкләр һ.б. тәшкил итә. М., мәчет архит-расы элементы буларак, Өммәвиләр династиясе идарә иткән чорда (661–750) барлыкка килә. Җирле шартларга һәм традицияләргә карап, М.ның зурлыгы, формасы (квадрат, күппочмаклык, ярымтүгәрәк), уеп ясалган бизәкләре төрлечә була. Гадәттә, таштан, мәрмәрдән, керәчтән, агачтан төзелә.

**МИЧ**, бинаны җылыту, кайнар ризык әзерләү өчен төзелгән корылма. Таш гасырда ук гади учаклар булуы мәгълүм. М.ләр торакның сакраль үзәкләре булып та хезмәт иткәннәр (йорт һәм гаилә рухларының яшәү урыны), хәзер дә аларның форма һәм конструкцияләрендә халыкларның көнкүреш мәдәниятенә хас кайбер традицияләр саклана.

Төтен үткәргеч морҗалар — төтен юллары идән астыннан һәм дивар эченән үткән үзенчәлекле үзәк җылыту системалы М.ләрнең респ-ка терр-ясендә Идел буе Болгар дәүләте заманнарында ук булуы билгеле. Кагыйдә буларак, андый катлаулы, кыйммәткә төшкән конструкцияләр б-н феодал йортлары, җәмәгать мунчалары җиһазландырылган. Идел буе һәм Урал алды авылларында яшәүче татарларда рус М.ләреннән үзгә тәбәнәгрәк авызлы һәм төпле, гөмбәзе эчендә ян учак (төтене төп морҗага суырылган аерым ягу урыны) булган һәм аның өстенә ризык әзерләү өчен металл казан батырып урнаштырылган йорт М.е — күбесенчә кирпечтән (элек кулдан сугылган) салынган катлаулы корылма файдаланыла. Сергач мишәрләрендә, Мәлки керәшеннәрендә һәм төбәкнең башка халыкларында (мәс., чуашларда) М. алдына ыргакка казан аса торган булганнар. Элек-электән татарларның йортлары «ак М.ләргә» ягып җылытылган (М.тәге төтен морҗадан күтәрелгән). «Кара М.ләр» (төтен өйгә таралып, юллык аша яки ачык ишектән урамга чыккан) 20 йөз ахырында сирәк кенә керәшеннәр, Ука-Сура елгалары арасында яшәгән мишәрләр, Урал алды һәм чыпца татарлары көнкүрешендә файдаланылган. Татар М.ләре кырыена русларга хас булган М. яны сәке-ятаклары корылмаган. Татар крәстияне өендә М.ләр, гадәттә, ишек тирәсендә, йортның «ак» ягыннан такта яки тукыма чаршау б-н бүлеп алынган аш-су әзерләнә торган «кара» якта урнаша. Яшәгән төбәккә карап, М.ләрдә утын, салам, кизәк һ.б. ягыла. Урал алдында, Себердә, Әстерхан өлкәсендә хәзер дә вакытлыча корылган торакларда куллану, җәйге чорда аш-су әзерләү һ.б. максатлардагы эшләр өчен уңайлы чуваллар — каркаслары чыбык һәм колгалардан эшләнгән, камин сыман балчык М.ләр файдаланыла. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан татарлар көнкүрешенә голланд М.ләре үтеп керә; аларны йортның «ак» ягында чыгаралар, еш кына чынаяк плитәләр б-н бизиләр, бу корылмага еш кына казан, самавыр кую өчен чыгынты өстәлә. Хәзерге вакытта, электрлаштыруга һәм газлаштыруга карамастан, авыл җирләрендә татар М.ләре көнкүрештә күп функцияле һәм гадәти корылма буларак саклана.

*Әд.:* Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татары. М., 2001.

*Ф.Ф.Гулова.*

**МИЧӘНБА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 19 *км* төньяктарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 154 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм; 1930 елларга кадәр Югары Мичән исемен йөрткән. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1154,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда. 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 404, 1897 дә — 608, 1908 дә — 545, 1920 дә — 613, 1926 да — 633, 1938 дә — 685, 1949 да — 442, 1970 тә — 328, 1979 да — 232, 1989 да — 140, 2002 дә — 168 кеше.

**МИЧКӘ́-КИСМӘ́К КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, юка тар такталарны бер-берләренә ырмавын ырмауга туры китереп беркетеп, кыршаулап, төпләп, мичкә, кисмәк, су һәм күәс чиләкләре, ләгәннәр һәм хуҗалыкка кирәкле башка төр зур савытлар җитештерү. 17–19 йөзләрдә Казан губернасының Козьмодемьянск, Лаеш, Мамадыш, Зөя, Спас, Тәтеш, Чабаксар өязләрендә аеруча киң таралыш ала. М.-к.к. ике мөстәкыйль тармактан тора: 1) имән, юкә, усак яки чыршыдан, кисеп һәм ярып, махсус юка такта әзерләү; 2) такталардан эреле-ваклы савытлар җыю. Суык вакытта бу эш җылы урында, елның җылы фасылларында өсте ябулы ачык җирдә башкарылган. Эш барышында агач калып (бүкән), киң һәм гадәти ышкы, чүкеч, кыска саплы балта, кәкре пычак кебек эш кораллары кулланылган. Гадәттә, бу эш гаилә кәсебе булган. 1887 елда М.-к.к. б-н — 763, 1895 тә 384 кеше шөгыльләнгән. 20 йөздә, фабрика-заводлар металл һ.б. материаллардан күп төрле әйберләр ясап чыгара башлаганнан соң, әлеге кәсеп бетүгә йөз тота. Хәзерге вакытта респ-ка авылларында агач савыт-саба ясаучылар сирәк очрый.

*Әд.:* Бусыгин Е.П. Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966.


**МИЧУРИ́Н** посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 61 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 310 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 63%, чуашлар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1923 тә Иске Куак авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Красный Ключ, 1937–59 да — Микоян исем. посёлок. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Чирмешән волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1958 дә — 464, 1970 тә — 551, 1979 да — 467, 1989 да — 371, 2002 дә — 326 кеше.

**МИША́НИН** Тимофей Андреевич (21.2.1890, Казан губ., Лаеш өязе Аркатау а. — 28.6.1941, Украина ССР, Львов өлкәсе Дубно ш. янында һәлак була), танк гаскәрләре генерал-майоры (1940). Хәрби хезмәткә чакырылганчы, Мамадыш тракты төзелеше өчен табигый ташлар чыгаруда эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Прапорщиклар мәктәбен (Житомир ш.) тәмамлый, Петербургта лейб-гв. полкында хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң туган авылына кайта. 1918 дән Кызыл Армия сафларында. Гражданнар сугышы елларында Н.И.Махноның крәстиян армиясенә, петлюрачыларга, ак полякларга каршы сугыша; Көньяк-Көнбатыш фронтның 34 нче һәм 366 нчы укчы полклары командиры. 1921 дән 142 нче өйрәнү полкы батальоны командиры, Идел буе хәрби округы курслары тыңлаучысы. 1922 дән 1 нче Казан укчы полкының полк мәктәбе башлыгы һәм 1 нче укчы дивизиясе батальоны командиры. 1923 тән рота командиры, 1925 тән Төркестан фронтының 3 нче Төркестан укчы полкы командиры ярдәмчесе. 1929 дан «Выстрел» курслары тыңлаучысы. 1929 дан 3 нче тау укчы полкы командиры ярдәмчесе. 1935 тән Кызыл Армиянең танклар частенда. 1939 дан 23 нче җиңел танк бригадасы командиры. 1939 ның сентябрь–октябрендә сов. гаскәрләренең Көнбатыш Украинага походында катнаша. 1940 тан 15 нче танк дивизиясе командиры. Бөек Ватан сугышы чорында 8 нче механикалаштырылган корпусның 12 нче танк дивизиясе командиры. Сугышта һәлак була. Питрәч р-ны Питрәч авылының бер урамына М. исеме бирелә. Орден, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Гришин Я.Я., Шарафутдинов Д.Р. На службе Родине. К., 2005.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МИШӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 186,4 *км*, бассейнының мәйданы 4180 *км²*. Елга башы Кукмара р-ны Ятмас-Дусай авылыннан 1,4 *км* төньяк-көнчыгыштарак урман массивында, Саба, Теләче һәм Питрәч р-ннары терр-ясеннән ага; түбән агымы һәм тамагы Лаеш р-ны терр-ясендә. Элек елга тамагы Ташкирмән һәм Макаровка авыллары янында була, хәзер Карадулат авылыннан түбәнрәк, елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган һәм суднолар йөрерлек Мишә култыгы хасил иткән. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданы елга кушылдыклары, сыза һәм ерым үзәннәре б-н бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән тора. Елга бассейны асимметрияле: уңъяк яр өлеше шактый зур. Үсемлекләр дөньясы, нигездә, караңгы ылыслы-киң яфраклы һәм киң яфраклы урманнардан, тугайлы болыннардан тора. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 17%. Сөрүле җирләр якынча 80%. М. бассейны күп кенә урыннарда дүртенчел система яшендәге токымнар б-н капланган Пермь системасы Казан һәм татар ярусы токымнарыннан тора. Су җыелу мәйданында рельефның карст формалары очрый. М. бассейны өчен көлсу типтагы урман туфраклары (аксыл соры, кара соры), ш.у. кәсле-көлсу туфраклар хас. Елга үзәне трапециясыман, түбән агымында җиңелчә генә беленә; уңъяк



Мишә елгасының урта агымы.

сөзәклекләре, нигездә, текәрәк. Үзәннең киңлеге югары агымында 30 *м* дан түбән агымында 4–5 *км* га кадәр. Тугае киң, ике яклы, түбән агымда уйсулыклар, ерганаклар һәм элекке күлләр күп; тамак өлешендә елга өлешчә Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган. М. елгасының юлы бормалы, урыны-урыны б-н болын һәм куакчыл үсемлекләр үскән утраулар (озынлыгы 15–65 *м*, киңлеге 20 *м* га, биеклеге 3 *м* га кадәр) хасил итеп тармаклана. Урта һәм түбән агымында киң плёслар (озынлыгы 0,2 дән 3 *км* га кадәр, киңлеге 15–40 *м*, тирәнлеге 2–5 *м*), аларда исә агым тизлеге 0,1–0,2 *м/с* тан артык түгел. Елганың күп кенә урыннары сайлыклар б-н катлауланган, аларда исә елга юлының киңлеге 10 *м* га кадәр, тирәнлеге 0,2–0,6 *м*, агым тизлеге 1–2 *м/с*. М. ярлары комсыл балчыклы һәм балчыксыл комлы туфрактан тора, урыны б-н текә, биеклеге 2–4 *м*, Казкаш елгасы тамагы янында 10 *м* га кадәр. Башлыча, елга төбе тигез, борылмаларда чокырлар очрый. М.нең 45 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Нысы (22,2 *км*), Нырсы (33,4 *км*) — сул; Казкаш (28,4 *км*), Кече Мишә (49,9 *км*), Тәмте (24,6 *км*), Кибәче (14 *км*), Норма (40 *км*), Сола (23 *км*), Шемелка (16,6 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*$^2$. М.нең туенуы катнаш, агым кар сулары, җир асты кушылдыклары, явым-төшемнәр исәбенә барлыкка килә. Елга режимын күзәтүләр Питрәч р-ны Чыты (1932–53) һәм Лаеш районы Рождествено (1932–55), Обухово (1931–59) авыллары янындагы гидрологик постта алып барыла. Хәзерге вакытта Питрәч авылы янында пост эшли (1959 дан). Гидрологик режим өчен ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу чорлары хас, аларга еллык агымның 70% туры килә. Тигезлекнең уртача еллык тирбәнеше 7 *м* (макс. 9,8 *м*). Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 162 *мм*, ташу вакытында су катламы 113 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры–апрель башында башлана. М. ноябрь уртасында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 35–50 *см* га җитә. Елга суының иң аз вакытында җир асты сулары б-н туена. Бассейнының төрле урыннарында җир асты сулары б-н туену модуле 0,5 тән 10 *л/с·км*$^2$ ка кадәр. Җәйге корылыклар вакытында М.нең югары агымы һәм аның кушылдыклары тар инешләргә әйләнеп кибә. Суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы югары агымында 0,008 *м*$^3$*/с* тан урта агымында, Теләче авылыннан түбәндәрәк 2,4 *м*$^3$*/с* ка кадәр һәм түбән агымында (Питрәч р-ны Колай а. янында) 6,2 *м*$^3$*/с*. Елга тамагында суының уртача күпьеллык чыгымы 17,4 *м*$^3$*/с* (1979). Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. М.бассейнында суның гомуми күләме 25,7 млн.*м*$^3$ һәм мәйданы 855 *га* булган 45 буа бар. Су ресурслары якынча 10 мең *га* га якын а.х. җирләрен сугару өчен кулланыла. Яр буйлары ял итү урыннары булып тора. М. — ТРның табигать истәлеге (1978). Аның уңъяк ярында «Иске тегермән» табигать истәлеге урнашкан.

**МИШӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кече Мишә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 31,5 *км*, бассейнының мәйданы 255 *км*$^2$. Саба р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Кукмара р-ны Яңа Комар авылыннан 1,7 *км* көньяк-көнчыгыштарак урман массивында, тамагы Саба р-ны Сабай авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 89 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. М.нең 0,3 тән алып 10,8 *км* га кадәр озынлыктагы 25 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнында еллык су агымының уртача



Мишә елгасының түбән агымы.

күпьеллык катламы 119 *мм*, ташу вакытында су катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. М. ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 *м*$^3$*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.


**МИШӘ́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́**, Мамадыш, Балык Бистәсе, Питрәч һәм Саба р-ннары терр-ясендә урнашкан. Мәйданы 131,7 мең *га*, ш.и. урманнар 23,9 мең *га*. Кызыл Йолдыз һәм Лаеш урманчылыкларының ылыслы, катнаш һәм вак яфраклы урман участокларын үз эченә ала. Мишә, Нырсы, Әшнәк, Бәтке, Шомбыт, Бөрсет һ.б. кече елгалар ага. 1984 елда аучылык-промысел фаунасын (елга кондызы, гади тиен, суер, соры көртлек) саклау максатыннан оештырыла. Пошы, кәҗәболан, кабан дуңгызы, төлке, урман сусары, Америка чәшкесе, селәүсен, үр куяны һәм ак куян яши.

**«МИШӘ́ 2»**, йомшак уҗым бодае сорты, 1990 елда Э.Ф.*Ионов*, Г.Х.*Вәлиуллин*, П.П.Дёмкин, Н.П.*Капитонова*, Л.А. *Семахина* тарафыннан Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Мишә сортыннан кызыл бөртекле формаларны күпләп сайлап алу юлы б-н чыгарыла. 1992 дә бу сорт Урта Идел төбәгендә куллануга рөхсәт ителгән Дәүләт селекция казанышлары реестрына кертелә. Салкынга чыдамлыкка донор сыйфатында селекция өчен тәкъдим ителә. Өнчыл чыкка һәм көрән яфрак гөмбәсенә аз бирешүчән. «М.2.» — эритроспермум төрчәләренең төрле биотипларыннан торган популяция. Куагы арадаш. Башагы цилиндрик формада, озын, уртача тыгызлыкта, кылчыклары озын, ак, башакның бөтен буена урнашкан. Башак тәңкәсе озынча-йомыркасыман формада, теше кыска, туры. Киль ачык күренә. Бөртеге озынча, буразнасы тирән түгел. Җиргә 3–5 *см* тирәнлеккә чәчкәндә, орлыкларны 1 *га* га чәчү нормасы 5,5 *млн*. Иң яхшы чәчү вакыты 20–31 август. Иң югары уңыш чиста парга чәчкәндә алына. ТРның Кама аръягы р-ннарында һәм биләүле пар элгәрләренә чәчкәндә, чәчү 15 августтан башланырга мөмкин. Уртача өлгерешле сорт, «Мироновская 808» сортыннан 1–2 көнгә соңрак өлгерә. Уңышы 1 *га* дан 5 *т* чыга. Бөртеге эре, югары продуктлы (1 мең бөртекнең авырлыгы 38–41 *г*), составында 32,4% чи клейковина (җилемчә), 13,8% чи протеин бар, икмәк пешерүдә сыйфаты югары (4,3 балл). Корылыкка бик чыдам. ТРда бу сорт 1993 тән чәчүгә кертелгән.

*И.Д.Фадеева, Э.Ф.Ионов.*

**МИШӘБА́Ш** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы (Мишә бассейны) буенда. 2010 елда 301 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Мишәбаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 939,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 262, 1897 дә — 363, 1908 дә — 416, 1920 дә — 412, 1926 да — 370, 1938 дә — 376, 1949 да — 363, 1970 тә — 292, 1979 да — 254, 1989 да — 236, 2002 дә — 281 кеше.

**МИШӘ́Н КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Мишә һәм Идел елгаларының субүләрендә урнашкан, Лаеш р-ны Пиголи авылыннан 1,9 *км* төньяктарак. Су өслегенең мәйданы 3,1 *га*. Су күләме якынча 90 мең *м*$^3$. Озынлыгы һәм киңлеге якынча 170 *м*. Уртача тирәнлеге 2,9 *м*, иң зур тирәнлеге 5 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы түгәрәк. Ярлары сөзәк, төньяк һәм көнбатыш өлешләрендә кат-



Мишән күле.

наш урман үсә. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**МИШӘ́Р ДИАЛЕКТЫ́**, Идел һәм Урал буе мишәрләре субэтник төркеменең *сөйләшләре* җыелмасы. М.д. ш.у. «көнбатыш диалект» буларак та билгеле. Мишәр сөйләшләре Г.Әхмәров («Мишәрләрнең теле һәм халкы турында» — «О языке и народности мишарей», 1903) һәм С.Е.Малов («Мишәрләр янында булып кайтканнан соң (Чистай өязе мишәрләренең шивәсе турында)» — «Из поездки к мишарям (о наречии мишарей Чистопольского уезда)», 1903) хезмәтләренә бәйле рәвештә өйрәнелә башлый. «М.д.» термины беренче тапкыр Л.Җәләйнең «Татар телендә диалектлар» (1938) дип аталган фәнни хезмәтендә кулланыла. «Татар диалектологиясе» (1947) китабында ул М.д. сөйләшләренең кайбер үзенчәлекләрен яктырта. Мишәр сөйләшләрен өйрәнү-тикшерену эшләре 1950 еллар ахырында активлаша төшә, ел саен М.д. вәкилләре тыгыз урнашып яшәгән районнарга экспедицияләр оештырыла башлый. Алынган мәгълүматлар Л.Ш.Арсланов, Ф.С.Баязитова, Н.Б.Борһанова, Р.Р.Минголова, Д.Б.Рамазанова, З.Р.Садыйкова, Т.Х.Хәйретдинова, Р.Ф.Шакирова һ.б.ның басмаларында чагылыш таба. Система буларак, М.д. Л.Т.Мәхмүтова тарафыннан тасвирлана. М.д.ның таралышын күрсәтүче диалектологик карталарның системалы җыелмасы *Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласында* урын ала. М.д.нда ц-лаштыручы һәм ч-лаштыручы сөйләшләрдән торган 2 төркем аерып карала. Ц-лаштыручылар төркеменә — сергач (Түбән Новгород өлкәсе), чүпрәле (Татарстан һәм Чуаш Респ-калары), байкибаш (Башкортстан) сөйләшләре; ч-лаштыручылар төркеменә темников, ләмбрә (Мордва), кузнецк (Пенза өлкәсе), хвалын, мәләкәс, карсун (Ульянов өлкәсе), подберезенск-керәшен, чистай-керәшен (Татарстан), эстәрлетамак (Башкортстан), шарлык (Оренбург өлкәсе), куршин (Тамбов өлкәсе), волгоград (Әстерхан һәм Волгоград өлкәләре, Ставрополь крае) сөйләшләре керә. Кама аръягында формалашкан чистай сөйләше катнаш характерда, биредә ц-лаштыручылар да, ч-ләштерүчеләр дә яши. М.д.ның барлык сөйләшләренә дә хас гомуми үзенчәлекләр бар. Фонетика тармагында болар түбәндәгеләр: 1) [а]ның иренләшмәве, 2) дифтонгларның монофтонглашуы: кү (әдәби телдә — көй), бәлә (әдәби телдә — бәйлә), курик (әдәби телдә — койрык); 3) урта диалекттагы һәм татар әдәби телендәге увуляр (кече тел) [к], [ғ] тартык авазлары урынына бары тел арты [к], [г] авазларын гына куллану; 4) й-лаштыруның активлыгы: йәй (әдәби телдә — җәй), йиң (әдәби телдә — җиң); 5) [ч] һәм [ж] авазлары урынына [тч], [дж] авазларын куллану: катчан (әдәби телдә — кайчан); 6) ц-лаштыру күзәтелгән сөйләшләрдә [ч] урынына [ц] дип: пыцах (әдәби телдә — пычак); [ж] урынына [дз] дип әйтү: эндзе (әдәби телдә — энҗе) һ.б. Морфологиядә бу үзенчәлекләр түбәндәгеләр: 1) фигыльгә -гы/-ге кушымчасы һәм кели сүзе ялганып (-гы/-ге + кели), эш башкаручының теләге белдерелә: баргым кели (әдәби телдә — барасым килә), укык кели (әдәби телдә — укыйсы килә); ш.у. -ма + кели формасы да бар: барма келим (әдәби телдә — бармакчы булам); 2) -гакла/-гәклә (әдәби телдә — -галә/-гәлә) кушымчасы ярдәмендә эш-хәрәкәтнең күп тапкырлар кабатлануы күрсәтелә: килгәклә (әдәби телдә — килгәлә), укыкла (әдәби телдә — укыштыргала); 3) вакыт рәвешләренең кулланылуы күзәтелә: кыш ката (әдәби телдә — кыш буе) һ.б.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск, 2003; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006. Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М., 1978.

*Д.Б.Рамазанова.*

**МИШӘ́Р ЙОРТЫ́** (Мещера, Мещера төбәге, рус елъязмаларында «Мещерский юрт»), Мишәр җирләрендә һәм Алтын Урданың төньяк биләмәсе *Мухша олысындагы* терр. бүленеш берәмлеге. 13 йөзнең 2 нче яртысында М.й.на татарлар килеп утыра башлый. Татарларның бу төбәктә яшәве археол. истәлекләр (Итәк, Саров шәһәрлекләре) һәм җирле топонимика (Томников) б-н раслана. 14 йөз ахырында Алтын Урдада үзара низаг барганда М.й.нда татарлар саны арта. Шушы чорда Мишәр крае Мәскәү дәүләте составына кертелә. 1460 еллар тирәсендә М.й. терр-ясендә башында Касыйм хан торган *Касыйм ханлыгы* оеша (үзәге — Городец-Мещерский, соңрак — Касыйм шәһәре); 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр ул кайбер чыганакларда М.й. исеме б-н бирелә.

*Әд.:* Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–87. Ч. 1–4; Баязитов Р.Ж., Макарихин В.П. Восточная Мещера в средние века. Н.Новгород. 1996; Исхаков Д.М. От средневековых татар к татарам нового времени. К., 1998; шул ук. Тюрко-татарские государства XV–XVII вв. К., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МИШӘРЛӘ́Р** (үзатамалары — татар), Идел буе — Урал алды татарларының субэтник төркеме. 1897 елгы халык саны алу мәгълүматлары буенча аларның гомуми исәбе — 622,6 мең, 1926 елгы исәп буенча — 200 мең кеше чамасы. М.не төньяк (Сергач), көньяк (Темников), Ләмбрә, көнбатыш-Урал алды, төньяк-көнчыгыш этнографик төркемнәргә бүләләр. М.нең халык сөйләм теле татар теленең көнбатыш диалектын хасил итә, ул татар әдәби теле формалашуга зур йогынты ясый (к. *Мишәр диалекты*). Диндар М. — сөнни мөселманнар. Элек М. арасында «мишәр» этнонимы, этниконнар рәвешендәге «төмән», «алатыр» дигән якташлык атамалары, «мөселман» конфессионимы һ.б. кулланыла. Аларның этномәдәни асылы формалашуда бортаслар, төркиләр (ш.и. *болгарлар, кыпчаклар*), җирле фин-угор халыклары (мещера, мордвалар һ.б.), ихтимал, *маҗарлар* катнаша. М.нең Алтын Урда чорына барып тоташкан этник компоненты, гадәттә, болгарларның көчле йогынтысын кичергән бортаслар б-н бәйләп күрсәтелә. Бортасларның этник тамырлары хәзергәчә ачыкланмаган. Килеп чыгышлары буенча аларның угор яки төрки-угор кабиләләре булуы да мөмкин. Болгар феодаль халкы формалашкан чорда бортасларның үз төбәкләренә хас кайбер үзенчәлекләрен саклаулары ихтимал. Алтын Урда оешканнан соң бортасларның варислары яшәгән төбәкләргә күпсанлы кыпчак-нугай төркемнәре үтеп керә, алар 14 йөздә *Мухша олысы* составында булалар. Бу чорда һәм соңрак «можар» — «мещера» этнонимы актив кулланыла, әмма чыганакларда «татарлар» атамасы да еш очрый. 13 йөз борынгы рус әдәбияты ядкәре «Аңлатмалы Палея» («Толковая Палея») тексты нигезендә «мещера» терминының политоним сыйфатында кулланылуы хакында нәтиҗә ясарга мөмкин. 1401–02 елларга нисбәтле рус грамоталарына караганда, Мещераның үз волостьлары булган. *Фра-Мауро* картасында (портоланда) Meschiera провинциясе һәм Macharini торулыгы билгеләнгән. Ихтимал, 1434 һәм 1447 еллардагы рус грамоталарында искә алынган «мещера кенәзләре» Мещераның сәяси үзәгендә яшәгәннәрдер. М.нең алга таба (14 йөз —16 йөз уртасы) халык буларак формалашуы башкаласы баштарак *Городец-Мещерский* дип аталган *Касыйм ханлыгы* чикләрендә «можар» (борынгырак) һәм «татар» (башлыча, кыпчак-нугай) компонентлары җирлегендә бара. Мещера төбәгендә (Касыйм ханлыгының икенче аталышы) әлеге ике этноатамалы страталарның булуы чыганакларда сакланган 2 этнонимик системада чагыла. Аларның беренчесе — «Мещера җирләре», «Мещера урыннары», «Мещера волостьлары белән», «Мещера», «Meschiera провинциясе», «Мещера төбәге», «Мещера кенәзләре». Бу сүзләрдән, ихтимал, бортасларны билгеләүче «Мещера кешеләре» төшенчәсе, кыскартылма рәвештә «можеряннар», «можарлар», «мещеряннар» («мещериннар») атамалары барлыкка килә. Системаларның икенчесе Касыйм ханлыгының феодаль катлавы б-н бәйле: 15 йөздә ул катлау «татарлар», 16 йөздә «Городец татарлары», «Мещера татарлары» дип атала. Бу компонент берничә этник элементтан тора. Башта аның үзеген «Мещера татарлары», ягъни Алтын Урда татарлары (Ширин ыругыннан һ.б.) тәшкил итә. Соңрак аларга Касыйм хан б-н килгән татарлар, аннары чыгышлары б-н Кырым ханлыгыннан һәм Нугай Урдасыннан булганнар кушыла. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөз башында Мещера төбәгендә яшәгән төрки халыкка карата ешрак «татар» этнонимы кулланыла; бу исә әлеге чорда инде мишәрләрнең төп этник компонентлары туплалып бетүен күрсәтә. Әмма нугайларның һ.б. төрки төркемнәрнең даими рәвештә килеп торулары, ш.у. йомышлы-мишәр төркемнәренең миграцион активлыгы сәбәпле процесс тәмамланмыйча кала. 16 йөзнең 1 нче яртысында барган киң колачлы миграция процесслары нәтиҗәсендә М. Иделнең уң ярындагы җирләрдә, Кама аръягы төбәкләрендә һәм Урал алдында таралып урнашалар. М.нең *Казан татарлары* б-н актив этносара бәйләнешлары бу субэтник төркемнәр арасындагы интеграцион процессларның көчәюенә китерә (16–19 йөзләр). Казан татарлары

М.нең этномәдәни үсешендә зур роль уйныйлар. М., үз чиратында, татарларның башка төркемнәренең, ш.у. башкортларның, типтәрләрнең һ.б. халыкларның матди һәм рухи мәдәниятенә көчле этномәдәни йогынты ясыйлар.

М. арасында җирле үзатамалар, акрынлап, гомуммилли «татарлар» этнонимы тарафыннан кысрыклап чыгарыла. Әлеге этнонимга көчү чорында «мөселман» этноконфессионимы кулланыла. Татар милләте формалашу дәверендә М. күп кенә субэтнос билгеләрен, беренче чиратта, үзенчәлекле үзаңнарын югалталар. Ләкин 1926 да халык исәбен алу вакытында да татарларның бер өлеше үзен мөстәкыйль халык — М. сыйфатында күрсәтә. «Мишәр» этнонимының тотрыклылыгы Идел буе–Урал алды татарларының берләшү процессы төгәлләнмәве, ш.и. 1860 елларга кадәр ярымхәрби типтагы аерым «мещералар» кантоннары сакланган Урал алдында яшәгән М.нең ярым сословиеле асылы б-н бәйле. Моннан тыш, озак вакытлар М.нең кайбер тел һәм мәдәни үзенчәлекләре яшәп килә (мәс., Казан татарларыннан аермалы буларак, 1950 еллар уртасына кадәр М. *Сабан туен* һәм *Җыенны* бәйрәм итмиләр). 20 йөздә бу аерымлыкларның күбесе юкка чыга яки йотыла. Хәзерге вакытта «М.» этнонимы, икенче дәрәҗәдәге үзатама сыйфатында, локаль рәвештә саклана.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск, 2003; Ахмаров Г.Н. О языке и народности мишарей. К., 1903; Васильев Б.А. Проблема буртасов и мордва // Тр. Ин-та этнографии АН СССР. 1960. Т. 13; Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов (мишарский диалект татарского языка). М., 1978; Сенютов С.Б. История татар Нижегородского Поволжья с последней трети XVI до начала XX вв. (Историческая судьба мишарей Нижегородского края). Ниж. Новгород, 2001; Vasary I. The Hungarians or Mozars and the Mescers / Mizers of the Middle Volga region. Lisse, 1976.

*Д.М.Исхаков.*

**МИШӘТАМА́К ШӘҺӘРЧЕГЕ́**, кальга, *Казан җирләрендә азатлык сугышлары* (1552–56) барышында рус гаскәрләренә каршылык күрсәткән үзәкләрнең берсе. Львов елъязмасында теркәлгәнчә (1553 нең марты), «Казаннан 70 чакрымнарда», Мишәнең Чулманга койган урынында төзелә. 1553–54 еллар кышында рус гаскәрләре М.ш.н басып алалар һәм яндыралар, «... анда булган аз сандагы халыкны кыралар, кайберләре чыгып качарга өлгерә». М.ш. урыны Саба р-ның Өтернәс авылына якын, археол. калдыклары сакланган.

*Әд.:* Полное собрание русских летописей. СПб., 1914. Т. 20, Ч. 2; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МИ́ШИН** Владимир Иванович (17.2.1906, Сухуми ш. — 1988, Казан), җылылык техникасы инженеры, «Татэнерго» идарәсе управляющие (1957–66). Кубань индустриаль техникумын тәмамлый (1928), Грозный җылылык техникасы инженерлары ин-тында укый (1929–33). Хезмәт эшчәнлеген 1922 елда «Севкавжирмасло» з-дында слесарь буларак башлый (Краснодар ш.). 1928–41 дә «Грознефть» идарәсендә эшли; 1941–45 тә «Красная турбина» ГЭСы директоры (Грозный ш.), 1945–48 дә Грозный шәһәре башкарма ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1948–57 дә «Урыссуэнерго» район энергетика идарәсе управляющие. М. җитәкчелегендә Урыссу ГРЭСында 227 мең *кВт* егәрлеккә исәпләнгән 6 турбогенератор гамәлгә кертелә, Зәй ГРЭСы төзелә, Казандагы ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2 газ ягулыгы куллануга күчерелә, «Татэнергоремонт» з-ды төзелә, электр тапшыру линияләре челтәрләре киңәйтелә, Түбән Кама ТЭЦы төзелеше башлана; республика электр станцияләренең гомуми куәте 3 тапкырдан күбрәккә (ш.и. авыл җирендә урнашкан станцияләрнең куәте — 2 тапкыр) арта, еллык электр энергиясе җитештерү 9550 млн. *кВт* ка җитә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МИ́ШКА-ОВРА́Г** посёлогы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 39 *км* төньяк-көнбатыштарак, Күклек елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 18 кеше (марилар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.-О.та тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 454,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 100, 1887 дә — 201, 1905 тә — 253, 1920 дә — 220, 1926 да — 256, 1949 да — 87, 1958 дә — 36, 1970 тә — 37, 1979 да — 27, 1989 да — 33, 2002 дә — 26 кеше.

**МИШКӘ́ РАЙОНЫ́**, БРның төньягында урнашкан. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 1689 *км²*. Үзәге — Мишкә авылы (Уфадан 131 *км* төньяктарак). Халкы — 24498 мең кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 8404, 1979 да — 6191, 1989 да — 5296, 2002 дә — 4291, 2010 да — 4027 кеше. М.р.нда 78 торак пункт, ш.и. 16 татар, берәр татар-башкорт, татар-мари, татар-рус һәм татар-мари-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009): Татарбай (478 кеше), Яңакош (417), Иштебай (327), Бабай (252). 2004/05 уку елында районның 9 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 4 сендә татар теле фән буларак өйрәнелә.

**МИШКЕ́ВИЧ** Али (23.6.1945, Вурцбах ш., Германия), тарихчы, гуманитар фән. д-ры (1984). Польша-Литва татарларыннан. А.Мицкевич исем. ун-тны тәмамлый (Познань ш., 1975). 1975–78 елларда — Югары пед. мәктәбе каршындагы Көнбатыш Поморье ин-тында (Шецин ш.), 1983–84 тә Гдынь шәһәре музеенда эшли. 1984 нең октябреннән Варшава ун-тының Белосток шәһәре ф-лында укыта. Хезмәтләре Польша татарлары тарихына карый.

Хезм.: Tatarzy polscy 1918–1939. Warsz., 1990; Tatarzy polscy 1945–1990. Bialystok, 1993.

**МИ́ЩЕНКО** Александр Павлович (26.3.1948, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2002), ТРның атказ. икътисадчысы (2004). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тының механика ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, җитештерү процессын автоматлаштыру кафедрасында, 1980 нән җылылык техникасы кафедрасында эшли. 1985–2003 тә Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ин-тында: менеджмент кафедрасын төзүдә катнаша һәм аның беренче мөдире була, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базарында коммерция эшчәнлеге каф. мөдире (2000–01), пр-тиеләр икътисады һәм алар б-н идарә итү каф. профессоры (2002). 2003 тән Казан финанс-икътисад ин-тының (хәзер Казан ун-ты) маркетинг каф. мөдире. Хезмәтләре базар субъектлары арасында икътисади бәйләнешләрнең нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә, рациональ оештырылган структуралар булдыруга карый.

Хезм.: Трансакционные издержки в торговле. М., 1999 (автордаш); Механизм расчёта экономических связей на основе трансакционных издержек // Маркетинг. 2000. № 4; Эффективность товарного обращения и трансакционные издержки // Экономист. 2000. № 9; Поиски путей роста эффективности экономических связей // Федерализм. 2001. № 2; Формирование рациональных торговых сетей. К.,2004.

**МИ́ЩЕНКО** Фёдор Герасимович (6.2.1848, хәзер Чернигов өлкәсе — 28.10.1906, Киев), тарихчы, филолог, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1895), Казан ун-тының атказ. профессоры (1902). Киев ун-тын тәмамлый (1870). Киев (1872–84) һәм Казан (1889–1903) ун-тларында укыта. «Учёные записки Казанского университета» («Казан университетының гыйльми язмалары») ж-лы мөхәррире. Хезмәтләре эллинизм чоры Греция, Херсонес һәм Ольвия шәһәрләре тарихына карый. Борынгы грек теленнән Страбонның «География» (М., 1879), Геродотның «Тарих» (т. 1–2, М., 1885–86), Фукидидның «Тарих» (т. 1–2, М., 1887–88), Полибийның «Гомуми тарих» (т. 1–3, М., 1890–99) һ.б.ның хезмәтләрен тәрҗемә итеп, аларга шәрехләүләр, кереш мәкаләләр һәм сүз ахырлары яза. Ф.А.Брокгауз һәм И.А.Ефронның «Энциклопедия сүзлеге»ндәге (т. 1–86, П., 1890–1907) Греция тарихы һәм грек әдәбиятына багышланган мәкаләләр авторы.

Хезм.: Историко-литературное значение комедии Аристофана «Облака». Киев, 1872; Фиванская трилогия Софокла. Киев, 1872; Торговые сношения Афинской республики с Босфором. Киев, 1878; Изучение античного мира в зависимости от успехов науки и просвещения. К., 1893.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Шкляев Н.П. Казанский период научной деятельности профессора Ф.Г. Мищенко // Уч. зап. Казан. ун-та. 1956. Т. 116, Кн. 5.

**МИЯКӘ́ РАЙОНЫ́**, БРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 2051 *км²*. Үзәге — Кыргыз-Миякә авылы (Уфадан 190 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 27063 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 18344, 1979 да — 15079, 1989 да — 16731, 2002 дә —


12116, 2010 да — 11091 кеше. Районда 101 торак пункт, ш.и. 29 татар, 13 татар-башкорт һәм 2 татар-рус авылы бар. Иң зур татар авыллары (2009): Кыргыз-Миякә авылы (8325 кеше), Җелдәр (1013), Әнәс (989), Мәнәвезтамак (998), Родниковка (975 кеше). Иң борынгы авыллар: Мәнәвезтамак (1746 ел), Миякәтамак (1752), Өршәкбаш-Карамалы (1755), Баязит (1766 лар тирәсе), Кыргыз-Миякә (1767). 2004/05 уку елында районның 10 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 14 ендә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Октябрь» г-тасы татар, башкорт һәм рус телләрендә нәшер ителә.

**МИЯ́Ш** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 3,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 10 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1929 да нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Минзәлә волостенда. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1938 дә — 133, 1949 да — 135, 1958 дә — 143, 1970 тә — 144, 1979 да — 122, 1989 да 77, 2002 дә — 68 кеше.

**МНЕ́КИН** Равил Васильевич (1.9.1946, Казан), радиофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996), техник фән. канд. (1989). 1964 елда Казан авиация техникумын тәмамлаганнан соң, оборона пр-тиесендә эшли. 1971 дә Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, Радиоэлектроника һәм телекоммуникацияләр ин-ты директоры урынбасары (2001 дән). Уйлап табуга 24 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге «Машиналар һәм приборларны виброакустик сынау өчен радиоэлектрон системалар һәм комплекслар (теориясе, алымнар һәм чаралар)» хезмәте өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оптимизация устройства имитации эксплуатаций вибрации // Измерительная техника. 1989. № 2; Имитация и компенсация случайной вибрации. К., 1996 (автордаш); Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1996 (автордаш).

**«МОАБИ́Т ДӘФТӘРЕ́»**, М.*Җәлил* тарафыннан 1942–44 елларда, күбесенчә Моабит (Берлин) төрмәсендә үлем көткәндә язылган шигырьләр циклы. 93 шигырь теркәлгән 2 блокнот сакланган. Гарәп графикасында язылган беренче блокнотны төрмәдән әсир сугышчы Г.Шәрипов алып чыга. Ул аны Франция Каршылык хәрәкәтендә катнашкан Н.Терегуловка бирә. Терегулов блокнотны 1946 ның мартында СССРга алып кайта. Латин графикасында язылган икенче блокнотны шагыйрьнең камерадашы, Бельгия Каршылык хәрәкәтендә катнашкан А.Тиммерманс алып чыга. 1947 нең язында совет консуллыгы аны Брюссельдән Казанга җибәрә. Ул елларда М.Җәлил исеме тыелган була. СССР КГБсы шагыйрьне гаепләп эш ача, аңа сатлыкҗан исеме тагыла. Тик И.В.Сталин үлгәннән соң гына, И.Френкель тәрҗемәсендә шагыйрьнең берничә шигыре «Литературная газета»да (1953 нең 25 апреле) басылып чыга. Шигырьләр тулысынча татар телендә 1953 нең ахырында «Моабит дәфтәре» исеме б-н (Г.Кашшаф редакциясендә) дөнья күрә. «М.д.» циклы — Бөек Ватан сугышы еллары татар поэзиясенең иң зур казанышларыннан берсе. М.Җәлил шигъри сүзне гражданлык яңгырашы б-н баета, татар поэзиясенә героик пафос алып килә («Җырларым», «Алман илендә», «Ышанма» һ.б.). «М.д.»ндә ш.у. лирик, юморга корылган шигырьләр һәм балладалар да урын алган. Шагыйрь ил сакчысының эчке дөньясын, Ватанына кайнар мәхәббәтен һәм тугрылыгын, дошманга нәфрәтен тирән ача алган. Патриотизм темасы «М.д.»ндә яңа эстетик дәрәҗәгә күтәрелә һәм нык тәэсирле сәнгати көч б-н ачыла. Шигырьләр күпгасырлык татар язма әдәбияты традицияләре, татар фольклоры мотивлары, ш.у. Шәрекъ поэтикасы, рус һәм дөнья әдәбияты тәэсирендә язылган.




Моабит дәфтәре.

«М.д.» күп тапкырлар татар һәм рус телләрендә басыла, 60 тан артык чит телгә тәрҗемә ителә. Рәссам В.П.Аршинов, «М.д.» мотивларына нигезләнеп, югары сәнгати цикл иҗат итә. Татар композиторлары (С.Сәйдәшев, Р.Яхин, З.Хәбибуллин) «М.д.» шигырьләренә җырлар язалар. Цикл поэтикасының йогынтысы Р.Фәйзуллин, Р.Харис, И.Юзеев иҗатларында сиземләнә. «М.д.»нең төп нөсхәсе ТР Милли музеенда саклана, һәр елда шагыйрьнең туган көнендә экспозиция оештырыла. Цикл өчен М.Җәлилгә 1957 дә (үлгәннән соң) Ленин бүләге бирелә.

*Әд.:* К а ш ш а ф Г. Муса Җәлил. К., 1961; М у с т а ф и н Р. По следам оборванной песни. К., 2004.

*Р.Ә.Мостафин.*

**МОГИ́ЛЬНИКОВА** Галина Аркадьевна (6.9.1928, Түбән Новгород губ. Арзамас ш. — 8.2.2001, Казан), сәнгать белгече, музей эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1974). Ленинград ун-ты тарих ф-тының сәнгать белеме бүлеген тәмамлый (1952). 1952–54 елларда Чкалов шәһәрендә (хәзерге Оренбург ш.) өлкә мәдәният идарәсендә өлкән инспектор булып эшли. 1955 тән ТАССР Дәүләт музеенда фәнни хезмәткәр (хәзер ТР Милли музее), соңрак картиналар галереясы мөдире булып эшли. 1959 дан сынлы сәнгать музеенда, фәнни эшләр буенча директор урынбасары (1968–82), музейның үзе оештырган фәнни архивы мөдире (1983 тән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). М. тикшеренүләре рәссамнар С.О.Лывин, И.К.Колмогорцева, К.Е.Максимов, Н.Д.Кузнецов, М.Г.Госманов һ.б.ның иҗатларын, ш.у. сынлы сәнгать музее коллекциясен өйрәнүгә, Казан һәм Татарстанның сәнгать тормышындагы билгесез фактларны ачуга багышлана. М. Н.И.*Фешинның* иҗади мирасын өйрәнү һәм пропагандалауга күп игътибар бирә; рәссам чит илгә киткәннән соң, беренче тапкыр аның музейда сакланган картиналарыннан күргәзмә оештыра (1958), Фешинның Советлар Союзы терр-ясе музейларындагы һәм шәхси тупланмалардагы әсәрләрен ачыклау һәм өйрәнү буенча зур эш башкара, Казанда Фешин хезмәтләренең бөтенсоюз күргәзмәсен оештыра (1963–64), соңыннан алар Мәскәү, Ленинград, Киров, Рига шәһәрләрендә узган күргәзмәләргә куела. Аның актив катнашында ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда Фешин хезмәтләренең зур коллекциясе һәм архивы туплана, «Фешин залы» мемориалы төзелә. М. сынлы сәнгать музееның Алабуга (1961) һәм Чаллы (1990) ф-лларын оештыруда катнаша. 1950 еллар ахырында Казан сәнгать уч-щесендә укыта, ТАССР МС каршындагы Сәнгать советы әгъзасы була. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Произведения В.А.Тропинина в собрании музея. К., 1956; Художественные выставки в Казани во второй половине XIX века. К., 1958; Николай Иванович Фешин: Документы. Письма. Воспоминания художника. Л., 1975; Государственный музей изобразительных искусств РТ. Русское искусство XVII — начала XX веков. Живопись: Каталог. К., 2005.

*Әд.:* Т у л у з а к о в а Г. Служение подвижницы // Казань. 2006. № 3.

**МОДА́ЛЬ СҮЗЛӘ́Р**, хәбәр ителә торган фикергә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр, субъектив-модаль мәгънәләрне белдерүдә төп лексик чара хезмәтен үтиләр. М.с. чынбарлыктагы предметларны да атамыйлар, аларның билгеләрен дә белдермиләр, аларга сүз ясагыч кушымчалар ялганмый. Татар телендә М.с.не төзелеше ягыннан гади (ахры, бугай, бәлки, мөгаен, икән, имеш, дөрес, билгеле, әлбәттә һ.б.) һәм кушма (чыннан да, чынлап та, булса кирәк, булырга кирәк һ.б.) төрләргә аерып карыйлар. Мәгънә ягыннан М.с.: а)раслауны (әлбәттә, дөрес, бәхәссез, чыннан да һ.б.); б)фараз кылу, ихтималлык, икеләнү төсмерләрен (ихтимал, мөгаен, бәлки һ.б.) белдерүче төрләргә бүленә.

Җөмләдә М.с. кереш сүз (кыскасы, әлбәттә һ.б.) һәм хәбәрлек сүз (тиеш, мөмкин һ.б.) вазифаларын үти; синтаксик яктан бәйсез кисәкләр буларак, алар җөмләнең төрле урынында килә ала: әлбәттә, мөгаен, шаять, күрәмсең кебек М.с. җөмләнең башында да, уртасында да, ахырында да кулланыла; дөрес, шиксез, ихтимал, чыннан да кебек М.с. җөмлә башында яки җөмлә уртасында языла; имеш, бугай, булса кирәк М.с.е җөмлә ахырында, сирәк кенә җөмлә башында килә.

*Әд.:* Х а н г и л д и н В.Н. Татар теле грамматикасы. К., 1959; Г а р д а н о в а Л. Татар телендә модаль сүзләрне өйрәнү // Совет мәктәбе. 1965. № 12; Татар грамматикасы. Морфология. М.-К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Современный татарский литературный язык. М., 1978.

**МОДАЛЬЛЕ́К** (лат. modus — чама, ысул) (лингв.), сөйләүченең сөйләм эчтәлегенә, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерүче функциональ-семантик категория. М. раслау, боеру, теләк, шарт, чынлык, кирәклек, тиешлек һ.б. мәгънәләргә ия. Татар телендә М.: а) *наклонение* формалары (затланышлы фигыльләр) (Идел буйларына тагын / **Әйләнеп кайтсам иде**, / Ал чәчәкләр арасында / Бер җырлап **ятсам иде**. Ф.Кәрим); б) аерым *интонация* яисә пауза (Син... кайттың?); в) *модаль сүзләр* (Сабан туена, **тәгаен**, кайтырбыз. Г.Бәширов); г) *кисәкчәләр* (**Әх**, матур ла матур бу дөнья. Х.Туфан); д)модаль мәгънәле аналитик *фигыль* формалары (Безгә икенче юлдан **барасы булган**) һ.б. б-н белдерелә.

*Әд.:* З ә к и е в М.З. Татар грамматикасы. Синтаксис. М.-К., 1999. 3 т.; Татар грамматикасы. Морфология. М.-К., 2002. 2 т.; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

**МОДЕ́РН** (франц. moderne — өр-яңа, заманча), 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Америка һәм Европа (ш.и. рус) архит-ра сәнгатендәге стиль юнәлеше. Архит-рада М. стиле әүвәлге (1895–1905) һәм соңгы төрләргә бүлеп карала, алар исә романтик һәм рационалистик агымнарга бүленә (1890 еллар ахыры — 1910 еллар). Элгәреге М. корылмаларына (Казанда *Мюфке йорты*, Олешкевич йорты һ.б.) асимметрик композицияле индивидуальләштерелгән образ һәм тышкы формаларны пластик оештыру хас. Романтик М. корылмаларында узган чорлар архит-расы б-н кызыксыну гына түгел, аларның оригиналь интерпретациясе дә күзәтелә (әлеге агымның берничә юнәлеше билгеләнә: неорус, неоготик, неоклассицистик һ.б.). Төрле төбәкләрдә милли үзенчәлекләр эзләү милли-романтик М. барлыкка китерә. Казанда ул *Апанаев йорты, Шамил йорты, Ислам кабул итүнең мең еллыгы шәрәфенә салынган мәчет* кебек биналарда чагыла. *Зобнин йорты, Казан хәрби округы командующие йорты*, *Оконишников йорты* һ.б. романтик М. стилендә төзелә. Рационалистик М. биналарның каркаслы структурасы, бер типтагы элементларның кабатлануы, бизәү чараларының саранлыгы б-н аерылып тора; провинциаль М. башкала стиле нормаларыннан шактый калыша.

Сынлы сәнгатьтә М. стиле 1910 елларда Н.И.*Фешин*, Н.М.*Сапожникова*, Б.М.*Столбов*, А.М.*Родченко* нәкыше һәм графикасында, Питрәч, Балык Бистәсе, Чабакса һөнәри-сәнгать остаханәләрендәге кул һөнәре эстетикасында кабаттан яңартыла. М. символизмы һәм эстетикасы А.Ф.Мантельның «На рассвете», «Зилант» альманахларында һәм «Жизнь», «Волжские дали» ж-лларында дөнья күргән мәкаләләрендә пропагандалана.


*Х.Г.Надыйрова, Е.П.Ключевская.*

**МОДЕРНИ́ЗМ**, 20 йөз башында барлыкка килеп, әдәбият һәм сәнгатьтәге «сул» агымнарны (кубизм, сюрреализм, футуризм, экспрессионизм, символизм, орфизм, фовизм, пуризм һ.б.) берләштергән иҗат юнәлеше. Киңрәк мәгънәдә — 19 йөз — 20 йөз уртасы сәнгатенең тарихи үсеш чоры.

Әдәби М.ның төп үзенчәлекләре — классик сәнгатьнең гармонияле формаларына каршы чыгып, яңа формалар тудырырга омтылу, күзгә бәрелеп торган шартлылык, чынбарлыкны сәнгати дәрәҗәдә бозып үзгәртү, мәгънәләр б-н уйнау, дөнья һәм кеше турында төп, бәхәссез хакыйкатьнең юклыгын раслау. М.ның төп темалары — шәхеснең яшәештәге урынын идея һәм сәнгати чаралар ярдәмендә эзләү һәм бу мәсьәләне гаклый хәл итүгә ышанычның югалуы. М. агымнары сәнгатьне яшәешнең яшерен серләренә ишек ача торган гыйлем итеп карый. Тормышны кабул итү, матурлыкны изгеләштерү модернның төп сыйфатына әйләнә.

Татар әдәбиятына модернистик сурәт тудыру омтылышлары 20 йөз башында үтеп керә башлый. Модернистик тәҗрибәләрне үзләштерүгә һәм иҗади төшенүгә татар әдәбиятының тамырлары Шәрекъкә барып тоташу ярдәм итә. Шулай ук фәлсәфи-эстетик нигезләре символизмга һәм экзистенциаль фәлсәфәгә якын буларак, суфичылык мәдәнияте традицияләре модернизм б-н авазлаш тоела. Модернистик стильләрнең реализм һәм романтизм б-н синтезлашуы аеруча Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Н.Думави, Г.Ибраһимов, С.Рәмиев, Ш.Бабич һ.б. иҗатында үзенчәлек сиздерә.

1906–08 елларда Дәрдемәнд, 1920–30 да Һ.Такташ иҗатларында символизмның фәлсәфәсе һәм эстетикасы тамырлана. 1910 елларда проза һәм лиро-эпикада реалистик һәм мифологик, романтик һәм мифологик, шартлы-лирик һәм тарихи катламнарның мәдәни синтезы барлыкка килә. Бу синтезның үзәген символ-идея яки символ-проблема тәшкил итә (Ф.Әмирханның «Татар кызы», М.Хәнәфинең «Айсылу», Б.Мансурның «Татар егете», Г.Рәхимнең «Хан мәчетендә», М.Гафуриның «Бу кемнең кабере?», «Бер чәчәкнең наләсе» әсәрләре). Татар язучыларын аеруча экзистенциализм фәлсәфәсе (кеше табигатенең камил түгеллеге, төп мотив буларак, җир тормышының фанилыгы) үзенә тарта. М.Гафуриның «Болгар кызы Айсылу», Ф.Әмирханның «Бер хәрабәдә», М.Хәнәфинең «Милләтем», «Тегеннән», «Гөл бакчасында», Г.Газизнең «Бер хыял» әсәрләрендә тормыш акылдан язган куркыныч «кара көчләр патшалыгы» кебек тасвирлана. Г.Газизнең «Юлдаш эзләгәндә», М.Хәнәфинең «Кайдан? Кайда!», Г.Насрыйның «Мазарстанда» хикәяләрендә кешенең яшәеше көнкүреш ваклыкларыннан бертуктаусыз качу итеп аңлатыла. Саф импрессионистик характердагы хикәяләр дә языла (к. *Импрессионизм*), мәс., Г.Исхакыйның «Бер манзара», Фәйзи Вәлиевнең «Көймәдә» һ.б. Экспрессионизм 20 йөз башында С.Рәмиев, Н.Думави, Б.Мирзанов һ.б. лирикасы һәм лиро-эпикасында да күзәтелә башлый. 1920–30 да Һ.Такташ, К.Нәҗми, Г.Кутуй, Н.Исәнбәт һ.б. иҗатларында исә аеруча зур үсеш ала. Рус әдәбиятындагы кебек артык көчле тәэсир итәрлек сәнгать б-н мавыгу 1920 елларда футуризм (Г.Кутуй) һәм *имажинизмнарны* (К.Нәҗми) барлыкка китерә. 1930 еллардан татар әдәбиятында М. үсеше әкренәя. 1980 еллардан башлап, ул яңадан активлаша, *постмодернизм* (Ф.Бәйрәмова, З.Хәким, Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, М.Гыйләҗев һ.б.) элементлары б-н баетыла. Сынлы сәнгатьтә М.ның



**Модерн.** 1. К.С.Олешкевич йорты фасады фрагменты. Элгәреге модерн. Казан. 1915. Арх. К.С.Олешкевич; 2. Зобнин йорты фасады фрагменты. Милли-романтик юнәлештәге модерн. Казан. 1914. Ф.П.Гаврилов проекты; 3. Сәнгать мәктәбе бинасы фасады фрагменты. Романтик юнәлештәге модернның яңа рус агымы. Казан. 1901. Арх. К.Л.Мюфке; 4. Шамил йорты фасады фрагменты. Милли-романтик юнәлештәге модерн. Казан. 1903. Арх. Ф.Р.Амлонг; 5. Ислам кабул итүнең меңьеллыгы шәрәфенә төзелгән мәчет манарасы. Милли-романтик юнәлештәге модерн. Казан. 1924–26. Арх. А.М.Печников.





**Модернизм.** 1. К.К.Ч е б о т а р ё в. «Малайлар». 1918; 2. А.А.А н и к е ё н о к. «Ат абзарлы йортлар». 1966; 3. Р.К.Н ә ф ы й к о в. «Композиция». Киндер. Катнаш алым. 2005. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

төп үзенчәлекләре — әсәрләрдә тормышны соңгы чиккә кадәр каралтып күрсәтү яки тормышны үзенә охшатып кабатлаудан тулысынча баш тарту. Аларда гадәттәгечә сәнгати формага басым ясала. Форма исә сәнгать әсәренең асылы итеп кабул ителә һәм аның эчтәлегенә тәңгәл була. Футуризм, конструктивизм, абстракт сәнгатьнең стиль үзенчәлекләрен үз эченә алган авангард сәнгатьне модернистик сәнгать дип карап, М.ны еш кына авангардизмга тиңлиләр.

Татарстан сынлы сәнгатендә кайбер модернистик агымнарның (кубофутуризм, экспрессионизм, абстракционизм) сыйфатлары 1910 еллар ахыры — 1920 еллар башында «Подсолнечник» (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, И.А.Никитин, Д.П.Мощевитин, И.И.Алпатов, Василий Вера (В.Попов), Н.Диомиди (Н.И.Михайлов), П.М.Зотов, Г.И.Потапов, Г.П.Соловьёв-Озеров, Д.М.Фёдоров) төркеме рәссамнары һәм 1920–23 тә эшләп килгән «Всадник» графиклар төркеме иҗатларында барлыкка килә. Ике төркем дә абстракцияле рәсем сәнгатен 1920 елларда С.С.Фёдоров һәм П.А.Мансуров укыткан АРХУМАСта (Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре, 1918–25) оеша. Авангард сәнгатенең башында бу чорда ш.у. *ТатЛЕФ* рәссамнары да (К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, М.В.Барашов, С.Хромов, А.Н.Кашаев) була. ТатЛЕФка татар мәдәнияте эшлеклеләреннән торган «Сулф» («Сул фронт») төркеме дә керә; оештыручыларның берсе ТатЛЕФның президиум әгъзасы, татар полиграфикасына нигез салучы Ф.Ш.Таһиров була. Ул әсәрләрендә конструктивизм алымнарын (фотомонтаж) файдалана, татар авангарды тарихында якты эз калдыра. Алга таба, 1960 еллар уртасына кадәр, Татарстан сынлы сәнгатендә модернистик юнәлешләр үсми. 1960 елларда модернистик юнәлешне сынлы сәнгатьтә А.А.Аникеёнок, Р.А.Килдебәков дәвам иттерә. 1970 елларда экспрессионизм чалымнары В.П.Аршинов, Н.У.Әлмиев графикасында гәүдәләнеш таба; И.К.Зарипов иҗатында халык сәнгате традицияләрен модернистик рәвештә чагылдыру (неопримитивизм) күзәтелә. 1990 елларда аерым модернистик агымнар киңрәк таралыш ала. Абстракционизм традицияләре эзлекле рәвештә — З.М.Миңнеәхмәтов (Алабуга ш.), Р.К.Нәфыйков (Казан), сюрреализм В.Я.*Акимов*, Ю.Г.Свинин (Чаллы ш.) иҗатларында чагыла. Казан рәссамнары Е.Г.Голубцов, А.И.Дорофеев, А.М.Артамонов, И.А.Хәсәнов, И.В.Гыймранов, Ә.Р.*Ильясова*, Р.А.Салихов әсәрләрендә төрле модернистик агымнарның стиль үзенчәлекләре постмодернизм контекстында күзәтелә.

*Әд.:* З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. К., 2003; С а р а б ь я н о в Д.В. Стиль модерн: Истоки. История. Проблемы. М., 1989; С а я п о в а А.М. Дардменд и проблема символизма в татарской литературе начала XX века. К., 1998; Теория литературы. Литературный процесс. М., 2001. Т. 4; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; АРХУМАС: Казанский авангард 1920-х. М., 2005.

*Д.Ф.Заһидуллина, Г.Р.Фәйзрахманова.*

**МОЖАРО́ВСКИЙ** Аполлон Фёдорович (14.12.1841, Казан губ., Зөя өязе Бишбатман а. — 22.10.1900, Түбән Новгород ш.), тарихчы, теология магистры (1881). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1866), шунда укыта. 1873 елдан — Түбән Новгород руханилар семинариясендә. Хезмәтләре Урта Идел буенда яшәүче керәшен татарлар, мордвалар, руслар тарихы һәм этнографиясе, христианлаштыру, рухани уку йортлары тарихы, агиографиягә карый. Мәсәл рухында язылган, ләкин кыйммәтле фәнни-мәгълүмати эчтәлеккә ия булган һәм төбәктә конфессияара мөнәсәбәтләрне үстерүдә төп этапларны ачыклаган «1552–1867 елларда Казан әҗнәбиләрен христиан дине б-н агартуда миссионерлык эше турында бәян» («Изложение хода миссионерского дела по просвещению христианством казанских инородцев с 1552 по 1867 год», 1880) монографиясе б-н Урта Идел буенда яшәүче татар халкының һәм башка халыкларның тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Краткая историческая записка о Казанской духовной семинарии за её полуторавековое существование. К., 1868; Старая Казанская академия. К., 1877.

*Әд.:* З н а м е н с к и й П.В. История Казанской Духовной Академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы): В 3 ч. К., 1891–92; Аполлон Фёдорович Можаровский // Изв. Тамбов. учёный архивной комиссии. Тамбов, 1903. Вып. 48.

*Е.В.Липаков.*

**МОЖГА́ КАЛКУЛЫГЫ́**, Вятка, Кама һәм Иж елгалары арасында, ТРның Көнчыгыш Кама алдында һәм Удмурт Респ-касының көньяк чигендә урнашкан. Күпчелек биеклекләр 180–220 *м*, макс. биеклек — 256 *м*. Пермь системасы югары бүлегенең (Уфа, Казан һәм Татар яруслары) известьташлары, доломитлары, комташлары, балчыклары һәм мергельләреннән гыйбарәт. Татар гөмбәзенең төньяк күтәрелмәсенең көнчыгыш өлешенә туры килә. Елга үзәннәрендә аллювиаль утырмалар урын алган, алар елга террасалары комплексын хасил итәләр. Калкулык елга, сыза һәм ерымнар челтәре б-н бүлгәләнгән, Татарстан чикләрендә аларның тыгызлыгы 0,6, 0,5 һәм 0,39 *км/км²* тәшкил итә. Елга



Можга калкулыгы.

үзәннәренә сөзәклекләрнең ачык чагылышлы асимметриясе хас. Зур елгаларның уңъяк сөзәклекләре, кече елга үзәннәренең көньякка һәм көнбатышка юнәлгән яхшы җылынучан сөзәклекләре текәрәк. Урманнарның күпчелеге киселгән, җире сукаланган. Көньякта, Кама үзәнендә, Түбән Кама милли паркының уңъяк яр буе өлешендә нарат урманнары һәм болыннар, Иж үзәнендә «Кичке таң» комплексы табигать тыюлыгына керүче урман массивлары урнашкан.

*А.П.Дедков.*

**МОЖГА́ РАЙОНЫ́**, *Удмурт Республикасының* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1929 елның 15 июлендә оештырыла. Мәйданы — 2004 *км²*. Үзәге — Можга шәһәре (Ижевскидан 97 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 77394, ш.и. Можгада — 49428 кеше (2012). Татарлар саны — 8153 кеше (2010). Алар, башлыча, район үзәгендә (7135

кеше), Пычас, Горняк, Люга посёлокларында, Сасмак авылында яшиләр. Район терр-ясенә татарларның күченүләре 1920–30 елларда-гы а.х.н күмәкләштерү сәясәте б-н бәйле. Бу чорда Татарстанның Кукмара, Әгерже, Алабуга р-ннарыннан чыккан таза тормышлы крәстияннәр, йорт-җирләреннән куылудан һәм репрессияләрдән куркып, яңа төзелә башлаган Можга шәһәренә урнашалар. Күчеп килгән татарлар М.р. терр-ясендә традицион һөнәрләр (күн аяк киеме һәм чималэшкәртү, мех баш киемнәре һәм тун, киез аяк киемнәре тегү, юкә кайрысыннан чыпта сугу һ.б.) б-н шөгыльләнүләрен дәвам итә. Хәзерге вакытта районда берничә татар милли оешмасы: Татар ижтимагый үзәгенең Можга бүлекчәсе (1991), «Йолдыз» Татар мәдәни үзәге (1998), Удмурт Респ-касының «Иман» татар яшьләре берләшмәсе, М.р. һәм Можга шәһәре татарларының милли-мәдәни автономиясе (2001) бар. Бу оешма каршында берничә клуб: татар җырларын яратучылар, «Галилә клубы», «Якташлык», «Татар мәдәнияте» балалар клубы эшли. Җирле радио һәм телевидениедә татарча тапшырулар алып барыла. 3 мәктәптә татар теле факультатив дәресләрдә һәм түгәрәкләрдә өйрәнелә. Татар теле түгәрәкләре 5 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесендә дә оештырылган. 1992 дән Балалар иҗат йортында татар мәдәниятен өйрәнү түгәрәге эшли. Монда ш.у. Татар мәдәни үзәге һәм Можга татарларының милли-мәдәни автономиясе б-н берлектә Яңа ел, беренче сыйныфка керүчеләрне мәктәпкә кабул итү тантанасы, Нәүрүз бәйрәмнәре оештырыла. 1991 дән Татар мәдәни үзәгенең Можга бүлекчәсе балалар һәм олылар өчен Яңа ел бәйрәмнәре үткәрә. Мәгариф учреждениеләрендә татар мәдәнияте почмаклары оештырылган, бөтен мәктәпләр һәм балалар бакчалары татар әдәбияты б-н тәэмин ителгән. «Мәгариф», «Салават күпере», «Сабыйга» ж-лларына язылу оештырыла, бу журналлар балалар б-н эшләүдә файдаланыла. Мәктәптә татар әдәбияты атналыклары, Идел буе халыкларының бердәмлек бәйрәмнәрен үткәрү традициягә керә, китапханәләрдә Татарстан тарихын чагылдырган китап күргәзмәләре оештырыла. Мәгариф идарәсендә укытучылар һәм тәрбиячеләрнең методик берләшмәсе эшли, алар балаларга татар телен һәм мәдәниятен өйрәтә. 1991 дән ел саен Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

**МОЗА́ИКА** (фр. mosaique), төсле ташлар, тонык пыяла (смальта), агач, мех, күн (к. *Каюлы күн*), керәч плитәләр һ.б. материаллардан эшләнгән бизәк, сурәт; бизәлеш сәнгате һәм монументаль нәкышь сәнгате (к. *Нәкышь сәнгате*) төре. Таш һәм смальта М.сы антик чорлардан ук билгеле, ул биналар бизәү өчен кулланылган. Урта гасырларда Европадагы һәм Шәрекътәге дини корылмаларда алтын йөгертелгән төсле смальта М.сы б-н диварлар һәм гөмбәзләр бизәлгән; 17 йөздән башлап, нәкышь әсәрләре нөсхәләреннән мозаик картиналар һәм миниатюралар күчереп ясау киң тарала.

Аерым алганда, Биләр мәчетенең эчке диварларының сакланып калган зәңгәр һәм яшел төстәге чынаяк кирпеч фрагментлары Идел буе Болгар дәүләтендә монголларга кадәрге чорда ук тышлау керәче булуы турында сөйли (к. *Болгар бизәлеш сәнгате*). Ләкин мозаик чынаяк кирпечнең археол. табылдыклары бары тик Алтын Урда чорына гына карый. М. бина диварларының эчке һәм тышкы якларын бизәүдә файдаланыла. Сары, күк, зәңгәр төстәге өч һәм биш почмаклы керәч плитәләр, ш.у. куе зәңгәр, күк, яшел, ак, сирәк кенә кызыл төстәге үзле тыгыз балчыктан эшләнгән тишекле һәм ялтыравыклы чынаяк кирпечләр табыла (к. *Алтын Урда сәнгате*). Болгар шәһәрлегендә Хан төрбәсенең эчке диварларында уеп бизәлгән майолик М. кулланылган. Ул квадрат плитәләр (20×20 *см* һәм аннан да кечерәк) б-н тышәлгән, үсемлек, геом. һәм эпиграфик орнаментлар б-н бизәлгән. Бөтен фрагментлар һәм ялтыравык б-н капланган полихром плитәләрнең аерым өлешләреннән җыелган композиция детальләре (туры, өч, биш почмаклы, трапеция рәвешле, кыек сызыклы геом. фигуралар), ш.у. керәч остаханәләренең урыннары Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Үвәк һәм Түбән Идел буеның башка шәһәрләрендә алып барылган археол. казу эшләре вакытында табыла. М. җирле осталар тарафыннан һәм үзенчәлекле сәнгать традицияләрен саклап башкарылучы технология үзенчәлекләрен (ак төсле кашиннан файдалану), колорит үзенчәлеген (күк, фирәзә, сары һәм кызыл төс бирелгән зәңгәр төс) һәм орнамент стилен (гарәп рәсеме тибындагы үсемлек бизәкләре һәм каллиграфик гарәп язуларыннан төзелгән купшы композицияләр) чагылдыра. Казан ханлыгы чорына бары тик Н.Ф.Калинин тарафыннан Казан Кремлендә алып барылган археол. казу эшләре вакытында табылган берничә архитектур М. үрнәкләре генә карый (күк ялтыравыклы ак төстә). Казан яуланганнан соң, М. монументаль татар архит-расы б-н бәйле сәнгать төре буларак юкка чыга. Аның шушы төбәктә рус сәнгатенә күчеп дәвам итүе турында дәлилләр юк. 20 йөз башында Казанда Овсянойның ялтыравык плитәләр җитештерүче мозаика-цемент з-ды эшли, әмма бу плитәләр М. сыйфатында кулланылыш тапмый. 1920 елларда, совет дәүләте тарафыннан җәелдерелгән «монументаль пропаганда планы» кысаларында, Казан рәссамнары Н.В.Пузанков һәм С.С.Федотов, бина фасадларын бизәү өчен, коелган төсле гипстан М. үрнәкләрен эшлиләр.

Монументаль-бизәлеш сәнгате төре буларак, М. 1939 елда Мәскәүдә Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә ТАССР павильонының алгы ишеген бизәгәндә кулланыла (арх. И.Г.*Гайнетдинов*, рәссамы П.Т.Сперанский). Анда, Ленин ордены скульптур сурәтенең гипс барельефына фон буларак, татар үсемлек бизәкле майолик чынаяк кирпеч кулланыла. Стильләшкән намазлык бизәкләрендә мозаик панно композицияләре яңадан торгызыла. 1930 еллар ахырында Казан мех комб-тында В.И.Ленин һәм И.В.Сталин портретларының мех М.сы иҗат ителә, 1940 еллар ахырында — 1950 еллар башында төсле мех М. композициясенә тамбур техникасында чигелгән бизәкләр кушылган (к. *Чигү*) келәм үрнәкләре барлыкка килә. Алар Мәскәүгә — шәһәрнең 800 еллыгына һәм ТАССРның 30 еллыгы уңаеннан Сталинга җибәрелә.

1960–1980 еллар М. сәнгате җәмәгать корылмалары төзелешләренең киң җәелүе һәм архит-ра б-н монументаль бизәлеш сәнгате синтезы нәтиҗәсендә көчле үсеш кичерә. Смальта һәм керәч М.сы (иҗат техникасы сов. мозаика сәнгате мәктәбе казанышларына таяна) киң кулланылыш таба. Татарстанда смальта җыелмалы М. беренче тапкыр Казандагы «Татарстан» кунакханәсе интерьерын бизәгәндә кулланыла (арх. М.Х.Агишев). Вестибюльнең ян диварында рәссам С.М.Бубеннов тарафыннан «Кунакларны болгарларча каршылау» М.сы иҗат ителә. Нәфис колоритлы (алтынсу-сары, ак, фирәзә-яшел, якты-канәфер һәм йомшак-җирән төсләр өстенлек итә) М. темасы һәм композициясе б-н татар халкы тарихына, болгар орнаментына бәйле сюжетларны яңарта. Рәссам В.К.*Фёдоровның* «Татарча чәй эчү» М.сы (мәйданы 70 $м^2$) кунакханә ресторанының зур залы диварын бизи. Җылы монохром колоритлы М. келәм композициясендәге бөтеркә бизәк фонындагы фигуралы рәсемнәрдә татар сәнгатенең орнамент-бизәкләр системасы файдаланыла. Ресторан, аерым алганда, банкетлар залы бизәлешендә төсле бизәкле күн кисәкләреннән төзелгән күн М.сы техникасындагы тиңдәшсез дивар панносы аерылып тора. Аның фонында металлга чүкеп ясалган Шүрәле сурәте урнаштырылган (эскиз авторы Р.Ә.*Килдебәков*). Смальта М.сы респ-кадагы байтак эре архит-ра корылмаларын бизи: Казанда Яшьләр үзәгендәге (хәзерге «Ак Барс» банкы урнашкан бина) йөзү бассейны интерьеры (рәссам В.К.Фёдоров, 1972–73); Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният йорты экстерьеры (рәссам Р.Ә.Килдебәков, 1973); Яшел Үзән шәһәрендәге мәдәният йорты интерьеры (рәссамнар Р.Ә.Килдебәков, В.В.*Карамышев*, Н.Д.*Кузнецов*, 1971). Кайвакыт М. аерым дивар панносы рәвешендә урнаштырыла — Бөгелмәдәге Техниклар йорты фасады (рәссамнар А.Ә.*Абызгилдин*, В.И.Охотин, 1971). Керәч М. 1980–90 елларда, башлыча, интерьерлар бизәгәндә (вестибюльләр, рекреацияләр, биналар һ.б.) яки интерьерның бер өлешен (су бассейннарын), сирәк кенә — бина фасадларын, мәгариф, балалар учреждениеләрен, ш.у. монументаль-бизәк сыннар иҗат иткәндә Казанда, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә һ.б. шәһәрләрдә киң кулланылыш таба. М.ның әлеге төрен үстерүгә рәссамнар К.М.*Сафиуллин* (ш.у. таш М.сында иҗат итә), Р.М.Вахитов, Х.М.Гыймазетдинов, В.Н.Николаев, И.М.*Ханов* (скульптур композицияләр), Л.Ф.Шаһиев, А.Ә.Абызгилдин һ.б. өлеш кертә. 2005 тә Казанның 1000 еллыгы уңаеннан М.да тиңдәшсез әсәрләр иҗат ителә. Смальта М.сы Казан Кремлендәге «Кол Шәриф» комплексы интерьерларында *михраб* өстендәге гөмбәзне бизи; намаз уку залы һәм хатын-кызлар галереясы панно һәм ялгаулар рәвешендәге керәч М. б-н бизәлә (арх. А.Г.Саттаров, рәс-

самнар Р.Ә.Килдебәков, Р.В.Сәлахетдинов, Р.С.Саттаров, Н.Т.Хаҗиәхмәтов һ.б.). Шунда ук, беренче буларак, «Болгар» һәм «Мәккә» *шәмаилләре* рәвешендә М.дан дивар панносы урнаштырылган (рәссам Р.В.Сәлахетдинов). Казан метросының «Тукай», «Кремль» җир асты станцияләре интерьерларын бизәүдә дә М. киң кулланыла (дизайнерлар С.Ә.Мамлиева, Р.М.Нургалиева, рәссам Н.Т.Хаҗиәхмәтов; А.Г.*Хәбибуллин* һәм А.С.Хөснетдинов җитәкчелегендәге иҗат төркеме). 2000 еллардан башлап, М. (смальта, пыяла плитә файдаланыла) мәчетләр бизәгәндә еш кулланыла: Түбән Кама р-нының Зур Афанас авылы (фасад өлеше, 2003), Түбән Кама р-нының Шәңгәлче авылы (михраб өлешенең тышкы ягы, интерьерда — гөмбәз, барабан, колонналар, 2006) мәчетләре; Түбән Кама (манараларның тышкы ягы һәм үзәк портал, 2005), Лениногорск (интерьердагы гөмбәз һәм михраб, 2006) шәһәрләрендә җамигъ мәчетләр. Әлеге мәчетләрдәге М. авторлары — В.И.Суриков исем. Мәскәү әвәләү, нәкышь һәм скульптура ин-тын тәмамлаган Д.Р. һәм Л.В.Мусиннар.

Хәзерге заман М.сы рәссамнары куп-шы, ш.и. гарәп рәсеме характерындагы, үсемлек һәм эпиграфик бизәкле орнаменталь һәм колористик татар бизәлеш сәнгате традицияләрен яңарталар, яңа милли һәм мөселман символларын өстиләр.

*Әд.:* Сперанский П.Т. Татарский народный орнамент: Альбом. К., 1948; Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Калинин Н.Ф. Раскопки в Казанском Кремле в 1953 г. // Изв. КФАН СССР. Сер. гуманитар. наук. 1955. Вып. 1; Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Фёдоров-Давыдов Г.А. Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; шул ук. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х гг.). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МОЗАФФАРИЯ́** Маһруй Габделвәли кызы (1873, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Торма а. — 5.12.1945, Казан), язучы, педагог. Мулла гаиләсеннән. Башлангыч белемне атасыннан ала, соңыннан үзлегеннән укый. 1891 елдан туган авылында балалар укыта. 1894 тә Казанга күчә. 1901 дә үз өендә кыз балалар өчен җәдит мәктәбе («М.Мозаффариянең абыстайлар мәктәбе») ача, соңыннан Хәдичә Әхмәрованың хосусый хатын-кызлар мәктәбендә укыта. 1917 дән соң хатын-кызлар арасында агитатор була, 5 нче мәктәптә укыта (1925 кә кадәр); 1935 тән мәктәпкә кадәрге балалар оешмалары инспекторы. 1905 тән матбугат битләрендә хатын-кыз эмансипациясенә багышланган мәкаләләр һәм шигырьләр бастыра («Мәшһүр хатыннар», 1907; «Габдулла Тукаевның хатын-кыз галәменә тәэсире», 1913 һ.б.). «Яднамә» (1901) укыту әсбабы авторы.

*Әд.:* Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Рәсүлева З., Хуҗиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлыгында. К., 1998; Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.


*А.М.Ахунов.*


**МОЗАФФАРИЯ́** Мәхмүдә Хуҗәхмәт кызы (1893, Казан — 1969, шунда ук), шагыйрә, педагог. М.Г.*Мозаффария* кызы. Ф.Аитованың хосусый мәктәбендә, 1922 елдан Казанның Яңа бистә татар мәктәбендә укыта. Беренче шигырьләрен 1907 дә «әл-Ислах» г-тасында бастыра. Чыгышларында хатын-кызларның ирләр б-н бер хокукка ия булырга тиешлеге мәсьәләләрен күтәрә, аларны мөстәкыйль булырга өнди, белем алырга чакыра («Уйганыйк, ханымнар!», «Ханымнар», 1907 һ.б.).

*Әд.:* Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988; Рәсүлева З., Хуҗиәхмәтов Ә. Мәгърифәт йолдызлыгында. К., 1998; Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

*З.З.Рәмиев.*

**МОЗАФФА́РОВ** Гайфулла (Гайфулла бине Мозаффар) (19 йөз уртасы — 20 йөз башы), хаттат. Казанда эшли. *Казан университеты басмаханәсендә* басылган аклы-каралы литографик шәмаилләр авторы («Мәккә һәм Кәгъбә мәчете күренеше», 1890; «Пәйгамбәр


1



2


3


4



5


6


7


8

**Мозаика. Каюлы күн.** 1. Алтын Урда биналарындагы керәч бизәге фрагментлары. Ялтыравык керәч. Сарай әл-Җәдид шәһәрендәге табылдыклар. Эрмитаж; 2. Болгар шәһәре биналарының бизәк фрагментлары. Ялтыравык керәч. 13–14 йөзләр. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 3. Фарсы язулы дивар медальоны. Ялтыравык керәч. 14 йөз. Әстерхан берләштерелгән тарих-архитектура музей-саклаулыгы; 4. Р.Ә.Килдебәков. Г.Камал исем. Татар акад. театры бинасы фасадындагы декоратив бизәк. Төсле смальта. 1985; 5. С.М.Бубеннов. Казандагы «Татарстан» кунакханәсе вестибюлендә «Кунакларны болгарларча каршылау» дивар панносы фрагменты. Төсле смальта. 1970; 6. А.Г.Саттаров, Ф.А.Вәлиуллин, Р.Ә.Килдебәков. Казандагы «Кол Шәриф» мәчетенең намаз уку залында түшәм гөмбәзе. Төсле смальта. 2005; 7. Р.З.Фәхретдинов. «Музыка коралында уйнаучы кыз» дивар панносы. Төсле смальта. 1980 еллар; 8. Р.М.Вахитов. Чаллы шәһәрендәге мәктәп интерьерына куелган «Тынычлык» дивар панносы. Керәч. 1974.



Г.М о з а ф ф а р о в. «Серле сүз». Литография. 1900. ТР Милли музее.

Мөхәммәд с.г.в. хәмед», 1898; «Серле сүз», 1900). График композицияләре литографик шәмаилләрдәге декоратив бизәлешкә хас күппланлы образлар, Коръән текстлары һәм рәсем сюжетларының органик бәйләнеше, ислам атрибутларын һәм символларын файдалануы, кире перспектива һәм яссы чишелешләр б-н аерылып тора. М. осталыгы каллиграфик нәфислеге һәм язу стилендә, язманы кәгазьнең барлык мәйданына киң колачлы, ритмлы итеп урнаштыра алуында ачыла. Текст эчтәлегендә тормыштагы төрле авыр хәлләрне Коръән аятьләре б-н аңлатуы, җәһәннәм һәм җәннәт күренешләрен сурәтләве, Мөхәммәд пәйгамбәрнең могҗизаи көчкә ия булган әйберләрен атап үтүе аның тирән дини белемле шәхес булуы турында сөйли. Дөньяның халык аңындагыча яратылуын образлы элементлар б-н аңлата. М. әсәрләре ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Ш ә м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003; Шамаилы из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец XIX — начало XX вв.): Альбом. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МОЗАФФА́РОВ** Евгений Нәҗип улы (13.10.1944, Саратов өлкәсенең Балашов ш.), биохимик, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, биол. фән. д-ры (1991), проф. (1993), Мәскәү өлкәсенең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1971 елдан (1977–78 дә бүленеп) СССР ФАнең Туфрак белеме һәм фотосинтез ин-тында (Пущино ш., Мәскәү өлкәсе), гыйльми секретарь (1988–90), фотосинтезны һәм үсемлекләр үсешен гормональ көйләү лаб-ясе мөдире (1989–97). 1997 дән Пущино шәһәре хакимияте башлыгы урынбасары, 2002–2006 да 1 нче урынбасары. 2006 дан Тула ун-тының биотехнол. каф. мөдире. Хезмәтләре табигый факторлар һәм химик кушылмалар ярдәмендә фотосинтезны һәм үсемлекләрнең үсешен көйләүгә карый. М. полифеноллар биосинтезының кояш яктысының спектраль составына һәм аның көченә бәйлелеген, ультрашәмәхә радиациянең бу процесска тәэсир итү үзенчәлекләрен ачыклый; фенол табигатьле үсемлек матдәләрен үсемлекләр үсешен көйләгеч сыйфатында куллану мөмкинлекләрен анализлый.

Х е з м.: Регуляция энергетического обмена хлоропластов и митохондрий эндогенными фенольными ингибиторами. Пущино, 1977; Свойства флавоноидов и их функции в метаболизме растительной клетки. Пущино, 1986; Световая и гормональная регуляция фотосинтеза и роста растений. Пущино, 1995 (автордаш).

**МОЗАФФА́РОВ** Искәндәр Шәйхи улы (13.10.1952, Буа р-ны Кайбыч а.), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1980). 1972–75 елларда Биектау р-нының «Чулпан» һәм «Кызыл Байрак» к-зларында агроном-орлыкчылык белгече булып эшли. 1975 тән Зеленодольск р-нының «Майский» с-зында: 2 нче цехта звено җитәкчесе, үсемлекләрне тукландыру һәм су сибү буенча бригадир ярдәмчесе, оператор, 5 нче цех бригадиры, 7 нче цех башлыгы (1983–89), баш агроном (1989–97), директор урынбасары (1997 дән). Дәүләт бүләге экологик зарарсыз яшелчә үстерүдә ресурс саклаулы технологияләр булдырганы һәм җитештерүдә гамәлгә керткәне өчен бирелә. СССР ВДНХсының бронза медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


**МОЗАФФА́РОВ** Йосыф Хәсән улы (1887 — 1929 елдан соң), сәясәт эшлеклесе. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, прапорщик (1917). 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң мөселманнарның хәрби хәрәкәтендә актив катнаша; Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең беренче корылтаенда (Казан, 1917 нең 17–25 июне) *Хәрби Шура* башкарма ком-ты составына сайлана. Россияне федерализм нигезендә үзгәртеп коруга омтылган өлкәләрдән Үзәк рада чакырткан халык вәкилләре съездында (Киев, 8–15 сентябрь) Бөтенроссия мөселман хәрби ком-ты исеменнән катнаша. *Милләт Мәҗлесе* депутаты. Октябрьдә Көньяк-Көнбатыш фронтның 8 нче армия мөселман гаскәриләре съездын әзерләп үткәрүчеләрнең берсе, съездда рәис итеп сайлана. Румын фронтында Хәрби Шура комиссары буларак, ноябрь башында кичектермәстән мөселман хәрби частьларын оештырырга өнди. Эшне тизләтү максаты б-н, Румын фронты штабы каршында мөселман хәрби ком-тлары һәм Хәрби Шура вәкилләреннән торган комиссия булдырырга тәкъдим итә. Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае делегаты (Казан, 1918 нең 8 гыйнвары — 18 феврале), Идел-Урал штаты оештыру мәсьәләсе буенча төп докладчы (доклад *Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү һәйәте* тәкъдимнәренә нигезләнеп язылa). Эшче һәм крәстиян депутатларының Казан советы боерыгы б-н, съезд һәм Хәрби җитәкчеләренең берсе буларак, 15 февральдә кулга алына, шул көннең кичендә азат ителә. Докладның төп фикерләре «Идел-Урал республикасы» («Урало-Поволжская республика») мәкаләсе рәвешендә «Известия Всероссийского Мусульманского Совета» г-тасында дөнья күрә (1918 нең 17 феврале). 1918 нең уртасыннан эмиграциядә, Англия колонизаторларының Шәрекъ илләрендә хакимлек итүенә каршы мөселманнар ассоциациясе хәрәкәтендә, илгә кайткач, 1919 да, ингушларның инглиз интервентларына һәм акгвардиячеләр армиясенә каршы оештырылган партизаннар хәрәкәтендә катнаша. 1919–21 дә Ингушетиядә партия эшендә. Аннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа. К., 1999; И с х а к о в С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 — лето 1918). М., 2004.

**МОЗАФФА́РОВ** Мансур Әхмәт улы (6.3.1902, Казан — 20.11.1966, шунда ук), композитор, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1950), ТАССРның халык артисты (1964). Татар композиторлары арасында махсус югары белемле беренче композитор. Иҗат эшчәнлеген милли музыка уен кораллары ансамбльләрендә музыкант буларак башлый. 1931 елда Мәскәү консерваториясенең этнография бүлеген (А.Александровның композиция классы) тәмамлый. 1934–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә укый. 1945 тән Казан консерваториясендә (1949–61 дә композиция каф. мөдире) укыта. Төрле елларда радиода, Татар опера һәм балет театрында (Казан) иҗат эшендә. М.ның композиторлык мирасы бик зур: фольклор көйләре эшкәртмәләреннән алып, оригиналь җырларны, романсларны, опера, симф. поэмалар, инструменталь концерт жанрындагы масштаблы әсәрләрне колачлый. М.ның лирик-көнкүреш һәм лирик-психол. темаларга М.Фәйзи драмасы буенча Ә.Ерикәй либреттосына язылган «Галиябану» операсы (премьера 1940 та Татар опера һәм балет театрында була) һәм Ә.Фәйзи либреттосына язылган «Зөлхәбирә» операсы татар опера сәнгатендә яңа юнәлеш ачып җибәрә. Бу әсәрләрнең төп үзенчәлеге — халык җырларына таяну һәм музыканың гадилеге, аңлаешлылыгы: «Галиябану» әсәре шактый фольклор материалы цитаталарына нигезләнә, «Зөлхәбирә» татар халкының традицион муз. мирасының интонацион һәм ритмик яктан баетылуы, муз. хәрәкәтнең драматиклашуы, муз. аһәңлелекнең классик чаралары җәлеп ителү б-н аерылып тора. М.ның иҗатында Г.Тукайга һәм М.Вахитовка багышланган программа характериндагы симф. поэмалар зур урын били. Аларда композитор, татар музыкасында беренче буларак, реаль тарихи шәхесләрнең ышандырырлык образларын тудыра, кеше һәм җәмгыять, шагыйрь һәм халык кебек катлаулы темаларны күтәрә. Автор бу поэмаларда программлыкның гомумиләштерелгән төренә мөрәҗәгать итә, аның специфик үзенчәлекләрен милли материалда файдалана. М.татар музыкасы тарихында беренче тапкыр скрипка концерты жанрына караган әсәрләр иҗат итә. Матур мелодикага, тәэсирле лирикага ия әлеге әсәрләр концерт репертуарында төп урын алып тора. М.ның симф. әсәрләре драматургиясенең бөтенлеге, ачыклыгы һәм халык җырларының табигыйлеге б-н генә аерылып тормый, ә халыкның инструментовка принципларына нигезләнгән музыка уен коралларында башкару алымы б-н дә җәлеп итә. М. иҗатының зур өлешен вокаль музыка били. Композиторның Ә.Ерикәй шигырьләренә «Яшь егетләр, яшь кызлар», «Кызлар җыры», М.Җәлил шигыренә «Җиләк җыйганда» һ.б. җырларының тематикасы күптөрле һәм үзен-



М.Ә. Мозаффаров.



И.И. Мозжаров.

чәлекле, яңача интонацион төзелеше, якты лиризмы, шигырь ритмын ихлас сиземләве, саф мелодиясе, интонация-гармониягә бай булуы б-н игътибарга лаек. М.ның Ә.Ерикәй шигыренә «Безнең юллар якты», Ә.Исхак шигырьләренә «Поход җыры», «Идел турында җыр», Г.Кутуй шигыренә «Туган ил» һ.б. җырлары гражданлык һәм патриотизм тематикасы б-н аерылып тора. М.иҗатында вокаль лириканың үзенчәлекле төре формалаша. Текстларның поэтик эчтәлеге, җырларның мелодик төзелеше һәм үзенчәлекләре җыр-романслар барлыкка китерә, мәс., Ә.Ерикәй шигыренә «Тын бакчада», М.Садри шигыренә «Җырла сандугач», С.Хәким шигыренә «Башка берни дә кирәкми» һ.б. Композитор иҗатында балалар өчен язылган көйләр шактый зур урын алып тора. Аның әсәрләре музыка мәктәпләренең укыту программаларына кертелә. М. татар музыка фольклористикасы үсешенә дә зур өлеш кертә. Композитор тарафыннан тупланган татар көйләре язмалары аның милли муз. материалына сак һәм иҗади якын килүен күрсәтә. Ул йөздән артык татар көйләрен язып ала. Татар халкы муз. мирасының иң яхшы үрнәкләре кергән, иҗади һәм укыту практикасында актив кулланылган язмаларны бастырып чыгара (1964). М. төрле вокаль һәм инструменталь коллективлар өчен гаять күп татар халык көйләрен эшкәртә. Бу эшкәртмәләрдә халык көйләре классик фактура-гармоник чаралары һәм халыкчан башкару үзенчәлекләре б-н табигый кушыла. «Салкын чишмә», «Эрбет», «Әллүки», «Сакмар» һ.б. озын көйләрнең хор эшкәртмәләре сәнгати әһәмиятләре б-н аерылып тора. М. хәзерге проф. татар музыкасына нигез салучыларның берсе буларак танылу ала. Аның иҗатына тирән миллилек хас. Композитор, классик музыка формаларына татар муз. фольклорының үзенчәлекләрен органик рәвештә кертеп, традицион халыкчан мелодик идея кысаларын шактый киңәйтүгә ирешә. Иҗатының демократик юнәлеше, үзенчәлекле мелодик сәләт, күтәренке хис, ш.у. халык лирикасы катламнарына мөрәҗәгать итүе, милли музыканың эпик, драматик, гомумфәлсәфи образлылык б-н баетылуы М.ка киң танылу китерә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1959).

Төп әсәрләре: М.Фәйзинең шул исем. драмасы буенча Ә.Ерикәй либреттосына «Галиябану» (1940, 2 нче ред. 1966), «Зөлхәбирә» (1943, 2 нче ред. 1944) опералары; Симфония (1944), Симфониетта (1945), Г.Тукай (1952), М.Вахитов (1956) истәлекләренә симф. поэмалар, оркестр б-н скрипка өчен 2 концерт (1959, 1962), Х.Вахит шигырьләренә «Бәхеткә юл» һәм «Чәчәк ат, Татарстан» (1950, 1956) кантаталары, вокаль-инструменталь әсәрләр, 100 дән артык татар халык җырлары язмалары һәм эшкәртмәләре һ.б.

*Әд.:* Тазиева К. Мансур Музафаров. К., 1994; Дулат-Алеев В.Р. Татарская музыкальная литература. К., 2007.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МОЗАФФА́РОВА** Нэлли Һидият кызы (20.12.1941, Чаллы), тарихчы, тарих фән. д-ры (1992), проф. (1993). Свердловск пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Рус-Потамск урта мәктәбе (Свердловск өлкәсе Әчет районы) директоры булып эшли. 1967–98 елларда Свердловск юридик ин-тында, Урал ун-тында, Урал икътисад ун-тында (тарих һәм политология каф. мөдире). Бер үк вакытта Свердловск өлкә башкарма ком-ты (аннан соң губернатор администрациясе) каршындагы милли һәм дини мәсьәләләр буенча экспертлар советы әгъзасы, Свердловск өлкәсе татар һәм башкортларның иҗтимагый-сәяси хәрәкәте (1995–98) һәм Татарларның өлкә милли-мәдәни автономиясе (1997–98) рәисташе. 1998 дән Мәскәүдә: Мәскәү пед. ун-тының гомууниверситет тарих кафедрасында, 2000 нән Икътисад һәм эшмәкәрлек ин-тының тарих һәм политология каф. мөдире. Югары уку йортлары өчен «Диннәр тарихы» («История религий», М., 2004) уку әсбабы авторы. Хезмәтләре Совет дәүләтенең диннәргә карата сәясәте тарихына багышлана.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001.

**МОЗЖА́РОВ** Иван Иванович (15.12.1915, хәзер Смоленск өлкәсе, Починок р-ны Буловицы а. — 6.2.1958, Чаллы ш.), Сов. Союзы Герое (3.6.1944), гв. старшинасы. Туган авылында колхозда эшли. 1936–38 һәм 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 208 нче танк батальоны танк механик-йөртүчесе (5 нче гв. танк корпусының 22 нче гв. танк бригадасы). Воронеж фронты гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (икесе дә — 1943) катнаша. 1943 нең сентябрь–октябрендә, Десна һәм Днепр елгаларын кичкәндә, командир танкы экипажы составында Днепрның уңъяк ярындагы Букрино плацдармын яулап алу һәм киңәйтү сугышларында батырлык күрсәтә. Сугыштан соң туган авылында һәм Чаллы шәһәрендә эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Буловицы авылында Геройга һәйкәл куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Золотые Звёзды Прикамья. Пермь, 1974; Воробьёв М.В., Титов В.Е., Храпченков А.К. Смоляне — Герои Советского Союза. М., 1982.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОЗЖЕ́РИН** Владимир Ильич (30.8.1949, БАССРның Бөре р-ны Иваново пос. — 15.10.2010, Казан), географ-геоморфолог, геогр. фән. д-ры (1994), проф. (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1973), шунда ук эшли, физик геогр. һәм геоэкология каф. мөдире (2001–05). Хезмәтләре Көнчыгыш Рус тигезлегендә җирнең эрозияләнүе, туфракның агым сулардан юылуы мәсьәләләренә, ерымнар эрозиясенә карый. М. Җир шарындагы тигезлекләрдә әлеге күренешләрнең һәм химик денудациянең зональлеген исбатлый; эрегән матдәләрнең агымы һәм механик кителмәләр күләме бүленешендә төп факторларның ролен билгели. Идел буеның күпшәк утырмаларын һәм рельефын өйрәнү буенча оештырылган экспедицияләрдә катнаша. Татарстан терр-ясен комплекслы рәвештә картага (гидрологик һәм геоморфологик) төшерү буенча хезмәтләр тәкъдим итә.

Х е з м.: Климатическая геоморфология денудационных равнин. К., 1977 (автордаш); Овражная эрозия востока Русской равнины. К., 1984 (автордаш); Химическая денудация на равнинах умеренного пояса. К., 1988 (автордаш); Эрозия на равнинах Восточной Европы // Геоморфология. 1996. № 2 (автордаш).

**МОИСЕ́ЕВ** Виктор Сергеевич (26.8.1946, Казан), информацион технологияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (2000), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2003). 1970 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, бер үк вакытта (2003 тән) Казан техник ун-тының гамәли матем. һәм информатика каф. ф-лы мөдире (АЙ-СИ-ЭЛ-КПО ВС). Хезмәтләре матем. модельләрне һәм алымнарны төрле максаттагы катлаулы системаларны анализлау һәм синтезлау өчен куллануга карый. М. авиация техникасы эшләнмәләрен сынаулар һәм тепловизион системаларны проектлау эшләрен комплекслы автоматлаштыру технологияләрен төзи. Югары төгәллектәге артиллерия снарядларын куллануны оптимальпланлаштыру, ш.у. функцияләре анык билгеләнмәгән һәм чикләүләре булган оптимальләштерү мәсьәләләрен чишүдә яңа юллар тәкъдим итә. Яңа фәнни юнәлеш — проектлау һәм идарә итү карарларын оптимальләштерүнең гамәли информацион технологиясе нигезләрен эшли. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы систем автоматизированного проектирования. К., 1988 (автордаш); Автоматизированные испытания в авиастроении. М., 1989 (автордаш); Метод малого параметра для решения неявно заданных функциональных зависимостей в задачах проектирования // Изв. вузов. Авиац. техника. 1998. № 4 (автордаш).

**МОИСЕ́ЕВ** Николай Андреевич (17.12.1954, Тәтеш р-ны Кече Фролово а.), автопокрышкалар җыючы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). 1976–2009 да «Түбәнкамашин» АҖдә эшли. Дәүләт бүләге хезмәттәге алдынгы казанышлары һәм техник җайланмалардан, чимал һәм ягулык-энергия ресурсларыннан файдалануны яхшыртуга зур өлеш керткәне өчен бирелә. Халыклар дуслыгы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**МОИСЕ́ЕВ** Сергей Андреевич (7.2.1957, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2000). ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1979), РФА КГҮнең Фи-

зика-техника ин-тында, өлкән фәнни хезмәткәр (2002 дән). Хезмәтләре нәсызыкча когерент һәм квант оптикасына, мюон спектроскопиягә карый. М. ультракечкенә фәзаи периодның фәза рәшәткәләре формалаштыру мөмкинлеген, фаза хәтере булган тирәлекләрдә яктылыкның квант интерференциясен күзәтү схемасын, нульле магнит кырларында мюон спин кайтавазын алдан әйтә, соңгысы 1998 елда тәҗрибәдә табыла. Фотон кайтавазы техникасында квантлы хәтерне чынга ашыру юлын тәкъдим итә (2001).

Х е з м.: Влияние параметров накачки на кинетику возбуждения аккумулированных решёток // Оптика и спектроскопия. 1991. Т. 71, вып. 3 (автордаш); Световое эхо на одном фотоне // Изв. РАН. Сер. физ. 1994. № 8 (автордаш); Радиочастотная деполяризация мюона в системе мюоний + ядерный спин // Журн. эксперим. и теорет. физики. 2003. Т. 124, № 6.

*Р.Г.Усманов.*

**МОЙСА́К** Иван Ефимович (19.2.1900, Чернигов губ. Корп ш. — 1.3.1973, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1951), проф. (1951), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1955). Шостка химия-технол. ин-тын (Украина ССР) тәмамлаганнан соң, Чапаевск, Новочеркасск, Шостка шәһәрләре пр-тиеләрендә эшли. 1931 елдан Казан химия-технол. ин-тында, махсус ф-т деканы (1942 дән), институт директоры урынбасары (1951–57) һәм азотның органик кушылмалары химиясе һәм технологиясе каф. мөдире (1951–69). Хезмәтләре махсус химиягә карый. М. термототрыклы шартлаткыч матдәләр (ТШМ) эшләү принципларын нигезли. Күптөшле карбо- һәм гетероароматик кушылмаларның электрофиль һәм нуклеофиль алыштыру реакцияләрендә үз-үзен тотышы закончалыкларын өйрәнә. Туенган углерод атомы янында нуклеофиль алмашу реакцияләрен (ачыткычлар булганда) ача һәм эшкәртә. Аның җитәкчелегендә энергия сыйдырышлы нитроалифатик кушылмалар синтезлана, нефть чыгару һәм оборона сәнәгатьләре, 300 °С ка кадәр куллану өчен ТШМ булдырыла (фәнни эшкәртмәләре җитештерүгә кертелгән). 300 дән артык фәнни хезмәт авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, РСФСР, ТАССР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

*В.Г.Абзалова.*

**МО́КИЧЕВ** Сергей Васильевич (4.11.1942, Чиләбе өлкәсенең Кыштым ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1969 елда Казан ун-тының юридик ф-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, политэкономия кафедрасында эшли, 1993 тән икътисад каф. мөдире, 1994–98 дә икътисад ф-ты деканы. Хезмәтләре милек мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә, хосусыйлаштыруны дәүләт көйләвенә, икътисади системаны үзгәртүгә (трансформацияләүгә) карый.

Х е з м.: Общенародная собственность на средства производства: Преимущества и закономерности развития. К., 1988; Структура общественной собственности. К., 1992; Трансформационная экономика. Гессен-К., 2002.

**МОКРЫ́Й БИСТӘСЕ́**, Казанның көньяк читендә, Казансуның сулъяк ярында урнашкан торулык. Чыганакларда беренче тапкыр 1646 елда телгә алына. 18 йөздә шәһәр эчендә кала. М.б.нең урамнары: Беренче Мокрый, Икенче Мокрый, Алгы Мокрый, Арткы Мокрый, Аркылы Мокрый (хәзерге тимер юл вокзалы алдындагы мәйдан, Вахитов р-нының Коротченко, Сәетгалиев, Сакко һәм Ванцетти урамнары тирәсендә). М.б. элек үзенең кунып чыгу йортлары б-н атаклы була. Шулардан берсен А.М.Горький үз әсәренә кертеп сурәтли: «Куну йорты эчендә — дүрткә алты сажин чамалы озынча куыш... Штукатурланмаган кирпеч диварлар... корымга каткан... Диварлардан төтен, җир идәннән — күгәрек, сәкеләрдән — черегән чүпрәк исе килә...» («Элеккеге кешеләр» — «Бывшие люди», 1897). Мәскәү–Казан тимер юлын төзегәндә Икенче Мокрый урамы урынында вокзалы б-н станция салына (1895–96).

*Әд.:* История Казани. К., 1988. Кн. 1; Б и к б у л а т о в Р., М у с т а ф и н Р. Казань и её слободы. К., 2001.

**МО́КРЫЙ РЖАВЕ́Ц** елгасы, к. *Устье.*

**МОКУ́ЛОВЛАР**, к. *Макуловлар.*


**МО́КШИН** Александр Фёдорович (1927, Буа кантоны Городище а. — 1996, Рязань ш.), оператор, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1942–44 елларда Куйбышев өлкәсендә совхозда эшли. 1951–60 та нефть эшкәртү з-дларында оператор ярдәмчесе (Куйбышев ш.), 1960–77 дә өлкән оператор (Рязань ш.). Герой исеме 8 нче бишьеллык планын уңышлы үтәгәне өчен бирелә (1966–70). КПССның 25 нче съезды делегаты (1976). Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Чүпрәле р-нының Городище авылында сугыш һәм хезмәт даны музеенда М.га стенд куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МОЛЛЮ́СКЛАР**, й о м ш а к т ә н л е л ә р (Mollusca), умырткасыз хайваннар тибы. Хәзерге заман дөнья фаунасында 7 класска (*корсагаяклылар*, моноплакофорлар, панцирлылар, улаккорсаклылар, калагаяклылар, башаяклылар һәм *ике кабырчыклы моллюсклар*) бүленә. Күпчелеге диңгезләрдә яши, төче суда һәм җир өстендә яшәүче формалары бар. Гәүдәләре йомшак һәм лайлалы (икенче исеме шуннан), баш (ике кабырчыклыларда юк), аяк һәм гәүдәгә бүленгән. Аяк гәүдәнең корсак өлешендә һәм үрмәләү, сирәк кенә йөзү өчен хезмәт итә яисә редукцияләнгән. М.ның зурлыгы 1 *мм* дан (вак корсагаяклылар һәм ике кабырчыклы моллюсклар) 18 *м* га кадәр (гигант Architeuthis dux кальмары). Гәүдә җыерчыклы тире — мантия б-н капланган һәм мантия куышлыгы хасил итә, аның эчендә исә кайбер эчке органнар урнашкан. Мантияның тышкы ягыннан М.ның гәүдәсе кабырчык б-н капланган (күпчелек төрләрдә ул үсеш алмаган яки бөтенләй юк). Бу икенчел куышлыклы, чыгышы б-н икеяклы-симметрияле хайваннар; күп кенә корсагаяклылар асимметрияле. Нерв системасы таркау-төенле типта, башаяклы М.да кимерчәкле баш сөяге тартмасы б-н капланган катлаулы ми була; сулау органнары — саңаклар (җир өсте формаларында мантия куышлыгы үпкә буларак хезмәт итә); кан системасы йомык түгел, йөрәкләре бар; бүлеп чыгару органнары — бөерләр; ашкайнату системасында зур ашкайнату бизе (бавыр) урнашкан; җенси юл б-н генә үрчиләр, күпчелеге — аерым җенеслеләр, кайберләре (үпкә корсагаяклылары) — гермафродитлар. М. кембрийгача чорда барлыкка килә, яссы яки аз сегментлы божралы суалчаннардан килеп чыккан дип фаразлана. Палеозой һәм мезозой эрасына караган 50 меңгә якын үлеп беткән төре билгеле, алар арасында башаяклы М. классы вәкилләре аеруча таралган. Татарстан терр-ясендә аммоноидларның, белемнитларның («шайтан бармаклары») һ.б. казылма М. кабырчыклары Тәтеш шәһәреннән көньяктарак очрыйлар.


А.Ф. Мокшин.

ТРның хәзерге заман фаунасында 2 класс вәкилләре яши — корсагаяклылар яки әкәм-төкәмнәр (Gastropoda) һәм ике кабырчыклы М. (Bivalvia). Татарстанда корсагаяклы М.ның 90 нән төреннән 150 дән артыгы, ш.и. 100 гә якыны — җир өстендә, 50 дән артык төре төче суларда яшиләр. Кабырчыгы, гадәттә, спиральсыман бормалы, әмма җир өсте лайлачларының (ТРда 10 га якын төр) кабырчыгы юк. Җир өсте корсагаяклы М.дан кыр лайлачы (Agriolimax agrestis), Deroceras, Arion ыругы *лайлачлары*, гади гәрәбә (Succinea putris), Cochliopa ыругы *әкәм-төкәмнәре* таралган. Казанның нейрофизиология лаб-яләрендә тәҗрибә максатларында һәм һәвәскәрләр тарафыннан эре җир өсте корсагаяклы М.ы — ахатина (Achatina fulica) (Африка төре) һәм Россиянең көньяк өлкәләрендә очраучы виноград әкәм-төкәме (Helix pomatia) үрчетелә (күп кенә илләрдә бу җир өсте әкәм-төкәмнәре азык буларак кулланыла). Татарстанда корсагаяклы төче су М.ыннан *буа әкәм-төкәмнәре* (Lymnaeidae семьялыгы — 13 төр), *кәтүкләр* (Planorbidae — 16 төр), вальватлар (Valvatidae семьялыгы — 9 төр), *тереләй тудыручы моллюсклар* (Viviparidae семьялыгы — 2 төр) киң таралган. Ике кабырчыклы М.ның 20 меңгә якын төре билгеле, ТРда — 58. Аларның кабырчыгы арка ягында кушылган ике капкачтан тора. Бары тик су мохитендә генә яшиләр. ТРда *бөрчекләр* (Pisidiidae семьялыгы — 31 төр) шарчык моллюсклар (Sphaeriidae — 13 төр), *тешсез әкәм-төкәмнәр* (Anodonta — 6 төр) һәм *перловицалар*




Моллюсклар: 1. Тешсез әкәм-төкәм (Anodonta); 2. Күп рәвешле дрейссена (Dreissena polymorpha); 3. Битиния (Bithynia leachi); 4. Гади буа әкәм-төкәме (Lymnaea stagnalis); 5. Виноград әкәм-төкәме (Helix pomatia); 6. Тереләй тудыручы моллюсклар (Viviparus conteclus); 7. Мөгезсыман кәтүк (Planorbarius comeus); 8. Казылма аммонит Douvilleieeras .

(Unio — 4 төр) аеруча күп очрый. Соңгы берничә унъеллыкта Куйбышев сусаклагычына Кама плёсының түбәнге өлешенә кадәр Понт-Каспий ике кабырчыклы тозлы су М.ы: елга (Dreissena polymorgha) һәм буг *дрейссеналары* (D.bugensis), монодакна (Monodacna (Hypania) colorata) үтеп керде. Ике кабырчыклы М. судагы бик вак организмнар һәм кисәкчекләр б-н туена, шул рәвешле суны арындыруда катнашып, үзләре балыклар өчен азык булып торалар. Лайлачлар кыр һәм бакчага, урман агачларына зыян китерә. Корсагаяклы М.ның күп кенә төрләре (Lymnaeidae, Bithyniidae h.б. семьялыгы) паразит суалчаннарның арадаш хуҗалары булып тора. Элек перловицаларның күп кенә эре төрләрен азык итеп кулланганнар, йорт хайваннарын симертүдә яки төймәләр ясауда файдаланганнар. Сулыклар пычрану сәбәпле, М.ның ареалы (аеруча перловицалар һәм тешсез әкәм-төкәмнәр) тарая, һәм алар саклауга мохтаҗ.

*Әд.:* Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных безпозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Догель В.А. Зоология беспозвоночных. М., 1981; Жизнь животных. М., 1988. Т. 2; Любарская О.Д., Сабиров Р.М., Галимова Д.Н. Аннотированный каталог моллюсков водоёмов Татарстана // Тез. докл. VIII съезда гидробиологического общества РАН. Калининград, 2001. Т. 1; Ruppert E., Barnes D. Invertebrate Zoology. L., 1994.

*Р.М.Сабиров, В.А.Яковлев.*

**МОЛОДЁЖНЫЙ** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бота елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 518 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 25%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, җәнлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, балалар сәнгать мәктәбе. 1968 дә Әлмәт җәнлек с-зының үзәк утары буларак нигез салына. 1980 нән хәзерге исемен йөртә. Оештырылган көненнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1979 да — 241, 1989 да — 481, 2002 дә — 509 кеше.

**«МОЛОДЁЖЬ ТАТАРСТА́НА»**, атналык респ-ка яшьләр газетасы. 1919 елның 25 октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. Исеме үзгәреп тора, өзеклекләр б-н чыга: 1919–25 тә — «Клич юного коммунара», 1930–33 тә — «На штурм», 1938–41, 1949–91 дә — «Комсомолец Татарии», 1991–92 дә — «Комсомолец Татарстана», 1992 дән — «М.Т.» Совет чорында ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты һәм ВЛКСМның Казан шәһәр ком-ты органы. Төрле елларда мөхәррирләре: «Клич юного коммунара» — А.Безыменский, Ю.Федмидин, Н.Абакумов, С.Заболотский; «На штурм» — С.Яхкинд, В.Сарапкин, П.Семёнов, В.Знаменский, В.Коган; «Комсомолец Татарии» һәм «Комсомолец Татарстана» — В.Федотов, Л.Ханин, А.Малов, Ф.Г.*Надыйров*, Н.Г.Харитонов, Е.Г.Ухов, А.П.Путилов, В.Н.Шевчук, Р.А.*Ратникова*; «М.Т.» — Р.А.Ратникова, Ә.А.Кармеев, Р.М.Кадыйров, Р.В.Билалов, Б.А.Срурров, Т.Н.Вафина (2011 дән). Совет чорында партия һәм дәүләтнең яшьләр сәясәтен оештыручы булып тора, комсомол оешмалары, Татарстанның укучы яшьләре тормышын һәрьяклап яктырта, КПСС программасын тормышка ашыруда актив катнашырга чакыра. ВЛКСМ таркалганнан соң, газетаны оештыручылар — ТР-ның Яшьләр оешмалары советы, Матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр чаралары министрлыгы, «М.Т.» г-тасы редакциясе. 2014 тә чыгудан туктый.

*Әд.:* Ершов А.Н. Молодёжная пресса Татарии (1917–1921 гг.). К., 1983.

**МОЛОКО́ВИЧ** Юрий Матвеевич (13.12.1927, Мәскәү өлкәсенең Реутово пос.- 28.3.2005, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). 1953 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли: Матем. һәм механика ин-тында җир асты гидромеханикасы бүлеге мөдире (1968–83), механика-матем. ф-ты деканы (1962–65), аэрогидромеханика каф. мөдире (1983–94). Хезмәтләре җир асты гидромеханикасына, нәсызыкча һәм релаксацион фильтрлау теорияләренә карый. М. хәрәкәт итүче сыеклыкның күзәнәкчел тирәлектә үз-үзен тотышын исәпкә алган тигезсез фильтрлау модельләрен тәкдим итә, бу модельләрнең тикшерелә торган скважина тирәсендәге фильтрлау параметрларын билгеләү өчен кулланылу мөмкинлеген күрсәтә.

Хезм.: Основы теории релаксационной фильтрации. К., 1987 (автордаш); Выработка трещиновато-пористого коллектора нестационарным дренированием. К., 2000 (автордаш); Пьезометрия окрестности скважины. К., 2000 (автордаш).

**МОЛОСТВО́В** Анатолий Петрович (1.9.1945, Аксубай р-ны Ерепкино а.), генерал-майор (1990). Омск танк техник уч-щесен (1966), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Мәскәү хәрби бронетанк гаскәрләре академиясенең инженерлар ф-тын (1973) һәм житәкче инженерлар составы ф-тын (1982), СССР Кораллы көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Академиясен (Мәскәү, 1986) тәмамлый. 1962–63 елларда Серов исем. металлургия з-дында (Свердловск өлкәсе, Серов ш.) эшли. 1963 нең августыннан Совет Армиясе сафларында. 1966–69 да Германиядә (Стендаль ш.) совет гаскәрләре төркеменең техника буенча рота командиры урынбасары. 1973–80 дә Ерак Көнчыгыш хәрби округында танк полкының техника буенча командир урынбасары, армияне коралландыру идарәсенең бронетанк хезмәте башлыгы урынбасары. 1982–84 тә Киев хәрби округында (Артёмовск ш.) кораллану буенча дивизия командиры урынбасары. 1986–93 тә Семипалатинск шәһәрендә һәм Германиядәге Көнбатыш гаскәрләре төркемендә кораллану буенча идарә башлыгы — кораллану буенча армия командующие урынбасары. 1993 тән отставкада. 2005–06 да Аксубай р-ның Иске Тимошкино авылы җирлеге башлыгы. 2007 нең гыйнварыннан «Камагросервис» ярдәмче хуҗалыгының куркынычсызлык хезмәте башлыгы (Аксубай р-ны Яңа Тимошкино а.). 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОЛОСТВО́В УРЫ́**, *Кама аръягы иске чик сызыгы* ныгытмаларының берсе. Гомуми озынлыгы 7,5 *км* чамасы. Кама аша кичүне көньяктан каплаган. Берничә тапкыр тикшерелә һәм тасвирлана (С.М.Шпилевский, Н.Ф.Калинин, Р.Г.Фәхретдинов). Кайбер ар-


хеологлар (А.П.Смирнов, Р.Г.Фәхретдинов) фикеренчә, М.у. Болгар чорына карый.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Фахрутдинов Р.Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1975.

*И.Л.Измайлов.*

**МОЛОСТВОВЛА́Р**, борынгы дворяннар нәселе, Казан губернасында эре җирбиләүчеләр. 15 йөз уртасында Бөек Новгородта җирләре була, 15 йөз ахырында алар елганың түбән агымы тирәсендәге шәһәрләргә күчереләләр. 100 елдан соң М. Мәскәү йомышлы дворяннары исәбенә керәләр. **Салтан** һәм **Улан Семёнович** М. 17 йөз башында Түбән Новгород өязенең Березопольский станында җирләр биләгән. **Улан** (? — ?) — Яранскида яши, Зөя кешесе (свияженин). 1652 елда аның Зөя дисәтинәсендә язылган хезмәт өчен бирелгән җир биләмәсе 750 чирек була. Оныклары: **Дмитрий Иванович** (? — 1724) — Зөя кешесе, 1692 дән стольник, 1697 дән Уфада воевода, 1703 тән «йомышчы казанлылары булган дүртенче стольник». **Иван Иванович** (? — 1717 гә кадәр) — Мәскәү дворяны (1692 дән), «Казанда Низовый полкта хезмәт итүче унынчы дворян» (1703 тән). 1691 дә аңа бертуганының уллары Андрей һәм Иван Дмитриевич б-н бергә Казан өязендә Кама аръягы чик сызыгы буенда җирләр бирелә (һәрберсенә 720 шәр чирек). **Иван Дмитриевич** (? — 1736 га кадәр) — Зөя кешесе, стряпчий (1703), үз эскадронында капитан (1709), майор (1716). Казан губернасында селитра з-ды хуҗасы. 1 нче ревизия вакытында Казан губернасының Зөя өязендә аның исеменә 357 ир-ат крепостной крәстиян языла. Улы **Лев Иванович** (? — 11.2.1768) — прапорщик (1736), Олонецк полкы кавалериясе поручигы (1743), Вологда полкы кавалериясе капитаны (1749), майор (1755), отставкадагы секунд-майор (1761). 1760 елларда Казан губернасында ата-бабаларына бүлеп бирелгән барлык җирләр б-н идарә итә. 1273 ир-ат крепостной крәстияне була.

1770 еллардан Казан губернасы Спас өязенең Рождественское (Өчкүл) һәм Никольское авылларында М.ның 2 нәсел тармагы оеша. Нәселнең өлкән тармагын нигезләүче — **Христофор Львович** М. (3.5.1757 — 11.5.1842, Никольское авылында җирләнә) — отставкадагы гв. прапорщигы (1785), библиофил. Аның китапханәсендә «Никольское китапханәсендә саклаңган китаплар исемлеге» буенча 272 исемдәге 524 том исәпләнә. Уллары **Валериан** (24.7.1792 — 27.8.1813, Лион ш., Франция), **Памфамир** (12.5.1793 — 4.7.1828, С.Петербург) һәм **Таврион** (21.8.1795, Казан — 9.1.1844, С.-Петербург), 1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813–14 тә Көнбатыш Европа илләренә яуларда катнашалар. **Валериан Таврионович** (8.8.1828, Казан — 31.3.1909, Никольское авылында җирләнә) — хакыйкый статский советник (1898), Венгриягә яуда (1849), Кырым сугышында (1853–56) катнаша. 1862–64 тә Спас өязенең 3 нче участок мировой арадашчысы, 1872–87 дә мактаулы мировой судья, 1896 дан император галиҗәнаплары сарае шталмейстеры. 1866 ның 23–24 августында ул, бертуганы — подполковник, Казан хәрби губернаторы адъютанты **Александр Таврионович** (8.8.1829, Казан — 21.7.1891, Спас өязенең Ширбәт авылында җирләнә) б-н бергә Никольское авылындагы утарында тәхет варисын — булачак император Александр III не кабул итә, аның хөрмәтенә ау оештыра. **Лев Валерианович** (1.10.1875, Казан — 1921, Кукша кальгасы) — галиҗәнап лейб-гв. гусарлар полкы корнеты, 1910 нан отставкадагы полковник, 1911–17 дә Спас өязе дворяннары башлыгы. Гражданнар сугышында катнаша. **Александра Валериановна** (2.9.1886, Никольское а. — 23.9.1945, Яшел Үзән ш.) 1918 дә Никольское авылында саклаңган гаилә китапханәсендәге китаплар, архив һәм сәнгать әсәрләре тупланмасының тасвирламасын төзи һәм Казанга алып килә. Алар дәүләт милкенә әверелә (гаилә китапханәсе китаплары һәм кульязмалары Казан ун-ты Фәнни китапханәсендә, нәкышь әсәрләре тупланмасы ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана). 1938 нең 21 маенда кулга алына, 1940 ның 27 февралендә 3 елга хөкем ителә һәм Вятка хезмәт б-н төзәтү лагерына җибәрелә. Аклана.



«Х.Л. Молоствов портреты». Билгесез рәссам. 18 йөз ахыры – 19 йөз башы. ТР Милли музее.

Христофор Львовичның энесе — **Феопемпт Львович** (20.12.1758 — 30.9.1817, С.-Петербург янындагы Сергий пустынена җирләнә) — отставкадагы секунд-майор (1788), библиофил һәм коллекционер; С.-Петербург шәһәрендә яши (китапларының һәм картиналарының бер өлеше Казан ун-ты Фәнни китапханәсендә, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана).

Нәселнең кече тармагын нигезләүче — **Порфирий Львович** (9.2.1760 — 29.12.1808, Өчкүл авылында җирләнә) отставкадагы секунд-майор (1788), надворный советник (1807), Казан наместниклыгы (1793–96) һәм Казан губернасы (1806–08) дворяннары башлыгы. Балалары: **Александр Порфирьевич** (1786-?) — Кременчуг пехота полкы полковнигы. **Владимир Порфирьевич** (7.6.1794, Казан — 12.3.1863, Югары Силезиянең Карлсруэ шәһәрендә җирләнә) — генерал-лейтенант (1855), сенатор (1859). Дәрәҗә алыр



В.П. Молоствов. 19 йөз уртасы фоторәсеме.

өчен, Казан ун-тында имтиханнар тапшыра (1810), С.-Петербургтагы Колонновожатыйлар әзерләү мәктәбендә укый. 1814–28, 1831–39 да принц Евгений Виртембергский адъютанты (1831 дән генерал-майор). 1839 дан Оренбург казаклар гаскәре командующие, 1841 нең 6 гыйнварыннан наказной атаман. 1841 нең 3 мартыннан 15 апреленә кадәр Воронеж шәһәре губернаторы һәм Воронеж гражданнар губернаторы, 1847 нең 22 маеннан 1857 нең 12 маена кадәр Казан уку-укыту округы попечителе. 1812 елгы Ватан сугышында, 1813–14 тә Көнбатыш Европа илләренә яуларда, 1828–29 дагы рус-төрек сугышында, Польшадагы күтәрелешне бастыруда (1831), Хивага яуда (1839–40) катнаша. Казан рус теле һәм әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте шәрәфле әгъзасы (1847), Рус геогр. җәмгыяте хакыйкый әгъзасы (1852), Казан руханилар семинариясе конференциясе (1855), Казан ун-ты шәрәфле әгъзасы (1857). Казан уку-укыту округы попечителе буларак, хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге сәясәте кысаларында эшли, Казан уку-укыту округының уку йортларына, беренче чиратта Казан ун-тына игътибар бирә: күренекле Казан галимнәрен башкаладагы югары уку йортларына күчерүне тоткарларга тырыша, Казан ун-тының Шәрекъ бүлеге ябылу б-н килешми; ректорлар Н.И.Лобачевский, И.Н.Симонов б-н уртак тел таба, О.М.Ковалевскийны ректор итеп билгеләүне яклап чыга. 4 нче дәрәҗә Изге Георгий, 3 һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1 һәм 4 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары; «Батырлык өчен» алтын шпагасы, медальләр, Польшаның 3 нче дәрәҗә хәрби абруй билгесе б-н бүләкләнә. **Модест Порфирьевич** (18.8.1799 — 28.9.1845, Өчкүл авылында җирләнә) — отставкадагы поручик (1823). 1815 тә бертуганы **Орест Порфирьевич** (11.11.1801 — 25.4.1870, Казан, Өчкүл авылында җирләнә) б-н бергә күренекле астроном, Казан ун-ты профессоры И.А.Литтров пансионы укучылары арасында исәпләнә. 1815 нең 27 августында бертуган М. — Казан ун-тының тел һәм әдәбият бүлеге студентлары; 1817 нең гыйнварында хәрби хезмәткә алыналар. Модест 1819 ның 9 гыйнварыннан лейб-гв. драгун полкы юнкеры, 1933 тән Казан дворяннар

җыены депутаты, 1836–45 тә Спас өязе дворяннары башлыгы. Болгар акчаларын туплый.

Владимир Порфирьевичның балалары: **Вадим** (10.2.1825, Карлсруэ ш. — 31.7.1881, Казанда җирләнә) — отставкадагы штабс-капитан (1859). Рус-төрек сугышында катнаша (1877–78), батырлык күрсәткәне өчен, алтын корал б-н бүләкләнә. 1860–64 елларда Спас өязе дворяннары башлыгы. **Герман** (5.5.1827, Карлсруэ ш. — 1894, Казанда җирләнә) — отставкадагы артиллерия генералы (1889). Артиллерия уч-щесен тәмамлый (1846). 1856 дан Кавказ армиясе башкомандующие адъютанты, 1864 тән Әстерхан казаклар гаскәренең наказной атаманы. 1867 дән Казан хәрби округы гаскәрләре командующие каршында махсус вазифалар башкаручы чиновник. 1869 дан Тәтеш мәхкәмә округы шәрәфле мировой судьясы. 1879 дан Казан хәрби Округы җирле гаскәрләре башлыгы. 2, 3, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 һәм 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, Ак бөркет орденнары, 2 нче дәрәҗә Церинген Арысланы Баден командир хачы, медальләр б-н бүләкләнә.

Модест Порфирьевичның балалары: **Порфирий Модестович** (5.6.1827, Казан — 21.10.1890, шунда ук җирләнә) — генерал-лейтенант (1879), Венгрия һәм Төркиягә яуларда (1849), Кырым сугышында (1853–55), Кавказны буйсындыруда (1860) катнаша. 1864 тән Казан хәрби округының җирле гаскәрләре штабы башлыгы, 1867 дән Харьков хәрби округы штабы башлыгы ярдәмчесе, генерал-майор. 1878 дән Адрианополь санджакында губернатор, 1885 тән отставкада. **Зинаида Модестовна** (18.11.1827, Өчкүл а. — 10.2.1897, Казанда җирләнә) Казанда Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тын тәмамлый. Ире — Н.В.Тиле. **Владимир Модестович** (24.11.1829, Өчкүл а. — 19.11.1890, шунда ук җирләнә) Казан алпавыт крәстияннәренең тормыш-көнкүрешен һәм хәлен яхшырту ком-ты эшендә катнаша (1858). 25 ел дәвамында Казан губернасының Тәтеш өязеннән гласный итеп сайлана. 1870–73 тә Казан губернасының земство идарәсе рәисе. 1875 тә Казан губернасы дворяннары башлыгы вазифасына кандидат итеп сайлана. **Михаил Модестович** (9.7.1841, Өчкүл а. — 23.8.1882, шунда ук) гв. подпрапорщиклары һәм кавалерия юнкерлары мәктәбен тәмамлый, лейб-гв. Преображение полкы прапорщигы. Отставкага чыкканнан соң, Томск губернаторы карамагында була. Мировой судья булып хезмәт итә. 1875–80 дә Спас өязе дворяннары башлыгы. Модест Порфирьевич М., Депрейс Н.И. (Наталья Порфирьевна М.га өйләнгән), Владимир Германович М. гаиләләре Л.Н.Толстойның Казан танышлары була.

Герман Владимировичның уллары: **Владимир Германович** (9.4.1859, Казан — 18.1.1918, Тәтеш өязе Долгая Поляна авылында җирләнә) — хакыйкый статский советник (1912). Пажлар корпусын тәмамлаганнан соң, Болгария гаскәрләрендә (1883–85), удел ведомствосында (1886–92) хезмәт итә. 1892–95 тә Шәрекъкә сәяхәт кыла, Сүрия чүлен җәяү уза. 1896–1904 тә Финанс министрлыгының Крәстияннәр һәм дворяннар җир банклары Казан бүлекчәләрендә хезмәт итә. 1904–16 да Тәтеш өязе земствосы җыены гласные, 1906–15 тә шәрәфле мировой судья, 1905–17 дә Тәтеш өязе дворяннары башлыгы. 1913 тә «Kazan Oil-fields Limited» компаниясенең Казан бүлекчәсе директоры. Долгая Поляна утары хуҗасы (хәзер тарих-мәдәният һәм табигать паркы). 1910 ның 21 февралендә хатыны б-н Ясная Полянада Л.Н.Толстой янында булалар. **Николай Германович** (21.1.1871, Казан — 20.5.1910, С.-Петербург) әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә.

М.ның нәселе Казан губернасы шәҗәрәләр китабының 6 нчы бүлегенә кертелгән. Нәсел туграсы 1886 да раслана, Россия империясе Гомуми тугралар җыентыгының 14 нче бүлегенә кертелгән.

*Әд.:* К о р с а к о в Д.А. Владимир Модестович Молоствов: Некролог. К., 1890; Л о д ы ж е н с к и й И.Н. Родословная Молоствовых. СПб., 1990; Ф р о л о в а С.А. Казанская ветвь дворянского рода Молоствовых (вторая половина XVIII в. — 1861 гг.): Дис. ... К., 1998; ш у л у к. Феопемпт Львович Молоствов: библиофил, коллекционер // Чтения, посвящённые 225-летию со дня рождения Гавриила Каменева, поэта и жителя Казани: Материалы выступлений. К., 1998.

*С.А.Фролова.*

**МОЛОСТВОВЛА́Р КИТАПХАНӘСЕ́**, Христофор һәм Феопемпт Львовичлар, Валериан һәм Таврион Христофоровичлар һәм Валериан Таврионович Молоствовларның китап тупланмаларын үз эченә ала. Китаплар Казан губернасының Спас өязе Никольский һәм Рождественский (Өчкүл) авылларындагы *Молоствовлар* утарларында саклanган, 1918 елда гаилә архивы б-н бергә Казанга китерелә. Казан ун-тының Фәнни китапханәсе фондларында М.к.нә кергән, 1761–1860 та (50 исемдә) басылган китаплар табыла. Аларның экслибрислары, номерлары, иясен күрсәткән язмалары бар. Китапханәнең ике кульязма каталогы сакланган: «Никольский китапханәсендә калган китаплар реестры» («Реестр книгам, оставшимся в Никольской библиотеке», 1822–25) һәм «Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волосте Никольский авылындагы бертуган Валериан, Феопемпт һәм Таврион Христофорович Молоствовларның элекке китапханәсе каталогы» (1917 ел ахыры — 1918 ел башы) («Каталог старой библиотеки братьев Молоствовых Валериана, Феопемпта и Тавриона Христоф[оровича] в с. Никольском Щербетской вол. Спасского у. Казанской губ., кон. 1917 — нач. 1918»). Х.Л.Молоствовның китапханәсе «Реестр» буенча 272 исемдәге (524 том) китаптан тора. Дини эчтәлектәгеләре — 110, чит ил һәм рус әдәбияты әсәрләре — 55, тарихи әсәрләр — 23, а.х.на караган китаплар — 13, геогр. һәм табигыять фәннәренә караганнары — 10, вакытлы матбугат басмалары — 11 исемдә. Ф.Л.Молоствов китапханәсендәге китаплар арасында Вольтер, рус әдипләре (В.В.Капнист, А.П.Сумароков, Н.М.Карамзин) әсәрләре җыентыклары, «Аглая», «Аониды» альманахларының тулы комплекты, «Чит телдәге әдәбият пантеоны» («Аониды» һәм «Аглая» 19 йөздә үк сирәк очрый торган китаплар саналган), дини һәм табигыять фәннәре өлкәсенә караган китаплар була. Т.Х.Молоствов китапханәсендә Вольтер, рус шагыйрьләре (Д.И.Давыдов, И.А.Крылов, М.М.Херасков), К.Эккартсгаузенның дини-мистик характердагы әсәрләре бар. Таврион китапханәсенең 1830 елларга караган исемлеге сакланмаган. «Каталог» буенча рус телендәге китаплар — 596, француз телендә — 420 исемдә. М.ның нәселдән тупланган китапханәсенең нигезен беллетристика (барлык китапларның 40%ы) тәшкил итә: рус һәм чит ил матур әдәбияты (154 һәм 81 исемдә), ш.и. И.Ф.Богданович, С.Н.Глинка, Г.Р.Державин, И.И.Дмитриев, В.И.Жуковский, Я.Б.Княжнин, И.А.Крылов, А.С.Пушкин, А.П.Сумароков, М.М.Херасков һ.б., В.Г.Белинский әсәрләре җыентыгы (1861–74 елгы басма), А.Н.Радищевның беренче (үлгәннән соң) һәм 1807 дә басылып чыккан, 1907 гә кадәр бердәнбер рөхсәт ителгән әсәрләр җыентыгы. Соңгысы сирәк китап санала, чөнки Мәскәүдә 1812 елгы янгын вакытында китапның бөтен тиражы диярлек янып бетә.

Француз телендәге китаплар арасында Бөек француз рев-циясе тарихы, Наполеон Бонапартның тормышы һәм эшчәнлеге турындагы хезмәтләр зур урын били.

Гаилә китапханәсендә тарихка караган әсәрләр икенче урынны алып тора (140 исемдә). Әлеге бүлектәге китапларның яртысыннан артыгын рус тарихына, Екатерина II патшалык иткән чордагы хәрби һәм сәяси эшлекләләргә, 19 йөз башы тышкы сәясәтенә, Пётр I һәм аның көрәштәшләре эшчәнлегенә (И.И.Голиков, Ф.О.Туманский, И.И.Виноградов һ.б.ның хезмәтләре), 1812 елгы сугышка багышланган хезмәтләр тәшкил итә. Молоствовлар Идел буенда яшәгән халыклар тарихы б-н кызыксыналар. Аларның китапханәләрендә Г.Ф.Миллерның «Казан губернасындагы мәҗүси халыкларны тасвирлау» («Описание языческих народов Казанской губернии», М., 1791), В.А.Сбоевның «Казан губернасындагы әҗнәбиләргә кагылышлы тикшеренүләр» («Исследование об инородцах Казанской губернии», 1856), К.Ф.Фуксның «Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәттә» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношении», 1844), ш.у. сирәк очрый торган китаплар бар: «Зур сызымга өстәмә китап яки Россия дәүләтенең борынгы картасы» («Книга Большому чертежу или древняя карта Российского государства», СПб., 1792), «Россиядән киткән һәм Россиядә яшәүче кенәзләр, дворяннарның шәҗәрә китабы» («Родословная книга князей и дворян Российских и выезжих», ч. 1–2, М., 1787), А.Шлецерның «Нестор. Борынгы славян телендә рус елъязмалары» («Нестор. Русские летописи на древнеславянском языке», СПб., 1809), «Ялган Пётр III яки фетнәче Емелька Пугачёвның тормышы, холкы һәм явызлыклары» («Ложный Пётр III или жизнь, характер и

злодеяния бунтовщика Емельки Пугачёва», ч. 1–2, 1809).

М. китапханәсендә китаплар саны буенча өченче урынны дини әдәбият (86 исемдә) били. Әлеге бүлектәге китапларның яртысын — илаһият әсәрләре, өчтән бер өлешен Рус православие чиркәве тарихына багышланган хезмәтләр тәшкил итә; ш.у. тыелган масон китаплары да (И.А.Штарк, Ю.Штиллинг, К.Эккартсгаузен хезмәтләре) була. Молоствовлар масон А.Ф.Лабзин тарафыннан чыгарылган, соңыннан Россиядә тыелган «Сионский вестник» ж-лын, вакытлы басмалардан «Казанские губернские ведомости», Н.И.Новиковның «Кошелёк» ж-лын, Н.М.Карамзин, А.А.Дельвиг тарафыннан басылган әдәби альманахлар һ.б.ны алдыралар. М. китапханәсендә балалар өчен рус, француз һәм немец телләрендәге китаплар да була (дәреслекләр, төрле кулланмалар, балалар өчен энциклопедияләр). М.к. 1781–1840 елларда аеруча актив тулыландырыла.

*Әд.:* Ф р о л о в а С.А. Библиотека дворянского рода Молоствовых в фондах Научной библиотеки Казанского государственного университета // Рукописная и старопечатная книга: проблемы сбора, сохранения и изучения: тез. докл. и выступлений науч.-практич. конф., посв. 130-летию Нац. б-ки РТ (14–15 декабря 1995). К., 1995.

**МО́ЛОТОВ** (Скрябин) Вячеслав Михайлович (25.2.1890, Вятка губ., Нолинский өязе Кукарка бистәсе — 8.11.1986, Мәскәү), дәүләт һәм партия эшлеклесе, Соц. Хезмәт Герое (1943). 1902–09 елларда Казанда 1 нче реаль уч-щедә укый. 1905 тә революцион хәрәкәткә кушыла, «Казан урта мәктәпләре укучыларының берләштерелгән төркеме» әгъзасы, 1905–07 елгы Рев-циядә катнаша (Казан). Петербург политехник ин-тында укый. 1912–16 да революцион эшчәнлеге өчен берничә тапкыр кулга алына һәм Себергә сөрелә. 1917 нең көзендә Петроградта Вакытлы революцион ком-т әгъзасы. 1919 да Түбән Новгород губерна башкарма ком-ты рәисе, РКП(б)ның Донецк губерна ком-ты секретаре, 1920 дә Украина КП(б) ҮК секретаре. 1921–30 да ВКП(б) ҮК секретаре. 1930–41 дә ХКС рәисе, бер үк вакытта, 1930–37 дә, СССР Хезмәт һәм оборона советы рәисе. 1939–49, 1953–56 да СССР тышкы эшләр халык комиссары, министры. 1921–57 дә КПССның ҮК әгъзасы (1920 дән канд.). 1941–45 тә Оборона дәүләт ком-ты рәисе урынбасары. 1941–57 дә СССР ХКС (МС) рәисенең 1 нче урынбасары. Союздаш державаларның (СССР, АКШ, Бөекбритания) Тәһран (1943), Кырым, Потсдам (икесе дә — 1945) конференцияләрендә катнаша. И.В.Сталинның иң якын сәяси фикердәшләреннән берсе, 1930 елларда — 50 еллар башындагы СССРда массакүләм репрессияләрне оештыручыларның берсе. 1957 дә Л.М.Каганович, Г.М.Маленков һ.б. бергә Н.С.Хрущёвның сәясәтенә каршы чыга, КПСС ҮК Президиумыннан һәм ҮКнан чыгарыла. 1957–60 та СССРның Монголия Халык Респ-касындагы илчесе. 1960–62 дә СССРның Халыкара атом энергетикасы агентлыгы каршындагы даими вәкиле. 1926–57 дә КПСС ҮК Политбюросы, Президиумы әгъзасы (1921 дән канд.). СССРның БҮБК һәм ҮБК әгъзасы. 1937–58 дә СССР ЮС депутаты.

*Әд.:* Политические деятели России 1917: Биогр. словарь. М., 1993.

**МОНА́Й** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, Алабуга–Ижевск автомобиль юлы буенда. 2010 елда 494 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 74%, руслар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән Починок Манай Враг исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, ятьмә үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1911 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 859,5 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1859 да — 227, 1887 дә — 352, 1905 тә — 453, 1920 дә — 584, 1926 да — 647, 1938 дә — 624, 1949 да — 432, 1958 дә — 380, 1970 тә — 425, 1979 да — 301, 1989 да — 305, 2002 дә — 501 кеше.

**МОНАСЗО́Н** Эммануил Александрович (18.4.1927, Новгород ш. — 15.4.2010, Мәскәү), пианист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). 1950 елда Мәскәү консерваториясен (К.Игумнов һәм Я.Зак класслары) тәмамлый. 1958–79 да Казан консерваториясендә укыта. Башкаручы буларак, М.га фикерләү киңлеге, драматургик идеянең ачыклыгы, фортепиано әсәрләренең формасын төзү осталыгы хас. Казанда «Фортепиано музыкасының сайланма сәхифәләре», «П.Чайковскийның фортепиано әсәрләре» һ.б. соло концертлары циклын башкара. Күренекле музыкантлар б-н пианист-ансамблист буларак чыгышлар ясап танылa. Казан пианистлар мәктәбен оештыруга зур өлеш кертә. 47 пианист һәм 8 ассистент-стажёр әзерли, шуларның күбесе музыка-җәмәгать эшлеклесе, башкаручы, педагог (Р.Абдуллин, Р.Еникиева, Л.Круглова, Э.Бурнашева, Л.Леонтьева, Р.Сабитовская, Ф.Хәсәнова һ.б.) булып танылa. Казанда үзенең укучылары б-н Л.Бетховен, С.Прокофьевның барлык сонаталары һәм С.Рахманинов концертлары кергән зур концерт программалары циклларын әзерли. М. зур пед. талантка, укучының иҗади индивидуальлеген ачу һәм үстерү сәләтенә ия. М.ның төп пед. принцибы — мөстәкыйль иҗади фикерләүгә ирешкән, автор әсәрен тирәнтен аңлаган һәм аны тыңлаучыга ачып бирә белгән пианист тәрбияләү. М.ның башкару һәм пед. тәҗрибәсе фортепиано җыентыкларын төзеп редакцияләүдә, фортепиано ансамбльләре өчен опера, балет һәм симф. музыка эшкәртүдә, методик материаллар төзүдә чагылыш таба. М. әлеге тәҗрибәсен ачык дәресләр үткәрүдә уңышлы куллана.

*Әд.:* С п и р и д о н о в а В. «Ничто в прошедшее не канет...» // Казань. 1996. № 5/6; С е р ё г и н а И. Эммануил Монасзон // Музыкальное обозрение. 1997. № 5–6; Эммануил Монасзон: Статьи. Воспоминания. Материалы. К., 2007; Н и к и ф о р о в а А. Българска клавирна музыка // Българска музыка. 1988. № 6.

*В.М.Спиридонова.*

**МОНАСТЫ́РСКИЙ** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 386 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз башында Тәтештәге Покров монастыре җирләрендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Средне-Монастырская, Средняя исемнәре б-н дә билгеле. 17 йөзнең 2 нче яртысында М. халкы Мәскәүдәге Яңа Спас монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, такта яру, кирпеч сугу, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Илья чиркәве, земство мәктәбе (1883 тә ачыла), 10 җил тегермәне, 2 тимерчелек, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 10 нан артык вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2376 дис. тәшкил итә. 1912 дә һөнәр уч-щесе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 87, 1782 дә — 249 ир-ат; 1859 да — 1357, 1897 дә — 1880, 1908 дә — 2064, 1920 дә — 2109, 1926 да — 1947, 1938 дә — 1598, 1949 да — 1277, 1958 дә — 1375, 1970 тә — 1174, 1979 да — 935, 1989 да — 657, 2002 дә — 455 кеше.

*Әд.:* Есть на Волге городок ... (из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана). К., 2004.

**МОНАСТЫ́РЬ КРӘСТИЯННӘРЕ́**, монастырьларга беркетелгән җирләрдә яшәгән, феодаль бәйлелектәге крәстияннәр катлавы. Киев Русенда 11 йөздән билгеле. 15 йөз ахырында — 17 йөзнең 1 нче яртысында монастырь биләмәләрендә крепостной хокук һәм барщина хуҗалыгы киң таралыш ала. Аерым феодал биләмәләрендәге крәстияннәр б-н чагыштырганда, М.к. азрак изелә, шул сәбәпле монастырь җирләре тизрәк үзләштерелә һәм эшкәртелә, монастырьларның саны һәм биләмәләре арта бара. 17 йөз уртасына дәүләттәге эшкәртелә торган җирләрнең һәм барлык крәстияннәрнең чиреге чамасы чиркәү кулында була, бу хәл хакимияттә дә, феодалларда да ризасызлык тудыра. 1649 елгы Кануннар мәҗмугасы чиркәү учреждениеләренә яңа җирләр алуны тыя. 18 йөз башыннан, самодержавиенең ныгый баруы б-н бәйле рәвештә, монастырьларның крәстияннәр өстеннән адм. һәм икътисади хакимлеге чикләнә, М.к.нә зур салымнар салына, алар дәүләт файдасына өстәмә йөкләмәләр үти. 1764 тә чиркәү җирләре секуляризацияләнә, М.к. дәүләт крәстияннәренең аерым категориясенә кертелә.

Элекке Казан ханлыгы җирләрендә монастырь биләмәләре 1557 дән барлыкка килә.

1646 га Казан өязендә ир затыннан булган 2 меңнән артык монастырь крәстияне исәпләнә, Зөя өязендә дә М.к. якынча шулкадәр була. 17 йөзнең 2 нче яртысында үзләштерелә башлаган Кама аръягында, андагы биләмәләрне киңәйтү тыелганлыктан, монастырь җирләре булмый. 1740 елгы җанисәп нәтиҗәләре буенча Казан, Зөя, Чабаксар, Царёвококшайск, Сембер, Сызрань һәм Уфа өязләрендәге ревизиягә кертелгән 12 мең крәстиян Казан епархиясе монастырьлары карамагында тора. Зөядәге Успение (6045 җан) һәм Казандагы Спас-Преображение (1606 җан) монастырьлары иң эре җирбиләүчеләр булып саналалар. М.к., башлыча, руслардан була, алар авыллардагы рус халкының өчтән берен тәшкил итә. Монастырь җирләрендә Мамадыш, Югары Ослан, Биектау, Питрәч кебек зур авыллар барлыкка килә.


*Әд.:* Покровский И.М. К истории Казанских монастырей до 1764 года. К., 1902; Булыгин И.А. Монастырские крестьяне России в первой четверти XVIII века. М., 1977.

*Е.В.Липаков.*

**МОНАСТЫРЬЛА́Р** (грек. monastḗrion — дәрвиш хөҗрәсе), 1)бердәм яшәү кагыйдәсе (устав) кабул иткән монахлар һәм монашкалар, буддачылар яки христианнар җәмгыяте; 2)дини җәмгыять урнашкан биналар комплексы. Казан төбәгендә беренче М. 1552 елдан соң әүвәл шәһәрләрдә барлыкка килә; православие монахларының ныгытылган авыллары һәм Урта Идел буендагы рус булмаган халыклар арасында христиан динен таратучы дини үзәкләр буларак оешалар. М. башта агач диварлар б-н әйләндереп алына; 17 йөз уртасыннан алар манаралы таш диварлар б-н тотып алына башлый. Таш койма эчендә, кагыйдә буларак, кирпеч-таштан собор һәм чиркәүләр, ашханә, торак, дәваланү һәм хуҗалык корпуслары төзелә. М.га терлек абзары, буа, җиләк-җимеш, яшелчә бакчалары булдыру хокукы бирелгән, шуңа күрә аларның терр-яләре еш кына эчке койма б-н яшәү һәм хуҗалык зоналарына бүленгән. Монастырь зиратлары собор яки чиркәүләрнең берсе янында була. Казандагы иң зур һәм билгеле М.: *Казан Богородица хатын-кызлар монастыре, Успение ирләр монастыре* (Елантау) һәм *Кизик ирләр монастыре*. Торак пунктлардан еракта урнашкан М. пустынь дип аталган. 20 йөз башында ТР терр-ясендә 16 М., ш.и. *Раифа Богородица пустыне*, *Макарий монастыре*, *Седмиозёрный пустыне* эшләгән, пустыньнарга исем үзәк храм яки дәрәҗәле престолга карап бирелгән. Кайвакыт М. исемендә урындагы топономика чагылыш тапкан. 1930 еллар башыннан М. эшләүдән туктый. 1990 елларда алар кабат торгызыла. 2007 елга Татарстанда 7 ирләр (Кизик, Казан Богородица һәм Казан Иоанн Предтеча; Раифа; Седмиозёрный, Макарий; Зөядә Успение) һәм 3 хатын-кызлар (Казанда Успение, Елантау; Зөядә Иоанн Предтеча) монастырьлары эшли.

*Х.Г.Надыйрова.*

**МОНАСЫ́ЙПОВ** Алмаз Закир улы (11.7.1925, Казан — 22.7.2008, Мәскәү), композитор, дирижёр, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1969, 1987), ТРның халык артисты (2000). 1950 елда Казан консерваториясен (виолончель, А.Броун классы һәм композиция, А.Леман классы), 1964 тә симф. дирижёрлык буенча ассистентура-стажировка (И.Шерман классы) тәмамлый. 1959–70 тә Татар опера һәм балет театрында дирижёр. А.Даргомыжскийның «Су кызы» («Русалка»), Ш.Гуноның «Фауст», Дж.Вердиның «Леньяно янындагы сугыш» («Битва при Леньяно», С.Прокофьевның «Дуэнья», М.Мусоргскийның «Борис Годунов», Д.Шостаковичның «Катерина Измайлова», Н.Җиһановның «Җәлил», «Түләк һәм Сусылу» һ.б. операларны сәхнәләштерүдә катнаша. 1970–71 дә Татар филармониясе симф. оркестры дирижёры; 1968–72 дә Казан консерваториясендә укытучы (композиция классы). Укучылары арасында — Ш.Шәрифуллин, А.Миргородский, А.Корепанов, Л.Чиркова, Д.Хәсәншин. М.ның күп планлы һәм күптөрле жанрдагы иҗатын симф., камера-инструменталь һәм вокаль әсәрләр, драма спектакльләренә язылган музыка тәшкил итә. М. — танылган композитор-симфонист. Бу жанрга караган 4 симфониясе (Икенче — «Муса Җәлил» симф.-поэмасы, аның музыкасына 1971 дә балетмейстер Д.Арипова тарафыннан Татар опера һәм балет театрында «Үлмәс җыр» балеты куела һәм Дүртенче — «Дастан»), «Бәйрәм бүген!» һәм «Идел-йорт», «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» симф. поэмалары милли симфонизмның яңа сәхифәләрен ача. М.ның симф. әсәрләре б-н татар музыкасына сәнгати образлылыкның трагик драматургия фабуласы һәм драматик фикерләү алымнары, муз.-тематик өлкәдәге сатира-гротеск б-н бәйле яңа системасы килеп керә. Композитор, яңа темаларга тирән мәгънә салып, муз. материалны эшкәртүдә яңа алымнар кулланып, үзен зур симф. формалар иҗат итү остасы буларак таныта. Ул музыкаль тел чараларын, бигрәк тә пентатоник фикерләү системасында гармоник лад моделен сизелерлек яңарта. Аның әсәрләре эчтәлеге ягыннан тирән концептуаль, күптөрле ассоциацияләр тудыра. Композиторның иҗат биографиясендә вокаль әсәрләр аерым сәхифә булып тора. Аның күп җырлары татар музыка сәнгатенең алтын фондына кергән. Моңлылык, ирекле формалар, шигъри сөйләм б-н көйлелекнең ярашуы, импровизация — аларның үзенчәлекле сыйфатлары. Композитор иҗатында «Тукай аһәңнәре» вокаль-инструменталь поэмасы аерым урын тота, анда авторның оригиналь музыка теле, татар халык җырлары интонациясе, Шәрекъ мотивлары һәм ритмнарының тәэсирлелеге, джаз стилистикасы элементлары һәм гадәти булмаган инструментарийлар бергә үрелгән. М. татар музыкасының традицион интонация өлкәсен шактый киңәйтә. Иҗатында бәет һәм мөнәҗәт интонацияләрен, «китапча көйләү»нең киң мөмкинлекләрен файдалана. Бу иҗади юнәлеш Икенче һәм Дүртенче симфонияләрендә, күпләгән вокаль-инструменталь әсәрләрендә, фольклор музыкасы ансамбле өчен язылган «Чал Болгардан килгән аһәң-хикмия» сюитасында да дәвам итә. Композитор керәшен татарлар муз. культурасын яңача ача, фольклор үрнәкләре җирлегендә «Керәшен моңнары» концерт рапсодиясен иҗат итә. М. иҗаты «милли композитор» төшенчәсен күпкә үзгәртә. Аның музыкасында татар моңы бөтен бер төрки дөньяның аерылгысыз өлеше булып тора. Композитор иҗатының үзенчәлеге Шәрекъ мөселманнары музыкасы интонациясен һәм ритмнарын гамәлгә кертүдә чагыла. Интонация б-н баетылган тематизм, яңача җырланган орнаментика, әсәрләрне ритмик оештыру, инструментовка алымнары, импровизация элементлары, пентатоник көйләр б-н табигый кушылып, М.ның әсәрләренә аерым үзенчәлек бирә. Композитор иҗатында Шәрекъ элементлары б-н беррәттән Европа традицияләре дә аерым урын алып тора. Европага хас музыка жанрлары: скрипка һәм симф. оркестр өчен концерт-серенада, көймәчеләр җыры (баркарола), Өченче симфониядәге испан биюе (пассакалья) һәм сицилиана, «Тукай аһәңнәре» поэмасындагы испан биюе автор тарафыннан бик киң һәм табигый рәвештә файдаланыла. М. музыкасында барокко чоры б-н бәйләнеш, симф. әсәрләрдә полифоник техника, орган, вокализ (И.С.Бахның клавир прелюдиясенә «Ave, Maria») куллану аеруча көчле сизелә. М. иҗатына хас икенче интонацион өлкә — джаз. Джаз интонацияләре, ритм һәм гармонияләре аның музыкасына кабатланмас төсмерләр, динамика, энергия, оригинальлек бирә. М.ның инструменталь джаз композицияләре (беренчеләре О.Лундстрем җитәкләгән оркестр өчен иҗат ителә), ш.у. күпсанлы вокаль музыка әсәрләре әлеге стилистика б-н сугарылган. Тулаем алганда, композитор үзенең иҗатында гомумкешелек мәдәниятенең сәнгать дөньясын чагылдыра һәм аңа табигый рәвештә татар халкының милли



А.З.Монасыйпов.



А.З.Монасыйпов Казан консерваториясенең актлар залында. 70 нче еллар.

муз. традицияләрен кертә. М.ның иҗади ачышлары Ш.Шәрифуллин, М.Шәмсетдинова, Р.Кәлимуллин, ш.у. Татарстанның күпләгән башка композиторлары иҗатына да зур йогынты ясый. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1991).

Төп әсәрләре: симф. әсәрләр — дүрт симфония (1963; «Муса Җәлил», 1971; 1974; «Дастан», 1978, симф.-поэма), симф. оркестр өчен балет сюитасы (1960), симф. оркестр һәм скрипка өчен концертино-серенада (1979), «Бәйрәм бүген!» (1975), «Идел-йорт», (1994), «Салих Сәйдәшевкә музыкаль бүләк» (1990), Казанның 1000 еллыгына багышланган «Бәйрәм увертюрасы» (2005) симф. поэмалары; вокаль-инструменталь әсәрләр — баритон һәм кыллы бәрмә уен кораллары, электр гитаралары ансамбле, фортепиано һәм орган өчен Г.Тукай шигырьләренә «Тукай аһәңнәре» вокаль-симф. поэмасы (1975), тенор, сопрано һәм камера оркестры өчен халык сүзләренә «Керәшен моңнары» концерт-рапсодиясе (1998), фольклор музыкасы ансамбле өчен С.Бакыргани, Г.Кандалый шигырьләренә, халык сүзләренә «Чал Болгардан килгән аһәң-хикмия» сюитасы (2002), тенор һәм симф. оркестр өчен Ә.Атнабаев шигырьләренә «Атнабай дөньясына сәяхәт» вокаль-симф. поэмасы (2006); камера-инструменталь әсәрләр — скрипка һәм фортепиано өчен соната (1954), гобой һәм кыллы оркестр өчен ария (1970), өч флейта һәм арфа өчен камера концерты (1979), фортепиано цикллары — «Биш лирик күренеш һәм марш» (1972), «Мозаика» (1975), «Бизәкләр» (1981), виолончель, скрипка һәм фортепиано өчен пьесалар, эстрада оркестры өчен әсәрләр; Лопе де Веганың «Белисса шуклыклары» («Проделки Белиссы», 1963), Т.Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» (1976), А.Гыйләҗевнең «Югалган көн», «Китмәгез, тургайлар» (1977), Н.Исәнбәтнең «Идегәй» (1994) пьесалары буенча куелган драма спектакльләренә музыка, документаль фильмнарга музыка; 300 дән артык җыр һәм романслар һ.б.

*Әд.:* Алмазова А.А. Алмаз Монасыпов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Губайдуллина Г.Б. Родное в памяти и сердце // Казань. 2005. № 6; Дулат-Алиев В.Р. Татарская музыкальная литература. К., 2007.

*Г.Б.Гобәйдуллина.*

**МОНАСЫ́ЙПОВ** Вахит Сабит улы (20.12.1928, Актүбә ш., Казакъстан ССР), язучы. Татар һәм рус телләрендә яза. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1971). 1959 елга кадәр Актүбәдә яши, паровоз депосында слесарь, Көнбатыш Казакъстан геол. экспедициясе коллекторы, өлкә радиосында хәбәрләр челтәре җитәкчесе, «Ленин алмашчылары» («Ленинская смена») яшьләр г-тасында махсус хәбәрче булып эшли. 1959 дан Казанда, 1969 га кадәр «Чаян» ж-лының фельетоннар бүлеген җитәкли. 1980 дә Әстерханга китә. Аеруча юмор һәм сатира өлкәсендә иҗат итә. Әсәрләре Казанның «Чаян», «Казан утлары», «Сөембикә», «Ялкын» ж-лларында, Мәскәүнең «Крокодил», «Смена», «Наш современник», Польшаның «Карусель», Чехиянең «Рогач», Венгриянең «Лудаш мати» ж-лларында басыла. М.ның җанлы, тапкыр телле сатирик хикәяләре, фельетоннары һәм юморескаларында кешегә хас кимчелекләр, җәмгыять тормышындагы тискәре күренешләр көлкегә алына. «Сак булыгыз» (1965), «Көлке — гөнаһ түгел» («Смеяться не грешно», 1967), «Кешеләр арасындагы кеше» («Человек меж людей», 1972), «Күктән иңгән бәхет» («Счастье с неба», Волгоград, 1981), «Усал юморист» («Злой юморист», 1988), «Соңгы ачы көлчә» («Последняя горькая лепёшка», Волгоград, 1990) хикәяләр җыентыклары авторы. Балалар өчен язылган китапларына («Сәләхетдин бүреге», 1967; рус телендә 1976; «Тайга печән кем сала?», 1970) кергән әсәрләрендә автор нәни геройларының ялкаулык, дорфалык, саранлыгыннан көлүдән тыш, аларга яшел аптеканың байлыклары, чәчәкләр сәгате һ.б. турында сөйли. М.ның хикәяләре башкорт, мари, кыргыз, украин, казакъ, алман һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.

*Г.М.Габделхакова.*


**МОНАСЫ́ЙПОВ** Габделгазиз (1888 — 1918, Ташкент), җәмәгать эшлеклесе, язучы. 1906–08 елларда Көнчыгыш Төркестанда, уйгыр халкы арасында яши. 1911 дән Казанда. 1911–14 тә «Йолдыз» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында хәрби хезмәткә алына. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң милли азатлык хәрәкәтенә актив кушыла, сул канат лидерларының берсе. 1917 нең маенда Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае (Мәскәү) эшчәнлегендә катнаша, мөселман хәрби берләшмәләре булдыру турында доклад ясый. 1917–18 дә Мөселман хәрби ком-ты (Казан) рәисе урынбасары, соңрак рәисе, Хәрби Шураның башкарма ком-ты әгъзасы. Бер үк вакытта «Безнең тавыш» г-тасын оештыручы һәм аның беренче мөхәррире. 1918 нең мартында Мөселман революцион штабы рәисе. Татар отрядлары («тимер дружиналар») оештыру б-н җитәкчелек итә (к. *Болак арты республикасы*). «Таранчы кызы, яки Хәлимәнең беренче мәхәббәте» романы (1918), «Өзелгән өмет» повесте (1918), «Имчеләр корбаны» (1912), «Ышанычсыз юлга бер адым» (1915) драмалары авторы.

*Д.М.Госманова.*

**МОНАСЫ́ЙПОВ** Камил Хәмит улы (16.7.1950, Казан), альтчы, педагог, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), ТРның халык (1999), РФнең атказ. артисты (2005), проф. (2002). Гнесиннар исем. Дәүләт музыка-пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Мәскәү хәрби округы ансамбле артисты. 1975 елдан Казанда, музыка уч-щесендә һәм консерваториядә (2004 тән альт, виолончель һәм контрабас каф. мөдире) укыта. Бер үк вакытта, 1979 дан, Казан консерваториясенең кыллы квартеты составында (1996 дан ТР Дәүләт квартеты) Россиядә һәм чит илләрдә (АКШ, Япония, Бөекбритания, Германия, Франция, Италия, Нидерланд, Чехия, Финляндия, Төркия, Һиндстан, Австралия һ.б.) чыгышлар ясый; халыкара «Мәскәү көзе», «Төньяк Пальмира», «Гаудеамус», «Европа-Азия»,



К.Х. Монасыйпов.



Ш.Х. Монайсыпов.

«Яңа күчмә иҗат» муз. фестивальләрендә катнаша. М. виртуоз башкару техникасына ия, аның уйнау стиле күтәренке, тәэсирле, үзенчәлекле тавышы б-н аерылып тора. Күп кенә илләрдә эшләүче 50 дән артык музыкант әзерли. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1987) һәм ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре (2002) лауреаты.

*Ш.Х.Монасыйпов.*

**МОНАСЫ́ЙПОВ** Шамил Хәмит улы (31.10.1944, Днепродзержинск ш.), скрипкачы, педагог, сәнгать фән. канд. (1983), проф. (1999), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1983), ТРның халык (1999), РФнең атказ. артисты (2005). 1968 елда Гнесиннар исем. Дәүләт музыка пед. ин-тын (А.Марков классы) тәмамлый. 1968–71 дә Татар филармониясендә солист, Казан музыка уч-щесендә укытучы. 1970 тән Казан консерваториясендә (1992–2000 дә татар традицион башкару сәнгате каф. мөдире, 2002–03 тә татар музыкасы каф. мөдире, 2004 тән скрипка каф. профессоры) укыта. Россиядә һәм чит илләрдә эшләүче 100 дән артык скрипкачы тәрбияли (алар арасында халыкара һәм төбәк конкурслары лауреатлары Р.Сафин, А.Зәйнуллин бар). 1979 да Казан консерваториясенең кыллы квартет ансамблен оештыра һәм җитәкли, ул 1996 да ТР Дәүләт квартеты статусын ала (1 нче скрипка). Татар халкының музыка сәнгате тарихына караган 50 дән артык фәнни хезмәт, музыка дәреслекләре (ш.и. татар музыкасы материалына нигезләнеп язылган «Яшь скрипкачы» (1–2 кисәк, 1977–78), «Беренче адымнар» (1986) исемле беренче хрестоматияләр һ.б.), скрипка өчен ноталы әсәрләр җыентыгы авторы. Камера ансамбле составында солист буларак, Россиядә һәм чит илләрдә (АКШ, Япония, Бөекбритания, Германия, Франция, Италия, Нидерланд, Чехия, Финляндия, Төркия, Һиндстан, Австралия һ.б.) актив концерт эшчәнлеге алып бара. Халыкара «Мәскәү көзе», «Төньяк Пальмира», «Гаудеамус», «Европа-Азия», «Яңа күчмә иҗат» музыка фестивальләрендә катнаша.

М.ның иҗаты ихласлыгы, көчле хислелеге, тәэсирлелеге һәм техник камиллеге б-н җәлеп итә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1987) һәм Г.Тукай исем. Дәүләт бүләкләре (2002) лауреаты.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МОНА́ХОВ** Валентин Николаевич (12.7.1932, Украина ССРның Енакиево ш. — 18.10.2006, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1968), РФА акаде-

мигы (2003, 1991 елдан мөхбир әгъза). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли (бүленеп, 1958–61 дә Казан авиация ин-тында), 1964 тән оборона пр-тиесендә (Казан). 1966 дан РФА Себер бүлегенең М.А.Лаврентьев исем. Гидродинамика ин-тында, проф. (1968), лаб. мөдире (1970 тән) һәм бер үк вакытта Новосибирск ун-тының теоретик механика каф. мөдире (1966 дан). Хезмәтләре тоташ тирәлекләр механикасы модельләрен теоретик анализлауга, матем. физикага, комплекслы анализга, квазиконформ чагылдыруларга карый. М. чикләре ирекле (билгесез) булган тоташ тирәлекләр механикасының бик күп мәсьәләләре куелышының төгәллеген исбатлый; ике фазада фильтрлашуның өч үлчәнешле модельләрен матем. нигезли һәм бу процессның яңа модельләрен тәкъдим итә; чагылдырулар классында автоном булмаган дифференциаль тигезләмәләрнең (аерым алганда, Эйлер һәм Лагранж үзгәрешлеләре кергән рәвешүзгәртүләрнең) тотрыклылыгын тикшерә; үзле сыеклыкның төрле юнәлешле агымнарының иярүчәнлеген төгәл куелышта өйрәнә. Әлеге тикшеренүләре нигезендә М. җитәкчелегендә гидродинамиканың күп кенә гамәли мәсьәләләре: ташкүмер катламнарын газсызландыру һәм нефть ятмаларын эшкәртү, газларның соплода тавыш тизлегенә якын агымнары турындагы һ.б. мәсьәләләр хәл ителә. Нефть чыгаруның компьютерлы системасын төзү һәм гамәлгә кертүдә катнаша (1993–2000, Казакъстан Респ-касы). Акробатика буенча СССРның спорт остасы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Краевые задачи со свободными границами для эллиптических систем уравнений. Новосиб., 1977; Краевые задачи механики неоднородных жидкостей. Новосиб., 1983 (автордаш); Гидродинамика нефтедобычи. М., 2003 (автордаш); Краевые задачи и псевдодифференциальные операторы на римановых поверхностях. М., 2003 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**МОНА́ШЕВО** (Вандэмо) авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 23 *км* төньяктарак, Бужәй елгасы буенда. 2010 елда 353 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөз ахырында Иске Юмья авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Вандэм авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, капчык туку, олаучылык б-н шөгыльләнә. 1879 елгы мәгълүматларга караганда, ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне эшли; 1903 тә земство мәктәбе ачыла. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 975,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1920 дән Вотяк автономияле өлкәсендә. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1836 да — 135, 1859 да — 208, 1887 дә — 276, 1905 тә — 339, 1920 дә — 349, 1926 да — 389, 1938 дә — 407, 1949 да — 337, 1958 дә — 311, 1970 тә — 341, 1979 да — 327, 1989 да — 325, 2002 дә — 358 кеше.

**МОНГО́Л ИМПЕ́РИЯСЕ** (Йеке Монгол Олыс), 13 йөзнең 1 нче яртысында *Чыңгыз хан* һәм аның варислары яулары нәтиҗәсендә дәүләт булып оешкан мәмләкәт. Бөек ханнардан Үгәдәй (1229–41), Гөек (1246–48) һәм Мөнке (1251–59) идарә иткәндә, Төньяк Евразиянең Монголиядән төньякка таба Байкал күленә кадәрге, Төньяк һәм Үзәк Кытайның Янцзы елгасына кадәрге, Корея, Үзәк һәм Урта Азия, Кавказ арьягы, Һинд елгасына кадәрге Алгы Азия, Палестинага кадәрге Якын Көнчыгыш, ш.у. Дунай елгасына кадәрге Көнчыгыш Европа (Идел буе Болгар дәүләте, Дәште Кыпчак, рус кенәзлекләре һ.б.) терр-яләрен үз эченә ала. Башкаласы — *Каракорым* шәһәре. М.и. бөек ханга (каганга) формаль рәвештә буйсынулы чыңгызый ханнар хакимлегендәге олысларга бүленә. Бу җирләр Чыңгыз хан нәселенең уртак биләмәсе санала, ләкин аның варисларының һәркайсы аерым биләмә — *олыс* хакиме була. Олыс ханнары каган исеменнән акча сугыралар һәм аңа ясак түләп торалар. М.и.нең бөтен терр-ясе буенча 1257–59 елларда җан исәбе алу уздырыла һәм ясак нормалары билгеләнә, империядә уртак кануннар — Чыңгыз хан ясасы гамәлдә була, уртак юл һәм почта хезмәте (ям — җам системасы) эшли. 13 йөзнең 2 нче яртысында, тәхет өчен барган көрәш һәм бөек хан хакимияте көчсезләнү нәтиҗәсендә (Арык Буга, соңрак Хайду б-н Хубилай арасындагы каршылык чоры — 1260–1300 еллар), Хубилай чыңгызыйлар ризалыгыннан башка үзен бөек хан дип игълан итә. Бу хәлләр олыс хакимнәре арасында аерымлануга омтылышны көчәйтә. 1269 да Талас елгасы (Көнчыгыш Казакъстан) буендагы корылтайда Алтын Урда, Чагатай һәм Һулагу олыслары ханнары, Хубилай хакимлеген танымауларын белдереп, Хайдуны бөек хан дип игълан итәләр, тәхеткә күтәрәләр. Шушы вакыйга М.и.нең Алтын Урда дәүләтенә һәм башка төрки-монгол дәүләтләренә таркалуына сәбәп була. 1271 дә бөек хан Хубилай башкаланы Каракорымнан Пекинга (Ханбалыкка) күчерә, шуның б-н Монголия һәм Кытай җирләрендәге яңа — Юань империясенә нигез салына.

*Әд.:* О с с о н К. (d'Ohsson). История монголов: от Чингизхана до Тамерлана. Иркутск, 1937; Я к у б о в с к и й А.Ю. Монгольская империя // Ист. журн. 1940. № 3; Татары-монголы в Азии и Европе. М., 1977; Д а л а й Ч. Монголия в XIII–XIV веках. М., 1983; К ы ч а н о в Е.И. Жизнь Темучина, думавшего покорить мир: Чингиз-хан. Личность и эпоха. М., 1995; Х р а п а ч е в с к и й Р.П. Военная держава Чингисхана. М., 2004; У э з е р ф о р д Дж. Чингисхан и рождение современного мира. М., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**«МОНГО́Л-ТАТА́Р ИЗҮЕ́»** («Монголо-татарское иго»), 13–15 йөзләрдә рус кенәзлекләренең *Алтын Урда* ханнарына икътисади һәм сәяси буйсынулы мөнәсәбәтен тасвирлау өчен рус мәдәниятендә һәм историографиясендә традицион кулланылган төшенчә. Рәхимсез җәберләү, кысу, баскынчылык мәгънәсендә йөри. «М.-т.и.» термины 14–16 йөзләр чиркәү елъязмалары традициясеннән туа. Библиядә бәян ителгән вакыйгалар («Иоанн Богослов вәхие») һәм эсхатологик текстлар («Мефодий Патарский вәхие») б-н ассоциатив бу традиция нигезендә Русьның монгол ханнары тарафыннан яулануын аңлау һәм аңлату омтылышы ясала. Мәскәү кенәзлеге ныгып, Идел буе Рус дәүләтенә буйсындырылганнан соң (15 йөз ахыры — 16 йөз), православиегә нигезләнгән империячел бердәм держава идеологиясе («Мәскәү — Өченче Рим») формалаша башлый, яңа идеология буенча Русь-Урда мөнәсәбәтләре тарихы «үткәндәге кара чор» итеп күзаллана. 16 йөз — 17 йөз башы тарихи публицистикасында (к. «*Казанский летописец*») ул «татар изүе» тарихи формуласында чагылыш таба, 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында яшәгән рус тарихчылары Н.М.Карамзин, С.М.Соловьёв һ.б.ның хезмәтләрендә тенденциоз тарихи фактлар б-н ныгытылып, кайвакыт «М.-т.и.» яки «татар-монгол изүе» формасында историографик концепция буларак тәкъдим ителә. Әлеге мифологема әдәбиятта, публицистикада һәм дәреслекләрдә киң таралыш ала. 18–19 йөзләрдә ул чит илләрнең гыйльми даирәләрендә, еш кына сәяси максатларда — Россиянең артта калганлыгын исбатлау өчен кулланыла. 1930–40 елларда, сталинизм һәм империячел идеология яңарылышы чорында, рус историографиясендәге традицион мифологемалар б-н бергә «М.-т.и.» төшенчәсенә марксизм-ленинизм классиклары биргән бәяләр киң әйләнешкә кертелә: «Бу золым изү б-н бергә аның корбанына әверелгән халыкны кимсетә, җанын киптерә» («Это иго не только давило, оно оскорбляло и иссушало душу народа, ставшего его жертвой». К.Маркс); «империалистлар ... штык очларында яңа — иске татар золымыннан һич кенә дә яхшырак булмаган мәсхәрәле золым алып киләләр» («империалисты ... несут на своих штыках новое позорное иго, которое ничуть не лучше старого татарского ига». И.В.Сталин). Тоталитар хакимият шартларында мондый бәяләмәләр сов. историографиясендә «М.-т.и.» турында берьяклы гына күзаллау барлыкка килүгә зур йогынты ясый. Чит илләр историографиясендә «М.-т.и.» теориясе Г.В.Вернадский һәм аның фикердәшләре тарафыннан тәнкыйть ителә. 1990 еллардан башлап, яңа концепцияләр һәм фактлар нигезендә, әлеге мифологема Россиянең фәнни даирәләрендә анализлана һәм тәнкыйть объектына әверелә бара. Чит ил галимнәре һәм Россия тарихчыларының тикшеренүләрендә Алтын Урданың рус дәүләтчелеге үсешендәге роле төрле яклап карала, рус кенәзләре һәм Алтын Урда ханнары арасындагы элек күзаллаганнан күпкә катлаулы мөнәсәбәтләр ачыклана, Русьта Мәскәү гегемонлыгы урнашу процессы өйрәнелә, 13–15 йөзләр Русенең чын тарихын «татар изүе» мифологемасына

кайтарып калдыруның ялгыш булуы исбатлана.

*Әд.:* Насонов А.Н. Монголы и Русь. М., 1940; Татаро-монголы в Азии и Европе. М., 1978; Каргалов В.В. Конец ордынского ига. М., 1980; Назаров В.Д. Свержение ордынского ига на Руси. М., 1983; Соловьёв С.М. Сочинения. М., 1988–89. Кн. 2–3; Кучкин В.А. Русь под игом: Как это было? М., 1991; Карамзин Н.М. История государства Российского. М., 1992–93. Т. 4–5; Вернадский Г.В. Монголы и Русь. Тверь, 1997; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2000; Halperin Ch.J.The Tatar Yoke. Columbus (Ohio), 1986; шул ук. Russia History. Bloomington, 1987; Hartog L. Russia and the Mongol Yoke. L., 1996.

*И.Л.Измайлов.*

**МОНГО́Л-ТАТАРЛА́Р**, 19 йөз башыннан Россиядә элекке *Монгол империясе* халкына, монгол халыкларына һәм төрки-татарларга карата кулланылган атама. Беренче мәртәбә 19 йөз тарихчысы П.Наумов хезмәтләрендә очрый, шуннан фәнни әйләнешкә кереп китә. 19 йөздә сирәк кулланыла. Сов. историографиясендә һәм уку-укыту әдәбиятында киң кулланылыш ала (ешрак татар-монголлар формасында йөртелә). Чит ил тарихчылары тарафыннан кулланылмый диярлек. Охшаш термин — «мэн-да» (М.-т.) — 13–14 йөзләр кытай историографиясендә төньяк кучмә халыкларның гомуми атамасы буларак кулланылып ала, ләкин акрынлап башка төшенчәләр б-н алыштырыла.

*Әд.:* Наумов П. Об отношениях российских князей с монгольскими и татарскими ханами (1224–1480). СПб., 1823; Мэн-да бэй-лу («Полное описание монголо-татар»). М., 1975; Гольман М.И. Изучение истории Монголии на Западе (XIII — середина XX вв.). М., 1988.

*И.Л.Измайлов.*

**«МОНГО́ЛЬСКАЯ ХРЕСТОМА́ТИЯ»**, китап ядкәре, 19 йөз башындагы Казан китап басу үрнәге, укучылар, студентлар өчен монгол әдәбияты буенча беренче ярдәмлек. Шәрекъне өйрәнүче белгеч, Казан ун-тының монгол теле каф. мөдире проф. О.М.*Ковалевскийның* Себергә һәм Пекинга (1828–31) фәнни командировкасы вакытында алынган материаллар нигезендә төзелә. Ул текстны үзе җыя, корректурасын да үзе укый, чөнки ул вакытта Казанда монгол телен белгән хәреф җыючы булмый (хәрефләр Петербург ФА басмаханәсеннән җибәрелә). 1836 елда чыккан 1 нче томда монгол повестьлары, риваятьләр, кыска хикәяләр урын ала. 1837 дә басылган 2 нче томга Тибет, Монголия, Кытайдагы будда дине тарихы буенча фәнгә билгеле булмаган чыганаклардан алынган мәгълүматлар керә. Ковалевский тарафыннан рус телендә төзелгән тарихи, этнографик һәм филол. искәрмәләр һәм күрсәткечләр (сүзлекле, исемле, предметлы) басманы аеруча әһәмиятле итә. Моннан тыш 2 нче томга монгол ел исәбе таблицасы һәм Шакьямуни (Будда) турындагы риваятьләр дә керә. Хрестоматиядә монгол әдәбиятының барлык жанрларыннан да үрнәкләр бирелә. «М.х.»не төзегән өчен, проф. Ковалевскийга тулы Демидов бүләге бирелә, ул Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1837), академигы (1847) итеп сайлана, әмма сәяси сәбәпләр аркасында Николай I галимне акад. дәрәҗәсендә расламый. Ковалевский Мәскәү ун-ты каршындагы Россия тарихы һәм борынгылык җәмгыятенә, Париждагы Азия җәмгыятенә әгъза итеп алына. «М.х.» Россия уку йортларында гына түгел, Берлин ун-тында да монгол телен укытуда нигез булып тора; Көнчыгыш Себернең өяз уч-щеләрендә, Иркутск һәм Нерчинск рухани уч-щеләрендә, Иркутск семинариясендә, Казан руханилар академиясендә дә уку ярдәмлеге буларак файдаланыла, аны Казан, С.-Петербург һәм Харьков ун-тлары китапханәләре алдыра.

*Әд.:* Парамонова Н.Б. Книгоиздательская деятельность Казанского университета в первой половине XIX века: Дис. Л., 1977.

*И.А.Новицкая.*

**«МОНОМА́Х БҮРЕГЕ́»** («Шапка Мономаха»), баш киеме; русларның бөек кенәзләре һәм патшаларының хакимият билгесе буларак танылу алган; 13 йөз ахырында — 14 йөз башында Алтын Урда осталары тарафыннан ясалган, татарларның туйда кия торган баш киеме буларак билгеле.



«Мономах бүреге». Алтын. Асылташлар. Ябыштырма җепкыр. 13 йөз ахыры – 14 йөз башы. Мәскәү Кремленең Дәүләт Кораллар палатасы.

Беренче тапкыр «М.б.» 1340 елларда Мәскәү кенәзе Иван I нең (Калита) милкен санап чыкканда искә алына. Василий III хакимлек иткән чорда бүрекне Киев кенәзе Владимир Мономахка Византия императоры Константин Мономах (ә ул Владимир кенәз туганга кадәр 50 ел элек вафат) бүләк итеп җибәргән дигән риваять туа. Иван III 1498 елда, үзенең оныгы Дмитрийны тәхеткә билгеләгәндә, шушы бүрекне таҗ итеп кидерә. Шул вакыттан башлап, «М.б.» югары хакимлек символы булып кала. Барлык рус патшалары, ш.и. Пётр I дә, тәхеткә утырганда, шушы бүрекне кигәннәр. Пётр I 1721 дә, Россияне империя дип игълан иткәндә, таҗ кидерү йоласын үзгәртә: «М.б.»н тәхеткә утыру йоласының тантаналы йөреше алдыннан алып бара башлыйлар. «М.б.» бер-берсенә беркетү өчен кисек түбәле һәм ян-якларына тишекләр ясалган сузынкы өчпочмаклар формасындагы сигез алтын пластинадан эшләнгән. Эчлеге бәрхет тукымадан. Пластиналар бик нечкә алтын чыбыклар б-н җепкыр һәм бөртекләү техникасында катлаулы орнамент б-н бизәлгән, асылташлар һәм мәрҗәннәр б-н корланган. Маңгайга төшеп торган асылмасы (С.Герберштейн) һәм кучәрле күтәрмәсе булган, алар 16 йөздә хачлы капкачка алмаштырыла, 17 йөздә кеш тиресеннән кайма барлыкка килә.

Н.П.Кондаковтан башланган рус тарих белеме традициясе бүрекнең чыгышы Византиядән дигән фаразда тора; А.А.Спицын (1844–1925) әлеге фикергә каршы килә, ул бүрекнең монгол чорына каравын әйтә, Америка галиме Г.Вернадский да аны Иван I гә Үзбәк ханнан күчкән дип исәпли. Идел буе Болгар дәүләте халкы, Алтын Урда, Кырым, Төньяк Кавказ, Идел-Урал төбәге татарлары һәм аларга тугандаш төрки халыклар (нугайлар, төрекмәннәр, чуашлар һәм башкортлар) сәнгатен характерлаучы яңа археол. һәм этнографик материаллар «М.б.»нә бүтән билгеләмә бирә (М.Г.Крамаровский, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова). Кисек конус рәвешендәге ярымтүгәрәк формалы «М.б.» төрки хатын-кызлар баш киеме — *тәкыягә* (төрекмәннәрдә — тәхья) туры килә; ул чуашларда, удмуртларда, башкортларда очраштыргалый. Маңгай асылмалары һәм тәңкәләр б-н бизәлгән тәкыя нугайларда кызлар баш киеме булып санала. Аның төп бизәкләреннән купба — очлы гөмбәзчек рәвешендәге көмеш күтәрмә (ябалак каурые кую өчен) кыпчак баш киемнәренә хас, аскы ягындагы көмеш асылмалар ярымтүгәрәк бүрекнең үзе кебек, урта гасырлардагы болгарлар традицияләренә карый (10–12 йөзләр). Гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута Алтын Урда шәһәрләрендә «затлы татар хатын-кызлары бүрек очында тавис каурыйлары б-н бизәлгән һәм кыйммәтле асылташлар сибелгән алтын түгәрәк йөрткәннәр», — дип хәбәр итә. *Аксак Тимер* станында Испания илчесе Рюи Гонзалес де-Клавихо әмирнең өлкән хатыны Сараи-Мөлек ханымның баш киемен тасвирлап калдыра: очына өч кызыл якут ташлы «түгәрәк беседка» беркетелгән, асылташлар б-н бизәлгән биек баш киеме, ди. Түгәрәк өстендә очы асылташлар, энҗе-мәрҗәннәр б-н бизәлгән, алтын җеп б-н кош каурыйлары чугына беркетелгән ак солтан — ап-ак каурый күренеп тора.

14 йөз Идел буе һәм Кырым ядкәрләренә хас «М.б.»нең бизәлеше (лотос чәчәге бизәге, ягъни эченә камалган 12 таҗ яфракчыклы һәм аларсыз алтыпочмаклы йолдыз, яфраксыман, үрелмә) һәм җепкыр технологиясе (спиральсыман бизәк каркасының ике ягын да бөтеркә ысулы б-н сулдан уңга таба бөтереп, үсемлек ботагына охшаган бизәк б-н тулыландыру) Алтын Урда зәркәнчелек һөнәре мәктәбенә карый (к. *Алтын Урда сәнгате*). Мондый охшашлыклар Симферополь хәзинәсеннән табылган хатын-кыз баш киемнәре калдыкларында (бизәлеш үрнәкләре, асылташларны беркетү формалары һәм ысуллары), Идел буе Болгар дәүләте шәһәрлекләрендә һәм хәзинәләрендә табылган эшләнмәләрдәге җепкыр технологияләрендә һәм Алтын Урда торевтикасы дип фаразланган «Бохара аелы»нда очрый.

«М.б.»нә Мәскәүнең бөек кенәзләре Үзбәк ханның сеңлесе Кончак (чукындырылганнан соң Агафья) Мәскәү кенәзе Юрий Да-

нилович б-н никахлангач ия булалар. Хәзерге вакытта Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында саклана.

*Әд.:* Т и з е н г а у з е н В. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; К о н д а к о в Н.П. Русские клады. СПб., 1896. Т. 1; С п и ц ы н А.А. К вопросу о Мономаховой шапке // Зап. Отд-ния рус. и славян. археологии Рус. археол. об-ва. СПб., 1906. Т. 8, вып. 1; К р а м а р о в с к и й М.Г. «Шапка Мономаха: Византия или Восток? // Сообщения Гос. Эрмитажа. 1982. вып. 47; С о л о в ь ё в С.М. История России с древнейших времён. М., 1988–89. Т. 3–6; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Короны русских царей — памятники татарской культуры // Казань, Москва, Петербург: Российская империя взглядом из разных углов. М., 1997; Ж и л и н а Н.В. Шапка Мономаха: Ист.-культурное и технол. исслед. М., 2001; Vernadsky. G. The Mongols and Russia. New Haven, 1953.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МО́НСТЕРА** (Monstera), ароидчалар семьялыгыннан күпьеллык лианалар ыругы. 27 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Үзәк Американың дымлы тропик урманнары. Сабагы агачланган, 6 *м* га кадәр биеклектә, өстәмә һава тамырлары ярдәмендә үрмәли, аларның кайберләре стенага, агачка яки башка терәүгә беретү өчен хезмәт итәләр, икенчеләре җиргә кадәр җитәләр һәм тамырланалар. Яфраклары зур (70 *см* га кадәр), куе яшел, озынча түгәрәк, озын сапларда урнашкан. Яшь үсемлекләрнең яфрак пластинкалары бөтен, йөрәксыман, олы үсемлекләрдә — тишекле каурыйсыман-киселмә, яктыда күләгәдәгегә караганда күбрәк телгәләнә (яшь үсемлекләрне еш кына филодендрон б-н бутыйлар). Вак чәчәкләре цилиндрсыман яфрак куентыгындагы юан чәкәнгә җыйналган (бүлмә шартларында сирәк чәчәк ата). Җимеше — күп орлыклы ачык төстәге, 20 *см* га кадәр озынлыктагы җиләк, ашарга яраклы, ананас тәме һәм исе килә. Татарстанда татлы М. (M. deliciosa), Карвинский М.сы (M. karwinskyi), тигезсез янлы М. (M. obliqua) һәм кайбер башка төрләре декоратив бүлмә үсемлеге буларак үстерелә. Ботаклардан яки һава бәбәкләреннән җиңел үрчи. Туры кояш нурларын яратмый, яфракларына су бөркү уңай нәтиҗәләр бирә. 2 ел саен үсемлекне зуррак чүлмәккә күчереп утырталар, ел саен туфракның өске катламын алыштыралар. Туфрак бик дымлы булганда, М. «еларга» мөмкин (махсус авызчык аша дымны чыгара), шунлыктан аны «елак» дип тә йөртәләр.


**МОНУМЕНТА́ЛЬ-БИЗӘЛЕ́Ш СӘНГАТЕ́**, бизәлеш сәнгате өлкәсе; биналарны, скульптура-парк ансамбльләрен, фонтаннарны һ.б.ны бизәү өчен архитектур-фәза мохитендә иҗат ителгән әсәрләр. М.-б.с.нә архитектур һәм скульптур декор (әвәләп ясау, уеп бизәкләү һ.б.), дивар бизәге, мозаика, витраж, гобелен һ.б. керә. Татарстан терр-ясендә сакланып калган элгәреге М.-б.с. әсәрләрен 13–14 йөз Болгар шәһәре архит-расы истәлекләрендә (к. *Болгар бизәлеш сәнгате, Алтын Урда сәнгате*), Казан Кремлендәге таш корылмаларның архитектур фрагментларында (к. *Казан ханлыгы сәнгате*) күрергә мөмкин. 16 йөз уртасыннан башлап, рус М.-б.с.нең төзелүче биналарның экстерьерларын һәм интерьерларын бизәүдә кулланылган таш рельефка уеп бизәк төшерү, диварны фреска б-н бизәкләү (к. *Фреска*), керәч б-н тышлау (пыяласыман ялтыравыклы чынаяк кирпеч б-н бизәлеш кирпечен аралаштырып өю), агачны уеп бизәкләү һ.б. төрләре үсеш ала (Казан Кремлендәге *Благовещение кафедраль соборы*, Гостиный двордагы Никола чиркәве, *Петропавел соборы*, Зөя шәһәрендәге Успение соборы һ.б.). Таштан салынган татар мәчетләре (Казандагы Мәрҗани мәчете, Апанаев мәчете, Зәңгәр мәчет; Кышкар мәчете һ.б.) бизәлешендә (ташка уеп бизәк төшерү, гипс б-н тышлау, чынаяк кирпеч б-н тышланган декор) Европа стильләре йогынтысы сизелә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан эклектика һәм модерн стильләрендә төзелгән рус һәм татар аксөякләре йортлары, җәмәгать биналары бизәлешендә (бизәкле таш һәм кирпеч, гипс б-н әвәләп ясау, дивар бизәге, скульптур рельеф, төсле пыяла) М.-б.с. киң үсеш ала: Казандагы *Дворяннар җыены бинасы*, *Александровлар пассажы*, Кекин йорты, Ушкова йорты (хәзер ТР Милли китапханәсе бинасы), Дәүләт банкы бинасы, *Апанаев йорты*, *Шамил йорты*, Печән базары, Борнай һәм Әҗем мәчетләре һ.б. Казандагы биналарны металл б-н бизәү игътибарга лаек үзенчәлек булып тора: *Чабакса тимерчелек кәсепчелеге* осталары тарафыннан эшләнгән бакча һәм парк коймалары, үтеп йөрү капкалары, шпильләр, балкон һәм баскыч рәшәткәләре, каминнар һ.б. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Кокшан керәч з-ды (хәзерге Яңа Кокшан пос.) идәннәр өчен югары сыйфатлы кафель һәм камин плитәләре җитештерә башлый; алар Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә югары бәя ала, Казан ун-ты, Мәскәүдәге Казан вокзалы, Венадагы (Австрия) Үзәк вокзал һ.б.ның интерьерларын бизәп тора. 20 йөз башында Казандагы күп кенә биналарның Овсяной мозаика-цемент з-ды чыгарган кафель плитәләр б-н тышлануы турында мәгълүматлар бар; ш.у. Казандагы сәүдә биналарын панно һәм эленмә такталар б-н сәнгатьчә бизәү омтылышлары билгеле (мәс., 1913 елда рәссамнар Д.П.Мощевитин һәм С.Г.Кирин Желонкин кафесында дивар бизәкләре иҗат итәләр). 20 йөз башында М.-б.с. кризис кичерә; 1920 елларда В.И.Ленин игълан иткән «монументаль пропаганда» планы уңае б-н аны яңадан торгызу омтылышы ясала. Бу юнәлештә, башлыча, агитацион эчтәлектәге монументаль дивар бизәкләре, дивар паннолары, мозаик, символик-аллегорик композицияләр эскизлары тудырган «*Подсолнечник*», «*ТатЛЕФ*», «*Сулф*» иҗат коллективлары рәссамнары зур роль уйный (К.К.*Чеботарёв*, Ф.П.*Гаврилов*, И.А.*Никитин*, Н.П.Христенко, В.Л.*Лаптев*, Н.В.Пузанов, С.С.Федотов, С.Герштейн һ.б.). Гражданнар сугышы һәм авыр икътисади хәл иҗади башлангычларның күпчелеген тормышка ашырырга комачаулый. 1930–40 елларда М.-б.с.нең мәгълүм төрләреннән татар бизәлеш сәнгате традицияләрен яңарткан биналарга уеп бизәк төшерү һәм әвәләп ясау, гипстан скульптур барельеф эшләү (Казанның Ирек мәйданындагы бәйрәм трибуналары, 1935; Татар акад. театры интерьеры, 1941, рәссам С.С.*Ахун*), дивар бизәге (Татар опера һәм балет акад. театры интерьерларында «Музыка», «Бию», «Рәссам» фрескалары, 1956, рәссам Ч.Г.*Әхмәров*) аеруча үсеш ала. 1960 еллар башында М.-б.с.нең сизелерлек үсеше сов. архит-расында стиль юнәлеше үзгәрү һәм сәнгать алдында яңа бурычлар куелу б-н бәйле. Татарстанда бизәлешендә М.-б.с. әсәрләренә күп урын бирелгән җәмәгать биналары төзелә башлый; социаль заказ таләпләре рәссамнарның киң даирәсе килүенә юл ача; М.-б.с.нең яңа төрләре барлыкка килә: сграффито («Волга» кунакханәсе фасады, 1963, рәссамнар С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков, В.М.Маликов һәм шәһәр яны тимер юл вокзалы фасады, 1967, рәссамнар С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков, В.К.*Фёдоров*; Казандагы хисап-кредит техникумы бинасы, 1967, рәссам С.М.Бубеннов һ.б.), коры штукатуркага бизәк ясау (Казанда Кызыл Позиция урамындагы торак йорт дивары, 1972, рәссам В.К.Фёдоров), сыек пыяла бизәге (Казандагы Яшьләр үзәге вестибюле дивары, 1976, рәссам В.К.Фёдоров), смальта мозаикасы (Казандагы Химиклар мәдәният сарае фасадлары, 1969, рәссамнар С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков, В.К.Фёдоров һ.б.), металл пластика (Химиклар мәдәният сарае (1969) һәм Яшел Үзән шәһәре мәдәният йорты (1972) интерьерларындагы бакырга чүкеп ясалган бизәкләр, 1972, рәссам Е.В.Киселёва; Казандагы Сәүдә үзәге ресторань интерьерларындагы рельеф һәм скульптура, 1977, рәссамнар И.Н.*Башмаков*, Г.В.Богородская), рельеф керәче (Казандагы Яшьләр үзәге, 1976, рәссамнар А.В.Горев, А.С.Маяков, Е.А.Симбирин һәм Чаллыдагы «Татарстан» кунакханәсе фасадларындагы шамот , 1977, рәссамнар Р.М.Вахитов, В.Н.Николаев (к. *Керәч сәнгате*), гипска уеп бизәк төшерү (Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты, 1971 һәм «Акчарлак» рестораны, 1973 (рәссам Е.В.Киселёва, 21 йөз башында сүтелә), диварда агачка уеп бизәк төшерү (Чаллыдагы «Энергетик» мәдәният йорты, 1974 һәм Санэпидстанция бинасы, 1977, рәссам Р.З.Круглякова, Түбән Камадагы 21 нче балалар бакчасы интерьерлары, 1974, рәссам Ә.С.Фәтхетдинов һ.б.), витраж (Казан ун-тының төп бинасы, 1977, рәссам В.К.Фёдоров һ.б.), гобелен (Казандагы Көнкүреш йорты, 1976; Сәүдә үзәге, 1978; к. *Гобелен*).

М.-б.с.нең аеруча зур үсеш чоры 1970 еллар ахыры — 1980 еллар уртасына туры килә. Яңа шәһәрләрдә — Түбән Кама, Чаллы, Әлмәт, Лениногорск, Яшел Үзән һ.б.да — М.-б.с. әсәрләре типлаштырылган проектлар буенча төзелгән җәмәгать биналарына сәнгатьлелек һәм үзенчәлек биреп торалар (мәдәният йортлары, кинотеатрлар, сәүдә һәм ресторан комплекслары һ.б.). Аерым бер төркем материалларны һәм башкару техникаларын файдалануда гомуми үсеш юнәлешләре дә билгеләнә. Мәктәпләрне бизәүдә — керәч мозаика, гипска уеп бизәк төшерү, дивар бизәге; балалар бакчаларында — майолика, мозаика, агачка уеп бизәк төшерү, эре мәдәният объектларында М.-б.с.нең барлык












**Монументаль-бизәлеш сәнгате. Монументаль сәнгать мәкаләләренә.** 1. Казандагы Мәрҗани мәчетенең намаз залы бизәлеше. 1770 еллар; 2. Казандагы Александровлар пассажының төп фасады фрагменты. Арх. Г.Б. Руш. 1886; 3. Казандагы Ленин бакчасы (элеккеге Николай I бакчасы) фонтаны. 1894; 4. С.М. Б у б е н н о в, В.М. М а л и к о в, Р.Ә. К и л д е б ә к о в. «Волга» кунакханәсе фасадындагы «Казан – биш диңгез порты» сграффитосы. 1963; 5. С.М. Б у б е н н о в. Казандагы «Татарстан» кунакханәсе вестибюлендә «Кунакларны болгарларча каршылау» дивар панносы фрагменты. Төсле смальта. 1970; 6. Ә.К. С ә й ф е т д и н о в һ.б. Казандагы С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы түшәме бизәге. Темпера. 1996; 7. Р.Ә. К и л д е б ә к о в. Г. Камал исем. Татар дәүләт акад. театры интерьерындагы «Халык театры» гобелены. 1986; 8. В.К. Ф ё д о р о в. А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музее интерьерында «Казан» витражы. Пыяла. 1987; 9. А.И. Дербилов. Чаллы шәһәре музыка мәктәбе фасадындагы «С. Сәйдәшев» мемориаль рельефы. Мәрмәр. 1994; 10. И.М. Х а н о в. Арча р-ны Яңа Кырлай авылындагы «Шигърият агачы» скульптурасы. Бетон. Смальта. 1986; 11. Р.Х. Н и г ъ м ә т у л л и н а. «Хушлашу» һәйкәле эскизы. Мастика. 1997; 12. Б.И. У р м а н ч е, А.К. З а һ и р о в. Арча р-ны Яңа Кырлай авылы музей комплексындагы «Г.Тукай» скульптурасы. 1976.

төп төрләре синтезы популяр була. Әсәрләрнең образлы телендә, чит илләрдәге алдынгы тәҗрибәне үзләштерү б-н бергә, милли сәнгать традицияләрен үстерү, камилләштерүгә бәйле стильле яңа үсеш юнәлешләре барлыкка килә. 1980–90 елларда респ-каның күренекле рәссам-монументалистлары — В.Я.Акимов, В.В.Анютин, И.Н.Башмаков, Р.М.Вахитов, Х.М.Гыймазетдинов, А.К.Заһиров, И.К.Зарипов, Я.Г.Зиннәтуллин, Г.Н.Капитов, Р.Ә.Килдебәков, В.Ф.Крайников, Р.З.Круглякова, М.М.Минһаҗев, Ш.Г.Нигъмәтуллин, Г.Ф.Новиков, А.А.Пашин, Д.Г.Рәхмәтуллин, Р.М.Сәлахов, К.М.Сафиуллин, Ю.Г.Свинин, В.А.Ткаченко, Ә.С.Фәтхетдинов, В.К.Фёдоров, Х.М.Шәрипов, Р.С.Шиһабетдинов һ.б.

20 йөз ахыры — 21 йөз башы М.-б.с.нең үзенчәлекле ягы — дини корылмаларның архит-ра-сәнгать ансамбльләре барлыкка килү. Шуңа бәйле рәвештә ислам һәм христиан сәнгате традицияләрен үстерүче бай рухлы фәзаи мохит тудыру аерым әһәмияткә ия була. Мәчетләр бизәлешендә (Казандагы «Кол Шәриф», Чаллыдагы «Тәүбә», Әлмәттәге «Ринат», Түбән Кама, Лениногорск һ.б. шәһәрләрдәге җамигъ мәчетләр) М.б.с.нең мозаика, майолика, гипс рельефлары, витраж, чиркәүләрдә майлы дивар бизәкләре, иконостасларда агачка һәм ташка уеп бизәк төшерү (Раифа Богородица монастырендагы Грузия Мәрьям Ана иконасы соборы, Синай б-н Раифада шәһит киткән Изге аталар чиркәве, Казандагы «Умиление» һәм Серафим Саровский чиркәүләре һ.б.) кебек төрләре үсеш ала. Казан метрополитены станцияләре (Тукай, Кремль һ.б.), экспозицияләрдәге дивар язмалары («Казан» милли мәдәният үзәге, ТР Милли музее һ.б.), мемориаль ансамбльләрдәге бизәлеш композицияләренең скульптура б-н синтезы (Казандагы Җиңү паркы, Әлмәттәге мемориаль комплекс һ.б.), мәйданнарны һәм җәяүлеләр урамнарын (Казандагы Г.Тукай мәйданы, Бауман урамы, Лениногорскидагы Тукай урамы) бизәү рәссамнарның иҗат объектлары булып әверелә. Яңа үсеш юнәлешләре — эскиз авторы һәм аны тормышка ашыручы башкаручы-рәссам хезмәтләренең бүленеше, рәссамнар, архитекторлар һәм дизайнерларның уртак эше, Россия төбәкләрендәге татар диаспорасы рәссамнарын җәлеп итү. Хәзерге вакытта М.-б.с. өлкәсендә актив эшләүчеләр — ТР архитекторлары һәм рәссамнары А.Г.Саттаров, А.А.Идрисов, С.Ә.Мамлиева, С.М.Михайлов, В.А.Нестеренко, Р.М.Нургалиева, Ф.Г.Халиков, Н.Т.Хаҗиәхмәтов, Д.Р. һәм Л.В.Мусиннар, Р.В.Сәлахетдинов, шу. Үзбәкстаннан рәссамнар О.Г.Хәбибуллин, Ә.С.Хөснетдинов, Башкортстаннан Р.М.Кадыйров, Р.Миңнебаев, И.Г.Гаянов һ.б. Ш.у.к. *Бизәлеш сәнгате*, *Дизайн*.

*Әд.:* Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; шул ук. Народные художественные традиции в современном монуметально-декоративном искусстве Татарстана. К., 1984; Ахметшина А.К. Архитектура и декор новых мечетей восточного Татарстана // Ислам в Евразии. М., 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МОНУМЕНТА́ЛЬ СӘНГА́ТЬ**, сынлы сәнгатьнең бер төре; сәнгать формасының эреләндерелгән булуы, аерым архитектоник һәм төсле төзелеше б-н аерылып тора. М.с. әсәрләренә нинди дә булса тарихи вакыйгаларны билгеләп үтү өчен төзелгән архит-ра истәлекләре һәм корылмалары; скульптур, мозаикалы (к. *Мозаика, Скульптура*) бизәлешле торак һәм җәмәгать биналары (к. *Нәкышь сәнгате*); күренекле җәмәгать эшлеклеләренә, сугышчыларга, әдәбият һәм сәнгать вәкилләренә, галимнәргә багышланган монументлар; бакча-парк скульптурасы керә. М.с. әсәрләре еш кына архит-ра б-н синтезда корыла.

Татарстан терр-ясендә сакланып калган болгар-татар корылмалары (к. *Болгар бизәлеш сәнгате*, *Алтын Урда сәнгате, Татарстан архитектурасы*) М.с.нең иң борынгы истәлекләренә карый.

16 йөзнең 2 нче яртысыннан М.с. төбәктә рус архит-расы истәлекләрендә үсеш ала. Иң беренче, борынгы традицияләргә туры китереп һәм мәгълүм вакыйгаларның билгеләнеп үтелүе уңаеннан, чиркәүләр һәм монастырьлар төзелә, мәс., 1579 елда *Казан Мәрьям Ана иконасы* табылган урында төзелгән *Казан Богородица хатын-кызлар монастыре* һ.б.. Шулай ук монументаль нәкышь ядкәрләре — дини темаларга багышланган *фрескалар* да чиркәүләр б-н бәйләнгән (Зөядә сакланып калган тиндәшсез 16 йөз үрнәкләре). 18 йөздә Казанда *Петропавел соборы*, император Екатерина II килү хөрмәтенә сыннар б-н һәм уеп бизәлгән триумфаль аркалар төзелә (сакланмаган). 19 йөздә М.с.нең яңа төр әсәрләренә күчеш сыйфатлары күзәтелгән мемориаль корылмалар барлыкка килә: тулы фигуралы сыннар, портрет бюстлар, обелисклар һ.б. Мәс., 1813–23 елларда Казанны алганда һәлак булган Иван IV сугышчылары каберлеге урынында арх. Н.Ф.Алфёров проекты буенча дүрт яктан дорик порталлары һәм киң баскычлары булган, кисек пирамида рәвешендәге һәйкәл куела (к. *Рус гаскәрләре һәйкәл-төрбәсе*). 1847 дә Казан ун-тының ишегалдында скульп. С.И.Тальберг башкаруында Г.Р.Державинга һәйкәл куела. 1931 дә ул сүтелә, 2003 тә скульп. М.М.Гасыймов тарафыннан кабат торгызыла һәм яңа урынга — Лядский бакчасына куела. 1888 дә традицион триумфаль капкалар формасында арх. И.П.Котелов проекты буенча Казан дары з-дының 100 еллыгы хөрмәтенә *Юбилей аркасы* — «Кызыл капка» корыла. 1895 тә Казанда шәһәр думасы урнашкан бина каршындагы мәйданда скульп. В.О.Шервуд проекты буенча *Император Александр II һәйкәле* ачыла (һәйкәл өчен челтәрле рәшәткәне Чабакса осталары әзерли). 1896 да скульп. М.Л.Диллон проекты буенча тууына 100 ел тулу уңаеннан куелган *Лобачевский* Н.И. *һәйкәле* Казанда 19 йөзгә караган портрет бюсты үрнәге булып тора. 1917 дән соң М.с. Ленинның монументаль пропаганда планы һәм РСФСР ХКСның 1918 нең 12 апрелендә игълан ителгән «Патшалар һәм аларның ялчыларына куелган һәйкәлләрне урыннарыннан алып, Россия Социалистик Революциясе һәйкәлләре проектларын эшләү турында»гы Декреты буенча үсә. 1920 елларда Казанда вакытлы (гипстан) монументлар — 1 нче Май мәйданына «Эшче-металлист» (император Александр II һәйкәле алынган пьедесталга) һәм Иске татар бистәсендәге Юнысов мәйданына скульп. В.С.Богатырёв иҗат иткән М.Вахитов бюсты куела. 1924 тә Николай бакчасы Ленин бакчасы итеп үзгәртелә, аның түбәнге һәм өске өлешләре арх. Ф.П.Гаврилов проекты буенча әзерләнгән монументаль баскыч б-н берләштерелә. 1925 тә әлеге бакчаның югары өлешендә В.И.Ленинның тулы фигуралы һәйкәле урнаштырыла (скульп. Н.И.Шильников, арх. Ф.П.Гаврилов). 1920 елларда Казан шәһәре башкарма ком-тының утырышлар залы өчен В.И.Ленин һәм К.Маркс портретларын эшләгән Н.И.Фешин; П.П.Беньков, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова һ.б. рәссамнар станлы нәкышь чаралары ярдәмендә интерьерлар бизиләр. 1930 елларда Казанда М.с. өлкәсендә «Динамо» стадионы капкасын бизәп торучы «Ядрә ыргытучы» һәм «Теннисчы кыз» фигураларын, Киров (хәзер Мәскәү) урамындагы бакча фонтаны өчен Җир шарын күтәреп торучы өч эшче фигурасыннан «Интернационал» аллегорик композициясен иҗат иткән скульп. С.С.Ахун эшли. 1934 тә Куйбышев мәйданында (хәзер Тукай мәйданы) Н.Э.Бауманга (скульп. И.А.Менделевич, арх. Ә.Г.Бикчәнтәев) һәйкәл куела; 1937 дә ул Н.Ершов урамындагы Ветеринария ин-ты бинасы янына күчерелә. Спас, Чистай, Минзәлә шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Бондюг посёлогында (хәзер Менделеев шәһәре), район үзәкләрендә Гражданнар сугышында һәлак булганнарның исемнәре язылган һәйкәл-обелисклар, стелалар барлыкка килә. Сугыштан соңгы елларда М.с. үсешенең яңа этабы башлана. Казанда һәм респ-каның эре шәһәрләрендә, тарихи вакыйгалар һәм күренекле шәхесләр турындагы истәлекләрне мәңгеләштерү б-н бергә, күп кенә кварталларны бизәүче монументаль скульптура да киң тарала. 1950 елларда В.И.Ленинның күпсанлы һәйкәлләре барлыкка килә. Аларның кайберләре хәзер дә сынлы сәнгать әсәрләре буларак әһәмиятле: Казанның Ирек мәйданындагы *Ленин В.И. һәйкәле* (1954, скульп. П.П.Яцыно, арх. А.И.Гегелло), Казан ун-тының төп бинасы үзәк портигы каршындагы *Ульянов Владимир-студент һәйкәле* (1954, скульп. В.Е.Цигаль, арх. В.В.Калинин), Әлмәт (1967, скульп. П.П.Яцыно, арх. Е.И.Кутырев) һәм Алабуга (1981, скульп. А.П.Кибальников, арх. Р.И.Миңнуллин) шәһәрләрендәге В.И.Ленин һәйкәлләре. Сугыштан соңгы елларда сәнгать эшлеклеләренә беренче зур һәйкәл — *Тукай Габдулла һәйкәле* куела (1958, скульп. С.С.Ахун, Л.Е.Кербель, Л.М.Писаревский, арх. Л.Н.Павлов). Бу елларда скульптура б-н беррәттән монументаль нәкышь тә үзенең чәчәк ату чорын кичерә. 1940 елларның 2 нче яртысында аның үсешендә сугыштан кайткан рәссамнар: И.А.Новосёлов, Н.А.Костин, Б.М.Салмин, Г.Д.Нечиталюк катнаша. 1950 елларда М.с. әсәрләрен иҗат итү эшенә рәссамнар А.А.Го-

лубев, С.Ш.Мостафин, А.А.Крымов, Е.А.Макаров, Р.М.Якупова, Л.П.Иванова, Н.В.Родионова һ.б. килеп кушыла. Монументаль хезмәтләрне проектлаштыру һәм гамәлгә куюда Татар сәнгать-җитештерү комб-ты зур роль уйный (к. *Татарстан Республикасы Сәнгать фонды*). 1960–90 елларда М.с.нең шактый зур әсәрләре галереясына Казанда — *Җәлил Муса һәйкәле* (1967, скульп. В.Е.Цигаль, арх. Л.Г.Голубовский), А.М.Бутлеров (1978, скульп. Ю.Г.Орехов), Муллanур Вахитов (1985, скульп. Ю.Г.Орехов) һәйкәлләре, Алабугада *Дурова Н.А. музей-утары* һ.б. керә. Респ-каның күп кенә шәһәрләрендә һәм авылларында Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булган якташлар истәлегенә монументлар урнаштырыла. Казанның әйдәп баручы монументалистлары арасында Казанда һәм ТР районнарында иҗтимагый һәм тарихи әһәмияткә ия вакыйгаларга багышланган скульптур монументлар һәм комплекслар иҗат итүчеләр — В.М.Маликов, А.Х.Габдрәшитов, Н.И.Гаделов, Ә.К.Бәширов, Р.Х.Нигъмәтуллина, В.И.Рогожин. М.с. өлкәсендә милли традицияләрне үстергән архитектур-скульптур һәм бакча-парк ансамбле беренче тапкыр Арча р-нының Яңа Кырлай авылында Б.И.Урманче тарафыннан иҗат ителә (арх. Ш.Н.Фәхретдинов). Казаннан кала, рәссам-архитекторларның шактый зур төркеме (Р.А.Агафонов, В.Я.Акимов, А.И.Дербилов, Ә.К.Заһиров, Я.Г.Зиннәтуллин, Ә.С.Фәтхетдинов, И.М.Ханов, М.Г.Шәйдуллин һ.б.) Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Бөгелмә, Лениногорск, Яшел Үзән шәһәрләрендә туплана. 20 йөз ахырында Казандагы «ВНИИВОЛТ» тәҗрибә-җитештерү з-дында бронза монументлар кою, ш.и. РФнең башка төбәкләреннән һәм БДБ илләреннән алган заказларны үтәү башлана (2000 дә — Мәскәү өлкәсе өчен маршал Г.К.Жуков; 1999 да — Дүшәмбе өчен таҗикларның беренче милли дәүләте оешуга 1100 ел тулу уңаеннан Исмаил Саманиның 9 метрлы фигурасы). 20 йөз ахыры — 21 йөз башында Казан һәм ТРның башка шәһәрләре әһәмиятле тарихи вакыйгаларга, күренекле фән һәм мәдәният эшлеклеләренә багышланган М.с. әсәрләре б-н байый: Казанда — *Фукс К.Ф. һәйкәле* (1996, скульп. А.В.Балашов, И.Козлов), *Урманче Бакый һәйкәле* (1997, скульп. М.М.Гасыймов), *Шаляпин Ф.И.һәйкәле* (1999, скульп. А.В.Балашов), *Казан Кремлен төзүчеләр һәйкәле* (2003, скульп. А.В.Головачёв, В.А.Демченко), Салих Сәйдәшев һәйкәле (2005, скульп. М.М.Гасыймов), *Кол Гали һәйкәле* (2005, скульп. А.В.Балашов, А.М.Миңнуллина); Алабугада — Шишкин И.И. һәйкәле (1991, скульп. Ю.Г.Орехов, А.В.Степанов, арх. С.Н.Куприянов), Марина Цветаева һәйкәле (2002, скульп. А.В.Головачёв, В.А.Демченко, арх. Ф.Ш.Галиев), Д.И.Стахеев һәйкәле (2003, скульп. А.В.Головачёв, В.А.Демченко), Әмир Ибраһим һәйкәле (2007, скульп. М.М.Гасыймов), В.М.Бехтеров һәйкәле (2007, скульп. А.В.Головачёв, В.А.Демченко); Чаллыда — сугышчан хезмәт урыннарында һәлак булган милиция хезмәткәрләренә багышланган һәйкәл (1999, скульп. А.И.Дербилов, арх. В.Н.Нестеренко), Владимир Высоцкий һәйкәле (2004, авторы — В.Н.Нестеренко) һ.б. М.с.нең күпгасырлык үсеш юлында Татарстан шәһәрләренә үзенчәлекле төс бирүче күпсанлы күренекле һәйкәлләр иҗат ителә. Ш.у.к. *Монументаль-бизәлеш сәнгате*.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Древнее и средневековое искусство Среднего Поволжья. Йошкар-Ола, 1975; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; шул ук. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*А.И.Новицкий.*

**МОҢ**, татар халкы рухи мәдәниятенең милли чагылышын, дөньяны тоюның үзенчәлекле сыйфатын, эчке сагыну-юксыну халәтен белдерә һәм төп аһәңнең төсмерләрен уйнатуда чагыла торган атама. М. бигрәк тә музыка, шигърият һәм сынлы сәнгатьтә ачык чагыла.

**МОҢТАҺИ́РОВ** Александр Әбүбәкер улы (21.5.1955, Свердловск өлкәсенең Первоуральск ш.), балет артисты, балетмейстер, педагог, РСФСРның халык артисты (1983). Пермь хореография уч-щесен (1973, педагоглары Ю.Плахт, Л.Мосалова, И.Шаповалов), Чиләбе мәдәният һәм сәнгать ин-тын (1995, балетмейстер белгечлеге буенча) тәмамлый, хореография укыта. 1973–95 елларда Чиләбе опера һәм балет театрында балет солисты, 1995–2000 дә балет труппасының сәнгать җитәкчесе. 2002 дән Мәскәү мәдәният һәм сәнгать ун-тының Ханты-Мансийск ф-лында хореография каф. мөдире. Төп хореографик партияләре: Альберт («Жизель», А.Адан), Зигфрид («Аккош күле», П.Чайковский), Солор («Баядерка», Л.Минкус), Ромео («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Ржевский («Гусар балладасы», Т.Хренников), Касыйм («Анам кыры», К.Молдобасанов), Адәм («Дөньяның яралуы», А.Петров), Тиль («Тиль Уленшпигель», И.Глебов), Тореро («Кармен-сюита», Ж.Бизе — Р.Щедрин), Яшүсмер («Диалоглар», Д.Шостакович), Остап Бендер («Унике урындык», Г.Гладков), Модест Петрович («Анюта», В.Гаврилин) һ.б. М. — югары профессиональлеккә һәм тәэсирле актёр уенына ирешкән биюче. Лирик-романтик рольләрне дә, характерлы, гротесклы рольләрне дә гаҗәеп оста башкара. 1990 елларда чит илләрдә С.Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта» (Бухарест, Румыния), А.Аданның «Жизель» (Мерсин ш., Төркия) һ.б. балетларны куя. СССРның халык артисты Е.Максимовага багышланган Халыкара балет фестивале проекты авторы (2000 нән Чиләбе шәһәрендә ел саен уздырыла). Казанда берничә тапкыр Р.Нуриев исем. Халыкара классик балет фестивале спектакльләрендә катнаша.



А.Ә.Моңтаһиров Альфред роленд ә (Дж. Верди музыкасына «Камелияле ханым» балеты).

*В.Н.Горшков.*

**МОПР**, к. *Революция көрәшчеләренә халыкара ярдәм оешмасы.*

**МОРА́Д МУЛЛА́** (18 йөз), җәмәгать һәм дин эшлеклесе. 1755–56 елгы *Батырша хәрәкәте* бастырылганнан соң, христианлаштыру сәясәтенең йомшаруы шартларында татар җәмгыятенең үсеш юлларын билгеләргә омтыла. М.М. карашларында, «динне төзәтү» һәм дөньяның камил булмавы б-н бәйле рәвештә, яңа пәйгамбәр пәйда булу идеясе әһәмиятле урын алып тора. Аның фикеренчә, яңа пәйгамбәргә бөтен дөнья буйсыначак, көнчыгышта һәм көнбатышта халыклар аңа иярәчәк; көнчелек-хөсетлек, нәфрәт, кайгы-хәсрәт бетәчәк; гөнаһлылар җәзага тартылачак. М.М. Болгар шәһәрен, андагы мәчетне торгызу һәм тагын төзеләчәк җиде мәчет турында яза, мөселманнар алдында торган мәсьәләләрнең хәл ителүен дөньяда хөкем сөргән явызлыкка чик кую б-н бәйли. М.М. раславынча, аның әсәре Иске Гаһед, Псалтырь, Инҗил, Коръәнгә ачкыч булып тора. Мөселман руханилары йөрткән дәрәҗәләрдән баш тартып, ул «иң югары изге», «югары изге», «изге», «кече изге» кебек дәрәҗәләрне әченә алган иерархия баскычы тәкъдим итә. 1760–70 еллар башында Идел буе һәм Урал алды мөселманнары арасында үз карашларын таратырга омтыла. Аның сүзләренчә, Казан һәм Уфа өязе муллаларының күбесе аның сөйләгән-язганнарына колак салалар, үзләренең дә шуңа омтылганнарын дәлиллиләр һәм ул әйткәннәрнең тормышка ашуын телиләр. Мөселман дине башлыкларының бер өлеше М.М. фикерләрен бозык караш дип бәяли. Оренбург губернаторы И.Рейнсдорп М.М.ның хөкүмәткә каршы эш алып барыннан (Кырым ханы һәм Төркия солтаны һ.б. б-н элемтәләр урнаштыру) шикләнә. 1771 дә М.М. һәм берничә яраны кулга алына, Екатерина II боерыгы б-н, тикшерүне дәвам иттерү өчен, сак астында С.-Петербургка — Идарәче Сенатка озатыла. 1771 нең декабре ахырында Сенатта М.М. эше карала. И.Рейнсдорпның М.М. кылган «явызлыклар» (Казан һәм Әстерхан губерналарында үз артыннан иярергә өндәү, Кырым б-н элемтәләр урнаштырырга омтылу, башкортлар миграциясе һәм М.М. эшчәнлеге арасындагы бәйлелек) турындагы дәлилләре кире кагыла. 1772 нең гыйнварында М.М.ны, китап язмаска һәм ялган дини тәгълимат таратмаска кушып, җәза бирмичә, Оренбургка кайтарып җибәрәләр. М.М.ның шуннан соңгы язмышы билгесез. Хезмәтләренең аерым өземтәләре Россия борынгы актлар дәүләт архивы фондларында саклана.

*Әд.:* Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. К., 2000.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МОРА́Д РӘМЗИ́** (10.10.1854 яки 25.12.1855, Уфа губ., Минзәлә өязе Әлмәт а. — 2.4.1934, Кытай, Чүгүчәк ш.), тарихчы, дин эшлеклесе. «Мәрҗания» мәдрәсәсендә укый (Казан, 1877). 1877 елдан Шәрекъ илләренә сәяхәт кыла, Мәккә шәһәрендә *нәкышбәндийә* суфичылык мәзһәбе тарафдарларына кушыла; берничә тапкыр Россиягә кайтып китә. «Казанда вә Болгарда булган вакыйгалар һәм татар мәликләре турында хәбәрләр» («Тәлфыйк әл-әхбар вә тәлкыйх әл-асәр фи вәкаигъ Казан вә Болгар вә мөлүк әт-татар», Оренбург, 1908) исемле 2 томлык хезмәт авторы. Әлеге хезмәттә ул патша хакимиятенең дини сәясәтен тәнкыйтьли. Хезмәт патша цензурасы тарафыннан тартып алына, авторга карата җинаять эше кузгатыла. Гарәбстанга качып, М.Р. кулга алынудан котылып кала. Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаенда (Казан, 1917) катнаша. 1917 дән соң Чүгүчәк шәһәре имамы. Татар халкы тарихына нисбәтле гарәп һәм фарсы язма чыганакларын өйрәнә.

*Әд.:* Г ә р ә е в а Н. Кем ул Морад Рәмзи? // Казан утлары. 1990. № 2.

*М.Г.Госманов.*

**МОРА́Н** Рувим Давидович (8.9.1908, Херсон губ. Берёзовка а. — 1986, Мәскәү), шагыйрь, тәрҗемәче. «Сайлау» («Выбор», 1968), «Соңгы сәгатьтә» («В последний час», М., 1990) тәрҗемә һәм шигъри җыентыклары авторы. Рус теленә Мәүлә Колый, Г.Кандалый, Я.Емельянов, Г.Тукай, Н.Думави, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Х.Туфан, С.Хәким, Ә.Ерикәй шигырьләрен (татар телен өйрәнеп) тәрҗемә итә. 1948–55 елларда репрессияләнә; аклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Орден, медальләр б-н бүләкләнә.

**МОРАСА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 39,6 *км*, бассейнының мәйданы 400 *км²*. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Нурлат р-ны Кычытканлы авылыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Алексеев р-ны Мораса авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. М.ның 12 кушылдыгы бар. Алар арасында иң зурысы — Гәрәй елгасы (18 *км*, уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м³/с*. Суы бик каты, язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. М. бассейнында суның гомуми күләме 1,8 млн.м³ булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МОРАСА́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 65 *км* көньяктарак, Мораса елгасы буенда. 2010 елда 159 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский, Мораса исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Казан Богородица чиркәве (1812 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1896 да ачыла), фельдшерлык пункты, су һәм җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1172 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән ТАССРның — Спас, 1924 тән Чистай кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 163 ир-ат; 1859 да — 750, 1897 дә — 1106, 1908 дә — 1109, 1920 дә — 1333, 1926 да — 1077, 1938 дә — 914, 1949 да — 533, 1958 дә — 405, 1970 тә — 380, 1979 да — 327, 1989 да — 253, 2002 дә — 208 кеше.

**МОРА́Т** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 10,4 *км*, бассейнының мәйданы 44,5 *км²*. Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Колшәрип авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Бакалы посёлогыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 89 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. М.ның 1 һәм 3,6 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 *км/км²*. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 112 *мм*, ташу вакытында су катламы 62 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. М. ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,009 *м³/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**МОРА́Т** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 146 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. Казан ханлыгы чорында, 1550 елларда рус авылы буларак нигез салына. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та Казан Богородица чиркәве (1841–57 дә төзелә, архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), җил тегермәне, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете, 1 казна шәрабханәсе була; якшәмбе көннәрендә — базар, Пасхадан соң тугызынчы җомгада ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 860,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 255 ир-ат; 1859 да — 527, 1897 дә — 820, 1908 дә — 913, 1920 дә — 918, 1926 да — 856, 1938 дә — 512, 1958 дә — 196, 1970 тә — 162, 1979 да — 122, 1989 да — 162, 2002 дә — 165 кеше.

**МОРА́Т** (Моратов) Газинур Васикъ улы (18.8.1959, Кукмара р-ны Зур Сәрдек а.), шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), «Татарстан яшьләре» г-тасында бүлек мөхәррире. 1984–88 елларда «Ялкын» ж-лында бүлек мөдире, 1989–91 дә ВЛКСМ Өлкә ком-ты каршындагы Респ-ка әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе, 1991–93 тә «Идел» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире, 1993–95 тә «Татар иле» г-тасының баш мөхәррире. 1995 тән «Мәдәни җомга» г-тасында баш мөхәррир урынбасары. «Җир хәтере» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1985 тә дөнья күрә. Аның «Мин дөньяны тыңлыйм» (1988), «Оча җырлар» (1991), «Түбә» (1998), «Төнге әверелеш» (2005) җыентыкларына тирән фәлсәфи уйланулар, тормыш вакыйгаларын киң колачлау, аларны сурәтләгәндә әхлакый аспектларга басым ясау хас. Шигырьләре романтик рухлы, бер үк вакытта заманча публицистик яңгырашлы. 1990 еллар татар поэзиясендә М.ның «Ачлык» (1992) поэмасы аерым урын алып тора. Анда татар халкының милли үзаңы үсешенә бәйле 1990 еллар башындагы вакыйгалар, суверенлык өчен көрәш темасы яктыртыла. М. ш.у. — «Җәяүле кошлар» (2002) исемле әдәби-публицистик, балалар өчен язылган «Тылсымлы тел» (1989), «Ачык дәрес» (1995), «Йолдыз илчеләре» (2013) җыентыклары авторы. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. (2000), респ-каның М.Җәлил исем. (2007) бүләкләре лауреаты.

*Әд.:* Ш ә р ә ф и е в Р. Хакны әйтүчеләр илдә бер // Казан утлары. 2003. № 8; М а н с у р о в З. Чичәннәр кайтавазын кемнәр көчәйтә // Казан утлары. 2005. № 9; Г а л и у л л и н Т. Поэтическая публицистика // Татарстан. 2003. № 11.

*Г.М.Габделхакова.*

**МОРА́ТОВ** Дамир Рәүф улы (1967, Төмән өлкәсенең Тобол ш.), график, нәкышьче. 1998 елда Омск пед. ун-тының сынлы сәнгать-графика ф-тын тәмамлый. Постмодернизм юнәлешендә эшли. М.ның иҗаты сәнгатьнең нәкышь, арт-объект һәм дизайн кебек төрләрендә гәүдәләнә. Төп әсәрләре: «Көймә» (киндер, майлы буяу, 1993), «Помпеяның соңгы көне» (янгын сүндерү калканы; калай, 1998), «Нью-Йорк күгe» (1999), «Көнкүреш астрономиясенең башлангыч курсы» (2000), «Кы-

лычлы бию» (2001), «Шәһәрләрне атау уены» (гофрокатыргы, 2001), «Гольф уйнаучы самурай» (2001), «Che Burashka» (2001), «West is dead» (гофрокатыргы, 2003), «Mickey Mao» (2004); серияле эшләре: «Че» (гофрокатыргы, акрил, 2001–05), «Уятма» (оргалит, принт, 2002), «66 нчы маршрутның 9 тукталышы» графика сериясе (2004), «Без булган җирдә рәхәт» (2006). Рәссамнарның «Манара», «Хач» ширкәтләре (Омск ш., 1988, 1989), «Хәзерге заман Себер сәнгате» (Варшава, 1991), «Провинциаль модернизм» (Мәскәү, 1993), «Өченче халыкара музей биенналесе» (Красноярск ш., 1999), «Беренче халыкара станок графикасы биенналесе» (Новосибирск ш., 1999), «Себернең йөз рәссамы» (Новокузнецк ш., 2003) күргәзмәләрендә, «Арт-Манеж» (Мәскәү, 2003–04),«Арт-Конституция» (Мәскәү, 2003), «ARTS-2003» (Мәскәү) халыкара сынлы сәнгать ярминкәләрендә, «Арт-Новосибирск» фестивалендә (2004), хәзерге заман сәнгате биенналесендә һәм халыкара «Ак чәчәкләр» графика биенналесендә (С.-Петербург, 2006) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Омскида (1994, 1995, 1997, 2004), Таллинда (2006) уза. Әсәрләре Дәүләт хәзерге заман сәнгате үзәгендә (Мәскәү), М.А.Врубель исем. Омск өлкә сынлы сәнгать музеенда, «Омск сәнгате» музеенда, Новосибирск, Новокузнецк, Алтай крае, Курган, Сургут сынлы сәнгать музейларында,



1



2

Д.Р. М о р а т о в. 1. «Казанова». 1990. Шәхси тупланма; 2. «Көймә». 1993. М.А. Врубель исем. Омск өлкә сынлы сәнгать музее.

«Артгентум» (Мәскәү), «Иске шәһәр» (Новосибирск ш.) шәхси галереяларында һәм чит илләрдәге тупланмаларда саклана. 1995 тә М. Омск шәһәрендә «Күчүм» галереясын оештыра, аның эшчәнлеге шәһәрнең сәнгать тормышында әһәмиятле урын тота.

*Әд.:* Б ы с т р ы х Н. Символы перехода из одного мира в другой: Опыт субъективной интерпретации картин Дамира Муратова // Вторые омские искусствоведческие чтения: Сб. материалов. Омск, 1998; К о р ш у н о в а Н. Галерея быстрого реагирования // Искусство. 2002. № 1; М у р а т о в а Н.В. «Античные» фантазии Дамира Муратова // Памятники археологии и художественное творчество. Омск, 2004; Сибирский поп-арт: Интервью Дамира Муратова Михаилу Боде // Искусство. 2005. № 4.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МОРА́ТОВ** Зиннәт Ибәт улы (27.12.1905, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Калмаш а. — 31.5.1988, Мәскәү), партия һәм дәүләт эшлеклесе. Ленинград политехник ин-тын тәмамлый (1930). 1930–33 елларда Ленинград су хуҗалыгы инженерлары ин-тының сәяси икътисад каф. мөдире. 1933 тән СССР Юллар халык комис-тының Сәяси идарәсендә партия хезмәтендә: 1933–35 тә Омск тимер юлының сәяси бүлегендә сектор мөдире, 1935–37 дә Ленинградта тимер юл транспорты сәяси хезмәткәрләрен әзерләү курслары башлыгы, 1937–42 дә Сәяси идарәнең партия курслары башлыгы, бер үк вакытта, 1941 дә Хәрби эксплуатация идарәсендә Юл хәрәкәте халык комис-тының сәяси идарәсе вәкиле (ВЭО-38). 1943 тә КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1944–57 дә 1 нче секретаре. 1957–60 та КПСС ҮК аппаратында. Татарстанда нефть индустриясе үсеше башлану, яңа шәһәрләр һәм эшчеләр посёлоклары (Әлмәт, Лениногорск, Җәлил һ.б.) барлыкка килү, СССР ФАнең Казан ф-лы, Казан консерваториясе һ.б. ачылу М. эшчәнлеге б-н бәйле. 1980 елларда «Советская Татария» г-тасында Бөек Ватан сугышы, М.Җәлил һ.б. турында хатирә-мәкаләләр бастыра. КПСС ҮК (1952 дән), СССР ЮС Президиумы әгъзасы. 1946–58 дә СССР, 1947–59 да РСФСР һәм 1947–59 да ТАССР ЮСлары депутаты. Ленин ордены, Октябрь революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х а м м а т о в а Ш., Х а б и б у л л и н а Ф. Секретарь обкома (К 80-летию со дня рождения З.И.Муратова) // Советская Татария. 1985. 27 дек.; С а й д а ш е в а М.А. Муратов Зиннат Ибетович // Борцы за счастье народное. К., 1988. Кн. 3.

*М.А.Сәйдәшева.*

**МОРА́ТОВ** Каранай (? — ?) Уфа өязенең Нугай даругасы Бөрҗән волосте йөзбашы, Е.И.Пугачёвның баш күтәрүчеләр армиясе полковнигы. Пугачёвка 1773 елның ноябрендә килеп кушыла. Ноябрь ахырында М. җитәкчелегендәге отряд Уфаны, декабрьдә аның барлыгы 10–12 мең кешедән торган отряды Минзәләне камап ала. 1774 нең апрель–октябрь айларында М. отряды Уфа, Табын, Эстәрлетамак һәм Бөгелчән пристаньнәре тирәсендә, Зилаир ныгытмасы янында барган сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. 1774 нең июлендә Пугачёвның төп көчләренә ярдәм итү максатында Казан та-



З.И. Моратов.

рафына юнәлә. Ләкин Каманы кичә алмый. 1774 нең октябре ахырында И.Л.Тимашев җитәкчелегендәге җәза отряды тарафыннан әсирлеккә алына. Казан яшерен комиссиясендә тоткынлыкта була, шуннан Мәскәүгә җибәрелә. 1775 нең гыйнварында Пугачёвны җәзалауның шаһиты була, аннары аны Казанга кайтаралар. 1775 нең мартында Сенатның яшерен экспедициясе тарафыннан М. мәңгелек солдат хезмәтенә «остзей гарнизоннарына» җибәрелә.

Чыг.: Документы ставки Е.И.Пугачёва, повстанческих властей и учреждений: 1773–1774. М., 1975; Крестьянская война 1773–75 гг. на территории Башкирии: Сб. док. Уфа, 1975; Воззвания и переписка вожаков Пугачёвского движения в Поволжье и Приуралье. К., 1988.

*Әд.:* Оренбургская Пушкинская энциклопедия. Оренбург, 1997.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**МОРА́ТОВ** Равил Фатих улы (30.8.1949, Октябрь р-ны «Төрнәс» с-зы), дәүләт эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (1997), ТР ФА Президиумы әгъзасы (2006). Бөтенсоюз совет сәүдәсе читтән торып уку ин-тын тәмамлый (Казан, 1980). 1966–67 елларда «Татэнергострой» трестының 7 нче махсус идарәсендә (Түбән Кама ш.), 1967–68 дә «Промстрой» трестының «Центролитстрой» махсус идарәсендә (Липецк ш.), 1970–72 дә Төрнәс спирт з-дында, 1972–74 тә Бөтенсоюз җитештерү фәнни-реставрацияләү комб-тының Воронеж участогында (Мәскәү) эшли. 1974–76 да Мамык (Октябрь р-ны) ваклап сату сәүдә пр-тиесе директоры, 1976–79 да Октябрь р-ны кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары, 1979–83 тә Чистай р-ны кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе. 1983–87 дә Татарстан Респ-касы кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе урынбасары. 1987–89 да ТАССР сәүдә министры. 1989–91 дә ТССР МС рәисе урынбасары. 1991–95 тә ТР Премьер-министры урынбасары, 1995–2013 тә — 1 нче урынбасары. Бер үк вакытта, 1996 дан, «Укртатнафта» трацмиллли компаниясенең, 1997–99 да «КамАЗ» АҖнең, 1997–2000 дә «Татинком» АҖнең директорлар советы рәисе. М. Татарстанның икътисады үсешенә зур өлеш кертә. Кризиска каршы идарә итүгә сәләтле җитәкче буларак танылa. Нефть чыгаруны тотрыклыландыруга, ТРның нефть чыгару тармагы һәм нефть-химия комплексы нәтиҗәлелеген үстерүгә юнәлтелгән хөкүмәт программаларын эшләүгә һәм тормышка ашыруга җитәкчелек итә. Бу, үз чиратында, нефть эшкәртү һәм нефть-химия пр-тиеләренең икътисадын савыктыруга уңай йогынты ясый.



Х.И. Моратхуҗин.

«КамАЗ»дагы кризис шартларында АҖнең финанс-икътисади хәлен ныгыту, идарә системасын үзгәртеп кору, заводның продукция сәүдәсен яңадан торгызу эшен координацияли. «Укртатнафта»ның күзәтчелек советын җитәкләп, үзара файдалы мөнәсәбәтләр системасын төзи һәм сәнәгый берләшмәне Көнчыгыш Европадагы иң зур нефть эшкәртү компаниясенә әверелдерүгә ирешә. М. авылларга газ кертү, тузган тоpактан арыну, халыкны адреслы социаль яклау программаларын оештыручыларның һәм ТРның социаль-икътисади үсеше һәм инновацион-җитештерү техно-паркларын (ИҖТ) булдыру турындагы хөкүмәт карарларын тормышка ашыручыларның берсе. 2006 ның мартыннан «Идея» ИНТ АҖнең директорлар советы рәисе. Кара диңгез флоты үсеше б-н бәйле чараларда катнаша. Хезмәтләре Татарстанның хәзерге чор социаль-икътисади үсешенә карый. «Почёт билгесе», Дуслык, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дорогу осилит идущий. К., 1996.

**МОРА́ТОВ** Раднэр Зиннәт улы (21.10.1928, Ленинград — 11.12.2004, Мәскәү), кино актёры, РСФСРның атказ. артисты (1986). Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (М.И.Ромм, С.И.Юткевич остаханәсе, 1951). 1951–88 елларда Мәскәүдә Киноактёр театр-студиясендә актёр. Эпизодлар башкаруда тиңсез оста буларак, М.ны бик күп кино режиссёрлары эшкә чакыра, 40 тан артык фильмда төшә: «Максим Перепелица» (1955, реж. А.М.Граник), «Көрәш» («Поединок», 1957, реж. В.М.Петров), «Солдат әтисе» («Отец солдата», 1964, реж. Р.Д.Чхеидзе), «Айболит-66» (1966, реж. Р.А.Быков), «Алтын бозау» («Золотой телёнок», 1968, реж. М.А.Швейцер), «Унике урындык» («Двенадцать стульев», 1971, реж. Л.Н.Гайдай), «Афоня» (1975, реж. Г.Н.Данелия) һ.б. «Җәнлек аулаучылар» («Звероловы», 1958, реж. Г.И.Нифонтов), «Уңышлы джентльменнар» («Джентльмены удачи», 1972, реж. А.И.Серый) фильмнарында зур рольләр башкара; Али Алибабаевич роле аңа киң танылу алып килә; Р.Хөснетдинованың татар авылындагы вакыйгаларны гәүдәләндерүче «Хисләрнең яңаруы» («Возвращение чувств», 1980) һәм «Зифа оныгы Ришад» («Ришад — внук Зифы», 1981) сценарийлары буенча реж. М.Д.Осепьян фильмнарында төшә. Геройларына хас гадилек, эчкерсезлек, лиризм, теләсә нинди шартларда да актёрның табигый яшәеше, теге яки бу образны иҗат иткәндә чаралар төрлелеге — тирән психологизмнан алып, трагикомик гротескка кадәр — М.ны кинематографта күренекле фигура итә.

М. катнашкан башка фильмнар: «Таулардагы застава» («Застава в горах», 1953), «Баһадир» Мартога бара» («Богатырь» идёт в Марто», 1954), «Кунакханә хуҗасы» («Хозяйка гостиницы», 1956), «Кыен бәхет» («Трудное счастье», 1958), «Икмәк һәм розалар» («Хлеб и розы», 1960), «Эш көннәре һәм бәйрәмнәр» («Будни и праздники»), «Командировка», «Любушка», «Шайтан саны» («Чёртова дюжина», барысы да — 1961), «Уйлап чыгарылмаган вакыйга» («Непридуманная история», 1963), «Вакыт, алга!» («Время, вперёд!»), «Безнең өстә — Көньяк Хач» («Над нами Южный Крест», икесе дә — 1965), «Кыргый бал» («Дикий мёд»), «Аталар җире» («Земля отцов», икесе дә — 1966), «Еракта, Көнбатышта» («Далеко на Западе»), «Русь буйлап» («По Руси», икесе дә — 1968), «Өчләтә тикшерү» («Тройная проверка», 1969), «Кабулдагы миссия» («Миссия в Кабуле», 1970), «Җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең эш көннәре» («Будни уголовного розыска»), «Төзәлмәс ялганчы» («Неисправимый лгун»), «Нейлон — 100%» (барысы да — 1973), «Мөмкин түгел!» («Не может быть!»), «Югалган экспедиция» («Пропавшая экспедиция», икесе дә — 1975), «Алтын инеш» («Золотая речка», 1976), «Яныма утыр, Мишка!» («Садись рядом, Мишка!», 1977), «Кечкенә трагедияләр» («Маленькие трагедии», 1979), «Кичке лабиринт» («Вечерний лабиринт»), «Гражданин Лёшка» (икесе дә — 1980), «Серле брелок» («Брелок с секретом»), «Сак бул!» («Смотри в оба!», икесе дә — 1981), «Законлы никах» («Законный брак», 1985), «Мин сине яраткан кебек ярат мине» («Люби меня, как я тебя), «Океандагы җиде аваз» («Семь криков в океане», икесе дә — 1986).

*Е.П.Алексеева.*

**МОРА́ТОВ** Родэс Зиннәт улы (15.7.1937, Ленинград), физик, физика-матем. фән. д-ры (1982). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1960), РФАнең Мәскәү радиотехника ин-тында эшли. Хезмәтләре эллипссыман җисемнәрдә түбән ешлыклы дифракциянең аналитик теориясенә, нәсферик җисемнәрнең тартылу теориясенә карый. М. бериш булмаган эллипсоидның потенциаллары теориясен үстерә (1971); плазма эллипсоидның резонанслы квазистатик тирбәнешләре ярсыну теориясен эшли (1985); эллипсоид потенциалларын мультикырлы (гравитацион, электростатик яки магнитик кырлар) итеп күзаллау теориясен төзи (1990).

Х е з м.: Потенциалы эллипсоида. М., 1976.

**МОРА́ТОВА** Надежда Георгиевна (12.4.1952, Мари АССРның Звенигово штп.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1975). 1975–79 елларда ТАССР Прокуратурасы тикшерүчесе. 1979 дан Казан ун-тының җинаятьчелек процессы һәм криминалистика кафедрасында. Хезмәтләре законлылыкны ныгытуның һәм җинаятьчелек буенча суд процессын камилләштерүнең процессуаль һәм криминалистик проблемаларына карый. Җинаятьчелек процессы һәм прокурор күзәтчелеге буенча уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Процессуальные акты органов предварительного расследования: Вопросы теории и практики. К., 1989; Кассационное определение по уголовным делам. К., 1995 (автордаш); Система судебного контроля в уголовном судопроизводстве: Вопросы теории, законодательного регулирования и практики. К., 2004.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**МОРА́ТОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Бихан бәк варислары. 16 йөздә рус патшасына хезмәткә күчәләр. 17 йөз уртасында морза М. Касыйм шәһәрендә яшиләр. 1610 елда морза М. нәселе башлыгы морза Айки Уразаев исеменә Тамбов губернасының Темников өязендә 30 чирек сөрүлек җирләре булган 8 крәстиян һәм бобыль хуҗалыклары теркәлә. 1719 да бәк М. Тамбов губернасы Кадом өязенең Салмовка һәм Якса авыллары халкы арасында да теркәләләр. 18 йөзнең 1 нче чирегендә бәк Морат морза Моратовның Темников өязе Югары Мокша станы Кучатбәк авылындагы биләмәсендә 26 крепостной крәстияне була. 18 йөздә морза М. Пенза губернасы Краснослободский өязенең Айкеево авылында да яшиләр; 1795 нең 1 июль килешүе нигезендә М. токымы — Булкай һәм Муса Сөләймановлар — шуннан хәзерге Башкортстан Респ-касының Чакмагыш р-ны Яңа Калмаш авылына күченәләр. Соңрак М. нәселе вәкилләре хәзерге Башкортстан Респ-касының Кушнаренко р-ны Мәүлет, Бакай авылларында һәм Бүздәк районы Бүздәк авылында урнашалар. 1802 нең 9 апрель карары нигезендә М. нәселе (барлыгы 74 кеше) дворянлыкта раслана. 1837 дә Яңа Калмаш авылында бәк М.ның 7 гаиләсе яши. Краснослободский өязендәге бәк М. (Җәмил Усманов, Габдрахман Илюков, Алмай Казбулатов, Габдрахман Илюков гаиләләре б-н) Пенза губернасының дворян нәселләре китабының 5 нче һәм 6 нчы кисәкләренә кертелә. Хәзерге вакытта М. Рязань губернасының Касыйм өязе Болотце авылында яшиләр.

*Әд.:* Н о в и к о в В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Списки дворянских родов, внесённых в родословную книгу Пензенской губернии. Пенза, 1908; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МОРАТХУ́ҖИН** Харис Ибраһим улы (1895 нең декабре, Уфа губ., Минзәлә өязе Останково а. — 1956, Казан), дәүләт эшлеклесе. Гражданнар сугышында катнаша. Казан химия-технол. ин-тында укый (1932–33). 1911–24 елларда Бондюг химия з-дында эшли (бүленеп: 1915–17 дә Россия армиясендә, 1920 дә 2 нче Алабуга коммунистлар отряды башлыгы). 1924–25 тә Алабуга, 1925–27 дә Лаеш кантоннары башкарма ком-тлары рәисе. 1927–29 да ТАССРның эчке эшләр халык комиссары. 1929–32 дә ТАССРның ҮБК Президиумы рәисе. 1933–37 дә МТСның сәясәт бүлеге башлыгы, ВКП(б)ның Чаллы район ком-тының

1 нче секретаре. 1937 дән «Кызыл Шәрекъ» з-ды директоры. 1937 нең августында кулга алына. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана (1958). Бөек Ватан сугышында катнаша. Бүләкләре бар.

*Әд.:* Тагиров Э. Мратхузин Харис Ибрагимович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**МОРДВА́ АФО́НЬКӘСЕ** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 122 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.А.ндә волость идарәсе урнаша; земство һәм чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2728 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 673, 1889 да — 995, 1910 да — 1211, 1920 дә — 1312, 1926 да — 972, 1949 да — 594, 1958 дә — 626, 1970 тә — 636, 1979 да — 491, 1989 да — 283, 2002 дә — 190 кеше.

**МОРДВА́ БАГАНАЛЫСЫ́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Олы Бахта елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 14 кеше (мордвалар) яши. 1710 еллардан Красное Болото исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве, 5 тегермән, ярма яргыч, чәйханә; 1 казна шәрабханәсе һәм 4 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1973 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 154 ир-ат; 1859 да — 880, 1897 дә — 2000, 1908 дә — 2221, 1920 дә — 2201, 1926 да — 1627, 1938 дә — 1446, 1949 да — 1214, 1958 дә — 609, 1970 тә — 364, 1979 да — 177, 1989 да — 44, 2002 дә — 14 кеше.

**МОРДВА́ БОЛАГЫ́** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы буенда. 2010 елда 145 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.Б.нда 2 җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 472 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 26 ир-ат; 1859 да — 185, 1897 дә — 379, 1908 дә — 452, 1920 дә — 409, 1926 да — 333, 1938 дә — 245, 1949 да — 222, 1958 дә — 180, 1970 тә — 182, 1979 да — 154, 1989 да — 146, 2002 дә — 149 кеше.

**МОРДВА́ ИВА́НОВКАСЫ** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Баллы елгасы буенда. 2010 елда 29 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 1785 тән Баллы исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880–90 да М.И. — волость үзәге. 1910 елгы мәгълүматларга караганда, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1384 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Ивановкасы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 26 ир-ат; 1859 да — 625, 1889 да — 541, 1910 да — 625, 1920 дә — 678, 1926 да — 806, 1938 дә — 458, 1949 да — 435, 1958 дә — 305, 1970 тә — 318, 1979 да — 155, 1989 да — 65, 2002 дә — 31 кеше.

**МОРДВА́ КАРМАЛЫСЫ́** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 67 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 404 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1785 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мордва Сарабикколы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе, земство станциясе урнаша; чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3307 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Кармалкасы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 171 ир-ат; 1859 да — 1060, 1883 тә — 992, 1889 да — 1280, 1910 да — 1479, 1920 дә — 1597, 1926 да — 4211, 1938 дә — 1018, 1949 да — 901, 1958 дә — 957, 1970 тә — 887, 1979 да — 696, 1989 да — 556, 2002 дә — 566 кеше.

*Әд.:* Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

**МОРДВА́ КАРАМАЛЫСЫ́ БИТУМНА́Р ЧЫГАНАГЫ́**, Татарстан терр-ясендә беренчеләрдән булып эшкәртелүче *битумнар* чыганагы. Лениногорск р-ны терр-ясендә, Мордва Карамалысы авылыннан 1,5 *км* читтә, Чишмә елгасы бассейнында. 1970 елда ачыла, 1978 дән эшкәртелә. Татар гөмбәзенең көнбатыш сөзәклегенә, битумнарның төп ятмасы Пермь системасы Уфа ярусы утырмаларына туры килә, битум чагылмалары Казан ярусының кавернозлы известьташларында күренә. Продуктив пластның яту тирәнлеге 60 тан 170 *м* га кадәр, уртача — 85 *м*; коллекторның токым массасы буенча битум б-н туенганлыгы 7,5 тән 18,8% ка кадәр, уртача — 11,2%. Битумнарның баланс запасы 3,7 млн. *т* дан артык. Битумнар составында сирәк элементлар (V, Ni һ.б.) бар. Ванадийпорфирин составы 340 тан (пласт эчендә яну) 600 *г/т* га кадәр (табигый режим), никельпорфириннар — 122 *г/т*. Битумнарның баланс запасында (373 мең *т*) ваннадий күләме — 1,3 мең *т* дан артык, никель — 0,2 мең *т* га якын, күкерт — 152,9 мең *т* тәшкил итә (1992). Пласт суларында бром бар. Битумлы нефть пласт эчендә яндыру, пар, һава яки пар-газ тутыру ысулы б-н чыгарыла. Уртача тәүлеклек чыгару 33,9 *т*.

*Б.В.Успенский.*

**МОРДВА́ КАРАТАЕ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы буенда. 2010 елда 82 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1620 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, сәүдә, таш, известь, алебастр һәм күкерт чыгару б-н шөгыльләнә, бурлаклыкта эшли. 20 йөз башында М.К.нда Рождество чиркәве (1868–70 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1871–86 елларда эшләгән Изге Гурий братстволары мәктәбе урынына 1890 да төзелә), баптистлар гыйбадәтханәсе, 4 җил тегермәне, чүлмәк ясау бинасы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2415,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Сөйке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 271 ир-ат; 1859 да — 848, 1897 дә — 1217, 1908 дә — 1321, 1920 дә — 1352, 1926 да — 935, 1938 дә — 578, 1949 да — 372, 1958 дә — 470, 1970 тә 284, 1979 да — 173, 1989 да — 120, 2002 дә — 103 кеше.

**МОРДВА́ РЕСПУ́БЛИКАСЫ**, РФдә. Көнчыгыш Европа тигезлегенең үзәк өлешендә, Ука б-н Сура елгалары арасында урнашкан. Мәйданы — 26,2 мең *км*². Халкы — 818566 кеше (2012). 2002 елгы халык исәбе буенча, 46,3 мең, 2010 да — 43392 татар. Башкаласы — Саранск шәһәре. Татарларның ата-бабалары Мордва җирләренә борынгы чорларда килеп урнаша. Төрки кабиләләрнең (Идел буе болгарлары, бортаслар) Мордва җирләренә таралуы б.э.ның 1 меңьеллыгында башлана, һәм ул гасырлар буена дәвам итә. Бортаслар Идел буе болгарлары, 11–12 йөзләрдән кыпчаклар йогынтысында татар-мишәр халкының этник нигезен тәшкил итә дигән фаразлар бар. 14 йөз башында Алтын Урда кешеләре Наручат шәһәрендә олыс үзәген (к. *Мухша олысы*) оештыралар. Күп кенә татар торак пунктлары 16 йөздә барлыкка килә, бу — Россия дәүләтенең көньяк-көнчыгыш чигендәге мөһим хәрби-стратегик пунк-

ты — Темников шәһәренең 1536 елда төзелә башлавы б-н бәйле. Рус хөкүмәте Темников татарларын *чик буе киртәләрен* каравыллау хезмәтенә җәлеп итә. Алар арасында кенәзләр, морзалар була; тархан грамоталары нигезендә аларның имана җирләре акчалата һәм натуралата салымнардан, транспорт бурычларыннан азат ителә. Бу — Мордва төбәгендә чик буе киртәләрендә татар торак пунктлары үсеп чыгуга ярдәм итә. 16 йөздә Темников чик буе киртәләрендә хезмәт итүче йомышлы татарлар Күгеш (Акчеево), Зур Татар Карае авылларына, 17 йөздә Түбән Пешләй, Кыштору (Зур Шуструи) һәм Дәлек (Кече Шуструи) авылларына, 17 йөздә Керенск чик буе киртәләрендә Горенка авылына нигез салалар. 1631 дә патша Михаил Фёдорович татар кенәзе Уразай Тәңкәчиевкә җир бүләк итә, һәм бу урында Татар Пешләсе, Урузаевка (хәзер Рузаевка ш.) авыллары төзелә. 1642 дә 40 лап морза һәм йомышлы татар Темниковтан Саранск-Атемар чик буе киртәләренә күчерелә, һәм монда Ләмбрә, Щербаково, Чирмеш, Пензятка исемле татар авыллары барлыкка килә. 17 йөздә Темников йомышлы татарлары Кырви (Кривозерье), Азюрка (Белозерье), Ләбәҗә (Алтары), Яндовище, Өрләдем (Верхний Урледим), Татар Щебдасы авылларын нигезли. Хәзерге вакытта татарлар яши торган кайбер торак пунктларның атамалары йомышлы татарларның фамилияләреннән (Аксюн (Аксёново) — Аксёновлардан, Иске Аллагол (Искил исеме дә бар) — Аллаголовлардан, Насакан-Потьма — Насакиннардан, Вәчи — Вәчиевләрдән, Инәт (Пүнәт) — Инәевләрдән, Енакай — Енакаевлардан, Енгураз — Енгуразовлардан, Идәй — Идәевләрдән, Татар Акашы — Акашевлардан, Төви — Төвиевләрдән, Шурбино — Шурбиннардан) алынган. 2002 дә М.Р.ның Ләмбрә, Рузай, Ромодан, Кадошкин, Темников, Атюрьев, Ельник, Инсар, Дубёнки, Кочкуров, Ковылкин, Краснослободск, Тәрби, Теньгушев һәм Зубово-Поляна р-ннарында 60 тан артык татар торак пункты исәпләнә. 2003 тән М.Р. татар төбәк милли-мәдәни автономиясе эшли. 1991 дә М.Р. татар мәдәнияте оешмасы булдырыла, 1999 дан «Якташлар» татар мәдәнияте оешмасы эшли. Аның җирле бүлекчәләре бар, ул башка төбәкләрдәге татар иҗтимагый оешмалары б-н бәйләнештә тора, Бөтендөнья татар конгрессын оештыручыларның берсе була, оешма әгъзалары респ-ка радиосында татарча тапшырулар алып бара. 1997 дән атна саен 5 мең данә тираж б-н татар һәм рус телләрендә «Татар газетасы» (1999 ның октябреннән Интернетта газетаның татар, рус, инглиз телендәге электрон версияләре чыга) нәшер ителә, анда татар җәмгыятенең мәдәни-агарту һ.б. проблемалары яктыртыла. М.Р.ның *Рузаевка р-нында* Ш.Камал исем. оешма эшли. 2003 тә респ-када 14 урта, 5 тулы булмаган урта, 6 башлангыч татар мәктәбе (1990 да Ләмбрә р-нының Пүнәт авылында 1 башлангыч татар мәктәбе була, ә башкаларында укыту рус телендә бара) эшли. 6 меңгә якын татар баласының 2 меңнән артыгы (35,7%) туган телне өйрәнә, 5 меңләбе татарча сөйләшә. М.Р.да 2 үзәкләштерелгән (М.Р. Мөселманнары төбәк диния нәзарәте — Уфа шәһәрендәге Россия Мөселманнары үзәк диния нәзарәте каршындагы Мордва мөфтияте һәм М.Р. Мөселманнары диния нәзарәте — ул Россиянең Европа өлешендәге Мәскәү Мөселманнар диния нәзарәтенә карый), 21 җирле мөселман дини оешмасы (2001), Саранскида мөселман дини җәмгыяте оешмасы эшли. 58 мәчет бар, ш.и. 6 сы рев-циягә кадәр төзелгән (2005). *Ләмбрә р-нының* Ләмбрә авылында Татар милли мәдәният үзәге (1991), «Умырзая» халык җыр һәм бию ансамбле (1969), «Чулпан» (1987) «Дуслык» (2004) эстрада ансамбльләре; Свәрби (Татар.Свербейка) авылында «Зөләйха» фольклор ансамбле (1995) эшли. Татарлар — Сов. Союзы Геройлары А.А.*Абдершин*, А.А.*Баляев*, Ф.Х.*Чураков*; мәгариф эшлеклесе М.И.*Мәхмутов*; журналистлар И.Д.*Биккинин*, А.Х.Габунова, А.Кучушев, Р.Р.Мортазин; педагоглар З.А.Вахидова, З.Д.Исхакова, М.А.Котлышова; шагыйрь һәм прозаиклар Г.С.*Әпсәләмов*, Ф.Н.Агиев, И.Й.*Башмаков*, Ш.*Камал*, Ә.С.Симаев, Һ.*Такташ*, К.А.*Тангалычев*, А.И.*Шадрин*; рәссамнар Х.И.Бикбаев, Ә.Г.*Китаев*; атаклы галимнәр: акушер-гинеколог Х.Х.*Мещеров*, тарихчы М.Г.Сәфәргалиев, әдәбият белгече М.Г.*Мамин*, нефтехимик З.И.*Сунәев*, офтальмолог С.Б.*Еналиев*, галим агрономнар Ш.И.*Әхмәтов* һәм Ә.Т.*Мещеров*, химиклар И.С.*Мостафин*, Ф.Җ.*Ямбушев*, физиолог О.Җ.*Курмаев*, философ Ф.Ә.Айзәтов, эпизоотолог Ә.Х.*Лаишев*; спортчылар Р.Г.*Биккинин*, К.А.Нарбеков, Р.К.Насыйбуллов, К.А.Хәлилов; халык җырларын, бәетләрен җыючы һәм башкаручылар Х.*Ишмәмәтов*, А.*Кротов* М.Р.да туган. 2004 нең 31 декабрендә ТР б-н М.Р. арасында икътисади, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела.

*В.А.Юрчёнков.*

**МОРДВА́ ТЕЛЛӘРЕ́**, фин-угор телләре семьялыгына караган Идел буе-фин телләре төркемчәләре. Аларга 5–6 йөзләрдә бердәм мордва теленнән аерылып чыккан мукшы (мукшы-мордва) һәм эрзя (эрзя-мордва) телләре керә. М.т.ндә сөйләшүчеләр Мордва, Башкортстан, Татарстан Респ-каларында (нигездә, мукшы теле киң таралган), Самара, Оренбург, Пенза, Ульянов, Түбән Новгород һәм РФнең башка өлкәләрендә тыгыз урнашып яши. Бу телләрдә сөйләшүчеләрнең гомуми саны 615 меңгә җитә, ш.и. ТРда — 23,7 мең кеше (2002). М.т.нә мукшы яки эрзя тибындагы күчемле һәм катнаш сөйләшләр күплеге хас. М.т. нигез телдән агглютинатив телләргә хас сүз һәм форма ясауны мирас иткән. Аларда род грамматик категориясе юк, предлог урынына послелог (бәйлек) кулланыла. М.т.нең сөйләм төзелешенә рус теленең йогынтысы зур. Мукшы теленең авазлар системасында — 7 сузык аваз, 33 тартык аваз; эрзя телендә — 5 сузык аваз, 28 тартык аваз.

Эрзя әдәби теле — 1920 еллар ахырына, мукшы әдәби теле 1930 еллар уртасына формалашып җитә. Мордва язуы рус графикасына нигезләнә (18 йөз уртасыннан). П.П.Орнатов тарафыннан мукшы телендә төзелгән беренче «Мордва грамматикасы» («Мордовская грамматика») — 1838 дә, А.Ф.Юртов тарафыннан эрзя телендә әзерләнгән беренче әлифба 1884 тә дөнья күрә. Мукшы һәм эрзя телләре рус теле б-н беррәттән Мордва Респ-касының дәүләт телләре булып санала.

М.т. мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында өйрәнелә; Мордва теле, әдәбияты, тарихы һәм икътисады фәнни-тикшеренү ин-ты, Мордва ун-ты аларның фәнни тикшеренү үзәкләре булып тора. Бу телләрдә дәреслекләр, публицистик һәм матур әдәбият нәшер ителә, газета һәм журналлар чыга, театрлар эшли, теле- һәм радиотапшырулар алып барыла. Мукшы-мордва һәм эрзя-мордва телләрендә Мордва энциклопедиясе (Мордовия: энциклопедия: В 2 т. Саранск, 2007) басыла. Ш.у.к. *Мордвалар*.

*Әд.:* Мордва: Этническая история мордовского народа. Хозяйство и материальная культура. Общественная жизнь и духовная культура. Саранск, 2004; Русско-мокшанско-эрзенский словарь. Саранск, 2011.

**МОРДВА́-КАРАТАЙЛА́Р**, *мордваларның* этник төркеме. Электән хәзерге Кама Тамагы р-ны терр-ясендә — Мукшы Каратае, Кече Менситово, Шершалан авылларында, ш.у. татарлар б-н бергә Балтач авылында яшиләр. Мөгаен, Лаеш р-ны Ташкирмән авылында яшәүчеләр — 17 йөздә Иделнең сул ярына күченгән каратайларның варисларыдыр, алар шул ук диалектта сөйләшәләр, ләкин мордва үзаңын югалтканнар, үзләрен керәшен татарлар дип исәплиләр. 20 йөз башына каратайларның гомуми саны 4 меңләп кеше тәшкил итә, 1958 елда Кама Тамагы р-ны терр-ясендә алар 1 мең чамасы, 1976 да — 300 гә якын, хәзерге вакытта 100 ләп кеше исәпләнә. Халык саны кимү шәһәрләшү, 1950 еллардан М.-к. яшәгән барлык авылларның Куйбышев сусаклагычы сулары астында калуы б-н бәйле. Хәзерге вакытта ул төбәктә калган каратайларның күп өлеше Кама Тамагы авылында һәм шәһәр тибындагы Куйбышев Затоны посёлогында яши. М.-к. атамасы фәнни әйләнешкә 18 йөздә керә. М.-к. хакында беренче тапкыр Идел буе халыкларын өйрәнгән И.Лепёхин яза. Ул аларны, эрзя һәм мукшылар кебек үк, аерым мордва кабиләсе дип саный. 19 йөздә акад. П.Кеппен һәм 20 йөздәге кайбер этнографлар да шундый ук фикердә торалар. Тикшеренүчеләрнең күпчелеге (А.Риттих, С.Кузнецов) М.-к. татарларның көчле йогынтысына дучар булган, ягъни үзләренең этник мордва үзаңын сакласалар да, татар телен һәм кайбер мәдәният элементларын үзләштергән мордва-эрзяларның җирле төркеме дип исәпли. Алар фикеренчә, «каратайлар» атамасы этник түгел, геогр. хасияткә ия. 19 йөз ахырында Тәтеш өязендә руслар яшәгән Каратай исемле берничә авыл була: Заовражные Каратаи, Барские Каратаи. М.-к. вәкилләре үзләрен мордвалар һәм керәшеннәр дип атыйлар. Шулай ук М.-к. — бабалары б.э.ның беренче йөзләрендә Дон буеннан килгән аерым халык дигән фараз да яши. Үзләренең антропологик кыяфәте буенча М.-к. күбрәк мордваларга тартым, күрше районнарда яшәүче та-

тарлардан күпкә аерылалар: кыска буй һәм тар маңгай аларны — мордва-мукшылар, калку каш өсте, алга чыккан ияк, тар иреннәр мордва-эрзя б-н охшаш итә. Матди һәм рухи мәдәнияттә мордвалар б-н кайбер параллельләр бар: мәс., М.-к. мичтә пешерелгән һәм мордваларның башка төркемнәренә хас булган аш-суны милли ризыклар дип саныйлар («бәрәңге калгасы», йомыркадан әзерләнә торган «калдя» һ.б.). Һәркайда төркиләр яки татарлар йогынтысы (мәс., өйләрне полихром төсләргә буяу) күзәтелә. М.-к. татар телен үзләренең туган теле дип исәплиләр, ләкин үзенчәлекләре булу сәбәпле, алар аны каратай теле дип атыйлар. Эрзя һәм мукшы телләре сүзләре туганлык атамаларында, балык төрләре исемнәрендә һ.б.да сакланган. Электән руслар б-н багланышлар җәелә, 19 йөз ахырында ук каратайларның күпчелек өлеше рус телендә иркен сөйләшә. Мордваларның башка төркемнәренең һәм керәшен татарларның ерактарак яшәве, ир-атларның бурлаклык хезмәте һәм читкә китеп башка кәсепләр б-н шөгыльләнүе моңа этәргеч бирә. Торакларның эче үзәк-рус тибындагыча җиһазландырыла. М.-к. аңлы рәвештә православие динe тоталар, 19 йөздә инде мәҗүсилек калдыклары әллә ни сакланмый, каратай авылларында 3 чиркәү приходы эшли. 20 йөз башында М.-к.ның бер өлеше үзләрен эшкә яллаган Идел буе немецларында таралган баптистлыкка күчә. М.-к.ның җыр фольклоры да гаять үзенчәлекле: җырлар-импровизацияләр һәм, үзләрендә билгеләнгәнчә, җырлар-гамәлләр (аларда башкаручылар тарафыннан үзләренең тирә-ягындагы бар нәрсә җентекләп тасвирлана).

*Әд.:* Б е л и ц е р В.И. Мордва-каратаи и их культура // Вопросы этнической истории мордовского народа: Тр. мордовской этногр. экспедиции. М., 1960. Вып. 1. Мордва-каратаи: язык и фольклор. К., 1991.

**МОРДВАЛА́Р**, Россиядәге халык, *Мордва Республикасының* төп халкы. РФдә М.ның саны — 744237 кеше (2010), шулардан 333112 кеше Мордва Респ-касында гомер кичерә. Самара (65447 кеше), Пенза (54703), Оренбург (38682), Ульянов (38977) өлкәләрендә, Башкортстан Респ-касында (20300) тупланып яшиләр. ТРда мордва халкы — 19156 кеше (2010), башлыча, Әлмәт (2749), Бөгелмә (2533), Лениногорск (4006), Тәтеш (2399) р-ннарында, Чаллы шәһәрендә (1979) гомер кичерәләр. М. 2 субэтноска бүленәләр (үзатамалары — эрзя һәм мукшы), аларның һәрберсенең үз теле — эрзя һәм мукшы телләре; икесе дә Урал телләре семьялыгының фин-угор төркеменә карый. Эрзя теле — 5 диалектны, мукшы теле 3 диалектны үз эченә ала. Язулары рус графикасы нигезендә, Мордва Респ-касында мукшылар, башлыча, аның көнбатыш һәм көньяк төбәкләрен, эрзя көньяк төбәген били. Кечерәк этнографик төркемнәр дә аерыла: күбесенчә Мордва Респ-касының Теньгушев р-нында яшәүче, кайбер очракта «шокша» (Шокша авылына нисбәтле рәвештә) дип аталучы теньгушев М.ы, Татарстанның Кама Тамагы р-нында көн күрүче каратай М.ы (к. *Мордва-каратайлар*). М.ның эрзя субэтносына кергән теньгушев төркеме мукшылар ягыннан өлешчә йогынтыга дучар була; тикшеренүчеләрнең бер өлеше мукшылар, икенчеләре эрзялар, өченчеләре эрзя-мукшылар дип исәпләгән каратай төркеме татарларның көчле йогынтысын кичерә. Инанучылар православие динен тота.

М.ның бабалары — фин-угор кабиләләре — б.э.к. 1 нче меңьеллыкның 2 нче яртысында Идел-Ука-Сура елгалары аралыгын билиләр. «М.» атамасы (Mordens) беренче тапкыр 6 йөздә гот тарихчысы Иордан хезмәтләрендә искә алына, 11 йөздән борынгы рус елъязмаларында очрый. Эрзя һәм мукшыларга бүленү процессында (6–7 йөзләрдән) Ука-Сура елгалары аралыгындагы борынгы М., ш.у. Сура һәм Мукшы елгаларының югары агымы буйларында көн күргән көньяк кабиләләрнең терр. яктан аерымланып яшәүләре зур роль уйный. Зур терр-яләрдә таралып урнашу нәтиҗәсендә, кабилә төркемнәре арасында багланышлар кыенлаша, бу төркемнәрнең башка халыклар б-н элемтәләре көчәя, мукшылар һәм эрзяларның телләрендә, мәдәниятендә һәм көнкүрешендә үзгәлекләр барлыкка килә. Озак вакытлар дәвамында М. төрки халыклар (болгарлар, татарлар һ.б.) һәм Борынгы Русь б-н багланышта яшиләр. Борынгы М.ның этник терр-ясендә барган миграция процесслары да аларның икегә бүленүенә мөһим сәбәп була. Болгарларның Урта Идел буен биләве һәм анда аларның дәүләт берләшмәсе — Идел буе Болгар дәүләте оешу, соңрак монгол яулары мордва этносының ике юлдан киткән үсешенә этәргеч бирә, бу үзгәлек хәзергәчә саклана. Феодаль таркаулык чорында М. рус кенәзлекләре б-н якыная башлыйлар. Бергәләп Алтын Урдага каршы көрәшү бу процесска зур йогынты ясый. Мордва аксөякләре вассаллар сыйфатында Алтын Урда ханнарына хезмәт итәләр, үзара көрәштә алардан рус кенәзләре дә файдалана. Казан ханлыгы яулангannan соң (1552), М. Рус дәүләте составына керәләр, аларның күпчелек өлеше патша хөкүмәте тарафыннан ясаклы кешеләр катлавына күчерелә. 18 йөз уртасына кергәндә, М., башлыча, православие диненә күндерелә. М. Идел буеның аеруча христианлаштырылган халкы саналсалар да, аларның инануларында билгеле бер дәрәҗәдә православие б-н катнашкан мәҗүсилек эзләре хәзергәчә саклана. 1917 елда Казанда Мордва мәдәни-агарту оешмасы нигезләнә, аның идарә рәисе беренче мордва мәгърифәтче-галиме М.Е.*Евсевьев* була.

М.ның электән килгән төп шөгыле — сөрүле игенчелек (уҗым арышы, борай, тары, җитен, киндер). Терлекчелек (мөгезле эре һәм вак терлек), чолыкчылык, соңрак умартачылык сизелерлек роль уйный. Элек М.да традицион торулыклар — урамлап төзелгән авыллар һәм салалар таралыш ала. Тораклары, гадәттә, ике яки өч өлешкә бүленгән урта-рус планировкалы өйләрдән, мукшыларда кайчак көньяк-рус планировкалы өйләрнең көнбатыш төреннән гыйбарәт була.

Элек-электән мордва хатын-кызлары киеменең нигезен сары һәм яшел төс кушып, кызыл, кара, зәңгәр төстәге чигүләр б-н мул бизәлгән ак киндер күлмәк (панар) тәшкил итә. Эрзя хатын-кызлары арасында өслегә тулысынча чигүле йола күлмәге (аны кызлар балигълык көнендә яки туйда кияләр), ак киндердән тегелгән, ике чабулы, халат рәвешендәге өске кием киң тарала. Мукшы хатын-кызлары балаклары тубыкка җиткән ак киндер ыштан кияләр, аларның киеме металл, сәйлән, тәңкәләр һәм кабырчыклардан эшләнгән төрле бизәмәләр б-н тулыландырыла, өске кием — чикмән, туннар. М.да үзенчәлекле күкрәк бизәмәсе сыйфатында яка каптырмасы кулланыла. Эрзяларда ул — йомылмаган овал, мукшыларда трапеция рәвешендә. Эрзя хатын-кызларының үзенчәлекле янбаш бизәмәсе — мул чигешле, укалар, йон чуклар, металл аеллар куелган пулагай, аны беренче тапкыр балигълык көнендә кияләр. Хатын-кызлар сүрәкә рәвешендәге, сөлгеләрдән, япмалардан каты өслектә биек итеп эшләнгән төрле баш киемнәре кияләр. Кызлар арасында сәйлән б-н һәм укалап чигелгән маңгай тасмасы таралган. Элек кыеклап үрелгән чабаталар кигәннәр. Аякларга ак һәм кара чолгаулар ураганнар. Хатын-кызлар киеменең үзгәртелгән төрләре хәзер дә киелә. Ир-атларның төп өлешләре ак күлмәк һәм киндер ыштаннан гыйбарәт булган киеме 20 йөздә кулланылыштан чыга.

Башлыча, М.ның ризыклары игенчелек продуктларыннан әзерләнә: ачы икмәк, төрле эчлекле (күбесенчә боткалы) бәлешләр, бодай, тары, борчак онынnan коймак, токмач, салма. Ит ризыклары (мукшыларда — суган б-н кыздырылган ит, эрзяларда — кыздырылган ит һәм тәмләткечләр салынган терлек эч-башлары) элек, башлыча, бәйрәмнәрдә һәм йолалар башкарганда әзерләнгән. Эчемлекләр — пуре (балдан), йорт сырасы, квас.





1. 19 йөз мордва хатын-кызлары костюмы. Россия этнография музее. С.-Петербург; 2. Мордва кызы традицион милли киемдә. 20 йөз башы фоторәсеме. ТР Милли музее.



Г.Г. Морзаханов.

20 йөз башына кадәр М.да кечкенә индивидуаль гаилә һәм ир ягыннан варисларның 3–4 буыннан үз эченә алган, бүленмәгән зур гаилә яшәп килә. Совет чорында кечкенә гаилә таралыш ала башлый. Тугандаш гаиләләр арасында традицион якын мөнәсәбәтләр саклана: бергә гаилә бәйрәмнәре үткәрелә, йорт салганда, уңышны урып-җыйганда һ.б. вакытларда үзара ярдәм күрсәтелә.

Мордва халык бәйрәмнәре игенчелек календарена бәйле. Әлек яклаучы Вель-авега багышланган җәйге бәйрәм — велень-озкс тантаналы рәвештә күп халык катнашында уздырылган.

Безнең көннәрдә традицион мордва аш-су бәйрәмнәре билгеләп үтелә. Фольклорның күпчелек өлешен йолалар — календарь һәм гаилә шигърияте (кәләшне йортыннан елап озату, туйдагы «шелтәләү» һәм мәдхия җырлары), гаилә-көнкүреш җырлары, эпик (илаһ тарафыннан урланган Литова исемле кыз, халыкны яклаучы каһарман һәм юлбашчы Тюшт турында), тарихи җырлар, баһадирлар, христиан диненә кадәрге аллалар, хайваннар турындагы әкиятләр тәшкил итә. Халык арасында ш.у. озын лирик җырлар, такмаклар, мәкальләр, әйтемнәр саклана.

*Әд.:* Народы Поволжья и Приуралья: Коми-зыряне. Коми-пермяки. Марийцы. Мордва. Удмурты. М., 2000; Мокшин Н.Ф. Материальная культура мордвы: Этногр. справ. Саранск, 2002; Народы России: Энцикл. М., 1994.

*В.А.Юрчёнков.*

**МОРДВАСУ́** елгасы, Идел алдында, Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 18,7 *км*, бассейнының мәйданы 116,9 *км*$^2$. Елга башы Тәтеш р-ны Лаптевка авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Кама Тамагы р-ны Кирельский посёлогы янында. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы сулары астында калган һәм култыкка әйләнгән. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. М.ның 0,6 дан алып 5,6 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,53 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 62 *мм*, ташу вакытында су катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. М. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,033 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**МОРДВАСУ́** елгасы, Идел алдында, Шарманка елгасының (Идел елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,5 *км*, бассейнының мәйданы 36,7 *км*$^2$. Идел буе калкулыгыннан, Кама Тамагы р-нында ага. Елга башы урман массивында, Осинники посёлогыннан 3 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Тәмте авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 76 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. М. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*$^3$*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**МОРДЫБА́Й** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Чаж елгасы буенда. 2010 елда 150 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына (башта — алпавыт Яушевлар, 1730 еллардан морза Тәфкилевләр карамагында) керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, балта эше, кәрзин үрү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 18 йөздә *Тирсә крәстияннәре кузгалышларында* актив катнашалар. 20 йөз башында М.да почта станциясе урнаша; мәчет, мәктәп, рус-татар земство мәктәбе, сәүдәгәр И.Вишняковның пыяла з-ды (1883 тән), базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 392,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Ильинка волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 204, 1887 дә — 321, 1905 тә — 412, 1920 дә — 539, 1926 да — 474, 1938 дә — 425, 1958 дә — 251, 1970 тә — 174, 1989 да — 148, 2002 дә — 141 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**МОРЗА́** (мирза) (фарсы. میرزا әмирзадә — әмир улы), 1) Иранда идарәче династия әгъзалары титулы; күчерелмә мәгънәдә — кәтиб, эш башкаручы (чиновник), сәркәтип. Титул аксөяклек дәрәҗәсе буларак кулланганда, «М.» термины исем артыннан куела (мәс., Мәхмүд морза). 2) Алтын Урда һәм соңыннан Россия империясенә кергән төрки-татар халыкларында эре феодал яки аерым ыруг, кабилә башлыгы, рус дворяннарына тиңләштерелгән феодаль аксөяк вәкилләре дәрәҗәсе (ш.у.к. «*Чабаталы морзалар*»). 3) Татар теленең кайбер диалектларында һәм казакъ телендә түбәнчелек б-н мөрәҗәгать итү формасы. 4) Хәзерге төрки халыкларның кайберләрендә ир-ат исеме яки исеменең бер өлеше.

*Әд.:* Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Госманов М.Г. Татарские исторические источники. К., 1972.

*М.Г.Госманов.*

**МОРЗА́ БӘРЛЕБАШЫ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 10 *км* көньяктарак, Бәрле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 157 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, чөгендер үстерү. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.Б.нда мәчет, мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 301 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 199, 1897 дә — 342, 1908 дә — 409, 1920 дә — 361, 1926 да — 316, 1938 дә — 365, 1949 да — 314, 1958 дә — 284, 1970 тә — 232, 1979 да — 211, 1989 да — 226, 2002 дә — 209 кеше.

**МОРЗАЛА́Р** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 478 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кошчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1647–51 дән Елева авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Кокеев, Мурзицы, Починок Урекеев исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 711 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 327, 1897 дә — 474, 1908 дә — 575, 1920 дә — 565, 1926 да — 527, 1938 дә — 755, 1949 да — 498, 1958 дә — 504, 1970 тә — 513, 1979 да — 444, 1989 да — 391, 2002 дә — 455 кеше.

**МОРЗАХА́НОВ** Галләм Гыймади улы (27.3.1925, Зөя кантоны Татар Наратлысы а. — 25.5.1990, Казан), Сов. Союзы Герое (7.3.1945), матрос. Сугышка кадәр тракторда эшли. 1943 елдан СССР Хәрби-диңгез флотында. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 66 нчы төтен маскировкасы һәм газсызландыру аерым отряды строевое (Днепропетровск хәрби флотилиясе). 1944 нең июлендә Пинск шәһәре өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: 5 десант опера-

циясендә катнаша, дошманның 5 ут ноктасын юк итә. 1944 тә авырып демобилизацияләнә. «Комсомолец» к-зында (Яшел Үзән р-ны) ревизия комиссиясе рәисе булып эшли. 1947–55 елларда ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза Военно-Морского флота. 1937–1945. М., 1977; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОРКВА́Ш** елгасы, Идел алдында, Идел елгасының уң кушылдыгы. Югары Ослан р-ны терр-ясеннән ага. Озынлыгы 14,4 *км*, бассейнының мәйданы 87,9 *км*². Елга башы Никольский посёлогыннан 2 *км* көнбатыштарак, тамагы Яр буе Морквашы авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы 53 *м*. Су җыелу мәйданының өслеге ерым, сыза һәм кушылдык үзәннәре б-н нык кына ергаланган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. М.ның 0,7 дән алып 5,2 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су мullлыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Корылыклы елларда М. һәм аның күп кенә кушылдыклары урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу вакытында су катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. М. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. М. бассейнында табигать истәлеге *Кликовка сөзәклеге* урнашкан.

**МОРКИ́ РАЙОНЫ́**, Мари Республикасының көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 2272 *км*². Үзәге — Морки посёлогы (Йошкар-Оладан 114 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 30391 (2012), татарлар — 2700 кеше (2010). Татарлар, башлыча, Күлбаш (644 кеше), Кышна (354), Татар Чодраялы (Мари Комыргуҗасы (283), Ишли-Пичуш (112), Шиньша һәм Петровское (138 кеше) авылларында, Морки (715), Октябрьский (396), Зеленогорск (230), Мамай посёлокларында яшиләр (2002). 1919–63 елларда Куян исемле татар авылы була. 1917 гә кадәр район терр-ясендә 4 мәчет һәм мәдрәсә эшли. Хәзерге вакытта мәчетләр Татар Чодраялы (1998 дән), Кышна (2001 дән) авылларында, Морки посёлогында (2004 тән) бар. Күлбаш, Кышна, Ишли-Пичуш авылларында мәчет биналары (19 йөз уртасы — 20 йөз башы) саклана. Күлбашта мәдәният йорты, татар урта мәктәбе, китапханә (8700 данә китап бар), Кышнада «Ялкын» муз. студиясе (1993), Татар Чодраялында «Яшьлек» муз. студиясе (1991 дән) эшли. М.р.нда РФ нең атказ. а.х. хезмәткәре Х.С.Җиһаншин туган.

*М.С.Алексеева.*

**МОРКО́ВНИКОВ** (Марковников) Владимир Владимирович (16.1.1866, Казан губ., Чистай өязе Дмитриевка а. — 1918 дән соң), җәмәгать эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Җирбиләүче (Чистай өязендә 992 дис. җире була). Мәскәү ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1891). 1891–1900 елларда Чистай өязе земство идарәсендә 3 нче участок башлыгы, 1900–04 тә Казан земство идарәсе рәисе, 1904–12 дә Казан губернасының а.-х. инспекторы. Земство эшлеклеләре киңәшмәсе (С.-Петербург, апрель 1903), Бөтенземство съездлары (С.-Петербург, 1904 нең ноябре; Мәскәү, 1905 нең апреле) эшендә катнаша. «Унҗиденче октябрь берлеге» партиясенең Казан бүлеге әгъзасы. 1912–17 дә 4 нче Дәүләт Думасы депутаты, сәүдә-сәнәгать комиссиясе әгъзасы (секретаре). 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, бронза медаль б-н бүләкләнә.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МОРО́ЗОВ** Валерий Иванович (28.11.1955, Кама Тамагы р-ны Куйбышев исем. Затон эшчеләр посёлогы), балалар хирургы, мед. фән. д-ры (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук, балалар хирургиясе кафедрасында эшли, 1996 елдан — хирургия һәм урология кафедрасында. Хезмәтләре яңа туган балалар патологиясенә, балаларда ашказаны-эчәк трактында нейроген дискинезия очракларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Нейрогенные дисфункции висцеральных органов у детей (хирургические и педиатрические аспекты). К., 2008 (автордаш); Неврологические аспекты хронического обстипационного синдрома у детей // Казан. мед. журн. 2009. № 2 (автордаш); Редкий случай натальной травмы печени у новорождённого // Вестн. совр. клинической медицины, 2012. № 4 (автордаш).

**МОРО́ЗОВ** Василий Петрович (? — 1631), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1607). 1591 елда стольник, 1598 дә Кырым татарлары һөҗүме вакытында патша полкында башлык һәм есаул. 1604 тә Ялган Дмитрий I гә каршы яуда катнашкан алдынгы полкта 2 нче воевода. 1606 ның маенда Ялган Дмитрий I не бәреп төшерүгә һәм тәхеткә Василий Шуйский килүгә китергән фетнәдә катнаша. Полк воеводасы, 1606 ның көзендә Мәскәү, 1607 дә Тула һәм Калуга янында И.И.Болотников гаскәре б-н сугышларда катнаша. 1608 дә Мәскәү янында Ялган Дмитрий II тарафдарлары б-н сугыша. 1609 ның 12 апреленнән Казанда 1 нче воевода. Б.Я.Бельский б-н берлектә патша Василий Шуйский ягында Урта Идел буендагы хәрби хәрәкәтләр б-н җитәкчелек итә. 1611 нең июнендә Казан дворяннары, укчылары һәм йомышлы татарлары башында 1 нче ополчениегә җибәрелә, Мәскәү янында сугышларда катнаша. Ополчение таркалгач, Түбән Новгород (2 нче) ополчениесенә кушыла. 1612 нең башыннан К.Минин һәм кенәз Д.М.Пожарский б-н берлектә Земство хакимияten җитәкли һәм полякларга каршы хәрби хәрәкәтләр б-н идарә итә. 1613 елгы Земство җыенында катнаша, 13 февральдә, беренчеләрдән булып, халыкка Михаил Фёдоровичның патша итеп сайлануын игълан итә. 1615–16 да Псков шәһәрендә 1 нче воевода, 1616 да шәһәрне шведлардан саклау б-н уңышлы җитәкчелек итә; соңыннан Столбово килешүенә кул куела. 1627–28 дә Казанда 1 нче воевода; 2 нче воевода В.В.Волынский б-н ызгышканнан соң, икесе дә вакытыннан алда Мәскәүгә чакыртып алыналар. 1629 дан Владимир мәхкәмә приказы судьясы.

*Е.В.Липаков.*

**МОРО́ЗОВ** Виктор Валентинович (9.4.1946, Казан), санитария табибе, сәламәтлек саклау органнары эшлеклесе, ТРның атказ. табибе (1993). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), Киров өлкәсенең Верхочижемский р-ны санэпидстанциясендә баш табиб булып эшли. 1973–74 елларда Казанның Киров р-ны санэпидстанциясе сан. табибе. 1974–76 да ТАССР МС каршындагы Җәмәгать туклануы идарәсенең үзәк санитария-азык-төлек лаб-ясендә сан. табибе, 1976–78 дә лаб. мөдире. 1978–82 дә Казанның Идел буе р-ны санэпидстанциясе баш табибе. 1882–84 тә КПССның Казан шәһәр ком-тының адм. һәм сәүдә-финанс органнары бүлеге инструкторы. 1984–92 дә Республика санэпидстанциясе баш табибе, ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары; 1992–2001 дә ТРның Дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге ком-ты рәисе; ТРның дәүләт баш сан. табибе. 2001 дән «Татарстан Республикасында дәүләт сан.-эпид. күзәтчелеге үзәге» федераль дәүләт учреждениесе баш табибе. Хезмәтләре әйләнә-тирә мохитнең сыйфатын һәм ТР халкының сәламәтлеге торышын өйрәнүгә карый. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Перфторографические соединения в биологии и медицине. Пущино, 2001; Природные очаги зооантропонозов трансформированных ландшафтов во второй половине XX в. К., 2001; О санитарно-эпидемиологической обстановке в РТ в 2009 г. К., 2010; О санитарно-эпидемиологической обстановке в РТ в 2010 г. К., 2011.

**МОРО́ЗОВ** Владимир Владимирович (15.12.1910, Вологда ш. — 1.1.1975, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1943), проф. (1944). ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). 1930 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан мед. ин-тында (1934 кә кадәр) һәм Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында (1932–41) эшли. 1941 дән Казан ун-тында, механика-матем. ф-ты деканы (1944–45), алгебра каф. мөдире (1947–70), бер үк вакытта Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (1947–53), алгебра кафедрасының фәнни консультанты (1970 тән). Хезмәтләре алгебрага һәм математика тарихына карый. М. комплексы примитив Ли төркемнәренә үзе исбатлаган «регулярлык теоремасы» нигезендә тулы классификация бирә. Аның җитәкчелегендә нильпотент һәм зур үлчәнешле булмаган чишелешле алгебраларны классификацияләү алымнары үстерелә, Чеботарёв резольвентлары проблемасы буенча нәтиҗәләр алына. М. Казан ун-тында матем. тарихы мәсьәләләре, француз, немец, инглиз телл-

реннән фәнни һәм әдәби тәрҗемәләр б-н шөгыльләнә. Н.Г.Чеботарёв хезмәтләре җыентыгының мөхәррире була. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О некоторых вопросах проблемы резольвент // Уч. зап. Казан. ун-та. 1954. Т. 114, кн.2; Об уравнении пятой степени // Уч. зап. Казан. ун-та. 1955. Т. 115, кн.14; Классификация нильпотентных алгебр Ли шестого порядка // Изв. вузов. Математика. 1958. № 4.

*Әд.:* Д о р о д н о в А.В., С у л ь д и н А.В., Э с к и н Л.Д. Владимир Владимирович Морозов (К 60-летию со дня рождения) // Изв. вузов. Математика. 1970. № 3.

**МОРО́ЗОВ** Владимир Гаврилович (15.7.1923, Пенза губ. Надеждино а.), хирург, мед. фән. д-ры (1970), проф. (1971). Проф. В.Н.Шубин шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда эшкә калдырыла, 1957 елдан гомуми хирургия кафедрасында, 1961–91 дә каф. мөдире, 1997 гә кадәр проф.-киңәшче. Хезмәтләре авыртуны басу төрләренә һәм операциягә әзерләү үзенчәлекләренә бәйле рәвештә организмда барган окисьлашу-төзәлү процессларын өйрәнүгә; кайбер авырулар вакытында канны оету системасының аерым компонентлары тирбәнешләрен ачыклауга карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар (сыеклыкны тире астына кертү аппараты, 1957; уртак үт юлын дренажлау ысулы, 1982). Бөек Ватан сугышы ветераны. Ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Перфорации «простых язв» тонкого кишечника // Казан. мед. журн. 1961. № 1; Профилактика послеоперационных тромбозов и эмболий // Клиническая хирургия. 1963. № 8; Синдром Монтореля // Клиническая медицина. 1984. № 9; Хирургическое лечение гнойно-некротических поражений стоп при сахарном диабете // Хирургия. 1988. № 4.

**МОРО́ЗОВ** Владимир Петрович (13.11.1955, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2009), ТРның атказ. геологы (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), ЦНИИгеолнерудта эшли. 1986 елдан Казан ун-тында, минерал. һәм петрография каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре литология, минерал., рентгенография, оптик микроскопиягә карый. Карбонатлы токымнарда — нефть ятмалары коллекторларында икенчел кавернозлык формалашу моделен эшли.

Х е з м.: Карбонатные породы турнейского яруса среднего карбона. К., 2007 (автордаш); Карбонатные породы визейского, серпуховского и башкирского ярусов нижнего и среднего карбона. К., 2008 (автордаш); Литология нефтеносных карбонатных отложений. Турнейский и башкирский ярусы юго-востока Татарстана. Saarbrucker, 2011 (автордаш).

**МОРО́ЗОВ** Геннадий Александрович (30.9.1940, Питрәч р-ны Питрәч а.), радиотехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2002). 1964 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Гамәли электродинамика фәнни-тикшеренү үзәге директоры (1988 дән). Хезмәтләре микродулкын технологияләренә, үтә югары ешлыклы (СВЧ) антенналарга һәм җайланмаларга карый. М. җитәкчелегендә хокук саклау органнары хезмәтендә мәгълүмат алмашу, Эчке эшләр министрлыгының мобиль объектлары тарафыннан оператив тикшерү һәм идарә итү радиосистемасы; милек саклау сигналларының мәгълүмат системасы; магистраль нефть үткәргечләрнең транспорт һәм су аша кичүләрен контрольдә тотуның оптоэлектрон алымнары (эшкәртмәләре ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән) эшләнә. Уйлап табуга 43 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының «Радиоэлектроника» советында «Микродулкын процесслары һәм комплекслары» секциясе рәисе (1995 тән). Медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1995 (автордаш); Системы экологического радиомониторинга: Проблемы и пути их решения // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1997. № 1 (автордаш); Низкоинтенсивные СВЧ-технологии (проблемы и реализации). М., 2003 (автордаш).

**МОРО́ЗОВ** Глеб Иванович (? — 7.12.1661, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, бояр (1638). Патша Алексей Михайловичның (1645–48) хөкүмәт башлыгы Б.И.Морозовның бертуганы, И.В.*Морозовның* өченче буын туганы, танылган боярыня Ф.П.Морозованың ире. 1642–45 елларда Новгород шәһәрендә, 1649–51 дә Казанда 1 нче воевода.

*Е.В.Липаков.*

**МОРО́ЗОВ** Иван Васильевич (? — 1656 дан соң), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1634). В.П.*Морозовның* улы. Кече воевода, polякларга һәм шведларга каршы сугышта (1615–17) һәм Россия–Польша сугышында (1632–34) катнаша. 1636–39 елларда Казанда 1 нче воевода. 1634–36, 1645–48 дә Владимир мәхкәмә приказы судьясы. 1649 елгы Кануннар мәҗмугасын төзүдә катнаша. 1655 тә монахлык кабул итә.

*Е.В.Липаков.*

**МОРО́ЗОВ** Иван Титович (1888–1957), партия эшлеклесе. Окт. рев-циясендә, Гражданнар сугышында катнаша. 1918–23 елларда Бөтенроссия металлургия эшчеләре профсоюзы ҮК секретаре һәм РКП(б)ның Самара губерна ком-ты секретаре. 1924–25 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. 1926 дан Казакъстанда партия эшендә. 1931–33 тә Әзәрбайҗанда Испарт мөдире. «Бакинский рабочий» г-тасы мөхәррире. 1934 тән Мәскәүдә хуҗалык эшендә. СССРның БҮБК һәм ҮБК әгъзасы.

**МОРО́ЗОВ** Николай Алексеевич (26.6.1947, Приморье краеның Иман ш.), кинооператор, кинорежиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997). Бөтенсоюз кинематография ин-тының операторлар ф-тын тәмамлый (1982). 1965 елдан, Казан авиация ин-тында укыганда, киногa төшерү б-н мавыга башлый (һәвәскәр). 1968 дән Казан телевидение студиясенең кино төркемендә, 1979 дан Казан кинохроника студиясендә оператор, 1994 тән «Эрго-медиум» мед. фәнни-җитештерү фирмасының «ЭРТ-видео» студиясе җитәкчесе һәм режиссёры. М.ның беренче операторлык эше — «КамАЗ. Династия барлыкка килү» («КамАЗ. Рождение династии», 1976, реж. Н.К.Вәлитов) фильмы; ул Ленинградта (1977) һәм Кишинёвта (1978) узган бөтенсоюз телевизион фильм фестивальләренең дипломнары б-н билгеләп үтелә. «Сабантуйга бару юлы» («Дорога на Сабантуй», 1980, реж. Н.К.Вәлитов) фильмы Респ-каның М.Җәлил исем. бүләгенә лаек була. Минскида күрсәтелгән «Түбән Кама варианты» («Нижнекамский вариант», 1985, реж. В.Е.Игнатюк) фильмы операторлык осталыгы өчен 13 нче Бөтенсоюз кинофестивале дипломы б-н бүләкләнә, «Космик соната» («Космическая соната», 1981), «Азнакай карабодае» («Азнакаевская гречиха», 1984) фильмнары СССР ВДНХсының бронза медаленә лаек була. «Без — пыяла өрдерүчеләр» («Мы — стеклодувы», 1977), «КамАЗ. Эш ритмнары» («КамАЗ. Рабочие ритмы», 1977), «Канатлану килсен сезгә» («И да придёт к вам окрылённость», 1978), «Карате. Буш кул» («Карате. Пустая рука», 1979) фильмнарында бер үк вакытта режиссёр вазифасын да башкара. М.ның режиссёр Р.Г.Хисамов б-н берлектә төшерелгән, яшь буынны тәрбияләү, балалар арасындагы җинаятьчелеккә каршы көрәш мәсьәләләрен яктырткан «Апрелия иле чакыра» («Зовёт страна Апрелия», 1987), «Бушлык» («Пустота», 1988), «Җан авазы. ПТУның эчке доньясы» («Крик. ПТУ не с парадного подъезда», 1989) фильмнары аеруча зур иҗтимагый яңгыраш ала. «Яшьләрнең хәтәр уеннары» («Страшные игры молодых», 1988) фильмы киң экранга чыга, инглиз теленә тәрҗемә ителгәннән соң, 1990 да Дәһли шәһәрендә узган Халыкара кино фестивалендә күрсәтелә. М. ш.у. Татарстан милициясе эшчәнлегенә багышланган «Һәм бу — без сайлаган һөнәр» («И это был наш выбор», 2001, РФнең Эчке эшләр министрлыгы дипломы), «Исән-сау әйләнеп кайту» («Вернуться живыми», 2003, Чечняда хезмәт итү турында), автор җырларына багышланган «Җырлыйбыз, димәк, без исән» («Мы живы, покуда поём», 1996, «Эфир» телестудиясе), «Өч аккорд» («Три бардовских аккорда», 1997, «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясе) фильмнарын төшерә. М. фәнни-популяр кино үсешенә саллы өлеш кертә, аның җитәкчелегендә яңа эндохирургия методикалары һәм технологияләре турында дистәләрчә фильм төшерелә. Алар нигезендә РФ һәм БДБ илләре терр-ясендә эшләүче хирурглар белемнәрен яңарта. Португалиядә уздырылган 1 нче Халыкара FILMO-BIDOS-97 мед. фильмнары фестивалендә М.ның «Россиянең гади халыктан чыккан лидеры» («Российский лидер из глубинки») фильмы Россияне тәкъдим итә. 15 елдан артык ул ТР Кинематографистлар берлегенең операторлар секциясен җитәкли, шәкертләре арасында Д.Яшонков, Г.Морозов, Ә.Габдрәкыйпов һ.б. бар. Казан ТЮЗы спектакльләренең шактый гына видеоверсияләрен төшерә. Төрле тормыш күренешләренә, үзгәрешләргә һәрвакыт игътибарлы булуы, үзенчәлекле, кабатланмас чишелешләр эзләве һәм

табуы, камерасының җитезлеге, кадрының күппланлылыгы М.ның эшен Татарстан Респ-касы кинодокументалистикасында зур казаныш итә.

*Е.П.Алексеева.*

**МОРО́ЗОВ** Николай Васильевич (25.3.1940, Саба р-ны «Алга» участогы), биолог, биол. фән. д-ры (2003), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1968), Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү ин-тының (Ленинград) Казан гидрология һәм су ресурслары бүлегендә эшли, суны саклау һәм аның сыйфатын көйләү лаб-ясе мөдире (1975–86). 1987 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында, үзе оештырган биотехнол. каф. мөдире, 2002–2010 да ботаника һәм биотехнол. экологиясе каф. мөдире. Бер үк вакытта «Биотехнология» ФҖБ директоры. 2011 дән Казан ун-тының микробиол. нигезләре һәм биотехнол. лаб-се мөдире. Хезмәтләре экология мониторингы, әйләнә-тирә мохит компонентлары б-н идарә итүгә һәм аларны көйләүгә карый. М. су ресурсларын чистарту һәм зарарсызландыруның яңа алымнарын эшли, алар исә халык хуҗалыгында: ТР («Татнефть» АҖ, Менделеев химия з-ды һ.б.) һәм РФнең («Оренбургнефть», Краснодар химия з-ды һ.б.) сәнәгать пр-тиеләрендә кулланыла. Кече елгалардан файдалану, аларны көйләү, саклау, ш.и. су хуҗалыгын исәпләү алымнарына багышланган «Россиянең кече елгалары» («Малые реки России». Свердловск, 1988) монографиясе авторларының берсе. СССР ВДНХсының бер көмеш һәм ике бронза медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биометоды регулирования качества поверхностных вод, загрязнённых сточными водами животноводческих комплексов. К., 1997; Экологическая биотехнология: очистка природных и сточных вод макрофитами. К., 2001.

**МОРО́ЗОВ** Олег Викторович (5.11.1953, Казан), сәясәт эшлеклесе, филос. фән. канд. (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук фәнни коммунизм кафедрасында эшли (1985 елга кадәр), 1985–87 дә партия ком-ты секретаре урынбасары. 1987–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1989–91 дә КПСС ҮКнда инструктор, референт, ҮК секретаре ярдәмчесе. 1991–94 тә «Республика Татарстан» г-тасының сәяси күзәтүчесе, «Биотехнология» АҖнең ген. директоры урынбасары (Мәскәү). 1994–95 тә РФ Дәүләт Думасының Федерация эшләре һәм региональ сәясәт ком-ты әгъзасы, 1996–99 да рәисе урынбасары, бер үк вакытта, 1996 дан, «Россия төбәкләре» төркеме рәисе урынбасары, 1997–2003 тә «Россия төбәкләре (Бәйсез депутатлар берлеге)» төркеме рәисе, «Бөтен Россия» хәрәкәте сәяси советы президиумы әгъзасы, башкарма ком-ты рәисе, «Ватан — бөтен Россия» координацион блогының җаваплы секретаре, 2004 тән РФ Дәүләт Думасы рәисе урынбасары, 2005–11 дә — 1 нче урынбасары, 2011–12 дә РФ Федераль җыенының Дәүләт Думасы рәисе урынбасары. 2012 дән РФ Президенты Администрациясенең эчке сәясәт идарәсе башлыгы. Хезмәтләре философия, политология мәсьәләләренә карый. 1987–89 да ТАССР ЮС, 1993–2012 дә РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты. 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Критика буржуазных фальсификаций социалистического интернационализма. К., 1984; Дума: Россия, которую мы выбираем. М., 2007.

*Әд.:* С а м о й л о в В.А. Олег Морозов. Золотая середина: Страницы биографии. К., 2003; Казанский университет (1804–2004): библиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**МОРО́ЗОВ** Олег Геннадьевич (30.10.1960, Казан), радиотехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004). 1983 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1979 дан), квант электроникасы һәм лазер технологиясе лаб-ясе мөдире (1989–93), радиоэлектрон һәм квант җайланмалары каф. профессоры (2004 тән), телевидение һәм мультимедия системалары кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире вазифаларын башкаручы (2005 тән). Хезмәтләре лазерлы, оптик-җепселле, микродулкынлы үлчәү һәм телекоммуникация системаларына карый. М. бер ешлыклы когерент нурланышны ике ешлыклы симметрикка әверелдерүнең амплитуда-фазалы алымын; атм. газларының йотылу сызыклары контурларын ике ешлыклы күчергеч зондлау принципларын; ике ешлыклы симметрик лидар системалар, транспорт чараларының структур бөтенлеген тикшерүче оптик-җепселле системалар һәм аларга датчиклар төзүнең фәнни-техник нигезләрен эшли. М. эшкәртмәләре ТР һәм РФ пр-тиеләрендә, Гамәли оптика ин-тында (Казан), Аэросыгылма системалар фәнни-тикшеренү ин-тында (Украина) гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар.

Х е з м.: Низкоинтенсивные СВЧ-технологии (проблемы и реализации). М., 2003 (автордаш); Перспективные методы и средства траекторных измерений. К., 2005 (автордаш); Reflectometry in open and fiber mediums: technology transfer // Optical Technologies for Telecommunications / Proceedings of SPIE. 2005. V. 5854 (автордаш).

**МОРТ** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 24 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 889 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Агропромхимия һәм а.х. техникасы пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле эшкә яллана. 20 йөз башында М.та 2 мәчет, 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2731,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән Костенеево р-нында. 1944 нең 8 июненнән — Морт р-ны үзәге. 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 885, 1887 дә — 1656, 1905 тә — 2128, 1920 дә — 2047, 1926 да — 2372, 1938 дә — 2206, 1949 да — 1759, 1958 дә — 1689, 1970 тә — 1379, 1979 да — 1134, 1989 да — 1026, 2002 дә — 878 кеше.

**МОРТ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә *Костенеево районы* буларак оештырыла, адм. үзәге Костенеево авылы була. 1944 нең 8 июнендә район үзәге Морт авылына күчерелгәч, район М.р. дип атала башлый. 1948 дә районда 19 авыл советы, 52 торак пункт исәпләнә. 1954 нең 19 ноябрендә, биләмәсе Алабуга р-нына бирелү сәбәпле, район таркатыла.

**МОРТАЗА́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 395 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Мортаза исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1289 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Александровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 309, 1889 да — 502, 1910 да — 917, 1920 дә — 874, 1926 да — 694, 1938 дә — 684, 1949 да — 581, 1958 дә — 445, 1970 тә — 547, 1979 да — 492, 1989 да — 367, 2002 дә — 380 кеше.

**МОРТАЗА́ *бине́* ГАБДЕЛГАЗИ́З *бине́* БИКМӨХӘММӘ́Т** (18 йөз башы, Уфа өязенең Казан даругасындагы Каратай а., хәзер Лениногорск р-ны Зәй-Каратай а. — 1797, Казан), дин эшлеклесе, язучы. Кышкар мәдрәсәсендә белем ала. Казанда имам-хатип булып тора. «Нигъмәтулла» (1754) исемле дини-дидактик китап авторы.

*Әд.:* Ф ә х р е т д и н Р. Асар. Оренбург, 1901. 2 җөзья.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МОРТАЗА́ *бине́* ГАЛИ́ әл-БИЗНӘВИ́** (? — 1744 яки 1745), дин эшлеклесе, илаһият галиме. Сембер губернасының Буа өязе Татар Бизнәсе авылы мәчете имамы һәм мәдрәсә мөдәррисе. Хезмәтләре илаһиятка, тел белеменә, ш.и. «Мохтасар әз-Зәнҗани»га (әз-Зәнҗанинең кыскача бәяны, 1691) карый.

**МОРТАЗА́ *бине́* МОСТАФА́** (19 йөз), шагыйрь. Фольклор-әкияти хәлләр чынбарлык тормыш күренешләре б-н үрелеп барган «Хәзрәти Зөлкарнәйн Дахма Шаһангa барганлары кыйссасы» (1889) дастаны авторы. Әсәрнең төп герое Искәндәр (Александр Македонский) шаһлар (Фирдәүсинең «Шаһнамә» поэмасы геройлары) каберлегенә сәяхәт кыла. Кара көчләрнең каршы торуын җиңеп, шаһларның юлламалары сакланган табутлар янына үтеп керә. Ул юлламаларда түрәләр үзләренең гаделсез яшәүләре, фәкыйрь-ярлылар турында кайгыртмаулары, үзләре башла-



К.А. Мортазин.



М.Ш. Мортазин.

ган сугышларның халыкка зур бәла-казалар китергәне өчен үкенәләр. Карашларына каршы килгән бу сүзләр Македонскийның ачуын чыгара, һәм ул үз ихтыярына каршы чыккан һәр кешене үтерү б-н яный.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.

*А.М.Ахунов.*

**МОРТАЗА́ әс-СИМЕТИ́** (?, Казан өязе — 1723 тән соң, Мамадыш өязе Симет а., хәзер Саба р-ны), илаһият галиме, мөдәррис. Ясәвийә суфичылык борадәрлеге тарафдары. Дагстанда укып кайтканнан соң, туган авылында мәдрәсә ача. Казан ханлыгы яулангапнан соң, татарлар арасында беренчеләрдән булып, хаҗ сәфәреннән (1697–98) алган тәэсирләре нигезендә язылган бәянында М.ә.-С. мөселман пәйгамбәрләренең, изгеләренең — әүлия һәм шәехләрнең каберләрен, изге урыннарны тасвирлый. Иң мөхтәрәм татарлар арасыннан ул төрле суфичылык борадәрлекләрендәге сөнни һәм шигый илаһият галимнәренең, шәехләренең исемнәрен атый. Көндәлек биш вакыт намаз уку тәртибе, мөселман кагыйдәләрен сакламый чалынган корбан итен кулланудан тыю, рус хатын-кызлары б-н никахлашуга юл куймау кебек мөселман догматикасына караган күп кенә хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Ислам на европейском Востоке. К., 2004.

**МОРТАЗА́ ХАН** (? — 1515 тән соң), Олы Урда ханы (1480–91, бүленеп). *Әхмәд ханның* өлкән улы. Атасы вафатыннан соң Олы Урда тәхетенә утыра, ханлыкның бердәмлеген торгыза. Речь Посполита б-н илчелекләр алмаша. Кырым ханлыгы б-н сугышлар алып бара, 1485 елда Миңлегәрәй ханга әсирлеккә эләгә. 1491–94 тә бертуганнары б-н тәхет өчен көрәштә җиңелә һәм Төньяк Кавказга качып китә, анда ул Төмән олысында идарә итә. Олы Урда Кырым ханлыгы тарафыннан җиңелгәч, Әхмәд ханның яңа ханлык оештыруга омтылыш ясаган варислары Төмән олысына качып китә (1515). М.х.ның шуннан соңгы язмышы билгесез.

*Әд.:* Н е к р а с о в А.М. Международные отношения и народы Западного Кавказа (последняя четверть XV — первая половина XVI в.). М., 1990; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; З а й ц е в И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МОРТАЗИ́** Фәрит Фатыйх улы (29.6.1910, Златоуст ш. — 25.2.1996, Казан), эмбриолог, биол. фән. канд. (1941). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1932), Казан мед. техникумында эшли. 1934–36, 1946–70 елларда Казан ун-тында, бер үк вакытта, 1935 тән, Казан мед. ин-тында. 1841–42 дә, клиник эвакогоспитальнең рентгенология бүлеге башлыгы булып эшләгәндә, йомшак тукымаларда озак төзәлми торган утлы корал яраларын рентген б-н дәвалау алымын эшли (М.И.Гольдштейн б-н берлектә). 1942–46 да Казанның Свердлов р-ны сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1946 дан РФА КГҮнең Биол. ин-тында, гыйльми секретарь (1965 кә кадәр). Хезмәтләре цитофизиологиягә карый. М. амфибияләрдә саңак яралгысы үсешендә критик чорны билгели. Кайбер бодай коңгызы яралгыларының дифференциаль сизгерлеген ачыклый. Организм яралгыларының тышкы тәэсирләргә реакциясе бер типта булуын күрсәтә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Неспецифическая реакция устойчивости зародышей пшеницы к неблагоприятным воздействиям // Изв. КФАН СССР. Сер. биол. наук. 1963. Вып. 9; Реактивные изменения энергетического состояния зародышей и дыхания зерновок пшеницы // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1976. Сб. 6.

*Әд.:* Г о р д о н Л.Х. Фариду Муртази — 80 // Наука. 1990. 31 июля.

*Л.Х.Гордон.*

**МОРТА́ЗИН** Әнвәрбәк Гали улы (12.8.1941, Казан), тренер (футбол, алкалы хоккей), РСФСРның атказ. тренеры (1989), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (2002). РСФСРның Үзәк тренерлар мәктәбен (Мәскәү өлкәсенең Малаховка ш., 1971), Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын (1979) тәмамлый. 1963–65 елларда Урицкий исем. спорт клубының Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә футбол һәм хоккей буенча тренер (Казан), 1966–70 тә «Нефтяник» мастерлар футбол командасында (Бөгелмә) уйный, 1970–72 дә «Гаро» з-дында («Гараж һәм авторемонт җиһазлары», Казан) физик тәрбия инструкторы, 1972–76 да «Радиоприбор» ҖБнең «Электрон» футбол командасында өлкән тренер, 1976–93 тә олимпия резервы «Рубин» махсус балалар-яшүсмерләр мәктәбендә (Казан) футбол буенча тренер-укытучы. 1993–94 тә ТР Футбол федерациясенең тренерлар советы рәисе, 1994–98 дә ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тының Үзәк спорт клубында әйдәп баручы белгеч, 1998–2005 тә алкалы хоккей буенча олимпия резервы «Бөркет» Республика махсус балалар-яшүсмерләр мәктәбендә директор, 2006 дан «Рубин» футбол клубында тренер-селекционер. Шәкертләре арасында — Ә.Әкбәров, И.Яшагин (РСФСР яшүсмерләр җыелма командасы), А.Абайдулов, Р.Хәлиуллин (РСФСР җыелма командасы составында СССР яшүсмерләр беренчелекләрендә җиңүчеләр, 1987), Р.Хуҗин (РСФСР җыелма командасы составында ике Бөтенсоюз яшүсмерләр уеннарында җиңүче, 1988). РСФСР тренерлар смотр-конкурсында 1 нче бүләк лауреаты (1987).

**МОРТА́ЗИН** Кәрим Абдулла улы (1920, Украина ССРның Харьков ш. — 25.4.1946, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (16.1.1944, 20.2.1945, 15.5.1946), гв. өлкән сержанты. 1943 елның февраленнән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 104 нче аерым гв. сапёрлар батальонында отделение командиры (53 нче һәм 5 нче удар армияләрнең 89 нчы гв. укчы дивизиясе). Дала, 2 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (икесе дә — 1943), Кировоград, Корсунь-Шевченко, Дебрецен (барысы да — 1944), Варшава-Познань һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1945) катнаша. 1944 нең 5 гыйнварында Глубокая Балка (Кировоград өлкәсе) посёлогы тирәсендә (миналы кырлар аша бернечә үтү юлы ясый); 1945 нең 14 гыйнварына каршы төндә Варка шәһәреннән (Польша) көньяктарак (сапёрлар төркеме составында миналы кыр аша үтү юлы ясый); 1945 нең 14 апрель төненә каршы Одер елгасының сул ярындагы Киц торак пунктыннан (Германия) төньяк-көнбатыштарак (сапёрлар төркеме б-н дошманның тимерчыбыклы тоткарлык сызыгы аша үтү юлы ясый) барган сугышларда батырлык күрсәтә. Сугыштан соң демобилизацияләнә. Харьков трактор з-дында эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОРТА́ЗИН** Мөхәммәтфатих Шиһабетдин улы (1875, Сембер губ., Сембер өязе Сөндек а. — 1938, Куйбышев ш.), журналист, дин эшлеклесе. Башлангыч белемне туган авылында ала, 1904 елда, мәдрәсәне тәмамлагач, Самара мәчетенең имам-хатибы була. 1907–13 тә — Татар мөселман җәмгыяте рәисе. Әлеге җәмгыять ярдәме б-н Самарада мөселман китапханәсе, китап кибете ачыла, өлкәннәр өчен укырга-язарга өйрәтү курслары оештырыла, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтелә һ.б. Иҗтимагый эшчәнлеге б-н риза булмаган Эчке эшләр министрлыгы 1913 нең 17 мартында аның эшен туктата. М. татар телендәге иң беренче икътисади вакытлы матбугат органы *«Икътисад»* (1908–1913) ж-лының нашире һәм мөхәррире була, «Вакыт», «Йолдыз» г-талары, «Шура» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. Дини һәм наширлек эшчәнлеген эшмәкәрлек б-н бергә алып бара, Самара кредит банкы составына керә. Рус интеллигенциясе вәкилләре б-н аралаша, Л.Н.Толстой б-н языша. Самара мәчете мөселманнар яшәгән төбәкнең рухи-мәдәни үзәгенә әверелә; М. монда Г.Тукай, Ф.Кәрими, Г.Кутуй һ.б. б-н очраша. Бөтенроссия мөселманнар корылтае (С.-Петербург, 1906) делегаты, мөфти М.Солтановның 25 еллык эшчәнлегенә багышланган Россия мөселманнар җыены делегаты (Уфа ш., 1911). Окт. рев-циясеннән соң имамлык хезмәтен дәвам итә. 1932 дә сөргенгә җибәрелгән мөселманнар, мөселман руханилары файдасына матди ярдәм күрсәтүне оештырганы өчен хөкем ителә; Ак диңгез–Балтыйк каналы төзелешенә 2 елга эшкә җибәрелә. 1937 дә икенче мәртәбә кулга алына, 1938 дә атып үтерелә; үлгәннән соң акланә.

*Әд.:* Р ә м и И., Д а у т о в Р. Әдәби сүзлек. К., 2001; Г а з и з у л л и н Ф.Г. Становление и разви-

тие социально-экономической мысли татарского народа. СПб., 2004.

*М.А.Сәгыйров.*

**МОРТА́ЗИН** Наил Җиһанша улы (15.2.1938, Яңа Писмән р-ны Яңа Елховой а.), нефтьче, «Татнефть» АҖнең «Җәлилнефть» НГДУы башлыгы (1986–2001), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1989), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1993). Хезмәт эшчәнлеген 1958 елда «Татнефть» АҖнең «Әлмәтнефть» нефть промыселы идарәсендә катлам басымын саклау цехының машинист ярдәмчесе буларак башлый. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), «Әлкинефть» нефть промыселы идарәсендә эшли: мастер, участок башлыгы, цехның өлкән инженеры. 1968 дән «Җәлилнефть» НГДУында: нефть промыселы өлкән инженеры, үзәк инженер-диспетчерлык хезмәтенең смена башлыгы, фәнни-тикшеренү һәм җитештерү эшләре цехы башлыгы, производствога хезмәт күрсәтү базасы башлыгы, НГДУ башлыгы урынбасары, башлыгы киңәшчесе (2001–03). 1972–76 да идарә парткомы секретаре. Респ-ка нефть-газ чыгару сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Сарман р-ны шәһәр тибындагы Җәлил посёлогының мактаулы гражданы (1998).

**МОРТА́ЗИН** Рәүф Әхмәт улы (15.1.1910, хәзер БРның, Баймак р-ны Темәс а. — 10.4.1994), композитор, педагог, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1937–41 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт студиясендә (Г.Литинский, Е.Месснер, Ю.Яцевич класслары) укый. 1946 да Мәскәү консерваториясен композиция (В.Белог классы) һәм труба (С.Еремин классы) буенча, 1947 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт студиясен тәмамлый. 1947 дән БАССР Мәдәният министрлыгының муз. фольклор кабинеты мөдире. 1951–57 дә Уфа музыка уч-щесендә (труба классы) укыта. Башкорт АССРның Салават Юлаев исем. Респ-ка бүләге лауреаты. Бөек Ватан сугышында катнаша.

Төп әсәрләре: Б.Бикбай либреттосына «Азат» операсы (1948); Ф.Гаскәров либреттосына «Сабантуйда» вокаль-хореографик күренеш (1952); 7 симфония (1952, 1957, 1963, 1970, 1976, 1980,1984); оркестр б-н скрипка өчен концерт (1964); оркестр б-н труба өчен концерт (1987); скрипка, виолончель һәм фортепиано өчен трио (1944); фортепиано өчен квинтет (1976); фортепиано өчен трио (1986); 150 дән артык җыр һәм романслар һ.б.

*Әд.:* Е л о в с к а я И. Рауф Муртазин // Композиторы и музыковеды Башкортостана: Очерки жизни и творчества. Уфа, 2002.

**МОРТА́ЗИН** Рәшит Муса улы (17.5.1911, Оренбург губ. Троицк ш. — 23.1.1987, Казан), архитектор, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970). Троицкида «төзүче-десятник» белгечлеге буенча «Стройуч» һөнәри-техник мәктәбендә укый (1928), Казан коммуналь-төзелеш инженерлары ин-тыннан күчеп (1934), Ленинград коммуналь-төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлый (1937). 1937–59 елларда Казанның проектлау оешмаларында: архит-ра-төзелеш төркемнәре җитәкчесе, бүлекләр башлыгы.

1959–62 дә «Приволжгипросельхозстрой» ин-тының Казан ф-лы директоры, 1963–67 дә «Союзпромпроект» ин-тының баш архитекторы. Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләрендәге архит-ра-планлаштыру комплекслары һәм биналары (1950–70, П.А.Саначин һәм Г.А.Солдатов б-н автордаш), Яшел Үзәндәге Серго исем. з-дның мәдәният йорты (1954), Ирек мәйданындагы Казан авиация ин-тының уку корпуслары (1954–57, хәзер техник ун-т), Казанның Пушкин урамындагы элек



Р.М.М о р т а з и н. Казан техник университетының 2 нче корпусы. 1954–57. Ирек мәйданы ягыннан күренеше.

китап кибете урнашкан йорт һ.б.ның ген. планнары һәм күп биналар проектлары авторы. 1966–71 дә Казан төзүче-инженерлар ин-тында. СССР Архитекторлар берлегенең Татарстан бүлеге идарәсе рәисе (1941–43).

**МОРТА́ЗИН** Хәниф Мөбарәкҗан улы (26.9.1939, Кама-Тамагы р-ны Олы Кариле а.), ТРда физик культура һәм спорт хәрәкәтен оештыручы, РСФСРның атказ. тренеры (1987), РФнең атказ. физик культура хезмәткәре (1996). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын тәмамлый (1961). 1956–58 елларда Олы Карамалы урта мәктәбендә, 1960–62 дә Казанның 80 нче мәктәбендә физкультура укыта. 1964–68, 1974–83 тә Казан ун-тында укыта. 1968–74 тә «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятьнең Татарстан советы рәисе. 1983–2001 дә ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-ты рәисе. 2001 дән РФ Велосипед спорты федерациясе вице-президенты (Мәскәү). 2007 дән ТР «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте рәисе киңәшчесе. Шәкертләре арасында җиңел атлетика буенча РСФСР, СССР, Европа беренчелекләрендә медаль алучылар һәм чемпионнар В.А.Голованов, И.Доникевич, Л.В.Касатова, Р.И.*Кашапов,* Е.С.Мөхәммәтҗанова, Х.М.Салихов, В.Смелова бар. «Россиядә физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» билгесе б-н бүләкләнә. 2004 тән Кама Тамагы р-нында ел саен М. призына көрәш буенча респ-ка турниры уздырыла.

**МОРТА́ЗИН-ИМА́НСКИЙ** (Мортазин) Вәлиулла Гайназар улы (4.12.1885, Оренбург губ., Оренбург өязе Имангол а. — 10.7.1938), драма актёры, режиссёр, БАССРның халык артисты (1922), РСФСРның атказ. артисты (1935). 1907 елда И.Б.Кудашев-Ашказарский труппасына керә, 1907–15 тә (бүленеп) «Сәйяр» труппасында эшли. 1915 тә Оренбург шәһәрендә «Ширкәт» труппасын оештыра (1917 дә «Мортазин-Иманский театры» дип үзгәртелә); Гражданнар сугышы елларында 1 нче Рев-цион армиянең сәяси бүлеге каршында мөселман театры труппасына нигез сала. 1919 да башкорт проф. театрын (соңрак М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театры) оештыра; 1919–37 дә анда актёр, режиссёр, сәнгать җитәкчесе һәм директор була. 1922 дә әлеге театр труппасы б-н Петроградта эшли, спектакльләрдән җыелган акча Башкортстанда ачлыктан интегүчеләргә ярдәмгә тотыла. Бер үк вакытта БАССР Мәгариф халык комис-тында сәнгать бүлеге җитәкчесе, театраль тамаша пр-тиеләре идарәсе һәм БАССР ХКС каршындагы сәнгать эшләре буенча идарә башлыгы була. Теге яки бу рольне башкару ягыннан М.-И. С.Гыйззәтуллина-Волжская иҗатына якын тора. Ул тудырган образлар романтик төсмерләргә бай, дәртле, хисле булулары, сәхнә активлыклары б-н үзенчәлекле. Аеруча зур әһәмияткә ия булган тирән эчтәлекле рольләре: Фәхретдин («Мөсибәте Фәхретдин», Н.Вәзиров), Закир («Бәхетсез егет», Г.Камал), Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Кәрим («Яшь хатын», Д.Таждаров), Салих («Мөгаллим», Г.Исхакый), Салават, Карагол (Д.Юлтыйның шул исем. драмалары), Борис («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Фердинанд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Егор Булычёв («Егор Булычёв һәм башкалар», М.Горький). М.-И.ның режиссёрлык осталыгы уй-фикер төгәллеге, аныклыгы, форма бөтенлеге б-н аерылып тора. Ф.Әмирханның ул сәхнәләштергән «Тигезсезләр» пьесасы милли театр тарихында бер этап була. Беренчеләрдән булып, М.Фәйзинең «Галиябану», Х.Ибраһимовның «Башмагым» пьесаларын сәхнәгә чыгара; ш.у. Ж.Б.Мольерның «Ирексездән табиб» («Лекарь поневоле»), А.Деннериның «Хөкемдә хаталык» («Ошибка правосудия»), Һ.Һейненең «Әлмансур» («Альманзор»), А.Н.Островскийның «Төшемле урын» («Доходное место»), М.Горькийның «Мещаннар» («Мещане») әсәрләре буенча спектакльләр куя. «Сәйяр» труппасы һәм аның җитәкчесе Г.Кариев традицияләрен үстереп, М.-И. үзе оештырган труппаларда актёрлар б-н пед. эшчәнлек алып баруга зур игътибар бирә. Вакытлы матбугат битләрендә театр теоретигы буларак чыгышлар ясый, Т.Ченәкәй б-н берлектә «Татар театры тарихыннан» («Из истории татарского театра», М., 1926) китабын яза. Әлеге хезмәттә татар проф. театрының барлыкка килү һәм оешу тарихын беренче тапкыр эзлекле бәян итү омтылышы күзәтелә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.



В.Г. Мортазин-Иманский.

*Әд.:* Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Башкирский государственный академический театр драмы. Уфа, 1969; Смирнова Т. Татарский театр в Петрограде-Ленинграде // Казань. 2003. № 5/6; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996; Зөбәиров Э. Башҡорт дәүләт күсмә театры ауылдарҙа. Өфө, 1928.

*И.И.Илялова.*

**МОРТУ́К** (Eremopyrum), кыяклылар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 8 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — бодай М.ы (E. triticeum) бар; Көнбатыш Кама алдында һәм Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Корылыклы далаланган сөзәклекләрдә, юл буйларында үсә. 5–20 *см* биеклектәге үсемлек, күтәрелмә сабаклы. Яфрак җәймәсе яссы. Чәчәк төркеме — йомыркасыман-эллиптик кыска башак, 3–6 чәчәкле, берле, утырма, ян-яктан кысылган. Җимеше — бөртекчә. Апрель–майда чәчәк ата. Июньнән җимеш бирә башлый. Орлыктан үрчи. Терлек азыгы.

**МОРТЫШБА́Ш** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 285 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1755 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, 3 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3444,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 135, 1834 тә — 183 ир-ат; 1870 тә — 901, 1897 дә — 1299, 1913 тә — 1700, 1920 дә — 1551, 1926 да — 1121, 1938 дә — 1087, 1949 да — 755, 1958 дә — 580, 1970 тә — 529, 1979 да — 407, 1989 да — 236, 2002 дә — 300 кеше.

**МОРТЫШТАМА́К** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 4 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 458 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, авыл тарихы музее, мәдәният йорты, китапханә. 1735 тән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.та мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, 5 ярма яргыч, 5 әвен, 2 тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4442,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 110, 1834 тә — 144 ир-ат; 1870 тә — 861, 1897 дә — 1173, 1913 тә — 1599, 1920 дә — 1417, 1926 да — 1271, 1938 дә — 950, 1949 да — 721, 1958 дә — 510, 1970 тә — 629, 1979 да — 604, 1989 да — 537, 2002 дә — 506 кеше.

**МОРТЫШТАМА́К** посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 28 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (татарлар) яши. 1913 тә Мортыштамак авылыннан (хәзер Сарман р-нында) күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1920 дә 194, 1926 да — 177, 1949 да — 99, 1958 дә — 78, 1970 тә — 81, 1979 да — 55, 1989 да — 14, 2002 дә — 9 кеше.

**МОРФЕ́МИКА** (грек. morphḗ — форма), 1) телнең морфемалы төзелеше, сүзнең мәгънәле кисәге булган морфемалар җыелмасы; 2) тел белеменең морфемалар төзелешен һәм төрләрен, аларның бер-берсенә һәм, гомумән, сүзгә мөнәсәбәтен өйрәнүче тармагы. М. сүз, сүзформа, морфема, морф төшенчәләрен билгели һәм алар б-н эш итә. Татар грамматикасында «М.» термины беренче тапкыр М.З.Зәкиев тарафыннан кулланыла башлый («Татар грамматикасы», 1998, 1 т.). Тел бәрәмлеге буларак, сүз сөйләмдә грамматик формаларга ия була һәм сүзформа дип, ә сүзформадагы иң кечкенә мәгънәле кисәк морф дип атала. Мәсәлән, балаларга дигән сүзформада бала/-лар/-га морфлары бар. Төрле сүзформада кулланыла торган бер исемдәге, бер мәгънәдәге һәм бер-берсенә якын яңгырашлы морфлар берләшмәсе морфема дип атала. Мәсәлән, ат**тан**, эш**тән**, кул**дан**, үлем**нән**, баласы**ннан** сүзформаларында аерып күрсәтелгән -тан/-тән, -дан/-дән, -нан/нән, -ннан/-ннән кушымча (аффиксаль) морфлары бер морфемага — чыгыш килеше морфемасына берләшә. Бер мәгънәдәге, фонематик якынлык күзәтелмәгән морфлар төрле морфемаларга карый. Мәсәлән, уйла**т**, аг**ыз** сүзформалары мәгънәләре ягыннан бер-берсенә якын тора (эшкә боеру), әмма фонемаларда охшашлык юк, шуңа күрә алар төрле морфемаларга карый. Сүзформа бер яки берничә морфтан торырга мөмкин. Татар телендә сүзформа ясаучы морфлар өч төрле була: тамыр, кушымча, ярдәмлек. Тамыр морф лексик мәгънәне иясе аның төп өлешен белдерә. Тамыр морфтан башка сүзформа була алмый. Кушымча морф — *аффикс* һәрвакытта да грамматик мәгънә белдерә. Ярдәмлек морфлар мәгънәләре ягыннан сүз ясагыч, сүз бәйләгеч һәм модаль төрләргә бүлеп карала (ш.у.к. *Ярдәмлек сүзләр*). Татар тел белемендә сүзформаның барлык төрләндергеч кушымча морфларын аерып алганнан соң калган өлеше нигез дип атала (ш.у.к. *Сүз ясалышы*).

*Әд.:* Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. К., 2005; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

*Х.Х.Сәлимов.*

**МОРФОЛО́ГИЯ** (грек. morphḗ — форма һәм ...*логия*), 1) телләр системасының грамматик мәгънәләргә ия сүзләрне, аларның грамматик төркемнәрен, яшәеш һәм форма ясалыш законнарын берләштергән өлеше; 2) *грамматиканың* сүз төзелешенең төрле аспектларын сүз мәгънәсенең сүз төзүче морфемаларга бәйлелеге ноктасыннан чыгып өйрәнә торган бүлеге. Татар тел белемендә М. мәсьәләләре беренче тапкыр 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башында өйрәнелә башлый. Алар С. һәм И.*Хәлфиннәр*, И.И.*Гиганов*, А.А.*Троянский*, М.И.*Иванов* хезмәтләрендә яктыртыла. Рус грамматикалары үрнәгендә төзелгән беренче татар грамматикаларында рус фәнендә чагылыш тапкан сүзләрне төркемләү принципларының (аларның билгеле бер сүз төркемнәренә каравыннан чыгып), төрле грамматик категорияләрне, терминологияне аерып карау һәм аны тасвирлауның йогынтысы сизелә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында М.не өйрәнүче татар теле грамматикалары гарәп теле грамматикалары үрнәгендә төзелә. Аеруча әһәмиятле хезмәтләрнең берсе — К.*Насыйриның* «Әнмүзәҗ» (1895) китабы. 1910–40 елларда татар телен үз нигезендә өйрәнүгә борылыш күзәтелә, мөстәкыйль татар грамматикасы төзү эше активлаша. Ә.*Максуди*, Ш.*Иманаев*, Г.*Ибраһимов*, Г.Сәгъди, Җ.*Вәлиди*, М.*Корбангалиев*, Г.*Алпаров* хезмәтләрендә татар теле М.се мәсьәләләре шактый тулы яктыртыла, лингвистик терминология тикшерелә. 20 йөз уртасыннан морфологик берәмлекләрне аерып карау һәм төркемләүнең объектив критерийларын эзләп табуга зур игътибар юнәлтелә. В.Н.*Хангилдин*, Д.Г.*Тумашева*, М.З.*Зәкиев*, Ф.Ә.*Ганиев*, Д.Ә.*Сәлимова* хезмәтләрендә, ш.у. «Татар теле грамматикасы» (1–3 т., 1998–2002; «Татарская грамматика», т. 1–3, 1993–95) коллектив монографиясенең 2 нче томында сүзләрне төркемләүнең гомуми принциплары, сүз төркемнәрен аерып карауның төп критерийлары яктыртыла, хәзерге татар әдәби телендәге барлык сүз төркемнәренә төгәл характеристика бирелә.

*Әд.:* Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. К., 1959; Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле: Морфология. К., 1978; Татар грамматикасы. Морфология. М.-К., 2002. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Ганиев Ф.Ә. Татар теленең морфологиясе турында кыскача белешмә. К., 2009; шул ук. Вопросы морфологии татарского языка. К., 1980; шул ук. Татарский язык: Проблемы, исследования. К., 2000; шул ук. Способы действия глаголов в татарском языке. К., 2003; Закиев М.З. Общие проблемы татарской морфологии // Вопросы структуры татарского языка. К., 1986; Мифтахова И.Г. История татарских грамматик: В 2 ч. К., 1998–99; Салимова Д.А. Части речи: История изучения и вопросы классификации. К., 2004.

*Ф.Ш.Нуриева.*

**МОРФОНОЛО́ГИЯ**, *тел белеменең* төрле типтагы морфемаларның фонологик төзелешен, морфологик процесслар вакытында сүзнең фонетик төзелешендә бара торган үзгәрешләрне, ягъни морфонологик күренешләрне өйрәнүче тармагы. М. *фонетика*, фонология, *морфология, синтаксис* б-н тыгыз бәйләнештә тора. Татар тел белемендә морфонологик күренешләрнең түбәндәге төрләре билгеле:

1. Нигез кыскару: артикуляция өчен авыр булган фонемалар төркеменнән котылу һәм

авазларның гадәти ярашуын булдыру максатыннан, морфологик үзгәрешләр вакытында бер яки берничә аваз төшеп кала (гадәттә, бу хәл ике мөстәкыйль сүз арасында яки ике сүзнең дә нигезенә төрле аффикслар ялганганда күзәтелә), мәс.: а)исемнәр нигезенә яки тамырына тартым кушымчалары ялганганда: халык + ы = халкы (татар халкы); б)исемнәрдән иркәләү-кечерәйтү формалары ясалганда: әни + кәй = әнкәй һ.б.

2. Асемантик (бернинди дә мәгънә белдерми торган) фонема ялгану: микъдар саннарыннан бүлем саннары ясалганда, нигез б-н аффикс арасына асемантик [ш] фонемасы ялгана: алты + ш + ар = алтышар һ.б.

3. Фонемалар керешүе: бу күренеш бер үк төрле фонемалар очрашканда, ягъни морфема җөендә — бер үк фонемага беткән сүзгә шул ук фонемага башланган икенче компонент ялганган вакытта күзәтелә, һәм яңа гына барлыкка килгән сүзформада бер үк төрле ике фонеманың берсе төшеп кала. Мәс., алмашлыкларда: мин + не = мине, син + не = сине; исемнәрдә: рус теленнән (яки башка телдән) кергән алынмаларга аффикслар ялганганда — поезд + да = поезда, артист + та = артиста (искәрмә: сонантлар катнашкан тартыклар җыелмасы үзгәрешсез кала, биредә фонемалар йотылмый: цемент + та = цементта, йорт + та = йортта һ.б.).

4. Сузык һәм тартык морфонемаларның чиратлашуы. Татар теленең вокализмы өчен *сингармонизм* законы төп үзенчәлек булып тора. Сингармоник модельләр сузыкларның рәте (алгы һәм арткы рәт) һәм иренләшүе (ирен гармониясе) б-н билгеләнә. Бу үз чиратында универсаль сузык морфонемалар тудыра: -лар/-ләр (китаплар, дәфтәрләр); -да/-дә (аланда, өйдә); -нан/-нән (урманнан) һ.б. Тартыкларның чиратлашуы морфемалар җөендә күзәтелә: янәшә торган фонемаларның беренчесе аннан соң килә торган фонемага тәэсир итә һәм киресенчә: чик + ә = чигә, чап + а = чаба, ун + бер = [умбер], ак + рак = аграк һ.б. 1980 еллардан бирле татар тел белеменең М. тармагы М.З.Зәкиев һәм Д.Ә.Сәлимова тарафыннан тикшерелә. Ш.у.к. *Морфемика*.

*Әд.:* З ә к и е в М.З. Морфонология турында // Совет мәктәбе. 1983; Татар грамматикасы. М.-К., 1998. 1 т.; С ә л и м о в Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. К., 2005; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; З а к и е в М.З. О тюркской морфонологии // Советская тюркология. 1984. № 1.

*М.З.Зәкиев, Х.Х.Сәлимов.*

**МОРЯ́ШИЧЕВ** Николай Иванович (8.8.1890, Вологда губ., Кадниковский өязе Галичиха а. — 1.5.1972, Казан), спортчы, тренер (грек-рим көрәше), СССРның атказ. тренеры (1957). Спорт б-н Казанда «Беркут» (1908 дә), «Көч һәм сәламәтлек» (1911 дә) спорт җәмгыятьләрендә шөгыльләнә башлый. 1912–16 да көрәшче буларак Мәскәү, Киев, Ростов-Дон, Симферополь һ.б. шәһәрләр циркларында чыгыш ясый. 1932 дән Казан сәнгать пр-тиеләренең физик культура коллективларында көрәш буенча тренер. Шәкертләре арасында СССРның халыкара классл спорт остасы, СССР, Европа, дөнья чемпионатларында җиңүчеләр һәм медаль алучылар (В.М.Журавлёв, Н.В.*Измайлов*, Р.Җ.*Камалов*, Г.М.Кондратьев, И.М.*Мөхәрләмов*, Л.С.*Сәлимуллин*, Р.А.Хәйруллин, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*, Р.Р.Шәрәфетдинов) бар.

**МОСАБИ́РОВ** Мөнәвир Һади улы (25.2.1957, Алабуга р-ны Абалач а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), ТатНИПИнефтьтә (Бөгелмә ш.) эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1990 нан), скважиналарны стимуллаштыру лаб-ясе мөдире (2001 дән), бер үк вакытта Әлмәт нефть ин-тында, нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү һәм эшләтү каф. профессоры (2008 дән). Хезмәтләре нефть чыгаруны арттыруга, скважиналарның продукт бирүчәнлеген күтәрүгә карый. М. скважиналарның продуктлылыгын арттыруны нефть чыгаруның тулы технол. чылбырында скважина тирәсе зонасының коллектор үзлекләрен саклау, яңадан торгызу һәм яхшырту б-н бергә тикшерә. М. җитәкчелегендә катламнарны ачу, скважиналарның тавышын киметү һәм аларны юу, терриген һәм карбонатлы коллекторларны физик-химик эшкәртү, катламнарны су б-н яру, судан саклау эшләре өчен водородлы, углеводородлы һәм композицион нигездәге бер- һәм күпмаксатлы эшче сыекчалар эшләнә һәм камилләштерелә. Уйлап табуга 33 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге иясе (2009). «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологии обработки призабойной зоны нефтяного пласта в процессе подземного ремонта скважин. М., 2002; Концепция развития и рационального применения солянокислотных обработок скважин // Нефтяное хоз-во. 2003. № 4 (автордаш); Сохранение и увеличение продуктивности нефтяных пластов. К., 2007.

**МОСЕ́ЙКО** Сергей Васильевич (22.5.1960, Зеленодольск р-ны Юдино штп.), драма актёры, ТРның халык артисты (2005). Казан театр уч-щесен тәмамлый (1983). 1983–96 елларда һәм 1997 дән Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актёры, 1996 ның маеннан декабренә кадәр Чиләбе яшь тамашачылар театрында (ТЮЗ) эшли. Труппаның әйдәп баручы актёрларыннан берсе, Казан ТЮЗы сәхнәсендә шактый гына зур рольләр башкара. Табигый органика, сәхнәдәге мөлаемлык М.га Рыжий («Утрау», Э.Акопов), Одуванчик («Рядовойлар», А.А.Дударев), рәссам Федя («Искремас турында риваять», Ю.Т.Дунский, В.С.Фрид), Бадри Ломидзе («Чинар манифесты», А.Чхаидзе), Деметрий («Җәйге төндә кергән төш», У.Шекспир) кебек яшь герой образларын тудыруга булышлык итә. Персонаж характерының күпмәгънәлелеген, аның рухи дөньясының катлаулылыгын җиткерергә омтылу М.ның Коля Третьяк («Җимерү», Б.Л.Васильевның «Кич тә булды, иртә дә булды» романы буенча), Хома Брут («Панночка», Н.Н.Садур), Калибан («Давыл», У.Шекспир) рольләрендә аеруча күзгә ташлана. Ангус («Пыяла читлек», Д.Б.Пристли), Барон («Санта Крус», М.Фриш), дон Жуан (Ж.Б.Мольерның шул исем. әсәре буенча), Беренче актёр («Розенкранц һәм Гильденстернның үлеме», Т.Стоппард) образларын гәүдәләндергәндә, актёрның тәҗрибә туплаган оста булып өлгергәнлеге күренә. М. рольнең эчке сурәтен бөтен нечкәлекләре б-н яктырта, төсмерләр байлыгына, форманың сәнгатьчә җыйнаклыгына ирешә, бер үк вакытта характерның асылына тирәнтен үтеп керә белә.



С.В.Мосейко.



С.В.М о с е й к о Барон ролендә («Санта Крус», М.Фриш).

*Ю.А.Благов.*

**МО́СИН** Василий Васильевич (22.4.1917, хәзерге Калуга өлкәсенең Ульянов р-ны Вяльцево а. — 18.6.1998, Казан), ветеринар-хирург, вет. фән. д-ры (1958), проф. (1960), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1973). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), шунда ук эшли: оператив хирургия каф. мөдире (1961–90), бер үк вакытта (1959–78) проректор. М. авырулары йогышлы булмаган терлекләрне дәвалауда патогенетик терапия — үпкә ярысы өсте нерв системасына: карын нервлары һәм систематик нерв кәүсәсенә новокаин блокадасы ясау ысулын эшли һәм гамәлгә кертә; терлек печүнең рациональ ысулларын тәкъдим итә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979).

Х е з м.: Новое в лечении незаразных болезней сельскохозяйственных животных. М., 1975.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*А.Н.Корнишин.*

**МОСИ́ХИН** Сергей Борисович (30.3.1963, Казан), отоларинголог, мед. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1986). 1990 нан Казан шәһәренең 12 нче хастаханәсендә эшли. 1991 дән Казан мед. академиясенең оториноларингология кафедрасында. Хезмәтләре авыз һәм борын куышлындагы кискен ялкынсыну очракларында диагноз кую һәм авыруларны дәвалауга карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Значение анатомо-топографических особенностей для эндоскопической диагностики и лечения сфеноидитов // Казан. мед. журн. 1995. № 1 (автордаш); Функциональная эндоскопическая ринохирургия в секционной. К., 2012 (автордаш).

**МОСКАЛЕ́НКО** Николай Иванович (30.12.1939, Томск өлкәсе Ново-Успенка а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1982). 1963 елда Томск ун-тын тәмамлаганнан соң, Федераль ГИПО фәнни-җитештерү үзәгендә эшли, сектор (1975 тән), лаб. (1987 дән), бүлек (1991 дән) башлыгы, баш фәнни белгеч (1996 дан). 2000 нән Казан техник ун-ты каршындагы Физик-химик процесслар диагностикасы һәм алар б-н идарә итү фәнни-тикшеренү ин-тында экол. технологияләр лаб. башлыгы. 2000 нән Казан энергетика ун-ты профессоры. Хезмәтләре атмосфера оптикасына, спектроскопиягә, радиацион җылылык алмашуга карый. М. атмосфераның оптик модельләрен эшли, планетар атмосфераларда спектраль үткәрү функцияләрен исәпләү өчен эквивалент массаның ике параметрлы алымын тәкъдим итә. Аэройөрткечләр факелының селектив нурланышы өчен атмосфераның ачыгаюы күренешен ача.

Х е з м.: Атлас спектров прозрачности по произвольно ориентированным трассам атмосферы. М., 1977 (автордаш); Тепловое излучение планет. Л., 1977 (автордаш); Атмосферный аэрозоль. Л., 1983 (автордаш).

**МОСКВА́** Виктор Владимирович (10.1.1936, Украина ССРның Житомир өлкәсе Любарск р-ны Борушковцы а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1979). РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995), ТАССРның атказ. химигы (1985). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, органик химия каф. мөдире (1980 нән). 2001 дән Россия химия-технол. ун-тында (Мәскәү). Хезмәтләре органик, фосфорорганик һәм биологик актив кушылмалар химиясенә карый. М. карбонилллы фосфорорганик кушылмалар һәм аларның чыгарылмалары химиясе буенча фәнни юнәлеш булдыра. Турыдан-туры һәм читләтеп фосфориллауның яңа реакцияләрен, фосфор атомына ябык формиль төркем кертү алымнарын ача. Алынган винилфосфонатлар синтезлау ысулларын, ш.у. кислород, азот һәм күкерт кергән гетероцикллар синтезының яңа юлларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 52 авторлык танылыгы һәм патенты бар. Медальләр, «РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорилированные альдегиды // Успехи химии. 1973. Т. 42, № 7 (автордаш); Фосфорорганические соединения в реакциях с хинонами // Успехи химии. 1987. Т. 56, № 11 (автордаш); Циклические моно- и дифосфазены // Успехи химии. 1990. Т. 59, № 6 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МОСКВИ́Н** Михаил Кириллович (11.1.1910, Казан губ., Мамадыш р-ны Албай а. — 7.11.1969, Мамадыш р-ны Кама урман хуҗалыгы а.), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), гв. майоры. Кече лейтенантлар курсын (1933), Ленинград югары офицерлар бронетанк мәктәбен (1945) тәмамлый. Туган авылында, Белоруссия һәм Төньяк Кавказ төзелешләрендә, Мамадыш район башкарма ком-тында эшли. 1932–35 елларда һәм 1941 нең октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 26 нчы гв. механикалаштырылган бригада батальоны командиры (60 нчы армиянең 7 нче гв. механикалаштырылган корпусы). Воронеж, Үзәк, 1 нче һәм 4 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Касторня, Харьков (икесе дә — 1943), Житомир-Бердичев (1944), Сандомир-Силезия һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең сентябрендә Киевтан төньяктарак Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: бригадада беренчеләрдән булып елга аша чыга, сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә һәм плацдармны яулап ала. 1946 дан запаста. Кама урман хуҗалыгында эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Мамадыш шәһәрендә Геройга бюст куела.


М.К. Москвин.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Есть на Вятке городок. К., 1981; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОСКО́ВСКИЙ** Геннадий Тимофеевич (21.4.1948, Казан — 3.10.2005, шунда ук), спортчы (академик ишү), СССРның халыкара классы спорт остасы (1973), Россиянең атказ. спорт остасы (2005). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1981). Спорт б-н 1965 елда шөгыльләнә башлый, тренерлары — Р.Мәгазов («Спорт» ирекле спорт җәмгыяте), 1968 дән В.Т.*Глухих* («Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте). СССР (1973 тә, А-4РбР; 1975–76 да А8РсР), СССР халыклары спартакиадасы (А-8РсР), Европа (1973 тә, А-4РсР) чемпионы, дөнья чемпионатларында (1974 тә, А-4РсР; 1975 тә, А-8РсР) көмеш медальләр ала. 1977 дән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тренер. ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**МОСКО́ВСКИХ** Виктор Владимирович (12.6.1947, Вена ш., Австрия), инженер-механик, спортчы (мотоцикл һәм автомобиль спорты), мотоцикл спорты буенча СССРның спорт остасы (1971), автомобиль спорты буенча СССРның халыкара классы спорт остасы (1976), ТРның атказ. спорт остасы (1996). Одесса политехник ин-тын тәмамлый (1993). Спорт б-н 1961 елда шөгыльләнә башлый. Бозда мотоциклда узышу буенча СССР чемпионы (1972). 1973 тән җиңел автомобильләрдә проф. узышчы, 1974 тән СССР җыелма командасында. Дөнья чемпионаты этабында (1985), «Русская зима» халыкара ярышларында (1982), «Большой приз Львова» призына авторалли һәм автомобильдә трек узышларында (1988) җиңүче. Дөнья чемпионаты этабында (1977), авторалли буенча Европа чемпионатында (1982) көмеш медальләр ала. 1990–99 да зур егәрлекле узышу машиналары һәм автомобильләрнең яңа модельләрен булдыруда һәм сынауда катнаша, «КамАЗ-мастер» командасы пилоты (Чаллы ш.). Автораллиларда: «Париж–Триполи–Дакар» (1990) — команда зачётында, «Париж–Мәскәү–Улан-Батор–Пекин» (1995), «Париж–Гранада–Дакар» (1996) шәхси зачётта җиңүче. Ралли-марафоннар буенча Россия чемпионы (1997). «Оптик-2000» (1997), «Париж–Гранада–Дакар» (1999) автораллиларында көмеш медальләр ала. Халыклар дуслыгы, Дуслык орденнары б-н бүләкләнә. 1999 дан Одессада яши.

**МОСКО́ВЦЕВ** Михаил Алексеевич (12.8.1948, Казан), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1971). 1966–69 елларда Казан авиация з-дында эшли. 1969 дан «Элекон заводы» АҖдә: инженер-технолог, баш технолог бүлегенең КБ башлыгы, берләшмәнең баш технологы урынбасары, баш технологы (1983 тән), Казан штепсель аергычлар КБнда баш инженер (1986 дан), АҖнең баш конструкторы (1999–2007). Конструкторлык бүлегенең баш белгече (2007 дән). Уйлап табуга 2 патенты бар. Дәүләт бүләге күп функцияле яңа лазер мед. техникасын эшләгәне, җитештерүне оештырганы һәм ТР мед. оешмаларына керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МОСКОТИ́ЛЬНИКОВ** Савва Андреевич (5.1.1768, Ярославль ш. — 5.8.1852, Казан), җәмәгать эшлеклесе, шагыйрь, тәрҗемәче, статский советник (1837). Сәүдәгәрләр нәселеннән. 1782–84 елларда Ярославль шәһәр магистратында күчереп язучы, 1784–86 да канцелярия хезмәткәре, 1786–88 дә Гражданнар мәхкәмәсенең Вологда палатасында, 1788–93 тә Түбән Новгород наместниклык идарәсендә канцелярия хезмәткәре. 1793–1801 дә Казан шәһәр магистраты секретаре. 1801–08 дә Җинаятьчелеккә каршы мәхкәмәнең Казан палатасы стряпчие. 1808–20, 1834–46 да Казан губерна идарәсе киңәшчесе. 1818–26 да Россия Библия җәмгыятенең Казан бүлеге сәркәтибе. 1827–31 дә Казан гражданнар губернаторы, 1831–34 тә хәрби губернатор каршында махсус күрсәтмәләр башкаручы чиновник. 1801 дә Казан губерна хакимиятенең үз вазифаларыннан законсыз файдалану очракларын ачыклауда, гражданнар губернаторы һәм хәрби губернатор А.И.Муханов һәм П.П.Пущинны урыннарыннан төшерүдә катнаша. Россия масоннарына якын була. 1790 еллар уртасында дини һәм фәлсәфи «уйланулар», ш.и. «Җисемнәрнең тууы һәм җимерелүе турында» («О рождении и разрушении тел»), «Геометрик фәлсәфәнең мөмкин булуы турында» («О возможности существования геометрической философии»), «Кеше тормышы ыгы-зыгысы турында» («О суете жизни человеческой») әсәрләрен яза. «Ике мәзәкче» («Два фигляра», 1786, басылмаган), «Бүре белән төлке» («Волк и лисица», 1815) мәсәлләре, «Үз догам» («Моя ж молитва», басылмаган) масон шигырьләре, «Бөек магистрга» («Великому магистру», 1902) гимны авторы. «Падишаһ, император Александр I гә

мәдхия» («Ода государю императору Александру I», 1801; СПб., 1903 тә басыла), «Падишаһ, император Александр I тәхеткә утырган көнгә мәдхия» («Ода на день коронования государя императора Александра I», 1815) әсәрләрендә патша урнаштырган ирек, кануннар һәм ул оештырган уку йортларына мәдхия җырлый. «Дустыма эпитафия» («Эпитафия другу», 1803) һәм «Дустым төше» («Сон друга», 1831) шигырьләре Казан шагыйре Г.П.Каменевка багышлана. Т.Тиссоның «Азат ителгән Иерусалим» («Освобождённый Иерусалим», М., 1819) поэмасын тәрҗемә итә. «Истәлекләр» («Воспоминания», басылмаган) авторы. Казан ватан әдәбиятын сөючеләр җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1812).

Чыг.: Б о б р о в Ж.А. Литература и просвещение в России XIX в. К., 1902. Т. 4.

*Әд.:* С.А. Москотильников: Некролог // Казан. губернские ведомости. 1853. 9, 16, 23 февр.; А г а ф о н о в Н.Я. Казань и казанцы. К., 1906. Ч. 1; Русские писатели 1800–1917: Биогр. словарь. М., 1999. Т. 4.

*Е.Б.Долгов.*

**МОСОЛО́В** Василий Петрович (25.8.1888, Вятка губ. Мари-Төрек а. — 10.2.1951, Мәскәү), галим агроном, ВАСХНИЛ академигы (1935) һәм вице-президенты (1939–51), РСФСР, ТАССР, Мари АССРның атказ. фән эшлеклесе (барысы да 1935 елда). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. ин-тын тәмамлый (1922). 1907–17 дә Казан губернасының Лаеш өязендә укытучы, 1917–19 да Вятка губернасының Сернур авылында агроном булып эшли. 1922 дән Мәскәү а.х. академиясендә. 1924 тән Казан а.х. һәм урманчылык ин-тында гомуми игенчелек каф. мөдире, проф. (1926); бер үк вакытта, 1935–38 дә, Казан селекция станциясендә агротехника бүлеге мөдире. 1938 дән ВАСХНИЛда. Хезмәтләре туфрак эшкәртү, кырларга ашлама кертү, уҗым чәчүлекләрен кышлату, үлән чәчү һәм чәчү әйләнеше мәсьәләләренә карый. М. чиста һәм биләүле (чәчүле) пар төрләренә бәя бирә, Татарстан туфрагының уңдырышлылыгына күпьеллык үлән чәчүлекләренең тәэсирен тикшерә; уҗым культураларының кыш көне һәлак булу сәбәпләрен классификацияли, инженер Т.Г.Ботов б-н берлектә үзе эшләгән өч яруслы сабан б-н сөрү катламын акрынлап арттыра бару ысулын эшли. Татарстанда һәм Мари АССРда клевер чәчүлекләрен тикшерә. Клевер, люцерна һ.б. өчен япма культуралар сайлауда тәҗрибәләр уздыра. Сәнәгать калдыкларын ашлама сыйфатында файдалану мөмкинлеген өйрәнә. Бүлбе очлары б-н бәрәңге утырту ысулын эшли һәм җитештерүгә кертә. 1938–53 тә РСФСР ЮС депутаты. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1943, 1951). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. Казан аграр ун-ты бинасына — М.ка мемориаль такта (1952), Мари ун-ты каршына һәйкәл куела (2004).

Х е з м.: Басу культуралары агротехникасы. К., 1949 (автордаш); Многолетние травы. М., 1950; Агротехника. М., 1952; Сочинения: В 5 т. М., 1952–55.

*Әд.:* Ш а к и р о в Я.Х. Жизнь академика В.П.Мосолова и вклад его школы в советскую агрохимию // Дифференцированное земледелие. К., 1970.

*А.А.Җиһаншин.*

**МОСОЛО́В** Георгий Константинович (3.5.1926, Уфа ш.), Сов. Союзы Герое (5.10.1960), полковник, СССРның атказ. очучы-сынаучысы (1967). В.П.Чкалов исем. Үзәк аэроклубта курсант була (Казан, 1943). Чугуев очучылар хәрби авиация уч-щесен (1948), СССР Хәрби-һава көчләренең Югары авиация офицер инструкторлар мәктәбен (Грозный ш., 1949), очучы-сынаучылар мәктәбен (Мәскәү, 1953), Мәскәү авиация ин-тын (1959) тәмамлый. 1944 елдан Кызыл Армия сафларында. 1953–66 да очучы-сынаучы, 155 нче тәҗрибә з-дының әйдәп баручы инженеры (хәзер — А.И.Микоян исем. тәҗрибә КБ, Мәскәү). 1960 ның 5 октябрендә яңа авиация техникасын сынаганда батырлык күрсәтә. 1966 дан запаста. 1967–92 дә Аэрофлотта эшли (Мәскәү). Ике Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. СССРның атказ. спорт остасы (1965). Тизлек һәм очыш биеклеге буенча 6 тапкыр (ш.и. 3 абсолют) дөнья рекорды куя.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои и подвиги. М., 1963. Кн. 1; Шаги в бессмертие. М., 1965; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОСТА́ЕВ** Рим Шаһгали улы (11.9.1949, Апас р-ны Апас а.), генерал-майор (1993), социол. фән. канд. (2002). Мәскәүнең югары гомумгаскәри командирлары уч-щесен (1971), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1980), Генштабның хәрби академиясен (Мәскәү, 1991), Гуманитар фәннәр академиясен (С.-Петербург, 2002) тәмамлый. 1971 елдан Төньяк гаскәрләр төркемендә, 1972–77 дә Урта Азия хәрби округында хезмәт итә. 1980–87, 1992–98 дә Ленинград хәрби округында: 1981 дән полк командиры, 1986 дан дивизия штабы башлыгы. 1992 дән дивизия командиры, 1995 тән 60 нчы армия командующиеның 1 нче урынбасары. 1987–89 да Төркестан хәрби округында мотоукчылар дивизиясе командиры урынбасары (Әфганстан Респ-касы). 1991 дән Карпат алды хәрби округында дивизия командиры. 1998–2006 да ТРның хәрби комиссары. Хезмәтләре хәрби хезмәт нигезләренә һәм РФ Кораллы көчләрен үзгәртеп коруга карый. Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз, 1 нче дәрәҗә «СССР Хәрби Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы военной службы. К., 2001 (автордаш); Афганистан живёт в моей душе: Записки командира. К., 2004; Уклонение от призыва на воинскую службу: Причины, следствия, социальные факторы. К., 2004.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**МОСТА́ЕВ** Шамил Әсгать улы (17.5.1929, Буа кантоны Норлат а. — 1.12.2012, Казан), дәүләт һәм профсоюз эшлеклесе, РСФСРның атказ. икътисадчысы (1983). Буа вет. техникумын (1946), Казан югары партия мәктәбен (1959), Казан финанс-икътисад ин-тын (1964) тәмамлый. 1959–64 елларда КПССның Татарстан өлкә ком-тында, 1964–69 да КПССның Апас район ком-ты 1 нче секретаре. 1969–84 тә ТАССРның финанс министры. 1984–86 да профсоюзларның Татарстан өлкә советы рәисе. 1986–90 да ТАССР ЮС Президиумы рәисе. 1990–95 тә ТР Финанс министрлыгының әйдәп баручы инспекторы, бер үк вакытта Мәскәү финанс колледжының Казан ф-лы укытучысы. ТРның Банклар ассоциациясе президенты. 1967–80, 1985–95 тә ТАССР, ТР ЮС депутаты. Кызыл Байрак, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә.



В.П. Мосолов.



Г.К. Мосолов.

*Әд.:* М и р с и я п о в Т.А., Ф о м и н А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995). К., 1995.

**МОСТАФА́** (?-1443), Олы Урда солтаны. Әстерхан (Хаҗитархан) идарәчесе булуы ихтимал, анда үз исеменнән акча суктыра (1430 еллар ахыры). *Гыясетдин* улы. 1443 тә *Әбелхәер* хан тарафыннан далага куыла. Үзара даими сугышлар һәм корылык 1443 нең көзендә М.ны төньяк җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр итә. Рязань кенәзлегенең бер өлешен бөлдерә һәм Переяславль-Рязанскийда кышларга карар кыла. Василий III М.га каршы гаскәр җибәрә. М. отрядлары Рязань янындагы Листань елгасы буенда камала һәм җиңелә, М. сугышта һәлак була.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; З а й ц е в И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МОСТА́ФИН** (Киек-Урман) авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зәй–Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 90 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 20 йөз башында нигез салына. Оештырылган көннән Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1920 дә — 175, 1926 да — 204, 1938 дә — 234, 1949 да — 200, 1958 дә — 191, 1970 тә — 197, 1979 да — 92, 1989 да — 93, 2002 дә — 126 кеше.

**МОСТА́ФИН** Әхмәтҗан Мөхәммәдрәхим улы (1860, хәзер Пенза өлкәсенең Кузнецк р-ны Татар Кынадысы а. — 15.11.1938, Казан),

җәмәгать эшлеклесе, педагог. 1894 елдан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта. 1906–11 дә мөселман кыз балалар мәктәбен ача. Бер үк вакытта, 1906–17 дә, «Әд-дин вәл-әдәб» ж-лында хезмәттәшлек итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң милли азатлык хәрәкәтенә кушыла; Бөтенроссия мөселман мөгаллимнәре бюросының башкарма ком-ты әгъзасы. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18). Уку ярдәмлекләре авторы. 1931 нең 27 июнендә «кулаклар-муллалар төркеме» әгъзасы буларак кулга алына, аннан соң азат ителә. 1938 нең 10 гыйнварында кабат кулга алына. Репрессияләр чоры корбаны (к. «*Совет властена каршы оешкан төркем*» эше); үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2003. Т. 9.

**МОСТА́ФИН** Вил Сәлах улы (3.5.1935, Казан — 16.9.2009, шунда ук), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, шагыйрь. Рус телендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1958). 1960–65 елларда Казан авиация ин-тының югары матем. каф. ассистенты. 1965–77 дә Хисаплау техникасын халык хуҗалыгына кертү ин-тында (ГНИПИ-ВТ) эшли; 1977–81 дә Казан исәпләү үзәгенең автоматлаштырылган идарә системасы бүлеге мөдире, 1981–86 да директорның проектлар буенча урынбасары; 1986–89 да Автомобиль транспорты автоматлаштырылган идарә системалары фәнни-тикшеренү ин-тының директор урынбасары; 1990–92 дә «Сигнал» пр-тиесе директоры. Фәнни хезмәтләре гамәли математикага карый. Әдәби иҗат б-н 1960 еллардан шөгыльләнә. «Тәүге тапкыр яшим» («Живу впервые», 1997), «Көндезге төшләр һәм йокысыз төннәр» («Дневные сны и бдения ночные», 1998), «Зираттагы әңгәмәләр» («Беседы на погосте», 2000), «Шигырьләр турында шигырь» («Стихи о стихах», 2002), «Сонет вариацияләре» («Сонетные вариации», 2002) шигъри җыентыклар авторы. Аның поэзиясе шәхеснең киеренке рухи эзләнүләрен, аның җәмгыять б-н каршылыклы мөнәсәбәтләрен чагылдыра.

*Әд.:* К у т у й Р. Вдох-выдох // Идель. 1990. № 4.

**МОСТА́ФИН** Илшат Гани улы (28.1.1964, Пермь өлкәсе Куеда пос.), биохимик, мед. фән. д-ры (2005), проф. (2006). Казан мед. ин-тының сан. ф-тын тәмамлаганнан соң (1987), Казан Эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1992–2002 елларда Респ-ка СПИДка каршы профилактика үзәгенең клиник иммунология лаб-ясе мөдире. 2002 дән Казан мед. ун-тында, 2006 дан биохимия каф. мөдире һәм 2009 дан мед.-профилактика ф-ты деканы. Хезмәтләре кан оешу, иммунитет, патологик процесслар барышында апоптоз (күзәнәкләр үлеме) күренеше биохимиясенә карый.

Х е з м.: Роль ВИЧ-1 белка NEF в патогенезе ВИЧ-1 инфекции // Казан. мед. журн. 2010. № 1 (автордаш); Предупреждение тромботических осложнений в малоинвазивной хирургии варикозной болезни // Казан. мед. журн. 2010. № 3 (автордаш).

**МОСТА́ФИН** Исхак Салих улы (3.9.1908, хәзер Мордва Респ-касының Рузаевка р-ны Югары Үрләдем а. — 1.12.1968, Саратов ш.), химик, химия фән. д-ры (1960), проф. (1960). 1936 елда Саратов ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, органик синтез лаб-ясе мөдире, аналитик химия каф. мөдире. Хезмәтләре аналитик химиягә карый. М. төрле матдәләрнең сыйфатын һәм микъдарын билгеләү алымнарын, аналитик алымнарның сизгерлек чикләрен күтәрү юлларын эшли, аналитик тикшеренүләр өчен органик реактивлар тәкъдим итә. Нефть барлыкка килү, гео- һәм биохимия теориясенә караган хезмәтләре бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ металлов. Саратов, 1967; Органические реактивы. Саратов, 1967; Очерки по истории химии. Саратов, 1969.

*Әд.:* К а з а к о в Б.И. Исаак Савельевич Мустафин. М., 1990. *В.Г.Абзалова.*

**МОСТА́ФИН** Камил Әхмәди улы (26.11.1932, Зеленодольск ш. — 30.9.2009, Чиләбе өлкәсенең Снежинск ш.), математик, шагыйрь, физика-матем. фән. канд. (1995). 1956 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Е.И.Забабахин исем. Бөтенроссия техник физика фәнни-тикшеренү ин-тының Россия федераль атом-төш үзәгендә (Чиләбе өлкәсе Снежинск ш.), сектор җитәкчесе (1990 нан соң), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2004 тән). Хезмәтләре гамәли математикага, ике үлчәнешле системаларда атом-төш физикасы процессларын модельләштерүгә карый. Махсус техника эшләнмәләре параметрларын матем. модельләштерүнең методикасын һәм программасын, ш.у. исәпләнгән дәлилләрен эшли. Энергетика өлкәсендәге теоретик хезмәтләр комплексы өчен СССР Дәүләт бүләгенә (1991) лаек була.

М.ның беренче шигырьләре Казан, Чиләбе, Свердловскида (хәзерге Екатеринбург) чыга торган матбугат битләрендә 1956 да күренә башлый. Аның шигъри дөньясының асылын яхшылык б-н яманлык көрәше, Ватанга мөнәсәбәт, мәхәббәт мотивлары тәшкил итә. «Җыр сафка чакыра» («Песня зовёт в строй», 1966), «Ачкыч» («Ключ», Чиләбе, 1971), «Горур ташлар» («Гордые камни», 1972), «Июнь таңнары» («Июньские ночи», Чиләбе, 1975), «Хыял кошы» («Птица мечты», 1984) һ.б. шигъри җыентыклар авторы. Татар теленә М.Ю.Лермонтов, В.В.Маяковский, С.И.Чекмарёв һ.б.ның шигырьләрен тәрҗемә итә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Численные расчёты термоядерной детонации в плотной плазме // Физика плазмы. 1984. Т. 10, вып. 3 (автордаш); Computation optimization of indirect-driven target for ignition and the engineering fest facility // Lazer and Particle Beame. 1997. V. 15, № 1 (автордаш).

*Әд.:* М у с т а ф и н Р. Сто первое чудо // Образ времени: Статьи. К., 1981.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МОСТА́ФИН** Камил Сабир улы (22.5.1921, Әгерҗе ш. — 28.8.1998, Казан), физик, техник фән. д-ры (1979), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980). 1948 елда Үзбәк ун-тын тәмамлаганнан соң, Таҗик ун-тында эшли, физика (1950–56), оптика һәм спектроскопия кафедралары мөдире (1961–63). 1963 тән ГИПОда: лаб-я (1963–77), бүлек (1977–78, 1987–91), оптик приборлар төзү һәм гамәли голография фәнни-тишеренү бүлекчәсе (1978–86) башлыгы, баш фәнни хезмәткәр (1991 дән). Хезмәтләре голографиягә, аны оптик тикшеренүләрдә һәм приборлар төзелешендә куллануга карый. М. җитәкчелегендә голограммаларны оптик элементлар сыйфатында куллану принциплары эшләнә. Голографик интерферометриянең, ш.и. нәсызыкча эффектлар куллану нигезендә югары сизгерлектәге интерферометриянең теоретик алымнарын үстерә. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998, вафатыннан соң).

Х е з м.: Определение функции распределения электронов по энергиям в разряде с полым катодом в смеси гелия и неона // Журн. техн. физики. 1966. Т. 36, № 3 (автордаш); Применение голографии для исследования распределения температурного поля пламени // Оптика и спектроскопия. 1967. Т. 22 (автордаш); Голографический интерференционный контроль асферических поверхностей // Оптико-механическая пром-сть. 1971. № 4; Голографические методы контроля асферических поверхностей // Оптико-механическая пром-сть. 1979. № 4 (автордаш.).

**МОСТА́ФИН** Лотфулла (19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче яртысы), график. Беренче татар карикатура рәссамы. 1906–07 елларда Оренбург шәһәрендә чыккан татар сатирик «Карчыга» ж-лындагы рәсемнәр авторы. Рәсемнәрен «Камчы» тәхәллүсе һәм «Л.Ф.» инициаллары б-н имзалаган (фаразлауларча).





Л.М о с т а ф и н. 1. «Хөррият кирәкме, кымызмы?»; 2. Дәүләт Думасы эшчәнлегенә карикатура. Кәгазь, тушь. «Карчыга» журналы. 1907. № 7.

*Әд.:* Гайнуллин М.Х. Татарская литература и публицистика начала XX века. К., 1983; Червонная С.М. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года. М., 1987.

**МОСТА́ФИН** Михаил Андреевич (Мөдәррис Идрис улы) (15.11.1916, Саратов губ., хәзер Пенза өлкәсе, Неверкин р-ны Карновар а. — 9.4.1987, шунда ук), Сов. Союзы Герое (26.10.1944), гв. капитаны. Энгельс очучылар хәрби авиация мәктәбен (1941) тәмамлый. Вольск шәһәрендә «Комсомолец» з-дында слесарь булып эшли. 1937 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 165 нче гв. штурм авиациясе полкында звено командиры (2 нче Һава армиясендә 10 нчы гв. штурм авиациясе дивизиясе). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы буенда барган сугышларда (икесе дә — 1943), Ровно-Луцк (1944), Сандомир-Силезия, Берлин һәм Прага (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең мартына дошман объектларына һөҗүм итү өчен 98 сугышчан очыш ясый. Сугыштан соң СССР Хәрби Һава көчләрендә хезмәтен дәвам итә. 1958 елдан запаста. Вольск шәһәрендә балык пунктында директор булып эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Румянцев Н.М. Люди легендарного подвига. Саратов, 1968; Андреев С.А. Совершённое ими бессмертно. М., 1976; Герои и подвиги. Саратов, 1984. Кн. 6.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОСТА́ФИН** Мөдәррис Мөҗип улы (14.12.1923, Минзәлә кантоны Мөслим а.), журналист, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967, 1978). Казан пед. ин-тының тарих ф-тын (1952), Горький Югары партия мәктәбен (1948) тәмамлый. 1941 елдан Мөслим р-ның «Күмәк хуҗалык» г-тасы мөхәррире. 1943–83 тә (бүленеп) «Социалистик Татарстан» г-сында эшли: партия тормышы, пропаганда һәм агитация, авыл хуҗалыгы бүлекләре мөдире. 1952–53 тә КПССның Чистай район ком-тының «Сталин байрагы» г-тасы мөхәррире, 1953–54, 1959 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Партия тарихы ин-ты хезмәткәре. Язмаларының төп темасы — Татарстанның социаль-икътисади һәм иҗтимагый-сәяси үсеше. М.ның язмалары, респ-ка газеталарыннан тыш, «Казан утлары», «Азат хатын», «Татарстан коммунисты» ж-лларында басыла. «Колхозның яшь хуҗалары» (1951), «Ышаныч» (1967) һ.б. очерклар җыентыклары авторы. Иҗтимагый-сәяси һәм матур әдәбият әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

*Әд.:* Без Мөслим балалары. К., 2006.

**МОСТА́ФИН** Мөсәгыйть (25.9.1909, Самара губ., Бөгелмә өязе Бәйрәкә а. — 6.12.1941), язучы. Балалар өчен язылган «Очрашу» (1931), «Үсү» (1931) хикәяләр җыентыклары авторы. 1941 елның августында үзе теләп фронтка китә, сугышта һәлак була.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МОСТА́ФИН** Мулланур Хәмзә улы (28.3.1932, Мамадыш р-ны Көек-Ерыкса а. — 17.8.2007, Минзәлә ш.), режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968). Татар театр техникумын (1947), Дәүләт театр сәнгате ин-тының режиссёрлык ф-тын (Мәскәү, 1956, Ю.А.Завадский курсы) тәмамлый. Минзәлә татар драма театрына чакырып алына, 1966–82 елларда баш режиссёр. М.ның «Галиябану» (М.Фәйзи) пьесасы буенча куйган беренче спектакле театр җәмәгатьчелеге тарафыннан хуплау таба һәм Мәскәүдә уздырылган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы программасына кертелә, анда ул, «җанлы һәм кызык» спектакль буларак, югары бәяләнә. Спектакльнең шартлы-фольклор формасы да актёрга үз геройларының рухи дөньясын ачарга комачауламый. М. Минзәлә театры сәхнәсендә 60 тан артык спектакль куя. С.Шәкүровның «Уракчы кыз», М.Кәримнең «Айгөл иле», Ә.Баянның «Һәйкәл», Ю.Әминевнең «Минем җәннәтем», Ә.Гаффарның «Язлар моңы», «Соңгы ләкләк», А.Баһаветдиновның «Соңгы кара кош», Г.Ахуновның «Ардуан батыр», Х.Вахитның «Хыянәт», «Сәер кеше», С.Кайтовның «Ана йөрәге», Р.Хәмиднең «Язмышлар хәл иткәндә», А.Д.Салынскийның «Мария», Н.П.Анкиловның «Мин — солдат хатыны» («Солдатская вдова») әсәрләре буенча куйган спектакльләре югары гражданлык хисе, заманча теманың тирән ачылуы ягыннан билгеләп үтелә. К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Г.Насрыйның «Алтын көз», «Күңел дәфтәре», Т.Гыйззәтнең «Наёмщик», З.Шаһиморатовның «Хәят», Х.Сафинаның «Җыр дәвам итә» әсәрләре буенча куйган муз.-драматик спектакльләре романтик башлангычның көнкүреш төгәллеге һәм психол. тулылык б-н нәфис үрелеп баруы ягыннан аерылып тора. М. чит ил һ.б. милләт драматурглары әсәрләренә дә еш мөрәҗәгать итә. Алар арасында аеруча зур әһәмияткә ия булган күләмле спектакльләре — «Шайтан шәкерте» («Ученик дьявола», Б.Шоу), «Иң гади кеше» («Обыкновенный человек», Б.Нушич), «Кара бүре» («Чёрный волк», Н.М.Арбан), «Хәйләкәр Бадамша» («Хитрый Бадамша», Ц.Шагжин), «Сылу кызлар» (К.Шыңгытбаев, К.Байсәетов). Театрның сәнгать җитәкчесе буларак, актёрларның осталыкларын үстерү юнәлешендә пед. эшчәнлек алып бара, репертуарны яңартырга омтыла, респ-каның әйдәп баручы драматурглары б-н тыгыз элемтәдә тора. М.ның югары поэтик рух б-н сугарылган, тормышчы, халык йолаларын яхшы белүе б-н аерылып торган спектакльләре тамашачы ихтыяҗын күздә тотып куела, респ-каның театр сәнгате үсешенә зур өлеш кертә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Минзәлә татар драма театры: Буклет. К., 1985; Гыймранова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт театры. К., 2007.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**МОСТА́ФИН** Рафаэль Әхмәт улы (14.5.1931, Баулы р-ны Баулы пос. — 14.4.2011, Казан), әдәбият белгече, әдәбият тәнкыйтьчесе, филол. фән. канд. (1971), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Казан ун-тын тәмамлый (1954). 1961–63 елларда Казан телевидение студиясенең әдәбият-сәнгать программалары мөхәррире, 1965–69 да «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире, 1978–91 дә Казан ун-тында укыта, 1991–97 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире, 1997–2001 дә «Казанские ведомости» г-тасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, 2001 дән кабат «Татарстан» ж-лында. М.Җәлилнең тормышына һәм иҗатына багышланган «Эзләнү дәвам итә» («Поиск продолжается», 1965, автордаш), «Герой шагыйрь эзләреннән» («По следам поэта-героя», М., 1971), «Өзелгән җыр эзеннән» (1974), «Муса Җәлил» («Муса Джалиль», 1986) китаплары авторы. Хәзерге татар әдәбияты, милли әдәбиятларның үзара баетылу мәсьәләләре, әдәби тәрҗемәгә багышланган мәкалә һәм рецензияләр авторы. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1976), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2006). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



М.А.Мостафин.



Р.Ә.Мостафин.

Әсәр.: Кабан күле серләре. К., 1990; Казань и её слободы. К., 2001 (автордаш); Репрессияләнгән татар әдипләре. К., 2009; О времени, о жизни, о себе. К., 2002; Силуэты: Литературные портреты писателей Татарстана. К., 2006.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МОСТА́ФИН** Рәис Рәүф улы (23.10.1980, Оренбург өлкәсенең Переволоцкий р-ны Алмалы а.), РФ Герое (11.7.2000), рядовой. 50 нче номерлы һөнәри-техник уч-щене (Оренбург өлкәсенең Кичкасс пос.) тәмамлый. 1998 елдан РФ Эчке эшләр министрлыгының Төньяк Кавказдагы эчке гаскәрләрендә, 8 нче махсус бригада пулемётчигы. 2000 нең 27 гыйнварында Төньяк Кавказда террорчыларга каршы операция барышында батырлык күрсәтә: Грозный шәһәрен штурмлаганда, подразделение составында мәктәпне азат итүдә катнаша, берничә террорчыны юк итә, тоткынлыкка эләгә, граната б-н каршы якның штабын шартлата; Россия бригадасы подразделениеләре һөҗүме вакытында, пулемёттан атып, аларга ярдәм күрсәтә. 2000 нән запаста. Бөтенроссия сугыш һәм хәрби конфликтлар инвалидлары иҗтимагый оешмасының Оренбург төбәк бүлегендә эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Иванов А.А. Герои Российской Федерации = Россия Федерациясе Геройлары. К., 2012, 105–106 бб.

**МОСТА́ФИН** Рәшит Шәкүр улы (6.1.1946, Казан), баянчы, педагог, ТАССРның халык

артисты (1986). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1976). 1964–76 елларда баянчы, бер үк вакытта, 1976 дан, оркестр җитәкчесе, 1998 дән ТР Дәүләт Җыр һәм бию ансамбленең баш дирижёры. Татарстан баянчылары арасында әйдәп баручы һәм татар көйләрен яхшы интерпретацияләүче музыкантларның берсе. Солист-баянчы буларак, М. югары профессиональлеге, үзенчәлеклеге, табигый музыкальлеге б-н зур башкару осталыгының гармониясе һәм милли муз. фольклор өлкәсендә тирән белемле булуы б-н аерылып тора. Аның репертуарын татар халык көйләре, татар композиторлары әсәрләре, халык музыкасы тәшкил итә. М. җитәкчелегендә Җыр һәм бию ансамбленең югары проф. дәрәҗәдәге оркестры оеша. Башкаручы һәм оркестр җитәкчесе буларак, М. татар музыкасын, Идел буе һәм Урал алды халыклары музыкасын актив пропагандалый. Җыр һәм бию ансамбле программасы өчен оркестр аранжировкалары, халык җырларына, баян өчен әсәрләргә, башлыча, җыр һәм биюләргә хор эшкәртмәләре авторы («Казан кызлары биюе», «Канатлы яшьлек», «Аулак өй», «Корбан бәйрәме», «Каз өмәсе», «Идел», «Әни» һ.б.) буларак таныла. Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче татарларның муз. фольклорын җыю б-н шөгыльләнә. Радио һәм телевидениедә соло концертлары һәм әйдәп баручы башкаручылар б-н чыгышлар ясый; солист һәм оркестр җитәкчесе буларак, ТР Җыр һәм бию ансамбленең программаларын әзерләүдә катнаша. Россия буйлап һәм чит илләрдә (Италия, Сенегал, Нигерия, Тунис, Йәмән, Гыйрак, Япония, Германия, Франция, Бөекбритания, Финляндия, Мисыр, Португалия, Испания, Бельгия, Бенин һ.б.) гастрольләрдә була. Халыкара, Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия музыкант-башкаручылар һәм иҗат коллективлары смотрлары, конкурслары һәм фестивальләре лауреаты.


Р.Ш.Мостафин.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МОСТА́ФИН** Фәрхәт Әхәт улы (7.9.1950, Мәскәү), спортчы, тренер (грек-рим көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1974), Халыкара категорияле судья (1985), Россиянең атказ. тренеры (2002). Мәскәү өлкә пед. ин-тын тәмамлый (1975). «Зенит» бөтенсоюз ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә, тренеры — В.А.Бурылин. СССР (1972–74, 1981), Европа (1974, 1976), дөнья (1974–75) чемпионы, И.М.Поддубный исем. призга халыкара турнирларда җиңүче (1973–74, 1977), Олимпия уеннарында бронза медаль ала (1976). 1970–90 да хәрби хезмәттә, бер үк вакытта, 1983–90 да, Мәскәү хәрби округында өлкән тренер. 1990 нан ЦСКА югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер (Мәскәү), 1998–2005 тә Россия җыелма командасында тренерлык эшендә. 2005 тән Мәскәү көрәш федерациясе вице-президенты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МОСТА́ФИН** Шаһинур Сафа (Әхмәтсафа) улы (12.2.1948, Мамадыш р-ны Арташ а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1968 елдан Мамадыш р-ны «Коммунистик хезмәт өчен» г-тасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1970–82 дә (бүленеп) Кукмара р-ны «Хезмәт даны» г-тасы редакциясендә башта әдәби хезмәткәр, соңрак бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1983–88 дә ТАССР Мәдәният министрлыгының фәнни-методик үзәгендә халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча баш мөхәррир. 1988–92 дә — СССР, РСФСР Язучылар берлеге Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. 1992–99 да «Казан утлары» ж-лы редакциясенең хатлар һәм пропаганда бүлеге мөдире. 1999–2005 тә ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары. 2006 дан «Сүз» нәшриятының баш мөхәррире. Документаль проза остасы һәм публицист буларак танылa. Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларны эзләп табу, исемнәрен халыкка кайтару буенча зур эш алып бара: «Хәтер яктысы» экспедициясен җитәкли, «Батырлар китабы — Книга Героев» (2000) белешмә басмасының мәкалә авторлары һәм мөхәррирләренең берсе. Документаль-публицистик характердагы «Васыять» (1995), «Хәтер яктысы» (2004) һәм «Яшәү яме» (2006) шигъри повесте, балаларга атап язылган шигырьләре тупланган «Бака кашыгы» (2003), «Яңа меңьеллыкка очыш» (2008) исемле документаль очерклар һәм повестьлар җыентыклары авторы. ТР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге (1982), РФнең М.Ломоносов исем. бүләге (2007) лауреаты.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

*Г.М.Габделхакова.*

**МОСТА́ФИН** Эдуард (Идик) Госман улы (31.1.1945, БАССРның Калтасы р-ны Кәс а. — 1997), шагыйрь. 1963 елдан Башкортстан һәм Татарстан район газеталары редакцияләрендә эшли. 1968–73 тә М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (Мәскәү) укый. Уралда төзүче булып, Чирчик (Үзбәкстан), Нефтекамск, Казан шәһәрләрендә рәссам булып эшли. Тәүге шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1970) күмәк җыентыгында дөнья күрә. «Бишенче фасыл» (1979), «Туасы көн» (1986), «Ут. Кәгазь. Каләм» (1992) җыентыклары авторы. М. иҗатында драматизм көчле, поэтик теле ассоциацияләргә, метафораларга бай.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

**МОСТА́ФИН** Ямил (Җәмил) Мостафа улы (20.5.1927, БАССРның Чишмә р-ны Усман а.), язучы, БАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Рус телендә иҗат итә. Хәрби (Ленинград, 1950) һәм Әдәбият (Мәскәү, 1962) ин-тларын тәмамлый. Хезмәт юлын 1942 елда Тайшет шәһәрендә Көнчыгыш Себер тимер юлының механика остаханәләрендә башлый. 1950–54 тә Порт-Артур шәһәрендә (Кытай) хәрби-диңгез базасында хезмәт итә. «Спортивная жизнь России» (1960–61), «Юный техник» (1961–63) ж-лларында җаваплы сәркәтип, «Советская Россия» (1964–71) нәшриятында мөхәррир. 1971–90 да (бүленеп) СССР Язучылар берлегендә эшли. Беренче хикәяләре 1951 дә «Порт-артурец» г-тасында басылып чыга. Әсәрләренә лиризм хас, алар гуманлылык, гражданлык хисләре б-н сугарылган. Аның «Янкан сырты» («Янканский перевал», М., 1964), «Кырыс балачак» («Суровое детство», 1968), «Себер могҗизасы» («Сибирское чудо», М., 1972), «Тере бозлар» («Живые льды», М., 1976) повестьлары Себер тайгаларында үткәргән балачак һәм үсмерлек еллары хатирәләренә, шәхес культы чорының авыр иҗтимагый-сәяси атмосферасын, репрессия һәм сугыш шартларында кешеләрнең аяныч язмышларын, аларның рухи ныклыгын, яшәргә омтылышын сурәтләүгә багышлана. «Кыргый» («Дикарка», 1967), «Зәңгәр ат» («Голубая лошадь», 1971) хикәяләрендә геройларның характеры хайваннарга мөнәсәбәтләре аша ачыла. «Күпер» («Мост», М., 1975) повесте һәм «Юл» («Дорога», М., 1985; 2 нче басма, 1989) романы Байкал-Амур магистрален төзүчеләр тормышыннан алып язылa. «Балалайкачы» («Балалаечник», М., 2002) повестенда беренче мәхәббәт темасы яктыртыла. М.ның әсәрләре кыска һәм ачык, үтә тәэсирле һәм ихласлыгы б-н аерылып тора. Ул татар язучыларыннан Г.Ахунов, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, башкорт язучыларыннан И.Абдуллин, Т.Ахунҗанов, Д.Бүләков әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итә. ВЦСПС һәм СССР Язучылар берлеге (1972), ВЛКСМ ҮК һәм СССР Госкомиздат (1972) бүләкләре лауреаты. «Почёт билгесе», «Дуслык» (Кытай) орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Шайтан. Уфа., 2000.

*Г.М.Габделхакова.*

**МОСТА́ФИНА** Алия Фәргать кызы (30.9.1994, Мәскәү өлкәсенең Егорьевск ш.), спортчы (спорт гимнастикасы). Россиянең атказ. спорт остасы (2010). 2000 елдан ЦСКАда (Мәскәү) тәрбияләнә. 2007 дән Россия җыелма командасы составында чыгыш ясый (тренер — А.С.Александров). Олимпия уеннарында (2012, брусларда күнегүләр ясау), дөнья чемпионатларында (2010, команда һәм абсолют беренчелектә), 2013 (бүрәнәдә күнегүләр ясау), Европа чемпионатларында (2010, команда беренчелегендә), 2013 (абсолют беренчелектә, брусларда күнегүләр ясау), Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарында (2013, абсолют һәм команда беренчелекләрендә, брусларда күнегүләр ясау) җиңүче; Дөнья кубогы (2011, брусларда, бүрәнәдә һәм терәк б-н сикерүдә; 2012, команда беренчелегендә) иясе; Олимпия уеннарында (2012, команда беренчелегендә көмеш, ирекле күнегүләр һәм күптөр ярышларда бронза), дөнья чемпионатларында (2010, көмеш, терәк б-н сикерүдә, брусларда һәм ирекле күнегүләрдә), 2013 (бронза, абсолют беренчелектә, брусларда күнегүләр ясауда), Европа чемпионатларында (2010, көмеш, бүрәнә һәм брусларда күнегүләр ясау), 2012 (көмеш, команда беренчелегендә), Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарында (2013, көмеш, бүрәнәдә күнегүләр ясауда),

Дөнья кубогы (2010, көмеш, бүрәнәдә күнегүләр ясауда), 2011 (көмеш, күптөр ярышларда) медальләр ала. Россиянең күп тапкыр чемпионы һәм Россия Кубогы иясе. «Серебряная лань» призы лауреаты (2013). «Дуслык» ордены б-н бүләкләнә.

**МОСТА́ФИНА** Асия Рафаэль кызы (30.9.1961, Казан), химик, химия фән. д-ры (2008), 1983 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1991 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, супрамолекуляр системаларның физик химиясе лаб-ясе мөдире (2008 дән). Хезмәтләре координацион һәм физик химия өлкәсенә, нанотехнологияләргә карый. Куелган электрохимик потенциалга һәм билгеле структуралы субстратларга люминесцент җавап кайтаруга сәләтле молекуляр һәм наноүлчәнешле системалар эшли. «Каликсареннар нигезендәге супрамолекуляр системалар» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

Х е з м.: Синтез трис (в()-дикетонов) и изучение их комплекса сообразования с некоторыми ионами переходных металлов // Изв. АН. Сер. хим. 2006. № 11 (автордаш); Внешнесферная ассоциация каликсаренов и других макроциклических лигандов с комплексами металлов как основа конструирования молекулярных устройств // Успехи химии. 2007. Т. 76, № 10 (автордаш).

**МОСТА́ФИНА** Динә Габделбәр кызы (23.11.1952, Магадан өлкәсе Омсукчан пос.), тарихчы-археограф, тарих фән. канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли, 1989–2012 елларда татар халкы тарихы каф. доценты, 2013 тән Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү ин-тының документлар һәм архивны өйрәнү каф. мөдире. Рус писцовый кенәгәләрен, ш.и. Казан һәм Зөя өязләренә караган кенәгәләрне өйрәнү һәм бастырып чыгаруга зур өлеш кертә. Урта Идел буенең 16–18 йөзләрдәге социаль-икътисади һәм сәяси тарихына караган чыганакларны өйрәнү һәм археографиягә багышланган фундаменталь басмалар авторы: «Казан өязенең 1647–1656 еллардагы писцовый кенәгәсе» («Писцовая книга Казанского уезда 1647–1653 годов», М., 2001), «1646–52 еллардагы теркәү материаллары буенча Зөя өязенең исемлек кенәгәсе» («Перечневая книга Свияжского уезда: По материалам писцового описания 1646–1652 годов», 2004); «Казан һәм Казан өязенең 1565–1568 еллардагы теркәү тасвирламасы» («Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 годов», 2006), «Россиянең Нугай Урдасы б-н элемтәләре турында илчелек кенәгәләре. 1551–1561 еллар» («Посольские книги по связам России с Ногайской Ордой. 1551–1561 гг.», 2006). Медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**МОСТА́ФИНОВ** Әхмәт Нурмөхәммәт улы (25.5.1904, Тамбов губ. Спас өязе, хәзер Мордва Респ-касы Торбеевка р-ны Сыркыды а. — 22.10.1963, Мәскәү), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (1960), Соц. Хезмәт Герое (1948). Әзәрбайҗан нефть ин-тын тәмамлый (1932). Баку һәм Краснодар нефть промыселларында эшли. 1941 елдан «Богысланнефть» трестында баш геолог, 1943 тән «Куйбышевнефть»тә, 1952 дән СССР Нефть сәнәгате министрлыгының геология идарәсе башлыгы урынбасары, 1957 дән СССР Госпланында нефть һәм газ сәнәгате бүлеге башлыгы урынбасары, 1961 дән Геол. һәм янучан казылмаларны эшкәртү ин-ты директоры. М. Идел-Урал нефть-газлы өлкәдә, ш.и. Татарстанда һәм Төньяк Каспий буенда нефть һәм газ чыганаклары таралуның төп закончалыкларын билгели. СССРның көнчыгыш районнарындагы девон утырмаларында нефть чыганакларын эзләве һәм ачуы өчен, СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1946, 1954).

Х е з м.: Нефтеносность девонских и каменноугольных отложений Куйбышевского Поволжья. М., 1958 (автордаш).

*Әд.:* М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России. М.-СПб., 2000.

**МОСТЮКО́В** Илдус Шәйхелислам улы (6.3.1928, Казан), конструктор, Соц. Хезмәт Герое (1980), техник фән. канд. (1978), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1986), Казан техник ун-тының шәрәфле профессоры (2004), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (2007). Казан механика-технол. техникумын (1947) һәм Казан авиация ин-тын (1955) тәмамлый. 1947–52 елларда «Казэнерго»ның район идарәсендә эшли. 1955 тән Авиация сәнәгате министрлыгының 294 нче Тәҗрибә-конструкторлык бюросында (СКБ), лаб. башлыгы (1957–58), бүлек җитәкчесе һәм баш конструкторы (1958 дән); 1960 тан СКБ башлыгы, 1962 дән СССР Радиосәнәгать министрлыгының шул ук СКБдан үзгәртелгән 334 нче фәнни-тикшерену ин-ты (1988 дән Казан радиоэлектроника фәнни-тикшерену ин-ты) башлыгы, директоры һәм ген. конструкторы (1962–88), фәнни консультанты (1989–95), шәрәфле директоры (1995 тән). М. җитәкчелегендә институт хәрби техникада кулланыла торган радиолокацион бердәм тану системасын төзү буенча илнең баш пр-тиесенә әверелә. Хезмәтләре радиотехник системалар һәм махсус максатлардагы аппаратура төзелешенә карый. 75 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 24 авторлык таныклыгы бар. «Татарстан геройлары» иҗтимагый оешмасы рәисе (1999 дан). ТАССР ЮС депутаты (1980–85). Россия Хәрби-тарихи фәннәр академиясе академигы, Россия Хәрби фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы. Казанның мактаулы гражданы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, «СССРның мактаулы радисты» билгесе, ТАССР, ТР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МОТАҺИ́Р** Яхъя (19 йөз ахыры — 20 йөзнең 1 нче яртысы), хаттат. Казанда эшли. Мәрҗани мәчетенең 20 йөз башы уникаль «атаклы шәмаиле» авторы (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана). Әсәр пыяла өслектә майлы буяу, алтын һәм көмеш фольга кулланып иҗат ителгән. Шәмаилнең сәнгати кыйммәте М.ны хаттатчылыкны югары проф. сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән талантлы осталар исәбенә кертергә мөмкинлек бирә. Декоратив бизәлеш композициясендә татар халык сәнгатенә хас төрле стильләштерелгән чәчәкләрне борма-борма сузылган сабакка тезү алымы кулланылган; болгарлар заманыннан популяр булган спиральсыман орнамент мотивлары сөлес язуындагы гарәп хәрефләрен органик бизәкли. Аларның михраб уемындагы композициясе чалма сурәте — суфи борадәрлекләреннән берсенең символы б-н тәгәлләнә. Нур чәчүче чалмадан өстәрәк, күләгәсыман фонда, болгар-татарлардагы «тормыш агачы»ндагы кебек ботаклар б-н татар халкы символы буларак танылган лалә мотивы сурәтләгән. Суфичылык йогынтысы шәмаилдә язылган «Кешенең саулыгы — телне саклауда» әйтемендә чагыла; бу сүзләр, тикшеренүчеләр фикеренчә, Нәкышбәндийә борадәрлегенең күңелдән әйтелә торган зикере б-н бәйле. Фондагы кара, зәңгәр һәм алтын-сары төсләргә көрән-кызыл төсмер һәм ялтыравык фольга бөрчекләре өстәлү шәмаилнең төсләр тупланмасына нәфислек бирә. Шәмаилнең симметрияле композициясе төрле билге үрнәкләре һәм символик эчтәлек б-н бергә аңа серле мәгънә өсти.



Ә.Н.Мостафинов.



И.Ш.Мостюков.



Я. М о т а һ и р. «Кеше саулыгы – телне саклауда» шәмаиле. Пыяла, майлы буяу, фольга. 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф., Ш а г е е в а Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990; Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МОТЕ́НКО** Борис Натанович (23.7.1930, Украина ССР, Винница өлкәсе Погребище а.), инженер-электромеханик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), техник фән. канд. (1970), РСФСРның атказ. уйлап табучысы



Г.М. Мотыйгуллин.



Р.Һ. Мотыйгуллина.

(1991). Киев политехник ин-тын тәмамлый (1952). «КОМЗ» АҖнең «Фотон» ҮЗәк КБсында эшли, бүлек (1965–74), тармак лаб-ясе (1974–76), Тәҗрибә КБ (1976–82), бүлекчә башлыгы — юнәлешнең баш конструкторы (1982–95); әйдәп баручы инженер-конструктор (1995 тән). Хезмәтләре оптик-электрон системалар, астрофизика аппаратурасы, төрле максаттагы лазер җайланмалары төзүгә карый. Дәүләт бүләге приборлар төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. 105 фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 53 авторлык таныклыгы бар.

**МО́ТИНА** Людмила Ивановна (20.6.1951, Әлмәт ш.), икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012), икътисад фән. канд. (1999), ТРның атказ. нефтьчесе (2003). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1975). ТатНИПИнефтьтә эшли, директор урынбасары (1996 дан). Хезмәтләре нефть чыганаклары эшкәртүнең икътисади мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге «Татнефть» АҖнең ресурслар базасын үстерү технологияләре һәм алымнары комплексының фәнни нигезләре һәм сәнәгатьтә кулланышка кертү» хезмәтендә катнашуы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МОТОЦИ́КЛ СПОРТЫ́**, спортның техник төре, махсус трассаларда, юлларда һәм юллардан читтә, юл яисә спорт мотоциклларында узышу; мотоциклларның һәр классы өчен аерым уздырыла. М.с.на шосседа туры һәм түгәрәк буенча узышлар (1,5 *км* дан озынрак йомык трассада), мотокросс (1,5 *км* дан 5 *км* га кадәрле йомык түгәрәк трасса буенча табигый каршылыклы урыннар буенча узышлар), мотоциклда күп төр ярышлар, күпкөнлек мотоцикл ярышлары (эндуро), стадионның шлаклы һәм бозлы юллары буенча треклы узышлар (спидвей), җирдәге юллар буенча ипподром узышлары, фигуралы йөртү, рекорд куюга махсус йөрешләр, туплы уеннар (мотобол) керә. Казанда спорт төре буларак 1939 елдан республика Автомотоклубында (1937 дә оештырыла, Чистайда ф-лы бар) үсеш ала. 1940–50 елларда Автомотоклуб, «Искра», «Локомотив», «Урожай», «Красное Знамя», «Наука» ирекле спорт җәмгыятьләре хәрбиләштерелгән җәйге һәм кышкы мотокросслар, республика шәһәрләре һәм районнары буенча мотоузышлар, мотоциклларда фигуралы йөрү буенча ярышлар, ипподром узышлары үткәрәләр. Казанның җыелма командасы Казан, Ижевск, Уфа, Чабаксар шәһәрләрендәге шәхси-команда ярышларында (1947) медаль (2 нче урын), ТАССР җыелма командасы РСФСР беренчелекләрендә (1949, 1950) медаль (2 нче урын) ала. 1960 еллардан М.с. ДОСААФның Татарстан өлкә оешмасының (1991 дән Россия оборона спорт-техник оешмасының (ОСТО) Татарстан бүлеге — ТР ОСТОсы Казан, Яшел Үзән, Бөгелмә, Чаллы һ.б. шәһәрләрдәге коллективларында һәм спорт-техник клубларында җәелдерелә. Татарстанның иң яхшы спортчылары, РСФСР, СССР чемпионатлары этапларында җиңүчеләр һәм медаль алучылар: 1950 елларда шоссе (туры һәм түгәрәк буйлап) узышлары, гадәти мотокросслар буенча — А.С.Андриянов, В.Б.Бикеев, И.А.Габидуллин, Г.Гиеров, Н.М.Кузнецов, Л.Липатов, Э.Ногманов, С.Петрухин, А.А.Суражская, А.Ташлыков; 1960–80 елларда боз спидвее буенча — Е.Афонин, В.Бодрецов, Л.Захматов, Л.Колесников; эндуро һәм мотокросс буенча — И.И.Кокшагин (берничә тапкыр РСФСР чемпионы, РСФСР халыкларының 8 нче Спартакиадасы чемпионы, 1983); мотокросс буенча — Ф.Т.*Бәдретдинов*, И.В.Бударин, И.Зайцев, В.Тарасов, А.Фролов (РСФСР чемпионатларында көмеш медаль алучылар, 1980), С.В.Черныш (СССР чемпионатында бронза медаль алучы, 1988). 2000 елдан Казан шәһәрендәге ТР ОСТОсы Идел буе р-н советының «Привolжанин» спорт-техник клубы — берничә тапкыр Идел буе һәм Урал шәһәрләре кубогы, Россиянең кышкы Кубогы иясе, Идел буе р-нының хакимият башлыгы призына ярышларда (1989 дан уздырыла) җиңүче. Иң яхшы спортчылар — Н.О.Береснев, К.С.Лефанов, А.Э.Флегонтов.

**«МОТЫЙГИЯ́»**, Уральск шәһәрендәге 1 нче (Кызыл) мәчет каршындагы мәдрәсә. 19 йөз уртасыннан эшли, мөдәррис М.Төхфәтуллин исеме б-н атала, ул «М.» мәдрәсәсен 1870 еллар уртасыннан 1918 гә кадәр җитәкли. Эшләвенең беренче ун елында мәдрәсә иске ысуллы була, ләкин мөселман хокукы һәм гарәп теле укытуның югары дәрәҗәсе һәм яхшы шартлары б-н аерылып тора; 10 лап укытучы эшли. 1890 еллар уртасыннан шәкертләр рус сыйныфында 3 ел мәҗбүри укыйлар. 1903 тән М.Төхфәтуллинның улы К.*Мотыйгый* «М.» мәдрәсәсендә укыта башлагач, яңача укыту ысуллары киң кулланыла башлый. 1903–05 тә мәдрәсәдә *«Гыйльми мәҗлес»* исемле әдәби җәмгыять эшли, кулъязма журналлар басыла. 1896–1906 да «М.» дә Г.Тукай укый, 1904 тән бер үк вакытта укыта. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында — М.*Чулпаный*, Г.*Кариев*.

*Әд.:* Нуруллин И.З. Тукай. М., 1977.

**МОТЫЙГУ́ЛЛИН** Габдулла Мотыйгулла улы (11.9.1923, Мамадыш кантоны Түбән Саурыш а. — 27.1.1988, Саба р-ны Байлар Сабасы а.), Дан орденының тулы кавалеры (5.5.1944, 1.8.1944, 15.5.1946), гв. сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең гыйнварыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 92 нче гв. укчы полкының снайперы, отделение командиры (5 нче гв. армиясенең 97 нче гв. укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Кировоград, Умань-Ботошани (икесе дә — 1944), Сандомир-Силезия, Түбән Силезия, Югары Силезия һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1945) катнаша. 1944 нең 4–5 апрелендә Тархановка (Николаев өлкәсе) авылы янындагы (снайпер винтовкасыннан 11 гитлерчыны юк итә); 1944 нең 2–5 маенда Аснашень (Молдовия ССР) авылы тирәсендәге (дошманның 10 солдатын юк итә); 1944 нең 17 августында Висла елгасының сул ярындагы Сандомир (Польша) шәһәре янындагы (аның җитәкчелегендәге отделение дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда 20 дән артык солдатын юк итә) сугышларда батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Совхоз (Байлар Сабасы) бригадиры булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китаәы — Книга Героев. К., 2000; Андреев Г.И., Вакуров И.Д. Солдатская слава. М., 1981; Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МОТЫЙГУЛЛИ́Н** Равил Хәйдәр улы (17.2.1952, Самара өлкәсенең Келәүле р-ны, хәзер Камышлы р-ны Яңа Усман а.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), РФнең 3 нче класслы Дәүләт киңәшчесе, ТРның атказ. геологы (2009), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), Карелия комплекслы геол. разведка экспедициясендә (Петрозаводск ш.) эшли. 1990 елдан Казанның геол. оешмаларында. 2005 тән Татарстан Респ-касының Җир асты байлыклары идарәсе башлыгы. Дәүләт бүләге нефть чыганакларын эзләүнең комплекслы алымнарын кулланып, ТРның көнбатыш өлешендә нефть перспективаларын бәяләү турындагы хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МОТЫЙГУ́ЛЛИНА** Рузия Һидият кызы (3.3.1950, Әлки р-ны Югары Әлки а.), драма актрисасы, ТССРның халык артисты (1991), РФнең атказ. артисты (2001). 1974 елда Казан театр уч-щесен тәмамлый һәм Татар акад. театры труппасына эшкә килә. Чибәрлеге, хис-тойгыларга байлыгы б-н М. Марийка («Солдат хатыны», Н.П.Анкилов), Росита («Канлы күләгәләр», Г.А.Боровик), Айсылу («Ташкыннар», Т.Гыйззәт) кебек беренче рольләрендә үк үзен танытуга ирешә. Зәримә образында («Китәм инде», Р.Хәмид) актрисаның драматик характер асылына тирән үтеп керә белүе күренә. М. тарафыннан иҗат ителгән аеруча игътибарга лаек образларның берсе — Лариса («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский). Әлеге спектакльдә актрисаның ачык, йомшак күңелле, эчкерсез героинясы кешене ниндидер бер «әйбер» кебек сату-алуга корылган дөньяны олы фаҗига буларак кабул итә. М. башкаруында Шәмсегаян роле («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев) психол. анализ тирәнлеге б-н аерылып тора. Тышкы сурәтләү чараларын мул кулланмый гына, актриса газиз туган җиреннән аерылып китәргә мәҗбүр ителгән хатынның газапларын бөтен нечкәлекләре б-н ача. М. төрле яшьтәге,



Р.Һ.Мотыйгуллина Шәмсия ролендә («Күрәзәче», З.Хәким; Хәнәви ролендә – Ә.Шакиров).

төрле характерлы хатын-кыз рольләрен башкара: Зөләйха (Г.Исхакыйның шул исем. әсәре буенча), Галимәбану («Галиябану», М.Фәйзи), Шәфәкъ («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Наталья («Илгизәр + Вера», Т.Миңнуллин), Ләйсән («Ләйсән ире Хәсән», Ю.Сафиуллин), Анджела («Болан-Патша», К.Гоцци), Беатриче («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Кәримә («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид; Г.Исхакый әсәре буенча), Ханума (А.Цагарелиның шул исем. әсәре буенча), Саярә («Искән җилләр көенә», З.Хәким), Бибикамал («Go! Баламишкин», Ф.Бүләков) һ.б.

*Әд.:* Г.Камал театры артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**МОТЫЙГЫ́Й** Камил Мотыйгулла улы (чын фамилиясе һәм исеме Төхфәтуллин Камил) (25.2.1883, Уральск өлкәсенең Уральск ш., хәзер Казакъстан Респ-касы — 26.1.1941, Казан), җырчы (баритон), журналист, нашир, җырлар авторы. Г.М.*Кайбицкаяның* абыйсы. «Мотыйгия» мәдрәсәсендә, 1900–02 елларда Каһирәдә «әл-Әзһәр» ун-тында (Мисыр) укый. 1902–07 дә «Мотыйгия» мәдрәсәсендә укыта, Г.Тукайның дөньяга карашы һәм аның шагыйрь булып формалашуында мөһим роль уйный. 1905–07 дә «әл-Гаср әл-җәдид», «Уклар» ж-ларын, «Фикер» г-тасын нигезләүче, аларның нашире һәм мөхәррире, «Уралец» (1906 дан — «Уральск көндәлеге») г-тасының нашире. «Яңа тормыш» г-тасын оештыручыларның берсе (1907–09). 1909–17 дә концерт эшчәнлеге алып бара. 1917 дә хәрби хезмәткә алына һәм Петроградка Главпочтамтка контролёр булып җибәрелә, 1918 дә «Ярлы халык» г-тасының мөхәррире. 1918 нең мартыннан Самара шәһәрендә «Киңәш» г-тасы мөхәррире. Самараны ак чехлар басып алганнан соң, *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* (КОМУЧ) хөкүмәте каршында чыгып килгән «Безнең фикер» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә, шуның өчен соңыннан берничә тапкыр акгвардиячеләр б-н эш йөртүдә гаепләнә. Самара шәһәре азат ителгәннән соң «Яңа көч» г-тасы хезмәткәре. 1919 дан соң Уральск шәһәрендә «Ихтилял байрагы» (1919), «Яңа фикер» (1920) г-талары мөхәррире. Соңрак ВКП(б)дан чыгарыла. 1924 тән Казанның «Гажур» нәшриятында консультант һәм ТАССР Халык мәгарифе ком-тында тәрҗемәче, бер үк вакытта, 1925–29 да, концертлар б-н чыгышлар ясый. 1930 елларда әдәби иҗат б-н шөгыльләнә башлый. М.ның «Шайтан өне», «Көрәш» пьесалары татар театры сәхнәләрендә куела.

Беренче проф. татар эстрадасы башкаручысы; аның репертуарына халык җырлары, Г.Тукай, Н.Думави һ.б.ның шигырьләренә иҗат иткән үз җырлары керә. Нота грамотасын белмәү сәбәпле, рев-ция чорында башкарган беренче җырлары 1919 да Саратов шәһәрендә проф. Л.Рудольф тарафыннан яздырыла. Татар халкы арасында «Ай былбылым» (Н.Исәнбәт шигырен М. гарәп көенә сала) һәм Г.Тукай шигыренә язылган «Пар ат» җырлары киң тарала.

Әсәр.: Бәхетле Мәрьям. СПб., 1903; Тозак (пьеса). К., 1932.

*Әд.:* Даутов К. Нашир һәм җырчы // Мирас. 2003. № 2; Нуруллин И.З. Тукай. М., 1977; Тухфатуллин Ф.К. Камиль Мутыги. К., 1992.

**МОХНА́ТКИН** Михаил Гурьевич (21.11.1955, Ульянов өлкәсенең Тирәнкүл р-ны Новая Жизнь пос.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1977). 1977–91 еллардан һәм 1995 тән «ТүбәнКамашин» АҖдә: инженер-лаборант, үзәк завод лаб-ясендә башлык урынбасары, цех башлыгы, производство-диспетчерлык бүлегендә өлкән диспетчер, директор урынбасары, баш технолог, йөк машиналары шиннары заводы директоры (2007 дән). 1991–95 тә Чаллы шәһәренең төрле пр-тиеләрендә. Дәүләт бүләге «Түбәнкамашин» АҖнең көндәшлеккә сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү максатында яңа төр материаллар эшләү һәм үзләштерүдә катнашканы өчен бирелә.

**МОХНА́ТКИНА** Елена Гордеевна (16.1.1955, Лениногорск ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), «Татнефть-Нефтехим» ҖЧҖ идарәче компаниясендә: инженер-лаборант, тикшерү секторы башлыгы, әйдәп баручы инженер-технолог, бүлек башлыгы, заводның үзәк лаб-ясе башлыгы, «Кама» фәнни-техник үзәге» ҖЧҖнең баш химигы, чимал һәм материаллар рецептурасы идарәсендә баш технолог. Уйлап табуга патенты бар. Дәүләт бүләге «Түбәнкамашин» АҖдә көндәшлеккә сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү максатында сыйфатлы яңа материалларны үзләштерү һәм эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**МО́ХОВ** Василий Иванович (13.2.1888, Казан губ., Спас өязе Гоголиха а. — ?), революцион хәрәкәттә катнашучы. Социалист-революционерлар партиясе әгъзасы. 1905–06 елларда Спас өязе крәстияннәре кузгалышында, террорчылык актларында катнаша. 1909 да Иркутск губернасына мәңгелек сөргенгә җибәрелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Спас өязенә кире кайта. 1917 нең май–июль айларында Мораса волость башкарма ком-ты рәисе, Спас өязенең 3 нче участогы милиция башлыгы (Ромодан а.) Крәстияннәрне алпавытлар милкен көч куллanып тартып алырга өнди. 24 июньдә делегатларның өяз съездында өяз комиссары итеп сайлана, әмма губерна комиссары съезд карарын кабул итми. 1917 елгы июль кризисыннан соң кулга алына, 1917 нең 14 сентябрендә Казан губернасы крәстияннәре съезды таләбе б-н ирекккә чыгарыла. 24 сентябрьдә Спас өязе съездында яңадан өяз комиссары итеп сайлана. Совет хакимиятен хуплый. 8 ноябрьдә губерна комис-ты рәисе итеп билгеләнә. 1917 нең декабреннән 1918 нең июленә кадәр Казан губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары Советының эчке эшләр комиссары, Казан Совет Эшче-Крәстиян Респ-касы ХКС әгъзасы. 1918 елгы сул эсерлар фетнәсеннән соң җитәкче эшләрдән читләштерелә. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

*С.И.Ионенко.*

**МОХТА́Җ СТУДЕНТЛАРГА́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Казан ун-тындагы хәйрия оешмасы. 1870 еллар башында проф. Н.А.*Виноградов* башлангычы б-н ярлы студентларга укуларын дәвам итү һәм тәмамлап чыгу мөмкинлеге тудыру өчен акча җыю максатыннан булдырыла (1870 елларда студентларның 28%ы гына үз хисабына яши). Җәмгыятьнең уставы эчке эшләр министры тарафыннан 1871 нең 28 апрелендә раслана. Җәмгыять эшчәнлегенең матди нигезен 15–20% лы взнос һәм иганәләрне Россия Дәүләт банкының 5% лы билетларына әйләндерүдән кергән кагылгысыз капитал тәшкил итә. Беренче рәисе — Казан уку-укыту округы попечителе П.Д.Шестаков. Гамәлгә куючы әгъзалар — 37 кеше; эшчәнлегенең беренче елында 145 хакыйкый әгъзаны берләштерә (һәрберсе җәмгыять кассасына елына 10 сум кертә). Иганә аерым затлардан, ш.у. спектакльләр куюдан, килгән артистлар чыгышларыннан, университет профессорларының ачык лекцияләреннән, китаплар нәшер итүдән җыела. Җәмгыятькә земство һәм шәһәр идарәләре, Казан, Түбән Новгород, Әстерхан һ.б. шәһәрләр халкы, Казан ун-тының элекке студентлары ярдәм күрсәтә. Мәс., Иркутск шәһәре идарәсе Көнчыгыш Себердән (башлыча, Иркутск) булган мохтаҗ студентлар өчен 300 сум күләмендә еллык стипендия билгели. Матди ярдәм кире кайтарылмый торган итеп (бер тапкыр, күләме — елга 20 сум чамасы) яки, күпчелек очракта, кергән үтенеч язулары буенча, факультет аша ссуда итеп бирелә (1870 елларда үтенечләр мед. һәм юридик ф-тлардан аеруча күп керә). Ссуда (200 сум чамасы) студентка эшли башлагач түләү шарты б-н бирелә, күләме дипломда күрсәтелә. Бурычлы студентның вафаты очрагында бурыч юкка чыгарыла. 1871/72 уку елында шундый 312 үтенеч язуы кабул ителә; 10 студент 120 шәр сум, 165 е тулаем 3165 сум 29 тиен күләмендә акчалата ярдәм ала, кассада акча булмау сәбәпле, калган студентларның үтенече канәгатьләндерелми. Алдагы уку елында 350 үтенеч язуы кабул ителә; 125 студентка тулаем 3040 сумлык матди ярдәм күрсәтелә. Ярдәмнең тагын бер төре — арзанлы төшке аш билетлары (айга 3 сумлык) б-н тәэмин итү. Җәмгыять ш.у. студентлар һәм балаларына репетитор эзләүче ата-аналар арасында арадашчы ролен



К.Г. Мохтаров.

үти: белдерүләр бастыра, студентларга рекомендация бирә. 1898 дә университетка Н.А.Виноградовның 45,8 мең сумлык капиталы тапшырыла. Н.А.Виноградовның хатыны да 10,2 мең сумлык капиталын университетка васыять итә. Бу акчалар мед. ф-тының чыгышы, башлыча, руханилардан булган студентларына Н.А.Виноградов исем. стипендия түләү һәм иң ярлы студентларга ярдәм күрсәтү өчен тотыла. Университетка ш.у. васыять буенча тапшырылган йортта аерым кешеләр биргән акча (башлыча, Г.К.Ушаковтан кергән 1,1 мең сум иганә) һәм шәһәр театрында махсус куелган опера спектакле керемнәре хисабына 100 урынлы ашханә ачыла, бушлай фатирлар арендалана. Казна хисабына укыган студентлардан калган көмеш аш-су приборларын университет ашханәгә бүләк итеп тапшыра. Университетта «Әстерхан губернасының эчке Урда кыргызлары өчен», «Оренбург төбәге мөселман башкортлары өчен», «Тургай өлкәсенең мохтаҗ студентлары һәм кыргыз балалары өчен» махсус стипендияләре тапшырыла. 1909 да Казан ун-тының Себер шәһәрләрендәге гимназияләрне тәмамлап килгән мохтаҗ студентларына ярдәм итү өчен оештырылган Себер җәмгыяте Уставы эшләнә.

Чыг.: Устав Общества для вспомоществования бедным студентам Казанского университета. К., 1871; Отчёт Общества для вспомоществования бедным студентам Казанского университета за 1887–88 г. К., 1889.

*И.А.Новицкая.*

**«МОХТАҖЛЫ́К БОРАДӘРЛЕГЕ́»**, к. *«Немецларның контрреволюцион-фашистик оешмасы» эше.*

**«МОХТАРИЯ́Т»** («محتاريت» — «Бәйсезлек»), иҗтимагый-сәяси газета. *Милли Шура* органы. 1917 елның ахырында Саратов шәһәрендә татар телендә атнага 2 тапкыр нәшер ителә. Мөхәррире — С.Янгалычев. Федералистлар мәнфәгатен яклый. Волость үзидарәсе һәм кооперация нигезендә җирле автономия төзүне хуплый.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«МОХТАРИЯ́Т»**, айлык дини журнал. *Милли Идарә* органы. *Мәгълүмате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургыя»* ж-лының дәвамчысы. 1917 елның октябрь аеннан 1918 нең апреленә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 9 саны чыга. «Тормыш» басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — М.Хәнәфи. Журнал б-н Ш.Алкин, Г.Баруди, И.Даутов, З.Кадыйри, Н.Корбангалиев, С.Максуди, Г.Сөләйманов, К.Тәрҗемани, С.Урманов, Г.Шәрәф һ.б. хезмәттәшлек итә. Даими рубрикалары: «Рәсми бүлек», «Дини идарәдә», «Мәгариф министрлыгында», «Малия министрлыгында», «Мәкаләләр», «Редакциягә хатлар», «М.» тә *Милләт Мәҗлесен* әзерләү, ачу һәм аның эше, кабул ителгән карарлар киң яктыртыла (Уфа ш., 1917 нең 20 ноябре — 1918 нең 11 гыйнвары). 1918 нең 16 гыйнварында Милләт Мәҗлесе тарафыннан кабул ителгән «Эчке Россия һәм Себер мөселман төрки татарларның милли-мәдәни мохтарияте нигезләре» басыла. Редакция Милләт Мәҗлесенең I сессиясе эшендә катнашкан делегатлар һәм делегатлыкка кандидатлар исемлеген, Милли Идарә рәисе һәм аның урынбасары исемен, Милли Идарәнең барлык министрлыклары әгъзалары исемлеген һәм Милләт Мәҗлесе утырышларында сайланган Идел — Урал штатын тормышка ашыру коллегиясе һ.б. эшче комиссияләр исемлеген бастыра. Журнал эчтәлегенең нигезен Милли Идарә, аның карарлары, рәисе һәм идарәнең өч министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәкаләләр тәшкил итә. Журналда ш.у. мәдрәсәдә укыту-тәрбия эшләрен оештыру турындагы мәкаләләр, татар телендә яңа вакытлы матбугат чыга башлау хакындагы хәбәрләр бирелә. Совет хакимияте тарафыннан Милли Идарә таратылгач, журнал чыгудан туктый.

*Т.М.Насыйров.*

**МОХТА́РОВ** Кәшшаф Гыйльфан улы (14.7.1896, Казан губ., Лаеш өязе Тауиле а. — 27.10.1937, Карелия АССРның Медвежьегорск р-ны Сандармох а.), дәүләт эшлеклесе. Пермьдә гимназия тәмамлый (1916), Пермь ун-тының мед. ф-тында укый (1916–17). 1917 елда «Безнең көннәр» г-тасын оештыручыларның берсе һәм мөхәррире (Пермь ш.). Гражданнар сугышында катнаша. 1918–19 да Көнчыгыш фронтта 51 нче укчы дивизиянең (В.К.Блюхер җитәкчелегендә) 21 нче мөселман полкы политругы. 1920–21 дә Казанда Вакытлы революцион ком-т әгъзасы, ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары, 1921–24 тә ТАССР ХКС рәисе. ТАССР ҮБК һәм ХКСның «Республиканың совет учреждениеләре эш кәгазьләрендә татар телен гамәлгә кертү» Декретын әзерләүдә катнаша (1921). Идел буенда ачлыктан интеккән халыкка ярдәм оештыручыларның берсе. 1924 тән Мәскәүдә, РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тының дәвалау бүлеге мөдире, РСФСР БҮБКның хатын-кызларның көнкүреш шартларын яхшырту комиссиясе әгъзасы. СССР Конституциясен эшләүдә актив катнаша. 1929 да ВКП(б)дан чыгарыла, 1931 дә репрессияләнә (кабат 1937 дә хөкем ителә); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Трёхлетие ТАССР. 1920–25 июня 1923: Докл. председателя СНК ТССР К.Г.Мухтарова. К., 1923.

*Әд.:* Б е л я л о в У.Б. Мухтаров Кашаф Гильфанович // Возвращённые имена: Док. очерки. К., 1990. *Ф.Г.Кәлимуллина.*

**МОХТА́РОВ** Низаметдин (25.3.1936, Сталинабад ш., хәзер Таҗикстан Респ-касы Дүшәнбе ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1998). 1962 елда Таҗикстан ун-тын тәмамлаганнан соң, Таҗикстан ФАнең Физика-техника ин-тында эшли, ультратавыш физикасы лаб-ясе мөдире (1974–78). 1998 дән Кама политехник ин-тының электротехника һәм электроника каф. профессоры (хәзер Кама икътисади-инженерлар академиясе, Чаллы ш.). Хезмәтләре камил булмаган диэлектрикларны I һәм II төр фаза күчеше ноктлары янында ультратавыш б-н тикшерүгә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Цифровой акустический интерферометр для исследования скорости УЗ в жидких средах // Изв. АН Тадж. ССР. 1983. № 1 (автордаш); Наблюдение размытого фазового перехода в цирконат-титанат-свинец-лантан керамике акустическими методами // Письма в журн. теоретической физики. 1988. Т. 14, вып. 14 (автордаш).

**МОХТА́РОВА** Нәзирә Җиһанша кызы (18.1.1925, Кыргызстан ССР, хәзер Кыргыз Респ-касының Каракүл ш.), невропатолог, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1983). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1947). 1948–65 елларда Кыргыз мед. ин-тында эшли. 1965 тән Украина гигиена, пестицидлар, полимерлар һәм пластик массалар токсикологиясе фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре өлкәннәр һәм балалар организмында химик матдәләр, полимерлар һәм пластик массалар тәэсирендә барлыкка килгән агулану-аллергия авыруларына диагноз кую, аларны дәвалау һәм булдырмауга карый. 10 рационализаторлык тәкъдиме бар.

Х е з м.: Клиника, патогенез, диагностика, лечение и профилактика поражений нервной системы при хронической интоксикации пестицидами в условиях химизации сельского хозяйства. Киев, 1982; Влияние комплекса приоритетных техногенных загрязнений окружающей среды на здоровье детей г. Киева. Киев, 1994.

**МОЧАЛО́В** Инар Иванович (20.1.1932), философ, филос. фән. д-ры (1971), проф. (1972). Ленинград ун-тын тәмамлый (1954). 1954–55 елларда Грозный ун-тында укыта. 1959–78 дә Казан авиация ин-тында, филос. каф. мөдире (1972 дән). 1978 дән — Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесенең филос. каф. профессоры; бер үк вакытта СССР ФА Табигыять һәм техника тарихы ин-тында фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре фәннәр тарихы һәм табигыять белеме, аерым алганда, В.И.Вернадский иҗатына карый.

Х е з м.: В.И.Вернадский — человек и мыслитель. М., 1970; Владимир Иванович Вернадский и религия. М., 1991.

**МОЧАЛО́В** Константин Николаевич (30.9.1902, Тула губ. Хотуши а. — 21.11.1973, Казан), химик, химия фән. д-ры (1956), проф. (1957), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1969). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), Казан химия-технол. ин-тында эшли, 1956 елдан аналитик химия каф. мөдире. Хезмәтләре газлы электрохимиягә карый. М. азотның төрле варианттагы фаКеллы бушануларда кинетикасын һәм оксидлашу механизмын өйрәнә. Химик реакцияләрне электр бушануы тәэсирендә активлаштыру ысулын тәкъдим итә. Инерт газлар тирәлегендә эмиссион спектраль анализны гамәлгә ашыра. Селтеле металлар боргидридларын тикшерә һәм аналитик химиядә беренче тапкыр аларны сусыз эреткечләр өчен төп титрантлар сыйфатында куллана. Авыр металл тозларының боргидридлар б-н реак-

цияләре (М. җитәкчелегендә өйрәнелгән) химик металлаштыру процессларының нигезен тәшкил итә. Аның тарафыннан эшләнгән: диңгез хайваннары тиресен селтеле металл боргидридлары кулланып агарту ысулы һәм кинофотоматериаллар өчен көмеш көлен яңача синтезлау технологиясе Казан мех комб-тында һәм В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-дында гамәлгә кертелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кинетика окислённого азота в факельном разряде // Журн. физ. химии. 1939. Вып. 9; Крекинг метана в факельном разряде // Тр. Казан. хим.-технол. ин-та. 1948. Вып. 13.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

*В.Г.Абзалова.*

**МОШКО́В** Валентин Александрович (25.3.1852, Кострома ш. — 1920 еллар тирәсе), муз. фольклор җыючы, этнограф, тел белгече, генерал-майор (1905). Михаил гв. артиллерия уч-щесен (Петербург, 1871) тәмамлый. Армия хезмәтендә була. 1874 елдан Баш артиллерия идарәсенең Олонец казна з-дларында (Петрозаводск ш.) заказ кабул итүче, 1888 дән Казан дары з-дында, 1892 дән Варшава хәрби округы штабында, 1913 тән отставкада. М.ның фәнни эшчәнлеге Казанда башлана, В.В.*Радлов* һәм Н.Ф.*Катанов* аның уникаль муз. һәм лингвистик сәләтләренә игътибар итәләр. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте эшендә катнаша (ш.и. Варшавага күчкәннән соң да). Төрки һәм фин-угор халыкларының муз. иҗат үрнәкләренең нота язмаларын җыя, аларны «Известия общества археологии, истории и этнографии при Казанском университете» («Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре») ж-лында бастырып чыгара: «Чуаш җырлары музыкасы» («Музыка чувашской песни», 1893, т. 11, чыг. 1), «Нугай һәм Оренбург татарлары көйләре» («Мелодии ногайских и оренбургских татар», 1894, т. 12, чыг. 1; 1895, т. 14, чыг. 3), «Әстерхан һәм Оренбург нугайлары, кыргызлары көйләре» («Мелодии астраханских и оренбургских ногайцев и киргизов», 1901, т. 17, чыг. 1). Варшавада хезмәт иткәндә гагауз телен һәм фольклорын беренче булып өйрәнә; гагаузларның, элек саналганча, төрекләрнең этник төркеме түгел, ә халык булуын фәнни яктан дәлилли. М. барлык тикшеренү материалларын үзенең кул астындагы солдатлардан җыя. Аның төрки музыка уен кораллары һәм фоторәсемнәр коллекцияләре Мәскәү ун-тының этнография музеенда саклана.

Ә с ә р.: Пермяцко-карельские параллели // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 6; Гагаузские тексты // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1895. Т. 13, вып. 2; Stōw kilka o ednjem z miṣdzynarodowych ubiorōw gtowy // Wista. 1897. Т. 11.

*Әд.:* П о к р о в с к а я Л.А. Грамматика гагаузского языка: Фонетика и морфология. М., 1964; Т о к а р е в С.А. История русской этнографии. М., 1966; А й п л а т о в Г.Н. Российский Нострадамус Валентин Мошков // Чудеса и приключения. 1993. № 7.

*Е.В.Липаков.*

**МӨӘЗИ́Н** (гарәп. مؤذن — хәбәр, игълан итү, төрки. — азанчы), манарадан азан — мөселманнарны *намазга* чакыру (ислам динендә каралган биш вакыт намазга өндәүче мәчет хезмәткәре. М. бурычларына ш.у. намаз уку алдыннан кычкырып махсус дога кылу (икамәт) керә. М.нәр мәчетләрне тәртиптә, чиста тотарга, *имам* кушуы буенча аерым дини йолалар үтәргә тиешләр. М.нең төп вазифалары Аллаһ хуплавына кергән гамәлләрдән гыйбарәт һәм еш кына алар җәмәгать башлангычында алып барылган. Кайбер мәчетләрдә М. вазифасын үзе теләп мәхәллә кешеләреннән берәрсе яки мәчет имамы башкарган. М., имамнар кебек, үз вазифаларын мөселман җәмәгате чыгымнары хисабына башкарган. Аның төп керем чыганагы булып шәхси хуҗалыгы саналган. Яшәү рәвеше һәм матди хәле буенча М. халыктан әллә ни аерылмаган. Хәзер һәр зур мәчеттә М. вазифалары бар, кечкенә мәчетләрдә бу хезмәтне, гадәттә, имам-хатип башкара. Ш.у. к. *Мөселман руханилары.*

*Әд.:* Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2006.

**МӨБАРӘ́К-ХАҖИ́** (? — 1347/48 тирәсе), Күк Урда ханы (1344/45). Урда Эҗен варисы, Эрзен улы. Алтын Урда ханы Җанибәктән бәйсез сәясәт алып барырга омтыла. Үз акчасын суга. 1345 елда Җанибәк тарафыннан тар-мар ителә, Алтайга кыргызлар янына кача һәм шунда үзара сугышта һәлак була.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨБАРӘ́КШИН** Рәхим Вәли улы (27.1.1920, Казан губ., Казан өязе Күлтәс а.-1998, Мәскәү), математик һәм механик, техник фән. д-ры (1963), проф. (1965). Казан ун-тын (1941) һәм Н.Е.Жуковский исем. Хәрби һава инженерлары академиясен (Мәскәү, 1944) тәмамлый. 1944 елдан Мәскәү хәрби уч-щесендә укыта, 1948 дән Хәрби һава инженерлары академиясендә каф. башлыгы; 1972 дән Мәскәү авиация ин-тында. М. идарә ителүле объектларны маневр ясаучы объектларга төзәү системалары төгәллегенең ихтимальный характеристикаларын һәм сугышчан нәтиҗәлелеген матем. исәпләү алымнарын эшли. Идарә ителүле стохастик динамик системаларның халәтен оптималь фаразлау теориясен тәкдим итә. Хезмәт нәтиҗәләре Россия Хәрби һава көчләрендә һәм сәнәгать пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2005, үлгәннән соң). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аналитическое исследование точности бортовых систем с программным сопровождением цели. М., 1961; Об оптимальной структурной схеме фильтров. М., 1962 (автордаш); Комплексное наведение летательных аппаратов и отделяемых средств. М., 1990.

**МӨВИҖӘ́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында. Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 18,2 *км*, ТР чикләрендә — 9 *км* га якын. Бассейнының мәйданы 134 *км²*. Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әгерҗе р-ны Биектау авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30 %. М.нең 0,9 дан алып 4,2 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,2 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. М. ноябрь уртасында туңа. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

**МӨГАЛЛИ́М** (гарәп. معلم — укытучы), 1) укытучы; 2) 1846–1917 елларда мәхәллә мулласы (имам-хатибы) вазифасын дәгъвалаучыларга Оренбург Мөхәммәд дине кануннары Җыены имтиханында бирелгән дәрәҗә, бер үк вакытта алар мәхәллә мәктәбендә укыту хокукы биргән М. исеме дә алалар; 3) 19 йөз ахырында — 20 йөз башында яңа ысуллы мәдрәсәне тәмамлаучылар, алар мәхәллә мәктәпләрендә укыталар, ләкин руханилар булып саналмыйлар. Кагыйдә буларак, алар укырга-язарга өйрәтәләр, татар теле, арифметика һ.б. дөньяви фәннәрне, кайвакытта рус телен дә укыталар. Хатын-кыз укытучыларны «мөгаллимә» дип атыйлар. М.нәр татар халкы мәгарифе һәм мәдәнияте үсешендә зур роль уйныйлар, дини мәктәпләргә җәдитчелек идеяләрен кертәләр. Аларның йогынтысы 1905 елдан соң аеруча көчәя. Татар вакытлы матбугатында М.нәрнең роле һәм дәрәҗәсе турындагы мәсьәләләр тикшерелә. М. образы матур әдәбиятта да чагылыш таба (Г.*Исхакыйның* «Мөгаллим», «Мөгаллимә» пьесалары). Казан губернасында М.нәрнең күбесе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаучылар була, бу мәдрәсә җирлегендә 1907 дән җәйге вакытта М.нәр өчен пед. курслар оештырыла. М.нәр укытучы буларак рәсми рәвештә теркәлмиләр, шуңа күрә аларның хезмәтенә авыл җәмәгате б-н телдән килешү буенча гына түләнә, кагыйдә буларак, тормыш дәрәҗәсе түбән була. М.нәрнең пед. эшчәнлеге иске карашлы руханиларда ризасызлык тудыра, хөкүмәттә һәм сәяси полициядә М.нәргә карата панисламизм, пантюркизм, рев-ция һәм соц. идеяләр таратучылар дигән шикләнүле мөнәсәбәт барлыкка килә. 1917 дән соң М.нәр совет татар мәктәпләрендә укытучылар булып китә, аларның яңа ысуллы мәдрәсә тәмамлаган таныклыклары урта пед. белемгә тиңләштерелә.

*Әд.:* К о б л о в Я.Д. Конфессиональные школы Казанских татар. К., 1916; Валиди Дж. Очерки истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.-П., 1923; М а х м у т о в а А.Х. Становление светского образования у татар. Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917. К., 1982.

**«МӨГАЛЛИ́М»**, рәсемле фәнни-пед., әдәби журнал. 1913 елның октябреннән 1914 нең

15 апреленә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә аена 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 9 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Х.Гали. Актив авторлар арасында — Г.Әэмитов, И.Бикчәнтәев, Җ.Вәлиди, Ш.Мостаев, Н.Надиев, А.Нургалиев, М.Нури, Г.Сәгъди, С.Хәбиров һ.б. Журнал татар башлангыч һәм урта мәктәп укытучыларының күбесе өчен алыштыргысыз ярдәмлеккә әверелә. «Мәктәп һәм мәгариф яңалыклары» бүлегендә укыту методикасы (әйдәп баручы укытучыларның дәрес конспектлары бирелә), укучыларны хезмәт б-н тәрбияләү, мәгариф өлкәсендәге реформалар, дини мәктәпләр һәм мәдрәсәләр, мәктәпкәчә тәрбия турында мәкаләләр басыла; атаклы фән һәм мәдәният эшлеклеләре иҗаты яктыртыла. Әдәби бүлектә Г.Акбирдин, Х.Габиди, Х.Мөхәммәдов, С.Сүнчәләй, З.Тукбаев шигырьләре бирелә.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**МӨГАЛЛИ́МОВ** Абрик Фазлыйәхмәт улы (20.12.1939, Мөслим р-ны Атлас а.), нефтьче. СССР һәм ТРның Дәүләт бүләкләре лауреаты (1988, 1996). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлый (1974). 1969 елдан «Татнефть» АҖдә, коррозиягә каршы чаралар үткәрү һәм табигатьне саклау бүлеге башлыгы (1980 нән), ген. директор урынбасары (2004 тән). СССР Дәүләт бүләгенә нефть һәм газ чыганакларында үткәргеч торбаларның эчке өслеген саклаучы капланмалар технологиясен эшләгәне һәм сәнәгый куллануга кертүе, ТРның Дәүләт бүләгенә «ТРның нефть чыгару районнарында техногенез, мониторинг, халык сәламәтлеге һәм экологик хәлне яхшырту чараларын сәнәгый кулланылышка кертү» («Техногенез, мониторинг, здоровье населения и промышленное внедрение мероприятий по оздоровлению экологической обстановки в нефтедобывающих районах РТ») хезмәте өчен лаек була.

**МӨГАММӘ́** (гарәп. معمّاة — шигъри табышмак, шарада, ребус), 1–2 бәйттән торган катлаулы шигъри шарада, табышмак. Шәрекъ әдәбиятында киң таралган, татар әдәбиятында сирәк очрый. Ул мөстәкыйль дә, аерым әсәрнең бер өлеше дә булырга мөмкин. М.дә кинаяле рәвештә шигырьдә кайбер гарәп хәрефләре б-н хәрәкәт итәргә күрсәтмәләр бирелә: мәс., ноктаны хәрефнең өстеннән астына күчерергә (нәтиҗәдә бүтән хәреф барлыкка килә); хәрефне бер сүздән икенчесенә күчерергә һ.б. Үзгәртелгән хәреф һәм иҗекләрдән җавап (чишелеш) барлыкка килә, мәс., ялгызлык исеме. Еш кына М. формасында әсәр ахырында кайбер мәгълүматлар (авторы, язылу урыны һәм вакыты) китерелә. Мәс., Һ.Салиховның «Төхвәт әл-әүлад» («Балаларга бүләк») китабында авторның һәм әсәрнең исеме М.не чишү аша билгеле була.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӨГЕЗБОРЫ́Н КОҢГЫ́З** (Oryctes nasicornis) куышлык коңгызлары ассемьялыгыннан коңгыз. Гәүдә озынлыгы 25–40 *мм*, коңгырт-көрән төстә, канат өслеге ялтырап тора; ата затларның маңгаенда артка бөгелгән озын мөгезе, аркасының алгы өлешендә өч тешле аркылы калкулык бар. Личинкасы С-сыман формада, көрән башлы һәм аркасы күпсанлы аркылы җыерчыклы, 80 *мм* озынлыкка җитә, үсемлек черемәсе өемнәрендә яши, яфраклы агач куышларында һәм хәтта парникларда яши; кайвакыт үсемлек тамырларына (мәс., виноградка һәм розаларга) зыян китерә. Үсеше 4 ел бара. М.к. тундра һәм тайгадан кала барлык җирләрдә очрый. Җәйге җылы кичләрдә оча һәм еш кына яктыга очып килә. 1960 еллар башыннан бирле Татарстан терр-ясендә барлык урында таралган. Хәзерге вакытта бик сирәк очрый. Идел-Кама саклаулыгы терр-ясендә очрый. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Илл. к. *Коңгызлар*.

*А.К.Жеребцов.*

**МӨГЕЗКОЙРЫКЛА́Р** (Sireidae), утырмакорсаклылар асотрядыннан элпәканатлы бөҗәкләр семьялыгы. 200 гә якын төре билгеле, киң таралганнар; Россиядә 30 га якын, Татарстан терр-ясендә 5 төре теркәлгән: каен мөгезкойрыгы (Tremex fuscicornis), зур ылыс мөгезкойрыгы (Sirex gigas), зәңгәр нарат мөгезкойрыгы (Sirex juvencus), шәмәхә мөгезкойрык (Paururus noctilo), кара мөгезкойрык (Xerix spectrum). Зур һәм уртача зурлыктагы бөҗәкләр (3 *см* га кадәр), казналыклары көчле булганлыктан, хәтта кургашны да кимерергә сәләтле. Ана затларның корсагы артында зур, кайвакыт бик озын һәм каты (исеме шуннан) күкәйсалгыч, аның б-н исә алар кайрыны тишә һәм авыру, хәтта сәламәт агач-куакларның үзагачына күкәй сала. М.ның личинкалары ак яки сары төстә, рудиментар күкрәк аяклары бар; гәүдәләренең арткы очында, юл тишкәндә терәлү өчен, үткен чыгынты урнашкан. Тишеп ясалган юлларының стеналарында һәм аның тирәсендәге үзагачта, күкәй салганда ана зат б-н кергән гөмбә спораларыннан личинкаларның туенуын яхшырта торган гифлар хасил була. Аларның үсеше 2 елдан да ким бармый. Курчакка әйләнер алдыннан личинка үзагач өслегенә үрмәли. Курчаклардан чыккан олы затлар үзагачны кимерәләр һәм тышка чыгалар. Личинкалар юллар тишеп агачларга зыян китерәләр.

**МӨГЕЗЛӘ́Ч**, к. *Болан коңгыз.*

**МӨГЕЗЛӘ́Ч** (Erucastrum), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 17 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: тар яфраклы М. (E. armoracioides), нигездә, Кама аръягында, Галлия М. (E. gallicum) Әлмәт шәһәре тирәсендә очрый. Карбонатлы ачылмаларда, даланлаган тау битләрендә үсә. 20–100 *см* биеклектәге ике- һәм күпьеллык үсемлек. Тамыр системасы үзәк, куәтле, орчыксыман. Сабагы төбеннән тармаклы. Яфраклары бөтен, калынрак, тамыр яныдагылары — озынча-йомыркасыман, тешсыман читле, өскеләре — утырма, кыяк, бөтен читле. Чәчәкләре ачык-сары, чукка җыйналган. Җимеше — кузак. Май–июньдә чәчәк ата. Июнь–июльдә җимешләре өлгерә. Орлыктан үрчи.

**МӨГЕЗЛЕ́ ЕЛГА́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 54 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 38 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Акташ волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 25 гыйнварыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 68, 1938 дә — 159, 1949 да — 184, 1958 дә — 137, 1970 тә — 201, 1979 да — 127, 1989 да — 74, 2002 дә — 60 кеше.

**МӨГЕЗЛЕ́ ОРЛЫ́К** (Ceratocephalus), казаякчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буенча таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — ураксыман М.о. (C. orthoceras) бар, Кама аръягында һәм Кама алдында очрый. Известьле тау битләрендә, көтүлекләрдә үсә. 2–8 *см* биеклектәге йонлач үсемлек. Яфраклары бармаксыман өчәр бүленмәле. Чәчәкләре вак, сары, оч чәчәк төркемендә. Җимешләре — кыска цилиндрсыман чәнечкеле чикләвекчекләр. Апрель–майда чәчәк аталар. Җимешләре сентябрь уртасында өлгерә. Вегетатив юл б-н үрчи. Хайван йонына эләгеп, җирдән ансат йолкына һәм тулысы б-н күчә.

**МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К**, куш тояклы, күшәүче, куыш мөгезлеләр семьялыгыннан булган йорт хайваннары. Сөт, ит һәм тире өчен үрчетелә. ТРда, башлыча, сөт җитештерү юнәлеше өстенлек итә. Төп токымнары: холмогор, кара-чуар, бестужев, швиц, голштин-фриз. 1986 елдан холмогор токымлы сыерларны кара-чуар, голштин токымлы нәсел үгезләре, бестужев, швиц токымлы сыерларны кызыл-чуар голштин токымлы үгезләргә йотылулы кушу алып барыла. Респ-ка буенча елга бер сыердан уртача 3 мең *кг* нан артык сөт савыла (Балтач р-нында — 5 мең *кг* нан артык). Сөтнең уртача майлылыгы — 3,6–3,7%. Рекордлы савымнар 10 мең *кг* га, майлылык — 6% ка җитә. Ит юнәлешендәге төп токымнар — шароле, гереford, абердин-аргус.

Татарстанда М.э.т.ләрнең баш саны үзгәрү динамикасы түбәндәге таблицадан күренә.

1930–2012 дә ТРда мөгезле эре терлекләрнең баш саны (мең баш) (барлык төр хуҗалыкларда)

| Еллар | Мөгезле эре терлекләрнең тулаем баш саны | Ш.и. сыерларның баш саны |
|---|---|---|
| 1930 | 632,5 | 416,8 |
| 1960 | 885,9 | 405,9 |
| 1990 | 1614,7 | 564,2 |
| 2000 | 1190,4 | 510,5 |
| 2005 | 1150,0 | 460,1 |
| 2012 | 1092,3 | 411,1 |

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**МӨГЕЗЬЯФРА́К**, су кычытканы (Ceratophyllum), мөгезьяфракчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 кә якын төре билгеле. Бөтен Җир шары буенча агымсыз һәм акрын агучы төче сулыкларда таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Күмелгән яки карасу-яшел М. (C. demersum) барлык районнарда, ярымкүмелгән яки ачык яшел (C. submersum) — Көнчыгыш Кама алдында очрыйлар. Су өстендә йөзеп йөрүче 60–90 *см* биеклектәге үсемлек, тамырлары юк. Сабагы тармаклы, сынучан.

Яфраклары кыяк өлешләргә телгәләнгән, бөжракка җыйналган. Чәчәкләре вак, берле, яфрак куентыгында. Су астында серкаләнә. Җимеше — чәнечкеле чикләвекчек. Җәй буе чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Очындагы тыгыз бөреләрдән кала, үсемлек үлә, алар исә сулык төбендә кышлыйлар. Балыклар һәм су кошлары өчен азык булып торалар.

**МӨГЪТӘЗИЛИЛӘ́Р** (гарәп. المعتزلة — аерылып чыгучы), илаһият гыйлеме — *каләмдә* ислам догмаларына акыл нигезендә аңлатма бирүче зур юнәлешләрнең берсе. Басра шәһәрендә Хәсән әл-Басриның илаһият түгәрәгеннән шәкертләре Вәсил бине Ата (748 елда вафат) һәм Әмир бине Гобәйдә (728 дә вафат) аерылып чыгу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Ислам диненең күпчелек догмаларын инкарь итүче М. 5 принципка нигезләнә: илаһи хакыйкать (изгелекләр яратуы һәм кешегә ихтыяр иреге бирүе б-н Аллаһ мотлакан хак); тәүхид (бераллалык); «вәгъдә бирү һәм янау» (Аллаһның тәкъва инсаннарга җәннәт вәгъдә итүе һәм гөнаһлыларга җәһәннәм җәзасы б-н янавы, һичшиксез, үтәләчәк); «ике арадагы халәт» — зур гөнаһ кылган мөселман иман белән имансызлык арасында кала (әмма мөселман булудан туктамый); «хупланган гамәлгә юл кую һәм шелтәле эшне тыю» (яхшылык һәм хакыйкать хакына сүз һәм көч кулланып көрәшү). М. татар илаһият һәм фәлсәфи фикерендәге төрле юнәлешләргә йогынты ясыйлар.

*Әд.:* Ж у з е П.К. Мутазилиты: Историко-догматическое исследование в области ислама. К., 1898; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; М у с а е в М.М. Мутазилиты. М., 1997.

**МӨДӘРИ́СОВ** Ринат Мансаф улы (1.5.1953, БАССРның Кушнаренко р-ны Иске Тукмаклы а.), җәнлек үрчетү буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (2004), проф. (2005). Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый (1978). 1979–84 елларда БАССРның Күмертау р-ны «Мораптал», «Таймас», Яңавыл р-ны «Буй», Аскын р-ны Урмияз, «Төй» совхозларында өлкән зоотехник, өлкән фәнни хезмәткәр. 1985 тән Башкорт а.х. ин-тының а.х. терлекләре үрчетү кафедрасында, 1993–99 да өлкән укытучы, 1998–2003 тә укыту-методика һәм вузга әзерлек бүлекләре мөдире. 2004 тән Башкорт аграр ун-тының фәнни-тикшеренү бүлеге башлыгы. Хезмәтләре интенсив технологияләр кулланганда мөгезле эре терлекләрнең продуктлылыгы күрсәткечләрен өйрәнүгә, кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең тире сыйфатын яхшырту максатыннан традицион булмаган азык өстәмәләре куллануга карый.

Х е з м.: Резервные повышения продуктивности пушного звероводства России. М., 2002 (автордаш); Применение долюцара при разведении серебристо-чёрной лисицы. Уфа, 2003 (автордаш).

**МӨДӘРРИ́С** (Мөдәррисов) Шәрәф Хасиятулла улы (1.11.1919, хәзер Чүпрәле р-ны Түбән Каракитә а. — 28.4.1963, Казан), шагыйрь. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1956). Бөек Ватан сугышында катнаша. Төньяк-Көнбатыш фронтның миномётчылар ротасында хезмәт итә, «За Родину», «Фронтовая правда», «Знамя победы» фронт г-таларында хәрби хәбәрче сыйфатында сугыш юлын уза. 1946 елдан «Кызыл Татарстан», «Яшь сталинчы» г-таларында әдәби хезмәткәр. «Үскәндә» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1937 дә басыла. Бөек Ватан сугышы темасы «Тупчы Вәһап» (1944) поэмасында, «Фронтовик татарлар» (1944) очерклар һәм «Җыр үткән юл» (1947) шигырь җыентыкларында чагылыш таба. «Биш минут» (1949), «Яшел тасма» (1952), «Үлемсезлек» (1959) поэмаларында сугыш фаҗигасе сурәтләнә, кичәге көрәшчеләрнең хезмәт батырлыкларына дан җырлана. Сугыштан соңгы елларда М. сатирик шигырьләр, памфлет һәм фельетоннар («Көлке түгел», 1954), сугыш һәм тыныч хезмәт геройлары, әдәбият һәм сәнгать әһелләре турында очерклар, әдәби-публицистик мәкаләләр («Йолдыз атыла», 1963; «Ильич нурлары», 1969 җыентыклары) иҗат итә. У.Шекспир, Дж.Байрон, М.Шелли, Һ.Һейне, А.С.Пушкин, Н.А.Некрасов, Т.Г.Шевченко әсәрләрен, К.Ивановның «Нарспи» әсәрен татар теленә тәрҗемә итә. Шекспир сонетларын тәрҗемә итү М.нең үзенә дә бу катлаулы шигырь формасында иҗат итәргә этәргеч бирә. Ул татар поэзиясендә беренчеләрдән булып сонет жанрына юл ача, аның матур үрнәкләрен тудыра. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Минем яшьтәш: Сайланма әсәрләр. К., 1956; Дуслар күңеле. К., 1980; Сквозь пепел дней. М., 1974.

*Әд.:* Х и с а м о в Н. Үлемсезлек җырчысы // Казан утлары. 1969. № 11; Ә х м ә д у л л а Ш. Нурлы сыны хәтер түрендә // Мирас. 2002. № 7.

**МӨДӘРРИ́СОВА** (псевд., фамилиясе Янгирова) Халисә Сәгыйть кызы (25.4.1953, БАССРның Ишембай ш.), язучы, Башкортстан Респ-касының атказ. мәдәният хезмәткәре (2003). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), БАССРның урта мәктәпләрендә укыта. 1981 елдан Нуриман р-нында Красная Горка авылында яши, район советы башкарма ком-ты секретаре, 1992–2000 дә район хакимиятендә эшләр б-н идарә итүче булып эшли, 2000–08 дә район хакимиятенең мәдәният идарәсен җитәкли. М. шигъриятенә эчкерсезлек, тормышны тоемлауда тирәнлек һәм бөтенлелек хас. Прозада М. әхлакый мәсьәләләр күтәрә. «Көмеш дага» (Уфа, 1982), «Җәй уртасы» (Уфа, 1993), «Балан» (Уфа, 1996), «Шәмәхә төн» (2003) шигъри җыентыклары, «Яр» (2002), «Соңгы сер» (2011) повестьлары, хикәяләр авторы. 2010 да Башкорт акад. театрында М.ның «Бәхет хакы» пьесасы куела.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Р.Р.Мусабәкова.*

**МӨҖТӘҺИ́Д** (гарәп. مجتهد — тырышу, иҗтиһад итү), мөселман хокукы белеме — *фикъһ* мәсьәләләре буенча мөстәкыйль хөкем чыгарырга хокукы булган илаһият галиме. Сөнни дин белгечләре дүрт дини-хокукый мәктәпкә — *мәзһәбкә* нигез салучыларны соңгы М.ләр дип саныйлар. Шигыйләрдә, тарихи үсеш үзенчәлекләре нәтиҗәсендә, мөстәкыйль карар чыгару сакланган: ислам дине догматларын белүдә һәм шәрехләүдә камиллек дәрәҗәсенә ирешкән теләсә кайсы хокук белгече фәкыйх М. була ала; Иранда аятолла дини иерархиясендәге югары титул ияләре М. дип йөртеләләр.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**МӨКЕРЛЕ́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 21 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 437 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният сарае, китапханә. 1662 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Байбулат, Мыгир исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 831,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Тимбай волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 294, 1859 да — 321, 1880 дә — 394, 1897 дә — 451, 1910 да — 549, 1913 тә — 613, 1920 дә — 624, 1926 да — 783, 1938 дә — 591, 1949 да — 545, 1958 дә — 552, 1970 тә — 544, 1979 да — 500, 1989 да — 453, 2002 дә — 462 кеше.

**МӨКСИ́НОВ** Равил Мөнир улы (11.6.1952, Ленинград), архитектор, архит-ра д-ры (1966), Кыргызстан Респ-касы Архит-ра һәм төзелеш академиясе хакыйкый әгъзасы (2000). Фрунзеда политехник ин-т тәмамлый (Кыргызстан ССР, 1974), 1981 елдан шул ин-тның архитектур проектлаштыру нигезләре каф. мөдире. 1995 тән Бишкәк финанс-икътисад академиясе проректоры, 1998 дән — Кыргызстан-Россия славян ин-тының архит-ра, дизайн һәм төзелеш ф-ты деканы, проф. (2000). Кыргызстан Респ-касының Архит-ра һәм төзелеш академиясе вице-президенты (2002 дән). Хезмәтләре Үзәк Азия респ-калары архит-расында генезис, эволюция, типологик үзенчәлекләр һәм милли традицияләр мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Архитектура села Киргизии. Бишкек, 1989 (автордаш); Народное зодчество Кыргызстана. Бишкек, 2000; История архитектуры Кыргызстана. Бишкек, 2007 (автордаш).

**МӨЛӘММӘ́ГЪ** (гарәп. ملمع — чуар, ялтыравык), Шәрекъ мөселман халыкларында шигъри юлларяки аерым очракларда мисраглар төрле телләр катнашында (гарәп, фарсы, татар һ.б.) иҗат ителгән шигырь. Гадәттә, робагый яки фәрд язганда файдаланыла. Татар поэзиясендә М. киң таралган; аның татар, гарәп, фарсы һәм рус сүзләреннән торган үрнәкләре Харәзми, Сәйф Сараи, Өмми Камал, Г.Утыз Имәни, Ш.Зәки, Г.Тукай, Г.Кандалый әсәрләрендә очрый.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӨЛЕ́КОВ** Бату Гатаулла улы (17.4.1928, Үзбәкстан ССРның Байсун а. — 23.10.1999, Казан), композитор, педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1977, 1981). Казан консерваториясен композиция буенча (А.Леман классы) тәмамлый (1957). Казан мәдәният һәм сәнгать академиясендә укыта (1970–96). Иҗаты жанрларның киң диапазоны б-н аерылып тора. М. монументаль

жанрларга (опера, оратория, симфония) тартыла, тарихның һәм хәзерге заманның актуаль проблемаларына мөрәҗәгать итә. Композитор ш.у. җыр жанры остасы буларак та билгеле. Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г.Рәхим либреттосына куелган «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы тыңлаучылар тарафыннан яратып кабул ителә. Аның музыкасында халык җырларына нигезләнгән тематизм рус һәм татар опера классикасы традицияләре б-н табигый рәвештә берләшә. Бу лирик-психол. операда социаль мотивлар ачык яңгырый. Вакыйга үзәгендә — Галимәнең фаҗигале язмышы. Бу партиядә героиняның рухи үзгәреше — якты, соклангыч гашыйклыктан алып, өметсезлек упкынына төшү — ышандырырлык итеп сурәтләнә. Опера драматургиясендә вакыйгаларга халыкның мөнәсәбәтен чагылдыруда хор номерлары мөһим роль уйный. Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә концерт башкаруында Н.Ханзафаров либреттосына куелган «Сөембикә» операсында фаҗигале хатын-кыз образы үзәктә тора. Күптәнге вакыйгаларны чагылдыручы сюжет һәм шул вакыйгаларда катнашучы реаль шәхесләрнең образлары опера жанрын тарихи драма буларак билгели. Мөһим роль хор күренешләренә бирелә; Сөембикә партиясе мелодик тәэсирлеге б-н аерылып тора. М. иҗатында кантата-оратория жанрындагы әсәрләр аерым әһәмияткә ия. Шагыйрьнең 100 еллык юбилее уңаеннан Х.Гарданов шигыренә иҗат ителгән «Тукай» ораториясендә аның тормыш юлының төп этаплары яктыртыла, иҗатының мәңге үлмәслеге раслана. Композитор бу әсәрендә Тукайның «Тәфтиләү», «Туган тел», «Пар ат» шигырьләренә башкарылган татар халык көйләре интонацияләрен файдалана. М.ның симф. әсәрләре арасында симфония һәм увертюралар: «Чаллыда бәйрәм» увертюрасы, «Бәйрәм увертюрасы», «Хезмәт турында поэма» аерым урын тота. Татар музыкасында бу жанрның беренче үрнәге — симф. оркестр б-н тавыш өчен язылган Концертта композиторның лирик үзенчәлекле сәләте аеруча ачык күренә. Автор үзенең әсәрендә, өч кисәкле циклның традицион структурасын саклап, контрастлык һәм тематик бөтенлек принципларын табигый рәвештә тормышка ашыра. М.ның татар шагыйрьләре әсәрләренә иҗат ителгән төрле тематикадагы, төрле характердагы җырлары (патриотик, мәхәббәт, лирик, шаян) күптөрле булуы б-н зур популярлык казана. Композитор иҗатының шактый өлешен Татарстан музыка уку йортларының укыту репертуарларында файдаланыла торган әсәрләр тәшкил итә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1984).


Б.Г. Мөлеков.

Төп әсәрләре: М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Г.Рәхим либреттосына «Каһәрләнгән мәхәббәт» (1981), Н.Ханзафаров либреттосына «Сөембикә» оперalары, Симфония (1969), «Чаллыда бәйрәм» симф. увертюрасы (1977), Р.Харис шигыренә «Казан» (1977), Х.Гарданов шигыренә «Тукай» ораторияләре, М.Хөсәен шигыренә «Ел фасыллары» кантатасы (1967), скрипкачылар ансамбле һәм фортепиано өчен концерт (1972), симф. оркестр б-н тавыш өчен концерт (1978), тынлы оркестр өчен сюита (1968), камера-инструменталь һәм камера-вокаль әсәрләр, җырлар, драма спектакльләренә музыка һ.б.

*Әд.:* Григорьев Л., Платек Я. Советские композиторы и музыковеды. М., 1981. Т. 2; Файзулаева М.П. Бату Мулюков // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Шулук. На юбилейных вечерах Бату Мулюкова // Советская музыка. 1988. № 9; Шамсутдинова Ф.Я. «Сююмбике» на Казанской оперной сцене // Казань. 1999. № 11; Нигматова Л. Память души // Казань. 2005. № 6.

*С.И.Раимова.*

**МӨЛЕ́КОВ** Марат Габдрәсүл улы (7.2.1930, Түбән өлкәсенең Ялутор р-ны Исәт а. — 26.5.1997, Казан), тарихчы, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Тобол пед. уч-щесен (1947), Казан пед. ин-тын (1951) тәмамлый. 1951 елдан Питрәч р-ның Шәле урта мәктәбендә эшли, директор (1952 дән). 1957 дән «Җиңү байрагы» район г-тасы мөхәррире, 1959 дан ТАССР Мәгариф министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы. 1962 дән Казан пед. ин-тында, 1972 дән Казан ун-тының КПСС тарихы каф. доценты. *Бөтентатар иҗтимагый үзәген* оештыручыларның берсе һәм беренче рәисе. ТР ЮС депутаты (1990–95), конституция комиссиясе әгъзасы, ТССРның дәүләт суверенлыгы турында Декларация әзерләүдә актив катнаша. Мөһаҗирләргә ярдәм фондын, «Мәгариф» һәм «Мәдәният» җәмгыятьләрен, «Солдат аналары» ком-тын, Мохтаҗларга ярдәм фондын оештыруда ярдәм итә. М. башлангычы б-н 1995 нең гыйнварында Татарстанның парламент делегациясе гуманитар ярдәм б-н Чечен Респ-касына бара. Хезмәтләре сәяси партияләр тарихына, милли азатлык хәрәкәтенә, милли дәүләт төзелешенә карый.

Хезм.: Борьба коммунистов Татарии за укрепление диктатуры пролетариата в первые годы Советской власти (Из опыта работы коммунистов в системе судебно-следственных учреждений). К., 1980 (автордаш); Деятельность большевиков по укреплению социалистической законности в первые годы Советской власти (На материалах партийных организаций национальных автономий Поволжья). К., 1988.

*И.М.Мөлеков.*

**МӨЛЕ́КОВ** Ренат Сәетгали улы (8.3.1944, БАССРның Аургазы р-ны Кәбәс а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1992), проф. (1993). 1964 елда Оренбург зенит-ракета уч-щесен, 1974 В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1994 тән РФ Оборона министрлыгы Хәрби ун-ты, Мәскәү) тәмамлый. 1964–70 тә 7 нче танк армиясенең сәясәт бүлегендә (Белоруссия ССР, Борисов ш.), 1974 тән Новосибирск югары хәрби-сәяси уч-щесендә укыта. 1976–98 дә Хәрби ун-тта адъюнкт, укытучы, кафедра башлыгы урынбасары (полковник). 1998 дән «Эйдинберг» ҖЧҖ ген. директоры. Хәрби фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы (1996). Хезмәтләре Кораллы Көчләрдә партия төзелешенә, XIX–XX йөз башында Россия Хәрби диңгез флотында рухи мирас формалашу тарихына багышлана.

Хезм.: История строительства политорганов и партийных организаций Красной Армии в 1921–1941: Проблемы, деформации, уроки. М., 1989; Методические рекомендации в изучении Отечественной истории. М., 1993; Отечественная история с древнейших времён до 1861 г. М., 1994.

**МӨЛЕ́КОВ** Сөләйман Мифтах улы (5.1.1920, Балтач р-ны Пыжмара а. — сентябрь 1941), шагыйрь. Туган як табигатенә, мәхәббәткә багышланган беренче лирик шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә 1930 еллар ахырында күренә башлый. 1940 та Кызыл Армия сафларына алына, сугышның беренче айларында Киев тирәсендә барган сугышларда һәлак була. Соңыннан шигырьләре «Алар сафта» (1961) исемле күмәк җыентыкка керә.

*Әд.:* Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МӨНӘҖӘ́Т** (гарәп. منجاة — Аллаһка ялвару), төрки һәм иран халыкларында фольклор һәм язма әдәбият жанры. Мәҗүсилек һава, кояш, айга һ.б.га табынудан килә, шаманлык б-н бәйле. Татар М.ләрендә мәҗүсилек эзләре сакланмаган, аларның асылында Аллаһы Тәгаләгә һәм аның пәйгәмбәрләренә мөрәҗәгать итү, ялварып ярлыкауны сорау ята. Татар халкында М.ләр Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителгәч тарала башлый (10–11 йөзләр). М.ләрне 4 төркемгә бүлергә мөмкин:

1. Дини-фәлсәфи М.ләр. Аларда Аллаһы Тәгаләгә һәм Мөхәммәд, Нух, Ибраһим, Гайсә һ.б. пәйгамбәрләргә дан җырлана: «Йә Рәсүлем», «Аллаһ дәйү-дәйү», «Раббыга мәдхия» һ.б. Коръәндәге әлеге сюжетлар борынгы Шәрекъ мифлары, легенда һәм риваятьләренә барып тоташа.

2. Туган ил турында М.ләр: «Аерылдым илләремдин», «Кайтыр идем туган илгә» һ.б. Әлеге М.ләрдә туган илне сагыну, аннан аерылу (гадәттә, сәбәбе билгесез) мотивлары ята. Аерылуның трагик нәтиҗәләре тасвирлау объектына әверелә.

3. Ана мәхәббәте турында М.ләр: «Ерак булды газиз балам», «Балаларым чыкмый истән», «Синең анаң түгелмени?» М.ләрендә баласыннан аерылган ана хәсрәте тасвирлана. Аерылышу сәбәпләре ш.у. билгесез.

4. Яшәү һәм үлем турында М.ләр: «Исмәле, җил!», «Сабыр савытларым тулды» һ.б. Лирик герой көндәлек тормышның авырлыгыннан зарлана, дөньяның фанилыгы, үлемнең котылгысызлыгы турында уйлана. Ул Коръән кануннары б-н каршылыкка керә. Коръән үлемнән курыкмаска өйрәтә, үлемне фани дөньядан бакыйга мәңгелеккә күчү дип аңлата. Кайбер М.ләрдә («Якты дөньяны күреп туймадым») герой үлем куркынычын яхшы эшләр б-н яисә үзе чыгарган М.тә үзе турында хатирәләр калдырып җиңәргә тырыша.

*Әд.:* Мөнәҗәтләр // Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; З ә й н у л л и н Җ. Мөнәҗәтләр, борынгы җырлар // Татар иле. 1996. № 46–47; Х ө с н у л л и н К. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. К., 2000; У р м а н ч е Ф. Мунаджат // Идель. 1999. № 1.

*Ф.И.Урманчеев.*

**МӨНБӘ́Р** (гарәп. منبر), җамигъ *мәчетендә* вәгазь уку өчен биек урын, күперчек, *михрабның* уң ягында урнашкан. Элек *Мөхәммәд* пәйгамбәр вәгазьләрен хөрмә агачының кәүсәсенә таянып сөйләгән, дип санала, соңрак бу урында тәбәнәк урындык сыман, ике баскычлы агач М. төзелә. Өммәвиләр династиясе идарәсенең (661–750) ахырына кадәр М. сәяси хакимият символы булып тора,



«Кол Шәриф» мәчете мөнбәре.

748 елда Мәрвә шәһәрендә вәгазь сөйләүче өчен кафедра рәвешендәге М. барлыкка килә. 9 йөздә югары мәйданчык өстендә чыгынтысы һәм баскычы булган биек трибуна рәвешен ала һәм хәзергәчә үзгәрешсез саклана.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**«әл-МӨНБӘ́Р»** («المنـبر»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби газета. Петроград татарларының атаклы вәкилләре кергән *«Әманәт»* нәшрияты органы. 1917 елның 24 декабреннән 1918 нең башына кадәр Петроградта татар телендә нәшер ителә, барысы 3 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — М.*Бигиев*. Басманың максаты — Россия татарларының милли-мәдәни мохтарияты мәсьәләләрен өйрәнү, башкалада эшләп килгән Россия мөселманнарының сәяси оешмалары — *Милли Шура*, Вилаять Шурасы, Дәүләт Думасының мөселманнар фракциясе эшчәнлеген яктырту. Газетада А.Атийтар, Г.Аялуддин, К.Бәйбулат, З.Вафа, К.Гата, З.Гыймад, А.Җамал, Л.Җамал, М.Җиһанша, М.Исмәгыйль, Л.Исхакый, А.Ихтари, Г.Максуди, Г.Нугай, И.Хисам һ.б.ның мәкаләләре басыла. Хөкүмәт декретлары, Петроград губерна мөселманнарының Беренче корылтае карарлары урын ала. Көнбатыш һәм Көнчыгыш илләрендәге иҗтимагый-сәяси хәлләр: герман-төрек мөнәсәбәтләре; Европа һәм Америка илләре үсешенә караган сәяси фаразлар; Палестина мәсьәләсе һәм аны хәл итү юллары турындагы мәкаләләр дөнья күрә. Сәяси каршылыкларга, милли-мәдәни мохтарият мәсьәләләренә зур игътибар бирелә, Петроградтагы мөселман хәйрия оешмалары эшчәнлеге яктыртыла. Эстон һәм украин полклары мисалында мөселман кораллы берләшмәләрен оештыру буенча хакимиятләр тарафыннан нәтиҗәле чаралар күрелергә тиешлеге турындагы мәсьәлә куела. Дини эчтәлектәге шигырьләр басыла, кайберләренең авторлары — газета укучылары.

*А.Г.Хәйретдинов.*


المنبر

«әл-Мөнбәр» газетасы.

**МӨНДЕ́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 9 *км* төньяктарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 485 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1341,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 398, 1897 дә — 549, 1908 дә — 585, 1920 дә 927, 1926 да -842, 1938 дә — 728, 1949 да — 530, 1958 дә — 572, 1970 тә — 533, 1979 да — 439, 1989 да — 410, 2002 дә — 449 кеше.

**МӨНДЕ́Ш** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Симет елгасы буенда. 2010 елда 33 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1653 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.тә волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 630,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 323, 1897 дә — 415, 1908 дә — 367, 1920 дә — 382, 1926 да — 389, 1938 дә — 376, 1949 да — 227, 1958 дә — 162, 1970 тә — 113, 1979 да — 82, 1989 да — 48, 2002 дә — 48 кеше.

**МӨНДЕ́Ш** т и м е р ю л р а з ъ е з д ы п о с ё л о г ы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Екатеринбург тимер юлы буенда. 2010 елда 12 кеше яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1938 дә — 13, 1970 тә — 69, 1979 да — 44, 1989 да — 22, 2002 дә — 10 кеше.

**МӨНИ́Р** Һади, к. *Һадиев* Мөхәммәдмөнир.

**МӨНКИ́Р ҺӘМ НӘКИ́Р** (منكـر و نكـير), мөселманнарның күзаллаулары буенча, мәрхүмнәрдән фани дөньяда вакытта дин кануннарын ни дәрәҗәдә саклаулары турында сорау алучы ике фәрештә. Хак мөселманнар, ш.и. дин юлында шәһит китүчеләр, чирләрдән (мәс., үләт) үлүчеләр, балигъ булмаган балалар һәм һәр көн Коръән укучылар тынычлыкта калдырыла; гөнаһлылар һәм кяферләр җәзага тартыла. М.һ.Н. Кыямәт көнендә җәһәннәмдә җәза башкаралар. Коръәндә аларның исемнәре телгә алынмый, беренче тапкыр хәдисләрдә очрый, дини, ш.и. татар әдәбиятында еш күренә.

**МӨРӘББӘ́ГЪ** (гарәп. مربّع — квадрат, дүрткырлы мәгънәсендә), Шәрекъ классик поэзиясендәге лирик шигырьнең строфик формасы. Төзелеше б-н 7–9 юллык строфалардан тора, аааб вввб рәвешендә рифмалаша. Гадәттә, һәр строфаның соңгы тезмәсе бөтен М. өчен бер. Автор текстына бүтән автор юллары да кертелергә мөмкин. Татар поэзиясендә М. киң таралыш таба; аның үрнәкләре Габдессәлам, Д.Юлтый, Г.Камал әсәрләрендә очрый.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӨРӘЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 288 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә мәчет, тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 864,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 450, 1897 дә — 622, 1908 дә — 688, 1920 дә — 680, 1926 да — 504, 1938 дә — 736, 1949 да — 505, 1958 дә — 541, 1970 тә — 433, 1979 да — 381, 1989 да — 315, 2002 дә — 277 кеше.



Ф.Х. Мөрсәлимов.

**МӨРӘЛЕ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 11 *км* көнчыгыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 496 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 3 тукыма һәм 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1488 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 86 ир-ат; 1859 да — 648, 1897 дә — 1251, 1908 дә — 1539, 1920 дә — 1483, 1926 да — 1197, 1938 дә — 1543, 1949 да — 981, 1958 дә — 917, 1970 тә — 876, 1979 да — 761, 1989 да — 611, 2002 дә — 507 кеше.

**МӨРӘ́СОВ** Рәхим Зәки улы (14.1.1940, БАССРның Эстәрлебаш р-ны Әмир а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (1990), проф. (1992), БРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), шунда ук эшли (1986 га кадәр). 1986–90 елларда Кама политехник ин-тында чит телләр каф. мөдире (Чаллы ш.). 1990–98 дә Башкорт ун-тында немец филологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта, 1992 дән, роман-герман филологиясе ф-ты деканы. Хезмәтләре немец телендә сүз ясалышына карый.

Х е з м.: Морфология производного слова. Уфа, 1992; Словарь словообразовательных элементов немецкого языка. М., 2000 (автордаш); Сопоставительная морфология немецкого и башкирского языков. Глагол. Уфа, 2002.

*Әд.:* Г а т а у л л и н Р.Г., Ш а ф и к о в С.Г. Патриарх башкирской германистики // Учитель Башкирии. 1999. № 12.

**МӨРИ́Д** (гарәп. مريد — эзләүче, эзеннән баручы), өлкән шәкерт, дини остазның (шәех, *ишан*) иярчене, исламда суфичылык тәгълиматларын өйрәнүче. З.*Рәсүлев*, М.*Камалов*, Ә.Ясәвинең үз М.ләре булуы мәгълүм. Ш.у.к. *Суфичылык*, *Нәкышбәндийә*.

**МӨРИ́Д** (1330 тирәсе — 1363), Алтын Урда ханы (1361 елдан). 1361 елның көзендә Күк Урда гаскәрләре ярдәмендә Килдебәк ханны куа. Үзәк хакимиятне ныгыту тарафдары. 1362 нең җәендә Азак шәһәре янында Килдебәк гаскәрен, 1362 нең көзендә Идел буенда, Сарай әл-Җәдидне алырга омтылган Мамай гаскәрен тар-мар итә. М. һәм Мамай арасындагы көндәшлек Русьта хан хакимиятенең көчсезләнүенә китерә. Шуннан файдаланып, Литва, татар отрядларын тар-мар итеп, үзенә Көньяк Русьны буйсындыра. М. Идел буенда хакимлек итә, үз исеменнән акча суктыра (1361–63). Күк Урдада Чимтай хан вафатыннан соңгы чуалыш вакытында М. ярдәмсез кала. Сарай әл-Җәдидтә аксөякләр фетнәсе вакытында үтерелә.


*Әд.:* Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Куликовская битва. М., 1980; Г о р с к и й А.А. Москва и Орда. М., 2000.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨРСӘЛИ́МОВ** Дилүс Минһади улы (1.12.1948, Оренбург өлкәсенең Шарлык р-ны Сарманай а.), график, нәкышьче. П.П.Беньков исем. Респ-ка сәнгать уч-щесен (Ташкент, 1968) һәм А.Н.Островский исем. Театр-сәнгать ин-тының китап графикасы бүлеген (Ташкент, 1974) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1981). 1974–78 елларда Кемерово китап нәшриятында бизәлеш мөхәррире булып эшли, бер үк вакытта сәнгать уч-щесендә укыта. 1978–88 дә нәкышь һәм рәсем укытучысы, 1992 дән Ташкент театр-сәнгать ин-тында гравюра буенча оста. М. китап графикасы һәм станлы графика өлкәсендә нәтиҗәле эш алып бара, жанрлы композицияләр һәм портретлар авторы. Күбесенчә офорт («Үзбәкстан пейзажлары» сериясе, 1977–78) һәм акварель («Көз», 1978; «Тау пейзажлары» сериясе, 1996–99; «Борынгы шәһәр», 1997; «Үргәнеч», 1999) техникаларында график цикллар иҗат итә. Ташкент нәшриятларында чыккан 100 дән артык китапның иллюстрация, бизәлеш һәм дизайн авторы, алар арасында: «Дөнья халыклары әкиятләре» (1990), «СССР халыклары әкиятләре» (1991) һ.б. 1990 нан станлы нәкышь остасы, пейзажлар («Ак Булак» сериясе, 1991–99; «Хан-Булат», «Тау тирәкләре», икесе дә — 1999) һәм натюрмортлар («Шәрекъ натюрморты», 1998; «Чәчәкләр» сериясе, 1999) яза. М., мозаика кисәкләрен туплаган фрагментлар барлыкка китереп, һәр детальне бердәм декоратив образга җентекләп кертә барып, табигатькә мәдхия җырлый. Фактураның композицион яссылыгы, төрле



Д.М. М ө р с ә л и м о в. «Көз». Кәгазь. Акварель. 1978. «Казан» милли мәдәният үзәге музее.



Д.М. М ө р с ә л и м о в. «Натюрморт». Кәгазь. акварель. 1999. «Казан» милли мәдәният үзәге музее.

төсләргә кереп ялтыравы һәм бөтенлеге, сары һәм кызыл төсләр б-н бөрчекләндерелгән күк, яшел, фирәзә, зәңгәр төсләрнең колоритлы берләшүе, графикада — нәфис ритмнар, формаларның вагаеп калуы, сәнгать теленең нечкәлеге һәм гүзәллеге М. әсәрләрен мөселман миниатюраларына, Шәрекъ сәнгатенә якынайта. Үзбәкстан Респ-касындагы татар рәссамнарының «*Ил*» иҗат оешмасы әгъзасы (1996). Халыкара (Югославия, 1987; Венгрия, 1988), бөтенсоюз акварель (Мәскәү, 1983, 1985, 1987, 1989), татар рәссамнары (Ташкент, 1992, 1994), «*Ил*» рәссамнары (Ташкент, 1996; Казан, 1999, М.Садыйков, Д.Уразов, О.Хәбибуллин, С.Рахмонов б-н бергә) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Ташкентта уза (1978). Хезмәтләре Ташкент, Ашхабад, Үргәнеч шәһәрләрендәге сынлы сәнгать музейларында саклана.

*Әд.:* Всесоюзная выставка акварели: Каталог. М., 1989.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӨРСӘЛИ́МОВ** Фәтрахман Хәбибрахман улы (26.8.1928, Оренбург өлкәсенең Саракташ р-ны Карагуҗа а. — 17.10.1995, Оренбург ш.), Соц. Хезмәт Герое (1966). 1945–50 елларда Магнитогорск монтажлау идарәсенең (Чиләбе өлкәсе) «Востокметаллургмаш» трестында җыючы-моторист. 1950–56 да «Уралмясомолстрой» (Оренбург өлкәсе) трестының 47 нче Чкаловск төзү-монтаж идарәсендә слесарь-монтажчы. 1956–93 тә Оренбург йөк автотранспорты ҖБдә машина йөртүче, адм.-хуҗалык бүлеге башлыгы. М. оештырып гамәлгә керткән автопоезд берьюлы 33 *т* ашлык төяп ташырга мөмкинлек бирә. Герой исеме халык хуҗалыгы йөкләре ташу буенча җидееллык планны (1959–65) үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Оренбургская биографическая энциклопедия. Оренбург, 2000.

**МӨРСӘЛИ́МОВ** Хәкимҗан Ибраһим улы (13.6.1927, Көнчыгыш Казакъстан өлкәсенең Самара р-ны Мәчет а. — 1990, Алма-Ата),

геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1973), проф. (1980). Казакъстан тау-металлургия ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казакъстан ССР-ның геол. җитештерү берләшмәләрендә эшли. 1960 елдан Казакъстан Минераль чимал фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, 1984 тән СССР Геология министрлыгы Җитәкче хезмәткәрләр һәм белгечләрнең квалификациясен күтәрү ин-тының Алма-Ата ф-лы директоры. М. сирәк металлы, алтын рудалы һ.б. полиметалл чыганакларны геол. разведкалау эшләренең нәтиҗәлеген күтәрү буенча тәкъдимнәр эшли.

Х е з м.: Пути рационализации методики разведки твёрдых полезных ископаемых. А.-А., 1965 (автордаш); Бурение многозабойных скважин при разведке рудных месторождений. А.-А., 1969.

**МӨСӘВӘ́РОВА** Лилия Камил кызы (15.8.1970, БАССРның Эстәрлетамак ш.), балет артисткасы, ТРның халык артисты (1995). 1989 елда Пермь хореография уч-щесен (педагог С.Губина) тәмамлый. 1989–93 тә Н.Касаткина һәм В.Василёв җитәкчелегендәге Мәскәү классик балет театры артисткасы. 1993 тән «International Guest Artist» фирмасында эшли. Россия һәм чит илләр (Канада, АКШ, Япония һ.б.) балетларында чакырылган артистка сыйфатында чыгышлар ясый. 1991 дән Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә даими чыгышлар ясый, бу коллективның гастрольләре б-н чит илләрдә Татарстанның хореография сәнгатен күрсәтә. М. репертуарында: Жизель (шул исем. балет,



Л.К.М ө с ә в ә р о в а һәм А.М.Әхмәтов Г.Малер музыкасына О.Арайс хореографиясендәге «Адажиетто» хореографик композициясендә.

А.Адан), Одетта-Одиллия, Маша («Аккош күле», «Щелкунчик», П.Чайковский), Китри, Никия һәм Гамзатти («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Золушка (шул исем. балет, С.Прокофьев), Гаяне (шул исем. балет, А.Хачатурян) һ.б. Балеринаның киң концерт репертуарында классик балет фрагментлары һәм хәзерге заман хореографлары композицияләре бар. М.ның иҗаты югары проф. әзерлеге һәм музыкальлеге, актёрлык осталыгы б-н аерылып тора.

*В.Н.Горшков.*

**МӨСӘГЫЙТЬ** (Мөсәгыйтов) Фатих Шәрәф улы (14.9.1904, Оренбург ш. — 1990, Казан), әдәбият тәнкыйтьчесе. «Хөсәения» мәдрәсәсендә укый (1916), Халык мәгарифе татар ин-тын (Оренбург, 1923), Татар коммунистик ун-тын (Казан, 1928) тәмамлый. «Кызыл яшьләр», «Кызыл Татарстан» г-талары редакцияләрендә эшли. 1920–30 еллардагы әдәби процессҡа багышланган, вульгар социологизм һәм сыйнфый якын килү б-н сугарылган мәкаләләр авторы.

**МӨСӘДДӘ́С** (гарәп. مسدس — алтыюллык, алты кырлы, алты тапкыр кабатлана торган), Шәрекъ классик поэзиясендәге фәлсәфә, мәхәббәт темасын үстерүче лирик шигырьнең строфик формасы. Төзелеше б-н аааааа бббба вввввва схемасы б-н рифмалашкан 4–10 алтыюллык строфадан тора. Строфаның ахыргы юлы бөтен шигырь өчен уртак. Соңгы строфада, гадәттә, псевдоним (тәхәллүс) кулланыла. Кайвакыт М. контаминация, нәзыйрә ысулы б-н языла. Бу очракта автор бүтән шагыйрь шигыренең (гадәттә, газәл) һәр бәйте алдыннан, аның үлчәмен, ритмын, төзелешен, идеясен саклап калып, үзенең 4 юлын өсти. Татар поэзиясендә М. фәкать строфик форма буларак кына очрый (Габдессәлам бине Ураи, Ш.Маннур һ.б. иҗатында).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Краткая литературная энциклопедия. М., 1968. Т. 5.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**«МӨСЕЛМА́Н»** («مسلم»), фәнни-популяр, әдәби һәм иҗтимагый журнал. 1908 елның 15 июленнән 1911 гә кадәр Парижда рус телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — М. Хаҗи-Теләши. 1908 дә журнал «Кавказ таулылары органы» дигән өстәмә исем б-н атнага 1 тапкыр чыга. Басманы чыгару өчен акчаны Кубань чиркәсләре җәмәгате бирә. Төркиянең яшь төрекләр түнтәрелешеннән соң (1908), мөхәррир б-н җәмәгать арасында журналның юнәлеше буенча фикер каршылыгы килеп чыга, һәм 1909 да, акчалата ярдәм бирелмәгәч, басма чыгудан туктый. Журнал 1910 нан, Хаҗи-Теләшинең мөселман журналын дәүләт финанславы турындагы идеясен П.А.Столыпин хуплап чыккач, Россия Эчке эшләр министрлыгы ярдәме б-н яңадан чыга башлый. Ул айга 2 тапкыр басыла. Редакция үз алдына мәгърифәт максатлары куя, милли һәм панисламизм идеяләре үсешенә борчылган Россия хөкүмәте яклы булуын игълан итә. Актив авторлар арасында — Д.Алиф, А.Аллаев, А.Батырбәков, С.Габиев (С.Кумухский), А.Датиев, К.Есиев, И.Ечерух, Ш.Сүнчәләй, Х.Хаҗимокор, Д.Хатакокор, М.Ясинский һ.б. Журналда гомум ислам мәсьәләләренә караган мәкаләләр басыла, Россия һәм чит илләрдәге мөселманнар тормышының мөһим проблемалары, аларның тарихлары һәм йолалары яктыртыла. Әдәби әсәрләр, фән үсеше хакында очерклар басыла. «М.»да мөселманнарның мәдәни үсеше — яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр ачу, матбугат эше, хәйрия оешмалары һәм китапханә-уку бүлмәләрен оештыру мәсьәләләренә күп урын бирелә. Басма үз укучыларына белем алуның кирәклеге һәм иске тәртипләрдән баш тарту идеяләрен җиткерергә тырыша, мөселманнарның кан үчен, фанатиклыгын һәм таркаулыгын гаепләп чыга. «М» мөселман хатын-кызларын гасырларга сузылган изелүдән котылырга һәм үз хокуклары өчен көрәшергә чакыра, күпхатынлылык ин-тына каршы чыгышлар ясый. Журналда хатын-кыз авторлар, ш.и. Хаҗи-Теләшинең хатыны Әйшә дә язмаларын бастыра. Мөселман җәмгыятендә зыялыларның роле турындагы мәсьәләләр бәхәсләрнең төп темасы була. Редакция фикеренчә, укымышлы мөселманнар халыкның мәдәни артталыгын бетерүдә активрак катнашырга тиеш. Мәкаләләрдә Россия хөкүмәтенең эчке сәясәте б-н килешмәүче мөһаҗирләр — Төркиягә күчеп китүчеләр хәрәкәте гаепләнә. «М»ның эшчәнлеге гомуммөселман юнәлешендә булса да, Кавказ халыклары тормышы турындагы мәкаләләргә күбрәк урын бирелә. Урыннардан килгән хатлар аерым халыкларның, бигрәк тә мөселман мәдәни хәрәкәтен әйдәп баручы Идел буе татарлары тормышын яктырта. Идел буеның эре шәһәрләрендә мәгърифәт үсеше редакциянең игътибар үзәгендә була. Хаҗи-Теләши рус һәм мөселман мәдәниятен якынайтырга омтыла һәм журнал битләрендә мөселманнарның Россия хөкүмәтенә лояльлеген күрсәтергә тырыша. Замандашлары һәм тикшеренүчеләр арасында Хаҗи-Теләши провокатор, патша хөкүмәте агенты исемен ала. Акча җитмәү һәм әбүнәчеләрнең ышанычы кимү сәбәпле, басманың эшчәнлеге тукталып кала.

*Әд.:* Б е с с м е р т н а я О. Русская культура в свете мусульманства // Христиане и мусульмане: Проблемы диалога. М., 2000; С е р о в а Е.А. История журнала «Мусульманин» // Татары в Санкт-Петербурге. СПб., 2003.

*Е.А.Серова.*

**МӨСЕЛМА́Н БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘ-СЕ́**, (Юнысовлар ятимханәсе), 1844 елның 6 декабрендә ачыла. Екатерининский урамында Юнысовлар тарафыннан төзетелеп, бакчасы һәм каралтылары б-н бергә бүләк итеп бирелгән йортта урнаша. Юнысовларның 14 кибетен (тулай бәясе — 5 мең сум, еллык керем 2 мең сумга кадәр) арендага бирүдән кергән акча хисабына тотыла. Ятимханәгә башка мөселманнар да иганә итәләр (1,5 мең сумнан 2 мең сумга кадәр). Директорлары — Юнысовлар нәселе вәкилләре: Ибраһим Гобәйдулла улы, Мөхәммәтрәхим Исхак улы. Ятимханәдә балаларга башлангыч белем, мәҗбүри русча уку-язу күнекмәләре бирелә, алар һөнәргә өйрәтелә, бушлай ашау, кием-салым, мед. ярдәме һ.б. б-н тәэмин ителә. Мөгаллимнәр арасында Х.Габәши, М.Х.Корбангалиев кебек милли мәгариф эшлеклеләре дә була. 19 йөз ахырында ятимханәдә 77 бала тәрбияләнә (34 е шунда яши, 43 е килеп йөри). 1904 тә бер балага 120 сум 85 тиен сарыф ителә. Ятимханәдән чыккан малайларны, гадәттә, сәүдәгәрләрнең кибетләренә яки мәдрәсәләргә мөгаллим итеп урнаштыралар. Окт. рев-циясеннән соң ятим-сукбайлар саны арта, ятимханәне янәшәдәге Габделкәрим Исхак улы Юнысов йорты хисабына киңәйтәләр. Тиф эпидемиясе вакытында балалар күпләп үлә һәм ятимханә ябыла.

*Әд.:* Историческая записка о мусульманском «Братьев Юнусовых» детском приюте г.Казани. К., 1895; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*Л.М.Свердлова.*

**МӨСЕЛМА́Н БӘЙРӘМНӘРЕ́**, *исламда Мөхәммәд* пәйгамбәрнең Сөннәсе (тәрҗемәи хәле), хәдисләре нигезендә билгеләнгән һәм

дини гамәлләр б-н ныгытылган тантана көннәре. Ай календаре буенча билгеләп үтеләләр. Бигрәк тә 4 «тыелган» ай (сугышлар өчен) аерып күрсәтелә: мөхәррәм, рәҗәб, шәгъбән һәм рамазан. Аеруча хөрмәт күрсәтелгән М.б. шул айларга туры килә. Иң әһәмиятле М.б. — *Корбан бәйрәме*, *Ураза бәйрәме*. Гомуми кабул ителгән М.б.: *һиҗри* ел исәбе б-н Яңа ел (мөхәррәмнең — мөселман елының 1 нче аеның 1 нче көне — Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килүе (һиҗрәт көне) һәм анда мөселман җәмәгате төзелү истәлегенә); Гашура (мөхәррәм аеның 10 нчы көне, Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы, шәһит киткән шигыйләр имамы Хөсәен истәлегенә; бу көндә сөнниләр Аллаһның пәйгамбәрләрен һәм рәсүлләрен искә алалар); *Мәүлид* (Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне); Рәгаиб (рәҗәб аеның 3 нче көненнән 4 нче көненә каршы кич, беренче җомгасына каршы кичкә туры килә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең атасы Габдулла б-н анасы Әминә никахлашкан көн истәлегенә); Мигъраҗ (пәйгамбәрнең Иерусалимга төнге сәфәре истәлегенә); *ураза* башлану (рамазан аеның 1 нче көне); *Кадер киче* (тәкъдир киче); Бәраәт киче (шәгъбән аеның 15 нче көненә каршы кичтә мөселманнар Аллаһтан рәхим-шәфкать сорап ялваралар); Гарәфә (Корбан бәйрәменнән алдагы көн; бу вакытта укылган намаз Аллаһ тарафыннан аеруча юмарт бүләкләнә). Мөхәррәм аеның 16 нчы көнендә Идел буе болгарларының ислам кабул итүе (922) билгеләп үтелә. *Җомга* атналык бәйрәм көне булып исәпләнә.

*Әд.:* Хәйри Ә. Ислам дине бәйрәмнәре. К., 1996; Ниязи А. Мусульманские праздники. М., 1990.

**МӨСЕЛМА́Н ИСЛАХЧЫЛЫГЫ́**, хакыйкатьне танып белүнең кайбер дини ысулларын һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җайга салуга, ислам күрсәтмәләренә аңлатма бирү алымнарын үзгәртүгә юнәлгән дини-иҗтимагый агым. М.и.ның чишмә башында иҗтимагый-сәяси проблемаларны хәл итүдә мөселман илаһияты кысаларында үз карашларын тәкъдим иткән төрек фикер иясе М.Биргәви (1573 елда вафат), һинд фикер ияләре Ә.Ф.Сирхинди (1564–1624) һәм Ә.Г.Шаһ Вәлиулла (1703–62) тора. 19 йөздән мөселман дөньясы үсеше Көнбатыш Европа илләренең колониаль сәясәте басымы астында бара. М.и. мөселман яңарыш идеологлары Җ.әл-*Әфгани* һәм М.*Абду* хезмәтләрендә чагылыш таба. Алар *тәкълидне* кире кагалар (абруйлы соңгы дин әһелләренә иярү) һәм илаһият-фикъһ сораулары буенча Мөхәммәд пәйгамбәр исән вакытта ук формалашкан хөкемнәр тәртибен (*иҗтиһад*) аңа каршы куялар. Турыдан-туры аларның идеяләре йогынтысында модернистик юнәлештәге күренекле мөселман фикер ияләре плеядасы формалаша (Абдаррахман Кавакиби, Рида Мөхәммәт Рәшид, М.Кемаль). 20 йөздә иң күренекле чит ил ислахчыларыннан традицион мөселман кыйммәтләрен табигыять фәннәре б-н иҗтимагый алгарыш казанышларының гармонияле бәйләнешен хуплаган философлар — М.Икбал, А.Ә.ән-Наим һәм Ф.Гөлән. Татарлардан Г.*Утыз-Имәни*, Г.*Курсави*, Ш.*Мәрҗани*, З.*Камали*, М.*Бигиев*, Р.*Фәхретдин* М.и.ның күренекле вәкилләре булалар. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында татар җәмгыятендә өч юнәлеш өстенлек итә: традиционализм, М.и. һәм модернизм, өстәвенә, шуларның соңгы икесе үзара тыгыз үрелгән (Россия империясендә татарларның нинди дә булса сәяси ин-тларын яңадан торгызу мөмкин булмаган шартларда исламның социаль-мәдәни интеграция факторы сыйфатында коллектив аң формасы буларак алга чыгуы б-н бәйле). Шуңа карамастан, М.и. һәм модернизм — төрле социаль төркемнәр һәм катламнарының мәнфәгатьләрен чагылдырган 2 мөстәкыйль юнәлеш: беренчесенә Г.Утыз-Имәни, Г.Курсави, икенчесенә татар җәмгыятенең сәяси төзелешен алга куйган Морад мулла һәм Батырша керә (к. *Батырша хаты*). М.и. идеясе мәдәниятнең һәм тормышның яңа элементларын ислам кагыйдәләренең традицион кыйммәтләренә яраклаштыруга юнәлгән. 18–19 йөзләрдә М.и.ның төп өлкәсе күбесенчә ислам догматикасы мохитенә карый. Иҗтиһадка чакырган Г.Утыз-Имәни хәнәфиләр *мәзһәбе* һәм традицион кыйммәтләр чикләреннән чыкмый. Г.Курсави, Ш.Мәрҗани эшчәнлеге нәтиҗәсендә М.и. яңа үсеш дәрәҗәсенәирешә. Г.Курсави иҗтиһадка чакырып һәм аның куллану мохитен социаль-хокукый характердагы мәсьәләләр б-н чикләп, ислам догматын читләтеп, төп игътибарны илаһият өлкәсеннән иҗтимагый проблемаларга күчерә. Ш.Мәрҗани *тәкълиднең* асылын үзенчә аңлата (аның фикеренчә, эчтәлек Коръәнгә, Сөннәгә һәм бөек илаһиятчыларның иҗтиһадына иярергә тиеш), исламны иң соңгы яңалыклардан (бидгать) чистартырга чакыра. 20 йөз башыннан татар дини ислахчылары кеше һәм Аллаһ мөнәсәбәтләре, иман һәм гыйлем, ихтыяр иреге (ирадә) һәм әхлакый тыюларга (хәрам) һ.б. темаларга мөрәҗәгать итәләр. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында татар фикер ияләре Ә.Максуди һәм Р.Фәхретдиннең фикерләре беренче тапкыр гомум мөселман кыйммәтләре системасында татар илаһияты традицияләренең урыны күрсәтелгән традицион илаһият юнәлешендә үсә. М.Бигиев татар фикер ияләре арасында беренче булып Аллаһның рәхим-шәфкатьле булуы темасын күтәрә һәм ислам кагыйдәләренең бөтенесен эченә алган һәм вакыт б-н чикләнмәгән характерда булуын исбатлап, диннәргә тигез караш идеясен алга сөрә. Ул аерым мәзһәбләрнең мөселман өммәсен таркатуга китергән тәгълиматларын абсолютлаштыруны кире кага. З.Камали илаһият һәм кешелек белемнәре, иман һәм фән нисбәте мәсьәләсенә катгый караштa тора, аларны аерылгысыз дип санарга тәкъдим итә. Совет чорында 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар илаһият фикере ислахчылык мирасы мәгърифәтчелек һәм *җәдитчелекнең* аерылгысыз өлеше итеп карала, 1920 елларда бу мирас М.и.ның состав элементы буларак бәян ителә (Р.Ибраһимов). Алдагы елларда мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек төшенчәләрен идеологик яктан бер-берсеннән аеру яссылыгында татар мөселман ислахчылыгын аңлату сәяси төсмер ала: 1970 елларга кадәр җәдитчелек *пантюркизм* һәм *панисламизм* идеяләре б-н бәйләнгән милли-буржуаз хәрәкәт дип санала, 1970–90 елларда җәдитчелек мәгърифәтчелек этабы һәм буржуаз-демократик хәрәкәт буларак бәяләнә (Я.Г.Абдуллин). М.и.н өйрәнүче галимнәр аны җәдитчелекнең үсеш еллары башланган чор б-н бәйлиләр: А.Беннигсен М.и. — Ш.Мәрҗани эшчәнлегеннән, Җ.Вәлидов, Т.Дәүләтшин, Р.Мөхәммәтшин, А.Кандидере, А.-А.Рорлих Г.Утыз-Имәни, Г.Курсави, И.Хәлфин хезмәтләреннән башлана дип исәплиләр. Совет чорыннан соңгы елларда М.и. идеяләре *евроислам* концепциясе кысаларында үсеш ала. Казан тарихчысы Д.М.Исхаков татарлардагы дини ислахчылыкның башлануын, Морад мулла эшчәнлегенә бәйләп, 1770 елларга нисбәт итә. Татарларда М.и. иң элек 18 йөздә барлыкка килгән, 19 йөз уртасыннан ул мәгърифәтчелек этабы б-н алышынган дигән фикер дә бар (А.Юзеев).

*Әд.:* Исхаков Д.М. Феномен татарского джадидизма: введение к социокультурному осмыслению. К., 1997; Абдуллин Я.Г. Джадидизм среди татар: Возникновение, развитие и историческое место. К., 1998; Юзеев А.Н. Татарская философская мысль конца XVIII–XIX вв. К., 2001; Мухаметшин Р.М. Татары и ислам в XX веке. К., 2003; Тухватуллина Л.И. Проблема человека в трудах татарских богословов: конец XIX — начало XX вв. К., 2003; Lazzerini Edward J.Ismail Bey Gasprlnskij and Muslim Modernist in Russia, 1878–1914. Wash., 1973; шул ук. Ethnicity and the uses of History: The case of the Volga Tatars and jadidism // Central Asian Survey. 1982. Vol. 1, № 2/3; Azade-Ayse Rorllch. The Volga Tatars. California, 1986; Kanledere A. Reform within Islam. The Tajid and Jadid Movement among the Kazan Tatars (1809–1917). Ist., 1997; Maraş I. Türk dünyasında dini yenileşme (1850–1917). Ist., 2002.

*Р.М.Мөхәммәтшин, А.В.Климин.*

**МӨСЕЛМА́Н КАЧАКЛАРГА́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ КОМИТЕТЫ́**, Россиянең фронт яны терр-яләреннән качып кайтканнарга ярдәм итү буенча Казан шәһәр ком-тының мөселман бүлеге, 1915 елның августында оештырыла. Җитәкчесе — С.Алкин, әгъзалары — Ф.Туктаров (урынбасар), И.Бикколов, В.Таначев һ.б. Ком-т кабулханә һәм ашханәне, торак, теркәү, сан.-гигиена, мәктәп комиссияләрен, ш.у. эшкә урнаштыру бюросын берләштерә. Хәйрия акчалары һәм, өлешчә, Казан шәһәр идарәсе исәбенә яши. Качакларны фатирга урнаштыру, хезмәткә яраклыларга эш табу, уку яшендәге балаларны мәктәпләргә беркетү, матди ярдәм күрсәтү һ.б. б-н шөгыльләнә. Ком-тта мөселман хатын-кызлар актив эшли. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң ком-т эшләре *Мөселманнар комитеты* карамагына күчә.

*Д.М.Госманова.*

**МӨСЕЛМА́Н КОММУНИСТЛА́Р КОМИТЕТЛАРЫ́** (МКК), Россия мөселман коммунистлар партиясенең урыннардагы оешмалары; 1918 елның июненнән *Мөселман социалистлар комитетларының* дәвамчысы. Татарлар һәм башкортлардан оеша. Ком-тларның составына РКП(б) әгъзалары һәм сул социалистлар оешмалары вәкилләре керә. М.к.к.на яңа әгъзалар ком-тның ике

әгъзасы тәкъдиме буенча гомуми җыелышта кабул ителә. 1918 нең ноябренә М.к.к. Архангельск, Әстерхан, Казан, Мәскәү, Мурманск, Пенза, Пермь, Петроград, Рыбинск, Самара, Сембер, Тәтеш, Түбән Новгород, Чистай һ.б. шәһәрләрдә оештырыла; алар 21 мең чамасы кешене берләштерә. Ком-тлар халык арасында сәяси агитация эшләре алып бара, газеталар нәшер итә, Кызыл Армия өчен гаскәри берәмлекләр туплауда катнаша. Эшчәнлекләрен РКП(б) җирле оешмаларының сәяси йогынтысында һәм матди ярдәме б-н алып баралар, ләкин мөстәкыйльлекләре саклана. *Мөселман коммунистларның Беренче Бөтенроссия съезды* карары б-н МКК урыннардагы РКП(б) ком-тларының мөселманнар бюросы яки секциясе итеп үзгәртелә.

**МӨСЕЛМА́Н КОММУНИСТЛАРНЫ́Ң БЕРЕНЧЕ́ БӨТЕНРОССИ́Я СЪЕЗДЫ́**, к. *Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Беренче Бөтенроссия съезды.*

**МӨСЕЛМА́Н МӘГЪРИФӘ́Т ҺӘМ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Пермь шәһәрендә, 1909 елның июненда оеша. Рәисе — З.Ибәтуллин, әгъзалары — Х.Тимкин, К.Галимов, Байчурин, Шәфиев һ.б. Төп максаты — мөселманнарның мәдәни-агарту учреждениеләре челтәрен киңәйтүгә булышу, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү. Пермьдә, Пермь губернасының Пермь өязендә эшчәнлек алып бара. 1917 дән соң яшәүдән туктый.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**МӨСЕЛМА́Н МӘГЪРИФӘ́Т ҺӘМ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Архангельск шәһәрендә, 1911 елның февралендә оеша. Гамәлгә куючылары — М.Ишмәмәтов, З.Фазлуллин, Г.Исхаков, С.Сәйфетдинов, С.Мифтахетдинов, Ш.Исхаков, И.Бикколов. Төп максаты — мөселманнарның мәдәни-агарту учреждениеләре челтәрен киңәйтүгә булышу, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү. Архангельск шәһәрендә һәм губернасында эшчәнлек алып бара. Беренче бөтендөнья сугышы елларында яшәүдән туктый.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**МӨСЕЛМА́Н РУХАНИЛАРЫ́**, 1) дини йолалар үткәрү (*мулла, мөәзин, хафиз*), мөселман хөкем процесслары мөселман хокуклары сорауларын тирәнтен өйрәнү һәм аңлату (*фәкыйһ*), илаһият (галим-голяма, *мөҗтәһид*), дини общиналарга җитәкчелек итү (имам-хатип) б-н проф. шөгыльләнүче социаль төркем; 2) дини общиналар, орденнар, бораderлек башлыклары (*шәех, ишан*, суфи), билгеле бер төбәк, дәүләттәге югары дини шәхес (*сәед, мөфти, ахун, мөхтәсиб*). Башка дөньяви диннәрдән аермалы буларак, исламда (тәкъвалар һәм Аллаһ арасында) арадашчылык хезмәтен башкарган чиркәү ин-ты булмаган кебек (бары тик шигыйләр мәзһәбендә «дин кешеләре» б-н Аллаһ арасында аерым бәйләнешләр булуы танылa һәм рухани дәрәҗәләр баскычы аеруча күзгә ташлана), гомуми рәхәткә ирешкән өстен рухани катлау юк. Шулай ук тиешле белемгә һәм әхлакый дәрәҗәгә ия булган, балигълык яшенә җиткән теләсә кайсы мөселман кешесе, тәкъвалар рөхсәте б-н, шул ук вакытта дәрәҗәгә күтәрү йоласы үткәрмичә һәм берниндиөстенлек казанмыйча, мөселман җәмгыятенең дини тормышы б-н идарә итә ала. Россиягә кушылганга кадәр Идел-Урал төбәгендә, Кырым, Кавказ, Казакъстан, Урта Азия җирләрендә яшәүче мөселманнар арасында шундый тәртип өстенлек итә. Россия дәүләтчелеге киңәйтелгәннән һәм ныгытылганнан соң, җитәкче руханиларның сайланып куелуы, иң әүвәл урта һәм түбән баскычларда, татар, башкорт, әзәрбайҗан, казакъ, үзбәкләр арасында сакланып кала, әмма хакимият әлеге чараны үз күзәтчелегенә алырга омтыла. 1765 елда император Екатерина II М.р.на ташламалар каралган «Сәдакалар» б-н бүләкләү турында Фәрман чыгара. 1788 дә Оренбург дини Мөхәммәди канун Җыены (1831 дә Симферопольдә — Таврия, 1872 дә Тифлистә — Кавказ арты (шигыйләр һәм сөнниләр) мөселманнары Диния нәзарәтләре) оештырылганнан соң, Россия терр-ясенең күпчелек өлешендә М.р.н билгеләү тәртибе кайбер мөһим шәригать нормаларына, ш.у. җирле гореф-гадәтләрне исәпкә алган дөньяви кануннар нигезендә азмы-күпме дәрәҗәдә билгеле бер кагыйдәләргә буйсындырыла. Дәүләт структуралары җирле халык тарафыннан сайланылучы рухани затларның дини әзерлекләрен һәм сәяси яктан ышанычлылыкларын тикшерәләр, хезмәт урыннарында раслыйлар. Тикшерү нәтиҗәләре буенча пед. дәрәҗәләре күрсәтелгән махсус таныклыклар б-н расланучы дини титуллар бирелгән. Аннары документлар раслату өчен губернатор идарәсенә кертелгән. Биредә төп игътибар сәяси тугрылыкка юнәлтелгән. Ышаныч югалтырлык нинди дә булса мәгълүмат табылмаса, хезмәт урынына билгеләү турында исемле император фәрманы тапшырылган. Мондый тәртип тиз генә урнашмый — күпмедер вакыт «указсыз» муллалар да эш итәләр.

Россия империясендә М.р. югары һәм түбән баскыч төркемнәренә бүленгән. Беренче төркемгә мөфтиләр, казыйлар, югары мөселман учреждениеләре утырышчылары, ш.у. ахуннар кергән. Мөфти һәм казыйлар казна хисабына тотылган. Дини җыен рәисе һәм әгъзалары хезмәт урыннарына гомерлеккә билгеләнгәннәр, Оренбург мөфтие ярдәмчесе 3 елга сайланып куелган. Ахуннар, өяз казыйлары һәм губерна диния мәҗлесләре әгъзалары, асылда, М.р.ның урта буынын тәшкил иткәннәр. Руханилар дәрәҗәсенең түбәнге баскычында хатиплар, имамнар, муллалар, ә Оренбург һәм Таврия мөфтиятләрендә аларның ярдәмчеләре (мөәзиннәр) торган. Мәчеттә хатип һәм имам (мулла) булуы каралган. Хатип — дәрәҗәсе буенча өлкәнрәк, җомга намазын (*хөтбә*) укый, әмма бу закон б-н ныгытылмый, еш кына муллалар арасында һәм мәхәллә халкында төрле аңлашылмаучылыклар, бәхәсләр тууга сәбәп була. Матди җитешмәүчелек хатипларның имам һәм мулла вазифаларын башкаруына китерә (мәс., 1911 нең 1 гыйнварына Оренбург җыенына караган 5771 мәхәлләгә 5409 җамигъ мәчет туры килә, аларда 3946 хатип, 3696 имам һәм 691 мулла хезмәт итә; зур җамигъ мәчетләрдә, губерна идарәсе җитәкчелеге рөхсәте б-н, муллалар саны, берсе өлкән булган хәлдә, 5 кә кадәр җитә. Дини вазифалар башкару б-н бергә хатиплар яки имамнар гражданлык хәле актларын да теркәп барганнар һәм Диния нәзарәте каршында хисап тотканнар. Түбән дәрәҗәле М.р.ның төп кереме *зәкят, сәдака* һәм *гошердән*, ш.у. *Ураза бәйрәме* һәм *Корбан бәйрәме* көннәрендә кергән һәм дини йолалар башкарган өчен бирелгән сәдакалардан торган. Мөәзиннәр, муллалар кебек үк, зур өстенлекләрдән файдаланмыйлар һәм казнадан хезмәт хакы алмыйлар, аларның хезмәтенә мәхәллә халкы түли, шәхси хуҗалыклары исәбенә яшиләр. Россия химаясындагы Казакъстан, Бохара әмирлеге һәм Хива ханлыгы М.р.ның хәлләре башкачарак тора: әлеге төбәкләрдә шәригать кануннары өстенлек итә. 20 йөз башында Казанда 12 югары, 24 урта типтагы мәдрәсә һәм алар каршында 13 мәктәп эшли. Алар арасында иң аерылып торганнары «*Мөхәммәдия*», «*Касыймия*», «*Мәрҗания*», «*Госмания*», «Гаффария» мәдрәсәләре. Авыл җирендә аеруча шөһрәт казанганнары — Иж-Буби, Кышкар, Курса, Ташкичү, Түнтәр, Сатыш мәдрәсәләре. Совет хакимияте елларында М.р.ның саны һәм вазифалары азая. Белемнәр бары тик Урта Азиядәге ике уку йортында гына бирелә (Бохарадагы «Мир-Араб» мәдрәсәсе һәм Ташкент ислам ин-ты). 1990 да М.р.н ТРда һәм РФдә яңадан ачылган мөселман дини уку йортларында әзерли башлыйлар (ТРда — 8, ш.и. Россия ислам ун-ты). Хәзерге вакытта респ-када 5 меңгә якын М.р. вәкилләре исәпләнә.

*Әд.:* Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1999. Вып. 2; Республика Татарстан: свобода совести и религиозного объединения. К., 2001; Мухаметшин Р.М. Мусульманское духовенство в постсоветском Татарстане // Государственно-конфессиональные отношения в современном Татарстане. К., 2003.

**МӨСЕЛМА́Н СӘНГАТЕ́** (ислам сәнгате), ислам эстетикасы кануннары буенча тудырылган декоратив һәм гамәли сәнгать, әдәбият, музыка, ш.у. архит-ра, нәфис иҗатның башка төрләре әсәрләренең җыелмасы. Тар мәгънәдә сынлы (хәзерге заман нәкыше, графика, скульптура һ.б.), декоратив (архит-ра бизәге) һәм гамәли сәнгатькә, каллиграфия сәнгатенә карый. 1930 еллар башында СССРның мөселман, нигездә, төрки телле халыкларының мәдәниятенә дини төсмер алып керүче термин буларак фәнни кулланыштан төшереп калдырыла. М.с. төшенчәсе сәнгать формаларында һәм төрләрендә, аның теләндә, бизәлеш-декоратив принципларында чагылыш тапкан ислам эстетикасына, *шәригать* нормаларына, мөселман гореф-гадәтләренә һәм йолаларына нигезләнгән нәфис иҗатның үзенә бер төрле тибына хас булган гомуми, күпкырлы сыйфатларны күз алдында тота. М.с.ндә сурәтләү чараларын чикләү дини традицияләр, кануни риваятьләр (*хәдисләр*), ш.у. эстетик-фәлсәфи концепцияләр (әл-Фараби, Ибне Сина, Әбү-Хәмид әл-Газәли) б-н бәйле.

Татар сәнгате, башка мөселман халыкларының сәнгате кебек үк, декоратив-гамәли бизәк төшерү һәм монументаль-декоратив иҗат


1


2


3


4


5


6


7


8


9


10


11


12


13


14

**Мөселман сәнгате.** 1. Болгар кабер ташы фрагменты. Таш. Яссы рельефлы уеп кисү. 14 йөз башы. Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгы; 2. Кулъязма Коръән. Кәгазь. Акварель, язу карасы. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Китабе – диван Ризаи» китабы унваны. Кәгазь. Язу карасы, алтын. 1840. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. Китап тышы. Күн, металл. Басма. 19 йөз. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивы; 5. Б.И. У р м а н ч е. «Аллаһ гүзәл, ул матурлыкны ярата». Кәгазь. Тушь, акварель, бронза. 1970. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Коръән тартмачыклары. Көмеш, алтын йөгертү, ярымасылташлар. Беркетелгән җепкыр, бөртекләү, чүкеп бизәк төшерү, уеплау. 18–19 йөз башы. ТР Милли музее; 7. Беләзек. Көмеш. Чүкеп бизәк төшерү, уеплау. 19 йөзнең 2 нче яртысы. Р.А. Мөхәммәтшин реконструкциясе. 2000. «Казан» милли мәдәният үзәге; 8. М.Х. Х у җ а с ә е т о в. «Билал Хәбәши мөнәҗәте» шәмаиле. Литография. ТР Милли музее. 1902; 9. Түбәтәй-кәләпүш. Бәрхет, алтын җеп. Чигү. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее; 10. З.Н. Н и з а м е т д и н о в. «Сөембикә» савыт-саба җыелмасы. Агач. Бизәк. «Казан» милли мәдәният үзәге. 2002; 11. Р.Г. Галиев исем. Әлмәт мөселман дини-мәгърифәт үзәгенең мәчет интерьеры гөмбәзендәге майолика плитәгә төшерелгән бизәкләр. Архитекторлар А.М.Закиров, Ф.М.Мәүлетов. 1999; 12. Намазлык. Ефәк. Әлмә. 19 йөз ахыры. ТР Милли музее; 13. Р.С. М ө х ә м м ә т җ а н о в. «Шаһәдә» шәмаиле. Агач җепселле плитә (ДВП). Майлы буяу. 2002; 14. Тукай р-нындагы Шәңгәлче авылы мәчетенең михраб фрагменты. Арх. Д.Р.Мусин. Мозаика. 2005–06.

формаларында үсә. Татарларның төбәк һәм җирле төркемнәрендәге этник традицияләрнең үзара йогынтысы «мөселманлык» асылы булган милли сәнгать барлыкка килүгә булышлык итә. М.с.нең Идел буе халыклары мәдәниятенә йогынты ясавында беренче дәлил булып иң элгәреге үрнәкләре 8 йөзгә нисбәтле болгар гамәли сәнгате эшләнмәләренә төшерелгән гарәп язулары санала. Гарәп язма графикасының таралуы төбәктә М.с. формалашуда әһәмиятле роль уйный. Соңрак аның нигезендә хаттатчылык сәнгате (татар кулъязма китабы, *шәмаилләр*, кабер ташлары) һәм эпиграфик бизәк төшерү (архитектур бизәлеш, декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре) югары үсешкә ирешә. 10–12 йөзләрдәге *болгар бизәлеш сәнгатендә* дөньяны сәнгатьчә гәүдәләндерү принципларының үсеше исламгача чорның мифологик фикерләүгә хас сурәтләвеннән М.с.нең шартлы декоративлыгына һәм бизәк төшерүгә күчүендә чагыла. Геом. һәм үсемлек бизәкләренең катлаулы композицияләре (гирих, арабескалар) пәйда була, «чәчәк стиле» сәнгать теленең образлы төзелешен билгели. Идел буенда М.с.нең чәчәк атуы 13–15 йөзләргә туры килә (Алтын Урда чоры). *Алтын Урда сәнгате* стиле хәлифәлек кануннары буенча үскән нәфис һөнәрчелекнең каллиграфия һәм бизәк төшерү кагыйдәләрен өлге итеп ала. Сәлҗүкләр Кече Азиясе, мәмлүкләр Мисыры, Сүрия, Иран кебек мөселман илләре б-н сәяси-сәүдә һәм мәдәни өлкәләрдә тыгыз элемтә урнаштыру М.с.нә хас сәнгать үрнәкләрен үзләштерүгә булышлык итә. Бу Алтын Урданың Болгар, Солхат, Кырык-Ер (Чуфут Кала), Иске-Йорт (Бакчасарай), Үргәнеч кебек шәһәрләрендә сакланып калган биналардагы декоратив бизәкләрдә һәм киресенчә, төрки-татар (болгар һәм кыпчак) мәдәнияте сыйфатлары, мәс., мәмлүкләр Мисыры сәнгатендә чагылыш таба. Алтын Урда таркалганнан соң татар дәүләтләре барлыкка килү чорында Идел буе, Урал алды, Кырым һәм Көнбатыш Себер татарларының ислам мәдәнияте сыйфатлары формалаша. 15–16 йөзләрдә Идел буенда М.с.нең үзәге Казанда — Казан ханлыгы башкаласында була. М.с.нең чәчәк атуы ислам яки «сәлҗүкләр бароккосы» дип аталган стильнең үсеше б-н бәйле. Казан ханлыгы һ.б. татар дәүләтләре яулап алынып, Рус дәүләте составына кушылганнан соң, М.с. дәүләт мәдәнияте буларак тулысынча диярлек юкка чыга. Ул урта гасырлардан сакланып калган традицияләре булган халык иҗаты формалары рәвешенә керә. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан Шәрекъ товарларының киң таралуы М.с.нә хас булган яңа идея-сәнгать тенденцияләрен үзләштерүгә булышлык итә. Аның образлылыгы исламның соңгы агымындагы катгый хасиятләре б-н билгеләнә. Әлеге чорда көнкүреш һәм зәркән әйберләрен бизәүдә, мөстәкыйль элементлар буларак, гарәп язуларының, Коръән гыйбарәләренең роле көчәя (*Коръән тартмачыклары*, беләзекләр, аеллар). Коръән аятьләре язылган, мөселманнарның изге урыннары сурәтләнгән, пыялада бизәкләр төшереп башкарылган (шәмаилләр), тукымада чигелгән (*ләүхә*) махсус дивар паннолары, график картиналар («аятел-көрси») барлыкка килә, китап япмалары тукыла.

Бизәкләрдәге «чәчәк стиле», ачык күптөслелек татарларның М.с.ндә әйдәп баручы сәнгать чаралары булып кала.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында Европа сынлы сәнгатенең станлы нәкышь, графика, скульптура, сценография жанрлары үсеш ала. Иҗатларында (образлылыкта, композицияләр системасында, төсләр б-н эш итүдә, гарәп каллиграфиясен куллануда) М.с. традицияләре чагылыш тапкан беренче татар проф. рәссамнары (М.Дәүләткилдиев, Х.Акчурина, Ф.Таһиров, Б.Урманче һ.б.) үсеп чыга. 20 йөз ахырына кадәр М.с. кире кагыла. 20 йөз ахырында — 21 йөз башында татар мәдәниятендә әсәрләрнең милли формаларын эзләүгә бәйле һәм мөселманлык традицияләренең дәвамчанлыгына таянган стиль тенденцияләре: образларның символик мәгънәсе, сәнгать теленең шартлылыгы, орнаменталь-декоратив һәм колористик системалар, кешене сурәтләмәү концепциясе, дөньяны предметлы-натуралистик чагылдырудан баш тарту өстенлек итә башлый. Аерым әсәрләрдә мөселманлык мистицизмы, суфичылык карашлары чагыла, аларда Шәрекъ миниатюралары, каллиграфия сәнгате традицияләре яңара (С.Гыйләҗетдинов, Ф.Гыйрфанов, Ә.*Ильясова*, Н.*Исмәгыйлев*, Д.Мусин, Л.Мусина, В.Попов, Р.*Сәлахетдинов*, В.*Шәйхетдинов*, Р.Шәмсутов, Х.*Шәрипов* һ.б.). М.с.ндәге заманча сыйфатлар Идел буенда һәм Урал алдында, Көнбатыш Себердә, Россиянең эре шәһәрләрендә (Мәскәү, С.-Петербург һ.б.) яшәүче татар рәссамнарының иҗатында берләштерүче башлангыч булып тора.

*Әд.:* Большаков О.Г. Ислам и изобразительное искусство // Тр. Гос. Эрмитажа. 1969. Т. 10; Яковлев Е.Г. Искусство и мировые религии. М., 1985; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Мусульманская культура Среднего Поволжья и Приуралья: Истоки и перспективы // Ислам и проблемы межцивилизационных взаимодействий. М., 1994; шул ук. Татарское декоративное искусство в системе мусульманской культуры // Ислам в Поволжье: История и проблемы изучения. К., 2000; шул ук. Мусульманское искусство татар Среднего Поволжья // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье. К., 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӨСЕЛМА́Н СОВЕ́Т УКЧЫЛАРЫНЫ́Ң ИКЕНЧЕ́ МӘКТӘБЕ́ (КУ́РСЛАРЫ)**, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе башлангычы б-н 1919 елның гыйнварында Казанда ачыла. Курсларның мөдире — И.О.Тальковский, комиссары — И.К.Фирдәүс (Фирдевс). Штат буенча 300 курсант укыту карала. Адмирал А.В.Колчак гаскәренең һөҗүмнәре сәбәпле, 1919 ның апрелендә курсларның шәхси составы тулысы б-н диярлек (мөдир һәм комиссардан тыш) 1 нче татар укчы полкы карамагына җибәрелә. Курслар рәсми рәвештә 1919 ның 18 сентябрендә ачыла. Курсантлар саны башта 151 кеше була, соңрак 270 кешегә җитә. Укыту өч бүлектә: әзерлек, гомуми, хәрби бүлекләрдә алып барыла. Гомуми бүлектә дүрт ай укыганнан соң, курсантлар дүрт айлык хәрби бүлеккә күчерелә. Башка дисциплиналар б-н беррәттән, курсантларга татар теле дәресе укытыла, бу дәрестә алар ш.у. кайбер гомуми белем предметларын да өйрәнәләр. Мәктәп 4 чыгарылыш ясый. Беренче чыгарылыш (1920 нең 18 гыйнвары) Кызыл Армиянең татар милли берләшмәләре өчен 99 командир әзерли. 1920 нең июлендә курслар Петергоф шәһәренә күчерелә һәм, аерым мөселман бүлеге буларак, 5 нче укчы курсларга кушыла. Ш.у к. *Уналтынчы үрнәк мөселман укчы командирлар мәктәбе*.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**МӨСЕЛМА́Н СОЦИАЛИСТЛА́Р КОМИТЕТЛАРЫ́** (МСК), татар-башкортларның революцион-демократик оешмалары. Беренчесе — *Казан мөселман социалистлар комитеты* — 1917 елның апрелендә оештырыла (рәисе — М.*Вахитов*), башка ком-тлар өчен җитәкче ролен үти. 1917 нең октябрендә Оренбургта Урал ком-ты, 1918 нең язында Төньяк өлкәләр ком-ты (Вологда ш.), 1918 нең җәендә Архангельск, Әстерхан, Мәскәү, Пермь, Петроград, Самара, Саратов, Сембер, Ташкент, Томск, Төмән һ.б. шәһәрләрдә шундый ком-тлар эшли. Алар бер милләт кешеләренең төрле катлау вәкилләрен (интеллигенция, эшчеләр, хезмәткәрләр) берләштерү нигезендә төзелә. Кайберләре составында сул эсерлар да була. Омтылыш-максатлары мөселман пролетариатын һәм хезмәтчел крәстияннәрне оештыру, алар арасында социализм идеяләре тарату дип билгеләнә. Окт. рев-циясеннән соң Мәскәү, Казан һ.б. кайбер шәһәрләрдә татарлар һәм башкортлардан булган коммунистлар, МСКның сул канаты вәкилләре б-н берләшеп, РКП(б)ның милли секцияләрен төзи башлыйлар. Совет хакимияте МСК әгъзаларын урыннарда мөселманнар комис-тлары төзү эшенә тарта. Үзәк мөселман комис-ты һәм Казан, Архангельск, Мәскәү, Петроград, Самара МСК тәкъдиме б-н Россия мөселман эшчеләре конференциясе уздырыла (Мәскәү, 1918, март). Конференциядә Үзәк Мөселман социалистлар ком-ты һәм аның башкарма ком-ты оештырыла (рәисе — М.Вахитов, урынбасары — М.Солтангалиев). Җитәкче документ итеп, кайбер төзәтмәләр б-н, *Казан мөселман социалистлар комитеты* Уставы вакытлыча кулланылышка кертелә. Көн кадагындагы төп максатлар ачыклана: хакимиятне ярлы халык Советларына бирү; барлык җирләрне җир эшләре ком-тларына тапшыру; завод, фабрика, табыш йортларын дәүләт милкенә әверелдерү. Конференция ш.у. РКП(б) Программасының РКП(б)ның 7 нче съездында В.И.Ленин тәкъдим иткән беренче проектын яклап чыга, шул көннәрдә оештырылган комиссиягә Мөселман социалистлар-коммунистлар партиясе программасын төзү бурычын йөкли (шушы вакыттан кайбер МСК Мөселман социалистлар-коммунистлар ком-тлары дип йөртелә башлый). Үзәк Мөселман социалистлар ком-ты органы буларак, «*Кызыл байрак*» г-тасы нәшер ителә. Конференциядән соң ком-тларда коммунистлар фракциясенең йогынтысы арта. Мөселман коммунистлар киңәшмәсе (Казан, 1918, 10 июнь) карары б-н МСК *Мөселман коммунистлар комитетлары* дип үзгәртелә.

**МӨСЕЛМА́Н СУГЫШЧЫЛАРЫНА́ ҺӘМ АЛАРНЫ́Ң ГАИЛӘЛӘРЕНӘ́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ ВАКЫТЛЫ́ КОМИТЕТЫ́**, хәйрия җәмгыяте. 1915 елның 5 февралендә Беренче бөтендөнья сугышында зыян күргән авырулар һәм яралыларга ярдәм итү максаты б-н Петроградта оеша. Ком-тның рәисе — генерал-майор Г.Дәүләтшин, аннан соң — С.Җантурин, әгъзалары — А.Әсәдуллаев, Ибнеәмин Әхтәмов, М.Байзаков, М.Җафаров, Н.Карпов, М.Максютов, Х.Мансырев, А.Мөфтизадә, А.Сыртланов, З.Шамил. Ком-т иганә ярдәме җыя, фронтка кучмә сан. отряды җибәртә, лазаретлар ача, сугышка алынганнарның гаиләләренә тиешле пенсия һәм ташламалар турында мәгълүмат бирүче татарча белешмәлекләр әзерләп бастыра. 1915 ел ахырына Россия төбәкләрендә ком-тның 100 ләп җирле бүлеге эшли. Бүлекләр Инвалидлар көне уздыра, авыру һәм яралы сугышчыларга концертлар куя, җылы кием-салым җыюны оештыра. Мөселман хәрби тоткыннарына һәм качакларга һәртөрле ярдәм күрсәтелә. Ком-т эшчәнлеге 1917 дән соң туктала.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**МӨСЕЛМА́Н ХАЛЫ́К КОМИССАРИАТЫ́**, хакимиятнең гадәттән тыш органы, Бөтенроссия мөселман гаскәриләренең икенче корылтае (1918 елның марты) карары б-н Идел-Урал Штатын гамәлгә кертү максатыннан оештырыла. Рәисе — И.Атнагулов, рәис иптәшләре (урынбасарлары) — И.Алмаев, И.Кәрим; секретарьлары — Г.Габдрәшитов, К.Терегулов; әгъзалары — Ф.Басыйров, Ә.Биглов, А.Габдуллин, С.Ловчицкий, Г.Моракаев, Ф.Мөхәммәдьяров, С.Полторжицкий, А.Таһиров, А.Якубовский. 5 бүлектән тора. «Идел-Урал өлкәсе» г-тасын нәшер итә. Идел-Урал Штаты (республикасы) урнаштыру хакына мөселманнарны берләшергә чакыра. Комис-т ш.у. әлеге респ-ка зарурлыгын таныган барлык оешмалар б-н хезмәттәшлек итәргә әзерлеген белдерә. «*Болак арты республикасы*»н тар-мар итү барышында, 1918 нең марты ахырында таратыла; М.х.к. әгъзалары кулга алына, соңрак ирекккә чыгарыла.

*Әд.:* В ә л и е в Р.К. Болак арты республикасы. К., 1999.

*Р.К.Вәлиев.*

**МӨСЕЛМА́Н ХЕЗМӘ́Т ТАИФӘСЕ́**, 2 нче Дәүләт Думасында (1907) трудовиклар фракциясе тарафдарлары булган сул мөселман депутатлар төркеме. 36 мөселман депутатның 6 сы шул төркемдә була: Һ.*Атласов* (Самара губ.), Г.С.*Бадамшин* (Казан губ.), З.Э.Зәйналов (Баку губ.), Х.М.*Мәсәгутов* (Вятка губ.), Г.А.*Нәҗметдинов* (Сембер губ.), К.Г.*Хәсәнов* (Уфа губ.). М.х.т.нең сәяси прогаммасын төзүдә һәм аның эшчәнлегендә Ф.Ф.*Туктаровның* йогынтысы зур була. 1907 елда төркем тарафыннан рус, татар, әзәрбайҗан телләрендә «Дума» г-тасы нәшер ителә, шуңа күрә аларны «думачылар» дип тә йөртәләр. Газетада басылып чыккан платформаларында алар «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен (Думада *Мөселманнар фракциясе* шушы партия исеменнән чыгыш ясый) байлар мәнфәгатен яклауда гаепләп чыгалар, татар милләтен күтәрү өчен хезмәтчел халык мәнфәгатьләрен якларлык Мөселман хезмәт партиясе оештыру зарурлыгына басым ясыйлар. 2 нче Дәүләт Думасында тикшерелгән төп мәсьәләләрдән иң кискене булган аграр мәсьәләдә М.х.т. трудовиклар фракциясе тәкъдим иткән җир реформасы проектын тулаем яклый. Думаның аграр мәсьәләгә багышланган утырышларында төркем исеменнән К.Г.Хәсәнов чыгыш ясый, ул Россия империясе чикләрендәге тарихи яктан шунда яшәүче халыкныкы дип танылган җирләрнең, аерым алганда, башкорт җирләренең, тартып алынуына каршы протест белдерә. Ул ш.у. хөкүмәтнең «Россиядә яшәүче әҗнәбиләр мәгарифенә караган чаралар турында» («О мерах к образованию населяющих Россию инородцев», 1870) Нигезләмәсе буенча оештырылган Россия мөселман мәктәбе системасын тәнкыйть итә. Депутат З.Э.Зәйналов аграр мәсьәләгә караган чыгышында ачлык афәтенә дучар булганнарга ярдәм оештырырга чакыра. Таифә әгъзалары башка сул депутатлар тәкъдим иткән закон проектларын һәм һәртөрле мөрәҗәгатьләрне дә хуплыйлар. М.х.т. 1907 нең апрелендә Эчке эшләр министрына Бөре һәм Бәләбәй өязләрендә милли һәм дини әдәбиятны конфискацияләү һәм юк итү, шул хәлләргә каршылык йөзеннән кузгалган җирле мөселманнарның стражниклар тарафыннан җәбер-золымга дучар ителүе, үлем һәм яралану очраклары булу турында мөрәҗәгать итә. Төркем әгъзалары дума комиссияләрендә: Г.Бадамшин — бюджет, К.Хәсәнов — азык-төлек, З.Зәйналов — аграр комиссиядә, ш.у. сәүдә һәм һөнәрчелек өлкәсе хезмәткәрләренең ялын оештыру комиссиясендә актив эшли.

Чыг.: Государственная дума. Второй созыв: Стенографические отчёты: В 2 *т.* СПб., 1907; Государственная дума. Второй созыв: Указ к стеногрфическим отчётам. Заседания 1 — 53 (20 февраля — 2 июня 1907 *г.*). СПб., 1907; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* У с м а н о в а Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906–1917). К., 1999; ш у л у к. Мусульманские представители в российском парламенте. 1906–1916. К., 2005; Ц и у н ч у к Р.А. Думская модель парламентаризма в Российской империи: Этноконфессиональное и региональное измерения. К., 2004.

*Р.А.Циунчук.*

**МӨСЕЛМА́Н ЯШЬЛӘРЕ́ ТҮГӘРӘГЕ́**, Вятка губернасы Алабуга өязенең Бондюга авылы яшьләре тарафыннан 1917 елның маенда оештырыла. Башлап йөрүчеләре: Г.Баһаветдинов, А.Галимбәков, М.Лотфуллин, Ш.Саттаров, А.Сәхабетдинов, Г.Фәсхетдинов, М.Шакиров һ.б. Драма түгәрәге оештыралар, гектографта татар һәм рус телләрендә «Яшьләр авазы» г-тасы чыгаралар, эшче яшьләр арасында агитация-пропаганда эшләре алып баралар. Түгәрәк 1918 ел башында таркала.

*Әд.:* Юность Татарстана (Очерки истории комсомола Татарии). К., 1978.

**МӨСЕЛМАННА́Р АРАСЫНДА́ БЕЛЕ́М АЛУНЫ́ ҖӘЕЛДЕРҮ́ САРА́ТОВ ҖӘМГЫЯТЕ́**, мәдәни-агарту оешмасы. 1916 елның маеннан Саратов шәһәрендә эшли. Гамәлгә куючылары — С.А.Казыймов (рәис), И.Б.Колахметов (Кулахметьев, сәркәтип), И.М.Курамшин, М.И.Солтанов. Максаты — мәктәптә һәм мәктәптән тыш белем бирүне җәелдерү, укытуның сыйфатын яхшырту юлы б-н халыкның мәдәни дәрәҗәсен күтәрү. 1916 ның ахырында җәмгыять тарафыннан Саратовның Татар урамында китапханә-уку залы ачыла (1917 дән соң эшләүдән туктый).

*Җ.С.Миңнуллин.*

**МӨСЕЛМАННА́Р БЕРЛЕГЕ́**, В а р ш а в а д а, 1922–25 елларда эшли. Польша мөселманнарының беренче легаль оешмасы. Уставы 1923 нең 14 декабрендә Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан раслана. Рәисе — А.Х.Хурамович, секретаре — О.Фазлыев. Мөселманнарның дини ихтыяҗларын гамәлгә ашыру б-н имам С.Хәбибуллин җитәкчелек итә. М.б.нең төп максаты — татарларга мәдәни һәм дини белем бирү, мохтаҗ мөселман гаиләләренә матди ярдәм күрсәтү. 1925 тә *Речь Посполита мөселманнары берлеге* итеп үзгәртелә.

*Я.Я.Гришин.*

**МӨСЕЛМАННА́Р БЕРЛЕГЕ́**, к. «*Иттифакъ әл-мөслимин*».

**МӨСЕЛМАННА́Р ДИНИ́ БЕРЛЕГЕ́**, Польша һәм Литва татарлары мөфтияте дәвамчысы буларак, 1947 елда Варшавада оештырыла. Максаты — Польша һәм Литва мөселманнарының дини ихтыяҗларын канәгатьләндерү. 6 дини гминаны (Варшава, Белосток, Бохоники, Гданьск, Гожов Великопольский, Крушыня) берләштерә. Җитәкче органы — башында рухани булмаган зат торган Югары коллегия. Рәисләре — С.Байрашевский, 1984 тән — С.Мухарский. Коллегиядә дини йолаларны үтәү мәсьәләләре б-н Л.Мухля (1947–79) һәм А.Халецкий (1979 дан) шөгыльләнә.

*Я.Я.Гришин.*

**МӨСЕЛМАННА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1918 елның гыйнварында Сембер губернасы Сембер өязенең Олы Тархан авылында оеша. Гамәлгә куючылар — Ш.Вәлитов, Ш.Гафаров, И.Ибраһимов, Г.Хәкимов, М.Хәкимов. Төп максаты — ярлыларга матди ярдәм күрсәтү, мөселманнарның мәдәни-агарту һәм дини учреждениеләре челтәрен үстерү. 1917 дән эшчәнлеге туктала.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**М Ө С Е Л М А Н Н А́ Р К О М И Т Е Т Ы́**, 1917–18 елларда Казандагы иҗтимагый-сәяси оешма. 1917 нең 7 мартында оештырыла. Рәисе — Ф.Туктаров, рәис урынбасары — В.Таначев, әгъзалары — С.Алкин, Г.Баттал, С.Габәши, М.Корбангалиев, С.Максуди, Л.Мостафин, Ә.Мөхетдинова, Г.Сәйфелмөлеков, И.Үтәмишев, Н.Хәлфин, С.Хөснетдинов һ.б. (барлыгы 200 ләп кеше). Ком-тта меньшевиклар һәм уң эсерлар партияләре вәкилләре өстенлек итә. М.к. урыннарда мөселман ком-тлары оештыру, Учредительләр җыенын чакыруны тизләтү, сугышны тәмамлау, крәстияннәрне Төркестан һәм Себергә күчерүне туктату мәсьәләләрен күтәрә. 5 бүлектән тора: оештыру, финанс, агитация-пропаганда һ.б. «*Корылтай*», ул ябылгач, «*Алтай*» г-таларын нәшер итә.

**МӨСЕЛМАННА́Р ФРА́КЦИЯСЕ**, Россиянең 1906–17 еллардагы Дәүләт Думасында эшләгән мөселман депутатлары фракциясе. Идел-Урал, Кавказ, Кырым, Урта Азия, Казакъстан төбәкләреннән сайланган мөселман халкы вәкилләреннән гыйбарәт була. Милли һәм дини тигезлек, тел, белем бирү, мәдәниятне үстерү идеяләрен алга сөрә. 1 нче Дәүләт Думасы (1906 нең 27 апреле — 9 июле, 1906) эшендә 22 мөселман депутат катнаша. Баштарак күпчелек — кадетлар, 3 кеше — мохтариятчеләр фракциясенә керә. Эш барышында мөстәкыйль фракция төзергә карар ителә, аның беренче утырышы 21 июньдә уздырыла. 7 кешедән фракция бюросы сайлана: Г.Тупчыбашев (фракция һәм бюро рәисе), С.Ш.*Алкин*, Ә.Г.*Әхтәмов*, С.С.*Жантурин* (бюро секретаре), И.А.Зиадханов, М.М.Рәмиев (*Дәрдемәнд*) (казначей), Ш.Ш.Сыртланов. Фракция әгъзаларының барысы да «*Иттифакъ әл-мөслимин*» партиясендә тора, фракция эшчәнлегенә бу партия гаять зур йогынты ясый. Сәяси карашлар буенча М.ф. *Конституцион демократлар партиясенә* (кадетлар) теләктәшлек итә. 1 нче Дәүләт Думасының М.ф. утырышларында Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаен (1906 нең августы) уздыру мәсьәләсе карала. Дума куып таратылганнан соң, 6 мөселман депутат хөкүмәткә каршы язылган *Выборг өндәмәсенә* кул куя.

2 нче Дәүләт Думасына (1907 нең 20 феврале — 3 июне) 36 мөселман депутат сайлана, шуларның 30 ы М.ф.нә кертелә. Калган 6 депутат мөстәкыйль *Мөселман хезмәт таифәсе* төзиләр. 2 нче Дәүләт Думасының М.ф. «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясенең Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтаенда кабул ителгән программасына нигезләнеп, үз программасын кабул итә. Ләкин партия программасының кайбер радикаль таләпләре фракция тарафыннан төшереп калдырыла яки үзгәртелә, мәс., шәхси милекнең кагылгысызлыгы, министрларның Дума каршында җавап тотарга тиешлеге, җир мәсьәләсен гадел хәл итү турындагы пунктлар алып ташлана. 1 нче Думадагы кебек үк, фракция кадетларга якын тора. МС рәисе П.А.Столыпинның либераль реформалар программасын тәкъдим иткән чыгышыннан соң 2 нче Дәүләт Думасы депутатлары тикшергән мәсьәләләр тавышка куелганда, М.ф. әгъзалары патша хөкүмәтен тәнкыйтьләүдән тайчынып, алда каралачак эшләргә күчү өчен тавыш бирәләр; 1906 ел 19 август Фәрманы б-н кертелгән хәрби-кыр мәхкәмәләре эшчәнлеген туктату зарурлыгы турында бер төркем депутат мөрәҗәгатен яклап чыгалар (М.Т.Шахтахтинский чыгыш ясый); аграр мәсьәләдә М.ф. кадетлар б-н бер караштa тора, шул ук вакытта дала халыкларының җир мәсьәләсен хәл итү зарурлыгына басым ясый, хөкүмәтнең халыкларны күчереп утырту һәм колонияләштерү сәясәтен гаепләп чыга (Ф.И.Хойский, Р.М.Медиев, Б.Б.Каратаев, Ш.Сәйфетдинов). Бөтенроссия мөселманнарының өченче корылтае карары, нигездә, М.ф. «Әҗнәби башлангыч училищеләренә кагылышлы 1906 ел 31 март кагыйдәләрен юкка чыгару турында» («Об отмене правил 31 марта 1906 г. о начальных училищах для инородцев») мөрәҗәгатен Дума тикшерүенә куя (мөрәҗәгать тексты «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе ҮКның вакытлы комиссиясе тарафыннан әзерләнә). Анда яңа кагыйдәләрнең төп максаты рус булмаган халыкларны аң-белемле һәм мәдәниятле итү түгел, ә аларны руслаштыру икәнлеге, мөселманнарның моның б-н килешмәячәге турында әйтелә. М.ф. әгъзалары ана телендә белем бирүче башлангыч мәктәп һәм укыту-тәрбия процессында җәмәгатьчелекнең катнашуы таләбен күтәреп чыга. 31 мөселман депутат кул куйган мөрәҗәгать, тикшереп өйрәнү өчен, Думаның май ахырында оештырылган халык мәгарифе комиссиясе карамагына тапшырыла. 1907 нең 7 июнендә 2 нче Дәүләт Думасы таратылу сәбәпле, мәсьәлә хәл ителмәгән килеш кала.

3 нче Дәүләт Думасына (1907 нең ноябре — 1912 нең 9 июне) 10 мөселман депутат сайлана; аларның 8 е — М.ф.нә, И.И.Гайдаров — с.-д. фракциясенә (1910 да М.ф.нә күчә), Г.Мөфтизадә — октябристлар фракциясенә керә. Дума утырышларында М.ф. исеменнән Х.Г.Хасмамедов (хөкүмәтнең 1905 ел 17 октябрь Манифестында игълан ителгән сәяси курстан тайпылмавын таләп итә) һәм Г.Ш.Сыртланов (1905–07 еллар Рев-циясе чорында Россия мөселманнарының гамәлдәге режимга лояль мөнәсәбәте хөкүмәт тарафыннан бәяләнмәү турында искәртә, сайлаулар турындагы 1907 ел 3 июнь законыннан канәгатьсезлек белдерә) чыгыш ясый. Мөселман крәстияннәрне хәерчелеккә төшерү һәм күпчелекне радикаль гамәлләргә этәрү, ш.у. мөселман җәмәгатьчелегенең бердәмлегенә зыян салу ихтималын күрсәтеп, М.ф. Столыпинның аграр реформасы кабул ителүгә каршы чыга. Фракция 19 йөз башында Россиягә кушылган вакытта мохтарият хокукы алган Финляндиягә карата аны әлеге хокукларыннан мәхрүм итәчәк «Финляндиягә кагылышлы дәүләткүләм көчкә ия закон һәм карарларны нәшер итү тәртибе турында» («О порядке издания касающихся Финляндии законов и постановлений общегосударственного значения») законы проекты кабул ителүгә дә каршы була. «Бер диннән икенче дингә күчүгә кагылышлы закон тәртипләрен үзгәртү турында» («Об изменении законоположений, касающихся перехода из одного исповедания в другое») законын, киресенчә, яклап чыга, чөнки мөселманнар арасында христиан саналып та, чынлыкта ислам дине тәртипләрен тотып яшәүче, әмма бу турыда ачыктан-ачык белдерүдән тайчынучылар байтак була (әлеге мәсьәләне К.Б.Тәфкилев күтәреп чыга; Дума тарафыннан яклау тапкан закон проекты Дәүләт Советында кабул ителми). М.ф. ш.у. мөселман дини учреждениеләрен үзгәртеп кору, мөселман руханиларының матди хәлен кайгырту мәсьәләләрен кузгата. «Сәүдә йортлары, склад һәм контора хезмәткәрләрен ял вакыты белән тәэмин итү турында»гы («Об обеспечении нормального отдыха служащих в торговых заведениях, складах и конторах») закон проектын караган вакытта М.ф. мөселман хезмәткәрләргә үз диннәрендә каралган көннәрдә ял итү мөмкинлеге бирү турындагы үтенеч б-н мөрәҗәгать итә. Православие динендәге күпчелек әлеге үтенечкә карата битарафлык күрсәтә, моңа протест йөзеннән фракция депутатлары утырышны ташлап чыгалар. С.Максуди Думада патша хөкүмәтенең аракы кибетләре һәм кабаклар челтәрен җәелдерүенә каршы чыгыш ясый. М.ф. «Хәрби хезмәт Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы («Об изменении Устава о воинской повинности») закон проектына мулла һәм мөәзиннәрне хәрби хезмәттән азат итү турында үзгәреш кертергә ирешә (Г.Ш.Сыртланов чыгыш ясый). Фракция мөселман халкының гражданлык хокуклары бозылу, аның милли һәм дини кысуларга дучар ителүе мөселманнарның сәяси хокуклары чикләнү, хакимиятнең югары даирәләренә, мәс., Дәүләт Советына мөселманнарны ачыктан-ачык уздырмау (С.Максуди); Төркестан һәм дала өлкәләре мөселманнарының хокуксызлыгы, сайлаулар турындагы 1907 ел 3 июнь законы нигезендә Дәүләт Думасында алар мәнфәгатен кайгыртучы вәкилләр булмау (К.Б.Тәфкилев); рус телен белмәүче әҗнәбиләргә мәхкәмә эшен үз телләрендә алып бару тыелган булу (С.Максуди); земство җыеннарына сайлауларда мөселманнарның хокуклары сакланмау (С.Максуди) мәсьәләләрен күтәрә. С.Максуди ш.у. либераль мөселманнар хәрәкәтендә катнашучыларны русларга һәм хөкүмәткә каршы көрәштә (панисламизм) урынсыз гаепләүләргә, «мөселман мәсьәләсе» дип махсус күпертелгән яла ягуларга протест белдерә. 1910 елда, Эчке эшләр министрлыгының агымдагы ел чыгымнарын тикшерү барышында, М.ф. хөкүмәтнең эчке сәясәтен тәнкыйть итә (К.Б.Тәфкилев). Фракция милли мәктәп ре-



Мөселман депутатлар.



2 нче Дәүләт Думасы мөселман депутатлары. 1907 елгы фоторәсем.

формасына карата үз проектын әзерли, гомуми башлангыч белем бирү проектын тикшергәндә, ана телендә белем бирүне яклап, актив катнаша. 1907 нең җәеннән, хөкүмәт «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясен ачыктан-ачык эшчәнлек алып бару хокукыннан мәхрүм иткәннән соң, Думадагы М.ф. Россиядәге мөселман халыкларының дини, сәяси һәм милли мәнфәгатьләрен кайгыртучы бердәнбер сәяси оешма булып кала.

4 нче Дәүләт Думасына (1912 нең 15 ноябре — 1917 нең 6 октябре) 6 депутат сайлана, барысы да М.ф.нә керә. 4 нче Дума сайлауларына либераль мөселманнар анык таләпләр (конституция; тулы тигез хокук; 1905 ел 17 октябрь Манифестында вәгъдә ителгән хокук һәм ирекләрнең тормышка ашырылуы; күп миллионлы Төркестан халыклары һәм кыргызларга 1907 ел 3 июнь законы б-н тартып алынган сәяси хокукларын кире кайтару; Дәүләт Думасының, земство һәм шәһәрләрнең, рухани идарәләрнең вәкаләт һәм хокукларын киңәйтү) күрсәтелгән сайлау алды платформасы төзеп баралар. Мөселманнар: «Русларда милләтчелек ничаклы нык һәм колачлы булса, без, мөселманнар да милләтебез, туган телебез, әдәбиятыбыз һәм милли мәктәбебезнең кагылгысызлыгына омтылырга тиешбез», — дип игълан итәләр. 1 нче Балкан сугышы башланып, анда Төркия дә катнашу сәбәпле, 4 нче Дәүләт Думасында М.ф.нә кыенга туры килә. Панславизм колач җәйгән шартларда диндәш төрекләргә карата аз гына теләктәшлек тә панисламизм һәм *пантюркизм* чагылышы буларак бәяләнә. Фракция Россиянең мөселман халыклары мәнфәгатьләрен кайгыртуны дәвам иттерә. Хөкүмәтнең Россиядә яшәүче барлык милләт вәкилләренә карата «хәерхаһлы мөнәсәбәте» ассызыкланган хөкүмәт декларациясен тикшерү вакытында Ә.Г.Әхтәмов мөселманнарга карата «ят кавем» дип карау сәясәтенең үзгәрмәвен әйтә. Фракция армиядә хәрби муллалар санын арттыру, хәрби хезмәтнең мөселман дине кануннары бозылу б-н бәйле кыенлыкларын булдырмау мәсьәләләрен куя (К.Б.Тәфкилев). Ул ш.у. казакъ далаларындагы җирле халыкка мед. ярдәм күрсәтүне яхшырту зарурлыгын күтәреп чыга. М.ф. башлангычы б-н 54 депутат тарафыннан Дума каравына «Мөселманнардан булган затларны антлы ышанычлылар катлавына алганда хокукларны чикләүне бетерү турында» («Об отмене ограничений в правах на вступление в сословие присяжных поверенных лиц мусульманского вероисповедания») закон проекты куела, ләкин ул тикшерелми. Г.Х.Еникиев хөкүмәткә бәйсез чыганаклар — иганә һәм земство акчасына яшәячәк һәм махсус программа нигезендә — 3 баскыч: түбән, урта, югары мәктәп формасында эшләячәк дөньяви белем бирүче милли мәгариф системасы концепциясен тәкъдим итә. Шул ук вакытта, мөселманнар традицион мәктәп һәм мәдрәсәләрне саклап калуны да кайгырталар, фракция аларны Мөселман Диния нәзарәте карамагында калдыру таләбен куя. 1914 нең мартында М.ф. Думада карап тикшерү өчен «Оренбург Диния нәзарәтенә мөселман дини (мәхәллә) мәктәп һәм мәдрәсәләре мөгаллиме һәм мөгаллимәсе вазифасына таныклык тапшыру вәкаләте бирү турында» («О предоставлении Оренбургкому духовному собранию права выдавать свидетельства на звание учителей и учительниц мусульманских духовно-приходских школ (мектебов и медресе)» закон проекты тапшыра, ул да тикшерелми. Аз санлы булуына карамастан, 4 нче Дәүләт Думасының М.ф. Россия мөселманнарының иҗтимагый аңы формалашуга зур йогынты ясый. Фракция әгъзалары, мәс., Эчке эшләр министрлыгы хәерхаһлыгында оештырылган карагруһчыл «Сират әл-мөстәкыйм» оешмасын фаш итеп чыгыш ясыйлар. 1913–16 да С.-Петербургта чыгып килгән «Миллият» г-тасына алар җитәкчелек итә. 1914 нең июнендә М.ф. башлангычы б-н С.-Петербургта Бөтенроссия мөселманнарының дүртенче корылтае җыела, анда мөселман кануннарына үзгәрешләр кертү мәсьәләләре тикшерелә; декабрьдә солдатларга һәм солдат гаиләләренә ярдәм оештыру мәсьәләсен хәл итү өчен Бөтенроссия мөселман иҗтимагый оешмалары корылтае чакырыла. 1916 да К.Б.Тәфкилев башлангычы б-н М.ф. каршында танылган мөселман җәмәгать эшлеклеләре катнашында зур җыен уздырыла. Анда фракциянең сәяси платформасы һәм тактикасы, М.ф. каршында даими бюро булдыру, Думада барлыкка килгән прогрессив блокка мөнәсәбәт мәсьәләләре карала. «Иттифакъ...» партиясенең элекке программасы М.ф. платформасына нигез итеп алына. Тактика мәсьәләсендә башка милли азчылык вәкилләре б-н берләшеп, әҗнәбиләрнең үз блогын булдырырга карар ителә; прогрессив блокка килгәндә, блок үз программасына Россиядә яшәүче мөселман халыкларының юридик хокукларындагы чикләүләрне бетерү турында таләпләр керткәннән соң, аңа кушылырга мөмкин булачак дип килешенә. М.ф. каршында депутатлар б-н тигез хокуклы дүрт зат, ш.у. сәркәтип, язу эшләре өчен өч хезмәткәр һәм фракциядән бер хезмәткәр составында даими Бюро төзелә. Бюро эшчәнлеге чыгымнарын Россия мөселманнары үзләре күтәрергә: ел саен Уфа мөселманнары — 5 мең, казанлылар — 6 мең, оренбурглылар — 4 мең сум акча бирергә, Троицк, Орск, Сәет (Каргалы) бистәсе, Семипалатинск, Мәскәү, Әстерхан мөселманнары ш.у. үз өлешләрен кертергә тиеш була. Тиздән Бюро (Ә.Т.Цаликов — рәис, Ш.З.Мөхәммәдъяров, Ә.Ә.Вәлиди) эшкә керешә. Прогрессив блок төзелүгә җавап йөзеннән, 1915 нең 3 сентябрендә хөкүмәт Думаны 1916 ның февраленә кадәр тарата. Февраль сессиясенең башында ук М.ф. хөкүмәт адресына тәнкыйть яудыра: К.Б.Тәфкилев — Б.В.Штюрмер хөкүмәтенең илне җиңүле солыхка илтә алмаячагы, Ә.Г.Әхтәмов мөселманнарга каршы пропаганда көчәю турында чыгыш ясый, М.Җафаров милли тормыш иреге таләп итә: «... Рус армиясе чит ил халыкларына азатлык алып килә икән, Россия империясе составына кергән күпсанлы халыкларга карата да шул ук азатлык, һичшиксез, игълан ителергә тиеш» — ди ул. 1917 нең 26 февралендә император Николай II иң соңгы Фәрманнарының берсе б-н Думаны 1917 нең апреленә кадәр яңадан тарата. Шуннан соң Дума кабат җыелмый. 27 февральдә Дәүләт Думасының 10 кешедән торган Вакытлы ком-ты оештырыла, әлеге ком-т Вакытлы хөкүмәт төзүдә турыдан-туры катнаша. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң М.ф. Бөтенроссия мөселманнары корылтае җыю турында карар кабул итә: 15–17 мартта фракция һәм аның Бюросы әгъзалары катнашында утырыш була. Корылтайга әзерлек эшләрен башкару өчен *Россия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросы* төзелә (рәисе — Ә.Т.Цаликов). Һәр дүрт чакырылышның М.ф. әгъзаларыннан иң күренеклеләре 1917–18 дә уздырылган Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары эшчәнлегендә актив катнашалар, күбесе яңа оешкан милли органнар — *Милләт Мәҗлесе, Милли Шура, Хәрби Шура* һ.б. составына кертелә. 4 нче Дәүләт Думасын тарату турындагы Фәрманга 1917 нең 6 октябрендә кул куела.

М.ф. әгъзаларының сайланган төбәге күрсәтелгән исемлеге. **1 нче Дәүләт Думасы:** З.Ш.Аджарский (Карс өлкәсе), М.Алиев (Баку губ.), С.Ш.Алкин (Казан губ.), А.Ахвердов (Елизаветполь губ.), Ә.Г.Әхтәмов (Уфа губ.), А.К.Беремжанов (Тургай өлкәсе), А.Н.Бүкәйханов (Семипалатинск өлкәсе), С.С.Жантурин (Уфа губ.), И.А.Зиадханов (Елизаветполь өлкәсе), А.К.Кальменев (Уральск өлкәсе), Ш.Кошегулов (Акмулла өлкәсе), Б.А.Кулманов (Әстерхан губ.), Д.Х.Курамшин (Уфа губ.), С.Д.Максудов (Уфа губ.), Ш.М.Матинов (Оренбург губ.), Ф.М.Миндубаев (Казан губ.), А.Мурдаханов (Баку губ.), М.М.Рәмиев (Оренбург губ.), Ш.Ш.Сыртланов (Уфа губ.), М.Таинов (Семиреченск өлкәсе), К.Б.Тәфкилев (Уфа губ.), Г.Тупчыбашев (Баку ш., Баку губ.), Я.Х.Хурамшин (Уфа губ.), Ш.Х.Хөсәенов (Вятка губ.), Т.Э.Эльдарханов (Терек өлкәсе), А.А.Эриванский (Эриван губ.).

**2 нче Дәүләт Думасы:** Т.Абдулхәлилов (Сәмәрканд өлкәсе), Т.Аллабиргәнов (Сырдәрья өлкәсе), А.К.Беремжанов (Тургай өлкәсе), М.М.Биглов (Уфа губ.), Г.Х.Еникиев (Казан губ.), Б.Б.Каратаев (Уральск өлкәсе), А.А.Кардашев (Дагстан өлкәсе һәм Закатальск округы), А.А.Кариев (Ташкент ш.), Ш.Кошегулов (Акмулла өлкәсе), Б.А.Кулманов (Әстерхан губ.), Ш.Г.Күлбаков (Уфа губ.), С.Н.Максудов (Садри Максуди, Казан губ.), С.Т.Максутов (Казан губ.), М.М.Мәхмүдов (Баку губ.), Р.М.Медиев (Таврия губ.), Г.М.Мусин (Казан губ.), С.А.Мөхәммәтҗанов (Фирганә өлкәсе), Х.Г.Нороконев (Семипалатинск өлкәсе), М.Нурбирдеханов (Каспий аръягы өлкәсе), Ш.Сәйфетдинов (Оренбург өлкәсе), Б.Солтанов (Дагстан өлкәсе һәм Закатальск округы), Ш.Ш.Сыртланов (Уфа губ.), И.З.Тагиев (Баку ш., Кавказ), К.Б.Тәфкилев (Уфа губ.), М.М.Тукаев (Уфа губ.), М.Т.Тынышпаев (Семиреченск өлкәсе), Х.Г.Госманов (Оренбург өлкәсе), К.Г.Хәсәнов (Уфа губ.), Х.Г.Хасмамедов (Елизаветполь губ.), Ф.И.Хан-Хойский (Елизаветполь губ.),

М.Т.Шахтахтинский (Эриван губ.), Т.Э.Эльдарханов (Терек өлкәсе).

**3 нче Дәүләт Думасы:** З.Н.Байбурин (Оренбург өлкәсе), И.И.Гайдаров (Дагстан өлкәсе һәм Закатальск округы), Г.Х.Еникиев (Оренбург өлкәсе), С.Н.Максудов (Садри Максуди; Казан губ.), Ш.Җ.Мәхмүдов (Уфа губ.), И.И.Мөфтизадә (Таврия губ.), Г.Ш.Сыртланов (Уфа губ.), К.Б.Тәфкилев (Уфа губ.), М.М.Тукаев (Уфа губ.), Х.Г.Хасмамедов (Баку, Елизаветполь, Эриван губерналары).

**4 нче Дәүләт Думасы:** Ә.Г.Әхтәмов (Уфа губ.), Г.Х.Байтирәков (Уфа губ.), М.М.Далгат (Кавказ), М.Җафаров (Баку, Елизаветполь, Эриван губерналары), М.Г.Миңнегалиев (Самара губ.), К.Б.Тәфкилев (Уфа губ.).

Чыг.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

*Әд.:* Усманова Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной Думе России (1906–1917). К., 1999; Циунчук Р.А. Думская модель парламентаризма в Российской империи: Этноконфессиональное и региональное измерение. К., 2004.

*Р.А.Циунчук.*

**МӨСЕЛМАННА́Р ХӘРБИ́ ҺӘЙӘТЕ́**, 1918 елның 17 июнендә Пермь шәһәрендә губерна хәрби комис-ты тәкъдиме б-н оештырыла. Рәисе М.Ю.*Борындыков*. Кызыл Армия өчен мөселман гаскәри берәмлекләрен туплау (мөселман социалистлар батальонын, 21 нче мөселман укчылары полкын, Урал кызыл коммунарлары ротасын һ.б.ны оештыру), мөселман кызылармиячеләрне сәяси һәм мәдәни агарту б-н шөгыльләнә. 1918 нең 25 декабрендә эшчәнлеге туктатыла.

*И.Г.Гыйззәтуллин.*

**МӨСЕЛМАННАРНЫ́Ң ДҮРТЕНЧЕ́ КОРЫЛТАЕ́**, к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары.*

**МӨСЕЛМАННАРНЫ́Ң КОММУНИСТЛА́Р КОМИТЕТЛАРЫ́**, к. *Мөселман коммунистлар комитетлары.*

**МӨСЕЛМАННАРНЫ́Ң ПАТША́-ХАЛЫ́К ҖӘМГЫЯТЕ́** (ЦНМО), татарларның 1908–09 елларда Казан губернасы Чистай өязендә эшчәнлек алып барган уң монархистлар иҗтимагый-сәяси оешмасы. Җәмгыятьнең оешуына Казандагы *Рус патша-халык җәмгыяте* рәисе, проф., татарлар арасында сепаратизм идеяләре таралуны һәм аларның революцион хәрәкәттә катнашуларын «әҗнәбиләрне сәяси яктан таркату» юлы б-н туктатырга омтылган В.Ф.*Залесский* этәргеч бирә. 1908 нең 9 декабрендә җәмгыятьнең уставы раслана, анда татар халкының «хакимлеге чикләнмәгән патшага Коръән тотып биргән антка тугрылык саклавы һәм рус патриотик җәмгыятьләре б-н ныклы бергәлеге» төп максат итеп күрсәтелә. Караган катлавы һәм мөлкәти хәленең ниндилегенә карамастан, фәкать тумышы б-н татар булган һәр ике җенес вәкилләре М.п.-х.җ. әгъзасы була ала. «Яһүдләр, диелә уставта, хәтта ислам диненә күчкән очракта да, Җәмгыятькә кабул ителми». Җәмгыять эшләре б-н 12 әгъза һәм 18 әгъзалыкка кандидатны берләштергән Баш шура идарә итә. Баш шура вакытлыча (җәмгыятьнең Казан бүлеге ачылганчыга кадәр) Чистай өязенең Кармыш авылында урнаша. Кармыш бүлегенең (бер үк вакытта — Баш шураның да) рәисе — крәстиян Х.Фәйзуллин, рәис урынбасарлары — С.Хисаметдинов һәм Г.Музинов, сәркәтип — Ш.Рәхмәтуллин, казначей — М.Әфләтунов. 1908 нең 9 декабреннән 1909 ның июле башына кадәр Кәркәле, Түбән Кәминкә, Яңа Дума, Яңа Ибрай, Яңа Кади, Яңа Үзи, Иске Ибрай, Иске Кармәт һ.б. авылларда 18 бүлек ачыла. 240 тан артык әгъзаның бик аз өлешеннән (авыл старостасы Х.Сираҗетдинов, мулла Г.Г.Тимербулатов һ.б.) калганнарын крәстияннәр тәшкил итә. Җәмгыять үз эшчәнлегендә революцион һәм либераль идеяләргә каршы эчтәлектәге яки халыкны «Бөек Рус патшасы хакимлеге астында рус халкы белән берләшергә» өндәгән мөрәҗәгатьләр б-н чыгудан ары узмый. 1909 ның 9 апрелендә «Речь» г-тасында «Ватанны коткаралар» («Спасают Отечество») мәкаләсе басылып чыкканнан соң уздырылган адм. тикшерү җәмгыять әгъзалары арасында үзләрен тиешенчә тотмаучы һәм сәяси яктан ышанычсызлар булуын ачыклый; мәс., Югары Татар Майнасы авылыннан берсе М.п.-х.җ.нең бүлек Шурасы рәисе, икенчесе бүлектә әгъза булып торган бертуган Юзиевлар панисламизмны пропагандалауда гаепләнә, Баш шура рәисе иптәше (урынбасары) С.Хисаметдиновның элегрәк татарларны Төркиягә күчеп китәргә өндәгәне өчен мәхкәмә җаваплылыгына тартылуы билгеле була. 1909 ның 23 июнендә Чистай өяз исправнигы Юзиевларны кулга ала һәм җәмгыятьнең Югары Татар Майнасындагы бүлеген яптыра. 1909 ның октябрендә М.п.-х.җ. бүлекләренең эшчәнлеге туктатыла, 1909 ның 30 декабрендә алар ябыла. М.п.-х.җ. рәсми рәвештә 1914 нең 20 сентябрендә, адм. тикшерүдән соң яшәүдән туктый. Ш.у. к. *Карагруһчылар.*

*И.Е.Алексеев.*

**МӨСЛИ́М** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 36 *км* төньяктарак, Ык елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 228 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; нефть чыгару. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1870 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Мөслим исеме б-н дә билгеле. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 832 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 30 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1889 да — 240, 1910 да — 423, 1920 дә — 451, 1926 да — 482, 1938 дә — 453, 1949 да — 364, 1958 дә — 320, 1970 тә — 336, 1979 да — 230, 1989 да — 155, 2002 дә — 228 кеше.

**МӨСЛИ́М** авылы, Мөслим р-ны үзәге, ТР-ның көнчыгыш өлешендә, Әгерҗе–Акбаш тимер юлындагы Бөгелмә станциясеннән 110 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда, Казаннан 319 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 7348 кеше (татарлар) яши. Майсызландырылган коры сөт з-ды, агрохимсервис, сельхозтехника, төзелеш пр-тиеләре. Һөнәр уч-щесе, 2 урта мәктәп, лицей, музыка мәктәбе. Мәдәният сарае, 2 китапханә. Мәчет 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә мәчет, мәктәп, су һәм җил тегермәне, 6 ярма яргыч, 3 тимерчелек, әвен эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3780,85 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында.







Мөслим авылы. 1. Үзәк мәйдан; 2. Мәдәният сарае; 3. Авыл панорамасы.

1930 ның 10 августыннан — Мөслим р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Сарман р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — кабат Мөслим р-ны үзәге. Халык саны: 1870 тә — 1084, 1897 дә — 1552, 1913 тә — 1996, 1920 дә — 1898, 1926 да — 1304, 1938 дә — 2452, 1949 да — 2323, 1958 дә — 2557, 1970 тә — 3623, 1979 да — 4509, 1989 да — 6202, 2002 дә — 7392 кеше.

**МӨСЛИ́М** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Талкыш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 571 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет — 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә волость идарәсе урнаша; 2 мәчет (1870, 1871 елларда салынган һәм 1891 дә янган мәчетләр урынына 1893 тә төзелә), 4 тегермән, 2 ярма яргыч, 12 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2756 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 176 ир-ат; 1859 да — 1561, 1897 дә — 1967, 1908 дә — 2057, 1920 дә — 2051, 1926 да — 1678, 1938 дә — 1276, 1949 да — 901, 1958 дә — 1086, 1970 тә — 1047, 1979 да — 784, 1989 да — 616, 2002 дә — 686 кеше.




**МӨСЛИ́М РАЙОНЫ́** ТРның көнчыгыш өлешендә, БР б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1464,3 *км*$^2$. 19 авыл җирлеген (җирле үзидарә советын), 71 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Мөслим авылы. 2012 елда 21,5 мең кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 89,8%, руслар — 6,7%, марилар — 2,7%) яши. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 15 кеше. Район 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязендә, 1920–30 елларда ТАССРның Минзәлә кантонында. Оештырылган көннән М.р.на 47 авыл советы, 92 торак пункт керә, аларда 45289 кеше (ш.и. татарлар — 35309, руслар — 8192) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә М.р.ның бер өлеше яңа оештырылган Калинин р-нына күчә. 1940 та районның мәйданы 1261 *км*$^2$, халык саны — 36 мең, 28 авыл советы, 77 торак пункт була. 1959 ның 12 октябрендә Калинин р-ны таркатылгач, берничә авыл советы М.р.на күчә һәм районның мәйданы 1593,3 *км*$^2$ га җитә, 19 авыл советы, 96 торак пункт була. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә М.р. таркатыла, биләмәләре Минзәлә һәм Сарман р-ннарына бирелә. Кабат торгызылганнан соң (1965 нең 12 гыйнвары), районның мәйданы — 1433 *км*$^2$, халык саны — 32,5 мең кеше, 17 авыл советы, 78 торак пункт исәпләнә. М.р.ның рельефы — тигезлек (биеклеге 100–200 *м*). Ык һәм аның кушылдыгы Мәллә елгалары ага. Җирләре селтесезләнгән, типик кара, соры урман, көрән соры туфраклы. Терр-ясенең 18,6% урманнар били. Чуерташ, известьташ, бентонит балчык ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: Ык елгасы, *Наратасты урманы*. М.р. — нигездә, а.х. районы. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау тармаклары үскән. А.х. җирләре — 108 мең *га*, ш.и. 85,5 мең *га* сөрүлек җир (2010). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, карабодай, борчак игелә, шикәр чөгендере үстерелә. 2012 дә М.р.да 5 а.х. пр-тиесе эшли. Сәнәгать пр-тиеләре Мөслим авылында тупланган. Район җиреннән Мөслим — Азнакай автомобиль юлы уза. 47 гомуми белем бирү мәктәбе, коррекция интернат-мәктәбе, һөнәр уч-щесе, 33 китапханә, 29 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 48 клуб, хастаханә (2011) эшли. Татар һәм рус телләрендә «Авыл утлары», «Сельские огни» район г-талары нәшер ителә.

**МӨСЛИ́М ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Мөслим авылында, 1989 елда төзелә, 1992 дә ТР Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2006 дан муниципаль музей. Башта бер катлы агач бинаны били. Экспозиция мәйданы — 100 *м*$^2$, музей фондында 2 меңгә якын саклау берәмлеге бар. Экспозиция төбәкнең борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәрге тарихына багышлана, өч залда урнаша. Төп бүлекләр: археол., этнография, 20 йөз төбәк тарихы. Этнография бүлегендә эш кораллары, көнкүреш кирәк-яраклары, татар — мөселман һәм керәшен, рус, мари халыкларының өс киемнәре, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы халык декоратив-гамәли сәнгате әйберләре куелган. 20 йөз төбәк тарихы бүлегендә якташлар — Сов. Союзы Геройлары Г.В.*Вәзетдинов*, П.А.*Днепров*, И.М.*Маннанов*; Дан орденының тулы кавалеры Б.М.*Салихов*; язучы Ф.М.*Садриев*, шагыйрьләр Х.Г.*Әюпов*, *Зөлфәт* (Д.Г.Маликов), Н.Г.*Гамбәр* документлары һәм фотосурәтләре куела. 2009 дан ике катлы бинага урнаша. Коллекцияләр 2013 тә 2930 саклау берәмлеген тәшкил итә. Аеруча кыйммәтле коллекцияләр — этногр. әйберләре. Ел саен Җиңү көне (9 май), Халыкара музейлар көне (18 май) уздырыла.



Мөслим авылында төбәк тарихы музее. Экспозиция фрагментлары: көнкүреш әйберләре. 20 йөз башы.

**«МӨСЛИМӘ́»**, люцерна сорты. 2001 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Ш.Лапина, З.Ф.Насретдинова, О.Л.Шайтанов тарафыннан чыгарыла. Биеклеге 60–90 *см*, чәчәк оешмасы цилиндрик формада, кузаклары 2–3 әйләнешле спиральсыман. 1000 орлыкның авырлыгы 2 *г*. Куагы ярым туры яисә ярым авыш формада, куаклануы уртача. Тамыр черегенә, сөрлегүгә бирешми, салкынга чыдам. Уртача печән уңышы 1 *га* дан 85 *ц*, орлыкныкы — 3 *ц*, яфраклануы 50%. Коры матдәдә протеин 18–20%. 2003 тә РФ селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелгән. РФнең Урта Идел (ш.и. ТР) һәм Идел-Вятка регионнарында чәчәргә рөхсәт ителгән.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**МӨСЛИ́МОВ** Равил Габдулла улы (17.5.1937, Кыргызстан ССРның Кызыл-Кия ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, җылылык энергетикасы инженеры, техник фән. канд. (1979), ТАССРның атказ. энергетигы (1988), РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1997). 1960 елда Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлаганнан соң, «Промстройэнергомонтаж» трестының Казан төзелеш-монтаж идарәсендә мастер, прораб, участок башлыгы булып эшли. 1968–71, 1979–91 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында: инструктор, сәнәгать (1979 дан), социаль-икътисад (1988) бүлекләре мөдире. 1971–79 да «Камгэсэнергострой» ҖБнең «Теплоэнергострой-2» төзелеш идарәсе башлыгы. 1992–93 тә — ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Кәрәзле телефон челтәре проекты дирекциясе, 1993–2002 дә — Россия «Газпром» АҖнең бүлендек пр-тиеләре: «Таттрансгаз» (1998 гә кадәр), «Сыек газ» (1998–2002 дән) ҖЧҖләре ген. директоры. М.җитәкчелегендә Казандагы ТЭЦ-1 киңәйтелә, ТЭЦ-3 нең 1 нче чиратының 4 энергоблогы, Шәмәрдән газ компрессорлары станциясе, шәһәрләрдә һәм авылларда күп кенә торак, социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары төзелә һәм файдалануга тапшырыла; ТР районнарын, шәһәрләрен һәм авылларын газлаштыру программасы, магистраль газ үткәргечләрне файдалануның яңа алымнары гамәлгә ашырыла. Хезмәтләре җылылык һәм масса алмашуга карый. Табигый газ чыгымын үлчәүнең алдынгы алымнарын эшли. 1980–90 да ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**МӨСЛИ́МОВ** Ренат Хәлиулла улы (31.10.1934, Казан), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (1992), ТР ФА академигы (2007), РСФСР, ТРның атказ. геологы (1989, 1995), СССРның мактаулы нефтьчесе (1984). Казан ун-тын тәмамлый (1957). «Татнефть» АҖдә эшли: «Бөгелмәнефть» нефть промыселе идарәсендә башлык урынбасары — баш геолог (1965 елдан), АҖнең ген. директор урынбасары — баш геолог (1966 дан). Бер үк вакытта, 1994 елдан Казан ун-тында нефть һәм газ каф. профессоры. 1998 дән нефть һәм газ өлкәсендә ТР Президенты каршында дәүләт киңәшчесе, 2007 дән нефть һәм нефть-газ чыганакларын эшкәртү мәсьәләләре буенча ТР Президенты киңәшчесе. М. углеводород ятмалары урнашуның төп закончалыкларын ачыклый, ТР терр-ясендә алмаз барлыгын, углеводородларны эзләү юнәлешләрен һәм аның ятмаларын, ш.и. кристаллик фундаментта разведкалау алымнарын (методикасын) нигезли. Үзлегеннән арта һәм даими рәвештә яңартыла торган нефть һәм газ чыганакларын, чыганакларны эшкәртүгә бәйле рәвештә углеводородларның тирәннән даими күчешен фаразлый. Күп катламлы нефть чыганакларын разведкалау һәм файдалануга әзерләү алымын тәкъдим итә. Кыен чыгарылучы нефть запасларын эшкәртүнең комплекслы системасын булдыруда катнаша. Татарстан, Көнбатыш Себер, Һиндстанның эре нефть чыганакларын разведкалау эшләре һәм эшкәртү М. җитәкчелегендә башкарыла. Уйлап табуга 90 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Хьюстон геол. оешмасының (АКШ, 1992 дән) шәрәфле әгъзасы, АКШ геолог-нефтьчеләре оешмасы, РФАнең Атом-төш физикасы бүлегенең фәнни советы әгъзасы (1194 тән). СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. (1977, 1982), СССР, ТР Дәүләт (1982, 1994), РСФСР (1986), РФ (2006) хөкүмәтләре бүләкләре лауреаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, «Чыганакларны беренче ачучы», «Фән һәм сәнгать рыцаре» билгеләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нетрадиционные источники углеводородного сырья — резерв дальнейшего развития старых нефтедобывающих регионов // Георесурсы. 1999. № 1; Стратегия и тактика освоения нефтяных ресурсов на поздней стадии разведки и разработки // Георесурсы. 2000. № 3; Потенциал фундамента нефтегазоносных бассейнов в пополнении резервов углеводородного сырья в XXI веке // Прогноз нефтегазоносности фундамента молодых и древних платформ. К., 2001; Современные методы повышения нефтеизвлечения: оптимизация, практирование и оценка эффективности. М., 2004.

**МӨСЛИ́МОВ** Фатих Мостафа улы (Фатыйх батыр) (1906, август, хәзерге Казакъстан Респ-касы Баскынча а. — 17.3.1975, Алма-Ата), Кытайда милли азатлык хәрәкәтендә катнашучы. Шәркый Төркестанның Элә өлкәсендә (Кытай) Гоминьдан гаскәрләренә каршы баш күтәрүчеләрнең җитәкчеләреннән берсе. 1945–51 елларда Элә өлкәсенең Нылкы өязе хакимияте башлыгы. 1951–52 дә, культура революциясе чорында, Кытай хакимиятләре тарафыннан репрессияләнә. 1954 тән СССРда яши.

*Әд.:* Т е й и п о в З. Шәрки Төркистан йеридә. Алмута, 1977.

*М.Г.Госманов.*

**МӨСЛИ́МОВА** Фәйрүзә Әсгать кызы (9.7.1954, Актаныш р-ы Иске Балтач а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1977). «Яшь ленинчы» (1976–79), «Алга» (Горбунов исем. КАПО, 1979–82) г-таларында, 1982 елдан «Ялкын» ж-лында эшли. «Ярату яралары» (2001), «Апрель кары» (2004), «Алтын йозак» (2009) шигъри җыентыклары, балалар өчен «Бүләк» җыентыгы (2012), хикәяләр авторы. М. поэзиясенә гадилек, эчкерсезлек, хисләр тирәнлеге һәм нечкәлеге, шигырьнең эчке ритмын оста куллану, нечкә юмор хас.

*Әд.:* В ә л и е в М. Оя тойгысы // Казан утлары. 2001. № 8.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**МӨСТӘКЫ́ЙМОВ** Габделмәннаф Биккенә улы (1808, Казан губ. Казан өязе, хәзерге Әтнә р-ны Олы Бәрәзә а. — 1869), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре. Бакалея әйберләре һәм икмәк б-н сәүдә итә. М. Казандагы Зәңгәр мәчетнең идарәче-химаячеләреннән берсе, 1864 елда аның өчен җир мәйданы бирә һәм мәчет мәнфәгатьләренә, ш.и. әйләнәсенә таш койма кордыруга зур суммада матди ярдәм итә. М. эшен аның улы — нәселдән килүче мактаулы граждан Әхмәдшакир (1842-?) дәвам итә.


*Р.Р.Хәйретдинов, Р.Р.Салихов.*

**МӨСТӘКЫЙМОВ** Зәйнулла Мөстәкыйм улы (1924, БАССРның Шаран р-ны Ямадыбаш а. — 28.2.1945, Калининград өлкәсенең Зеленоград р-ны Переславский бистәсендә туганнар каберлегендә җирләнә), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. рядовое. Туган авылында колхозда бригадир булып эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 536 нчы истребитель-танкка каршы артиллерия полкында орудие төзәүчесе (2 нче гв. армиясенең 14 нче истребитель-танкка каршы көрәшүче артиллерия бригадасы). Дон, Сталинград, Көньяк, 4 нче Украина һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Донбасс, Мелитополь (икесе дә — 1943), Шяуляй, Мемель (икесе дә — 1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 18 августында Шяуляй шәһәреннән (Литва ССР) көньяк-көнбатыш якта барган сугышта батырлык күрсәтә: һөҗүм вакытында дошманның 10 танкын яндыра. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медаль б-н бүләкләнә. М. исемен балыкчылар судносы йөртә. Туган авылында бюсты куела.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Лицом на Запад. Уфа, 1972; Звёзды не меркнут. Калининград, 1982.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МӨСТӘКЫ́ЙМОВ** Рәшит Галәветдин улы (10.10.1924, Чистай кантоны Мөслим а. — 6.11.1994, Дүшәнбе ш.), ветеринар-клиницист, вет. фән. д-ры (1969), ВАСХНИЛ мөхбир әгъзасы (1970), Таҗикстан а.х. фәннәре академиясе хакыйкый әгъзасы (1994), Таҗикстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Татарстан Респ-касында вет. клиницистлары мәктәбенә нигез салучы.



Р.Х.Мөслимов.




З.М.Мөстәкыймов.

Сәмәркәнд а.х. ин-тын тәмамлый (1951). 1958–70 елларда Таҗикстан ССР А.х. министрлыгының фәнни-тикшеренү ин-тында вет. санитариясе һәм йогышлы булмаган авырулар бүлеге мөдире, 1970–90 да Таҗикстан а.х. ин-тында хирургия, акушерлык, клиник диагностика, патология һәм терапия каф. мөдире. 1991–94 тә Таҗикстан СС ФАнең Вет. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1994 тән Таҗикстан а.х. фәннәре академиясе президиумы секретаре. Хезмәтләре терлекләрдә бронх ялкынсынуының төрле төрләре һәм витамин-минераллар алмашы бозылу очракларында флюорография ярдәмендә диагноз кую, дәвалау һәм авыруны контрольдә тоту ысулларын эшләүгә, гастроэнтерит, гиповитаминозларны кисәтүгә карый. М. вет. өчен зур кадрлы махсус рентген-флюорография аппараты төзи, аппарат соңрак сәнәгатьтә күпләп җитештерүгә кабул ителә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Флюорография в ветеринарии. М., 1970.

*Әд.:* Ветеринарная энциклопедия. М., 1973. Т. 4.

**«МӨСТӘФА́Д ӘЛ-ӘХБА́Р ФИ ӘХВАЛИ́ КАЗА́Н ВӘ БОЛГА́Р»** («مستفاد الاخبار في احوال قزان و بلغار» — «Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр»), тарихи чыганаклар тупланмасы; татар халкының тарихын өйрәнүгә багышланган беренче гыйльми хезмәт. 19 йөз ахырында Ш.*Мәрҗани* тарафыннан татар телендә языла. Бол-



Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабы тышлыгы.

гар, хәзәр, татар һәм Көнчыгыш Европаның башка төрки халыклары турындагы мәгълүматлар тупланган хезмәт ике китап итеп бастырыла (1 нчесе — 1885, 1897; 2 нчесе — 1900). 1 нче китапта кыскача гына Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы тарихы, бу дәүләтләрнең хакимнәре хакында бәян ителә, Урта Идел буенда яшәүче халыкларга этномәдәни яктан тасвирлама бирелә. Рус дәүләте тарихына аерым бүлек багышлана (Пётр I реформалары уңай яктан бәяләнә). 2 нче китапта Казан төбәгенең Рус дәүләте тарафыннан яулангannан (1552) соңгы тарихы яктыртыла; татарлар арасындагы мәгърифәтчелек хәрәкәтенә аерым игътибар юнәлтелә. Тупланмада урта гасырларның шәркый (Ибне Фазлан, Ибне Баттута, Ибне Халдун, әл-Гарнати, Ибне Хәүкаль, Ибне әл-Әсир һ.б.) һәм төрки (Х.Мөслими) авторлары, рус елъязмалары, шәҗәрәләр һәм фольклор әсәрләреннән алынган мәгълүматлар кулланыла. 1989 елда кабат Казанда (кыскартылган варианты), 1998 дә Төркиядә нәшер ителә.

*Әд.:* Усманов М. Источники книги Ш.Марджани «Мустафад аль-ахбар фи ахвали Казан ва Булгар» // Очерки истории Поволжья и Приуралья. К., 1969. Вып. 2; 1972. Вып. 3; Юсупов М. Шигабутдин Марджани как историк. К., 1981; Алишев С. По следам минувшего. К., 1986.

**МӨФТИ́** (гарәп. مفت — карар чыгаручы, фәтвә бирүче), *шәригать* белгече, аның төп кагыйдәләрен аңлатучы, фәтвә (дини-хокукый күрсәтмә) рәвешендә карар чыгарырга хокуклы рухани; 2) кайсы да булса төбәк мөселманнарының Диния нәзарәте башлыгы. Беренче М.ләр хәлифәләр һәм казыйлар идарәсендә киңәшче вазифасын башкарганнар (717–20 елларда хәлифә Гомәр II идарә иткән чордан алып). Соңрак М.ләр һәрбер мөселман дәүләтендә була. Татарстан терр-ясендә М. Идел Болгарстаны чорыннан ул мәгълүм. 1788 дә Оренбург дини Мөхәммәди канун Җыены оештырылганнан соң, М. вазифасы исламда югары рухани дәрәҗә буларак кертелә. М. эчке эшләр министры тәкъдиме б-н билгеләнгән һәм үз вазифаларын казна чыгымнары хисабына үтәгән. М. вазифасын төрле чорларда М.*Хөсәенов*, Г.Габдрахманов, Г.*Баруди*, Р.*Фәхретдин* башкара. 1992 дә *Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте* оештырылганнан соң, М. булып Г.*Галиуллин*, 1998 дә — Г.*Исхаков*, 2011 дә И.Фәизов, 2013 тә К.Сәмигуллин сайлана. Ш.у. к. *Мөселман руханилары*.

**МӨФТИ́ЕВ** Гамил Габбас улы (12.1.1954, БАССРның Кушнаренко р-ны Иске Тукмаклы а.), икътисадчы-географ, икътисад фән. д-ры (2001). 1977 елда Башкорт ун-тын тәмамлый. 1973–74 тә Кушнаренко р-ны Рәсмәкәй урта мәктәбендә геогр. укыта. 1977–84 тә СССР ФАнең Башкорт ф-лында икътисади тикшеренүләр бүлегендә, 1984–93 тә РФА Уфа гыйльми үзәгенең Икътисад һәм социол. ин-тында эшли. 1993–97 дә БРның Конъюнктура һәм маркетингны өйрәнү үзәге директоры (Уфа ш.). 1998–2002 дә Мәскәү коммерция ун-тының Уфа ин-тында, проректор (1999 дан), ректор (2001 дән). 2002 дән Россия сәүдә-сәнәгать ун-тының Уфа ин-ты директоры. Хезмәтләре сәүдәне, бизнес һәм эшмәкәрлекне үстерү һәм көйләү стратегиясе мәсьәләләренә карый. М. тарафыннан базарны һәм җитештерү средстволарын көйләүнең институциональ нигезләре һәм механизмнары эшләнә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Проблемы развития рыночных отношений и конкурентно-рыночных механизмов. М., 1991; Стратегия развития торговли, бизнеса и малого предпринимательства. Уфа, 2001; Социально-экономическое прогнозирование развития территориальных систем. Екатеринбург, 2002; Интернет-торговля. Уфа, 2003.

**МӨХӘММӘ́Д** (محمد) (570, Мәккә ш. — 632, Мәдинә ш.), ислам дине буенча *Аллаһның* пәйгамбәре һәм аның аша *Коръәнне* кешелек дөньясына тапшырган рәсүле; Гарәбстанда беренче мөселман өммәтенә һәм беренче ислам дәүләтенә нигез салучы. Аның шәхси тормышын һәм иҗтимагый эшчәнлеген үз күзләре б-н күрүчеләрнең күрсәтүләре, пәйгамбәрнең тормыш юлы (сира), әйткән сүзләре һәм кылган гамәлләре турында риваятьләр (*хәдисләр*), Коръән шәрехләре (*тәфсире*) пәйгамбәр турында мәгълүматлар чыганагы булып тора. М. — бик үк бай булмаган, ләкин Мәккә шәһәре аксөякләренә якын торган Корәеш кабиләсенең Һашим нәселеннән чыккан тарихи шәхес; аның атасы Габдулла — улы туганчы ук, анасы Әминә аңа алты яшь вакытта вафат була. М. сигез яшенә кадәр Габделмоталлиб бабасында, аннары әтисе б-н бертуган агасы Әбү Талибта тәрбияләнә. Көтү көтә; бик яшьли сәүдә кәрваннары б-н ерак сәфәргә йөри. Соңрак Мәккәдәге бай тол хатын — Һәвәйлид кызы Хәдичәгә хезмәткә керә; 25 яшендә аңа өйләнә. Аларның җиде баласы: өч ул (Касыйм, Габдулла, Таһир — барысы да сабый чакларында вафат булалар) һәм дүрт кыз (Зәйнәп, Рокыя, Өммегөлсем һәм Фатыйма) туа. Гарәбстанга һәм Сүриягә сәүдә эшләре б-н сәфәрләре вакытында кәрвансарайларда христиан монахлары б-н әңгәмәләр кора; яһүди-христиан монотеизмы нигезләре, бер илаһка иман китергән, тәкъва яшәү рәвеше алып барган гарәп хәнифләрнең карашлары б-н таныша. Риваятьләр буенча, М. эштән бушаган чакларында гел ялгызы калырга омтыла. Еш кына Мәккә янындагы Хира тавы мәгарәсендә уйланып утыра. Шулай мәгарәдә ялгызы утырган көннәрнең берсендә, якынча 609 елның (яки 610 ның) рамазан аенда, аңа шәүләләр күренә, тавышлар ишетелә башлый: янына *Җәбраил* фәрештә (Библиядәге — Гавриил) килә һәм М.кә Аллаһ тарафыннан рәсүллек һәм пәйгамбәрлек вазифалары йөкләтелүен, кешеләргә Аллаһның әмерләрен җиткерергә тиеш булачагын хәбәр итә. М. күктән иңгән вәхиләрнең хаклыгына ышана һәм бераздан, иске мәҗүси инануларны ачыктан-ачык кире кагып, *исламга* үгетли башлый. М.нең Аллаһның бөеклеге, үлгәннәрнең Кыямәт көнендә кабат тереләчәге һәм гөнаһ кылганнарны Тәмуг газабы көтәчәге турындагы беренче вәгазьләрен мәҗүси мәккәлеләр, җирле сәүдә башында торучылар ачыктан-ачык дошманлык б-н каршы алалар, шуңа күрә ул 622 нең 16 июлендә бер төркем тарафдарлары б-н Мәккәдән Ясрибкә (соңрак Мәдинә ш.) китәргә мәҗбүр була; шунда урнаша (к. *Һиҗрәт*). Мәдинәдә тумыштан сөйләү осталыгына ия булган пәйгамбәрнең фикердәшләре көннән-көн арта бара һәм тиздән ул гади вәгазьчедән ислам динен кабул иткән өммәт җитәкчесе булып өлгерә, аның йогынтысы шәһәрдә сәяси-дини төсмер ала. Биредә ул беренче мәчет сала, Кәгъбәне яңа диннең иң мөкатдәс урыны дип игълан итә, исламның төп принципларын халык арасында җәелдерә башлый, мөселман йолаларын, тәһарәт алу, намазга чакыру, *намаз* уку тәртипләрен кертә. 623 тән башлап мөселманнар намазны Иерусалимга түгел, бәлки *Кәгъбәгә* йөз тотып укый башлыйлар; *ураза* тоту кертелә. Бу чорда М. исламның хак дин буларак аерым роле турында хәбәр итә; ислам дине моннан элек җибәрелгән христиан һәм яһүди пәйгамбәрләрнең вәхиләрен кире какмый, аларның ислам дине б-н нигезләре уртак, әмма М.кә иңдерелгән вәхиләрдә яһүдиләр һәм христианнар бозган тәгълиматлар төзәтелеп бирелә. Шуңа күрә М. — барлык «пәйгамбәрләрнең мөһере», соңгы пәйгамбәр (алар башка булмаячак). Җәмгыять әгъзалары акрынлап аны Аллаһның хак илчесе буларак кабул итә башлыйлар. Бу чорда ислам диненең иң әһәмиятле төп кагыйдәләренең берсе раслана: «Ләиләәһә иллә аллаһу Мөхәммәд әр-рәсүлулләһ» — «Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд — Аллаһның рәсүле». Шулай М. янына яңа тарафдарлар туплана. Аларның саны арта барган саен Мәккә кяфирләре б-н көрәшү, ислам йогынтысын киңәйтү, Аллаһка иман китерүчеләрне яклау мәсьәләләре алга килеп баса. 623 тән мәккәлеләр б-н кораллы бәрелешләр башлана. Шундый сугышларның берсендә М.нең башы җиңелчә яралана. 629 елда мөселман гаскәрләре Мәккәгә керә. Шәһәрне буйсындыру бөтен Гарәбстанда М.нең йогынтысы көчәюгә китерә; 628 дән Мәдинә һәм Мәккә шәһәрләре б-н күрше терр-яләр, ш.у. Византия һәм Иран хакимнәре бер-бер артлы пәйгамбәрдән ислам диненә күчәргә тәкъдим иткән хатлар алалар; тәкъдим еш кына бу өлкәгә хәрби мөселман гаскәре яулары б-н бергә үрелеп бара. М., Гарәбстанның шактый өлешендә үз хакимиятен урнаштырып, 630–31 дә мөселманнарның дини һәм сәяси җитәкчесе генә түгел, яңа барлыкка килгән ислам дәүләтенең башлыгы да була. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Мәдинәдә яши. 630 да Кәгъбә янында Аллаһы Тәгаләгә табыну өчен Мәккәгә хаҗ кыла; 632 дә яңадан шунда китә, бу аның изге җиргә соңгы тапкыр баруы була. М. 632 нең июнендә (яки июлендә), аз гына авырганнан соң, 62 яшендә вафат була. Мәдинә шәһәренең Пәйгамбәр мәчетендә җирләнә.

Риваятьләр буенча, аның төрле кабиләләрдән, ыру, катлаулардан 9 хатыны булган (кайбер мәгълүматлар буенча — 11), никахлары аңа әлеге җәмгыятьләр б-н элемтәләрне ныгытырга ярдәм иткән; вафатыннан соң 9 хатыны кала. Кайбер илаһият галимнәре язганча, «алар аның б-н янәшә булдылар һәм шул сәбәпле дә барлык мөселманнарның аналары булып исәпләнәләр (Кыямәт көненәчә)». М.нең дүрт кызының берсе — Фатыйма

гына исән була; соңрак ул туганнан туганы һәм этисенең дусты Гали бине Әбү Талибка кияүгә чыга, аларның балалары һәм нәселләре — мөселман дөньясындагы «пәйгамбәр гаиләсе»нең күпсанлы буыннарында нәсел башлыклары булып торалар. М. исламда гайре табигый зат түгел, шуңа да карамастан, аның гомере дөньяның барлык дин тотучылары өчен Аллаһ тарафыннан кешеләргә җибәрелгән хак рәсүлнең тәкъвалык образы булып кабул ителә. М.нең вафатыннан соң мөселман җәмәгате б-н аның иң тугры сәхабәләре — *хәлифәләр* җитәкчелек итә. Беренче хәлифә — М.нең иң якын көрәштәшләреннән берсе — Әбү Бәкер була. 610–632 дә пәйгамбәргә иңдерелгән илаһи вәхиләр, М.нең укымышлы шәкертләре тарафыннан язып алынган вәгазьләре һәм аның эшен беренче дәвам иттерүчеләрнең истәлекләре буенча мөселманнарның изге китабы — Коръән тексты төзелә. Мәдинәдә М. пәйгамбәр җирләнгән урын мөселманнар өчен икенче (Мәккәдәге Кәгъбәдән соң) изге җир һәм хаҗ кылу урыны булып исәпләнә.

*Әд.:* Аль-Муба-ракфури Сафи-ар Рахман (Мухаммад, да благословит его Аллах и приветствует). М., 2000; Хишам И. Жизнеописания пророка Мухаммада. М., 2003; Гюлен М.Ф. Пророк Мухаммад — венец рода человеческого: В 2 т. М., 2004; Махмутов М.И. Мир ислама. Прошлое и настоящее. К., 2006; Сейид Хусейн Наср. Мухаммед — Посланник Аллаха. М., 2006; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1897. Т. 20; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**МӨХӘММӘ́Д СОЛТА́Н** (Мөхәммәдсолтан) (?-1380 елдан соң), Болгар әмирлеге идарәчесе (1370 елдан). Җүчи нәселеннән булуы ихтимал. Суздаль кенәзе Борис Константинович гаскәрләре һәм Алтын Урда илчесе Әчи Хуҗа (Мамай әмир вәкиле) тарафыннан тәхеткә утыртыла. *Хәсән* әмир б-н бергәләшеп идарә итә. Мамай сәясәтен яклый. Бу, үз чиратында, шул чорда Мамай Урдасы б-н каршылыкта торган Мәскәү кенәзе Дмитрий Ивановичның (Донской) канәгатьсезлеген уята. 1376 да Мәскәү гаскәре Болгарны камап ала һәм М. б-н Хәсәнне Мәскәүгә буйсынулы булуларын танырга мәҗбүр итә. Туктамыш хан идарә иткән чакта тәхеттән төшерелгән булуы ихтимал.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2000; Исхаков Д.М.; Измайлов И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨХӘММӘ́Д ТАЙБУГА́** (?-1495 тән соң), Себер ханы (1495 тән). Фаразланганча, Идегәй варисларының берсе тарафыннан нигезләнгән тайбугыйлар нәселе вәкиле. Себер ханлыгы олысларының берсенең идарәчесе (тайбуга), ихтимал, мангытлар ыругы башлыгы була. 1495 елда Себер олысбәкләренең *Ибакъ (Айбак) ханга* каршы фетнәсен җитәкли; ул үтерелгәннән соң үзен идарәче дип игълан итә һәм үз нәселен нигезли. Ул идарә иткән заманда Себер ханлыгы ныгый, аның чикләре Урал аръягы һәм Обь алды төбәкләренә кадәр җәелә, ханлыкның башкаласы Чыңгы-Турадан Кашлыкка күчерелә.

*Әд.:* Миллер Г.Ф. История Сибири. М.–Л., 1937. Т. 1; История Сибири. Л., 1968. Т. 1; Файзрахманов Г.Л. История сибирских татар (с древнейших времён до начала XX в.). К., 2002; Исхаков Д.М. Введение в историю Сибирского ханства. К., 2006.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨХӘММӘДӘМИ́Н** (1469–1518), Казан ханы (1487–95, 1502–18). *Ибраһим хан* һәм *Нурсолтан бикә* улы. Тәхеткә Мәскәү бөек кенәзе Иван III тарафыннан тәхеткә утыртыла. 1485 елда, хан тәхетенә ирешү өчен, үзенең абыйсы Илһам б-н каршылыкка керә. Казанны рус гаскәрләре камап алганнан һәм Илһам хан тәхеттән төшерелгәннән соң, Казан ханлыгы хакимиятенә килә (1487). М. вакытында Казан ханлыгында *Мәскәү протектораты* урнаша. Мәскәүгә бәйлелек татар аксөякләренең хәлен кыенлаштыра. Карачыбәкләрнең фетнәсе нәтиҗәсендә, 1495 тә М. тәхеттән төшерелә, Себер ханзадәсе Мамык хан дип игълан ителә. Мамык бәреп төшерелгәннән соң, Казан карачыбәкләре яңадан Мәскәү протекторатын таныйлар һәм тәхеткә М.нең бертуганы Габделлатыйфны утырталар. 1502 дә Мәскәү гаскәрләре ярдәме б-н М. яңадан Казан ханы тәхетенә күтәрелә. Хакимияткә килгәч, ул Мәскәүгә карата сәясәтен кискен үзгәртә, 1505–07 дә Рус дәүләтенә каршы сугыш алып бара, Кырым һәм Литва б-н бергәләп, русларга каршы коалиция оештырырга омтылыш ясый. 1507 дә Рус дәүләте б-н тигез хокуклылык һәм күршеләрчә дуслык шартларында солых килешүе төзи. Әлеге килешү 1508, 1512, 1516 елларда яңартыла. М. җирдән файдалану буенча берничә реформа үткәрә. Ул идарә иткән чорда Казанда мәчетләр төзелеше һәм ныгытмаларны яңарту бара. Үзара низаглар һәм Мәскәү б-н сугыш куркынычы аны 1518 дә Василий III б-н солых килешүе төзүгә һәм Касыйм ханы Шаһгалинең Казан тәхетенә хокукын танута этәрә.

*Әд.:* Фәхретдин Р. Казан ханнары. К., 1995; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: Межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995; Исхаков Д.М., Измайлов И.Л. Введение в историю Казанского ханства. К., 2005.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨХӘММӘДӘМИ́Н** Гомәр угылы (18 йөзнең 2 нче яртысы), язучы, Казан губернасы Иске Кишет авылы мәчете имам-хатибы. 1783 тә Гарәбстандагы изге урыннарга сәяхәт кыла. Бу турыда шартлы исем астында чыккан, танылган «Мөхәммәдәмин сәяхәтнамәсе» китабын язып калдыра. Алар «Ике хаҗиның рихләтнамәләре...» (1862) исемле җыентыкка кергән. М. әсәрләренең исемнәре теркәлгән 4 кульязма мәгълүм (Казан һәм С.-Петербург архивлары һәм китапханәләрендә сакланалар).

*Әд.:* Алеева А.Х. Списки «Мөхәммәд-Әмин сәяхәтнамәсе» и живая народная речь в её языковой структуре // Истоки татарского литературного языка. К., 1988.

**МӨХӘММӘДӘМИ́Н әл-БОЛГАРИ́** (15 йөз), шәех, болгар галиме. Болгар шәһәрендә яши. Идел буе Болгар дәүләтендә Нәкышбәндийә борадәрлеге вәкиле. Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы идарәчеләренең остазы була. 1468 елда Болгарда «Шифа» (1446) китабына аңлатмалар төзи. 1473 тә Багдадта икенче аңлатмасын яза. 1483 тә «Тәкъвалык юлы, яки Болгар шәехләренең тәкъва гамәлләре» дигән китабын язып төгәлли, ул Идел болгарлары тарихы буенча төп чыганакларның берсе булып тора.

*Әд.:* Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: Духовная культура. К., 1990; Хамид Альгар: Последний великий накшбандийский шейх Волго-Уральского региона // Татарстан. 1995. № 2.

**МӨХӘММӘДӘМИ́Н әс-САБАВЫ́Й** (? — 1833), дин эшлеклесе, педагог. Г.*Курсави* шәкерте. Казан губернасының, Казан өязе Наласа авылы мәчетенең имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе. 1826 елдан мөселман Шәрекъ илләре буйлап сәяхәт итә, Каһирә ун-тында фарсы телен укыта.

**МӨХӘММӘДБҮЛӘ́К** (1350 тирәсе — 1380 нән соң), Алтын Урда ханы (1369 елдан), Мамай әмир тәхеткә утырта. Мамай тарафыннан Алтын Урданың үзәге Кырымда булган көнбатыш өлеше б-н идарә итәргә куела. 1372–73 тә Сарай әл-Мәхрусә тәхетендә. Урдада, Кырымда һәм Маҗарда акчалар суктыра. 1379 ның җәендә Митяйга (митрополит Михаилга) тарханлык ярлыгы тапшыра. Кайбер тарихчылар (мәс., А.П.Кучкин) 1375/76 тирәсендә М. Мамай тарафыннан хакимияттән читләштерелгән дип, башкалары (А.П.Григорьев, А.А.Горский) ул Туктамыш хан хакимиятне үз кулына алганга кадәр (1380) хан булып калган, дип исәплиләр.


*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Прохоров Г.М. Повесть о Митяе. М., 1978; Куликовская битва. М., 1980; Мухаммадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Горский А.А. Москва и Орда. М., 2000; Григорьев А.П. Сборник ханских ярлыков русским митрополитам. СПб., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨХӘММӘДГАЛИ́** бине Минһаҗетдин (19 йөзнең 2 нче яртысы), хаттат. М.Чиркова басмаханәсендә басылган (1896), югары



Мөхәммәдгали бине Минһаҗетдин. «Камиллекләр мәҗмугасы» шәмаиле. Кәгазь, литография. М.Чиркова басмаханәсе. 1896. ТР Милли музее.


Ринат С. Мөхәммәдиев.


Х.Н.Мөхәммәдиев.

дәрәҗә график осталык б-н эшләнгән аклы-каралы «Камиллекләр тупланмасы» литографик *шәмаиле* авторы. Шәмаил битенең барлык мәйданын (38х50 *см*) каллиграфик язулар били: өске, сакраль өлешендә «әл-Көрси» аяте, «әл-Фатиха» сүрәсе, алтыпочмаклы йолдызлык рәвешендә мәгарәдә яшәгән легендар затларның исемнәре, изге мөһер сурәте урын алган. Шәмаилнең уртасында — кара квадрат эчендә Мөхәммәд пәйгамбәр хакында бәян ителә. Композициягә органик рәвештә үсемлек орнаменты мотивлары һәм ислам символлары сурәтләре кертелгән. Пәйгамбәрне тасвирлау стиле М. шәмаилен хилйә жанры б-н якынайта, ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003.

**МӨХӘММӘДГӘРӘ́ЕВ** Венер Мансур улы (22.12.1961, Уфа ш.), РФ Герое (4.6.2008), 1 нче класслы очучы-сынаучы (1997), капитан. Сызрань Югары очучылар хәрби авиация уч-щесен (1983), СССР Авиация сәнәгате министрлыгының очучы-сынаучылар мәктәбен (1989) тәмамлый. 1979 елдан Совет Армиясендә. СССР Хәрби Һава Көчләре сугышчан частьларында, Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә хезмәт итә. 1986–87 елларда совет гаскәрләренең Әфганстан Респ-касындагы чикләнгән контингенты составында, Ми-24 вертолёты командиры, 143 хәрби очыш ясый. 1988 дән запаста. 1989 дан М.М.Громов исем. очучылар тикшеренү ин-тында очу-сынау эшендә. Z-11 вертолёты, Ка-50 көч җайланмасы, Ми-34, Ка-32, АНСАТ һ.б. гражданнар һәм хәрби вертолётларына сынаулар уздыра. Герой исеменә авиация техникасы сынауларын гомеренә куркыныч янаган шартларда үткәргәндәге батырлыгы һәм фидакарьлеге өчен лаек була. Мәскәү өлкәсенең Жуковский шәһәрендә яши. Кызыл Йолдыз, Батырлык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И в а н о в А.А. Герои Российской Федерации = Россия Федерациясе Геройлары. К., 2012, 105–106 бб.

**МӨХӘММӘДГӘРӘ́Й ХАН** (1465–1523), Кырым ханы (1515–23). *Миңлегәрәй ханның* улы. Әтисе исән чакта калга дәрәҗәсенә ия һәм тәхетнең чын идарәчесе була. Бөек Мәскәү кенәзлеге сәясәте яклы әтисеннән аермалы буларак, русларга каршы сәясәт алып бара, Мәскәүгә хәрби һәм сәяси яктан басым ясый, Речь Посполита б-н хезмәттәшлек итә (1516, 1520). М.х. Кырым ханнары идарәчелегендә Алтын Урданың бөтенлеген торгызырга тырыша. 1521 елда Казан ханлыгы тәхетенә үзенең бертуганы Сәхибгәрәйне утыртырга ярдәм итә һәм аның б-н бергә Кырым һәм Казаннан Мәскәүгә уңышлы яу оештыра. М.х. тарафыннан тышкы сәясәтне билгеләү Госманлылар дәүләте хөкүмәтенә ошамый, М.х.га каршы фетнә оештырыла. Төньяк Кавказда һәм Дон буенда өстенлек алыр өчен Әстерхан ханлыгы б-н бертуктаусыз сугыш алып бара. 1523 нең көзендә Әстерханны яулап ала, әмма бертуганнарының фетнәсе һәм нугайларның хыянәте М.х.ның һәм аның улы Баһадиргәрәйнең үлеменә китерә.

Әд. к. *Миңлегәрәй хан* мәкаләсе.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Әзһәр Гатаулла улы (8.9.1933, БАССРның Илеш р-ны Сеңрән а.), тарихчы, нумизмат, тарих фән. д-ры (1992), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1963). 1965 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (бүленеп: 1970–74 тә Башкорт, 1977 дән Казан ун-тларының совет чорына кадәр СССР тарихы кафедрасында), 1988 дән археол. һәм этнография кафедрасында, проф. (1990), 1994 тән каф. мөдире. 30 меңнән артык акча һәм борынгы акча төрләрен өйрәнә, 6–15 йөзләрдә Идел буенда һәм Урал алдында акча әйләнешенең чорларга бүленешен эшли, дәүләт күләмендә үткәрелгән 10 төрле акча авырлыгы реформасын ачыклый. М. Харәзем акчаларына таянып төзегән Туран алфавиты Идел буенда һәм Урал алдында табылган б.э.к. 2 йөз — б.э. 8 йөзе акчаларындагы, ш.у. кыйммәтле металлардан эшләнгән савытлардагы һәм бизәнү әйберләрендәге һун язуларын укырга мөмкинлек тудыра. Әстерхан һәм Волгоград өлкәләрендәге Селитренный һәм Царёво шәһәрлекләре, Иске Казан, Казан Кремле һ.б. археол. истәлекләрне казып өйрәнүдә катнаша. Хезмәтләре Идел буе Болгары һәм Алтын Урда чоры акчаларын өйрәнүгә карый. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2008).

Х е з м.: Борынгы хазар һәм болгар-татар акчалары. К., 1986; Һуннар һәм Туран язмалары. К., 2000; Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; Древние монеты Поволжья. К., 1990; Общая и тюрко-татарская нумизматика. К., 2003; Древние монеты Казани. К., 2005.

*Әд.:* Тюркологи современного Татарстана. М., 1997; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Мөгафә Габделбәр улы (7.1.1927, хәзер Свердловск өлкәсенең Түбән Серга р-ны Васькино а. — 4.6.1995, Казан), тел галиме, лексикография белгече, филол. фән канд. (1971). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Пермь өлкәсенең Барда авылында район халык мәгарифе бүлеге инспекторы булып эшли. 1958 елдан кабат Казанда. 1961 дән СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты фәнни хезмәткәре. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (Т. 1–3, 1977–81) төзүдә катнаша һәм мөхәррире була, русча-татарча (1984), татарча-русча (1988) сүзлекләр, сәүдә хезмәткәрләренең кыскача русча-татарча сүзлеген (1995) төзүчеләрнең берсе. «Ш.Камал прозасы теле» (1991) монографиясе авторы. Хезмәтләре татар, башкорт телләре лексикасы һәм морфологиясенә карый.

Х е з м.: Татар телендә бәйлек сүзләр турында // Вопросы лексикологии и лексикографии. К., 1976; Ж.Вәлидинең лингвистик язмасы // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. К., 1988; Татар проза телен үстерүдә фразеологиянең роле (XIX йөз башы — XX йөз ахыры). К., 1993; Фразеология башкирского языка // Советская тюркология. 1977. № 1.

*Әд.:* Г а н и е в Ф., Г а з и з о в а Ф. Фидакарь галим // Проблемы лексикологии и лексикографии татарского языка. К., 1995. Вып. 2.

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Рамил Сафа улы (6.8.1956, Мамадыш р-ны Кече Кирмән а.), геофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ. нефтьчесе (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1978), Эвенкия нефть разведкасы экспедициясендә, «Енисейнефтегазгеология» геол. җитештерү берләшмәсендә эшли. 1982 елдан Әлмәт геофизика эшләре идарәсендә, идарә башлыгы (1999 дан). 2005 тән «Татнефтегеофизика» АҖнең ген. директоры урынбасары — промысел геофизикасы директоры. М. башлангычында Татарстанның төп чыганакларында кудыру скважиналарын геофизик тикшерүләр киң җәелә, эчәргә яраклы су катламнары арасында экологик шартлар мониторингы өчен контактсыз инфракызыл термометрия кертелә башлый (ТР Дәүләт бүләге). Горизонталь скважиналарны геофизик тикшерү методикасын камилләштерә.

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Ринат Сафа улы (10.12.1948, Мамадыш р-ны Кече Кирмән а.), язучы, әдәбият белгече, әдәби тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, ТАССР, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1986, 2010), филол. фән. канд. (1979). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1970–73 елларда ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар комтында телевизион тапшырулар мөхәррире, 1976–86 да «Казан утлары» ж-лында бүлек мөхәррире һәм баш мөхәррир урынбасары. 1986–89 да Татарстан китап нәшрияты директоры, 1989–99 да Татарстан Язучылар берлеге рәисе, бер үк вакытта, 1990–93 тә, РСФСР ЮСның мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясе рәисе. 2000 нән Мәскәүдә: Россия һәм БДБ илләре язучыларының халыкара берләшмәсе рәисе урынбасары. 2005 тән «Татар дөньясы» («Татарский мир») г-тасы баш мөхәррире. 2010 нан Мәскәүдә «Заман» нәшрият йортын гамәлгә куючы, аның баш мөхәррире. Әдәбиятка 1970 еллар башында Х.Туфан, С.Хәким, Н.Арсланов, Ш.Галиев, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Гәрәй Рәхим, Ә.Еники, А.Расих, А.Гыйләҗев, М.Мәһдиев кебек күренекле шагыйрьләр һәм прозаиклар, Ж.Вәлиди, Г.Кәрам, Г.Ибраһимов, Ф.Сәйфи-Казанлы кебек галим һәм фикер ияләре турында әдәби очерклар, иҗат портретлары, тәнкыйть мәкаләләре б-н килеп керә. Һәр язучының иҗат үзенчәлеген аерып күрсәтергә тырышып язылган, тирән фәнни анализга корылган бу хезмәтләре «Әгәр без

янмасак...», (1980); «Проблемы формирования татарской литературной критики 1905–1917», (1982); «Якутлар табыладыр вакыт белән» (1983) җыентыкларында тупланa. Әдәбият сөючеләр арасында М. үзенең «Беренче умырзая» (1983; рус теленә тәрҗемәсе «Первый подснежник», М., 1987), «Ак кыялар турында хыял» (1995) исемле лирик повестьлары, авыл проблемаларын яктырткан «Истәлек өчен — Гыйлемханга» әсәре (1986; шул исемдә нәфис телефильм, 1995) б-н танылa. Автор авылның әхлагы югалу, кешеләрнең табигатькә, җиргә битарафлана баруларының сәбәпләре турында уйлана. 1989 да «Кенәри — читлек кошы» социаль-психол. романын (рус теленә тәрҗемәсе «Львы и канарейки, или Невинные забавы мафии», М., 1992) бастыра. Шәхеснең әхлаксызлык сазлыгына бата баруын, деградациясен драматик вакыйгалар аша чагылдырган бу романы б-н М. 1990 нчы еллардагы татар прозасының үзенчәлекле тәнкыйди бер юнәлешен башлап җибәрә. М.нең иң зур иҗади уңышларыннан берсе — сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе М.Солтангалиевкә багышланган «Сират күпере» романы (1992; рус теленә тәрҗемәсе «Мост над адом», М., 1996; ТР-ның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1993; Төркиянең әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге халыкара бүләге, 1995; Азия һәм Африка илләренең «Алтын лотос» бүләге, 1995; Андрей Платонов исем. халыкара бүләк, 1996). М. ш.у. «Утлы таба өстендә» (1995; русчага тәрҗемәсе «На раскалённой сковороде», М.,1997; «Крушение» исеме б-н тулыландырган варианты, М., 2001; 5 басма 2005; М.А.Шолохов исем. халыкара әдәби бүләк, 2002) документаль повесте Россия тарихында булып узган 1991 нең августы һәм 1993 нең октябре вакыйгаларын искә төшерә. «Алланың кашка тәкәсе» романы (М., 2003; рус теленә тәрҗемәсе «Пуп земли», М., 2007) хакимият органнарында закон бозу, ришвәтчелек, азгынлык кебек күренешләрне фаш итүче, кискен конфликтка корылган әсәр. «Кош булып очар идем» романында (М., 2007; русчага тәрҗемәсе «Взлететь бы мне птицей», М., 2008) очучы булырга хыялланган малай язмышы үзәккә алына. Заман проблемаларын ачыктан-ачык күрсәткән сайланма әсәрләре «Үз кешеләр» (М., 2011; рус теленә тәрҗемәсе «Свои люди», М., 2012) җыентыгына кертелгән. Язучының романнары һәм повестьлары дистәдән артык чит илләрдә төрек, кытай, инглиз, гарәп, болгар, македон һ.б. телләрдә аерым китап буларак дөнья күрә. 1990–93 тә РФ ЮС, 1995–99 да ТР халык депутаты. Татарларның Мәскәүдәге милли-мәдәни мохтарияте рәисе (2014 тән).

*Әд.:* Г а л и у л л и н Т. Сәфәр чыгар аты бар // Мирас. 1998. № 12; Г а л и м у л л и н Ф. Кече Кирмәннең олы Ринаты // Казан утлары. 1998. № 12; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МӨХӘММӘДИ́ЕВ** Хәмзә Нурсәлим улы (2.1.1907, хәзер Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе, Улан р-ны Таргын а. — 8.9.1997, Новосибирск ш.), Сов. Союзы Герое (27.8.1943), гв. өлкән сержанты. Кемерово өлкәсендә эшли. 1928–29 һәм 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 205 нче гв. укчы полкында взвод командиры ярдәмчесе (13 нче армиянең 70 нче гв. укчы дивизиясе). Үзәк, Воронеж, 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы буенда барган сугышларда (икесе дә — 1943), Украинаның Уңъяк яры җирләрен һәм Польшаны азат итүдә, Берлин һәм Прага (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша, 1943 нең июлендә Курск сугышында батырлык күрсәтә: взвод командиры һәлак булганнан соң, командирлык вазифасын үз өстенә ала; взвод 10 көн чамасы дошман контрһөҗүмнәренә каршы торып 27 танкны сафтан чыгара; ш.и. М. тарафыннан 8 танк юк ителә. 1945 тә демобилизацияләнә. Прокопьевск шәһәрендә (Кемерово өлкәсе) шахтада забойчы булып, 1965 тән Новосибирскида 19 нчы тимер юл машина станциясендә эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Бесстрашные. А.-А., 1964; Звёзды доблести ратной. Новосиб., 1986.

*М.З.Хәбибуллин.*


**«МӨХӘММӘДИЯ́»**, Казандагы мәдрәсә. 1882 елда Галимҗан *Баруди* тарафыннан З.*Рәсүлев* ярдәме б-н ачыла. Хәйрияче М.И.*Галиев* исеме б-н атала. Икенче мәдрәсә булып санала, ә 1909 дан *Галиев мәчетендә* бердәнбер мәхәллә мәдрәсәсе (1810 еллардан Сәгыйтов мәдрәсәсе дә эшләгән була). Эшчәнлегенең беренче елларыннан мәдрәсә укыту дәрәҗәсенең югары булуы б-н аерылып тора. Г.Баруди Төркия, Мисыр һәм Мәккәгә барып кайтканнан соң, 1886–91 дә укыту процессы тулысынча үзгәртелә. «М.» Россиядә рәсми төстә *җәдитчелек* нигезендә эшләгән беренче мәдрәсә була. 20 йөз башына тотрыклыланган укыту системасы башлангычтан югары белемгә кадәр тулы курсны үз эченә ала: ибтидаи (башлангыч мәктәп, 6 ел), рөшдия (4 ел), игъдадия (3 ел), галия (якынча 3 ел). Башлангыч сыйныф укучылары Казанның татар бистәләреннән ир балалар була, өлкән сыйныфларга элек башка мәдрәсәләрдә белем алган яшүсмерләр укырга килә.

Дәресләр сыйныф-дәрес системасы буенча төзелә. Гарәп, фарсы телләре, Коръән, тәфсир, хәдисләр, фикъһ һ.б. дини фәннәр Г.Баруди төзегән яңа алымлы уку дәреслекләре (ярдәмлекләре) буенча өйрәнелә. Уку вакытының яртысы дөньяви фәннәргә (матем., геогр., табигать белеме, мед. һәм гигиена, гомуми тарих, Россия һәм татар халкы тарихы, педагогика) бирелә. Россия мәдрәсәсендә беренче булып татар теле фән буларак укытыла, ш.у. рус телен укытуга зур игътибар бирелә. Укытучылар арасында — Г.С.*Гобәйдуллин*, Б.Шәрәф, Ш.Шәрәф, З.*Солтан*, Ә.Р.*Мостафин*, К.*Тәрҗеман*, З.Ш.*Шакиров*. Медицинаны — Ә.Б.*Терегулов*, хокукны — С.Ш.*Алкин*, сәясәт тарихын — Й.Акчура укыта. 1908–12 дә, Г.Баруди сөргендә һәм чит илдә булганда, һәм 1918 дән мәдрәсәне аның тугāны Габдрахман *Баруди* җитәкли, дәресләр 1921 гә кадәр дәвам итә. «М.» Идел-Урал төбәгендә иң зур мәдрәсә була, 20 йөз башына укучылар саны 800 дән арта. «М.»нең программалары һәм уку процессын оештыру «Буби», «Хөсәения», «Галия» һ.б. шундый күп кенә җәдиди мәдрәсәләр өчен үрнәк булып тора. Мәдрәсәне тәмамлаучыларның күбесе имам-хатип һәм мөгаллим булып китә, алар мәдрәсә һәм мәктәпләргә яңа алым б-н укытуны кертәләр. 1907 дә «М.» җирлегендә мөгаллимнәр өчен җәйге курслар оештырыла. Югары дәрәҗәдәге белемнәре аларга, гимназия курслары өчен имтихан тапшырып, югары уку йортына керергә мөмкинлек бирә. Совет чорында мәдрәсәне тәмамлаучыларның күбесе мәктәпләрдә эшләүләрен дәвам итә, М. дипломы урта махсус пед. уку йортлары дипломына тәңгәлләштерелә.

Биналар төзү, җиһазлар һәм уку ярдәмлекләре б-н тәэмин итүдә М.М.Галикәев, А.Я.Сәйдәшев, М.И.*Утәмишев*, А.Хөсәенов һ.б булыша. 1906–08 дә һәм 1913–17 дә «М.» каршында «*әд-Дин вә әл-Әдәб*» исемле пед. ж-л чыгарыла. 1903 тән Ф.Әмирхан җитәкчелегендә әдәбият түгәрәге эшли, кулъязма ж-лар чыгарыла, пьесалар куела. Шәкертләр 1905–07 елгы рев-ция вакыйгаларында актив катнашалар, «*Берек*» һәм «*әл-Ислах*» җәмгыятьләренең нигезен тәшкил итәләр. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында: М.С.*Алмаев*, Ф.З.*Әмирхан*, И.З.*Әмирханов*, Х.*Бәдигый*, З.Ш.*Бәшири*, Х.М.*Биккинин*, Ф.З.*Бурнаш*, С.Г.*Вахидов*, С.Х.*Габәши*, М.*Гафури*, М.*Дулат-Али*, Н.*Исәнбәт*, А.А.*Исхак*, Камал I, Камал II, Г.Г.*Камал*, Г.Ш.*Нугайбәк*, Г.М.*Рәхим*, С.З.*Сәйдәшев*, З.*Солтанов*, К.Г.*Тинчурин*, Ф.К.*Туйкин*, М.*Укмаси*, Б.И.*Урманче*, З.Ш.*Шакиров*, Г.Ш.*Шәрәф*, К.Л.*Якубов*, Х.М.*Ямашев*.

Яңадан 1993 тә шул ук биналар комплексында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең югары мөселман мәдрәсәсе буларак ачыла. Ирләр һәм хатын-кызлар өчен көндезге, кич-





«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе. 1. Мәдрәсәдә дәрес вакыты. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Хәзерге күренеше.

ке, читтән торып уку бүлекләре эшли. 2014 елга укучылар саны 1093 кеше (ш.и. 182 көндезге бүлектә); укытучылар коллективында 23 кеше эшли.

Беренче бер катлы бина 1883 тә сәүдәгәр М.И.Галиев акчасына төзелгән була, 1885 тә — 2 нче каты, 1886 да — 3 нче, 1901 дә өч катлы өстәмә бина төзелә, 1909 да Сәгыйтов мәдрәсәсенең бер катлы бинасы «М.»гә күчә. Комплекс архит-ра истәлеге булып санала. 1995 тән Галиев мәчете «М.»нең бер өлешенә әверелә.

*Әд.:* Ә м и р х а н о в Р. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. К., 1992; В а л и д о в Д. Очерк истории образованности и литературы татар. К., 1998; Ю с у п о в М.Х. Галимджан Баруди. К., 2003.

**«МӨХӘММӘДИЯ́»**, төрек дини-шигъри әдәбияты ядкәре. Авторы — *Чәләби* Мөхәммәд (? — 1451). Ике өлештән тора. Беренче өлеше — Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышын сурәтләү жанрында (сира), икенчесе — «популяр» илаһият үрнәкләре рухында (Кыямәт көне, аның алдыннан булган вакыйгалар, ахирәт тормышы һ.б. тасвирлы итеп сурәтләнә). Китап татарлар арасында киң таралган; кадими мәдрәсәләрдә дәреслек итеп файдаланылган. 1845 елдан Казанда берничә тапкыр нәшер ителгән.

**МӨХӘММӘДКӘРИ́М** әл-Болгари (?, Идел буе — 19 йөз уртасы), тел галиме, лексикография белгече. Бохарада укый. Якынча 12 мең төрки сүзне (тәрҗемәсе б-н) үз эченә алган «Лөгате төрки вә фарсы вә гарәби» («Төрки, фарсы, гарәп сүзлеге», якынча 18 йөз ахыры) төзи; кереш өлештә М. сүзлекнең гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнүче татарлар өчен эшләнүен билгеләп үтә. Кульязмасы Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. Фәнни китапханәсендә саклана. Аны өйрәнү б-н Ә.Г.Кәримуллин һәм А.Фәтхи шөгыльләнә.

*Әд.:* К ә р и м у л л и н Ә. Төрки телләр белеме. К., 1962; Ф ә т х и А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульязмалары. К., 1968.

*В.Х.Хаков.*

**МӨХӘММӘДНӘҖИ́П** Түнтәри, к. *Түнтәри* Мөхәммәднәҗип.

**МӨХӘММӘ́ДОВ** Гомәр Габдрахман улы (22.5.1952, Казан), тренер (җиңел атлетика), РСФСРның атказ. тренеры (1990). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1974). 1974–81 елларда Казанның 101 нче мәктәбендә физкультура укыта, 1981–83 тә Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең «Комета» СКнда тренер-укытучы, 1983–92 дә Респ-ка югары спорт осталыгы мәктәбендә өлкән тренер, 1992 дән ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгының Үзәк спорт ком-тында өлкән тренер. Шәкертләре арасында Д.В.*Капустин*, И.Н.Переведенцев бар.

**МӨХӘММӘ́ДОВ** Ирек Җәүдәт улы (8.3.1960, Казан), балет артисты, педагог, балетмейстер, РСФСРның атказ. артисты (1985). 1978 елда Мәскәү акад. хореография уч-щесен (педагогы А.Прокофьев) тәмамлый. 1978–81 дә «Мәскәү классик балеты» хореография ансамбле (җитәкчеләре Н.Касаткина һәм В.Василёв) солисты, 1981–90 да



И.Ж. Мөхәммәдов.

СССРның Зур театрында балет солисты. 1990–2001 дә Лондон король балеты солисты. 2000 нән, чакырылган педагог буларак, Лондон король балетында, Англия милли балет мәктәбендә (Лондон), башка илләрнең балет труппаларында укыта. Хореография партияләре арасында: Альберт («Жизель», А.Адан), Базиль, Солор («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Дезире («Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Спартак (шул исем. балет, А.Хачатурян), Вершинин («Кышкы хыяллар», П.Чайковский музыкасы), Иван Грозный (шул исем. балет, С.Прокофьев музыкасы), Рудольф («Майерлинг», Ф.Лист музыкасы), Аполлон («Аполлон Мусагет», И.Стравинский), Сирано де Бержерак (шул исем. балет, В.Джозевс музыкасы) һ.б. М. — югары актёрлык осталыгына һәм классик биюләрне җитди башкару манерасына ия булган героик-романтик амплуадагы биюче. Байтак кына хореографик күренешләрне: П.Чайковскийның «Аккош күле» (Варшава милли балеты, 2001), Т.Хаттонның «Принц һәм хәерче» (Лондон балалар балеты, 2003), Н.Римский-Корсаков музыкасына «Испан каприччиосы» (Англия милли балет мәктәбе, Лондон, 2004), А.Хачатурянның «Спартак» (Милли балет театры, Гонконг, 2005) һ.б.ны сәхнәгә куя. 1997 дә Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә «Жизель», «Дон Кихот», «Баядерка» балетларында төп хореографик партияләр б-н чыгышлар ясый. Балет



И.Җ. М ө х ә м м ә д о в Альберт ролендә («Жизель», А. Адан). М. Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры спектакле. 1997.

артистларының 4 нче халыкара конкурсында «Гран-при» һәм Зур алтын медаль (Мәскәү, 1981), «Югары актёрлык казанышлары өчен» Л.Оливье исем. халыкара бүләк (Бөекбритания, 1987), Һ.К.Андерсен призы һәм «Дөньяның иң оста биючесе» исеме (Дания, 1988), «Бенуа де ла данс» халыкара ЮНЕСКО призы («Бенуа балеты», 1996), медаль һәм В.Нижинский исем. бүләк (Франция, 1998), Британия империясе ордены һ.б. б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ирек Мухамедов: Пусть меня запомнят принцем // Труд. 2003. №112, июнь; Ирек Мухамедов: Во мне слились две культуры — татарская и русская // Казанские истории. 2010, ноябрь.

*В.Н.Горшков.*

**МӨХӘММӘ́ДОВ** Мидәт Мингали улы (20.5.1955, Оренбург өлкәсенең Шарлык р-ны Мостафа а.), нәкышьче. Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлый (1979). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1995). М. иҗатының нигезендә татар халкының рухи мирасын тирәнтен аңлау, борынгы бабалар мәдәниятен, нәсел тамырларын ачыкларга омтылу, ислам традицияләре ята. Реалистик һәм авангард юнәлешләрдәге рәссам, табигать тәэсиреннән туган пейзажлар һәм татар мәдәниятенә хас эмоциональ һәм пластик чагылышлы образлар б-н сынландырылган символик-аллегорик композицияләр авторы. М. иҗатында үзенең нәсел-ыруы җирләнгән зират темасы — Урал



М.М. М ө х ә м м ә д о в. «Казан тракты буенда». Картон, майлы буяу. 1988. «Казан» милли мәдәният үзәге музее.

буе татарларына хас кабер ташлары формалары, шулар нигезендә мөселман символларын файдаланып ассоциатив образлар иҗат итү зур урынны биләп тора. Төп әсәрләре: «Оренбург ягы пейзажлары» сериясе (1969–90), Башкортстанның көньягы һәм Оренбург өлкәсе күренешләрен сурәтләгән этюдлары (1982–90), «Казан тракты буенда» (1988), «Бабалар каберлеге» (1989–91), «Җимерелгән мәчет» (1990), «Зират» (1991) пейзажлы этюдлары; «Бусагада», «Хат» (икесе дә — 1992), «Зират», «Сизенү», «Ирешү» (барысы да — 1993), «Үтеп баручы кыз», «Сак-Сок» (икесе дә — 1994), «Дога кылучы мөселман» (1995), «Табыну», «Тамгалар», «Тирмә» (барысы да — 1996–97) композицияләре. М. хезмәтләре арасында авылдашларының портретлары да байтак («Ана портреты», 1979; авыл әбиләре портретлары сериясе, 1979; «Хәйбул бабай», 1983; Автопортрет, 1992; «Татар хатын-кызларына багышлау», 1993; «В.Х. портреты», 1994).



М.М. М ө х ә м м ә д о в. «Башлангыч дәвер». 1992. «Шәрекъ» фондының традицион һәм заманча сәнгать галереясы. Уфа ш.

Респ-ка (Уфа ш., 1980 нән), өлкә («Яшь рәссамнар күргәзмәсе», Оренбург ш., 1981), бөтенроссия («Россиянең яшьлеге», Мәскәү, 1987) күргәзмәләрендә, «ТАТАРТ» төбәкара бөтентатар күргәзмәсендә (С.-Петербург-Казан, 1991), «Чыңгызхан» төркеме күргәзмәләрендә (Истанбул, 1994; Уфа ш., 1997; Новосибирск, Чиләбе, Мәскәү, 2007), «Сиякислун» төркем күргәзмәсендә (Уфа ш., 2001), «Алтын пайцза» проектындагы «Сульдә» перформансында (Уфа ш., 2002), «Авангард» халыкара күргәзмәсендә (Магнитогорск ш., 2005), «Күчмә төргәкләр — habar» (Әнкара, 2006; Мәскәү, 2006; Казан, 2007) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1981, 1985, 1992 (Шарлык р-ны Мостафа а.), 1993, 2006 (Уфа ш.) елларда уза. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан сәнгать музеенда (Уфа ш.), ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Казан), «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Оренбург өлкәсе Мостафа авылындагы Муса Җәлил музеенда, «Туран» милли-мәдәни үзәге фонды» ЖЧЖдә (Казан), «Шәрекъ» фондының традицион һәм заманча сәнгать галереясында (Уфа ш.), Новосибирск сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г. «ТАТАРТ» в Казани // Идель. 1992. № 1/2; Ш а г е е в а Р.Г. Новая живопись // Сююмбике. 1992. № 1; Галерея традиционного и современного искусства фонда «Восток»: Каталог. Уфа, 1997; С у в о р о в а Е. Знак Мидата // «ВХ». 2006. № 3.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӨХӘММӘ́ДОВ** Рәшит Алим улы (1.4.1956, Ульянов өлкәсенең Иске Кулатка р-ны Терешка а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2010). Ульянов а.х. ин-тының аграр ф-тын (1979), Югары партия мәктәбен (Ульянов ш., 1981) тәмамлый. 1979–91 елларда Ульянов өлкәсе Тирәнкүл р-ны «Борлы» с-зында участок агрономы, баш агроном. 1991–2008 дә Ульянов ун-тының төбәкләр һәм халыкара мөнәсәбәтләр каф. доценты. 2012 дән Ульянов пед. ун-ты профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буенда 19 йөз — 20 йөзнең 33 елларына кадәрге авыл кредит кооперациясе тарихына, 1920–30 еллар сов. планлы икътисадына, татар халкы тарихы һәм историографиясе мәсьәләләренә һәм урта гасырлар татар этник җәмгыятьләре оеша башлауны өйрәнүгә карый. Икенче бөтендөнья сугышына, милләтара мөнәсәбәтләргә, Россиянең 9–21 йөзләрдәге милли сәясәтенә багышланган уку ярдәмлекләре авторы. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Утверждение плановости в советской экономике в 1920–1930-е годы. Ульяновск, 2006; Организация системы сельской кредитной кооперации. Ульяновск, 2007; Становление и развитие аграрных кредитных товариществ (1870–1917 гг.). Ульяновск, 2008.

**МӨХӘММӘ́ДОВ** Шакир Мөхәммәтша улы (20.5.1865, Сембер губ., Сембер өязе Буа ш. — 10.11.1923, Оренбург ш.), язучы, нашир, журналист. 1879 елдан Оренбургта яши. Кибеттә хезмәтче, приказчик вазифаларын башкара, 1884 тән сәүдәгәр Хөсәеновлар конторасында хисапчы булып эшли. 1890 елларда Мәскәүгә күчә; бухгалтерлар курсын тәмамлап, һөнәре буенча эшли. 1900–01 дә Харбин шәһәрендә (Кытай) яши. Аннан Буага кайта, татар мөселман яшьләре арасында җәмгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1903 тә Оренбургка кайта: Гани бай Хөсәенов контрасында эшли, 1906–07 дә «Карчыга» сатирик ж-лының нашире һәм мөхәррире. 1917 дән соң приказчик һәм конторщиклар профсоюзларын төзү б-н шөгыльләнә, төрле оешмаларда хезмәт итә. Татар сәүдәгәрләренең тормышын һәм әхлагын тасвирлауга багышланган беренче «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» (1901), «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе» (Оренбург, 1901) исемле повестьларын яза. Язучы, геройларының үз катламнарына хас уртак сыйфатларын гына күрсәтеп калмыйча, аларның һәрберсен индивидуаль характерлар, гадәтләр б-н дә баета. Геройларын мәгърифәтче күзлегеннән бәяләп, М. аларның саранлыгын, наданлыгын тәнкыйтьли, укырга, белем эстәргә өнди. М.ның «Япон сугышы, яки добреволец Батыргали агай» (1905) повесте урыны б-н зәһәр сатирага күчкән; нечкә юмор, ирония б-н сугарылган. Язучы рус-япон сугышы барган чорда татар һәм рус сәүдәгәрләренең ялган патриотизмын көлке утына тота. «Доброволец»лар Батыргали б-н Шубинны крәстияннәрдән чыккан сугышчыларга каршы куеп, автор чын баһадирларның фәкать халыкның үз сафларында үсә алганын күрсәтә. Мавыктыргыч сюжет, төгәл билгеләнгән образлар, кеше психологиясенең нечкәлекләрен яхшы белү әсәрнең популярлашуына сәбәп була. «Хан кызы» (1908) романтик хикәясендә хан кызы Фатыйманың Иран шаһының улына — Ширин исемле әсир егеткә булган мәхәббәте тасвирлана. Егетнең исеме, геройларның очрашуын тасвирлау, вакыйгаларның алга таба үсеше укучы күңелендә урта гасырлар татар әдәбияты сюжетлары (Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е, Сәйф Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен»е) б-н охшашлык тудыра. Бу әсәрдә М. кодрәтле, ирек сөючән хатын-кыз идеалын сурәтли. Оригиналь тәмамланыш (кыю кызны кабып йоткан аллегорик аждаһа образы пәйда булу) хикәянең традицион укылышын (ата-ана сүзен тыңламау һәлакәткә китерә) фәлсәфи мәгънә (кешенең кимчелекләре мәхәббәт, бәхетне җимерүгә генә түгел, хәтта үтерүгә китереп җиткерергә мөмкин) б-н баета. М. поэзиясендә гражданлык, публицистик мотивлар өстенлек итә («Дума членнарына», 1907; «Җир кирәк», 1907 һ.б.). «Яңа Бәдәвам» (Оренбург, 1903) сатирик шигырь керешендә автор: «Милләтебез хастадыр... Безнең хасталыгыбыз наданлыктыр. Наданлык дәвасы, әлбәттә, гыйлем вә мәгърифәт вә укудыр», — дип яза. Публицистик мәкаләләрендә М. татар җәмгыятенең актуаль мәсьәләләрен күтәрә, төрле катлам халыкның демократик үзгәрешләргә карата мөнәсәбәтен яктырта, халыкны укырга өнди, татар уку йортларына реформа кирәклеге турында яза, кадимчеләрне тәнкыйтьли. М. әсәрләре аңлаешлы тел б-н язылган, тексттагы чит тел сүзләренә аңлатмалар бирелгән, әйтем һәм мәкальләр киң кулланылган.



Шакир Мөхәммәдов.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1958.

*Әд.:* З а к и р ж а н о в Ә. «Заманыбыз тәрәккыят заманыдыр...» // Казан утлары. 2005. № 5; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX века. К., 1975; История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX в.). К., 2003.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**МӨХӘММӘ́ДОВА** Гөлсем (Өммегөлсем) Даут кызы (19.9.1903, Әстерхан ш. — 11.3.1988, Казан), язучы, тәрҗемәче, биол. фән. канд. (1956). Әстерхан рус гимназиясен тәмамлагач (1919), татар башлангыч мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1922 елда Казанга килә, Казан ун-тының мед. ф-тында укый, бер үк вакытта ТАССР ХКСның юридик бүлегендә тәрҗемә эшен алып бара. Сәмәрканд мед. ин-тын тәмамлый (1944). Иренең — Г.*Ибраһимовның* шәхси сәркәтибе вазифаларын башкара; аның татар иҗтимагый фикере үсеше тарихы һәм революцион хәрәкәтенә багышланган «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» («Татары в революции 1905 года», 1926) хезмәтен рус теленә тәрҗемә итә. 1927–33 тә Ялта шәһәрендә авыру ирен карый. 1934–41 дә Симферополь шәһәрендә: Кырым-татар язучылары турында китап чыгаруда катнаша, архив идарәсендә эшли, «Кызыл Кырым» г-тасы редакциясе б-н хезмәттәшлек итә. 1941 дә Сәмәрканд шәһәренә эвакуацияләнә, башта хастаханәдә табибә, соңрак Бөтенсоюз каракүл сарыклары үрчетү фәнни-тикшеренү ин-тында фәнни хезмәткәр булып эшли. Г.Ибраһимов аклангач, аның тормышына кагылышлы мәгълүматлар җыю б-н шөгыльләнә, язучының белгән кешеләр б-н хатлар алыша. «Г.Ибраһимов турында истәлекләр» (1966) җыентыгын бастырып чыгаруда катнаша. Г.Ибраһимовка багышланган «Большая жизнь» (1968) мемуарлар җыентыгы, «Яшьлек көннәре»(1975) документаль повесте, язучының

тормышын һәм иҗатын, аның даирәсен колачлаган «Эзләнүләр» (1987) һәм «Олы юл» (1994) исемле истәлекләр җыентыгы авторы.

*Әд.:* Х ә м и д у л л и н Л. Тирән хатирәләр иясе // Мәдәни җомга. 2003. 19 сент.; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*Л.Х.Хәмидуллин.*

**МӨХӘММӘ́ДОВА** Рәмзия Гыйният кызы (23.12.1923, Сембер губ., Сембер өязе Яңа Ирикәй пос.), этнограф, тарих фән. канд. (1967), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан ун-тының геогр. ф-тын тәмамлый (1949). 1959–86 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, этнография төркеме мөдире (1972 дән); 1971–86 да «Татар халкының тарихи-этнографик атласы» («Историко-этнографический атлас татарского народа», 2002) дигән фундаменталь хезмәтнең җитәкчесе. 1986–2013 тә ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Дәүләт татар фольклоры үзәгенең (2010 нан Республика традицион мәдәният үсеше үзәге) әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, ТР Милли музее консультанты, ТР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең милли киемнәр буенча консультанты. Хезмәтләре татар этнографиясенә, милли кием-салымны өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләгенә «Татарлар» («Татары», М., 2001) коллектив монографиясен төзүдә катнашканы өчен лаек була.

Х е з м.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967 (автордаш); Очерки общей этнографии: Европейская часть СССР. М., 1968 (автордаш); Татары-мишари. М., 1972; Татарская народная одежда. К., 1997; Народный костюм татар-кряшен = Керәшен татарлары киеме. К., 2005.

**МӨХӘММӘДСАДЫ́ЙК** Иманколый (10.9.1870, Казан — май, 1932, Пермь өлкәсенең Красновишерск ш.), дин эшлеклесе, шагыйрь. Казанның нәселдән килгән мактаулы гражданы. Дини белемне Бохарада ала. 1894–1932 елларда Казанның Яңа татар бистәсендәге 6 нчы Җамигъ мәчетенең 2 нче имамы һәм имамы. 1919–24 тә Казан *мөхтәсибе*. 1931 дә «кулак-муллалар төркеме»ндә катнашучы буларак кулга алына һәм 5 елга лагерьга хөкем ителә. «Белобалтлаг»та авырып үлә; үлгәннән соң аклана. Дини хезмәтләр, шигъри әсәрләр, дәреслекләр, сүзлекләр авторы. Иң танылган әсәрләре: «Сәләтыйн ислам...» («Ислам солтаннары...», 1909) дини трактаты, «Тәрҗеман руси, фарси вә төрки» («Русча-фарсыча-төркичә сүзлек», 1909), «Тәсһил әл-бәйан фи тәфсир әл-Коръән» («Коръән тәфсиренең җиңеләйтелгән бәяны», т. 1–2, 1910; «Урта Азия мөселманнары арасында тарату өчен» дигән аңлатма б-н 1996 да Катарда репринт ысулы б-н кабат басыла), «Мәрсия император Александр II вә тәһния император Николай II» («Император Александр II гә мәрсия һәм император Николай II гә котлау», 1910). 2000 дә М.ның Казанда кульъязма хәлендә сакланган мөнәҗәтләре, газәлләре, касыйдәләре басылып чыга.

Х е з м.: Мөнәҗәтләр. Газәлләр. Касыйдәләр. К., 2000; Тәсһилүл бәян фи тәфсирил Коръән: Коръәннең 30 нчы парәсы тәфсире. К., 2002; Перевод-самоучитель для русского, персидского и тюркского языков, употребляемых в Туркестане. К., 1915.


*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Шагыйрь һәм дин галиме // Мирас. 1995. № 9; А х у н о в А. Мухаммад-Садык Иманкулый // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 3/4; Г а й н у т д и н о в М. В тисках безвременья: Классики 20-х гг., К., 2002.

*А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘДХАФИ́З КҮЧҮ́М** (19 йөзнең 2 нче яртысы, фаразланганча, Уфа губ., Бәләбәй өязе Килкәбез а. — 20 йөз башы), хаттат. 53х71 *см* зурлыгындагы төсле литография техникасында башкарылган «Пәйгамбәрләрнең яшәү еллары» һәм «Әсхаб әл-Кәхаф исемнәре» шәмаилләренең авторы; 1903 елда *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф коюю ширкәтендә* басыла. Беренче шәмаилдә «Иман көймәсе» исемле йөзеп баручы көймәнең шартлы сурәте кысага алынган; кысаның як-ягында пәйгамбәрләрнең исемнәре, яшәү еллары күрсәтелгән таблица урнаштырылган. Икенчесендә — стильләшкән пейзаж фонында мәчетләр рәсеме; аларның диварлары каллиграфик язулы Коръән аятьләре б-н бизәлгән. Көймәдә дә, куб формасындагы мәчет бинасында да Кәхаф мәгарәсендә 300 ел йоклап үткәргән һәм Аллаһ тарафыннан коткарылган алты легендар мәгарә иясенең һәм аларның эте Кытмырның исеме язылган. Ике шәмаилдә дә исемнәр композициянең үзәк урынын биләп тора, бу аларның татар мөселман мәдәниятендә саклаучы символик мәгънәгә ия булуларын дәлилли. Шәмаилләр колоритында кызыл төскә мөһим урын бирелгән, ул текстлар яссылыгында бизәкле кайма булып тора, «иман формуласында», сынлы детальләрдә һәм фон буларак файдаланылган. ТР Милли музеенда саклана.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003; Шамаилы из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец XIX — начало XX вв.) / Собр. проф. И.М.Покровского и Н.Ф.Катанова. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*



1



2

М ө х ә м м ә д х а ф и з К ү ч ү м. 1. «Пәйгамбәрләрнең тормыш еллары». Төсле литография. 1903; 2. «Әсхаф әл-Кәхаф исемнәре». Төсле литография. 1903. Икесе дә – ТР Милли музеенда.

**МӨХӘММӘДХӘНӘФИ́** (19 йөзнең 1 нче яртысы), ташка уеп бизәк ясаучы, хаттат, биографик белешмәләре ачыкланмаган. М. текстлары 15х60х130 *см* зурлыктагы известьташтан эшләнгән кабер ташларының алгы ягына урнаштырылган, каймалап кысага алынган. Кагыйдә буларак, беренче юлдагы язулар гарәп әлифбасының «тәгълик» стилендә яссы рельефта уелган. Текстның калган өлеше уеплап язылган. Бизәкләре юк. Һәйкәлләр ярымтүгәрәк формада төгәлләнгән. Ярмөхәммәд Нугайбәк улы истәлегенә куелган бер таштa: «Фәкыйрегез Мөхәммәдхәнәфи сәнгате», — дип имзаланган (1833). Азнакай р-ны Чалпы авылының борынгы зиратында 19 йөзнең 1 нче яртысында М. стилендә уеп бизәлгән кабер ташлары байтак, әмма аларның һәркайсында да аның исеме язылмаган.



М ө х ә м м ә д х ә н ә ф и. Кабер ташы. Уеп кисү. 1833. Чалпы авылы зираты.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**МӨХӘММӘДШӘРИ́Ф** Габдеррәшид угылы (18 йөз ахыры — 1834), шагыйрь. *Морад Мулла* хәрәкәтендә катнашкан 1нче Казан мәчете имамы Габдеррәшид хәзрәт улы. Сатирик эчтәлекле «Мөнәҗәте кәҗә», «Чәй бәете», «Кече хатын» һ.б. шигырьләр авторы. Көндәлек тормышны тасвирлап, эзоп телен кулланып, М. рәсми мөселман руханиларын тәнкыйтьли. Кульъязмалары РФА Шәрекъ кульъязмалары ин-тының Петербург бүлеге кульъязмалар фондында саклана.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2.

*А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘДЪЯ́Р** Мәхмүд Хаҗи угылы (1496 яки 1497 — 1549), шагыйрь. Дин әһеле гаиләсеннән. Гомеренең соңгы елларында Казанда Мөхәммәдәмин хан төрбәсенең караучы-мөҗәвире булып тора. 1549 елның көзендә Иван IV гаскәре Казанны камагаңда һәлак була. Безнең көннәргәчә сакланып калган ике поэмасы һәм бер шигыре мәгълүм. «Төхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге»,


1539–40) лироэпик поэмасында шагыйрьнең гуманистик карашлары, кешеләр тату, тыныч яши торган идеаль җәмгыять турындагы хыяллары чагыла. Поэманың лейтмотивы, социаль-этик концепция үзәге булып гаделлек идеясе тора. Игътибарның төп объекты — табигать тарафыннан акыл, матурлык, чибәрлек, нәфислек, тугрылык, тыйнаклык бирелгән кеше. М. фикеренчә, кеше үзен җәмгыятькә хезмәт итүгә, тәкәбберлек, мактанчыклык, икейөзлелек б-н көрәшүгә багышларга тиеш. Поэма җиде лирик чигенеш б-н чиратлашкан, аның аерым кисәкләрен бәйләп, ш.у. аны бербөтен иткән хикәяләүдән тора. Шаһ Һарун, акыл иясе Заһид, мәрхәмәтле кыз, аның усал әтисе һ.б. турында язылган зур булмаган гыйбрәтле хикәяләрдә автор шул заманның гореф-гадәтләрен тасвирлый. Үзе яшәгән җәмгыять төзелешен ул ислам әхлагы принципларыннан, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре тәгълиматыннан чыгып бәяли. М.ның гуманистик вәгазенең максаты — әхлакны төзәтү, шәхес һәм җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм шуның аша Аллаһка якынаю. М.ның җәмгыять тормышында, шәхеснең формалашуында телнең роле турындагы фикерләре аеруча игътибарга ия. Шагыйрь өчен тел — илаһи бүләк. Тел аша кеше акылы дөнья турындагы карашларын тапшыра, җиткерә ала. Туры сүз — туры эшләрне, гамәлләрне билгели. Тел ялганга корылган булса, барысы да ялган була.

«Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) дидактик поэмасында шагыйрь хөкемдарларга хас булырга тиешле әхлакый сыйфатлар турында фикер йөртә. Әсәрнең төп лейтмотивы — М. фикеренчә, игелек, тыныч һәм шат тормышның чыганагы — гаделлек: «Бер сәгать гадел кылмак йахшырак, Кем гыйбадәт алтмыш йылдин озакрак». Тасвирлы чагыштырулар б-н шагыйрь золымга чик куярга, хөкемдарларга йогынты ясарга, аларны гади халыкка карата юмарт һәм мәрхәмәтле булырга чакыра. Шулай итеп, М. урта гасырлар Шәрекъ мәдәниятенә хас алдынгы гуманистик идеяләрне үстерә. «Гаделлек белән, шаһ, чыкты атыгыз, Дөньяда һәрвакыт булсын затыгыз. Гадел хөкемеңнән куркып, шаһ җиһан, Көчле көчсезгә һич тидермәс зыян», — дип яза автор. Алай булганда: «Бүре белән сарык бергә су эчәр, Үрдәк белән карчыга бергә очар».

М. феодаль-теократик тәртипләрне, хөкем итүчеләрнең эш-гамәлләрен тәнкыйтьли, киң халык массаларының мәнфәгатьләре турында яза. Ул хезмәт кешесен мактый, аның намуслылыгына, әхлакый пакьлегенә мәдхия җырлый. М.ның гуманизмы ш.у. хатын-кыз б-н ирләр, өлкәннәр б-н балаларның бертигез булуын тануда чагыла. Шагыйрь күзаллавы буенча Аллаһ — бар нәрсәнең башы. Кеше — акыл иңдерелгән гүзәл зат. Ләкин тормышка аяк басканда, аның бертөрлесе мәрхәмәтле була, икенчесе явызга әйләнә. Гөрләп алга барган ил, М. фикеренчә, хөкемдар урнаштырган гаделлеккә нигезләнергә тиеш.

Поэмада Шәрекъ әдәбиятының иң танылган әсәрләре йогынтысы сизелә («*Кәлилә вә Димнә*», Низами Гәнҗәвинең «Хәмсә»се, Й.Баласагуниның «Котадгу белег»е, Сәгъдинең «Гөлестан»ы һ.б.). М. ш.у. татар фольклорының байлыгыннан да оста файдалана. Мәкальләр, әйтемнәр, аерым гыйбарәләр, шигъри юллар б-н органик рәвештә кушылып китеп, текстны кыска һәм ачык, образларны тере һәм тәэсирле итәләр. Поэма лексикасында гарәп-фарсы алынмалары, гомум халык сөйләме элементлары, диалектизмнар урын алган.

М. иҗатын өйрәнүгә М.И.*Иванов* башлангыч бирә; «Татар хрестоматиясе»нең («Татарская хрестоматия», 1842) икенче бүлегендә ул аның «Нәсыйхәт»ен бастыра. 1846 да шәркыятьче галим И.Н.*Березин* С.-Петербургның Азия музее фондларында «Төхфәи мәрдан» поэмасының кульъязмасын таба һәм үзенең «С.-Петербург китапханәләрендәге төрек-татар кульъязмаларының тасвирламасы» («Описание турецко-татарских рукописей, находящихся в библиотеках С.-Петербурга») мәкаләсендә аның турында беренче


Мөхәммәдъярның «Нуры содур» поэмасының кульъязма күчермәсе.

мәгълүматлар бирә. Аның фикеренчә, «Төхфәи мәрдан», Казан диалектына караган борынгы ядкәрнең берсе буларак, ... зур игътибарга лаек». Соңыннан поэманың аерым өзекләрен И.Н.Березин үзенең «Төрек хрестоматиясе»нең («Турецкая хрестоматия», т. 1–3, 1857–90) 1 нче томына кертә. М. иҗатын өйрәнүне язучы һәм галим Н.Исәнбәт дәвам итә. 1941 дә «Совет әдәбияты» ж-лында (№4), «Нуры содур» поэмасының Татарстан җирендә табылган һәм күчерелгән нөсхәсенә нигезләнеп, мәкалә бастыра. 1947 дә тарихчы Х.Гыймади И.Н.Березин тапкан поэма күчермәсенең урынын ачыклый. 1940–50 елларда М.ның иҗади мирасы б-н Б.Яфаров, Л.Җәләй, Н.Ф.Калинин һ.б. галимнәр шөгыльләнә. 1956–57 елларда М. поэмасыннан өзекләр «Татар поэзиясе антологиясе»ндә («Антология татарской поэзии») басыла. М. әсәрләрен җентекләп өйрәнүгә 1950 елларда Ш.А.Абилов алына. 1966 да ул ике поэманың текстларын, 1997 дә поэмаларның тулаем текстларын һәм «Нәсыйхәт» шигырен бастыра, хәзерге татар әдәби телендә аларның тәрҗемәләрен, шәрехләмәләрен бирә. Поэмалар күчермәләре (12 чамасы) С.-Петербург, Казан, Уфа архивларында һәм китапханәләрендә саклана. «Төхфәи мәрдан» (1600) поэмасының иң борынгы күчермәсе — Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә сирәк китаплар һәм кульъязмалар бүлегендә. М. әсәрләре М.Колый, Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд иҗатларына зур йогынты ясый.

Ә с ә р.: Төхфәи мәрдан. Нуры содур. Поэмалар. К., 1966; Нуры содур. Поэмалар, шигырь. К., 1997.

*Әд.:* Мухаммедъяр и его время. К., 1997; К а д и р о в а Э.Х. Поэмы Мухаммедъяра «Тухфа-и Мардан» и «Нур-и Содур»: Лексика. К., 2001.

*Ш.А.Абилов, А.М.Ахунов.*

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Ринат Әзәл улы (19.8.1948, Әлмәт р-ны Мәмәт а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1992, 1999). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1967 елдан Азнакай р-нында: район башкарма ком-тының мәдәният бүлегендә (1980 гә кадәр), «Янтарь» с-зы директоры (1984 кә кадәр), эшчеләрне тәэмин итү бүлегенең Актүбә бүлекчәсендә җитәкче (1985 кә кадәр). 1985 тән «Азнакай» с-зы директоры, 1998 дә хуҗалык «Мөхәммәдъяров һәм К°» ышанычлылык ширкәте итеп үзгәртелә, 2004 тә «Уразай» ҖЧҖ. М. эшләгән елларда хуҗалыкта юлларга асфальт җәелә, җитештерү корылмаларына һәм торак йортларга газ кертелә, социаль-мәдәният һәм көнкүреш биналары, мәктәп, балалар бакчасы, ясле, профилакторий, мәдәният йорты, мәчет һ.б. төзелә. 2005 тә, 2001 ел б-н чагыштырганда мөгезле эре терлекнең баш саны — 9% ка, дуңгызлар — 6% ка, ит җитештерү — 40% ка (сату — 46% ка), сөт — 5–8% ка (сату — 24% ка) арта. Мөгезле эре терлекнең тәүлеклек уртача артымы — 626 *г*, дуңгызларныкы 354 *г* тәшкил итә, 1 сыердан 5 елга (2001–05) уртача 4104 *кг*, ш.и. 2005 тә 4125 *кг* сөт алына. Җитештерүдәге уңышлары өчен М. медальләр, хуҗалык КПСС ҮКның Кызыл Байрагы б-н бүләкләнә (1988).

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Роберт Дәүләт улы (17.1.1940, БАССРның Бәләбәй ш.), радиоэлектроника өлкәсе галиме, конструктор, техник фән. д-ры (1992), проф. (2002), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000). 1964 елда Урал политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Урал оптика-механика з-дында (Свердловск ш.) эшли. 1979 дан ГИПОда: фәнни бүлек башлыгы — баш конструктор (1979–85), фәнни-техник комплекс башлыгы (1985–94), «Аэрокосмик приборлар җитештерү институты» АҖнең директоры — баш конструкторы (1994 тән), ген. директоры (2003 тән); бер үк вакытта, 1987 дән, Казан техник ун-тында. Хезмәтләре оптик дулкын озынлыклары диапазонында аэрокосмик дистанцион зондлау системалары теориясенә һәм конструкцияләүгә карый. М. эшкәртмәләре «Космос», «Метеор», «Океан-01» сериясендәге космик ракета йөрткечләрдә, самолётларда, вертолётларда кулланыла. Файдалы казылмалар, төче сулар һәм техноген җимерелү урыннарын эзләү өчен видеотепловизион алым эшли. Татарстан терр-ясендә борынгы Идел үзәненең 3 җир асты участогын тикшерә. Уйлап табуга 186 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең акад. В.Н.Челомей исем. һәм СССР Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин исем. алтын медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Детерминированный синтез оптико-электронных систем с симметричным входом //

Оптический журн. 1993. № 9; Космические технологии для приборного оснащения нефтегазового комплекса // Наука и техника в газовой пром-сти. 2000. № 2; Перенос излучений в листьях растений // Оптика и спектроскопия. 2001. Т. 90, № 4.

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Фатих Гариф улы (25.12.1883, Казан губ., Казан өязе Олы Җәке а. — 30.1.1950, Казан), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1933). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1917), Гражданнар сугышы фронтларында (өлкән табиб, бригада табибе). 1920 елдан Казанда: ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тында бүлек мөдире, ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары, ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары (1922–27). 1927–32 елларда Казан ГИДУВының җәмәгать-көнкүреш гигиенасы кафедрасында, бер үк вакытта (1930–35) Татарстан җәмәгать-көнкүреш гигиенасы ин-ты директоры. 1932–50 дә Казан мед. ин-тының җәмәгать-көнкүреш гигиенасы каф. мөдире. Хезмәтләре сәламәтлек саклауны оештыруга, демографиягә, мед. статистикасына, татар балаларының физик яктан үсешен бәяләүгә карый. М. — корсак тифына каршы көрәшү өчен дезинфекция отряды һәм махсус комиссияләр төзүне башлап җибәрүче, Татарстанда эпидемияләргә каршы чаралар оештыручы. ТАССР Дәүләт план ком-ты кушуы буенча, сәламәтлек саклау үсешенең беренче бишьеллык планын төзи (1928).

Х е з м.: К вопросу об изучении воспроизводства поколений // Казан. мед. журн. 1930. № 6; К вопросу об изучении переживаемости взрослого татарского населения. К., 1930; Опыт изучения плодовитости женщины татарки и переживаемости её ребёнка. К., 1930; Самодеятельность трудящихся в деле охраны здоровья. К., 1935.

*Әд.:* Профессор Фатых Гарифович Мухамедьяров. К., 1973; Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989.

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Хөсәен Хәсән улы (18.12.1927, Оренбург ш.), генерал-майор (1979). Иваново хәрби-сәяси уч-щесен (1950), М.И.Калинин исем. Югары хәрби-пед. ин-тын (Ленинград, 1957) тәмамлый. 1942–45 елларда 2 нче Чкалов хәрби штурманнар авиация уч-щесе каршындагы авиаремонт остаханәсендә эшли. 1947–48 дә Көньяк-Урал хәрби округында укчы батальон санинструкторы. 1950–53 тә Одесса хәрби округында мотоукчылар ротасы командирының сәясәт буенча урынбасары. 1957–59 да Кавказ аръягы хәрби округы авиация дивизиясендә сәяси бүлекнең пропаганда һәм агитация буенча өлкән инструкторы. 1959–66 да СССР Һава һөҗүменнән саклануның Баку округында: сәяси бүлекнең пропаганда һәм агитация буенча өлкән инструкторы, зенит-ракета полкы башлыгы, командиры урынбасары. 1966–71 дә Төркестан хәрби округында, СССР Һава һөҗүменнән саклану хезмәте сәяси бүлегенең партия-оештыру бүлеге инспекторы, башлыгы, СССР Һава һөҗүменнән саклану дивизиясе башлыгы, командиры урынбасары. 1971–75 тә СССР Һава һөҗүменнән саклану 4 нче Аерым армиясе сәяси бүлеге башлыгының 1 нче урынбасары. 1975–76 да Карпат алды хәрби округында СССР Һава һөҗүменнән саклану корпусының сәяси бүлеге башлыгы. 1976–80 дә Төркестан хәрби округындагы 12 нче Аерым армиянең хәрби советы әгъзасы, сәяси бүлек башлыгы. 1980–87 дә СССР Оборона министрлыгының 45 нче Махсус фәнни тикшерену ин-тында сәяси бүлек башлыгы. 1987 дә запаска җибәрелә. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Һашим Идрис улы (19.11.1900, Сембер губ. Буа ш. — 7.1.1952, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1951), ТАССРның атказ. табибе (1940). 1 нче Ленинград мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1928), шунда ук, тире-венерология клиникасында эшли. 1929 елдан Мамадыш кантоны Саба авылы участок хастаханәсе мөдире. 1930 дан А.В.Вишневский исем. хирургия клиникасында, 1934 тән Казан мед. ин-тында; бер үк вакытта, 1945 тән, Казан шәһәренең 3 нче хастаханәсе табибе. 1951 дән Казан ГИДУВы директоры. Хезмәтләре Вишневский ысулы б-н ясалган новокаин блогының тәэсир итү механизмын өйрәнүгә карый. Бөек Ватан сугышы ветераны. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Опыт применения аутогемотерапии при воспалительных гнойных процессах // Тр. Казан. мед. ин-та. 1935. Т. 1–2 (автордаш); Результаты хирургического лечения язв желудка и 12-перстной кишки // Казан. мед. журн. 1937. № 3 (автордаш).

*Әд.:* Казанская медицинская академия. 75 лет (1920–1995). К., 1997; П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Шакир Зариф улы (25.12.1883, Орск ш. — 1967, Ташкент), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог, публицист. Татар укытучылар мәктәбендә укый (Казан, 1901–04), анда ул Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Х.Ямашев б-н таныша. Петербург ун-тының юридик ф-тын (1915), Урта Азия ун-тының геогр. ф-тын (Ташкент, 1930 еллар) тәмамлый. «Таңчылар» төркемен оештыручыларның берсе (1906–07). Татар вакытлы матбугатының *«Казан мөхбире»*, *«Таң йолдызы»*, *«Ил»*, *«Сүз»*, *«Вакыт»* һ.б. басмалары б-н хезмәттәшлек итә. Полиция күзәтүе астында була. 1915–16 елларда Саратов шәһәрендә: хәрәкәттәге армиядәге 18 нче Көнбатыш инженер-төзүчеләр дружинасының эшчеләр төркеме мөдире. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Мәскәүгә күчә: Россия мөселманнарының Вакытлы үзәк бюросы әгъзасы, мөселманнарның 1 нче Бөтенроссия корылтаен әзерләүдә катнаша (Мәскәү, 1917 нең мае). Җир мәсьәләсе буенча резолюция авторы. Бөтенроссия мөселманнар советына сайлана. 2 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтае эшендә катнаша (Казан, 1917 нең июле). Оештыру җыелышында Самарадан делегат. 1918 нең язында Кырымда, совет хөкүмәте урнашкан вакытта төрле оешмаларда юрист, адвокат хезмәтендә. Соңрак Урта Азиягә күченеп килә, Нарында, Каракүлдә һ.б. урыннарда колхозлар оештыруда катнаша, Фрунзе шәһәрендә кооперативларда эшли. 1930 дан Ташкентта, Милиция мәктәбендә география һәм җинаять кодексы фәннәрен укыта.

Х е з м.: Алпавытлар заманы вә крәстияннарны азат итү (Оренбург, 1911); Сәүдә законнары, К., 1914.

*Әд.:* Е н и к и Ә. Татар зыялысы // Мирас. 1992. № 9. *Д.М.Госманова.*

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВ** Шамил Фатих улы (17.6.1923, Казан — 23.5.2005, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. канд., проф., ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан юридик ин-тын тәмамлый (1946). 1950–52, 1955–56 елларда СССР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1952–55 тә СССР ФА Шәрекъне өйрәнү ин-тының Совет Көнчыгыш халыкларының тарихы һәм мәдәнияте бүлегендә гыйльми секретарь. 1956–65 тә Казан ун-тында, 1959 дан СССР тарихы каф. мөдире. 1965–70 тә СССР ФАнең Себер бүлеге Якутск ф-лында. 1970–96 да РФА Россия тарихы ин-тының Россия халыклары тарихы һәм этносара мөнәсәбәтләр үзәгендә. «Зур совет энциклопедиясе»нең («Большая советская энциклопедия») 2 нче һәм 3 нче басмаларын, «Ватан тарихы» («Отечественная история», т. 1–3, М., 1994–2000) энциклопедиясен, «Татар энциклопедия сүзлеге»н (1999) әзерләүдә катнаша. Казан ханлыгы чорының язма ядкәрләрен — Ибраһим һәм Сәхибгәрәй ханнарның ярлыкларын басмага әзерли. Хезмәтләре Казан ханлыгы, Кырым, Якутия тарихына, татар халкының килеп чыгышы мәсьәләләренә, Идел буе һәм Уралдагы төрки, фин һәм угор халыкларының урта гасырлар тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Земельные правоотношения в Казанском ханстве. К., 1958; Тарханный ярлык Казанского хана Сахиб-Гирея 1523 г. // Новое о прошлом нашей страны: Памяти академика Тихомирова М.Н. М., 1967.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001; М е л у а А.Н. Российская академия естественных наук. М.-СПб., 2002.

**МӨХӘММӘДЪЯ́РОВА** Айсылу Камал кызы (6.2.1923, Тәтеш кантоны Көрәле (Әҗем) а.), онколог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. табибе (1967, 1974). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казан ГИДУВының онкология кафедрасында эшли. 1952–58 елларда РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгы аппаратында. 1958 дән Респ-ка онкология диспансеры баш табибе. 1986–94 тә диспансер поликлиникасы мөдире, бер үк вакытта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш онкологы. Хезмәтләре сәламәтлек саклауда, онкология өлкәсендә оештыру мәсьәләләренә карый. М. тарафыннан яман шеш авыруларына диагноз кую һәм авыруны дәвалауның төрле ысуллары тәкъдим ителә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рак и борьба с ним. Г., 1960; Рак кожи век и углов глаза. К., 1973 (автордаш).

**МӨХӘММӘТГАЛИ́ЕВ** Нурвахит Нургали улы (18.8.1953, Кузнечиха, хәзер Спас р-ны Иске Рәҗәп а.), терлекләрне тукландыру буенча белгеч, биол. фән. д-ры (2006), ТРның атказ. зоотехнигы (2003). Казан вет. ин-тын

тәмамлаганнан соң (1976), ТАССРның Кама Тамагы р-ны башкарма ком-тының а.х. җитештерү идарәсе өлкән зоотехнигы. 1977 елдан Казан вет. ин-тында, зооинженерлык ф-ты деканы (1992–2003), а.х. терлекләре каф. мөдире (1996). Төп хезмәтләре а.х. терлекләрен тукландыруда ферментлы препаратлар куллануга багышлана. М. сөт аксымының 16 фракциясенең генетик һәм паратипик үзгәрүчәнлеген өйрәнү буенча комплексны тикшеренүләр уздыра, аларның сөтнең сыр ясау өчен яраклылыгына һәм термик чыдамлылыгына тәэсир итүен ачыклый; сөт терлекчелеге селекциясенә сөтнең технол. үзенчәлекләрен яхшыртуга юнәлдерелгән яңалыклар кертә, сыр ясау процессында казеин фракцияләрен классификацияләүне тәкъдим итә.

Х е з м.: Пектофостидин в рационе // Кролиководство и звероводство. 1986. № 3. Холмогорский скот и его совершенствование в Татарстане. К., 2000 (автордаш); Развитие племенного молочного скотоводства в Татарстане. К., 2006 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2000 гг.). К., 2006.


**МӨХӘММӘТГАЛИ́ЕВ** Радик Раиф улы (31.5.1959, Әлмәт ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1982). 1976 елдан «Татнефть» АҖдә эшли: слесарь-ремонтчы, цех мастеры, компрессор станциясе башлыгы, өлкән мастер, инженер-технолог, «Татнефтегаз» идарәсенең җитештерү-техник бүлеге башлыгы, инженер, АҖнең нефть һәм газ әзерләү бүлеге башлыгы урынбасары, башлыгы. Дәүләт бүләге Урал-Идел төбәгендәге чыганаклар шартларында нефть әзерләүнең сыйфатын күтәрү технологияләрен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘТГАЛИ́ЕВ** Фәрит Нургали улы (10.9.1959, Спас р-ны Иске Рәҗәп а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2003), ТРның атказ. икътисадчысы (2001). Казан а-х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Кама Тамагы р-нының 22 нче партсъезд исем. к-зында баш икътисадчы булып эшли (бүленеп). 1987 елдан Казан аграр ун-тында, а.х. пр-тиеләрендә җитештерүне оештыру каф. мөдире (1994 тән). Хезмәтләре Агросәнәгать комплексында хуҗалыкны алып баруның икътисади механизмнарын камилләштерү һәм а.х. пр-тиеләрен яңа хуҗалык формаларына үзгәртү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Экономический механизм хозяйствования в агропромышленном комплексе. К., 2001; Организационно-экономические аспекты реформирования организаций аграрной сферы. К., 2003 (автордаш); Формирование и функционирование экономического механизма хозяйствования в организациях аграрной сферы. М., 2004.

**МӨХӘММӘТГАЛИ́ЕВА** Луиза Илдус кызы (16.10.1960, Казан), балет артисткасы, педагог, ТРның халык артисты (1997). 1978 елда Казан музыка уч-щесенең (педагогы — С.Юнысова) хореография бүлеген тәмамлый. 1978 дән балет артисткасы, Татар опера һәм балет театрында балет труппасының педагог-репетиторы (2002 дән), бер үк вакытта, 1993–98 дә һәм 2002 дән, Казан хореография уч-щесе педагогы. Киң иҗади диапазонлы классик биюче, үзенчәлекле хореографик партияләрне оста башкаручы, тәэсирле актёрлык осталыгына ия булган актриса. Хореографик партияләре: Мирта («Жизель», А.Адан), Одетта-Одиллия, Аврора һәм Канәфер чәчәге Тылсымчысы («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Китри («Дон Кихот», Л.Минкус), Синьора Капулетти («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Царь-девица («Конёк-горбунок», Р.Щедрин), Кармен («Кармен-сюита», Ж.Бизе, Р.Щедрин) һ.б. Зур концерт репертуары б-н чыгышлар ясый. Укучылары арасында — А.Белов, Е.Бортякова, Н.Заякина, И.Шәмсетдинов.


Л.И.Мөхәммәтгалиева.


Л.И.М ө х ә м м ә т г а л и е в а. Ф.Синатра музыкасына «My way» концерт номеры.

*В.Н.Горшков.*

**МӨХӘММӘТДИ́НОВ** Шамил Галиәхмәт улы (2.11.1924, хәзер Башкортстан Респ-касының Яңавыл р-ны Айбүләк а.), эшче, Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген 1941 елда Яңавыл эшчеләр посёлогында «Ашлык әзерләү» («Заготзерно») конторасында эшче булып башлый. 1943 тән хәзерге Самара өлкәсенең Чапаев шәһәрендә яши. 1946–76 да Чапаев химик ашламалар з-дында: агач-эшкәртү цехында станокта, карбит цехында эшли. Герой исеме 8 бишьеллык планын (1966–70) үтәгәндә ирешкән уңышлары, алдынгы хезмәт алымнарын керткәне һәм югары техник күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Әкълим Касыйм улы (14.2.1930, Бөгелмә кантоны Тимәш а. — 21.7.2004, Мәскәү), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Бөгелмә пед. уч-щесен (1946), Мәскәү нефтехимия һәм газ сәнәгате ин-тын (1966) тәмамлый. 1949–90 елларда «Татнефть» трестында (бүленеп): «Бөгелмәнефть» (1953–61), «Әлкинефть» (1963–67 дә башлык урынбасары), «Лениногорскнефть» (1967–77 дә башлык), «Прикамнефть» (1977–78 дә башлык) нефть промыселы идарәләрендә, трестның ген. директоры (1980–90). 1961–63 тә Татарстан ХХС транспорт тресты управляющие, 1979–80 дә Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре идарәсе (Казан) башлыгы. 1990–91 дә СССР нефть һәм газ сәнәгате министры урынбасары. Нефть үткәргечләрнең коррозиягә каршы торучанлыгын күтәрү һәм скважиналарны кустлап бораулау алымын кертү инициаторы. Татарстан һәм Көнбатыш Себер нефть промыселы идарәләре каршында ярдәмче а.х.н оештыручы. 1976–85 тә ТАССР һәм 1985–90 да СССР ЮСлары депутаты. ТАССР ЮС Президиумы әгъзасы (1978–80). Дәүләт бүләге товарлыклы нефть паркларында җиңел фракцияләрне тотып алу җайланмаларын булдырганы өчен бирелә. Ленин ордены, Окт. Рев-циясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Әлмәт-Альметьевск. К., 2003.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Габделнур Хәбибрахман улы (26.12.1930, Казан), җылылык физикасы галиме, техник фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2002). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, С.М.Киров исем. ФҖБдә (Пермь ш.) цех башлыгы урынбасары булып эшли. 1953–58 дә Пермь өлкәсендә МТС баш инженеры, директоры була. 1958 дән Казан технол. ун-тында, механика ф-ты деканы (1970–95), электрофизик җайланмаларның вакуум техникасы каф. мөдире (1985–2002). Хезмәтләре сыек органик тирәлекләрдә молекуляр көчнең җылылык физикасы процессларына карый. М., молекуляр һәм структур характеристикаларына бәйле рәвештә, темп-ра һәм басымның зур аралыкларында матдәләрнең үзлекләре үзгәрүнең гомуми закончалыкларын билгели. Баскетбол буенча халыкара категорияле судья (2000), Халыкара баскетбол федерациясе — ФИБА комиссары (1983). Төрле халыкара ярышларда, ш.и. Олимпия уеннарында (өч тапкыр), дөнья чемпионатларында (өч тапкыр), Европа чемпионатларында (10 тапкыр) катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының (ике тапкыр), ТССР, ТРның Мактау грамоталары; «РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теплопроводность органических жидкостей. Л., 1971; Определение теплофизических свойств галогензамещённых углеводородов в теплопроводящем колориметре // Теплофизика высоких температур. 2004. Т. 42, № 2; Теплоёмкость и температуропроводность водных растворов солей щелочных металлов в широком диапазоне давлений // Журн. физ. химии. 2004. Т. 78, № 5.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Гани Ибәтулла улы (9.8.1944, Оренбург өлкәсенең Илек р-ны Озерки а.), генерал-майор (1989). М.В.Фрунзе исем. Омск югары гомумгаскәри командир-



М.Н. Мөхәммәтҗанов.

лар уч-щесен (1967), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1975), Генштаб хәрби академиясен (Мәскәү, 1989) тәмамлый. 1975–82 елларда Белоруссия хәрби округында мотоукчылар часте командиры урынбасары, часть командиры; 1982–85 тә танк берләшмәсе, 1985–87 дә армия берләшмәсе командующие урынбасары. 1989 дан Себер хәрби округында штаб башлыгының 1 нче урынбасары. Орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Заһри (19.8.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Азнакай а. — 17.9.1999, Азнакай ш.), әкиятче, татар халык әкиятләрен җыючы. 1960–61 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты (1996 дан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) хезмәткәрләре тарафыннан М.тан 70 ләп татар әкияте язып алына. 17 әкият «Акыл белән Бәхет: Татар халык әкиятләре» (1963), «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» (1–3 кит., 1977–81) җыентыкларында басылып чыга.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Илдар Абдулла улы (1.12.1935, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1973), проф. (1976). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Раменск приборлар төзү КБсында (Мәскәү өлкәсе) эшли. 1965 тән Мәскәү авиация-технол. ин-тында. 1970 тән Россия Халыклар дуслыгы ун-тында (бүленеп: 1987–90 да Совет-Камбоджа дуслыгы уч-щесендә гомуми техник фәннәр каф. мөдире, Пномпень ш., Камбоджа). М. манипуляция ясаучы роботлар, адаптив оптик системалар, космик аппаратлар һәм башка идарә ителүле объектларның программалы хәрәкәтләре б-н идарә итү системаларын эшли. Потенциаль булмаган көч кырларында нәстационар хәрәкәтләрнең тотрыклылыгын тикшерә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Построение систем программного движения. М., 1971; Уравнение программного движения. Оптимизации и оценки. М., 1987 (автордаш); Уравнения программных движений манипуляционных систем. М., 1989 (автордаш).

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Искәндәр Шамил улы (15.6.1962, Казан), уролог, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2004), ТРның атказ. табибе (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1985). 1993 елдан Казан шәһәренең 6 нчы клиник хастаханәсендә гемодиализ бүлеге мөдире, 1997 дән шунда ук, организмны экстракорпораль ысуллар б-н чистарту үзәге җитәкчесе. Бер үк вакытта (1993–2002) алмаш дәвалау алымнары буенча ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш белгече. 2002 дән И.М.Сеченов исем. Мәскәү мед. академиясенең даруларны клиник юл б-н сынау бүлеге баш белгече. 2005 тән РМАнең Мәгарифне информатизацияләү ин-тында (Мәскәү) лаб. мөдире. Хезмәтләре сәламәтлекне ныгыту технологияләренә, нефрология, диализ, сәламәтлек психологиясе мәсьәләләренә, сәламәтлекне саклау ысулларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Влияние информационных технологий на здоровье студентов. Ижевск, 2006; Здоровьесберегающие аспекты информатизации образования. Ижевск, 2006; Патофизиология информатизации образования: Санитарно-гигиенические и медицинские аспекты информатизации образования. Ижевск, 2006.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Мансур Михаил улы (9.9.1936, Горький өлкәсенең Кызыл Октябрь р-ны Ключище а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1980), проф. (1994). Мәскәү тарих-архив ин-тын тәмамлый (1964). 1962–79 елларда Үзәк партия архивы фәнни хезмәткәре, 1979–85, 1988–91 дә КПСС ҮК каршындагы Марксизм-ленинизм ин-тында (Мәскәү). 1985–88 дә ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбенең Фәнни-тикшеренү үзәгендә бүлек мөдире, 1992 дә Россия социаль һәм милли мәсьәләләр мөстәкыйль ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, 1993–97 дә Мәскәүдә тарихи документлар коллекцияләрен саклау үзәге директоры. 1997 дән Мәскәү гуманитар ун-тының тарих кафедрасында. М. «Коминтерн, КИМ һәм яшьләр хәрәкәте. 1919–1943 еллар» («Коминтерн, КИМ и молодёжное движение. 1919–1943 гг.». М., 1977, Т. 1–2), «А.М.Коллонтай: дипломатик көндәлекләр. 1922–1940» («А.М.Коллонтай: дипломатические дневники. 1922–1940». М., 2001. Т. 1–2) документлар җыентыкларын төзүче. Хезмәтләре халыкара эшчеләр һәм яшьләр хәрәкәтенә, тарихи чыганаклар, архив белеме һәм археография мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Революция и молодёжь: У истоков международного революционного движения молодёжи. М., 1972; Суд над фашизмом: Исторический поединок Г.Димитрова с имперским судом. М., 1983; Из истории Коммунистического интернационала молодёжи. М., 1988. Архивоведение культурного наследия России. М., 1994.


**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Миңлекасыйм Низаметдин улы (1918, хәзер Красноярск краеның Зур Морты р-ны Куртинка а. — ?, Новокузнецк ш.), Дан орденының тулы кавалеры (19.8.1944, 27.4.1945, 15.5.1946), гв. сержанты. Туган авылында агач эшкәртү з-дында эшли. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 289 нчы гв. укчы полкында миномёт расчёты командиры (5 нче гв. армиясенең 97 нче гв. укчы дивизиясе). 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Кировоград, Умань-Ботошани (икесе дә — 1944), Сандомир-Силезия, Түбән Силезия, Югары Силезия һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1945) катнаша. 1944 нең 4 августында Падев (Польша) тимер юл станциясе өчен сугышта (дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда, миномёттан атып 3 ут ноктасын юк итә); 1945 нең 26 гыйнвары — 2 февралендә Опава шәһәре янында Одер елгасын кичкәндә (дошманның 5 контрһөҗүме барышында плацдармда миномёттан 10 ут ноктасын юк итә һәм 3 күзәтү пунктын сафтан чыгара), 1945 нең 19 апрелендә Шпревитц торак пункты (Германия) янында Шпрее елгасын кичкәндә (миномёттан 2 ут ноктасын юк итә) батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Новокузнецкида вагон депосында столяр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Фронтовики, наденьте ордена! Кемерово, 1970; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Рәүфәл Сабир улы (10.11.1949, Казан), музыка-театр эшлеклесе, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2002). 1974 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук студентлар клубында директор, соңыннан Казан мәдәният ин-тында ВЛКСМ ком-ты секретаре, Казан шәһәре укучы яшьләр комсомол ком-тында бүлек мөдире, Казан яшь тамашачылар театры директоры. 1981 дән Татар опера һәм балет театры директоры. М. җитәкчелегендә театр контракт системасы буенча эшләүгә күчә; репертуар иң яхшы Европа, рус опера һәм балетларыннан төзелә. 2000–05 елларда театр бинасына реконструкция ясала. Халыкара Ф.И.Шаляпин исем. опера һәм Р.Нуриев исем. классик балет фестивальләрен оештырып җибәрүчеләрнең берсе. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Рөстәм Сөләйман улы (24.5.1946, Казан), фоторәссам, журналист, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997). 1969 елда Казан мед. ин-тын тәмамлый, 1970 тә Бөтенсоюз кинематография ин-тында (Мәскәү) операторлык ф-тында укый. 1969–75 тә Казан кинохроника студиясендә оператор. 1975 тән «Комсомолец Татарии» г-тасында, «Азат хатын», «Сельская новь» (Мәскәү), «Ялкын» ж-лларында. М. иҗатын-



Р.С. М ө х ә м м ә т җ а н о в. «Сәлам сиңа, Бөек Болгар» шәмаиле. Агач-йомычкадан эшләнгән плитә. Майлы буяу, алтын йөгертү. Казан, 1996.

да татар авылы темасы зур урын алып тора. М. *шәмаилләр* өлкәсендә әйдәп баручы осталарның берсе, ул аларны рәсем сәнгатенең традицион техникасында пыялада эшли. «Тасма» иҗат төркеме әгъзасы. Бөтенроссия, Бөтенсоюз (Мәскәү, Рязань, Гродно, Новокузнецк, Таллин, Рига, Вильнюс һ.б.), чит илләр (Барселона, Реус, Париж, Прага, Берлин) фотокүргәзмәләрендә катнаша, бүләкләргә лаек була. «Чор портреты» («Портрет эпохи») өлкә фестиваль конкурсында (2000, 2002, 2004, 2005), Internet International Art/Photo Contest (2001, 1 нче премия), World Press Photo (Амстердам, 2003, 2004) фестивальләрендә катнаша, лауреат була. М. эшләре «Казань» (1977), «Советский Татарстан» (1980), «Шәһри Болгар» (1997), «Борынгы Казан» (1999), «Ислам сәнгате» (2001), «Сабантуй», «Казан турында хикәят» (барысы — 2005) һ.б. фотоальбомнарда урын ала.

*Әд.:* Кутуй Р. Память зеркала // Казань. 1998. № 9/10; Шагеева Р. Демиург хотений // шунда ук. Б. 25–32.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВ** Шакир Нигъмәт улы (1.1.1900, Семиреченск өлкәсе, хәзер Кыргызстан Респ-касы, Токмак а. — 22.10.1972, Казан), график, китап рәссамы, полиграфист. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936, 1 нче әгъзалык билеты), АХРР әгъзасы (1927). 1920–24 елларда Ташкент ун-ты рабфагында, аннары Казан ун-тының мед. ф-тында укый. 1925 тә Казан архит-ра-сәнгать остаханәләренә күчә (1927 дән — Казан сәнгать-театр техникумы), графика бүлеген тәмамлый (1929). 1931–60 та Таттосиздатта, бизәлеш редакциясе мөдире. Китап бизәү сәнгатенә үзе укыткан Казан графиклары һәм иллюстраторларын бердәм иҗат коллективына туплау буенча зур эш алып бара. Ташбасма техникасында китап басучы-рационализатор буларак уңышлы эшли. Татарстан Рәссамнар берлеген оештыруда башлап йөрүчеләрдән була. Рәссамнар берлеге советының оештыру бюросына (1935), аның 1 нче идарәсе составына керә (1936–38). Бөек Ватан сугышында 1 нче Белорус фронты составында Польша һәм Германия терр-ясендәге сугышларда катнаша, Берлинга барып җитә. М. татар китап графикасының беренче проф. осталары төркеменә керә. Техникумның диплом эшләре конкурсында (1929) ул тәкъдим иткән ташбасма хезмәтләр, плакатлар, китап тышлыклары сәнгать белгече П.М.Дульский тарафыннан уңай бәяләнә. 1920 ел ахыры — 1930 ел башында басылган китап тышлыклары эскизлары җыйнак, төгәл, оста эшләнүләре б-н күзгә ташлана: Б.Доминовның «Әлифба» («Азбука»), «Рәсем ясарга өйрән» («Учись рисовать», 1929), Ф.Гладковның «Энергия» (1933), Н.Баянның «Кырлар симфониясе» (1931), А.Серафимовичның «Тимер ташкын» («Железный поток», 1932), Г.Камалның «Өч гомер» (1933), А.Фадеевның «Тар-мар» («Разгром», 1933), ш.у. чит ил авторларыннан В.Хосоиның «Тукучы Хуҗа» («Текстильщик Ходзи», 1931), Дж. Лондонның «Тормыш төбендә» («На дне», 1932). М. А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Г.Тукай, Г.Камал, К.Насыйри, М.Әмир, И.Гази китапларын бизи. 1940–50 еллардагы китап басмалары арасында аның тарафыннан бизәлгән М.Җәлилнең «Алтынчәч» әкияте, Габдрахман Камалның «Галиәскәр Камал турында истәлекләр» (1941), ш.у. «Татар халык әкиятләре», «Мәскәү» җыентыгы (икесе дә — 1947), М.Пришвинның «Бабамның киез итеге» («Дедушкин валенок»), М.Горькийның «Давыл хәбәрчесе» («Буревестник») китаплары (икесе дә — 1948) һ.б. аерылып торалар. Татарстан китап нәшриятының 80 нән артык басмасын бизи. М. респ-каның төрле вакытлы матбугат чаралары б-н хезмәттәшлек итә. Аның 1929–1930 еллар башында «Чаян» ж-лында басылган рәсемнәре милли карикатура үсешендә якты эз калдыра. Үткен юмор, нечкә, керсез киная яшерелгән рәсемнәре персонажларның үзенчәлекле сыйфатларын төгәл ачып бирә. М. ш.у. «Атака» ж-лын (1930) һәм «Ярыш» балалар журнал-дәреслегенең (1931) беренче саннарын бизәүдә катнаша.



Ш.Н.Мөхәммәтҗанов. «Колхоз оешу». 1920. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Ш.Н.Мөхәммәтҗанов. «Завод комплексы». Кәгазь, акварель. 1920–30 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

М.ның станлы графикасы китап бизәү сәнгатенә якын. Башлангыч әсәрләре — «Оркестр», «Завод комплексы», «Завод корпуслары» (1920 еллар азагы) — шул чорның геом. формалары, конструктив идеяләре рухында башкарылган. М.ның иҗатында төрле елларда карандаш б-н башкарылган күп санлы автопортретлар, ташбасма техникасында эшләнгән хатын-кыз портретлары аерым урын били (1920 еллар ахыры — 1930 еллар башы). Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Франция, АКШ мәдәният фондларында саклана. Респ-ка ТАССР рәссамнары (Казан, 1930–50 еллар), ТАССРның 10 еллыгына багышланган (1930), «ТАССР рәссамнары график әсәрләренең беренче күргәзмәсе» (Казан, 1951) һ.б.; халыкара — «Китап сәнгате» (Париж, 1931); «СССРның хәзерге заман сәнгате» (АКШ, 1932–33); М.З.Кәримов, Д.Н.Красильников, Ш.Н.Мөхәммәтҗанов әсәрләреннән «Беренче татар нәкышьчеләре һәм графиклары» ретроспектив (Казан, 1979) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе тууына 100 ел тулу уңаеннан уздырыла (Казан, 2000).

*Әд.:* Дульский П.М. Конкурс графического отделения художественно-театрального техникума. К., 1929; шул ук. Оформление татарской книги за революционный период. К., 1930; Выставки советского изобразительного искусства: Справ.: В 5 т. М., 1965–81; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Сулф, Леф, ТатАХРР: Каталог выставки искусства Татарии 20–30-х годов. К., 1990; АРХУМАС. Казанский авангард 1920-х. М., 2005.

*И.Ф.Лобашева.*



Г.В. Мөхәммәтҗанова.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Гүзәл Вәли кызы (2.9.1938, Зәй р-ны Зәй а. — 15.10.2013, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1988), РМА академигы (1996; 1995 тән мөхбир әгъза), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1989), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1987). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Арча урта мәктәбендә эшли. 1966–70 елларда Татарстан укытучыларның белемен күтәрү ин-тында. 1970 тән Казан ун-тының пед. кафедрасында, проф. (1990). 1991 дән Казан технол. ун-тының гуманитар белем бирү каф. мөдире. 1992 дән РМАнең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм технологиясе ин-ты директоры. Казан социаль-юридик ин-тын (2004 тә Социаль белем бирү академиясе итеп үзгәртелә) оештыручы һәм аның ректоры (1993–2003, 2005 тән академиянең президенты). Төп хезмәтләре һөнәри белем бирүнең теоретик-методик нигезләрен эшләүгә һәм аның үсешен фаразлауга, белем бирү системаларын проектлауга карый. РМАнең Идел буе бүлеге рәисе (1996–2001 һәм 2006 дан), ТРның Дәүләтнеке булмаган югары уку йортлары ассоциациясе рәисе (1996 дан). Россия Президенты каршындагы РФ Дәүләт бүләкләре буенча совет әгъзасы (2004 тән), ТР Президенты каршындагы яр-



Л.Ф.Мөхәммәтҗанова

лыкау комиссиясе әгъзасы (2000 нән). «Казанский педагогический журнал»ның баш мөхәррире (1995 тән). РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты. «Һөнәри белемне модернизацияләү: проблемага системалы караш» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр, ш.и. РФ Мәгариф министрлыгының К.Д.Ушинский медале; ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратегия реформирования среднего профессионального образования. М., 1995; Подготовка специалиста социальной сферы: Региональный аспект. К., 2004 (автордаш); Модернизация качества высшего образования в России (стратегия, опыт, принятие решений). М., 2005 (автордаш); Профессиональное образование: проблемы качества и научно-методического обеспечения. К., 2005.

*Әд.:* Энциклопедия профессионального образования. М., 1999. Т. 2.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Зифа Васильевна (19.7.1951, Биектау р-ны Бимәр а. ), график, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан сәнгать уч-щесенең театр-декорация бүлеген тәмамлый (1973). 1974–83 елларда РСФСР Сәнгать фондының Татарстан сәнгать-җитештерү остаханәләрендә проектлаштыручы-рәссам булып эшли, 1980 нән — Татарстан китап нәшриятында рәссам, 1984 тән «Азат хатын» ж-лында бизәлеш мөхәррире, 1987 дән «Ялкын» ж-лының бизәлеш бүлеге мөдире. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994). Балалар китапларын бизәүче рәссам буларак уңышлы эшли. М.ның кәгазьдә акварель, гуашь һәм темпера б-н башкарылган матур, җанлы рәсемнәре милли үзенчәлекләре б-н аерылып тора. Аларга образның декоративлыгы, форманы бизәкләп бирү, билгеле бер урындагы төсләр пропорциясенә нигезләнгән композиция принциплары, яктылык, ачыклык, лиризм хас: Б.Рәхмәтнең «Курчак батыр» (1984), Х.Халиковның «Матурмы син?» (1987), М.Хәсәновның «Ут малай» (1989), Х.Туфанның «Акыллы бала» («Умница», 1991), Ш.Галиевнең «Кем нәрсә ярата» (1992), Р.Вәлиевнең «Кайтаваз кайда яши?» (1994) китапларына, «Гөрләвек» (1995), «Сандугачым, сайра» («Пой, мой соловей», 2002) муз. җыентыкларына, Ә.Вәлиеваның «Мин татарча өйрәнәм» («Я учу татарский», 1999) китабына иллюстрацияләр; «Гөлчәчәк», «Алтынчәч», «Көмеш толымлы Сылу кыз» («Сылу-краса — серебряная коса»; барысы да — 2005), «Гөлшикәр» (2006) татар халык әкиятләренә графика һ.б..



З.В.М ө х ә м м ә т җ а н о в а. «Гөлчәчәк» әкиятенә иллюстрация. Кәгазь, акварель. 2005.

Рәссам буларак танылу китергән фольклор сәхнә костюмнары иллюстрация һәм эскизларында М. татар халкының өс киемнәре турында үзе үк туплаган (ш.и. этнографик экспедицияләрдә) материалларны уңышлы файдалана, аның традицион элементларын яңа стиль формаларына күчерә. ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле костюмнарының сәхнә чишелеше өчен 2 нче Бөтенроссия ансамбльләр смотры дипломына (Мәскәү, 1986) лаек була. Милли киемдәге курчаклар, балалар өчен стильле милли өс киемнәре эскизлары авторы. Казанда узган «Зөбәрҗәт» респ-ка балалар модасы конкурсы лауреаты (2000).

Татарстанның китап графикасы (Казан, 1981), «Зур Идел» (Чабаксар ш., 1985), «Советская Россия» (Мәскәү, 1985), ТР Рәссамнар берлегенең 70 еллыгы (Казан, 2006) күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

*Әд.:* З а к и р о в а Э. Буяулары кояшлы көн кебек җылы // Сөембикә. 2001. № 6; Красочный мир детства // Татарстан. 2006. № 7.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Легия Фәйзрахман кызы (25.5.1935, Казан), химик-технолог, Соц. Хезмәт Герое (1971). Казан химия-технол. техникумын тәмамлый (1969). 1954–92 елларда В.И.Ленин исем. ФҖБдә смена мастеры, өлкән мастер, җыю цехы бригадиры (1969 дан). Рационализаторлык тәкъдимнәре бар. Герой исеме 8 нче бишьеллык планнарын (1966–70) һәм соц. йөкләмәләрне үтәгәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. ВЦСПСның 17 нче съезды (1982) делегаты. Берничә тапкыр «Иң яхшы җитештерү участогы остасы» исеменә лаек була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Предприятие музеенда Мөхәммәтҗановлар династиясенә багышланган стенд куелган.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; К а з а к о в В.С. 210 лет на службе Родине. К., 1988; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Любовь Рөстәм кызы (25.11.1971, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (2005). Студент вакытында И.М.Оксман стипендиаты була (1993). Казан мед. ун-тын тәмамлаганнан соң (1994), Казан ГИДУВының дәвалау стоматологиясе кафедрасында эшли. 1996 елдан Казан шәһәренең 16 нчы хастаханәсе поликлиникасында табиб-стоматолог. 1999 дан Казан мед. ун-тының дәвалау стоматологиясе кафедрасында. Хезмәтләре пародонтозны дәвалауда остеотроп препаратлар кулланууның нәтиҗәлелеген өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Стоматологические аспекты ишемические болезни сердца. К., 2002 (автордаш); Капилар в комплексном лечении генерализованного пародонтита // Успехи совр. естествознания. 2003. № 10; Эффективность применения остеотропных препаратов в процессе ортодонтического лечения больных с заболеваниями пародонта // Ортодонтия. 2004. № 2 (12) (автордаш).

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Фәридә Шамил кызы (1.8.1965, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2002), проф. (2005), РМА мөхбир әгъзасы (2012). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1987), В.И.Ленин Үзәк музееның Казан ф-лында эшли. 1994 елдан Казан технол. ун-тының гуманитар белем бирү кафедрасында. 1996 дан Республика дистанцион һәм максатчан укыту үзәгендә белем бирү буенча директор. 2003 тән Казан социаль-юридик ин-ты ректоры. 2006 дан Казан һөнәри пед. көллияте директоры. 2012 дән РМАнең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-ты директоры. Хезмәтләре дистанцион укыту, социаль эшләр белгечләре әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Подготовка специалиста социальной сферы в регионе: Психолого-педагогические концепции, инновационные парадигмы. К., 2000; Теория и практика дистанционной подготовки специалиста социальной сферы в регионе. К., 2002; Интеграционные процессы в современном профессиональном образовании. К., 2013 (автордаш).

**МӨХӘММӘТҖА́НОВА** Флёра Габделбәр кызы (17.2.1958, Арча р-ны Пөшәңгәр а.), педагог, пед. фән. д-ры (2003), проф. (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1980). 1985 елдан Алабуга пед. ин-тыда, 1996–2003 тә психол. каф. мөдире, бер үк вакытта, 2002 дән, психол. һәм пед. ф-ты деканы. 2003 тән Социаль белем бирү академиясендә (Казан) пед. һәм пед. психол. каф. мөдире, 2011 дән фәнни-тикшеренүләр бүлеге башлыгы. 2014 тән «ТИСБИ» идарә ун-ты проректоры. М. югары уку йортларында студентларны шәхес буларак үстерү һәм формалаштыру концепциясен эшли, мәгариф өлкәсендә шәхси-дифференцияләнгән, субъектлы һәм төрле яклап якын килү проблемаларын тикшерә.

Х е з м.: Формирующие силы субъектности студента. К., 2008; Негосударственный вуз как субъект образовательной деятельности в регионе. К., 2014 (автордаш)..

**МӨХӘММӘТЛАТЫ́ЙПОВ** Филор Госман улы (13.4.1946, Уфа ш.), икътисадчы, социол. фән д-ры (1991), проф. (1992). Урал ун-тының филос. ф-тын тәмамлый (Свердловск ш., 1974). 1970–74 елларда Уфа авиация ин-тының социол. лаб-ясе хезмәткәре. 1974–79 да Башкортстанда беренчеләрдән булып Уфа телефон аппаратлары з-ды каршындагы социол. хезмәтен җитәкли. 1979 дан Башкорт ун-тында, хезмәт социологиясе һәм эшмәкәрлек икътисады каф. мөдире (1990 нан). Тикшеренүләре хезмәтнең концептуаль модельләренә, җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә карый.

Х е з м.: Социоэкономика труда: Парадигма и реалии. Уфа, 1994; Работодатель и наёмный работник: Системное исследование. Уфа, 1997; Концептуальные модели экономики труда и общественного развития. Уфа, 2000.

**МӨХӘММӘ́ТОВ** Баязит Шәймәрдан улы (5.4.1931, Актаныш р-ны Югары Богады а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1989). Минзәлә пед. уч-щесен (1951), Свердловск югары партия мәктәбен (1963) тәмамлый. 1948 елдан Актаныш р-нында: Югары Богады башлангыч мәктәбендә, Яңа Богады, Иске Кормаш, Меңнәр җидееллык мәктәпләрендә укыта; 1956–59 да ВЛКСМ райкомының 1 нче секретаре; 1963–65 тә «Октябрьнең 12 еллыгы» к-зында, Киров исем. с-зда партком секретаре; 1965–69 да КПСС район ком-тының 2 нче секретаре, 1969–87 дә район башкарма ком-ты рәисе; 1987–2003 тә 80 нче Актаныш һөнәр уч-щесе директоры. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ТАССР, ТР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Актаныш р-ның Мактаулы гражданы (1991). Актанышның бер урамына М. исеме бирелә (2001).

**МӨХӘММӘ́ТОВ** Самат Әхмәт улы (26.5.1907, Казан губ., Спас өязе Иске Салман а. — 7.8.1942, Казан), хакимият эшлеклесе. Совет-партия мәктәбен (Артёмовск ш., Украина ССР, 1929), Татар коммунистик ун-тын (Казан, 1931), Татар югары коммунистлар а.х. мәктәбен (Казан, 1933), ВКП(б) ҮК каршындагы Я.М.Свердлов исем. Югары пропагандистлар мәктәбен (Мәскәү, 1937) тәмамлый. 1922 елдан Украинада: аяк киеме ф-касында мастер ярдәмчесе (Мариуполь ш.), 1925–27 дә шахтада вагон йөртүче (Лисичанск ш.), 1929–30 да Совет партия мәктәбенең уку бүлегендә секретарь (Артёмовск ш.). 1933 тән Әтнә р-ны МТСының сәясәт бүлеге г-тасы, Әтнә р-ны «Колхоз ударнигы» г-тасы мөхәррире. 1937 дән ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында: инструктор, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, 1938 дән пропаганда секретаре, 1942 дән 2 нче секретарь. 1938–42 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

**МӨХӘММӘ́ТОВА** Әлфия Фәхретдин кызы (15.4.1956, Төмән өлкәсенең Югра р-ны Вяткино а.), нәкышьче, график, бизәүче рәссам, педагог, РФ атказ. мәдәният хезмәткәре (2007). Түбән Тагил пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1979). 1979–84 елларда Мегион шәһәренең 2 нче урта мәктәбендә укытучы (Ханты-Манси авт. округы), 1989–2006 да үзе үк оештырган этнографик юнәлешле Балалар шәһәр сәнгать мәктәбе һәм Төньяк балалар иҗаты музее директоры. 2006 дан Төмән шәһәрендә, «Төньяк балкышы» ҖЧҖнең (сәнгать салоны) ген. директоры. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1996). М. — күпкырлы рәссам. Ерак Төньяк табигатенә һәм анда яшәүчеләргә хас ачыклыгы, үзенчәлекле образлылыгы б-н аерылып торган әсәрләр авторы, аның картиналары халык риваятьләре чагылышы булган әкияти һәм хыялый ассоциацияләр б-н тулган. М.ның әсәрләре — нәкышь картиналары, графика (станлы табаклар һәм китап иллюстрацияләре), коллаж яки ефәктәге бизәк (батик) — сәнгать теленең декоративлыгы, композиция үзенчәлекләре (фәзаи планнар тәңгәллеге), орнаментлар һәм колоритлар куелыгы б-н җәлеп итәләр. М.ның иҗади үзенчәлегендә татар декоратив культурасына якын торган ханты-манси сәнгатенең орнаментлар байлыгы зур роль уйный: «Орнамент» батик композицияләре (1989), «Чәчәкләр төше» (1996), «Мәхәббәт» (1998) диптихы, «Ак авазлар», «Хикәя» (икесе дә — 1999), «Алтын кош», «Болан авазы» (икесе дә — 2000), «Югра» сериясе (1997–2000). М. батик б-н беррәттән нәкышь һәм графика өлкәсендә дә үзенчәлекле авторлык стилистикасына ия пейзаж (киндер, майлы буяу — «Кара болыт», 1995; «Тундра җырлый», 1997; «Поляр йолдыз», 1999; акварельле монотипия — «Торум», «Мәңгелек», икесе дә — 1999; «Аганада көз» акварельләр сериясе, 1999), портрет (киндер, майлы буяу — «Аули», «Утчани — ак әби», «Шаман», барысы да — 1990; «Чехломейдан Света Покачёва портреты»; «Төньяк кызы» монотибы, 1995), композицияле картиналар («Шаман», 1995; «Аюлар бәйрәме», 1997; «Каен тузына язылган хикәя», 1998; «Аннэга багышлыйм», 1995; «Төньяк» монотипия триптихы, «Зәңгәр төньяк» монотипия һәм акварель триптихы, икесе дә — 1999; тушь б-н ясалган «Ана» рәсеме, 1995) жанрларында да уңышлы эшли. М. ханты шагыйре Ю.К.Вәлланың «Ак авазлар» китабына (Сургут ш., 1996), Н.Смирновның «Фетнә» повестена (Нижневартовск, 1997), Мегион авторларының «Төньяк күге астында» чәчмә һәм шигъри әсәрләр җыентыгына (Нижневартовск, 2001) һ.б.га иллюстрацияләр ясый. Аның әсәрләреннән иллюстрация һәм репродукцияләр «Югра» ж-лында, «Эринтур» альманахында басыла. М. — уку-укыту процессына, рәссамнар иҗатына, гамәли бизәлеш сәнгате өлкәсендәге орнаментларга һәм халык осталыгына; Ханты-Манси округындагы сәнгать мәктәпләрендә гамәли бизәлеш сәнгатен укыту программаларына багышланган язмалар авторы (2000, 2002). Төмән өлкәсенең сынлы сәнгать буенча В.И.Муравленко фонды бүләге лауреаты (2005). Шәһәр (Нижневартовск ш., 1987 дән; Мегион ш., 1989 дан), округ («Сәнгатьле Югра», Лангепас ш., 1996, 2001), өлкә (Мегион, Төмән, Тобол, 1990 нан), бөтенроссия («Россия рәссамнары», Мәскәү, 1993; «Сәнгать-сәнәгать күргәзмәсе», Новгород ш., 1996; «Россия — безнең йортыбыз», 2002), халыкара (София ш., Болгария, 1991), Фин-угор халыклары фестивале (Ханты-Мансийск ш., 2002) күргәзмәләрендә, ш.у. «Татарларның гамәли бизәлеш сәнгате: үткәне һәм киләчәге», «Төрки сәнгать» (икесе дә — Тобол ш., 2002) һәм «Пленэр» халыкара симпозиумы (Залаэгерсег ш., Венгрия, 2005) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Нижневартовск (1989, 1991 дә Ю.А.Бычков б-н бергә; 1994, 2000), Төмән (1992, 1997), Ноябрьск (1993), Лангепас (1994, 1995), Ханты-Мансийск (1995, 1998), Мегион (1996, 1998, 2000), Покачи (1996), Тобол (2001), Когалым (2001) шәһәрләрендә уза. Әсәрләре Германия, Кытай, Япония, АКШ, Болгария, Финляндия, Венгриядә шәхси тупланмаларда саклана.



Ә.Ф. М ө х ә м м ә т о в а. «Шаман». 1990. Мегион ш. музее.



Ә.Ф. М ө х ә м м ә т о в а. «Зәңгәр төньяк». Триптихның беренче өлеше. Акварель, монотипия. 1999. Нижневартовск ш. музее.

Х е з м.: Рисунки из стойбища: Первый сборник графических работ. Шадринск, 1992; Декоративно-прикладное искусство народов Севера. Мегион, 2000 (автордаш).

*Әд.:* Б о р к о Т. Творчество Альфии Мухаметовой, художника, директора детской художественной школы г.Мегиона // Югра. 1995. № 4; Альфея Мухаметова. Живопись, графика, декоративно-прикладное искусство: Каталог. Нижневартовск, 2001; Альфея Фахриттиновна Мухаметова: Биобиблиогр. указ. Мегион, 2001.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Газиз Фазлый улы (23. 12.1932, Минзәлә р-ны Яңа Бикчәнтәй а. — 17.2.1972, Казан), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1956). 1958–63 елларда «Чаян» һәм «Ялкын» ж-лларында әдәби хезмәткәр, 1963–65 тә «Совет әдәбияты» ж-лының җаваплы мөхәррире. 1960 та М. «Сер итеп кенә» дигән беренче хикәяләр җыентыгын бастыра. «Йолдызлар астында» повесте (1964) геологлар тормышына һәм хезмәтенә багышлана. «Без әле җирдә яшибез» (1963; русчага



Р.М. Мөхәммәтшин.



Ф.Х. Мөхәммәтшин.

тәрҗемәсе «Мы живём на Земле», М., 1977) повесте һәм «Йөрәктәге эзләр» романында (1971) мәхәббәт, гаилә тормышы, балалар тәрбияләү проблемалары күтәрелә. Шулай да, М.ны үзенчәлекле язучы итеп таныткан жанр — хикәя. Аның иң яхшы үрнәкләре «Мой характер» (М., 1968), «Тәрбия сәгате» (1973), «Кадерле бүләк» (1979) җыентыкларына тупланган. «Тынгысыз төн» комедиясе 1969 да Татар драма һәм комедия театрында куела.

Ә с ә р.: Саумысыз, аккошлар! К., 2006.

*Әд.:* Г ы й л ә җ е в а Н. Газизебез бар иде... // Казан утлары. 2005. № 4.

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Галим (Галимҗан) Мөхәммәтша улы (7.2.1911, Казан губ., Казан өязе Олы Солабаш а. — 10.5.1938, Казан), шагыйрь. Балалар өчен язылган «Үсеш балалары» (1931), «Пионерия» (1932), «Яшьлек» (1933), «Шигырьләр» (1935), «Яшьлек дәвам итә» (1958) шигъри җыентыклары авторы. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* Репрессияләнгән татар язучылары // Казан утлары. 1992. № 3.

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Гарифҗан Садыйк улы (12.10.1941, Чепья, хәзер Балтач р-ны Арбор а.), шагыйрь, ТССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1991). Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1964), Мамадыш р-ны Үсәли (1964–68) һәм Балтач р-ны Чепья (1968–75) урта мәктәпләрендә директор урынбасары, Яңгул урта мәктәбендә (1975–77) директор булып эшли, физика, матем. фәннәре укыта. 1977–91 елларда Балтач р-нында халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1991–2002 дә район хакимияте башлыгы урынбасары. «Яшьлегем кайтавазы» (1993), «Гомерлек язым» (1995), «Бәхет» (2001), «Керим әле урманнарга» (2001); балалар өчен «Уеннан уймак» (1988), «Серләвек» (1999), «Югалган йомгак» (2001) җыентыклары авторы. М. — лирик шагыйрь. Аның әсәрләрендә шәхси кичерешләр белән бергә фәлсәфи эчтәлекле кыска шигырьләр остасы. Әсәрләрендә милли характерның иң матур үрнәкләрен, халык традицияләрен чагылдыра. Аның шигырьләренә композиторлар Р.Яхин, С.Садыйкова, Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари тарафыннан язылган җырлар популярлык казана, 2001 дә «Җырлар тәлгәше» исемле видеокассетасы дөнья күрә. Матбугатта публицистик мәкаләләре басылып килә. Төрек язучылары Ә.Боенага, Й.Тауаслы һәм И.Җанан китапларын татар теленә тәрҗемә итә. «Балтач энциклопедиясе»нең (Т. 1–2, 2006–10) төзүче-мөхәррире.

*Әд.:* Г а т а ш Р. Туган җир гамен тоеп // Казан утлары. 2001. № 10; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

*Г.М.Габделхакова.*

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Йолдыз Галимҗан улы (6.6.1937, Казан — 22.2.2006, шунда ук, Чистай шәһәрендә җирләнә), этнограф, тарих фән. канд. (1974). Казан ун-тын тәмамлый (1966). 1969 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1997–99 да ТР ФАнең Тарих ин-тында. Хезмәтләре керәшен татарларның этнографиясе, татар халкында торак, традицион хуҗалык шөгыльләре, милли аш-су мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. 1977–95 тә татар халкының тарихи-этнографик атласын әзерләү программасы буенча экспедицияләр җитәкчесе.

Х е з м.: Татары-кряшены. М., 1977; Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования: Ист.-этногр. атлас. К., 2002 (автордаш).

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Камил Җиһанша улы (7.1.1931, Кыргызстан ССРның Каракол ш.), урман белгече, а.х. фән. д-ры (1970), проф. (1985), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Казакъстан а.х. ин-тын тәмамлый (1955). 1958–74 елларда Кыргызстан ССР ФАнең Биология ин-тында эшли, биогеоценология лаб-ясе мөдире (1967 дән). 1974–2002 дә Бөтенроссия урман хуҗалыгын химияләштерү фәнни-тикшеренү ин-тында экологик фаразлар лаб-ясе мөдире. 2002–03 тә Бөтенроссия урманчылык һәм урман хуҗалыгы эшләрен механикалаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында баш фәнни хезмәткәр. 2004 тән «Экопродукт» компаниясе директорының фән буенча урынбасары. Төп хезмәтләре урман хуҗалыгында химия чараларын комплекслы экологик зарарсыз куллану мәсьәләләренә карый. М., беренче булып, урман экосистемаларында радионуклидларның бүленеше, күчеше һәм хәрәкәте закончалыкларын ачыклый; радионуклидлар б-н зарарланган урман продукциясен сертификатлаштыру һәм куллану буенча нормативлар һәм кулланмалар эшли; утыртмаларның гомуми продукциялелеген, аларның биотөрлелеген арттыра һәм, радиация хәвефсезлеге таләпләрен саклаганда, норматив саф продукция алырга мөмкинлек бирә торган урман кисү технологиясен һәм алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Почёт ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Можжевеловые леса. М., 1982 (автордаш); Лесное хозяйство в районах расположения атомных электростанций. М., 1996.

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Кәшиф Җиһанша улы (13.9.1926, Кыргызстан ССРның Каракол ш.), хокук белгече, хокук фән. д-ры (1980), проф. (1981), Казакъстан ССРның атказ. хокук белгече (1986). Алма-Ата юридик ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук уку-укыту бүлеге башлыгы булып эшли. 1954–56 елларда Төньяк Казакъстан өлкәсенең чирәм җирләрендәге Докучаев исем. җәнлек үрчетү с-зы парторгы, 1956–63 тә Казакъстан ССР Эчке эшләр министрлыгының махсус урта мәктәбендә уку-укыту бүлеге башлыгы урынбасары. 1963–69 да СССР Эчке эшләр министрлыгы Югары мәктәбенең Алма-Ата бүлегендә дәүләт хокукы каф. башлыгы. 1969–89 да Казакъстан ССР Эчке эшләр министрлыгының (1991 гә кадәр СССР Эчке эшләр министрлыгының) Караганда Югары мәктәбендә шул ук исемдәге каф. башлыгы, 1989 дан профессоры.

Хезмәтләре дәүләт хокукы, законлылыкны ныгыту мәсьәләләренә карый. «Казакъча-русча һәм русча-казакъча юридик терминнар сүзлеге» («Казахско-русский и русско-казахский словарь юридических терминов», А.-А., 1996) авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Верховный Совет союзной республики и проблемы укрепления социалистической законности. Караганда, 1973; Деятельность Президиума Верховного Совета союзной республики по укреплению законности. М., 1975.

*Е.Б.Долгов.*

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Рәфыйк Мөхәммәтша улы (19.2.1955, Чепья, хәзер Балтач р-ны, Борнак а.), ислам дине белгече, сәясәт фән. д-ры (2001), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2007). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1977), РФА КФҮнең Тел, әдәбият, тарих ин-тында эшли (бүленеп: 1984–92 елларда — Казан консерваториясендә). 1996–2006 да ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тының фәнни-методик эш һәм контроль бүлеге мөдире. 2006 дан Россия ислам ин-ты ректоры (Казан), проф. (2006), бер үк вакытта, 2007 дән, — ТР ФА Гуманитар фәннәр бүлегенең академик-сәркәтибе, 2010 нан — ТР ФА Исламны өйрәнү үзәге директоры. Хезмәтләре ислам дине белгечлеге, Татарстанда татар иҗтимагый фикер тарихы, сәясәт фәннәренә карый. «Татар илаһият фикере антологиясе» һәм «Чит илләрдә ислам дине белеме» серияләренең фәнни җитәкчесе. Татар энциклопедия сүзлеген татар һәм рус телләрендә әзерләүгә зур өлеш керткән өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2005). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татары и ислам в XX веке. К., 2003; Ислам в общественной и политической жизни татар и Татарстана в XX веке. К., 2005; Ислам в Татарстане. К., 2009; Молодые мусульмане Татарстана: идентичность и социализация. К., 2012 (автордаш); Islam in Post-Soviet Russia. Public and Private Faces. L.–N.Y., 2002 (автордаш).

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Фәрид Хәйрулла улы (22.5.1947, Әлмәт р-ны Әлмәт а.), дәүләт эшлеклесе, сәясәт фән. д-ры (2001). Уфа нефть ин-тын (1979), Саратов югары партия мәктәбен (1986) тәмамлый. 1963–66 елларда Әлмәт газ-бензин з-дында токарь булып эшли. 1968–70 тә «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсендә контроль-үлчәү приборлары буенча слесарь вазифасын башкара. 1970–89 да Әлмәттә партия һәм хуҗалык эшендә: ВЛКСМ шәһәр ком-тында инструктор (1972–78); халык депутатларының шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары (1978–85); КПССның шәһәр ком-ты секретаре, 2 нче секретаре (1985–87); «Әлмәтнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең катлам басымын бер үлчәмдә тоту өчен технол. сыеклык әзерләү идарәсе башлыгы (1987–88); халык депутатларының шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе (1988–89). 1989–90 да ТАССР

сәүдә министры. 1990 да КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1990–91 дә ТР МС Рәисе урынбасары. 1995–98 дә ТР Премьер-министры. 1998 дән ТР Дәүләт Советы Рәисе. ТР халык депутаты (1990–95), ТР Дәүләт Советы депутаты (1995 тән). РФ Федераль Җыенының Федерация Советы депутаты (1993), әгъзасы (1998–2002). 1999 дан Респ-ка «Татарстан — яңа гасыр» иҗтимагый хәрәкәтенең сәяси советы рәисе, 2003 тән бөтенроссия «Бердәм Россия» сәяси партиясенең Татарстан бүлеге Югары советы әгъзасы, сәяси советы секретаре. 2003 тән Европадагы җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының Төбәкләр палатасы Мәдәният һәм мәгариф ком-ты рәисе урынбасары, рәисе. 2004 тән Европа Советының шул ук исемдәге пленар ком-ты рәисе урынбасары. 2001–05 тә «Зур Идел» ассоциациясе вице-президенты, 2005 тән РФнең Идел буе федераль округындагы субъектларының законнар чыгаручы дәүләт хакимияте органнары җитәкчеләре ассоциациясе координаторы. 1999–2006 да Җирле үзидарә буенча республика советы рәисе. 2007 дән Татарстан халыклары ассамблеясы рәисе. 2011 дән Европа Советының җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының актуаль мәсьәләләр буенча ком-ты рәисе урынбасары, 2012 дән рәисе. 2012 дән РФ Федераль Җыены Федерация Советы рәисенең милләтара мөнәсәбәтләр һәм дәүләтнең дини берләшмәләр б-н үзара багланышлары мәсьәләләре буенча урынбасары. М. ТРда парламентаризм, дәүләтчелек һәм демократия үсешенә, гражданнар җәмгыяте һәм җирле үзидарә ин-тлары барлыкка килүгә, РФ регионнары һәм чит илләр б-н парламентара хезмәттәшлекне нигытуга зур өлеш кертә. Хезмәтләре федерализм, Татарстанның социаль-сәяси һәм икътисади үсеше мәсьәләләренә карый. «Ел спикеры» номинациясендә «Россия милли олимпы» бүләгенә һәм «Намус һәм фидакарьлек өчен» орденына лаек була; Почёт, Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Халыклар дуслыгы (Башкортстан) орденнары, медальләр; РФ хөкүмәте һәм РФ Федераль Җыенының Федерация Советы Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татарстан на перекрёстке мнений: Проблемы, тенденции, перспективы. К., 1993 (автордаш); Республика Татарстан: от референдума до договора. К., 1995; Республика Татарстан в зеркале общественного мнения (90-е годы. Социолого-экономический аспект). К., 1998; Республика Татарстан: Особенности социально-политического развития на рубеже веков. К., 2000; Региональный политический процесс в федеративном и социологическом измерениях. К., 2002 (автордаш); Республика Татарстан: новейшая история: События. Комментарии. Оценки. В 3 т. К., 2000–09 (автордаш).

**МӨХӘММӘ́ТШИН** Фәрит Мөбәрәкша улы (31.1.1947, Апас р-ны Зур Күккүз а.), дипломат, РФ Язучылар берлеге әгъзасы (2009). Казан авиация ин-тын (1970), СССР Тышкы эшләр министрлыгының Дипломатия академиясен (1990) тәмамлый. 1977–87 елларда СССР Яшьләр оешмалары ком-тының җаваплы секретаре урынбасары, бүлек мөдире, рәисе урынбасары. 1990 нан дипломатия эшендә, 1993–95 тә РФ Тышкы эшләр министрлыгы Департаменты директорының 1 нче урынбасары, 1995 нең июленнән ТРның РФдәге тулы вәкаләтле вәкиле, 1999 дан РФ Хөкүмәте Аппаратының Федераль җыен, иҗтимагый оешмалар һәм дини берләшмәләр б-н багланышлар департаменты башлыгы. 2003–08 дә РФнең Үзбәкстан Респ-касындагы гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе. 2008–12 дә БДБ һәм чит илләрдә яшәүче ватандашлар эшләре һәм халыкара гуманитар хезмәттәшлек буенча федераль агентлык җитәкчесе һәм бер үк вакытта РФ Президентының БДБ дәүләтләре б-н багланышлар буенча махсус вәкиле. 2012 дән РФнең Молдова Респ-касындагы гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе.

**МӨХӘРЛӘ́МОВ** Илдус Мөхәммәтша улы (1.1.1946, Казан), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1970). Үзәк физкультура ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1972). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренерлары — Н.И.*Моряшичев*, Г.М.Кондратьев (1963–67), Г.А.Сапунов (1967–72). СССР (1964, яшүсмерләр арасында), Европа (1966, яшьләр арасында), «Италия Зур призы» Европа турниры (1966) чемпионы, И.М.Поддубный исем. призга халыкара турнирда җиңүче (1971). СССР чемпионатында 1965 (бронза), 1970 (көмеш), 1971 (бронза), «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Үзәк советы чемпионатында 1971 (бронза), СССР халыклары спартакиадаларында 1971 (бронза) медальләр ала. 1972–76 да югары спорт осталыгы мәктәбендә, 1976–85 тә Урицкий исем. СКнда, 1985 тән муниципаль берәмлек башкарма ком-тының физик тәрбия һәм спорт ком-тында (Казан) өлкән тренер. Шәкертләре арасында РСФСР, СССР, РФ беренчелекләрендә җиңүчеләр һәм медаль алучылар В.И.Бусыгин, Д.Р.Закиров, Л.М.Кәримов, Н.М.Мөхәрләмов, А.В.Свиридов, Ю.Ю.Станкевич бар.

**МӨХӘРЛӘ́МОВ** Нурмөхәммәт Мөхәммәт улы (4.12.1930, Сәмәрканд ш. — 21.6.1989, Мәскәү), кардиолог, мед. фән. д-ры (1967), СССР МФА мөхбир әгъзасы. Сәмәрканд мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда эшкә калдырыла. 1960 елдан СССР МФАнең Бөтенсоюз клиник фәнни үзәгендә, 1968 дән клиника бүлеге җитәкчесе, проф. (1970). Хезмәтләре кардиология һәм пульмонология өлкәсенә: кардиомиопатия, беренчел үпкә гипертензиясе, йөрәк эшчәнлеге зәгыйфьлеген дәвалау мәсьәләләренә карый. М. җитәкчелегендә 20 ләп диагностика аппараты эшләнә. Уйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт бүләге йөрәк эшчәнлеге зәгыйфьлегенә башлангыч чорында диагноз куюның, авыру барышын күзәтү һәм дәвалау, авыруны кисәтүнең заманча ысулларын эшләп гамәлгә керткән өчен бирелә (1980). СССР МФА каршындагы «Кан әйләнеше зәгыйфьлеге һәм йөрәк ритмы бозылу» проблемалары комиссиясе рәисе. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы каршындагы Кардиомиопатияләр ком-ты әгъзасы, эксперт; 1970–80 елларда СССР Оборона һәм Сәламәтлек саклау министрлыклары каршындагы космонавтларның сәламәтлеген тикшерү буенча баш комиссия әгъзасы.

Х е з м.: Гипертония малого круга кровообращения. М., 1971; Лёгочное сердце. М., 1973; Современные методы диагностики сердечной недостаточности. М., 1974; Кардиомиопатии. М., 1990.

**МӨХӘРЛӘ́МОВ** Роберт Гарәпша улы (21.7.1938, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1977), проф. (1979). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли. 1964 тән Россия Халыклар дуслыгы ун-тында (Мәскәү), теоретик механика каф. мөдире (1988 дән). 1971–73 тә Алжир нефть һәм текстиль үзәгендә (Бумердес ш.), 1986–87 дә — Шанхай технол. ун-тында (Кытай). Хезмәтләре механик системалар динамикасын матем. модельләштерүгә карый. М. нәсызыкча тигезләмәләрне, даими һәм үзгәрешле массалы физик системалар динамикасының кире мәсьәләләрен чишү алымнарын эшли. Каты җисемнең почмаклы хәрәкәте, робот-манипуляторлар, адаптив оптик системалар б-н идарә итү мәсьәләләрен чишү алгоритмнарын һәм программаларын тәкъдим итә.

Х е з м.: Построение систем программного движения. М., 1971 (автордаш); Уравнения программных движений. М., 1986 (автордаш); Уравнения движения механических систем. М., 2001.

**МӨХӘРЛӘ́МОВ** Сабирхан Фәйзрахман улы (5.5.1950, Балык Бистәсе р-ны Үрнәк а.), хуҗалык-хакимият эшлеклесе, ТРның атказ. төзүчесе (1996), техник фән. канд. (1998). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казанда комсомол-партия эшендә. 1990–91 елларда Казанның Вахитов р-ны башкарма ком-ты рәисе, 1992–99 да Вахитов р-ны хакимияте башлыгы. 1999–2007 дә Казан «Органик синтез» ААҖ ген. директоры урынбасары. 2007–10 да «Эндевер», «Иделбанк», «Автокредитбанк», «Татфондбанк» компанияләрендә һәм банкларында җитәкче вазифалар башкара. 2010 нан «Глобаль консалтинг» компаниясендә эчке контроль хезмәте директоры. 1995–2000 дә ТР Дәүләт Советы депутаты. ТАССР ЮС Президиумы, ТР Мактау грамоталары, медальләр б-н бүләкләнә.

**МӨХӘРРӘ́М** (гарәп. محرم — тыелган), мөселман календареның беренче ае. Мөхәррәм аеның беренче ун көне шөкер итү, рәхмәт көннәре дип йөртелә; бу көннәрдә фәкыйрьләргә хәер-*сәдака* бирелә.

**МӨХӘРРӘ́МОВ** Мидхәт Кәрим улы (27.4.1922, хәзер БРның Мәләвез р-ны Җиргән а. — 7.3.1993, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1964), проф. (1967), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1972, 1982). 1938–40 елларда Казан элемтә техникумында эшли. Казан юридик ин-тын тәмамлый (1948). 1940 тан Кызыл Армия сафларында, Сызрань танк уч-щесе курсанты. 1942–44 тә Көньяк-Көнбатыш фронтның 9 нчы армиясе аерым 12 нче танк бригадасының рота командиры, 1 нче танк армиясе 6 нчы танк корпусының элемтә офицеры; капитан. 1951 дән РФА КГҮнең Тел, әдәбият, тарих ин-тында: 1958 гә кадәр гыйльми секретарь, 1959–63 тә

тарих секторы мөдире, 1963–82 дә директор. Хезмәтләре Татарстанда Гражданнар сугышы, милли дәүләт төзелеше тарихына карый. «Татарстан АССР тарихы» («История Татарской АССР», 1960, т. 2), «Татарстан АССР тарихы: иң борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр» («История Татарской АССР: с древнейших времён до наших дней», 1968), «Татарстан АССР тарихы» («История Татарской АССР», 1980), «Татарстан партия оешмасы тарихы очерклары» («Очерки истории партийной организации Татарии», 1962), «Халык бәхете өчен көрәшүчеләр» («Борцы за счастье народное», 1967), «СССРда милли дәүләт төзелеше тарихы. Капитализмнан социализмга күчеш чорында СССРда милли дәүләт төзелеше (1917–1936 еллар)» («История национально-государственного строительства в СССР. Национально-государственное строительство в СССР в переходной период от капитализма к социализму (1917–1936 гг)», М., 1968), «Борынгы шәһәрнең яшьлеге» («Молодость древнего города», 1978), «Көрәш һәм казанышлар елъязмасы: Татарстан партия оешмасы хроникасы: 1883–1985» («Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии: 1883–1985», 1985, 1 кит.), «Татарстанда культура революциясе (1917–1937 еллар)» («Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг.)», 1986) күмәк хезмәтләре авторларының берсе. Окт. рев-циясе, Гражданнар сугышы, ТАССР төзелү тарихына караган документлар һәм материаллар җыентыгын әзерләүдә катнаша. Ленин ордены, ике Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из истории иностранной военной интервенции и гражданской войны на территории Татарии (1918–1920 гг.). К., 1954; Октябрь и национально-государственное строительство в Татарии. М., 1969; В те годы огневые (В.И.Ленин и борьба за власть Советов в Татарии). К., 1985.

*Әд.:* Памяти М.К.Мухарямова. К., 1995.

**МӨХӘРРӘ́МОВ** Наил Мидхәт улы (21.1.1953, Казан), сәясәт белгече, сәясәт фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли. 1996 елдан Казан энергетика ун-тында, сәясәт белеме һәм хокук каф. мөдире. Бер үк вакытта, 2004 тән, шул ук ун-тның икътисад һәм социаль технологияләр ин-ты директоры, 1999 дан ТИСБИ (Татарстан бизнеска ярдәм итү ин-ты, Казан) идарә академиясенең халыкара мөнәсәбәтләр каф. мөдире, 2012 дән Казан ун-тының Гаммәви коммуникацияләр һәм социаль фәннәр ин-ты директоры. Хезмәтләре теоретик һәм гамәли этносәясәт белеменә, төбәкне сәясәи өйрәнүгә һәм тел белеменә карый.

Х е з м.: Интернационалистические тенденции в истории революционного демократизма. К., 1984; Вопросы теории этнополитического анализа. К., 1996; Политическая лингвистика как научная дисциплина // Политическая наука. 2003. № 3.

**МӨХӘРРӘ́МОВА** Ләйсән Мөҗип кызы (12.1.1960, Сарман р-ны Сарман а.), сәясәт белгече, филос. фән. канд. (1986), сәясәт фән. д-ры (2004). Казан ун-тының тарих ф-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан мед. ун-тында эшли: проректор (1999 дан), бер үк вакытта тарих һәм социол. каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре сәяси тел белеменә, мед. социологиясенә, мәгариф социологиясенә карый.

Х е з м.: Языковые отношения: Политологический анализ. К., 2003; Российская Федерация: Язык и политика в условиях постсоветского развития // Государственная служба. 2004. № 4; Политическая лингвистика: Становление понятийного аппарата // Вестн. Моск. ун-та. Сер. Политические науки. 2004. № 3.

**«МӨХБИ́Р»** («المخـبر»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Урал өлкәсенең мөселман Милли Шурасы органы. 1917 елның 10 октябреннән 1918 нең 3 мартына кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 19 саны чыга. *«Хәбәрләр»* г-тасының дәвамчысы. Мөхәррире — Г.Ишмөхәммәтов. Газетада төп игътибар өлкәдәге мөселман җәмгыяте тормышы б-н бәйле проблемалар һәм вакыйгаларга юнәлтелә. «М.» — анык кына сәяси юнәлеше булмаган, урталыкны тоткан басма. Совет хакимияте органнары тарафыннан ябыла. *Т.М.Насыйров.*

**МӨХЕТДИ́НОВ** Әсгать Әхмәт улы (13.5.1941, Беренче Май р-ны Иске Кади а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1994), проф. (1995). 1966 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Түбән Кама химия комб-тында эшли. 1967 дән Казан технол. ун-тында (1980–84 тә Сетиф ун-тында, Алжир). Хезмәтләре резина сәнәгатендә инженерлык экологиясенең физик-химик нигезләренә карый. М. резин тотрыклыландыргычлар һәм резин катнашмалардагы вулканлаштыручы күкертле системаларның порошоксыман агулы компонентларын модификацияләүнең төрле ысулларының экологик аспектларын өйрәнә. Бинар һәм катлаулы эретмәләрдә кристаллик компонентларны модификацияләү мөмкинлеген фаразлау өчен, ингредиентларның кристалл-химик характеристикаларын, квант-химия хисаплауларын һәм молекуляр диаграммаларын эшли. Күп функцияләргә сәләтле кушылмалар алу өчен аларның ингредиентларын диалкилфосфит һәм диорганодитиофосфат к-талары чыгарылмалары б-н химик модификацияләү юлын тәкъдим итә. Күкертле вулканлаштыру системаларында һәм стабилизаторларда аминлы компонентлар урынына мондый кушылмаларны куллану нәтиҗәсендә резин эшләнмәләрне вулканлаштыру процессында канцероген нитрозоаминнарның кимрәк хасил булуын күрсәтә. Тузан һәм газ рәвешендәге зарарлы ташландыклар буенча белешмәләр китерә, аларның агулау үзлекләрен аңлата һәм шиннар җитештерүнең аерым стадияләрендә экологик хәлне яхшырту юлларын күрсәтә. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Основы и менеджмент промышленной экологии: Учеб. пособие. К., 1998 (автордаш); Экологические аспекты модификации ингредиентов и технологии производства шин. К., 1999 (автордаш); Шина: Некоторые аспекты производства и эксплуатации. К., 2000 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МӨХЕТДИ́НОВ** Иршат Закир улы (6.2.1929, Казан — 11.8.2008, шунда ук), сәламәтлек саклау эшлеклесе, эпидемиолог, мед. фән. канд. (1966), РСФСРның атказ. табибе (1974). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1956–64 елларда ТАССРның баш санитария табибе, Респ-ка сан.-эпид. станциясенең баш табибе. 1964–84 тә ТАССР сәламәтлек саклау министры. 1984–94 тә Казан мед. ин-тының эпидемиология каф. мөдире, бер үк вакытта (1986–89) Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1994 тән Казан мед. ин-тының эпидемиология кафедрасы киңәшчесе. 1960–80 елларда М. җитәкчелегендә респ-када сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди-техник базасы ныгытыла: Респ-ка балалар клиник хастаханәсе (1977), Респ-ка клиник хастаханәсе (1982), Чаллы шәһәрендә киң профильле хастаханә төзелә; барлык эре торак пунктларда участок хастаханәләре, район үзәкләрендә үзәк район хастаханәләре булдырыла. Хезмәтләре корсак тифы, эчәк инфекцияләре эпидемиологиясе һәм аларны булдырмауга карый. 1967–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, РСФСР һәм ТАССР ЮСлары Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Как предупредить кишечные заболевания. К., 1977; Диагностика и лечение вирусного гепатита у детей. К., 1979.

*Әд.:* Казанский государственный медицинский институт (1804–2004): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**МӨХЕТДИ́НОВ** Кәбир Хәял улы (6.6.1906, Казан губ., Зөя өязе Олы Кошман а. — ?), җылылык техникасы инженеры, «Казэнерго» район энергетика идарәсе управляющие (1942–52). Урта Азия политехник ин-тын тәмамлый (Ташкент, 1931). 1925–26 елларда Ташкент төбәк кооперациясе һөнәрләр берлеге идарәсе секретаре булып эшли, волость җир-су реформасы комиссиясе рәисе (Үзбәкстан ССРның Фирганә өязе Мәрхәмәт а.). 1931–32 дә Үзбәкстан ССРның Фирганә р-ны Кувасай станциясендә ГРЭС төзелеше башлыгы урынбасары. 1932–34 тә Казанда ТЭЦ-1 төзелеше һәм аны сафка бастыру җитәкчеләренең берсе (Татарстан Социалистик Төзелеш Батыры, 1933). 1934–42 дә Казандагы ТЭЦ-2 дә: монтаж бүлеге, котельный цехы башлыгы, баш инженер урынбасары, баш инженер (1939–41), монтаж һәм капиталь төзелеш буенча директор ярдәмчесе (1941 дән). 1952–58 дә Воронежда ТЭЦ-1, Яңа Воронеж атом электр станциясе төзелеше башлыгы, 1958–66 да Воронеждагы ТЭЦ-2 директоры. М. җитәкчелегендә файдалануга тапшырылучы яңа һәм Бөек Ватан сугышы елларында эвакуацияләнгән сәнәгать пр-тиеләренең энергетик куәтләрен үстерү гамәлгә ашырыла, Урыссу ГРЭСы төзелә, нефть чыгару сәнәгате үсә барган районнарны электрлаштыру башлана. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974.

**МӨХЕТДИ́НОВ** Насыйх Камал улы (1892, Чистай өязе Аппак а. — 10.7.1937, башка чыганаклар буенча 1943, Казан), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый, 1912 елда Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый, Казанда рус-татар башлангыч уч-щесендә һәм «Касыймия» мәдрәсәсе каршындагы рус сыйныфында эшли. 1918 дән Казан губернасы һәм ТАССР Халык мәгарифе органнарында. 1922–24 елларда Кырым АССР мәгариф халык комиссары. 1924 тән Шәрекъ пед. ин-тында, 1926 дан ТАССР Мәгариф халык комис-тында, халык комиссары урынбасары, 1929 дан халык комиссары, 1930 дан яңадан Шәрекъ пед. ин-тында. Бер үк вакытта, 1924–30 да, *Академүзәк* рәисе урынбасары, татар мәктәпләре өчен дәреслекләр нәшер итү б-н җитәкчелек итә. Педагогика һәм педагогика тарихы буенча татар телендә беренче уку ярдәмлекләре төзи. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Мәктәптә җәмгыятькә файдалы эшләр һәм аларны туган илне өйрәнүгә бәйләү (Авыл мәктәпләре укытучыларына кулланма). К., 1927; Мәктәптә җенси тәрбия мәсьәләләре. К., 1928; Педагогия тарихы. К., 1929.

*Әд.:* Х а н б и к о в Я.И. История педагогики татарского народа. К., 1975.

**МӨХЕТДИ́НОВ** Тимур Мөхәммәтсабир улы (26.1.1975, Төмән өлкәсенең Төмән р-ны Ямбай а. — 23.10.2010, Хасавюрт ш., Дагстан Респ-касы; туган авылында җирләнә), милиция майоры, Россия Герое (2011). 1999 елдан РФ эчке эшләр органнарында; 2009 дан Төмән өлкәсе буенча Эчке эшләр идарәсе махсус бурычлар башкаручы милициясе отрядының сугышчан отделениесендә аеруча мөһим эшләр буенча оперуполномоченный. Берничә тапкыр Төньяк Кавказда хезмәт командировкасында була. 2010 елның 23 октябрендә батырлык күрсәтә: үлемгә барган террорчыларның Россия гаскәрләре базасына һөҗүмен үз гомере бәрабәренә булдырмый кала, дистәләрчә кешене һәлакәттән коткара. Геройның исеме Ямбай авылындагы бер урамга бирелә, мемориаль такта урнаштырыла. Медальләр б-н бүләкләнә. *Ф.Г.Миңнеханов.*

**МӨХЕТДИ́НОВА** Әминә Фәсах кызы (8.9.1893, Казан — 26.12.1944, Красноярск крае Енисейск ш.), хокук белгече, сәясәт эшлеклесе. Кыз балалар гимназиясен (1914), Казан ун-тын (1919), Кызыл профессура ин-тын (Мәскәү, 1934) тәмамлый. 1917 елда Мөселман социалистлар ком-ты рәисе урынбасары, ком-т уставының хатын-кызлар арасында эш алып бару турындагы бүлеге авторы. 1917 нең апрелендә Бөтенроссия мөселман хатын-кызлар корылтае эшендә катнаша, татар хатын-кызларына икътисади һәм гражданлык ирекләре бирү таләбе б-н чыга. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (Мәскәү, 1917 нең мае) «Татар хатын-кызының социаль революциядәге роле» доклады б-н чыгыш ясый. *Милләт Мәҗлесе* депутаты (1917–18). Үзәк мөселман комис-тының гыйльми коллегиясе рәисе. 1919 ның июлендә Кызыл Армиядә сәяси эш алып барырга җибәрелә. 1920–21 дә ТАССР юстиция, мәгариф халык комиссары урынбасары. 1922–24 тә Симферополь революцион трибуналы, Кырым АССР Баш мәхкәмәсе прокуроры. 1924–26 да ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты җаваплы секретаре, ВКП(б)-ның Татарстан өлкә ком-ты әгъзасы, Татарстан ҮБК әгъзалыгына кандидат. 1926–28 дә ТАССР Юстиция халык комис-ты прокуроры ярдәмчесе. 1928–30 да РСФСР Югары мәхкәмәсе комиссиясе әгъзасы, 1936 дан ВКП(б) ҮК Аппаратында, нәшрият эшләре һәм матбугат бүлеге мөдире ярдәмчесе. 1937 дә репрессияләнә (к. *«Идел-Уралчылар оешмасы» эше*); үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С м и р н о в а В. Мухитдинова Аминя Фасаховна // Борцы за счастье народное. К., 1967; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*М.А.Сәйдәшева.*

**МӨХЕТДИ́НОВА** Надирә Мохтар кызы (6.7.1948, Мәскәү), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994). 1971 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү гражданнар авиациясе инженерлары ин-тында укыта. 1992–93 елларда РФ Хәрби көчләре секторы мөдире. 1994 тән РФ Федерация Советы аппаратының Аналитик идарәсе җитәкчесе урынбасары, киңәшче. Хезмәтләре дөнья икътисады, чит ил инвестицияләре проблемаларына, РФ һәм аның төбәкләренең инвестицияләр сәясәтенә карый. РФ Дәүләт Думасында экспертлар советлары әгъзасы.

Х е з м.: Совместное предпринимательство ТНК: Движущие силы и противоречия. М., 1991; Как инвестировать за рубежом: Пособие для российских предпринимателей. М., 1993 (автордаш); Инвестиционная политика в современных условиях. Чебоксары, 1996 (автордаш).

**МӨХЕТДИ́НОВА** Фәридә Ибраһим кызы (3.12.1954, Казан), патофизиолог, терапевт, мед. фән. д-ры (1991), проф. (1994). М.М.*Миңнебаев* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук патофизиол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре бизгәк реакциясе патофизиологиясенә карый. М. кисәк барлыкка килгән аллергия һәм бизгәк реакциясе вакытында лимфа системасының резорбция һәм транспорт функцияләрендә үзгәрешләр күзәтелүне, ш.у. лимфа төеннәрендә морфофункциональ үзгәрешләр килеп чыгуны ачыклый.

Х е з м.: Лимфатическая система и гомеостаз при лихорадочной реакции // Казан. мед. журн. 1994. № 3; Клиническая патофизиология сердца и сосудов. К., 2004; Лимфатическая система и лихорадочная реакция. К., 2008; Краткий русско-татарско-английский толковый словарь медицинских терминов. К., 2009 (автордаш).

**МӨХИЯ́РОВА** Рәзинә Хәйбрахман кызы (26.5.1956, БАССРның Чакмагыш р-ны Аблай а.), шагыйрә, тел белгече, филол. фән. канд. (1999). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), авыл мәктәбендә укыта. 1982 елдан Чаллы урта мәктәбендә, 1992 дән Чаллы пед. ин-тында укыта (2003–05 елларда татар теле һәм аны укыту методикасы каф. мөдире, 2006 дан проф.). «Сиңа булсын җырым» (Чаллы, 1997), «Шәмдәлләрдә утлар» (2001), «Алиһә» (2003), «Тыңла мине» (2004), «Җидегән йолдыз» (2007), «Энҗе тездем сүзләрдән...» (2011) шигъри җыентыклары авторы. Хезмәтләре лексикология, укыту методикасы, хәзерге татар теленең лингвистик поэтикасы мәсьәләләренә карый.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

**МӨХЛИ́СОВ** Фоат Габдулла улы (23.7.1935, Мамадыш р-ны Югары Ошма а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Себер бүлегенең Матем. ин-тында (Новосибирск ш.) эшли. 1962–90 елларда Казан авиация ин-тында. 1990 нан Татар гуманитар-пед. ун-тының матем. анализ каф. мөдире. Хезмәтләре матем. физиканың классик булмаган тигезләмәләре өчен кырый мәсьәләләргә карый. М. чикләнмәгән өлкәләрдә сингуляр эллиптик тигезләмәләр өчен кырый мәсьәләләрнең бердәнбер чишелешен тәэмин итә торган шартлар таба; гомуми тайпылыш операторы тудырган потенциал теориясен төзи; өлкәләрнең чиксезлектәге бүленеше чикләрендә иярешлелек шартларыннан чыгып, дифракциянең матем. теориясе мәсьәләсе бердәнбер чишелешкә ия булуын исбатлый.

Х е з м.: О существовании и единственности решения одной сингулярной задачи математической теории дифракции // Дифференциальные уравнения. 1989. Т. 25, № 12; Обобщённое решение задачи типа Дирихле для некоторых сингулярных эллиптических уравнений // Сибирский мат. журн. 1990. Т. 31, № 15; Потенциалы для некоторых сингулярных волновых уравнений // Неклассические уравнения мат. физики. Новосиб., 2002.

**МӨХСИ́Н** әш-Шаши (? — 1831), дин эшлеклесе, педагог. Бохара уку йортларында укыта. Урта Азия уку йортлары шәкертләре арасында абруй казанган галим-педагогларның берсе.

**МӨХТА́РОВ** Апуш (Габдулла) Сабир улы (1.1.1955, Әгерҗе ш.), химик аппаратлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2001). 1980 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1993–96 елларда күппрофильле «Контур» кече пр-тиесе директоры, 2000–03 тә Әлмәт нефть ин-тының проректоры һәм инж. графикасы каф. мөдире), 2003 тән машина детальләре каф. профессоры. Хезмәтләре химия технологиясе процесслары һәм аппаратларына карый. М. сусызландыру процессларын исәпләүнең методологик нигезләрен эшли, дымлылыкны бетерү өчен оптималь аппаратлар системасын тәкъдим итә (ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Кече пр-тиене үстерүнең перспективалылыгын исәпләү өчен эксперт программа төзи. Уйлап табуга 39 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Выбор оптимальной системы аппаратов и режимов при удалении влаги из суспензий и высоковлажных материалов // Тр. 3 Минского междунар. форума по тепло- и массообмену. Минск, 1996 (автордаш); Декомпозиционно-гипотетический подход как основа оптимального расчёта систем аппаратов обезвоживания // Успехи химии. 2000. Вып. 14.

**МӨХТӘСИ́Б** (гарәп. محتسب — тикшерүче), урта гасырларда базарлардагы тәртипне күзәтеп һәм сәүдә кагыйдәләрен тикшереп то-

рырга, ислам әхлагы нормаларын бозуга юл куймаска тиешле зат. Оренбург Мөхәммәди дини канун Җыены оештырылганчыга кадәр, татарларда М.нең дини иерархиядәге урыны *ахуннан* кала икенче булган, ләкин соңыннан, мөфтиятләр төзелгәч, ахун һәм М. вазифалары мөфти, казый һ.б. кулына тапшырылган, әмма бу үзгәрешләр хокукый ныгытылмаган, М.нең статусы аныкланмыйча калган. Шуңа карамастан, иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә шәригать кануннарының саклануын контрольдә тоту буенча түбәнрәк дәрәҗәдәге дин әһелләренә караганда М.кә киңрәк вәкаләтләр бирелгән. 1992 елда ТР мөселманнарының Диния нәзарәте төзелгәч, М.ләр ин-ты яңадан торгызыла. ТРның барлык районнарында имам-мөхтәсиб җитәкчелегендәге мөхтәсибәтләр оештырыла. 1998 дән республиканың баш М.е дә сайлана башлый. Ш.у. к. *Мөселман руханилары.*

*Әд.:* Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 2006. Т. 1.

**МӨҺАҖИРЛӘ́Р ХӘРӘКӘТЕ́**, Идел-Урал буе татарлары арасында, патша хөкүмәте тарафыннан татарларны милли, дини, социаль яктан изүнең көчәюенә җавап итеп, Россияне ташлап Төркиягә күчеп китү хәрәкәте. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан 20 йөз башына кадәр дәвам итә. Мөһаҗир (гарәп. *һиҗрәт* итүче, күченүче) атамасы башлап Мөхәммәд пәйгамбәр б-н Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт иткән (622) беренче мөселманнарга карата кулланыла. Соңрак дини һәм социаль сәбәпләр б-н ислам дине хакимлек иткән илләргә күченеп китүчеләрне мөһаҗирләр дип йөртә башлыйлар. 18 йөздә, Идел һәм Урал буенда яшәгән рус булмаган халыкларны мәҗбүриләп христианлаштыру сәясәте көчәйгәч, татарларның Төркиягә китү очраклары була. 1890 елда Россия Эчке эшләр министрлыгы илнең төрки халыклары вәкилләренә илдән күченеп китү хокукы бирә. 1892–94 тә татарлар Казан, Вятка, Уфа, Оренбург губерналарыннан күченәләр. Казан губернасыннан 400 гаилә Төркиягә күченү хакында бу ил хакимиятенә үтенеч б-н мөрәҗәгать итә. Күпләп күченүләргә, гадәттә, халык арасында мөселманнарны чукындыру хәрәкәте башланачагы турында хәбәрләр таралу сәбәп була. 1896–97 дә, Россиядә беренче гомуми халык санын алу б-н бәйле рәвештә, М.х. кабат көчәя, чөнки татарлар сан алуны хакимиятнең мөселманнарны чукындыруга юнәлдерелгән әзерлек чарасы дип кабул итәләр. 1900 дә император Николай II төрки халыкларның чит илләргә чыгуын тыя, ләкин М.х. 20 йөз башында да дәвам итә. Милләттәшләренең Төркиягә күченеп китүен татар зыялыларының бер өлеше кабул итә алмый. Г.Тукай «Китмибез» (1907) шигырендә болай дип яза:

«Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?

Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә ник керик?»

М.х. М.Г.Галәүнең «Мөһаҗирләр» романында (беренче тапкыр 1934 тә Мәскәүдә рус телендә «Мухаджиры» исеме б-н басылып чыга, татар телендә 1977 дә дөнья күрә) чагылыш таба.

*И.К.Заһидуллин.*


**МӨҺЕ́Р ЙӨЗЕ́К**, бадәм формасындагы йөзек мөһере, штамп, хәтем, тамга. 14–17 йөзләргә караган рәсми документларда йөзек-мөһер һәм бадәм-мөһер төрләре искә алына. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында мондый М.й. хакимлекнең, ягъни хан булуның рәсми билгесе (шаһәдәтнамәсе) булган тигез дүртпочмаклы (квадрат) *тамгадан* аермалы буларак, ханның яки хан гаиләсе әгъзаларының шәхси М.й.е булган. М.й.нең язуында (легендасында) хуҗаның исеме, титулы һәм атасының исеме, ә хан М.й.ендә нәсел гербы да күрсәтелгән. Татар сәүдәгәрләре һәм дин әһелләре соңрак үз шәхесләрен турыпочмаклы, түгәрәк, овал формасындагы М.й. тамгасы басып раслауны гадәткә кертәләр. Әлеге төр М.й. тамгаларының, башлыча, хатлар һәм кулъязмаларга басылган күпсанлы үрнәкләре ТР Милли музее фондларында саклана.

*Әд.:* Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979.

*М.Г.Госманов.*

**МӨЧӘЛИ́** авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 10 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 384 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1666 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М. дә волость идарәсе урнаша, 3 мәчет, 3 мәдрәсә, рус-татар земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1966 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мөчәли волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 1003, 1897 дә — 1477, 1913 тә — 2003, 1920 дә — 1831, 1926 да — 1884, 1938 дә — 1925, 1949 да — 1709, 1958 дә — 1306, 1970 тә — 1594, 1979 да — 1055, 1989 да — 561, 2002 дә — 444 кеше.

**МӨШЕГЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 29,5 *км*, бассейнының мәйданы 240 *км*$^2$. Елга башы Мөслим р-ны Торыш авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Минзәлә р-ны Яту авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Елганың үзәне асимметрияле: уңъяк битләре текәрәк. М.нең 0,6 дан алып 10 *км* га кадәр озынлыктагы 10 кушылдыгы бар, аеруча зурлары — Коралшат (10 *км*), Ташъелга (10 *км*) — сул. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су



Мөшеге елгасы Минзәлә р-ны Татар Мөшегесе авылы тирәсендә.

агымының уртача күпьеллык катламы 94 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренчеункөнлегендә башлана. М. ноябрь башында туңа. Елга тамагында суның иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 *м*$^3$*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. М. бассейнында суының гомуми күләме 5,8 млн.*м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**МӨШТӘРИ́** Данияр Хәмит улы (10.4.1945, Казан — 15.10.2013, шунда ук), математик, физика-матем. фән д-ры (1984), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының ихтималлык теориясе һәм матем. стат. бүлеге мөдире (1986 дан), бер үк вакытта матем. анализ кафедрасында (1977 дән), проф. (2003). Хезмәтләре ихтималлык теориясенә һәм функциональ анализга карый. М. Банах фәзаларында цилиндрик ихтималлыклар семьялыкларының начар оешуының һәм санау аддитивлыгының топологик критерийларын төзи. Гильберт фәзаларында һәм сызыкча фәзаларда идемпотент сызыкча операторларның квант логикаларында корылмалар характеризациясе турындагы теореманы исбатлый.

Х е з м.: Некоторые общие вопросы теории вероятностных мер в линейных пространствах // Теория вероятностей и её применения. 1973. Т. 18, вып. 1; Вероятности и топологии в банаховых пространствах. К., 1989; Подготовка к математическим олимпиадам. К., 2000; Gleason type theorems for signed measures on orthomodular posets of projections on linear spaces // International Journal of Theoretical Physics. 1995. V. 34, № 8.

**МӨШТӘРИ́** Хәмит Мозаффар улы (22.7.1900, Оренбург ш. — 23.1.1981, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1937), проф. (1938), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940, 1965). Сыгүләр теориясе буенча Казан фәнни мәктәбенә нигез салучы. Урта Азия ун-тын тәмамлаганнан соң (Ташкент, 1923), ТАССР Мәгариф халык комис-тының Академик үзәгендә гыйльми секретарь (1923–24), РСФСР Мәгариф халык комис-тының Милли азчылыклар советы татар-башкорт бюросында методист (1924–25) булып эшли. 1925–29 еллар-

да Мәскәү ун-тында, акад. С.А.Чаплыгин шәкерте. 1929–34 һәм 1937–38 дә Казан. пед. ин-тында. 1930–46 да Казан ин-тларында (коммуналь төзелеш инженерлары, авиация, химия-технол.) теоретик механика кафедралары мөдире, бер үк вакытта, 1934–38 дә, Казан ун-ты каршындагы Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. 1946 дан СССР ФА Казан ф-лы Физика-техника ин-тында: директор (1946–72), сүрүләр теориясе бүлеге мөдире (1946–76). Хезмәтләре сүрүләрнең гомуми теориясенә карый. М. нәсызыкча сүрүләр теориясендә дөнья әдәбиятында Мөштәри-Доннелл тигезләмәсе буларак танылган тигезләмәләр таба. Сызыкча һәм нәсызыкча сүрүләр теориясендә мөһим гомумиләштерүләр ясый, бу теориянең цилиндрик һәм коник сүрүләрнең сыгылмалы тигезләнеше мәсьәләләрен чишүдә күп төрле кулланылышын күрсәтә. М.нең сүрүләр теориясенә керткән гадиләштерүләре гомуми танылу ала, ә ул үстергән теория хәзерге заман «сөзәк сүрүләр теориясе»нең нигезен тәшкил итә. М. җитәкчелегендә халык хуҗалыгының төрле тармакларында, ш.и. машиналар төзү, приборлар төзү, төзелеш өлкәләрендә гамәли эшләр үтәлә. Аның хезмәте нәтиҗәләре аэрокосмик техника үрнәкләрен булдыруда, Казан циркының нигезен һәм сферик гөмбәзен төзүдә, оптик көзгеләрнең темп-ра һәм авырлык тәэсирендә киеренке деформацияләнгән халәтен билгеләүдә, төрле кулланылыштагы сүрүле техник корылмаларның ныклыгын һәм тотрыклылыгын исәпләүдә файдаланыла. 1940–50 елларда М. ракета системалары өчен корпус, юка тышчалы узеллар һәм детальләрнең тотрыклылыгын тәэмин итү проблемалары буенча киңәшче була.

Аэрокосмик техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Аэронавтика җәмгыятенең С.П.Королёв исем. медале б-н бүләкләнә (1990, үлгәннән соң). Татар телендә мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен физика һәм математика дәреслекләре, физика һәм метеорологиядән татарча терминнар җыентыгы авторы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. 1993 тә ТР ФА Х.М.Мөштәри исем. бүләк булдыра, ул өч елга бер тапкыр матем., механика һәм машиналар төзелеше өлкәсендәге танылган хезмәтләр өчен бирелә. М. исеме б-н Казанның бер урамы аталган. РФА КГУ Физика-техника ин-ты бинасы фойесында мемориаль такта куелган.

Х е з м.: О катании тяжёлого твёрдого тела вращения по неподвижной горизонтальной плоскости // Мат. сб. 1932. Т. 39; Об одном возможном подходе к решению задач устойчивости тонких цилиндрических оболочек произвольного сечения // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1935. Вып. 4; Некоторые обобщения теории тонких оболочек с приложениями к решению задачи устойчивости упругого равновесия // Изв. физ.-мат. об-ва и НИИ математики и механики при Казан. ун-те. 1938. Сер. 3, т. 11; Нелинейная теория упругих оболочек. К., 1957 (автордаш); Нелинейная теория оболочек. М., 1990.

*Әд.:* И л ь г а м о в М.А. Профессор Х.М.Муштари. М., 2001.

**МӨШТӘРИ́ЕВ** Мозаффар Таҗетдин улы (1.8.1863, Казан губ., Тәтеш өязе Үтәмеш а. — 4.1.1937, Казан), педагог, Хезмәт Герое (1923). Казанда «Халидия» мәдрәсәсендә укый. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1885). 1885 елдан Тәтеш (1887 гә кадәр), Сызрань, Оренбург, Әстерхан шәһәрләрендәге рус-татар уч-щеләрендә укыта. 1908–14 елларда — «Казан шәһәре ярлы мөселманнарына ярдәм җәмгыяте»нең кыз балалар рус-татар мәктәбе, 1917 дән Тәтеш өязенең Келәнче авылы югары башлангыч уч-щесе директоры, 1918 дән Тәтеш өязе Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатлары советы башкарма ком-тының халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1921 дән Оренбургта Татар халык мәгарифе ин-тында рус теле укыта. 1923 тән Үзбәкстан пед. ин-тында һәм Ташкент коммунистик ун-тында. 1924 тән Казанда, Татар пед. техникумында һәм башка урта махсус уку йортларында рус теле укыта.

*Әд.:* Х а м и т о в а Р. Муштариев Музаффар Тазетдинович // Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974.

**МӨЭМИ́Н** (гарәп. مؤمن), дингә ышанучы кеше, диндар, хак, игелекле мөселман. Ислам илаһиятчеләре фикеренчә, ислам динен кабул иткән кеше мөслим дип атала. Соңрак, дини белем һәм тәҗрибә туплагач, ул М. дәрәҗәсенә ирешә. Гомуммөселман традицияләрендә «мөслим» сүзе «М.» төшенчәсенең синонимы буларак кулланыла.

**МӨЭМИ́Н БИНЕ́ ӘХМӘ́Д** (?–977 дән соң), болгарлар идарәчесе (әмир). Талиб бине Әхмәднең бертуганы дип фаразлана. Суарда (975–76) һәм Болгарда (976–77) сугылган акчалардагы язулардан мәгълүм.

*Әд.:* к. *Мөэмин бине Хәсән.*

*И.Л.Измайлов.*

**МӨЭМИ́Н БИНЕ́ ХӘСӘ́Н** (?–?), Идел буе Болгар дәүләте идарәчесе. Болгарда сугылган акчалардагы язулардан (976–81) мәгълүм. Беренче булып М. бине Х. акчаларын Р.Р.Фасмер билгели. Берләшкән Болгар-Суар бәклегенең беренче идарәчесе дип фаразлана.

*Әд.:* М у х а м а д и е в А.Г. Древние монеты Поволжья. К., 1990; И з м а й л о в И.Л. Образование Булгарского государства // История татар с древнейших времён. К., 2006. Т. 2.

*И.Л.Измайлов.*

**МӨЭМИ́Н-КАРАТА́Й** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Каратай елгасы буенда. 2010 елда 325 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, ат, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1785 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.-К.да мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1750 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында.



Х.М. Мөштәри.



М.Т. Мөштәриев.

Халык саны: 1859 да — 352, 1889 да — 554, 1900 дә — 724, 1910 да — 861, 1920 дә — 978, 1926 да — 1049, 1938 дә — 752, 1949 да — 646, 1958 дә — 757, 1970 тә — 681, 1979 да — 517, 1989 да — 313, 2002 дә — 342 кеше.

**МӨЭМИ́НОВ** Зариф Латыйп улы (1893, Теләнче а., хәзер Мөслим р-ны Октябрь а. — 1966, шунда ук), әкиятче. 1938–41 елларда ТАССР ХКС каршындагы Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү ин-тына 50 дән артык халык әкияте текстларын җыеп тапшыра. Алар арасында: «Кәҗә белән Бүре», «Укымышлы кыз», «Кулсыз кияү», «Тугыз Тукылдык, бер Мимылдык». Әкиятләрнең бер өлеше «Халык иҗаты» (1940), «Татар халык иҗаты: Әкиятләр» (1–3 кит., 1977–81) җыентыкларында басылып чыга.

*Л.Ш.Җамалетдинов.*

**МӨЭМИ́НОВ** Малик Нил улы (6.12.1970, Казан), биолог, биол. фән. д-ры (2007). 1992 елда Ульянов Югары хәрби командирлар элемтә уч-щесен, 1998 дә Казан пед. ун-тын тәмамлый. 1998 дән Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү ин-тында. 2002 дән Татар гуманитар-пед. ун-тында. 2011 дән Казан ун-тының гамәли экология каф. профессоры. Хезмәтләре умарта кортларында йогышлы авыруларны дәвалауга һәм булдырмауга карый. М. аспергиллёз, аскосфероз, варроатозга каршы ярдәм система — полимераз-чылбыр реакциясе ысулы б-н бал кортларындагы гөмбә авыруларына экспресс-диагностиканың тест системасын эшли. Уйлап табуга 5 патенты бар.

Х е з м.: Индикация возбудителей аспергиллёза пчёл методом ПЦР // Вестн. Рос. акад. с.-х. наук. 2004. № 5 (автордаш); Стимулирующее действие ЭХА растворов // Пчеловодство. 2005. № 5 (автордаш); Ультраструктура конидий Aspergillus niger // Ветеринария. 2005. № 6.

**МӨЭМИ́НОВ** Рәис Әгъзәметдин улы (15.6.1941, БАССРның Благовар р-ны Кашкалаша а.), хезмәтне оештыру һәм аның куркынычсызлыгы өлкәсе галиме, техник фән д-ры (1988), проф. (1990), БРның атказ. халык мәгарифе хезмәткәре (1998). 1963 елда Уфа нефть ин-тын (хәзер Уфа нефть техник ун-ты), тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, ин-тның Октябрьскидагы кичке ф-лында (1963–68), хезмәтне һәм әйләнә-тирә мохитне саклау каф. мөдире (1972–84), проф. (1988 дән). Хезмәтләре нефть сәнәгатендә хезмәтне саклау процессларының икътисади һәм матем. модельләренә карый. М. оптимальләштерү алымнарын һәм сәнәгать кал-

дыкларын үтилләштерү принципларын тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә нефтьне промысел өчен җыю һәм эшкәртү процессларын акустик тирбәнешләр кулланып интенсивлаштыру технологияләре эшләнә (эшкәртмәләре Урал, Көнбатыш Себер, Идел буе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, «СССРның уйлап табучысы», «СССРның югары мәктәп отличнигы» билгеләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Экономические проблемы охраны труда. Уфа, 1985; Охрана труда: Методологические основы курса. Уфа, 1988.

**МӨЭМИ́НОВА** Багъбостан Вилдан кызы (1884, Уфа губ., Минзәлә өязе Мәндәй а. — 19.3.1963, Оренбург ш.), педагог. Оренбургта Ф.Адамованың рус-татар уч-щесендә һәм Оренбург Успение хатын-кызлар монастыренда кул эшләре курсларында укый (кул эшләре укытучысы дипломы ала). 1905 елда Оренбургта татар кыз балалары өчен чигү түгәрәге оештыра, ул 1907 дә «Багъбостания» татар кыз балаларына гомуми белем бирү мәктәбе итеп үзгәртелә. 1916 дан аның каршында кыз балалар пед.курслары эшли. Мәктәптә һәм курсларда Ш.М.*Бабич*, Н.С.*Надиев*, Р.*Фәхретдин*, Б.Шәрәф (к. *Шәрәфләр*) укыта. Мәктәптә 1200 кыз бала белем ала, соңрак шуларның 349 ы укытучы булып китә; пед. курсларда 190 укытучы әзерләнә. 1918 дән М. Оренбург урта уку йортларында эшли. «Сөембикә» ж-лы б-н актив языша. 1937 дә репрессияләнә, 10 ел лагерьларда була; 1959 да аклана.

*Әд.:* Кудаш С. Халкыбызның каһарман бер кызы // Казан утлары. 1984. № 10.

**МӨЭМИ́НОВА** Розия Гали кызы (31.12.1922, Казан — 12.1.2007, Ташкент), тарихчы, тарих фән. д-ры (1973), проф. (1990). Урта Азия ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1944), Үзбәкстан ССР ФАнең Тарих ин-тында эшли, борынгы һәм урта гасырлар тарихы бүлеге мөдире, баш фәнни хезмәткәр. Төп хезмәтләре Үзбәкстанның урта гасырлар тарихына карый. «Үзбәкстан ССР тарихы» («История Узбекской ССР», Таш., 1967, т. 1), «Сәмәрканд тарихы» («История Самарканда», Таш., 1969, т. 1), «Бохара тарихы» («История Бухары», Таш., 1976), «Үзбәкстан тарихы» («История Узбекистана», Таш., 1993, т. 3), History of civilizations of Central Asia (Париж, 2002, т. 5), «Үзбәкстан тарихы (XVI — XIX йөзнең беренче яртысы)» «История Узбекистана (XVI — первая половина XIX вв.)», Таш., 2012) һ.б. күмәк хезмәтләр авторларының берсе. «Мәхмүд Кашгари. Диване лөгать әт-төрк» («Махмуд ал-Кашгари. Диван Лугат ат-Турк», Алматы, 2005) фундаменталь хезмәтенең редакцион коллегиясе әгъзасы. «Михнәт Шөһрәти» (Үзбәкстан Респ-касы) һәм «Liyakat Nisani» (Төркия) орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К истории аграрных отношений в Узбекистане в XVI в.: По материалам «Вакф наме». Таш., 1966; Очерки по истории ремесла в Самарканде и Бухаре в XVI веке. Таш., 1976; Социальная дифференциация населения городов Узбекистана: Конец XV–XVI в. Таш., 1985; Амир Темур: Жизнь и общественно-политическая деятельность. Таш., 1999 (автордаш); Ташкент на перекрестке истории. Таш., 2001 (автордаш).

*Әд.:* Словарь отечественных востоковедов с 1917. М., 1995. Кн. 2.

**МӨЭМИ́НОВА** Энҗе Һилалетдин кызы (18.5.1924, Бөгелмә кантоны Яңа Кәшер а. — 2.3.2009, Әлмәт р-ны Габдрахман а.), шагыйрә, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Ташкент пед. ин-тын тәмамлагач (1948), Әлмәт р-нының Габдрахман авылында укытучы булып эшли. Матбугатта шигырьләре 1957 елдан басыла башлый. «Ефәк яулыгым» исемле лирик шигырьләр җыентыгы 1961 дә басылып чыга. Балалар өчен бик күп шигырьләр иҗат итә. «Әниләргә һәм нәниләргә» (1964), «Исемдә» (1984), «Дуслар җыелгач» (1986) җыентыкларында балаларның күңел дөньясын, психологиясен, әйләнә-тирәне ничек кабул итүләрен гади генә итеп ачып бирә. «Синең өчен язам» (1968), «Бүләгем» (1970), «Чәчәкләр китердем» (1974), «Әйтер сүзем бар» (1979), «Килер язлар өчен» (1988), «Ач сереңне миңа» (1999), «Еллар аша» (2004) җыентыкларында әниләргә, туган җиргә мәхәббәт турында сүз бара, әсәрләр балачак, кеше язмышы кебек лирик уйланулар б-н сугарылган. М.ның поэзиясе эчкерсезлеге, гадилеге б-н аерылып тора. Аның кайбер шигырьләре композиторлар И.Хисамов, Ә.Хәйретдинов тарафыннан көйгә салынып, популяр җырлар булып китә. ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. бүләге лауреаты (2005).

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МТС**, к. *Машина-трактор станциясе*.

**МУДРО́В** Александр Григорьевич (3.6.1942, Рязань өлкәсенең Сасово р-ны Теньсюпино а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТР, РФнең атказ. уйлап табучысы (1991, 1998). 1964 елда Ленинград урман техникасы академиясен тәмамлаганнан соң, Мед. радиологиясе ин-тында (Калуга өлкәсе Обнинск ш.) эшли. 1971 дән Казан аграр ун-тында. Хезмәтләре әйләнү шарнирлары булган фәзаи механизмнар төзүгә карый. М. мондый механизмнарга структура һәм көч ягыннан кинематик анализ ясый. Җайланмаларга ул уйлап тапкан тотрыклыландыру ысуллары катнаштыргычларда, болгаткычлы аппаратларда, тапшыру механизмнарында кулланыш таба (ТРның авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 93 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш һәм алтын медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Пространственные перемешивающие устройства. К., 1984; Пространственные механизмы с особой структурой (исследование). К., 2004.

**МУДРО́В** Пётр Григорьевич (18.6.1936, Рязань өлкәсенең Сасово р-ны Теньсюпино а. — 18.3.1997, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1979), проф. (1980), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). 1958 елда Ленинград урман техник академиясен тәмамлаганнан соң, Рязань шәһәре пр-тиеләрендә эшли. 1963–97 дә Казан а.х. академиясендә, механизмнар һәм машиналар теориясе каф. мөдире (1981 дән). Хезмәтләре фәзаи шарнирлы механизмнар теориясенә карый. М. модельләр һәм производство үрнәкләренең структурасын, әзерләү технологиясен эшли, механизмнарга кинематика һәм көч анализы ясый, җайланмаларны тотрыклыландыру ысулларын тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә эшләнгән механизмнар һәм югары нәтиҗәле җайланмалар машиналар төзелешендә кулланыш таба (ТР пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 103 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш һәм алтын медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: О пространственном шарнирном пятизвенном механизме // Анализ и синтез механизмов. М., 1970; Кинематика второго типа пространственного семизвенника с вращательными парами // Изв. вузов. Машиностроение. 1975. № 9; Пространственные механизмы с вращательными парами. К., 1976.

**МУЕНСА́**, муен-күкрәк бизәмәсе төре. Татар М.сы формалары элгәреге болгар чорына барып тоташа. Тар чылбырдан һәм имән чикләвеге рәвешендәге тагылмалардан гыйбарәт М.лар изге агач — төркиләрдә уңдырышлылык алиһәсе Һомайны гәүдәләндергән имән символикасын чагылдыра. Түбәндәге формалардагы татар М.лары кулланышта булган: 1) ярымтүгәрәк рәвешендәге тукымага акчалар, тәңкәләр, зәргәр асылмалары, сәйлән, ярымасылташлар, муен турысында эләктерелә торган каптырмалы М. (М.ларның бу төре татарларның төрле этнографик төркемнәрендә «тамакса», «тәңкәле муенса», «дәвәт-дәгъвәт» исемнәре б-н мәгълүм); 2) чылбырлы (буынлы, энҗе-мәрҗән бөртекләреннән, бөҗралардан җыелган чылбырлар) яки тоташ металл җирлеккә беркетелгән (ярымтүгәрәк яки ай рәвешендә) бизәкле металл асмалар, акчалар, ярымасылташлар, пыяла, ясалма асылташлар, акчалардан һәм зур асмалардан торган өстәмә асылмалар тагылган М.; 3) ак һәм төсле сәйлән, төрле төстәге ташлар, гәрәбә, энҗе, сирәк очракларда мәрҗән тезелгән, аскы рәте еш кына ташлар б-н бизәлгән тәңкәләр өстәлгән М. Керәшен татарларда, татар-мишәрләрдә һәм, гомумән, авыллардагы хатын-кызлар арасында тукымалы М. киң таралган; аны җиткән кызлар кигән, гадәттә, мондый М. тулысынча тәңкәләрдән торган (алар 3–4 рәтләп тагылган), аның өске кырыена тукыма кайма, берничә рәт мәрҗән, өслеккә ш.у. еш кына кабырчыклар һәм пыяла мәрҗән тегелгән. Шәһәрдә яшәүче Казан татар хатын-кызлары арасында еш кына ярымасылташлар беркетелгән җепкырлы асма бизәкләр җыелмасыннан торган М.лар өстенлек иткән; алар алтын яки көмеш кысага утыртылган түгәрәк формалы эре ярымасылташлар (топаз, аметист, сердолик, альмандин, гәрәбә һ.б.) беркетелгән асма бизәкләрнең, чәчәк һәм яфрак рәвешендә эшләнгән һәм еш кына бөтеркәле вак асылмалар өстәлгән җепкырлы яки тоташ асма бизәкләрнең (кагыйдә буларак, үзәктәге асылма) төрлелеге б-н аерылып тора. Кайбер очракларда М.лар асма бизәк яки тәңкәләрне бер-берсенә ялгап, күкрәккә кадәр төшеп торган 3–7 чылбыр рәвешендә эшләнгән, алар



**Муенса.** 1. Үрелгән муенса. Көмеш, ярымасылташлар. Җепкыр, бөртекләү. Болгар ш. 10–14 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Муенса. Көмеш, ярымасылташлар. Җепкыр. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Милли музее; 3. Муенса. Тукыма, мәрҗән, тәңкәләр. 19 йөз – 20 йөз башы. ТР Дәүләт татар фольклоры үзәге.

*яка чылбырына* охшаш булган. Бу төр М.лар 20 йөз башына кадәр кулланылган, әмма тәңкәләр тезеп эшләнгән М.лар татарлар яшәгән аерым төбәкләрдә 1940 елларга кадәр сакланган. Бүгенге көнгә кадәр бер җепкә бөртекләп тезелгән универсаль М.лар кулланыла.


Хәзерге зәргәрче-осталар М.ларны, күкрәккә төшеп торган асылма чылбырлы традицион төрләргә стильләштереп, еш кына алка б-н бер җыелма рәвешендә эшлиләр (С.Ковалевская-Шәкүрова, В.Ковалевский, Е.Бакакин, И.Васильева һ.б.). Борынгы татар М. үрнәкләре Россия этнография музее (С.-Петербург), ТР Милли музее, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее, Башкортстан туган якны өйрәнү музее (Уфа ш.) фондларында һ.б.да саклана.

*Әд.:* В а л е е в Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МУЗЕ́Й-САКЛАУЛЫКЛА́Р**, күчемсез истәлекләр нигезендә ачык һавада оештырылган музейлар. Алар тирәсендәге тарихи-мәдәни ландшафт саклана яки яңадан торгызыла. Билгеле объектларны саклау б-н генә чикләнмичә, аларның эшчәнлеген тәэмин итүче функцияләрне дә башкаралар. Россиядә истәлекле урыннарны музейлаштыруның беренче омтылышлары 1920–30 елларга карый, М.-с. тарихи кыйммәткә ия национализацияләнгән утарлар, монастырьлар, сарай-парк ансамбльләре җирлегендә оештырыла. М.-с. статусы 1960 елларда кертелә. ТРда федераль һәм республика статусындагы 6 М.-с. бар: *Биләр тарих-археология һәм табигать музей-саклаулыгы, Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы, Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы, Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы, Ленино-Кокушкино музей-саклаулыгы,* «*Казан Кремле*» тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгы. Музей объектларын һәм коллекцияләрне тәшкил иткән саклаулык терр-яләренең һәркайсында бөтенлек сакланган һәм тартып алу мөмкинлеге булмаган хәлдә тарих-архит-ра, сәнгать, археол., ландшафт-табигать комплексы формалаша. ТРда ш.у. тарихи-мәдәни саклаулы терр-яләр: «Чаллы» (к. *Чаллы шәһәрлеге*), «Җүкәтау» (к. *Җүкәтау комплексы*), «Ушковлар утары» (Менделеев шәһәрендә П.К.*Ушков* утары һәм паркы җирлегендә), *Түбән Кама милли паркы, Озын Алан* комплексы табигать һәм тарих-архит-ра истәлеге (ш.у. к. *Аеруча саклаулы табигать территорияләре һәм акваторияләре*) бар. 1990 еллар башына М.-с. музей учреждениеләренең аеруча актив үсеш алган категориясен тәшкил итә. Ул ш.у. музейлар эшендә тиңдәше булмаган, музей эшчәнлеге өлкәсенә мәдәни мирасның яңа элементларын җәлеп итү б-н бәйле яңалыклар кертелү б-н аерылып тора. Бу төр эшчәнлек милли мәдәниятнең саклануын гына түгел, тагын да ишәюен һәм үсешен тәэмин итә (мәс., Казанда «Иске татар бистәсе» тарихи-мәдәни саклаулык терр-ясе (1998) һәм аерым статуслы «Казан посады» (1997) терр-ясенең барлыкка килүе).

**МУЗЕЙЛА́Р** (грек. muséion — музалар храмы), матди һәм рухи мәдәният, табигать истәлекләрен туплау, саклау, тарихын өйрәнү һәм популярлаштыруны гамәлгә ашыручы фәнни-тикшеренү һәм фәнни-агарту, фәнни белем бирү оешмасы. М. төрләре: фәнни-агарту, тикшеренү, өйрәнү; профильләре: тарихи, сәнгати, әдәби, төбәкне өйрәнү, техника буенча, а.х. буенча, фәнни-табигыять, мемориаль, комплекслы һ.б. Казан губернасында беренче җәмәгать М.ы 19 йөз башында Казан ун-ты каршында барлыкка килә (к. *Казан университеты*). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр (Н.Ф.*Высоцкий*, Н.Ф.*Катанов*, А.А.*Штукенберг*, Н.П.*Загоскин*, Л.О.*Сиклер*, А.Ф.*Лихачёв*, М.И.Юнысов, Г.М.*Галиев* (*Баруди*), С.М.Аристов, А.М.*Миронов*, А.Ф.*Мантель*, П.М.*Дульский*, М.Г.*Худяков* һ.б.), матди ярдәм күрсәтүчеләр, М. га акча һәм кыйммәтле коллекция бүләк итүчеләр (О.С.Александрова-Гейнс, И.Ф.Лихачёв, В.И.Заусайлов, С.В.Дьяченко) башлангычы б-н Казанда шәһәр М.ы ачыла башлый. М. читтәре уку йортлары (руханилар академиясе, сәнгать мәктәбе, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты һ.б.) һәм Казан епархиясе тарих-археол. җәмгыятенең Борынгы әйберләрне саклауханәсе, Казан икътисад җәмгыятенең умартачылык музее һ.б. каршында барлыкка килә. *Казан губерна земствосының вак сәнәгать һәм һөнәри белем бирү үзәк музее*, Казан дворяннар җыены Борынгы әйберләр саклауханәсе оештырыла. 1895 тә Шәһәр фәнни-сәнәгать музее (хәзер — *Татарстан Республикасының Милли музее*, коллекцияләрендә 700 меңнән артык саклау берәмлеге, аеруча әһәмиятле мәдәни объект һәм респ-ка М.ы өчен методик үзәк) ачыла. 1920 дә респ-каның музей эшләре үсешендә һәм М.ның экспозиция фондын булдыруда Татарстан мәгариф халык комис-тының музей эшләре һәм борынгы сәнгать истәлекләрен саклау бүлеге зур роль уйный, хосусый затларның, дини оешмаларның Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы елларында реквизицияләнгән милекләрен исәпкә алу, тарихи-сәнгати кыйммәткә ия булганнарын ачыклап, М.га тапшыру эшен тормышка ашыра. *Төбәкчелек белеме* көчле үсеш алуга бәйле рәвештә, М.ның әһәмияте арта бара. 1920–24 тә Казанда «*Казанский музейный вестник*» (музей эшләре буенча беренче совет ж-лы) һәм «*Записки Тетюшского музея*» ж-ллары басыла,



Казан университетының зоология музее. 19 йөз ахыры.





1–2. Шәһәр музееның экспозиция заллары. 19 йөз ахыры.

аларда *музей белеменең* актуаль мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. 1920 нең ахырында М. эшчәнлегенә илдә төбәкләрне өйрәнүгә игътибар кимү тискәре йогынты ясый. 1930 да кантон һәм район М.ы ябыла, Үзәк музейның фәнни-тикшеренү һәм туплау эшчәнлеге кысыла. Яңа М. челтәре 1950 нең урталарыннан кабат үсеш ала. 1958 дә ТАССР Дәүләт музееның сәнгать коллекцияләре нигезендә Сынлы сәнгать музее, 1950–70 тә *мемориаль музейлар* ачыла. 1990 елларда республиканың адм. үзәкләрендә, шәһәр һәм авылларында төбәкне өйрәнү һәм мемориаль М.ның яңа киң челтәре булдырыла. Моңа төбәкне өйрәнүчеләр башлангычының җирле идарә органнары тарафыннан хуплануы, ш.у. музей эшләренең ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее базасында үзәкләштерелүе этәргеч бирә. М. челтәре Казанның югары уку йортларында (мед., техник, технол. ун-тлары, вет. академиясе), А.М.Бутлеров исем. Химия фәнни-тикшеренү ин-тында (*Казан химия фәнни мәктәбе музее*), А.Е.Арбузов исем. органик һәм физик химия ин-тында (*А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар музей-йорты*) булдырыла; ведомстволарга караган М. оештырыла (ТР Элемтә министрлыгы каршында Элемтә музее, ш.у. Эчке эшләр министрлыгы музее); Татар акад. театры, Казан Зур драма театры һәм Татар опера һәм балет театры каршында М. эшли. М. концепциясе 20 йөз ахырында зур үзгәрешләр кичерә. Иң зур үзгәреш музей объектларын сайлап алуга, ш.у. объект тирәсендәге мохиткә кагылышлы критерийларга карый. Бу тенденция музей-утарлар, *музей-саклаулыклар, аеруча саклаулы табигать территорияләре һәм акваторияләре* төзүдә чагылыш таба. М. эшенең хәзерге этабында шактый урынны музейга турыдан-туры кагылышы булмаган эшчәнлек төрләре: концерт программалары, шоу, фестивальләр, мастер-класслар һ.б. алып тора (ш.у. к. «*Казан» милли мәдәният үзәге*»). ТРда М. эше үсешенә Казанның меңьеллыгын бәйрәм итүгә әзерлек зур этәргеч була. *Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгы*, *Казан Кремле* музей-саклаулыгы (нигездә, тематик М., «Эрмитаж–Казан» үзәге төзелә), «Хәзинә» Милли сәнгать галереясы (ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее составында) ачыла, ТР Милли музее бинасында реконструкция эшләре башкарыла. Республика М.ы фәнни-тикшеренү, аң-белем тарату, туплау, реставрация эшләре (мәс., 18 йөзгә караган карета яңадан үз хәленә кайтарыла) б-н шөгыльләнә. Фәнни-практик конференцияләр, Горький, Шаляпин, Каменев, Тукай, Сәйдәш укулары, М.Җәлилне искә алу һ.б. чаралар үткәрелә. Илдәге зур М. — Рус музее, Третьяков галереясы, Россия СА музее, Эрмитаж б-н берлектә киң колачлы экспозиция-күргәзмә проектлары гамәлгә ашырыла. Фәнни мәкаләләр җыентыклары, монографияләр, каталог, буклетлар бастырыла, 1995 тән «Ежегодник Национального музея РТ» басмасы чыга башлый. М. эше үсешенә В.М.Дьяконов, Н.И.Воробьёв, Е.Г.Бушканец, М.Н.Елизарова, Л.Г.Вәлиева, С.В.Писарева, Ю.И.Петров, Г.А.Могильникова, М.Т.Низамиев, В.Н.Нуруллин, Р.Г.Гарифҗанова, Г.С.Муханов һ.б. зур өлеш кертә.

*Әд.:* Синицына К.Р. Полвека музеев Казани и Татарии: Очерки истории 1917–1967 годов. К., 2002; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004. *Е.П.Ключевская.*



Зирекле халык иҗаты һәм көнкүреше музее. Экспозиция фрагменты. Яңа Чишмә районы.

**МУЗИКӘ́Н**, татар халкының традицион тынлы музыка уен коралы. 190–230 *мм* озынлыктагы конуссыман металл трубадан гыйбарәт (нигезенең диаметры 50–60 *мм*, югары өлешенең 12–14 *мм*). Агач шүре (кәтүк җебеннән бушаган) эшләпәсенең өске ягына тарттырылган һәм конусның югары өлешенә кертелгән резин яисә туз тасма (өзгеч) тавыш чыганагы булып тора. Уен коралының бармак өчен бер (сирәк кенә ике) тишеме була. Гадәттә, М. калайдан эшләнә, көтүчеләр аны көзгә кадәр тавыш сигналы бирү өчен кулланалар. Тавыш чыгару өчен, кәтүкнең башын иреннәр б-н кысалар. Һаваны өргәндә, ул, тасма һәм кәтүк эшләпәсе аша үтеп, өзгечне тирбәтә һәм тирбәнеш уен коралы көпшәсенең һава баганасына бирелә. М. — көчле яңгырашлы (тавышы берничә *км* га ишетелергә мөмкин), кечкенә диапазонлы сигнал бирү коралы. Әмма оста музыкантлар, сигналларны калтыратып, яңгырашны төрле-төрле төсмерләр һәм ритмик комбинацияләр б-н тулыландырып, М.дә шактый гына көйләр дә башкаралар.

*Р.Ф.Халитов.*

**МУ́ЗЫКА БЕЛЕМЕ́ БИРҮ́**, музыка эшчәнлеге өчен кирәкле сәләт һәм осталыкны, системалаштырылган белемнәрне үзләштерү процессы һәм нәтиҗәсе. Шулай ук муз. уку йортларында укыту системасын оештыру да М.б.б.гә керә. Казан төбәгендә М.б.б. системасы формалашуның алшартлары 18 йөзнең 2 нче яртысында Казан руханилар семинариясендә чиркәү җыры һәм скрипкада уйнарга өйрәтү дәресләре укытыла башлагач барлыкка килә. Музыка класслары Казан гимназиясендә — 1759 елда, Казан ун-тында 1805 тә (1863 кә кадәр эшли) оештырыла. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында укучыларны укытучылык эшчәнлегенә әзерлиләр, 1841 дән укыту процессының мөһим өлешен хорда җырлау һәм фортепиано дәресләре алып тора. Композитор Р.А.*Гуммерт* укытуда төрле формада музыка уен коралларында уйнау, ш.и. ансамбль башкаруында ирекле уйнау алымнарын кертүгә этәргеч ясый. Институтта муз. тәрбия һәм белем бирүнең куелышы Казанның башлангыч М.б.б. системасын тәшкил итә. 1870 еллар башыннан фортепианога өйрәтү кыз балалар гимназияләрендә мәҗбүри фән була, *епархия уч-щеләрендә* укучыларның күп өлеше аерым түләп укытыла. *Казан укытучылар семинариясендә* (вазифаларына җыр дәресләре укыту да кергән халык мәктәпләре укытучылары әзерли) М.б.б. системасын кертүдә С.В.*Смоленский* зур роль уйный. Ул музыка теориясе б-н таныштыруны, хорда җырлау һәм хор б-н идарә итүне, музыка уен коралларында (скрипка, фисгармония) уйнауны колачлаган музыка дәресләре программаларын эшли.

Казанда 19 йөзнең 2 нче яртысында системалы проф. М.б.б.гә нигез салына башлый, аңа шул вакыттагы Л.К.*Новицкий* (1870 тән), А.А.*Орлов-Соколовский* (1886 дан) хосусый музыка мәктәпләре һәм С.В.*Гилевның* (1884–94) хор җыры класслары эшчәнлеге ярдәм итә, аларның структурасы һәм укыту программасында консерватория белеме традицияләре уңай файдаланыла. М.б.б. системасын демократлаштыру идеяләре В.Н.*Пасхалов* тарафыннан ачылган Казан музыка сөючеләр түгәрәгенең Түләүсез музыка мәктәбе (1882–85) эшчәнлегендә чагыла. Анда төп фәннәрне башлангыч музыка теориясе һәм хор җыры тәшкил итә. Казан М.б.б. системасында Р.А.Гуммертның музыка мәктәбе (1891–1904) мөһим роль уйный. Анда укыту программасы Петербург һәм Мәскәү консерваторияләренең кече класслар программа-

сына якын тора; уку йортын тәмамлаучыларга Рус музыка җәмгыятенең музыка мәктәпләрендә укытырга хокук бирүче таныклык тапшырыла. 1898 дә мәктәп каршында балалар музыка бакчасы ачыла, анда укулар Р.А.Гуммерт методикасы буенча алып барыла. 1904 тә мәктәп Рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге каршындагы музыка уч-щесе итеп үзгәртелә (укытучылары К.А.*Корбут*, Ф.А.*Ошустович*, М.А.*Пятницкая*, О.М.Родзевич һ.б.). 1920 дән Татарстанда М.б.б. мәдәни төзелеш программасының состав өлешенә әверелә.

Бу вакытта музыка уку йортлары күпсанлы үзгәртеп корулар кичерә. 1919 да Л.А.*Поляков* һәм Н.Д.*Кашкин* җитәкчелегендәге Казан музыка уч-щесе ике баскычлы музыка мәктәбе итеп үзгәртелә. В.М.Айонов һәм Р.А.Гуммерт проектлары нигезендә 1919 да Үзәк шәрекъ музыка мәктәбе ачыла (1920 дән Югары шәрекъ музыка мәктәбе, 1921 дән — *Шәрекъ консерваториясе*). Консерваториянең башкаручылык ф-ты фортепиано, кыллы һәм тынлы уен кораллары, ялгыз җырлау бүлекләрен колачлый; музыка-этнография ф-тында Идел буе халыкларының музыка фольклоры өйрәнелә. 1922 дә Шәрекъ консерваториясе һәм ике баскычлы музыка мәктәбе Шәрекъ музыка техникумына берләштерелә. Анда муз.-тәрбия функцияләрен балалар һәм өлкәннәр өчен әзерлек класслары һәм 1 нче баскычлы мәктәп гамәлгә ашыра. 1920 дә техникум татар һәм рус проф. музыка мәдәниятен формалаштыруга зур өлеш кертә. Моны музыка укыту коллективлары: симф. оркестр (җитәкчесе — А.А.*Литвинов*), рус (җитәкчесе — И.С.Морев) һәм татар (җитәкчесе — С.Х.*Габәши*) хорларының актив концерт эшчәнлеге раслый. 1930 да, сәнгать һәм театр техникумнары берләшкәннән соң, музыка техникумы Татар сәнгать техникумы составына керә, 1934 тә яңадан Казан музыка техникумы оеша (1937 дән музыка уч-щесе). 1930 елларда респ-када М.б.б.нең гомуми структурасын һәм бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән күп баскычлы М.б.б. системасын (музыка мәктәбе — махсус урта уку йорты — югары уку йорты) формалаштыру башлана. 1932 дә Казанда җидееллык укыту срогы б-н ике балалар музыка мәктәбе ачыла. 1941 дә ТАССРда — 5, 1950 дә 16 музыка мәктәбе (ш.и. Казанда — 6), 1960 та шәһәр һәм авылларда 24 мәктәп була. 1970 кә 44 музыка мәктәбендә 6 меңнән артык, ш.и. Казанда 2,5 мең бала укый.

20 йөзнең 2 нче яртысында махсус урта М.б.б. системасы үсә, Әлмәттә (1964), Түбән Камада (1969) һәм Чаллыда музыка бүлекләре булган (1979) сәнгать уч-щесе ачыла. 1960 тан Алабуга мәдәният уч-щесендә, 1969 дан Лениногорск музыка пед. уч-щесендә (хәзер барысы да колледжлар) музыка укытучыларын әзерләү алып барыла.

Югары квалификацияле проф. музыка кадрларын булдыруда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясе зур роль уйный. 1945 тә Казан консерваториясе ачыла, ул Татарстан, Урта Идел буе, Урал алдының башка республикалары өчен югары квалификацияле музыкантлар әзерләү үзәге булып тора. 1960 та аның каршында талантлы балаларны проф. яктан үстерү максатында *Махсус урта музыка мәктәбе* ачыла. 1960 та Казан пед. ин-тында музыка-пед. ф-ты (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-ты филол. һәм сәнгать ин-тының сәнгать бүлеге), 1974 тә Казан мәдәният ин-тында (хәзер *Казан мәдәният һәм сәнгать университеты*) музыка ф-ты оештырыла. Проф. һәм өстәмә М.б.б. системасы мәктәпләре б-н методик җитәкчелекне Казан консерваториясе, гомуми белем бирү мәктәпләрендә музыка укытуны Татар гуманитар пед. ун-тының музыка ф-ты тормышка ашыра. Укытуның сыйфатын күтәрүгә һәм уку процессына яңача белем бирү технологияләрен кертүгә ТР Мәдәният министрлыгы карамагындагы Республика мәдәният һәм сәнгать уку йортлары буенча методик кабинет булышлык күрсәтә. Укытучыларның квалификациясен күтәрү ТР Мәдәният министрлыгының Өстәмә һөнәри белем бирү ин-тында тормышка ашырыла. 2013 тә Татарстанда 43 балалар музыка мәктәбе һәм музыка бүлекләре б-н 41 сәнгать мәктәбе (30 меңнән артык укучы укый), Казан консерваториясе каршында урта махсус музыка мәктәбе (173 укучы) эшли. 716 кеше урта махсус музыка белеме, ә 1194 кеше югары белем ала; ел саен 500 ләп кеше квалификациясен күтәрә.

*Әд.:* Хайрутдинов А. Музыкальное образование в Татарии // Уч. зап. Казан. гос. консерватории. 1970. Вып. 4; Кантор Г.М., Орлова Т.Е. Первая попытка высшего музыкального образования в Казани // Вопр. истории, теории музыки и музыкального воспитания. К., 1976. Сб.4; Литвинова Э. Из истории фортепианного образования и исполнительства в Татарии. К., 1976; Вайда-Сайдашева Г. Звуки времени. К., 1991; Из истории музыкальной культуры и образования в Казани: Сб.науч. тр. К., 1993; Казанская государственная консерватория (1945–1995). К., 1998; Салитова Ф.Ш. Развитие музыкально-педагогической культуры Казанского края (середина XVI — начало XX вв.) К., 2002.

*Е.В.Порфирьева, В.М.Спиридонова.*

**МУ́ЗЫКА ГЫЙЛЕМЕ́**, музыка сәнгатен өйрәнүче иҗтимагый фән. Музыканы фәнни тикшерү антик чорда ук башлана. Борынгы грек, борынгы кытай, урта гасырлар Көнбатыш Европа һәм гарәп-фарсы-төрек трактатларында музыка фәлсәфә-эстетика, этика, физика-матем., пед., ритуал-символика, эзотерика белемнәре системасында карала. М.г.нең мөстәкыйль фән буларак яшәеше яңа Европа мәдәнияте б-н бәйле. 18 йөздән әкрен дисциплинар бүленү башлана, аның нәтиҗәсендә музыка тарихы һәм теориясе формалаша. Соңрак музыка сәнгате һәм проф. музыка белеме үсеше махсус музыка тарихы һәм музыка теориясе фәннәре комплексын барлыкка китерә. М.г. тарихы, гомуммузыка тарихы буларак, ш.у. төрле геогр., этник яисә тарихи-мәдәни бергәлекләр музыкасын, милли композиторлар мәктәпләрен һәм аерым тарихи чорларның музыка сәнгатен (Европа музыкасы тарихы, Азия һәм Африка халыклары музыкалары, муз. медиевистика, мөселман традицияләре музыкасы һ.б.) өйрәнә. Тикшеренү предметы анда кулланыла торган методологияне билгели. Теоретик М.г., музыка теленең төрле элементларын (гармония, полифония, музыка төрләре, ритм теориясе, инструментовка һ.б.) өйрәнүгә бәйле булганга, махсус фәннәр системасына бүленә. 20 йөздә М.г.нең методологик базасы сизелерлек киңәя, чөнки музыканы, үзенчәлекле сәнгать системасы буларак өйрәнү б-н бергә, җәмгыять үсешендәге тарихи-мәдәни һәм социаль-сәяси процесслар яссылыгында карау омтылышы туа. Музыка белеме тарихы һәм теориясенең тыгыз бәйләнеше, башка гуманитар фәннәрнең (тарих, филол., әдәбият белеме, психол., социол., антропология һ.б.) методологик аппараты җәлеп ителү, тикшеренүләрнең яңа юнәлешләре (музыка семантикасы, герменевтика, музыка социологиясе, музыканы аңлау психологиясе) барлыкка килү, күп кенә ярдәмче фәннәр (музыка гыйлеме чыганакларын өйрәнү, палеография, текстология һ.б.) үсеше шушы омтылыш б-н бәйләнгән. М.г.нең аерым өлкәсендә төрле халыкларның традицион музыка сәнгатен (бигрәк тә халык көйләрен) өйрәнүче музыка этнографиясе (хәзер этномузыкология) формалаша. Хәзерге вакытта М.г. фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр формасында үсеш ала; соңгылары музыка укыту системасы, мәгълүмати технологияләр, театрларда сәхнәгә кую, концерт, муз. тәнкыйть, нәшрият эшчәнлеге б-н бәйле.

Татар җәмгыятендә музыка турында фәнни фикерләр үсеше өчен кирәкле алшартлар 19 йөздә хәзерге милли мәдәният формалашканнан соң барлыкка килә. Татар фикер ияләре Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин һ.б.ның хезмәтләрендә, Х.Кильдебәковның «Музыка вә ислам» (1909) исемле хезмәтендә музыка сәнгатенең ислам динендәге әхлак традицияләре б-н бәйләнеше проблемалары карала. Татар традицион музыкасын өйрәнү К.Насыйриның «Фәвакиһелҗөләса фил әдәбият» (1884) хезмәтендә шактый урын били. 19–20 йөзләрдә милли музыка мәсьәләләре татар публицистикасында актив тикшерелә. Г.Тукай, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев, Г.Ибраһимов, М.Җәлил һ.б. матбугатта һәм халык алдындагы чыгышларында музыка сәнгатенең иҗтимагый тормыштагы роле һәм аны үстерү юллары турындагы фикерләрен җиткерәләр. С.Габәшинең «Яңалиф» ж-лында сорауларга җавап рәвешендәге беренче публицистик язмасы (1931) татар музыка сәнгатенең шул замандагы торышын һәм аны үстерү перспективасын фәнни яктан тикшерүнең беренче тәҗрибәсе булып тора, анда күренекле сәнгать эшлеклеләре арасында татар музыкасының үзенчәлеге һәм «европалашу» проблемалары турында сораштыру үткәрелә. Татарстанда беренче проф. музыка этнографы булып М.Мозаффаров һәм беренче проф. музыка белгече булып Х.Булатова-Терегулова санала. Мәскәү консерваториясендә белем алып, алар Казан консерваториясенең теория-композиторлык ф-ты педагогларының иң беренчеләреннән була. 1945 елда ачылган консерватория респ-када музыка белгечләре әзерләү, фәнни мәктәп булдыру эшенә керешә. Казанда музыка белгечләре

әзерләүнең башлангыч чорында Мәскәү һәм Ленинград консерваторияләрен тәмамлаган А.Бормусов, Ю.Виноградов, А.Корсунская, Г.Литинский эшли. Татарстанда М.г.н үстерүгә Я.Гиршман зур өлеш кертә, ул — татар музыкасына караган күп кенә хезмәтләрнең, ш.и. «Пентатоника һәм аның татар музыкасында үсеше» («Пентатоника и её развитие в татарской музыке», 1960), «Нәҗип Җиһанов» («Назиб Жиганов», М., 1975) китапларының авторы. Республикада М.г.н өйрәнү мәктәбе беренче оешкан елыннан ук традицион һәм хәзерге татар музыка сәнгате, ш.у. Идел буе халыкларының музыка мәдәнияте буенча өстенлекле юнәлешләрне билгели. 1958 дә Казан консерваториясе җирлегендә Кытай, Монголия, Төньяк Корея музыка белгечләре катнашында, СССРның автономияле респ-калары музыка мәдәнияте үсеше проблемаларына багышлап, пентатоника буенча 1 нче халыкара конференция уздырыла. Зур халыкара фәнни форум милли музыкалар культурасын һәм пентатоника теориясен өйрәнүдә Казан М.г.нең ролен үзенчәлекле ассызыклый (пентатониканы өйрәнүдә Казан М.г. мәктәбе бүгенге көнгә кадәр төп рольне уйный). Ангемитоника проблемалары Л.Бражник, Р.Исхакова-Вамба хезмәтләрендә тикшерелә. Музыка белгечләре татар музыка тарихын төрле яклап яктырталар. 20 йөзнең беренче ун еллыгында татар җәмгыятенең муз. тормышы музыка белгече З.Хәйруллина эшләрендә чагыла. Татар совет музыкасы үсеше мәсьәләләре Г. Касаткина хезмәтләрендә тикшерелә. Й.Исәнбәт хезмәтләре Р.Яхин иҗатына, татар музыкасы үсешендә М.Җәлилнең роленә, С.Габәши, Г.Әлмөхәммәтов, Ю.Виноградовлар иҗат иткән беренче татар операларына, милли опера һәм балет спектакльләренең куелу тарихына багышлана. Татарстан композиторлары иҗатларының төрле аспектлары А.Алмазова (татар балеты үсеше, Ф.Яруллин иҗаты), Т.Алмазова (татар инструменталь концерты үсеше, Р.Еникиев иҗаты), Ч.Бәхтиярова (Ф.Яруллин иҗаты), Ф.Бикчурина (татар композиторлары әсәрләре турында очерклар), З.Салехова (Н.Җиһановның симф. иҗаты), Ф.Салитова (С.Сәйдәшев иҗаты), К.Таҗиева (М.Мозаффаров иҗаты), М.Фәйзуллаева (татар операсында халык җырлары чыганагы), Ф.Шәмсетдинова (Ф.Әхмәтов иҗаты, Н.Җиһановның симф. әсәрләре) тикшеренүләрендә ачыла. Татар музыкасын өйрәнүдә этномузыкаль тикшеренүләр мөһим роль уйный. М.Нигъмәтҗановның 1970–80 дә басылып чыккан, аналитик мәкаләләре урын алган фольклор җыентыклары циклы милли сәнгатьне саклау һәм үстерү юнәлешендәге зур казаныш булып тора. Галимнең С.Габәши тормышы һәм иҗаты турындагы мәкаләсе (1985) татар музыка белеме тарихының фәнни парадигмасын яңартуга этәргеч бирә. Халыкның җыр культурасын, аның төрле тарихи һәм социаль аспектлары б-н үзара бәйләп, З.Сәйдәшева (Татарстанда музыка сәнгате белгечлеге буенча беренче фән. д-ры) тикшерә. 1980–90 да галимнәр татар музыка тарихының элек өйрәнелмәгән проблема һәм фактларына мөрәҗәгать итәләр. Г.Гобәйдуллина хезмәтләрендә С.Габәши иҗаты һәм 20 йөз башы татар клублары эшчәнлеге, Г.Сәйфуллина тикшеренүләрендә традицион татар-мөселман мәдәниятендә гыйбадәттән тыш Коръән уку үзенчәлекләре яңача яктыртыла. Скрипкада татар башкаручылык сәнгатен өйрәнүнең яңа тарихи-мәдәни аспектын Ш.Монасыйпов хезмәтләре ача. Халык уен коралларында уйнау традицияләре Г.Макаров, Р.Халитов, В.Яковлевның фәнни тикшеренүләрендә бирелә. В.Дулат-Алиев — милли мәдәният теориясенә караган хезмәтләр авторы. 1980 еллардан балалар музыка мәктәпләре, уч-щеләре һәм югары уку йортлары өчен татар музыкасы тарихына багышланган дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре төзелә. Аларның авторлары — В.Дулат-Алиев «Татар музыка әдәбияты» («Татарская музыкальная литература», 2007), С.Рәимова «Татар музыкасы тарихы» («История татарской музыки», 1986); сольфеджио буенча эшкәртмәләр, Ф.Салитова «Татар музыка мәдәнияте тарихы буенча очерклар» («Очерки по истории татарской музыкальной культуры», 1997; «Татар музыка педагогикасы тарихы» («История татарской музыкальной педагогики», 2008) һ.б.

М.г.нең актив үсә торган юнәлешләреннән берсе — төбәкнең муз.-иҗтимагый тормышы тарихын һәм музыка белеме бирүне өйрәнү. Әлеге теманы яктыртуга Г.Кантор, Е.Порфирьева, В.Спиридонова, Ә.Хәйретдинов үзләреннән зур өлеш кертәләр. Халык музыкасы тарихы О.Егорова хезмәтләрендә чагылыш таба. Урта Идел буе халыкларының проф. музыка мәдәнияте формалашу А.Маклыгин монографиясендә күрсәтелә, ул ш.у. хәзерге чор композиторлык техникаларын да тикшерә. Татарстанда музыка гыйлеме өлкәсендәге тикшеренүләр төбәк б-н генә чикләнми: Л.Федотова хәзерге заман гармония теле теориясен эшләүгә зур өлеш кертә, рус музыкасы тарихының төрле аспектлары В.Дулат-Алиев, А.Кудрявцева, Е.Смирнова, Е.Хадеева, чит ил музыкасы буенча тикшеренүләр О.Жесткова, А.Сокольская хезмәтләрендә карала.

Төбәктә М.г.нең төп үзәге булып «музыка гыйлеме» белгечлеге буенча кадрлар әзерләүче Казан консерваториясе (музыка теориясе һәм тарихы, татар музыкасы, этномузыкология кафедралары) санала. 2003 тән консерватория каршында музыка сәнгате белгечлеге буенча төбәктә бердәнбер диссертация яклау советы эшләп килә, 2004 тән яшь галимнәрнең музыка сәнгате өлкәсендәге фәнни эшләре буенча бөтенроссия конкурсы үткәрелә, 1989 дан махсуслаштырылган редакция-нәшрият бүлеге эшли. Татарстан музыка белгечләре халыкара, бөтенроссия һәм респ-ка фәнни конференцияләрендә, методик семинарларда, музыка уку йортлары укытучыларының методик эшләре конкурс-смотрларының жюри эшендә, теле- һәм радиотапшырулар әзерләүдә, халыкара музыка фестивальләрен оештыру һәм уздыруда актив катнашалар.

*Әд.:* Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Кто есть кто в науке об искусстве (Республика Татарстан): Справ. К., 1998; Музыкальная наука Среднего Поволжья: Итоги и перспективы. К., 1999; Кантор Г.М. Музыковеды Казани: Биобиблиогр. словарь. К., 2000; Дулат-Алеев В. Специализация «Исследователь татарской музыки» в системе подготовки музыковедов // Из педагогического опыта Казанской консерватории. К., 2005. Вып. 2.

*В.Р.Дулат-Алиев.*

**МУ́ЗЫКА МӘКТӘПЛӘРЕ́**. Казанда беренче музыка мәктәпләре 19 йөз ахырында ачыла башлый, ул вакытта шәһәр халкы арасында музыка белеменең иҗтимагый формаларына омтылыш көчәя. Болар шәһәрнең танылган музыкантлары тырышлыгы б-н ачылган түләүле хосусый уку йортлары була; аларның һәрберсе үз программасын тәкъдим итә һәм дәресләр алып барылырга тиешле белгечлекләр исемлеген билгели. Мәктәпләрдә күпчелекне пианино буенча укучылар алып тора. Шулай ук оркестр уен кораллары һәм җыр бүлекләре була. Укырга керүчеләр өчен яшь ягыннан катгый таләп куелмый. Укучылар саны күп булса да, аларның барысы да уку йортларын тәмамламый. 19 йөздә Казанда Л.К.*Новицкий* (1870–82 елларда эшли), В.Н.Пасхалов (бушлай, 1881–84), А.*Орлов-Соколовский* (1886–91) М.м. аеруча таныла.

Казан музыка белеме бирү тарихында Р.А.*Гуммерт* мәктәбе сизелерлек эз калдыра (1891–1904 тә эшли); аның җирлегендә Казан музыка уч-щесе ачыла (1904). Музыка уч-щесе уку планында башта 9 еллык укыту курслары күздә тотыла, нигездә, мәктәп аның структурасына кертелә, чөнки 3 еллык башлангыч һәм урта белем курслары программа таләпләре буенча хәзерге заман М.м.нә якыная. 1919 да музыка уч-щесе җирлегендә ике баскычлы Дәүләт М.м. ачыла, аны Петроград консерваториясен тәмамлаган Р.*Поляков* җитәкли; программа музыка белеме бирүнең мәктәп дәрәҗәсен генә түгел, хәтта уч-ще дәрәҗәсен дә колачлый. Музыка уку йортларының күпкырлы үзгәрешләре барышында ике баскычлы Дәүләт М.м. һәм Шәрекъ консерваториясе Шәрекъ музыка техникумына берләштерелә һәм шуның нигезендә 1 нче баскыч М.м. оеша. Укыту планы укучыларны төрле яклап үстерүгә юнәлтелә (уен коралларында уйнау, ритмика, хор, музыка тыңлау). 1924 тә, матди кыенлыклар сәбәпле, чираттагы үзгәрешләр була, Шәрекъ музыка техникумының өчьеллык М.м. 15 яшькә кадәрге балалар һәм өлкәннәр (яшь ягыннан чикләнмәгән) өчен ике бүлектән торган икееллык студия итеп үзгәртелә. 1925 нең мартыннан студиядә яңадан өчьеллык укыту кертелә.

1917 дән соң гомуми музыка белеме бирү учреждениеләре челтәре оештырыла башлый. Хезмәт ияләренә — өлкәннәргә һәм яшүсмерләргә башлангыч музыка белеме бирү максаты б-н завод һәм фабрикалар каршында М.м. ачыла. 1919 да Казанда 4 халык мәктәбе була (Постаучылар бистәсендә, Крестовниковлар з-ды каршында — Пләтән бистәсендә, Алафузовлар з-длары каршында — Адмиралтейство бистәсендә һәм Дары заводы каршында), 1920/21 уку елына аларның саны 6 га җитә. Шул ук максат б-н Буа шәһә-

рендә (1918) музыка студиясен ачу күздә тотыла, С.Сәйдәшев тәкъдиме б-н Чистай шәһәрендә (1918) фортепиано, скрипка, җыр һәм музыка теорияләре класслары буенча музыка курслары булдырыла. Казанда С.Геннер җитәкләгән Р.Гуммерт исем. (1925–29) 1 нче баскыч М.м. киң танылa, ул 2 бүлектән тора: балалар өчен 1 нче баскыч мәктәбе һәм өлкәннәр өчен курслар. Укыту ике белгечлек (фортепиано һәм җыр) буенча алып барыла; укучылар саны 150 гә җитә. 1926 ның көзеннән мәктәп каршында Елга аръягы бүлеге һәм балалар музыка бакчасы ачыла. Мәктәп мәгърифәт эшчәнлеге (эшчеләр һәм гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен концертлар) алып бара. 1930 да респ-када башлангыч музыка белеме системасы тагын да максатчанрак үсеш ала. 1932 дә Казанда 1 нче балалар музыка мәктәбе (БММ) һәм аның 2 ф-лы (алдагы елларда 2 нче, 3 нче БММ), 1936 да тагын бер ф-лы ачыла һәм 1948 дә аның җирлегендә 4 нче БММ оеша. Шуннан соңгы унъеллыкларда М.м.нең саны шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да артканнан-арта бара. 2013 кә Татарстанда ТР Мәдәният министрлыгы системасында 84 балалар М.м. һәм музыка бүлекләре б-н сәнгать мәктәпләре (ш.и. 19 ы авыл җирлегендә) исәпләнә, аларда 30 меңнән артык кеше укый. М.м. 2 мөһим мәсьәләне: гомуми башлангыч музыка белеме бирүне һәм сәләтле балаларны, проф. яктан әзерләп, урта махсус мәдәният һәм сәнгать уку йортларына укырга кертүне хәл итә. 1989 дан ТР Мәгариф министрлыгы системасында балалар М.м. челтәре киң җәелеп китә, аның эшчәнлеге, башлыча, мәктәп укучыларын муз.-эстетик яктан тәрбияләүне күздә тота. 2013 кә мондый мәктәпләр саны 40 ка җитә (шуларның 28 е Казанда, 15159 укучы). 20 йөз ахырында М.м. эшчәнлегендәге прогрессив тенденцияләрнең берсе бердәм укыту планнары һәм программалары формасыннан һәр мәктәпнең үзенчә иҗади эшчәнлеккә күчүе була. ТРда музыка белемен үстерүнең 1993 тә кабул ителгән Дәүләт программасына туры китереп, респ-када төрле типтагы балалар М.м. эшләп килә: шәһәр М.м., татар гимназияләре каршындагы гомуми муз. тәрбия бирү мәктәпләре, вариатив укыту планы буенча эшләүче авыл М.м.; алар, укытуда һәр баланың индивидуаль сәләтен исәпкә алып, дифференциаль укыту идеясен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Күп кенә мәктәпләр махсуслашкан: малайлар муз.-хор гимназиясе (12 нче БММ), эстрада М.м. (11 нче, 16 нчы БММ), тынлы М.м. (13 нче БММ) һ.б. Соңгы елларда милли музыка белеме системасы киң җәелә. 19 татар музыка мәктәбендә һәм М.м.нең татар бүлекләрендә татар халык һәм проф. музыкасы тирәнтен өйрәнелә, традицион халык музыка уен коралларында уйнарга өйрәтелә. М.м. укучылары Россиядә һәм чит илләрдә (Австрия, Болгария, Германия, Франция, Чехия һ.б.) яшь башкаручыларның күп кенә абруйлы халыкара конкурсларында катнашалар.

*В.М.Спиридонова.*

**МУЗЫКА́ЛЬ ДРА́МА**, музыкасы әдәби нигез, сәхнә һәм бию хәрәкәтләре б-н табигый үрелеп барган муз.-драма спектакленең бер төре. Беренче татар М.д.лары сәхнәдә 1917 елда: М.Фәйзинең «Галиябану» (музыкаль бизәлеше халык көйләренә нигезләнә) һәм Г.Исхакыйның «Зөләйха» (С.Габәшинең музыкаль бизәлеше) пьесалары буенча куела. 1920 еллар дәвамында Казанда Татар драма театры сәхнәсендә С.Габәшинең муз. бизәлешендә Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К.Рәхимнең «Бүз егет», К.Әмиринең «Йосыф белән Зөләйха» һ.б. пьесалар буенча куелган спектакльләр уңышлы бара. Татар музыкасы классигы С.Сәйдәшев иҗатында М.д. 1920–30 елларда үзенчәлекле милли жанр буларак формалаша; ул Татарстанда муз. театр, ш.у. тулысы б-н хәзерге проф. музыка сәнгате барлыкка килүдә мөһим роль уйный. С.Сәйдәшевнең оригиналь музыкасына нигезләнгән «Зәңгәр шәл» (1926), «Наёмщик» (1928), «Ил» (1929), «Кандыр буе» (1932) һ.б. муз. драмалар төрле вокаль, хор һәм инструменталь номерларны (җырлар, ария, дуэтлар, оркестр увертюралары, хореографик сюиталар һ.б.) үз эченә ала. Алар Татарстан композиторлык сәнгате үсешенең стиль һәм жанр нигезен тәшкил итәләр.

*Әд.:* Салих Сайдашев: Материалы и воспоминания. К., 1970; Нигмедзянов М.Н. Сайдашев Салих Замалетдинович // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Салитова Ф.Ш. Музыкальные драмы Салиха Сайдашева. К., 1988.

*Ф.Ш.Салитова.*

**МУЗЫКА́ЛЬ КОМЕ́ДИЯ**. Татар М.к.сенең барлыкка килүе 1920 еллар татар драма труппалары спектакльләренә (еш кына оперетта дип аталганнар) барып тоташа. Алар үз эченә күп кенә музыка күренешләрен алган, уен-көлке характерындагы пьесалар буенча куелганнар. Татар М.к.сенә *Ж.Фәйзи* нигез сала. Аның татар муз. театры өчен язылган беренче М.к.ләре — «*Хуҗа Насретдин*», «*Башмагым*», «Акчарлаклар», «Идел буенда», «Алтын көз» (2 нче редакция) 1940 елларда иҗат ителә. М.к. жанрына Ә.Бакиров («Тальян моңы», 1963), С.Садыйкова һәм Р.Гобәйдуллин («Мәхәббәт җыры», 1971; «Кияүләр», 1972) мөрәҗәгать итәләр.

**МУЗЫКА́ЛЬ КУЛЬТУ́РА**, җәмгыятьнең рухи яшәешенең бер өлеше. Музыка сәнгате өлкәсендәге проф. һәм халык иҗатын, аның тамашачылар алдында гамәлгә кергән формаларын, *музыка белеме бирү* системасын үз эченә ала. М.к. үсешенең төп юнәлешләре тарихи, социаль-икътисади, мәгълүмати-коммуникатив, иҗтимагый-сәяси факторлар б-н билгеләнә.

Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларында М.к. халык иҗаты һәм проф. иҗаттан торган. 20 йөзгә кадәр татар музыкасы халык авыз иҗаты рәвешендә яши, шуңа күрә борынгы һәм урта гасырлар көйләре бары фаразлауга нигезләнеп кенә яңадан торгызыла. Борынгы татар М.к.сы турында мәгълүматлар сәяхәтчеләрнең (Ибне Фазлан, Ибне Хаукаль, әл-Гарнати, Вильгельм де Рубрук) көндәлекләрендә, борынгы әдәби (Кол Галинең «Кыйссаи-Йосыф»ы) һәм фольклор әсәрләрендә бар; урта гасырлар гарәп-фарсы һәм төрки телле хезмәтләрдә, рус елъязмаларында турыдан-туры аңа карамаган тасвирламалар очрый. Халыкның тамырлары б-н ерак гасырларга киткән шигъри-муз. традициясе жанрлар системасыннан тора, алар халык тормышының төрле яклaрын: йола (туй, кунак хөрмәтләү, мәет җирләү һ.б.), хезмәт, риваять-фантастика, эпик, лирик һәм инструменталь көйләрен чагылдыралар. Проф. музыка тантаналы йолаларда һәм бәйрәм-күңел ачу формаларында яшәгән, сарай, хәрби, сәйяр музыкантлар ансамбльләре тарафыннан башкарылган.

Кайбер мәгълүматлар буенча Казан ханлыгы чорында формалашкан М.к. күптөрле жанр һәм стиль юнәлешләре б-н аерылып торган; музыка уен кораллары арасында этнотөбәк (курай, сорнай, гөслә), гомумтөрки (кубыз, думбра, сызгычлы кобуз), Шәрекъ-мөселман (гыйҗик, саз, дәф) компонентлары булган. Югары шигъри-муз. традиция жанрлары әдәби-шигъри әсәрләрне (дастаннар, лирик поэзия) көйләп сәнгатьле уку, сарай музыка уен коралларында уйнау рәвеше, ислам дөньясының мәдәни үзәкләре эстетикасы б-н бәйле була. Идел буенда ислам диненең таралуы мөселман илләре б-н элемтә үсүгә булышлык итә һәм татар М.к.на да, сәнгать традицияләренең үзара бәйләнешенә дә йогынты ясый. Халык арасында киң таралган проф. көйләп китап уку традициясе, татарча милли төсмерләр алган *мөнәҗәтләр* жанры, Коръәнне татар халкы интонацияләре нигезендә гыйбадәттән тыш көйләп уку гамәле әлеге үзара йогынтыга ачык мисал булып тора. Татар халык музыкасы традиция буенча ангемитон пентатоника — бишбаскычлы ладның интонация фондына нигезләнә, ул бүгенге көндә дә гамәлдәге муз.-интонацион сүзлек булып кала. Пентатоник көйләрдә гомуммөселман традицияләренең милли үзенчәлекле жанрларын интонация б-н башкару чагыла. Гыйбадәт формалары б-н күрсәтелгән ислам авазлар сәнгате (азан, тәҗвиднең әзлекле классик үрнәкләре) милли традицияләрдә жанр һәм интонацион этнотөбәк системалар б-н беррәттән үз урынын тота. 16 йөз урталарында, Казан ханлыгы җимерелү б-н, татар сәнгате изоляция шартларында кала. Дәүләтчелекне югалтканнан соң, проф. музыка сәнгате үсеше өчен социаль базаның юкка чыгуы байтак югары шигъри-муз. традиция үрнәкләренең таркалуына һәм югалуына китерә. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан 18 йөз ахырына кадәр татарларның тормыш шартлары музыка иҗаты яшәешен, башлыча, фольклор формалар рәвешендә калдыра. Йомык мәдәният шартларында татарларның төрле этник төркемнәренең муз. фольклоры үзенә бертөрле үзенчәлекле жанр-стильдә формалаша. Төп формалары арасында борынгы җырлау стиле б-н озын көйләр һәм тарихи яктан соңрак стиль б-н кыска көйләр, ш.у. аларның үзара бәйләнеше үрнәкләре б-н җырлау культурасы; *бәет* һәм мөнәҗәтләрне вокаль интонация б-н башкаруны кертеп, китапча көйләп уку, ш.у. такмакларны һәм инструменталь






































**Музыкаль культура**. 1. «Сания» операсын иҗат итүчеләр һәм беренче башкаручылар. 1925; 2. ТАССР Композиторлар берлеге. Утыралар (сулдан уңга): Ю. Виноградов, Н. Җиһанов, С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключарёв. Басканнар: А. Рыжкин, Х. Вәлиуллин, А. Леман, З. Хәбибуллин, Җ. Фәйзи. Казан, 1948; 3. Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетыннан күренеш; 4. ТР Дәүләт симфоник оркестры; 5. Казанда узган Р. Нуриев исем. 25 нче Халыкара классик балет фестивале афишасы. 2012; 6. М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрында куелган «Шагыйрьнең мәхәббәте» спектакленнән (Р. Ахиярова, Р. Харис) күренеш. Шагыйрь ролендә — Ә. Агади, Зәйтүнә — В.Ганиева; 7. Н. Җиһановның «Җәлил» операсыннан күренеш. М. Җәлил ролендә — Х.А. Бигичев; 8. Казан дәүләт «La Primavera» камера оркестры (җитәкчесе Р.Ю.Абязов); 9. ТР Дәүләт кыллы квартеты. Сулдан уңга — Ш. Монасыйпов (1 нче скрипка), М.Зарипов (2 нче скрипка), К. Монасыйпов — альт, А. Әсәдуллин — виолончель; 10. ТР Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры; 11. «Казан» бию ансамбле; 12. Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетыннан күренеш.

көйләрне үз эченә алган шигъри әсәрләрне (проф. авторлар һәм халык әсәрләрен) көйләп уку традициясе күрсәтелә. 18 йөз ахырыннан, Россия империясендә рус булмаган халыкларга карата Екатерина II нең беркадәр толерант сәясәте шартларында, татар традицион мәдәнияте үсешенең яңа чоры башлана. М.к. рәсми нигездә *мәктәп* һәм *мәдрәсәләр* торгызылу нәтиҗәсендә киң таралыш ала, аларның укыту программаларына китапларны («Бәдәвам», «Бакырган китабы», «Мөхәммәдия») вокаль интонация б-н көйләп өйрәнү кертелә.

Шул ук вакытта Казан көчле үсүче фәнни-мәдәни үзәккә әверелә. 19 йөздә шәһәр җәмәгатьчелеге тормышында музыка сәнгате мөһим урын били. Рус уку йортларында Европа музыка уен коралларында уйнарга өйрәнү дәресләре кертелә. Казан ун-ты, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты, гимназияләр муз. мәгърифәт үзәкләре булып торалар. 19 йөз ахырына Казанда яңа Европа тибындагы М.к. формалаша: концерт-филармония һәм опера антрепризалары актив эшчәнлек алып бара, проф. белемгә юнәлтелгән хосусый музыка мәктәпләре ачыла. Казанның актив концерт тормышы турында күренекле музыкантларның (С.Рахманинов, А.Скрябин, А.Гольденвейзер, К.Игумнов, Л.Ауэр, Б.Губерман, Я.Кубелик, Е.Цимбалист, Н.Фигнер, Л.Собинов, А.Нежданова һ.б.), С.-Петербургтан И.М.Петипаның балет төркеме һәм Мәскәүдән Зур театрның Е.Гельцер җитәкчелегендәге «Мәскәү Зимин опера артистлары опера ширкәте» («Товарищество оперных артистов московской оперы Зимина») гастроль чыгышлары күрсәтә. Репертуарына А.Даргомыжский, М.Мусоргский, А.Рубинштейн, П.Чайковский, Ж.Бизе, Дж.Верди, Р.Леонкавалло һ.б.ның әсәрләре кергән Казан опера труппасы спектакльләре шәһәрдә зур уңыш казана. Казанда Ф.И.*Шаляпинның* артистлык карьерасы башлана. Музыкаль җәмәгатьчелек тормышында Рус музыка җәмгыятенең Казан бүлеге, Казан музыка сөючеләр түгәрәге, Казан нәфис сәнгать сөючеләр һәм Казан халык ун-тлары җәмгыятьләре зур роль уйный.

Россия мәдәниятендәге бу үзгәрешләр милли мәдәниятне үстерү юнәлешендә эшчәнлек башлаган милли татар элитасы карашларында да чагыла. Татар халкының музыка традицияләре, җәмгыять тормышында М.к.ның роле Ш.Мәрҗани, К.Насыйри хезмәтләрендә киң чагылыш таба. Г.Тукай, Ф.Әмирхан һ.б. үзләренең мәкаләләрендә милли М.к. үсеше мәсьәләләренә зур игътибар бирәләр. Алдынгы татар интеллигенциясе эшчәнлеге халыкның милли мәдәниаттә яңа формалар, мәс., проф. татар театрын булдыруга ихтыяҗын чагылдыра. Театр 20 йөз башында оеша башлый һәм хәзерге татар музыка сәнгатенең формалашуында шактый зур роль уйный. «*Сәйяр*» театр труппасы спектакльләренең антрактлары вакытында составына еш кына скрипка, мандолина, гитара (кайвакыт фортепиано) кергән ансамбльләр татар музыкасын башкара. Милли оркестр дип аталучы милли ансамбльләр репертуарында татар халык җырлары һәм шул замандагы популяр бию көйләренең махсус күчермәләре була. Татар музыкасы концертлары Казандагы Шәрекъ клубының әдәби кичәләре программасына кертелә, һәм алар Мәскәү, С.-Петербург, Уфа, Оренбург, Саратов шәһәрләрендә күрсәтелә. Беренче татар концертын бирүче музыкантлар арасында җырчылар К.*Мотыйгый*, Ф.*Латыйпов*, Г.*Әлмөхәммәдов*, Ф.Гомәрова, скрипкачылар В.*Апанаев*, Г.*Зайпин*, Х.Әхмәдуллин, гармунчылар Ф.*Туишев*, Ф.*Биккинин*, пианист-импровизатор З.Яруллин була. Татар камера-инструменталь, вокаль һәм театраль-муз. әсәрләр авторларыннан берсе С.*Габәши* актив муз. мәгърифәт эшчәнлеге алып бара. Шулай ук рус музыкантлары — скрипкачы И.*Козлов* һәм дирижёр А.*Эйхенвальд* та концертларда татар халык җырларын авторлык эшкәртүендә башкаралар. 20 йөзнең 1 нче унъеллыкларында хәзерге татар М.к. инфраструктурасы: артистларның гастроль эшчәнлеген дә кертеп, халык алдында концерт һәм театр куюның; грампластинкалар яздыру, милли көйләр җыентыкларын, музыка буенча уку-укыту әсбапларын бастырып чыгару формалаша башлый. Совет власте елларында милли М.к.ны үстерүгә дәүләт органнары ярдәм итә. Республиканың муз. тормышы активлашуына татар телендә радиотапшырулар (1927), ТАССР җыр һәм бию ансамбле (1937) оештырылу, Татар филармониясе (1937), Татар опера һәм балет театры (1939), Халык иҗаты йорты (1939) ачылу зур этәргеч ясый. Музыка сәнгате өлкәсендә югары квалификацияле кадрлар әзерләү өчен, ТАССР хөкүмәте тырышлыгы б-н Мәскәү консерваториясе каршында Татар опера студиясе оештырыла (1934–38) һәм Казан консерваториясе ачыла (1945).

20 йөзнең 1 нче унъеллыгында татар композиторлар музыкасы формалашу концерт чыгышлары тәҗрибәсе шартларында башлана һәм традицион жанр-стиль үрнәкләре нигезендә җырлар һәм инструменталь пьесалар иҗат итүдә, халык җырларын эшкәртүдә чагыла. Музыка авторлары сыйфатында башкаручылар чыга. Әлеге иҗатның үзенчәлеге — милли традицияләр һәм дөнья музыка сәнгате казанышларының берләшүендә. Музыкасы бөтен халык мәхәббәтен яулаган һәм гомуммилли танылуга ирешкән беренче композитор С.*Сәйдәшев* була. Милли опера театрын оештыру омтылышы С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов, В.Виноградов составындагы авторлар коллективының беренче татар «Сания» (1925) һәм «Эшче» (1930) операларын иҗат итүендә чагылыш таба. 1930 елларда Мәскәүдә проф. белем алган атаклы татар композиторлары: Н.*Җиһанов*, Ф.*Яруллин*, М.*Мозаффаров*, Җ.*Фәйзи*, А.*Ключарёвларның* актив иҗат эшчәнлеге башлана. Аларның иҗатында муз. театр, симф. һәм камера-инструменталь жанрлар нәтиҗәле үсеш ала. Иң зур казанышлар арасында Ф.Яруллинның беренче татар балеты — «Шүрәле»се, Н.Җиһановның «Алтынчәч», «Җәлил», «Түләк һәм Сусылу», М.Мозаффаровның «Галиябану» оперлары, Җ.Фәйзинең «Башмагым» муз. комедиясе; М.Мозаффаровның «Г.Тукай истәлегенә», «М.Вахитов истәлегенә» симф. поэмалары һәм скрипка концертлары; Н.Җиһановның «Кырлай» симф. поэмасы, Татар халык темаларына сюитасы, «Симфоник җырлар»ы, «Сабантуй» симфониясе; А.Ключарёвның «Идел» симфониясе, З.*Хәбибуллинның* скрипка өчен язылган әсәрләре һ.б. бар. Татар халык сәнгатен яхшы белүчеләр һәм рус композиторлык мәктәбе шәкертләре буларак, алар Татарстанда М.к. үсешенә, тыңлаучыларның муз. зәвыгына зур йогынты ясыйлар. Аларның иҗатында татар композиторлары музыкасы профессиональлекнең яңа баскычына күтәрелә, Россиянең милли композиторлык мәктәпләренең иң уңышлылары исәбенә керә.

20 йөзнең 2 нче яртысыннан татар композиторлык мәктәбенең көчле үсеш алуы, һәрдаим яңа исемнәр б-н тулыланып торуы Н.Җиһанов җитәкләгән Казан консерваториясе эшчәнлеге б-н бәйле. 1950 елларда — Ә.*Бакиров*, Х.*Вәлиуллин*, М.*Латыйпов*, А.*Монасыйпов*, И.*Шәмсетдинов*, Р.*Яхин*; 1960 елларда — Ф.*Әхмәтов*, Р.*Белялов*, Р.*Еникиев*, Б.*Мөлеков*, И.*Якупов*, М.*Яруллин*; 1970 елларда — Р.*Абдуллин*, Л.*Батыр-Болгари*, Р.*Еникиева*, Ш.*Тимербулатов*, Л.*Хәйретдинова*, Ә.*Шәрәфиев*, Ш.*Шәрифуллин*, М.*Шәмсетдинова*; 1980–90 елларда Р.*Ахиярова*, Р.*Кәлимуллин* иҗатка килә. Республикадан читтә яшәп иҗат итүче композиторлар Л.*Хәмиди*, Р.*Гобәйдуллин* ш.у. татар музыка сәнгате вәкилләре булып саналалар.

20 йөзнең 2 нче яртысында А.*Леман* һәм А.*Луппов*, күп кенә муз. әсәрләрен татар интонациясе нигезендә иҗат итүчеләр һәм педагоглар буларак, татар композиторлык мәктәбе үсешенә зур өлеш кертәләр. Республиканың музыкаль җәмәгатьчелеге тормышында үзенчәлекле иҗатлары б-н Л.*Любовский*, Д.*Трубин* һәм А.Руденко үзләрен актив күрсәтәләр. 1930–50 дә татар композиторлары өчен төп стиль юнәлеше классик-романтик традициядәге рус һәм Европа музыкасы була, музыка теленең үзенчәлекләре, жанрлар өстенлеге, фольклор материалларын кулланып эшләү ысулы, башлыча, шуның б-н билгеләнә.

Романтик традициядәге татар музыкасы сәнгатенең ачык мисалы — татар музыкасы концерты репертуарын шактый баеткан беренче татар фортепиано концертлары, күпләгән күренекле камера-вокаль һәм камера инструменталь әсәрләр авторы Р.*Яхин* иҗаты. Музыкаль театр өлкәсендә Ә.Бакировның «Су анасы», З.Хәбибуллинның «Сихерләнгән малай» әкияти балетлары, Х.Вәлиуллинның «Самат» операсы җәмәгатьчелектә киң танылa. 1960–80 дә татар композиторлары иҗатында заманча композиторлык техникасы ысулларын куллану, Россия һәм чит илләрнең зур композиторлары иҗаты йогынтысына бәйле яңа тенденцияләр күренә. Унике тоннан торган серияле техник ысуллар файдаланыла башлый, диссонансларны (бер-берсе б-н ярашмаган тоннарның яңгырашы) куллану өлкәсе киңәя. А.Монасыйповның «Муса Җәлил» симф. поэмасында,

Р.Белялов һәм Р.Еникиевнең симф. һәм фортепиано әсәрләрендә, М.Яруллинның «Кеше» ораториясендә, Ф.Әхмәтовның «Казан» симфониясендә, Н.Җиһанов симфонияләрендә милли музыканың яңа стилистикасы эшләнә, аның мәгънәви образлар диапазоны киңәя. Ш.Шәрифуллинның «Мөнәҗәтләр» хор концерты, А.Монасыйповның «Тукай ритмнарында» вокаль-симф. поэмасы, «Дастан» симфониясе авторларның фольклор чыганакларын заманча ачып бирүе, милли традицияләрнең дини-фәлсәфи катламнарына мөрәҗәгать итүе б-н аерылып тора. Аларда традицион һәм заманча культураларның үзара йогынтысы өчен яңа мөмкинлекләр күрсәтелә, татар музыкасын үстерә торган яңа алымнар кулланыла. 20 йөзнең соңгы унъеллыклары татар мәдәниятенең совет чорында өзелеп торган элеккеге традицияләрен яңадан торгызу вакыты була. Көйләп китап уку, Коръәнне речитатив уку, мөнәҗәт әйтү, мөселман бәйрәмнәренә мөнәсәбәтле халык көйләре композиторлар әсәрләрендә яңа яңгыраш ала. Музыка иҗатында традицион татар мәдәниятенең яңа ачылган катламнары, тарихи үткәннәр б-н кызыксыну заманча милли музыканың стилен яңартуга һәм сәнгатьчә образлылыгын баетуга ярдәм итә. Р.Кәлимуллин, М.Шәмсетдинова иҗатында мөселман-шәрекъ классик музыка сәнгатенең эстетик принциплары үзенчәлекле чагылыш таба; моны оригиналь ансамбльләр составы б-н (ш.и. урта гасырлар уен кораллары кулланып) традицион интонация фонына, импровизацияләргә таянып табылган үзенчәлекле тавыш культурасында, тембрлар аша фикерләүдә күрергә мөмкин. Хәзерге татар композиторларының программалы музыкага һәм вокаль-симф. жанрларга омтылышы (Р.Ахиярованың «Моңлы сазым» симф. поэмасы, «Ак сөлге» вокаль-симф. поэмасы, Р.Кәлимуллинның «Риваять» поэмасы, М.Шәмсетдинованың «Тәкъдир билгеләнгән төн» оратория-балеты һәм «Адәм балалары» кантатасы) муз. иҗатның идея байлыгын һәм җәмгыятьнең рухи яшәешендәге актуаль проблемалар б-н бәйләнешен күрсәтә. Р.Ахиярованың «Шагыйрь мәхәббәте» операсы татар музыка сәнгатенә зур өлеш буларак бәяләнә. Татарстан композиторлары иҗатында балалар өчен язылган музыка әһәмиятле урын тота, һәм ул, муз. театр өчен зур әсәрләрдән (Л.Хәйретдинованың «Мәкерле песи» операсы) алып, пед. репертуарга керүче инструменталь миниатюраларга кадәр төрле жанрларны колачлый. Татарстан композиторларының әсәрләрендә җыр иҗаты зур урын били. Автор җырлары еш кына концерт сәхнәсеннән халык арасында тарала. Җыр жанрында аеруча Р.Ахиярова, Л.Батыр-Болгари, Р.Кәлимуллин, Р.Еникиев актив эшлиләр. Җыр иҗат итүче осталар буларак, проф. композиторлар гына түгел, 19–20 йөзләрдәге татар мәдәнияте традицияләрен дәвам итеп, җырчылар (шуның ачык мисалы — С.*Садыйкова* иҗаты) үзләре дә чыгышлар ясыйлар; милли җыр сөючеләр аудиториясендә үзешчән авторлар Ш.*Мәҗитов*, З.Гыйбадуллин, М.*Макаров*, Ф.*Әхмәдиев* һ.б.ның җырлары зур популярлык казана.

Хәзерге вакытта милли һәм хәзерге заман мәдәниятенең күп гасырлардан килгән традицияләре чагылган бай әсәрләр фонды тупланган. Татар композиторларының әсәрләре Россиядә һәм чит илләрдә башкарыла һәм халыкара конкурсларда уңыш казана.

Татарстанда проф. башкаручылыкның Европа, рус һәм татар милли традицияләре киң үсеш алган муз. башкару мәктәпләре барлыкка килә. Муз. театрны үстерүгә әйдәп баручы төп опера җырчылары З.*Байрашева*, М.*Булатова*, А.*Измайлова*, Г.*Кайбицкая*, М.*Рахманкулова*, У.*Әлмиев*, Н.*Даутов*, Ф.*Насретдинов*, Р.*Билалова*, Г.*Сәйфуллина*, З.*Хисмәтуллина*, В.*Шәрипова*, А.*Аббасов*, Л.*Верниковский*, Ю.*Борисенко*, З.*Сөнгатуллина*, В.*Ганиева*, Х.*Бигичев*, Г.*Ластовка*, Р.*Сәхәбиев*, Е.*Михайлова*, А.*Фадеичева*; балет солистлары А.*Гацулина*, Г.*Әхтәмов*, Н.*Юлтыева*, Ә.*Нарыков*, Г.*Калашникова*, Р.*Садыйков*, И.*Хәкимова*, С.*Хантимерова* шактый зур өлеш кертә. Концерт эшчәнлегендә дирижёрлар Н.*Рахлин*, Ф.*Мансуров*, Р.*Салаватов*, Р.Абязов, А.*Шутиков*; солист-башкаручылар Р.*Абдуллин* (орган), М.*Әхмәтов*, Ш.*Монасыйпов*, Р.*Абязов* (скрипка), Э.*Әхмәтова*, Ф.*Хәсәнова*, Г.*Абдуллина* (фортепиано), Ш.*Әмиров* (балалайка), Ә.*Фәйзуллин* (баян) һ.б. активлык күрсәтә. Гастрольдә эшләүче яшь музыкантлар: җырчы М.*Казаков*, пианистлар Е.Михайлов, Р.Урасин, С.Гуляк халыкара танылу ала.ТРның төп иҗади коллективлары булып *Татар опера һәм балет театры*, *Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры*, *Татарстан Республикасының Дәүләт халык музыка уен кораллары оркестры*, *Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле*, «La Primavera» (Казан) камера оркестры, «Провинция» камера оркестры (Чаллы ш.), *Татарстан Республикасының Дәүләт кыллы квартеты* санала. Татарстан М.к.сында традицион башкаручылык аеруча әһәмиятле урын тота. Милли җыр сәнгате осталары арасында Г.*Сөләйманова*, Р.*Ваһапов*, З.*Басыйрова*, Ә.*Авзалова*, И.*Шакиров*, Г.*Рәхимкулов*, Г.*Ильясов*, Ш.*Әхмәтҗанов*, Э.*Җәләлетдинов*, З.*Сәхәбиева* һ.б. киң таныла. Традицион музыка уен коралларыннан гармунда, курайда башкару сәнгате киң үсеш ала. Борынгы ансамбль музыка уен коралларында (думбыра, танбур, дәф) уйнауның өзелеп торган традицияләре 20 йөз ахырында яңадан торгызыла башлый. Хәзерге заман мәдәниятендә эстрада музыка сәнгате гаять зур үсеш ала. А.*Әсәдуллин*, Р.*Ибраһимов* бөтенроссия күләмендә киң танылу алалар. Татар эстрада җырларында хәзерге заман көйләренең төрле стиль юнәлешләре барлыкка килә, соңгы елларда FM-радиостанцияләр, продюсерлык үзәкләре (студия чыгара торган аудиоязмалар, җырларга видеоклип оештыру), ягъни аның инфраструктурасы киң үсеш ала. Зур уңыш б-н «Татар җыры», «Йолдызлык» һ.б. фестивальләр уздырыла. М.к. үсеше өчен Казан консерваториясе, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты, Казан гуманитар-пед. ун-тының музыка ф-ты, Казан, Әлмәт, Түбән Кама музыка уч-щеләре, Чаллы сәнгать уч-щесе, Лениногорск пед.-музыка уч-щесе, Казан консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәп-көллияте, проф. уку йортлары челтәре кадрлар әзерләп чыгару чыганагы булып тора. Балаларга өстәмә белем бирү системасында музыка профиле буенча 200 дән артык уку йорты эшли (балалар музыка мәктәпләре һәм сәнгать мәктәпләре), аларда 50 меңнән артык бала укый (2006). 1990 еллардан Татарстан башкаласы М.к.сы актив үсә торган халыкара үзәк булып исәпләнә. Казанда даими уңыш б-н Ф.И.Шаляпин исем. опера, Р.Нуриев исем. классик балет, «Европа-Азия» заманча музыка халыкара фестивальләре уздырыла; музыка сәнгатенең төрле белгечлекләре буенча халыкара, бөтенроссия һәм республика конкурслары, «Organo pleno» орган музыкасы фестивале, Казан хор ассамблеясы, яшь музыкантларның башка төрле форумнары оештырыла. 2006 да бөтен дөньяда танылу алган композитор һәм пианист С.*Гобәйдуллина* исем. халыкара пианистлар конкурсы булдырыла. Республикада *музыка гыйлеменең* фәнни мәктәбе формалашкан, аның казанышлары проф. һәм өстәмә белем бирү уку йортлары эшендә, музейлар, театрлар, концертлар оештыруда, махсус теле- һәм радиопрограммалар әзерләүдә файдаланыла. М.к. респ-каның массакүләм мәгълүмат чараларында киң чагылдырыла.

*Әд.:* Гиршман Я. Творчество композиторов Татарии. К., 1965; Хайруллина З., Гиршман Я. Из музыкального прошлого: Обзор татарской периодической печати 1905–1917 гг. // Вопр. татарской музыки. К., 1967; Нигметзянов М.Н. Татарские народные песни. К., 1984; Раимова С.И. История татарской музыки. К., 1986; Карпова Е. Хроника концертной жизни Казани: По материалам русской периодической печати, архивным документам (конец XVIII — начало XX в.) // Из истории музыкальной культуры и образования в Казани. К., 1991; Сайдашева З.Н. В мире татарской музыки. К., 1995; Дулат-Алеев В.Р. Татарская музыкальная литература. К., 1996; шул ук. Текст национальной культуры: Новоевропейская традиция в татарской музыке. К., 1999; Салитова Ф.Ш. Очерки по истории татарской музыкальной культуры. К., 1997; Маклыгин А.Л. Музыкальные культуры Среднего Поволжья: Становление профессионализма. К., 2000.

*В.Р.Дулат-Алиев.*

**МУЗЫКА́ЛЬ ФОЛЬКЛО́Р**, к. *Халык музыкасы.*

**МУЗЫКА́ЛЬ ҺӘВӘСКӘРЛЕ́К**, халык иҗатының бер төре; музыканы үзешчәннәр тарафыннан ялгыз һәм күмәк башкаруны үз эченә ала. Катнашучылары — клублар, мәдәният сарайлары, төрле түгәрәкләр, студия әгъзалары, уку йортлары укучылары һ.б. М.һ. казанышлары респ-ка, шәһәр, район смотрларында, конкурс, олимпиада, фестиваль, декада вакытларында күрсәтелә. Башкарудан тыш, М.һ. һәвәскәрләр тарафыннан язылган музыканы да үз эченә ала, ә ул музыка сәнгатенең яңа төре — «көнкүреш» җырларын, ягъни танылган совет музыка белгече А.Сохора фикеренчә, «турыдан-туры көндәлек тормышка кергән» җырларны тудыра. «Көнкүреш» җырлары фольклордан авторларның исеме күрсәтелү б-н аерылып тора; ул көйләр-

нең авторлары күбесенчә проф. башкаручылар: җырчылар (Р.Гатауллин, Г.Ильясов, М.Имашев, И.Мәҗитов, С.Садыйкова, З.Хәйретдинов һ.б.), инструменталистлар (Ф.Әхмәдиев, А.Батыршин, З.Гыйбадуллин, И.Закиров, М.Макаров, Г.Сәйфуллин, И.Хисамов, А.Хөсәенов һ.б.), шәһәр һәм авыл мәдәният хезмәткәрләре, һәвәскәр музыкантлар. Татарстан һ.б. респ-каларның кайбер проф. композиторларының җырларын ш.у. «көнкүреш» җырлары дип атап була, нәкъ менә халык башкаруында алар мөстәкыйль яшәеш ала, кайчагында икенче мәгънәгә дә ия була, чөнки «халык» үзенчәлекле төзәтмәләр ясый һәм җырлар текстына (музыкасына да, шигыренә дә) үзгәрешләр кертә. «Көнкүреш» җырлары эчтәлегендә мәхәббәтне, туган як гүзәллеген данлау кебек традицион темалар саклана. Әмма яшьләрнең авылдан шәһәргә күпләп күчеп китүе (1950 еллар ахырыннан) б-н бәйле иҗтимагый үзгәрешләр җырларның эчтәлегенә сизелерлек үзгәрешләр кертә. Туган як табигатенең матурлыгы темасы сагыну хисе аша бирелә, шул көйләргә моңсу төсмер өсти: «Кайтам инде» (С.Садыйкова көе, И.Юзеев сүзләре), «Туган авылыма» (С.Садыйкова көе, М.Ногман сүзләре), «Бик сагындым» (Р.Сафиуллин көе, М.Латыйфуллин сүзләре). Кайвакыт бу тема кызу һәм көчле ритмлы күңелле җырларда (юл җырлары) туган авылына кайтучы студент яшьләрнең хис-шатлыкларын ача: «Авылыбыз Күл Черкене» (Х.Гаязов һәм С.Нәҗмиев), «Сагынам сине, Питрәч» (Р.Сәйфетдинов һәм Х.Фәрхи). Яңартылган традицион темалар б-н беррәттән «көнкүреш» җырларына яшәешкә бәйле яңа темалар да керә башлый: алтын туй бәйрәме («Алтын туй җыры», Ф.Әхмәдиев һәм З.Насыйбуллин), кәләшне каршы алу («Килен төшкәндә», Р.Яхин һәм Р.Миңнуллин), ана фатихасы («Әнкәмнең догалары», И.Закиров һәм Р.Миңнуллин) һ.б.

«Көнкүреш» җырлары, көйләренә карап, 3 төркемгә бүленә. 1 нче төркемгә кергән «авыл көйләре», «салмак көй», «кыска көй» (1960–70 еллар өчен хас) җанрларында башлыча фольклор лирикасы традицияләре дәвам иттерелә; 2 нче төркем көйләрдә традицион чыганаклардан үлчәм (җөп) һәм темп (салмак яисә тиз) кына сакланган, ул күбесенчә традициядән ерак торучы интонацион һәм ритмик новацияләр кулланылган җырлардан тора; 3 нче төркемгә «чит» җанрларда туган өч өлешле «вальс көйләре», күтәренке «уңайлы» җырлар, сагышлы «танго» һ.б. җырлар керә. Югары социаль ихтыяҗга җавап биргән, җәмгыятьтәге рухи һәм психол. үзгәрешләрне сизгер тотып алган «көнкүреш» җырлары авылга хас фольклор җанрларын акрынлап кысрыклый. Нәтиҗәдә, традицион фольклор әсәрләре, эстрадада, радио, телевидениедә башкарылып, композиторлар иҗатында кулланылып, яңа мәгънә ала, эстетик ләззәт чарасы, үз халкыңны танып белү чыганагы булып тора. Үзешчәннәр башкаруында «Җырлыйк әле», «Аулак өй» телетапшырулары («Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе) массакүләм тамашага әверелде.

*Әд.:* С а й д а ш е в а З. Татарские современные бытовые песни. К., 1997; ш у л у к. Татарская бытовая песня (определение жанра) // Традиционное музыкальное искусство: История, современность, перспективы: Материалы междунар. науч.-практ. конф. 14–15 дек. 2001. Уфа, 2002.

*З.Н.Сәйдәшева.*

**МУКДЕ́Н КОНГРЕССЫ́**, Ерак Көнчыгыш төрки-татар мөселманнарының Мукден шәһәрендә (хәзер Шөнҗан шәһәре, Кытай) 1935 елның 4–14 февралендә узган җыены. Кытай, Корея һәм Япониядә (Шанхай, Нанкин, Харбин, Мукден, Сеул, Токио, Кобе, Нагоя һ.б. шәһәрләрдә) яшәүче татар якташлыкларыннан 40 вәкил катнаша. Төп максаты — шушы илләрдә яшәүче төрки-татарларның дини, мәдәни һәм сәяси оешмаларын берләштерү. Конгрессны оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе — Г.*Исхакый.* М.к.нда татар якташлыкларының дини-мәдәни эшчәнлеген өч юнәлештә: дин, мәгариф һәм финанс өлкәләрендә җитәкләргә, якташлыклар арасындагы бәйләнешларны көйләргә, бәхәсле мәсьәләләрне чишәргә, мәктәп, китапханә һәм басмаханәләр эшенә җитәкчелек итәргә тиешле «Ерак Шәрекъ төрки-татар мөселманнарының дини-милли Идел-Урал мәркәзе» оештырыла. Ком-т тарафыннан «Милли байрак» г-тасы һәм «Шәкертләр таңы» ж-лы нәшер ителә.

*И.А.Гыйләҗев.*

**МУКМЕНЁВА** Наталия Александровна (26.8.1933, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1981), проф. (1985), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), Казан химия-технол. ин-тында эшли, проблемалы фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1983 тән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. М. югары нәтиҗәле антиоксидантлар һәм стабилизаторлар — полимерларга химик өстәмәләр булдыру теориясенә һәм практикасына зур өлеш кертә. М.ның стабилизаторлар синтезы һәм реакциягә сәләте, тотрыклылык процессларын химик һәм матем. модельләштерү буенча тикшеренүләре стабилизаторлар структурасын һәм бик күп полимерларны тотрыклыландыру режимнарын фаразлауда нигез була. М. җитәкчелегендә полимерларның төсләрен тотрыклы итү принциплары эшләнә һәм, илдә беренче булып, полимерларның бик күп төрләрен эшкәртү һәм куллану процессында буямыйча саклый торган фосфорорганик стабилизаторлар эшләнә; полимер материаллар өчен химик өстәмәләр — ирекле радикал процессы ингибиторлары, антиоксидантлар, җылылык, яктылык һәм төс стабилизаторлары, күп функцияле модификаторлар синтезлана. М. тарафыннан тәкъдим ителгән контроль астында тотрыклыландыру һәм озак-ка чыдамлылыкны фаразлау принциплары полиолефин, ясалма каучук, термоэластопласт, поливинилхлорид һ.б. нигезендә химия һәм җиңел сәнәгать өчен яңа композицион материаллар табарга мөмкинлек бирә. Фәнни эшкәртмәләре «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим»; «Тольяттикаучук» пр-тиеләрендә, «Химпром» ЖБ (Чабаксар ш.), «Заря» ЖБ (Дзержинск ш.), Эстәрлетамак нефть эшкәртү з-дында, Владимир химия з-дында һ.б.да гамәлгә кертелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорорганические стабилизаторы полимеров // Старение и стабилизация полимеров. М., 1966 (автордаш); Синтез, антиокислительные и стабилизирующие свойства новых кислот трёх- и четырёхкоординированного фосфора // Журн. органич. химии. 1992. Т. 62, вып. 10 (автордаш); Синтез пространственно-затруднённых фенольных соединений на основе 3,5-ди-трет-бутил-4-гидроксибензилацетата // Журн. органич. химии. 2004. Т. 40, вып. 3 (автордаш).

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет /1971- 2001/): Краткий биогр. справ. К., 2001.

**МУКО́** Юлий Адольфович (?, фаразланганча, Варшава — 14.1.1945, Казан), балет артисты, балетмейстер, педагог. 1919 елга кадәр Казан опера театры балет солисты һәм балетмейстеры. 1920 дә Казанда Татар театр техникумы каршындагы Дәүләт балет студиясендә педагог, бер үк вакытта Татар акад. театрында (1929 га кадәр), биюләр куючы һәм аларны башкаручы буларак эстрада концертларында катнаша. 1938–41 дә ТАССР Җыр һәм бию ансамбле балетмейстеры. Г.Әлмөхәммәдов, В.Виноградов һәм С.Габәшиләрнең беренче татар опералары «Сания» (1925) һәм «Эшче»дәге (1930) хореографик күренешләр авторы. Татар акад. театрында Ф.Бурнаш пьесасы буенча С.Габәши, соңыннан С.Сәйдәшев музыкасына «Таһир-Зөһрә»; К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшевнең «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», Т.Гыйззәт һәм С.Сәйдәшевнең «Наёмщик» муз. драмалары спектакльләрендә хореографик күренешләрне сәхнәгә куючы. Хореограф буларак, Җыр һәм бию ансамбле программасын төзүдә, ш.и. «Әпипә», «Татар дуэты», «Татар яшьләренең күмәк биюе», «Белорус биюе», «Украин биюе», «Рус биюе» һ.б. бию композицияләрен





Ю.А.М у к о: 1. Ашуна (А.С.Аренский, «Мисыр төннәре»; Клеопатра ролендә — З.Чарушина). 20 йөз башы; 2. Зигфрид (П.И.Чайковский, «Аккош күле»; Одетта ролендә – З.Чарушина) рольләрендә. 1910.


иҗат итүдә катнаша. Хатыны З.Чарушина б-н бергә һәвәскәр бию коллективында актив эшли, шуннан яхшы башкаручыларны (Ф.Әсфәндиярова, Г.Баһманова, Ә.Кәлимуллин, А.Стеклова һ.б.) проф. сәхнәгә күтәрәләр. М.ның иҗатына бай фантазия һәм зәвыклылык хас була. Балетмейстер үзенең элеккеге спектакльләрендә классик балет алымнарын киң файдалана. Соңрак татар халык биюләрендәге образлылык һәм стиль үзенчәлекләрен үзләштерә һәм аларны уңышлы тормышка ашыра.

*В.Н.Горшков.*

**МУКШУ́Р** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 49 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Елангур, Еманчур, Татар Мукшуры исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, такта яру, кап сугу, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1128,5 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1744 тә — 30 ир-ат; 1859 да — 276, 1887 дә — 479, 1905 тә — 640, 1920 дә — 683, 1926 да — 661, 1938 дә — 635, 1958 дә — 302, 1970 тә — 242, 1989 да — 160, 2002 дә — 127 кеше.

*Әд.:* Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**МУКШЫ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 9 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ашыт елгасыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 58 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет — 20 йөз башы архит-ра истәлеге. 1653 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.да мәчет һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 164,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 29 ир-ат; 1859 да — 75, 1897 дә — 139, 1908 дә — 173, 1920 дә — 212, 1926 да — 221, 1938 дә — 205, 1949 да — 171, 1958 дә — 137, 1970 тә — 107, 1979 да — 73, 1989 да — 59, 2002 дә — 67 кеше.



Мукшы авылы. Мәчет. 1909.

**МУЛДА́ШЕВ** Эрнст Рифкат улы (1.1.1948, БАССРның Белорет р-ны Сермән а.), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1996), РФнең атказ. табибе (1998). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Уфа шәһәрендә: Күз авырулары фәнни-тикшеренү ин-тында (1972 елдан), 10 нчы хастаханәдә (1982 дән), «Күз микрохирургиясе» тармакара фәнни-техник комплексында офтальмохирургия лаб-ясе мөдире (1988 дән), Бөтенроссия күз һәм пластик хирургия үзәге директоры (1990 нан). АКШның Луисвилл шәһәре ун-ты киңәшчесе (1990 нан). Хезмәтләре офтальмохирургия өчен яңа төр аллоплантлар эшләү, тукыма күчереп утыртуның иммунологик аспектларын һәм аларның күрү системасы функцияләренә тәэсирен өйрәнүгә карый. М. күрү системасына зыян килгәндә авыру барышының гомуми механизмнарын тикшерә, күрү сәләтен психофизиол. юл б-н коррекцияләү ысулларын эшли. Аллоплантлар куллануның мөгез катлау, склера, конъюнктива, кимерчәкләр, паренхиматоз органнар, тире капламының кан һәм лимфа тамырлары регенерациясенә этәргеч булуын исбатлый. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 1990–93 тә РФ ЮС депутаты. Туризм буенча өч тапкыр СССР чемпионы.

Хезм.: От кого мы произошли? Сенсационные результаты научной гималайской экспедиции. М., 1999; Стафиломы склеры. Уфа, 2000 (автордаш).

*Әд.:* Гумеров Ш. Лицо ремонтируют ... подошвой // Изобретатель и рационализатор. 1978. № 12; Мазурова Л. Клиника последней надежды // Смена. 1998. № 8.

**МУЛЛА́** (гарәп. مولى — әфәнде, боеручы), мөселман дине һәм йолалары белгече, руханы, дини мәктәп мөдәррисе. Руханилар иерархиясендә хатип һәм имамнан түбәнрәк баскычта тора, әмма «М» атамасы еш кына «имам» төшенчәсенең (мөселман җәмгыятенең һәм җәмәгать намазының җитәкчесе) синонимы буларак та кулланыла. Идел буе татарларында 18 йөзгә кадәр М.ны *мәхәллә* әгъзалары сайлый, соңрак, Уфа дини Мөхәммәди канун Җыены оештырылгач (1788), М. статусы дәүләт карарлары б-н билгеләнә, раслану махсус дәүләт фәрманы нигезендә тормышка ашырыла. Рәсми рәвештә М. руханилар катлауга керми, раслануына кадәрге хәлендә кала бирә. Гадәттә, билгеле бер мәчеткә карый. Керменең төп өлешен *зәкят* (Коръәндә каралган хәйрия салымы), *гошер* (мөселман җәмгыяте ихтыяҗлары өчен салым), дини йолалар башкарудагы түләүләр, ш.у. дини бәйрәмнәр вакытында бирелгән сәдакалар тәшкил итә. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында, татарларның үз дәүләтчелеге булмаган чорларда, *мөселман руханилары*, ш.и. М.лар халыкның рухи тормышын агартуда һәм оештыруда мөһим роль уйныйлар. 1990 еллардан башлап, ТРда мөселман җәмгыятьләре тергезелү б-н бәйле рәвештә, муллалык вазифасы үсеш ала. Ш.у. к. *Татарстан Республикасы мөселманнарының дини нәзарәте, Мөселман руханилары.*

*Әд.:* Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1999. Т. 1; Ислам и мусульманская культура. К., 2007.

**МУЛЛА́ ИЛЕ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 33 *км* көньяктарак, Зөя елгасыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 780 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет — 19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.И.ндә 3 мәчет, 3 мәктәп, рус-татар земство мәктәбе, вак кредит учреждениесе, 2 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2990 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 302 ир-ат; 1859 да — 1246, 1897 да — 1895, 1908 дә — 2443, 1920 дә — 2440, 1926 да — 2159, 1938 дә — 2610, 1949 да — 1819, 1958 дә — 1608, 1970 тә — 1670, 1979 да — 1343, 1989 да — 1129, 2002 дә — 993 кеше. М.И.ндә җәмәгать-дин эшлеклеләре Б.Х.*Вәисов*, Газизҗан Б.*Вәисов*, Гайнанетдин Б.*Вәисов* туган.



Мулла Иле авылы. Мәчет. 1873.

**МУЛЛАГАЛИ́ЕВ** Сафуан Галәветдин улы (12.9.1927, хәзер Оренбург өлкәсенең Абдуллин р-ны Чаганлы а. — 19.09.2008, Казан), шагыйрь. 1947–82 елларда Үзбәкстанның Маргилан шәһәрендә яши. 1982 дән — Казанда. «Сәлам бирәм» (1986), «Күзге балкыш» (1988), «Мәңгелек йөрәк»(1989), «Йөрәктәге төеннәр» (1997) җыентыкларында туган як табигате, гади кешеләрнең күңел байлыгы

кебек темалар үзәктә тора. Туган ягыннан читтә яшәргә мәҗбүр булган кеше язмышын сурәтләгән «Биздерсәләр туган илеңнән» (1–2 кит., 1993–97) исемле шигъри повесте — М.нең иң уңышлы әсәрләреннән берсе.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МУЛЛАКА́ЕВ** Оразали Турман улы (15.3.1959, Казакъстан ССР, Чимкент өлкәсенең Сарыагач р-ны Капланбәк уку-өйрәнү хуҗалыгы), патологоанатом, вет. фән. д-ры (1999), проф. (2001), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1985), шунда ук эшли, терлекләр цитологиясе, гистологиясе һәм эмбриологиясе каф. мөдире (1999–2007), бер үк вакытта вет. ф-ты деканы (1999–2000), проректор (2000–03), 2007 дән Казан шәһәре Дәүләт вет. берләшмәсе башлыгы — Казан шәһәре Баш дәүләт вет. инспекторы. Бер үк вакытта Казан вет. медицинасы академиясенең патологик анатомия һәм гистология (2007–10), вет.-сан. экспертизасы (2010 нан) кафедралары профессоры. Хезмәтләре бруцеллёзга каршы төрле вакциналарның нәтиҗәлелеген һәм реактогенлыгын иммунологик, ультраструктур, иммуногенетик яктан бәяләүгә карый. М. терлекләрнең орган һәм тукымаларындагы төрле вакцина һәм апатоген штамм бруцеллаларын полимеразалы чылбыр реакциясе ярдәмендә индикацияләү ысулын тәкъдим итә; СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгының Дәүләт вет. идарәсе тарафыннан расланган 3 норматив-техник документ эшли (1991).

Х е з м.: Иммуноморфологические изменения в органах и тканях тёлок, привитых вакциной из штамма бруцелл 82-ПЧ в разных дозах // Ветеринария. 1993. № 5; Строение разных штаммов бруцелл // Морфология. 1998. № 3.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**МУЛЛАНУ́Р ВАХИ́ТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́** авыл, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Әлки р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1938 дә — 193, 1949 да — 208, 1958 дә — 200, 1970 тә — 231, 1979 да — 183, 1989 да — 136, 2002 дә — 107 кеше.

**МУЛЛАНУ́Р ВАХИ́ТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́** авыл, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 25 *км* көньяктарак, Идел елгасыннан 5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 203 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 157, 1938 дә — 258, 1949 да — 279, 1958 дә — 227, 1970 тә — 208, 1979 да — 216, 1989 да — 183, 2002 дә — 230 кеше.

**МУЛЛА́ШЕВ** Камил Вәлиәхмәт улы (27.10.1944, Шөнҗан провинциясе Орымчы ш., Кытай), нәкышьче, Казакъстан Респ-касының атказ. сәнгать эшлеклесе (1996), ТРның халык рәссамы (2003), Шаньтоу ун-тының шәрәфле профессоры (Кытай, 2000), Казакъстан Респ-касы СА академигы (2005). Орымчы шәһәренең Сәнгать ин-тын тәмамлый (Кытай, 1961). 1963 елдан Казакъстанда. Н.В.Гоголь исем. Алма-Ата сәнгать уч-щесен (1967), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын (СССРның халык рәссамы Т.Сәлахов остаханәсе, 1978) тәмамлый. 1978–80 дә Алма-Ата сәнгать уч-щесендә укыта, 1980–2001 дә «Онер» («Һөнәр») сәнгать комб-тында эшли, 2001 дән — Жургенов исем. Сәнгать академиясе профессоры. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). 1994 тән — Казакъстан Респ-касының Мәдәни үзәкләре ассоциациясе президиумы әгъзасы. М.ның әсәрләре чирәм җирләрне һәм галәмне үзләштерү, нефть чыгару («Корылык», 1974; «Иртә», 1976; «Җир һәм Вакыт. Казакъстан», 1978; «Чабан», 1979; «Авыл депутаты», 1985; «Көтү», 1995), табигатьне саклау («Арал фаҗигасе», «Семипалатта атом шартлавы» сериясе, икесе дә — 1988; «Бишек җыры», 1989; «Капчагай даласы», 1988) һ.б. темаларга багышлана. Күпчелек әсәрләре реализм традицияләрендә натура йогынтысында ясалган. 1980 елларда иҗат ителгән әсәрләр циклында рәссам иҗатының ассоциатив-хисси образлылык, пластик һәм төсле декоративлык ягына кучү эволюциясе ачыла («Рәссам дөньясы» сериясе, 1990; «Болан патшаның балык белән сөйләшүе», 1991; «Җәйләүдә», 1992; «Көнләшү», 1993). М.ның натурадан ясалган иртә портретларыннан башлап («Әти портреты», 1972; «Татар хатын-кызлары» сериясеннән «Татар кызы», 1986; «Тирмәдәге хатын», «Әни портреты», икесе дә — 1988; «Эшләпә кигән ханым портреты», 1992), борынгы милли каһарманнар образларына («Әбелхәер хан портреты», 1993; «Абай портреты», 1994; «Сөембикә ханбикә», «Кыпчак кызы Евразия», икесе дә — 1997; «Акын-Сара», 1998) һәм тарихи темаларга багышланган картиналар серияләренә кадәр портрет иҗаты камил һәм күптөрле. Алар арасында «Даһиның тууы», 1990; «Кичке кояш нурына күмелгән мәңгелек мизгел», «Сабан туе» (икесе дә — 1996); «Едил башланган урында», 1997; «Казан ханбикәсе тәхете янында», 1998;



К.В.М у л л а ш е в. «Сөембикә ханбикә». 1997. ТР Президент сарае картиналар галереясы.



К.В.М у л л а ш е в. «Акын Сара». 1998.

«Астананы тәкъдир итү», 1999 һ.б. картиналары фикер тирәнлеге һәм гражданлык позициясе б-н аерылып тора. М. иҗатында классик реализм һәм авангард юнәлеше, төрки сәнгатнең традицияләре янәшә яши, 1990 елларның 2 нче яртысыннан анда «салон» нәкыше тенденцияләре чагыла.

Респ-ка (1974 тән), бөтенсоюз («Җир һәм кешеләр», Мәскәү, 1979, 1984; «Илнең яшьлеге», Мәскәү, 1976, 1977, 1982; «Без коммунизм төзибез», 1981, 1982, 1986; «Нәкышь күргәзмәсе», Мәскәү, 1986), халыкара («Интеркосмос», Берлин, 1981; «Традицияләр һәм эзләнү», Париж, 1984; «ТЮРКСОЙ» әгъзасы булган илләр рәссамнары, Әнкара, 1998) күргәзмәләрдә, «Татарт» төбәкара бөтентатар күргәзмәсендә (С.-Петербург–Казан, 1991) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Алма-Ата (1985, 1999, 2001), Астана (2002), Казан (2003), Шанхай һәм Гуанчжоу (2004) шәһәрләрендә уза.

Әсәрләре Мәскәүдәге Третьяков галереясында, Казакъстан Респ-касының А.Кастеев исем. Дәүләт музеенда, Астана шәһәрендәге Сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Караганда өлкәсе музеенда, Алма-Ата, Астана, Казандагы Президент сарайларында, чит илләрдәге шәхси тупланмаларда (АКШ, Төркия, Германия, Англия, Лихтенштейн) саклана. ВЛКСМ ҮК бүләге лауреаты (1981). «Почёт билгесе» ордены, «Җир һәм Вакыт. Казакъстан» триптихы өчен Франция САнең көмеш медале (1986) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г.В. Бишек җыры // Казан утлары. 1993. № 10; Н е м и р о в с к а я О. Крылатые кони степи // Огонёк. 1981. № 18; Камиль Муллашев. Я всё делаю с любовью: Каталог персональной выставки. Алматы, 2001; К у м а р о в а С. Камил Моллашёв // Білім жəне енбек. 1984. № 11.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*



Р.Х. Муллин.



Р.М. Муллина


**МУЛЛАЯ́НОВ** Шамил Нургали улы (3.2.1944, БАССРның Уфа р-ны Октябрь пос.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын (1968), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (1978) тәмамлый. 1969–71 елларда ВЛКСМның Башкортстан өлкә ком-тының «Ленинец» г-тасы редакциясендә (Уфа ш.) эшли. 1971–88 дә «Советская Татария» г-тасында: әдәби хезмәткәр, пропаганда бүлеге җитәкчесе, мөхәррир урынбасары. 1989–91 дә КПССның Татарстан өлкә ком-тында матбугат секторы мөдире. 1991 дән «Республика Татарстан» г-тасының баш мөхәррире урынбасары. М. язган мәкаләләрнең тема һәм жанрлары күптөрле: алдынгы нефтьчеләр һәм КамАЗ төзүчеләр турында очерклар, яшьләр тәрбияләүнең патриотик һәм әхлакый нигезләре хакында язмалар.

**МУ́ЛЛИН** Борһанетдин Фәхретдин улы (5.5.1834, Казан губ., Казан өязе Каратмән а. — 1917), 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. Чәй һәм шикәр б-н сәүдә итә. 1879–1900 елларда Казан шәһәр Думасы гласные, бер үк вакытта, 1883 тән, шәһәр идарәсе әгъзасы. 1878–82 дә Казан татар сәүдәгәрләре җәмгыяте старостасы. Казан шәһәр ятимнәр мәхкәмәсе әгъзасы һәм казначее. «Мәрҗания» мәдрәсәсе төзелешенә һәм Мөселман хәйрия җәмгыяten оештыруга матди ярдәм күрсәтә. Казандагы Чукрак-телсез балаларны тәрбияләү, аларга белем бирү җәмгыяте һәм Ятим, авыру балаларга булышлык итү җәмгыяте әгъзасы. Ш.у. к. *Муллин йорты.*

*Р.Р.Хәйретдинов, Р.Р.Салихов.*

**МУ́ЛЛИН** Рөстәм Хан улы (26.7.1947, Кукмара р-ны Кәркәүч а.), драма актёры, ТРның халык артисты (1996). Алабуга мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлаганнан соң (1972), Минзәлә татар драма театрына актёр булып эшкә килә. Ул иҗат иткән Зөлфәт («Гарасат»,Г.Сабитов), Аллаһияр, Хөрмәт, Артист («Соңгы ләкләк», «Язлар моңы», «Сары чәчәк саплары», Ә.Гаффар), Хангилдин («Ардуан батыр», Г.Ахунов), Ибраһим, Мирвәли («Тын урамда гауга», «Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Бәрәгулла, Баһадур («Ярым ятларга кала», «Каерылмасын канатың», Р.Батулла), Габдрахман («Кишер басуы», З.Хәким), Сөләйман («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Камай морза («Хан кызы», Р.Хәмид), Жеронт («Скапен хәйләләре», Ж.Б.Мольер) образлары үзенчәлекле, көчле характерлы булулары б-н аерылып тора. Актёрның буыннар фаҗигасен, тормышка ышанычны югалту ачысын кичергән герой холкына хас кырыслыкның төп сәбәпләрен үтемле җиткерә алган Мирвәли образы аеруча зур иҗтимагый әһәмияткә ия. Матур тавышлы М. муз. спектакльләрдә Булат, Юлаучы («Зәңгәр шәл», «Ил», К.Тинчурин), Кәримулла, Садыйк («Ике килен-килендәш», «Җырым табар сине», Х.Вахит), Тархун («Кызыма килер йөз кеше», Х.Ибраһим) рольләрен башкара һәм әлеге образларның драматик эчтәлеген ышандырырлык итеп ачып бирә.

*Д.Ә.Гыймранова.*



Р.Х. М у л л и н  Күсәк Чынтимер ролендә («Айгырыңны үтечкә бир», Р. Кинҗәбаев; сулда — И. Әхмәтханов).



Р.Х. М у л л и н  Әхмәров ролендә («Хыянәт», Х. Вахит; сулда – В. Нигъмәтуллина һәм Ф. Зәйнетдинова).

**МУ́ЛЛИН ЙОРТЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казан сәүдәгәре Б.Ф.*Муллин* өчен, фасадларны бизәүдә классицизм архит-расы элементларын кертеп, татар халык архит-расы традицияләрендә төзелә. Иске татар бистәсендә урамга яны б-н салынган. Татар сәүдәгәрләренең ике катлы, ике кыеклы, традицион планлы шәһәр йорты үрнәге. Беренче катта — аш һәм хуҗалык бүлмәләре, икенчесендә торак бүлмәләре урнашкан. Ишек йортның ишегалды ягында уелган. Өйалды баскычыннан икенче катка күтәрелергә мөмкин. Чарлактагы пар колонналы традицион аркалы бүлмәдә кызлар яшәгән. М.й. тәрәзәләре сандриклы йөзлекләр, ябыштырылган декор б-н бизәлгән. Йортның бүрәнә диварлары такта б-н горизонталь юнәлештә тышланган, почмаклarda чыгып торган бүрәнә башлары такта пилястралар б-н капланган. Фасадлар татар халык архит-расы традицияләрендә төрле төсләргә буялган. 2010 елларда реконструкцияләнә.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*



Б.Ф. Муллин йорты. Казан. 19 йөзнең 2 нче яртысы. 21 йөз башы фоторәсеме.

**МУ́ЛЛИНА** Рәзилә Мирхәт кызы (7.9.1956, Минзәлә р-ны Татар Мөшегесе а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2011). Алабуга мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлый (1976). 1976–79 елларда Мамадыш халык театрында эшли, 1979 дан Минзәлә татар драма театрында. Гариплеккә дучар ителгән, кешеләргә ышаныч хисен югалта язган, әмма үзенең ачы язмышына буйсынырга теләмичә, хаклык өчен көрәш юлына баскан, рухи чыныгу алган яшь кыз бала Ирада («Язмышлар хәл ителгәндә», Р.Хәмид), кыю, хакыйкать хакына утка, суга керергә әзер торган Гөлҗамал («Син — минеке, мин — синеке», А.Гыйләҗев), ш.у. Тәнзилә («Сөйгәнемнең туган көне», И.Юзеев), Кәүсәрия («Сәер кеше», Х.Вахит) кебек беренче рольләре актрисаның, образның психол. халәтен тирән тоеп, күпкырлы характер тудыра алу сәләтен күрсәтә. М. жанр табигатен нечкә тоемлап эш итә, ул, Ә.Гаффарның «Бер картлыкта, бер яшьлектә» комедиясе буенча куелган спектакльдәге Хөснурия образын гәүдәләндергәндә гротеск алымнарыннан кыю файдалана; Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Сәрвәр («Башмагым», Х.Ибраһимов) кебек лирик образларны ышандырырлык итеп уйный. Алина («Упкын читендә», А.Дударев), Алия («Юлларыңа ак җәймә», Н.Асанбаев),



Р.М. М у л л и н а  Хөснурия ролендә («Бер картлыкта, бер яшьлектә». Ә. Гаффар; уңда — Ә.М. Исрафилов).

Шәмсегаян («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Энҗе («Һәркемгә бер кояш», Ф.Бәйрәмова), Филумена («Филумена Мартурано», Э.де Филиппо) образларын иҗат иткәндә, М.ның олы тәҗрибә туплаган оста булып өлгерүе күренә. Дамир Сираҗиев исем. бүләк лауреаты.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007. *Д.Ә.Гыймранова.*

**МУЛТА́Н**, к. *Пучинкә-Кучук*, Кукмара р-ны.

**«МУЛТА́Н ЭШЕ́»**, Вятка губернасы Малмыж өязе Иске Мултан авылының (хәзер Удмурт Респ-касының Кизнер р-ны Короленко авылы) бер төркем удмурт крәстияннәрен (вотякларны) мәҗүси аллаларга кеше корбан итүдә ялган гаепләү буенча мәхкәмә процессы. 1892–96 елларда дәвам итә. Эш ачылуга Аник һәм Иске Мултан авылы кешеләре арасындагы каршылык сәбәп була: Аникның ике крәстияне, үзләрен Иске Мултанның җәмәгать җиренә керттерергә теләмәгәннәре өчен, мултанлыларга гаеп ташлау һәм аларның җирләренә хуҗа булу максаты б-н бер сукбайны (Матюнин) үтерәләр. Мәхкәмә эше барышында һәм җәмәгатьчелекнең актив катнашында мәетнең, үтерүгә ритуаль корбан китерү рәвеше бирү өчен, полицейскийлар тарафыннан башы өзелү факты ачыклана. Милли дошманлык хисләре уяту максаты б-н рәсми хакимият әлеге эшнең киң таралыш алуына юл ача. Тикшерү эше Сарапул округ мәхкәмәсе прокуроры Н.И.Раевский җитәкчелегендә 29 ай буе алып барыла, 10 кешегә гаеп ягыла. Беренче мәхкәмә утырышы 1894 нең 10–11 декабрендә Малмыж шәһәрендә уздырыла: 3 кеше аклана, 7 кеше, ритуаль үтерүдә гаепләнеп, гомерлек каторгага хөкем ителә. Кассация шикаяте буенча Сенат хөкем карарын кире кага, эшне кабат тикшерү турында карар чыгара. Икенче мәхкәмә утырышы 1895 нең 29 сентябре — 1 октябрендә Вятка губернасының Алабуга шәһәрендә була — 1894 елгы хөкем карары үз көчендә калдырыла. Яклаучы Дрягин биргән кассация шикаятенә җавап итеп, Сенат Казан округ мәхкәмәсенә әлеге эшне кабат тикшерүне йөкли. 1896 ның 28 мае – 4 июнендә Казан губернасы Мамадыш шәһәрендә өченче мәхкәмә процессы үткәрелеп, хөкем ителүчеләр аклана. Гаепләнүчеләрне аклауда В.Г.*Короленконың* яклаучы буларак матбугатта һәм соңгы процесста ясаган чыгышлары, ш.у. яклау ягы шикаяте буенча юрист А.Ф.*Кони* чыгарган нәтиҗә зур роль уйный. 1895–96 да М.э. Россия матбугатында гына түгел, дөнья матбугатында барган дискуссияләргә җирлек була.

*Әд.:* Дело мултанских вотяков, обвинявшихся в принесении человеческой жертвы языческим богам. М., 1896; К о р о л е н к о В.Г. Мултанское жертвоприношение // Собр. соч. М., 1955. Т. 9; К о н и А.Ф. Избранные произведения. М., 1959. Т. 1; Ш а т е н ш т е й н Л.С. Мултанское дело. 1892–1896 гг. Ижевск, 1960.

**МУЛЯ́РЧИК** Пётр Афанасьевич (28.4.1908, Ковно ш., хәзер Литва Респ-касы Каунас ш. — 9.10.1979, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1957). 1914–25 елларда Саратов шәһәрендәге «Кызыл шәһәрчек» балалар йортында тәрбияләнә. 1925–27 дә агач эшкәртү остаханәсендә эшли, бер үк вакытта театр техникумында дәресләр ала, шунда аның сәхнә таланты ачыла. Юллама б-н Ленинградка килә, 1930 да Ленинград сәхнә сәнгатьләре техникумын тәмамлый. 1930–32 дә Ленинградтагы Кызыл Армия театры актёры, 1932–42 дә Сызрань, Сталиногорск, Сталинград шәһәр театрларында эшли. 1941–42 дә халык ополчениесе составында Сталинградны саклауда катнаша, хәрби медальләр б-н бүләкләнә. 1942 дә Сталинград яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актёрлары б-н Казанга күчерелә. 1942–68 дә Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актёры, рус



П.А.М у л я р ч и к Жан Вальжан ролендә («Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча).

һәм чит ил классикасы әсәрләре, шул чор драматургларының пьесалары буенча куелган спектакльләрдә 100 дән артык роль башкара. Аеруча зур рольләре — Городничий («Ревизор», Н.В.Гоголь), Кречинский («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Большов, Дикой, Мамаев («Агай-эне — ак мыек», «Яшенле яңгыр», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Берсенев («Бер көн элек», И.С.Тургенев), Лопахин («Чия бакчасы», А.П.Чехов), Тетерев («Мещаннар», М.Горький), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Жан Вальжан



П.А.М у л я р ч и к Василий Васильевич ролендә («Чын кеше», Б.Н.Полевой романы буенча; сулда – М.П.Неменко-Бабковская).

(«Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча), Монтанелли («Кигәвен», Э.Л.Войнич романы буенча), Гарифҗан Атабаев («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт). М.ның иҗат палитрасында романтик буяулар, хисләр югарылыгы һәм социаль характеристика төгәллеге, гаҗәеп тормыш чынлыгы, образның биографик детальләр б-н тулыландырылуы табигый үрелеп бара. М.ка халыкчан характерлар, хезмәт кешесе образы аеруча якын. Ул башкарган Енакиев («Полк улы», В.П.Катаев), Павлов, Заварин, Лапшин («Тормыш сәхифәләре», «Тигезсез көрәш», «Шатлык эзләгәндә», В.С.Розов), Василий Васильевич («Чын кеше», Б.Н.Полевой романы буенча), Богатырёв («Бер төн», Б.А.Горбатов) образлары үзләренең бөтенлеге, эчке ышандыру көченә ия булулары б-н игътибарны җәлеп итә.




П.А.Мулярчик.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986. *Ю.А.Благов.*

**МУНИЦИПА́ЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘ́Р**, муниципаль милке, җирле бюджеты һәм җирле үзидарәнең сайлау органнары булган шәһәр һәм авыл җирлекләре (аларның өлешләре), уртак терр-я б-н берләшкән берничә җирлек, җирле үзидарәсе булган башка терр-яләр. РФнең 2003 ел 6 октябрь Законы, ТРның 2004 ел 28 июль һәм 2006 ел 22 февраль законнары нигезендә ТРда Казан, Чаллы шәһәрләре һәм 43 районның (Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш, Алексеев, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә, Баулы, Балтач, Бөгелмә, Буа, Югары Ослан, Биектау, Чүпрәле, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеев, Минзәлә, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай, Ютазы) М.б.е булдырыла. *Е.Б.Долгов.*

**МУНЧА́**, юыну-чабыну өчен корылган махсус бина. Татарстан терр-ясендә Идел буе Болгар дәүләтенең шәһәр халкына бер үк вакытта үзенчәлекле җәмәгать клублары булып та хезмәт иткән көнчыгыш тибындагы М. калдыклары сакланып калган. Болгар шәһәрендәге казу эшләре нәтиҗәсендә 14 йөзгә нисбәтле 5 җәмәгать М.сы, ш.и. *Ак пулат*, *Кызыл пулат* булуы ачыклана. Тикшеренүчеләр фикеренчә, Кызыл пулат шәһәрнең төп М.сы булган. Күп гөмбәзле, уеп бизәкләр төшерелгән таш-кирпеч бинаның эчке планын өч төп корылмадан торган анфилада тәшкил итә: дивар буена утыргычлар куелган мунча алды; дүрт почмакта ябык араннар б-н бүленгән дүрт бүлмә һәм сулы зур таш савыт рәвешендәге үзәк өлеш; казаннар һәм мич аерым урнаша. Юыну залын яктырту максатында аның гөмбәзенә тәрәзәләр уела, бина идән астыннан уздырылган катлаулы система ярдәмендә җылытыла, су б-н тәэмин итү



Кызыл пулат — болгар җәмәгать мунчасы.

һәм канализация өчен керәч торбалар файдаланыла. Җәмәгать М.лары Казан ханлыгында да була. Мәс., *Даир мунчасы* хакында мәгълүматлар сакланган. Борынгы бабаларыннан татарлар М.ның авыл вариантларын мирас итеп алганнар. Аларның иң камилен — җир өстенә корыла торган буралы М.ны, ягъни юллыклы мичле ак мунчаны татар авылларында хәзергәчә салалар. Татар халкының бер өлеше көнкүрешендә әле 1970 елларда да кара М.лар очраштыра. Алар, гадәттә, ихатаның арткы яртысында урнашкан була. Русларның кара М.ларыннан аерылмыйлар диярлек: идәнле, түшәмле, атлама түбәле һәм ян диварына тәрәзә уелган җыйнак кына бура, читән яисә тактадан корылган, еш кына түбәсез, гади генә мунча алды. Эчке күренеше төрлечә, әмма ешрак түбәндәгечә була: тәрәзә ягына утырып юыну өчен эскәмияләр куела, аңа каршы яклап бер рәттә әвен миче һәм чабыну-парлану өчен тәбәнәк кенә ләүкә. Ак М.лар ишегалдында аерым яисә башка хуҗалык корылмалары б-н бер түбә астына кертеп төзелә. Аларның мунча аллары уңайлы, юллыклы торбалы мичнә су казаны утыртыла. Казан артында һәм Касыйм татарларында бай гаиләләрнең М.сы өч өлештән торган: М. үзе, чишенү һәм юынганнан соң чыгып ял итү бүлемнәреннән торган мунча алды. Элек татар гаиләләре үз М.ларын булдырырга яисә 2–3 гаиләгә бер М. булса да салырга тырышканнар. М. юыну өчен генә хезмәт итмәгән: анда кайчакларда бала да тапканнар, авыруларны да дәвалаганнар, кер юу, көлтә киптерү һ.б. өчен дә файдаланганнар. Хәзерге вакытта шәһәрләрдә типовой



Традицион бура мунча.

проект буенча төзелгән М.лар киң таралган. Авылда әүвәлгечә үк индивидуаль М.лар өстенлек итә, соңгы елларда аларны коры парлы фин М.лары (сауналары) үрнәгендә дә төзиләр.

*Әд.:* Смирнов А.П. Волжские булгары // Тр. Гос. ист. музея. М., 1951. Вып. 19; Мухамедова Р.Г. Татары-мишари. М., 1972; Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977; Айдаров С.С., Аксёнова Н.Д. Великие Булгары. Путеводитель по Булгарскому историко-архитектурному заповеднику. К., 1983; Червонная С.М. Искусство Татарии. М., 1987; Бушков Р.А. Баня по-Казански. К., 1993.

*Ф.Ф.Гулова.*

**МУНЧАЛА́ КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Ашыт, Сола, Питиал елгалары бассейны субүләрендә урнашкан, Биектау р-ны Ювас авылыннан көньяктарак. Су өслегенең мәйданы 8 *га*. Су күләме 288 мең $м^3$. Озынлыгы 470 *м*, иң зур киңлеге 250 *м*. Уртача тирәнлеге 3,6 *м*, иң зур тирәнлеге 9 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы катлаулы. Ярлары текә. Җир асты сулары б-н туена. Суы йомшак (2,5 *мг-экв/л*),



Мунчала күле.

гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 180,9 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 40 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

**МУНЧАЛЫ́**, к. *Мөчәли*, Чүпрәле р-ны.

**МУНЬКО́В** Николай Петрович (18.5.1923, Казан — 1.7.2002, шунда ук), тарихчы, проф. (1985), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1983) һәм ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1945), Казан пед. ун-тында эшли: 1951–56 елларда тарих ф-ты деканы, 1960–68 дә проректор, 1967–91 дә СССР тарихы (1967–85 тә каф. мөдире), 1991–98 дә Ватан тарихы, 1998–2002 дә Россия тарихы кафедраларында укыта. 1967–85 тә Казан шәһәр советы депутаты, халык мәгарифе даими комиссиясе рәисе. СССР ФАнең СССР тарихы ин-ты каршындагы «Тарих фәне тарихы» гыйльми советы әгъзасы (1977–85). Татарстан тарихы буенча дәреслекләр һәм уку-укыту ярдәмлекләре автордашы («Татарстан АССР тарихы: Урта мәктәпләр өчен уку-укыту ярдәмлеге» — «История Татарской АССР: Учебное пособие для средней школы», 1970 һ.б.). Хезмәтләре Россиянең тышкы сәясәте һәм дипломатиясе мәсьәләләренә, тарихи чыганакларны өйрәнүгә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, «Халык мәгарифе отличнигы» билгесе б-н бүләкләнә.

Хезм.: М.И.Кутузов — дипломат. М., 1962; Страницы памяти // Во имя Отчизны: Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1975 (автордаш); История Татарстана, XIX век: Учеб. пособие. К., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**«МУРАВЕ́ЙНИК»** («Кырмыска оясы»), әдәби, иҗтимагый-сәяси журнал. 1905 елның октябрь–декабрь айларында Казанда аена 2 тапкыр рус телендә нәшер ителә, барысы 5 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — В.Бартош. Актив авторлар арасында — Н.Новиков, Б.Розинский, В.Язвицкий. Журналдагы бүлекләр: «Беллетристик әсәрләр», «Шигырьләр», «Үзебезнеке», «Чит илдә», «Әдәбият һәм театр хәбәрләре», «Гигиена», «Төрлесеннән». Редакция журнал битләрендә иҗтимагый тормышның хәлиткеч проблемаларын әдәби һәм публицистик формада чагылдырырга, «әдәби үрләрдә яңа йолдызлар кабызу» өчен, төбәкнең иң яхшы язучылары иҗаты б-н таныштырырга тырыша. Журнал 1905–07 елгы рев-ция дулкынында барлыкка килә һәм революцион-демократик юнәлеш ала. Һәр санның беренче битендә көрәш һәм яңа тормышның җиңүе рухы б-н сугарылган шигырьләр басыла. Журналда кечкенә күләмле әдәби әсәрләр: шигырьләр, хикәяләр, сатирик-юмористик язмалар урын ала. Басмада Бартошның (псевд. Муравей) «Яктырта, тик җылытмый» («Светит да не греет»), «Көрәш» («Борьба») повестьлары басыла. Бартош журналда дөнья күргән публицистик мәкаләләрнең дә авторы була. «М.» социал-демократларны әйдәп баручылар дип саный, барлык алдынгы көчләрне Конституцияне әзерләү һәм 1905 нең 7 октябрь Манифесты игълан иткән хокук һәм ирекне тормышка ашыру өчен берләшергә чакыра, сәяси тоткыннарга өлешчә амнистияне хуплап чыга. Редакция Учредительләр җыенын чакыру идеясен яклый, законнар чыгару функцияләреннән азат Дума булдыруны яклаган уң карашны алга сөрүчеләрне тәнкыйтьли. «М.»та Көнбатыш Европа социал-демократлары эшчәнлеге тәфсилләп яктыртыла. Журналда чиновникларның бюрократлыгы көлкегә алына: алар «галиҗәнаплар», «өстәл башлыклары» һәм «өстәл




«Муравейник» журналы.

асты башлыклары» дип атала. «Авыл ихтыяҗлары» исемле мәкаләләр сериясе басыла, аларда крәстияннәрнең фәкыйрь тормышы тасвирлана, аграр мәсьәләнең хәл ителмәве авылдагы социаль киеренкелекнең төп чыганагы булуы ассызыклана. Мәкаләләрдә авыл мәктәпләрендә гомуми белем биргүне кертү, һәр урында игенчелек һәм һөнәрчелек мәктәпләре ачу, халык укытучыларының ролен күтәрү һәм аларның матди хәлләрен яхшырту мәсьәләләре күтәрелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**МУРАВЬЁВ** Анатолий Васильевич (2.7.1923, Казан — 11.9.2010, шунда ук), спортчы, тренер (туплы, алкалы хоккей), СССРның спорт остасы (1953), Белоруссия ССРның атказ. тренеры (1966). СССР һәм РСФСР чемпионатларында — футбол буенча мастерлар командаларында: 1940–50 дә — «Динамо» (Казан), 1950–51 дә — «Спартак» (Мәскәү), 1953–55 тә — «Даугава»да (Рига); туплы хоккей буенча: 1947–50 дә — «Динамо», 1950–52 дә «Ленин районы» (Казан), 1953 тә — «Округ офицерлар йорты»нда (Рига) катнаша, соңгысында СССР чемпионатында көмеш медаль ала; алкалы хоккей буенча: 1955–56 да — «Ленин районы», 1958 дә — «Җитен комбинаты» (Казан) катнаша. Алкалы хоккей буенча 1956–65, 1966–68 дә — «Машстрой», Урицкий исем. СК (Казан), 1965–66, 1968–76 да — «Торпедо» (Минск), 1976 да — «Рубин» (Төмән), 1977–80 дә — «Баильдон» (Катовице ш., Польша) командаларында өлкән тренер (1959 га кадәр — уйнаучы тренер). 1976–77, 1980–81 дә Белоруссия ССРның Физик культура һәм спорт дәүләт ком-тында дәүләт тренеры. 1981–86 да «Залесный» спорт комплексы базасы (Урицкий исем. СК, Казан), 1986–95 тә ракета гаскәрләренең Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесенең махсус ф-ты кунакханәсе директоры. 1995 тән «Ак Барс» хоккей спорт клубында тренер-консультант. Шәкертләре арасында В.А.Васильев, В.А.Елистратов, В.А.*Елфимов*, Л.А.Ефремов, С.А.*Котов*, М.Г.Маслов, А.Н.Орлов, А.П.Романов, В.Ф.Ткачёв бар.

**МУРАВЬЁВ** Владимир Юрьевич (8.12.1947, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1997), проф. (1999), ТАССР һәм РФнең атказ. табибе (1991, 1998). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Респ-ка онкология диспансерының торакаль бүлегендә хирург, бер үк вакытта (1978 елдан) Казан ГИДУВында. 1980 елдан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының эндоскопия үзәге мөдире һәм 1985 тән баш эндоскописты. Хезмәтләре сулыш әгъзалары һәм ашказаны-эчәк трактында шеш үсешен катнаш лазерлы эндоскоп ярдәмендә таркатуга карый. М. авыруларны амбулаториядә операциясез дәвалау мөмкинлеге биргүче «Медула» лазер системасын беренче булып куллана башлый. Эндоскопия буенча РФ чемпионы (2013). Танылган бард. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1985) башкару сәнгатендәге уңышлары өчен бирелә. Бәллүр эндоскоп иясе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Комбинированная эндоскопическая деструкция опухолей дыхательной системы и желудочно-кишечного тракта. К., 1997; Эндоскопия гортани, трахеи, бронхов, пищевода, желудка, двенадцатиперстной кишки. К., 2009.

**МУРАВЬЁВ** Иван Степанович (14.7.1922, Түбән Новгород өлкәсенең Бутурлинск р-ны Кетарша а. — 8.11.1990, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1969), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1972). Киев танк уч-щесен (1941), Казан югары офицерлар мәктәбен (1946), Казан ун-тын (1952) тәмамлый, шунда ук эшли, СССР геологиясе каф. мөдире (1975–87), проф. (1987 елдан). М. СССРның Төньяк Европа өлешендә геол.-төшерү эшләре үткәрә, Печора Урал буе триас, ташкүмер һәм Пермь утырмаларының, Урта Идел буе девон токымнарының үзенчәлекләрен ачыклый. СССР Дәүләт геол. картасын (масштаб 1:200000) төзүдә катнаша. Беренчеләрдән булып, Урта Печора бассейнының нефть, газ, күмер һ.б. файдалы казылмаларга бай булуын исбатлый, соңрак биредә сәнәгый чыганаклар ачыла. Татарстан терр-ясенең һәм аңа чиктәш регионнарның структур һәм фациаль карталарын төзи, тектоник структураларны билгели һәм аларга тасвирлама бирә, югары палеозой утырмаларына палеоботаник тикшерүләр үткәрә. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратиграфия и условия формирования пермских отложений Печорского Приуралья. К., 1972.

*Әд.:* А н у ф р и е в А.М., Б у р о в Б.В. И.С.Муравьёв. К., 2003.


**МУРАВЬЁВА** Елена Викторовна (12.6.1961, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2008). Казан мед. ин-тын (1983), Казан ун-тын (2003) тәмамлый. 1999 дан Казан техник ун-тының сәнәгать экологиясе кафедрасында, 2009 дан сәнәгать һәм экология куркынычсызлыгы каф. мөдире. ТР Җәмәгать палатасында куркынычсызлык буенча эксперт.

Х е з м.: Экологическая подготовка студентов технического вуза. К., 2006; Прикладная техносферная рискология. Экологические аспекты. К., 2007; Педагогические аспекты прикладной техносферной рискологии. К., 2011.

**МУРА́Т** Валерий Николаевич (30.9.1900, Иркутск ш. — 5.7.1976, Ленинград), анатом, мед. фән. д-ры (1942), проф. (1944), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). СССР МФА академигы В.Н.Терновский шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), шунда эшкә калдырыла, 1944 елдан анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта (1947–62) дәвалау ф-ты деканы. Бөек Ватан сугышы елларында Казандагы госпиталь башлыгы. 1962–67 дә С.М.Киров исем. Хәрби мед. академиясендә (Ленинград) анатомия каф. башлыгы. Хезмәтләре нейроморфологиягә, эчәклектәге нерв ганглийлары цитоархитектоникасына, күзнең хәрәкәт аппараты иннервациясенә карый. Бөтенсоюз анатомнар, гистологлар һәм эмбриологлар җәмгыятенең Татарстан респ-ка бүлеге рәисе (1953–60). Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Грудинный мускул (sternacis s.praesternalis): К вопросу о его морфологии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1930. Кн. 1 (автордаш); Экспериментально-морфологический анализ взаимоотношений симпатических нервов с поперечнополосатыми мышцами // Архив патологии. 1947. Т. 9, вып. 5; Проблемы морфологии нейротканевых и сосудистотканевых отношений. К., 1963.

*Әд.:* К о р о т к о в А.Г., В а л и ш и н Э.С. Памяти Валерия Николаевича Мурата // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1977. № 7.



И.Х.Мурзин.

**МУ́РЗИН** Александр Николаевич (19.8.1885, Мәскәү — 22.12.1954, Казан), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1935), проф. (1935), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1909), Калуга губернасының Жездринский өязе Подбужье авылында земство табибе, 1910 елдан Мәскәү губернасы Павлов-Посад шәһәрендә фабрика табибе, 1913 тән Саратов ун-тының күз поликлиникасында. 1925 тән Урта Азия ун-тының (Ташкент ш.) офтальмология каф. мөдире. 1932 дән Казан ГИДУВының офтальмология каф. мөдире, бер үк вакытта (1932–48) Трахоманы өйрәнү фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1951–54 тә Казан мед. ин-тының күз авырулары каф. мөдире. Урта Идел һәм Урал алды респ-каларында трахомага каршы көрәш эшен җитәкли. Хезмәтләре трахома, глаукома, күз җәрәхәтләрен дәвалау проблемаларына карый. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Комбинированные огнестрельные повреждения орбиты, носа и придаточных пазух. К., 1943; Руководство для работников трахоматозных пунктов. М., 1944; Современное состояние вопроса о лечении трахомы // Сб. тр. Врачебно-санитарной службы Казан. ж.д. 1950. Вып. 3.

*Әд.:* Профессор Александр Николаевич Мурзин // Вестн. офтальмологии. 1940. № 5; Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990.

**МУ́РЗИН** Ибрай Хөсәен улы (1916, Самара губ. Бөгелмә өязе, хәзер Лениногорск р-ның Иске Шөгер а. — гыйнвар 1946, Украина ССРның Одесса өлкәсе Харата пос.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты. Шөгер битум з-дында, аннары Краматорск (Донецк өлкәсе) шәһәрендә эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 158 нче гв. артиллерия полкында орудие командиры (5 нче гв. армиясенең 78 нче гв. укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск шәһәре һәм Днепр елгасы өчен барган сугышларда (икесе дә — 1943), Кировоград (1944), Львов-Сандомир, Түбән Силезия һәм Берлин (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең февралендә Призен посёлогы (Бжег шәһәрен-

нән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Польша) янында Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1 февральдә, беренче булып, орудиесен елга аша чыгара һәм плацдарм өчен сугышта катнаша; дошманның 3 пулемётын юк итә; 6 февральдә батарея составында чолганыштан чыгарга тырышкан дошман һөҗүмен кире кайтара.

1946 ның гыйнварында һәлак була. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Шөгер посёлогында Геройга бюст куела. Лениногорск шәһәренең бер урамы аның исемен йөртә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2. *М.З.Хәбибуллин.*

**МУРЗО́В** Александр Иванович (26.3.1929, Буа кантоны, хәзер Тәтеш р-ны Красная Поляна а. — 3.10.1993, Казан), агроном, урман белгече, мелиоратор, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003, үлгәннән соң), а.х. фән. канд. (1964), ТАССР, РСФСРның атказ. урман белгече (1972, 1987). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли. 1957–93 елларда Татарстан урман тәҗрибә станциясендә, директор (1960–89). М. җитәкчелегендә урман кисүнең ресурс саклаулы алдынгы ысуллары эшләнә һәм киң масштабта җитештерүгә кертелә (Татарстан, Мари, Мордва, Чуаш Респ-калары, Ульянов өлкәсе), йомшак яфраклы вак товарлыклы агачны тирәнтен эшкәртү, Саба урман хуҗалыгы чыршылыкларын тизләтелгән тергезү оештырыла (Дәүләт бүләге). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**МУ́РМАНСК ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Россиянең Европа өлешенең төньяк-көнбатышында, Кола ярымутравында урнашкан. 1938 елда оештырыла. Мәйданы — 144,9 мең *км²*. Үзәге — Мурманск шәһәре. Халкы — 780401 кеше (2012). Татарлар саны: 1926 да — 311, 1939 да — 4446, 1959 да — 5566 (Кырым татарларын да кертеп), 1989 да — 11459, 2002 дә — 7944, 2010 да — 5624 кеше. Татарлар, башлыча, Мурманск (3000 гә якын кеше), Североморск (700), Апатиты (600), Мончегорск (500), Кировск (400), Оленегорск (400) шәһәрләрендә яшиләр. М.ө.ндә алар 20 йөз башында күренә башлый, 1930–40 елларда татарлар шактый күбәя, бу Кола ярымутравында сәнәгать үсеше б-н бәйле. Монда күченгән халык арасында репрессияләнгәннәр дә күп була. Хәзерге вакытта Мурманскида «Гөлҗиһан» татар мәдәният үзәгенең төбәк иҗтимагый учреждениесе (1994 тән) һәм аның каршында якшәмбе татар мәктәбе, мөселман дини берләшмәсе (1999 дан), «Идел-Урал» татар-башкорт мәдәният үзәге (1990 нан) эшли. Мед. фән. д-ры Л.Г.*Попова*, РФнең атказ. спорт остасы А.Р.Гисмеев, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре И.М.Рәхимкуловның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге М.ө. б-н бәйле.

**МУ́РОМЛЫЛАР**, б.э.к. 1 нче меңьеллыктан Ука елгасы кушылдыклары Цна б-н Клязьма тамаклары арасында яшәгән фин-угор кабиләсе. Рус елъязмаларында беренче тапкыр 9 йөз ахырында «мурома» буларак искә алына. М.ның археол. культурасы үзенчәлекләре — мәетне башы б-н төньякка каратып җирләүдә, хатын-кызлар костюмының аерым төр бизәлешендә (чуклы башлыклар, баш әйләнәсе баулары, чигә асылмалары, күкрәк аеллары, кушаклар). Сугышчы ирләр сугыш киемнәре һәм кораллары, атлар б-н бергә җирләнгән. М.ның төп шөгыле — терлекчелек, игенчелек, сунарчылык, балык тоту, чолыкчылык, тимер һәм бакыр кою, зәркән һөнәрчелеге. 7 йөздә М. аерым кабиләләр берлегенә оеша. 9–10 йөзләрдә сыйнфый җәмгыять барлыкка килә, хәрби дружина аерым урын тота. Шул ук вакытта берлек терр-ясенә славян кабиләләре үтеп керә башлый, кысрыклау нәтиҗәсендә М.ның бер өлеше Идел буе Болгар дәүләтенә күчеп утыра. 11 йөздә М. Киев Русенең сәяси йогынтысына эләгә, 12 йөздә Төньяк-Көнчыгыш Русь халкы б-н кушылып, ассимиляцияләнеп бетә. «М.» этнонимы Ука буе топонимикасында саклanып калган (Муром).

*Әд.:* Финно-угры и балты в эпоху средневековья. М., 1987; Гришаков В.В., Зеленеев Ю.А. Мурома VII–XI вв. Йошкар-Ола, 1990; Рябинин Е.А. Финно-угорские племена в составе Древней Руси. СПб., 1997; Финно-угры Поволжья и Приуралья в средние века. Ижевск, 1999.

*И.Л.Измайлов.*

**МУРЧИСО́Н** (Murchison) Родерик Импи (19.2.1792, Таррадейл, Шотландия — 22.10.1871, Лондон), инглиз геологы, Петербург ФАнең чит ил шәрәфле әгъзасы (1845). Эдинбург ун-тында укыта, проф. (1831 елдан). Симур һәм девон системаларын аерып күрсәтә (1835). Россиядә геол. объектларны, аерым алганда, Идел һәм Кама елгалары бассейнын өйрәнеп, 1841 дә *Пермь системасын* аерып өйрәнүне нигезли. Рус палеонтологы А.А.Кейзерлинг һәм француз палеонтологы Ф.Вернейл б-н берлектә Россиянең Европа өлеше һәм Урал геологиясе буенча белешмә төзи (1845). Палеозойның бүленеше буенча төп эшләр әлеге тикшеренүләр б-н тәмамлана. Корольлекнең фәнни җәмгыяте әгъзасы (1826 дан), Лондон геол. җәмгыяте президенты (1831 дән).

Хезм.: Геологическое описание Европейской России и хребта Уральского: В 2 ч. СПб., 1849 (автордаш).

**МУСА́**, Коръән персонажы, *Аллаһның* пәйгамбәре һәм рәсүле — илчесе, Библиядәге Моисейга туры килә. Аңа күктән Тәүрат индерелә (яһүдиләрдә Муса пәйгамбәрнең 5 китабы). М.ны фиргавен хатыны тәрбияли. Бервакыт яшь М., исраильлене яклап сугышканда, ялгыш Мисыр кешесен үтерә һәм Мисырдан качып китәргә мәҗбүр була. Шуннан соң ул шактый вакыт Мәдйәндә яши (Кызыл диңгездәге Акаб култыгы). М., төнлә гаиләсе б-н чүл буйлап барганда, еракта ут күрә. Учакка күмер алып кайту уе б-н, гаиләсен калдырып, утка таба юнәлә. Ут янына килеп җиткәч, Аллаһ тавышын ишетә. Ул М.ны үзенең сөеклесе дип атый һәм аңа мисырлыларны Аллаһның берлегенә өндәргә боера. М. туганы Һарун б-н (Библиядәге Аарон) Мисырга әйләнеп кайта һәм үзен бердәнбер илаһ дип санаучы фиргавен каршысына килеп баса. Төрле могҗизалар күрсәтеп, алар Аллаһның бөеклеген дәлиллиләр (М.ның таягы еланга әверелә, кул тиресенең төсе карадан акка әйләнә һ.б.), ләкин фиргавен аларны сихерчеләр дип уйлый һәм Мисыр күз буучылары б-н ярыштыра. Соңгылары җиңелә. Шуңа карамастан, фиргавен пәйгамбәрнең дингә өндәвен кире кага, М. һәм аның халкы мисырлыларны туган җирләреннән куарлар дип куркып, Аллаһка ышанучыларны эзәрлекли башлый. Моның өчен Аллаһ Мисырга җиде төрле бәла-каза җибәрә (табигать гарасатлары, бетми торган авырулар, саранча һөҗүме һ.б.); М.га халкын Мисырдан чыгарырга боера. Качаклар Кызыл диңгезгә җиткәч, пәйгамбәр, таягы б-н диңгезгә сугып, суны ике якка аерып куя һәм халкы б-н коры юлдан үтә, ә эзәрлекләүче гаскәр исә суга батып үлә (фиргавен тәүбәгә килә һәм котылып кала; икенче бер риваятьтә исә батып үлә). М. үз халкын Сина тавына алып килә. Ялгызы калып, Аллаһтан: «... һәр нәрсәнең үгет-нәсихәте һәм һәрбер нәрсә өчен аңлатмасы бирелә», — дип язылган сәхифәләр тактасын ала. М. югында аның кардәшләре, таштан пот-сын ясап, шуңа табына башлыйлар. Пәйгамбәр потны юк итә, халыкны иманга китерә һәм чүл буйлап алга таба алып китә. М.ның үтенече б-н Аллаһ күктән ашамлык һәм бүдәнә көтүе җибәрә. Пәйгамбәр исраильлеләрне изге Кәнган җиренә алып килә. Ләкин алар, анда яшәүче озын буйлы кешеләрдән куркып, алга барудан баш тарталар, Аллаһ сүзенә буйсынмыйлар, шуның өчен чүлдә кырык ел буе каңгырып йөрүгә дучар ителәләр һәм яһүдиләргә вәгъдә ителгән җиргә М. үлгәннән соң гына аяк басалар.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**МУСА́** (? — 1501/02), мангыт *морзасы* һәм *бәге* (1440 еллар ахырыннан). Уаккас (Ваккас) улы, Идегәй әмир оныгы. Атасының үлеменнән соң (1440 еллар ахыры), аның бертуганы Аббас бәк һәм үзенең бертуганнары Хәрәзми һәм Ямгырчы кебек үк, Мангыт ыруының иң зур йогынтылы вәкиленә әверелә. М. идарә иткәндә Нугай Урдасы дәүләт буларак оеша. Мөстәкыйль сәясәт уздырырга омтыла, Шәйбанилар б-н сугыш алып бара. Күк Урда тәхетенә Ядегәр ханны утырта, аның сараенда *бәкләр бәге* була. 1460–70 елларда М. һәм аның ыруы казакълар ханы Җанибәк хакимлеген таный, Җанибәк хан үлеменнән соң алар Мөхәммәд Шәйбани б-н союз төзергә тырышалар. Бу омтылышлар уңышсыз тәгәлләнә, формаль рәвештә *Ибакъ хан* хакимлеген танылар, һәм ул Шәйбанилар олысы (Төмән ханлыгы) тәхетенә утыртыла. Нугайларның көчәюе Идел аръягында һәм Түбән Идел буенда Олы Урда ханнары б-н бәрелешләргә китерә. 1481 дә, Ибакъ һәм Ямгырчының Олы Урдага каршы берләшкән явы нәтиҗәсендә, Сарай әл-Җәдид шәһәре бөлдерелә, Әхмәд хан һәлак була. 1480–90 елларда, Казакъ ханлыгы һәм Олы Урданың көчсезләнүе шартларында, мангыт идарәчеләре карамагындагы терр-я Арал буйларыннан Идел аръягына һәм Мангышлактан Көньяк Урал алдына кадәр җәелә. Бу вакыттан Нугай Урдасы биләмәләре киңәеп, Казан ханлыгы чикләренә орына, нугай бәкләре

аның эчке һәм тышкы сәясәтендә актив роль уйный башлыйлар. Нугай Урдасының йогынтысы бигрәк тә 1490 елларда, Олы Урда таркалганнан соң, кискен көчәя. Бу хәлдән файдаланып, М. Идел-Дон елгалары арасындагы терр-янең бер өлешен басып ала. Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III һәм Кырым ханы Миңлегәрәй б-н союзга кереп, Речь Посполитага һәм Олы Урда ханнарына, Әхмәд хан варисларына карата актив тышкы сәясәт уздыра. М. идарә иткән заманда Алтын Урдадан соң барлыкка килгән төрки-татар дәүләтләрендә ханнарның күпчелеге хөкүмәтендә *карачыбәкләрнең* берсе Мангыт ыруы вәкиле булу тәртибе беркетелә. М. Мамык, Илһам, Мөхәммәдәмин ханнарга, кайчакта аларның дошманнарына — Казан карачыбәкләренә ярдәм итә. Бу чорда М. Алтын Урданың номиналь ханнары хакимияте булышлыгыннан баш тарта. Асылда ул үзенең этносәяси (ыру) һәм хәрби-адм. структурасы булган үз дәүләтен төзергә керешә.

*Әд.:* Перетяткович Г.И. Поволжье в XV и XVI вв. М., 1877; Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Сафаргалиев М.Г. Разгром Большой Орды // Зап. науч.-исслед. ин-та при Совете Министров МАССР. 1949. Вып 11; Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972; Жирмунский В.М. Избранные труды: Тюркский героический эпос. Л., 1974; Кочекаев Б.-А.Б. Ногайско-русские отношения в XV–XVIII вв. А.-А., 1988; Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой: 1489–1549. Махачкала, 1995; Трепавлов В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; Зайцев И.В. Астраханское ханство. М., 2004.

*И.Л.Измайлов.*

**МУСАБА́Й-ЗАВО́Д** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяктарак, Борды елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 552 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1881 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мусабай исеме б-н дә билгеле. Халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 3 ярма яргыч, 3 әвен, тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5528,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 1119, 1913 тә — 1685, 1920 дә — 1562, 1926 да — 1050, 1938 дә — 1051, 1949 да — 626, 1958 дә — 532, 1970 тә — 598, 1979 да — 568, 1989 да — 581, 2002 дә — 517 кеше.

**МУСА́ЕВ** Иван Дмитриевич (14.1.1925, Минзәлә кантоны Актаныш а. — 26.6.2004, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1954–59 елларда КПССның Актаныш райкомы пропагандисты, китапханә мөдире. 1959–60 та КПССның Әлмәт шәһәр ком-ты инструкторы. 1960–62 дә, хезмәт ияләре депутатларының Әлмәт район советы башкарма ком-ты, 1965–73 тә Әлмәт шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе. 1973–79 да ТАССР МСның Хезмәт идарәсе башлыгы. 1979–85 тә ТАССРның Дәүләт хезмәт ком-ты рәисе. 1985–87 дә ТАССР ЮС Президиумының кабул итү бүлеге мөдире. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**МУСА́ЛОВ** Габделхак Хөснетдин улы (19.10.1922, Әстерхан өлкәсенең Красноктябрьский р-ны Кызылтъяр а. — 8.7.2005, Мәскәү), монументалист, график, нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). Әстерхан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1953). Г.Рублёв, В.Иорданский, Б.Аракеловта белем ала. 1958 елдан Мәскәү өлкәсенең Алабушев посёлогында, 1966 дан Мәскәүдә яши, монументаль-бизәлеш сәнгате комб-ты рәссамы (1990 га кадәр). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1957). Бөек Ватан сугышында катнаша. Беренче карандаш рәсемнәрен фронтта ясый. Сугыш темасына соңрак та әйләнеп кайта. Монументаль сәнгать үсешенә зур өлеш кертә, Мәскәү, Казан, Бөгелмә, Саранск, Нөкес, Дербент, Әстерхан, Уфа шәһәрләре биналарының фасад һәм интерьерларындагы сграффито, маркетри, мозаика, фрескалар авторы (1970–80 еллар). Төп әсәрләре: «Бөгелмә» кунакханәсен (1978, маркетри техникасындагы панно) һәм Бөгелмә шәһәрендәге фарфор з-дын (1985, сграффито, маркетри, витраж техникасындагы панно) комплекслы бизәү,



Г.Х.Мусалов. Иске йорт. Кәгазь, темпера. 1965.

Нөкес шәһәрендә Каракалпак АССРның МС бинасы витражы (1987), Әстерхан филармониясе бинасы витражы (1976) һ.б. График (карандаш, гуашь, акварель) һәм нәкышь (темпера, майлы буяу) портретлар, пейзажлар авторы. Пленэрда Каспий, Идел буе, Кавказ, Кырым, Мәскәү өлкәсе табигатен сурәтли: «Балыкчы кыз» (1951), «Колхоз корылмалары» (1958), «Кисловодск» (1977), «Буа күпере» (1979), «Кичке моңнар» (1981), «Яңгырдан соң» (1982), «Ялта. Волошин йорты», «Урам» (икесе дә — 1990), «Пахра буендагы таң» (1958). 1954 елдан: «Мәскәү рәссамнары — сугыш ветераннары», «Сугыш юллары буйлап» (1958, Вена, Австрия) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре: 1976, 2002 (Иванов б-н бергә), 2003 (Мәскәүдә М.Саттаров б-н бергә) елларда уза. Әсәрләре «Казан» милли мәдәният үзәгендә саклана. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МУ́СИН** Әгъзам Хәмит улы (2.11.1945, Казакъстан ССРның Көнчыгыш Казакъстан өлкәсе Глубокое р-ны Белоусовка пос.), электр энергетикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (1998). Томск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), шунда укыта. 1978 елдан Алтай техник ун-тында (Барнаул ш.), производствоны һәм көнкүрешне электрлаштыру каф. профессоры (2001 дән). Бер үк вакытта, 1986–98 дә, «Алтайкрайэнерго» энергетика идарәсендә җитәкчелек эшендә; «Алтайэнергопроект» ФҖБдә, директор урынбасары (1993–96). Хезмәтләре электр тәэминаты системасын нәтиҗәле эшләтүгә карый. Шәһәрләрне, сәнәгать пр-тиеләрен, агросәнәгать комплексларын, шахталарны, электр станцияләренең үз ихтыяҗларын һ.б. электр б-н тәэмин итү системаларында аварияләрне булдырмый калуның техник чараларын эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2009). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Непрерывный контроль изоляции вводов по уровню высших гармоник в токах утечки // Изв. вузов СССР. Энергетика. 1983. № 11 (автордаш); Модель процесса технического обслуживания систем электроснабжения 6–10 кВ. городов // Промышленная энергетика. 1998. № 10; Риск — показатель качества электроснабжения городов // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2009. № 11–12.

**МУ́СИН** Әзһәр Гәрәй улы (19.11.1937, Минзәлә р-ны, хәзер Тукай р-ны Югары Байлар а.), географ, карст белгече, геогр. фән. д-ры (1990), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1960). Ерак Көнчыгыш фәнни-промысел эзләнү оешмасында инженер-гидролог (Владивосток ш.) булып эшли. Дагстан пед. ин-тында (1966–69), Уфа нефть ин-тының Октябрьск ф-лында (1969–71) укыта. Таулы Алтай пед. ин-тында физик геогр. каф. мөдире (1971–75). 1975–87 елларда Чечен-Ингуш ун-тында, физик геогр. каф. мөдире (1975–83). 1988–90 да Омск пед. ин-тында. 1990 нан Чаллы пед. ин-тында геогр. каф. мөдире (2001 гә кадәр), бер үк вакытта проректор (2002 гә кадәр). 2002 дән Казан энергетика ун-тында, 2004 тән Татар гуманитар-пед. ун-тында (2011 дән Казан ун-ты). Хезмәтләре геоморфологиягә карый. М. Җирнең геогр. тышчасы үсеше барышында карст күренешләренең төп тенденцияләрен билгели; карстның төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүнең яңа юлын эшли; Төньяк-Көнчыгыш Кавказ, Таулы Алтай, Новгород өлкәсе, Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы карстларын тикшерә. «Җир турындагы фәннәр» («Науки о Земле», 2005) уку ярдәмлеге авторларының берсе.


Хез.: Состояние окружающей человека среды в г.Набережные Челны. Наб. Челны, 1966; Географический анализ карста Бугульминско-Белебеевской возвышенности. Грозный, 1979; Физико-географические комплексы Земли. Наб. Челны, 1997.

**МУ́СИН** Гомәр Муса улы (1854, Казан губ., Тәтеш өязе Болын-Балыкчы а. — 1928, шунда ук), җәмәгать эшлеклесе. Крәстияннәр катлавыннан. Мәдрәсәдә укый. Тәтеш өязен-

дә волость старшинасы була. М. башлангычы б-н аның туган ягында икееллык земство уч-щесе ачыла. Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), җирле мәхкәмәне үзгәртеп кору комиссиясе һәм мөселманнар фракциясе әгъзасы. Карашлары буенча консерватор. Дума таркалгач, туган ягына кайта, а.х. б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

**МУ́СИН** Госман Яхъя улы (14.2.1908, Казан губ., Зөя өязе Кече Шырдан а. — 1942), график, нәкышьче. Казан сәнгать техникумын тәмамлый (1930). Б.*Урманче* шәкерте. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1939). Иҗат юлын театр рәссамы булып башлый. 1930–40 елларда Татарстан дәүләт нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә, балалар китапларына, мәктәп дәреслекләре, хрестоматияләргә рәсемнәр ясый. Татар китабын бизәүче беренче рәссамнардан. 1930 елларда дөнья күргән басмалар арасында М. Г.Тукайның «Авыл мәдрәсәсе», «Кәҗә белән Сарык», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Буран» кебек әсәрләренә карандаш һәм тушь б-н ясалган рәсемнәре, ш.у. «М.Горький Казанда» китабындагы график рәсемнәре б-н таныла. Татар




Г.Я. М у с и н. Г. Тукайның «Авыл мәдрәсәсе» шигыренә иллюстрация. Кәгазь, тушь. 1935.

китабын бизәүдә 1920 еллардагы конструктивизм һәм стиль шартлылыгыннан реализмга күчү М. исеме б-н бәйле. Аның хезмәтләрендә күренешләрне дөрес кору, әсәрнең фәзаи тирәнлеген ачу, декоратив яссылык һәм образлы шартлылыкка алмашка килгән күләмнәр һәм төсләр нисбәтен күрсәтү омтылышы сизелә. М.ның станлы нәкышь әсәрләре сакланмаган, әмма аның «Кызыл металлист» заводында» (1936 еллар тирәсе), «Каз өмәсе» (1940–41, Мәскәүдә узачак Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына әзерләнә) картиналарының авторы булуы мәгълүм. «Татхудожник»ның 1 нче күчмә күргәзмәсендә катнаша (Зеленодольск ш., 1936). 1941 дә армиягә алына; сугышта һәлак була.

*Әд.:* И ш м о р а т о в а С. Тукай иҗаты иллюстрацияләрдә // Габдулла Тукай: Шагыйрьнең тууына 60 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары. К., 1948; Ч е р к а с о в а Н.В. Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**МУ́СИН** Лотфулла Ногман улы (7.11.1913, Вятка губ., Сарапул өязе Сукман а. — 5.10.1997, Мөслим а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1971). Казан пед. ин-ты тарих ф-тының 3 курсын тәмамлый (1938). 1932–33 елларда Әгерҗе р-нының Тирсә башлангыч мәктәбендә укытучы, 1933–34 тә Чишмә башлангыч мәктәбендә директор. 1934 тән



Л.Н. Мусин.

Мөслим р-нында: Ташлыяр җидееллык мәктәбендә, 1936 дан Мөслим урта мәктәбендә директор; 1937 дән район халык мәгарифе бүлеге мөдире; 1941–44 тә Митрәй җидееллык мәктәбе директоры; 1944–48 дә район финанс бүлеге мөдире; 1949–55 тә Мөслим урта мәктәбе укытучысы; 1955–56 да район башкарма ком-тының культура бүлеге мөдире, 1956–58 дә район башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1958–76 да Киров исем. к-з рәисе. М.җитәкчелегендә 1970 тә 1 *га* дан 25,1 *ц* бөртекле ашлык уңышы алына (1958 дә — 1 *га* дан 9 *ц*), бишьеллык план (1966–70) бөртекле ашлык сату буенча 103% ка, сөт — 121%, йон 123% ка үтәлә. Колхозчыларның 3 нче Бөтенсоюз съезды делегаты (1969). Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Т а и р о в Н. Мусин Латфулла Нугманович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**МУ́СИН** Марат Мәҗит улы (16.2.1959, Уфа ш.), икътисадчы, математик, хокук белгече, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2008). Мәскәү ун-тының механика-матем. ф-тын (1980), Мәскәү юридик ин-тын (2006) тәмамлый. 1980–89 елларда СССР ФАнең Космосны өйрәнү ин-тында, СССР МФА акад. Ф.И.Комаровның акад. төркемендә өлкән фәнни хезмәткәр (1982). 1989–1990 да «Россия» җәмгыяте рәисенең 1 нче урынбасары. 1990–96 һәм 1999–2003 тә РФА Микроэлектроника технологияләре проблемалары ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, лаб. мөдире (1999 дан). 1997–98 дә «Инкомбанк» АҖнең мәгълүмат үзәге директоры. 2003 тән Россия сәүдә-сәнәгать ун-тында каф. мөдире, бер үк вакытта, 2005–06 да, «Базовый элемент» компаниясенең тәвәккәллек менеджеры. М, беренчеләрдән булып, икътисад күзлегеннән чыгып идарә итү мәсьәләләрен, идарә итү бәясе теориясе нигезләрен өйрәнә башлый. Аның тарафыннан геофизикада, хронобиологиядә, хрономедицинада циклик процессларны анализлауның яңа алымнары (1982–89) эшләнә һәм кулланыла, Россиядә беренче сертификацияләнгән цифрлы имзалау һәм түләү кәгазьләрен криптографик саклауның сертификацияләнгән системасы тәкъдим ителә (Мәскәү һ.б. шәһәрләрнең хисап-касса үзәкләрендә, 1993–94), «Инкомбанк» АҖ материаллары буенча икътисади һәм сәяси тәвәккәллекләр мониторингы мәгълүмати-аналитик системасының беренче чираты булдырыла (1997–98), беренче тапкыр Россия икътисадының «соры» секторына трансакцион анализ ясала, «юылган» акчалар күләмен ачыклау методологиясе эшләнә. Публицистик мәкаләләр б-н, ш.у. Россия радиосы һәм телевидениесе аша чыгышлар ясый. РФ Язучылар берлеге әгъзасы (1999 дан).

Х е з м.: Ресурс влияния. М., 2002; Матрицы влияния: теория и практика экономического управления. М., 2003 (автордаш); Концепция формирования услуг бизнес-консалтинга на основе матриц экономических интересов. М., 2004; Управление интересами. М., 2005; Управление экономическими интересами. М., 2006.

**МУ́СИН** Мәснәви Фәйзрахман улы (18.11.1928, хәзер БРның Дүртөйле р-ны Үткен а. — 11.6.2004, Казан), рентгенолог, мед. фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Проф. М.И.Гольштейн шәкерте. Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Дүртөйле район хастаханәсендә хирург, баш табиб булып эшли. 1953–55 елларда Совет Армиясендә: мед.-сан. батальонында табиб, хирург-рентгенолог. 1958 дән Казан мед. ин-тында, 1969 дан рентгенология һәм радиология каф. мөдире. 1964–66 да чит илдә командировкада: Улан-Батор (Монголия) махсус клиникасы киңәшчесе, 1979–83 тә Вьентьян мед. ин-тында (Лаос) рентгенология һәм радиология каф. оештыру эшендә. 1989 дан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсендә, 1983 тә шунда кан тамырлары хирургиясе бүлеген оештыра. Хезмәтләре клиник ангиологиягә, интенсив рентгенологик диагноз кую — ангиографиягә карый.

Х е з м.: Введение в клиническую рентгенологию. К., 1975; Некоторые вопросы клинической рентгенологии. К., 1980; Вертебро-висцеральные синдромы поясничного остеохондроза. К., 1985 (автордаш); Рентгенология — основа стратегии интенсивной диагностики // Казан. мед. журн. 1990. № 2.

*Әд.:* М и х а й л о в М.К. Профессор Маснави Файзрахманович Мусин // Казан. мед. журн. 1999. № 1.

**МУ́СИН** Мөдәррис Муса улы (8.2.1923, Спас кантоны Бибай а., хәзерге Әлки р-ны Бибай Чаллысы а. — 1994, Казан), партия хезмәткәре, журналист, филос. фән. канд. (1964), РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (1957), Иҗтимагый фәннәр академиясен (1964) тәмамлый (Мәскәү). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946–47 елларда Апас р-ны Кабык Күпер авылы мәктәбендә укытучы, Әлки р-ны халык мәгарифе бүлеге инспекторы. 1947–48 дә ВЛКСМның Әлки райкомы секретаре. 1948–50 дә Горький югары партия мәктәбе тыңлаучысы. 1951–54 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1957–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы. 1959–62, 1964–69 да «Коммунист Татарии» ж-лы мөхәррире. 1969–84 тә КПССның Татарстан

өлкә ком-тында мәдәният бүлеге мөдире. 1984 тән Саратов югары партия мәктәбенең Татарстан укыту-консультация пункты мөдире. 1960–65 тә ТАССР ЮС депутаты. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*С.С.Елизарова.*

**МУ́СИН** Рәшит Муса улы (12.11.1927, хәзер БРның Кушнаренко р-ны Чатра а. — 2.10.1982, Казан), партия эшлеклесе. Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый (1950). 1950 елдан Казанда 1 нче ТЭЦта эшли: инженер (1950–53), башлангыч партия оешмасының башка вазифалардан азат секретаре (1953–56), директор (1956–57). 1958 дән ТАССР ХХС рәисе урынбасары. 1961–79 да КПССның Казан шәһәр ком-ты 1 нче секретаре, 1979–82 дә Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. КПСС ҮК әгъзасы (1979 дан). М. респ-ка химия һәм энергетика сәнәгатьләрен үстерүгә зур игътибар юнәлтә, Казан химия сәнәгате объектлары төзелеше штабын җитәкли. Ул җитәкчелек иткән чорда Казан органик синтез з-дында — фенол, ацетон, пропилен, 9 нчы з-дта — желатин, Куйбышев исем. з-дта кино тасмалары һ.б. җитештерелә башлый. М. оештыру-партия һәм массакүләм-сәяси эшне пр-тиеләрнең хуҗалык эшчәнлеге б-н осталарча берләштереп алып бара. Казанның киң күләмле капиталь төзелеш, фән һәм мәдәният үсеше программасын гамәлгә ашыруга сизелерлек өлеш кертә. 1959–67, 1980–82 дә ТАССР, 1970–79 да СССР, 1967–71 дә РСФСР ЮСлары депутаты. СССР ЮС Президиумы әгъзасы (1980–82). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан урамнарының берсенә М. исеме бирелә.

*Л.М.Айнетдинова.*

**МУ́СИН** Реалиль Кашшаф улы (5.9.1946, Омск өлкәсе Седельниково а.), генерал-майор (1995). М.В.Фрунзе исем. Омск югары гомумгаскәри командирлар уч-щесен (1969), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (Мәскәү, 1981) тәмамлый. 1969–78 елларда Ерак Көнчыгышта, 1981–86 да совет гаскәрләренең Көнбатыш төркемендә (Германиядә) хезмәт итә. 1986 елдан полк командиры, 1989 дан Балтыйк буе хәрби округында штаб идарәсе башлыгы урынбасары, 1993 тән Себер хәрби округында. 1994 тән Новосибирск өлкәсенең хәрби комиссары. Кызыл Йолдыз, «Хәрби казанышлар өчен» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**МУ́СИН** Роберт Ринат улы (16.4.1964, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. икътисадчысы (2002). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1985). 1985–87 елларда ТАССР Финанс министрлыгы инспекторы. 1987–92 дә «Татпошивобувьбыт» ҖБдә бүлек башлыгы, ген. директор урынбасары. 1993–94 тә ТРның Милли инвестиция фонды, 1994–96 да «ТатИнк» инвестиция компаниясе президенты, 1996–97 дә Татфондбанк идарәсе рәисе. 1997–98 дә ТР финанс министрының 1 нче урынбасары, 1998–2002 дә ТР финанс министры. 1998–2000 дә «Түбәнкамашин», 2002–06 да «Түбәнкаманефтехим», 2002–13 тә «АК БАРС» Банк» ААҖләренең Директорлар советы рәисе. 2010–13 тә «Татфондбанк» ААҖнең Идарә рәисе, 2013 тән «ТФБ Холдинг» ҖЧҖ директоры. 1995–99 да, 2004 тән ТР Дәүләт Советы депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

**МУ́СИН** Ровель Габделкәрим улы (14.6.1940, Пермь ш.), эретеп ябыштыру металлургиясе һәм металлар белеме өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1990), проф. (1991). 1964 елда Пермь политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Чиләбе трактор з-дында (1964–65) һәм Пермь моторлар төзү з-дында (1965–67) эшли. 1971 дән Пермь техник ун-тында, эретеп ябыштыру производствосы һәм конструкцион материаллар технологиясе каф. мөдире (1981 дән), бер үк вакытта (1997 дән) эретеп ябыштыру производствосы буенча Россия милли ассоциациясенең «Көнбатыш Урал аттестация үзәге» АҖнең ген. директоры. Хезмәтләре металларны, эретмәләрне, металл булмаган материалларны диффузияле эретеп ябыштыруга карый. М. бериш булмаган материалларның (ш.и. ионлы-ковалент бәйләнешле функциональ керамик материаллар, химик бәйләнешләре юнәлешсез һәм туенмый торган нәметалл материаллар) каты фазасында эретеп ябыштырылган тоташтырмалар формалаштыру механизмнарын тикшерә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Россия Космонавтика федерациясенең К.Э.Циолковский исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Диффузионная сварка жаропрочных сплавов. М., 1979 (автордаш); О механизме активации при сварке металлов с неметаллическими материалами // Докл. АН СССР. 1990. Т. 310, № 6 (автордаш); Соединение металлов с керамическими материалами. М., 1991 (автордаш); Физические и химические основы формирования сварных соединений металлов с неметаллическими материалами // Сварка и диагностика. 2007. № 1(автордаш).

**МУ́СИН** Флүн Мөслах улы (23.2.1939, Мөслим р-ны Иске Карамалы а. — 22.9.2009, Казан), әдәбият галиме, әдәби тәнкыйтьче, филол. фән. д-ры (1983), проф. (1993), ТССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1962). 1963 елдан (бүленеп) ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында эшли, 1987–97 дә, 2007 дән соң әдәбият белеме бүлеге мөдире. 1997–2003 тә ТРның Укытучылар белемен күтәрү ин-тында татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире. 1980 еллар ахырыннан 20 йөз татар әдәбияты тарихын яңа редакциядә язу буенча иҗат төркемен җитәкли. Татар әдәбияты тарихын өйрәнү һәм укыту методологиясе мәсьәләләрендә тарихилык һәм милли юнәлеш принципларыннан чыгып эш итә. Хезмәтләре 20 йөз татар әдәбияты тарихы һәм теориясенә; Г.Исхакый, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Һ.Такташ, М.Җәлил иҗатларына; РФ һәм БДБ илләренең татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә милли уку-укыту системасының актуаль мәсьәләләренә карый.

Ә с ә р.: Тормыш сынавы аша. К., 1969; Чор белән аваздаш. К., 1983; Гаяз Исхакый тормышы һәм эшчәнлеге. К., 1998; По координатам жизни. М., 1976; Связь времён. К., 1979.

*Әд.:* Ханзафаров Н. Танылган галим // Казан утлары. 1999. № 2; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**МУ́СИН** Харис Гайнетдин улы (19.8.1952, Кызыл Йолдыз, хәзер Балык Бистәсе р-ны Күки а.), урман белгече, ТР, РФнең атказ. урманчысы (1995, 2004), а.х. фән. д-ры (2014). Лубян урман хуҗалыгы техникумын (1972), Мари политехник ин-тын (1982) тәмамлый. 1972 елдан Кәләй һәм Кызыл Йолдыз урман хуҗалыкларында эшли. 1986 дан ТР Урман хуҗалыгы министрлыгы Шәһәр яны урман хуҗалыгының баш урманчысы, 1993 тән директоры. ТРның баш дәүләт урманчысы, урман хуҗалыгы министры урынбасары (2010 нан), 2011 дән ТР урман хуҗалыгы министрының 1 нче урынбасары. Хезмәтләре яшел зона урманнарының сан.-гигиена, сәламәтләндерү һәм эстетик функцияләрен өйрәнүгә карый. М. ылыслы-киң яфраклы асзона урманнарының 1 нче төркем наратлыкларында урманны карау һәм тергезү максатыннан кисү эшләрен экологик-урманчылык ихтыяҗыннан чыгып нигезли. Казан аграр ун-тында урман хуҗалыгы һәм экология ф-тын (2001) оештыручыларның берсе. М. җитәкчелек иткән Шәһәр яны урман хуҗалыгы алдынгы технологияләрне һәм урман хуҗалыгын алып бару ысулларын гамәлгә кертү буенча тәҗрибә базасы булып тора.

Х е з м.: Зелёная зона города Казани. К., 2006; Оптимизация рекреационного лесопользования в зоне хвойно-широколиственных лесов. М., 2006 (автордаш); Экология и экономика рекреационного лесопользования. К., 2010 (автордаш); Постоянство лесопользования в рекреационных лесах. М., 2011.

**МУ́СИН-ПУ́ШКИН** Михаил Николаевич (25.11.1795, Казан — 25.6.1862, С.-Петербург), граф, дәүләт эшлеклесе, Петербург ФАнең шәрәфле әгъзасы (1837), сенатор (1849), хакыйкый яшерен советник (1849). Дворяннар нәселеннән. 1810 елдан хәрби хезмәттә. 1812 елгы Ватан сугышында һәм рус армиясенең 1813–15 еллардагы чит ил яуларында катнаша. 1827–45 тә Казан уку-укыту округы попечителе. М.-П. эшчәнлеге чорында университет шәһәрчегенең төп корпусларын төзү тәмамлана, Фәнни китапханә эше оештырыла, кафедраларда вазифаларга хезмәткәрләр билгеләнә, Шәрекъ бүлегендә (1828–42) 5 яңа кафедра ачыла, Казан ун-тының юридик ф-тында камераль бүлек булдырыла (1841); «Император Казан университетының гыйльми язмалары» («Учёные записки Императорского Казанского университета») ж-лын чыгарырга булыша (1834). М.-П. ярдәме б-н Казан уку-укыту округында 2 гимназия, 2 дворяннар ин-ты, 20 өяз уч-щесе, 10 хосусый пансион һ.б. оештырыла; укытучыларның һәм укучыларның саны ике тапкыр арта. 1840–45 тә Казан икътисадчылар җәмгыятенең 2 нче бүлеге рәисе. 1845–52 дә Петербург уку-укыту округы по-

печителе, бер үк вакытта, 1847–56 да, Халык мәгарифе министрлыгының цензура ком-ты әгъзасы. 1855 тә Казан ун-тының Шәрекъ бүлеген Петербург ун-тына күчертә. Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тының (1828), Казан ватан әдәбиятын сөючеләр җәмгыятенең (1828), Казан ун-тының (1845) шәрәфле әгъзасы. 1845 тә университетта М.-П. исем. стипендия булдырыла.


М.Н. Мусин-Пушкин.

Чыг.: Отчёт Казанского учебного округа с 1827 по 1 января 1844 года по управлению тайного советника М.Н.Мусина-Пушкина. К., 1844.

*Әд.:* Галиуллина Р.Х. Михаил Николаевич Мусин-Пушкин — попечитель Казанского учебного округа: Дис. ... К., 1997; Казанское дворянство 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001.

*Р.Х.Галиуллина.*

**МУ́СИН-ПУ́ШКИН** Платон Иванович (1698, Мәскәү — 1750 дән соң), граф, дәүләт эшлеклесе, дипломат, сенатор (1739), яшерен советник (1736). Дворяннар нәселеннән. 1716 елдан Голландия, Дания, Франциядә дипломатлык хезмәтендә. 1722–27 дә Сенатның Мәскәү конторасында, 1727–30 да Мәскәү акча сугу конторасы әгъзасы. 1730–31 дә — Смоленск, 1731–35 тә Казан губернаторы. М.-П. эшчәнлеге чорында Казанда руханилар семинариясе (1732), шәһәр полициясе (1733) оештырыла; губернада икенче Кама аръягы чик сызыгы корыла (1731–34). Петербург ФАнең Себер–Камчатка экспедициясенә (1733), И.К.Кириловның Оренбург экспедициясенә (1734) булышлык итә, В.Н.Татищевка файдалы казылмалар эзләүдә һәм заводлар төзү өчен урыннар билгеләүдә ярдәм күрсәтә (1735). Яңа чукындырылганнар эшләре комиссиясе б-н бергә Казан губернасының рус булмаган халыкларын массачыл христианлаштыруны гамәлгә ашыра. 1735 тә татар-башкорт кузгалышын булдырмау омтылышы уңышсыз төгәлләнә. 1735–36 да Эстландия губернаторы. 1736–40 та Коммерц-коллегия президенты, бер үк вакытта, 1737–40 та, Конфискация канцеляриясе һәм 1739–40 та Экономия коллегиясе директоры (С.-Петербург). Дәүләт реформалары проектларын эшләүдә кабинет-министр А.П.Волынскийның иң якын хезмәттәше. 1740 та кулга алына, хөкем ителә һәм Соловки монастырена сөрелә. Иреккә чыгарылганнан соң, 1742 дән, Казан губернасының Сембер провинциясендә яши. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Петров П.Н. История родов русского дворянства. СПб., 1886. Т. 1; Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**МУ́СИНА** Әнисә Шәриф кызы (14.4.1924, Минзәлә кантоны Яңа Әлем а. — 18.3.2011, Казан), партия, хакимият-хуҗалык хезмәткәре, педагог. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1944 елда ВЛКСМның Актаныш р-нының 2 нче, 1945–48 дә Кызыл Армия райкомының 1 нче секретаре. 1951–56 да Казан пед. уч-щесе укытучысы. 1956–62 дә Казанның Идел буе р-нында мәгариф бүлеге мөдире, КПСС райкомының 2 нче секретаре, район башкарма ком-ты рәисе. 1963–79 да ТАССР ЮС Президиумы секретаре. 1979 дан Казан ун-тында. 1963–80 дә ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МУ́СИНА** Линара Тәбрис кызы (20.1.1961, Чистай ш.), микробиолог, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук микробиол. кафедрасында эшли, бер үк вакытта (1997 дән) югары уку йортына кадәрге белем бүлеге башлыгы. Хезмәтләре төрле профильдәге стационарларда хастаханә эче инфекцияләренең микробиол. мониторингына, аларның этиологик структурасын һәм госпиталь штаммнарын өйрәнүгә карый. М. РФ терр-ясендә таралган, метициллинга бирешмәүчән алтынсу стафилококклар популяциясенең гетерогенлыгын ачыклый.

Х е з м.: Этиология и нозология внутрибольничных гнойно-воспалительных заболеваний у новорождённых детей // Рос. вестн. перинатологии и педиатрии. 1995. Т. 40, № 1 (автордаш); Разработка и апробация реакции латекс-агглютинации для экспресс-диагностики стафилококковой инфекции // Журн. микробиологии, эпидемиологии и иммунологии. 1995. № 6 (автордаш).

*Әд.:* Казанский медицинский университет (1804–2004): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

**МУ́СИНА** Розалинда Нури кызы (22.2.1947, Белоруссия ССРның Бобруйск өлкәсе Слуцк ш.), этнограф, тарих фән. канд. (1984), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1970); урта мәктәптә укыта (Казан). 1981 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында, этнология бүлеге мөдире (2000 нән). Хезмәтләре этносоциология һәм этнопсихология мәсьәләләрен өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге «Татарлар» («Татары», М., 2001) коллектив монографиясен төзүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Семейный быт народов СССР. М., 1990 (автордаш); Социальная и культурная дистанции: Опыт многонациональной России. М., 1998 (автордаш); Этнография татарского народа. К., 2004 (автордаш).

**МУ́СИННАР**, татар морзалары нәселе. 1764 ел 17 март язмасы буенча, Югары Тимкәй авылында (хәзер БРның Кырмыскалы р-нында) яшиләр. Типтәрләр катлавы составына керәләр. 19 йөз башында аларга дворянлык дәрәҗәсе бирелә. 20 йөз башында Югары Тимкәй авылында морза М.дан 25 гаилә яши.

*Әд.:* Новиков В.А. Сборник материалов для истории татарского дворянства. Уфа, 1879; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**МУ́СКУСЛЫ КҮСЕ́**, к. *Ондатра.*

**МУСЛИ́НКИН** Абдрәхим Абдрәхим улы (10.11.1929, Әстерхан ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994), химия фән. канд. (1966), ТАССРның атказ. химигы (1989). 1956 елда Югары корал инженерлары хәрби-диңгез уч-щесен (Ленинград) тәмамлаганнан соң, Севастополь шәһәрендәге хәрби частьтә лаб. башлыгы булып эшли. 1958 дән СССР ФА Органик химия ин-тында (Казан), 1961–65 тә Экспериментал хирургия аппаратурасы һәм инструментлары фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында пластмассаларны медицинага кертү лаб-ясе мөдире. 1965 тән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында технол. лаб-ясе мөдире, 1998 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нәзек органик синтез продуктлары һәм фосфорорганик кушылмалар химиясенә һәм технологиясенә карый. М. гөмбәгә каршы хлорацетофос препаратын, пешүләрдән һәм хирургик авыруларны дәвалау өчен ксимедон, тиредәге яман шешне дәвалау өчен глицифон препаратларын тикшерү, эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнаша (бу препаратларның дару формалары «Татхимфармпрепаратлар» химия-фарм. берләшмәсендә чыгарыла). Дәүләт бүләге метаболик дәвалау өчен димефосфон дару чарасын эшләгәне өчен бирелә. Уйлап табуга 85 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

*Әд.:* Нугманов В. Создатели новых препаратов // Науч. Татарстан. 1995. № 3.

**«МУСУЛЬМА́НСКАЯ ГАЗЕ́ТА»** («Мөселман газетасы»), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1912 елның 12 октябреннән 1914 нең 8 июненә кадәр С.-Петербургта рус телендә (1912 нең 1, 2 нче санында һәм 1913 нең 10 нчы санында текстларның бер өлеше татар теленә тәрҗемә итеп бирелә) нәшер ителә. 1912 дә — 2 атнага 1 тапкыр, соңрак атна саен чыга. Наширләре — И.Шаһиәхмәтов, С.Габиев. Газетаның 3 нче санынннан С.Габиев берdәнбер нашир-мөхәррир була. «М.г.» үзенең сәяси партияләргә катнашы булмавын, Россия мөселманнары тормышын яктыртырга омтылуын игълан итә. Газетаның төп идеясе — мөселман халыклары арасында белем тарату. Басмада халыкның мәдәниятен үстерү турындагы фикер күтәрелгән әдәби әсәрләр, иҗтимагый һәм мәдәни тормыш яңалыклары, мөселман мәктәпләре һәм китапханәләре ачылу турындагы хәбәрләр урын ала. «М.г.» редакциясе җәдитчеләр хәрәкәтен яклый, иске руханиларны алгарышны тоткарлаучылар дип саный, мөселман укымышлыларының рухи зәгыйфьлеген, булдыксызлыгын күрсәтә. «М.г.»нда Дәүләт Думасы эшчәнлеге яктыртыла, ул мөселман фракциясен яклап чыгышлар ясый, мөселман депутатларының сайлаучылары б-н үзара элемтәләрен тәэмин итә. Газетада «хатын-кызлар мәсьәләсе» дә еш күтәрелә: үз хокуклары өчен көрәшкән белемле төрек хатыннары үрнәк итеп күрсәтелә. Һәр санда Россия һәм чит илләр басмаларында тышкы сәясәтнең ничек яктыртылуына күзәтү ясала, Балкан сугышы барышы турында хәбәрләр бирелә, мөселман илләре тормышы яктыртыла. Мәкаләләрнең күбесен С.Габиев

яза, авторлар арасында Д.Александрович (Җ.Алиф), М.Дахадаев, С.Сиюхов, И.Хубиев, А.Цаликов та була. Басмада ислам турындагы мәкаләләре, татарларның мәдәни тормышы хакындагы язмалары б-н М.*Вахитов* чыгыш ясый, сәясәтче М.*Солтангалиев* (псевд. Калку-Баш) газетада үзенең «Аккурат», «Татар кызының төше», «Башкорт кызы», «Томанда», «Җырланып бетмәгән җыр», «Мин — кеше», «Тормыш ялганы» һ.б. хикәя-шигырьләрен бастыра. Гомумән алганда, «М.г.» төрекләргә йөз тоткан газета була. Төркия дәүләте тормышы б-н һәрдаим кызыксыну, Дагстан хакимиятен тәнкыйтьләп тору хөкүмәт б-н бәрелешләргә китерә. Газета 6 тапкыр кулга алына, матди кыенлыклар китереп чыгарган штрафларга тартыла. С.Габиев, лекцияләр б-н Россия буйлап йөреп, басма өчен акча табарга тырыша; еш кына диндәшләре аңа ярдәм итә. Хөкүмәтнең каршы торуына карамастан, «М.г.» мөселманнар арасында киң таныла һәм тиз арада тарала. Газетаның хакимияткә карата оппозицион юнәлештә булуы аның ябылуына китерә.

*Е.А.Серова.*

**МУ́ТИН** Мохтар Исхак улы (25.12.1885, Уфа губ., Минзәлә өязе Такталачык а. — 3.6.1941, Магадан өлкәсе), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1926). Сәхнә эшчәнлеген 1908 елда «Сәйяр» труппасында башлый, 1912–15 елларда «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларында. 1920 дән Казанда. Беренче проф. татар дәүләт театрын оештыруда актив катнаша, 1922–37 дә Татар акад. театры актёры. Татар театр сәнгатендә романтик юнәлешнең аеруча күренекле вәкилләреннән берсе. Татар театры тарихына кереп калырлык образлар иҗат итә: Карл Моор («Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Гамлет, Отелло (У.Шекспирның шул исем. әсәрләре буенча), Тартюф (Ж.Б.Мольерның шул исем. әсәре буенча), Барон, Бардин («Тормыш төбендә», «Дошманнар», М.Горький), Вершинин («Бронепоезд 14–69», В.В.Иванов), Батырхан («Яңа кешеләр», Г.Ибраһимов), Минһаж («Кандыр буе», К.Тинчурин), Кәрим («Дошманнар», Ф.Сәйфи-Казанлы), Франко («Салют, Испания!», А.Н.Афиногенов). М. геройлары дәртлелекләре, дөньяви проблемалар, гуманизм фәлсәфәсе хакындагы ялкынлы уй-фикерләре б-н тамашачыны таң калдыра. Х.Туфан аның турында: «Ул хәтердә Мутин буларак түгел, ә Отелло, Гамлет булып кала: аңарда Җир көче бар», — дип яза. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.



М.И. Мутин.



М.И. Мутин Отелло ролендә (У. Шекспирның шул исем. әсәре буенча).

*Әд.:* Иялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биографик белешмәлек. К., 2005.

*И.И.Иялова.*

**МУТРИСКО́В** Анатолий Яковлевич (9.8.1935, Чуаш АССРның Мариинский Посад р-ны Зур Аккоз а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1985), проф. (1988). 1958 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казанның оборона пр-тиесендә эшли. 1961 дән Казан технол. ин-тында, инженерлык графикасы каф. мөдире (1985–97). 2002 дән Казан энергетика ун-тында. Хезмәтләре күп фазалы күбекле системаларда гидродинамикага һәм масса алмашуга карый. М. газлы катнашмалар һәм эремәләр компонентларын күбек ясалу шартларында бүлү алымнарын тәкъдим итә. Гликольләрне винилллау, углеводородларны сыек фазада оксидлаштыру, углеводород чималын күкерттән арындыру, газлар б-н туенган нефтьләрне аеру, нефть-газ җыю системасын герметиклаштыру, күбекле флотация химик процесслары режимнарын һәм аларга аппарат конструкцияләрен эшли. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Некоторые вопросы гидродинамики динамической ячеистой пены // Журн. прикладной химии. 1979. Т. 52, № 5; Гидродинамика и массообмен в пенном слое // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1991. Т. 34, № 9 (автордаш); Моделирование механизма инверсии фаз в струйном аппарате // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2005. № 7/8.

**МУХА́НОВ** Александр Ильич (8.1.1766, Мәскәү — 22.10.1815, шунда ук), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1799). Дворяннар нәселеннән. 1784 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1798–99 елларда Новгород вице-губернаторы. 1799–1801 дә Казан гражданнар губернаторы. М. эшчәнлеге чорында *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы* һәм *Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасы* торгызыла (1801), полициядә реформа уздырыла; Казанда Гостиный дворның яңа бинасы төзелә (1800–01). М. адм. башбаштаклыгы һәм хакимияттән явызларча файдалануы өчен вазифаларыннан читләштерелә. 1805–06 да Полтава, 1806–11 дә Рязань гражданнар губернаторы. 1811 дән Патша сарае ат з-длары директоры (Мәскәү).

*Әд.:* Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**МУХА́НОВ** Геннадий Степанович (4.3.1947, Чистай ш.), музей хезмәткәре, филолог, филол. фән. канд. (1981), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), комсомол эшендә; 1971 елдан ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты лекторлары төркемендә, 1974 тән аның җитәкчесе; 1977 дән КПССның Татарстан өлкә ком-ты Сәяси мәгариф йорты консультанты. 1987–2006 да *Татарстан Республикасының Милли музее* директоры. Шул елларда музей бинасы реконструкцияләнә, 1987 дәге янгын китергән зыян бетерелә, даими экспозиция өлешчә торгызыла, 50 дән артык музей-филиал оештырыла. М. совет язучыларының 1941–43 тә Чистайда эвакуация вакытында иҗат иткән әсәрләре, ш.у. аларның шул чорга багышланган истәлек һәм язмалары кергән «Чистай сәхифәләре» («Чистопольские страницы», 1987) китабын төзи, кереш сүз һәм аңлатмалар авторы.

Хезм.: История Государственного музея Республики Татарстан в зеркале 20 века. К., 1997.

**МУХА́РСКИЙ** Әнвәр Даут улы (8.6.1928, БАССРның Белорет ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1974), проф. (1986), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1976). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1951). Уфа Нефть фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, лаб. мөдире (1959 дан). 1964 елдан ТатНИПИнефтьнең нефть чыганакларын эшкәртү бүлеге мөдире. 1978 дән Бөтенсоюз Комплекслы җылылык-энергетика мәсьәләләре фәнни-тикшеренү ин-тында нефть чыгару сәнәгате бүлеге мөдире. 1994–2003 тә «Россия инновацион җылылык-энергетика компаниясе» АҖнең ген. директор урынбасары. М. Татарстан нефть чыганакларын эшкәртүнең 40 ка якын технол. схемасын һәм проектын, ш.и. Ромашкино чыганагын эшкәртүнең 2 ген. схемасын төзи. Нефтьне сайлап чыгаруның аның тарафыннан эшләнгән схемасы ТР, Көнбатыш Себер һ.б. регионнарда киң кулланылыш таба, АКШ, Канада һәм Франция патентлары б-н саклана. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**МУ́ХИН** Василий Георгиевич (24.12.1901, Казан губ., Чистай өязе Биләр а. — 9.8.1952, Казан), ветеринар-клиницист, вет. фән. д-ры (1939), проф. (1939), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1927). 1927–28 елларда Түбән Новгород губернасының Павлово өязе Панино авылында вет. участогы мөдире, 1928–30 да Улала шәһәрендә (Ойрот автономияле өлкәсе) өлкә җир эшләре идарәсендә вет. бүлеге мөдире. 1930 дан Казан вет. ин-тында, клиник диагностика каф. мөдире (1939–52), бер үк вакытта, 1932–43 тә, институт директоры урынбасары, 1943–45 тә директоры. Хезмәтләре рахит авыруының башлангыч чорында диагноз кую һәм аны паратиреолизат б-н дәвалауга; атларда корсак чәнчүенең этиологиясе һәм патогенезы, бавыр авыруларына функциональ диагноз куюга карый. М. кан әйләнеше тизлеген билгеләү ысулын эшли. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О функциональном направлении в диагностике заболеваний сельскохозяйственных животных // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1949. Т. 56; Показатели температуры, пульса, дыхания и картина крови у беспородных лошадей различного возраста // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1952. Т. 59.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

**МУХША́** (Наручат), урта гасырлардагы (14–15 йөзләр) Алтын Урда шәһәре, Мукша (Мохша) елгасының югары агымында (хәзер Пенза өлкәсенең Наручат авылы янында) урнашкан була. Мухша олысы үзәге һәм акча сугу урыны (1313–67). 1367 елда Алтын Урда бәге *Тагай* тарафыннан яулап алына. 1395 тә, фаразланганча, Урта Азия хакиме Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан талана. 15 йөз башларыннан элекке әһәмиятен югалта. Кирпеч йорт, мунча, мөселман төрбәләренең археол. калдыкларын беренче тапкыр А.А.Кротков тикшерә (1925–26). Соңрак Е.А.Алихова (1959–60) һәм Ю.А.Зеленеев (1989–91) өйрәнә.

*Әд.:* К р о т к о в А.А. К вопросу о северных улусах золотоордынского ханства // Изв. Об-ва обследования и изучения Азербайджана. 1927. № 5; А л и х о в а Е.А. Мавзолеи города Мохши-Наровчата // Советская археология. 1973. № 2; ш у л у к. Постройки древнего города Мохши // Советская археология. 1976. № 4.

*И.Л.Измайлов.*

**МУХША́ ОЛЫСЫ́** (Наручат кенәзлеге) 15–16 йөзләрдә Алтын Урданың адм.-терр. берәмлеге. Сура һәм Цна елгалары арасында урнашкан. Үзәге — *Мухша* шәһәре. 1360 елларда Тагай бәк, Алтын Урдада үзәк хакимиятнең көчсезләнүеннән файдаланып, М.о. җирләренә хуҗа була. 1367–68 еллар тирәсендә аны *Мамай* гаскәрләре яулап ала. 1395 тә олыс үзәге Мухшаны Урта Азия хакиме *Аксак Тимер* явы җимереп-талап китә. 15 йөз башларыннан олыс бетүгә йөз тота. М.о. халкы, татар этносының бер компоненты булarak, мишәр субэтник төркеменең барлыкка килүендә билгеле бер роль уйный.

*Әд.:* С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*


**МУШИ́НСКИЙ** Әхәт Хәй улы (27.5.1951, Казан), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Рус телендә яза. Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1976–82 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасының җаваплы сәркәтибе, 1982–89, 1992–94 тә ТАССР Язучылар берлегенең әдәби консультанты, 1989–92 дә «Идел» ж-лы баш мөхәррире урынбасары, 1993–2003 тә «Яшел камин янында» («У зелёного камина») телевидение тапшыруын алып бара. 1994 тән Милли китапханәдә, 1995 тән Татар ПЕН-үзәгендә эшли, бер үк вакытта, 2006 дан, «Казан альманахы» («Казанский альманах») ж-лы баш мөхәррире. «Өчпочмаклар» («Треугольники», 1984) хикәя һәм повестьлар җыентыгы, балалар өчен язылган «Бер тибүдә — гол» (2000, рус телендә «Гол в девятку», 1991), «Минем адаш малай» («Мой тёзка — Адаш малай», 1994), «Әнәс-ананас һәм башкалар» = «Анас-ананас и другие» (2004; РФнең балалар өчен «Күңелдәге хыял» милли әдәби бүләге, 2006) исемле китаплар; «Шәех һәм астролог» («Шейх и звездочёт», 1991), «Бөкре кеше язмалары» («Записки горбатого человека», 2000, Г.Р.Державин исем. бүләк, 2002) романнары авторы. М. әсәрләренә психологизм, фәлсәфи тирәнлек хас; алар Казан һәм респ-ка турындагы мәгълүматларга бай.

Ә с ә р.: Яблони цветут в октябре. К., 2011.

*Әд.:* Г а м б ә р Н. Очканында ни булса... // Казан утлары. 2001. № 5; М а л ы ш е в С. Обречённая на успех // Идель. 2000. № 6.

**МҮК ГӨМБӘЛӘРЕ́** (Xerocomus), болетачалар семьялыгыннан көпшәле гөмбәләр ыругы. 18 төре билгеле, ике ярымшарның да уртача поясларында, сирәк кенә тропикларда таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Чуар мүк гөмбәсе (X. chrysenteron) яфраклы урманнарда июль–сентябрьдә үсә. Еш, әмма аз күләмдә очрый. Эшләпәсенең диаметры 10 *см* га кадәр, кабарынкы, итчел, коры көннәрдә — коры, дымлыда — ябышкак, аксыл-коңгырт төстә. Йомшагы аксыл-соргылт, көпшәк, сынган урынында җиңелчә зәңгәрләнә. Споралы порошогы саргылт-яшел. Сабы цилиндрик, тигез, 10 *см* га кадәр озынлыкта. Кызыл мүк гөмбәсе (X. rubellus) яфраклы урманнарда, куаклар арасында, канау кырыйларында август–сентябрьдә үсә. Сирәк очрый. Эшләпәсенең диаметры 9 *см* га кадәр, алсу-җете кызыл төстә, итчел, мендәрсыман, җепселле. Йомшагы сары, сынган урыннарда зәңгәрләнә. Споралы порошогы коңгырт. Сабы цилиндрик, тигез, эшләпә астында ачык сары, астарак кызыл тәңкәле коңгырт төстә. Саргылт-көрән мүк гөмбәсе (X. variegatus) нарат урманнарында комсу туфракта ялгыз һәм төркем булып үсә. Эшләпәсенең диаметры 10 *см* га кадәр, итчел, кабарынкы, куе сары яки сары-коңгырт, коңгырт тәңкәле. Йомшагы саргылт, сынган урынында җиңелчә зәңгәрләнә, тәме әчкелтем. Споралы порошогы сары-яшел. Сабы тигез, цилиндрик, тыгыз, соргылт-сары, кайвакыт кызгылт төсмерле. Барлык төрләре дә ашарга яраклы.

**МҮК ҖИЛӘГЕ́** (Oxycoccus), арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел ярымкуаклар ыругы. 4 төре билгеле. Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача поясларында таралган. ТР терр-ясендә бер төр — гади М.җ. (O. palustris) бар. Кама алдында торфлы сазлыкларда очрый. Очлы кырлы кызгылт сабаклы түшәлмә кечкенә ярымкуак, озынлыгы 1 *м* га кадәр җитә. Яфраклары чиратлашкан, өскеләре очлы, кыска сапта, итчел, өсте кара яшел, ялтырап тора, асты — балавыз кунычлы зәңгәрсу-куксел төстә. Чәчәкләре вак, иенке чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — шарсыман яки озынча түгәрәк күп орлыклы ачы куе кызыл җиләк. Орлыклары вак, озынча йомыркасыман. Июньдә чәчәк ата. Җимешләре сентябрь–октябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамырланган үрентеләрдән) б-н үрчи. Уңайсыз һава шартларына бик чыдам, кышны җиңел кичерә. Җиләгендә шикәр, пектин һәм дуплау матдәләре, органик к-талар һәм микроэлементлар бар. Составында бензой к-тасы булганлыктан, эшкәртелмичә дә озак саклана ала. Гамәли медицинада җиләкләре хәл кертү һәм темп-ра төшерү чарасы, витамин чыганагы буларак файдаланыла. Халык медицинасында М.җ. морсы һәм сиробы авитаминоз һәм төрле ялкынсынулар вакытында, сусауны басу өчен, җиләге һәм согы азык сәнәгатендә киң кулланыла. Татарстан флорасы өчен сирәк төргә әйләнеп бара, ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Гади мүк җиләге.

**МҮКЛӘ́Р**, м у к с ы м а н н а р (Bryophyta), югары споралы үсемлекләр бүлеге. 1 меңгә якын ыругы һәм 25 меңгә якын төре билгеле. Бөтен Җир шарында очрыйлар. ТРда 200 гә якын төре бар, нигездә, Кама алдында һәм Кама аръягында сазлыкларда, болыннарда, сазлыкланган һәм дымлы урманнарда үсә. М.нең күбесе — күпьеллык, яшәү озынлыгына бәйсез рәвештә тәбәнәк үсемлекләр, төркемнәр булып үсә: кәс, күч, мендәрчекләр хасил итә. Катламнан (кайбер бавырсыман М.) гыйбарәт яки сабак һәм яфракка (яфрак-сабаклы М.) бүленгән. Спораларда һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. М.нең үсеше спораларының шытуыннан башлана, алардан исә бөреле ботакчыл, җепсел яки пастинкалы күпкүзәнәкле шытым барлыкка килә. Аларның берсеннән М.нең катлам, икенчеләреннән яфраклы үрентеләре (гаметофитлар) үсеп чыга, аларда исә җенси күзәнәкләр ясаучы җенси үрчү органнары хасил була. Аталанганнан соң, катлам яки яфраклы үренте б-н тоташкан беркадәр озын саптагы споралы тартмачыктан торучы спорангий үсә. Шулай итеп, М. гаметофитлары, җенси үрчүне тәэмин итү б-н бергә, төп вегетатив функцияләрне башкара: фотосинтез, су б-н тәэмин итү, минераль туендыру; М.дә спорофитның үсеше мөстәкыйль организм кебек (агач һәм үләнчел үсемлекләрдән аермалы буларак) бармый. М.нең күп кенә төрләре урман тормышында мөһим роль уйныйлар. Урманда дымны саклыйлар, яфрак түшәлмәсен таркаталар, чери торган агачны таркатып, механик һәм химик тәэсир ясыйлар. Күп кенә умырткасызларның яшәү мохите булып торалар. Кайбер кошлар (көртлек, бożырлар) М.не икенчел азык буларак, ш.у. оя ясау өчен (шәфәкъ чыпчыклары өчен төп төзү материалы) кулланалар. Әйләнә-тирәлекнең биоиндикаторы булып торалар. Уйсулыклы сазлыкларда яшел М. тоташ келәм булып, файдалы матдәләргә бай уйсулыклы торф ятмалары (а.х.нда ашлама буларак файдаланыла) хасил итәләр. Шул ук ва-

кытта, тоташ сөрүле келәм хасил итеп, туфрак аэрациясен кыенлаштыралар, бу исә үсемлекләр үсешенә тискәре йогынты ясый. М.нең 24 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**МҮКЛЕ́ КҮЛ** (М и х о в к а), Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-ны Габишев авылыннан көньяктарак эрозияле уйсулыкта урнашкан. Су өслегенең мәйданы 10 *га*, шуның 4,4 гектарын урыны-урыны б-н ярга якын булган йөзмә утрау били. Су күләме якынча 400 мең *м*$^3$. Озынлыгы 870 *м*, иң зур киңлеге 215 *м*. Уртача тирәнлеге 3,9 *м*, иң зур тирәнлеге 11,5 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыка килгән. Формасы катлаулы. Төньяктан көньякка таба чылбыр рәвешендә сузылган өч аерым сулыктан тора. Көнбатыш яры текә, ерымнар б-н ергаланган, көнчыгыш яры сөзәгрәк; нарат агачлары үсә. Явым-төшемнәр һәм грунт сулары б-н туена. Суы йомшак (0,6 *мг-экв/л*), җиңелчә минеральләшкән (61,8 *мг/л*), гидрокарбонат-хлорид-магнийлы типта. Үтә күренмәлелеге 20 *см*. Күл акрынлап сазлыклана бара. Ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).



Мүкле күл Габишев авылы тирәсендә.

**МҮКЛЕ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-нының Тамгачы авылыннан 2,7 *км* көнбатыштарак һәм Тетеево (Тәти) авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 6,4 *га*. Су күләме 13,5 мең *м*$^3$. Озынлыгы 506 *м*, иң зур киңлеге 280 *м*. Уртача тирәнлеге 2,11 *м*, иң зур тирәнлеге 5,3 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә хасил булган. Формасы озынча түгәрәк. Ярлары сөзәк. Суы йомшак (0,6 *мг-экв/л*), җиңелчә сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 75,5 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 50 *см*. Көнчыгыш һәм төньяк яр буе зонасы сазлыклы, көньяк һәм көньяк-көнбатышта кәсләнгән. Күл буенда балаларны сәламәтләндерү лагерьлары урнашкан. Ял итү урыны.

**МҮКЛЕ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының тәбәнәк террасасында, Лаеш р-ны Матюшино авылының төньяк читендә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 3,5 *га*. Су күләме 82 мең *м*$^3$. Озынлыгы 420 *м*, иң зур киңлеге 80 *м*. Уртача тирәнлеге 2,3 *м*, иң зур тирәнлеге 4,9 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Сузынкы, бөгелгән формада. Ярлары сөзәк, нарат агачлары үсә. Сулыкның көньяк өлешендә йөзмә утрау бар. Явым-төшем һәм грунт сулары б-н туена. Ял итү максатларында файдаланыла.



Мүкле күл Матюшино авылы янында.

**МҮКЛЕ́ КҮЛ**, Көнчыгыш Кама аръягында. Ык елгасының сулъяк кушылдыкларының субүләрендә, Азнакай р-ны Чәкән авылыннан 1,9 *км* көньяктарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 2,84 *га*. Су күләме 26,4 мең *м*$^3$. Озынлыгы 300 *м*, иң зур киңлеге 150 *м*. Уртача тирәнлеге 0,93 *м*, иң зур тирәнлеге 2 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы катлаулы. Яр буе зонасы кәсләнгән. Суы бик йомшак (1,36 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 111,2 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 42 *см*. Саргылт төстә. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.


**МҮКЛЕ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының биек террасасында урман массивында, Лаеш р-ны Татар Сараланы авылыннан 1,5 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 2,72 *га*. Су күләме якынча 8 мең *м*$^3$. Озынлыгы 290 *м*, иң зур киңлеге 120 *м*. Уртача тирәнлеге 2,95 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы катлаулы. Сулыкның уртасында йөзмә утрау бар. Ярлары күтәренке, күбесенчә сөзәк. Суы бик йомшак (0,7 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 45,2 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 150 *см*. Ял итү максатларында файдаланыла.



Мүкле күл Татар Сараланы авылы янында.

**МҮКЛЕ́ КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Спас р-ны Отрада авылыннан 1,1 *км* көньяк-көнчыгыштарак (Чуртан күленнән көнчыгыштарак). Су өслегенең мәйданы 1,72 *га*. Су күләме якынча 35 мең *м*$^3$. Озынлыгы 230 *м*, иң зур киңлеге 110 *м*. Уртача тирәнлеге 2 *м*, иң зур тирәнлеге 4,7 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы бик йомшак (1,4 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Гомуми минеральләшүе 105,3 *мг/л*. Үтә күренмәлелеге 174 *см*.

**МҮКЧӘЛӘ́Р** (Bryozoa), умырткасыз хайваннар тибы. 4 меңгә якын төре билгеле. Колониаль, күбесенчә диңгез хайваннары. Зооид затларның озынлыгы 1 *мм* тирәсе, бөтен колониянеке — берничә *см* га кадәр. Колонияләр тәңкә, калак рәвешендә куакчыл, кабыксыман булырга мөмкин. Кайбер затлар кармавычлы таҗ урнашкан алгы (полипид) һәм саклагыч кутикула б-н капланган капчыксыман арткы (цистид) бүлекләрдән тора. Авыз әйләнәсендә дугасыман яки түгәрәк лофофорда урнашкан кармавычлар таҗы — М.нең төп үзенчәлеге. Колониядә-




Мүкчәләр:
1. Сырлы бүрекчә (Cristatella mucedo);
2. Plumatella repens шуышма мүкчәләр колониясе участогы;
3. Dendrobaenia мүкчәләренең калаксыман колониясе;
4. Idmonea мүкчәләренең куакчыл колониясе.

ге затларның күпчелеге саклагыч функция үти. М. — икенчел куышлыклы хайваннар. Ашкайнату системасы элмәксыман, тышкы яктан лофофор түбәндәге аналь ачыклык б-н ачыла. Нерв системасы йоткылык яны ганглийлары рәвешендә һәм аннан таралучы нервлардан тора. Кан, сулыш, бүлеп чыгару системалары юк. Гермафродитлар. Колонияләрнең үсеше җенессез, бөреләнеп үсү хисабына бара. Төче су М.е ш.у. «эчке бөреләр» — статобластлар барлыкка килү юлы б-н дә үрчергә мөмкин, алар исә көзен формалашалар һәм кышлыйлар. Төче су М.енең колонияләре, нигездә, кыш башланыр алдыннан үләләр.

Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Сырлы бүрекчә (Cristatella mucedo) суалчансыман колония булып яши, субстратка ныклап берекмәгән, акрын гына шуышырга сәләтле. Колонияләрнең тышчасы желатинлы, койкасыман. Зооидлар суырыла алмый, лофофор дагасыман, статобластлар чәнечкеле һәм ыргаклы түгәрәк формадан тора. Йомгаксыман мүкчәләрнең (Plumatella fungosa) — кайвакыт бик зур тыгыз күрән төстәге йомгаклар рәвешендәге колонияләре төрле су асты предметларына урнашалар, ш.и. сүүткәргечләрдә билгеле бер зыян салып яшиләр. Көпшәләрнең кутикуласы хитинлашкан, зооидлар цисталар эченә суырылып керә, статобластлар һава камералы һәм тышкы ыргакларсыз. Шуышма мүкчәләр (P. repens) — ятып үскән тармаклы көпшәләр рәвешендәге колония, субстратка ныклап берегә. Көпшәләрнең кутикуласы хитинлашкан, зооидлар эчкә суырыла ала, статобластлар 2 төрле: утырма түгәрәк һәм озынча вак түгәрәк, нык хитинлы кутикула б-н капланган иркен йөзүчеләр. М. суларның химик токсиннар б-н пычрануына бик сизгер.

*Әд.:* К л ю г е Г.А. Мшанки северных морей СССР. М.–Л., 1962; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных России. Т. 1. Низшие беспозвоночные. СПб., 1994.

*Р.М.Сабиров.*

**МҮЛМӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2010 елда 699 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында М.дә волость идарәсе урнаша; 2 мәчет, 2 мәктәп, җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1536,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 147 ир-ат; 1859 да — 606, 1897 дә — 947, 1908 дә — 1189, 1920 дә — 1141, 1926 да — 1084, 1938 дә — 1074, 1949 да — 855, 1958 дә — 753, 1970 тә — 758, 1989 да — 664, 2002 дә — 676 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**МЫЕКЛА́Ч КОҢГЫЗЛА́Р** (Cerambicidae), коңгызлар семьялыгы. 25 меңгә якын төре билгеле. Татарстан терр-ясендә төгәл төре билгеләнмәгән. Нигездә, зур яки уртача зурлыктагы коңгызлар. Гәүдә озынлыгы 9–60 *мм*, сузынкы, төкчәле, мыекчыклары ярты гәүдәдән озынрак. Урта күкрәкнең алгы күкрәккә ышкылуы нәтиҗәсендә, күп кенә төр коңгызлар үзенчәлекле шыгырдавык тавыш чыгарырга сәләтле. Личинкалары агач эчендә һәм кайры астында үсә, күпләре агачларга зур зыян китерә. Имән М.к.ы (Cerambyx cerdo), Келер М.к.ы (Purpuricenus Kaehleri) һәм тал М.к.ы (Lamia textor) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965. Т. 2; Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. Киев, 1974. Т. 2; Красная книга Республики Татарстан: Животные, растения, грибы. К., 1995.

*С.М.Шәфигуллина.*

**МЫСЫ́** посёлогы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 31 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Лаеш кантоны Нармонка волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 75, 1938 дә — 116, 1958 дә — 122, 1970 тә — 124, 1979 да — 110, 1989 да — 72, 2002 дә — 48 кеше.

**МЫШЬЯКОРГА́НИК КУШЫЛМАЛА́Р**, мышьяк-углерод бәйләнеше булган кушылмалар. Мышьякның органик кушылмалары турында беренче мәгълүмат француз галиме Л.Каде соңыннан аның үз исеме б-н аталган сыеклык синтезлаган 1760 елга карый. М.к. химиясенә немец химигы Р.В.Бунзен нигез сала, ул «Каде сыекчасы»ның составын өйрәнә, какодил (диметиларсин калдыгы) радикалының формуласын чыгара, какодил оксидының башка матдәләр б-н реакцияләрен өйрәнә (1827–43); соңгысы органик химиядә катлаулы радикаллар теориясе төзелүгә һәм ныклы урын алуга этәргеч булып тора (швед химигы Й.Я.Берцелиус). Мышьяк кушылмалары, беренче нестицидлар буларак, үсемлек корткычларына каршы көрәшү өчен кулланыла башлый. 20 йөздә М.к. б-н кызыксыну мышьякорганик дәвалау чараларын синтезлау һәм куллануга бәйле. Спирохетлар китереп чыгарган авыруларны нәтиҗәле дәвалау өчен, немец биохимигы П.Эрлих мед. практикасына сальварсан һәм неосальварсан препаратларын кертә. Дару препаратлары синтезлана (аларның кайберләре хәзер дә, бигрәк тә тропиклар медицинасында, кулланыла). Антибиотиклар уйлап табылганнан соң (20 йөз уртасы), химия белән дәвалауда мышьякорганик дәва чараларының роле кими. Синтезлап табылган М.к.ның биол. активлыгын тикшерүләр гадәттән тыш агулы кушылмалар барлыгын күрсәтә, алар сугышта кулланылучы агулау матдәләре (люизит, адамсит) сыйфатында тәкъдим ителә. М.к. агач материалы консервантлары, аналитик реагентлар буларак, ш.у. микроэлектроникада, голографиядә, җепселле оптикада кулланылыш таба.

Татарстанда М.к. өлкәсендәге тикшеренүләр 1930 елларда башланып китә. Бу юнәлешкә нигез салучы Г.*Камай*, беренчеләрдән булып, М.к.ның стереохимиясен өйрәнә башлый, оптик актив арсоний тозларын синтезлый һәм аерып күрсәтә; фосфор-мышьякорганик катнаш кушылмалар классын ача, мышьякның төрле координацион санлы кислородлы кушылмаларын синтезлау алымнарын эшли. М.к.ның реакциягә керү сәләте һәм химик-физик үзлекләре (Б.Д.*Чернокальский*), мышьякның стереохимиясе (Ю.Ф.*Гатилов*) өлкәсендә тикшеренүләр үсеш ала. Өч, дүрт һәм биш координацияле мышьякның кислородлы, күкертле һәм азотлы кушылмалары, мышьякның гетероциклик кушылмалары (ш.и. макроцикллар, төрле полидентат лигандалар) синтезлана. М.к.ның нуклеофиль реакциягә сәләте (кислородлы һәм күкертле кушылмалар мисалында) тикшерелә, дүрт координацияле мышьякның алифатик кушылмалары өчен ретроарбузов реакциясенең универсаль характерда булуы ачыклана (В.С.*Гамаюрова*). Өченчел арсиннарның сульфидлар, оксидлар һәм селенидлар рәтендә ретроарбузов реакциясе гамәлгә ашырыла (Б.Е.Абалонин). М.к.ның электрон төзелеше һәм фәзаи структурасы оптик спектроскопия, диполь моментлар һәм структур рентген анализы алымнарын кулланып өйрәнелә (Р.Р.Шаһидуллин, Ф.Г.Халитов, Г.И.Кокорев). Фәнни тикшеренүләргә нигезләнеп, сугышта кулланылучы агулау матдәләрен үтилләштерү технологияләре эшләнә, полимерлар өчен яңа биоцидлар, сүүсемнәр ябышудан саклый торган буяу компонентлары (В.И.*Гаврилов*), вет. препаратлары (В.С.Гамаюрова), авыр металлар (ш.и. уран һәм трансуран) экстрагентлары (Б.Д.Чернокальский) синтезлана. Фәнни хезмәтләр «Пигмент» ФҖБдә (Ленинград), оборона сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә, вет. гамәлендә кулланыла. М.к. өлкәсендәге тикшеренүләр Казан технол. ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында, Татар гуманитар-пед. ун-тында (Казан (Идел буе) федераль ун-тында) алып барыла.

*Әд.:* К а м а й Г.Х., Ч е р н о к а л ь с к и й Б.Д. Методы синтеза и реакции эфиров кислот мышьяка // Реакции и методы исследования органических соединений. М.–Л., 1964. Кн. 13; Г а м а ю р о в а В.С. Мышьяк в экологии и биологии. М., 1993.

*В.С.Гамаюрова.*

**МЮД** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* көньяктарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 428 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 25%, чуашлар — 21%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты, китапханә. 1930 елларда нигез салына.

Оештырылган көннән — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 287, 1949 да — 370, 1958 дә — 507, 1970 тә — 662, 1979 да — 593, 1989 да — 518, 2002 дә — 491 кеше.

**МЮ́ФКЕ** Карл Людвигович (Карл Герман Людвиг) (30.1.1868, Воронеж ш. — 13.2.1933, Саратов ш.), архитектор. 1896 елда, төзелеш алып бару хокукына ия архитектура рәссамы исеме алып, Петербург САнең Югары сәнгать уч-щесен тәмамлый. 1897 дән Казан сәнгать мәктәбе укытучысы, архит-ра бүлеге җитәкчесе, 1899–1900 елларда аның урынбасары. Бер үк вакытта, 1898–99 да, Казан сәнгать уч-щесенең техник сурәтләр һәм төзелеш сәнгате укытучысы. 1900–02 дә Казан ун-ты архитекторы. 1909 дан Саратов ун-тының төзүче архитекторы, 1912 дә даими яшәргә Саратовка күчеп китә. 1920 дән Саратов политехник ин-тының гражданнар архит-расы һәм архит-ра формалары, Саратов гамәли-инженерлар ин-тының архит-ра һәм архитектур проектлаштыру профессоры.



К.Л. М ю ф к е. Сәнгать мәктәбе бинасы. Казан. 1900–05. Карл Маркс урамы ягыннан күренеше.

19–20 йөзләр чигендәге күренекле Казан архитекторы. Яңа рус, яңа классицизм һәм модерн стильләрендә эшли. М. проектлары буенча Казан сәнгать мәктәбе бинасы (1900–05), Казан ун-ты төп бинасының көнбатыш канаты (1902–04), *Ушкова йорты* (1904–08), *Мюфке йорты* (1907–08), Саратов ун-ты комплексы һәм Агафоновка авылында ун-тның клиник шәһәрчеге төзелә (1909–30); Казан ун-тының төп бинасы үзгәртеп корыла (1902–12).

*Әд.:* О с е т и н с к и й А.П. Архитектурный ансамбль К.Л.Мюфке в Саратове. Саратов, 1984; С а н а ч и н С.П. Карл Мюфке, его жизнь и архитектура // Казань. 1996. № 9–12.

*С.П.Саначин.*

**МЮ́ФКЕ ЙОРТЫ́**, Казанда модерн стилендәге һәм ялгыз торак йорт үрнәгендәге архит-ра истәлеге. 1907–08 елларда элекке Академия бистәсе терр-ясендә хуҗасы арх. К.Л.Мюфке проекты буенча төзелә. Кирпеч з-ды урамы тәмамланган урындагы агачлыкта урнашкан. Биек калай түбәле, штукатурланган ике катлы кирпеч йорт. Фасадлары симметриясез. Беренче катта челтәр баскычлы вестибюль, юыну һәм кер юу, кунак бүлмәләре һәм көньяк фасад буйлап сузылган



К.Л. Мюфке йорты. Казан. 1907–08. Һади Атласи урамы ягыннан күренеше.

террасага чыгучы ашханә урнашкан; икенче катта — зур зал, йокы бүлмәләре, кабинет, бәдрәф һәм юыну бүлмәсе; чарлакта — хезмәтчеләр бүлмәсе. Һәр бүлмә үзенә бер нәфислек б-н бизәлгән. Икенче каттагы зур тәрәзәле, конструкциясе готика стилендәге нервюралардан торган һәм балкон ишеге түгәрәгрәк залга ачылган бүлмә гаять үзенчәлекле. М.й. 1930 дан — Казан коммуналь төзелеш ин-ты, соңрак КПССның Татарстан өлкә ком-ты карамагына тапшырыла. 1957–60 та биредә өлкә ком-тының 1 нче секретаре С.Д.Игнатьев һәм ТАССР МС рәисе Г.Ә.Әбдерәзәков яши. 1960 тан — балалар бакчасы.

*Е.В.Афонина, Л.М.Мортазина.*

**МЯГКО́В** Герман Пантелеймонович (10.7.1946, Ярославль ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2001), проф. (2002), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1971 елдан Казан мәдәният ин-тында марксизм-ленинизм кафедрасында (1981 гә кадәр), проректор (1984 кә кадәр), философия һәм фәнни коммунизм каф. доценты. 1988 дән Казан ун-тында борынгы заман һәм урта гасырлар кафедрасында, бер үк вакытта, 1995–98 дә, тарих ф-ты деканы урынбасары. Бөтенроссия урта гасырлар һәм яңа заманның элгәре чоры тарихчылары ассоциациясе (Мәскәү, 1994 тән, Россия интеллектуаль тарих җәмгыяте (Мәскәү, 2000 тән) әгъзасы. Хезмәтләре урта гасырлар тарихына, гомуми тарих историографиясенә, Россия иҗтимагый-сәяси фикер тарихына, тарих теориясе һәм методологиясенә, фәнне өйрәнү мәсьәләләренә карый.


Х е з м.: Международные отношения эллинистических государств в 280–220 гг. до н. э. К., 1980; Древность и её место в историческом процессе. Самара, 1996; Максим Максимович Ковалевский — почётный член Казанского университета // Учёные записки Казанского государственного университета. Сер. Гуманит. науки. 2011. Т. 153, кн. 3; Историки России в спорах о Ранке // История и историки в прошлом и настоящем. М., 2013; Научное сообщество в исторической науке: опыт «русской исторической школы». К., 2000.

**МЯГЧЕНКО́В** Виталий Алексеевич (17.3.1937, Омск ш.), физик-химик, химия фән. д-ры (1974), проф. (1978), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Ленинград ун-тын тәмамлый (1959), Казан технол. ун-тында эшли. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар һәм коллоид системалар химиясенә һәм физик химиягә карый. М. катлаулы күп компонентлы системаларда радикаль полимерлаштыру һәм бергә полимерлаштыруның кинетикасын һәм механизмын тикшерә. Катлауландырылган 1 нче һәм 2 нче төр системалар синтезлауның төп закончалыкларын һәм аларның аерымлык билгеләрен ачыклый (проф. С.Я.Френкель б-н берлектә). Катлауландырылган системаларны бергә полимерлаштыру процессларын төгәл анализлау өчен макромолекулаларның уртача составы турындагы мәгълүмат кына җитмәвен, бу полимерларның составы буенча полидисперслыклары турында өстәмә белешмә дә кирәклеген исбатлый. Составы буенча полидисперслыкны бәяләүнең төрле алымнарын тәкъдим итә, бергә полимерлашучыларның химик гетерогенлыгын чагыштырмача микъдари бәяләү өчен матем. аппарат булдыра. Бу исә бергә полимерлаштыру процессларының катлауландырылган вариантлары өчен состав буенча теоретик һәм экспериментaль бүленеш кәкреләре арасында ышанычлы тәңгәллек урнаштыру мөмкинлеген бирә. Ионоген мономерларны бергә полимерлаштыруның төп закончалыкларын, ш.у. әлеге ионоген полимерлашучыларның сулы, сулы-органик һәм органик тирәлекләрдәге үзлекләрен анализлый. Модельдәге һәм чынбарлыктагы күп компонентлы дисперс системаларда суда эрүчән полимерлашучылар тәэсирендә (башлыча, акриламидның анионлы һәм катионлы полимерлашучылары) флокуляция кинетикасын һәм механизмын өйрәнә. Молекуляр (составы һәм молекуляр массасы буенча бүленеш кәкреләре дәрәҗәсендә) һәм конформацион параметрларның сәнәгати силоксанлы полимерлашучылар үзлекләренә тәэсирен тикшерә. Суда эрүчән полимерлашучыларның турбулент су-тоз һәм су-нефть агымнарының гидравлик каршылыгын киметүче агентлар сыйфатында файдалы булуын күрсәтә. Күп кенә бинар композицияләр (полимер — полимер, полимер — актив өслек матдәсе) өчен синергизм һәм антагонизм эффектларын ача. «Полимерлар энциклопедиясе» («Энциклопедия полимеров», М., 1977. Т.3), «Химия энциклопедиясе» («Химическая энциклопедия», М., 1993. Т.3) һәм «Полимер материаллар энциклопедиясе» («Polymeric Materials Encyclopaedia», Нью-Йорк, 1996) басмаларында күзәтү мәкаләләре авторы.

Х е з м.: Композиционная неоднородность сополимеров. Л., 1988 (автордаш); Полимеры и сополимеры стиролсульфокислоты. А.-А., 1989 (автордаш); Поверхностные явления и дисперсные системы. К.,2007.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**МЯ́СНИКОВ** Андрей Гаврилович (якынча 1806, Казан — 2.6.1863, шунда ук), Казанда китап кибете һәм җәмәгать файдалануындагы иң беренче хосусый китапханә хуҗасы (к. *Мясников А.Г. китапханәсе*). «Изгелек кабул иткән» иске карашлы дин тарафдарларыннан. Казан шәһәр думасына өч тапкыр депутат булып сайлана. Сәүдә киңәшчесе,



«Казанның китап сатучысы А.Г. Мясников портреты». Рәссам З.И. Иванов. 1839. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

3 нче гильдия сәүдәгәр. Түбән Новгород ярминкәсендә сәүдә итә. Казан ун-ты китапханәсенең, аерым затларның, ш.и. М.П.Коринфский, Г.И.Солнцев, А.И.Артемьев һ.б.ның китапларга заказларын үти. Казан икътисадчылар җәмгыятенең (1845 елдан), Законнар җыентыгы һ.б. казна китапларын сату буенча император канцеляриясенең 2 нче бүлеге басмаханәсенең (1850 дән) хакыйкый әгъзасы һәм комиссионеры. 1852 дән Казан ун-ты комиссионеры. 1860 тан Мария хатын-кызлар уч-щесенең Попечительләр советы әгъзасы, 1862 дән Ирекле икътисадчылар җәмгыятенең мөхбир әгъзасы һәм Файдалы китаплар тарату җәмгыяте әгъзасы. «Ватан мәгарифе өлкәсендә...» хәленнән килгән кадәр файда итү теләге б-н М. илнең төрле китапханәләренә шактый өлеш кертә: зур кыйммәткә ия бүләкләр ясый. 1858 дә аңа, шул заманның әдәби әсәрләрен җибәрүен сорап, Кырым сугышында (1853–56) китаплары югалган Керчь иҗтимагый китапханәсе дирекциясе мөрәҗәгать итә, М. әлеге гозерне бик теләп үти һәм Кырым сугышы истәлеге бронза медале б-н бүләкләнә. 1858–62 дә Мәскәүдәге Җәмәгать китапханәсенә 47 кулъязма һәм басма китап, ш.и. 1800 дә Мәскәү митрополиты Платон хатын, А.А.Фуксның «Казан шәһәренә нигез салыну» («Основание города Казани») кулъязмасын, «Иван Грозныйның законнар җыелмасы»ның («Судебник Ивана Грозного») В.Н.Татищев искәрмәләре кергән 18 йөз күчермәсен, Казан планын, җирле халыкның Е.И.Пугачёвның Казанга килүе турындагы риваятен, кенәз А.Вяземскийның 1779 елгы ике хатын, 1815 елгы янгынга кадәрге Казан Кремле чиркәве һәм Кремль манарасы күренеше төшкән китап, «Җәяүле гаскәр полкы уставы»н («Строевой устав пехотного полку», СПб., 1762) һ.б.ны бүләк итә. 1863 тә Хабаровск краеның Николаевск-Амур шәһәре җәмәгать китапханәсенә 200 басма (2 мең томнан артык) бүләк итә, шуның өчен император Александр II исеменнән рәхмәт ала. М. гомеренең 45 елын Казанда мәгариф һәм мәдәният эшенә бирә. М.ның китап кибетендә эшләгән Казан библиофилы Н.Я.Агафонов әйтүенчә, аның хуҗасы сирәк китаплар аулаучы «бөек һәм бәхетле аучы» була.

*Әд.:* Парамонова Н.Б. Г.И. и А.Г.Мясниковы — книготорговцы русской провинции первой половины XIX века // Книга в России XVII — начала XIX в.: Проблемы создания и распространения. Л., 1989.

*И.А.Новицкая.*

**МЯ́СНИКОВ А.Г. КИТАПХАНӘСЕ́.** 1860 елларга кадәр Казанда беренче һәм җәмәгать файдалануындагы иң эре хосусый китапханәләрнең берсе. 1834 тә сәүдәгәр һәм китап сатучы А.Г.Мясниковның (1806–63) шәхси китап кибете каршында ачыла. С.-Петербург, Мәскәү, Новгород, Ярославль, Харьков шәһәрләренең китап ярминкәләрендә сатып алынган китаплар хисабына туплана бара; анда каталог һәм библиографик күрсәткечләр була. Бу китапханә казанлылар арасында абруй казана: 1841 нең 2 нче яртысында китапханә ай саен 18–25 кешегә (студентлар, түрәләр, мещаннар, сәүдәгәрләр) хезмәт күрсәтә. Монда төрле белем өлкәләренә караган китаплар, беллетристика, ш.у. француз, немец телләрендә әдәбият, вакытлы матбугат (1843 тә — 20 ләп, мәс., «Современник», «Отечественные записки», «Сын Отечества») була. Җирле басмаларның бай тупланмасы: Н.И.Лобачевский, Н.Н.Зинин, И.М.Симонов һәм Казан ун-тының башка галимнәре хезмәтләре; «Казанские известия», «Казанский вестник», «Прибавление к «Казанскому вестнику», «Казанские губернские ведомости», «Заволжский муравей», «Учёные записки Казанского университета» һ.б. газета һәм журнал төпләмәләре китапханәдә саклана. 1863 тә хуҗасының вафатыннан соң ябыла. А.Г.Мясников архивы Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* Васильев П.П. Частные библиотеки в Казани // Журн. М-ва нар. просвещения. 1863. Ч. 119; Агафонов Н.Я. Казанское книжное дело. К., 1866. Вып. 1; Шишкин В.И., Щелыванова Ж.В. Казанские частные библиотеки для чтения 30–60-х годов XIX века // Библиотека Казан. ун-та: фонды, раритеты, история...: Сб. статей. К., 1989; Парамонова Н.Б. Г.И. и А.Г.Мясниковы — книготорговцы русской провинции первой половины XIX века // Книга в России XVII — начала XIX в.: Проблемы создания и распространения. Л., 1989.

*Г.Г.Габделганиева.*

# Н

**«НА ВО́ЛГЕ ШИРО́КОЙ»**, к. «*Киң Иделдә*».

**«НА СТРА́ЖЕ ЗАКО́ННОСТИ И ПОРЯ́ДКА»** («Законлылык һәм хокук тәртибе сагында»), юридик журнал. 1923–24 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. 1923 нең маеннан «Вестник советской юстиции Автономной Татарской Социалистической Советской Республики» исеме б-н чыга. ТАССР Юстиция халык комис-ты органы буларак, журнал ТАССР прокуроры Г.Б.*Баһаветдинов* тырышлыгы б-н аның мөхәррирлегендә нәшер ителә башлый; кайбер саннарны аның урынбасарлары М.Усманов һәм Ш.Саттаров редакцияли. Журналны оештырганда Мәскәүдә нәшер ителгән «Еженедельник советской юстиции» ж-лы тәҗрибәсе исәпкә алына. Журнал совет хокукының теоретик һәм гамәли мәсьәләләрен аңлатырга, гамәлдәге законнар җыелмасының бәхәсле проблемаларын күтәрергә, халык комис-ты органнары эшчәнлеген яктыртырга тиеш була. Басманың РСФСР һәм ТАССР юстиция органнары, ТАССР өлкә мәхкәмәсе карарлары һәм документлары басыла торган зур рәсми бүлеге була. ТАССР төзелүнең 3 еллыгы уңаеннан басылган 1923 елгы 4 нче сан тулысы б-н мәхкәмә органнары, тикшерү аппараты, революцион трибунал, дәүләт нотариаты, адвокатура, ТАССР Законнар нигезләмәсе комиссиясе эшчәнлеген анализлауга багышлана. Юбилей санында ТАССР Юстиция халык комис-ты каршындагы гадәти мөселман хокукларын, шәригатьне өйрәнүче Шәригать комиссиясенең эшли башлавы һәм аны Татарстан шартларында куллану мөмкинлеге дә карала. Кайбер саннарда төрмәләр Баш идарәсе каршындагы криминаль психологияне өйрәнү түгәрәге материаллары басыла. 1924 тә журнал ТАССРның Юстиция һәм Эчке эшләр халык комис-тларының уртак органына әверелә һәм «На страже законности и порядка» исеме б-н чыга башлый. Шул вакыттан башлап аңарда ТАССР Эчке эшләр халык комис-ты циркулярлары, Җинаять кодексы аңлатмалары басыла, хакимият эше мәсьәләләренә, җинаятьчелек торышына күзәтү ясала, аның б-н көрәш мәсьәләләре, криминаль хроника яктыртыла башлый. Авторлар арасында — респ-каның күренекле юристлары А.Бажанов, Г.Борисенко, Н.Быховский, С.Венецианов, В.Виноградов, Б.Змиев, Е.Ивановский, К.Остров, К.Харлампович, Б.Царегородцев һ.б. Журнал чыгаруны дәвам итү мөмкин булмаганлыктан, ТАССРның Юстиция халык комис-ты 1925 нең сентябрендә рәсми материалларны бастыру өчен «Юстиция халык комиссариаты бюллетене»н оештырып карый, әмма аның Г.Баһаветдинов редакциясендә берничә саны гына чыгып кала.

*Р.А.Айнетдинов.*



Ә.Х. Нагаев.

**НАГА́ЕВ** Әнвәр Хәсән улы (28.1.1922, Әстерхан ш. — 11.12.2002, Казан), театр рәссамы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957), ТАССРның халык рәссамы (1970). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1950), Татар опера һәм балет театрында эшли, баш рәссам (1964–82). Бөтенроссия театр җәмгыяте әгъзасы (1950). 150 дән артык спектакль, шул исәптән П.Чайковскийның «Иоланта» (1952), Н.Җиһановның «Җәлил» (1956), Х.Вәлиуллинның «Самат» (1957), Дж.Вердиның «Травиата» (1958), Р.Леонкаваллоның «Паяцы» (1962), Х.Вәлиуллинның «Дим буенда» (1965), Дж. Вердиның «Аида» (1967), М.Глинканың «Иван Сусанин» (1968), Н.Җиһановның «Алтынчәч» (1979) опералары; А.Ключарёвның «Тау әкияте» (1959), К.Караевның «Яшен сукмагыннан» («Тропою грома», 1959), З.Хәбибуллинның «Раушан» (1960), Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетларын (1968) һ.б.ны бизи. Татар академия театрында уйналган А.Шамовның «Рәүфә» (1958), М.Кәримнең «Кыз урлау» (1958, 1966) һ.б. спектакльләргә декорация эскизларын әзерли. Н. иҗат иткән декорацияләргә образны монументлаштыру, татар милли сәнгате традицияләренә, фольклорына мөрәҗәгать итү, сәнгатьле-ачык палитра байлыгы хас. Мәскәүдә узган Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында (1957), «РСФСРның 16 автономияле республикасы» (Мәскәү, 1971), «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1972), «Татарстанның театр рәссамнары Мәскәүдә» (1976–77), «Татарстан рәссамнары Уфада» (1976) күргәзмәләрендә катнаша. Хезмәтләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында саклана. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**НАГА́ЕВ** Рәис Әнвәр улы (6.4.1952, Казан), театр һәм кино рәссамы. Ә.Х.*Нагаевның* улы. Казан сәнгать уч-щесен (1972), Бөтенсоюз кинематография ин-тын, Г.Мясников һәм А.Дегтярь остаханәсен тәмамлый (1980). Татар опера һәм балет театры рәссамы (1972–74). 1980 елдан «Мосфильм» киностудиясе рәссамы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (2003). «Мосфильм»да төшерелгән картиналарның куючы-рәссамы: «Алтын аттагы җайдак» («Всадник на золотом коне», реж. В.Н.Журавлёв, 1980), «Генерал Нестеровка йөкләргә» («Поручить генералу Нестерову», реж. Б.Галкин, 1984), «Иске рухта шаярулар» («Проделки в старинном духе», реж. А.Панкратов (Белый), 1986), «Базар мәйданындагы карусель» («Карусель на базарной площади», реж. Н.Стамбула, 1986), «Вәсвәсә» («Наваждение», реж. Н.Стамбула, 1989), «Афәрин» («Браво» фильм-концерты, реж. Ю.Даниялов, 1988), «Борынгы Болгарның җылы җилләре» («Тёплые ветры древних Булгар», реж. Б.Мансуров, 1995), «Арнольд» белән репетиция» («Репетиция с «Арнольдом» , реж. В.Морозов, 1998), «Рухлар тарла-







Ә.Х. Н а г а е в. Декорация эскизлары: 1. Х. Вәлиуллинның «Самат» операсына. 1957; 2. К.Караевның «Яшен сукмагыннан» балетына. 1959; 3. Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсына. 1979. Барысы да – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

выгы» («Ущелье духов», реж. С.Нилов, 1991), «Севастьян Баховның интим тормышы» («Интимная жизнь Севастьяна Бахова», реж. М.Воронков, 2001), «Шымчылар-4» («Сыщики-4», реж. Б.Щербаков, Б.Казаков, 2004) һ.б.; «Үзбәкфильм»да — «Уран планетасы иярчене» («Спутник планеты Уран», реж. Ж.Ахмар, Ташкент, 1990), «Таркифильм» киностудиясендә — «Шамил. Кылычлар күләгәсендәге оҗмах» — («Шамиль. Рай под тенью сабель», реж. И.Казиев, 1992), «Росфильм»да — «Антифауст» (реж. Г.Фризен, 1993), «Аграс-Синема»да — «Тәвәккәл пар» («Лихая парочка», реж. А.Сиренко, 1993), «Ступень»дә — «Винт» (реж. А.Казаков, 1993) кинокартиналарының куючы-рәссамы. Рәссам-декоратор буларак, Н. М.Горький исем. киностудиядә төшерелгән «Әтиләр һәм бабайлар» («Отцы и деды», реж. Ю.Егоров, 1980), «Мосфильм» киностудиясендә төшерелгән «Безне чиркәүдә никахламадылар» («Нас венчали не в церкви», реж. Б.Токарев, 1982), «Яр» («Берег», реж. А.Алов, В.Наумов, 1983), «Йокы бүлмәсе ачкычы» («Ключ от спальни», реж. Э.Рязанов, 2004) фильмнарын бизи.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НАГА́ЕВ** Роберт Тимербай улы (20.10.1953, БАССРның Аургазы р-ны Исмәгыйль а.), инженер-механик, икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), ТРның атказ. икътисадчысы (2000). 1979 елда Казан. а.-х. ин-тын тәмамлый. 1979–87 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында эшли, 1987–91 дә Яшел Үзән р-ны «Бишнә» хуҗалыгы б-н җитәкчелек итә. 1991 дән җир ресурслары һәм җир реформасы буенча Казан шәһәр ком-ты рәисе (2001 дән Казан буенча җир кадастры хезмәте җитәкчесе). Хезмәтләре игенчелектә техниканы нәтиҗәле куллану, хуҗалык исәбендәге механикалаштырылган бүлекчәләрдә кеше факторының роле, җир ресурслары б-н идарә итү һәм җир кадастрын камилләштерү мәсьәләләренә, җир өчен түләүне билгеләүгә һәм күчемсез милек базарына карый.

Х е з м.: Недвижимость. Землеустройство. Градостроительство и экономика: Терминол. словарь. К., 1998; Управление земельными ресурсами и развитие рынка земли в городах: Теория, анализ, практика. К., 1998; Оценка земли: Курс лекций. К., 2001 (автордаш); Управление земельными ресурсами в городах на основе земельно-кадастровых систем. К., 2001; Недвижимость: Энцикл. словарь. К., 2003.

*Ф.С.Зыятдинов.*

**НАГА́ЕВ** Роберт Фәрит улы (26.1.1938, Ленинград, хәзер С.-Петербург — 3.11.2004, шунда ук), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1982), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2003). 1961 елда Ленинград политехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Файдалы казылмаларны механик эшкәртү фәнни-тикшеренү һәм проектлаштыру ин-тында («Механобр», Ленинград) эшли. 1976 дан С.-Петербург тау эшләре ин-тында, теоретик механика каф. мөдире (1976–98). Хезмәтләре гомуми механикага, нәсызыкча тирбәнешләр теориясенә, динамик системаларны синхронлаштыруга карый. Н. үзара зәгыйфь тәэсир итешә торган динамик объектлар синхронлашуын тикшерүнең гомуми методикасын тәкъдим итә. Чиксез бәрүле процессларны анализлау һәм төрле типтагы фрикцион автотирбәнешләрне тикшерү теориясен эшли. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (1998). Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Периодические режимы вибрационного перемещения. М., 1978; Самосинхронизация инерционных вибровозбудителей. Л., 1990; Квазиконсервативные синхронизирующиеся системы. СПб., 1996; Mehanical processes with repeated attenuated impacts. World scientific. Singapure, 1999.

**НАГА́Й** посёлогы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 21 *км* көнчыгыштарак, Лагерка елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (мордва, рус) яши. 1920–30 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1949 да — 109, 1958 дә — 100, 1970 тә — 101, 1979 да — 67, 1989 да — 24, 2002 дә — 3 кеше.

**НАГАЙБӘКЛӘ́Р** (үзатамалары нагайбәк), керәшен татарларның субэтник берләшмә билгеләренә ия этнографик төркеме. Элек Оренбург казакларының бер өлеше. Чиләбе өлкәсенең Нагайбәк һәм Чибәркүл р-ннарында яшиләр. Н.нең гомуми исәбе 1719 елда — 1,5 мең, 1744 тә — 1,8 мең, 1762 дә — 2,7 мең, 1833 тә — 5,5 мең, 1857 дә — 6,8 мең, 1897 дә — 8,7 мең, 1926 да — 11,2 мең, 2002 дә — 9,6 мең кеше. Телләре татар теленең урта диалекты составындагы сөйләштән гыйбарәт. Башлыча православие динен тоталар һәм «элек чукынганнар» (христианлыкны 18 йөзгә кадәр кабул иткәннәр) төркеменә керәләр. «Н.» атамасының килеп чыгышын төрлечә — нугайлар, Казан татарлары һәм фин-угорлар б-н бәйләп фаразлаулар бар. Н.нең баштан ук нугай-кыпчак этник асылы булуы һәм Казан арты төбәгендә яшәүләре хакындагы фикер тулырак дәлилләнә. Аларның башка — фарсы, гарәп, бохари, каракалпак этник компонентлары да бар. Н. Кама аръягының көнчыгышында «Уфа ягы яңа чукындырылганнары» рәвешендә 1729 дан мәгълүм (бу вакытта Уфа өязенең Казан даругасындагы 25 авылында яшиләр). Кайбер мәгълүматлар буенча, алар анда 1652–56 да Кама аръягы чик сызыгын корганнан соң килеп утыралар. 1730 елларда Н. Минзәлә шәһәренә һәм төбәкнең башка кальгаларына «казак хезмәтенә» билгеләнәләр. Хөкүмәткә тугрылык саклаганга, бу чукындырылган казаклар 1736 да Минзәләдән 60 чакрым ераклыктагы Нагайбәк авылына (риваять буенча, шул җирләрдә күченеп йөргән башкорт исеме б-н атала, соңрак кальга итеп үзгәртелә) урнаштырыла. 18 йөздә Нагайбәк кальгасында, Бакалыда һәм 12 авылда яшиләр. Бу авылларда ш.у. яңа чукындырылган татарлар һәм типтәрләр гомер кичерә, чукындырылган казаклар алар б-н никах-туганлык мөнәсәбәтләренә керәләр. Казакларның җирдән файдалануын тәртипкә салуга бәйле рәвештә, 1842 дә Н. Нагайбәк кальгасы төбәгеннән Оренбург губернасының Югары Урал һәм Оренбург өязләренә күчереләләр. (Югары Урал өязендә алар тарафыннан нигезләнгән авыллар Россиянең Франциягә һәм Германиягә җиңүе хөрмәтенә Кассель, Остроленко, Фершампенуаз, Париж, Требий, Краснокаменск, Астафьевский һ.б. исемнәр б-н аталалар.) Оренбург өязендә Н. татар казаклары торак пунктларына (Подгорный Гирьял, Алабайтал, Ильинский, Неженский) килеп урнашалар. Анда алар мөселман татарлар б-н якынаялар һәм 20 йөз башында ислам диненә күчәләр. Югары Урал өязенә күчеп килгән Н. элеккечә аерымланып яшиләр һәм 19 йөзнең 2 нче яртысында ук Н. буларак аерылып торалар. Гомумән, Н. тарафыннан үзгә этноним кабул ителү аларның христианлашуы (конфессиональ аерымлану), озак вакыт казаклар составында булу (катлау буларак аерымлану), ш.у. 1842 дә Н. төркеменең төп өлешенең Урал алдында яшәгән Казан татарларыннан терр. бүленүе б-н бәйле. 19 йөзнең 2 нче яртысында Н. керәшен татарларның үзгә этник төркеме буларак аерылып торалар, 1920 дә һәм 1926 да халык исәбен алу вакытында мөстәкыйль халык сыйфатында күрсәтеләләр. Хәзерге вакытта, әлеге төркем вәкилләренең татар халкы б-н уртаклыгын аңлауларына карамастан, аларның үзаңында Н. булулары шактый ачык чагыла. 2000 дә Н. РФнең аз санлы төп халыкларының бердәм исемлегенә кертелә.

Н.нең хуҗалыгы «далалы» типтагы игенчелеккә нигезләнә. Яткын-кысыр җирле система файдаланыла, төп культура буларак бодай игелә, солы, арпа, элеккеге традиция буенча арыш һәм борай үстерелә. Сөрү коралларыннан Урта Идел буе татарларында таралган авыр сабан өстенлек итә. Яшелчәләр (бәрәңгедән гайре) үстерелми. Н. умартачылык б-н дә шөгыльләнәләр. Терлекчелек зур әһәмияткә ия була, ул ш.у. «далалы» рәвештә таралыш ала (бай тормышлылар көтүләре б-н күченеп йөриләр — «көзләү»гә чыгалар яки үз терлекләрен (кайбер чакта 1,5 мең башка җиткән мал-туарларын) казакълар көтүенә кертәләр). Ашлык сугуда атлар файдаланылган (аларга тәгәрәткеч яки арба тагылган); әвен кулланылмавы «далалы» традицияләргә туры килә. Гадәти кәсепләр (яллanып эшләү, олаучылык, таш чыгару, сәүдә) арасында балта эше б-н шөгыльләнү һәм экипаж (тарантас арбалар) ясау аерым урын били (бу һөнәр Кама алды керәшеннәре арасында да очрый).

Торулыклар елга буйларында урнаша, кварталлардан тора, аларда гадәттә чиркәү була. Йортлар урам сызыгы буенча төзелә. Хуҗалык корылмалары тораклан аерым урнаштырыла. Башлыча ике бүлмәле кышкы (бура) һәм җәйге (саман кирпечтән салынган) торакларда яшиләр. Өй диварлары балчык б-н сылана һәм агартыла. Торакларның эчке планы көньяк рус тибындагы торакларның көнчыгыш вариантына туры килә, әмма урта рус планы да очрый. Интерьер киң сәке, агач караватъ, кайбер чакта сәндерәдән һ.б.дан гыйбарәт. Савыт-саба шкафлары да була, 19 йөз ахырыннан шәһәр җиһазлары файдаланыла башлый. Урын-җир кирәк-яракларын әзерләүдә дөя йоны кулланыла. Йорт эче тукымадан эшләнгән үзенчәлекле әйбер-

ләр (бәйрәмнәр вакытында — чигүле сөлгеләр, пәрдәләр, чаршаулар, челтәр кәрнизләр) б-н бизәлә.

20 йөз башына кадәр эчке кием өйдә тукылган тукымадан тегелә. Хатын-кызлар күлмәге туника сыман өлгеле, бала итәкле була. Ирләр күлмәге гадәттә каралы-аклы яки зәңгәрле-каралы вак шакмаклы куе кызыл алачадан тегелә. Аның өстеннән тар күкрәкчәле эрерәк шакмаклы алъяпкыч киелә. Билдән түбәнге кием (чалбар) киң итеп буйлы алачадан киселә. Эчке киемнәрне бизәүдә нәфис туку һәм аппликация алымнары аеруча киң кулланыла. Өске кием — җилән — төсле плис, бәрхет, кәшемирдән тегелә. Өлгесе — билле, өстәп киселгән һәм җыелган арттакта б-н. Җилән өстеннән кулдан тукылган билбау бәйләнә. Язгы-көзге кием — чикмәнне тоташ, җиңелчә генә билләнгән арттакта һәм бөкләмнәр б-н үзләре әзерләгән постаудан теккәннәр. Туннар иләнгән тиредән яисә тирене фабрикада җитештерелгән тукыма б-н тышлап, бил турысыннан бөрмәләп тегелә. Кызларның баш киеме (ак калфак) толым бизәмәләре б-н киелә. Хатыннарда ул «сүрәкә» дип атап йөртелә торган комплекс б-н алышына. Кабырчыксыман тәңкәләр б-н капланган күкрәк бизәмәсе — муенса киң таралган була. Оренбург казакларының гадәти киеме ирләр киеме булып санала.

Н.нең еллык циклында бәйрәмнәр, православие календарена туры китерелеп, христиан исемнәре б-н атала (Тройсын — Троица, Май чабу — Масленица һ.б.). Үз атамалары да гамәлдә була (мәс., *Нардуган* — раштуа (рождество) циклы). Язгы-җәйге бәйрәмнәр башка татарлар (иң элек, Казан татарлары) бәйрәмнәре б-н уртак. Йолаларның пасха циклы булган «сөрән» вакытында «бәрмәнчек боткасы» да пешерелә, балалар, өйдән-өйгә йөреп, буялган йомыркалар, бүләкләр җыялар, төрле ярышлар да (көрәш, йөгереш, ат чабышы) уздырыла, ягъни болар барысы да *Сабан туе* чаралары б-н тиңдәш. Корылык янаган очракта, болыннарда гыйбадәт кылу һәм ботка б-н сыйлау йоласы (чук итү) башкарыла. Мөселман татарларда да шундый ук йола бар. Халык авыз иҗатында борынгы җырлар һәм бәетләр сакланган. Мөселман татарлардан аермалы буларак, Н.дә күмәк (хор б-н) җырлау киң таралган. Җырларда казак хезмәте авырлыклары, туган җирдән һәм якыннардан аерылу сагышы чагыла. Кайбер фольклор әсәрләре («Сак-Сок», «Хан кызы», «Сараш урамы» һ.б.) керәшен татарларның бу үзенчәлекле төркеменең татар халкының калган өлеше б-н ныклы берлеген гәүдәләндерә. Н. мәдәнияте тулаем Казан татарлары, бигрәк тә керәшеннәр мәдәниятенә якын, әмма Н.нең элек казаклар катлавына керүе б-н бәйле үзенчәлекле элементлар да бар.

*Әд.:* Юсупов Ф.Ю. Татар теленең диалектлары: Урал сөйләшләре. К., 2003; Нагайбаки (комплексное исследование группы крещёных татар-казаков). К., 1995.

*Д.М.Исхаков.*

**НАГАЙБӘ́КОВ** Измаил Әхмәт улы (20.9.1896, хәзер Курган өлкәсенең Шадринск ш. — 15.2.1959), танк гаскәрләре генерал-лейтенанты (1945). Ташкент кадетлар корпусын (1914), Константин исем. хәрби артиллерия уч-щесен (Петроград, 1915), М.В.Фрунзе исем. Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе хәрби академиясен (Мәскәү, 1929) тәмамлый. 1915 елдан Россия армиясендә. 1915–16 да запастагы атлы артиллерия дивизиясендә батарея прапорщигы. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша: 1916–17 дә 26 нчы атлы артиллерия батареясында подпоручик, поручик. Гражданнар сугышы елларында — 1918–19 да 9 нчы армия составында интернациональ отрядның штаб башлыгы урынбасары вазифасында Терек өлкәсендә (Төньяк Кавказ) Ирекләләр армиясенә каршы сугышларда, 1920 дә Урта Азиядә басмачылар б-н көрәштә катнаша. 1920 нең гыйнвар–апрелендә мусаватчылар армиясендә (Баку) батарея офицеры, 1920–21 дә Ташкент шәһәрендәге Командирлар составы белемен камилләштерү югары хәрби мәктәбендә взвод командиры, батарея командиры ярдәмчесе. 1922–23 тә В.И.Ленин исем. 23 нче Ташкент пехота мәктәбендә укыта. 1923–26 да Әзәрбайҗан дивизиясендә: дивизион командиры, батарея командиры, полк мәктәбе башлыгы, полк командиры вазифаларын башкаручы, артиллерия полкы штабы башлыгы. 1931–35 тә Томск артиллерия мәктәбендә участок башлыгы, штаб башлыгы. 1935–37 дә 218 нче укчы полк командиры. 1938 нең 14 гыйнварында советларга каршы троцкийчылар оешмасында булуда гаепләнеп кулга алына (1940 та эш туктатыла). 1940 ның февраль–сентябрендә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә укыта. 1940–42 дә Казан пехота уч-щесендә (1941 дә танк уч-щесе итеп үзгәртелә), укыту буенча башлык ярдәмчесе, уч-ще башлыгы урынбасары (1941 дән). 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, Брянск, Воронеж, 1 нче Украина фронтларының 148 нче танк бригадасы командиры урынбасары, 17 нче танк корпусы штабы башлыгы. 1945–46 да 4 нче гв. Кантемир дивизиясендә танк корпусы штабы башлыгы. 1946–50 дә Германиядәге совет гаскәрләре төркеменең 1 нче механикалаштырылган армиясе штабы башлыгы. 1950–54 тә СССР Кораллы көчләренең Маршал Ф.И.Толбухин исем. Югары үзйөрешле артиллерия офицерлары мәктәбе башлыгы. 1954 тә, авыру сәбәпле, Совет Армиясе сафларыннан җибәрелә. Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



И.Ә.Нагайбәков.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НАГАЙБӘ́КОВ** Руслан Измаил улы (20.10.1930, Курган өлкәсенең Шадринск ш.), генерал-майор (1978). Харьков танк уч-щесен (1951), Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1958) тәмамлый. 1951–53 елларда Ленинград, 1958–73 тә Ерак Көнчыгыш хәрби округларында танк батальоны командиры, берләштерелгән ракета полкы командиры. 1973–86 да Төньякта хезмәт итә, СССР Оборона министрлыгының махсус гаскәрләре берләшмәсе командиры. 1986–88 дә СССР Оборона министрлыгының укыту үзәге башлыгы (Мәскәү хәрби округы). Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2000.

**НАГА́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы бассейнында. 2010 елда 43 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1680 нән татар авылы буларак билгеле, 18 йөздә руслар килеп урнаша. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зур Чаксы исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), су тегермәне, 2 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 487 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 276, 1897 дә — 545, 1908 дә — 528, 1920 дә — 599, 1926 да — 599, 1949 да — 700, 1958 дә — 135, 1970 тә — 98, 1979 да — 61, 1989 да — 40, 2002 дә — 47 кеше.

**НАГИБА́РОВ** Вилен Романович (9.1.1935, Украина ССРның Каменск р-ны Рашково утары — 9.10.1977, Белоруссия ССР Минск ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1972), проф. (1973). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация ин-тында эшли. 1964–71 дә СССР ФАнең Физика-техника ин-тында, 1971 дән Казан пед. ин-тының физика каф. мөдире һәм бер үк вакытта, 1972 дән, проректоры. 1976–77 дә Белоруссия ССР ФАнең Каты җисемнәр һәм ярымүткәргечләр физикасы ин-тында лаб. мөдире. Хезмәтләре нәсызыкча һәм когерент оптикага, магнитик квант акустикасына, радиоспектроскопиягә карый. Н. магнитик квант акустикасы нигезләрен эшли; *яктылык кайтавазы* күренешен (У.Х.Копвиллем б-н бергә, 1962), модуляцияле оптик кайтаваз спектроскопиясен алдан фаразлый. Фотон кайтавазын ярсытуның кинетик алымын эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Световое эхо на парамагнитных ионах // Физика металлов и металловедение. 1963. Т. 15, № 2 (авторда ш); Теория формы линий оптического и микроволнового поглощения // Физика твёрдого тела. 1963. Т. 5, № 10 (автордаш); Световое эхо в рубине // Физика твёрдого тела. 1972. Т. 14, № 6 (автордаш); Acoustic superradiance [review] // Advances in Molecular Relaxation Processes. 1976. V. 8, № 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НАГО́РНАЯ** Мәрьям Әхмәдулла кызы (11.5.1932, Томск ш.), педагог, хокук белгече, хокук фән. д-ры (1991), проф. (1994). Томск

ун-тын тәмамлый (1955). 1955–57 елларда «Красное Знамя» г-тасы (Томск) редакциясе хезмәткәре. 1957–59 да — Ерак Көнчыгыш хәрби округы штабының Тыл идарәсе, 1959–62 дә Хабаровск крае балыкчылык кулланучылар берлеге күмәртәле сәүдә базасы юрисконсульты. 1962–71 дә хезмәт ияләре депутатлары советының Хабаровск шәһәре Индустриаль р-ны башкарма ком-ты секретаре. 1971–76 да Хабаровск, 1976–91 дә Горький югары партия мәктәпләре, 1991–92 дә Түбән Новгород социаль-сәяси ин-ты укытучысы. 1992 дән Түбән Новгород ун-тында, дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы (1994 кә кадәр), конституцион һәм административ хокук (1994–97) кафедралары мөдире. Хезмәтләре дәүләт хокукы, административ, конституцион хокук, генеалогия мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Планирование работы местных Советов. М., 1977; Информация в практике работы местных Советов. М., 1986; Конституционное право. Н.Новгород, 1998; Родословная Казаковых (XVI–XXI века). Н.Новгород, 2002 (автордаш).

*Е.Б.Долгов.*

**НАГО́РНЫЙ** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 205 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (завод хуҗасы В.П.Шелашниковның крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; селитра з-дында эшли. 20 йөз башында Н.да земство мәктәбе (1892 дә ачыла), 2 су тегермәне, май язу з-ды була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 915 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кичү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 350, 1889 да — 538, 1897 дә — 746, 1910 да — 855, 1926 да — 914, 1938 дә — 776, 1949 да — 643, 1958 дә — 528, 1970 тә — 455, 1979 да — 337, 1989 да — 191, 2002 дә — 203 кеше.

**НАГО́РНЫЙ** посёлогы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 76 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1920–30 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1949 да — 203, 1958 дә — 126, 1970 тә — 161, 1979 да — 136, 1989 да — 76, 2002 дә — 78 кеше.

**НАГУЕ́ВСКИЙ** Дарий Ильич (26.10.1845, Подольск губ. Орлово а. — 9.1.1918, Казан), филолог, борынгы классик филол. д-ры (1883), 1870 елда Новороссийск ун-тын (Одесса) тәмамлый. Анда Ф.А.*Струве* һәм В.Н.Юргевич кебек профессорлар җитәкчелегендә классик филология б-н шөгыльләнә. 1870–83 тә Рига гимназияләрендә латин теле һәм география укыта. 1883–1914 тә Казан ун-тында: ординар проф. (1883–1908), атказ. ординар проф. (1908–18), 1886 дан Нумизматика музее директоры. Хезмәтләре рим сатирасына (Ювенал, Гораций), Вергилий иҗатына карый.

Х е з м.: Библиография по истории римской литературы в России с 1709 по 1889 год. К., 1889; «Энеида» Вергилия. К., 1891.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

*И.А.Новицкая.*

**НАГУМА́НОВ** Дмитрий Ногман улы (12.12.1950, Киров өлкәсенең Сосновка ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1972). 1972–75 елларда ТАССР Финанс министрлыгында өлкән ревизор, 1975–77 дә өлкән икътисадчы. 1977–89 да халык депутатларының Казан шәһәре Киров р-ны советы башкарма ком-тының финанс бүлеге мөдире. 1989–90 да ТР финанс министры урынбасары, 1990–96 да — министры. 1996–99 да Казанның Идел буе р-ны хисап-касса үзәге башлыгы. 1999–2006 да Татарстан агросәнәгать банкының идарә рәисе. 2006 дан Татфондбанк идарәсе рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**НАДАНЛЫКНЫ́ БЕТЕРҮ́** (ликбез), 1920–30 елларда СССРда хөкүмәт һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан уздырылган пед. һәм адм. чаралар комплексы. 1897 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, Казан губернасында укый-яза белү дәрәҗәсе 9 яшьтән өлкәнрәкләрдә: русларда — 20%, татарларда — 14% (ана телендә) һәм 3% (рус телендә) тәшкил итә. 1917 гә укый-яза белү дәрәҗәсе күтәрелә, ләкин, гомумән алганда, югары булмый. Илдә гомуми укый-яза белүне күтәрү буенча кампания башлануга РСФСР ХКС ның 1919 ның 26 декабрендә кабул ителгән «РСФСР халыклары арасында укый-яза белмәүне бетерү хакында» декреты башлангыч була, аның нигезендә өлкәннәрне гомуми укырга-язарга өйрәтү мәгариф органнарына, авыл һәм шәһәр мәктәпләренә йөкләнә. 1920 нең 19 июнендә наданлыкны бетерү буенча Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (ВЧК) оештырыла, аңа өлкәннәр өчен мәктәпләрдә (ликбез пунктларында) укудан баш тарткан өчен административ һәм җинаять кысаларында эзәрлекләү хокукы бирелә. 1920–21 дә ТАССРда якынча 350 шундый пункт эшли; аларда 200 меңнән артык кеше укый. 1921–22 еллардагы ачлык һәм 1922 дә ВЧК таркатылу сәбәпле, ТАССРда наданлыкны бетерү эшчәнлеге туктатылып тора. НЭП кертелү аркасында мәгарифне финанслау кыскартыла, гомуми белем бирү мәктәпләре кими; укый-яза белмәүчеләрнең саны мәктәпләрдә укымаган балалар хисабына арта. 1923 тән өлкәннәрне һәм яшүсмерләрне укырга-язарга өйрәтү оешмалары б-н Бөтенсоюз «Бетсен наданлык» җәмгыятенең Татарстан бүлеге җитәкчелек итә. Өлкәннәр өчен дәреслекләр комплекты чыгарыла (татар телендәге күпчелек дәреслекләрне М.Х.*Корбангалиев* төзи). Н.б. кампаниясе барышында идеологик мәсьәләләр дә хәл ителә. Әлифбалар, уку китаплары аша коммунистик идеология, атеизм пропагандалана, рев-циягә кадәрге Россиягә тискәре мөнәсәбәт формалаштырыла. 1920 еллар ахырына ТАССР мәктәпләрендә һәм ликбез пунктларында ел саен 350 мең кеше укый. Шәһәрләрдә сәнәгать пр-тиеләре эшчеләрен мәҗбүри рәвештә профсоюз оешмалары укыта; комсомол һәм пионер оешмаларының да үз ликпунктлары була. Шуңа карамастан, олыларның укый-яза белү дәрәҗәсе 1929 да 50% тан артмый.

1930 елларда гомуми наданлыкны бетерү мәдәният өлкәсендә мөһим бурычларның берсе буларак билгеләнә. 1929 да үзешчән җәмәгать курслары һәм мәктәпләре «ликпунктчылык» буларак гаепләнә, 1931 дә «Бетсен наданлык» җәмгыяте таркатыла. Н.б. программалары дәүләт тарафыннан финанслана башлый. Укыту авыл башлангыч мәктәпләре җирлегендә, расланган программалар буенча алып барыла һәм 2–3 ел дәвам итә. 1930/31 уку елында балаларга мәҗбүри гомуми белем бирүне гамәлгә кертү нәтиҗәсендә СССРда укый-яза белү дәрәҗәсе тиз үсә башлый. ТАССРда 1928–32 дә татар язуы системасы латин шрифтына — *яңалиф*кә, 1939 да — кириллицага күчү сәбәпле, бурычлар катлаулана, гарәп алфавитында укый-яза белүчеләрне яңадан укытырга туры килә. Татар мәктәпләре программасына, уку-язу һәм арифметикадан тыш, рус телен өйрәтү дә керә. 1920–30 елларда Н.б. кампаниясе кысаларында ТАССРда барлыгы 1800 меңнән артык кеше укытыла. 1938 дә СССРда, шул исәптән ТАССРда да наданлыкның бетерелүе турында игълан ителә. Ләкин, 1939 елгы халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, РСФСРда өлкәннәрнең укый-яза белмәү дәрәҗәсе якын-






1. «Бетсен наданлык» җәмгыятенең әгъзалык билеты тышлыгы; 2. Наданлыкны бетерү дәресендә. 1922. Казанның Болак арты районы.

ча 20% тәшкил итә. 1939 дан, Бөек Ватан сугышы башланганчы, олыларны укыту программасы яңадан финанслана. Сугыштан соңгы чорда, 1955 кә кадәр, өлкәннәрне укырга-язарга өйрәтү халык мәгарифе оешмалары вазифасы булып кала һәм мәктәпләр каршында шәхси формада алып барыла, әмма махсус программасыз һәм дәреслекләрсез укытыла. Ш.у.к. *Культура революциясе*.

*Әд.:* К у м а н ё в В.А. Социализм и всенародная грамотность. Ликвидация массовой неграмотности в СССР. М., 1974; Г а р и п о в а З.Г. Культурно-просветительская работа в Татарии в годы первой пятилетки (1928–32 гг.). К., 1985; М у р т а з и н а Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов на примере Республики Татарстан. К., 2002. *Е.В.Липаков.*

**НАДЕ́ЖДИНО** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сулы елгасының (Димнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 14 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да башлангыч мәктәпләр эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 310 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 147, 1889 да — 230, 1910 да — 408, 1920 дә — 358, 1926 да — 409, 1938 дә — 131, 1949 да — 296, 1958 дә — 226, 1970 тә — 195, 1979 да — 138, 1989 да — 45, 2002 дә — 32 кеше.

**НАДЕ́ЖДИНО** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 164 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 429 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 396, 1897 дә — 737, 1908 дә — 882, 1920 дә — 691, 1926 да — 718, 1938 дә — 409, 1958 дә — 170, 1970 тә — 173, 1973 тә — 181, 1989 да — 169, 2002 дә — 194 кеше.

**НАДЕ́ЖДИНО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 249 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Ия исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 511,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 27 ир-ат; 1859 да — 187, 1897 дә — 371, 1908 дә — 384, 1920 дә — 319, 1926 да — 400, 1949 да — 344, 1958 дә — 305, 1970 тә — 228, 1979 да — 217, 1989 да — 259, 2002 дә — 256 кеше.

**НАДИ́ЕВ** Гадел Фирад улы (15.6.1964, Казан), радиоэлектроника өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2001), ТРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2007). 1987 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1992–96 да Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында), радиоэлектрон һәм телекоммуникацион системалар каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре мобиль коммуникацион системаларда сигналларны эшкәртү-алмашу модельләренә һәм алымнарына, мәгълүматны оптимальләштерүгә карый. Н. очраклы нәгаусс сигналларның яңа ихтималый модельләрен эшли; нәгаусс комачаулыклар комплексында күбәлементлы очраклы сигналларны комачауга тотрыклы итү алымнарын тикшерә.

Х е з м.: Оптимальный приём многопозиционных сигналов при комплексе шумовых и импульсных помех с произвольными флуктуациями // Радиотехника. 1990. № 12 (автордаш); Многоотсчётная совместная обработка многопозиционных сигналов при комплексе негауссовских помех // Радиоэлектроника. 1991. № 1 (автордаш); Марково-смешанные полигауссовы вероятностные модели случайных процессов // Телекоммуникации. 2000. № 1; Сотовая связь стандарта GSM: Современное состояние, переход к сетям третьего поколения. М., 2004 (автордаш). *Р.Г.Усманов.*

**НАДИ́ЕВ** Нургали Сибгатулла улы (20.8.1882, Пенза губ., Кузнецк өязе Сөләй а. — 21.6.1940, Казан), педагог. 1894 елдан «Касыймия» мәдрәсәсендә укый, 1904 тә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1904 тән Уфа губернасының рус-татар уч-щеләрендә укыта. 1913 тән Оренбург земство татар әзерлек мәктәбе (татар яшьләрен гимназиягә керергә әзерли) директоры, бер үк вакытта «Хөсәения» мәдрәсәсендә рус теле укыта. 1919 дан Татар халык мәгарифе ин-тында, 1921–24 елларда М.*Җәлил* аның шәкерте була. 1925 тән Татар пед. техникумында, бер үк вакытта, 1928–29 да, ТАССР Мәгариф халык ком-тының Академик үзәге рәисе урынбасары. 1930 дан Казан пед. ин-тының пед. каф. мөдире, 1938 дән Татарстан фәнни-тикшеренү ин-тында өлкән фәнни хезмәткәр. 1904 тә Д.Дефоның «Робинзон Крузо маҗаралары» китабын татар теленә тәрҗемә итеп бастыра. Рус-татар уч-щеләре һәм яңа ысуллы мәдрәсәләр өчен Н. тарафыннан төзелгән «Россия тарихы» уку ярдәмлеге 1908–17 дә 5 тапкыр бастырыла. Татар телендә педагогика буенча беренче совет уку курсын («Педагогика конспекты», 1920), 1920 елларның 1 нче яртысында — татар совет башлангыч мәктәбе укытучылары өчен программа һәм китаплар җыелмасын әзерли.




Г.И. Надрюков.

Х е з м.: Ибтидаи мәктәптә хисап укыту ысуллары. Оренбург, 1918.

*Әд.:* Х а н б и к о в Я.И. История педагогики татарского народа. К., 1975.

**НАДРЮ́КОВ** Гали (Миңлегали) Ислам улы (25.10.1909, Оренбург губ. Варна а. — 23.11.1989, Казан), драма актёры, ТАССРның халык (1967), РСФСРның атказ. (1976) артисты. Троицк шәһәрендә уч-ще тәмамлый, 1935–37 елларда Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате ин-тында (ГИТИС) укый. Сәхнә эшчәнлеген 1930 да Троицк татар театрында башлый, 1931–33 тә — Свердловск шәһәрендә Урал өлкәсе татар-башкорт күчмә эшче театрында, 1933–34 тә — Чистай татар драма театрында, 1934–35 тә һәм 1936 дан — Татар акад. театрында, 1935–36 да Әстерхан татар драма театрында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Н.ның сугыш еллары тәҗрибәсе капитан Севастьянов, генерал Проценко («Безнең шәһәр егете», «Көннәр һәм төннәр», К.М.Симонов), дивизия командиры Харитонов («Диңгездәгеләр өчен», Б.А.Лавренёв) рольләрен башкарганда ачык чагылыш таба. Богатырёв («Бер төн», Б.Л.Горба-



Г.И. Надрюков Богатырёв ролендә («Бер төн», Б.Л. Горбатов).



Г.И.Н а д р ю к о в Госман Ганиевич ролендә («Күк капусы ачылса», Х.Вахит).

тов) ролендә актёр психол. тирәнлек һәм тормыш хакыйкате б-н аерылып торган образ иҗат итә. Н. башкаруында ялкау һәм җавапсыз Осип («Ревизор», Н.В.Гоголь), үз керемнәренә катнашы булмаган бар нәрсәгә карата ваемсыз, тәкәббер фабрикант Бардин («Дошманнар», М.Горький) рольләре үзенчәлекләре, социаль характеристика төгәллеге б-н сокландыра. Н. ш.у. комедия рольләрен дә уңышлы башкара: Галәви («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Госман Ганиевич («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Дәүләтбай («Кыз урлау», М.Кәрим) һ.б. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Иялова И. Г.Камал театры артистлары: Биографик белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980; Иялова И. Театр имени Камала. К., 1986.

*И.И.Илялова.*

**НАДЫ́ЙРОВ** Илбарис Нурислам улы (15.4.1925, Бөгелмә кантоны Түбән Надыйр а. — 20.8.2009, Казан), фольклорчы, филол. фән. канд. (1959), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1956 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында (1965 тән директор урынбасары, 1972–91 дә халык иҗаты секторы мөдире). Хезмәтләре татар халык җырларын һәм бәетләрен өйрәнүгә карый. «Халык һәм җыр: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык поэтик иҗаты» (1961) монографиясе авторы. РФ дә татарлар күпләп яшәгән урыннарга экспедицияләргә бару нәтиҗәсендә «Кыска җырлар (дүртьюллыклар)» (1976), «Йола һәм уен җырлары» (1980), «Тарихи һәм лирик җырлар» (1988) җыентыкларын нәшер итә. «*Татар халык иҗаты*» күптомлы татар фольклоры җыентыгының (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1989) фәнни җитәкчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Мәхмүтов Х. Җырга гашыйк галим // Казан утлары. 1985. № 4; Фәнни эзләнүләр юлында. К., 2000; Тюркологи современного Татарстана. М., 1997.

**НАДЫ́ЙРОВ** Фаикъ Газиз улы (4.11.1921, Бөгелмә ш. — 7.6.2012, Казан), журналист. 1940–43 елларда Казан авиация ин-тында укый, 1953 тә Мәскәү юридик ин-тын тәмамлый. 1943–44, 1946–48 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында, 1948–50 дә ВЛКСМның Казан шәһәр ком-тының 2 нче секретаре. 1950–60 та «Комсомолец Татарии» г-тасында мөхәррир урынбасары, мөхәррир; 1960–62 дә «Советская Татария» г-тасында мөхәррир урынбасары. 1962–82 дә ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты рәисе. 1984–89 да ТАССР Журналистлар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе. ТР Журналистлар берлеге бүләге лауреаты (2003).

**НАДЫ́ЙРОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Надыйров волосте старшинасы Надир *Уразмәтов* варислары. Чыгышлары б-н Адай авылыннан (хәзерге Кукмара р-ны). Казан ханнары Мөхәммәдәмин һәм Сафагәрәй идарә иткән чорда Н. нәселенә хәзерге ТР терр-ясенең көньяк-көнчыгыш тарафындагы җирләрне биләү хокукы биргән тарханлык ярлыклары бүләк ителә. Самара губернасы Бөгелмә өязенең Яңа Нәдер һәм Яңа Кәшер авылларында (хәзерге Әлмәт р-ны) яшиләр. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышы чорында хөкүмәткә каршы күтәрелешләрне бастыруда катнашканы өчен баш старшина Йосыф Н.ка прапорщик чины (1776), аның улы Монасыйпка 1787 дә поручик чины бирелә. Икесе дә алтын медаль һәм кылыч б-н бүләкләнә. 18 йөздә — 20 йөз башында Н. нәселенең күп кенә вәкилләре Әлмәт төбәгендә күренекле дин эшлеклеләре булалар. 18 йөз ахырында Н. нәселенең дворянлык хокуклары кайтарыла.

*Әд.:* Әхмәтҗанов М. Татар шәҗәрәләре. К., 1995; Новиков В.А. Сборник материалов для истории Уфимского дворянства. Уфа, 1879; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**НАДЫ́СЕВА** Анна Алексеевна (18.7.1920, Зөя кантоны, хәзер Кама Тамагы р-ны Тәмте а. — 20.1.2006, шунда ук), агроном, кыр белгече, селекционер. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1944). 1946–75 елларда Татарстан җиләк-җимеш тәҗрибә станциясендә өлкән фәнни хезмәткәр. Каен җиләгенең «Татарстан», кура җиләгенең «Теньковская ранняя» һәм «Юбилейная» сортлары авторы. Хезмәтләре җиләк культуралары сортларын яхшыртуга карый. Н. Татарстан җиләк-җимеш питомникларында кара карлыган һәм кура җиләгенең элгәрләрен уңышлырак һәм тотрыклырак сортлар б-н яңарта. Кара карлыган өчен ашламалар системасын эшли һәм гамәлгә кертә.

Хезм.: Система удобрений для чёрной смородины // Тр. Татар. респ. с.-х. опытной станции. 1961. Вып. 1; Селекция земляники и малины // Тр. Татар. респ. с.-х. опытной станции. 1969. Вып. 2; Лучшие сорта и формы ягодных культур для Татарии // Новое и прогрессивное в садоводстве. К., 1970.

*В.А.Наумов.*

**«НАЁМЩИК»**, музыкаль драма (Т.*Гыйззәт* пьесасы, 1928, С.*Сәйдәшев* музыкасы, 1928). Татар акад. театрында спектакльнең беренче куелышында (1928) төп рольләрне С.Айдаров (Батырҗан), Р.Кушловская (Гөлйөзем) башкара, режиссёр-куючы С.*Вәлиев-Сульва*, дирижёры С.Сәйдәшев була. 1920 елларда татар муз. театры сәнгатендә милли музыка театры үсешенә этәргеч ясаган иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе санала. «Н.»ның музыкасы яңалыгы б-н аерылып тора. Т.Гыйззәт пьесасы сюжетына таянып (вакыйга Россиядә крепостнойлыкны бетерү чорында бара), С.Сәйдәшев татар халык музыкасы традицияләрен Европа һәм рус классик музыкасы б-н берләштерә. Биредә музыка авторлар фикеренең сәнгатьчә гәүдәләнешен, вакыйгалар барышын, образлар үсешен сурәтләү чарасы булып тора. Драма зур күләмле хор чыгышлары, хореографик сюиталары, оркестр эпизодлары б-н аерыла. Геройларның рухи дөньясы арияләрдә, ансамбль, җыр һ.б. вокаль номерларда нык индивидуальләштерелеп ачыла. «Н.»ның шуннан соңгы куелышлары Татар опера һәм балет театрында гамәлгә ашырыла (1948, 1990).



«Наёмщик» спектакленнән күренеш. Татар акад. театры. 1930.



«Наёмщик» спектакленнән күренеш (Батырҗан ролендә — С.Х.Айдаров, Гөлйөзем — Г.М.Кайбицкая). Татар акад. театры. 1928.

*Ф.Ш.Салитова.*

**НАҖА́Р** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,9 *км*, бассейнының мәйданы 31,9 *км*². Можга калкулыгы буйлап Әгерҗе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Никольский посёлогыннан 1 *км* көнбатыштарак, тамагы Наҗар авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Н.ның 0,8 дән алып 4 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,65 *км/км*². Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь урталарында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**НАҖА́Р** елгасы, к. *Урдалы*.

**НАҖА́Р** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 32 *км* көньяктарак, Иж елгасы

буенда. 2010 елда 99 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1646 дан алпавыт *Яушевлар* биләмәсе буларак билгеле. 17 йөз — 18 йөз башы чыганакларында Нажарбаш исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөзнең 2 нче чирегендә Тәфкилевләр нәселенең шәхси милкенә күчә, 19 йөздә дворян *Алкиннар, Моратовлар*, кенәз *Чанышевларныкы* була. Халкы игенчелек, итек тегү, агач әзерләү, сал агызу, тарантас ясау б-н шөгыльләнә; *Тирсә крәстияннәре кузгалышында* һәм Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышында актив катнаша. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, татар-рус земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 660,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Тирсә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерже, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерже, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1762 дә — 163, 1858 дә — 395, 1887 дә — 363, 1920 дә — 709, 1926 да — 550, 1938 дә — 527, 1958 дә — 271, 1970 тә — 213, 1989 да — 137, 2002 дә — 96 кеше.

**НАЗА́РОВ РАЙОНЫ́**, *Красноярск краеның* үзәгендә урнашкан. Мәйданы — 4,2 мең *км²*. 1924 елда оештырыла. Үзәге Назарово ш. Халкы — 23225 кеше (2012), 484 татар (2002). Татарлар тупланып Дорохово, Сохновка, Ельник, Югары Ададым, Түбән Ададым, Московка, Медведск, Урта Берёзовка авылларында, Преображенский посёлогында яшиләр.

**НАЗИ́МОВ** Пётр Сергеевич (12.11.1851, Мәскәү губ. Серпухов ш. — 14.12.1901, Казан), математик, саф математика д-ры (1885). 1873 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү һәм Ярославль гимназияләрендә, Варшава (1886 дан) һәм Казан (1889 дан) ун-тларында укыта, саф матем. каф. профессоры (1897 дән). Хезмәтләре саннар теориясенә, югары алгебрага, дифференциаль тигезләмәләр теориясенә, аналитик геометриягә, нәевклид геометриягә, чагыштырмалылык теориясенә карый. Н. аерым чыгарылмалы дифференциаль тигезләмәләрне, эллиптик функцияләрнең саннар теориясендә кулланылышын, берничә функциянең аерым чыгарылмаларыннан торучы кайбер тигезләмәләр классларын интеграллауны тикшерә, билгесез зурлыклар ниндидер төгәл шартларны канәгатьләндергән очракта иң кечкенә квадратлар алымын куллана, дифференциаль тигезләмәләр җыелмасының интегралы булуын исбатлый.

Соч.: Об интегрировании некоторых классов уравнений с частными производными нескольких функций при двух независимых переменных 1-го порядка. М., 1881; Введение в высшую геометрию. К., 1893; Геометрическое доказательство теоремы Ли // Изв. Казан. физ.-мат. об-ва. 1897. Т. 7.

**НАЗЫЙРӘ́** (гарәп.-фарсы. نظـيرة — өлге, үрнәк, охшатма), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Урта Азия, Идел буе халыклары әдәбиятында киң таралган, бүтән автор әсәренә җавап рәвешендә языла торган шигъри форма. Автор танылган әдипнең аңа кадәр язган билгеле бер сюжетын һәм төп персонажлар образларын ала да, үзенчә ачып биреп, башка әсәр иҗат итә. Кагыйдә буларак, төп тема, шигъри үлчәм, рифмага салу тәртибе, әсәрнең троп системасы саклана. Шулай итеп, Н. танылган әсәрнең фабуласы һәм образларына оригиналь үзенчәлекләр кертелгән каноник үзгәртү формасы булып тора. Бу мәгънәдә Н. — Шәрекъ поэзиясенең күчмә әдәби формасы. Татар әдәбиятында Н.гә Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Ш.Зәки, Г.Тукай (аның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» поэмасы урта гасырлар «Кисекбаш китабы» дини-дидактик әсәренә Н. булып тора), Ш.Бабич, Г.Камал һ.б. әдипләр мөрәҗәгать итәләр.

*Әд.:* Квятковский А. Поэтический словарь. М., 1966.


**НАЗЫ́ЙРОВ** Заһретдин Сәгадәт улы (1.9.1909, хәзер Семипалатинск өлкәсенең Усть-Каменогорск ш. — 1989, Алма-Ата), нәкышьче, театр рәссамы, бизәүче. Сәнгать-сәнәгать техникумын (Омск ш., 1930), Мәскәү сынлы сәнгать ин-тының квалификация күтәрү курсларында А.В.Лентулов һәм Б.В.Иогансонда театр рәссамнары бүлеген тәмамлый (1939). 1933 елдан Алма-Атада, Казакъстан Тарих музее рәссамы (1933–41), бер үк вакытта Пионерлар йорты укытучысы (1933–36). Уйгур театрының баш рәссамы (1939–40), «Аршын мал алан» һәм «Манан» спектакльләрендә декорацияләр эскизлары авторы (1940). 1941–53 тә Алма-Ата киностудиясе рәссамы, «Сугышчы улы» («Сын бойца»), «Авыл кызы» («Девушка из аула») һ.б. фильмнарның куючы-рәссамы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1939). Казакъстан Рәссамнар берлеген оештыручыларның берсе. Реалистик юнәлештә эшли («Турксиб», 1928; «Алмагачлар чәчәктә», 1961; «Балхаш», 1967; «Чик сакчысы байрак янында», 1969; «Казакъстан ССРның халык артисты Бадыров», 1973). ФАнең Геол. музее фасадындагы яшмадан уеп ясалган Казакъстан ССР гербы авторы. Казакъстан рәссамнары хезмәтләренең 1 нче Күчмә күргәзмәсендә (Семипалатинск–Петропавловск–Кызыл-Орда, 1928), Казакъстан ССР рәссамнары әсәрләренең 1 нче күргәзмәсендә (Мәскәү, 1944), Казакъстан рәссамнарының ел саен уздырылучы респ-ка күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре Алма-Ата Картиналар галереясында саклана. Медальләр, Казакъстан ССР ЮСның Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Нурмухаммедов Н.Б. Искусство Казахстана. М., 1970.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НАЛАСА́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Аты елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 698 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да 2 җамигъ мәчет, мәдрәсә, кредит ширкәте, 4 җил һәм 2 су тегермәне, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2677,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 314 ир-ат; 1859 да — 1415, 1897 дә — 1684, 1908 дә — 1894, 1920 дә — 1695, 1926 да — 1596, 1938 дә — 1351, 1949 да — 944, 1958 дә — 858, 1970 тә — 890, 1979 да — 785, 1989 да — 685, 2002 дә — 682 кеше.

**НАЛИ́М**, жумба (Lota lota), тәрәч балыклар семьялыгыннан. Евразиядә, Төньяк Америкада таралган. Тәрәч балыклар семьялыгыннан Европада бердәнбер төче су вәкиле. ТР терр-ясендә салкын чишмә сулы күп кенә елгаларда очрый. Суга баткан агач ботаклары, ташлар астында ялгыз яши. Озынлыгы 60 *см* га кадәр. 1,5 *кг* чамасы авырлыкта. Озынча гәүдәле, тиредә тирән утыручы циклоидсыман вак тәңкәләр б-н капланган, алар исә күп итеп лайла бүлеп чыгара. Башы киң, җәлпәк, өске казналыгына караганда аскысы кыскарак. Аркасы кара тимгелле зәйтүнсыман яшел, корсагы саргылт яисә соры төстә. Н. башка балыклардан икенче озын арка һәм койрык асты йөзгечләре б-н аерыла, аскы



казналыгында 1 һәм борын тишекләре янында 2 кечкенә мыекчыгы бар. Яшәвенең өченче елында җенси яктан җитлегә. Җирле ихтиофауна вәкилләреннән аермалы буларак, уылдыкны кышын чәчә. Абсолют үрчемлелеге — 300 меңнән 1 млн. га кадәр уылдык бөртеге. Эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Җәен аз хәрәкәтләнүчән яшәү рәвеше алып бара, эссе көннәрдә йокыга тала. Ике яшькә кадәрге вак Н. — су төбендәге төрле умырткасызлар, өч-дүрт яшьтәгеләр күбесенчә вак балыклар (кыртыш, ташбаш, алабуга) б-н туклана. Кәсәбәчелек объекты.

**НАМА́З** (фарсы نماز – көндәлек гыйбадәт), мөселманнарда кануни гыйбадәт; *ислам* динендә биш фарыз гамәлнең берсе. Н. вакытында укыла торган догаларның һәм башкарыла торган хәрәкәтләрнең һәрбер циклы (баш ию, тез чүгү) «рәкагать» дип атала. Н. уку тәртибе *Мөхәммәд* пәйгамбәр тарафыннан билгеләнгән һәм М. әш-Шәйбәни (805 елда вафат) кулы б-н язмача теркәлгән. Барлык догалар бары тик гарәп телендә укыла һәм мәзһәбкә бәйле рәвештә аз гына аерылырга мөмкин. Н. тәүлегенә 5 тапкыр: таң атканда, кояш чыкканчы — иртәнге намаз (әл-фәҗер), көндез — өйлә (әз-зоһер), кояш баер алдыннан — икенде (әл-гасыр), кояш баегач та — ахшам (әл-мәгъриб), кичен — ястү укыла, аны ялгыз да, җәмәгать б-н дә төрле урында укырга мөмкин. Җомга намазы (*җомга*) исә җәмәгать б-н мәчеттә укыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**НАМАЗЛЫ́К**, мөселманнарда кагыйдәләр б-н билгеләнгән догаларны башкару — *намаз* уку өчен җәелә торган келәм, кагыйдә буларак, аңа түбәсе исламның төп гыйбадәт-

ханәсе — *Кәгъбәгә* юнәлтелгән *михраб* (мәчет диварындагы куыш) а́ркасының схематик сурәте төшерелгән. Гадәттә, шәхси куллану өчен билгеләнә, әмма 3 яисә 5–6 кешелек Н.лар да була. Элек-электән Н.лар гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләре буларак та билгеле. Алар традицион рәвештә келәмчелек (ш.и. киез), тукучылык һәм *чигү* техникаларында эшләнә һәм бизәлә. Н.лар татарларның көнкүрешендә мәҗбүри кулланыштагы әйбер, алар, кунак бүлмәсе («ак як») интерьерының бизәнү әйбере буларак, түшәм б-н тоташмаган бүлмә тактасына (исарчык) да, тәрәзә араларындагы диварларга да эленә; намаз уку өчен файдаланыла торганнарыннан аермалы буларак, андый Н.лар аеруча купшы итеп бизәлә. Н.лар кәләшкә бирнә итеп әзерләнә; дини йола предметы буларак, алар аеруча кадерләп саклана һәм буыннан-буынга тапшырыла. Борынгыдан Н.лар бер төстәге (ак) һәм 2–3 төстәге (кызыл, зәңгәр, яшел, ак төсләр кулланып) җепләрдән буй-буй яисә шакмаклы итеп кулдан тукыла (нигездә, авыл осталары тарафыннан), бу очракта михраб сурәте төшерелми. Шәһәрдә яшәүче баерак татарлар Н.ларны чигү б-н бизиләр. Гадәттә, бер төстәге (яшел, аксыл көрән, куе зәңгәр, зәңгәр, куе кызыл) ефәк, парча, юка постау тукымалар кулланыла; тискәре ягына, кагыйдә буларак, киҗе-мамык тукыма тегелә. Чигешләр тамбурлы, шома, элмәкләп чигү ысуллары б-н башкарыла. Чигү композициясе симметрияле була. Н.ның үзәк өлеше П сыман тар кайма б-н әйләндереп алына; ул киль рәвешендә уксыман яисә ярымтүгәрәк булып очлана. Ян-яктагы кайма бизәге җәйләп кына өске өлештәге бизәлешкә күчә. Аның уртасына гадәттә чәчәк бәйләме — «Тормыш агачы» (кайчак ул канатларын җәйгән кош рәвешендә эшләнә) яки бизәкләр б-н тутырылган чәчәк таҗлары чигелә.

Үзәктәге бизәкнең ике ягына симметрияле итеп кечерәк чәчәк бәйләмнәре урнаштырыла, кайвакыт Н.ның өске өлеше тоташ үсемлек бизәкләре б-н тутырыла. Ян кайма-



Намазлык. Киҗе-мамык тукыма. Тамбурлы чигү. 20 йөз башы. Яңа Чишмә районы Зирекле авылының Халык иҗаты һәм көнкүреше музее.



Намазлык. Ефәк. Тамбурлы чигү. 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ларда чәчәкләр, яфраклар, җимешләрдән сыгылып торучы ботак күренеше алга чыга. Борынгы Н.ларда (19 йөзнең 2 нче яртысына караган берничә Н. сакланып калган) борынгы төркиләр һәм Идел буе болгарлары сәнгатеннән үк килә торган архаик лотос, пальметта, лалә, спираль мотивлары чигелә; 19 йөз ахырында Н.ның буеннан буена билгеле бер эзлеклелек б-н урнаштырылган чәчәк бәйләмнәре мотивлары килеп керә. 20 йөздә чигүле Н.ларның сәнгати-стиль бердәмлеге югала, алар йорт шартларында кул һөнәре б-н шөгыльләнүчеләр тарафыннан гына иҗат ителә. 19 йөзнең ахырында — 20 йөзнең башында бизәкле киез Н.ларның Кырым татарларында кулланышта булуы мәгълүм (к. *Киез*, *Келәмчелек*). Совет чорында Н.лар җитештерү келәм туку сәнгатеннән читләштерелә. 20 йөз ахырыннан Н.лар, гамәли бизәлеш сәнгате әсәрләре буларак, проф. рәссамнар иҗатында яңадан тергезелә, аларның кайберләре (Н.Х.Кумысникова, «Туран» милли мәдәният үзәге фонды» ҖЧҖ осталары) Н.ларның яңа төрен — каюлы күннән эшләнгәннәрен (к. *Каюлы күн*) гамәлгә кертә, әмма Н.ларның иң күп өлеше Төркия, Иран һ.б. мөселман илләреннән кайтарыла.

*Әд.:* В а л е е в Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; ш у л у к. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НАМӘ́** (фарсы نامه, китап, документ, хат, мөрәҗәгать һ.б.), әдәби әсәр, тарихи-мемуар, сәяси хезмәтләр, проза яисә шигырь китапларының кушма исемнәре составында килә (мәс., Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Гаттарның «Панднамә»се, Низамелмөлекнең «Сиясетнамә»се, Бабурның «Бабурнамә»се). Мондый мисаллар татар әдәбиятында да бар (Харәзминең «Мәхәббәтнамә»се, Г.Чокрыйның «Хаҗнамә»се, Г.Утыз Имәнинең «Горбәтнамә»се һ.б.).

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**НАМЁТКИН** Николай Сергеевич (3.8.1916, Мәскәү — 24.11.1984, шунда ук), химик-органик, химия фән. д-ры (1956), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1962), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1966). С.С.*Намёткинның* улы. 1942 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1944–58 дә Мәскәү нефть ин-тында, проф. (1956). 1958 дән СССР ФАнең Нефтехимик синтез ин-тында, 1963 тән директор. Хезмәтләре нефтехимик синтезга, нафтеннарга һәм кремнийорганик кушылмаларга карый. Н. нафтен к-таларының төзелешен һәм үзлекләрен, аларны ацетиленлы углеводородлар б-н алкиллауны өйрәнә. Югары молекуляр кушылмаларның яңа классын — поликремнийуглеводородларны таба. Ярым үткәрүчән полимер мембраналарны һәм аларны сәнәгатьтә куллану мөмкинлекләрен тикшерә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Октябрь Революциясе ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нафтеновые кислоты и продукты их химической переработки. М., 1982 (автордаш); Пиролиз смесей изобутана с этаном // Нефтехимия. 1984. Т. 24, № 2 (автордаш); Термический распад дибутилсульфида при температурах выше 500°C // Нефтехимия. 1985. Т. 25, № 4 (автордаш).

*Әд.:* В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**НАМЁТКИН** Сергей Семёнович (21.6.1876, Казан — 5.8.1950, Мәскәү), химик-органик, СССР ФА академигы (1939; 1932 дән мөхбир әгъза), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1947). 1902 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1911 дә, мәгариф министрының реакцион сәясәтенә каршылык йөзеннән, ун-ттан китә. 1912 дән — Югары хатын-кызлар курслары, 1919 дан — 2 нче Мәскәү ун-ты (1919–24 тә ректоры), 1930 дан — Мәскәү нечкә химик технол. ин-ты, 1938 дән Мәскәү ун-ты профессоры. Бер үк вакытта, 1939–48 дә — СССР ФАнең Янучан казылмалар ин-ты, 1948 дән Мәскәү нефть ин-ты директоры. СССР ФАнең Әзәрбайҗан ф-лы Президиумы рәисе (1940–43). Хезмәтләре органик химиягә, нефть химиясенә һәм технологиясенә карый. Н. төрле класс углеводородларын тикшерә, күп кенә бициклик углеводородларның төзелешен ачыклый. 2 нче төр камфен төркемләнешен (Намёткин яңадан төркемләнеше) ача, камфенның күп кенә саф кушылмаларын синтезлый һәм үзлекләрен өйрәнә. СССРның төрле чыганакларыннан алына торган нефть һәм табигый газның составын һәм үзлекләрен тикшерә. Нефть продуктларында чиксез углеводородларны билгеләү методикасын, нефтьне күкерттән арындыру юлларын эшли. Чиксез углеводородларны гидро- һәм дегидрополимерлаштыру каталитик реакциясен ача. Нефтехимик синтезның күп кенә мәсьәләләрен: нефть фракцияләрен каталитик ароматлаштыру, хлорлы кушылмаларны һәм спиртларны нефть углеводородлары нигезендә синтезлау, парафинны альдегидларга һәм спиртларга кадәр турыдан-туры оксидлау, юу чаралары эшләп чыгару һ.б.ны хәл итүдә актив катнаша. Н. мотор ягулыклары һәм майлау матдәләренең сыйфатын яхшыртучы өстәмәләрне өйрәнә, аларга фәнни-техник классификация бирә; хуш исле матдә-

ләр, үсемлекләрнең үсешен тизләтә торган матдәләрне синтезлау өлкәсендә эшләр алып бара. СССРда беренче булып, Н. нефть химиясенең системалы курсын әзерли һәм укый, шуның нигезендә «Нефть химиясе» («Химия нефти», 1–2 кисәкләр, М., 1932–35) монографиясен нәшер итә. СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1943, 1949). Ленин ордены, тагын өч орден, медальләр б-н бүләкләнә.


С.С. Намёткин.

Х е з м.: Собрание трудов: В 3 т. М., 1954–55.

*Әд.:* Сергей Семёнович Намёткин / АН СССР // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М.–Л., 1946. Вып. 2; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

**«НАМУСЛЫ́ ХЕЗМӘ́Т ӨЧЕ́Н» МЕДАЛЕ́**, ТР Дәүләт бүләге. ТРның 2004 ел 24 март Законы б-н гамәлгә куела. Гражданнарга респ-каның дәүләт, социаль-икътисад һәм мәдәни үсеше өлкәсендә хезмәттәге югары казанышлары, ш.у. актив җәмәгать һәм хәйрия эшчәнлеге өчен бирелә. ТР Президенты тарафыннан тапшырыла. ТР Президентының 2004 ел 16 июнь һәм 25 ноябрь Указлары буенча медаль диаметры 32 *мм* лы түгәрәк рәвешендә көмештән эшләнә, уң ягы каймалана, уртасына нефть вышкасы, ике төзелеш краны, архит-ра капителе, КамАЗ автомобиле, ачып куелган китап сурәтләре урнаштырыла. Аскы өлешендә башаклардан тәкыя, ә өстә — түгәрәк буйлап «Хезмәткә дан — Слава труду» дигән язу, язу өстендә түгәрәк буйлап — тешле тәгәрмәч сурәте. Икенче ягында лавр ботагы, аның астында — номер. Медаль соры-яшел-ак-кызыл төсләрдәге муар тасма тарттырылган биш почмаклы кысага тоташа. Тасманың киңлеге 24 *мм*, һәр соры буйның киңлеге 8 *мм*, яшеле һәм кызылы — 3 *мм*, ак төстәге буй — 2 *мм*. Бүләккә 1815 кеше лаек була ( 2013).

*Е.Б.Долгов.*

**НАРА́Т** (Pinus), наратчалар семьялыгыннан мәңге яшел ылыслы агачлар, сирәк кенә куаклар ыругы. 100 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясындагы урманнарда һәм субтропик зонаның таулы өлкәләрендә таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төр — гади Н. (P. sylvestris) бар. Биеклеге 35 *м* га, кәүсәсенең диаметры 1 *м* га кадәр җитә. Тирәнгә китүче үзәк тамырлы һәм киң булып ян-якка таралган тамыр системасы яхшы үсеш алган. Ябалдашы җыйнак, яшь агачлар конуссыман, боҗрадагы ботаклары горизонталь рәвештә як-якка китә, үсә-үсә түгәрәк форма ала. Яшел яки күгелҗем ылыслар (яфраклар) бәйләме бәбәкләрдә утыра. Ылыслары тар, чәнечкеле (энәсыман), агачта 2–9 ел сакланалар. Сары яки кызгылт ата күркәчекләр агымдагы ел бәбәгенең төбендә урнашалар һәм күпсанлы тәңкәсыман серкәчләрдән торалар. Ана күркәчекләр, гадәттә, агач башында һәм үсүче бәбәкләр очында ялгыз яки төркем булып үсәләр. Орлыклары чикләвексыман канатчалы; икенче елны өлгерәләр. Н. орлыктан үрчи. Урман барлыкка китерүче төп токымнарның берсе. Идел, Кама, Вятка елга террасаларының комлы һәм балчыксыл комлы туфракларында нарат урманнарының аеруча зур массивлары саклана. Наратлыкларның гомуми мәйданы 180 мең *га* дан артык. Кама аръягында һәм Идел алдында күпләп үстерелә. Нык һәм җиңел сумалалы үзагачы торак һәм гидротехника төзелешендә, авиация һәм суднолар төзелешендә, агач җиһазлары җитештерүдә кулланыла. Сагызыннан (чәереннән) канифоль һәм скипидар алалар. Нарат урманнары мөһим санитар-гигиеник функция үти. Н. һаваны авыру барлыкка китерүче микроорганизмнардан саклаучы фитонцидлар бүлеп


Гади нарат.

чыгара. Н. бөресе какырык чыгару, бәвел кудыру һәм дезинфекция чарасы буларак кулланыла. Н. комнарны ныгытуда файдаланыла. Төп корткычлары — май коңгызлары, зур нарат филчеге, нарат ябалакчыгы һ.б. Сирәк кенә Себер Н.ы яки Себер эрбете (P. sibirica) үстерелә (к. *Эрбет паркы*).

**НАРА́Т** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 85 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кырыкмас елгасы буенда. 2010 елда 181 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Наратово, Сосново, Токуз исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә (1832 дә ачыла), мәктәп (1841), татар-рус земство мәктәбе (1904) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2193,7 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 546 кеше, 1890 да — 876, 1905 тә — 881, 1920 дә — 1126, 1926 да — 1071, 1938 дә — 991, 1949 да — 692, 1958 дә — 544, 1970 тә — 521, 1989 да — 289, 2002 дә — 243 кеше.

*Әд.:* М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

**НАРА́Т** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 9 *км* көнчыгыштарак, Сумка елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 81 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, урманчылык. 1988 дә нигез салына. Оештырылган көннән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1989 да — 100, 2002 дә — 104 кеше.

**НАРА́Т ГӨМБӘЛӘРЕ́** (Russula), ал гөмбәчәләр ыругыннан гөмбәләр төркеме. Чын *гөреҗдәләргә* охшаш, әмма сөтчел сыекчасыз. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Ак Н.г. яки ак гөреҗдә (R. delica) — иң күп таралган гөмбәләрнең берсе. Июльдән октябрьгә кадәр яфраклы һәм катнаш урманнарда еш һәм күпләп очрый. Зур төркемнәр хасил итеп үсә. Эшләпәсе кабарынкы, картайган гөмбәнең — бүрәнкәсыман, диаметры 20 *см* га кадәр, тонык, ак, кайвакыт сары-коңгырт тимгелле, кырыйлары аска таба бөгелгән. Кабыгы эшләпәсеннән купмый. Сабы кыска, түбәнге өлешендә аз гына тарая, тыгыз, ак төстә яки коңгырт. Йомшагы ак, сындырганнан соң төсе үзгәрми, хуш исле. Кара Н.г. яки кара гөреҗдә (R. adusta) июльдән октябрьгә кадәр яфраклы, ылыслы һәм катнаш урманнарда очрый. Төркем хасил итеп үсә. Эшләпәсенең диаметры 5–15 *см*, кабарынкы, өлгергән гөмбәнең бүрәнкәсыман, тонык соры төстә. Сабы тыгыз, кыска, эшләпәсе б-н бер төстә. Йомшагы ак, сындырганда башта алсу-соры, аннары кара, каты. Каралучан Н.г. (R. nigricans) июльдән октябрьгә кадәр ылыслы һәм яфраклы урманнарда очрый. Зур төркемнәр хасил итеп үсә. Эшләпәсенең диаметры 15 *см* га кадәр, башта кабарынкы, соңыннан үзәгендә батынкы, тонык ак төстә, ярылучан. Йомшагы тыгыз, ак, сындырганда башта кызара, аннары карала, хуш исле. Споралы порошогы ак. Сабының биеклеге 8 *см*, юанлыгы 2 *см* га кадәр, туры, тигез, ак төстә. Ак Н.г. һәм кара Н.г. ашарга яраклы. Каралучан Н.г. шартлыча ашарга яраклы. Бөҗәкләр б-н нык зарарлана.

**НАРА́Т ҖИЛӘГЕ́** (Vaccinium vitis-idaea), арчанчалар семьялыгыннан мәңге яшел куакчык. Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында таралган. ТР терр-ясендә ылыслы, катнаш һәм яфраклы урманнарда



үсә. 25 *см* га кадәр биеклектәге үсемлек, озын шуышма тамырчалы. Сабагы туры, тармаклы. Яфраклары вак, эллипссыман, итләч, өсте куе яшел, ялтыравыклы, асты ачык яшел, тонык, таркау көрән нокталы. Чәчәкләре аксыл-алсу, иенке чукларда, җиңелчә генә хуш исле. Җимеше — күп орлыклы, шарсыман ачык-кызыл җиләк.

Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Күбесенчә тамырчалардан үрчи. Җимеш һәм яфракларында органик к-талар, шикәр, дуплау матдәләре, C һәм P витаминнары, эфир мае бар. Җиләкләре татлы ашамлыклар әзерләүдә файдаланыла. Халык медицинасында яфрак төнәтмәсе бәвел кудыру һәм антисептик чара, бал б-н пешерелгән Н.җ. үпкә туберкулёзын дәвалауда кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

*Әд.:* Иванова Р.Г. Дикорастущие съедобные растения Татарии. К., 1988.

**НАРА́Т ЧЫПЧЫКЛАРЫ́** (Phylloscopus), әрәмә чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 30 дан артык төре билгеле, күпчелеге Евразиядә, берничә төре — тропик Африкада, Аляскада таралган. Татарстан терр-ясендә 8 төре бар. Яз Н.ч. (P. trochilus), чикерткә Н.ч. (P. collybita), чытырдавык Н.ч. (P. sibilatrix), яшел Н.ч. (P. trochiloides) респ-каның бөтен терр-ясендә, таллык Н.ч. (P. borealis) — төньяк районнарда, таң Н.ч. (P. inornatus) Казансу һәм Кесмәс елгалары үзәннәрендә көзге очып килү вакытында очрыйлар, кәрлә Н.ч. (P. proregulus) һәм коңгырт Н.ч. (P. fuscatus) — бик сирәк төрләр. Күчмә кошлар. Урманнарда, урман буйларында, аланнарда, болыннарда яшиләр. Гәүдәләре озынча, 10–14 *см* озынлыкта. Каурый катламы күпереп тора, коңгырт, асты аксыл яки саргылт. Койрыгы туры. Томшыгы зур түгел, нәзек, безсыман. Кайбер төрләренең күзләре астында ачык төстә сызык бар. Яшел Н.ч. башка төрләрдән канатларындагы аркылы аксыл сызык б-н аерыла. Ояларын яннан керә торган шарсыман формада җирдә яки куакларда коралар. Коңгырт-кызыл тимгелле 3–8 ак йомырка салалар. Н.ч. бер-берсе б-н бик охшаш, тышкы билгеләре буенча аларны кыр шартларында аеру мөмкин түгел диярлек, әмма сайраулары б-н бер-берсеннән аерылалар.

**НАРАТАСТЫ́** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ык елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 152 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1762 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1339,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 163, 1913 тә — 370, 1920 дә — 372, 1926 да — 317, 1938 дә — 389, 1949 да — 343, 1958 дә — 284, 1970 тә — 334, 1979 да — 235, 1989 да — 184, 2002 дә — 166 кеше.

**НАРАТАСТЫ́** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 49 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1719–22 еллардан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чаналар ясау б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Н.да су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 559,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 279, 1913 тә — 606, 1920 дә — 563, 1926 да — 439, 1938 дә — 238, 1949 да — 169, 1958 дә — 188, 1970 тә — 190, 1979 да — 145, 1989 да — 72, 2002 дә — 69 кеше.

**НАРАТАСТЫ́ УРМАНЫ́**, табигать тыюлыгы. Мөслим р-ны терр-ясендә Наратасты авылы янында. 1994 елда оештырыла. Мәйданы 468 *га*. ТРның Кама аръягы шартлары өчен уникаль, яхшы сакланган нарат урманы. Ык елгасы зур борылма хасил иткән урында, уңъяк ярының комсу утырмаларында урнашкан. 1 нче яруста — аерым агачларның яше 120 һәм күбрәк тә булган наратлар, 2 нче яруста чыршы, имән, юкә, каен үсә. Куаклардан — шомырт, кабар агачы, гөлҗимеш, миләш. Үлән капламында дала үсемлекләре, ш.и.



Наратасты урманы.

сүсән солыча (типчак) очрый. Н.у. терр-ясендә ял базалары, балалар өчен җәйге сәламәтләндерү лагерьлары урнашкан.

**НАРАТБА́Ш** (Equisetum), наратбашчалар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле, Австралиядән кала бөтен Җир шарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 9 төре бар. Кыр Н.ы (E. arvense), кышлаучы Н. (E. hyemale), саз Н.ы (E. palustre), болын Н.ы (E. pratense) һ.б. һәр җирдә очрыйлар; елга буе Н.ы (E. litorale), кытыршы тешле Н. (E. trachyodon) — сирәк төрләр. Сирәкләнгән урманнарда, кырларда, су буйларында, сазлы болыннарда үсәләр. 15–100 *см* биеклектәге үсемлекләр. Тамырлары озын. Бәбәкләрендә буын арасы һәм буыннары яхшы беленә, аларда исә бөжралап яфраклар урнашкан. Күзәнәкләренә кремнезём утыру сәбәпле, сабагы бик каты. Яфраклары вак, тәңкәсыман. Споралы һәм вегетатив бәбәкләре яшел. Споралы бәбәкләре апрель–июльдә чыга. Клоннар барлыкка китереп, күбрәк тамырчалардан үрчи. Н. корылыкны һәм урман янгыннарын яхшы кичерә. Әче туфракларны өстен күрә. Кыр Н.ы үләнендә алкалоидлар, сапонин, флавоноид, эфир майлары, кремний кис-тасы бар; халык медицинасында үлән төнәтмәсе ревматизмны дәвалаганда, бавыр һәм бәвел куыгы авырулары вакытында һәм кан туктату чарасы буларак кулланыла. Н. — авыр бетерелә торган чүп үлән. Саз Н.ы терлекләр өчен агулы. Тармаклы Н. (E. ramosissimum) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НАРАТЛЫ́** күле, Идел алды төбәгендә. Бола һәм Зөя елгалары субүләрендә, Буа р-ны Кабалан авылыннан 0,3 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Күлдән 100 *м* көнбатыштарак автомобиль юлы үтә. Су өслегенең мәйданы 0,48 *га*, күләме 39 мең $м^3$. Озынлыгы 100 *м*,



Наратлы күле.

иң зур киңлеге 80 *м*. Уртача тирәнлеге 0,81 *м*, иң зур тирәнлеге 1,1 *м*. Күл казанлыгы ясалма. Формасы калаксыман. Суы каты (6,5 *мг-экв/л*), болганчык, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, саргылт төстә. Гомуми минеральләшүе 147,7 *мг/л*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

**НАРАТЛЫ́** (Чалпы) елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*, бассейнының мәйданы 188,2 $км^2$. Елганың төп агымы Азнакай р-ны терр-ясендә, иң түбән агымы — Башкортстан Респ-касында. Елга башы Ирекле авылы янында, тамагы Азнакай р-ны Чалпы авылыннан 9 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Н.ның 1,9 дан 9,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, аеруча зурысы — Иске авыл (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,14 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 $л/с{\cdot}км^2$. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Җәйге чорда елганың түбән агымы еш кына кибә һәм тамагына кадәр су барып җитми. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,195 $м^3/с$. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Н. бассейнында суының гомуми күләме 3,8 млн. $м^3$ булган 8 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НАРАТЛЫ́** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 47 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Салкынсу елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1925 тә хәзерге Сарман р-нының Ләшәү-Тамак һәм Иске Кәшер авылларыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Кармалы р-нында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 73, 1938 дә — 178, 1949 да — 138, 1958 дә — 123, 1970 тә — 280, 1979 да — 96, 1989 да — 74, 2002 дә — 78 кеше.

**НАРАТЛЫ́** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 705 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Семёново авылы буларак билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, Н.да 2 су тегермәне, 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1222 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 452, 1897 дә — 414, 1908 дә — 713, 1910 да — 820, 1920 дә — 870, 1926 да — 788, 1938 дә — 729, 1949 да — 672, 1958 дә — 734, 1970 тә — 769, 1979 да — 719, 1989 да — 779, 2002 дә — 725 кеше.

**НАРАТЛЫ́К**, к. *Сосновый Бор, Тукай р-ны.*

**НАРАТЛЫ́К** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 36 *км* төньяктарак, Шушма елгасы бассейнында. 2010 елда 93 кеше (татарлар) яши. Урман хуҗалыгы; мунчала ясау цехы. Башлангыч мәктәп. Торак пункт буларак, 1996 ның 11 ноябрендә теркәлә. Халык саны: 2002 елда 88 кеше.

**НАРАТЛЫ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 50 *км* төньяк-көнбатыштарак, Илләт елгасы буенда. 2010 елда 182 кеше (татарлар) яши. Урман материаллары әзерләү, умартачылык б-н шөгыльләнәләр. Тулы булмаган урта мәктәп. 1989 да торак пункт буларак теркәлә.

**НАРАТЛЫКИЧҮ́** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 327 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1716 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, таш чыгару һәм таштан терлек абзары һ.б. корылмалар төзү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.дә почта станциясе урнаша, мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1611 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 162, 1858 дә — 410, 1870 тә — 462, 1884 тә — 584, 1906 да — 903, 1920 дә — 1078, 1926 да — 695, 1938 дә — 784, 1949 да — 430, 1958 дә — 342, 1970 тә — 471, 1979 да — 356, 1989 да — 314, 2002 дә — 329 кеше.

**НАРАТЪЕЛГА́** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 239 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да мәчет, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1947 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Мөслим волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 78 ир-ат; 1859 да — 657, 1897 дә — 942, 1908 дә — 1044, 1920 дә — 993, 1926 да — 787, 1938 дә — 800, 1949 да — 967, 1958 дә — 449, 1970 тә — 385, 1979 да — 297, 1989 да — 260, 2002 дә — 318 кеше.

**НАРБЕ́КОВ** Василий Андреевич (1.8.1862, Владимир губ., Муром өязе Вареж а. — ?), чиркәү археологы, сәнгать белгече, христиан теологиясе магистры (1887), чиркәү тарихы д-ры (1897). Владимир руханилар семинариясен (1884), аннары Казан руханилар академиясен (1887) тәмамлый, шунда ук эшли. Шул ук академиядә (бүленеп: 1888 елда Полтава руханилар семинариясендә), 1899–1921 дә литургика һәм чиркәү археологиясе кафедрасында, бер үк вакытта, 1911 дән, чиркәү археологиясе һәм чиркәү сәнгате кафедрасында проф. (1897). Хезмәтләре Россиянең төрле чорларында һәм төрле төбәкләрендә православие гыйбадәтенә, чиркәү сәнгатенә (нәкышь, чигү, зәркәнчелек) карый.

Х е з м.: Номоканон константинопольского патриарха Фотия с толкованиями Вальсамона. К., 1899; Орфей в древнехристианском изобразительном искусстве // Православный собеседник. 1900. Ч. 2; Южнорусское религиозное искусство XVII–XVIII вв. // Православный собеседник. 1903. Ч. 1; Костромские церковные древности // Православный собеседник. 1913. Ч. 1–2.

*Е.А.Липаков.*

**НАРДУГА́Н**, кышкы кояш торгынлыгы бәйрәме. Керәшен татарлар, мишәрләр, нагайбәкләр, ш.у. Вятка губернасының Бистә һәм Глазов өязләрендә яшәүче мөселман татарлар арасында киң таралган була. Бәйрәм итү төрлечә уздырыла. Казан татарлары Н.ны бәйрәм итмиләр диярлек. Бәйрәм атамасы аның нигезенә («нар» — «ут, ялкын», «дуган» — «туган») Кояшка борынгыдан ук килә торган иң бөек алла (Тәңре) итеп табыну идеясе салынуны раслый. Н. вакытында, көн иң кыска булып, Кояш еракка — көньякка киткәндә, борынгы төркиләр гыйбадәт кылалар һәм югары алланың тизрәк кайтуын сорыйлар. Керәшеннәрдә «Н.» атамасы иске стиль б-н 25 декабрьдән 5 гыйнварга кадәрге вакытка туры килә. Киенеп-ясанып йөрүне алар «Н. булып җөрү», «Н. чабу», «Н. бабалары» дип йөртәләр. «Н.» термины мишәр татарлар яшәгән берничә авылда да теркәлә. Мишәрләрнең күбесе әлеге бәйрәмне Раштуа, Раштва (Рождестводан үзгәртелгән) дип атыйлар. Урта Идел һәм Урал алдында яшәүче башка халыкларда әлеге термин очраклы рәвештә генә, алар керәшен татарлар, мишәрләр б-н тыгыз бәйләнештә көн иткән төбәкләрдә генә күзәтелә. Чуашларда бәйрәмнең ике атамасы өстенлек итә: төньяк районнарда — «сурхури» («сарык аягы»), көньякта — «раштав»; мариларда — «сарык аягы»; удмуртларда бердәм атама булмый, әмма святки (дини бәйрәм) вакыты гомумән алганда «вожодыр», «инвожо» (мордва-мукшыларда — «роштувань ши», мордва-эрзяларда — «роштувань чи») дип йөртелә. Вятка губернасы Бистә өязе татарлары кышкы кояш торгынлыгы б-н бәйле йолаларны «чибитья», Вятка губернасы Глазов өязе татарлары удмурт сүзе б-н «вожо» («божо») дип атыйлар.

Бәйрәмнең төп элементлары матур итеп киенеп өйдән өйгә йөрү, тиешле җырлар башкарып, йөзекләр б-н багу (йөзек салу), язмыш, кияү буласы кеше һ.б. хакында күрәзәлек итү була. Киенеп-ясанып йөрүләр барлык керәшеннәрдә дә, ш.у. Бистә һәм Глазов өязе татарларында яшәп килә; керәшеннәрдә ул берничәшәр көн — Рождестводан алып Крещениегә кадәр дәвам итә, Чепья татарларында 1–2 көн уздырыла. Бәйрәмдә катнашучылар төрле киемнәргә төренәләр, гадәттә, аю, кәҗә рәвешенә керү өчен туннар, бүрекләрен әйләндереп кияләр; ярлылар, картлар, карчыклар, чегәннәр булып киенәләр, яшь егетләр — яшь кызлар, картлар — кәләшләр һ.б. кыяфәтләргә кереп, йөзләрен танымаслык итеп яшерәләр һәм, шау-шулы төркем булып, өйдән өйгә йөриләр. Кайвакыт аларны вак клиндерләр яисә бәйрәм өчен махсус пешерелгән күмәч, көлчәләр б-н сыйлап җибәрәләр. Әгәр өйгә киенеп-ясанып йөрүчеләрне кертсәң, уңыш яхшы була дип исәпләнә («чибитьяне кертсәң, ашлык яхшы була»). Татар авылларында киенеп-ясанып йөрүчеләр беркайчан да җырламаганнар, нинди дә булса теләкләр әйтмәгәннәр. Яңа елга каршы төндә күрәзәлек итү мишәр татарларда да күзәтелә (аерым районнарда ул Н. дип атала). Ләкин, әгәр дә керәшеннәрдә бу йолада яшь егетләр дә катнашкан булса, мишәрләрдә ул кызлар багуы рәвешендә һәм өлкән яшьтәге хатын-кыз күзәтчелегендә уза. Мөселман руханилары Н.ны мәҗүсилек калдыгы буларак халык көнкүрешеннән төрле юллар б-н кысрыклап чыгарырга омтыла. Этнограф Х.Гатина фикеренчә, татарлар яшәгән районнарда уеннар, шаян йолалар, җырлар б-н уза торган Н.ны бәйрәм итү тулаем алганда 20 йөзнең башларына кадәр саклана. Әлеге бәйрәмнең ел циклына бәйле аерым йолалары хәзерге көнгә кадәр үзешчән сәнгать коллективлары репертуарында чагылыш та-

ба. Мәс., Н., милли йола бәйрәме буларак, керәшен татарлар тарафыннан Чаллы шәһәрендә уздырыла. Гомумән, Н. Яңа елны каршылау бәйрәме б-н кушыла һәм, традицион элементларны саклаган хәлдә, көнкүрешкә башка эчтәлек б-н килеп керә. Бу көнне ел буе кылган гамәлләргә нәтиҗә ясала, киләчәккә планнар корыла.

*Әд.:* Татары. М., 2001; Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX — нач. XX вв.). К., 2001.

*Л.М.Айнетдинова.*

**НАРИМА́Н** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 59 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мораса елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1920 елларның 1 нче яртысында Нариман посёлогы буларак нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Иске Әлмәт волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 344, 1938 дә — 328, 1949 да — 203, 1958 дә — 282, 1970 тә — 260, 1979 да — 180, 1989 да — 95, 2002 дә — 70 кеше.

**НАРИМА́Н** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Кама — Кама Аланы автомобиль юлы буенда. 2010 елда 153 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларның 1 нче яртысында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Иске Чишмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 270, 1949 да — 297, 1958 дә — 292, 1970 тә — 379, 1979 да — 289, 1989 да — 261, 2002 дә — 196 кеше.

**НАРИМА́Н** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 30 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 79 кеше (руслар, татарлар) яши. Төзелеш участогы. 1924 тә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Ташёвка волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 92, 1938 дә — 255, 1949 да — 137, 1958 дә — 98, 1970 тә — 99, 1979 да — 86, 1989 да — 193, 2002 дә — 116 кеше.

**НАРИМА́Н РАЙОНЫ́**, Әстерхан өлкәсенең көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 6,1 мең *км²*. 1931 елда оештырыла. Үзәге — Нариманов шәһәре (Әстерхан шәһәреннән 50 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 46250 кеше (2012), 9165 мең татар (2010). Татарлар тупланып Биштүбә (870 кеше), Картузан (325), Кәменни (1021), Каңга һәм Килдермеш (3405), Сүләнкә (2250), Урта Авыл (440), Яңа Әскәр (262) авылларында яшиләр (2002). Н.р.да беренче татар авыллары 1780 елларда барлыкка килә. 1917 дә монда 8 мәчет була. Хәзерге вакытта районда 7 мәчет эшли. Кәменни, Сүләнкә, Каңга, Яңа Әскәр авыллары мәктәпләрендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла. Кәменни (1992 дән) һәм Каңга (1998 дән) авылларында татар мәдәни үзәкләре эшли. Нариманов шәһәрендә татар халык театры (1959) һәм «Яз» татар эстрада ансамбле (1996, 2000 нән — халык ансамбле), Кәменни авылында «Авылдашлар» татар җыр ансамбле (1986–88 дә — «Сельчанка», 1999 дан — халык ансамбле), Урта Авыл авылында «Ак чәчәкләр» татар җыр ансамбле (1974) эшли. 1995 тә Кәменни авылы музыка мәктәбендә татар җыры вокаль бүлеге ачыла. Ел саен Килдермеш авылында Сабан туе үткәрелә.

**НАРИМА́НОВ** Нариман Кербәләй Нәҗаф оглы (2.4.1870, Тифлис ш. — 19.3.1925, Мәскәү, Кремль дивары буенда җирләнә), әзәрбайҗан дәүләт эшлеклесе, язучы. Сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килә. Гори шәһәрендә укытучылар семинариясен (1890), Новороссийск ун-тының мед. ф-тын (Одесса ш., 1908) тәмамлый. Баку, Тифлис шәһәрләрендә укытучы, табиб булып эшли. 1905 елда «Гуммет» с.-д. оешмасына керә, матбугатта публицистик мәкаләләр б-н чыгышлар ясый, РСДРП программасын әзәрбайҗан теленә тәрҗемә итә. 1908–14 тә Әстерханда сөргендә чагында шәһәрнең мөселманнар җәмгыяте мәдәни тормышында актив катнаша, «Борһане тәрәкъкый» г-тасында дини темаларга мәкаләләр бастыра, 1908 дә Казан-Кавказ артистлары ширкәтен оештыру эшен башлап җибәрүчеләрнең берсе була. 1917 дә «Гуммет» ком-ты рәисе, РСДРП(б)ның Баку ком-ты әгъзасы, «Гуммет» г-тасы мөхәррире. 1918 нең язында Баку ХКСның шәһәр хуҗалыгы комиссары. 1919 дан РСФСР тышкы эшләр халык комис-тының Якын Көнчыгыш бүлеге җитәкчесе, милләтләр эшләре халык комиссары урынбасары. 1920 дә Әзәрбайҗан революцион ком-ты, Әзәрбайҗан ХКС рәисе. 1922 дән СССР ҮБК рәисләреннән берсе. Н.ның әдәби әсәрләре 20 йөз башы төрки халыкларының милли азатлык һәм революцион хәрәкәтен чагылдыра. Н. — милли хорафатларны гаепләгән «Баһадур вә Сона» (1896) романы, әзәрбайҗан әдәбиятында беренче тарихи пьеса — халык күтәрелешен күрсәткән «Надиршаһ» (1899) һ.б. әсәрләр авторы.

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 2 т. М.–Л., 1926; Повести и пьесы. М., 1971.

*Әд.:* Казиев М. Н.Нариманов. Баку, 1970; Кочәрли Ф. Нәриман Нәриманов. Бакы, 1965.

**НАРКОЛО́ГИЯ** (грек. nárkē — катып калу һәм *...логия*), алкоголизм, наркомания, токсикоманиянең этиологиясен, патогенезын һәм клиник күренешен өйрәнүче, аларны кисәтү, дәвалау, реабилитацияләү ысулларын булдыручы фән. *Психиатриянең* бер тармагы. Россиядә, традиция буенча, Н. фәкать химик бәйлелекләрне генә өйрәнә, чит илләрдә химик һәм химик булмаган бәйлелекләрне өйрәнүче аддиктология фәне Н.нең тиңдәше булып тора. Н. Халыкара психик һәм гамәли (тышкы, кешенең үз-үзен тотышындагы) тайпылышлар классификациясенә кертелгән тайпылышларны өйрәнә. Дәвалау максатыннан наркотиклар куллану урта гасырлар башыннан билгеле (опийлы дарулар — лауданум, перегорик, Доверов порошогы һ.б. кулланылган). Вудд тарафыннан шприц уйлап табылганнан соң, наркотиклы матдәләрне авыртуны басу һәм психоаддуктив эффектка ирешү өчен венага кертә башлыйлар. Морфий билгеле булып, хирургия һәм онкологиядә авыртуны басу өчен кулланылуга кертелгәннән бирле, морфинизм үзе авыру төре буларак карала. 20 йөз башыннан дөньяда наркотик матдәләр куллану эпидемиясе җәелә. 1920 елларда Көнбатыш Европада яңа химик психостимуляторлар: амфетамин, метамфетамин һ.б. барлыкка килә. Икенче бөтендөнья сугышы аларның киң кулланылышына китерә, яралыларның авыртуларын басар өчен уйлап табылган героин халык арасында наркомания таралуга бер сәбәп була. Кокаин, опиум, киндерне «затлы» салоннарга җыелып кулланалар. 1960 еллардан ацетон, толуол, трихлорэтил һ.б. нигезендә ясалган препаратлар куллану тарала. Яңа төшенчәләр туа: башлыча психик бәйлелеккә китерүче наркотикларны «йомшак», моңа физик бәйлелекне дә өстәгәннәрен «каты» наркотиклар дип йөртә башлыйлар. Кулланучы «йомшак» матдәләрдән бик тиз «каты» матдәләргә күчә. 20 йөз ахырында Россиядә, ш.и. Татарстанда да яшүсмерләр наркоманиясе куркынычы килеп баса: химик матдәләр һәм таблеткалы синтетик наркотиклар кулланучы яшүсмерләргә кичектергесез һәм стационар ярдәм күрсәтү зарурлыгы туа. Бу төр авырулар өчен махсус реабилитация программалары төзелә, наркоманияне кисәтү чаралары күрелә. 20 йөз ахырында яшьләр арасында ш.у. алкоголизм күренеше (ш.и. кызлар арасында да) арта. Суррогат эчемлекләр куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән психоз очраклары ешая. Татарстанда Н. фән буларак 1980 еллардан үсеш ала. Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе галимнәре, республиканың Н. диспансерларында эшләүче табибләр б-н бергә, Н.нең теоретик һәм практик нигезләмәләрен, авыруларны дәвалауның нәтиҗәле ысулларын эшлиләр. А.М.Карпов тарафыннан фармако- һәм психотерапия, ш.у. хезмәт б-н дәвалау методикасы эшләнә, аерым психотроп дарууларга клиник бәя бирелә һәм сынау уздырыла. В.Д.Менделевич Н.гә караган авыруларны кисәтү һәм дәвалау, психик авыруларның үз-үзләренә ярдәм күрсәтү мөмкинлекләрен тикшерү юнәлешендә үз тәкъдимнәрен эшли. Л.К.Шайдукова тарафыннан Казан табибләренең тәҗрибәләрен гомумиләштерү нигезендә авыруларны кисәтү һәм дәвалау буенча тәкъдимнәр әзерләнә һәм спиртлы эчемлекләрне чамадан тыш кулланучы гаиләләрдә парлап-төркемләп эчү үзенчәлекләре өйрәнелә. Фәнни эзләнүләр нәтиҗәсе булып, аддиктология проблемаларына багыш-

ланган хезмәтләрнең махсус җыентыгы дөнья күрә.

*Әд.:* Ш т е р ё в а Л.В. Клиника и лечение алкоголизма. Л., 1980; Ч у д н о в с к и й В.С., Ч и с т я к о в Н.Ф. Основы психиатрии. Ростов н/Д., 1997; Ш а й д у к о в а Л.К. Социальная и клиническая психиатрия. К., 1997; ш у л у к. Зависимости — выбор и преодоление. К., 2005; М е н д е л е в и ч В.Д. Наркозависимость и каморбидные расстройства поведения. М., 2003.

*Л.К.Шайдукова.*

**НАРКОМА́НИЯ** (грек. nárkē — катып калу һәм mania — мания), психоактив (ш.и. наркотик) матдәләр куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән хроник авырулар төркеме. Наркотик матдәләрдән физик һәм психик бәйлелектә булган авыру аларсыз тора алмый, һәм аның наркотик матдәләргә булган тыелгысыз ихтыяҗы торган саен арта бара. Археол. табылдыклар кешелекнең исерткеч һәм миңгерәткеч матдәләр б-н борынгыдан таныш булуын күрсәтә. Аларны куллануның сәбәпләре яуга яки аучы аугa әзерлек, дини ритуаллар, тотемга табыну б-н бәйле булырга мөмкин. Н.нең иң төп билгесе — бәйлелек синдромы (зыянын күрә торып та, матдәне кабул итәргә тыелгысыз теләк), матдәнең микъдарын, тәэсир итә башлавының башын һәм ахырын контрольдә тоту бозылу. Психоактив матдәне кабул итүдән тыелганнан соң бер тәүлек эчендә вегетатив тайпылышлар өстенлек итә, ш.у. тынычсызлану халәте, фобик, астеник һәм депрессив тайпылышлар күзәтелә. Икенчел психик тайпылышлар да зыян сала, алар депрессия, эпилептик пароксизмнар, ш.у. соматик симптомнар б-н уза. Кискен агулану очрагында авыруда аң тайпылышлары, агрессивлык, үз эшчәнлеген оештыра алмау, кайчак патологик исерү күзәтелә. Н.нең эчкәреге этапларында резидуаль психотик тайпылышлар барлыкка килә, бу халәт психозлар, шәхеснең тотрыклы үзгәрешләре б-н характерлана. Авыруны дәвалау: кискен психопатологик симптоматикага чик кую (агусызландыру) һәм төп симптомны — психоактив матдәгә патологик тартылуны туктату. Дәвалау схемалары Н.нең клиник төрләреннән чыгып билгеләнә. Реабилитация барышында дәвалауның психотерапевтик ысуллары зур роль уйный. Наркологиягә караган авырулар хроник рәвештә уза һәм пациентның даими диспансер күзәтүендә торуын таләп итә, пациент ш.у. авыруыннан арынганчы мед. ярдәме б-н тәэмин ителергә тиеш. Н.не кисәтү һәм дәвалау махсус хезмәтләр — наркология диспансерлары, поликлиникалар һ.б. тарафыннан башкарыла.

Казанда респ-ка наркология диспансеры 1976 елда төзелә (баш табиб — Л.А.Никольская, 1998 дән — Ф.З.Фәттахов), 2007 елдан — «Республика наркология диспансеры» дәүләт автономияле сәламәтлек саклау учреждениесе. Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Бөгелмә шәһәрләрендә ф-ллары бар. Алар ТРның наркологик ярдәм күрсәтүне оештыру структурасында төп берәмлек тәшкил итә, оештыру-методик эш алып бара, авыруларга мед. ярдәме күрсәтә. Филиалларда реабилитация үзәкләре һәм бүлекләре, инвалидлар өчен бер үк вакытта мед. ярдәме күрсәтелә торган хезмәт остаханәләре эшли. ТР диспансерлары һәм поликлиникаларында 800 белгеч исәпләнә, ел саен 18 мең авыру дәвалана (660 ятак-урын). Авырулар алардагы өлкәннәр өчен — 39, балалар һәм яшүсмерләр өчен 37 кабинетта, табибләр күзәтүендә торып, тиешле мед. ярдәме алалар. Ш.у.к. *Наркология*.

*Әд.:* Б р а т у с ь Б.С. Аномалии личности. М., 1988; П я т н и ц к а я И.Н. Наркомания. М., 1994; Ш а б а н о в П.Д., Ш т а к е л ь б е р г О.Ю. Наркомании. СПб., 2000; Р о х л и н а М.Л., К о з л о в А.А. Наркомании: Медицинские и социальные последствия. Лечение. М., 2001; Ш а й д у к о в а Л.К. Наркомании, алкоголизм: Вопросы профилактики и реабилитации. К., 2002; Г о ф м а н А.Г. Клиническая наркология. М., 2003; С и в о л а п Ю.П., С а в ч е н к о в В.А. Злоупотребление опиоидами и опиоидная зависимость. М., 2005.

*В.Д.Менделевич.*

**НА́РМОНКА** авылы, Лаеш р-нында; к. *Нурминкә*.

**НА́РМОНКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 7 *км* көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 206 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Үләмә, Нармоцкая исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1888 дә ачыла), 2 җил тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, йон тетү бинасы, 2 кибет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 725 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 465, 1897 дә — 571, 1908 дә — 665, 1920 дә — 649, 1926 да — 704, 1938 дә — 682, 1949 да — 577, 1958 дә — 567, 1970 тә — 363, 1979 да — 317, 1989 да — 262, 2002 дә — 218 кеше.

**«НАРО́ДНАЯ А́РМИЯ»** («Халык армиясе»), беркөнлек иҗтимагый-сәяси газета. КОМУЧ Халык армиясе органы. Бердәнбер саны 1918 елның 21 августында Казанда рус телендә нәшер ителә. Губерна басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — П.Л.*Драверт*. Халык арасында Халык армиясенең популярлыгын арттыру, аның фондына акча җыю һәм армия сафларына үзләре теләп килүчеләрне җәлеп итү максатыннан чыга. «Н.а.» басмасының чыгачагы турында Казан газеталарының күпчелеге хәбәр итә. Зур форматлы, дүрт битле, төсле буяулар б-н бизәлгән санда 1918 нең август башында Казанны алу сугышлары турында КОМУЧның Казан гаскәрләре төркеме командиры А.П.Степановның «Казанга яу» («Поход на Казань»), КОМУЧның гадәттән тыш вәкаләтле вәкиле В.И.Лебедевның «Көндәлектән» («Из дневника») хатирәләре, проф. А.Я.Богородский («Яшик, гражданнар» — «К жизни, граждане»), М.В.Бречкевич («Славяннар һәм немецлар» — «Славяне и немцы»), Н.Н.Парфентьев («Кайбер параллельләр» — «Некоторые параллели»), Н.Н.Фирсов («Халык армиясе» — «Народное войско») һ.б.ның, Россиядәге сәяси вакыйгаларга бәя биреп, халык армиясен хуплаган һәм большевикларны тәнкыйтьләгән мәкаләләре басылып чыга. Газетада Казан өчен барган сугыш мизгелләре, шәһәрдә акгвардиячеләр булган вакыттагы сәяси вазгыять һәм интеллигенция вәкилләренең рухи тормышы турында мәгълүматлар урнаштырыла.

*Әд.:* М а л ы ш е в а С.Ю. Комучевская Казань // Татарстан. 2001. № 9.

*Т.М.Насыйров.*

**«НАРО́ДНАЯ ВО́ЛЯ»**, революцион народниклар оешмасы. 1879 елның августында С.-Петербург шәһәрендә барлыкка килә. Программаларында: патша монархиясен юк итү, Учредительләр җыенын чакыру, гомуми сайлау хокукы кертү һәм сайлауларга халык вәкилләрен куйдыру, сәяси ирекләр, җәмәгатьчелек үзидарәсе булдыру һәм крәстияннәргә җир бүлеп бирү, изелгән халыкларның үзбилгеләнүенә ирешү. «Народная воля» г-тасы һәм «Рабочая газета» дәүләт хакимиятен тартып алу өчен революцион көрәшкә һәм крәстиян рев-циясенә өндиләр. 1880–81 дә «Н.в.» оешмасы тырышлыгы б-н «Казан социалистик-революцион үзәк түгәрәге» оеша, түгәрәк 50 ләп кешене берләштерә: С.С.Яковлев, П.Т.Семёнов (җитәкчеләр), Н.А.Бухалов, А.А.Дудкин, М.Я.Ловейко, В.А.Померанцев, А.А.Пуссет, Н.И.Тезяков, Д.С.Яковлев һ.б. (башлыча университет, вет. ин-ты һәм руханилар академиясе студентлары). Түгәрәк әгъзалары укучылар һәм эшче яшьләр арасында листовка-прокламацияләр, народникларның революцион әдәбиятын тараталар; Мәскәү, Пермь, Самара, Сембер һ.б. шәһәрләрдәге народниклар оешмалары б-н элемтә урнаштыралар. «Н.в.»ның Казан оешмасы эшчәнлеге 1880 елларның 2 нче яртысында туктатыла. Башка төбәкләрдәге аерым оешмалар 19 йөз ахырына кадәр гамәлдә була. «Н.в.»ның программасы һәм тактикасының күп кенә принциплары *Социалист-революционерлар партиясе* эшчәнлегендә дәвам иттерелә.

*Әд.:* С м и р н о в а Т.М. Революционное подполье Казани в первой половине 80-х гг. XIX в. // Из истории Казанского революционного подполья 80-х годов XIX века. К., 1970.

*Е.Б.Долгов.*

**«НАРО́ДНАЯ ЖИЗНЬ»** («Халык тормышы»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Казан губерна земствосы органы. 1918 елның 23 августыннан (КОМУЧ Халык армиясе шәһәрне алганнан соң) 7 сентябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барлыгы 13 саны чыга. Редакция газетаны аерым партиягә бәйләнмәгән, Россиядә халык бердәмлеген һәм демократик респ-ка строен ныгытуны яклаучы орган буларак тәкъдим итә. «Н.ж.» элек эшләп килгән, большевиклар тарафыннан ябылган «*Крестьянская Казанского губернского земства газета*», «*Крестьянская жизнь*», «*Трудовой путь*» г-талары юнәлешен дәвам итә. «Н.ж.» сәхифәләрендә С.И.Абакумов, П.Г.Архангельский, М.С.Бухов, Ю.П.Денике, П.Л.Драверт, П.К.Жузе, М.П.Забусов, С.А.Знаменский, Н.М.Пет-

ровский, Ю.Л.Салин, Е.Ф.Сосунцов, Н.Н.Фирсов, К.В.Харлампович, Е.И.Шамурин, П.В.Ящерицын язышалар .Төп рубрикалары: «Рәсми бүлек», «Земство тормышы», «Шәһәр думасы», «Бүгенге Казан», «Учредительләр җыены агентлыгы телеграммалары», «Халык армиясенә ярдәмгә», «Казан фронтында». Газета укучыларын демократиянең торгызылуы, 8 сәгатьлек эш көне турында бәян иткән язмалар, эшчеләр конференцияләрен һәм крәстиян съездларын чакыруга, фабрика-завод ком-тлары һәм профсоюзлар эшчәнлегенә рөхсәт биргән КОМУЧ җитәкчеләре В.Вольский, Н.Галкин, Я.Дворжец, П.Климушкин, С.Чечек һ.б.ның гамәлләре б-н таныштыра. Редакция большевиклар тарафыннан юкка чыгарылган губерна земствосы, земство идарәсе, шәһәр думасы эшчәнлегенең яңадан торгызылуы турында сөйли. «Н.ж.» сәхифәләрендә 1918 нең августында Казанны алу һәм шәһәрдә яңа хәрби частьлар оештыру б-н җитәкчелек иткән Төньяк төркеме группасы гаскәрләре командиры А.П.Степанов эшчәнлеге, ш.у. КОМУЧның Казан һәм Казан губернасы буенча вәкаләтле вәкилләре эше яктыртыла. Газета аклар армиясенең уңышларын мактаган материаллар, сугыш хәрәкәтләре барышы хакында Төньяк төркем штабы төзегән көндәлек хәбәрләр бастыра, берничә санында Константиновка, Чабакса, Ключище авыллары тирәсендәге сугышларда яраланып, губерна земство хастаханәсендә дәваланучы яралыларның фамилияләрен бирә. Редакция Халык армиясе фондына акча җыюда актив катнаша, аның сафларына басарга үгетли. Соңгы сан «Гражданнар! Казанга җитди куркыныч яный. Шәһәрне саклау безнең кулыбызда!» дигән өндәмә б-н чыга.

*Т.М.Насыйров.*

**НАРО́ДНИКЛЫК**, 19 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә чыгышлары б-н дворян булмаган зыялы катлау вәкилләре арасында таралган идеология һәм хәрәкәт. Крепостнойлыкка, Россиядә капитализм үсешенә каршы, патша самодержавиесен крәстиян рев-циясе ясап бәреп төшерүгә юнәлдерелгән була. «Н.» термины еш кына «демократизм» сүзенең синонимы буларак кулланыла. Н.ның нигезен соц. мөнәсәбәтләрнең башлангыч формасы итеп каралган крәстиян җәмгыятьләре һәм артельләренә таянырга омтылыш һәм Россияне капиталистик булмаган юл б-н үстерү мөмкинлекләренә ышаныч тәшкил итә. Хәрәкәткә нигез салучылар — А.И.Герцен, Н.Г.Чернышевский, идеологлары — М.А.Бакунин, П.Л.Лавров, П.Н.Ткачёв. Казанда беренче Н. оешмалары 19 йөзнең 60 нчы елларында барлыкка килә. Шулар арасында: «Земля и воля» җәмгыятенең Казан бүлеге (әгъзалары — Г.Иловайский, Н.Кониченко, Ю.Мосолов, П.Ровинский, И.Умнов, А.Христофоров, Н.Шатилов һ.б.), «Студентлар клубы» (әгъзалары — К.Бургер, А.Петров, В.Полиновский һ.б.); 1870 еллар башында: Н.Я.Агафонов иҗтимагый-әдәби түгәрәге (әгъзалары — А.Гацисский, К.Лаврский, В.Малинин, В.Португалов һ.б.), Е.М.Овчинников (1872 дән), П.А.Голубев (1876 дан, әгъзалары — С.Вершинин, Л.Квашнин-Лойко, М. һәм С.Мышкиннар, Е.Печорин һ.б.) түгәрәкләре. Голубев түгәрәгенә А.М.Пешков (М.Горький) һәм Н.Е.Федосеев та йөри. Әлеге оешмалар Н. идеологиясен тарату б-н шөгыльләнәләр. 1874 елда «халык арасына» чыгалар — «Хождение в народ» хәрәкәтендә катнашалар. Кайбер түгәрәкләр 19 йөз ахырына кадәр эшли. 20 йөз башында таркау Н. оешмалары һәм түгәрәкләре җирлегендә *Социалист-революционерлар партиясе* барлыкка килә.

*Әд.:* История Татарской АССР: С древнейших времён до наших дней. К., 1968; Из истории Казанского революционного подполья 80-х годов XIX века. К., 1970; Д о л г о в Е.Б. Некоторые вопросы общественно-политического движения в Казанской губернии во второй половине XIX века // Историко-археологический сборник. Наб. Челны, 1996. Сб. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**«НАРО́ДНОЕ ДЕ́ЛО»** («Халык эше»), крәстияннәр һәм эшчеләр газетасы. *«Голос труда»* г-тасы дәвамчысы. Уң эсерлар партиясенең Казан оешмасы органы. 1917 елның декабрендә оешма эшчәнлеге торгызылганнан соң басыла башлый. 1918 нең 1 гыйнварыннан 31 гыйнварына кадәр Казанда атнасына 2 тапкыр рус телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. «Хезмәт» ширкәте басмаханәсендә басыла. Мөхәррирләре — Ф.Рудько, С.Калистов. «Көрәштә генә табарсың үз хокукыңны!» дигән шигарь астында дөнья күрә. 1918 нең 9 августында яңадан чыга башлый һәм шул елның 10 сентябренә кадәр (24 сан; мөхәррире — С.Калистов; социалист-революционерлар партиясенең Казан оешмасы органы), Казанда Чех-словак корпусы һәм КОМУЧның Халык армиясе частьләре булган вакытта басыла. Губерна земствосы басмаханәсендә нәшер ителә. Газета б-н Ж.Алкин, Г.Алюнов, В.Архангельский, В.Лебедев, В.Пирогов, А.Смолин һ.б. хезмәттәшлек итә. «Н.д.» Учредительләр җыены б-н КОМУЧның Халык армиясен яклап чыгыш ясый, «Бөтен власть Учредительләр җыенына!», «Яшәсен көчле, җиңелмәс Халык армиясе! Аның байраклары тирәсенә ашыгыгыз!» дигән өндәмәләр б-н чыга. Анда кызылармиячеләргә, латыш укчыларына Халык армиясе ягына чыгарга өндәгән чакырулар, ш.у. КОМУЧ органнары, яңадан торгызылган шәһәр думасы һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы игъланнар һәм боерыклар басыла. «Бердәм Россия һәм милләт мәсьәләсе», «Мөселманнар һәм большевиклар», «Татарлар һәм Учредительләр җыены» һ.б. язмаларда Россиядә милли мәсьәләне хәл итү юллары яктыртыла.

*Әд.:* М у х а р я м о в М.К. Гражданская война в Татарии (1918–1919). К., 1969.

*Т.М.Насыйров.*

**НАРУЧА́Т БӘКЛЕГЕ́**, к. *Мухша Олысы.*

**НАРУЧА́Т ШӘҺӘРЛЕГЕ́**, к. *Мухша.*

**НАРЫ́ЙК УЛЫ́ ГАЛИКӘ́Й БӘК**, Казан ханлыгы дәүләт эшлеклесе, к. *Галикәй Нарыйк улы.*

**НАРЫ́ЙК УЛЫ́ ЧУРА́ БӘК**, Казан ханлыгы дәүләт эшлеклесе, к. *Чура бәк.*



Ә.Ф. Нарыйков.

**НАРЫ́ЙКОВ** Әдһәм Фазылҗан улы (29.9. 1923, Чиләбе өлкәсенең Троицк ш. — 8.10. 1968, Казан), балет артисты, педагог, балетмейстер, РСФСРның атказ. артисты (1957). 1941 елда Ленинград хореография уч-щесен тәмамлый. 1941 дә һәм 1945–47 дә Башкорт опера һәм балет театрында балет солисты. 1947–65 тә Татар опера һәм балет театрында балет солисты, 1965–68 дә ТАССРның Җыр һәм бию ансамблендә баш балетмейстер. Хореографик партияләре арасында — Зигфрид, Дезире һәм фея Карабос («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Гәрәй («Бакчасарай фонтаны», Б.Асафьев), Северьян («Ташчәчәк», С.Прокофьев), Командор («Лауренсия», А.Крейн), Ленни («Яшен сукмагыннан», К.Караев), Былтыр («Шүрәле», Ф.Яруллин) һ.б. Мәһабәт гәүдәле классик биюче Н. акад. бию техникасына, тәэсирле актёрлык уенына, күркәм сәхнә манерасына һәм парлы биюдә аеруча нәзакәтлелеккә ия була. Татар опера



Ә.Ф. Н а р ы й к о в Вацлав ролендә («Бакчасарай фонтаны», Б.В. Асафьев).

һәм балет театры сәхнәсендә опера һәм оперетталарда биюләр куючы. ТАССРның Җыр һәм бию ансамбле өчен «Туй» (1960) вокаль-хореографик композициясе авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*В.Н.Горшков.*

**НАРЫ́ШКИН** Михаил Кириллович (18.11.1825, Мәскәү — 13.10.1890, С.-Петербург), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1878). Дворяннар нәселеннән. 1843 елдан хәрби хезмәттә. Венгриядә революцияне бастыруда (1849), 1853–56 дагы Кырым сугышында катнаша. 1863 нең апрель–маенда *Казан фетнәсен* ачуга ярдәм итә. 1863–1866 да гражданлык мәсьәләләрен хәл итүгә вәкаләтле Казан хәрби губернаторы. Н. җитәкчелегендә Казан губернасында удел һәм дәүләт крәстияннәре (1863, 1866),

земство (1864) реформалары уздырыла. 1863–66 да Казан икътисадчылары җәмгыяте президенты. Н. эшчәнлеге чорында Казан хәрби округы оештырыла (1864), Казанда Үзәк керәшен-татар мәктәбе (1864), шәһәр җәмәгать китапханәсе (1865), шәһәр почтасы һәм пехота юнкерлары уч-щесе (1866) ачыла. 1865 тә Н. Казан а.х. күргәзмәсен уздыруга булыша. Губернаның уку-укыту оешмаларына ярдәм күрсәтә. 1866 дан император Александр II даирәсендә, 1878–83 тә һәм 1888 дән Петербург хәрби округында була. Чистай шәһәренең мактаулы гражданы (1866). 1867 дә Казан Мария хатын-кызлар гимназиясендә Н.ның шәхси стипендиясе булдырыла.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. «Высочайшим приказом произведён в генерал-майоры»: Михаил Кириллович Нарышкин // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4.

*Е.Б.Долгов.*

**НАРЫ́ШКИН** (Махотин) Николай Васильевич (12.6.1938, Ульянов өлкәсенең Карсун р-ны Кадышево а.), икътисад белгече, язучы, публицист, икътисад фән. канд. (1973), проф. (1998), ТАССР, РФның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986, 1996). Казан. ун-тын тәмамлаганнан соң (1966), Казан. техник ун-ты икътисад теориясе һәм хокук кафедрасында укыта. Хезмәтләре РФ, ТРның а.х. өлкәсенә карый. Россия авылының киләчәге хакында уйланулар б-н сугарылган хикәя, очерк, новелла, эссе һәм повестьлар авторы. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Махотин извоз. К., 1998; Мятущаяся Россия, К., 1999; Священная сура. К., 2000; Кадышевский эпос. К., 2002; Русский дневник, или По Святым местам Русского Духа. К., 2004. Т. 1.

**НАСРЕТДИ́НОВ** Гаффар Назар улы (26.2.1923, Омск өлкәсенең Исилкүл пос., хәзер шул исемдәге шәһәр — 12.4.1994, Белоруссия Респ-касы, Минск), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), гв. полковнигы. Новосибирск хәрби пехота уч-щесен (1942), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (1954) тәмамлый. Новорождественка (Исилкүл р-ны) авылында башлангыч мәктәптә укыта. 1942 ел башыннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 294 нче гв. укчы полкында рота командиры (5 нче армиянең 97 нче гв. укчы дивизиясе). Воронеж, Дала, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск дугасы һәм Днепр елгасы янындагы сугышларда (икесе дә — 1943), Кировоград, Львов-Сандомир (икесе дә — 1944), Түбән Силезия, Берлин һәм Прага (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Линден торак пункты (хәзер Бжег шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнбатыштарак Липки торак пункты, Польша) тирәсендә Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә. 1945 нең 26 гыйнварында Н. ротасы һөҗүмгә күчә һәм Олау шәһәренә (хәзер Олава, Польша) чыга, аны азат итүдә катнаша. Сугыштан соң Совет Армиясе сафларында хезмәтен дәвам итә. 1978 дән запаста; Белоруссия ун-тында хәрби каф. башлыгы, «Луч» ф-касында гражданнар оборонасы штабы башлыгы булып эшли (Минск). Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ш л е в к о Г.М. Ради жизни на земле. Омск, 1972.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НАСРЕТДИ́НОВ** Фәхри Хөсәен улы (23.10.1911, Зөя өязе, хәзер Апас р-ны Шәмбалыкчы а. — 4.10.1986, Казан), җырчы (лирик тенор), ТАССР, РСФСРның халык артисты (1950, 1957). 1928–34 елларда Мәскәү үзәк татар эшче театры артисты. 1938 дә Мәскәү консерваториясе (В.Садовников классы) каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый. 1939–83 тә Татар опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты. Н. репертуарының нигезен Көнбатыш Европа һәм рус классик опера репертуарының лирик тенор партияләре: Альфред, герцог Мантуанский («Травиата», «Риголетто», Дж.Верди), Фауст (Ш.Гуно), Ромео («Ромео һәм Джульетта», Ш.Гуно), Ленский («Евгений Онегин», П.Чайковский), Владимир Игоревич («Князь Игорь», А.Бородин), Лыков («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Назар («Тарас гаиләсе», Д.Кабалевский) һ.б. тәшкил итә. Татар композиторларының муз.-сәхнә әсәрләрендә төп партияләрне (башлыча, беренче башкаручы буларак) башкаруы Н. иҗатының аеруча мөһим өлкәсе булып тора, ул Кирәмәт, Җик һәм Урмай, Түләк («Качкын», «Алтынчәч», «Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов), Галимҗан һәм Кәрим бай («Башмагым», Җ.Фәйзи), Мулла («Җиһангир», Р.Гобәйдуллин) һ.б. кебек истә калырлык образлар тудыра. Актив концерт эшчәнлеге (репертуарында — классик һәм заманча вокаль музыка) алып бара. Татар халкының «Сибелә чәчәк», «Сакмар», «Су буйлап», «Рәйхан» һ.б. көйләрен үзенчәлекле оста башкаручы буларак танылa. Киң иҗади диапазонга ия җырчы, вокаль һәм сәхнә осталыгының югары дәрәҗәсенә ирешә. Н.ның башкару сәләте эчкерсезлеге, үткен лирик тәэсире, бай динамик яңгырашы, төгәл дикциясе б-н аерылып тора. «Татарстан» ДТРК фондында 200 гә якын язмасы саклана. СССР шәһәрләрендә, ш.и. Мәскәүдә, чит илләрдә (Бирма, Вьетнам, Кытай) гастрольләрдә була. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1959). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З ә й н а ш е в а Г. Бәхетле гомер // Казан утлары. 1971. № 11; С а л и к о в а Ф. Он с детства полюбил народные мелодии // Театральная жизнь. 1963. № 23; Народные артисты. К., 1980.



Г.Н. Насретдинов.



Ф.Х. Насретдинов.



Ф.Х. Н а с р е т д и н о в Әскәр ролендә («Аршын мал алан», У. Хаҗибәков). Г. Камал исем. Татар акад. театры.



Ф.Х.Насретдинов герцог Мантуанский ролендә («Риголетто», Дж. Верди).

**НАСРЕТДИ́НОВ ФӘХРИ́ ҺӘМ ВӘЛИ́ЕВА БАНУ́ МУЗЕЕ́**, Апас р-нының Шәмбалыкчы авылында. 1996 елның 2 апрелендә З.К.Хәйруллин (хәзер директор) тырышлыгы б-н ТР Дәүләт музее (2001 дән ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2007 дән муниципаль музей. Кирпечтән төзелгән бер катлы клуб бинасында өч бүлмәне били. Экспозиция мәйданы — 58 $м^2$, музей фондында 2800 саклау берәмлеге бар. Музейда Ф.Х.*Насретдиновның* мемориаль әйберләре (фотосурәтләр, театр костюмнары, бүләкләре, көнку-



Ф.Насретдинов һәм Б.Вәлиева музее. Ф.Насретдиновның шәхси әйберләре.



И.Н.Насыйбуллин.

реш әйберләре), ул төп рольләрне башкарган әсәрләр — Н.Җиһановның «*Алтынчәч*» операсы һәм Җ.Фәйзинең «*Башмагым*» муз. комедиясе яздырылган магнит тасма куелган. Ш.у. күргәзмәдә җырчы Б.*Вәлиеваның* фотосурәтләре, бизәнү әйберләре һәм концерт костюмнары саклана. Бөек Ватан сугышына багышланган бүлектә сугышта катнашкан авылдашларның фотосурәтләре, документлары бар. Музей тарафыннан ел саен



Ф.Насретдинов һәм Б.Вәлиева музее. Экспозиция фрагменты.

Ватанны саклаучылар көне (23 февр.), Җиңү бәйрәме (9 май), Халыкара музейлар көне (18 май), Ф.Насретдинов туган көн (23 окт.) үткәрелә.

**НАСРУЛЛА́ЕВ** Мөхәммәд Нухкади улы (27.3.1951, Дагстан АССРның Акуша р-ны Акуша а.), хирург, мед. фән. д-ры (2000). Дагстан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Чистай шәһәрендәге үзәк район хастаханәсендә табиб-хирург. 1984–86 елларда Казан ГИДУВының хирургия һәм онкология кафедрасында хирург-онколог. 1986 дан 2 нче Республика клиник хастаханәсендә хирург-онколог, 1989–2000 дә хирургия бүлеге мөдире; 2003 тән Казан мед. академиясенең эндоскопик һәм гомуми хирургия кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 2005 тән, «Казан авиапредприятиесе» ҖЧҖ медсанчастендә баш табиб. Хезмәтләре күкрәк рагының таралышын өйрәнүгә һәм бу авыруга нурлар ярдәмендә диагноз куюга карый.

**НАСРЫ́Й** (Насретдинов) Гамир Гариф улы (3.1.1916, хәзер БРның Кызыл Кама р-ны Иске Янҗегет а. — 27.12.1959, Казан), драматург. Казан театр техникумын тәмамлый (1937). Туган районында колхоз театрын оештырып, аңа җитәкчелек итә. Инсценировкалар, этюдлар, бер пәрдәлек пьесалар, скетчлар яза («Колхоз театры» җыентыгы, 1934). 1941–49 елларда (бүленеп) ТАССР МС каршындагы радиотапшырулар ком-тында муз. һәм драматик тапшырулар мөхәррире булып эшли. «Ялкау Бикмөхәммәт» исемле беренче драмасы 1932 дә басылып чыга. Аның күп кенә пьесалары крәстияннәр тормышына, авылдагы социаль-икътисади үзгәрешләргә багышлана. «Бухгалтер Ашмасов» (1940), «Путёвка» (1941), «Патриотлар семьясы» (1941), «Таныш кешеләр» (1942) пьесаларында автор күмәкләштерүгә каршы кешеләрне фаш итеп, колхоз тормышын мактап сурәтли. Бөек Ватан сугышы елларында совет сугышчыларының батырлыклары турында шигырьләр, җырлар, хикәяләр, очерклар иҗат итеп, «Фронтовая правда» г-тасында бастырып килә. 1950 елларда Н. респ-ка театрлары б-н актив эшли. Аның «Идел буенда» муз. комедиясе (1948), «Көндәлек дәфтәре» (1949), «Без капчыкта ятмый» (1950), «Кушнарат» (1952) комедияләре, «Кадерле минутлар» (1953), «Туган авылым» (1955), «Яшел эшләпә» (1956) драмалары Татар опера һәм балет, Татар акад., Татар драма һәм комедия, Минзәлә татар драма, Башкорт акад. театрларында уңыш б-н бара. Пьесалары «Комедияләр» (1950), «Пьесалар» (1953), «Кадерле минутлар» (1955; рус теленә тәрҗемәсе «Дорогие минуты», М., 1957), «Яшел эшләпә» (1958; рус теленә тәрҗемәсе «Зелёная шляпа», М., 1959) җыентыкларында урын ала. Кайбер шигырьләре композиторлар З.Хәбибуллин, Җ.Фәйзи, С.Сәйдәшев, Р.Яхин тарафыннан көйгә салына. Н. совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: пьесалар, җырлар. К., 1966.

*Әд.:* Г ы й з з ә т Т. Гамир Насрый турында // Әсәрләр. К., 1978. Т. 4.

*Г.М.Габделхакова.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Арслан Валерьевич (26.11.1973, Красноярск ш.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. Казан ун-тын тәмамлый (1996), ТатНИПИнефтьтә эшли, бүлек мөдире (2004 тән). Хезмәтләре нефть чыганакларын файдалану һәм запасларын исәпләүгә карый. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлаштыру технологияләре нигезендә нефть чыганакларын эшкәртүдә идарә алымнарын эшләгәне һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Технология построения геологотехнологических моделей нефтяных месторождений Татарстана // Нефтяное хоз-во. 2003. № 8 (автордаш); Выбор технологии и оптимального масштаба гидроразрыва пластов для условий ОАО «Татнефть» // Нефтяное хоз-во. 2007. № 5 (автордаш).

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Габделхак Гыйльмулла улы (30.11.1923, Арча кантоны Казанбаш а. — 1.10.2007, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1978). Казан стоматология ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Пермь өлкәсендә Эчке эшләр министрлыгы системасында табиб. 1953 елдан — Пермь, 1957 дән Казан мед. ин-тларының ортопедия кафедрасында. 1976 дан Казан ГИДУВының ортопедик һәм хирургик стоматология каф. мөдире. 1990 нан шунда ук проф.-консультант. Хезмәтләре ортопедик стоматологиягә, рентген нурлары ярдәмендә диагноз куюга, теш казналыгын үзгәртүгә, яңак-аскы теш казналыгы буыны дисфункцияләрен дәвалауга карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Татарстан стоматологлары җәмгыяте рәисе (1990–93). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Клинические основы протезирования при полном отсутствии зубов. М., 1967. Ортодонтическая диспансеризация детей в периоде сменного прикуса. К., 1985; Оптимизация изготовления люстовидных протезов в клинике: Учеб. пособие для врачей-курсантов. Л., 1988.

*Әд.:* Профессор Г.Г.Насибуллин (к 70-летию со дня рождения) // Стоматология. 1994. № 3.

*В.Ф.Богоявленский.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Зиннур Сәгыйдулла улы (12.11. 1937, БАССРның Нуриман р-ны Кече Теңкәш а. — 8.1.1986, Казан), шагыйрь. Башкорт ун-тын тәмамлагач (1968), респ-каның төрле газета-журнал редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, Башкортстан радиоком-тында мөхәррир булып эшли. 1969 елдан ТАССР МСның телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында. Тәүге шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1969) күмәк җыентыгында урын ала. Шагыйрьнең сугыш вакытына туры килгән авыр балачак һәм яшьлек мәхәббәте темаларына багышланган лирик характердагы шигырьләре «Тәлгәш» (1973), «Гамьнәр илендә» (1987) исемле җыентыкларында тупланган.

*Әд.:* Г а м б ә р о в Н. Тәлгәшләрдә сусыл җимешләр // Казан утлары. 1973. № 10; Р ә ш и т Ә. Якты эзе калды // Казан утлары. 1997. № 11.

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Ислам Насыйбулла улы (10.10.1918, Казан губ. Тәтеш өязе, хәзер Апас р-ны Багыш а. — 30.12.1981, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (25.11.1943, 27.8.1944, 31.5.1945), старшина. Туган авылында колхозда эшли. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1030 нчы укчы полкның 76 *мл* лы туплар батареясында туп командиры (11 нче һәм 47 нче армияләрнең 260 нчы укчы дивизиясе). Төньяк-Көнбатыш, 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Демян оборона (1942) һәм һөҗүм (1943) операцияләрендә, Люблин-Брест (1944), Варшава-Познань, Көнчыгыш Померания һәм Берлин һөҗүм операцияләрендә (барысы да — 1945) катнаша. 1943 нең 21 ноябрендә Золотой Рог авылы (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Ветка шәһәреннән көньяк-көнбатыштарак) өчен барган (расчёты б-н бергә дошманның 3 пулемётын, 2 блиндажын һәм 3 тубын юк итә), 1944 нең 6–8 июнендә Ковель шәһәре (Украина ССР) янындагы (дошманның 3 ут ноктасын юк итә, гаскәрнең алга китүенә булыша), 1945 нең 20–22 февралендә Шнайдемюль шәһәре (хәзер Пила ш., Польша) өчен барган (туптан атып дошманның берничә ут ноктасын сафтан чыгара) сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Апас р-нының Чирмешән авыл советы рәисе

булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Р о щ и н И.И. Солдатская слава. М., 1988. Кн. 7; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Мәгъсүм Нәҗип улы (15.10.1925, Мамадыш кантоны Байлангар а. — 14.10.2009, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Свердловск шәһәрендә юридик (1954) һәм пед. (1959) ин-тлар тәмамлый. 1962–64 елларда Урал һәм Казакъстанның Күкчәтау өлкәсе шәһәрләрендә тикшерүче, прокурор вазифаларын башкара. 1960 тан хокук темаларына очерк, хикәяләрен җирле һәм үзәк матбугатта бастыра башлый. Очерклардан торган беренче китабы «Хәвефле сукмак» («Конец опасной тропы», 1968) рус телендә нәшер ителә. БАССР (1964–70) һәм ТАССР (1970–81) прокуратураларында эшләгән елларында аеруча актив иҗат итә. Укучыларга «Без капчыкта ятмый» (1972), «Телсез шаһитлар» (1974; рус теленә тәрҗемәсе «Немые свидетели», 1979), «Төнге ату» (1975), «Алтын алка» (1977), «Яшерен касса» (1978; рус теленә тәрҗемәсе «Тайная касса», 1982), «Син тикшерүче бит» (1987), «Күктән иңгән дәлил» (1991), «Кайтаваз» (1996), «Елан гадәтен үзгәртми» (2000), «Дулкынга — дулкын» (2005) детектив хикәяләр һәм повестьлар җыентыклары авторы буларак билгеле. Әсәрләренең нигезендә авторның криминаль дөньяны күзәтүләре, җинаятьчелекнең социаль тамырлары, хокук саклау органнары хезмәткәрләренең җәмгыятьтәге роле турында уйлanулары ята. Н.ның күп кенә әсәрләре украин, грузин, удмурт, чуаш телләренә тәрҗемә ителә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г а л и м у л л и н Ф. Ак теләкне җилкән итеп // Казан утлары. 1995. № 10; М и н ш и н М. Детектив // Правосудие в Татарстане. 2002. № 1.

*Г.М.Габделхакова.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Минзаһир Насыйбулла улы (1.7.1908, Казан губ., Тәтеш өязе Иске Барыш а. — 17.10.2001, Казан), шахтёр, Соц. Хезмәт Герое (1957). 1923–30 елларда Калатинск бакыр руднигында (Урал өлкәсе) эшли. 1932–39 да В.И.Ленин исем. Мәскәү метрополитены төзелешендә казучылар бригадиры, 1939–61 дә «Егоршинуголь» трестының «Буланаш-4» шахтасында (Свердловск өлкәсе). Н. җитәкчелегендә шахтёрларның хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә, шахта коесын түгәрәк металл тюбинглар б-н ныгытуга, күмерне шартлату ысулы б-н чыгаруга булышлык итүче алдынгы алымнар үзләштерелә. Герой исеме илнең халык хуҗалыгын үстерүнең 5 еллык планын үтәүдәге хезмәтләре өчен бирелә (1956–60). Ленин ордены, медальләр, «Мактаулы шахтёр» билгесе (1947) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Ш и т и н С. Проходчик Минзагир Нацибуллин. Свердловск, 1958; Герои Трудовой Славы. Свердловск, 1969; Б р ы л и н А.И., К о в е р д а П.Т. Артёмовский. Свердловск, 1983.

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Равил Талип улы (24.12.1945, Үзбәкстан ССРның Ташкент өлкәсе, Хаваст р-ны Зур Чокыр а.), социолог, социол. фән. д-ры (1991), проф. (1992). Башкорт ун-тының филол. ф-тын тәмамлый (1971). 1971–74 елларда урта мәктәптә укыта (Уфа ш.). 1974 тән Уфа авиация ин-тында, социол. һәм политология каф. мөдире (1990 нан). Хезмәтләре социол.-политология процессларына, идарә итү социологиясенә карый.

Х е з м.: Коллективы станут стабильными. Уфа, 1988; Социальные проблемы миграции. Уфа, 1989; Основы социологии: Учеб. пособие. Уфа, 1993 (авторлаш); Население Башкортостана: Социально-демогр. анализ. Уфа, 1995.

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Руслан Сәгыйть улы (4.12.1937, Азнакай р-ны Азнакай а.), биофизик, физика-матем. фән д-ры (1991), проф. (1992). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, авиация техникасы буенча Дәүләт ком-тында эшли (Уфа). 1962 дән СССР ФАнең Башкорт ф-лы Органик химия ин-тында, 1978 дән Башкорт мед. ин-тында, физика каф. мөдире (1982 дән). Хезмәтләре молекулаларның структураларын тикшерүгә, биол. актив кушылмаларның молекуляр тәэсир итү механизмын өйрәнүгә карый. Н. микродулкын спектрографын эшли. Кайбер молекулаларда азот атомнарының квадруполь бәйләнешләре структурасын билгели һәм тензорларын таба. Азот атомнары кергән гетероциклик молекулаларның күзәнәк мембранасының фосфолипидларына тәэсир итү механизмын тикшерә, үзара тәэсир итешүче молекулаларның электрон төзелеше үзгәрешен һәм конформацион халәтләрен күрсәтә.

Х е з м.: Микроволновой спектр изотопозамещённых молекул пиразола // Оптика и спектроскопия. 1973. Т. 1, вып. 1 (автордаш); Квантово-химический подход к процессам взаимодействия эндогенных факторов с фосфолипидами клеточных мембран // Успехи физиологических наук. 1994. Т. 25, № 1 (автордаш); Методы и технические средства медицинской визуализации. Уфа-М., 2003 (автордаш); Effect of pyrazole on the conformational state of cell membrane phospholipides // Biophysics. 1993. V. 38, № 4 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Хәмидулла Нотфулла улы (24.1.1919, Казан губ., Спас өязе Әлки а. — 2.1.1984, Тольятти ш.), Дан орденының тулы кавалеры (23.2.1944, 14.8.1944, 15.5.1946), гв. старшинасы. Туган авылында колхозда эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1942 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 172 нче гв. укчы полкында автоматчылар взводы командиры ярдәмчесе (8 нче армиянең 57 нче гв. укчы дивизиясе). Коньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Изюм-Барвенково, Донбасс (икесе дә — 1943), Никополь-Кривой Рог, Белоруссия (икесе дә — 1945), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 1 февралендә Натальевка авылы (Украина ССР, Днепропетровск өлкәсе Межевая р-ны) өчен барган сугышларда (авылны алу өчен отделениене һөҗүмгә күтәрә; дошман контрһөҗүмен кире кайтарганда танкларын сафтан чыгара), 1944 нең 20–21 июлендә Любомль шәһәреннән



Минзаһир Н. Насыйбуллин.



Х.Н. Насыйбуллин.

(Волынь өлкәсе) көнбатыштарак Көнбатыш Буг елгасын кичкәндә (беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга; Рудка (Магнуш плацдармы) торак пунктын алуда катнаша), 1945 нең 16–27 апрельләрендә Зеелов шәһәре, Зеелов калкулыгы һәм Берлин янындагы сугышларда (сафтан чыккан взвод командирын алыштыра; сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә; беренче булып Шпрее елгасын кичеп чыга; Берлин урамнарындагы сугышта дошманның контрһөҗүмнәрен кире кайтара) батырлык күрсәтә. 1946 да демобилизацияләнә. Тольятти шәһәрендә «Куйбышевгидрострой» трестында эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий. биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИН** Ярулла Насыйбулла улы (15.11.1904, Казан губ., Тәтеш өязе Коллар а., хәзер Апас р-ны Кызыл Тау а. — 15.5.1973, Казан), хокук белгече. ВКП(б) ҮК каршындагы Югары парторглар мәктәбен (Мәскәү, 1941), Бөтенсоюз юридик читтән торып уку ин-тының Казан ф-лын (1952) тәмамлый. 1929–30 елларда ВКП(б)ның Иваново өлкә ком-ты инструкторы. 1933–35 тә ТАССРның Балтач р-ны МТСының сәясәт бүлеге башлыгы урынбасары. 1935–37 дә Мәскәүнең Киров район халык мәгарифе бүлеге парткомы, 1937–38 дә ВКП(б)ның Сокольники район ком-ты секретаре. 1938–39, 1948–50 дә ВКП(б)ның Казан шәһәре Бауман райкомы 1 нче секретаре. 1939–40 та ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты секретаре. 1945–48 дә Казандагы 741 нче з-дта ВКП(б) ҮК парторгы. 1950–57 дә ТАССР юстиция министры. 1957–58 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгының бүлек башлыгы. 1958–65 тә ТАССР Югары мәхкәмәсе рәисе. 1938–51, 1959–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов, М.М.Мәүләтшин.*

**НАСЫЙБУ́ЛЛИНА** Гөлназ Рөстәм кызы (15.6.1988, Лаеш р-ны Хәерби а.), спортчы (самбо, дзюдо); дзюдо (2004), самбо (2006) буенча Россиянең спорт остасы. Әлмәт нефть ин-тын тәмамлый (2010). Спорт б-н 1999 елда шөгыльләнә башлый, тренеры — Р.Г.Насыйбуллин. ТР (2003–06, 2009 — самбо, 2007–08 — дзюдо), РФ Фән һәм мәгариф министрлыгы (2004 — самбо), Идел буе феде-

раль округы (2003 һәм 2007–08 — дзюдо), ТР «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте (2009 — дзюдо), РФ (2004–06 — самбо, 2007–08 — дзюдо), дөнья (2006 — самбо) чемпионатларында җиңүче. ТР (2007–08 һәм 2010, көмеш — самбо), РФ Фән һәм мәгариф министрлыгы (2005, көмеш — самбо), Идел буе федераль округы (2004, бронза — самбо, 2004 һәм 2009 — дзюдо) чемпионатларында, Россия беренчелекләрендә (2007, көмеш; 2008, бронза — самбо), В.И.Карпычев истәлегенә дзюдо буенча турнирда (2004 — көмеш) медальләр ала. 2005 тән Әлмәт шәһәрендә яши. 2009–10 да «Юность» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы, 2011 дән Татарстан нефть-газ эшкәртү идарәсендә инженер.

**НАСЫ́ЙР ОСТА́** (15 йөз ахыры — 16 йөзнең 1 нче яртысы), металлны сәнгатьле эшкәртү остасы, каллиграф. Казан ханы Мөхәммәдәмин сараенда эшләгән *бакырчы* улы. Н.о. исеме 16 йөз уртасында алтынсу-сары җиздән чүкеп ясалган шәраб кувшины сабына язылган («Әмин ханның бакырчы остасы улы Насыйр оста»). Кувшинны казанлы Ә.Ишморатов таба, текстны галим Ә.Хәйруллин укый. Аны бизәүдә татар, гарәп һәм фарсы телләрендә шигъри миниатюралар композициясендә үсенте рәвешендәге (йөзем тәлгәше) бизәк файдаланылган. Шигырьләр *Кибәккә* багышланган (тарихи чыганакларда искә алынган, 1552 елда Казанны саклаганда һәлак булган *карачыбәк* исеме), мәхәббәт шигырьләренең авторы Сөембикә ханбикә дип фаразлыйлар. Нәфис борынлы,төбе алты кырлы кувшин суда йөзүче кошны хәтерләтә. Сабы елан рәвешендә бөгелгән, югары өлешендә болгар балчык савытларына хас сылап ябыштыру алымы файдаланылган (к. *Керәч сәнгате*). Савытка ике яклап бадәмсыман формада кургаш күзгеләр эретеп ябыштырылган. Канфарланган фонда чүкеп ясалган бизәк җанлы, иҗади эшләнгән, язулар уеплау ысулы б-н төшерелгән. Рәвеше б-н фарсы һәм Урта Азия савыты афтабага охшаган, әмма үзенә генә хас булган сыйфатлар җирле болгар-татар сәнгать традицияләре турында сөйли. Кувшин ТР Милли музеенда саклана.



Насыйр оста. Кувшин. Җиз, аккургаш. Чүкеп бизәк төшерү, уеплау, кою. 16 йөз уртасы. ТР Милли музее.

*Әд.:* Хәйри Ә. Җиз савытка язылган борынгы язу (XV гасырның азагы — XVI гасырның башы) // Мирас. 1994. № 11/12; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НАСЫ́ЙР ХӨСРӘ́Ү** (نصـــير خســرو, псевд., чын исеме Әбү Могыйн әл-Кубадияни әл-Мәрвәзи) (1004 — Кубадиян а., Әфганстанның Бәлх ш. янында — 1072 дән соң, Әфганстанның Бадахшан өлкәсе Иомган а.), фарсы-таҗик шагыйре. Исмәгыйлияләр мәзһәбе идеяләрен тарата. Көферлектә гаепләнеп, Бәлхтән куыла. Гомеренең ахырына кадәр Бадахшан тауларында яши. Әдәби мирасын 12 мең бәйттән торган диван, «Раушанайинамә» («Балкышлар китабы») поэмасы, Мисырга сәяхәт кылганда (1046–52) алган тәэсирләре нигезендә язылган «Сәфәрнамә», берничә дини-фәлсәфи трактат тәшкил итә. Әсәрләрендә Н.Х. хакимият башлыклары алдында түбәнсенгән сарай шагыйрьләрен, фәнни һәм фәлсәфи фикер үсешенә киртә куючы мөселман ортодоксаль руханиларын тәнкыйтьли, фәкыйрьләргә мәрхәмәтле булуны таләп итә. Җәмгыятьтәге бәлаләрнең сәбәбен «яман дин» һәм «гаделсез хакимият»нең таралуыннннан күрә.

Әсәр.: Сафар-наме. Книга путешествия. М.–Л., 1933.

*Әд.:* Бертельс А.Е. Насир-и Хосров и исмаилизм. М., 1959.

**НАСЫЙРИ́** Зыя (1886–1933), язучы. Югары белемне Төркиядә ала. Кайткач, Оренбургта укыта, «Вакыт», «Йолдыз» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. 1913 елдан сәүдә фирмасында эшли. 1907–09 да язылган «Кемнең баласы?», «Ахирәт йорты», «Поездда угрылык» исемле хикәяләр, «Ятимнәр» пьесасы, «Көчләп кияүгә бирмиләр» комедиясе һ.б.ның авторы.

**НАСЫЙРИ́** (Насыйров) Имай (Имаметдин) Низаметдин улы (12.10.1898, хәзер БРның Эстәрлетамак р-ны Түбән Усылы а. — 29.3.1942 яки 29.9.1942), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1910–14 елларда Эстәрлетамак мәдрәсәсендә укый. 1914–18 дә авыл китапханәсе мөдире. Гражданнар сугышында катнаша. 1919 да Урал фронтындагы Башкорт бригадасы политбүлегенең агитаторы итеп билгеләнә, Күдәй кантонында милиция башлыгы булып эшли (1920); 1921–22 дә — БАССР милициясе баш идарәсенең сәяси комиссары. 1923–31 дә респ-ка басма органнарын оештыруда катнаша, «Белем», «Сәсән», «Керпе» ж-лларын, «Коммуна» г-тасын редакцияли (1931–32). 1934 тә Мәгариф халык комис-тында инспектор, 1934–36 да «Башкортстан вышкаһы» г-тасы, 1936 дан «Коммуна» г-тасы һәм «Һәнәк» ж-лы мөхәррире. 1920–24 тә РКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты һәм Башкортстан ҮБК әгъзасы буларак РКП(б)ның 10 нчы съездына делегат итеп сайлана. Революциягә үзгәрешләргә, яңа тормыш төзүгә дан җырлаган беренче шигырьләре 1920 дә языла. Н. — «Терeләй ҡаберҙә» (Уфа, 1926), «Вагонда» (М., 1929), «Гөлдәр» (Уфа, 1930) исемле маҗаралы повестьлар авторы. «Сибай» (Уфа, 1936), «Еңелгән ятыу» (Уфа, 1937) повестьларында колхоз төзү, «Күҙәй» (Уфа, 1936 ) романында Башкорстанның бер кантонында совет хакимияте урнаштыру вакыйгалары (романда сүз реаль тарихи шәхесләр һәм автор үзе шаһит булган вакыйгалар турында бара) тасвирлана. «Беҙ һул яҡ ярҙан» романы төгәлләнми кала. Н. — башкорт әдәбиятына һәм сәнгатенә багышланган мәкаләләр авторы. 1937 нең февралендә репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Әсәрҙәр: 3 томда. Өфө, 1957–68.

*Әд.:* Зарипов Н.Т. Имай Насыйри: Тормошо һәм ижады. Өфө, 1983.

**НАСЫЙРИ́** Каюм (Габделкаюм) Габделнасыйр углы (2.2.1825, Казан губ., Зөя өязе Югары Шырдан (Кече Шырдан) а. — 20.8.1902, Казан), мәгърифәтче, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф. Н.ның бабасы һәм атасы филол. буенча берничә китап язган гыйлемле кешеләр була. Башлангыч белемне Н. атасы мәктәбендә ала, 1841–55 елларда Казанда «Касыймия» мәдрәсәсендә укый.



«К.Насыйри портреты». Рәссам Ф.М.Михайлов. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Үзлегеннән рус телен өйрәнә. 1855–71 дә — Казан руханилар уч-щесендә, соңыннан Казан руханилар семинариясендә татар теле укыта. 1871 дә татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләре буенча Казан укыту округы инспекторы В.В.Радлов тәкъдиме б-н Казанда татар балалары өчен башлангыч рус-татар мәктәбе ача. Соңрак В.В.Радлов б-н укыту методикасы мәсьәләләрендә фикер каршылыклары килеп чыгу сәбәпле, 1876 да мәктәптән китә һәм әдәби, фәнни эшчәнлек б-н шөгыльләнә башлый. Н. фикеренчә, татар халкына белем бирү юлында рус мәдәнияте б-н танышу һәм якынаю зур әһәмияткә ия. 1885 тә Н. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза булып сайлана. Н. гуманитар фәннәрнең төрле өлкәләрен үстерүгә үзеннән зур өлеш кертә, хәзерге татар әдәби теленә нигез сала. Татар лексикологиясе буенча — русча-татарча «Ләгать китабы» сүзлеге (1892), татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге «Ләһҗәи татари» (1–2 т., 1895–96), фонетика һәм грамматика буенча «Кавагыйд китабет,

ягъни тасниф вә имлә кагыйдәләрен бәян кыйлучы бер яңа фәндер» (1892), «Әнмүзәҗ. Лисаныбызның сарыф вә нәху кагыйдәләре бәянында» (1895) хезмәтләрен яза. Кеше акылына, фәнгә, этика, тел мәсьәләләренә, фольклор, әдәбият, музыкага һ.б.га багышланып, 40 бүлектән торган, асылда беренче татар энциклопедиясе «Фәвакиһелҗөләса фил-әдәбият» (1884) фундаменталь хезмәте татар тарихында зур яңалык була. Н.ның фәнни хезмәтләренең күбесе татар халкы тарихын, Россия һәм гомумхалык тарихын өйрәнүгә багышлана. Этнографиягә караган хезмәтләрендә бик күп халык сынамышлары, әкиятләр, әйтемнәр, җырлар, туй, мәет озату һ.б. гаилә йолалары тасвиры, татар халкының матди мәдәниятен тәшкил итүче йорт-җир, кием-салым, азык-төлек, халык медицинасы турында мәгълүматлар зур урын ала. Галим тарафыннан табигать күренешләре турында татар телендә беренче фәнни-популяр «Буш вакыт» әсәре (1860) бастырыла (татар балалар әдәбиятының беренче үрнәге санала). «Хисаплык, ягъни гыйльме хисап кагыйдәләре, яки арифметика вә һәм хисаплык мәсьәләләре» (1873), «Истыйляхат гыйльме һәндәсә» (1895), «Ысул җәгърафияи кабир» (1–3 кис., 1894–99) дәреслекләре авторы. Табигать фәннәренә караган «Зирагать гыйльме, ягъни иген икмәк вә ашлык чәчмәк вә җимеш бакчалары ихъя кыйлмак бәянында бер яңа фәндер» (1892), «Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек» (1894) хезмәтләрендә, зәркән һәм слесарь һөнәрләре, ризык әзерләү турындагы брошюраларында күп кенә файдалы мәгълүмат тупланган. Н. җитәкчелегендә 1871–97 дә (1886, 1887, 1895 тә туктатылып тора) ел саен «Казан календаре» басылып чыга. Анда, календарьларга хас мәгълүматтан тыш, күп кенә фәнни һәм әдәби материал да бирелә. Н. мирасы Г.Тукайга, М.Гафуригә, Г.Камалга зур йогынты ясый.

Ә с ә р.: Әбугалисина. К., 1881; Басылмаган әсәрләр. К., 1926; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1974–75; Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2003–06; Поверья и обряды Казанских татар, образовавшиеся мимо влияния на жизнь их суннитского магометанства // Зап. Имп. Рус. геогр. об-ва по отделению этнографии. СПб., 1880. Т. 5; Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах. К., 1960; Книга о воспитании. К., 1992.

*Әд.:* Каюм Насыйри мәҗмугасы: Вафатына егерме ел тулу мөнәсәбәте белән чыга. К., 1922; Каюм Насыри. 1825–1945 (Материалы науч. сессии, посвящённой 120-летию со дня рождения). К., 1948; Г а й н у л л и н М.Х. Каюм Насыров и просветительское движение среди татар. К., 1955; Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри: Сб. науч. докладов. К., 1976.

*Р.М.Мөхәммәтшин, А.В.Климин.*

**НАСЫЙРИ́ КАЮ́М ИСЕМЕНДӘГЕ́ АРХИТЕКТУ́РА-ЭТНОГРА́ФИЯ КО́МПЛЕКСЫ**, Яшел Үзән р-нының Олы Ачасыр авылында. 1992 елның 1 гыйнварында оештырыла, 1947 дә мәгърифәтче-галим *К.Насыйриның* туган авылы Кече Шырданнан Олы Ачасыр авылына күчерелгән йортта 1997 нең 1 мартында ачыла. Экспозиция мәйданы — 290 *м*², парк зонасы — 0,15 *га*. Коллекциядә 750 саклау берәмлеге исәпләнә. Комплекс крәстиян утарыннан (йорт, абзар, сарайлар, келәт, мунча, ат дирбияләре өчен лапас) гыйбарәт. Йортта өч бүлмә: килгән кунаклар өчен ак бүлмә, хатын-кызлар ягы һәм тәһарәт бүлмәләре бар. Экспонатлар арасында — К.Насыйриның мемориаль әйберләре: күн тышлы диван, агач өстәл, К.Насыйриның үз кулы б-н эшләнгән шкаф, үзе тарафыннан төзелгән һәм шәхси мөһере куелган





Олы Ачасыр авылында Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы.
1. Музей бинасы; 2. Каюм Насыйри остаханәсе.



Олы Ачасыр авылында Каюм Насыйри исемендәге архитектура-этнография комплексы. Экспозиция фрагменты: галимнең шәхси әйберләре.

русча-татарча сүзлек, гарәп орнаменты төшерелгән өч фарфор чынаяк («Кузнецов һәм К°» фирмасы тарафыннан татар сәүдәгәрләре заказы б-н эшләнгән) бар. Ш.у. К.Насыйриның нәсел агачы һәм Олы Ачасыр авылының Насыйри хезмәтләрендә искә алынган барлык имамнары *шәҗәрәсе* куелган. Хуҗалык каралтыларыннан ашлык саклаулары, яңа өйләнешүчеләр өчен чыбылдыклы урын җәелгән «кияү келәте» әһәмияткә ия. Ш.у. 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар крәстияннәренә хас булган көнкүреш әйберләре һәм эш кораллары, ш.и. чана, ат дирбияләре, арба һ.б. күргәзмәгә куелган. Кыйммәтле экспонатларга 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Идел елгасының уң ярында яшәгән Казан татарларының көндәлек көнкүреш әйберләре (мәс., йорт җиһазы, хуҗалык кирәк-яраклары, өс киемнәре һ.б.) керә.

Музей тарафыннан ел саен музей оешу һәм ачылу көннәре, ш.у. К.Насыйри туган көн (2 февр.), Халыкара музейлар көне (18 май), Белем көне (1 сент.), Өлкәннәр көне (1 окт.) һ.б. үткәрелә.

**НАСЫЙРИ́ КАЮ́М МУЗЕЕ́**, Казанда. 2002 елның 2 февралендә ТР Милли музее ф-лы буларак ачыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында төзелгән һәм яңадан торгызылган татар төзелеш сәнгате истәлеге булган бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы 113 *м*²; 373 саклау берәмлеге. Музей комплексының фәнни концепциясе авторы һәм музейның сәнгать проекты автордашы — Р.С.Хөснетдинова. К.*Насыйрига*, 19 йөз татар мәгърифәтчелеге фикеренең үзенчәлекләренә һәм үсешенең төп этапларына, Ш.Мәрҗани һәм Х.Фәезханов иҗатларына багышланган тарихи-биографик һәм мемориаль-көнкүреш әйберләр бүлекләре экспозициянең төп бүлекләрен тәшкил итә. Экспозициядә К.Насыйриның кульязмалары һәм басма хезмәтләре, аның турында истәлекләр, шәхси архивлардан фотосурәтләр, мәдрәсәләр өчен төзегән дәреслекләре һәм татар халык авыз





Казанда Каюм Насыйри музее. 1. 2 нче зал экспозициясенең гомуми күренеше;
2. Экспозиция фрагменты: галимнең бүлмәсе.

иҗаты әсәрләренең язмалары куелган. Бай этнографик коллекцияләр һәм көнкүреш әйберләре Казанның Иске Татар һәм Яңа Татар бистәләре һәм элеккеге Зөя өязе татар авылларының көнкүрешен чагылдыра (самовар-кухня, үтүк; фарфор савыт-саба, комганнар һ.б.). К.Насыйриның абыйсы Габделхәй һәм аның улы Габделмәннең әйберләре, ш.у. бертуганының кызы — тел белгече һәм фольклорчы Х.*Насыйриянең* (Хөсәеннованың) стена көзгесе, өстәл вазасы, фарфор пудра савыты, җилпәзәсе бар. Кыйммәтле экспонатлар арасында — К.Насыйри күчереп язган кульъязма китап, аның шәхси китапханәсеннән алты китап (шәхси мөһере б-н), язучыныкы дип исәпләнгән сандык, таяк һәм хронометр-сәгать, Хөсәеновлар һәм Игъламовлар нәселеннән килгән 19 йөз ахыры — 20 йөз башындагы шәхси әйберләр (115 саклау берәмлеге), Казанның Иске Татар бистәсе (60 саклау берәмлеге) һәм Казан артының 19 йөз ахырына — 20 йөз башына караган көнкүреш әйберләре (90 га якын саклау берәмлеге), китаплар коллекциясе, ш.и. мәдрәсәләр өчен гарәп һәм татар телләрендә язылган дәреслекләр (135 саклау берәмлеге) саклана.

Музей тарафыннан ел саен К.Насыйри (2 февр.) һәм Халыкара музейлар көннәре (18 май) үткәрелә.

**НАСЫЙРИЯ́** Хәбирә Габделкави кызы (1882–1912), тел галиме, фольклорчы. К.Насыйриның шәкерте һәм бертуганының кызы. «Мөлтәкат әл-лөгат нам фарси, гарәби вә төрки» сүзлеген (1902) төзүче. Татар халкы тормышын төрле яктан яктырткан 100 гә якын кызыклы хикәяләр туплаган «Мөзахикә, яхуд Әкавиле гъәрибә» (1904) исемле җыентык авторы.

*Әд.:* Х а к о в В.Х. Хәбирә Насыйрия // Социалистик Татарстан. 1987. 7 март.

*В.Х.Хаков.*

**НАСЫ́ЙРОВ** Альберт Мәхмүт улы (7.3.1940, Казан), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (1989), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Проблемалы радиоастрономия лаб-ясендә эшли, 1978 дән В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясенең метеорлар бүлеге мөдире, 1992 дән радиоэлектроника каф. мөдире, бер үк вакытта, 2000 нән, Казан ун-тының Яшел Үзән ф-лы директоры. Хезмәтләре ионосфераның метеор күренешләре физикасына һәм радиодулкыннарның еракка таралу үзенчәлекләренә карый. Н. җитәкчелегендә радиодулкыннар таралуны тикшерү өчен үлчәү җайланмалары һәм комплекслары, радиодулкыннарның ионосферада метрлы һәм декаметрлы радиоканалларга чәчелү тәэсирен исәпләү методикалары һәм алгоритмнары эшләнә. Ионосфераның ясалма модификациясе (ионосфераның инжекция радиоканалларына ракета һәм спутниклар бортларыннан химик актив матдәләрнең һәм тизләнешле плазма бәйләмнәренең тәэсире) буенча тиңдәше булмаган эксперименталь нәтиҗәләр алына, аның радиофизик моделе төзелә.

Х е з м.: Исследования ограничения длительностей метеорных радиоэхо // Метеорное распространение радиоволн. К., 1969. Вып. 6 (автордаш); Рассеяние радиоволн анизотропными ионосферными неоднородностями. К., 1991; Исследования искусственных образований в ионосфере радиофизическими методами. Ч. 1. Искусственные ионосферные облака // Космические исследования. 1993. Т. 3, вып. 2 (автордаш); Искусственное свечение ионосферы при кратковременном воздействии мощного радиоизлучения // Изв. вузов. Радиофизика. 1999. Т. 42, № 6 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НАСЫ́ЙРОВ** Венер Тимергали улы (23.2.1949, БАССРның Чишмә р-ны Чишмә а.), генерал-майор (1994). Чиләбе хәрби танк командирлары уч-щесен (1970), Р.Я.Малиновский исем. бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1977), Генштабның хәрби академиясен (Мәскәү) тәмамлый. 1991 елга кадәр Совет Армиясендә командирлык вазифаларын башкара (Ульянов, Чиләбе, Свердловск, Пермь). 1991–2004 тә Коми Респ-касының хәрби комиссары. Медальләр б-н бүләкләнә.

**НАСЫ́ЙРОВ** Илгиз Котдус улы (23.9.1943, Төрекмәнстан ССРның Чарджоу ш.), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2002). 1966 елда Казан. ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан техник ун-тында эшли, микроэлектроника аппаратуралары конструкцияләү һәм җитештерү каф. мөдире (1996 дан), бер үк вакытта Укыту-методик үзәк җитәкчесе, проректор (1999 дан). Хезмәтләре молекуляр электроникага, радио- һәм микроэлектроникага, гидроакустикага карый. Уйлап табуга 26 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.


Х е з м.: Разработка методов и средств информационно-измерительной техники на основе ЭХПИ // Вестн. Казан. техн. ун-та. 1995. № 1 (автордаш); Проектирование новых конструкций СВЧ-устройств на основе изоморфных преобразований СВЧ-элементов // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2000. № 4 (автордаш); Информационные технологии проектирования радиоэлектронных средств в сфере пакета Microwave office: Учеб. пособие. К., 2005 (автордаш).

**НАСЫ́ЙРОВ** Мәсгут Кашшаф улы (11.8.1933, Казан – 4.10.2011, шунда ук), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1993), проф. (1996). 1957 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1957–62 дә идарә ителүле зенит ракеталары төзү пр-тиесендә әйдәп баручы инженер (Свердловск ш.). 1962–65 тә Казан «ОКБ-Союз» ракета пр-тиесендә. 1965–77, 1991–98 дә Казан авиация ин-тында, икътисад, сәнәгать һәм җитештерүне оештыру каф. мөдире (1991 дән). 1978–85 тә Казан ун-тының политэкономия кафедрасында, 1985–89 да ВЦСПСның Бөтенсоюз социаль иминиятләштерү фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары (Казан). 1998 дән Мәскәү коммерция ун-тының Казан ин-тында дөнья икътисады каф. профессоры. Хезмәтләре җитештерүнең, инвестициянең, яңа техниканың икътисади нәтиҗәлелеге мәсьәләләренә карый. 1995–2000 елларга ТРның икътисади һәм социаль үсеше Дәүләт программасының автордашы. Н. тарафыннан инвестициянең нәтиҗәлелеген билгеләү методикасы эшләнә.

Х е з м.: Измерение эффективности научно-технического прогресса в рыночных условиях. К., 1990; Анализ и основные направления развития размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996.

**НАСЫ́ЙРОВ** Минвәли Шәйхаттар улы (26.6.1930, Беренче Май р-ны Каменка а.), агроном-икътисадчы, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1984). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1968). 1945–80 елларда Чирмешән р-нында эшли: «Кызыл Сабанчы» к-зында, Орджоникидзе исем. к-зда хисапчы ярдәмчесе (1947–54), район финанс бүлегенең участок инспекторы (1954–58), Югары Каменка авыл советы рәисе (1958–60), Орджоникидзе исем. к-з рәисе (1960–71), район а.х идарәсе башлыгы (1971 дән). 1980–95 тә «Мамадыш» с-зы директоры. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**НАСЫ́ЙРОВ** Ринат Сәхиулла улы (5.1.1942, БАССРның Аургазы р-ны Толбазы а.), архитектор, нәкышьче. Урал политехника ин-тының архит-ра ф-тын тәмамлый (Свердловск ш., 1965). 1965–70 елларда «Башкортгражданпроект» ин-тында (Уфа ш.). 1970 тән Казандагы «Татгражданпроект» ин-тында проектларның баш архитекторы, Чаллы шәһәренең баш архитекторы, шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары (1973–84). 1984–90 елларда ТАССРның Төзелеш һәм архитектура эшләре дәүләт ком-ты рәисе. 2005 тән «Татстройпро» ҖЧҖнең баш



Р.С.Н а с ы й р о в. «Галәм хакимнәре тәгълиматы». Фрагмент. 2004.

рәссамы, архитекторы (Казан). Архитекторлар берлеге (1969), Рәссамнар берлеге (1983) әгъзасы. Уфадагы «Тужиловка» (автордаш, 1966), «Телеүзәк» шәһәр р-ннарын детальләштереп планлаштыру (1968), Эстәрлетамактагы торак микрорайоннары проектлары авторы (1965–68).

Чаллы шәһәренең көньяк-көнбатыш р-нын (1975–90, Г.А.Бурков, Ю.К.Наймарк б-н автордаш), Алабуга шәһәренең эскиздагы ген. планын (Ю.К.Наймарк б-н берлектә, 1985), «Татэнерго» административ бинасын (Г.А.*Ба-*

*кулин* б-н берлектә, 1985–86), Казанның Кремль урамындагы Прокуратура бинасын (1973) һ.б.ны планлаштыру проектлары авторы. Чаллы шәһәрен архитектур-сәнгати бизәү ген. планы авторларының һәм тормышка ашыручыларның берсе: «Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл» монументаль-скульптура композициясе (И.М.*Ханов* б-н берлектә, 1974–75), «Энергетик» мәдәният сараена каршы мәйдандагы фонтан (1980 еллар), «Казан» кунакханәсенә каршы мәйдандагы (1978), «Төзүче» стадионы каршындагы (1979–82), «Энтузиастлар» бульварындагы (1978–82), шәһәр ял итү зонасындагы скульптур композицияләр (1984–86), Арча р-нындагы Яңа Кырлай музей комплексы (1996) архитекторы. 1990 еллар башыннан биналарны борынгы Һиндстан архит-расы кануннары буенча проектлый: Түбән Кама шәһәрендәге традицион булмаган мед. буенча дәвалау үзәге (2004), «Дөнья манарасы» халыкара проекты (Айне Хартман б-н автордаш, 2002). 1980 еллардан станлы нәкышь б-н актив шөгыльләнә, авангард юнәлешендәге рәссам буларак танылa. Төп әсәрләре: «Автопортрет» (1987), «Сабыен кочкан Мадонна» (1989), «Билгеләр» (1990–2003), «Аң сәяхәте» (1990), «Минем рухиятем» (1991), «Планетаның яратылышы» (1944) серияләре, «Эволюция» триптихы (1994), «Адәм б-н Һауа» (1999), «Ислам дөньясы» (2000–02), «Гыйрәкта туган уйлар» (2003), «Веда дәватлары» (2004). «Медитация», «Капка» (икесе дә — 2005). Н. — «Билгеләр мәңгелек» инсталляциясе (2006), видеоарт жанрындагы «Төргәкләр», «Индиго», «Аң сәяхәте» (барысы да — 2006) компьютер графикасы әсәрләре авторы.

Респ-ка (1967 дә Уфада, 1983 тән — Казанда), зона — «Зур Идел» (Түбән Новгород ш., 2003), халыкара (Дюссельдорф ш., Германия, 1991; Флодроп ш., Голландия, 1992; «Күчмә төргәкләр — habar» сәнгать проекты, Мәскәү-Казан-Әнкара, 2006), уртак (Ә.Ильясова, Ш.Фәрхетдинов, И.Хәсәнов б-н берлектә, 2006, Мәскәү) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1994, 2003; хатыны С.Силантьева һәм Ш.Фәрхетдинов б-н берлектә 1996, 1997, 1998, 2000 дә) уздырыла. Әсәрләре «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, чит илләрдәге шәхси тупланмаларда (Албания, Һиндстан, Голландия) саклана.

*Әд.:* Вәлиева-Сөләйманова Г.Ф. Бәхет кошы кая куна? // Казан утлары. 1994. № 2; шул ук. Врата открыты ... // Идель. 1994. № 3/4; Ринат Насыйров. Живопись, графика: Каталог. М., 2006.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НАСЫ́ЙРОВ** Тәлгат Мирзасалих улы (20.8.1925, Актаныш р-ны Иске Әгъбәз а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1962). Благовещенск пед. ин-тын (1951) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша (1942 елдан), 1953 кә кадәр Совет Армиясендә. 1956–97 елларда Казан а.х. ин-тында, 1969–85 тә КПСС тарихы каф. мөдире. Татар вакытлы матбугаты (ш.и. эмиграция матбугаты), Татарстан матбугатын һәм ТАССРда китап нәшер итүнең 1941–45 тәге тарихы буенча күренекле белгеч. Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышында катнашучыларның тормышы һәм эшчәнлекләре турындагы хезмәтләр авторы. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бессмертные имена. Хасан Урманов. К., 1967; Октябрь и печать Татарии. 1917–1920 гг. К., 1975; Репрессии против небольшевистской татарской прессы в 1917–1919 годах // Отеч. история. 2000. № 4.

**НАСЫ́ЙРОВ** Хәлим Мөсәвир улы (1.10.1942, БАССРның Әлшәй р-ны Ыслак а. — 24.9.2003, Уфа), фармаколог, мед. фән. д-ры (1986), проф. (1987). Башкорт мед. ин-тын тәмамлагач (1967), шунда ук эшли, үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1978 елдан), фармакология каф. мөдире (1986 дан), бер үк вакытта фармакология ф-ты деканы (1985 тән). Хезмәтләре яңа табигый һәм синтетик дарулар эшләү, аларның дәвалау үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый.


Х е з м.: Фитология: Лекарственные растения в научной медицине. Уфа, 1993 (автордаш); Фармакология в Башкирском государственном медицинском университете: Учеб. пособие. Уфа, 2001 (автордаш).

**НАСЫ́РОВ** (Насыйров) Семён Рафаилович (14.12.1958, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1996), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2007). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли: Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында һәм матем. анализ кафедрасында (1987 дән, 1998 дән каф. мөдире), механика-матем. ф-ты деканы (1996 дан), проф. (1998). Хезмәтләре комплекслы үзгәрешле функцияләр теориясенә, кырый мәсьәләләргә, риманча өслекләргә карый. Н. риманча өслекләрдә ирекле чикләре булган яңа класс кырый мәсьәләләрнең чишелүчәнлеген билгели; аналитик функцияләр бербитлелегенең җитәрлек шартларын таба; риманча өслекләр төшенә таба җыелучанлыкның төрле төрләрен кертә һәм өйрәнә; мероморф функцияләр әзлекләлеге җыелучанлыгы б-н аларга тиңдәш булган риманча өслекләр төшләренә таба җыелучанлык арасында бәйләлек турында күп кенә теоремаларны исбатлый; битләрнең төренә һәм санына карата төрле фаразлар өстәп бирелгән кәкреләр б-н чикләнгән риманча өслекләрнең булуы өчен кирәкле һәм җитәрлек шартлар таба; туры һәм кире кырый мәсьәләләр чишүнең күп кенә билгеле якынча алымнарының җыелучанлыгын дәлилли; иң зур күтәрү көченә ия булган аэродинамик дуга табу турындагы гомумиләштерелгән М.А.Лаврентьев мәсьәләсенең чишелүчәнлеген тикшерә. Математика, механика һәм информатикадан яшьләр мәктәп-конференцияләрен үткәрү буенча Н.И.Лобачевский исем. матем. үзәкне оештыручы.


Х е з м.: Смешанная обратная краевая задача на римановых поверхностях // Изв. вузов. Математика. 1990. № 10; Разветвлённые накрытия римановых поверхностей с заданной проекцией края // Алгебра и анализ. 1993. Т. 5, № 3; Метрическое пространство римановых поверхностей над сферой // Мат. сб. 1994. Т. 185, № 7; К экстремальной задаче М.А.Лаврентьева о подъёмной силе при обтекании дужки малой кривизны // Докл. РАН. 1999. Т. 365, № 5.

**НАТЮРМО́РТ** (франц. nature morte, сүзгә-сүз — «үле табигать»), жансыз предметларны: йорт кирәк-ярагы, җиләк-җимеш, чәчәкләр, атылган киек, диңгез байлыклары, нинди дә булса эшчәнлек атрибутларын һәм коралларын сурәтләүгә багышланган сынлы сәнгать жанры (башлыча станлы нәкышь, графика). Н. башка сынлы сәнгать жанрларыннан сюжетның тышкы күренеш өчен формаль рәвештә кулланылуы б-н аерылып тора. Аның үзенчәлекле сыйфаты — ассоциативлык. 19 йөз башында Л.Д.*Крюков* Казан сәнгатендә беренчеләрдән булып, «тәҗрибә өчен» натурадан «табигать тарихы әйберләрен»: минераллар, чәчәкләр, кош карачкыларын рәсемгә төшерә. Н. — мәгънәне әйбер б-н күрсәтүче эмблемалар атрибуты — Казан ун-ты басмаханәсенең китап продукциясен бизәүче политипажларда кулланыла. Н. сәнгатен үзләштерү сынлы сәнгать өлкәсендә иҗатка өйрәнүнең мәҗбүри башлангыч этабы булып санала. Рәссамнар В.Г.Худяков, П.П.Рёмер һәм И.И.Шишкиннан нәкышь дәресләре алган А.Ф.*Лихачёв* Н.лары моңа ачык мисал. *Казан сынлы сәнгать мәктәбендә* Н. классы уку программасының мөстәкыйль бүлеген тәшкил иткән. Көнкүреш әйберләреннән төзелгән Н. күпчелекне алып торган. З.Д.Агафонова, П.М.*Дульский*, О.П.Приклонская һ.б.ның әсәрләре шундыйлардан. Н.И.*Фешин* җитәкчелегендәге (1908 дән) натюрморт классының укыту программасы эчтәлеге тамырдан үзгәрә: моңа кадәрге сюжетлы-тематик әсәрләр урынына колоритлы һәм фактуралы характердагы күренешләргә өстенлек бирелә. Н., мөстәкыйль жанр һәм портрет композицияләренең бер өлеше буларак, Фешин иҗатында югары үсешкә ирешә. 1920 еллар башында Н. «*Подсолнечник*» һәм «*Всадник*» берләшмәләре әгъзаларының нәкышь һәм графика әсәрләрендә форма иҗат итүдә кыю эзләнүләр чарасы булып санала. Казан ирекле сәнгать остаханәләренең тәҗрибә-әзерлек остаханәсе җитәкчесе рәссам К.К.*Чеботарёв* Н.ны тәҗрибәләр өчен ачылган жанр буларак аңлавын аеруча ачык чагылдыра. Уку программасына формасы һәм төсе б-н чикләнмәгән Н. иҗат итү биремнәре кертелә, 1930–50 елларда Н. көнкүреш характерындагы этюдлардан тора (Н.М.*Сокольский*, В.К.*Тимофеев*, М.М.Васильева, Н.Н.Ливанова һ.б.ның әсәрләре). Н. шундый ук сыйфатта жанрлы һәм тарихи картиналарда да урын ала, бизәк буларак, сюжетның төп фабуласын тагын да тулыландыра һәм ача. Н. жанрына Б.И.Урманче да күп тапкырлар мөрәҗәгать итә. Акварель техникасында зур осталык б-н төрле чәчәкләр һәм җиләк-җимешләрне рәсемгә төшерә. 1960 еллардан башлап, сюжетлы-тематик картиналар жанры үсеш алу һәм «кырыс стильдәге» идея эчтәлегенең әһәмияте көчәю сәбәпле, Н., композициядәге мохитне тасвирлавы б-н бергә, кинаяле мәгънәләр салынган рольне дә башкара (З.Ф.*Гыймаев*, И.К.*Зарипов*, В.Н.*Скобеев*, Ш.М.*Шәйдуллин*, В.К.Фёдоров һ.б.ның әсәрләре). Татарстан сәнгатендә әйдәп баручы Н. остасы Е.В.*Зуев* аны сюжетлы-тематик жанрлар б-н тигез хокуклы дәрә-











**Натюрморт.** 1. Е.К. Ч а с т и х и н а. «Натюрморт». 1921. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. А.А. Г о н ч а р о в. «Натюрморт». Линогравюра. 1920 еллар уртасы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. Б.И. У р м а н ч е. «Салатлы натюрморт». 1945; 4. К.Е. М а к с и м о в. «Ак вазадагы йөзем». 1956. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. Г.Г. Р а х м а н к у л о в а. «Казан сувенирлары». Акварель. 1969. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Е.В. З у е в. «Катык». 1976. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. И.К. З а р и п о в. «Авыл натюрморты». 1982–85. Картон. Майлы буяу. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. С.В. Н е у с т р о е в. «Узган еллардан». 1987. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. Р.А. Г ы й л ә җ е в. «Натюрморт». 1990; 10. М.Ә. В а һ а п о в. «Чәчәк бәйләмнәре. Бүләккә». 1996; 11. А.М. А р т а м о н о в. «Скрипка белән натюрморт». Агач җепселле плитә (ДВП). Акрил, алтын кәгазь. 1998; 12. О.А. К у л ь п и н. «Көзге байлык». «Әбием мәшәкатьләре» сериясеннән. 1999. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. Р.М. Я к у п о в а. «Яңа самавыр». 2000; 14. Г.Р. Ф ә й з р а х м а н о в а. «Үсемлек дөньясы анатомиясе: сарымсак һәм кабак». 2001. «Форма һәм образ» галереясы. Нидерланд. Зутфен шәһәре; 15. М.М. М и н һ а җ е в. «Дуга белән натюрморт». 2004.

җәгә күтәрә. Рәссамның иҗади уй-фикерләре аның триптихларында, серияләрендә, циклларында гәүдәләнеш таба. Рәссамнар С.В.Неустроев, Б.И.Майоров, Ә.С.Фәтхетдиновлар Н.ны халык иҗаты әсәрләре, крәстиян көнкүреше әйберләре б-н тулыландыра, Р.М.Якупов чәчәкләрне сурәтли. Н. 1970–80 еллар рәссамнары: Г.Архиреев, З.П.*Аршинов*, Н.П.*Индюхов*, В.И.Кочунов һ.б. иҗатында Н. дәвамлы үсеш ала. И.К.Зарипов, Р.Ә.*Килдебәков*, Г.Г.Рахманкулова, Ә.Б.Саттаров иҗатларында халык гамәли-бизәлеш сәнгате әйберләре б-н тулыландырылган татар милли көнкүреше һәм интерьерының матурлыгы раслана. 1990–2000 еллар рәссамнарының иҗатында Н.ның әһәмияте арта. Тирән эчтәлекле символика һәм композиция төзелеше, үз карашыңны сайлау, формалашкан нәкышь традицияләренең үсеш алуы яки яңа, авангард һәм модернистик формалар сайлау җентекле анализ предметына әверелә. Татар орнаменты һәм гамәли сәнгать өлгеләреннән борынгы көнкүреш әйберләре Н.ы, рәссам иҗатының программ характерына басым ясарга өндәгән «авыл Н.»ы аеруча популярлык казана (З.А.Бикбов, Б.Ш.Мәрданов, М.М.Минһаҗев, В.С.Низаметдинов, Д.Р.Рәхмәтуллин, Ә.Б.Саттаров, Ф.Ш.Хәсьянова, Р.М.Хөснетдинов һ.б.). В.Я.Акимов, Э.Б.Бусова, Ә.Т.Вәлиуллина, Р.Ф.Галиуллина, А.В.Карпенко, М.И.Кузнецов, О.А.Кульпин һ.б. әсәрләрендә кеше б-н табигать бердәмлеге һәм пейзаждагы Н. шигърияте ачыла. М.А.Ваһапов, Е.Ф.Грабенко, А.И.Дорофеева, Г.М.Недовизий, А.В.Новикова, А.В.Тугаринова, А.Т.Хәмидуллин Н.лары төзелешләренең классик ачыклыкка тартылуы, көнкүреш детальләренең махсус төшереп калдырылуы, монохром, еш кына якын тоннарда төзелгән төсләренең гармониясе б-н аерылып тора. В.И.Сынков графикада үзенчәлекле Н. — уйланулар жанрын тудыра. А.А.Артамонов, А.В.Бусыгин, Е.Г.Голубцов, В.А.Нестеренко, Г.Р.Фәйзрахманова, В.Харисов, И.Ә.Хәсәнов иҗатында Н. жанрындагы постмодернистик эзләнүләр сизелә.

*Әд.:* Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978.

*Е.П.Ключевская.*

**НАУ́МЕНКО** Вячеслав Васильевич (27.6.1941, Иркутск өлкәсе Нижнеудинск ш.), галим-зоотехник, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. зоотехнигы (1985). Төмән а.х. ин-тын тәмамлый (1975). 1962–73 елларда (бүленеп) Төмән өлкәсендә эшли: 1962–64, 1966–70 тә «Тобольский» с-зында (җәнлек үрчетүче, бригадир), 1966 дан чәшке фермасында управляющий, өлкә а.х. идарәсендә өлкән зоотехник, 1970–73 тә «Рощинский» с-зында баш зоотехник. 1964–66 да Омск өлкәсенең «Речной» с-зында бригадир. 1973–78 дә Чистай р-нының «Луч» җәнлек с-зында баш зоотехник. 1978 дән Менделеев р-нының «Тойма» җәнлек с-зында директор; ул җитәкләгән елларда хуҗалыкта төп фондлар яңартыла, төлке һәм көзән фермалары, склад биналары, суыту, столярлык һәм төзелеш цехлары, мәктәп, социаль-мәдәният биналары төзелә. «Почёт билгесе» ордены, СССР ВДНХсының ике бронза медале б-н бүләкләнә.

**НАУ́МОВ** Анатолий Алексеевич (29.10.1950, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2000). 1974 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Спорт авиациясе тәҗрибә КБнда эшли (1975 кә кадәр). 1977 дән Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында (хәзер Казан энергетика ун-ты), 2000 нән электротехниканың теоретик нигезләре каф. профессоры, 2006 дан — мөдире. Хезмәтләре радио- һәм электротехник җайланмалар (миллиметрлы диапазондагы дулкын озынлыкларын рекордлы флуктуацион сизгерлектә үлчи торган радиометрлар, радиометрларның идарә ителүле вольт-ампер характеристикалы Джозефсон элементлары куелган яңа типлары) төзүгә һәм куллануга карый. Н. каты ягулыклы двигательләр нурланышларын тикшерә, Җирнең түшәлмә өслеген тикшерү өчен радиодулкыннар системасын булдыра, электротехник җайланмалар диагностикасы буенча комплекслы эшләр үткәрә.

Х е з м.: Флуктуационная чувствительность радиометра с управляемой вольт-амперной характеристикой // Радиотехника. 1987. № 7; Характеристики последовательных цепочек YbaCuO джозефсоновских переходов на бикристаллической подложке // Письма в журн. техн. физики. 1998. Т. 24, вып. 24; Методы приёма и обработки широкополосных СВЧ-сигналов сверхпроводниковыми джозефсоновскими структурами. К., 2004.

*Р.Г.Усманов.*

**НАУ́МОВ** Виктор Анатольевич (1.8.1932, Казан — 23.12.2007, шунда ук), физик-химик, химия фән. д-ры (1973), проф. (1990), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992). 1955 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Азот сәнәгате ин-тының Лисичанск ф-лында эшли (Украина ССР). 1962 дән РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, дифракцион тикшеренү алымнары лаб-ясе мөдире (1986–98), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998 дән). Рентгеноструктур анализның Казан төркемен оештыручы, газ электронографиясе төркеме җитәкчесе. Хезмәтләре органик һәм элементорганик кушылмаларның структур химиясенә карый. Н. органик һәм элементорганик кушылмалар молекулаларының газ фазасындагы фәзаи төзелешен газ электронографиясе алымнары б-н квант-химия исәпләүләрен кулланып тикшерә. Фосфин, фосфит, тиофосфитларның, кислород һәм күкертнең органик кушылмаларының структур химиясе буенча хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Молекулярные структуры фосфорорганических соединений. М., 1986 (автордаш); Молекулярное строение органических соединений кислорода и серы в газовой фазе. М., 1990 (автордаш).

**НАУ́МОВ** Виктор Фёдорович (4.7.1930, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1988), ТАССРның атказ. табибе (1981). Казан мед. ун-тын тәмамлагач (1958), Шөгер р-н хастаханәсендә эшли. 1959 елдан Әлмәт шәһәр хастаханәсендә, 1963–66 да хирургия бүлеге мөдире. 1961–63 тә Казан ГИДУВының онкология каф. ординаторы. 1966 дан — Казан шәһәренең 9 нчы хастаханәсендә, 1975 тән — елгачылар хастаханәсендә, 1977 дән Казан шәһәренең 11 нче хастаханәсендә хирургия бүлеге мөдире. 1992 дән Казан шәһәре гастрохирургия үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре ашказаны һәм уникейлле эчәккә операция ясаганда әгъзаларны саклап калырлык ысуллар куллануга карый. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Сфинктеросохраняющая пластинка гастродуоденального «перехода». К., 1991.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1996.


**НАУ́МОВ** Владислав Алексеевич (20.10.1928, Лаеш р-ны Лаеш а.), бакчачы-селекционер, биол. фән. канд. (1963), ТАССР, РСФСРның (1980, 1991) атказ. агрономы. Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1952). 1958–62 елларда Югары Ослан р-ның «Приволжский» с-зында эшли. 1962–97 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында: бакчачылык бүлеге мөдире (1967–94), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1994–97), 1999–2001 дә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре бакча һәм җиләк культуралары селекциясенә карый. Н. сәнәгый бакчаларны җитештерү процессларын макс. механикалаштыру нигезендә планлаштыру һәм утырту технологиясен, аларны утырткannan соңгы карап үстерү, тау битләрен бакча өчен сөреп террасалау технологияләрен эшли һәм гамәлгә кертә. Урта Идел буе бакчаларында туфрак саклау чараларын системасын булдыра. Су режимының төп закончалыкларын билгели. Каен җиләге һәм алмагачларны сугару режимын эшли. «Память Сахарова», «Обильная», «Шакировская», «Севастьяновская», «Наумовская» чия сортлары авторларыннан берсе.

Х е з м.: Генеративное расщепление у яблони в первом гибридном поколении // Тр. Татар. респ. с. х. опытной станции. 1961. Вып. 1; Закладка сада. М., 1965 (автордаш); Агробиологические основы полива плодовых деревьев и ягодников // Садоводам — добрые советы: Новое и прогрессивное в садоводстве. К., 1972.

*Әд.:* Садоводы-учёные России. Орёл, 1997.

**НАУ́МОВ** Вячеслав Игоревич (2.3.1953, Казан), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1999). 1976 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очкыч аппаратлар двигательләре ф-ты деканы (1995–99), автомобиль двигательләре һәм сервис каф. мөдире (1996–2005). Хезмәтләре аэрокосмос һәм автомобиль техникасы двигательләрендә һәм энергия җайланмаларында барган процессларның химик кинетикасына карый. Н. химик яктан тигезләнешсез процессларны исәпләү һәм энергия-көч җайланмаларының параметрларын оптимальләштерү өчен алымнар, модельләр һәм универсаль программалар эшли (Россия авиация-космос агентлыгы пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Математическое моделирование высокотемпературных процессов в энергосиловых уста-



П.И. Наумов.

новках. М., 1989 (автордаш); Горение и течение в агрегатах энергоустановок: Моделирование, энергетика, экология. М., 1997 (автордаш); Моделирование и исследование процессов в пограничных слоях при испарении жидкого компонента // Изв. РАН. Энергетика. 2001. № 3 (автордаш).

**НАУ́МОВ** Игорь Петрович (6.6.1929, Чита ш. — 29.11.1992, Казан), хакимият эшлеклесе. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1953). 1953–56 елларда Казан моторлар төзү з-дында конструктор, өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары, 1955–56 да Казан «Сантехприбор» механика з-дының бүлек башлыгы урынбасары. 1956–61 дә Казан авиация ин-тының машина детальләре каф. укытучысы. 1961–62 дә Казанның 296 нчы пр-тиесендә цех башлыгы, 1962–64 тә партия ком-ты секретаре. 1964–66 да Казан мед. аппаратлары з-ды директоры. 1966–71 дә КПССның Казан шәһәре Киров район ком-ты 1 нче секретаре; 1971–83 тә КПССның Казан шәһәр ком-ты 2 нче секретаре. 1983–90 да ТАССР Халык контроле ком-ты рәисе. 1967–90 да ТАССР ЮС депутаты. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**НАУ́МОВ** Леонид Григорьевич (30.10.1951, Алексеев р-ны Кыр Күле а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2001), ТРның атказ. транспорт хезмәткәре (1999). 1975 елда Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң, Кама Тамагы р-ны башкарма ком-тының а.х. идарәсендә баш инженер булып эшли. 1977–83 тә Кама Тамагы «Сельхозтехника» берләшмәсе управляющие, 1983–87 дә КПССның Кама Тамагы райкомының 2 нче секретаре, 1987–90 да Апас р-ны башкарма ком-ты рәисе. 1990 нан «Казанның 1 нче автотранспорт предприятиесе» АҖ ген. директоры. Хезмәтләре туфрак өслеген эшкәртү өчен спираль тешле машиналар төзүгә карый. Уйлап табуга 82 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теоретические исследования параметров спиралезубового рыхлителя-выравнивателя почвы с автовибратором СПВУП-2 // Сб. трудов молодых учёных / Казан. с.-х. академия. К., 1996 (автордаш); Теория и расчёт ротационных почвообрабатывающих машин. К., 1999 (автордаш); Учебное и лабораторное оборудование по механике. К., 2004 (автордаш).

**НАУ́МОВ** Пётр Иванович (4.12.1912, Казан губ., хәзер Лаеш р-ны Зур Кабан а. — 24.8.1991, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (4.7.1944, 28.11.1944, 10.4.1945), кече сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1940 елда һәм 1941 дән Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 740 нчы укчы полкта 76 *мм* лы туплар батареясында туп төзәүче (48 нче армиянең 217 нче дивизиясе). 1, 2 һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Гомель-Речица, Белоруссия (икесе дә — 1944), Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 25 июнендә Колотовка авылы (Белоруссия ССР, Гомель өлкәсенең Рогачёв р-ны) өчен барган (дошман пулемётын юк итеп, сугышчан бурычны уңышлы үти), 1944 нең 14 ноябрендә Хылины (Макув-Мазовецкидан көньяк-көнчыгыштарак, Польша) торак пункты тирәсендәге (дошманның 2 пулемёт ноктасын зарарсызландыра, торак пунктны алуга ирешә), 1945 нең 14–16 гыйнварында Маковица торак пункты (Макув шәһәреннән көнчыгыштарак, Польша) һәм Макув шәһәре өчен барган (туптан атып, тимерчыбыклы каршылык сызыгы аша 2 үтү юлы ясый, дошманның 7 ут ноктасын юк итә) сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Туган ягында вет. фельдшеры булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полные кавалеры ордена Славы — наши земляки. К., 1986; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НАУ́МОВА** Римма Павловна (19.11.1933, Мәскәү өлкәсенең Загорск р-ны Абрамцево пос. — 17.1.2013), микробиолог, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1993). Табигый булмаган кушылмаларның микробны метаболизмы яңа фәнни юнәлешенә нигез салучы. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1956), Бөтенсоюз гидрогеол. һәм геол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү) эшли. 1961 елдан Казан ун-тында, микробиол. каф. мөдире (1976–82), экологик биотехнол. лаб-ясенең фәнни җитәкчесе (1991 дән). 2011 дән КФУда. Хезмәтләре микроорганизмнар биохимиясе һәм физиологиясенә, экологик биотехнологиягә һәм табигый булмаган кушылмалар метаболизмына карый. Н. әйләнә-тирә мохит өчен экологик яктан куркыныч булган химик пычраткыч матдәләрне (синтетик мономерлар, шартлаткыч кушылмалар компонентлары, канцероген углеводородлар) юк итүнең элек билгеле булмаган яңа юлларын таба. Уйлап табуга 16 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Аларның кайберләре производствога кертелә: агынты суларның агулылыгын экспресс-тикшерү («Казаноргсинтез»), «Түбәнкаманефтехим» нефть химиясе комплексы сәнәгать агынты суларын биол. чистарту ысуллары, газ һәм каты калдыкларны чистарту технологияләре һ.б. ТР ФАнең биол. һәм а.х. фән. өлкәсендәге В.И.Энгельгардт исем. бүләге лауреаты. Казан ун-тының атказ. профессоры (2009).

Х е з м.: Микробный метаболизм неприродных соединений. К., 1985; Трансформация 2,4,6-тринитротолуола лактобациллами с образованием токсичных гидроксиламинопроизводных // Микробиология. 1999. Т. 68, № 1 (автордаш); Особенности распределения и физиологического состояния микроорганизмов нефтешлама — отхода нефтехимического производства // Микробиология. 2003. Т. 72, № 5 (автордаш).

**НАУ́МОВО** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да 2 тимерчелек, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 376 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 241, 1897 дә — 315, 1908 дә — 313, 1920 дә — 321, 1926 да — 298, 1949 да — 253, 1958 дә — 145, 1970 тә — 90, 1989 да — 21, 2002 дә — 9 кеше.

**«НАУ́ЧНЫЙ ТАТАРСТА́Н»** («Фәнни Татарстан»), ТР ФА журналы. Оештыручысы — ТР ФА Президиумы, баш мөхәррирләре — М.Х.*Хәсәнов*, Ә.М.*Мазһаров* (2006 елдан). 1995 тән Казанда нәшер ителә. Журналның максаты — хәзерге фәннең казанышлары һәм проблемаларын, ТР ФА һәм респ-каның башка фәнни оешмалары эшен яктырту. Төп урын көндәшлеккә сәләтле техника һәм алдынгы технология булдыруда, җәмгыятьне иҗтимагый гаделлек һәм базар икътисады принциплары нигезендә реформалауда хәлиткеч роль уйнарга сәләтле фәнни-техник белем һәм казанышларны пропагандалауга бирелә. Мәкаләләрдә гуманитар,




«Научный Татарстан» журналының беренче саны.

табигыять һәм техник фәннәрне үстерү тенденцияләре ачыла; фәнни-тикшеренү оешмаларының икътисад, экология, техник сәясәт, иҗтимагый өлкә, мәдәният, милли дәүләт төзелеше өлкәләрендә Татарстан алдында торган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән тәҗрибәсе яктыртыла. ТР галимнәренең РФдәге, якын һәм ерак чит илләрдәге фәнни

үзәкләр, мәктәпләр б-н интеграциясе темасы чагылыш таба. Яңа фәнни әдәбиятка күзәтү, монографияләр һәм фәнни җыентыкларга җентекле рецензияләр, Татарстандагы фәнни тормышның тәфсилле хроникасы басыла. ТР һәм ТР ФА галимнәре, хезмәткәрләре журнал б-н хезмәттәшлек итәләр.

**НАЦИОНАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ**, (хосусый милекне дәүләт милкенә әверелдерү), җирләрнең, сәнәгать һәм сәүдә пр-тиеләренең банклар, транспорт һ.б.ның дәүләт милкенә күчүе. ТАССРда Н. 1917 елның ноябреннән 1921 нең маена кадәр уздырыла. Н. 1917 нең 26 октябрендә Эшче һәм солдат депутатларының 2 нче Бөтенроссия съездында кабул ителгән, хосусый милектәге җирләрне конфискацияләү һәм барлык җирләрнең дәүләт милкенә күчүе турында белдергән Җир турындагы декрет б-н башлана. Әлеге декретка нигезләнеп, Казан губернасы крәстиян депутатларының 3 нче съезды алпавыт, хосусый милекче, монастырь, чиркәү, патша гаиләсе һ.б. милек хуҗасына караган барлык сөрүле җирләр һәм болыннарның халык байлыгы дип игълан ителүе һәм волость җир ком-ты карамагына тапшырылуы турында карар чыгара. 1917 елгы сан алу нәтиҗәләре буенча, ТАССР өязләрендәге файдалануга яраклы барлык җирләрнең тулай мәйданы 5,5 млн. *га*, ш.и. крәстиян җирләре — 3,3 млн. *га* (58,3%), хосусый милектәге җирләр — 926,8 мең га (14,1%), казна, чиркәү һәм монастырь җирләре 1,3 млн. *га* дан артык (27,6%) тәшкил итә. Хосусый милектәге җирләрнең 60% тан артыграгы алпавыт җирләре була. Алпавыт утарларын конфискацияләү 1918 нең язына нигездә тәмамлана. Ноябрьгә монастырь һәм чиркәү җирләре ш.у. волость җир ком-тлары һәм өяз Крәстиян депутатлары советлары карамагына күчә. 1 млн. *га* га якын җир крәстияннәргә файдалану өчен бушлай бирелә, 151 мең дис. мәйдандагы урман национализацияләнә. Бу чаралар б-н бергә, крәстияннәр җир өчен еллык аренда түләвеннән азат ителәләр. Аренда бәясенең тулай суммасы алтын акча б-н 10 млн. сум исәпләнә.

Казан губернасында банкларны Н. процессы Казанда совет хакимияте урнашу б-н үк башлана. 1917 нең 26 октябрендә Кызыл гв. тарафыннан почта, телеграф, телефон станциясе, вокзал һәм Дәүләт банкының Казан бүлеге алына. Банк исәп-хисапларын һәм мөлкәтен тикшерү, ш.у. Дәүләт банкы эшен оештыру өчен РКП(б)ның Казан ком-ты һәм ревком әгъзасы А.И.Бочков — Дәүләт банкының комиссары, Эшче һәм солдат депутатларының Казан губерна башкарма ком-ты әгъзасы А.С.*Гордеев* казначысы итеп билгеләнә. Казан губернасында банк-кредит учреждениеләрен Н. БҮБКның банклар эшен дәүләт монополиясе дип игълан иткән «Банкларны национализацияләү турында»гы 1917 ел 14 декабрь Декреты нигезендә башкарыла. ХКСның «Хосусый җир банкларын ликвидацияләү турында»гы 1917 ел 24 декабрь Декреты нигезендә 1919 ның февралендә Дворяннар җир банкы һәм Крәстиян җир банкының Казан бүлекләре һ.б. банклар бетерелә. 1918 нең 10 мартында Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан советы президиумы «Финанс комиссарына элеккеге хосусый банкларны бетерү эшенә керешергә тәкъдим итәргә» дигән карар чыгара. Шул ук айда Казан шәһәр җәмәгать һәм сәүдәгәрләр коммерция банклары; Төньяк, Рус-Азия, Азов-Дон, Петроград халыкара коммерция банкларының, Идел-Кама коммерция банкының Казан бүлекләре национализацияләнә. Башта алар җирлегендә — 7 бүлек, соңрак 3 банк ачыла: Дәүләт банкы, 1 нче халык банкы (элеккеге Сәүдәгәрләр банкы) һәм 2 нче халык банкы (элеккеге Идел-Кама банкы). Төп эшчәнлекне Дәүләт банкы алып бара, башкалары аның ф-ллары санала. 1918 нең көзендә барлык банклар РСФСР Халык банкының Казан бүлеге составына кертелә, төбәктәге барлык акча операцияләре шушы банкта башкарыла.

Сәнәгатьтә, транспортта һәм халык хуҗалыгының башка тармакларында Н. 1917 нең ноябрь–декабрендә — 1918 дә тормышка ашырыла башлый. 1918 нең 23 гыйнварында ХКСның диңгез һәм елга флотын Н. турындагы Декреты басылып чыга. 1918 нең 27 гыйнварында суднолар берлегенең Казан район ком-ты Идел елгасы флотын (комиссары итеп И.Гаврилов билгеләнә) Н. тәртибе турында карар кабул итә. Идел елгасы бассейнының фәкать бер Казан р-нында гына да 19 пароход компаниясенең һәм суднолар тотучы 94 хосусый милек хуҗасының йөзмә милке һәм яр буе корылмалары национализацияләнә. Сәнәгатьтә һәм траспортта эшчеләр контроле (Э.к.) кертелү Н.не тормышка ашыруның бер шарты итеп куела. БҮБК һәм ХКСның 1917 ел 14 ноябрь Нигезләмәсе б-н 5 яки артыграк яллы эшче эшли торган һәм еллык әйләнеше 10 мең сумнан арткан барлык пр-тиеләрдә Э.к. кертелә. Күзәтчелек итү җитештерү процессына, продукция һәм чималны сатып алу, сату, саклауга, ш.у. пр-тиенең финанс эшчәнлегенә кагыла, шушы пр-тиенең үз эшчеләре тарафыннан сайлау оешмалары аша башкарыла. Казан губернасында Э.к. органнарыннан фабрика-завод ком-тлары һәм алар тарафыннан төзелгән контроль комиссияләре киң таралыш ала. Э.к. органнары кабул иткән карарлар эшмәкәрләргә мәҗбүри итеп куела. 1918 нең көзенә барлыгы 21623 эшче исәпләнгән 147 завод һәм фабриканың 83 ендә (56,5%) фабзавкомнар оештырыла, 48 ендә (32,7%) Э.к.нең махсус органнары була. 1918 ел ахыры — 1919 ел башына төп эшче массалар тупланган пр-тиеләрдә Э.к. һәм эшчеләр идарәсенең йогынтысы көчәя. Э.к. органнары эшмәкәрләрнең җитештерү, финанслар, заказларны үтәү һәм урнаштыру, чимал б-н тәэмин итүгә кагылышлы идарә эшчәнлегендә катнашалар. Совет хөкүмәте Э.к.ннән банклар, сәнәгать, транспортны Н. нигезендә турыдан-туры хуҗалык б-н идарә итүгә күчерүне РСФСР Югары Халык хуҗалыгы советы (ЮХХС) һәм аның җирле органнарына (ХХС) тапшыра. Н. 3 этапта тормышка ашырыла. 1 нче этап 1917 нең ноябреннән ХКСның эре сәнәгатьне Н. турындагы 1918 ел 28 июнь Декреты басылып чыкканчыга кадәрге чорны эченә ала. Татарстан терр-ясендә сәнәгатьне Н. «казна предприятиеләре» дип йөртелгән пр-тиеләрне (дары, снаряд, артиллерия, хәрби оптика һәм хәрби химия складлары, Казандагы һәм Чистайдагы хәрби складлар, типографияләр һ.б.) совет хакимиятенең беренче көннәреннән үк дәүләткә күчерүдән башлана. 1 нче этапта сәнәгатьне Н. мәсьәләсе «югарыдан» һәм «түбәннән» революцион ыргым юлы б-н хәл ителә. 1918 нең июленә кадәр Н.дә төп рольне депутатларның җирле советлары башкара. Алар башлыча азык-төлек пр-тиеләрен һәм җирле тормышта уңайлыклар тудыру б-н шөгыльләнүче пр-тиеләрне национализациялиләр. Фабрика һәм заводларны Н. өчен эшмәкәрләр тарафыннан саботаж оештырылу, аларның дәүләткә буйсынмаулары һәм Э.к.н танымаулары; хуҗаларның пр-тиене ябарга омтылуы; финанс ягыннан җитешсезлекләр яки пр-тиенең бурычлары сәбәп итеп күрсәтелә; дәүләт дәрәҗәсендә әһәмияткә ия пр-тиеләр ш.у. беренче чиратта дәүләт милкенә күчерелә. Н. конфискация рәвешендә уздырыла, ягъни пр-тие бушка алына. 1 нче этап дәвамында 50 ләп сәнәгать пр-тиесе национализацияләнә; дәүләт милкенә фәкать 2 пр-тие күчерелә. ЮХХСның 1918 ел 31 май һәм 27 июнь карарлары нигезендә «И.Г.Стахеев һәм варислары» сәүдә йорты һәм, «дәүләт дәрәҗәсендәге әһәмияткә ия» пр-тиеләр буларак, Ушковның Бондюгтагы, Казан, Кокшан һәм Самарадагы химия з-длары национализацияләнә. 2 нче этап 1918 нең 28 июненнән (Эре сәнәгатьне Н. турында декрет кабул ителгән көннән) 1920 нең 29 ноябренә кадәр дәвам итә. Бу чорда губерна ХХС, ЮХХС һәм ХКС санкцияләренә таянып, сәнәгатьнең аерым тармакларында Н. уздыра, бу эш эзлекле рәвештә, тәртип б-н, пр-тиеләрнең күчешкә әзерлеге исәпкә алынып үткәрелә. Ләкин Татарстан терр-ясен дә чолгап алган Гражданнар сугышы Н. барышына үзгәрешләр кертә. Хосусый милектәге байтак пр-тиеләрнең (40 лап завод һәм фабрика, шулардан 32 пр-тиедә эшләүчеләрнең гомуми саны — 10172 кеше) хуҗалары акгвардиячеләргә ияреп качып китә. Әлеге пр-тиеләр дәүләт милкенә әверелә. Тизләтелгән Н. җитештерүне көйләүдә өстәмә кыенлыклар тудыра, чөнки эшчеләрнең идарә итү тәҗрибәсе булмый. 1918 нең 28 июнь Декреты нигезендә, дәүләткүләм әһәмияткә ия булулары исәпкә алынып, иң беренчеләрдән Алафузов пр-тиеләре һәм бертуган Крестовниковлар з-длары национализацияләнә. 3 нче этап ЮХХСның вак пр-тиеләрне Н. турындагы 1920 ел 29 ноябрь карары кабул ителүдән башланып китә. Бу карар аерым шәхесләр яки җәмгыятьләр милке булган, эшләүчеләр саны 5 тән арткан һәм механик двигательләр кулланылган яки эшләүчеләр саны 10 нан арткан, әмма механикалаштырылмаган пр-тиеләргә кагыла. Бу чорда Татарстанда шундый 103 пр-тие национализацияләнә. 1917–21 дә полиграфия, химия, металл эшкәртү, агач эшкәртү, урман, азык-төлек, тире-күн сәнәгатенә, җиңел сәнәгатькә караган завод һәм фабрикалар дәүләт милкенә күчерелә. 1921 нең маена Татарстан

буенча 450 дән артык пр-тие национализацияләнә. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында ТАССРның цензлы сәнәгатендә хосусый сәүдә-сәнәгать капиталы ахыргача бетерелә.

Н. нәтиҗәсендә хосусый җир милекчелеге, базар мөнәсәбәтләренә корылган сәүдә-сәнәгать эшмәкәрлеге юкка чыгарыла, аларга алмашка дәүләт милкенә нигезләнгән, продукция җитештерү-тарату катгый үзәкләштерелгән, алга таба «социалистик икътисад» дип аталачак система төзелә.

*Әд.:* Белялов У.Б. Начало социалистических преобразований в экономике Казанской губернии (октябрь 1917 — август 1918). К., 1961; Залялов А.М. Социалистические преобразования сельского хозяйства в Татарии (1917–1937 гг.). К., 1974; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии (1917–1921). М., 1976.

*К.А.Нәҗипова.*

**«НАЧА́ЛЬНОЕ ОБУЧЕ́НИЕ»** («Башлангыч белем бирү»), пед. журнал. 1901–16 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. «*Циркуляр по Казанскому учебному округу*» ж-лына кушымта буларак чыга башлый. 1910 нан Казан уку-укыту округы идарәсенең мөстәкыйль журналы буларак басыла. Мөхәррире элек «Городской и сельский учитель» ж-лын чыгарган атаклы педагог А.И.*Анастасиев* була. Актив авторлар арасында — Н.А.Бобровников, А.А.Красновский, И.П.Мордвинов, К.С.Нечаев, А.С.Никольский, И.М.Петляев, А.С.Рождествин. Журналның төп эчтәлеген рәсми һәм рәсми булмаган бүлекләр тәшкил итә. Рәсми бүлектә башлангыч уч-щеләргә кагылышлы боерыклар, Халык мәгарифе министрлыгы, Казан уку-укыту идарәсе җитәкчелеге, халык уч-щеләре директорлары һәм инспекторлары күрсәтмәләре басыла. Рәсми бүлектә төп урын халык уч-щеләрендә кулланырга рөхсәт ителгән китаплар исемлегенә бирелә. Рәсми булмаган бүлектә мәктәптә башлангыч уку-укыту һәм тәрбия мәсьәләләре буенча теоретик һәм методик эшкәртмәләр басыла, җентекле аңлатмалар б-н якынча дәрес планнары тәкъдим ителә. Журнал рус булмаган халык уч-щеләрендә рус телен укыту темасына аерым игътибар бирүе б-н аерылып тора. «Педагогика тарихыннан очерклар» рубрикасында атаклы фәлсәфәчеләр, педагоглар (И.Б.Базедов, Дж.Локке, И.Г.Песталоцци, Ж.-Ж.Руссо, Ф.Фенелон, А.Г.Франк, Ф.Фребель һ.б.) һәм аларның педагогикага керткән өлешләре турындагы материаллар басыла. Редакция Россиядә чыгып килгән «Воспитание и обучение», «Журнал министерства народного просвещения», «Педагогический листок», «Русский начальный учитель», «Русская школа» һ.б. пед. ж-лларга күзәтү ясый. «Башлангыч мәктәп тормышыннан» рубрикасында Казан уку-укыту идарәсендә яңа уку йортлары һәм укытучылар өчен курслар ачылу, уку ярдәмлекләре б-н тәэмин ителеш, халык уч-щеләре директорлары һәм инспекторлары киңәшмәләрен, съездларны, мәктәптән тыш белем бирүне оештыру, пед. җәмгыятьләр эшчәнлеге турындагы мәкаләләр бирелә; уч-щеләрне төзекләндерү буенча киңәшләр басыла. «Чит илләрдә башлангыч белем һәм тәрбия» дигән даими бүлек алып барыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«НАЧА́ЛЬСТВЕННЫЕ РАСПОРЯЖЕ́НИЯ ПО КАЗА́НСКОМУ УЧЕ́БНОМУ О́КРУГУ»** («Казан уку-укыту округы белән җитәкчелек итү өчен боерыклар»), журнал, к. «*Циркуляр по Казанскому учебному округу*».

**«НАШ КРАЙ»** («Безнең төбәк»), атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби журнал. 1912 елның сентябрь–октябрендә Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 3 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Н.П.Гусев. Редакция басманы партиясез дип игълан итүгә карамастан, журналның эчтәлеге аның Казан губернасында 4 нче Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында барлыкка килеп, кадетлар, сул октябристлар һәм меньшевиклар партияләрен берләштергән Прогрессив блок идеяләре тарафдары икәнен күрсәтә. «Н.к.» мөхәррире, кадетлар партиясенең Казан губерна ком-ты секретаре буларак, блокның эшлекле әгъзаларының берсе була. Журнал беренче санындагы «Өлкәнең матбугат органы максатлары» дигән мәкаләсендә үзен кызыксындырган тармакларны билгели: земстволар эше, Дәүләт Думасының законнар чыгару эшчәнлеге. Редакция «законлылык идеясен үткәрү, чагыштырмача түбән культуралы Урал һәм Идел буйларында тамыр җәйгән башбаштаклыкка каршы көрәшү» өчен тырышачагын игълан итә. Сайлау кампаниясе чорында оешкан журнал мәкаләләренең күп өлешен сәяси көндәшләрен (карагруһчылар һәм уң октябристлар блогы) тәнкыйтьләүгә, сайлау барышына анализ ясауга багышлый. Беренче санда кенәз А.А.Кропоткинның Лаеш өязендә тараткан «Крәстияннәргә» һәм «Җирбиләүчеләргә» дигән өндәмәләре кискен тәнкыйтьләнә. «Ике өндәмә» мәкаләсендә Кропоткинның Думага сайлау вакытында рус крәстияннәрен татарларга каршы берләшергә, Россия алпавытларының өстенлекләрен сакларга һәм арттырырга чакырган карашларының милләтчел һәм консерватив юнәлеше билгеләп үтелә. Казан губернасындагы сайлау кампаниясенең беренче яртысы тәмамлануны анализлаган мәкаләләрдә 1907 ел 3 июнь сайлау законының гаделсез булуы күрсәтелә. А.Вдовин Прогрессив блокның җиңелү сәбәпләрен ачыклап, аның хакимият басымы көчсез булган урында гына җиңүгә ышанычы барлыгын билгеләп үтә. Журнал мөселман мәсьәләләренә дә игътибар итә. Редакция алдынгы мөселманнарның платформасын «Уфа хәбәрчесе»ннән күчереп бастыра; аңарда, 3 нче Дәүләт Думасы эшчәнлеген тәнкыйть итүдән тыш, 4 нче Думага таләпләр дә куела: 1907 нең 3 июнь законын сайлау хокукларын киңәйтү ягына үзгәртергә, Россия мөселманнары телләренең рус теле б-н тигезлеген танырга, гражданнар ирегенә ирешергә. «Татар-мөселман матбугаты нәрсә бирә?» мәкаләсендә татар вакытлы матбугаты (иң абруйлы газеталар арасында «Йолдыз» һәм «Бәянелхак» билгеләп үтелә) хәленә характеристика бирелә; 1905–08 еллар б-н чагыштырганда, басмаларның саны кискен кимү, дәрәҗәсе төшү ассызыклана. А.Васильев хәбәрләрендә Казан губернасы Мамадыш өязендә Столыпинның аграр реформасын тормышка ашыруның үзенчәлекләре хакында хәбәр ителә. Татар крәстияннәренең авыл җәмәгатеннән чыгарга теләмәүләре, чөнки җәмәгатьнең дини берләшмә дә булып торуы, мөселманнар фикеренчә, реформаның мөселман авылындагы канунннарны өзүгә юнәлтелгән булуы күрсәтелә. Халыкара проблемалардан төп игътибар Балкан сугышына бирелә, редакция сугыш башлаучыларны тәнкыйтьли.

*Л.М.Айнетдинова.*

**НАЯ́ДА** (Najas), наядачалар семьялыгыннан бердәнбер үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шары буенча таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — зур наяда (N. major) бар, Көнбатыш (Олы Чирмешән елгасы тугае) һәм Көнчыгыш (Сөтле күл) Кама аръягында очрый. Зур булмаган инешләрдә, тугайлы сулыкларда, буаларда үсә; суга күмелгән. 10–60 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Сабагы каты, сынучан, тармаклы. Яфраклары бөҗрәдә, озынча кыяк. Чәчәкләре вак, берле, яфрак куентыгында. Су астында серкәләнә. Җимеше төшсыман. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Югала баручы бик сирәк төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НАЯСО́ЛКА** (Янасолка) елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Бизнә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,2 *км*, бассейнының мәйданы 122,3 *км²*. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Әлки р-ны Яңа Такталы авылы янында, тамагы Спас р-ны Антоновка авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 110 *м*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Н.ның 0,8 һәм 13,5 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар, аеручә зурысы — Такталы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Еллык агымның 95% ка кадәре язгы ташу чорына туры килә. Җәен елга кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу агымы катламы 92 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,022 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада суының күләме 1,3 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НӘБИ́ЕВ** Ринат Әхмәтгали улы (13.9.1950, БАССРның Чакмагыш р-ны Имәнлекүл а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1977). 1980 елдан шунда ук КПСС тарихы кафедрасында (1991 дән сәяси партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләр тарихы каф., 1997 дән Татарстан

тарихы каф.) эшли. 1997–2007 дә ТР МК каршындагы Дин эшләре буенча совет рәисе. 2007 дән Казан ун-тының сәяси тарих, 2013 тән сәяси тарих һәм дөньяви сәясәт каф. мөдире. Хезмәтләре атеизм, ислам, дини мөнәсәбәтләр тарихына карый.

Х е з м.: На путях научного мировоззрения: История, проблемы, уроки. К., 1991; Ислам и государство: Культурно-историческая эволюция мусульманской религии на Европейском Востоке. К., 2002.

**НӘБИ́ЕВ** Фәнис Галинур улы (1.3.1937, Актаныш р-ны Иске Әлем а. — 16.03.2011, шунда ук), фармаколог, вет. фән. д-ры (1991), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000), Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Куйбышев (1961–62) һәм Алабуга (1962–65) р-ннары нәсел с-зларында вет. табибе, Алабуга җәнлек үрчетү с-зында өлкән вет. табибе булып эшли (1966–70). 1970 елдан Казан вет. ин-тында (1995 тән Казан вет. медицинасы академиясе), фармакология һәм токсикология каф. мөдире (1996 дан), проф. (2010 нан). Хезмәтләре затлы мехлы җәнлекләр авыру очракларында нейролептиклар куллану, чәшкеләрнең бер-берсен ашавын кисәтү, авыруның этиологиясе, патогенезы, симптоматикасы, авыру җәнлекләрне дәвалау мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы һәм 2 патенты бар.

Х е з м.: Лекарственные средства и биопрепараты в звероводстве. М., 1986 (автордаш); Лекарственные препараты для ветеринарии: В 2 ч. К., 2000; Практикум по ветеринарной рецептуре с основами технологии лекарств. К., 2004 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**НӘБИУ́ЛЛИН** Газиз Нәбиулла улы (15.2.1920, хәзер Саба р-ны Керәнле а. — 14.5.1986, шул ук районның Байлар Сабасы а.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). 1940–80 елларда «Җиңү байрагы» район г-тасы редакциясендә бухгалтер, 1944 тән мөхәррир, 1954 тән җаваплы сәркәтип. Редакция каршында «Мишә дулкыннары» әдәби-иҗат берләшмәсен оештыра, аны җитәкли. Балалар өчен шигырьләр, хикәя, пьесалар иҗат итә: «Безнең авыл балалары» (1948), «Әнем турында шигырьләр» (1957), «Икмәк исе» (1965) исемле шигырьләр, «Яшел эстафета» (1968) исемле хикәяләр, «Пьесалар» (1964), «Үрләрем» (1970), «Тын елга җыры» (1980) исемле пьесалар җыентыклары авторы. Н.ның әсәрләре балаларны туган җирне яратырга, табигатькә сак карарга, дуслыкның кадерен белергә өйрәтә. Кайбер шигырьләре «Татар балалар поэзиясе антологиясе» (1980) һәм «Татар поэзиясе антологиясе»ндә (1–2 кит., 1992) урын алган.

*Әд.:* И б р а һ и м о в а Ф. Сабыйларны үз итеп // Татар балалар әдәбияты. К., 1998.

**НӘБИУ́ЛЛИН** Мансур Кәрим улы (13.10.1944, Алабуга р-ны Бәзәкә а. — 30.12.2000, Иркутск ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1997). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук, теоретик механика кафедрасында эшли. 1976 елдан РФАнең Себер бүлегендә (Иркутск ш.): Себер энергетика ин-тында (1976–80), Системалар динамикасы һәм идарә теориясе ин-тында (1980–2000). Хезмәтләре деформацияләнә торган конструкцияле космик орбиталь системаларның тотрыклылыгын тикшерүгә карый.

Х е з м.: Стационарные движения и устойчивость упругих спутников. Новосиб., 1990; Моделирование и исследование устойчивости стационарных движений орбитальных упругих систем: Дис.... Иркутск, 1995.

**НӘБИУ́ЛЛИНА** Эльвира Сәхипзадә кызы (29.10.1963, Уфа ш.), дәүләт эшлеклесе. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1986). 1991–94 елларда Россия сәнәгатьче һәм эшмәкәрләре берлегендә. 1994–96 да РФ Икътисад министрлыгының Икътисади реформалар департаменты башлыгы урынбасары, 1996–97 дә — башлыгы. 1997–98 дә РФ икътисад министры урынбасары. 1998–99 да «Промторгбанк» акционерлык компаниясендә, Европа–Азия рейтинг хезмәтендә. 1999–2000 дә «Стратегик проектлар үзәге» фонды вице-президенты, 2003–05 тә — президенты, 2006–07 дә төркем җитәкчесе. 2000–03 тә РФ икътисади үсеш һәм сәүдә министрының 1 нче урынбасары, 2007 дән — министры. 2012 дән РФ Президенты ярдәмчесе. 2013 тән РФнең Үзәк банкы рәисе. Хезмәтләре Россиянең социаль-икътисади мәсьәләләренә карый. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Дуслык орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**НӘВАИ́** Галишер (Низамеддин Мир Галишер Нәвои) (9.2.1441, Һират ш., Әфганстан — 3.1.1501, шунда ук), Урта Азия шагыйре, фикер иясе, дәүләт эшлеклесе. Төрки һәм фарсы телләрендә яза. Дини белемне Һират, Мәшһәд, Сәмәрканд шәһәрләре мәдрәсәләрендә ала. 15 яшендә үк шагыйрь булып таныла. 1469 елда Хорасан солтаны, шагыйрь б-н мәдрәсәдә бергә укыган Хөсәен Байкар тәхеттә утырган елларда Н.га тамга саклауны йөклиләр. 1472 дә сарайда вәзир итеп билгеләнә, әмир титулы бирелә. Галим, рәссам, музыкант, шагыйрь, хаттатларны үз яклавына ала, мәдрәсәләр, хастаханәләр, күперләр төзүдә булышлык итә. Түрәләрнең яман эшләренә каршы торуы сарай даирәсендә ризасызлык тудыра. 1487 дә шагыйрьне ерак провинциягә — Астрабатка сөрәләр, анда аны агулап үтермәкче булалар. 1488 дә хезмәтен ташлап Һиратка кайта һәм калган гомерен фәнгә, әдәбиятка багышлый.

Беренче тапкыр төрки телдә Низами һәм Әмир Хөсрәү Дәһләвинең «Хәмсә»сенә язылган назыйрә авторы. Назыйрә «Хәйрәт әл-әбрар» («Тәкъвалар хәйраны», 1483), «Ләйлә вә Мәҗнүн» (1484), «Фәрһәд вә Ширин» (1484), «Сабъәи сәйар» («Җиде планета», 1484), «Сәдд-и Искәндәрий» («Искәндәр дивары», 1485) поэмаларыннан тора. Фәлсәфи-публицистик «Хәйрәт әл-абрар» поэмасында Н.нең дөньяны күзаллавы, эстетик һәм этик карашлары чагылыш таба. «Ләйлә вә Мәҗнүн» — көтүче Кайсаның күрше күчмә кабилә кызы Ләйләгә фаҗигале мәхәббәте, аннан аерылгач, егетнең акылдан язуы һәм үлеме турындагы танылган борынгы гарәп риваятенә нигезләнгән романтик поэма. «Фәрһәд вә Ширин» — Иран шаһы Хөсрәү дәгъва иткән гүзәл Ширингә баһадир Фәрһәднең мәхәббәте турындагы героик-романтик поэма. Бу сюжетка нигезләнеп алдарак язылган әсәрләрдән аермалы буларак, поэманың төп герое — Хөсрәү түгел, ә дөреслек һәм гаделлек өчен көрәшкән Фәрһәд. Аның кыю гамәлләре шаһның куркаклыгына каршы куела. «Җиде планета» поэмасы Тимериләр хакимнәре һәм аларның яраннарына карата сатирик ишарәле 7 әкияти новелладан тора. «Искәндәр дивары» поэмасы үзәгендә — гадел, гакыллы, камил хаким Искәндәр.

«Хәмсәт-әл-мөтәхәййирин» («Хәйран калганнар бишлеге», 1492) китабы фарсы шагыйре Габдрахман Җәмигә (1414–92) багышланган. Үзбәк һәм фарсы-таҗик әдәбиятларын, аларның багланышларын өйрәнүдә Н. төзегән җыентыкларның әһәмияте зур. Алар арасында: Урта Азия, Иран тарихчылары турындагы «Тарих-и мөлек-и Гаҗәм» («Иран патшалары тарихы», 1489), зороастризм һәм Коръән риваятьләрендәге персонажлар турындагы «Тарих-и әнбия вә хөкәма» («Пәйгамбәрләр һәм акыл ияләре тарихы», 15 йөз ахыры), Н. чорында иҗат иткән язучылар турында мәгълүматлардан торган «Мәҗалисән-нәфаис» («Зәвыклылар мәҗлесе», 1491–92). «Мизан әл-әүзан» («Үлчәмнәр бизмәне», 1499) трактатында әдәбият теориясе, ш.и. шигырь төзелеше мәсьәләләре яктыртылган. Аллегорик «Лисан әт-тайр» («Кошлар теле», 1499) поэмасы һәм фәлсәфи-дидактик хезмәт «Мәхбүб әл-колүб» («Гашыйклар калебе», 1500) Н.нең гадел җәмгыять хакында уйлануларын чагылдыра. Бәхәскә корылган «Мөхакамәт әл-лөгатәйн» («Ике телнең бәхәсе», 1499) трактат ул заман әдәбиятында хөкем сөргән, төрки тел шигырь язу өчен дорфа, килешсез, дигән фикергә каршы чыга, Урта Азия төрки теленең мәдәни һәм сәнгати әһәмиятен дәлилли.

Татарлар Н.не үз итәләр, шигырьләрен оригинал телендә укыйлар. Шигырь төзелешенә караган хезмәтләре татар мәдрәсәләрендә уку-укыту ярдәмлеге булып йөри. Шагыйрьнең шигырьләре 19 йөздә Ә.Мөтәххәр, М.Иванов, С.Кукляшев, К.Насыйри һ.б. тарафыннан төзелгән күп кенә җыентыкларга кертелә. Н. әсәрләрен Дәрдеменд, Ф.Халиди, Ә.Исхак татар теленә тәрҗемә итә. Н. иҗаты буенча беренче докторлык диссертациясен татар әдәбият галиме Г.Сәгъди яклый («Нәваи иҗатында уңай образлар» — «Положительные образы в творчестве Навои», 1940). Н. иҗатының унай тәэсире Мөхәммәдъяр, Г.Тукай, Дәрдеменд, М.Җәлил һ.б.ның әсәрләрендә үзен нык сиздерә. Н.нең 19 йөз ахырында күчерелгән әсәрләре Казан ун-ты Фәнни китапханәсе фондында саклана.

Ә с ә р.: Тула асарлар туплами: 20 жилдли. Тошкент, 1987–2000; Сочинения: В 10 т. Таш., 1968–70.

*Әд.:* А б и л о в Ш. Галишер Нәваи — төрки шигърият йолдызы // Казан утлары. 2001. № 2; Б е р т е л ь с Е.Э. Навои: Опыт творческой биографии. М.–Л., 1948; З а х и д о в В. Мир идей и образов Алишера Навои. Таш., 1961.

*Р.К.Ганиева, А.М.Ахунов.*

**НӘДЕРБА́Ш**, к ү р к ә б о р ы н ы (Stachys), иренчәчәклеләр семьялыгыннан бер-

һәм күпьеллык үләннәр яисә ярымкуакчыклар ыругы. 300 гә якын төре билгеле, ике ярымшарның да уртача һәм субтропик, тропикларның тауларында таралган. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Берьеллык Н. (S. annua), туры Н. (S. recta), дару Н.ы (S. officinalis) һ.б. һәр җирдә, Идел Н.ы (S. wolgensis) — Кама һәм Идел алдында очрый. Урман буйларында, куаклар арасында, су буйларында, дымлы болыннарда үсә. 8–120 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы кытыршы төкчәле. Яфраклары бөтен яки тешәүле, каршыдаш урнашканнар. Чәчәкләре алсу, аксыл шәмәхә, куе кызыл яки сары, башаксыман чәчәк төркеме хасил итүче ялган бөҗрәгә җыйналган. Җимеше — чикләвекчек. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. Халык медицинасында дару Н.ы, туры Н., урман Н.ы (S. sylvatica) үләне тонәтмәсе үт һәм бәвел кудыру, ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Баллы үсемлек.

**«НӘҖА́Т»** («نجات» — «Котылу»), иҗтимагый-сәяси, әдәби атналык журнал. 1907 елда С.-Петербургта татар телендә нәшер ителә. «Өлфәт» г-тасының дәвамчысы. Нашире һәм мөхәррире — Р.Ибраһимов. Беренче саны чыкканнан соң конфискацияләнә.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**НӘҖИ́П** Әмир Нәҗип улы (10.3.1899, хәзер Казакъстан Респ-касының Семипалатинск өлкәсе Бахты а. — 28.3.1991, Мәскәү), тел галиме, филол. фән. д-ры (1966). Тере Шәрекъ телләре ин-тын (Мәскәү, 1923) тәмамлаганнан соң, Бохара Халык Совет Респ-касына җибәрелә, анда ул «Азад Бохара» дип аталган беренче дәүләт нәшрияты оештыра. Төрле елларда Мәскәү, Сәмәрканд, Ташкентта яши. 1924–33 елларда СССР халыкларының Үзәк нәшриятында, Таҗик һәм Үзбәк дәүләт нәшриятларында эшли; 1933–39 да ВКП(б) ҮК каршындагы Партия нәшриятының тәнкыйть-библиография бюросы һәм НКВДның Геодезик рәсемгә төшерү һәм картография баш идарәсенең төрки-татар секторы б-н җитәкчелек итә. 1940 тан СССР ФАнең Үзбәк ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1942 дән директоры). 1944 тә СССР ФАнең Үзбәк ф-лы нәшрияты директоры. 1940 еллар уртасыннан Мәскәү ун-тында, Көнчыгышны өйрәнү ин-тында, Сов. Армиясенең Чит телләр хәрби ин-тында укыта. СССР ФАнең Тел белеме (1954 тән) һәм Көнчыгышны өйрәнү (1958–86) ин-тларында эшли. Хезмәтләре урта гасырлар төрки (ш.и. уйгыр) телләрен һәм 11–14 йөзләрдәге төрки телле әдәби ядкәрләрне өйрәнүгә карый. Харәзминең «Мәхәббәтнамә» (1353), Сәйф Сараиның «Китабе Гөлестан бит-төрки» (1391) һ.б. әсәрләрен өйрәнә һәм беренчеләрдән булып бастырып чыгара (рус теленә тәрҗемәсе һәм аңлатмалар б-н). Икетелле һәм орфографик сүзлекләр төзүче, югары уку йортлары өчен уйгыр, каракалпак һәм үзбәк теле дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Современный уйгурский язык. М., 1960; Кыпчакско-огузский литературный язык мамлюкского Египта XIV века. М., 1965; Уйгурско-русский словарь. М., 1968; Историко-сравнительный словарь тюркских языков XVI века: на материале «Хосрау и Ширин» Кутба. М., 1979. Кн. 1; Исследования по истории тюркских языков XI–XIV веков. М., 1989.

*Әд.:* Наджип Эмир Наджипович // Советская тюркология. 1989. № 2.

*Ф.Ш.Нуриева.*

**НӘҖИ́ПОВ** Айрат Габделхак улы (23.5.1937, Казан — 2001, шунда ук), анестезиолог-реаниматолог, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1991). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Чаллы р-ны «Татарстан» с-зы участок хастаханәсенең баш табибе. 1965–79 елларда Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1970–2001 дә Казан ГИДУВында, анестезиология һәм реаниматология каф. мөдире (1986 дан). Хезмәтләре анестезия вакытындагы патологияләр, интенсив терапия һәм реанимация мәсьәләләренә, хирургик дәвалау процессында организмның функциональ халәте үзгәрүне өйрәнүгә, перитонитка диагноз кую, хроник авыруларның ашказаны-эчәк тракты гемодинамикасын ачыклауга карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гемодинамика в сосудах желудка и кишечника у больных при обезболивании, перитоните, травме и кровопотере // Казан. мед. журн. 1986. № 5; Сравнительная характеристика интенстенальной гемодинамики и кардиодинамики во время различных видов общей анестезии // Анестезия и реаниматология. 1987. № 5; Кровяное давление во внутристеночных сосудах желудка и кишки и кардиодинамика у больных инфарктом кишечника // Казан. мед. журн. 1988. № 1.

**НӘҖИ́ПОВА** Әлфия Якуп кызы (25.2.1960, Арча р-ны Шушмабаш а.), невролог, мед. фән. канд. (2011), ТРның атказ. табибе (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1983). 1984–90 елларда Казандагы балалар йогышлы авырулары хастаханәсендә табиб. 1990 нан 7 нче шәһәр клиник хастаханәсендә: табиб-невролог, 1994 тән неврология бүлеге мөдире. Н. дәвалау һәм фәнни-пед. эшчәнлек юнәлешләрен бергә бәйләп алып бара. Аның җитәкчелегендә дәвалауның яңа принцплары — плазмаферез, озон терапиясе, лазер гемокоррекциясе гамәлгә кертелә, вертебраль патологияле авыруларны дәвалау һәм тернәкләндерүнең яңа технологияләре, нәтиҗәле алымнары эшләнә һәм кулланыла башлый. Хезмәтләре неврология өлкәсенә карый.

Х е з м.: Результаты лечения больных с мозговым инсультом в условиях неврологического отделения и стационара с инсультным блоком // Неврологический вестн. Журн. им. В.М.Бехтерева. 2006. № 1-2 (автордаш); Методические основы оценки эффективности лечения неврологических больных в стационаре дневного пребывания. К. 2010 (автордаш); Клинико-организационное обоснование эффективности стационаров дневного пребывания как формы организации неврологической помощи // Общественное здоровье и здравоохранение. 2011. № 2 (автордаш).

**НӘҖИ́ПОВА** Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы (10.2.1961, Минзәлә р-ны Тойгуҗа а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2009), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1983–84 елларда Минзәлә пед. уч-щесендә тарих һәм җәмгыять белеме фәннәрен укыта. 1984–88 дә А.М.Горький әдәби-мемориаль музее хезмәткәре. 1992 дән ТР Милли музеенда: этнография бүлеге мөдире (1992–97), ген. директор урынбасары (1999–2006), 2006 дан ген. директор. Россия музейлар берлегенең вәкилләр советы әгъзасы (2010 нан). Татарстан музейлары эшенә, Сов. Союзы Герое П.М.Гаврилов музеен (Питрәч р-ны, 2010), Ф.Г.Яруллин музеен (Баулы ш., 2010) һ.б.ны оештыруга зур өлеш кертә. Хезмәтләре төбәк музейлары тарихына, Казанда ун-т һәм музей хезмәттәшлегенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Казанский городской музей: Очерки истории 1895–1917 гг. К., 2000; Университет и музей: Исторический опыт губернской Казани. К., 2004; «Казанский антиквариум». К., 2006 (автордаш).

**НӘҖМЕТДИ́НОВ** Габдулла Аймтдин (Гыймадетдин) улы (1869–1915, Сембер губ., Курмыш өязе Кызыл Атау а.), җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. Буа шәһәрендә мәдрәсә тәмамлый, белемен камилләштерү өчен Бохарага һәм Һиндстанга сәяхәт кыла. Красный Остров авылында мулла була (1890 елдан), бер үк вакытта сәүдә һәм игенчелек б-н шөгыльләнә. Сембер губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзасы.

*Әд.:* Туктаров М.Ф. (Усал). Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре. К., 1909; Члены второй Государственной Думы. СПб., 1907; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917 гг.: Сб. док. и материалов.

*Д.М.Госманова.*

**НӘҖМЕТДИ́НОВ** Рәшит Гыйбат (Һибәтулла) улы (15.12.1912, Актүбә ш. — 3.6.1974, Казан), спортчы, тренер (шахмат, шашка), шахмат буенча халыкара оста (1954), шашка буенча СССРның спорт остасы (1949), СССРның атказ. тренеры (1962), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972). К.*Нәҗминең* энесе. 1919 елдан Казанда яши. Казан пед. уч-щесенең физика-матем. бүлеген тәмамлый (1940). Казан (1927, мәктәп балалары арасында; 1930, олылар арасында), РСФСР (1950–51, 1953, 1957–58), СССР (1954–55 — команда беренчелегендә) чемпионы. РСФСР беренчелекләрендә (1950, көмеш — шашка буенча), шахмат буенча халыкара турнирларда (1954, Бухарест, 2 нче урын; 1961, Ростов-Дон ш., 2–3 нче урыннар; 1964, Баку, 3 нче урын; 1967, Варшава, 3–4 нче урыннар) медальләр ала. 1946 дан «Спартак» иректле спорт җәмгыятенең Татарстан советында, 1972 дән Казан югары спорт осталыгы мәктәбенең шахмат бүлегендә өлкән тренер, бер үк вакытта, 1948 дән, СССР команда беренчелекләрендә һәм СССР халыклары спартакиадаларында 5 тапкыр җиңүче булган РСФСР җыелма командасында тренер, дөнья чемпионы исеменә М.М.Ботвинник б-н матчта М.Н.Тальның секунданты (1960–61). Шәкертләре арасында — СССРның спорт осталары В.М.Волошин, Р.А.Габдрахманов, Я.В.Дамский,

Н.И.Мөхәммәтҗанов, Ю.Б.Смирнов. «Шахмат уены» (1953; русча тәрҗемәсе «Шахматы», 1985), «Сайланма партияләр», 1975) китаплары авторы. Гыйрак шахмат федерациясенең шәрәфле әгъзасы (1971). Медаль, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. 1975 тә 10 нчы Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенә аның исеме бирелә. 1988 дә Казанда Н. яшәгән йортка мемориаль такта куела. 1979 дан Казанда Р.Г.Нәҗметдинов исемендә Бөтенсоюз (Бөтенроссия) балалар шахмат турниры уздырыла.

*Әд.:* К у з н е ц о в В.Г., М у с и н Б.М. Шахматные звёзды Татарстана. К., 2005.

**НӘҖМЕТДИ́НОВ** Ринат Равил улы (15.11.1960, Ташкент ш.), электрохимик, химия фән. д-ры (1999), проф. (2000). 1983 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре квант электрохимиясенә һәм фазаара электрохимик чикләрне компьютерлы модельләштерүгә карый. Н. электролитның төрле фазаара электрод/эремә чикләренең микроскопик төзелешен, электрон һәм протон күчеше реакцияләре механизмының молекуляр аспектларын ачыклый. Ул беренче булып тәкъдим иткән суның терекөмеш өслеге б-н тәэсир итешү потенциалы төшенчәсе терекөмеш/эремә фазаара чиген молекуляр динамика алымы ярдәмендә тикшерүләрнең нигезен тәшкил итә. Ионнарның электролит эремәләреннән электродларга үзенчәлекле адсорбциясе вакытында корылманың өлешчә күчүе микроскопик эффектларны аңлата. Электрон күчерү реакцияләре тизлегенә асимметрик активлаштыру барьерының тәэсирен тикшерүдә катнаша. Активлаштырусыз бушанулар тирәсендәге электродлы процессларның молекуляр-орбиталь табигатен өйрәнә, төрле кинетик режимнарда уза торган реакцияләрнең хәлиткеч параметрларын исәпләүнең оригиналь юллары комплексын үстерә һәм сыный. Н.нең фәнни эшкәртмәләре наноүлчәнешле кисәкчәләр электрохимиясе, адсорбциясе, туннельле спектроскопиясе өлкәсендәге тәҗрибә нәтиҗәләрен аңлатуда һәм тәҗрибәләр үткәрүдә кулланыла.

Х е з м.: Квантово-химический подход к описанию процессов переноса заряда на межфазной границе металл/раствор: вчера, сегодня, завтра // Электрохимия. 2004. Т. 38, № 2; Contemporary quantum chemical modelling of electrified interfaces // Electrochimica Acta. 1996. V. 41, № 14 (автордаш); Micrscopic modelling of the reduction of a Zn(II) aqua-complex on metal electrodes // Chemical Physics. 2005. V. 310 (автордаш).


*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт – КХТИ-КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**НӘҖМЕТДИ́НОВ** Тансык Кави улы (30.3.1927, Урал өлкәсе Троицк ш. – 21.3.2008, Казан), радиофизик, физика-матем. фән. канд. (1965). К.*Нәҗми* һәм С.С.*Әдһәмованың* улы. 1957 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1995 кә кадәр), радиофизика каф. мөдире (1969–83), бер үк вакытта махсус ф-тның деканы (1978–93). 1995–98 дә ТР Дәүләт милке б-н идарә итү ком-тының Сәнәгать департаменты ген. директоры киңәшчесе. Хезмәтләре стратегик планлаштыруның фәнни-методик һәм мәгълүмати технологияләренә, катлаулы мәгълүмати системалар төзү һәм, төрле факторларны исәпкә алып, алар б-н идарә итүне оптимальләштерүгә карый. Н. махсус кулланыштагы перспективалы катлаулы радиоэлектрон системалар төзү принципларын тикшерә, аларны проектлаштыру һәм үсешләре б-н идарә итүне автоматлаштыру алымнарын эшли, гамәли программалар пакетлары б-н бергә ярымнатураль модельләштерү стендларын тәкъдим итә (хезмәтләре оборона сәнәгате тармакларында гамәлгә кертелә). «Приём и обработка информации в сложных информационных системах» җыентыгының фәнни мөхәррире (1969–92). Публицистик хезмәтләр авторы. «Михайло Ломоносов» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале; РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Применение методов ТМО к анализу структурных помех в АРТС // Вопр. радиоэлектроники. 1966. Вып. 4; Асинхронные радиотелемеханические системы: Особенности проектирования. К., 1967 (автордаш); Введение в теорию проектирования асинхронных импульсных радиосистем. М., 1971 (автордаш); Оценивание и классификация параметров объектов в условиях неопределённости. Рига, 1987 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НӘҖМЕТДИ́НОВ** Тимур Гарәфетдин улы (27.12.1924, Зөя кантоны Шуширмә а. – 26.10.1977, хәзер Үзбәкстан Респ-касы, Әндиҗан өлкәсенең Мархамат р-ны Палванташ пос.), Дан орденының тулы кавалеры (21.7.1944, 16.1.1945, 19.4.1945). Геол. эзләнүләр партиясендә бораулаучы булып эшли (Фиргани өлкәсе). 1942 елның ноябреннән Кызыл Армия сафларында, 437 нче укчы полкта 45 *мм* лы туп командиры (6 нчы гв. һәм 2 нче гв. армияләренең 154 нче укчы дивизиясе). Воронеж, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Курск (1943) сугышында, Витебск-Орша, Полоцк, Рига (барысы – 1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 13 июлендә Дундары авылы (Белоруссия ССР, Минск өлкәсенең Вилейка р-ны) өчен (пулемёт расчётын сафтан чыгара, укчыларга алга китүне, авылны алуны тәэмин итә), 1944 нең 1 ноябрендә Беты (Латвия ССР) торак пункты өчен (туптан атып дошманның 2 пулемёт расчётын сафтан чыгара; контрһөҗүмне кире кайтарганда яралана, әмма ут яудыруын дәвам итә), 1945 нең 1–9 февралендә Зандляк (Бартенштайн шәһәреннән – хәзер Бартошице, Польша – 2,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак һәм Коббельбуде (Бартенштайн шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнбатыштарак) торак пунктлары янында (танкны сафтан чыгара, дошман контрһөҗүмен өзә, 2 пулемёт расчётын юк итә) барган сугышларда батырлык күрсәтә. Палванташта нефть скважиналары ремонтлау бүлегендә эшли. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Палванташта бер урамга аның исеме бирелә.



Р.Г.Нәҗметдинов.



Т.Г.Нәҗметдинов.

*Әд.:* К у р г у з о в И.П. Солдатская доблесть. Таш., 1970; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НӘҖМЕТДИ́НОВА** Әлфия Билал кызы (29.4.1949, Сверловск ш.), спортчы, тренер (нәфис гимнастика), СССРның атказ. спорт остасы (1978). Спорт б-н 1957 елда шөгыльләнә башлый, «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятенең Бөтенсоюз өлкә советы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнә, тренерлары – Л.Б.*Нәҗметдинова*, 1965 тән Е.А.Облыгина. Шәхси күптөр ярышларда: РСФСР беренчелегендә (1969, 1972), РСФСР чемпионатында (1970), соц. илләрнең халыкара турнирында (1970, ГДР), халыкара очрашуларда (1969, Куба), (1970, ГДР – СССР; «Юрмала Кубогы»), (1971, «Латвия рәссамнары призы») җиңүче; СССР (1970–71), РСФСР (1971) кубоклары иясе. Шәхси күптөр ярышларда: дөнья беренчелегендә (1969, 1972 – күптөр ярышларның аерым төрләрендә чемпион һәм көмеш медаль), СССР беренчелегендә (1972), халыкара очрашуларда (1971, ГДР – СССР), (1972, Куба – СССР, күптөр ярышларның аерым төрләрендә ике тапкыр) – көмеш приз; РСФСР (1968), СССР (1966, кызлар арасында), 1967, 1970 (күптөр ярышларның аерым төрләрендә чемпион һәм көмеш приз), 1971 (күптөр ярышларның аерым төрләрендә көмеш медаль) беренчелекләрендә, РСФСР (1967), СССР (1968, күптөр ярышларның аерым төрләрендә бронза медаль) чемпионатларында, «Студент трибунасы» кубогында (1969), РСФСР (1968), «Теләктәшлек матчы»нда (1968, Югославия), яшьләр һәм студентларның бөтендөнья чемпионатында (1968, күптөр ярышларның аерым төрләрендә бронза медаль) бронза приз иясе. СССР Кубогында (1969) чемпион һәм бронза медаль иясе (күптөр ярышларның аерым төрләрендә). 1965 тән Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Екатеринбург ш.) нәфис гимнастика буенча тренерлык эшендә. 1965–91 елларда Бөтенсоюз «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятенең өлкә советында, 1991–93 тә профсоюзларның бөтенсоюз ирекле физкультура-спорт җәмгыятендә, 1993–2000 дә физкультура һәм спорт өлкә ком-тында, 2000 нән нәфис гимнастика балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең балаларга өстәмә белем бирү өлкә дәүләт учреждениесендә (2003 тән бертуган Нәҗметдиновалар исемендә) тренер.

**НӘҖМЕТДИ́НОВА** Лилия Билал кызы (13.6.1936, Свердловск ш.), спортчы, тренер (нәфис гимнастика), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1964), бөтенсоюз категорияле судья (1972), РФ һәм ТРның атказ. физкультура хезмәткәре (1992, 2003). Спорт б-н 1946 елда шөгыльләнә башлый, «Трудовые резервы» бөтенсоюз ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (тренеры Е.А.Облыгина). Омск физкультура ин-тын тәмамлый (1961). 1951–71 елларда СССРның 15 тапкыр (абс. — 4 тапкыр), РСФСРның 12 тапкыр (абс. — 5 тапкыр) чемпионы, «Болгария — Чехословакия — СССР» халыкара ярышларында җиңүче (1960), дөнья беренчелегендә бронза медаль иясе (1965). 1951–70 тә РСФСР һәм СССР җыелма командаларында. Төрле дәрәҗәдәге ярышларда 500 дән артык чыгышта катнаша (күптөр ярышларның һәрбер төрендә җиңүчеләрне билгеләү квалификациясе буенча якынча 400 призлы урын ала). 1954 елдан Свердловск шәһәрендә: Урал пед. ин-тының физик тәрбия кафедрасында укыта, 1955–73 тә «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятенең Бөтенсоюз өлкә советында, 1973–91 дә — «Спартак», 1991 дән нәфис гимнастика буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең балаларга өстәмә белем бирү өлкә дәүләт учреждениесендә өлкән тренер. Спорт ярышларында дәвамлы катнашуы (1951–71) һәм рәсми ярышлардагы җиңүләр саны буенча (68 беренче урын, 25 икенче урын, 12 өченче урын) Гиннесс рекордлар китабына кертелә. Шәкертләре арасында Ю.Иванова — 1996 елгы Олимпия уеннарында бронза медаль алучы (төркемле күптөр ярышларда), Ә.Б.*Нәҗметдинова* бар. «Физик тәрбия һәм спорт отличнигы» билгесе (1968), «Физик тәрбия һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» бөтенроссия мактау билгесе (1995), медальләр б-н бүләкләнә. Свердловск өлкәсенең Мактаулы гражданы (2006).

**НӘҖМЕТДИ́НОВАЛАР**, атаклы спортчылар, СССР, РФ тренерлары (нәфис гимнастика), бертуган Л.Б.*Нәҗметдинова*, Р.Б.Нәҗметдинова-Ратманская, Ә.Б.*Нәҗметдинова*, И.Б.Нәҗметдинова. Нәфис гимнастиканың олимпия спорт төре буларак үсешенә зур өлеш кертәләр. **Нәҗметдинова-Ратманская Розалия Билал кызы** (15.11.1946, Свердловск ш.) — тренер, СССРның мактаулы спорт остасы (1968), РФнең атказ. тренеры (1997). Свердловск пед. ин-тын тәмамлый (1969). Кызлар арасында СССРның берничә тапкыр чемпионы (1962–63). 1968 елдан балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (2000 нән балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең балаларга өстәмә белем бирү өлкә дәүләт учреждениесе) тренер-укытучы. **Нәҗметдинова Илмира Билал кызы** (8.11.1951, Свердловск ш.) — тренер, СССРның спорт остасы (1967), респ-ка категорияле судья (1986). Свердловск пед. ин-тын тәмамлый (1973). Бөтенсоюз «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыяте, РСФСР матч очрашулары, чемпионатлары беренчелекләрендә күп тапкырлар җиңүче һәм медальләр алучы (1965–73). 1973 тән нәфис гимнастика буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы. «Физик тәрбия һәм спорт отличнигы» билгесе б-н бүләкләнә (1995). 2003 тә Екатеринбург шәһәре нәфис гимнастика буенча балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең балаларга өстәмә белем бирү өлкә дәүләт учреждениесенә бертуган Нәҗметдиновалар исеме бирелә, 2006 дан бертуган Н. кубогына ачык ярышлар уздырыла.

**НӘҖМИ́** (Нәҗметдинов) Кави (Габделкави) Һибәтулла улы (15.12.1901, Сембер губ., Курмыш өязе Кызыл Атау а. — 24.3.1957, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1919 елда Сембердә пед. курслар, 1922 дә Мәскәүдә Югары хәрби пед. ин-тын тәмамлый. 1927 дән 6 нчы Берләштерелгән татар-башкорт (хәрби) командирлар мәктәбе укытучысы һәм комиссары, бер үк вакытта, 1928–33 тә, «Кызылармеец» г-тасы җаваплы мөхәррире, 1933–34 тә «Совет әдәбияты» ж-лы мөхәррире. *ТАППны* оештыручы һәм җитәкчеләреннән берсе. 1932 дә ТАССР Язучылары берлеген оештыру ком-тында. Соңыннан берлек эшендә актив катнаша. 1934 тә 1 нче Бөтенсоюз язучылар съездында чыгыш ясый, Берлек идарәсенә сайлана. 1934–37 дә ТАССР Язучылар берлеген җитәкли. 1937 дә хәрби контрреволюцион фетнә әзерләүдә гаепләнә, репрессияләнә; 1939 ның декабрендә азат ителә, аклана. Ф.*Кәримне* аклауга күп көч куя. 1942–45 тә ТАССР ХКС каршындагы Радиофикация һәм радиотапшырулар буенча Татарстан рескомының агитация һәм пропаганда бүлеген җитәкли, 1947–49 да «Совет әдәбияты» ж-лы редакциясендә. 1954 тә 2 нче Бөтенсоюз язучылар съездында татар әдәбияты турында доклад ясый.

1912 дә «Көз» исемле беренче шигырен яза, М.Кольцовның «Лес» («Урман») шигырен татар теленә тәрҗемә итә. 1918 дә Н. тырышлыгы б-н туган авылында «Безнең иҗат» исемле кулъязма ж-л чыга башлый (1941 гә кадәр чыга). 1918 дән соң шигырьләре матбугат битләрендә күренә башлый. Беренче җыентыклары — «Өермәләр» (шигырьләр), «Кабыргасы белән тора» (шигырьләр һәм хикәяләр) 1925 тә чыга. Н.нең бу чор поэзиясе стиль, образларның үзенчәлеге, яңа шигъри формалар (к. *Имажинизм*) эзләү б-н аерылып тора. Автор чорга аваздаш актуаль социаль-әхлакый проблемалар күтәрә, аның шигырьләре, поэмалары үткәннәрне инкарь итү рухы б-н сугарылган. Н.нең тәүге прозасына да новаторлык хас. Тематикасы — борылыш чорында татар авылы язмышы, халыклар дуслыгы, интернационализм. Геройлары — гаделлек нигезендә яңа җәмгыять төзү хыялы б-н янучы солдатлар һәм матрослар, эшчеләр һәм крәстияннәр. «Шобага» (1926), «Иң соңгысы» (1927), «Миңлебикә кодагыйның кайгысы» (1927) хикәяләрендә, «Яр буендагы учаклар» (1928), «Якты сукмак» (1929) һ.б. повестьларында рев-ция вакыйгалары, Гражданнар сугышы, социализм төзү күренешләре чагылыш таба. Социаль-икътисади формация алмашыну б-н бәйле катлаулы һәм каршылыклы иҗтимагый процессларны анализлап, язучы мәңгелек темаларга — иске б-н яңаның, яхшы б-н яманның көрәше темаларына мөрәҗәгать итә. Аның әсәрләре хәрәкәткә бай, җанлы сюжет сызыклары, көчле, истә калырлык характерлар, татар теленең сәнгать чараларыннан оста файдалану б-н аерылып торалар. Н. прозасы ул чор әдәбиятында хөкем сөргән вульгар социологизм тәэсиреннән дә азат түгел.


К. Нәҗми.

Бөек Ватан сугышы елларында Н. күбрәк публицистика жанрында эшли. Аның мәкаләләрендә, очеркларында («Азатлык сугышы», 1941; «Намус эше», 1943; «Гани Сафиуллин», 1944) халыкларны берләшергә чакыру яңгырый, совет кешеләренең немец илбасарларыннан мораль-психол. өстенлеге ассызыклана. Сугыш еллары поэзиясе («Хәят апа», 1941; «Фәридә», 1944, композитор М.А.Юдин тарафыннан шул ук исемдә опера язылa) ватанпәрвәрлеккә, Ватанга һәм сугышчы бурычына тугрылыкка мәдхия җырлый. Ул «Ватан сугышы фронтларындагы улларына татар халкыннан хат»ның (март, 1943) оештыручысы һәм авторларыннан берсе була. Н. — татар милләтеннән булган Советлар Союзы геройларының батырлыклары турындагы «Батырлар китабы»ның (1945) мөхәррире һәм төзүчесе. М.*Җәлил* исемен аклау мәсьәләләрен хәл итүдә катнаша (КПСС ҮК һәм СССР ЮСна аның исемен аклауны сорап мөрәҗәгать итә); «Моабит дәфтәре»нең рус теленә сүзгә-сүз беренче тәрҗемәсен эшли.

Язучының 1928 дә яза башлаган «Язгы җилләр» (1949; СССР Дәүләт бүләге, 1951) тарихи-революцион романы — социалистик реализмның классик әсәре. Әсәр чынлыкта булган вакыйгаларга нигезләнгән, яза башлар алдыннан Н. озак кына архив материаллары б-н эш итә. Хикәяләү үзәгендә — зур татар гаиләсенең тарихы. Геройлар язмышы киң тарихи җирлектә күрсәтелә; алар рев-ция вакыйгаларында, соңрак социализм нигезләрендә яңа тормыш төзүдә катнашалар. Роман күпмилләтле совет әдәбиятының зур казанышы дип бәяләнә, 26 телгә тәрҗемә ителә. Бәхәссез югары сәнгати дәрәҗәсенә карамастан (гади эшчеләрнең тормышын күрсәтү, аларның психологиясен ачу, хезмәт батырлыгы, сыйнфый көрәш, интернационализм темалары), әсәргә күпмедер дәрәҗәдә ясалмалык, схематизм хас. «Язгы җилләр» романының дәвамы буларак, «Тирән агым» язылырга тиеш була. Автор роман өстендә гомеренең соңгы елларына кадәр эшли, ләкин төгәлләргә өлгерми. Н. — балалар өчен йомшак лирика, нечкә юмор б-н сугарылган шигырьләр авторы. Рус теленнән татар теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, А.А.Блок, С.Я.Маршак, А.И.Безыменский һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итә. Гражданнар сугышында катнаша. 1947–57 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Н. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

Ә с ә р.: Әсәрләр: 4 томда. К., 1981–84.

*Әд.:* Кашшаф Г. Кави Нәҗми // Совет әдәбияты. 1947. № 2–3; Гиззатуллин Н. Кави Наджми. К., 1957; Нежметдинов Т. Течения и водовороты жизни // Казань. 2000. № 10; Фаттахов Р. Кави Наджми. Личность и эпоха // Татарстан. 2001. № 10; Сильнее смерти и страха жизни: История любви: Док., письма, стихи. К., 2004.

*Р.Ә.Фәттахов, Т.К.Нәҗметдинов.*


**НӘҖМИ́** (Нәҗметдинов) Нажар Нәҗметдин улы (5.2.1918, Уфа губ., Бөре өязе Миңеште а. — 6.9.1999, Уфа ш.,Миңештедә җирләнә), шагыйрь, драматург, Башкортстан Респ-касының халык шагыйре (1992). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Башкорт ун-тын тәмамлый (1947). 1947–49 елларда «Совет Башкортстаны» г-тасы һәм «Әдәби Башкортстан» ж-лы редакцияләрендә эшли. 1955–59 да «Һәнәк» ж-лында мөхәррир. 1962–69 да Башкортстан АССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе. Лирик шигырьләре тупланган «Тамсылар» исемле беренче җыентыгы 1950 елда дөнья күрә. 1950–60 елларда Н. иҗаты фәлсәфи мотивларга байый («Тулҡындар», Уфа, 1955; «Көтөлмәгән ямғыр», Уфа, 1960 җыентыклары). «Шиғырҙар һәм поэмалар» (Уфа, 1964), «Көҙгө һыуҡтар» (Уфа, 1967), «Ут күрше» (1972), «Яҡты күҙҙә» (Уфа, 1984), «Йаҡынайыу» (Уфа, 1994), «Күңел сәхифәләре» (Уфа, 1999) кебек җыентыкларына патриотик пафос хас. Н. 1970 елларда хәзерге татар һәм башкорт поэзиясендә беренчеләрдән булып туган халкының этносы һәм тарихы, шәхесе һәм туган тел проблемаларын күтәреп чыга. Аның «Татар теле» (1966) шигыре һәм «Иблис» (1970) фәлсәфи поэмасы жанр классикасы буларак бәяләнә. Татар халкының милли үзаңы үсүгә мөнәсәбәтен белдереп, 1980 елларда «Бар!», «Татар бугазы», «Париж өстендә» («Тарафлар» җыентыгында, Уфа, 1988) шигырьләрен иҗат итә. Әлеге һәм соңгы еллардагы күп кенә шигырьләре б-н шагыйрь җәмәгатьчелекнең игътибарын татар диаспорасы вәкилләренең туган мәдәниятеннән аерылуы, ассимиляция проблемаларына юнәлтә. Милләтнең үсү, чәчәк ату юлын ул башка халыклар б-н тигез хокуклы хезмәттәшлектә күрә («Татар каны» поэмасы, 1986). Н. ш.у. башкорт һәм татар драматургиясе үсешенә дә лаеклы өлеш кертә. Башкорт акад. театры аның «Яҙғы йыр» (1951), «Хуш, Хәйрүш!» (1953), «Саҡырылмаған ҡунаҡ» (1954), «Гармунсы дус» (1963), «Күршеләргә кунак килгән» (1974) пьесаларын сәхнәләштерә. Көндәлек матбугат битләрендә «Яҡтылыҡ юғарынан төшә» (Уфа, 1972), «Кем уйлаган» (Уфа, 1983) җыентыкларына тупланган әдәби-тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре б-н даими басылып килә. «Һиндостан сәхифәләре» (Уфа, 1960) исемле юлъязмалар китабы авторы. Н. популяр җырлар текстлары авторы буларак та киң танылa. Башкорт теленә А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, Н.А.Некрасов, К.Кулиев, Р.Гамзатов, А.Нәваи шигырьләрен тәрҗемә итә. С.Юлаев исем. Республика бүләге (1972), РСФСРның А.М.Горький исем. Дәүләт бүләге (1982), ТРның Г.Исхакый исем. Язучылар берлеге бүләге (1994) лауреаты. Октябрь Революциясе, ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Һайланма әҫәрҙәр. Өфө, 1968; Әҫәрҙәр: 3 томда. Өфө, 1977–78; Синҡа барам: Шигырьләр, поэмалар. К., 1988; Стороны: Стихи и поэмы. М., 1982.

*Әд.:* Хәйбрахманов Р. Н.Нәҗми шигърияте. К., 2004.

*Г.М.Габделхакова.*

**НӘҖМИ́ЕВ** Нуретдин Гыйлемхан улы (5.10.1946, Балык Бистәсе р-ны Балыклы Чүкәй а.), драма актёры, ТРның халык артисты (1997). Казан театр уч-щесен тәмамлый (1971). Сәхнә эшчәнлеген, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Минзәлә татар драма театрында башлый. 1976 елдан — Татар драма һәм комедия театрында. Минзәлә татар драма театры сәхнәсендә Н. социаль характеристикалар төгәллеге, тормыш дөреслеге б-н аерылып торган, юморга бай Шофёр («Ана йөрәге», С.Кайтов), Әмшә («Хикмәтле Сәйфи», Р.Ишморат), Нияз («Соңгы хөкем», Т.Абдулмамутов), Илһам («Мария», А.Д.Салынский), Сәлмән («Гарасат», Г.Сабитов) рольләрен башкара. Көчле характерлы актёр, эпизодлар остасы буларак, Н. һәр ролен ышандырырлык итеп ачып бирә һәм тиз арада танылу ала. Аның уены халык юморы б-н сугарылган, төрле чараларга бай, ул һәр образны индивидуаль якын килеп иҗат итә. Т.Миңнуллинның «Алай түгел, болай ул» әсәре буенча куелган спектакльдә (1978) актёр бер-берсенә охшамаган, һәркайсы үзенә генә хас кабатланмас характерга ия булган дүрт карт ролен зур осталык б-н башкара. Колобок образы («Трибунал», А.Е.Макаёнок) Н. башкаруында герой килеп эләккән катлаулы психол. халәткә тирәнтен үтеп керә белүе б-н аерылып тора. Актёр иҗат иткән




Н.Г.Нәҗмиев Костылёв ролендә («Тормыш төбендә», М.Горький; уңда – Р.Шәмсетдинов).


образлар арасында Ирбулат («Кайту», Р.Ишморат), Шәйхел («Ак күгәрченнәр», Р.Батулла), Надирша («Мәкәрҗәгә барган идек», И.Юзеев), Хәмитнур, Өлфәт («Тынгысыз өч көн», М.Мәһдиев), Мәрдәнша («Курай моңы», Ш.Шаһгали), Вагыйз («Назлы кияү», К.Тинчурин), Талут («Ител суы ака торур», Н.Фәттах), Рөстәм («Яз галәмәте», Р.Сәгъди), Полковник («Кураж ана һәм аның балалары», Б.Брехт) бар.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**НӘҖМИ́ЕВ** Ринат Госман улы (5.5.1946, Казан), химик-технолог, техник фән. канд. (1986), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1987), РФнең атказ. машина төзүчесе (1996). 1972 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый.



Н.Нәҗми.



Н.Г.Нәҗмиев.

1966–98 дә Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1995 тән директор урынбасары. 1998 дән «Рособоронэкспорт» федераль дәүләт унитар пр-тиесенең ТРдагы вәкаләтле вәкиле урынбасары. Хезмәтләре эчке баллистикага карый. Н. ату зарядларының эчке баллистикасы процессларын, ату б-н бергә бара торган күренешләрне тикшерә. Көпшәле системалар өчен ату зарядлары проектлауның исәпләү һәм лаб.-стенд методикаларын эшли һәм гамәлгә кертә. Яңа буын 10 нан артык ату зарядын булдыруда һәм серияләп җитештерүгә кертүдә катнаша (Дәүләт бүләге шуларның берсен эшләгәнә һәм гамәлгә керткәнә өчен бирелә). Уйлап табуга 32 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

**НӘҖМИ́ЕВ** Тәлгат Самат улы (1.3.1950, Кукмара р-ны Байлангар а.), публицист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1981 елдан Саба р-ны «Җиңү байрагы» (хәзерге «Саба таңнары») г-тасы баш мөхәррире. «Яшә, Саба-йорт!» (1999), «Туган туфрак кадерле» (2001), «Сабаларда эчәр суым булгач» (2006) очерклар, «Саба мәзәкләре» (1999), «Тагын... Саба мәзәкләре» (2001), «Тагын... тагын... Саба мәзәкләре» (2004), «Саба: елмаюлы тарих» (2012) мәзәкләр җыентыклары авторы. ТР журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. бүләге иясе (2002).

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**НӘҖМИ́ЕВ** Юрий Гаяз улы (19.8.1946, Казан — 27.7.2006, шунда ук), җылылык энергетигы, техник фән. д-ры (1987), РФА мөхбир әгъзасы (1997), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997). 1971 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 1965–71 дә Казан язу җайланмалары з-дында эшли, цех башлыгы урынбасары (1969 дан). 1973–86 да Казан химия-технол. ин-тында, лаб. мөдире (1973–74). 1986 дан Казан энергетика ун-тында: җылылык энергетикасы ф-ты деканы (1987–93), сәнәгать җылылык энергетикасы каф. мөдире (1987–2003), проф. (1989), директор урынбасары (1993–94), директор (1994–99), ректор (1999–2003). Хезмәтләре гидродинамикага, җылылык алмашу процессларына, станция җылылык энергетикасы мәсьәләләренә карый. Н. төрле типтагы сыеклыкларның фәзаи ламинар агымнары өчен эксперименталь һәм теоретик тикше-

ренүләр үткәрә, химия һәм нефть химиясе сәнәгатендәге энергия саклаулы өзлексез процессларга структур, җылылык һәм термодинамик анализ ясый, электр станцияләрендә көл-шлактан арындыру системаларын проектлау методикасын эшли. Аның җитәкчелегендә җылылык электр станцияләрендәге җылылык алмашу җиһазларының һәм турбиналарны майлау системаларының нәтиҗәлелеген комплексы тикшерүләр уздырыла. РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутаты (2004–06).

Хезм.: Гидродинамика и теплообмен закрученных потоков реологически сложных жидкостей. М., 1996; Теплообмен при ламинарном течении жидкости в дискретно-шероховатых каналах. М., 1998; Организация энерготехнологических комплексов в нефтехимической промышленности. М., 2001; Мазутные хозяйства ТЭС. М., 2002; Системы золошлакоудаления на ТЭС. М., 2002.

**НӘҖМИ́ЕВА** Резидә Разак кызы (14.8.1961, Алексеев р-ны Левашёво а.), галим, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), а.х. фән. канд. (2007). 1983 елда Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, бәрәңге һәм җиләк культуралары үрчетү лаб-ясендә өлкән фәнни хезмәткәр (2004 тән). Дәүләт бүләге сәламәтләндерелгән меристемлы нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләгәне һәм ТРда гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**НӘЗИ́РОВ** Марис Нәзиф улы (4.8.1949, БАССРның Чакмагыш р-ны Каракөчек (хәзер Үрнәк) а. — 3.2.2013, БРның Чакмагыш р-ны Чакмагыш а.), шагыйрь, Башкортстан Респ-касының атказ. матбугат һәм массакүләм мәгълүмат хезмәткәре (2004). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Бөре пед. ин-тын тәмамлый (1972). 1973–93 елларда «Кызыл таң» (Уфа ш.) г-тасы редакциясендә әдәби хезмәткәр, үзхәбәрче, күзәтүче мөхәррир вазифаларын башкара, 1994–95 һәм 2000–01 дә «Мәгърифәт» (Уфа) нәшрияты мөхәррире, 1995–2000 дә «Тулпар» ж-лы җаваплы сәркатибе, соңрак баш мөхәррир урынбасары. 2003 тән БРның «Чакмагыш мәгълүмат үзәге» редакция-нәшрият комплексы дәүләт унитар пр-тиесе директоры. «Сакматаш» (Уфа, 1972), «Мәңгелек осош» (Уфа, 1978), «Йолдызлар табын кора» (Уфа, 1992), «Янә утларга керәм» (Уфа, 1994), «Бәрәкәтле җирем — Чакмагышым» (Уфа, 2000), «Еллар кары» (Уфа, 2002), «Һаумы, кояш!» (Уфа, 2003), «Ак торналар бүләге» (Уфа, 2006) исемле шигырь җыентыклары авторы. Шигърияте бүгенге катлаулы вазгыятьне чагылдыра, татар халкының язмышын фәлсәфи яссылыкта сурәтли, нечкә кичерешләргә бай, аһәңле яңгырашлы. Шунлыктан Н.ның шигырьләре композиторлар Р.Хәсәнов, Ф.Габдрәков, Ф. Гасакирова һ.б. тарафыннан көйгә салына, популяр җырларга әверелә.

*Әд.:* Марис Нәзиров шигърияте. Уфа, 2000.

**«НӘЗУРА́Т ӘЛ-ХАК»** («نظورات الحق» — «Китабе нәзурат әл-хаки фи фәрдият әл-эша вә ин лям ягиб эш-шәфак») — «Кичке намазның укылуы караңгы төшүгә бәйле булмавы турындагы хакыйкатькә бер караш»), Ш.Мәрҗанинең гарәп телендәге күп кенә мөһим мәсьәләләрне күтәргән дини-фәлсәфи хезмәте. 1870 елда басыла. «Н. әл-Х.»та ислам догматикасының иҗтиһад һәм тәкълид кебек мөһим төрләре тикшерелә. Татар мөселман реформаторы Г.*Курсавидан* соң, иҗтиһад принципларын — теге яки бу сорау буенча *Коръән* һәм *Сөннәдә* турыдан-туры күрсәтмәләр булмаган очракларда, дини һәм иҗтимагый тормыш турында шуларга нигезләп үз фикереңне әйтү хокукын яклый. Шул ук вакытта мөселман традицияләренчә — тәкълидчә эш итәргә дә юл калдыра. Ш.Мәрҗани, бер-берсен кире какмыйча, «бердәм хакыйкать чыганагыннан барлыкка килгән һәм чынлыкта кулга-кул тотынып барган игезәкләр кебек» дип, дин һәм фәлсәфә бәйләнешенә үз аңлатмасын формалаштыра. «Н. әл-Х.»ның нәшер ителүе мөселман Шәрегында авторга шөһрәт китерә һәм бер үк вакытта илаһият галимнәре, татар зыялылары арасында бәхәсләр уята, кадими муллалар тарафыннан гаепләнә.

*Әд.:* Юзеев А.Н. Ш.Марджани и арабо-мусульманская философия. К., 1992; шул ук. Шихаб ад-дин Марджани: Мыслитель, религиозный реформатор, просветитель. К., 1997.

**НӘКЫШБӘНДИЙӘ́** (гарәп.-фарсы نقشبندى — рәсем ясаучылык, бизәк төшерүчелек), сөнни юнәлештәге суфыйлык борадәрлеге, 14 йөздә барлыкка килә. Баһаветдин Нәкышбәнди (1318–89) нигез сала. Мөселман дөньясында 15 йөздән иң киң таралган (кадирийәдән соң) руханилар борәдәрлеге. Россиянең Төньяк Кавказ, Идел буе һәм Урал алды төбәкләрендә тарала. Н. әкренләп Идел буендагы башка руханилар борадәрлеген — Ясәвийәне (Ә.*Ясәви* нигез сала) кысрыклап чыгара, 18 йөздән гамәлдә — Урта Азия дәүләтләре, аеруча Бохара һәм Сәмәрканд б-н тыгыз элемтәләр урнаштыра. Н.нең төбәктәге үсеше 3 этапка бүленә: 1) башлангыч чоры — тәгълиматның Урта Азиядән Идел буена үтеп керүе; 2) 18 йөз уртасыннан — тәгълиматның яңартылуы, ул Н. мөҗәддидийә дип йөртелә һәм А.Сирхинди (1624 елда вафат) эшчәнлеге б-н бәйле була, татар-башкорт шәкертләре аның б-н Урта Азиядә таныша; 3) 19 йөз ахыры — Идел буе һәм Урал алды төбәкләрендә Н.нең хамидийә юнәлеше тамыр җәя, бу тәгълимат Госманлылар империясеннән һәм Төньяк Кавказдан килә, ул үсеп килүче татар җәмгыятенең мәнфәгатьләре алышынуны чагылдыра. Бу тәгълимат намаз вакытында җырлау, бию кебек экстаз халәте, кычкырып зикер әйтү — намазга чакыру (эчтән зикер әйтү кулланыла), катгый демонстратив суфыйлык һәм хөҗрәдәге суфыйлык элементларының булмавы б-н характерлана. Үз чиратында борадәрлектә махсус психофизик күнекмәләр кулланыла, нәтиҗәдә остаз һәм шәкерт арасында бергәләп фикерләр туплау юлы б-н рухи бердәмлек барлыкка килә. Б.*Вәисов*, Г.*Курсави*, Ш.*Мәрҗани*, З.*Рәсүлев*, Г.*Утыз-Имәни*, Р.*Фәхретдин*, М.*Хөсәенов*, Г.*Чокрый*, Т.*Ялчыгол* төрле елларда борадәрлек әгъзалары булалар.

*Әд.:* Ишмухамметов З.А. Социальная роль и эволюция ислама в Татарии. К., 1979; Кемпер М. История суфизма в Поволжье и Приуралье // Мир ислама. 2005. № 1; Ислам на территории бывшей Российской империи: Энцикл. словарь. М., 1998. Вып. 1.


**НӘКЫ́ШЬ СӘНГАТЕ́**, *сынлы сәнгатьтә* төп урынны алып торучы төр. «Н.с.» атамасы 18 йөздән кулланышта — ул турыдан-туры гамәли кулланылышта булмаган визуаль, хәрәкәтсез, фәзаи сәнгать төре. Н.с.нең төп төрләре нәкышь әсәрен төшерүче нигез б-н бәйләнгән: станлы әсәр махсус станокта — мольбертта иҗат ителә; монументаль һәм монументаль-бизәлеш әсәре архит-раны бизәү өчен билгеләнә һәм сәнгать синтезында мөһим роль уйный. Өслеккә пигмент төшерүнең технол. мөмкинлекләренә карап, Н.с.н майлы, җилемле (акварель, гуашь, темпера), керәч һәм силикат буяулары кулланылышлы һәм фреска төрләренә аералар; сәнгатьнең мозаика һәм витраж кебек төрләре Н.с. б-н якын тора. Тема мохитына тәңгәл китереп, Н.с. портрет, пейзаж, натюрморт, көнкүреш, тарихи, баталия, анималистик жанрларга бүленә.

Татарстан терр-ясендә монументаль-бизәлеш Н.с.нең иң борынгы үрнәкләрен Болгар шәһәренең 13–14 йөзләрдәге архит-ра истәлекләре фрагментларында күрергә була (Хан төрбәсе, Кызыл пулат һ.б.): мозаик һәм майолика тышлыклар, фреска бизәге (к. *Алтын Урда сәнгате, Монументаль-бизәлеш сәнгате*). Н.с. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан икона язу, фреска кебек борынгы рус сәнгате кысаларында үсеш ала (Успение соборының нәкышь ансамбльләре, Зөядәге Троица чиркәве, Казандагы Благовещение соборы һ.б.). 17 йөз ахырыннан башлап, сәнгатьнең дөньяга гуманистик карашларга нигезләнгән яңа принциплары ныгып урнаша. Н.с. дөньяны һәм кешенең көндәлек тормышын тагын да тулырак һәм төгәлрәк сурәтләүгә йөз тота. Аның үсеше барокко, рококо, классицизм, романтизм, салон академизмы, натурализм, реализм кебек төрле стильдәге системалар кысасында бара. 18 йөздә татарларда Н.с.нең майлы буяулар б-н пыялада башкарылучы үзенчәлекле төре — *шәмаил* барлыкка килә. Н.с. 18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан төбәгендә күбрәк көнкүреш портреты жанрларында (К.В.*Барду*, И.И.*Журавлёв*, Н.И.*Зеблов*, С.С.Ершов, З.И.Иванов, Л.Д. һәм Л.Л.Крюковлар, И.П.Петров, Р.А.Распутин, Ф.И.Чекиев һ.б.), табигать күренешләре пейзажларында (А.Н.Ракович), тарихи-дини композицияләрдә (И.Александров, П.Гаврилов, Т.Иванов, Р.Ж.Колосов, А.И.Нечаев, П.Д.Пономарёв, А.Соколов, В.С.Турин һ.б.), театр-декорация сәнгатендә (М.И.Живокини, Г.Я.Паулино) үсеш ала. Казанда эшләүче нәкышьчеләрнең күбесе А.В.Ступинның Арзамас нәкышь мәктәбен һәм Петербург сәнгать академиясен тәмамлаган, шуңа бәйле үзенчәлекле стилистика б-н аерылып торган профессиональ осталар була. Сәнгатьнең башка төрләре б-н беррәттән, Н.с. төбәктәге сәнгать үсешенең актив өлешен тәшкил итә. Н.с. Казандагы урта һәм югары уку йортлары — Беренче ир балалар гимназиясенең, ун-тның, руханилар академиясенең уку-укыту программаларына кертелә, бу, үз чиратында, нәкышь мәдәниятенең киң таралуына китерә һәм сән-


1


2


3


4


5


6


7


8


9


10


11


12


13

**Нәкышь сәнгате.** 1. Л.Д. К р ю к о в. М.С. Коринфская портреты. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Н.А. Р а к о в и ч. «Гостинозаводский чиркәве»; 3. Н.И. Ф е ш и н. «Варя Адоратская портреты». 1914. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. П.П. Б е н ь к о в. Л.Н. Толстой портреты. 1928 (?). ТР Милли музее; 5. П.А. Р а д и м о в. «Ишегалды». 1919. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Б.И. О с и п о в. «Верочка» (Рәссамның хатыны портреты)». 1924. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Б.И. У р м а н ч е. «Сөт аертканда». 1928. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. В.К. Т и м о ф е е в. «Мари туе». 1929. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. Л.Г. Ф ә т т а х о в. «Яңа бура». 1959. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Е.В. З у е в. «Урман күчтәнәчләре». 1966. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Х.Г. Я к у п о в. «Көчле кешеләр (Сыер савучылар Ф. Гәрәева, М. Исламова, С. Сәгъдиева)». 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. С.О. Л ы в и н. «Татарстан киңлекләрендә». 1960. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. И.К. З а р и п о в. «Матур көз». 1999.

гать зәвыгы тәрбияләүгә хезмәт итә. 19 йөз дәвамында Казан төбәгендә төрле елларда үз әсәрләрендә төбәк тарихын һәм табигатен чагылдырган күренекле рус нәкышьчеләре А.П.*Боголюбов*, К.Ф.*Гун*, В.Г.*Худяков*, Г.Г. һәм Н.Г.*Чернецовлар*, И.И.*Шишкин* һ.б. эшли. Казан 19 йөздә җирле һәм башка шәһәрләр рәссамнарының, Рус рәссамнары берлеге әгъзаларының, күчмә сәнгать ширкәтләренең күргәзмәләрен, ш.у. шәхси тупланмалардагы әсәрләрдән күргәзмәләр уздыру урынына әверелә (к. *Сәнгать күргәзмәләре*). Казан сәнгать мәктәбенең нәкышь бүлеге ачылу (1895) нәкышьчеләр әзерләүгә ныклы нигез була, алга таба аларның күпчелеге Татарстанда (П.П.*Беньков*, Н.М.*Сапожникова*, В.К.*Тимофеев*, Н.И.*Фешин*, К.К.*Чеботарёв* һ.б.), аннан читтә (Д.Д.*Бурмон*, Р.Либерт, К.М.Летелов, В.Э.Тюлькин, А.М.Соловьёв, М.С.Спиридонов, Н.М.Сверчков һ.б.) Н.с. үсешенә зур йогынты ясый. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Н.с. үсеше аерым стилистик агымнарның — реализм, импрессионизм, модерн, кубизм, футуризм һ.б.ның киеренкелеге, катлаулылыгы һәм төрлелеге б-н аерылып тора. Н.с.нең жанр чикләре киңәя, натюрморт, интерьер, көнкүреш һәм тарихи жанрлар үсеш ала. Театр-бизәлеш Н.с.нең 20 йөз башында алга китүе П.П.Беньков иҗаты б-н бәйле. Беренче татар нәкышьчеләре арасында «Сәйяр» труппасы спектакльләрен бизәгән С.*Яхшыбаев*, иҗат тормышы Башкортстанда узган К.Ә.*Дәүләткилдиев*, нәкышь һәм рәсем укытучысы Ш.А.*Таһиров* һ.б. була.

1920 елларда Н.с. өлкәсендә тормышны индустрияләштерү күтәренкелеге һәм яңа техник эраның эстетикасына төшенү, конструктив стилистиканың аерым күренешләрендә гәүдәләнеп, «*Подсолнечник*», «*ТатЛЕФ*» берләшмәләре, *КЭМСТ* театр коллективы рәссамнары иҗатында чагылыш таба. *ТатАХРР*ның иҗади программасы традицион жанрлар һәм төрләр кысаларында, еш кына агитацион юнәлештәге һәм публицистик үткенлек б-н чагылдырылган сыйфатлар йөртә. Станлы Н.с.нә, аеруча аның портрет һәм көнкүреш жанрлары үсешенә Н.И.Фешин лаеклы өлеш кертә. 1920 елларда заман таләпләренә җавап биргән татар Н.с. формалаша. Әсәрләре милли үзенчәлек б-н аерылып торган Б.И.*Урманче* татар милли Н.с.нә нигез салучы булып танылa. Монументаль-бизәлеш Н.с.нең яңарып алуы Казан архит-ра-сәнгать ин-тының Н.В.Пузанков җитәкчелегендәге яңа материалларны (төсле гипс һ.б.) эшкәртү буенча нәкышь лаб-ясе эшчәнлеге, Казандагы җәмәгать бииналары өчен монументаль бизәк эскизлары әзерләп тә, гамәлгә ашмаган К.К.Чеботарёв, С.И.Герштейн, С.С.Федотов, П.Т.Сперанский иҗаты б-н бәйле.

1920 еллар ахырында респ-када Н.с.нең Казаннан байтак әйдәп баручы осталарының китүенә бәйле (Н.И.Фешин, П.П.Беньков, Б.И.Урманче, П.И.*Радимов*, К.К.Чеботарёв, А.Г.*Платунова*, Н.М.Сапожникова һ.б.) илдәге сынлы сәнгатьнең гомуми үсеш дәрәҗәсеннән артта калу тенденциясе сизелә. 1930–50 елларда, соц. реализм принципларына туры китереп, Н.с. сюжетның идеялелегенә, аны ачуда иллюстратив-хикәяләү башлангычына йөз тота. Көнкүреш жанрына һәм тарихи-рев. тематик картиналарга өстенлекле әһәмият бирелә (Д.П.Архипов, П.М.*Байбарышев*, Д.Г.*Булат*, М.М.Васильева, Х.И.Казаков, В.Л.*Лаптев*, Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов*, Н.К.*Вәлиуллин*, В.А.Радионов, С.А.Ротницкий, Н.М.Сокольский, В.К.Тимофеев һ.б.). Театраль-бизәлеш Н.с.нең алга таба үсеше Ә.Х.*Нагаев*, М.Г.*Сутюшев*, Ә.И.Тумашев, В.С.*Никитин* һәм П.Т.Сперанский, ш.у. Казанда төрле елларда эшләп алган Россия рәссамнары — Н.А.Андреев, Н.Н.Золотарёв, А.А.Осмёркин, Б.Г.Кноблок, Ш.И.Сельвинский һ.б. иҗатында дәвам иттерелә. 1960–80 нче елларда Н.с. үсеше совет сынлы сәнгатенә хас булган «кырыс стиль» һәм романтик юнәлеш дип аталган кысаларда эчтәлек һәм сәнгать формасын яңарту процесслары б-н характерлана. Илнең сәнгать вузларында проф. әзерлек алган һәм респ-каның Н.с.н яңа стилистик агымнар б-н баеткан нәкышьчеләр контингенты шактый киңәя. Алар арасында милли формалар эзләгән әсәрләр мөһим урын биләп тора (А.Ә.*Абызгилдин*, И.К.*Зарипов*, Е.В.*Зуев*, Р.Ә.*Килдебәков*, И.В.*Рәфыйков*, В.Н.*Скобеев*, М.Г.*Усманов*, Л.Г.*Фәттахов*, В.К.Фёдоров, Х.Х.Хәйдәров һ.б.). Н.с.нең алга таба үсешендә һәм яшь нәкышьчеләрнең осталыгын күтәрүдә 1977 елда Казанда ачылган Х.Г.*Якупов* җитәкчелегендәге *Россия Сәнгать академиясенең* (1992 елга кадәр СССР СА) *Иҗат остаханәсе* әһәмиятле роль уйный. Татарстан Рәссамнар берлегенең КамАЗда, респ-каның нефть һәм авыл районнарында эшләгән нәкышьчеләрнең иҗат төркемен төзүе Н.с. әсәрләрендә хәзерге заманны тагын да киңрәк һәм күптөрлерәк тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә. Н.с.дә жанр полифониясе (төркемле портрет, индустриаль һәм лирик пейзаж, натюрморт, көнкүреш һәм тарихи-революцион жанрлар) нәфис һәм композицион башкару алымнарын яңарту б-н аралашып килә: киң форматлы картиналарга, тегe яки бу дәрәҗәдә социальләшкән сюжет б-н күп фигуралы күмәк композицияләргә, конкрет өлкәгә хас типик, характерлы чалымнар эзләүгә өстенлек бирелә (Н.Д.Кузнецов, И.В.Рәфыйков, Л.Г.Фәттахов, В.К.Фёдоров, И.М.*Хәлиуллов*, М.Х.Хәйретдинов, Х.Г.Якупов һ.б.). Респ-када төзелешләрнең киң колач алуы, яңа шәһәрләрнең, эре иҗтимагый биналар һәм мемориаль ансамбльләрнең калкып чыгуы Н.с.нең монументаль-бизәлеш төре үсешенә, темпера һәм фреска бизәлеше, мозаика, витраж техникасының яңаруына һәм яңа төрләреннән — керәч плитәгә ялтыравык бизәк төшерү, сграффитто һ.б. техникасыннан файдалануга китерә (А.Ә.Абызгилдин, Н.П.Артамонов, С.М.Бубеннов, Р.М.Вахитов, Р.Ә.Килдебәков, Е.В.Киселёва, В.И.Охотин, К.М.Сафиуллин, Ә.С.Фәтхетдинов, В.К.Фёдоров, И.М.Ханов һ.б.). Респ-каның сәнгатенең торган саен йогынтылырак өлеше була барган Н.с. кызу темплар б-н Казаннан читтәге шәһәрләрдә: Әлмәттә (Р.В.Гомәров, Г.А.Стефановский, А.Ф.Косолапов, А.И.Максютин, Н.М.Горланов һ.б.), Бөгелмәдә (Ф.Е.Корнилов, И.М.Насретдинов һ.б.), Яшел Үзәндә (Р.Ф.Галиуллин, Ю.Е.Ершов, А.В.Крылов, Х.К.Сибгатуллин һ.б.), Лениногорскида (А.Г.Горюнов, Я.Г.Зиннәтуллин, А.М.Ильин, О.А.Кульпин, Д.К.Садретдинов, А.И.Юдин һ.б.), Түбән Камада (Г.Н.Капитов, Р.М.Мәрданшин, Ә.С.Фәтхетдинов һ.б.), Алабугада (М.М.Кузнецов, З.М.Миңнәхмәтов, Р.М.Сәләхов һ.б.), Чаллыда (В.Я.Акимов, Н.А.Бикташев, Э.В.Бутова, А.И.Вашуров, Г.А.Иванов, В.Ф.Крайников, А.В.Карпенко, К.М.Сафиуллин, Ю.Г.Свинин, М.Ш.Хаҗиев һ.б.) үсеш ала.

Төбәкләрдә эшләүче рәссамнарның иҗатында иң киң таралган жанрларга пейзаж һәм портрет, ш.у. район үзәкләренең һәм яшь шәһәрләрнең мәдәни үсеш ихтыяҗларына бәйле монументаль-бизәлеш сәнгате керә (к. *Монументаль-бизәлеш сәнгате*).

Н.с.нең 1980–90 еллар азагындагы үсеш үзенчәлекләре илдәге мәдәни тормышта барган гомуми процесслар, тарихның хәлиткеч чорында мәдәният өлкәсендәге беренчел максатлар турында яңача фикерләүләр б-н бәйле була. Н.с.дә милли сәнгати фикерләүнең чагылышы үзенчәлекле хисси-сиземләү башлангычының көчәюе б-н кушыла. Бер үк вакытта реализмның стилистик төрләренең киң спектры (А.Ә.Абызгилдин, В.Я.Акимов, В.В.Анютин, Р.М.Вахитов, З.Ф.Гыймаев, Б.А.Гыйльванов, Р.Г.Заһидуллин, И.К.Зарипов, К.А.Нәфыйков, Ш.А.Нигъмәтуллин, Ш.М.Шәйдуллин һ.б.) б-н бергә респ-каның Н.с. рәссамнары иҗатында — «Группа-17» рәссамнар берләшмәсе әгъзалары, «Дастан», «Тамга» һ.б.ның (А.М.Артамонов, А.В.Бусыгин, Е.Голубцов, А.И.Дорофеев, А.Р.Ильясова, В.А.Нестеренко, Ә.Сәйфетдинов, И.А.Хәсәнов, Х.М.Шәрипов һ.б.) үзләрен төрле поставангардизм агымнары итеп күрсәтәләр. Чаллы төркеме «Ансваки» иҗатында (В.В.Анютин, Ю.Г.Свинин, В.Я.Акимов) антиурбанистик, «соцарт» нәкыше үсеш ала. Н.с. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм аның филиалларында, ТР Милли музеенда һәм аның филиалларында, Әлмәт, Чаллы картиналар галереяларында, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда һ.б. саклана.

*Әд.:* Дульский П.М., Искусство в Татарстане за годы революции. К., 1929; Черкасова Н.В. Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. М., 1978; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983; Валеева Д.К. Искусство Татарстана (20 век). К., 1999; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Республики Татарстан. К., 2001; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002.

*Е.П.Ключевская.*

**НӘЛЕ́Т** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 94 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Майна елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 4 кеше (мордвалар) яши. 1710–11 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.тә земство мәктәбе, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл

җәмәгатенең имана җире 1166 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Иске Бәрән волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 149 ир-ат; 1859 да — 641, 1897 дә — 1046, 1908 дә — 1320, 1920 дә — 1396, 1926 да — 706, 1938 дә — 458, 1949 да — 470, 1958 дә — 405, 1970 тә — 358, 1979 да — 160, 1989 да — 37, 2002 дә — 23 кеше.

**НӘОРГА́НИК ХИ́МИЯ**, химик элементлар һәм алар төзегән гади һәм катлаулы матдәләр (углерод кушылмаларыннан тыш; аларын *органик химия* фәне өйрәнә), аларның төзелеше, әверелеше һәм реакцияләргә керү сәләте турындагы фән. Н.х. — химиянең зур өлкәсе, органик химиядән тыш, ул химиянең башка бүлекләре: *аналитик химия*, коллоидлар химиясе, биохимия, кристаллохимия, *физик химия*, химик термодинамика, *электрохимия*, радиохимия, химик физика һ.б. б-н тыгыз бәйләнгән. Нәорганик һәм органик химияләр чигендә металлорганик кушылмалар һәм *элементорганик кушылмалар* химиясе аерылып тора. Н.х. геол.-минерал. фәннәре, барыннан да элек *геохимия* һәм минералогия, ш.у. техник фәннәр — *химия технологиясе* (аның нәорганика өлеше), металлургия һәм *агрохимия* б-н бәйләнгән. Н.х.нең төп бурычы: атомнарның электрон төзелешен һәм алар төзегән кушылмаларның составын, үзлекләрен һәм структурасын ачыклау; заманча техника өчен алдан билгеләнгән үзлекләргә ия булган яңа материаллар табу юлларын эшләү һәм фәнни нигезләү. Н.х. тикшеренүләренең төп ысуллары — перспектив алым (юнәлтүле кристаллаштыру, зоналап яңача кристаллаштыру, вакуумлы сублимация, фракцияләп кудыру һ.б.) һәм физик-химик анализ алымы (системадан кушылманы (фазаны) турыдан-туры аерып алу таләп ителми). Хәзерге Н.х.дә ш.у. тикшерүнең физик алымнары: спектроскопия, беренче чиратта оптик һәм радиоспектроскопия, структур рентген анализы, масс-спектроскопия, дериватография һ.б. кулланыла.

Нәорганик материаллар турында беренче төшенчәләр борынгы заманда чүлмәк ясау, металлургия, пыяла ясау, ману һ.б. һөнәрләргә бәйле рәвештә туа. Дөньяда барган химик әверелешләрнең табигатен аңларга тырышулар шушы чорга карый: дүрт элемент (стихия) — ут, су, һава, җир турында тәгълимат; алхимиядә «фәлсәфи таш»; ятрахимиядә (дарулар турындагы фән) өч башлангыч (терекөмеш, күкерт һәм тоз) теориясе; флогистон теориясе барлыкка килә. Гарәп алхимигы әр-Рази (10 йөз) матдәләрне килеп чыгышы буенча җир (минерал), үсемлек һәм хайван чыгышлыларга бүлә. Инглиз галиме Р.Бойль, химик элементларга билгеләмә биргәндә (17 йөзнең 2 нче яртысы), алар башкаларына таркала алмый торган матдәләр, дип әйтә, экспериментка (анализ һәм синтезга) беренчел дәрәҗәдә әһәмият бирә. Н.х.нең фән буларак формалашуына рус галиме М.В.Ломоносов һәм француз химигы А.Лавуазье хезмәтләре йогынты ясый, алар бер-берсенә бәйсез рәвештә химик реакцияләрдә матдә массасы саклану законын ачалар. Ломоносов тагын йөз елдан соң гына үсеш алачак корпускуляр (атом-молекуляр) тәгълимат нигезләрен бәян итә (1740 еллар); җылылыкның кинетик теориясен аерып күрсәтә, химик күренешләрне аңлату өчен физика төшенчәләрен куллану кирәклеген нигезли һәм химиянең теоретик өлеше өчен — «физик химия», гамәли өлеше өчен «техник химия» терминнарын кертә. Лавуазье химик элемент төшенчәсен конкретлаштыра, барлык матдәләрне гади һәм катлаулыга бүлеп, беренче рациональ химик номенклатураны һәм җисемнәрнең классификациясен эшли (1786–89). 19 йөз гомуми химик законнар ачылу, атом-молекуляр тәгълиматның үсеше, структур күзаллаулар б-н тарихка керә. Инглиз галиме Дж.Дальтон химиягә атомизмны кертә, элементларның беренче атом үлчәүләре таблицасын эшли, тапкырлы нисбәтләр законын формалаштыра. Гей-Люссак, Авогадро, составның даимилеге (француз химигы Ж.Пруст) законнары ачыла. Англия галиме Г.Дэви электрохимик якынлык теориясен бастырып чыгара, электролиз юлы б-н калий, натрий, барий, кальцийны, стронций һәм барий амальгамаларын таба. Швед галиме Й.Я.Берцелиус химиядә атомизмны тулысы б-н ныгыта, химик элемент символларының хәзерге тамгаланышын һәм кушылмаларының беренче формулаларын кертә; церий, селен, торийны ача; кремний, титан, тантал, цирконийны таба; атом үлчәүләренең яңа системасын тәкъдим итә һәм күп кенә кушылмаларның формуласын төзәтә. Берцелиус һәм аның шәкерте Ф.Вёллер заманыннан химияне нәорганик һәм органикка бүлү башлана. 19 йөз уртасыннан атом, молекула һәм эквивалент төшенчәләре ачык билгеләнә (француз химигы Ш.Ф.Жерар, итальян химигы С.Канниццаро). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында физик химиянең төп законнары һәм теориясе формалаша (массалар тәэсире законы, электролитик диссоциация законы, Освальдның сыеклау законы, Ле Шателье принцибы, Нернст теоремасы һ.б.). Алар Д.И.Менделеевның периодик законы (1869 да ачыла) һәм периодик системасы б-н бергә хәзерге Н.х.нең һәм технологиянең теоретик нигезен тәшкил итәләр. Химик-нәорганиклар металл эретмәләрне өйрәнә башлыйлар, термик анализ алымнарын нигезләүгә керешәләр (француз физик-химигы А.Ле Шателье, рус химиклары Н.С.Курнаков, А.А.Байков һ.б.) Дж.У.Гиббсның фазалар кагыйдәсе эретмәләр тәгълиматының теоретик нигезен тәшкил итә. 20 йөздә Н.х.нең төп юнәлешләреннән берсе — комплекслы (координацияле) кушылмалар химиясе, аларның төзелеше һәм үзлекләренең гомуми теориясе төзелә (Швейцария химигы А.Вернер, рус галимнәре Л.А.Чугаев, И.И.Черняев). Инерт газлар — аргон, гелий, криптон, неон, ксенон, радон (инглиз галимнәре Д.Рэлей, У.Рамзай, М.Траверс, немец химигы Ф.Дорн); уранның (француз физигы А.Беккерель) һәм торийның үзлегеннән радиоактивлыгы (француз химигы һәм физигы М.Склодовская-Кюри, рус химигы Г.Шмидт), полоний һәм радий элементларының радиоактивлыгы (П.Кюри, М.Склодовская-Кюри) ачыла. Бу ачышлар изотопларны табуга, радиохимия һәм атом төзелеше теориясе (инглиз физигы Э.Резерфорд, Дания физигы Н.Бор һ.б.) барлыкка килүгә этәргеч була. Кристалларда рентген нурларының интерференциясе ачылу нәорганик матдәләр структурасын (фәзада урнашуы һәм кристаллда атомнарның бәйләнеше) аларның химик һәм физик үзлекләре б-н бәйләргә мөмкинлек бирә. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында квант механикасының үсеше һәм аның химиядә кулланылуы *квант химиясе* һәм химик физика кебек фәнни дисциплиналар формалашуга китерә. Төш физикасындагы уңышлар трансуран элементлар синтезлау мөмкинлеген бирә. Сирәк мәгъдән һәм платиналы элементларны аерып алуның нәтиҗәле алымнарын (хромотография, экстракция һ.б.) эшләү, алардан махсус үзлекле яки алдан билгеләнгән үзлекле сирәк элементлар һәм материаллар табу Н.х.дә яңа сыйфат үзгәрешләре туга сәбәп була, 1940 еллар уртасында ЭПР һәм ТМР күренешләре ачылу Н.х.гә кушылмаларның төзелешен һәм реакция сәләтен тикшерүнең куәтле ысулларын бирә. 1950 елларда биополимерлар комплексларын яки тере организмнарда була торган металл ионнары катнаш түбән молекулалы табигый матдәләрне өйрәнүче бионәорганик химия формалаша; химик тәэсир итешүгә сәләтсез дип саналган инерт газлар химиясе барлыкка килә. 1960 елларда каты җисем химиясе мөстәкыйль фән булып бүленеп чыга, 20 йөз ахырында, биол. молекулалар кебек, үз-үзен оештыруга, көйләүгә һәм репликациягә сәләтле супромолекуляр кушылмалар химиясе үсеш ала. Фундаменталь Н.х. ачышлары гамәли химиянең алгарышын тәэмин итә: абразив һәм кискеч кораллар өчен үтә каты материаллар, үтә саф металл һәм эретмәләр, пьезоэлектриклар, ярымүткәргечләр, электрон техника өчен үтә үткәргечләр, нәорганик полимерлар, җиңеләйтелгән төзелеш материаллары, космик ракеталар өчен ягулык, оксидлагычлар, керамик капламнар, ш.у. радиация, югары темп-ра, басым, механик йөкләнешләр һәм агрессив мохитнең җимергеч тәэсиренә тотрыклы башка нәорганик матдәләр булдырыла.

Россиядә 1820 еллар башында 7 университет (ш.и. Казанда) эшләп килә, алар каршында химия кафедралары һәм лаб-ияләре оештырыла. Казан ун-тында Н.х.нең үсеше химик-аналитик тикшеренүләр кысасында алып барыла. Казандагы коеларның суы анализлана (Ф.Л.Эвест), тоз, скипидар, табигый су үрнәкләре тикшерелә (И.И.*Дунаев*), бакыр кою өчен күрсәтмәләр эшләнә (И.Ф.Вуттиг), бинар металл системалар өйрәнелә, һавага анализ ясала (А.Я.*Купфер*), күкертле минераль суларның, дәвалау ләменең составы билгеләнә (К.*Клаус*). Химик-органиклар Н.Н.*Зи-*

*нин*, А.М.*Бутлеров*, В.В.*Марковниковның*, химик-технолог М.Я.*Киттарының* беренче хезмәтләре Н.х.гә карый. Урал чыганакларының платиналы рудалар калдыкларыннан платиналы металларны аерган вакытта Клаус *рутений* элементын ача, аның химик үзлекләрен өйрәнә, атом массасын билгели, рутений-родий-палладий һәм осмий-иридий-платина триадалары арасындагы охшашлыкка игътибар итә, металларның бер-берсенә модификация ясаучы тәэсирен ачыклый, комплексны кушылмалар төшенчәсенә якын килә. 19 йөз ахырында эремәләрдәге һәм каты халәттәге металл тозларын тикшерү, аларны өйрәнү алымнарын булдыру Н.х.нең үсешенә сәбәп була. Химик кушылмалар төзелеше һәм формасы теориясе, яңа химик анализ системасы тәкъдим ителә, эремәләрнең химик теориясе төзелә (Ф.М.*Флавицкий*). Термохимия һәм электрохимия фәнни юнәлеше формалаша. Эретелгән тозлар электролизы буенча тикшеренүләр үткәрелә, «состав-үзлек» диаграммаларын төзү өчен электр үткәрүчәнлекне үлчәү тәкъдим ителә, диссоциациянең гидролитик теориясе үстерелә, электр үткәрүчәнлеккә нәэлектролитларның йогынтысы өйрәнелә (А.Я.*Богородский*). Факеллы бушануның химик тәэсирен (К.Н.*Мочалов*), химик процессларга ультракыска дулкыннар тәэсирен (В.Я.Куренев) тикшерү, электр үткәрүчәнлекне өйрәнү методикаларын эшкәртү (Г.П.*Дезидерьев*) гамәли әһәмияткә ия була. Коллоид системалар химиясе буенча (А.Ф.*Герасимов*), химик анализның классик алымнарын камилләштерү, нәорганик матдәләрнең эвтектиясе һәм төзелеше буенча (А.М.*Васильев*) тикшеренүләр үсеш ала. Физик-химик анализ алымы буларак, җылыту кәкреләрен (термографияне) билгеләүнең теоретик һәм эксперименталь нигезләре эшләнә, тозлы һәм ярымүткәргечле системалар өйрәнелә (Л.Г.*Берг*). Бинар системалар диаграммаларын төзү закончалыклары ачыла, катлаулылык дәрәҗәсе һәм типлары төрле булган системалар өчен интерполяцион формулалар чыгарыла, аларга термодинамик нигезләмә бирелә (С.Д.Громаков). Тозлы тигезләнешләр өйрәнелә; электролитта үзара химик тәэсир итешми торган изотоник эремәләрне катнаштырганда суның активлыгы үзгәрми дигән кагыйдә чыгарыла; тоз системаларының эрүчәнлеге буенча 4 томлы белешмәлек төзелә (А.Б.Здановский). 1930 еллар ахырында, полярография алымын кулланып, эремәләрдә комплекслар барлыкка килүне системалы тикшерә башлыйлар, аналитик һәм нәорганик химияләрдә электрохимик алымнар куллану буенча фәнни юнәлеш барлыкка килә (В.Ф.*Торопова*). Бөек Ватан сугышы елларында затлы металларның фосфорорганик (элементорганик) лигандлар б-н комплексны кушылмаларын тикшерүләр оештырыла (А.А.*Гринберг*). Бу юнәлеш б-н А.Д.*Троицкая* җитәкчелек итә, ул күрсәтелгән лигандлар һәм аларның үз сферасындагы әверелешләре (таутомерия, гидролиз, сольволиз, редокс-процесслар) транстәэсиренең гомуми закончалыкларын ачыклый. Палладий, платина һәм родийның элементорганик лигандлар б-н гадәти булмаган оксидлашу дәрәҗәләрендәге кушылмалары синтезлана, яңа кайтаргычлар кулланып, платина төркемендәге югары дисперслы металлар алу юллары эшләнә (В.К.*Половняк*). Платиналы һәм күчеш металларының азот- һәм күкерторганик лигандлар (ш.и. биоактив) б-н реакцияләре өйрәнелә, сусыз тирәлекләрдә хелат комплекслар катнашында барган электродлы процессларның һәм реакцияләрнең үзенчәлекләре ачыклана (Н.А.*Улахович*). 1950 елларда нәорганик кушылмаларны яңа физик-химик анализлау һәм тикшерү ысулы — төш-магнит релаксациясе ысулы эшләнә, аның ярдәмендә эремәдәге кисәкчекләрнең составы, тотрыклылыгы һәм динамик тотышы билгеләнә, металл-лиганд бәйләнешенең характеры ачыклана (А.А.*Попель*). Бу ысулны аналитик һәм нәорганик химияләрдә куллану мөмкинлекләре (Е.Д.Гражданников), парамагнитик ионнар эремәсендә кисәкчәара тәэсирләшүләрнең характеры (З.А.Сапрыкова) өйрәнелә; төрле тирәлекләрдә физик-химик үлчәү нәтиҗәләрен матем. модельләштерү аспектлары карала (Ю.И.*Сальников*); күчеш металларының гетеровалент һәм гетеротөш комплекслары барлыкка килү шартлары һәм аларның үзлекләре өйрәнелә (А.Н.*Глебов*). Комплекслар эремәләрендә сольват, лиганд, протон һәм электрон алмашу реакцияләре турында яңа мәгълүмат алына (А.В.*Захаров*, В.Г.Штырлин) һәм ул процессларның механизмы тәкъдим ителә. Металл катыш желатин иммобильләшкән матрицалы системаларда комплекслар хасил булу һәм темплат синтезы реакцияләре өйрәнелә (О.В.*Михайлов*). Бинар тирәлекләрдә сольватлашу һәм комплекслар хасил булуны тикшерү өчен яңа структур-динамик юл тәкъдим ителә (Ф.В.*Девятов*). Молибденның элек билгеле булмаган кушылмалары синтезлана, аларның структурасы һәм үзлекләре өйрәнелә (Н.Д.*Чичирова*), сулы эремәдә лантаноидларның гомо- һәм гетеротөшле каты булмаган конформацион комплексларының төзелеше билгеләнә (В.В.*Чевела*). Г.С.*Воздвиженский* җитәкчелегендә комплексны кушылмалар электрохимиясе буенча фәнни юнәлешкә нигез салына, бу тикшеренүләрнең гамәли мөмкинлекләре билгеләнә. Металлар һәм эремәләрне электрохимик утырымга төшерү һәм металларны анодлы эретү процессларына күләмле (электролит массасында) һәм өслекчә (электродларда) комплекслар оештыруның, ш.у. тирәлек ачылыгының тәэсире өйрәнелә (Н.В.*Гудин*, С.И.*Березина*), композицион капламнар табу шартлары ачыклана (Р.С.*Сәйфуллин*). Матдә төзелеше турында квант-механик күзаллауларны һәм химик процессның термодинамик сыйфатларын файдаланып, мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен яңа фәнни-методик нигездә гомуми һәм Н.х. дәреслеге эшләнә (Н.С.*Әхмәтов*). Молекуляр һәм ионлы адсорбациянең фазара электрохимик чикләрдәге ролен ачыклау, ш.у. редокс-процессларның термодинамик параметрларын теоретик бәяләү, металл комплекслары катнашкан реакцияләрдә элементар акт кинетикасын һәм механизмын өйрәнү өчен, электрохимик процесслар квант химиясе ысулларын кулланып модельләштерелә (М.С.*Шапник*, А.М.*Кузнецов*). Корылма күчерүнең традицион булмаган микроскопик модельләре (Р.Р.*Нәҗметдинов*), эремәләрдә металларның комплексны кушылмалары электрохимиясе мөмкинлекләре (Г.К.*Будников* һ.б.) тикшерелә. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан Н.х.нең яңа перспективалы юнәлешләре үсеш ала: күчеш металларының координацион һәм бионәорганик кушылмалары структурасы, термодинамикасы, кинетикасы, аларны хасил итү һәм электрон күчерү реакцияләре һәм механизмнары, биол. актив кушылмалар синтезлау (А.В.Захаров, В.Г.Штырлин); күп компонентлы супрамолекуляр системаларда металл ионы-лиганд (функцияләшкән каликсареннар)-амфифиль субстрат нигезендә идарә ителешле үзоешу (А.Р.Мостафина, Р.Р.Әмиров); супрамолекуляр системаларда — актив өслекле матдәләрнең оешкан ансамбльләрендә, ш.у. макроциклик лигандларда комплекслар хасил булу процесслары (Р.Р.Әмиров); координацион һәм металлорганик сыек кристаллы кушылмалар — металломезогеннар (И.В.*Овчинников*, Ю.Г.*Галәметдинов*); югары һәм түбән молекуляр эффекторлы ДНК комплекслары хасил булу (С.С.Бабкина); яңа типтагы супрамолекуляр лигандлар синтезлау һәм аларның металл ионнары б-н тәэсир итешүләрен өйрәнү (Н.Г.*Зәбиров*); фосфорлы һәм металл координацияле эпоксид олигомерлар нигезендә яңа материаллар (Л.М.Әмирова), оптик квант генераторлары өчен I–III төркем металл фторидлары һәм лигандлар (З.М.Латыйпов, Р.Ю.Абдулсабитов һ.б.) булдыру. Н.х. буенча төп фәнни тикшеренүләр Казан ун-тында, Казан техник һәм технол. ун-тларында, ТРның кайбер тармак фәнни-тикшеренү ин-тларында алып барыла. Төп эшләр: нефть химиясе синтезы өчен яңа катализаторлар (А.А.Ламбедов), төрле ашламалар, полимер фосфатлар, бәйләгеч матдәләр, пыяла ясау материаллары технологияләре (Л.И.*Кузнецов-Фетисов*), минераль тозлар, кислоталар, катлаулы ашламалар, аеруча саф металлар табу технологияләре (Т.Г.*Әхмәтов*); саф магнит оксиды алу өчен гадәти булмаган магнезиаль чимал эшкәртүнең физик-химик нигезләре (В.А.*Хөснетдинов*) һ.б., ш.у. ионлы плазма җиһазлары ярдәмендә тотрыклы капламнар ясау, металларны югары сыйфатлы өрдерү нигезләре эшләнә. Заманча перспектив материаллар, биол. актив препаратларның яңа классын булдыру эшләре алып барыла. Фәнни эшкәртмәләр машиналар төзелеше, космик, электрон, фармацевтика сәнәгатьләрендә, төзелештә, авыл хуҗалыгында һ.б. тармакларда зур гамәли әһәмияткә ия.

*Әд.:* Неорганическая химия в Казанском университете: Люди, события, направления исследований. К., 2001; Хаускрофт К., Констебл Э. Современный курс общей химии: В 2 т. М., 2002.

*А.В.Захаров.*

**НӘРКИ́З** (Narcissus), амариллисчалар семьялыгыннан күпьеллык үсемлек ыругы. Чыгышы — Кавказ һәм Көньяк Европа. Якынча

60 төре билгеле. Культурада Н.нең 25 төре киң кулланыла һәм бик күп гибрид формалары бар. Суганчалары күпьеллык, коңгырт элпәле, тәңкәле. Кыяк яфраклы. Чәчәкләре, гадәттә, сары яисә ак, чәчәк сабында ялгыз яки берничәшәр урнашканнар. Таҗ авызчыгының өстендә цилиндрсыман көпшә һәм таралган, алты бүлемле көпшәсыман, кыңгыраусыман яисә касәсыман себеркәчле (таҗлы). Май–июнь айларында чәчәк ата. Җимеше — өч якка ачылмалы итләч тартмачык. Н.нең якынча 9 мең сорты һәм төрле төрләре билгеле, алар формалары, үлчәмнәре, чәчәкләренең төсе б-н аерылучы 12 төркемгә берләшәләр. Н.не суганча һәм орлыклардан үрчетәләр. Орлыкларны җыеп алгач ук, киптермичә, 1 *см* тирәнлектә чәчәләр. Күчереп утыртылмый. Чәчкәннән соң 4–5 нче елда чәчәк ата башлый. Утыртканда уртача яктытулы, грунт сулары 50–60 *см* дан югары булмаган участокларны сайлыйлар. Туфракка талымсыз. ТРда Н.нең гибрид формасы декоратив үсемлек буларак бакчаларда, паркларда үстерелә. Кайбер төрләренең чәчәкләрендә эфир майлары бар (бик исле), суганчалары — алкалоидлар. Төрле халыкларның мәдәниятында Н. күп төрле легенда һәм ышанулар б-н бәйле.

**НӘСЕЛЛЕ́ ТЕРЛЕ́К ҮРЧЕТҮ́**, а.х. терлекләренең токымнарын яхшырту һәм җирле шартларга җайлашкан яңа, тагын да отышлырак токым, линия, семьялык һәм кросслар чыгару буенча зоотехник чаралар системасы. Терлекләрнең нәселен үзгәртү һәм продукция бирүен арттыру, югары сыйфатлы үрчем (ана һәм ата зат) алу максатыннан нәсел з-длары һәм фермалары (репродукторлар) булдырыла.

**Нәселле терлек заводлары.** Нәселле терлек хуҗалыкларына, дәүләт нәсел үрчетү һәм ясалма орлыкландыру станцияләренә, ш.у. товар җитештерүче хуҗалыкларга сату өчен югары җитештерүчәнлекле нәселле терлекләр үрчетү б-н шөгыльләнәләр. Кагыйдә буларак, һәр токым буенча терлекләрнең нәселе, аерым үзенчәлекләре һәм продукция бирү сыйфатлары яхшыру дәрәҗәсе исәпкә алынып, төрле типтагы берничә завод булдырыла.

Нәселле терлекләр «элита» классына керергә яки 1 нче класслыдан түбән бәяләнмәскә, завод тибына хас үзенчәлекләрне сакларга, нәсел эше нәтиҗәсендә булдырылган һәм камилләштерелгән сыйфатларын үз токымына тайпылышсыз рәвештә күчерергә сәләтле булырга тиеш. Һәрбер терлекнең нәселе һәм продукциялелеге аерым теркәп куела. Завод терлекләренең баш саны сыйфатлары билгеләнгән таләпләргә туры килгән яңа үрчем хисабына тулыландырыла. Ана затка кушу өчен фәкать үз ата затлары гына кулланыла. Аерым очракларда башка заводларның шул ук токым ата затлары файдаланылырга мөмкин.

**Нәселле терлек фермалары.** Төп бурычы — нәсел яхшырту максатыннан башка хуҗалыкларга сату өчен аерым токымнарга хас сыйфатларга ия, үз сыйфатларын нәсел буенча тайпылышсыз тапшырырга сәләтле, югары продукцияле ана зат һәм нәсел башы (ата зат) терлекләр үстерү. Нәселле терлек үрчетү төрле юллар б-н, беренче чиратта, терлекләрне типлары буенча аерып, иң яхшы яңа сыйфатларны үстерү юнәлешендә алып барыла. Бу бурыч уңышлы гамәлгә ашырылган очракта, нәселле терлек фермасы нәселле терлек з-ды итеп үзгәртелергә мөмкин. Икенче юл — бу ферма ана затларын даими рәвештә аерым бер завод нәсел башлары (ата зат) б-н кушу (йотылу) һәм ферманың бүлендек з-дка әверелүе. Өченче ысул — даими һәм планлы рәвештә төрле заводларның төрле нәсел башларын (ата затлар) кулланып, продукция бирүчәнлекләре б-н кайвакыт завод терлекләреннән дә өстенрәк гомуми токымлы тип китереп чыгару. Шулай итеп, төрле заводларның терлекләренә хас иң отышлы, әмма типлары буенча бериш булмаган сыйфатларның рациональ кушылмасына ирешелә. Бу очракта төрле заводларның нәсел башларын (ата зат) төрле сыйфатларга ия ана зат б-н кушуның иң уңай нәтиҗәләрен ачыклау һәм нәсел башын билгеле бер система буенча куллану мөһим.

**Товар җитештерү хуҗалыклары.** Товар җитештерүче хуҗалыкларда терлек үрчетүнең төп максаты — аз чыгым тотып, күп күләмдә иң яхшы сыйфатлы терлекчелек продукциясе алу. Чиста токым үрчетү б-н бергә катнаш кушылдыру алымы да кулланыла. Терлекләрнең продукция бирүен арттыру өчен, чиста токым үрчетү очрагында үз хуҗалыгыңның нәсел башлары (ата зат) б-н бергә башка нәселле терлек хуҗалыкларының шушы ук токымлы нәсел башларын да куллану отышлы. Төп тип итеп яхшыртучы тип сайлап алына. Ел саен бонитировка уздырыла, язын һәм көзен нәсел башлары җентекләп тикшерелә, ясалма орлыкландыру үткәрелә. Терлекләрнең элита һәм аерып сайлап алынган төркемнәре яхшы ашатыла, иң уңай шартларда тотыла; алынган үрчем (ана затлар) хуҗалыкның үз көтүен яңарту өчен асрала.

2010 елда Татарстанда сөт терлекчелеге буенча 10 нәсел заводы (Әтнә р-нының Ленин исем., Балтач р-нының «Игенче», Кукмара р-ның Вахитов исем. а.х. җитештерү кооперативлары һ.б.), 53 нәсел фермасы-репродуктор (Әтнә р-ның «Дусым», Азнакай р-нының «Шахтёр», Саба р-ның «Шытсу авыл хуҗалыгы предприятиесе» ААҖләре һ.б.); ит терлекчелеге буенча 12 нәсел заводы (Актаныш р-нының «Татарстан», Лениногорск р-нының «Йолдыз», Балык Бистәсе р-нының «Слободское» ААҖләре һ.б.); сарык үрчетү буенча 5 нәсел фермасы (Арча р-нының «Пионер» нәсел хуҗалыгы», Балтач р-нының Тимирязев исем., Яңа Чишмә р-нының «Архангельское» крәстиян-фермер хуҗалыгы» ААҖләре һ.б.); дуңгыз үрчетү буенча 10 нәсел фермасы (Балтач р-нының «Татарстан» һәм «Алга», Саба р-нының «Саба агрофирмасы», Тукай р-нының «Камский Бекон» ААҖләре һ.б.); ат үрчетү буенча 1 нәсел заводы (Питрәч р-нының «Казанский» нәсел заводы дәүләт унитар пр-тиесе) һәм 1 нәсел фермасы (Биектау р-нының «Өмет» крәстиян-фермер хуҗалыгы исәпләнә.

ТРда нәселле терлек үрчетү хезмәтенә җитәкчелек итү Нәселле терлек үрчетү буенча авыл хуҗалыгы баш идарәсе (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына карый) тарафыннан алып барыла. Исеме күп тапкырлар үзгәртелә: Нәселле терлек үрчетү һәм ясалма орлыкландыру буенча респ-ка станциясе (1957 дән), Нәселле терлек үрчетү һәм а.х. терлекләрен ясалма орлыкландыру буенча Татарстан респ-ка станциясе (1966 дан), Нәселле а.х. терлекләре үрчетү, ясалма орлыкландыру, нәселле һәм яхшы сыйфатлы терлек, кош сатып алу, сату буенча Татарстан респ-ка җитештерү берләшмәсе (1993 тән), 1997 дән хәзерге исемдә. Нәселле терлек үрчетү хезмәтенең бурычы һәм максаты: а.х. терлекләренең токым, тип, линия һәм гибридларын камилләштерү, яңаларын китереп чыгару; нәселле терлекләрнең төбәкләр буенча таралышын билгеләү; нәселле терлек генофондын саклау; нәселле терлекләрнең нәтиҗәле рәвештә яңартылып торуын тәэмин итү; нәселле терлек үрчеме алу өчен нәсел базасы булдыру. Н.т.ү. идарәсе ш.у., токымнарны яхшырту программасы нигезендә, терлекләрнең сыйфатын күтәрү буенча чаралар күрә, алынган үрчем сыйфатларына карап, нәсел башларын (ата зат) тикшерә һәм бәяли, нәселле терлек фермалары һәм хуҗалыкларында терлекләргә бонитировка уздыра, ана затларны ясалма орлыкландыру һәм нәсел башларын ротацияләү б-н җитәкчелек итә, продукцияне исәпкә алуны оештыра, нәселле терлекләр кенәгәсе өчен документлар әзерли, товар җитештерүче хуҗалыкларны нәселле терлекләр б-н тәэмин итә. Н.т.ү. хезмәте крәстиян (фермер) хуҗалыкларының, оешма һәм учреждениеләр ярдәмче хуҗалыкларының нәселле терлек үрчетү б-н шөгыльләнүче пр-тиеләрендә селекция-нәсел эшен оештыра һәм тормышка ашыра, юридик затларның, гражданнарның нәселле терлек үрчетү эшчәнлеген координацияли. Нәселле терлек үрчетү хезмәте структурасы ТР хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

*Әд.:* К р а в ч е н к о Н.А. Разведение сельскохозяйственных животных. М., 1963; Л и т о в ч е н к о Г.Р., Е с а у л о в П.А. Овцеводство. М., 1972; Н и к о л а е в А.И., Е р о х и н А.И. Овцеводство. М., 1987; К р а с о т а В.Ф., Д ж а п а р и д з е Т.Г. Разведение сельскохозяйственных животных. М., 1999; Современное состояние селекционно-племенной работы в хозяйствах Республики Татарстан и пути её улучшения (итоги бонитировки за 2006 год). К., 2007.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**НӘСЕ́Р** (гарәп. نثر — «проза», «чәчеп җибәрү», чәчмә әсәр), лирик, хис-кичерешләргә бай, кечкенә күләмле, шигъри сөйләмгә якын проза әсәре; Шәрекъ әдәбиятында киң таралган жанр. Хислелеге, сюжетсыз төзелеше б-н лирик поэзиягә якын, ләкин шигырьгә хас сыйфатларга (ритм, строфа, рифма) ия түгел. Татар әдәбиятында Н. жанрына Ф.Әмирхан, М.Максуд, Ф.Әсгать, Г.Кутуй, Ә.Еники һ.б. мөрәҗәгать итә. «Н.» атамасы б-н ш.у. хикәяләүгә корылган төрле әсәрләрне атыйлар.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**НӘСИМИ́** (псевд., чын исеме Сәед Имамеддин) (якынча 1369 — 1417, Алеппо ш., Су-

рия), әзәрбайҗан шагыйре. Төрки, фарсы, гарәп телләрендә яза. Дин гыйлемен, мантыйк, матем., астрономияне өйрәнә. Якын Көнчыгыш буйлап сәяхәт итә; хөрефчелек (пантеистик тәгълиматның бер төре — «хөреф» сүзеннән килә; нигез салучысы — Фәйзулла Астрабатлы) тарата; матурлыкны табигатьтән һәм аның иң югары баскычы булган кешедән эзләргә өнди.

Автор табигый куанычларга мәдхия җырлый, кеше акылы һәм матурлыгы алдында баш ия. Рәсми руханиларны тәнкыйтьли, алар «дин белән сату итүчеләр» ди. Көферлектә гаепләнеп үтерелә. Н. шигырьләре суфи шагыйрьләр җыентыкларына, ш.у. «Бакырган китабы»на да кертелә. Н. иҗаты С.Рәмиев, Н.Думави һ.б. татар шагыйрьләренә зур йогынты ясый. Шигырьләре Ә.Исхак (1995) тарафыннан татарчага тәрҗемә ителә.

*Әд.:* Смирнов В. Очерк истории турецкой литературы. СПб., 1892; Ариф М. История азербайджанской литературы. Баку, 1971; Араслы Г.Т. Имамеддин Несими: Жизнь и творчество. Баку, 1972.

*Р.К.Ганиева.*

**«НӘСЫЙХӘ́Т ӘС-САЛИХИ́Н»** («الصالحين نصيحة») — «Игелекле кешеләрнең нәсыйхәте»), урта гасырлар татар әдәбияты (якынча 16–17 йөзләр) ядкәре; дини-дидактик һәм нәсыйхәт характерындагы кыска *хикәятләр* җыентыгы. Бертөрлеләре пәйгамбәр, мөселман әүлиялары, суфиларга багышланган, икенчеләрендә эчкечелек, азгынлык, рибачылык ише кимчелекләр тәнкыйтьләнә. Аерым хикәятләрдә гыйлемле булу, һөнәр өйрәнүнең әһәмияте, кешенең әхлакый һәм рухи камиллеккә омтылырга тиешлеге турында бәян ителә. Төзүчесе билгесез. Кульязмалары татарлар арасында киң тарала һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту ярдәмлеге булып хезмәт итә. 1853 елдан җыентык 20 тапкырдан да күбрәк басыла. 1996 да хәзерге татар графикасында «Нәсыйхәт әс-салихин, яки Изгеләрнең нәсыйхәтләре» дөнья күрә (текстолог Ә.Алиева әзерли). Ш.у.к. *Нәсыйхәтнамә.*

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**НӘСЫЙХӘТНАМӘ́** (гарәп-фарсы نامه نصيحة — үгет, яхшылыкка өндәү), урта гасырлар фарсы һәм төрки-татар әдәбиятларында дидактик эчтәлекле чәчмә яки тезмә-чәчмә әсәр. Афористик рәвештә укучыга киңәш, нәсыйхәт бирелә. Н. тә мөрәҗәгать, риторик сорау, комментарий, интерпретация, антитеза һ.б. чаралар кулланыла. Иллюстрация сыйфатында төрле гыйбрәтле мәгълүматлар һәм фактлар китерелә. Н.гә идея-тематик төрлелек хас. Мәс., «Нәсыйхәт әс-салихин» (16–17 йөзләр) җыентыгы — дини-дидактик әсәр; ә Р.Фәхретдиннең әсәрләре әхлакый-гуманистик идеяләр б-н сугарылган.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**НӘҮРҮ́З** (фарсы. نوروز), борынгы төрки календарь буенча Яңа елны каршылауга багышланган бәйрәм, гадәттә, язгы көн б-н төн тигезлеге көненә туры килә. Иранда Н. — яңа ел көне («яңа көн»). 19 йөз ахырында — 20 йөз башында язгы көн һәм төн тигезлеге көнен (иске стиль б-н 1 март) бәйрәм итү Әстерхан һәм Себер татарлары яшәгән аерым районнарда гына сакланып кала (Әстерхан, Төмән, Омск өлкәләрендәге кайбер авылларда). Бәйрәм «әмәл» дип атала (Иранда хәмәл — март ае). Себер татарларында Н.не бәйрәм итүнең төп өлеше бергәләшеп, Яңа ел теләкләре әйтеп, өйдән өйгә йөрүгә кайтып кала, анда күбесенчә балалар катнаша, еш кына өлкәннәр дә кушылып китә. Өй хуҗалары аларга пешкән крендельләр, күмәчләр һ.б. бирәләр. Өйдән-өйгә йөрү таң б-н башлана, ә көндез гаилә б-н җигүле атларга утырып йөрүләр оештырыла. Атлар, ат дирбиясе һәм олаулар мөмкин кадәр купшы итеп бизәлә, һәркем үзенең мал-мөлкәтен, җитеш тормышын күрсәтергә омтыла. Әстерхан татарларында йортта махсус ботка пешереп, күршеләрне чакырып сыйлау гадәткә кергән. Шул ук көнне яисә икенче көнне төрле ярышлар уздырылган. Җиңүчеләргә авылның таза тормышлы кешеләре тарафыннан бүлеп бирелгән бүләкләр (сарык, бозау, тукыма һ.б.) тапшырылган. Ат чабышы һәм көрәш төп ярышлардан исәпләнгән. Татарлар яшәгән башка төбәкләрдә (Ука һәм Сура елгалары арасы, Урта Идел буе, Урал) Н.не бәйрәм итү традициясе сакланмаган. Кайбер авылларда язгы көн һәм төн тигезлеге көнне бер төркем шәкертләрнең, яхшы теләкләр юрап, өйдән өйгә йөрү гадәте булган (гадәттә, Н.не мактап китаптан алынган яки шәкертләр үзләре язган шигырьләр сөйләнгән; алар барысы да сый, бүләк яки акча сорау б-н төгәлләнгән).

*Әд.:* Уразманова Р.К. Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX — нач. XX вв.): Ист.-этногр. атлас татарского народа. К., 2001; Татары. М., 2001.

**«НӘҮРҮ́З» ТЕА́ТР ФЕСТИВАЛЕ́** (төрки халыкларның халыкара «Нәүрүз» театр фестивале), 1989 елда СССР Театр эшлеклеләре берлеге карары нигезендә Урта Азия төбәкләре театрлары казанышларына ел саен үткәрелә торган смотр сыйфатында оеша; союздаш республикалар мәркәзләрендә чиратлап уздырыла һәм традицион яз бәйрәме (нәүрүз) көннәренә туры килә. Фестивальдә спектакльләрне *төрки телләрдә* куючы театр коллективлары катнаша. Беренче «Н».т.ф. Алма-Ата шәһәрендә, алга таба әзлекле рәвештә Бишкәк, Дүшәнбе, Ташкент, Ашхабад шәһәрләрендә уза. 1993 тә Ашхабадта булып узган «Н».т.ф.ндә Татар акад. театры М.Гыйләҗевнең «Бичура» һәм К.Гольдониның «Ике хуҗаның хезмәтчесе» («Слуга двух господ») спектакльләре б-н катнаша. СССР таркалу һәм элекке союздаш респ-каларның мөстәкыйль дәүләтләр булып үзбилгеләнүләре сәбәпле, «Н».т.ф. 1993 тән башлап 5 ел дәвамында уздырылмый һәм ТР җитәкчелеге инициативасы б-н 1998 дә яңадан торгызыла. Алга таба фестивальләр 3–4 елга бер тапкыр Казанда уздырыла башлый (1998, 2002, 2005, 2009, 2011, 2013). Фестивальләрдә ТРның театр коллективлары, ш.у. Башкортстан, Чуаш, Хакас, Якутия-Саха, Тува, Дагстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Кабарда-Балкар, Әзәрбайҗан, Казакъстан Респ-калары, Алтай крае, Оренбург өлкәсе, Кырымтатар, Гагауз, Төрек театрлары; 2009 елдан фестивальдә курчак, студентлар һәм яшьләр театрлары катнаша. «Н».т.ф. төрки халыклар театр эшлеклеләренең зур форумы булып тора, дусларча аралашу һәм иҗади фикер алышу мөмкинлеген тудыра.



Төрки халыкларның XI «Нәүрүз» халыкара театр фестивале. Казан. 2013.





Фестивальне ябу тантанасы һәм театраль Сабан туе.

**НӘҮРҮ́З ХАН** (? — 1360), Алтын Урда ханы (1359 елдан). Сарай әл-Җәдид аксөякләре (һәм Тайдула ханбикә ) ярдәмендә Алтын Урдада хакимиятне үз кулына ала. Урданың эре шәһәрләрендә үз акчаларын суктыра. Күк Урда идарәчесе Чимтай тарафыннан тәхеттән төшерелә һәм җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Куликовская битва. М., 1980.

*И.Л.Измайлов.*

**НӘҮРҮЗГӨ́Л**, бадьян чәчәк, примула (Primula), нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төр — язгы Н. (P. veris) Кама һәм Идел алдында, эре касәле Н. (P. mac-



Язгы нәүрүзгөл.

rocalyx) Көнчыгыш Кама аръягында очрый. Урманнарда, урман буйларында, аланнарда, болыннарда үсә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска, куе нәзек тамырлардан тора. Яфраклары тамыр яны таралгысында, гади, җыерчыклы, кыройлары дулкынсыман, бәрхетсыман. Чәчәкләре 5 өлешле, сары, хуш исле, чатыр чәчәк төркемендә. Эре касәле Н. киң эре чәчәк касәләре б-н аерылып тора. Җимеше коңгырт төстәге күборлыклы тартмачык. Иртә язда чәчәк аталар. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Дару үсемлекләре. Тамырларында сапониннар, эфир майлары, гликозидлар, яфракларында С витамины бар. Тамырларыннан ясалган төнәтмә какырык чыгару, бәвел кудыру һәм тирләтү чарасы буларак кулланыла; яфраклары гипо- һәм авитоминоз вакытында файдаланыла. Декоратив, баллы үсемлекләр.

**НӘҮРҮЗГӨЛЧӘЛӘ́Р** (Primulaceae), нәүрүзгөлчәләр рәтеннән ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Үләннәр, сирәк кенә куаклар яки ярымкуаклар. 1000 гә якын төре билгеле (30 га якын ыруг), башлыча, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын өлкәләрендә таралган. Татарстан терр-ясендә 6 ыругтан 11 төр бар. Бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Күпчелек төрләрнең сабагы туры. Яфраклары чиратлашкан, каршыдаш яки әвернә торышлы, гади яки калаксыман, кайвакыт нык кына теленмә, тамыр яны таралгысында урнашкан. Чәчәкләре ялгыз, куентылы яки сабак очында. Касә һәм таҗ яфраклары кушылган. Җимеше — тартмачык. Орлыклары вак яралгылы. *Нәүрүзгөл, тишмәнут* (җепсыман һәм төньяк), *болынчәй, талакдар* халык медицинасында кулланыла; гади болынчәй, дарулы талакдар — баллы, тишмәнут, нәүрүзгөл — декоратив үсемлекләр. Диңгез буе глауксы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НӘФИ́ЕВ** Сәйфихан Хәбибулла улы (26.11.1941, Чүпрәле р-ны Мочәли а. — 31.8.2004, Казан), хокук белгече, хокук фән. канд. (1999), ТАССР, РФнең атказ. хокук белгече (1988, 1997). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1965–79 елларда Чүпрәле р-нында эшли: ВЛКСМ район ком-тының бүлек мөдире (1967–68), КПСС район ком-ты инструкторы (1968–69 һәм 1975–76), Калинин исем. к-зның партком секретаре (1969–75), прокурор ярдәмчесе (1976 дан). 1979–82 дә Әлки р-ны, 1982–88 дә Бөгелмә, 1988–92 дә Казан прокуроры. 1992–2000 дә ТР прокуроры. 2000 нән ТР Конституцион мәхкәмәсе рәисе. Хезмәтләре җинаять эшләре хокукы, прокуратура тарихы мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Европейские стандарты обеспечения конституционных прав личности при расследовании преступлений. К., 1988 (автордаш); Прокуратура Татарстана: История и современность. К., 1997; Квалификация преступления: Учеб. пособие. К., 1999 (автордаш); Корыстное убийство: понятия, виды, квалификация: Уголовно-правовые и криминологические аспекты. К., 1999.

**«НӘФИ́С КОСМЕ́ТИКС»**, химия сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 2,5 мең кеше (2013). Крестовниковларның 1918 елда национализацияләнгән *Шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин җитештерү химия заводы* җирлегендә «1 нче дәүләт сабын кайнату һәм шәм заводы» буларак нигезләнә. 1919 да аңа М.Ә.Апанаев, И.В.Пекин, К.Н.Краснов һ.б.ның национализацияләнгән һәм ябылган сабын заводлары чималы һәм җиһазларының бер өлеше тапшырыла. 1922 дән «Мулланур Вахитов исем. 1 нче дәүләт сабын кайнату, шәм һәм химия заводы», 1934 тән Казан терлек мае комб-ты, 1964 тән Казан химия комб-ты. 1993 тән «Нәфис» АҖ, 2002 дән «Нәфис Косметикс» АҖ — М.Вахитов исем. Казан химия комб-ты.

1918–20 елларда завод сабын, стеарин шәмнәр, олеин һәм глицерин эшләп чыгара. 1926 да кер порошогы чыгару үзләштерелә. 1930 елларда реконструкция һәм алдынгы чит ил җиһазларын кую нигезендә җитештерү куәтләре арта (сабын — 46,5 мең *т* га кадәр, стеарин — 3,5 мең *т*, шәм — 6,8 мең *т*, олеин к-тасы — 2,8 мең *т*, глицерин — 2,1 мең *т*, саломас — 16 мең *т*). Бөек Ватан сугышы елларында пр-тие терр-ясендә бронетанк техникасын ремонтлау базасы урнаша. Эшләүчеләр саны 1500 кешедән 600 гә калуга карамастан, комбинат фронт ихтыяҗлары өчен кер сабыны, оборона пр-тиеләре өчен кислоталар һәм глицерин чыгаруын дәвам итә. 1955–65 тә җитештерү куәтләре арта, илдә беренче тапкыр синтетик юу чараларын эшләп чыгару үзләштерелә (елга 30 мең *т*); 1980 елларда агымлы-механикалаштырылган линияләр гамәлгә кертелә. 1991 дә җитештерү күләме (мең *т*): синтетик юу чаралары — 41,7; кер сабыны — 32,6; исле сабын — 17,4. Техник продукциянең 70% ы чамасы хәрби сәнәгать комплексы пр-тиеләренә җибәрелә. Эшләнмәләр Англиягә, Болгария, Польша, Югославия, Чехословакия, Әфганстан, Сүрия, Вьетнам, Кубага чыгарыла. 1998 гә синтетик юу чаралары һәм кер сабыны — 8, исле сабын җитештерү 17 тапкыр кими. Кризиска каршы тышкы идарә һәм пр-тиене финанс ягыннан савыктыру чаралары гамәлгә кертелгәннән соң (1998–99), төп производстволарда киң колачлы модернизация һәм реконструкция ясала, нәтиҗәдә куәтләр елга 25 мең *т* исле сабын, 70 мең *т* синтетик юу чаралары җитештерерлек дәрәҗәгә күтәрелә. 1999–2007 дә сыек юу һәм чистарту чаралары з-ды (елга 500 мең шешә; гель, шампунь, ванна күбеге, савыт-саба, пыяла юу өчен сыеклыклар һ.б.), синтетик юу чаралары з-ды (елга 100 мең *т*) төзелә, коры чистарту чаралары; 2010 да автомобильләр чистарту товарлары җитештерү оештырыла.

Пр-тиедә кулланылучы технологияләр нигезендә өзлексез химик процесслар ята (басым астында каталитик гидрирлау, гидролизлы дистилляция, җиңелчә актив матдәләр синтезы, сиптереп киптерү, су электролизы һ.б.). Италиянең «Маццони», «АКМА», «Баллестра», «Мачик», «Корниани» фирмалары һ.б.ның заманча җиһазлары киң кулланыла. Полимер савытлар эшләү һәм аларга сыек юу чараларын бүлеп салу, ш.и. илдә беренче тапкыр «Дой-пак» утырма пакетларына тутыру Америкада һәм Италиядә чыгарылган тизлекле линияләрдә башкарыла. Гамәлгә кертелүче куәтләр Россиянең һәм чит илләрнең танылган җитештерүчеләре тарафыннан эшләнгән югары технологияле механикалаштырылган һәм тулысынча автоматлаштырылган җиһазлар б-н тәэмин ителә. «Сульфурекс» җайланмасы (2004, синтетик юу һәм чистарту чараларының нигезен тәшкил иткән җиңелчә актив матдәләр җитештерүдә файдаланыла) һәм май экстракциясе з-ды (2007, майлы к-талар һ.б. төр продукция җитештерү өчен рапс орлыгыннан май аерып алу б-н шогыльләнә) төзелеп беткәч, «Н.К.»та тулысынча йомык технол. цикл оеша. Пр-тиенең сыйфат менеджменты — халыкара ИСО 9001:2008 стандартына (2004), экологик менеджменты ИСО 14000 стандартына (2005) туры килә. 350 дән артык исемдә чыгарылган продукциянең гомуми күләме 168 мең *т* тәшкил итә (2011). Шулардан сыек юу чаралары — 70 мең, коры чистарту чаралары — 7,4 мең, исле сабын — 8,4 мең *т* һ.б. Массакүләм куллану товарлары BiMax, Sorti, AOS, Биолан һ.б. популяр сәүдә маркалары б-н чыгарыла. Ел саен көндәшлеккә сәләтле продукциянең төрле кулланылу сыйфатларына ия яңа төрләре эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. «Н.К.» — РФдә майлы к-талар җитештерүдә әйдәп баручы, глицерин эшләп чыгаруда бердәнбер пр-тие, кер порошоклары һәм исле сабын җитештерүче иң эре пр-тиеләрнең берсе. Аның өлешенә ил базарындагы стеарин к-таларының 60% ы чамасы, олеин к-таларының 70% ы, глицеринның 40% ы (нефть химиясе, җиңел, лак-буяу, кәгазь җитештерү, оборона сәнәгатьләрендә һ.б. тармакларда кулланылалар), савыт-саба юу чараларының 20% тан артыгы, исле сабынның 10% тан артыгы, синтетик юу чараларының 10% ы туры килә. Продукциянең бер өлеше якын чит илләргә чыгарыла.

Пр-тие һәм аның эшләнмәләре күп кенә халыкара һәм илдәге бүләкләр, ш.и. «Сыйфат өчен алтын йолдыз» (Мадрид, 1993), «Россиянең иң яхшы 100 товары», «ТРның иң яхшы товарлары» конкурслары дипломнары (2007, 2003–11), халыкара «Бытхимэкспо» күргәзмәләрендә (Мәскәү, 2005–06) «Гран-при» һәм медальләр б-н билгеләп үтелә. Бөек Ватан сугышы чорында планнарны арттырып үтәгән өчен комб-тка беренчә тапкыр Дәүләт Оборона Ком-тының күчмә Кызыл Байрагы тапшырыла; 1976 да җитештерелүче продукциянең күләме һәм сыйфаты буенча югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен



Р.И. Нәфыйгов.

пр-тие Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә Соц. Хезмәт Герое исеме бирелә, 3 кеше — Ленин ордены, 2 кеше — Октябрь Революциясе, 26 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 13 кеше — «Почёт билгесе», 15 кеше 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — Н.Сигорский (1920), Н.Г.Кетура (1920–27), И.К.*Неометов* (1927–30), З.В.Вәлиев, Г.И.Мурин, А.М.Рәхмәтуллин; Д.А.Харитонов (1998–2003), Д.В.Хәйбуллин (2003 тән). Ш.у. к. *Сабын җитештерү*.

*Әд.:* К л ю ч е в и ч А.С. История Казанского жирового комбината имени Мулла-Нур Вахитова (1855–1945). К., 1950; Акционерное общество «Нэфис» — химкомбинат им. М.Вахитова: Фотоальбом. К., 1995.

*С.Г.Белов.*

**НӘФИ́С СӘНГА́ТЬ СӨЮЧЕЛӘРНЕ́Ң КАЗА́Н ҖӘМГЫЯТЕ́**, җәмәгать оешмасы, 1895 елда Казанда сәнгатьне җәелдерү һәм популярлаштыру, төрле өлкәдәге сәнгать эшлеклеләренең хезмәттәшлегенә ярдәм итү максатында оештырыла. Устав нигезендә җәмгыять эшчәнлегенә музыка, драма, сынлы сәнгать, сәнгать тарихы һәм теориясе, әдәбият керә. Җәмгыятьнең беренче рәисе шәһәр башлыгы С.Г.Дьяченко була, гамәлгә ашыручы 118 кеше арасында — сәнгать тарихчысы Д.В.Айналов, Казан ун-ты профессоры Н.П.Загоскин, сәүдәгәр Д.В.Вараксин, ш.у. җәмәгать эшлеклеләре, чиновниклар һ.б. бар. Оештырылуының беренче елы ахырында җәмгыять 300 дән артык кешене берләштерә. Драма (рәисе — Н.Н.Михайлов), әдәбият (рәисе — Н.П.Загоскин), музыка (рәисе — О.А.Лебедева, әгъзалары — В.В.Вараксин, А.М.Кокорев, А.И.Пиотровский, Е.Г.Семченко, Л.О.Сиклер, В.Г.Фёдоров) секцияләре оештырыла. Җәмгыять Сәүдәгәрләр клубында урнаша, чаралар уздыру өчен ш.у. шәһәр думасы залы файдаланыла. Драма секциясенең (җитәкчесе һәм режиссёры Н.Н.Михайлов) П.Гнедич пьесалары, Ж.Оффенбах, Ф.Зуппе оперетталары буенча әзерләнгән һәвәскәрләр спектакльләре тамашачыларда зур уңыш казана. Музыка секциясе танылган Казан музыкантлары Н.Н.Ворошилов, А.И.Панаев, К.И.Гриняски, В.А.Больтерман, ш.у. Р.А.Гуммерт җитәкчелегендәге музыка мәктәбе укытучылары, һәвәскәр музыкантлар тарафыннан ел дәвамында 10–15 кичә уздыра. Концертлар күбесенчә агарту юнәлешендә үткәрелә: муз. әсәрләр композиторларның биографиясен сөйләү б-н үрелеп бара. Әдәби-музыкаль кичәләр дә бик популяр була, әдәби әсәрләрдән укылган өзекләр музыкаль яңгыраш б-н чиратлашып бара. Сынлы сәнгать секциясе «тере картиналар» дип аталган ысулны куллана. Рәссамнар мөстәкыйль һөнәри берләшмә оештырырга омтылыш ясыйлар. 1897 дә «азмы-күпме әһәмияткә ия булган Идел буе шәһәрләрендә күргәзмәләр үткәрү» максатында «Идел буе рәссамнары җәмгыяте» Уставының проекты әзерләнә. 1898 дә «Җирле һәм читтән килгән рәссамнарның картиналары һәм этюдлары күргәзмәсе» (200 гә якын әсәр) рәссам Ю.А.Тиссен озата баруында Идел буйлап Сембер, Саратов, Әстерхан шәһәрләренә җибәрелә. Җәмгыять әгъзасы Д.В.Айналов сынлы сәнгать буенча лекцияләр укый (мәс., 1898 дә музыка мәктәбендә аның тарафыннан «Кеше тормышында сәнгатьнең әһәмияте» дигән лекция укыла). 1900 еллар ахырында җәмгыять әгъзаларының саны шактый кими, 1910 да ул фондларын һәм милкен Казан халык ун-тлары җәмгыятенә һәм Рус Император музыка җәмгыятенең Казан бүлегенә тапшыра һәм ябыла.

Чыг.: Устав Казанского общества любителей изящных искусств. К., 1895; Первый отчёт о деятельности Казанского общества любителей изящных искусств за 1896 г. К., 1897; Второй отчёт о деятельности Казанского общества любителей изящных искусств за 1897 г. К., 1898.

*Әд.:* С е в е р ю х и н Д.Я., Л е й к и н д О.Л. Золотой век художественных объединений в России и СССР (1820–1932). СПб., 1992.

*Е.В.Порфирьева, Е.П.Ключевская.*

**НӘФЫ́ЙГОВ** Рәфикъ Измаил улы (15.7.1928, Уральск ш., хәзерге Казакъстан Респ-касы — 9.12.2001, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1964), ТР ФА академигы (1992), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1978, 1989). Урал пед. ин-тын тәмамлый (1951). Шул ук елдан Казан ун-тында эшли: тарих-филол. ф-ты деканы (1960–62), КПСС тарихы (1963–91), сәяси тарих (1991–94) кафедралары мөдире, проф. (1966). Хезмәтләре татар иҗтимагый-сәяси фикере формалашуы һәм үсеше тарихына карый. Идел буенда 19 йөздә — 20 йөз башында барган азатлык хәрәкәте тарихына багышланган «1907–1914 елларда Казан социал-демократлар оешмасы: Кыскача очерк» («Казанская социал-демократическая организация в 1907–1914 гг.: Краткий очерк», 1961), «Яшерен революцион эшчәнлек: Архивтагы эзләнүләр һәм табышлар» («Тайны революционного подполья: Архивные поиски и находки», 1981), «Тарихның билгесез сәхифәләре» («Неизвестные страницы истории», 1989) хезмәтләре, ш.у. М.М.Вахитов турында очерк авторы. Аның «Революциягә беренче адым: В.И.Ульянов һәм XIX гасырның 80 нче еллары Казан студентлары» («Первый шаг в революцию: В.И.Ульянов и Казанское студенчество 80-х годов XIX в.», 1970), «Инанган марксистка әверелде» («И стал убеждённым марксистом», 1985) монографияләрендә В.И.Ленинның тормышы һәм эшчәнлегенең Казан чоры җентекләп тикшерелә. Н. — Г.Тукай турында китаплар һәм мәкаләләр авторы, шагыйрьнең татар телендә әсәрләре тупланмасын (т. 1–5, 1985–86) нәшер итүдә катнаша. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.


Ә с ә р.: Мулланур Вахитов: Ист.-биогр. очерк. К., 1960; Формирование и развитие передовой татарской общественно-политической мысли: Очерк истории. 1895–1917 гг. К., 1964; Тукай и его окружение. К., 1986; Поиск продолжается. К., 1993; Наш Тукай: Новые страницы из жизни поэта. К., 1998.

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского университета (1939–1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

*Е.Б.Долгов, В.А.Шагалов.*


**НӘФЫ́ЙКОВ** Әхтәм Зәки улы (2.10.1950, Бөгелмә р-ны Карабаш пос.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТР, РФнең атказ. геологы (1993, 2002). Казан ун-тын тәмамлый (1973). «Татнефть» АҖдә эшли: 1975 елдан «Әлмәтнефть» НГДУында, нефть чыганакларын эшкәртү буенча технол. бүлеге башлыгы урынбасары (1980 нән), 1983 тән берләшмәнең нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү буенча технол. бүлеге башлыгы урынбасары, 1989 дан — «Ямашнефть» НГДУында, 1993 тән «Елховнефть» НГДУында баш геолог, 1998 дән АҖ аппаратының геол. бүлеге башлыгы, 2000 нән Углеводородлы чимал чыганакларын геол. эзләү һәм эшкәртү идарәсе башлыгы. Н. ТРның нефть чыганакларында катламнарны суландырганда нефть чыгару процессын көйләү ысулларын, аларны компьютерлы геол. картографияләү, «Лазурит» нефть чыганагын эшкәртүне модельләштерү системасын эшләүдә һәм сәнәгатьтә киң кулланышка кертүдә, Көнбатыш Себердә Лангепас һәм Покачёв нефть чыганаклары төркемен үзләштерүдә катнаша (1984–89). Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыгаручы районнарындагы шәһәрләрне су б-н тәэмин итү өчен җир асты су чыганакларын эзләүнең югары нәтиҗәле методикасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**НӘФЫ́ЙКОВ** Канәфия (Хәнәфи) Абзалетдин улы (15.11.1938, Чирмешән р-ны Иске Үтәмеш авылы), нәкышьче, театр рәссамы, график, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан сәнгать уч-щесен (1966), А.Н.Островский исем. Ташкент театр-сәнгать ин-тын (1973) тәмамлый. 1960–67 елларда Казан «Тасма» з-дында бизәүче-рәссам, 1973–79 да Казан сәнгать уч-щесендә укыта,



К.А. Н ә ф ы й к о в. Н. Фәттахның «Сармат кызы Саринә» спектакленә декорация эскизы. Картон, темпера. 1985. «Казан» милли мәдәният үзәге музее.

1979–98 дә ТР Сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). А.Островскийның «Яшенле яңгыр» (1976–77, Бөгелмә рус драма театры, И.Юзеевнең «Командировка» (1978, Татар драма һәм комедия театры, Казан), Р.Ишморатның «Тормыш дулкыннары» (1979, Татар академия театры, Казан), Н.Фәттахның «Сармат кызы Саринә» (1985, Әлмәт татар драма театры), Ф.Яхинның «Мөхәммәдъяр» (1997, Татар академия театры) спектакльләрен куючы-рәссам. Н.Җиһановның «Түләк һәм Сусылу» (1973), «Алтынчәч» (1975) операларына, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетына (1974), Ф.Шиллернең «Мария Стюарт» драмасына (1973), Ә.Фәйзинең «Тукай» (1976), Ф.Бәйрәмованың «Атылган йолдыз» (1986) драмаларына декорация эскизлары, Б.Липаевның «Казан бәяны» мюзиклына костюм эскизлары (2005) авторы. Н.нең театр декорацияләре күренешләренең ачыклыгы, композицияләрнең күптөсле бизәкләргә бай булуы б-н аерылып тора, аларда Шәрекъ миниатюралар сәнгате йогынтысы чагыла. Станлы нәкышьтә тарихи картиналар жанрында эшләүче әйдәп баручы рәссамнарның берсе



К.А.Н ә ф ы й к о в. «Гаяз Исхакый». 1990. Чистай р-нының Яуширмә авылында Гаяз Исхакыйның тарихи-мемориал һәм этнография комплексы.

(к. *Сынлы сәнгатьтә тарихи жанр*). Урта гасырлар татар тарихына кагылышлы зур картиналар иҗат итә: «Болгар урамы» (1975), «Болгардагы Ага базар» (1976), «Борынгы Казанда шагыйрьләр бәйгесе» (1977), «Борынгы Болгарда чуен коючылар» (1978), «Казанны чукындыру» (1978), «Борынгы Казанда Сабан туе» (1981), «Сөембикә» триптихы (1978–2000), «Борынгы төркиләр», «Хан анты» (1990–2003) һ.б. Татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре портретлары сериясе авторы: Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Акмулла, Г.Тукай, С.Рәмиев, Ш.Мәрҗани, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Б.Урманче (1976–90). Н. әсәрләре татар халык сәнгатенең үзенчәлекле гармониясенә нигезләнгән сәнгатьчә нечкәлеге һәм төсләр композициясенең нәфислеге б-н аерылып торалар. Бу аеруча аның пейзажларына һәм натюрмортларына («Җилкәнле көймә», 1979; «Күл буенда», 1981; «Ак вазадагы чәчәкләр», 1985 һ.б.), пастель техни-



К.А.Н ә ф ы й к о в. «Йосыф турында хикәя». 1991.

касындагы этюдлы бизәкләренә («Яңа Татар бистәсе», 1982; «Мәрҗани мәчете», 1987; «Шамил йорты», 1987) хас.

Респ-ка (1973 тән), зона — «Зур Идел» (Горький ш., 1974; Казан, 1980; Түбән Новгород ш., 2003; Саранск ш., 2004), бөтенроссия («Бөек Октябрьгә 60 ел», Мәскәү, 1977; «Советская Россия», Мәскәү, 1980; «Россия Х», 2004), бөтенсоюз («Театр һәм кино рәссамнары», Мәскәү, 1978) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Сарман авылында (1985), Казанда (1987, 1988, 1995, 1998) уза. ТРның сынлы сәнгать өлкәсендәге Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (1999). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, Әлмәт картиналар галереясында саклана.


Х е з м.: Путешествие в прошлое — Үткәнгә сәяхәт. К., 1993.

*Әд.:* Ш ә м с и С. Тарихка сыену // Идел. 1991. № 10/11; М и ң л е б а е в К. Иман нуры // Казан утлары. 1993. № 1; С и р м а т о в И. Тарих башы — ерак гасырларда // Казан утлары. 1998. № 2; З а р и ф Ф. Киләчәккә баручы иҗат // Мирас. 2003. № 7; Канафи Нафиков: Альбом. К., 2005.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**НӘФЫ́ЙКОВА** Әдилә Әхәт кызы (31.10.1940, Үзбәкстан ССРның Харәзем өлкәсе Санаат а. — 15.4.2011, Казан), радиофизик, физика-матем. фән. канд. (1977), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (1974 кә кадәр һәм 2005–09 да). 1974–2005 тә Органик һәм физик химия ин-тында. Хезмәтләре пиримидин рәтендәге актив кушылмаларның, биополимерлар һәм элементорганик кушылмаларның структурасы һәм динамикасы өлкәсенә карый. Югары төгәллектәге ТМР спектроскопиясе алымы б-н яңа кушылмалар классларында (супрамолекуляр, фуллирен) молекула эчендәге һәм молекулаара үзара тәэсирләрне тикшерә. Дәүләт бүләге молекуляр системаларны структур-динамик тикшерүләрдә югары төгәллектәге төш-магнит резонансына караган хезмәтләр циклы өчен бирелә.

**НӘФЫ́ЙКОВА** Сәрвәр Нәфыйк кызы (6.9.1925, Арча кантоны Норма а. — 4.9.2012, Балтач р-ны, Сасна а.), механизатор, Соц. Хезмәт Герое (1967). Тракторчылар (1941), эретеп ябыштыручылар (1946) курсларын тәмамлый. 1937–41 елларда Балтач р-нының Тимирязев исем. к-зында эшли, 1942–52 дә МТС-та тракторчы-машинист, эретеп ябыштыручы, 1952–82 дә шул ук р-нның «Правда» к-зында тракторчы-машинист, тимерче. Герой исеменә а.х. җитештерүендә югары күрсәткечләргә ирешкәне өчен лаек була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Балтач р-нының Түбән Сасна авылындагы бер урамга Н. исеме бирелә.



С.Н.Нәфыйкова.

*Әд.:* Г л у х о в М. Нафикова Сарвар Нафиковна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**«НӘШРИЯ́Т»** («نشـــريات»); 1922–28 елларда Мәскәүдәге кооператив нәшрият. Башкортстан һәм Татарстаннан читтә яшәүче татар-башкорт оешмаларыннан сайланган 1 нче Бөтенроссия конференциясе һәм ВКП(б) ҮКның агитация һәм пропаганда бүлеге карары нигезендә барлыкка килә. Нәшриятны оештыру эше РКП(б) ҮК каршындагы Татар-башкорт Үзәк бюросына йөкләнә. Продукция ТАССР һәм БАССРдан читтәге милли мәктәпләрне дәреслекләр б-н тәэмин итү өчен чыгарыла. 1922 нең 8 августында Нәшрият турындагы нигезләмә раслана. «Н.» әгъзалары: Үзәк татар-башкорт бюросы, Әстерхан, Царицын шәһәрләрендәге татар газеталары редакцияләре, татарлар яшәгән губерналарның РКП(б) ком-тлары, Мәскәүдәге Үзәк эшчеләр клубы, а.х. ширкәтләре, ш.у. язучылар, журналистлар, галимнәр, укытучылар, партия хезмәткәрләре, ш.и. Г.Ибраһимов, К.Нәҗми һ.б. «Антик» басмаханәсе һәм гарәп шрифтлары сатып алына. Басмаханә эшен М.М.*Идрисов* оештыра. Басмаханә каршындагы хәреф кою ширкәте Татарстан, Башкортстан, Урта Азиядән дә заказлар кабул итә. Китап төпләү остаханәсе дә була. Нәшрият каршында СССРдагы барлык нәшриятларның татар телендәге әдәбияты сатыла торган китап кибете дә эшли. «Н.»та гарәп шрифты б-н китап басу машиналары да эшләнә. Нәшрият хуҗалык исәбендә санала, авторлар б-н килешү төзелә. Төп эшләр РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты заказы нигезендә алып барыла (150 китап, ш.и. дәреслекләр, методик ярдәмлекләр, иҗтимагый-сәяси әдәбият, К.Маркс, В.И.Ленин хезмәтләренең тәрҗемәләре). СССР Хәрби диңгез эшләре халык ком-ты заказы б-н русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге «Тылмач» бастырыла. РСФСР Мәгариф халык комис-ты заказы б-н 1926 дан *«Мәгариф эшчесе»* ж-лы чыгарыла. «Н.» 74 үз басмасын, нигездә, матур әдәбият: М.Гафуриның «Кызыл тәлгәшләр» (1925), Ш.Усмановның «Бирегез тупны ки-

ре» (1927), К.Нәҗминең 2 шигырьләр җыентыгын һ.б.ны бастыра. Драма әсәрләре, ш.и. үзешчән театрлар өчен, рев. бәйрәмнәр оештыручылар өчен җыентыклар, татар әдәбияты тарихы буенча хезмәтләр: Г.Ибраһимовның «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар», Ф.Гладковның «Цемент», Дж.Лондонның «Сер» («Тайна») тәрҗемә әсәрләре һ.б. басыла. Ш.у. иҗтимагый-сәяси, а.х., мед., техник әдәбият нәшер ителә. 1928 нең 16 маенда «Н.» ябыла, аның вазифалары СССР халыкларының Үзәк нәшриятына тапшырыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Книги и люди: Исслед. К., 1985.

*И.А.Новицкая.*

**НЕБЕНЦА́ЛЬ** (Nebenzahl) Леон (1910, Воронеж ш. — 1991), немец язучысы, тәрҗемәче. 1920 елдан Берлинда яши. Фашистлар хакимияткә килгәннән соң, концлагерьга ябыла, 1945 тә азат ителә. Матбугат эшләре буенча совет хәрби администрациясе идарәсендә эшли. 1940 еллар ахырында «Печать Советского Союза» ж-лын оештыруда катнаша һәм аны 8 ел җитәкли. 1957 дән «Проблемы мира и социализма» ж-лының немец варианты мөхәррире (30 елга якын), «ГДР — СССР» дуслык җәмгыяте җитәкчесе. Рус теленнән немец теленә В.С.Гроссманның «Степан Кольчугин» романын, Д.Д.Нагишкинның «Бонивур йөрәге» («Сердце Бонивура»), Е.Я.Драбкинаның «Кара сохари» («Чёрные сухари») повестьларын, И.М.Майскийның «Совет дипломаты истәлекләре» («Воспоминания советского дипломата») мемуарларын һ.б.ны тәрҗемә итә. М.Җәлил б-н бер камерада утырган А.Тиммермансны, Шпандау төрмәсендә шагыйрьнең көрәштәшләре б-н очрашкан Р.Ланфрединины эзләп таба, Г.Кормаш төркеменең җәзалап үтерелүе турындагы документлар ш.у. аның тарафыннан табыла. Германия Демократик Республикасы Фәннәр академиясендә «Муса Җәлил — шагыйрь һәм көрәшче» доклады б-н чыгыш ясый. Муса Җәлилгә багышланган «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» — кешелекнең вәхшилекне фаш итүче документы» («Mussa Dshalils «Moabit Hefte» — Zeugnis der Menschlichkeit irmitten von Barbarei») мәкаләсе һәм М.Җәлилгә багышланган күпсанлы башка хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Мансурова М. Леон Небенцаль — исследователь творчества Джалиля // Комсомолец Татарии. 1969. 29 окт.

*Р.Ә.Мостафин.*

**НЕБОЛЮ́БОВ** Василий Петрович (19.2.1852, Сембер губ., Буа өязе Шераугы а. — 1936, Казан), мәхкәмә медицинасы белгече, медицина д-ры (1893). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1880), Пермь губернасы Соликамск өязендәге Дедюкино тоз промыселында табиб. 1881–84 елларда Вятка губернасының Сарапул земствосында мед. хезмәтендә, 1885 тән Уфа губернасының Минзәлә өязе Чаллы авылында табиб. 1886–1922 дә Казан ун-тында: мәхкәмә медицинасы кафедрасында прозектор ярдәмчесе (1895–96 да мәхкәмә медицинасы һәм беренче мед. ярдәме курсларында лекция укый), мәхкәмә медицинасы каф. мөдире (1904 тән), проф. (1909). 1890 елларда Казан губернасы Чабаксар өязендә зоб авыруы мәсьәләләрен өйрәнә. 1892 дә Сембер шәһәрендә Азия вабасы авыруына каршы көрәш кампаниясендә катнаша. Хезмәтләре асфиксияне өйрәнүгә, йөрәк һәм кан тамырлары зарарланганда мәхкәмә медицинасы бәяләмәсенә карый.

Хезм.: Случай врождённого отсутствия глазных яблок // Мед. обозрение. 1890. № 6; Случай разрыва сердца при падении с высоты // Дневник Казан. об-ва врачей. 1896. Вып. 2; Разрывы селезёнки в судебно-медицинском отношении // Казан. мед. журн. 1902. Апр., сент.

*Әд.:* Научные работники СССР. Л., 1928. Ч. 6.

**НЕВЕ́РКИН** районы, *Пенза өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 777 *км*². 1935 елда оештырыла. Үзәге — Неверкино авылы (Пензадан 170 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 15565 кеше (2012), 7949 татар (2002). Татарлар, башлыча, Мазарлы (1928 кеше), Али (1300), Дөмавыл (1164), Карновар (800), Бикмаси (598), Сарбай (446), Исәкәй (163) авылларында яшиләр. Алар Н.р.на 17 йөз ахырында күчеп килә. 1917 дә 7 мәчет була. Хәзерге вакытта районда 15 мәчет эшли. Н.р.да Сов. Союзы Геройлары Б.М.*Еналиев*, М.И.*Мостафин* туган.

**НЕВО́ЛИНО КУЛЬТУ́РАСЫ** (Сылва культурасы) (археол.), Каманың югары агымында Сылва елгасы (Кама елгасының сул кушылдыгы) бассейнындагы элгәрге тимер гасырга караган археол. культура (якынча 5 йөз — 9 йөз уртасы). Н.к. ядкәрләре 19 йөз ахырыннан тикшерелә. Башта Н.к. ядкәрләренең әйберләр җыелмасы *Ломоватово культурасына* нисбәт ителә, 1960 елларда В.А.Оборин, В.Ф.Генинг, Р.Д.Голдина аны мөстәкыйль археол. культура буларак аерып чыгаралар. Н.к. авыллыклар, шәһәрлекләр, каберлекләрдән, хәзинәләрдән гыйбарәт. Бигрәк тә курганлы (Бродовский, Югары Саин һ.б.) һәм кургансыз (исеме культура атамасына нисбәтле Неволино, Горбунятский һ.б.) каберлекләрдә казу эшләре вакытында бай материаллар табыла. Н.к. халкы игенчелек, терлекчелек, сунарчылык, балыкчылык һәм җыючылык хөкем сөргән комплекслы хуҗалык алып барган. Тимер металлургиясе, сөяк, таш, агач һ.б.ны эшкәртү, ш.у. сәүдә шактый югары үсешкә ирешә. Халык кара мичләр ягып җылытылган агач йортларда (уртача 4×4 *м*² мәйданлы) яшәгән. Хуҗалык ихтыяҗлары өчен базлар казылган. Н.к.ның мәгълүм каберлекләрендә мәетләр төрле әйберләр куелган сай чокырларда, кагыйдә буларак, башлары төньяк-көнчыгыш тарафка юнәлтеп җирләнгән. Н.к. керамикасы кисеп ясалган тарак тешләре яки киндерә эзе сыман бизәкләр төшерелгән йомры төпле савыт-сабадан гыйбарәт. Н.к. ядкәрләре терр-ясендә дини йолаларда кулланылган әйберләр, ат дирбиясе (авызлыклар, өзәңгеләр), сугыш кораллары (туры һәм кәкре кылычлар, уклар), киемсалым, бизәмәләр, Сасанилар дәүләте акчалары һ.б. табыла. 9 йөзнең 2 нче утызъеллыгында, ихтимал, маҗар-бәҗәнәк бәрелешләренә бәйле вакыйгалар аркасында, бу культура яшәүдән туктый. Н.к. халкының бер өлеше Идел буе Болгар дәүләтендә сыену таба, бу *Олы Тархан каберлегендә, Танкеевка каберлегендә*, Шайтан шәһәрлегендә (Ульянов өлкәсенең Иске Майна р-ны), болгарларның 9 йөзнең 2 нче яртысына — 10 йөз башына караган башка ядкәрләрендә табылган керамик әйберләрдә чыгыла.



Танкеевка каберлегеннән табылган балчык савыт. ТР ФА Тарих институты фондлары.

*Әд.:* Голдина Р.Д., Водолаго Н.В. Могильники неволинской культуры в Приуралье. Иркутск, 1990; Казаков Е.П. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992; Erdelyi J., Ojtozi E., Gening W, Das Craberfeld von Nevolino. Bdpst., 1969.

*Е.П.Казаков.*

**НЕВОСТРУ́ЕВ** Капитон Иванович (28.2.1816, Вятка губ. Алабуга ш. — 29.11.1872, Мәскәү), тарихчы, археолог, археограф, Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1861). Руханилар катлавыннан. Алабуга руханилар уч-щесен (1830), Вифания руханилар семинариясен (1836), Мәскәү руханилар академиясен (1840) тәмамлый. 1840–49 да Сембер руханилар семинариясендә укытучы. 1849 елдан Мәскәүдә: А.В.Горский б-н бергә «Мәскәү синод китапханәсенең славян кулъязмалары тасвирламасы»н («Описание славянских рукописей Московской синодальной библиотеки», М., 1855–1869; отд. 1–3) төзи һәм нәшер итә. «Самара шәһәрендә булган Спас-Преображение ирләр һәм Спас хатын-кызлар монастырьларының тарихи тасвирламасы» («Историческое описание бывших в городе Самаре мужского Спасо-Преображенского и женского Спасского монастырей», М., 1867), «1645–1666 елларда Мәскәү чиркәүләренең билгеләп куелган затлары турында язма: Мәскәү чиркәүләрен тасвирлау өчен материаллар» («Запись о ставленниках московских церквей 1645–1666 годов: Материалы для описания московских церквей», М., 1869), «Сембер шәһәренә үткән заманнардан губерна шәһәре дәрәҗәсенә күтәрелүгә кадәр тарихи күзәтү» («Историческое обозрение Симбирска от первых времён его до возведения в степень губернского города», Симбирск, 1909) һ.б. хезмәтләре чиркәү тарихына багышлана. Борынгы заманнардан 16 йөзгә кадәр Казан төбәге археологиясеннән хезмәтләр авторы.

Хезм.: Ананьинский могильник Вятской губернии вблизи города Елабуги. М., 1871; О городищах древнего Волжско-Болгарского и Казанского царств в нынешних губерниях Казанской, Симбирской, Самарской и Вятской. М., 1871.

*Е.Б.Долгов.*

**«НЕВРОЛОГИ́ЧЕСКИЙ ВЕ́СТНИК И́МЕНИ В.М.БЕ́ХТЕРЕВА»** («В.М.Бехтерев исемендәге неврология хәбәрчесе»), фәнни журнал. Беренче исеме — «Неврологический вестник». 1893 елдан 1918 ел башына кадәр Казанда рус телендә квартал саен нәшер ителә. 1993 нең апреленнән яңадан чыга башлый; 1995 тән хәзерге исеме б-н басыла. Оештыручылары — ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы, Казан мед. ун-ты, Казан мед. академиясе, ТР Невропатологлары һәм психиатрларының фәнни мед. җәмгыяте. В.М.*Бехтерев* тарафыннан Казан ун-ты каршындагы Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте органы буларак оештырыла. Журналның мөхәррирдәшләре — Н.М.*Попов* (1894 тән), Н.А.*Миславский* (1903 тән), В.П.*Осипов* (1906 дан). Даими авторлары: Бехтеревның укучылары — В.И.Воротынский, Н.А.Вырубов, П.А.Останков, Н.Н.Реформатский; невропатологлар — Л.О.Даркшевич, В.П.Первушин, Г.Я.Трошин, А.В.Фаворский; физиологлар һәм анатомнар — А.В.Вишневский, Н.А.Миславский, В.В.Чирпковский; гистолог К.А.Арнштейн, фармаколог И.М.Догель. Редакция төрле фәнни юнәлешләрдә эшләгән галимнәрне неврология проблемалары тирәсендә берләштерүне максат итеп куя. Журналда мәхкәмә-психиатрия казуистикасы катнаш невропатологиягә, рух һәм нерв тайпылышларының патологик анатомиясенә, нерв системасы анатомиясе, гистологиясе һәм эмбриологиясенә, нерв физиологиясе һәм психологиясенә багышланган хезмәтләр басыла. Басманың һәр чыгарылышында үзенчәлекле мәкаләләр, елъязмалар, Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте утырышларының беркетмәләре бирелә, тәнкыйть-библиография бүлеге була. Җәмгыять утырышларында тикшерелгән хәбәрләр мәкалә итеп бирелә. Россия һәм чит ил галимнәренең монографияләре, чыгышлары кушымта буларак басыла. Петербург, Мәскәү, Харьков һ.б. мед. фәнни җәмгыятьләре эшчәнлеге, психиатрия хастаханәләре эше яктыртылып бара. Беренче санының 100 еллыгы уңаеннан журнал яңадан чыга башлый, мөхәррире — М.Ф.*Исмәгыйлев* (1993 тән). Аңарда нейрофәннәр — невропатология, нейрохирургия, нейрофизиол., психол. һ.б. эргәдәш фәннәр өлкәсендәге казанышларга багышланган материаллар, сәламәт яшәү рәвеше турындагы мәкаләләр басыла. Авторлары — РФ, БДБ илләре, Европа һәм АКШ галимнәре. Мәкаләләргә аңлатмалар рус, татар, инглиз телләрендә бирелә.

*Әд.:* Исторические вехи журнала «Неврологический вестник» (к 100-летию со дня основания журнала) // Неврологический вестн. 1993. Т. 25, вып. 1–2; Исмагилов М.Ф. Казанскому журналу «Неврологический вестник имени В.М.Бехтерова» исполнилось 105 лет // Неврологический вестн. имени В.М.Бехтерева. 1998. № 1/2.

*Р.А.Айнетдинов.*

**НЕВРОЛО́ГИЯ** (грек. néuron — нерв ...*логия*), нерв системасының структурасы, функцияләре һәм авырулары турындагы мед. һәм биол. фәне. «Н.» термины, башлыча, клиник медицинаның нерв системасы авыруларын һәм нерв системасының организмдагы башка системалар һәм органнар патологиясендә тоткан урынын өйрәнүче бүлеген билгеләү өчен кулланыла. 19 йөзнең 2 нче яртысында клиник Н. медицинаның аерым тармагы булып аерылып чыга, мөстәкыйль тармак башында Ж.Шарко, Ж.Дежерин, И.Бабинский (Франция), А.Штрюмпель, К.Вестфаль, Г.Оппенгейм (Германия), Д.Джексон, У.Говерс (Англия) кебек танылган табибләр тора. Россиядә Н.нең фәнни-гамәли яктан формалашуы дөньяда иң беренчеләрдән неврология клиникасы (1869) булдырган һәм Мәскәү ун-тындагы Россиядә беренче нерв авырулары кафедрасына (1870) җитәкчелек иткән А.Я.Кожевников исеме б-н бәйле. Казан ун-тында Н. 1876 елда патология һәм терапия кафедрасында укытыла башлый, 1885 тә, Мәскәү һәм Петербургтан соң Россиядә өченче булып, нерв авырулары каф. булдырыла. 1887 дә Казан ун-ты каршында Нерв авырулары клиникасы ачыла; 1892 дә В.М.Бехтерев Невропатологлар һәм психиатрларның Казан җәмгыятен оештыра, хәзерге Татарстан неврологлары җәмгыяте — шуның варисы. Соңрак Мәскәү һәм Петербург Н. мәктәпләре б-н бергә Россиядә Н.нең төп юнәлешләрен билгеләячәк Казан Н. мәктәбенә исемнәре бөтен дөньяга билгеле профессорлар В.М.Бехтерев (1885–93 тә Казан ун-тының психиатрия каф. мөдире) һәм Л.О.Даркшевич (1893–1917 дә Казан ун-тының нерв авырулары каф. мөдире) тарафыннан нигез салына. Казанда эшләү чорында В.М.Бехтерев Европада икенче, Россиядә беренче булган психофизиол. лаб-ясе оештыра; яңа авыру — анкилозга китерүче спондилартритка, яки «Бехтерев авыруы»на тасвирлама бирә (1892). Н.А.Миславский б-н бергә баш мие кабыгының эчке органнар эшчәнлегенә йогынтысын өйрәнү буенча экспериментлар юлы б-н фундаменталь тикшерүләр уздырыла, арка миенең үткәргеч юллары һәм баш миенең функциональ анатомиясе турында тәгълимат булдырыла; «Минең үткәргеч юллары» («Проводящие пути мозга», 1892) китабы нәшер ителә (соңрак ул тулыландырыла, кабатлап бастырыла, чит телләргә тәрҗемә ителә). Л.О.Даркшевич Казанга килгәнгә кадәр ачыш ясый — баш миенең арткы спайкасы төшенә тасвирлама бирә (хәзер аның исеме б-н йөртелә). Аның кайбер хезмәтләре атаклы француз неврологы Ж.Дежерин (1885) һәм психоанализга нигез салучы З.Фрейд (1886) б-н автордаш буларак нәшер ителә. Казанда эшләү дәверендә Даркшевич неврология клиникасын киңәйтә һәм җиһазландыра, Н. буенча Россиядә беренче капиталь кулланма — «Нерв авырулары курсы»н («Курс нервных болезней», т. 1–3, 1904–07) әзерләпләп бастыра, хирурглар В.И.Разумовский һәм А.В.Вишневский б-н берлектә Россия медицинасында нейрохирургия тармагын булдыруга зур хезмәт куя.

Алга таба Казанда Н. үсеше гомумән Россия Н.се үсешен тәэмин иткән галим-профессорлар А.В.*Фаворский*, В.П.Первушин, И.С.*Алуф*, Л.И.*Омороков*, И.И.*Русецкий*, Г.Б.*Максудов*, В.М.*Сироткин*, Я.Ю.*Попелянский*, И.Н.*Дьяконова*, А.Ю.*Ратнер*, В.П.*Веселовский*, Х.М.*Шульман*, Д.М.*Табиева*, М.Ф.*Исмәгыйлев* һ.б.ның хезмәтләре б-н бәйле. Казан неврологлары баш һәм арка миенең кан тамырларын, периферик нерв системасын, нерв системасының вертеброген авыруларын, таркау склерозны, вегетатив нерв системасы авыруларын, балалар Н.сен, талпан энцефалитын, эпилепсия, паркинсонизм, сирингомиелияне, мануаль мед. өлкәсендә — рефлексотерапия, нейрофармакология, клиник нейрофизиология, нейрорадиологияне өйрәнүгә зур өлеш кертәләр. Казан неврологларыннан И.И.Русецкийның «Вегетатив нерв тайпылышлары» («Вегетативные нервные нарушения», 1958), Л.И.Омороковның «Клиник невропатологиягә кереш» («Введение в клиническую невропатологию», 1961), Я.Ю.Попелянскийның «Бил остеохондрозының вертебраль синдромнары» («Вертебральные синдромы поясничного остеохондроза», 1974), Г.А.*Иваничевның* «Мануаль медицина» («Мануальная медицина», 1998) хезмәтләре Н. буенча Россиядә басылган китапларның алтын фондына кертелгән, табиб-галимнәрнең хәзерге эзләнү нәтиҗәләре дөньяның Н.гә багышланган иң танылган басмаларында дөнья күрә тора.

Казанда 6 Н. кафедрасы бар (2010): Казан мед. ун-тында — Н., нейрохирургия һәм мед. генетикасы (каф. мөдире — М.Ф.Исмәгыйлев); Н. һәм реабилитация (Э.И.Богданов); Н. һәм нейрохирургия (В.И.Данилов); Казан мед. академиясендә — Н. һәм рефлексотерапия (Г.А.Иваничев); вертеброневрология (Ф.Ә.Хәбиров); балалар Н.се (В.Ф.Прусаков). Н.гә караган 2 журнал нәшер ителә: «Неврологический вестник» (1893 елда В.М.Бехтерев тарафыннан нигезләнә, баш мөхәррире — М.Ф.Исмәгыйлев) һәм «Вертеброневрология» (баш мөхәррире — Ф.Ә.Хәбиров). Казан мед. академиясе каршында Н. өлкәсендә докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау буенча Фәнни совет эшли. Казанда ике тапкыр Бөтенроссия неврологлары съезды уздырыла (1974, 2001).

Татарстанда 650 невролог эшли (10 мең кешегә — 1,72 туры килә), республика стационарларында нерв авырулы өлкәннәр өчен 2000, балалар өчен 240 ятак-урын бар (2010). Казандагы махсус Н. үзәкләрендә (респ-ка инсульт регистры, респ-ка таркау склероз б-н авыручыларга ярдәм күрсәтү үзәге, респ-ка неврологик авырулар өчен терапәкләндерү хастаханәсе, нерв системасының экстрапирамид авыруларына дучар булганнарга ярдәм күрсәтү үзәге) фәнни-тикшеренү эшләре алып барыла, респ-кадан һәм башка төбәкләрдән килгән пациентларга гамәли ярдәм күрсәтелә. Респ-ка клиник хастаханәсендә эпилептологик һәм отоневрологик авырулар кабул ителә.

*Әд.:* Дьяконова И.Н., Попелянский Я.Ю., Чудновский В.С. История развития неврологии и психиатрии в Казани. К., 1974.

*Э.И.Богданов.*

**НЕДА́ЧИН** Александр Васильевич (10.7.1888, Смоленск губ., Бельский өязе Травино а. — 1940), Россиядә вет. хезмәтенә нигез салучыларның берсе. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1913), Петербург губернасының Ямбург өязендә земство вет. табибе булып эшли. 1914 елдан хәрәкәттәге ар-

миядә, соңрак күчмә вет. лазаретларында вет. табибе.

Окт. рев-циясе көннәрендә Царское Село янында генерал П.Н.Краснов гаскәрләренә каршы бәрелешләрдә, контрреволюцион оешмаларны юк итүдә катнаша. 1917–19 да Петроград хәрби округының вет. идарәсе мөдире, бер үк вакытта Төньяк өлкә коммуналары союзының сәламәтлек саклау халык комиссары урынбасары (1917–18), Петросоветның вет. бүлеге мөдире (1919). 1919 ел ахырында Идел буе хәрби округының вет. идарәсе башлыгы итеп күчерелә. 1921–25 тә ТАССР вет. идарәсе башлыгы һәм комиссары, бер үк вакытта Казан вет. ин-ты комиссары, ТАССР Дәүләт план ком-ты рәисе. 1925 тә Мәскәүгә күчерелә һәм РСФСР Җир эшләре халык комис-тының Үзәк вет. идарәсе башлыгы итеп билгеләнә, бер үк вакытта, 1927 дән, СССР Хезмәт һәм Оборона Советы каршында аның тәкъдиме б-н оештырылган Вет. эшләре ком-ты рәисе урынбасары, 1930 дан СССР Җир эшләре халык комис-тының вет. идарәсе башлыгы. Үзәк вет. идарәсе Н. җитәкчелегендә яңа тип вет. учреждениеләре оештыра: а.х.нда вет. челтәре үзгәртеп корыла, терлекләрнең күп кенә йогышлы авыру төрләрен бетерү чаралары күрелә. Беренче тапкыр вет. өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләренең планлы рәвештә алып барылуына ирешелә. Н. ТАССРда эшләгән дәвердә барлык вет. учреждениеләре 35 вет. табибе һәм 83 вет. фельдшеры эшли торган вет. хезмәте системасына берләштерелә; 1921 дә серодиагностика лаб-ясе ачыла, вет. табибләре участокларының саны арта. Н. ш.у. оештыру мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, йогышлы а.х. терлекләре авыруларына багышланган популяр брошюралар авторы. 1937 елда репрессияләнә, төрмәдә үлә (1940); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Очерк по истории строительства ветеринарных организаций (к 10-летию Октябрьской революции) // Вест. современной ветеринарии. 1928. № 4. Задачи ветеринарии в реконструктивный период народного хозяйства. М.–Л., 1930; За неуклонное разрешение проблем животноводства // Советская ветеринария. 1933. № 10.

*Әд.:* Недачин А.В. // Вестн. современной ветеринарии. 1925. № 10; Д о б р о х о т о в А.М., Р а ж д а е в В.И. А.В.Недачин (к 75-летию со дня рождения) // Ветеринария. 1963. № 7.

*И.Н.Никитин.*

**НЕДАШКО́ВСКИЙ** Леонард Фёдорович (30.8.1973, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: 1995–2006 елларда Археология музеенда баш саклаучы, 2006 дан археол. һәм этнология кафедрасында, 2011 дән доцент. Хезмәтләре археол., нумизматика һәм Түбән Идел буеның Алтын Урда чоры тарихына багышлана.

Х е з м.: Золотоордынский город Укек и его округа. М., 2000; Золотоордынские города Нижнего Поволжья и их округа. М., 2010.

**НЕДБА́ЙЛО** Анатолий Константинович (28.1.1923, Донецк өлкәсенең Изюм ш. — 13.5.2008, Киев), авиация генерал-майоры (1970), ике тапкыр Сов. Союзы Герое (19.4.1945, 29.6.1945). Очучыларның Ворошиловград хәрби авиация мәктәбен (1943), Хәрби-Һава академиясен (Монино пос., Мәскәү өлкәсе, 1951) тәмамлый. Бөек Ватан сугышы елларында очучы-штурмовик (1943 елның мартыннан), Көньяк, 4 нче Украина һәм 3 нче Белоруссия фронтларында 75 нче гв. авиаполкының звено командиры, эскадрилья командиры урынбасары, командиры. 219 сугышчан очыш ясый. 1960 тан Харьков югары хәрби команда-инженерлар уч-щесендә каф. башлыгы. 1962 дән Казан югары артиллерия командирлар уч-щесе башлыгы урынбасары. 1964 тән Рига югары хәрби команда-инженерлар уч-щесенең читтән торып уку ф-ты башлыгы. 1968–83 тә Киев югары хәрби авиация инженерлары уч-щесе башлыгы урынбасары. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Туган ягында Геройга бронза бюст куелган.

Ә с ә р.: В гвардейской семье. К., 1975.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; С о к о л о в В.Д. Мои друзья — лётчики. М., 1969; Подвиги во имя Отчизны. Хар., 1974; Люди бессмертного подвига. М., 1975. Кн. 2.

**НЕДОШИ́ВИН** Андрей Яковлевич (15.12.1883, Вятка губ. Вятка ш. — 29.7.1950, Казан), ихтиолог, биол. фән. д-ры (1934), проф. (1934). Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлый (1910). Каспий, Төньяк һәм Азов фәнни-промысел экспедицияләрендә (1912–15, 1921, 1922–25) катнаша. Әзәрбайҗан политехник (1928–30) һәм Әзәрбайҗан балык промыселы (1931–32) ин-тлары профессоры. 1933 елдан Казан ун-тында умырткалылар зоологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре диңгез, күл һәм елга балык ресурсларыннан рациональ файдалануга карый. Н. беренче булып ата балык агын балыкны ясалма үрчетү максатларында файдалану өчен саклау буенча тәҗрибәләр үткәрә. Дагстан сельд промыселын саклау һәм үстерүнең кирәклеген дәлилли. Әзәрбайҗан балык промыселы ин-тын оештыра. Иделнең кереп йөрүче сельд балыкларын өйрәнүгә зур өлеш кертә.

Х е з м.: Рыболовство в водах южного Каспия // Тр. Ин-та рыбного хоз-ва и промысловых исследований. Л., 1929. Т. 1; Материалы к изучению Донского рыболовства // Тр. Азовско-Черноморской научно-промысловой экспедиции. М., 1929. Вып. 4; Отчёт об искусственном разведении стерляди на нерестилищах весной 1933 года. К., 1933.

*В.А.Кузнецов.*

**«НЕЗАВИ́СИМОСТЬ»** («Бәйсезлек»), иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-нәфис газета. Күпмилләтле «Суверенитет» демократик хәрәкәте органы. Оештыручысы — Татарстан мөстәкыйльлеген саклау ком-ты. 1992–94 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Ә.Г.*Мәхмүдов.* Газета татар милли хәрәкәте күтәрелү дулкынында барлыкка килә. Аның битләрендә Татарстан һәм татар халкының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышының бүгенгесе һәм киләчәге мәсьәләләре күтәрелә. «Н.» «Суверенитет» хәрәкәтенең сәяси белдерүләрен, ТР һәм РФдә барган сәяси вакыйгаларга бәяләмәләр бастыра. Публицистик мәкаләләре б-н Я.Абдуллин, М.Әхмәтҗанов, М.Вәлиева, Ә.Кәримуллин, Ә.Мәхмүдов, А.Хәлим, Н.Хисамов һ.б. чыгыш ясый. Редакция М.Насыйбуллинның «Чакырылган кунак», Д.Вәлиевнең «Кәрлә буйвол», Я.Мостафинның «Шайтан», З.Зәйнуллинның «Полковникны озату», Ф.Галиевның «Хәйретдин мулланың соңгы батырлыгы», Р.Хәмиднең «Марс билгесе астында», И.Салаховның «Карлыгач», Ә.Мәхмүдовның «Туй булачак», М.Скороходовның «Орилена» һ.б. әсәрләреннән өзекләр бастыра. Газетада Ә.Гадел, З.Әкбәров, Р.Вәлиев, М.Зарецкий, Р.Кожевникова, Ю.Макаров, Ә.Мәхмүдов, Т.Пашагина, Ә.Саттар, Р.Фәйзуллин һ.б.ның шигырьләре дөнья күрә. Тарихи-мәдәни мирас бүлегендә Г.Исхакыйның тарихи хезмәте — «Идел-Урал» тәрҗемәсе, «Идегәй» дастаны басыла. Россия матбугатының Татарстандагы вакыйгаларга багышланган мәкаләләренә күзәтүләр, укучылар хатлары даими урын ала.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«НЕЗАВИ́СИМЫЙ СОЦИАЛИ́СТ»** («Бәйсез социалист»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Бәйсез социалистлар партиясе органы. 1917 елның 19 июненнән 7 октябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 11 саны чыга. Казан ун-ты басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — бәйсез социалистлар партиясенең Казан ком-ты рәисе А.Г.Муравьёв. Актив авторлар арасында — М.М.Агарков, И.А.Антропов, П.Г.Архангельский, А.Г.Бать, К.Г.Горштейн, В.П.Денике, Н.И.Дамперов, Л.К.Ильинский, Г.Каминский, Г.Ю.Манис, В.И.Огородников. Төп рубрикалары: «Партиянең Вакытлы Үзәк комитетыннан», «Партия тормышыннан», «Бүгенге Казан», «Авыл тормышы», «Социалистик партияләрдә». Газетада партиянең Вакытлы ҮК составы, аның урындагы бүлекләре, партия әгъзалыгына керү тәртибе турында мәгълүматлар бирелә. Редакция Вакытлы хөкүмәт эшен хуплый, алар тарафыннан чыгарылган «Ирек заёмы»н яклап чыгыш ясый. Басма большевикларны Петроградтагы 1917 нең июль канлы вакыйгаларында гаепли, әлеге хәлләрне тикшерү буенча Вакытлы хөкүмәт комиссиясе эшчәнлеге, большевиклар җитәкчеләрен кулга алулар турында тәфсилле сөйли. Әлеге чорда хөкүмәт составыннан чыгулары өчен кадетларны тәнкыйтьли. «Н.с.» Учредительләр җыенын чакыруны, аны сайлау чорында бердәм Соц. блок (большевиклардан тыш) оештыруны яклый. Милли мәсьәләгә зур игътибар бирелә. «Җиргә бәйләнмәгән автономия һәм милли мәсьәлә», «Белоруссия автономиясе», «Алкин хаты хакында» мәкаләләрендә экстерриториаль милли-мәдәни автономия идеясе хуплана. Газета 1917 нең июль–августында Казанда узган өч Бөтенроссия мөселманнар корылтае материалларына җентекле аңлатма бирә. Басма саннан санга «Рус революциясе тарихы буенча полиция департаменты әгъзалары хезмәтләре» мәкаләсен бастыра. Мәкаләдә 1860 еллардан башлап департамент эшчәнлеге яктыртыла. Тарихи темага багышланган басмалар арасында «Казан журналистикасы тарихыннан» аерылып тора. Аңарда

20 йөз башындагы алдынгы матбугатка мөнәсәбәттә Матбугат эшләре буенча җирле вакытлы ком-тның сәясәте бәян ителә. Соңгы санда Казан шәһәр думасына сайлауларда Соц. блок өчен тавыш бирергә чакырыла, блок кандидатлары исемлеге бирелә.

*Т.М.Насыйров.*

**«НЕЗЕ́РЫН ШАМА́КШЫ»** («Ярлы тавышы»), газета; к. «*Тор*».

**НЕ́ЙМАН** (Neumann) фон Иоанн Георг (Иван Егорович) (1780, Марбург ш., Германия — 13.12.1855, Петербург губ., Царское Село өязе Иске Калитино а.), хокук белгече, статский советник. Дворяннар нәселеннән. 1806–09 елларда Законнар төзү комиссиясе советында мөхәррир ярдәмчесе, 1 нче экспедиция (гражданлык законнары) башлыгы ярдәмчесе, секретарь (С.-Петербург). 1809–11 дә Казан ун-тының — гражданлык һәм җинаять эшләре буенча мәхкәмә процессы, политэкономия һәм статистика, 1814–17 дә — табигый, сәяси һәм халык хокукы кафедралары; Дерпт ун-тының 1811–14 тә — дәүләт һәм халык хокукы, 1817–21 дә — Лифляндия хокукы, 1821–26 да — Россия теоретик һәм гамәли хокук белеме кафедралары ординар профессоры. Карашлары буенча хокук белгече В.Блекстон һәм икътисадчы А.Смит юлын дәвам итүчеләрдән санала. Россия хокукын өйрәнүгә өлеш кертә. Хокук буенча яшәп килгән тармакларга аңлатмалар төзүче. Җинаять эшләре хокукы, политэкономия буенча уку ярдәмлекләре һәм программалар авторы.

Х е з м.: Начальные основания уголовного права. СПб., 1814; Исследование правил политической экономии по системе Адама Смита. СПб., 1817.

*Әд.:* Б у л и ч Н.Н. Из первых лет Казанского университета (1805–1819). К., 1891. Ч. 2; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Юрьевского, бывшего Дерптского, университета (1802–1902). Юрьев, 1902. Т. 1. Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**НЕЙРОХИРУРГИ́Я** (грек. néuron — нерв һәм *хирургия*), клиник медицинаның нерв системасы авырулары һәм имгәнү-җәрәхәтләренә диагноз кую һәм аларны оператив юл б-н дәвалау ысулларын эшләү б-н шөгыльләнүче бүлеге. Неврология өлкәсендәге казанышлар һәм хирургия техникасы үсеше нигезендә 1920 елларда аерым белгечлек булып аерылып чыга. Н. нейрофизиология, рентгенология, радиология һәм клиник медицина б-н тыгыз бәйләнештә тора. Микрохирургия Н.нең иң мөһим бүлеген тәшкил итә. Н. ш.у. нейротравматология, нейроонкология, баш һәм арка миендәге кан тамырлары патологиясе, артериаль һәм артеровеноз аневризмалар, артерия һәм вена куышлыкларындагы тайпылышлар, геморрагик инсульт һәм ишемия инсульты кебек бүлекләргә аерып карала. Н. үсешенә Казан профессорлары В.М.Бехтерев, Л.О.Даркшевич, А.Н.Миславский, Л.Л.Лёвшин, В.И.Разумовский, А.А.Вишневскийлар тарафыннан нигез салына. В.И.Разумовскийның «Баш мие хирургиясе буенча иң яңа мәгълүматлар» («Новейшие данные по черепно-мозговой хирургии», СПб., 1913) хезмәте — Россиядә баш мие хирургиясе проблемаларына багышланган иң беренче тикшеренүләрнең берсе. В.И.Разумовский Джексон һәм Кожевников эпилепсияләрен дәвалау өчен беренче булып баш мие кабыгының аерым участокларын резекцияли, өч япьле нерв невралгиясе очрагында Гассер төенен кисеп ала, баш сөяге трепанациясе ысулларын камилләштерә. А.В.Вишневский беренче булып баш сөяге дефектларын кальцийсызландырылган сөяк пластинкасы б-н каплау ысулын тәкъдим итә. 1934–60 елларда Казан нейрохирургларын В.А.Гусынин әйдәп бара. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда 1000 һәм 400 ятак-урынлык 2 Н. госпитале ачыла, аларда Мәскәү Н. ин-тының Казанга эвакуацияләнгән атаклы профессорлары — А.А.Аренд, М.Ю.Рапопорт, Н.Д.Лейбзон, А.Р.Лурия, С.М.Блинков һ.б. эшли. Госпитальләрнең берсе базасында Ортопедия һәм травматология ин-ты оештырыла, аның структурасына 60 ятак-урынга исәпләнгән 1 нче Н. бүлеге кертелә (мөдирләре — Г.С.Книрик (1945–76), Е.К.Вәлиев (1976 дан).

Нейрохирургларның 1 нче Бөтенроссия конференциясенең (1950) Казанда уздырылуы Казан табибләренең Бөек Ватан сугышы яралыларын дәвалауга керткән өлешен тану һәм бәяләү була. 1966 да Казан шәһәренең 15 нче клиник хастаханәсе базасында 60 ятак-урынга исәпләнгән 2 нче Н. бүлеге ачыла, мөдирләре — Х.М.Шульман (1966–69), Ю.А.Менялкин (1969–74), Р.В.Сарымсаков (1974–83), В.Е.Яковлев (1983–99), Р.Х.Кәримов (1999 дан); 1982 дә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсендә 40 ятак-урынга исәпләнгән, авыруларны планлы рәвештә кабул итүче Н. бүлеге булдырыла, мөдирләре — Г.В.Савкин (1980–85), Ю.А.Менялкин (1985–91), А.В.Горожанин (1991–94), Л.П.Дюдин (1994–2006), Т.А.Бикмуллин (2006 дан). 1994 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә балалар Н.се бүлеге ачыла, мөдире — В.С.Иванов. «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәге һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсенең Н. бүлекләре базасында өлкәара Н. үзәге эшли, җитәкчеләре — Г.С.Книрик (1954–76), Е.К.Вәлиев (1976–84), Х.М.Шульман (1984–91). 1980 нән Чаллы шәһәренең ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсендә 56 ятак-урынга исәпләнгән Н. бүлеге эшли, мөдирләре — В.С.Антонов (1980–86), Н.В.Дубровин (1986–97), А.С.Гроздов (1997 дән). Төбәкара клиника-диагностика үзәгендә югары мед. технологияләренә нигезләнгән, 60 ятак-урынга исәпләнгән Н. бүлеге ачыла, мөдирләре — В.И.Данилов (1994–2006), А.Г.Алексеев (2006 дан). 1999 дан Түбән Кама шәһәренең 2 нче хастаханәсендә 30 ятак-урынлык махсус бүлек эшли, мөдирләре — А.А.Саушев (1999–2004), Е.П.Баранов (2004 тән). ТР районнарында нейрохирурглар Бөгелмә, Алабуга, Әлмәт, Лениногорск, Чистай, Яшел Үзән шәһәрләре һәм Алексеев шәһәр тибындагы посёлогы үзәк район хастаханәләренең травматология бүлекләре составына кертелгән.

ТР микрохирурглары тарафыннан хирургия инструментлары б-н баш миенең иң эчкәреге структураларына янәшәдәге участокларны зарарламаслык итеп үтеп керергә мөмкинлек бирүче стереотаксик ысул үзләштерелгән. Хирурглар практикасында — эндоваскуляр ысуллар, эндоскопик алымнар, шунтлау операцияләре, интраоперация мониторингы.

Казанда Н. 1966 да укытыла башлый, 1972 дә — ординатура, 1998 дә — аспирантура (Х.М.Шульман, В.И.Данилов, А.А.Калашников, Р.И.Яһудин, Т.А.Бикмуллин) булдырыла; 1981 дә Н. каф. ачыла (мөдире — Х.М.Шульман), ул 1986 да нерв авырулары кафедрасы б-н берләштерелә (неврология, Н. һәм мед. генетикасы каф., мөдире — М.Ф.Исмәгыйлев), 1996 дан башлап Н. табибләре махсус әзерләнә. 2002 дә Татарстан нейрохирурглары ассоциациясе төзелә (идарә рәисе — В.И.Данилов). Ассоциация Казаннан һәм Татарстанның башка шәһәрләреннән 70 ләп нейрохирургны берләштерә (араларында 9 мед. фән. канд-ты, 3 мед. фән. д-ры, 4 ТРның атказанган табибе бар). 2007 дә Казанда В.М.Бехтеревның тууына 150 ел тулуга багышланган «В.М.Бехтерев — нейрофәннәргә нигез салучы. Иҗади мирасы, тарих һәм заман» («В.М.Бехтерев — основоположник нейронаук. Творческое наследие, история и современность») Россия фәнни конгрессы уздырыла.


*В.И.Данилов.*

**НЕЙТРОННЫ́Ң МАГНИ́Т МОМЕНТЫ́** ($\mu_н$), нейтронның төп характеристикаларыннан берсе; зурлыгы $\mu_н = -1{,}91315(7)\mu_т$, биредә $\mu_т$ — төш магнетоны (магнит моментын үлчәү берәмлеге). Н.м.м.ның булуы нейтрон ул — электрик нейтраль ноктадай кисәкчек дигән күзаллауларга каршы килә һәм, протонның магнит моментының аномаль зурлыгы б-н ($\mu_п$, биредә $\mu_п \approx 2{,}79\mu_т$) бергә, нуклоннарның (протоннар һәм нейтроннарның) катлаулы структурасын күрсәтә. Н.м.м.ның барлыгы, тамгасы һәм якынча зурлыгы, Мәскәү ун-тының Физика фәнни-тикшеренү ин-тында так сандагы нейтроннары булган төшләр спектрын анализлау нигезендә физиклар С.А.*Альтшулер* һәм И.Е.Тамм тарафыннан теоретик фаразлана (1934).

*Әд.:* А л ь т ш у л е р С.А., Т а м м И.Е. Магнитный момент нейтрона // Докл. АН СССР. 1934. Т. 1, № 8.

*Л.К.Әминов.*

**НЕКЛЕ́СОВА** Ирина Дмитриевна (1.1.1919, Рязань губ. Спасск ш., хәзер Рязань өлкәсенең Спасск-Рязанский ш. — 20.1.1980, Казан), токсиколог, мед. фән. д-ры (1978). 1941 елда Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Мари фәнни-практик зоб станциясендә эшли. 1946–51 дә Респ-ка кан салу станциясенең хирургия төркеме мөдире (Казан). 1951–80 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында. Казанда беренче токсикология лаб-ясен оештыручы (1965) һәм аның җитәкчесе. Хезмәтләре элементорганик кушылмаларның биол. активлы-



С.Е. Немасев.



М.П. Неменко-Бабковская.

гын тикшерүгә һәм яңа дару чараларын эзләүгә; фосфор, мышьяк һәм күкерт катнашкан органик кушылмаларның химик төзелеше б-н биол. активлыгы арасындагы бәйләнешләрне, ш.у. аларның тәэсир итү механизмын өйрәнүгә карый. Н. а.х. культуралары корткычларына һәм авыруларына каршы препаратлар (дитиофос, октаметил), глаукоманы (фосарбин, хлорофтальм) һәм гөмбәле чирләрне (хлорацетофос) дәвалау өчен дару чаралары булдыру эшендә катнаша. Орлыкларны чәчү алдыннан эшкәрткәндә, үсемлекләрдә системалы октаметил инсектициды циркуляциясенең периодын билгели. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорорганические инсектициды // Изв. КФАН СССР. 1957. № 4; Влияние фосфорорганических антиглаукоматозных препаратов на периферические сосуды // Фармакология и токсикология. 1962. № 6 (автордаш); Химическое строение и антимикробные свойства фосфорорганических соединений // Докл. АН СССР. 1964. Т. 154, № 1 (автордаш); Синтез и некоторые свойства акриловых и метакриловых производных хлорофоса и его аналогов // Изв. АН СССР. 1973. № 4 (автордаш).

*В.Г.Абзалова.*

**НЕКРА́СОВ** Александр Александрович (15.8.1837, Тверь губ. — 13.5.1905, Казан), христиан дине һәм тел галиме, христиан теологиясе магистры (1863). Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, Казан руханилар академиясендә эшли. 1869 елдан грек теле каф. мөдире. Хезмәтләре дини әдәбиятны грек теленнән рус теленә тәрҗемә итү мәсьәләләренә карый. Н. җитәкчелегендә Шәрекъ чиркәүләре Вселенский һәм Поместный соборлары Язмаларының фәнни тәрҗемәләре һәм басмалары әзерләнә. Казан руханилар академиясендә дини һәм фәлсәфи-фәнни мәктәпләр үсешенә ярдәм итә (Н. шәкертләре арасында — И.С.*Бердников*, М.И.*Богословский*, В.И.*Несмелов*). *Инҗил* текстларына шәрехләүләр авторы.

Х е з м.: Чтение греческого текста св. Евангелий. К., 1888; Чтение греческого текста Деяний и Посланий апостольских. К., 1892.

*Әд.:* Александр Александрович Некрасов: Некролог. К., 1905; Р е д н и к о в Н. Очерк учёно-литературной и профессорской деятельности Александра Александровича Некрасова // Православный собеседник. 1906. Ч. 1.

**НЕКРА́СОВКА** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кондырча елгасы буенда. 2010 елда 121 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1938 дә — 178, 1949 да — 141, 1958 дә — 121, 1970 тә — 184, 1979 да — 187, 1989 да — 134, 2002 дә — 149 кеше.

**НЕЛИ́ДОВ** Николай Константинович (16.12.1832, Сембер губ., Ставрополь өязе Иске Майна а. — 28.10.1888, Казан), хокук белгече, дәүләт хокукы д-ры (1874), хакыйкый статский советник (1875). Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1856). 1856–57 елларда — Пенза, 1857–58 дә Казанның Беренче ир балалар гимназияләре өлкән укытучысы. 1858–86 да (бүленеп) Казан ун-тында: 1861–69 да адъюнкт, 1869–70 тә доцент, 1874–83 тә ординар проф., 1883 тән дәүләт хокукы каф. атказ. профессоры һәм юридик ф-т деканы. 1870–74 тә Демидов юридик лицее (Ярославль ш.) дәүләт хокукы каф. экстраординар профессоры. Россиядә социологик дәүләт белеме юнәлешенә нигез салучыларның берсе. 1860 еллар реформалары алдыннан рус җәмгыятендә хокукый һәм сәяси белемнәрне гамәлгә кертүне яклап чыгышлар ясый. Гомуми дәүләт хокукы буенча хезмәтләре бар. «Борынгы Германия дәүләт төзелешенә караган кайбер мөһим мәсьәләләргә күзәтү» («Обзор некоторых существенных вопросов, относящихся к древнегерманскому государственному устройству», 1868) хезмәтендә дәүләтнең җәмгыять төзелеше б-н үзара бәйләнешен үзәккә куя һәм дәүләт хакимиятенең сыйнфыйлык сыйфатын тикшерә, икътисади якның дәүләт үсешендә хәлиткеч фактор булуын таный. «Дәүләт турында фән» («Наука о государстве», Ярославль, 1872) очеркында Көнбатыш Европада һәм Россиядә хокукый белем бирү тарихына күзәтү ясый, дәүләт хокукы фәнен югары уку йортларында укыту кирәклеген нигезли. «Дәүләт хезмәтенең юридик һәм сәяси нигезләре» («Юридические и политические основания государственной службы», Ярославль, 1874) монографиясе дәүләт мәнфәгатьләрендә «махсус белемле түрәләрнең» хезмәт итүләре асылын һәм тарихын өйрәнүгә багышлана. Җәмгыять турында аерым фән — социологияне булдыру кирәклеген ассызыклый. Казан ун-ты каршындагы Юридик җәмгыятьнең оештыручы-әгъзасы (1879).

Х е з м.: О необходимости приобретения обществом юридических и политических сведений. К., 1861; Система курса общего государственного права. К., 1875.

*Әд.:* Памяти Н.К.Нелидова. К., 1889; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; А г а ф о н о в Н.Я. Из Казанской истории. К., 1906.

*Е.Б.Долгов.*

**НЕМА́СЕВ** Сергей Егорович (25.9.1928, Буа кантоны Хорновар-Шигали а.), механик, Соц. Хезмәт Герое (1957). Ульянов механика техникумын тәмамлаганнан соң (1952), Идел (1953–57) һәм Братск (1957–61) ГЭСлары төзелешендә механик булып эшли. Герой исеме 5 еллык план (1956–60) йөкләмәләрен үтәүдәге казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НЕМАТОДАЛА́Р**, й о м р ы с у а л ч а н н а р (Nematoda), беренчел куышлы суалчаннар классы. Соңгы карбон чорыннан билгеле. Гәүдәсе сегментларга бүленмәгән, орчыксыман, җепсыман, кечкенә мичкәсыман, йомры (икенче исеме шуннан). Дөнья фаунасында 500 меңнән артык төре билгеле; вәкилләренең саны буенча бөҗәкләрдән соң 2 нче урынны алып тора. Дөньяның барлык өлешләрендә таралган, диңгезләрдә, төче сулыкларда, туфракта яшиләр. Күп кенә Н. үсемлекләрдә (фитонематодлар), умырткасыз, умырткалы хайваннарда һәм кешедә паразит булып яшиләр. Бик кечкенә, ирекле яшәүчеләр (*мм* ның өлешләреннән алып — 5 *мм* га, сирәк кенә 50 *мм* га кадәр); паразит формалары, гадәттә, кечкенә, әмма кайберләре 40–100 *см* (8,5 *м* га кадәр) озынлыкка җитә. Н.ның гәүдәсе күпкатламлы кутикула (үзенчәлекле тышкы скелет ролен һәм саклагыч функцияне башкара) б-н капланган, аның астында гиподерма урнашкан. Буй мускулатура орчык формасындагы озын мускул җепселләреннән хасил була. Аерым җенесле, җенси диморфизм күзәтелә (ата затлар аналарыннан кечерәк). Күкәй салучылар, сирәк кенә тереләй тудыручылар. Күбесе арадаш хуҗаларыннан башка гына җитлегә. Ирекле яшәүче Н. микроорганизмнар, суүсемнәр, детрит б-н туена, ерткычлары бар, үсемлек, гөмбә согы, азык яки хуҗасы тукымасы б-н туена торган паразитлар аеруча күп. Аерым төрләре кешедә һәм хайваннарда җитди авырулар тудырырга мөмкин. ТР терр-ясендә — *бабасырлар, аскаридалар, чәчбашлар, трихинеллалар*, токсокаралар, анпилостом, стронгилидалар, трихостронгилидалар семьялыгыннан кешедә паразитлык итүче Н.ларның 8 төре билгеле. Беренче 3 се энтеробиоз, аскаридоз, трихоцефалёз кебек авырулар китереп чыгара. Фитонематодалар (Татарстанда 7 төре теркәлгән) үсемлекләрне зарарлый: бәрәңге Н.ы (Heterodera rostochiensis), чөгендер Н.ы (H. schachtii), солы Н.ы (H. avenae) тамырларда паразитлык итә, аларның көчле тармаклануын һәм вак тамырларның черүен китереп чыгара; оры Н. (Meloidogyne spp) яшелчә культураларының тамырларында орылар хасил итә; Ditylenchus ыругыннан сабак Н.ы үсемлекләрнең сабагын, суганчасын, тамырчасын (суган, сарымсак, чөгендер, каен җиләге һ.б.) зарарлый, үсешнең началаюын һәм җир өсте органнарының деформациясен китереп чыгара.

*О.Д.Любарская.*

**НЕМЕЖА́НОВ** Марат Камил улы (16.2.1978, Казан), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Казан химия-технол. ун-тын тәмамлый (2001). 1998–2001 елларда «Казан» зона йон лаб-ясендә эшли. 2001 дән Казан дәүләт казна дары заводында: мастер, инженер-технолог, технол. җиһазларны ремонтлау мастеры. Дәүләт бүләге көндәшлеккә сәләтле продукция җитеште-

ру максатында диверсификацион технологияләр булдыруда катнашканы өчен бирелә.

**НЕМЕ́НКО-БАБКО́ВСКАЯ** Мария Павловна (18.12.1911, Курск губ. Рыльск ш. — 29.8.1994, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1956), РСФСРның атказ. артисты (1957). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык (1934) һәм актёрлык (1959) ф-тларын тәмамлый. 1934–35 елларда Ташкент яшь тамашачылар театры режиссёры, 1935–42 дә Севастополь шәһәрендәге Кара диңгез флоты театры, Ростов-Дон һәм Сталинград яшь тамашачылар театрлары актрисасы. 1942 дә Сталинград яшь тамашачылар театры труппасы б-н Казанга эвакуацияләнә. Травести (яшүсмер малайлар) һәм яшь героинялар рольләрен башкара. Н.-Б.ның лирик-драматик сәләте, сәхнәдәге мөлаемлыгы аны Казанның күренекле актрисалары рәтенә күтәрә, сәхнәдәге һәр чыгышын театр тормышында зур вакыйга итә. Актрисаның, Ваня Солнцев («Полк улы», В.П.Катаев), Саша Бутузов («Өйгә кайтасым килә!», С.В.Михалков) кебек яшүсмер малай рольләрен башкарып, сугыш дәһшәтләрен күреп яраланган сабый йөрәгенең үзәк өзгеч әрнүен үтемле итеп җиткерә белүе тамашачыда көчле тәэсир калдыра. Ватаны хакына гомерен фида кылган халык героинясы — Зоя образы («Дөреслек турында әкият», М.И.Алигер) аша актриса зур эпик куәткә ирешә. Надя («Черкизоводагы кечкенә йорт», А.Н.Арбузов), Таня («Әкият», М.А.Светлов), Катя Татаринова («Ике



М.П.Н е м е н к о - Б а б к о в с к а я Луиза ролендә («Мәкер вә мәхәббәт», Ф. Шиллер; сулда — В.А. Чернецкий).

капитан», В.А.Каверин романы буенча), Машенька (А.Н.Афиногеновның шул исем. әсәре буенча), Людмила, Наташа («Аның дуслары», «Тормыш сәхифәләре», В.С.Розов), Клавдия Михайловна («Чын кеше», Б.Н.Полевой романы буенча) рольләрендә Н.-Б., героиняларын үз карашлары яклаганда рухи ныклык, тәвәккәллек, хис-тойгыларында сафлык, хезмәткә тугрылык б-н сугарып, замандаш хатын-кызларның идеаль образларын гәүдәләндерә. Үтә калку пафосны да ул ышандырырлык һәм җитди итеп җиткерә белә. Образның тормыштагыча төгәллеген игътибар үзәгенә алып, героиняларын көнкүреш чынбарлыгыннан өстен куя, аларның рухи байлыкларын ассызыклап яктырта белә. Актриса классик репертуар рольләрендә дә иң элек образның рухи асылын ачарга омтыла. Н.-Б. башкарган Катерина, Верочка, Людмила, Полина («Яшенле яңгыр», «Шаяннар», «Кичеккән мәхәббәт», «Төшемле урын», А.Н.Островский), Аня («Чия бакчасы», А.П.Чехов), Татьяна («Мещаннар», М.Горький), Луиза, Амалия («Мәкер вә мәхәббәт», «Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Козетта («Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча), Бәләкәч Доррит («Явыз дөнья», А.Я.Бруштейн) образлары гадәттән тыш бай эчке дөньялары, хис-кичерешләр бөеклеге, намуслылыклары б-н аерылып тора. Актриса ш.у. әкият-спектакльләрдә шактый танылган Герда («Кар патшасы турында әкият», Е.Л.Шварц), Алёнушка («Финист Ясный Сокол», Н.Я.Шестаков) образларын да иҗат итә. Соңгы елларда олы яшьтәге характерлы хатын-кыз рольләрен башкара: Огудалова, Глумова («Бирнәсез кыз», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Федосья («Соңгылар», М.Горький), Фру Сетерген («Пеппи Озыноек», А.Линдгрен). 1944 тә ике ай дәвамында Казан артистлары бригадасы составында 3 нче Балтыйк буе фронты сугышчылары өчен концертларда катнаша.



М.П.Н е м е н к о - Б а б к о в с к а я Наташа ролендә («Тормыш сәхифәләре», В.С.Розов; уңда — Борис Богатырёв ролендә В.А.Чернецкий).

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Б л а г о в Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**«НЕ́МЕЦ ШВЕЙЦА́РИЯСЕ»**, 19–20 йөзләрдә Казанның төньяк-көнчыгыш читендә, Казансу елгасының агачлык б-н капланган таулы сулъяк ярында, Подлужный бистәсе һәм «*Рус Швейцариясе*» артында урнашкан ял итү урыны. Иң беренче булып бу урынга Казан ун-тында укытучы чит ил галимнәре игътибар итә. «Казанские губернские ведомости» г-тасы 1843 елда болай дип яза: «Кайчандыр университетта физика укыткан танылган идиллист, швейцарияле Ф.К.*Броннер* бу тирәлекнең Колумбы булган һәм аны үз ватаны исеме белән атаган диләр». И.Ф.Эрдманның «Россия турында мәгълүматлар» («Сведения о России») китабына урнаштырылган Казанның 1822 елгы планында «Н.Ш.» юк, ул тагын ун елдан соң гына пәйда була. М.С.Рыбушкин 1830 елларда Казанда «евангелистлардан булган һәм, гомумән, чит илдән килгән 300 ләп кеше яши» дип күрсәтә; «гыйльми дәрәҗәгә яки аерым һөнәргә ия бу ят кавем үзара тыгыз элемтәдә тора. ...Аларның бәйрәм итә торган урыннары бар, гап-гади кыргый табигатькә ... чәчәк түтәлләре һәм беседкалар белән бизәп, ямьле бакча рәвеше бирелгән. ...Чит ил кешеләренең тырышлыгы белән барлыкка китерелгән һәм немец дачасы дип атала башлаган бу бакча соңгы вакытта җәй өчен иң яхшы күңел ачу урыны санала. Бездәге чит ил вәкилләре бәйрәм саен һәм еш кына атна арасында да нәкъ менә шунда җыела» («Казан шәһәренең кыскача тарихы» — «Краткая история города Казани», 1834). Немецлар тарафыннан ял итү-күңел ачу өчен сайлап алынган бу урын Казан ун-ты профессоры Л.Л.Фогель шунда дача төзеткәч танылу ала. 1828 дә ул «Подлужный бистәсе артындагы, чишмәгә якын урыннан 3627 кв. сажинлы буш җир кишәрлеген» вакытлыча — 12 елга файдалануга бирүләрен үтенеп, Казан думасына мөрәҗәгать итә. Ул «кайбер җәйге корылмаларны халыкка күңел ачу, кайберләрен медицина тәҗрибәләре уздыру — чишмә суының үзлекләрен өйрәнү урыннары итеп кулланырга» ниятли. Фогель чишмә суының дәвалау үзлекләрен ачарга өметләнә, әмма әлеге чишмәнең суы, яхшы сыйфатлы булса да, гадәти су булып чыга. Проф. Фогельның үтенече җавапсыз кала, ләкин бу урынны ошаткан профессор анда дача кордыра: йорт һәм карета сарае салдыра, үз куллары б-н кечкенә урман хасил итәрлек итеп каен һәм нарат утырта, бакча юллары ясата, беседкалар төзетә, яшелчә үстерү өчен аерым кишәрлек калдыра. Фогель янәшәсенә кунакханә хуҗасы Геделер килеп урнаша (берничә елдан әлеге дачалар аптекарь Грахе һәм гимназия директоры Крелленберг карамагына күчә). 1835 тә Фогель зур мәйданлы җир кишәрлегендә (5 дис. 3112 кв. сажин) рөхсәтсез төзү эшләре алып баруына аңлатма бирү өчен думага чакыртыла. Думадагы очрашу нәтиҗәсе билгеле түгел (1852 дә әлеге җирне 12 елга арендага бирү, 1864 тә аренда срогын 12 елга озайту турында контрактлар төзелә). Немецлардан агачларны кисмәскә вәгъдә алына, шуның нәтиҗәсе буларак, яр өстендәге юкәлек саклап калына. Куаклык-чытырманлыктан чистартылган, тәртипкә китерелгән «Н.Ш.» 19 йөз ахырында немецларның дача колониясенә әверелә, әмма аны алга таба үстерү омтылышлары сүнүгә бара. 1910 да Казан шәһәр идарәсе, шәһәрнең «Н.Ш.» урман-паркындагы дача хуҗалыгын җәйга салу мәсьәләсен күтәреп, «Н.Ш.» терр-ясен вак кишәрлекләргә бүләргә һәм арендага таратырга дигән тәкъдим кертә (карар үтәлми кала). «Красная Татария» г-тасы 1925 нең 24 март санындагы «Шәһәр бакчалары һәлакәте» («Гибнут сады в городе») мәкаләсендә: «Швейцариядән истәлекләр генә калды», — дип яза. 1932 дә Казанда А.М.Горький исем. Үзәк мәдәният һәм ял паркы төзелә башлый һәм «Н.Ш.» аның составына кертелә.

*Әд.:* П о н о м а р ё в П.А. О начале «Немецкого гулянья» в Казани // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1895. Т. 12, вып. 6.

*А.В.Гарзавина.*

**«НЕ́МЕЦЛАРНЫҢ КОНТРРЕВОЛЮЦИО́Н-ФАШИ́СТИК ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́** («Братство в нужде» оешмасы бүлекчәсе), 1937 елда НКВД органнары тарафыннан оештырылган, бер төркем кешене «Братство в нужде» немец-фашистлар оешмасы б-н элемтәдә булуда, Совет хакимиятенә карата канәгатьсезлек тудыру һәм колхоз-совхозларны таркату өчен төрле уйдырмалар уйлап чыгаруда гаепләү эше. Әлеге эш буенча Россия немецлары А.А.Гельцер, А.К.Финк, П.Л.Вебер хөкемгә тартыла. Мәхкәмә утырышы 1937 нең 28 октябрендә Казанда уздырыла. Гаепләнүчеләр үлем җәзасына хөкем ителә (соңыннан карар озак срокка төрмәгә ябылу б-н алыштырыла). 1957 дә ТАССР Югары мәхкәмәсе президиумы карары б-н, гамәлләрендә җинаять составы булмау сәбәпле, гаепләнүчеләр аклана.

**«НЕ́МЕЦЛАРНЫҢ СОВЕ́Т ХАКИМИЯТЕНӘ́ КАРШЫ́ ФЕТНӘЧЕ́Л ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́** («Кара Рейхсвер»), 1942 елда НКВД органнары тарафыннан оештырылган, бер төркем тоткынны «Волжлаг» терр-ясендә (Зөя шәһәре) контрреволюцион немец-фашистлар төркеме туплап, кораллы чыгышлар, тылда диверсияләр әзерләүдә гаепләү эше. 59 кеше хөкемгә тартыла, ш.и. А.А.Тейхриб, Е.П.Анкудинов, М.П.Гельман, П.Я.Классен, А.А.Рам, Я.И.Шнейдер, Н.А.Эде. Мәхкәмә утырышы 1942 нең 12 декабрендә Мәскәүдә уздырыла. 54 кеше үлем җәзасына, калганнары, балигълык яшенә җитмәү сәбәпле, 10 ар елга лагерь хезмәтенә хөкем ителә.

**НЕМЧИ́НОВКА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 171,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 26, 1880 дә — 135, 1897 дә — 134, 1913 тә — 177, 1920 дә — 159, 1926 да — 218, 1938 дә — 222, 1949 да — 186, 1958 дә — 155, 1970 тә — 105, 1979 да — 78, 1989 да — 31, 2002 дә — 34 кеше.

**НЕНА́ШЕВА** Елена Ефимовна (4.12.1963, Ижевск ш.), драма актрисасы, педагог, ТРның халык артисты (2007). 1986 елда Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, Казан яшь тамашачылар театры труппасына кабул ителә. Ул анда П.Корнель пьесасы буенча «Сид» спектаклендә Химена, Е.Л.Шварц пьесасы буенча «Аждаһа» спектаклендә Эльза һәм А.М.Галин пьесасы буенча «Иртәнге күктә йолдызлар» спектаклендә Лоран кебек төп рольләрне башкара. Әлеге рольләр актрисаның зур эмоциональ көчкә һәм психологик тирәнлеккә ия образлар иҗат итәргә сәләтле булуын күрсәтә. 1989 да, М.А.Булгаковның «Мастер һәм Маргарита» романы буенча куелачак спектакльдә Маргарита ролен башкару өчен, Н. Казан Зур драма театрына чакырыла. Аннан соң иҗат иткән Мария («Мария Стюарт», Ф.Шиллер), Беатриче («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Войницкая («Утардагы үлем», А.П.Чеховның «Платонов» пьесасы буенча), Изабелла («Замокка чакыру», Ж.Ануй), Маргарита Готье («Камелияле ханым», А.Дюма-улы) образлары аны труппаның әйдәп баручы актрисалары рәтенә чыгара. «Театр-99»да уйнаган Лолита (В.В.Набоковның шул исем. романы буенча Э.Олби пьесасы), Юлия («Фрёкен Юлия», Ю.А.Стриндберг) рольләрендә Н. сәләтенең яңадан-яңа үзенчәлекләре ачыла. Актриса Казан Зур драма театры сәхнәсендә Марья Антоновна («Ревизор», Н.В.Гоголь), Липочка («Банкрот», А.Н.Островский), Наталья Петровна («Авылда бер ай», И.С.Тургенев), леди Мильфорд («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер), Голда («Түбәдәге скрипкачы», Д.Стайн) рольләрен башкара. 2002 дә яңадан Казан яшь тамашачылар театрына кайта, анда ул Тойбеле («Тойбеле һәм аның иблисе», И.Б.Зингер, И.Фридман), Люсьена («Орфей», Ж.Ануйның «Эвридика» пьесасы буенча), Кормилица («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир) рольләре б-н сәхнәгә чыга. Н. — киң иҗат диапазонына ия актриса; ул драматик рольләрне дә, көчле характерлы һәм комик рольләрне дә бер үк дәрәҗәдә ышандырырлык итеп башкара. Бер үк вакытта телевизион программалар алып бара. Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында һәм Казан театр уч-щесендә укыта.

*Ю.А.Благов.*



Е.Е.Ненашева.

**НЕОГЕ́Н СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, неоген, *кайнозой эратемасының* (*эрасының*) урта системасы. Палеогеннан соң, *дүртенчел система* (*чор*) алдыннан килә. 24,6 млн. еллар элек башланган, 1,6 млн. ел элек тәмамланган. 2 бүлеккә аерыла: түбән — миоцен (19,5 млн. ел дәвам итә, Татарстан терр-ясендә күп өлеше юк) һәм югары — плиоцен (якынча 3,5 млн. ел). Инглиз геологы Ч.Лайель тарафыннан билгеләнә (1833). Н.с.(ч.) утырмалары барлык континентларда һәм океан төпләрендә таралган. Бу чор ахырында хәзерге рельефның һәм гидрочелтәрнең төп билгеләре формалаша, Альп, Карпат һ.б. тау системаларының барлыкка килүе тәмамлана. Н.с.(ч.) өчен климатның шактый салкынаюы (Антарктида һәм Гренландия боз капламы хасил булу) һәм җылынуының чиратлашуы хас. Үсемлекләр дөньясында төп рольне хәзерге чор үсемлекләре уйный. Миоценның башлангыч чорының 2 нче яртысында Евразиядә — хортумлылар (мастодонтлар) һәм атсыманнар, Н.с.(ч.) ахырында мамонтлар, сарыкүгезләр һ.б. килеп чыга. Неоген диңгезләрендә иң гади төзелешлеләр (фораминифералар, радиолярияләр, ике кабырчыклы моллюсклар), кысласыманнар, сөякле һәм кимерчәкле балыклар, су имезүчеләре тарала.

Хәзерге Татарстан терр-ясе Н.с.(ч.)нда рельефы ачык чагылган коры җирне тәшкил итә: Идел, Кама, Вятка һәм Агыйдел төп елга системаларына нигез салына һәм алар үзләренең үсешен башлыйлар, бу чорда аларның тугайлары шактый батынкы була. Плиоценның 2 нче яртысында бу терр-ягә үзән батынкылыклары буенча Акчагыл диңгезе сулары керә (бассейн утырымнары Кама һәм аның кушылдыклары үзәннәрендә, Вятканың сулъяк яры буенда, Иделнең аның б-н Мишә арасындагы үзәннәрендә һәм күп кенә башка урыннарда табыла). Татарстан терр-ясендә Н.с.(ч.) утырмалары киң таралган, төче (түбән һәм югары горизонтлар) һәм тозлы сулы (урта өлеше) токымнардан гыйбарәт. Н.с.(ч.)ның аеруча борынгы катламнары (6 млн. ел) Татарстан терр-ясендә бүлгәләнмәгән (понт һәм киммерий яруслары), аллювиаль ком вак чуерташ, чуерташ һәм балчык катламлы вакланган таштан тора. Сидерит конкрецияләре, органик калдыклар, нарат, чыршы һәм җылы яратучан үсемлекләрнең споралары һәм серкәләре, моллюсклар очрый. Неогенның югары өлешендәге утырмалар (Акчагыл) киң таралганнар һәм ком, комташ, вак чуерташ, чуерташ, торф һәм балчыктан торалар, соңгыларында пирит, сидерит, вивианит кушылмалары, ә Балык Бистәсе р-нында 0,5 *м* га кадәр калынлыктагы күмер катламы күзәтелә. Нигездә, күпчелекне юкә, карама, каен, имән тәшкил иткән караңгы ылыслы нарат-чыршылы тай-





Е.Е.Н е н а ш е в а : 1. Тойбеле («Тойбеле һәм аның иблисе», И.Б.Зингер, И.Фридман); 2. Маргарита («Мастер һәм Маргарита», М.А.Булгаков; сулда – Коровьев ролендә Ф.М.Пантюшин) рольләрендә.

га өстенлек иткән. Плиоценның калынлыгы 310 *м* га кадәр, яше 4–1,83 млн. ел. Неогенның файдалы казылмалары: бентонит, керамзит һәм кирпеч балчыклары, кварц һәм кварц-глауконит комнары, вивианит, торф, көрән күмер. Ком һәм вак чуерташ кушылмасы — җир асты су чыганаклары өчен яхшы коллектор.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**НЕОКЛАССИЦИ́ЗМ**, 20 йөз башы сәнгатендә, ш.и. архит-расында сәнгать стиле. Н.га антик, яңарыш һәм классицизм сәнгатьләре традицияләренә мөрәҗәгать итү хас. Н. 1900 елларда классик традицияләр нигезендә *модернның* ретроспектив агымнары рәвешендә барлыкка килә. Аның тууы каршылыклы чынбарлыкка «мәңгелек» эстетик кыйммәтләрне каршы куярга омтылу б-н бәйле. Архит-рада Н.ның 3 чорын билгелиләр: 1 нче чор — якынча 1910–1920 еллар уртасы; 2 нче чор — башлыча, 1930 еллар; 3 нче чор — 1940 еллар ахыры — 1950 еллар башы. 1 нче чорда классик формалар лаконизмы эклектизм архит-расының стилистик башбаштаклык б-н кирәгеннән артык бизәлешенә һәм модерн стиленә каршы куела (Франциядә О.Перре һәм Т.Гарнье, Германиядә П.Беренс, Австриядә А.Лоз һәм О.Вагнер, СССРда И.А.Фомин һәм В.А.Щуко һ.б. иҗаты). 1930 елларда Н.ның артык зурайтылган һәм монументаль формалардагы чаралары (портиклар, гөмбәзләр, ротондалар һ.б.) Италия (М.Пьячентини һ.б.), Германия (П.Л.Трост һ.б.), Сов. Союзы архит-расында әлеге дәүләтләр идеологиясен пропагандалауга хезмәт итүче корылмалар төзү өчен файдаланыла. Казанда Н. Дәүләт банкы (к.*Милли банк*), Сапожниковның сәүдә йорты һ.б. биналарда гәүдәләнеш таба. Н. стилендә Казанда архитекторлар Л.К.*Хрщонович*, И.Н.*Колмаков*, В.А.*Трифонов* эшли. ТАССРда 1930 елларның 2 нче яртысы — 1950 еллар башы архит-расында Н. принциплары болгар-татар һәм Шәрекъ архит-расы үрнәкләре б-н тулылана. 1940 еллар ахыры — 1950 еллар совет архит-расындагы Н. (кайвакыт аны «Сталин ампиры» дип атыйлар) Казанда *Татар опера һәм балет театры*, «Победа» кинотеатры биналарында һ.б.да чагыла. Совет Н. стилендә Казан архитекторлары И.Г.*Гайнетдинов*, Г.И.*Солдатов*, П.А.*Саначин*, Ә.Г.*Бикчәнтәев*, М.К.*Игъламов*, Р.М.*Мортазин* һ.б. эшли.

*Х.Г.Надыйрова.*

**НЕОЛИ́Т** (грек. néos — яңа һәм líthos — таш), яңа таш гасыр, таш гасыр дәверен тәмамлаган, үзләштерүче хуҗалыктан (җыючылык, аучылык) җитештерүче хуҗалыкка (игенчелек, терлекчелек) күчү чоры (якынча б.э.к. 8–3 нче меңьеллыклар). «Н.» термины фәнни әйләнешкә инглиз археологы Дж.Леббок тарафыннан кертелә (1865). Н. дәверендә хуҗалык алып баруның яңа формалары — игенчелек һәм терлекчелек барлыкка килә, кешеләр балчык савыт-саба, тишү, шомарту юлы б-н һ.б. техник алымнар кулланып тагын да камилрәк эш кораллары ясарга өйрәнәләр, эрләү һәм туку б-н шөгыльләнәләр. Евразиянең көньяк зонасындагы иң борынгы неолитик ядкәрләр б.э.к. 8 нче меңьеллыкка карый; б.э.к. 7–6 нчы меңьеллыкларда ул җирләрдә бакырдан эшләнгән беренче әйберләр барлыкка килә. Игенчелек һәм терлекчелекнең яралуы көньяк төбәкләр өчен Н. ка күчүнең төп критерие булып санала. Төньяк-көнчыгыш Евразиянең төньяктагы урманлы р-ннарында бу күчеш комплекслы үзләштерүче хуҗалыкның — аучылык, балыкчылык һәм җыючылыкның катлаулы үсеше шартларында бара (якынча б.э.к. 5–3 нче меңьеллыклар). Урман зонасындагы неолитик кабиләләрнең таштан кораллар ясау индустриясендә чакматаш эшкәртүнең мезолитик алымнары саклана, шул ук вакытта эш коралларының төрләре күбәя һәм таш эшкәртүнең яңа техникасы (шомарту, тишү, тоташ сөзәк итеп эшкәртү һ.б.) барлыкка килә. Агач йортлар, төрле хуҗалык кораллары, терлек абзарлары, балыкчылык һәм аучылык максатында читән-киртәләр кору өчен кирәкле



Неолит чоры керәче.

агач эшкәртү кораллары — балта, өтерге, аркылы балталар һ.б.ның әһәмияте шактый арта. Н. чорында ш.у. махсус кораллар — ике яклап тоташ сөзәкләп китеп ясалган ук һәм дротик очлыклары, күбесенчә йомры төпле, ярымйомырка һәм казан рәвешендәге бизәкләр төшерелгән балчык савыт-саба барлыкка килә.

Татарстан терр-ясендә Н. ядкәрләре өч төркемгә бүленә. 1950 еллар башында О.Н.Бадер тарафыннан Каманың югары һәм урта агымы буйларында табылган материаллар буенча бүлеп чыгарылган *Чулман культурасы* ядкәрләре, башлыча, Идел һәм Каманың тугай-үзәннәрендә, аларның зур кушылдыкларының тамакларында тупланган (иң эре туктаулыклар: Алексеев р-нында — I һәм II Лебедино, Апас р-нында — II Кабык Күпер, Тукай р-нында — II Дубовая Грива, Минзәлә р-нында — Игим һәм II Золотая Падь, Актаныш р-нында — Рус Әҗбие). Бу культура торулыклары, күбесенчә төркемнәр хасил итеп, болынлыклар янындагы комлы дюналарда, елгаларның иске юллары һәм күлләр буенда урнашкан. Халык яртылаш җир өстенә күтәртелгән, турыпочмаклык рәвешендәге зур корылмаларда яшәгән, бу корылмалар эчендә учаклар һәм хуҗалык чокырлары урын алган. Таш кораллар ясау индустриясенә чакматашны яру-эшкәртүдә яссы кисәкләр телеп алу техникасы кулланылу, телемнәрнең читләрен өлешчә китеп төшерү һәм агач эшкәртү коралларының шактый күп булуы хас. Бигрәк тә пычаклар, кыргычлар, өтергеләр, аркылы балталар киң тарала, ук һәм сөңге очлыклары сирәгрәк очрый. Керәч әвәләп ясалган (измәсенә шамот һәм вак ком кушылган) йомры төпле, бизәкләр төшерелгән казан һәм ярымйомырка формасындагы зур балчык савытлардан гыйбарәт. Гадәттә, бизәк савыт-сабаның барлык өслегенә вак һәм уртача зурлыктагы тешле эзләр рәвешендәге штамп б-н төшерелгән (башлыча, бизәкләр үрүнең төрле вариантларын чагылдыра). Савытларны ясау технологиясе, аларның формалары һәм орнамент типлары әлеге савыт-сабаны иң элгәреге неолитик керәч буларак билгеләү мөмкинлеге бирми. Халык күбесенчә аучылык, балыкчылык, җыючылык б-н шөгыльләнгән (Башкортстандагы Муллино торулыгында терлекчелек эзләре табыла). Чәнчеп-сызып ясалган бизәкле савыт-сабалы ядкәрләр икенче төркемгә карый. Кама Тамагы төбәгендәге һәм Иделнең урта агымы буендагы Н. чоры ядкәрләрендәге таштан кораллар эшләү индустриясе форма-типологик сыйфатлары буенча Чулман культурасына тартым. Әйберләр җыелмасында, балта, өтерге һәм аркылы балталардан аермалы буларак, пластиналардан эшләнгән кораллар өстенлек итә. Керәч әвәләп ясалган юка стеналы, яссы төпле, бизәкле балчык савыт-сабалардан гыйбарәт. Бизәкләр таякчык ярдәмендә төшерелгән; кояшсыман мотивлы бизәлешле савытлар да очрый. Ядкәрләрнең бу төркеменең этномәдәни асылы хәзергәчә бәхәсле булып кала; керәч эшләнмәләрнең форма-типологик билгеләре буенча ул көньяк (Каспий буйларының төньягы һәм Иделнең түбән агымы) һәм көньяк-көнбатыш (Днепр-Дон) культураларга якын тора. Иделнең сул ярында Казан янында һәм Зөянең түбән агымы буенда табылган *Балахна культурасы* ядкәрләре өченче төркемне тәшкил итә.

*Әд.:* Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Г а б я ш е в Р.С. Население Нижнего Прикамья в V–III тысячелетиях до нашей эры. К., 2003.

*Р.С.Габәшев.*

**НЕОЛОГИ́ЗМНАР** (грек. néos — яңа һәм lógos — сүз, тәгълимат), яңа предметларны һәм төшенчәләрне белдерү өчен барлыкка килгән яңа сүзләр. Татар телендә килеп чыгышы ягыннан Н. лексик һәм семантик төрләргә бүленә. Лексик Н. телнең сүз ясагыч чаралары ярдәмендә барлыкка килә: кушымчалар ялгау (омон**чы**, хәбәрдар**лык**), нигезләрне кушу (кул+чатыр — зонтик, ил+башы — дәүләт башлыгы), аббревиацияләр (Татар иҗтимагый үзәге — ТИҮ) һ.б. Мондый Н.га башка телләрдән *алынмаларны* да кертеп карыйлар: брокер, саммит, хакер һ.б. Семантик Н. иске сүзләргә яңа мәгънә өстәлеп ясала (юллама, бергәлек). Галимнәр, язучылар, шагыйрьләр һ.б. тарафыннан уйлап табылган индивидуаль-автор Н.ы да билгеле: мәс., «Мин Марстан, тик марсиян түгел, // Мин **җирский**, Тузан бер, бала»

(Р.Гатауллин). Алар, гадәттә, киң таралыш алмый.

*Әд.:* Мөхиярова Р.Х. XX гасырның 80–90 нчы елларында татар әдәби теле лексикасы. Яр Чаллы, 2000; Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. К., 2001; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

*Р.Х.Мөхиярова.*

**НЕОМЕ́ТОВ** Ибраһим Камалетдин улы (16.12.1880, Сембер губ. Коромысловка а. — 1944, Казан), сәясәт, хуҗалык эшлеклесе. 1905–07 еллардагы Рев-циядә катнаша (Чита ш.). Красноярск тимер юл уч-щесен тәмамлый (1899). 1896–1906 да Себер һәм Байкал аръягы тимер юллары эшчесе. Шул чорда актив революцион эшчәнлек алып бара, шуңа күрә берничә тапкыр кулга алына. Читада кораллы күтәрелеш әзерләүдә катнашканы өчен 1905 тә читтән торып үлем җәзасына хөкем ителә, аны тотып бирүгә зур күләмдә акча билгеләнә. 1917 гә кадәр Н. полиция эзәрлекләвеннән яшеренеп яши. 1917–18 дә Бурея округы (Амур өлкәсе) комиссары, соңрак тау эшчеләре башкарма ком-ты рәисе. 1920 дән Благовещенск шәһәрендә, өлкә башкарма ком-ты секретаре, өлкә ХХС рәисе, пыяла з-ды җитәкчесе. 1925 тә Башкортстан АССР ХХС рәисе урынбасары, соңрак Башкортстанның тау эшләре тресты рәисе. 1927 дән ТАССР ХХСның азык-төлек тресты, М.Вахитов исем. 1 нче сабын, шәм һәм химия з-ды директоры. Завод каршындагы Югары техник уку йортын оештыручыларның берсе һәм аның беренче ректоры (1930–33). Татарстан май сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. 1932–33 тә киноплёнка ф-касы төзелеше башлыгы (Казан), 1934–37 дә БҮБК Президиумы каршындагы ТАССР Вәкиллегенең тулы вәкаләтле вәкиле. 1937 дә, улы Ю.И.*Неометов* кулга алынганнан соң, вазифасыннан читләштерелә һәм Үзбәкстанга хуҗалык эшенә җибәрелә. 1941 дән Уралда яши, 1944 тә Казанга күченә. Татарстанның Соц. Төзелеш Батыры.

*Әд.:* Ключевич А.С. История Казанского жирового комбината имени М.М.Вахитова (1855–1945). К., 1950; Назипова К.А. Неометов Ибрагим Камалетдинович (1880–1944) // Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974.

*К.А.Нәҗипова.*

**НЕОМЕ́ТОВ** Юнис Ибраһим улы (25.3.1903, Чита ш. — 27.9.1972, Казан), сәнәгый җитештерүне оештыручы. И.К.*Неометовның* улы. Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесендә укый. 1918 елда Благовещенск машиналар төзү з-дында (Амур өлкәсе) слесарь өйрәнчеге. 1919–23 тә елга һәм диңгез флоты судноларында майлаучы, машинист ярдәмчесе булып эшли. 1923 нең июнендә Омск шәһәрендәге хәрби-сәяси мәктәпкә укырга җибәрелә, аны тәмамлаганнан соң, Иркутск шәһәре янында урнашкан полк политругы итеп билгеләнә. 1924–26 да Баймак металлургия з-дын (БАССР) торгызуда катнаша, 1926 да М.Вахитов исем. 1 нче номерлы сабын кайнату, шәм һәм химия з-ды директоры урынбасары; шул ук елда Васильево «Победа труда» пыяла з-ды директоры итеп билгеләнә. 1928–30 да — «Кызыл текстильче» киез итек ф-касы (Кукмара), 1930–32, 1946–52 дә В.И.Ленин исем. җитен ком-ты директоры. 1932–34 тә ТАССР җиңел сәнәгать халык комиссары урынбасары. 1934–37 дә Яшел Үзән суднолар төзү з-ды директоры. 1937 дә әләк буенча уң троцкийчылар төркемендә катнашуда гаепләнеп кулга алына. 1940 та, җинаять составы булмау сәбәпле, азат ителә. 1940–42 дә «Урак һәм чүкеч» з-ды директоры. 1952–54 тә «Гражданстрой» төзелеш трестында (Чистай) эшли. Н.ның турыдан-туры катнашында пр-тиеләрнең төп куәтләре төзелә һәм реконструкцияләнә, төп технол. процесслар камилләштерелә. Кадрлар әзерләүгә, хезмәткәрләрнең эш һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга, җитештерүнең алдынгы алымнарын гамәлгә кертүгә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә зур игътибар бирә. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Анисимов Н.Г. Казанский льнокомбинат. К., 1960; шул ук. Огни над Волгой: Очерк истории Васильевского стеклозавода «Победа труда». К., 1967; Назипова К. Неометов Юнус Ибрагимович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*Г.Я.Мәүлетова, К.А.Нәҗипова.*

**НЕОТЕКТО́НИК ХӘРӘКӘТЛӘ́Р** (иң яңа тектоник хәрәкәтләр), җир кабыгының кайнозойда башланган (24–26 млн. ел элек) һәм бүгенге көнгә кадәр дәвам итүче тектоник үзгәрешләре. Башка тектоник хәрәкәтләр б-н бергә Н.х. Җирнең хәзерге рельефының төп үзенчәлекләрен формалаштыралар. Рус геологы В.А.Обручев тарафыннан тектониканың мөстәкыйль бүлеге буларак билгеләнә (1948). Н.И.Николаев тектоник хәрәкәтләр көчәюенең неоген-дүртенчел этабын күрсәтә, аны Җир үсешенең иң яңа этабы дип атый һәм башлангычы итеп эоцен-олигоцен чиген алуны тәкъдим итә (1950). Н.х.нең теоретик бурычларын хәл итү гамәли мәсьәләләрне чишү б-н тыгыз бәйләнештә: озак вакытка исәпләнгән корылмаларны проектлаштыру, су б-н тәэмин итү, чыганаклар эзләү, җир тетрәүләрен алдан әйтү һ.б. Татарстан терр-ясендә Н.х. анализы, аерым алганда, атом электростанциясе төзелешен дәлилләү максатында үткәрелә. Н.х. кайнозойның геол. тарихында, хәзерге һәм күмелгән рельефларда, гидрографиядә, елга челтәре төзелешендә, гидрогеол. шартларда, геофизик һәм геодезик параметрларда, сейсмиклыкта һ.б.да чагыла. Татарстан терр-ясендә 1 нче тәртиптәге (кечерәк тәртиптәге структуралар б-н катлауланган) эре 7 неотектоник структураны аерып күрсәтәләр: чагыштырма күтәрелгән Көнбатыш (Идел алды) өлкәсе, Вятка зонасының көньяк чигендәге күтәрелеш, Идел аръягы бөгелеше, Татар гөмбәзенең Көньяк һәм Төньяк күтәрелешләре, Урта Кама валсыман күтәрелешләр зонасы, Югары Кама иңкүлеге. Бу зона чикләрендә неотектоник кузгалулар төрле көч б-н барган. Уртача амплитудасы 500 *м* га кадәр булган һәм 200 *м* чиккә җиткән эрозион киселешле аеруча әһәмиятле күтәрелешләр Татарстанның көнбатыш өлешендә — Карлы елгасы р-нында (Буа р-ны Ямбулат а.) башлангыч плиоценда һәм башлангыч миоценда була. Неоген-дүртенчел чорда барлыкка килгән кече тәртиптәге структураларга бөтен Идел һәм Кама буенда киң таралган уннарча метр амплитудалы вак җыерчыклык керә. Аның барлыкка килүенә рельефның эрозия б-н ергалануы шартларында пластик токымнарга тигезсез статик басым ясалу сәбәп була. Нәтиҗәдә, балчыксыл токымнар субүләрдән елга үзәннәренә кысып чыгарыла һәм алар дисгармоник җыерчыклар хасил итәләр, мәс., Тәтеш шәһәре янындагы җыерчыклар. Хәзерге заманда Татарстан терр-ясендә Н.х. елына 44 *мм* га кадәр тизлек б-н терр-янең аерым участокларының күтәрелүендә һәм иңүендә чагыла һәм, аеруча сусаклагыч зоналарда һәм җир кабыгының ярылган урыннарында, палеозойның карстланучы токымнарының юылуына һәм утыруына сәбәп була. Татарстан терр-ясендә, ш.и. Казанда кайбер урыннарда карст утырмалары елына уннарча миллиметр тәшкил итә. Аерым карст упкыннарының тирәнлеге һәм диаметры уннарча метрга җитә (к. *Акташ упкыны*). Татарстанда хәзерге заман Н.х.н һәм бер үк вакытта карст утырымнарын күзәтү «Татнефть» АҖнең Татарстан геол. разведка идарәсенең «Геодинамика» фәнни-җитештерү үзәге тарафыннан алып барыла. Ш.у.к. *Карст.*

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

*К.М.Мирзоев, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**НЕОТТИА́НТА** (Neottianthe), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 6 төре билгеле, Евразиянең уртача поясында таралганнар. Россиядә бер төре — калпаксыман Н. (N. cucullata) бар. ТР терр-ясендә Көнбатыш Кама алдында очрый. Нарат урманнарында үсә. 8–15 *см* биеклектәге, 2 калакка бүленгән шарсыман бүлбеле үсемлек. Сабагы нәзек, кабыргалы, аксыл-яшел төстә, 8–15 *см* биеклектә. Өске яфраклары — тар, ланцетсыман, аскылары — (сабак төбендә) — эллипссыман, кыска, очлы. Чәчәк төркеме — бер яклы йомшак чук. Чәчәкләре ачык алсу, сирәк кенә ак төстә, исе юк. Җимеше — тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Декоратив үсемлек. Югала баручы сирәк төр, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НЕПЛЮ́ЕВ КАДЕТЛА́Р КО́РПУСЫ**, Оренбург шәһәрендә, урта хәрби уку йорты, Россиядә мөселманнар өчен махсус беренче уку йорты. 1824 елның 2 февралендә император Александр I раслаган проект б-н 1825 нең 2 гыйнварында Неплюев хәрби уч-щесе буларак ачыла, 1844 тә кадетлар корпусы итеп үзгәртелә. Оренбургның беренче губернаторы И.И.Неплюев исеме б-н атала. Үзенең уставы була, Оренбург хәрби губернаторына буйсына, кыргыз, казак, башкорт, татар һәм төрле дәрәҗәдәге мөселман балаларын укыту өчен махсус билгеләнә, алар укучыларның яртысын тәшкил итәргә тиеш була. Беренче тапкыр 20 кеше укырга алына, уку срогы 6 ел була, 1844 тән 8 елга җитә. 1844–63 тә укучылар 2 эскадронга бүленә, беренчесендә дворян һәм казак балалары укый, икенче-



Оренбургта Неплюев кадетлар корпусы. Гомуми күренеш. 20 йөз башы фоторәсеме.

сендә, «азиатлар» эскадронында, 30 казакъ (кыргыз) һ.б. мөселманнар, нигездә, татар һәм башкорт балалары укый. Укыту хәрби түгел, ә гомуми белем бирү характерында була. Рус, татар, гарәп, фарсы телләре, матем., табигыять фәннәре, тарих, география, а.х., ислам нигезләре яки Илаһи Канун укытыла. Н.к.к. Оренбург губернасы һәм Казакъстан мөселманнары арасында рус телен таратуда, белем бирүдә әһәмиятле роль уйный. Н.к.к.н тәмамлаучы татар һәм башкортларның күбесе чиновник һәм офицерлар булып китәләр, ә кайберләре, ш.и. М.М.*Бикчурин* һәм С.Б.*Кукляшев* Казан ун-тына укырга керә, соңрак алар корпуста укыталар. 1864 тә Н.к.к. император Александр II нең хәрби реформасы б-н типовой уставлы һәм программалы уку йорты итеп үзгәртелә. Анда укырга керү өчен башлангыч мәктәп белеме һәм рус телендә иркен сөйләшү таләп ителә. Шәрекъ телләрен укыту туктатыла. Шул вакыттан монда бары тик аз санда гына мөселманнар, башлыча Н.к.к.н тәмамлаганнан соң хәрби уч-щегә укырга керүче затлы нәсел казакъ, башкорт һәм татар дворяннары балалары гына укый. 1918 дә ябыла.

*Әд.:* Оренбургский Неплюевский кадетский корпус как первое учебное заведение русского образования киргиз. Оренбург, 1896; Краткий очерк истории Оренбургского Неплюевского кадетского корпуса. Оренбург, 1913.

**НЕПОГО́ДИН** Иосиф Андреевич (14.1.1936, Чистай ш.), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (1998). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый, Россия Гадәти кораллар агентлыгы Федераль ДУП ФҖБнең Гамәли оптика ин-тында эшли, лаб. (1973 тән), бүлек башлыгы (1976 дан), өлкән фәнни хезмәткәр (1996 дан), баш фәнни хезмәткәр (2000 нән). Хезмәтләре лазер локациясе проблемаларына карый. Н. объектлар һәм фоннарның барлык төр чагылдыру характеристикаларын тикшерү алымнары комплексын һәм чараларын, лазерлы-локацион системалар сигналларының адекват мәгълүмати модельләрен эшли. Атмосфера тоныклану шартларында оптик сигналларны сайлап алу алымнарын тәкъдим итә. Статистик фотометрия һәм радиооптика карашыннан чыгып, лазерлы фотометриянең күп кенә нигезләмәләрен формалаштыра.

Х е з м.: О точности измерения временного положения сигналов методом выделения максимума при квазиоптимальной фильтрации // Радиотехника и электроника. 1969. Т. 14, № 3 (автордаш); Основные виды отражательных характеристик тел в направлении приёма и методы их измерения в оптике // Импульсная фотометрия. 1981. Вып. 7; Фасетно-лучевой метод расчёта энергетических отражательных характеристик объёмных тел // Радиотехника. 1984. № 4 (автордаш).

**НЕПРИМЕ́РОВ** Николай Николаевич (1.5.1921, Воронеж өлкәсенең хәзерге Бобров р-ны Анновка а.), физик, техник фән. д-ры (1963), проф. (1966), Казан ун-тының атказ. профессоры (2004). 1951 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоэлектроника каф. мөдире (1960–92), тирәлекләрдә дулкын процесслары лаб-ясенең баш фәнни хезмәткәре (1992 дән). Хезмәтләре магнитик һәм диэлектрик радиоспектроскопиягә, нефть чыганакларын эшкәртүгә, гетероген тирәлекләрнең физик динамикасына, Җирнең физикасына, биол., пед. мәсьәләләренә карый. Н. микродулкыннар полярлашу яссылыгының резонанслы парамагнитик әйләнүе күренешен ача (1953); деформацияләнүче күзәнәкчел тирәлектән бер сыеклыкны икенчесе б-н кысып чыгару хисабына нефть катламын оптималь эшкәртү технологиясен эшли һәм җитештерүгә кертә, бу технол. Татарстан нефть ятмаларын өстәмә эшкәртү проектларының нигезен тәшкил итә. Публицистик хезмәтләр, ш.и. социаль варислык (бер буын икенчесенә тапшыра торган төп белемнәр җыелмасы) программасы авторы. «Георесурсы» ж-лын гамәлгә куючыларның берсе һәм редколлегия әгъзасы (1999 дан инглиз һәм рус телләрендә чыга). Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальные исследования некоторых особенностей добычи парафинистой нефти. К., 1958; Трёхмерный анализ нефтеотдачи охлаждённых пластов. К., 1978; Геотермия областей нефтегазонакопления. К., 1983 (автордаш); Десятитомное собрание научных и литературных трудов. К., 2003–06.

*Әд.:* Николай Николаевич Непримеров: Учёный. Воин. Педагог: В 2 т. К., 2001–02.

**НЕПРЯ́ХИН** Гавриил Георгиевич (24.3.1896, Әстерхан ш. — 20.3.1980, Казан), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1923). Саратов ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1919), Саратов госпиталендә табиб-инфекционист, 50 нче Кызыл Тамань дивизиясе табибе. 1920 елдан Әстерхан мед. ин-тында, 1927–51 дә патологик анатомия каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы елларында Әстерханның фронт яны эвакогоспитальләрендә баш патологоанатом. 1951 дән Төньяк Осетия мед. ин-тының гистология каф. мөдире. 1959 дан Казан мед. ин-тының патологик анатомия каф. мөдире, 1967 дән ин-тның Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә морфология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре. Н. 1963 тә Казан патологоанатомнарының фәнни җәмгыятен оештыра. Хезмәтләре малярия, туберкулёз, үпкә ялкынсынуын анатомик-клиник өйрәнүгә, майлы күзәнәкләрне өйрәнү ысулларына карый.

Х е з м.: О тучных клетках нервной системы // Архив патологии. 1960. № 10; Об этиологии, патогенезе и патоморфологии самопроизвольной гангрены // Казан. мед. журн. 1970. № 5.

*Әд.:* Профессор Гавриил Георгиевич Непряхин // Казан. мед. журн. 1976. № 5.

**НЕПТУ́Н** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 67 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1949 да — 141, 1958 дә — 161, 1970 тә — 147, 1979 да — 129, 1989 да — 83, 2002 дә — 85 кеше.

**НЕРА́ТОВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 44 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Алпавыт Нератов йорты (19 йөз ахыры архит-ра истәлеге). 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Новоселье, Яңа Сәрәпәле, Югары Сәрәпәле исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, чана, тәгәрмәч ясау, итек басу б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, поташ з-ды була; 20 йөз башында чиркәү, земство мәктәбе (1910 да ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1216 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 214, 1870 тә — 278, 1913 тә — 645, 1920 дә — 943, 1926 да — 586, 1938 дә — 550, 1949 да — 402, 1958 дә — 356, 1970 тә — 309, 1979 да — 129, 1989 да — 50, 2002 дә — 48 кеше.

**НЕСМЕ́ЛОВ** Виктор Иванович (1.1.1863, Саратов губ., Саратов өязе Курдюм а. — 30.6.1937, Казан), философ, христиан теологиясе д-ры (1898). Саратов руханилар семинариясен тәмамлый (1883). Казан руханилар семинариясен тәмамлаганнан соң (1887), шунда ук логика һәм филос. кафедрасында эшли, проф. (1896). 1895 елда Н. Казан шәһәр думасында «Яңа Гаһед вәхиләрендә яшәү мәгънәсе мәсьәләсе» («Вопрос о смысле жизни в Новозаветном откровении») дигән темага ачык лекция укый. Анда Н.ның «Кеше турында фән» («Наука о человеке») исемле саллы хезмәтендәге төп идеяләре салынган була (1 т.: «Психологик тарих һәм тормышның төп мәсьәләләрен тәнкыйтьләү тәҗрибәсе» — «Опыт психологической истории и критики основных вопросов жизни», 1898; 2 т.: «Тормыш метафизикасы һәм христиан вәхие» — «Метафизика жизни и христианское откровение», 1902). 1913 тә Н.ка Казан руханилар академиясенең атказ. профессоры дәрәҗәсе бирелә, һәм ул надворный һәм коллегия советнигы чинына күтәрелә. 1921 дә академия ябылганнан соң, Н. Казан ун-тының психол. кафедрасына урнашырга тели, әмма аңа иҗтимагый фәннәр профессоры вазифасы бирүдән баш тарталар. 1931 нең июлендә



А.Н. Несмеянов.

«Казан чиркәүчеләре оешмасы»н төзүдә, ш.у. телгә алынган оешманы «Хак Православие Чиркәве» Бөтенсоюз чиркәү-монархия оешмасы үзәгенең ф-лы итеп үзгәртүдә һәм әлеге ф-лның советка каршы эшчәнлегендә якыннан катнашканы өчен кулга алына. Сорау алу беркетмәсендә: «өлешчә гаебен таныды», дип теркәлә, тиздән азат ителә. Рус дини философиясендә Н., асылда, беренчеләрдән кеше турындагы православие тәгълиматының бербөтен фәлсәфи интерпретациясен булдыра. Философ Н.А.Бердяев аның «Кеше турындагы фән»ен дини антропология төзелешендә үзенә күрә бердәнбер тәҗрибә дип бәяли. Н. үзенең тәгълиматын иң элек чынбарлыкны механик аңлау расланган, материализм һәм атеизм көчәйгән, мәдәни-цивилизация процессында матди омтылышлар киң колач алган шартларда христианлыкны саклау зарурлыгы б-н дәлилли. Н.ның дөньяга карашы үзәгендә Яңа Гаһед вәхие канун-нары буенча яшәүче, яшәргә тиешле һәм яшәячәк кеше феномены. Кеше феномены турындагы табышмак — кешенең үзендәге «физик» һәм идеаль шәхеснең фундаменталь дуализмы чагылышы ул. Кеше үзен «дөньяның гап-гади әйбере» итеп таный, аңа яраклашып яши, шул рәвешле кешедә «психик механизм» эшли башлый. Бер үк вакытта кешедә «психик организм» да гамәлдә; кеше, физик дөньядан аерылгысыз буларак, ирекле-гакыллы шәхес, шуңа карамастан, «үтә физик зат», табигатьтән өстен һәм асылы беркайчан үзгәрми торган, тере гыйлем. Н. концепциясендә ул бернинди шартлар б-н дә чикләнмәгән илаһи шәхес образы. Н. кеше шәхесе Аллаһка мөнәсәбәте буенча көзге түгел: шәхеснең тере эчтәлеге турыдан-туры «үз-үзендә яшәүче Аллаһ табигатен» ача дипраслый. Кеше турындагы табышмак призмасы, «үзенең тере гыйлеме» аша хәзерге заман кешесе физик дөньяның башка яшәеш ачышы булуын таныйрга, дөньяви процесслар картиналарын логик эзлеклелектә төзергә мөмкин — кеше кылган гөнаһ нәтиҗәсендә барлыкка килгән вакытлы физик дөнья кеше б-н бергә коткарылырга тиеш. Н., нигездә, христиан динен хисапсыз формулаларны хисапсыз ышану б-н кузаллау итеп түгел, бәлки безнең дөнья турындагы танып белүләребезнең барлык җыелмасын ап-ачык һәм тулысынча акылга муафыйк итеп аңлатырга омтыла, дини фикернең исә «философия ярдәмендә төпле фән җирлегенә» аяк басуын тели.

Х е з м.: Догматическая система св. Григория Нисского. К., 1887; Вера и знание с точки зрения гносеологии. К., 1913; Вопрос о смысле жизни в учении Новозаветного откровения // Русская философия: Конец XIX — начало XX века. СПб., 1993.

*Әд.:* Епископ Константин (Горянов). Жизнь и творчество В.Несмелова // Человек. 1992. № 2; К и н о с ь я н В.А. Загадка человека. К., 2006.

*В.А.Киносьян.*

**НЕСМЕ́ЛОВ** Евгений Андреевич (25.7.1936, Казан — 19.11.2007, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (2001). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлый. Россия Гадәти кораллар агентлыгы Федераль ДУП ФҖБнең Гамәли оптика ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1988 дән), баш фәнни хезмәткәр (2004 тән). Хезмәтләре юка плёнкалар физикасы һәм оптикасына карый. Н. махсус кулланылыш техникасы өчен вакуумлы юка оптик капламнар исәпләү алымнарын һәм программаларын эшли.

Х е з м.: Свойства зеркал: Аналит. обзор № 2723. К., 1980 (автордаш); Расчёт оптических постоянных тонких плёнок: Аналит. обзор № 4983. М., 1990 (автордаш); Интерференционные покрытия для оптического приборостроения. К., 2002 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НЕСМЕ́ЛОВ** Олег Владимирович (23.11.1930, Казан), тарихчы, сәясәт белеме галиме, тарих фән. д-ры (1974), проф. (1975), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1986), РФнең атказ. югары уку йорты хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1953). 1956–61 елларда Казан финанс-икътисад ин-тында, 1961 дән Казан вет. ин-тының марксизм-ленинизм, 1990 нан — иҗтимагый фәннәр, 1992 дән — гуманитар фәннәр, 1999 дан филос. һәм тарих кафедралары мөдире. 2005–10 да ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте ин-тының хокук, тарих һәм политология каф. профессоры. Хезмәтләре СССРның тышкы сәясәте мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Какого мирного сосуществования хотят идеологи империализма? М., 1964; Марксизм-ленинизм и стратегия мира: Проблема мира и марксистско-ленинской теории. К., 1970.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*В.А.Шагалов.*

**НЕСМЕ́ЛОВА** Ирина Михайловна (10.12.1934, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). 1957 елда Казан ун-тын тәмамлый, Россия Гадәти кораллар агентлыгы Федераль ДУП ФҖБнең Гамәли оптика ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1989 дан). Хезмәтләре каты җисем һәм ярымүткәргечләр физикасына карый. Н. Д.И.Менделеевның химик элементларның периодик таблицасындагы икеле һәм өчле ярымүткәргечләрнең электрофизик үзлекләрен тикшерә, кушылмаларның зоналы структурасы параметрларын билгели һәм аныклый, 4 пр-тие стандартын эшли, төсле металлургия пр-тиеләрендә ярымүткәргеч кристалларны аттестацияләү методикаларын гамәлгә кертә. Кечкенә үлчәмле һәм инерцияле, югары төгәллеккә ия булган темп-ра датчикларының макет үрнәкләрен булдыра. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оптические свойства узкощелевых полупроводников. Новосиб., 1992; Материалы для ИК приёмников излучения, альтернативные CdHgTe: обзор // Оптический журн. 2007. Т. 76, № 3 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НЕСМЕ́ЛОВА** Ольга Олеговна (13.9.1956, Казан), әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1982 елдан Мари, 1985 тән Казан пед. ин-тларында, 2000 нән Казан ун-тында эшли (2003 тән чит илләр әдәбияты каф. мөдире). Хезмәтләре 20 йөз Америка прозасына, Россиядә Американы өйрәнү тарихына, әдәбият процессында сәнгати һәм документаль күренешләрнең үзара тәэсир итешү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Пути развития отечественной литературной американистики. К., 1998.

**НЕСМЕЯ́НОВ** Александр Николаевич (28.8.1899, Мәскәү — 17.1.1980, шунда ук), химик-органик, элементорганик кушылмалар химиясе фәнни мәктәбенә нигез салучы, СССР ФА академигы (1943; 1939 елдан мөхбир әгъза), ике тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1969, 1979). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1922), шунда ук эшли: органик химия каф. профессоры (1935), мөдире (1944 тән), химия ф-ты деканы (1944–48), ректор (1948–51); Мәскәү ун-тының Ленин тауларындагы яңа бинасын проектлаштыру һәм төзүдә турыдан-туры катнаша. Бер үк вакытта СССР ФА учреждениеләрендә эшли: Ашламалар һәм инсектофунгицидлар фәнни-тикшеренү ин-тында (1930–34), Бөек Ватан сугышы елларында Казанга эвакуацияләнгән (1941–44) Органик химия ин-тында (1934 тән, 1939–54 тә директоры), Элементорганик кушылмалар ин-тын оештыручы һәм директоры (1954 тән; 1980 нән Н. исем.); СССР ФАнең Химия фәннәре бүлеге (1946–51), Гомуми һәм техник химия бүлеге (1961–75) акад.-секретаре, СССР ФА президенты (1951–61). Хезмәтләре металлорганик кушылмалар (МК) химиясенә карый. МКны икеле диазоний тозлары ярдәмендә табуның Н. тәкъдим иткән диазоалым элементорганик кушылмаларның күптөрле классларын алу өчен беренчел матдәләр синтезларга мөмкинлек бирә. Н. МКның күпсанлы үзара әверелеш юлларын, ш.и. күкерторганик кушылмалар б-н магний, цинк, кадмий, алюминий, теллур, кургаш, аккургашның һ.б.ның органик кушылмалары арасындагы күчешләрне тикшерә. Органик кушылмаларның таутомер характерда булмаган икеле реакциягә керү сәләтен ача; α-, ω-хлоралканнар синтезлау алымнарын эшли, шулар нигезендә сүс ясагыч полимерлар, пластификаторлар, эреткечләр җитештерүдә кулланыла торган ярымпродуктлар таба. Металлотропия күренешен — күкерторганик калдыкның n-нитрозофенолның окси- һәм нитрозогруппалары арасындагы кайтма күчешен ача. Тикшеренүләрнең яңа юнәлешенә — синтетик азык продуктлары булдыруга нигез сала.

Эвакуация елларында Казанда Н. җитәкчелегендә җәрәхәтләрне дәвалау чарасы буларак кулланыла торган винилацетиленлы карбиноллар табу ысулы эшләнә һәм җитештерүгә кертелә; дары ясау өчен сульфитлы целлюлоза куллану ысулы табыла. Н. —

«Синтетические методы в области металлоорганических соединений» (1945–50) һәм «Методы элементоорганической химии» (1963–76) серияле басмалар авторларының берсе һәм мөхәррире (акад. К.А.Кочешников б-н бергә). Фән һәм техника өлкәсендә Ленин һәм Дәүләт бүләкләре ком-ты рәисе. СССР ЮС депутаты (1950–62). Ленин бүләге (1966), СССР Дәүләт бүләге (1943) лауреаты. Алты Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең М.В.Ломоносов исем. алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Избр. труды: В 4 т. М., 1959; Химия ферроцена. М., 1969; Элементоорганическая химия. М., 1970; Исследования в области органической химии. М., 1971.

*Әд.:* Александр Николаевич Несмеянов // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1951. Вып. 15; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**НЕ́СТЕРОВ** Аркадий Павлович (30.6.1923, Самара губ. Бозаулык ш.), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1964), РМФА академигы (1991; 1978 елдан СССР ФАнең мөхбир әгъзасы), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1974). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук эшли. 1964 тән Казан мед. ин-тының күз авырулары каф. мөдире, проф. (1965). 1974 тән Мәскәүдәге 2 нче мед. ин-тында күз авырулары каф. мөдире. Хезмәтләре күз микрохирургиясенә, күз гидродинамикасы һәм гидростатикасына, глаукома патогенезына, авыруга диагноз кую, дәвалауга; диабетик ретинопатиягә; күз авыруларын консерватив һәм хирургик дәвалау ысулларына, дарулар б-н дәвалауга карый. Н. ачык почмаклы глаукома патогенезында склераль синусны блокадалау феноменын («Нестеров эффекты») ача (1985). Уйлап табуга 29 авторлык таныклыгы бар. СССРның Дәүләт бүләге (1975), СССР МФАнең М.И.Авербах исем. бүләге (1969), РМФАнең Н.И.Пирогов исем. бүләге (1994) лауреаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидродинамика глаза. М., 1968; Первичная глаукома. М., 1982; Физиология и патология внутриглазного давления. М., 1982; Профессиональная патология органа зрения. М., 1988.

*Әд.:* Академик Аркадий Павлович Нестеров (к 75 летию со дня рождения) // Вестн. офтальмологии. 1998. № 6.

**НЕ́СТЕРОВ** Василий Максимович (18.1.1936, хәзер Пенза өлкәсенең Зур Вьяс р-ны Белый Ключ а. — 2.9.2010, Мәскәү), инженер-очучы, ТРның Һава транспорты төбәк идарәсе башлыгы (1994–96), Россиянең атказ. транспорт хезмәткәре (1996). ДОСААФның Саранск очучы-техниклар мәктәбен (1957), Красный Кут гражданнар авиациясе очучылары уч-щесен (1959), Саратов ун-тын (1967) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1954 елда «Трансводстрой» трестының Сталинград идарәсендә слесарь буларак башлый. 1957 дән Кузнецк укыту-өйрәтү үзәгендә Як-18, Як-11 самолётларында эшли. 1960–63 тә Красный Кут очучылар уч-щесендә (Саратов өлкәсе) Як-18, Ан-2 самолётларында очучы-инструктор. 1963–73 тә Пенза берләштерелгән авиаотрядында, Ан-2 самолёты һәм звено командиры, авиаэскадрилья командиры урынбасары, командиры. 1973–74 тә — Саратов берләштерелгән авиаотрядының 171 нче очучылар отряды, 1974–84 тә — Бөгелмә, 1984–94 тә Казан берләштерелгән авиаотрядлары командиры, «Татарстан авиалинияләре» авиакомпаниясенең Казан шәһәр агентлыгы башлыгы, Татарстан берләштерелгән авиаотряды командирының 1 нче урынбасары, командиры, ген. директоры. 1997–98 дә Татарстан һава юллары агентлыгы ген. директоры урынбасары (Казан), 1998 дән «Компания Турамко» АҖ директоры, ген. директоры, бер үк вакытта «Казан транспорт агентлыгы» АҖ директорлар советы рәисе (2004 тән). Н. җитәкчелегендә Бөгелмә аэропортында — пассажирлар павильоны, күтәрелү-төшү полосасы, ангар, кунакханә һ.б., Сарман, Минзәлә, Актаныш аэропортларында каты түшәмәле күтәрелү-төшү полосалары файдалануга тапшырыла. Казан шәһәр агентлыгында авиабилетлар сату б-н идарә итүнең үзәкләштерелгән 2 нче буын «Сирена-2» системасы гамәлгә кертелә; «Казан» халыкара аэропортында реконструкция уздырыла һ.б. эшләр башкарыла. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* И б р а г и м о в Р.А. Крылья Татарстана. К., 1985; Жизнь в полётах: История развития Бугульминского авиационного предприятия 1953–2003. Бугульма, 2003.


**НЕ́СТЕРОВ** Владимир Николаевич (18.3.1954, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2010). Казан фин. икътисад ин-тын тәмамлый (1979). 1972–75 елларда Казан оптика-механика з-дында һәм Татарстан мех берләшмәсендә эшли. 1979 дан Казан фин.-икътисад ин-тында (хәзер Казан ун-тының финанс һәм икътисад ин-ты), икътисади анализ һәм аудит каф. мөдире (2006 дан). Хезмәтләре җитештерүнең оештыру-техник дәрәҗәсенә анализны камилләштерү, инновацион икътисадтагы чыгымнарны тикшерү һәм хисаплау мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Анализ издержек в инновационном развитии организации. К., 2002; Учётно-аналитические системы управления затратами. К., 2009 (автордаш); Управление затратами. К., 2011 (автордаш).

**НЕТТЕ́ВИЧ** Энгель Данилович (4.2.1928, Смоленск губ. Красный пос. — 15.7.2002, Мәскәү өлкәсенең Одинцово р-ны Марфино а.), агроном-селекционер, ВАСХНИЛ, РАХФАнең мөхбир әгъзасы (1988, 1992), ТР ФАнең шәрәфле академигы (1998), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1988). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1952), Орёл а.х. тәҗрибә станциясендә эшли. 1957 елдан СССРның Кара туфраклы булмаган зона Үзәк р-ннары а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, бүлек мөдире (1969 дан), баш фәнни хезмәткәр (1993 тән). Хезмәтләре бөртекле культуралар селекциясе, орлыкчылыгы, биологиясе, генетикасы, үстерү технологиясе мәсьәләләренә карый. Н. бөртекле культураларның яңа сортларын



А.П. Нестеров.



Э.Д. Неттевич.

булдыруның нәтиҗәле алымнарын эшли. Аның җитәкчелегендә язгы бодай, арпа, солы, карабодайның 30 сорты чыгарыла. 1970–2004 тә Татарстанда 19 сорт районлаштырыла; 1986 да бу сортлар чәчелгән мәйданнар якынча 1 млн. *га* тәшкил итә. Респ-када иң күп таралган сортлар: язгы бодай — «Московская 35», «Энита», «Люба», «Лада», «Приокская», «Мис», «Әмир», «Эстер» һ.б.; арпа — «Московский 121», «Московский 2», «Эльф», «Раушан», «Нур», «Рәхәт»; солы — «Руслан», «Друг»; карабодай — «Шатиловская 5». СССР, РФ Дәүләт бүләкләре лауреаты (1977, 1995). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Яровая пшеница в Нечернозёмной зоне. М., 1976; Рождение и жизнь сорта. М., 1983; Высокопродуктивные сорта зерновых культур для Нечерноземья. М., 1987.

**НЕ́ТТОВ** Газиз Гыйният улы (5.8.1942, Әстерхан өлкәсенең Нариман р-ны Приволжье пос.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1992). Әстерхан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), Нариман р-ны участок хастаханәсе хирургы һәм баш табибе. 1970 елдан Әстерхан шәһәре клиник хастаханәсе травматологы. 1972 дән Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1991 дән кул чугы имгәнүләре һәм авырулары бүлеге мөдире. Хезмәтләре кул чугы хирургиясенә карый. Н. тарафыннан кул чугы һәм бармаклар тоташтан зарарланган очракта хирургик дәвалауның яңа тактикасы тәкъдим ителә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 21 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Межвертельная остеотомия при коксартрозе. К., 1979; Исходы лечения открытых повреждений кисти и пальцев // Советская медицина. 1984. № 12; Пути снижения инвалидности при сочетанной травме кисти // Советская медицина. 1988. № 9.

**НЕУСТРО́ЕВ** Сергей Васильевич (25.6.1927, Вятка губ., Нолинск өязе Подгорное авылы), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1981). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1958). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1980). 1959–87 елларда ТАССР Сәнгать фондында. Киң иҗат диапазонлы рәссам буларак, Н. пейзаж, натюрморт, портрет, тематик картиналар жанрларында эшли. Аның иҗатында станлы нәкышь төп урынны алып тора. Портрет геройлары — замандашлары: эшчеләр, колхозчылар, галимнәр, сугыш һәм хезмәт ветераннары: «С.А.Кудряшов, Идел

буе флотилиясе командиры» (1959–60), «Әлфия» (1965), «Бабай» (1970). Н.ның лирик-романтик пейзажлары Урта Идел һәм Урал буе табигатенә, шәһәр күренешләренә мәдхия җырлый: «Дача бистәсе» (1962), «Яр Чаллы» (1968), «Йөзьяшәр чыршылар» (1974), «Болытлы көн» (1975), «Октябрь» (1977). Натюрморт жанрын үстерүгә лаеклы өлеш кертә: «Ромашкалар» (1965), «Самавырлы натюрморт», «Кыр чәчәкләре» (икесе дә — 1968), «Алтын чәчәкләр» (1970). Тематик натюрмортлары аеруча зур әһәмияткә ия: «Картлач» (1970), «Рәхим итегез!» (1970–72), «Өй эче күренеше» (1979) — аларда рәссам татар халык көнкүрешенең характерлы үзенчәлекләрен чагылдыра. Н. Казандагы җәмәгать корылмаларының интерьерларын бизи: елга порты вокзалы, «Луч» кафесы (икесе дә — 1965), «Поволжье» кибете (1965, Р.Р.Һибәтуллин б-н бергә). Казакъстан ССРда (Алма-Ата, 1962), Әзәрбайҗанда (Баку, 1979), Каракалпак АССРда (Нукус, 1980) узган күргәзмәләрдә, ТАССР рәссамнары әсәрләре күргәзмәләрендә, РСФСР автономияле респ-калар рәссамнарының әсәрләре күргәзмәсендә (Мәскәү, 1971), «Зур Идел-5» зона күргәзмәсендә (Казан, 1980) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда уза (1970, 1980, 1987). Н. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында, шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*М.Е.Ильина.*

**НЕФЕ́ДЬЕВ** Анатолий Алексеевич (23.11.1910, Алтай краеның Камень а., хәзер Камень-на-Оби ш. — 14.9.1976, Казан), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1959), проф. (1959). Томск ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Казан ун-тының В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә эшли, директор урынбасары (1944–58), директор (1958 елдан). Хезмәтләре Айның фигурасын һәм әйләнүен өйрәнүгә карый. Күпьеллык гелиометрик күзәтүләр нигезендә Н. Ай әйләнешенең яңа элементларын чыгара, Ай фигурасының көньяк ярымшардагы асимметриясе турындагы «Яковкин эффектын» һәм Айның көнчыгыш һәм көнбатыш радиусларының тигезсезлеге турында И.В.Белькович нәтиҗәсен раслый. Күзәтүләр нәтиҗәсендә Айның оптик либрациясе параметрларының кыйммәтен билгели. Халыкара астрономнар берлеге әгъзасы (1950). «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физическая либрация Луны // Уч. зап. Казан. ун-та. 1951. Т. 111, кн. 2; Вывод постоянных физической либрации Луны по методу Краковиана // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1953. № 34; Карты рельефа краевой зоны Луны на общем нулевом уровне // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1958. № 30.

*Р.Г.Усманов.*

**НЕФЕ́ДЬЕВ** Евгений Алексеевич (7.6.1851, Сембер губ., Сызрань өязе Ратовка а. — 12.3.1910, Мәскәү), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1892), хакыйкый статский советник (1901). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1875). 1875–81 елларда Сызрань өязе җәмәгать судьясы. 1881–82 дә Казан мәхкәмә палатасы округ антлы ышанычлысы. 1882–88 дә Казан ун-тының гражданлык мәхкәмәсе эшләре каф. приват-доценты, 1888–92 дә экстраординар профессоры, 1892–96 да гражданлык хокукы каф. ординар профессоры. 1896–1907 дә Мәскәү ун-тының сәүдә хокукы һәм мәхкәмә эшләре каф. ординар профессоры, 1907 дән атказ. профессоры. Хезмәтләре гражданлык хокукы һәм процессы, сәүдә, су хокукы мәсьәләләренә карый. «Гражданлык процессында судьяларны эштән азат итү» («Устранение судей в гражданском процессе», 1885) хезмәтендә Гражданлык процессы уставының эштән бушатылырга тиешле судьяларны чагыштырмача булдыксызларга һәм шикләләргә бүлү кагыйдәләрен эшли. «Гражданлык процессында якларны килешүгә этәрү» («Склонение сторон к миру в гражданском процессе», 1890) хезмәте якларны килештерүдә мәхкәмәнең бурычларын өйрәнүгә багышлана. «Гражданлык процессының асылы турындагы тәгълиматка. Гражданлык процессында бергә катнашу» («К учению о сущности гражданского процесса. Соучастие в гражданском процессе», 1891) монографиясендә процессның теориясен ачып бирә һәм аны бергә катнашу турындагы өйрәтүләргә карата куллана. «Дәгъва турындагы тәгълимат» («Учение об иске», 1895) дигән эшендә дәгъвага карата яңа караш булдыра. Хокук тарихы буенча тикшеренүләре бар; «Сперанский карашыннан чыгып, Тулы тупланма һәм Законнар җыентыгын бастырып чыгаруның сәбәбе һәм максаты» («Причина и цель издания Полного собрания и Свода законов с точки зрения Сперанского», 1889) хезмәтенең авторы. «Гражданлык мәхкәмәсе процессы курсы»нда («Курс гражданского судопроизводства», 1–3 чыг., М., 1902–06) Россиядә 1864 елгы мәхкәмә реформасыннан соң гражданлык процессы башлангычын һәм принципларын һәркемгә аңлаешлы формада һәм фәнни нигездә бәян итә.

Х е з м.: О способах освобождения недвижимых имуществ от описи третьими лицами, не имеющими на свои имущества актов укрепления. К., 1881; Производство в коммерческих судах. К., 1893; Основные начала гражданского судопроизводства. К., 1895; Очерки по водному праву. М., 1899; Учебник торгового права. М., 1904.

*Әд.:* Гольмстен А.Х. Е.А.Нефедьев: Некролог // Журн. М-ва юстиции. 1910. № 10; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**НЕФЕ́ДЬЕВ** Евгений Сергеевич (19.10.1947, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1974). Казан технол. ун-тында эшли, физика каф. мөдире (1994 елдан). Хезмәтләре полимерларның физика-химиясенә карый. Н. полимерметалл фазаара катлам формалашуның физик-химик нигезләрен билгели. Полисульфид һәм эпоксид олигомерлар нигезендә ябышучан, электр үткәрүчән герметик композицияләр булдыра. Шиннар сәнәгате өчен ныклык һәм адгезия үзлекләре яхшыртылган, модификацияле резиналар («Түбәнкамашин» АҖдә гамәлгә кертелә), җылыта торган үзкөйләнешле кабельләр һәм капламнар җитештерү өчен материал тәкъдим итә. Нәньютон сыеклыкларның структур үзлелеген киң диапазонда үлчәү приборлары булдыруда катнаша («Татнефтепром-Зүзәйнефть» АҖдә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые аспекты влияния рецептурных факторов на прочностные свойства шин. Нижнекамск, 2001 (автордаш); О природе комплексов меди в переходном слое адгезионного соединения тиоколового герметика и латуни // Журн. прикладной химии. 2002. Т. 75, вып. 8 (автордаш); ESEEM of copper complexes formed in the interlayer between tiokol-epoxy adhesive and brass substrate // Appl. Magn. Res. 2002. № 22 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

**НЕФЕ́ДЬЕВ** Леонид Анатольевич (11.7.1947, хәзер Яшел Үзән р-ны Октябрь пос.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1971 дән Казан пед. ин-тында (2010 нан Казан ун-тында), гомуми һәм эксперименталь физика каф. мөдире (1991 дән). Хезмәтләре оптик кайтаваз-голографиядәге мәгълүмат процессларына карый. Н. газларда һәм плазмада оптик үтә нурланыш теориясен үстерә; яктылык кайтавазы полярлашуның кайтмалыгы эффектын алдан әйтә һәм ача; төсле кайтаваз-голография теориясен үстерә; мәгълүматның кайтаваз-голографиядә бикләнүе эффектын алдан әйтә һәм тикшерә; фаза хәтере булган өч баскычлы тирәлекләрдә мәгълүматның квант битлары күчермәләре барлыкка килү эффектын алдан әйтә.

Х е з м.: Динамическая эхо-голография в вырожденных и многоуровневых системах // Изв. АН СССР. Сер. физич. 1986. Т. 50, № 8; Цветная эхо-голография // Оптика и спектроскопия. 1987. Т. 62, № 3 (автордаш); Многоканальная эхо-голографическая запись и обработка информации на основе стимулированного фотонного эха в газовой среде // Оптика и спектроскопия. 1996. Т. 80, № 1; Copying Quantum Information in a three-level Medium with a Phase Memory // Laser Physics. 2002. V. 12, № 3 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НЕФЕ́ДЬЕВ** Юрий Анатольевич (6.6.1955, Юдино р-ны Октябрьский пос.), астроном, физика-матем. фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлаганан соң (1977), шунда ук, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә эшли: 1991–2007 елларда директор урынбасары, 2007 дән директор (бер үк вакытта, 1986–2011 дә Татар гуманитар-пед. ун-тында, 2008 дән проф.; 2011 дән Казан ун-тының Физика ин-ты проф.). Хезмәтләре астрометриягә һәм күк механикасына, планеталар физикасына, астрономия приборлары төзүгә карый. Ай өслегенең динамик координаталары системасына навигацион таяну челтәрен төзи. Сейсмик процессларны һәм астрономик күзәтүләрне корреляцияләү алымнарын, астрономик рефракция параметрларын атмосфера катламнарын исәпкә алып тикшерү алымын, йолдызлар торышының хәзерге космик каталогларын анализлау алымын эшли. Халыкара астрономнар берлеге әгъзасы (2007 дән).


Х е з м.: История астрономии в Казани. К., 2009 (автордаш); Photographic observations of Solar System bodies at the Engelhardt astronomical observatory // Astronomy and Astrophysics. 2005. № 444 (автордаш); Analysis of data of «CLEMENTINE» and «KAGUYA» missions and «ULCN» and «KSC-1162» catalogues // Advanced in Space Research. 2012. №50 (автордаш).

**НЕФЕ́ДЬЕВА** Антонина Ивановна (29.5.1921, Пенза губ. Саранск ш.), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1983), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990), Казан ун-тының атказ. профессоры (2006), 1942 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясендә эшли (2011 гә кадәр), астрономия бүлеге мөдире (1956 — 2000), бер үк вакытта, 1953–72 дә, Казан пед. ин-тында укыта. Хезмәтләре фундаменталь астрономиягә карый. Н. яңа астрономик рефракция теориясен эшли һәм аның таблицаларын төзи; аэрологик мәгълүмат нигезендә атмосфераның төрле биеклекләрендә һәм Җир өслегенең төрле өлкәләре өчен бертөрле тыгызлыктагы һава катламнарының авышуларын билгели; йолдызларның координаталарын билгеләү һәм йолдыз каталогларын төзү буенча халыкара һәм илкүләм программаларда катнаша. Астрономия буенча фәнни-популяр хезмәтләр авторы. Халыкара астрономия берлеге әгъзасы (1970 тән). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дифференциальный каталог 2288 звёзд каталога слабых звёзд // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1963. № 33; Астрономическая рефракция // Изв. Астрон. обсерватории им. В.П.Энгельгардта. 1968. № 36; Фундаментальная астрономия. К., 1989; Служба вращения Земли. К., 1994.

*Р.Г.Усманов.*

**«НЕФТЕАВТОМА́ТИКА»**, нефть-газ машиналары төзү пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 300 кеше (2013). 1962 елда Казанның 490 нчы пр-тиесе (1959 да нигезләнә) ф-лы җирлегендә Бөгелмә «Н.» тәҗрибә з-ды буларак оештырыла. 1987 дән «Н.» ФҖБ (Уфа ш.) составында, 1993 тән төбәкара АҖ ф-лы — Бөгелмә «Н.» тәҗрибә з-ды. 1980 елларда заводта реконструкция уздырыла. Төп производство структурасына — әзерләү, механика, эретеп ябыштыру-җыю, җыю, корыч кою участоклары, ярдәмче производствога инструментлар, ремонт, электр, столярлык, транспорт участоклары керә. Пр-тиенең машиналар паркында металл эшкәртү (188 берәмлек), насос-компрессорлар (25 берәмлек), эретеп ябыштыру (19 берәмлек), термик эшкәртү (16 берәмлек) җиһазлары; 10, 16, 25 *т* куәтле пресслар, пневматик чүкечләр, металл табакларны бөгү машиналары, хромлаучы һәм цинклаучы гальваник линияләр тупланган. Заводта эшләнмәләрне полимер порошок б-н пневмоэлектростатик каплау алымы, хромлау, цинклау, химик оксидлау кулланыла. Термопластик, термореактив пластмасса детальләрне пресслау һәм резинотехник эшләнмәләр ясау, басым астында кою, эрүчән кендекле модельләр буенча коелмалар эшләүнең прогрессив ысуллары үзләштерелгән. 40 тан артык исемдә эшләнмәләр: нефть тармагы өчен приборлар һәм автоматлаштыру чаралары — нефтьне исәпкә алу блоклары (узеллары), нефть, газ, сыеклык күләмнәрен исәпләү җайланмалары, программалы идарәдән алынган мәгълүматларны электрон эшкәртүче икенчел приборлар, нефть үрнәкләрен алу җайланмалары, үлчәү линияләре, чи нефтьнең дымлылыгын үлчәү, скважиналарны тикшерү приборлары җитештерелә. Продукция Россия, Казахстан, Украина, Белоруссия нефть тармаклары пр-тиеләренә җибәрелә. Металл б-н тәэмин итүче төп пр-тиеләр: «Энергопромметаллоснаб» (Первоуральск ш.), «Стальсервис» (Уфа), «Нефтехимзапчасть» (Сызрань ш.) АҖләре, «Логотранс» ҖЧҖ (Мәскәү); комплектлау эшләнмәләре җибәрүчеләр: «Энерпредярдос» инженерлык компаниясе ҖЧҖ, «Манометр» сәүдә йорты (икесе дә — Мәскәү), «Союзэлектроника» ҖЧҖ (Самара ш.), «Элемент трубопроводов» АҖ (Екатеринбург ш.); комплектлау материаллары б-н тәэмин итүчеләр: «Техкомплект-Сервис» ҖЧҖ, «Лаки и краски» ҖЧҖ (икесе дә — Казан), «Белфорт» ҖЧҖ (Әлмәт ш.). Җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен завод КПСС ҮК, СССР ЮС Президиумы, СССР МС, ВЦСПСның мактау билгесе (1972), ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1981) б-н бүләкләнә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 4 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 6 кеше — «Почёт билгесе», 6 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены, 180 кеше медальләр (шулардан 94 кеше — СССР ВДНХ-сы медальләре), 1 кеше ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.



«Нефтеавтоматика» предприятиесе продукциясе: нефть үрнәкләрен алу җайланмасы.

Завод җитәкчеләре арасында: А.М.Исхаков (1959–62), А.К.Гумовский (1962–85), Н.А.Самков (1986–89), Ю.А.Заварницын (1989–93), В.И.Чудин (1993–2002), Р.Т.Териков (2002–06), И.В.Пяткин (2012 дән).

*М.Ж.Гаитов, А.А.Куприянова.*

**НЕФТЕКА́МСК** шәһәре, БРның төньяк-көнбатыш өлешендә, Уфадан 250 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1957 елда төзелә, 1963 тән — шәһәр. Халкы — 123540 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 13549, 1979 да — 21048, 1989 да — 33955, 2002 дә — 38405, 2010 да — 41701 кеше. Шәһәрдә Татар милли-мәдәни үзәге, «Без» татар халык театры, «Карман бизәкләре» татар-башкорт фольклор төркеме, «Сандугач» татар вокаль ансамбле («2012 елгы студент очрашулары — дус гаилә традицияләре» респ-ка фестиваленең төбәк этабында 1 нче урынны ала) эшли. «Дуслык-моно» татар һәм башкорт җыры халыкара фестивале уздырыла. Н.да ТР иҗат төркемнәре гастрольләре даими булып тора. 2004/05 уку елында Н.ның 21 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар телендә «Кама таңнары» г-тасы нәшер ителә.

**«НЕФТЕМА́Ш»**, нефть машиналары төзү пр-тиесе. Әлмәт шәһәрендә. 1963 елда Әлмәт автомобиль-тракторлар ремонтлау з-ды (файдалануга 1966 да тапшырыла) буларак нигезләнә. 1990 нан Әлмәт «Н.» машиналар төзү з-ды, 1993 тән АҖ. Баштарак нефть чыгару пр-тиеләренең транспорт бүлекчәләренең дизель двигательләрен, тракторларны, йөк автомобильләрен һ.б. техникасын ремонтлау, үз ихтыяҗлары өчен стандарт булмаган җиһазлар җитештерү, төрле детальләр ясау һәм аларны яңарту б-н шөгыльләнә. 1970 еллар башында бораулау һәм нефть промыселы машиналарына запас частьлар, халык куллануы товарлары чыгаруга керешәләр. 1970–80 елларда ДТ-75 тракторы, «ЗИЛ», «КРАЗ», «Урал», «КАМАЗ» автомобильләре шассилары нигезендә төрле җайланмалар, нефть үткәргечләр өчен корыч фланецлар җитештерү оештырыла; скважиналарны ремонтлау өчен АзИНМАШ-37 һәм А-50 җайланмаларын капиталь ремонтлау үзләштерелә (илдә беренче тапкыр). Җитештерү үсү б-н яңа корпуслар һәм котельный төзелә, специальләшкән заманча җиһазлар, ш.и. санлы программалар б-н идарә ителүче станоклар куллануга кертелә. 1980 елларда завод продукциясе илнең барлык нефть чыгаручы төбәкләренә җибәрелә. 1990 елларда респ-ка авылларын *газлаштыру* вакытында җылыту казаннары ясау үзләштерелә. 2000 еллар башында скважиналарны ремонтлау өчен «КАМАЗ-43118» шассие нигезендә УПР-32Т җайланмасы эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. 2007–10 да «Н.» АҖ үзгәртеп корыла, аның нигезендә берничә пр-тие оештырыла, эшләүчеләрнең гомуми саны 90 лап кеше (2013).

Төрле шассилар нигезендә завод технол. сыеклыклар, нефть һәм нефть продуктларын күчереп йөртү өчен вакуумлы автоцистерналар, продуктларны саклау өчен сыешлыклар, күтәрү җайланмалары, агрегатлар, скважиналарны һәм нефть үткәргечләрне җир өстендә ремонтлау өчен күчмә кыр остаханәләре, цемент измәсен болгату, насос-компрессор торбаларын сынау һәм алардагы җитешсезлекләрне ачыклау өчен җайланмалар, телескоплы вышкалар эшләп чыгара. Чуеннан һәм корычтан коелган күптөрле эшләнмәләр, эретеп ябыштырылган металл төзелеш конструкцияләре, а.х. техникасы (тешле катоклар, төрәннәр, запас частьлар), аерым торак йортлар, эре производство һәм социаль объектлар өчен җылыту казаннары, борау-





«Нефтемаш». Завод продукциясе: 1. УПР-32 Т күтәрү җайланмасы; 2. АНРВ-1К скважиналарны җир өстендә ремонтлау агрегаты.

лау һәм нефть промыселы җиһазларына запас частьлар җитештерелә. Пр-тиедә йөк автомобильләре, двигательләр, нефть чыгару станоклары һ.б. техника ремонтлана. Продукцияне төп кулланучылар — «Татнефть», «АлАЗ», «Нефтекама машиналар төзү заводы» (БР) АҖләре, кече нефть компанияләре. Пр-тие лаек булган бүләкләр арасында — «Сыйфат өчен» (Франция, 1997), бизнес-партнёрларның «Australiana discovery market» халыкара ассоциациясенең «Ел предприятиесе» (2000, 2001) халыкара призлары, «Россия икътисады лидеры» сертификаты (1995), Бөтенроссия «Югары социаль нәтиҗәлелек оешмасы» конкурсы грамотасы (2001). «Н.»ның күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 7 кешегә — РФ, ТАССР, ТРның атказ. машина төзүчесе, 1 кешегә ТРның атказ. транспорт хезмәткәре исеме бирелә; 36 кеше орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: А.Ш.Рамазанов (1963–67), А.К.Бикташев (1967–71), В.Г.Кензерский (1971–72), Ф.Г.Габдрахманов (1972–87), Р.Р.Шәрифуллин (1987–2003; 2003 тән — директорлар советы рәисе), А.К.Кашапов (2003–07).

*Р.Р.Шәрифуллин.*

**«НЕФТЕХИ́МИК»**, футбол командасы. 1963 елда «Түбәнкаманефтехим» ЖБ (Түбән Кама ш.) каршында оештырыла, 1991 дән шул ук исемдәге футбол клубы командасы респ-ка ярышларында (1968–91), СССР (1991, 2 нче лига), Россия (1992, 1999–2000, 2005 тән, 2 нче лига, дивизион; 1993–98, 2001–04, 1 нче лига, дивизион) беренчелекләрендә катнаша. Клубның президентлары: Р.Т.Шияпов (1991–92), Н.Н.Гыйззәтуллин (1992 дән). Спорт казанышлары: «Россия футболы» (1990) турнирында, 2 нче дивизион командалары арасында Россия беренчелекләрендә (1992, 2000) җиңүче, 1 нче лигада 6 нчы урын (1994), ТР Кубогы иясе (1997, мастер командалар арасында). Баш тренерлары: В.А.Морозов (1991–92, 2001–02), В.Муханов (1992), Г.А.Сарычев (1993–96, 1998), В.П.Антихович (1996–97), А.Д.Афонин (1997), Б.А.Синицын (1998), И.Н.Буталий (1999–2001), В.Н.Пачко (2003–04), А.Ю.Ефремов (2004), В.Я.Клонцак (2004 тән). Иң яхшы спортчылар: А.Әхмәтгалиев, И.Әхмәтҗанов, С.Будылин, Е.Ефремов, А.Ситчихин, Р.Фәхретдинов.

**«НЕФТЕХИ́МИК»**, шул ук исемдәге хоккей спорт клубы каршындагы хоккей командасы (1991 дән, Түбән Кама ш.). 1968 елда Түбән Кама нефть химиясе комб-ты каршында туплана. 1969–89 да ТАССР чемпионатларында берничә тапкыр медаль ала, «Труд» ирекле спорт җәмгыяте профсоюзларының Татарстан өлкә советы кубогы иясе һәм чемпионы (1981). 1990–91 дә СССР беренчелегенең «А» классында (2 нче лига), 1991–95 тә Россия беренчелегенең югары лигасында, 1995–96 да Милләтара хоккей лигасында, 1997–2008 дә Россия чемпионаты суперлигасында, 2008 дән Континенталь хоккей лигасында. Спорт казанышлары: Россия чемпионатында 3 нче урын ала (2000/01); «Тампере» (Финляндия, 2002), «Татры» (Словения, 2003), «Лада» (2007), Мәскәү (2007) һәм Чиләбе (2012) өлкәләре губернаторлары кубокларына лаек була. «Нефтехимик» командасының иң атаклы уенчылары: О.В.Антоненко, Д.Балмин, М.Ю.Грабовский, С.Е.Звягин, А.Ивашкин, А.Н.Калюжный, Р.Касьянов, И.Мөхәммәтов, А.Степанищев, А.Юдин, Р.Якубов; тәрбияләнүчеләр — И.Билалов, П.Валентенко, Е.Муратов, М.Пастушко, А.Угаров, Д.Франскевич, И.Р.Якупов. Баш тренерлары: В.В.Голубович, В.В.Крикунов, Ю.А.Немов, Б.П.Павлов, Г.А.Сергеев, А.В.Смирнов. Клубның президенты В.М.Бусыгин (1999 дан).

**НЕФТЕЮГА́НСК** шәһәре, *Төмән өлкәсендә*. Халкы — 125882 кеше (2012), 11,7 мең татар (2002). Татарлар Н.да 1970 еллар башында Самотлор — Усть-Балык — Төмән — Уфа — Әлмәт нефть үткәргече төзелүгә бәйле рәвештә күренә башлый. Хәзерге вакытта шәһәрдә «Тальян» татар-башкорт мәдәни үзәге (1997 дән) бар, аның каршында «Гөлнәзирә» халык хореография коллективы, «Тамчылар» фольклор һәм «Өмет» вокал студияләре, «Чишмә» театр коллективы, «Ләйсән» халык вокаль ансамбле (1978 дән) эшли.

**НЕФТЬ** (фарсы. نفت), үзенә генә хас исле янучан майлы сыеклык; файдалы казылма. Углеводородлар һәм кислород, күкерт, азот кушылмалары катнашмасы. Төсе көрән (күбесенчә), сары-яшел, кара; сирәк кенә — төссез. Н.тә эрегән газлар (1 *т* га 30 дан 300 $м^3$ га кадәр), минераль тозлар, металлар (V, Ni, Cu, Co, Mo һ.б.) бар. Тыгызлыгы 750 дән 1040 $кг/м^3$ га кадәр, дөньяда чыгарылган нефтьнең 60% ы җиңел (870 кә кадәр), 31% ы уртача (910 га кадәр) һәм якынча 10% ы авыр Н.кә туры килә. Органик эретмәләрдә эри. Тыгызлыгы, күкерт, майлар, фракция, асфальтен, парафиннар күләме, җылылык бирүчәнлеге һ.б. буенча классификацияләнә. Н.нең барлыкка килүе турында төрле карашлар (органик, нәорганик һәм катнаш) яшәп килә. Табигый көчләр (гравитацион, гидравлик, молекуляр) йогынтысы астында барлыкка килгәннән соң, Н., ятмалар хасил итеп, иң якын коллекторларга, күтәренке участокларга (Н. җыелу урыннарына) күчә. Н. җыелу урыннарының аеруча күтәренке өлешендә кайвакыт газ (газ «эшләпәсе»), астарак, катлам басымы астында Н., аннан соң су ята. Тирәнлек арту б-н, катлам темп-расы 100 *м* саен уртача 2,5–3,5 °С ка үсә. Н. уннарча метрдан алып 5–6 *км* да һәм тагын да тирәнрәк (тирәнлек арту б-н, ятмаларда газ да күбәя) ята. Н.нең иң күп ятмалары 1–3 *км* тирәнлектә урнашкан. Хәзерге ысуллар б-н катламнан 70–80% ка кадәр Н. алырга мөмкин, әмма алынучы запаслар геол. запасларның 30–40% ын гына тәшкил итә. Гамәли әһәмияткә запасы йөзләрчә мең һәм артыграк тонна булган катламнар ия. Ятмалар җыелмасы чыганак барлыкка китерә. Беренче эзләнү эшләре Н. һәм газның җир өслегенә чыгу урыннарында (биредә коелар төзелә) яки сулыклар өслегендә үткәрелә. 1866 елдан Н.не эзләү һәм чыгару скважиналар бораулау алымы б-н алып барыла, озак вакытлар урынны төгәл белмичә («кыргый мәче» ысулы) бораулана. Башта чыганакларның күтәренке зоналар б-н бәйләнеше ачыклана, биредә катламнар гөмбәзсыман участоклар хасил итә, аннары ятмаларның, ш.у. катламнарның югары районнары, риф ясаучы структуралар, тоз гөмбәзләре һ.б. б-н бәйле булуы билгеләнә. 20 йөз башында — структур геол. төшерүләр, структур бораулау, 1930 елларда структураларны ачыклауның геофизик алымнары (барыннан да бигрәк электроразведка) киң кулланышка керә, алар 1940 елларда Н. эзләүдә төп ысул булып тора. Н. һәм газ эзләүдә геофизик алымнар б-н бергә геохимик, соңрак — биологик, аэрокосмик һәм матем. алымнар да кулланыла башлый. 20 йөзнең 2 нче яртысында эзләү-разведка эшләре диңгездә киң үсеш ала. Н. чыганаклары җир кабыгының барлык горизонтларында: кайнозойда (Н. запасының якынча 25%ты), мезозойда (55%), палеозойда (20%, ТРда 100%), протерозойда (1% ка якын) ачылган. Кристаллик фундамент токымнарында ачылган чыганакларның өлеше ел саен арта бара. Чыганаклар барлык континентларда (Антарктидадан кала) һәм аларга тоташкан шельфның шактый зур мәйданында билгеләнгән. Н.нең 65% тан артыгы Азиядә, шуның якынча 95% ы Якын һәм Урта Көнчыгышта. Н.нең дөньякүләм запаслары 143 млрд. *т* дан артык, ш.и. РФдә — 8,2 млрд. *т* (төп запаслар Көнбатыш Себердә). РФдә 2300 дән артык чыганак билгеле, шуның 10 ы, ш.и. *Ромашкино нефть чыганагы* уникаль булып исәпләнә.

18 йөздә Идел, Чишмә, Сок елгалары буенда Н. табу һәм куллану омтылышын эшкуар-

лар Я.Д.Шаханин, Н. һәм Ю.Уразмәтовлар, А. һәм Х.Музяковлар, П.И.Ягужинский һ.б. ясый. 19 йөздә Түбән Карамалы, Сарабиккол, Шөгер авыллары янында Я.Молокиенко, Л.Шандор тарафыннан бораулау эшләре алып барыла. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Юзбашевлар, «Бертуган Нобельләр», «Дёмин һәм К$^{о}$» фирмалары һ.б., 20 йөзнең 1 нче яртысында Идел буе нефть разведкалау идарәсе, «Востокнефть», «Сызраньнефть», «Туймазынефть» трестлары һәм Татгеолтрест сәнәгый Н. чыганакларын табарга тырышалар. Татгеолтрест 1940 та геол. мәгълүматларны фәнни яктан эшкәртү өчен Үзәк фәнни-тикшерү лаб-ясе оештыра, шул ук елда ул Шөгер нефть эзләү партиясе итеп үзгәртелә. 1941 дә Змеево (Чистай р-ны) авылында Пермь системасы Уфа ярусы комташларыннан Н. агып чыга, бу утырмалардан 1943 тә Сарабиккол мәйданындагы 5 скважинадан 12,5 *т* нефть һәм 40 *т* гудрон чыгарыла. Беренче сәнәгый Н. чыганаклары карбон утырмаларында 1943 тә шәһәр тибындагы Шөгер посёлогы р-нында, девонда — 1946 да Баулы шәһәре тирәсендә, 1948 дә Лениногорск р-ны Тимәш авылы (к. *Ромашкино нефть чыганагы*) янында ачыклана. Сәнәгый запаслар 1950 елга 430 млн. *т* (СССРда иң зур) тәшкил итә. Татарстан терр-ясендә 140 ка якын чыганак (3 меңнән артык ятма) ачылган (2013), аларда палеозой утырмаларындагы Н.нең күләме 1 млрд. *т* чамасы исәпләнә. Углеводород эзләре кристаллик фундаментның протерозой һәм архей токымнарында табыла. ТР терр-ясендә Н. коллекторлары булып терригенлы (комташ һәм комлы алевролитлар) һәм карбонатлы (известьташлар һәм доломитлар) токымнар тора. Сәнәгый әһәмияткә (запасларның 64,5% ы) терригенлы девон (1,5–2 *км* тирәнлектә) һәм карбонат-терригенлы ташкүмер (0,8–1,3 *км* тирәнлектә) утырмалар ия. Девонның катлам-коллекторлары — структур, структур-литологик, карбоннықылар — зур күләмле һәм гөмбәзсыман-катламлы типтагы Н. җыелу урыннары барлыкка китерә. Төп сәнәгый тупланмалар, структур-тектоник яктан караганда, Көньяк гөмбәзгә, запасларының зур булмаган өлеше — Татар гөмбәзенең Төньяк күтәрелешенә һәм Мәләкәс иңкүлегенең көнчыгыш читенә туры килә. Татарстан терр-ясендәге Н. чыганакларының төп үзенчәлекләре: газ «эшләпәсенең» булмавы, нефтьле катның чагыштырмача юкалыгы, файдалы катламнарның литологик-фациаль яктан еш үзгәрүе, аларның даими булмаган күп кенә кечкенә катламнарга бүлгәләнүе, ятманың су өсте өлешенең зур мәйдан алып торуы һ.б. Көньяктан төньякка таба нефтьле кат һәм газ факторы, күкерт күләме кими, киселеш буенча астан өскә таба, газ факторы кимү б-н бергә нефтьнең чагыштырма күләме һәм үзлелеге арта. Уртача (0,871–0,910 $г/см^3$), авыр (0,910 $г/см^3$ дан артык), ш.у. югары күкертле (83%) һәм үзле (71%) Н.ләргә аералар. Н.нең составы геол. утырмаларның яшенә бәйле: девон Н. җиңелрәк (0,833–0,900 $г/см^3$), азрак күкертле (күкерт күләме 0,4–1,8%), парафинлырак (3,5–5,1%), ачык фракцияләр күбрәк (43%); карбон Н., нигездә, авыр (0,900 $г/см^3$ һәм артыграк), югары күкертле (2,4–4,7%), парафинлы (2,6–3%), девон Н.енә караганда ачык фракцияләр азрак (25–38,7%); Пермь Н. авыр (0,899–1000 $г/см^3$), күкертле, ачык фракцияләр 4,9–20,9 % ка кадәр. Ш.у.к. *Идел-Урал нефть-газ төбәге* (*«Икенче Баку»*), *Янучан табигый газлар, Нефть һәм газ геологиясе, «Нефть чыгару», Нефть-газ чыгару сәнәгате, «Татнефть»*.

*Әд.:* Юсупов Б.М., Веселов Г.С. Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1973; Муслимов Р.Х., Тахаутдинов Ш.Ф. Путь длиною в 60 лет // Нефтегазовая вертикаль. 2003. № 12.

*Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков.*

**НЕФТЬ СӘНӘГАТЕ́ ХИ́МИЯСЕ ИНСТИТУТЫ́**, (НИИнефтепромхим), фәнни-тикшеренү ин-ты, 1978 елда Казанда «Союзнефтепромхим» ФҖБ составындагы ТатНИПИнефть ф-лы базасында Бөтенсоюз нефть сәнәгате химиясе фәнни-тикшеренү һәм проект ин-ты буларак оештырыла. 1992 дән хәзерге исемендә, 1997 дән — АҖ. Эшләүчеләр саны 250 кеше, ш.и. 40 тан артык фән д-ры һәм канд-ты (2012). Институт составына җитештерү һәм гамәлгә кертү оешмалары керә. Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен физик-химик һәм микробиол. алымнар эшләү; тутыгудан, парафин һәм тоз утырымнарыннан саклау, нефть промыселы җиһазларында бу утырымнарны бетерү, нефть әзерләү һәм транспортлау; нефть чыгаруда технол. процессларны химияләштерүнең техник чараларын булдыру; фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен метрологик тәэмин итү; химия продуктлары җитештерү параметрлары һәм технологияләре системасын булдыру; экологик мониторинг юнәлешләрендә эшли. Институтта 200 гә якын технология, 50 дән артык «СНПХ» сәүдә маркалы химия продуктлары базасы тудырылган, соңгылары производствога кертелгән. Күбесе үзенең сыйфаты буенча илнең аналогларыннан өстен, аларны Россия, Казакъстан, Украинаның нефть чыгару пр-тиеләре сатып ала. Химия продуктлары чыгаруның гомуми күләме елына 20 мең *т* дан артык (2012). Эшкәртмәләр сыйфат буенча халыкара Алтын йолдыз б-н билгеләнә. Күп кенә хезмәткәрләре ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе, ТРның атказ. химигы, ТРның атказ. нефтьчесе дигән мактаулы исемнәргә, ТР Дәүләт бүләкләренә, СССР ВДНХсының һәм Бөтенроссия күргәзмә үзәгенең медальләренә лаек була. Уйлап табуга 330 дан артык авторлык таныклыгы һәм патент алынган.

*Әд.:* Лебедев Н.А., Гусев В.И., Хлебников В.Н. Развитие научных исследований и опытно-контрольных работ промышленного использования средств химизации нефтяного производства // Нефтяное хозяйство. 1998. № 2.

**НЕФТЬ СЕ́КЦИЯСЕ**, ТАССР Дәүләт план ком-ты каршындагы *Фәнни-техник совет* секциясе. 1941 ел ахырында Казанда оештырыла. Рәисе — СССР ФАнең мөхбир әгъзасы С.Ф.Фёдоров, әгъзалары — акад. С.С.*Намёткин*, мөхбир әгъзалар М.А.Капелюшников, Л.М.*Миропольский*, Е.И.*Тихвинская*, В.А.*Чердынцев* һ.б. Н.с.нең төп максатлары: катламнарны сәнәгатьтә кулланылышлы нефть тупланмалары коллекторлары буларак өйрәнү, нефть чыганакларындагы суның химик составын анализлау, иң отышлы бораулау ысулларын кулланышка кертү, Татарстан геол.-разведка трестына нефть эзләү һәм нефть чыганакларын куллану буенча консультатив ярдәм күрсәтү. Эзләнү эшләре респ-ка терр-ясенең байтак өлешендә җәелдерелә. 1942 нең язы һәм җәендә Н.с. эзләнү эшләрен Бөгелмә шәһәре тирәсендә һәм Аксубай р-нында алып бара. Шәһәр тибындагы Шөгер посёлогы һәм Сарабиккол авылы янында нефтьле катламнар барлыгы ачыклана. 1943 нең сентябрендә Шөгердәге 1 нче скважина Татарстанда иң беренче булып халык хуҗалыгында файдаланырлык нефть бирә башлый.

*Әд.:* Будков А.Д., Будков Л.А. Нефтяная промышленность СССР в годы Великой Отечественной войны. М., 1985; Попов В.А. Мобилизация и использование трудового потенциала производственно-технической и научной интеллигенции в годы Великой Отечественной войны. К., 1991.

*В.Ф.Телишев.*

**НЕФТЬ ХИ́МИЯСЕ**, химия өлкәсе, *нефтьнең*, нефть фракцияләре һәм углеводородлы газларның составын һәм үзлекләрен, ш.у. аларны эшкәртү һәм химия продуктларын җитештерүне өйрәнә. Нефть төрле углеводородлардан (алкан, циклоалкан, ареннар) һәм, углерод б-н водородтан тыш, составына гетероатомнар: кислород, күкерт, азот һәм кайбер металлар да (ванадий, никель һ.б.) кергән кушылмалардан тора. Җир астыннан нефтьне бораулау скважиналары б-н чыгаралар, иярчен газны, катламнарның минераль тозлар катыш суын аералар. Нефть эшкәртүнең иң төп процессы (сусызландыру, тозсызландыру, тотрыклы халәткә кертүдән тыш) — нефтьне кудыру. Бензин, реактив ягулык, яктырту өчен керосин, дизель ягулыгы, мазут фракцияләре аерып алына. Мазут дистиллят майлар, парафин, *битумнар* алу өчен чимал сыйфатында, крекинг өчен яки котельныйларда сыек ягулык буларак кулланыла. Мазуттан майлы дистиллятларны кудырганнан калган гудрон калдык майлар ясау яки нефтьне икенчел — термик эшкәртү, термоконтактлы кокслау өчен чимал буларак тотыла; дистиллят фракцияләр углеводородларның төзелешен үзгәртү, шулай ук кислород, азот, хлор һ.б. элементлар кергән функциональ кушылмалар хасил итү б-н бәйле термокаталитик процесслар (термик һәм каталитик крекинг, риформинг, алкиллау, изомерлау, пиролиз) өчен чимал булып торалар.

Икенчел процесслар нәтиҗәсендә нефтьтән ясалма каучук, сүсләр, пластик массалар, юу чаралары, пластификаторлар, буягычлар һ.б. җитештерү өчен беренчел матдәләр алына.

Нефть, битум, асфальт (к. *Асфальтитлар*) һәм углеводородлы газлар борынгы заманнардан ук билгеле. Инде б.э.к. 3 мең еллар элек үк Елгаара өлкә дәүләтләрендә һәм Борынгы Мисырда асфальт һәм битумны юллар яки башка корылмалар төзелешендә ябыштыру һәм гидроизоляция материалы буларак кулланалар. Нефть хәрби эшләрдә («утлы

уклар» һәм «утлы чүлмәкләр» әзерләү өчен селитра, күкерт һәм сумала б-н бергә ялкын тудыру матдәсе ясала), медицинада, көнкүреш ихтыяҗлары өчен (биналарны яктырту) кулланыла. Нефть һәм асфальтны тикшерү нәтиҗәләре буенча беренче фәнни хезмәтләр грек галиме Эйрини де Эйринис тарафыннан языла (1721). 19 йөзнең 2 нче яртысында нефть чыгару сәнәгати төс ала, шунлыктан аның составын һәм үзлекләрен өйрәнү зарурлыгы туа. Россиядә акад. Ф.Ф.Бейльштейн, беренчеләрдән булып, Кавказ нефтен тикшерә (1870 еллар) һәм анда гексагидроароматик кушылмалар барлыгын исбатлый. Мөстәкыйль фән буларак Н.х.нә В.В.Марковников нигез сала, ул Кавказ нефтеннән ароматик углеводородларны аерып ала (1880 еллар), аларның башка класс углеводородлары б-н азеотроп катнашмалар ясый алу сәләтен ача; углеводородларның яңа классын — нафтеннарны ача һәм аларның ароматик углеводородларга әверелүен өйрәнә. Д.И.Менделеев нефтьнең авыр металлар карбидларыннан килеп чыгуы турында фаразын әйтә һәм нефтьләрне бүлгәләп (ваклап) куу принцибын тәкъдим итә. 19 йөз ахырында Россиядә нефть эшкәртү сәнәгатенең төп продуктларын керосин һәм мазут тәшкил итә. Бензин нефтьне турыдан-туры кудыру юлы б-н алына. 20 йөз башына нефть эшкәртүнең беренчел углеводородларны югары темп-ра һәм басым тәэсирендә таркату б-н бара торган процесслары өйрәнелә. Акад. Н.Д.Зелинский крекингны «бензинлаштыру» эшләрен үткәрә (1920–22), нефть цикланнарын каталитик ациллау юлы б-н алициклик кетоннар таба (1924), нефтьләрне каталитик һәм пирогенетик ароматлаштыруны гамәлгә ашыра (1931–37). Нефть химиясе һәм технологиясе тикшеренүләренә С.С.*Намёткин* зур өлеш кертә. 1930–60 елларда нефть чыгару күләме арту *нефть сәнәгатен* барлыкка китерә, аның шуннан соңгы үсешенә акад. С.В.Лебедевның каучук синтезлауның сәнәгый ысулын уйлап табуы (беренчел чимал сыйфатында нефть пиролизы газлары кулланыла) зур этәргеч бирә. В.Н.Ипатьевның югары басым һәм темп-ралар астында гетероген катализ өлкәсендәге тикшеренүләре Н.х.дә каталитик процессларны үстерүдә мөһим роль уйный.

Татарстанда нефть составын системалы тикшерүләр 1940 еллар ахырында башлана (Е.А.Робинзон). Татарстанның төрле тектоник зоналары нефть геохимиясе, табигый битумнар химиясе һәм геохимиясе буенча тикшеренүләр үткәрелә (Г.П.*Курбский*). Югары үзлелекле нефтьләрне, нефть эшкәртү һәм Н.х. продуктларын (И.Н.*Дияров*, М.С.*Вигдергауз*), нефть фракцияләренең төркемчә химик составын тикшерү ысуллары эшләнә, бу составның нефть продуктларының үзлелегенә тәэсире (Р.А.Всеробянц) өйрәнелә. Яңа фәнни юнәлеш — калдык нефтьләр химиясенә нигез салына (Г.В.Романов).

Татарстанда Н.х. сәнәгате үсешенә нефть һәм иярчен газ запасларының зурлыгы, табигый битумнар һәм үзле нефтьләрнең бай чыганаклары булу, Н.х. пр-тиеләре төзелеше (ясалма каучук з-ды, «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин» з-длары), ш.у. фәнни-тикшеренү эшләрен оештыру ярдәм итә. Парафинлы һәм алкилароматик углеводородларны сыек фазада оксидлаштыру эшләрен интенсивлаштыру буенча фәнни юнәлеш формалаша (В.В.Несмелов). Нефть һәм газны күкертле катнашмалардан чистарту технологияләре (Ә.М.*Мазһаров*), углеводородларны изомерлаштыру, гидрогенлаштыру, дегидрогенлаштыруның каталитик процесслары (Р.И.*Измайлов*), углеводородлар һәм күкертле кушылмаларны каталитик оксидлаштыру (Н.М.*Лебедева*, Х.Э.*Харлампиди*), ацетиленлы һәм олефинлы углеводородларны каталитик гидрогенлаштыру, этилбензолны эпоксидлау, дегидрогенлаштыру, изобутиленны гидратлаштыру процесслары (Б.Р.*Серебряков*, А.Ш.*Зыятдинов*, Х.Э.Харлампиди), чит реакцияләрне булдырмый калу, полимерлаштыру, термополимерлаштыру, үзлегеннән полимерлаштыруны ингибирлау ысуллары (А.Г.*Лиакумович*, Н.П.*Борейко*, Б.Е.*Иванов*, Я.А.*Левин*), табигый битумнарны эшкәртү технологияләре һәм аппаратлары, битумнар һәм биополимер материаллар модификаторларын җитештерү технологияләре (И.Н.Дияров, А.Ф.Кемалов) эшләнә. Ясалма каучук мономерлары җитештерүдә каталитик системалар (П.А.*Кирпичников*, Б.Р.Серебряков, А.А.*Петухов*, В.А.*Курбатов*, А.Ш.Зыятдинов), Н.х. җитештерүендә күп тонналы чит продуктларны эшкәртү һәм рациональ файдалану процесслары (Т.И.*Лонщакова*) тәкъдим ителә. Н.х. буенча фундаменталь һәм гамәли тикшеренүләр РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында, Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, «Түбәнкаманефтехим» АҖ фәнни-технол. үзәгендә, Казан ун-тында, «Казаноргсинтез» АҖдә алып барыла. Фәнни эшкәртмәләр «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин», «Казаноргсинтез», Казан ясалма каучук з-дында, ТР һәм РФнең башка пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә.

*Әд.:* П е т р о в а А.А., Л и ф ш и ц И.М., Ц и т р и н а Л.Н. Большая химия Татарии. К., 1967; Д а л и н М.А. Пути развития нефтехимии. Баку, 1989; Я к у ш е в И.Я. Основные направления развития нефтехимической промышленности Республики Татарстан. К., 2003.

*И.Н.Дияров, Г.В.Романов.*

**НЕФТЬ ХИ́МИЯСЕ СӘНӘГАТЕ́**, авыр индустриянең башлыча нефть, табигый һәм иярчен нефть газларын эшкәртү продуктлары нигезендә синтетик материаллар һәм эшләнмәләр җитештерүче тармагы.

Татарстан Н.х.с. углеводород чимал (әйдәп баручы пр-тиеләре: «*Татнефть*» АҖнең «Татнефтегазпереработка» идарәсе, «ТАИФ-НК»), төп органик синтез продуктлары — изопрен, стирол, бутадиен һ.б. — һәм алар нигезендә материаллар — ясалма *каучуклар*, пластмасса, сумалалар һәм сүсләр (*«Түбәнкаманефтехим», Казан «Органик синтез» ачык акционерлык җәмгыяте, Казан ясалма каучук заводы*, «НефтеХимСэвилен»), корым (Түбән Кама техник углерод з-ды), резин эшләнмәләр — автомобиль шиннары, резина-техник эшләнмәләр, аяк киемнәре (*«Түбәнкамашин»*, Түбән Кама йөк машиналары шины з-ды, *«Кварт»*, *«Эластик» заводы»*), технол. сыеклыклар, лак-буяу материаллары һ.б. төр продукция җитештерүче, технол. яктан үзара бәйләнешле пр-тиеләр комплексын үз эченә ала. Н.х.с. респ-кадагы куәтле фәнни-тикшеренү потенциалына һәм инженер-техник кадрлар әзерләү җирлегенә таяна. Н.х.с.нең 50 дән артык эре һәм урта, 500 дән артык кече пр-тиеләре, башлыча, Казанда һәм Түбән Камада тупланган, аларда 40 меңнән артык кеше эшли.

Татарстанда Н.х.с. — югары технологияле тармак. Углеводород чималын эшкәртеп, кирәкле продуктлар җитештергәндә катлаулы химик реакцияләр — пиролиз, оксидлау, алкиллау, дегидрирлау, гидрирлау, галогенлау, полимерлау, нитритлау, сульфатлау һ.б. кулланыла. Н.х.с. пр-тиеләренә җитештерүнең зур колач алуы һәм эшләнгән продукциянең чисталыгына карата аерым таләпләр, технол. процессларның өзлексезлеге, бер үк вакытта бара торган берничә реакцияне файдалану (оксидлаучы аммонолиз, оксидлаучы дегидрирлау һ.б.), җитештерү процессларының һәм катлаулы химия-технол. комплекслары б-н идарә итүнең югары дәрәҗәдә автоматлаштырылуы хас. Аерып алу һәм чистарту процессларының әһәмияте зур, шул сәбәпле пр-тиеләрнең төп фондлары бәясенең 20% ка кадәрге өлеше ректификация җиһазларына туры килә, бүленү процессларына сарыф ителгән энергия чыгымнары продукция үзкыйммәтенең 50% ын һәм аннан да күбрәген тәшкил итә. Зур күләмдәге сәнәгый калдыкларны һәм атмосферага чыккан зарарлы матдәләрне чистарту һәм утильләштерү катлаулы технол. мәсьәлә булып кала.

Татарстан терр-ясендә *нефть-газ эшкәртү сәнәгатенең* беренче пр-тиеләре 19 йөз ахырында барлыкка килә. Казандагы Башмаков һәм Е.Гордеева з-дларында урам фонарьлары өчен газ һәм керосин аерып алалар. 1930–40 елларда анда азык спиртыннан ясалма каучук һәм резина-техник эшләнмәләр җитештерүче заводлар төзелә. Татарстанда Н.х.с.нең интенсив үсешенә КПСС ҮКның май Пленумы (1958) карарлары, КПСС ҮКның һәм СССР МСның шул ук елның 23 июлендә кабул ителгән «1958–1965 елларда халык һәм сәнәгать ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен ясалма һәм синтетик сүсләр, пластик массалар һәм башка синтетик материаллар һәм эшләнмәләрне җитештерүне тизләтү турында» карары башлангыч бирә. Соңгысында, нефтьнең һәм иярчен нефть газының зур запаслары, җитәрлек күләмдә электр энергетикасы базасы, су юллары һәм тимер юллар, химия производствосын оештыруда бай тәҗрибә, квалификацияле кадрлар булуы исәпкә алынып, респ-ка терр-ясендә нефть-газ чималыннан полимер материалларның яңа төрләрен җитештерүче куәтле пр-тиеләр төзү күздә тотыла. Татарстанда җитештерү объектлары һәм аларга өстәмә социаль объектлар төзелешен оештыруда, хезмәт, техник һәм матди ресурсларны туплауда КПСС өлкә оешмасының җитәкче ор-

ганнары зур роль уйный. Миңлебай газ-бензин з-ды (к. *Миңлебай газ эшкәртү заводы*) төзелү нәтиҗәсендә респ-када нефть химиясенең чимал базасына нигез салына. Шуннан соң полимер материаллар җитештерүче 2 куәтле пр-тие — Казан органик синтез з-ды һәм Түбән Кама нефть химиясе комб-ты төзелә. Аларны төзегәндә төп игътибар көчәйтелгән куәтле эре тоннажлы җиһазлар һәм агрегатлар коруга, махсуслашкан производстволар булдыруга, иң яңа техник казанышларны файдалануга, каталитик системаларны камилләштерүгә, автоматлаштырылган идарә системаларын, эластомерлар һәм алардан эшләнмәләр җитештерү өчен агымлы-автомат линияләрне гамәлгә кертүгә юнәлтелә. 1963 тә — Казан һәм 1967 дә Түбән Кама пр-тиеләрендә беренче зур тоннажлы производстволар сафка баса; 1980 еллар башына, проектланган төп куәтләре файдалануга тапшырылганнан соң, бу пр-тиеләр СССР Н.х.с.дә әйдәүче урыннарга чыгалар. Тамырдан реконструкцияләнгәннән соң (1965), Казан ясалма каучук з-ды тулысынча нефть химиясе чималын куллануга күчә, бу — каучукларның һәм резина катнашмаларның яңа төрләрен эшләп чыгаруны үзләштерү, продукциянең үзкыйммәтен 3 тапкыр киметү мөмкинлеген бирә. 1969 да Түбән Кама шин з-дын төзү башлана, 1991 дә анда илнең шин җитештерү сәнәгате тарихында иң югары күләмгә ирешелә. 1980 еллар ахырында «Түбәнкаматехуглерод» з-ды сафка баса. Н.х.с. пр-тиеләре файдалануга тапшырылу нәтиҗәсендә 1960–90 да Татарстан химия сәнәгате продукциясе күләме 21,5 тапкыр арта һәм респ-ка сәнәгате продукциясенең гомуми күләменең 20,4% ын тәшкил итә; респ-ка сәнәгатенең төп фондларында тармакның өлеше 7,8% тан 20% ка кадәр арта. 1990 да җитештерелгән продукция (мең *т*): синтетик сумала һәм пластмассалар — 345,4, полиэтилен — 335,5, торба һәм үткәргеч торба детальләре — 33,1, ясалма каучук — 434,6, формалы һәм формасыз резина-техник эшләнмәләр — 4,9; металл б-н үрелгән шланглар — 4,7 млн. *м*, автомобиль шиннары — 12,3 млн. данә.

Респ-када Н.х.с. формалашу нәтиҗәсендә фәннең *нефть химиясе* һәм *органик химия* кебек өлкәләре интенсив үсеш ала, синтетик материалларны җитештерү һәм кулланудагы технол. процесслар өлкәсендә теоретик һәм гамәли эшләр җәелдерелә. Күп кенә фәнни-тикшеренү ин-тлары оештырыла (хәзер Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты, к. *Бөтенроссия углеводород чималы институты*, *Органик һәм физик химия институты*, *Полимерлар һәм махсус каучуклар институты*), югары уку йортларында (хәзер Казан технол. ун-ты, Казан ун-ты, Түбән Кама химия-технол. ин-ты һ.б.) полимер материаллар, алардан ярымпродуктлар һәм эшләнмәләр җитештерү өлкәсендә квалификацияле кадрлар, химия машиналары төзелеше һәм автоматлаштыру чаралары буенча белгечләр әзерләү өчен яңа факультетлар һәм белгечлекләр ачыла.

1990 елларда, башка тармакларда сәнәгый җитештерү кимегән вакытта, Татарстан Н.х.с. үз потенциалын, эчке һәм тышкы базарларда тоткан урынын саклап кала. 1990 елларның 2 нче яртысында, уңайлы базар конъюнктурасы һәм нәтиҗәле төбәк сәнәгать сәясәте шартларында, җитештерүнең үсеше, продукциянең яңа төрләрен үзләштерү, инвестицияләрне актив стимуллаштыру, углеводород чималын респ-каның үзендә үк эшкәртү дәрәҗәсен күтәрү һәм эзлекле рәвештә нефть чималын, ярымфабрикатларны читкә чыгарудан әзер продукция экспортлауга күчү өчен яңа оештыру формаларын тудыру башлана. Тармак б-н идарә итү инструменты сыйфатында, ш.у. нефть чыгару һәм нефть химиясе сәнәгатендә дәүләт йогынтысын саклау максатында «Татнефтехиминвестхолдинг» төзелә (1995), аңа Н.х.с. пр-тиеләренең дәүләт акцияләре тапшырыла. Н.х.с. өчен дәүләт ярдәме чаралары: чимал һәм нефть химиясе продукциясе б-н үзара тәэмин итешү юнәлешендә республика эчендә интеграцияне көчәйтү, чимал, нефть химиясе ресурслары һәм әзер продуктлар җитештерүчеләр арасында бәяләрне пропорциядә тоту чаралары, ел саен читтән углеводород чималы җибәрүчеләр б-н килешүләр төзү, энергия чыганаклары тарифларын көйләү, салым ташламалары, инвестицияләрнең дәүләт тарафыннан гарантияләнүе, ТР нефть-газ химиясе комплексының 1999–2003, 2004–08 һәм 2010–14 елларга исәпләнгән үсеш программаларын эшләү һәм гамәлгә кертү зур әһәмияткә ия. Н.х.с.ндә 2000 еллардагы структур үзгәрешләрнең берсе — тармакка «Татнефть» («Түбәнкамашин», «Түбәнкаматехуглерод»), «ТАИФ» («Түбәнкаманефтехим», «Казаноргсинтез», «ТАИФ-НК»),«Татгазинвест» (Казан ясалма каучук з-ды) кебек эре стратегик инвесторларның килүе. Н.х.с.дә кече һәм урта пр-тиеләрнең роле арта. 2000–07 дә «Данафлекс» (бөгелүчән төрү материаллары җитештерү), «Техстрой» (полиэтилен торбалар), «СафПласт» (поликарбонат плитәләр) компанияләре РФ базарында әйдәп баручы урыннарны били. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын җәлеп итеп яңа производстволар оештыру юлы б-н нефтьне һәм нефть химиясе чималын эшкәртүне тирәнәйтү һәм өстәлгән бәяне арттыру өчен эре нефть химиясе пр-тиеләре җирлегендә технопарклар челтәрен оештыру башлана (Түбән Кама сәнәгый округы, «Кама Аланы» индустриаль паркы, «Химград» технополисы һ.б.). Респ-ка эчендә нефть химиясе пр-тиеләренең «Нәфис Косметикс», «КамАЗ», «АлАЗ» ЖБ АҖләре һ.б. б-н кооперациясе үсеш ала.

Респ-када барлык сәнәгать инвестицияләренең 30% ы чамасы Н.х.с. өлешенә туры килә. Эре инвестиция программалары арасында — этилен комплексларын («Түбәнкаманефтехим» һәм «Казаноргсинтез») модернизацияләү, бер стадияле синтез алымы нигезендә ясалма каучуклар, полимерлар, гади полиэфирлар, неоноллар, изопрен эшләп чыгаручы яңа производстволар оештыру, ш.у. полиуретан системалары, бәрелүгә чыдам полистирол, галобутилокаучуклар, синтетик майлар җитештерү («Түбәнкаманефтехим»), газ тәэминаты өчен торбалар, металл-пластик торбалар, катнашмалы термоэластопластлар, түбән басымлы полиэтиленнан техник углерод концентратлары, яңа маркалы полиэтилен плёнка диэмульгаторларының яңа төрләрен («Казаноргсинтез») эшләп чыгаруны үзләштерү, Италиянең «Пирелли» фирмасы технологиясе нигезендә радиаль шиннар җитештерү («Түбәнкамашин»). Кайбер проектлар Казан ясалма каучук з-дында һәм «Кварт» АҖдә гамәлгә ашырыла. Түбән Камада еллык куәте 1 млн. *т* булган яңа этилен комплексын, АБС-пластиклар җитештерү з-дын, Казанда метилхлорсилан җитештерү з-дын төзү эшләре бара.

2011 елда Н.х.с. продукциясенең төп төрләрен чыгару күрсәткечләре: пластмассалар — 1,4 млн. *т*, ясалма каучук — 567 мең *т*, этилен — 1 млн. *т*, стирол — 198,7 мең *т*, полимер торбалар, җиңсәләр һәм детальләр — 68,5 мең *т*, полимер плитәләр һәм плёнкалар — 62,6 мең *т*, резин җиңсәләр — 16,7 млн. *м*, автомобиль, а.х. һ.б. техника өчен шиннар — 11 млн. данә. Тармакның гомуми җитештерү күләме 200 млрд сум (ТРның гомуми җитештерү күләменең 20% тан артыгы).

ТРның Н.х.с.нә гомумроссия химия продукциясе күләменең 11% тан, ш.и. ясалма каучукның 40% тан артык өлеше, автомобиль шиннарының 30% ы, полистиролның 60% ы, полиэтиленның 50% ы тирәсе, галабутилкаучукларның, поликарбонат һәм сәвиленның 100% ы туры килә.

Татарстан Н.х.с. пр-тиеләре эшләнмәләрнең күп кенә төрләрен җитештерү буенча Россиядә әйдәүче урыннар били. Алар өлешенә илдә чыгарылган пластик торба һәм торбаүткәргечләрнең термопласт детальләренең 40% ы, полиэтиленның 35% ы чамасы, автомобиль һәм башка көпчәкле техника шиннарының 30% тан артыграк өлеше, ясалма каучукларның 30% чамасы, синтетик сумалалар һәм пластмассаларның 15% чамасы туры килә.

Нефть химиясе пр-тиеләре күп кенә муниципаль бюджетларны һәм республика бюджетының шактый зур өлешен формалаштыра, киң колачлы социаль программаларны гамәлгә ашыра.

*Әд.:* Нефтегазохимический комплекс Татарстана: Стратегическое управление. Конкуренция. Инвестиции. К., 1998; Перспективы и направления развития нефтехимической и нефтеперерабатывающей промышленности. К., 2004.

*С.Г.Белов.*

**НЕФТЬ ҺӘМ ГАЗ ГЕОЛО́ГИЯСЕ**, Җир астында нефть һәм газ ятмаларының урнашу закончалыкларын һәм формалашу шартларын, башлангыч (табигый) торышта чыганакларның геол. төзелеше үзенчәлекләрен өйрәнүче фән; геология бүлеге. Н.һ.г.г.нең теоретик нигезе соңгы унъеллыкларда киңәя һәм тирәнәя бара. Гомуми геол., химия, биол., икътисад, матем. һ.б.ның күп кенә бүлекләре өлешчә яки тулысы б-н аның фәнни тикшеренүләрендә кулланыла.

Н.һ.г.г.нә, аерым алганда, Идел-Урал төбәгендәге чыганакларны эзләү һәм разведкалауга — И.М.Губкин, Идел-Кама төбәгендәге эшләрдә — Казан ун-ты, ЦНИИгеолнеруд (1950–60 еллар), ТатНИПИнефть галимнә-

ре, ТР нефтенең составын өйрәнүдә РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-ты тикшеренүчеләре шактый өлеш кертәләр.

1930 елда Татарстанның беренче структур-геол. картасы булдырыла, Е.И.Тихвинская тектоника буенча хезмәтләрне гомумиләштерә, алар беренче тирән скважиналарны урнаштыру өчен нигез була. Нәтиҗәдә, ТР терр-ясендә максатчан нефть эзләү эшләре башлана. 1940–50 елларда нефть үзлекләре һәм нефть геологиясе бүлекләре (СССР ФАнең Казан ф-лы), нефть кафедрасы (Казан ун-ты), Татарстан нефть фәнни-тикшеренү ин-ты (Бөгелмә ш.), «Татнефтегазразведка», «Татнефтегеофизика» трестлары оештырыла. ТР галимнәре күп кенә теоретик мәсьәләләрне хәл итәләр: нефть катламының фәзаи торышы ачыклана, ятмалар барлыкка килүне билгеләүче төп факторлар күрсәтелә; төп табигый ресурслар, аларның барлыкка килү һәм аларда нефтьле катламнарның урнашу шартлары ачыклана; нефть җыелу урыннарының урнашу закончалыклары, урнашуның фациальпалеогеографик, гидрохимик һәм тектоник критерийлары күрсәтелә; нефтьләрнең үзлекләре һәм аларның фәзаи үзгәрешләре билгеләнә; палеозойның традицион нефтьле утырмаларында углеводородлы чимал ресурслары фаразлана; нефть эзләү һәм разведкалау эшләренең, ш.и. разведкалауга кадәр ачыкланган чыганакларны тикшерүнең нәтиҗәле методикасы эшләнә. ТР геологлары Рус платформасы кристаллик фундаментының борынгы токымнарында углеводород ятмаларын эзләүнең традицион булмаган юнәлешләрен өйрәнү, Пермь утырмаларының битумлылыгын тикшерү, нефть һәм газ барлыкка килү мәсьәләләрен фәнни нигезләү, җир астында углеводород ятмаларын эзләүнең традицион булмаган борынгы юнәлешләрен үстерү б-н шөгыльләнәләр. *Р.Х.Мөслимов.*

**НЕФТЬ ЧЫГАРУ́**, нефть сәнәгатенең Җир астыннан нефть һәм газ чыгару б-н шөгыльләнүче тармагы. Н.ч.ның бурычлары: нефть чыганакларын рациональ эшкәртү, чыгарылган продукцияне җыюны оештыру һәм алдан эшкәртү — аны күчерү-кудыруга әзерләү (нефтьне тоздан, судан арындыру, стабильләштерү). Эшкәртү объектлары — нефть һәм газ ятмалары; чимал скважиналардан, сирәк кенә шахталардан һ.б. тау казылмаларыннан чыгарыла. Нефтьне скважиналардан чыгару 19 йөз уртасыннан киң кулланыла башлый. Дөньяда беренче нефть скважинасы Баку тирәсендә бораулана. 1855 елда Себер тау сәнәгатьчесе Сидоров Ухта тирәсендә бораулау эшләре башлый. Әмма, кабул ителгәнчә, дөнья нефть сәнәгатенең оеша башлавы 1859 га, Пенсильваниядә 21,2 *м* тирәнлектәге беренче нефть скважинасы бораулаган вакытка туры килә. Россиядә беренче нефть фонтаны Кудако елгасы (Кубань елгасының кушылдыгы) үзәнендә 1866 да күтәрелә (скважина 1864 тә бораулана, шул вакыттан Россия нефть сәнәгате тарихы башлана). Дөньяда Н.ч. 1859 дагы 1 мең *т* дан 1900 дә 19,8 млн. *т* га һәм 2012 тә 4,3 млрд. *т* га кадәр арта. Беренче йөз елда аны чыгару күләме буенча АКШ — 1 нче, Россия 2 нче урынны били, 1898–1901 дә (12 млн. *т* чамасы), 4 ел дәвамында, ул дөньяда 1 нче урында була. Алдагы чорда Н.ч. кими, 1928 дә генә рев-циягә кадәрге дәрәҗәгә ирешелә. СССРда 1940 та нефть 31,1 млн. *т* чыгарыла; 1987 дә иң зур күрсәткеч — 624 млн. *т* дан артык, ш.и. РСФСРда 570 млн. *т* чамасы. 1990 еллар уртасында Россиядә елына газ конденсатлы 500 млн. *т* дан артык нефть чыгарыла, 2006 да — 480 млн. *т* (дөньяда 1 нче урын). Чыгарылган нефть күләмен 1 кешегә күчереп исәпләгәндә, РФ нефть чыгаручы илләрнең беренче унлыгына керә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында нефть эзләү һәм чыгару, нефть продуктлары сәүдәсе б-н берничә фирма һәм аерым затлар шөгыльләнә: Л.Шандор, «Бертуган Нобельләр», «Мазут», «Волга», «Дёмин һәм К°» һ.б. 1918 дә Россиядә Нефть комис-ты, соңрак Баш нефть ком-ты төзелә, «Казан нефть секциясе» оештырыла, шул ук елда ул Казан нефть ком-ты, 1922 дә Бөтенроссия нефть синдикатының Казан район конторасы итеп үзгәртелә. Шөгер (1943), Баулы (1946), Ромашкино (1943–48) чыганаклары һ.б. ачылганнан соң беренче нефть промыселлары (НГДУ) оештырыла. Н.ч. бик тиз үсә (елга млн. *т*): 0,8 (1950), 103,7 (1975), соңрак ул 23,8 гә кадәр кими (1994), аннары 31,9 га кадәр арта (2007). 1970 елларда Н.ч.ның суммар күрсәткече буенча Татарстан дөньяда 7 нче (1 кешегә күчереп исәпләгәндә — 5 нче), 2002 дә 10 нчы урынны били. 2007 нең 1 сентябренә ТРда 3 млрд. *т* дан артык, ш.и. Ромашкино чыганагыннан — 2,2 млрд. *т* чамасы, Яңа Елховой чыганагыннан — 0,28 млрд. *т* га якын, Баулы чыганагыннан — 0,12 млрд. *т* дан артык, Бондюг чыганагыннан 0,06 млрд. *т* дан артык нефть чыгарыла. Сәнәгый нигездә чыгарылырлык калдык запаслар якынча 1 млрд. *т*, ләкин аларның күп өлешен чыгару кыен. Чыгарылырлык нефть запасларын суыртып алу мөмкинлеге якынча 30 елны колачлый. Тикшерелмәгән ресурслар (чыгарылырлык запаслар) 1,4 млрд. *т* чамасы. Н.ч. барышында иярчен газ да чыгарыла (елга якынча 0,7–0,9 млрд. $м^3$). Татарстанда 60 ел эчендә 100 млрд. $м^3$ дан артык күләмдә газ чыгарылган. 20 йөз ахырыннан ТРда нефть һәм газ чыгару б-н 30 лап нефть компаниясе шөгыльләнә; аларның иң эреләре — «Татнефть», «Татех», «Татнефтеотдача», «Татойлгаз», «Геотех». 2014 нең башына 160 тан артык чыганак эшкәртелә. Нефть — Түбән Кама (елга 7 млн. *т*) һәм Кичү (400 мең *т*) нефть куу з-дларында, иярчен газ Миңлебай газ эшкәртү з-дында эшкәртелә. Нефть-газ сәнәгате базасында нефть химиясе пр-тиеләре — «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин», «Казаноргсинтез» һ.б. эшли. 1963 тә Татарстанда нефть чыгару техникасы җитештерүче пр-тиеләр (*Нефть-газ машиналары төзү сәнәгате*, «*Нефтемаш» з-ды*) төзелә. Ш.у. к. *Нефть-газ чыгару сәнәгате*.

*Әд.:* Щ е л к а ч ё в В.Н. Отечественная и мировая нефтедобыча: История развития, современное состояние и прогнозы. М., 2001.

*Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков.*

**НЕФТЬ-ГАЗ МАШИНАЛАРЫ́ ТӨЗҮ́ СӘНӘГАТЕ́**, машиналар төзүнең нефть-газ промыселлары техникасын җитештерүдә специальләшкән тармагы. Татарстанда Н.-г.м.т.с. *нефть-газ чыгару сәнәгатенә* хезмәт күрсәтүче ремонт оешмалары җирлегендә оеша башлый. Н.-г.м.т.с.нең беренче пр-тиеләре — *Бөгелмә механика заводы* (1956 елда төзелеш механизмнарын ремонтлау з-ды җирлегендә оештырыла), Бөгелмә «*Нефтеавтоматика*» тәҗрибә з-ды (1959 да нигезләнә), Бөгелмә электротехника җиһазларын ремонтлау з-ды (1962 дә җиһазларны төзәтү остаханәләре һәм төягеч электр двигательләрен ремонтлау участогы җирлегендә төзелә). 1960 та Казан компрессорлар з-дында (к. *Казан компрессор машиналары төзү заводы*) нефть чыгару һәм иярчен газларны кудыру өчен үзәктән куулы компрессорлар җитештерелә башлый (ел саен яңа 4–5 төр гамәлгә кертелә). 1960 еллар уртасында Н.-г.м.т.с. сәнәгатьнең мөстәкыйль тармагы булып бүленеп чыга, аның пр-тиеләрендә нефть-газ чыгару җиһазларын комплектлы технол. линияләрдә һәм макс. завод әзерлеге дәрәҗәсендә җитештерүгә керешәләр. 1960 еллар ахыры — 1970 елларда нефть-газ чыгару җиһазлары штангасыз насослар з-дында һәм спиральле-җөйле торбалар ясау базасында (Әлмәт ш.), «Газспецмашремонт» һәм «Нефтеавтоматика» (Лениногорск ш.), «*Нефтемаш*» (Әлмәт ш., Азнакай штп.), Алабуга арматура з-дларында эшләнә. 1980 еллар уртасына Татарстанда 12 Н.-г.м.т.с. пр-тиесе исәпләнә. Ш.у. «*Татнефть*» ҖБдә нефть чыгару җиһазларын төзәтү базасы һәм бу җиһазларның аерым өлешләрен җитештерү үсеш ала. 1981–85 тә республикада тармак җитештерүенең күләме 198% ка арта. Н.-г.м.т.с. продукциясе Сов. Союзының нефть чыгарылган барлык төбәкләренә һәм дөньядагы 16 илгә җибәрелә (экспорт 1962 дә Бөгелмә механика з-дының җылылык күчерү җиһазларын Болгариягә чыгарудан башлана). Бөгелмә электротехника җиһазларын (электр двигательләре, егәрлекле трансформаторлар һәм трансформатор подстанцияләре, шартлаудан саклаулы электр җылыткычлары һ.б.) ремонтлау з-ды СССР Нефть сәнәгате министрлыгының бу юнәлештәге төп пр-тиесе була. 1982 дә Әлмәттә нефть чыгару өчен илдәге бердәнбер батырылма насослар һәм электр двигательләре з-ды файдалануга тапшырыла.

Җирле шартларга яраклы яңа нефть чыгару техникасын эшләү *Татарстан нефть машиналары төзү институтына* (ТатНИИнефтемаш), *Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институтына* (ТатНИПИнефть), *Үзәктән куглч һәм роторлы компрессорлар институтына*, Вакуумлы машиналар төзү фәнни-тикшеренү ин-тына (к. *Вакуummаш*), «Союзнефтепромхим» (хәзер Нефть промыселы химиясе фәнни-тикшеренү ин-ты) һәм «Нефтепромавтоматика» фәнни-җитештерү берләшмәләренә (икесе дә Казанда) тапшырыла. Алар тарафыннан җирле һ.б. пр-тиеләрдә серияләп җитештерүгә кертелгән, катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру өчен пар яки төрле химик ре-

агентлар ясаучы һәм кудыручы блоклы һәм күчмә җайланмалар; табигый битум һәм югары үзлелекле нефть чыгарганда катлам эче яндыруларын тудыру, шельфлардагы нефть ятмаларын үзләштерү скважиналарын сынау һәм файдалану өчен эре комплекслар; берничә катламнан бер скважина аша нефть чыгаруда бергә-аерым файдалану өчен техник чаралар; нефтьне газ-лифт алымы б-н чыгару өчен автоматлаштырылган төркемле компрессор станцияләре; нефтьне, газ һәм суны җыю, әзерләү һәм күчерүнең промысел системалары өчен автоматлаштырылган блоклы җайланмалар; нефть чыгарганда күп хезмәт таләп ителгән эшләрне механикалаштыру, нефть промыселы техникасына хезмәт күрсәтү һәм аны ремонтлау өчен күчмә җайланмалар һ.б. җиһазлар эшләнә.

Базар мөнәсәбәтләренә күчү һәм СССР таркалу сәбәпле җитештерүчеләр һәм кулланучылар арасындагы хуҗалык бәйләнешләренең өзелүе нәтиҗәсендә тармакның күп кенә пр-тиеләрендә продукция җитештерү күләме азая. 1991–99 да Казан компрессор машиналары төзү з-дында, Лениногорск һәм Бөгелмә «Нефтеавтоматика» з-дларында, Бөгелмә электротехника җиһазларын ремонтлау з-дында, Әлмәт һәм Азнакай «Нефтемаш» з-дларында җитештерү 3–5 тапкыр кими. Шул ук вакытта, җитештерүне оештыруны яхшырту һәм заманча маркетинг сәясәте уздырылу нәтиҗәсендә, Әлмәт насослар заводында («*Әлнас*»), *Әлмәт торбалар заводында*, Баулы кабельләр з-дында тотрыклылык саклана, базарда аларның урыны ныгый. Сов. Союзы таркалу сәбәпле, ТР нефть чыгару сәнәгатен җиһазларның күп кенә төрләре б-н тәэмин итү туктала. Аларны яңа техник казанышлар нигезендә модернизацияләү б-н бергә республиканың үз пр-тиеләрендә эшләп чыгару җайга салына. «Татнефть» АҖ оешмаларында җитештерелүче нефть промыселы җиһазлары, узел һәм приборларының төрләре күпкә арта. Төрле эшләнмәләрне җитештерү оборона комплексы һәм машина төзүнең башка тармаклары пр-тиеләре — «АлАЗ» ЖБ (магистраль газүткәргечләр өчен кучмә ремонт техникасы һәм пневматик күчергечләр), Казан моторлар төзү ЖБ («Волга» газ кудыру агрегатлары; Казан компрессор машиналары з-ды б-н берлектә), А.М.Горький исем. Яшел Үзән з-ды һәм Казан дары з-ды (хәвеф-хәтәр ихтимал булган җирләрдә куллану өчен титан һәм ферросилидтан бикләгеч арматура), «Серго исемендәге завод», Казан «Союз» тәҗрибә КБ, «Татэлектромаш», «Электроприбор», «Радиоприбор» з-длары һ.б. тарафыннан үзләштерелә. 1990 еллар ахыры — 2000 елларда тармакта мөһим структур үзгәрешләр була. Бөгелмә механика, Баулы кабельләр, Түбән Кама механика, «Нефтемаш» (Азнакай), «Газспецмашремонт» (Лениногорск), пыяла-пластик торбалар (Казан) з-длары, ш.у. Татарстан нефть машиналары төзү ин-ты — «Татнефть» АҖ, Бөгелмә электротехника җиһазлары (хәзер Бөгелмә электр насослары) һәм Әлмәт инструментлар з-длары «*Әлнас*» АҖ карамагына күчә. Нефтьнең җиңел фракцияләрен тотучы җайланмалар, катламга реагентлар кудыручы насослар, контроль-үлчәү приборлары, скважиналар һәм нефть промыселы җиһазларын ремонтлау буенча узеллар, детальләр һәм запас частьлар, инструментлар җитештерүче төрле милек формасындагы 20 ләп кече һәм урта пр-тие барлыкка килә.

ТРда (башлыча, Әлмәттә, Бөгелмәдә, Казанда) 30 га якын Н.-г.м.т.с. пр-тиесе эшли. Кайбер пр-тиеләр Лениногорскида һәм Азнакайда урнашкан. Респ-ка Н.-г.м.т.с. «Татнефть» АҖнең җиһазларга һәм кирәк-яракларга ихтыяҗының 25% тан күбрәк өлешен тәэмин итә. Аның продукциясенә Көнбатыш Себердә, Башкортстанда, Самара һәм Пермь өлкәләрендә, РФнең башка төбәкләрендә ихтыяҗ зур, эшләнмәләр дөньяның 20 дән артык иленә, ш.и. Белоруссиягә, Казакъстан, Украина, АКШ, Германия, Бөекбритания, Канада, Норвегия, Кытай, Һиндстанга һ.б. илләргә чыгарыла. Дөньяда батырылма насослар җитештерүче иң эре пр-тие — «Әлнас» АҖ үз продукциясенең 30% ын чит илләргә җибәрә. «АлАЗ» ЖБ скважиналарны ремонтлауда кулланылучы күтәрү агрегатлары эшләп чыгаруда җитештерү күләме буенча РФдә икенче урынга чыга; бу агрегатлар «ЛУКОЙЛ», «Сургутнефтегаз», «ТНК-ВР», «Роснефть» компанияләренә һ.б.га озатыла.


Махсуслашкан учреждениеләр б-н берләттән, яңа техниканы эшләү һәм гамәлгә кертү б-н РФА КГҮ, Казан ун-ты, Казан техник һәм технол. ун-тлары галимнәре, «Татнефть» АҖ белгечләре шөгыльләнә. Тармак пр-тиеләре өчен кадрларны Казан технол. ун-ты, Әлмәт нефть ин-ты, Әлмәт политехник һәм Лениногорск газ техникумнары, 3 башлангыч һөнәри белем бирү учреждениесе әзерли.

*К.Ф.Фәсхетдинов, А.Ф.Садыйков.*

**НЕФТЬ-ГАЗ ЧЫГАРУ́ СӘНӘГАТЕ́**, ТР ягулык-энергетика комплексының нефть-газ һәм газ чыганакларын эзләү, эшкәртү, нефтьне әзерләү, аны күчерү һәм файдаланучыларга җибәрү, ш.у. нефть газын җыю һәм эшкәртү б-н шөгыльләнүче әйдәп баручы тармакларының берсе. Эшләүчеләр саны — 32 мең кешедән күбрәк (2011). Россиядә беренче нефть скважиналары 1864 елда Кубаньда бораулана, 1866 да аларның берсендә (Кудако елгасы үзәнендә) нефть фонтаны күтәрелә. Россиянең нефть сәнәгате тарихы шул вакыттан башлангыч ала. Нефть чыгару б-н монополияләр, башлыча, инглиз монополияләре шөгыльләнә. Татарстан терр-ясендә нефть 1868 дә Түбән Карамалы авылы (хәзер Чирмешән р-нына керә) тирәсендә табыла. Татарстанда нефть сәнәгыйнең нигездә 1943 нең 9 сентябрендә чыгарыла башлый — пар машинасы күчергече куелган тибрәлмә станок ярдәмендә *Шөгер чыганагының* 1 нче скважинасы файдалануга тапшырыла. Ел ахырына 641 *т* нефть чыгарыла. 1945 тә, шул ук чыганакта икенче, баерак нефть горизонты ачылганнан соң, республикада беренче Шөгер эреләндерелгән нефть промыселы оештырыла. 1945 нең ахырына анда нефть чыгару тәүлегенә 100 *т* га җитә.

Девон утырмаларында югары дебитлы нефть чыганаклары ачылу б-н, респ-ка нефть сәнәгате үсешендә яңа этап башлана. 1947 дә, 1946 да ачылган *Баулы чыганагы* базасында, «Туймазынефть» тресты системасында икенче — Баулы эреләндерелгән нефть промыселы оештырыла. 1948 дә запаслары буенча уникаль *Ромашкино чыганагы* ачылу Н.-г.ч.с.нең тизләтелгән үсешендә зур роль уйный. Республика нефтьнең сәнәгый запаслары буенча Идел-Урал нефть-газ провинциясенең башка төбәкләре арасында 1 нче урынны били. 1949 да Бөгелмәдә Татарстандагы беренче нефть чыгару тресты — «Татарнефть» төзелә (беренче управляющие — Ф.Г.*Ефремов*), аның составына элегрәк оештырылган Шөгер, Баулы эреләндерелгән нефть промыселлары һәм 1949 да яңа оештырылган Ромашкино нефть промыселы керә. 1950–58 еллар Н.-г.ч.с. Татарстан икътисадының әйдәп баручы тармагына әверелүе, илнең яңа иң эре нефть чыгару төбәге формалаша башлавы б-н характерлана. 1950 дә «*Татнефть*» берләшмәсе оештырыла, аның составына «*Баулынефть*», «Бөгелмәнефть» (к. «*Лениногорскнефть*») нефть чыгару трестлары, «Татбурнефть» бораулау тресты һ.б. оешмалар керә. 1953 тә нефть чыгару буенча республика Самара өлкәсен узып китә, 1955 тә Әзәрбайҗан ССР б-н тигезләшә, 1957 дә илнең нефть чыгаручы төбәкләре арасында 1 нче урынга чыга һәм шул позицияне 1974 кә кадәр саклап килә. 1970 тә елга 100 млн. *т* нефть чыгару дәрәҗәсенә ирешелә, бу күрсәткеч 7 ел дәвамында саклана. 1971 дә — беренче, 1981 дә — икенче, 2007 дә өченче миллиард тонна нефть чыгарыла. 2006 ның башына ТР терр-ясендә 140 ка якын яңа нефть чыганагы ачыла.

Яңа чыганакларны ачу заманча технологияләр һәм җиһазлар гамәлгә кертелү б-н бергә алып барыла. Башта Ромашкино нефть чыганагында, аннары *Яңа Елховой нефть чыганагында, Бондюг нефть чыганагында* һәм *Беренче Май нефть чыганагында* контур эченә су кудыру системасын куллану гамәлдәге нефть чыгару технологияләрен тамырдан үзгәртү, нефть чыганакларыннан файдалануның техник-икътисади күрсәткечләрен күпкә күтәрү мөмкинлеген бирә. Үзәктән куулы батырылма электр насослары һ.б. гамәлгә кертелә, 1980 елларда промыселларда технол. җайланмаларны автоматлаштыру башлана, аларны төзүдә индустриаль алымнар киң та-



ТРда 3 миллиард тонна нефть чыгаруга багышланган монумент. Әлмәт ш. 2007.

рала, нәтиҗәдә, 1950 ел б-н чагыштырганда, бораулау җайланмаларын төзү вакыты 46 көннән 5,5 көнгә кадәр кыскара. Яңа техника куллану һәм бораулауның оптималь режимнарын гамәлгә кертү бер бораугa туры килгән бораулау күләмен 5 тапкыр, механик тизлекне 10 тапкыр арттырырга мөмкинлек бирә. 1958 дә газ җыю системасын булдыру буенча киң программаны гамәлгә ашыру башлана. Аңа кадәр газ углеводородларының 75% ы факелларда яндырыла яки һавага чыгарыла. Нефтьне җыю, күчерү-кудыру системаларын герметиклаштыру, нефть әзерләү технологияләрен камилләштерү нәтиҗәсендә 1975 елга герметиклаштырылган схема буенча эшләүче скважиналарның өлеше гомуми фондта 96,7% ка, табигый газны куллану коэффициенты 95% ка кадәр (тармактагы уртача күрсәткечтән 1,5 тапкыр күбрәк) арта; эшкәртелүче табигый газ күләме 3,4 млрд. *м*$^3$ га җитә. 1990 да иярчен газ чыгару 1,27 млрд. *м*$^3$ тәшкил итә. 1990–2000 елларда «Татех» компаниясе республиканың барлык товарлыклы нефть паркларын нефтьнең җиңел фракцияләрен (газ конденсатын) тоту җайланмалары б-н җиһазлый.

ТР терр-ясендә нефть һәм газ чыгару, аларны эшкәртү б-н «Татнефть» АҖ һәм 30 лап нефть чыгаручы кече пр-тие («Татех», «Татнефтеотдача», «Татойлгаз», «Иделойл», «Алойл», «Троицкнефть» һ.б.) шөгыльләнә. 2011 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанда 32,5 млн. *т* (гомумроссия күрсәткеченең 6,5% ы), ш.и. «Татнефть» АҖ тарафыннан 25,9 млн. *т* нефть чыгарыла. Иярчен газ чыгару 858 млн. *м*$^3$ тәшкил итә. Хәзер нефть чыгаруның төп өлеше 6 эре чыганакка — Ромашкино, Яңа Елховой, Баулы, Бондюг, Беренче Май, Сабанчы чыганакларына туры килә. 2004 тән Әшәлче чыганагында югары үзлекле нефть чыгарыла. Кулланучыларга продукция магистраль үткәргеч торбалар буенча, тимер юл һәм су транспорты б-н җибәрелә (к. *«Дуслык»*, *Төньяк-Көнбатыш магистраль нефть үткәргечләре, Таттрансгаз*). 1963–74 тә нефть чыгару техникасы җитештерүче пр-тиеләр төзелә (*«Әлнас»*, *«Нефтемаш»*, *«Бөгелмә механика заводы»* з-длары һ.б.). 1978 дә «Союзнефтепромхим» бөтенсоюз фәнни-тикшеренү ин-ты оештырыла (к. *Нефть сәнәгате институты*). Чыганакларны рациональ эшкәртү мәсьәләләре б-н ТатНИПИнефть (1956 да Бөгелмәдә ачыла, к. *Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проект институты*) шөгыльләнә. Н.-г.ч.с. өчен кадрларны Казан (Идел буе) федераль ун-ты, Казан технол. ун-ты, Әлмәт нефть ин-ты, Әлмәт һәм Лениногорск нефть техникумнары, «Татнефть»нең кадрлар әзерләү үзәге һәм аның 8 ф-лы әзерли. Югары менеджерлык составы «Нефть-газ бизнесы институты» (Мәскәү) тарафыннан әзерләнә. Ш.у. к. *Әлмәт-Бөгелмә сәнәгать төйнәлеше, Газлаштыру, Нефть чыгару, Нефть.*

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; К н я з е в С.Л. Нефть Татарии: Страницы истории. К., 1981; Геологи-нефтяники в становлении и развитии нефтяной промышленности Татарстана. К., 2000; Г а т и я т у л л и н Н.С., Х а й р е т д и н о в М.Н., В о й т о в и ч Е.Д. Нефтеразведчики Татарстана: Дела и люди. К., 2002.

*Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Г.Я.Мәүлетова.*

**НЕФТЬ-ГАЗ ЭШКӘРТЎ СӘНӘГАТЕ́**, авыр индустриянең нефтьтән, нефть битумнарыннан, табигый газдан һәм нефть иярчен газыннан ягулык, майлау материаллары, электр изоляциясе чаралары, эреткечләр, юл өслекләре, төзелеш материаллары, *нефть химиясе сәнәгате* өчен чимал сыйфатында кулланыла торган углеводородлар җитештерүче тармагы. ТРда милекнең төрле формаларындагы, ш.и. уртак милектәге (4) 42 нефть-газ эшкәртүче пр-тие (алар арасында 6 эре, 22 кече пр-тие) исәпләнә, аларда 4,9 мең кеше эшли (2011).

ТР терр-ясендә өстәрәк ятучы нефтьне товарлыклы продукциягә әверелдерү буенча беренче омтылышлар 1850 елларда ясала. 1860 еллардан башлап Казан губернасының Тәтеш һәм Чистай өязләрендә, Самара губернасының Бөгелмә өязендә битумлы токымнарны эшкәртү һәм асфальт җитештерү өчен гудрон аерып алу пр-тиеләре барлыкка килә. Аларның хуҗалары арасында эшмәкәрләр Смолянинов, Глинский, Малакиенко, Америка сәнәгатьчесе Л.Ф.Шандор, «Траузе һәм Кº», «Дёмин һәм Кº», «Сызрань-Печера асфальт заводлары җәмгыяте», «Броун һәм Кº» (Бельгия), «Казан Ойл Филде» (Англия) компанияләре була. Шактый эре пр-тиеләр исәбенә «Сызрань асфальт заводы ширкәте»нең 1881 дә нигезләнгән Шөгер гудрон з-ды керә (30 дан артык кеше эшли), анда ел саен 6,5–15 мең пот продукция чыгарыла. 1882 дә Россиядә беренче тапкыр Зөя өязенең Печище авылында эшмәкәр Е.Гордеева нефть эшкәртү калдыкларыннан керосин җитештерүне оештыра. 1915–16 да шунда ук илдә беренче тапкыр каталитик пиролиз алымы б-н шартлаткыч матдәләр өчен бензол һәм толуол эшләп чыгару җайга салына. Казанда урам фонарьлары өчен нефтьтән (Башмаков з-ды, 1874–95 тә 15 кеше эшли), нефть һәм күмердән (Бельгиянең «Газ һәм электр» АҖнең газ з-ды, 1893 тә 32 кеше эшли) газ җитештерүче пр-тиеләр эшли; 1916 да «Газ һәм электр» АҖнең газ з-дында ш.у. салицил дару препаратлары җитештерү өчен нефть кудыру юлы б-н углеводородлар аерып алалар. 1918–21 дә национализация тудырган икътисади кыенлыклар аркасында тармак пр-тиеләре ябыла. 1924 тә Шөгер з-ды яңадан ачыла.

1950 елларда, *нефть-газ чыгару сәнәгатенең* барлыкка килүе һәм интенсив үсеш кичерүе нәтиҗәсендә, респ-када эре Н.-г.э.с. оеша башлый. Баулы газолин күмер адсорбциясе җайланмасы, 1953–66 да СССРдагы иң эре Миңлебай газ-бензин з-ды (к. *Миңлебай газ эшкәртү заводы*) төзелә, аларда элек яндырылган иярчен нефть газыннан органик синтез пр-тиеләренә җибәрелүче этан, пропан һ.б. газ фракцияләре, коммуналь-көнкүреш ихтыяҗлары өчен кысылган газ, ш.у. стабиль газ бензины һәм гелий җитештерәләр. Республиканың газ промыселларында газ җыю җайланмалары һәм газ кудыручы компрессор станцияләре, нефтьне комплекслы әзерләү җайланмалары һәм электр б-н сусызландыру җайланмалары челтәре булдырыла. Шөгер битум з-ды, табигый битумлы токымнарны эшкәртү б-н бергә, юл һәм төзелеш битумы, нефть чималыннан мастика һәм лаклар эшләп чыгаруны үзләштерә. 1962 дә газ җыю комплексы, Миңлебай һәм Шөгер з-длары «Татнефть» ҖБнең «Татнефтегаз» трестына берләштерелә. 1970 тә *«Иркеннефть»* НГДУында (Бөгелмә р-ның Карабаш штп) елга 30 мең *т* га исәпләнгән куәтле нефть-битум җайланмасы эшли башлый. 1960–70 тә «Казаноргсинтез» һәм *«Түбәнкаманефтехим»* ҖБләре сафка баса, алар ясалма каучуклар һ.б. нефть химиясе продуктлары җитештерүдә Миңлебай з-дыннан җибәрелгән чималны файдаланалар. Нефть эшкәртү з-дын төзү проекты эшләнә (гамәлгә ашырылмый). 1979 да «Түбәнкаманефтехим» ҖБдә нефтьне беренчел эшкәртү (елга 7 млн. *т*) һәм турыдан куылган бензин (этилен җитештерүдә төп чимал), ш.у. өстәмә продуктлар — мазут һәм дизель ягулыгы эшләп чыгару өчен ЭЛОУ-АВТ-7 җайланмасы кулланууга кертелә. 1990 да республикада нефтьне беренчел эшкәртү — 7,52 млн. *т*, нефть химиясе сәнәгате өчен бензин җитештерү — 1,63 млн. *т*, дизель ягулыгы эшләп чыгару — 1,5 млн. *т*, мазут 4,57 млн. *т* тәшкил итә. 1960 елларда Н.-г.э.с.нең фәнни мәсьәләләрен хәл итү өчен Казанда Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-ты (к. *Бөтенсоюз углеводород чималы институты*) оештырыла, кадрлар б-н тәэмин итү өчен Казан химия-технол. ин-тында нефть һәм газ эшкәртүнең химик технологиясе белгечләрен әзерләү башлана.

1990 еллар башында экология мәсьәләләренә зур игътибар бирелә башлый. 2005 елга «Татех» Россия-Америка пр-тиесе (Әлмәт ш.) респ-каның барлык товарлыклы нефть паркларын нефтьнең җиңел фракцияләрен (газ конденсатын) тоту җайланмалары б-н җиһазландыра. «Татойлгаз» пр-тиесе (Әлмәт ш.) скважиналар бораулаганда һәм нефть чыгарганда хасил булучы нефть шламнарын утильләштерү б-н шөгыльләнә. 1990 елларның 2 нче яртысыннан Н.-г.э.с.нең үсеше респ-када вертикаль интеграцияләнгән, нефть чыгару, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе продуктларын җитештерүне һәм сатуны үз эченә алган комплекс төзүгә, читкә чимал һәм ярымфабрикатлар чыгаруны әзер продукция экспортлау б-н алыштыруга, Татарстанда түбән сыйфатлы, күкерткә бай нефтьне эшкәртү күләмнәрен арттыру юлы б-н аны сатудагы югалтуларны киметүгә юнәлтелгән сәясәт б-н билгеләнә. 1999 дан ТРның нефть-газ комплексын үстерү программалары кабул ителә. Аларда төп үсеш индикаторларын эшләү, эре масштаблы инвестицияләр һәм инновацияләр проектларын гамәлгә ашыру, тармак пр-тиеләрен җитәрлек дәрәҗәдә чимал б-н тәэмин итү чаралары күздә тотыла. Тармак б-н идарә итүне координацияләү өчен «Татнефтехиминвест-холдинг» төзелә. 1995 тә *«Елховнефть»* НГДУында экологик яктан чиста «Петрофак» нефть эшкәртү җайланмасында (еллык куәте — 400 мең *т* нефть) бензин, дизель ягулыгы, ягулык-майлау материаллары, югары сыйфатлы юл битумы

эшләп чыгарыла башлый. 1999 да «Татнефтепром-Зүзәйнефть» НГДУында (Нурлат р-ны Мамык а.) 70 мең *т* чамасы нефть продуктлары, ш.и. юл һәм төзелеш битумы, бензин һәм дизель фракцияләре, ягулык мазут җитештерүгә исәпләнгән җайланма сафка баса. 2003 тә «Татнефть» һәм «Түбәнкаманефтехим» АҖләре Россиядә беренче гидравлика, трансмиссиядә кулланылучы майлар, ш.у. мотор майлары җитештерүче з-дны файдалануга тапшыралар. 1997–2009 да Түбән Кама шәһәрендә «ТАИФ-НК» АҖнең нефть эшкәртү һәм бензин з-длары комплексы төзелә. Анда респ-када беренче тапкыр нефтьне, газ конденсатын, табигый битумнарны тирән эшкәртү үзләштерелә, «Евро-4» экологик стандартлы автомобиль бензиннары һәм «Евро-5» экологик стандартлы дизель ягулыгы, авиация керосины, нефть химиясе чимала, юл битумнары, майлар, гранулы күкерт җитештерү оештырыла. 2011 нең декабрендә «Танеко» нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары комплексының беренче чираты: елына 7 млн. тоннага кадәр нефть эшкәртүгә, керосин, мич ягулыгы, мазут чыгаруга исәпләнгән ЭЛОУ-АВТ-7 җайланмалары һәм бензинны турыдан-туры куены тотрыклыландыру блогы эксплуатациягә кертелә. Төп инвесторы һәм координаторы «Татнефть» АҖ булган бу проект Түбән Кама шәһәрендә елына 14 млн. *т* га кадәр нефть эшкәртүгә сәләтле, 20 гә якын төрдәге ягулык, нефть химиясе өчен чимал һ.б. чыгара алырлык, илдәге иң зур нефть эшкәртү з-дларын сафка кертүне күздә тота.

Яңа зур нефть эшкәртү куәтләре төзелү нәтиҗәсендә 2000 нән 2011 гә кадәр респ-када нефтьне беренчел эшкәртү 5,9 млн. нан 10,7 млн. *т* га; дизель ягулыгы чыгару 1,15 млн. нан 2 млн. *т* га; автомобиль бензиннары 60 меңнән 650 млн. *т* га; ягулык мазуты 2,9 млн. нан 3,2 млн. *т* га; тармак җитештерүенең гомуми күләме 80,2 млрд. тан 158,6 млрд. сумга; нефть продуктлары экспорты 222,3 млн. нан 3,5 млрд. долларга кадәр арта. ТРда чыгарылган нефтьне эшкәртү 21,8% тан 33,4% ка; респ-каның гомуми сәнәгать продукциясе күләмендә Н.-г.з.с. пр-тиеләренең өлеше 1,6% тан 11,8% ка; респ-ка экспортында нефть продуктлары өлеше 9% тан 16% ка җитә. Н.-г.з.с. пр-тиеләре респ-ка һәм муниципаль бюджетлар формалаштыруга зур өлеш кертә.

*Әд.:* Нефть, газ и нефтехимия Татарии. К., 1979. Т. 2; К н я з е в С.Л. Нефть Татарии: Страницы истории. К., 1981; ТАИФ: сила во благо // Татарстан. 2006. № 10.

*С.Г.Белов.*

**НЕ́ФТЬНЕҢ ИЯРЧЕ́Н ГАЗЛАРЫ́**, Җир кабыгында нефть ятмалары өстендә (газ «эшләпәсе») һәм эрегән халәттә нефтьтә һәм катлам суларында очрый торган метан рәте углеводородлары һәм углеводород булмаган компонентлар катнашмасы. Метан рәтендәге углеводородлар метан (85–95%), этан, пропан, бутаннан һәм сирәк кенә пентаннан; углеводород булмаган компонентлар, башлыча, азот, углекислый һәм күкертле газлардан, су парлары, гелий һ.б.дан гыйбарәт. Н.и.г.ның яну җылылыгы уртача 32,7 *МДж/м*$^3$. Ятмаларда Н.и.г. катлам басымы астында ята, ул исә өстәрәк ятучы тау токымнары басымы һәм катлам сулары этеме нәтиҗәсендә хасил була. Н.и.г. ятмаларының урнашуында, нефтьнеке кебек, аерым җирлек яки зональлек күзәтелә. Н.и.г.ның яшь буенча таралу диапазоны — дүртенчел чордан архей-протерозойга кадәр, акбур чоры утырмаларында запаслар күбрәк; Татарстан терр-ясендә — девон һәм ташкүмер яшендәгеләр таралган. Чыганаклар — 10–20 *м* дан алып 8 *км* га (Төньяк Америка), запасларның төп өлеше — 2–3 *км* га, ТРда 1–2 *км* га кадәр тирәнлектә урнашалар. Дөньяда иректе газның һәм Н.и.г.ның сәнәгый запаслары 140 трлн. *м*$^3$ (РФдә шуның 37% ы, 1999) булган 18 мең тирәсе чыганак ачылган, дөньякүләм чыгару елына 2,3 трлн. *м*$^3$ (РФ дә 0,6 трлн. *м*$^3$) (к. *Янучан табигый газлар*) тәшкил итә. Татарстанда иректе газ булган чыганаклар табылмаган. Нефть чыганакларыннан газ нефть б-н бергә чыгарыла, 1 *т* нефтьтә 30–40 *м*$^3$ газ («газ факторы») була. 86 чыганак буенча Н.и.г. запасы якынча 19 млрд. *м*$^3$ (1999), чыгару — елына 0,86 млрд. *м*$^3$ (2011).

РФдә Газ б-н тәэмин итүнең бердәм системасы (ЕСГ) оештырылган, аңа ТР да керә. ЕСГ эшкәртелүче чыганакларны, газүткәргечләрне, компрессор станцияләрен, җир асты газ саклагычларын, урыннардагы газ тарату системаларын берләштерә. РФдә газүткәргеч магистральнең гомуми озынлыгы 140 млн. *км* дан артык. Республика терр-ясе аша Көнбатыш Себердән Европага газүткәргеч уза. Н.и.г. югары күрсәткечле энергия чыганагы һәм метанол, формальдегид, серкә к-тасы, ацетон һ.б. органик кушылмалар алу өчен кыйммәтле химик чимал буларак кулланыла.

*Әд.:* Ю с у п о в Б.М., В е с е л о в Г.С. Размещение нефтяных месторождений Татарии. М., 1973; Минеральное сырьё. Газы горючие: Справ. М., 1999.

*Э.Х.Рәхмәтуллин.*


**«НЕФТЯ́НИК ТАТА́РИИ»** («Татарстан нефтьчесе»), респ-ка газетасы. КПССның Татарстан өлкә ком-ты органы. 1956 елның 1 июленнән 1957 гә кадәр Казанда атнага 3 тапкыр рус телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Г.Е.*Беляев*. Нефть сәнәгатен һәм нефть пр-тиеләре төзелешен үстерү мәсьәләләрен яктырта, җитештерүне үстерү, ТАССР нефтьчеләре арасында партия-сәясәт, мәдәни агарту, профсоюз һәм комсомол эше мәсьәләләрен күтәрә. Респ-каның нефть р-ннарындагы шәһәр һәм посёлокларны (Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Азнакай һ.б. шәһәрләр) төзекләндерү темасына аерым урын бирелә. Газета нефтьчеләр тормыш-көнкүрешенә багышланган күп кенә очерклар һәм мәкаләләр бастыра.

*Р.А.Айнетдинов.*

**НЕХОТЯ́ЕВ** Алексей Николаевич (5.12.1879, Сембер ш. — 9.11.1927, Казан), хокук белгече, дәүләт эшлеклесе. Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1904). 1903 елда Казанда студентлар чуалышларында катнаша. 1904–06 да Казан округ мәхкәмәсендә хезмәт итә. 1906–17 дә Казан мәхкәмә палатасы округ антлы ышанычлысы ярдәмчесе. 1917 нең февраленнән — Казан җәмәгать куркынычсызлыгы ком-ты, майдан Казан губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советы башкарма ком-ты әгъзасы. 1917 нең октябрендә большевиклар ягында була. Окт. рев-циясеннән соң мәхкәмә эшләре буенча комиссар, юстиция комиссары ярдәмчесе, кассация мәхкәмәсе рәисе. 1918 дә Казан округ мәхкәмәсе рәисе, 1919–20 дә Казан губернасы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советының юстиция бүлеге мөдире. ТАССРны төзү буенча әзерлек эшләрендә катнаша. 1920–21 дә ТАССР юстиция халык комиссары. 1921 дән Татарстан куллануч ылар җәмгыятьләре берлегендә.

*Әд.:* Е м е л ь я н о в а И.А. Из истории судебной системы Татарской АССР. К., 1970; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*



А.В. Нечаев.

**НЕЧА́ЕВ** Алексей Васильевич (19.11.1864, Казан губ., Лаеш өязе Монастырь Урае а. — 26.8.1915, Петроград), геолог, географ, минералогия һәм геология д-ры (1898), проф. (1899). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1887), шунда ук эшли, Киев политехник ин-тының минерал. һәм геол. каф. профессоры, химия бүлеге деканы (1903–11). Дәүләтнең югары уку йортларына карата сәясәтен гаепләгәне өчен, 1911 елда ин-ттан чыгарыла. 1912 дән Геол. ком-тында (С.-Петербург). Казан һәм күрше губерналарның терр-яләрен геол.-геогр. тикшерүләр нигезендә, елга үзәннәре һәм субүләрләре рельефында асимметрияле формаларның килеп чыгышы турында топографик теория тәкъдим итә (1894, к. *Нечаев-Борзов теориясе*), Пермь системасы стратиграфиясенә нигез сала, Пермь системасы югары бүлеге төшенчәсен кертә, бу бүлекне өч өлешкә аеруны палеонтологик яктан нигезли. Урта Азиянең палеозой һәм Идел буеның Пермь (258 форма һәм төр, ш.и. 83 яңа) һәм кайнозой (170 форма һәм төр, ш.и. 77 яңа) утырмаларының фаунасын тасвирлый. Казан ун-ты геологлары б-н берлектә Казан губернасының геол. картасын төзи. Геол. фәне эволюциясе юлларын, Казан губернасы терр-ясендә фосфорит ятмаларын өйрәнә. Минералогия (1908), табигать белеме (1911), табигыять тарихы (1912) буенча һ.б. дәреслекләр авторы.

Х е з м.: Казанский и уфимский ярусы пермской системы // Геолог. вестн. 1915. Т. 1, № 1; Верхнепермские отложения // Геология России. 1921. Т. 2, ч. 5, вып. 3.

*Әд.:* С и л а н т ь е в В.В. А.В.Нечаев. К., 2003.

**НЕЧА́ЕВ-БОРЗО́В ТЕО́РИЯСЕ**, үзәннәр б-н киселгән тигезлекле өслек авышлыгы тәэсирендә елга үзәннәре сөзәклекләре асимметриясенең килеп чыгуы турында топографик теория. Өслек авышлыгы юнәлеше б-н



М.В.Нечкина.

туры килүче үзән сөзәклеге каршы як сөзәклеккә караганда шактый зур субүләр мәйданына ия, шунлыктан кар сулары һәм яңгыр агымнары б-н көчлерәк юыла һәм тизрәк сөзәкләнә. Каршы як сөзәклек текәлеген озаграк саклый. Теория Көнбатыш Кама алдын өйрәнгәндә — Казан ун-ты профессоры А.В.Нечаев (1894) һәм Көнчыгыш Европа тигезлегенең көньяк-көнбатышын тикшергәндә Мәскәү ун-ты профессоры А.А.Борзов (1913) тарафыннан эшләнә. Бер-берсенә бәйсез рәвештә, галимнәр елга үзәннәре асимметриясенең субүләр плато асимметриясе формалашуга китерүен һәм субүләр сызыкларның текәрәк сөзәклекләргә авышуын күрсәтәләр. Татарстан терр-ясендә елга үзәннәре сөзәклекләре асимметриясен аңлату өчен бу теория, эзлекле булуына карамастан, киң кулланыш тапмый.

*Әд.:* Н е ч а е в А.В. Геологическое описание северо-западной части Казанской губернии // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1894. Т. 25; Б о р з о в А.А. К вопросу об асимметрии междуречных плато. М., 1913.

*А.П.Дедков.*

**НЕЧА́ЕВА** Ирина Анатольевна (15.2.1961, Казан), спортчы (йөзү), СССРның спорт остасы (1975). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1982). «Локомотив» ирекле спорт җәмгыятенең 5 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнә (Казан), тренеры — А.Г.*Әхмәтов* (1970 тән). РСФСР халыклары спартакиадасы (1975, 1979), СССР халыклары спартакиадасы (1975), СССР беренчелекләре (1971, 1973, мәктәп укучылары арасында; 1975, яшүсмерләр арасында) чемпионы, БДБ чемпионатында (1992, ветераннар арасында), Бөтендөнья тимерьюлчылар берлегенең халыкара ярышларында (1975, 1977) җиңүче. Ветераннар арасында Европа (1997, 2003, бронза), дөнья (1998, көмеш) чемпионатларында медаль ала. Ветераннар арасында РФ, Россия кубогы чемпионатларында (1992 дән) берничә тапкыр җиңүче. 72 тапкыр ТАССР, 12 тапкыр РСФСР (100, 200 һәм 400 *м* лы дистанцияләрдә комплекслы йөзүдә) һәм СССР (1975, 1500 *м* лы дистанциядә ирекле йөзүдә) рекорды куя. 1982–88 дә Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лында, 1989–2005 тә Казан шәһәре Совет р-нының «Балалар академиясе» өстәмә белем бирү иҗади реабилитация бүлегендә укыта. 2005 тән «Планета-Фитнес» спорт-сәламәтләндерү клублары челтәрендә аква-фитнес буенча «мастер +» категорияле хосусый тренер (Казан).

**НЕЧКӘ́ САБА́К**, к е л е р и я (Koeleria), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, ике ярымшарның да тропиктан тыш поясларында һәм тропикларның биек тауларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Делявин Н.с.ы (K. delavignei), күгелҗем Н.с. (K. glauca) ара-тирә барлык районнарда очрыйлар; кикрикле Н.с. (K. cristata) — Кама аръягында; зур Н.с. (K. grandis), каты яфраклы Н.с. (K. sclerophylla) һәм ком Н.с.ы (K. sabuletorum) — респ-ка өчен сирәк төрләр. Нарат урманнарында, далаланган комлы сөзәклекләрдә, ачылган известьташларда, су баса торган болыннарда, урман буйларында үсәләр. 20–80 *см* биеклектәге үсемлекләр тыгыз кәсләр барлыкка китерәләр. Көпшә сабаклы, буынтыклы. Яфраклары — күгелҗем-яшел төстәге тар кыяк. Күп санлы башакчыклары кыска сапларда урнашкан, 2–5 чәчәкле, тар куе башаксыман себеркәчтә. Җимеше — бөртекчә. Май–июльдә чәчәк аталар. Июль–августта җимешләре өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Яшь үсемлекләр терлек азыгы булып тора. Күгелҗем Н.с. комнарны ныгыта. Каты яфраклы Н.с. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НЕ́ЧКИНА** Милица Васильевна (12.2.1899, Чернигов губ. Нежин ш. — 16.5.1985, Мәскәү), тарихчы, тарих фән. д-ры (1936), СССР ФА академигы (1958). 1911 елдан гаиләсе б-н Казанда яши. Казан Ксения хатын-кызлар гимназиясен тәмамлаганнан соң (1917), Казан ун-тының тарих-филол. ф-тына ирекле тыңлаучы сыйфатында кабул ителә, 1920 нең февраленнән студент. 3 нче курста проф. П.Г.Архангельский җитәкчелегендә «Рус тарихы икътисади материализм яктысында» («Русская история в освещении экономического материализма») темасы өстендә эшли башлый. Университетны тәмамлаганнан соң (1921), проф. П.Г.Архангельский җитәкчелегендә профессор дәрәҗәсенә әзерләү өчен калдырыла. Бер үк вакытта сәнгать-техник һәм политехник ин-тларда, Казан ун-тының эшчеләр ф-тында сәнгать социологиясе, тарихи материализм, политэкономия укыта. 1924 тән Мәскәүдә: Кызыл профессорлар ин-тының тарих бүлегендә ирекле тыңлаучы (1927 гә кадәр), соңрак Мәскәү югары уку йортларында укыта. 1934–54 тә Мәскәү ун-тында эшли, проф. (1935 тән). Бер үк вакытта, 1936 дан, СССР ФА каршындагы СССР тарихы ин-тында, 1961–71 дә тарих фәне тарихы секторы җитәкчесе. Хезмәтләре историографиягә, тарих методологиясе, декабристлар хәрәкәте һәм 19 йөз иҗтимагый фикер тарихы мәсьәләләренә карый. Россиядә 1850 еллар ахыры — 1860 еллар башындагы революцион вазгыятьне өйрәнү буенча тикшеренүчеләр төркеме, А.И.Герцен һәм Н.П.Огарёвның Ирекле рус басмаханәсе басмаларын («Колокол», «Полярная звезда» һ.б.) әзерләү б-н җитәкчелек итә. 1960–85 тә «Очерки истории исторической науки в СССР» басмасының баш мөхәррире. Сталин бүләге лауреаты (1948). Өч Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Русская история в освещении экономического материализма (Историографический очерк). К., 1922; А.С.Грибоедов и декабристы. М., 1951; Восстание 14 декабря 1825 г. М., 1951; Движение декабристов: В 2 т. М., 1955; Василий Осипович Ключевский: История жизни и творчества. М., 1974; Декабристы. М., 1982; Дневник М.В.Нечкиной: Казань и Казанский университет (1917–1924 гг.). К., 2003.

*Әд.:* Г р е б ё н к и н а А.Н. Научно-педагогическая деятельность М.В.Нечкиной в начале 20-х гг. (Казанский период): Дис. ... К., 1992; Историки России: Биографии. М., 2001; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*А.Н.Бикташева.*

**«НИ́ВА ТАТАРСТА́НА»**, к. *Татарстан авыл хуҗалыгы институты.*

**НИГЪМӘТҖА́НОВ** Линар Фәрит улы (25.10.1966, Владимир өлкәсе Владимир ш.), генерал-майор (2013). СССР Эчке эшләр министрлыгының Югары хәрби командирлар уч-щен (Орджоникидзе ш., 1986), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү, 1998), РФ Кораллы Көчләре Ген. штабы хәрби академиясен (2009) тәмамлый. Кораллы Көчләрдә 1987 елдан; 1987–95 тә РФ Эчке эшләр министрлыгы эчке гаскәрләренең — Себер, 1998–2011 дә Идел буе округында (2009–11 дә оператив бүлек башлыгы — штаб башлыгы урынбасары). 2011 дән РФ Эчке эшләр министрлыгының Самара эчке гаскәрләр берләшмәсе командиры. Төньяк Кавказда сугышчан хәрәкәтләрдә катнаша (2005–10). 2 нче дәрәҗә Бөек Пётр ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* З а й ц е в В.В. Знания реализуют на практике // На боевом посту. 2006. № 7.

**НИГЪМӘТҖА́НОВ** Мәхмүт Нигъмәтҗан улы (10.5.1930, Саба р-ны Олы Арташ а.), музыка белгече, педагог, сәнгать фән. канд. (1972), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979). Казан консерваториясен тәмамлый (1958). 1960–67, 1974–84 елларда СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1967–73 тә Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе. 1984–2003 тә Казан пед. ун-тының татар музыкасы һәм халык музыка уен кораллары каф. мөдире, проф. (1990 нан). Татар музыка фольклоры әсәрләрен туплаучы һәм өйрәнүче. Татар (1964, 1970, 1976, 1984) һәм рус (2003) халык җырларын туплап бастыра. Хезмәтләре татар музыка мәдәниятенә, музыка теориясе һәм тарихына, музыка психологиясе мәсьәләләренә карый. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1985).

Х е з м.: Музыкальный Татарстан. К., 1970; Народные песни волжских татар: Исслед. М., 1982; Татарская народная музыка. К., 2003.

*Әд.:* В ә л и е в М. Моң чишмәләрен эзләгәндә // Казан утлары. 1980. № 5; Б а х т и я р о в а Ч.Н. Нигмедзянов Махмут // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Махмут Нигмедзянов–70: Альбом-буклет. К., 2000.

**НИГЪМӘТҖА́НОВ** Харис Шәрип улы (22.4.1947, Казан), баянчы, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1986). 1973 елда Казан консерваториясенең халык музыка уен кораллары ф-тын тәмамлый. 1966–73 тә — балалар музыка мәктәпләрендә (Мөслим а. һәм Казан), 1973–77 дә Казан

пед. ин-тының муз. пед. ф-тында укыта, 1977–86 да Чаллы балалар музыка мәктәбе директоры, 1986–99 да ТР Дәүләт музыка уен кораллары ансамбленең сәнгать җитәкчесе. 1999 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында, татар музыкасы каф. мөдире (2000–11). «Бәрмәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамблен оештыручы, баш дирижёры һәм оркестр җитәкчесе (2011). Уен кораллары оркестры коллективын оештыручы һәм җитәкчесе буларак, актив концерт эшчәнлеге (тематик концерт программалары циклы һәм телевизион фильм-концертлар) алып бара, милли музыка уен коралларында башкару үсешенә зур өлеш кертә. «Татарстан» ДТРК фондында концерт программалары язмаларын булдыра. Төрле составтагы халык музыка уен кораллары ансамбльләре өчен татар халык көйләренә 200 дән артык эшкәртмәләр (сюиталар, фантазияләр, халык көйләреннән тезмәләр һ.б.), вокаль әсәрләр, спектакльләргә музыка авторы.

*Ф.Ш.Салитова.*

**НИГЪМӘТИ́** (Нигъмәтуллин) Галимҗан Әмирҗан улы (26.7.1897, хәзер БРның Чишмә р-ны Үдрәкбаш а. — 1941, Коми АССР), әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе. Уфада — «Галия» мәдрәсәсендә, 1922 елда — Шәрекъ хезмәт ияләре коммунистик ун-тында (Мәскәү), 1924 тә Мәскәү журналистика ин-тында укый. 1926 га кадәр ВКП(б) ҮКның матбугат бүлеге инструкторы. 1926 дан Казанда. «Кызыл Татарстан» г-тасының (1926–27), Татиздатның (1928–30) баш мөхәррире, «Яңалиф» ж-лының җаваплы мөхәррире (1930–32), бер үк вакытта, 1929–37 дә, Шәрекъ пед. ин-тында (1934–37 дә татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире, 1935 тән проф.). 1920–30 елларда татар әдәбият белемендә мәдәният-тарих мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Н. татар әдәбият белеменең фәлсәфи-эстетик нигезләрен, нәфис иҗатны әдәбият белеме, фәлсәфә, эстетика, тарих, психол., социол. фәннәренең үзара йогынтысы нигезендә комплекслы өйрәнү принципларын эшли. Шәрекъ һәм Гареп әдәбиятларын чагыштырып өйрәнә. Татар әдәбиятына А.С.Пушкин, Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, М.Горький, Н.Г.Чернышевскийның тәэсире (гуманистик пафос, демократизм, иҗади хезмәтне һәм шәхес иреген шигърияттләштерү, сәнгати-эстетик осталык, иҗади шәхеснең батырлыгы һәм какшамаслыгы) турындагы мәкаләләр, татар әдәбияты дәреслекләре һәм укыту программалары авторы. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Әдәбият мәйданында. М., 1925; Революция елларындагы әдәбиятыбыз. М., 1929; Әдәбият һәм тормыш (Әдәбият фәне мәсьәләләре, тәнкыйть). К., 1931; Сайланма әсәрләр. К., 1958.

*Әд.:* Г а л и е в а Э.Г. Татар әдәбияты белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002; Г и л я з о в Т. Выдающийся татарский литературовед (к столетию Галимджана Нигмати) // Науч. Татарстан. 1997. № 2; Н и г м а т у л л и н Э.Г. Жизнь. Творчество. Память: Очерк жизни и деятельности Галимжана Нигмати // Казань. 2002. № 9.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**НИГЪМӘ́ТОВ** Җәмил Газиз улы (3.11.1939, Баулы р-ны Урал пос.), педагог, пед. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТАССРның атказ. мәктәп укытучысы (1994), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (2001). Казан пед. ин-тын (1963), В.И.Ленин исем. Мәскәү пед. ин-тын (1974) тәмамлый. 1963 елдан Азнакай р-нының Җәлил посёлогында урта мәктәптә укыта, 1971 дән Казанның 81 нче урта мәктәбендә директор. 1974 тән Могадишо (Сомали) пед. көллиятендә математика укыта. 1977 дән Казан пед. ин-тының мәктәп б-н идарә итүнең фәнни нигезләре каф. мөдире һәм укытучыларның квалификациясен күтәрү ф-ты деканы. 1986 дан Алабуга пед. ин-ты ректоры, 1989 дан проректоры, 2002 дән ректор вазифаларын башкаручы. 2003 тән Казан пед. ун-ты ректоры, 2005–08 дә Татар гуманитар-пед. ун-ты ректоры, бер үк вакытта пед. тарихы һәм этнопед. каф. мөдире (1989–2010). 2011 дән Казан. ун-тында пед. каф. мөдире. Хезмәтләре гуманистик тәрбия мәсьәләләренә, этнопедагогикага карый. РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (2003). ТР Дәүләт бүләге (2007) лауреаты. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Этнопедагогика: Халыкчанлык һәм гуманлылык: Югары һәм махсус урта уку йортлары өчен уку ярдәмлеге. К., 2002; Воспитание социалистической гуманности у школьников. К., 1987; Гуманизм: Педагогика и школа. К., 1988; Уважение к человеку труда. К., 1988; Курс лекций по педагогике. К., 2000 (автордаш).


**НИГЪМӘТУЛЛА́** әл-Эстәрлебаши (19 йөз), дин эшлеклесе. Г.Курсави идеяләрен дәвам итүче һәм популярлаштыручы. Уфа губернасындагы Эстәрлебаш авылы мәдрәсәсе мөдәррисе.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Әхәт Зәйнетдин улы (30.11.1921, хәзер Оренбург өлкәсенең Кызыл гвардия р-ны Үтәй а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1993), БАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1982). Казан ун-тын тәмамлый (1949). 1952 елдан Тобол укытучылар ин-тында татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. 1954 тән Башкорт ун-тында, 1993 тән Башкортстан пед. ин-тында (хосусый белем бирү методикалары каф. мөдире), 1997 дән Башкортстан мәгарифен үстерү ин-тында (туган тел һәм әдәбият каф. мөдире, 1998–2000 елларда туган тел һәм чит телләр каф. мөдире). Хезмәтләре Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Камал, Һ.Такташ, Ф.Кәрим, М.Җәлил, Г.Кутуй, Х.Туфан иҗатларына, агымдагы әдәби процесска, урта мәктәптә татар әдәбиятын укытуга карый. «И гомернең үзәннәре, үрләре» (Уфа, 2002), «Өздереп бер карадың да» (Уфа, 2006), «Көзге кыек күрсәтә» (Уфа, 2007) исемле шигъри җыентыклар авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сәнгатьле уку (теориясе һәм гамәли методикасы). К., 1968; Урта мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең фәнни-методик нигезләре. К., 1982; Проблемно-развивающие уроки литературы. Уфа, 2000.

*Әд.:* А с а н б а е в Н.А. Судьба // Агидель. 2006. № 12; Г а р е е в а Г.Ф. Основатель методики татарской литературы как науки // Учитель Башкортостана. 2006. № 12.

*Р.Р.Мусабәкова.*



Г.Ә. Нигъмәти.



Г.Я. Нигъмәтуллин.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Булат Искәндәр улы (16.5.1944, Мәскәү), җылылык физикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1992). 1967 елда Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесен (МВТУ) һәм 1969 да Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1967–71 дә — МВТУда, 1971–75 тә — Бөтенсоюз җылылык техникасы ин-тында, 1975–89 да Бөтенсоюз «Энергия» ФҖБ АЭС фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1989–98 дә АЭС куркынычсызлыгы буенча Электрогорск фәнни-тикшеренү үзәге директоры (Мәскәү өлкәсе). 1998–2002 дә РФнең атом энергетикасы буенча министры урынбасары. 2002–04 тә «Группа МДМ» АҖ финанс-сәнәгать корпорациясенең вице-президенты. 2005 тән «Энергомаш-Альянс» АҖнең ген. директор урынбасары, бер үк вакытта, 2006 дан, Табигый монополияләр проблемалары ин-тының директор урынбасары (Мәскәү). Хезмәтләре АЭСларда җылылык-масса алмашуга, атом-төш энергетикасы җайланмаларына һәм аларның куркынычсызлыгы мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Динамики многофазных сред. М., 1982 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Гафият Ярмөхәммәт улы (15.3.1915, Казан губ., Мамадыш өязе Кече Кирмән а. — 8.5.1945, Берлин янында җирләнә), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), өлкән политрук. Хәрби-сәяси академия (БАССР, Бәләбәй ш., 1942) тәмамлый. Свердловск һәм Чиләбе шәһәрләре з-дларында эшли. 1938 елдан туган ягында «Пятилетка» с-зында сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе. 1939 дан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша, 86 нчы мотоукчылар дивизиясендә рота политругының урынбасары (7 нче армия). Төньяк-Көнбатыш фронты гаскәрләре составында 1940 ның гыйнварында Виипури торак пункты (хәзер Ленинград өлкәсе Выборг ш.) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: төркемне чолганыштан алып чыгуны оештыра. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Мамадыш шәһәрендә Геройга бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Есть на Вятке городок. К., 1981; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Искәндәр Нигъмәтулла улы (23.1.1908, Уфа губ., Бәләбәй өязе Түбән



Н.Т. Нигъмәтуллин.



Р.Ш. Нигъмәтуллин.

Каргалы а. — 28.6.1980, Мәскәү), җылылык физикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1955), проф. (1955). 1935 елда Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1964–80 дә Бөтенсоюз политехник читтән торып уку ин-тында (Мәскәү) җылылык энергетикасы җайланмалары каф. мөдире. Хезмәтләре җылылык һәм атом электр станцияләрен эксплуатацияләүгә карый. Н. эчке янулы двигательләрдә торба б-н өрдерү теориясен эшли. Энергетика буенча дәреслекләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рабочие процессы в турбопоршневых двигателях. М., 1962; Современные ядерные реакторы. М., 1971; Будущее теплоэнергетики. М., 1975.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Нәфкать Тимергали улы (16.11.1962, БАССРның Яңавыл р-ны Уракай а.), җырчы, ТРның халык артисты (2012). Авыл хуҗалыгы ин-тын (1989), Казан музыка уч-щесенең вокал бүлеген (1992, Р.Нуриева классы) тәмамлый. 1995–2009 елларда «Идел буе һәм Урал алды респ-каларының төбәгара композиторлар йорты»нда (Казан) эшли. Соло концерт программалары б-н чыгышлар ясый, 10 нан артык аудио- һәм видеоальбомнар чыгара. Репертуарында татар һәм башкорт халык җырлары, хәзерге композиторларның эстрада әсәрләре, ш.и. үзенең җырлары бар. Татар җыры фестивале һәм конкурслары лауреаты.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Равил Рәшит улы (24.9.1947, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1997). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, теоретик физика каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре каты җисемнәрдәге тигезләнешсез үзлекләргә һәм күмәк күренешләргә карый. Н. фракталь күплекләрдә шома функцияләрне уртачалаштыру барышында килеп чыга торган гамәлнең — реаль һәм комплекслы дәрәҗә күрсәткечле вакланмалы интеграллаштыруның мәгънәсен аңлатып бирә һәм тармакланучы системалар өчен вакланма чыгарылмалы гомумиләштерелгән диффузия тигезләмәсен чыгара. Вакланмалы кинетикага нигезләнгән диэлектрик релаксация теориясен эшли. Ирекле алынган реаль һәм комплекслы күрсәткечле моментларның тулы җыелмасын кертүгә нигезләнгән матем. статистиканы гомумиләштерә. Төрле теоретик кәкреләрне эксперимент бирелмәләренә яраштыруның яңа һәм югары нәтиҗәле алымын (үз координаталар алымы) тәкъдим итә.

Х е з м.: The fading of memory during the regression of structural fluctuations // Adv. in Chem. Phys. 1985. V. 63 (автордаш); Fleches du temps et geometric fractale. P., 1998 (автордаш); The justified data-curve fitting approach: recognition of the new type of kinetic equations in fractional derivatives from analysis of raw dielectric date // J. Phys. D: Appl. Phys. 2003. V. 36 (автордаш).

*Р.Г.Усманов.*

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Рәис Искәндәр улы (1.1.1946, Мәскәү), җылылык физикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (2000). 1969 елда Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң, Физика-энергетика ин-тында (Калуга өлкәсе Обнинск ш.) эшли. 1970 тән Бөтенсоюз җылылык техникасы ин-тында, 1980 нән СССР ФАнең Машиналар төзү ин-тында эшли, 1995 тән РФАнең Нәсызыкча дулкын механикасы һәм технологиясе фәнни үзәгендә лаб. мөдире (Мәскәү). Бер үк вакытта, 1998 дән, Мәскәү авиация ин-тында. Хезмәтләре җылылык-масса алмашу өлкәсенә карый: җылылык алмашуның кризислы процессларын, торбадагы газ-сыеклык агымнарына ике фазалы катнашма пульсацияләре һәм тышкы вибрацияләр тәэсирен тикшерә; төрле газларның барботажлы куыклы кайнавын модельләштерү, ш.у. фәнни һәм сәнәгый максатларда өермәле агымнар булдыру өлкәсендә эшли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование газожидкостных потоков в трубе при наличии внешних поперечных вибраций // Теплофизика высоких температур. 1991. Т. 29, № 5; Исследование газожидкостных потоков в трубе при наличии пульсаций расхода // Теплофизика высоких температур. 1992. Т. 30, № 4; Физическая гидродинамика. М., 2005 (автордаш).

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001; М а м л е е в М., М а м л е е в Р. Каргалинские корни. Уфа, 2003.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Рәшит Шакир улы (1.5.1923, Казан — 7.7.1991, шунда ук), физик, физика-матем. фән. д-ры (1965), проф. (1967), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1950 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1953 тән Казан авиация ин-тында, теоретик радиотехника һәм электроника каф. мөдире (1954–88), бер үк вакытта ректор (1967–77), микроэлектроника проблемалы лаб-я бүлегенең фәнни җитәкчесе (1962 дән), мәгълүматны электрохимик үзгәрткечләр — ЭХПИ лаб-ясе мөдире (1975 тән), шул ук кафедраның профессоры (1988 дән). Казан авиация ин-тында Н. җитәкчелек иткән елларда 2 факультет — автотөзелеш (1970), хисаплау һәм идарә итү системалары (1972) ф-тлары оештырыла, яңа уку биналары, тулай тораклар, спорт комплексы төзелә, Казансу елгасының уңъяк ярында институт шәһәрчеге проектлаштырыла һәм төзелә башлый; институт Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1967), акад. А.Н.Туполев исеме бирелә (1973). Н. хемотроника — молекуляр электроника өлкәсендә яңа фәнни юнәлешкә нигез сала. ЭХПИ, электрон җайланмалар һәм алар нигезендә системалар төзү өлкәсендә эшли. Н. молекуляр электрониканың теоретик нигезләрен; ЭХПИнең матем. һәм электрик модельләрен төзи, аларда вакланмалы интегродифференциаллау операцияләре барын ачыклый, мондый операцияләрнең төрле сигналларны функциональ рәвеш үзгәртү һәм эшкәртү өчен кулланууда отышлы булуын күрсәтә. СССРда беренче булып матдәләрнең составын һәм үзлекләрен экспресс-анализлау өчен осциллографик полярограф куллана (1952); электр үткәрүчән сыеклык агымнарында турбулентлыкны һәм күчерү процессларын өйрәнүдә, диңгез суын тикшерүдә үлчәү системалары төзү өчен электрохимик алымнар һәм датчикларның өстенлекләрен һәм отышлылыгын күрсәтә. Электр чылбырлары теориясенә яңа тип элементлар (реконд, реинд) кертә (1989), алар исә Лаплас операторының ирекле вакланмалы дәрәҗәсе булган электр чылбырлары, ш.у. даими фазалы системалар (CPE-элементлар) синтезларга мөмкинлек бирә, вакланмалы операторлар б-н электрод-электролит бүленеше чигенең фракталь геометрия арасындагы бәйлелекне күрсәтә.

СССР ФАнең электрохимия буенча фәнни советы әгъзасы (1968–91); «Труды КАИ» радиотехник сериясенең һәм югары уку йортлары өчен «Радиотехнические устройства и системы» җыентыгының җаваплы мөхәррире (1964–91). 1970–81 дә ТАССР ЮС депутаты. ТАССР ЮС рәисе (1971–80). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре; ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Н. исемен йөртә.

Х е з м.: Теория электрохимического диода // Докл. АН СССР. 1963. Т. 150, № 3; Общее уравнение и электрический аналог электролитической ячейки со сферическим стационарным микроэлектродом // Докл. АН СССР. 1963. Т. 151, № 6; Электрохимические методы исследования процессов переноса в жидкостях // Успехи химии. 1975. Т. 44, вып. 11 (автордаш).

*Әд.:* Рашид Шакирович Нигматуллин в воспоминаниях современников и фотографиях. К., 2003.

*Р.Г.Усманов.*

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Роберт Искәндәр улы (17.6.1940, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1971), РФА академигы (1991; 1987 елдан СССР ФАнең мөхбир әгъзасы), ТР ФАнең шәрәфле академигы (2008). 1963 елда Н.Э.Бауман исем. Мәскәү югары техник уч-щесен, 1965 тә Мәскәү ун-тын тәмамлый. 1963–86 да Мәскәү ун-тының Механика ин-тында эшли, проф. (1975), лаб. мөдире (1980 нән). 1986–95 тә РФА Себер бүлегенең Төмән гыйльми үзәгендә: Төньякны үзләштерү проблемалары ин-тында директор урынбасары (1986–90), Күп фазалы системалар механикасы ин-ты директоры (1990–95), бер үк вакытта Төмән ун-тының күп фазалы системалар механикасы каф. мөдире (1986–93). 1993–2006 да РФАнең Уфа гыйльми үзәге рәисе, 1995–2004 тә БР ФА президенты. 2006 дан РФА Океанология ин-ты директоры, РФА Президиумы әгъзасы. Хезмәтләре күп фазалы тирәлекләр механикасына, термофизикасына, дулкынсыман динамикасына карый. Н. төрле типтагы күп фазалы яки гетероген катнашмаларда фаза



Р.И. Нигъмәтуллин.

эчендәге яки фазаара процессларны сурәтләү алымнарын, ш.у. аларның механик һәм термодинамик тигезләмәләренең йомык системаларын төзи. Металларны шартлау юлы б-н ныгыту теориясен, бәрмә яки акрын процессларда металларда дислокацион процесслар кинетикасын һәм фаза күчешләре нигезләрен билгеләү теориясен үстерә. Дислокацияләр тизлеген һәм үрчүен исәпкә алып, каты җисемнәрне фаза күчешләре ярдәмендә тизләнешле деформацияләү закончалыкларын тикшерә, фаза күчешле эластик-пластик җисемнәрне югары тизлекле бергә бәрдерү мәсьәләсен беренче булып куя һәм чишә. Торба рәвешле мичләрдә углеводородлы газ-сыеклык чималын җылыту процессын һәм аларны кокслау механизмын өйрәнә. Резонанслы ультратавыш тәэсирендә газның микрокуыкларын үтә нык кысу алымын эшләүдә катнаша. Н.ның тикшеренүләре атом энергетикасы җайланмаларында, үткәргеч торбалар транспортында һ.б. җайланмаларда авария ситуацияләрен анализлауның нигезен тәшкил итә. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Н. җитәкчелек иткән Океанология ин-ты Дөнья океанын, Россия диңгезләрен һәм аларда бара торган физик, химик, биол. һәм геол. процессларны комплексы өйрәнә. РФ Дәүләт Думасы депутаты (1999–2003). СССР Дәүләт бүләге газ һәм сыеклык халәтендәге матдәләрнең дулкын динамикасына нисбәтле фәнни хезмәтләре өчен бирелә (1983). Почёт ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы медале, РФ Космонавтика федерациясенең К.Э.Циолковский һәм акад. В.П.Макеев исем. медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы механики гетерогенных сред. М., 1978; Динамика многофазных сред: В 2 т. М., 1987; Nano-scale thermonuclear fusion in imploding vapor bubbjes // Nuclear Engineering and Design. 2005. V. 235; Как обустроить экономику и власть России: Анализ инженера и математика. М., 2007.

*Әд.:* Всемирный биографический словарь. М., 2000; Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Рошаль Габделхәй улы (5.12.1939, Казан — 19.12.1986, шунда ук), математик, физика-матем. фән. канд. (1967). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1970 тән теоретик кибернетика кафедрасында. Хезмәтләре дискрет математикага һәм катлаулылык теориясенә карый. Н. Буль модельләре өчен катлаулылык функцияналлары тәртибенең асимптотик закончалыкларын урнаштыру юлын эшли (Н. вариацияле принцибы). Аның дискрет оптимальләштерүдә якынча исәпләү алгоритмнары б-н табылган чишелешләрнең төгәллеген бәяләү буенча нәтиҗәләре киң танылу ала. Катлаулылык теориясе өлкәсендә Н. Буль функцияләренең конкрет эзлеклелекләре б-н эшләү катлаулылыгының нәтиҗәле түбән бәяләмәләрен исбатлау модельләрен тәкъдим итә.

Х е з м.: Экспоненциальные нижние оценки сложности и пошагово моделирующие схемы // Кибернетика. 1987. № 4; Нижние оценки сложности и сложность универсальных схем. К., 1990; Сложность булевых функций. М., 1991; Models of lower-bounds proofs // Theoret. Comput. Sci. 1987. V. 52.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Руслан Кәрим улы (7.10.1974, Казан), спортчы (футбол), Россиянең спорт остасы (1996). Спорт б-н 1988 дә «Электрон» СКнда шөгыльләнә башлый (Казан). Россия (1996, 1997, 2004) чемпионы, Россия чемпионатларында көмеш медаль (1999, 2000, 2001, 2002), бронза медаль (1995, 1998), Россия кубогы (2000, 2001) иясе. «КамАЗ» (Чаллы ш., 1992–94), «Спартак» (Мәскәү, 1995–97), Локомотив (Мәскәү, 1998–2001, 2003–04), «Верона» (Италия, 2002), ЦСКА (Мәскәү, 2002), «Салернитана» (Италия, 2003), «Терек» (Грозный, 2005) командаларында уйный. Тренерлары: И.Я.Гыйбадуллин, О.И.Романцев, Ю.П.Сёмин. Н. — Россиянең иң яхшы футболчысы (2001), Россиянең иң яхшы капкачысы (2000, 2001). Россия җыелма командасы өчен 5 матч уйный. Дөнья чемпионатында катнаша (2002).

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Шамил Габдрахман улы (4.1.1951, Буа р-ны Күл Черкене а. — 1.2.2004, Казан), нәкышьче, монументалист. ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1999). Казан сәнгать уч-щесен (1975), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын, СССР САнең мөхбир әгъзасы Ю.К.Королёв җитәкчелегендәге монументаль-декоратив нәкышь остаханәсен (1981), СССР САнең Х.Г.Якупов җитәкчелегендәге иҗат остаханәсен тәмамлый (1984). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). 1984–93 елларда РСФСР Сәнгать фондының Татарстан ф-лында. 1993–2002 дә ТР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе. Н. Мәскәүдә укыган елларында ук үзен монументалист рәссам буларак таныта (1979–80 дә Мәскәүнең Жданов р-ныңдагы Балалар спорт сараенда темпералы рәсемнәр төшерә, Саяногорскидагы Иҗтимагый үзәк бинасында «Канатлы металл» сграффитосын иҗат итә). 1978 дән Заполярьеда (Дудинка, Хатанга, Норильск ш.), Себердә (Саян-Шушенск ГЭСы, Саяногорск, Байкал күле) иҗади сәфәрдә була. Беренче монументаль әсәрләрен Казанда иҗат итә — Казан авиация ин-тының 3 нче уку бинасы вестибюлендә темпералы рәсемнәр төшерә: «Беренче очучылар», «Профессор Одинцов мәктәбе» (икесе дә — 1985). Н. Казандагы Спорт сарае (1993), Чаллыдагы кунакханә өчен витраж эскизлары иҗат итә; К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакленә театр декорациясе эскизлары ясый. 1990 елларда күбесенчә станлы нәкышь өлкәсендә эшли. «Иртәгә бәйрәм» (1984), «Җиңеп кайтыгыз» (1997) һ.б. картиналар авторы. Нәкышь иҗатында татар халык сәнгатенең телен, аның полихромиясен, бизәкләрен үз итүе ачыла («Рабига әби портреты», 1980). Пейзажлары композициясенең ачыклыгы, күп планлылыгы, төсләр палитрасының байлыгы б-н аерылып тора («Август узып китте», 1993; «Казансу ташыганда», 1994; «Тынлык», 2000). Респ-ка (1982 дән), зона — «Зур Идел» (1985, 1998, 2004) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәсе Казанда уза (2001). Н. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чабаксар шәһәренең Картиналар галереясында, чит илләрдә шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Р а з у м е й ч е н к о В. Постижение натуры // Казань. 2002. № 1; Ш а г е е в а Р. Мелодия кисти // шунда ук. Б. 121–130.

*М.Е.Ильина.*

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИН** Энгель Галимҗан улы (6.11.1930, Казан — 16.7.2001, шунда ук), әдәбият галиме, әдәбият тәнкыйтьчесе, тәрҗемәче, филол. фән. канд. (1972). Казан ун-тын (1952), 1 нче Мәскәү чит телләр пед. ин-тын (1967) тәмамлый. 1967–72 елларда урта мәктәптә эшли, 1972 дән Казан ун-тында. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре: татар әдәбиятын дөнья әдәбияты контекстында системалы-комплексы өйрәнү (социология-тарих, филос.-эстетика, культурология һәм әдәбият белеме аспектларында), татар әдәбиятының рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятлары б-н үзара бәйләнешләрен һәм татар әдәбияты үсешен фаразлау, хәзерге татар прозасының поэтикасы. Иске татар, немец, инглиз, француз телләреннән татар һәм рус телләренә татар халкының тарихы, мәдәнияте, мәгърифәтенә багышланган фәнни мәкаләләр тәрҗемә итә. Европалыларның татарларга, татар





Ш.Г. Н и г ъ м ә т у л л и н. 1. «Август узып китте». 1993; 2. «Җиңеп кайтыгыз». 1997.



В.Ф. Нигъмәтуллина.



Г.Н. Нигъмәтуллина.

мәдәниятенә мөнәсәбәтен белдергән документаль мәгълүматлар җыеп бастыра.

Х е з м.: Европа һәм татарлар: Тарихи парчалар // Мирас. 1999. № 8–9; Раздвигая века и границы: К вопросу о связях татарской литературы первой трети XX века с литературой Западной Европы. К., 1977; Диалог литератур: Указ. переводов произведений русской литературы на татарский язык. К., 2002.

*Әд.:* Б а л а ш о в Ю. В сговоре с совестью // Казань. 2002. № 9; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. Системно-комплексное исследование художественного творчества: История научного направления в Казанском университете. К., 2004.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Венера Фәйзеләхәт кызы (1.3.1949, Тукай р-ны Таулык а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2007). Казанда Актёрлар йорты каршындагы драма актёрлары өчен кичке курсларны тәмамлый (1969). 1966–67 елларда һәм 1969 дан Минзәлә татар драма театрында. Н., нигездә, характерлы рольләр башкара һәм һәр ролендә, ш.и. Сайра («Гөлҗәннәтнең җәннәте», Ю.Әминев), Тәнзилә («Хыянәт», Х.Вахит), Зөлхәбирә («Ардуан батыр», Г.Ахунов), С.Шәкүровның «Гапсаттар бабайның Кырымга сәяхәте», «Карт гашыйк» пьесаларындагы Шәмсераван, Гүзәлия кебек яшь героиняларында да характерның мәгънәви асылын ачып бирә торган, һәркайсының үзенә генә хас тормышчан дөрес һәм ышандырырлык үзенчәлекле якларын таба белә. Шуның б-н бергә актриса героиняларын рухи бөтенлек, эчке мәгънә б-н баетырга омтыла. Н. иҗат иткән Сара («Язлар моңы», Ә.Гаффар), Мөнирә («Моңнар төште башыма», М.Маликова), Мөршидә («Газиз ярым», Х.Ибраһим) образлары психологик анализның тирәнлеге б-н аерылып тора. Ул әхлакый сайлау зарурлыгы алдында торган героиняларының рухи халәтләрен бик оста гәүдәләндерә. Н.ның Сәрби («Башмагым», Т.Гыйззәт), Мәрфуга («Кишер басуы», З.Хәким), Гөлмәрфуга («Париж егете Әлфәнис», Л.Вәлиев), Фазыйлә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Сәмәния («Сөйгәнемнең туган көне», И.Юзеев), Матуркай («Каерылмасын канатың», Р.Батулла), Гәүһәршат («Хан кызы», Р.Хәмид) кебек характерлы образлары роль тудыруда кулланылган сурәтләү чараларының муллыгы б-н аерылып тора. Н.Гыйматдинованың «Сихерче» (Маһруй), Б.Сәлахованың «Яр» (Ана), Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» (Фәхирә) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә Н. башкарган хатын-кыз образларына тормыш зирәклеге, эпик масштаблылык хас. С.Өметбаев исем. бүләк лауреаты.

*Әд.:* Г ы й м р а н о в а Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007. *Д.Ә.Гыймранова.*



В.Ф. Н и г ъ м ә т у л л и н а Аруна Райна ролендә («Һәркемгә бер кояш», Ф. Бәйрәмова; уңда— Удвал Райна ролендә Р. Юзикеев).

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Галия Нигъмәтҗан кызы (2.1.1907, Оренбург губ. Орск ш. — 4.1.1990, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1975). М.Х.*Сәлимҗановның* әнисе. Татар театр техникумын тәмамлый (Казан, 1926, 1 нче чыгарылыш). Сәхнә эшчәнлеген 1923 елда Орск шәһәрендә татар һәвәскәрләр коллективында Зөһрә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш) роле б-н башлап җибәрә. Техникумны тәмамлаганнан соң, Татар дәүләт театрына (хәзер Татар акад. театры) кабул ителә, 1928–30 да — Әстерхан татар театрында, 1930 дан Татар акад. театрында эшли. Беренче зур роленнән үк (Сара — «Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин) Н. катлаулы иҗади бурычларны хәл итәргә сәләтле актриса буларак ачыла. Ул драматик, көлкеле, ш.у. характерлы рольләрне дә бер үк дәрәҗәдә оста башкара. Аның барлык рольләре дә тормыш дөреслеген гәүдәләндерүләре һәм гадәттән тыш булулары б-н көчле тәэсир калдыра. Н. иҗат иткән образлар арасында Фәрхәнә, Зәмзәмбану («Чаткылар», «Шомлы көннәр», «Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Нәгыймә («Банкрот», Г.Камал), Хәдичә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Фәтхия, Миңзифа («Татар хатыны нишләр күрми», «Тирән тамырлар», Г.Ибраһимов), Галия («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт), Зарифа («Туган туфрак», С.Шәкүров), Бәдыйга («Галиябану», М.Фәйзи), Соня («Канат җәйгәндә», Н.Асанбаев) һ.б. бар. Тормышчан төгәллек һәм образның психол. тирәнлеге Н.га рольнең масштабын зурайтырга, аны халык иҗатындагы традицион персонажлар турында яшәп килүче күзаллаулар дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкинлек тудыра. Аның башкаруында ялкаулык, шапшаклык, мәгънәсезлек кебек ямьсез сыйфатларны үзендә туплаган Мәпә («Рәйхан», Н.Исәнбәт) образы шундыйлардан. Ватанын өзелеп сагынучы Газизә («Муса Җәлил», Н.Исәнбәт) — үзенең иҗтимагый яңгырашы б-н бөтенләй капма-каршы образ. Актрисаның Ана («Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов), Гөлҗан («Шамил Усманов», А.Гыйләҗев, А.Яхин), Сабира («Чикләвек төше», Г.Ахунов), Ләйлә («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт), Сафура («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Ниса («Тол хатыннар, тол кызлар», С.Шәкүров), Җиһан, Гөлнар («Назлы кияү», «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин) рольләрендә халыкчан характерларның асылына үтеп керә белү, драма әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен тиешле югарылыкта яктырта алу осталыгы күзәтелә. Сәхнә дөньясында тирән эз калдырган Г.Болгарская, Ф.Ильская, Г.Камская традицияләрен үстереп, Н. татар театрының иҗади мирасына зур өлеш кертә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



Г.Н. Н и г ъ м ә т у л л и н а Газизә ролендә («Муса Җәлил», Н.Исәнбәт).

*Әд.:* И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005; Народные артисты. К., 1980. *Д.Ә.Гыймранова.*


**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Йолдыз Галимҗан кызы (29.4.1929, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1971), проф. (1973), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1979, 1981), атказ. проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1951), 1957–2010 елларда шунда ук эшли. Казан ун-ты каршында нәфис иҗатны системалы-комплекслы өйрәнү вузара фәнни эзләнүләр юнәлешен оештыра һәм җитәкли, аның методологик һәм теоретик нигезләрен эшли. Фәнни эшчәнлегенең төп юнәлешләре: әдәбият теориясе һәм әдәбият белеме методологиясе, цивилизация һәм культурология аспектларында диннәр һәм мәдәниятләр диалогы, нәфис иҗат үсешен фаразлау, әдәби багланышлар (татар әдәбиятының рус, ш.у. төрек, әзәрб., әрмән әдәбиятлары б-н); татар сәнгатендә модернизм. Күп кенә хезмәтләре чит илләрдә (Австрия, Германия, Кытай, Төркия) басыла. ТР ның Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

Х е з м.: Комплексное исследование художественного творчества: Проблемы прогнозирования. К., 1990; Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. К., 1997; «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; Системно-комплексное исследование художественного

творчества: История научного направления в Казанском университете. К., 2004.

*Әд.:* С а я п о в а А.М. На высоте мировой научной мысли // Науч. Татарстан. 1999. № 1; Ф а с х у т д и н о в а Э. Верность призванию // Казань. 2004. № 10.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Рада Хөсәен кызы (14.4.1931, Казан), сынчы. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984), ТР, РФнең халык рәссамы (2002, 2012). Казан сәнгать уч-щесен, С.С.*Ахунның* скульптура остаханәсен (1954), СССР САнең И.Е.Репин исем. нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (М.К.Аникушин җитәкчелегендәге скульптура остаханәсе) тәмамлый (1960). 1960 елдан Татарстан сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). Татарстанда беренче хатын-кыз сынчы, якты, иҗади үзенчәлеккә ия булган, скульптурага милли образлылык алып килеп, пластикага нәфислек рухы өргән әйдәп баручы уеп бизәү остасы. Н.ның әсәрләре тәэсирлелеге, фактураның нәфислеге һәм яктылыгы, җанлылыгы һәм



Р.Х. Нигъмәтуллина.

динамизмы б-н аерылып тора. Әле Казанда укыган елларында үк ул Х.Әбҗәлилов, С.Сәйдәшевнең натурадан скульптур портретларын, «Балыкчы», «Яшь футболчы» (барысы да — 1951), «Бишек җыры» (1957) жанрлы композицияләрен иҗат итә; соңгысы РСФСР Рәссамнар берлегенең 2 нче дәрәҗә дипломына лаек була (күп тапкырлар Кытай, Корея, Монголия, Чехословакия, Венгрия, Польшада үткәрелгән күргәзмәләргә куела). Ленинградта укыганда, В.И.Рогожин б-н берлектә С.Сәйдәшев, Г.Камал (мәрмәр), Алёша Пешков, М.Горький (бронза) портретларын иҗат итә. Н. иҗатының иң көчле ягы — көнкүреш жанрындагы скульптура. Агачта, бронзада, шамотта башкарылган әсәрләре ана һәм бала, халык көнкүреше эпизодлары, татар фольклоры образлары, театр күренешләреннән сәхнә сюжетлары темаларын чагылдыралар («Беренче сыйныф кызлары», 1963; «Хәерле төн», 1963; «Барып чыкты», 1969; «Ана», 1975; «Әллүки», 1976; «Эшлекле Татарстан», 1978; «Малай чак төшләре», 1979; «Җирдә тынычлык булсачы...», 1980) . Н. шаржлар һәм юмористик композицияләрдән торган вак пластик фигуралар сериясен (40 тан артык хезмәт) иҗат итә (1979–81).



Р.Х. Н и г ъ м ә т у л л и н а. «Бишек җыры». Төсле гипс. 1957. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

2000 еллар башында ул мастикадан байтак кына сюжетлы-тематик композицияләр эшли, фактураның сәнгатьлелеген көчәйтә торган төсләр куллана.

Н. — портретлар остасы; ул иҗат иткән образлар монументаль һәйкәлләрнең эскиз проектларына тупланган (С.Сәйдәшев, Ф.И.Шаляпин, Казан ханбикәсе Сөембикә, Г.Тукай, С.Садыйкова һ.б.). Байтак әсәрләре гаилә коллективы: ире В.И.Рогожин һәм кызлары — И.В.Рогожина һәм М.В.Нигъмәтуллина б-н башкарыла (Кама Тамагы р-нының Красновидово авылында М.Горький һәйкәле, Питрәч р-нының Ленино-Кокушкино авылында М.А.Ульянова һәйкәле, икесе дә — 1979; Яшел Үзәндә Бөек Ватан сугышы каһарманнары аллеясы, 2000). 1996 да алар тарафыннан ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы өчен татар, рус һәм Европа композиторларының бюст һәм барельефлары иҗат ителә. 1980 еллардан башлап, Н. Татар акад. театрында куелган «Зәңгәр шәл», «Галиябану», «Банкрот», «Беренче театр» кебек драматик спектакльләргә нигезләнеп иҗат итә. 1980–2000 елларда ул скульптурада Г.Тукай образын һәм аның әсәрләрендәге геройларны гәүдәләндерә: «Апуш», «Саубуллашу», «Кырлай», «И туган тел», «Бишек җыры» (барысы да — 1986–87); «Хатирәләр. Ташаяк ярминкәсе» (1996). 2006 да, Г.Тукайның 120 еллыгына, И.Рогожина һәм М.Нигъмәтуллина б-н иҗатташлыкта «Тукайга мәхәббәт илә»



Р.Х. Н и г ъ м ә т у л л и н а. «Хуҗа Насретдин». Шамот. 1985. Г. Камал исем. Татар акад. театры.

исемле масштаблы әсәрләр сериясен эшли: «Апушның Сабан туе», «Асрамага бала бирәм, кем ала?», «Апушның төше», «Ялкау Маэмай», «Кырлай — минем бишегем» (ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2007). Респ-ка (1953 тән), зона — «Зур Идел» (1964, 1969, 1980), бөтенроссия (Окт. рев-циясенең 40 еллыгына, Мәскәү, 1957; РСФСРның автономияле респ-калары рәссамнары, Мәскәү, 1971), бөтенсоюз («Җир һәм кешеләр», Мәскәү, 1971), халыкара («Совет графикасы һәм скульптурасы», Пхеньян ш., Корея; 1963; «РСФСРның автономияле республикалары сәнгате», Улан-Батор, Монголия; Берлин, ГДР; Прага, Чехословакия; Варшава, Польша; 1971–72) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1959, В.Рогожин б-н берлектә; 1994, В.Рогожин, И.Рогожина,



Р.Х. Н и г ъ м ә т у л л и н а. «Салих Сәйдәшев». Төсле гипс. 1996. ТРның Казандагы С. Сәйдәшев исем. Зур концерт залы.

М.Нигъмәтуллина б-н берлектә) уза. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгенең Милли мәдәният музеенда, А.М.Горькийның әдәби-мемориаль музеенда (Казан), Әлмәт Картиналар галереясында саклана. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Х и с а м о в а Д.Д. Рада Нигъматуллина: Альбом. К., 2005.


*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Рәзинә Рамазан кызы (16.12.1959, Кемерово өлкәсенең Прокопьевск ш.), физиолог, биол. фән. д-ры (2000), проф. (2006). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1983), шунда ук эшли. 2000 елдан Казан мед. ун-тында. Хезмәтләре үсә торган организмда йөрәк эшчәнлегенең төрле режимда хәрәкәтләнү активлыгына яраклашу механизмын өйрәнүгә карый. Н. йөрәк кыскару ешлыгы, канның тибү һәм кан әйләнешенең минутлык күләме үзгәрешләренең үзенчәлекләрен ачыклый. Вегетатив нерв системасының йөрәккә тәэсире механизмнарын өйрәнә. Күнектерелгән йөрәкнең мускул йөкләнешләренә яраклашуында адренорецепторларның ролен күрсәтә.

Х е з м.: Сердечный выброс в онтогенезе у крысят // Физиол. журн. СССР, 1988. № 7 (автордаш);



Х.Х. Нигъмәтуллина.



Ә.Г. Низаев.

Особенности адренергической и холинергической регуляции сердечного выброса развивающегося организма // Эволюционная физиология и биохимия. 1999. № 5 (автордаш); Клеточно-молекулярные механизмы функционирования и регуляции сердца. К., 2004 (автордаш).

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Фәүзия Гыйният кызы (15.7.1923, Лаеш кантоны Югары Мәтәскә а., — 17.2.1978), токарь, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1977). 1939–43 елларда Казан дирбия-ияр ф-касында тегүче-мотористка. 1943–77 дә Казан төгәл машиналар төзү з-дында. СССР Дәүләт бүләге хезмәтне оештыру формаларын һәм алдынгы алымнарны гамәлгә керткәне һәм хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә.

**НИГЪМӘТУ́ЛЛИНА** Халисә Хәмит кызы (2.6.1949, Усть-Камчатка өлкәсенең Козырево а.), балет артисткасы, педагог, балетмейстер, ТРның халык артисты (2007). 2009 елда Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын тәмамлый. Үзешчән сәнгать коллективларында чыгыш ясый. 1967–85, 1988–2002 дә Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең бию төркемендә, 1985–88 дә ТАССРның Дәүләт филармониясе солисткасы, 2002–10 да ТР Дәүләт фольклор музыка ансамбле директоры һәм балетмейстеры, 2010 нан «Казан» бию ансамбле педагог-репетиторы. «Кияүләр», «Язгы моң», «Героик этюд», «Хәйләкәр карт», «Әрмән көтүчеләре биюе», «Башмагым», «Бондюг биюе», «Көндәшләр», «Башкорт биюе», «Чегән» хореографик композицияләрендә ялгыз биюләр башкара. Ул сәхнәдә ачык, истә калырлык лирик һәм ш.у. характерлы образлар тудыра, югары бию техникасы алымнарын иркен куллана. Фольклор музыка ансамблендә Свердловск өлкәсендә яшәүче татарлар фольклоры нигезендә «Чабата», Пермь татарлары фольклоры нигезендә «Буталдым», «Париж-Париж» рекрутлар биюен, «Егетләр», «Чәкчәк», «Җаныем-җаныем» һ.б. биюләрне сәхнәгә куя (барлыгы 30 га якын композиция).

*В.Н.Горшков.*



Х.Х. Нигъмәтуллина «Татар биюе»ндә. Сәхнәгә куючы — Г.П. Скалозубов. 1980.

**НИ́ЖНЕЕ О́ЗЕРО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 54 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәми елгасы буенда. 2010 елда 183 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1923 тә Олы Мәми авылыннан күченүчеләр нигез сала. Башта ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 478, 1949 да — 312, 1958 дә — 361, 1970 тә — 355, 1979 да — 264, 1989 да — 201, 2002 дә — 185 кеше.

**«НИЖНЕКА́МСКАЯ»**, чия сорты. 1985 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының бакчачылык бүлегендә А.М.Тверитинов һәм Л.А.*Севастьянова* (ирекле серкәләнүдән «Морель ранняя» чәчкене) тарафыннан чыгарыла. Кышка чыдам, уртача иртә өлгерешле, коккомикозга бирешми. Куагы 1,5–2 *м* биеклектә. Ябалдашы киң түгәрәк. Үрентеләре уртача озынлыкта һәм юанлыкта, җиңелчә дугасыман бөгелгән, соры кунык һәм сирәк аксыл-соры ясмыкчыклар б-н. Яфраклары вак, озынча, ике башыннан да очлы. Яфрак читләре вак — ике-өч каяулы. Чәчәкләре уртача зурлыкта, ак төстә. Иртә чәчәк ата. Үзеннән серкәләнеп җимеш бирүе түбән, 5–12%. Иң яхшы серкәләндерүчеләр: «Маяк», «Труженица Татарии», «Ранняя сладкая», «Морель ранняя». Җимешләре уртача зурлыкта (3,1 *г*), түгәрәк, куе-кызыл төстә, тәме әчкелтем-баллы. Җимеш йомшагы кызыл, сусыл, уртача тыгызлыкта. Орлыгы (төше) зур түгел, җимешеннән ярым коры килеш аерыла. 3 елдан җимеш бирә башлый. Уңышы 1 куактан 16 *кг*. Яшь (яшел) чыбыкчалар (тамырлануы 70–80%) һәм дала чәчкеннәренә бөре ялгау ысулы б-н үрчетелә. Яңа өлгергән килеш һәм эшкәртелеп кулланыла. Татарстанда 1988 дән районлаштырылган.

**НИЗА́ЕВ** Әбүзәр Гаяз улы (19.7.1914, хәзер БРның Благовар р-ны Сынташтамак а. — 7.1.1997, Уфа), Дан орденының тулы кавалеры (24.2.1944, 7.2.1945, 29.6.1945), өлкән сержант. 1932–36 елларда «Ленэнерго» системасында слесарь булып эшли (Ленинград). 1936–38 дә һәм 1941 нең июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 314 нче укчы полкта отделение командиры (67 нче һәм 2 нче удар армияләренең 46 нчы укчы дивизиясе). Ленинград, 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Ленинград (1941–44) оборонасында, Краснопольск-Ропша, Нарва, Таллин (барысы да — 1944), Көнчыгыш Померания һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 12 февралендә Луга (Ленинград өлкәсе) тимер юл станциясеннән көнбатыштарак (кул пулемётыннан атып, дошманның 2 контрһөҗүмен кире кайтара; яралана, әмма сугыш кырын ташламый), 1945 нең 15 гыйнварында Пултуск шәһәреннән (Польша) төньяк-көнбатыштарак (гаскәр б-н җитәкчелек итеп, дошман тылына барып керә һәм кинәт һөҗүм итеп сугышның уңышлы тәмамлануын тәэмин итә), 1945 нең 10–11 мартларында Данциг (хәзер Гданьск ш., Польша) шәһәренә керү юлларындагы сугышларда батырлык күрсәтә (беренчеләрдән булып һөҗүмгә күтәрелә; биеклекне алуда катнаша). 1945 тә демобилизацияләнә. Туган авылына кайта. 1952 елдан Уфада яши. Уфа нефть эшкәртү з-дында тәэминат цехы башлыгы урынбасары булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Славные сыны Башкирии. Уфа, 1985. Кн. 5; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НИЗА́ЕВ** Рамил Хәбетдин улы (13.7.1951, Аксубай р-ны Иске Кирәмәт а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2011). 1974 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, машиналар төзү КБнда (Чиләбе өлкәсенең Миасс ш.), «Әлмәтнефть» НГДУында (1983–84) эшли. 1984 тән ТатНИПИнефтьтә, нефть чыганакларын эшкәртүне геол. һәм гидродинамик модельләштерү лаб-ясе мөдире (1998 дән). Бер үк вакытта (2005 тән), Әлмәт нефть ин-тында, информатика каф. профессоры (2010 нан). Хезмәтләре ракеталар проектлаштыруга, төрле геол.-физик шартларда нефть чыгару технологияләрен үстерүгә карый. Ике фазалы фильтрлауның уртачалаштырылган блоклы моделен кулланып, нефть чыганакларының технол. күрсәткечләрен исәпләүнең программ чараларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Блочное осреднение модели двухфазной фильтрации в трещиновато-пористом пласте // Моделирование процессов фильтрации и разработки нефтяных месторождений: Сб. статей. К., 1992 (автордаш); Теория и практика моделирования разработки нефтяных месторождений в различных геолого-физических условиях. К., 2009 (автордаш); Моделирование потокоотклоняющих технологий в нефтедобыче. К., 2011 (автордаш).

**НИЗАМЕТДИ́НОВ** Назым Минсаф улы (9.10.1939, Куйбышев өлкәсенең Яңа Малыклы р-ны Урта Исәнтимер а.), физик-кристаллограф, физика-матем. фән. д-ры (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1966), шунда ук эшли, минерал. һәм петрография каф. профессоры (2004 тән). Хезмәтләре табигый һәм синтетик кристаллик матдәләрнең анион-катион вакансияләрен һәм кушылма составын өйрәнүгә карый. ЭПР алымы б-н кристалларда ноктадай парамагнитик дефектларның урнашу закончалыкларын билгели.

Х е з м.: Теоретико-групповой метод представления голоэдрических форм кристаллов сопряжённы-

ми простыми формами. Сростки кристаллов // Кристаллография. 2000. Т. 45(4) (автордаш); Dissymmetrization of crystals. Theory and experiment // Phys. Chem. 1980. № 6 (автордаш).

**НИЗАМЕТДИ́НОВ** Равил Мифтах улы (10.3.1929, Буа кантоны Яңа Чокалы а. — 10.6.1993, Чаллы ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1990), РСФСРның атказ. а.х. хезмәткәре (1983). КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1967). 1943–72 елларда Чүпрәле р-нында эшли: Тукай исем. (1943–61), Бауман исем. к-злар рәисе (1962–67), район а.х. идарәсе башлыгы (1967 елдан). 1972–76 да Чаллы теплица комб-ты директоры, 1976–93 тә «Весенний» с-зы директоры. Н. җитәкчелегендә 280 мең *м*² мәйданда теплица комб-ты, 10 мең *м*² мәйданда шампиньон үстерү бstandalone биналары төзелә; совхоз ел саен 5–6 млн. сум табыш ала, табышлылык 85% тәшкил итә. Герой исеме а.х. продукциясен җитештерү һәм сатуда югары күрсәткечләргә ирешкәне, социаль мәсьәләләрне хәл итүгә зур өлеш керткәне өчен бирелә. «Бездә ел буе җәй» (1981; русчага тәрҗемәсе «Дарите красные тюльпаны», 1984), «Весенний» совхозы» (1987) басмалары авторы. 1990–93 тә ТР ЮС халык депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. «Весенний» с-зында Н. хөрмәтенә мемориаль такта ачыла (1995). Чаллы шәһәрендә бер урам аның исеме б-н атала (2000), ул урамга обелиск куела. Туган авылы Яңа Чокалыда музей ачыла.

*Әд.:* Кешеләргә барам! К., 1998; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

*И.Н.Афанасьев.*

**НИЗАМЕТДИ́НОВ** Шамил Гыйльметдин улы (14.12.1930, БАССРның Бүздәк р-ны Арыслан а. — 23.5.2003, Казан), тромбончы, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991), проф. (1993). 1957 елда Мәскәү консерваториясен (В.Щербинин классы) тәмамлый. 1952 дән Мәскәүдә үзешчән оркестр коллективлары б-н җитәкчелек итә. 1957–97 дә Казан консерваториясендә, тынлы уен кораллары каф. мөдире (1962–77). Бер үк вакытта, 1966–67 дә, Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе. Н.ның укучылары арасында — А.П.Баранцев, Г.З.*Ройтфарб*. Тынлы уен коралларында башкару методикасы буенча хезмәтләр, тромбон һ.б. тынлы уен кораллары өчен эшкәртмәләр авторы. Мәскәүдә узган Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале лауреаты (1957).

*Әд.:* Усов Ю. История отечественного исполнительства на духовых инструментах. М., 1975; Болотин С.В. Энциклопедический биографический словарь музыкантов-исполнителей на духовых инструментах. М., 1995.

**НИЗАМЕТДИ́НОВА** Гөлнара Борһан кызы (1.8.1967, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). 1990 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый, Идел буе углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында (ВНИИУС) эшли. Хезмәтләре күкертле кушылмаларны каталитик оксидлаштыру реакцияләренең кинетикасына һәм механизмына карый. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләгәне һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

**НИЗАМЕТДИ́НОВА** Наилә Хәсән кызы (9.11.1955, Свердловск ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). 1979 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1983–2003 тә һәм 2005 тән Казан дары заводында инженер-технолог, цех лаб-ясе, заводның үзәк лаб-ясе башлыгы. 2003–05 тә «Казан «Электроприбор» заводы» АҖдә әйләнә-тирә мохитне саклау бүлеге һәм санитар-сәнәгать контроле башлыгы. Дәүләт бүләге Казан дары з-дында кондәшлеккә сәләтле продукция җитештерү максатында диверсификацион технологияләр булдыруда катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

**НИЗАМИ́ ГАНҖӘВИ́** (Әбү Мөхәммәд Ильяс Йосыф оглы) (1141 тирәсе, Атабәкләр дәүләтенең Ганҗә ш., хәзер Әзәрбайҗан Респ-касы — 1209 тирәсе, шунда ук), әзәрбайҗан шагыйре, фикер иясе. Фарсы телендә яза. Шәһәр халкының урта хәлле катлавыннан. Төпле белем ала: матем., астрономия, химия, мед., геогр., тарих, мантыйк фәннәрен, чит телләрне өйрәнә. Биш поэманы эченә алган һәм күләме ике юллык 30 мең бәйт тәшкил иткән «Хәмсә» («Бишлек») әсәренең авторы. Беренче «Мәхзән әл-әсрар» («Серләр хәзинәсе», 1180) поэмасы төзелеше б-н «тартмалы композиция»не тәшкил итә; 2 бүлеккә бүленгән: яшәешнең төрле мәсьәләләренә багышланган фикерләүләрдән һәм хикәяләрдән гыйбарәт 20 мәстәкыйль бүлекчәдән тора. «Мәхзән әл-әсрар» 1414 елда Хәйдәр Харәзми тарафыннан төрки-татар теленә тәрҗемә ителә. Әсәрнең аерым өзекләре И.Березинның Казанда басылган «Төрек хрестоматиясе»нә («Турецкая хрестоматия», 1 т., 1857) керә. «Хөсрәү вә Ширин» (1181) исемле икенче поэмасы мәхәббәтнең бөеклегенә һәм гуманистик идеяләргә мәдхия җырлый. Аңа нигезләнеп, төрки-татар шагыйре Котб 1342 дә шул ук исемдә шигъри роман яза. «Ләйлә вә Мәҗнүн» (1188) исемле өченче поэма фаҗигале мәхәббәтне тасвирлауга багышлана. 1950 дә ул, М.Максуд тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителеп, аерым китап булып басылып чыга. Дүртенче «Хафт пейкар» («Җиде гүзәл», 1196) поэмасының сюжеты саф күңелле җиде патша кызы тәэсирендә шаһ Бәһрам Гүрнең гадел, акыллы хөкемдарга әверелүенә корылган. Циклның «Искәндәрнамә» исемле соңгы поэмасы 2 кисәктән — «Шәрәфнамә» («Дан поэмасы») һәм «Икъбальнамә» («Бәхет поэмасы») өлешләреннән тора. Аларда Искәндәр җиһангир патша, философ, акыл иясе һәм пәйгамбәр итеп тасвирлана. «Искәндәрнамә» иҗат ителгән телдә һәм тәрҗемәләрдә Идел һәм Урал буйларында киң тарала. Төрек шагыйре Әхмәди (1334–1413) тарафыннан тәрҗемә ителгән вариант аеруча популярлык



Р.М.Низаметдинов.

казана, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә дәреслек буларак кулланыла, С.Кукляшевның «Татар хрестоматиясе»нә («Татарская хрестоматия», 1859) кертелә. Әзәрбайҗан галиме А.А.Гаджиев фикеренчә, «Хәмсә» — иң элек гомернең асылы, яшәешнең мәгънәсе, кешенең бурычы турында ренессанс (яңарыш) характерындагы эпик-фәлсәфи трактат. «Хәмсә» Шәрекъ һәм бөтендөнья әдәбияты үсешенә зур йогынты ясый. Шулай ук лирик диванның бер өлеше — 6 касыйдә, 116 газәл, 2 кыйтга һәм 30 робагый да сакланган. Диванның лирик әсәрләре һәм поэмалардан өзекләр татар теленә Г.Рәшиди, Н.Исәнбәт, Ә.Исхак, Л.Шагыйрьҗан тарафыннан тәрҗемә ителә. Н.Г. иҗаты татар халкының рухи тормышында, татар әдәбиятының үсешендә зур роль уйный. Н.Г.нең геройлары, образ, сюжет, мотивлары Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдъяр, Г.Кандалый, Дәрдемәнд, Г.Тукай һ.б. татар шагыйрьләре әсәрләрендә очрый. Тукай тәхәллүсләренең берсе «Мәҗнүн» була, «Мәхәббәт» исемле шигырендә ул Н.Г. геройларының исемнәрен бөек мәхәббәтне гәүдәләндерүче чара итеп файдалана.

«Искәндәрнамә» поэмасының күчермәләре ТР Милли музее фондларында, Казан ун-ты Фәнни китапханәсендә саклана.

*Әд.:* Әхмәтова Э. Низами һәм Котб иҗатына бер караш // Татарстан. 1996. № 6; Бертельс Е.Э. Низами: Творческий путь поэта. М., 1956; Алиев Г.Ю. Темы и сюжеты Низами в литературах народов Востока. М., 1985; Минһегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**НИЗАМИ́ЕВ** Борһан (1901, хәзер Яшел Үзән р-ны Әрә а. — 1976, шунда ук), татар фольклор әсәрләрен җыючы. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондына 2 меңгә якын мәкаль, мәзәк, җыр һәм бәет җыеп тапшыра, аларның бер өлеше «*Татар халык иҗаты*» (1–13 т., 1976–93) җыентыгында урын алган.

**НИЗАМИ́ЕВ** Мөҗип Таҗи улы (1.5.1934, Сарман р-ны Күтәмәле а. — 16.1.2012, Казан), мәдәният эшлеклесе, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977, 1984). Казан пед. ин-тын (1955), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1969) тәмамлый. 1951 елдан Сарман р-ны мәктәпләрендә укытучы. 1956–67 дә КПССның Сарман райкомында (инструктор, 3 нче секретарь, 2 нче секретарь). 1969 дан КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы. 1971–97 дә ТРның мәдәният министры урынбасары. Халыкны мәдәни агарту һәм аның ялын оештыру эшләрен алып бара. Бу ел-

ларда республикада 70 яңа музей төзелә. Н. тырышлыгы һәм катнашы б-н фольклор, ш.и. «Уйнагыз, гармуннар!» фестивальләре популярлаша. 1999–2004 елларда Г.Тукай әдәби музее (Казан) директоры.

Х е з м.: Полвека на ниве культуры. К., 1998.

**НИЗАМИ́ЕВ** Рашат Мияссәр улы (1.3.1950, Саба р-ны Олы Мишә а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Казан ун-тын тәмамлагач (1972), Биектау р-ны Олы Битаман урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укыта. 1974–81 елларда «Татарстан яшьләре» г-тасында корректор, җаваплы сәркәтип булып эшли. 1981–83 тә «Ялкын» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1983–97 дә «Казан утлары» ж-лында проза бүлеге мөхәррире, баш мөхәррир урынбасары. 1997–2005 тә «Идел» ж-лы баш мөхәррире. 2007 дән кабат «Казан утлары» ж-лында. «Йолдыз яңгыры» исемле беренче шигырь җыентыгы 1980 елда дөнья күрә. Шигырьләре тупланган «Кызыл җәй» (1983), «Тормыш трамвае» (2005), повестьлар һәм хикәяләрдән торган «Бөек сер» (1986), «Кызыл кар яугач» (1993), «Яшьлеккә хат» (2003), балаларга атап язылган «Яралы керпе» (1987), публицистик язмалардан торган «Алдым каләм кулыма» (2007) исемле китаплар авторы. Н.нең иҗатында яшь буынны тәрбияләү, әдәп-әхлак кагыйдәләре, милли традицияләрне яңарту кебек мәсьәләләр игътибар үзәгендә тора. Ул ш.у. күренекле татар композиторының тормышы һәм иҗатына багышланган «Фәрит Яруллин» документаль романы (1990, тулыландырылган варианты «Ут һәм җыр», 2000) авторы. Н. иҗатына публицистик үткенлек, драматик киеренкелек, фәлсәфилек һәм лирик җылылык хас.

*Әд.:* Ш а б а е в М. Үз йолдызы бар // Казан утлары. 2000. № 2; Х ә л и м А. Милли тәсбих турында хикәят // Мәдәни җомга. 2002. 15 февр.

*Г.М.Габделхакова.*

**«НИЗАМИЯ́»**, Әстерхан шәһәрендәге яңа ысуллы мәдрәсә. 1893 елда Г.*Гомәри* тарафыннан 6 нчы мәчет каршындагы мәктәп буларак ачыла, 1895 тән мәдрәсә. Дәресләр, башлыча, Гомәри төзегән дәреслекләр буенча алып барыла, үзе ул гарәп теле һәм әдәбиятын укыта. Тиздән «Н.» Түбән Идел буенда төп мөселман уку йортларының берсенә әверелә; 20 йөз башында анда 100 дән артык шәкерт укый. 1917 елга Әстерхан губернасындагы барлык мәчетләрнең дә диярлек имамнары «Н.»не тәмамлаучылар була. Татарлардан тыш бу мәдрәсәдә казакълар, төрекмән, нугай, кумык, чечен, ингушлар укый. «Н.»не тәмамлаучылар арасында — Б.М.*Сәлиев*, Б.З.Халидов, нугай алфавитын төзүче Б.Мостафаев-Киләче, төрекмән шагыйре Г.Душәнов була. 1909 да, Гомәри мәдрәсәдән киткәннән соң, туганы А.Гомәров мөдәррис була, аның вакытында укыту дәрәҗәсе түбәнәя. 1919 га кадәр эшли.

*Әд.:* Габдрахман Гомәри: Фәнни-биогр. җыентык. К., 2002; Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. К., 2000.

**НИЗА́МОВ** Илдар Малик улы (3.9.1936, Әтнә р-ны Олы Бәрәзә а.), тел галиме, язучы, журналист, филол. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Башкорт ун-тын (1967), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1976) тәмамлый. 1957 елдан Уфа шәһәрендә яши: Агыйдел елга пароходчылыгында (1957–60), «Кызыл таң» г-тасында (1961–67) эшли. 1968 дән Казанда. «Социалистик Татарстан» г-тасы редакциясендә (1968–74), Татарстан китап нәшриятында (1976–87). Вакытлы матбугатта хезмәт кешеләре турында очерклар, мәкаләләр, репортажлар б-н чыгышлар ясый. 1987 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре массакүләм аралашуда татар сөйләм системасы функциясенә, социолингвистикага карый. «Русча-татарча иҗтимагый-сәяси сүзлекчә» («Краткий русско-татарский общественно-политический словарь», 1995), «Дәүләт-идарә аппараты һәм җәмәгать оешмалары хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлекчә» («Русско-татарский словарь-минимум для работников государственно-управленческого аппарата и общественных организаций», 2001) басмаларын төзүче. Журналистика теориясенә (риторика, очерк, эссе) караган дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы. «Өмет» (1977), «Ул кабызган маяклар» (1980; рус теленә тәрҗемәсе «Маяки, зажжённые Ильичом», 1987; Х.Ямашев исем. бүләк, 1981); «Мәхәббәт хакы» (1986), «Бер карадым ...» (1989) дип аталган хикәя һәм повесть җыентыкларын бастыра.

Х е з м.: Уем — тел очында. К., 1995; И туган тел... К., 1998; Ярдәмең берлән синең... К., 2009; Татар социолингвистикасы хәрәкәттә. К., 2011; Татарча әдәби редакцияләү. К., 2013; Татарская речь. К., 2002.

**НИЗА́МОВ** Илдус Гали (Галирзин) улы (10.1.1938, БАССРның Яңавыл р-ны Йогәмеш а.), җәмәгать-көнкүреш гигиенасы белгече, мед. фән. д-ры (1986), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2001), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1992, 1996). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Ютазы р-ны Бәйрәкә участок хастаханәсендә, 1965 елдан Баулы р-ны үзәк хастаханәсендә баш табиб. 1968 дән Ленинград ГИДУВында. 1971 дән Казан мед. ин-тында, 1977 дән җәмәгать-көнкүреш гигиенасы һәм сәламәтлек саклауны оештыру каф. мөдире, бер үк вакытта терапия һәм сан.-гигиена ф-тларында декан урынбасары, декан (1971–81), проректор (1981 дән), проф. (1987). Хезмәтләре эшкә сәләтен вакытлыча югалткан авыруларны дәвалау, икътисади актив яшьтәгеләрнең сәламәтлеген кайгырту мәсьәләләренә карый. «Общественное здоровье и здравоохранение» ж-лы баш мөхәррире (2003). ТРның Сәламәтлек саклау тармагы җитәкчеләре ассоциациясе президенты (1995), Европа-Азия мед. фәннәре академиясе президенты (2001). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Здоровье населения Республики Татарстан на пороге третьего тысячелетия. К., 1990; Заболеваемость с временной утратой трудоспособности и оптимизация управления охраной здоровья трудовых коллективов. К., 1993.

**НИЗА́МОВ** Ильяс Сәет улы (3.1.1958, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2003), проф. (2013). Казан ун-тын тәмамлый (1981), СССР ФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2005 елдан). Бер үк вакытта Казан технол. ун-ты (2003–05), Татар гуманитар-пед. ун-ты (2003 тән; 2007 дән фосфорорганик кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясе җитәкчесе), Казан ун-тының А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты (2005 тән) профессоры. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. Н. эфирлар һәм өчвалентлы фосфорның тиокислота хлорангидридларының карбониль кушылмалар б-н реакцияләрен тикшерә, 1-алкилтиоалкилфосфонатлар синтезлау ысулын тәкъдим итә. Дүрт координацияле фосфор тиокислоталарының элементорганик кушылмаларын синтезлый, аларның үзлекләрен өйрәнә. Озын чылбырлы фосфорорганик кушылмаларны моноолефиннарның $C_{16}$-$C_{18}$, $C_{20}$-$C_{26}$, $C_{28}$-$C_{40}$ сәнәгать фракцияләре һәм пропилен тетрамерын фосфориллап табу юлларын; бисдитиофосфонат к-таларын регионселектив синтезлау алымнарын, аларның реакциягә сәләтен; күп кенә иң түбән изопреноид, монотерпеноид һәм дитерпеноидларның табигый кушылмаларын фосфориллау алымнарын фәнни һәм технол. яктан нигезли. Фосфорлап модификацияләнгән полиэфирларны үтә тармакланган полимерларны фосфориллау реакцияләре нигезендә таба. Синтезланган фосфорорганик кушылмалар арасында бактериаль, фунгистатик, инсектоакарицид һәм гербицид активлыгына, ш.у. майлагычларның сыйфатын яхшыртучы өстәмәләр һәм корыч коррозиясенә ингибитор үзлекләренә ия булган матдәләр табыла. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Органические реакции сульфидов фосфора // Получение и свойства органических соединений серы. М., 1998 (автордаш); Фосфорорганические соединения на основе 1,3,2,4-дитиадифосфетан-2,4-дисульфидов. Синтез и свойства // Журн. общей химии. 2002. Т. 72, № 9 (автордаш); Disilyl dithiophosphonates in the synthesis of open chain and cyclic organothiophosphorus compounds // Heteroatom Chem. 2004. V.15, № 3 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**НИЗА́МОВ** Равил Авзал улы (17.9.1930, Чаллы р-ны Бигеш а. — 6.8.2007, Казан), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. канд. (1962), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1992). Алабуга китапханә техникумын (1948), Казан пед. ин-тын (1954) тәмамлый. 1948–50 елларда Кызыл Йолдыз р-ны китапханәсе мөдире. 1954 тән Иж-Бубый авылы урта мәктәбе укытучысы, 1956 дан Әгерҗе р-ның Сарсак-Омга урта мәктәбе директоры. 1958 дән Казан ун-тында: 1962–63 тә тарих-филол. ф-ты деканы урынбасары, 1969–79 да пед. каф. мөдире. 1980–90 да ТАССР мәгариф министры. 1990–2001 дә ТР Мәгариф министрлыгының Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү ин-тында пед. каф. мөдире. Хезмәтләре мәктәп укучыларын хезмәткә өйрәтү, студентларның уку эшчәнлекләрен оештыру мәсьәләләренә карый. 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты, 1990–93 тә ТР ЮС депутаты. Хезмәт

Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Педагогик уйланулар. К., 1994; Татар халык педагогикасы. К., 2002 (автордаш); Повышение активности школьников на уроках труда. К., 1971; Дидактические основы активизации учебной деятельности студентов. К., 1975.

**НИЗА́МОВ** Рәмзи Низам улы (7.1.1939, Ворошилов, хәзер Тукай р-ны Теләнче Тамак а.), ветеринар-микробиолог, радиобиолог, вет. фән. д-ры (1992), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1966), Кукмара р-ны вет. станциясендә табиб-эпизоотолог. 1969–90 елларда Казан вет. ин-тында. 1990 нан Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (ВНИВИ), 1994 тән радиоэкология һәм радиацион тикшерү ысуллары лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре түләмә авыруын кисәтү һәм бу авыруга диагноз кую ысулларын эшләү һәм гамәлгә кертүгә, ш.у. а.х. терлекләренә радиация зыянын булдырмау, диагноз кую һәм авыруны дәвалау ысулларына карый. Уйлап табуга 31 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Ветеринарная радиоэкология и радиоиммунология. К., 2000 (автордаш); Патоморфогенез сибирской язвы. М., 2002 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 г.г.). К., 2006.

**НИЗА́МОВ** Рәшит Корбангали улы (23.5.1957, Буа ш.), төзелеш материаллары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007), проф. (2008). 1979 елда Казан төзелеш инженерлары ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1979–86 да һәм 1989–94 тә Казан технол. ун-тының Түбән Кама ф-лында), 1994 тән төзелеш материаллары, эшләнмәләре һәм конструкцияләре технологиясе кафедрасында, каф. профессоры (2008 дән), 2001–08 дә төзелеш-технол. ф-ты деканы, ректор (2008 дән). Хезмәтләре поливинилхлорид (ПВХ) нигезендә югары нәтиҗәле төзелеш материаллары һәм эшләнмәләре булдыруга, аларның чимал базасын киңәйтү һәм энергия саклаулы калдыксыз технологияләр эшләүгә карый. Н. термик тотрыклылык һәм пластификация үзлекләренә ия булган ПВХ тутырмаларның полифункциональлеге принцибын фәнни нигезли, алар нигезендә алынган төзелеш материаллары һәм эшләнмәләренең технологик һәм техник эксплуатацияләү үзлекләре яхшыруын күрсәтә. Фаразланган полифункциональ модификация тәэсиренә ия булган, ПВХ-композицияләрдә стабилизатор, пластификатор һәм тутыргыч ролен үтәүче нәтиҗәле дисперс тутырмалар эзләүнең физик-химик нигезләре эшләнә. ПВХ нигезендәге төзелеш материаллары һәм эшләмәләренең кабаттан эшкәртү, термототрыклылык үзлекләре яхшыртылган һәм тиешле таләпләргә җавап бирерлек төп составлары һәм рецептуралары тәкъдим ителә. Хезмәт нәтиҗәләре ЮНЕСКОның Халыкара фәнни-техник эшләр каталогына кертелгән.

Х е з м.: Полимерные материалы: Структура, свойства, применение. К., 2001 (автордаш); Полифункциональные наполнители поливинилхлорида. К., 2005; Полифункциональные наполнители для поливинилхлоридных композиций строительного назначения // Строительные материалы. 2006. № 7.

**НИЗА́МОВ** Сәлах Низам улы (6.12.1905, Казан губ., Лаеш өязе Шәдке а. — 1.2.1975, Казан), дәүләт эшлеклесе. Татарстан югары коммунистик а.х. мәктәбен тәмамлый (1937). 1938–52 елларда (бүленеп) Казанда ВКП(б)ның Дзержинский район ком-ты пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, секретаре. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952–59 да ТАССР ЮС Президиумы рәисе. 1951–59 да ТАССР, 1955–59 да РСФСР ЮС лары депутаты. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**НИЗА́МОВ** Хәләф Мирзамөхәммәт улы (20.10.1941, Актаныш р-ны Иске Кадермәт а. — 14.7.2013, Казан), партия, хакимият хезмәткәре, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Алабуга пед. ин-тын (1965), КПСС ҮК каршындагы Читтән торып уку Югары партия мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1974). 1959–60 елларда Актаныш р-нының Иске Әлем авыл китапханәсе мөдире, 1964 тән шул ук районның Яңа Богады урта мәктәбендә, директор урынбасары (1966 дан). 1968 дә КПССның Актаныш райкомында пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, 1969 дан секретарь, 1977 дән 2 нче секретарь, 1982 дән 1 нче секретарь. 1985–89 да ТАССР МСның, 1989–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты оештыру-инструкторлык бүлекләре мөдире. 1990–91 дә ТССР ЮС Президиумы секретаре. 1991–98 дә ТР Президенты аппараты җитәкчесе. 1985–95 тә ТР ЮС депутаты, 1995–2000 дә ТР халык депутаты. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**НИЗА́МОВ** Һәвәс Нуретдин улы (6.2.1935, БАССРның Дүртөйле р-ны Баргызбаш а. — 2.3.2006, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1993), проф. (1993), РФнең атказ. уйлап табучысы (1998). 1961 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, «Энергия» ФҖБдә (Мәскәү өлкәсе Калининград ш.) эшли. 1975 тән Мәскәүдә: Җылылык техникасы фәнни-тикшеренү ин-тында (1975–77), СССР ФАнең Машиналар белеме ин-тында (1977–84), Төгәл машиналар төзү КБнда (1984–89), Мәскәү техник ун-тының Энергетика машиналары фәнни-тикшеренү ин-тында (1989- 93). 1993 тән Россия Халыклар дуслыгы ун-тында. Хезмәтләре энергетика җайланмаларының үткәргеч торбалар системаларында басым тирбәнешләрен демпфирлауга карый. Н. төрле системаларда гидравлик бәрүләрне, вибрация процессларын сүндерү җайланмаларын эшли. Уйлап табуга 90 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Гидроупругие колебания и методы их устранения в закрытых трубопроводных системах. Красноярск, 1983 (автордаш); Гидродинамика одно- и многофазных сред. Таш., 1986 (автордаш); Комплексные исследования двухфазных потоков с целью создания устройств для управления гидродинамическими процессами. М., 1991 (автордаш).

**НИИНЕФТЕПРОМХИ́М**, к. *Нефть сәнәгате химиясе институты.*

**НИИСПЕЦКАУЧУ́К**, к. *Махсус каучук полимерлары институты.*

**НИКА́НДРОВА** Людмила Геннадьевна, к. *Володина* Л.Г.

**НИКАНО́Р** (Бровкович Александр Иванович) (20.11.1826, Могилёв губ. Высокое а. — 27.12.1890, Одесса ш.), дин эшлеклесе, философ-православие теологы, теология д-ры (1869), Петербург ФАнең шәрәфле әгъзасы (1889). Могилёв руханилар уч-щесен (1841), Петербург руханилар семинариясен (1847) һәм руханилар академиясен (1851) тәмамлый. 1850 елда монахлык кабул итә (1851 дән иеромонах). 1851–56 да Петербург руханилар академиясендә бакалавр. 1856–58 дә Рига руханилар семинариясе ректоры, архимандрит (1856). 1856–65 тә Саратов руханилар семинариясе ректоры, бер үк вакытта Спас-Преображение монастыре башлыгы. 1865–68 дә — Полоцк руханилар семинариясе, 1868–71 дә Казан руханилар академиясе ректоры. 1871–77 дә Аксай епископы, бер үк вакытта Дон епархиясе викарие. 1877–84 тә Уфа һәм Минзәлә, 1884–90 да Херсон һәм Одесса епископы (1886 дан архиепископ). Изге Синод әгъзасы (1887 дән). Хезмәтләре философиягә, чиркәү тарихына карый, аларда белем, дини ышанулар һәм әхлакый кыйммәтләр берлеген православиегә нигезләнеп дәлилләү тәкъдим ителә.


Х е з м.: Разбор римского учения о видимом (папском) главенстве в церкви. К., 1871; Позитивная философия и сверхчувственное бытие: В 3 т. СПб., 1875–88; Поучения Никанора, епископа Уфимского и Мензелинского. Уфа, 1883.

*Әд.:* С о л о в ь ё в В.С. Опыт синтетической философии // Православное обозрение. 1876. № 5; З е ф и р о в Е. Мои воспоминания о Преосвященном Никаноре за время его пребывания на Уфимской кафедре (1877–1884). СПб., 1894.

**НИКАНО́Р** (Каменский Никифор Тимофеевич) (25.5.1847, Әстерхан губ., Чёрный Яр өязе Солодовников а. — 27.10.1910, Казан), дин эшлеклесе, христиан дине галиме, тарихчы, христиан теологиясе д-ры (1894). Әстерхан руханилар семинариясен тәмамлый (1868). 1874 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, Казан укытучылар семинариясендә дин укытучысы һәм семинария чиркәвендә өлкән поп. 1876 дан протоиерей. 1879–81 дә Казан руханилар семинариясе ректоры. 1889 дан монахлыкта. 1891–93 тә Чабаксар епископы, Казан епархиясе викарие. 1893 тән — Архангельск, 1896 дан — Смоленск, 1899 дан — Орёл, 1902 дән — Екатеринбург, 1903 тән Гродно епископы; 1905 тән — Варшава, 1908 дән Казан һәм Зөя архиепископы. Н. мәгариф өлкәсендә Н.И.*Ильминский* идеяләрен дәвам итә. Чиркәү-приход мәктәпләрендә *Ильминский системасын* таратуга ярдәм итә. 1908–10 да руслаштыру тарафдарларының ул системаны тәнкыйтьләүләренә каршы чыга. Идел буе халыклары телендә гыйбадәт кылуны киңәйтүгә булышлык итә, 1910 да Казанда миссионерлар съезды оештыра. Руханиларның сәясәттә актив катнашуларын яклый, уң сәяси



П.Р. Никитенко.



В.С. Никитин.

оешмаларга булышлык күрсәтә. Хезмәтләре Казан төбәгендәге православие тарихына карый. Н. кыйммәтле тарихи чыганакларны фәнни әйләнешкә кертә, алар «Архиепископ Никанорның Казан статьялары җыентыгы»нда («Казанский сборник статей архиепископа Никанора», 1911) басыла. Казан епархиясенең Чиркәү тарих-археол. җәмгыяте эшчәнлегенә ярдәм итә.

Х е з м.: Изображение Мессии по Псалтыри. К., 1879; Экзегетико-критическое исследование послания святого апостола Павла к евреям. К., 1903; Толковый апостол: В 3 ч. СПб., 1904–05.

*Е.В.Липаков.*

**НИКА́Х** (гарәп. نكــاح – өйләнешү), исламда шәригать буенча *өйләнешү* йоласы. Мөселманнарда Н.сыз өйләнешүләр гамәлгә кермы, андый очракларда туган балалар законсыз дип исәпләнә. Дини-хокукый мәзһәбләрдә Н. гаилә кору килешүе дип карала, хатын-кызның кияүгә чыгуы раслана. Мөселманга христиан һәм яһүди хатын-кызлар б-н никахлашу рөхсәт ителә (матди яктан тәэмин итү шарты б-н 4 хатынга кадәр); мөселман хатын-кызның ире мөселман гына була ала. Турыдан-туры туганнар, нәселнең ян тармаклар буенча 3 нче буыннан якынрак вәкилләре, 2 нче буыннан да якынрак сөт кардәшләре арасында Н. тыела. Н. ир б-н хатынның аерылышуга ризалыгы булганда һәм ирнең теләге буенча таркала. Иренең үз вазифаларын башкармавын, кырыс мөнәсәбәт күрсәтүен яки матди мөмкинлекләре булмавын исбатлаган очракта, хатын, мәхкәмәгә мөрәҗәгать итеп, Н.ны өзә ала. Рев-циягә кадәр Н. кәләш йортында бары тик ирләр (кияүнең һәм кәләшнең әтиләре, туганнары) катнашында (гадәттә, кияүдән башка) пәнҗешәмбе яки җомга көннәрендә укылган. Мулла яңа өйләнешүчеләрнең исемнәрен теркәү китабына язган, *мәһәр* күләмен, туй уздыру өчен азык-төлек исемлеген яки аның бәясен, кияүнең кәләшкә бирергә тиешле бүләкләрен (аерылышу очрагында ирнең хатынына бүлеп бирәчәк мөлкәтен) билгеләгән. Шуннан соң мулла яшьләрнең Н.ка ризалыкларын сораган, кияү өчен ризалыкны аның әтисе, күрше бүлмәдә яисә чаршау артында утырган кәләш өчен ризалыкны 2 шаһит биргән. Анналары Коръәннән Н. сүрәсе укылган. Никахлашу төгәлләнгәч, Н. килешүе хатынга тапшырылган, ир кеше мулланы бүләкләгән. Совет чорында өйләнешүнең төп формасы загс органнарында теркәлүдән гыйбарәт була. Татар авылларында кайбер үзгәрешләр б-н Н. йоласы сакланган: аны мулла яки йоланы белүче өлкән яшьтәге абруйлы мөселман укый; шәригать буенча каралган мәһәр символ төсен ала; кайбер очракта Н. кияү йортында үткәрелә. Совет чорыннан соң Н. йоласын башкару милли мәдәниятнең бер өлеше (йола) буларак кабул ителә, ул кайбер үзгәрешләр б-н традицион форма кысаларына кайта: Н. кияү б-н кәләш катнашында кайчакта мәчеттә һәм, кагыйдә буларак, өйләнешү рәсми рәвештә теркәлгәнче укыла. 1990 нчы еллардан соң әкренләп татарларнаң дөньви яшәешенә яңадан кайта. Н. мәчетләрдә укыла башлый.

*Әд.:* Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татары. М., 2001.

**НИКИТЕ́НКО** Пётр Романович (6.8.1920, хәзер Белоруссия Респ-касы, Гомель өлкәсенең Хойник р-ны Омельковщина а. — 3.9.2011, Киев), генерал-лейтенант (1981). 2 нче Ленинград артиллерия уч-щесен (1942), Югары артиллерия штабы мәктәбен (Ленинград, 1947), Ф.Э.Дзержинский исем. артиллерия инженерлары академиясен (Мәскәү, 1955) тәмамлый. Совет-фин сугышында катнаша. 1942–44 елларда кече офицерлар курсларында тактик әзерлек укытучысы. Бөек Ватан сугышы елларында 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтларында артиллерия дивизионы штабы башлыгы, артиллерия дивизиясендә бригада разведкасы башлыгы. 1947–50 дә Югары артиллерия штабы мәктәбендә артиллерия разведкасы укытучысы (Мәскәү өлкәсенең Коломна ш.). 1955 тән Киев хәрби округында артиллерия бригадасы командиры урынбасары, 1956 дан артиллерия штабы бүлеге башлыгы. 1961–63 тә Синай армиясенең артиллерия командирлары киңәшчесе (Мисыр). 1963–70 тә Киев хәрби округында ракета бригадасы командиры. 1970–72 дә Совет гаскәрләренең Көньяк төркемендәге ракета һәм артиллерия гаскәрләре штабы башлыгы (Будапешт). 1972–74 тә Германиядә совет гаскәрләре төркемендәге ракета гаскәрләре һәм артиллерия командующиеның 1 нче урынбасары — штаб башлыгы. 1974–83 тә ракета гаскәрләренең М.Н.Чистяков исем. Казан югары хәрби команда инженерлары уч-щесе башлыгы.

1983–93 тә Электроника сәнәгате фәнни-тикшеренү ин-тында баш хәрби белгеч (Киев). Хезмәтләре артиллерия һәм ракета частьләренең сугышчан килешенүен камилләштерүгә карый. 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Б у л а т о в Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000.

**НИКИ́ТИН** Валерий Григорьевич (11.3.1943, Яшел Үзән ш.), химик-технолог, химия фән. канд. (2002), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). 1965 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, Инженерлык химия-технол. ин-ты директоры урынбасары (2005 тән). Хезмәтләре шартлаучан составлар һәм композицияләрдәге югары нәтиҗәле компонентларның теоретик нигезләренә, күп кенә фуроксан һәм фуразаннарның биол. актив кушылмаларын синтезлауга карый. Н. фуроксан, фуразан һ.б. төркемнәр булган фтординитрометил кушылмалар синтезлау алымнарын эшли. Дәүләт бүләге махсус химия өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. 150 дән артык фәнни хезмәт авторы, уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы бар. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004).

*Әд.:* Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

**НИКИ́ТИН** Виктор Яковлевич (8.9.1928, Үзбәкстан ССР, Ташкент өлкәсенең Янгиюл р-ны Чиназ кышлагы), ветеринар-акушер, вет. фән. д-ры (1971), проф. (1972), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1988). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук эшли. 1956 елдан Дагстан а.х. ин-тының акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. 1968 дән Ставрополь аграр ун-тының акушерлык каф. мөдире, бер үк вакытта вет. ф-ты деканы (1982 гә кадәр), проректор (1982–83), ректор (1984–99). Хезмәтләре а.х. терлекләрен үрчетү, сарыкларда җилен шешү авыруын дәвалауга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ветеринарное акушерство, гинекология и биотехника размножения животных. М., 2000 (автордаш); Практикум по акушерству, гинекологии и биотехнике размножения животных. М., 2003 (автордаш).

*Әд.:* Кафедра акушерства имени профессора А.П.Студенцова // Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993.

*М.Г.Миролюбов.*


**НИКИ́ТИН** Владимир Дмитриевич (1907, Ярославль ш. — 1959), партия эшлеклесе. Ярославль сәнәгать-икътисад техникумын тәмамлый (1922). 1922–25 елларда элемтә конторасында эшли (Ярославль). 1925 тән Ярославль, Иваново, Мәскәүдә комсомол эшендә. 1931–37 дә ВКП(б) ҮКның оештыру-инструкторлык, җитәкче партия органнары бүлекләре инструкторы, җаваплы инструкторы. ВКП(б)ның Курск өлкә ком-тының 2 нче секретаре (1937), Воронеж (1937–41), Куйбышев (1942–43), Татарстан (1943–44) өлкә ком-тларының 1 нче секретаре. Н. һәм ВКП(б) ҮКның Пропаганда һәм агитация идарәсе башлыгы урынбасары М.Т.Иовчук доклады буенча 1944 нең 9 августында ВКП(б) ҮКның *«Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»* карары кабул ителә. Соңрак ВКП(б) ҮК кадрлар идарәсе башлыгы урынбасары, инспекторы. Ленин ордены б-н бүләкләнә.


**НИКИ́ТИН** Владимир Степанович (11.7.1900, Саратов ш. — 23.11.1974), театр рәссамы, педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1940, 1950), ТАССРның халык рәссамы (1954). Саратовта Боголюбовск рәсем уч-щесен (1918) һәм Югары

Ирекле-дәүләт сәнгать остаханәләрен (1920) тәмамлый. 1918–19 елларда ВХУТЕМАСта (П.П.Кончаловский, И.И.Машков остаханәләре) укый. Иҗат эшчәнлеген 1920 дә Кавказ фронтының сәяси бүлеге каршында рәссам-монументалист буларак башлый, агитация поездларын бизи, Грозный, Махачкала, Нахичевань һ.б. шәһәрләрдәге вокзал интерьерларында революцион темаларга дивар композицияләре иҗат итә. 1921 дә Ерак Көнчыгыш Респ-касындагы театр бүлегенең күчмә театрында рәссам булып эшли башлый, 1922–37 дә — Саратов, Әстерхан, Краснодар, Ашхабад, Владикавказ театрларында. 1937 дән — Казан Зур драма театрында рәссам, 1939–65 тә баш рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1952) П.П.*Беньков* һәм П.Т.*Сперанский* б-н беррәттән, Татарстанда театр бизәлеше сәнгатенә нигез салучыларның берсе. Театрда сәхнәгә кую һәм оештыру принципларын төзи, сәхнә технологиясенә зур игътибар бирә. 200 дән артык драматик һәм опера спектакльләренә, ш.и. Казан театрлары сәхнәләрендә куелган 120 спектакльгә декорацияләр иҗат итә. 1920 елларда Н. иҗатында конструктивизм йогынтысы сизелә, 1930 дан декорацияләр бизәлешендә күбрәк нәкышьле чишелешләр куллана башлый. Тарихи интерьерлар белгече буларак, А.К.Толстойның «Фёдор патша» («Царь Фёдор Иоаннович», 1940, 1955), В.А.Соловьёвның «Фельдмаршал Кутузов» (1941), А.Н.Толстойның «Иван Грозный» (1945) һәм «Михнәтле заман» («Хождение по мукам», 1947, шул исем. романы буенча), А.Н.Островскийның «Иделдә төш» («Воевода»), А.И.Степанов, И.Ф.Поповның «Порт-Артур» (икесе дә — 1953), П.И.Мельников-Печерский романы буенча «Урманнарда» («В лесах», 1958) кебек монументаль спектакльләргә декорацияләр ясый. Пейзаж остасы буларак, Н. хәрәкәт атмосферасы тудыру өчен табигать мотивларынан файдалана. И.С.Тургенев романы буенча «Дворяннар оясы» («Дворянское гнездо», 1941, 1944), И.А.Гончаровның «Текә яр» («Обрыв», 1948), А.П.Чеховның «Өч сеңел» («Три сестры», 1951), Я.Райнисның «Ис әйдә, җил, ис!» («Вей, ветерок!», 1951), А.П.Чеховның «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», 1960) әсәрләре буенча куелган спектакльләрне бизи (алар театр бизәлеше сәнгатенең күренекле әсәрләре булып танылалар). Н.Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» (1950), М.Н.Елизарованың «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» («Юность Буревестника», 1955), М.Горькийның «Карт» («Старик», 1956), Л.Н.Толстойның «Караңгылык хакимлеге» («Власть тьмы», 1959), Д.Н.Мамин-Сибирякның «Төшемле урында» («На золотом дне», 1970) исемле әсәрләре буенча сәхнәләштерелеп, Н. тарафыннан бизәлгән спектакльләргә тарихи һәм конкурeш чынлыгы, драматургия материалына тирәнтен үтеп керә белү хас. Шулай ук Татар акад. театры, Казан яшь тамашачылар театрының күп кенә спектакльләрен бизи, Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетына (1941, куелмый кала) костюм эскизлары ясый. Казандагы сәнгать һәм театр уч-щеләрендә укыта, сәхнә әзерләү технологиясенә зур игътибар бирә. Берничә тапкыр сәнгать күргәзмәләрендә, ш.и. бөтенроссия һәм зона күргәзмәләрендә катнаша. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Театр музеенда (Мәскәү), Рига театр һәм музыка сәнгате музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Казан Зур драма театры каршындагы Театр музеенда саклана. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Благов Ю. Казанский сын саратовского цехового. К., 2000; Театральная энциклопедия. М., 1965; Русский драматический театр: Энцикл. М., 2001.

*Ю.А.Благов.*






В.С.Никитин. 1. А.Н.Толстойның «Иван Грозный» романы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. Кәгазь, гуашь. 1945; 2. А.Н.Островскийның «Иделдә төш» («Воевода») пьесасы буенча куелган спектакльгә декорация эскизы. Кәгазь, гуашь. 1953. Икесе дә Казан Зур драма театры музеенда.

**НИКИ́ТИН** Евгений Васильевич (23.1.1936, Воронеж өлкәсенең Мичуринск ш. — 10.12.2006, Казан), химик, химия фән. д-ры (1985), проф. (1989), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФАнең Казан ф-лы Химия ин-тында. 1961 дә Чуаш электротехника фәнни-тикшеренү ин-тында (Чабаксар ш.), 1962 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре металлар һәм элементорганик кушылмалар электрохимиясенә карый. Элементорганик катион-радикалларны генерирлау анод реакцияләре һәм аларның шуннан соңгы әверелешләренең кинетикасы һәм механизмнары буенча фәнни юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Н., беренче булып, Арбузов реакциясенең фосфит к-тасы эфирларының электрохимик оксидлашу шартларында узу мөмкинлеген тормышка ашыра. Фосфор, мышьяк һәм сөрмә атомнары кергән органик кушылмаларны электрохимик синтезлау алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Анодно-инициируемое свободно-радикальное фосфорилирование олефинов // Журн. общей химии. 1997. Т. 67, вып. 2 (автордаш); Синтез триалкилфосфатов из белого фосфора // Журн. общей химии. 1998. Т. 68, вып. 7 (автордаш); Electrochemically induced phosphorylation of alkens // Electrochimica Acta. 1997. V. 42, № 14 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.



И.М.Никитин.

**НИКИ́ТИН** Иван Моисеевич (30.5.1892, Самара губ. Бөгелмә өязе, Чемодурово а. — 6.9.1972, Бөгелмә ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), рядовой. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнаша. Туган авылында колхоз рәисе булып эшли. 1942 елның декабреннән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 57 нче мотоукчы бригада укчысы (2 нче танк армиясенең 3 нче танк корпусы). Үзәк һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Чернигов-Припять (1943) һәм Корсунь-Шевченко (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 13 мартыннан Берёзки-Берщадский авылы (Винница өлкәсенең Берщадский р-ны) янында Көньяк Буг елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: сугышчылар төркеме б-н кул астында булган әйберләрдән җиңел күпер ясап, өстәмә көчләр килеп җиткәнче, төн буе аны үз кулында тота. 1944 тә авыр яраланганнан соң демобилизацияләнә. Бөгелмәдә яши. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Ханин Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НИКИ́ТИН** Иван Николаевич (6.9.1934, Чуаш АССР, Яльчик р-ны Ново-Байдеряково а.), вет. табибе, вет. эшен оештыручы, вет. фән. д-ры (1980), проф. (1982), ТАССРның атказ. вет. табибе (1973), РФ, Чуаш Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (1994, 1995). Казан. вет. ин-тын тәмамлый (1958). 1958–65 елларда Иркутск өлкәсенең вет. учреждениеләрендә эшли: Тайшет р-ны вет. лаб-ясе мөдире (1958–59), Бохонский р-ның баш вет. табибе (1959–60), Иркутск өлкә башкарма ком-тының а.х. идарәсендә вет. бүлеге башлыгы (1961–65). Бер үк вакытта (1960–61), Бохонский р-ны башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1965 тән Казан вет. ин-тында (хәзер Казан вет. медицинасы ака-



С.П.Никитин.



Е.Т.Никитина.

демиясе), 1976 дан вет. эшен оештыру һәм икътисад каф. мөдире. Н. тарафыннан вет. эшен оештыру һәм аның икътисадына кагылышлы теоретик, методик, гамәли мәсьәләләр карала, аның җитәкчелегендә РФ һәм ТРда вет. эшчәнлеген көйләүче 70 тән артык норматив-хокук документы гамәлгә кертелә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең Мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1997).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 г.г.). К., 2006.

**НИКИ́ТИН** Игорь Александрович (20.10.1899, Екатеринбург ш. — 1947, Казан), нәкышьче, график, бизәүче-рәссам. Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый (1914). Уку елларында А.М.*Родченко* б-н дуслаша, мәктәп күргәзмәләрендә символик графика хезмәтләре б-н катнаша. 1910 елларның 2 нче яртысында Казанда Розенбергның «Ша нуар» миниатюралар театрында эшли. Кызыл Армиядә хезмәт иткәндә (1918–21), Көнбатыш армиянең Идел буе округы Сәяси идарәсе штабы каршындагы сәнгать студиясен җитәкли, сәяси плакатлар яза. Казан архит-ра-техника ин-тында укыта (1920–25), сынау-әзерлек остаханәсен җитәкли, сәнгать советы әгъзасы була. «*Подсолнечник*» (1918), «*ТатАХРР*» (1923 тән; 1924 тән секретарь, 1926–31 дә — рәис), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1936). «Татхудожник»ны оештыруда актив катнаша (1934). Окт. рев-циясенең 10 еллыгы уңаеннан Казан мәйданнарын, урамнарын һәм биналарын бизәү эскизларын эшли. 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында китап графикасы өлкәсендә күп хезмәт куя.

1910 еллардагы Казан авангард сәнгатенең иң көчле вәкилләреннән. Рәссамның иҗаты импрессионизм (Гоген һәм Матисска ияреү), кубизм, экспрессионизм, предметсыз һәм «әйберләрдән гыйбарәт булган» сәнгать (киндер, чыпта, пыяла һ.б. материаллардан коллажлар) кебек ясалма агымнардан әкренләп тормыш, көнкүрешне «ТатАХРР»да таралган сурәтләүгә күчә бара. Төп әсәрләре: «Автопортрет» (1915), «Предметсыз нәкышь» (6 вариантта, 1919–21), «Портрет (Сафка тезелү)», «Төс һәм форма» (икесе дә — 1920), «Кызыл кавалерия һөҗүме» (1921), «М.Вахитов исем. завод» (1925), «Отволжский» колхозы» (1929), «Колхозда ашлык суктыру (Тәмте а.)» (1935). Җирле һәм башка шәһәрләрдәге рәссамнарның 5 нче даими күргәзмәсендә (Казан, 1915), «Подсолнечник» берлегенең 1 нче күргәзмәсендә (Казан, 1918), 1 нче һәм 2 нче дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә (Казан, 1920, 1921), Главмузейның 2 нче һәм 3 нче сәнгать күргәзмәләрендә (Советск ш., 1920, 1921), «ТатАХРР»ның 4 нче күргәзмәсендә (Казан, 1925), Октябрьнең 10 еллыгына (Казан, 1927), ТАССРның 10 еллыгына (Казан, 1930) багышланган күргәзмәләрдә, «Татхудожник»ның 1 нче күчмә күргәзмәсендә (Зеленодольск ш., 1936), Мәскәү һәм Татарстан рәссамнары күргәзмәсендә (Казан, 1937), «Китап сәнгате» (Париж, 1931), «СССРда хәзерге заман сәнгате» (АКШ, 1932–33) халыкара күргәзмәләрендә катнаша. Н. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.



И.А.Н и к и т и н. «Испан тавернасы». Кәгазь, акварель, карандаш. 1918. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

*Әд.:* Актуальная графика. К., 1935; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

*Е.П.Ключевская.*

**НИКИ́ТИН** Семён Павлович (15.2.1921, Тәтеш кантоны Төбәк Черкене а. — 2.7.1968, Чуаш АССРның Канаш ш.), токарь, Соц. Хезмәт Герое (1959). 1938–68 елларда Канаш вагоннар ремонтлау з-дында эшли. Н. тимер юл вагоннарын конвейерлы системада ремонтлауны камилләштерү буенча якынча 200 рационализаторлык тәкъдиме кертә; аларның күбесе вагон ремонтлау з-дларында производствога кертелә, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүгә ярдәм итә һәм икътисади нәтиҗә бирә (мәс., авыр вагоннарны күтәрү өчен пневмогидравлик күтәргеч (инженер Ф.М.Леонтьев б-н автордаш), гидрокүтәргеч, пневмочүкеч; станокларны энергия челтәреннән автомат рәвештә сүндерү приборы). Герой исеме тимер юл транспортын үстерүдәге уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, «Мактаулы тимерюлчы» билгесе б-н бүләкләнә. Канаш шәһәренең мактаулы гражданы.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НИКИ́ТИН** Сергей Николаевич (23.1,1851, Мәскәү — 5.11.1909, С.-Петербург), геолог, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1902). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1871), шунда ук эшли. 1882 елдан Россия Геология ком-тында өлкән геолог. 1907 дән Игенчелек һәм дәүләт милке министрлыгында. Хезмәтләре югары палеозой, мезозой һәм кайнозой утырмалары геологиясенә, юра һәм акбур аммонитлары палеонтологиясенә, гидрология һәм гидрогеологиягә карый. Н. Россиянең Европа өлешен һәм Урал алдын, ш.и. Идел-Урал өлкәсе терр-ясен тикшерә. Россиянең күп кенә губерналарының, ш.и. Казан губернасының геол. карталарын төзи. Юра системасында югары һәм түбән Идел ярусларын, Пермь системасында Татар ярусын аерып күрсәтә. Рус тигезлеге рельефының борынгылыгы турында нәтиҗә ясый. Россиядә гидрогеологик тикшеренүләрне башлап җибәрүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Общая геологическая карта России (лист 57) // Тр. Геол. комитета. 1890. Т. 5, № 1.

*Әд.:* М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России. М.–СПб., 2000.

**НИКИ́ТИН** Фауст Васильевич (20.7.1894, Смоленск өлкәсенең Гжатск, хәзер Гагарин ш. — 16.10.1992, Биектау р-ны Бөреле җәнлек с-зы пос.), зоотехник-селекционер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1950). Кировоград шәһәрендә (Украина ССР) а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1928), Одесса өлкәсенең Киров шәһәре туган якны өйрәнү музеенда эшли. Репрессияләнә, 1930–35 елларда Эчке эшләр халык комис-тының 3 нче Темников лагеренда (Мордва АССР) куян үрчетү буенча зоотехник. 1935–40 та Куянчылык фәнни-тикшеренү ин-тының Воронеж тәҗрибә-өйрәнү пунктында фәнни хезмәткәр, Курск өлкәсенең Солнцево куян үрчетү с-зында өлкән зоотехник. 1941–57 дә «Бөреле» җәнлек с-зының куян фермасында өлкән зоотехник. 1959 да аклана. Н. куяннарның 9 яңа токымын (кара-көрән, өрфия зәңгәрсу, мамыклы великан, татар көмешсыман куяны, Казан зәңгәр куяны, шиншилла великан, котик, зәңгәр котик, ак котик) чыгара. Яшь куяннарны җир өстеннән күтәртелгән челтәрле идәндә асрау ысулын гамәлгә кертә, төркемләп асрау өчен 2 төр челтәрле читлек, ачык һавада тоту максатыннан, һава шартларының ниндилегенә карап, 3 төр читлек конструкцияли. Ил күләмендә киң кулланылган рационализаторлык тәкъдимнәре авторы. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша (1914–18). 4 нче дәрәҗә Изге Георгий, Изге Анна орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые породы кроликов. К., 1949; Кролиководство. К., 1957; 100 советов кролиководу. К., 1960.

*Әд.:* Б р а ж н и к о в Е.Н. О выведенных Ф.В. Никитиным новых породах кроликов // Разведение и содержание кроликов. Краснодар, 1951; Беспокойное сердце // Кролиководство и звероводство. 1964. № 2.

*Ә.Х.Фазылҗанов, С.А.Захарова.*

**НИКИ́ТИНА** Евдокия Тимофеевна (19.2.1916, Лаеш өязе Новосёлок а. — 21.3.1990, Казан), йон кыркучы, Соц. Хезмәт Герое (1960). 1932–66 елларда Татарстан мех җитештерү берләшмәсендә ярдәмче эшче, йон кыркучы, смена мастеры, эшкәртү цехы башлыгы. Н. смена нормаларын 2,5–3 тапкыр арттырып үти. Герой исеме җитештерүдәге югары күрсәткечләре һәм продукциянең югары сыйфаты өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. «Мелита» АҖнең Хезмәт Даны музеенда Н.га багышланган стенд бар. 1985 тән пр-тиедә Н. исем. бүләк булдырыла, ул иң яхшы эшчеләргә бирелә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НИКИ́ТИНА** Лилия Евгеньевна (5.12.1965, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1987), Казан мед. ун-тында эшли, гомуми һәм органик химия каф. мөдире (2004 елдан). Хезмәтләре терпенлы кушылмалар синтезына һәм аларның реакциягә сәләтен өйрәнүгә карый. Н. 3-карен, α- һәм β-пиненнар, камфен, лимонен һ.б. монотерпен кушылмаларын региоһәм стереоселектив синтезлауның яңа алымнарын эшли. Аларның фәзаи төзелешен билгели, күкерт катышмалы реагентлар б-н реакцияләренең стереохимик үзенчәлекләрен ачыклый, күп кенә биол. актив кушылмалар ала.

Х е з м.: Реакции окиси камфена с серосодержащими нуклеофилами // Химия природных соединений. 1994. № 2 (автордаш); Каталитическое электрофильное присоединение тиолов к (+)-лимонену // Журн. органич. химии. 2000. Т. 36, вып. 4 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**НИКИ́ТИННАР**, рус эшмәкәрләре һәм цирк артистлары гаиләсе. Бертуган Дмитрий Александрович (1835 — 13.1.1918), Аким Александрович (1843 — 21.4.1917) һәм Пётр Александрович (1846 — 20.8.1921) кечкенәдән этиләре (крепостной крәстиян) б-н ярминкәләр һәм халык күңел ачулары вакытында төрле шәһәр мәйданнарында һәм урамнарында балаганнарда чыгыш ясыйлар. 1873 елда — Пензада, 1876 да — Саратовта, 1886 да Мәскәүдә үз циркларын ачалар. 1887 дә Н. Казанда Николаев мәйданында үз акчаларына цирк өчен таш бина төзү тәкъдиме б-н Казан шәһәр идарәсенә мөрәҗәгать итәләр. 20 елдан бу бина шәһәр милкенә күчәргә тиеш була. Эчке эшләр министрлыгы б-н килешү вакыты 3 елга сузыла. 1890 да Казанда павильоннары Николаев мәйданында урнашкан фәнни-сәнәгый күргәзмә уздырыла, шуңа бәйле рәвештә циркның агач бинасы Мунча күле урынында торгызыла. Цирк 1890 елның 20 маенда ачыла. Ш.у.к. *Казан циркы.*

**НИКИ́ФОРОВ** Анатолий Иванович (3.1.1949, Ширәмәт р-ны Елантау а.), механик, физика-матем. фән. д-ры (2006). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Компрессорлар төзү буенча тәҗрибә КБнда (Казан) эшли. 1973–85 тә СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында. 1985–89 да «ТатНИПИнефть»тә (Бөгелмә ш.) проектлаштыру методикасы лаб-ясе мөдире. 1989 дан РФА КГҮнең Механика һәм машина төзелеше ин-тында фильтрлау процессларын матем. модельләштерү лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре нефтьле һәм сулы катламнарда фильтрлау процессларын матем. модельләштерүгә карый. Н. катламнарга физик-химик тәэсир иткәндә күзәнәкле тирәлекнең фильтрлану-күләм сыйфатларын үзгәрүен тикшерә. Ике фазалы фильтрлау агымы б-н төрле үлчәмле кисәкчекләрне күчерү моделен эшли, төче су тутырганда балчыклы нефть катламының «бикләнү» күренешен модельли. Нефть катламнарына полимердисперс системалар б-н тәэсир итүнең матем. моделен эшли; аларны куллану нәтиҗәсендә катламны зуррак күләмдә суландыру һәм өстәмә нефть запасларын эшкәртү мөмкинлеген, скважиналарда продукциянең сулылыгы кимүне һәм нефть чыганагын актив файдалану вакыты озаюны, нефть чыгару коэффициенты артуны күрсәтә. Н. бериш булмаган катламнарның ахыры нефть бирү коэффициентын киметә торган суландыру режимнарын ачыклый.

Х е з м.: Перенос частиц двухфазным фильтрационным потоком // Мат. моделирование. 1998. Т. 10, № 6 (автордаш); О моделировании суффозии водоносных пластов // Инженерно-физ. журн. 2000. Т. 73, № 5; Математическая модель вытеснения нефти водой с применением полимердисперсных систем // Инженерно-физ. журн. 2002. Т. 75, № 1 (автордаш); О моделировании вытеснения нефти водой с гелеобразующими добавками // Мат. моделирование. 2002. Т. 14, № 12 (автордаш).

**НИКИ́ФОРОВ** Владимир Давыдович (20.2.1943, Чирмешән р-ны Яңа Котыш а.), механик, судно йөртүче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991). Казан елга техникумын тәмамлый (1966). 1961–2003 елларда Чистай суднолар ремонтлау з-дында, «Велигис» теплоходында моторист-рулевой (1965), «Герой Ю.Гагарин» теплоходында механик ярдәмчесе (1965 тән), «Озёрный-97» теплоходында механик, бер үк вакытта 2 нче штурман (1970 тән), «Прага-5» земснарядында механик, командир ярдәмчесе (1976 дан), командир (1988 дән). Дәүләт бүләге хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**НИКИ́ФОРОВ** Николай Анатольевич (24.6.1982, Казан), хакимият эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2011). Казан ун-тын тәмамлый (2004), 2004–06 елларда шунда ук, Чеботарёв исем. матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Бер үк вакытта, 2001–05 тә, «Казан порталы» компаниясе директоры урынбасары, 2004–05 тә «Заманча Интернет технологияләре» АҖ ген. директоры урынбасары. 2006–10 да ТРның Мәгълүмат технологияләре үзәге ген. директоры. 2010–12 дә ТР Премьер-министры урынбасары – ТР мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры. 2012 дән РФ элемтә һәм гаммәви мәгълүмат чаралары министры. Медальләр б-н бүләкләнә.

**НИКИ́ФОРОВКА** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 25 *км* төньяктарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. 1861 елга кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (19 йөзнең 2 нче чирегендә Н.да туган атаклы революцион хәрәкәт эшлеклесе В.Н.*Фигнер* һәм опера җырчысы Н.Н.Фигнерның эти-әниләре җирле алпавытлар була) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да волость идарәсе урнаша; Казан Богородица чиркәве (1878 дә төзелә), земство мәктәбе (1869 дан эшли, бүленеп, 1876–84 елларда), җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1484,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Никифоровка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 343 ир-ат; 1859 да — 463, 1897 дә — 697, 1908 дә — 810, 1920 дә — 660, 1926 да — 493, 1938 дә — 450, 1949 да — 345, 1958 дә — 204, 1970 тә — 162, 1979 да — 128, 1989 да — 85, 2002 дә — 77 кеше.

**НИКИ́ФОРОВО**, к.*Чиябашы*, Мамадыш р-ны.

**НИКИ́ШИН** Вячеслав Николаевич (1.1.1949, Липецк өлкәсенең Долгоруково р-ны Кече Колодезь а.), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007). 1971 елда Мәскәү автомеханика ин-тын тәмамлаганнан соң, Ярославль моторлар з-дында эшли. 1980–95 тә «КамАЗ» АҖнең фәнни-техник үзәгендә, 1999–2004 тә «КАМАЗ-Дизель» АҖдә сыйфат системасын сертификацияләү үзәге директоры, 2004–05 тә Алтай моторлар з-ды директоры урынбасары. Бер үк вакытта, 1981 дән, Кама икътисад инженерлары академиясендә, автомобильләр һәм эчке янулы двигательләр каф. мөдире (2011 дән). Хезмәтләре автомобиль двигательләрен эшләүгә, аларның сыйфат һәм куркынычсызлык күрсәткечләрен тәэмин итүгә карый.

Х е з м.: Обеспечение качества коленчатого вала автомобильного дизеля // Вестн. Саратов. гос. техн. ун-та. 2006. № 4 (16), вып. 3 (автордаш); Формирование и обеспечение качества автомобильного дизеля. Наб. Челны, 2006; Прикладная теория колебаний в автомобиле- и двигателестроении. Наб. Челны, 2012.

**НИКО́ЛА НИ́ЗСКИЙ ЧИРКӘВЕ́** (Никола кафедраль соборы), Казандагы архит-ра истәлеге (*Покров чиркәве* комплексына керә). Исеме Гостиный двордагы Никола чиркәвеннән түбәнрәк урнашуы б-н бәйле. 1565 елда аның урынында агачтан төзелгән Никола Боровский чиркәве урнашкан була. 17 йөз ахырында Раштуа бәйрәме хөрмәтенә таштан ике тәхетле, янкормалы Н.Н.ч. корыла. 19 йөз уртасында әлеге баганасыз, бер гөмбәзле, бер апсидалы храм, искерү сәбәпле, 1883 тә сүтелә. 1885 тә аның урынында арх. П.И.Романов проекты буенча яңа бина төзелә. Ике як тәрәзәле, турыпочмаклы храмны сандриклы, катлаулы йөзлекләр б-н бизәлгән биек, турыпочмаклы тәрәзәләр яктырта. Чиркәүнең



Никола Низский чиркәве.
Арх. П.И. Романов. 1885.


төп ишеге — көнбатыш фасадта (Бауман урамы ягында), икенче ишек ишегалдындагы көньяк фасадта урнашкан. Н.Н.ч.нең төньяк өлеше Покров чиркәве б-н тоташкан. Фасадлар эклектиканың ялган рус стилендә төзелгән һәм яссы лопаткалар б-н өч өлешкә бүленгән, уртанчысы фигуралы, аттик барабанлы гөмбәз б-н очланган. Тышкы як диварларын бизәгәндә икенче каттагы яктылык тәрәзәләре астына иконалар куелган ялган тәрәзәләр уелган. Лопаткалар, фризлар һәм тәрәзә төпләре яссы куышларга бүленгән һәм уеп ясалган филёнкалар б-н бизәлгән. Диварлар, аралаштырып, сыек яшел һәм ак төсләргә буялган. 1930 елда ябыла, 1946 да диндарларга кабаттан кайтарыла, шул вакыттан бирле Казан епархиясенең кафедраль соборы функцияләрен башкара. Соборда Казан изге әйберләре: хөрмәтләнүче Казан Мәрьям Ана иконасының күчермәсе, Феодор Мәрьям Ана иконасы (Казандагы элеккеге Феодор хатын-кызлар монастыренең төп изге әйбере) саклана.

*Әд.:* Православные храмы Татарстана: Альбом. К., 2000.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**НИКО́ЛА СОБОРЫ́**, Минзәлә шәһәрендәге ампир стилендәге архит-ра истәлеге. 1813 елда отставкадагы солдат М.Д.Ситниковның Уфа һәм Казан губернасындагы шәһәр-авыллардан җыйган иганә акчасына төзелә. 1880 елларда сәүдәгәрләр И.Г. һәм Д.И.Стахеевлар, П.В.Щетинкин акчасына үзгәртеп корыла (чаң манарасы төзелә). 1936 да ябыла, 1991 дә диндарларга кабат кайтарыла; 2006 да «Россия инвестиция ягулык-энергетика компаниясе» АҖ акчасына реставрацияләнә (сүтелгән манарасы яңадан төзелә).

Оригиналь манаралы, өч зур престоллы, өч нефлы храм. Апсидалы үзәк неф шактый ук алга чыгып тора. Төньяк, көньяк һәм көнбатыш фасадлардагы ишекләр дорик ордердагы портиклар б-н бизәлгән, апсидалар, төньяк һәм көньяк ишекләр өстенә кечкенә гөмбәзләр куелган. Храм өлешенең үзәк күләме өстендә тар барабандагы кечкенә гөмбәзле, ярымтүгәрәк түбә б-н ябулы, ике рәт пыяла уемлы (һәр рәттә 10), зур диаметрлы цилиндр урнашкан. Бер яруслы ашханәдә төньяк һәм көньяктан 5 әр биек тәрәзә уемы, өч ярусы чаң манарасы (кечкенә гөмбәзле, зур булмаган ярымтүгәрәк түбәле) бар.



Минзәлә шәһәрендәге Никола соборы. Арх. П.Г.Пятницкий. 1813.

*Әд.:* З л а т о в е р х о в н и к о в И. Уфимская епархия. Уфа, 1899; Свод памятников истории и архитектуры Республики Татарстан. Том 1. Административные районы. К., 1999.

**НИКО́ЛА СОБОРЫ́**, Чистайдагы архит-ра истәлеге. 1838 елда арх. П.Г.Пятницкий проекты буенча классицизм стилендә сәүдәгәрләр Г.А. һәм Д.А.Поляковлар акчасына төзелә. Койма һәм капкалары 1842 дә арх. Ф.И.Петонди проекты буенча корыла. 1902 дә архитекторлар В.Гесте, В.Морган тарафыннан реконструкцияләнә. Храмның интерьеры арх. П.В.Тихомиров проекты буенча яңартыла. Кама елгасының биек ярында урнашкан, шәһәр манзарасын калку итеп күрсәтә.



Чистай шәһәрендәге Никола соборы. Арх. П.Г.Пятницкий. 1838.

Соборның терр-ясе тоскана ордерындагы цилиндрлы колонналарга беркетелгән чүкелгән тимер койма б-н әйләндереп алынган. Храм кирпечтән, хач рәвешендә биш гөмбәзле итеп төзелгән. Бер катлы ашханә аша көнбатыш яктан чиркәү алды баскычы б-н чаң манарасы тоташкан. Храмның көнчыгышындагы апсида ике кыеклы түбә астындагы турыпочмаклы күләм рәвешен алган. Төньяк һәм көньяк фасадларның үзәге буенча өчпочмаклы, түбән фронтонлы, ике кыеклы түбә астында ионик ордердагы, дүрт колонналы портиклар чыгып тора. Храм фасадларындагы колонналар ионик ордердагы пилястраларга тәңгәл килә; аттиклы билдәү, портиклар кебек, кронштейнлы кәрниз б-н төгәлләнгән. Ярымтүгәрәк гөмбәз зур яктылык барабаны өстендә тора. Аның әйләнәсендәге як-ягына яктылык тәрәзәләре уелган биек барабаннарга шундый формадагы 4 гөмбәз урнашкан. Үзәк барабан коринф ордерындагы пилястралар б-н бүлгәләнгән, һәм аны төп өлешләре ярымкултыксалы, рельефлы парапетлар б-н эшләнгән, архивольтлы, а́ркалы биек тәрәзәләр яктырта. Соборның турыпочмаклы биек тәрәзәләре яссы, а́ркалы куышлар эченә батырылган һәм ионик ордердагы пилястралар б-н бизәлгән. Куышлардагы тимпаннарда, фронтоннардагы портикларда, фризларда әвәләп ясалган декор урын алган. 1936 да собор ябыла, 1990 да кабат диндарларга кайтарыла. 1930 еллар ахырында сүтелгән биш ярусы чаң манарасы 2002 дә яңадан торгызыла.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**НИКО́ЛА ЧИРКӘВЕ́**, Алабугадагы архит-ра истәлеге, 18 йөздә салынган шул исем. таш чиркәү урынында 1818 елда классицизм стилендә төзелә. Шәһәрнең яр буе өлешендәге төп доминанталарның берсе. 2009 елда кабат ачыла. Апсидалы чыгынтысыз, яктылык барабаны гөмбәз б-н очланган ике катлы, баганасыз храм. Икенче катта төп Никола престолы, беренче катта җылытулы чиркәү урнашкан. Храм, ашханә һәм чаң манарасы бинаның үзәк композициясен тәшкил итә. 1848–52 дә көньяк һәм төньяк фасадлардагы бер катлы, канатлар чыгып торган ике янкорма (сәүдәгәр А.И.Стахеев акчасына өстәп төзелә) чиркәүнең әүвәлге йөзен беркадәр боза. Ике катлы, турыпочмаклы күләм храмның көнчыгышында зур яктылык барабаның, көнбатыш өлешендә ике ярусы кыңгырау манарасын күтәреп тора. Ашханә диварлары эчкә батырылган. Храм фасадларын өчпочмаклы фронтоннар б-н төгәлләнгән ризалитлар аерып тора. Шундый ук фронтоннар б-н эшләнгән ике катлы чаң манарасының нигезендә ярымтүгәрәк гөмбәз б-н ябылган сигезкырлы ике югары ярус төзелгән. Биек, а́ркалы тәрәзәләр, алар арасындагы ионик ордердагы, пилястралы ротондалар — храмның бизәге. Ике кат арасын төгәлләп, аерып һәм дөрес профиль биреп торучы кәрниз корылманың ярусы булуын күрсәтә. Биек, турыпочмаклы, а́ркалы тәрәзәләр һәм куышлар, ризалитларның ионик пилястралары һәм киң лопаткалар бинага дөньяви төсмерләр бирә. Интерьерларда 1870 елларда рәссам



Алабуга шәһәрендәге Никола чиркәве. 1813–18, 1852.

В.В.Верещагин ясаган бизәкләр сакланып калган.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**НИКОЛА́ЕВ** Алексей Михайлович (15.3.1905, Казан — 19.12.1983, шунда ук), химик-технолог, техник фән. д-ры (1956), проф. (1958), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1965). 1929 елда Түбән Новгород ун-тының механика ф-тын тәмамлаганнан соң, Казанның төрле пр-тиеләрендә эшли. 1932–33 тә Казан энергетика ин-тында, 1933 тән Казан химия-технол. ин-тында, химия сәнәгате машиналары һәм аппаратлары каф. мөдире, (1940–73), механика ф-ты деканы (1956–58). Хезмәтләре масса алмаштыру машиналары һәм аппаратларына карый. Н. үзәктән куулы масса алмаштыру аппаратларының яңа классын төзи. Күп компонентлы ректификация һәм экстракция теорияләрен үстерүгә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 167 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Новые аппараты для процессов абсорбции и ректификации // Вестн. техн. и экон. информации. 1964. № 8 (автордаш); Исследование массообменного аппарата с прямоточными вихревыми контактными устройствами // Хим. и нефтяное машиностроение. 1970. № 2 (автордаш); Исследование переноса массы в жидкой фазе в аппаратах вихревого типа с осевыми завихрителями // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1973. № 2 (автордаш).

**НИКОЛА́ЕВ** Анатолий Васильевич (14.11.1902, Оренбург ш. — 13.2.1977, Новосибирск ш.), химик-нәорганик, СССР ФА академигы (1966; 1958 елдан мөхбир әгъза). Ленинград ун-тын тәмамлый (1924). 1927 дән СССР ФАнең — Павлодар тоз, 1931 дән Кулунда комплекслы экспедицияләре башлыгы. 1935–57 дә СССР ФАнең Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында (ИОНХ, 1945 тән лаб. мөдире). Бер үк вакытта, 1936–41 дә, Мәскәү полиграфия ин-тында (каф. мөдире), 1945–58 дә Мәскәү төсле металлар һәм алтын ин-тында (аналитик химия каф. мөдире), проф. (1946). 1941–43 тә СССР ФАнең Идел буе ресурсларын илне саклау ихтыяҗларына мобилизацияләү буенча Идел комиссиясенең химия секциясе гыйльми секретаре (Казан). 1957 дән СССР ФАнең Себер бүлеге Нәорганик химия ин-ты директоры, бер үк вакытта, 1959 дан, Новосибирск ун-тында каф. мөдире. Хезмәтләре тозлы системаларның физик-химик анализына, нәорганик кушылмалар термографиясе, радиохимиясе һәм экстракциясенә карый. Н. тозлы системалар хасил булу шартларын һәм аларны эшкәртү алымнарын ачыклый. Аның табигый тозларны тикшерүгә караган хезмәтләре Кучук сульфат комб-тын (Алтай крае) төзү өчен нигез була. Термографик тикшеренүләр барышында боратның кабаттан төркемләнүен ача һәм платинидларның күп кенә комплекслы кушылмаларының (цис-кушылмалар, димерлар һ.б.) тигезләнешсез торышын ачыклый. Сирәк мәгъдән элементлары тозларының 4 типтагы каты эремәләрен билгели. Бөек Ватан сугышы елларында ИОНХның Казанга эвакуациясе вакытында (1941–45) Н. тозларда элпәләр хасил итү буенча күп хезмәт куя. Бу хезмәтләр «Тозларда саклагыч элпәләр» («Защитные плёнки на солях», 1944) монографиясендә берләштерелә һәм су, бензин, нефть продуктларын саклау өчен җирдән сыешлыклар төзү, гидротехник корылмалар төзегәндә грунтны ныгыту өчен нигез була. Нәорганик кушылмалар экстракциясе теориясендәге тикшеренүләре катламнарга бүленү (клатратлар таркалу) өлкәсендә түбәнге критик ноктаның характерын ачыклый һәм лантаноидлар, актиноидлар, күп кенә төсле һәм затлы металлар өчен эффектив яңа экстрагентлар тәкъдим итәргә мөмкинлек бирә. Экстрагентларны рентгеноспектраль тикшерү нәтиҗәләре аерып алына торган матдәләр арасындагы бәйләнешләрнең характерын билгеләү өчен беренче тапкыр кулланыла. «Журнал структурной химии» басмасының баш мөхәррире (1967–77), «Известия СО АН СССР. Серия химических наук» ж-лының җаваплы секретаре (1963–76). СССР ФАнең В.И.Вернадский исем. (1946) һәм Н.С.Курнаков исем. (1977) бүләкләре лауреаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кулундинские соляные озёра и пути их освоения. Новосиб., 1935; Защита продуктов, фуража и воды от боевых отравляющих веществ. К., 1943; Экстракция неорганических веществ. Новосиб., 1970.

*Әд.:* Анатолий Васильевич Николаев // Материалы к биобиблиографии учёных. Сер. хим. наук. М., 1992. Вып. 91; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

*В.Г.Абзалова.*

**НИКОЛА́ЕВ** Андрей Николаевич (19.7.1961, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1999). 1983 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз углерод чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (бүленеп: 1985–88 дә СССР ФАнең Гомуми һәм нәорганик химия ин-тында, Мәскәү). 1995 тән Казан технол. ун-тында (бүленеп, 2000–02 дә «Спецгазавтоматика» пр-тиесенең баш технологы), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998–2000), азык-төлек җитештерү җиһазлары каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре гидродинамикага, ике фазалы агымнарда җылылык һәм масса алмашуга карый. Н. өермәле типтагы аппаратларның яңа конструкцияләрен булдыра. Масса алмашу һәм кисәкчекләрне утырымга төшерү процессларының матем. модельләрен, газларны эче кушылы һәм өермәле күп баскычлы аппаратларда чистарту алымын эшли. Цилиндрик каналда стенага уралган сыек элпәнең калынлыгын һәм дулкынча параметрларын билгеләү юлларын ачыклый. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патентлы бар.

Х е з м.: Гидродинамика полых вихревых аппаратов // Теорет. основы хим. технологии. 1991. Т. 25, № 4 (автордаш); Расчёт эффективности массопереноса в полых вихревых аппаратах // Теорет. основы хим. технологии. 1992. Т. 26, № 19 (автордаш); Оценка энергетических затрат на перемещение потока в вихревых аппаратах // Теплоэнергетика. 1997. № 7 (автордаш); Очистка промышленных газовых выбросов в аппаратах вихревого типа // Хим. пром-сть. 1998. № 4 (автордаш).



В.Н.Николаев.

**НИКОЛА́ЕВ** Владимир Васильевич (17.2.1871, Воронеж губ. Задонск ш. — 4.2.1950, Мәскәү), фармаколог, физиолог, медицина д-ры (1902), мед. фән. д-ры (1934), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук, фармакология кафедрасында эшли. 1897 елдан — Казан акушерлык ин-тында, 1899 дан теш табибләре мәктәбендә укыта. Бер үк вакытта зәңгеләгә каршы көрәш һәм Казан губернасы халкына азык-төлек б-н ярдәм итү отрядына җитәкчелек итә (1899). 1903–04 тә Германиядә стажировка уза. 1915 тән Казан ун-тының фармакология һәм фармакогнозия каф. профессоры. Казан хатын-кызлар мед. ин-тына (1915) нигез салучыларның берсе. 1921–23 тә Мәскәү ун-тының фармакология һәм рецептура каф. мөдире. 1922 дә Мәскәү фармацевтика җәмгыятен оештыра. 1923–38 дә Смоленск ун-тының фармакология каф. мөдире, бер үк вакытта Мәскәүдәге 3 нче мед. ин-тында (1934–39), фармакология (1936–38) һәм стоматология (1937–39) ин-тларында шул ук вазифаны башкара. 1940 та Бөтенсоюз дару үләннәре һәм хуш исле үсемлекләр фәнни-тикшеренү ин-тының фармакология каф. мөдире. Хезмәтләре фармакология, фармация һәм аптека эшен оештыру мәсьәләләренә карый. Н. йөрәктәге парасимпатик нерв тармакларының ике нейронлы төзелешен ача (1893–94), фундаменталь дару үләннәре тәгълиматын төзи. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу об иннервации сердца лягушки // Неврологический вестн. 1894. Т. 2, вып. 4; Фотографирование глазного дна животных // Неврологический вестн. 1901. Т. 9, вып. 3, 4.

*Әд.:* Л е в ч е н к о М.А. Памяти В.В.Николаева (к 5-летию со дня смерти) // Фармакология и токсикология. 1955. № 4.

**НИКОЛА́ЕВ** Владимир Николаевич (9.2.1921, Казан — 30.10.1944, Украина ССРның Львов ш.), Сов. Союзы Герое (23.9.1944), гв. капитаны. Чкалов танк уч-щесен тәмамлый (1941). Казанда мех ф-касында слесарь булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 56 нчы танк бригадасының (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы) батальон командиры урынбасары. Брянск, Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Орёл, Житомир–Бердичев (икесе дә — 1943), Проскуров–Черновцы һәм Львов–Сандомир (икесе дә — 1944) һөҗүм операцияләрендә катна-



А.И. Николаева.

ша. 1944 нең 3–4 августында Висла елгасын һәм Коло посёлогы тирәсендә (Баранув-Сандомерски шәһәреннән 2 *км* көнбатыштарак, Польша) кичкәндә батырлык күрсәтә: Н., яраланган килеш, хәлиткеч моментта елга аша кичүне саклауны җитәкли; дошманның барлык һөҗүмнәрен кире кайтара. Ике Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль белән бүләкләнә. Геройның исеме Казанның бер урамына бирелә.

*Әд.*: Советлар Союзы Геройлары — якташларыбыз. К., 1990; Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Звёзды доблести боевой. Львов, 1968; Р о к о т о в Г.Н. Холм славы. Львов, 1984.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НИКОЛА́ЕВ** Геннадий Алексеевич (30.12.1935, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), Казанның 7 нче интернат-мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1961 елдан Казан ун-тында, рус теле тарихы һәм тел белеме каф. мөдире (1979–2008). Варшава (Польша, 1976–79), Лейпциг, Гиссен (Германия, 1989–90, 1992, 1994), Гранада (Испания, 1997–99) ун-тларында лингвистика курслары алып бара. Хезмәтләре рус әдәби теленең сүз ясалышы, стилистикасы һәм семасиологиясе тарихына карый. «Рус телендә сүз ясалышы» («Русское словообразование», 1985), «Рус телендә сүз төзелеше һәм орфография» («Структура слова и орфография русского языка», 1993) һ.б. дәреслекләр һәм уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Русское историческое словообразование: Теоретические проблемы. К., 1987; Сопоставительное словообразование и формообразование русского и польского языков: Имя существительное. К., 1990 (автордаш); Русское и славянское словообразование. К., 2011.

**НИКОЛА́ЕВ** Герман Михайлович (1.3.1926, Казан — 10.6.1985, шунда ук), хирург, мед. фән. д-ры (1964), проф. (1966). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1952), шунда ук, педиатрия ф-тының 2 нче хирургия кафедрасында эшли, 1967–84 елларда травматология-ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1968 дән, Казан шәһәре сәламәтлек саклау бүлегенең баш хирургы, 1984 тән «Мединструмент» ФҖБдә шул вазифаны башкара. 1964–65 тә Йәмән Гарәп Респ-касының Ходейда шәһәре госпиталендә эшли. Хезмәтләре панкреатит этиологиясе, патогенезы һәм аны хирургия ысулы б-н дәвалау, корсак куышлыгы органнарындагы имгәнүләргә диагноз кую һәм аны дәвалау мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Влияние поясничной новокаиновой блокады на фагоцитоз // Хирургия. 1952. № 3; О содержании диастазы мочи после резекции желудка // Казан. мед. журн. 1960. № 4; Новокаиновая блокада чревных нервов и симпатических стволов в лечении острого панкреатита. К., 1968.

**НИКОЛА́ЕВ** Николай Алексеевич (17.5.1937, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, азык-төлек җитештерү җиһазлары каф. мөдире (1989–2002). Хезмәтләре газ-сыеклыклы системаларда барган процессларны көчәйтүгә карый. Н. туры юнәлештәге өермә контактлы җайланмалар нигезендә җылылык һәм масса алмаштыру аппаратларының яңа классын булдыра. Гетероген системаларны бүлү һәм гидродинамик параметрларны үлчәү алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 125 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Плёночные биореакторы. К., 2000 (автордаш); Расчёт и конструирование оборудования пищевых и химических производств. К., 2002 (автордаш); Комплексная очистка стоков промышленных предприятий. К., 2005 (автордаш).

**НИКОЛА́ЕВ** Павел Николаевич (12.5.1881, Смоленск ш. — декабрь 1943, Саратов ш.), терапевт, медицина д-ры (1910), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1935). Дерпт ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1906), Варшавада терапия клиникасында эшли. 1909 елдан Эксперименталь мед. ин-тында (С.-Петербург). Париж, Лондон, Берлин, Осло, Стокгольм клиникаларында стажировка уза. 1911 дән Сембер губ. хастаханәсендә терапия бүлеге мөдире, 1914 тән — баш табиб. 1920 дән Казан ун-тының эчке авырулар диагностикасы каф. мөдире. 1927 дән Саратов мед. ин-ты профессоры, факультет терапиясе каф. мөдире. Бөек Ватан сугышы елларында Саратов эвакогоспитальләрендә консультант. Хезмәтләре физиология, кардиология, нефрология, эндокринологиягә, йогышлы авыруларны дәвалауга, медицинаның теоретик һәм методологик мәсьәләләренә карый. Бөтенсоюз терапевтлар җәмгыятенең Саратов ф-лы рәисе (1930 дан).

Х е з м.: Об основных принципах распознавания болезней. К., 1921; О порхании и мерцании предсердий. К., 1923. Туберкулёз (Общее учение, клиника, профилактика, лечение). Саратов, 1940 (автордаш).

*Әд.:* К и р и л л о в М.М. Профессор П.Н.Николаев: научная и лечебная деятельность в годы Великой Отечественной войны // Клиническая медицина. 1991. № 5.

**НИКОЛА́ЕВА** Александра Дмитриевна (4.5.1922, Зөя кантоны Соболевское а. — 25.3.2004, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1961), проф. (1962), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1965, 1973). 1944 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1948 дә үзе оештырган югары энергияле кушылмалар химиясе һәм технологиясе лаб-ясенең фәнни җитәкчесе, шул исемдәге каф. мөдире (1962–89), проблемалы фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1989 дан). Хезмәтләре ракета һәм махсус ягулыклар компонентлары химиясе һәм технологиясенә карый. Н. җитәкчелегендә туендырылмаган углеводородларны тринитрометан, тетранитрометан, хлортринитрометан һ.б.ны алу максатында деструктив нитратлау реакцияләренең механизмнары эшләнә; тринитрометан табуның нәтиҗәле технологиясе булдырыла һәм җитештерүгә кертелә (бу ачыш Казан химия-технол. ин-тында, оборона сәнәгатенең тармак ин-тлары һәм пр-тиеләрендә күпсанлы югары энергияле матдәләр синтезларга мөмкинлек бирә); фуразан һәм фуроксан фрагментлары кергән сусыз һәм аз сулы югары энергияле кушылмалар синтезлана. Бу рәттәге аерым кушылмалар оборона техникасының мөһим мәсьәләләре үсешен хәл иткән дөньяда беренче производстволарның нигезен тәшкил итә. Монохлоргликсим һәм дихлоргликсим табу алымы югары энергияле матдәләрнең яңа төркемен синтезлау технологияләрен тудыра. Югары энергияле кушылмалар синтезлаганда табылган ярымпродуктлар һәм чит матдәләр күпкырлы бактерицид һәм спороцид тәэсирләргә ия булган дезинфектантлар ясау мөмкинлеген бирә. 1000 нән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 200 авторлык таныклыгы бар. СССР МС бүләге лауреаты (1990). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

*В.Г.Абзалова.*

**НИКОЛА́ЕВА** Александра Ивановна (6.1.1924, ТАССРның Буа кантоны Адав-Толымбай а.), игенче, Соц. Хезмәт Герое (1948). 1939–90 елларда Буа р-нының Коминтерн исем. к-зында колхозчы, комсомол-яшьләр звеносы җитәкчесе, кырчылык бригадасы бригадиры, ферма мөдире. 1947 дә Н. звеносы 10 *га* мәйданда ул елларда күрелмәгән арыш уңышы (1 *га* дан 31 *ц*) ала, шуның өчен Герой исеме бирелә. ВЛКСМ (1949) һәм КПСС (1961) съездлары делегаты. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НИКОЛА́ЕВА** Татьяна Михайловна (28.10.1937, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (2002). 1960 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1969 дан шунда ук эшли, проф. (2002). 1983–86 да Прешан ун-тында (Словакия) рус теле укыта. Хезмәтләре рус әдәби теле, сүз ясалышы тарихларына карый. «Грамматик лексикология» («Грамматическая лексикология», 1971), «Рус телендә сүз ясалышы» («Русское словообразование», 1985) монографияләре автордашы.

Х е з м.: Очерки по исторической стилистике и словообразованию. К., 2000; Актуальные процессы семантического словообразования в русском литературном языке конца XX века // Семантическая деривация и её взаимодействие с морфемой: Сб. статей. Омск, 2003; История русского литературного языка. К., 2012.

**НИКОЛА́ЕВКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да башлангыч белем мәктәбе (1903 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 251 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 174, 1897 дә — 333, 1908 дә — 354, 1920 дә — 370, 1926 да — 308, 1938 дә — 343, 1949 да — 294, 1958 дә — 130, 1970 тә — 123, 1989 да — 10, 2002 дә — 4 кеше.

**НИКОЛА́ЕВКА** авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 25 *км* көньяктарак, Ык елгасыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 448 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Элеккеге татар авылы Тауборын урынында 1780 елларда дворяннар Матвеев һәм Никита Можаров рус авылына нигез сала, 19 йөзнең 1 нче чирегеннән — алпавыт Пальчиковлар милке. Халкы игенчелек, терлекчелек, таш чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Смоленск Богородица чиркәве (1843 тә төзелә), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), пар тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, май язу з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1092 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 203, 1859 да — 385, 1870 тә — 551, 1884 тә — 689, 1897 дә — 772, 1913 тә — 741, 1920 дә — 878, 1926 да — 880, 1938 дә — 325, 1949 да — 238, 1958 дә — 435, 1970 тә — 583, 1979 да — 575, 1989 да — 481, 2002 дә — 479 кеше. Н.ның истәлекле урыны — алпавыт Н.Е.Пальчиков йорты (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге).

**НИКОЛА́ЕВКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше яши. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 240 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 136, 1897 дә — 264, 1908 дә — 301, 1920 дә — 332, 1926 да — 331, 1949 да — 279, 1958 дә — 184, 1970 тә — 109, 1979 да — 54, 2002 дә — 8 кеше.

**НИКОЛА́ЕВКА** посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы бассейнында. 2010 елда 1 кеше яши. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1883 тә ачыла), вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 385 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 192, 1897 дә — 275, 1908 дә — 351, 1920 дә — 370, 1926 да — 357, 1938 дә — 191, 1949 да — 91, 1958 дә — 85, 1970 тә — 52, 1979 да — 13, 1989 да — 10, 2002 дә — 16 кеше.

**НИКОЛА́Й I** (25.6.1796, Царское Село ш., Петербург губ. — 18.2.1855, С.-Петербург), Россия императоры (1825 елдан). 1836 ның августында Россия буйлап сәяхәте вакытында Казанда була, андагы истәлекле урыннарны (Кремль, Благовещение соборы, университет, Беренче ир балалар гимназиясе, 1552 дә шәһәрне яулаганда һәлак булган рус сугышчыларына куелган һәйкәл) карый; университет ишегалдында Г.Р.Державинга куелачак һәйкәл урынын хуплый; университет клиникалары бинасы төзелешенә иганә чарасы кыла. Император хөрмәтенә губернатор С.С.Стрекалов һәм дворяннар тантаналы мәҗлес оештыралар. 1842 елгы янгыннан соң Н.I Казанны торгызу өчен 1 млн. сум акча бүлеп бирү турында фәрман чыгара.

Н.I патшалык иткән чорда рус чиркәвенең Идел буе халыклары арасында миссионерлык эшчәнлегенә булышлык күрсәтелә, православие динендәгеләрнең мөселманнар б-н элемтәләре чикләнә, салымнар түләүдән, рекрутлык бурычыннан азат итү кебек ташламалар һ.б.ны куллану юлы б-н татарларның православиегә күчүе стимуллаштырыла. Икенче яктан, мөселманнарга ирекле рәвештә үз диннәрен тоту һәм дини йолаларын башкару, югары һәм урта уку йортларында белем алу, илнең төрле төбәкләрендә дини биналар төзү хокукы бирелә. Н.I Россиянең Европа өлеше өчен «үрнәк» мәчет проектларын раслый (1829, 1844), хосусый басмаханәләргә татар телендә китаплар бастыруга рөхсәт бирә, мөселман руханиларын тән җәзаларыннан һәм рекрутлыкка алынудан азат итә, кайбер хәрби частьларда муллалар вазифасын гамәлгә кертү һ.б. б-н ризалаша.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; К а з а н с к и й М.В. Путеводитель по Казани. К., 1899; Д о л г о в Е.Б. Император Николай I в Казани в 1836 г. // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2006. № 1.

*Е.Б.Долгов.*

**НИКОЛА́Й ИСЕМЕНДӘГЕ́ БАЛАЛА́Р ЯТИМХАНӘСЕ́**, 1844 елның 11 гыйнварында сәүдәгәр А.Л.Крупеников тырышлыгы б-н (к. *Крупениковлар*) ачыла, кыз балаларга атап оештырыла. 1844 нең 15 гыйнварыннан император Николай I хөрмәтенә аның исеме б-н атала. Ятимханә императрица Мария Фёдоровна карамагындагы учреждениеләрнең Казан губернасы балалар ятимханәләре җәмәгать идарәчелеге (попечительлеге) күзәтүендә тора. Беренче попечителе — Казан губернаторының хатыны А.Е.Шипова. Ятимханә ачу өчен Җәмәгать тәрбиясе приказына матди ярдәм күрсәтүчеләр: А.Л.Крупеников (3 мең сум, 1839), Казан шәһәре башлыгы, сәүдәгәр С.Е.Александров (2 мең сум, 1842), Мамадыш сәүдәгәрләре Н.И.Щербаков һәм Таганов (3 әр мең сум). 1843 елга ассигнацияләр б-н 12 мең сум акча җыела. Казан шәһәр думасы ятимханә өчен Зур Проломный урамыннан 2 катлы таш йорт бирдертә. 1892 дә сәүдәгәр М.И.Попов акчасына йортка су кертелә. Ятимханә җәмәгать идарәчелегенең төп капиталыннан җыелган процентлар, хәйрия чаралары уздырудан җыелган керем, шәһәр идарәсенең матди ярдәме, взнос акчалары, аерым кешеләр иганәсе хисабына яши. 1844 нең 11 мартында ятимханә каршында хастаханә эшли башлый, 1846 ның 26 февралендә А.Л.Крупеников акчасына 25 урынлы төн куну бүлеге ачыла. 1890 ның 2 февралендә М.И.Попов васыяте буенча, аның исемен бирү шарты б-н, 10 урынлы төн куну йорты төзү өчен 10 мең сум акча тапшырыла. А.Х.Шамова васыяте буенча, Николай һәм Александра исемендәге ятимханәләрне тоту өчен 4 мең сум иганә бирелә. 1909 да 6 бала Е. һәм В.Змеевлар стипендияләренә тәрбияләнә. Мед. кирәк-яраклары Э.Ф.Грахе даруханәсеннән бушлай китертелә. Ятимханәдә тәрбияләнүчеләр М.М.Данилов мунчасыннан ш.у. бушлай файдаланалар. Баштагы чорында Н.и.б.я. 30–50 кыз балага исәпләнгән була. Беренче айларда ук аңа 80 бала кабул ителә, 1894 тә ятимханәдә 115 бала тәрбияләнә, 60ы шунда даими яши, 55е килеп-китеп йөри. 1909 елда биредә чыгышлары б-н мещан, крәстиян, чиновниклардан булган 71 бала, ш.у. 5–16 яшьләрдәге тулы ятимнәр тәрбияләнә. Ятимханәдән киткәндә кызларга зур булмаган күләмдә (5–20 сум) акча биреп озаталар. Укыту шәһәр башлангыч уч-щеләре программасы буенча алып барыла: Илаһи канун, уку-язу, кыскача Россия тарихы дәресләре укытыла, ш.у. рәсем, күмәк җыр, кул эше, йорт эше күнекмәләре бирелә. Нинди дә булса белгечлек алган кызлар төрле остаханәләргә (корсет тегү, чигү һ.б.) яки асрау хезмәтенә урнашалар. Кыз балаларның кул эшләре — сөлгеләр, яулыклар, шарфлар һ.б. 1909 да Казанда уздырылган земство күргәзмәсендә күрсәтелә. Ятимханә яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы, парник тота. Җәйкөне балалар Югары Осланда арендаланган дачага күчерелә. Ял итү өчен ш.у. «Рус Швейцариясе»нә, пароход б-н Кабан күле буендагы Ботаника бакчасына да алып баралар. Н.и.б.я. 1917 дән соң ябыла.

*Әд.:* Отчёт Казанского губернского попечительства детских приютов за 1889 год. К., 1890; Историческая записка о Казанском Николаевском детском приюте, открытом 11-го января 1844 года. К., 1894; Отчёт Казанского губернского попечительства детских приютов за 1909 год. К., 1910; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998.

*И.А.Новицкая.*

**НИКОЛА́ШКИНО** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 356 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1760–80 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Васильевский-Урустамак исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2767 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 172, 1889 да — 236, 1910 да — 394, 1920 дә — 410, 1926 да — 489, 1938 дә — 460, 1949 да — 727, 1958 дә — 457, 1970 тә — 549, 1979 да — 417, 1989 да — 347, 2002 дә — 352 кеше.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 33 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 808 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 2 урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан Караево авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Тарлашы, Ильинский исемнәре б-н дә билгеле. Н.га руслар 17 йөзнең 2 нче яртысында килеп урнаша. 18 йөз уртасына кадәр халкы Казан архиерей йортыныкы булып исәпләнә; 1764 тә җирле халык — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никола чиркәве, кәшәнә (1843–48, 1889 да төзелә; архит-ра истәлекләре), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), 6 җил тегермәне, 3 тары яргыч, май язу, йон тетү йортлары, тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2823,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 260 ир-ат; 1859 да — 853, 1897 дә — 1549, 1908 дә — 1871, 1920 дә — 1816, 1926 да — 1827, 1949 да — 1259, 1958 дә — 1015, 1970 тә — 1048, 1979 да — 937, 1989 да — 852, 2002 дә — 908 кеше. Н. — «Каравон» фольклор бәйрәмен традицион үткәрү урыны.



Лаеш р-нының Никольский авылы. Никола чиркәве. 1843-48.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 28 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2010 елда 686 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ат асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да Казан Богородица чиркәве (1795 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1886 да ачыла), 1 су һәм 4 җил тегермәне, ярма яргыч, 1 казна шәраб, 1 зур һәм 4 кечкенә вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 449 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязендә, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 332 ир-ат; 1859 да — 961, 1897 дә — 1428, 1908 дә — 1570, 1920 дә — 1527, 1926 да 1139, 1938 дә — 1051, 1949 да — 917, 1958 дә — 1051, 1970 тә — 1165, 1979 да — 937, 1989 да — 798, 2002 дә — 695 кеше.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 25 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. 18 йөзнең 2 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чигреева Пустошь, Кукмара исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Никольский чиркәве (1878 дә төзелә), земство мәктәбе (1873 тә ачыла), земство китапханәсе-уку залы, почта бүлекчәсе, 4 тимерчелек, 1 казна шәраб һәм вак-төяк кибетләре, 2 сыраханә, 5 юлаучылар йорты була; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 430,7 дис. тәшкил итә. 1920 елга кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1859 да — 277, 1897 дә — 482, 1908 дә — 428, 1920 дә — 559, 1926 да — 640, 1938 дә — 468, 1949 да — 666, 1958 дә — 113, 1970 тә — 86, 1979 да — 64, 1989 да — 28, 2002 дә — 24 кеше.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 16 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 106 кеше (татарлар, руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык. Клуб. 1920 елда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1920 дә — 66, 1926 да — 92, 1938 дә — 541, 1949 да — 376, 1958 дә — 200, 1970 тә — 253, 1979 да — 155, 1989 да — 103, 2002 дә — 97 кеше.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Владимир Александрович (4.10.1870, Түбән Новгород губ., Ардатов өязе Смирнов а. — ?), христиан дине галиме, христиан теологиясе магистры (1897), проф. (1908). Казан руханилар академиясен тәмамлый (1895). 1896–98 елларда Әстерхан, 1898–99 да Харьков руханилар семинарияләрендә укыта. 1899–1918 дә — Казан руханилар академиясендә, әхлакый теология каф. укытучысы. Бер үк вакытта, 1902–17 дә, немец теле лекторы, 1913–18 дә «Православный собеседник» ж-лы мөхәррире. Хезмәтләре әхлакый теологиягә карый.

Х е з м.: Вера в Промысел Божий и её основания. К., 1899; Христианство, патриотизм и война // Православный собеседник. 1904. Ч. 1–2; Христианское учение о любви ко врагам в его отношении к учению классической древности // Православный собеседник. 1911. Ч. 1.

*Е.В.Липаков.*

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Григорий Борисович (11.11.1785, Владимир губ. Судогорск округы — 11.9.1844, Казан), математик, Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1839). 1808 елда Петербург пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан ун-тында эшли (бүленеп), гамәли матем. каф. профессоры (1817–19), ректор (1820–23), проректор (1829–36), бер үк вакытта физика-матем. ф-ты деканы (1827–28, 1830–39), атказ. проф. (1839), 1819–20 дә Казанның Беренче ир балалар гимназиясе директоры. Хезмәтләре математика укыту методикасына карый. Казан. ун-тының архив кәгазьләрендә Н.ның математиканың файдасы, тәрбия һәм мәгарифнең әһәмияте турындагы чыгышлары сакланган.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Евгений Евгеньевич (11.4.1947, Таллин), физиолог, мед. фән. д-ры (1991), РФАнең мөхбир әгъзасы (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук эшли, 1983 тән мед. һәм биол. физика каф. мөдире, 1992 дән проф. 1992 дән РФА КГҮнең Биофизика һәм биохимия ин-тында, 2008 дән РФАнең КГҮ Президиумы рәисе. Хезмәтләре синаптик процесслар биофизикасына, мускул җепселләре функцияләрен нейрональ көйләү механизмнарын өйрәнүгә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Чехословакия ФАнең И.Главка исем. медале б-н бүләкләнә. СССРның спорт остасы (фехтование, 1967).

Х е з м.: Моделирование действий блокаторов ионных каналов на постсинаптические токи // Нейрофизиология. 1989. № 4; Эффекты ингибирования ацетилхолинэстеразы в нервно-мышечных синапсах с разным исходным функциональным состоянием // Нейрофизиология. 1996. № 4/5.

*Әд.:* А н д р е е в И.М., К р а с и л ь н и к о в С.Н. Никольский Евгений Евгеньевич // Стоматологический факультет. История в биографиях. К., 1996.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Михаил Васильевич (1.2.1827, Казан губ. Зөя ш. — 19.12.1880, Казан), офтальмолог, медицина д-ры (1858). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлагач (1851), шунда ук, хирургия клиникасында эшли, 1865 тән офтальмология кафедрасында, 1869 дан проф., 1870 тән госпиталь хирургия клиникасында, бер үк вакытта мед. ф-ты деканы (1878–79). Хезмәтләре литотрипсиягә карый.

Х е з м.: De lithotripsia: Дис. ... К., 1858.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Николай Васильевич (7.5.1878, Казан губ., Ядрин өязе Юрмекейкино а. — 2.5.1961, Казан), тел белгече, педагог, этнограф, җәмәгать эшлеклесе, дин белеме магистры (1913), тарих фән. д-ры (1947). Псаломчы булып киткән чуаш крәстияне улы. Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1903), Казан руханилар семинариясендә күзәтүче булып эшли. 1906–10 елларда Казан руханилар семинариясендә — тарих һәм геогр., бер үк вакытта Казан миссионерлар курсларында (1906–17), руханилар семинариясендә (1907–16) һәм халык укытучыларына белем бирү земство мәктәбендә (1909–17) чуаш теле укыта. 1915 тән Казан ун-тының чиркәү тарихы кафедрасында приват-доцент, 1918 дән проф., 1919 дан иҗтимагый фәннәр ф-тында. 1917 нең июненнән 1918 нең гыйнварына кадәр Казан губерна земство идарәсе рәисе (Вакытлы хөкүмәт вакытында губерна земство управасы рәисләре губернатор вазифаларын башкаралар). 1921–22 дә Шәрекъ консерваториясе ректоры. 1922 дән Шәрекъ пед. ин-тында этнография һәм чуаш теле укыта. 1931 дә кулга алына, озакламый азат ителә, ләкин институттан җибәрелә, 9 ел даими хезмәт урыны булмый. 1933 нең 25 мартында яңадан кулга алына, 1933 нең 10 октябрендә азат ителә. 1940–50 дә Мари тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында (Йошкар-Ола ш.), бер үк вакытта Мари пед. ин-тында укыта. 1906 ның гыйнварында «*Хыпар*» исемле беренче чуаш г-тасын чыгара башлый, аның беренче мөхәррире була. «Идел буендагы вак халыклар җәмгыяте»н (Казан, 1917 нең 22 марты) төзүдә һәм аның чуаш секциясен оештыруда башлап йөри. Бөтенроссия чуаш съездын (Сембер ш., 1917) оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе була, съезд барышында чуаш милли хәрәкәтенең тагын да радикальрәк эшлеклеләре (С.Н.Николаев, Г.Ф.Алюнов һ.б.) тарафыннан җитәкчелектән азат ителә. Хакимияткә большевиклар килүгән хупламый, ләкин яңа хакимияткә каршы көрәштә катнашмый. Гомеренең ахырына кадәр үзенең динилеген яшерми, марксистик методологияне танымый.

Фәнни кызыксынулары даирәсе киң була. Чуашларны христианлаштыру тарихына һәм чуаш халкы этнографиясенә караган 20 дән артык мәкалә һәм «Урта Идел буе чуашлары арасында христианлык» («Христианство среди чуваш Среднего Поволжья», 1912) монографиясен яза. Идел буендагы башка халыкларның, ш.и. татарларның («Керәшен татарлар. Статистика мәгълүматлары» — «Крещёные татары. Статистические сведения», 1914) этнографиясен һәм фольклорын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Марилар тарихы буенча беренче гомумиләштерүче хезмәтнең авторы: «Марилар тарихы» («История мари», 1920). «Чуаш теле грамматикасы б-н рус-чуаш сүзлеге»н («Рус.-чуваш. словарь с приложением грамматики чувашского языка», 1909; 2 нче басма 1919) бастыра. 1902–17 дә Православие миссионерлык җәмгыятенең тәрҗемә комиссиясендә эшли (дини әдәбият, а.х., умартачылык, гигиена буенча брошюраларның тәрҗемәләре, 1906–14 тә чуаш «Султанак кенеки» календарьлары нәшер ителә).

Х е з м.: Народное образование у чуваш. К., 1906; Народная медицина у народностей Поволжья. М., 1909; Сборник исторических материалов о народностях Поволжья. К., 1919; Творчество чуваш. К., 1921; Краткий курс этнографии чуваш. Чебоксары, 1929; Народная медицина у чуваш. Чебоксары. 1929; О пословицах чувашского народа. Чебоксары, 1958; Чувашские сказки. Чебоксары, 1960.

*Әд.:* Д и м и т р и е в В.Д. Николай Васильевич Никольский — учёный, педагог, общественный деятель. Чебоксары, 2002.

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Пётр Андреевич (18.6.1858, Томск губ., Барнаул округы Брюхановский а. — 18.1.1921, Казан), икътисадчы, хокук белгече, политэкономия д-ры (1896), хакыйкый статский советник (1906). Руханилардан. Казан ун-тын тәмамлый (1887), шунда ук эшли: проф. стипендиаты (1890 га кадәр), 1890–92 дә политэкономия һәм статистика каф. приват-доценты, 1892–96 да экстраординар проф., 1896–98 дә полиция хокукы кафедрасында ординар проф., 1898–1915 тә — политэкономия кафедрасында, 1915–18 дә атказ. проф., 1918–20 дә шул ук кафедрада проф., 1907 дә юридик ф-т деканы. Бер үк вакытта, 1919 дан, Казан политехник ин-тының икътисад ф-ты деканы. Икътисад буенча төп мәсьәләләрдә Д.Рикардо карашларын дәвам итә. Төп хезмәтләре акчаның килеп чыгышы һәм аның халык хуҗалыгына йогынтысы турында өйрәтүләргә, иминиятләштерү мәсьәләләренә багышлана. Россиядә вак һөнәрчелек, авыл хуҗалыгында җитештерү һәм салым системасы, Россия-Германия сәүдә килешүләре турында басылып чыккан хезмәтләре бар. Политэкономия дәреслекләре авторы.

Х е з м.: Бумажные деньги в России. К., 1892; Основные вопросы страхования. К., 1896; Учебник политической экономики. К., 1916.

*Әд.:* Т р у с ф у с М. Профессор П.А.Никольский // Изв. ЦИК ТАССР. 1921. № 28; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**НИКО́ЛЬСКИЙ** Юрий Алексеевич (14.12.1926, хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Балахна ш.), инженер-конструктор, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979), ТРның атказ. машина төзүчесе (1995). Николаев кораблльләр төзү ин-тын тәмамлый (1954). 1942–47 елларда Горький җылылык электр станциясендә, 1947–48 дә Баксанск ГЭСында (Нальчик ш.) эшли. 1954–2001 дә Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросында, башлыкның — корабларны эксплуатацияләү буенча баш конструкторның урынбасары (1962–64), 1124 проектының һәм аның модификацияләренең баш конструкторы (1964–68), башлык — проектларның баш конструкторы (1968–70), башлык — баш конструктор (1970–88), 3 нче дәрәҗә баш конструктор (1988–98), башлык — оешыру һәм кадрлар буенча баш конструктор ярдәмчесе (1998–2001), башлык — баш конструктор киңәшчесе (2002). СССР Хәрби Диңгез флоты, чик буе гаскәрләре һәм чит илләр өчен кораблльләр һәм судноларны төзү эшләре б-н җитәкчелек итә. Дәүләт бүләге судноларны төзү өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы, ТАССР МСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**«НИКО́ЛЬСКИЙ»** ерым-сызалар системасы, ТРның табигать истәлеге. Яшел Үзән р-ны Никольский авылыннан көнбатыштарак урнашкан. 1981 елда билгеләнә. Мәйданы 35 *га*. Уразлы елгасы үзәненең сулъяк сөзәклеге буйлап кеше тарафыннан булдырылган урман-болын биоценозы. 1976 да Татарстан урман тәҗрибә станциясе (Ч.С.Хәсәнкәев, Н.А.Миронов) Яшел Үзән үрнәк тәҗрибә урман хуҗалыгы б-н берлектә туфракның



«Никольский» ерым-сызалар системасы.

сызма эрозиясенә каршы урман-мелиорация эшләре үткәрә. 24,5 *га* мәйдан биләгән зурая баручы ерымнарның сөзәкләрендә гади гидротехник корылмалар (су тоткарлау валлары, агым бөркегечләр) б-н бергә каен, карагай, чыршы, тополь, тал һ.б. агачлардан торган саклаучы урманнар булдырыла. Туфракны эшкәртү тоташ һәм буйга сөрү, сабан буразналары, микротеррассалар, мәйданчыклар ясау ысулы б-н бара. 1980 еллар башына эрозия процессы тулысынча туктатыла, болын үсемлекләре күпләп үсә башлый.

**НИКО́ЛЬСКИЙ БАРА́Н КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Кече Чирмешән елгасының уң ярында Алексеев р-нында урнашкан (элеккеге Никольский Баран авылы янында, хәзер Арбузов-Баран авылы составында). Н.Б.к. ядкәрләре 1881 елда — В.А.Казаринов, 1962–1970 тә — Р.Г.Фәхретдинов, 1970–80 елларда А.Х.Халиков, Ф.Ш.Хуҗин һ.б. тарафыннан тикшерелә. 10–13 йөзләргә караган 2 шәһәрлекне, 3 авыллыкны һәм 1 каберлекне үз эченә ала. Түгәрәк формалы (мәйда-

ны 0,8 *га* чамасы) беренче шәһәрлек божрасыман ур һәм чокыр б-н камалган. Культура катламының калынлыгы 1 *м* га җитә. Фаразланганча, Биләр шәһәре янындагы хәрби кальга булган. Төньяктарак, текә борын түбәсендә урнашкан икенче шәһәрлек барлык яктан да ур һәм чокыр, төньяктан ике рәт урлар һәм өч рәт чокырлар б-н ныгытылган. Культура катламы юк. Фаразланганча, 13 йөзнең 1 нче яртысында төзелеп бетмәгән болгарлар шәһәре калдыклары. Ике шәһәрлек арасында, ш.у. алардан көнбатыш һәм төньяк тарафларда авыллыклар урнашкан (мәйданнары 4–6 *га*). 1983 тә А.Х.Халиков тарафыннан беренче авыллык янындагы мөселман зиратында 24 кабер өйрәнелә. Каберлекнең борынгырак өлеше 10–11 йөзләр торулыгы катламы б-н капланган. Анда, Ибне Фазлан билгеләп үткәнчә, 922 елда ук агач мәчетләре булган мөселман бәрәнҗәрләр җирләнгән булуы ихтимал.

*Әд.:* Археологические памятники бассейна р. Черемшан. К., 1990; Д р о з д о в а Г.И. Исследование окрестностей Билярского городища (по материалам А.Х.Халикова) // Биляр и Волжская Булгария: Изучение и охрана археологических памятников. К., 1997. *Ф.Ш.Хужин.*

**НИ́КОНОВ** Виктор Петрович (28.2.1929, хәзер Ростов өлкәсе, Шолохов р-ны Базковский станицасы — 17.9.1993, Мәскәү), дәүләт, партия эшлеклесе. Азов-Кара диңгез а.х. ин-тын тәмамлый (1950). 1958 елдан партия эшендә, КПССның Татарстан өлкә ком-тының 1 нче секретаре (1967–78). 1979–85 тә Бөтенсоюз «Союзсельхозхимия» берләшмәсе рәисе — СССР а.х. министры. 1985–89 да КПСС ҮК секретаре. 1976–90 да КПСС ҮК әгъзасы. 1987–89 да КПСС ҮК Политбюросы әгъзасы. 1962–89 да — СССР, 1963–71 дә ТАССР ЮСлары депутаты, 1989–91 дә СССР халык депутаты.

**НИ́КОНОВ** Георгий Николаевич (11.5.1954, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1988). 1976 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, фосфорорганик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1994–98). 1999 дан АКШта, Флорида ун-ты һәм Alchem Laboratory Corporation химия-фармацевтика компаниясенең Гетероциклик кушылмалар үзәгендә әйдәп баручы фәнни тикшеренүче (Гейнсвилл ш., Флорида). Хезмәтләре фосфорорганик һәм элементорганик кушылмалар химиясенә карый. Н. фосфорның бороксиалкил чыгарылмалары химиясе буенча яңа фәнни юнәлеш булдыра. Бор һәм фосфор катнашкан гетероциклик кушылмалар синтезлый, аларның фәзаи төзелешен, биол. активлыгын, дару чаралары сыйфатында кулланылу мөмкинлекләрен тикшерә. Уйлап табуга 24 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Функциональнозамещённые фосфины // Успехи химии. 1984. № 4 (автордаш); Функциональнозамещённые фосфины и их производные. М., 1986 (автордаш); Phosphorus Heteroatomic ring from a-oxyalkylphosphines and ethenophosphines // Advances in Heterocyclic Chemistry. 1994. V. 61 (автордаш).

**НИ́КОНОВА** Валентина Геннадьевна (5.3.1952, Казан), спортчы (фехтование), СССРның атказ. спорт остасы (1973), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (1994). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1975). Спорт б-н 1966 елда 3 нче балалар спорт мәктәбендә шөгыльләнә башлый, 1970 тән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан), тренеры — В.В.*Житлов*. Дөнья беренчелекләрендә 1970 тә (шәхси зачётта яшьләр арасында), дөнья чемпионатларында 1973 тә (шәхси зачётта), 1974, 1977 дә (команда зачётында), СССР чемпионатларында 1974 тә (шәхси зачётта), 1974–78 дә (команда зачётында) җиңүче; Европа кубогы (1974–78 дә, команда зачётында) иясе; Олимпия уеннары чемпионы (1976 да, команда зачётында). Европа (1973–74, 1977), дөнья (1973), «Россиянең көчлеләр кубогы» (1980 дә, команда зачётында) чемпионатларында көмеш медаль ала. 1973 тә дөньяның иң яхшы хатын-кыз фехтование остасы булып таныла. 1969–73, 1983–87 елларда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан советында, 1973–82 дә ТАССР МС каршындагы физкультура һәм спорт ком-тында инструктор, 1982–83 тә олимпия резервындагы 3 нче махсус балалар-яшүсмерләр мәктәбендә методист. 1987–95 тә Казан технол. ун-тында өлкән укытучы, 1995–2004 тә Казан архит-ра-төзелеш академиясендә, физик тәрбия каф. профессоры (2000 нән). 2004–11 дә ТР Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте ин-тында физик тәрбия каф. мөдире. Медаль, ТАССР, ТР ЮСның Мактау грамотасы; «Физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен», «Россиядә олимпия хәрәкәтен үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгеләре б-н бүләкләнә.

**НИ́КОНОВА** Лидия Владимировна (13.9.1947, Киев өлкәсенең Умаль а.), физиотерапевт, мед. фән. д-ры (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Казан шәһәренең 12 нче хастаханәсендә эшли. 1976 елдан — Казан мед. ин-тының физиотерапия һәм дәвалау физкультурасы, 1991 дән — 1 нче эчке авырулар кафедрасында. Хезмәтләре ревматик авырулар вакытында (системалы склеродермия, Бехтеров авыруы, атеросклерозга бәйле ревматоидлы артрит, нефропатия һәм резус-конфликт б-н катлауланган йөклелеккә бәйле ревматоидлы артрит) микрогемоциркуляцияне өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Микрогемодинамические нарушения при системной склеродермии и их коррекция лазерным излучением // Казан. мед. журн. 1994. № 6; К обоснованию воздействия диуцифон электрофореза в диметилсульфоксиде на микрогемоциркуляцию и периферический кровоток в комплексной терапии болезни Бехтерева // Каз. мед. журн. 1998. № 6; Ревматоидный артрит. Проблемы микрогемоциркуляции и периферического кровотока. Дифференцированная физическая терапия. Методические рекомендации. К., 2001.

**НИ́КОНОВА** Светлана Игоревна (12.9.1959, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2009), проф. (2011). Казан ун-тын тәмамлый (1986). 1978 елдан Казан архит-ра һәм төзелеш ун-тында: тарих һәм культурология каф. мөдире (2007 дән), студентларның «Факел» эзләнү проекты җитәкчесе (2005 тән). Әлеге проектның эш нәтиҗәләре буенча Бөек Ватан сугышы ветераннарының истәлекләр җыентыклары чыгарыла. Хезмәтләре Бөек Ватан сугышы тарихына, совет хакимияте мәдәнияте һәм идеологиясенә, СССРда интеллигенция һәм башкача фикерләү мәсьәләләренә багышлана. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Духовная жизнь советского общества в 1965–1985: идеология и культура. К., 2006; Этот день мы приближали как могли! К., 2010; Последние десятилетия советской власти: идеология и культура. 1965–1985 гг. Saarbrücken, 2011.

**НИКОНО́РОВ** Константин Васильевич (11.5.1913, Казан — 3.3.1999, шунда ук), химик-органик, химия фән. канд. (1941), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1938). 1946 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Органик һәм физик химия ин-тында, 1958–87 дә директор урынбасары. Хезмәтләре биол. актив фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Н. яңа «Бойд хлорангидридлары»ның төзелешен өйрәнә. Ацилланган α-окси-β, β, β-тригалоидэтилфосфонатларның биол. активлыгын ача. Кешедә һәм хайваннарда була торган гөмбәчек авыруларын дәвалау өчен хлорацетофос препаратын эшли, Казан химия-фарм. з-дында аны җитештерүне оештыруда катнаша (1969). Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, РСФСР ЮСның Мактау грамотасы, ТАССР ЮСның ике Мактау грамотасы, КПССның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О получении некоторых эфиров триарилметилфосфиновой кислоты // Журн. общей химии. 1947. Т. 17, вып. 12 (автордаш); О действии аналогов хлорангидрида Бойда на алкоголяты спиртов // Журн. общей химии. 1948. Т. 18, вып. 6 (автордаш); О получении фосфорилированных ацеталей хлораля, их свойствах и превращениях // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1966. № 3 (автордаш).

**НИКОНО́РОВ** Пётр Михайлович (13.1.1923, Чистай ш. — 5.7.1983, Украина ССРның Харьков ш.), Сов. Союзы Герое (1.7.1944), гв. майоры. Циорис-Цхалин хәрби авиация мәктәбен (Грузия ССР, 1942) тәмамлый. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 88 гв. авиация истребительләре полкында звено командиры (2 нче һава армиясендә 5 нче авиация истребительләре корпусының 8 нче гв. авиация истребительләре дивизиясе). Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Н. Курск дугасы һәм Днепр елгасы буендагы (икесе дә — 1943) сугышларда, Житомир-Бердичев, Ровно-Луцк (икесе дә — 1944), Түбән Силезия, Берлин һәм Прага (барысы да — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең февраленә 167 сугышчан очыш ясый, 44 һава сугышында шәхсән үзе дошманның 17 һәм төркем составында 5 самолётын бәреп төшерә. Сугыштан соң Хәрби Һава көчләрендә хезмәтен

дәвам итә. 1957 дән запаста. Харьковта яши. Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Х а н и н Л. Герои Советского Союза — сыны Татарии. К., 1963; Герои Советского Союза — наши земляки. К., 1984. Кн. 2.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НИКО́ШИН** Леонид Иванович (19.9.1923, Спас кантоны Базарлы Матак а. — 1989, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1981). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1945), Төньяк хәрби-диңгез флотында хәрби табиб. 1946 елдан Әлки р-ның Яңа Салман авылы хастаханәсе табибе. 1958–77 дә, 1982–89 да Казан ГИДУВында. 1977–82 дә Мордва ун-тының оператив хирургия һәм топографик анатомия, бер үк вакытта гистология кафедралары мөдире. Хезмәтләре баш мие һәм баш сөяге яраларын дәвалауга, баш түбәсе сөякләре кимчелекләрен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Глухой шов после хирургической обработки осложнённых инфекций ран черепа и мозга // Казан. мед. журн. 1971. № 1; Проекция внутренних органов и сосудисто-нервных образований на наружные покровы тела человека: Учеб. пособие. М.–Л., 1984.

*Әд.:* Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина (1920–1990). К., 1990.

**НИКУ́ЛИН** Валентин Николаевич (26.7.1908, Пенза ш. — 22.2.1994, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1967), проф. (1968), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1968). 1937 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1991 гә кадәр шунда ук эшли (бүленеп: 1942–45 тә В.И.Ленин исем. з-дта), физик һәм коллоидлы химия каф. мөдире (1965–87). Хезмәтләре органик кушылмалар электрохимиясенә, электрокатализга карый. Н., беренчеләрдән булып, электрохимик реакцияләр кинетикасына электрод төзелешенең тәэсирен өйрәнү өчен, монокристаллар алымын куллана, органик кушылмаларны каты электродларда электросинтезлау алымын кулланып табу юлын күрсәтә. Коррозия, электр б-н шомарту процесслары, ультратавышның органик кушылмаларны электрохимик кайтаруны көчәйтү тәэсире турындагы хезмәтләр авторы. Трофей дарыларның составын тикшерүдә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Восстановление пировиноградной кислоты в зависимости от структуры и кристаллографической характеристики электрода // Журн. физ. химии. 1961. № 34 (автордаш); Краткий курс физической химии. М., 1978 (автордаш); Электрохимические реакции с участием 1,3,5-тринитрозо-,1,3,5-триазациклогексана // Журн. общей химии. 1990. Т. 60, вып. 1 (автордаш).

*Әд.:* Институт полимеров (полимерный факультет 1971–2001): Краткий биогр. справ. К., 2001.

*В.Г.Абзалова.*

**НИКУ́ЛИН** (чын фамилиясе Гайдуков) Иван Васильевич (26.11.1898, Самара губ., Николаев өязе Озинки а., хәзер Саратов өлкәсенең Озинки штп — 11.10.1954, Казан), драма актёры, ТАССР, РСФСРның атказ. артисты (1950, 1954). Гимназия тәмамлаганнан соң, Пугачёв шәһәр театры каршындагы драма студиясенә (Саратов өлкәсе, 1918) укырга килә, бер үк вакытта, 1918–19 елларда, әлеге театрның актёры. Аннан соң Самара, Сталинград, Воронеж, Белгород, Курск, Львов шәһәрләрендәге театрларда эшли, 1935–36 да Чкалов өлкә драма театрында актёр һәм режиссёр, 1938 дә Дагстан театрында, 1939–46 да Рязань өлкә драма театрында. 1946 дан Казан Зур драма театрында. Казан театры труппасына тәҗрибә туплаган оста буларак килә, аның репертуарында инде рус классикасына һәм заманча драматургиягә караган шактый гына зур рольләре була. Н. тарафыннан иҗат ителгән һәр образ сәнгатьчә сурәтләү чараларының җентекле сайланышы, тышкы күренешнең, сәхнәдә үзләрен тотышларының төгәл бирелеше ягыннан аерылып тора: һәрбер хәрәкәт, интонация, костюмның һәр детале рольнең драматургик идеясен ачарга ярдәм итә. Аның геройлары җиңел танып беленә, тормышчан. Н.ның Шмага, Грознов («Гаепсездән гаеплеләр», «Дөреслек яхшы, ә бәхет яхшырак», А.Н.Островский), Собакевич («Үле җаннар», Н.В.Гоголь поэмасы буенча), Медведев, Печенегов («Тормыш төбендә», «Дошманнар», М.Горький), Расплюев («Кречинскийның туе», А.В.Сухово-Кобылин) рольләре театр сәнгатендә зур вакыйга була. Актёр әлеге персонажларда гәүдәләнеш тапкан күренешнең масштабын һәм әһәмиятен тамашачыга уңышлы җиткерә. Тятькин («Газап чигеп йөру», А.Н.Толстой романы буенча), Милягин («Бөек көч», Б.С.Ромашов), Куприянов («Хәсрәт дәрьясы», В.Я.Шишков романы буенча), Атабаев («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт) рольләре социаль характерның эчке мәгънәсе һәм әһәмияте, төгәллеге һәм үткенлеге б-н аерылып торалар. Н., искиткеч көлдерү сәләтенә ия буларак, Лыняев («Бүреләр һәм сарыклар», А.Н.Островский), Оргон («Суган суфые», Ж.Б.Мольер), Альфред Дулитл («Пигмалион», Б.Шоу), Хардкестль («Хаталар төне», О.Голдсмит), Мендозо («Гаҗәеп ялганнар көне», Р.Шеридан), Романюк («Баланлык», А.Е.Корнейчук), Пирогов





И.В. Н и к у л и н 1. Собакевич («Үле җаннар», Н.В.Гоголь поэмасы буенча); 2. Печенегов («Дошманнар», М.Горький) рольләрендә.



П.М. Никоноров.



И.В. Никулин.

(«Бирнәле туй», Н.М.Дьяконов) рольләрендәге теләсә нинди сәхнә ситуацияләрендә дә үзенең табигый яшәеше б-н тамашачының игътибарын җәлеп итә. Ул тудырган образлар күпкырлы колориты, кеше характерына тирән үтеп керә белүе б-н аерылып тора. Бөек Ватан сугышы елларында артистлар бригадасы б-н фронтта чыгыш ясый, Б.Н.Полевойның «Чын кеше турында повесть» («Повесть о настоящем человеке»), «Алтын» («Золото») һ.б. романнары буенча әдәби композицияләр авторы һәм башкаручысы сыйфатында концертларда актив катнаша.

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**НИКУ́ЛИН** Иван Семёнович (29.8.1879, Казан губ., Казан өязе Кече Алат а. — 1943), уйлап табучы, рационализатор. Хезмәт Батыры (1930). Казанда башлангыч шәһәр уч-щесен (1892), һөнәр уч-щесен (1896) тәмамлый. 1896 елдан Алатырь тимер юл остаханәләрендә слесарь ярдәмчесе булып эшли, 1900–02 дә Казан һөнәр уч-щесенең тимерчелек классында укыта; шуннан соң Некрасов остаханәсендә, Свешниковның механика з-дында тимерче булып эшли. 1905–07 еллардагы Рев-ция чорында Казан металлистлары забастовкасын оештыручыларның берсе. 1906–12 дә — механика остаханәләрендә тимерче. 1912 ел ахырында инженер Чиховның гидротехника отрядында, Фирганә үзәненең далалы районнарының үзәк өлешен сугару буенча тикшеренү эшләрендә катнаша, 1914 тән Казан һәм Пермь бораулау идарәләрендә бораулау мастеры. 1916 да Трапезунд ныгытылган р-ның (Төркия) стереофотограметрик партиясендә геогр. карталар төзү буенча өлкән десятник вазифаларына керешә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң, Казанга кайткач, Козловның механика з-дында тимерче, Окт. кораллы күтәрелешендә катнаша. 1917 дә транспорт, коммуналь пр-тиеләр бүлекләре һ.б. мөдире. 1920 дә Бакалтай тимер юл тармагы (Казан) төзелешенә комиссар итеп билгеләнә. 1921–22 дә Казан шәһәр башкарма ком-тының коммуналь хуҗалык бүлеге мөдире. 1923–24 тә ТАССР Электротресты директоры. 1926–27 дә Таттекстилькомбинат управляющие урынбасары (рационализаторлар һәм уйлап табучылар бюросы б-н җитәкчелек итә). Бер үк



Х.Ә.Ниятбәков.

вакытта итек басу-киез ф-касы директоры. Н. тарафыннан 20 дән артык машина, станоклар һәм механизмнар: тиредән йонны кырку өчен электр кайчылары, киез итек чистарту өчен пневматик кыса һ.б. уйлап табыла; эчке янулы 2 двигатель камилләштерелә. Н. эшләгән, киез итек җитештерүдә барлык процессны механикалаштыру мөмкинлеге биргән 8 станок Кукмарадагы «Кызыл текстильче» ф-касында урнаштырыла. Н. уйлап тапкан җайланмалар һәм яңалыклар республика сәнәгатенең күп кенә тармакларында гамәлгә кертелә. Ул — уйлап табучыларның Казан гомумшәһәр конференциясен (1931 нең гыйнвары) оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе, конференциядә Казан уйлап табучылар бюросына әгъза булып сайлана. Уйлап табучыларның 1 нче Бөтенсоюз съезды (Мәскәү, 1932 нең гыйнвары) делегаты. 1937 нең октябрендә «уң троцкийчылар оешмасы»нда катнашуда гаепләнеп, нигезсез кулга алына. 1938 нең сентябрендә ике елга ирегеннән мәхрүм ителүгә хөкем карары чыгарыла; ноябрьдә эш яңадан карала һәм җинаять составы булмау сәбәпле туктатыла. 1938 дән ФЗӨ мәктәбе укытучысы. «СССРның иң яхшы уйлап табучысы» көмеш билгесе (1933), «СССР Уйлап табучылар җәмгыятенең иң яхшы уйлап табучысы» билгесе (1937) б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974; Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2004. Т. 10.

*Л.М.Айнетдинова.*

**НИ́ЛОВ** Пётр Андреевич (29.5.1771, Воронеж губ., Тамбов провинциясе Покровское а. — 13.4.1839, Киев), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1820). Дворяннар катлавыннан. 1784 елдан хәрби хезмәттә, 1798 дән гражданлык хезмәтендә. 1799 дан сенат генерал-прокуроры канцеляриясе сәркәтибе, 1802 дән Юстиция министрлыгы департаменты экспедиторы (С.-Петербург). 1811–13 тә — Тамбов, 1820–23 тә Казан гражданнар губернаторы. 1823 тән Казан губерна азык-төлек комиссиясе рәисе. Халыкны корылык чорларында тәэмин итү өчен кибетләрнең икмәк запасларын булдыру б-н шөгыльләнә; губерна терр-ясендә җинаятьчелеккә каршы көрәш алып баруны җайга сала. 1822 дә Казан вакытлы комиссиясенең (С.С.Кушников һәм П.Л.Сантиның сенатор ревизиясе вакытында ачыкланган башбаштаклыклар турындагы эшләрне карау һәм хәл итү өчен 1820 дә оештырыла) ябылуына ирешә. Җирле уку йортларына химаячелек итә, М.Л.Магницкийга Казан ун-тын Изге Союз идеяләре рухында реформалауда ярдәм күрсәтә. Н. вакытында «Казанский вестник» ж-лы басыла башлый (1821). Административ тәртипсезлекләр сәбәпле вазифаларыннан азат ителә. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1820).

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**НИ́ЛОВ** Степан Сергеевич (20.4.1924, Тәтеш кантоны Бессоново а. — 8.3.1991, Казан), зоотехник, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, а.х. фән. канд. (1975). КПСС ҮК каршындагы Югары партия читтән торып уку мәктәбен (Мәскәү, 1957), Минзәлә а.х. техникумын (1966) тәмамлый. 1940–42, 1947–51 һәм 1955–59 елларда Тархан (хәзерге Тәтеш) р-нында эшли, КПССның район ком-ты инструкторы (1947–49), секретаре (1956–57), район башкарма ком-ты рәисе урынбасары (1957 дән). 1951–53 тә КПССның Мамадыш райкомы оештыру бүлеге мөдире, 1953–55 тә секретаре. 1959–62 дә Алексеев р-нының «Большевик» с-зында, 1962–67 дә Азнакай р-нының Вахитов с-зында директор. 1967–72, 1975–76 да ТАССР а.х. министрының беренче урынбасары. 1972–75 тә ТАССРның Республика совхозлар берләшмәсе башлыгы. 1976–81 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары. 1981–83 тә Татарстан хуҗалыкара «Свинопром» ЖБ башлыгы. 1983–86 да Биектау р-нының «Озёрный» с-зы директоры. 1963–70 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, РСФСР, ТАССР ЮСлары Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

**НИМФАЛИДЛӘ́Р** (Nymphalidae), тәңкә канатлылар отрядыннан көндезге чукмар мыеклы күбәләкләр семьялыгы. Көндезге күбәләкләр арасында иң күп санлысы. 2,5 меңгә якын төре билгеле, Россиядә — 140 ка якын. Татарстан терр-ясендә 17 ыругтан 38 төре бар: перламутрлы күбәләкләр (Аглая, Нибба), *тасмачлар*, әрекмән күбәләге, *кычыткан күбәләге* һ.б. Болыннарда, урман аланнарында, урман, юл буйларында очрыйлар. Еш кына чәчәкләргә куналар, аерым төрләрен зарарланган агач кәүсәләрендә, азык калдыкларында, пычракта, тирестә күрү гадәти күренеш. Канат җәеме 2,5 тән 18 *см* га кадәр, ачык төстә: канатларының өске ягы аксыл яисә карасу буйлы кара яки кызыл-көрән, кызгылт сары төстә, аскы ягы кайры, кипкән яфраклар яки туфрак төсенә охшаш. Алгы аяклары үсеш алмаган. Гусеницаларның гәүдәсендә яки башында чәнечкеләр сизелеп тора. Үсемлекләрдә яшиләр, үлән, агач, куак яфраклары б-н туеналар. Курчаклары металлсыман ялтыравык тимгелле; башлары аста килеш асылынып торалар. Гадәттә, күбәләкләр яки яшь гусеницалар кышлый. Төс үзгәртүчән күбәләк (Apatura iris), *адмирал*, *кайгылы күбәләк*, бизәкле күбәләк (Nymphalis polychloros), почмак канатлы күбәләк (Polygonia V-album), тирәк тасмач (Lemenitis vernalis) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*С.Г.Гордиенко.*

**НИША́Н** (гарәп. نشــان — мөһер, тамга). 10–12 йөзләрдәге төрки язмаларга, ш.у. Алтын Урда ханнарының ярлык һәм хат-юллаларына сугылган мөһер яки тамга. «Н.» термины, предмет буларак, *мөһер* һәм ал яки зәңгәр төстәге квадрат тамганы да аңлаткан.

*М.Г.Госманов.*

**НИШИЯ́МА** (Nishiyama) Кацунори (9.3.1951, Япониянең Хоккайдо утравы, Сибинай а.), тарихчы, тюрколог, проф. (1996). Хоккайдо ун-тын тәмамлый (1974), 1979 елдан шунда ук эшли, 1979–90 да Саппоро ун-тында приват-доцент. Япониядә (япон телендә) нәшер ителгән «Россия революциясе һәм милли мәсьәлә» (1985), «Бер партияле система урнашу һәм милли мәсьәлә б-н бәйле рәвештә Башкортстан АССРның оешуы» (1987), «Россия империясенең мөселман регионында шәһәрләр» (1990) хезмәтләре авторы. Колониаль сәясәт, Россиядә крәстияннәр һәм милли мәсьәләләр, Идел буенда һәм Урал алдында милли җөмһүриятләр оешу һ.б. мәсьәләләрне өйрәнә.

**НИЯЗБА́ЕВ** Габделрәүф Хәким улы (3.12.1881, Оренбург губ. Каргалы бистәсе — 1920), драматург. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1906 елда «*Шимбәчеләр*» әдәбият, театр һәм музыка сәнгате сөючеләр түгәрәге әгъзасы була, татар театрының беренче спектакльләрендә катнаша. Соңыннан Урта Азиядә укытучылык хезмәтендә. 1919 дан соң мәгариф оешмаларында, ш.и. Башкортстан АССРның Мәгариф комис-ты инспекторы. Н.ның «Беренче таң» (1918), «Борадәрән Галимовлар» (1918) пьесалары «Сәйяр» труппасы тарафыннан Казанда куела. «Кызыл истикъбаль өчен көрәш», «Гөлбостан», «Кара көннәр» һ.б. пьесалар авторы.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н Х. Габделрәүф Ниязбаев // Казан утлары. 1967. № 4.

*А.М.Ахунов.*

**НИЯ́ЗОВ** Мөхтәсиб (19 йөз уртасы), педагог. Әстерхандагы Беренче ир балалар гимназиясендә татар һәм гарәп телләре укыта.

**НИЯТБӘ́КОВ** Хәмит Әхмәт улы (1904, хәзер Төмән өлкәсенең Яркәү р-ны Карбан а. — 23.10.1944, Краков воеводасының Санок торак пунктында җирләнә, Польша), Сов. Союзы Герое (13.11.1943), өлкән сержант. Туган авылында эшли. 1942 елның башыннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 520 нче укчы полкында санинструктор (38 нче армиянең 167 нче укчы дивизиясе). Брянск һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Кастория һөҗүм операциясендә (1943), Курск сугышында (1943), Украинаның Уң як ярын азат итүдә (1943) катнаша. 1943 нең 3–4 октябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: дошманның көчле уты астында елганың уң ярынна 86 яралыны чыгара, 1943 нең 1 августыннан 14 октябренә кадәр сугыш кырыннан яралыларны б-н барлыгы 104 яралы солдатны алып чыга. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Кузьмин М.К. Медики — Герои Советского Союза. М., 1970; Герои земли Тюменской. Свердловск, 1975; Сатрапинский Ф.В. Военные медики — Герои Советского Союза. Л., 1975.

*М.З.Хәбибуллин.*

**«НО́ВАЯ ДЕРЕ́ВНЯ»** («Яңа авыл»), газета; к. «*Колхозник Татарии*».

**НОВЕ́ЛЛА** (итал. novella — яңалык), эпик жанр, хикәянең оригинальлек («яңалык»), үткен, парадоксаль сюжет, композицион төгәллек б-н аерылып торган бер төре. Италиядә Яңарыш чорында барлыкка килә, соңрак Англия, Франция, Испаниядә тарала. Аның чәчәк атуы романтизм чорына карый (П.Мериме, Э.По, Ги де Мопассан, О'Генри). Рус әдәбиятында Н. А.П.Чехов, Л.Н.Андреев, И.А.Бунин, В.В.Набоков, И.Э.Бабель, М.М.Зощенко, Ю.М.Нагибин, А.Г.Битов һ.б. исемнәр б-н бәйле. Шәрекъ һәм татар әдәбиятларында Н. сюжетының парадоксальлеге һәм тасвирлау үзенчәлеге б-н кысалы композициягә корылган кыйсса һәм хикәяткә якын тора (Сәйф Сараиның «Гөлестан бит-төрки», Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләре һ.б.). 20 йөз татар әдәбиятында Н.га еш кына психол. («Уяну», «Буранда», «Сулган гөл») һәм сатирик («Депутат», «Сәмруг кош», «Холера вакытында») әсәрләр авторы Ш.Камал мөрәҗәгать итә. 20 йөзнең 1 нче яртысында бу жанрда Ш.Мөхәммәдов («Аз гына хата булган», «Судта»), Ф.Әмирхан («Хәзрәт үгетләргә килде», «Сәмигулла абзый»), Г.Гобәйдуллин («Вәсвәсә», «Исерек», «Шомлы көн», «Хәзрәт икегә бүлә») яза. Бүгенге татар әдәбиятында Н. киң таралыш тапмый, ләкин аерым чалымнары Ф.Хөсни, Р.Төхфәтуллин, Г.Сабитов, М.Юныс, Ф.Шәфигуллин, Р.Харрасова хикәяләрендә күренә.

*Әд.:* Хатипов Ф.Х. Әдәбият теориясе. К., 2000; Миннегулов Х. Татарская литература и восточная классика. К., 1993; Ганиева Р.К. Татарская литература: Традиции, взаимосвязи. К., 2002. *Д.Ф.Заһидуллина.*

**НО́ВИКОВ** Валерий Александрович (8.3.1939, Чуаш АССР, Красночетай р-ны Атаи а.), ветеринар-токсиколог, вет. фән. д-ры (1991). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Чуаш АССРның Ядрин вет. станциясендә баш вет. табибе. 1966–69 елларда СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Токсикология ин-тында эшли. 1969–83 тә Казан вет. ин-тында, 1984 тән Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (ВНИВИ), техноген экотоксикантлар индикациясе һәм контроле лаб-ясе мөдире (1999 дан). Хезмәтләре фосфорорганик пестицидлар һәм авыр металл тозлары б-н агуланган а.х. терлекләрен дәвалауга, әлеге авыруларны кисәтү чараларын һәм ысулларын эшләүгә, агулы элементларны ачыклау ысулларын модификацияләүне камилләштерүгә карый. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Влияние натрия сульфида на токсикокинетику свинца и кадмия // Ветеринария. 2001. № 12 (автордаш); Тяжелые металлы — техногенный фактор воздействия на окружающую среду и животных // Ветеринарный врач. 2002. № 4 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**НО́ВИКОВ** Владимир Алексеевич (27.6.1894, Казан — 26.6.1964, шунда ук), рентген җиһазлары технигы, РСФСРның атказ. уйлап табучы-рационализаторы (1964). 1911 елдан Казан шәһәренең техник остаханәләрендә эшли. 1923–64 тә Казан ГИДУВында: рентген кабинеты җиһазлары һәм электр-яктыртү җайланмаларына хезмәт күрсәтү технигы, рентген техникасы курсы укытучысы (1935 тән). Беренче совет томографын (1936) һәм вертикаль топографны (1951) уйлап табучы. Н. тарафыннан Казан ГИДУВында 70 тән артык физиотерапия җиһазы һәм рентген аппараты, приборлар, мед. җайланмасы конструкцияләнә һәм гамәлгә куела. Казандагы һәм республикадагы рентген җиһазларының күпчелеге аның җитәкчелегендә урнаштырылып көйләнә. Медальләр, СССР ҮБК һәм ТАССР ЮСның Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Файзуллин М.Х., Авдонин С.И. В.А.Новиков // Казан мед. журн. 1965. № 1.

*М.Х.Фәйзуллин.*

**НО́ВИКОВ** Вячеслав Фёдорович (10.9.1941, Мари АССРның Оршанка р-ны Оршанка а.), химик, химия фән. д-ры (1993), проф. (2000). 1966 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Бөтенсоюз углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, нефть химиясе технологияләре лаб. мөдире (1974 тән). 1975–86 да Казан химия-технол. ин-тында, 1986 дан Казан архит-ра-төзелеш академиясендә. 2001 дән Казан энергетика ун-тында, физик тәрбия каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре газ хроматографиясенә карый. Н. газохроматографик сорбентларның селективлык үзлекләрен тикшерә һәм аларның яңа төрләрен тәкъдим итә. Газ хроматографиясе алымнарын эргәдәш экосистемаларның экологик мониторингында, әйләнә-тирә мохитне һәм сәнәгать пр-тиеләрен контрольдә тотуда куллана. Полиэтиленны углеводород чималын пиролизлап табу технологияләрен эшләүдә, пиролиз сумаласын үтилләштерүдә катнаша. Уйлап табуга 50 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. 200 *м* га йөгерүдә СССР чемпионы (1959).

Хезм.: Проблемы экологической химии Республики Татарстан. К., 1998 (автордаш); Органические производные фосфора и мышьяка в качестве неподвижных фаз для газовой хроматографии // Журн. физ. химии. 1993. Т. 67, № 4.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**НО́ВИКОВ** Георгий Матвеевич (16.4.1898, Казан губ., Цивильск өязе Русские Норваши а. — 25.12.1976, Мәскәү), хирург, мед. фән. д-ры (1936), проф. (1938), мед. хезмәте генерал-майоры. А.В.*Вишневский* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1925), Цивильск өязендә хирург булып эшли. 1927 елдан Казан ун-тында, 1936 дан топографик анатомия һәм оператив хирургия каф. мөдире. 1938 дән Казан мед. ин-тының гомуми хирургия клиникасы мөдире, бер үк вакытта Казан ГИДУВының кичектергесез һәм хәрби-кыр хирургиясе клиникасы җитәкчесе. 1940 тан Мәскәүдә: НКВДның санитария бүлеге башлыгы урынбасары һәм НКВД үзәк поликлиникасы баш хирургы, Мәскәүнең 2 нче мед. ин-тында педиатрия ф-тының госпиталь хирургиясе каф. мөдире (1970 кә кадәр), бер үк вакытта СССР МС каршындагы КГБ клиникасы баш хирургы. Хезмәтләре трофик җәрәхәтләр патогенезы, аларны дәвалау, аерым урында авыртуны басу мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Новокаиновый блок нервов при спонтанной гангрене // Новый хирург. архив. 1933. Т. 29, кн. 3, № 115 (автордаш); Хирургия печени и желчных путей в свете местного обезболивания по методу ползучего инфильтрата // Сб. работ хирургической клиники. К., 1934; Местная анестезия по методу проф. А.В.Вишневского в условиях участковой больницы. К., 1938.

*Әд.:* Вишневский А.А., Шапошников А.В., Хватов Н.Ф. К 70-летию проф. Г.М.Новикова // Хирургия. 1969. № 2.

**НО́ВИКОВ** Николай Алексеевич (4.11.1963, БАССРның Ишембай ш.), хокук белгече. Свердловск юридик ин-тын тәмамлый (1991). 1992–99 елларда Эстәрлетамак шәһәрендә Урта Идел транспорт прокуратурасы тикшерүчесе, прокуроры (Башкортстан Респ-касы). 1999–2000 дә Самара шәһәрендә Урта Идел транспорт прокуратурасы прокуроры урынбасары. 2000–01 дә РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиллеге аппаратында бүлек башлыгы (Түбән Новгород ш.). 2001–03 тә РФ Юстиция министрлыгының Идел буе федераль округы буенча Федераль идарәсе башлыгы урынбасары. 2004–13 тә Самара өлкәсе Арбитраж мәхкәмәсе рәисе. 2013 тән ТР Арбитраж мәхкәмәсе рәисе. Медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

**НО́ВИКОВ** Пётр Георгиевич (1906, Казан губ., Чистай өязе Югары Кондрат а. — 1944), генерал-майор (1941). Милләте буенча татар. Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен, Татар-башкорт командирлар мәктәбен (Казан, 1926), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү) тәмамлый. 1936–39 елларда Испаниядә Интернациональ бригада составында сугыша. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең 22 июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: Н.ның укчы полкы Прут елгасы буенда оборона тота, соңыннан Одессаны, Севастопольне саклый. Приморье армиясендә 109 нчы укчы дивизия б-н җитәкчелек итә, бер үк вакытта Севастополь оборона р-нының 1 нче секторы коменданты була. 1942 нең 30 июненнән 2 июленә кадәр Кара диңгез флоты һәм Приморье армиясенең Новороссийск ягына чигенешен каплаган гаскәрләр төркеме б-н җитәкчелек итә. Отрядның калдыклары иң соңгы булып чигенү омтылышы ясыйлар, әмма аларның катерлары сафтан чыга; тигезсез сугышта күп сугышчылар һәлак була, Н. әсирлеккә эләгә. Немецларга хезмәт итү турында тәкъдимнәрне кире кага; Хаммельсбург концлагерендә фашистларга каршы яшерен оешма б-н җитәкчелек итә. Гитлерчылар тарафыннан Флоссенбург (Германия) лагеренда җәзалап үтерелә. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Севастополь

шәһәренең бер урамы Н. исеме б-н атала, шул урамда 109 нчы укчы дивизиянең Дан музее урнашкан.

*Әд.:* Булатов Н.Х. Йолдызлы йолдызлар. К., 2000; Гармаш П.Е. Севастополь: Очерк-путеводитель. Симферополь, 1969; Моргунов П. Героический Севастополь. М., 1979; Крылов Н.И. Не померкнет никогда. М., 1984; Глухов-Ногайбек М.С. Казанский ретро-лексикон. К., 2002.

*Ф.Ф.Гулова.*

**НО́ВИКОВА** Клавдия Николаевна (7.3.1957, Рязань өлкәсенең Скопин ш.), хакимият эшлеклесе, социол. фән. канд. (2001), ТРның атказ. халыкны социаль яклау хезмәткәре (2001). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1979). 1979–85 елларда С.П.Горбунов исем. Казан авиация ҖБ инженеры, 1985–87 дә КПССның Казан шәһәре Ленин райкомы секретаре, 1990–95 тә халык депутатларының Ленин р-ны советы рәисе урынбасары, 1995–96 да Казан шәһәренең Авиатөзелеш р-ны хакимияте башлыгы урынбасары. 1996 дан ТР социаль тәэминат министры, 2001–07 дә ТР социаль яклау министры. Бер үк вакытта, 2001 дән, Татарстан бизнеска булышлык ин-тында укыта. 2007 дә ТР МКның Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы. 2007 дән РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты. Идарә социологиясе буенча язмалары бар.

*Е.Б.Долгов.*

**НОВИ́ЦКИЙ** Людвиг Казимирович (?, Варшава, Польша — 7.1.1886, Казан), пианист, педагог. Варшавада укый, 1863 елда укыта. Польша милли азатлык хәрәкәтендә катнашканы өчен Уфа шәһәренә сөргенгә җибәрелә, анда хосусый дәресләр бирә. 1870 тә Казанда беренче хосусый музыка мәктәбенә нигез сала, гомеренең ахырына кадәр аның җитәкчесе була. Мәгариф эшчәнлегендә җәмгыять ихтыяҗларын күздә тота. Музыкант, җәмәгать эшлеклесе һәм концерт бирүче пианист буларак, Казанда концертлар үсешенә булышлык күрсәтә. Н. мәктәбенең аеруча нәтиҗәле эшчәнлеге — халык алдында үткәрелә торган концертлар (ш.и. хәйрия максатлары б-н), аларны Н. гамәлгә кертә, аңа укытучылар һәм укучылар актив җәлеп ителә. Мәскәү консерваториясенә нигез салган Н.И.Рубинштейн 1873 елда Казанда гастрольләр вакытында мәктәпкә югары бәя бирә. Н. мәктәбе укучыларының кайберләре, проф. пианистлар буларак (Казанда В.Шидловский, И.Петропавловский, Э.Кондратович), пед. һәм башкару эшчәнлеген уңышлы алып бардылар. Фортепианода башкару теориясенә һәм практикасына караган хезмәтләре бар.

Хезм.: Полная теоретико-практическая школа, или Руководство к достижению правильной и основательной игры на фортепиано. СПб., 1850.

*Әд.:* Кантор Г.М., Карпова Е.К. Музыкальное образование в Казани в XIX в. // Из истории музыкальной культуры и образования в Казани. К., 1993; Порфирьева Е.В. Музыкальное образование в Казани в XVIII — начале XX века (становление и развитие): Автореф. дис. ... К., 2004.

**НОВИ́ЦКИЙ** Анатолий Иванович (16.6.1937, Кырым өлкәсенең Симферополь р-ны Ангара бистәсе — 2.4.2008, Казан), сәнгать белгече, музей хезмәткәре, төбәк тарихчысы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988), Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). Ленинград ун-тында тарих ф-тының сәнгать белгечлеге бүлеген тәмамлый (1959). 1959 елдан ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, 1992–2006 да рус сәнгате бүлеге мөдире, 2007–08 дә сәнгать белгече-методист. 1968 дән — Бөтенроссия тарих һәм мәдәният ядкәрләрен саклау җәмгыятенең Татарстан бүлеге сәркәтибе, 1989–92 дә рәис урынбасары. Б.Урманче, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова һ.б. Казан рәссамнарының иҗаты, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның рус нәкыше тупланмасы турындагы хезмәтләр, хәзерге заман сәнгате, Казандагы скульптур һәм мемориаль һәйкәлләр мәсьәләләрен үзәктә тоткан мәкаләләр авторы. ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исем. бүләге лауреаты (2007).

Хезм.: Моя Казань. К., 1984 (автордаш); Баки Урманче. К., 1994; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан, Казань. М., 2002; Баки Урманче (1897–1990). СПб., 2005.

*Әд.:* Лобашёва И.Ф. Верный рыцарь искусства // Казань. 2007. № 8.

*Е.П.Ключевская.*

**«НО́ВОЕ КАЗА́НСКОЕ СЛО́ВО»** («Казанның яңа сүзе»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. 1918 елның 9 августыннан 7 сентябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 23 саны чыга. Мөрәҗәгать һәм игъланнарның бер өлеше татар һәм поляк телләрендә басыла. Мөхәррирләре — Д.Деникe (хәрби-сәяси бүлек), Г.Жаровников. Актив авторлар арасында — А.Блинов, И.Бусыгин, М.Горбунов, Н.Данилов, А.Доброгаев, П.Зобнин, С.Казельский, А.Красновский, В.Огородников, Д.Петров, И.Порфирьев, Е.Сосунцов, В.Торский, К.Харлампович. Газетада яңа хакимиятнең күрсәтмәләре басыла, КОМУЧның Самара һәм Казан үзәк хакимиятләре, ш.у. яңа торгызылган җирле үзидарә органнары — шәһәр думалары, земстволар һ.б. эшчәнлеге яктыртыла. КОМУЧның аерым вәкилләренең Казан губернасында хәрби-сәяси шартлар һәм халыкның хәле турындагы хәбәрләре басыла. Редакция Халык армиясенә матди һәм кеше ресурсларын җәлеп итүдә нәтиҗәле катнаша. 14 августта Казанның Юнисовлар мәйданында узган митинг турындагы хисапта кавалерия полкы оештыру хакында мөселманнарга өндәмә дә бар. Крәстияннәрне яңа хакимияткә булышырга һәм Кызыл Армия частьларына каршылык күрсәтергә чакырган өндәмәләр нәшер ителә; Казан губернасы терр-ясендә булган кызыл террор фактлары турында җентекләп сөйләнә. Кызыл террорчылар контрольдә тоткан урыннарда редакциянең үз хәбәрчеләре була һәм аларның мәкаләләре «Фронтның теге ягында», «Кызыл лагерьда» дигән баш астында басыла. Газета 1918 нең 25 августында 400 делегат катнашында узган һәм демократик карарлар кабул иткән Казан губерна эшчеләренең партиясез конференциясе барышы турында яза. Казан дары з-ды эшчеләренең КОМУЧ хакимиятенә каршы чыгышы һәм гаскәрләр тарафыннан бастырылуы турында да мәгълүмат бирә. Соңгы саны «Түзеп торырга кирәк!» лозунгы һәм шәһәрне Кызыл Армиядән саклауда казанлыларны Халык армиясенә ярдәм итәргә чакыру б-н чыга.

*Т.М.Насыйров.*

**«НО́ВОЕ СЛО́ВО»** («Яңа сүз»), ТР Профсоюзлары федерациясе газетасы. 1989 елның октябреннән Казанда рус телендә нәшер ителә. 1991 нең апреленә кадәр «Профсоюзный вестник» исемендә чыга. «Гаделлек! Теләктәшлек! Бердәмлек!» девизы б-н басыла. Төрле еллардагы мөхәррирләре А.Ожегов, В.Судаков, А.Барабанов. Профсоюзлар эшчәнлеген билгеләүче аңлатмалар б-н документлар, профсоюзның җитәкче органнары карарлары урнаштырыла. Редакция ТР профсоюз оешмалары тормышын киң яктырта, аларның хезмәт ияләре мәнфәгатьләрен яклау акцияләрен хуплап чыга.

*Р.А.Айнетдинов.*

**НОВОКАИ́Н БЛОКА́ДАСЫ**, к. *Вишневский А.В. ысулы белән авыртуны вакытлыча туктату*.

**НОВОЛА́ЕВ** Владимир Иванович (25.9.1929, Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе, Костюкович р-ны Негино а. — 4.6.2003, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Грузия политехник ин-тын (Тбилиси, 1960), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1965) тәмамлый. 1950–62 елларда (бүленеп) Бөгелмә тимер юл станциясендә эшли, 1953–57 дә һәм 1960 тан станция башлыгы. 1962–63, 1965–66 да КПССның Бөгелмә шәһәр ком-ты секретаре, 1966–78 дә 1 нче секретаре. 1978–86 да ТАССР МС рәисе урынбасары. 1986–95 тә «Тепличный» с-зы директоры. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**НОВОЛО́ДСКИЙ** Алексей Борисович (30.3.1930, Бурят-Монгол АССРның Турка а. — 3.7.1994, Чаллы ш.), төзүче, Соц. Хезмәт Герое (1971), Якутия АССР, ТАССРның (1970, 1973) атказ. төзүчесе. 1942–53 елларда Бурят-Монгол АССРның Байкал буе р-ны урман сәнәгате хуҗалыгында эшли. 1953–55 тә Приморье краеның «Артёмуголь» шахтасында проходчик. 1955–59 да Иркутск ГЭСы төзелешендә «АнгарГЭСстрой» идарәсе электр б-н эретеп ябыштыручысы. 1959–71 дә Вилюй ГЭСы (Якутия АССР) төзелешендә электр б-н эретеп ябыштыручы, монтажчылар бригадиры. 1971–77 дә «Камгэсэнергострой» ҖБнең «Металлургстрой» идарәсендә монтажчылар бригадиры. 1977–88 дә «НерюнгриГРЭСстрой» (Якутия АССР) идарәсендә комплекслы бригада бригадиры. Герой исеме Вилюй ГЭСының 1 нче чираты төзелешендә ирешкән уңышлары, җитештерүгә төзелеш-монтаж эшләренең яңа алдынгы алымнарын кертканә өчен бирелә. 1979–89 да СССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Полухин Ю. Заколдованные берега. М., 1976; Злобин А. Встреча, которая не кончается. М., 1981; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НОВОНИКОЛА́ЕВСКИЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 34 *км* көнчыгыштарак, Казан урау юлы буенда урнашкан. 2010 елда 707 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 52%, руслар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык. Төзелеш пр-тиесе. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1910 елларда нигез салына. Беренче исеме — Николаевский Выселок (Николаевка). Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 35, 1926 да — 258, 1938 дә — 331, 1949 да — 350, 1958 дә — 138, 1970 тә — 114, 1979 да — 102, 1989 да — 781, 2002 дә — 753 кеше.

**НОВОПО́ЛЬСКИЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 17 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 184 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57%, чуашлар — 23%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 1910 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 66, 1926 да — 67, 1938 дә — 98, 1949 да — 100, 1958 дә — 106, 1970 тә — 310, 1979 да — 299, 1989 да — 228, 2002 дә — 227 кеше.

**НОВОПОСЕЛЁННАЯ ЛЕБЁДКА** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Лебёдка елгасы буенда. 2010 елда 116 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 654 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 251, 1897 дә — 389, 1906 да — 365, 1920 дә — 406, 1926 да — 276, 1949 да — 244, 1958 дә — 290, 1970 тә — 254, 1979 да — 155, 1989 да — 54, 2002 дә — 176 кеше.

**НОВОСЁЛКИ** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 97 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Борындык иseme б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, почта эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 140 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 188, 1880 дә — 301, 1897 дә — 450, 1903 тә — 529, 1920 дә — 527, 1926 да — 635, 1938 дә — 507, 1949 да — 345, 1958 дә — 309, 1970 тә — 261, 1979 да — 196, 1989 да — 115, 2002 дә — 129 кеше.


**НОВОСЁЛОВ** Кузьма Васильевич (8.2.1919, хәзер Мари Респ-касы, Сернур р-ны Климино а. — 20.3.1985, Украина ССРның Луганск ш.), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), гв. подполковнигы. Иркутск хәрби авиация уч-щесен тәмамлый (1941). 1936–39 елларда Казанда яши, күн ф-касында эшли. 1939 дан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 115 нче гв. авиация истребительләре полкында эскадрилья командиры урынбасары (2 нче һава армиясенең 2 нче авиация истребительләре корпусында 7 нче гв. истребительләр дивизиясе). 1 нче Украина фронты авиациясе составында гв. өлкән лейтенанты Н. 1945 нең апреленә 132 сугышчан очыш ясый, 29 һава сугышында шәхсән үзе — 12, ә төркем составында 5 самолётны бәреп төшерә. Сугыштан соң СССР Хәрби Һава көчләрендә хезмәтен дәвам итә. 1953 тән запаста. Ворошиловград шәһәрендә (хәзер Луганск ш.) яши. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НОВОСЁЛОК** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сеин елгасы буенда. 2010 елда 81 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1602–03 тән Кече Сия исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында икмәк саклау-сату, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1153 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 30 ир-ат; 1859 да — 453, 1897 дә — 812, 1908 дә — 709, 1920 дә — 710, 1926 да — 691, 1949 да — 478, 1958 дә — 261, 1970 тә — 211, 1979 да — 192, 1989 да — 155, 2002 дә — 87 кеше.

**НОВОСИБИ́РСК ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Мәйданы — 178,2 мең *км*². Үзәге — Новосибирск шәһәре. Халкы — 2709461 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 да — 24926, 1970 тә — 28823, 1979 да — 28547, 1989 да — 29428, 2002 дә — 27874, 2010 да — 24158 кеше. Татарлар туп-



А.Б. Новолодский.



К.В. Новосёлов.

ланып Бараба, Венгерово, Каргат, Колывань, Куйбышев, Кыштовка, Татарск, Уба, Усть-Тарка, Чаны р-ннарында яшиләр. Н.ө.ндә Себер татарлары элек-электән яши. Идел буе Болгар дәүләте чорында болгарлар б-н Себер татарларының борынгы буыннары арасында бәйләнешләр урнашкан була. Алтын Урда чорында бу элемтәләр зур үсеш ала. Казан ханлыгы таркалгач, татарлар күпләп Көнбатыш Себергә күчеп килә. 17 йөзнең 1 нче чирегеннән башлап, Идел һәм Урал буе татарларының Себергә күченүе даими күренешкә әверелә. Күченүләрнең соңгы зур дулкыны 19 йөз ахырыннан башлап Беренче бөтендөнья сугышына кадәрге чорга туры килә. Көнбатыш Себер терр-ясенә Идел һәм Урал буе татарлары, гадәттә, Себер татарлары яшәгән волостьларга килеп төпләнә. 19 йөз ахырында читтән килгән татарлар Себердәге татар авылларының 52% да яши. Идел-Урал төбәгеннән күченгән халык Себергә үзе б-н камилрәк игенчелек культурасы һәм терлекчелек технологиясе, йолалар, матди мәдәният, язма әдәби тел һәм фольклор алып килә. Себер татарлары мәктәп һәм мәдрәсәләрдә әдәби татар телендә укыйлар. 1922–36 да Новосибирскида татар телендә «*Азат Себер*» (кушымталары: «Яшьләр сәхифәсе» ж., 1921–23; «Яңалифче» ж., 1933–34), «Яңалиф походы» г-талары нәшер ителә. 1924–41 дә Новосибирскида җидееллык татар мәктәбе эшли. Күп кенә татар галимнәре СССР ФАнең Себер бүлекчәсен төзүдә катнаша һәм Новосибирск Академшәһәрчегендә эшли. Хәзерге вакытта өлкәдә 3 татар җәмгыяте бар: Новосибирск өлкә татар мәдәният үзәге, Н.ө.нең татар милли-мәдәни автономиясе (1997 дән), «Азат Себер» Татар иҗтимагый үзәге (1989 дан). Татарларның төбәк милли-мәдәни автономиясе каршында «Азат Себер» г-тасы нәшер ителә, Татар җәмгыятьләренең координацион советы эшли.

Н.ө.нең 8 мәктәбендә (Куйбышев, Колывань, Кыштовка, Венгерово, Чаны р-ннарында) татар теле факультатив дәрес буларак укытыла. 2001 дән Куйбышев р-нының мәдәният бүлеге каршында Татар мәдәният үзәге, Кыштовка р-нының Усманка һәм Әлмән авылларында үзешчән татар коллективлары, Каргат р-нының Теренино посёлогында «Чишмә» татар вокаль төркеме (1995) эшли. Новосибирскида шәһәр милли мәдәният үзәгендә татар әдәбияты фонды бар. Татарларның төбәк милли-мәдәни автономиясе ярдәме б-н Новосибирскида «Татарстан» сәүдә йорты төзелә. 2004 тән Н.ө. терр-ясендә



М. Ногман.



Д.С. Ногманов.

«Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары күрсәтелә. Өлкәдә Татарстан селекционерлары тарафыннан чыгарылган «*Казан 506*» һәм «*Каракитә*» карабодай сорты районлаштырыла. РФАнең хакыйкый әгъзалары Ренат һәм Роальд *Сәгъдиевләрнең*, техник фән. д-рлары М.Х.*Әхмәтҗанов* һәм Т.С.*Йосыповның*, биол. фән. д-ры Х.Л.*Гайнетдиновның*, физика-матем. фән. д-рлары Ф.Х.*Гыйлемханов*, Ә.Җ.*Җаффаров*, Э.Х.*Гыймади*, Н.Х.*Ибраһимов*, А.И.*Хисаметдинов*, М.М.*Шахмаев*, Н.В.*Хөснетдинованың*, геол.-минерал. фән. д-ры Э.Г.*Дистанов*, химия фән. д-ры З.Р.*Исмәгыйлев*, икътисад фән. д-ры Г.Й.*Шәрипов*, генерал-майорлар Р.К.*Мусин* һәм Ю.А.*Ширинскийның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Н.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* Файзрахманов Г.Л. История татар Западной Сибири: С древнейших времён до начала XX века. К., 2007.

**«НО́ВОСТИ ТАТАРСТА́НА»** («Татарстан яңалыклары»), к. «*Татар-информ*».

**НОВОТРО́ИЦК** шәһәре, *Оренбург өлкәсенең* көнчыгышында, *Оренбург* шәһәреннән 315 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 1920 еллар башында нигез салына, 1945 тән — шәһәр. Халкы — 102340 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 елда — 2016, 1970 тә — 2686, 1979 да — 3156, 1989 да — 3723, 2002 дә — 3670, 2010 да — 3238 кеше. Татарлар Н.да нигез салынган көннән яшиләр. 1961 дән шәһәрдә «Юллар» татар-башкорт үзешчән ансамбле (1985 тә халык ансамбле исемен ала) эшли, ул 1987 дә 2 нче Бөтенсоюз халык иҗаты фестивалендә лауреат була, 2000 дә Казанда «Уйнагыз, гармуннар!» фестивалендә чыгыш ясый, ел саен Оренбург өлкәсендә уза торган «Татар мәдәнияте көннәре» фестивалендә катнаша.

**НОВОЧУВА́ШСКИЙ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Казан–Түбән Новгород автомагистрале тирәсендә урнашкан. 2010 елда 120 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1898 дә нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Казан өязе Ильинский волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1920 дә — 133, 1926 да — 122, 1938 дә — 175, 1958 дә — 256, 1970 тә — 107, 1979 да — 229, 1989 да — 155, 2002 дә — 97 кеше.

**НОВОШИ́НОВ** Геннадий Павлович (24.6.1922, Сембер губ. Алатырь ш. — 1.10.2001, Казан), биофизик, вет. фән. д-ры (1970), проф. (1971). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук эшли, биофизика лаб-ясе мөдире (1967–84), патологик физиол. каф. мөдире (1985–91), профессоры (1991–96). Төп хезмәтләре төрле авыру очракларында терлек организмында баручы биофизик процессларны өйрәнүгә, аеруча куркыныч йогышлы авыруларга (бруцеллёз, түләмә, котыру авыруы, гадәти дуңгыз чумасы) диагноз кую өчен иммуноферментизнелеш? 

Ике «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Показатели электрокардиограммы у кроликов // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1969. Т. 103; Чувствительность лейкоцитов крови свиней к вирусу болезни Ауески // Уч. зап. Казан. гос. вет. ин-та им. Н.Э.Баумана. 1977. Т. 127 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**НО́ВЫЙ** посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 63 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 473 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 72%, руслар — 26%) яши. Урман сәнәгате хуҗалыгы. Клуб. 1952 дә нигез салына. Оештырылган көннән Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1970 тә — 788, 1979 да — 690, 1989 да — 542, 2002 дә — 490 кеше.

**НОГМА́Н** (Ногманов) Мостафа Ногман улы (22.12.1912, Казан губ. Царёвококшайск өязе, хәзер Арча р-ны Кызыл Яр а. — 4.9.1976, Казан), шагыйрь, тел белгече, филол. фән. канд. (1964). Көнчыгышны өйрәнү ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1951). 1931 елдан Татарстан авыллары мәктәпләрендә, соңрак Таҗикстанда балалар укыта. 1935–37 дә Дүшәмбе шәһәрендә Хәрби трибуналда сәркәтип вазифасын башкара. 1937–41 дә Дүшәмбе пед. ин-тында укый. 1945–47 дә «Пионерская правда» г-тасының Татарстандагы үз хәбәрчесе булып эшли. 1953–57 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1957–59 да Казан ун-тының фәнни китапханәсендә Шәрекъ кулъязмаларын өйрәнү бүлеге мөдире. 1960 тан Казан ун-тында фарсы һәм иске татар телләре укытучысы. «Давыллы еллар лирикасы» исемле беренче җыентыгы 1941 дә басылып чыга. «Апрель җилләре» (1954) (рус теленә тәрҗемәдә «Грозовое лето», М., 1963; 3 нче басма, 1977), «Кокушкино таңнары» (1964) җыентыклары В.И.Ленинның Казан чоры тормышына багышлана. «Таң йолдызы» (1959), «Каеннар шаулый» (1967), «Иртәнге җырлар» (1973), «Акчарлаклар оча Иделдә» (1982) җыентыклары авторы. Н.ның шигырьләре нечкә лиризм, аһәңлелек б-н аерылып тора. Композиторлар Р.Яхин («Оныта алмыйм», «Бөдрә таллар»), С.Садыйкова («Актаныш таңнары», «Арча кичләре»), ш.у. А.Ключарёв, М.Мозаффаров, А.Монасыйпов, Ф.Әхмәтовлар б-н берлектә популяр җырлар һәм романслар иҗат итә. Н.Хикмәт, Рудаки, Г.Хәйям, А.Кадыйри әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 17–18 йөзләрдәге кулъязма рус-татар сүзлекләрен өйрәнә. Югары уку йортлары өчен фарсы, иске татар телләре буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Сөнгатев М. Яшьлек хыялларын җилкән итеп... // Казан утлары. 1982. № 12.

*Г.М.Габделхакова.*

**НОГМА́НОВ** Айдар Илсур улы (28.3.1965, Свердловск өлкәсенең Кировград ш.), тарихчы, тарих фән. канд. (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1990). 1994 елдан ТР ФА нең Татар энциклопедиясе ин-тында, торак пунктлар тарихы бүлеге мөдире (1995 тән) һәм гыйльми секретарь (2008 дән), 2011–13 тә директор урынбасары. Бер үк вакытта, 2003–08 дә, Казан ун-тында укыта. ТР торак пунктлары тарихын һәм Татарстаннан читтә татарлар куплап яшәгән төбәкләрне өйрәнү буенча фәнни юнәлеш җитәкчесе. Хезмәтләре 16 йөз – 20 йөз башында Россия дәүләтендә татарларның социаль-хокукый халәте мәсьәләләренә карый. ТР ФА Президиумының Ш.Мәрҗани исем. бүләге лауреаты (2007). Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Населённые пункты Республики Татарстан: Краткий справ. К., 1997 (автордаш); Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI–XVIII вв. К., 2002; Мусульмане Волго-Уральского региона в российском законодательстве XIX в. // Новая волна в изучении этнополитической истории Волго-Уральского региона. Sapporo, 2003; Самодержавие и татары: Очерки истории законодательной политики второй половины XVI–XVIII вв. К., 2005.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**НОГМА́НОВ** Дәүләтгәрәй Сирай улы (6.10.1922, хәзер БРның Ишембай р-ны Түбән Әрмет а. — 12.10.1944, Варшавадан төньяктарак Велишев пос. тирәсендә җирләнә, Польша), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), өлкән лейтенант. Саратов танк уч-щесен тәмамлый (1943). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 166 нчы аерым инженерлар танкы полкында мина эзләүче танклар взводы командиры (70 нче армиянең 2 нче инженер-сапёрлар һөҗүм бригадасы). 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Полесье һәм Люблин-Брест һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1944) катнаша. 1944 нең 12 октябрендә Михалув посёлогы (Варшавадан 20 *км* төньяктарак) янында барган сугышта батырлык күрсәтә: сугышта дошманның 3 танкын яндыра; үзенең танкы сафтан чыкканнан соң, экипажга машинаны ташлап чыгарга әмер бирә һәм, үз танкы б-н дошман танкын бәрдереп, аны юк итә; үзе дә һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Эстәрлетамак шәһәренең (Башкортстан Респ-касы) бер урамына Геройның исеме бирелгән.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Славные сыны Башкирии. Уфа, 1966. Кн. 2; Лицом на запад. Уфа, 1972; Ракипов Ш.З. По следам героев. К., 1975.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НОГМА́НОВ** Зөфәр Хөснетдин улы (1.1.1931, Урта Идел крае, Ульянов өлкәсенең Богдашкино р-ны Елховой Күле а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1955 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона пр-тиесендә эшли. 1960–61 дә Казан химия-технол. ин-тында. 1961 дән Казан техник ун-тында. Хезмәтләре самолёт канаты аэродинамикасына карый. Н. канат профилен ягалап агуны һәм кысылмаучан идеаль агымның канатның азаккы җәемен ягалап агуын исәпләүнең санлы алымнарын, ш.у. һаваның кысылучанлыгы һәм үзлелеге исәпкә алынган алымнарны тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Определение коэффициента коррекции давления при расчёте обтекания профиля // Изв. вузов. Авиац. техника. 1998. № 2; О методе Галёркина для решения краевой задачи аэродинамики // Инженерно-физ. журн. 1998. № 5; Численный метод расчёта обтекания профиля вблизи экрана // Изв. вузов. Авиац. техника. 1999. № 3 (автордаш).

**НОГМА́НОВ** Рафил Габдерәфыйк улы (1.7.1949, Кайбыч р-ны Салтыган а.), милиция генерал-майоры (2000), ТРның атказ. хокук белгече (1999), РФнең атказ. эчке эшләр органнары хезмәткәре (2006). СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясенең Казан ф-лын тәмамлый (1981). 1970 елдан ТР эчке эшләр органнарында: 1981–85 тә Әгерҗе р-ны, 1985–89 да Әлмәт, 1991–93 тә Чистай шәһәре эчке эшләр бүлекләре, 1990–91 дә профилактика хезмәте идарәсе, 1993 тән ТР Эчке эшләр министрлыгының җәмәгать куркынычсызлыгы милициясе башлыгы. Бер үк вакытта, 1993 тән, ТР эчке эшләр министры урынбасары. Батырлык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**НОГМА́НОВ** Рәмзи Галимҗан улы (26.2.1933, Буа р-ны Күл Черкене а.), культуролог, техник фән. канд. (1971), культурология фән. д-ры (2000), проф. (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук, химик технол. процесслары һәм аппаратлары кафедрасында эшли. 1997 елдан Казан энергетика ун-тының культурология каф. профессоры, культурология каф. мөдире (2000–2008). Хезмәтләре культура философиясе һәм теориясе мәсьәләләренә карый. Мактаулы югары мәктәп хезмәткәре (2003).

Х е з м.: Проблемы теории и истории культуры. К., 1997; Перспективы развития культуры в Татарстане. К., 2003; Философия культуры. Теория духовной личности. К., 2006; Основы рациональной теории культуры. К., 2008.

**НО́ГТЕВ** (Ногтев-Суздальский) Андрей Иванович (? — февраль, 1579, Казан), кенәз, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1559 тирәсе). 1556 елда шведларга каршы яуда Уң кул полкында 1 нче воевода, Орешек һәм Выборг тирәсендәге сугышларда катнаша. 1559–60 та Зөя шәһәрендә 1 нче воевода. 1560 та Дерпт шәһәренә яуда каравыл полкында 1 нче воевода. 1563 тәге яуда Уң кул полкында 3 нче воевода, Полоцк шәһәрен алганда батырлык күрсәтә. 1564–65 тә Полоцк шәһәрендә 1 нче воевода. 1565–68 дә Старица удел кенәзлегендә бояр, кенәз Владимир Андреевичны күзәтү максатыннан, патша Иван IV тарафыннан билгеләнә. 1573 тә 1572–73 тәге баш күтәрүне (*Казан ханлыгы яулангannan соңгы фетнә-чуалышлар*) бастыру өчен Муромда оештырылган гаскәрдә 2 нче воевода. 1576–79 да Казанда 1 нче воевода.

*Е.В.Липаков.*

**НОЗЕМАТО́З АВЫРУЫ́** (Nosematosis apis), у м а р т а  к о р т л а р ы н д а  п е б р и н а,  к а р а  э ч  к и т ү, бер күзәнәкле эчәк паразиты — Nosema apis микроспоридиясе китереп чыгара торган инвазион авыру. Бал кортлары булган һәр җирдә очрый. Авыру билгеләре кыш ахырына таба һәм бал кортларын чыгарганнан соңгы 2 айда күренә. Н.а. кузгалуга кышлату урыннарындагы темп-ра тирбәлешләре, артык дымлылык, ояның көчсезлеге, сыйфатсыз азык (пестицидлар, баллы чык б-н агуланган азык), умарта кортлары организмының резистентлыгы кимү, башка авырулар сәбәп булырга мөмкин. Инвазиянең төп чыганаклары: авыру бал кортлары һәм аларның яшәү эшчәнлеге калдыклары (бал, бал икмәге); нозема споралары б-н зарарланган бал корты үләксәсе; авыру бал кортлары тизәге тигән кәрәз, умарта оясы, ашау-эчү улаклары, җылыту материаллары. Авыру таратучылар — карак бал кортлары, адашкан бал кортлары, сорыкортлар, балавыз көясе, шөпшәләр, кырмыскалар, талпаннар. Н.а. ш.у. авыру оя кәрәзләрен сәламәт ояга күчергәндә, персонал тарафыннан уртак инвентарь һәм эш киеме кулланылганда да йога. Бал кортларының паразит споралары йотуыннан башланган авыру барышының тулы циклы — 48–72 *сәг.* Төп билгеләре: оя эчендәге тынычсызлык, көчле гүләү, бал кортының корсагы күперү, канатлары дерелдәү, хәрәкәт координациясе югалу, ш.у. эче китү. Умарта кортлары кәрәздә тотынып тора алмый, начар үсәләр. Н.а. йокканда умарта кортларының үрчү мәйданы 4–5 тапкыр кими, корт анасы салган күкәйләрнең 10–20% ы үлә. Авыру йоктырган оялардан алынган бал сәламәт ояларныкыннан 12–50% ка азрак була. Н.а.нан арыну өчен кышлатуга иң көчле ояларны гына калдыру, көчсез ояларның 2–3 ен бер итеп, яхшылап җылыту мәҗбүри. Язга чыккач, иртә чистарыну очышына җибәрү, баллы чык б-н агуланган балны сыйфатлы бал б-н алыштыру, бал кортларын чистартылган һәм дезинфекцияләнгән кәрәз һәм ояларга урнаштыру кирәк. Н.а.ннан дәвалау өчен фумагиллин, сульфадимезин, сульфапиридазин, нозематол, апифит, ноздин кулланыла. ТРда бу авыруны өйрәнү, аны булдырмау һәм дәвалау чаралары комплексы Казан галимнәре С.В.Жданов, аның шәкертләре Н.Г.Сидоров, Г.И.Чебунин тарафыннан эшләнә.

*Әд.:* Ж д а н о в С.В. Нозема и морфологические изменения пчёл // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1960. Т. 20, кн. 6; ш у л у к. Комплекс профилактических мероприятий при нозематозе пчёл в Татарской АССР. К., 1969 (автордаш); П о л т е в В.И., Н е ш т а е в а Е.В. Болезни и вредители пчёл. М., 1977; Г р о б о в О.Ф., С м и р н о в А.М., П о п о в Е.Т. Болезни и вредители медоносных пчёл. М., 1987; Опасные болезни пчёл. М., 1992.

*Р.И.Михайлова.*

**НОИ́НСКИЙ** Михаил Эдуардович (15.11.1875, Түбән Новгород губ. Сергач ш. — 7.8.1932, Казан), геолог. Казан ун-тын тәмамлый (1900), шунда ук эшли, геол. кабинеты мөдире (1914–32), геол. каф. профессоры (1914 тән), бер үк вакытта физика-матем. ф-ты деканы (1922 дән). Хезмәтләре Урта Идел һәм Урал буе төбәкләренең стратиграфиясе, гидрогеологиясе, палеогеографиясенә һәм файдалы казылмаларына карый. Ритмостратиграфиягә һәм фациаль анализга нигез салучы. «Самара Дугасы» («Самарская Лука») монографиясе авторы, акад. Н.М.Страхов фикеренчә, бу хезмәт литологиянең мөстәкыйль фән буларак аерылып чыгуына ярдәм иткән чорның фациаль-литологик тикшеренүләре арасында иң зур казанышы булып тора. Беренчеләрдән булып, Урал-Идел буе төбәгендә нефтьле катламнар барлыгын нигезли. Доломитлар барлыкка килү шартларын торгызу өчен яңа палеоэкологик анализ куллана. Печище авылы янында — Казан ярусы, Самара Дугаенда карбон һәм Пермь системасы типларын җентекләп өйрәнә. Аның тикшеренүләре Татарстан һәм Башкортстан терр-яләренең геол. карталарын төзергә мөмкинлек бирә. Гидрогеолог буларак, Татарстан терр-ясендә тимер юл күперләрен, Казанның су б-н тәэмин ителешен һәм коммуникацияләрен проектлауда катнаша.



М.Э. Ноинский.

Х е з м.: Материалы по гидрогеологии Казанской губернии. К., 1917; Краткий очерк истории изучения недр Татарской республики. К., 1932.

*Әд.:* С т р а х о в Н.М. Развитие литологических идей в России и СССР. М., 1971; С о л о в ь ё в Ю.Я. Выдающийся палеогеограф // Советская геология. 1976. № 8; Казанский университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

**НОКРА́Т ҖИРЕ́** (рус тарихи чыганакларында «Вятская земля»), Нократ елгасының югары һәм өлешчә урта агымы бассейнындагы тарихи өлкә. Б.э.к. 1 нче меңьеллыкта Н.җ. терр-ясендә Ананьино культурасы кабиләләре яшәгән, 6–8 йөзләрдә фин кабиләләренең Пермь төркеме (удмурт һәм комиларның борынгы бабалары), аннары төрки телле кабиләләр — болгарлар һ.б. күчеп утыра. Н.җ. болгарлар б-н сәүдә итә, аларга кыйммәтле җәнлек тиреләре сата. 14 йөзнең 2 нче яртысында Нократ елгасының урта агымында Хлынов (1374 елда нигез салына, хәзер Киров шәһәре), Котельнич, Орлов (хәзер Халтурин шәһәре) кебек авыллар барлыкка килә. «Нократ җире турында хикәят» («Повесть о земле Вятской», 17 йөз) мәгълүматлары буенча, Н.җ.ндә славяннар 12 йөз ахырыннан бирле яшиләр. *Нократ татарлары* бу төбәккә 14 йөздә — 15 йөзнең 1 нче яртысында килеп урнаша, төп шәһәрләре — Карино (хәзер Киров өлкәсендәге авыл). Этнограф Д.М.Исхаков фикеренчә, Нократ татарлары җирләре элгәре Казан ханлыгы составына кергән. Н.җ. сайлап куелулы затлар — зем-

ство воеводалары, подвойскилар (гражданлык идарәчеләре) һәм старосталар тарафыннан идарә ителә. Адм. һәм икътисади үзәкләре — Хлынов, Орлов, Котельнич. 14–15 йөзләрдә Н.җ., формаль рәвештә рус кенәзләре хакимиятен таныган хәлдә, сәяси яктан мөстәкыйль була, 1383–1402 дә Суздаль һәм Түбән Новгород кенәзләре карамагында тора. 1402–03 тә Н.җ. Василий I кулына күчә, ул аны туганы Юрий Дмитриевичка (Юрий Галицкий) бирә. 1425–53 тәге феодаль сугышлар вакытында Н.җ. Галич кенәзләре ягында була. 1459 да Василий II тарафыннан буйсындырыла. Казан ханлыгы оешканнан соң, Мәскәү кенәзләре һәм Казан ханнары арасындагы көрәшкә җәлеп ителә. Казан ханлыгына карата мөстәкыйль сәясәт алып бара, 1471 дә Ибраһим хан б-н берлектә Сарай әл-Мәхрусага яу чаба, 1467–69 да Иван III нең Казанга каршы сугышларында катнашудан баш тарта, 1460–80 елларда Мәскәү карамагындагы Великий Устюг җирләренә талау яулары оештыра. 1485–86 да Иван III Мәскәүгә каршыларның фетнәсен бастыра, һәм 1489 ның августында Д.В.Щёкин һәм Г.В.Морозов җитәкчелегендәге гаскәр Н.җ.н буйсындыруга ирешә. Фетнә башында торучылар җәзага тартыла, Н.җ. аксөякләре Мәскәү янына күчереп утыртыла, земство үзидарәсе бетерелә. Нократ шәһәрләре б-н Мәскәү тарафыннан утыртылган наместниклар идарә итә башлый. Н.җ. Рус дәүләтенең Казан ханлыгы б-н көрәшендә әһәмиятле роль уйный, көрәш барышында нократ татарлары Мәскәү ягыннан торып катнаша. Бу шул төбәкнең югары катлавына — *ар ягы бәкләренә* (рус елъязмаларында «арские князья») 1620 елларга кадәр мөстәкыйль һәм салымнардан азат кылырга, шул төбәктәге мөселманнарның һәм беркадәр рус халкының да хезмәтеннән файдаланырга мөмкинлек бирә. 18 йөз ахырында, Вятка губернасы оештырылганнан соң, «Н.җ.» атамасы әйләнештән төшеп кала.

*Әд.:* Васильев Н., Бехтерев Н. История Вятского края. Вятка, 1870; Спицын А.А. Татары в истории Вятского края. Вятка, 1885; Вештомов А.И. История вятчан. К., 1907; Эммаусский А.В. Вятская земля в период образования русского государства. Киров, 1949; Вятская земля в прошлом и настоящем (к 500-летию вхождения в состав Российского государства). Киров, 1989; Макаров Л.Д. Некоторые проблемы славянской колонизации бассейна р.Вятка // Проблемы этногенеза финно-угорских народов Приуралья. Ижевск, 1992.

*Е.В.Липаков.*

**НОКРА́Т ТАТАРЛАРЫ́** (карин, Чепья татарлары), *Казан татарларының* этнографик төркеме. 1920 елларда 15 меңгә якын кеше исәпләнә. Нигездә, Удмурт Респ-касында (Юкаменск, Глазов, Балезино, Яр р-ннарында), Киров өлкәсендә яшиләр. Нократ (карин), Чепья (Югары Чепья) астөркемнәренә бүленәләр. Телләре — көньяк удмуртларга хас аерым үзенчәлекләре булган татар теле, мөстәкыйль Чепья сөйләшен барлыкка китерә. Дин тотучы Н.т. — сөнни мөселманнар. Атамалары аларның тарихи үзәге — Нократ (Карино) авылы исеменнән килеп чыккан, ул беренче мәртәбә 1542 дә *Вятка җире* шәһәрләре б-н беррәттән телгә алына. Язма чыганакларда Н.т.ның бабалары, 1489 дан башлап, биләмәләре Вятка җире составында Мәскәү дәүләтенә кушылган *Арча кенәзләре* буларак билгеләп үтелә. Этник нисбәттә Н.т. төркеме ике компоненттан: Арча кенәзләре варисларыннан һәм элеккеге *бисермәннәрдән* тора. Н.т.ның күпсанлы шәҗәрәләре буенча Арча кенәзләре нәселе тармагы *Бачманнан* башлана. Алтын Урда чорында алар күпмедер вакыт Сакмар һәм Агыйдел елгалары бассейннарында яшиләр; Казан ханлыгы формалашу чорында аның идарә итүче ыругларының берсе — Кыпчак ыругы булып китәләр, үзәге Арча шәһәрендә булган *Арча даругасын* үз кулларында тоталар. Чепья елгасы бассейнына Арча кенәзләре 1468 гә кадәр үзләренә буйсынган бисермәннәр, көньяк удмуртлар б-н бергә килеп утыралар, Арча даругасының төньяк районнарын контрольгә алалар. Аларның варисларының бисермәннәр (алар составына көньяк удмуртларны да кертеп) б-н этник кушылуы 17–18 йөзләрдә Казан татарлары составында ике астөркеме — Нократ һәм Югары Чепья (тарихи яктан беренчесеннән бүленеп чыга) — булган Н.т. этнографик төркеме барлыкка килүгә китерә. 20 йөз башында Н.т. яшәгән кайбер авылларда бисермәннәрнең татарлар б-н кушылуы процессы ахыргача төгәлләнми кала. Нократ астөркеме оешуда — Арча кенәзләре варислары, Югары Чепьяныкында бисермәннәр зур роль уйный. Шуңа да карамастан, төп мәдәни-көнкүреш һәм тел үзенчәлекләре Н.т.ның ике астөркеме өчен дә уртак.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Нократ сөйләше: Рухи мирас. Гаилә-көнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклор. К., 2006; Исхаков Д.М. Нократ татарлары // Казан утлары. 1990. № 3; шул ук. Новое в энографических исследованиях татарского народа. К., 1978; шул ук. Татаро-бесермянские этнические связи как модель взаимодействия булгарского и золотоордынско-тюркского этносов // Изучение преемственности этнокультурных явлений. М., 1980.

*Д.М.Исхаков.*

**НОКСА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 42 *км*, бассейнының мәйданы 215 *км*$^2$. Елга башы Питрәч р-ны Кощаково авылыннан 5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Казанның Совет р-ны Кече Дербышки авылында; төп агымы Биектау р-ны терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Абсолют биеклеге 130–150 *м* булган калкулыклы платодан тора, озынча ерым-сызалар (4–5 *км* озынлыкта) системасы б-н ергаланган. Н. бассейнының шактый өлеше сукаланган һәм анда а.х. культуралары үстерелә. Лёссыман делювиаль комсыл балчыкта соры җиңелчә көлсу туфраклар өстенлек итә. Катнаш һәм киң яфраклы урманнар, тугай, болын үсемлекләре үсә. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 6%. Елга үзәне асимметрияле: югары агымында сулъяк сөзәклеге, ә урта һәм түбән агымында уңъягы текәрәк. Үзән сөзәклекләрендә җир өслегенә якын ятучы доломит-известьле катламнарда хасил булган карст бүрәнкәләре бар. Н. бассейнында ерым эрозиясе көчле үсеш алган; ерым челтәренең уртача тыгызлыгы Константиновка авылы янында, эрозияле киселешнең тирәнлеге 75–85 *м* булганда, 0,9–1,1 *км/км*$^2$ га җитә. Елга юлы бормалы, тармакланмаган, киңлеге 2–8 *м*. Плёсларда иң зур тирәнлек 0,8–1,5 *м*, сайлыкларда 0,3–0,5 *м*; агым тизлеге ярашлы рәвештә 0,1–0,2 *м/с* һәм 0,3–0,4 *м/с* тәшкил итә. Н.ның 1,7 дән 7,4 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Язгы ташу апрельнең 1 нче ункөнлегендә башлана, еллык агымның 80% ка кадәре шушы вакытка туры килә. Плёслы күлләр челтәре хасил итеп, җәен елга урыны-урыны б-н кибә; агымның кимүе елга төбендәге көпшәк утырмаларның һәм бассейнындагы карст бушлыкларының шактый суны йотуы б-н бәйле. Елга җәйге чорда, нигездә, җир асты чыганакларыннан туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–3 *л/с·км*$^2$. Урта агымда суның уртача күпьеллык чыгымы 0,008 *м*$^3$*/с*, тамагында — 0,02 *м*$^3$*/с*. Гадәттә, ноябрьнең беренче яртысында, боз кату б-н кышкы саегу башлана.



Нокса елгасының түбән агымы.

Боз катуның уртача озынлыгы 140–150 көн. Кыш ахырында бозның калынлыгы 55 *см* га җитә. Елганың аерым участоклары, җир асты сулары чыгышлары һәм сәнәгать предприятиеләре агынтылары урынында, кыш буена диярлек боз б-н капланмый. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, җәен 700–1000 *мг/л*. Н. бассейнында суның гомуми күләме 0,54 млн. *м*$^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НОЛИ́НКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дала Зәе елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 175 кеше (руслар) яши. 19 йөз башында нигез салына. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Нолинский Завод, Солововский Завод исемнәре б-н дә билгеле. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 406 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартын-

нан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1859 да — 76, 1889 да — 130, 1897 дә — 125, 1910 да — 232, 1926 да — 239, 1938 дә — 279, 1949 да — 319, 1958 дә — 225, 1970 тә — 243, 1979 да — 165, 1989 да — 76, 2002 дә — 87 кеше.

**...НО́МИЯ** (грек. nómos — закон), кушма сүзләрнең бер өлеше; фән, карашлар яки кагыйдәләр системасы (мәс., астрономия) дигәнне аңлата.

**НОНЕ́Я**, н о н н е  ү л ә н е (Nonea), кыярчалар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 35 төре билгеле. Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — рус Н.сы (N. rossica) үсә. Сирәк кенә барлык районнарда, ешрак Кама һәм Идел елгасыннан көньяктарак очрый. Далаланган сөзәклекләрдә, кырларда, чүпле урыннарда, юл буйларында үсә. 15–30 *см* биеклектәге үсемлек, төкчәле, соры-яшел, озын, бизле төкләр б-н капланган. Сабагы туры, тармаклы. Чәчәкләре яфраклы гади бөтеркәгә җыйналган. Җимеше — каты төкчәле җыерчыклы чикләвекчек. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–августта өлгерә.

**НО́РДЕН** Александр Петрович (24.7.1904, Саратов ш. — 13.2.1993, Казан), математик, геометр, физика-матем. фән. д-ры (1937), проф. (1937), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1954, 1964). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), шунда ук эшли. 1941–45 елларда Новосибирск хәрби тимер юл транспорты инженерлары ин-тында матем. каф. мөдире. 1945–80 дә Казан ун-тының геом. каф. мөдире. Хезмәтләре дифференциаль геометриягә, математика тарихына карый. Н. проектив фәза күптөрлелекләрендә бәйләнешләр төзүнең универсаль алымын тәкъдим итә, бу алым проектив фәзада һәм фундаменталь төркемнәре булган башка фәзаларда күптөрлелекләрне тикшерүнең төп инструменты булып тора (Норденның нормальләштерү алымы). Катламлы фәзалар геометриясен тикшерүнең нәтиҗәле алымнарын үз эченә алган композицияләр теориясен эшли. Н.ның тикшеренүләре аффин бәйләнешле фәзалар теориясенә, проектив-дифференциаль геометриягә, конформ геометриягә, сызыкчалы геометриягә, челтәрләр теориясенә зур өлеш кертә. Н. — Казан геом. мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Аның биаксиаль, биаффин, бипланар фәзаларны, нәевклид фәзаларның сызыкчалы геометриясен тикшергәндә 2 нче тәртип алгебралар куллануы яңа фәнни юнәлеш — алгебралар б-н күптөрлелекләр теориясе туууга сәбәп була. Монографияләр һәм югары уку йортлары өчен геометрия дәреслекләре авторы (күп кенә чит телләргә тәрҗемә ителгәннәр). Н. редакциясендә һәм аның шәрехләвендә Н.И.Лобачевский хезмәтләренең тулы җыелмасының 2 нче һәм 3 нче томнары нәшер ителә. «Известия вузов. Математика» ж-лын оештыручы һәм аның баш мөхәррире (1957–79). Казан физика-матем. җәмгыяте рәисе (1950–93). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә. Н.И.Лобачевский исем. «Геометрия өлкәсендәге зур казанышлары өчен» медаленең беренче лауреаты (1992).

Х е з м.: Дифференциальная геометрия. М., 1948; Элементарное введение в геометрию Лобачевского. М., 1953; Теория поверхностей. М., 1956; Краткий курс дифференциальной геометрии. М., 1957; Элементы конформной геометрии. К., 1973 (автордаш); Пространства аффинной связности. М.–Л., 1976.

*Әд.:* Л а п т е в Б.Л. Александр Петрович Норден (к 70-летию со дня рождения) // Изв. вузов. Математика. 1974. Т. 5; Александр Петрович Норден. К., 2002; М а л а х а л ь ц е в М.А., Ш у р ы г и н В.В. А.П.Норден — выдающийся советский геометр // Уч. зап. Казан. ун-та. 2005. Т. 147, кн. 1.

*М.А.Малахальцев, В.В.Шурыгин.*


**НОРИ́ЛЬСК** шәһәре, *Красноярск краенда* урнашкан. Халкы — 178586 кеше (2012), 2972 татар (2010). Н.га татарларның килеп урнашуы 1930 елларда Норильск тау-металлургия комб-ты (хәзер «Норильск никеле» тау-металлургия компаниясе» АҖ) төзелә башлау б-н бәйле. 1998 дән шәһәрдә «Нуркамал» мәчете эшли.

**НО́РКИН** Иван Андреевич (24.9.1919, Вятка губ. Сметанино а. — 28.7.2002, Яшел Үзән ш.), Сов. Союзы Герое (9.2.1944), кече сержант. Колхозда, соңыннан мебель ясау комб-тында (Санчурск пос.) эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. Амур өлкәсендә Кызыл Байраклы 2 нче Ерак Көнчыгыш армиясендә хезмәт итә. 1943 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 12 нче танкка каршы артиллерия полкында туп остасы (40 нчы армия). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Украина (1943–44), Польша (1944), Германияне (1945) азат итүдә, Прага операциясендә (1945) катнаша. 1943 нең 21 ноябрендә Яңа Озерана (Украина ССР, Житомир өлкәсенең Коростышев р-ны) авылы читендә дошманның танк һәм пехота контрһөҗүмнәрен кире кайтарганда батырлык күрсәтә: һәлак булган туп төзәүчене алыштырып, үзе дошманның 8 танкын һәм пехота төялгән 3 автомашинасын сафтан чыгара, алдагы сугышта тагын 1 танкны юк итә, дошман взводын таркатып юкка чыгара. 1946 да демобилизацияләнә. Яшел Үзән шәһәрендә яши, А.М.Горький исем. (1946–51), Серго исем. з-дларда (1952–74) эшли. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Яшел Үзәндә бер урам Н. исеме б-н атала.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НОРЛА́Т** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 12 *км* төньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 259 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1830 елларга кадәр халкы удел һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә; лашман хезмәтен үти, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Н.та мәчет була. 20 йөз башында Н.та 2 мәчет, 1 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1608 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 746, 1880 дә — 522, 1897 дә — 1144, 1913 тә — 1457, 1920 дә — 1156, 1926 да — 1121, 1938 дә — 887, 1949 да — 654, 1958 дә — 518, 1970 тә — 463, 1979 да — 301, 1989 да — 211, 2002 дә — 313 кеше.



А.П.Норден.



И.А.Норкин.

**НОРЛА́Т** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 33 *км* көньяк-көнбатыштарак, Албаба тимер юл станциясе посёлогыннан 3 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 2693 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, бакчачылык; а.х. химиясе пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Балалар йорты. Мәчет (1991–94 тә төзелә). Казан ханлыгы чорында Мөхәммәдәмин хан биләмәсе була. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.та 2 мәчет, 3 җил тегермәне, 3 тимерчелек, 2 ярма яргыч, 12 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3573 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан Норлат р-нында. 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 342 ир-ат; 1859 да — 1889, 1897 дә — 3279, 1908 дә — 3407, 1920 дә — 3360, 1926 да — 2413, 1938 дә — 3595, 1949 да — 2115, 1958 дә — 2667, 1970 тә — 2863, 1979 да — 2828, 1989 да — 2571, 2002 дә — 2805 кеше.

**НОРЛА́Т РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1927 елның 14 февралендә Норлат-Ачасыр р-ны буларак оештырыла, 1927 нең 1 августында Н.р. итеп үзгәртелә. Үзәге — Норлат авылы. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя һәм Цивильск өязләренә керә, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. Районның адм.-терр. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1930 да Н.р.да 33 авыл советы, 48 торак пункт исәпләнә, аларда 38205 кеше (татарлар — 27071, руслар — 11134) яши. 1931 нең 20 октябрендә район составына таркатылган *Зөя районының* берничә авыл советы кертелә. 1930 еллар уртасында Воробьёвка авыл советындагы берничә авыл Чуаш АССР составына күчерелә. 1940 та Н.р.ның мәйданы — 719 *км²*, халык саны — 42,5 мең кеше, 34 авыл советы,

61 торак пункт була. 1950 еллар ахырында район составына Югары Ослан р-ның шәһәр тибындагы Карамалы Тау посёлогы һәм аның тирәсендәге авыл торак пунктлары керә. 1960 та Н.р.ның мәйданы 794,9 *км²* була, анда 1 посёлок һәм 13 авыл советы, 72 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Н.р. таркатыла, терр-ясе Яшел Үзән р-нына кушыла.

**НОРЛА́Т-АЧАСЫ́Р РАЙОНЫ́**, к. *Норлат районы*.

**НОРМА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 40 *км*, бассейнының мәйданы 561 *км²*. Елга башы Арча р-ны Каенсар авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, тамагы Питрәч р-ны Әлбәдән авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Н.ның 14 кушылдыгы бар, аеруча зурлары — Щира (13 *км*), Үшнә (26,9 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Язгы ташу март ахырында башлана һәм еллык агымның 80% ка кадәре шушы чорга туры килә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 161 *мм*, ташу агымы катламы 127 *мм*. Елга, гадәттә, ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,65 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*),



Норма елгасының түбән агымы.

кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Н. бассейнында суның гомуми күләме 4,6 млн. *м³* булган 6 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Н.ның югары агымының уңъяк ярында «Яңасала сөзәклеге» табигать истәлеге урнашкан.

**НОРМА́** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Оштырма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 20,9 *км*, бассейнының мәйданы 107,9 *км²*. Кукмара р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Нормабаш авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы шәһәр тибындагы Кукмара посёлогының көньяк-көнчыгыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 69 *м*. Су



Норма елгасы шәһәр тибындагы Кукмара посёлогы тирәсендә.

җыелу мәйданы яссы яки җиңелчә авыш түбәле аерым уваларга бүлгәләнгән калкулыклы тигезлектән (абс. биеклеге 175–220 *м*) гыйбарәт. Н. үзәне асимметрияле: сулъяк сөзәклекләр текәрәк; урыны б-н аларда нарат, чыршы, юкә, өрәңге, каен үскән катнаш урманнар сакланган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Үзәннең уңъяк сөзәклекләре а.х. культуралары үстерү өчен кулланыла. Су җыелу мәйданының өслегендә ерымнар (5 *км* га кадәр озынлыкта) күп, аларның үсешенә исә терр-янең тирән уемлы эрозияләр б-н бүлгәләнүе (90 *м* га кадәр һәм күбрәк тә), балчыксыл текә битләр булу һәм елга бассейнының шактый өлешендә урман үсемлекләренең булмавы булышлык итә. Елга юлы бормалы, тармакланган. Н.ның 0,9 дан 4,7 *км* га кадәр озынлыктагы 16 кушылдыгы бар, аларның күпчелеге — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Еллык агымның 80% ка кадәре язгы ташу чорына туры килә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 120 *мм*, ташу агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,085 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. М. бассейнында суның гомуми күләме 1,5 млн. *м³* булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла. Н. үзәне буенча Мәскәү–Казан–Екатеринбург тимер юлы участогы үтә. Н. — ТРның табигать истәлеге (1978). Елга үзәненең сулъяк сөзәклегендә «Кукмара тавы» ландшафтлы табигать истәлеге урнашкан.

*О.Н.Урбанова.*

**НОРМА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,1 *км*, бассейнының мәйданы 102,6 *км²*. Балтач р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Нормабаш авылында, тамагы Кариле авылының төньяк чигендә. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Н.ның 0,2 дән 6,4 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Еллык агымның 90% ка якыны язгы ташу чорына туры килә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу агымы катламы 102 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,045 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**НОРМА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Норма елгасы буенда. 2010 елда 1264 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1664 тән Пустошь Норма буларак мәгълүм; 1930 еллар уртасына кадәрге рәсми чыганакларда Олы Норма исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, балта эше, урман кисү, чабата үрү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1338,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 139 ир-ат; 1834 тә — 512, 1859 да — 729, 1884 тә — 770, 1897 дә — 733, 1908 дә — 826, 1920 дә — 836, 1926 да — 830, 1938 дә — 846, 1949 да — 772, 1958 дә — 577, 1970 тә — 547, 1979 да — 581, 1989 да — 536, 2002 дә — 1062 кеше.

**НОРМА́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 24 *км* көнбатыштарак, Омар елгасы бассейнында. 2010 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да мәчет, 2 тимерчелек, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 766 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 43 ир-ат; 1859 да — 254, 1897 дә — 554, 1908 дә — 607, 1920 дә — 637, 1926 да — 682, 1938 дә — 569, 1949 да — 385, 1958 дә — 401, 1970 тә — 378, 1979 да — 305, 1989 да — 224, 2002 дә — 178 кеше.

**НОРМАБА́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 182 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1664 тән мәгълүм. 1930 еллар уртасына кадәрге рус чыганакларында Вершина Нурмы исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1911 дә төзелә), вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 337,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 19 ир-ат; 1834 тә — 73, 1859 да — 111, 1884 тә — 193, 1897 дә — 242, 1908 дә — 274, 1920 дә — 306, 1926 да — 302, 1938 дә — 406, 1949 да — 408, 1958 дә — 333, 1970 тә — 266, 1979 да — 259, 1989 да — 202, 2002 дә — 204 кеше.

**НОРМАБА́Ш** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 14 *км* көнбатыштарак, Нурминкә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 97 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек- киез җитештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.та мәчет, йон-тукыма ману остаханәсе, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 823,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 61 ир-ат; 1859 да — 479, 1897 дә — 611, 1908 дә — 737, 1920 дә — 800, 1926 да — 658, 1938 дә — 594, 1949 да — 359, 1958 дә — 326, 1970 тә — 293, 1979 да — 177, 1989 да — 116, 2002 дә — 120 кеше.

**НО́СОВО** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бәтке елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1617 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Носовка исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 381 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир-ат; 1859 да — 281, 1897 дә — 380, 1908 дә — 403, 1920 дә — 386, 1926 да — 325, 1938 дә — 268, 1949 да — 205, 1958 дә — 120, 1970 тә — 131, 1989 да — 17, 2002 дә — 4 кеше.

**НОСРАТУ́ЛЛИН** Вил Касыйм улы (18.8.1946, БАССРның Нуриман р-ны Кызыл Тау а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (2001). 1975 елда Башкорт а.х. ин-тын тәмамлый. 1963–66 да «Челябстрой» трестында ташчы (Чиләбе ш.). 1980–85 һәм 1990–92 дә Башкорт а.х. ин-тында, икътисади кибернетика каф. мөдире (1990 нан). 1985–90 нан СССР ФА Урал бүлегенең Башкорт ф-лында икътисади тикшеренүләр бүлеге фәнни хезмәткәре (Уфа). 1992 дән РФА Уфа Гыйльми үзәгенең Икътисад һәм социология ин-тында. 1997–99 да Башкорт дәүләт хезмәте һәм идарәсе академиясенең фәнни-тикшеренү бүлеге башлыгы. 2000 нән Башкорт ун-тында икътисад теориясе каф. мөдире. Хезмәтләре аграр икътисад һәм сәясәткә, социаль-икътисади процессларны модельләштерүгә карый. Н. икътисад фәнендә яңа юнәлешкә — тигезләнешсез икътисад теориясенә нигез сала, икътисадны мобиль һәм глобаль анализлау өчен универсаль инструмент — тигезләнешсез модель тәкъдим итә.

Х е з м.: Рента и регулирование экономических отношений. Уфа, 1996; Аграрная политика: Макроэкономические аспекты. Уфа, 1998; Моделирование социальных процессов. Уфа, 1999; Неравновесная экономическая теория: В 2 кн. Уфа, 1999.

*Әд.:* Учёные-экономисты Башкортостана: Научно-информ. справ. Уфа, 2000.

**НОСТО́К** (Nostok), ностокчалар семьялыгыннан зәңгәрсу-яшел суүсемнәр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, барлык климатик зоналарда диярлек таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — сливасыман Н. (N. pruniforme) бар. Мезотроф күлләрнең планктон һәм бентосында, буаларда очрый. Н.ка тыгыз элпә б-н капланган зәңгәрсу-яшел яки зәйтүнсыман төстәге колонияләр (шар яки эллипссыман, кайвакыт җепселсыман) хас. Типик җенси процесс юк. Спорalardan һәм җепселләренең кисәкләреннән үрчи. Гөмбәләр б-н симбиозга кереп, лишайниклар барлыкка китерә. Хемосинтезга (атм. азотын туплауга) яраклашкан. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**НОСЫ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 42 *км* төньяктарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 321 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1672,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1905 тә — 1027, 1920 дә — 1162, 1926 да — 1019, 1938 дә — 883, 1949 да — 542, 1958 дә — 352, 1970 тә — 476, 1979 да — 412, 1989 да — 302, 2002 дә — 339 кеше.

**НОТАРИА́Т** (лат. notarius сүзеннән — күчереп язучы, секретарь), килешүләрне таныклау, варислык хокукларын рәсмиләштерү, гражданлык хокукларын юридик яктан беркетү һәм аларны бозуга юл куймауга юнәлтелгән гамәлләрне башкару бурычлары йөкләнгән органнар системасы. Казан төбәге терр-ясендә беркетү-рәсмиләштерү актлары 16 йөзнең 2 нче яртысыннан — мәйдан подъячийлары, 1781 елдан *Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасы* һәм өяз мәхкәмәләре каршындагы махсус «беркетү эшләре» бүлекчәләре тарафыннан гамәлгә ашырыла. Казан губернасында Н. учреждениеләре 1866 ның 14 апрелендә чыгарылган Нотариат бүлеге турындагы нигезләмә җирлегендә 1870 тә барлыкка килә. Н. б-н җитәкчелек итү *Казан округ мәхкәмәсе* каршында вазифалар башкарган өлкән нотариуска һәм Казан мәхкәмә палатасының өлкән рәисе тарафыннан билгеләнгән башка нотариусларга йөкләнә. Моннан тыш җирле сәүдәгәрләр биржа нотариусларын сайлыйлар. Өлкән нотариус «беркетү актлары»н (сату-алу кәгазьләре һәм күчемсез мөлкәткә милек хокукы күчү турындагы шартнамәләр) раслый һәм Округ мәхкәмәсе каршындагы Н. архивы б-н җитәкчелек итә. Башка нотариусларның вазифаларына төрле юридик актлар, шартнамәләр, васыятьнамәләр төзү, аларны махсус актлар китапларына теркәү; актлар китапларыннан күчермәләр һәм өземтәләр бирү; актларның һәм шартнамәләрнең кулланылуын, күчермәләрнең һәм имзаларның чынлыгын, вексель протестларын таныклау һ.б. керә. ХКСның 1917 нең 22 ноябрендә чыгарылган 1 нче «Мәхкәмә турында» Декреты б-н Н. бетерелә; 1922 гә кадәр, эчтәлекләренә карап, нотариаль гамәлләр урыннарда төрле дәүләт органнары тарафыннан башкарыла. РСФСР дәүләт Н.ы турындагы 1922 ел 4 октябрь Нигезләмәсе, СССР ҮБК һәм ХКСның 1926 ел 14 май карары (икесе дә СССРның 1973 ел 19 июль Законы б-н раслана) б-н Татарстан шәһәрләрендә һ.б. торак пунктларда ТАССР Юстиция халык комис-тына (1946 дан — министрлыгына) буйсынулы дәүләт нотариаль конторалары оештырыла. Н. конторалар булмаган торак пунктларда нотариаль гамәлләрнең бер өлешен район, шәһәр, посёлок һәм авыл советлары башкарма ком-тлары башкара. 1993 нең февраленнән Н. оешу һәм аның эшчәнлеге РФ Н. турындагы законнар нигезләре б-н көйләнә. Законда каралганча, 2 параллель структура — дәүләт Н.ы һәм хосусый Н. барлыкка килә. Нотариаль гамәлләр нотариуслар тарафыннан башкарыла. Дәүләт нотариаль конторалары һәм хосусый нотариуслар карамагындагы конторалар реестрын РФ Юстиция министрлыгы алып бара. Дәүләт нотариуслары ТР Юстиция министрлыгына буйсыналар. Аерым эшчәнлек алып баручы нотариуслар б-н сайланып куелган профессиональ, коммерцияле булмаган оешма — ТР Нотариаль палатасы җитәкчелек

итә. Нотариуслар килешүләрнең (шартнамәләр, васыятьләр, ышаныч язулары) дөреслеген раслыйлар; ир б-н хатынның уртак милектәге өлешенә милек хокукы турында таныклык бирәләр; милекне тартып алуга тыю кертәләр; документларның күчермәләренең һәм аларның өземтәләренең дөреслеген, имзаның чынлыгын, документларның бер телдән икенче телгә тәрҗемәсенең дөреслеген раслыйлар; әгәр мәхкәмәдә эш кузгатылмаган булса, дәлилләр б-н тәэмин итүне гамәлгә ашыралар; башкаручы язмаларны, вексельләр дәгъваларын үтиләр; депозитка акчалата суммалар һәм кыйммәтле кәгазьләр, саклауга документлар алалар һ.б. гамәлләрне башкаралар. Болардан тыш дәүләт нотариуслары мираска хокук турында таныклык бирәләр, мирас булып калган милекне саклау буенча чаралар күрәләр. Нотариус булмаган торак пунктларда кайбер нотариаль гамәлләр җирле башкарма хакимият органнарындагы бу гамәлләрне кылырга вәкаләт бирелгән вазифаи затлар тарафыннан башкарыла.

*Е.Б.Долгов.*

**НОХРА́Т** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Салман елгасының (Актай елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 14,1 *км*, бассейнының мәйданы 55,2 *км*². Идел аръягы түбәнлеге буйлап Әлки р-нында ага. Елга башы Иске Нохрат авылының көньяк-көнчыгыш чигендә, тамагы Хлебодаровка авылыннан 1,5 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Н.ның 2 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Җәен елга аерым урыннарда кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада суының күләме 0,6 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НӨГЕ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 7,7 *км*, бассейнының мәйданы 15,5 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгы буйлап Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Танай посёлогыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Түбән Яке авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 290 *м*, тамагыныкы — 158 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

**НӨНӘГӘ́Р** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 910 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1664 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Чутай исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, аучылык, тимерчелек, мич чыгару, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет, 2 мәдрәсә, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2560,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Түбән Чутай волосте үзәге була, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 1160, 1884 тә — 1329, 1905 тә — 1616, 1920 дә — 1916, 1926 да — 1800, 1938 дә — 1511, 1949 да — 1051, 1958 дә — 921, 1970 тә — 1070, 1979 да — 949, 1989 да — 926, 2002 дә — 920 кеше.

**НУГА́ЕВ** Мәһди Галимҗан улы (26.4.1921, хәзер Казакъстанның Уральск ш.), философ, филос. фән. д-ры (1978), проф. (1979), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Мәскәү Халыкара мөнәсәбәтләр ин-тының хокук ф-тын тәмамлаганнан соң (1952), КПССның Татарстан өлкә ком-ты лекторы, лекторлар төркеме мөдире булып эшли. 1961–2006 елларда Казан пед. ин-тында: 1961–76 да филос. һәм фәнни коммунизм кафедрасында, 1976–91 дә социол. лаб-ясе мөдире, 1991 дән — политология һәм социол. кафедрасында. Бер үк вакытта, 1994–2004 тә, ТР ФАнең социаль-икътисади һәм хокук фәннәре ин-тында социол. бүлеге баш фәнни хезмәткәре. 2004 тән ТР ФАнең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәгендә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Трудовая активность рабочего класса развитого социалистического общества. К., 1975; Базовая модель качества социального потенциала региона. К., 2009; Из жизни социолога. Воспоминания и размышления. К., 2009.

**НУГА́ЕВ** Нәҗип Ногман улы (1910, хәзер Ульянов өлкәсенең Иске Кулатка а. — 6.5.1946, Үзбәкстан ССР, Кашкадәрья өлкәсе Шәһрисабз ш.), Сов. Союзы Герое (26.10.1943), гв. кече сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның октябреннән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1669 нчы танкка каршы артиллерия полкында туп төзәүче (7 нче гв. армиясе). Дала фронты гаскәрләре составында 1943 нең 5 октябрендә Бородаевка авылы (Днепропетровск өлкәсе Верхнеднепропетровск р-ны) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: дошманның контрһөҗүмен кире кайтарганда, расчёты б-н бергә 4 танкны юк итә. Яралана, ләкин сугыш кырын ташламый. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Шәһрисабз шәһәрендә Геройга бюст куелган, бер урамга аның исеме бирелгән.



Н.Н. Нугаев.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НУГА́ЕВ** Рәис Янфур улы (15.5.1931, Уфа ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1989), БР ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. нефтьчесе (1980). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), «Башнефть» трестында эшли, нефть промыселы мөдире (1964 тән), трестның үзәк фәнни тикшеренү лаб-ясе башлыгы (1966 дан). 1968 елдан СССР Нефть сәнәгате министрлыгының Куркынычсызлык техникасы һәм сәнәгать санитариясе буенча көнчыгыш нефть-газ фәнни-тикшеренү ин-ты (Уфа) директоры, проф. (1992). 1994 тән БР ФАнең Экология фәнни-техник ассоциациясе директоры. Хезмәтләре углеводородлар чыгару технологиясенә һәм техникасына, экологик һәм сәнәгый куркынычсызлыкка карый. Н. бер скважинаның берничә катламны бер үк вакытта аерым эшкәртүе технологиясен фәнни яктан нигезли һәм эшли, нефть чыгаруда «кеше–машина–мохит» системаларының хәвефсез эшләвен фәнни-методик яктан нигезли. Нефть сәнәгатендә хезмәтне саклау принципларын эшли. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Одновременная раздельная эксплуатация скважин на нефтепромыслах Башкирии. Уфа, 1970; Безопасное ведение работ при раздельной эксплуатации пластов одной скважиной. М., 1979; Безопасная эксплуатация нефтепромысловых объектов. М., 1990.

**НУГА́ЕВ** Рәшит Галимҗан улы (11.7.1927, хәзер Казакъстанның Уральск ш. — 9.7.2006, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1977), ТР ФА мөхбир әгъзасы, ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984), РСФСРның атказ. мәдәният эшлеклесе (1988). Саратов юридик ин-тын тәмамлый (1952). 1952–59 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. 1959–77 дә Казан ун-тында эшли. 1977 дән Казан технол. ун-тының икътисад теориясе каф. мөдире, проф. (1979). Хезмәтләре халык хуҗалыгында эшче көчләрне формалаштыру һәм эшләтү, хезмәтне оештыру һәм хезмәт көчләре ресурсларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә карый. Республика «Белем» җәмгыяте идарәсе рәисе (1985–95); ТР Президенты каршындагы Дәүләт советы әгъзасы (1991–93).

Х е з м.: Об основных направлениях экономического и социального реформирования в Республике Татарстан. К., 1996; Программа социаль-

но-экономического и духовного возрождения Республики Татарстан. К., 1996; Слагаемые экономического роста // Науч. Татарстан. 1997. № 3/4.

**НУГА́ЕВ** Ринат Мәһди улы (30.5.1953, Казан), философ, филос. фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2003). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли: психол. каф. хезмәткәре, бер үк вакытта, 1976–94 елларда, филос. кафедрасында (бүлеп: 1979–82 дә Казан химия-технол. ин-тының шул исем. кафедрасында). 1994–95 тә Казан мед. ин-тының филос. каф. мөдире. 1995–2000 дә ТР ФА Социаль-икътисади һәм хокук фәннәре ин-тының социол. һәм филос. бүлеге мөдире, 2001–03 тә — филос. бүлеге мөдире, 2004 тән Россия кооперация ун-тының Казан кооперация ин-тында. Хезмәтләре танып белү философиясе, социол. фәннәренә карый.

Х е з м.: Реконструкция процесса смены фундаментальных научных теорий. К., 1989; Эйнштейновская революция 1898–1915: интертеоретический подход. К., 2010; Коперниканская революция: синтез физики Земли и математики неба. К., 2012.

**НУГА́Й БӘК** (? — 1299/1300), Алтын Урданың көнбатыш олысы әмире (идарәчесе). Җүчи хан оныгы улы. Бәркә хан сәясәте тарафдары буларак, ул идарә иткән чорда сарай аксөякләре һәм гаскәр башлыклары даирәсенә керә. Кавказ артына яу б-н барганда Н.б. уңышсыз хәрәкәт итә. 1262 елның 14 ноябрендә аның гаскәрләре Һулагу хан тарафыннан тар-мар ителә, Н.б. үзе авыр яралана. 1264–65 еллар тирәсендә Алтын Урданың көнбатышында Днепр һәм Днестр елгалары арасында аңа олыс бирелә. Бәркә хан әмере буенча Н.б. шул җирләрдән Византиягә яулар б-н бара, Константинопольне камый (1265), Балкан ярымутравын бөлгенлеккә төшерә (1270). Бу яулар Византия б-н союз төзеп тәгәлләнә. Н.б. император Михаил Палеологның никахсыз туган кызы Ефросиниягә өйләнә. 1271–78 дә ул болгар кенәзлекләренең (Тырново, Видин һ.б.) һәм Сербиянең Урдага буйсынуларын танытуга ирешә. Бер үк вакытта Н.б. гаскәрләре рус отрядлары б-н бергә Литвага (1274–75) һәм Польшага (1280) бәреп керәләр. 1285–86 да Н.б. *Теләбуга хан* б-н бергә Венгриягә һәм Польшага яулар оештыра. Соңрак Теләбугага каршы чыга, аны тәхеттән төшерә һәм хакимияткә *Тукта ханны* китерә (1291). Алтын Урдада үз абруйларын ныгыту максатында Н.б. һәм Тукта хан Руська яу б-н баралар (1293). 1290 елларда Н.б. чынлыкта Алтын Урданың хакименә әверелә, аның биләмәләре Кырымны кушу хисабына киңәя. Болар барысы да Алтын Урда аксөякләренең бер өлешендә һәм Тукта ханда ризасызлык тудыра. Алар Н.б.кә каршы күтәреләләр, ләкин җиңеләләр (1297). Н.б. олысы эчендә дә аксөякләр каршы чыга башлыйлар. Кырымда улы Актаҗу һәлак булганнан соң, Н.б. Кырым шәһәрләрен бөлдерә. Аның сәясәте популярлыгын югалта, әмирләр Тукта хан ягына чыгалар. 1299–1300 дә Н.б. җиңелә, әсирлеккә эләгә һәм үтерелә. Соңрак Н.б. биләмәсендә яшәгән халык аның исеме б-н — *нугайлар* дип атала башлый.

*Әд.:* В е с е л о в с к и й Н.И. Хан из темников Золотой Орды. Ногай и его время // Зап. РАН. Сер. 8. 1922. Т. 13, № 6; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.


*И.Л.Измайлов.*

**НУГА́Й ДАРУГАСЫ́**, 16 йөз — 18 йөз башында Казан ханлыгында һәм Казан өязендә адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Төгәл билгеләнгән чикләре булмый. Аңа Болын ягының Эчке Казан, Мишә, Чулман, Бутырка, Чырпы, Бирлә, Ячи, Бимә, Дәүләшәр, Салман, Кирмән, Бизнә, Әшнәк, Арыш һ.б. елга буйлары, Тау ягының Имәлле, Ольховка, Идел, Зөя, Килнә, Тархан, Чирмешән һ.б. елга буйларындагы җирләр керә. Үзәге — урта гасырлар Чаллы каласы. Үзләренә буйсынучы авыллар б-н бергә Казан өязенең эчке өязләрен тәшкил иткән Лаеш һәм Тәтеш калалары ш.у. Н.д.сына караган. Н.д. терр-ясе хосусый биләмәләргә, чиркәү-монастырь биләмәләренә, патша сарае биләмәләренә, ясаклыларга бирелгән җирләргә бүленә. Ш.у.к. *Даруга.*

Чыг.: Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов. К., 1978.

*Д.Г.Мостафина.*

**НУГА́Й УРДАСЫ́** (Мангыт йорты), Алтын Урда таркалганда, 14 йөз ахыры — 15 йөз башында барлыкка килгән күчмә төркиләр (*нугайлар*) дәүләте. 14 йөз ахырында *Идегәй* Җаек б-н Җембе (Эмба) елгалары арасындагы җирләрдә ярыммөстәкыйль Мангыт йорты олысына нигез сала. 1430–50 елларда Мангыт йорты *Әбелхәер хан* төзегән күчмә дәүләт составында була. Бу дәүләт таркалганнан соң, мангытлар мөстәкыйль дәүләт булып оешалар. 15 йөзнең 2 нче яртысында мангытларның бәкләренә һәм морзаларына буйсынулы кабиләләрнең күпчелеге уртак исем б-н «нугай» дип атала башлый. Мангыт йорты «Н.У.» яки «Нугай Олысы» дигән исем ала. 16 йөздә Н.У. көнчыгышта Иртеш елгасыннан алып, көнбатышта Иделгә кадәр һәм төньякта Чулман буйларыннан башлап, көньякта Сырдәрьяга кадәр җәелгән була. Үзәге — Сарайчык шәһәре. Н.У. 120 тирәсе ыруг-кабиләне (илне) берләштергән, шулардан эрерәкләре: бодрак, каңгылы, кыпчак, катай, мангыт, уйшун, мин (меңнәр), найман. Идарәче бәкләр, гадәттә, Идегәй нәселеннән була. Н.У. ике өлештән торган: Җаектан көнбатыш тарафтагы Уң канат б-н бәк билгеләгән *нурадын*, Җаектан көнчыгыш тарафтагы Сул канат б-н *кековат* идарә иткән; 16 йөз ахырында, Н.У.ның төньяк-көнчыгыш өлкәләре б-н идарә итү өчен, тайбуга вазифасы булдырыла. Уң һәм Сул канат биләмәләре аерым олыслардан тора, алар б-н морзалар идарә итә. Дәүләт дине — ислам. Халкының төп шөгыле — күчмә терлекчелек, кышлау тирәләрендәге җирләрдә, бик примитив рәвештә булса да, иген иккәннәр. Казан, Әстерхан, Мәскәү һ.б. төбәкләр б-н сәүдә иткәннәр. Шәех Мамай (1548–49) һәм Йосыф (1549–54) бәкләр идарә иткәндә, Н.У. Көнчыгыш Европа һәм Себер төбәгенең халыкара мөнәсәбәтләрендә актив роль уйный, еш кына Әстерхан, Казан, Себер һәм Кырым ханлыкларының эчке эшләренә дә тыкшына. Казан тәхетенә *Мамык хан* (1496), *Сафагәрәй хан*ның (1546) нугайлар гаскәре ярдәмендә утыртылуы мәгълүм. Казан ханлыгы һәм Н.У.ның идарәчеләре үзара мөнәсәбәтләрне никахлар аркылы да ныгытканнар: Казан ханнарыннан Ибраһим — Н.У. бәге Тимернең кызы Нурсолтанга, Мөхәммәдәмин — Муса бәк кызы Фатыймага, Җангали һәм аның вафатыннан соң Сафагәрәй — Йосыф бәк кызы Сөембикәгә өйләнәләр. Мәскәү кенәзлеге Казан ханлыгын басып алганнан соң, Н.У.нда Мәскәү яклы һәм аңа каршы булган аксөяк-



ләр арасында көрәш башланып, дәүләт көчсезләнә һәм таркалуга йөз тота. Соңрак ул *Олы Нугай Урдасына, Кече Нугай Урдасына*, урдачыкларга (Шәех Мамай нәселе урдасы һ.б.) бүлгәләнә.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2; Т и з е н г а у з е н В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. М.–Л., 1941. Т. 2; С а ф а р г а л и е в М.Г. Ногайская Орда во 2-й пол. XVI в. // Сб. науч. работ Мордов. пед. ин-та. Саранск, 1949; ш у л у к. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

*В.В.Трепавлов.*

**НУГАЙБӘ́К** Гыймад (Гыймадетдин) Шәрифҗан улы (13.2.1881, хәзер Ульянов өлкәсенең Николаев р-ны Олы Чирекле а. — 8.1.1943, Казан), тел галиме, журналист. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (Казан, 1897), шунда ук укыта. Казанда чыга торган «Кояш» (1912 дән) һәм «Кызыл байрак» (1917 дән) г-таларында эшли, аларда ул татар теле орфографиясенә һәм морфологиясенә караган мәкаләләр бастыра. 1918–20 елларда Эчке Россия мөселман комис-ты каршындагы фәнни коллегиянең орфография комиссиясе хезмәткәре. Саратов губернасының Кузнецк өяз мөселман комис-ты халык мәгарифе бүлеге б-н җитәкчелек итә. 1924 тән Татар дәүләт нәшриятында. Хезмәтләре татар алфавитын һәм орфографиясен камилләштерүгә, лексикографиягә карый. Татар теле морфологиясе буенча «Төрлек» (1911) китабы авторы. «Русча-татарча сүзлек» (1938) һәм «Иҗтимагый-политик терминнар сүзлеге»н (1938) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Башлангыч. К., 1911.

*Әд.:* Я к у п о в а Г.К. К 100-летию со дня рождения Гимада Нугайбека // Советская тюркология. 1981. № 4.

*Ф.Ш.Нуриева.*

**НУГАЙБӘ́КОВ** Ардинат Гали улы (17.6.1947, Азнакай р-ны Тымытык а.), нефтьче, техник фән. д-ры (2002), ТРның атказ. нефтьчесе (1992). Казан ун-тын тәмамлый (1970), «Татнефть» АҖдә (бүленеп, 1978–81 дә КПССның Әлмәт шәһәр ком-тында сәнәгать-транспорт бүлеге мөдире): «Сөләйнефть» (1970–78), «Әлмәтнефть» (1981–84) НГДУларында, «Елховнефть» НГДУы башлыгы (1984 тән). Хезмәтләре нефть чыгаруга, углеводородлар эшкәртүгә һәм экологиягә карый. Н. нефть чыгаруның нәтиҗәлелеген күтәрү алымнарын эшли, карбонат коллекторларыннан нефть суыртуның геотехнологик үзенчәлекләрен ачыклый. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2002). Әлмәт шәһәрендә уникаль мемориаль һәм мәдәни-сәламәтләндерү архит-ра корылмалары төзегәнә өчен ТРның Дәүләт бүләгенә (2004) лаек була. Дуслык ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кинетика неизотермического выщелачивания карбонатных коллекторов нефти раствором HCl // Башк. хим. журн. 1996. Т. 3, вып. 7 (автордаш); Совершенствование систем разработки продуктивных пластов Ново-Елховского месторождения. Уфа, 2001 (автордаш).

**НУГАЙБӘ́КОВЛАР**, татар морзалары нәселе. Н. нәселе вәкилләре Оренбург губернасы Бөгелмә өязенең Юрма волосте Урсай һәм Чалпы авылларында (хәзер ТРның Азнакай р-нында) яшәгәннәр. Дворяннар катлавына кантон чиновниклары буларак 19 йөзнең 1 нче яртысында күчереләләр (Оренбург губернасы дворяннар шәҗәрәсе китабының 2 нче кисәгенә кертелгәннәр). Морза Н.ның берсе Шаһингәрәй Кормәкәй улы (1799 ел тирәсе — ?) 12 нче башкорт кантоны башлыгы була (1820 нең 23 сентябреннән). Н. нәселеннән А.Г.*Нугайбәков* чыккан.

*Әд.:* Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

*И.Р.Габдуллин.*

**НУГАЙЛА́Р** (үзатамалары — ногай), РФдәге халык. 1959 елда 39 мең кеше, 1989 да 75 мең кеше; 2010 да РФдә — 103,6 мең, ш.и. Дагстанда — 40,4 мең, Ставрополь краенда — 22 мең, Карачай-Чиркәс Респ-касында 15,6 мең кеше, ш.у. Чечен Респ-касында яшиләр. Субэтник төркемнәре: каранугайлар (Дагстан), ачику-лак һәм кум Н.ы (Ставрополь крае), Кубань (Карачай-Чиркәс) һәм Әстерхан Н.ы (Әстерхан өлкәсе). Шулай ук Төркиядә, Румыниядә һәм кайбер башка илләрдә яшиләр. Телләре нугай теле, кыпчак төркеменә карый, 2 диалекты: каранугай һәм Кубань диалектлары бар. Әдәби тел каранугай диалекты һәм нугай сөйләше нигезендә формалашкан. Язулары 1928 гә кадәр — гарәп, 1928 дән — латин, 1938 дән рус графикасы нигезендә. Дин тотучы Н. — сөнни мөселманнар. «Н.» этнонимы барлыкка килүне Алтын Урда әмире Нугай (13 йөз) исеме б-н бәйлиләр. Нугай халык риваятьләренә караганда, Н.ның борынгы бабалары кыпчаклар, ш.у. Үзәк Азиядән килгән мангытлар һәм найманнар була, алар 14 йөз ахырында Мангыт йорты дәүләте (соңгырак атамасы *Нугай Урдасы*) төзиләр. *Идегәй* әмир (14 йөз ахыры — 15 йөз башы) һәм аның варислары заманында этноним киң тарала. 1520 елларда мангыт морзалары, хакимияттән чит кабилә аксөякләрен кысрыклап, бөтен илләр (күчмә халыкларның туктау урыннары) б-н идарәне үз кулларына алалар. «Мангыт» термины «нугай» сүзенә синоним буларак кулланыла башлый. Дәүләти бердәмлек, гомуми идеология (ислам дине) Н.ның этник үзаңы формалашуга булышлык итә. Казан ханлыгы терр-ясенең Нугай Урдасы б-н чиктәш көньяк өлеше (Нугай даругасы исемен ала) Н. йогынтысында була. Нугай бәкләре Казан, Әстерхан һ.б. төрки-татар дәүләти оешмаларының эчке сәясәтендә актив катнашалар: бәреп төшерелгән ханнар ягында сугышалар (*Сафагәрәй* һ.б.), татар ханнарына кызларын бирәләр (*Сөембикә*, *Нурсолтан* һ.б.). Нугай Урдасы таркалганнан соң, Н.ның аерым төркемнәре Казакъстан, Урта һәм Түбән Идел буе, Төньяк Кавказ һәм Кара диңгез буе терр-яләренә күчеп утыра. Н.ның бер өлеше казакълар, каракалпаклар, башкортлар, Кырым һәм Идел буе–Урал яны татарлары составына кушылып китә, икенче өлеше үз этнонимын саклап кала һәм хәзерге нугай халкының нигезен төзи. Кайбер төрки халыклар (казакълар, үзбәкләр, каракалпаклар һ.б.) Идел–Урал буе татарларын ш.у. Н. дип йөртәләр.

Н.ның Төньяк Кавказ далаларында, ш.и. Терек һәм Сулак елгалары үзәннәрендә күренүе турында беренче мәгълүматлар 15 йөз ахырына карый. 16 йөзнең 2 нче яртысында, Нугай Урдасы таркалганнан һәм ике олыс (Олы һәм Кече Урдалар) барлыкка килгәннән соң, Төньяк Кавказның көнчыгыш р-ннары *Кече Нугай Урдасында*, ә Сулак һәм Терек түбәнлекләре *Олы Нугай Урдасында* яшәүчеләр тарафыннан үзләштерелә. 17 йөз ахырында Н.ның байтак өлеше Терек һәм Сулак түбәнлекләреннән Моздок даласына күчеп утыра, алар каранугайлар дип йөртелгән төньяк-көнчыгыш Н. төркемен барлыкка китерә. Н. Россия составына кертелгәч, аларның дәүләтчелеге юкка чыгарыла. Алга таба Н. даласының адм.-терр. бүленеше берничә мәртәбә үзгәрешләр кичерә.

Н.ның традицион шөгыльләре — күчмә һәм күчмә көтүлекле терлекчелек (сарык, кәҗә, мөгезле эре терлек), ат һәм дөя үрчетү. Күпмедер күләмдә алар игенчелек (тары, солы, бодай), яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерү б-н шөгыльләнәләр, йорт кошлары (тавык, каз, үрдәк) үрчетәләр. Башка шөгыльләр арасында аучылык һәм балыкчылыкка өстенлек бирелә. Һөнәрләрдән постау, күн, сарык тиресе, агач әзерләү, киез җитештерү үсеш ала, аңардан чикмәннәр (буркалар), итекләр, баш киемнәре, арбабаш-келәмнәр эшләнә. Нугай даласы аша Көнчыгыш Кавказдагы иң әһәмиятле сәүдә юллары, ш.и. Бөек ефәк юлы үтә, бу Н.да сәүдә үсешен тәэмин итә. Н., нигездә, күчмә авылларда яшиләр. Традицион яшәү урыннары — күчмә һәм утрак тормышка туры килә торган тирмә һәм йорт; борынгырак торак урыннары — юрталар, алар — күчмә халыклар өчен типик түгәрәк формадагы тирмәләр. Утрак Н. ярымземлянкаларда һәм саман кирпечтән салынып, сөзәк ике кыеклы түбә ябылган йортларда яшиләр. Йортта аш бүлмәсе — өйалды һәм йокы бүлмәсе бар; уллар өйләнгән саен яңа бүлмәләр өстәп корыла. Елның салкын вакытында ризык әзерләү һәм тирмәне җылыту өчен ачык учак кулланыла, өчаяк та шунда ук тора. Стационар торакларда дивар каминнары кулланылышта була. Традицион ирләр киеме туника рәвешендәге өлгеле эчке күлмәктән, киң балаклы чалбар, җиңсез куртка, кафтан, бишмәт һәм якасыз җилән (байларда), чикмән, сәхтиян, хром аяк киеме, папаха, киез, тукыма яки мех эшләпә, бил каешыннан гыйбарәт. Кышын ярлылар — сарык тиресеннән тегелгән туннардан, байлар бүре, төлке, тиен, каракүл туннардан йөри. Ирләр киемен коралларһ һәм сугыш кирәк-яраклары тулыландыра: җәя һәм уклар, балта, сөңге, көбә кием, шишәк, калкан, садак, хәнҗәр, кылыч, 17 йөз уртасыннан — утлы корал (мылтык һәм төрле пистолетлар). Хатын-кызлар киеме өлгесе буенча ирләрнекенә якын: эчке күлмәк, төрле типтагы күлмәкләр, туннар, мех яисә тукыма башлыклар, яулыклар, кыек яулыклар, йон, күн, сәхтиян аяк киемнәре, ш.у. бил каешлары

һәм төрле төрдәге бизәмәләр. Традицион ризыклар — итле, сөтле, камыр һәм балык ашлары: итле токмач (бишбармак), суган б-н кыздырылган ит (куырдак), шашлык, казылыклар (казы, тутырма), пилмән (казан бөрек), чумар (инкал), уха (балык сорпа), боткалар, төрле сырлар, бәлешләр, йомырка тәбәсе һ.б. Иң киң кулланыла торган эчемлекләр — нугай чәе (ногай шай), йогырт, кымыз, әйрән, әче бал һ.б.

19 йөздә Н.да гаиләнең ике: зур (патриархаль) һәм кече формалары яши. Зур (сирәк кенә кече) гаиләнең көнкүреше катгый билгеләнеп куела. Үзара мөнәсәбәтләр гадәт (гадәти хокук) һәм шәригать (мөселман хокукы системасы) кагыйдәләренә нигезләнә, бу гаиләнең авторитар структурасы, хатын-кызлар һәм кечерәк яшьтәге ир-атларның хокуксызлыгы саклануга китерә. Халык авыз иҗаты үсештә була. Фольклор әсәрләре арасыннан геройлары Айсыл улы Әхмәт, Капланлы батыр, Идегәй, Мамай, Манаша, Аманхор һ.б. булган баһадирлар турындагы поэмалар, йола поэзиясе, җырлар, әкиятләр һ.б. танылу ала. «*Идегәй*» эпосының беренче варианты Н. арасында барлыкка килә.

*Әд.:* К а л м ы к о в И.Х. Ногайцы: Ист.-этногр. очерк. Черкесск, 1988; Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002; Народы и религии мира: Энцикл. М., 2000.

**НУ́ЖДИН** Владимир Иванович (20.3.1957, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011). 1983 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1978 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында (бүлеп, 1999–2006 да «Нур» АҖнең сыйфат бүлеге башлыгы). Хезмәтләре ион-нурлы тизләткечләр өчен үлчәү комплекслары әзерләүгә карый. Дәүләт бүләге зәркән ташларын затлыландыру нанотехнологияләре буенча хезмәтләр циклы өчен бирелә.

Х е з м.: Система контроля ионного тока в ускорителе ИЛУ-3 // Приборы и техника эксперимента. 2011. № 5 (автордаш); Особенности синтеза наночастиц серебра в кварцевом стекле при низкоэнергетической ионной имплантации // Рос. нанотехнологии. 2011. Т. 6, № 7–8 (автордаш).

**НУ́ЖИН** Михаил Тихонович (21.10.1914, Пермь губ., Оха р-ны Острожка а. — 11.8.1983, Казан), математик, механик, физика-матем. фән. д-ры (1954), проф. (1955), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1964). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1938), шунда ук эшли, ректор, теоретик механика каф. мөдире (1954–79), проф.-киңәшче (1979 елдан), бер үк вакытта (1947 дән) Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, механика секторы мөдире (1951–52). Хезмәтләре математика һәм механика өлкәсенә карый. Н. — матем. физикада фәнни юнәлешләрнең берсенә — аналитик функцияләр һәм аларның кулланылышы өчен кайтма кырый мәсьәләләр (ККМ) теориясенә нигез салучыларның берсе. ККМне классификацияли, аналитик функцияләр өчен контурлар үзгәрү (модификацияләнү) турындагы мәсьәләгә кире мәсьәлә төзи һәм аны чишә, ККМ чишелешенең тотрыклылыгын тикшерә. Тизлек зурлыгының бирелгән бүленеше буенча канат профиле формаларын яки агымда һәм әзләнелгән контурда үзенчәлекләр булганда басымны билгеләү мәсьәләсен чишү юлларын үстерә. Гидротехник корылмалар астында фильтрлану теориясендә кире мәсьәләләр үсешенә юл сала. Н. тарафыннан фильтрлану тизлегенең бирелгән зурлыгы буенча җир асты контуры үзгәрү турындагы мәсьәләгә кире мәсьәлә куела һәм чишелә. Стационар электр (җылылык) кыры өчен кире мәсьәләләрне тикшерә, ККМне детальләрне үлчәм буенча электрохимик эшкәртү теориясендә куллана. Университет б-н Н. җитәкчелек иткән елларда 2 яңа факультет, 10 нан артык яңа белгечлек ачыла; Хисаплау үзәге, Төньяк Кавказда астрономия станциясе (Ставрополь краеның Зеленчук ст.), 2 лаб.-уку корпусы, Фәнни китапханәләр, криоген лаб., 5 студентлар тулай торагы, сәламәтләндерү-спорт лагере төзелә; ун-тның мәдәният-спорт комплексы төзелә башлый, нәшрият оештырыла, Казан ун-ты тарихы музее ачыла. РСФСР (1959–67), ТАССР (1971–79) ЮСлары депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы орденнары б-н бүләкләнә. Казан ун-тында аңа мемориаль такта куела, Казанның бер урамы Н. исеме б-н атала, 2004 тә ун-тның төп бинасы каршында бюсты урнаштырыла (скульп. А.А.Бичуков).



М.Т. Нужин.

Х е з м.: О решении основной обратной задачи и задач, приводящихся к ней // Уч. зап. Казан. ун-та. 1951. Т. 111, кн. 8; О постановке и решении обратных задач напорной фильтрации // Докл. АН СССР. 1954. Т. 96, № 4; Методы построения подземного контура гидротехнических сооружений. Обратные краевые задачи теории фильтрации. К., 1963 (автордаш); Об обратных краевых задачах для многосвязных областей // Изв. вузов. Математика. 1964. № 5; Обратные краевые задачи и их приложения в механике. К., 1965 (автордаш).

*Әд.:* Михаил Тихонович Нужин: Воспоминания современников. К., 1999; И л ь и н с к и й Н.Б. Михаил Тихонович Нужин, 1914–1983. К., 2002.

*Н.Б.Ильинский.*

**НУ́ЖИН** Семён Григорьевич (1.6.1902, Сембер губ., Алатырь өязе Чуварлеи а. — 20.8.1953, Казан), аэродинамика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1946), проф. (1946), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1950). 1920 елда Алатырь реаль уч-щесен тәмамлаганнан соң, Казан тимер юлларында эшли. 1930 да Казан ун-тын тәмамлый. 1932 дән Казан авиация ин-тында, махсус лаб. башлыгы урынбасары (1940–41) һәм аэродинамика каф. мөдире (1940–41, 1948–53). Хезмәтләре канат, әйләнү җисемнәре һәм күп бәйләнешле контурлар аэродинамикасына карый. Н. тавыш тизлегенә кадәрге кече һәм зур тизлекләр вакытында кысылучан һәм кысылмаучан сыеклыкның ясссы агымында канат теориясен, канатның азаккы җәеме һәм рәшәткәләрне ягалап агу теориясен эшли. Азаккы җәелгән канат өчен төп интеграль-дифференциаль тигезләмәне чишү юлын тәкъдим итә, бу юл катлаулы формадагы, уемтылары, авыш элероннары, япкычлары һ.б. булган канатларның җәелмәсе буенча циркуляция бүленешен тиз исәпләп табарга мөмкинлек бирә. Бөек Ватан сугышы елларында Идел яры буйлап салынган саклану поясы төзелеше бригадиры, Алексеев р-ны «Восход» к-зы рәисе булып эшли. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу приближённого решения интегрального уравнения моноплана // Тр. КАИ. 1935. Вып. 4; К теории обтекания тел газом при больших дозвуковых скоростях // Прикладная математика и механика. 1946. Т. 10, вып. 5–6; Расчёт распределения циркуляций по размаху крыла // Тр. КАИ. 1953. Вып. 27.

**НУМИЗМА́ТИКА** (лат. numisma, грек. nomisma — акча), акчалар, акча коелмалары һ.б. матди ядкәрләр буенча акча сугу һәм акча әйләнеше тарихын өйрәнүче ярдәмче тарихи фән. Традицион рәвештә «Н.» төшенчәсе кәгазь акчаларны (бонистика), медальләр, жетоннар, плакеткалар (медальерлык сәнгате), орденнар, значокларны (фалеристика) өйрәнүне үз эченә ала. Акчалардан тыш Н.ның тикшеренү өлкәсенә акча штемпельләре, акча чыгарылу яки аның әйләнеше чорына караган сурәтләр, акчалар чыгаруга яки аларны әйләнештән алуга, акчалар алмашуга, акча сугу урыннарының эшчәнлегенә, акча реформаларына, акча әйләнешенә һ.б.га нисбәтле рәсми актлар һәм декретлар, ш.у. урта гасырларда тарихи яки геогр. эчтәлектә язылган әсәрләрдәге акчалар һәм акча сугу урыннары турындагы тасвирламалар һәм хәбәрләр керә. Акчалар идарә итү формасы, патшалык итү чорларының алмашынуы, династияләр хронологиясе, вассаллар һәм сюзерен мөнәсәбәтләре, дәүләт түнтәрелешләре һ.б. хакында фикер йөртү мөмкинлеге бирәләр. Нәфис һөнәрчелек эшләнмәләре буларак та, акчалар техника һәм сәнгать тарихын өйрәнү өчен чыганак ролен башкаралар. Акча сугуның авырлык стандартларын өйрәнүче нумизматик метрология мөстәкыйль тармак булып тора. Н.дан нумизматик туплауны яки акчалар коллекцияләүне аера белү зарур. Кагыйдә буларак, коллекционерларны акчаның фәнни әһәмияте түгел, аның сирәк очравы һәм сәнгати кыйммәтләре кызыксындыра.

Фәнни Н. 18 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә, нумизматик тикшеренүләре тарихның фәкать антик чорына караган Вена нумизматы И.И.Эккель аңа нигез салучы булып санала. Тора-бара Н.да аерым юнәлешләр — антик дәвер, Көнбатыш Европа, Шәрекъ юнәлешләре һ.б. формалаша. Шәрекъ Н.сы өлкәсендә аеруча Россия галимнәре зур эшләр башкаралар. Фәннең бу тармагына шәркыятьче галим, Казан ун-ты профессоры Х.М.*Френ* нигез сала. Ул Рус археол.-нумизматика җәмгыятен оештыручыларның берсе була (1846); аның саманилар һәм бөвәйхиләр суктырган акчаларны тасвирлауга багышланган беренче фәнни хезмәте гарәп телендә Казан ун-тында басылып чыга. Френ уннарча мең берәмлек Шәрекъ акчаларын фәнни



Алтын Урда чорына караган көмеш акчалар (җүчиләр тәңкәләре).

әйләнешкә кертә, күпсанлы коллекцияләрне тасвирлый, акчаларның йөзләрчә тибын аерып күрсәтә. Аның традицияләре Б.А.Дорн, П.С.Савельев (гарәп акчалары топографиясе һәм Алтын Урда Н.сы), В.В.Григорьев, В.Г.Тизенгаузен (Хәлифәлек һәм Саманилар дәүләте акчалары), А.К.Марков, О.Ф.Ретовский (Кырымның 15–18 йөзләр акчалары) тарафыннан дәвам ителә. С.И.Шодуар, С.М.Георгиевский, А.О.Ивановский, А.В.Гребенщиков, В.М.Алексеев хезмәтләрендә игътибар Ерак Көнчыгыш Н.сына юнәлтелә, аларда 16 йөздә Япониянең үзәк хакимияте тарафыннан һәм шул илнең үзәк уделларында сугылган алтын һәм көмеш акчалар, ш.у. борынгы (б.э.к. 3–1 йөзләр) һәм урта гасырлар (6–12 йөзләр) Кытай акчалары һ.б. тасвирлана. Шәрекъ Н.сы һәм нумизматик тикшеренүләрнең гомуми үсешендә нумизмат Р.Р.Фасмер зур роль уйный; Фасмер Шәрекъ акчалары хәзинәләре материалы нигезендә, борынгы акча әйләнешен өйрәнү бурычыннан чыгып, хәзинәләрне тикшерүнең төп принципларын эшли. Казанда Н.га карата башлангыч кызыксыну коллекцияләр туплау б-н чикләнә. К.Ф.*Фукс* һәм А.Ф.*Лихачёв* Шәрекъ акчаларының зур җыелмасын туплыйлар. Н. буенча тикшеренүләр ш.у. Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* әгъзалары тарафыннан да алып барыла. А.Ф.Лихачёвның «Биләр туфрагында скифлар эзе» («Скифский след на Билярской почве», 1885), «1887 елгы яңа болгар хәзинәсе» («Новый булгарский клад 1887 г.», 1888), Казан ун-ты каршындагы Нумизматика музее директоры Д.Нагуевскийның «Казан университетының Нумизматика музеенда саклanучы фарсы акчаларына күзәтү» («Обозрение персидских монет, хранящихся в Нумизматическом музее Казанского университета», 1892) хезмәтләре басылып чыга.

СССРда Шәрекъ Н.сы б-н О.И.Смирнов (борынгы Согда Н.сы), Е.А.Давидович, М.Е.Массон, Е.А.Пахомов, Д.Г.Капанидзе, А.А.Быков (Урта Азия һәм Кавказ арты Н.сының төрле бүлекләре), С.А.Янина, Г.А.Фёдоров-Давыдов (куфи акчалары һәм Алтын Урда Н.сы) шөгыльләнә. 1920–30 елларда Алтын Урда дәвере акчалары хакында аерым язмалар басыла (А.В.Васильев, А.А.Кротков, Р.Р.Фасмер). С.А.Янина тарафыннан күп эшләр башкарыла: ул моңарчы мәгълүм булган болгар акчалары типларының иң борынгысын ача, Алтын Урда дәвере археол. истәлекләрен казу эшләре вакытында табылган акчалар материалларын өйрәнә-эшкәртә, болгар-татар акчаларын классификацияли. Г.А.Фёдоров-Давыдов беренче тапкыр Алтын Урда акчалары хәзинәләренең һәм аерым табылдыкларының топографиясен төзи. Ул, Идел буе, Харәзем, Төньяк Кавказ һәм Кырым б-н генә чикләнмичә, Русьтагы акча әйләнешен дә тикшерә. Аның тарафыннан Алтын Урда акча терминнары һәм акча-авырлык берәмлекләре килеп чыгышы мәсьәләләре яктыртыла, акча системалары манзаралы торгызыла, аларның эволюциясе күрсәтелә.

1950 еллардан Казан ун-тының СССР тарихы (соңыннан Ватан тарихы) кафедрасында Н. буенча лекцияләр курсы укытыла. Шәрекъ Н.сын өйрәнү б-н Ә.Г.*Мөхәммәдиев*, В.Н.Настич, А.З.Сингатуллина һ.б. шөгыльләнә.

*Әд.:* Френ Х.М. Монеты ханов Улуса Джучи, или Золотой Орды, с монетами разных иных Мухаммеданских династий в прибавлении. СПб., 1832; Савельев П. Мухаммеданская нумизматика в отношении к русской истории. СПб., 1847; Фёдоров-Давыдов Г.А. Монеты — свидетели прошлого: Популярная нумизматика. М., 1963; шул ук. Денежное дело Золотой Орды. М., 2003; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; шул ук. Древние монеты Поволжья. К., 1990; Шельди Н.М. Булгаро-татарские монеты XIII–XV веков: Практ. рук. для нумизмата-ориенталиста. К., 2002.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев, Л.Ф.Недашковский.*

**«НУР»**, Уфа губернасы Эстәрлетамак шәһәрендәге басмаханә (ширкәт формасында). 1910 елның 28 июлендә ачыла, татар китапларын басу һәм сату б-н шөгыльләнә. Оештыручы-пайчылары — сәүдәгәрләр Г.Үтәмишев, К.Баязитов, Г.Усманов; күмәк пайчысы «Каләм» нәшрияты була. 1916 да басмаханә идарәче Г.Фәйзигә сатыла, 1918 ел башында алты елга «Кредит ширкәтләре берлеге» шәһәр банкына арендага бирелә. Эстәрлетамак шәһәренең Мөселман (татар) хәйрия җәмгыятенә һәм Беренче бөтендөнья сугышында яраланган сугышчыларга матди ярдәм күрсәтә. Басмаханәдә «Каләм», «Акча» нәшриятлары һәм шәхси заказчылар өчен татар телендә 40 ка якын китап нәшер ителә.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**«НУР»**, Казандагы автомобиль җитештерү сәнәгатенә караган компанияләр төркеме. Эшләүчеләр саны 250 кеше (2013). 1990 елда, алгарышлы технологияләрне, техниканы, заманча материалларны тиз арада гамәлгә кертү, көндәшлеккә сәләтле продукция җитештерүне оештыру өчен Татарстан республикасы яңа технологияләр үзәге буларак оештырыла, 1999 дан ҖЧҖ. 2010 нан хәзерге исемдәге фәнни-җитештерү берләшмәсе, ААҖ. Составына «Биектау» ААҖ идарәпр-тиесе, «Нур» яңа технологияләр үзәге» ҖЧҖ, «Нур-тех» ҖЧҖ, «Вектор» ААҖ, «Нурсервис» ҖЧҖ керә. Эшчәнлегенең төп юнәлешләре: плазма-вакуум технологиясе кулланып, эшләнмәләрне алюминий, титан, титан нитриды, тутыкмаучан корыч, башка металлар һәм аларның эретмәләре б-н каплау, шул нигездә автомобиль һәм көнкүреш көзгеләре җитештерү; полимер-порошок технологияләрен файдаланып, коррозиягә чыдам декоратив өслек б-н каплау; электростатик кырны полимер-порошок өслек б-н каплау җиһазлары эшләп чыгару; автомобильләр җитештерү сәнәгате өчен комплектлаучы эшләнмәләр (ш.и. тормоз системасы өчен дүрт контурлы саклагыч клапаннар) ясау. Пр-тиедә Россиядә беренче тапкыр (1993) плазма-вакуумлы сиптерү алымы б-н йөк автомобильләре һәм җиңел автомобильләр өчен арткы күренешне чагылдыручы сферик көзгеләрне серияләп җитештерү оештырыла. «Н.» «КАМАЗ», «ГАЗ» (Түбән Новгород ш.), «Павлово автобусы» (Түбән Новгород өлкәсенең Павлово ш.), «И.А.Лихачёв исемендәге завод» (Мәскәү), «САЗ» (Мәскәү өлкәсенең Серпухов ш.) АҖләре өчен — тоткычлы көзгеләр, җылытулы көзгеләр, «АвтоВАЗ», «ГАЗ» АҖләре өчен ш.у. көзге элементлары эшкәртеп җитештерә, чит илләрдәге автомобиль з-длары б-н дә хезмәттәшлек итә. Барлык типлардагы көзгеләр халыкара сыйфат сертификатлары б-н бәяләнгән, берләшмәдә ИСО 9001 сыйфат менеджменты системасы гамәлгә кертелгән. Касабланкада (Марокко, 1998) һәм Софиядә (Болгария, 1999) уздырылган 4 нче һәм 6 нчы Халыкара яңа технологияләр, продуктлар һәм инновацияләр күргәзмәләренең 2 алтын, 1 көмеш медале, 2 «Гран-при» кубогы иясе. Җитәкчеләре: З.Х.Исрафилов (1990–2012), И.К.Низаметдинов (2012 дән).

**«НУР»**, тары сорты. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында 2001 елда Л.Г.Сәгъдиева, Н.Ш.Хисаметдинов, Х.З.Хәсәнова, З.Г.Хәмидуллина тарафыннан чыгарыла. Бу сорт азык-төлек өчен үстерелә, соң өлгерешле (вегетация чоры 75–85 көн), сөрлегүгә һәм некротик меланозга чыдам, яхшы куаклана. Үсемлекнең биеклеге 90–100 *см.* Сабагы юан, көчле, аз ботаклана. Яфраклары эре, киң. Себеркәче иенке. Себеркәчнең ботаклары озын, нечкә, асылынып торучан. Бөртеге эре, кызыл төстә, озынча түгәрәк формада. 1000 орлыкның авырлыгы 7,8–8 *г.* 2003 елда бу сорт Дәүләт реестрының РФнең Идел-Вятка регионнарында чәчәргә рөхсәт ителгән сортлар исемлегенә кертелгән.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**«НУР»**, атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета, татар телендә беренче вакытлы матбугат басмасы. 1905 елның 2 сентябреннән 1914 нең 22 июненә кадәр С.-Петербургта нәшер ителә, барысы 310 саны чыга. Оештыручы, нашир һәм мөхәррире — Г.*Баязитов*, аннан соң — М.*Баязитов.* К.Бәкер, Г.Еникеев, Г.Исхакый, Ш.Камал, Ф.Кәрими, С.Максуди,



«Нур» газетасы саннарының берсе.

Һ.Максуди, К.Мотыйгый, С.Сүнчәләй, К.Тәфкилев һ.б. хезмәттәшлек итә. Г.Баязитовның «Н.» г-тасын басарга рөхсәт алудагы авырлыкларын исәпкә алып, бигрәк тә басыла башлаган чорда, «хөкүмәт теләкләре»нә яраклаштырылган, халыкның хәлле катлаулары, руханилар һ.б. мәнфәгатьләрен һәм фикерләрен чагылдырган мәкаләләр дөнья күрә. Шуның б-н беррәттән «Н.» гомумкешелек кыйммәтләрен хуплый, җәмгыятьтәге капма-каршылыкны һ.б. мәсьәләләрне көч б-н хәл итүне кире кага, әдәбият, мәгариф, дин бурычлары хакында мәкаләләр бастыра, татар халкының үзенчәлекләрен саклауны, тел, әдәбият һәм мәдәниятне үстерүне яклап чыга. Дини тормыш проблемалары Россиядә барган вакыйгалар контекстында карала; Россия җәмгыятендә ислам турында уңай фикер тудыруга омтылыш ясала. «Н.» г-тасын алдынгы татар интеллигенциясе кайнар яклап чыга, соңга таба газета консервативлаша, күбесенчә уң көчләр мәнфәгатьләрен чагылдыра. Милли матбугат үсешенә зур этәргеч бирә. 1990 ның 19 февралендә рус телендәге айлык газета буларак яңадан чыга башлый. Оештыручысы — С.-Петербург татарларының милли-мәдәни мохтарияте; мөхәррире — Р.Р.Мәһдиев.

*Ж.С.Миңнуллин, А.Ә.Хәсәвнех.*


**«НУР»**, татар театр труппасы. 1912 елның маенда Уфа шәһәрендә оеша; сәнгать җитәкчесе, режиссёры, әйдәп баручы актрисасы С.Гыйззәтуллина-Волжская була. Труппаның составында беренче елда — Ф.Сәмитова, Ф.Булатова, Ш.Шамильский, Г.Казанский, Н.Сакаев, Ф.Латыйпов, Н.Хәнҗәров, Ф.Йосыпов, М.Мутин, З.Богданова, Тукумбитов, соңрак К.Шамил, Б.Тарханов, Л.Аитов, И.Әлмәшев, Н.Якупов, А.Хисамов, М.Тупикский була. 1913–15 еллардагы кышкы сезоннарны труппа Оренбург шәһәрендә уздыра. Үз бинасы булмый, вакытның күбрәк өлешен труппа Урал, Идел буе, Урта Азия, Казакъстан, Себер шәһәрләрендә гастрольләрдә йөреп уздырырга мәҗбүр була. Театрның репертуарында күбесенчә «Сәйяр» труппасы куйган спектакльләр кабатлана. Репертуарның нигезен Г.Камал («Бәхетсез егет», «Уйнаш», «Беренче театр», «Бүләк өчен», «Дәҗҗал», «Каениш», «Банкрот»), С.Рәмиев («Яшә, Зөбәйдә, яшим мин»), М.Фәйзи («Кызганыч»), Г.Коләхмәтов («Яшь гомер»), Д.Таждаров («Яшь хатын») пьесалары тәшкил итә. Труппа ш.у. әзәрб. («Мөсибәте Фәхретдин», Н.Вәзиров; «Бәхетсез Бибиҗан», Сәетзадә), рус («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский; «Кыз сорау», А.П.Чехов) һәм Европа («Саран», Ж.Б.Мольер, «Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, «Хөкемдә хаталык», А.Деннери) драматургларының пьесаларына да мөрәҗәгать итә. Реализм принципларына нигезләнеп, труппа, көндәлек тормышның төгәл, чын күренешләренә генә игътибар биреп калмыйча, яшәешнең рухи эчтәлегенә дә басым ясап, чынбарлыкны шигъриятләштереп сурәтләүгә омтыла. «Н.» актёрларының башкару манерасына көчле эмоциональлек, хисләр югарылыгы, уңай героик характерларны сурәтләүдә романтик рух һәм тискәре образларны тасвирлауда сатирик үткенлек хас. Тормышка гуманлы мөнәсәбәт, мәгърифәтле булу идеяләрен, белем алу мөһимлеген пропагандалау һәм бер үк вакытта дини фанатизмны, сабырсызлыкны, наданлыкны, реакцион консерватизмны тәнкыйтьләү «Н.» театрын оештыручыларның төп бурычы булып тора. Труппа татар милли театры, татар театр сәнгатенең төп принциплары формалашуда зур роль уйный. 1918 нең маена кадәр эшли, Гражданнар сугышы башлану сәбәпле таркала; актёрларның шактые татар фронт театры труппасына керә.

*Әд.:* М о р т а з и н В., Ч е н ә кә й Т. Татар театры тарихыннан. М., 1926; Татар театры (1906–1926). К., 1926; Татар совет театры. К., 1975; Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988.

*И.И.Илялова.*

**«НУР»**, Уфа шәһәрендәге татар драма театры. Яшь актёрлар төркеме тырышлыгы б-н 1989 елда театр-студия буларак оеша; 1991 дә дәүләт театры статусы ала. Труппа составын Башкортстан Респ-касы театрларыннан татар актёрлары, Уфа сәнгать ин-тын тәмамлаучылар, ш.и. Р.Гандәлипова, Р.Фәхруллина, М.Исхаков, Р.Гайфуллина, И.Кәлимуллин, Э.Газизуллин, С.Нурисламов, Г.Мөхәммәдиева, М.Сәетова, Л.Хәйретдинова, Р.Галиев, С.Сираева, Д.Фәйзуллина, В.Калмантаева тәшкил итә. Театрның беренче баш режиссёры Б.Ибраһимов Уфа һәм Казан тамашачылары арасында уңыш казанган шактый гына спектакльләр куя: «Ямьсез тормыш» (Ф.Сәйфи-Казанлы), «Башмагым» (Т.Гыйззәт һәм Ж.Фәйзи), «Зөләйха» (Г.Исхакый). Татар акад. театры режиссёры Ф.Бикчәнтәев Г.Исхакый повесте буенча «Көз» спектаклен куя, ул 1998 дә халыкара «Нәүрүз» театр фестивалендә «Иң яхшы режиссура өчен» призын ала. Репертуарның нигезен татар әдәбияты классикларының әсәрләре тәшкил итә. Эшләү дәверендә театр үзеннән алда хезмәт күрсәткән «*Нур*» татар театры труппасының иҗат принципларын яңадан торгызуга омтыла. Театр б-н 1990 еллар уртасыннан җитәкчелек иткән Ә.Сафиуллин көчле театральлек хас булган спектакльләр куя: «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), «Аршин мал алан» (У.Хаҗибәков), «Беренче театр» (Г.Камал), «Яшьләр алдатмыйлар» (М.Фәйзи), «Гашыйклар көне» (Н.Гаетбай), «Американ» (К.Тинчурин), «Коеп куйган фәрештә» (Э.Яһудин), «Ха-







1. «Нурлы сәфәр» спектакленнән күренеш. Сәхнәгә куючы — У.Гыйрфәтуллин; 2. «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал) спектакленнән күренеш; 3. Театр бинасы.

тын түгел — аждаһа» (Д.Салихов) һ.б. Театрның директоры — БР һәм ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе У.Гыйрфәтуллин (1994 тән).

*И.И.Илялова.*

**НУР ЯРДӘМЕНДӘ́ ДИА́ГНОЗ КУЮ́**, к. *Рентгенология*.

**НУРАДЫ́Н**, идарәче хаким титулы. Фаразларның берсе буенча, Нугай Урдасы идарәчесе *Нурадын бәкнең* үлеменнән соң исеме урталык исемгә әверелә. Тагын бер фараз Кырым ханлыгында Н. титулы калга (рәсми варис) артыннан соң килүче тәхет варисын аңлаткан, Н. атамасы Сәгадәтгәрәй солтанның *аталыгы* Нурадыннан киткән дип исәпли. Мөхәммәдгәрәй II хан (1577–84) вакытында Нурадын тәхетнең икенче варисы итеп билгеләнә. Шул заманнардан Кырым дәүләте документларында «Н.» титулы «калга» титулы б-н янәшә куела.

*М.Г.Госманов.*

**НУРАДЫ́Н БӘК** (? — 1440), Нугай Урдасы бәге (идарәчесе) (1426 дан). *Идегәйнең* кече улы. Әтисенең сәясәтен дәвам итә. Нугай Урдасының бәйсезлегенә ирешү өчен көрәшә. Соңыннан исеме күмәклек исемгә әверелә (к. *Нурадын*).

*Әд.:* Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

**НУРАКО́В** Серик Нурак улы (1.1.1939, Казакъстан ССР, Кургум р-ны Куйган а.), механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (2001). 1961 елда Казакъстан а.х. ин-тын (Алма-Ата) тәмамлаганнан соң, Усть-Каменогорск шәһәрендә төзелеш оешмаларында эшли. 1968 дән Евразия милли ун-тында (Астана ш.): төзелеш машиналары каф. мөдире (1989–96), инженерлык ф-ты деканы (1974–86, 1998–2000), Төзелеш, транспорт һәм архит-ра ин-ты директоры (2000–01), төзелеш һәм транспорт процесслары технологиясе, аларны механикалаштыру һәм автоматлаштыру фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (2004 тән). Хезмәтләре төзелеш машиналарын конструкцияләүгә, автомобиль юлларын төзекләндерүгә карый. Гидросистемадагы эшче сыекчаның эксплуатацион һәм физик-химик үзлекләренең машина гидрокүчергечләре чыдамлыгына тәэсирен тикшерә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экскавационно-погрузочные машины с инерционным ротором нижней разгрузки. Алматы, 1995; Основы технологии машиностроения. Астана, 2001; Землеройные машины непрерывного действия с бесковшовыми роторами: Теории, конструкции, расчёт. Астана, 2008.

**НУРАЛИ́ БӘК** (? — 1551 елдан соң), Казан ханы Шаһгали хөкүмәтендә бәкләр бәге (1551 дән). *Булат Ширин* бәк улы. 1551 нең сентябрендә Мәскәүгә җибәрелгән Казан ханлыгы илчелеген җитәкли. Шуннан соңгы язмышы билгесез. Казан Кремлендәге бер капка (к. *Казан капкалары*) һәм мәчет (к. *Нурали мәчете*) Н. исеме б-н аталган.

*Әд.:* Х у д я к о в М. Очерки истории Казанского ханства. К., 1923.

**НУРАЛИ́ МӘЧЕТЕ́**, Казан ханлыгы башкаласындагы мөселман дине корылмаларының берсе. 16 йөзгә кадәр төзелгән. Архит-ра тарихчылары фаразлары буенча, госманлылар архитектурасы стилендә бер-ике манаралы, гөмбәзе үзәккә урнашкан җамигъ мәчет тибына караган. Манарасы түбәгә урнаштырылган ике катлы таш бина рәвешендә булган. Аның янында Казан ханнарының төрбәләре б-н югары катлау кешеләре җирләнгән зират урнашкан була. 1552 елда Казан ханлыгы яуланганнан соң, мәчет бинасы сугыш кораллары складı итеп файдаланыла. 1567 дән соң җимерелә.

*Әд.:* Х а л и т Н. Архитектура ханской Казани: Гипотезы. Факты. Размышления. К., 1999.

**НУРВАХИ́Т** (Мулланур Вахитов) авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 13 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 235 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Буа волостенда. 1930 елның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 199, 1938 дә — 263, 1949 да — 279, 1958 дә — 298, 1970 тә — 405, 1979 да — 311, 1989 да — 237, 2002 дә — 215 кеше.


**НУРГАЛИ́ *бине́* МӨХӘММӘ́Д** (19 йөз ахыры, фаразлауларча, Чистай өязе Күлбай Мораса а. — 20 йөз башы), хаттат, ташбасма ысул б-н бастырылган *шәмаилләр* авторы. Аның әсәрләре арасында 1903 елда Перов басмаханәсендә (Казан) басылган һәм догалар, саклау бөтиләреннән торган аклы-каралы шәмаил (40×60 *см*) бар. Геом. фигуралар (түгәрәк һәм квадрат) эчендәге ачык каллиграфик язулар үсемлек үрнәкләре б-н табигый ярашып килә; композициянең характеры (симметрия һәм асимметриянең, шартлы һәм реалистик бизәкләрнең контрастлы кушылмасы, формаларның нәфислеге) модернизм стиле йогынтысын дәлилли. Шәмаилнең аерым фрагментлары тылсымлы символларны чагылдыра (Мөхәммәд пәйгамбәрнең сандалы сурәте, түгәрәк әйләнәләре рәвешендәге «изге мөһер», догалык формулалары таблицасы, «Фатыйма кулы» сурәте һ.б.). Н. бине М. 1904 тә Казанда бертуган Кәримовлар басмаханәсендә басылган «Сөләйман (Соломон) мәйданы» төсле ташбасма шәмаилендә (53×71 *см*) Сөләйман пәйгамбәрне зурлаган каллиграфик текст б-н аллегорик сюжетны (ачык итеп ясалган урындыклар һәм шартлы челтәрләр б-н бизәлгән пәрдә сурәте) сыйдырган. Н. бине М.нең бертуган Кәримовлар басмаханәсендә басылган өченче — «Сөләйман тәхете» шәмаиле дә (53–71 *см*) Сөләйман пәйгамбәргә багышланган (1906). Шәмаилләр ТР Милли музеенда, ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты архивында саклана.

*Әд.:* Ш а м с у т о в Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: От прошлого до настоящего. К., 2003.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НУРГАЛИ́ЕВ** Данис Карлович (1.9.1956, БАССРның Борай р-ны Абдулла а.), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1978), шунда ук эшли, файдалы казылма чыганакларны геофизик ысуллар б-н эзләү каф. мөдире (1997 елдан), проректор (2007 дән). Геол. һәм нефть-газ технологияләре ин-ты директоры (2011 дән). Хезмәтләре палеомагнетизм, петрофизикага, эзләнү һәм исәпләү геофизикасына, геоэкологиягә





Нургали бине Мөхәммәд әл-Мөрәсәви. 1. «Бөтиләр» шәмаиле. Кәгазь. Ташбасма. И.С. Перов басмаханәсе. 1903; 2. «Сөләйман тәхете». Кәгазь. Төсле ташбасма. Бертуган Кәримовлар басмаханәсе. 1906. Икесе дә ТР Милли музеенда.

карый. Н. утырма токымнарның табигый калдык магнитлануы юнәлешләрен анализлау методикасын эшли, соңгы палеозой һәм башлангыч мезозойда геомагнит кыры вариацияләренең төп үзенчәлекләрен билгели. РФАнең Магнетизм буенча гыйльми советы әгъзасы.

Х е з м.: Палеомагнитный анализ. К., 1986 (автордаш); Аппаратура ядерно-магнитного резонанса для исследования полноразмерных кернов в лабораторных и полевых условиях // Георесурсы. 2012. № 4; Магнито-тактические бактерии природных водоёмов РТ // Вода: химия и экология. 2011. № 3 (автордаш).

**НУРГАЛИ́ЕВ** Илдар Гали улы (18.3.1948, Казан), архитектор. ТАССРның атказ. архитекторы (1984). 1971 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң, «Татаргражданпроект» ин-тында эшли. 1977 елдан «Казгражданпроект» проект ин-тының баш архитекторы. 1990 нан «Среда» фирмасында, 1995 тән үзенең шәхси «Архитектор Нургалиевнең иҗат остаханәсе»н җитәкли. Казанда Н. проектлары буенча «Новинка» күргәз-

мә павильоны (1985, И.Д.Галанин б-н берлектә), Азино-2 нең 1 нче микрорайонындагы иҗтимагый үзәк (1989, А.Исаев б-н берлектә), 10-А, 11-А микрорайоннардагы торак йортлар (1990–97, Т.Попко б-н берлектә) төзелә. Н. иҗат остаханәсендә, башлыча, шәһәрнең үзәк өлешендә, күпфатирлы 15 торак йорт, офис һәм сәүдә биналары, «Җиңү паркы» мемориаль комплексы, Ф.И.Шаляпин һәйкәле, «Динамо» стадионы, Татар ашлары йорты, Дворяннар җыены бинасы, Казан консерваториясе һ.б.ны реконструкцияләү проектларын эшли.

**НУРГАЛИ́ЕВ** Рәшит Гомәр улы (8.10.1956, Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Джетыгара ш.), армия генералы (2005), икътисад фән. канд. Петрозаводск ун-тын тәмамлый (1979). 1979–81 елларда Карелия АССРның Надвоицы посёлогы мәктәбендә укытучы. 1981 дән Карелия АССРның Дәүләт куркынычсызлыгы ком-ты органнарында. 1995–2002 дә (бүленеп) РФ Федераль иминлек хезмәтендә (Мәскәү): Оештыру-инспекторлык идарәсе баш инспекторы, Шәхси иминлек идарәсенең бүлек башлыгы (1998 гә кадәр), 1999–2000 дә Икътисади куркынычсызлык департаментының Контрабанда һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш идарәсе, 2000 нән Инспекторлык идарәсе башлыгы; бер үк вакытта, 2000 нән, директор урынбасары. 1998–99 да РФ Президентының Баш контрольлек идарәсендә бүлек башлыгы. 2002–04 тә РФ эчке эшләр министрының 1 нче урынбасары — Криминаль милиция хезмәте башлыгы. 2004–12 дә РФ эчке эшләр министры. 2012 дән РФнең Куркынычсызлык Советы секретаре урынбасары. Икътисади куркынычсызлык проблемалары буенча язмалар авторы. 2, 3, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Почёт» орденнары белән бүләкләнә.

Х е з м.: Экономическая безопасность и незаконный оборот наркотических средств в Российской Федерации. СПб., 2003; Система обеспечения экономической безопасности государства. М., 2005.

*Е.Б.Долгов.*

**НУРГАЛИ́ЕВА** Нурия Гавәз кызы (1.3.1966, Әлмәт ш.), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1988), шунда ук эшли, нефть һәм газ геологиясе каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре литология, стратиграфия, петрофизика һәм углеводород чыганаклары геологиясенә карый. Идел һәм Кама елгалары бассейннарының Пермь утырмалары өчен стратиграфиянең литологик үзенчәлекләрен билгели, циклы төзелеш закончалыкларын ачыклый; беренчеләрдән булып, углерод, кислород һәм стронцийның изотоп бәйләнеше турында мәгълүматлар ала. Идел-Урал һәм Көнбатыш Себер нефть-газ бассейннары чыганаклары һәм ятмаларының литологик-фациаль, пертофизик һәм секвенс-стратиграфик үрнәкләрен булдыруда катнаша.

Х е з м.: Пермские осадочные разрезы востока Русской плиты: Цикличность и фрактальные образцы. Саарбрюкен, 2010; Изотопы углерода, кислорода и стронция в карбонатных отложениях. Саарбрюкен, 2011; Микрофации, пертофизика и секвенсстратиграфический каркас карбонатных нефтеносных отложений кизеловского горизонта // Нефтяное хоз-во. 2012. № 3.

**НУРДӘҮЛӘ́Т ХАН** (? — 1491 тирәсе), Касыйм ханы (1486 дан). Кырым ханы Хаҗигәрәй улы. Кырым ханлыгы тәхетеннән бертуганы Миңлегәрәй тарафыннан төшерелә, Бөек Литва кенәзлегенә кача. 1479 елда Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III гә хезмәткә керә. 1480 дә воевода Василий Ноздреватый б-н бергәләп Сарай әл-Җәдидкә һөҗүм ясый. Касыйм ханлыгы тәхетенә Иван III тарафыннан утыртыла.

*Әд.:* В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах. СПб., 1863–64. Ч. 1–2.

*И.Л.Измайлов.*

**НУРЕТДИ́НОВ** Әнәс Кәшфи улы (10.3.1952, Казан), контр-адмирал (1992), хокук фән. канд. (2001). Адмирал С.О.Макаров исем. Югары хәрби-диңгез уч-щесен (Владивосток ш., 1976), Хәрби-диңгез академиясен (Ленинград, 1984), РФ Кораллы Көчләре Генштабы академиясен (Мәскәү, 1996) тәмамлый. Уч-ще тәмамлагач, Тын океан чик буе округында (Курил утраулары) хезмәт итә, штурманнан алып, чик буе сакчы корабль командирына кадәр хәрби юл үтә. 1985–91 елларда Балтыйк буе чик буе округында (Латвия): 1985 тән чик буе корабльләре берләшмәсенең штаб башлыгы (Лиепая ш.): 1987 дән чик буе корабльләре берләшмәсе командиры (Вентспилс ш.). 1992–94 тә Тын океан чик буе округы командиры ярдәмчесе — округ хәрби көчләр командующие (Владивосток ш.). 1996 дан Кавказ махсус чик буе округы хәрби көчләре командующие (Ставрополь ш.). 1998 дән — запаста. 1998–2004 тә халыкара «Дуслык һәм Бердәмлек федерациясе» оешмасы рәисе урынбасары. 2004 тән РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгының Балыкчылык хуҗалыгы департаменты директоры урынбасары. 2006 дан «Россельхознадзор»ның Камчатка өлкәсе һәм Коряк автономияле округы буенча терр. идарәсе башлыгы. 2 һәм 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (2002).

*М.З.Хәбибуллин.*

**НУРЕТДИ́НОВ** Дамир Мәхмүт улы (14.6.1937, Әгерҗе р-ны Красный Бор а.), бораулау мастеры, Соц. Хезмәт Герое (1981), ТАССР, РСФСРның атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1977, 1987), РФ ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1992). «Татнефть» берләшмәсенең бораулаучылар мәктәбен тәмамлый (1967). 1952–56 елларда Әгерҗе р-ның Степан Разин исем. к-зында эшли. 1958–95 тә «Татнефть» АҖнең Әлмәт бораулау эшләре идарәсендә бораулаучы ярдәмчесе, бораулаучы, бораулау мастеры (1967 дән). «Нефть скважиналарын — агымга» алымы авторы. Герой исеме җитештерүдәге уңышлары, бишьеллык планны (1976–80), соц. йөкләмәләрне вакытыннан алда үтәгәне, хезмәттәге батырлыгы өчен бирелә. СССР профсоюзларының 17 нче съезды делегаты (1982). Хезмәттәге казанышлары, техника һәм алдынгы технологияләрдән нәтиҗәле файдалану нигезендә нефть чыгаруда иң югары җитештерүчәнлеккә ирешкәне өчен, СССР ФАнең Дәүләт бүләге (1978), СССР ФАнең И.М.Губкин исем. бүләге (1982) бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.



Р.Г.Нургалиев.



Д.М.Нуретдинов.

*Әд.:* З а р и п о в И. Нурутдинов Дамир Махмутович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**НУРЕТДИ́НОВ** Илдус Әгъләм улы (13.5.1935, Бондюг пос., хәзер Менделеев ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (1977), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1957 елда Горький ун-тын тәмамлаганнан соң, Әзәрбайҗан ФАнең Химия ин-тында. 1959 дан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, физиол. актив элементорганик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1979 дан), директор урынбасары (1989–92), проф. (1990). Хезмәтләре физиол. актив элементорганик кушылмалар химиясенә, стереохимиясенә, фуллереннар химиясенә карый. Н. этилениминның фосфориллы чыгарылмаларын синтезлый һәм тикшерә, аларның кайберләрен эффектив хемостерилентлар — буынтыгаяклы бөҗәкләр б-н көрәшү чарасы буларак тәкъдим итә. Югары эффектив препаратлар: бициклат (а.х. үсемлекләре корткычларына каршы), гипхлофос (а.х. терлекләре паразитларына каршы) җитештерү технологияләрен эшли. Селен- һәм теллурофосфорорганик кушылмаларны синтезлау алымнарын эшләүгә, аларның төзелешен һәм үзлекләрен тикшерүгә зур өлеш кертә, бу кушылмаларның химик, физик һәм биологик үзлекләренә аларның структурасы тәэсиренең яңа закончалыкларын ачыклый. Метанофуллереннарның үзе синтезлаган нитроксил чыгарылмаларында матдәнең үтә нәзек ярсынган квинтет халәте структурасын таба. Фәнни хезмәтләре илнең а.х.нда үсемлекләрне һәм терлекләрне саклау максатында кулланыла. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Направленный синтез новых производных фуллерена // Юбилейный сб. избр. трудов членов АН РТ. К., 2002 (автордаш); Молекулярная электрохимия фуллеренов и их производных // Электрохимия. 2003. № 11 (автордаш); First observation of the hyperfine structure of an exited quintet state in liquid solution // Chemical Communication. 2005. № 16 (автордаш); Synthesis, structure and bio-



Л.Ф. Нуретдинова.



З. Нури.

logical activity of nitroxide malonate methanofullerenes // Organic Biomolecular Chemistry. 2007. № 5 (автордаш).

**НУРЕТДИ́НОВ** Минсәгыйр Гайса улы (6.12.1955, Чирмешән р-ны Кара Чишмә а.), зооинженер, а.х. фән. д-ры (2007), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (2001, 2013). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли, зооинженерия ф-тында декан урынбасары (1985–86), декан (1986–92). 1992–95 елларда «Татстрой» Татарстан төзелеш берләшмәсенең 5 нче төзү-монтаж тресты «Казанка» ярдәмче хуҗалыгы директоры. 1995–98 дә Арча р-нының «Коммунист» к-зы рәисе. 1998–99 да Биектау р-ны хакимияте башлыгы урынбасары. 1999 дан ТР а.х. һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары. 2014 тән «Гади сөт» ҖЧҖ идарәче компаниясе ген. директорының агросәнәгать комплексы мәсьәләләре буенча беренче урынбасары. Дәүләт бүләге «Буа р-ны а.х. җитештерүендә ТР агроминераль чимал кулланып ресурс саклаулы технологияләрне гамәлгә кертү» хезмәте өчен бирелә. Хезмәтләре югары продуктлы терлекләрне хайван организмы һәм төбәкнең зональ үзенчәлекләрен исәпкә алып ашату нормалары нигезендә комбиазык җитештерүгә карый.

**НУРЕТДИ́НОВ** Салихҗан Хәсәнҗан улы (1.7.1934, Аксубай р-ны Иске Ибрай а.), химик, химия фән. канд. (1967), проф. (1994), ТРның атказ. химигы (1994), Казан. технол. ун-тының атказ. проф. (2007). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, нефть ф-ты деканы (1971–91). Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. Н. өч валентлы фосфор к-талары галогенангидридларының карбонил кушылмалар һәм карбон к-талар (альдегидлар, кетоннар, туенган һәм чиксез к-талар һәм аларның хлорангидридлары) б-н үзара тәэсирен тикшерә. Фосфорның төрле кислоталарын, оксафосфоленнар, биш валентлы фосфорның альфа, бета-кеточыгарылмалы, альфа-оксичыгарылмалы кислоталарын синтезлау алымнарын эшли. Фосфорорганик продуктларның радикал-чылбырлы процессларга (пиролиз, ачыту) тәэсирен өйрәнә. Н. тарафыннан синтезланган матдәләр газ-сыеклыклы хроматографиядә сорбентлар, поливинилхлоридка стабилизаторлар һәм пластификатор, антипиреннар сыйфатында кулланыла; ул кайбер кушылмаларның гербицид һәм фунгицид үзлекләренә ия булуын күрсәтә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование фосфорорганических неподвижных фаз на основе хроматографических факторов полярности // Журн. аналитической химии. 1979. Т. 34, вып. 12 (автордаш); Некоторые реакции оксафосфоленов // Журн. общей химии. 1983. Т. 53, вып. 5 (автордаш); Научные и тривиальные названия органических соединений: Конспекты лекций и справ. материал. К., 1999 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**НУРЕТДИ́НОВ** Фоат Шәйхетдин улы (1.11.1938, Чистай р-ны Наратъелга а.), спортчы, тренер (җиңел атлетика), СССРның спорт остасы (1968, ун төр ярыш), РСФСР, СССРның атказ. тренеры (1990, 1991). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1963). ТАССР чемпионы (1959–65). 1963–65 елларда Казан югары хәрби уч-щесендә физкультура укыта, 1965–75 тә югары спорт осталыгы мәктәбендә тренер, бер үк вакытта «Труд» ирекле спорт җәмгыятенең өлкә советында тренер (Курган ш.). 1975 тән Чаллы шәһәрендә: «КамАЗ» СКның 3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1975–79), «Строитель» стадионында (1979–81) директор; йортлар төзү комб-тында тренер (1981–86), пед. уч-щесендә физкультура укытучысы (1986–89), ТАССР физик культура һәм спорт дәүләт ком-ты үзәк СКнда тренер-укытучы (1985–92), Волгоград физик культура ин-тының Чаллы ф-лында укытучы (1992–2004), «Дельфин» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе балаларга өстәмә белем бирү муниципаль учреждениесендә укытучы (2004 тән). Шәкертләре — Г.В.Алексанова, М.Балабанова, Л.Ф.*Нуретдинова*, С.В.Осетрин, О.Н.Шушарина. Медаль б-н бүләкләнә.

**НУРЕТДИ́НОВ** Шамил Рамил улы (2.8.1956, Балык Бистәсе р-ны Яңа Арыш а. — 24.10.2007, Казан), дискрет математика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2006). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук системалы анализ һәм мәгълүмати технологияләр кафедрасында эшли. Хезмәтләре матем. модельләштерү өлкәсенә карый. Н. мәгълүматның дискрет үзгәрткечләре модельләрен төзү һәм очраклы процессларны модельләштерү мәсьәләләрен чишә. Аның тарафыннан эшләнгән алымнар һәм алгоритмнар интеграль схемалар базисында кулланыла торган автомат модельләрне исәпләүне күпкә җиңеләйтә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Перестраиваемые схемы в системах встроенного тестирования // Автоматика и телемеханика. 1995. № 11 (автордаш); Моделирование цепей Маркова в полях Галуа // Дискретная математика. 2004. Т. 16, вып. 2; Основы теории полиномиальных моделей автоматных преобразований над полем Галуа. К., 2005.

**НУРЕТДИ́НОВ** Ядкәр Кәрам улы (10.11.1947, Әлмәт р-ны Нәдер а.), геофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), геол.-минерал. фән. канд. (2002), Удмурт Респ-касының атказ. нефтьчесе (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1971), «Татнефтегеофизика» АҖдә эшли, ген. директор урынбасары (1998 дән). Дәүләт бүләге эчәргә яраклы су йөртүче катламнарның экологик торышы мониторингы өчен геофизик ысуллар эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**НУРЕТДИ́НОВА** Лилия Фоатовна (20.9.1963, Чистай р-ны Наратъелга а.), спортчы (җиңел атлетика), СССРның атказ. спорт остасы (1991). Кама политехника ин-тын тәмамлый (1987). Профсоюзлар физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Чаллы ш.), тренерлары — Ф.Ш.*Нуретдинов*, П.Ф.Литовченко. Дөнья (1991, 800 *м* га йөгерүдә), Олимпия уеннары (1992, 4×400 *м* эстафетада йөгерүдә) чемпионы, СССР Кубогы иясе (1989, 800 *м* га йөгерүдә). Игелекле уеннарда (1990), СССР чемпионатында (1990), Олимпия уеннарында (1992), СССР халыклары спартакиадасында (1991, 800 *м* га йөгерүдә), СССР Кубогы финалында (1990, 600 *м* га йөгерүдә) көмеш медаль ала. Европа чемпионатында (1990, 800 *м* га йөгерүдә), Яшьләр уеннарында (1981, 1500 *м* га йөгерүдә) бронза медаль ала. 1988–93 елларда СССР, Россия җыелма командалары әгъзасы. 1995–99 да контракт буенча Малайзия җыелма командасы спортчылары б-н эшли. 1999 дан Мәскәүдә яши, «Будь здоров» теннис клубында гомуми физик әзерлек буенча тренер булып эшли.


**НУРИ́** (Нуретдинов) Зәки Шәрәфетдин улы (24.12.1921, Буа кантоны Татар Төкесе а. — 28.2.1994, Казан), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). Мәскәүдә А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый (1957). Бөек Ватан сугышында катнаша, мәшһүр К.Заслонов җитәкчелегендәге белорус партизаннары берләшмәсендә дошман объектларын шартлатучы, разведка отряды башлыгы. 1944–46 елларда Орша шәһәр советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1946–49 да Татарстан урман хуҗалыгында эшли. 1949–51 дә «Яшь сталинчы» г-тасында мөхәррир урынбасары, 1951–55 тә Татарстан китап нәшриятында балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясе мөдире. 1957–63 тә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе җаваплы сәркәтибе, 1971–74 тә аның рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе президиумы әгъзасы (1970–75). 1964–71, 1974–82 дә «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире. Н.ның беренче шигырьләре респ-ка газета-журналларында, сугышка кадәр нәшер ителгән күмәк җыентыкларда чыга. Беренче җыентыгы («Шигырьләр») 1945 тә дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең ныклыгын, батырлыгын сурәтләгән «Дан юлы» (1949), «Чын күңелдән сөйләшү» (1955), «Күтәрелү» (1956) поэмалары, «Без яшибез Иделдә» (1951; рус теленә тәрҗемәсе «Мы живём на Волге», 1956) җыентыклары авторы. Н.ның сугыштан соңгы иҗаты гражданлык пафосы б-н сугарылган, публицистик яңгырашка ия. Халыклар дуслыгы, интернационализм — «Ел буе яз» (1958), рус теленә

тәрҗемәдә басылган «Есть цветы у нас» (1969), «Еллар һәм юллар» (1971), рус теленә тәрҗемәдә басылган «Навстречу дружбе» (М., 1976), «Килә дә китә яз» (1978), «Күңел яктысы» (1980), рус теленә тәрҗемәдә басылган «Озарённость»(М., 1981) җыентыкларының төп темаларыннан берсе. Юмор-сатира әсәрләре, ш.у. балалар өчен язылган шигырьләре фольклор мотивлары б-н сугарылган: «Лирика, юмор, сатира» (1963), «Елмаябыз, көләбез» (1966), «Бу безнең китап» (1967). Н. — ш.у. Бөек Ватан сугышы елларында Белоруссиядәге партизаннар хәрәкәте турында «Үлгәннәр дә үч алды» (1962; рус теленә тәрҗемәсе «И мёртвые мстили», 1976) исемле хикәяләр җыентыгы, Түбән Кама шәһәре төзүчеләре хезмәтенә багышланган «Батырлар һәм матурлар» (1965) исемле очерклар җыентыгы авторы да. Төрле халыкларның фольклор әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп, «Күңелле китап» (1969; 2 нче басма 1979) һәм «Алтын хәзинә» (1973) исемле китаплар бастырып чыгара; А.Твардовский, Н.Некрасов, С.Щипачёв, Мәхтүмколый, Я.Колас, Я.Купала әсәрләрен тәрҗемә итә. Аның китаплары рус, казакъ, әзәрбайҗан, белорус, мари, якут телләренә тәрҗемә ителә. 1961–68, 1974–78 дә ТАССР ЮС депутаты. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Халыклар Дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Орша шәһәренең Мактаулы гражданы.

*Әд.:* Х и с а м о в Н. Заман һәм шагыйрь // Казан утлары. 1975. № 2; М ө х ә м м ә д и е в Р. Иманлектән башланган юл // Якутлар табыладыр вакыт беләп. К., 1983.

*Г.М.Габделхакова.*

**НУРИӘХМӘ́Т бине́ ВӘЛИӘХМӘ́Т** (22.12.1880, Самара губ., Бөгелмә өязе Әлмәт а. — ?), ташка уеп бизәк ясаучы, хаттат. 20 йөзнең 1 нче чирегенә кадәр Әлмәттә яши, Әлмәт, Бигәш (хәзер Әлмәт ш. чигендә), Мәлбәгыш (хәзер Азнакай р-нында) һ.б. авылларның зиратларында кабер ташлары әзерләү һәм бизәү б-н шөгыльләнә. Н. бине В. эшләгән кабер ташларының өске өлеше ярымтүгәрәк формада төгәлләнгән, алгы ягына Коръән аятьләре урнаштырылган. Язуларның композициясе ачыклыгы һәм нәфислеге б-н аерылып тора, текстлар «сөлес» стиле б-н, батынкы-график техникада язылган. Бизәкләре юк. Кайбер ташларның ян-ягында сырлап ясалган бизәкләр бар. Н. бине В. үзенең хезмәтләренә «язучы Нури», «кятиб Нуриәхмәт», «эшләүче Әлмәттән Нури» дип кул куйган.



Н у р и ә х м ә т б и н е В ә л и ә х м ә т. Кабер ташы. Ташка уеп бизәк төшерү. 1911. Әлмәт ш.

*Әд.:* Ә х м ә т җ а н о в М. Үлгәннәрнең каберен бел. К., 2000.

**НУРИӘХМӘ́ТОВ** Фирдант Сәлимҗан улы (5.12.1961, БАССРның Караидел р-ны Караяр а.), сынчы, педагог. Уфа сәнгать уч-щесен (1981), Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1989). 1990 елдан З.Исмәгыйлев исем. Уфа сәнгать академиясенең сынлы сәнгать ф-тында укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1993). Заманча скульптур пластика өлкәсендә, бигрәк тә модернизм стилендә эшләүче танылган осталарның берсе. Мәрмәр, гранит, габбро, доломит, известьташ, бронза, алюминий, кургаш кулланып, станлы, монументаль-декоратив һәм парк скульптурасы, медальер сәнгате әсәрләре иҗат итә. Металл, агач, папье-маше, буялган киндер, ясалма материаллардан монтажланган объектлар авторы. Н.ның 10 нан артык әсәре скульптура симпозиумнары вакытында иҗат ителгән һәм Уфа, Казан, Пенза, Рязань, Элиста, Ростов-Дон һ.б. шәһәрләрдә куелган: «Әсир» (Уфадагы парк, 1990), «Кеше-тәхет» (Рязань курчак театры каршындагы мәйданчык, 1993), «Вакыт» (Пенза урамнарының берсендә, 1994), «Казанга багышлау» («Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы мәйданчык, 1996), «Тулпар» (Уфа, 1999), «Ай колоннасы» (Уфа, 2002–05). Рәссамнар портретлары («Н.Калинушкин», 1990; «М.Назаров», 1997; «Юкин», «Кокурин», икесе дә — 2000), тематик композицияләр («Эпитафия», 1989, «Чагылдыру», 1991; «Мәхәббәт колоннасы», 1992–94 һ.б.), вак пластикалар («Таң кошы», 2003) авторы.



Ф.С. Н у р и ә х м ә т о в. «Ай колоннасы». Декоратив скульптура. Катнаш техника. 2002–05. Уфа ш.

Халыкара (Элиста ш., 1997; Сент-Жорж де Кото ш., Франция, 1998; Уфа, 1999; Кутаиси ш., 2001; Петергоф ш., 2005) һәм Россия скульптура симпозиумнары («Таштагы сын», Уфа, Пенза, Ростов-Дон, Рязань, Азов, Казан, Мәскәү, 1988 елдан), бөтенсоюз скульптура (Мәскәү, 1991), «Татарт» бөтентатар төбәкара (С.-Петербург-Казан, 1991) күргәзмәләрендә, халыкара «Арт-Манеж» сәнгать ярминкәсендә (Мәскәү, 1996; 1997) катнаша. Шәхси күргәзмәләре Мәскәүдә (1996, К.*Габәйдуллин*, И.Тонконогий б-н берлектә), Уфада үткәрелә. Әсәрләре Третьяков галереясында (Мәскәү), М.В.Нестеров исем. Башкорт сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Рязань өлкә сәнгать музеенда, «Урал» хәзерге заман сәнгать галереясында (Уфа), Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. «Сәнгатьтә тарих» респ-ка күргәзмә-конкурсы (Уфа, 1999, «Скульптура» номинациясендә 1 нче бүләк), халыкара «Таштагы сын» симпозиумы (Кутаиси ш., 2001, Россия СА дипломы), 9 нчы «Зур Идел» күргәзмәсе (Саранск ш., 2004) лауреаты.



Ф.С. Н у р и ә х м ә т о в. «Таң кошы». Бронза. 2003. Уфа ш.

*Әд.:* Фирдант Нуриахметов // Информель. Живопись. Графика. Скульптура. Ассамбляж. Уфа, 1997; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Объекты: Каталог выставки. Уфа, 2005.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НУРИ́ЕВ** Габделхак (Габдулла) Гаделша улы (6.2.1922, Арча кантоны Иске Мәңгәр а. — 16.2.2004, Казан), мед. фән. д-ры (1982), ТАССРның атказ. табибе (1989). Казан мед. ин-тын тәмамлагач (1950), шунда ук тире авырулары һәм венерик авырулар кафедрасында эшли. 1954–57 елларда Респ-ка клиник хастаханәсенең тире-венерология диспансерында баш табиб урынбасары. 1961 дән Казан мед. ин-тының дерматовенерология каф. мөдире, проф. (1983), 1990 нан — проф.-консультант. Хезмәтләре тире авырулары патогенезында микроблы аллергия һәм аутоаллергия мәсьәләләренә карый. Н. стрептококка һәм стафилококка аллергиясе булган хроник дерматозлы авырулар өчен үзенчәлекле гипосенсибилизация терапиясе ысулын эшләп тәкъдим итә. Татарстан дерматовенерологлары фәнни җәмгыяте рәисе (1989 дан). Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы,

Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Роль аллергических и аутоаллергических факторов в патогенезе микробной экземы // Вестн. дерматологии и венерологии. 1971. № 11; Случай гипертрофического твёрдого шанкра // Вестн. дерматологии и венерологии. 1980. № 9; Специфическая гиперсенсибилизирующая терапия больных дерматозами растворимыми бактериальными аллергенами // Вестн. дерматологии и венерологии. 1987. № 7.

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; Профессор Габдул Гадельшевич Нуреев // Казан. мед. журн. 2002. № 1.

*В.Ф.Богоявленский.*


**НУРИ́ЕВ** Габдрәүф Салих улы (10.1.1951, Арча р-ны Урта Бирәзә а.), филолог, филол. фән. д-ры (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Казан мәдәният ин-тын (1977), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, 1980) тәмамлый. 1977–78 елларда ТАССРның Мәдәният министрлыгында методист, 1978–80 дә ГИТИСның сәхнә сөйләме кафедрасында. 1980 нән ТАССР Мәдәният министрлыгы каршындагы фәнни-методик үзәктә инспектор, бүлек мөдире. 1989 дан Казан театр уч-щесендә укыта. Хезмәтләре театр сәнгате поэтикасына, татар сәхнә сөйләмен укыту методикасына карый.

Х е з м.: Татар сәхнә сөйләме. К., 1998; Татар классик драматургия поэтикасы. К., 1999; Дөрес һәм анык сөйләм. К., 2005; Сәнгатьле сөйләм. К., 2005; Лингвистическая поэтика татарской драматургии. К., 2002.

**НУРИ́ЕВ** Наил Кашшаф улы (12.1.1952, Әтнә р-ны Иске Мәңгәр а.), педагог, математик, техник фән. канд. (1984), пед. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан техник ун-тында информатика һәм гамәли математика кафедрасында эшли, 2002 елдан каф. мөдире. Хезмәтләре инженер-программистлар әзерләү мәсьәләләренә карый. РФнең мәгариф өлкәсендәге дәүләт бүләге лауреаты (2013)

Х е з м.: Экстремальная методология в дидактике программной инженерии. К., 2004; Дидактическое пространство подготовки компетентных специалистов в области программной инженерии. К., 2005.

**НУРИ́ЕВ** Рудольф Хәмит улы (17.3.1938, Иркутск ш. — 6.1.1993, Париж, Сен-Женевьев-де-Буа зиратында җирләнә), хәзерге заман балетының мәшһүр артисты, балетмейстер. Бию сәнгатенә Уфа шәһәре балалар хореографик коллективларында педагоглар А.Удальцова һәм Е.Войтовичта өйрәнә башлый. 1958 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагогы А.Пушкин) тәмамлый. 1958–61 дә С.М.Киров исем. Ленинград опера һәм балет акад. театрында балет солисты. Н. СССР сәнгать эшлеклеләре арасында чит илләрдән «кире кайтмаучыларның» берсе була. 1961 дә Франциядә Ленинград опера һәм балет театры гастрольләре тәмамлангач, шунда калырга теләп, сәяси сыену урыны сорый. 1962 дә, «иленә хыянәт итүче» буларак, үзеннән башка үткәрелгән мәхкәмә карары б-н 7 елга ирегеннән мәхрүм ителә. 1962–81 дә Король балетында (Бөекбритания) «даими чакырылучы солист» буларак эшли.



Р.Х. Нуриев.

Н. үзенең төп партнёры — аның сәхнә карьерасын үстерүгә зур булышлык күрсәткән күренекле балерина М.Фонтейн б-н бергә кабатланмас дуэт тудыра. 1981–83 тә бу сәхнәдә ул аз чыгыш ясый. Бер үк вакытта, 1970–83 тә, күп илләрнең балет труппаларында солист һәм сәхнәгә куючы. 1983–89 да Париж театрының балет труппасы директоры (сәнгать җитәкчесе), «Гранд-Опера» театры балетмейстеры, шунда ук биюче булып чыгышлар ясый. 1992 дә бию карьерасын төгәлли, дирижёр буларак чыгышлар ясый башлый.

1959 да, 7 нче Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивалендә (Вена) катнашканы өчен, алтын медаль б-н бүләкләнә. Совет чоры эшчәнлегендә СССР шәһәрләрендә, Болгариядә, Мисырда, ГДРда гастрольләрдә була. Альберт («Жизель», А.Адан), Дезире, Зигфрид («Йокыга талган гүзәл», «Аккош күле», П.Чайковский), Базиль, Солор («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Фрондосо («Лауренсия», А.Крейн), Армен («Гаянэ», А.Хачатурян) хореографик партияләрен башкара.

Чит илләрдә балет һәм хореография композицияләрендә 120 дән артык партия, ш.и. Альберт («Жизель», А.Адан), Яшүсмер («Шопениана», Ф.Шопен музыкасына), Петрушка (шул исем., И.Стравинский), Жан де Бриен («Раймонда», А.Глазунов), Ромео һәм Меркуцио («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Фавн («Фавнның төшке ялы», К.Дебюсси музыкасына), баш роль («Юлдан язган угыл», С.Прокофьев музыкасына) партияләрен башкара. Бер үк вакытта, 1963 тән, балетмейстер. Король балеты өчен М.Петипа редакциясендә Л.Минкусның «Баядерка» (1963) балетыннан «Күләгәләр»не, А.Глазуновның «Раймонда» (1964), В.Чабукиани редакциясендә А.Крейнның «Лауренсия»



Р.Х. Н у р и е в  Принц ролендә («Щелкунчик», П.И. Чайковский). 1959.

(1964) балетыннан па-де-сисны, П.Чайковскийның «Щелкунчик» (1968) балетын, П.Чайковский музыкасына У.Шекспир пьесасы буенча «Давылда» әсәрен сәхнәгә куя. «Гранд-Опера»да Зигфрид, Ротбарт («Аккош күле», П.Чайковский), лорд Байрон («Манфред», П.Чайковский музыкасына үзенең оригиналь хореографиясендә) партияләрен һәм төп ирләр партиясен («Мөкатдәс яз», И.Стравинский) һ.б.ны башкара. Н.ның хореографик постановкалары арасында И.С.Бах музыкасына «Сюита» (1984), Ш.Ив музыкасына Г.Джеймс романы буенча «Вашингтон мәйданы», С.Прокофьевның



«Рудольф Нуриев». З.К.Церетели. Горельеф. Бронза. 2000.

«Золушка», П.Чайковскийның «Щелкунчик» (барысы да — 1985), Л.Минкусның «Баядерка» (1992) балетлары бар. Ел саен 200–300 балет спектаклендә чыгыш ясый, күп илләрнең телевизион постановкаларында, сәнгать фестивальләрендә катнаша; 1974–91 дә «Нуриев һәм аның дуслары» антреприза концертлар циклы турнесын үткәрә.

Н. бию техникасының иң югары дәрәҗәсенә ирешә, романтик пландагы бөек биюче исеменә лаек була. Ул балетта ирләр партияләрен башкару осталыгы үсешенә зур өлеш кертә, аны элек ирешелмәгән дәрәҗәгә күтәрә, аяк очларында гадәттән тыш югары күтәрелештә бии, әйләнү хәрәкәтләрендәге яңа торышларны (ракурслар) беренче булып үзләштерә башлый. Н.ның биюен көч, дәрт, бәйсезлек аерып тора. Ул үзенең сөйкемлелеге, осталыгы б-н әсир итә һәм сәхнәгә җәлеп итү көченә ия була. Классик балетта һәм заманча бию сәнгатенең төрле стильләренә нигезләнгән постановкаларда партияләрне бертигез дәрәҗәдә уңышлы башкара. Н. өчен балетлар һәм хореографик композицияләрне атаклы балет театры осталары Дж. Баланчин, Ф.Аштон, К.Макмиллан, Р.Пети, П.Тейлор, М.Грехем һ.б. куя.

Дирижёр булып, Ф.Гайдн, В.Моцарт, Л.ван Бетховен, С.Прокофьев, И.Стравинский, П.Чайковский һ.б.ның әсәрләреннән төзелгән репертуар б-н Вена, Афина, Нью-Йорк шәһәрләрендә чыгышлар ясый.

29 фильмда төшә, шулар арасында — «Ромео һәм Джульетта» (1964), «Яшүсмер һәм үлем» (1966), «Дон Кихот» (1973) фильм-балетлары; «Мин — биюче» (1972) документаль фильмы бар, «Валентино» (1977) нәфис фильмында төп рольне, «Фаш ителгән» (1983) фильмында ялгыз скрипкачы ролен һ.б.ны башкара.

Эмиграциядән соң Россиягә беренче тапкыр 1987 елда кайта. 1989 да Ленинград опера һәм балет театрының 5 спектаклендә Джеймс («Сильфида», Х.Левенсхольд) партиясе б-н чыгыш ясый. 1992 нең маенда Казанга кайта, Казанның Зур концерт залында ТР Дәүләт симф. оркестрына (С.Прокофьевның «Ромео һәм Джульетта» балеты музыкасыннан кисәкләр) һәм соңыннан 6 нчы классик балет фестивалендә Татар опера һәм балет театрында П.Чайковскийның «Щелкунчик» балетына дирижёрлык итә. Шәрәфле легион ордены, Сәнгать һәм әдәбиятның Командор ордены кавалеры (Франция, 1990). Австриянең мактаулы гражданы (1983).

Казанда, 1987 дән башлап, ел саен балет фестивале (1993 тән Н. исем.) үткәрелә. 1993 тән Н. истәлегенә балет фестивальләре Уфа шәһәрендә оештырыла. Башкорт хореография уч-щесенә Н. исеме бирелә. Н. образы сынлы сәнгатьтә гәүдәләндерелә (З.К.Церетели, А.Ә.Абызгилдин).

*Әд.:* Г о р ш к о в В.Н. Рудольф Нуриев: Судьба и танец. К., 1995; Р ю н т ю М.Р. Руди Нуриев без макияжа. М., 1995; Рудольф Нуриев: Фотоальбом. СПб., 1998; С т ю а р т О. Рудольф Нуриев: Вечное движение. Смоленск, 1998; Рудольф Нуреев. Автобиография. М., 2000; И ш м у р а т о в Р., М а г д е е в М. Знаки Рудольфа. К., 2007; шулар ук. Нуреев в Казани. К., 2008; С и н е н п о С. Рудольф Нуреев: Истоки творчества, превратности судьбы. Уфа, 2008; Н а д е ж д и н Н.Я. Рудольф Нуриев. М., 2011.

*В.Н.Горшков.*

**НУРИ́ЕВ Р. ИСЕМЕНДӘГЕ́ КЛА́ССИК БАЛЕ́Т ФЕСТИВАЛЕ́.** ТАССР Мәдәният министрлыгы һәм Татар опера һәм балет театры б-н берлектә оештырыла. Ел саен май аенда уздырыла (2005 елда Татар опера һәм балет театры бинасын реконструкцияләү вакытында үткәрелми). Беренче фестиваль 1987 нең 12 маенда А.Аданның «Жизель» балеты б-н ачыла. 1–5 фестивальләр Россия күләмендә уздырыла, 6 нчы фестиваль (1992) халыкара статус ала. 1992 нең 12 маенда П.И.Чайковскийның «Щелкунчик» балетында легендар биюче Рудольф Нуриев дирижёрлык итә, 1993 тә фестивальгә аның исеме бирелә.

Төрле вакытта фестивальдә күренекле балет башкаручылар: В.Васильев, И.Васильев, Е.Максимова, М.Ивата, И.Душкевич, А.Моңтаһиров, И.Думпе, Н.Яковлева, Ю.Карлин, Л.Мөсәвәрова, А.Әхмәтов, И.Кирсанова, Н.Павлова, Ю.Петухов, С.Фечо, У.Лопаткина, Ю.Махалина, Е.Князькова, Е.Березина, Н.Ледовская, В.Дик, Т. һәм А. Ратманскийлар, В.Кириллов, Р.Усма, Г.Комлева, Д.Матвиенко, Ф.Фогель, М.Аллаш һ.б. дөнья балеты йолдызлары катнаша. Дирижёр пульты артында Н.Депонте, И.Лацанич, В.Рылов, В.Соболев һ.б. чыгыш ясый.



1



2

Р.Нуриев исем. классик балет фестивале. 1. «Баядерка» балеты, Л.Минкус. Солор – А.Әхмәтов, Гамзатти – И.Шапчиц. Мәскәү; 2. «Дон-Кихот» балеты, Л.Минкус. Базиль — И.Галимуллин. Мәскәү.

Фестиваль «классик» балет дип атала, әмма төрле илләрдә аның кунаклары сыйфатында классик һәм ш.у. заманча юнәлештәге солистлар һәм балет коллективлары: Балалар һәм яшүсмерләр муз. театры (Киев ш.), Борис Эйфман балет театры (С.-Петербург), «Мәскәү» Рус камера балеты, Брауншвейг шәһәре балет труппасы (Германия), «Мәңге яшел шәһәр балеты» (Портсмут ш., АКШ), Рус империя балеты (Мәскәү) һ.б. катнаша. Фестивальне күп еллар дәвамында идея ягыннан рухландыручы һәм төп оештыручыларның берсе — балет тәнкыйтьчесе Н.Садовская (Мәскәү). Фестивальнең сәнгать җитәкчесе — В.Яковлев. 26 нчы фестиваль 2013 тә үткәрелә.

*В.Н.Горшков.*





Фестиваль афишасы. 2012.

**НУРИ́ЕВА** Фәнүзә Шәкүр кызы (8.3.1956, Баулы р-ны Иске Чүте а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2005), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), Баулы р-нының Байрак-Тамак мәктәбендә укыта. 1989 елдан Казан ун-тында, татар теле тарихы һәм гомуми тел белеме каф. мөдире (2008 дән). Хезмәтләре 13 йөз — 15 йөз башы татар әдәби теле тарихына, борынгы төрки ядкәрләр теленә карый.

Х е з м.: Борынгы төрки рун язмалары: Күлтәгин һәм Тоньюкук ташлары // История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1; Борынгы төрки тел. Орхон-Енисей язмалары (VII–VIII гасырлар). К., 2007; «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Булгари. К., 1999; Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода. К., 2004; Атрибуция языка письменных памятников золоордынского периода. Астана, 2011.

**НУРИМА́Н РАЙОНЫ́**, БРда урнашкан. 1930 елда оештырыла. Мәйданы — 2634 *км²*. Үзәге — Красная Горка авылы (Уфадан 100 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 20723 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 12844, 1979 да — 10001, 1989 да — 8735, 2002 дә — 6863, 2010 да — 5824 кеше. Районда 51 торак пункт, ш.и. 10 татар, 6 башкорт-татар, 4 татар-рус, 3 башкорт-татар-рус, 1 башкорт-мари-татар авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары (2009): Нимесләр (771 кеше) һәм Байгилде (449). Элегрәк төзелгән авыллар — Бикморза (1651) һәм Үкәрле (1660 еллар тирәсе). 2002 дән Байгилде авылы мәдәният йорты каршында «Ихлас» татар фольклор коллективы (2012 дән халык коллективы исемен йөртә) эшли. 2004-05 уку елында районның 5 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 5 сендә татар теле дәрес булараk укытыла.



Т.Л.Нуркәев.

**НУРКӘ́ЕВ** Талип Латыйп улы (9.3.1925, хәзер БРның Бакалы р-ны Үстем а. — 24.9.1997, БРның Октябрьский ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), гв. капитаны. Уфа хәрби пехота уч-щесен тәмамлый (1946). Сугышка кадәр туган авылында умартачы булып эшли. 1943 елның февраленнән Кызыл Армия сафларында. 1943 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 105 нче гв. укчы полкында автоматчы (46 нчы армиянең 34 нче гв. укчы дивизиясе). 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен (1943) сугышта, Уңъяк яр Украинаны азат итүдә (1943–44), Яссы-Кишинёв (1944), Будапешт (1944–45) һәм Вена (1945)

һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 17–18 апрелендә Раскаецы авылы (Молдавия ССРның Суворов р-ны) янында Днестр елгасының уңъяк ярындагы плацдарм өчен сугышта батырлык күрсәтә: гв. лейтенанты Б.С.Васильев-Кытин җитәкчелегендәге ун сугышчыдан торган төркем составында граната б-н дошманның күзәтү пунктын шартлата, 18 солдатын юк итә. 1947 дән запаста. Октябрьский шәһәрендә яши. 1951–88 дә «Туймазынефть» НГДУында нефть һәм газ чыгаруда өлкән оператор, бригадир булып эшли. Пенсиягә чыкканнан соң, сугыш һәм хезмәт кораллы көчләр ветераннарының шәһәр советын җитәкли. Фән һәм техника өлкәсендә СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). Ленин ордены, Октябрь рев-циясе, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**НУ́РКИН** Заһид (Заһидулла) Садретдин улы (1888, Тамбов губ., Спас өязе Сургодь а. — 11.6.1966, Казан), журналист, тәрҗемәче. Мулла гаиләсендә туа. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен (1918), Мәскәү ун-тының юридик ф-тын (1928) тәмамлый. 1922–27 елларда ТАССР Академүзәге редколлегиясенең фәнни сәркәтибе, 1928–30 да ТАССР ХКСның Дәүләт план ком-ты икътисадчысы, 1931–32 дә Казан төзүче инженерлар ин-тында политэкономия укытучысы, 1931–38 дә Татарстан китап нәшриятында әдәби хезмәткәр. Журналистлык эшчәнлеген 1913 тә «Кояш» г-тасында башлый. «Ярдәм кирәк», «Татар графикасы», «Авыл мәгарифе реформасы һәм без» һ.б. мәкаләләрендә Н. укытучыларның авыр хәлләре турында яза, укытуны тормышка якынайту, татар теле орфографиясендә бердәм кагыйдәләр булдыру кирәклеген әйтә. «Сәйяр» труппасы куйган спектакльләргә рецензияләр язып, Г.Болгарская, Ф.Ильская, Г.Кариев, К.Тинчурин һ.б. актёрларның иҗатын анализлый. М.Сервантесның «Дон Кихот» (1929), Л.Толстойның «Отец Сергий» (1930), И.Тургеневның «Муму» (1930) әсәрләрен, В.И.Ленин һәм К.Маркс хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итә. Башлангыч мәктәпләр өчен уку ярдәмлекләре төзүдә катнаша («Туган тел», 1–4 кис., 1916–18; «Татарча уку», 1920; «Яңалиф», 1929). 1932–33 тә «*Милләтчеләрнең контрреволюцион-фетнәчел оешмасы*» эше буенча мәхкәмә тикшерүенә җәлеп ителә.

*Ф.И.Ибраһимова.*

**НУРЛА́Т** (Норлат) шәһәре, респ-ка карамагындагы шәһәр. ТРның көньягында, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Ульянов–Уфа тимер юл станциясе. Аэропорт. Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Чистай, Самара, Ульянов, Тольятти шәһәрләренә автобус юллары уза. Казаннан 220 *км* ераклыкта урнашкан. Мәйданы — 7,6 *км²*. 2014 елда 33,3 мең кеше (2002 елгы халык саны буенча, татарлар — 58,8%, руслар — 20,7%, чуашлар — 19%) яши. 1909 да Сембер–Уфа тимер юлы төзелешенә бәйле рәвештә нигез салына, 1911 дән Н. — тимер юл станциясе. Оештырылган көннән Самара губернасының Мәләкәс өязе Шлама волостенда, 1928 нең 23 гыйнварыннан ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-ны үзәге. 1938 нең 28 августыннан — шәһәр тибындагы эшчеләр посёлогы, 1961 нең 10 июненнән — район, 1997 нең 10 декабреннән — респ-ка карамагындагы шәһәр. Хәзерге Н. — ТРда социаль һәм икътисад өлкәсендә кызу темплар б-н үсүче шәһәрләрнең берсе. 1990 еллар ахырыннан яңа микрорайоннар төзелә, сәнәгать, мәдәният, спорт һәм социаль өлкәдә күп кенә объектлар корыла һәм реконструкцияләнә, шәһәрне төзекләндерү һәм инфраструктураны яхшырту буенча чаралар үткәрелә. Н.та нефть чыгару пр-тиеләре (*«Нурлатнефть»* НГДУы, «Татнефтепром — Зүзәйнефть», «Кондырчанефть», «Татнефтьбораулау» ҖЧҖнең Нурлат бораулау эшләре идарәсе һ.б.) һәм азык-төлек сәнәгате (*Нурлат шикәр заводы*, аракы-ликёр з-ды, «Нурлат сөте» ҖЧҖ, Нурлат-Октябрь ит комб-ты, икмәк з-ды, элеватор), машиналар төзү (Нурлат машиналар төзү з-ды), төзелеш материаллары сәнәгате (тимер-бетон җиһазлар җитештерү з-ды, төзелеш материаллары комб-ты, кирпеч һәм асфальт з-ды) пр-тиеләре урнашкан (2010). Шәһәрнең икътисади үсешендә «Нурлатнефтепродукт» һәм «Нурлатгаз» АҖ мөһим роль уйный. Н.та гимназия, 6 гомуми белем бирү мәктәбе, һөнәри лицей; Казан а.х. академиясе, Мәскәү икътисад, статистика һәм информатика ун-ты ф-ллары; Әлмәт нефть ин-ты һәм ТИСБИ идарә академиясе вәкиллекләре, Казан технол. ун-ты каршындагы университетка керү өчен әзерлек көллияте эшли. Мәдәният йорты, «Нефтьчеләр» мәдәният йорты, Яшьләр йорты, балалар сәнгать мәктәбе, балалар-яшүсмерләр үзәге; үзәк хастаханә, «Ана һәм бала» мед. үзәге; боз сарае «Ледок», стадион, ипподром, 2 спорт-савыктыру комплексы, 3 ябык бассейн, 2 теннис корты, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 10 нан артык китапханә, Кама аръягы һәм Н. шәһәре тарихы музее эшли. Мәчет һәм Преподобный Серафим Саровский, Илья пәйгамбәр православие храмнары бар. «Нурлат» телерадиокомпаниясе эшли. Халык саны: 1928 дә — 254 кеше, 1939 да — 4,5 мең, 1959 да — 12,7 мең, 1970 тә — 17,5 мең, 1979 да — 23,5 мең, 1989 да — 23,5 мең, 2002 дә — 32,5 мең кеше.

*Әд.:* Нурлат — время перемен. К., 2004.

*А.И.Ногманов.*

**НУРЛА́Т НЕФТЬ ЧЫГАНАГЫ́**, ТРның көньягындагы иң зур чыганакларның берсе. Нурлат р-нында урнашкан. Мәләкәс иңкүлегенең көнчыгыш чигенә туры килә. 1956 елда ачыла. 1975 тән эшкәртелә. Сәнәгый катламнары — югары девонның (кын горизонты) комсу-алевролитлы токымнары һәм урта карбонның 915 тән 1950 *м* га кадәр тирәнлектә ятучы карбонатлы һәм комсу утырмалары. Үтешлелеге 0,2 дән 1,2 *мкм²* га кадәр булган токым-коллекторлар күзәнәкле һәм күзәнәкле-ярыкланган типта. Ятмалар катламлы гөмбәзсыман, литологик һәм зур күләмле. Башлангыч катлам басымы 8 дән 17,5 *МПа* га кадәр. Нефтьнең тыгызлыгы 870–924 *кг/м³*, темп-ра 20 °С булганда, үзлелеге 14,8–69,3 *МПа*, күкертлелеге 1,76–4,2%, парафинлылыгы 2,4–4,1%, газ факторы 38–41,3 *м³/т*. Төп файдалы объектлары — кын һәм бобрики горизонтлары, аерым скважиналар б-н нефть башкорт һәм верей катламнарыннан чыгарыла. Чыганак катлам басымын тотып эшкәртелә. Үзләштерү ысуллары — тирәннән насос б-н һәм электр б-н үзәктән куу. Нефть дебиты тәүлегенә 3,3 *т*. Баланстагы нефть запасы якынча 100 млн. *т* һәм чыгарылучысы 16 млн. *т* дан артык. 5,1 млн. *т* га якын нефть чыгарылган. Еллык макс. чыгарылыш 247,7 мең *т* (1989). Нефть бирүчәнлеге 0,05.

*А.Х.Хәсәншина.*


**НУРЛА́Т РАЙОНЫ́**, ТРның көньяк өлешендә, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 2293,7 *км²*. 26 авыл җирлеген, 82 торак пунктны үз эченә ала. Үзәге — *Нурлат* шәһәре. 2012 елда халык саны — 26795 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 44,6%, чуашлар — 36%, руслар — 18,3%); халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км²* га 11,7 кеше. Район 1930 ның 10 августында Октябрь р-ны буларак оештырыла.







Нурлат шәһәре. 1. Тимер юл вокзалы; 2. Шәһәр һәм район хакимияте бинасы; 3. Мәдәният сарае.




Район терр-ясе 1920 гә кадәр Самара губернасының Мәләкәс өязе һәм Казан губернасының Чистай өязләренә керә, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1928 дә берничә торак пункт, ш.и. Нурлат тимер юл станциясе посёлогы да (1961 дән — Нурлат ш.) Самара губернасыннан ТАССР составына күчерелә. Оештырылганда район 44 авыл советын, 117 торак пунктны берләштерә, аларда 48201 кеше (татарлар — 16800, руслар — 13568) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 нең 10 февралендә Октябрь р-ныннан *Тельман районы* бүленеп чыга. 1940 та аның мәйданы — 1119 *км²*, халкы — 45,3 мең кеше, 33 авыл советы, 84 торак пункт була. 1958 нең 16 июлендә таркатылган Тельман р-ның бер өлеше Н.р.на кушылгач, район терр-ясе 1744,8 *км²* га җитә, анда 1 посёлок һәм 18 авыл советы, 111 торак пункт исәпләнә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, 1963 нең 1 февралендә Октябрь р-нына Аксубай р-ны, Биләр һәм Беренче Май р-нnарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3635 *км²*, халкы — 123,7 мең кеше, 40 авыл советын, 233 торак пунктны берләштерә. ТАССРда адм.-терр. бүленеш үзгәрү сәбәпле, 1965 нең 12 гыйнварында район терр-ясе — 2146 *км²*, халык саны — 72,1 мең кеше, авыл советлары — 20, торак пунктлар 113 кә кала. 1997 нең 10 декабрендә Октябрь р-ны Нурлат р-ны итеп үзгәртелә.

Н.р.ның рельефы — тигезлек (биеклеге 100–150 *м*): Олы Сөлчә, Кондырча елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, типик, көлсуланган кара, кара төстәге болын, карасу-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 35% ы — урманлык. Нефть, газ, торф, бентонитлы балчык ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Олы Чирмешән* һәм *Олы Сөлчә* елгалары, Кара Күл күле, *Биләр аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә бронза, элгәреге тимер гасыр, болгар чорының 100 гә якын археол. истәлекләре табыла. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау тармаклары үскән. А.х. җирләре — 112,1 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 88,4 мең *га* (2010). Сабан бодае һәм көзге бодай, арыш, солы, тары, борчак игелә; шикәр чөгендере, бәрәңге үстерелә. 2010 да районда 16 а.х. пр-тиесе, 32 фермерлык хуҗалыгы эшли. «Нурлат җиләк-җимеш питомнигы» ҖЧҖ бар. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан. Н.р. терр-ясеннән Ульянов–Уфа тимер юлы, Чистай–Нурлат автомобиль юлы уза. Районда (район үзәген дә кертеп) 34 гомуми белем бирү мәктәбе, 16 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 57 клуб, 48 китапханә, 1 хастаханә, 1 амбулатория эшли. Татар, рус һәм чуаш телләрендә «Дуслык» — «Дружба» — «Туслах» район г-талары нәшер ителә.

*Әд.:* Нурлат — время перемен. К., 2004.

**НУРЛА́Т УРМАНЧЫЛЫГЫ́**, Нурлат һәм Аксубай р-ннары терр-яләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1931 елда Октябрь урман хуҗалыгы буларак оештырыла. Берничә тапкыр үзгәртелә. 1963–92 дә — Октябрь урман сәнәгате хуҗалыгы, 1998 дән — Нурлат урман хуҗалыгы, 2007 дән — Н.у. Урманчылыкның гомуми мәйданы 88545 *га*. 6 урманчылык — Восход (11796 *га*), Чияле Алан (12133 *га*), Мамык (16938 *га*), Тимерлек (17486 *га*), Тумба (16668 *га*), Чулпан (13504 *га*) участокларыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан 84478 *га*, ш.и. йомшак яфраклы токымнар 65329 *га*, ылыслылар — 10596 *га*, каты яфраклылар 8553 *га* тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: усак (36,9%), каен (21,6%), юкә (14,1%), имән (8,7%), ш.и. биек кәүсәле имән (6%), кара зирек (4,6%), нарат (8,4%), чыршы (3,7%) һ.б. Өстенлек итүче урман типлары: сырмавыклы каенлыклар һәм усаклыклар, төрле үләнле юкәлекләр. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар (30,1%), урта яшьтәгеләре (31,7%), өлгереп килүчеләре (18,7%), өлгергәннәре һәм картайганнары (19,5%). Ел саен 85–100 *га* мәйданда урман культуралары, 40 *га* мәйданда а.х. җирләрен ышыклау утыртмалары булдырыла. Мәйданы 10 *га* булган питомникта елына 8 млн. данәгә кадәр утырту материалы үстерелә. С.З.Щербаков (1968), М.В.Кузнецов (1999), Р.М.Мәхмүтов (2007) — «РСФСРның (РФнең) атказ. урманчысы» исеменә, А.Н.Семёнов (2002) «ТРның атказ. урманчысы» исеменә лаек була.

*Р.Ш.Ганиев.*

**«НУРЛА́Т ШИКӘРЕ́»**, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе. Нурлат шәһәрендә урнашкан. Эшләүчеләр саны — 426 кеше (2012). 1958 елда Нурлат шикәр з-ды буларак файдалануга тапшырыла (тәүлеккә 1200 *т* шикәр чөгендере эшкәртүгә исәпләнә). 1994 тән АҖ, 2000 нән хәзерге исемдә. Шикәр чөгендереннән шикәр комы эшләп чыгара. 1960 та тәүлеккә 200 *т* рафинад шикәр җитештерүче зур цех сафка баса. Пр-тиедә яңа җиһазлар гамәлгә кертелә, технол. камилләштерелә. 1963 тә юу бүлегендә тәүлеклек җитештерүчәнлеге 1500 *т* булган 2 линия урнаштырыла. 1970 елларда парландыру станциясе алыштырыла, суыту буасы төзелә, завод әйләнешле тәртиптә су б-н тәэмин ителә башлый; 1980 елларда известь бүлегендә реконструкция уздырыла, диффузия согын фильтрлау җиһазлары алыштырыла. Пр-тие елга 20–25 мең *т* шикәр комы, 30–50 мең *т* рафинад шикәр (1961–97) җитештерә.

1990–2000 дә продукция һәм юу бүлекләре реконструкцияләнә: үзәктән кугычлар, шикәр комын киптерү барабаны алыштырыла, диффузия аппаратлары урнаштырыла. Нәтиҗәдә, пр-тиенең шикәр чөгендерен эшкәртүдә тәүлеклек куәте 2 мең *т* га җиткерелә. З-дта шикәр чөгендерен эшкәртүне автоматлаштыру, җитештерү куәтләрен үстерү юнәлешендә эшләр алып барыла. 2008–12 дә з-дта инновация алымнары нигезендә реконструкция үткәрелә һәм тәүлеклек шикәр чөгендере эшкәртү 2,4 *т* га җитә.


Шикәр чөгендере Аксубай, Нурлат, Чирмешән р-ннарыннан, 2004 тән Самара өлкәсеннән китерелә. 1992–98 дә шикәр комы камыш чималдан (Австралиядән, Бразилиядән, Кубадан кертелә) эшләнә. Рафинад җитештерү өчен шикәр комы Белгород өлкәсендәге заводлардан кайтарыла (елга 20–25 мең *т*). Шикәр чөгендере үстерүнең кимүе, камыш чимал килүе тукталу шикәр җитештерүнең азаюына китерә: 1998–2004 тә продукциянең уртача еллык күләме 9,5 мең *т* дан артмый, 2005–06 да 16 мең *т*, 2012 дә 37,7 мең *т* тәшкил итә. Завод ш.у. жом һәм меласса чыгара.

Күп кенә хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә лаек була: 5 кешегә ТАССРның атказ. азык-төлек индустриясе хезмәткәре исеме бирелә; 3 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны», 4 кеше — «Почёт билгесе» орденнары, 7 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында: В.Г.Медведский (1958–74), А.И.Смирнов (1974–79), В.В.Богатиков (1979–88), Ш.В.Кашапов (1988–92), А.К.Савинов (1992–2000), М.М.Фәррахов (2001–04, 2009–2011), А.В.Ветохин (2004–2006), Р.Р.Хәмзин (2012 дән).

*М.Ж.Гаитов.*

**«НУРЛАТНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү, нефтьне чыгару, әзерләү һәм сату, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлау, төзү һәм файдалану б-н шөгыльләнүче нефть-газ чыгару идарәсе (НГДУ). Эшләүчеләр — 800 дән күбрәк кеше (2012). 1979 елда «Ямашнефть» НГДУы нефть промыселларының берсе җирлегендә оештырыла. «Н.» карамагына эшкәртелүче Ивашкино–Кече Сөлчә, Ульянов, Карамалы, Нурлат чыганаклары бирелә, соңрак 12 вак чыганак өстәлә. 2007 дә ТРның 5 адм.



З.З.Нурмөхәммәтов.

районы терр-ясендә — 28, 2012 дә 31 чыганак эшкәртелә. Үзәкләштерелгән сәнәгый базалары Нурлат шәһәрендә урнашкан. «Н.» нефть һәм газ чыгаручы 4 цехны, катламнарның басымын нормада тотучы цехны, нефтьне әзерләү һәм кудыру цехын, сәнәгый базага хезмәт күрсәтүче 5 цехны үз эченә ала. «Н.»тә авыр суыртылучы күкертле, үтә үзле нефть чыгарыла. НГДУ чыганакларын эшкәртү фильтрация агымнарының юнәлешен үзгәртә барып, циклик рәвештә су кудыру б-н үзенчәлекле. Нефть чыгаруны арттыру өчен, катламга һәм скважинаның забой алдына физик-химик, геол.-физик, гидродинамик тәэсир итү алымнары кулланыла. Нефть җыю системасы герметиклаштырылган. Чыгарылучы продукция составында 66,5% су була. «Н.»нең барлык нефть промыселлары комплекслы автоматлаштырылган һәм телемеханикалаштырылган. 2004 тән җитештерү б-н автоматлаштырылган идарә итү системасын реконструкцияләү уздырыла. Эшкәртелүче нефть чыганаклары нефть чыгаруны арттыруның алдынгы алымнарын сынау һәм җитештерүдә куллану буенча полигон буларак та файдаланыла.

«Н.», ш.у. 17 бәйсез нефть компаниясе тарафыннан чыгарылган нефть җиңел фракцияләрне тоту технологиясе булган 2 модернизацияләнгән җайланмада әзерләнә. 2005 тән 1 нче группа сыйфатлы нефть тапшырыла. 2001 дән НГДУда эксперимент рәвешендә Бөгелмә механика з-дында җитештерелгән, штангаларга һәм көчергечкә динамик басымны киметү, тирәнлек насосларының куллану вакытын озайту, энергия чыгымнарын миним. дәрәҗәгә төшерү мөмкинлеге бирүче чылбырлы көчергечләр гамәлгә кертелә. 2005 тән «Н.»тә берьюлы-аерым файдалану технологиясе үзләштерелә, моның нәтиҗәсендә бер скважина б-н катламнарында төрле басым булган берничә горизонт эшкәртелә. Лениногорск катламнарның нефть бирүен арттыру һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсенә кергән Актүбә канат-контейнер, пакер алымнары һәм катламны гидроисул б-н өзү җиһазлары идарәсенең «бөгелүчән труба» җайланмасы ярдәмендә НГДУ скважиналарында Россиядә беренче тапкыр ачык горизонталь кәүсәдә катлам, идарә ителеп, кислота кулланып өздерелә. 2007 нең 1 гыйнварына 3,45 млн. *т* (ш.и. 2006 да 1,898 *т*) нефть чыгарыла. 1454 чыгаручы һәм 320 басым тудыручы скважина файдаланыла. Прогрессив алымнар б-н чыгарылган нефть еллык продукциянең 30% ын тәшкил. 2005 тә «Н.» идарәсе карамагына табигый битум чыганаклары тапшырыла. 2006 да, Әшәлче чыганагында пар-гравитация дренажы алымын кулланып, битумлы нефть чыгару башлана (тәүлеккә 9 *т* га кадәр).

«Н.» идарәсе ш.у. вак нефть компанияләренә хезмәт күрсәтә. НГДУда пычранган җирләрне элеккеге хәлгә кайтаруга, чишмәләрне төзекләндерүгә, әйләнә-тирә мохиткә техноген тәэсирне киметүгә даими игътибар юнәлтелә. «Н.» — шәһәр формалаштыручы пр-тие; Нурлат шәһәрендә тораклар, мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт, мәдәният объектлары, мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениеләре һ.б. төзелешләрнең заказчысы. Ял базасы, җәйге сәламәтләндерү лагере, спорт комплексы, тулай торагы, ярдәмче хуҗалыгы бар.

«Н.»нең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кешегә — РФ, ТРның атказ. геологы, 3 кешегә — ТРның атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, 12 кешегә — ТРның атказ. нефтьчесе, 3 кешегә — ТРның атказ. транспорт хезмәткәре, 3 кешегә — ТРның атказ. төзүчесе, 1 кешегә — ТРның атказ. сәнәгатьчесе, 1 кешегә ТРның атказ. юристы исемнәре бирелә, 1 кеше — ТР Дәүләт бүләге лауреаты; 1 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны», 2 кеше «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: Р.З.Сафуанов (1979–86), М.М.Хуҗин (1986–2003), И.М.Салихов (2003 тән).

*Әд.:* НГДУ «Нурлатнефть»: Вчера, сегодня, завтра: Нефтегазодобывающему управлению — 25 лет. К., 2004.

*Г.Я.Мәүлетова, Р.Р.Әхмәдуллин, А.Х.Гомәров.*



«Нурлатнефть» НГДУы. «Андреевка» югары күкертле нефть әзерләү җайланмасы технологик мәйданчыгы.

**НУРЛЫ́ КОҢГЫЗЛӘ́Р** (Donaciinae), яфрагашарлар семьялыгыннан коңгызлар ассемьялыгы. Гәүдәсе сузынкы, озынлыгы 15 *мм* га кадәр; металл төсмерле ачык төстә. 150 гә якын төре билгеле, нигездә, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Россиядә 60 тан артык төре билгеле. Урта Идел буенда 3 ыруг вәкилләре яши: нурлы коңгыз (Donacia) — 15 төрдән дә аз түгел, ялган нурлы коңгыз (Plateumaris) — 2 төр, Macroplea — 1 төр. Су үсемлекләрендә яшиләр, аларның яфраклары б-н туеналар. Сулау өчен һаваны үсемлекләрнең су асты өлешендәге сулыш тамырларыннан алалар, ш.у. тире аркылы сулауга да сәләтлеләр. Төнбоекта яшәүче юан аяклы нурлы коңгыз (Donacia crassipes) һәм, нигездә, күрән һәм керпебашта очраучы су нурлы коңгызы (D. aguatica) еш очрый.

*Әд.:* Исаев А.Ю. Определитель жесткокрылых Среднего Поволжья. Ч. 3. Polyphaga phytophaga. Ульяновск, 2007.

*Р.М.Җәләев.*

**НУРМИНКӘ́** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 34 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1837 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50%, руслар — 47%) яши. Халкының төп шөгыле — яшелчәчелек. Консерв з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1565–67 елгы теркәү кенәгәсендә Менгер на Лихом болоте исеме б-н дә билгеле. 18 йөз рус чыганакларында Менгер Нармацкое буларак та мәгълүм. Халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, еш кына бер хуҗадан икенче хуҗага күчеп йөри, 1820 дә аларның бер өлеше (алпавыт Жеребцовның элеккеге крепостнойлары) ireккә чыгарыла һәм иректе игенчеләр булып китә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе, этап йорты урнаша; земство мәктәбе (1877 дә ачыла), халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе, почта бүлекчәсе, 3 тимерчелек, 1 тукымалар, 1 казна шәраб һәм 4 вак-төякләр кибете, 2 сыраханә, йон-тукыма ману остаханәсе, 17 юлаучылар йорты, трактир була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1298 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1956 ның 14 декабреннән — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 130, 1859 да — 335 ир-ат; 1897 дә — 1099, 1908 дә — 1148, 1920 дә — 1074, 1926 — 1259, 1938 дә — 938, 1949 да — 569, 1958 дә — 457, 1970 тә — 319, 1979 да — 407, 1989 да — 1653, 2002 дә — 1846 кеше.

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Габделфәрт Нурмөхәммәт улы (2.2.1926, Лаеш кантоны Максабаш а. — 8.9.2005, Казан), оптик-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). 1941–89 елларда «Казан оптика-механика заводы» ҖБдә эшли. Дәүләт бүләге оптик эшләнмәләр иҗат иткәне һәм камилләштергәне өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Зиннур Закир улы (11.12.1941, Әстерхан ш. — 8.10.2003, Казан), җырчы (тенор), ТАССРның халык артисты (1987). 1962 елдан Тын океан флотының җыр һәм бию ансамбле хоры солисты. 1965 тән Бөтенроссия эстрада сәнгатенең иҗат остаханәсендә (педагоглары Г.Виноградов һәм И.Яунзем) укый (Мәскәү). 1969–92 дә Татар филармониясендә солист. Көчле эстрада җырчысы, матур үзенчәлекле тавышы, аудиториядә үзен иркен тотуы, артистлык осталыгы б-н аерылып тора. Җырчының репертуары Европа, рус, татар композиторлары әсәрләрен үз эченә ала. Н. татар вокаль музыкасын (С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, А.Ключарёв,

Р.Яхин, М.Макаров һ.б.) пропагандалауга зур өлеш кертә. Җырчы, сценарий язучы һәм режиссёр буларак зур күләмле концерт программалары, ш.и. М.Җәлилнең тууына 70 ел тулуга багышланган «Гомерем минем моңлы бер җыр иде», «Гомерем — мәхәббәтем», «Рус, татар һәм чит ил авторларының романслары», «Йолдызлар сәламе», Бөек Ватан сугышында җиңүнең 50 еллыгына багышланган «Берлиннан кайту», «Кайда сез хәзер, полкташлар?», Бөек Ватан сугышында җиңүнең 55 еллыгына багышланган телевизион фильм-концерт әзерли. Бөтенсоюз эстрада артистлары конкурсы дипломанты (1970). Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1977).

*М.Я.Коварская.*

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Ильяс Нуретдин улы (2.11.1926, Әгерҗе р-ны Биектау а. — 3.4.2000, Ижевск ш.), нәкышьче, график, монументчы, Удмурт АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966), Удмурт Респ-касының Дәүләт бүләге лауреаты (1976).

1927 елда Нурмөхәммәтовлар гаиләсе Ижевск шәһәренә күчә. Сугыш вакытында Н. Ижевскидагы металлургия з-дында эшли. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1952), Удмурт китап нәшриятында рәссам. 1956–71 дә Ижевск телестудиясендә куючы рәссам, баш рәссам. 1972 дән РСФСР Сәнгать фонды Удмурт бүлегенең сәнгать-җитештерү остаханәләрендә монументчы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964). Удмуртиядәге әйдәп баручы рәссамнарның берсе, станлы һәм китап графикасы үсешенә зур өлеш кертә. «Удмуртия» нәшриятында 100 дән артык матур әдәбият, балалар әдәбияты, иҗтимагый-сәяси әдәбият әсәрләрен бизи, алар арасында В.Бианкиның «Урманда су басу» («Наводнение в лесу», 1972), А.Алдан-Семёновның «Кызыллар һәм аклар» («Красные и белые», 1980), «Г.Тукай экиятләре» («Сказки Тукая», 1970), «Баллы ипи» исеме белән басылган удмурт халык экиятләре (1972) һәм удмурт тендәге «Чечыен нянь» («Баллы ипи») (1984) китапларына ясалган иллюстрацияләр бар. Казанда уку елларында Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. Н.ның станлы графикасы (пастель, күмер, акварель, карандаш, тушь, гуашь) образларның ачыклыгы һәм җанлылыгы, сызыклар б-н осталарча эш итә белүе, форманы яктылык һәм күләгә, төсле тоннарда модельләштерүе б-н аерылып тора: «Телестудиядә» (1964–69), «Балериналар» (1964), «Зәңгәр экран артында» (1967), «Операторлар» (1969) сериясе, «В.З.Баранов портреты» (1985) һ.б. Сугыш темасы «Равенсбрюк хатын-кызлары» триптихында (1968), «Туган җир» (1966), «Зоя» (1970) картиналарында һ.б.да чагылыш таба. Нәкышь өлкәсендә Н. тарихи һәм көнкүреш жанрларындагы тематик картиналарга, портретка мөрәҗәгать итә («Тимер начдив В.Азин», 1971; «Автопортрет», 1970 еллар; «Рәссам», 1974; «Хатыным истәлегенә», 1985; «Ижевск яуланды!», 1987; «Ислам. Уйлану», 1990; «Реквием», 1995 һ.б.). Җәмәгать биналарын бизәгәндә, Н. тарафыннан иҗат ителгән монументаль бизәкләр витраж эскизлары формаларының масштаблылыгы, композицияләренең фигураларга бай булуы, архит-ра б-н үзара ярашуы ягыннан аерылып тора. Бу Сәяси мәгариф йорты (хәзер Ижевскидагы Дәүләт филармониясе) фасадындагы «Без яңа, үз дөньябызны төзербез» дигән дивар бизәгендә ачык чагылыш таба. Телевизион спектакльләр (Н.Погодинның «Кремль курантлары» («Кремлёвские куранты») һ.б.), концерт куелышларын бизи.

1953 тән респ-ка, 1964 тән «Зур Идел» төбәк күргәзмәләрендә, «Советская Россия» (Мәскәү, 1970), «Идел буе рәссамнары» күчмә күргәзмәсендә (1965), «РСФСРның автономияле республикалары рәссамнары әсәрләре» күргәзмәсендә (Мәскәү, 1971) һ.б. катнаша. Шәхси күргәзмәләре Ижевскида 1966, 1987 елларда уза.

Әсәрләре Удмурт Респ-касының Сынлы сәнгать музеенда һәм Милли музеенда саклана. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П о л я к А.И. Изобразительное искусство Удмуртии: Библиогр. справ. Ижевск, 1974; Ими гордится удмуртская земля. Вып. 3: Деятели искусства: Библиогр. указ. Ижевск, 1980; Удмуртская Республика: Культура и искусство: Энцикл. Ижевск, 2013.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Рауль Вәли улы (25.5.1922, Оренбург өлкәсенең Троицк ш. — 7.9.1988, Казан), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1948). 1951–52 елларда ТАССР МСның сәнгать эшләре инспекторы, 1953–88 дә Сәнгать фондында (1953–56 да директор), бер үк вакытта, 1949–55 тә, Казан сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1950). Иҗат юлын тарихи жанрда башлый («А.С.Пушкин Казан аксакаллары б-н сөйләшә», 1949), «Горький Казанда» темасына картиналар һәм этюдлар («Яшь Горький Иделдә», 1948), А.С.Деренков яшәгән Красновидово авылыннан пейзажлы этюдлар сериясен («Илгизәр еллар», 1955) иҗат итә. 1960–70 елларда хатыны Л.П.Иванова б-н берлектә җәмәгать интерьерларында күп кенә монументаль-декоратив композицияләр ясый (Казанда Химиклар мәдәният сарае фойесы, 1969, штукатуркага бизәк төшерү һ.б.).



Р.В.Н у р м ө х ә м м ә т о в. «Ишегалды». 1955.

Әйдәп баручы пейзажчы-рәссамнарның берсе буларак, Н. Казанның борынгы урамнарына, истәлекле урыннарына, Казан арты авыллары күренешләренә багышланган лирик-камера пейзажлары («Паркта көз», 1953; «Җепшек көн», 1953; «Ишегалды», 1955; «Лобачевский һәйкәле», 1955; «Кырлай», 1976;



Р.В.Н у р м ө х ә м м ә т о в. «Сынлы сәнгать музее». 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

«Шәһәр чите», 1981–82), контраст колоритлы индустриаль пейзажлар («Яхталар. Чусовая елгасы», 1961; «Кыя», 1963; «Порт», 1978–79) яза. Идел буе рәссамнарының зона (Сталинград ш., 1953), «Зур Идел» (Куйбышев ш., 1964; Казан, 1980), РСФСР рәссамнары (Мәскәү, 1953–54, 1955), РСФСРның автономияле респ-калары рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1971) күргәзмәләрендә катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Н. әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемориаль музеенда, Әлмәт картиналар галереясында саклана.

*Әд.:* Ч е р к а с о в а Н. Изобразительное искусство Советского Татарстана. К., 1957; Ф а й н б е р г А.Б. Художники Советской Татарии. К., 1983.

*М.Е.Ильина.*

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Рафаил Сәет улы (10.8.1949, БАССРның Кырмыскалы р-ны Бозаяз а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТРның атказ. нефтьчесе (1993). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1974). 1966 елдан Салават нефть химиясе комб-тында эшли, 1967 дән — Уфа нефть эшкәртү з-дында. 1968 дән «Татнефть» АҖдә (бүленеп: 1987–89 да Төмән өлкәсе «Покачевнефть» НГДУы башлыгы), «Лениногорскнефть» НГДУы башлыгы (1989 дан). Дәүләт бүләге ТР нефть промыселларында энергия саклаулы технологияләр эшләгәне һәм аларны сәнәгать күләмендә кулланышка керткәне өчен бирелә. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Рәшит Мөхәммәтбарый улы (4.9.1925, Уфа ш. — 23.8.1986, шун-

да ук), нәкышьче, педагог, РСФСРның халык рәссамы (1977), БАССР, РСФСРның атказ. рәссамы (1968, 1970). Уфа сәнгать уч-щесен (1950), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын тәмамлый (1956). 1958 елдан Уфа сәнгать уч-щесендә, бер үк вакытта, 1958–72 елларда, Уфа сәнгать ин-тында каф. мөдире. Талантлы татар һәм башкорт нәкышьчеләре плеядасын тәрбияли (Н.Г.*Байбурин*, Н.С.*Лотфуллин*, Р.Р.*Кадыйров*, В.М.*Ханнанов*, Р.З.*Харисов* һ.б.). БАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1958), 1960–65 һәм 1971–80 дә идарә рәисе. 1976 елдан РСФСР Рәссамнар берлеге идарәсе әгъзасы.

Н. — БАССРның сынлы сәнгать үсешенә зур йогынты ясаган рәссам, жанрлы һәм нәкышьле портретлар остасы. Аның әсәрләре совет сынлы сәнгатенең классикасына әверелә, илнең зур музейлары, китап сәнгате басмалары тупланмасына кертелә. Н. үзенең иҗат юлын 1950 еллар уртасында, соцреализм сәнгатенең «кырыс стиле» үсеш алган һәм аның эзеннән килүче «лирик-романтик» агымнар чорында башлый, нәкышькә яңа тормышчан рух күтәренкелеге, хезмәт романтикасы, образларның тирән психол. холкын һәм динамик ритмнар алып килә. Н. — ш.у. Башкортстанда яшәүче беренче татар рәссамы К.С.*Дәүләткилдиев* башлаган традицияләрне дәвам иттерүче дә, аның картиналарында милли образлар, тематика, колорит зур урын алып тора. 1971–74 тә ул Төмән өлкәсенең төньягында иҗади сәфәрдә





Р.М.Нурмөхәммәтов. 1. «Эш көне азагында». 1956; 2. «Урал киңлекләрендә». 1963. Икесе дә М.В.Нестеров исем. Башкортстан Сынлы сәнгать музеенда.



Р.М. Нурмөхәммәтов.

була, Төньякта эшләүче нефтьчеләргә багышланган картиналар циклы иҗат итә; Финляндия (1976), Алжир (1977), Таулы Алтайда (1983) иҗади командировкаларда булып кайта, тәэсирләрен пейзажларга һәм портретларга төшерә. Совет бишьеллыкларын тормышка ашыручы нефтьчеләр, геологлар, авыл хезмәтчәннәре, мәдәният һәм фән эшлеклеләренең фидакарь хезмәтенә мәдхия җырлаган зур масштаблы станлы тематик картиналар авторы. Аларның якты һәм истә калырлык образларын Н. үзенең бай портретлар галереясында гәүдәләндерә.

Төп әсәрләре: «РСФСРның атказанган артисткасы Бану Вәлиева» (1952), «Сәгыйт Агиш портреты» (1953), «СССРның халык артисты З.Насретдинова портреты» (1955), «Бораулаучы Гафур» (1962), «Шәригать корбаннары» (1963–69), «Сынчы Мансур Якубов портреты» (1967), «Игенче портреты» (1973), «Төньяк тормышы» триптихы (1973–74), «Төньякка юл салучылар» (1974), «БАССРның халык шагыйре Мостай Кәрим» (1974), «Димдә ташу вакыты» (1979), «РСФСРның халык артисты Э.Куватова» (1981) һ.б.

Респ-ка (1947 дән), зона («Социалистик Урал», 1964–91, 1986 дан — вафатыннан соң), бөтенроссия («РСФСР рәссамнары», Мәскәү, 1952; «Совет Россиясе», Мәскәү, 1960, 1967; «Туган ил буйлап», Мәскәү, 1981), бөтенсоюз (Бөек Октябрьнең 50 еллыгына багышланган, Мәскәү, 1967; В.И.Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган, Мәскәү, 1970; «СССР — безнең Ватаныбыз», Мәскәү, 1973), халыкара («Совет сәнгате», «Улан-Батор», Монголия, 1970; Галле шәһәрендә БАССР рәссамнары әсәрләре, ГДР, 1975) күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Севастополь шәһәрендә (1975), Уфада һәм Алма-Атада (1975), Казанда һәм Ленинградта (1976) уза. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан Сынлы сәнгать музеенда саклана. 1975–79 елларда БАССР ЮС депутаты. Респ-каның С.Юлаев исем. бүләге лауреаты (1969). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Голованов Н.Р. Рашид Мухаметбареевич Нурмухаметов. Л., 1972; Бодрова Э. Рашит Нурмухаметов. Уфа, 1976; Рашит Нурмухаметов: Живопись. Уфа, 1986; Байбурин Н. Сияющий человек // «ВХ». Уфа, 2005. № 2.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**НУРМӨХӘММӘ́ТОВ** Таһир Мирзагаллəм улы (14.4.1930, Казакъстан ССРның Семипалатинск ш. — 25.9.1999, Казан), тәрҗемәче, ТАССР, РФнең атказанган мәдәният хезмәткәре (1980, 1992). 1953 елда Казан. пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан китап нәшриятында эшли, 1990 нан «Шәһри Казан» г-тасы редакциясендә. Татар теленә А.Н.Рыбаковның «Кортик» («Хәнҗәр», 1961), «Бронзовая птица» («Бакыр кош», 1961) повестьларын, Р.Гүнтәкиннең «Чалы кошы» (1970) романын, Р.И.Фраерманның «Дикая собака Динго, или Повесть о первой любви» («Кыргый эт Динго, яки Беренче мәхәббәт турында хикәя», 1973) повестен, Г.Н.Троепольскийның «Белый Бим Чёрное ухо» («Акбай Караколак», 1975) повестен, В.П.Астафьевның «Последний поклон» («Бәхилләшү», 1980), «Кража» («Талау», 1983), «Звездопад» («Сүнмәс йолдызлар», 1983) повестьларын, «Царь-рыба» («Патша-балык», 1986) романын, Г.Н.Паустовский, А.И.Куприн, С.Җамал, Э.Сетон-Томпсон повестьларын һәм хикәяләрен тәрҗемә итә.

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**НУРСОЛТА́Н БИКӘ́** (фаразланганча, 1446, Нугай Урдасы — 1519, Бакчасарай ш.), Казан (1463–79), Кырым (1486 елдан) ханбикәсе. *Мангыт* ыругыннан булган нугай бәге Тимер кызы. 1463 елда Казан ханы *Хәлилгә* кияүгә бирелә. Шул ук елда Хәлил хан үлгәннән соң, тәхеткә аның энесе *Ибраһим* утыра. *Левират* йоласы буенча Н.б. Ибраһим хатыны була: аңардан ике угыл — *Мөхәммәдәмин* һәм *Габделлатыйф* ханнарны тудыра. Ихтимал, 1485 тән соң, ягъни тәхет өчен барган көрәштә Мөхәммәдәмин икенче тапкыр (бертуганы Илһам тарафыннан) тәхеттән төшерелгәч, Н.б. Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыга һәм, Габделлатыйфны үзе б-н алып, Бакчасарайга китә; Мөхәммәдәмин, 1479 елдагы (әтисе үлгән ел) кебек үк, кабат Иван III хөкүмәте яклавына — Мәскәүгә китә. Кырым илчелек китабында Н.б. Миңлегәрәй хан хатыннары арасында «олуг патшабикә» буларак искә алына («тирән акылга һәм характерга ия»); чибәрлеге, дәүләт эшләрендә, бигрәк тә Мәскәү бөек кенәзлеге б-н аркадашлык мөнәсәбәтләрен саклауда катнашып зирәклек күрсәтүе б-н аның исеме Алтын Урда, Русь, Төркия, Якын Көнчыгыш илләрендә һәм Мисырда киң таныла. Мәскәүнең бөек кенәзләренә язган хатларында, үзенең тиңдәш затлылыгын ассызыклап, Н.б. төрек солтаны Баязитны «ахирәт-атабыз» дип атый, Иван III гә «агам» (ул аңа — «сеңлем») дип мөрәҗәгать итә. 1494–95 тә Н.б. 50 кешелек яраннар төркеме б-н Согуд Гарәбстанына зур сәфәр кыла, Мәдинә, Мәккә, Мисырда була. Һәркайда зур хөрмәт б-н кабул ителә. Мөселманнарның изге шәһәренә хаҗ кылганнан соң, Н.б. «хаҗия» дип атала башлый, алга таба ул дипломатик язышуларда имзаларында шул дәрәҗәсен күрсәтә. Әлеге ерак сәфәрдән кайтканнан соң, Мәскәүнең бөек кенәзе б-н мәртәбәле дуслык билгесе сыйфатында, Иван III гә хат юллый һәм, бу гамәлне «ихтирам буш булмасын өчен» кылуын әйтеп, аңа үзе атланып сәяхәткә барган атны бүләк итеп җибәрә. Н.б. тормышының соңгы егерме елы кискен каршылыклы халыкара вазгыять шартларында уза. Ул, бер яктан, Миңлегәрәй хан һәм Иван III, Иван III үлеменнән соң (1505) — Василий III арасында, икенче яктан, алар һәм 1502–18 дә Казан тәхетен биләгән улы Мөхәммәдәмин арасында союздашлык мөнәсәбәтләрен саклау өчен сак, уйлап эш

йөртергә мәҗбүр була. 1510 да Василий III ризалыгы б-н Н.б. Бакчасарайдан Мәскәүгә, аннан улы янына Казанга бара. Мәскәүгә 1510 ның 21 июнендә килеп җитә, бөек кенәз Василий III һәм боярлар тарафыннан зурлап каршы алына. Анда Н.б. 20 августка кадәр була, шуннан соң Казанга кузгала, Казанда 9 айдан артык яши. Бу чорда Мәскәүдә һәм Казанда аның катнашында Мәскәү бөек кенәзлеге б-н Казан ханлыгы арасында ныклы татулык мөнәсәбәтләре урнаштыру буенча берничә тапкыр сөйләшүләр булып уза. Шул сәбәпле 1511 нең 22 июнендә кабат Мәскәүгә килә, зур хөрмәт б-н кабул ителә. Анда 6 ай чамасы яши; 1511 нең 5 декабрендә бөек кенәз илчесе Гучков б-н Бакчасарайга китә. Бу сәфәрдә аны Миңлегәрәй ханның башка хатыныннан туган улы *Сәхибгәрәй* солтан озатып йөри. Казанлылар киләчәктә тәхет дәгъвачысы булачак зат б-н танышырга тиеш булалар, чөнки Мөхәммәдәминнең дә, Габделлатыйфның да уллары булмый. Олыгайган ханбикәнең (аңа 65 яшь чамасы була) Мәскәүгә баруы Мәскәү бөек кенәзлеге һәм Казан арасындагы мөнәсәбәтләрнең яхшыруына булышлык итә: 1507 нең язынннан 1521 гә кадәр алар арасындагы татулык бозылмый, ләкин 1515 тә Миңлегәрәй хан вафатыннан соң Кырым ханлыгы б-н Мәскәү кенәзлеге арасындагы мөнәсәбәтләрдә кризис башлана. 1517 дә Кашира шәһәрендә билгесез шартларда Габделлатыйф һәлак була, 1518 нең декабрендә Казанда озакка сузылган авырудан соң 46 яшьлек Мөхәммәдәмин үлә, бер елдан Н.б. үзе дә дөнья куя. Шуның б-н чыңгызыйларның Казан тәхетендә *Олуг Мөхәммәд* ханнан башлангыч алган династиясе өзелә. 1521 дә Сәхибгәрәй хан Кырым һәм Казан ханлыклары көчләре б-н Мәскәү бөек кенәзлегенә каршы сугыш хәрәкәтләре башлый.

*Әд.:* У р м а н ч е Ф. Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә. К., 1997; И ш б у л д и н әл-Бәкри Б. Татарлар тарихы. К., 2003; Б е р е ж к о в Н.М. Нур-салтан, царица Крымская // Изв. Таврической учёной архивной комиссии. Симферополь, 1897. № 27; Х у д я к о в М., Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; С а б и р з я н о в Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1995.

*Г.С.Сабирҗанов.*

**«НУРУЛЛА́» МӘЧЕТЕ́**, к. *Печән базары мәчете.*

**НУРУЛЛА́ЕВ** Абдул Абдулваһап улы (10.9.1929, Үзбәкстан ССРның Ташкент өлкәсе Янгиюл ш.), ислам дине галиме, философ, филос. фән. д-ры (1990), проф. (1997). Ташкент юридик ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Төрекмәнстан ССР Юстиция министрлыгының Чарджоу өлкә идарәсе ревизоры, башлык урынбасары булып эшли. 1954–61 елларда Чарджоу өлкә ком-тының бүлек мөдире урынбасары, 1964–67 дә Төрекмәнстан КП ҮКның бүлек мөдире урынбасары була. 1967–87 дә СССР МС каршындагы Дин эшләре советы әгъзасы. 1987–97 дә Россия бәйсез социаль һәм милли проблемалар ин-тының баш фәнни хезмәткәре. 1997 дән Россия Халыклар дуслыгы ун-тының сәясәт белеме каф. профессоры. Хезмәтләре ислам дине, милли мөнәсәбәтләрдә дини фактор, милләтара татулык проблемаларына карый. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эволюция ислама в СССР. М., 1972; Ислам и нации. М., 1975; Социальная доктрина ислама. М., 1982; Ислам и мусульмане в России. М., 1999 (автордаш).

**НУРУ́ЛЛИН** Азат Һидиятулла улы (2.2.1937, Куйбышев р-ны Әхмәт а. — 5.6.2012, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. сәүдә хезмәткәре (1986). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1970). 1959–61 елларда Әлки р-ны Юхмачы авылы кулланучылар җәмгыяте склады мөдире. 1961–65 тә Яшел Үзән шәһәрендә эшче, 1965–72 дә ашханә мөдире. 1972–73 тә Яшел Үзән шәһәре сәүдә оешмасы директоры урынбасары, 1973–90 да директоры. 1990–96 да ТР сәүдә министры. 1997–98 дә «Силена», 1998–99 да «Базир» АҖлары ген. директоры. 2000–03 тә «ТАИФ-Сервис» АҖ ген. директоры урынбасары. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**НУРУ́ЛЛИН** Вакыйф Нурулла улы (1.5.1935, Балык Бистәсе р-ны Югары Әшнәк а.), язучы, ТАССР, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1972, 1985). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1962), «Казан утлары» ж-лы редакциясендә эшли. 1977–88 елларда Татарстан китап нәшрияты баш мөхәррире. 1992–2010 да ТР Милли музеенда әдәбият бүлеге мөдире. «Шинельсез солдатлар» (1968) исемле беренче повесте бала чаклары авыр сугыш елларына туры килгән авыл малайлары турында. Сугыш чоры һәм сугыштан соңгы еллардагы татар авылларын сурәтләү Н. әсәрләренең төп темасына әверелә: «Күпер чыкканда» (1971; Казан телестудиясендә шул исем. телеспектакль, 1974), «Әгәр син булмасаң...» (1975; рус теленә тәрҗемәсе «Если бы не ты...», М., 1979), «Аккан су юлын табар» (1979), «Һәлакәт» (1983; рус теленә тәрҗемәсе «Расплата», 1984) «Ике урам арасы» (1985), «Сагынырсыз әле...» (1989) повестьлары, «Яшьнәп үткән яшьлек» (1977; рус теленә тәрҗемәсе «Грозовая молодость» , 1980; Казан телестудиясендә шул исем. телеспектакль, 1977) документаль повесте. Ф.Булатовның «Записки генерала» («Генерал язмалары», 1963) истәлекләрен, Р.Мостафинның «По следам оборванной песни» («Өзелгән җыр эзеннән», 1982) китабын татар теленә тәрҗемә итә. Н. әсәрләре таҗик, әзәрбайҗан, казакъ, төрекмән, чуаш телләренә тәрҗемә ителә.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1991; Җавап бир, кеше! Повестьлар. К., 2001; Әгәр син булмасаң: Повестьлар. К., 2005; Повести. М., 1982; Бабье лето: Повести. М., 1989.

*Әд.:* М ө х ә м м ә д и е в Р. Тормышның үз моңын тоеп // Якутлар табыладыр вакыт беләнь. К., 1983; М и ң н у л л и н Ф. Ягымлы геройлар // Затлылык. К., 1989; Г а л и м у л л и н Ф. Җавап бирер чак // Казан утлары. 1994. № 4; В ә л и е в М. Чынлыкка омтылу // Гамәл дәфтәре. К., 2003.

*Г.М.Габделхакова.*

**НУРУ́ЛЛИН** Гата Исай улы (9.5.1923, Лаеш кантоны Ябынчы а. — 10.2.2001, Казан), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1980). 1949 елда Татар театр уч-щесен тәмамлый һәм Татар респ-ка күчмә театрына кабул ителә. Образга керә белү сәләтенә ия булган Н. шактый үзенчәлекле образлар иҗат итә: Хафиз («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Марат, Алиш («Бистә кызы Гөлсинә», «Үлмәс җыр», Р.Ишморат), Хуан Шижень («Чал чәчле кыз», Хэ Цзинчжи һәм Дин Ни) һ.б. Бер үк вакытта режиссёр да, драматург та була. М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасы буенча Н. тарафыннан куелган спектакль РСФСР Мәдәният министрлыгы дипломы б-н бүләкләнә (1959). Н.ның «Вөҗдан» пьесасы буенча куйган спектакле Татар респ-ка күчмә, Оренбург татар, ш.у. Башкортстан театрлары сәхнәләрендә зур уңыш б-н бара. 1959 да ТАССР Мәдәният министрлыгы тарафыннан, татар халык театрлары оештыру өчен, Әстерхан шәһәренә җибәрелә (20 дән артык спектакль куя). 1969–89 да яңадан Татар респ-ка күчмә театрында, анда ул шактый гына образлар иҗат итә: Нури («Өти балак», Ю.Әминев), Хак («Тынгысыз төн», Г.Мөхәммәтшин), Исак («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Ягъфәр («Айгөл иле», М.Кәрим), Ашот Ашотович («Күктән төшкән бәхет», Н.Асанбаев), Сираҗи («Туйлар узгач», Р.Батулла), Сәлим («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Суфый («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Мотыйгулла («Кайтыр идем», Р.Хәмид), Мулла («Кара йөзләр», М.Гафури), Нариман («Үзебез сайлаган язмыш», Т.Миңнуллин), Казый («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Хәмзин, Халикъ, Ак бабай («Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан», «Онытылмас бәет», И.Юзеев). Н.ның сәхнәдә үз-үзен тотышына табигыйлек, гадилек хас; ш.у. ул персонажның поэтик асылын, аның эчке дөньясын тирәнтен ача һәм җиткерә белә.



Г.И.Нуруллин.



Г.И. Н у р у л л и н Казый ролендә («Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт; сулда — Хуҗа ролендә Н.Шәйхетдинов).

*Әд.:* И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002.

*Д.Ә.Гыйммранова.*



Р.Ш. Нуруллин.



Ф.Н. Нуруллина.

**НУРУ́ЛЛИН** Ибраһим Зиннәт улы (18.4.1923, Самара губ., Мәләкәс өязе Парау а. — 1.7.1995, Казан), әдәбият галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1968), проф. (1970). 1943–45 елларда туган авылы мәктәбендә укыта. Казан ун-тын тәмамлый (1950), шунда ук укыта (1953–90). Хезмәтләре 20 йөз башы һәм совет чоры татар әдәбиятына, иҗади алымнар теориясенә, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Ш.Камал, И.Гази, М.Әмир, С.Кудаш, Ә.Еники, Г.Ахунов, Н.Фәттах һ.б. иҗатларына карый. Язучы шәхесен һәм аның иҗат процессының асылын ачу Н. хезмәтләренең төп темасы булып тора. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләренә аның «Тукай Петербургта» (1965), «Аның йолдызы» (1973) пьесалары; «Габдулла Тукай» (1977; рус теленә тәрҗемәсе «Тукай», М., 1979; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1982), «Фатих Әмирхан» (1988; рус. теленә тәрҗемәсе «Прометей из Ново-Татарской слободы», 1991) исемле әдәби-биографик китаплары багышланган. Н. Г.Исхакый мирасын татар халкына кайтаруга зур өлеш кертә (ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты, 1992). Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар әдәбияты дәреслекләре һәм хрестоматияләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тукай эстетикасы. К., 1956; XX йөз башы татар әдәбияты. К., 1966; Реализм турында. К., 1974; Әдәбият теориясе. К., 1977; Тормыш һәм сәнгать чынлыгы. К., 1983; Путь к зрелости. К., 1971.

*Әд.:* Ибраһим Нуруллин: Истәлекләр. К., 2008; Н у р у л л и н а Р.М. Ибрагим Зиннатович Нуруллин. 1923–1995. К., 2000; Ибрагим Нуруллин в воспоминаниях. К., 2013.

**НУРУ́ЛЛИН** Рафаил Әсгат улы (26.8.1958, Казан), философ, филос. фән. д-ры (2006), проф. (2007). Казан ун-тының физика ф-тын тәмамлый (1986). Казан радиокомпонентлар з-дында (1979 елдан), Казан моторлар төзү з-дында (1980 нән) инженер булып эшли. 1983–98 елларда Казан ун-тының радиофизика кафедрасында, бер үк вакытта, 1997 дән, Казан технол. ун-тының филос. кафедрасында. Хезмәтләре онтология, метафизика һәм виртуалистика, фән һәм мәдәният философиясенә карый.

Х е з м.: Виртуальность как основа бытия. К., 2004; Виртуальность как условие существования реальности // Вестн. Самар. гос. ун-та. 2005. № 4; Пространство как единство бытия и небытия // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2006. № 5.

**НУРУ́ЛЛИН** Рәүф Шәйхулла улы (25.12.1954, Чиләбе өлкәсенең Златоуст ш.), генерал-лейтенант. Югары командирлар танк уч-щесен (Чиләбе, 1977), Сов. Союзы Герое маршал Р.Я.Малиновский исем. бронетанк гаскәрләре академиясен (Мәскәү, 1987), Украина Кораллы Көчләр академиясен (Киев, 1998) тәмамлый. 1977 елдан Белоруссия хәрби округында, 1987–91 дә Совет Армиясенең көньяк гаскәрләре төркемендә (Венгрия). 1991 дән Украина Кораллы Көчләрендә: 1998–2003 тә 6 нчы армия корпусы командиры урынбасары, корпус командиры (Днепропетровск ш.), 2003 тән Көньяк оператив командование гаскәрләре штаб башлыгы урынбасары, 2005 тән штаб башлыгы, командующийның 1 нче урынбасары (Одесса ш.). 2005–10 елларда Коры җир гаскәрләре командующиеның 1 нче урынбасары, 2010 нан Украина Кораллы Көчләренең Берләштерелгән оператив командованиесе командующие (Киев ш.). Орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.

*Ф.Г.Миңнеханов.*

**НУРУ́ЛЛИН** Рөстәм Габдерәхим улы (4.1.1929, Наманган ш., Үзбәкстан ССР), тарихчы, тарих фән. д-ры (1970), проф. (1975), Үзбәкстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Урта Азия ун-тын тәмамлый (Ташкент, 1953). 1956 елдан Бөтенсоюз энергетика читтән торып уку ин-тының Урта Азия ф-лы КПСС тарихы кафедрасында, 1959 дан Үзбәкстан ФАнең Тарих һәм археол. ин-ты өлкән фәнни хезмәткәре. 1972–78, 1988–91 дә Үзбәкстан КП ҮК каршындагы Партия тарихы ин-ты директоры урынбасары. 1978–88 дә «Коммунист Узбекистана» ж-лы баш мөхәррире. 1991–98 дә Үзбәкстан Респ-касы ФАнең Тарих ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, Үзбәкстанның совет чоры тарихы бүлеге мөдире. Хезмәтләре Төркестан, Бохара һәм Харәзем респ-калары, Төркестан КПнең гражданнар сугышы чоры тарихына карый. «Үзбәкстанда гражданнар сугышы тарихы» («История гражданской войны в Узбекистане», Таш., 1970. Т. 2), «Үзбәкстан Коммунистлар партиясе тарихы очерклары» («Очерки истории Коммунистической партии Узбекистана », Таш., 1974), «Бохараның борынгы заманнардан безнең көннәргәчә тарихы» («История Бухары с древнейших времён до наших дней», Таш., 1976), «Төркестан XX гасыр башында: Милли бәйсезлек тарихына карата» («Туркестан в начале XX века: К истории истоков национальной независимости», Таш., 2000) коллектив монографияләрен әзерләүдә катнаша.

Х е з м.: Рабочее движение и распространение марксизма в России. М., 1958; Советы Туркестанской АССР в период иностранной военной интервенции и гражданской войны. Таш., 1965; Борьба Компартии Туркестана за осуществление политики «военного коммунизма». Таш., 1975; Партия — наш рулевой. Таш., 1981.

**НУРУ́ЛЛИН** Эльмас Габбас улы (5.1.1965, Куйбышев р-ны Татар Такталысы а.), авыл хуҗалыгын механикалаштыру өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2008). 1990 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, машина-трактор паркыннан файдалану лаб-ясе мөдире (1990–92), а.х. машиналары каф. мөдире (1997–2011), бер үк вакытта авыл хуҗалыгын механикалаштыру ф-ты деканы (2003–07). Хезмәтләре ярма культураларын кабыктан арындыру юлларын һәм механизмнарын эшләүгә карый. Н. пневмомеханик типтагы яңа кабыктан арындыру машиналарының конструктив-технол. схемаларын теоретик һәм гамәли нигезли. Машиналарның 5 тибына күрсәтмәләр һәм конструкторлык документларын әзерли (шуларның 3 се ТРның а.х. пр-тиеләрендә җитештерүгә кертелгән). Уйлап табуга 10 патенты бар.

Х е з м.: Определение механических характеристик зерна гречихи // Хранение и переработка сельхозсырья. 2003. № 5; Переработка зерна гречихи на новой технологической основе // Техника в сельском хозяйстве. 2003. № 4; Способы и машины для шелушения зерна (классификация, краткий анализ). К., 2003 (автордаш); Пневмомеханическое шелушение зерна крупяных культур. К., 2004.

**НУРУ́ЛЛИНА** Розалина Мәрдан кызы (12.11.1929, Арча кантоны Ташсу а. — 10.12.2012, Казан), журналистика белгече, журналист, филол. фән. канд. (1966), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1952 елда Татгосиздатта мөхәррир. 1952–60 та «Татарстан яшьләре» г-тасында: тәрҗемәче, 1958 дән — укучы яшьләр бүлеге мөдире. 1960–63 тә «Ялкын» ж-лының пионер тормышы бүлеге мөдире. «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан», «Мәдәни җомга», «Татарские края», «Выбор» г-таларында мәкаләләре басыла. 1966–2002 дә Казан ун-тының журналистика һәм татар журналистикасы кафедраларында эшли. Хезмәтләре рев-циягә кадәрге һәм совет татар вакытлы матбугаты һәм журналистикасы тарихына; Г.Кутуй, атаклы татар публицистлары һәм мәдәният эшлеклеләре иҗатына карый. «Илһам» (1982), «Кутуй турында истәлекләр» (1984) тупланмалары, «Татар телендәге газета һәм журналлар (1905–1990)» (1990), «Голос времени (Газеты и журналы на татарском языке)» (1991) библиографик күрсәткечләрен, күренекле әдәбият белгече И.З.Нуруллин турында истәлекләр китабын («Томаннарга еллар күмелде», 2003) төзүче.

Х е з м.: «Кызыл байрак» газетасы. К., 1976; Татар вакытлы матбугаты тарихыннан (1905–1907 елларда демократик газеталар). К., 2002; Татарская революционно-демократическая печать в период подготовки Октябрьской революции. К., 1974; Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978; Ибрагим Зиннатович Нуруллин. К., 2003.

*Әд.:* М и н н и б а е в Т. Чувствовать современность истории // Профессиональная культура журналиста. К., 1989.

**НУРУ́ЛЛИНА** Фидания (Дания) Нургаяз кызы (23.8.1946, Казан), драма актрисасы, ТССРның халык артисты (1991), РФнең атказ. артисты (2010). 1966 елда Казан театр уч-щесен тәмамлый һәм Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Сәхнәдә үзенә җәлеп итә торган мөлаемлыкка, көчле темпе-

раментка ия, үзенчәлекле детальләр һәм алымнар ярдәмендә героиняларының чын асылын ача белүче актриса күпләгән яшь хатын-кыз образларын иҗат итә: Айсылу («Миркәй белән Айсылу», Н.Исәнбәт), Шәфәкъ («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Чәчәк («Кол Гали», Н.Фәттах), Варя («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Зәмзәмбану («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Наилә («Үзеңә хыянәт итсәң», Д.Вәлиев), Саҗидә, Мәрфуга («Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Мәчтүрә («Портфельле кияү», Н.Исәнбәт), Йолдыз («Туй алдыннан», Х.Вахит), Смеральдина («Болан-Патша», К.Гоцци). Өлкән яшьтәге хатын-кыз рольләрен уйный башлагач, Н.ның көлдерү сәләтенә ия булуы, үткен сатирик



Ф.Н. Нуруллина Дилфүзә ролендә («Кичер мине, әнкәй!», Р.Батулла; сулда – Р.Сәлахов).

образларны оста гәүдәләндерүгә ачыла; ул хәзерге драматургиядә халык ихтирамын казанган сатирик һәм драматик образлар тудыра: Гөрпинә, Дания («Гөргөри кияүләре», «Илгизәр + Вера», Т.Миңнуллин), Мөршидә («Мин төш күрдем», З.Хәким), Люция («Баскетболист», М.Гыйләҗев), Фәнисә («Дивана», Т.Миңнуллин), Мөхлисә Бубый («Үлеп яратты», Р.Зәйдулла).

*Әд.:* Иляловa И. Г.Камал театры артистлары=Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005.

*И.И.Илялова.*

**НУРХӘМИ́ТОВ** Харис Гариф улы (2.10.1931, Биләр р-ны Тукай а. — 10.10.1998, Уфа ш.), ветеринар-гельминтолог, вет. фән. д-ры (1991), проф. (1991). Башкорт а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), БАССРның Илеш р-нында эшли: Яркәй МТСында, 1958–60 елларда район вет. дәваханәсендә вет. табибе. 1960–65 тә Эстәрлетамак зоотехникумында. 1967 дән Башкорт а.х. ин-тында, микробиол., патофизиол. һәм ветсанэкспертиза каф. мөдире (1992–98). Хезмәтләре а.х. терлекләренә, хайваннарны гельминтлардан дәвалауга карый. Н. гельминтларга каршы препаратлар (дифенил-сульфидлар) уйлап таба, фасциолёз б-н авырган сарыкларны, тернәкләнү процессы тиз барырлык һәм артым нәтиҗәлелегенә ирешерлек итеп, «Мамил» премиксы ярдәмендә гельминтлардан арындыру технологиясен эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Антигельминтики при цестодозах животных. Уфа, 1996; Метаболические процессы в организме овец при гельминтозах. Уфа, 1997; Фасциолёз животных и человека (интенсивность катаболических и анаболических процессов). Уфа, 1997 (автордаш).

**НУ́ТРИЯ**, к. *Су кондызы.*

**НУХ**, Коръән персонажы, пәйгамбәр, Библиядәге Ной; *Мөхәммәд* пәйгамбәргә кадәр яшәгән пәйгамбәрләрнең берсе. Коръәндә Н.ның потка табынган халыкны Аллаһның берлегенә ышандыру өчен җибәрелүе бәян ителә. Пәйгамбәрнең вәгазьләрен кабиләдәшләре мыскыллап көлү һәм дошманлык б-н каршы ала. Якынлашып килгән туфаннан котылу өчен, Аллаһ Н.ка зур көймә ясарга, аңа үзенең якыннарын, ш.у. барлык хайваннарның берәр парын алырга боера. Туфан вакытында Җирдә калган гөнаһлылар һәм Н.ның этисенә ышанмаган улы батып үлә. Коръәндәге Н. турындагы бәян Библиядәге хикәяткә туры килә, әмма Коръәндә төп басым пәйгамбәрләрнең кабиләдәшләре б-н бәхәсенә юнәлтелгән, белгечләр әлеге вакыйга һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәре халкы б-н бәхәсе арасында тәңгәллек бар, дип фаразлыйлар.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**НҮКӘ́Р** (Нөгер, Нукер; монг. нөхер — дус, иптәш), 12–13 йөзләрдә Монголиядә аксөякләрдә хезмәттә торган гаскәри. Н. хезмәте өчен азык-төлек, кием-салым, корал, яуда табылган мал, җир биләмәсе б-н бүләкләнә. 13 йөздә югары хәрби башлыклар да Н. дип атала. 14–20 йөзләрдә Алгы һәм Урта Азиядә Н. төшенчәсе «хезмәтче» мәгънәсендә кулланыла.

*Әд.:* Владимирцов Б.Я. Общественный строй монголов: Монгольский кочевой феодализм. Л., 1934.

**НЫРСУА́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 36 *км* көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 139 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 619,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 114 кеше, 1897 дә — 260, 1908 дә — 344, 1920 дә — 458, 1926 да — 439, 1938 дә — 395, 1949 да — 389, 1958 дә — 355, 1970 тә — 428, 1979 да — 363, 1989 да — 221, 2002 дә — 180 кеше.

**НЫРСЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 33,4 *км*, бассейнының мәйданы 235 *км*². Елга башы Теләче р-ны Борчаклы Яз авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак, тамагы Питрәч р-ны Раевка авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Н.ның 1,6 дан 6,3 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы су ташу вакытында муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 166 *мм*, ташу агымы катламы 109 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,45 *м*³*/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**НЫРТЫ́ ЗАВОДЫ́**, к. *Завод-Нырты.*

**«НЫРТЫ́»** совхозы посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 34 *км* көньяктарак, Нысы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 703 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә; урман хуҗалыгының картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йорты ф-лы. 1930 еллар башында нигез салына. Оештырылган көннән Тәкәнеш р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1949 да — 821 кеше, 1958 дә — 1053, 1970 тә — 1029, 1979 да — 1051, 1989 да — 803, 2002 дә — 821 кеше.

**НЫРЬЯ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 227 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Н.да Козьмодемьянск чиркәве, Халык мәгариф министрлыгы мәктәбе (1872 дә ачыла), 2 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 606,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 151, 1897 дә — 230, 1908 дә — 304, 1920 дә — 328, 1926 да — 308, 1938 дә — 296, 1949 да — 333, 1958 дә — 175, 1970 тә — 173, 1979 да — 119, 1989 да — 154, 2002 дә — 215 кеше.

**НЫСЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 22,2 *км*, бассейнының мәйданы 127,2 *км*². Елга башы Кукмара р-ны Нырты совхозы посёлогыннан 0,6 *км* көнбатыштарак, тамагы Саба р-ны Өчнарат авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 94 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Н.ның 0,8 дән 6,8 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,37 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар су-

лары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 140 *мм*, ташу агымы катламы 109 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана һәм еллык агымның 80% кадәргесе шушы чорга туры килә. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,13 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Н. бассейнында суның гомуми күләме 1,5 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НЫСЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,4 *км*, ТР чикләрендә — 8 *км* чамасы. Бассейнының мәйданы 47,4 *км²*. Елга башы Мари Респ-касында, урман массивында, тамагы Арча р-ны Үгез Елга авылыннан көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 106 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Н.ның 0,4 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н үзенчәлекле. Еллык агымның 90% ка якыны язгы ташу чорына туры килә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 135 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), җәен һәм кышын бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суның күләме 0,7 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

**НЫ́ТВА РАЙОНЫ́**, Пермь краеның үзәгендә урнашкан. 1924 елның 27 февралендә оештырыла. Мәйданы — 1650 *км²*. Үзәге — Нытва шәһәре (Пермьнән 70 *км* көнбатыштарак). Халкы — 42901 кеше (2012), 899 татар (2000). Н.р.на татарлар 1920 елларның 2 нче яртысында урнаша башлый, бу Нытва металлургия з-ды үсеше б-н бәйле. Күчеп килүчеләрнең икенче дулкыны Татарстан һәм Башкортстаннан кулаклар дип куылган кешеләрнең нәселе була, аларга 1940 елларда Себер һәм Архангельск өлкәләреннән Уралга күчәргә рөхсәт ителә.

**НЭП**, к. *Яңа икътисади сәясәт*.

# О

**ОБАДИЯ́ КАГА́Н** (? — 820 тирәсе), Хәзәр дәүләте *каганы* (790 еллардан). *Болан* каган нәселеннән. Тәхеткә этисе үлгәннән соң килә. Үз хакимиятен көчәйтүгә, илнең чын җитәкчесе булган каганбәк йогынтысын көчсезләндерүгә ирешә. 799–809 еллар тирәсендә яһүдилекне дәүләт дине дип игълан итә. Якын Көнчыгыш илләреннән шул динне өйрәтүче яһүдләрне чакыртып ала, синагогалар төзетә. Болар мәҗүсилекне кайтарырга теләүче аксөякләрнең баш күтәрүенә (кабарлар хәрәкәте) китерә. Бу вакыйгалар нәтиҗәсендә (810–820 тирәсе) Хәзәр иленең үзәк өлкәләренә зыян салына, ш.и. Дон буендагы шактый ныгытмалар җимерелә. Кабарлар кузгалышын бастырганда О.к. һәм аның уллары һәлак була.

*Әд.:* А р т а м о н о в М.И. История хазар. Л., 1962. *И.Л.Измайлов.*

**«ОБИ́ЛЬНАЯ»**, чия сорты. 1990 елда Тәмте җиләк-җимеш станциясендә Л.А.Севастьянова һәм В.А.Наумов тарафыннан «Крупноплодная вишня № 6» сортыннан ирекле серкәләнүдән аналитик селекция алымы б-н чыгарыла. Бу сорт югары уңышлы, кышка чыдам. Куагы тәбәнәк, 1–1,5 *м* биеклектә, ярымшарсыман-түгәрәк ябылдашлы. Үсентеләре нечкә, кара-коңгырт төстә, өскә таба үсәләр. Яфраклануы яхшы. Яфраклары вак, ланцетсыман, озынча очлы, куе яшел, вак тешәүле ике тапкыр каяу читле. Яфрак сабы кыска, уртача нечкә, аз пигментлы. Чәчәк төркемендә 5–6 чәчәк чатыр урнашкан. Чәчәкләре вак, ак төстә. Җимешләре кызыл, озынча, түгәрәк башлы (өске өлеше түгәрәк), җимеш сабакчасы нечкә, 3,6–4 *г*; август ахырында өлгерәләр. Җимеш йомшагы сусыл, тәме — әчкелтем-баллы, аксыл-алсу төстә. Орлыгы (төше) — вак, озынча, җимешеннән яхшы аерыла. 3–4 нче елда җимеш бирә башлый, тулысынча җимеш бирүе 6–8 нче елда була. Чәчәкләренең 40% ы үзеннән серкәләнә; чиянең башка сортларын яхшы серкәләндерүче. Бөре ялгау һәм яшел чыбыкча ялгау ысулы б-н үрчетелә. Коккомикоз авыруына чыдам. Татарстанда 1997 дән районлаштырыла. Урта Идел буе, Көнбатыш Себер, Урал төбәкләрендә үстерүгә тәкъдим ителә.

**«ОБНОВЛЕ́НИЕ»** («Яңарыш»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. «*Унҗиденче октябрь берлеге*» партиясенең Казан ком-ты органы. 1906 елның 10 гыйнварыннан 21 маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 104 саны чыга. Беренче нашир-мөхәррире — М.И.Лопаткин, соңрак — нашире В.В.Перцов, мөхәррире — Б.В.*Варнеке*. Мәкаләләрнең күбесе авторы күрсәтелмичә басыла, редакция хезмәткәрләр исемлеген игълан итә: Г.Н.Әхмәров, А.Я.Богородский, А.Н.Боратынский, В.С.Груздев, Н.Ф.Катанов, Д.А.Корсаков, В.В.Марковников, Н.В.Никольский, К.В.Харлампович, С.П.Шестаков һ.б. Беренче саны Казан 17 октябрь Манифесты партиясе программасы б-н чыга; аның татар телендәге тексты «О.»гә кушымта буларак басыла (Г.Н.*Әхмәров* тәрҗемәсе). 19 гыйнвар санында газета Казан 17 октябрь Манифесты партиясе, Сәүдә-сәнәгать партиясе, Казанның Руханилар һәм чиркәү старосталары берлегенең бердәм «Унҗиденче октябрь берлеге»нә берләшүләре турында хәбәр итә. Газета «Унҗиденче октябрь берлеге» мөрәҗәгатен бастыра. Мөрәҗәгатьтә октябристлар баш күтәрүчеләр һәм эш ташлаучыларны якламаска, 1 нче Дәүләт Думасы сайлауларына катнашырга һәм үз депутатлары аркылы хөкүмәткә йогынты ясарга өндиләр. Газета революцион көч куллануны кире кага, түземле булырга чакыра, үсешнең эволюцион юлын пропагандалый. Редакция сайлаулар тәртибен аңлата, Дәүләт Думасына сайлаулар турындагы Нигезләмәдән өземтәләр бастыра. 1906 ның 26 мартында булган сайлаулар алдыннан газетада Казан буенча октябрист кандидатлар исемлеге бирелә. Сайлау алды кампаниясе барышында либераль лагерь буенча көндәшләр — кадетлар партиясе актив тәнкыйтьләнә, партиянең сул канаты социалистларга ярарга тырышуда гаепләнә, Казанның «*Вечернее эхо*», «*Волжский вестник*» г-талары б-н бәхәс алып барыла. Бигрәк тә сәяси карьерист дип бәяләнгән Казан кадеты Г.Ф.*Шершеневич* тәнкыйтьләнә. Газета карагруһчы оешмаларны (Чиркәү-халык җәмгыяте, Рус җыены һ.б.ны) консерватив-саклау позициясендә торулары, «уңнар революциясе»нә омтылулары өчен тискәре бәяли. Казан октябристларының аграр проблемаларга карашын аңлатуга зур игътибар бирелә. Җирнең хосусый милек буларак кагылгысызлыгы турындагы гомуми лозунг б-н беррәттән, «хосусый милектәге җирләрнең бер өлешен гадел бәягә сату» турындагы мәсьәлә куела. «Бүленмәс Россия» лозунгын яклап, редакция милли автономиянең һәртөрле формаларын кире кага; «О.» милли мәсьәләне хәл итүне әһәлиләрнең мәдәни дәрәҗәсен күтәрүдә, китап бастыруны җәелдерүдә, а.х. мәктәпләре оештыруда, милли интеллигенцияне үстерүдә күрә. Татарларның милли мәнфәгатьләрен игътибарсыз калдыру нәтиҗәсендә, сайлауларда октябристлар аларның тавышын җыя алмый. Газета татар сайлаучыларына игътибарын сайлаулардан соң гына юнәлтә. Сәяси булмаган мәсьәләләрдән университетлар реформасы, Казан ун-тындагы вазгыять, җирле хакимият органнары эше, приказчиклар җәмгыяте эшчәнлеге, Казандагы иске дин тарафдарлары тормышы турындагы язмаларга киң урын бирелә. Казанның театр тормышы хакындагы кыска язмалары б-н Б.В.Варнеке һ.б. катнаша. Әдәби бүлектә Н.В.Сорокин һ.б.ның фельетоннары басыла. Акад. рухта (авторларның күбесе университет профессорлары була) һәм уртачыл карашта булуы аркасында газета рев-ция чорында популярлык казанмый һәм октябристларның сайлауларда җиңелүеннән соң чыгудан туктый.

*Әд.:* Э л е р т А.А. Из истории общественно-политической борьбы в Казанской губернии на выборах в первую Государственную думу // Революционно-освободительное движение в Поволжье и Приуралье. К., 1974.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ОБНОВЛЁННАЯ РОССИ́Я»** («Яңартылган Россия»), көндәлек иҗтимагый-сәяси газета. 1918 елның 1–10 сентябрендә Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. Нашир-мөхәррире — элек монархия яклыларның «*Город Казань*» һәм «*Казанское слово*» г-талары мөхәррире булган Ю.А.Еленев. Казанга КОМУЧның Халык армиясе гаскәрләре кергәннән соңгы чорда нәшер ителә; икенче мөхәррире — Ген. штаб полковнигы П.И.Виноградов. Авторлары арасында — профессорлар М.Бречкевич, Б.П.Иванов, Н.Бугульминский, С.Павловский. Газета уртачыл-консерватив юнәлеш ала; большевистик булмаган күп кенә басмалардан аермалы буларак, «Бөтен хакимият Учредительләр җыенына» дигән өндәмәне пропагандаламый. «О.Р.»нең рәсми бүлегендә КОМУЧның Самара һәм Казан администрациясе боерыклары һәм күрсәтмәләре, җирле хакимият органнары (шәһәр думасы, земство) эшчәнлегенә кагылышлы мәгълүмат, Идел буендагы сугыш хәрәкәтләре, беренче чиратта Казан янындагы сугышлар барышы турында хәбәрләр басыла. Редакция Халык армиясе фондына акча җыюда катнаша. Күп мәкаләләр халык арасындагы «кызыл террор»га багышлана. Газетада меньшевиклар партиясенең Казан ком-ты башлангычы б-н оештырылган һәм демократик резолюцияләр кабул иткән партиясез эшчеләр конференциясе (1918 нең август ахыры — сентябрь башы, Казан) турында тәнкыйть мәкаләләре басыла. Редакция Казан дары з-ды эшчеләренең кораллы чыгышларын, большевикларның шәһәрдә актив рәвештә алып барган яшерен эшләрен гаепли. Тарихи темаларга багышланган мәкаләләр дә басыла. Газетаның соңгы ике саны Халык армиясе сафына басарга һәм Казанны сакларга чакыра. Басма Казанны Кызыл Армия частьлары азат иткәннән соң чыгудан туктый.

*Т.М.Насыйров.*

**ОБНО́СОВ** Юрий Викторович (15.1.1946, Мәскәү), математик, физика-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли, дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире (1999 дан). Хезмәтләре матем. модельләштерүгә, тоташ

тирәлек механикасы мәсьәләләрен чишү алымнарына, аналитик функцияләр теориясенең сызыкча һәм нәсызыкча кырый мәсьәләләренә карый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2006).

Х е з м.: Решение смешанной краевой задачи теории аналитических функций // Тр. семинара по краевым задачам. 1983. Т. 19; Оценки интегральных средних гиперболически выпуклых функций // Сиб. матем. журн. 2005. Т. 46, № 6 (автордаш); Задача R-линейного сопряжения для софокусного параболического кольца // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. физ.-мат. наук. 2009. Т. 151, № 3 (автордаш).

**ОБОРО́НА ФОНДЫ́**, СССРда Бөек Ватан сугышы елларында (1941–45) фронт ихтыяҗлары өчен халыктан ирекле рәвештә җыелган кыйммәтле әйберләр һәм акчалар тупланмасы. Респ-ка халкы фронтка актив рәвештә ярдәм итә. Сугыш башланып бер ай узуга, Мәскәү халкының О.ф. оештыру тәкъдименә бөтен ил кушыла. Пр-тие һәм учреждениеләрнең эшче-хезмәткәрләре О.ф.на бер көнлек хезмәт хакларын тапшыралар, колхозчылар, акча кертемнәреннән тыш, ашлык, ит, сөт һ.б. б-н ярдәм итәләр. Яшьләр тарафыннан оештырылган өмәләрдән кергән акча ш.у. О.ф.на бирелә. 1941 ел ахырына ТАССР халкы О.ф.на 16 млн. сум акча, 26 *кг* көмеш, 796 *г* алтын тапшыра. 1943 ел ахырына О.ф.на кертемнәр суммасы 51 млн. сумга җитә. ТАССР һ.б. төбәкләрдә җыелган акча самолётлар, танклар һ.б. сугыш техникасы төзүгә тотыла.

*Әд.:* Татарстан в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. — Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында: 1941–1945. К., 2000; Г и л ь м а н о в З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне (1941–1945 гг.). К., 1977.

**«ОБРАЗОВА́НИЕ»** («Мәгариф»), Казандагы нәшрият йорты. 1997 елның 25 сентябрендә оеша. Ачылуына беренче саны 1996 ның декабрендә дөнья күргән шул ук исемдәге газета нигез булып тора. Газетаның ТРда кризиска каршы идарәчелеккә багышланган китаплар, каталоглар, буклетлар, 1996 ның маеннан «Вестник Комитета РТ по делам о несостоятельности и финансовому оздоровлению» («ТРның Түләргә мөмкинлеге булмаганнар һәм финанс ягыннан сәламәтләндерү эшләре буенча комитеты хәбәрчесе») ведомство бюллетенен нәшер итә. «Кризис-менеджер китапханәсе» («Библиотека кризис-менеджера») китап сериясендә кризиска каршы идарә практикасы, пр-тиеләрнең финанс хәлен ныгытучы норматив актлар, Россия законнары тарихы яктыртыла. 2000–2005 тә 13 томлык «Финанс иминлеге формулалары» («Формулы финансового здоровья») дип аталган китаплар сериясе басыла (компакт-дискларда электрон версиясе дә бар). Басма продукциядән тыш (китаплар, каталоглар, буклетлар һ.б.), нәшрият йорты телевидение продукциясе дә («Вариант» һәм «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе телеканалында махсус программалар, тематик фильмнар һ.б.) җитештерә. «Бәллүр каләм» конкурсының «PR — ел проекты» (2001) номинациясендә лауреат исемен ала, ТРның арбитраж идарәчеләре гильдиясе дипломы б-н бүләкләнә (2003).

Генераль директоры — Г.Ф.Морозова, баш мөхәррире — М.В.Агафонова.

**«ОБСЕРВАТО́РИЯ»**, респ-ка балаларны туберкулёздан дәвалау санаторие; гомуми белем бирү мәктәбе (1–9 сыйныфлар) булган дәвалау-профилактика учреждениесе. Хәзер Яшел Үзән р-нының Октябрьский пос. (Казаннан 18 *км*) нарат урманында, элекке сәүдәгәрләр дачалары җирлегендә, табибләр С.С.*Зимницкий*, В.Ф.*Орловский*, Ә.Б.*Терегулов* тәкъдиме б-н 1921 елда ачыла. Балалар һәм яшүсмерләрдә туберкулёзның төрле формаларын, ш.и. терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын да дәвалый. 2011 гә санаторийда 115 ятак-урын исәпләнә. 2 бүлек (үпкә туберкулёзы, сөяк туберкулёзы) эшли. 1987 дә сафка баскан дәвалау корпусында рентген, энә терапиясе, термо- һәм электростимуляция, микродулкынлы резонанс терапиясе, дәвалау физкультурасы, массаж, хезмәт б-н дәвалау кабинетлары, остаханәләр, бассейн бар. 1997 дә санаторий хезмәткәрләре өчен торак йорт, мунча һәм кер юу комплексы, чистарту корылмалары төзеп тапшырыла. «О.» санаториенда 80 нән артык хезмәткәр (ш.и. 17 табиб, 58 урта мед. хезмәткәре, 13 укытучы) эшли. Санаторийга Респ-ка туберкулёз авыруыннан дәвалау диспансеры даими ярдәм күрсәтә. «О.» санаторие ел әйләнәсе эшли.

*Әд.:* Здоровье детей в надёжных руках: 75 лет противотуберкулёзному санаторию «Обсерватория». К., 1996.

*И.М.Шакиров.*

**О́БУХОВ** Сергей Георгиевич (26.3.1960, Удмурт АССРның Балезино р-ны Карсовай а. — 1.8.2005, Чаллы ш.), термотехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1999), проф. (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Кама политехник ин-тында (Чаллы ш.) эшли, сызма геометрия һәм инженерлык графикасы (2000–02), электротехника һәм электроника (2002 елдан) кафедралары профессоры. Хезмәтләре нефть продуктларының фаза әверелешләрендә җылылык алмашуга карый. О. стационар, баскычлап җылылык аерылып чыгу һәм бәрмә җылылык шартларында су һәм углеводород ягулыгы кайнаганда җылы бирүчәнлек кризисын тикшерә. Авиация керосинының җылыну чиген исәпләү алымын тәкъдим итә. О. хезмәтләре РФнең авиация-ракета һәм автомобильләр төзү сәнәгатьләрендә гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Термодинамический кризис теплообмена при ступенчатом тепловыделении // Авиац. техника. 2001. № 2; О влиянии длительности работы поверхности на коэффициент теплоотдачи при кипении керосина и воды в условиях электрического нагрева // Инж.-физ. журнал. 2005. Т. 78, № 2.

**ОБУХО́ВИЧ** Ольга Андриановна (18.4.1952, Төрекмәнстан ССРның Ашхабад ш.), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). 1974 елда Грозный нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Идел буе углерод чималы фәнни-тикшеренү ин-тында (ВНИИУС) эшли. Хезмәтләре нефтьне, нефть продуктларын, углеводородлы газларны һәм агынты суларны күкертле катнашмалардан чистарту технологияләренә карый. Дәүләт бүләге углеводород чималын чистарту өчен фталоцианинлы катализаторлар эшләп гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.

**ОБУ́ХОВО** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 29 *км* төньяктарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 68 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1649 да Салтык авылы буларак билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 493 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 216, 1897 дә — 203, 1908 дә — 232, 1920 дә — 327, 1926 да — 347, 1949 да — 288, 1958 дә — 260, 1970 тә — 149, 1979 да — 84, 1989 да — 62, 2002 дә — 69 кеше.

**ОБЫДЁННОВ** Александр Павлович (20.8.1932, Үзәк-Кара туфраклы өлкәнең Уварово р-ны Моисеево-Алабушка а. — 3.10.1994, Казан), хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (1993), РСФСРның атказ. транспорт хезмәткәре (1987). Хезмәт эшчәнлеген 1950 елда Алтай транспорт з-дында слесарь-электрик буларак башлый. Воронеж урман-техник ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Васильево урман-техник техникумында эшли. 1959–61 дә Казан авторемонт з-ды баш инженеры, директоры, 1961–63 тә Татарстан автотранспорт тресты баш инженеры, 1963–94 тә Татарстан автотранспорт пр-тиеләренең «Татавтотранс» респ-ка ассоциациясе ген. директоры. О. респ-када автомобиль транспорты үсешенә зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә респ-ка терр. берләшмәсе һәм автотранспорт пр-тиеләре дәрәҗәсендә йөкләр һәм пассажирлар ташу б-н автоматик идарә системасы (АСУ) эшләнә. 1990–94 тә ТССР, ТР ЮС депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын, бер көмеш, ике бронза медале, РСФСР, ТАССР ЮСлары Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. О. исеме Казан автотранспорт техникумына бирелә (2002).

Х е з м.: Управление автомобильным транспортом с применением ЭВМ. М., 1989; Совершенствование системы управления автотранспортным предприятием. М., 1992 (автордаш).

**ОБЫДЁННОВА** Гөлнара Тәлгат кызы (11.4.1955, Чиләбе ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2003), проф. (2011), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1978). 1978 елдан Башкорт пед. ун-тында укыта. 1988 дән ун-т каршындагы Тарих һәм хокук белеме ин-ты директоры. Хезмәтләре археол. тарихы, Урал-Идел буе төбәгендә бронза гасыр та-

рихы һәм пед. белем бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Тюбяк-поселение бронзового века на Южном Урале. Уфа, 2001 (автордаш); Уфаведение (история Уфы с древнейших времён до XIX в.): Учеб. пособие для общеобразовательных заведений. Уфа, 2011 (автордаш).

**ОВРУ́ЦКИЙ** Григорий Давидович (8.2.1928, Киев ш.), стоматолог, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1967), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1988). Киев стоматология ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Днепропетровск өлкәсендә стоматология поликлиникасында эшли, Днепропетровск теш дәвалау мәктәбендә укыта. 1951–56 елларда стоматология бүлеге башлыгы вазифасында Сов. Армиясендә хезмәт итә. 1957 дән Киев шәһәренең Мәскәү р-ны 2 нче хастаханәсендә бүлек мөдире. 1961–90 да Казан мед. ин-тының дәвалау стоматологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре стоматологиядә фтор куллануга һәм организмның иммунобиол. халәте б-н теш авыруларының үзара бәйләнешенә карый. О. периодонтитны дәвалауның оригиналь ысулын эшли, цебанит препаратын куллану методикасын тәкъдим итә (1966). «Стоматологиядә һәм гигиенада фтор» («Фтор в стоматологии и гигиене», 1969, автордаш) монографиясе инглиз теленә тәрҗемә ителә һәм АКШта бастырып чыгарыла (1977). Уйлап табуга 4 патенты бар. Бөтенпольша стоматологлар җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1965), «Казанский медицинский журнал» басмасының редколлегия әгъзасы (1971–90). Татарстан стоматологлар җәмгыяте рәисе (1971–90), Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз стоматологлар җәмгыятьләре президиумнары әгъзасы (1969–90). РСФСР Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы, СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. 1990 нан Израильдә яши.

Х е з м.: Флюороз зубов. К., 1962; Фтор в профилактике кариеса зубов. К., 1964; Болезни зубов. К., 1969; Пародонтит. К., 1990; Одонтогенный очаг. М., 1991.

*Әд.:* Григорий Давидович Овруцкий (к 50-летию со дня рождения) // Стоматология. 1978. № 4; А н д р е е в И.М., К р а с и л ь н и к о в С.Н. История в биографиях: Казан. гос. мед. ун-т. Стоматологический факультет. К., 1996.

**ОВСЕ́ЕНКО** Александр Дмитриевич (1903–1983), генерал-майор (1942). Гражданнар сугышында катнаша. 1925–41 елларда Кавказ арты хәрби округында, дивизия командиры урынбасары. Бөек Ватан сугышында Приморье флоты укчы дивизиясенең өйрәнү бригадасы командиры. 1946 дан Тбилиси ун-тында хәрби каф. башлыгы. 1947 дән Идел буе хәрби округында офицерлар составының белемнәрен камилләштерү курслары башлыгы. 1954–66 да ТАССРның хәрби комиссары. 1966 дан отставкада.

**ОВСЯ́ННИКОВ** Филипп Васильевич (14.6.1827, С.-Петербург — 26.5.1906, С.-Петербург губ., Луга өязе Заполье утары), физиолог, гистолог, анатом, медицина докторы (1854), Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1863). Дерпт ун-тын тәмамлаганнан соң (1853), С.-Петербургта 2 нче коры җир гаскәрләрендәге, соңрак патша сарае карамагындагы госпитальләрдә. 1856 елда Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан Идел елгасы һәм Каспий диңгезендә балык тоту шартларын өйрәнү өчен Саратов һәм Әстерхан шәһәрләренә җибәрелә. 1858 дән Казан ун-тының физиол. һәм гомуми патология каф. мөдире. 1860–61 дә Көнбатыш Европа илләрендә фәнни командировкада була, физиол. лаб-яләре эше б-н таныша, нервизм турындагы тәгълимат нигезләрен эшли. 1863 тән С.-Петербургта: Петербург ун-тының анатомия һәм физиол. каф. мөдире, 1886–92 дә анатомия-гистология кабинеты мөдире. О. — Казан (1858), Петербург ун-тларында (1863, хәзер А.А.Ухтомский исем. Физиол. ин-ты), Петербург ФАндә (1864, хәзер И.П.Павлов исем. Физиол. ин-ты) физиол. лаб-яләренә нигез салучы. 1886 да үз утарында крәстиян балалары өчен мәктәп ача.

Хезмәтләре үзәк нерв системасы морфологиясенә һәм физиологиясенә карый. О. беренче булып озынча мидәге кан-хәрәкәт үзәген тасвирлый, диңгез йолдызчыкларында нерв системасы булуын исбатлый. Россиядә гистологиягә, нерв системасының чагыштырма физиологиясенә нигез салучыларның берсе. Петербург табигыять җәмгыятенең зоол. бүлекчәсе рәисе (1880–1906). «Вестник естествознания» журналының баш мөхәррире (1890–93). О.ның «Зур мидәге нерв очларын микроскоп б-н тикшерү» («Микроскопическое исследование начала нервов в большом мозгу») хезмәте Париж ФА бүләгенә лаек була (1857). Медальләр, ш.и. чөгә балыгын үрчетүдәге уңышлары өчен Париж климатка яраклаштыру җәмгыятенең 1 нче дәрәҗәдәге медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Микроскопические исследования начал нервов в большом мозге // Военно-мед. журн. 1856. Ч. 6–8, разд. 9 (автордаш); Обзор исследований о теменном глазе у земноводных, пресмыкающихся и рыб // Вестн. естествознания. 1891. № 3; О строении нервной системы речного рака // Изв. Имп. АН. 1898. Т. 9, № 3.

*Әд.:* З е ф и р о в А.А., З в ё з д о ч к и н а Н.В. Филипп Васильевич Овсянников (1827–1906). К., 2002.

**ОВЧИ́НИН** Андрей Викторович (17.8.1966, Алабуга р-ны Бехтерово а.), слесарь, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). 1987–94 елларда Приморье крае пр-тиеләрендә эшли. 1994–96 да «Тракторзаводстрой» (Алабуга ш.) трестының Җитештерү-технол. комплектациясе идарәсендә, 1997 дән «ЕлАЗ» ЖБ»нең Станок-инструментлар з-ды АЖдә. Дәүләт бүләге 50 һәм 60 *т* йөк күтәрешле нефть һәм газ скважиналарын үзләштерү һәм ремонтлау өчен югары технологияле күтәрү агрегатларын эшләүдә һәм җитештерүдә катнашканы өчен бирелә.

**ОВЧИ́ННИКОВ** Александр Александрович (7.1.1874, Вятка губ., Слободский өязе Спас-Заозерницкий а. — 15.9.1936, Берлин), статист, политэкономия магистры (1912), статский советник (1916). Руханилар катлавыннан. Казан ун-тын тәмамлый (1897); шунда ук эшли: 1900 елга кадәр политэкономия һәм статистика кафедрасында профессорлык стипендиаты, 1900–13 тә (бүленеп) приват-доцент, 1913–15 тә экстраординар проф., 1915–19 да ординар проф., 1919–22 дә иҗтимагый фәннәр ф-тының юридик-сәясәт бүлеге профессоры; 1913–17 дә проректор, 1921–22 дә ректор. Бер үк вакытта, 1903–17 дә, Казан губерна земство идарәсенең статистика бүлеге мөдире, 1919–22 дә Казан губерна стат. бюросының игенчелек хуҗалыгы статистикасы секциясе мөдире. Дрезден, Прага, Бреславль, Мюнхен (1905–06), Гейдельберг (1908–09) ун-тларында, Югары хатын-кызлар курсларында (Казан, 1910–17), Югары халык мәгарифе ин-тында (Казан, 1919–22) укыта. Казан ун-тында ректорлыгы чорында О. тарафыннан Төньяк Боз океаны ярларына экспедиция оештырыла; мед. ф-тында табибләр җәмгыяте, иҗтимагый фәннәр ф-тында Көнчыгыш телләре каф. оештырыла; авыл хуҗалыгы һәм урманны өйрәнү ф-ты төзелә. 1922 дә О. университет профессорлары забастовкасының башында тора һәм шул ук елның сентябрендә РСФСРдан Германиягә сөрелә. 1922 дән Берлинда Рус фәнни ин-тында һәм Рус акад. берлегендә эшли. Төп тикшеренүләре — «Халык статистикасы буенча таблицалар» («Таблицы к статистике населения», 1903), «Элементар статистика курсы» («Элементарный курс статистики», 1907), «Хезмәтне берләштерү турындагы тәгълиматка карата» («К учению о соединении труда», 1912) — политэкономия, стат. алымы теориясе, халык санын исәпкә алу мәсьәләләренә багышлана. О.ның вак һөнәрчелек җитештерүе һәм кредитлау ширкәтләре мәсьәләләре буенча тикшеренүләре «Лаеш өязе Емельяновка кредитлау ширкәте эшчәнлеге турында очерк» («Очерк деятельности Емельяновского, Лаишевского уезда, кредитного товарищества», 1903), «Казан губернасының Царёвококшайск, Чабаксар һәм Козьмодемьянск өязләрендә сумала кайнату» («Смолокурение в Царёвококшайском, Чебоксарском и Козьмодемьянском уездах Казанской губернии», 1905) дигән хезмәтләрендә урын ала.

Х е з м.: Об ответственности предпринимателей за несчастные случаи с рабочими // Тр. Юрид. об-ва при Казан. ун-те за 1900 г. К., 1901; Определение и классификация кустарных промыслов // Тр. съезда деятелей по кустарной промышленности. СПб., 1902.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Ректоры Казанского университета 1804–2004 гг.: Очерки жизни и деятельности. К., 2004.

*Е.Б Долгов.*

**ОВЧИ́ННИКОВ** Алексей Леонидович (8.9.1961, Казан), радиоинженер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996), техник фән. канд. (1989). 1984 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп: 1990–92 дә Контроль һәм диагностика чаралары тәҗрибә КБнда бүлек башлыгы). 1999 дан ТР ФАнең Информатика проблемалары ин-тында бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге «Машиналар һәм приборларны виброакустик сынаулар өчен радиоэлектрон системалар һәм комплекслар (теория, алымнар, чаралар)» («Радиоэлектронные системы и комплексы для виброакустических испытаний машин и при-

боров (теория, методы, средства)») хезмәте өчен бирелә. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1996 (автордаш); Вибрационный анализ конструкционных элементов. К., 2003 (автордаш).

**ОВЧИ́ННИКОВ** Виталий Витальевич (29.11.1947, Казан), химик, химия фән. д-ры (1989), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1987 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1992 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, бер үк вакытта РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында термохимия төркеме җитәкчесе (1992–2001). 2006 дан Казан техник ун-тында. Хезмәтләре биол. актив элементорганик кушылмаларның термодинамикасына, реакциягә сәләтенә, төзелешенә карый. О. Пудовик реакциясенең электрофиль вариантын, ш.у. Кляйзен яңадан төркемләнешенең фосфорлы гетероцикллар өчен яңа вариантын эшли. Эремәләрдә һәм газ фазасында Арбузов, Пудовик, Кухтин-Рамирец реакцияләренең термохимиясен өйрәнә. Төрле фәзаи төзелешле фосфор- һәм мышьякорганик кушылмаларның парга әйләнү, сольватация, хасил булу һәм яну җылылыкларын билгели. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые аспекты термохимии органических соединений фосфора // Рос. хим. журн. 1999. № 3/4 (автордаш); The experimental and theoretical termochemistry of P-H — containing organophosphorus compounds // Phosphorus, Sulfur and Silicon and the Related Elements. 2004. V.179, № 1.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ОВЧИ́ННИКОВ** Евгений Михайлович (9.1.1847, Вятка губ., Нолинск өязе Лудяны а. — 22.11.1912, Мәскәү), революцион хәрәкәттә катнашучы. Рухани гаиләсеннән. Вятка руханилар семинариясен (1871), Петербург мед.-хирургия академиясен (1881) тәмамлый. 1871–74 елларда Казан ун-тының мед. ф-тында укый. 1872 дә Казанда беренче народниклар түгәрәген оештыра һәм җитәкли (к. *Овчинников түгәрәге*); укучы яшьләр һәм крәстияннәр арасында пропаганда алып бара, хөкүмәткә каршы булган әдәбият тарата; Петербургтагы народниклар түгәрәкләре («Чайковчылар», С.Ф.Ковалик түгәрәге һ.б.) әгъзалары б-н аралаша. 1874 тә Казан губернасының Осиновка авылы крәстияннәрен кораллы чыгыш ясарга өнди, 4 августта кулга алына, 1876 га кадәр Казан төрмәсендә утыра, шуннан соң Петербургка күчерелә. 1877 дә «Империя заговоры» эше («193 процессы») буенча хөкем ителә, 1878 дә аклана. 1890 елларда Мәскәүдә земство һәм фабрика табибе. 1900 елларда Мәскәү губернасының Чёрная Грязь авылында земство табибе. 1907 дә тыелган әдәбият саклаган өчен берничә тапкыр кулга алына.

*Әд.:* Н а ф и г о в Р.И. Первый шаг в революцию. К., 1970; Деятели революционного движения в России: От предшественников декабристов до падения царизма: Биобиблиогр. словарь. М., 1931. Т. 2, вып. 3; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ОВЧИ́ННИКОВ** Игорь Васильевич (20.9.1935, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1982), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1994, 1999). 1958 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1961 дән СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында, 1964 тән Казан ун-тында. 1972 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, молекуляр радиоспектроскопия лаб-ясе мөдире (1980 нән). О. өлешчә тәртипкә салынган тирәлекләрдә координацион кушылмаларны тикшерү өчен (сыек кристаллар, сузынкы полимерлар) ЭПР алымын эшли, ЭПР спектрларында йотылуның өстәмә пиклары турында аналитик чишелеш таба. Беренче булып координацион кушылмалар нигезендә магнитик сыек кристаллар (нематиклар һәм смектиклар), ш.у. рекордлы магнит анизотропиясенә ия булган һәм үзгәрүчән магнит (спин) үзлекле сыек кристаллар ача һәм тикшерә. Металлы сыек кристаллар буенча Халыкара ком-т әгъзасы (1991 дән). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001).

Х е з м.: Парамагнитные жидкокристаллические металлокомплексы // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1989. Т. 53, № 10 (автордаш); Магнитные жидкие кристаллы на основе координационных соединений // Рос. хим. журн. 2001. Т. 45, № 3 (автордаш); Extra absorption peaks in EPR spectra of systems with anisotropic g-tensor and hyperfine structure in powders and glasses // Journal of Magnetic Resonance. 1978. V.32, № 2 (автордаш).

**ОВЧИ́ННИКОВ** Марат Николаевич (21.12.1958, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). 1981 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук радиоэлектроника кафедрасында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2006 дан). Хезмәтләре сыеклык, газ һәм плазма механикасына карый. О. үз-үзен стохастик тоткан өлкәнең таралу концепциясен эшли, спектраль тавыш үлчәү (шумометрия) алымын гамәлгә кертә. Нефть чыганакларын эшкәртүне оптимальләштерүдә кулланыла торган күзәнәкле туенган катламнарның гидродинамик параметрларын контрольдә тоту алымнарын эшли һәм гамәлгә ашыра.

Х е з м.: Стохастичность в системах с потенциалом Леннарда-Джонса при малом числе частиц // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 54, вып. 7 (автордаш); Генерация звука фильтрационным потоком в пористых средах // Акустический журн. 1992. Т. 38, № 1 (автордаш); Интерпретация результатов исследований пластов методом фильтрационных волн давления. К., 2003.

**ОВЧИ́ННИКОВ ТҮГӘРӘГЕ́**, народникларның Казандагы беренче оешмаларының берсе. 1872 елда Петербург народниклары төркемнәреннән «чайковскийчылар» җәмгыяте, «оренбурглылар» түгәрәге һәм С.Ф.Ковалик йогынтысы һәм ярдәмендә Е.М.*Овчинников* тарафыннан оештырыла. Әгъзалары — А.Вихарев, К.Вяткин, П.Голубев, П.Иорданский, С.Чугунов һ.б. (башлыча, Казан ун-ты һәм вет. ин-ты студентлары). О.т. әгъзалары укучы яшьләр, зыялылар һәм эшчеләр арасында народниклык идеяләре аңлатылган әдәбият тараталар, «халык арасына чыгып», Казан губернасы крәстияннәрен кораллы көрәшкә күтәрергә омтылыш ясыйлар. С.-Петербург, Мәскәү һ.б. шәһәрләрнең народниклар оешмалары б-н элемтәдә торалар. 1874 нең көзендә О.т. полиция тарафыннан тар-мар ителә, түгәрәк әгъзалары кулга алына.

Чыг.: Синегуб С. Воспоминания чайковца // Былое. 1906. № 8.

*Әд.:* Н а ф и г о в Р.И. Первый шаг в революцию. К., 1970; Д о л г о в Е.Б. Некоторые вопросы общественно-политического движения в Казанской губернии во второй половине XIX века // Ист.-археол. сборник. Наб. Челны, 1996. Сб. 2.

*Я.Я.Гришин.*

**«ОГОНЁК»**, көзге арыш сорты. 2001 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында М.Л.Пономарёва, С.Н.Пономарёв, Р.Ә.Әсретдинова, Ю.В.Еров тарафыннан чыгарыла. Бу сорт уртача өлгерешле, вегетация чоры 316–340 көн. Үсемлекнең биеклеге 100–110 *см*, сабагы нык. Башагы ачык сары, кылчыклары сары төстә. Бөртеге эре, соры-яшел төстә, сары бөртекләр катнашында, ярым ачык, 1000 орлыкның авырлыгы 32–38 *г*. Сөрлегүгә чыдамлыгы югары, салкынга чыдамлыгы уртачадан югары. Икмәк пешерү сыйфатлары яхшы. Корылыкка чыдам. Бу сорт бөртегенең югары физик һәм технол. сыйфатлары, яхшы терлек азыгы һәм гомуми биол. кыйммәтенең югары булуы б-н аерылып тора. 2003 тән «О.» РФ Дәүләт реестрының Урта Идел буе һәм Үзәк регионнарында чәчәргә рөхсәт ителгән сортлар исемлегенә кертелгән. 3,5 мең *га* мәйданда үстерелә, 1 *га* дан 37,5 *ц* уңыш алына.

*Әд.:* Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

**ОГОРО́ДНИКОВ** Владимир Иванович (16.5.1886, Вятка губ., Уржум өязе Пустополье а. — 22.9.1938, Архангельск өлкәсе), тарихчы. Руханилар катлавыннан. Вятка руханилар семинариясен (1906), Казан ун-тын (1910) тәмамлый. 1910–18 елларда Казан ун-тында: проф. стипендиаты (1914 кә кадәр), 1914–18 дә приват-доцент, 1918 дә рус халкы тарихы каф. профессоры. 1918–21 дә Иркутск ун-тының тарих-филол. ф-ты деканы, 1923 тә Ерак Көнчыгыш ун-ты (Владивосток ш.) ректоры. 1921–23 тә Халык мәгарифе ин-ты (Чита ш.) ректоры. 1923 тән Камчатка АҖдә. 1930 еллар башында Арктика ин-ты (Петропавловск-Камчатка ш.) директоры урынбасары. Хезмәтләре 18 йөзнең 1 нче чирегендәге Россиядә дәүләт оешмалары тарихына, борынгы заманнардан алып 17 йөзгә кадәр Себер һәм Ерак Көнчыгыш тарихы һәм этнографиясенә, русларның колонияләштерүенә һәм Себер ханлыгын буйсындыруга багышлана. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы һәм казначысы. Репрессияләнә (1933); үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Из истории вопроса о центральных учреждениях в России при Петре Великом: Приказы, канцелярии, коллегии. К., 1917; Русская государственная власть и сибирские инородцы в XVI–XVIII вв. Иркутск, 1920; Очерк истории Сибири до начала XIX в.: В 2 ч. Иркутск-Владивосток, 1920–24; Из истории инородческих волнений в Сибири. Чита, 1922; Из истории покорения Сибири: Покорение Юкагирской земли. Чита, 1922.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ОДИНО́КОВ** Юрий Георгиевич (6.5.1910, Сембер ш. — 28.4.1996, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1945), проф. (1945), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957, 1970). 1934 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очкыч аппаратлар төзү механикасы каф. мөдире (1938–83), самолётлар төзү ф-ты деканы (1938–42), директор урынбасары (1944–55). Казан очкыч аппаратларның ныклыгын тикшерү фәнни мәктәбенә нигез салучы. О. юка стеналы авиация конструкцияләрен аркылы кисемнәр депланациясенә нигезләп исәпләү теориясен һәм алымнарын эшли. «Самолётны ныклыкка исәпләүләр» («Расчёт самолёта на прочность», М., 1973) дәреслеге авторы. «Авиационная техника» ж-лының баш мөхәррире (1957–60). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Кызыл Йолдыз, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан техник ун-ты диварына мемориаль такта элenә.

Х е з м.: Расчёт тонкостенных конструкций типа крыла, фюзеляжа и оперения самолёта // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1946. Вып. 18; Напряжения и деформации тонкостенных конструкций переменного сечения // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1948. Вып. 20; Приближённое решение уравнений коробления тонкостенных конструкций // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1958. Вып. 33–34 (автордаш).

**ОДИНЦО́В** Борис Михайлович (28.10.1947, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993). 1971 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли (бүленеп: 1983–89 да СССР ФА Казан ф-лы Президиумының гыйльми секретаре), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1989 дан). 1998 дән Мәскәүдә. Хезмәтләре төшләрне динамик поляризацияләштыруга карый. О. нәстационар төш-электрон резонансы алымнарын эшли.

Х е з м.: Электронно-ядерный эффект Оверхаузера в растворах. К., 1986; Влияние фазовых превращений гелия-3 в порах древесного карбонизата на спиновую кинетику ядер ³He // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 2006. Т. 84 (автордаш).

**ОДНОЦЕ́НОВ** Герман Петрович (21.1.1923, Казан — 8.3.1945), Сов. Союзы Герое (29.6.1945, үлгәннән соң), лейтенант. Очучыларның Пермь хәрби-авиация мәктәбен тәмамлый (1941). 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 951 нче штурм авиациясе полкында звено командиры (17 нче Һава армиясенең 306 нчы штурм дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск (1943) сугышларында, Сулъяк яр һәм Уңъяк яр Украинаны (1943–44), Румыния (1944), Болгария (1944), Венгрияне (1944–45) азат итүдә катнаша. 150 сугышчан очыш ясый, сугыш барышында дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын, каршы тору үзәкләрен, аэродромнарын, елга кичүләрен, күперләрен юк итә. Ике Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



Г.П. Одноценов.

**ОДО́ЕВСКИЙЛАР**, рус кенәзләре, Рюриковичлар, Ярослав Мудрыйның улы Святослав, кенәз Михаил Черниговский нәселеннән. 16–17 йөзләрдә Россиянең сәяси тормышында мөһим роль уйныйлар. Иван (Меньшой) Никитич һәм Никита Иванович Казан тәбәге б-н бәйле булалар. **Иван Никитич** (1570 тирәсе — 1629, Мәскәү) хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1613). Хезмәтен 1586 елда стольник булып башлый. 1591 дә, кече воевода буларак, Кырым ханлыгы б-н сугышта катнаша, 1607–10 да Россия тәхетен дәгъвалаган Ялган Дмитрийга каршы, Василий Шуйскийны яклап көрәшә. 1610 нан Вологда шәһәрендә воевода. Д.М.Пожарский һәм К.М.Мининның Түбән Новгород ополчениесе (1612 дән) хөкүмәте әгъзасы, Мәскәүне поляклардан азат итүдә катнаша. 1613–14 тә Казан дворяннарыннан, стрелецлардан, йомышлы татарлардан тупланган гаскәр башында тора; 1614 нең августында Әстерханны баш күтәрүчеләрдән азат итә, аларның җитәкчеләре атаман И.М.Заруцкийны, Марина Мнишекны һәм «карак Ивашка»ны (Ялган Дмитрийның улы) кулга ала. 1614–15 тә Әстерхан шәһәрендә воевода. 1620 дән Владимир мәхкәмә приказы судьясы. 1622–24 тә Казанда 1 нче (баш) воевода. **Никита Иванович** (1605 тирәсе — 12.2.1689, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1640). Иван (Меньшой) Никитичның бертуганының улы. 1632–34 тәге рус-поляк сугышында катнаша, кече воевода. 1643 тән Әстерханда воевода. 1644 тән Казан сарай идарәханәсе судьясы. 1646–48 дә Ливны шәһәрендә воевода. 1648 дә, *1649 елгы Кануннар мәҗмугасын* төзегән комиссияне җитәкли. 1651–53 тә Казанда 1 нче (баш) воевода. 1653 тә Земство җыенында, 1654 тә Переяславль Радасында катнаша. 1654–67 елгы рус-поляк сугышы вакытында сугышны туктату турында сөйләшүләр б-н җитәкчелек итә. Россия дәүләтенең тышкы сәясәтен оештыруда катнаша. 1681 дә урынчылыкны бетерүне тәкъдим итүче һәм оештыручы була.

*Әд.:* Русский биографический словарь. Т.: Обезьянинов-Очкин. СПб., 1905.

*Е.В.Липаков.*

**ОЕ́Т** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 237 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Уют, Починок Буклуют исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1004 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 509, 1897 дә — 794, 1908 дә — 996, 1920 дә — 995, 1926 да — 930, 1938 дә — 949, 1949 да — 656, 1970 тә — 521, 1979 да — 421, 1989 да — 269, 2002 дә — 258 кеше.

**ОЕШМА́ ЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р**, к а ш к а р ы й ч а л а р (Compositae, яки Asteraceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. 1 меңнән артык ыруг һәм 25 меңнән артык төре билгеле. Үләннәр, сирәк кенә ярымкуак, куак, зур булмаган агачлар. Бөтен Җир шары буйлап таралганнар. Татарстан терр-ясендә 64 ыруг, 235 төр бар. Бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, сирәк кенә каршыдаш яки боҗрасыман утырышлы, гадиләр, бөтен яки теленмә, гадәттә төпчек яфракларсыз. Чәчәкләре ике яки бер җенеслеләр, көпшәле, телсыман, ялган телсыман һәм ике иренле, 5 буыннан торучы тоташ яфракчыклы таҗлы (серкәчләре 5, җимеш яфрагы 2), кәрзин чәчәк төркеменә җыйналган, алар исә башак, калкан һ.б. катлаулы чәчәк төркемнәре хасил итергә мөмкин. Җимеше — орлыкча, еш кына очкак. О.ч. арасында дару (*каклавыч, әрекмән, үги ана яфрагы*, тырнак гөл (к. *Календула*), *тузганак, әрем, эт сырганагы* һ.б.) терлек азыгы (*андыз, агулы билчән, топинамбур* һ.б.), декоратив (кашкарый, *кукчәчәк*, маргаритка, *болын ромашкасы, шайтан таягы* һ.б.), баллы (күкчәчәк, ачыкый, дөгәнәк, билчән һ.б.), майлы (*көнбагыш*), инсектицид (яткын борча үләне, *гөлбадран, өчкырлык, меңьяфрак* һ.б.) чүп (каклавыч, әрекмән, билчән, *убыр уты* һ.б.) үсемлекләре бар. 31 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**«ОЕШТЫРУЧЫ́ ҮЗӘ́К»**, к. *«Солтангалиевчеләрнең Мәскәү үзәге» эше.*

**ОЖБУ́Й** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 99 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда. 2010 елда 40 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. 18 йөздә нигез салына. 1860 ка кадәр халкы типтәрләр һәм асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 215,6 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостена керә. 1921 дән — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 59,

1887 дә — 75, 1905 тә — 100, 1920 дә — 106, 1926 да — 322, 1938 дә — 146, 1958 дә — 159, 1970 тә — 133, 1989 да — 55, 2002 дә — 58 кеше.

**ОЖИГА́НОВ** Леонид Иванович (4.7.1940, Мари АССРның Ронги р-ны Ожиганово а. — 9.10.1998, Казан), информатика һәм хисаплау техникасы өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1970), проф. (1991). 1964 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, автоматлаштырылган мәгълүмат эшкәртү һәм идарә итү системалары кафедрасын оештыручы, аның мөдире (1972–98), техник кибернетика һәм информатика ф-ты деканы (1973–74, 1983–93), проректор (1974–81, 1993–98). Хезмәтләре фәнни-тикшеренү, проектлаштыру һәм укыту процессларына автоматлаштырылган интеллектуаль мәгълүмати ярдәм системаларына карый. О. мәгълүмат системаларында бирелгәннәрне кысу алымнарын һәм чараларын эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар. Югары уку йортлары карамагындагы «Автоматизированные обучающие системы» җыентыгының җаваплы мөхәррире (1977–81). ТРның Мәгълүматлаштыру буенча «Татинформ» ассоциациясе вице-президенты (1991–98). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә. О. исеме Мари Респ-касының Орша авылы мәктәбенә бирелгән (2005).

Хезм.: Эффективное исследование шумового сигнала // Электронная техника. Сер. 6. Микроэлектроника. М., 1971. Вып. 4(30); Автоматизированные системы обработки данных. К., 1989 (автордаш); Региональная программа информатизации Республики Татарстан // Информатика и вычислительная техника. М., 1993 (автордаш).

**ОЗО́Л** Альфред Альфредович (8.7.1935, Белоруссия ССР, Могилёв өлкәсенең Чаусы р-ны Сухари а. — 9.8.2008, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1979), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), СССР ФАнең Казан ф-лында эшли. 1961–64 елларда Ерак Көнчыгыш һәм Оренбург геол. идарәләрендә. 1965 тән ЦНИИгеолнерудта, баш фәнни хезмәткәр (1997 дән). Хезмәтләре файдалы казылма чыганаклары геологиясенә һәм экологиягә карый. О. руда булмаган файдалы казылмаларның вулканоген-утырма чыганакларының төп урнашу һәм формалашу закончалыкларын ачыклый, аларны фаразлау һәм эзләүнең теоретик нигезләрен эшли, СССРда беренчеләрдән булып вулканоген-утырма боратларның рудалы чыганакларын ача; полиген нефть-газ һәм руда барлыкка килү процессларын нигезли, нефть-газ чыганакларын эзләү алымнарын эшләүдә катнаша, Татарстанда нефть булырга тиешле урыннарны билгели. Биол. актив элементларның миграциясе, таралу һәм концентрациясе закончалыкларын ачыклый, аларның кешегә тәэсире үзенчәлеген билгели, ТР халкының авырулар санын киметүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр эшли.

Хезм.: Осадочный и вулканогенно-осадочный рудогенез бора. М., 1983; Прогнозирование и поиски месторождений горно-химического сырья. М., 1990; Процессы полигенного нефтегазо- и рудообразования и их экологические последствия. К., 2004.


**ОЗО́Л** Альфред Эрнестович (13.7.1891, Рига ш. — 26.9.1979, Казан), эпидемиолог, мед. фән. д-ры (1941), проф. (1949). 1911 елдан, бүленеп, Юрьев (хәзерге Тарту ш.) ун-тының мед. ф-тында укый (ун-т 1916 дан Воронежга эвакуацияләнә). 1920 дә Кызыл Армия сафларына алына, Воронеж эвакогоспитальләренең йогышлы авырулар бүлекләрендә табиб булып эшли; 1921 дән запас кыр госпиталендә химия-бактериология лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта, Воронеж санитария-бактериология ин-тының диагностика бүлегендә табиб-лаборант, 1924–42 дә Воронеж мед. ин-тының бактериология һәм эпидемиология бүлекләре мөдире, бер үк вакытта эпидемиология каф. мөдире (1931–34), 1939–42 дә өлкәнең бруцеллёз станциясе башлыгы. 1928 дән Воронеж, Курск, Тамбов, Орёл өлкәләрендә йогышлы авыруларга (чәчәк, туберкулёз, түләмә, бруцеллёз) каршы көрәшкә җитәкчелек итә. 1938 дә кулга алынып, иреккә чыгарыла. 1941 дә диссертация якламыйча гына мед. фән. д-ры гыйльми дәрәҗәсе ала. 1942 дән ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты һәм Казан эпидемиология һәм микробиол. ин-ты консультанты. 1942–68 дә Казан мед. ин-тының эпидемиология каф. мөдире. Хезмәтләре туберкулёз, чәчәк, туляремия һ.б. авыруларга диагноз куюга, чәчәк салдыруны оештыруга, мед. статистикасына карый. Медаль, ТАССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Новый метод окраски туберкулёзных бацилл в толстом патолого-анатомическом срезе // Журн. микробиологии, патологии и инфекционных болезней. 1929. Т. 6, вып. 3/4; Метод смывов для выделения бацилл сибирской язвы из почвы, воды, шерсти, кожи и других объектов // Журн. микробиологии и иммунобиологии. 1930. Т. 7, вып. 1; К вопросу об эффективности энтеральной вакцинации против дизентерии // Журн. микробиологии, эпидемиологии и иммунобиологии. 1940. № 7.

**ОЗО́Л** Эльмарс Альфредович (4.1.1922, Воронеж ш. — 31.10.1981, Казан), кардиолог, мед. фән. д-ры (1973), проф. (1981). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), Казан ГИДУВында эшли. 1952 елдан Дзержинск шәһәрендә (Горький өлкәсе) табиб. 1960 тан Союз дәрәҗәсендәге конструкторлык техник бюросының (Казан) «Медфизприбор» пр-тиесендә. 1962 дән Казан шәһәрендәге 6 нчы хастаханәдә табиб. 1965 тән Казан мед. ин-тының Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә. 1974 тән Казан ГИДУВының функциональ диагностика каф. мөдире. Хезмәтләре йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларын тикшергәндә электрокардиограммаларны анализлау ысулларын камилләштерүгә карый. Франк ортогональ системасына яңартулар кертә.

Хезм.: Современные методы исследования в клинике и эксперименте. К., 1975 (автордаш); Электрокардиографическая диагностика предсердной и желудочковой электросистолии. К., 1978; Актуальные вопросы ревматизма у детей. Л., 1980.

**ОЗЫ́Н АЛА́Н**, табигать тыюлыгы; Тәтеш р-нында. 1996 елда комплекслы тарих-архит-ра һәм табигать истәлеге буларак оештырыла. 2000–04 тә тарих-архит-ра һәм табигать паркы. 2004 тән хәзерге исемдә. Мәйданы



Озын Алан. Карагай аллеясы.

406 *га*. Идел үзәненең күтәренке уңъяк яр битендәге («Сөйке таулары») киң яфраклы урман (мәйданы 287 *га*, Тәтеш урманчылыгы) һәм урман аланы б-н бергә Озын Алан авылы терр-ясен, алпавыт Молоствовлар утары составына кергән 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең башына караган алпавыт йортын (эклектика стилендәге архит-ра истәлеге; Г.В.Молоствов тарафыннан төзетелгән, соңгы хуҗасы — В.Г.Молоствов), карагай, юкә һәм каен аллеяләрен, экзотик агачлар һәм куакларны үз эченә ала. Парк терр-ясендә ТРның Кызыл китабына кертелгән үсемлекләрнең (Венера башмакчәчәк, күкәйсыман листера уты, чын оялаш уты, су сусыны, урман җиләге, урман әрекмәне, дала сливасы) һәм хайваннарның (соры көртлек, дүдәк, елга каракошы, балыкчы карчыга, яшел һәм чал тукран, гади яр чыпчыгы) сирәк төрләре очрый. О.А. терр-ясендә күп кенә мөһим археол. объектлар — I һәм II Озын Алан авыллыклары, I–V туктаулыклар, Озын Алан каберлеге урнашкан.

*Әд.:* Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. К., 1999. Т. 1.

**ОЗЫ́Н АЛА́Н**, к. *Долгая Поляна.*

**ОЗЫ́Н КОЛАКЛЫ́ ЯРКАНАТЛА́Р** (Plecotus), шома борынлы ярканатлар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 6 төре билгеле, Евразиянең урта зонасында, Төньяк Африкада, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — көрән О.к.я. (P. auritus) очрый. Катнаш һәм киң яфраклы урманнарда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 40–48 *мм*, авырлыгы 6–12 *г*. Колаклары зур, 30–36 *мм* озынлыкта. Озын йонлы. Аркасы көрән-соры, бүксәсе аксыл. Акрын, пырылдап оча. Һавада туктап калырга сәләтлеләр. Көндез мәгарә, корылмалар, агач куышларына яшеренә. Төнге күбәләкләр (ябалакчыклар, карышлавыклар, ефәк күбәләкләре, яфрак төргечләр һ.б.) б-н туклана. Үрчү чорында О.к.я. 20–30 заттан торучы колонияләр хасил итә. Ана зат бер бала тудыра. Штольняларда, мәгарәләрдә, хуҗалык корылмаларында кышлый. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ОЗЫ́Н КҮЛ**, Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогында урнашкан күл-сазлык, Яшел Үзән р-ны Дубровка посёлогыннан 4 *км* төньяктарак. Күлнең шактый өлеше таллар, тәбәнәк каен һәм наратлар үсүче йөзмә «үлән-утрау» б-н капланган; көньяк өлешендә ачык су өслекле участоклар сакланган. Гомуми мәйданы 60 *га*, су өслегенең мәйданы 0,3 *га*, озынлыгы 140 *м*, иң зур киңлеге 28 *м*, иң зур тирәнлеге 13,5 *м*. Күбесенчә атм. явым-төшемнәре исәбенә туена. Көнчыгыш өлешендә күлгә сызалар тоташа, алар буенча



Озын күл.

исә яңгыр һәм кар сулары агып төшә. Сулыкның төньяк-көнбатыш өлешенә тоташучы уйсулык буенча язын эрегән кар сулары О.к.дән Сәр-Болак елгасына агып керә. Ярлары буенда биек кәүсәле ылыслы (чыршы, нарат) һәм яфраклы (имән, юкә, каен) агачлар үсә. *Н.М.Минһаҗева.*

**ОЗЫ́Н КҮЛ**, Көнбатыш Кама аръягында. Актай елгасы бассейнында, Спас р-ны Ямбакты авылыннан 1 *км* төньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 6,52 *га*. Су күләме 65 мең. *м*$^3$. Озынлыгы 450 *м*, иң зур киңлеге 200 *м*, уртача тирәнлеге 1,1 *м*, иң зур тирәнлеге 1,7 *м*. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча. Туенуы катнаш, атм. явым-төшемнәре яки грунт сулары исәбенә туена. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак, болганчык (үтә күренмәлелеге 9 *см*). Суы хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**ОЗЫ́Н УР**, җирне өеп ясалган ныгытма. Озынлыгы гадәттә берничә *км* га сузыла. Туфрак өемнәре һәм чокырдан тора. Өем сырты буйлап койма коела. 17–18 йөзләрдә күчмә халыклар һөҗүменнән саклану өчен төзелә. Кама аръягы чик сызыгы системасына кергән Яңа Чишмә, Елховой, Никольский, Молоствов, Кожаев урлары билгеле. Кайбер галимнәр (А.П.Смирнов, Р.Г.Фәхретдинов) аларны Идел буе Болгар дәүләте чорына карый дип исәпли.

*Әд.:* Ф а х р у т д и н о в Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; И з м а й - л о в И.Л. К вопросу об исторической интерпретации длинных валов в Закамье // В.О.Ключевский и современность. Пенза, 1991.

*И.Л.Измайлов.*

**ОЗЫНАЯКЛА́Р** (Tipulidae), икеканатлылар отрядыннан семьялык. 25 меңнән артык төре билгеле, БДБнең Европа өлешендә — 160 тирәсе, Татарстан терр-ясендә якынча 100 төре бар. Озын аяклы, озынборынсыман зур бөҗәкләр. Талгын очалар, юеш урыннарны яраталар. Личинкалары кечкенә башлы һәм кыска мыекчалы, арттан гәүдәсе тупыйк, итчел орылары бар. Юеш туфракта, чери торган үсемлек калдыкларында, кайберләре суда яшиләр; үсемлек өлешләре һәм таркала баручы үсемлек матдәләре б-н туеналар. Tipula ыругының кайбер төрләренең личинкалары а.х. культураларын зарарлый.

*Әд.:* Определитель насекомых Европейской части СССР. М.-Л., 1965. Т. 2; Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ОЗЫНБЫ́**, к. *Рус-Мари Кавалы куле*.

**ОЗЫНТОМШЫ́К** (Plegadis falcinellus), ибис кошлар семьялыгыннан. Европа, Азия, Австралия, Африка, Америкада таралган. ТР терр-ясендә Минзәлә р-нында Кама елгасы тугаенда күренә. Очып килгән төр. Кураклар үскән сай сулыкларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 60 *см* га якын, авырлыгы 500–600 *г*. Каурый капламы металлсыман ялтыравыклы куе коңгырт төстә. Аяклары һәм муены озын. Томшыгы ш.у. озын, нечкә, урaксыман бөгелгән. Ояларын кураклар арасында кора. Ләмле сай сулыклардагы вак умырткасызлар б-н туена. Югала баручы кош, ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ОКО́НИШНИКОВ ЙОРТЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. 1907 елда, фаразлар буенча, арх. К.С.Олешкевич проекты буенча, романтик модерн стилендә икмәк б-н сәүдә итүче һәм он тарту пр-тиеләре хуҗасы, борынгы помор бердәмлегендәге иске дин тарафдарлары җәмәгате лидерларының берсе М.И.Оконишников өчен салына. Бакчага караган көньяк-көнчыгыш почмагы түгәрәкләнгән, Чабакса осталары чүкеп ясаган тимер рәшәткә эчендәге кишәрлекнең түрендә урнашкан һәм бакча б-н әйләндереп алынган ике катлы, турыпочмаклы бина. Йортның төп ишеге урам фасадының төньяк-көнбатыш ягына күчерелгән һәм биек түбә астында кисек чатыр рәвешендәге ризалит булып тора. Беренче катка алгы бүлмә, кунак бүлмәсе, ашханә һәм хуҗалык бүлмәләре, икенче катта тәрәзәләре бакчаның көньягына караган тантаналар залы, кабинет һәм торак бүлмәләре урнашкан. Беренче катта шул ук яктагы бакчага ике баскычлы терраса чыгып тора. Икенче каттагы веранда көнчыгыш якта урын алган. Кирпеч диварлар штукатурланган. Фасадлар купшы декоратив бизәлеше б-н аерылып тора. Катлар әвәләп ясалган үсемлек бизәкләре төшерелгән фризлы, профиль бирүче кәрниз б-н бүленгән. Урам фасадының үзәк өлеше ян-якларына гөл чүлмәкләре куелган аттик б-н аерылып тора. Кәрниз астыннан әвәләп ясалган тасмалы һәм чуклы тәкыя б-н бизәлгән киң фриз сузылган. Тулаем фасадларны бизәгәндә барокко стиленең стильләшкән формалары киң файдаланылган. Сырлап бизәлгән имән ишек өстендәге кронштейннарга беркетелгән бизәкле чуен чыгынты фасадның бизәге булып тора. 1920 елларда бинада — НКВД бүлекчәләре, соңрак балалар поликлиникасы эшли; 1989 дан биредә ТР Язучылар берлеге идарәсе урнаша.



М.И. Оконишников йорты.
Арх. К.С. Олешкевич. Казан. 1907.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

**О́КСМАН** Исаак Михайлович (24.6.1892, Подольск губ. Калюс а. — 16.5.1978, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1945), проф. (1946), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1931), Пермь стоматология ин-тының хирургик стоматология кафедрасында эшли. 1932 елдан Казан мед. ин-тының стоматология клиникасында, 1938–50 дә ортопедик стоматология каф. мөдире, бер үк вакытта, 1942–44 тә, Казан стоматология ин-ты директоры һәм хәрби госпитальләр консультанты. 1950–52 дә Казан ГИДУВында. 1952 дән Казан мед. ин-тында, 1956 дан ортопедик стоматология каф. мөдире, 1969 дан проф.-консультант. ТАССР Стоматологлар җәмгыяте рәисе (1956–69). Хезмәтләре авыз куышлыгының лайлалы тышчасы һәм пародонт нейроморфологиясенә, теш пульпасын, эмален, дентинын һәм цементын гистологик тикшерүгә, тешсез уртларга протез кую ысулларына карый. О. анатомик артикулятор һәм окклюцион кәкрелекне билгеләү өчен фиксатор-аппарат, механик ирен тоткыч, селәгәй җыйгыч, яктырткычлы шпатель, уксыман кламмерларны бөгү өчен кыскыч һ.б.ны уйлап таба һәм камилләштерә. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Материалы к изучению иннервации зуба и слизистой оболочки полости рта. К., 1947; Челюстно-лицевая ортопедия. М., 1957; Клинические основы протезирования больных при полном отсутствии зубов. Л., 1967; Ортопедическая стоматология. М., 1968.

*Әд.:* К р а с и л ь н и к о в С.Н., А м и р о в Н.Х. Оксман Исаак Михайлович // Поклонимся и мёртвым и живым. К., 2000.

**ОКТЯБРИ́НА** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 110 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1918 дә нигез салына. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1949 да — 240, 1958 дә — 233, 1970 тә — 307,

1979 да — 252, 1989 да — 118, 2002 дә — 130 кеше.

**ОКТЯ́БРИНО** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* көньяктарак, Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 8 кеше (татарлар) яши. 1923–27 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Тәкәнеш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1970 тә — 27, 1979 да — 16, 1989 да — 8, 2002 дә — 6 кеше.

**ОКТЯБРИСТЛА́Р**, к. *Унҗиденче октябрь берлеге.*

**ОКТЯ́БРЬ** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак. Сөлчә елгасыннан 3 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 53 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда, 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 205, 1949 да — 203, 1958 дә — 162, 1970 тә — 164, 1979 да — 104, 1989 да — 78, 2002 дә — 55 кеше.

**ОКТЯ́БРЬ** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 30 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2010 елда 296 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Баштагы атамасы — Теләнче авылы (рус чыганакларында — Тлянчина), 1941 нең 17 февраленнән — Октябрь. 1860 ка кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Теләнче авылында мәчет һәм мәдрәсә була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1952 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 655, 1897 дә — 981, 1913 тә — 1196, 1920 дә — 1120, 1926 да — 638, 1949 да — 537, 1958 дә — 542, 1970 тә — 565, 1979 да — 509, 1989 да — 426, 2002 дә — 367 кеше.

**ОКТЯ́БРЬ** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 450 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 63%, татарлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда маркиз Паулуччиларның Александров хуторы урынында нигез салына. 1930 дан — 4 нче совхоз утары үзәге (икенче исеме — «Пролетарский сороковник»), 1970 тән 23 нче партсъезд исемендә. Оештырылган көненнән Казан губернасының Зөя өязе Ташёвка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1926 да — 58, 1938 дә — 452, 1949 да — 596, 1958 дә — 465, 1970 тә — 367, 1979 да — 342, 1989 да — 464, 2002 дә — 475 кеше.

**ОКТЯ́БРЬ** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 23 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 2673 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 58%, татарлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кошчылык («Юдино» нәселле кошчылык репродукторы» ҖЧҖ). Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү, мәчет. 1919 да нигез салына. 1930 еллардан — 3 нче совхоз посёлогы, соңрак — Кызыл Октябрь, 1940 еллардан хәзерге исемдә. Оештырылган көненнән ТАССРның Арча кантоны Ильинка волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл районында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1949 да — 1000, 1958 дә — 1764, 1970 тә — 2186, 1979 да — 2009, 1989 да — 2690, 2002 дә — 2661 кеше. О.да В.П.Энгельгард исем. *Астрономия обсерваториясе* урнашкан.

**«ОКТЯ́БРЬ»**, Арча р-ндагы колхоз. 1959 елда Сталин исем. (1930 да төзелгән) һәм «Алга» (1953) к-злары җирлегендә оештырыла. Хуҗалык берничә тапкыр үзгәртелә: 1995 тә — күмәк пр-тие, 2002 дә — «Наласа» агрофирмасы, 2004 тә — «Батыр» а.х. кооперативы» ҖЧҖ, шул ук елда — «Наласа» а.х. җитештерү кооперативы, 2005 тә — «Наласа машина-трактор станциясе» ҖЧҖнең төп пр-тиесе. 2004 тә — «О.» к-зы составына Урта Бирәзә һәм Наласа (үзәк утары) авыллары керә, 263 хуҗалыкта 904 кеше (шуларның 216 сы — хезмәткә яраклы яшьтә). Хуҗалыкта 3352 *га* а.х. файдалану җирләре (ш.и. 3142 *га* сөрүлек җирләр), 981 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 390 сыер), 436 баш дуңгыз, 22 баш ат исәпләнә. Җитештерү эшчәнлегенең төп юнәлеше — бөртекле ашлык, бәрәңге, ит, сөт җитештерү. 2004 тә бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 52 *ц*, бәрәңге — 280 *ц* тәшкил итә; 1 сыердан 4003 *кг* сөт алына; 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 466 *ц* сөт, 49 *ц* ит җитештерелә; колхозның табышлылыгы 17,5%. Хуҗалыкта җитештерү биналары һәм торак йортларга газ, телефон кертелә, үзәктән су б-н тәэмин ителә, юлларга асфальт салына. 1980–90 да һәр елны 5 яңа торак йорт төзелә. «О.» к-зы «Югары культуралы игенчелек хуҗалыгы» дигән исемгә лаек була (1970), Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1971). 24 эшчегә дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәр бирелә, ш.и. Ленин ордены 1 кешегә, Хезмәт Кызыл Байрагы — 9, «Почёт билгесе» — 7, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» — 2; медальләр — 7 кешегә, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале — 2, көмеш — 2, бронза — 2 кешегә; РФ, ТАССР, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре исеме 4 кешегә бирелә.

Хуҗалык үсешенә зур өлеш керткән җитәкчеләр: Х.Г.Гафуров (1933–41), А.Ш.Шаһиев (1946–53), М.Ш.Вахитов (1960–76), С.С.Гыймадиев (1976–81), В.И.Мифтахов (1984–96), Н.С.Хөсәенов (1986–99).

**«ОКТЯ́БРЬ»**, 1927 елда ВХУТЕМАСта (Мәскәү) төзелгән «Октябрь» берләшмәсенең (сәнгати хезмәтнең яңа төрләре оешмасы) Татарстан бүлекчәсе. 1928 дә рәссам А.Н.Кашаев тырышлыгы б-н оештырыла. Рәссамнар, архитекторлар, сәнгать белгечләрен, кино һәм фотография сәнгате осталарын берләштерә. 1930 еллар башында ТатАХРР б-н берләштән Казан рәссамнарының зур төркемен үзенә туплый. 1932 дә тарала.

**«ОКТЯ́БРЬ БАЛАСЫ́»**, балалар өчен айлык рәсемле журнал. ВЛКСМ ҮК һәм Мәгариф халык комис-ты органы. «*Кечкенә иптәшләр*» ж-лының дәвамчысы. 1929 елның августыннан 1932 нең декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 41 саны чыга. СССР халыклары Үзәк нәшриятында һәм «Молодая гвардия» нәшриятында басыла. Мөхәррире — М.*Җәлил*. Журналда М.Җәлил, Ә.Ерикәй, М.Крымов, Ш.Маннур, Б.Мансуров, Т.Ченәкәй h.б. язучыларның, ш.у. Г.Әпсәләмов, Ә.Гәрәй, Н.Дәүли, И.Закиров, Р.Ильяс, Г.Мөхәммәтшин, М.Садри, Г.Теләшев, С.Урайский кебек башлап язучыларның әдәби әсәрләре бастырыла. «Безнең үсеп килүче шагыйрь һәм язучыларыбыз» рубрикасындагы шигырь һәм хикәяләр яратып укыла. «Шахмай» псевдонимы б-н (М.Җәлил булуы ихтимал) балалар җибәргән әдәби әсәрләргә бәяләмәләр бирелә. Журналда балалар үзешчән сәнгате өчен язылган берничә драма әсәре (скетчлар, бер актлы пьесалар, курчак театры өчен инсценировка) басыла, аларның сюжет нигезен кулаклар б-н көрәш, руханиларны тәнкыйтьләү, дәүләткә вакытында ашлык тапшыру h.б. тәшкил итә. Балаларга аңлаешлы телдә индустрияләштерү, күмәкләштерү, наданлыкны бетерү турында сөйләнә. Басмадагы мәкаләләр балаларда илнең соц. киләчәгенә ышаныч тәрбияләүгә юнәлтелә. Һәр санда чыга килгән «Музыка дәресләре» рубрикасында композитор Л.Хәмиди гармунда һәм мандолинада уйнарга өйрәтә, ул көй язган җырларның текстлары һәм ноталары басыла. «Фән һәм техника» рубрикасы мәкаләләре укучыларны радиоалгыч, автомобильләр, а.х. машиналары төзелеше б-н таныштыра, ш.у. мәктәп яны тәҗрибә кишәрлекләрендә эш алып бару тәртибе турындагы мәкаләләр дә дөнья күрә. 1933 нең гыйнварында журнал редакциясен Казанга күчерәләр, ул «Пионер каләме» (хәзер «Ялкын») исеме б-н чыга башлый.

*Әд.:* З а к и р о в а Э. «Без яз көне туганбыз!» // Ялкын. 2004. № 3; Х а м м а т о в Ш. Муса Джалиль — солдат партии. К., 1984; М у с т а ф и н Р. Муса Джалиль: Жизнь и творчество: Довоенный период. К., 1986.

*Т.М.Насыйров.*

**ОКТЯ́БРЬ БҮЛӘГЕ́** авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Сарсаз елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1921 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Азнакай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 337, 1938 дә — 432, 1949 да — 412, 1958 дә — 354, 1970 тә — 343, 1979 да — 161, 1989 да — 112, 2002 дә — 117 кеше.

**ОКТЯ́БРЬ БҮЛӘГЕ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Чаллы-Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 98 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Абдул волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 202, 1949 да — 179, 1958 дә — 128, 1970 тә — 225, 1979 да — 177, 1989 да — 106, 2002 дә — 96 кеше.

**«ОКТЯ́БРЬ БҮЛӘГЕ́»**, Түбән Кама р-нындагы совхоз. 1970 елда бер үк исемдәге колхоз җирлегендә оештырыла. Кызыл Кадка, Түбән Чаллы, Зур Аты, Югары Чаллы, Урта Чаллы (үзәк утары) авылларын үз эченә ала. 1997 дә эшләүчеләр саны 477, шуларның 424 се а.х.нда җитештерүдә эшли. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 6231 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр — 5298 *га*, печәнлек — 135 *га*, көтүлекләр — 798 *га*. Терлекчелекнең төп юнәлеше — нәселле мөгезле эре терлек үрчетү. «О.б.» — Татарстанда суган җитештерүче иң зур совхоз. 1975–90 да с-з ел саен 2 мең баш бозау һәм үгез, 3 мең *т* га кадәр суган сата. 1997 дә бөртеклеләрнең уңышы 1 *га* дан 40,3 *ц* тәшкил итә; 1 сыердан уртача еллык савым — 4489 *кг*; 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 230 *ц* сөт, 54 *ц* ит җитештерелә. Хуҗалыкта дәүләт бүләге һәм мактаулы исемнәр алган эшчеләр бар, ш.и. ТАССР(ТР)ның атказ. а.х. хезмәткәре исеме 5 кешегә; Ленин ордены — 1, Хезмәт Кызыл Байрагы — 1, «Почёт билгесе» — 1, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены — 2; медальләр — 9 кешегә, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале — 1, бронза — 4 кешегә бирелә.

Хуҗалыкның җитәкчеләре: М.Н.Нуретдинов (1970–79), Н.Н.Гыйбадуллин (1979–87), А.Г.Нигъмәтҗанов (1987–94 һәм 1998 дән), Р.Г.Гарипов (1995–98). 1998 дә «О.б.» «Чаллы» а.х. җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә (2005 тән «Бәхетле-Агро» ҖЧҖ ф-лы).

*И.Н.Афанасьев.*

**ОКТЯ́БРЬ РАЙОНЫ́**, к. *Нурлат районы.*

**ОКТЯ́БРЬ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньягында урнашкан. 1965 елда оештырыла. Мәйданы — 2,7 мең *км*². Үзәге — Октябрьск авылы (Оренбургтан 78 *км* төньяктарак). Халкы — 20152 кеше (2012). Татарлар саны: 1989 да — 1529, 1994 тә — 2058, 1997 дә — 2376, 2004 тә — 2200, 2006 да — 2114, 2010 да 1975 кеше. Татарлар, башлыча, тупланып 2 нче Имангол (2006 да — 688 кеше) һәм Биккол (319 кеше) авылларында яшиләр. О.р. терр-ясенә татарлар 1740 елларда килеп урнашалар, бу Яңа Мәскәү юлы төзелеше б-н бәйле. Казан губернасыннан күченгән татарлар бу юлдан почта ташыганнар. Иң борынгы авыл — Биккол (1740 еллар башында төзелә). 1746 да 1 нче Имангол татар-башкорт авылына нигез салына. 1918–19 да ул икегә бүленә, һәм татарлар яшәгән өлешендә 2 нче Имангол авылы барлыкка килә. 1920 елларда 2 нче Имангολда мәчет, мәчет каршында мәдрәсә эшли. 2006/07 уку елында районның өч мәктәбендә (Биккол, 1 нче Имангол, 2 нче Имангол а.) татар теле фән буларак укытыла. 2 нче Имангол авылындагы китапханә фондында татар телендә 144 басма исәпләнә. Китапханә, авыл клубы б-н берлектә, милли мәдәният көннәре үткәрә. Районда татар үзешчән коллективлары: «Чишмәләр» (Биккол а.) һәм «Умырзая» (Краснооктябрьск а.) вокаль төркемнәре, «Шүрәле» драма коллективы (2 нче Имангол а.), «Гүзәлләр» бию коллективы (Биккол а.) эшли.

*Әд.:* Гончаров Н. Октябрьский район: История, документы, люди. Оренбург, 2002.

**ОКТЯ́БРЬ РАЙОНЫ́**, *Пермь краеның* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1931 елда оештырыла. Мәйданы — 3,4 мең *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Октябрьский посёлогы (Пермьнән 220 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 29427 (2012), татарлар — 12664 кеше (2002). О.р. терр-ясенә татарлар 15–16 йөзләрдә килеп урнаша. Хәзерге вакытта алар, нигездә, Бикбай, Басино, Әтнәгуҗа, Енапай, Ишим авылларында яшиләр. Иң борынгы татар авылы — Енапай (1566). 1920 елларга кадәр район терр-ясендә 10 лап мәчет була. 1991 дән районда татар-башкорт иҗтимагый үзәге эшли. 1974 тән Енапай авылында — «Әллүки», 1987 дән Әтнәгуҗада «Чишмә» (1997 дән халык ансамбле) ансамбльләре эшли. Енапай авылында ел саен район Сабан туе үткәрелә. О.р.ның 10 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла һәм татар теле фән буларак укытыла. Районда — 13 мәчет, Енапай авылында мәдрәсә эшли. 2000 нән «Ватандашлар» район г-тасына кушымта нәшер ителә (2 айга 1 тапкыр). Татарстаннан О.р.на гастрольләр б-н күренекле татар җырчылары З.Билалов, А.Галимов, З.Фәрхетдинова, Х.Фәрхи, С.Фәтхетдинов, З.Хәйретдинов h.б. киләләр. О.р.нда мед. фән. д-ры Х.С.*Хәмитов*, тарих фән. д-ры Ф.Г.Ислаев туган. Сов. Союзы Герое Л.С.*Сибгатуллин* Енапай авылы мәктәбен тәмамлый.

**ОКТЯ́БРЬ РАЙОНЫ́**, *Чиләбе өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 4354 *км*². Үзәге — Октябрьский авылы (Чиләбе шәһәреннән 125 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 20450 (2012), татарлар — 800 гә якын кеше (2002). Татарлар район терр-ясенә 18–19 йөзләрдә



В.А.Окулов.

килеп урнашалар. Башлыча, алар Тирән Күл (344 кеше), Әмин (140), Подовинное (200) авылларында, Свободный (100 кеше) посёлокларында яшиләр. 19 йөз ахырында Подовинное авылында сәүдәгәр М.Ә.Яушевның тегермәне һәм кибете була. О.р. б-н Сов. Союзы Герое Х.Ә.*Ниатбәковның* тормыш юлы бәйле.

**ОКТЯ́БРЬ РЕВОЛЮЦИЯСЕ́** 1917, к. *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелеше.*

**«ОКТЯ́БРЬ ЯШЬЛӘРЕ́»**, журнал; к. *«Колхоз яшьләре»*.

**ОКТЯ́БРЬСКИЙ** шәһәре, Башкортстан Респ-касының көнбатыш өлешендә, Ык елгасының уңъяк ярында, Уфа шәһәреннән 188 *км* читтә урнашкан. 1937 дә посёлок (1946 дан шәһәр) буларак нигез салына. Халкы — 111551 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 23327, 1979 да — 29210, 1989 да — 38600, 2002 дә — 40306, 2010 да — 41346 кеше. О. милли мәдәниятләр үзәге каршында «Татар конгрессы» милли-иҗтимагый берләшмәсе эшли. «Татарстан» Дәүләт һәм «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпанияләре тапшыруларын карыйлар. Октябрь музыка уч-щесе укучылары башкорт һәм татар җырын башкаручыларның «Дуслык моңы» (Нефтекамск ш.) һәм Р.Ваһапов исем. (Казан) халыкара фестивальләрендә, ш.у. Бөтенроссия халык уен кораллары иҗат фестиваль-конкурсында (Казан) лауреат дипломнары б-н бүләкләнә. 11 нче татар гимназиясе эшли. 2004–05 уку елында 21 мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. «Туган як» татар г-тасы нәшер ителә.

**ОКУ́ЛОВ** Василий Андреевич (15.3.1899, хәзер Свердловск өлкәсенең Алапаевск ш. — 10.2.1974), СССР авиация сәнәгатен оештыручы, инженерлык-техник хезмәт генерал-лейтенанты (1944). Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава академиясен тәмамлый (1934). Хезмәт эшчәнлеген 1915 елда машинист ярдәмчесе буларак башлый, заводта электрик булып эшли (хәзерге Свердловск өлкәсе). 1918 елдан Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышында катнаша. 1934–38 дә Мәскәүдәге 22 нче авиация з-дында хәрби вәкил, 1938 дән шул заводның директоры. 1941–42 дә Мәскәүдәге 23 нче авиация з-ды, 1942–49 да Казандагы 22 нче авиация з-ды директоры. О. илдә чыгарылган югары тизлекле беренче бомбардировщикларны сынауда һәм камилләштерүдә катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында аның җитәкчелегендәге коллектив уңышлы рәвештә СССР Хәрби-һава көчлә-

рен авиация техникасы б-н тәэмин итә. 1949–51 дә Үзәк авиация моторлары төзү ин-тының ф-лы башлыгы, 1951–74 тә Үзәк аэродинамика ин-ты (ЦАГИ) башлыгы урынбасары. ЦАГИның яңа эксперименталь базасын төзүдә, аны модернизацияләүдә турыдан-туры катнаша, нәтиҗәдә авиация техникасының яңа үрнәкләрендә фәнни һәм эксперименталь тикшеренүләр уздыру мөмкинлеге гамәлгә ашырыла. Дүрт Ленин ордены, Октябрь Революциясе, ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Кутузов, Кызыл Йолдыз, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Д.С.Фәхретдинов.*

**ОКУЛОВ** Николай Михайлович (30.12.1835, Ярославль губ. — 23.1.1899, Ницца ш., Франция), хокук белгече, сенатор (1883), яшерен советник (1883). Дворяннар катлавыннан. Хокук белеме уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1855). 1855–58 елларда Сенатның 1 нче департаментында хезмәт итә. 1858–60 та Вологда җинаять эшләре мәхкәмә палатасы рәисенең иптәше (урынбасары). 1860–63 тә Вологда губернасы төрмәләр попечительләре ком-ты директоры. 1863–65 тә Пенза, 1865–66 да Псков губерналары прокуроры. 1866–68 дә Рыбинск округ мәхкәмәсе прокуроры. 1868–70 тә Харьков мәхкәмә палатасының прокурор иптәше (урынбасары). 1870–71 дә Самара, 1871–77 дә Ярославль округ мәхкәмәләре рәисе. 1877–83 тә Казан мәхкәмә палатасының өлкән рәисе. 1883–84 тә Сенатның гражданлык кассацияләре, 1884 тән җинаять эшләре кассацияләре департаментларында. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Альманах современных русских государственных деятелей. СПб., 1897.

*Е.Б.Долгов.*

**ОЛА́Н** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чангар елгасы буенда. 2010 елда 79 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1565–68 еллардан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агач савыт-саба, тәгәрмәч, чана табаны һәм тугым ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да Спас-Преображение чиркәве (1802–05 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1898 дә ачыла), фельдшерлык пункты, май язу з-ды, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1208 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 25, 1782 дә — 248 ир-ат; 1859 да — 702, 1897 дә — 765, 1908 дә — 868, 1920 дә — 847, 1926 да — 694, 1938 дә — 575, 1949 да — 444, 1958 дә — 319, 1970 тә — 205, 1979 да — 133, 1989 да — 137, 2002 дә — 120 кеше.

**ОЛА́Н ИЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 2 *км* көнбатыштарак, Сола елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 394 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 52%, татарлар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Беренче исеме — Карамыш-Уланово. 1562 дә йомышлы руслар И.Михнеев һәм Ф.Заболоцкийга алпавыт җире буларак бирелә, һәм анда рус крәстияннәре килеп утыра. 1860 елларда халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.И.ндә земство мәктәбе (1860 та ачыла), су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1148,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 134 ир-ат; 1859 да — 303, 1897 дә — 483, 1908 дә — 541, 1920 дә — 618, 1926 да — 750, 1949 да — 560, 1958 дә — 426, 1970 тә — 296, 1979 да — 260, 1989 да — 144, 2002 дә — 355 кеше.

**ОЛЕА́РИЙ** (Oelschlager, Olearius) Адам (якынча 1599, Ашерслебен ш., Саксония — 22.2.1671, Готторп ш.), немец галиме һәм сәяхәтчесе. Лейпциг ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук укыта; Герцог Голштинский янында математик һәм китапханәче булып хезмәт итә. 1639 елдан Готторп шәһәрендә яши. Рус һәм гарәп телләрен камил белә. 1633–34 тә Шлезвиг-Голштейн илчелеге б-н Россиягә килә. 1635–39 да Идел буйлап Персиягә барып кайта. 1635–39 да Мәскәүдә була. Патша Михаил Фёдорович хөкүмәте О.ны ике тапкыр сарай каршындагы хезмәткә чакыра. 1636 һәм 1638 дә Казанга килә, шәһәр күренешләрен сурәтли. 1643 тә Россия һәм Персиягә ясаган сәяхәтләрен тасвирлый (1647 дә Шлезвиг шәһәрендә немец телендә нәшер ителә, соңрак инглиз, француз, голланд, итальян, рус һ.б. телләргә тәрҗемә ителә). Сәяхәтнамәдә 17 йөзнең 1 нче яртысындагы Россия, татар халкы тарихы һәм Идел буенда яшәүче башка халыклар тарихы турындагы мәгълүматлар кергән кыйммәтле чыганак буларак бәяләнә. О. үз әсәрендә Казан манаралы агач диварлар б-н әйләндереп алынган, йортлар агачтан, «Кремль калын таш диварлар, корал һәм солдатлар б-н яхшы саклана», шәһәрдә руслар һәм татарлар, Кремльдә — руслар гына яши, «бер татар да, үлем җәзасына дучар буласы килмәсә, анда күренергә тиеш түгел», дип яза. О. Сәгъдинең «Гөлстан» әсәрен фарсы теленнән немец теленә тәрҗемә итә («Persianisches Rosenthal», Шлезвиг, 1654).

Х е з м.: Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. СПб., 1906.

*Әд.:* Знаменитые люди о Казанском крае. К., 1987.

**ОЛЕ́КСЕНКО** Иван Петрович (30.11.1905, хәзер Украина Респ-касы, Киев өлкәсенең Черкассы р-ны Лески а. — 1.8.1980, Казан), генерал-майор (1957). Машиналар төзү кичке ин-тының 1 нче курсын тәмамлый (Мәскәү). 1927 елдан СССР Кораллы көчләрендә. Бөек Ватан сугышы елларында самолётлар ремонтлау һәм эксплуатацияләү буенча инженер. 1945–53 тә Һава армиясендә өлкән инженер, Көнбатыш Себер хәрби округының Хәрби һава көчләре баш инженеры. Балтыйк буе, Белоруссия, Себер хәрби округларында самолётлар ремонтлау бүлекләре б-н җитәкчелек итә. 1953–56 да Кытай Халык Респ-сы Хәрби һава көчләрендә хәрби киңәшче, баш инженер. 1956–60 та Казан авиация-техника уч-щесе башлыгы, Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.З.Хәбибуллин.*

**О́ЛЕСОВ** Иннокентий Никитич (26.12.1892, Якутск ш. — 13.3.1943, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1930), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Мәскәүдә 1 нче мед. ин-тын тәмамлый (1922). 1922 елдан тире-венерология клиникасында (Мәскәү). 1930–32 дә Мәскәү венерология ин-ты директоры. 1932–42 дә Казан мед. ин-тының дерматовенерология каф. профессоры (бер үк вакытта ГИДУВта). 1935–36 да дәвалау-профилактика ф-ты деканы. Хезмәтләре тире авырулары барышын өйрәнү һәм аларны дәвалау ысулларына карый.

Х е з м.: К вопросу о кожном ксантоматозе // Рус. клиника. 1928. Т. 10, № 52 (автордаш); Сифилис и борьба с ним. К., 1934; Учебник кожных и венерических болезней. М.-Л., 1935 (автордаш); Эфедрин в терапии зудящих дерматозов // Казан. мед. журн. 1941. № 3.

*Әд.:* Казанский медицинский институт, 1814–1889. К., 1989. Ч. 1; Деканы Казанского медицинского института. К., 1997.

**ОЛЕШКЕ́ВИЧ** Константин Саввинович (8.7.1873, Вильно губ. Вильно ш. — 1935, Казан), архитектор. Гражданлык инженерлары ин-тын тәмамлый (С.-Петербург, 1897). 1899 — 1918 елларда Казан сәнәгать уч-щесендә укыта, 1906 дан төзелеш уч-щесенең укыту бүлеге мөдире (сәнәгать уч-щесенең бүлекчәсе). Бер үк вакытта, 1900–03 тә һәм 1910–11 дә Казан шәһәре архитекторы, 1911–13 тә шәһәр управасы техникы, 1901–03 тә — Казан губернасының земство идарәсе архитекторы. 1909–13 тә Казан шәһәр думасы гласные. 1918 дән Казан политехник ин-ты (1930 дан — Коммуналь төзелеш ин-ты) укытучысы, 1922 дән — архит-ра ф-ты деканы. 1930 ның декабрендә корткычлыкта



К.С. О л е ш к е в и ч. Сәнәгать училищесе бинасы. Казан. 1899. (Хәзер Казан технол. ун-тының «Б» корпусы). 2005 елгы фоторәсем.

гаепләнеп кулга алына, бер елдан азат ителә. Казанда район архитекторы булып эшли. О. үзен аеруча модерн стилендәге зур иҗтимагый һәм торак корылма проектлары төзү остасы итеп таныта: М.Марко (20 йөз башы), Докучаев (1902, реконструкция), Ю.С.Волкова (1905), С.А.Чукашев (1908) йортлары, Е.С.Смоленцевның табыш йорты (1907–09), Шамов хастаханәсе (1908–10), шәхси йорты (1915), С.Е.Павлов һәм Е.С.Прибытковның күн з-ды бинасы (1901, реконструкция).

*Әд.:* О с т р о у м о в В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; Республика Татарстан: Памятники истории и культуры: Каталог-справ. К., 1993; М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**ОЛИ́ВКОВ** Борис Михайлович (25.7.1892, Рязань губ., Сапожок өязе Копнино а. — 9.12.1954, Мәскәү), ветеринар-хирург, вет. фән. д-ры (1934), проф. (1935), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1952). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1918), шунда ук, оператив хирургия кафедрасында эшли, 1925–35 елларда мөгезле эре терлек хирургиясе каф. мөдире. 1935–48 дә Мәскәү вет. академиясенең гомуми һәм махсус хирургия каф. профессоры, 1948–54 тә каф. мөдире. О. яраларны яра фазаларын исәпкә алып дәвалау ысулын эшли. Ветеринар-хирургларның Мәскәү мәктәбенә нигез салучы. Йорт хайваннарына караган оператив һәм гомуми хирургия буенча югары уку йортлары өчен 2 дәреслек һәм күпсанлы монографияләр авторы. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение инфицированных ран у животных. М., 1950; Хирургические болезни мочеполовых органов. М., 1952; Автогенетическая терапия в ветеринарной хирургии. М., 1955.

*Әд.:* Казанский ордена Ленина ветеринарный институт им. Н.Э.Баумана. К., 1993; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

*М.Ш.Шәкуров.*

**ОЛИГОХЕТЛӘ́Р**, к. *Аз төкле суалчаннар.*

**ОЛИ́МПИЕВ** Вадим Владимирович (22.12.1938, Воронеж ш. — 15.1.2013, Казан), термофизик, техник фән. д-ры (1996), проф. (2001), ТРның атказ. энергетигы (1999). 1962 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона пр-тиесе КБнда эшли (Казан). 1967–77 дә Казан авиация ин-тында. 1977 дән Казан энергетика ун-тында, җылылык техникасының теоретик нигезләре кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1992–2000). Хезмәтләре җылылык алмаштыру җайланмасында энергия күчерү процессларын интенсивлаштыруга карый. О. интенсив җылылык алмашы булдыра торган аппаратларны исәпләү һәм проектлаштыру алымнарын тәкъдим итә. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теплообменные аппараты с интенсифицированным теплообменом. К., 1999 (автордаш); Существо интенсификации теплообмена на поверхности со сферическими выемками // Изв. РАН. Энергетика. 2002. № 2 (автордаш); Теплогидравлический расчёт и проектирование оборудования с интенсифицированным теплообменом. К., 2004 (автордаш).

**ОЛИМПИ́Я УЕННАРЫ́**, 1) Борынгы Грециядә грекларның гомуми бәйрәмнәре һәм ярышлары. О.у. башлангычын, үткәрү урынын һәм вакытын Олимпиядә — б.э.к. 776 ел элек булган дип санау кабул ителгән. 394 тә Рим императоры Феодосий I нең Декреты б-н О.у. уздыру мәҗүсилек традициясе буларак тыктатыла. 2) Борынгы грек О.у. үрнәгендәге бөтендөнья спорт ярышлары 4 елга бер тапкыр уздырыла (кышкы һәм җәйге). 1894 нең 16 июнендә Сорбонна ун-тында (Париж) узган халыкара конгресста Халыкара олимпия комитеты (ХОК) оештырыла. Аның беренче президенты грек шагыйре Деметриос Викелас, ген. секретаре — француз бароны Пьер де Кубертен (1896–1925 тә ХОК президенты) була. Беренче О.у. (җәйге) 1896 ның 6–15 апрелендә Афинада (Греция), кышкысы 1924 нең 25 гыйнвары — 5 февралендә Шамони шәһәрендә (Франция) уздырыла. Россия спортчылары О.у.нда беренче тапкыр 1908 һәм 1912 дә катнашалар, 7 медаль, ш.и. 1 алтын медаль алалар (Н.А.Панин-Коломенкин, тимераякта фигуралы шуу). Беренче тапкыр рәсми команда булып, СССР спортчылары — җәйге О.у.нда 1952 дә (Хельсинки, Финляндия) һәм кышкы О.у.нда 1956 да (Кортина-д'Ампеццо ш., Италия); РФ спортчылары 1994 тә (Лиллехаммер ш., Норвегия) һәм 1996 да (җәйге, Атланта, АКШ) О.у.нда катнаша. Татарстан спортчылары О.у.нда 1952 дән катнаша. О.у.нда катнашучылар: Н.С.*Тетёркин* һәм И.Л.*Феоктистов* (1952), С.М.Абрамов (1994), Л.А.*Аверьянова* (1988), Н.С.Апалинов (2012 — алтын), Н.К.Афанасьев (1996), Ю.В.Бережко (2012 — алтын), Г.И.Бухарин (1956 — бронза), А.А.Волков (2012 — алтын), Е.Г.Волкова (2008 — бронза), О.Б.*Вощакина* (1988, 1992), З.Р.*Гарипова* (1996), К.Ю.Гафурҗанова (2012 — көмеш), Н.Ф.*Гыйләҗева* (1976 — алтын, 1980 — көмеш), О.В.*Данилова* (1992, 1994, 2002), А.Ю.Деманов (2012), А.Денисенко (2012 — бронза), С.А.*Дёмина* (1996, 2000 — көмеш, 2004, 2008), А.А.Доценко (2014), А.Н.Егорчев (2004 — бронза), Г.Е.Еврюжихин (1972 — бронза), Ю.М.Зарипова (2012 — алтын), А.В.Зацепин (2004), И.Х.Зиннуров (2000 — көмеш, 2004 — бронза), Д.В.*Капустин* (2000 — бронза), Р.И.*Кашапов* (1988), А.В.Казаков (2000 — көмеш, 2004 — бронза), О.Н.Князева (1976 — алтын), Н.А.*Колесников* (1976 — алтын), А.Н.*Колесникова* (2000 — көмеш), В.М.Колотов (1972, 1976 — бронза), А.Б.Косарев (2008 — бронза), А.П.*Курынов* (1960 — алтын), Л.И.Логинова (1980 — алтын), Я.В.Мартынова (2004, 2008, 2012), А.В.Мастров (2000), Е.С.Мигунова (2008 — көмеш), М.М.Михайлов (2012 — алтын), В.А.Мосин (2004, 2008, 2012 — бронза), Н.Г.Наговицин (1976), Н.Г.Нәбиев (2010, 2014), В.Г.*Никонова* (1976 — алтын), Л.Ф.Нуретдинова (1992 — алтын), А.А.Обмочаев (2012 — алтын), И.А.Панин (2014), А.В.*Плюшкин* (1976), В.Ф.*Потапов* (1976), Н.А.Петрушин (1998), И.И.Радугин (2004), О.М.*Рукавишникова* (1980 — көмеш), Р.И.Сафин (1972 — алтын), Г.И.Сәмитова (2004, 2008 — алтын, 2012), Ф.П.Симашев (1972 — алтын, көмеш), О.В.Смирнова (2004), Ф.Р.Солтанова (1996), С.Ю.Тетюхин (2008 — бронза), С.Ф.*Тимофеев* (1976), А.В.*Устинов* (1996), И.С.Утробин (1964 — бронза), Э.Р.Хәсәнова (2008, 2012 — алтын), Д.В.Шкурихина (2008 — алтын), Н.С.Шукова (2014). Россиянең башка регионнарында яшәүче, О.у.нда медальләр алган татарлар: А.Д.Альметов, З.Х.Билалетдинов, М.Ганиев, Р.А.Гатауллин, М.Г.Девятьяров, Р.Н.Ерошина, А.М.Кабаева, У.А.Мәүлиханов, Ф.А.Мостафин, Л.Мостафина, Э.Ф.Саади, Ш.А.Сабиров, Р.Г.Салихова, Ш.С.Сафин, Д.М.Сафина, К.М.Фаткуллин, Ш.Ш.Хисаметдинов. 2014 елга О.у.на респ-кадан барысы 95 спортчы җибәрелә; 52 медаль алалар: 24 алтын, 12 көмеш, 16 бронза медаль.

**ОЛУ́ГЪ МӨХӘММӘ́Д** (1405 тирәсе — 1445), Алтын Урда ханы (1420–37, бүленеп), Казан ханлыгына нигез салучы һәм беренче ханы. *Җәләлетдин* ханның улы, *Туктамыш* ханның оныгы. Әмир *Идегәй* һәм *Кадыйрбирде* хан һәлакәтеннән соң тәхеткә утыра. 1421–22 елларда *Баракъ* хан б-н көрәшә, җиңелеп, Литва чикләренә чигенә. Бөек Литва кенәзе Витовт ярдәме б-н О.М. Баракъны Кырымнан, соңрак Идел буеннан кысрыклап чыгара, 1425 тә Алтын Урданың көнбатыш өлешендә хакимиятен торгыза. 1429 да *Дәүләтбирде* ханны җиңә. Бөек Литва кенәзенең Псков (1426) һәм Рязань (1427) шәһәрләренә оештырган яуларында катнаша. 1428 дә Төркия солтаны Морад II б-н илчелек мөнәсәбәтләре оештыра. О.М. хакимиятенең көчәюе сарай аксөякләренең канәгатьсезлеген тудыра, моннан О.М. дошманнары, башка җучиләр файдалана. 1437 дә О.М. *Тимер* ханның улы Кече Мөхәммәд һәм аның тарафдары Нәүрүз морза тарафыннан Рус дәүләте чикләренә, Биләү шәһәре янына куыла. 1437 нең 5 декабрендә О.М. *Биләү (Белёв) янындагы сугышта* Мәскәү кенәзе Василий II тарафыннан җибәрелгән зур гаскәрне җиңүгә ирешә. 1438 дә О.М. Биләүдән Урта Иделгә юнәлә һәм анда Казан ханлыгын оештыра. Яңа дәүләттә тупланеп ныгуга, Рус дәүләтенә яулар оештыра. 1445 тә О.М. улы Мәхмүд Суздаль шәһәре янында Василий II гаскәрен тар-мар итә (*Суздаль янындагы сугыш*). Василий II тоткын итеп алына һәм, йолым түләнгәч, кире җибәрелә. О.М. исеме 1445 тән соң елъязмаларда телгә алынмый.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.


*И.Л.Измайлов.*

**«ОЛУ́ГЪ ТӨРКЕСТА́Н»**, иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм әдәби газета. Ташкент мөселман оешмалары органы. 1917 елның 25 апреленнән 1918 гә кадәр Ташкентта татар һәм үзбәк телләрендә атнага 2–3 тапкыр нәшер ителә. Төркестан краеның татарлар җәмгыяте Үзәк бюросы басмасы. Мөхәррире — К.Бәкер, мөхәррир булмаганда, аның вазифаларын С.Абдусаттаров башкара. Актив авторлары

арасында: Н.Сәйфелмөлеков, Ф.Солтанбәк, И.Таһиров, Н.Яушев һ.б. Газета төрки һәм мөселман халыкларының туганлык һәм тигезлек нигезендә берләшү идеяләрен пропагандалауга зур игътибар бирә. «Төркестан автономиясе турында» мәкаләсендә Н.Яушев, Төркестан халыкларының хокукларын кысу каршылыкка китерәчәк дип кисәтеп, Төркестанга автономия статусы бирүгә чакыра. Милли-терр. федератив башлангычта демократик респ-ка төзергә ниятләнелә («Гомуммөселман корылтае»). «О.Т.» битләрендә Учредительләр җыены турында тәфсилле мәгълүмат бирелә; И.Таһир «Учредительләр җыены нәрсә ул?» дигән тәфсилле мәкаләсендә аңа булышлык итүгә чакыра. Газета битләрендә фронттагы хәлләр, хәрби бурычка мөнәсәбәт турында сөйләнә, милли армия булдыру мәсьәләсе карала. Редакция газетаны уртак төрки тел һәм уку йортларын үзгәртеп коруга карата И.Гаспринский һәм аның «*Тәрҗеман*» г-тасы идеяләрен дәвам итүче дип белдерә. «О.Т.» язмаларында яңа үрнәктәге мәктәпләр оештыру, фән һәм мәдәниятне үстерү мәсьәләләре яктыртыла, хатын-кызларның тигез хокуклылыгы, татар иҗтимагый оешмалары эшчәнлеген активлаштыру темасы күтәрелә. Ташкент, Бохара, Хива, Оренбург шәһәрләрендәге һәм Россия өлкәләрендәге вакыйгалар турындагы хәбәрләрдән тыш, чит илләрдән дә хәбәрләр басыла. «Тормыш», «Йолдыз» һ.б. татар газеталарыннан күчереп бастырылган язмаларга да зур урын бирелә.

*З.З.Гыйләҗев.*

**ОЛЫ́ АККО́Ш КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында, *Аккош күлләре* системасында иң зурысы. Казанның Киров р-ны терр-ясендә «Аккош күле» урман паркында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 12,4 *га*, ташу вакытында — 27,9 *га*. Су күләме 101 мең $м^3$, ташу вакытында — 547 мең $м^3$. Озынлыгы 576 *м*, иң зур киңлеге 320 *м*; уртача тирәнлеге 2 *м*, ташу вакытында — 3,4 *м*. Күл казанлыгы дюналар арасындагы иңкүлекләрдә карст-суффозия



Олы Аккош күле.

процесслары нәтиҗәсендә катлауланып ясалган. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Ярлары сөзәк, урыны б-н сазлыклы. Суы бик йомшак (0,8–1,1 *мг-экв/л*), аз минеральләшкән, гидрокарбонат-кальцийлы типта. О.А.к. — ял итү урыны.

*Н.М.Минһаҗева.*

**ОЛЫ́ АРТА́Ш** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 57 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 84 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Әрнәш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.А.та су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1699 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 581, 1897 дә — 923, 1908 дә — 1091, 1920 дә — 1006, 1926 да — 1061, 1938 дә — 953, 1949 да — 496, 1958 дә — 470, 1970 тә — 516, 1989 да — 199, 2002 дә — 126 кеше.

**ОЛЫ́ АРТА́Ш** (Теләнче) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 295 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 16 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Келәнче исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, урман кисү, тегү, чыпта сугу һәм йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.А.та мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 907,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 372, 1897 дә — 536, 1908 дә — 683, 1920 дә — 720, 1926 да — 688, 1938 дә — 676, 1949 да — 467, 1970 тә — 547, 1979 да — 458, 1989 да — 340, 2002 дә — 333 кеше.

**ОЛЫ́ АТЫ́** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 31 *км* көньяктарак, Зәй елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 250 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1724 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше, олаучылык б-н шөгыльләнә; алпавыт утарларында ялланып эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, О.А.да су тегермәне була. 1887–90 да Алабуга сәүдәгәре И.Г.Стахеев иганәсенә Покров чиркәве төзелә (1990 еллар башында яңадан эшли башлый; архит-ра истәлеге). 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2251 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 848, 1897 дә — 1298, 1920 дә — 1707, 1926 да — 1014, 1938 дә — 1122, 1949 да — 819, 1958 дә — 608, 1970 тә — 602, 1979 да — 554, 1989 да — 271, 2002 дә — 273 кеше.

**ОЛЫ́ АФАНА́С** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 2 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 3168 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 46%, руслар — 44%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, вак-төяк сәүдә, олаучылык б-н шөгыльләнә, бурлаклыкта йөри. 1817 дә О.А.та таштан Покров чиркәве төзелә (архит-ра истәлеге; 1980 еллар ахырында яңадан ачыла). 20 йөз башында земство мәктәбе, 6 җил тегермәне була; җомга көннәрендә базар эшли, ел саен 1 октябрьдә һәм Изге Троица көнендә ярминкә үткәрелә. Бу чорда



Олы Афанас авылы. Покров чиркәве. 1817.


авыл җәмәгатенең имана җире 2434,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 823, 1870 тә — 932, 1897 дә — 1361, 1920 дә — 1548, 1926 да — 1778, 1938 дә — 1214, 1949 да — 785, 1958 дә — 675, 1970 тә — 1471, 1979 да — 3305, 1989 да — 2685, 2002 дә — 2780 кеше.

**ОЛЫ́ АЧАСЫ́Р** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Буа елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 694 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. *Насыйри Каюм исемендәге архитектура-этнография комплексы.* Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.А.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 3 йон-тукыма ману остаханәсе, 8 тегермән, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2389 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат, 1963 нең 1 февра-

леннән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 103 ир-ат; 1859 да — 1778, 1897 дә — 3034, 1908 дә — 3413, 1920 дә — 2973, 1926 да — 3498, 1938 дә — 2765, 1949 да — 1728, 1958 дә — 1687, 1970 тә — 1716, 1979 да — 1500, 1989 да — 1077, 2002 дә — 900 кеше.

**ОЛЫ́ ӘРӘМӘЛЕ́** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Әнҗерә елгасы буенда. 2010 елда 194 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә, Алабугада көнлекле эштә эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Ә.дә тегермән була. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 2087,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 649, 1887 дә — 953, 1920 дә — 871, 1926 да — 1084, 1938 дә — 523, 1949 да — 399, 1958 дә — 308, 1970 тә — 255, 1979 да — 192, 1989 да — 209, 2002 дә — 209 кеше.

**ОЛЫ́ ӘТНӘ́** авылы, Әтнә р-ны үзәге. ТР-ның төньяк-көнбатыш өлешендә, Коркачык тимер юл станциясеннән (Казан — Екатеринбург юнәлеше) 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әтнә елгасы буенда, Казаннан 71 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 3536 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Май з-ды, «Әтнә сәнәгать комбинаты» тегү пр-тиесе. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, а.х. техникумы, район мәдәният йорты, 2 китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, тегү, балта эше, он тарту, йон-тукыма ману, бакыр савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ә.дә волость идарәсе урнаша, 3 мәчет, фельдшерлык пункты, 3 җил һәм 2 су тегермәне, 2 тимерчелек, казна шәраб кибете, 3 сыраханә, ашханә, 4 юлаучылар йорты була; шимбә көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4704,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әтнә р-ны, 1959 ның 12 октябреннән Тукай р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында, 1990 ның 25 октябреннән — кабат район үзәге. Халык саны: 1782 дә — 397 ир-ат; 1859 да — 2006, 1897 дә — 2715, 1908 дә — 3539, 1920 дә — 3349, 1922 дә — 3545, 1926 да — 3560, 1949 да — 2664, 1958 дә — 2816, 1970 тә — 3399, 1979 да — 3375, 1989 да — 3049, 2002 дә — 3651 кеше. Истәлекле урыннар — сәүдәгәр Гатаулла, Вәли, Саттар бай йортлары (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге).



Олы Әтнә авылы. Мәчет.





Олы Әтнә авылы. 1. Район үзәк хастаханәсе. 2. Гатаулла сәүдәгәр йорты. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

*Әд.:* Описание уездных городов и замечательных селений Казанской губернии. К., 1862.

**ОЛЫ́ ӘШНӘ́К** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан хәзерге О.Ә. урынында авыллар була. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ә.тә 2 мәчет, 2 тимерчелек, тегермән, 3 ярма яргыч, 12 вак-төякләр кибете эшли. Бу елларда авыл җәмәгатенең имана җире 2794,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 236 ир-ат; 1859 да — 1482, 1897 дә — 1942, 1908 дә — 2240, 1920 дә — 2337, 1926 да — 1982, 1949 да — 1236, 1958 дә — 1159, 1970 тә — 921, 1989 да — 562, 2002 дә — 405 кеше. О.Ә. тирәсендә кабер ташлары — 13–14 йөзләр ташъязма истәлекләре саклана.

*Әд.:* Х ә л и у л л и н И. Олы Әшнәк // Мирас. 1993. № 5; Г а р и п о в а Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан: 2 томда. К., 2001. Т. 1; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987.

**ОЛЫ́ БАТРА́С** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 34 *км* көньяк-көнбатыштарак, Батрас елгасы буенда. 2010 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Драгуново, Драгун-Бехметьево, Барский Батрас исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, вак һөнәрчелек: чана, арба, тәгәрмәч ясау, киез итек басу, киндер туку б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында О.Б.та алпавыт П.И.Кукаркин иганәсенә чиркәү төзелә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1726 дис. тәшкил итә. 1927 дә О.Б.тан күченүчеләр Салкын Чишмә авылына нигез сала. Күмәкләштерү чорында монда «Беренче май» к-зы оештырыла, 1950 еллар башында ул «Пролетарий» к-зы (Тѳги а.) б-н берләшә. 1959 дан О.Б. Энгельс исем. к-з составында, соңрак «Рассвет» итеп үзгәртелә, 1966 дан «Батрас» а.х. товарлары житештерү кооперативында. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1724 тә — 12, 1795 тә — 51 ир-ат; 1859 да — 356, 1897 дә — 527, 1920 дә — 604, 1926 да — 642, 1938 дә — 322, 1949 да — 250, 1958 дә — 216, 1970 тә — 206, 1979 да — 100, 1989 да — 120, 2002 дә — 107 кеше.

**ОЛЫ́ БАХТА́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 40,7 *км*, бассейнының мәйданы 384 $км^2$. Чистай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Мордва Баганалысы авылы янында, тамагы Байтирәк авылыннан төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. О.Б.ның су җыелу мәй-



Олы Бахта елгасының урта агымы.

даны төньякка авыш дулкынсыман тигезлек. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 4%. О.Б.ның 2,5 тән 16,3 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар, иң зурысы Кече Бахта (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км*$^2$. Башлыча, кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,5 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытына су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу вакытына еллык агымның 80% ы туры килә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,083 *м*$^3$*/с*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л* га кадәр. О.Б. елгасы бассейнында су күләме 3 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОЛЫ́ БӘРӘЗӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 12 *км* көнбатыштарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 536 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.дә мәктәпләре булган 3 мәчет, су һәм 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 тимерчелек, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3866 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 264 ир-ат; 1859 да — 1618, 1897 дә — 2622, 1908 дә — 3294, 1920 дә — 1717, 1926 да — 2800, 1938 дә — 2606, 1949 да — 1723, 1958 дә — 1248, 1970 тә — 387, 1979 да — 369, 2002 дә — 566 кеше.

**ОЛЫ́ БИСӘ́Р** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бисәр елгасы буенда. 2010 елда 257 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.дә чиркәү-приход мәктәбе, 3 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу елларда авыл җәмгатенең имана җире 1969,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 170 ир-ат; 1859 да — 470, 1897 дә — 894, 1908 дә — 1006, 1920 дә — 915, 1926 да — 930, 1938 дә — 567, 1949 да — 545, 1958 дә — 589, 1970 тә — 545, 1979 да — 445, 1989 да — 333, 2002 дә — 285 кеше.

**ОЛЫ́ БИТАМА́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 607 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.да мәчет, мәктәп, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1488 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 965, 1908 дә — 1086, 1920 дә — 1105, 1926 да — 1304, 1938 дә — 1308, 1949 да — 1117, 1958 дә — 912, 1970 тә — 879, 1989 да — 655, 2002 елда 655 кеше.

*Әд.:* Износков И.А. Список населённых мест Казанского уезда, с кратким их описанием. К., 1885; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ БОЛГАЕ́Р** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 26 *км* көнчыгыштарак, Олы Шаһиян елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 238 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.да мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2063,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Келәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 870, 1897 дә — 1613, 1908 дә — 1671, 1926 да — 886, 1938 дә — 914, 1949 да — 596, 1958 дә — 564, 1970 тә — 544, 1979 да — 428, 1989 да — 287, 2002 дә — 292 кеше.

**ОЛЫ́ БОРТА́С** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 33 *км* төньяк-көнбатыштарак, Саравыл елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.та мәчет, мәктәп, җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 917,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 375, 1884 тә — 485, 1897 дә — 630, 1908 дә — 733, 1920 дә — 660, 1926 да — 380, 1938 дә — 326, 1949 да — 252, 1958 дә — 166, 1970 тә — 87, 1979 да — 74, 1989 да — 68, 2002 дә — 72 кеше.

**ОЛЫ́ БУТЫ́РКА** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 235 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 53%, татарлар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Каенсар-Бутырка исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Б.да чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 943 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Черемыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 318, 1897 дә — 509, 1908 дә — 478, 1920 дә — 502, 1926 да — 397, 1949 да — 244, 1958 дә — 208, 1970 тә — 226, 1979 да — 200, 1989 да — 198, 2002 дә — 205 кеше.

**ОЛЫ́ ДЕРБЫ́ШКИ** авылы, Казан шәһәренең Совет р-ны карамагында, Казанка елгасы буенда. 2000 елда 918 кеше (1989 елгы халык исәбе буенча, руслар — 57%, татарлар — 38%) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тәгәрмәч ясау һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Д.да иске дин тарафдарлары кәшәнәсе, земство мәктәбе, 15 тимерчелек, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 838,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1950 нең 16 маеннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында, 1984 нең 15 октябреннән Казанның Совет р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 516, 1897 дә — 411, 1908 дә — 614, 1920 дә — 765, 1926 да — 895, 1938 дә — 953, 1949 да — 610, 1958 дә — 924, 1970 тә — 1006, 1989 да — 1058 кеше.

**ОЛЫ́ ДҮРТӨЙЛЕ́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 27 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 1861 елгы реформага ка-

дәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Д.дә 2 вак-тәүклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 731,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 111 ир-ат; 1859 да — 161, 1878 дә — 319, 1897 дә — 325, 1908 дә — 401, 1920 дә — 416, 1949 да — 357, 1958 дә — 219, 1970 тә — 217, 1979 да — 118, 1989 да — 44, 2002 дә — 33 кеше.

**ОЛЫ́ ЕЛГА́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 21 *км* көнбатыштарак, Шуран елгасы буенда. 2010 елда 881 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы чыганакларда О.Е.да мәчет телгә алына, һәм ул 1879 да төзелгән яңа бинага (архит-ра истәлеге) күчә. 1908 дә авылда икенче мәчет ачыла. Мәчетләр каршында мәктәпләр эшли. 20 йөз башында О.Е.да тимерчелек һәм 5 вак-тәүклэр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2356,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Масловка волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе



Олы Елга авылы. Мәчет. 1879.

р-нында. Халык саны: 1782 дә — 278 ир-ат; 1859 да — 722, 1897 дә — 1327, 1908 дә — 1687, 1920 дә — 1737, 1926 да — 1116, 1949 да — 932, 1958 дә — 905, 1970 тә — 1041, 1989 да — 853, 2002 дә — 863 кеше.

**ОЛЫ́ ЕЛО́ВО** (Олы Елау) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 33 *км* көнбатыштарак, Вятка елгасыннан 5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 305 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 53%, татарлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, филтә ясау, ятьмә үрү б-н шөгыльләнә. 1868 дә О.Е.да земство уч-щесе ачыла. 1885–90 елларда янган агач чиркәү урынына сәүдәгәр Стахеевлар иганәсенә таштан Архангел Михаил чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1782 дә — 131 ир-ат; 1834 тә — 496, 1887 дә — 1153, 1920 дә — 1261, 1926 да — 999, 1938 дә — 914, 1958 дә — 348, 1970 тә — 375, 1989 да — 248, 2002 дә — 309 кеше.

**ОЛЫ́ ЕЛО́ВО КҮЛЕ́**, Көнчыгыш Кама алдында, элекке су юлында сакланып калган күл. Вятка елгасының уңъяк яры тугаенда урнашкан, Алабуга р-ны Олы Елово авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 20 *га*. Су күләме 400 мең $м^3$. Озынлыгы 600 *м*, киңлеге 200–400 *м*. Формасы калаксыман. Ярлары сөзәк, урыны б-н таллар үскән. Күл агымсыз, туенуы катнаш. Суы үтә күренмәле диярлек, яшькелт төстә, чагыштырмача каты, уртача минеральләшкән. Елга төбе утырмалары комсу һәм комсу-ләмле. Күлнең үсемлекләр б-н каплану дәрәҗәсе уртача (25% ка кадәр), чатырлы сусак, сары төнбоек, су кәбестәсе үләннәре өстенлек итә. Су үсемлекләренең сирәк төрләреннән — сливасыман носток үсә. Ихтиофаунасында — бәртәс, табан балык.

*Н.М.Минһаҗева.*

**ОЛЫ́ ҖӘКӘ́** (Олы Яке) авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 588 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Балалар йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, такта яру, курыс төшерү-мунчала ясау, щётка ясап сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ж.дә мәчет, мәктәп, җил тегермәне, 5 вак-тәүклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1718,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 138 ир-ат; 1859 да — 745, 1897 дә — 976, 1908 дә — 1130, 1920 дә — 1037, 1926 да — 1259, 1938 дә — 997, 1949 да — 300, 1958 дә — 613, 1970 тә — 651, 1979 да — 611, 1989 да — 594, 2002 дә — 583 кеше.

**ОЛЫ́ ЗӘҢГӘ́Р КҮЛ**, Көнбатыш Кама алдында. Казансу елгасының уңъяк ярында ур-



Олы Зәңгәр күл.

нашкан, Биектау р-ны Щербаково авылыннан 0,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 2,2 *га*. Озынлыгы 800 *м* га якын, киңлеге 20–100 *м*. Төньяк киңәйгән өлешендә ике карст бүрәнкәсе — Олы Упкын һәм Кече Упкын бар. Күлнең формасы сузынкы, бөгелгән. Килеп чыгышы буенча, О.З.к. — Казансу елгасының элекке юлында сакланып калган, карст күренешләре нәтиҗәсендә катлауланып ясалган күл. Дамба б-н ныгытылган, ул аны Казансу елгасыннан аерып тора. Суының минеральләшүе югары (якынча 2,5 *г/л*), бик каты (31–32 *мг-экв/л*), кислород составы түбән һәм табигый күкертле водород югары, үтә күренмәле (төбенә кадәр), үзенә генә хас зәңгәрсу төстә (исеме шуннан), гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта. О.З.к.нең җир асты сулары б-н туенуы тотрыклы: төбендә көчле җир асты сулары чыгышы бар. Күл агымлы: аннан Казансу елгасына су чыгымы якынча 250 *л/с* булган дулкынлы инеш агып чыга. Су әйләнеше елына якынча 700. Күл боз б-н капланмый. Су темп-расы ел дәвамында даими диярлек, 6-8 °С тәшкил итә. Елга төбе утырмалары үсемлек калдыклары катнашмасы һәм күкертле водород (сапропельләр) исе килеп торган кара һәм куе соры ләмнән гыйбарәт. Физик-химик составы буенча алар минеральләшүе түбән булган, җиңелчә сульфатлы дәвалау ләмнәренә (пелоидларга) карый, бальнеологик әһәмияткә ия. Күл ял итү-сәламәтләндерү (салкын суда коену) һәм бальнеологик (җирле санаторийлар өчен дәвалау ләмен чыгару) максатларында файдаланыла. О.З.к. Урта Идел буендагы уникаль күлләргә керә, аны элек-электән «Казан яны зәңгәр могҗизасы» дип йөрткәннәр. Беренчеләрдән булып, ТРның табигать истәлеге итеп билгеләнә (1972), 1994 елдан *Зәңгәр күлләр* табигать тыюлыгы составына керә.

*Әд.:* Сементовский В.И. Голубое озеро // Природа Татарии. К., 1947; Памятники природы Татарии. К., 1977.

*Н.М.Минһаҗева.*

**ОЛЫ́ ИМӘ́Н** (Олыймән) авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 42 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сикия елгасы бассейнында. 2010 елда 330 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Улуйменево исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлек-





Олы Кайбыч авылы. 1. Гомуми күренеше; 2. Район элемтә бүлеге бинасы.

челек, урман кисү, тәгәрмәч, тугым, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1809 дан мәгълүм), мәктәп (1838 дә ачыла), бакалея кибете, 2 икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2458 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 128, 1834 тә — 313, 1859 да — 599, 1870 тә — 710, 1897 дә — 857, 1906 да — 1104, 1913 тә — 1193, 1926 да — 867, 1938 дә — 803, 1949 да — 480, 1958 дә — 446, 1970 тә — 505, 1979 да — 477, 1989 да — 417, 2002 дә — 334 кеше.

*Әд.:* Актанышым — ак илем. К., 2010.

**ОЛЫ́ КАБА́Н** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 38 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 646 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Введенский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, сарык тиресе эшкәртү һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 1840 та О.К.да Дәүләт милке министрлыгы мәктәбе ачыла, 1869 да земство мәктәбе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында Спас-Преображение чиркәве (18 йөзнең 1 нче яртысында



Олы Кабан авылы. Спас-Преображение чиркәве.

төзелә; архит-ра истәлеге), 5 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 тимерчелек, казна шәраб һәм 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4055,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 285 ир-ат; 1859 да — 998, 1884 тә — 1172, 1897 дә — 1407, 1920 дә — 1547, 1926 да — 1669, 1949 да — 983, 1958 дә — 1060, 1970 тә — 610, 1979 да — 598, 1989 да — 508, 2002 дә — 543 кеше.

*Әд.:* История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

**ОЛЫ́ КАВА́Л** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Солонка елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 466 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, тегүчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.да 2 мәчет, мәдрәсә, мәктәп, 2 су һәм 3 җил тегермәне, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2988,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 303 ир-ат; 1859 да — 1355, 1897 дә — 1385, 1908 дә — 1878, 1920 дә — 1506, 1926 да — 1618, 1938 дә — 1337, 1949 да — 968, 1958 дә — 889, 1970 тә — 787, 1989 да — 546, 2002 дә — 513 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ КАЙБЫ́Ч** авылы, Кайбыч р-ны үзәге, ТРның көнбатыш өлешендә, Колангы тимер юл станциясеннән (Ульянов-Зөя юнәлеше) 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәрле елгасы буенда, Казаннан 120 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 1600 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; икмәк комб-ты. Урта мәктәп, мәдәният йорты, 2 китапханә. Җырчы Г.М.Кайбицкая музее. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.та мәчет, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1844 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя



Олы Кайбыч авылы. Г.М. Кайбицкая музее.

кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково р-нында, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1965 нең 12 гыйнварыннан Апас р-нында, 1991 нең 19 апреленнән — кабат район үзәге. Халык саны: 1782 дә — 209 ир-ат; 1859 да — 1158, 1897 дә — 1864, 1908 дә — 2193, 1920 дә — 1969, 1926 да — 1527, 1938 дә — 1816, 1949 да — 1782, 1958 дә — 1861, 1970 тә — 1575, 1979 да — 1328, 1989 да — 942, 2002 дә — 1578 кеше.

**ОЛЫ́ КАРАГУҖА́** (Олы Караужа) авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 31 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 656 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба ясау, чыпта сугу, капчык тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.да мәчет, мәктәп, 3 җил тегермәне, тимерчелек, 8 вак-төякләр кибете, пәнҗешәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире

2358,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 264 ир-ат; 1859 да — 1102, 1897 дә — 1596, 1908 дә — 1796, 1920 дә — 1426, 1926 да — 1636, 1949 да — 641, 1958 дә — 874, 1970 тә — 1048, 1979 да — 847, 1989 да — 750, 2002 дә — 702 кеше.

**ОЛЫ́ КАРАМАЛЫ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогыннан 11 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 146 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Карамалы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Халык мөселманнар һәм православие динендәгеләргә бүленә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.К.да мәчет була, мәчет каршында зур мәдрәсә эшли, 1911 дә ул 4 сыйныфлы рус-татар уч-щесе итеп үзгәртелә. 20 йөз башында 5 җил тегермәне, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1012,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 112 ир-ат; 1859 да — 393, 1884 тә — 580, 1897 дә — 697, 1920 дә — 874, 1926 да — 576, 1938 дә — 730, 1949 да — 510, 1958 дә — 375, 1970 тә — 263, 1979 да — 217, 2002 дә — 156 кеше. О.К.да язучы И.*Гази* туган.

**ОЛЫ́ КАРИЛЕ́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы поселогыннан 24 *км* көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 399 кеше (татарлар) яши. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, урманчылык эше, агач эшкәртү пр-тиесе. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.дә мәчет, 2 су һәм 2 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1232,5 дис. тәшкил итә. 1933–43 елларда О.К.дә МТС эшли. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 191 ир-ат; 1859 да — 657, 1884 тә — 952, 1897 дә — 1281, 1908 дә — 1326, 1920 дә — 1260, 1926 да — 843, 1938 дә — 686, 1949 да — 769, 1958 дә — 828, 1970 тә — 643, 1979 да — 588, 1989 да — 502, 2002 дә — 445 кеше.

**ОЛЫ́ КАРЛЫ́** елгасы, Идел алдында, Карлы елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 28 *км* (ТР чикләрендә 12 *км*), бассейнының мәйданы 215,2 *км²*. Идел буе калкулыгыннан, Чүпрәле р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Яңа Ишле авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Чуаш Респ-касы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 105 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 13%. О.К.ның 1,2 дән 16 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар, иң зурысы Кече Карлы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,40 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 76 *мм*, ташу вакытында су катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,12 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. О.К. елгасы бассейнында су күләме 0,6 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

**ОЛЫ́ КАЧЫ́К** (Олы Качкын), авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Танай елгасы буенда. 2010 елда 256 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысына кадәр Танай авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Качка (Дмитриевское) исеме б-н дә мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, май язу, чүлмәк ясау, утын кисү б-н шөгыльләнә, шәһәрләргә китеп, көнлекле эштә эшли. 18 йөзнең 60 елларыннан авылда приход була. 20 йөз башында О.К.та волость идарәсе урнаша, таш Троица чиркәве (1811–26 да төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1825,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Качык волостенда, 1920–21 дә Вотяк автономияле өлкәсе составында. 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 877, 1887 дә — 1118, 1920 дә — 1029, 1922 дә — 1133, 1926 да — 1108, 1938 дә — 880, 1949 да — 385, 1958 дә һәм 1970 тә — 311, 1989 да — 226, 2002 дә — 445 кеше.

**ОЛЫ́ КӘМИНКӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 17,4 *км*, бассейнының мәйданы 223 *км²*. Чирмешән р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Кызылъяр авылыннан төньяктарак, тамагы Яшәүче авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 9%. О.К.нең 2 дән 16,4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы Сөлчә (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км²*. Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,296 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. О.К. елгасы бассейнында су күләме 3,9 млн. *м³* булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОЛЫ́ КИБӘХУҖА́** (Яңавыл) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 9 *км* төньяктарак, Макса елгасы буенда. 2010 елда 299 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Кибәхуҗа исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.К.да мәчет була. 20 йөз башында мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1604,25 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 129 ир-ат; 1859 да — 644, 1897 дә — 835, 1908 дә — 927, 1920 дә — 988, 1926 да — 724, 1938 дә — 699, 1949 да — 746, 1958 дә — 548, 1970 тә — 492, 1979 да — 383, 1989 да — 311, 2002 дә — 304 кеше.

**ОЛЫ́ КИБӘЧЕ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы поселогыннан 33 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нысы елгасы буенда. 2010 елда 554 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Салкын Чишмә исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.К.дә мәчет була. 20 йөз башында су тегермәне һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 546,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губер-

насының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 294, 1897 дә — 534, 1908 дә — 575, 1920 дә — 719, 1926 да — 614, 1949 да — 637, 1970 тә — 719, 1979 да — 725, 1989 да — 636, 2002 дә — 576 кеше.

**ОЛЫ́ КИТӘ́К** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бөре елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,2 *км* (ТР чикләрендә 7 *км*), бассейнының мәйданы 92,8 *км²*. Елга башы Кукмара р-ны Чәти посёлогыннан 2,8 *км* төньяк-көнбатыштарак; Яңа Сәрдек авылыннан тамагына кадәр Киров өлкәсе терр-ясе буенча ага. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 59 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 12%. О.К.нең 0,4 тән 5,4 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 112 *мм*, ташу вакытында су катламы 73 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,094 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л* га кадәр.

**ОЛЫ́ КӨЕ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 48 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 77 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.тә мәчет (1875–77 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, тимерче остаханәсе, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 788,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан өязенең Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 89 ир-ат; 1859 да — 503, 1897 дә — 825, 1908 дә — 867, 1920 дә — 974, 1926 да — 848, 1949 да һәм 1958 дә — 489, 1970 тә — 374, 1989 да — 148, 2002 дә — 100 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ КҮЛ**, к. *Мәми*.

**ОЛЫ́ КҮЛБА́Ш** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 255 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Синтәк исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше һәм чыпта-кап сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.К.та мәчет, мәдрәсә, тимерчелек, 2 җил тегермәне, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 898,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 90 ир-ат; 1859 да — 464, 1897 дә — 602, 1908 дә — 750, 1920 дә — 1014, 1926 да — 1259, 1938 дә — 739, 1949 да — 600, 1958 дә — 663, 1970 тә — 627, 1979 да — 467, 1989 да — 356, 2002 дә — 283 кеше.

**ОЛЫ́ КҮЛГӘ́** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Суша елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 352 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%, татарлар — 31%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Күлгә, Архангельский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 1758 дән авылда православие приходы була. 1840 та алпавыт Е.А.Безобразова иганәсенә Архангел Михаил чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында О.К.дә земство мәктәбе, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 571,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 188 ир-ат; 1859 да — 656, 1897 дә — 726, 1908 дә — 933, 1920 дә — 760, 1926 да — 889, 1938 дә — 603, 1949 да — 482, 1958 дә — 354, 1970 тә — 288, 1989 да — 369, 2002 дә — 397 кеше.

**ОЛЫ́ МӘМИ́** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 50 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәми елгасы буенда. 2010 елда 302 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 63%, чуашлар — 34%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.М.дә Александр Невский чиркәве (1892–94 тә төзелә), земство мәктәбе (1883 тә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе буларак ачыла), 3 су һәм 3 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 2 ярма яргыч, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2914 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 97 ир-ат; 1859 да — 1035, 1897 дә — 1437, 1908 дә — 1618, 1920 дә — 1577, 1926 да — 1287, 1938 дә — 807, 1949 да — 538, 1958 дә — 617, 1970 тә — 595, 1979 да — 412, 1989 да — 369, 2002 дә — 338 кеше.

**ОЛЫ́ МӘҢГӘ́Р** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 8 *км* көнчыгыштарак, Симет елгасы буенда. 2010 елда 680 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Сәүдәгәр Бакиров йорты (19 йөзнең 1 нче яртысы архит-ра истәлеге). Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон тетү, тимерчелек һәм балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.М.дә 3 мәчет, 2 мәктәп, 7 юлаучылар йорты, 2 җил һәм 3 су тегермәне, 3 тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете була; сишәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3298,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 1881, 1897 дә — 1893, 1908 дә — 1832, 1920 дә — 1387, 1926 да — 1398, 1938 дә — 1277, 1949 да — 1011, 1958 дә — 940, 1970 тә — 952, 1989 да — 655, 2002 дә — 699 кеше.

**ОЛЫ́ МӘРӘТХУҖА́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.М.да мәчет була. 20 йөз башында ш.у. 2 җил тегермәне, мануфактура-бакалея һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1782 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 134 ир-ат; 1859 да — 561, 1897 дә — 860, 1908 дә — 1033, 1920 дә — 915, 1926 да — 650, 1938 дә — 706, 1949 да — 602, 1958 дә — 382, 1970 тә — 223, 1979 да — 152, 1989 да — 91, 2002 дә — 95 кеше. О.М.да драматург Т.Г.*Миңнуллин* туган.

**ОЛЫ́ МӘТӘСКӘ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 7 *км* көнбатыштарак, Мәтәскә елгасы буенда. 2010 елда 558 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. *Хөсни Фатих музее*. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.М.дә мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 2 су тегермәне, тимерчелек, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1598 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 190 ир-ат; 1859 да — 1209, 1897 дә — 1503, 1908 дә — 1633, 1920 дә — 1575, 1926 да — 1177, 1938 дә — 1061, 1949 да — 926, 1958 дә — 745, 1970 тә — 811, 1979 да — 672, 1989 да — 573, 2002 дә — 560 кеше.

**ОЛЫ́ МИРӘТӘ́К** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 25 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.М.тә Троица чиркәве, земство мәктәбе, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1012,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 390, 1897 дә — 516, 1908 дә — 671, 1920 дә — 794, 1926 да — 712, 1938 дә — 524, 1949 да — 326, 1958 дә — 363, 1970 тә — 159, 1979 да — 104, 1989 да — 74, 2002 дә — 53 кеше.

**ОЛЫ́ МИШӘ́** (Олы Яңавыл) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 362 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.М.дә мәчет була. 20 йөз башында 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу елларда авыл җәмәгатенең имана җире 893 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир-ат; 1859 да — 323, 1897 дә — 465, 1908 дә — 573, 1920 дә — 579, 1926 да — 540, 1938 дә — 533, 1949 да — 530, 1970 тә — 495, 1979 да — 440, 1989 да — 369, 2002 дә — 372 кеше.

**ОЛЫ́ НОРМА́** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Нурминкә елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1 кеше яши. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Норма, Мурма исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне һәм икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 269 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 38 ир-ат; 1859 да — 56, 1897 дә — 100, 1908 дә — 80, 1920 дә — 203, 1926 да — 218 кеше, 1989 һәм 2002 дә даими яшәүчеләр юк.

**ОЛЫ́ НУГА́Й УРДАСЫ́** (Олы Нугай), нугайларның мөстәкыйль дәүләти берәмлеге. 16 йөзнең 2 нче яртысында *Нугай Урдасыннан* бүленеп чыга. Каспий диңгезенең төньягында, Идел б-н Урал арасындагы җирләрдә барлыкка килә. Нигезләүчесе Исмәгыйль бәк (1555–63) һәм аның варисы Динәхмәд бәк (1563–78) заманында Мәскәүгә яраклы сәясәт алып барыла. Ырыс бәк идарәсе вакытында (1578–90) Кырым ханлыгы б-н дуслык килешүе төзелә һәм Идел буенда мөселманнарның өстенлеген тәэмин итү өчен күп еллар буе Россия б-н көрәш бара. Шушы көрәш-бәрелешләр, йогышлы чирләр таралу һәм корылык нәтиҗәсендәге ачлыклардан соң дәүләт көчсезләнә. Иштирәк бәк (1600–19 елларда идарә итә) О.Н.У.ның вассал рәвешендә Россиягә буйсынуын таный. 1634 елда халкының күпчелек өлеше Иделнең уңъяк ярына күчә һәм, *Кече Нугай Урдасына* кушылып, күчмә тормыш алып баруын дәвам итә.

*Әд.:* Т р е п а в л о в В.В. История Ногайской Орды. М., 2002.

**ОЛЫ́ НЫРСЫ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 24 *км* көньяктарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 494 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Н.да мәчет була. 20 йөз башында мәдрәсә, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1619,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1859 да — 512, 1897 дә — 875, 1908 дә — 895, 1920 дә — 958, 1926 да — 890, 1938 дә — 829, 1949 да — 574, 1958 дә — 757, 1979 да — 702, 1989 да — 513, 2002 дә — 506 кеше.

**ОЛЫ́ НЫРТЫ́** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 21 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 239 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, челтәр бәйләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Н.да мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 781,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 72 ир-ат; 1859 да — 217, 1897 дә — 386, 1908 дә — 399, 1920 дә — 415, 1926 да — 386, 1938 дә — 373, 1949 да — 251, 1970 тә — 277, 1979 да — 254, 1989 да — 240, 2002 дә — 254 кеше.

**ОЛЫ́ ОСИ́НОВКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Урай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 47 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.О.да Илья чиркәве, земство мәктәбе (1882 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2003 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 755, 1897 дә — 1128, 1908 дә — 1318, 1920 дә — 704, 1926 да — 1017, 1938 дә — 655, 1949 да — 460, 1958 дә — 344, 1970 тә — 382, 1989 да — 159, 2002 дә — 122 кеше.

**ОЛЫ́ ӨСКЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнбатыштарак, Өске елгасы буенда. 2010 елда 247 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта-кап сугу, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Ө.дә мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, су тегермәне, ярма яргыч, йон-тукыма ману бинасы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1324,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри

волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 749, 1897 дә — 972, 1908 дә — 1120, 1920 дә — 911, 1926 да — 772, 1949 да — 482, 1958 дә — 470, 1970 тә — 522, 1979 да — 433, 1989 да — 274, 2002 дә — 291 кеше.

**ОЛЫ́ ӨШКӘТӘ́** авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 11 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 75 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ө.дә мәчет, мәдрәсә, 2 чыпта сугу бинасы, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1461,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 137 ир-ат; 1895 тә — 837, 1897 дә — 1122, 1908 дә — 1351, 1920 дә — 1264, 1926 да — 1153, 1938 дә — 842, 1949 да — 542, 1958 дә — 411, 1970 тә — 352, 1989 да — 128, 2002 дә — 97 кеше.

**ОЛЫ́ ПЕЛӘМӘ́Ш** елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Бима елгасының (Кырыкмас, Иж елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,6 *км*, бассейнының мәйданы 62 *км²*. Әгерҗе р-ны терр-ясе буйлап ага. Елга башы Пеләмәш авылыннан 5,8 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Бима авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 193 *м*, тамагыныкы — 115 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 26%. О.П.нең 7 *км* га кадәр озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,26–0,5 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа.

**ОЛЫ́ ПОДБЕРЕ́ЗЬЕ** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәрле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 730 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Гыйбадәтханә. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.П.да Изге Сергий Радонежский чиркәве, земство мәктәбе, 3 тимерчелек, су һәм 11 җил тегермәне, казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете була; дүшәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5784 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч р-нында, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье р-ны үзәге, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 653 ир-ат; 1859 да — 2512, 1897 дә — 3342, 1908 дә — 3647, 1920 дә — 3575, 1926 да — 3383, 1938 дә — 2179, 1958 дә — 1321, 1970 тә — 1096, 1979 да — 1017, 1989 да — 860, 2002 дә — 802 кеше.

**ОЛЫ́ ПҮЧИНКӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяктарак, Тож елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 94 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Лубяной Мост исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез басу һәм тукучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.П.дә земство уч-щесе, 2 тегермән, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1210,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1763 тә — 230 ир-ат; 1859 да — 413, 1897 дә — 450, 1908 дә — 632, 1920 дә — 494, 1938 дә — 524, 1949 да — 339, 1958 дә — 254, 1970 тә — 247, 1989 да — 108, 2002 дә — 113 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ ПЫЧРА́К КҮЛ**, Көнчыгыш Кама аръягында, элекке су юлында сакланып калган күл. Вятка елгасының уңъяк яр тугаенда урнашкан, Алабуга р-ны Айталан авылыннан 1,8 *км* көньяк-көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 4 *га*. Су күләме 80 мең *м³*. Озынлыгы 1750 *м*, киңлеге 40–100 *м*. Суы саргылт-көрән төстә, чагыштырмача каты, уртача минеральләшкән. Елга төбе утырмалары ләмле, кара төстә, черек исе килә. Яр буе өлеше үсемлекләр (сары төнбоек, күрән, чатырлы сусак) б-н каплана бара.

*Н.М.Минһаҗева.*

**ОЛЫ́ РӘС** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 11 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тегүчелек, арба ясау, башмак тегү, мичкә ясау, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Р.тә мәчет (1853 тә төзелә), мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 383,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 246, 1897 дә — 354, 1908 дә — 379, 1920 дә — 323, 1926 да — 321, 1938 дә — 268, 1949 да — 177, 1958 дә — 108, 1970 тә — 102, 1989 да — 10, 2002 дә — 17 кеше.

**ОЛЫ́ САЛТЫ́К** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Алгама елгасы буенда. 2010 елда 388 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз башында Ташкирмән һәм Татар Сараланы авылларыннан (хәзер Лаеш р-нында) христиан диненә күчәргә теләмәгәннәр нигез салган, дип фараз ителә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.С.та мәчет (1856 да төзелә), мәктәп, 6 җил тегермәне, тимерчелек, йон-тукыма ману бинасы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1350,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 168 ир-ат; 1859 да — 612, 1884 тә — 1032, 1897 дә — 1301, 1908 дә — 1500, 1920 дә — 1433, 1926 да — 1012, 1938 дә — 852, 1949 да — 591, 1958 дә — 509, 1970 тә — 479, 1989 да — 373, 2002 дә — 404 кеше.

**ОЛЫ́ САУРЫ́Ш** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 23 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 102 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек, итек басу б-н шөгыльләнә. 1868 дә О.С.та — ир балалар, 1898 дә кыз балалар өчен Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе ачыла. 20 йөз башында Козьма-Демьян чиркәве, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1259,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 575, 1897 дә — 971, 1908 дә — 1213, 1920 дә — 1014, 1926 да — 1137, 1938 дә — 846, 1949 да — 506, 1958 дә — 382, 1979 да — 319, 1989 да — 199, 2002 дә — 123 кеше.

*Әд.:* Историко-статистическое описание церквей и приходов Казанской епархии. К., 1904.


**ОЛЫ́ СОЛАБА́Ш** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 31 *км* төньяктарак, Сола елгасының (Казансуның уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 36 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Олы Алат Солабаш исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, тукыма туку б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.С.та мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1194,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 439, 1897 дә — 757, 1908 дә — 938, 1920 дә — 746, 1926 да — 853, 1938 дә — 617, 1949 да — 417, 1958 дә — 263, 1970 тә — 219, 1989 да — 66, 2002 дә — 46 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ СОЛТА́Н** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 27 *км* төньяк-көнбатыштарак, Солтан елгасы буенда. 2010 елда 272 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.С.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 3 су тегермәне, ярма яргыч, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1844,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан р-ны үзәге, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 153 ир-ат; 1859 да — 988, 1897 дә — 1283, 1908 дә — 1513, 1920 дә — 1378, 1926 да — 1160, 1949 да — 859, 1958 дә — 718, 1970 тә — 570, 1989 да — 420, 2002 дә — 344 кеше. О.С.да актёр Р.Ш.*Шәрәфиев* туган.

**ОЛЫ́ СОСНО́ВКА** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 70 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 6 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сосновка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.С.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 359 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 341, 1897 дә — 418, 1908 дә — 439, 1920 дә — 415, 1926 да — 496, 1938 дә — 420, 1949 да — 311, 1958 дә — 209, 1970 тә — 113, 1979 да — 51, 1989 да — 22, 2002 дә — 16 кеше.

**ОЛЫ́ СӨЛЧӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 117,2 *км*, бассейнының мәйданы 1864 *км²*. Елга башы Чирмешән р-ны Әмир авылы янында, Аксубай р-ны терр-ясе буенча ага, тамагы Нурлат р-ны Салдакай авылыннан 5 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 69 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 38%. О.С.нең 34 кушылдыгы бар, иң зурлары — Сөлчә (21,5 *км*), Кече Сөлчә (66,2 *км*), Сәләнгеш (21,6 *км*) — уң, Зирекле (10,1 *км*) — сул кушылдык. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,49 *км/км²*. О.С.нең үзәне асимметрияле, уң сөзәклеге текәрәк; киңлеге — тамак өлешендә 2–3 *км* га кадәр. Тугае ике яклы, тигез түгел. Елга юлы бормалы, киңлеге 5–8 *м*. Плёсларда зур тирәнлекләр — 1–1,5 *м* һәм перекатларда — 0,3–0,7 *м*. Агым тизлеге 0,2 дән 1 *м/с* ка дәр. Елга режимы 1934–64 елларда Нурлат р-ны Мамык авылы янында гидрологик постта өйрәнелә. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу вакытына еллык су агымының 90% ы туры килә. Мамык авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 4,5 *м* (иң зуры 6 *м*) тәшкил итә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу вакытында су катламы 89 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана, 25–30 көн дәвам итә. О.С. ноябрь башында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 76 *см* га җитә. Югары агымында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,049 *м³/с* һәм елга тамагында 0,525 *м³/с*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, бик каты (язын 9–12 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен (20 *мг-экв/л* дан күбрәк). Гомуми минеральләшүе язын 100–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. О.С. бассейнында су күләме 24 млн. *м³* булган 25 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. О.С. — ТРның табигать истәлеге (1978).



Олы Сөлчә елгасының югарыдан күренеше.



Олы Сөлчә елгасының түбән агымы.

**ОЛЫ́ ТАЛКЫ́Ш** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 34 *км* көнчыгыштарак, Талкыш елгасы буенда. 2010 елда 363 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дмитриевский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элек Вознесенский з-дына беркетелгәннәр) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Т.та Изге Дмитрий Солунский чиркәве (1878 дә төзелә), чиркәү-приход (1885 тә ачыла) һәм земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, 3 тимерчелек, ярма яргыч, казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1414,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 297 ир-ат; 1859 да — 1116, 1897 дә — 1923, 1908 дә — 2298, 1920 дә — 2234, 1926 да — 1976, 1938 дә — 1800, 1949 да — 1005, 1958 дә — 807, 1970 тә — 780, 1979 да — 745, 1989 да — 487, 2002 дә — 444 кеше.

**ОЛЫ́ ТАРХА́Н** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тархан елгасы буенда. 2010 елда 1221 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды, а.х. техникасы пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли: Казан һәм Сембер губернасы авылларында такта яра, йөк ташу, тегермәнчелек, балта эше б-н шөгыльләнә; Баку нефть промыселларында эшли. 20 йөз башында О.Т.да волость идарәсе урнаша; 4 мәчет, 5 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 3639,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә

кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан р-ны үзәге, 1959 ның 12 октябреннән — яңадан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 1829, 1910 да — 3439, 1920 дә — 2713, 1926 да — 3564, 1938 дә — 3063, 1949 да — 2775, 1958 дә — 2933, 1970 тә — 2097, 1979 да — 1818, 1989 да — 1446, 2002 дә — 1290 кеше. О.Т. авылы янында *Олы Тархан комплексы* урнашкан.

**ОЛЫ́ ТАРХА́Н АВЫЛЫ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1908 елның гыйнварында мохтаҗ диндәшләргә, мөселман мәдәният һәм мәгариф оешмаларына ярдәм итү максатыннан Сембер губернасы Олы Тархан авылында оештырыла. Башлап йөрүчеләре: Ш.Вәлитов, Ш.Гафаров, И.Ибраһимов, Г.Хәкимов, М.Хәкимов. Эшчәнлеге 1917 елдан соң туктатыла.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**ОЛЫ́ ТАРХА́Н КАБЕРЛЕГЕ́** (археол.), Тәтеш р-нының Олы Тархан авылы янында урнашкан, 8 йөзнең 2 нче яртысы — 9 йөз археол. истәлеге. 1939–41 елларда ачыла, 1950,



Олы Тархан каберлеге. Һөнәрче түгәрәгендә эшләнгән Салтау керамикасы. Казан ун-ты Археология музее фондлары.

1957, 1960 та А.Х.Халиков һәм В.Ф.Генинг тарафыннан тикшерелә. *Олы Тархан комплексы* составына керә. 2 мәҗүси каберлектән тора. Аларның беренчесендә 360 тан артык кабер, икенчесендә ярымҗимерек өч кабер тикшерелә. Мәетләр башлары б-н төньякка юнәлтеп җирләнгән, яннарына әйберләр (балчык савытлар, сугыш һәм хезмәт кораллары — садаклар, җәяләр, ук һәм сөңге очлыклары, кылычлар; ат дирбиясе әйберләре — авызлыклар, өзәңгеләр, җиз аеллар; кием-салым һ.б.) куелган. Кайбер тикшеренүчеләр фаразлаганча, О.Т.к. каберләре Урта Идел буйларына 8 йөз ахырында килгән болгарларга нисбәтле, аларда Салтау-Маяк культурасының төп элементлары сакланган.



Олы Тархан каберлеге.
75 нче кабер: план һәм табылдыклар.

*Әд.:* Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964.

*Е.П.Казаков.*

**ОЛЫ́ ТАРХА́Н КО́МПЛЕКСЫ** (археол.), Тәтеш р-нының Олы Тархан авылы янында урнашкан. О.Т.к. археол. истәлекләре 1950 елларда А.Х.Халиков, В.Ф.Генинг тарафыннан тикшерелә. Бронза дәвер туктаулыгын, Имәнкискә һәм Болгар археол. культураларына караган шәһәрлекне, 7 авыллыкны, әлгәрге болгарларга нисбәтле 2 каберлекне (к. *Олы Тархан каберлеге*), 14 йөз кабер ташлары сакланган мөселман зиратын («Ташбилге» буларак мәгълүм) һ.б.ны үз эченә ала. О.Т.к. терр-ясендә хезмәт һәм сугыш кораллары, балчык савытлар, пыяла әйберләр (муенсалар һ.б.), хайван сөякләре һ.б. табыла.

*Әд.:* Генинг В.Ф., Халиков А.Х. Ранние болгары на Волге. М., 1964; Археологическая карта Татарской АССР. Предволжье. К., 1985.

**ОЛЫ́ ТАРХА́Н РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1938 елның 4 августында оештырыла. Үзәге — Олы Тархан авылы. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязендә һәм Казан губернасының Тәтеш өязендә, 1920–27 дә — ТАССРның Буа һәм Тәтеш, 1927–30 да Буа кантонында, 1930–38 дә Тәтеш һәм Будённый р-ннарында. 1940 та О.Т.р.ның мәйданы — 770 *км*², халкы — 33,3 мең кеше, 23 авыл советы, 54 торак пункты була. 1956 да район 768,9 *км*² җир били, аңа 19 авыл советы, 52 торак пункт керә. 1959 ның 12 октябрендә таркатыла, биләмәсе Тәтеш р-нына бирелә.

**ОЛЫ́ ТӘРБИ́Т** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 38 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 608 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Т.тә Троица чиркәве, 2 чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете була; сишәмбе көннәрендә базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1911 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Кошелеев волостенда, 1920–21 дә Чуаш автономияле өлкәсе составында, 1921 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 14 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 205 ир-ат; 1859 да — 542, 1897 дә — 901, 1908 дә — 1062, 1920 дә — 1124, 1926 да — 1237, 1938 дә — 1225, 1949 да — 883, 1958 дә — 769, 1970 тә — 869, 1989 да — 569, 2002 дә — 547 кеше.

**ОЛЫ́ ТИЛӘҖЕ́** авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 11 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 242 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Т.дә мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу елларда авыл җәмәгатенең имана җире 1206,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 487, 1897 дә — 749, 1908 дә — 734, 1920 дә — 790, 1926 да — 637, 1938 дә — 627, 1949 да — 489, 1970 тә — 366, 1979 да — 312, 1989 да — 238, 2002 дә — 230 кеше.

**ОЛЫ́ ТИЛЧӘ́** елгасы, Идел алдында, Чилчә елгасының (Зөя елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 33 *км*, бассейнының мәйданы 151,4 *км*². Елга башы Яңа Чынлы авылыннан көнбатыштарак, тамагы Канау авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Шәйморза авылына кадәр, О.Т. 9 *км* озынлыкта Буа һәм Чүпрәле р-ннары адм. чикләре буйлап ага. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре юк. О.Т.нең 2,4 һәм 7,2 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,28 *км/км*². Күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 52 *мм*, ташу вакытында су катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. О.Т. бассейнында су күләме 0,5 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. О.Т.бассейнында ТРның табигать истәлеге *Яңа Тинчәле сөркә (байбак) колониясе* билгеләнгән.

**ОЛЫ́ ТОРМЫ́** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәтеш–Апас автомобиль юлы буенда. 2010 елда 380 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-

лек асрау б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Т.да мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1778,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 207 ир-ат; 1859 да — 823, 1897 дә — 1138, 1908 дә — 1502, 1920 дә — 1305, 1926 да — 808, 1938 дә — 772, 1949 да — 570, 1958 дә — 521, 1970 тә — 551, 1979 да — 517, 1989 да — 392, 2002 дә — 401 кеше.

**ОЛЫ́ УКМА́С** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 17 *км* төньяктарак, Укмас елгасы буенда. 2010 елда 121 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.У.та мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, тегермән, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 426,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1944 нең 19 февраленнән — Солтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 358, 1897 дә — 259, 1908 дә — 357, 1920 дә — 215, 1926 да — 349, 1949 да — 296, 1958 дә — 327, 1970 тә — 318, 1989 да — 238, 2002 дә — 147 кеше.

*Әд.:* Малов Е. Село Бетьки. К., 1868.

**ОЛЫ́ УЛУ́Й РАЙОНЫ́**, Красноярск краеның көньягында урнашкан. Үзәге — Олы Улуй авылы (Красноярскидан 227 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 7800 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 елда — 503, 1970 тә — 510, 1979 да — 414, 1989 да — 254, 2000 дә — 234, 2010 да —188 кеше. О.У.р. терр-яләренә татарлар (Чулым татарлары) элекке заманнардан ук килеп урнашалар. 19 йөз ахырында Транссебер тимер юл магистрале төзелү уңаеннан Россиянең үзәк өлешеннән монда татарлар күчеп килә. 1926 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, алар районның 5 торак пунктында: Олы Улуй, Берёзовка, Кумыры, Баженовка, Сучково авылларында яшиләр. 1929 да Елга авылына нигез салына һәм тирә-як авыллардан татарлар шунда күченә. 1930–50 елларда җирле мәктәптә укыту татар телендә алып барыла, 1990 еллардан татар теле фән буларак укытыла. 1979 дан авыл клубы каршында «Идел» милли фольклор төркеме эшли. Сабан туе бәйрәме үткәрелә.

*Әд.:* Усков В.В. Мы — большеулуйцы. Зеленогорск, 2000.

**ОЛЫ́ УРДА́** (Олуг Олыс, Бөек Урда), татар ханлыгы. 15 йөзнең 30 елларында Алтын Урданың таркалу чорында Кара диңгез алды далаларында — Идел б-н Днепр елгалары арасында барлыкка килә. Ул асылда Алтын Урданың дәвамчысы булып тора. Башкаласы — Сарай әл-Җәдид. Төп халкы — татарлар. Ханлыкта яшәүчеләр күчмә терлекчелек, игенчелек б-н шөгыльләнәләр, Урта Азия, Кавказ арты, шәркый гарәп илләре һ.б. мәмләкәтләр б-н сәүдә итәләр. Халык аксөякләр (*солтан, әмир, бәк, морза* һ.б.) һәм ясаклылар (*кара халык*) катлауларына бүленә. Ханлыкның адм.-терр. төзелеше һәм хакимият органнары структурасы Алтын Урда дәүләтендәге тәртипләргә нигезләнә. О.У. хакиме — хан, ул хан диванына кертелгән *карачыбәкләр* аркылы идарә итә. Гаскәр башлыклары, дәүләт хезмәтендәге түрәләр, ш.у. дин әһелләре зур булмаган биләмәләргә ия булалар, хезмәтләреннән беркадәр керем алалар. Дәүләт дине — ислам. Ханлыкның беренче идарәчесе — *Сәед Әхмәд хан*. 15 йөзнең 2 нче яртысында О.У. Көнчыгыш Европада әһәмиятле сәяси роль уйнаучы көчле дәүләткә әверелә. О.У. ханнары актив тышкы сәясәт алып баралар. Русь һәм Кырым дәүләтләренә каршы көрәшү максатыннан Бөек Литва кенәзлеге (1472) һәм Төркия (1476) б-н дипломатик мөнәсәбәтләр булдыралар. О.У. Әстерхан ханлыгында протекторат урнаштыра, Кырым ханлыгына бәреп керә, рус җирләренә яу чаба. *Әхмәд хан* идарә иткәндә О.У. иң югары күтәрелеш чорын кичерә. Хан дәүләткә Алтын Урда дәрәҗәсен кайтарырга, рус кенәзләреннән Урдага ясак түләттерергә омтыла (к. «*Угра буендагы капма-каршы тору*»). Далада хакимлек итү өчен Мәскәү кенәзлеге һәм Кырым ханлыгы б-н барган көрәштә О.У. җиңелә; 1491 елда (*Шәех Әхмәд хан* чорында) Кырым ханы Миңлегәрәй ханлыкны тар-мар итә, 1502 дә О.У.ны мөстәкыйль дәүләт буларак юкка чыгара.

Ханнары: Сәед Әхмәд (1430 еллар — 1460 еллар башы), Әхмәд (1460 еллар башы — 1481), Шәех Әхмәд (1481–1500 еллар башы).

*Әд.:* Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

*И.Л.Измайлов.*

**ОЛЫ́ УРСА́К** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 16 *км* көнчыгыштарак, Имәнле елгасы буенда. 2010 елда 360 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.У.та мәчет була. 20 йөз башында 2 мәчет, Халык мәгарифе министрлыгының рус-татар уч-щесе, җил һәм 2 су тегермәне, 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1943 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 177 ир-ат; 1859 да — 1166, 1897 дә — 1993, 1908 дә — 2262, 1920 дә — 1791, 1926 да — 1225, 1938 дә — 1417, 1949 да — 877, 1958 дә — 818, 1970 тә — 938, 1979 да — 754, 1989 да — 456, 2002 дә — 426 кеше.

**ОЛЫ́ ХОДЯ́Ш** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 13 *км* көньяктарак, Ульянов — Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 314 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ходяш исеме б-н дә билгеле. 1764 кә кадәр авыл Зөя Успение монастыре карамагында, соңрак халкы дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1729 да О.Х.та Спас чиркәве төзелә. 20 йөз башында 11 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1548 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ширдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 347 ир-ат; 1859 да — 753, 1897 дә — 1264, 1908 дә — 1351, 1920 дә — 1312, 1926 да — 1384, 1938 дә — 1361, 1949 да — 706, 1958 дә — 668, 1970 тә — 509, 1979 да — 330, 1989 да — 380, 2002 дә — 367 кеше.

**ОЛЫ́ ЧАКМА́К** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 11 *км* көньяктарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 493 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1795 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Чакмак исеме б-н дә билгеле. 18 йөз ахырында — 19 йөздә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ч.та 2 мәчет, мәктәп һәм мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 5204 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Шуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 828, 1897 дә — 1483, 1920 дә — 1799, 1926 да — 1166, 1938 дә — 1172, 1949 да — 877, 1958 дә — 675, 1970 тә — 758, 1979 да — 668, 1989 да — 516, 2002 дә — 502 кеше.

**ОЛЫ́ ЧИРМЕШӘ́Н** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 336 *км* (ТР чикләрендә 160 *км*), бассейнының мәйданы 11500 *км*². Елга башы Самара өлкәсе терр-ясендә, тамагы Ульянов өлкәсе терр-ясендә Димитровград шәһәре янында. ТР терр-ясендә Нурлат һәм Чирмешән р-нлары буйлап ага. Елга башының абс. биеклеге 237 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. О.Ч.нең су җыелу мәйданы ерым һәм сызалар б-н ергаланган, дулкынсыман, урыны б-н калкулыклы тигезлек. Су җыелу мәй-

данының урманлылыгы 25%. О.Ч.нең 78 кушылдыгы бар, иң зурлары: Кече Чирмешән (188 *км*), Олы Сөлчә (117 *км*), Тимерлек (33 *км*), Сәләнгеш (21 *км*), Киекле (25 *км*), Шарла (20 *км*) — уң кушылдыклар; Чаллы (29 *км*), Аксумла (12,3 *км*), Аксумла (Аксумлинка, 22,4 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,21 $км/км^2$. О.Ч.нең үзәне асимметрияле, уңъяк сөзәклекләре текәрәк, киңлеге югары агымда 1–3 *км* дан урта агымында 6–8 *км* га кадәр. Тугае ике яклы, тигез түгел, киңлеге югары агымда 1–1,5 *км* дан уртада — 3–4 *км* га һәм түбән агымында 7 *км* га кадәр. Елга юлы бормалы, киңлеге югары агымда 8–12 *м* дан түбән агымында 100 *м* га кадәр. Плёсларда өстенлек итүче тирәнлекләр 2–4 *м* һәм перекатларда — 0,5–0,7 *м*. Күп кенә урыннарда ярлары өзек-өзек текә, 1–3 *м* биеклектә. Елга төбе комсу-балчыксыл, урыны б-н комсу-чуерташлы. Перекатларда агым тизлеге 0,5–0,8 *м/с*, плёсларда 0,1–0,2 *м/с*. 1933–43 елларда елга режимы Нурлат р-ны Салдакай авылы янында су үлчәгеч постта өйрәнелә. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбе-



Олы Чирмешән елгасы, Нурлат районында.

нә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–3 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу вакытында еллык агымның 80% ка кадәрге өлеше туры килә. Салдакай авылы янында су биеклегенең уртача еллык тирбәнешләре 4,7 *м* (иң зуры 6 *м*) тәшкил итә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 125 *мм*, ташу вакытында су катламы 87 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 60 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 2,42 $м^3/с$, Чирмешән р-нында (Самара өлкәсе б-н чиктә) — 0,685 $м^3/с$, Нурлат р-нында (Ульянов өлкәсе б-н чиктә) — 1,451 $м^3/с$. 1979 ның язында Новочеремшанск шәһәре (Ульянов өлкәсе) янында иң зур су чыгымы (1660 $м^3/с$) билгеләнә. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийле, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9 *мг-экв/л* дан күбрәк). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 600–800 *мг/л* га кадәр. Димитровград шәһәре янында йөзмә китерелмәләрнең уртача еллык агымы 22,3 *кг/с*. Суының уртача болганчыклыгы 215 $г/м^3$. О.Ч. бассейнында су күләме 38 млн. $м^3$ булган 53 буа бар. Су ресурслары сугару өчен һәм хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла. О.Ч. кушылдыклары — Кече Чирмешән һәм Олы Сөлчә — ТР-ның табигать истәлекләре (1978). О.Ч. бассейнында *Биләр аучылык тыюлыгы* һәм *Биләр тарих, археология һәм табигать музей-саклаулыгы* урнашкан.

**ОЛЫ́ ЧИШМӘЛЕ́ КҮЛ**, Көнчыгыш Кама алдында, элеккеге су юлында сакланып калган күл. Кама һәм Иске Кама кушылдыгы б-н хасил булган Котловка утравында урнашкан, Алабуга р-ны Котловка авылыннан 1,9 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Чишмәле, Култык күлләреннән тора. Су өслегенең гомуми мәйданы 73,48 *га*. Озынлыгы 3140 *м*, иң зур киңлеге 300 *м*.

**ОЛЫ́ ШАҺИЯ́Н** елгасы, Идел алдында, Коры Үләмә елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 14 *км*, бассейнының мәйданы 94 $км^2$. Елга башы Апас р-ны Кече Болгаер авылыннан 4,8 *км* көньяктарак, тамагы Кама Тамагы р-ны Бишалаб авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 178 *м*, тамагыныкы — 76 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. О.Ш.ның 1,7 дән 9,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,33 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,025 $м^3/с$. О.Ш. бассейнында су күләме 1,2 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОЛЫ́ ШӘМӘ́К** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тормы елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 603 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Идел буе Болгар дәүләте чорыннан ук хәзерге О.Ш. урынында авыллар була. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кошки, Шонгыт исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Ш.тә волость идарәсе урнаша, чиркәү, земство мәктәбе, кредит ширкәте, тимерчелек, 4 җил тегермәне, казна шәраб һәм 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2862,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 232 ир-ат; 1859 да — 1033, 1897 дә — 1868, 1908 дә — 2356, 1920 дә — 2239, 1926 да — 1660, 1938 дә — 1540, 1958 дә — 1425, 1970 тә — 1371, 1979 да — 1075, 1989 да — 671, 2002 дә — 664 кеше.

**ОЛЫ́ ШИЛНӘ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шилнә елгасы буенда. 2010 елда 588 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында авыл янында Шильвинский бакыр кою з-ды эшли. 1823 тә О.Ш.дә Троица чиркәве төзелә (1993 тә яңадан эшли башлый; архит-ра истәлеге). 20 йөз башында земство уч-щесе, икмәк саклау-сату кибете, су тегермәне, 3 бакалея кибете була. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Макарий волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән хәзерге Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 424 ир-ат; 1870 тә — 1212, 1897 дә — 1157, 1913 тә — 1356, 1926 да — 1269, 1949 да — 1218, 1958 дә — 742, 1970 тә — 698, 1989 да — 279, 2002 дә — 274 кеше.

**ОЛЫ́ ШҮРНӘ́К** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 471 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, читкә китеп эшли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Ш.тә тегермән була. 1880 елларда авыл җәмгатенең имана җире 3282,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 517, 1887 дә — 776, 1920 дә — 1016, 1926 да — 1024, 1949 да — 453, 1958 дә — 418, 1970 тә — 464, 1979 да — 112, 1989 да — 442, 2002 дә — 410 кеше.

**ОЛЫ́ ШЫҢА́Р** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 14 *км* көнбатыштарак. 2010 елда 440 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Ш.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, тимерчелек, су тегермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1472,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Са-

ба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 132 ир-ат; 1859 да — 850, 1897 дә — 871, 1908 дә — 997, 1920 дә — 1004, 1926 да — 958, 1938 дә — 883, 1949 да — 706, 1970 тә — 703, 1979 да — 601, 1989 да — 469, 2002 дә — 458 кеше.

**ОЛЫ́ ШЫРДА́Н** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 346 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Мәчет. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Ш.да мәчет була. 20 йөз башында мәктәп, 2 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 927 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 140 ир-ат; 1859 да — 866, 1897 дә — 1312, 1908 дә — 1447, 1926 да — 1666, 1938 дә — 1438, 1949 да — 967, 1958 дә — 908, 1970 тә — 803, 1979 да — 730, 1989 да — 406, 2002 дә — 380 кеше.

**ОЛЫ́ ЯКЛЫ́** елгасы, Идел алдында, Барыш елгасының (Сүрә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 55 *км* (ТР чикләрендә 20,1 *км*), бассейнының мәйданы 758 $км^2$ (ТР чикләрендә 312,1 $км^2$). Елга башы Чүпрәле р-ны Иске Чокалы авылының көнбатыш читендә, тамагы Ульянов өлкәсе терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. О.Я.ның 2 дән 18,7 *км* га кадәр озынлыкта 14 кушылдыгы бар, иң зурысы — Маклауш (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,18 *км/км*². О.Я.ның үзәне ачык беленә, ике бите дә сөзәк, ерым һәм сызалар б-н ергаланган. Күбесенчә кар сулары б-н туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,11–0,5 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Югары агымы җәен кибә. Елга бассейнында еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,235 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. О.Я. бассейнында суының гомуми күләме 0,98 млн. $м^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. О.Я. бассейнында ТРның табигать истәлеге *Кирәмәт* (*Яңа Чәке урман даласы*) билгеләнгән.

**ОЛЫ́ ЯЛА́Н** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 40 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алпавыт Желтухиннар крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.Я.да Покров чиркәве (1735 тә төзелә), земство мәктәбе (1884 тә ачыла), су һәм 2 җил тегермәне, 3 тимерчелек, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 881 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Черемыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 190, 1782 дә — 242 ир-ат; 1859 да — 589, 1897 дә — 560, 1908 дә — 610, 1920 дә — 749, 1926 да — 791, 1938 дә — 357, 1949 да — 266, 1958 дә — 217, 1970 тә — 59, 1989 да — 10, 2002 дә — 6 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ОЛЫ́ ЯҢАСАЛА́** авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Симгә елгасы буенда. 2010 елда 332 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз уртасында О.Я. авылыннан 21 гаилә Лаеш өязенең Мордва Чаллысы авылына күченә һәм Яңасала торак пунктын нигезли. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, О.Я.да мәчет була. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, мәдрәсәле 2 мәчет (икенчесе 1864 тә ачыла), 11 җил тегермәне, ярма яргыч, йон тетү йорты, тимерчелек, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2945,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Яңасала волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 341 ир-ат; 1859 да — 1308, 1884 тә — 1804, 1897 дә — 2077, 1908 дә — 2426, 1920 дә — 2354, 1926 да — 1885, 1938 дә — 1137, 1958 дә — 704, 1989 да — 382, 2002 дә — 343 кеше.

**ОЛЫ́С** (монгол. — дәүләт, халык, кешеләр), 1) Монгол дәүләте оешу чорында (13 йөз башы) феодалга (нойонга) буйсынган һәм аның җирләрендә күчмә тормыш алып барган гаиләләр яки кабиләләр төркеме; 2) Чыңгыз хан мәмләкәтендә гомумән Монгол дәүләте атамасы; 3) 13 йөзнең 2 нче яртысыннан Чыңгыз хан варисларына бүлеп бирелгән мөстәкыйль биләмәләр атамасы (Җүчи Олысы, Чагатай Олысы һ.б.). О. башында *олыс бәге* тора. Чыңгыз хан тарафыннан улы Җүчигә бирелгән җирләрдә *Алтын Урда* дәүләте (1269–1502) барлыкка килә, ул үз чиратында О.ларга бүленә.

*Әд.:* Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

**ОЛЫ́С БӘГЕ́**, хакимият, югары хәрби түрәлек дәрәҗәсе. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында аерым өлкә, олыс идарәчесе. 4 идарәче ыруг — *Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин* нәселләре олыс бәкләре *карачыбәк* дәрәҗәсендә хан диваны әгъзалары булганнар. 15 йөз башыннан олысның мөстәкыйль идарәчеләре. Соңрак шул олыслар җирлегендә мөстәкыйль *татар ханлыклары* барлыкка килә.

*Әд.:* Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

*И.Л.Измайлов.*

**ОЛЫЯ́З** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 27 *км* төньяктарак, Тож елгасы буенда. 2010 елда 147 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 дән Олыяз Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1879–80 дә төзелә), мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 506,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1859 да — 272, 1897 дә — 372, 1908 дә — 411, 1920 дә — 462, 1926 да — 470, 1938 дә — 400, 1949 да — 318, 1958 дә — 237, 1970 тә — 198, 1989 да — 139, 2002 дә — 145 кеше.

**ОЛЫЯ́З** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 840 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Науз Нурма, Ульяз буларак та телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 1670,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Кошки волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 1464, 1920 дә — 1421, 1926 да — 1190, 1938 дә — 1150, 1949 да — 1244, 1958 дә — 953, 1970 тә — 1069, 1979 да — 1042, 1989 да — 803, 2002 дә — 873 кеше.

**ОЛЫЯ́З** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 587 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Макарон цехы. Авыл хуҗалыгы лицее, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710–11 еллардан Большое Поле исе-

ме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Улуяс буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тегермән, ярма яргыч, йон-тукыма ману йорты, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1423,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 664, 1897 дә — 926, 1908 дә — 1105, 1920 дә — 969, 1926 да — 840, 1949 да — 616, 1958 дә — 534, 1970 тә — 700, 1979 да — 635, 1989 да — 579, 2002 дә — 575 кеше.

**ОЛЫЯ́З** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 16 *км* төньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 326 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1678 дән Зур Шикша буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1038,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1924 тән Арча кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1859 да — 518, 1897 дә — 671, 1908 дә — 847, 1920 дә — 768, 1926 да — 683, 1938 дә — 817, 1949 да — 562, 1970 тә — 394, 1979 да — 369, 1989 да — 314, 2002 дә — 333 кеше.

**О́ЛЬГИНО** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 10 *км* көнчыгыштарак, Казанчы елгасы буенда. 2010 елда 78 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Беренче исеме — Иштирәк. 1740–50 елларда бу җирләрне Иректе волосте асабалары Казан сәүдәгәре Семён Иноземцевка сата, анда ул Иштирәк бакыр кою з-дын төзеп эшләтә башлый (1751). Заводта төп эшче көчләр булып төрле җирләрдән Иштирәккә күчерелгән крепостной крәстияннәр тора. 1773 нең декабрендә Е.И.Пугачёв отряды заводны җимерә, завод 1775 нең гыйнварында кабат эшли башлый. 1820 елларда пр-тиегә сәүдәгәр М.Ярцев, 1840 ларда подполковник хатыны Ольга Ивановна Берг (торак пунктның хәзерге атамасы аның исеме б-н бәйле) хуҗа була. Завод ябылганнан соң (1851), халык игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү, көпчәк ясау, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да кәшәнә, чиркәү-приход мәктәбе, 2 су тегермәне, аракы з-ды, 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1038,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1795 тә — 238 ир-ат; 1870 тә — 1089, 1897 дә — 921, 1920 дә — 950, 1926 да — 870, 1938 дә — 637, 1949 да — 601, 1958 дә — 311, 1970 тә — 225, 1979 да — 154, 1989 да — 112, 2002 дә — 86 кеше.

**ОЛЬКЕНИ́ЦКИЙ** Гирш Шмулевич (17.9.1893, Вильно губ., Лида ш. — 23.6.1918, Казан губ., Казан өязе Займище а.), революция хәрәкәтендә катнашучы. 1912 елда Уфага килә, гимназия тәмамлый (1914). Петроград психоневрология ин-тында (1914–15), Казан ун-тында (1915–16) укый. РСДРП әгъзасы (1915). Казан ун-ты каршындагы студент с.-д. оешмасы Уставы авторларының берсе. Уставта яшерен оешма булдыру, студентлар һәм эшчеләр арасында марксистик идеяләр тарату, «яшәп килгән стройны җимерергә» омтылган башка студент оешмалары б-н элемтәләр урнаштыру турында белдерелә. Казанда И.Н.*Волков* б-н берлектә массачыл студентлар оешмасын — Коалицион ком-т оештыра. 1916 ның июль аенда революцион пропаганда алып барган өчен кулга алына һәм Чистай шәһәренә сөрелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Казанга кире кайта. РСДРП(б)ның Казан ком-тына сайлана; 1917 нең март–август айларында «Рабочий» г-тасы редколлегиясе әгъзасы. Ком-т рәисе В.А.Тихомирнов Казаннан киткәч, РСДРП(б)ның Казан оешмасын җитәкли. 1917 нең октябрендә Казанда кораллы восстание җитәкчеләреннән берсе. 1917 нең ноябреннән Эшче, крәстиян, солдат депутатларының Казан Советында тикшерүләр комиссиясе рәисе, 1918 нең гыйнварыннан Казан губернасының Гадәттән тыш комиссиясе рәисе. Бер үк вакытта РКП(б)ның Казан ком-ты секретаре. Займище авылында кораллы талаучылар кулыннан һәлак була.

*Әд.:* Литвин А.Л. Гирш Ольկеницкий. К., 1976.

**ОМА́Р** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 34,9 *км*, бассейнының мәйданы 361,6 *км*$^2$. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Яке авылыннан 3,8 *км* төньяктарак, тамагы Омар авылыннан көньяктарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы астында калган. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. О.ның 0,6 дан 36,3 *км* га кадәр озынлыктагы 15 кушылдыгы бар, иң зурлары Кирмән (36,3 *км*), Дегетле (9,5 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 5–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык сагаюы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 160 *мм*, ташу вакытында су катламы 91 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,85 *м*$^3$*/с*. Суы язын йомшактан (1,5–3 *мг-экв/л*) чагыштырмача катыга кадәр (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. О. бассейнында суның гомуми күләме 1,7 млн. *м*$^3$ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОМА́Р** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Омар елгасы буенда. 2010 елда 414 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Благовещенский исеме б-н дә билгеле. Башта Казан *Архиерей йортыныкы* була. 1764 тә халкы экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, бакчачылык, агач материаллары хәзерләү, мичкә ясау, балта эше һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 1843 тә Дәүләт милке министрлыгының приход уч-щесе ачыла, 1873 тә аның җирлегендә Халык мәгарифе министрлыгының кыз балалар земство мәктәбе һәм ир балалар уч-щесе ачыла. 20 йөз башында авылда волость идарәсе, этап йорты урнаша; Благовещение чиркәве (1753 тә төзелә; архит-ра истәлеге), мед. һәм вет. фельдшерлык пунктлары, тегермән, 3 тимерчелек, 2 постау басу һәм 2 йон-тукыма ману бинасы, 1 казна шәраб һәм 12 вак-төякләр кибете, 2 сырыханә, чәйханә була; дүшәмбе саен базар һәм 2 ярминкә: Ивановкада (24 июнь) һәм Ильинкада (20 июль) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7554,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр О. — Казан губернасының Мамадыш өязе Омар (Благовещение) волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 1059 ир-ат; 1834 тә — 2833, 1850 дә — 2640, 1859 да — 2935, 1897 дә — 2875, 1908 дә — 2987, 1920 дә — 2777, 1926 да — 2232, 1938 дә — 1329, 1949 да — 692, 1958 дә — 804, 1970 тә — 770, 1979 да — 685, 1989 да — 595, 2002 дә — 488 кеше.

**ОМА́Р ПҮЧИНКӘСЕ́** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәренән 28 *км* көньяк-көнбатыштарак, Омар елгасы буенда. 2010 елда 73 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1652 дән Зур Пүчинкә исеме б-н мәгълүм. Башта Казан *Архиерей йорты* карамагында була. 1764 тә халкы экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.П.ндә земство мәктәбе (1893 тә ачыла), кредит ширкәте, йон-тукыма ману йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3432,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 354 ир-ат; 1859 да — 1044, 1897 дә — 1113, 1908 дә — 1273, 1920 дә —

1301, 1926 да — 1171, 1938 дә — 765, 1949 да — 378, 1958 дә — 297, 1970 тә — 267, 1979 да — 236, 1989 да — 182, 2002 дә — 99 кеше.

**ОМО́НИМНАР** (грек. homós — бертөрле һәм ónyma — исем), мәгънәләре ягыннан төрле, яңгырашлары һәм язылышлары ягыннан бертөрле сүзләр. Татар телендә дә, башка телләрдәге кебек үк, тулы (лексик) һәм өлешчә (омографлар, омофоннар, омоформалар) омонимияне аерып карыйлар. Телдә лексик О. барлыкка килүнең сәбәпләре төрле. Аеруча еш очрый торганы — күпмәгънәле сүзләргә хас булган мәгънәләр арасындагы бәйләнешнең юкка чыгуы: бит (кеше бите) — бит (китап бите) — бит (кисәкчә); кыл (уен коралы кылы) — кыл (хайваннардагы кыл). О.ның мәгънәсе (күпмәгънәле сүзләрдәге кебек) контексттан чыгып билгеләнә. Омографлар — язылышлары бертөрле, әйтелешләрендә аерма булган сүзләр. Аларның барлыкка килүе башка телләрдән яңа сүзләр керү хисабына, ягъни алынма сүзләр аваздашлыгы нәтиҗәсендә булырга мөмкин: бал (ашамлык) — бал (биюле кичә), шик (хис, кичереш мәгънәсендә) — шик (купшылык, зиннәтлелек). Омофоннар — әйтелешләре бертөрле, язылышлары төрле булган сүзләр: мәс., картаю — карт аю, Айтуган — ай туган, кызарган — кыз арган һ.б. Омоформалар — билгеле бер грамматик формада гына охшаш яңгырашка ия булган сүзләр: мәс., үпкәләр (күплек сандагы исем) — үпкәләр (күңеле калыр мәгънәсендәге фигыль).

*Әд.:* Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. К., 1999; Зәкиев М.З., Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

**ОМОРО́КОВ** Леонид Иванович (29.4.1881, Таврия губ., Бердянск өязе Каменка а. — 30.3.1971, Казан), невропатолог, медицина докторы (1911), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (1907), шунда эшкә калдырыла. Беренче бөтендөнья сугышы елларында фронт госпитале башлыгы. 1917 елдан Төмән ун-тының нерв авырулары каф. профессоры, Себердә беренче нерв авырулары кафедрасын оештыручы. 1936–67 дә Казан мед. ин-тының нерв авырулары каф. мөдире. Хезмәтләре эпилепсия авыруы патогенезына һәм аны дәвалауга карый. О. нерв күзәнәкләрен ясалма тирәлектә үстерү буенча махсус методика эшли. Эпилепсиянең үзгә төрен — Бехтерев «хореик өянәге»нең патоморфологик субстратын ачыклый. Себердә Кожевников эпилепсиясен өйрәнүгә багышланган хезмәтләре б-н дөньяга танылa. Георгий хачы, Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Искусственное выращивание нервной ткани вне организма. Томск, 1921; Курс нервных болезней. Общая часть. К., 1939; Введение в клиническую невропатологию. Томск, 1961.

*Әд.:* Попелянский Я.Ю. Профессор Л.И.Омороков // Казан. мед. журн. 1981. № 5.

**ОМСК ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Мәйданы — 139,7 мең *км²*. Халкы — 1973985 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 тә — 44328, 1979 да — 46712, 1989 да — 49784, 2002 дә — 47796, 2010 да — 41870 кеше. Үзәге — Омск шәһәре. Төп халкы — Себер татарлары. Урта гасырларда О.ө. терр-ясе *Җучи олысы*, *Себер ханлыгы* составына керә, Идел-Урал буе татарлары бу җирләргә Алтын Урда чорында урнаша башлыйлар. Казан ханлыгы яулангач, күчеп килүчеләр күпкә арта. Тарихи чыганакларга караганда, 1594 елда Тара шәһәрен төзүдә Казан һәм Зөя татарлары катнаша. 17 йөздә Көнбатыш Себердә Казан татарлары авыллары барлыкка килә. О.ө. терр-ясенә халык күпләп 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында күченә, бу — төбәкне үзләштерү б-н бәйле. 1908 дә Тара өязендә генә дә 15452 татар исәпләнә. 1919–21 дә Омскида — «*Азат Себер*», 1919 да — «Хакыйкать», 1920 дә — «Кызыл Шәрекъ яшьләре», 1936 ел — 1940 елларның 1 нче яртысында «Сталин юлы» г-талары нәшер ителә. Хәзерге вакытта татарлар тупланып О.ө.нең төньяк р-ннарында: Большеречье (3828 кеше; халыкның 11,2%), Знаменское (847 кеше; 6,1%), Колосовка (948 кеше; 6%), Муромцево, Седельниково, Тара (3921 кеше; 7,9%), Тевриз (4063 кеше; 22,5%), Усть-Ишим (4174 кеше; 25,3%) р-ннарында яшиләр. Большеречье, Колосовка, Тара, Тевриз, Усть-Ишим р-ннарында һәм Омскида 21 мәктәптә татар теле өйрәнелә, Знаменское һәм Муромцево р-нның 2 мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла. 2002 дә Омск пед. көллиятендә татар теле укытучылары әзерләүче татар төркеме ачыла. Татарларның төбәк милли-мәдәни автономиясе (1998), Омск татар милли-мәдәни автономиясе (1997), «Әл-Вәһдәт» төрки яшьләр оешмасы (1997), «Фәния» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы (2002), «Ак калфак» мөселман мәдәни үзәге (1996), Мөселман аксакаллар шурасы (1997), О.ө. төрки халыклар һәм мөселман милли-мәдәни үзәге (1998) эшли. 2002 гә кадәр Омск Дуслык йорты җирлегендә татар халкының телен, тарихын, мәдәниятен өйрәнү курслары эшли. Омск милли-мәдәни автономиясе каршында «Туган тел» мәгариф, «Изгелек» социаль эшләр бүлекләре; үзешчән сәнгать коллективлары; «Көмеш энә» кул эшләре түгәрәге; Г.Тукай исем. театр клубы эшли. 1998 дән «Бердәмлек» өлкә милли мәдәният фестивале үткәрелә. О.ө.ндә татар бәйрәмнәре: Тара шәһәрендә (1998 дән), Большеречье р-нының Үләнкүл (2001) һәм Усть-Ишим (1999 да һәм 2005 тән) авылларында, шәһәр тибындагы Тевриз посёлогында (2007 дән) *Сабан туен* бәйрәм итәләр; *Корбан бәйрәме*, *Нәүрүз* уздырыла; «Татар җыры» (1998 дән, 2 елга 1 тапкыр), «Себер моңы», «Яңа йолдыз» (2004 тән) конкурслары үткәрелә. 1989–2006 да «Иртыш» телерадиокомпаниясе «Сәлам» радиотапшыруын, 1994–97 дә татар телендә «Очрашу» телетапшыруын алып бара; 2003 нең декабреннән айга 1 тапкыр «Татар дөньясы» г-тасы чыга. Россия а.х. ФАнең мөхбир әгъзасы К.Г.*Азиевның*, мед. фән. д-ры Р.Г.*Бакыеваның*, геогр. фән. д-ры Ә.Г.*Мусинның*, СССРның атказ. спорт остасы Г.Ә.*Шөгеровaның*, тарих фән. д-ры З.Ш.*Янгузовның*, фольклорчы С.М.*Зәйнетдиновның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге О.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* Файзрахманов Г.Л. История татар Западной Сибири: С древнейших времён до начала XX века. К., 2007.

**О́МСКИДАГЫ А́ЗИЯ ТЫЛМАЧЛА́Р МӘКТӘБЕ́**, 1789 елда Себер саклану сызыгының Чик буе идарәсе каршында ачыла, 1808 дән яңа оешкан Себер казак гаскәре карамагына күчерелә. 1836 да мөстәкыйль уку йорты буларак ябыла, укытучылары һәм укучылары Себер казак гаскәренең Омск уч-щесенә (1866 дан — казак хәрби прогимназиясе) күчерелә, анда тылмачлар бүлеге 1871 гә кадәр эшли. Бу кечкенә мәктәптә татар һәм монгол-маньчжур (1826 га кадәр) бүлекләре эшли. Аңа башлангыч белемле укучылар кабул ителә (1808 дән — Себер казаклары һәм мөселман түрәләренең балалары гына); уку вакыты 4 ел. Ел саен мәктәпне тәмамлаган 6–8 кешегә коллегия теркәүчесе яисә хорунжий чины бирелә, һәм алар — Себернең дәүләт оешмаларына һәм хәрби частьларына хезмәткә, иң яхшылары, 1808–35 елларда, укуларын дәвам итәр өчен Казан гимназиясенә җибәрелә.

*Әд.:* Веселовский Н.И. Сведения об официальном преподавании восточных языков в России // Тр. 3 междунар. съезда ориенталистов в С.-Петербурге. СПб., 1879–80. Т. 1; Из истории Омска (1716–1917 гг.). Омск, 1967; Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982.

**ОН КОҢГЫЗЛАРЫ́**, кара коңгызлар семьялыгыннан Tenebrio һәм Tribolium ыруглары коңгызлары. Киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә зур О.к. (Tenebrio molitor) һәм кечкенә О.к. (Tribolium confusum) бар. Зур О.к.ның озынлыгы 12–16 *мм*, кара яки көрән төстә, сасы исле. Йортларда һәм складларда онда, икмәк ризыкларында, көрпәдә, сиркәнә туфракта һәм чери торган үзагачта яши. Личинкалары (ашлык кортлары) ачык сары төстә. Кечкенә О.к. 3–4 *мм* озынлыкта, кызыл-җирән төстә. Җылы биналарда елына берничә буын бирә. Он, икмәк ризыкларын ярма, борчак, тәмәкене зарарлыйлар.

**ОНДА́ТРА**, мускуслы күсе (Ondatra zibethicus), кыр тычканнары ассемьялыгыннан имезүче җәнлек. Табигый ареалы Төньяк Американың төньяк һәм үзәк өлешен били. Евразия климатына яраклаштырыла. Татарстанда беренче тапкыр 1944 елда — Көләгеш сазлыгына (Актаныш һәм Минзәлә р-ннары), 1947 дә Кама елгасы тугаена (Алексеев р-ны) җибәрелә; хәзерге вакытта барлык районнарда да яши. Гәүдәсенең озынлыгы 30–36 *см*, койрыгы 28 *см* га кадәр; авырлыгы 1,2–1,5 *кг*. Зур гәүдәле, танавы җаенке,



колаклары бөтенләй диярлек күренми. Койрыгы ян-яктан кысылган һәм вак мөгезләч тәңкәләр б-н капланган, алар арасында кыска сирәк төкләр бар. Йон капламы куе, озын, ялтыравыклы, җиңелчә юешләнеп тора. Мехының төсе көрәннән (кайвакыт җирән төсмерле) кара төскә кадәр. Аяклары кыска, зур киң табанлы. Арткы аяк бармаклары йөзү ярылары б-н тоташкан. Тәпие каты төкләр б-н каймаланган. Куышу чорында ата затларның касык бизләре көчле исле матдә — мускус бүлеп чыгара. О. җир-су хайваны, яхшы йөзә. Төрле сулык, ш.и. ясалма буа һәм сугару каналлары ярлары буенда оялый. Өннәрдә яши. Эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Парлашуы апрельдә, буазлык чоры якынча 25 көн. Ана зат бер җәйдә 1–3 тапкыр 4–13 әр бала китерә. Җенси яктан 5–7 айда өлгерә. Су үсемлекләре (җикәнбаш, курак, камыш, кондыз үләне, укъяфрак) ш.у. моллюсклар, бакалар, вак балыклар б-н туклана. Түләрәмә һәм паратиф авыруларын йоктыручы булырга мөмкин. Якынча 10 ел яши.

**ОНЕ́ГОВ** Алексей Петрович (30.3.1907, Вятка губ., Малмыж өязе Сухарек а. — 4.7.1988, Казан), зоогигиена белгече, вет. фән. д-ры (1946), проф. (1946), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1973). Казан вет. ин-тын тәмамлый (1929). 1929–31 елларда Минзәлә терлекчелек техникумы укытучысы һәм техникумның өйрәнү-тәҗрибә хуҗалыгында вет. табибе. 1931–33 тә Казан вет. ин-тының зоогигиена кафедрасында. 1933–39 да Белорус фәнни-тикшеренү ин-тында (Витебск ш.) зоогигиена һәм вет. санитариясе бүлеге мөдире. 1939–41 дә Витебск вет. ин-тының зоогигиена каф. мөдире. 1941–1964 тә Киров а.х. ин-тының зоогигиена каф. мөдире, бер үк вакытта зоотехния ф-ты деканы (1946–50), директор урынбасары (1950–54). 1964–84 тә Казан вет. ин-тының зоогигиена кафедрасында, 1964–77 дә — каф. мөдире. Фәнни эзләнүләренең төп юнәлешләре: а.х. терлекләренең продуктлылыгын күтәрү һәм авыруларын кисәтүдә витаминнарның, макро- һәм микроэлементларның ролен өйрәнү, терлекчелек комплекслары һәм кошчылык ф-калары өчен зоогигиена һәм вет.-санитария кагыйдәләрен эшләү. Диетотерапия буенча тикшеренүләре ветеринариядә яңа юнәлешкә нигез була. О. — вет. һәм а.х. югары уку йортлары өчен язылган «Авыл хуҗалыгы терлекләре гигиенасы» («Гигиена сельскохозяйственных животных», 1963; 4 басма, 1984) дәреслеге авторларының берсе. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Практикум по гигиене сельскохозяйственных животных. М., 1964; Справочник по гигиене сельскохозяйственных животных. М., 1984.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

*В.Г.Софронов.*

**ОНКОЛО́ГИЯ** (грек. ónkos — масса, шеш һәм ...*логия*), мед. һәм биол. фәне; онкогенезның — организмдагы нормаль күзәнәкләрнең шешкә әверелү процессының — теоретик, эксперименталь һәм клиник аспектларын, шешләргә диагноз кую, аларны дәвалау ысулларын һәм кисәтү чараларын өйрәнә. О. өлкәсендәге үсеш табигыять фәннәре, теоретик һәм клиник дисциплиналарда ирешелгән уңышлар б-н турыдан-туры бәйле. Россиядә беренче булып, проф. Н.М.Любимов көчле лейкоз вакытында әгъзалардагы үзгәрешләргә бәяләмә бирә; Ф.Я.*Чистович* үпкә һәм бронхлар беренчел рагы гистогенезын һәм ангиосаркомаларны өйрәнә; И.П.*Васильев* плевра, баш мие шешләре һәм эксперименталь шешләрне дәвалау нәтиҗәләре турында хезмәтләр язып бастыра.

Казанда О.не фән буларак өйрәнә башлау иң беренче чиратта профессорлар Ю.А.*Ратнер* һәм М.З.*Сигал* исемнәре б-н бәйле. 1947 елда Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе) О. кафедрасы оештырыла (мөдире — Ю.А.Ратнер, 1967 дән — М.З.Сигал, 1985 тән — Р.М.Таҗиев, 2004 тән — Р.Ш.*Хәсәнов*). М.З.Сигал үңәч резекциясе, ашказаны һәм эчәк асептик электрохирургиясе, радикаль гастроэктомия очрагында ирекле тире пластикасы, ашказаны рагына операция вакытында трансиллюминация тикшерүләре методикаларын эшли; тире рагын дәвалауның радиохирургик ысулын тәкъдим итә (Г.И.*Володина* б-н берлектә); К.В.Кабанов б-н берлектә кабырга дугаларын киңәйтү-күтәртү җайланмасын конструкцияли (Сигал-Кабанов киңәйткече, 1959); ашказаны һәм туры эчәк рагы очрагында, илдә иң беренчеләрдән булып, киңәйтелгән лимфаденэктомия ясый башлый. 1965 тә Казан мед. академиясендә нур ярдәмендә диагноз кую кафедрасы оештырыла (мөдире Д.Е.Гольштейн, 1999 дан — М.К.*Михайлов*, кафедрада яман шешләргә нур ярдәмендә диагноз кую һәм яман шеш авыруларын (лимфогранулематоз, нейроэндокринологик авырулар һ.б.) дәвалау ысуллары камилләштерелә, ашказаны һәм туры эчәк рагы фармакорентгенологик юл б-н өйрәнелә. Онкогинекология өлкәсендәге тикшеренүләр Казан мед. академиясенең 2 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында, З.Ш.*Гыйләҗетдинова* һәм З.В.Мәулетова җитәкчелегендә алып барыла. 1975 тә Респ-ка онкология диспансерында онкогинекология бүлеге ачыла. Казан мед. ун-тының 1 нче хирургик авырулар кафедрасы (мөдире Ф.Ш.*Әхмәтҗанов*) О. курсында күкрәк рагы операцияләре вакытында әгъзаларны саклап калу, ш.и. ирекле тире пластикасы буенча фәнни тикшеренүләр алып барыла. 1970–90 елларда О. үсешенә Казан галимнәре Ә.С.*Абдуллин*, Б.Л.Еляшевич, А.П.Старостин зур өлеш кертә. Клиник О. өлкәсендәге уңышлар профессорлар Р.М.Таҗиев, Р.Ш.Хәсәнов, И.Г.Гатауллин, Ф.Ш.Әхмәтҗанов, И.Р.*Әһлиуллин*, В.П.*Потанин*, Е.И.*Сигал*, А.Х.Исмәгыйлев һ.б. исемнәре б-н бәйле. Казан онкологлары тарафыннан яман шешләрне хирургик юл б-н дәвалауның төрле методикалары эшләнә һәм камилләштерелә, ш.и. кече оча сөяге әгъзаларындагы яман шешләр эвисцерациясе; күкрәк куышлыгы һәм кече оча сөяге органнарындагы яман шешләрне эндохирургик һәм тораскопик ысуллар б-н дәвалау; ашказаны асты бизе рагы очрагында киңәйтелгән һәм комбинацияле панкреатик-дуоденаль резекцияләр; күкрәк һәм бугаз-йөткылык рагы очракларында пластик операцияләр; бронхлар, трахея, үңәч рагы очракларында брахитерапия; күкрәк рагы очрагында эчке тукымалар гамма-терапиясе һ.б. О.дә эндоскопик тикшеренүләр Б.К.Дружков һәм В.Ю.*Муравьёв* тарафыннан гамәлгә кертелә. Яман шеш авыруларына нур ярдәмендә диагноз кую һәм авыруларны нурлар б-н дәвалау; яман шешләрне (йомшак тукымалар саркомасы, күкрәк бизләре, үңәч шешләре) төрле ысуллар кулланып дәвалау; яман шешләргә радионуклид диагностикасы; үзара бәйләнештә булган әгъзаларны зарарлаган авырулар (система авырулары), сөяк һәм буын шешләре очракларында нур б-н диагноз куюның комплекслы ысулларын эшләү (М.И.Гольштейн, 1950 еллар; Г.И.Володина, 1970 еллар) ш.у. О.нең аерым юнәлешләрен тәшкил итә. Кешедә очрый торган яман шешләрне морфологик өйрәнүләр (макро- һәм микроскопик бәяләмә бирү) Казан мед. ун-тының патологик анатомия кафедрасында 1960 еллардан алып барыла. Шешләргә гистохимия ысулы б-н диагноз куела башлау да шул ук чорга карый (В.А.*Добрынин*, В.П.Нефёдов). 1996 дан ТРның Онкология клиник диспансерында С.В.*Петров* тарафыннан авыруга диагноз кую һәм авыру барышын фаразлау өчен шешле күзәнәкләрдәге аксым молекулаларына гистоцитохимик анализ ясау ысулы гамәлгә кертелә. Әлеге ысул шешләрнең морфологик верификациясе сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә. С.В.Петров редакциясендә рус телендәге бердәнбер фундаменталь хезмәт — «Шешләргә иммуногистохимик диагностика буенча кулланма» («Руководство по иммуногистохимической диагностике опухолей», 1998; 4 басма, 2012) нәшер ителә. 1995 тә халыкка О. ярдәме күрсәтү буенча координация советы булдырыла, респ-ка ракка каршы көрәш программасы кабул ителә, ТРның ракка каршы көрәш җәмгыяте оештырыла. ТРның О. хезмәте структурасын ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы *Республика онкология клиник диспансеры*, аның Чаллы шәһәрендәге ф-лы, Әлмәт шәһәрендәге О. поликлиникасы, поликлиникалардагы һәм Респ-ка клиник хастаханәсендәге 72 О. кабинеты тәшкил итә. Респ-ка онкология клиник диспансерында кешедәге яман шешкә иммуногистохимик юл б-н диагноз кую һәм респ-ка дәвалау учреждениеләрендә төшерелгән рентгеномаммограммаларга бәяләмә бирү максатыннан референц-үзәкләр эшли. 6 тапкыр Казанда, чит ил галимнәре катнашында, кешедәге яман шешкә иммуногистохимик юл б-н диагноз кую мәсьәләләренә багышланган Бөтенроссия укулары оештырыла, ел саен онкологиянең төрле юнәлешләре буенча халыкара дәрәҗәдәге конференцияләр үткәрелә. Онкологларның 5 нче Бөтенроссия съезды ш.у. Казанда уздырыла (2000).

*Әд.:* Основы теоретической онкологии. М., 1961; Г и л я з у т д и н о в И.А. Опухоли гипофиза. Л., 1982; Х а с а н о в Р.Ш. Злокачественные новообразования по Республике Татарстан в 1993–98 годах. К., 2000.

*И.А.Гыйләҗетдинов, Р.Ш.Хәсәнов.*

**ОНЛЫЧА́** (Chenopodium), алабутачалар семьялыгыннан бер-, ике-, сирәк кенә күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуаклар, кайвакыт куаклар яки агачлар. 200 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендә 16 төре бар. Күксел О. (C. glaucum), гибрид О. (C. hybridum), ак О. (C. album) һ.б. киң таралган. 10–100 *см* биеклектәге үсемлек. Яфраклары чиратлашкан, гади, күп төрләрендә озынча-йомыркасыман яки озынча түгәрәк. Чәчәкләре ике җенесле, яшькелт, себеркәч чәчәк төркеме хасил итүче йомгакларга җыелган. Җимешенең юка элпәле җимеш тирәлеге бар. Орлыклары вак, шома, кара. Сабагы һәм яфракларының аскы ягы онычыл кунык б-н капланган. Июнь–сентябрьдә чәчәк аталар. Орлыктан үрчиләр. Ак О., шәһәр О.сы (C. urbicum), күксел О. һ.б. авыл хуҗалыгы культуралары чәчүлекләрен чүпли. Үрчемлелеге б-н аерылалар — бер үсемлек 100 меңгә кадәр орлык бирергә мөмкин. Көрәш чаралары: орлыклык материалны чистарту, туфракны йомшартып туңга сөрү, тишемнәр чыккан вакытта чәчүлекләрне тырмалау. Гибрид О. — агулы үсемлек. Ак О. һәм күгелҗем О.ның яфракларын һәм яшь ботакларын терлек яратып ашый, шунлыктан аларны силос салуда кулланырга мөмкин.



Ак онлыча.

**ОНОМА́СТИКА** (грек. onomastikós — исемгә караган), *тел белеменең* ялгызлык исемнәрне, аларның килеп чыгышы һәм чыганак телдә озак вакытлар кулланылышта йөрүләре нәтиҗәсендә яисә башка телләргә күчүгә бәйле рәвештә үзгәреш кичерү тарихын өйрәнүче тармагы. Исемнәрнең төренә карап, О. традицион рәвештә түбәндәге тармакларга бүленә: *антропонимика* — кеше исемнәрен, *топонимика* — геогр. төшенчәләр атамаларын, *этнонимика* — ыру, кабилә, халык, этник төркемнәр атамаларын, зоонимика — хайван исемнәрен, астронимика (космонимика) күк җисемнәренең исемнәрен өйрәнә һ.б. Матур әдәбиятта, халык авыз иҗатында кулланылган ялгызлык исемнәрне өйрәнү б-н шөгыльләнүче поэтик О. тармагын да аерып карыйлар. О. тарих, этнография, археология, география, геральдика, илләр өйрәнү б-н тыгыз бәйләнгән. Татар телендә ялгызлык исемнәрне һәм аларның килеп чыгышын өйрәнү 19 йөзнең 2 яртысыннан башлана. Бу юнәлештә тикшеренү эшләренә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Әхмәров, В.В.Радлов, Н.И.Ашмарин, Г.Тукай һ.б. зур кызыксыну күрсәтәләр. Татар топонимикасына, антропонимикасына, этнонимикасына караган тикшеренүләр аеруча зур үсеш алган. Хәзерге заман О.сының төрле аспектлары Г.Ф.Саттаров, Ф.Г.Гарипова, Р.Х.Субаева, Д.Б.Рамазанова, М.З.Зәкиев, Г.В.Йосыпов, Г.Р.Галиуллина һ.б.ның хезмәтләрендә карала.

*Әд.:* Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. К., 1990; шул ук. Татар топонимикасы. К., 1994; Гарипова Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан: 2 томда. К., 2001–03; Галиуллина Г.Р. Личные имена татар в XX веке. К., 2000; Татарские личные имена лингвокультурных традиций. К., 2008.

**ОНЧЫ́Л ЧЫК ГӨМБӘЛӘРЕ́** (Erysiphales), аскомицетлар классыннан гөмбәләр рәте. 20 ыругы һәм 100 гә якын төре билгеле. Югары төзелешле үсемлекләрдә паразитлык итәләр. Күпчелеге төрле үсемлек органнарының өслекләрендә яши. Үсемлек тукымаларына үтеп керүче гаусторияләр ярдәмендә тукланалар. Спорлардан үрчиләр. Үсеш циклында 2 стадия күзәтелә: җенессез-конидияле һәм җенси-сумкалы. Үсемлекләрнең яфракларына һ.б. органнарына эләгеп, споралар онычыл кунык (онычыл чык авыруы исеме шуннан) хасил итеп үсәләр. Кунык әкренләп үсә бара һәм яшел органнарның шактый өлешен каплап ала. Үсемлекләр кибеп үләләр, уңыш кими, аның сыйфаты начарлана. Татарстан терр-ясендә алмагачта (Podosphaera leucotricha), крыжовникта (Sphaerotheca mors), имәндә (Microsphaera alphitoides), кыяклыларда (Erysiphe graminis) һ.б.да онычыл чык авыруын китереп чыгаручы О.ч.г. киң таралган. Онычыл чык һава шартлары уңай булганда (җылы һәм дымлы җәй), Америка өрәңгесендә һәм очлы яфраклы өрәңгедә, корычагач, дүләнә, миләш, зелпедә үрчи. О.ч.г. чәчүлекләрне, яшь үсентеләрне һәм чәчкеннәрне зарарлап, сабакчалы имәнгә шактый



Имәндә онычыл чык авыруы.

зыян китерәләр. О.ч.г. б-н зарарланудан саклану ысуллары: агач һәм куак токымнарын үстерү агротехникасын саклау (имән чикләвекләрен көзен чәчү күпкә отышлырак), чәчүлекләргә һәм утыртмаларга 3–4 тапкыр 1-процентлы коллоид күкерт суспензиясе яки 0,2–0,3-процентлы байлетон бөркү; үсемлекчелектә һәм бакчачылыкта онычыл гөмбә авыруына чыдам сортлар куллану, санитар саклау чараларын үтәү, фосфорлы-калийлы ашламалар куллану.

*Әд.:* Защита леса от вредителей и болезней: Справ. М., 1988. *Н.М.Ведерников.*

**ОПА́ЦКИЙ** Станислав Флорианович (20.5.1847 — ?), филолог, рим теле һәм әдәбияты магистры (1879). Новороссийск ун-тын тәмамлаганнан соң (Одесса ш., 1870), гимназияләрдә латин теле укыта. 1885 елдан Казан ун-тында классик филол. кафедрасында эшли (1890 нан экстраординар проф.). Хезмәтләре Ювенал, Кече Плиний иҗатларына карый. Гимназияләр өчен латин теле дәреслекләре авторы.

Әсәр.: О сатирах Ювенала. Разбор мнений Отто Риббека // Журн. М-ва народного просвещения. 1874. № 3–4, 6; Плиний Младший, литературный деятель времён Нервы и Траяна. Варшава, 1878; Критическое исследование по латинскому синтаксису. К., 1885.

**О́ПЕРА** (итал. opera — әсәр). Татарстанда 1920 елларда үсеш ала. Г.С.Әлмөхәммәдов, В.И.Виноградов, С.Х.Габәшинең «*Сания*» (1925), «*Эшче*» (1930) беренче татар опералары һәм С.Ж.Сәйдәшевнең муз. драмалары куелу Казанда милли музыка театры ачу зарурлыгы турындагы фикерне раслый. Жанрның яңалыгы, кирәклеге өлкән буын татар композиторларына опералар тудырырга этәргеч бирә; Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә премьералары булган 16 әсәрдән (М.Юдинның «Фәридә» операсыннан башка) 11 е аларныкы: Н.Җиһановның «Качкын», «Ирек», «*Алтынчәч*», «Илдар» (2 нче редакциясе «Җиңү юлы»), «Түләк» (2 нче редакциясе «Түләк һәм Сусылу»), «Шагыйрь», «Намус», «*Җәлил*» (Ә.Фәйзи, З.Сафин, М.Җәлил, Н.Исәнбәт, Ә.Исхак либреттолары), М.Мозаффаровның «Галиябану» (Ә.Ерикәй либреттосы), Ж.Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар» (автор либреттосы), С.Сәйдәшев һәм А.Ключарёвның «Наёмщик» (Х.Вахит либреттосы) әсәрләре. 1950 елларда һәм бераз соңрак татар музыкасына килүче композиторлар опера юнәлешендә эшләмиләр. Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (1957) Х.Вәлиуллинның «*Самат*» операсы (Х.Вахит либреттосы) куелганнан соң, тамашачыга Х.Вәлиуллинның «Дим буенда» (Х.Вахит либреттосы), Л.Хәйретдинованың «Мәкерле песи» (Зөлфәт либреттосы), Р.Габәйдуллинның «Җиһангир» (Х.Вахит либреттосы), Б.Мөлековның «Кара йөзләр» (Г.Рәхим либреттосы) опералары тәкъдим ителә. 1990 да Р.Кәлимуллинның «Ерактагы кәккүк авазы» (И.Юзеев либреттосы) рок-операсы куела. Милли музыка тарихында мөһим вакыйга булып Р.Ахиярованың Татар опера һәм балет театры сәхнәсендә куелган «Шагыйрь мәхәббәте» операсы (Р.Харис либреттосы) санала. Татар опералары Уфа, Алма-Ата, Мәскәү, Прага театрларында куела. М.Мозаффаровның «Зөлхәбирә» һәм Ә.Бакировның «Тукай» опералары сәхнәдә куелмый кала.

*Әд.:* Татарский академический театр имени М.Джалиля. К., 1994.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ОПО́КА** (геол.), бик вак (0,005 *мм* дан кечерәк) кремнезём кисәкчәләреннән торучы нечкә күзәнәкле тыгыз, җиңел тау токымы. Тыгызлыгы 1100–1600 $кг/м^3$, күзәнәклелеге 55% ка кадәр, гадәти токымнарның (төрләрнең) ныклыгы — 5–20 *МПа*, төсе аксыл сорыдан куе сорыга кадәр. Суда юешләнми. Сәнәгый төрләренең компонент составы түбәндәгечә: опал-кристобалит 50–90%, балчык-

сыл минераллар 10–40%, кисәкле (күбесенчә кварцлы) материал 10–20% ка кадәр. Сәнәгый ресурслары Идел буе, Россиянең Үзәк һәм Көньяк-Көнбатыш р-ннарының, Урал, Сахалин, Үзәк һәм Көнбатыш Европаның (Англия, Франция, ГФР), Кытай һ.б.ның палеоген һәм югары акбур утырмалары б-н бәйле. О. Татарстанның көньяк-көнбатыш өлешендә (Бизнә, Чынлы елгаларының югары агымы) табылган. Файдалы катламның калынлыгы 20–38 *м*. Татар Шатрашаны чыганагы тикшерелгән, $A+B+C_1$ категориясе буенча баланс запаслары — 88,3 млн. *т*. Цеолитлы һәм карбонатлы төрләреннән алып, цеолитлы мергельләргә кадәр очрый. ТРда О. ресурслары 0,5–0,6 млрд. $м^3$ тәшкил итә. Цементларга актив гидравлик өстәмәләр, ашлама тәэсирле мелиорант һәм пролонгатор ашламалар, суны әзерләү өчен адсорбентлар (бөртекле һәм порошоксыман) буларак, майларны һ.б.ны чистарту, сыек пыяла алу өчен, волластонитлы керамика ясауда, терлек азыгы җитештерүдә һ.б.да кулланыла.

*Әд.:* Кремнистые породы СССР. К., 1973; Д и с т а н о в У.Г. Минеральное сырьё. Породы опал-кристобалитовые: Справ. М., 1997; ш у л у к. Опал-кристобалитовый цеолитсодержащий промышленный тип // Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

*У.Г.Дистанов.*

**О́ПТИК КАПЛАМНА́Р**, оптик детальләрнең нурны сындыручы һәм кайтаручы өслекләренә ягыла торган плёнкалар (элпәләр) системалары. Төрле материалларның бер яки берничә катламыннан торалар. Һәрбер катламның сындыру күрсәткече һәм яктылык дулкыны озынлыгы б-н чагыштырырлык дәрәҗәдәге калынлыгы төрлечә була. О.к.ның физик нигезен яктылык интерференциясе — когерент яктылык дулкыннарының, фазалары арасындагы нисбәткә бәйле рәвештә, бер-берсенә салынганда көчәюе яки көчсезләнүе тәшкил итә. О.к. хәзерге оптик-электрон системаларның элементлар базасында мөһим урын алып тора, чөнки аларның оптик параметрларын күпкә үзгәртергә һәм функцияләрен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Билгеләнү өлкәсенә карап, О.к. ачыклаучы, кайтаручы, фильтрлаучы, спектрга бүлүче, полярлаучы һәм яктылык йотучы капламнарга бүленәләр. О.к. химик һәм вакуумлы юллар б-н эшләнә. Вакуумлы алымнар аеруча күп таралган, чөнки алар югарырак техник характеристикалы эшләнмәләр алырга мөмкинлек бирә.

Бөек Ватан сугышы елларында *Казан оптика-механика заводында* химик ысул б-н капланган ачыгайткач капламлы бинокль һәм төзәгечләр эшләп чыгарыла башлый. 1957 елда О.к. уйлап табу буенча фәнни-тикшеренү эшләрен Ленинград оптика-механика ин-тының Казан ф-лы (к. *Гамәли оптика институты*) башлап җибәрә. Соңрак институт илдәге О.к. эшләү һәм җитештерү буенча әйдәп баручы пр-тиеләрнең берсенә, спектрның инфракызыл диапазоны капламнары өлкәсендә төп җитештерүчегә әверелә. Биредә 6 лаб-яне, вакуумлы асфериклаштыру секторын эченә алган зур фәнни-тикшеренү һәм җитештерү үзәге формалаша. О.к.ны тикшерү һәм эшләп чыгаруга И.С.*Гайнетдинов*, М.Ә.*Вәлидов*, Е.А.*Несмелов*, Г.А.Александров, М.Х.Әхмәдиев һ.б. зур өлеш кертә. Институтта технол. процессларны матем. модельләштерү алымнарын, күп катламлы интерференцион системаларны исәпләү алымнарын үстерү эшләре үткәрелә; материалларның элпә халәтендәге үзлекләрен билгеләү буенча экспериментал тикшеренүләр үткәрелә. Элпә ясаучы материаллар әзерләү технологияләре, катламнарның калынлыгын аларның формалашуы процессында контрольдә тоту аппаратлары булдырыла, капламнар ябыштыру процесслары ЭВМ кулланып автоматлаштырыла. Эшләнелгән һәм гамәлгә кертелгән О.к.: космик аппаратлар өчен оптик-электрон күзәтү системаларына интерференцион капламнар; бөҗралы лазер гироскоплары өчен диэлектрик көзгеләр; тепловизион приборлар өчен ачыгайтучы, спектрга бүлүче, көзгеле металл капламнар; көч куллану оптикасында көзгеле, полярлаштыручы һәм ачыгайтучы капламнар; лазерларда кулланылучы дулкын озынлыкларына исәпләнгән тар буйлы фильтрлар; газ анализаторы, радиометрия, мед. приборлары, спектраль анализ приборлары, авиакосмик приборлар өчен бөҗралы фильтрлар; ачык космоста эшләү өчен тирән суытулы фильтрлар, бәрелүгә югары дәрәҗәдә чыдам фильтрлар һ.б.; тармак пр-тиеләре өчен элпә ясау материалларын серияләп җитештерү оештырыла. Институтның эшкәртмәләре Казан, Азовск, Урал оптика-механика з-дларында, «Арсенал» з-дында (Киев ш.), Красногорск механика з-дында, «Астрофизика» һәм «Геофизика» фәнни-җитештерү берләшмәләрендә (икесе дә Мәскәүдә) гамәлгә кертелә. Иң яңа күптөсле («мозаикалы») фото кабул иткечләр өчен спектрның инфракызыл өлкәсендә микрофильтрлар (0,1–3 *мм*); ультрамиләүшә нурланыш куллана торган оптик-электрон системалар өчен югары сизгерлектәге «кояшлы-сукыр» фильтрлар; төс турындагы мәгълүмат карарлар кабул итү өчен нигез булып торган системаларда төсне югары төгәллек б-н тапшыруны тәэмин итүче капламнар; яктылык ташкынын 2–10 спектраль канал буйлап бүлү өчен төрле типтагы капламнар чыгару өстендә эшләр алып барыла. О.к. эшләп чыгару өлкәсендәге казанышлары өчен М.Ә.Вәлидов — СССР Дәүләт бүләгенә (1970), И.С.Гайнетдинов һәм А.С.Макаров — СССР МС бүләгенә, ин-тның күп кенә хезмәткәрләре орден һәм медальләргә лаек була; уйлап табуга 100 гә якын авторлык таныклыгы алына. О.к. б-н бәйле тикшеренүләр Казан ун-тында (Р.Б.Таһиров), Казан техник һәм Казан технол. ун-тларында алып барыла. Юка элпәләрне өйрәнү һәм модификацияләү РФА КГҮнең Казан физика-техника ин-тында гамәлгә ашырыла. О.к. Казан оптика-механика з-дының вакуумлы капламнар участогында җитештерелә.


*И.С.Гайнетдинов.*

**О́ПТИКА** (грек. optikē̄ — күрү үзлеге турындагы фән), физиканың оптик нурланышның (яктылыкның) табигатен, аның таралуын һәм матдә б-н үзара тәэсир итешүен өйрәнә торган бүлеге. Дулкын озынлыкларының оптик диапазоны электромагнитик нурланышлар (ультрамиләүшә — 10–380 *нм*, күренмә — 380–760 *нм*, инфракызыл — 760 *нм* — 1 *мм*) спектрының корпускуляр-дулкын дуализмы үзлекләре ачык чагылган зур өлкәсен алып тора. Күренешләрне бу диапазонда тикшерү кулланыла торган техник чаралар һәм алымнарның бер үк булуына бәйле. О. — көндәлек гамәлләр б-н бәйләнгән иң борынгы фәннәрнең берсе. 20 йөзнең 2 нче яртысында традицион фәнни юнәлешләр — геом., физик, физиол. О. б-н беррәттән яңалары — хисаплау, нәсызыкча, көч, интеграль О.лар, голография һ.б. юнәлешләр барлыкка килә. «О.» төшенчәсе ш.у. төрле кулланылыштагы, оптик күренешләрнең закончалыкларына нигезләнеп эшләнгән оптик детальләрнең һәм системаларның, оптик-механик һәм оптик-электрон приборларның җыелма атамасы да булып тора.

ТРда О. өлкәсендәге эшчәнлек «ГИПО» да (к. *Гамәли оптика институты*), «Фотон» КБ, *Казан оптика-механика заводы*, Казан ун-ты, Казан техник ун-ты, РФА КГҮнең *Казан физика-техника институты* тарафыннан алып барыла. Татарстанның фәнни-техник мөмкинлекләре һәм сәнәгый базасы, башлыча, Россия армиясе һәм флотына, ш.у. чит илләргә чыгарыла торган оптик приборларны фәнни тикшерү, тәҗрибә-конструкторлык эшләрен алып бару һәм серияләп җитештерү мөмкинлекләренә ия. «ГИПО»да барлык төр дифракция рәшәткәләренең технологияләрен булдыру һәм эшләп чыгару буенча дөньяда тиңе булмаган фәнни-җитештерү үзәге оештырылган; *оптик капламнар*, яктылык фильтрларының төрле типлары (кисеп алучы, буйлы, тар буйлы һ.б.) эшләнә; асферик оптика, *дифракцион оптика*, *динамик голография*, киноморф, интеграль О.лар, инфракызыл объективлар төзү үсеш ала. Институт — тепловидение өлкәсендә РФдә әйдәп баручы оешма. «Фотон» Үзәк КБнда һәм Казан оптика-механика з-дында, СССРда беренче булып, армия өчен БН-1 һәм БН-2 *төнлә күрү приборлары*, идарә итү машиналары һәм артиллерия разведкасы өчен ДКРМ-1, Д11, Д5М лазерлы ерактан күрү приборлары, су асты флоты өчен МТ-70 астронавигация перископы, УА-47, НА-100 төнге аэрофотоаппаратлары уйлап табыла һәм серияләп җитештерүгә кертелә; 1 ПН62, Ц53, ШН-86–2 тепловизион приборлары һәм башка оптик-электрон җиһазлар төзелә. «Салют-6» орбиталь станциясе өчен көзгеле объективының диаметры 1,5 *м* булган субмиллиметрлы зур орбиталь инфракызыл телескоп, «Салют-7» станциясе составындагы «Космос-1686» иярчене өчен төп объективының диаметры 250 *мм* булган автоматик приборлы оптик «Пион-К» комплексы — иң әһәмиятле проектлар булып исәпләнә. Казан ун-тында 1950 елларда атомар һәм молекуляр спектроскопия буенча тикшеренүләр башлана. Спектроскопик тәҗрибәләрне матем. эшкәртү һәм интерпретацияләү, квант динамикасы һәм күп корылмалы ионнар спектроскопиясе, когерент һәм нәсызыкча

оптика өлкәләрендә эшләр алып барыла. Казан техник ун-тында 1970 еллардан газлы лазерлар, дистанцион экол. мониторингның оптик-электрон лидар системаларын төзүгә, адаптив О.га (автомат идарә алымнары һәм чаралары кулланыла торган югары сыйфатлы оптик системалар), лазер җайланмаларын медицинада куллануга караган эшләр алып барыла. РФА КГҮ Казан физика-техника ин-тының нәсызыкча оптика лаб-ясе оптик күчеш процесслары (озакка сузылган *фотон кайтавазы*) һәм үтә нурланыш нигезендәге оптик фаза хәтере эшчәнлегенең физик принципларын тәҗрибәдә һәм теоретик яктан тикшерү эшләрен алып бара. Теоретик һәм гамәли О. өлкәсендә белгечләрне Казан ун-ты һәм Казан техник ун-ты әзерли.

**Асферик оптика** (АО) — барлык нокталары өчен бердәм кәкрелек үзәге булмаган бер яки берничә өслекле оптик элементлар (линзалар, көзгеләр). Күпчелек очракларда АОда күчәр симметрияле асферик әйләнү өслекләре яки андый өслекләрнең күчәрдән читтәге фрагментлары файдаланыла. Аерым очракларда, мәс., катлаулы фәзаи сурәтләр формалаштырганда яки эшкәрткәндә, симметрия күчәре һәм яссылыгы булмаган өслекләр дә (даими булмаган өслекләр) кулланыла.




Асферик өслекләр.

АО элементларының асферик өслекләре элементлары кәкрелеген оптик системаның таләп ителгән сыйфатламаларына карап үзгәртергә мөмкин, шуңа күрә АОның коррекцияләү (төзәтү) мөмкинлекләре сферик оптиканыкыннан күпкә югары. АО куллану чагыштырма тишемне, күрү почмагы кырын арттырырга, оптик элементлар санын киметтә һәм оптик системаның үлчәмнәрен кечерәйтә барып, сурәтнең сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирә. Барлык сферик өслекләрне асфериклар б-н алыштырганда иң зур нәтиҗәгә ирешелә, әмма АО эшләп чыгару, технол. һәм үлчәү җайланмаларының мөмкинлекләре чикле булу сәбәпле, катлаулы эш санала. Компьютерлар техникасын куллanып, беренчел сферик әзерләнмәдән материалны алып ташлауга (ерагайтуга) нигезләнгән алымнарның перспективасы зур.

СССРда АО җитештерү технологияләре өлкәсендәге эшләр 1950 елларда башлана. Татарстанда Ленинград оптика ин-тының Казан ф-лы составында (к. *Гамәли оптика институты*) асферик оптика лаб-ясе оештырыла (1959), 1960 еллар ахырына ул тармакта әйдәп баручы оешмага әверелә. Институт галимнәре (О.Г.Карлин, В.Г.Кукс, А.Г.Хөснетдинов һ.б.) тарафыннан асферик өслекләрне хисаплау техникасы куллануга нигезләнеп эшкәртүнең оригиналь алымнары тәкъдим ителә, Казан һәм Азовск оптика-механика з-дларында, Новосибирск приборлар төзү з-дында, «Арсенал» з-дында (Киев ш.) һ.б. пр-тиеләрдә гамәлгә кертелгән җиһазлар эшләнә. Институтта асферик оптик детальләр (20 дән 600 *мм* га кадәр диаметрлы) җитештерү үзләштерелә, алар инфракызыл объективларда, спектраль, телескопик (мәс., космик техника өчен), тепловизион приборларда (ш.и. Хәрби диңгез флоты өчен «Дрофа» «Снегирь» һәм танкларга каршы «Метис-М» ракета комплексларында) кулланыла; прецизион детальләр әзерләү өчен асферикләштеруның яңа алымнары эшләнә. Асферик элементлар Германиягә, Словакиягә, Кытайга, Кореягә һ.б. чит илләргә чыгарыла.

*Әд.:* Л а н д с б е р г Г.С. Оптика. М., 1971; С о р о к о С.М. Основы голографии и когерентной оптики. М., 1971; К е н и х С. Молекулярная нелинейная оптика. М., 1980; Научно-производственное объединение «Государственный институт прикладной оптики» (1957–1997 гг.): В 2 ч. К., 1997; Казанский оптико-механический завод. 1940–2000. К., 2000; М а н д е л ь Л., В о л ь ф Э. Оптическая когерентность и квантовая оптика. М., 2000.

*В.М.Иванов, В.Г.Кукс.*

**ОПТИМАЛЬЛӘШТЕРҮ́**, мөмкин булганнар арасыннан иң яхшысын сайлап алу процессы яки системаны иң яхшы торышына китерү процессы. Казанда матем. О. мәсьәләләрен чишү 1950 елларда проф. Н.В.Куршев тарафыннан самолёт аэромеханикасы өлкәсендә башланып китә. Казан авиация ин-тында аерым чыгарылмалы дифференциаль тигезләмәләр б-н бирелә торган процессларны О. буенча фундаменталь тикшеренүләр, ш.у. детерминант һәм стохастикларны да кертеп, төрле класстагы тигезләмәләр системалары өчен максимум принцибын үстерү буенча тикшеренүләр үткәрелә. Ляпунов функцияләре алымы б-н Беллманның динамик программалаштыру алымының уртаклыгы идеясе бүленгән параметрлы системалар өстендә тикшерелә, алар өчен динамик программалаштыру алымының төп тигезләмәсе алына. Бу алым матем. физиканың күп кенә мәсьәләләрен чишкәндә, сыгылмалы очкыч аппаратлар б-н оптималь идарә итү һәм стабильләштерү законын эшләгәндә уңай бәя ала. Соңрак динамик программалаштыру алымы һәм Ляпунов функцияләре алымы абстракт процесслар өчен үстерелә, биредә Беллманның оптимальлек принцибының чикләнгәнлеге һәм аның кулланылу чикләре күрсәтелә (Т.К.Сираҗетдинов, Г.Л.Дегтярёв, А.А.Балоев, Е.А.Клестов, Э.Т.Смирнова, В.Н.Куршев, О.Г.Дивалов, В.И.Елизаров һ.б.). Өзекле системаларга карата кулланылып, стохастик системалар б-н оптималь идарә итү теориясе нигезләре эшләнә (Ю.В.Кожевников). Стат. критерийлар нигезендә теоретик һәм гамәли мәсьәләләр чишү алымнары тәкъдим ителә; ышанычлылык һәм төгәллек критерийларын исәпкә алып, очраклы үзлекле системалар өчен максимум принцибы бирелә (И.Х.Садыйков). Дифференциальләшми торган функцияләрне О. проблемалары тикшерелә (В.И.Заботин). Идарә итү теориясендә өзлексез Ли төркемнәрен куллану юлы б-н мөһим нәтиҗәләр алына: бүленгән һәм тупланган параметрлы системаларны О. проблемасын теоретик-төркемләп чишү юлы эшләнә; бу нәтиҗәләр Ли-Овсянников инфинитезималь аппаратын һәм Э.Нётерның вариатив инвариант мәсьәләләр теориясен бергә куллануга нигезләнә һәм чик катламның оптималь мәсьәләләрендә кулланылышы күрсәтелә (В.Г.Павлов, К.Г.Гәрәев).

*Әд.:* К у р ш е в Н.В., К о ж е в н и к о в Ю.В. Оптимальные задачи динамики полёта. К., 1967; С и р а з е т д и н о в Т.К. Оптимизация систем с распределёнными параметрами. М., 1977; К о ж е в н и к о в Ю.В. Статистическая оптимизация летательных аппаратов. М., 1978; Д е г т я р ё в Г.Л., С и р а з е т д и н о в Т.К. Теоретические основы оптимального управления упругими космическими аппаратами. М., 1986; Г а р а е в К.Г. Группы Ли и теория Нётер в проблеме управления с приложениями к оптимальным задачам пограничного слоя. К., 1994.

*В.Н.Куршев.*

**ОПТЫ́** (Aspius aspius), карплар семьялыгындагы балык. Төньяк, Балтыйк, Кара, Азов, Каспий һәм Арал диңгезе бассейннарындагы елгаларда таралган. ТР терр-ясендә мул сулы елгаларда (Идел, Кама, Зөя, Казансу, Мишә, Ык, Дала Зәе, Чишмә, Олы Чирмешән, Кече Чирмешән) һ.б. агымлы сулыкларда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 80 *см* га кадәр, авырлыгы 5 *кг* нан артык. Сырты зәңгәрсу-соры, ян-яклары көмешсыман, корсак һәм аналь йөзгечләр кызгылт төсмердә, сырт һәм койрыктагылары соры. О.ның ике рәтле эләктереп ала торган ыргаксыман тешләре бар. Ата балыкның җенси җитлегү чоры — 5, ана балыкларныкы 6 яшьтә була. Уылдыгын иртә язда, су темп-расы 4 °С тан югары булганда, елганың ташлы урыннарында берьюлы чәчә. Үрчемлелеге — 50 меңнән 350 меңгә кадәр уылдык бөртеге. Вак балыклар — планктон, бөҗәкләр, личинкалар, зурлары вак балык б-н туклана. Елга тамакларында «чокырларда» кышлый. 12 яшькә кадәр яши. О. — балык тоту спорты объекты.

**ОР** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 448 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Служилая Ура, Студёный Ключ исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, тәгәрмәч ясау, тимерчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында сәүдәгәр Хуҗасәетовларның күн һәм комач мануфактуралары эшли. Шул ук чорда 2 нче мәчет имамы Хәбибулла Оруви (әл-Ори) киң таныла, ул Оренбург Мөселман диния нәзарәтенең беренче мөфтие М.*Хөсәеновка* каршы чыга һәм Мөселман диния нәзарәтенә альтернатива төзү проектын тәкъдим итә. 20 йөз башында О.да 2 мәчет (1905 һәм 1915 тә төзелә), мәктәпләр, бакалея һәм вак-төякләр кибете, юлаучылар йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2470 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Яңгул волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кан-

тонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1762 дә — 227 ир-ат; 1859 да — 996, 1884 тә — 1125, 1905 тә — 1205, 1926 да — 1404, 1938 дә — 1205, 1949 да — 557, 1958 дә — 550, 1970 тә — 640, 1979 да — 534, 1989 да — 435, 2002 дә — 427 кеше.

**О́РБАХ-ӘМИ́НОВ ПРОЦЕССЫ́**, кристалларда парамагнитик ионнарның ике баскычлы спин-рәшәткәле релаксациясе процессы, ул кристаллик рәшәткә тирбәнешләренең ике кванты — фононнар катнашында бара. Бу процессның беренче баскычында ион, $\omega_{ca}$ ешлыклы фононны йотып, бер магнитик халәттән (а) арадаш ярсынган халәткә (с) күчә, икенче баскычта, $\omega_{cв}$ ешлыклы фононны нурландырып, (в) магнитик халәтенә күчә. Нәтиҗәдә ион рәшәткә б-н (а) һәм (в) халәтләре энергияләре аермасына тигез булган энергия б-н алмаша. Күп кенә парамагнитик системаларда О.-Ә.п. спин-рәшәткә релаксациясенең төп сәбәпчесе булып тора. О.-Ә.п. нәтиҗәсендә туган релаксациянең вакыты түбән темп-раларда үзенчәлекле, темп-ра б-н кире экспоненциаль бәйлелеккә ия. Шушы бәйләнеш буенча ярсынган ион энергиясенең зурлыгын табарга мөмкин. Процесс теоретик яктан Америка физигы Р.Орбах (АКШ, 1961) һәм, аңа бәйсез рәвештә, Л.К.Әминов (1962) тарафыннан тикшерелә. Бу теориянең нигезләмәләре магнит резонансы һәм релаксациясенең күп кенә үзенчәлекләрен аңлату өчен файдаланыла (к. *Ван-Флек парамагнетизмы*).

*Әд.:* А м и н о в Л.К. К теории спин-решёточной релаксации в парамагнитных ионных кристаллах // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1962. Т. 42; F i n n C.B. O r b a c h R. W o l f W.P. Spin-Lattice Relaxation in Cerium Magnesium Nitrate at Liguid Helium Temperature: A New Process // Proc. Phys. Soc. 1961. T. 77; O r b a c h R. Spin-Lattice Relaxation in Rare-Earth Salts // Proc. Roy. Soc. 1961. T. A264.

**ОРГА́НИК АШЛАМАЛА́Р**, үсемлек һәм терлекләрдән барлыкка килгән органик кушылмалар формасында туклыклы матдәләре булган ашламалар. О.а.га тирес, тирес сыекчасы, кош тизәге, торф, сапропель, тизәк компостлары, яшел (сидераль) ашламалар, зарарсызландырылган көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, агымсуларның утырымнары һ.б. керә. Барлык О.а. (сидекчәдән башкалары), күчереп йөртү мөмкинлеге булмаганлыктан, җирле ашламаларга карый; минеральләшү вакытында тозлар рәвешендә таркалучы элементларына карап бәяләнәләр, алар үсемлекләрнең тамырдан тукландыру нигезен тәшкил итәләр, ш.у. аның сыйфатын күтәрүгә — черемә туплауга, су һәм һава режимы структурасын яхшыртуга, үзләштерү сәләтен арттыруга, буферлыкка, әчелекне йомшартуга һәм файдалы микрофлораның эшчәнлеген активлаштыруга ярдәм итәләр.

О.а. ш.у. үсемлекләр үзләштерә торган углекислый газның әһәмиятле чыганагы булып тора. Черемә, черегән яисә ярым черегән тирес, уйсулык *торфы* органик-минераль катнашмалар әзерләгәндә төп компонентлардан саналалар, аларны туфракка кертү а.х. культураларының уңышын арттыруга һәм продукциянең сыйфатын яхшыртуга мөмкинлек бирә. О.а. чәчүлекләрне мүлчәләү өчен минераль ашламалы күпсанлы туфрак катнашмаларын әзерләгәндә биоягулык буларак кулланылалар.

О.а.га ихтыяҗ планлаштырылган а.х. культуралары уңышын алуга һәм черемәнең җитәрлек, аз черемәле туфракларда уңай балансын булдыру кирәклегенә карап билгеләнә. О.а. а.х. культураларыннан югарырак һәм тотрыклырак уңыш алу мөмкинлеген бирә. Җиңел һәм уртача гранулланшкан составлы кәсле-көлсу һәм соры урман туфраклы, бигрәк тә сугарулы җирләрдә бәрәңгегә, кукуруз, терлек азыгы культуралары, яшелчә, көзге бөртекле культураларга керткәндә уңышның зуррак артымына ирешелә. О.а. аша туклыклы матдәләрнең: туфрак — үсемлек — тере организмнар — туфрак схемасы буенча әйләнеше гамәлгә ашырыла.

О.а.ның чәчү әйләнешендә алмашып килүче культуралар уңышына тәэсире 3–4 елдан 7–8 елга кадәр бара. Балчыксыл туфракларга О.а.ны кертү 3–4 елга бер тапкыр кабатлана. О.а.ның микъдары 1 *га* га 20–80 *т* исәбеннән а.х. культураларының планлаштырылган уңышына һәм туфракның уңдырышлылыгы дәрәҗәсенә карап билгеләнә. О.а. туфракка пар яисә туңга сөрү вакытында кертелә. 1 *т* тирес үзенең тәэсир итү вакытында (6–8 ел дәвамында) бөртеклеләргә күчереп исәпләгәндә 1 *ц* өстәмә продукция алуны тәэмин итә.

Казан губернасында О.а. игенчелек системасының ялга калдырылган кысыр җирләрдән (яткын җир — кысыр җир) пар җирләренә күчүенә бәйле рәвештә 19 йөздән киң кулланыла башлый, соңгысында сөрү җирләренең ял вакыты кыска (бер ел) булу сәбәпле, туфракның уңдырышлылыгын киметмәс өчен ашлама кертү таләп ителә, ул вакытта пар җирләре өчен бердәнбер чара — тирес кертү була. Кара туфраклы җирләрдә ашламалар сирәк кулланылган. Басуларга тирес кертүче общиналар саны 1880 елларда гына арта. Атлар булмау, җирләрнең аз булуы һәм шунлыктан мал-туарның азлыгы һәм община җирләрен яңадан бүлүнең еш кабатлануы аркасында тирес кулланылмый. Казан губернасының стат. ком-ты мәгълүматлары буенча, 1 дис. пар басуына 1–3 мең пот урынына 433 пот тирес кертелә. ТРда О.а.ның кулланылган күләме (*млн. т*) 1995 тә — 13,01, 2000 дә — 6,33, 2005 тә — 4,88, 2006 да — 3,70, 2011 дә — 3,94 (ягъни 1 *га* сөрү җиренә 3,5–1,6 *т*) тәшкил итә.

*Әд.:* П р я н и ш н и к о в а Д.Н. Избр. соч. М., 1963. Т. 3; Ш а к и р о в Р.С. Земное плодородие. К., 1989; Ш а к и р о в Р.С., Ш а к и р о в В.З. Применение удобрений в энергосберегающей системе земледелия // Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ОРГА́НИК СИ́НТЕЗ»**, к. *Казан «Органик синтез» ачык акционерлык җәмгыяте.*

**ОРГА́НИК ХИ́МИЯ**, химиянең бүлеге, углеводородлар һәм аларның кушылмаларының килеп чыгышын, төзелешен һәм химик әверелешләрен өйрәнә. О.х.нең бүлекләре химия фәненең мөстәкыйль өлкәләрен тәшкил итә: *стереохимия, элементорганик кушылмалар, югары молекуляр кушылмалар* химиясе, *табигый кушылмалар* химиясе, электрохимик синтез һ.б. О.х. чиктәш табигыять фәннәре: *биология, биохимия, медицина* һ.б. б-н тыгыз бәйләнгән. Органик матдәләр үсемлек һәм хайван организмнары төзелешендә мөһим роль уйный (күзәнәкләр, тукымалар, органнар), органик реакцияләр (химик һәм физик-химик әверелешләр) аларның тереклек эшчәнлеге процесслары нигезендә ята. О.х. алымнары б-н нуклеин к-талары, аксымнар һ.б. катлаулы табигый кушылмаларның төзелеше билгеләнә, аксым синтезының механизмы һәм көйләнеше ачыла, күп кенә полипептидлар, ш.и. ферментларны синтезлау эшләнә, кайбер синтетик геннар алына. Углерод кушылмаларының күптөрлелеге аның атомнарының уникаль үзлеге — башка элемент атомнары б-н генә түгел, бер-берсе б-н дә ныклы бәйләнешләр ясап кушыла алулары һәм, кушылганда, теләсә нинди озынлыктагы сызыкча һәм тармакланган чылбырлар, ш.у. теләсә нинди үлчәмле һәм топологияле цикллар (йомык чылбырлар) төзи алуы б-н бәйле. Бер углерод молекуласында чылбырлар һәм (яки) цикллар була алу, аларга исә водород атомнары б-н бәйләнгән (мәс., кислород, азот, күкерт, фосфор) атомнарының керүе (яки кермәве) органик матдәләрнең сыйфат һәм микъдар ягыннан төрлелеген билгели. Углерод кушылмаларына изомерлык — составы һәм молекуляр массасы буенча бертөрле, әмма атомнарның кушылу тәртибе яки аларның фәзада урнашуы буенча һәм, шуның нәтиҗәсендә, физик һәм химик үзлекләре дә аерыла торган кушылмалар булу күренеше хас. Шушы үзенчәлек аркасында өйрәнелгән органик матдәләр саны 15 млн. га якынлаша, бу билгеле нәорганик кушылмалар саныннан уннарча тапкыр күбрәк. Органик кушылмаларның чагыштырмача зур булмаган өлеше биол. чыганаклардан, нигездә, органик синтез юлы б-н ясалма рәвештә алынган. Дару матдәләре, витаминнар, буяу, лак, полимер материаллар (мәс., *каучук, пластмассалар*, ясалма сүсләр, плёнкалар), электротехника һәм электроника сәнәгате өчен сыек кристаллар һ.б. материаллар, әчке яну двигательләре, ракета двигательләре өчен ягулык, атом сәнәгате өчен материаллар, транспорт чаралары һәм металл эшкәртү өчен майлау материаллары, шартлаткыч матдәләр, химия-фотография материаллары, а.х. үсемлекләрен саклау чаралары һ.б. алына; алдан бирелгән үзлекләре буенча яңа материаллар эшләнә. О.х. алымнары төп органик синтез өлкәсендә әһәмиятле урын тота, күп кенә химик җитештерүләрнең технологияләрен үзгәртә, табигый газларны һәм нефтьнең кайбер тар фракцияләрен химик эшкәртү нигезендә яңа төр продукцияләр булдыру мөмкинлеген бирә. Органик синтезның тискәре нәтиҗәләре — тереклек тирәлеген пычратуы, кеше организмына ксено-

биотиклар эләгүгә бәйле авырулар барлыкка килү.

«О.х.» терминын 1827 елда швед галиме Й.Берцелиус кертә, әмма бик борынгы заманнарда ук спиртлы һәм серкәле ачыту билгеле була, табигый буяулар кулланыла. 16 йөздә органик матдәләрне медицинада куллану буенча тикшеренүләр башлана (үсемлекләрдән эфир майлары алына, агачның коры кудыру юлы б-н серкә к-тасы һәм кырмыска спирты табыла, гади эфир әзерләү ысулы эшләнә һ.б.). 1823 тә немец химиклары Ф.Вёлер һәм Ю.Либих тарафыннан изомерлык күренеше ачыла. Органик матдәне беренче булып Вёлер синтезлый. Ул кузгалак к-тасы һәм сидекчә таба (1828). 19 йөз уртасында синтетик органик матдәләр саны арта: серкә к-тасы (Г.Кольбе), май тибындагы матдәләр (П.Бертло), шикәрсыман матдә — метиленитан (А.М.*Бутлеров*) синтезлана. 19 йөзнең 1 нче яртысында О.х.нең теоретик төшенчәләре үстерелә: радикаллар теориясе, типлар теориясе эшләнә, валентлык кагыйдәсе билгеләнә, углеродның 4 валентлы була алуы һәм углерод атомнарының чылбыр ясап кушылу мөмкинлеге исбатлана. 1861 дә Бутлеров органик кушылмаларның *химик төзелеш теориясен* төзи, О.х.гә химик бәйләнеш, молекулада атомнарның бәйләнү тәртибе, атомнарның бер-берсенә тәэсире турында һ.б. төшенчәләр кертә. Төзелеш теориясе инде билгеле булган изомерлык күренешләрен аңлатып бирә. 1864 тә Бутлеров углеводородлар изомерлыгы күренешен фаразлый һәм аны изобутан синтезлау б-н раслый (1867). Оптик (Я.Вант-Гофф, Ж.А.Ле Бель) һәм геом. (Й.Вислиценус) изомерлык күренешләре ачыла. Төзелеш теориясенең молекулада атомнарның үзара тәэсир итешүе турындагы бер нигезләмәсе соңрак В.В.*Марковников* тарафыннан үстерелә. Атомнарның бензолда (М.Фарадей ача, 1825) һ.б. ароматик һәм чиксез кушылмаларда үзара тәэсир итешү табигате квант механик кагыйдәләр нигезендә 20 йөзнең уртасында өйрәнелә. Микъдари микроанализ ясау (1920 еллар), физик алымнарны камилләштерү һәм яңаларын булдыру (хроматография, ЭПР, рентген-структур анализ, масс-спектроскопия, ТМР-, ИК-, УМ-спектроскопия һ.б.) органик матдәләрнең структурасын, химик алымнар кулланмыйча диярлек, тиз һәм төгәл билгеләү мөмкинлеген бирә. Квант механикасы алымнары иярмә системаларда электроннар тыгызлыгы бүленешен, алмаштыргычлар тәэсирендә бу тыгызлыкның авышуын, органик кушылмаларның реакциягә ике яклы сәләтен аңлатып бирә. Матем. модельләү юлы б-н алдан билгеләнгән үзлекле матдәләрне максатчан эзләп табалар. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан тикшеренүләрнең кинетик алымнары үсеш ала, чылбырлы реакцияләр теориясе (Н.Н.*Семёнов*), кислота-нигезле һәм гетероген катализ теориясе барлыкка килә, шулар нигезендә углеводородларны дегидрирлау (ш.и. нефтьтән олефиннар, бензол һәм аның гомологларын алу), парафиннарны олефиннар б-н алкиллау һ.б.ның сәнәгый ысуллары эшләнә. Углерод оксидын водород б-н кайтарып метанол һәм чикле углеводородлар табу, Дильс-Альдер реакциясе (к. *Диен синтезы*), пептидларның карбодиимид синтезы, аксымнарда аминокислоталарның эзлеклелеген билгеләү алымнары, полимерлар химиясе зур әһәмияткә ия була. *Фосфорорганик кушылмаларны* тикшерү (А.Е.Арбузов) физиол. актив кушылмалар: дару препаратлары, агулы матдәләр, үсемлекләрне саклау чаралары, антипиреннар һ.б. ачылуга сәбәп була. Фтор һәм аның кушылмалары химиясе, күчеш металлары химиясе, буяулар химиясе мөстәкыйль бүлекләргә әверелә, О.х.нең яңа өлкәләре — супрамолекуляр химия, фуллереннар химиясе үсеш ала.

О.х. фәнендә Татарстан галимнәре бөтендөнья химия җәмәгатьчелеге тарафыннан танылу алган зур казанышларга ирешәләр. Нәкъ менә Казан ун-тында 1830 елларда Н.Н.Зининның ароматик нитрокушылмаларны кайтару буенча (к. *Зинин реакциясе*) хезмәтләре Россиядә О.х.не үстерүнең төп юнәлешләрен билгели, Казан химия мәктәбенә нигез салучыларның берсе Бутлеровның химик төзелеш теориясе О.х.не фән буларак нигезли. Бутлеров шәкертләре В.В.Марковников, А.М.*Зайцев*, А.Н.*Попов*, Е.Е.*Вагнер*, С.Н.Реформатский органик кушылмаларның төзелеше тәгълиматын тагын да үстерү буенча тикшеренүләрне дәвам итәләр. *Бутлеров реакциясе*, *Вагнер реакциясе, Зайцев-Вагнер реакциясе, Вагнер-Меервейнның яңадан төркемләү ысулы,* Реформатский реакциясе ачыла; *Зайцев кагыйдәсе, Зайцев-Вагнер кагыйдәсе, Марковников кагыйдәсе, Попов кагыйдәсе* чыгарыла; органик кушылмаларның төрле класслары синтезлана; органик кушылмаларның оптик активлыгы буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә һәм нәтиҗәләр алына (И.И.*Канонников*). Терпеннар (Ф.М.*Флавицкий*, А.Е.Арбузов, Б.А.Арбузов), фосфорорганик кушылмалар (А.Е.Арбузов), мышьякорганик кушылмалар (Г.Х.*Камай*) химияләре буенча фәнни юнәлешләргә нигез салына.

20 йөздә фосфорорганик кушылмалар химиясе буенча тикшеренүләр өстенлек итә — *Арбузов реакциясе, Абрамов реакциясе, Пудовик реакциясе, Камай реакциясе* ачыла. *Фосфорорганик дару кушылмалары* синтезлана. О.х. үсешен Б.А.Арбузовның Казан физикляры (Б.М.Козырев, Й.Ю.Сәмитов, Р.Р.Шаһидуллин) б-н берлектә төзегән *химиядә фәнни-тикшеренүләрнең физик ысуллары* комплексы билгели. Кислород, күкерт, фосфор, мышьяк һ.б. элементларның циклик кушылмалары стереохимиясе, органик молекулаларның конформацион үзенчәлекләре (к. *Конформацион анализ*) өйрәнелә. Мышьяк, сөрмә, күкерт, селен, бор, фтор химиясе; металлорганик кушылмалар һәм металларның органик комплекслары химиясе, терпеннар һ.б. табигый кушылмалар химиясе, диеннар химиясе, диен синтезы, азотлы гетероцикллар химиясе, гидразоннар химиясе, нитрокушылмалар химиясе, техник химия, физик О.х., электрохимик синтез буенча тикшеренүләр үсеш ала. *Химик кинетика* буенча тикшеренүләр, *катализны* теоретик һәм гамәли яктан өйрәнү органик һәм нефтехимик синтез нигезләрен үстерергә, җитештерү технологияләрен камилләштерергә, яңа төр продукцияләр алырга (к. *Нефть химиясе*) мөмкинлек бирә. 1990 еллар уртасыннан фәннең О.х. өчен яңа өлкәләре: супрамолекуляр химия (А.И.Коновалов, И.С.Антипин) һәм фуллереннар химиясе (О.Г.Синяшин, И.Ә.Нуретдинов, В.И.Коваленко) үсә башлый. О.х. буенча тикшеренүләр Казан ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында, Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, Казан фотоматериаллар ин-тында, «Түбәнкаманефтехим» АҖнең Фәнни тикшеренү һәм тәҗрибә эшләре идарәсендә, Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан), Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, Казан мед. ун-тында, респ-каның башка югары уку йортларында һәм тармак фәнни-тикшеренү ин-тларында алып барыла.

*Әд.:* Общая органическая химия: В 12 т. М., 1981–89; Коновалов А.И., Чмутова Г.А. Казанская химическая школа: История и современность // Рос. хим. журн. 1999. Т. 43, № 3/4; Смит В., Бочков А., Кейпл Р. Органический синтез: Наука и искусство. М., 2001; Коновалов А.И. Казанская школа химиков-органиков // Изв. РАН. Сер. хим. 2004. № 1; Будников Г.К., Сорокина Т.Д. История и методология химии в Казанском университете. К., 2006.

*Я.А.Левин.*

**ОРГА́НИК һӘМ ФИ́ЗИК ХИ́МИЯ ИНСТИТУТЫ́**, РФА КГҮнең А.Е.Арбузов исем. фәнни-тикшеренү ин-ты (ОФХИ), 1965 елда А.Е.Арбузов исем. Химия ин-тын һәм СССР ФАнең Органик химия ин-тын (ОХИ) берләштерү нигезендә оештырыла. 1973 тән — СССР ФАнең Казан ф-лы, 1990 нан — СССР ФАнең КГҮ, 1991 дән РФАнең КГҮ составына керә. ОФХИ 4 бүлектән, 20 лаб. һәм фәнни төркемнән тора (2012). 243 фәнни хезмәткәр, ш.и. РФАнең 2 академигы, 2 мөхбир әгъзасы, ТР ФАнең 2 академигы һәм 3 мөхбир әгъзасы, 41 фән. д-ры һәм 135 канд-ты эшли.

Химия ин-ты 1945 тә СССР ФА Казан ф-лы составында оештырыла; 1947 дән А.Е.Арбузов (беренче директоры) исемендә; 1963 тән СССР ФАнең Гомуми һәм техник химия бүлеге каршында мөстәкыйль оешма. Органик химия бүлегендә фосфор һәм мышьяк кушылмалары өйрәнелә, аларның биол. актив кушылмалары синтезлана һәм бу кушылмаларны дару матдәләре, а.х. өчен агулы химикатлар сыйфатында куллану мөмкинлекләре тикшерелә. Офтальмология практикасына фосарбин препараты кертелә. Физик химия бүлегендә электролиз процесслары, термохимик алымнар ярдәмендә югары молекуляр кушылмаларда фаза күчешләре процесслары өйрәнелә. Металл өслекләрне шомарту һәм ялтырату алымнары эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Химия бүлеге тарафыннан Татарстан чыганакларының нефте өйрәнелә һәм аны эшкәртү өчен күрсәтмәләр бирелә. 1955 тән фосфорорганик кушылмалар химиясе һәм аларны куллану буенча бөтенсоюз, соңрак халыкара киңәшмәләр үткәрелә.

ОХИ 1958 дә химия сәнәгатенә, беренче чиратта, нефть, нефть эшкәртү сәнәгатьләренә, пластик массалар җитештерүне үстерүгә ярдәм итү максатыннан оештырыла (директоры Б.А.Арбузов). 1963 тә лаб-яләр корпусы төзелә һәм кулланугa тапшырыла. 2 институтны берләштергәннән соң, яңа лаб. корпуслары: модельле (ярымзавод) җайланмалар, химик-биол. тикшеренүләр корпуслары, ш.у. виварий, остаханәләр, сыек азот станциясе төзелә. ОФХИ матдәләрнең химик төзелешен һәм процессларны инфракызыл спектроскопия, яктылыкның катнаш чәчелүе, радио- һәм масс-спектроскопия, электрон-, рентген-, термо- һәм хроматография алымнары ярдәмендә тикшерү өчен заманча приборлар б-н җиһазландырылган. Институтта синтезлауның яңа алымнары эшләнә, төрле органик һәм элементорганик кушылмаларның төзелеше, реакциягә сәләте һәм физиол. активлыгы өйрәнелә; үсемлекләрне саклый торган химик чаралар, репеллентлар, актив өслекле матдәләр, химия һәм нефть химиясе производстволары технологияләре эшләнә. Аз токсинлы холинэстеразга каршы булмаган кушылмалар арасыннан яңа дару матдәләре эзләүдә үз алымнарын булдыру мед. гамәленә күп кенә оригиналь препаратлар кертү мөмкинлеген бирә, алар арасында *димефосфон* — метаболик дәвалауда тәэсир итү мөмкинлекләре зур булган матдә, *глицифон* — бластомаларга каршы чара бар. Органик кушылмаларның яңа реакцияләре ачыла, фосфор атомы төшенең химик реакцияләр барышында динамик поляралашу күренеше билгеләнә. Урал-Идел буе нефте һәм табигый битумнары аларның геол. урнашу һәм катламга тәэсир итү шартларына бәйләп тикшерелә, нәтиҗәдә ярлыланган чыганаклардан нефть алуны көчәйтүче алымнар булдырыла.

1990 елларда ОФХИны үстерү концепциясе эшләнә, аңа фундаменталь тикшеренүләрне гамәли эшкәртмәләр б-н төгәлләү, төбәк бурычларын хәл итүдә катнашу, үз фәнни җитештерү базасын булдыру керә. Фәнни тикшеренүләр стратегиясе шуңа бәйле рәвештә формалаштырыла. Модельле җайланмалар корпусының матди базасын институтта уйлап табылган дару матдәләрен эшләп чыгару өчен нигыту, төбәк бурычларына (нефть һәм авыр битумнар химиясе һәм геохимиясе, дару матдәләре эшләү) кергән эшләрне ТР ФА б-н берлектә җайга салу башлана. ОФХИнең төп тикшеренү юнәлешләре: яңа матдәләр, материаллар һәм технологияләр тудыруның нигезе буларак, фосфор, аның органик һәм элементорганик кушылмалары химиясе; супрамолекуляр органик химия, фуллереннар химиясе, наноүлчәнешле кисәкчекләр; катлаулы молекуляр системаларның физик химиясе; макро- һәм политөшле карбо- һәм гетероциклик кушылмалар химиясе; мед., азык-төлек сәнәгате һәм а.х. өчен биол. актив препаратлар алуның фәнни нигезләре; органик, элементорганик һәм комплекслы кушылмаларның стереохимиясе һәм кристалл химиясе; нәрацемик матдәләр табу, анализлау һәм алардан файдалану; нефть һәм битум химиясе, геохимиясе һәм аларны эшкәртүнең фәнни нигезләре; биополимерлар һәм түбән молекуляр табигый кушылмалар химиясе; интеграль оптик электроника өчен полимер материаллар. Институт Германия, АКШ, Франция, Чехия, Польша, Көньяк Корея, Япониянең фәнни оешмалары б-н иҗади бәйләнештә тора; Испания, Казакъстан, Молдавия, Италия, Австрия, Греция, Аргентина, Белоруссия, Нидерланд, Канада, Швейцария, Бельгия, Англия, Кытай, Вьетнам галимнәре б-н хезмәттәшлек итә (стажировкалар, уртак тикшеренүләр, халыкара конференцияләр). Аспирантурада 5 белгечлек буенча фән кандидатлары әзерләнә. ОФХИда, Россиядә беренче булып, Дару матдәләренең сыйфатына дәүләт контроленең төбәк үзәге, Авыр чыгарыла торган нефть һәм табигый битумнар фәнни-тикшеренү үзәге (ТР ФА һәм «Татнефть» АҖ б-н берлектә), Матдәләр һәм материалларның



Казанда А.Е. Арбузов исем. Органик һәм физик химия институты.

төзелешен, үзлекләрен һәм составын физик-химик тикшерүләрнең күмәк спектроаналитик үзәге, Стандарт үрнәкләр һәм реактивлар үзәге булдырыла. Институт каршында «Перспектив материаллар һәм технологияләр» фәнни-уку үзәге (Казан ун-ты һәм Казан технол. ун-ты б-н берлектә оештырыла), академиклар А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар музей-йорты бар. Фәнни эшчәнлеге һәм кадрлар әзерләве өчен ОФХИ Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә (1969). Ленин бүләгенә — 2, СССР Дәүләт бүләгенә — 2, ТР Дәүләт бүләгенә — 2, Халыкара Арбузовлар бүләгенә 1 кеше лаек була. Фәнни тикшеренү эшенә А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, А.Н.Пудовик, А.И.Коновалов һ.б. зур өлеш кертә. Институтның җитәкчеләре: Б.А.Арбузов (1965–71), А.Н.Пудовик (1972–89), А.Н.Верещагин (1989), Ә.С.Батыева (1989–90, директор вазифаларын башкаручы), А.И.Коновалов (1990–2001), О.Г.Синяшин (2001 дән).

*Әд.:* Институт органической и физической химии имени А.Е.Арбузова КНЦ РАН. Факты — люди — память. К., 2001.

*Л.В.Нестеров.*

**ОРГЫДЫ́** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ургыды елгасы буенда. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1747 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр, асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да мәчет, мәктәп, икмәк саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 329,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 66, 1816 да — 87 ир-ат; 1834 тә — 169, 1859 да — 305, 1870 тә — 455, 1897 дә — 602, 1906 да — 891, 1920 дә — 710, 1926 да — 451, 1938 дә — 344, 1949 да — 235, 1958 дә — 176, 1970 тә — 195, 1979 да — 132, 1989 да — 64, 2002 дә — 78 кеше.

**ОРЕНБУ́РГ** шәһәре, *Оренбург өлкәсе* үзәге. 1743 елда нигез салына. Халкы — 571752 (2012), татарлар — 42172 кеше (2010). Татарлар О.та шәһәргә нигез салынган көннән яшиләр. Алар Россиянең Казакъстан һәм Урта Азия якларына таралалар, мөһим тәрәк пункт булган шәһәр төзүдә катнашалар, О. чик буенда хезмәт итәләр. 1740 елларның 2 нче яртысыннан Россия дәүләте б-н Көнчыгыш илләре арасындагы сәүдә мөнәсәбәтләрендә татарлар төп рольне уйный башлый. 1761 дә О.та 109 сәүдәгәр (аларның 65% тан артыгы — татар) сәүдә итә. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында О.та татар сәнәгатьчеләренең күпләгән терлек чалу, туңмай эретү биналары; җилем, сабын кайнату, тире эшкәртү, кирпеч һәм чүлмәк ясау з-длары; икмәк пешерү биналары һәм икмәк з-длары була. 19–20 йөзләрдә сәүдә йортлары (иң эреләре — бертуган *Хөсәеновләр* һәм *Рәмиевләр* сәүдә йортлары) төзелә башлый. 1891 дә О.та сәүдәгәр Хөсәеновләр иганәсенә 6 нчы җамигъ мәчет каршында яңа ысул б-н эшләүче (җәдиди) «Хөсәения» мәдрәсәсе ачыла. Шул ук вакытта шәһәрдә зур «Вәлия» кадимчеләр мәдрәсәсе эшли. О. — татар проф. театры туган җир. 1907 дә «Сәйяр» беренче татар театры труппасы, 1915 тә «Ширкәт» труппасы оештырыла. 1916 да Оренбург мөселманнары музыка-драма җәмгыятенә нигез салына, аның каршында музыка мәктәбе (1920–23 тә аны С.Җ.*Сәйдәшев* җитәкли) эшли. 20 йөз башында О. татар китаплары басу һәм татар публицистикасы үзәкләренең берсе була. 1901 дә монда *«Г.Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе* (1902 дән улы Ф.*Кәрими* җитәкли) ачыла; 1906 да аның җирлегендә «Кәримов, Хөсәенов вә шөрәкясе» басмаханәсе төзелә, 1914 тә ул Ә.Г.Хөсәенов һәм К$^{0}$ сәүдә йортына күчә. 1906 да М.Г.Хөсәеновның *«Дин вә мәгыйшәт» басмаханәсе* ачыла, Ш.К.Шаһидуллин ширкәте һәм К$^{0}$ басмаханәсен ачуга рөхсәт бирелә, 1909 да бертуган Рәмиевләрнең «Вакыт» басмаханәсе эшли башлый. 1906–17 дә О.та татар телендә 12 вакытлы матбугат басмасы: *«Вакыт»*, *«Урал»* г-талары; *«Шура»*, *«Дин вә мәгыйшәт»*, «Ислах көтебханәсе», *«Мәгариф»*, *«Мөгаллим»*, *«Кармак»*, *«Карчыга»*, *«Чикерткә»*, *«Чүкеч»*, *«Яз»* журналлары нәшер ителә. 1906 да О.та беренче түләүсез татар китапханәләреннән берсе (хәзер Х.Ямашев исемен йөртә) ачыла. Мөселман хәйрия

һәм мәдәни-агарту оешмалары киң үсеш ала. 1898 дә — «Оренбург мөселман хәйрия җәмгыяте», 1906 да — «Оренбург губернасы мөселманнары җәмгыяте», 1912 дә — *«Оренбург мөселман хатын-кызлар җәмгыяте»*, *«Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте»*, 1917 дә «Оренбург губернасы төрки-татар укытучылары җәмгыяте», «Оренбург мөселман коммерция эшләрен башкаручылар җәмгыяте», «Оренбург мөселман хатын-кызлар комитеты» оештырыла. Хәзерге вакытта О.та «Туган тел» шәһәр татар милли-мәдәни автономиясе (1998), «Яшьлек» татар яшьләре иҗтимагый оешмасы (2003); татар телен тирәнтен өйрәнү мәктәбе эшли. Оренбург пед. ун-тының татар-башкорт бүлегендә һәм 2 нче пед. көллиятендә татар теле укытучылары әзерләнә. 2006 да «Вакыт» татар г-тасы чыга башлауның 100 еллыгына һәм М.*Җәлилнең* тууына 100 ел тулуга багышланган чаралар; «М.Җәлилнең батырлыгы һәм рухи мирасы Россия хәзинәләр системасында», «Вакыт» газетасының 100 еллыгы: Оренбург яклары татар вакытлы матбугаты», «Х.Ямашев исем. китапханә: тарих һәм хәзерге заман» бөтенроссия фәнни-гамәли конференцияләре үткәрелә. «Яңа вакыт» һәм «Болгар иле» г-талары нәшер ителә. «Якташлар» телетапшыруы һәм «Хәерле кич» радиотапшыруы чыга. *Оренбург татар драма театры* эшли. Татар халкының күп кенә күренекле вәкилләренең тормышы О. б-н бәйле.

*Әд.:* Татары в Оренбургском крае: Материалы науч.-практ. конф. Оренбург, 1997; Из истории татар Оренбуржья (к 260-летию Татарской Каргалы): Сб. материалов обл. науч.-практ. конф. Оренбург, 2005; Д е н и с о в Д.Н. История заселения и этнокультурное развитие татар Оренбургского края (XVIII — начало XX вв.). Оренбург, 2006.

*В.В.Амелин.*

**ОРЕНБУ́РГ ГУБЕ́РНАСЫ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, дини һәм хәйрия оешмасы. 1906 елның июнендә Оренбург шәһәрендә оештырыла. Гамәлгә куючылары: Ж.Н.*Байбурин*, Б.Г.Баязитов, М.М.Күрпәчев, Х.У.Донской, А.Ю.Капкаев, К.М.Мөхәммәтрәхимов. Җәмгыять б-н рәис, сәркәтип, казначы, шура җитәкчелек итә; кирәк очракта комиссияләр төзелә. Җәмгыятьнең рәисләре: Ф.Г.Кәрими (1906 дан), А.Капкаев (1908 дән), Г.Мишкин (1911 дән), Ә.Хөсәенов (1913 тән). О.г.м.җ.нең эшчәнлеге Оренбург шәһәрендә һәм Оренбург губернасында алып барыла. Беренче җыелышлар Ж.Н.Байбурин фатирында уза, аннары «Хөсәения» мәдрәсәсендә җыела башлыйлар. Төп максатлары — мохтаҗларга һәм мөселманнарның мәдәният, мәгариф оешмаларына матди ярдәм итү. Җәмгыять Дәүләт Думасына депутатлар сайлауда, шәһәр һәм земство органнарына сайлауларда катнаша, ярлы гаилә балалары укый торган мәктәпләргә, «Хөсәения» мәдрәсәсенә химая итә, ачлар өчен ашханәләр ача, мохтаҗ мөгаллимнәргә матди ярдәм күрсәтә. Җәмгыять карамагында уку залы булган китапханә эшли, анда дини һәм фәнни-популяр китапларны кычкырып уку оештырыла. Җәмгыять әгъзалары ярдәмендә Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте, Оренбург губернасының Каргалы авылында (Сәет бистәсе) хәйрия җәмгыяте төзелә. О.г.м.җ. Оренбург губернасында татар милли хәрәкәтен җәелдерү һәм үстерүгә зур өлеш кертә. Эшчәнлеге 1917 дән соң туктатыла.

*Әд.:* Я м а е в а Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественно-политическое движение (по материалам Уфимской и Оренбургской губерний). Уфа, 2002.

*А.А.Гатин.*

**ОРЕНБУ́РГ КӘРВАНСАРАЕ́**, архит-ра истәлеге. Оренбург губернаторы В.А.Перовский башлангычы б-н Петербург архитекторы А.П.Брюллов тарафыннан проектлаштырыла. Оренбург губернасы татарлары һәм башкортлары акчасы һәм губерна бюджеты хисабына төзелә. Төзелеш эшләре 1837 елда Оренбург шәһәре чигенең тышкы ягында башлана;



Оренбург кәрвансарае. Арх. А.П.Брюллов. 1837–46. 20 йөз башы фоторәсеме.

1842 дә төп корпусы төзелә, мәчет төзелеше тәмамлана; 1846 да Кәрвансарайны ачу тантанасы була. 5 *га* дан артык мәйдандагы парк б-н әйләндереп алына. Төп корпустан, мәчеттән һәм манарадан тора. Композициянең нигезендә — эчке ишегалды булган төп корпус. Башка 2 бина төп корпус контурына кертелгән һәм симметрия күчәренә «утыртылган». Мәчетнең гөмбәз б-н ябылган сигез кырлы бинасы композициянең үзәге булып тора, манарасы ишегалдына керү ягында төзелгән. Төп корпус П-рәвешле форма ясый торган, биеклекләре бер үк төрле 5 корылма кушылмасыннан гыйбарәт. Ул көньякка таба ике капкалы ярымачык ишегалдын колачлый (48х53 *м*). Баштарак бинада үрнәк остаханәләре булган уч-ще урнаштыру карала, биредә ш.у. офицерларның һәм мишәр-башкорт гаскәрләре башлыкларының фатирлары урнашырга тиеш була. Һәр учреждениегә аерым ишек аша керелә. Барлык 13 ишек тә эчке ишегалды ягында: 3 әр ишек көнчыгыш һәм көнбатыш якларда, 5 ишек — төньякта һәм ат б-н керү өчен берәр ишек ян-якта урнашкан. Корпуста катлар арасында йөрү өчен 5 урында баскыч төзелгән. Хуҗалык ихтыяҗлары өчен төп корпуска көнчыгыш һәм көнбатыш яклардан тоташкан аерым ишегаллары беренче катның ике ягында урнашкан а́ркалы уемнар аша үтәргә мөмкин була.

Бина шәрекъ-мөселман архит-расының стильләшкән элементлары файдаланылган (өч калаклы һәм уксыман а́ркалар) әүвәлге эклектика стилендә бизәлгән. Төп корпусның эчке ишегалдына караган фасадлары биеклеге буенча икенче каттагы тәрәзә төпләре һәм кат арасындагы түшәмә тигезлегендә сузылган горизонталь билбауларга бүленгән. Бик нык рустланган ниргәдән югарырак, беренче катның шома диварларындагы шпора сыман аркаларга охшашлы сай куышларга квадрат тәрәзәләр һәм ишекләр урнашкан. Икенче кат фасадлары, беренче каттагы тәрәзәләр кебек, өч калаклы а́рка б-н очланган куышлар эченә кертелгән биек, турыпочмаклы тәрәзәләр б-н бүлгәләнгән. Тәрәзәләр арасындагы киң диварлар шундый ук а́ркалы куышларга ябылган ялган тәрәзәләргә әйләндерелгән. Бинаны гади профильле кәрниз һәм фризның киң тасмасы төгәлли. Тышкы фасадлар башкача хәл ителгән. Сирәк тәрәзәле дивар өслеге шома калдырылган. Төп фасадның почмакларына өскә таба тараеп баручы ризалитлар төс биреп тора, өске өлеш исә үзенчәлекле сталактит фриз б-н бизәлгән; кәрниз өстеннән дүрт катланып түбә очланып күтәрелә. Башка тышкы фасадлар төп фасад б-н тәңгәл эшләнгән. Бинаның һәр почмагына кечкенә манаралар куелган. Кирпеч диварлар штукатурланган һәм буялган. Катлар араларындагы түшәмәләрнең күпчелеге тышкы диварларга һәм эчке биналарга терәлеп торган кирпеч гөмбәзләрдән тора, түшәмәләрнең калган өлешенә яссы агач матчалар сузылган. Күп кенә бүлмәләр үтәли йөрелмәле итеп эшләнгән, шунлыктан коридорлар мәйданы шактый кимегән.

Мәчет турыпочмаклы ишегалдының үзәгендә урнашкан. Аның фәзаи-планлаштыру чишелеше күчмә халыкларның тирмәсен хәтерләтә. Мәчет төзек сигезпочмаклык формасында төзелгән. Ишек төньяк ягында урнашкан. Көньяк фасадта михраб чыгынтысы юк. Бина гөмбәз б-н ябылган. Аның түбән өлеше — шарсыман, өске өлеше конуссыман формада эшләнгән. Гөмбәз басымын бина почмакларында диварларга күчерүче уксыман тәрәзә а́ркалары гөмбәзнең терәге булып хезмәт итәләр. Тышкы яктан почмаклар диварлар б-н бөтенлек тәшкил итүче турыпочмаклы киселештәге контрфорслар б-н ныгытылганнар. Гөмбәз өслегенең интерьеры биеклеге буенча боҗралар формасындагы 2 горизонталь сызык б-н 3 өлешкә бүленгән: иң югарысының үзәгендә, зәңгәр фонда кояш сурәтләнгән, аның тирәли 8 ай урагы һәм күп кенә алтыпочмаклы йолдызлар; ике боҗралы сызык арасындагы урта өлеш тигез 8 кисәккә бүленгән. Кырлар сылап ясалган бертөрле бизәкләр б-н бизәлгән. Гөмбәзнең аскы өлеше буенча чәчәк витражлары куелган а́ркалы тәрәзәләр урнашкан. Мәчетнең тәрәзәсез шома диварлары мәрмәр б-н эшләнгән, почмаклар пилястралар б-н бизәлгән. Алар өстеннән бинаның 3 ягын колачлап алган тар галерея үтә. Тәрәзәләрне әйләндереп алган һәм ниргәгә кадәр төшерелгән киң архивольтлар мәчет фасадларының бердәм архитектур бизәлеш үрнәге итеп файдаланылган. Биек, өч яруслы итеп төзелгән манараның зур дүрткырлык рәвешендәге түбәнге ярусы сигезкырлыкка, аннары — күпкырлык рәвешен-

дә — урта яруска күчә. Манара кәүсәсенең каннелюр рәвешендә бизәлгән 24 кыры тыштан ялтыравык йөгертелгән ак төстәге чыная к кирпеч б-н капланган. Манараның урта ярусы сталактит кәрниз б-н төгәлләнгән, аның өстеннән челтәрле металл рәшәткә б-н тотылган галереялы, цилиндр формасындагы өченче ярус калкып чыга. Манара очлы башлы конус рәвешендә төгәлләнгән.

Комплекс кәрвансарай буларак билгеле, чөнки баштарак Оренбургка килгән мөселманнарны урнаштыру өчен тәгаенләнә, ләкин төзелеш тәмамлангач та, мишәр-башкорт гаскәре командующиеның канцеляриясен, офицерлар фатирларын, солдатлар казармаларын О.к.на күчерәләр. Әлеге гаскәрне 1863 тә таратканнан соң, комплексга кабулханәләр, губернатор фатиры урнаша. Мөселманнарга мәчет һәм руханилар өчен 2 фатир калдырыла. 2006 да О.к. реставрацияләнә. Комплекска Оренбург өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәте, мәдрәсә керә.

*Әд.:* Караван-сарай: Ист.-архитектурное описание памятника зодчества. Уфа, 1995.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ОРЕНБУ́РГ МӨСЕЛМА́Н ДИНИ́Я НӘЗАРӘТЕ́**, к. *Россия һәм БДБнең Европа илләре мөселманнары диния нәзарәте.*

**ОРЕНБУ́РГ МӨСЕЛМА́Н ХАТЫ́Н-КЫЗЛА́Р ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1912 елның маенда оештырыла. Гамәлгә куючылары: Ф.М. һәм З.М.Әдһәмовалар, Х.М.Котлыбулатова, Р.Б.Мөхәммәдъярова, З.М.Рәмиева, Б.Сөләйманова, Ф.М.Тенишева, Ф.М.Ураева, М.И.Хөсәенова. Төп максаты — мөселман хатын-кызлар өчен уку йортлары челтәрен җәелдерүгә ярдәм итү, хатын-кызларның ялын һәм көнкүрешен кайгырту. Эшчәнлеге 1917 дән соң туктатыла.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**«ОРЕНБУ́РГ МӨСЕЛМА́Н ХӘРБИ́-ИНКЫЙЛА́Б КОМИТЕТЫНЫ́Ң МӨХБИРЕ́»**, иҗтимагый-сәяси газета. Шул ук исемдәге оешма органы. 1918 елның 19 февраленнән 29 маена кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә атнага 1–3 тапкыр нәшер ителә, барысы 30 саны чыга. Актив авторлары арасында — Ф.Әмиров, Ф.Бакайский, Г.Габидов, С.Гайфи, Б.Камский, К.Ризван, Х.Сәйфи, Ю.Фәхретдинов, К.Шәркый. Газета Татар-башкорт автономияле респ-касы төзүне яклап чыга. Оренбург хәрби инкыйлаб ком-ты эшчәнлеген, Мөселман эшчеләре берлегенең 1 нче һәм 2 нче съезды эшен яктырта. Басмада К.Маркснең эшчәнлеге һәм тәгълиматы турындагы материаллар, М.Килдебәков, Ф.Мәҗит шигырьләре басыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ОРЕНБУ́РГ МӨСЕЛМА́Н ШӘКЕРТЛӘРЕНӘ́ ЯРДӘ́М ИТҮ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1912 елның маенда оештырыла. Гамәлгә куючылары: М.М.Рәмиев (рәис), Г.Г.Хөсәенов (казначы), М.Г.Кәримов (Ф.Кәрими), С.М.Рәмиев, Х.З.Фәйзуллин, Г.Р.Фәхретдинов, Х.М.Хөсәенов, Б.Б.Шәрәф. Төп максатлары: мөселман мәктәп-мәдрәсәләре эшчәнлеген җәелдерүгә иганә кылу һәм ярдәмгә мохтаҗ шәкертләргә булышлык итү. Эшчәнлеге 1917 дән соң туктатыла.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**«ОРЕНБУ́РГ МӨХБИРЕ́»** (أورنبـورغ مخبر — «Оренбург хәбәрчесе»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. Оренбург мөселман бюросы органы. Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Беренче саны 1917 елның июлендә чыга. Мөхәррирләре — Б.Шәрәф (к. *Шәрәфләр*), М.Рәфыйков һ.б. «О.м.»дә рәсми хәбәрләр, төрле оешмаларның карарлары басыла. Газетадагы материаллар, нигездә, мәгълүмати характерда. Илдәге әчке сәяси вакыйгаларга кагылышлы ачык кына позициясе булмый.

*Әд.:* Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

**ОРЕНБУ́РГ ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Көньяк Уралда урнашкан. 1934 елның 7 декабрендә оештырыла. Мәйданы — 124 мең *км²*. Үзәге — *Оренбург* шәһәре. Халкы — 2016086 кеше (2012). Татарлар саны: 1959 да — 120944, 1989 да — 156564, 2002 дә — 165967, 2010 да 151492 кеше. Алар тупланып Оренбург (42172 кеше), *Орск* (9170), Богырыслан (5120) шәһәрләрендә; Әсәкәй (10383), Абдулин (5731), Матвеевка (3944), Сакмар (5922), Переволоцкий (4660), Тоцкий (2953), Илек (2873) р-нnарында яшиләр. О.ө. терр-ясендә татарлар 17 йөздә урнаша башлый. 1610–20 елларда йомышлы татарларга тарханлыкка чолыкчылык (урман умартачылыгы) өчен җирләр бирелә, һәм хәзерге Әсәкәй, Богырыслан, Матвеевка, Пономарёвка һәм Северный р-ннарында кушылдыклары булган Сок, Зур һәм Кече Кенәле елгаларында кондыз ауларга рөхсәт ителә. Халыкны бу җирләргә утырту берничә этапта бара. 1 нче этап Россия империясенең көньяк-көнчыгыш читендәге халык сирәк урнашкан җирләрне үзләштерү һәм 1734–44 тә бу җирләрне өйрәнүче Оренбург экспедициясе (комиссиясе) эшчәнлеге б-н бәйле. Яңа терр-яләрне саклау өчен Оренбург хәрби-чик буе ныгытмасы төзелә. Монда, башкалар б-н бергә, хөкүмәт тарафыннан күчерелгән татарлар да хезмәт итә. 1730–70 тә күченгән татарлар Яңа Мәскәү юлы буйлап О.ө.нең хәзерге Октябрьский, Шарлык, Пономарёвка, Матвеевка һәм Абдулин р-ннары терр-яләренә, крайның төньяк-көнбатышы — Әсәкәй һәм Северный р-ннарына, ш.у. Оренбург губернасының сәяси һәм икътисади үзәге — Оренбург тирәсенә төпләнәләр. Аларның күпчелеге хәзерге ТРның Саба, Балтач, Кукмара, Теләче, Мамадыш, Әгерҗе, Кама Тамагы, Апас, Кайбыч р-ннарыннан күчеп килә. 1744 тә Оренбург янында *Каргалы бистәсе* төзелә, һәм ул озак еллар Россия татарларының мәшһүр сәүдә-икътисади, мәгърифәт һәм мәдәни үзәге булып кала. Аның халкы Россиянең Урта Азия һәм Көнчыгыш илләре б-н сәүдә бәйләнешләрендә арадашчы ролен үти. 18 йөзнең 2 нче яртысында Оренбург һәм Троицк чик буе товар алмашуларында татарлар өстенлек итә. Экспортка, нигездә, йон һәм җитен тукыма, эшкәртелгән күн (юфть, сафьян), буяулар, металл эшләнмәләр, ашлык чыгарыла. 1780–1820 елларда (2 нче этап) татарлар актив рәвештә Тоцкий, Ташлы, Сорочинский һәм Новосергиевка р-ннарының чүлле җирләренә, хәзерге Саракташ һәм Переволоцкий р-ннарының Урал һәм Сакмар елгалары яр буйларына төпләнәләр; кайбер торак пунктлар хәзерге Абдулин, Әсәкәй, Матвеевка, Новосергиевка, Кызыл Гвардия һәм Беляевка р-ннары терр-ясендә төзелә. Күчеп килүчеләрнең төп төркеме ТРның хәзерге Чүпрәле, Буа, Әлки һәм Спас р-ннары терр-яләреннән килә, миграция ш.у. БРның Ярмәкәй, Әстәрлебаш р-ннарыннан, Татарстанның Әлмәт, Лениногорск һәм Сарман р-ннарыннан да була. 19 йөз башында Каргалы сәүдәгәрләре башкортлар арендалаган җирләрдә поташ һәм сабын кайнату производствосы оештыра. 3 нче этапта (1820–50 еллар) күченүчеләрнең күбесе өлкәнең хәзерге Александровка р-ны, кайберләре Северный һәм Абдулин р-ннары терр-яләренә юнәлә. Алар, башлыча, — *Мордва Республикасының* хәзерге Ельник, Темников, Ләмбрә һәм Атюрьев р-ннарыннан чыккан кешеләр. 4 нче этапта (1860 еллар — 20 йөз башы) күченүчеләрнең күбесе Оренбург, Орск һәм Тозтүбә шәһәрләренә юнәлә. Татар мигрантларының күбесе хәзерге Татарстанның төньяк-көнбатыш (Әтнә, Балтач, Кукмара) һәм Башкортстанның көньяк һәм үзәк р-ннарыннан була. Оренбург төбәгенә татарлар урнаша башлауга, монда мөселман мәгърифәте һәм мәдәниятенең мәшһүр үзәге оеша. 19 йөз башында Оренбург губернасының 12 өязендә — 1258 агач һәм 4 таш, 19 йөз уртасында 1925 агач һәм 7 таш мәчет була. 1916 да хәзерге О.ө. чикләрендә 226 мәхәллә (казакъ торак пунктларын исәпләмичә) эшли. Зур мөселман җәмгыятьләре Каргалы бистәсендә (10 мәчет), Оренбургта (8), Яңа Муса (6), Орскида (5) оештырыла. 1899–1901 дә Г.Г.Хөсәенов иганәсенә Каргалы авылындагы 9 нчы җамигъ мәчет каршында яңа аваз системасы б-н укыту буенча укытучыларның белемен күтәрү курслары оештырыла. 1903 тә Орскидагы 3 нче җамигъ мәчет каршында җәдит мәдрәсәсе ачыла. Яңа ысуллы мәктәпләр Оренбургта, Каргалы бистәсендә, Алабайтал, Линевка, Рәдүт, Микул һ.б. авылларда эшли. Троицкида «*Акмулла*» ж-лы чыга. Оренбург губернасында мөселман хәйрия җәмгыяте һәм культура-агарту оешмалары киң үсеш ала. 1901 дә — «Троицк мөселман хәйрия җәмгыяте», 1906 да — «Чиләбе мөселман хәйрия җәмгыяте», «Тозтүбә шәһәре мөселман җәмгыяте», «Җиде Үсергән волосте мөселман җәмгыяте», «Сәет бистәсе мөселман җәмгыяте», 1908 дә — «Пречистенский станицасының Никитинский посёлогы мөселман җәмгыяте», 1911 дә — «1 нче Имангол хәйрия мәдәни-икътисади җәмгыяте» һәм «2 нче Имангол авылы хәйрия җәмгыяте», 1913 тә «Романовлар Йорты патшалык итүенең 300 еллыгына багышланган Троицк «Хәйрәт» җәмгыяте», «Романовлар Йорты патшалык итүенең 300 еллык юбилеена багышланган Чиләбе хәйрия җәмгыяте» ачыла. Хәзерге вакытта О.ө.дә 9 татар милли берләшмәсе эшли. Өлкәнең 75 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла (татар теле һәм әдә-

бияты буенча Казанда уздырыла торган төбәгара олимпиадаларда укучылар берничә ел рәттән призлы урыннар алалар). 2006 да О.ө.нең Әсәкәй р-нында татар теле укытучыларының өлкә семинары уздырыла. 170 тән артык татар иҗат төркеме эшли. Новотроицк шәһәрендә «Урал авазлары» радиотапшыруы чыга. Өлкәнең көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш р-ннары Казан телетапшыруларын тота. Төбәк милли сәясәтен тормышка ашыру кысаларында өлкә хөкүмәте Мостафа авылында М.*Җәлилгә* багышланган мәдәни комплекс (музей, китапханә, мәдәният йорты) төзүдә, «*Моабит дәфтәре*» җыентыгын яңадан бастыруда, *Оренбург татар драма театрын* ремонтлауда, Сабан туе бәйрәмен үткәрүдә (2007) шактый гына зур финанс ярдәме күрсәтә. Татар халкының күп кенә күренекле вәкилләре: дин эшлеклеләре Г.*Утыз Имәни*, М.*Хөсәенов*, Г.*Габдерәхимов*, Г.*Сөләйманов*, Р.*Фәхретдинов*, М.*Бигиев*; шагыйрьләр С.*Рәмиев*, С.*Сүнчәләй*, М.Җәлил; язучылар Ш.*Камал*, Ф.*Кәрими*; драматург М.*Фәйзи*; композитор С.*Сәйдәшев*; сәнгатьче һәм җәмәгать эшлеклеләре бертуган *Хөсәеновләр* һәм *Рәмиевләр*; дәүләт эшлеклесе Ш.*Усманов* һ.б.ның тормышы О.ө. б-н тыгыз бәйле.

*Әд.:* Татары в Оренбургском крае: Материалы науч.-практ. конф. Оренбург, 1997; Из истории татар Оренбуржья (к 260-летию Татарской Каргалы): Сб. материалов обл. науч.-практ. конф. Оренбург, 2005; Д е н и с о в Д.Н. История заселения и этнокультурное развитие татар Оренбургского края (XVIII — начало XX вв.). Оренбург, 2006; Подвиг и духовное наследие М.Джалиля в системе российских ценностей. Оренбург, 2006.

*В.В.Амелин.*

**ОРЕНБУ́РГ ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ**. 1907 елда И.Кудашев-Ашказарский тарафыннан оештырылган «Россиядә беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы»ннан (к. «*Сәйяр*») башлангыч ала, 1915 тә аның җирлегендә В.Мортазин-Иманский тарафыннан «*Ширкәт*» төркеме булдырыла. Аның составында С. һәм Җ.Байкиннар, Л.Сыртланова, Ф.Сәмитова, Г.Мангушев, М.Мортазин, М.Мутин, Ф.Камская, Камал I була. Репертуарында Г.Камал, Г.Исхакый, Ш.Камал, М.Фәйзи, Ф.Сәйфи-Казанлы, И.Богданов, Ж.Б.Мольер, Н.В.Гоголь, А.Н.Островский пьесалары урын ала. 1920 дә Камал I «Шәрекъ» труппасын оештыра, аның составына «Ширкәт» һәм «Берек» («Союз») театрлары труппалары актёрлары Ф.Ильская, И.Әлмәшев, Х.Әбҗәлилов, С.Кудашев керә. Театрда ш.у. Ф.Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь»), П.Джакометтиның «Җинаятьче гаиләсе» («Семья преступника»), А.Андриенконың «Хезмәткә дан» («Слава Труду») әсәрләре буенча да спектакльләр куела. 1921 дә труппага *Самара татар драма һәм музыка студиясен* тәмамлаучылар килеп кушыла, ул «Г.Кариев истәлегенә» дип атала башлый. 1922–23 тә труппа кабат — «Шәрекъ», 1923–24 тә «Туплан» исеме ала. 1925 тә Оренбург шәһәр советы аңа бина бирә, анда труппа, башта «Татар артистларының драматик коллективы», соңрак «Йолдыз» исеме б-н аталып, даими рәвештә эшли башлый. 1931–32 дә коллектив Оренбург колхоз-совхоз театры дип үзгәртелә, 1938 дән «Идел буе колхоз-совхоз театры» дип атала, 1941 дән концерт бригадасы буларак яши башлый һәм 1949 дан Оренбург филармониясе составына керә. 1989 дан яңадан хәзерге исемдәге стационар дәүләт театры, 1991 дән М.Фәйзи исемендә. Театрда төрле елларда актёрлардан Г.Әхмәтова, Ф.Камалова, Р.Кушловская, Җ.Хәмидуллина, Х.Ханская, Ф.Бакиров, С.Габитов, М.Илдар, Х.Кәтиев, Ш.Мәҗитов, Ю.Уральский, В.Фатыйхов һ.б. эшли. Спектакльләр И.Әлмәшев,



Оренбург татар драма театры труппасы. 1929.

С.Вәлиев-Сульва тарафыннан куела. 1989 дан театрның баш режиссёры, 1990 нан директоры һәм бер үк вакытта сәнгать җитәкчесе — ТР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе Р.Абдуллаев; театр труппасында РФнең атказ. артисты Л.Абдуллаева, ТРның атказ. артистлары А.Хәбибуллин, Н.Фатыйхова, актёрлар М.Рәхмәтуллин, М.Мәхмүтова, Н.Дибаева, А.Мостафин, Д.Сәлахов, М.Сәгыйтова һ.б. эшли. Репертуарын Г.Камалның «Банкрот», З.Хәкимнең «Алтын тарак», Ф.Бүләковның «Дүрт әби һәм Әхмәди», А.Нәсиннең «Алтын туй» («Золотая свадьба»), А.Н.Островскийның «Капкан саен калҗа булмый» («Не всё коту масленица»), Д.Салиховның «Хатын түгел — аждаһа», М.Гыйләҗевнең «Кар астында кайнар чишмә», Ә.Гаффарның «Язлар моңы», Т.Миңнуллинның «Алты кызга бер кияү», «Нәзер», К.Тинчуринның «Хикмәтле доклад» әсәрләре буенча спектакльләр тәшкил итә. Театр Россия буйлап гастрольләрдә йөри, еш кына Казанга килә; төрки халыкларның халыкара «Нәүрүз» театр фестивальләрендә, К.Тинчурин исем. респ-ка фестивалендә актив катнаша.

*Әд.:* Г о б ә й д у л л и н Х. Оренбург татар театры // Татар совет театры. К., 1975.

*И.И.Илялова.*

**ОРЕ́ХОВ** Ян Владимирович (21.12.1970, Куйбышев өлкәсенең Нефтегорск пос.), хәрби дирижёр, педагог, ТРның халык артисты (2010), подполковник (2006). Мәскәү консерваториясенең хәрби-дирижёрлык ф-тын тәмамлагач (1995), Оренбург өлкәсенең Тоцкий посёлогында 2117 нче хәрби частьның хәрби дирижёры, 1996 елдан Казанның югары хәрби командирлар уч-щесе оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ОРЕ́ХОВКА** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 18 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 211 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган вакытыннан ТАССРның Арча кантоны Ильинка волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 72, 1949 да — 355, 1958 дә — 202, 1970 тә — 194, 1979 да — 173, 1989 да — 100, 2002 дә — 128 кеше.

**ОРЕ́ШИН** Павел Яковлевич (27.8.1907, Казан губ., Зөя өязе Тихий Плёс а. — 13.12.1972, Югары Ослан р-ны Югары Ослан а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Тихий Плёс авылында чиркәү-приход мәктәбен тәмамлый (1920). Бөек Ватан сугышында катнаша. Югары Ослан р-нында эшли: «Спартак» к-зында хисапчы (1931–32), Тихий Плёс авыл советында бухгалтер (1932–33), «Пробуждение» к-зы рәисе (1933–34), Каинки авылында авыл советы рәисе (1934–35), «Заречный» к-зы рәисе (1935–38), Куралово МТСында директор урынбасары (1938–41), район башкарма ком-тының а.х. бүлеге мөдире (1945–53). 1953–69 да Ворошилов исем. к-з (1957 дән «Путь к коммунизму» тәҗрибә-үрнәк хуҗалыгы) рәисе. О. җитәкләгән елларда хуҗалыкта электростанция (1953), техник-җитештерү корылмалары, колхоз сөт з-ды (1954) төзелә. Хуҗалык акчалата керем буенча Татарстанда елына 1 *млн* сум керем алучы колхозларның беренчесе була. Колхозда берничә тапкыр үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен җитештерү технологиясе һәм оештыру мәсьәләләре буенча респ-ка һәм союз семинарлары уздырыла. Бу хуҗалыкның тәҗрибәсен Болгариядән, Румыниядән килгән делегацияләр өйрәнә. СССР ЮС (1954–58), ТАССР ЮС (1959–63) депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К у р к и н М.И. Колхоз имени Ворошилова. К., 1955.

**ОРЕ́ШИНА** Нонна Николаевна (30.6.1933, Мәскәү), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2005). 1939 елдан Казанда. Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1956). 1957–69 да шунда ук укыта, 1969–71 дә Казан авиаотряды авиахимия эшләре эскадрильясы инженеры, 1973–88 дә «Правда» г-тасында хәрби бүлекнең махсус хәбәрчесе. О. очкыч аппаратларның 36 төрендә 800 дән артык очыш ясый, парашют б-н сикерә. Аның иҗаты хәрби, гражданнар һәм спорт авиациясе кешеләренә багышлана. «Сиңа унҗиде» («Тебе семнадцать», 1967), «Беренче адым» («Первый шаг», 1971), «Күк белән янәшә...» («А небо рядом...», 1982), «Җирдән атлау» («Шаг по земле», 1983), «Чиксез күк» («Такое огромное небо», М., 1984), «Кошлар кебек!..» («Хочу как птица!», 1993) исемле хикәяләр һәм повестьлар, «Күкнең бер йотым һавасы» («Высокого неба глоток», М., 1988) исемле очерклар җыентыклары, психол. «Соңрак шартлаячак мина» («Мина

замедленного действия», 2003) романы һ.б. авторы. ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә. Г.Державин исем. әдәби бүләк лауреаты (2010).

*Әд.:* Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

**ОРЁЛ** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 34 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 838 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 69%, татарлар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — җәнлек үрчетү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 176, 1958 дә — 216, 1970 тә — 256, 1979 да — 508, 1989 да — 843, 2002 дә — 838 кеше.

**ОРИБАТИДЛА́Р**, к. *Каты кабыклы талпаннар.*

**ОРИЕНТАЛИ́СТИКА**, к. *Шәркыять гыйлеме.*

**ОРЛИ́НСКИЙ** Борис Михайлович (5.11.1933, Нальчик ш.), нефтьче, геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1979), проф. (1986). Грозный нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), ВНИИгеофизиканың Идел-Урал ф-лында (Октябрьский ш.) эшли. 1961 елдан ТатНИПИнефтьтә, 1980 нән ВНИИнефтепромгеофизикада (Октябрьский ш.), 1984 тән Уфа нефть техникасы ин-тының геофизик тикшеренү ысуллары каф. мөдире. О. радиометриянең нейтрон алымнарын куллану тирәнлеген ачыклый, нефть һәм су катламнарын аерып алу технологиясен эшли, сулы-нефтьле зонаның төзелеше үрнәген нигезли, нефть чыгаруның геофизик ысулларын эшләүдә катнаша, нефть чыгаруны контрольдә тоту өчен геофизик алымнарны нигезле куллану принципларын формалаштыра.

**ОРЛО́В** Александр Кириллович (12.10.1923, Тәтеш кантоны Чинчурино а. — 12.4.1999, Мәскәү), хокук белгече. Бөтенсоюз юридик читтән торып уку ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1955). 1950–54 елларда ТАССР Югары мәхкәмәсе әгъзасы, 1954–58 дә рәисе, 1958–59 да рәисе урынбасары. 1959–61 дә Ульянов өлкә мәхкәмәсе рәисе. 1962–72 дә РСФСР Югары мәхкәмәсе рәисенең 1 нче урынбасары, 1972–84 тә рәисе. Мәхкәмә практикасы мәсьәләләре буенча мәкаләләр авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Кызыл Йолдыз», 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*М.М.Мәүләтшин.*

**ОРЛО́В** Александр Петрович (18.5.1929, Спас кантоны Зур Алан а. — 10.6.1982, Биектау р-ны Шәпше а.), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Тәмте а.х. мәктәбен (1949), Чабаксар совет-партия мәктәбен (1961) тәмамлый. Алексеев р-нында: Алексеев авылында көтүче (1945–47), Зур Алан МТСында хисапчы (1953–54), ВЛКСМның район ком-ты инструкторы (1954–56), ДОСААФның район оешмасы рәисе (1956–57), КПССның район ком-ты инструкторы (1957–58); Биектау р-нында: «Урак һәм Чүкеч», «Дружба» к-злары партия оешмалары секретаре (1961–62), «Урак һәм Чүкеч» к-зы рәисе (1962–82), бу колхоз О. җитәкчелегендә икътисади артта калган хуҗалыктан Татарстанның алдынгы, югары табышлы колхозларының берсенә әверелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан — 1970 тә 19,1 *ц*, 1982 дә 24,6 *ц* тәшкил итә. 1 сыердан уртача савым 1970 тә 3605 *кг*, 1980 дә 3760 *кг* була. Шәпше тәҗрибә посёлогы төзелеше өчен («Урак һәм Чүкеч» к-зы үзәк утары) О.ка СССР МС бүләге бирелә (1973). ТАССР ЮС депутаты (1980–84). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ОРЛО́В** Алимҗан (Галимҗан) Мостафа улы (10.10.1929, хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Сергач р-ны Камка а.), тарихчы, филос. фән. канд. (1977). Кучкай Пожары пед. уч-щесын (1951), Горький югары партия мәктәбен (1960) тәмамлый. 1951–56 елларда ВЛКСМның Горький өлкәсе Кызыл Октябрь райкомында 1 нче секретарь. 1960–67 дә Горький өлкәсе башкарма ком-ты аппаратында эшли. 1967–97 дә Горький а.х. ин-тында укыта. 1990 да Түбән Новгород «Туган як» татар мәдәнияте җәмгыятен (хәзер Түбән Новгород татар мәдәнияте үзәге) оештыра һәм җитәкли, 2012 дән үзәкнең шәрәфле рәисе. Хезмәтләре татарлар тарихына, милләтара мөнәсәбәтләргә, диннәрнең социаль җирлеген ачыклауга карый.

Х е з м.: Мещера, мещеряки, мишари. К., 1992; Нижегородские татары: Этнические корни и исторические судьбы. Н.Новгород, 2003 (автордаш).

**ОРЛО́В** Григорий Алексеевич (2.12.1933, Ярославль өлкәсенең Шибаново а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), техник фән. канд. (1979). 1965 елда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый. 1959–71 дә һөнәри-техник уч-щедә эшли (Бөгелмә ш.), 1968 дән — директор, 1971–2005 тә ТатНИПИнефтьтә, сектор мөдире (1978 дән), лаб. мөдире (1986–2001). 2006 дан «Наука» ААҖдә әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре нефть чыгаруны интенсивлаштыруга карый. Дәүләт бүләге нефть скважиналарын саклау, яңадан торгызу һәм аларның продуктлылыгын арттыруга юнәлтелгән техник һәм технол. комплекс эшләгәне һәм сәнәгатькә керткәне өчен бирелә. Скважиналардан файдалану технологияләре Татарстан, Удмуртия, Көнбатыш Себер нефть промыселларында гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 44 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә (1993). Нефть сәнәгате отличнигы (1981), СССРның уйлап табучысы (1985).

**ОРЛО́В** Дмитрий Александрович (23.3.1894, Пенза ш. — 1937), партия эшлеклесе. Пензада гимназия тәмамлый, Мәскәү ун-тында укый. 1914 елдан РСДРП әгъзасы, революцион хәрәкәттә катнаша. Кулга алынганнан соң, 10 айдан артык Таганка төрмәсендә (Мәскәү) утыра. 1916 да гомерлеккә Иркутск губернасына җибәрелә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Мәскәүгә кире кайта. 1917 нең августында Россия армиясенә алына, 192 нче пехота полкы рядовое. Окт. рев-циясендә (Мәскәү), Гражданнар сугышында катнаша. 1919 да Респ-ка Запас армиясенең сәяси бүлек башлыгы (армия штабы 1919 ның сентябре — 1920 нең декабрендә Казанда урнаша). 1920–21 дә РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1920–23 тә бюро әгъзасы, Профсоюзларның Татарстан өлкә советы секретаре, «Известия Татцик» г-тасының җаваплы мөхәррире, соңыннан Пенза, Свердловск шәһәрләрендә партия эшендә. 1929 дан Воронеж шәһәрендә: өлкә җир идарәсе, ВКП(б) өлкә ком-тының а.х. бүлеге мөдире, өлкә башкарма ком-ты рәисе урынбасары, рәисе. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* С а р к и н В., Ш е х о в а А. Орлов Дмитрий Александрович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

**ОРЛО́В** Иван Николаевич (24.12.1834, Мәскәү — 30.8.1907, Петербург губ. Павловск ш.), хокук белгече, сенатор (1877), хакыйкый яшерен советник (1896). Дворяннар катлавыннан. Александр лицеен тәмамлый (С.-Петербург, 1854). 1854–60 елларда Юстиция министрлыгында хезмәт итә, 1860–64 тә — Диңгез эшләре министрлыгының Корабльләр төзү департаментында (С.-Петербург). 1866–68 дә Петербург округ мәхкәмәсе әгъзасы, 1868–69 да Курск округ мәхкәмәсе рәисе иптәше (урынбасары), Харьков мәхкәмә палатасы прокуроры иптәше. 1869–71 дә Симферополь, Херсон, Бессарабия төрмә ком-тлары вице-президенты. 1871–77 дә Казан мәхкәмә палатасы өлкән рәисе. Казан мәхкәмә округы терр-ясендә Мәхкәмә реформасы уздыруга өлеш кертә. 1881–83 тә Киев мәхкәмә палатасы өлкән рәисе. 1877–81, 1883–90 да — Сенатның җинаять эшләре кассацияләре, 1890 нан 1 нче департаментында. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Альманах современных русских государственных деятелей. СПб., 1897.

*Е.Б.Долгов.*

**ОРЛО́В** Наум Юрьевич (20.2.1924, Украина ССРның Чернигов ш. — 1.8.2003, Чиләбе ш.), режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970), РСФСРның халык артисты (1985). 1949 елда Киев театр ин-тын (режиссёрлык һәм театр сәнгате белеме ф-тларын) тәмамлый. Александрия, Одесса (Украина ССР) театрларында баш режиссёр, 1962–65 тә Одесса киностудиясе каршындагы кино актёры студиясенең сәнгать җитәкчесе. 1965–73 тә Казан Зур драма театрында баш режиссёр, бер үк вакытта Казан театр уч-щесендә укыта. О. режиссурасына драматургия материалының тирән укылышы, сурәтләнә торган чорның тарихи чынбарлык күренешләренә зур игътибар, катнашучылар характерларының җентекле эшләнеше хас, болар М.Горькийның «Зыковлар» («Зыковы», 1966) һәм «Варварлар» («Варвары», 1972), М.А.Булгаковның «Качу» («Бег», 1967), Н.Думбадзеның «Мин, әби, Илико һәм

Илларион» («Я, бабушка, Илико и Илларион», 1969), Д.Н.Мамин-Сибирякның «Төшемле урында» («На золотом дне», 1970), А.С. һәм П.Л.Турның «Бердәнбер шаһит» («Единственный свидетель», 1971) әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә аеруча ачык чагылыш таба. Конфликтның кискенләшүе, вакыйгалар барышы, төп персонажлар характеристикасының социаль төгәллеге хисабына классик әсәрләр заманча яңгыраш ала. Сатирик әсәрләрне («Мунча» («Баня»), В.В.Маяковский, 1967; «Геростратны онытыргамы?» («Забыть Герострата?»), Г.И.Горин, 1973) сәхнәләштергәндә, О. гротеск алымнарыннан, сәхнә метафорасының мәгънәви байлыгыннан файдалана. А.П.Штейнның «Көчле яңгырлар арасында» («Между ливнями», 1969), В.В.Вишневскийның «Беренче атлы армия» («Первая конная», 1970), Д.Н.Вәлиевнең «Дәвам» («Продолжение», 1972) әсәрләре буенча куелган спектакльләр эпик зурлыклары ягыннан аерылып торалар. Сәхнә алымнарының төрлелеге, спектакльләр бизәлешенең поэтик тәэсирлелеге, вакыйгаларның интеллектуальлеге һәм логик чишелеше ягыннан О. куйган спектакльләр театр сәнгатендә зур казаныш була, Казан Зур драма театры тарихында сизелерлек эз калдыра. Театрның сәнгать җитәкчесе буларак, ул кадрлар һәм репертуар сәясәтенә күп игътибар бирә. Аның тарафыннан театр труппасына актёрлардан П.П.Бетев, Г.И.Ишкова, Ю.А.Коршок, В.Г.Острапольский, Б.Н.Петров, Л.Б.Кара-Гяур, Мәскәү һәм Ленинград югары театр уку йортларын тәмамлаучылардан О.М.Вавилов, Н.В.Корчагина, В.А.Пильников, режиссёрлар В.М.Миллер, В.М.Стрижов, В.И.Соловьёв, аерым спектакльләрне сәхнәгә кую өчен режиссёрлар Э.М.Митницкий, Ш.М.Сарымсаков, М.Х.Сәлимҗанов, рәссамнар Д.Л.Боровский, Т.И.Сельвинская



Н.Ю. Орлов.



В.В. Маяковскийның «Мунча» («Баня») әсәре буенча Н.Ю. Орлов сәхнәгә куйган спектакльдән күренеш.

чакырып алына. Репертуарның нигезен классик әсәрләр б-н беррәттән хәзерге заманның аеруча мөһим проблемаларын яктырткан пьесалар да тәшкил итә. 1973 тән Чиләбе драма театрының баш режиссёры (2003 тән театр аның исемен йөртә). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Данилова Г. Пути, которые мы выбираем // Театр. жизнь. 1968. № 5; Романович И. Большие ожидания // Театр. 1970. № 9; Ингвар И., Иляловa И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ОРЛО́В** Николай Иванович (15.8.1873, Владимир губ., Покров өязе Орехово а. — 22.2.1923, Казан), гигиенист, медицина докторы (1909). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1900), земство фельдшерлар мәктәбендә укыта, Казан губ. земствосының Чәчәк салдыру ин-тына җитәкчелек итә, бер үк вакытта Казан ун-тында лекцияләр укый. 1903 елдан проф. М.Я.Капустинның гигиена лаб-ясендә эшли. 1910–12 дә чит илдә фәнни командировкада. 1913 тән Саратов ун-тында. 1915 тән Казан ун-тында, 1921 дән гигиена каф. мөдире, проф. (1918). Хезмәтләре туклану гигиенасына карый. О. җитен маеның әһәмиятен гигиена күзлегеннән чыгып өйрәнә.


Хезм.: Материалы к вопросу о значении варёного льняного масла (олифы) с гигиенической точки зрения. К., 1908; Опыт количественного определения карбоксигемоглобина в смеси с оксигемоглобином спектрометрическим способом с применением формулы Viervordt'а. К., 1910; Съедобные и ядовитые грибы, грибные отравления и их профилактика. М., 1953.

*Әд.:* Казанский медицинский институт, 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

**ОРЛО́В** Сергей Леонидович ( 10.6.1954, Ленинград), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2003). 1975 елда Җәмәгать туклануы ин-тын тәмамлый (Харьков ш.). Бердянск рестораннар һәм ашханәләр трестында эшли (Украина ССРның Запорожье өлкәсе). 1979–82 дә Дубна җәмәгать туклануы комб-тының «Вечерний» рестораны директоры (Мәскәү өлкәсе). 1983–97 дә Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ин-тында, икътисади һәм оештыру-идарә фәннәре (1989–91), товарлар һәм хезмәт күрсәтү базарында коммерция эшчәнлеге (1993–95) кафедралары мөдире. 1997–99 да «КамАЗ» сәүдә-финанс компаниясе» АҖдә ген. директор урынбасары. 1999 дан Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан), икътисад һәм маркетинг каф. мөдире (2006–08). Хезмәтләре регионнар икътисады, сәүдә һәм хезмәт күрсәтү даирәсе, финанс хезмәте базары икътисады мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Рыночные отношения и торговля. К., 1991; Потребительский рынок Татарстана. К., 1998; Использование долговременных инвестиционных ресурсов для развития региональной экономики: Сб. науч. трудов АН РТ. К., 2004.

**ОРЛО́В ЮРТАКЛАРЫ́ ТОКЫМЫ́**, җигелә торган ат. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында граф А.Г.Орлов һәм аның ярдәмчесе В.И.Шишкин тарафыннан Воронеж губернасындагы Хреновский ат заводында гарәп токымлы айгырларны Дания, Голландия, инглиз һ.б. токымлы бияләргә кушу юлы б-н китереп чыгарыла. Маңгай өстендә чыгынтысы булган какча башлы, озын муенлы, биек җилкә калкымлы, озын, киң аркалы, киң, көчле савырлы елгыр, чыдам ат. Ялы, койрыгы калын, кабарып тора. Холкы тыныч. Күбесенчә күк, кара төстә, туры. Тиз җитлегә, 4–5 яшьләрдә физиол. җитлегүе тәмамлана, елгырлыкның иң югары дәрәҗәсенә 6 яшьтә һәм соңрак ирешә. Төрле хуҗалык шартларында һәм климатик зоналарда җитлеккән атларның үлчәмнәрендә бераз аерма булырга мөмкин. Токымның иң яхшы сыйфатлары



Орлов юртагы.

даими камилләштерелә. О.ю.т. Россиядә генә түгел, Европа илләрендә дә югары бәяләнә. Россиядә, ш.у. Көнбатыш Европа, АКШта ат токымын яхшыртуда файдаланыла. *Рус юртаклары токымын* чыгаруда нәсел башы булып тора. 1920 еллардан О.ю.т. фәкать чиста токым куллану ысулы б-н үрчетелә һәм камилләштерелә. 20 йөз дәвамында токымлы атларның баш саны арта, Орлов юртаклары Россиянең төрле төбәкләрендә, союздаш һәм автономияле респ-каларда тарала, алар СССРның, хәзер РФнең барлык ипподромнарында диярлек уздырылучы ярышларда катнаша, ил күләмендәге һәм төбәкләр масштабындагы рекордларның байтагы О.ю.т.на туры килә.

Татарстандагы барлык атларның 5% ын О.ю.т. тәшкил итә (2013 ел башына). Респ-када аны үрчетү б-н 15 дәүләт нәсел з-ды һәм дәүләт нәсел фермасы, ш.и. «Татарский», «Казанский» нәсел з-длары, Чистай, Алабуга, Әлмәт, Буа, Баулы, Нурлат, Минзәлә шәһәрләрендәге, шәһәр тибындагы Балтач посёлогындагы, Мөслим, Актаныш һ.б. авылларындагы фермалар шөгыльләнә. Юртаклар катнашындагы ярышлар, чабышлар респ-каның 15 ипподромында уздырыла. Ш.у.к. *Ат асраучылык*.

*Әд.:* Козлов С.А., Парфенов В.А. Коневодство. СПб.–М.–Краснодар, 2004.

*М.Г.Миролюбов, Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ОРЛО́В-СОКОЛО́ВСКИЙ** Александр Александрович (25.8.1855, Мәскәү — 12.9.1892, шунда ук), композитор, дирижёр, педагог. 1875 елда Мәскәү консерваториясен (кларнет классы) тәмамлап, Казанда П.Медведев оештырган опера труппасында дирижёр булып эшли. 1878 дән Мәскәүнең

Кече театры һәм Мәскәү симф. музыка сөючеләр түгәрәге дирижёры. 1884 тән Казан театрында дирижёр буларак актив концерт эшчәнлеге алып бара (1888–89 да ш.у. антрепренёр), симф. концертлар б-н чыгышлар ясый. Казанда һәркем кереп укый алырлык беренче музыка мәктәбен (фортепиано, оркестр, вокал, драма сәнгате класслары б-н, төрле яшьтәге 300 гә якын укучы укый) ача (1886–91). Мәктәп эшчәнлеген опера театры каршындагы үзенчәлекле студия эшчәнлеге кебек оештыра, укытучылар һәм укучыларны театр эшенә җәлеп итә, шул сәбәпле мәктәп таркала, аны Рус музыка җәмгыяте карамагына күчерәләр. Драма спектакльләренә, ш.и. А.Н.Островский пьесаларына күпләгән увертюралар һәм антрактлар авторы.

*Әд.:* Кантор Г.М. Музыкальный театр в Казани XIX — начала XX вв. К., 1997.

**ОРЛО́ВСКИЙ** Витольд Францевич (24.1.1874, Вильно ш. — 2.12.1966, Варшава), терапевт, медицина докторы (1900). Петербург хәрби мед. академиясен тәмамлаганнан соң (1896), шунда ук, проф. Ф.И.Пастернацкий карамагында калдырыла. 1906 елдан табиб диагностикасы каф. профессоры һәм мөдире, 1912 дән Казан ун-тының госпиталь терапиясе каф. профессоры һәм мөдире. 1918 дән Краков ун-ты (Польша) профессоры. Хезмәтләре эчәкләрне, бавыр, ашказаны асты бизен, бөерләрне физик һәм лаборатор юллар б-н тикшерүгә, диагноз кую ысулларын камилләштерүгә карый.

Хезм.: Клиническая врачебная диагностика внутренних болезней. К., 1916.

*Әд.:* Вайнштейн С.Г. В.Ф.Орловский в Казани // Arch. Med. Wewn. 1974. № 52.

**ОРЛЫКЧЫЛЫ́К**, *үсемлекчелек* тармагы, уңышны, продукциянең сыйфатын күтәрү һәм аның үзкыйммәтен түбәнәйтү буенча әһәмиятле чара буларак, районлаштырылган сортлардан күпләп орлык үрчетү б-н шөгыльләнә. А.х. культураларын үстерүдә махсус технологияләр, төрләп һәм сортлап утау, апробация кулланыла, алар чиста сортлылыкны, биологик һәм уңыш сыйфатларын саклауны тәэмин итәләр. О. орлыкчылык белеме (агрономия бүлеге, а.х. культуралары орлыкларының үсешен һәм төзелешен өйрәнә, орлыклык материалны бәяләү һәм тикшерү алымнарын эшли) һәм *селекция* б-н турыдан-туры бәйләнештә. О.ның бурычлары: хуҗалыкларны тулысынча тәэмин итү өчен районлаштырылган сортларның орлыкларын үстерү; аларның уңыш бирү һәм чәчүлек сыйфатларын күтәрү һәм саклау; сорт алыштыру һәм сорт яңарту.

Россиядә О. 19 йөзнең 2 нче яртысында барлыкка килә. Аның б-н шикәр чөгендере һәм бөртекле культуралар үстерүче алпавыт хуҗалыкларында шөгыльләнәләр. Шәхси крәстиән хуҗалыкларында оешкан О. булмый. Октябрь рев-циясеннән соң сортлы орлык үстерү б-н 1919–20 елларда Саратов (хәзер Көньяк-көнчыгыш а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты) һәм Шатилов тәҗрибә станцияләрендә шөгыльләнә башлыйлар. О. (селекция б-н бердәм системада) 1921 дә «Орлыкчылык турында декрет» кабул ителгәннән соң үсеш ала. Җирле шартларга яраклаштырып О. һәм селекцияне үстерү, беренчел орлыкларның дәүләт питомникларын оештыру өчен 9 тәҗрибә станциясе булдырыла. Татарстанда крәстиян хуҗалыклары б-н дәүләт җитәкчелеге максатларында 1920 ел башында махсус органнар — гамәли ярдәм күрсәтү һәм орлык б-н тәэмин итү өчен чәчү ком-тлары оештырыла. 1924 тә — сортларны сынау оештырыла, 1926 да орлыкларның сыйфатын тикшерүче дәүләт контроле кертелә, 1931 дә ХКСның «Селекция һәм орлыкчылык турында» карары кабул ителә, 1934 тә орлыкка беренче дәүләт стандартлары раслана. 1937 дә СССРның барлык терр-яләре өчен бердәм О. схемасы кертелә. Орлыкларның барлык хәрәкәте Госсортсемфонд (Дәүләт сорт орлык фонды) аша уза. 1945 тә махсус элитхозлар — элиталы орлыкчылык хуҗалыклары оештырыла. 1952 дә ТАССРда колхоз һәм совхозларны орлыклык материал б-н тәэмин итүне яхшырту максатында «Заготзерно» конторасы каршында орлыкчылык бүлеге булдырыла, 1960 тан колхоз һәм совхозларга турыдан-туры элиталы орлык һәм беренче репродукцияне сату рөхсәт ителә. 1960 та Татарстан респ-ка а.х. тәҗрибә станциясе каршында 3 совхоз җирлегендә — «Столбище», «Красный Октябрь», «Семеновод», 1967 дә «Кыят», Ленин исем., «Ямашев» тәҗрибә-җитештерү хуҗалыклары оештырыла. 1974 тә Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-тында беренчел О. бүлеге ачыла, бу тәҗрибә-җитештерү хуҗалыкларын суперэлита орлыклык материал б-н тәэмин итүне яхшырта, селекционерларга яңа сортлар чыгару мөмкинлеген бирә. 1976 да «Татарсортсемпром» берләшмәсе оештырыла, аңа 37 совхоз һәм колхоз керә (1985 тә, агросәнәгать ком-тында структуралы үзгәртеп кору башлану б-н ябыла). 1987 дә сортлы орлыклар үстерү буенча фәнни-җитештерү берләшмәләре булдырыла башлый.

ТРда бөртекле культуралар орлыкчылыгын оештыруның заманча системасы: Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-ты һәм башка фәнни-тикшеренү оешмалары (респ-када сортлар җитештерүгә рөхсәт бирелгән оригинаторлар) Р1, Р2 һәм суперэлита орлыкларын үстерәләр. Аннары 72 район орлыкчылык хуҗалыкларын берләштерүче «Татарстанның элита орлыклары» ассоциациясе (1997 дә оештырыла) оригинаторлардан бөртеклеләр, бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары сортлары орлыкларын сатып ала һәм аларны фермерлык хуҗалыкларына һәм а.х. пр-тиеләренә хуҗалык эчендәге О. өчен сата. Югары сыйфатлы орлыклар 1 *га* дан якынча 3–4 *ц* өстәмә уңыш алуны тәэмин итә. Күпьеллык үләннәр О.ы проблемаларын чишү максаты б-н 2001 дә «Күпьеллык үләннәр «Био-Виктория» ЖЧЖ оештырыла. 2001 дән бәрәңге О.ы б-н Татарстан а.х. фәнни-җитештерү ин-тының а.х. биотехнол. бүлеге шөгыльләнә; алар тарафыннан сәламәтләндерелгән бәрәңге О.ы системасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә (тиз үрчетүнең оригиналь технологиясе, җирле шартларда орлыклык материалны кабат вирус б-н зарарланудан саклау; 100 мең *га* га азык-төлек өчен утыртылган бәрәңге О.ның кыскартылган 6 еллык схемасы). Бәрәңге О.ы б-н ш.у. «Татарстан бәрәңгесе» ЖЧЖ дә (Респ-ка бәрәңге җитештерүчеләр ассоциациясе) шөгыльләнә. Ялган орлыклык материалдан саклауны 2000 нән ТР буенча «Россельхозцентр» Федераль дәүләт учреждениесе ф-лы тәэмин итә. 2008 дә сыйфаты халыкара стандарт таләпләренә туры килүче сәламәтләндерелгән бәрәңге үстерү мәйданы Татарстан өчен җитәрлек дәрәҗәгә җитә. Кукуруз, май культуралары, шикәр чөгендере, яшелчә һәм бакча культураларының орлыклары республикага Россиянең башка төбәкләреннән һәм чит илләрдән кайтартыла. Судан үләне һәм сорго-суданка гибридларының О.ы б-н Кама аръягы зональ селекция-орлыкчылык тәҗрибә станциясе (Алексеев штп) шөгыльләнә. 2008 дә Татарстанда чәчүлек мәйданнарның 83% ына бөртекле культураларның районлаштырылган сортлары чәчелә (шуларның 70% ы — югары репродукцияле орлыклар). Орлык базарының ышанычлылыгын һәм тотрыклылыгын орлыкның региональ иминлек һәм күчмә фондлары тәэмин итә. О. буенча барлык эшләр 1997 елгы «Орлыкчылык турында» Федераль законга туры китереп уздырыла. 2003 тән башлап ТРда оригиналь орлык сатып алу тендер нигезендә оештырыла.

*Әд.:* Система семеноводства зерновых культур. К., 2005; Современные направления и развитие адаптивного семеноводства, его технической базы как фактора стабилизации и повышения урожайности сельскохозяйственных культур: Материалы науч.-практ. конф. К., 2007.

*Р.Р.Муллахмәтова.*

**ОРМЫШЛЫ́** (Урмышлы) авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 65 *км* төньяк-көнбатыштарак, Вятка елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 477 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1746 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да 2 мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2193 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Варварино волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 23 ир-ат; 1859 да — 780, 1883 тә — 918, 1889 да — 1436, 1897 дә — 1587, 1910 да — 1911, 1920 дә — 2059, 1926 да — 1167, 1949 да — 770, 1958 дә — 889, 1970 тә — 1006, 1979 да — 815, 1989 да — 530, 2002 дә — 519 кеше.


**ОРНА́МЕНТ** (лат. ornamentum — бизәлеш), абстракт-геометрик һәм сурәтләү элементларының (раппортлар) ритмлы чиратлашуына һәм буяулар кушылмасына корылган бизәк. *Бизәлеш сәнгатендә, гамәли-бизәлеш сәнгатендә, дизайнда, китап графикасында, каллиграфиядә* төп сәнгать чараларының берсе, сәнгатьнең башка төрләрендә дә кулланыла. Татар сәнгатендә О.ның стильләшү үзенчәлекләре халыкның сурәтләү культурасы традицияләре б-н билгеләнә һәм ачык чагылышлы милли характерда була. О.ның



Җәймә кашагасы фрагменты. Чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы.

сәнгати-стильләшкән типлары һәм аның төрдәш формаларының (геом., үсемлек, зооморф, эпиграфик) тарихи үсеш чорлары (Идел буе Болгары, Алтын Урда һәм аннан соң чор һ.б.) б-н нык бәйле. О.ның килеп чыгышы борынгы татарларның күчмә тормыш һәм игенчелек культурасына барып тоташа. Аларның беренчесенең традицияләре *аппликация сәнгатендә*, күн мозаикасы, йон һәм мех мозаикасы, тамбурлап (кабартып) чигү (к. *Чигү*), киез басу (к. *Киез*), зәргәрчелек алымнары нигезендәге бизәк формаларында һәм төрләрендә чагылыш тапкан. О.ның байтак ясалма бизәкләргә башлангыч биргән игенчелек һәм терлекчелек төрләре синтезы ташка һәм агачка уеп кисүдә, тукучылыкта, укалап чигүдә, зәргәрчелек алымнарының кайбер төрләрендә һ.б.да ачык чагыла. О.ның гомумтөрки мирасындагы архаик төркемнә Таулы Алтай, Көнчыгыш һәм Үзәк Азия сәнгатенә хас табылдыклар, Салтау культурасы һәм угыз-бәҗәнәк, кыпчак кабиләләре культурасындагы үрнәкләр хас: бөтеркә бизәкләр, интеграль спиральләр, яфраксыман, йөрәккә охшаган, таҗ яфракчыгы кебек розеткалар һәм пальметталар, лалә чәчәге үрнәкләре, атлар һәм кошлар (еш кына ике башлы итеп ясалган сурәтләре), борма мөгезле сарык башлары, мәчесыман токымлы ерткычлар һ.б. Әүвәлге болгар О.ындагы «кош-җәнлек стиле» үрнәкләре (лачын, киек каз, үрдәк, этәч, мәче башлы ябалак; поши, аю, эт, куян, сусар; арыслан, барс, грифон һ.б.), үсемлек («тормыш агачы», лотос, лалә, имән чикләвеге, тукранбаш һ.б.) һәм мифология б-н бәйләнешле мәҗүси табынуларны чагылдыручы астраль дөнья (тәгәрмәч рәвешендәге күпнурлы тамгалар, хач, бөтеркә бизәк формасындагы нурлы билгеләр, ромб, ноктадлы түгәрәк үрнәкләре) бер очракта — символик-магия, икенчесендә бизәлеш функцияләре б-н бирелгән.

Ислам дине кабул ителү б-н, Идел буе Болгар дәүләте сәнгатендә О. теле декоратив шартлылык һәм абстрактлаштыру юнәлешендә үсә башлый. Гадиләшә һәм схемалаша барган зооморф О. әһәмиятен югалта бара. Алтын Урда чорында эпиграфик О. тарала, купшы чәчәк стилендәге О. күтәрелеш чорын кичерә, еш кына үсемлек композицияләренең «куфи» һәм «сөлес» стильләрендәге гарәп язулары б-н аралашкан арабеска һәм гирих төрләре барлыкка килә; матем. төзү кануннарына буйсынган О. геометрик төс ала. О.та *мөселман сәнгате* йогынтысы сизелә (аеруча Кече Азиядә, мәмлүкләр Мисырында, Кырымда), Шәрекъ-Азия сәнгатенең аерым үрнәкләре — лотос, «мәңгелек төен», «болытсыманнар» һ.б. үсеш ала. Казан ханлыгы чорында О. Идел буе болгарлары (к. *Болгар бизәлеш сәнгате*) һәм Алтын Урда татарлары (к. *Алтын Урда сәнгате*) сәнгать традицияләрен чагылдырган стиль билгеләренә ия була. Анда төп урынны безнең көннәргә кадәр килеп җиткән ташка уеп ясалган архит-ра фрагментларында, кабер ташларында, зәркән әйберләрдә чагылыш тапкан чәчәк стиле, бизәк б-н баетылган композицияләр ала.



1. Кабер ташы каймасы. Ташка чокып бизәк ясау. 16 йөз; 2. Сөлгедәге тасмалы орнамент. Чигү. 19 йөзнең 2 нче яртысы.



Койма башы. Агачны уеп бизәкләү. 20 йөз уртасы.

18 йөздә — 20 йөз башында татар О.ының прогрессив үсеше күрше һәм тугандаш төрки халыклар О.ыннан аерылып торган үзенчәлекле стиль булдыруга ярдәм итә (бу О.ның сәнгати-образлылыгына да, композицияле, колоритлы структурасына, башкару техникасына да карый). Күн, йон һәм тукыма аппликациясендә, тамбурлап чигүдә, ш.у. авыл йортлары фасадларын бизәүдә кулланылган контурлы һәм кисеп эшләнгән бизәк мозаикасындагы О. өлге алу принцибына нигезләнә. Аның үзенчәлеге ш.у. кәкре сызыклы формаларга һәм сызыклы силуэт-бизәкләргә, күп буяулы төсләргә, контуры б-н охшаш фигураларны бер-берсе эченә кертү, бизәк һәм фонны бер-берсенә туры китерүгә корылган. Гамәли-бизәлеш сәнгатенең барлык төрләрендә үсеш алган чәчәк-үсемлек О.ы үрнәкләреннән бай мотивлар репертуары туплана һәм ул гамәли бизәлеш сәнгатенең барлык төрләрендә үсеш ала. Аңа дала, болын һәм бакча чәчәкләре, лалә, гөлҗимеш, ромашка, дәлия, алтын чәчәк, кашкарый, ала миләүшә, нәркис, ирис, чәчәкле розеткалар, борынгыларыннан — пальметталар, тукранбаш, лотос керә.

Чәчәк рәсемнәре стильләшә, профильләп яки зурайтылып, еш кына букет яки «җәннәт бакчасы» композицияләре рәвешендә бирелә, дулкынсыман үренте йөзем тәлгәше үрнәкләре б-н аралашып килә. Геом. өлгеләрдән традицион үрнәкләр булып әверелгән бизәкләргә дулкын, бау, спираль, үрмә, борма, тәкә мөгезе, йолдыз, розетка, йөрәксыман, катлаулы кәкре сызыклы конфигурацияләр керә. Зооморф О. башлыча агачны уеп бизәкләгәндә, кайсы вакытта чиккән бизәкләрдә, укалы чигүдә, зәркән әйберләрдә очрый. Стильләшкән кош сурәтләре (еш кына канатлары җәелгән, ике башлы, кайвакыт кыр үрдәге, ябалак, күгәрчен рәвешендә, балык, ярканат, елан, пар ат һ.б. үрнәкләрдә очрый), «тормыш агачы»ның як-ягында урнашкан композицияләр аеруча тотрыклы О.лардан санала. О. композицияләре бай эчтәлекле (шәмаил һәм ләүхә) һәм символик-декор (Коръән тартмачыклары, беләзекләр, зәркән аеллар һәм вак-төяк әйберләр ясауга китә торган ташлар) функцияләр үтәүче гарәп графикасындагы язулар б-н ярашып килә. Татар О.ын өйрәнүче Ф.Х.*Вәлиев* аның көнкүреш һәм сәнгать комплексларын күрсәтеп, мотив генезисларын тарихи чыганак буларак тикшереп системалаштыра һәм беренче тапкыр тарихи-этнографик һәм сәнгать белеме аспектларында анализ ясый. Ф.Х.Вәлиевнең рәсемле, фотографияләр һәм таблицалар б-н баетылган китаплары хәзерге заман рәссамнары, архитекторлары һәм дизайнерлары өчен өстәл китабы булып тора, иҗади эшләрендә еш кулланыла. Милли О., гаять мөһим тәэсир итү чарасы буларак, бүгенге сәнгатьтә традицион нигезләргә таянып үсә, стильләшә, әйберләрнең яңа төрләренә һәм декор. алымнарына туры килүче образлары да үзгәрә.

*Әд.:* Сперанский П.Т. Татарский народный орнамент — Татар халык орнаменты: Альбом. К., 1948; Валеев Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; шул ук. Татарский народный орнамент. К., 2002.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ОРНА́Ш-ЧИШМӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кызылсу елгасының (Казансу елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,8 *км*. Бассейнының мәйданы 26,3 $км^2$. Арча р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Орнашбаш авылыннан 2 *км* төньяктарак, тамагы Урта Сәрдә авылында. Елга башының абс. биеклеге 165 *м*, тамагыныкы — 94 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми. О.Ч.нең 0,7 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 $км/км^2$. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары өлешенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с \cdot км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда ел-

лык су агымының уртача күпьеллык катламы 136 *мм*, ташу вакытында су катламы 105 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 $м^3$/*с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен (12–20 *мг-экв/л*) бик каты. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада су күләме 0,5 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОРНАШБА́Ш** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 20 *км* төньяк-көнбатыштарак, Орнаш-Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 263 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урманбаш, Кичертаң исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1907 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, җил тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1071 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 52 ир-ат; 1859 да — 746, 1897 дә — 582, 1908 дә — 728, 1920 дә — 669, 1926 да — 637, 1938 дә — 474, 1949 да — 575, 1958 дә — 530, 1970 тә — 478, 1979 да — 419, 1989 да — 363, 2002 дә — 318 кеше (1859, 1897 һәм 1908 еллардагы мәгълүматлар Кичертаң авылын да кертеп бирелә).

**ОРСК** шәһәре, *Оренбург өлкәсендә*, Оренбургтан 327 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Халкы — 240484 (2012), татарлар — 9170 кеше (2010). 1750–60 елларда шәһәргә, нигездә, Казан губернасыннан чыккан татарлар килеп урнаша. 19 йөзнең 2 нче яртысында О. Оренбург губернасының икътисади үзәгенә әйләнә. Монда татар эшмәкәрләренең туңмай эретү һәм күн з-длары эшли. 1917 гә кадәр шәһәрдә Татар бистәсе, 5 мәчет, ш.и. җамигъ мәчет (1900 дә төзелә); 5 мәдрәсә (берсе — җәдиди); китапханә һәм клуб була. 1908 дә «Орск шәһәре мөселманнары җәмгыяте» ачыла. 1911 дә беренче драма түгәрәге оештырыла, анда М.М.*Фәйзи* пьесалары куела. 1923–25 тә «Ирек» г-тасы нәшер ителә. 1930–50 дә 4 нче татар урта мәктәбе эшли. 1989 дан О.да «Туган тел» татар-башкорт мәдәни үзәге эшчәнлек алып бара, ул ш.у. «Орск яңалыклары» г-тасына — «Туган тел», «Орск газетасы»на «Болгар Иле» кушымтасын нәшер итүдә ярдәм күрсәтә; ветераннарның «Туган тел» үзешчән вокаль ансамбле, Т.Шевченко исем. китапханә каршында татар китабы бүлеге бар. Язучы, драматург М.М.Фәйзинең, алтын приисклары хуҗалары һәм эшмәкәрләр Ш.Рәмиев һәм З.Рәмиев (*Дәрдемәнд*) (к. *Рәмиевләр*), шагыйрь М.*Җәлил* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге, шахматчы Г.Р.*Камскийның* биографиясе О. б-н бәйле. Шәһәрдә композитор З.В.*Хәбибуллин*, ТАССРның халык артисты Г.Н.Нигъмәтуллина, актёр Х.Й.*Сәлимҗанов* туган.

*Әд.:* Орская биографическая энциклопедия. Оренбург, 2005. *Р.В.Вәлетдинов.*

**О́РСК ӨЯЗЕ́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия оешмасы. 1908 елның ноябрендә Оренбург губернасының Орск шәһәрендә оештырыла. Гамәлгә куючылары: С.Абдуллин, Г.Борнаев, Г.Вилданов-Әдиһәмов, Ш.Дәминов, Г.Киникиев, Ә.Рәхмәтуллин, З.Садыйков, Р.Фәхретдинов, В.Хәсәнов. Идарә әгъзалары: В.Хасимов (рәис), Г.Габдрахманов (казначы), С.Габдрахманов, И.Борнаев, С.Борнаев, С.Гыйләҗетдинов, Ш.Гобәйдуллин, Х.Долотказин, А.Исхаков, Ю.Мозафаров, Г.Салихов, С.Умарбаев, М.Ураев. Төп максаты — мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү, мөселманнарның мәдәният, мәгариф оешмалары эшчәнлеген җәелдерү һәм аларга игана кылу.

*Әд.:* Я м а е в а Л.А. Мусульманский либерализм начала XX в. как общественно-политическое движение (по материалам Уфимской и Оренбургской губерний). Уфа, 2002.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**ОРТИ́ЛИЯ** (Orthilia), каеш яфракчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 40 ка якын төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — берьяклы О. (О. secunda) ара-тирә барлык районнарда да очрый. Ылыслы, катнаш урманнарда, кисентеләрдә, урман буйларында, урман ерганакларында үсә. Озын тармаклы тамыр системасының күп санлы өстәмә тамырлары бар. Сабагы сәнәксыман тармаклы, 10–15 *см* биеклектә. Яфраклары чиратлашкан, йомыркасыман, тыгыз, итчел, озын сапта урнашканнар. Чәчәкләре вак, кыңгыраусыман, аксыл яшел, берьяклы иенке чукка җыйналган. Җимеше — бик күп вак орлыклы тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Яфракларында дуплау матдәләре, сапониннар, С витамины бар. Халык медицинасында дезинфекцияләү чарасы буларак, ш.у. бөер, цистит авырулары вакытында кулланыла.

**ОРТОПЕ́ДИЯ** (грек. orthós — туры, дөрес һәм paidéia — тәрбия), клиник мед. бүлеге, терәк-хәрәкәт аппараты авыруларын, функциональ тайпылышларга (тумыштан килгән деформация, җәрәхәт алу, ялкынсынулар нәтиҗәсендәге зәгыйфьлек) диагноз кую, аларны дәвалау ысулларын өйрәнә. Травматология б-н берлектә мөстәкыйль бүлек тәшкил итә. Гәүдә төзелешендәге тайпылышларны өйрәнүне фәнни нигезгә салу омтылышы Яңарыш чорында, француз хирургы А.Паре тарафыннан ясала. Фәнни О.нең барлыкка килүе француз табибе Н.Андриның «Ортопедия» китабы басылып чыгу (1741) б-н бәйләп карала. 18 йөз ахырында ортопедик дәвалау учреждениеләре булдырыла, сынган урыннарны беркетеп ялгау өчен гипс кулланыла башлый (голланд табибе Гендрихс һәм рус табибе К.Гибенталь, 1815), дәвалауда массаж, гимнастика, очлыкларның функцияләрен тергезү өчен тарттыру ысуллары гамәлгә кертелә. Россия медицинасында антисептика һәм наркоз кулланыла башлаганнан соң, О.да хирургик ысуллар үсеш ала (мускул һәм сеңерләрне күчереп утырту һ.б.). Е.О.Мухинның 1806 елда нәшер ителгән «Сөякләрне дәвалау фәне башлангычлары» («Первые начала костоправной науки») китабы Россиядә хирургик О. үсешенә этәргеч була. Н.И.Пирогов хезмәтләрендә рус галим-табибләренең О.гә караган тәүге фәнни эшләре гомумиләштерелеп, нәтиҗәләр ясала; дисмургия (Н.Эллинский, 1834), О. (Н.И.Студенский, 1885) буенча ярдәмлекләр басылып чыга. 1791 дә И.П.Кулибин тарафыннан шин-шарнирлы протезлар конструкцияләнә, 1830 елларда Р.Черносвитов протезларның камилрәк төрләрен тәкъдим итә. И.А.Бредихин (1862), С.Ф.Феоктистов (1863), Н.П.Никольский (1870), Н.И.Носилов (1875), В.И.Кузьмин (1893) хезмәтләре О.не алга таба үстерүгә өлеш кертә. К.Ф.Бернер Россиядә беренче буларак скелетны тарттыру ысулын куллана. 1906 да Россиядә беренче О. каф. һәм беренче О. клиникасы ачыла, Г.И.Турнер тарафыннан беренче О. ин-ты оештырыла (ин-тка Р.Р.Вреден җитәкчелек итә). СССРда ортопедотравматология ярдәме системасына Н.Н.Приоров тарафыннан нигез салына, 1921 дә Мәскәүдә Дәвалау-протез ин-ты ачыла (1971 дән Приоров исемен йөртә). 1925 тә Бөтенсоюз хирурглар җәмгыятендә ортопедлар секциясе оеша, 1963 тә Халыкара ортопедик хирургия һәм травматология җәмгыятенә әгъза булып кергән Бөтенсоюз травматологлар һәм ортопедлар җәмгыяте төзелә, Казанда җәмгыятьнең бүлеге эшли. «Ортопедия, травматология и протезирование» ж-лы нәшер ителә.

Фән буларак О. Казанда 19 йөзнең 2 нче яртысыннан үсеш ала (В.В.Владимиров, Н.А.Студенский һ.б.); 1918 дә Казанда Ортопедия ин-ты оештырыла; 1945 тән фәнни тикшеренүләр М.О.Фридланд, Ә.Л.Латыйпов, Л.И.Шулутко, Г.С.Самойлов, Х.З.Гафаров, Ф.С.Йосыпов, А.А.Румянцева, Н.А.Завьялова, У.Я.Богданович һ.б. тарафыннан алып барыла; 2009 дан Респ-ка клиник хастаханәсенең Травматология үзәге ТР Сәламәтлек саклау өлкәсендәге төп учреждение булып тора (к. *Травматология һәм ортопедия үзәге*). Татарстан һәм Россиянең башка төбәкләре өчен травматолог-ортопедлар һәм нейрохирурглар әзерләү үзеген Казан мед. академиясенең травматология һәм ортопедия каф. тәшкил итә. 2000 еллар башыннан О.гә кагылышлы түбәндәге фәнни мәсьәләләр өйрәнелә: сөякләр сыну, биомеханика, травмаларны дәвалау (эндопротезлау, эре буыннар регенерациясе, нейрохирургия, микрохирургия һ.б.); умыртка сөяге сыну очрагында модификацияләнгән сөяк цементы ярдәмендә вертебропластика ясау ысулын куллану (ш.и. арка миенең зыян күргән урынына берничә мәртәбә кәүсә күзәнәкләр трансплантацияләү); очлыклары зарарланган авыруларны дәвалауда васкуляризацияле тире пластикасы (очлыкларның кан б-н тәэмин ителешенең топографик-анатомик үзенчәлекләрен өйрәнү); травмаларны кисәтү; сөяк яраларының төзәлү процессы, авыруның кискенләшүен

кисәтү, репаратив регенерациягә лазер тәэсире (ТР ФАнең Физика-техника ин-ты б-н берлектә). 2010 да ТРда 200 дән артык табиб-травматолог эшли.

*Әд.:* Гафаров Х.З., Богданович У.Я. 75 лет Казанскому институту ортопедии и травматологии // Казан. мед. журн. 1993. № 5.

*Р.Я.Хәбибҗанов, Р.Г.Исхакова.*

**ОРФОГРА́ФИЯ** (грек. orthós — дөрес һәм *...графия*), 1) дөрес язу — сөйләмне язмача рәвештә җиткерү ысулларының бертөрлелеген билгеләүче кагыйдәләр җыелмасы; 2) тел белеменең әлеге кагыйдәләр җыелмасын өйрәнүче бер тармагы. Хәзерге О.дә фонетик, морфологик, традицион, график, дифференциацияләү принциплары кулланыла. Татар О.се, тулаем алганда, фонетик принципка нигезләнә, ягъни сүзләрнең язылышы әйтелешләре б-н туры килә: тор, әйт, китте һ.б. Кушымчалар сингармонизм законы нигезендә алдагы иҗекнең фонетик үзенчәлекләренә яраша. Электән рус теленнән татар теленә кереп калган сүзләр дә фонетик принципка буйсына: чират, өстәл. О.дә морфологик принцип сүз тамырының морфологик бөтенлеген саклап язу мөһим булганда кулланыла: тозсыз, унбер (орфоэпик: тоссоз, умбер урынына). О.нең традицион принцибына ярашлы рәвештә, хәрефләрне сайлап алу этимология һәм традиция нигезендә тормышка ашырыла. Мәсәлән, тәртип саннарыннан соң сызыкча куймыйча гына кушымча ялгау: 6 нчы, 50 нче. Бу традиция — гарәп язуына хас күренеш. График принцип буенча гарәп, фарсы һәм рус телләреннән алынган сүзләр чыганак телдәгечә языла: сәлам, бәла, комитет, аппарат. Дифференциацияләү принцибына мәгънәләре ягыннан аерылган охшаш яңгырашлы сүзләрнең төрлечә язылышы нигезләнә: бал (ашамлык), балл (билге, бәя). *Алфавитларның* (к. *Гарәп язуы*, *Латин язуы*, *Кириллица*) еш алмашынып торуы татар теленең бердәм нормага салынган О. кагыйдәләрен эшләп чыгаруда билгеле бер кыенлыклар тудыра. Татар теле О.се үсешенә Г.Ибраһимов, Г.Нугайбәк, С.Хәлфин, Ш.Рамазанов, Х.Курбатов һ.б. зур өлеш кертә. О. социаль мәгънәгә ия, чөнки ул бөтен җәмгыятьнең мәнфәгатьләрен үз эченә ала һәм шул сәбәпле сөйләм культурасы мәсьәләләре б-н шөгыльләнүче тел белеме оешмаларының һәрдаим игътибар үзәгендә.

*Әд.:* Татар грамматикасы. К., 1998. Т. 1; Курбатов Х. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Татар теленең орфографик сүзлеге. К., 2010.


**ОРФОЭ́ПИЯ** (грек. orthós — дөрес, épos — сөйләм), 1) телнең авазлар бирелешендәге бертөрлелекне тәэмин итә торган әйтелеш нормалары тупланмасы; 2) тел белеменең нормага салынган әдәби әйтелешне өйрәнүче тармагы. О.нең төп кагыйдәләре телнең фонетик һәм грамматик төзелеше нигезендә эшләнә. Татар теле О.се тел формалаша башлаган вакытта ук барлыкка килә һәм 19 йөз ахыры — 20 йөз башында тулысынча ныгып җитә. Хәзерге татар әдәби теле О.се һәм традицион, һәм ш.у. яңа нормаларны да үз эченә алган тарихи ныгып җиткән система буларак күзаллана. Татар әдәби теленең орфоэпик нормалары *урта диалект* җирлегендә формалаша. Татар әдәби теленең 2 төп әйтелеш стиле бар: тулы (яки төгәл) һәм сөйләшү (яки иректә) стильләре. Тулы стиль сөйләмнең бик анык булуы таләп ителгән очракларда — теле- һәм радиотапшыруларда (диктор сөйләме), халык алдында чыгыш ясаганда, лекция укыганда, дәрес биргәндә; сөйләшү стиле кешеләрнең бер-берсе б-н аралашуы вакытында кулланыла. Тулы стильдә сүз һәм аның иҗекләре ачык әйтелә. Сөйләшү стилендә кайбер иҗекләр кыскарырга, хәтта төшеп тә калырга мөмкин (алып бар — [аппар], мин әйтәм — [мәйтәм]). О. авазлар әйтелешендә, интонациядә, сүз просодиясендә һәм аның акцентлашуында бертөрлелекне тәэмин итә; мәс., әгәр беренче иҗектә алгы рәт сузыгы булса, калган иҗекләр дә алгы рәт сузыклары б-н әйтелә һәм киресенчә: чәчәк, күгәрчен; урам, алан. Кайбер кушма сүзләр һәм башка телләрдән алынган сүзләр бу кагыйдәгә буйсынмый: билбау, көнчыгыш, китап. Ирен-ирен [w] авазын бирү өчен хәзерге татар алфавитында махсус билгеләр юк: иҗек башында ул — «в» хәрефе б-н, иҗек ахырында «у», «ү» хәрефләре б-н бирелә: waтан (язуда — ватан), wакыт (вакыт) — taw (тау), дәw (дәү). Татар теле О.сенә В.Н.Хангилдин, Л.Җ.Җәләй, Ү.Ш.Байчура, Ә.Ш.Әфләтунов, Х.Р.Курбатов, Х.Х.Сәлимов һ.б. галимнәрнең хезмәтләрендә фәнни нигез салына. «Татар грамматикасы» (К., 1998, 1 т.) китабында О. мәсьәләләре шактый тулы яктыртыла.

*Әд.:* Хангилдин В. Татар теленең орфоэпик нормалары мәсьәләсе // Совет мәктәбе. 1941. № 5; Җәләй Л. Татар теленең орфоэпик нигезләре. К., 1953; Курбатов Х. Сөйләү стиленең үзенчәлекләре // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1963; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006.

**ОРХО́Н-ЕНИСЕ́Й ТАШЪЯЗМА́ ЯДКӘРЛӘРЕ́**, борынгы төрки язуы үрнәкләре. 7–11 йөзләргә карый. Аталышлары Енисей һәм Орхон елгалары үзәннәрендә табылуларына нисбәтле. Енисей елгасы буйларындагы борынгы кабер ташларына чокылган язуларны 1696–1722 елларда Себерне өйрәнгән галимнәр С.У.Ремезов, Д.Г.Мессершмидт, Ф.И.Страленберг таба. Скандинавиянең рун язуына охшаш булулары сәбәпле, ташъязма үрнәкләре *рун язуы* дигән исем ала. 1889 да Монголиядәге Орхон елгасы буенда тикшеренүче галим Н.М.Ядринцев Төрки каганлык идарәчесе *Билге каган* һәм аның туганы *Култәгин* хөрмәтенә куелган, рун һәм кытай язулы текстлар чокылган таш һәйкәлләргә тап була (к. *Култәгингә куелган һәйкәлташ*). Һәйкәлләрдәге язмаларны Дания галиме В.Томсен укып шәрехли (1893). 1894 ел башында рус тюркологы В.В.*Радлов* Күлтәгин ташындагы текстның беренче тәрҗемәсен тәкъдим итә. Табылган төбәкләренә нисбәтле рәвештә, О.-Е.т.я.н берничә төркемгә бүлеп йөртәләр: Көнчыгыш төрки, Көнбатыш төрки, Уйгыр, Кыргыз каганлыкларына, Курахан кабиләләре берләшмәсенә караган язмалар; Монголия (Орхон, Тола, Селенга бассейнындагы Билге каган, Күлтәгин һәм Кули Чурага куелган һәйкәлташлар, Тоньюкук һәйкәле, Онгин, Карабалгасун һәм Суджа язулары, Селенга ташы) язмалары; Енисей; Лена-Байкал; Алтай; Көнчыгыш Төркестан; Урта Азия; Көнчыгыш Европа язмалары. О.-Е.т.я. арасында атаклы төрки, уйгыр, кыргыз аксөякләренә багышланган тарихи-биогр. текстлар, ш.у. эпитафик лирика («зират шигърияте») үрнәкләре бар, кабер ташларында шул кабердә ятучының исеме, яше, титулы, тормышының мөһим вакыйгалары турында язылган. Язмалар кыяларга, ташларга, корылма диварларына төшерелгән. Көнкүреш кирәк-яракларында — савыт-саба, көзге, керәч әйберләрдә тамга итеп уелган, ясаган останың яки әйбер хуҗасының исеме аталган, теләкләр теләнгән язулар очрый. Кайбер язмаларда хокукка, ырым-ышануларга, дини карашларга бәйле мәгълүмат бирелгән. О.-Е.т.я. текстларыннан ш.у. төрки каганлыклар, Уйгыр каганлыгы тарихына кагылышлы мәгълүматлар алырга була. Әлеге язмаларны өйрәнүче галимнәрнең берсе С.Г.Кляшторный фикеренчә, Монголиядә һәм Енисейда табылган рун язмалары, кыйммәтле тарихи документ булулары б-н беррәттән, шундый ук мөһим әдәби ядкәр дә булып тора; ул: «Урта гасырлар төрки әдәбиятында бу дәрәҗәдәге сәяси проза үрнәге башка юк»,– дип бәяли. Ш.у.к. *Орхон-Енисей язмалары*.

*Әд.:* Бернштам А. Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI–VIII веков. М.–Л., 1946; Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Кляшторный С.Г. Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии. М., 1964; История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1.

**ОРХО́Н-ЕНИСЕ́Й ЯЗМАЛАРЫ́**, 7–11 йөзләрдәге төрки кабиләләр язуы; *борынгы төрки рун язуы* ядкәрләрендә беркетелеп кал-




Борынгы төрки рун язуы алфавиты.

ган, структур-генетик яктан *борынгы уйгыр теленә* якын тора. О.-Е.я. башта, нигездә, кабер ташларына, кыяларга, соңрак металл, керамика һәм агачтан эшләнгән әйберләргә язулар төшерү өчен файдаланыла, шуңа күрә аларда уеп алу яки чокып ясау өчен уңайлы булган очлы геом. формалар өстенлек ала. Язуы горизонталь формада, уңнан сулга, кайвакыт сулдан уңга языла. Орхон-Енисей алфавитында 40 тан артык хәреф бар, шуларның 4 есе — сузык авазлар (Енисей рун алфавитында — 5 сузык аваз). Язуда алгы яки арткы рәт сузыклары аерылмый, бериш тартыкларның язылышы алардан соң килүче сузыкларның алгы яки арткы рәтнеке булуларына бәйле. О.-Е.я. шул ук вакытта кулланылышта йөргән уйгыр, ә ислам динен кабул иткән халыкларда гарәп алфавитлары тарафыннан кысрыклап чыгарыла. О.-Е.я.ның серенә Дания тел галиме В.Томсен (1893) төшенә, беренче мәртәбә рус тюркологы В.В.Радлов (1894) тарафыннан укыла. Соңрак О.-Е.я.н өйрәнү б-н күренекле тюркологлар С.Е.Малов, Д.Д.Васильев, И.В.Кормушин, А.М.Щербак шөгыльләнә. Ш.у.к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*.

*Әд.:* К у р б а т о в Х.Р. Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. К., 1999; К о р м у ш и н И.В. К основным понятиям тюркской рунической палеографии // Советская тюркология. 1975. № 2; Щ е р б а к А.М. Тюркская руника: Происхождение древнейшей письменности тюрок, границы её распространения и особенности использования. СПб., 2001.

*Р.Ә.Закиров.*

**ÓРША УКЧЫ́ ДИВИ́ЗИЯСЕ**, 1941 елның август–ноябрендә Бөгелмә шәһәрендә 352 нче укчылар дивизиясе буларак оештырыла. Башлыча Татарстанның запастагы кадрларыннан туплана. Беренче командиры — подполковник Ю.М.Прокофьев. Дивизияне фронтка озату алдыннан ТАССР ЮС Президиумы рәисе Г.А.Динмөхәммәтов респ-ка хезмәт ияләре исеменнән полкларга шефлык байраклары тапшыра. О.и.у.д. 20 нче, 5 нче, 49 нчы, 31 нче армияләр составында була. Мәскәү янында — Волоколамск шәһәре р-нында беренче мәртәбә сугышка керә. Смоленск өлкәсен һәм Белоруссияне азат итүдә катнаша, немец гаскәрләрен Польша һәм Көнчыгыш Пруссия җирләрендә тар-мар итешә. Сугышчан юлын Чехословакиядә тәмамлый. Орша шәһәрен алганы өчен Орша дивизиясе дигән мактаулы исем бирелә (1944, июнь). Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Г и л ь м а н о в З.И. Трудящиеся Татарии на фронтах Великой Отечественной войны. К., 1981; Д ю р я г и н Г.М. Сквозь пламя войны. К., 1982.

*В.Ф.Телишев.*

**ОРЫ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ашыт елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 12,5 *км*. Бассейнының мәйданы 102,3 *км²*. Вятка увалы калкулыгы буйлап ага. Елга башы Арча р-ны Югары Оры авылыннан 0,4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Әтнә р-ны Иске Өҗем авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 114 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. О.ның 0,8 дән 7,6 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,26 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 158 *мм*, ташу вакытында су катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. О. бассейнында суның гомуми күләме 0,95 млн. *м³* булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОРЫ́ ТАЛПАННАРЫ́** (Tetrapodili), акариформчалар отрядыннан дүртаяклы талпаннар өссемьялыгы. Дөнья фаунасында 1500 дән артык төре исәпләнә, Татарстан терр-ясендә Eriophyidae семьялыгына караган 30 га якын төре ачыкланган. Барлык җирдә дә таралганнар. Гәүдәсе 0,1–0,6 *мм* озынлыкта, озынча, бөҗрасыман буынлы; алгы өлеше кыска, күзе юк, өсте калканчык б-н капланган, ике пар аягы тигез түгел; гәүдәсендәге аяклары үсеш алмаган; сулыш һәм кан системасы юк; чәнчеп суыра торган авыз органы улакка кертелгән хәнҗәрсыман казналык (өске) рәвешендә. О.т. үзләренең үсешендә талпаннар өчен гадәти цикл уза: күкәй-личинка-нимфа-олы зат (имаго). Вегетация чорында, уңайлы шартлар булганда, О.т. 5 буынга кадәр үрчи; үсешенең бөтен стадиясендә тигез дәрәҗәдә кышлый. Барлык О.т. — фитофаглар. Бөре, яфрак, бәбәк, чәчәк, җимеш, орлыкларның күзәнәк согы б-н туенып, аларда тукыма участокларының яки тулысы б-н органнарның деформациясен китереп чыгара, җыерчыклану, бөдрәләнү, киезләнү, куыксыман, орылы һәм башка формалар хасил итеп, а.х., бакча, декоратив һәм урман культураларына шактый зыян китерә. О.т. үсемлекләрдә вируслы авырулар таратырга мөмкин, бу пассив һәм талпаннарның башка төр орыларына күчәргә сәләтле ирекле яшәүче төрләренә хас.

*Әд.:* Р е к к Г.Ф. Клещи, вредящие культурным растениям. Тб., 1941; Классификация клещей // Сельскохозяйственная энтомология. М.–Л., 1955.

*В.Д.Капитов, О.В.Краснов.*

**ОРЫ́ ЧЕБЕННӘРЕ́** (Cecidomyiidae), ике-канатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Дөнья фаунасында 4000 гә кадәр, Татарстан терр-ясендә 60 тан артык төре исәпләнә. Бөтен җирдә яшиләр. Канат сеңерчәләнүе нык кыскарган һәм озын мыекчалы (8–30 буынчыклы) вак (1–5 *мм*) чебенчекләр. Олы О.ч., гадәттә, тукланмыйлар, 20 көнгә кадәр яшиләр. Ана затлар 500 гә кадәр үтә күренмәле, орчыксыман күкәйләр сала, алардан исә 1–4 *мм* зурлыктагы личинкалар чыга. Уңайсыз шартларда диапаузага талалар (берничә атнадан берничә елга кадәр). Личинкалары да, курчаклары да (кузыда) кышлый. Туену ысулы буенча личинкаларны түбәндәге төркемнәргә бүләләр: мицетофаглар — мицелийларда һәм чери торган үсемлек калдыкларында җитлегәләр, фитофаглар — үсемлек тукымаларында туеналар, орылар (исеме шуннан) барлыкка китерәләр һәм зоофаглар — паразитлык итүче яисә оры фитофагларын һәм гөбләләрне юк итүче ерткычлар. Фитофаглардан икмәк озынборыннары (Stenodiplosis) — талкыш, тары, төлкекойрык һәм кыяклылар чебенчекләре (Mayetiola) — гессен, солы, йонча чебенчекләре аеруча куркыныч. Алар бодай, арыш, солы, арпа башакларын зарарлыйлар. Шулай ук бакча (груша һәм кура җиләге озынборыннары, карлыган О.ч.), яшелчә (кузак озынборыны, әвернә чәчәкле О.ч.) культуралары һәм урман агачлары (каен, тал, нарат О.ч.) корткычлары да куркыныч. Ерткычлардан гөблә О.ч. (Monobremia subterranea, Aphidoletes aphidimiza, A. urticariae) зур гамәли әһәмияткә (а.х. культуралары корткычларына каршы биол. көрәш) ия.

*Әд.:* М а м а е в Б.М. Галлицы, их биология и хозяйственное значение. М., 1962; М а м а е в Б.М., К р и в о ш е и н а Н.П. Личинки галлиц. М., 1965.

*В.Д.Капитов, О.В.Краснов.*

**ОРЫМШИРМӘ́** (Ырымширмә) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 201 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез басу, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.дә мәчет (1887 дә төзелә), су тегермәне, ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1050,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 610, 1897 дә — 855, 1908 дә — 832, 1920 дә — 808, 1926 да — 695, 1938 дә — 743, 1949 да — 550, 1958 дә — 447, 1970 тә — 404, 1979 да — 280, 1989 да — 202, 2002 дә — 200 кеше.

**ОСА́ РАЙОНЫ́**, Пермь краеның көньягында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 2057,5 *км²*. Үзәге — Оса шәһәре (Пермь шәһәреннән 146 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 29304 (2012), татарлар — 641 кеше (2002, 1989 да — 732 кеше). Татарларның күбесе Оса шәһәрендә яши. Оса пед. уч-щесендә татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләнә (1960 еллардан); 2001–05 елларда «Нәүрүз» балалар берләшмәсе эшли, анда татар теле һәм мәдәнияте өйрәнелә. 2001 дән татар-башкорт иҗтимагый үзәге, 2002 дән Халык мәдәни үзәге каршында «Татар-башкорт мәдәнияте бүлеге» эшли. 2004 тә «Кама буе халыкларының үзенчәлекләрен саклау» темасын яктырткан «Канатлар ныгыганда» проекты тормышка ашырыла, аның нигезендә «Сәйлән» гамәли сәнгать клубы; Оса музеенда милли бүлмәләр; «Мил-

ли кием», «Безнең яңәшәбездә» исемле халык мәдәниятен өйрәнү дәресләре; «Ядкәр» җыр һәм бию ансамбле оештырыла; Казанның меңьеллыгына багышланган ток-шоу үткәрелә. О.р. б-н ТР арасында тыгыз мәдәни бәйләнешләр яшәп килә; Казанга туристлык сәяхәте оештырыла.

**ОСИ́НИН** Алексей Александрович (1881, Казан губ., Мамадыш өязе Гремячка а. — 1922), матрос. Изге Георгий орденының тулы кавалеры. 1904–05 еллардагы рус-япон сугышында «Стерегущий» миноносецында 1 нче статьялы кочегар. Берничә япон корабы б-н бәрелештән соң, экипажның исән калган дүрт әгъзасының берсе. Японнарда әсирлектә үз корабының флагын саклап кала һәм Ватанына кайткач, аны рус хәрби-диңгез командованиесенә тапшыра. О. һәм экипажның башка әгъзалары — А.С.Новиков-Прибойның «Цусима» романы геройларының прототиплары.

*Әд.:* Есть на Вятке городок: Ист.-краевед. очерки. К., 1981; Глухов-Ногайбек М. Казанский ретро-лексикон. К., 2002.

**ОСИ́ННИКИ** посёлогы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 58 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы буенда. 2010 елда 215 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда «Зорька» артеле буларак нигез салына. Оештырылган көненнән Тәмте р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1926 да — 48, 1949 да — 346, 1958 дә — 418, 1970 тә — 368, 1979 да — 331, 1989 да — 265, 2002 дә — 259 кеше.

**ОСИ́НОВКА** авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш. 2010 елда 4 кеше (чуашлар) яши. 1922 дә Ерепкино авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган вакыттан ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 107, 1938 дә — 106, 1949 да — 148, 1958 дә — 69, 1970 тә — 45, 1979 да — 24, 1989 да — 10, 2002 дә — 2 кеше.

**ОСИ́НОВО** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 28 *км* көнчыгыштарак, Казанга әйләнеч юл буенда. 2010 елда 8725 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 49%, татарлар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кошчылык («Казанская» кошчылык ф-касы), яшелчәчелек («*Майский*» теплица комб-ты); үткәргеч торбалар төзелеше («Альтаир» ЯАҖ). 2 урта, 1 музыка мәктәбе. Мәдәният йорты, төбәк тарихы музее, китапханә. Чиркәү, мәчет. 1793 тән Осиново Пүчинкәсе буларак мәгълүм, соңыннан — Осиновка авылы, 1852 дән хәзерге исемдә. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, умартачылык, бакчачылык, тимерчелек, арба, мичкә ясау, тегүчелек һәм ярма яру б-н шөгыльләнә. 1852 дән О.да Грузия Мәрьям Ана иконасы чиркәве (таш бинасы 1884–89 да төзелә; 1930 да ябыла, 1992 дә кабат эшли башлый; архит-ра истәлеге) эшли. 1869 да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе ачыла (1884 тә земство мәктәбе итеп үзгәртелә). 20 йөз башында О.да вак кредит учреждениесе, 3 җил тегермәне, 2 сырыханә, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1205,7 дис. тәшкил итә. 1914 тә халык китапханәсе-уку йорты ачыла. 1930 да «Культиватор» машина һәм «Производитель» терлекчелек ширкәтләре җирлегендә (икесе дә 1929 да оештырыла) Гинзбург исем. к-з (1953 тән Карл Маркс исем.) төзелә, 1960 тан «Юдино» с-зы составында. О. тормышына 1970 еллар башында «Казан» кошчылык ф-касы һәм «Майский» теплица комб-ты төзелү зур йогынты ясый. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Казан өязе Ильинка волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл районында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1817 дә — 366, 1834 тә — 532, 1859 да — 634, 1870 тә — 735, 1897 дә — 916, 1908 дә — 954, 1920 дә — 1030, 1926 да — 1193, 1938 дә — 1000, 1949 да — 1083, 1958 дә — 792, 1970 тә — 955, 1979 да — 3784, 1989 да — 6339, 2002 дә — 7812 кеше. О.да Соц. Хезмәт Герое И.И.*Журин* туган.

*Әд.:* Архипов В.А. Осиновские страницы. К., 2002.

**ОСИ́НОВО КҮЛЕ́**, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында урнашкан, Яшел Үзән р-ны Осиново авылының төньяк-көнбатыш чигендә. Су өслегенең мәйданы 8,2 *га*. Су күләме 720 мең $м^3$. Озынлыгы 600 *м*, иң зур киңлеге 200 *м*, уртача тирәнлеге 9 *м*, иң зур тирәнлеге 24 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы сузынкы. Ярлары чагыштырмача текә һәм күтәренке. Туенуы катнаш, атм. явым-төшемнәре һәм грунт



Осиново күле.

сулары исәбенә туена. Суы җиңелчә минеральләшкән, бик йомшак, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Үтә күренмәлелеге 60 *см*. Яр буе өлеше сазлыкланган. Сугару һәм ял итү максатларында файдаланыла.

**О́СИПОВ** Адольф (Илия Карл) Михайлович (20.7.1842, Подольск губ., Литинский өязе Синява бистәсе — 1917 дән соң), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1872), хакыйкый статский советник (1877). Дворяннар катлавыннан. Варшава дворяннар ин-тын (1862), Гейльдельберг ун-тын (Германия, 1864) тәмамлый. 1864–67 елларда Варшава гражданнар трибуналы мәхкәмә чиновнигы. 1869–96 да Казан ун-тында: мөһим чит ил законнары тарихы кафедрасында доцент (1872 гә кадәр), 1872–73 тә экстраординар проф., 1873–76 да ординар проф., гражданлык хокукы һәм гражданнар эшләре кафедрасында 1876–94 тә ординар проф., 1894 тән атказ. проф., бер үк вакытта юридик ф-т деканы (1886 дан). 1874–83 тә «Казан Император университетының гыйльми язмалары» («Учёные записки Императорского Казанского университета») мөхәррире, 1882 дән Казанның аерым цензоры. 1897–1917 дә Халык мәгарифе министрлыгында хезмәт итә (С.-Петербург). Карашлары буенча хокук тарихчылары мәктәбе — ориенталистлар тарафдары була. Дәүләт барлыкка килүнең патриархальлек теориясен яклый, хокукның җәмгыять тормышындагы көнкүреш шартларына бәйлелеген таный. «Кытай хатын-кызының гаиләдәге һәм дәүләттәге хәле» («Положение китайской женщины в семье и государстве», 1871), «Борынгы Шәрекътә никах хокукы» («Брачное право древнего Востока», вып. 1, 1872), «Кытай хокукы чыганаклары исемлеге» («Перечень источников китайского права», 1875) исемле хезмәтләрендә хокук кагыйдәләрен гомумиләштерә, Борынгы Шәрекътә никах-гаилә мөнәсәбәтләре йолаларын өйрәнә. Вексель хокукы б-н кызыксынуы бу хакта махсус очерк язуга этәрә. 1864 елгы Мәхкәмә реформасыннан соңгы гражданлык процессында прокуратура эшчәнлегенә багышланган хезмәт авторы.

Хезм.: Die Thaetigkeit der Staatsanwaltschaft im russischen Civilverfahren, nebst einigen einschlagenden Zehren. Дерпт, 1868; Вексель в его прошедшем и настоящем. К., 1873.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Емельянова И.А. Всеобщая история права в русском дореволюционном правоведении (XIX в.). К., 1981. Ч. 1.

*Е.Б.Долгов.*



В.И. Осипов.

**О́СИПОВ** Василий Иванович (20.2.1913, Казан губ., Казан өязе Неялово а. — 8.3.1944, Украина ССРның Тернополь өлкәсе Подволочиск штп.), Сов. Союзы Герое (16.10.1943), рядовой. Кызыл Армия сафларына чакырылганчы (1942) туган авылында һәм Казанда эшли. 1942 елдан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 310 нчы укчы полкта укчы (13 армиянең 8 нче укчы дивизиясе). Үзәк, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрлә-

ре составында Курск (1943), Днепр елгасы өчен сугышларда (1943), Уңъяк яр Украинаны (1943–44) азат итүдә катнаша. 1943 нең 22 сентябрендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: десант отряды составында беренче булып елганы кичеп чыга һәм дошман солдатлары б-н кул сугышына керешә. Супруновка авылы (Украина ССРның Подволочиск р-ны) өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Питрәч р-ны Питрәч авылының бер урамы аның исемен йөртә; Олы Бутырка авылында (Питрәч р-ны) Геройга бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**О́СИПОВ** Виктор Петрович (12.11.1871, С.-Петербург — 22.5.1947, Ленинград), психиатр, медицина докторы (1898), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1939), СССР МФАнең хакыйкый әгъзасы (1944), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1933), мед. хезмәте генерал-лейтенанты. В.М.Бехтерев һәм Э.Крепелин шәкерте. Петербург хәрби мед. академиясен тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук, В.М.Бехтерев клиникасында калдырыла. 1898 елда Көнбатыш Европа клиникаларында командировкада була. 1901 дән Казан ун-тының психиатрия клиникасында приват-доцент (бүленеп: 1906–14 тә психиатрия каф. профессоры). 1915 тән Петербург хәрби мед. академиясенең психиатрия каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1928 дән, В.М.Бехтерев исем. Баш миен өйрәнү ин-ты директоры. Хезмәтләре клиник психиатриягә, неврология, психозлар патофизиологиясе, психол., үзәк нерв системасы морфологиясе һәм физиологиясенә карый. О.ның «Фотографик кычкырып уку» («Фотографическое чтение вслух», «Неврологический вестник» ж-лы, 1908) хезмәтендә соңрак фотографик кычкырып уку дип атала башлаган, охшатып хәрәкәтләнү өлкәсенә кертелгән симптом беренче тапкыр тасвирлана. Петербург психиатрлар һәм невропатологлар җәмгыяте әгъзасы (1896 дан), рәисе (1918 дән). Ике Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Кататония Kahlbaum'а. К., 1907; Курс лечения о душевных болезнях. П., 1917; Руководство по психиатрии. М.–Л., 1931.

*Әд.:* П о л я к о в а М.Я. Жизнь и деятельность В.П.Осипова // Из истории отечественной психиатрии. Л., 1967.

**О́СИПОВ** Владимир Иванович (26.4.1939, Юдино р-ны Киндерле а.), спортчы, тренер (дзюдо көрәше), СССРның спорт остасы (1968), бөтенсоюз категорияле судья (1978), РСФСРның атказ. тренеры (1976). Үзәк тренерлар мәктәбен (Мәскәү, 1968), Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын (1979) тәмамлый. «Зенит» ирекле спорт җәмгыятенең Үзәк советы беренчелекләренең чемпионы һәм медаль иясе (1966–71). 1963–71 елларда «Ракета» физик культура коллективында тренер, 1971–78 дә Республика югары спорт осталыгы мәктәбендә директор, 1978–93 тә Урицкий исем. СКда өлкән тренер, 1993–2003 тә ТР Спорт һәм яшьләр эшләре министрлыгының үзәк СКда баш белгеч. 1993 тән ТР Дзюдо федерациясе президенты, 1997 дән Россия дзюдо федерациясе президиумы әгъзасы, 2005 тән Россия Дзюдо федерациясенең ТР төбәк бүлеге рәисе. 1974 тә дзюдо буенча СССР белгечләре составында Японияда стажировка уза. РСФСР җыелма командасын СССР халыклары спартакиадаларына әзерли (1974–75, 1979, 1989), 1986–90 да СССР җыелма командасында (хатын-кызлар) тренер. Шәкертләре арасында: РСФСР беренчелекләре чемпионнары (медаль алучылары) Д.Е.Яковлев (1973, яшүсмерләр), И.Н.Алексеев (1982, бронза), А.А.Захаров (1981), Е.А.Герасимов (1972, бронза), А.Низамиев (1975–76, яшүсмерләр), И.Н.Захарова (1986–88); СССР беренчелекләре чемпионнары (медаль алучылары): Р.Хәмидуллин (1977, бронза, яшүсмерләр), А.Д.Миңлебаев (1992, бронза), И.Н.Захарова (1968, хатын-кызлар, 1988), Р.З.Ларин (1971, 1972, бронза, 1974–75, яшүсмерләр, юниорлар); СССР Кораллы көчләре чемпионатында җиңүче В.И.Михайлов (1972), ВЦСПС беренчелекләрендә җиңүче Е.Суворов (1994). «Россия Физик культура һәм спорт дәүләт комитетына 80 ел» медале, РФ Олимпия ком-тының «Россиядә олимпия хәрәкәтен үстерүдәге казанышлары өчен» билгесе; Халыкара олимпия ком-тының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**О́СИПОВ** Геннадий Емельянович (16.9.1958, Тукай, хәзер Арча р-ны Яңа Кенәр а.), генетик, бакчачы-селекционер, а.х. фән. д-ры (2012). ТРның атказ. агрономы (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, җиләк-җимеш культуралары селекциясе лаб-ясе мөдире (1994 тән). ТРда районлаштырылган слива сортлары: «Сверхранняя», «Волжанка» (2001), «Теньковская голубка» (2002), «Память Хасанова» (2002), «Казан» (2005) һәм алмагачның «Теньковская» сорты автордашы. Хезмәтләре сливаның чәчәкләр органогенезына һәм цитоэмбриологик үзенчәлекләренә карый.

Х е з м.: Особенности органогенеза цветков у слив в Татарстане // Бюл. ВИР. 1993. Вып. 231 (автордаш); Цитоэмбриологические особенности слив в Татарстане // Тр. Всесоюз. НИИ растениеводства. 1999. Т. 155; Урожайность сортов и форм сливы в Татарстане // Научные основы устойчивого садоводства в России. Мичуринск, 1999 (автордаш).

**О́СИПОВ** Илья Тимофеевич (1922, хәзер Алтай краеның Красногорск р-ны Сарыково пос. — 1944), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), рядовой. Милләте буенча татар. Кызыл Армия сафларына чакырылганчы (1941), туган посёлогында урман кисүче булып эшли. 1942 елның сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 134 нче аерым моторлаштырылган понтон-күперләр төзү батальонында (40 нчы армиянең 6 нчы понтон-күперләр төзү бригадасы) хезмәт итә. Брянск, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Ворошиловград (1942), Белгород-Харьков (1943) операцияләрендә, Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Уңъяк яр Украинаны азат итүдә (1943–44) катнаша. 1943 нең 25–29 сентябрендә Киев өлкәсендәге Балыко-Щучинка (Кагарлык р-ны) һәм Козинцы (Переяслав-Хмельницк р-ны) авыллары тирәсендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: дошман уты астында бер төркем сугышчылар б-н пристань төзи һәм баткан паромны яңадан сафка кертә, танклар һәм артиллерияне вакытында уңъяк ярга чыгаруны тәэмин итә. 1944 нең гыйнварында хәбәрсез югала. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**О́СИПОВ** Пётр Николаевич (10.7.1950, Чистай р-ны Берёзовка а.), педагог, пед. фән. д-ры (1993), проф. (1993), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1998). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук эшли, бер үк вакытта Казанның 1 нче мәктәбендә укыта. 1976 елдан РМАнең Һөнәри белем бирү психологиясе һәм педагогикасы ин-тында, 1981 дән һөнәри белем бирүнең төбәк проблемалары лаб-ясе мөдире, ин-тның гыйльми секретаре (1981–93), бер үк вакытта Социаль белем бирү академиясенең социаль эшләр каф. профессоры. «Казанский педагогический журнал»ның баш мөхәррире (1995–2004). 2006 дан Казан технол. ун-ты каршындагы Идел буе һәм Урал югары мәктәп укытучыларын әзерләү һәм яңадан әзерләү үзәгенең югары һөнәри белем бирү методикасы һәм педагогикасы кафедрасында. Хезмәтләре шәхеснең үзлегеннән камилләшүен стимуллаштыру, мәгариф социологиясе мәсьәләләренә карый. РФ хөкүмәте бүләге лауреаты (2005).

Х е з м.: Новые социально-экономические условия переходного периода и общественные требования к личности. К., 1996; Стимулирование самовоспитания учащихся. К., 1997; Профессиональное развитие студента среднего специального учебного заведения: Социально-психологический аспект. К., 2002.

**О́СИПОВ** Пётр Петрович (19.3.1957, Украина ССРның Полтава өлкәсе, Чутово р-ны Артёмовка пос.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2005). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. 1988 дән РФА КГҮдә: Физика-техника ин-тында, 1991 дән Механика һәм машиналар төзү ин-тында. Хезмәтләре технол. процессларны модельләштерү һәм оптимальләштерүгә карый. О. күзәнәкчел тирәлекләрдә, релаксация тәэсирләрен исәпкә алып, нефтьләр фильтрлаштыруның матем. теориясен эшли (Ю.М.Молокович б-н берлектә). Электр дугалы мичләрдә корыч эретүнең матем. моделен; нурлы күчерү тәэсирендә эретү мәсьәләләрен исәпләү алгоритмнарын; мич б-н идарә итүнең динамик программалаштыруга нигезләнгән, ш.у. күпсанлы производство чикләмәләре очрагында векторлы диаграмма буенча идарә итүнең билгеле алымын гомумиләштерү принцибын, хәрәкәтчән стеналы каналларда газның ирекле молекуляр агымнарын исәпләү алымнарын тәкъдим итә. Матдәләрне җентекләп чистарту өчен хәрәкәтчән бандта фракцион кристаллаштыруның матем. моделен эшли, процессны оптимальләштерә, туры агымлы схеманың кире агымлы схемадан күпкә файдалы-

рак булуын күрсәтә. Дискрет хәлләр симуляторын — Pla(i)n (сәүдә маркасы), ш.у. критиктан югары экстракциядә һәм үсемлек чыганаклы ике күзәнәкле тирәлекләрдән масса күчерү симуляторын эшләүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Основы теории релаксационной фильтрации. К., 1987 (автордаш); Задачи переноса при свободномолекулярном течении газа и лучистом теплообмене. К., 2004; Method of calculating planar and nonplanar problems of molecular gas flow in curvilinear channel with moving walls // Vacuum. 1996. V.47, № 1.

**О́СИПОВА** Раиса Якимовна (9.7.1944, Югары Ослан р-ны Рус Борнашы а.), радиоэлектрон аппаратуралар монтажлаучы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1947). 1962–66 елларда п/я 421 номерлы пр-тиенең (Казан) диспетчерлык хезмәтендә оператор, браковщик булып эшли. 1966–92 дә Казан төгәл машиналар з-дында радиоэлектрон аппаратуралар җыючы, монтажчы. О. берничә төрдәш һөнәрне үзләштерә, бу аңа заводта беренчеләрдән булып бригада подрядын кертү мөмкинлеген бирә. Хезмәттәге уңышлары өчен заводның Мактау китабына кертелә, бригадасы «СССР Машиналар төзү министрлыгының иң яхшы бригадасы» исеменә лаек була. Дәүләт бүләге хезмәттәге һәм алдынгы алымнар кертүдәге, аларны оештыру формаларын булдырудагы казанышлары өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ОСЛО́ПОВ** Владимир Николаевич (20.10.1945, Ворошилов ш., хәзер Приморье краеның Уссурийск ш.), терапевт, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2005). Шпага фехтованиесе буенча СССРның спорт остасы (1967). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли, 1989 елдан эчке авырулар пропедевтикасы каф. мөдире. 1996–99 да ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш кардиологы. Хезмәтләре гипертония авыруы патогенезына һәм авыруны дәвалау ысулларына карый. О. артериаль гипертензияне күзәнәк мембраналары халәте позициясеннән тикшерә, кешедәге патологияләрнең мембранага бәйле нигезләрен өйрәнү буенча фәнни юнәлеш булдыра. ТРда 1999–2009 да төп йөрәк-кан тамырлары авыруларының беренчел һәм икенчел профилактикасы программасын төзи, балаларда атеросклероз авыруын фаразлау һәм ишемияне алдан кисәтү ысулларын эшли.

Х е з м.: Изменения глюкокортикоидной функции коры надпочечников у больных инфарктом миокарда, леченных триоксазином и аминазином // Кардиология. 1976. № 7 (автордаш); Повреждение цитоплазмических мембран и тромбопластинемия при гиперхолестеринемии // Бюл. эксперим. биологии и медицины. 1981. № 6 (автордаш); Клиническое значение определения ионтранспортных функций клеточных мембран при гипертонической болезни и её церебральных осложнениях // Казан. мед. журн. 2000. № 3 (автордаш); Общий уход за больными в терапевтической клинике. М., 2004 (автордаш).

**ОСО́КИН** Дмитрий Яковлевич ( 3.11.1937, Казан — 20.12.2009), физик, физика-матем. фән. д-ры (1984). 1959 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, оборона з-дында (Казан) эшли, радиотехника бүлегендә төркем башлыгы (1963 тән). 1965 тән РФА КГУнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1986 дан), төш магнетизмы лаб-ясе мөдире (1988–91), баш фәнни хезмәткәр (1992 дән). Хезмәтләре каты җисемнәрдә төш квадруполь резонансына (ТКР) карый. О. төрле кушылмаларда ТКРның яңа спектраль сызыкларын эзләү һәм релаксацион үлчәүләр алу өчен дөньяда беренче киң диапазонлы импульслы когерент ТКР спектрометрын эшли (1967). Беренче булып азот-фосфор, азот-мышьяк, азот-бор, азот-кремний, азот-хлор, азот-күкерт химик бәйләнешләре булган кушылмаларда ТКРның спектраль ешлыкларын терки һәм шулар нәтиҗәсендә мондый бәйләнешләрнең параметрларын (полярлык, кабатлану дәрәҗәсе) таба; күп импульслы резонанс вакытында ТКР спектрометрларының сизгерлеген унарча тапкыр күтәрә торган когерент стационар халәтләрне ача (1980); күп импульслы ТКРда күчеш процессларын тикшерә, күп импульслы эзлеклелекләр кайтавазы сигналларын чорнаучыда кайтаваз-сигналлар барлыгын ачыклый; күзәтүче координатлар системасында ТКР-томография алымын тәкъдим итә. СССР Космонавтика федерациясенең акад. Н.А.Пилюгин исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ядерный квадрупольный резонанс в соединениях азота. М., 1977 (автордаш); Формирование сигналов эха в выстроенных (неполяризованных) квадрупольных системах // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1994. Т. 106, вып. 2 (автордаш); Pulsed line narrowing in nitrogen-14 NQR // Phys. Stat. Solidy (b). 1980. V.102; NQR transient nutation and rotary echoes in the effective field of multiple — pulse sequences // Solid State Nuclear Magnetic Resonance. 1997. V.10 (автордаш).

**ОСО́КИН** Евграф Григорьевич (1819, Вологда ш. — 17.3.1880, Казан), хокук белгече, икътисадчы, сәясәт фән. д-ры (1849), яшерен советник (1876). Руханилар катлавыннан. Вологда руханилар семинариясен (1837), Баш пед. ин-тын (С.-Петербург, 1841) тәмамлый. 1845 елдан Казан ун-тында: дәүләт салымнары һәм финанслары турында законнар кафедрасында адъюнкт (1849 га кадәр), 1849–55 тә экстраординар проф., 1855–70 тә ординар проф., 1870 тән атказ. проф., бер үк вакытта, 1855–63 тә, юридик ф-т деканы, 1863–72 дә һәм 1876 дан ректор. Рау индивидуалистик һәм тарихи-физиол. мәктәпләр икътисадчылары карашларын яклый. Политэкономия, стат., финанс хокукы буенча хезмәтләр авторы. О.ның «Пауперизмны тарихи-тәнкыйди өйрәнү» («Историко-критическое исследование пауперизма», 1846) хезмәтендә Россия һәм Көнбатыш Европадагы түбән катлау вәкилләренең хәле яктыртыла һәм фәкыйрьлеккә каршы законлы чаралар билгеләнә. «Россиядә эчке таможня салымнары» («Внутренние таможенные пошлины в России», 1850) монографиясе борынгы заманнардан башлап 18 йөз уртасына кадәр таможня җыемнары тарихына багышлана. «Рус финанс хокукы тарихы буенча берничә бәхәсле мәсьәлә» («Несколько спорных вопросов по истории русского финансового права», «Д.И.Мейерның юридик җыентыгы»нда 1855 тә басыла) мәкаләсендә юридик белемнең системалылыгы принцибын яклап чыга.

Х е з м.: Об организации финансового управления в Афинах. К., 1852; О понятии промыслового налога и об историческом его развитии в России. К., 1856.

*Әд.:* С т е п а н о в Я.С. Евграф Григорьевич Осокин: Некролог. К., 1881; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Ректоры Казанского университета. 1804–2004 гг.: Очерки жизни и деятельности. К., 2004.

*Е.Б.Долгов.*

**ОСО́КИН ЙОРТЫ́**, Казанда архит-ра истәлеге. 1767 елда арх. В.И.Кафтырев проекты буенча, Петербург бароккосы стилендә Казан постау мануфактурасы хуҗасы И.П.Осокин өчен төзелә. Шәһәрнең түбән өлешендә, Постаучылар бистәсендә урнашкан. Башта ике катлы турыпочмаклы бина буларак төзелә. Дүрт кыеклы түбә калай б-н ябыла. Йортка ишегалды ягыннан керелә.



И.П. Осокин йорты.
Арх. В.И. Кафтырев. 1767. Казан.

Бинаның урам фасады почмаклары һәм аркылы диварлар тоташкан урыннары терәкләр б-н ныгытыла. Ишегалды фасадында ризалит чыгып тора. Катлар, терәкләр куелган урыннары ныгытылган өске кәрниз кебек профиль бирүче тәҗе б-н бүленгән. Кирпеч диварлар штукатурлап агартылган. 19 йөз ахырында йорт, бинаның күләме сакланган хәлдә, өч катлы итеп үзгәртеп корыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Н.Г.Надыйрова.*

**ОСО́КИН** Николай Алексеевич (10.4.1843, С.-Петербург — 29.12.1895, Казан), тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, гомуми тарих д-ры (1872), хакыйкый статский советник (1877). Мещан гаиләсеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1865); шунда ук эшли: профессорлык стипендиаты (1867 елга кадәр), 1867–69 елларда приват-доцент, 1869–72 дә доцент, 1872–92 дә ординар проф., 1892 дән гомуми тарих кафедрасының атказ. профессоры; 1872–74 тә тарих-филол. ф-ты сәркәтибе, «Известия Императорского Казанского университета» һәм «Учёные записки Императорского Казанского университета» ж-ллары мөхәррире. Бер үк вакытта, 1873–81 дә, Казан җәмәгать округының участок мировой судьясы. Казан җәмәгать округының шәрәфле мировой судьясы (1881 дән). Россия либераль медиевистикасында сәяси юнәлеш вәки-

ле. «Ачкыччы» («Ключница», СПб., 1859) повесте авторы. Хезмәтләре Италия, Франция, Англия, көнбатыш славяннар тарихына карый. «Альбигойлар һәм алар заманы тарихы» («История альбигойцев и их времени», т. 1–2, 1869–72) фундаменталь хезмәтендә О. альбигойлар хәрәкәте һәм Көнбатыш Европада (13 йөз) шуңа бәйле тарихи процесслар мәсьәләсен тикшерә. Көнбатыш Европа илләре тарихы, тарих белеме һәм мәдәниятенә багышланган лекцияләр, ш.и. «Гомуми әдәбият» («Всеобщая литература», 1873), «XIX йөз тарихы» («История XIX столетия», 1873), «Иң яңа тарих» («Новейшая история», 1–2 кит., 1874–76), «Яңа заман тарихы» («История нового времени», 1–2 кис., 1880–81), «Урта гасырлар историографиясен тасвирлау: Университет укуларыннан» («Очерк средневековой историографии: Из университетских чтений», 1888), «Урта гасырлар тарихы» («История средних веков», т. 1–2, 1888–89) кебек хезмәтләре дә әһәмиятле урын алып тора. Казанда югары хатын-кызлар курслары ачылуга өлеш кертүчеләрнең берсе (1876), пед. совет рәисе (1877 дән). Казанда уку-укыту (1887) һәм шәһәр (1895) музейларын оештыруда, Казан губернасы аша Себергә тимер юл салу мәсьәләсен хәл итүдә катнаша; «Патша тарафыннан расланган Себер тимер юлы магистраль линиясе» («Высочайше утверждённая магистральная линия Сибирской железной дороги», 1883), «Себер тимер юлы мәсьәләсенә карата, Муром–Казан линиясе» («К вопросу о сибирской железной дороге, муромско-Казанская линия», 1884) язмаларын бастыра. Җирле халык мәктәпләре, хатын-кызлар белеме мәсьәләләрен кайгырта. Казан шәһәр думасы (1878 дән), Казан өяз (1879 дан) һәм губерна (1880 нән) земство җыеннары гласные. Изге Гурий Борадәрлеге советы әгъзасы (1880 еллардан) һәм казначысы (1892 дән). Казан реаль уч-щесе попечительлеге әгъзасы (1887–90). Рус техника җәмгыятенең Казан бүлеге рәисе (1889 дан).

Х е з м.: Внутреннее состояние Римско-католической церкви в XIII веке и отношение к ней общества. СПб., 1869; Политические движения в Западной Европе в первой половине нашего века. К., 1885; Профессиональное направление женских гимназий и прогимназий. СПб., 1890; Автобиография // Ист. вестн. 1896. Т. 63, № 1.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; А г а ф о н о в Н.Я. Из Казанской истории. К., 1906; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1; Я г у д и н Б.М. Николай Алексеевич Осокин, 1843–1895. К., 2003.

*Е.Б.Долгов.*


**ОСО́КИННАР**, Казан сәүдәгәрләре һәм дворяннары, эшмәкәрләр, җәмәгать эшлеклеләре. **Иван Петрович** (1745 — ?), *Казан постау мануфактурасын* һәм сәүдәгәр И.Ф.Дрябловның (к. *Дрябловлар*) милкен мирас итеп ала. Казанга император Екатерина II килгәч, Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстияннәр сугышыннан зыян күрүче буларак, аңа — полковник, соңрак коллежский советник дәрәҗәсе бирелә һәм ул нәселдән килгән дворянлык титулы ала. 1796 елда Казанда 4 таш йорты була (Черек күл артында, Петропавел тыкрыгында, Георгиевский һәм Гостинодворский урамнарында). Уфа наместниклыгының Бәләбәй округында Түбән Троицкий (Нижне-Троицкий) һәм Усень-Ивановский бакыр кою з-длары, Вятка краенда Омутнитский тимер кою з-ды төзи. Аның милкен гвардия прапорщигы **Гавриил Иванович** (1785 — 31.1.1869, Казан, Арча кыры зиратында җирләнә) мирас итеп ала. Казан губернасының Мамадыш өязе Нырты авылында бакыр кою з-ды хуҗасы (елына 2100 поттан күбрәк бакыр коела). Аның балалары: **Алексей Гаврилович** (15.3.1818 — 1887) хакыйкый статский советник, Император сарае камергеры. 1871–86 да Казан губернасында дворяннар башлыгы. 1850 дән Казан икътисадчылар җәмгыятендә: а.х. бүлеге рәисе (1855–69), вице-президент (1869–78), президент (1878–87). 1 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә. **Пётр Гаврилович** (29.3.1821 — 23.2.1898) гвардия подпоручигы, хакыйкый статский советник, вакытлы 1 нче гильдия сәүдәгәре. Казан постау мануфактурасын арендага бирә. Казанда ике катлы таш һәм агач йортлары, Казан губернасының Лаеш өязендә ярма яргыч, су тегермәне, 4340 дис. җире була. 1853–58, 1860 та — Лаеш өязе, 1862–70 тә Казан губернасы дворяннары башлыгы. Казан шәһәр думасы гласные, Казан земство йөкләмәләре буенча махсус кабулханә әгъзасы. Вафатыннан соң банкрот дип игълан ителә. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә. Ш.у.к. *Осокин йорты.*

*Әд.:* С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Казанское дворянство. 1785–1917 гг.: Генеал. словарь. К., 2001.

**ОСО́СКОВ** Павел Иванович (28.12.1897, Воронеж ш. — 4.8.1968, Украина ССРның Симферополь ш.), драма актёры, ТАССРның халык артисты (1945). Гражданнар сугышында катнаша. 1918 елда Казак армиясенең җәза отрядына алына, Уральск прапорщиклар мәктәбендә укый, 1920 дә кызылармиячеләргә әсирлеккә бирелә, концлагерьга җибәрелә, 1921 дә азат ителә һәм Владимир губернасының Муром шәһәрендәге театр труппасына актёр булып урнаша. 1924 тә Саратов театр техникумына укырга керә, аны тәмамлаганнан соң, Воронеж (1927–31), Казан Зур (1931–50), Симферополь (1950–59) драма театрларында эшли. Казан театры сәхнәсендә 100 гә якын роль башкара. О. — көчле характерлы, иҗади хыялга бай һәм күзәтүчән актёр; зур булмаган рольдә дә сәнгатьчә чаралар табып, истә калырлык образ тудыра ала. Аның башкаруында Сенечка Перчаткин («Чит кеше баласы», В.В.Шкваркин) — гротесклы фигура, Василий Шуйский («Фёдор патша», А.К.Толстой) — икейөзлелекне гәүдәләндерүче образ. Актёрга тормышчан оптимизм б-н сугарылган, кыю, акыллы, халыкчан характерлар аеручак якын була. Ул иҗат иткән Денис Давыдов («Фельдмаршал Кутузов», В.А.Соловьёв), чик буе сугышчысы Кульков («Чик сакчылары», Н.Ф.Погодин), француз эшчесе Селестен («Интервенция», Л.И.Славин), комиссар Иван Гора («Михнәтле заман», А.Н.Толстой романы буенча) шундыйлардан. О. рус һәм дөнья классикасы әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә зур рольләр башкара. Алар арасында Загорецкий («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Бобчинский, Хлопов («Ревизор», Н.В.Гоголь), Белогубов, Аркадий Счастливцев («Төшемле урын», «Урман», А.Н.Островский), Костылёв («Тормыш төбендә», М.Горький) була. Актёрның Казан театры сәхнәсендә башкарган соңгы зур рольләренең берсе — Н.Исәнбәт пьесасы буенча куелган «Мулланур Вахитов» спектаклендәге Тимербай образы. 1934–35 тә Казан ун-тында студентлар театры б-н җитәкчелек итә.



П.И.О с о с к о в Тимербай ролендә («Мулланур Вахитов», Н.Исәнбәт).



П.И.Осоское.

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И., Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ОСТА́НКОВО** авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 128 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында Бекметево авылы (Түбән Башинда, Бишинды, Бушанды атамалары да билгеле) буларак нигез салына, 1750 елларда авыл тирәсендәге җирләр Казан драгун полкы капитаны И.И.Останковка сатыла, анда ул рус крәстияннәрен урнаштыра. Рев-циягә кадәрге чыганакларда О. Яңа Спас, Бишенде-Останково исемнәре б-н телгә алына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да волость идарәсе урнаша; Спас чиркәве (1798 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1876 да ачыла), фельдшерлык пункты, җил тегермәне, 20 вак-төякләр кибете эшли; базар (сишәмбе саен) һәм ярминкә (8 ноябрь) үткәрелә. 1920 гә кадәр авыл — Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны:

1870 тә — 1611, 1897 дә — 745, 1920 дә — 973, 1926 да — 772, 1938 дә — 656, 1949 да — 366, 1958 дә — 378, 1970 тә — 264, 1979 да — 201, 1989 да — 121, 2002 дә — 126 кеше.

**ОСТРО́В УКЧЫ́ ДИВИ́ЗИЯСЕ**, 1941 ел ахырында — 1942 ел башында Казанда 146 нчы укчы дивизия буларак оештырыла. Беренче командиры итеп генерал-лейтенант Ю.В.Новосельский билгеләнә. 50, 49, 67 нче армияләр һәм 3 нче удар армия составында сугыша. 1942 нең апрелендә Мәскәү янында беренче тапкыр сугышка керә. Спас-Деменск, Остров, Тарту, Рига, Варшава шәһәрләрен азат итүдә һәм Берлинны алуда катнаша. Батырлыгы өчен Остров дивизиясе дигән мактаулы исем бирелә (1944, июль). Тарту һәм Берлин шәһәрләрен алганы өчен Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов орденнары б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кирсанов Н., Гильманов З. Шла дивизия вперёд. К., 1972.

*В.Ф.Телишев.*

**ОСТРО́ВА** Светлана Олеговна (15.5.1938, Казан), радиотехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994). 1962 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, очкыч аппаратлар җитештерү каф. профессоры (1995 тән), бер үк вакытта «Радар» порошоклы капламнар үзәгендә (1993 тән). Хезмәтләре электрик флуктуацияләрне физик-техник һәм мед. тикшерүләргә карый. О. электрон элементларны аларның сыйфатын бозмыйча электрофлуктуацион тикшерү теориясен, алымнарын һәм чараларын эшли. Фликкеррефлексотерапия өчен мед. приборлары һәм алымнары, ш.у. порошоклы полимер капламнар төшерү өчен җиһазлар (ТР һәм РФнең оборона комплексы пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә) булдыру эшендә катнаша. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Исследование связи между уровнем токовых шумов и качеством микроплёночных резисторов // Микроэлектроника. 1969. Вып. 4 (автордаш); Измерение токовых шумов как метод контроля качества микроплёночных резисторов // Изв. вузов. Радиоэлектроника. 1970. № 10 (автордаш); О возможности определения величины допустимой мощности микроплёночных резисторов по шумовым характеристикам // Микроэлектроника. 1971. Вып. 6 (автордаш).


**ОСТРО́ВКА** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Башкортстан чигендә урнашкан. 2010 елда 18 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 еллар башында нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Иректе (1924 тән — Мөслим) волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 179, 1938 дә — 204, 1949 да — 221, 1958 дә — 125, 1970 тә — 93, 1979 да — 61, 1989 да — 45, 2002 дә — 48 кеше.

**ОСТРОПО́ЛЬСКИЙ** Вадим Григорьевич (8.8.1927, Украина ССРның Харьков ш. — 22.6.1980, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССРның халык артисты (1976). Харьков театр ин-тын (1949), Дәүләт театр сәнгате ин-ты (ГИТИС) каршындагы Югары режиссёрлык курсларын (Мәскәү, 1967) тәмамлый. 1949–50 елларда — Харьков өлкә театрында, 1950–51 дә — Харьковның украин,



В.Г.Остропольский.

1951–67 дә Севастопольнең рус драма театрларында актёр, бер үк вакытта режиссёр да була. 1967 дән Казан Зур драма театры актёры. Теге яки бу образны иҗат иткәндә, аның тышкы үзенчәлекләрен дә исәпкә алу б-н бергә, актёр игътибарны героеның эчке дөньясына юнәлтә, аның фикер йөртү рәвешен, әйләнә-тирә тормыш вакыйгаларын аңлап кабул итү үзенчәлекләрен тиешле югарылыкта җиткерергә омтыла. Теге яки бу образны гәүдәләндерүдә О. иҗаты югары зәвыклылыгы б-н аерылып тора. Рольнең хәрәкәт линиясен төгәл һәм җентекле кора, тамашачының игътибарын героеның һәр сүзе, һәр гамәле б-н үзенә җәлеп итә. О. сәхнәдәге табигый яшәешкә һәрдаим рухи киеренкелектә булуы, өзлексез фикер йөртә белүе нәтиҗәсендә ирешә. Актёр башкаруында Александр Машков («Гадәт буенча җыелу», В.С.Розов), Пётр Адуев («Гадәти вакыйга», И.А.Гончаров романы буенча), Ленин («Көчле яңгырлар арасында», А.П.Штейн), Плинер («Озату», И.М.Дворецкий), Луначарский («Большевиклар», М.Ф.Шатров), Троян («Астория» кунакханәсе», А.П.Штейн) образлары шундыйлардан. О.ның Корзухин («Качу», М.А.Булгаков), Крутицкий («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Монахов («Варварлар», М.Горький), Нуретдин («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Пунтила («Пунтила һәм аның хезмәтчесе Матти», Б.Брехт) рольләре социаль гомумиләштерү тирәнлеге б-н аерылып тора. Аның Родион Николаевич («Модадан чыккан комедия», А.Н.Арбузов), Узып баручы («Валентин һәм Валентина», М.М.Рощин), Илико («Мин, әби, Илико һәм Илларион», Н.Думбадзе повесте буенча) образлары нечкә лиризм һәм бер үк вакытта зирәклек б-н сугарылган. Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) сәхнәсендә М.Горькийның «Соңгылар» («Последние») һәм А.Г.Алексинның «Кире адрес» («Обратный адрес») спектакльләрен куя. О. дирижёр Н.Г.Рахлин һәм Татар филармониясенең симфоник оркестры б-н берлектә Ю.А.Осносның П.И.Чайковский һәм Н.Ф. фон Мекк хатлары буенча «Мәңгелек өчен яшәү» («Жизнь для вечности») спектаклен Татар филармониясенең концертлар залы сәхнәсендә куя. Казан театр уч-щесендә укыта.



В.Г.Остропольский Корзухин ролендә («Качу», М.А.Булгаков).

*Әд.:* Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991; Благов Ю. Всегда современный актёр // Татарстан. 1997. № 9.

*Ю.А.Благов.*

**ОСТРОУ́МОВ** Алексей Александрович (29.1.1858, Сембер ш. — 1.2.1925, Казан), зоология д-ры (1889). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1882), Новороссийск ун-тында (Одесса ш.) эшли. 1885 елда Неаполь шәһәренә (Италия), җирле биол. станциягә командировкага җибәрелә. 1886 дан Казан ун-тында (бүленеп: 1891–97 дә Севастополь биостанциясе мөдире), зоол. каф. профессоры һәм зоол. кабинеты мөдире, бер үк вакытта Көнчыгыш пед. ин-ты укытучысы (1922 дән). Хезмәтләре җир өсте умырткалылары эмбриологиясенә, гидробиологиягә карый. Кара диңгез, Азов диңгезе фаунасының 18 яңа төрен ачыклый (Moerisia inkermanica медузасы, алабугалар семьялыгы балыгы Asperina improvisu һ.б.). Мәрмәр, Япон диңгезе, Кара һ.б. диңгезләргә оештырылган күп кенә экспедицияләрдә катнаша. Казан табигыятьчеләр җәмгыятенең президенты (1912 дән), аның шәрәфле әгъзасы (1919 дан); Мәскәү табигатьне тикшерүчеләр җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1925 тән).

Хезм.: К истории развития ящериц Phrynocephalus helioscopus // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1888. Т. 19, вып. 3; Краткий отчёт о гидробиологических исследованиях в 1897 г. // Изв. Имп. АН. 1898. Т. 8, № 2; Периодичность роста стерляди: Аутокатализ. К., 1911.

*Әд.:* Кузнецов В.А., Галанин И.Ф. Алексей Александрович Остроумов, 1858–1925. К., 2002.

*В.А.Кузнецов.*

**ОСТРОУ́МОВ** Всеволод Петрович (26.1.1918, Саранск ш. — 10.5.1981, Казан), архитектор, төзүче-инженер, педагог. Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), Байкал аръягында хәрби инженер булып хезмәт итә. 1946 елдан Чита шәһәрендә: өлкә башкарма ком-тының төзелеш һәм архит-ра бүлеге башлыгы, бер үк вакытта, 1948 дән, пед. ин-тында, төзелеш, тау һәм урман технол. техникумнарында укыта. О. Читаның ген. планын әзерләүдә катнаша, аның проектлары буенча өлкә партия мәктәбе бинасы (1952), спорт сарае (1961), торак йортлар төзелә. 1956 да Чита өлкәсендә мәңгелек туң шартларда төзелеш практикасына кертү өчен расланган биналар төзелеше кагыйдәләрен эшли. 1958 дән Саранскида: «Мордовпромпроект» ин-тының баш инженеры, бер үк вакытта Мордовия ун-тында укытучы. 1961 дән Казанда, «Татнефтепроект» ин-тының баш инженеры, 1962 дән Казан төзүче инженерлар ин-тының архит-ра кафедрасында, архит-ра ф-тының беренче деканы (1969–75). Казан һәм Татарстан архит-расы тарихы буенча хезмәтләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Саранск: Ист.-архитектур. очерк. Саранск, 1960 (автордаш); Свияжск: История планировки и застройки. К., 1971 (автордаш); Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ОСТРОУ́МОВ** Николай Петрович (15.11.1846, Тамбов губ., Елатинск өязе Сасово а. — 17.11.1930, Ташкент янындагы Луначарский а., башка мәгълүматлар буенча Никольский пос.) миссионер, ислам дине галиме, тарихчы, филолог, христиан дине теологы, теология магистры (1871), *Изге Гурий борадәрлегенең* (1874), Казан руханилар академиясенең шәрәфле әгъзасы (1892), Тамбов руханилар семинариясен (1866), Казан руханилар семинариясен (1870) тәмамлый. Н.И.*Ильминский* шәкерте. 1870–77 елларда Казан руханилар академиясендә эшли, «Мөхәммәд динен фаш итү», «Мөхәммәд тарихы» миссионерлык предметлары буенча лекцияләр укый; гарәп һәм татар теле дәресләре алып бара. Бер үк вакытта, 1870–71 дә, Казан руханилар семинариясендә — татар теле һәм миссионерлык вәгазьләре, 1872–74 тә Казан укытучылар семинариясендә тарих һәм география укыта. 1871–76 да «Миссионерский противомусульманский сборник» ж-лын чыгару буенча комиссия әгъзасы, 6 нчы һәм 7 нче чыгарылышлар мөхәррире. 1872–77 дә «Изге Гурий борадәрлеге»ндә эшләр башкаручы һәм аның советы әгъзасы була, борадәрлек мәктәпләре укытучыларының еллык съездларында лекцияләр укый. 1877 дән Ташкентта эшли (бүленеп, 1917–21 дә туган авылында яши): 1877–89 да Төркестан төбәге мәдрәсәләрендә инспектор, бер үк вакытта, 1879–89 да, Ташкент укытучылар семинариясе директоры; 1889–1917 дә Ташкент ир балалар гимназиясендә директор; бер үк вакытта Урта Азия халыклары телендәге беренче вакытлы басма — «Туркестанская туземная газета» (1883 кә кадәр сарт һәм кыргыз телләрендә чыга, 1885 тән — рус теленә тәрҗемә б-н сарт телендә басыла) мөхәррире. О. катнашында үзбәк телендә А.С.Пушкин һәм Л.Н.Толстойның кайбер әсәрләре дөнья күрә. 1886 да, Урта Азиядә Император археол. комиссиясе вәкиле буларак, төбәктә беренче археол. казу эшләре үткәрә. 1895 тә Урта Азиядә беренче Шәрекъне өйрәнү үзәге — Төркестан археол. сөючеләр түгәрәгенә нигез сала. 1904 тән Урта һәм Көнчыгыш Азияне өйрәнүче Рус ком-ты мөхбир әгъзасы. 1905 елда С.-Петербургта «рус булмаган милләт вәкилләренең мәгариф мәсьәләләре буенча махсус киңәшмәсе» эшендә, 1910 да Казанда узган «миссионерлар съезды»нда катнаша, анда «Рус Православие чиркәвенең миссионерлык карашларында рус хөкүмәтенең икеләнүе» темасына доклад ясый. 1916–17 дә Төркестан хәрби округы штабы каршындагы Төркестан һәм чиктәш Шәрекъ илләре халыклары телләре тәрҗемәчеләрен әзерләүче Ташкент офицерлар мәктәбендә мөселман хокукын укыта. Хезмәтләре Урта Азия халыкларының тарихы, археологиясе һәм этнографиясенә, таҗик, үзбәк һәм кыргыз халыкларының төрки лексикографиясенә, матди һәм рухи культурасына карый. Британия Библия җәмгыяте кушуы буенча сарт теленә Дүрт Инҗил китабын тәрҗемә итә (Лейпциг, 1891). 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче һәм 2 нче дәрәҗә Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Критический разбор мухаммеданского учения о пророках // Миссионерский противомусульманский сборник. К., 1874; Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещёных татар Казанской губернии. К., 1876; Мир ислама в прошлом и настоящем. Таш., 1912; Вероучение Корана. М., 1915.

*Әд.:* Л у н и н Б.В. Из истории русского востоковедения и археологии в Туркестане. Таш., 1958; Х а б и б у л л и н М.З. Михаил Александрович Машанов — профессор Казанской духовной академии, миссионер и исламовед. К., 2006.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ОСТРЯ́КОВ** Александр Николаевич (14.8.1871, Самара губ. Богырыслан ш. — 25.12.1951, Краснодар краеның Сочи ш.), туфрак белгече, а.х. фән. д-ры (1940). Казан ун-тын (1894), Мәскәү а.х. ин-тын (1898) тәмамлый. 1898–1901 елларда Иваново һәм Костычёво а.х. тәҗрибә станцияләрендә эшли. 1901–31 дә Казан ун-тында, 1906 дан проф. һәм аграр кабинет мөдире. 1907–11 дә Германия, Франция, Австриядә фәнни командировкада була. Бер үк вакытта, 1922–31 дә, Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты профессоры, туфрак белеме каф. мөдире (1925 тән). 1931 дә Алма-Атага сөргенгә җибәрелә (1934 кә кадәр), 1933–36 да Казакъстан а.х. ин-тының органик химия каф. мөдире. 1938 дән Сочи шәһәрендә, Сочи субтропик һәм көньяк җимеш культуралары тәҗрибә станциясендә консультант (1943–51). Хезмәтләре туфрак барлыкка килү мәсьәләләренә карый. О. Россиянең чүлле-далалы һәм субтропик өлкәләренең туфрак катламын тикшерә. Самара һәм Саратов губерналарының аксыл-коңгырт һ.б. туфракларын тасвирлый, сугару кирәклеген күрсәтә һәм тузлануга каршы агротехник чаралар системасын эшли. Кавказның Кара диңгез яр буе субтропикларындагы дымлы шартларда җил б-н кибү процессын, латеритлы туфракларны (кызыл һәм сары туфрак) тикшерүе аеруча әһәмияткә ия. «Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты хәбәрләре»ндә редколлегия әгъзасы, «Сельское хозяйство Татарстана» ж-лының беренче мөхәррире (1921–22). Үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Влияние условий поверхностного увлажнения на процессы почвообразования в сухих областях. К., 1905; Вегетационные и полевые опыты с термофосфатом и другими минеральными удобрениями в 1913. К., 1914; К познанию латеритных почв: В 2 ч. К., 1915–17; Почвоведение: Курс лекций для студентов вуза: В 2 ч. К., 1928–29.

*Әд.:* К о л о с к о в а А.В. Александр Николаевич Остряков и его работы в области почвоведения // Почвоведение. 1988. № 2; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*В.Н.Доронин, Н.В.Мезрина.*

**ОСЫ́КА** Иван Иванович (16.1.1953, Украина ССРның Одесса өлкәсе Измаил ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Киев политехник ин-тын тәмамлый (1976). 1975–77 елларда «Прогресс» з-дының механикалаштыру һәм автоматлаштыру бүлегендә инженер-конструктор (Чернигов өлкәсенең Нежин ш.). 1977–86 да «Укрсельхозтехника"ның Измаил технол. җиһазлары з-дында инженер-технолог, технол. бюросы, бүлеге башлыгы, баш технолог. 1986–92 дә һәм 1993 тән «АлАЗ» ЖБ» АҖдә: Станок-инструментлар з-дында инженер-технолог, бүлек башлыгы, техник үзәкнең баш белгече, баш технолог (2002 дән). Дәүләт бүләге 50 һәм 60 *т* йөк күтәрешле нефть һәм газ скважиналарын үзләштерү һәм ремонтлау өчен югары технологияле күтәрү агрегатларын эшләүдә һәм җитештерүдә катнашканы өчен бирелә.

**ОТА́РКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Вятка елгасындагы Отар пристане. 2010 елда 287 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Покров чиркәве. 1680 нән Атарка авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский исеме б-н дә билгеле. Халкы башта монастырь крәстияннәре катлавына керә, 1764 тә Саклык коллегиясе карамагына тапшырыла, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да Покров чиркәве (1853–56 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 җил тегермәне, май язу йорты, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4018 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красная Горка волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 249 ир-ат; 1859 да — 1138, 1897 дә — 1254, 1908 дә — 1490, 1920 дә — 1388, 1926 да — 1438, 1938 дә — 1373, 1949 да — 1228, 1958 дә — 772, 1970 тә — 849, 1979 да — 548, 1989 да — 460, 2002 дә — 398 кеше.

**ОТОРИНОЛАРИНГОЛО́ГИЯ** (грек. ús (ōtós) — колак; rhís (rhinós) — борын; lárynx (lárygos) — бугаз һәм ...*логия*), л а р и н г о - о т о р и н о л о г и я (ЛОР), клиник мед. бүлеге; колак, борын, йоткылык, бугаз авыруларын, ш.у. баш сөяге куышлыгы, күз чокыры, авыз куышлыгы, муен тирәсе органнарындагы (трахея, калкансыман биз, үңәч) ялкынсыну процессларын өйрәнә, авыруларны дәвалау һәм кисәтү ысулларын эшли. Органнарның функциональ бәйлелеге, анатомик яктан якын урнашулары, авыруларның үзара тәэсир итешүе отология, ринология һәм фарингоЛарингологияне уртак системада өйрәнүгә сәбәп булып тора. Гомуми О. үз эченә фонопедия һәм фониатрияне (тавыш ярылары физиологиясе һәм патологиясен, тавыш ясалышын өйрәнә; тавыш ясалышы бозылуны кисәтү һәм дәвалау ысулларын эшли), аудиология һәм сурдологияне (чукраклык һәм колакка катылыкның сәбәпләрен һәм клиник барышын өйрәнә; ишетү сәләтен коррекцияләү, компенсацияләү, бу төр авыруларны кисәтү һәм дәвалау ысулларын эшли), ЛОР-онкологияне (яман шеш алды халәте үзгәрешләре, шеш һәм яман шешләрне өйрәнә, авыруларны кисәтү, дәвалау, реа-

билитация ысулларын эшли) ала. О. ш.у. ЛОР-педиатрия, ЛОР-фтизиатрия, ЛОР-аллергология, ЛОР-ринологияне берләштерә.

19 йөздә О., гомуми хирургия һәм терапиядән аерылып, мөстәкыйль мед. дисциплинасы булып оеша. Көнбатыш Европада француз галиме Ж.Итарның «Колак һәм ишетү авырулары турында трактат» («Трактат о болезнях уха и слуха», 1821, Франция), Австрия анатомнары И.Хиртльнең «Бугаз авырулары» («Болезни гортани», 1845) һәм Л.Тюркның «Бугаз һәм өске сулыш юллары авыруларының барышы» («Клиника болезней гортани и верхних дыхательных путей», 1866, Австрия), немец галиме Б.Френкельның «Борын авыруларының гомуми диагностикасы һәм авыруларны дәвалау» («Общая диагностика и лечение болезней носа», 1876, Германия) китаплары кебек классик хезмәтләр басылып чыга.

19 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә колак, борын, тамак (ЛОР) авырулары проблемалары б-н П.А.Загорский, Е.О.Мухин, Н.И.Пирогов, Д.И.Кошлаков, И.И.Насилов, А.Ф.Пруссак, В.Т.Покровский (С.П.Боткин шәкертләре), В.Н.Никитин, В.Н.Окунев, Б.В.Верховскийлар шөгыльләнә. Фәнни эзләнүләр физиол., патофизиол., проф. патологиягә, авыруларны «җиңелчә» хирургик ысуллар б-н дәвалауга багышлана. 1908 елда оториноларингологларның 1 нче Бөтенроссия съезды, 1924 тә Бөтенсоюз съезды уздырыла. О. буенча беренчә эре фәнни мәктәп оеша (Ленинград, Мәскәү, Казан, Саратов, Киев, Харьков һ.б.). Беренче рус фәнни мәктәбенә С.П.Боткин шәкерте С.П.Симаковский нигез сала. Аның тарафыннан Петербургта төзелгән Оториноларингологлар җәмгыяте «Журнал ушных, носовых и горловых болезней» басмасын нәшер итә.

Казанда О. проблемалары 19 йөз ахырында өйрәнелә башлый. Казан ун-тында отиатрия курсын Н.Ф.Высоцкий (1868–90), ларингология курсын М.Ф.Болдырев (1870–98), ринология курсын Н.А.Геркен (1897–1925) алып бара. О.нең фән буларак үстерелә башлавы О. клиникасы һәм ун-тының мед. ф-тында О. кафедрасы ачылу б-н бәйләп карала. ЛОР-белгечләрнең Казан фәнни мәктәбен В.К.Трутнев нигезли, аның эшен П.Д.Буев, В.В.Громов, С.П.Яхонтов, З.И.Вольфсон һ.б. дәвам итә. 1927 дә Казанда Оториноларингологлар фәнни җәмгыяте төзелә; клиник тикшеренүләр борын, борын куышлыгы, йоткылыктагы ялкынсынуларны, бугазның кискен һәм хроник стенозларын, мастоидитларны, баш сөяге куышлыгындагы катлаулы авыруларны өйрәнүгә; шешләргә диагноз куюда, куышлыклардан ят матдәләр алу, үлек җыелу очракларында бронхоэзофагоскопия куллануга юнәлдерелә. 1940 елларда борын, йоткылык, бугаз, трахея, үңәч җәрәхәтләренә, ш.и. сугыш яраларына диагноз кую, яраларны дәвалау (хирургик юл б-н дә); ЛОР-органнарда, ишетү аппаратында шеш булган очракларда диагноз кую һәм авыруны дәвалау (Н.Н.Лозанов һәм А.Н.Мурзин җитәкчелегендә) ысуллары эшләнә һәм камилләштерелә. Йоткылык һәм ишетү юлы стенозларын дәвалауның Н.Н.Лозанов тәкъдим иткән ысуллары күптомлы «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында совет медицинасы тәҗрибәсе» («Опыт советской медицины в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг.», т. 1–35, М., 1951) җыентыгында тасвирлап аңлатыла. 1950 еллардан ЛОР-онкологиягә, баш сөяге куышлыгындагы катлаулы отоген авыру очракларына караган мәсьәләләр, бу төр авыруларны диагнозлау ысуллары тикшерелә башлый. Колак авырулары, колакка катылык, аларны диагнозлау һәм дәвалауны камилләштерү ысуллары б-н Л.Г.Сватко, Л.Д.Нестерова, Р.В.Холопов, В.И.Галочкин, Р.М.Нурсәитовалар шөгыльләнә (1960–80 еллар). 1970 еллардан отосклерозның патогенетик факторлары һәм колакка катылыкның нейросенсор төрен вакытында диагнозлау ысуллары өйрәнелә. Йоткылык һәм бугаз шешләрен диагнозлау һәм нәтиҗәле дәвалау, яман шеш сәбәпле зыян күргән бугазны реконструкцияләү һәм тавыш ясалу б-н бәйле органнар пластикасы ысулларын 1980–90 елларда Г.Г.Автандилов, Л.Г.Сватко, Х.А.Алиметов өйрәнә һәм камилләштерә. Р.А.Заһидуллин, М.Г.Рәуфов (1998, 2004) тавыш ясалышы бозылуны (дисфония) диагнозлау һәм дәвалау ысулларын эшли. Беренче булып борын аша сулыш алу бозылу (вазомотор ринит), тамакка «төер утыру», буылу, йоткылыктагы сызлаулы авырту, йоту һәм сөйләмдәге тайпылышлар, муен тирәсендәге тукымалар патологиясе һәм умыртка баганасы остеохондрозы арасындагы бәйләнешләр ачыклана (патологияләргә тасвирлама бирелә); диагноз кую һәм дәвалау ысуллары тәкъдим ителә (Х.А.Алиметов). Респ-када яшәүчеләргә фониатрия ярдәме өске сулыш юлларын тернәкләндерү хирургиясе мед. үзәкләрендә, ишетүне яхшырту һәм фониатрия кабинетларында (Казан шәһәренең 18 нче клиник хастаханәсендә һәм Респ-ка клиник хастаханәсендә), ш.у. Казан консерваториясе һәм Татар опера һәм балет театры каршындагы фониатрия кабинетларында күрсәтелә. ЛОР-онкологик авырулар респ-ка һәм шәһәр диспансерларында дәвалана. 2010 елга дәвалау учреждениеләрендә 230 дан артык табиб-оториноларинголог эшли.

*Х.А.Алиметов.*

**ОТРА́ДА** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 157,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Рунга волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 83, 1897 дә — 157, 1913 тә — 216, 1920 дә — 242, 1926 да — 240, 1938 дә — 137, 1949 да — 150, 1958 дә — 172, 1970 тә — 143, 1979 да — 96, 1989 да — 95, 2002 дә — 74 кеше.

**ОТРА́ДА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш. 2010 елда 116 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында О.да земство мәктәбе (1889 дан эшләп килгән чиркәү-приход мәктәбе җирлегендә 1900 да ачыла), җил тегермәне, тимерчелек-слесарьлык остаханәсе, 1 зур кибет, 1 вак-төяк кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 315 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Ширбәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1859 да — 234, 1897 дә — 409, 1908 дә — 507, 1920 дә — 574, 1926 да — 436, 1938 дә — 386, 1949 да — 248, 1958 дә — 189, 1970 тә — 173, 1979 да — 159, 1989 да — 152, 2002 дә — 142 кеше.

**ОТРЕ́ШКО** Алексей Иванович (18.3.1927, Украина ССР, Полтава өлкәсенең Кременчуг р-ны Пустовиты а. — 1.1.1991, Симферополь ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1970). Харьков ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), СССР Химия сәнәгате министрлыгының геол.-разведкалау партияләрендә эшли. 1958 елдан РСФСРның Баш геол. идарәсендә. 1963 тән *ВНИИгеолнерудта* (1968 дән тау химиясе чималы геологиясе бүлеге мөдире). 1977 дән Минераль ресурслар ин-тының (Симферополь) руда булмаган чимал ресурсларын фаразлау секторы мөдире. Хезмәтләре руда булмаган чимал геологиясенә, карстка, неотектоникага һ.б.га карый. О. Идел буенда күп кенә саф күкерт чыганакларын ачуда катнаша һәм эзләү критерийларын эшли, СССР терр-ясендә күкерт чималы запасларына бәяләмә бирә. Татарстанда саф күкертне беренче чиратта эзләү участокларын күрсәтә.

Х е з м.: Новые находки самородной серы в Среднем Поволжье // Докл. АН СССР. 1963. Т. 150, № 6; Сероносные провинции СССР // Тр. Геол. ин-та. К., 1968. Вып. 20.

**О́ТРУБ**, Россиядә хосусый имана җире. 20 йөз башында *Столыпинның аграр реформасы* барышында җәмгать җирләре биләмәсеннән бүлеп алынып, крәстияннең хосусый милкенә бирелгән җир кишәрлеге. Ул кишәрлек бер тирәдәнрәк бүленә, хуторлардан аермалы буларак, крәстияннең йорт-курасы күчереп утыртылмый. Казан губернасында 1914 елның 1 гыйнварына 12416 О. исәпләнеп, алар карамагындагы җирләр 83 мең дис. тәшкил итә. О.лар бигрәк тә Чистай (барлык О. хуҗалыкларының 26,6% ы), Тәтеш (17,4%), Спас (11,3%), Лаеш (10,8%) өязләрендә таралыш ала. Руслар б-н чагыштырганда, татарлар арасында имана җирен хосусыйлаштыру акрынрак бара. 1910 ел мәгълүматлары буенча, О.ларга бүленгән җирләрдән 4595,1 дис. (59,4%) — русларга, 935,4 дис. (12,2%) — татарларга, 664,7 дис. (8,7%) — чуашларга туры килә. 1917–18 ел-

лардагы аграр рев-ция вакытында О.лар бетерелә, авылларда җир кишәрлекләре яңача бүленә башлый.

*Әд.:* Крестьянское землевладение Казанской губернии. К., 1909. Вып. 13; Кабытов П.С. Поволжская деревня накануне февральской буржуазно-демократической революции (Предпосылки и ход столыпинской реформы 1907–1917 гг.). Куйбышев, 1977.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ОТУ́ЧЕВ** Чапкын, к. *Чапкын Отыч улы.*

**ОФИЦЕ́РОВ** Евгений Николаевич (4.5.1948, Горький өлкәсенең Ардатов р-ны Нуча а.), химик, химия фән. д-ры (1991), проф. (1995). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1980 нән Казан ун-тында, органик кушылмалар биотрансформациясе фәнни-тикшеренү лаб-ясен оештыручы һәм аның җитәкчесе (1985 тән), биохимия каф. мөдире (1993 тән). 1994 — 2004 тә Ульяновск ун-тында, фармакол., биохимия һәм химия каф. мөдире (2000 гә кадәр). 2004 тән Казан техник ун-тында. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. О. элементорганик кушылмалар синтезына һәм аларның реакциягә сәләтен тикшерүгә, кабаттан яңартылулы үсемлек чималы химиясенә һәм технологиясенә зур өлеш кертә. Кремнийорганик кушылмалар метаболизмын һәм биоген кремнезёмның табигатьтә әйләнешен өйрәнә. Авыл хуҗалыгы һәм күп кенә сәнәгать пр-тиеләренең органик калдыкларын (чистарту корылмалары ләме, хромлы калдыклар, куллану вакыты чыккан пестицидлар, сыра кайнату берләшмәләре калдыклары) органик «биогумус» ашламасы итеп кабаттан эшкәртү технологиясе схемаларын эшли. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реакции некоторых фосфорилированных триалкилфосфитов с нитрилом бензоилмуравьиной кислоты // Журн. органич. химии. 1982. Т. 52, № 12 (автордаш); Углеводы амаранта и их практическое использование. Ульяновск, 2001 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ОФО́РТ** (франц. eau-forte — азот кислотасы), металларда тирән уемлы гравюра техникасының төрдәше; гравюра тактасыннан төшерелгән басма бизәк; *эстампның* бер төре. О.ны энәле яки штрихлы төргә, йомшак лак, акватинта, резерваш, лавис һ.б.га аерып йөртәләр. Инәле О.та рәсем махсус инәләр ярдәмендә штрихлы рәсемне ирекле техникада металл такта өслегендәге грунтны (штрихлы фон) тырнау юлы б-н барлыкка килә. Алга таба кислоталар б-н ашатып рәсемнең аерым детальләрен ачыклыйлар, нәтиҗәдә штрих б-н бирелгән аермалыкларга ирешелә. О. техникасы 15–16 йөзләр чигендә барлыкка килә, 17–18 йөзләрдә Европа сәнгатендә киң таралыш ала (бакыр, 19 йөздә цинк пластиналар кулланыла). О.ның төбәктәге үсеше җирле типография (Азия, Губерна идарәсе, Казан ун-ты типографияләре) басмалары өчен иллюстрацияләр эшләгән рәссам һәм гравюрачылар Н.Н.Кафтанников, А.В.Котельников, Л.Шевиц, П.Ф.Табуре иҗатларына нисбәтле.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казанда О.ның темасы һәм стиле китап һәм журнал графикасы, уку әсбапларын бизәү, картографика басмалары үсешенә бәйле була. О. техникасында башкарылган Казан күренешләре һәм архит-ра һәйкәлләре, борынгы Болгар истәлекләре, җирле халыклар тормышыннан күренешләр, аңлатмалар урнаштырылган төрле планнар күп кенә Казан басмаларында, ш.и. «*Заволжский муравей*» ж-лында дөнья күрә. О.ка беркатлы, хәйләсез чынбарлык, техник алымнарның гадилеге, табигый хисләрнең җанлылыгы һәм эчкерсезлеге, гравюраны көндәлек альбом графикасы б-н якынайтучы ышанычлы автор интонациясе хас. Казан рәссамы В.С.Турин О. өлкәсендә зур осталарның берсе була. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында сәнгатьнең мөстәкыйль төре буларак О.ның үсешендә 1896 елда САнең әйдәп баручы рәссам-педагогы В.В.Матэның актив катнашы б-н Ю.И.Тиссен җитәкчелегендә Казан сәнгать мәктәбендә гравюра бүлеге ачылу мөһим роль уйный. Уеп киселгән классик гравюра һәм О. укытыла (САдә кабул ителгән методика буенча). Тиссен һәм аның укучылары А.Г.Лошадкин һәм Д.Д.Агафонов хезмәтләрендә «Матэ мәктәбе»нең тонлы гравюра йогынтысы бәхәссез; Л.Ф.Овсянников, П.М.Дульский, В.С.Щербаков О.ларында материалга һәм техникага шәхси авторлык мөнәсәбәте күбрәк чагыла. Техника күптөрлелеге (йомшак лак, акватинта, тарттыру, коры инә) һәм төрләре (авторларның тематик О. альбомнары, ш.и. Казан архит-расы истәлекләренә багышланганнары), стилистик юнәлешләре һәм жанрлары (портрет, пейзаж, жанрлы композицияләр, натюрмортлар) булган О. сәнгате үсеше Казан дәүләт сәнгать остаханәләре берләшмәсе «*Всадник*» (1920–24) әгъзалары Н.С.Шикалов, И.Н.Плещинский, М.Г.Андреевская, В.В.Кудряшов һ.б.ның эшчәнлегенә нисбәтле. О. үсешендә И.П.Плещинский иң нәтиҗәле рәссамнарның берсе була. Аның әсәрләрендә сәнгати образ уеплауның техник алымнарын файдалану юлы б-н барлыкка килә. Алга таба О. соц. реализмның кырыс кысалары һәм 1920 елларның 2 нче яртысында — 30 еллар башында Казаннан күп кенә әйдәп баручы осталарның (О. техникасы Н.М.Сокольскийның аерым әсәрләрендә генә файдаланыла) китүе сәбәпле кими төшә.

О.ның 20 йөзнең 2 нче яртысында кабаттан яңарыш кичерүе илнең төрле югары уку йортларында һөнәри әзерлек алган һәм күптөрле стилистик агымнар алып килгән рәссам-графикларның иҗаты б-н бәйле (И.К.Колмогорцева, Л.М.Кальюранд, Т.А.Зуев, Ю.М.Каспин, А.Р.Туманов, Ю.Б.Лысогорский). 1960 елларда М.К.Мавровскаяның актив катнашында ТАССР Рәссамнар берлегендә офорт остаханәсе оештырылу аның техник базасын ныгыта, офортчы-рәссамнар даирәсе киңәя (Н.У.Әлмиев, И.В.Антонова, Ю.Л.Бердников, Р.Х.Галимов, В.А.Дайчман, С.Х.Ибраһимова, В.Р.Иванов, В.И.Ильин, В.В.Карасёва, Р.Т.Сафиуллин, Г.Л.Эйдинов). 20 йөз ахырыннан О. респ-каның башка шәһәрләрендә дә уңышлы үсеш ала (Р.Ф.Галиуллин, Яшел Үзән ш.; В.И.Сынков, А.В.Халдеев, Ю.Г.Свинин, Т.Т.Самойлова, Чаллы ш. һ.б.). Әлеге сәнгать төренең тематикасы баеганнан-байый: шәһәр пейзажы жанры, Бөек Ватан сугышына, борынгы әйберләргә, архит-ра истәлекләренә багышланган аерым тематик серияләр, әдәби әсәрләр үрнәкләре буенча хикәяләү һәм символик-аллегорик характердагы әсәрләрнең киңәйтелгән цикллары һәм ш.у. портрет жанры — мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре образлары. О.тагы сәнгати сурәтләү чаралары диапазоны күптөрле: төсле О., миниатюралардан алып зур табаклы хезмәтләргә кадәр төрле форматлардан файдалану, акварель б-н иллюминацияләү, тагын да катлаулана һәм камилләшә барган уеплау техникасы. О.тагы заманча агымнар постмодернизм сәнгате йогынтысы һәм сәнгать теленең милли үзенчәлекләрен эзләү б-н бәйле.

*Әд.:* Дульский П.М. Книга и её художественная внешность (В связи с Казанским книгопечатанием). К., 1921; Корнилов П.Е. Кабинет гравюр Центрального музея ТАССР. К., 1926; Ключевская Е.П. Гравёрное отделение Казанской художественной школы // Вопр. худож. образования. 1984. Вып. 34; шул ук. У истоков Казанской графики // Художник. 1990. № 6; шул ук. Живая старина гравёрного резца // Татарстан. 1997. № 7; Султанова Р.Р. Искусство новых городов Татарстана. 1960–1990-е годы. К., 2001.


*Е.П.Ключевская.*

**ОФТАЛЬМОЛО́ГИЯ** (грек. ophthalmós — күз һәм ...*логия*), клиник мед. өлкәсе, күрү органнарының төзелешен, функцияләрен һәм авыруларын, ш.у. бу чирләргә диагноз кую, аларны дәвалау һәм булдырмау ысулларын өйрәнә. Россиядә О. фән буларак 19 йөз башында барлыкка килә. Күз көзгесе — офтальмоскоп уйлап табылганнан соң (немец физигы Г.Гельмгольц, 1851), күзнең тирәндәге өлешләре (челтәр катлау, кан тамырлары, нервлар) өйрәнелә башлый; күз рефракциясе һәм аккомодациясе турында аерым тармак туа. 1805 елда Мәскәүдә Ф.А.Гильденбрандт башлангычы б-н беренче күз хастаханәсе ачыла, 1818 дә Петербург мед.-хирургия академиясендә беренче О. каф. оеша. Россия О.се үсешенә Казан (Е.В.Адамюк, В.В.Чирковский һ.б.), Киев (А.В.Иванов һ.б.), Харьков (Л.Л.Гиршман һ.б.), Петербург (Л.Г.Беллярминов һ.б.), Мәскәү (С.С.Головин, А.Н.Маклаков, А.А.Крюков, В.П.Одинцов, М.И.Авербах һ.б.), Одесса (В.П.Филатов, Н.А.Пучковская һ.б.) галимнәре зур өлеш кертә.

Казан ун-тында 1850 елларда О. факультет хирургиясе кафедрасында А.Н.Бекетов тарафыннан алып барыла. Мөстәкыйль О. каф. 1867 дә оештырыла (мөдире М.В.Никольский, 1870 тән — Е.В.Адамюк). Хирургия клиникасында офтальмологик авыруларга 15 урын бирелә. Е.В.Адамюкның «Күз авыруларын өйрәнүдә гамәли ярдәмлек» («Практическое руководство к изучению болезней глаза», 1884), «Күзнең яктылык сизү аппараты авырулары» («Болезни светоощущающего аппарата глаза», 1897) хезмәтләре Казан





**Офорт.** 1. О. К о х. «Казан шәһәре күренеше» (А. Олеарий рәсеменнән). 18 йөз ахыры; 2. С.П. К о з л о в. «Эскәмиядә». Кәгазь, коры энә. 1924. Икесе дә ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда; 3. И.Н. П л е щ и н с к и й «Урак өсте». Кәгазь, коры энә. 1924. И.И. Галиевнең шәхси тупланмасы (Мәскәү); 4. М.К. М а в р о в с к а я. «Элекке Яңа Комиссариат урамында. Кыш». «Якын үткәндәге Казан» сериясеннән (1987–89); 5. И.К. К о л м о г о р ц е в а. «Казан Кремленең почмак манарасы». Акватинта. 1970 нче еллар; 6. Н.У. Ә л м и е в. «Моңлы сазым». Акватинта. 1998. Өчесе дә ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

ун-тына дөньякүләм танылу китерә, офтальмологларның Казан фәнни мәктәбе оешуда әһәмиятле роль уйный. 20 йөздә О. яңа ысулларга байый, инструменталь диагностика (биомикроскопия, рентгенография, электр һәм изотоп диагностикасы, флюоресцент ангиография һ.б.) алга китә. Рефракция тайпылышларын төзәтү ысуллары камилләштерелә, анастигматик һәм контактлы линзалар, телескопик күзлекләр кулланышка керә, күзнең мөгез катлавын күчереп утырту, күз шешләре очрагында фотокоагуляция операцияләре үзләштерелә. Е.В.Адамюк укытып чыгарган земство табиб-офтальмологлары (А.Г.Агабабов, В.В.Чирковский, К.Х.Орлов, В.Е.Адамюк, В.П.Иванов һ.б.) соңрак зур галимнәр булып таныла; А.Г.Агабабов җитәкчелегендә күрү органы физиологиясен өйрәнү дәвам итә. 1900 дә университет каршында 30 ятак-урынлык күз клиникасы ачыла. Бу чорда О.дә бактериология һәм иммунитет мәсьәләләре, күз басымының күзнең кан б-н тәэмин ителешенә бәйлелеге өйрәнелә. В.В.Чирковский тарафыннан трахоманы өйрәнү материаллары гомумиләштерелә («Трахома», 1933; 6 басма, 1953; СССР Дәүләт бүләге, 1948), «Вопросы трахомы» журналы нәшер ителә (1935–37). 1960–80 елларда М.Б.Вургафт, А.П.Нестеров һ.б. глаукома проблемаларын өйрәнәләр (алар тарафыннан тәкъдим ителгән күзнең гидродинамик күрсәткечләрен тикшерү ысуллары О.дә киң кулланыла). А.П.Нестеров тарафыннан ачык почмаклы глаукоманың төп сәбәбе дип күрсәтелгән шлём каналын блокадалау теориясе ачыш дип табыла (1985). Фотоэлектротонограф, төсле катлау ретракторы приборлары авторы М.Б.Вургафт, тикшеренүләренең нәтиҗәләрен гомумиләштереп, «Глаукома» (1980) хезмәтен яза. М.В.Кузнецова җитәкчелегендәге галимнәр төркеме миопия һәм умыртка сөягенең муен бүлеге халәте арасындагы бәйләнешне өйрәнә («Күрә алмаучанлыкның сәбәпләре һәм авыруны дәвалау» — «Причины развития близорукости и её лечение», 2005). Миопатияне кисәтү өчен ортокератологик линзалар сайлау ысулы; рефракцион амблиопияне, кылый күзлелекне, ачык почмаклы глаукоманы дәвалау; катарактаны хирургик булмаган юл б-н таркату, мөгез катлау томанлануны, глаукоматоз оптиконейропатияне, алкоголь амблиопиясен һ.б.ны таркату юлы б-н дәвалау ысуллары гамәлгә кертелә. Макулодистрофия, челтәр катлауда пигмент дистрофиясе, күрү нервы атрофиясе очракларында Э.Р.Мулдашев ысулы б-н дәвалау методикасы кулланыла. Челтәр катлау васкулитларын, күрү нервын һ.б. дәвалауда лазер технологиясенә мөрәҗәгать ителә (Я.М.Вургафт, А.Н.Самойлов). ТРда ел әйләнәсендә 2 меңнән артык микрохирургик операция ясала, 4 меңләп авыруга консультация бирелә. Казанда 1907 елдан бирле Офтальмологлар җәмгыяте эшли (1995 тән — Бөтенроссия офтальмологлар җәмгыяте ф-лы).

*М.В.Кузнецова, Р.Г.Исхакова.*

**«ОФЫ́К»**, рәсемле иҗтимагый-сәяси, пропаганда-агитация журналы. КПССның Татарстан өлкә ком-ты органы. 1937–92 елларда Казанда атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Исеме үзгәреп тора: 1937 нең мартыннан «Агитатор блокноты» (1938 нең маеннан 1943 кә кадәр «*Татарстан большевигы*» ж-лы б-н берләшеп чыга), 1943 тән «Пропагандист һәм агитатор блокноты», 1944 тән «Агитатор блокноты», 1987–89 да «Агитатор сүзе», 1990 нан — соңгы исемендә. 1942 дән рус телендә дә басыла башлый: 1942 нең ноябреннән «Блокнот пропагандиста и агитатора», 1944 нең апреленнән «Блокнот агитатора», 1948 дән «Блокнот пропагандиста и агитатора», 1949 дан «Блокнот агитатора», 1987 дән «Слово агитатора», 1990–92 елларда «Панорама». Төрле еллардагы мөхәррирләре: С.Г.Гыйрфанов, Х.Р.Рәхмәтуллин, Я.З.Ярмәкаев, М.Х.Шәфыйков, Н.А.Андриа-

нов, А.И.*Афанасьев*. Актив авторлары арасында — С.Аздуни, А.Әхмәдуллин, Л.Бауман, Ф.Борһанова, М.Бохараев, Э.Ваһапов, Ш.Вәлиев, И.Герасимов, Б.Зиннәтуллин, И.Исхаков, Д.Мөфахарова, С.Мөхәммәтов, С.Тайбинский, К.Фасиев, Ф.Шаһиәхмәтов һ.б. «О.» партия оешмасы секретарьлары, политинформаторлар, пропагандистлар, урта мәктәп директорларына һ.б.га адреслана. Даими рубрикалары: «Көндәлек вакыйгалар», «Капитал дөньясында», «Безнең календарь», «Саннар һәм фактлар», «Туган илебездә» һ.б. Журнал илдәге һәм респ-кадагы сәяси, икътисади, мәдәни вакыйгалар, халыкара хәлләр, сәяси агитация тәҗрибәсе б-н таныштырып бара һәм сәяси агитациянең бурычларын аңлата. «О.» СССР халыкларының дуслыгы һәм хезмәттәшлеге идеяләрен пропагандалый, яшьләрне интернациональ рухта тәрбияләүгә зур игътибар бирә. Язучылар, шагыйрьләр иҗаты б-н таныштыра.


*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ОХО́ТИНА** Наталья Антониновна (3.4.1941, Казан), химик-технолог, техник фән. канд. (1967), Дәүләт бүләге лауреаты (2007). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, эластомерлар химиясе һәм аларны кабаттан эшкәртү технологиясе каф. профессоры (2007 дән). Хезмәтләре төрле максатта кулланылучы каучук һәм резина өчен полифункциональ тәэсирле өстәмәләр синтезлау һәм тикшерүгә карый. О. катнашмалы стабилизатор, газсыман күкерт һәм туендырылмаган полимерлашучылар нигезендә металлокорд системалар өчен вулканлаштыручы агентлар, шиннар һәм күп катламлы башка эшләнмәләр җитештерүдә резин катышмаларының конфекцион ябышучанлыгын арттыру өчен сумала, тышкы катлам резиннарының салкынга чыдамлыгын күтәрү өчен пластификатор җитештерү һәм куллану технологияләрен эшли. Дәүләт бүләге көндәшлеккә сәләтле радиаль шиннар җитештерү технологиясен камилләштерү максатында өр-яңа материаллар эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә («Түбәнкамашин» ЖБ) катнашканы өчен бирелә. Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Медальләр б-н бүләкләнә. Россиянең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1997).

Х е з м.: Технология резиновых изделий: Учеб. Л., 1991 (автордаш); Влияние пластификатора тофинол на свойства протекторных резин // Каучук и резина. 2006. № 2 (автордаш); Углеводородная смола пикар — новый повыситель клейкости резиновых смесей // шунда ук. Б. 21–23.

**ОЧА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шыя елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 24 *км*. Бассейнының мәйданы 132,8 *км*$^2$. Елга башы Кукмара р-ны Яңа Каенсар авылында, тамагы Мамадыш р-ны Дусай авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагынықы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. О.ның 0,6 дан 6,9 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар, иң зурысы — Ушма елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 101 *мм*, ташу вакытында су катламы 85 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,07 *м*$^3$*/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. О. бассейнында су күләме 0,05 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОЧКАЛА́К ТИЕ́Н** (Pteromys volans), кимерүчеләр отрядындагы очкалаклар семьялыгыннан имезүче җәнлек. Төньяк һәм көнчыгыш Европа урманнарында һәм Азиянең төньяк өлешендә таралган. ТР терр-ясендә Кама алдында очрый. Каен, зирек, усак өстенлек иткән биек кәүсәле катнаш һәм яфраклы урманнарда яши. Гәүдәсенең озынлыгы 23 *см* га җитә, койрыгы 9–14 *см*, авырлыгы якынча 160 *г*. Очлыклары йон б-н капланган тиречел яры б-н тоташкан. Тыныч халәттә яры бөрмәләргә җыйналып тора, хәрәкәт вакытында сузыла. Йон капламы тыгыз, йомшак, ефәксыман. Аксыл соры төстә, кайвакыт охра яки көрән төсмердә, корсагы ак, кышын



Очкалак тиен.

йоны озынрак һәм тыгызрак. Карт агач куышларына оялый, аларда йомшак асылма мүкләрдән оя ясый. Кайвакыт тиен ояларын, тукран куышларын били. Утырма яшәү рәвеше алып бара, эңгер-меңгердә һәм төнлә актив. Елның салкын вакытында активлыгы кинәт кими, әмма кышкы йокыга талмый. Очлык ярысы ярдәмендә 40–50 *м* ераклыкка кадәр агачтан-агачка сикерешләр ясарга сәләтле. Җиргә сирәк төшә. Агач бөреләре һәм орлыклар, җиләк, гөмбә б-н туена. Май–июньдә ана затлар 1–4 бала тудыра. О.т.нең табигый дошманнары — зур ябалаклар, кеш, урман сусары. 5 яшькә кадәр яшиләр. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ОЧКЫЛЫ́К ҮЛӘНЕ́**, к ы р к ы р ы й (Berteroa), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 7 төре билгеле. Европа һәм Азиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — соры О.ү. (B. incana) бар; респ-каның бөтен терр-ясендә таралган. Коры тау битләрендә, юл буйларында, ш.у. чүп үләне буларак чәчүлекләрдә үсә. 20–50 *см* биеклектәге соргылт төстәге икееллык үсемлек, йолдызсыман төкчәләр б-н капланган. Тамыры — үзәк. Сабагы туры, ботаклы. Яфраклары бөтен, чиратлашкан, чит-читләре вак тешле. Чәчәкләре вак, ак төстә, куе башчалы чукка җыйналаган. Җимешләре — ике капкачлы, озынча түгәрәк, кузак, йөнтәс-йомшак. Орлыклары — яссы, көрән. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Орлыктан үрчи (бер үсемлек 1,5 меңгә кадәр орлык бирә, шыту сәләтен туфракта берничә ел саклый). Үсемлектә органик к-талар, алкалоидлар, флавоноид, кумарин, дуплау матдәләре, майлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Баллы үсемлек.

**«ОЧКЫ́Н»**, иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Көнгер округ ком-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның округ Советы һәм профсоюзларның шәһәр Советы органы. 1926–28 елларда Көнгер шәһәрендә (Пермь өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**«ОЧКЫ́Н»**, иҗтимагый-сәяси атналык газета. ВКП(б)ның Оренбург округ ком-ты һәм Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның округ башкарма ком-ты органы. 1927 елда Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 12 саны чыга. Мөхәррире — З.Шәркый. Актив авторлары арасында — Х.Билкитова, Г.Габделмәнов, А.Габдрахманов, Г.Галиәкбәров, Б.Гомәров, Ф.Исхаков, Г.Мудрова, И.Рәфыйков, Б.Рәшитова һ.б. Даими рубрикалары: «Атна арасында», «Оренбург хәбәрләре», «Чит илләрдә». «О.»да ВКП(б)ның 15 нче съезды, 13 нче губерна партия конференциясе (1927 нең декабре) эше турында хисаплар, ВКП(б) Политбюросы әгъзаларының фотолары, докладлары һәм мөрәҗәгатьләре басыла. А.х.ндагы һәм сәнәгатьтәге хәлләр турындагы материалларга, илдәге һәм чит илләрдәге сәяси хәбәрләргә аерым урын бирелә.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ОЧКЫ́Н»**, иҗтимагый-сәяси атналык газета. ВКП(б)ның Лысьва шәһәр ком-ты, Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның шәһәр Советы һәм профсоюзларның шәһәр Советы органы. 1932–34 елларда Лысьва шәһәрендә (Пермь өлкәсе) татар телендә нәшер ителә.

*Әд.:* Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1989.

**ОША́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 35,8 *км*, бассейнының мәйданы 146,5 *км*$^2$. Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Оша авылыннан 2,5 *км* көнчыгыштарак, тамагы Ачы авылыннан 3 *км* ераклыкта. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы төбәге астында калган. Елга башының абс. биеклеге 196 *м*, тамагынықы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 70%. О.ның 0,6 дан 3,5 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су

агымының уртача күпьеллык катламы 96 *мм*, ташу вакытында су катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадəттə, апрельнең беренче ункөнлегендə башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,13 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һəм җəен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральлəшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һəм җəен 500–700 *мг/л*. О. бассейнында суның гомуми күлəме 1 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОША́** авылы, Түбəн Кама р-нында, Түбəн Кама шəһəреннəн 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оша елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 29 кеше (чуашлар) яши. Башлангыч мəктəп. 20 йөз башында нигез салына. Оештырылган көненнəн Казан губернасының Чистай өязе Богородский волостенда. 1920 дəн ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширəмəт, 1963 нең 1 феврaленнəн — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбəн Кама р-нында. Халык саны: 1920 дə — 125, 1926 да — 149, 1949 да — 214, 1958 дə — 219, 1970 тə — 215, 1979 да — 111, 1989 да — 54, 2002 дə — 42 кеше.

**ОШТЫРМА́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 37 *км*, ТР чиклəрендə — 29 *км*. Бассейнының мəйданы 590 *км²*. Елга башы Кукмара р-ны Югары Юмья авылыннан 2,6 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Киров өлкəсенең Вятка Аланы шəһəре янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мəйданының урманлылыгы 5%. О.ның 20 кушылдыгы бар, иң зурлары — Норма (20,9 *км*), Туйма (16,4 *км*) — сул, Кенə (11,4 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтəренең тыгызлыгы 0,38 *км/км²*. Туенуы катнаш, чама б-н дүрттəн өч өлеше кар сулары исəбенə туры килə. Җир асты сулары б-н туену модуле елга бассейнының төрле өлешлəрендə 1 дəн 10 *л/с·км²* га кадəр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һəм җəен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 132 *мм*, ташу вакытында су катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадəттə, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,675 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һəм җəен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральлəшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һəм җəен 700–1000 *мг/л*. О. бассейнында суның гомуми күлəме 4 млн. *м³* булган 9 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ОШТЫРМА́-ЮМЬЯ́**, авылы, Кукмара р-нында, шəһəр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 323 кеше (2002 елгы халык исəбе буенча, удмуртлар — 73%, татарлар — 23%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мəктəп, клуб, китапханə. Чиркəү. 1710 еллардан мəгълүм. 18 йөздə — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дəүлəт крəстияннəре катлавына керə, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльлəнə. 20 йөз башында О.-Ю.да Казан Богородица чиркəве, земство мəктəбе (1845 тəн эшлəүче авыл приход мəктəбе җирлегендə 1885 тə ачыла; 1909 дан Халык мəгарифе министрлыгы карамагында), 1 казна шəраб һəм 3 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җəмəгатенең имана җире 1043,1 дис. тəшкил итə. 1920 гə кадəр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дəн ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 феврaленнəн — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дə — 54 ир-ат; 1859 да — 371, 1897 дə — 646, 1908 дə — 641, 1920 дə — 797, 1926 да — 887, 1938 дə — 581, 1949 да — 459, 1958 дə — 371, 1970 тə — 305, 1979 да — 334, 1989 да — 309, 2002 дə — 339 кеше. О.-Ю.да педагог И.С.*Михеев* туган.

**ОШУСТО́ВИЧ** Феликс Антонович (1870 еллар тирəсе, Одесса ш. — ?) җырчы (лирик-драматик тенор), педагог. 1890 елда Киев театры сəхнəсендə беренче тапкыр Манрико партиясе («Трубадур», Дж.Верди) б-н чыгыш ясый. Җырчының репертуары үз эченə 50 дəн артык опера партиясен ала. Рус композиторлары операларында төп партиялəрне, ш.и. Кащей («Үлемсез Кащей», Н.Римский-Корсаков) партиясен беренче башкаручы. Россия шəһəрлəре (Одесса, Харьков, Вильно, Минск, Саратов, Екатеринбург, Мəскəү һ.б.) опера сəхнəлəрендə чыгышлар ясый. 1900 елларда Казан шəһəре сəхнəсендə җырлый, Казан музыка уч-щесендə укыта. Укучылары арасында СССРның халык артисты М.Д.*Михайлов* бар.

*Əд.:* Ф.А.Ошустович (к 20-летию сценической деятельности) // Рампа и жизнь. 1910. № 6.

**ОЯЛА́Ш УТЫ́** (Neottia), сəхлəбчəлəр семьялыгыннан күпьеллык үлəнчел үсемлеклəр ыругы. 9 төре билгеле, Европа һəм Азиянең уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясендə бер төре — чын О.у. (N. nidus-avis) бар, барлык районнарда очрый. Күлəгəле һəм катнаш урманнарда, коелган яфрак арасында үсə. Хлорофиллсыз, 20–45 *см* биеклектəге үсемлек. Тамыр системасы кош оясы рəвешендə җыелган (исеме шуннан) итчел тамырчыклар б-н капланган. Яфраклары үсеш алмаган. Чəчəклəре көрəн яки саргылт-көрəн, баллы исле, чукка җыйналган. Җимеше — тартмачык. Июнь–июльдə чəчəк ата. Нигездə, орлыктан үрчи. О.у.нда фотосинтез юк, туклану матдəлəрен ул тамырлары б-н симбиозда яшəүче гөмбəлəр ярдəмендə туфрактан ала. Дару үсемлеге. Чын О.у. ТРның Кызыл китабына кертелгəн.

# Ө

**ӨБРӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасы буенда. 2010 елда 148 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. Композитор С.Сәйдәшев музее. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мич чыгару, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә мәчет, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 630,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 444, 1897 дә — 680, 1908 дә — 671, 1920 дә — 528, 1926 да — 642, 1938 дә — 599, 1949 да — 454, 1958 дә — 344, 1970 тә — 263, 1989 да — 150, 2002 дә — 153 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ӨЕ́Р АБАГА́** (Gymnocarpium), татлы абагачалар семьялыгыннан абагалар ыругы. 10 га якын төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Линней Ө.а.сы (G. dryopteris) Кама елгасыннан төньяктарак очрый, Роберт Ө.а. (G. robertianum) Биектау р-нында теркәлә. Күләгәле урманнарда үсәләр. Нечкә кара шуышма тамырчалы, 15–50 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Яфрагы каты, куе яшел, өчәр каурыйсыман-бүленмә. Соруслары аскы ягында. Спораларын июнь–июльдә чәчәләр. Тамырчаларында 8–12 % дуплау матдәләре бар. Декоратив үсемлекләр. Роберт Ө.а. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ӨЙ ИЯСЕ́** (Йорт иясе), Казан һәм Себер татарлары мифологиясендә *ия*ләрнең бер төре; өй хуҗасы, рухы. Түбән мифология персонажы. Башкорт халкындагы өй иясе, мордваларлардагы кудова, юрхтава б-н туры килә. Казан татарлары ышануынча, Ө.и. — гадәти киенгән, озын ак чәчле, кечкенә буйлы кеше. Идән астында, кайчак мич артында яши. Ө.и. йортны, гаиләне саклый, көнкүрештә булыша, бәла-каза ихтималын искәртә. Ө.и. тавыш-гаугa, шапшаклык, тәртипсезлекне яратмый. Үпкәләгән Ө.и. бәхетсезлек һәм авырулар китермәсен өчен аның күңелен күрергә — ботка пешереп почмакка куярга яки мохтаҗларга сәдака бирергә кирәк. Ө.и. кешеләргә һөнәр сайларга ярдәм итә дип санала. Әгәр аның «акча сукканы» ишетелсә — сәүдә итәргә, кәгазь кыштырдатса — язу б-н шөгыльләнергә киңәш ителә. Яңа йортка күченгәндә Ө.и.н дә яңа урынга чакырырга кирәк. Көнбатыш Себер татарларында Ө.и. — ямьсез карчык рәвешендәге явыз рух. Ул төннәр буе өйдә йөгереп йөри, кыштырдый, елый, кешеләрне борчый. Ө.и.нең күренүе бәхетсезлек килачәгенә юралган, ул булган йорттан котылу чарасын күрергә тырышканнар.

*Әд.:* Н а с ы й р и К. Өй иясе // Сайланма әсәрләр. К., 1975. Т. 2; Өй иясе (Өй анасы) // Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Б а с и л о в В.Н. Ой иясе // Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2; М о к ш и н Н.Ф. Религиозные верования мордвы. Саранск, 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ӨЙ КЕЛӘВЕ́**, йортны саклау һәм чистартуның борынгы йоласы. 20 йөз башына мишәр татарлар (к. *Мишәрләр*), ш.у. керәшен татарлар көнкүрешендә «йорт урынын уздыру» исеме б-н сакланып калган. Өй (йорт) иясенә ышануга бәйле (к. *Ия* мәкаләсе). Гаилә учагын саклау һәм чистарту, йорт иясендә мәрхәмәт уяту өчен. Ө.к.н яңа йортка күченгәч уздырганнар һәм ел саен үткәрергә тырышканнар. Йолада, башлыча, хатын-кызлар катнашкан. Ө.к.нә чакырылган кыз туганнар, күршеләр йортның, гаиләнең иминлеген теләп дога кылганнар, аннары хуҗа хатын аларны йола боткасы яисә кош итеннән әзерләнгән ризык б-н сыйлаган; 3–4 елга бер корбанга сарык чалганнар. Йорт иясен дә «сыйлаганнар», мишәрләр аны ат абзарында яши дип уйлаганнар. Аның өчен дип абзарда тозсыз йола боткасы һәм төче күмәч («питрач») калдырганнар. Керәшен татарларда йорт иясен юмалау өчен, гадәттә, өйнең идән асты почмагына тимер пластина кыстырганнар («корыч кыстыру»).

*Әд.:* Б а я з и т о в а Ф.С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары. К., 1995; М у х а м е д о в а Р.Г. Татары-мишари. М., 1972; М у х а м е т ш и н Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ӨЙ ТУЕ́**, яңа йортка күчү уңае б-н оештырылган гаилә бәйрәме. Аңа, гадәттә, туганнар, дуслар һәм күршеләр чакырыла, алар яңа торакны җиһазлауда ярдәм итү өчен акчалата яки әйберләтә бүләкләр китерәләр. Ө.т., гадәттә, хуҗаларга бәрәкәт, сәламәтлек һәм байлык теләп дога кылудан башланып китә. Еш кына өлкәннәр өчен, мулла яисә абыстайны чакырып, аерым коръән ашлары уздырыла. Ө.т. 20 йөзнең 2 нче яртысында массакүләм торак төзелеше киң колач алган шәһәр җирләрендә аеруча еш оештырыла. Шәхси корылмаларга өстенлек бирелгән авыл җирләрендә йорт төзелешенең аерым этапларын чагылдырган борынгы халык йолалары да өлешчә сакланып калган: нигез салу (*нигез боткасы*), матча кую (матча мае), мич чыгару (мич (пич) ачу) һ.б.

Әд. к. *Өй келәве* мәкаләсе.

*Ф.Ф.Гулова.*

**ӨЙ ЧИКЕРТКӘЛӘРЕ́** (Grylloidea), турыканатлылар отрядының озынмыеклылар асотрядындагы бөҗәкләр өссемьялыгы. Дөнья фаунасында 2 меңнән артык төр исәпләнелә, БДБ илләрендә 50 дән артык, Татарстан терр-ясендә 4 төре теркәлгән. Башка турыканатлылардан нечкә туры, очында сөңгесыман киңәйгән күкәй салгыч (ата затларда) булуы б-н аерыла (аючикерткәләрдә күкәй салгыч юк). Аяклары 3 буынлы, сыгылмалы озын церкалары бар. Тыныч халәттә канат өслекләре аркасына ятып тора. Җир өслегендә яки өннәрдә, ш.у. җылы биналарда яшиләр. Татарстан терр-ясендә өй чикерткәсе (Acheta domestica) таралган. Гәүдәсе — 16–20 *мм*, күкәй салгычы 11–15 *мм* озынлыкта. Икмәк валчыклары, башка азык-төлек калдыклары б-н туена, ачык һавада да яши. Дөлаланган участокларда бик сирәк булса да кыр чикерткәсе (Melanogryllus compestris) очрый.

Ө.ч.нә ш.у., гадәттә, сулыклар янында яшәүче *аючикерткәләрне* дә кертәләр. Аларның беренче пар аяклары казырга җайлашкан һәм сукыр тычкан аякларына бик охшаш (аючикерткәнең лат. исеме — *Gryllotalpa* чикерткә-сукыр тычкан дип тәрҗемә ителә). Йорт яны участокларында аючикерткәләр культуралы үсемлекләрнең тамыр һәм бүлбеләрен зарарлап, зур зыян салырга мөмкин.

*Н.В.Шулаев.*

**ӨЙДӘ́ ТУКЫЛГА́Н ПОСТА́У**, өйдә эшләнгән йон яки яртылаш йон кушылган тыгыз тукыма. Татарлар аның тупас йон постаудан (өске кием өчен) юка постауга (оек өчен) кадәрге төрләрен тукыйлар. Эрләү өчен язгы һәм көзге чорда кыркылган сарык, кәҗә, дөя йоны кулланыла. Постау киндер сугу өчен файдаланылган станда, шул ук ысуллар б-н, өч төстә (ак, кара һәм көрән) тукыла. Ак постау кыйммәтрәк бәяләнгән, аннан оеклар, кара һәм соры постаудан кием теккәннәр. Постау эшләү өчен, гадәттә, йон тукыманы сәкедә, керәшен татарлар киледә аунатканнар. Постау эшләүнең иң борынгы ысулларының берсе идәндә аяк б-н таптап басудан гыйбарәт булган (19 йөз ахырына кадәр Урта Азиядәге төрки халыклар, Урта Идел һәм Урал буйларындагы руслар, Дагстан кумыклары арасында таралган): әзер йон тукыманы кайнар сулы казанга салганнар, аннары алып, идәнгә җәеп аунатканнар. Татарларда махсус уклау — кырлы бәләк кулланып әвәләү ысулы аеруча киң таралыш алган. Әзер постауны талдан үрелгән рәшәткәгә яки сәкегә салганнар, сәкенең такталарын юан җепләр б-н урап, кысып бәйләгәннәр. Сәке кырыйларына баскан хатын-кызлар, тукымага кайнар су сибеп торып, аны кул б-н таушалдырганнар. Тыгызлаганнан соң, постау вертикаль хәлдә бөкләнмәсә, ул эшләнеп җиткән дип

бәяләнгән; тукыманы елгада чайкаганнар, суын сыгып киптергәннәр. Постау эшләү вакытында яшьләр өмәләре оештырылган (к. *Өмә*).

*Әд.:* Сафина Ф.Ш. Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX вв.): Ист.-этногр. атлас татар. народа. К., 1996.

**ӨЙЛӘНЕШҮ́**, никахлашучы парлар (ир б-н хатын) барлыкка килү процессы. Социаль-мәдәни нормалар б-н яраша һәм көйләнә, хокукый, социаль, икътисади һ.б. аспектларга ия, халыкның никах структурасын билгели. Ө. мәгълүматлары агымдагы елның гражданлык хәле актлары нигезендә, ягъни теркәлгән никахлар, аерылышу һәм үлемнәр (тол калу), халык саны исәбе һәм махсус тикшеренүләр буенча алып барыла. Никах хәле: бер тапкыр да никахта булмаганнар, никахта торучылар (беренче яки кабат; теркәлгән һәм фактик), толлар, аерылышканнарга бүленә. Никах хәле турындагы рәсми мәгълүматлар тулы түгел, чөнки дини йолалар тәртибендә корылган һәм консенсуаль (хокукый яктан рәсмиләштерелмәгән) никахлар исәпкә алынмый. Халыкның никах структурасы күрсәткечләре арасында гомуми Ө. коэф. (1 елда 1000 кешегә туры килүче никахлар саны), һәрбер буынның кайчан да булса никахлашкан (яки никахлашмаган) өлеше, беренче тапкыр никахлашучыларның уртача яше, аерылганнан яки тол калганнан соң кабат никахлашучылар өлеше еш кулланыла. Ө.нең рәсми күрсәткечләренә хокукый сәбәпләр, аеруча закон тарафыннан ныгытылган иң иртә никахлашу яше (ТРда да, РФдәге кебек, ирләр һәм хатын-кызлар өчен 18 яшь), милләт һәм дин аерымлыклары, яшәү урыны буенча аерымлык (шәһәр-авыл), белем дәрәҗәсе, хезмәт үзенчәлеге һ.б. йогынты ясый. Казан губернасы халкына өйләнешмәү һәм аерылышуларның аз булуы, иртә никахлашу хас була. Татарстанда, Ө. саны кимү б-н беррәттән, аерылышулар саны арта (к. табл.).

| Еллар | 1000 кешегә туры килгән теркәлүләр | |
|---|---|---|
| | никахлар | аерылышулар |
| 1950 | 9,1 | 0,4 |
| 1960 | 11,8 | 0,8 |
| 1970 | 9,0 | 1,9 |
| 1980 | 10,6 | 3,3 |
| 1989 | 10,0 | 3,2 |
| 1991 | 8,6 | 3,2 |
| 1997 | 6,2 | 3,3 |
| 1998 | 5,4 | 2,9 |
| 1999 | 5,7 | 3,0 |
| 2000 | 5,7 | 3,4 |
| 2001 | 6,4 | 4,2 |
| 2002 | 6,7 | 5,6 |
| 2003 | 7,0 | 4,7 |
| 2004 | 6,5 | 3,4 |
| 2005 | 7,2 | 3,8 |
| 2006 | 7,4 | 4,1 |
| 2007 | 8,7 | 4,1 |
| 2008 | 7,8 | 4,2 |
| 2009 | 7,8 | 3,9 |
| 2010 | 8,3 | 3,7 |
| 2011 | 9,5 | 3,9 |
| 2012 | 8,7 | 3,3 |

1950 елда теркәлгән 100 никахка — 4, 1990 елда — 31, 1990 еллар ахырында — 54, 2000 дә 60, 2012 дә 39 аерылышу туры килә. Авыл һәм шәһәр халкы никахлар ныклыгы буенча шактый аерыла: авылда — 40 никахның, шәһәрдә 22 никахның 10 ысы таркала.

*М.Р.Мостафин.*

**ӨЛӘ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ашыт елгасының (Иллэт елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 13,1 *км*, бассейнының мәйданы 75,5 *км²*. Елга башы Әтнә р-ны Яңа Шимбер авылыннан 4 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Биектау р-ны Алат спирт заводы авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 89 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,17 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 157 *мм*, ташу вакытында су катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,057 *м³/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ӨЛӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 40 *км* төньяктарак, Өлә елгасы буенда. 2010 елда 218 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә мәчет, тимерчелек, тукымалар һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1260 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 534, 1897 дә — 825, 1908 дә — 897, 1920 дә — 934, 1926 да — 970, 1938 дә — 1015, 1949 да — 956, 1958 дә — 675, 1970 тә — 573, 1989 да — 317, 2002 дә — 244 кеше.

**ӨЛГЕ́** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 6 *км* көньяктарак, Оштырма елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 403 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә волость идарәсе урнаша, мәчет, 2 тегермән, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2151,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 134 ир-ат; 1859 да — 971, 1897 дә — 1139, 1908 дә — 1208, 1920 дә — 1039, 1926 да — 1012, 1938 дә — 893, 1949 да — 627, 1958 дә — 584, 1970 тә — 513, 1979 да — 462, 1989 да — 347, 2002 дә — 402 кеше,

**«ӨЛФӘ́Т»** (الفت — «Дуслык»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. «*Иттифакъ әл-мөслимин*» фиркасенең Петербург бюросы органы. 1905 елның 11 декабреннән 1907 нең 9 июненә кадәр С.-Петербургта татар телендә нәшер ителә, барысы 85 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Р.*Ибраһимов*. Газета эшчәнлегендә татар сәяси эшлеклесе һәм публицист М.*Бигиев* актив катнаша. Басма Россия мөселманнарының сәяси эшчәнлектәге беренче адымнарын, 1905–07 еллар рев-циясе чорында ачылган сәяси азатлык шартларында башка сәяси фиркаләр һәм хәрәкәтләр вәкилләре б-н бәйләнешләрен яктырта. Р.Ибраһимов үз мәкаләләрендә Россия татарларының терр. автономиясе принципларын аңлата: аерым земство идарәләре, милли мәктәпләр булдыру, мөселман хәрби частьларын оештыру, тыныч вакытта аларны мөселман халкы яшәгән терр-яләргә урнаштыру һ.б. Газетада Бөтенроссия мөселманнарының 1906 ның гыйнварында С.-Петербургта узган икенче корылтае, аның барышы һәм нәтиҗәләре тәфсилләп бәян ителә (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Россиянең төрле өлкәләрендә мөселман уку йортлары ачылу, аларда уку барышын оештыру турында мәкаләләр басыла. Мөселман дини учреждениеләрен үзгәртеп кору, аларның мөстәкыйльлеген тәэмин итү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә. Газета иске карашлы мөселман руханилары вәкилләренең тоткан урынын, ш.и. аларның татар милли хәрәкәтен берләштерү сәясәтенә кагылышлы тискәре ролен тәнкыйтьли. Басма хөкүмәткә каршы эчтәлектәге язмалары өчен ябыла, Р.Ибраһимов хөкемгә тартыла.

*Әд.:* Хабутдинов А.Ю. «Ульфат» // Ислам в Санкт-Петербурге. М.–Н.Новгород, 2009.

**«ӨЛФӘ́Т»**, С.-Петербургтагы шәркый басмаханә. 1906 елда шул ук исемдәге газета нәшер итү максаты б-н җәмәгать, сәясәт һәм дин эшлеклесе, публицист, мөхәррир һәм нашир Р.*Ибраһимов* тарафыннан ачыла. Басмаханәдә ш.у. «Нәҗат», «әт-Тилмиз» г-талары, сирәк кенә сәяси характердагы китаплар һәм брошюралар, мәктәпләр өчен дәреслекләр, дини-дидактик һәм дини-тарихи әсәрләр дә нәшер ителә. Басмалар арасында — Сөләйман Айричинскийның «Автономия яхуд идарәи мохтария», «Татар хәятенең 1002 нче кичәсе», «Мөселман фиркасе уставы» һ.б. Ачыкланган китапларның гомуми саны — 25 (1906 да — 5, 1907 дә — 20), тулаем тиражы — 66900 данә. Газеталар һәм китаплар цензура эзәрлекләвенә дучар ителә. Газеталарның кайбер саннарына, «Нәҗат», «Мең дә бер хәдис» (Казанда да басыла),

«Чулпан йолдызы» басмаларына тыю кертелә. 1907 дә хакимият тарафыннан ябыла.

*Әд.:* Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ӨМӘ́**, төрки халыкларда күмәкләп үзара ярдәмләшүнең традицион формасы; хуҗалык эшләрен җәмәгать б-н башкару рәвеше. Тамырлары б-н җыеннар чорына барып тоташа. Ө., кагыйдә буларак, община (элегрәк — җыен) яки *мәхәллә* әгъзасының үз хуҗалыгындагы авыр эшләрне: печән чабу, урак уру, ашлык сугу, төзелеш материаллары һәм утын әзерләү, өй күтәрү һ.б.ны тизрәк төгәлләү өчен мөрәҗәгате яки тәкъдиме буенча уздырыла. Җәмәгать тәртибендәге Ө.ләр авыл (сирәгрәк волость) җыены яисә авыл аксакаллары карары б-н торак пунктларны, зиратларны, эчәргә яраклы су чыганакларын (чишмәләр, коелар, күлләр һ.б.ны) торгызу һәм чистарту, авыллар, көтүлекләр, утлауларны киртәләү, мәчет һәм мәктәпләр төзү, юллар, күперләр һәм дини корылмаларны төзәтү һ.б., ш.у. бәла-казалардан (янгыннар, су басулар, давыллар һ.б.) зыян күрүчеләргә, тол хатыннарга, картларга, ятимнәргә ярдәм итү өчен оештырыла. Хәллерәк хуҗалыклар, крәстияннәрне мул сый б-н җәлеп итеп, Ө.ләрне авыр һәм ашыгыч эшләр башкару өчен оештырганнар. Постау җитештерү (тула Ө.се), киндер, җитен, йон эрләү (җеп, иисә орчык Ө.се), каз йолку (*каз өмәсе*) һ.б. хатын-кызлар Ө.ләре традициягә әйләнә. Ө.ләр һәрвакыт диярлек күмәк сый, йола-гамәлләр, кайберләре уеннар, кайберләре җыр-биюләр тулы бәйрәм киче б-н төгәлләнә. Совет чорында алар шимбә һәм якшәмбе Ө.ләре рәвешен ала. Татарларда Ө. оештыру традициясе яшәвен дәвам итә, тик мондый ярдәмләшү торган саен сирәгәя һәм анда азрак кеше катнаша.

*Р.В.Шайдуллин.*

**ӨМБЕ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шәмәк елгасы буенда. 2010 елда 158 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1602–03 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә мәчет (1842 дә төзелә), мәктәп, тукыма һәм вак-төякләр кибете, күн складлы, 10 олаучылар йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 535,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 240, 1897 дә — 385, 1908 дә — 509, 1920 дә — 509, 1926 да — 469, 1938 дә — 511, 1949 да — 472, 1958 дә — 379, 1970 тә — 314, 1989 да — 193, 2002 дә — 145 кеше.

**«ӨМЕ́Т»**, респ-ка иҗтимагый-сәяси яшьләр газетасы. 1991 елның 12 июненнән Уфада татар телендә атнага 3 тапкыр нәшер ителә. Төрле елларда мөхәррирләре — М.Н.Муллакаев, Ф.К.Фәтхетдинов, Р.Г.Ногманов (2001 дән). Актив авторлары арасында — Э.Әсәдуллина, Э.Ибраһимова, Я.Юнысова һ.б. Газетада яшьләр тормышы, аның аерым вәкилләре турында сөйләнә. Редакция күп урынны яшьләрнең хәзерге җәмгыятьтә тоткан урыны, төрле өлкәләрдәге эшчәнлеге, яшьләр мәнфәгатьләре һәм яшьләргә кагылышлы башка мәсьәләләр турындагы язмаларга бирә; яшь кешенең эчке дөньясына зур игътибар юнәлтелә. Яшь журналистлар һәм язучылар актив катнаша. «Ө.» яшьләрнең аралашу мәйданы, аларның фәнни һәм иҗади потенциалын чагылдыру чарасы булып тора. Газета битләрендә актуаль иҗтимагый-сәяси темалар күтәрелә, мөһим мәсьәләләрнең төрле катламы анализлана: Россия Федерациясе, үзгәреп торган дөньяда татарларның тоткан урыны мәсьәләләре, сәяси һәм эшлекле элита эшчәнлеге. Ул тарих, мәдәният, әдәбият һәм сәнгать, күренекле шәхесләр, татарларның хәзерге тормышы һәм милли проблемалары, Россиядә яшәүче башка халыклар б-н үзара мөнәсәбәтләре турында сөйли. Газета татар тарихын үткән заманнар һәм хәзерге дөнья, Россия чынбарлыгы контекстында аңларга омтыла. Төп рубрикалары — «Башкортстан: Кичә, бүген, иртәгә», «Республиканың иҗтимагый тормышы», «Атналык күзәтү», «Бу — актуаль», «Уртаклашасы килә», «Алло, «Өмет» тыңлый», «Автомобиль полосасы». Газета сайтында (www.omet-ufa.ru) аеруча кызыклы язмалар урнаштырыла. 2001 дән «Өмет» төсле басма булып чыга башлый. Һәр елда «Өмет гүзәле» бәйгесе уздырыла, штаттан тыш хәбәрчеләрдән рухи-әхлакый темага иң яхшы язма авторына Нәзирә Бәширова исем. бүләк тапшырыла. Кушымталары: «Чаткылар» (1991 дән), «Сихәт» (2001 дән), «Мин — яшь!» (2007 дән).

*З.З.Гыйләҗев.*

**«ӨМЕ́Т»**, к. *«Выбор»*.

**ӨМЕТБА́ЕВ** Мөхәммәтсәлим Ишмөхәммәт улы (21.8.1841, хәзер БРның Кырмыскалы р-ны Йомран-Ибраһим а. — 28.7.1907, шунда ук), тел белгече, җәмәгать һәм дин эшлеклесе. Татар һәм башкорт телләрендә яза. Неплюев кадетлар корпусын (Оренбург ш.) тәмамлаганнан соң, туган авылында мәдрәсә оештыра, анда укыта. Уфа губерна земствосы гласные була. 1883 елда мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилевнең ярдәмчесе сыйфатында император Александр III нең тәхеткә утыруы хөрмәтенә уздырылган тантанада катнаша. С.-Петербургта, Кырымда хезмәт итә. Лирик шигырьләр һәм эссе («Йадкәр» җыентыгы, 1897), ш.у. башкорт тарихына һәм мәдәниятенә багышланган публицистик әсәрләр авторы. Лексикология һәм синтаксиска караган хезмәтләре («Фарсыча-русча сүзлек», 1882; «Фарсыча-татарча-русча сүзлек», 1887; «Татар теленең кыскача нәхүе», 1901) бар. Туган авылында Ө. музее ачыла (1991).

*Әд.:* Хусаинов Г.Б. Литература и наука: Избр. труды. Уфа, 1998.

**ӨМЕТБА́ЕВ** Рөстәм Бари улы (28.10.1933, Уфа ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1983), проф. (1984). Ленинград тау ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Магадан шәһәрендә — Төньяк-Көнчыгыш геол. идарәсендә, 1968 елдан СССР ФАнең Ерак Көнчыгыш бүлегенең Төньяк-Көнчыгыш комплекслы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1987 дән Бөтенроссия геол. фәнни-тикшеренү ин-тында (С.-Петербург), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1994 кә кадәр). Хезмәтләре файдалы казылмалар геологиясенә карый. 1:200000 масштаблы СССР Дәүләт геол. картасын (Төньяк-Көнчыгыш участок) төзи. Алтын һәм көмеш чыганакларын ачыклауда катнаша.

Хезм.: Охотско-Чаунская металлогеническая провинция (строение, рудоносность, анализ). М., 1986.

**ӨМЕТБА́ЕВ** Сабир Гаделҗан улы (15.10, 1908, Казан губ., Тәтеш өязе Олы Кариле а. — 18.5.1982, Әлмәт ш.), режиссёр, актёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1954). Казан театр техникумын тәмамлап (1929), Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тына (ГИТИС) укырга керә, бер үк вакытта Мәскәү үзәк татар эшче театрында актёр булып эшли. 1934–35 елларда Татар акад. театрында. 1935 тән Чистай колхоз-совхоз театрында директор һәм баш режиссёр. Ш.Камалның «Козгыннар оясында», М.Фәйзинең «Галиябану», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», К.Әмиринең «Кара тап» әсәрләре буенча спектакльләр куя. 1936 дан театр Минзәлә шәһәренә күчерелә һәм Минзәлә колхоз-совхоз театры дип атала башлый. Анда Ө. тарафыннан «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), «Гөлзадә» (Р.Ишморат), «Банкрот», «Бүләк өчен» (Г.Камал), «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», А.Н.Островский), «Бирнәсез кыз» («Бесприданница», А.Н.Островский), «Мәкер вә мәхәббәт» («Коварство и любовь», Ф.Шиллер) спектакльләре куела. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыштан соң Минзәлә театрына кайта. Ө. сәхнәләштергән «Тормыш җыры» (Д.Аппакова), «Рәйхан» (Н.Исәнбәт), «Акчарлаклар» (Ә.Фәйзи), «Идел буенда» (Г.Насрый) спектакльләре киң иҗтимагый танылу ала. Ю.Әминевнең «Тамырлар», «Язылмаган законнар» пьесалары буенча куйган спектакльләре өчен Ө. 1960 та ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була. Ө. театрда чын күңелдән сәнгатькә хезмәт итүче, коллективның сәнгатьчә-иҗади йөзен билгеләүче актёрлар буынын тәрбияли. Ул Әлмәт татар драма театрында да спектакльләр куя («Васса Железнова», М.Горький, 1968; «Кичеккән мәхәббәт» — «Поздняя любовь», А.Н.Островский, 1972 һ.б.). 1996 дан *Минзәлә татар драма театры* Ө. исемен йөртә, Сабир Өметбаев исем. бүләк булдырыла. Минзәлә татар драма театры бинасы каршысында Ө.ка бюст куела (2012).

*Әд.:* Гыймранова Д.Ә. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт театры. К., 2007.

*Д.Ә.Гыймранова.*

**«ӨМИ́Д»** басмаханәсе, к. *«Сабах» китапханәсе һәм нәшрияты*.

**ӨММӘ́**, өммәт (гарәп. امة — халык, милләт) мөселманнарның дини җәмәгате. *Мөхәммәд* пәйгамбәр Мәккәдән Мәдинәгә күчкәнче,

аның дини-иҗтимагый эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килә (622). Коръәннең Мәдинә дәвере сүрәләрендә (622–32) Мәдинә шәһәрендә яшәүче барлык мөселманнар һәм яһүдиләр җәмгате әгъзалары — Ө. дип бәян ителә. Әлеге атама Мөхәммәд пәйгамбәр исән чагында ук барлык Гарәбстан халкын күз алдында тоткан. Соңрак, ислам тантанасы өчен көрәш җәелдерелгәч (7 йөз уртасы — 9 йөз башы) һәм буйсындырылган халыкларның ислам динен кабул итүе башлангач, «Ө.» атамасы мөселманнар бергәлеген белдергән. Мөселман илләрендә милли гражданлык турындагы күзаллаулар 19 йөз ахырында барлыкка килә һәм «Ө.» төшенчәсе «халык», «милләт» төшенчәләре б-н тиңдәш мәгънәгә ия була. Панисламизм һәм панарабизм дини-сәяси идеологияләрдә «ислам Ө.се» — «гарәб милләте» дигән төшенчә яши. Татарларда «Ө.» атамасы мөселман җәмгатен аңлату өчен кулланыла.

*Әд.:* Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

**ӨММӘТИ́-АЛМАТАВИ́** Лотфулла ибне Галиулла (Сабир) (19 йөзнең 2 нче яртысы, Казан өязе Рәс авылы), шагыйрь, хаттат. «Сабир» тәхәллүсе б-н дә билгеле. «Кыйссаи Таһир» поэмасы (1877) ахырындагы мәгълүматларга караганда, балачагы Петропавловск шәһәрендә уза, шунда белем ала. Мануфактура б-н сәүдә итә. Шәрекътә киң таралган ике гашыйкның фаҗигале мәхәббәте турындагы сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Таһир» исемле поэма-легенда авторы. Ташбасма ысулы б-н китап бастыру остасы. Шушы ысул б-н татар телендә беренче тапкыр Европа һәм Азия карталарын (1861), ш.у. «Диван-е Ризаи» (1860) исемле шигъри җыентыгын бастыра.

*Әд.:* История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX вв.). К., 2003.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ӨММИ́ КАМА́Л** (чын исеме Исмәгыйль) (14 йөз ахыры — 1475, Кече Азия), төрки-татар шагыйре. Чыгышы б-н Караман шәһәреннән. Гомеренең төп өлешен Кырымда, Урта Иделдә яши. Беренче тапкыр «Өмми Камал китабы» исемле җыентыгында басылган (1884, 4 басмада дөнья күрә) лирик шигырьләр авторы. Татарлар арасында кулъязма рәвешендә дә киң таралган Ө.К. иҗаты суфичылык мотивлары б-н сугарылган; шагыйрь табигать, кешеләр тормышының һәр күренешен, чагылышын Аллаһ кодрәте б-н аңлата. Ул кеше тормышы — вакытлы күренеш, мәңгелеккә күчү юлында бер баскыч кына; бу тормышның максаты — Аллаһ б-н кушылу, моңа фәкать Аллаһка карата мәхәббәт аша гына ирешергә мөмкин дигән фикерне алга сөрә. Ө.К. иҗаты Дәрдемәнд, Тукай иҗатларына йогынты ясый. Аның әсәрләренең кулъязмалары (якынча 13) С.-Петербург, Казан китапханәләрендә саклана.

*Әд.:* К а д ы й р о в а Э.Х. Өмми Камал әсәрләренең Казан нөсхәләре // Татар әдәбияты текстологиясе мәсьәләләре (Урта гасырлар — XX йөз башы). К., 2006; А б и л о в Ш.Ш. Умми Камал // История татарской литературы средневековья (VIII–XVIII вв.). К., 2007.

*А.М.Ахунов.*

**ӨНБИЯ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* көньяктарак, Шумыш елгасы бассейнында. 2010 елда 15 кеше (руслар) яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә; 18 йөз ахырында — 19 йөз башында Ижевск казна з-дында эшли. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Ө.дә чиркәү, чиркәү-приход мәктәбе, 2 су тегермәне була. 1875 тә агач чиркәү урынына таштан Покров чиркәве (архит-ра истәлеге) төзелә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 2703 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1795 тә — 141, 1859 да — 646, 1870 тә — 830, 1897 дә — 1370, 1913 тә — 1568, 1920 дә — 1468, 1926 да — 1145, 1938 дә — 622, 1949 да — 589, 1970 тә — 320, 1979 да — 111, 1989 да — 42, 2002 дә — 18 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ӨНСӘ́** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 17 *км* төньяктарак, Кырлай елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 338 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык (Уфа губернасына товар ташу) б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, 5 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 905,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 538, 1897 дә — 590, 1908 дә — 736, 1926 да — 785, 1949 да — 669, 1958 дә — 542, 1970 тә — 533, 1989 да — 344, 2002 дә — 344 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ӨРӘ́К**, татар мифологиясендә фаҗигале рәвештә үлгән яки явыз ният б-н үтерелгән кешенең рухы-җаны; явыз зат. Ышанулар буенча, Ө. кеше һәлак булган җирдә яши; ул ир-ат яки актан киенгән кыз рәвешендә күренергә мөмкин, җан өшетерлек итеп ыңгыраша. Ислам кабул ителгәнче татарларның бабалары арасында таралган бу ышану кешенең җаны аның канына сеңгән, шуңа күрә җиргә аккан кан Ө.кә әверелә дигән караш б-н бәйле. Шул канны яндыргач, Ө. башка күренмәячәк, дип санаганнар. Мәетне һәлак булган урынында җирләү йоласы Ө.кә ышануга барып тоташа.

*Әд.:* Н а с ы р о в К. Поверья и обряды Казанских татар // Зап. Имп. Рус. геогр. об-ва по отделению этнографии. СПб., 1880. Т. 4; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967.

**ӨРӘҢГЕ́**, ч а г а н (Acer), чаганчалар семьялыгыннан яфрак коючан агачлар яки куаклар ыругы. Якынча 150 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТРда 6 төре бар. Гиннал яки елга буе Ө.се (A. ginnala), Көнбатыш Кама алдында декоратив үсемлек буларак үстерелә; татар чаганы (A. tataricum) — Идел алдында, ара-тирә кыргыйлана; яшел кабыклы Ө. (A. tegmentosum) һәм башаклы Ө. (A. spicatum) Раифа урманчылыгында интродукцияләшкән; Америка Ө.се (A. negundo), очлы яфраклы Ө. (A. platanoides) катнаш һәм киң яфраклы урманнарда үсәләр. 20 *м* га кадәр биеклектәге бер һәм ике өйле агачлар һәм 6 *м* га кадәр биеклектәге зур булмаган куаклар. Тамыр системасында өске горизонталь тамырлар өстенлек итә. Яфраклары каршыдаш, сабакчалы, гади яки каурыйсыман катлаулы. Чәчәкләре вак, күпчелеге саргылт-яшел, ике яки бер җенесле, калканчык яки чук чәчәк төркемендә; башлыча, яфраклар күренгәнче яисә алар б-н бер вакытта, иртә язда чәчәк ата. Өлгереп җитмәгән җимешләре ике канатлы җимешчектән тора, алар исә өлгергәннән соң аерылалар һәм берәмләп коелалар. Һәрбер җимешчектә (аның киң өлешендә) яссы түгәрәк бер орлык була.



Очлы яфраклы өрәңге.

Август-сентябрьдә өлгерәләр. Орлыктан һәм вегетатив юл — төптән чыккан үсентеләрдән үрчиләр. Күләгәгә чыдам һәм яктылык яратучы агач. Һаваның дымлылыгы артканда, агач «елый» (кагыйдә буларак, яңгыр яварга берничә сәгать кала). Ө. 150–200 ел яши. Халык медицинасында очлы яфраклы Ө.нең яшь яфраклары үт кудыру, антисептик, ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Ө. — урман барлыкка китерүче кыйммәтле токым. Барлык төрләре дә баллы. Орлыклары б-н иманборыннар, чукырлар һ.б. урман кошлары туклана. Ө.нең кайбер төрләренең үзагачын җиһаз һәм музыкаль инструментлар ясау өчен, агач эшендә, төзелештә файдаланалар.

*Әд.:* А л е к с е е в Ю.Е. Деревья и кустарники. М., 1997.

**ӨРГӘНЧЕ́** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 18,7 *км*. Бассейнының мәйданы 96,8 $км^2$. Елга башы

урман массивында, Түбән Кама р-ны Оша авылыннан 4,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы — Яңа Чишмә р-ны Зирекле авылыннан төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагынықы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 70%. Ө.нең 0,8 дән 3,5 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 115 *мм*, ташу вакытында су катламы 69 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,154 *м³/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

**ӨРГӘНЧЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 24 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Өргәнче елгасы буенда. 2010 елда 57 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1739 га кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә Никольский чиркәве (1856 да төзелә), земство мәктәбе (1873 тә ачыла), 3 тегермән, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2002 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 607, 1897 дә — 967, 1908 дә — 1050, 1910 да — 1180, 1920 дә — 1245, 1926 да — 1064, 1949 да — 729, 1958 дә — 389, 1970 тә — 313, 1979 да — 88, 1989 да — 99, 2002 дә — 86 кеше.

**ӨРКЕ́Ш** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 246 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урнуш исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.тә мәчет, мәктәп, земство мәктәбе, тимерчелек, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 904,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 34 ир-ат; 1859 да — 487, 1897 дә — 768, 1908 дә — 916, 1920 дә — 813, 1926 да — 889, 1949 да — 465, 1958 дә — 364, 1970 тә — 496, 1979 да — 310, 1989 да — 230, 2002 дә — 245 кеше.

**ӨРПӘ́К**, 20 йөз башына кадәр күбесенчә Казан татар хатын-кызларының борынгы баш япмасы. Ө. турыпочмаклы өчпочмак рәвешендә тегелә, 2–2,5 *м* лы озын кыек ягының уртасы җиңелчә сырлар б-н җыйдырыла. Өйдә тукылган юка ак тукымадан яки ефәктән эшләнә, тамбурлы чигү б-н бизәлә (бизәкләр, кагыйдә буларак, шахмат тәртибендә урнаштырылган чәчәк бәйләмнәреннән — укалы парчалардан (глазет) тора). Чәчәкле бизәкләрнең өслеге еш кына келәм җөе б-н тутырыла яисә алтын һәм көмеш җепләр б-н каплана (к. *Чигү*). Ө.нең чит-читләренә еш кына чук тотыла, маңгай өлешенә укалы тасмадан битлек тегелә. 19 йөздә Ө. Казан һәм Вятка губерналары терр-ясендә өлкән яшьтәге шәһәр татар хатын-кызлары киемендә сакланып килә, әмма 20 йөз башында фабрикада эшләнгән яулыклар б-н алышына.



Өрпәк. Ефәк, укалы тасма, чук. 19 йөз башы. ТР Милли музее.

Ө.нең бер төре булган кыекча, шул ук формада һәм зурлыкта булып, чигү б-н түгел, тәңкәләр яисә укалы тасма кисәкләре б-н бизәлә һәм күбесенчә авыл татар хатын-кызлары киеменең бер өлеше булып тора. 19 йөз уртасында кыекча Казан, Уфа, Оренбург, Самара һәм Вятка губерналарындагы авылларда таралыш ала. Кайчак аның астыннан маңгай бизәмәсе — сарынҗә бәйләп калдырыла. Ө. һәм кыекча б-н беррәттән, татар киеме элементы буларак сөлгесыман һәм квадрат баш япмалары: тастар, яулык (түгәрәк яулык, ак яулык, бистәр), бөркәнчек (баш бөркәү, каплама) һ.б. да кулланылган.



Яулык һәм өрпәк ябынган татар хатыны. Казан арты. 1920 елгы фоторәсем.

*Әд.:* Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ӨСКЕ́** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шыя елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 23 *км*, бассейнының мәйданы 116,4 *км*². Елга башы Кукмара р-ны Югары Өскебаш авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Мамадыш р-ны Олы Өске авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагынықы — 73 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 36%. Ө.нең 1,4 тән 8,6 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,51–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу вакытында су катламы 78 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,095 *м³/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ө. бассейнында су күләме 0,48 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ӨТӘ́К** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 41 *км* көньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1565–67 еллардан мәгълүм. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастыре карамагында, 1764 тән — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.тә Тихвин чиркәве (1864 тә төзелә), земство мәктәбе (1873 тә ачыла), 3 җил тегермәне, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1255 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 112 ир-ат; 1859 да — 362, 1897 дә — 637, 1908 дә — 792, 1920 дә — 726, 1926 да — 834, 1938 дә — 896, 1949 да — 499, 1958 дә — 346, 1970 тә — 272, 1979 да — 173, 1989 да — 110, 2002 дә — 99 кеше.

**ӨТӘШКӘ́** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010

елда 203 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.дә башлангыч мәктәп (1901 дә ачыла), 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 951,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Нурлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Нурлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 124 ир-ат; 1859 да — 423, 1897 дә — 736, 1908 дә — 919, 1920 дә — 806, 1926 да — 772, 1938 дә — 810, 1949 да — 448, 1958 дә — 424, 1970 тә — 368, 1979 да — 278, 1989 да — 206, 2002 дә — 275 кеше.

**ӨТЕРНӘ́С** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 12 *км* төньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 197 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аланъелга, Яңа Шекше исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.тә мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 622,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 122, 1897 дә — 265, 1908 дә — 303, 1920 дә — 323, 1926 да — 360, 1970 тә — 205, 1979 да — 238, 1989 да — 211, 2002 дә — 210 кеше. Ө. янында Өтернәс шәһәрлеге (14–15 йөзләр) урнашкан.

**ӨТНӘ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 14 *км* төньяктарак, Өтнә елгасы буенда. 2010 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 17 йөз ахырында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Өтнә, Әтнә исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киндер һәм чыпта сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1800 дә салынган иске мәчет урынына 1908 дән соң төзелә), мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 558,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 46 ир-ат; 1859 да — 325, 1897 дә — 468, 1908 дә — 437, 1920 дә — 455, 1926 да — 402, 1938 дә — 332, 1949 да — 258, 1958 дә — 195, 1970 тә — 172, 1979 да — 176, 1989 да — 120, 2002 дә — 127 кеше.

**«ӨЧ КЫЗ ТУГА́Н»**, тылсымлы татар халык *әкияте*. Нигезендә мифологик мотивлар ята.

Өч кызын кияүгә биргәч, әниләре ялгыз кала (табигатьтә кешенең ялгызлык мотивы) һәм дусты Тиен б-н генә аралаша (кешенең хайваннар б-н тыгыз мөнәсәбәте). Авырып киткәч, ул Тиеннән кызларына хәбәр бирүен үтенә. Тиен килгәндә, олы кызы җиз ләгән чистарта торган була. «Ләгәннәрне чистартып бетергәч барырмын», — ди ул. Тиен: «Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңге аерылма!» — ди. Олы кыз шунда ук ташбакага әверелә (ташбаканың һәм аның кабыгының барлыкка килүен аңлата торган этиологик мотив). Тиен уртанчы кызга чыгып йөгерә. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга торган була. Уртанчы кыз да: «Әшем беткәч барырмын», — ди. Тиен, ачуланып: «Алайса, гомереӊ буе киндер сук!» — ди. Кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелә (үрмәкүч һәм пәрәвезнең барлыкка килүен аңлата торган этиологик мотив). Шуннан соң хикәяләү тылсымлы әкияткә әверелә. Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның (әкиятләрдәге кече ул персонажына охшаган) камыр баскан чагы икән. Ул, бер сүз дә әйтмичә, кулын да сөртеп тормыйча, әнисе янына йөгерә. «И, сөекле бала, гомереӊ буе игелек күр!» — дип әйтеп кала аңа Тиен. Әкияти һәм мифологик элементларның үрелеп баруы әкиятнең борынгылыгын чагылдыра.

*Әд.:* Өч кыз туган // Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр. К., 1994; Этиологические мифы // Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2.

*Ф.И.Урманчеев.*

**«ӨЧ МИЛЛИА́РД ТО́ННА ТАТАРСТА́Н НЕ́ФТЕН ЧЫГАРУ́ УҢАЕ́ БЕЛӘ́Н» МЕДАЛЕ́**, ТР дәүләт бүләге. ТРның 2007 елның 28 апрелендә кабул ителгән «ТРның «Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турында» Законына үзгәрешләр кертү турында» Законы нигезендә гамәлгә куела. ТР нефть сәнәгате хезмәткәрләренең (ш.и. пр-тиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренең) хезмәттәге югары казанышлары, ш.у. халык хуҗалыгының башка тармаклары, дәүләт органнары һәм оешмалары хезмәткәрләренең ТР нефть сәнәгате оешуга һәм үсешенә керткән өлешләре өчен билгеләнә. ТР Президенты тарафыннан тапшырыла. ТР Президентының 2007 ел 4 май Указы буенча медаль түгәрәк рәвешендә көмештән (диаметры 32 *мм*) эшләнә, ике ягы да алтынсыман төс б-н каймалана. Уң ягы шомартылган тонык өслектән гыйбарәт, аның әйләнәсенә алтын төсендәге татар милли бизәге төшерелгән. Өслекнең үзәгендә — Татарстанның алтын төсендәге геогр. картасы, рельефлы үзәгенең уртасында өч миллиард тонна нефть чыгаруны символлаштырган фонтан рәвешендәге мемориал урнаштырылган. Республика картасы астында өслекнең түбәнге өлешен алтын төсендәге «Татарстан» язуы били. Өслекнең югарыгы өлешендә алтын төсендәге «3» саны куелган. Өслекнең эчке радиусы буйлап бер юнәлештә алтын төсендәге язулар урнаштырылган: сул якта — татар телендә «миллиард тонна нефть», уң якта — рус телендә «миллиарда тонн нефти». Медальнең икенче ягында, шомартылган батынкы өслек үзәгендә — алтын төсендәге лавр ботагы сурәте, аның астында — медальнең номеры. Ботак диаметр буенча өслектән алтын төсендәге кабарынкы кайма б-н аерыла. Ялтыратылган түгәрәкнең өске өлешендә алтын төсендәге «1943–2007» даталары урнаштырылган. Даталар башка мәгълүматтан алтын төсендәге дүрт почмаклы ике йолдыз б-н аерыла. Аннан соң түгәрәк диаметры буенча кечерәк зурлыкта алтын төсендәге 3 дата куелган: «1943–1971 — I млрд.», «1971–1981 — II млрд.», «1981–2007 — III млрд.». Медаль өч төстәге муар тасма тарттырылган бишпочмаклы кысага тоташа. Тасманың киңлеге 24 *мм*: сул якта — яшел, уң якта — кызыл буйлар (һәркайсының киңлеге — 10 *мм*), кысаның кырыйларында — алтын төсендәге (киңлеге 2 *мм*) буйлар. 2008 нең 1 гыйнварына бүләккә 3005 кеше лаек була.




*Е.Б.Долгов.*

**ӨЧЕНЧЕ́ А́РМИЯ**, Гражданнар сугышы вакытында *Көнчыгыш фронт* составындагы хәрби берләшмә. 1918 елның 20 июлендә оештырыла. Командирлары — Р.И.Берзин, М.М.Лашевич, С.А.Меженинов, М.И.Алафузо, М.С.Матиясевич; штаб башлыклары — В.Ф.Орёл, М.М.Лашевич, Ю.Ю.Аплок, М.И.Алафузо, И.И.Герасимов, В.В.Любимов, Е.Н.Сергеев. Ө.а.гә Көнчыгыш пехота дивизиясе (1918 нең июль–октябре, 1918 нең августыннан — 1 нче Урал пехота дивизиясе), 2 нче Урал пехота дивизиясе (1918 нең июль–октябре), 1 нче оештырылыш 4 нче Урал дивизиясе (1918 нең июле – 1919 ның ноябре; 1919 ның ноябреннән — 30 нчы укчы дивизия), 3 нче Урал дивизиясе (1918 нең август–ноябре), 5 нче Урал пехота дивизиясе (1918 нең сентябрь–декабре), Төньяк Урал кушма дивизиясе (1918 нең октябре – 1920 нең гыйнвары, 1918 нең ноябреннән — 29 нчы укчы дивизия), махсус юнәлешле дивизия (1918 нең ноябрь–декабре), 2 нче оештырылыш 4 нче Урал укчы дивизиясе, 21 нче укчы дивизия (1919 ның июль–сентябре), 51 нче укчы дивизия (1919 ның июль–ноябре), 62 нче укчы дивизия (1919 ның ноябрь-декабре), Урал укчы дивизиясе (1919 ның ноябре – 1920 нең гыйнвары), 10 нчы кавалерия дивизиясе (1919 ның ноябре – 1920 нең гыйнвары) керә. 1918 дә Златоуст–Чиләбе, Екатеринбург һәм Пермь юнәлешендәге сугышларда, адмирал А.В.Колчак армиясенә каршы Сарапул-Воткинск, Пермь, Екатеринбург, Петропавловск һәм Омск операцияләре

рендә катнаша. Ө.а. составында 21 нче мөселман укчы полкы сугыша. Армиянең сәяси бүлеге каршындагы татарлар секциясе (рәисе — К.Г.Мохтаров), тарафыннан татар телендә «Коммунист» г-тасы нәшер ителә. Ө.а. 1920 нең гыйнварында 1 нче революцион хезмәт армиясе дип үзгәртелә.

**ӨЧЕНЧЕ́ БӨГЕЛДЕ́** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 5 *км* төньяктарак, Зәй елгасыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 72 кеше (руслар) яши. 1906–1911 елларда нигез салына. 1912–13 тә авыл җәмәгатенең имана җире 383 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1913 тә — 232, 1920 дә — 213, 1926 да — 173, 1938 дә — 264, 1949 да — 226, 1958 дә — 292, 1979 да — 61, 1989 да — 8, 2002 дә — 29 кеше.

**ӨЧЕНЧЕ́ ИНТЕРНАЦИОНА́Л ИСЕМЕНДӘГЕ́** авыл, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 78 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 98, 1970 тә — 180, 1979 да — 138, 1989 да — 100, 2002 дә — 108 кеше.

**ӨЧЕНЧЕ́ СЪЕЗД ИСЕМЕНДӘГЕ́** посёлок, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Киекле елгасы буенда. 2010 елда 31 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1922 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чистай кантоны Котыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән хәзерге Нурлат р-нында. Халык саны: 1949 да — 121, 1958 дә — 158, 1970 тә — 138, 1979 да — 130, 1989 да — 57, 2002 дә — 39 кеше.

**ӨЧИЛЕ́**, к. *Үсәли*, Мамадыш р-ны.

**ӨЧИЛЕ́** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 13 *км* төньяктарак, Бирәзә елгасы буенда. 2010 елда 272 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. 1920 елларга кадәр Кече Бирәзә исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Сюля буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, орчык һәм көянтә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1878 дә төзелә; архит-ра истәлеге; 1879–1907 дә аның имам-хатибы булып Г.Тукайның бабасы Зиннәтулла Зәйнелбәширов тора), мәктәп, су тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 545,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 293, 1897 дә — 445, 1908 дә — 420, 1920 дә — 455, 1926 да — 421, 1938 дә — 396, 1949 да — 390, 1958 дә — 283, 1970 тә — 244, 1979 да — 245, 1989 да — 224, 2002 дә — 248 кеше.

**ӨЧИЛЕ́ САКЛА́У** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Саклаусу елгасы буенда. 2010 елда 225 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1731 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Верхний Саклов, Усюлю-Саклова исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 648,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 129 ир-ат; 1870 тә — 491, 1897 дә — 798, 1920 дә — 867, 1926 да — 703, 1938 дә — 429, 1949 да — 349, 1958 дә — 341, 1970 тә — 380, 1979 да — 313, 1989 да — 186, 2002 дә — 260 кеше.

**ӨЧКҮ́Л** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 10 *км* көньяктарак урнашкан. 2010 елда 573 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1690 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Рождество Христово чиркәве (1777 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход (1888 дә ачыла) һәм 2 земство (1880 елларда ачыла) мәктәбе, фельдшерлык пункты, 10 тегермән, 2 ярма яргыч, 3 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 9 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 923,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Өчкүл волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апр. — 1991 нең 4 окт. — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 731 ир-ат; 1859 да — 2183, 1897 дә — 3127, 1908 дә — 3362, 1920 дә — 3205, 1926 да — 2635, 1938 дә — 1444, 1949 да — 1125, 1958 дә — 1488, 1970 тә — 1156, 1979 да — 873, 1989 да — 712, 2002 дә — 597 кеше.

**ӨЧКЫРЛЫ́К** (Tripleurospermum), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 30 га якын төре билгеле. Төньяк ярымшарның тропиктан тыш өлкәләрендә таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — тишкәләнгән яфраклы Ө. (T.inodorum) бар, барлык районнарда да очрый. Елга ярларында, юл буйларында, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында, кырларда, болыннарда үсә. 20–80 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры нечкә, орчыксыман. Сабагы туры, тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, икешәр, өчәр каурыйсыман-теленмә. Чәчәкләре сабак очында кәрзингә җыйналган, кырый чәчәкләр — телле-телле бер рәтле, ак; уртадагылар — көпшәле, сары. Җимешләре — үткен өч кырлы (исеме шуннан) куе көрән төстәге яньчек орлыкчалар. Май–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Дым яратучы, туфракка талымсыз (орлыклар туфракта шыту сәләтен 6–7 ел саклыйлар). Бөртеклеләр һәм күпьеллык үләннәр чәчүлекләрен чүплиләр. Көрәш чаралары: урылган кырны йомшарту, туңга сөрү, чәчү алдыннан культивация, чәчү материалын чистарту, чәчү әйләнешен саклау. Инсектицид үсемлек.

**ӨЧМУНЧА́** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* төньяктарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 155 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.да мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 647,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир-ат; 1859 да — 594, 1897 дә — 813, 1908 дә — 981, 1920 дә — 879, 1926 да — 655, 1938 дә — 441, 1949 да — 345, 1958 дә — 302, 1970 тә — 285, 1979 да — 94, 1989 да — 158, 2002 дә — 164 кеше.

**ӨЧНАРА́Т** (Түбән Өчнарат) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 102 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, кошчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ө.та 2 су тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 760 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 297, 1897 дә — 383, 1908 дә — 380, 1920 дә — 478, 1926 да — 429, 1938 дә — 355, 1949 да — 278, 1970 тә — 271, 1979 да — 210, 1989 да — 127, 2002 дә — 105 кеше.

**ӨЧПОЧМА́К**, татар милли ризыгы. Әче, сирәгрәк төче камырдан вак итеп туралган ит, бәрәңге һәм суган б-н әчләп әзерләнгән өчпочмак рәвешендәге камыр ашы. Ө. әзерләгәндә әчлек, пәрәмәч ясагандагы кебек үк, башка шуңа охшаш ризыклардан аермалы буларак,



чи килеш салына. 20 йөз башыннан Ө. бәйрәм табынының төп сыйларыннан исәпләнә, шулпа б-н яисә чәй янына бирелә. Хәзерге вакытта Ө., Татарстанда гына түгел, Россиянең күп кенә төбәкләрендә дә, аеруча Идел һәм Урал буенда, бик популяр санала.

*Әд.:* Пища // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. К., 1967; Татарская кухня. К., 1985; Мухамедова Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. М., 2001.

**ӨЯ́З**, Россиядә адм.-терр. бүленеш берәмлеге, 13 йөздән мәгълүм атама. Казан ханлыгы буйсындырылганнан соң (1552), аның җирләре башында воевода торган Казан, Зөя һәм Чабаксар өязләренә бүленә (к. *Воевода идарәсе*). Урта Идел төбәгендә Ө.ләр баштарак *даругалар*га бүленүле хәлдә калдырыла, соңрак *волость* һәм *стан* берәмлекләренә бүленә. 1708 дән Ө. — *Казан губернасы* составындагы адм.-терр. бүленеш берәмлеге. 20 йөз башында Казан губернасында Казан, Зөя, Козьмодемьянск, Лаеш, Мамадыш, Спас, Тәтеш, Царёвококшайск, Цивильск, Чабаксар, Чистай, Ядрин — барлыгы 12 Ө. була. 1920 елларда Татарстанда Ө.ләр бетерелә, алар җирлегендә *кантоннар* төзелә.

*Әд.:* Ермолаев И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв.: Управление Казанским краем. К., 1982.

*Д.Г.Мостафина.*

**ӨЯ́З ГАЗЕ́ТАЛАРЫ**, Татарстан терр-ясендә 19–20 йөз чикләрендә чыга башлыйлар һәм 1920 елга кадәр нәшер ителәләр. Төбәкнең беренче өяз вакытлы басмасы — «Камский листок объявлений» 1897–1904 тә **Алабуга** шәһәрендә басыла (42 сан, нашире һәм мөхәррире И.Н.Кибардин). Рус телендәге газеталар да шунда ук басыла: «Елабужские вести» (1906, 96 сан, нашире — И.Н.Зубарев, мөхәррире — В.А.Куличенко), «Елабужская жизнь» (1917–18, 122 сан, мөхәррире — В.А.Куличенко), «Телеграммы газеты «Елабужская жизнь» (1917–18, мөхәррире — В.А.Куличенко), «Елабужская маленькая газета» (1917, 28 сан), «Елабужская рабочая газета» (1917, 7 сан), «Крестьянская газета Елабужского уездного земства» (1917–18, 5 сан, нашире — Алабуга земство идарәсе), «Бюллетень Елабужского комитета спасения революции» (1917), «Народная воля» (1917–18, 145 сан, редколлегия: В.А.Беляев, П.П.Гвоздев, Б.В.Коровин, М.Г.Худяков, 1917 нең декабреннән Н.Конкин, А.Тунгусков), «Известия Елабужского исполнительного комитета Совета рабочих и солдатских депутатов» (1918), «Вперёд» (1918, 19 сан), «Известия Елабужского революционного комитета» (1918, 31 сан), «Луч коммунизма» (1918–19, 41 сан), «Красный путь» (1919–20, 142 сан, И.А.Волков, А.П.Гришина, А.Сәхәбетдинов, А.И.Степанова, Я.С.Тугаров, А.Р.Чигвинцев хезмәттәшлек итә), «Официальный листок» («Красный путь» г-тасына кушымта, 1920), «Известия Елабужского уездного комитета РКП(б)» (1920), «Бюллетень Елабужского отдела народного образования» (1920), Россия телеграф агентлыгының (РОСТА) басмаханә ысулы б-н чыгарылган «Красный колокол» стена г-тасы (1920). Башка телләрдәге газеталар да нәшер ителә: татар телендә — «Чулман» (1918–19, нашире — Алабуга өяз мөселман комис-ты), «Кызыл юл» (1919–20, 64 сан, Г.Баһаветдинов, Г.Балтанов, Т.Насыйров, Ш.Саттаров хезмәттәшлек итә), керәшен татарлар өчен кириллицада «Алга» г-тасы (1919), удмурт телендә акгвардиячел «Кам тулкым» (1918), «*Гудыри*». Алабугада, ш.у. удмурт телендә, «*Сюрло*» г-тасы, Россия телеграф агентлыгының (РОСТА) «Горд гырлы» стена г-тасы һәм мари телендә «Тул» г-тасы нәшер ителә.

**Бөгелмә** шәһәрендә «Бугульминская газета» (1906, 62 сан, мөхәррир-нашире Я.А.Рыжаков), аның кушымтасы «Телеграммы «Бугульминской газеты», ш.у. «Мирный путь» (1906, 19 сан, нашире һәм мөхәррире А.П.Самарин), «Бугульминец» (нашир-мөхәррире В.Н.Носин), «Возрождённое крестьянство» (1906–12, 70 сан, нашир-мөхәррире А.И.Зерюнов), «Телеграммы типографии В.Ф.Викторова» (1914–16), «Известия Бугульминского Совета рабочих, солдатских и крестьянских депутатов и Комитета народной власти» (1917, 33 сан), «Известия Бугульминского Совета рабочих, солдатских и крестьянских депутатов» (1917, нашире — Бөгелмә башкарма ком-ты каршындагы секретариат), «Вестник Бугульминского Совета рабочих и крестьянских депутатов» (1918, 15 сан), акгвардиячел «Бугульминская газета» (1918), «Советская республика» (1919–20, 132 сан), «Светлый путь» (1920, 36 сан) г-талары, «Бугульминский уезд РОСТА» стена г-тасы (1920) һәм татар телендәге «Бөгелмә мөхбире» (1920), «Якты юл» (1919–20, 41 сан, мөхәррире — М.Мохтасаров) г-тасы, «Бөгелмә өяз РОСТАсы» (1920) стена г-тасы басыла.

**Чистай** шәһәрендә «Бюллетень Чистопольской биржи» (1911–17, 69 сан, нашире — Чистай биржа ком-ты, мөхәррире — Н.И.Шашин), «Известия уездного комитета общественной безопасности» (1917), «Власть Советов» (1918–19, 220 сан, мөхәррире — З.М.Путилов; Л.И.Артос, И.М.Бажанов, Н.И.Барышев, А.В.Белов, И.Н.Буржинский, И.Н.Гуськов, О.А.Цветкова хезмәттәшлек итә), акгвардиячел «Чистопольский вестник» (1918), «Бюллетень текущих событий» (1919), «Власть труда» (1919–20, 64 сан), «Плакатный вестник» (1920) г-талары нәшер ителә. Татар телендә «Берлек» (1918–20, 70 сан, мөхәррире — К.Тактамышев; Б.М.Билялов, Н.К.Камалетдинов, К.Х.Хәмзин хезмәттәшлек итә), «Бөтен Шәрекъ ярлылары, берлек әләме астына!» (1919–20) г-талары басыла.

**Минзәлә** шәһәрендә чыккан газеталар: «Телеграммы Петроградского телеграфного агенства» (1914–16), «Известия Мензелинского Совета крестьянских депутатов» (1917, 13 сан), «Известия Мензелинского Совета крестьянских и солдатских депутатов» (1917–18, 58 сан, нашире — Совет башкарма ком-ты, мөхәррирләре — П.П.Санников, А.Г.Туманов), «Красные известия» (1918–19), «Пролетарский путь» («Красные известия», 1919–20), «Крестьянин» («Пролетарский путь», 1920, мөхәррирләре — П.П.Санников, В.Г.Кальницкий, И.П.Лопухов), РОСТАның «Красный маяк» стена г-тасы (1919–20). Татар телендәге газеталар: «Хәбәрләр. Минзәлә өязендәге крестьян депутатлары киңәшенеке» (1917, 7 сан, мөхәррире — М.Чернов; кириллицада нәшер ителә), «Минзәлә иле» (1917–19, 84 сан), «*Кызыл әләм*» (1919–20), «Игенче» (1920, 18 сан, мөхәррирләре — Ш.Хәмиди, Г.Мөслими); РОСТАның «Кызыл маяк» стена г-тасы (1920).

**Спас** шәһәрендә «Крестьянин» (1917–19, 95 сан, мөхәррире — П.Кучумов), «Бюллетень Спасского уездного Совета» г-талары, РОСТАның «Труд» стена г-тасы, татар телендә «Халык теләге» (1918–19, 20 сан, мөхәррирләре — Х.Сафа һәм Г.Сөләйманов) г-тасы һәм РОСТАның «Эш» стена г-тасы дөнья күрә.

**Мамадыш** шәһәрендә басылган газеталар: «Наши дни» (1918, А.В.Давыдов тарафыннан оештырыла, 70 сан), акгвардиячел «Мамадышский вестник» (1918), «Голос пролетариата» (1918–19), «Вестник информации Мамадышского уездного отдела управления» (1919, 7 сан), «Пролетарский труд» (1919–20), «Красный пахарь» (1920), «Красный вестник» (1920); «РОСТА Мамадышского уезда» стена г-тасы (1920); ш.у. татар телендә «Мамадыш тавышы» (1918–20, мөхәррире — М.Бәдәйли), «Кызыл көч» (1920, 18 сан, мөхәррирләре — М.Искәндәров, Г.Рәхмәтуллин) г-талары, «Мамадыш өяз РОСТАсы» стена г-тасы (1920).

**Тәтеш** шәһәрендә басылган газеталар: «Телеграммы Петроградского телеграфного агенства» (1914), «Голос пахаря» (1918, 44 сан), «Известия Тетюшского временного гражданского революционного комитета» (1918), «Известия Тетюшского уездного Совета рабочих, красноармейских и крестьянских депутатов» (1918–19), «Красный маяк» (1919), «Информационная листовка» (1919), «Плакатный вестник» (1919–20), «Друг народа» (1920), «Красный луч» (1920–21), ш.у. татар телендә: «Тәтеш хәбәрләре» (1918), «Тәтеш хакыйкате» (1919, И.Әмиров, бертуган Исмаевлар, И.Казаков, бертуган Маликовлар, Г.Халиков хезмәттәшлек итә).

**Буа** шәһәрендә «Буинская беднота» (1919–20, И.Евграфов, С.Узюков, К.Пестковскаялардан торган редколлегия), «Власть труда» (1920) һәм татар телендә «Яңа тормыш» (1920) г-талары нәшер ителә.

**Зөя** авылында 1920 нең гыйнвар аеннан шул ук елның җәенә кадәр «Вести революции» өяз г-тасы, соңыннан «Красный пахарь» (1920–22, мөхәррире Ф.С.Микерин) нәшер ителә.

**Лаеш** шәһәрендә «Лаишевские вести» (1920–21) г-тасы, «РОСТА Лаишевского уезда» стена г-тасы басыла.

ТАССР төзелү чорында — 1920 дә аның составына кергән өязләрдә рус һәм татар телләрендә 18 өяз г-тасы (РОСТАның стена г-таларыннан тыш) басыла. 1920 ел ахырында, яңа адм.-терр. бүленеш кертелү сәбәпле, кантон вакытлы басмасы итеп үзгәртеләләр. Бу газеталарның күбесе Татарстанның хәзерге *шәһәр, район-шәһәр, район газеталарының* башлангычы булып тора.

*Әд.:* Е м е л ь я н о в Л.П. Печать Удмуртии (из истории возникновения и развития партийно-советской печати Удмуртии. 1905–1934). Ижевск, 1964; С е р г е е в М.П. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1971; Н а с ы р о в Т.М. Октябрь и печать Татарии. 1917–1920. К., 1975; Ф а с а х о в К.М. С жизнью в ногу (Периодическая печать Татарии в восстановительный период). К., 1979; Н у р у л л и н а Р.М. Газеты и журналы на татарском языке (1905–1985). К., 1985; Г а й н а н о в Р.Р., М а р д а н о в Р.Ф., Ш а к у р о в Ф.Н. Татарская периодическая печать начала XX в.: Библиогр. указ. К., 2000.


*Т.М.Насыйров.*

**ӨЯ́З МӘХКӘМӘЛӘРЕ́**, Россиядә җирле мәхкәмә органнары. Казан губернасында 1775 елгы «Губерналар турында нигезләмә»не гамәлгә ашыру барышында оештырылалар, дворяннар өчен 1781 нең декабрь ахыры — 1782 нең гыйнварыннан һәм крәстияннәр өчен 1801 дән гамәлгә куела. Беренче инстанция мәхкәмәсе сыйфатында вак җинаять һәм гражданлык эшләрен карыйлар, алпавытлар арасында җир эшләре мәсьәләләренә караган бәхәсләрне хәл итәләр, җирне һәм крәстияннәрне теркәп, иялек кәгазе бирәләр, түбәнге *земство мәхкәмәләре* өчен апелляция инстанциясе булып торалар. Өяз дворяннары тарафыннан 3 елга сайланган һәм губернатор раслаган өяз судьясы һәм 2 утырышчыдан торалар. Ө.м.нең аерым зат яисә стряпчий шикаяте буенча гына, ш.у. башка мәхкәмә яки *Казан губерна идарәсе* боерыгы б-н генә мөстәкыйль рәвештә эш кузгату хокукы булмый. Елга 3 тапкыр сессиягә җыелалар. Ө.м. каршында дворян опекалары (тол хатыннар һәм кече яшьтәге дворяннар өчен) эшли, аларга өяз дворяннары башлыклары рәислегендә эш итүче өяз судьялары һәм утырышчылары керә. Югары земство мәхкәмәсенә (1796 га кадәр), губерна идарәсенә, *Казан җинаять эшләре мәхкәмә палатасына, Казан гражданлык эшләре мәхкәмә палатасына* буйсыналар. 1869–70 еллар башында, 1864 елгы Мәхкәмә реформасы барышында бетереләләр. Вәкаләтләре җәмәгать судына тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 20. № 4392; Собр. 2. СПб., 1867. Т. 39, отд. 2. № 41475.

*Әд.:* Д о л г о в Е.Б. Административные и судебные органы власти в городе Казани и Казанской губернии в XVIII веке // Столичные и периферийные города Руси и России в средние века и раннее новое время. М., 1996; ш у л у к. Органы суда в Казанской губернии XVIII — начала XX вв. // Правосудие в Татарстане. 2000. № 2/3; Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 4.

*Е.Б.Долгов.*





Алабуга шәһәрендә В.М. Бехтерев исем. өяз медицинасы музее: 1. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында даруханә интерьеры; 2. В.М. Бехтеревка багышланган зал.

**ӨЯ́З МЕДИЦИ́НАСЫ МУЗЕЕ́**, В. М. Б е х т е р е в и с е м е н д ә, Алабуга шәһәрендә, 2007 елда *Алабуга тарих-архитектура һәм сәнгать музей-саклаулыгының* бүлекчәсе буларак ачыла. 2 нче гильдия сәүдәгәр А.Баранов тарафыннан төзелгән элеккеге земство хастаханәсенең хирургия корпусында урнашкан (1881; архит-ра истәлеге). Экспозиция мәйданы — 300 $м^2$. Музей фондында 1 мең саклау берәмлеге бар. Экспозиция дүрт залда урнаштырылган. 1–2 нче залларда Алабуга өязендә сәламәтлек саклау системасының үсеше чагылдырылган. Им-том итүчеләр йорты һәм 19 йөзнең 2 нче яртысы земство табибе кабинеты интерьерлары, психик авырулар өчен палаталар бар. Алабуга хастаханәсенең эше турында архив документлары куелган. «Аптека эшләрен оештыру» бүлегендә дару шкафлары, дару ясау үлчәүләре, хастаханә корпусларының берсендә сакланып калган рецептлар урын алган. 20 йөз медицина үсешенә багышланган залда операция бүлмәсе һәм балалар бүлеге интерьерлары урнаштырылган. Алабуга табибләре Л.П.Нечаев, Т.А.Нечаева, Т.И.Уртаев, Н.В.Швалёвның шәхси әйберләре һәм архивлары; Бөек Ватан сугышында катнашкан мед. хезмәткәрләренең бүләкләре, 20 йөз мед. инструментлары күргәзмәгә куелган. Залларның берсе Алабуга өязендә туган В.М.Бехтеревка багышлана. Музей чаралары үткәрү өчен аудио- һәм видеоаппаратлар, мед. техникасы б-н җиһазланган аерым зал каралган; фитобар (үләннәр б-н дәвалау) эшли. Музей терр-ясендә В.М.Бехтеревка һәйкәл урнаштырылган (2007, скульпторлар А.Головачёв, В.Демченко). Ел саен В.М.Бехтерев туган көн (20 гыйн.), Халыкара музейләр көне (18 май) үткәрелә.

**ӨЯ́З УЧИ́ЛИЩЕЛӘРЕ**, шәһәр балалары өчен билгеләнгән, тулы булмаган урта уку йортлары. Алабуга шәһәрендә училище 1809 елда, Казан губернасының калган барлык өяз шәһәрләрендә 1816–18 дә, Казанда 1835 тә Казан хосусый *халык училищесе* җирлегендә, Минзәләдә 1839 да, Буада 1842 дә, Бөгелмәдә 1854 дә ачыла. Башлангыч белемле ир балалар кабул ителә. 1804 елгы халык уч-щеләре уставы буенча уку срогы 4 ел (ике сыйныфта 2 шәр ел), штатта 2 укытучы эшли. 1828 елгы устав буенча уку срогы 5 елга кадәр арта, укытуга фәннәр системасы кертелә, штатка — күзәтүче (директор), арифметика һәм геом., рус теле, тарих һәм география, рәсем һәм матур язу укытучылары алына; ш.у. Ходай кануны укытыла. Ө.у.нең укытучылары, нигездә, гимназия һәм руханилар семинариясен тәмамлап, махсус имтихан тапшыручылар була. Ө.у. каршында әзерлек сыйныфлары эшли, алар күп кенә өяз шәһәрләрендә бердәнбер башлангыч мәктәп исәпләнәләр. Укучыларның күпчелеге түләүсез белем ала, калганнары өчен дә түләү зур булмый. Укыту дәрәҗәсе тиешле югарылыкта булса да, программада чит телләр һәм алгебра фәне укыту каралмаганлыктан, укуны гимназия һ.б. уку йортларында дәвам итү мөмкин булмый. Кечкенә шәһәрләрдә Ө.у.нең социаль роле шактый ук югары була, алар ярлы гаилә балаларына да белем алу мөмкинлеген бирәләр. Ө.у. тәмамлаучыларның күбесе кече чиновниклар, хосусый компания хезмәткәрләре, 1860 тан земство мәктәпләре укытучылары булалар. 1870 елларның 2 нче яртысыннан 20 йөз башына кадәр Ө.у. акрынлап *Шәһәр училищеләре* итеп үзгәртеләләр.

# П

**ПА́АСОНЕН** (Paazonen) Хейки (2.1.1865, Финляндия — 24.8.1919, Хельсинки), фин тюркологы, фольклорчы. 1899–1900 елларда Самара губернасының Бөгелмә өязендә яшәүче татарлардан фольклор материаллары язып ала. Алар татар һәм немец телләрендә «Татар җырлары» (Хельсинки, 1901), «Татар-мишәр халык җырлары» (Хельсинки, 1953) дигән хезмәтләрдә басылып чыга.

**ПА́ВЕЛ** (Зернов Пётр Сергеевич (1742, башка мәгълүматлар буенча 1738, Мәскәү — 14.1.1815, Казан), дин эшлеклесе. Мәскәү руханилар академиясен, башка чыганаклар буенча Троица-Сергий монастыре семинариясен тәмамлый, 1763 елдан шунда эшли: җыр укытучысы, китапханәче, тәрҗемәче, мөгаллим була. 1767 дән монахлык кабул итә. 1770–75 тә Троица-Сергий монастырендa: наместник һәм семинария ректоры, бер үк вакытта Савва-Сторожевский монастыре игумены. 1775 тә Ярославль руханилар семинариясендә архимандрит, ректор һәм Спас ирләр монастыре башлыгы. 1776–78 дә Донской монастыре (Мәскәү) наместнигы. 1778–80 дә Кострома һәм Галич епископы. 1780–1801 дә Тверь епископы (1801 дән архиепископ). 1803–15 тә Казан һәм Сембер архиепископы.

*Әд.:* Л и п а к о в Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

**ПА́ВЕЛ** (Лебедев Пётр Васильевич) (12.12.1827, Тверь губ. Весьегонск өязе — 23.5.1892, Казан), дин эшлеклесе, христиан дине теологы, теология магистры. Тверь руханилар семинариясен (1849), Петербург руханилар академиясен тәмамлый (1853). 1853 елда монахлык кабул итә, 1858 дән архимандрит. 1853–59 да — Петербург руханилар семинариясендә, 1859–61 дә Петербург руханилар академиясендә укыта, проф. (1859). 1861–66 да Смоленск руханилар семинариясе ректоры, бер үк вакытта Спас-Авраам монастыре башлыгы, 1866–69 да Петербург руханилар семинариясе ректоры, бер үк вакытта, 1868 дән, Выборг епископы, Петербург епархиясенең 2 нче викарие, 1869 дан Ладога епископы, 1871 дән Кишинёв һәм Хотин епископы (1879 дан — архиепископ). 1882 дән Карталия һәм Кахетия архиепископы, Грузия экзархы, Изге синод әгъзасы. 1887 дән Казан һәм Зөя архиепископы. П. булышлыгы б-н 1889 да Казан руханилар академиясе каршында *Казан миссионерлык курслары* ачыла. «Борынгы Шәрекъ чиркәвендә чиркәү идарәсенә караган вазифалар һәм учреждениеләр турында» («О должностях и учреждениях по церковному управлению в древней Восточной церкви», СПб., 1857) хезмәте авторы.

*Әд.:* Л и п а к о в Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

**ПА́ВЕЛ I** (20.9.1754, С.-Петербург — 12.3.1801, шунда ук), Россия императоры (1796 елдан). Патшалык итә башлагач, үзгәртеп корулар уздыра, алар барышында Казан наместниклыгы (1796), Арча, Спас, Тәтеш өязләре (1799) бетерелә, Казан полициясе оештырыла (1797–98), Казан руханилар семинариясе академия итеп үзгәртелә (1798). 1796 да наместниклык идарәсе губерна идарәсенә әверелә; гражданлык эшләре һәм җинаять эшләре мәхкәмә палаталары мәхкәмә һәм җәза бирү палатасына берләштерелә; югары земство мәхкәмәсе, губерна магистраты, түбән расправалар һ.б. бетерелә. 1798 нең маенда П. I Оренбург хәрби инспекциясе гаскәрләрен тикшерү өчен Казан губернасына сәяхәт кыла. 22–24 майда ул Козьмодемьянск, Чабаксар, Зөя шәһәрләрендә була, 24–30 майда Казанда генерал Лецкий йортында туктала. Кремльне, Благовещение соборын, Казан Богородица хатын-кызлар монастырен һ.б. истәлекле урыннарны карый. Дворяннар һәм шәһәр кешеләрен кабул итә, Арча кырында хәрби өйрәнүләр б-н җитәкчелек итә. Казан шәһәренә яңа җирләр «кисеп бирергә» боера; *Гостиный двор*, лазаретлар, Богородица монастырендагы собор төзелешенә үзеннән акча кертә, казна урманнарын саклау өчен Адмиралтейств-коллегия каршында урманчылык департаменты оештыра; Беренче ир балалар гимназиясе уставын раслый, гимназия өчен Воскресенский урамындагы губернатор йортын һәм кенәз Г.А.Потемкин китапханәсен тапшыру турындагы боерык бирә. Император Казанга утырып килгән катер соңыннан җирле адмиралтейство саклауга бирелә (1950 еллар уртасында яна).

**ПА́ВЛОВ** Александр Алексеевич (15.1.1925, Арча кантоны, хәзер Питрәч р-ны Шихазда а., — 14.8.2001, шунда ук), Соц. Хезмәт Герое (1976). Юдино тимер юл уч-щесен тәмамлый (1943). 1943–92 елларда Горький тимер юлының Казан бүлеге Юдино депосында слесарь-ремонтлаучы. Бөек Ватан сугышы елларында «Кызыл Татарстан» бронепоездын төзүдә хезмәт хакы алмыйча эшли. Беренчеләрдән булып тепловозларның төзелешен өйрәнә һәм аларны ремонтлауны үзләштерә (1957). Рационализаторлык тәкъдимнәре кертә, алар җитештерүдә файдаланыла. Герой исеме 9 нчы бишьеллык планнарын (1971–75) һәм соц. йөкләмәләрне арттырып үтәгәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПА́ВЛОВ** Александр Филиппович (25.6.1938, Питрәч р-ны Надеждино а.), хакимият-хуҗалык хезмәткәре, авиация двигательләре



А.А. Павлов.

төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1994), проф. (1998), ТССРның атказ. машина төзүчесе (1991). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1970). 1960 елдан Казан моторлар төзү ҖБдә эшли: шомартучы, өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, производство башлыгы (1974 тән), җитештерү буенча директор урынбасары (1975 тән), баш инженер (1976 дан), ген. директор (1983 тән), берләшмә дирекциясе киңәшчесе (2004–10). П. авиация сәнәгате үсешенә зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә пр-тиедә берничә тапкыр реконструкция уздырыла, алдынгы технологияләр гамәлгә кертелә, Ил-62, Ту-154, Ил-86 самолётлары өчен Н.Д.Кузнецов конструкцияләгән НК-86, НК-93 двигательләрен, магистраль газ үткәргечләр өчен НК-16СТ, НК-16 — 18СТ, НК-38СТ двигательләрен җитештерү оештырыла. Хезмәтләре авиация һәм газ-турбиналы двигательләр төзүгә карый. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы бар. Украина ССР Дәүләт бүләге (1983), СССР МС бүләге (1984) лауреаты. 1984–90 да ТАССР ЮС, 1990–95 тә ТССР һәм ТР ЮСлары депутаты. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пластичность и резание металлов. М., 1994 (автордаш); Размерное и безразмерное формообразование сложнопрофильных поверхностей. М., 1996 (автордаш); «Мои 65 ...». К., 2003.

*Әд.:* Ф р о л о в а Л. Помнить о прошлом, думать о настоящем и работать для будущего: Казанскому моторостроительному — 70 лет. К., 2001.

**ПА́ВЛОВ** Алексей Степанович (1832, Томск губ. — 16.8.1898, Мәскәү), хокук белгече, чыганакларны өйрәнүче галим, кануни хокук д-ры (1869), яшерен советник (1892). Руханилар нәселеннән. Казан руханилар академиясен тәмамлый (1858); 1859–64 елларда шунда ук эшли. 1864–65 тә Казан ун-тының кануни хокук каф. доценты, 1867–70 тә экстраординар профессоры, 1870–75 тә Новороссийск ун-тының (Одесса ш.) шул ук исемдәге кафедрасының ординар профессоры. 1875–84 тә Мәскәү ун-тының кануни хокук каф. ординар профессоры, 1884 тән атказ.



Г.Р. Павлов.

профессоры. Бер үк вакытта, 1881 дән, Халык мәгарифе министрлыгының Археография комиссиясе әгъзасы. П. дини хокукны хокук фәненең бер өлеше дип саный. Борынгы рус язуы тарихына багышланган «XVI йөздә рус рухани язуының земствога караган өлеше» («Земское направление русской духовной письменности в XVI веке», 1863), «Латинчыларга каршы борынгы грек-рус бәхәсләре тарихы буенча тәнкыйди тәҗрибәләр» («Критические опыты по истории древнейшей греко-русской полемики против латинян», СПб., 1878) хезмәтләре авторы. «Россиядә чиркәү җирләрен секуляризацияләү турында тарихи очерк» («Исторический очерк секуляризации церковных земель в России», Од., 1871) монографиясендә П. 16 йөздә дәүләт тарафыннан Рус чиркәвенең милек хокуклары бозылуын анализлый; «Олы догалыктагы Номоканон. Аның тарихы һәм текстлары» («Номоканон при большом требнике. Его истории и тексты», Од., 1872; 2 изд., М., 1897), «Рус никах хокукының тарихи һәм гамәли чыганагы буларак, Баш китапның 50 нче бүлеге» («50-я глава Кормчей книги, как исторический и практический источник русского брачного права», М., 1887), «Чиркәү хокукы курсы» («Курс церковного права», М., 1902) хезмәтләрендә Россиядәге кануни (дини) хокукның гомуми догмалар системасын булдыру омтылышы ясый. Үзе тарафыннан Казан руханилар академиясе китапханәсендә табылган, Россиянең урта гасырлар тарихына караган чыганакларны, ш.и. «Кенәз А.М.Курбскийның өч хаты»н («Три послания князя А.М.Курбского», 1863) бастырып чыгара.

Х е з м.: Сборник неизданных памятников византийского церковного права. СПб., 1898.

*Әд.:* С у в о р о в Н.С. Памяти А.С.Павлова // Византийский временник. 1898. Т. 5; К р а с н о ж ё н М.Е. Профессор Алексей Степанович Павлов: Его биография и учёно-литературная деятельность. Юрьев, 1909.

*Е.Б.Долгов.*

**ПА́ВЛОВ** Борис Петрович (29.11.1949, Арча штп.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. канд. (1999), ТРның, РФнең атказ. икътисадчысы (1997, 2000). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1979). 1968–78 елларда Дәүләт гамәли оптика ин-тында (Казан). 1978–80 дә Автомобиль транспорты б-н автоматлаштырылган идарә итү системалары фәнни-тикшеренү проектлау институтында (Казан) инженер, лаб. мөдире, бюро мөдире. 1980–90 да Статистика буенча СССР дәүләт ком-ты Идел-Вятка ф-лының Бөтенсоюз стат. мәгълүмат фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында бүлек мөдире урынбасары, баш проект конструкторы, баш проект инженеры, бүлек мөдире. 1990–93 тә Казан хакимияте икътисад һәм сәнәгать ком-тының бүлек мөдире, 1993–2001 дә — рәисе. 2001–05 тә ТР Икътисад һәм сәнәгать министрлыгының икътисад һәм сәнәгать ком-ты рәисе. 2005–10 да ТР Премьер-министрының 1 нче урынбасары, бер үк вакытта, 2005–07 дә, ТР икътисад һәм сәнәгать министры, 2005 тә ТР Сәнәгать пр-тиеләре ассоциациясе президенты. 2010–13 тә «Газпромбанк» ААҖнең Казан ф-лы вице-президенты—управляющие, 2013 тән «Газпромбанк» ААҖ вице-президенты (Мәскәү). Хезмәтләре сәнәгать пр-тиеләренең икътисады, экологик яктан ышанычлылыгы мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

**ПА́ВЛОВ** Валентин Гаврилович (20.6.1932, Мәскәү — 8.8.2007, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1956 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, 1958 дән шунда ук эшли (1956–58 дә М.И.Калинин исем з-дта, Свердловск ш.), махсус матем. (1972–75), аэрогидродинамика (1975–2005) кафедралары мөдире, проф. (2005 тән). Хезмәтләре сыеклыклар һәм газлар механикасы тигезләмәләрен теоретик-төркемләп анализлауга карый. П. бүленгән һәм тупланган параметрлы системаларны оптимальләштерү проблемасын алгебра алымнарын кулланып чишү юлын эшли. А.Н.Туполев исем. Авиация фәнни-техник комплексы (Мәскәү), В.П.Макеев исем. Машиналар төзү КБ (Миасс ш., Чиләбе өлкәсе), «Сокол» Тәҗрибә КБ (Казан) хезмәткәрләре б-н берлектә оборона техникасының яңа үрнәкләрен төзүдә катнаша. СССР ФАнең Казан ф-лы президиумы каршындагы Механика һәм машина төзелеше комиссиясе рәисе (1979–85). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об инвариантности оптимального процесса с распределёнными параметрами // Прикладная математика и механика. 1970. Вып. 4; Системы инвариантные относительно групп преобразований // Кибернетика и вычислительная техника. 1983. Вып. 58.

**ПА́ВЛОВ** Владимир Александрович (11.7.1911, хәзер Владимир өлкәсенең Вязниковский р-ны Ерофеево а. — 13.9.1985, Казан), тренер (авыр атлетика), РСФСРның атказ. тренеры (1960). 1946–70 елларда Казан авиация ин-тында эшли, физик тәрбия каф. мөдире (1959–62). А.П.*Курыновның* беренче тренеры. Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПА́ВЛОВ** Владимир Александрович (26.4.1937, Куйбышев өлкәсенең Кошки а.), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1982), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2003). 1960 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, 1962 дән шунда ук эшли (1960–62 дә — Горький авиация з-дында), очкыч аппаратлар ф-ты деканы (1982–87), очкыч аппаратлар төзү механикасы каф. мөдире (1989 дан). Хезмәтләре очкыч аппаратлар динамикасына һәм ныклыгына карый. П. самолёт канаты һәм вертолёт калагы аэросыгылмалылыгының геом. нәсызыкча матем. модельләре фәнни юнәлешен нигезли. Авиация һәм космос конструкцияләрен (Ту-22М, Ту-154, Су-27, Ил-76, Ан-74, «Буран», Ка-50, «Ансат») исәпләү теориясен һәм алымнарын тәкъдим итә. Вертикаль күтәрелә һәм төшә торган, тавыш тизлегеннән югарырак тизлектә яңа тип самолёт эшли (Брюссель халыкара күргәзмәләрендә алтын һәм көмеш медальләр, 2002, 2006). Газ яисә сыеклык агымында төзелмә җисемнәрнең формасы һәлакәтле үзгәрә торган тирбәнешләр барлыкка килү күренешен ача (РТ ФАнең П.Л.Капица исем. медале, 2004). П. тырышлыгы б-н Казан техник ун-тында яңа — «вертолётлар төзү» белгечлеге ачыла. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Геометрически нелинейная теория расчёта тонких стержней крыльевого профиля // Изв. вузов. Авиац. техника. 1981. № 2; Расчёт управляющих поверхностей самолёта. К., 1984; Динамика и прочность несущего винта. К., 1986 (автордаш); Механика авиаконструкций. К., 1999.

**ПА́ВЛОВ** Григорий Иванович (16.12.1961, Чуаш АССРның Урмар штп.), гамәли акустика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004), проф. (2006). 1984 елда Ракета гаскәрләренең Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесен тәмамлаганнан соң, Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә. 1987 дән Казан югары артиллерия командирлары уч-щесендә, подразделение командиры (1987–91), укыту лаб-ясе башлыгы (1991–94), проф. (2005 тән). Хезмәтләре реактив двигательле очкыч аппаратлар кузгалганда барлыкка килә торган акустик кырларны өйрәнүгә карый. П. старт алучы машиналар тавышының көчен киметү буенча күп кенә чаралар тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә пульсацияле яну принцибы буенча эшли торган сәнәгый җайланмалар уйлап табыла һәм төзелә (алар нефть химиясе тармагында, а.х.нда гамәлгә кертелә, энергия саклаулы технологияләрдә кулланыла, сәнәгать калдыкларын зарарсызландыру б-н бәйле экол. проблемаларны хәл итүгә булыша). Юл-төзелеш җиһазлары булдыру буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре җитәкчесе (термогазодинамик «Шайтан-1» һәм «Шайтан-1М» җайланмалары юллар төзәтү өчен серияләп җитештерүгә кертелә). Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Безопасность жизнедеятельности. М., 2004; Утилизация изношенных шин: экологические аспекты // Экол. вестн. России. 2004. № 3 (автордаш); Перспективные технологии, основанные на камерах пульсирующего горения // Радиотехника. 2005. Т. 6, № 8–9 (автордаш).

**ПА́ВЛОВ** Григорий Родионович (10.2.1920, Казан губ., Казан өязе Керасиново а. — 5.11.1994, Киев), Сов. Союзы Герое (2.10. 1943), генерал-лейтенант (1980). Очучыларның К.Е.Ворошилов исем. 1 нче Чкалов хәрби авиация уч-щесен (Оренбург ш., 1940), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби һава академиясен (Мәскәү өлкәсенең Монино штп, 1949), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. хәрби академиясен

(Мәскәү, 1960) тәмамлый. 1938 елдан Кызыл Армия сафларында. Бөек Ватан сугышында Төньяк-Кавказ, Көньяк-Көнбатыш фронтларында 42 нче гв. авиация истребительләр полкының эскадрилья командиры урынбасары. 1943 нең июненә 378 хәрби очыш ясый, 61 һава сугышында дошманның шәхсән — 11, төркем составында 5 самолётын бәреп төшерә. Сугыш елларында 507 хәрби очыш ясый. Сугыштан соң хезмәтен СССР Хәрби Һава Көчләрендә дәвам итә. 1980 нән отставкада. Ростов-Донда, соңыннан Киевта яши. Ленин ордены, дүрт Кызыл Байрак, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Биектау посёлогында Геройлар аллеясында П. бюсты куелган. Биектау р-ны Чыпчык авылының бер урамына аның исеме бирелгән, мәктәп музеенда П.ка багышланган стенд бар.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПА́ВЛОВ** Дмитрий Васильевич (26.10.1905, С.-Петербург — 17.6.1991, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе, интендантлык хезмәте генерал-лейтенанты (1944). Тышкы сәүдә академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1936). 1924 елдан хакимият-хуҗалык эшендә. 1929–31 дә Ленинград өлкәсе Луга шәһәрендә дәүләт сәүдәсенең округ конторасы мөдире. 1932–34 тә «Лензаготпушнина» Ленинград өлкә конторасы директоры. 1936–38 дә Казан мех ф-касы директоры. 1938–39 да ТАССР сәүдә халык комиссары. 1939–46 да РСФСР сәүдә халык комиссары. Бер үк вакытта, 1941 дән, Дәүләт Оборона Ком-тының Ленинградны һәм Ленинград өлкәсен азык-төлек б-н тәэмин итү буенча вәкаләтле вәкиле, 1942–46 да Кызыл Армияне азык-төлек б-н тәэмин итү Баш идарәсе башлыгы. 1946–48 дә СССР балыкчылык сәнәгате министры урынбасары, 1952–53 тә министры, 1948–49, 1951–52 дә СССР МС каршындагы Азык-төлек сәнәгате бюросы рәисе урынбасары. 1949–51 дә СССР азык-төлек сәнәгате министры. 1953–55 тә СССР сәүдә министрының 1 нче урынбасары, 1955–58 дә сәүдә министры. 1958–72 дә РСФСР сәүдә министры. 1953–61 дә КПСС ҮК әгъзалыгына кандидат. 1938–39 да — ТАССР ЮС, 1938–47 һәм 1959–75 тә РСФСР ЮС депутаты. Өч Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ПА́ВЛОВ** Иван Ульянович (26.11.1893, Херсон губ. Андреевка а. — 11.4.1936), Кызыл Армия командиры. Гатчина хәрби авиамәктәбен (1915), Франциядә 2 авиамәктәп (1916, 1917), М.В.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне (Мәскәү, 1932) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, өлкән унтер-офицер. 1918 елның апреленнән Кызыл Армиядә, Көнчыгыш һәм Көньяк фронтларда 1 нче совет сугышчан истребительләр авиатөркеме командиры. Казанны азат итү сугышларында батырлык күрсәтә (1918). Казан янында беренчеләрдән булып штурм хәрәкәтләрендә истребитель файдалана. 1919 ның гыйнварыннан 8 нче армиянең авиация һәм очышлар башлыгы ярдәмчесе, шул ук елның маеннан — башлыгы (бер үк вакытта — авиатөркем командиры). 1920 нең маеннан Көньяк-Көнбатыш фронтта һава флоты башлыгының авиация буенча ярдәмчесе. Шул ук елның сентябреннән — Көньяк фронтның һава флоты башлыгы. Алга таба Кызыл Армиядә командирлык вазифаларында: Киев, Төньяк Кавказ һәм Мәскәү хәрби округларында авиация башлыгы, Кызыл Армия Хәрби Һава Көчләре инспекторы ярдәмчесе һәм баш инспекторы. Өч Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Гражданской войны. М., 1963.

**ПА́ВЛОВ** Леонид Николаевич (24.4.1932, Казан), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002), РСФСРның атказ. технологы (1990). Казан авиация техникумын тәмамлый (1956). 1956–63, 1965–67 елларда п/я 634 номерлы пр-тиедә (Казан) технолог, цех башлыгы урынбасары, производство башлыгы урынбасары. 1963–65 тә Урта Идел халык хуҗалыгы советының агрегат төзелеше идарәсе җитештерү бүлегендә (Куйбышев ш.) өлкән инженер. 1967–2006 да «Казан вертолёт заводы» АҖдә: баш технолог урынбасары, баш технолог (1971 дән). Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге модернизацияләнгән «МИ-8МВТ-1, МИ-8МВТ-2, МИ-8МВТ-3, МИ-8МВТ-5, МИ-172 вертолётлары һәм аларның модификацияләре гаммасын серияләп җитештерүгә кую» эше өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПА́ВЛОВА** Валентина Михайловна (26.7.1909, Петербург губ. Мурзинка а. — 2.11.1978, Казан), театр эшлеклесе, драма актрисасы, ТАССР, РСФСРның халык артисты (1956, 1970). Түбән шәһәрендә 2 нче баскыч мәктәп тәмамлаганнан соң, Пермь губернасының Шадринск шәһәрендәге драма театры труппасына урнаша (1926). Аннан соң Курган, Чита, Якутск, Красноярск, Благовещенск, Ворошилов (Уссурийск), Владивосток шәһәрләрендәге театрларда эшли. 1945–46 елларда, Кызыл Армия һәм Флот частьларына мәдәни хезмәт күрсәтү максатыннан, Маньчжурия (Кытай) һәм Кореяга командировкага җибәрелә. 1948 дән Казан Зур драма театрында актриса, 1967–75 тә директор; директор вазифасын башкарганда, коллективның иҗади һәм җитештерү эшчәнлеген тотрыкландыруга, репертуарны камилләштерүгә зур өлеш кертә. Театр сәхнәсендә шактый зур рольләр иҗат итә. Алар арасында Анна («Анна Каренина», Л.Н.Толстой романы буенча, 1948), Настя, Татьяна («Тормыш төбендә», «Дошманнар», М.Горький, 1949, 1952), Ольга, Раневская («Өч сеңел», «Чия бакчасы», А.П.Чехов, 1951, 1960), патшабикә Ирина («Фёдор патша», А.К.Толстой, 1955), Элиза Дулитл («Пигмалион», Б.Шоу, 1950) образлары да бар. П. уенында нечкә лиризм, рольнең тышкы күренешенең җентеклелеге эчке катгыйлык, логик эзлеклелек б-н бергә үрелеп бара. П. тарафыннан иҗат ителгән Капитолина («Мәскәүдә таң ата», А.А.Суров, 1951), Бережная («Кояшлы як», С.Е.Голованивский, 1952), Топилина («Йөрәк кичерми», А.В.Софронов, 1954), Прохорова («Ерактагы йолдыз яктысы», А.Б.Чаковский романы буенча, 1964), Ольга Игнатьевна («Тын ярда», Б.Н.Полевой романы буенча) кебек замандашлары образлары тормышчан булулары, характерлар бөтенлеге б-н ышандыра. Актриса М.А.Ульянова образына («Гаилә», И.Ф.Попов, 1952; «Давылга табан», Р.Ф.Ишморат, 1963) ике мәртәбә мөрәҗәгать итә. Бу рольдә ул балаларының карашларын хуплаучы, аларның куркыныч янаган язмышлары өчен бик борчылучы күпкырлы ана образын гәүдәләндерә. П.ның Софья Марковна («Карт», М.Горький, 1956), Филумена («Филумена Мартурано», Э. де Филиппо, 1957), Юстина (Х.Вуолийокиның шул исем. әсәре буенча, 1959) образлары тирән психологизм б-н сугарылган булулары ягыннан аерылып тора. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты.



В.М.Павлова.



В.М.Павлова Ольга рольендә («Өч сеңел», А.П.Чехов).



В.М.Павлова Анна рольендә («Анна Каренина», Л.Н.Толстой романы буенча).

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ПА́ВЛОВА** Мария Филипповна (12.1.1954, Питрәч р-ны Надеждино а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1999), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли, хисаплау математикасы каф. профессоры (2000 елдан). Хезмәтләре матем. физиканың үзенчәлекле нәсызыкча стационар мәсьәләләренә карый. П. чикле градиентлы нәстационар фильтрлану мәсьәләләрен чишүнең аермага нигезләнгән алымнарын; җир өсте һәм җир асты суларының бергә хә-

рәкәтләнүе мәсьәләләрен; икеләтә үзенчәлекле тигезләмәләр һәм вариатив тигезсезлекләр чишелешләрен; туенган һәм туенмаган фильтрланулар кушылган мәсьәләләрнең куелышы төгәллеген тикшерә. Икеләтә үзенчәлекле мәсьәләләр чишелешенең барлыгы һәм бердәнберлеге турындагы теореманы исбатлый.

Х е з м.: Исследование корректности задачи фильтрационной консолидации при неполном насыщении // Дифференциальные уравнения. 1998. Т. 34, № 7; Теорема о единственности решения одной задачи теории совместного движения русловых и подземных вод // Изв. вузов. Математика. 2000. № 11 (автордаш); О существовании слабого решения одной задачи ненасыщенной фильтрационной консолидации // Изв. вузов. Математика. 2001. № 10 (автордаш).

**ПА́ВЛОВА** Ольга Ивановна (18.5.1965, Йошкар-Ола ш.), педагог, биол. фән. (1997), пед. фән. (2005) д-ры, Россиянең атказ. тренеры (җиңел атлетика) (2006). Казан ун-тын (1987), Казан пед. ун-тының физик культура ф-тын (1991) тәмамлый. 1983–2003 елларда Казан пед. ун-тында физик тәрбиянең мед.-биол. нигезләре кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 1998–2012 дә, җиңел атлетика буенча РФ җыелма командасының әйдәп баручы тренеры. 2003 тән «Тренер» ж-лының шеф-редакторы. 2012 дән Казандагы 2013 елгы XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиаданың башкарма дирекциясе ген. директорының спорт буенча киңәшчесе. Югары казанышлар спортының теоретик нигезләре һәм инновацион технологияләре өлкәсендә методик эшләр авторы.

Х е з м.: Методология отбора и прогнозирования результатов в лёгкой атлетике. М., 2003; Современная тренировка юных легкоатлетов. М., 2004.

**ПА́ВЛОВКА** авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 14 кеше (руслар, чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Чирмешән волостенда. 1930 елның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1926 да — 145, 1949 да — 119, 1958 дә — 118, 1970 тә — 114, 1979 да — 84, 1989 да — 45, 2002 дә – 21 кеше.

**ПА́ВЛОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. Династияне нигезләүче **Егор Иванович** (?–?), 2 нче гильдия сәүдәгәр (1808 елдан), Питрәч авылы экономик крәстияннәреннән, күн эшкәртү кәсебен нигезли. Казанның алты тавышлы думасына — гласный (1806), Казан шәһәре магистратына ратман булып сайлана (1807–09). Аның уллары: **Яков Егорович** (1772–1844), 2 нче гильдия сәүдәгәр, сабын кайнату з-ды хуҗасы була, Гостиный дворда күн итекләр б-н сәүдә итә, Ложкиннар картлар йортын нигезләүгә 3 мең сум бирә. **Сергей Егорович** (?–?), 2 нче гильдия сәүдәгәр, атасының күн заводын мирас итеп ала, аны шактый зурайта һәм Казанда иң эре күн җитештерүчеләрнең берсенә әверелә. Аның акчасына (100 мең сум) Адмиралтейство бистәсендә янәшәсендә сәүдәгәр П.Прибытковлар төрбәсе булган Боголюбский чиркәве төзелә. 1830–31 дә вабага каршы көрәшү өчен шактый күләмдә хәйрия бирә. Аның кызы **Екатерина Сергеевна** (1823–97) Казан сәүдәгәре П.А.Прибытковка кияүгә чыга һәм әтисенең эшен дәвам итә.

**ПАВЛО́ВСКИЙ** Евгений Никандрович (29.9.1904, Казан губ. Лаеш ш. — 24.1.1975, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1940), проф. (1941), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1924), Зәй шәһәрендә вет. табибе булып эшли. 1925 елдан Казан вет. ин-тында. 1932 дән терлекләр физиологиясе каф. мөдире. 1932–34 тә сөт хуҗалыгы ин-тында физиол. каф. мөдире, бер үк вакытта кошчылык бүлеге мөдире һәм директор урынбасары. 1934–36 да Казан а.х. ин-тының физиол. каф. мөдире. 1936 дан Казан вет. ин-тында, физиол. каф. мөдире (1965 кә кадәр), бер үк вакытта ректор (1947–63), терлекләр физиологиясе каф. киңәшчесе (1963–75); бер үк вакытта Казан фәнни-тикшеренү вет. ин-ты директоры (1944–47). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: сулыш алу физиологиясен, лизатлар һәм цитотоксиннар тәэсирен, хайваннарның эчке сулыш органнарының функциональ-трофик көйләнешен өйрәнү. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О некоторых механизмах эффекта последствия новокаиновой блокады чревных нервов и симпатических стволов // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1970. Т. 103.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Т.Е.Костина.*

**ПАВЛУ́ХИН** Яков Георгиевич (22.4.1926, Чистай кантоны Черёмухово а. — 26.1.2011, Казан), хирург, сәламәтлек саклау эшлеклесе, РСФСРның атказ. табибе (1967). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Кызыл Армия р-нының Изгар участок хастаханәсендә хирург һәм баш табиб булып эшли. 1951 елдан Яшел Үзән шәһәр хастаханәсе хирургы һәм баш табибе. 1952 дән өлкә сәламәтлек саклау бүлегенең Чистай дәвалау-профилактика секторы башлыгы. 1953 тән Бөгелмә шәһәре сәламәтлек саклау бүлеге мөдире, шәһәр хастаханәсе баш табибе. 1961–87 дә ТАССР сәламәтлек саклау министры урынбасары. 1987 дән Респ-ка сугыш һәм хезмәт ветераннары советы рәисе урынбасары. 1994 тән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының респ-ка мед. китапханә-мәгълүмат үзәге мөхәррире. Хезмәтләре Татарстан медицинасы тарихына карый. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: История медицины Татарстана в лицах. К., 1997; Очерки истории медицины Татарстана (до 1917). К., 2005 (автордаш).

**ПА́ВЛЫЧЕВА** Надежда Константиновна (26.9.1942, Төньяк Осетия АССР Дигорск р-ны Николаевская станицасы), физик, техник фән. д-ры (1997), проф. (1999). 1964 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан оптика-механика з-дының (КОМЗ) Үзәк КБнда эшли. 1974–95 тә ГИПО ФҖБдә, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1991 дән). 1995–98 дә «КОМЗ» АҖдә лаб. башлыгы. 1998 дән Казан техник ун-тының оптика-электрон системалар каф. профессоры. Хезмәтләре спектраль приборлар төзүгә карый. П. классик булмаган дифракцион рәшәткәле спектраль приборларның оптик схемаларын исәпләү алымнарын эшли; ул тәкъдим иткән схемалар нигезендә төзелгән яңа буын оптика приборлары югары оптик характеристикалары һәм конструкцияләренең гадилеге б-н аерылып торалар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Расчёт спектрографа с плоским полем на основе голографической решётки // Оптико-мех. пром-сть. 1979. № 7; Методы расчёта оптических схем дифракционных спектрографов // НПО «Государственный институт прикладной оптики» (1957–1997 гг.). К., 1997. Ч. 2; Спектральные приборы с неклассическими дифракционными решётками. К., 2003; New generation spectrographs // Optical Engineering. 1994. V. 33 (автордаш).

**ПАДЕ́РИН** Валерий Константинович (20.8.1947, Белоруссия ССРның Гродно өлкәсе Вольковыск ш.), философ, филос. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1974 елдан Алабуга пед. ин-тында, филос. каф. мөдире, 1976 дан Казан ун-тында, социол. каф. мөдире, 1987 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында. Хезмәтләре иҗтимагый фикер социологиясенә, сәясәт фәннәренә карый.

Х е з м.: Общественное мнение: сущность и закономерности формирования. К., 1980; Общественное мнение в политической жизни общества. К., 1987; Социология семьи. К., 1999 (автордаш); Социология культуры. К., 2004 (автордаш).

**ПАЗИ́КОВ** Хәбир Мөхәррәм улы (15.10.1896, Оренбург губ., Троицк өязе Кочкар приискы — 22.4.1975, Мәскәү), партия эшлеклесе. Шәрекъ хезмәт ияләре Коммунистик ун-тында (1928–30), Кызыл профессорлар ин-тында укый (Мәскәү, 1935–38). 1910–17 елларда Оренбург губернасы шахталарында атлы эшче, күмер ташучы, казучы. 1917–18 дә — Кызыл гвардиядә. 1918–19 да — Эстәрлетамак шәһәре тегермәнендә йөкче, Златоуст тимер юл станциясендә кара эшче. 1919–26 да Чиләбе, Семипалатинск, Томск губерналары шахталарында казучы. 1926–28 дә ВКП(б)ның Томск, Канск округлары ком-тлары инструкторы. 1930–35 тә ВКП(б)ның Башкортстан АССР Баймак райкомы, Фирганә шәһәр ком-ты, Кыргызстан өлкә ком-ты пропаганда төркеме әгъзасы, җитәкчесе. 1938–42 дә ВКП(б) ҮКның җитәкче партия органнары бүлегенең җаваплы оештыручысы, ВКП(б)ның Көнбатыш Казакъстан, Караганда өлкә ком-тлары 1 нче секретаре. 1942–44 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты 2 нче секретаре. 1944–52 дә ВКП(б)ның Көньяк Казакъстан, Көнчыгыш Казакъстан өлкә ком-тлары 1 нче секретаре. 1953–62 дә РСФСР МС Эшләр идарәсенең персональ пенсияләр бүлеге мөдире. 1937–54 тә СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПАЙМУ́ШИН** Виталий Николаевич (17.3.1947, Чуаш АССРның Комсомольск р-ны Яңа Сундырь а.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1981), ТР ФА академигы (2008; 1992 елдан мөхбир әгъза), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2001). 1972 дә Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, материаллар каршылыгы каф. мөдире (1980 нән), проф. (1985), Динамика һәм ныклык проблемалары фәнни-техник үзәген оештыручы һәм аның директоры (1989 дан). Хезмәтләре деформацияләнүче каты җисем механикасына һәм очкыч аппаратларның ныклыгына карый. П. катлаулы формадагы һәм нәканоник сызылмалы сөрүләр теориясен һәм аларны исәпләү алымнарын, кырый мәсьәләләр чишүнең санлы гибрид һәм санлы аналитик юлларын эшли. Өч- һәм күпкатлы пластиналар, ш.у. сөрүләр теориясенең төгәлрәк вариантларын тәкъдим итә. Квадратик якынчалык б-н сыгылмалылыкның геом.-нәсызыкча теориясенең каршылыксыз вариантын эшли, шуның нигезендә сөрүләр һәм кендекләр теориясенең тиңдәшле тигезләмәләрен төзи. Төрле төрдәге йөкләнешләр вакытында юка сөрүләр һәм кендекләрнең гадәти булмаган тотрыклылык югалту формаларын ачыклый. П. җитәкчелегендә уникаль объектларның (грунтлы массивлардан торучы механик системалар, төзелеш корылмалары) торышын фаразлау өчен инструменталь программа-аппарат чаралары булдырыла. Тикшеренү нәтиҗәләре Казансу күперен реконструкцияләгәндә, Кама елгасы күперен (Саескан Тавы а.), Казан метрополитенын проектлаштырганда файдаланыла. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. ТР ФАнең Х.М.Мөштәри исем. бүләге (1995), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вычислительная геометрия в задачах механики оболочек. М., 1989 (автордаш); Оболочки из стекла. Расчёт напряжённо-деформированного состояния. М., 1993 (автордаш); Основания нелинейной теории оболочек. К., 1996 (автордаш).

**ПАЙЦЗА́** (пайдза, пайза, пайзе), нинди дә булса эш башкару йөкләнгән затларга монгол ханнары тарафыннан бирелгән пластинка. Иясенә юл йөрүдә таныклык булып хезмәт иткән, аның хокукларын һәм вәкаләтләрен раслаган. П.лар алтыннан, көмеш, бронза һәм агачтан эшләнгән; алар язулы һәм язусыз булган. Илл. к. *Басма* мәкаләсендә.

*Әд.:* Б а н з а р о в Д. Пайзе, или металлические дощечки с повелениями монгольских ханов // Зап. С.-Петербургского археол.-нумизмат. об-ва. 1850. Т. 2.

**ПАКЕ́РЛЫ** елгасы, Идел алдында, Кече Чынлы елгасының (Чынлы, Зөя елгалары бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,9 *км*, бассейнының мәйданы 31,5 *км*$^2$. Идел буе калкулыгы буенча Чүпрәле р-нында ага. Елга башы Яңа Чүпрәле авылыннан 4 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Татар Саплыгы авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 133 *м*. Су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми. П.ның 2,6 *км* озынлыктагы бер кушылдыгы бар. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Җәен, яңгырлар озак яумый торганда, елга урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 88 *мм*, ташу вакытында су катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елганың югары агымында су күләме 0,65 млн. *м*$^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ПАКШИ́Н** (Кәкре чишмә) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 23,3 *км*, бассейнының мәйданы 175,5 *км*$^2$. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Рус Пакшины посёлогыннан 5 *км* төньяктарак, тамагы Яңавыл авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. П.ның 1,1 дән 11,3 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар, иң зурлары — Кутушка (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 5–10 *л/с·км*$^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 97 *мм*, ташу агымы катламы 83 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,085 *м*$^3$*/с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

**ПАЛЕО**... (грек. palaiós — борынгы), кушма сүзләрнең борынгы мәгънәсен аңлата торган беренче өлеше (мәс., *палеография*, *палеолит* һ.б.).

**ПАЛЕОБОТА́НИКА** (*палео*... һәм *ботаника*), казылма үсемлекләрне өйрәнүче фән; *палеонтология* бүлеге. Үткән геол. эпохаларның җир катлауларында сакланып калган үсемлек калдыкларын һәм эзләрен өйрәнә. П., үсемлекләр дөньясы үсешенең тарихын ачып, гамәлдә эволюция тәгълиматының нигезен тәшкил итә, шунлыктан үсемлекләр морфологиясе һәм систематикасы өчен аның әһәмияте гаять зур. Җир кабыгының аерым бер катлауларында табылган үсемлек калдыкларын палеоботаник тикшерү алымнары аларның барлыкка килү вакытын чагыштырмача төгәллек б-н билгеләргә мөмкинлек бирә. Казылма үсемлекләр турында беренче мәгълүматлар б.э.к. барлыкка килә. Нигездә, аларның тере үсемлек калдыклары булуын беренче тапкыр Леонардо да Винчи (15 йөз ахыры) аңлата. 19 йөз ахырында П. мөстәкыйль фән буларак нигезләнә һәм француз галиме А.Броньяр исеме б-н бәйле. Россиядә беренче палеоботаник тасвирламалар 1793 елда П.С.*Паллас* тарафыннан ясала. 19 йөз уртасыннан палеоботаникларның төп игътибары Россиядә, ш.у. чит илләрдә дә үсемлек калдыкларын өйрәнүгә һәм төрле эпохалардагы үсемлекләрнең сыйфатын ачыклауга юнәлә.



В.Н. Паймушин.

Татарстанда палеоботаник тикшеренүләргә нигез салучы булып Казан ун-тының ботаника кафедрасы проффессоры В.И.*Баранов* тора, ул исә 1930 еллардан Идел буе, Көньяк Урал, Казакъстан, Себернең кайнозой утырмаларында казылма флораны җыю һәм өйрәнү б-н шөгыльләнә; 1942–59 да СССРның югары акбур, палеоген һәм неоген флоралары буенча күп кенә иллюстрацияле монографияләр басыла. 1950 елларда, макрокалдыкларны (яфрак эзләре, казылма җимеш һәм орлыклар, ташка әйләнгән агачлар) өйрәнү б-н беррәттән, палинологик тикшеренүләр — төрле регионнардагы кайнозой утырмаларында казылма үсемлек серкәләре һәм споралары өйрәнелә башлый (В.И.Баранов, О.Г.Николаева, Н.Ф.Закирова, Л.М.Ятайкин, Л.Н.Михайлова, И.М.Васильева, О.М.Мокшин һ.б.). 1950 елларда В.И.Баранов тарафыннан ботаника кафедрасында палеоботаника музее оештырыла, бирегә яфрак эзләренең, казылма агач, җимеш һәм орлыкларның бай коллекциясе булдырыла. Камышлы һәм Көньяк Уралның палеоген флорасы, Балык Бистәсенең плиоцен флорасы — экспонатлар саны ягыннан иң зурысы. Шушы вакыттан Казан ун-ты студентларына П. курсы укытыла башлый. 1960 еллардан Печора Урал буеның антропоген үсемлекләре тарихы (К.В.Николаева), Татарстан, Чуаш, Мари Респ-каларының плиоцен һәм дүртенчел чор утырмаларына палинологик характеристика (Л.Л.Әүхәдиева), Татарстанда голоцен үсемлекләре тарихы (В.Т.Шаландина), Красноярск краеның көньягындагы тауара казанлыклар шартында палиноспектрлар формалашу үзенчәлекләре (С.А.Сәфәрова) өйрәнелә.

Казан ун-тының оешуыннан башлап, аның геология галимнәре Рус плитәсенең Пермь утырмаларын палеоботаник тикшерә башлый. Кама буе Пермь утырмалары үсемлекләренең җыелмалары Р.И.*Мурчисон*, А.А.*Штукенберг*, П.И.*Кротов*, М.Д.*Залесский* (соңгысы үзенең тикшеренү нәтиҗәләрен «Ангариданың Урал чикләрендәге Пермь флорасы» («Пермская флора Уральских пределов Ангариды», Л., 1927) атласында гомумиләштерә) коллекцияләре аша дөньяда киң танылу алалар. Соңыннан М.Э.Ноинский,

В.А.Чердынцев, Е.И.Тихвинская, В.И.Игнатьев, А.К.Гусев, М.Г.Солодухо, Т.А.Тефанова, А.В.Богов, Н.К.*Есаулова* җыелмалары Казан ун-тының Геология музее коллекциясен Пермь флорасының төрле үрнәкләре б-н шактый баета. Палеофлористика мәсьәләләрен анализлап, С.В.*Мейен*: «Урал буеның Пермь флорасы... аны Ангара палеофлористик өлкәсенең Көнчыгыш-Европа провинциясендәге аерым бер территория сыйфатында карарга мөмкинлек бирә», — дип билгели. Н.К.Есаулованың докторлык диссертациясе Урал-Идел буе югары Пермь флорасына багышланган, биредә исә соңгы Пермь флорасына җентекле характеристика бирелә, флористик комплексларның эволюцион зональ шкаласы эшләнә, дөньяның төрле регионнарында бер үк яшьтәге биеклекләр эзлекле рәвештә өйрәнелә. 1950–70 елларда СССР ФА Казан ф-лының Геол. ин-тында Идел буе һәм Түбән Каманың неоген (Т.А.Кузнецова), девон, карбон (Л.С.Тузова, Л.С.Фомина) палинологиясе һәм стратиграфиясе буенча палеоботаник эшләр үткәрелә. Татарстанда 1950 елларда нефть чыгару башлану сәбәпле, девон, ташкүмер, Пермь утырмалары серкәләре һәм споралары киң өйрәнелә башлый (О.Г.Николаева, Е.А.Блудорова, А.В.Богов).

Археол. тикшеренүләрдә П. алымнары киң кулланыла. 1980 еллардан Казан ун-ты ботаника кафедрасында Биләр шәһәрлеге һәм Казан Кремленең культура катлауларында күмелгән туфракларда палеоботаник тикшеренүләр үткәрелә. Кешенең хуҗалык эшчәнлеге тәэсирендә табигый үсемлек капламының үзгәрүе — 11 йөздән башлап терр-ядә урманнарның киселеп бетүе дәлилләнә (В.Т.Шаландина, В.В.Туганаев, К.В.Николаева һ.б.).

*Әд.:* К р и ш т о ф о в и ч А.Н. Палеоботаника. Л., 1957; Б а р а н о в В.И. Этапы развития флоры и растительности в третичном периоде на территории СССР. М., 1959; К у з н е ц о в а Т.А. Флора верхнеплиоценовых отложений Среднего Поволжья и её стратиграфическое значение // Тр. КФАН. СССР. Сер. геол. наук. 1964. Вып. 10; Я т а й к и н Л.М., Ш а л а н д и н а В.Т. История растительного покрова в районе Нижней Камы с третичного времени до современности. К., 1975; История растительного покрова северной части Среднего Поволжья в плиоцене и антропогене. К., 1980; Б л у д о р о в а Е.А., Н и к о л а е в а К.В. Геологическая и палинологическая характеристика плиоценовых отложений Казанского Поволжья и Прикамья. К., 1986; Е с а у л о в а Н.К. Флора Казанского яруса Прикамья. К., 1986; М е й е н С.В. Основы палеоботаники. М., 1987.

*К.В.Николаева, Б.В.Буров.*

**ПАЛЕОГЕОГРА́ФИЯ** (*палео*... һәм *география*), борынгы геол. чорларның физик-геогр. шартлары турындагы фән; тарихи геол. һәм гомуми физик геогр. бүлеге. П. алымнары матдә составын, тау токымнарының яту шартларын һәм алардагы органик калдыкларны өйрәнүгә нигезләнә. П. фация, *литология, стратиграфия, тектоника, палеонтология*, палеоэкология, *климатология, геохимия* һәм *геофизика* тәгълиматлары б-н тыгыз бәйләнештә. Берничә юнәлештән тора: палеобиогеогр., палеомагнит, палеоэкологик, геохимик һ.б. П.нең төп эше — палеогеографик һәм литологик-фациаль карталар төзү. П. 19 йөз уртасында барлыкка килә, аның нигезендә инглиз геологы Ч.Лайель, Россия галимнәре А.П.Карпинский, Н.И.Андрусов, А.Д.Архангельский хезмәтләре ята.

П.нең үсешенә Казан галимнәре: Н.А.*Головкинский*, А.А.*Штукенберг*, П.И.*Кротов* һ.б. шактый зур өлеш кертәләр. 1920 еллардан Көнчыгыш Рус платформасының югары палеозой утырмалары фацияләре һәм формацияләрен анализлау алымнары (М.Э.*Ноинский*, Е.И.*Тихвинская*, В.И.*Игнатьев* һ.б.) эшләнә. Пермь утырмалары барлыкка килүнең геохимик шартларын тикшерүләр (Б.П.*Кротов*, Л.М.*Миропольский* һ.б.) алып барыла. 1930 еллардан палеогеогр. төзелешләр файдалы казылмаларны эзләүдә зарур алшарт була. 20 йөзнең 2 нче яртысында соңгы чор Пермь утырмаларында палеомагнит тикшеренүләре (В.П.*Боронин*, Б.В.*Буров*, Д.К.*Нургалиев* һ.б.) үткәрелә һәм Идел-Кама төбәгенең плейстоцен климат шартлары ачыклана, дүртенчел (А.П.*Дедков*, О.Н.Малышева, Г.П.*Бутаков* һ.б.), неоген (Н.В.*Кирсанов*, А.А.Сабитов һ.б.), акбур, юра (У.Г.*Дистанов*, С.О.*Зорина*, В.Н.Незимов һ.б.), Пермь (В.И.*Игнатьев*, Е.И.Тихвинская, И.Н.*Тихвинский* һ.б.), ташкүмер һәм девон (И.А.Антропов, Л.С.Тузова, В.Г.*Халымбаджа* һ.б.), кембрийгача чорларның (Е.М.*Аксёнов*, А.Н.Диденко, Л.Ф.Солонцов һ.б.) төрле горизонтларының палеотектоник карталары төзелә. Палеогеографик тикшеренүләр Казан ун-тында, ЦНИИгеолнерудта, «Татнефть» АҖдә алып барыла.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**ПАЛЕОГРА́ФИЯ** (*палео*... һәм *...графия*), тарихи үсештәге борынгы кульъязма ядкәрләрнең тышкы билгеләрен өйрәнүче ярдәмче тарихи фән. Палеографик тикшеренүләр объекты булып язу үрнәкләре (алфавит системасы), аларның язылыш үзенчәлекләре (графика эволюциясе, почерк), язу материалы, язу коралы, бизәлеше (кыр чәчәкләре, язу ахырына куела торган бизәк, орнамент, миниатюралар, инициаллар), буяулар, каралар, филигрань (су билгеләре), тамгалар, штемпельләр, формат, тышлык, күбесенчә 19 йөзгә кадәрге кульъязмаларны раслаучы билгеләр (беркеткечләр, мөһерләр һ.б.) тора. П. бурычлары: текстны хатасыз укып чыгу һәм аның мәгънәсенә төшенү күнекмәләрен булдыру, кульъязманың язылу вакытын, урынын һәм авторын, ш.у. аның төп нөсхә булуын билгеләү. Палеографик ысулның асылы — кульъязманың тышкы билгеләре җыелмасын өйрәнү һәм аларның бер-берсенә, ш.у. җәмгыятьнең билгеле бер чордагы социаль-мәдәни үсеш дәрәҗәсенә (житештерүнең торышына, дәүләт аппаратының эшләү, эш башкару системасы үзенчәлекләренә, идеологик карашларга) туры килүен ачыклау. Кульъязма билгеләрен тикшерү текстны тарихи хронология, метрология, дипломатика, тарихи география, тел тарихы, генеалогия, топонимика, ономастика, кодикология кебек башка ярдәмче тарихи фәннәр, ш.у. чыганакларны өйрәнү гыйлеме б-н бергә алып барылырга тиеш. Кульъязманың датасын күрсәткәндә П.нең төп принцибы — иң соңгы палеографик билгеләрне кую. Алфавит һәм тел системасыннан чыгып, грек, латин, славян-рус, әрмән, грузин, борынгы төрки (уйгыр язулы), төрки-татар (гарәп язулы) һ.б. П. аерып күрсәтелә. Көнчыгыш Европаның борынгы төрки П.сенә караган тикшеренүләр — Я.О.Ярцов, В.В.Радлов, төрки-татар П.се тикшеренүләре В.В.Григорьев, И.Н.Березин, Д.Банзаров, В.Г.Тизенгаузен, Х.Фәезханов, В.В.Вельяминов-Зернов, А.Н.Самойлович, С.Г.Вахитов, В.А.Крачковская хезмәтләрендә яктыртыла. Җучи Олысына караган рәсми актларны палеографик тикшерүгә М.Г.Госманов шактый өлеш кертә. 1970 еллардан Казан ун-тының тарих ф-ты студентларына гарәп язулы татар, ш.у. рус П.се курслары укытыла.

*Д.Г.Мостафина.*

**ПАЛЕОЗО́Й ЭРАТЕ́МАСЫ (Э́РАСЫ)**, п а л е о з о й (*палео*... һәм грек. zōē — яшәү), Җирнең геол. тарихындагы борынгы этапларның берсе. 542±1 млн. ел элек башлана, 290 млн. елдан артык дәвам итә. 6 геол. системаны үз эченә ала, Татарстан терр-ясендә яшьрәк өч утырма: 1,5 тән 3 *км* га кадәр гомуми калынлыктагы девон, ташкүмер һәм Пермь системалары утырмалары билгеле. Палеозой утырмалары 3 *км* га кадәрге тирәнлектә ята һәм урыны б-н җир өстенә чыга. Эра материклар күчешенә бәйле булган планетар масштабтагы күләмендәге көчле тектоник хәрәкәтләр б-н сыйфатлана. Палеозой эрасы дәвамында Европа Көньяк ярымшардан (Австралия киңлекләреннән) Төньякка күчә, һәм ТР терр-ясе хәзерге чор торышыннан 20° көньяктарак, 35° лы киңлектә кала. Эра ахырында Европа Азия б-н кушыла, континентлар чигендә Урал таулары барлыкка килә. Берничә тапкыр диңгезләр киңәя һәм кысыла, континенталь, лагуна һәм диңгез утырмалары, вулканоген жисемнәр, таштоз, гипс, ангидрит һ.б. б-н катнаш кварцлы комнар, алевролит, балчык, известьташлар, эра соңында — кызыл төстәге комлы-балчыклы токымнар утыра. Соңрак палеозой токымнарында нефть, газ, битум, минеральләшкән су барлыкка килә; сазлык утырмалары ташкүмергә әйләнә. Протерозойга караганда палеозойның органик дөньясы шактый төрләнә: сулыкларда умырткасызлар үсеш ала, соңрак — мәрҗәннәр, примитив балыклар, амфибияләр, коры җирдә — бөҗәкләр, сөйрәлүчеләр, беренче җылы канлылар — борынгы имезүчеләр, җир өсте үсемлекләре — псилофитлар, наратбашлар, абагасыманнарның агачка охшаш формалары, эра азагында хәзерге заман абагалары, ылыслылар барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә палеозой утырмалары б-н нефть, битум, ташкүмер, минераль төзелеш материаллары, минераль су чыганаклары һ.б. бәйле.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

**ПАЛЕОЛИ́Т** (*палео*... һәм грек. lithos (таш) сүзләреннән), борынгы таш гасыр; *таш гасырның* ике төп чорының беренчесе. Таш га-

сырны П.ка һәм *неолитка* (яңа таш гасырга) бүлү беренче тапкыр 1865 елда инглиз археологы Дж. Леббок тарафыннан тәкъдим ителә. П. — казылма кеше (палеантроп һ.б.) яшәгән дәвер. Җирнең ул дәвердәге климаты, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы хәзерге шартлардан күпкә аерылган. Борынгы кешеләр кителгән таш кораллар кулланганнар, шомартылган таш кораллар һәм балчык савыт-саба ясый белмәгәннәр. Алар ут табарга өйрәнгәннәр, аучылык һәм азык җыю б-н шөгыльләнгәннәр, кием әзерләгәннәр, тораклар төзегәннәр. Балыкчылык яңа барлыкка килгән, игенчелек һәм терлекчелек кешеләргә әле мәгълүм булмаган.

П.ның башлануы җирдә иң борынгы маймылсыман кешеләрнең барлыкка килүе б-н туры килә (якынча 3 млн. еллар чамасы элек). П. безнең заманнан 12 мең ел элек тәмамланган (П.тан *мезолитка* — П. һәм неолит арасындагы дәвергә күчеш). П. борынгы П. (олдувa дәвере, якынча 3 млн. — 700 мең еллар элек, борынгы ашель — 700–300 мең еллар, урта һәм соңгы ашель — 300–100 мең еллар, мустье дәвере — 100–35 мең еллар элек) һәм соңгы, яки югары П.ка (35–10 мең еллар элек) бүлеп карала. Күп кенә тикшеренүчеләр тарафыннан мустье дәвере аерым чорга — урта П.ка аерып чыгарыла.

Татарстан терр-ясендә беренче кешеләр, фаразланганча, мустье дәверендә килеп чыга. Ихтимал, Урта Идел буендагы иң борынгы таш эшләнмәләр урыннарының берсе — Иделнең уң як ярында *Красная Глинкада* 1953 тә М.З.Паничкина тарафыннан табылган әйберләр (зур чакматаш ярчыклардан ясалган 3 кыргыч, «чопперлар» — очлары кителеп үткенләнгән 2 чуерташ, эшкәртелгән ярчык, аморф нуклеуслар, ш.у. эшкәртелмәгән эре ярчыклар) шул дәвергә карыйлар.





1. Беганчик туктаулыгында табылган трапеция рәвешендәге һәм башка чакматаш ук очлыклары; 2. Сөйке Кичүе туктаулыгында табылган чакматаш трапецияләр.

Охшаш предметлар элеккеге Мысы авылы (Лаеш р-ны) янындагы борында табыла. Татарстан терр-ясендәге мустье чоры табылдыкларына фрагментар сыйфат хас. Куйбышев сусаклагычы ярында, Кама елгасы тамагындагы югары П. туктаулыклары М.Г.Косменко һәм М.Ш.Галимова тарафыннан өйрәнелә. Шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы янында чакматашны яргалау остаханәсе калдыклары сакланган, анда таш кораллар һәм күпләп чакматаш кораллар ясау калдыклары — кисәкләр, ярчыклар, кыйпылчыклар табыла. Таш кораллар арасында кискечләр һәм төрле типтагы нуклеуслар өстенлек итә. Шулай ук төрле кыргычлар, кырыйларын китеп үтмәсләндерелгән пластиналар, очлыклар, өтергесыман, кыргычсыман кораллар очрый. Бу туктаулыктагы чакматаш әйберләрнең үзенчәлеге коралларның еш кына пычаксыман пластиналардан түгел, озын, кыска аморф китек-ярчыклардан эшләнүеннән гыйбарәт. Лобач тавы (шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 1,5–2 *км* ераклыкта) янындагы туктаулыкта 5 нуклеус һәм күпчелек өлеше озын китекләр һәм пластиналардан ясалган 15 чакматаш корал табыла. Рус тигезлегенең югары П. ядкәрләре өчен гадәти кораллар: кыргычлар, кискечләр, пластиналардан эшләнгән очлыклар. Иделнең уң як ярында Долгая Поляна туктаулыгында (Тәтеш р-ны) охшаш типтагы кораллар табыла. Сөйке Кичүе һәм Кама Тамагы торак пунктлары (Кама Тамагы р-ны), Әҗмәр авылы (Спас р-ны) янындагы туктаулыклар югары П.ның соңгы чорына карый. Чакматаш предметлар һәм алар арасында күп күләмдә очрый торган җитештерү калдыклары (китекләр) туктаулыкларның культура катламнарында тупланмалар рәвешендә табылалар (бу тупланмалар чакматаш чимал кисәкләрен — Иделнең сутлы балчыклы һәм известьташлы текә ярларыннан яки ярдагы чуерташлы урыннардан алынган конкрецияләрне һәм эре чуерташларны яргалау б-н шөгыльләнгән аерым осталарның эш урыннары булган). Чакматаш коралларны ахыргача эшләп бетерү өчен, гадәттә, икенчел эшкәртү алымнары — пластинаның кырыен китү яки киртекләү («кискеч китекләре») кулланылган. Коралларның кайбер типлары, мәс., чабу-кисү кораллары (балта, өтерге, кәйләләр) һәм очлыклар (сөңге һәм дротиклар) ясау өчен башта тоташ чакматашны яки эре ярчыкларны ике яклап буйдан-буйга китеп төшергәннәр. Таш кораллар арасында кискечләр, кыргычлар һәм очлары бөгелгән ышкылар өстенлек итә. Кырыйлары чалыш кителгән пластина пычаклар, ш.у. очлыклар һәм тешле-уентыклы эшләнмәләр табыла. Бу коралларның күбесе эре һәм уртача зурлыктагы пластиналардан эшләнгән. Дротиклар һәм укларның таш очлыкларының китеп ясалган өстәмә пластиналары да очрый. Соңгы П. чоры туктаулык-остаханәләре тикшеренүчеләр тарафыннан *Чулман тамагы культурасы* үсешенә башлангыч биргән ядкәрләр буларак карала.

Урта Идел буендагы П. ядкәрләрендә расланырлык торак һәм учак калдыклары табылмый (сөякләр, агач күмерләре һ.б.лар сакланмаган), шул сәбәпле туктаулыкларның абс. яшен билгеләү мөмкин түгел. Урынның рельефын, таш кораллар табылган утырмаларның үзенчәлеген геол. тикшерүләр, утырмаларның спора-серкә анализы палеолитик остаханәләр соңгы Валдай чоры ахырындагы кырыс климат шартларында эшләгәннәр дип фаразларга нигез тудыра. 10 мең еллар элек климат бик тиз җылына башлый — дүртенчел периодның (голоценның) хәзерге этабы, шуның б-н бергә мезолит башлана.

*Әд.:* Паничкина М.З. Разведки палеолита на Средней Волге // Советская археология. 1953. № 18; Косменко М.Г. Основные этапы развития мезолитической культуры в Среднем Поволжье // Советская археология. 1972. № 3; Галимова М.Ш. Итоги раскопок двух мезолитических памятников в устье Камы // Проблемы археологии Среднего Поволжья. К., 1991; шул ук. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье реки Камы. М.–К., 2001.

*М.Ш.Галимова.*

**ПАЛЕОМАГНЕТИ́ЗМ** (*палео...* һәм магнетизм), тау токымнарының Җирнең магнит кыры йогынтысында формалашуы вакытында магнитлану һәм шуннан соңгы чорларда магнитлануны саклау үзлеге. 20 йөз уртасыннан дөньяда палеомагнитик тикшеренүләр даими алып барыла. В.П.*Боронин* җитәкчелегендә 1963 елда Казан ун-тында фәнни-тикшеренү палеомагнит лаб-ясе оештырыла. Тау токымнарының магнетизмын өйрәнү алымнары эшләнә, Пермь һәм триас чорында геомагнит кыры үзгәрешләренең үзенчәлекләре ачыклана, Рус платформасының көнчыгыш өлеше (ш.и. ТР терр-ясе) палеомагнит шкаласы төзелә, Пермь һәм голоценда геомагнит кыры элементлары вариацияләренең характеры, Пермь геомагнит инверсияләрнең үзенчәлеге тикшерелә. Палеомагнитик тикшеренүләр шактый ераклыкка тыныч катламнарга корреляция үткәрергә, токымнар формалашуның фациаль шартларын, ТР терр-ясенең геол. тарихында палеография һәм палеоклиматны ачыкларга мөмкинлек бирә (В.П.Боронин, Б.В.*Буров*, Д.К.*Нургалиев*, П.Г.Ясонов, Л.В.Халепп, Ю.П.Балабанов һ.б.).

*Д.К.Нургалиев.*

**ПАЛЕОНТОЛО́ГИЯ** (*палео...*, грек. ón, И.к. óntos — булган һәм *...логия*), борынгы геол. чорларда яшәгән организмнар (казылма калдыклар, аларның тереклеген чагылдыручы эзләр), аларның вакыт һәм фәзада алышынулары турындагы фән. П. — биол. фәне, әмма геол. белән, аның тарихи геол. һәм *стратиграфия* бүлекләре б-н тыгыз бәйләнештә туа. П.нең төп бүлекчәләре — казылма хайваннарны өйрәнүче палеозоология (умырткасызлар һәм умырткалылар) һәм *палеоботаника*. П. мәгълүматлары барлык палеогеогр. реконструкцияләрдә: файдалы казылмаларны эзләү-разведкалауны фаразлауда, гидротехник корылмалар проектлауда, геол. төшерүдә, геол. истәлекләрне билгеләүдә кулланыла. Француз геологы Ж.Кювье П.гә нигез салучы (18 йөзнең 2 нче яртысы) дип санала. Казанда палеонтологик тикшеренүләрне Н.А.*Головкинский* башлап җибәрә, ул «Ка-

ма-Идел бассейнының үзәк өлешендә Пермь формациясе турында» («О пермской формации в центральной части Камско-Волжского бассейна», 1868) дигән монография авторы, биредә исә беренче тапкыр палеофаунистик тикшеренүләр фацияләрне өйрәнүгә бәйләп алып барыла. А.А.*Штукенберг* палеозой фаунасы коллекцияләрен системалаштыра һәм палеофауна анализы алымын эшли. Ул ташкүмер яшендәге мәрҗәннәрнең һәм мүкчәләрнең 600 дән артык формасын, ш.и. яңа 15 төрен тасвирлый. 19 йөз ахырында П.И.*Кротов* аммоноидалар (башаяклы молюсклар) классификациясен төзи, А.В.*Нечаев* Пермь һәм эоцен яшендәге казылма хайваннарның 300 дән артык төрен җентекләп тикшерә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан ун-ты хезмәткәрләре (М.Э.*Янишевский*, Б.П.*Кротов* һ.б.) тарафыннан Урал, Урал буе, Идел буе һәм Россиянең башка төбәкләренең фаунасы җентекләп өйрәнелә, аерым алганда, Янишевский ташкүмер яшендәге фаунаның 328 төренә (шуларның 60 ы — яңа төр) тасвирлама бирә (1900). «Самара Дугасы: Геологик тикшеренүләр» («Самарская Лука: Геологические исследования», 1913) монографиясендә М.Э.*Ноинский* П.нең төбәк геологиясе б-н тыгыз бәйләнештә булуын исбатлый. Е.И.*Тихвинская* (1924) һәм Н.П.*Герасимов* (1929) Пермь брахиоподаларының (моллюскларының) уннарча яңа төрен тасвирлый. 1935 елда Казан ун-тында П. кафедрасы оештырыла, аның хезмәткәрләре В.А.*Чердынцев*, М.Г.*Солодухо*, И.С.*Муравьёв* һ.б. палеозой стратиграфиясенә палеонтологик нигезләмә бирәләр, ул исә Идел буенда нефть эзләү һәм гидротехника эшләренең (аерым алганда, Куйбышев һ.б. ГЭСлар төзү өчен) куелышы өчен зур әһәмияткә ия була. 1940–50 елларда палеонтологик тикшеренүләр СССР ФАнең Казан ф-лы Геология ин-тында (хәзер ЦНИИгеолнеруд), «Татнефтегазразведка» трестында, Татарстан фәнни-тикшеренү ин-тында башлана, Казан ун-тында (В.И.*Аверьянов,* И.А.Антропов, А.К.Гусев, В.М.Игонин, Ф.Я.Курбанов, В.А.Лукин, В.В.*Силантьев,* В.Г.*Халымбаджа,* С.С.*Эллерн* һ.б.) дәвам итә, биредә стратиграфия максатларында һәм нефть эзләү эшләренең куелышы өчен мәрҗәннәр, моллюсклар, конодонтлар (балык тешләре яки суалчан казналыклары, организмнар терекләгенең фосфатлы эзләре) өйрәнелә. ТР галимнәре Бельгия, Бөекбритания, Һиндстан, Кытай палеозой моллюскларын һәм конодонтларын өйрәнү буенча халыкара программаларда катнашалар. Казан палеонтология мәктәбе традицияләрен П. каф. мөдирләре — А.В.Нечаев (Киев политехника ин-ты), М.Э.Янишевский (Томск ун-ты), Н.А.Герасимов (Пермь ун-ты) һ.б. дәвам итә. Казан ун-тының геол. музеенда ташка әверелгән хайван һәм үсемлекләр коллекциясе, күп кенә казылма хайван төрләре: мамонт скелеты, сыртлан баш сөяге, Англиядән ихтиозавр, Германиядән җир-су хайваннары, АКШтан трилобитлар һ.б. саклана.

*Әд.:* Тихвинская Е.И., Гусев А.К., Солодухо М.Г. Палеонтологическая школа Казанского университета // Отечественная палеонтология за 100 лет. Л., 1977; Всесоюзное палеонтологическое общество: Справ. Л., 1984.

*В.В.Силантьев, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**ПА́ЛЕЦКИЙ** Ф.Д., к. *Фёдор Пёстрый.*

**ПА́ЛИЦЫН** (чын фамилиясе Палице) Иван (Ян) Осипович (17.11.1865, Киев — 3.4.1931, Свердловск ш.), дирижёр, режиссёр, РСФСРның атказ. артисты (1925), Хезмәт Герое (1925). Киев музыка уч-щесен тәмамлый (1889). 1890 елдан Казан һәм бер үк вакытта Саратов театрларында, 1901 дән Киев опера театрында, 1906–13 тә Мәскәүдә Зимин опера театрында, 1924 тән Свердловск опера һәм балет театрында дирижёр; ш.у. Одесса, Харьков, Баку һ.б. шәһәр театрларында эшли. Казанда рус телендә Дж. Вердиның «Дон Карлос», Ж.Массненың «Наваррьянкалар» (1895) операларын куя.


*Әд.:* Боголюбов Н. Полвека на оперной сцене. М., 1957; Кантор Г.М. Музыкальный театр в Казани XIX — начала XX века. К., 1997.

**ПАЛЛА́ДИЙ** (Раев Пётр Иванович) (20.6.1827, Түбән Новгород ш. — 5.12.1898, С.-Петербург), дин эшлеклесе. Түбән Новгород руханилар семинариясен (1848), Казан руханилар академиясен (1852) тәмамлый. 1852–62 елларда Түбән Новгород руханилар семинариясендә эшли (башка предметлар б-н беррәттән, татар теле дә укыта). 1861 дә монахлык кабул итә, 1862 дән архимандрит. 1863–69 да Петербург руханилар семинариясендә, 1864 тән ректор, бер үк вакытта, 1866–68 дә Ладога епископы, Петербург епархиясе викарие. 1869 дан — Вологда һәм Тотьма, 1873 тән — Тамбов, 1876 дан Рязань һәм Зарайск епископы (1881 дән — архиепископы). 1882 дән — Казан һәм Зөя, 1887 дән Карталия һәм Кахетия архиепископы, Грузия экзархы, 1892 дән Петербург һәм Ладога митрополиты, Изге синод әгъзасы. П. үтенече буенча Казан руханилар академиясе корпусларын реконструкцияләү өчен зур күләмдә акча бүленеп бирелә, шуннан соң алар икеләтә зурайтыла.

Хезм.: Слова и речи Палладия, епископа Рязанского и Зарайского. СПб., 1881.

*Әд.:* Липаков Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

**ПАЛЛА́С** (Pallas) Пётр Симон (22.9.1741, Берлин — 8.9.1811, шунда ук), табигыять фәннәре белгече, сәяхәтче, Петербург ФА академигы (1767). Милләте буенча немец; мед. профессоры гаиләсендә туа. 1760 еллар башында Галледа, Геттингенда (Германия), Лейденда (Голландия) укый. 1760 та мед. буенча диссертация яклый. Укуын Англиядә дәвам итә: ботаника һәм зоол. коллекцияләрен өйрәнә. 1763–66 да Голландиядә дипломатик хезмәттә вакытта мед. һәм зоол. буенча фәнни эш б-н шөгыльләнә. Берлинга кайткач, фән дөньясында танылган «Spicilegia zoologika» (т. 1–2, Берлин, 1767–1804) хезмәтен бастыруга әзерли. Тарихи-эволюцион типология тәкъдим итеп, суалчаннарның Линней классификациясенә җитди үзгәрешләр кертә; ул типология, фәндә эволюционизм идеяләре раслангач, хайваннар төрләре систематикасының нигезенә әверелә. П. Лондон король җәмгыяте (1764), Рим академиясе (1766) әгъзасы итеп сайлана. 1767 дә Петербург ФА чакыруы буенча Россиягә килә, *Академия экспедицияләрендә* катнаша. 1768–74 тә Идел буе, Көньяк Урал һәм Себерне комплекслы рәвештә өйрәнү алып барган Оренбург экспедициясен җитәкли (экпедиция маршрутының гомуми озынлыгы 30 мең *км* тәшкил итә; хайваннарның 250 төре тасвирлана). П. экспедиция нәтиҗәләрен «Россия империясенең төрле провинцияләре буенча сәяхәт» («Путешествие по разным провинциям Российской империи», т. 1–3, 1771–76 — немец, 1773–88 — рус, 1802 — инглиз телләрендә) исемле хезмәтендә гомумиләштерә. Экспедиция дөнья һәм Россия фәне (биол., геогр., геол., филол., этнография) үсеше өчен зур фәнни һәм гамәли әһәмияткә ия була; Уралда һәм Себердә гаять зур табигый байлыклар булуы хакында мәгълүматлар алына. 1792 дә П.ны акад. экспедицияләрендә катнашудан читләштерәләр; ул үз акчасына С.-Петербургтан Идел һәм Төньяк Кавказ аша Кырымга һәм Новороссиягә баруны оештыра. П.ның әлеге төбәкләр сәнәгать тарафыннан үзләштерелә башлаганчы алардагы табигатьне, климатны һәм хайваннар дөньясын тасвирлавының әһәмияте хәзерге фән өчен дә кимеми (мәс., ул тасвирлаган кыргый атларның тарпан дигән төре хәзер юкка чыккан). П. тарафыннан хайваннарның, кошлар, үсемлекләр, минералларның (ш.и., Россиядәге иң эре сидеролит — тимер-таш метеорит, яки палласит) яңа төрләре ачыла һәм язма сурәтләнә. Идел буен, Себерне һәм татарларның, башкортларның һәм Идел буенда, Себердә, Кырымда яшәгән башка халыкларның тормыш-көнкүрешен тасвирлавы да фән өчен зур әһәмияткә ия. 1796 да П. Симферополь шәһәренә җибәрелә (монда аңа утар бирелә), анда ул Кырымның көньяк яр буйларын тикшерә. Энциклопедист, зоолог, ботаник, палеонтолог, минеролог, геолог, топограф, географ, табиб, этнолог, археолог, филолог буларак тикшеренүләрен чагылдырган 170 тән артык хезмәт яза. 1810 да ул Берлинга кайта. П. исеме б-н Курил утрауларындагы вулкан, Яңа Гвинея ярлары буендагы риф, Көньяк Уралдагы тау (хәзер Свердловск өлкәсенә керә), шәһәр, атаклы тикшеренүчегә һәйкәл куелган Палласовка тимер юл станциясе (хәзер Волгоград өлкәсендәге район үзәге) атала.



П.С.Паллас.

Хезм.: Описание растений Российского государства, с их изображениями. СПб., 1786; Сравнительные словари всех языков и наречий, собранные десницей Всевысочайшей Особы (императрицей Екатериной II): В 2 т. СПб., 1787–89; Наблюдения, сделанные во время путешествия по южным наместничествам Русского государства в 1793–1794 годах. М., 1999; Merkwürdigkeiten des Morduanen, Kasaken, Kalmüken, Kirgisen, Baschkiren etc. Frankfurt, 1773–77. V. 1–3; Sammlungen historischer Nachrichten über die Mongolischen

Völkerschaften. SPb., 1776–1801. V. 1–2; Flora Rossica. SPb., 1784–88. V. 1–2; Reise durch verschiedene Provinzen des Russischen Reichs in den Jahren 1768–73. SPb., 1871–76. V. 1–3.

*Әд.:* Маракуев В.Н. Пётр Симон Паллас, его жизнь, учёные труды и путешествия. М., 1877; Берг Л.С. Очерки по истории русских географических открытий. М.–Л., 1949; Ефремов Ю.К. П.С.Паллас // Отечественные физико-географы и путешественники. М., 1959; Муравьёв В.Б. Дорогами российских провинций: Путешествия Петра Симона Палласа. М., 1977; Сытин А.К. Пётр Симон Паллас — ботаник. М., 1997.

*И.Л.Измайлов.*

**ПАЛЫГОРСКИ́Т**, су силикатлары төркеменнән балчыксыл минерал. Төрле төсмерле ачык соры төстә. Катылыгы 3; тыгызлыгы 1–2,4. Тышкы билгеләре буенча асбестны («тау җитене») хәтерләтүче озын җепселле һәм микробөртекле ике модификациядә очрый. Коры климатик зона утырмаларында һәм җилләнү кабыгында барлыкка килә. Татарстан терр-ясендә П. чыганаклары Пермь һәм ташкүмер утырмаларында табылган. П. балчыклар а.х.нда, төзелештә, газларны, нефть, майларны чистарту һәм киптерү өчен, бораулау эшләрендә кулланыла.

*Әд.:* Зайнуллин И.И. Палыгорскитовые глины // Неметаллические полезные ископаемые СССР. М., 1984.

**ПА́ЛЬМАЛАР** (Arecales), пальмалар семьялыгыннан күпьеллык үсемлекләр ыругы. Башлыча, агач һәм куаклар, кайвакыт — лианалар. Якынча 3400 төре билгеле. Чыгышы — күбесенчә ике ярымшарның да тропик пояслары. Яфрак формасы буенча П. җилпәзәсыман яфраклыларга — тәбәнәк хамеропс (Chamaerops humilis), кытай ливистонасы (Livistona chinensis) һ.б.; каурыйсыман яфраклыларга — Форстер ховеясы (Howea forcteriana), матур неанта (Neanthe belba), Канар хөрмәсе (Phoenix canariensis), бармаксыман хөрмә яки хөрмә пальмасы (Ph. dactylifera) һ.б.га бүленә. Җилпәзәсыман яфраклыларның яфраклары күпсанлы сегментларга телгәләнгән, караңгы яки соры-яшел төстә, каты, яфрак пластинкасының диаметры 1–1,5 *м* га кадәр. Саплары озын (3 *м* га кадәр), ян-яклары каты чәнечкеле. ТР терр-ясендә П.ның кайбер төрләре декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Каурыйсыман яфраклылар арасында «хөрмә» дип аталучылары киң таралган. Ябык шартларда алар кәүсә хасил итми диярлек, әмма дуга кебек бөгелгән каурыйсыман эре яфраклар хасил итәләр, кайбер төрләренең түбәнге өлеше 2–3 *м* га кадәр биеклектә чәнечкеле энәләргә әверелгән. Хөрмә пальмасын өй шартларында җимеш орлыкларыннан үстерергә була, яхшы тишелсен өчен тышчасын җиңелчә кырырга яки кайнар суда тотып алырга мөмкин.

Барлык П. да, нигездә, орлыктан үрчи, озак үсә. Киңлек яраталар, караңгылыкны җиңел кичерәләр. Су җәен мул, кышын уртача сибелә. Яшь үсемлекләрне ел саен тирән чүлмәкләргә күчереп утырталар.

**ПА́ЛЬМИН** Михаил Архипович (1783, Рязань губ. — 15.3.1852, С.-Петербург), хокук белгече, надворный советник (1822). Рязань руханилар семинариясен (1803), Баш пед. ин-тын (С.-Петербург, 1808) тәмамлый. 1808 елларда Петербург ир балалар гимназиясендә өлкән укытучы. 1820–22 дә Казан ун-тының филос., дипломатика һәм сәяси икътисад кафедраларының экстраординар профессоры, 1822–24 тә профессоры; бер үк вакытта, 1820–22 дә, әхлак-сәясәт бүлеге деканы. 1820–22 дә «Казанский вестник» ж-лын нәшер итү ком-ты әгъзасы. Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий тарафдары, аның кушуы буенча филос., дипломатика һәм сәяси икътисад укыту өчен «Инструкция...» төзи (1822). 1825–32 дә Петербург ун-тының теоретик һәм гамәли филос. каф. профессоры. Инглиз теленнән Э.Боркның «Безнең мәһабәтлек һәм гүзәллек турындагы төшенчәләребезнең килеп чыгышын фәлсәфи тикшерү» («Философское исследование происхождения наших понятий о высоком и прекрасном») дигән хезмәтен тәрҗемә итә (басылмаган).

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**ПАЛЬЦО́ВКА** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 77 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 20 йөз башында нигез салына. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1920 дә — 116, 1926 да — 144, 1938 дә — 60, 1949 да — 57, 1958 дә — 272, 1970 тә — 229, 1979 да — 138, 1989 да — 57, 2002 дә — 96 кеше.

**ПА́ЛЬЧИКОВ** Николай Евграфович (11.3.1838, Уфа губ., Минзәлә өязе Николаевка а. — 25.9.1888, Самара ш.), музыка фольклорчысы, рус халык җырларын җыючы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1862), Николаевка авылында үзенең утарында яши. 1864 елдан рус музыка фольклорын җыя башлый. Фольклорчы Ю.Н.Мельгуновның рус крәстиян хоры җырларының табигате турындагы фикерләрен үстерә. Бер үк көйнең төрле башкаручы-информатор вариантларын соңрак берләштереп, халык иҗаты әсәрләре язуның үзенчәлекле алымнарын эшли. Шуңа күрә П. язмалары шактый дәрәҗәдә дөреслеге б-н аерылып тора. П.ның күпьеллык хезмәтләренең төп нәтиҗәсе — 125 җыр, ш.и. язгы, озын, туй җырлары, мактап җырлау, кыска җырлар, йола җырлары (аларның төп өлеше басылып чыкканчы билгеле булмаган) тупланган «Николаевка авылында язылган крәстиян җырлары» («Крестьянские песни, записанные в селе Николаевке Мензелинского уезда Уфимской губернии», СПб., 1888) җыентыгы була. П.тан соң басылмый калган 100 дән артык җырның язмасын энесе А.Е.Пальчиков системалаштыра.

Әсәр.: О музыкальном записывании русских народных песен с голоса крестьян с. Николаевки Мензелинского уезда // Изв. Имп. Рус. геогр. об-ва, СПб., 1888. Т. 24.

*Әд.:* Пушкина С.И. По следам Николая Евграфовича Пальчикова. М., 1978.



Н.В.Пальчикова.

**ПА́ЛЬЧИКОВА** Надежда Викторовна (якынча 1863, Уфа губ., Минзәлә өязе Николаевка а. — 31.12.1915, Казан), драма актрисасы, педагог. Н.Е.*Пальчиковның* бертуганының кызы. Вокал (җитәкчесе А.С.Аренский) һәм драма сәнгате (җитәкчесе И.В.Самарин) класслары буенча Мәскәү консерваториясен тәмамлый. 1885 елда Казан шәһәр театры сәхнәсендә П.М.*Медведев* труппасында беренче тапкыр чыгыш ясый. Аеруча күренекле рольләре: Медея (А.С.Суворин һәм В.П.Буренинның шул исем. әсәре буенча), Иоанна д'Арк, Мария («Орлеан кызы», «Мария Стюарт», Ф.Шиллер). Түбән Новгород театрында хезмәт куя, Александра театрына (С.-Петербург) чакыру ала. Аннан соң Вильно, Кострома, Вятка, Пермь, Екатеринбург, Иркутск, Әстерхан шәһәрләре театрларында эшли. 1905 тә Казанга кайта һәм Н.И.Собольщиков-Самарин труппасына эшкә урнаша; бер елдан соң сәхнәне калдыра һәм, Казан музыка уч-щесе каршында драма классы ачып, пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә башлый (аны тәмамлаучылар арасында соңрак Казан Зур драма театрында эшләгән, А.И.Баева, К.Н.Яхонтов һ.б. бар). Чукрак-телсезләр өчен Казан уч-щесенә нигез салучыларның берсе. П. ш.у. тәрҗемә эше, балалар әдәбияты нәшер итү б-н шөгыльләнә.

*Әд.:* Благов Ю. «... получил прозвище Казанский». К., 2001; Гольцман С.В. Ф.И.Шаляпин в Казани. К., 2002.

**ПАЛЮ́ТИН** Хафиз Рәхмәтулла улы (3.3.1896, Тамбов губ., Темников өязе Югары Пешлә а. — 13.11.1937, Казан), хакимият эшлеклесе, партия хезмәткәре. Югары юридик курслар тәмамлый (Мәскәү, 1929). 1918–19 елларда Темников өязе Югары Пешлә авыл советы рәисе, БҮБК матбугат агентлыгының Тамбов губернасы Темников шәһәрендәге вәкаләтле вәкиле. 1919–20 дә 1 нче Мәскәү запас полкының башлангыч партия оешмасы секретаре һәм сәяси комиссары, Үзәк мөселман хәрби һәйәтенең сәясәт бүлеге бүлекчәсе башлыгы (Мәскәү). 1920–21 дә РКП(б)ның Мамадыш кантон ком-ты секретаре, 1921–22 дә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Буа Советы кантон башкарма ком-ты рәисе. 1922–24 тә РКП(б)ның Әгерже кантон ком-ты секретаре һәм Эшче, крәстиян, кызылармияче депутатларының Әгерже Советы кантон башкарма ком-ты рәисе.

1924–26 да ТАССР эшче-крәстиян инспекциясе халык комиссары урынбасары. 1926–28 дә ТАССР юстиция халык комиссары һәм ТАССР прокуроры. Казан ун-тында совет төзелеше һәм хокукы ф-тын оештыруда катнаша (1928). 1929–31 дә ТАССР сәүдә халык комиссары урынбасары, шәһәр сәүдә оешмасының Казан бүлекчәсе директоры. 1931–35 тә СССР Тышкы сәүдә халык комис-тының ТАССР буенча вәкиле. 1935 тән ВКП(б)ның Әгерҗе райкомы 1 нче секретаре. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

*Әд.:* З а л я л о в А., Ш а к и р С. Палютин Хафиз Рахматуллович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

*Е.Б.Долгов.*

**«ПА́МЯТЬ–ХӘТЕ́Р»**, к. «Хәтер-Память».

**«ПА́МЯТЬ ЛЕ́НИНА»**, Буа р-нындагы крәстиян хуҗалыклары ассоциациясе. 1994 елда шул ук исемдәге колхоз җирлегендә оештырыла. 2003 тә 4 торак пунктны: Мулланур Вахитов исем., Теңкәш, Кайрев, Алших (үзәк утары) авылларын үз эченә ала; 630 хуҗалыкта 1435 кеше яши (шуларның 262 се а.х. җитештерүендә эшли); а.х. файдалану җирләренең мәйданы 5865 *га* (ш.и. 5413 *га* сөрүлек җирләр), 1570 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 495 сыер), 1458 баш дуңгыз, 95 баш ат исәпләнә; 2 балалар бакчасы, 3 мәктәп, мәдәният сарае, 3 клуб, 4 мед. пункты, 5 кибет, 3 ашханә, профилакторий эшли. Җитештерү объектларына һәм торак йортларга газ кертелгән. 11196 *т* бөртекле ашлык, 7643 *т* шикәр чөгендере, 1680 *т* сөт, 306 *т* тере үлчәмдә ит җитештерелгән. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 47,1 *ц*, шикәр чөгендере — 212 *ц* тәшкил итә, 1 сыердан 3394 *кг* сөт алына. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә 286 *ц* сөт, 52 *ц* ит җитештерелә.

Хуҗалык СССР ВДНХсы күргәзмәләрендә катнаша (1957, 1960, 1962, 1967), СССР ВДНХсы (1965, 1973), ТАССР ВДНХсы (1967, 1968, 1970, 1971, 1973) дипломанты; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1970), СССР ЮС Президиумының Истәлек билгесе (1970), «Югары культуралы игенчелек хуҗалыгы» исеме (1971), ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮК дипломы (1972), СССР А.х. министрлыгы һәм ВЛКСМ ҮКның Истәлек байрагы (1973), РСФСР А.х. министрлыгының Истәлек байрагы (1973), СССР А.х. министрлыгының Мактау грамотасы (1975) б-н бүләкләнә. Хуҗалык эшчеләре дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә лаек була, ш.и. 10 кешегә — ТАССР һәм ТРның атказ. а.х. хезмәткәре, 1 кешегә Соц. Хезмәт Герое дигән мактаулы исемнәр бирелә; 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 8 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 32 кеше медаль (ш.и. 4 кеше — СССР ВДНХсының алтын, 9 кеше — көмеш, 11 кеше бронза медале) б-н бүләкләнә. Җитәкчеләрнең берсе — Соц. Хезмәт Герое Р.Г.*Әхлиуллин* (1960–78, 1988–94). 2004 тә хуҗалык «Татфондбанк»ның «Агросоюз» ҖЧҖ идарә итүче компаниясенең «Нива» ҖЧҖ составына кертелә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ПАНА́ЕВ** Владимир Иванович (17.11.1792, Казан губ. Тәтеш ш. — 2.12.1859, Харьков ш., С.-Петербургта җирләнгән), шагыйрь, мемуарлар язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1811; 1849 дан аның шәрәфле әгъзасы). Казанда Беренче ир балалар гимназиясендә һәм университетта укыган чоры, аерым алганда укытучысы Н.М.*Ибраһимов* турында «Күп якларым белән аңа бурычлымын», — дип истәлекләр язып калдыра. Абыйлары Александр һәм Иван б-н «Аркадские пастушки» (1804) исемле кульязма ж-л, С.Т.Аксаков б-н «Журнал наших занятий» (1806–07) ж-лын чыгара. Аларда Н.М.Карамзинга ияреп язган «идиллик проза», оригиналь һәм тәрҗемә шигырьләр урын ала. Рус әдәбиятын сөючеләрнең Казан җәмгыяте эшчәнлегендә актив катнаша (1847 дән шәрәфле әгъзасы). 1812 нең декабрендә җәмгыятне ачу тантанасында «Александр I гә мәдхия» («Похвальное слово Александру I») укый. 1815 тән С.-Петербургта. Рус әдәбияты тарихына ирекле версификация, табигый хикәяләү, төзек шигъри тел б-н язылган рус идиллияләре авторы буларак кереп кала. Идиллиянең жанр



«В.И.Панаев». Рәссам Шерли. Ташбасма. 19 йөзнең 1 нче яртысы.

буларак төп принципларын «Көтүчеләр, яисә авыл шигърияте турында» («О пастушеской, или сельской поэзии») мәкаләсендә язып калдыра. «Владимир Панаев идиллияләре» («Идиллии Владимира Панаева», СПб., 1820) җыентыгы өчен Петербург ФАнең алтын медале б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Воспоминания // Вестн. Европы. 1867. № 3, 4.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. История Императорского университета за первые сто лет его существования (1804–1904): В 4 т. К., 1902–06; Б у ш к а н е ц Л.Е. Писатель и чиновник // Казань. 1999. № 7/8.

*М.М.Сидорова.*

**ПАНА́ЕВ ТЕА́ТРЫ**, җәйге театр. Зур Лядской (хәзерге М.Горький) урамындагы Панаевлар утары б-н чиктәш булган шәһәр бакчасында урнашкан була. 1880 елларда Л.А.Панаев агач театр, концерт эстрадасы (вокзал), бакча павильоннары төзи. 1886 ның апрелендә шәһәр тамашачысы өчен бакчаны ачу тантанасы Н.В.Гогольнең «Ревизор» ко-



Панаев бакчасындагы җәйге театр бинасы. 20 йөз башы фоторәсеме.

медиясе куела башлауның 50 еллыгын бәйрәм итү көненә туры килә. 1887 дә бакчаны һәм театрны В.Б.Серебряков арендага ала. Ул театр бинасын үзгәртеп төзи (арх. М.Н.Литвинов), аны драма һәм опера тамашалары өчен яраклы итә: 13 рәтле театр залындагы партерда 282 урын; аннан соң аскы һәм өске 2 купон, 2 амфитеатр урнаштырыла. Ложа 2 яруслы була. Театрның барлык бүлмәләре дә электр уты б-н яктыртыла. П.т.нда, нигездә, провинция һәм башкала театрларының гастрольләр б-н йөрүче труппалары чыгыш ясый. Аның сәхнәсендә Г.Н.Федотова, А.Н.Южин, А.П.Ленский, М.Т.Иванов-Козельский, М.В.Дальский, В.Ф.Комиссаржевская, П.Н.Орленев, П.М.Медведев һ.б. уйный, 1887 дә драма труппасында Ф.И.Шаляпинның дебюты була.

Театрда еш кына татар театр труппалары да чыгыш ясый (1920 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе сәяси бүлегенең 13 нче номерлы татар театр труппасы «Бертуган Гасыймовлар» спектаклен күрсәтә). 1924 тә П.т. яна.

*Әд.:* К л ю ч е в с к а я Е.П. Казанские сады прошлого столетия // Татарстан. 1997. № 6; Б л а г о в Ю. «... получил прозвище Казанский». К., 2001; Г о л ь ц м а н С.В. Ф.И.Шаляпин в Казани. К., 2002.

**ПАНА́РИН** Александр Тимофеевич (18.7.1951, Әлмәт р-ны Сөләй а.), геолог-нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТРның атказ. геологы (1993), геол.-минерал. фән. канд. (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Татнефть» АҖнең «Лениногорскнефть», «Нурлатнефть» (1979 елдан баш геолог), «Әлмәтнефть» (1986 дан) нефть-газ чыгару идарәләрендә. 1999 дан «ЛУКОЙЛ» ААҖнең Нефть чыгару идарәсе башлыгы урынбасары, 2006 дан «Газпромнефть» АҖнең Нефть һәм газ чыганакларын эшкәртү департаменты башлыгы. Дәүләт бүләге аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүдә яңа экспресс технологияләр эшләүдә һәм киң күләмдә куллануга кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ПАНА́РИН** Михаил Петрович (21.11.1918, Самара губ., Бөгелмә өязе Кырымсарай а. — декабрь 1943, Украина ССР, Кировоград өлкәсе Знаменка ш.), Сов. Союзы Герое (22.2.1944, үлгәннән соң), гв. старшинасы. Электровоз машинистлары курсын, Бийск финанс уч-щесен (Алтай крае, 1935) тәмам-

лый. Бийск шәһәрендә шахтёр, финанс бүлеге инспекторы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 106 нчы гв. аерым разведка ротасында разведка взводы командиры ярдәмчесе (37 нче армиянең 110 нчы гв. укчы



М.П.Панарин.

дивизиясе). Дала, 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен (1943) барган сугышта катнаша. Куцеволовка авылы (Кировоград өлкәсе Онуфриев р-ны) янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 29 сентябрендә беренчеләрдән булып дошман уты астында П. каршы ярга йөзеп чыгып, дошман гаскәрләре һәм техникасы урнашкан урынны күзәтә; кире кайтканда дошман солдатын әсирлектә ала; 5 октябрьдә аның җитәкчелегендәге разведчиклар төркеме дошман тылына бәреп керә һәм сугыш кораллары складын шартлата. 1943 нең декабрендә Знаменка тимер юлы узелы өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Сарканд шәһәрендәге (Казакъстан) һәм шәһәр тибындагы Краснозёрский посёлогындагы (Новосибирск өлкәсе) урамнарга П. исеме бирелә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПАНАСЮ́К** Михаил Валентинович (10.3.1955, Яшел Үзән ш.), икътисади география белгече, геогр. фән. д-ры (2001), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1977), шунда ук эшли. 2007 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында, дөнья икътисады каф. мөдире (2008–10). 2011 дән Казан ун-тында. Хезмәтләре гамәли информатика, мәгълүмати системалар географиясе, төбәк б-н идарә итү өлкәләренә карый. П. төбәк системаларын анализлау, аларның мониторингы һәм оператив идарә итү буенча күп кенә алымнар һәм матем. модельләр эшли.

Х е з м.: Геоинформационные системы и проблемы управления окружающей средой. К., 1984 (автордаш); Управление экономико-географическими объектами. К., 1989; Управление регионом: территориальный подход. К., 2005.

**ПАНА́У** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1651–54 тән Панау Пүчинкәсе буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никольский чиркәве, 2 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 503,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 291, 1897 дә — 623, 1908 дә — 767, 1920 дә — 802, 1926 да — 765, 1938 дә — 153, 1949 да — 297, 1958 дә — 187, 1970 тә — 157, 1979 да — 182, 1989 да — 120, 2002 дә — 87 кеше.

**ПАНДОРИ́НА** (Pandorina), вольвокслар рәтендәге хәрәкәтчел яшел суүсемнәр ыругы. Төче су үсемлекләре. 2 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади П. (P. morum) бар. Елгаларда, сай сулы күлләрдә һәм буаларда үсә. Колонияләре шар яки эллипс формасында, диаметры 70–150 *мкм*, лайлалы тышча б-н капланган, 2 шәр төкчәле 16 (сирәгрәк 8 яки 32) күзәнәктән тора. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ПА́НИН** Пётр Иванович (14.6.1721, Мәскәү губ., Мещовский өязе Везовна а. — 15.4.1789, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-аншеф (1762), сенатор (1764), граф (1767). Дворяннар нәселеннән. 1735 елда хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1735–39 да, 1768–70 тә рус-төрек, 1741–43 тә рус-швед сугышларында, 1756–63 тә Җидееллык сугышта катнаша. 1764 тән Сенатның 1 нче департаментында. 1770–74 тә — отставкада. Император Екатерина II хөкүмәтенә карата оппозиция лидерларыннан берсе. 1774–75 тә Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге Крәстияннәр кузгалышын бастыруда катнашкан гаскәрләрнең башкомандующие, бер үк вакытта — Казан, Оренбург һәм Түбән Новгород генерал-губернаторы. 1774 нең август-сентябрендә Идел буенда һәм Уралда баш күтәрүчеләр хәрәкәтен бастыруга җитәкчелек итә. П. исәпләүләре буенча, ул җитәкчелек иткән чорда 324 фетнәче үтерелә, 399 кеше камчы б-н суктырылуга һәм колакларын кистерүгә дучар ителә, 7 меңләп кеше башка төрле җәзага тартыла. 1774 нең 2–6 октябрендә Сембер шәһәрендә Е.И.Пугачёвтан сорау ала, аннан соң аны генерал А.В.Суворов сагы астында Мәскәүгә озата. Идел буенда ачлыкны булдырмау максатыннан, П. җирле хакимият органнары б-н берлектә азык-төлеккә бәяләрне контрольдә тота, халык өчен җәмәгать эшләре оештыра, Казан губернасында казна икмәк кибетләре төзетә, Казанда яшәүчеләргә акчалата ярдәм бирдертүгә ирешә. Үзе җитәкләгән Эчке чуалышларны бастыру комиссиясенең эшчәнлеге туктатылу сәбәпле, 1775 тә командующий постыннан китә. Россияне үзгәртеп кору проектлары авторы. Изге Андрей Первозванный ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л е б е д е в П.С. Графы Никита и Пётр Панины. СПб., 1863; А н у ч и н Д. Граф Панин, усмиритель пугачёвщины: Материалы для истории пугачёвского бунта // Рус. вестн. 1869. Т. 80, № 3; Г е й с м а н П.А., Д у б о в с к о й А.Н. Граф Пётр Иванович Панин: Исторический очерк военной и государственнолй деятельности. СПБ., 1897.

*Е.Б.Долгов.*

**ПА́НИН** Фёдор Иванович (4.3.1918, хәзер Рязань өлкәсенең Кече Екатериновка а. — ?), партия эшлеклесе, Щацк а.х. техникумын (1938), Кубань а.х. ин-тын (1959) тәмамлый. 1938–39 елларда Бастановский МТСында участок агрономы (Рязань өлкәсе). 1939–41 дә — хәрби-пехота уч-щесе (Белоруссия ССР, Калинковичи ш.), махсус мәктәп (Мәскәү) курсанты. Бөек Ватан сугышында катнаша: 1941–45 тә 14 нче танк, 1 нче Мәскәү гвардия мотоукчы дивизия, Кызыл Армия бронетанк гаскәрләренең үзйөрешле артиллерия (уку үзәге (Мәскәү) контрразведка бүлекләренең оператив хезмәткәре. 1945–49 да Воронеж, Ладожск (Краснодар крае) МТСларында агроном, өлкән агроном. 1949–60 та Краснодар краенда партия һәм хакимият эшендә: КПССның Ладожск райкомында бүлек мөдире, 2 нче секретарь; КПССның Темиргоевский райкомы 1 нче секретаре, КПССның Краснодар крайкомы а.х. бүлеге мөдире, РСФСР МСның Краснодар крае буенча Совет контроле төркеме җитәкчесе. 1960–67 дә КПСС ҮК а.х. бүлегендә сектор җитәкчесе. 1967–78 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты 2 нче секретаре. 1978–82 дә — КПСС ҮК каршындагы Партия контроле ком-тының җаваплы контролёры. 1967–80 дә ТАССР ЮС, 1970–79 да СССР ЮС депутаты. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПАНИСЛАМИ́ЗМ**, нигезендә барлык мөселманнарның бердәмлеге (милләтенә, яшәү урынына, социаль хәленә бәйсез булган) һәм мөселман халыкларын бердәм теократик дәүләткә (хәлифәт) берләштерү идеясе яткан дини-сәяси идеология. Мөселманнарның тыгыз бердәмлегенә һәм исламны «сафландыру»га омтылу тамырлары тирәндә ята, ләкин төшенчә буларак, П. идеясе 19 йөз ахырында төрек мәгърифәтчесе Н.Кемаль хезмәтләрендә генә формалаша. Европа колонизаторларына каршы көрәштә исламның әүвәлге сафлыгын торгызу өчен барлык мөселманнарның берләшүе кирәк дип санаучы әфган дини һәм сәяси эшлеклесе әл-*Әфгани Җамалетдин* П.ны актив пропагандалау б-н шөгыльләнә. Әл-Әфгани идеяләре күп илләрдәге абруйлы сәясәт эшлеклеләре, илаһиятчеләр, ш.и. М.*Абду* тарафыннан яклау таба. П. идеологлары максатларын тормышка ашыру өчен сәяси көчләр эзләп әле төрек солтанына, әле Иран шаһына мөрәҗәгать итеп карыйлар, бу исә аларның демократия һәм азатлык идеяләреннән әкренләп баш тартуына сәбәп була, шунлыктан 20 йөзнең 1 нче чирегендә үк әлеге хәрәкәт реакцион көчкә әйләнә. П. идеяләрен үзләренә корал итеп алган сәяси көчләр терр. экспансия чарасына керешәләр (мәс., төрек солтаны Габделхәмид II). Һиндстанда П. идеяләре хәлифәлекне торгызу яклылар хәрәкәтендә ачык чагыла. П. яклыларның позицияләре 1924 елда Төркиядә солтанлык бетерелгәннән соң, аларның хәлифәлекне торгызырга омтылышы барып чыкмау нәтиҗәсендә шактый көчсезләнә. Гәрчә П. агым буларак яшәвен дәвам итсә дә, аның йогынтысы кими бара, төрле мөселман илләрендә социаль-сәяси һәм дини-мәдәни үзгәртеп коруны максат итеп куйган, нигез-

дә милләтчелек рухындагы яңа, модернизацияләнгән һәм реформацияләнгән агымнар барлыкка килә. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, П. идеяләре мөселманнарны берләштерүче сәяси программаларга караганда, күбрәк ялкынлы өндәмәләргә якын торалар. Дини һәм сәяси эшлеклеләрне — мөселман бердәмлегенең иң актив тарафдарларын үзләре янына туплаган мөселман оешмаларының төзелүе (Бөтендөнья ислам конгрессы, 1926; Ислам дөньясы лигасы, 1962; Ислам конференциясе оешмасы, 1969) «ислам бердәмлеге» идеясенең гамәли гәүдәләнеше булып тора. Россиянең мөселман зыялылары арасында теократик дәүләт идеясе киң таралмый, мөселманнарны берләштерү омтылышы алар арасында Россия дәүләте чикләрендә яшәүче мөселман халыкларының бердәмлеге буларак кабул ителә. П. идеологиясен шул рәвешчә аңлау мөселманнарның бөтенроссия съездлары документларында чагыла (1905–18). Ләкин патша хөкүмәте һәм Россиянең идарәче даирәләре мөселман халыкларын, беренче чиратта, татарларны П. идеяләрен яклауда даими гаепләләр; шуның б-н бергә, алар П.ны мөселманнарның үзәге Төркия булган бердәм ислам дәүләте төзергә ашкынуы дип түгел, ә бәлки сәяси эшчәнлекләренең активлашуы, дәүләткә куркыныч янаучы сәяси оешмалар тупларга омтылулары дип аңлый. СССРда П. идеяләренә рәсми аңлатма тагын да кискенрәк төс ала. 1921 дә узган ВКП(б)ның 10 нчы съезды П.ны «буржуаз-демократик милләтчелек» чагылышы дип атый; П. идеяләре 1980 елларның уртасына кадәр рәсми тарих фәнендә «феодаллар-байлар реакциясе», «халыкара империализм» һәм «мөселман милләтчелеге» төшенчәләре б-н бәйләп аңлатыла. Совет чорында җәмгыятьне алласызландыру, мөселманнарның сәяси, иҗтимагый, дини оешмаларын тоташтан тыю П. идеяләрен иҗтимагый тормыштан кысрыклап чыгара. Шул ук вакытта, тышкы сәясәттә капиталистик Көнбатыш һәм социалистик лагерьның кара-каршы торуы сәбәпле, совет җитәкчелеге күп кенә ислам илләренә шактый зур сәяси һәм икътисади ярдәм күрсәтә. 1990 еллардан башлап, Россиядә исламның кабат яңару һәм Россиянең иҗтимагый тормышында ислам факторы йогынтысының үсү уңае б-н РФнең тышкы сәясәтендә мөселман дөньясы илләре б-н якынаю курсы алына. 2005 елда РФ, күзәтүче сыйфатында, Ислам конференциясе Оешмасына кабул ителә.

*Әд.:* Смирнов Н.А. Современный ислам. М., 1930; Аршаруни А., Габидуллин Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931; Бартольд В.В. Халиф и султан // Соч. М., 1966. Т. 6; Нафигов Р.М. Общественно-политическая мысль в Поволжье в XIX — начале XX вв. К., 1977; Гордон-Полонская Л.Р. Современный панисламизм и его националистическая сущность. М., 1982.

*Р.М.Мөхәммәтшин.*

**ПАНКРА́ЦИУМ** (Pancratium), амариллисчалар семьялыгыннан суганчалы үсемлекләр ыругы. 14 төре билгеле. Чыгышы — Африка, Евразиянең тропик һәм субтропик пояслары. Яфраклары кыяк, еш кына улаксыман, кышын шиңмиләр. Чәчәкләре вак, хуш исле, тар өлешле чәчәк тирәлекле һәм серкәчләр төбендә тоташучы үзенә бер төрле элпәле таҗдан тора. ТРда декоратив үсемлек буларак матур П. (P. speciosum) киң таралган. Көзен яки кыш башында чәчәк ата. Суганчадан үрчи. Чәчәк атарга 2 ай кала (августта) су сибү туктатыла.

**ПАНО́ВА** Валентина Даниловна (14.6.1930, Мамадыш кантоны Богдановка а.), төзүче инженер, ТАССР, РСФСРның атказ. төзүчесе (1978, 1985). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), «Татнефтепроект» ин-тында эшли. 1956 елдан «Саратовгипрогорсельстрой» проектлаштыру ин-тында. 1958–91 дә «Татаргражданпроект» ин-тында, инженер, проектның баш инженеры, 1 нче архит-ра-планлаштыру остаханәсе башлыгы (1963 тән). Архитекторлар берлеге әгъзасы (1985). 1991 дән «Татинвестгражданпроект» фирмасының баш инженеры. Авторлар төркеме составында П. мөһим объектларны (*Казан циркы* (1967), Казандагы Химиклар мәдәният сарае (1972), ТАССР Рәссамнар берлегенең *Күргәзмәләр залы* (1981), Респ-ка клиник хастаханәсе (1982), КПССның Татарстан өлкә ком-ты бинасы (1983, 2000 дә сүтелә), Респ-ка балалар клиник хастаханәсе (1989), Менделеев, Алабуга шәһәрләрендә җәмәгать биналары һ.б.) проектлаштырганда һәм төзегәндә инженерлык мәсьәләләрен хәл итүдә катнаша. П. җитәкчелегендә Казандагы *Татар гуманитар-педагогика университетының* төп бинасы (хәзер Казан ун-тының Филология һәм сәнгать ин-ты бинасы), ТР Прокуратурасы һәм ТР Арбитраж мәхкәмәсе биналары проектлаштырыла; Казан сәнгать мәктәбе, Бөгелмә рус драма театры биналары һ.б. реконструкцияләнә. П.ның инженерлык иҗаты, архитектур планын ассызыклаган хәлдә, биналар һәм корылмалардагы конструктив чишелешләрнең җыйнаклыгы һәм сакчыллыгы б-н аерылып тора. СССР МС бүләге лауреаты (1972). Медальләр б-н бүләкләнә.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ПАНО́ВАЯ ГОРА́** (Пановка) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 8 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 3 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Петров Починок авылы буларак та телгә алына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 280 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Ключище волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 474, 1897 дә — 367, 1908 дә — 522, 1920 дә — 382, 1926 да — 397, 1938 дә — 331, 1949 да — 303, 1958 дә — 131, 1970 тә — 51, 1979 да — 34, 1989 да — 21, 2002 дә — 4 кеше.

**ПАНО́ВКА** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Бәтке елгасының (Кама елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*, бассейнының мәйданы 49,5 *км²*. Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Яңа Пүчинкә авылыннан 3,3 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Иске Арыш авылыннан 6 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. П.ның 0,2 дән 5,4 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км²*. Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегу б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 177 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. П. ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м³/с*. Суы язын каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада суның күләме 0,51 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ПАНО́ВКА**, к. *Пановая Гора, Теләче р-ны.*

**ПАНО́ВКА** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 42 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Шигалки, Гурьевка исемнәре б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында башлангыч мәктәп (1890 да ачыла), 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 511 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Николо-Пичкас волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алексеев, 1935 нең 10 февраленнән — Спас, 1935 нең 1 апреленнән — Куйбышев, 1960 тан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 202, 1897 дә — 335, 1908 дә — 354, 1920 дә — 362, 1926 да — 230, 1958 дә — 163, 1970 тә — 124, 1979 да — 95, 1989 да — 46, 2002 дә — 58 кеше.

**ПАНО́ВКА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Киндерле елгасы буенда. 2010 елда 277 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 77%, татарлар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп. 16 йөзнең 2 нче яртысында татар авылы буларак нигез салына. Беренче атамасы — Борнаш. 17 йөз

уртасына даими яшәүчеләр калмый һәм алпавытларга (1780 еллардан — бәк Тенишевларга, 1840 еллардан — алпавыт Мамаевларга) биләмәгә бирелә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский буларак та билгеле. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, сатуга агачтан кабер хачы әзерли, 1880 еллардан Казан суүткәргечендә су җибәрү эшендә эшли. 20 йөз башында Никола чиркәве (1824 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1869 да ачыла), вак кредит оешмасы, тимерчелек, казна яхшы токымлы атлар үрчетү абзары, 1 җәмәгать-кулланучылар һәм 3 вак-төякләр кибете, китапханә-уку бүлмәсе була; 9 майда бер көнлек ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 652 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощак волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл районында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 393, 1897 дә — 706, 1920 дә — 877, 1926 да — 866, 1938 дә — 858, 1949 да — 686, 1958 дә — 521, 1970 тә — 404, 1989 да — 287, 2002 дә — 326 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ПАНО́ВКА** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сеин елгасы буенда. 2010 елда 1611 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 61%, татарлар — 30%) яши. Хезмәт б-н төзәтү учреждениесе. Урта мәктәп, китапханә. 1602–03 тә татар авылы Кече Шигали буларак мәгълүм; 17 йөз уртасына даими яшәүчеләр калмый, биләмәләре рус алпавытларына бирелә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да волость идарәсе урнаша; Никольский һәм Знаменский чиркәүләре, земство мәктәбе (1858 дән эшләп килгән авыл приход мәктәбе җирлегендә 1868 дә ачыла) һәм хастаханәсе, вет.-фельдшерлык пункты, телефон, ашлык саклау-сату кибете, 1 су һәм 2 җил тегермәне, 2 тимерчелек, 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли; шимбә саен базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 705 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волосте үзәге, 1920 дән — ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 141 ир-ат; 1859 да — 288, 1897 дә — 503, 1908 дә — 449, 1920 дә — 572, 1926 да — 473, 1949 да — 341, 1958 дә — 413, 1970 тә — 463, 1979 да — 380, 1989 да — 708, 2002 дә — 1644 кеше.

**«ПАНОРА́МА-ФО́РУМ»**, сәяси журнал. 1995–2000 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Наширләре — Гуманитар проектлар һәм тикшеренүләре үзәге (Казан), Милләтара һәм өлкәара икътисади мәсьәләләрне тикшерү үзәге (Мәскәү). Баш мөхәррире — Р.С.*Хәкимов*. Журналда басылган мәкаләләр Татарстан һәм Россиядәге сәяси процесслар б-н бәйле мәсьәләләргә, иң беренче чиратта федерализм формалашуның теоретик һәм гамәли мәсьәләләренә, милли сәясәт, икътисади стратегия темаларына, ш.у. цивилизацияара йогынтының әһәмиятле аспектларына кагыла. Татарстан һәм татар халкының этносәяси тарихы проблемаларына зур игътибар бирелә.

**ПАНО́РМОВ** Алексей Александрович (4.10.1859, Самара губ. Бөгелмә өязе — 16.1.1927, Казан), биохимик, медицина д-ы (1886). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1882), шунда ук, терапия клиникасы каршындагы факультет терапиясе кафедрасында эшли; 1886 елдан мед.-химия лаб-се ординаторы һәм лаборанты, 1887 дән аерым патология һәм терапия каф. приват-доценты, 1894 тән мед. химиясе каф. профессоры. Хезмәтләре гликоген һәм альбуминнар химиясенә карый.

Х е з м.: О количественном определении гликогена и посмертном образовании сахара в печени // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1886. Т. 16, Вып. 5; О некоторых свойствах альбуминов, находящихся в белке утиных яиц // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1905. Т. 37, вып. 7.

**ПАНТЕЛЕ́ЕВ** Валерий Николаевич (1.7.1950, Азнакай р-ны Сәпәй а.), вице-адмирал (1996). Севастополь югары хәрби диңгез инженерлар уч-щесен (1972), А.А.Гречко исем. Хәрби диңгез академиясен (Ленинград, 1986) тәмамлый. 1972–99 елларда атом су асты көймәләрендә һәм Төньяк флоты частьларында (командующий урынбасары) хезмәт итә. Су асты көймәләрендә хезмәт итү чорында 9 тапкыр ерак походларда катнаша. 2000 нән Росатомның «Радиоактив калдыклар белән эшләүче төньяк федераль предприятие» («СевРАО») Федераль Дәүләт унитар пр-тиесе директоры. Батырлык, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПАНТЕЛЕ́ЕВ** Николай Леонтьевич (1.12.1936, Чаллы р-ны Олы Афанас а.), физик, техник фән. д-ры (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Мәскәү югары техник уч-щесен (1961) һәм Казан авиация ин-тын (1965) тәмамлый. 1961 елдан ГИПО ФЖБдә, әйдәп баручы инженер (1969–72), лаб. башлыгы (1973–81, 1985–87), бүлек башлыгы вазифаларын башкаручы (1981–85), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1987–2003), баш фәнни хезмәткәр (2003 тән). Бер үк вакытта, 1976–79 да һәм 2004 тән, Казан техник ун-тында укыта. Хезмәтләре махсус кулланылыштагы инфракызыл һәм тепловизион техникага карый. П. җитәкчелегендә махсус куллану өчен күп кенә оптик-электрон приборлар, тепловизион техника өчен стенд җиһазлары һәм контроль-үлчәү аппаратлары булдырыла (эшләнмәләре Россия армиясендә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 19 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Самолётные многоспектральные сканирующие системы для дистанционных исследований природных ресурсов и окружающей среды: Аналит. обзор. М., 1979 (автордаш); К вопросу об



В.Н. Пантелеев.

обнаружении, распознавании и идентификации посредством тепловизионного прибора ростовой фигуры человека // Прикладная физика. 2005. № 5 (автордаш).

**ПАНТУРАНИ́ЗМ**, нигезендә Евразия төрки («туран») халыкларының генетик берлеге һәм аларның бердәм дәүләтчелек төзүе турындагы идея яткан иҗтимагый-сәяси идеология. «Туран» атамасының килеп чыгышы борынгы Иранга нисбәтле; аны фарсылар үзләрендә дошман варварлар буларак кабул ителгән төньяк күчмә төркиләр яшәгән җирләргә карата кулланганнар. «Туран» («Турия») төшенчәсе беренче тапкыр, арийларга (Иранның арий халыкларына) карата дошман көчләр туплану үзәге буларак, утка табынучы зороастриялеләрнең изге язмаларында теркәлгән. Күп кенә тикшеренүчеләр фикеренчә, П. идеяләре 19 йөз ахырында Госманлылар империясендә түгел, Россиядә, татар интеллигенциясе арасында, *җәдитчелек* рәвешендә барлыкка килә. П.ны нигезләүчеләр булып А.Агаев, Й.*Акчура*, И.*Гаспринский* һ.б. санала. 1905–07 еллар Рев-циясе йогынтысында П. идеяләре Төркиядә дә тарала (Россиядә реакция башлангач, кайбер татар җәмәгать-сәясәт эшлеклеләре — Й.Акчура һ.б. Төркиягә күчеп китә). Моңа госманлылык идеясенең таркалуы һәм 1908–09 дагы яшь төрекләр рев-циясе юл ача. Рев-ция нәтиҗәсендә хакимият алмашыну төрек интеллигентларын һәм җәмәгать-сәясәт эшлеклеләрен Госманлылар империясе өчен яңа идеологик нигезләр эзләүгә этәрә. 1911 дә төрек шагыйре Зыя Гөкальп «Туран» шигырендә беренче тапкыр төрки халыкларга берләшү өндәмәсе б-н мөрәҗәгать итә («Төркиләрнең ватаны Төркия дә, Төркестан да түгел, аларның ватаны — иркен һәм мәңгелек ил — Туран»). З.Гөкальп төрки халыкларның исламгача тарихын идеальләштерә, аларны борынгы тамырларына кайтырга, телне гарәп һәм фарсы сүзләреннән чистартырга чакыра. Төркиләрне туплау өчен иң мөһим фактор дип ул расачыл, антропологик яки этник сыйфатларны түгел, телне саный. «Туран» төшенчәсе тора-бара яшь төрекләр карашындагы төп этносәяси юнәлешләрнең берсенә әверелә. П. тарафдарлары актив пропаганда эшчәнлеге җәелдерәләр: төрек язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Х.Адивар — «Яңа Туран» романын, А.Тевфик «Туранчы көндәлеге» мәкаләләрен бастыра. Беренче бөтендөнья сугышы елларында пантуранистларның «Туран» дәүләтен төзү хәрәкәте аеруча активлаша; алар бу проектны Европаның алдынгы державалары хуплавына өметләнәләр. Әмма кемальче-

ләр рев-циясе (1918–23) җиңүе һәм М.Кемальнең сәяси хакимияте ныгуы нәтиҗәсендә Төркиядә П.га алмашка төрек милләтчелеге (төрекчелек) идеологиясе килә, туранчылык зарарлы концепция дип таныла; пантуранистларны һәм аларның басмаларын эзәрлекләү башлана. Бер үк вакытта Төркиядә панисламизмга, гарәп этномәдәни йогынтысына каршы (гарәп графикасына нигезләнгән төрек язуыннан латин алфавитына күчү, төрек әдәби телен гарәп һәм фарсы сүзләреннән чистарту һ.б.) һәм милли азчылыкларны: гарәпләрне, грекларны, көрдләрне, татарларны һ.б.ны «төрекләштерү» буенча киң колачлы сәясәт уздырыла. Бу чорда П. идеологлары — яшь төрекләр оппозициягә күчәргә мәҗбүр булалар. П. идеяләре ш.у. Венгриядә дә билгеле бер үсеш кичерә, анда Туран җәмгыяте эшли, «Туран» ж-лы чыгарыла (1913–70). Танылган венгр тюркологы А.Вамбери П. идеяләрен актив пропагандалый. Икенче бөтендөнья сугышы башында Германиянең күп кенә рәсми актларында, газета һәм журнал битләрендә кабат «Туран», «П.» атамалары урын ала. Германия Тышкы эшләр министрлыгында «П.» грифы куелган махсус документлар папкасы ачыла, әлеге мәсьәләләр б-н шөгыльләнүче дипломат билгеләнә. Германиянең Төркиядәге илчелеге даими рәвештә ул илдә П. хәрәкәтенең үсеш перспективалары хакында хәбәр итә.

Тарихи әдәбиятта, гадәттә, П. дип барлык төрки халыкларның, ш.у. венгрлар, эстоннар һәм финнарның сәяси, мәдәни һәм этник бердәмлеге хәрәкәтен яки идеясен атыйлар. Әмма фин-угор халыклары арасында (венгрлардан гайре) П. идеяләре киң таралмый. Хәзергәчә фәндә «П.» һәм «*пантюркизм*» төшенчәләренең тәмам расланган билгеләмәләре юк. «П.» атамасы, төрки халыклар тупланып яшәгән терр-яне генә күздә тоткан «пантюркизм» атамасына караганда, киңрәк мәгънәгә ия. Мәс., А.Агаев «туран дөньясы»на Балкан ярымутравын, Кече Азияне, Кырым ярымутравын, Әзәрбайҗанны, Дагстанны, Идел буе һәм Урал алдын (Әстерхан, Саратов, Самара, Казан, Уфа, Оренбург һ.б.), Себерне, Монголияне, Кытай Төркестанын, Урта Азияне (Бохара, Хива, Хорасан һ.б.), Иранны кертә. Төрек П.ы «туран халыклары»ның төрки төркеме яшәгән терр-я б-н чикләнә, бу терр-ягә Себер, Үзәк Азия, Идел буе, Кара диңгез төбәге, Иран һәм элеккеге Госманлылар империясе төркиләре керә. 1920 елларда СССР милләтчеләре тарафыннан Туран дәүләтенең берничә проекты тәкъдим ителә (шуларның өчесе мәгълүм, берсе дә гамәлгә ашырылмый). Шәрекътәге милли респ-каларның сәясәт эшлеклеләре алга сөргән «Төрки халыкларның социаль-сәяси, икътисади һәм мәдәни үсеше нигезләре турындагы фикерләр» проектында «Туран дәүләте»нә Урта Азиянең төрки телле респ-калары, ш.у. Татарстан һәм Башкортстан АССРлар кертелә. 20–21 йөзләр чигендә дини уртаклыкка, тел һәм мәдәният якынлыгына таянган, панэтник теләктәшлек рәвешендә һәм яшерен хәлдә хөкем сөргән П. идеяләренең тарафдарлары барлыкка килә. 1992 дә Әнкарада рәсми очрашу вакытында Төркия, Әзәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан һәм Кыргызстан җитәкчеләре уртак декларациядә икътисад, сәясәт һәм мәдәният өлкәсендә халыкара эшчәнлекне үзара килештереп алып барырга омтылуларын белдерәләр. СССР таркалганнан соң Россиядәге төрки халыклар (татарлар, башкортлар һ.б.), этник һәм этнодини милләтчелекнең көчле йогынтысында, үзләренең этносәяси һәм этномәдәни хокукларын һәм мәнфәгатьләрен киңәйтү хакына күтәрелгән көрәш чорын узалар (к. *Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация*).

*Әд.:* Мандельштам А.Н. Турция и пантуранизм. Париж, 1930; Аршаруни А., Габидуллин Х. Очерки панисламизма и пантюркизма в России. М., 1931.

*Р.Г.Хәйретдинов, Д.Р.Хәйретдинова.*

**ПАНТЮРКИ́ЗМ** (тюркизм), төрки халыкларның берлеген ныгытуга һәм хезмәттәшлекне киңәйтүгә юнәлгән, этник уртаклыкны, телләр кардәшлеген һәм мәдәниятләрнең якынлыгын тануга нигезләнгән иҗтимагый-сәяси идеология. 19 йөз ахырында үзләренең икътисади, сәяси һәм этномәдәни мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны максат итеп куйган Россия империясендәге мөселман халыкларының хокукларын кысучы патша хөкүмәте сәясәтенә реакция буларак барлыкка килә. П. идеяләрен беренче булып «*Тәрҗеман*» г-тасы чагылдыра. Аның нашире һәм идеологы И.*Гаспринский* мәдәни-мәгърифәтчелек юнәлешендәге П.га нигез салучы булып тора. Ул гомумтөрки тел, яңа ысуллы мәгариф системасы (к. «*Җәдитчелек*»), төркиләрнең басма нәшрияты булдыруны П.ның төп максаты дип саный. П.ның сәяси идеяләре төрки халыкларның сәяси берлеген (үзәге Төркиядә урнашкан) төзергә чакырган Й.*Акчура* хезмәтләрендә үсеш ала. Татар милли-демократик хәрәкәтендә П. киң мәгънәдә милли үзбилгеләнүгә ирешүдә, милли мәдәният һәм үзаң үсешендә, тугандаш төрки халыкларның якынаюында төп ысул буларак кабул ителә. Патша Россиясендә П. законнан тыш дип игълан ителә, аның тарафдарлары хөкүмәт тарафыннан эзәрлекләнә. 1920 елларда П. идеологиясе төрек журналисты һәм социологы Зыя Гөкалып хезмәтләрендә билгеле бер үсеш ала һәм кемальчеләр Төркиясе сәясәтенең нигезенә әверелә.

Россиядә төрки бердәмлек идеяләре 1990 елларда, СССР таркалгач һәм сәяси аренада яңа бәйсез төрки дәүләтләр барлыкка килгәч яңарыш ала. 1992 нең октябрендә Әнкарада төрки дәүләтләр (Төркия, Әзәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан) тарафыннан үзара хезмәттәшлек турында Декларациягә кул куела. 1993–2007 дә төрки дәүләтләр һәм халыклар дуслыгының һәм хезмәттәшлегенең 11 съезды була (10 сы — Төркиядә, 1 се 2007 дә Әзәрбайҗанда уза). Соңгы ике съездда Төркия премьер-министры Рәҗәп Эрдоган Төрки дәүләтләр бергәлеген (ТДБ), ТДБның Аксакаллар шурасын төзергә, төрки дәүләтләрдәге урта мәктәпләр өчен төрки дөнья тарихы буенча гомуми үрнәк дәреслек бастырырга тәкъдим итә. Төрки дөньяның интеграцияләшүе өлкәсендә дәүләт структуралары б-н беррәттән төрки халыкларның иҗтимагый оешмалары да эшли. 1990–2007 дә Бөтендөнья төрки халыклар ассамблеясенең (БТХА) 5 корылтае уза, 1 нчесе 1990 да Мәскәүдә (чакырылышның башлап йөрүчесе — казакъ шагыйре О.Сөләйманов), 2 нчесе 1991 дә Казанда, 3 нчесе 1993 тә Чабаксарда, 4 нчесе 1997 дә Измирда (Төркия), 5 нчесе 2007 дә Шымкент шәһәрендә (Казакъстан) үткәрелә. Корылтайларда төрки дәүләтләр һәм халыкларның икътисади, сәяси һәм мәдәни интеграцияләшү идеяләре берләшә, БТХАның 3 программасы кабул ителә. 1 нче программада антиколониализм һәм антиимпериализм, кеше хокуклары, демократия, милли азатлык өчен көрәш юлында төрки бердәмлек идеяләре раслана, төрки халыклар арасында сәяси, иҗтимагый һәм мәдәни багланышлар үсешенең механизмнары тәкъдим ителә. 2 нче программага демократиянең төрки халыклар тарихы һәм мәдәнияте традицияләренә нигезләнгән төрки моделен оештыру кирәклеге турындагы бүлек өстәлә. Төркиләргә үзләрен Көнбатыш һәм гарәп-ислам дөньясының гадәттән тыш йогынтысыннан сакларга, геосәясәттә үзләренең мөстәкыйль рольләрен уйнарга тәкъдим ителә. 3 нче программада төп игътибар төрки телләрнең, фольклорының һәм сәнгатенең байлыгына таянган төрки дөньяның гомуми рухи-дөньяви карашлар нигезләренең яңарышына һәм үсешенә, төрки дөнья б-н багланышлар чарасы буларак, гомуми «анатүрк» телен, яңа иҗтимагый һәм социаль-икътисади үсеш моделе эшләнмәләрен булдыруга юнәлтелә. 20–21 йөзләр чигендә Төркия һәм төрки дәүләтләр һәм БДБ халыклары арасында икътисади, сәяси һәм мәдәни багланышлар ныгый, уртак университетлар, лицейлар, телевизион тапшырулар каналлары эшли, газеталар чыгарыла башлый.

*Әд.:* Акчура Ю. Три вида политики. Каир, 1904; Мухаметдинов Р.Ф. Зарождение и эволюция тюркизма. К., 1996; Тюркский пояс стабильности. Алматы, 2008; Gökalp Ziya. Türkqülüğün esaslari. Ankara, 1923; Francois G. Turk milliyetciliginin kokenleri. Ankara, 1986.

*Р.Ф.Мөхәммәтдинов.*

**ПАНТЮ́ШИН** Феликс Михайлович (7.8.1945, Казан), драма актёры, ТАССРның халык, РФнең атказ. артисты (1986, 1996). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, 1970, И.М.Раевский курсы) тәмамлаганнан соң, Киров (1970–72), Рига (1972–74), Ленинград (В.Ф.Комиссаржевская исем. театр, 1974–75) театрларында эшли. 1975 елдан Казан Зур драма театры артисты. П.ның театр тәнкыйте игътибарын үзенә җәлеп иткән тәүге рольләреннән берсе поляк язучысы Т.Новак повесте буенча куелган «Ничек патша буласың, ничек җәллад буласың?» (1976) спектаклендәге Блаженный Юзек роле була. Анда актёрның масштаблы фикер йөртә алу сәләте, аерым бер кеше характерында тирән фәлсәфи идея б-н сугарылган эпик образны гәүдәләндерә белү осталыгы күренә. П.га хас булганча, характерны гомумиләштерүгә, билгеле бер социаль категориягә хас типик якларны ачып



Ф.М.П а н т ю ш и н Аким Касьянов ролендә («Ак таулар турында төш», В.П.Астафьев әсәре буенча).

күрсәтүгә омтылыш аның Никитин («Яр», Ю.В.Бондарев романы буенча), Мансур («Югалган көн», А.Гыйләҗев), Аким Касьянов («Ак таулар турында төш», В.П.Астафьевның «Патша-балык» хикәяләре буенча), Кинг («Карагыз, кем килгән!», В.К.Арро), Петька Богоматерь («Иван һәм Мадонна», А.И.Кудрявцев) образларында күзәтелә. Парадоксаль сәхнә шартларында табигый яшәеше актёрга М.А.Булгаков әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә Коровьев («Мастер һәм Маргарита», 1989) һәм Рокк («Хәтәр йомыркалар», 1997) кебек истә калырлык, ышандырырлык образлар иҗат итәргә мөмкинлек тудыра. Комедия репертуарында П. рольләре жанр табигатенең төгәл тоемлануы, лирика б-н ирониянең, тормышчан дөреслек б-н хыялда тудырылган театральлекнең бергә үрелеп баруы ягыннан үзенчәлекле: Дон Жуан, Скапен («Дон Жуан», «Скапен хәйләләре», Ж.Б.Мольер), Блез д'Амбрье («Блез», К.Монье) һәм Антонио («Җәмгыять әфәндесе», Дж. Скарначчи, Р.Тарабузи), Кияү («Ачы!», М.М.Зощенко әсәре буенча). П. классик (Тарелкин — «Эш», А.В.Сухово-Кобылин; Незнамов, Ризположенский — «Гаепсездән гаеплеләр», «Банкрот», А.Н.Островский) һәм тарихи (Свердлов — «Большевиклар», Дзержинский — «Алга... алга... алга!», М.Ф.Шатров) драматургиядә дә шактый гына тирән эчтәлекле, зур әһәмияткә ия рольләр иҗат итә. Концерт эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, зур концерт программалары арасында комп. С.Сәйдәшевкә багышланган моноспектакль, муз.-поэтик спектакль «Ave, Maria» (З.*Сөнгатуллина* б-н) һ.б. бар. Кинога төшә («Син генә» — «Только ты», 1973; «Чанита үбүе» — «Поцелуй Чаниты», 1974; «Башка алай эшләмәм» — «Я больше не буду», 1975).



Ф.М.П а н т ю ш и н Свердлов ролендә («Большевиклар», М.Ф.Шатров).

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ПАНФИ́ЛОВ** Алексей Павлович (17.5.1898, Казан — 18.5.1966, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (29.5.1945), танк гаскәрләре генерал-лейтенанты (1944). Югары башлангыч составны камилләштерү курсларын (1926), И.В.Сталин исем. Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясен механикалаштыру һәм моторлаштыру хәрби академиясен (Мәскәү, 1937), СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. хәрби академиясе каршындагы югары академик курсларны (Мәскәү, 1954) тәмамлый. Казан тимер юлында эшли. 1918 елның апреленнән Кызыл Армия сафларында. Гражданнар сугышында, Хасан күле һәм Халхин-Гол елгасы буенда япон милитаристларына каршы сугышта катнаша. 1939 дан Кызыл Армиянең Баш автобронетанк идарәсе башлыгы ярдәмчесе. 1940–41 дә башлык урынбасары, 1941 нең октябреннән Кызыл Армия Генштабының Баш разведка идарәсе башлыгы. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында 3 нче, 5 нче танк армияләре командующие урынбасары, 6 нчы гв., 10 нчы һәм 3 нче гв. танк корпуслары командиры. 2 нче Белоруссия фронты составында П. җитәкчелегендәге 3 нче гв. танк корпусы 1945 нең 25 феврале — 30 мартында Көнчыгыш Померания операциясендә батырлык күрсәтә. Сугышлар б-н 400 *км* дан артык юл үтә, Гдыня һәм Данциг (Польша) шәһәрләре янында 2 нче немец армиясе калдыкларын чолганышка ала һәм тар-мар итә. Сугыштан соң 3 нче танк дивизиясе б-н җитәкчелек итә. 1954 тән Мәскәүдә, Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясе ф-ты башлыгы, СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. хәрби акдемиясендә өлкән укытучы. 1959 дан запаста. Ике Ленин ордены, биш Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Суворов орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПАНФИЛО́ВИЧ** Казимир Брониславович (4.7.1937, Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе Чериков ш.), теплотехник, техник фән. д-ры (1985), проф. (1987). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Пермь шәһәре оборона пр-тиесендә инженер-конструктор булып эшли. 1961 дән Казан технол. ун-тында, электрофизик җайланмаларның вакуум техникасы каф. профессоры. Хезмәтләре каты, сыек матдәләрнең һәм кысылган газларның радиацион һәм оптик үзлекләренә карый. П. металларда җылылык нурланышының — периодик һәм аналог-кушылмаларның аерым класслары (оксидлар, карбидлар, нитридлар) нурланышының икенчел периодик икәнлеген ачыклый. Агымлы вакуум насосларының үзлекләрен тикшерә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Измерение радиационных характеристик веществ при фазовых переходах // Инженерно-физ. журн. 1995. Т. 68, № 2 (автордаш); Тепловое излучение твёрдых оксидов, карбидов и нитридов // Теорет. вопр. теплофизики. 1995. Т. 33, № 1; Зависимость вязкости некоторых органических жидкостей от средней молекулярной массы // Журн. физ. химии. 1997. Т. 71, № 6.



Ф.М.Пантюшин.



А.П.Панфилов.

**ПАПУНИ́ДИ** Константин Христофорович (25.10.1944, Грузия ССР, Тетри-Цкаро р-ны Джиграшени а.), вет. токсиколог-терапевты, вет. фән. д-ры (1985), проф. (1992), ТР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995, 2001), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2003). 1967 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда эшкә калдырыла. 1985–92 дә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшерену ин-тының (ВНИВИ, Казан) токсикология бүлегендә лаб. мөдире; 1992–2005 тә Казан вет. медицинасы академиясенең терапия каф. мөдире, бер үк вакытта (1995–2003) проректор; 2001–03 тә ректор вазифаларын башкара. 2005 тән Терлекләрнең токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы федераль үзәге (элеккеге ВНИВИ) директоры урынбасары. Хезмәтләре а.х. терлекләре, кыйммәтле тиреле җәнлекләр, кошларда токсикозга диагноз кую, авыруны кисәтү һәм дәвалау, хайваннарда матдәләр алмашы бозылу очракларын ачыклау, кисәтү һәм дәвалау чараларына карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013).

Х е з м.: Руководство по защите животных от химического оружия. М., 1975; Практикум по внутренним болезням животных: Учеб. для вузов. М., 2004 (автордаш); Физические методы лечения и профилактики болезней животных: Учеб. пособие. К., 2004 (автордаш).

*Әд.:* Ректоры России. М., 2002; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ПАР**, п а р б а с у ы, тулы бер вегетация чорында яки аның билгеле бер аралыгында, чәчү уздырылмыйча, йомшартылып һәм чүп үләннәреннән арындырып тотыла торган чәчү әйләнеше кыры. Туфракта дым туплау, аның уңдырышлылыгын күтәрү һәм а.х. культураларының уңышын арттыруда, а.х. продукциясенең сыйфатын яхшыртуда нәтиҗәле агротехник чара; гадәти *игенчелек* системасында әһәмиятле чараларның берсе. П. кара П. (көздән сөреп калдырыла) һәм иртә П. (парны яз көне күтәрү), ш.у. биләүле П. һәм чиста П. җирләренә бүленә. Әгәр җәйнең беренче яртысында пар җирендә тиз өлгерә, уҗым культураларын чәчкәнче 3–4 атна элек җыеп алына торган культуралар үстерелсә, ул җир биләүле П. санала; П. җирендә сөреп күмдерелә торган культуралар үстерелсә, ул сидераль П. була. Төп а.х. культурасын чәчүгә кадәр чәчелми торган басу — чиста П. са-

нала. ТР шартларында, кагыйдә буларак, болар — уҗым, бодай, арыш яисә басуларның чисталыгын һәм туфракның югары уңдырышлылыгын таләп итә торган башка (язгыларын кертеп) а.х. культуралары, мәс., шикәр чөгендере, орлыкка калдырылган күпьеллык үләннәр.

Чиста П. калдыру алымын игенчеләр б.э.к. 2–1 меңенче елларда Днепр, Днестр, Ока бассейннарында, Швейцария, Венгрия, Дания терр-яләрендә көзге арыш үстерә башлаган вакыттан куллана башлыйлар. Яткын кысыр җирләр игенчелек системасыннан П. һәм арыш игү системасына күчү Россия дәүләтендә һәм хәзерге Татарстан терр-ясендә (Идел буе Болгар дәүләтендә) 11–12 йөзләргә карый. Сөрелмәгән җирләрнең мәйданы кимү б-н кысыр-яткын җирләр 1 елдан артык ятмый, ягъни күп тапкырлар ялга калдырылган җирләр чиста П.га күчә.

П. басуларында *туфракны комплексны агрохимик культуралаштыру* уздырыла, бу а.х. культуралары чәчү әйләнешендә көзге бодай, арыш h.б. үстерүдә интенсив технологияләр куллану өчен нигез булып тора. П. системасында басулар чүп үләннәрдән нәтиҗәле чистартыла, органик ашламаларның тәэсире арта.

Хәзерге адаптив-ландшафтлы, биологик игенчелек системаларында тирес җитмәгәндә П. басуының уңдырышлылыгын күтәрү максатында, сөреп күмдерү өчен сидераль культуралар (донник, май тормасы, рапс, люпин h.б.) чәчелә.

Татарстан шартларында 19 йөздә һәм 20 йөз башында өч басулы һәм күп басулы чәчү әйләнешенең беренчел элементлары кертелә башлау б-н чиста П. сөрүлек җирләрнең өчтән бер өлешен били. Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү елларында (1930 еллар) игенчелекнең күп басулы һәм үлән басулы чәчү әйләнеше системасы кулланыла башлый һәм чиста П. мәйданы кими, 1940 елда ул дүрттән бер өлешне, 1960 та алтыдан бер өлешне тәшкил итә. 1960 елларда игенчелекнең үлән басулы чәчү әйләнеше системасын гамәлдән чыгару аркасында чиста П. мәйданнары кимүен дәвам итә һәм 1965 тә 78,2 мең *га*, 1980 дә 180,1 мең *га* тәшкил итә. Бу елларда биләүле П. системасы кертелә. Төп пар биләү культуралары — берьеллык үләннәр һәм борчак, аларның мәйданы 883,6 мең *га* (1970). Бу мәйданнарның аз өлеше генә сидераль П.га бирелә. 20–21 йөзләр арасында чиста П.ның роле үсә; аларның мәйданы 2000 дә 487,4 мең *га*, 2006 да — 517,9 мең *га* тәшкил итә, көзге культураларны урып-җыю мәйданнары өлеше 1990 да — 56,5%, 2000 дә — 134,7%, 2006 да — 180,2%, 2012 дә — 109,3% була.

*Әд.:* Краюшкин В.П. Занятые пары в Татарской АССР // Занятые пары — крупный резерв увеличения производства сельскохозяйственной продукции. М., 1960; Прянишников Д.Н. Избр. соч. М., 1965. Т. 3; Воробьёв С.А., Буров Д.М., Туликов А.М. Земледелие. М., 1977; Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

*И.Н.Афанасьев.*

**ПАРАМАГНИ́ТИК КО́МПЛЕКСЛАР**, өлешчә d- яки f- электрон сүрү б-н тутырылган күчеш элементларының парамагнитик химик кушылмалары (координацион кушылмалары) классы. Үз эченә үзәк атомны яки металл ионын (комплекс ясаучы) һәм аның б-н бәйләнгән молекулалар яки ион-лигандаларны ала. Физикада, химия, сәнәгый технология, авыл хуҗалыгында, медицинада (ТМР томография өчен контраст агентлар) киң кулланыла. П.к. өлкәсендәге тикшеренүләр химик төзелешнең хәзерге заман теориясен тудыруда зур роль уйныйлар. Мондый комплексларны өйрәнүнең иң киң таныган алымнарыннан берсе булып *электрон парамагнит резонансы* тора. Казан галимнәре Б.М.Козырев һәм Н.С.Гарифьянов ТМР алымын П.к.ны каты халәттә һәм эремәләрдә, ш.и. тотрыксыз комплексларда, аларны саф килеш аерып алмыйча да куллануга нигез салалар. П.к. эремәләрен тикшерүдә төш магнит релаксациясе (ТМР) алымы нигезләнә (А.И.Ривкинд, А.А.Попель). Күп төшле парамагнит кластерларны (Ю.В.Яблоков), электрохимик юл б-н генерацияләнүче комплексларны (А.В.Ильясов), эремәләрдә һәм полимерлардагы (Г.П.Вишневская), анизотроп эреткечләрдәге (И.В.Овчинников) П.к.ны ЭПР ярдәмендә тикшерүләр, ш.у. эремәләрдә ТМР күренешен өйрәнү (А.В.Захаров, Ю.И.Сальников) үсеш ала. П.к. нигезендә дөньяда беренче магнитлы сыек кристаллар төзегәне һәм тикшергәне өчен РФА КГҮнең Физика-техника ин-ты галимнәре төркеме (И.В.Овчинников, Ю.Г.Галләметдинов, И.Г.Бикчәнтәев, Г.И.Иванова) ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2001).

*И.В.Овчинников.*


**ПАРАМО́НОВ** Егор Иванович (1845, Томск ш. — ?), педагог. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1861), Томск гимназиясендә география укыта. 1869 елдан Пермь губернасының халык уч-щеләре инспекторы, 1871 дән Самара укытучылар семинариясе директоры. 1876–96 да Казан укытучылар ин-ты директоры.

*Әд.:* Троицкий С.М. Историческая записка о Казанском учительском институте за 25 лет его существования. К., 1901; Исхакова Р.Р. Педагогическое образование в Казанской губернии в середине XIX — начале XX веков. К., 2001.

**ПАРАМО́НОВ** Игорь Петрович (24.6.1936, Казан), төзүче-инженер, ТССРның атказ. төзүчесе (1991), Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт бүләге лауреаты (1981). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1959). 1959–85 елларда (бүленеп) Главтатстройның 2 нче төзелеш-монтаж трестында: мастер, 8 нче төзелеш-монтаж идарәсендә прораб, трестның производство бүлеге башлыгы урынбасары (1964–65), 10 нчы төзелеш-монтаж идарәсендә (1966–68), трестта (1971–74) баш инженер, 10 нчы төзелеш-монтаж идарәсе башлыгы (1974–85). Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тының капиталь төзелеш буенча директор урынбасары (1985–95), директор ярдәмчесе (1995–97). 1997–2009 да Казан электромонтаж пр-тиесендә директор урынбасары. П. «Татарстан» кунакханәсен, Казан ун-тының, Казан технол. ун-тының уку корпусларын төзүдә катнаша. Дәүләт бүләге Казанда ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы бинасын проектлаганы һәм төзегәне өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

**ПАРГА́ ӘЙЛӘНҮ́**, матдәләрнең сыек һәм каты агрегат халәтләрдән газсыман халәткә — парга күчүе. Табигатьтә су пары атмосферага су, туфрак, үсемлекләр, боз, кар өслегеннән күтәрелә. П.ә. *һава дымлылыгына* һәм темп-расына, җил тизлегенә, өслек түшәлмәсенең үзенчәлегенә бәйле. ТР терр-ясендә уртача еллык П.ә. күләме 350–390 *мм* га тигез, иң югары уртача айлык күрсәткеч 70–80 *мм* (май–июнь), иң түбәне — 4–5 *мм* (декабрь–февраль). Җәен озак вакыт явым-төшемнәр булмаганда һәм коры җилләр вакытында П.ә. процессы тукталмый һәм *корылык* барлыкка килүгә сәбәп була. Кыр ышыклау урман полосалары, сусаклагыч ярлары буенда туфракны йомшарткан очракта П.ә. кими. Гамәлдәге метеорологик шартларда һәм өслекнең шактый дымлылыгы вакытында иң зур П.ә. мөмкинлеге парга әйләнүчәнлек дип атала. ТР терр-ясендә бу күренешнең уртача еллык күрсәткече, Идел һәм Кама үзәннәренә таба үсә барып, 538–635 *мм* га тигез (к. *Атмосфера күренешләре* мәк. карта).

**ПАРКАНАТЛЫЛА́Р** (Diptera), бөҗәкләр отряды. 100 меңгә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә якынча 6 мең. Гәүдәсенең озынлыгы 0,3–50 *мм.* П.ның үзенчәлекле билгесе — бер пар элпәле канатлары, аларның җепселләре төрле һәм систематикада бу мөһим критерий булып тора. Кайбер паразит формаларда канатлар өлешчә яки тулысы б-н үсеш алмаган. Башлары бик хәрәкәтчел, аваз аппараты чәнчү, чәнчү-кисү яки ялау тибындагы хортумчык, кайвакыт бөтенләй үсеш алмаган. Күкрәк өлеше тыгыз тоташкан 3 бөҗрадан тора. Арткы күкрәкнең арка ягында бызылдавыклар (чукмарсыман органнар) — сизү, юнәлеш һәм тигезлек саклауны тәэмин итүче икенче пар канат гомологлары бар. Корсагы утырма, кайвакыт сабакчалы, күренеп торучы 4–10 сегменттан тора. Аларның соңгылары ата затларда копуляция органына әйләнергә мөмкин, ана бөҗәкләрдә гәүдә эченә тартылучы күкәй салгыч хасил итәләр. Личинкалары суалчансыман, аяксыз, озынча, кайберләрендә баш капсуласы яхшы үскән, кайвакыт бөтенләй үсеш алмаган. Курчаклары өстәмә капламнарсыз яки ялган кузыда (пупарийда). П. соңгы триас чорыннан ук билгеле, бөҗәкләрнең зур һәм күп өйрәнелгән отряды, ул исә өч асотрядка бүленә: озын мыеклылар — Nematocera (мыекча буыннары алтыдан да ким түгел) — *черкиләр, яңгыравык озынборыннар, юешчәләр*; кыска мыеклылар — Brachycera (мыекчалары өч буынлы) — *кигәвеннәр, ктырьлар*, безелдәвек чебеннәр; түгәрәк бөҗралылар — Cyclorrhapha (олы бөҗәк пупарийдан чыкканда, ул түгәрәктәге бөҗра буенча ачыла) — аларга бөтен чебеннәр керә. Күпчелек П.ның җитлекәннәре нектар һәм серкәләр б-н туена




**Парканатлылар** мәкаләсенә. 1. Йөнтәс мыеклы дергун (яңгыравык) (Tendipes plumosus), а – олы зат, б – личинка («мотыль»); 2. Бизгәк озынборыны (Anopheles maculipennis), а – ана зат, б – личинка; 3. Черки (Simulium), а – олы зат, б – личинка; 4. Юешчә (Culicoides pulicfrius); 5. Дрозофила (Drosophila fasciara); 6. Бизәкле безелдәвек чебен (Sherophoria scripta); 7. Гади арысланча чебен (Stratiomyia chamaeleon); 8. Бүлмә чебене (Musca domestica); 9. Усал чебен (Stomoxys calitrans); 10. Соры чебен (Chrysops); 11. Ат канәчкече (Hippobosca equina); 12. Сарык канәчкече (Melophagus ovinus); 13. Тире асты бөгәлчәне (Hypoderma bovis); 14. Вольфарт чебене (Wollfahrtia magnifica); 15. Шөпшәсыман юл чебене (Asilus crabroniformis L.); 16. Личинка ашаучы тахин (Tachina larvarum).

һәм шул рәвешчә үсемлекләрне серкәләндерә.

Күп төрләре канәчкеч, кайберләре — ерткыч (бөҗәкләр б-н туеналар). П. арасында кешедә (*бүлмә чебене*, бизгәк озынборыны, кигәвеннәр һ.б.) һәм хайваннарда (кигәвеннәр, *күзге усал чебен* һ.б.) авыру таратучылар бар. Күп кенә П.ның личинкалары (*озынаяклар*, Гессен чебене һ.б.) — үсемлекләр өчен куркыныч корткычлар. *Вольфарт чебене* личинкалары кеше тукымасында үсеп миаз авыруын («кортлы авыру») китереп чыгара; а.х. хайваннарында паразитлык итүче тире асты һәм ашказаны бөгәлчәннәре терлекчелеккә зыян китерә.

*Әд.:* Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1966; Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1969. Т. 5.

*С.М.Шәфигуллина.*

**ПАРМЕ́ЛИЯ** (Parmelia), пармелиячәләр семьялыгыннан лишайниклар ыругы. 900 гә якын төре билгеле, башлыча тропикларда таралганнар. Татарстан терр-ясендә кәҗә П.се (P. caperata), җыерчалы П. (P. sulcata), тәлинкәсыман П. (P. acetabulum) һ.б. очрый. Агачларда, чери башлаган үзагачта, сирәгрәк — туфракта үсәләр. Катламасы киселмә-калаксыман яфрак таралгысы рәвешендә субстратка берегә, аксыл-соры, соры, саргылт-яшел, карага якын куе көрән төстә. Бер күзәнәкле спорлалардан үрчиләр. Һаваның пычрануына сизгерләр, атм. чисталыгын биоиндикацияләү өчен кулланылалар. Кайбер төрләре микробларга каршы тору үзлегенә ия.

**ПАРО́ДИЯ** (грек. parōdia — кабатлау, көлке тудыру өчен бозып күрсәтү), язучының нинди дә булса әсәренә ияреп, аның стиленнән, теле, геройлары, мәгънәсе, композициясеннән көлү ысулы. П.дә оригинал әсәр гипербола, шарж рәвешендә бирелә, аңа хас үзенчәлек-сыйфатлар абсурд дәрәҗәсенә җиткерелә, нәтиҗәдә сатирик-комик эффект тудырыла. Әдәби мода, ялган сәнгати принциплар, стилистик үзенчәлекләр һ.б. П. тууга этәргеч була, искергән шаблоннар һәм әдәби нормалар көлке объекты итеlә. П. сатирик та, юмористик та булырга мөмкин. П. аеруча әдәбиятта барган төрле каршылыклар чорында киң тарала. Татар әдәбиятында әдәби П.нең беренче үрнәкләре 20 йөз башында барлыкка килә. Мәс., Г.Тукайның «Печән базары, Яхут яңа Кисекбаш» поэмасы урта гасырлар төрки-татар әдәбияты ядкәре — «Кисекбаш китабы»на П. рәвешендә язылган. 20 йөздә П.нең сатирик формасы үсеш ала. Төрле социаль күренешләрдән көлгән әсәрләр туа: Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» хикәясендә 1920 еллар шаукымы — социаль идеяләргә артык мөкиббәнлек — П. тууга сәбәп була; Т.Миңнуллинының «Минһаҗ маҗаралары» романында 20 йөзнең тарихи һәм сәяси эшлеклеләре Николай II, В.И.Ленин, И.В.Сталин, Н.С.Хрущёв, Л.И.Брежнев һ.б. комик күзлектән, карикатура ысуллары ярдәмендә тасвирлана; Хәсән Сәрьянның «Нокталы өтер» повесте надан галим эзләнүләрен күрсәтүгә багышлана; Ф.Шәфигуллинның «Суда балык йөзәдер» һәм «Ботка» хикәяләрендә «фәнни» диссертацияләр һәм йомшак тәнкыйди мәкаләләр П. язарга этәргеч була.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; М а к а р о в а В.Ф. Татар сатирасының үсеш үзенчәлекләре. К., 2007; Литературный энциклопедический словарь. М., 1987.

*Ә.М.Шәрипов.*

**ПА́РСИН** Мөхәммәт Зариф улы (9.3.1899, Казан губ., Казан өязе Олыяз а. — 8.4.1963, Яшел Үзән ш.), журналист. Укытучылар курсын тәмамлаганнан соң, Казан өязе мәктәпләрендә укыта, үзешчән театрлар оештыруда катнаша. Комсомол ячейкалары оештыру буенча эшләр алып бара, Татарстан комсомолының 1 нче өлкә конференциясендә РКСМ өлкә ком-тына сайлана (1920, сентябрь). 1919 елда «Эш», «Кызыл Армия» г-талары б-н хезмәттәшлек итә башлый. 1920 елларда Мәскәү журналистика ин-тында укый, комсомол басмалары: «Кызыл яшьләр» (Казан) г-тасы, «Кызыл Шәрекъ яшьләре» (Казан), «Яшь эшче» (Мәскәү) ж-лларында мөхәррир булып эшли. 1925 тән «Кызыл Татарстан» г-тасы хәбәрчесе, «Крестьян газеты», «Эшче» г-тасына, «Кызыл Шәрекъ», «Чаян» ж-лларына һ.б.га сәнәгать һәм а.х. үсеше турында яза. Татар театрына багышланган мәкаләләр, спектакльләргә рецензияләр, татар әдәбияты һәм сәнгате үсеше хакында язмалар бастыра. «Театр мәҗмугасы: Татар театрының 20 еллык бәйрәме» (1925), «Татар театры. 1906–1926» (1926) җыентыкларын төзүче. 1941 нең 7 октябрендә, советка каршы милли оешмалар эшчәнлегендә катнашы бар дип, кулга алына (кулга алынганчы «Красный дорожник» артелендә эшли); 1942 дә Красноярск өлкәсенә 5 елга сөргенгә сөрелә; 1948 дә сөргеннән кайта; 1956 да аклана. 1949 дан Яшел Үзән шәһәрендә яши.

Ә с ә р.: Ураза бәйрәмендә: Комедия 2 пәрдәдә. К., 1926.

*Әд.:* Книга Памяти жертв политических репрессий. К., 2003. Т. 11.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ПАРСЫ́З ЕФӘ́К КҮБӘЛӘГЕ́** (Lymantria dispar), дулкынчалар семьялыгыннан күбәләк. Кырый Төньяктан кала бөтен җирдә таралганнар. Гадәттә, уртача зурлыкта. Гәүдәсе төкчәле, хортумчыгы рудиментар. Канатлары киң. Җенси диморфизм ачык чагыла — ата һәм ана затлар зурлыгы, төсе, мыекчаларының төзелеше буенча аерылалар. Ата зат көрән төстә, канат җәеме 35–40 *мм*; ана күбәләкләр ак, канат җәеме 55–70 *мм*. Ataларының мыекчалары сырлы, аналарының җепсыман. Июль–августта очалар, ата күбәләкләр генә хәрәкәттә, канатлары җыелган ана затлар агачта утыра. Агач төбендәге бер ояга 450 гә кадәр күкәй сала, саклау өчен өстен җирән төкчәләр б-н тыгызлап каплый, аларны ул корсагыннан бүлеп сала. Күкәйләр кышлый. Май башында беренче гусеницалар чыга. Аларның агулы сыекчалы куе төкчәләрдән торучы үзенчәлекле чуклары, гәүдәнең алгы өлешендә — 5 пар зәңгәр, арттa 6 пар кызыл сөялләре бар. Гусеницалар ефәк җепләреннән ясалган ояларда курчакланалар. Җепшекләрсез салкын кыштан соң килгән җәйге эссе һава П.е.к.нең үрчүенә булышлык итә. Күпләп үрчегәндә гусеницалар үсемлек яфракларын тулысынча ашап бетерәләр. П.е.к. үсемлекләрнең 300 дән артык төрен (бигрәк тә имән, тирәк, җимеш агачларын) зарарлый.

*С.Г.Гордиенко.*

**ПАРТИЗАННА́Р ХӘРӘКӘТЕ́**, Б ө е к В а т а н с у г ы ш ы ч о р ы н д а, СССРның вакытлыча оккупацияләнгән терр-ясендә сов. халкының немец-фашист басып алучыларына каршы кораллы көрәшенең состав өлеше. П.х. РСФСРның Орёл, Смоленск, Ленинград һәм Калинин өлкәләрендә, Белоруссия ССРда һәм Украина ССРда киң җәелә. Партизан отрядларында 1 млн.нан артык кеше исәпләнә. П.х. б-н гомуми стратегик җитәкчелек Югары башкомандование Ставкасы тарафыннан гамәлгә ашырыла. 1942 елның маенда оештырылган Партизаннар хәрәкәтенең үзәк штабы (башкомандующий — маршал К.Е.Ворошилов, 1942 нең сентябре–ноябре; штаб башлыгы — П.К.Пономаренко) П.х. б-н турыдан-туры җитәкчелек итә, аңа өлкәләрнең һәм респ-каларның штаблары буйсына.

Татарстанлылар РСФСР, Украина һәм Белоруссиянең кайбер өлкәләре терр-ясендә П.х.ндә актив катнашалар. Хәрәкәттә катнашкан ТАССР вәкилләренең төп өлеше Кызыл Армиянең чолганыштан чыга алмаган яки, әсирлеккә эләгеп, хәрби әсирләр лагерьларыннан качкан сугышчыларыннан гыйбарәт була. Татарстанлылар яуланган терр-яләргә махсус төркемнәр составында разведка, диверсияләр һәм П.х. оештыру өчен дә җибәреләләр.

Мәскәү өлкәсендә — И.Д.Шамонинның партизаннар отряды, Псков өлкәсендә А.Н.Ситдыйков полкы хәрәкәт итә. Смоленск өлкәсендә респ-каның 200 дән артык кешесе, ш.и. 1941 нең июлендә чолганышта калган *Унсигезенче укчы дивизия* сугышчылары сугыша. Яшерен төркемнәрнең берсе б-н 97 нче укчы полк батальоны командиры майор Б.Х.Кадермәтов (Кудров) җитәкчелек итә. Шул дивизия подразделениеләре командирлары Ә.Ш.Бикбаев һәм М.Х.Садров «Саша» партизаннар отрядын җитәклиләр. 1942 нең декабре — 1943 нең сентябрендә отряд дошманның 33 тимер юл составын һәм 1,5 мең солдатын юк итә. Смоленск өлкәсендә ш.у. Н.А.Бирюков оештырган 5 отряд көрәшә. Смоленск партизаннары сафларында партизаннар полкы комиссары Г.С.Әмиров, разведчиклар М.Гыйльфанов, Г.Г.Ларин һ.б. сугыша. Белоруссия терр-ясендәге П.х.ндә С.Әминов, Ш.Бәдретдинов, Ч.М.Заһирова, Т.Моратов, Б.Пахомов, Г.Уленгов, С.Хәлиуллов, С.Хафизов һ.б. катнашалар. ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тының элеккеге секретаре И.Заикин һәм шагыйрь З.Ш.*Нури* белорус хәрәкәтендә актив катнашулары б-н танылалар. Әсирлектән качкан лейтенант И.К.*Кабушкин* Минск яшерен хәрәкәтенә килеп кушыла, партиянең яшерен шәһәр ком-тының оператив төркемен җитәкли, немец офицерларын һәм чиновникларын юк итү буенча диверсияләр һәм операцияләр оештыра. Украинада П.х.н оештыручыларның берсе 1941

нең октябрендә төркем составында Сумы өлкәсе терр-ясенә җибәрелгән политрук П.В.Васильев була. Ул 19 үзоборона төркеме (соңрак — партизан отрядлары) төзи. Соңыннан П.В.Васильев С.А.Ковпакның партизаннар берләшмәсендә бригада комиссары була. Литвадагы «Мститель» («Үч алучы») партизаннар отрядында 1943–44 тә А.Я.Зәкиев («Лёша Татарчук») сугыша. С.А.Ковпакның, А.Н.Сабуровның, А.Ф.Фёдоровның партизан берләшмәләрендә В.Алексич, Г.М.*Минаев* (Николай Орлов), Н.Маханов, Г.Спиридонов, Б.Х.Хәлиуллин көрәшәләр. Г.М.Минаевның диверсия төркеме шоссе һәм грунт юллардагы 27 күперне, 4 тимер юл күперен шартлата, дошманның 35 паровозын, 350 вагонын, 1,5 меңләп солдатын һәм офицерын юк итә. 1943 нең җәендә, Курск сугышы вакытында, Б.Х.Хәлиуллин үзенең төркеме б-н дошманның 53 эшелонын шартлата. Башка партизаннар отрядларында М.Атналов, М.Ф.Бәхтиярова, Г.Баев, П.П.Белозёров, С.В.Быстров һ.б. сугышалар.

ТАССР вәкилләре яшерен эшчәнлектә дә катнашалар. Г.Әһлиуллин — А.Морозова җитәкләгән Сещин яшерен оешмасында (Брянск өлкәсе), К.Галләмов, Т.Гайнанов, Н.А.Барышев һ.б. — Кырымдагы яшерен хәрәкәттә, Ф.Гафурова, М.Х.Калинкин Днепропетровскида яшерен эш алып баралар.

Татарстан хезмәт ияләре партизан отрядлары сугышчылары өчен кирәк-яраклар, җылы әйберләр, дарулар җыеп җибәрәләр.

*Әд.:* Г и л ь м а н о в З.И. Татарская АССР в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг. К., 1977.

**«ПАРТРАБО́ТНИК»** («Партия хезмәткәре»), иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты органы. 1932 елдан Казанда рус телендә нәшер ителә. Беренче саны 1932 нең октябрь аенда дөнья күрә. Мөхәррире — Т.Матюнин. Мәкаләләрнең беркадәре татар телендә (латин графикасында) басыла. Газетада ВКП(б)ның шәһәр ком-ты документлары һәм карарлары биреп барыла, партия укулары, коммунистик белем мәктәпләре һәм түгәрәкләре эшен оештыру мәсьәләләре күтәрелә, Казан пр-тиеләрендәге партия оешмалары эшчәнлеге, аларның җитештерү планнарын вакытында үтәүне оештыру тәҗрибәләре яктыртыла.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ПАРФЕ́НТЬЕВ** Николай Николаевич (19.3.1877, Казан — 22.1.1943, шунда ук), математик һәм механик, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). А.В.*Васильев* шәкерте. 1899 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Самара хатын-кызлар гимназиясендә матем. һәм физика укыта. 1900 дән Казан ун-тында, саф матем. кафедрасының приват-доценты (1904 тән), бер үк вакытта 3 нче Казан гимназиясенең матем. укытучысы (1899–1905). 1905 нең апрелендә Идел буе (съездның рәисе) һәм Мәскәүдә укытучыларның легаль булмаган съездларындагы чыгышлары өчен ун-тта укыту хокукыннан мәхрүм ителә, шул ук елның декабрендә «сул укытучылар» төркеме йогынтысында эшенә кире кайтарыла. 1908–10 да Франциядә һәм Германиядә стажировка үтә. 1911 дән Казан ун-ты профессоры, 1917–22 дә һәм 1928–33 тә физика-матем. ф-ты деканы, 1930 да һәм 1940 тан механика каф. мөдире. Хезмәтләре функцияләр теориясенә, фәннең методологиясенә, табигыять философиясенә, матем. тарихына карый. П. Казан ун-тында беренче булып тензорлы анализ, чагыштырмалылык теориясе, интеграль тигезләмәләр, күплекләр теориясе, матем. статистика, группалар теориясе, фәнни хисаплаулар техникасы, номография буенча лекция курслары укый. Югары мәктәптә укыту һәм фәнни эшләрнең яңа формаларын оештыра: университетта рабфак ачу комиссиясенең башында тора (1919) һәм аның идарәсендә эшли, Авыл хуҗалыгы һәм урманчылык ин-тын оештыруда (1922–24 тә ин-тның ректоры), университет составыннан аерылып чыккан яңа югары уку йортларын (мед., пед., химия-технол.) сафка бастыруда, университет каршында Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тын оештыруда катнаша.



Н.Н.Парфентьев.

1933–35 тә Казан ун-тының Фәнни китапханәсе директоры. 1930 дан Казан физика-матем. җәмгыяте рәисе һәм «Известия физико-математического общества при Казанском университете» ж-лының җаваплы мөхәррире. Н.И.Лобачевский исем. бүләккә Халыкара конкурс оештыручыларның берсе. Татарстанның Соц. Төзелеш Герое (1932).

Х е з м.: Исследования по теории роста функций. К., 1910; Проблемы пространства в современном освещении. К., 1924; Геометризация Вселенной. К., 1926; Основные принципы статистической механики. К., 1929.

*Әд.:* Герои труда Татарии. 1920–1938 гг.: Док. очерки. К., 1974; Л а п т е в Б.Л. Николай Николаевич Парфентьев // Рассказы о Казанских учёных. К., 1983.

**ПАРФЁНОВ** Виктор Всеволодович (25.9.1950, Казан), физик, физика-матем. фән д-ры (2006). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, каты җисемнәр физикасы кафедрасында эшли. Хезмәтләре оксидлы магнитик ярымүткәргечләрнең магнитик, электрик һәм оптик үзлекләре структурасын, ш.у. металлоорганик кушылмаларда күчерү күренешләрен өйрәнүгә карый. П. оптик нурланышның ярымүткәргечләрнең Мёссбауэр спектрлары параметрларына тәэсирен ача (1978). Металлоорганик эластомерларда корылма йөрткечләрнең күчерү механизмын тикшерә; яңа оксидлы магнитик ярымүткәргечләрнең катион бүленешен ачыклый; перовскит структуралы сирәк мәгъдән элементлары ферриманганитларында аномаль югары уңай магнит каршылыгы булуын ача. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004).

Х е з м.: Влияние оптического излучения на параметры мёссбауэровских спектров полупроводников // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1978. Т. 27; Электрофизические свойства полиуретанов, координированных 3d-ионами с переменной валентностью // Докл. АН СССР. 1984. Т. 277, № 6; Гигантское положительное магнитосопротивление в ферриманганитах лантана // Изв. РАН. Сер. физ. 2001. Т. 65.

**ПАРХО́МЕНКО** Иван Филиппович (23.10.1904, Харьков губ., Изюм өязе Славянск ш. — 3.7.1979, Казан), авиация технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1951). 1929 елда Харьков транспорт инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Харьков шәһәре пр-тиеләрендә эшли. 1934 тән Казан авиация ин-тында, самолётлар җитештерү каф. мөдире (1934–38), самолётлар төзү ф-ты деканы (1952–60), проф. (1961); 1956–57 дә КХРда командировкада була, Пекин авиация ин-тында самолётлар төзү технологиясе буенча тулы лекцияләр курсы укый. Бөек Ватан сугышы елларында 387 нче Казан авиация з-дында баш технолог, техник контроль бүлеге башлыгы. Хезмәтләре табаклы һәм профильле металлдан деталь формаларын ясау процессларына карый. Очкыч аппаратларның махсус җыелма конструкцияләрендә чүкеп беркетү процессларын механикалаштыру алымнарын эшли. Самолётлар җитештерүгә технол. әзерлек срокларын кыскарту юлларын тәкъдим итә. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПАРЧА́** (фарсыча: پارچه — кисәк, бүлем, өлеш, бөртек) кыска шигырь яки кечкенә күләмле чәчмә әсәр, авторның теге яки бу уңай б-н туган хис-тойгыларын, фәлсәфи фикерләрен, күзәтүләрен эченә алган миниатюр язма. Татар әдәбиятында Г.Тукай, Дәрдемәнд, Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Ш.Галиев һ.б. әсәрләрендә очрый. Лирик П.лар кыйтга жанрына якын.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

**ПАСКАТИРЛА́Р**, к. *Маҗарлар.*

**ПАСЛЁН** (Solanum), паслёнчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуаклар һәм куаклар ыругы. 1700 гә якын төре билгеле, тропик, субтропик һәм уртача поясларда, күбесенчә Көньяк Америкада таралганнар. П. ыругына әһәмиятле культуралы үсемлекләр — *бәрәңге*, баклажан керә. Татарстан терр-ясендә кыргый 3 төре очрый: әчкелтем П. яки карга җиләге (S. dulcamara) — лианасыман куак, кара П. яки карга борыны (S. nigrum), Шультез П.ы (S. schultesii) — 30–180 *см* биеклектәге берьеллык үсемлекләр. Сулык ярларында, зирек урманнары, кыр һәм бакчаларда, чүплекләрдә һәм тимер юл буйларында үсәләр. Яфраклары эре, чиратлашкан яки парлы, озынча-йо-



Карга җиләге.



Б.Л.Пастернак.

мыркасыман. Чәчәкләре ак, чатыр чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — күп орлыклы ике оялы җиләк. Июнь–сентябрьдә чәчәк аталар. Җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Агулы үсемлек. Карга җиләге һәм карга борыны халык медицинасында кулланыла. Яшь ботакларында — алкалоид, гликозид, яфракларында аксым матдәләре, крахмал, каротин бар. Үлән төнәтмәсе невроз, ревматизм вакытында, ш.у. бәвел һәм үт кудыру, какырык куптару чарасы буларак кулланыла.

**ПАСЛЁНЧАЛАР** (Solanaceae), сыраҗсыманнар рәтендәге ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Үләннәр, ярымкуаклар, куаклар яки тәбәнәк агачлар. 2,9 меңнән артык төре, якынча 80–90 ыругы билгеле, тропик, субтропик һәм уртача поясларда, башлыча, Көньяк һәм Үзәк Америкада үсәләр. Татарстанда 9 ыругтан 14 төр билгеле. Яфраклары чиратлашкан, гади, бөтен яки каурыйсыман-теленмә, төрле дәрәҗәдә төкчәле яки шома. Чәчәкләре ике җенесле, 5 буынлы, касәле, ялгыз яки бөтеркә чәчәк төркемендә, серкәчләре 5. Җимешлеге бер, ике оялы өске җимшәнле һәм күп санлы орлык бөреле. Җимешләре — күп орлыклы сусыл җиләкләр яки коры тартмачыклар. П.га а.х. үсемлекләре: *бәрәңге*, *томат*, баклажан, борычның берьеллык борыч керә. Кара тилебәрән үләне, гади тилерткеч, әчкелтем П., кара П. — дару үсемлекләре; бакра гөл, физалис, хуш исле тәмәке декоратив үсемлек буларак үстерелә; кара тилебәрән үләне, карга борыны — чүп үләннәре.

**ПАССА́Ж** (франц. passage — үтү, күчү), пыяла түбә астындагы үтү юлының ян-якларына кибетләр урнашкан сәүдә бинасы төре. Россиядә беренче П. 19 йөз уртасында төзелә башлый; иң билгеле П. 1889–93 елларда Мәскәүдә Кызыл мәйданда төзелә (хәзерге ГУМ; арх. А.Н.Померанцев, инженер В.Г.Шухов). Казанда 1880 еллар уртасында *Александровлар пассажы*, 20 йөз башында — *Черноярлар пассажы* корыла.

*Әд.:* Пилявский В.И., Тин А.А., Ушаков Ю.С. История русской архитектуры. М., 1984.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ПАСТЕРНА́К**, гәзнич (Pastinaca), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 15 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: кыргый П. (P. sylvestris), болыннарда, аланнарда, каралты-кура тирәсендә, юл буйларында очрый; игүле П. (P. sativa) тәмләткеч, яшелчә һәм терлек азыгы буларак бакчаларда үстерелә. Сабагы туры, кабыргалы, 40–120 *см* биеклектә. Яфраклары чиратлашкан, каурыйсыман-теленмә, очлы тешле, өсте ялтыравыклы, аскы ягы төкчәле. Чәчәкләре вак, сары төстә, катлаулы чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — ике орлыкча, өлгергәч 2 өлешкә аерыла. Орлыклары вак. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. П. — суыкка чыдам үсемлек. Тамыр һәм яфракларында эфир мае, җиңел үзләштерелүче углеводлар, минераль тозлар, гликозидлар бар. Халык медицинасында үлән һәм тамыр төнәтмәсе аппетитны ачу өчен, спазмолитик, авыртуны басу, какырык куптару, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Баллы үсемлек.



Игүле пастернак.

**ПАСТЕРНА́К** Борис Леонидович (10.2.1890, Мәскәү — 30.5.1960, Переделкино), шагыйрь. «Тормыш — минем туганым» («Сестра моя — жизнь», 1922), «Икенче тууым» («Второе рождение», 1932), «Иртәнге поездларда» («На ранних поездах», 1943) исемле җыентыклар, «Көн аязгач» («Когда разгуляется», 1961) циклы, «Тугыз йөз бишенче ел» («Девятьсот пятый год», 1927), «Доктор Живаго» романы (Милан, 1957, СССРда 1988; Нобель бүләге, 1958, дипломы 1990 елда улына тапшырыла), повестьлар, автобиографик проза, тәрҗемәләр авторы. Татарстанга беренче килүе хәрби хезмәт б-н бәйле: 1916 ның сентябреннән 1917 нең мартына кадәр Алабуга өязенең Тихие Горы авылында (1967 дән Менделеев шәһәренә керә) хәрби ведомство канцеляриясендә хәрби-хисап бүлегендә исәпләнә. Бу елларда П. инглиз теленнән сонетлар, А.Суинбергның «Мария Стюарт» драматик трилогиясен, «Киртәләр өстеннән» («Поверх барьеров», 1917) исемле җыентыгын басмага әзерли. 1941 нең октябреннән 1943 июненә кадәр Татарстанда эвакуациядә була (күбесенчә Чистайда яши). Чистайда ул «Шәһәр» («Город»), «Кыш якынлаша» («Зима приближается»), «Киләчәк бар нәрсәгә карашларны үзгәртәчәк...» («Грядущее на всё изменит взгляд:»), «В.Д.Авдеевка» («В.К.Авдееву»), «Марина Цветаева истәлегенә» («Памяти Марины Цветаевой»), «Ашыгулы юллар» («Спешные строки») исемле шигырьләрен яза. Шул ук вакытта У.Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» («Ромео и Джульетта»), «Антоний һәм Клеопатра» («Антоний и Клеопатра») трагедияләрен, Ю.Словацкий шигырьләрен тәрҗемә итә.

*Ә с ә р.:* Собр. соч.: В 5 *т.* М., 1989–91.

*Әд.:* Чистопольские зимы Бориса Пастернака. Чистополь, 2005; Быков Д.Л. Борис Пастернак. М., 2006; Пастернак З. Воспоминания. М., 2006.

*А.Э.Скворцов.*

**ПАСТЕРНА́К БОРИ́С МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕЕ́**, Чистай шәһәрендә. ТАССР Мәдәният министрлыгының 1990 елның 12 февр. боерыгы б-н ТАССРның Берләштерелгән дәүләт музее (2001 дән — ТР Милли музее) ф-лы буларак оеша. Б.Л.*Пастернак* 1941 нең 18 октябреннән 1943 нең 25 июненә кадәр эвакуация вакытында яшәгән йортта (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге) 1990 да ачыла. 2007 дән муниципаль музей. 2009 дан «Чистай шәһәренең музей берләшмәсе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең структур бүлекчәсе. Экспозиция мәйданы — 114 $м^2$. Музей фондында 4686 саклау берәмлеге. «Чистай сәхифәләре» әдәби экспозициясе Бөек Ватан сугышы елларында шәһәргә эвакуацияләнгән шагыйрьнең һ.б. язучыларның иҗатына багышлана; анда ш.у. кульъязмалар, хатлар, фотосурәтләр, Укытучылар йортындагы әдәби-муз. кичәләрнең афишалары, Б.Л.Пастернак китаплары куелган. Мемориаль бүлмәдә фатир хуҗасы Е.И.Вавилова-Коростылёваның көнкүреш әйберләре һәм шагыйрьнең улы Е.Б.Пастернак архивыннан фотосурәтләр, китаплар бар. Тупланманың аеруча кыйммәтле өлешенә: Б.Л.Пастернакның шәхси әйберләре — кара савыты, стакан асты; ул файдаланган җиһаз: өстәл, урындыклар, карават, шкаф (10 саклау берәмлеге) һ.б.; шул төбәк рәссамы И.А.Нестеровның карандаш б-н ясалган рәсемнәр коллекциясе (язучыларның портретлары, 250 саклау берәмлеге), Б.Л.Пастернак әсәрләренең үзе исән чагындагы басмалары коллекциясе (30 га якын саклау берәмлеге) бар. Экспозиция авторлары — О.И.Шашина, М.Я.Гыйсмәтуллин, Н.С.Харитонова.

Ел саен Б.Л.Пастернак туган көн (10 февр.), Халыкара музейлар көне (18 май).



1



2

Б.Пастернак мемориаль музее. 1. Йортның гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты: шагыйрьнең эш өстәле.

Б.Л.Пастернакны искә алу көне (30 май), музей ачылу көне (12 сент.), сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне (30 окт.) үткәрелә.

Музей директоры — Л.Г.Демченко (1990 нан).

**ПАСХА́ЛОВ** Виктор Никандрович (18.4.1841, Саратов ш. — 1.3.1885, Казан), композитор, пианист, педагог, хор дирижёры, музыкант, җәмәгать эшлеклесе. 1861–66 елларда Париж консерваториясенең ирекле тыңлаучысы була, 1866–67 дә Мәскәү консерваториясендә (Н.Г.Рубинштейн классы) укый, патша сарае җырчылар капелласында дирижёрлык итү өчен имтихан тапшыра. 1871 дән Мәскәү кадетлар корпусында җыр укытучысы. 1873 тән Казанда, аерым дәресләр бирү б-н шөгыльләнә, Казан ун-тының студентлар хоры б-н җитәкчелек итә, концертлар б-н чыгышлар ясый, фортепиано әсәрләрен һәм үзе язган романсларны башкара. Түләүсез музыка мәктәбен оештыручы һәм җитәкчесе була (1882–84). С.-Петербургтагы М.А.Балакирев исем. мәктәп үрнәгендә П. мәктәбенең эшчәнлеге нигезенә музыка коралларында күмәк уйнау (хор җыры, инструменталь оркестр һәм ансамбль башкаручанлыгы) принциплары салына. Бигрәк тә рус музыкасын популярлаштыруга игътибар ителә. Мәктәптә фортепиано, вокал, оркестр уен кораллары, музыка теориясе буенча дәресләр алып барыла. П. ялгыз җырлау һәм музыка теориясе классларын алып бара. М.Ю.Лермонтов, А.К.Толстой, Н.П.Огарёв, А.С.Кольцов, И.С.Никитин һ.б.ның, ш.у. үзенең әнисе — шагыйрә А.Н.Мордвинова шигырьләренә 60 тан артык романс яза. Әсәрләре 19 йөз ахыры — 20 йөз башында күп кенә күренекле җырчыларның репертуарына («Дитятко, милость господня с тобой», «Под душистою ветвью сирени», «Что, моя нежная», «Нивушка» һ.б.) керә. П. әсәрләре П.И.Чайковский, М.П.Мусоргский иҗатларына йогынты ясый (Мусоргский П.ның көчле хисләрне гади һәм тәэсирле итеп чагылдыра белүен, П. романсларының башкару һәм тыңлау өчен җиңел булуын искәртә).

*Әд.:* Б е л е ц к и й Н.В., Н а з а р е в с к и й П.П. Пасхаловы: Страницы музыкального прошлого. Л., 1970.

**ПАСЮ́К**, к. *Соры күсе.*

**ПАТИ́Й** (Патиев) Кашшаф (Габделкашшаф) (19 йөз ахыры, Сембер губ. Зимничә а. — 20 йөз башы), шагыйрь. 1909 елда туган авылында мулла. Шигырьләре һәм публицистик мәкаләләре «Идел» г-тасында, «Шура» ж-лында басыла. 1910 да беренче шигъри җыентыгы чыгу уңаеннан «Идел» г-тасы: «Гүзәл, милли вә тәэсирле шигырьләр. Кәшшаф Патии җәнабләренә ошбу мәҗмугадагы шигырьләре илә Г.Тукаевтан соң беренче шагыйребез диюгә лаектыр», — дип язып чыга. «Патии шигырьләре» (1910), «Әшгар» (1915) исемле җыентыклар авторы. Габделкашшаф Зимнәчәви псевдонимы б-н 1906 да басылган «Тугыз чәчәк» исемле китап авторы дип фаразлана.

*Әд.:* Татар шигърияте. XX гасыр башы. К., 2004.

**ПАТОЛО́ГИК АНАТО́МИЯ**, мед. фәне, тукымалар, әгъзалар һәм системаларның авыру барышындагы үзгәрешләрен, авыруларның этиологиясен һәм патогенезын өйрәнә. Гомуми, аерым, махсус төрләргә бүленә. П.а.дә, башлыча, морфологик, гистохимик, рентгенохимик, ауторадиографик, иммуногистохимик һ.б., ш.у. эксперименталь ысуллар кулланыла. Мәетләрдән һәм авырулардан операция вакытында яки диагностика максатларында махсус алынган тукымалар (биопсия) өйрәнелә. Дәвалау учреждениеләрендә мәетләрне ярып, авыру кешегә диагноз кую һәм дәвалауның дөреслеге тикшерелә.

Гомуми П.а. гомуми патологик процессларны: кан әйләнешендәге тайпылышларны, тукымаларда матдәләр алмашы бозылуны, ялкынсынулар, шешләр һ.б.ны; аерым П.а. әгъзалар һәм системалардагы (мәс., нерв системасында, сулыш органнарында һ.б.) патологик процесслар барышын; махсус П.а. билгеле бер авыру барышында барлыкка килгән үзгәрешләр комплексын (патогенез) өйрәнә.

Пётр I идарә иткән чорда Россиядә, табибләргә анатомия өйрәтү максаты б-н, госпитальләрдә мәетләрне ярып карау зарурлыгы турында берничә күрсәтмә кабул ителә. 1704 елда мед.-госпиталь курслары оештырыла. 1755 тә Мәскәү ун-тында мед. ф-ты ачылу ш.у. П.а. үсешенә этәргеч була. И.А.Костомаров тарафыннан, Россиядә беренче буларак, рус теленә аерым П.а. дәреслеге тәрҗемә ителә (1826). Россиянең югары мед. уку йортларында махсус П.а. кафедралары барлыкка килү (Мәскәү ун-ты, җитәкчесе — А.И.Полунин, 1849; С.-Петербург Хәрби-мед. академиясе, җитәкчесе — Т.С.Иллинский, соңрак М.М.Руднев, 1859) ш.у. алга таба бер адым буларак бәяләнә. Казан ун-тының мед. ф-тында Е.Ф.Аристов П.а. буенча кыскача мәгълүмат бирүче лекцияләр уку оештыра (1850). Фәнни тикшеренүләр 1860 еллардан уздырыла башлый. Р.Кох тарафыннан туберкулёз таякчыгы ачыклангага кадәр үк, Казан галиме А.В.*Петров* туберкулёз патологиясен һәм бу авыруның йогышлылыгын өйрәнү буенча тәҗрибәләр уздыра (1862). Н.М.Любимовның фәнни хезмәте туберкулёз авыруы вакытында гигант күзәнәкләр барлыкка килүгә багышлана. Аның «Кискен лейкемия авыруын өйрәнүгә карата» («К изучению острой лейкемии», 1890) монографиясе П.а. буенча бердәнбер ярдәмлек була. Галим ш.у. Азия вабасы очрагында баш миендәге үзгәрешләрне, рахит авыруын, туберкулёз авыруы очрагында ялкынсынулар һәм шешләрне, остеомаляция, эпидемик энцефалитны өйрәнә (1920 еллар). Ф.Я.*Чистович* ачкан ят аксымның үзенчәлекле антитәнчек б-н преципитациясе (реакциягә керү күренеше) феномены (1904) диагноз кую өчен кулланыла торган преципитация реакцияләренең (мәхкәмә медицинасында «Чистович-Уленгут реакциясе» дип йөртелә) фәнни нигезен тәшкил итә. И.П.Васильев тәҗрибә юлы б-н карнификацияләүче үпкә ялкынсынуын торгызып, кешедән алынган секцияле материал аша аның морфологиясен һәм морфогенезын өйрәнә (1912). Хезмәтләренең берничәсе яман шешләргә багышлана. Галимнең тикшеренүләрен шәкертләре дәвам итә (Г.Г.Непряхин, Н.С.Подольский, Н.Ф.Порываев). Ревматизм, атеросклероз, эпидемик зоб, балалардагы патологияләрне вакытында ачыклау кебек мәсьәләләр дә өйрәнелә (Г.Г.Непряхин, Н.Ф.Порываев). В.А.Добрынин хезмәтендә (1968) П.а.нең бик катлаулы бүлеге — эвволютив һәм ялкынсыну процесслары б-н үпкә рагы арасындагы бәйләнешләр тасвирлана. 1990 нан ТР патологоанатомнарының фәнни эзләнүләрендә рак авырулары патогенезын молекуляр дәрәҗәдә өйрәнү һәм авыруга диагноз куюның заманча ысулларын эшләү, яман шеш күзәнәкләре биологиясе мәсьәләләре төп юнәлешләрне тәшкил итә. Н.Ш.Шәмсетдиновның «Селәгәй бизләре шешләре гистогенезы» («Гистогенез опухолей слюнных желёз») фәнни-тикшеренү эше мед. өлкәсенә караган хезмәтләр арасында РФ күләмендә иң яхшысы дип табыла (1991). Казан галим-патологоанатомнарының фәнни эшләреннән берничәсе цитоскелетның (цитокератиннарның) шеш алды процессларындагы ролен өйрәнүгә, шешләрнең ракка әверелүен һәм авыру барышын фаразлау проблемаларына карый. Голландия галимнәре б-н берлектә «Аналык муентыгындагы яссы күзәнәкле рак барышында эпителиаль маркерлар һәм кеше папилломасы вируслары роленә анализ» («Анализ эпителиальных маркеров и роли вирусов папилломы человека в течении плоскоклеточного рака шейки матки») темасына тикшеренүләр уздырыла (Голландия ягыннан проф. В.Хармсель, Россия ягыннан — проф. Н.Т.Райхлин, Н.Ш.Шәмсетдинов җитәкчелек итә, 1990–98). Чылбырлы полимераза реакциясе ярдәмендә беренче булып Россиядә ачыкланган мәгълүматлар сәламәт хатын-кызлар арасында кайберләренең кеше папилломасы вирусын йөртүче булуын күрсәтә (1996). Ракка каршы көрәш программасы нигезендә ТР Онкология үзәгендә иммуногистохимик диагностика лаб-ясе ачыла (җитәкчесе — С.В.Петров). Яңа технологияләр ракның үтә катлаулы очракларын ачыкларга, диагностика мөмкинлекләрен дөньяның иң алдынгы мед. үзәкләре дәрәҗәсенә җиткерергә мөмкинлек бирә.

*Әд.:* Труды кафедры патологической анатомии. 1865 — 100 лет — 1965. К., 1967. Т. 23; Д о б р ы н и н В.А. Кафедра патологической анатомии // Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989. Ч. 1; БСЭ. 3 изд. М., 1975. Т. 19.

*Н.Ш.Шәмсетдинов, Р.Г.Исхакова.*

**ПАТОЛО́ГИК ФИЗИОЛО́ГИЯ**, патологик процессларның механизмы: барлыкка килүе, барышы һәм ахыры, авыру организмындагы компенсатор-җайлашу реакцияләре турындагы мед. фәне. Авырулар барышының гомуми процессларын, универсаль чагылышларын, аерым әгъза һәм системаларның функциональ эшчәнлегендәге тайпылышларның сәбәпләрен тикшерә. П.ф.нең төп ысулы — эксперимент, ягъни кешедә авыру килеп чыгу закончалыкларын ачыклау, дәвалау һәм кисәтүнең нәтиҗәле ысулларын булдыру максатыннан, лаб. хайваннарында патологик процессларны модельләштерү. Рос-

сиядә беренче мөстәкыйль П.ф. каф. 1874 елда, Казан ун-тының мед. ф-тында барлыкка килә. 1880 елларда Россия П.ф.сенә нигез салучыларның берсе В.В.*Пашутин* тәҗрибәләр уздыруны фәнни практикага кертә, авыру кеше организмында матдәләр алмашы процесслары бозылу механизмын өйрәнә. Шушы елларда хайваннардагы гипотермик халәт физиологиясен һәм кышкы йокыга талу күренешен өйрәнү буенча беренче тикшеренүләр уздырыла (проф. А.Н.*Хорват*), тикшеренү нәтиҗәләре гипотермияне йөрәккә һәм баш миенә операцияләр вакытында киң кулланууга нигез итеп алына. 20 йөз башында иммунобактериаль юнәлеш интенсив үстерелә; И.Г.*Савченко* (иммунитет реакцияләрен өйрәнүдә физик-химик юнәлешкә нигез салучы) тарафыннан фагоцитоз механизмнарының һәм кызылча (скарлатина) иммунологиясенең яңа фактлары ачыклана. 1930 елларда Казан мед. ин-тында кислород җитешмәү һәм аллергик реакция механизмнарын өйрәнү башлана (Н.Н.*Сиротинин*, А.Д.*Адо*, М.Г.*Ерзин*). Соңрак яңа фәнни юнәлеш — аллергик реакцияләр патогенезын, гемостаз механизмнарын, лимфа системасы патофизиологиясен, иммунопатологияне ачыклауга зур йогынты ясаган *аллергология* барлыкка килә (И.М.*Рәхмәтуллин*, Л.М.Ишимова, Т.Б.*Толпегина*, Д.М.*Зөбәеров*, Д.Н.Маянский, М.М.*Миңлебаев*, А.П.*Цибулькин*, Р.С.*Фәссахов*, Ю.Е.*Микусев*, Л.Н.Иванов, В.И.Курочкин, И.П.Гаранина, А.М.*Девятаев*, Ф.И.*Мөхетдинова*, С.В.*Бойчук*, О.К.*Поздеев* һ.б.). Аллергологиянең фән буларак үсеш алуы һәм илкүләм аллергология хезмәте җәелдерелүдә ш.у. А.Д.Адо исеме б-н бәйле. 1970–80 елларда Казан ГИДУВында беренче аллергология, клиник иммунология, балалар аллергологиясе кафедралары оештырыла; аллергология буенча фәнни-тикшеренү лаб-яләре төзелә, Казандагы 7 нче хастаханәдә һәм 7 нче балалар хастаханәсендә аллергология бүлекләре ачыла. 1928 дән респ-када Татарстан патофизиологлары җәмгыяте эшли. 1952 дә Казанда П.ф. буенча 1 нче Бөтенсоюз конференциясе уздырыла. 1984 тә аллергологиягә багышланган хезмәтләре өчен А.Д.Адо СССР Дәүләт бүләгенә лаек була; 1984 тән башлап, П.ф. өлкәсендәге иң яхшы фәнни-тикшеренү эшләре өчен ТР ФАнең А.Д.Адо исемендәге бүләге бирелә башлый. Ш.у.к. *Казан медицина фәнни мәктәбе*.

*Әд.:* Тель Л.З., Лысенков С.П., Шастун С.А. Патологическая физиология: интерактив: Курс лекций. М., 2007; Популярная медицинская энциклопедия. М., 1987.

*М.М.Миңлебаев.*

**ПАТОЛО́ГИЯ-АНАТО́МИЯ МУЗЕ́Е**, Казан мед. ун-ты карамагында, 1863 елда патологик анатомия кафедрасында гамәли һәм гыйльми максатларда оештырыла. Медицинага караган беренче музей б.э.к. 3 йөз башында Александриядә төзелә. Соңрак голланд табибе, анатом Ф.Рюйшның Амстердам шәһәрендәге анатомия музее киң танылу ала. 1719 да С.-Петербургта Кунсткамера ачыла, Россиядә мед. музейлары тарихы шуннан башлана. Казан коллекциясенә Германия музейларында стажировка узып кайткан А.В.*Петров* (кафедраның беренче мөдире) нигез сала, тәүге 100 препарат аның үз кулы б-н эшләнә. 1865 тә ун-тның *Анатомия театрында* музей өчен махсус урын бирелә. 1930 да, Казан ун-тының мед. ф-ты Мед. ин-ты итеп үзгәртелгәннән соң, патологик анатомия каф. б-н бергә музей да Толстой урамындагы уку бинасына күчерелә. Музей фондларында 2 меңнән артык экспонат: гомуми һәм аерым патологик анатомиягә караган макропрепаратлар, ш.у. әгъзалар патологиясенең барлык төр белгечлек табибләрен кызыксындырырлык сирәк, уникаль нөсхәләре саклана. Фондларда юкка чыккан һәм сирәк очрый торган авыруларны (махау, чәчәк, чума, түләмә, тимгелле тиф, ваба һ.б.), авыруларның азган формаларын (сөякләргә инфильтрацияләнгән бит тиресе рагы, 30 *кг* лы аналык фибромиомасы, 15 *см* диаметрлы тире папилломасы, 200 *г* лы бәвел куыгы ташы, 6 *кг* лы кул чугы шеше, мускулларны һәм тире катлавын чорнаган зур балтыр сөяге остеосаркомасы, кызамык нәтиҗәсендә барлыкка килгән нома (биттәге йомшак тукымалар некрозы) һ.б.ны тасвирлаучы препаратлар бар. Тумыштан килгән гариплек төрләреннән аерым коллекция туплана: маңгай уртасында сыңар күзле «циклоп», түбән очлыклары балык койрыгына охшаш «сирена», «ихтиоз» — кешенең тән тиресендә тишекләр булмау, тиренең «балык тәңкәсе» б-н каплануы һ.б.

Экспонатлар арасында бик сирәк очрый торган үрнәкләр: «таш яралгы» — 69 яшьлек хатын-кыз мәетен яргандa алынган, известь б-н капланган бала гәүдәсе; туберкулёзның, беренчел стадиясеннән башлап, барлык әгъзаларны чолгап алган формалары; йөрәк-кан тамырларының төрле патологияләренә караган 30 дан артык аномаль йөрәк; өченчел сифилистан үлгән субъектның макропрепаратлары. Патологик анатомия каф. күп еллардан бирле онкология проблемалары б-н шөгыльләнә — музейда шешләрнең кешедә очрый торган барлык төрләренә диярлек караган макропрепаратлар саклана, алар арасында патологиянең үтә сирәк очраклары бар. Казан П.-а.м. — Россиядәге уникаль музейларның берсе: препаратларның барысы да диярлек раритет санала, коллекциянең туплана башлавына 200 ел чамасы. 19 һәм 20 йөзләрдә музей эше профессорлар Н.М.*Любимов*, Ф.Я.*Чистович*, И.П.*Васильев*, В.С.Подольский, Г.Г.*Непряхин*, В.А.*Добрынин*, Н.Ш.Шәмсетдинов, Д.Э.*Цыплаков* тарафыннан дәвам иттерелә.

*Д.Э.Цыплаков.*

**ПАТРИКЕ́ЕВО** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 48 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 117 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1646 дан Починок Патрикеев исеме б-н билгеле. Җирле крәстияннәр башта Зөя Троица-Сергий монастырена карыйлар, 1764 тә Икътисад коллегиясе карамагына бирeләләр, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керәләр, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында земство мәктәбе (1909 да ачыла), 3 җил тегермәне, вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1730 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановo волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 102 ир-ат; 1859 да — 500, 1897 дә — 709, 1908 дә — 850, 1920 дә — 904, 1926 да — 885, 1938 дә — 641, 1949 да — 410, 1958 дә — 381, 1970 тә — 300, 1979 да — 307, 1989 да — 160, 2002 дә — 159 кеше.

**ПАТШÁ ГАИЛӘСÉ БИЛӘМӘЛӘРЕНÉҢ КАЗÁН ÓКРУГЫ**, Казан губернасы терр-ясендә патша гаиләсе милкенә кергән җирләр, урманнар, сулар һәм җир асты байлыклары б-н идарә итүче адм. орган. 1797 елның 5 апрелендәге «Император фамилиясе турында нигезләмә» буенча Казан удел экспедициясе буларак оештырыла, 1808 нең 15 маенда кабул ителгән Уделлар департаменты кагыйдәләре б-н Казан уделлар конторасы итеп, император Александр III нең 1892 ел 26 декабрь Фәрманы б-н П.г.б.К.о. дип үзгәртелә. Округ идарәсе патша гаиләсе биләмәләре б-н һәм 1863 кә кадәр *патша гаиләсе (удел) крәстияннәре* б-н җитәкчелек итә, крәстияннәргә җир һәм урман участокларын арендага биреп тору һәм сату юлы б-н табыш алу, югары нәтиҗәлелеккә ирешүче хуҗалыкларны үстерү б-н шөгыльләнә. П.г.б.К.о.ның идарә составына башлык, канцелярия мөдире, ревизорлар, эш башкаручылар, контролёрлар, мәхкәмә эшләре буенча уполномоченный, сызым бүлмәсе мөдире, лесничийлар, җир үлчәүчеләр (барлыгы 60 тан артык кеше, 1917) керә. Канцелярия оброк, җир үлчәү, урман, мәхкәмә, инспектор, сызым, өлкән лесничий, бухгалтерия эшләрен алып бара. Уделлар департаментына, 1892 дән Россия Император сарае министрлыгының Уделлар баш идарәсенә буйсына. П.г.б.К.о. Россия Игенчелек һәм дәүләт милке министрлыгының вакытлы урман бүлегенең 1917 ел 12 июль һәм 10 август күрсәтмәләре, Эшче, солдат һәм крәстиян депутатларының Казан губерна Советы башкарма ком-тының 1917 ел 23 декабрь карары нигезендә бетерелә; 1918 нең 1 гыйнварыннан яшәүдән туктый. Ш.у.к. *Патша гаиләсе крәстияннәре*, *Удел мәктәпләре*.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 24. № 17906; Т. 30. № 23020; Собр. 3. СПб., 1895. Т. 12. № 9197.

*Е.Б.Долгов.*

**ПАТШÁ ГАИЛӘСÉ КРӘСТИЯННӘРÉ**, 18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә феодаль бәйлелектәге крәстияннәр, император Павел I фәрманы б-н 1797 елда *патша сарае крәстияннәреннән* барлыкка килә. Император гаиләсе карамагында булалар. Император гаиләсе әгъзалары биләмәсендәге җирләр һәм крәстияннәр б-н идарә итү өчен Уделлар департаменты

оештырыла. Җирлекләрдә удел экспедицияләре (ш.и. Казан экспедициясе) ачыла, 1818 дә алар удел конторалары дип үзгәртелә. П.г.к. алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре арасында тора; беренчеләренә караганда чагыштырмача иреклерәк булалар. 19 йөздә П.г.к. хәле, дәүләт крәстияннәреннән аермалы буларак, начарлана бара. Файдаланыла торган җирнең күләме сакланган хәлдә, халык санының табигый артуы сәбәпле, җан башына туры килгән имана җирләре кими бара (1820 елларда Казан губернасындагы дәүләт крәстияннәренең имана җире уртача 1 ир-атка 8 дис., П.г.к.неке бары 4 дис. генә тәшкил итә). П.г.к. дәүләт салымнары һәм имана салымы (оброк) түлиләр, алар даими артып тора. 18 йөз ахырында удел салымы ревизия буенча җан башына 5 сум 10 тиен, 1811 дә — 8 сум, 1824 тә — 10 сум була. 1830 елларда җан башыннан түләнә торган салым күләме 50994 сум, удел имана салымы — 175735 сум, халык җыемнары — 25991 сум (ш.у. земство һ.б. акчалата салымнар да була) тәшкил итә. Казан губернасында 1800 дә 10069, 1859 да 16185 ир заты исәпләнә. 1842 ел мәгълүматлары буенча Казан өязендә имана түләтү өчен исәпкә алынган 5028 зат, Лаеш өязендә — 4377, Царёвококшайскида — 2567, Тәтештә — 1013, Чистайда — 543, Спаста — 158, Мамадышта 65 зат санала.

П.г.к. яшәгән Казан тирәсендәге авылларда яшелчәчелек алга киткән була (Царицыно, Сапуголи, Аргы һәм Кече Атар, Константиновка, Әки, Щербаковка һәм Олы Дербышки авылларында сату өчен суган, кәбестә, кыяр һ.б. үстерелә). Царёвококшайск П.г.к. колмак үстерү б-н шөгыльләнәләр. Казан өязе крәстияннәре арасында агач эшкәртү һөнәрчелеге үсешкә ирешә (Коры Елга, Борисоглебский, Каравай, Кадыш авыллары); Царёвококшайск өязенең 14 удел авылы крәстияннәре дә шулай ук агач эшкәртү һәм урман кәсепчелеге б-н мәшгуль була. 1863 тә П.г.к. ирек ала.

*Әд.:* История уделов за столетие их существования. 1797–1897: В 3 т. СПб., 1901–02; Гриценко Н.П. Удельные крестьяне Среднего Поволжья: Очерки // Уч. зап. Чечено-Ингуш. гос. пед. ин-та. 1959. Вып. 11.

*Л.М.Айнетдинова.*

**ПАТШÁ САРАÉ КРӘСТИЯННӘРÉ**, Россиядә 16–18 йөзләрдә бөек кенәзләр һәм патшалар җирләрендә яшәгән, алар файдасына феодаль бурычлар башкарган феодаль бәйлелектәге крәстияннәр. Казан төбәгендә патша сарае җирбиләүчелеге 16 йөзнең 2 нче яртысыннан урнаштырыла: элек Казан ханнары һәм бәкләре милкендә булган, яуланган җирләрдә рус патшасы авыллары (Алабуга, Чаллы, Балык Бистәсе һ.б.) барлыкка килә. 17 йөз ахырында — 18 йөздә П.с.к.нең саны аларны патшаның яраннарына хосусый милек сыйфатында өләшү хисабына кими. 17 йөз ахырында Зөя өязенең Шыланглы, Тәмте һ.б. авылларында яшәгән берничә мең крәстиян император Пётр I нең өч буын туганы К.А.Нарышкинга бүләк ителә. П.с.к. башта *Казан сарай идарәханәсе*, 1724 елдан — Баш сарай канцеляриясе, 1786 дан Сарай конторасы карамагында була. 1797 дә *патша гаиләсе (удел) крәстияннәре* дәрәҗәсенә күчереләләр.

*Әд.:* Ермолаев И.П., Липаков Е.В. Крестьяне дворцовых сёл Казанского уезда в конце XVI — первой четверти XVII века (по материалам дозорных и переписных книг) // Исследования по истории крестьянства Татарии доoктябрьского периода. К., 1984.

*Е.В.Липаков.*

**ПАТШÁ ФЁДОР ИВÁНОВИЧ ФӘРМАНЫ́** (1593 ел 18 июль. «О новокрещённых татарах, об отведении для них особых пашен и истреблении мечетей»), патша хакимиятенең татар халкын ирексезләп чукындыруга юнәлтелгән документларының берсе. Фәрман Казан өязенең яңа чукындырылган, әмма православие динен ахыргача үз итеп бетермәгән татарларын Казанда аерым бистәгә күчереп утыртуны, алар өчен шәһәр янында сөрүлек җирләр бүлеп бирүне һәм чиркәү төзүне күздә тота. Христианлыктан чыккан өчен гаеплеләр төрмәгә ябыла, богаулап куела һ.б. җәзаларга дучар ителә. Фәрман мөселманнарны хезмәткә алуны, аларга акча биреп торуны тыя. Мөселманнарга үз биләмәләрендә православиедәге русларны крепостнойлыкта тотарга рөхсәт ителми. Воеводаларга Иске Татар бистәсендәге барлык мәчетләрне җимерергә әмер бирелә. Фәрман 18 йөз уртасына кадәр мөселманнарның гыйбадәтханәләрен юк итү өчен нигез буларак файдаланыла.

Чыг.: История Татарии в материалах и документах. М., 1937.

*Е.Б.Долгов.*

**ПАУ́ТКИН** Николай Михайлович (22.5.1881 — 1963), математик, проф. (1940), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1945, 1950). 1904 елда Мәскәү техник уч-щесен тәмамлаганнан соң, Мәскәү губ-насының Вороново земство хастаханәсендә су һәм канализация үткәрү б-н шөгыльләнә, 1905–06 да Акцизлар идарәсендә лаб. мөдире (Мәскәү). 1907 дән Казанда: Казан елга уч-щесендә матем. һәм механика укытучысы (1907–15), Казан сәнәгать уч-щесендә матем. укытучысы (1907–19). 1919–29 да Казан политехник ин-тында матем. профессоры, ректор ярдәмчесе (1919–21), ректор (1921–22). 1930–59 да Казан химия-технол. ин-тында проф. һәм матем. каф. мөдире, бер үк вакытта, 1930–38 дә, Казан энергетика ин-тында һәм Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында матем. кафедралары проф. һәм мөдире. Хезмәтләре матем. укыту методикасына карый. П. җепләр б-н хәрәкәтчән модельләр төзү идеясен эшли һәм тормышка ашыра, матем. кабинеты һәм оригиналь модельләр әзерләү буенча эксперим. остаханә төзи. П.ның үзгәрүчән параметрлы геом. образлар модельләштерү буенча фәнни эшләре югары техник уку йортларында югары матем. укыту өчен беренче методик ярдәмлек була. П. яңак сөяге һәм баш миенең бу сөяк янында урнашкан өлкәсе төзелешендә математ. закончалыкларны ачыклый. Рус техник җәмгыятенең Казан бүлекчәсе (1904–17), Казан физика-матем. җәмгыяте (1924 тән) әгъзасы. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Двигатель дизеля в качестве судовой машины. К., 1909; Математическое определение подхода к антруму сосцевидного отростка. К., 1928; Программа по высшей математике. К., 1932; Сопротивляемость черепа человека механическим воздействиям. К., 1935.

**ПА́УШКИН** Геннадий Александрович (28.2.1921, Казан — 15.10.2007, шунда ук), язучы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1981). Казан ун-тын тәмамлый (1949). 1950–53 елларда «Комсомолец Татарии» г-тасы редакциясендә эшли, 1953–55 тә «Комсомольская правда» г-тасының махсус хәбәрчесе. 1950 еллар ахырыннан «Литературный Татарстан» альманахы мөхәррире, 1955–65 тә ТАССР Язучылар берлегенең рус секциясе консультанты. Беренче шигырьләре армия һәм фронт газеталарында басыла башлый. «Һәрвакыт юлда» («Всегда в пути», 1954), «Туган яклар» («Родные просторы», 1958), «Кайту» («Возвращение», 2004) исемле җыентыкларга кергән шигырьләр — «фронт юллары җырлары», Ватанга, хатын-кызга, табигатькә лирик мәхәббәтне белдерү. Алар образларның реалистик символикасы б-н аерылып торалар. «Ерактагы заставада» («На дальней заставе», 1952), «Кошлар китте» («Птицы улетели», 1962), «Элемтәгә чыгам» («Слушай мои позывные», 1965), «Йолдызлар сүнми» («Звёзды не гаснут», 1967), «Кайтыгыз, ләкләкләр» («Вернитесь, аисты», 1970) исемле чәчмә әсәрләрендә солдатның хәрби батырлыгы темасына мөрәҗәгать итә. Автобиографик жанрда язылган «Карлар тагын яуды» («И так же падал снег», 1981), «Томалану» («Затмение», 1990) әсәрләр циклы, туган җир турында повесть һәм хикәяләр, Татарстан төзүчеләре һәм нефтьчеләре турында очерклар авторы. Рус теленә Х.Туфан, А.Расих, Карәхмәт һ.б.ның әсәрләрен тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Байрак орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 2.

*И.И.Андреева.*

**ПАФНУ́ТИЙ** (Шикин Потап Максимович) (1815, Саратов губ. Хвалынск ш. — 10.12.1890, шунда ук), дин эшлеклесе. Начётчик (иске дин тарафдарлары йолалары белгече), соңрак Хвалынскида иске дин тарафдарлары җәмгыяте җитәкчесе. 1855 тән — рухани, соңрак — монахлыкта. 1856 дан Рус православие иске дин тарафдарлары чиркәвенең Казан-Вятка епархиясе епископы, идарәчесе. Эзәрлекләүләрдән шикләнеп, епархия б-н, башлыча, Хвалынск янындагы Яшерен Черемшан иске дин тарафдарлары монастыреннан торып идарә итә, чит кеше документлары б-н Казанга бик еш килә. П. иске дин тарафдарларының иң абруйлы эшлеклеләренең берсе була, аның күпсанлы хезмәтләре кулъязма хәлендә тарала. Иске дин тарафдарларының Россиядәге дәүләт төзелешен һәм хакимлек итүче патриарх чиркәвен бәяләгәндә бер читтән икенчесенә ташлануларына каршы чыга. Аның шәкерте епископ Александр (Богатенко) 1920 елларда Рус

православие иске дин тарафдарлары чиркәвенең гамәлдәге җитәкчесе була.

Х е з м.: Нечаянная беседа на берегу озера «Кабана» невдалеке от архиерейского загородного дома. К., 1872; Записки по народным беседам иеромонаха Пафнутия. М., 1877; Письмо епископа Пафнутия // Старообрядческая мысль. 1915. № 1–12.

*Әд.:* М е л ь н и к о в Ф.Е. Краткая история древлеправославной (старообрядческой) церкви. Барнаул, 1999.

*Е.В.Липаков.*

**ПА́ХМАН** Семён Викентьевич (27.4.1825, Херсон губ. Одесса ш. — 29.11.1910, С.-Петербург), хокук белгече, гражданлык хокукы д-ры (1852), сенатор (1882), хакыйкый яшерен советник (1896). Дворяннар нәселеннән. Ришелье лицеен (Одесса ш., 1843), Мәскәү ун-тын (1845) тәмамлый. 1846–48 елларда Тула ир балалар гимназиясендә өлкән укытучы. 1848–52 дә Ришелье лицееның энциклопедия һәм хокук белеме тарихы каф. адъюнкты. 1852–59 да Казан ун-тында: адъюнкт, экстраординар проф. (1853–56), ординар проф. (1856 дан). 1859–66 да — Харьков, 1866–76 да Петербург ун-тларының ординар профессоры. 1873–82 дә Император галиҗәнаплары канцеляриясенең икенче бүлегендә. 1884–96 да Сенатның гражданлык кассацияләре департаментында, 1896 дан гомуми җыелышы әгъзасы. П. — хокук белемендә догматик формаль-логик юнәлеш вәкиле; Россиядә «юридик позитивизм» принципларын эшләүчеләрнең берсе. «Борынгы рус хокукы буенча мәхкәмә дәлилләре хакында» («О судебных доказательствах по древнему русскому праву», М., 1851), «Казан губернасы әҗнәбиләренең хокукый көнкүреше хакында» («О юридическом быте инородцев Казанской губернии», 1856), «Россиядә гадәти гражданлык хокукы: Юридик очерклар» («Обычное гражданское право в России: Юридические очерки», т. 1–2, СПб., 1877–79) хезмәтләре гадәти хокук системасына багышлана. «Гражданлык хокукын кодификацияләү тарихы» («История кодификации гражданского права», т. 1–2, СПб., 1876) монографиясендә П. Көнбатыш Европада һәм Россиядә борынгы заманнардан 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр кодификацияләү эшчәнлегенең механизмнарын һәм нәтиҗәләрен бәян итә. «Рус гражданлык законнары предметы һәм системасы хакында» («О предмете и системе русского гражданского уложения», СПб., 1882), «Гражданлык хокукында шәхеснең әһәмияте хакында» («О значении личности в гражданском праве», СПб., 1882) хезмәтләрендә Гражданлык законнары мәҗмугасын төзүдә Рим системасын тәкъдим итә, бу мәҗмугага сәүдә хокукын кертә, хосусый хокук кысаларын билгели һәм шәхес хокуклары турындагы нигезләмәне әйләнешкә кертә. «Гражданлык мәхкәмәсе эшләре курсы» («Курс гражданского судопроизводства», урыны һәм елы күрсәтелмәгән) һ.б. авторы. Казан ун-тының шәрәфле әгъзасы (1880). Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

*Әд.:* К о р с а к о в Д.А. Несколько слов о С.В.Пахмане // Волжский вестн. 1896. № 131; Альманах современных русских государственных деятелей. СПб., 1897; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; А ф а н а с ь е в Н.И. Современники: Альбом биографий. СПб., 1909. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ПАХО́МОВ** Алексей Михайлович (15.1.1945, Куйбышев өлкәсенең Кинель-Чиркәс р-ны Лозов МТСы пос.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2004), РФнең атказ. текстиль һәм җиңел сәнәгать хезмәткәре (1994). Куйбышев политехник ин-тын тәмамлый (1969). 1969–85 елларда Х.М.Ямашев исем. Татарстан мех җитештерү берләшмәсендә: инженер, 1971–76 да цех башлыгы, баш энергетик, 1976–84 тә ген. директор урынбасары, 1984 тән баш инженер. 1985–88 дә КПССның Казанның Бауман райкомы секретаре. 1988–2002 дә Татарстан «Мелита» мех җитештерү сәүдә-сәнәгать АҖ ген. директоры. 2002–05 тә ТР Премьер-министры урынбасары — ТР икътисад һәм сәнәгать министры. 2005–11 дә РФ Федераль Җыенының Федерация Советында ТР Дәүләт Советы вәкиле. Татарстан икътисадына караган хезмәтләр авторы. 1999–2002 дә ТР халык депутаты. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПАХО́МОВА** Валентина Михайловна (24.6.1959, Горький өлкәсенең Балахна р-ны Первомайка а.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Горький ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), РФА КГҮнең Казан биол. ин-тында эшли. 1994 елдан Казан ун-ты каршындагы Ботаника бакчасында. 1997 дән Казан аграр ун-тында, ботаника һәм үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1999 дан), биотехнол., терлекчелек һәм химия каф. профессоры. Хезмәтләре үсемлекләрнең стресслар тәэсиренә тотрыклылыгын өйрәнүгә карый. П. үсемлек күзәнәкләрендә стресс-чикләгеч сәбәпләр булуы турындагы тәгълиматны күрсәтә. Ачыгу шартларында (модельле система — киселгән тамырлар мисалында) күзәнәкләр яшәешендәге гомумбиол. закончалыкларны билгели. Һава темп-расы түбән булганда ачыгу шартларында үсемлек тукымаларының кетоз халәтен ача һәм аңа экспресс-диагностика тәкъдим итә. Үсемлек күзәнәкләрендә $H^+$-АТФаза көчәрү режимының аларның физиол. халәтенә бәйлелеге турындагы фаразны нигезли. Үсемлек күзәнәкләренең ачыгуы вакытында күзәнәк тышчасы компонентлары метаболизмын эндоген туклануның резервлы чыганагы буларак күрсәтә. РАХФАнең К.А.Тимирязев исем. алтын медале б-н бүләкләнә (2006).

Х е з м.: Модели стрессовых воздействий и общебиологические закономерности. К., 1999; Неспецифический адаптационный синдром биосистем и общие закономерности реактивности клеток. К., 2000; Биология экстремального состояния растительных клеток. К., 2001.

**ПАЦАНО́ВСКИЙ** Игорь Иванович (27.6.1955, Казан — 31.3.1998, шунда ук), химик, химия фән. д-ры (1995), проф. (1997). 1977 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1995 тән). Хезмәтләре элементорганик кушылмаларның конформацион анализына карый. П. өч һәм биш валентлы фосфорның чиксез кушылмаларының полярлыгын, полярлаша алуын һәм төзелеш үзенчәлекләрен өйрәнә. Түбән координацияле фосфор кушылмаларына конформацион анализ үткәрә (Э.А.Ишмаева б-н берлектә). Фосфор (бер һәм ике координацияле) бәйләнешләренең полярлыгы шкаласын төзи, шуның нигезендә фосфаалкиннар, фосфаалкеннар, фосфазеннар, дифосфеннар һәм башка фосфорорганик кушылмалар классларының фәзаи һәм электрон төзелеше үзенчәлекләрен һәм закончалыкларын тикшерә.

Х е з м.: Фосфаалкины — соединения однокоординированного фосфора // Успехи химии. 1985. Т. 54, № 3 (автордаш); Соединения фосфора низкой координации. Полярность, поляризуемость и особенности строения // Журн. общей химии. 1993. Т. 63, вып. 11 (автордаш); Пространственное строение галогеннитроэтенфосфонатов // Журн. общей химии. 1998. Т. 68, вып. 3 (автордаш).

*Э.А.Ишмаева.*

**ПАЧЕЛМА́ РАЙОНЫ́**, *Пенза өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 1332 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Пачелма посёлогы (Пенза шәһәреннән 110 *км* көнбатыштарак). Халкы — 15887 кеше (2012), ш.и. 2,8 меңләп татар. Татарлар тупланып Ногай авылында (2002 дә — 1308 кеше) һәм Чулпан посёлогында (129), Татар Никольскоесы авылында (135 кеше) руслар б-н катнаш яшиләр. 1877 елгы мәгълүматларга караганда, Ногайда 1474 татар исәпләнә; 2 мәчет, 2 ипи кибете, 3 тегермән, 1 тимерчелек эшли; 1894 тә Татар Никольскоесы авылында 1620 кеше яши; 2 мәчет: таш (1920 еллар ахырына кадәр эшли) һәм агач (1961 елда ябыла), 2 мәдрәсә, 4 поташ з-ды, 5 су тегермәне була. 1927 дән Татар Никольскоесында башлангыч татар мәктәбе (1947 дә җидееллык рус мәктәбе итеп үзгәртелә) эшли. Хәзерге вакытта Ногай авылы урта мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Ногай һәм Татар Никольскоесы авылларында мәчет эшли (1994 тән).

**ПА́ШИН** Дмитрий Михайлович (19.5.1963, Мәскәү), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002), проф. (2007). 1986 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук микроэлектрон аппаратуралар конструкцияләү һәм җитештерү кафедрасында эшли, бер үк вакытта «Нанотехнологияләр һәм наноматериаллар» фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары (2007 дән), ТР нанотехнологияләр үзәге ген. директоры (2012 дән). Хезмәтләре мәгълүматны электрохимик үзгәртүгә нигезләнгән информацион-үлчәү техникасына карый. П. гидроакустик сигналларны комачаулыклар фонында, бу сигнал чыганакларының параметрларын оптималь табу һәм фильтрлаштыруны да кертеп, күпкомпонентлы кабул итү теориясен һәм алымнарын эшли.

Х е з м.: Информативные признаки гидроакустических полей подвижных источников // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2000. № 3 (автордаш); Многокомпонентный приём гидроакустических сигналов на фоне помех. К., 2001 (автордаш); Анализ вариантов технических и технологических решений электронных устройств при обеспечении их конкурентоспособности. К., 2006 (автордаш).

**ПАШИ́НО** Пётр Иванович (5.2.1836, Пермь губ. Эрбет ш. — 3.9.1891, С.-Петербург), сәяхәтче, журналист. 1845–52 елларда Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укый, татар, монгол, кыргыз һ.б. телләрне өйрәнә; И.И.Хәлфинның «Татар риваятьләре»ннән бер өзекне тәрҗемә итә («Казанские губернские ведомости» г-тасында басыла). 1852 дә Казан ун-тының тарих-филол. ф-тына кабул ителә, тиздән гарәп-төрек-татар бүлегенә күчерелә. 1855 тә Казан ун-тының Шәрекъ бүлеге Петербургка күчерелү сәбәпле, Петербург ун-тының Шәрекъ телләре ф-тына күчә (аны 1856 да тәмамлый). 1856 да Болгар шәһәрлегендә казу эшләрендә катнаша (аның нәтиҗәләре диссертация нигезенә салына). 1857 дә Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында хезмәт итә. 1861–62 дә Персиядә Россия илчелегенең 2 нче сәркәтибе була. 1864 тә татар телендә «Файда» ж-лын чыгарырга ниятли, әмма хакимият рөхсәт бирми. 1864–69 да Тышкы эшләр министрлыгының Азия департаментында тәрҗемәче. 1866 ның февралендә Оренбург хәрби округы командующие гаскәре карамагына Төркестан һәм Урта Азиянең күрше ханлыклары турында мәгълүматлар җыю максатыннан командировкага җибәрелә. 1870–72 дә Төркестан өлкәсе генерал-губернаторы канцеляриясендә тәрҗемәче булып эшли. 1872 дә «Азиатский вестник» ж-лы чыгарырга омтылыш ясый (бер саны дөнья күреп кала). Сәяхәтләре һәм күзәтүләре турындагы очеркларын «Очерки», «Голос», «Санкт-Петербургские ведомости», «Новости», «Русский мир» г-таларында, «Живописное образование», «Церковно-общественный вестник» ж-лларында бастыра. 1860 та «Современник» ж-лында П.А.Шино псевдонимы б-н «Идел буе татарлары» («Волжские татары»), «Җыен» («Джийин»), «Авыл мулласы» («Деревенский мулла»), «Акбодай авылы һәм Ризван бай» («Деревня Акбудаево и Ризван-бай») очерклар сериясен бастыра. Аның очерклары Россия һәм Шәрекъ халыкларына ихтирам хисе б-н сугарылган. 1873–76 да Һиндстан һәм Әфганстан буйлап 3 сәяхәт кыла. Һиндстанда алган тәэсирләре «Сыерлар патшалыгында алты ай» («Шесть месяцев в коровьем царстве»), «Һинд табибе» («Индийский доктор») очеркларында да чагылыш таба.

Х е з м.: Туркестанский край в 1866 г.: Путевые заметки. СПб., 1868; Вокруг света. Т. 1. По Индии: Путевые впечатления. СПб., 1885.

*Әд.:* Г н е в у ш е в а Е.И. Забытый путешественник: Жизнь и путешествия П.И.Пашино. М., 1958; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. М., 1989; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**ПАШКО́ВСКИЙ** Христофор Григорьевич (4.5.1842 — 4.3.1911, Казан), архитектор, педагог, уйлап табучы. 1866 елда САн архит-ра рәссамы һәм гимназиядә рәсем укытучысы дәрәҗәләренә ирешеп тәмамлый. С.-Петербургта төзелеш ведомствосы учреждениеләрендә эшли. 1875–1911 дә Казан реаль уч-щесендә рәсем һәм сызым дәресләрен алып бара, бер үк вакытта Казандагы башка урта уку



Х.Г.П а ш к о в с к и й. Реаль училище бинасы. Казан. 1878.

йортларында (кызлар гимназиясендә, укытучылар ин-тында) эшли. П.да Ш.Ә.*Таһиров* рәсем ясарга өйрәнә. Казандагы күп кенә зур биналарның (Реаль уч-ще (1878), А.А.Кремлёвның табыш йорты (1880) һ.б.) проектлары авторы; башлыча, классицизм юнәлешендәге эклектика стилендә эшли. Яңа төзелеш материаллары уйлап табу б-н шөгыльләнә.

Х е з м.: Огнестойкие бетонные и глинобетоноцементированные крыши системы Пашковского. К., 1890.

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина, Е.В.Липаков.*

**ПА́ШКУРОВ** Алексей Николаевич (25.6.1972, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1994), 1997 дән шунда ук эшли. Фәнни хезмәтләре Г.Р.Державин, А.Н.Муравьёв, Е.А.Боратынский, Г.П.Каменев иҗатларына карый. «Рус сентиментализмы һәм башлангыч романтизмында Күтәренкелек категориясе: Эволюция һәм типология» («Категория Возвышенного в поэзии русского сентиментализма и предромантизма: Эволюция и типология», 2004) монографиясе авторы.

**ПАШУ́ТИН** Виктор Васильевич (16.1.1845, Новочеркасск ш. — 20.1.1901, С.-Петербург), патофизиолог, медицина д-ры (1870). Россия мед. фәнендә патологик физиологиягә нигез салучы. Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (1868), шунда ук эшли. 1871 дә Германиядә (Лейпциг, Страсбург шәһәрләре) фәнни командировкада була. 1874 тән Казан ун-тының гомуми патология кафедрасында, проф. (1879). 1890 нан Петербург хәрби-мед. академиясе башлыгы. Бер үк вакытта, 1889 дан, Эчке эшләр министрлыгының мед. советы рәисе. Хезмәтләре ашказаны физиологиясенә, матдәләр алмашы патологиясенә, ач торуны өйрәнүгә карый. Кеше организмын күзәтү өчен, П. беренче булып калориметр конструкциясен эшли. Чума эпидемиясе чыганакларында эшләүче мед. персоналы өчен саклагыч костюм уйлап таба.

Х е з м.: О движении кишок у кошки при раздражении блуждающих нервов // Мед. вестн. 1865. № 14; Разрушение витамина вследствие действия его на крахмалистые вещества. СПб., 1871; Понятие о миазматических и контагиозных началах; место, занимаемое чумою в ряду других заразных болезней // Уч. зап. Казан. ун-та. 1879. Т. 15, вып. 2.

**ПӘРӘВЕЗЛЕ́ ТАЛПАННА́Р** (Tetranychidae), акариформлы талпаннар отрядыннан үрмәкүчсыманнар семьялыгы. Россиядә 100 дән артык төре билгеләнгән. Татарстан терр-ясендә П.т. киң таралганнар, әмма төр составлары өйрәнелмәгән. Үсемлекләрдә яшиләр. Вак (0,2–1 *мм*) талпаннар. Гәүдәсе озынча түгәрәк, бөтен, инә-, яфрак- һәм каурыйсыман төкчәле. Капламы юка. Саргылттан ачык кызгылт-сарыга кадәр һәм кызыл төстә. Авыз аппараты капламнарны тишүгә һәм күзәнәк сыекчасын суырууга җайлашкан. Кыска, төбеннән үк кушылып үскән педипальпалар эчендә пәрәвез бизләре (исеме шуннан) урнашкан, арткы очындагы буынында аларның юллары ачыла. Пәрәвез аларга сакланырга һәм һава агымы б-н очып таралырга булыша. Аяклары нечкә, тырнаклы тәпиләре яфракларда тотынып тору өчен кирәк. Эчке аталану хас, кайвакыт партеногенез күзәтелә. П.т. күкәйләрен яфрак өслегенә беркетәләр, кайры ярыкларына кышлаучы күкәйләрне салалар. Үсеш циклын личинка, 2 нимфа һәм җитлеккән зат чорлары тәшкил итә. П.т. арасында культуралы үсемлек корткычлары очрый. Гади пәрәвез талпаны (Tetranychus telarius) аеруча күп зарар китерә, ачык грунтта, ш.у. теплицада үсүче үсемлекләрне зарарлый. П.т. ш.у. үсемлекләрдә йогышлы авыруларны тараталар.

*Н.В.Шулаев.*

**ПӘРӘМӘ́Ч**, традицион татар милли ризыгы; камыр ашы. Гадәттә, түгәрәк итеп, өске өлешендә зур булмаган тишек калдырып ясала; эче камырдан эченә ит (майлы сарык ите яисә сыер ите), бәрәңге, сирәк кенә эремчек (эремчекле П. өчен төче камыр кулланыла) салып әзерләнә. П.не кайнап торган майда



Пәрәмәч.

яки мичтә пешерәләр. Табынга кайнар килеш шулпа, *катык* яисә *әйрән* б-н бирелә. Татарларда кияүне П. б-н сыйлау гадәте сакланып калган; «кияү пәрәмәче» гадәти П.тән ваграк итеп әзерләнә.

*Әд.:* Татарская кулинария. К., 1981; Х а й р у т д и н о в а Т.Х. Названия пищи в татарском языке. К., 1993.

**ПӘРӘ́Ү** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 21 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 750 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә.

1602–03 еллардан Перевьи (Перово) авылы буларак билгеле, хәзерге исеме 1710–11 елгы чыганакларда очрый. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.дә мәчет, мәдрәсә, 2 су һәм 6 җил тегермәне, тимерчелек, 6 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2431,37 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1728 дә — 140 ир-ат; 1859 да — 866, 1897 дә — 1611, 1908 дә — 1826, 1920 дә — 1921, 1926 да — 1694, 1938 дә — 1530, 1949 да — 1127, 1958 дә — 1077, 1970 тә — 1189, 1979 да — 994, 1989 да — 825, 2002 дә — 791 кеше.


**ПӘРИ́** (Пери, Пәри), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Урта Азия, Кавказ һәм Идел буе халыкларының мифологиясе, фольклоры һәм язма әдәбияты персонажы, рух. Тамыры б-н борынгы фарсы мифологиясенә барып тоташа, анда ул явыз рух. Аның асылына уңай төсмерләр, сыйфатлар килеп керә. Урта гасырлар башында төрки халыклар мифологиясе, фольклоры һәм язма әдәбиятында П. — явызлык (*аждаһа, дию* б-н охшаш) һәм мәрхәмәтлелек сыйфатларын гәүдәләндергән катлаулы һәм каршылыклы персонаж. П. хатын-кыз, сирәгрәк ир-ат, җәнлек, күгәрчен кыяфәтендә яисә учак ялкыны рәвешендә күренергә мөмкин. Идел буе, Урал төркиләре ышануларында икенче бер явыз рух — дию б-н янәшә куела. Татар әкиятләре, хикәяләре һәм дастаннарында чибәр һәм батыр каһарманнар, гадәттә, кеше б-н П. никахыннан туган дип санала («Идегәй», «Сәйфелмөлек»), кайчак алар су асты патшалыгына нисбәтле («Түләк», «Ийртөшлек», «Алтын балык»). Кайбер фольклор әсәрләрендә П. көтүләре («Чүмеч», «Өч күгәрчен»), П. шәһәрләре («Тапкыр егет») турында сөйләнә. Бараба татарларында П. — зәхмәтле тәмугъ көче, ул һавада очып йөри, П. кагылган кеше сөйләшү һәм ишетү сәләтен югалта. П. кешеләрне, күп очракта сабый балаларны һәм балигъ булмаган яшь кызларны алыштыру сәләтенә ия («пәри алмаштырган» кебек әйтемнәр шуны раслый). Кешене алыштыру темасы «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да чагылыш таба: Зөләйха үзенең карт ире, Мисыр хакимe янына гүзәл П. кызларын җибәрә. Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Харәзминең «Мәхәббәтнамә» поэмаларында П.ләр гүзәллек фәрештәләре, оҗмахтагы хур кызлары кыяфәтендә сурәтләнә (мәҗүсилек һәм мөселман күзаллауларының үрелүе). П. образы Г.Тукай, Г.Исхакый, Н.Думави әсәрләрендә дә урын ала.

*Әд.:* Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Баязитова Ф.С. Себер татарлары. Рухи мирас: Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. К., 2001; Авеста в русских переводах (1861–1996). СПб., 1997; Рак И.В. Мифы древнего и раннесредневекового Ирана (Зороастрийская мифология). СПб., 1998.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ПБЛ-5 ТЫРМАСЫ́**, туфракның су-һава режимын яхшырту максаты б-н камыллы, кәсле җирләрне 5–7 *см* тирәнлектә аэрацион тырмалау өчен ЛДГ-5 туфрак йомшарткычына куелган конуссыман тешле дисклы тырмалау җайланмасы.

Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Н.К.*Мәҗитов* тарафыннан уйлап табыла (1989). «Сибсельмаш» ҖБнең Баш махсус конструкторлык бюросы, Бөтенроссия механикалаштыру ин-ты тарафыннан эшләнә һәм «Нива Татарстана» ФҖБ җитештерүенә күпләп кертелә. Болын һәм көтүлекләрне эшкәрткәндә сулыклар экологиясенә зыян китерми торган бердәнбер функциональ машина. Тырманың секциясе кисек конус формасында, туфрак йомшарткычтагы һәрбер дискның диаметры 15 *мм* га кечерәя бара. Кисә торган дискларында йомшарткыч тешләр бар (8 дән 14 кә кадәр). Тырманың төрле диаметрлы секциясенең берничә әйләнмә



ПБЛ-5 тырмасы.

тизлектәге дисклары ярдәмендә махсус күчергечтән башка да туфракны нәтиҗәле эшкәртә. Туфрак йомшарткыч секция б-н конуслы секциянең унификация дәрәҗәсе — 70%. Җитештерүчәнлеге — 6 *га/сәг.* Нәтиҗәлелеге: күпьеллык үләннәрнең уңышы — 12–50% ка арта, энергия чыгымы 2 тапкыр кими. ПБЛ-5 тырмасы СССР ВДНХсының алтын медаленә лаек була. 1989 елда Дәүләт комиссиясе тарафыннан дөньякүләм дәрәҗәгә туры килүче һәм югары категорияле сыйфатка ия буларак җитештерүгә кертелә. Татарстан, Литва, Белоруссиядә сынау үтә.

**ПЕДАГО́ГИЯ ИНСТИТУТЫ́**, Казан университеты каршында, 1804 елгы Устав нигезендә ун-т тәмамлаучыларны укытучылык эшчәнлегенә әзерләү өчен оештырылган бүлекчә. 1812 нең 28 маенда ачыла. Институтка әхлак һәм сәясәт, физика һәм матем., тел фәннәре бүлекләрен тәмамлаучылар кабул ителә. Уку срогы 3 ел була. Укучылар укыту өчен сайлаган фәннәр буенча үзләренең белемнәрен камилләштерәләр, ун-т студентлары өчен сынау лекцияләре уздыралар, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә дәресләр бирәләр. Университетның иң яхшы студентлары өчен П.и. хәзерге аспирантурага охшаш була, уку барышында алар магистрлык диссертациясе әзерлиләр, укуларын тәмамлаганнан соң, университет укытучылары итеп билгеләнәләр. 1835 елгы Устав нигезендә П.и. студентларны пед. эшчәнлеккә әзерләү бүлекчәсе итеп үзгәртелә. Институтка «казна карамагындагы» студентлар мәҗбүри тәртиптә кабул ителә. Физика-матем. һәм тарих-филол. ф-тларының 2 нче курс студентлары алына. Алар атналык семинарларда катнашалар, шәһәрнең урта уку йортларында дәресләр бирәләр, студентларга лекцияләр укыйлар, 1851 дән, каф. булдырылганнан соң, пед. тарихы һәм дидактика фәннәрен өйрәнәләр. 1855 тә ябыла, пед. эшчәнлеккә әзерләү ун-тның физика-матем. һәм тарих-филол. ф-тларының мәҗбүри уку планына кертелә. Институтта укучылар арасында Н.И.*Лобачевский*, И.М.*Симонов*, И.Н.*Ульянов* һ.б. була.

**ПЕДИАТРИ́Я** (грек. páis, и.к. paidós — бала һәм iatréia — дәвалау), мед. өлкәсе, бала организмының анатомик-физиол. үзенчәлекләрен, балаларның авырып китү механизмын һәм сәбәпләрен, балалар авыруларына диагноз кую, аларны дәвалау һәм кисәтү ысулларын өйрәнә. П.нең иң мөһим бүлекләреннән берсе — балалар һәм үсмерләр гигиенасы. П.гә б.э. кадәр 4 йөздә нигез салынган дип санала (Гиппократның «Бала табигате турында» — «О природе ребёнка» хезмәте). 15–18 йөзләрдә яңа туган балаларны карау һәм тәрбияләү турындагы хезмәтләр барлыкка килә (мәс., Ф.Глиссонның — рахит, Т.Сиденхем, Э.Дженнерның — йогышлы авырулар, Ниль Розен фон Розенштейнның П. турындагы хезмәтләре һ.б.). П., мөстәкыйль фәнни дисциплина буларак, терапия, акушерлык кебек мед. белгечлекләреннән аерылып чыга. Россиядә галим-акушер, педиатр С.Ф.Хотовицкий Петербург мед.-хирургия академиясендә балалар авырулары курсыннан лекцияләр укый (1831–47), 1847 елда балалар авырулары буенча беренче русча ярдәмлек — «Педиятрика» дәреслеген нәшер итә. 1834 тә Мәскәүдә беренче балалар хастаханәсе ачыла (хәзер Россиядә П.гә нигез салучыларның берсе Н.Ф.Филатов исемен йөртә, шунда табибкә, «Балалар дустына» дип язып, һәйкәл куелган). 1909 да Казанда Балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыяте оештырыла. 1900 елларга кадәр П.дә үсү чорлары физиологиясе һәм балалар авырулары турында актив рәвештә гыйлемнәр туплау дәвере бара. 1920 елларда П. мәктәпләре челтәре җәелдерелә; 1922 дә Мәскәүдә «Педиатрия» ж-лы чыга башлый.

Казан ун-тының мед. ф-тында балалар авырулары буенча аерым курсны акушерлык осталыгы профессоры А.Е.Лентовский кертеп җибәрә (1844); гамәли курс клиникада (авыруның ятагы янында) уздырыла, пациентның авыру тарихын тутыру мәҗбүри итеп куела (1850). 1853 тән П. курсын Г.И.Блосфельд, И.И.Зедерштадт, Л.К.Сутковский, А.Н.Бекетов, А.И.Козлов алып бара. Ун-тның мед. ф-тында П. кафедрасының беренче җитәкчесе итеп проф. Н.А.Толмачёв сайлана (1875–93). Ул балаларны объектив тикшерү ысулын кертә, махсус җиһазландырылган лаб-ядә клиник һәм биохимик тикшеренүләр үткәрелә. Н.А.Толмачёв, В.М.Флоринский һәм Н.А.Виноградов үтенече б-н факультет клиникасында беренче балалар амбулаториясе оештырыла, шунда ук, «иске клиникада», балалар бүлеге дә урнаша (1879). Мед. ф-тында балалар авырулары курсын укытуны, балалар авыруларын өйрәнүне камилләштерүдә П.М.Аргутинский-Долгору-

ков инициативасы б-н төзелгән, Арча кырындагы мед. шәһәрчегендә 1909 да ачылган, табиб-педиатрлар өчен үрнәк мәктәпкә әверелгән яңа балалар клиникасының роле зур була. Мед. персоналы өчен оештырылган әзерлек дәресләрен П.М.Аргутинский-Долгоруков алып бара, клиника китапханәсе ш.у. аның тарафыннан оештырыла. 1911 дән клиника б-н проф. В.К.Меньшиков җитәкчелек итә; 1 яшькә кадәрге балалар үлеме аеруча югары булу сәбәпле, ул күкрәк балалары бүлегенең эшен Европа клиникалары үрнәгендә оештыра, анда сәламәт һәм авыру балалар диетикасы буенча тикшеренүләр уздырыла — шул рәвешле кече яшьтәге балалар диетологиясен өйрәнүгә нигез салына. 1930 дан клиника Казан мед. ин-тының укыту базасына әверелә. Балалар тукылануы проблемалары Е.М.Лепский һәм аның җитәкчелегендәге хезмәткәрләр тарафыннан өйрәнелә; 1917 дә Е.М.Лепский җитәкчелегендә Сабыйлар йорты ачыла, анда иң кече яшьтәге балалар өчен барлык шартлар тудырыла. 1918 дә Казан губернасы мед. хезмәткәрләренең 2 нче съезды була. 1919 да Е.М.Лепский, Казан губерна сәламәтлек саклау бүлеге кушуы буенча, шул чорның иң яхшы балалар учреждениеләре үрнәгендә, җитлекмичә туган балалар өчен аерым бүлеге, сөт кухнясы, клиник, биохимик һәм бактериологик лаб-яләре, балалар консультациясе булган хастаханә ачтыра. 1921 дә хастаханә, балалар клиникасы буларак, Казан ГИДУВы составына кертелә. Йогышлы авырулар киң таралу һәм балалар үлеме, аеруча 1 яшькә кадәрге балалар үлеме югары булу педиатрлар алдына йогышлы авырулар патологиясен өйрәнү бурычын куя; педиатрия, эпидемияләргә һәм йогышлы авыруларга каршы көрәш хезмәтләре оештырыла, нәтиҗә буларак, кызамык, кызылча (скарлатина), бума ютәл, дифтерия кебек йогышлы авырулар йоктыру очраклары кими.

Казан мед. ин-тында педиатрия ф-тын оештыручы һәм аның беренче деканы Е.М.Лепский була; аның җитәкчелегендә авитаминоз һәм гиповитаминоз проблемалары өйрәнелә; тикшеренү нәтиҗәләре «Рахит һәм рахит белән авыручыларда тетания» («Рахит и тетания рахитиков», 1945, Р.И.Лепская б-н берлектә), «Авитаминоз һәм гиповитаминозларны дәвалауга кереш» («Введение в клинику авитаминозов и гиповитаминозов», 1948) монографияләрендә чагылыш таба.

Респ-када химия сәнәгатенең интенсив үсеш алуы балаларда аллергия авырулары ешаюга сәбәп була. 1948 дә Казанда Казан ГИДУВындагы аллергология кафедрасының уку-укыту базасына әверелгән 7 нче балалар хастаханәсе (120 ятак-урын) ачыла. Бөек Ватан сугышыннан соң мед. ин-тында П.гә караган кафедралар: балалар авырулары (1948), госпиталь һәм ф-т П.се (1952), балалар хирургиясе (1967), балалар йогышлы авырулары (1980) кафедралары оештырыла. 1950–80 елларда яңа туган балалар физиологиясе һәм патологиясе (А.Х.Хәмидуллина, Е.В.Белогорская), рахит, ревматоидлы артрит, бөер авырулары, эндемик зоблы балалар үсеше (К.А.Святкина) проблемаларын өйрәнү актуальләшә.

Казан мед. ин-тының А.Ф.*Агафонов* тарафыннан оештырылган балалар йогышлы авырулары каф. балаларда була торган йогышлы авыруларның кайберләрен юкка чыгаруга зур өлеш кертә. 1955 тән табибләр һәм галимнәр, максатчан рәвештә, ТАССРда дифтерияне бетерү юнәлешендә эшлиләр (М.С.Залужная, В.И.Качурец, Г.В.Краева, Н.П.Кудрявцева, Л.М.Малышева, Г.Г.Надыйрова, О.П.Румянцева, С.Х.Хәбибуллина, А.Р.Шәһидуллина, Н.С.Шәмсетдинов һ.б.).

1960–70 елларда байтак фәнни эшләр менингококк инфекциясен өйрәнү б-н бәйле була. Шокка каршы актив терапия һәм нейроинфекциянең авыр формаларына дучар балаларны дәвалау буенча тәкъдим ителгән эшләр хәзерге чор терапиясенең нигезен тәшкил итә. Казан балалар йогышлы авырулары хастаханәсендә авыр хәлдәге балалар өчен проф. А.Д.Царегородцев башлангычында ачылган реанимация бүлеге эшли.

1972 дән Татарстанда балалар неврологиясе хезмәте эшли, 1988 дә Казан. мед. ин-тының балалар неврологиясе каф. (мөдире А.Ю.Ратнер) өчен база булып торган Казан шәһәре 8 нче клиник хастаханәсе (120 ятак-урын) сафка баса. 1977 дә ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка балалар клиник хастаханәсе ачыла, ул Россия күләмендәге алдынгы мед. учреждениеләренең берсенә әверелә. 1982 дә Казан мед. ин-тында балалар авырулары гомуми каф. (мөдире Н.А.Романова), соңрак 1 нче һәм 2 нче балалар авырулары кафедралары (мөдирләре О.И.Пикуза һәм В.П.Булатов), 1989 да — поликлиника П.се каф. (мөдире А.П.Пигалов) оештырыла. Алар балалар авыруларының таралышы, төрле яшьтәге балаларда сулыш алу әгъзалары авыруларын стационар һәм амбулатор шартларда дәвалау һәм кисәтү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә. 1991 дән, неонатология каф. ачылганнан соң (мөдире Л.К.Фазлыева), яңа туган балалар физиологиясе һәм патологиясе проблемалары тирәнтен өйрәнелә башлый.

1980–90 елларда фәнни эзләнүләр өлкәсе киңәя: дифтерия, әчәклектәге бактериаль йогышлы авырулар, дисбактериозлар, СПИД, вируслы гепатитлар (балалар йогышлы авырулары кафедрасы мөдире В.А.Анохин) өйрәнелә. 1990 еллар башына Татарстанда дифтерия бетерелә.

2000 еллардан П. галимнәренең игътибар үзәгенә балаларда ВИЧ-инфекция патологияләрен өйрәнү, авыру балаларны комплекслы тикшерү һәм дәвалау, дәвамлы күзәтүдә тоту мәсьәләләре куела. 2004 тән Казан мед. ин-тының П. кафедраларында алып барыла торган төп фәнни юнәлешләр: балалар авырулары патогенезын, клиникасын, диагностикасын өйрәнү; зарарлы экологик шартларда яшәүче балаларда гастродуоденобилиар зона һәм ашказаны асты бизе авырулары очракларында дәвалауның патогенетик схемаларын эшләү; яңа туган балалар патологияләрен дәвалау (госпиталь П.се кафедрасы). 1 нче балалар авырулары кафедрасының үз алдына куйган бурычларыннан берсе — ТРдагы антропоген тәэсиргә дучар булган балаларга мед. тикшерүне уздыру; кафедрада авыруларны терапия чаралары б-н алдан кисәтү ысуллары, көчле респиратор авыруларны дәвалау стандартлары, балаларда көчле үпкә ялкынсынуы очракларына экспресс-диагностика методикасы эшләнә, фармакоэпидемиологик тикшеренүләр уздырыла. 2006 дан Казан мед. ун-тында балалар авырулары пропедевтикасы һәм факультет П.се кафедралары (мөдире О.И.Пикуза), госпиталь П.се каф. (мөдире В.П.Булатов), балалар йогышлы авырулары каф. (мөдире В.А.Анохин) эшли. ТРның балалар дәвалау учреждениеләре: Респ-ка балалар клиник хастаханәсе, 12 балалар хастаханәсе, 17 балалар поликлиникасы, 8 балалар санаторие; реабилитация, перинаталь, гаиләне планлаштыру үзәкләре һ.б. Татарстанда 1600 дән артык педиатр исәпләнә (2011).

*Әд.:* Популярная медицинская энциклопедия. М., 1987; Билиарная патология у детей. М., 1993.


*В.А.Анохин.*


**ПЕЙЗА́Ж** (франц. paysage), табигать күренешләрен, ш.у. нигездә шул жанрда башкарылган сәнгать әсәрен сурәтләүгә багышланган сынлы сәнгать, бигрәк тә нәкышь һәм графика жанры. П., мөстәкыйль жанр буларак, 7 йөздә Кытай, 17 йөздән Европа сәнгатендә үсеш ала. Күренеш П.ы жанрында Казан һәм Казан төбәге гәүдәләндерелгән әсәрләр 17 йөздән күп кенә чит ил һәм рус рәссамнары тарафыннан иҗат ителә (А.Олеарий, Н.Витсен, И.-В.Люрсениус, К. де Бройн, Ж.Жакотте, А.Дюран, Н.Ф.Челнаков, А.Г.Рудаков, М.И.Махаев, А.И.Свечин, П.Т.Балабин, Е.М.Корнеев, Г.Г. һәм Н.Г.Чернецовлар, К.П.Беггров һ.б.). 19 йөзнең 1 нче яртысында Казанда яшәгән рәссамнар В.С.Турин, Э.Турнерелли график күренеш пейзажы жанрында иң яхшы архит-ра истәлекләреннән һәм шәһәр күренешләреннән торган эстамп серияләрен иҗат итәләр. Н.Н.Кафтанников, П.Ф.Табуреның 1830 еллардагы Казан басмаларында, «*Заволжский муравей*» ж-лындагы график рәсемнәре П. характерында. Казан ун-тының рәсем классы укытучысы, САдә белем алган Н.А.Ракович (яңа П. нәкыше мәктәбенә нигез салучы М.Н.Воробьёв шәкерте) П.ы нәкышь жанрында эзлекле һәм нәтиҗәле эшли. Аның нәкышь һәм акварельләре Казанда П. жанрын яңа дәрәҗәгә күтәрә.



19 йөзнең 2 нче яртысында Урта Идел һәм Кама буе табигате рус пейзаж нәкышенең «алтын» фондын тулыландырган күренекле рус пейзажчылары И.И.Шишкин, Л.Л.Каменев, А.П.Боголюбов, К.Ф.Гун картиналарында урын ала. 1895 елда ачылган Казан сәнгать мәктәбе, махсус пейзаж классы булмаса да, П. жанрын үстерүгә көчле этәргеч бирә. Мәктәп укытучылары И.А.Денисов, Х.Н.Скорняков нигездә пейзаж осталары булып таныла, Г.А.Медведев, П.П.Беньков, Н.И.Фешин иҗатында П. зур урын алып тора. 1920 еллар сәнгатендә П. жанры, шактый зур үзгәрешләр кичереп, графикада аеруча ачык гәүдәләнеш ала. Экспрессионизмнан










**Пейзаж.** 1. В.С.Турин. «Гостиный дворның бер өлеше һәм Казан руханилар семинариясе». Агач өслегенә ябыштырылган кәгазь. Майлы буяулы офорт. 1820 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Э.П.Турнерелли. «Воскресенский урамы». «Казан күренешләре» альбомы бите. 1839. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. А.Н.Ракович. «Ослан тавыннан Казан күренеше». Акварель. 1845. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. В.Л.Лаптев. «Шәһәр». Кәгазь, линогравюра. 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. И.Н.Плещинский. «Паркта». Кәгазь. Акварель, графитлы карандаш. 1924. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Б.И.Урманче. «Әүлияата даласы». 1949; 7. К.Е.Максимов. «Урман». 1950. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. М.Г.Госманов. «Яңа Кама». 1970. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. К.А.Васильев. «Зөя өстендә». 1975. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Э.Я.Зарипов. «Тынлык». Линогравюра. 1979; 11. Л.А.Потягунин. «Елга киңлекләре. Алабуга шәһәре янында Кама елгасы». Линогравюра. 1985. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. Л.В.Прокопьев. «Яз исе килә». 1985–86. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 13. И.К.Зарипов. «Кышкы пейзаж». 1992; 14. А.Р.Ильясова. «Күл буенда». Ташбасма. 1993. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

алып кубофутуризмга кадәрге яңа стилистик юнәлешләрне ачыклау өчен киң мөмкинлекләр биргән шәһәр П.ы яңа эчтәлек б-н тулылана. Вак темаларның һәм «этюдчылык»ның капма-каршысы булган урбанистик үрнәкләр «Подсолнечник», «Всадник», ТатЛЕФ берләшмәләре әгъзалары — рәссамнар: К.К.Чеботарёв, И.Н.Плещинский, Е.А.Александров, Д.М.Фёдоров һ.б.ның әсәрләрендә зур урын били. Н.М.Сокольский, В.В.Кудряшов, Н.С.Шикалов, П.М.Дульскийның графика П.ы серияләрендә Казан архит-расы истәлекләре яңача ачыла. А.Г.Платунова, П.М.Зотовның камера пейзажы характерындагы әсәрләре символик-аллегорик эчтәлеге б-н аерылып тора. ТатАХРР вәкилләре Г.А.Медведев, П.А.Радимов, Н.П.Христенко, И.И.Князьков, А.К.Лукоянов һ.б. иҗатында П., заманның социаль әһәмияткә ия билгеләре б-н баетылып, традицион реализм юнәлешендә үсә. Әлеге тенденция соц. реализм кысаларында иҗат алымнарын унификацияләү чоры булган 1930–50 елларда өстенлек итә. Д.П.Архипов, В.Л.Лаптев, П.М.Байбарышев, В.А.Родионов, Д.Г.Булат, Ш.Н.Мөхәммәтҗанов, В.К.Тимофеев һ.б. картиналарында П. еш кына индустриаль һәм колхоз хезмәте кайнаган күренеш фонына әйләнеп кала. Әлеге чорның барлык диярлек рәссамнары иҗатындагы камера П.нда объективлыкка, реалистик конкретлыкка, табигать күренеше һәм халәтенең тормыштагыча чынлыгына ачыктан-ачык омтылу хас. 19 йөзнең 2 нче яртысында рус П. нәкышенең (аерым алганда, И.И.Шишкин) традицияләренә таянган К.Е.Максимов иҗаты эпик П. жанрын яңарту теләге б-н сугарылган.

20 йөзнең 2 нче яртысы сәнгатендә П. жанры зур үзгәрешләр кичерә. П.ның географиясе киңәя, жанр күренеш типларына байый, индустриаль һәм тарихи П. үсеш ала — тематик серияләр, триптихлар һәм полиптихлар, жанрара характердагы әсәрләрнең яңа формалары барлыкка килә: натюрморт П.ы, тематик картиналар П.ы һ.б. Графика сәнгатендә П. яңадан тигез хокуклы урын ала. Пейзаж нәкыше палитрасы төсләр һәм тоннар нисбәтләренең киң спектры б-н байый. Н.Д.Кузнецов, Р.В.Нурмөхәммәтов, В.А.Попов, М.Г.Госманов әсәрләрендә нефть химиясе сәнәгате гигантлары, респ-кадагы яңа шәһәрләр, тимер юл һәм елга транспорты магистральләре төзүдәге югары рух күтәренкелеге б-н сугарылган индустрия П.ы сәнгатьтәге «җепшеклек» чорында (1950 еллар ахыры — 1960 еллар башы) әйдәп баручы һәм бер үк вакытта иҗади казанышлар өлкәсе булып тора. Татарстан сәнгатендә махсус лирик-эпик юнәлештәге П.ны С.О.Лывин, М.Х.Хәйретдинов, лирик күңел һәм халәт П.ларын А.Л.Прокопьевлар тудыра. Э.Б.Гельмс, Э.Спориус, Т.А.Зуева, Н.У.Әлмиев, Р.Ә.Госманов һ.б.ның акварель, пастель, карандаш б-н башкарылган юл пейзажы сәхифәләренең зур осталык б-н иҗат ителүләре билгеләп үтелә. Казан, Болгар, Алабуга, Зөя шәһәрләренең архит-ра ядкәрләре, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең тормышы б-н бәйле урыннар М.К.Мавровская, И.К.Колмогорцева, Л.А.Потягунин, Р.Ә.Госманов, Г.А.Рахманкуловалар тарафыннан тудырылган тәфсилле график серияләрнең эчтәлеген тәшкил итә. П. сәнгатендә А.А.Аникеёнокның сюжет эчтәлегеннән азат, үзенчәлекле эзләнүләр агымында үсүче иҗаты аерым урын алып тора. Картиналарында П.ны портрет жанры элементлары б-н берләштергән һәм тормыш-көнкүрешнең милли традицион формаларын шигъри кануннарга буйсындырган И.К.Зарипов иҗаты — үзенчәлекле аерым сәхифә. 20 — 21 йөзләр чигендә П. сәнгате рәссамның эчке дөньясын күбрәк турыдан-туры күчерү ягына үзгәрә, милли традицияләр б-н кинаяләргә һәм сәер омтылышларга хас поставангард стиленең бер юнәлештә булуын тигезләп тора. Ә.Р.Ильясова, Е.Г.Голубцов, Ш.М.Шәйдуллин, З.М.Миңнәхмәтовларның нәкышь, М.И.Кузнецов, В.И.Сынковның графикадагы иҗатлары шушы рәвештә үсә. А.Ф.Иншаков, А.С.Федотов һәм башка бик күпләрнең иҗатында традицион лирик П. үсеш ала. Мәдәниятне милли тиңләштерү контекстында тарихи П. жанры Ә.И.Тумашев, К.А.Нәфыйков, Р.Г.Заһидуллин, Ф.Г.Халиков һ.б. иҗатында яңа үрләргә ирешә. Ш.у.к. *Сынлы сәнгатьтә тарихи жанр*, *Архитектура графикасы*.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 г. М., 1987; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

*Е.П.Ключевская.*

**ПЕЙСА́ХОВ** Нисон Меерович (Михаил Миронович) (26.12.1923, Белоруссия ССРның Витебск ш. — 13.4.1996, Казан), психолог, психол. фән. д-ры (1989), проф. (1990). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959). 1946 елдан Казан урта мәктәпләрендә физкультура укыта. 1962 дән Казан ун-тының физик тәрбия (1962–74), пед. һәм психол. (1974–94), психол. (1994–95) кафедраларында. Хезмәтләре шәхеснең психол. үзидарәсе проблемаларына, югары уку йортларында психология хезмәтен оештыру мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Саморегуляция и типологические свойства нервной системы. К., 1974; Закономерности динамики психических явлений. К., 1984.

*Әд.:* Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. К., 1999; Психология в Казанском университете. К., 2004.

**ПЕЙСАХО́ВСКИЙ** Наум Григорьевич (10.4.1909, хәзер Тверь өлкәсе Көнбатыш Двина р-ны Ильино а. — 24.8.1999, Мәскәү). Сов. Союзы Герое (31.5.1945), полковник. Сәяси состав курсларын (Саратов ш., 1934), Хәрби-сәяси академия (Мәскәү, 1939), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия каршындагы Командирлар составын камилләштерү курсларын (Мәскәү, 1942) тәмамлый. Окт. рев-циясеннән соң П. гаиләсе б-н Казанга күченә. «Спартак» ф-касында эшли. 1934 елдан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 164 нче укчы полк командиры (3 нче удар армиянең 33 нче укчы дивизиясе). Калинин һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Ленинград оборона сугышында (1941–44), Рига (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 16–30 апрелендә Берлин операциясе барышында батырлык күрсәтә: П. җитәкчелегендәге укчы полк дошманның күпсанлы җанлы көчләрен һәм техникасын тар-мар итә, шәхсән үзе сугышчыларны атакага күтәрә һәм шунда яралана. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам итә. 1953 тән запаста, соңыннан отставкага җибәрелә. Мәскәүдә яши. Көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсендә эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 3 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче (ике тапкыр) һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Н.Г.Пейсаховский.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЕЛАРГО́НИЯ** (Pelargonium), яранчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 280 гә якын төре билгеле. Чыгышы — Көньяк Африка. Сабагы туры, сынучан, 60 *см* га кадәр биеклектә. Яфраклары 7–10 *см* киңлектә, түгәрәк, саерак кына уемлы, озын саплы, кайвакыт нык кына төкчәле. Караңгы яшел яки ачык-яшел төстә, күпчелек төренең яфраклары дагасыман көрән бизәкле. Чәчәкләре гади яки катмарлы, чатыр чәчәк төркеменә җыйналган, ак, алсу, кызыл, куе алсу төстә. ТРда эре чәчәкле яки өй П.се (P. domesticum), зона П.се (P. zonale) һ.б. бүлмә гөле («чәчәкле яраннар») буларак үстерелә, хуш исле төрләрен — башчалы П. (P. capitatum), исле П. (P. graveolens), хуш исле П. (P. fragrans) һ.б. — бүлмәләргә хуш ис таратучы сыйфатында файдаланалар, яфракларын чәчәк кәрзиннәрен бизәүдә (флористикада), кулинариядә кулланалар. Язын (февраль–март) һәм җәен (июль–август) ботаклардан җиңел үрчи. Утырту алдыннан ботакларны җиңелчә генә киптерәләр. Яктылык, җылылык һәм дым ярата.

**ПЕЛӘМЕ́Ш** авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 91 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Пеләмеш елгасы буенда. 2010 елда 392 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, төрле урман эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмгатенең имана җире 362,7 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Пьянобор волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1927 дән Чаллы кантонында. 1930 нең 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябрен-

нән — Әгерже, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерже р-нында. Халык саны: 1762 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 136, 1887 дә — 267, 1905 тә — 422, 1920 дә — 393, 1926 да — 450, 1938 дә — 569, 1949 да — 460, 1958 дә — 505, 1970 тә — 536, 1989 да — 396, 2002 дә — 415 кеше.

**ПЕ́НЗА ӨЛКӘСЕ́**, РФдә. Россиянең көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 43,3 мең *км²*. Үзәге — Пенза шәһәре. Халкы — 1368657 кеше (2012). Татарлар саны: 1939 да — 64660, 1959 да — 62224, 1970 тә — 74835, 1979 да — 78236, 1989 да — 81307, 2002 дә — 86805, 2010 да — 86431 кеше. Идел буе Болгар дәүләтенә, Алтын Урдага кергән Урта Сура буйларына борынгы бабаларыбыз элек-электән килеп урнаша. П.ө. терр-ясе рус дәүләтенә кушылгач, 17 йөздә чик буе киртәләре төзелү б-н, бу җирләргә Темников, Алатырь, Арзамастан *йомышлы татарлар* килеп урнаша башлый. 1630 елларда алар — Югары Ломов, Түбән Ломов, Керенск (хәзер Вадинск), 1660–80 нәрдә Мокшан, Пенза, Городище ныгытмаларын төзүдә катнашалар. Төбәк тарихында якты эз калдырган татар бәкләре һәм морзалары нәселләре: Акчуриннар, Алышевлар, Бибарсовлар, Бигловлар, Дашкиннар, Дәүләкилдиевләр, Енгалычевлар, Еникиевләр, Кугушевлар, Кушаевлар, Макуловлар, Мәмәтовлар, Мәүлиевләр, Моратовлар, Сакаевлар, Тенишевлар, Терегуловлар, Үтәшевләр, Чанышевлар, Шаһмәмәтовлар. Татар халкының традицион шөгыле тәгәрмәчле авыр сука — сабан б-н иген игү (күбесенчә ашлык һәм ш.у. техник һәм яшелчә культуралары үстерелә) була. Терлекчелек (вак һәм мөгезле эре терлек үрчетү), зәркән һәм күн эшкәртү алга китә. 19 йөзнең 2 нче яртысында татар крәстияннәре тормышында читкә китеп эшләү (эре сәнәгать үзәкләре — Мәскәү, С.-Петербург, Саратов, Самара һ.б.да, Донецк ташкүмер бассейны шахталарында, Идел буе пристаньнарында) мөһим урын тота башлый. П.ө. ислам динен актив тарату зоналарының берсе була. Төбәктә беренче мәчетләр 14 йөз башында барлыкка килә. *Мухша* шәһәрендә 2 таш мәчет (14 йөз ахырында *Аксак Тимер* яулары вакытында җимерелә) төзелә. 1740–50 дәге көчләп христианлаштыру кампаниясе чорында күп кенә мәчетләр юкка чыгарыла. Пенза губернасында 1826 да — 70, 1912 дә 98 мәчет исәпләнә. Күп кенә торак пунктларда берничә мөселман гыйбадәтханәсе (Кикин авылында — 5, Качкаруда (Кутеевка) — 4, Мачали (Мочалейка), Кабылкин, Татар Кынадысында (Татар. Канадей) — 3 һ.б.) була. Мәчетләрнең күбесе каршында мәктәп һәм мәдрәсәләр эшли. Окт. рев-цияссеннән соң дәүләтнең атеизм сәясәте шартларында мәчетләр саны кими (1980 еллар башына 11 гә кала). Совет чорында Пенза пед. техникумында башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче татар бүлеге эшли. Пензада элеккеге җамигъ мәчет бинасында (1894–1929 да эшли, 1994 тә яңадан эшли башлый) татар милли мәктәбе урнаша, 1960 елларда татар драма түгәрәге эшли. Хәзерге вакытта татарлар тупланып Спасск (Шалдавыч (Татар. Шелдаис) а.), Белинский (Качкару (Кутеевка) а.), Вадинск (Татар Шуриновкасы, Чудовка а.), Городище (Югары Әләзән, Түбән Әләзән а.), Исса (Югары Салман, Кәмәнәк (Кильмаевка), Плетнёвка а.), Каменка (Ятмис (Кочелейка), Кикин, Кабылкин, Мачали, Тәләтен (Телятино) а.), Кузнецкий (Берлек (Большой Труев), Дәхтәрни (Малый Труев), Татар Кынадысы, Пәлдәңге (Татар. Пенделка) а.), Лопатин (Иске Вершаут, Иске Карлыган, Берлек, Суляевка а.), Лунино (Шыкча (Синорово) а.), Неверкин (Гали, Биги, Бикмуса, Дөмавыл, Җәлил, Исәкәй, Кырнавар, Мансур, Мазарлы (Октябрьское), Пачелма (Ногай (Решетино), Чулпан а.), Сосновоборск (Индерка, Сәләмәс (Татар. Сыромяс), Әлмәш а.), Шемышейка (Оз (Усть-Уза) а.) р-ннарында яшиләр. Татарларның шактый өлеше катнаш торак пунктларда: Батрак (Каменка р-ны), Әләзән (Кузнецк р-ны), Чардым (Лопатин р-ны), Неверкино (Неверкин р-ны), Татар Никольскоесы (Пачелма р-ны), Засечное (Пенза р-ны) һ.б.да яши. 1989 да Пензада «Якташлар» татар җәмгыяте оеша, 1991 дә ул өлкә татар мәдәни җәмгыяте итеп үзгәртелә. Җәмгыять милли мәдәниятне үстерүгә, туган телне, татар халкының традицияләрен, йола һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүгә, рухи, мәдәни, дини ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә; Городище пед. уч-щесендә һәм Татарстан югары уку йортларында татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләүгә булышлык итә. Пенза һәм П.ө.нең 24 мәктәбендә татар теле — фән буларак, 8 мәктәбендә факультатив дәресләрдә укытыла. 1997 дән П.ө.ндә татар-мөселман үзәге эшли. Өлкә терр-ясендә 60 лап мәчет (ш.и. Урта Әләзәндә — 4, Югары Әләзәндә, Мазарлыда — 3), берничә мәдрәсә эшли. «Пензенская правда» өлкә г-тасында «Якташ» махсус полосасы даими чыгып килә. 1998 дә милли мәсьәләләргә багышланган «Халык дөньясы» бите «Новая газета — Мир людей» г-тасында чыга. 1999 дан бу басма булышлыгында «Арба» г-тасы нәшер ителә. «Солнце Ислама» г-тасы чыгып килә. Өлкә районнарында Сабан туе (Пензада 1989 дан), Корбан һәм Ураза бәйрәмнәре үткәрелә. 2004 тә Сосновоборск р-нының Индерка авылында беренче төбәк татар мәдәнияте фестивале үткәрелә. Дин галиме М.*Бигиев*, әдипләр З.*Бигиев*, К.Г.*Тинчурин*, язучылар М.*Акъегетзадә*, Г.Ю.*Коләхмәтов*, Г.Н.*Кутуй*, Ш.Х.*Усманов*, М.Х.*Мазунов*, Х.Г.Шабанов, партия эшлеклесе А.К.*Акчурин*, Сов. Союзы Геройлары А.Х.*Акжегетов*, Б.М.*Еналиев*, Т.К.*Кержнев*, М.И.*Мостафин*, Дан орденының тулы кавалерлары А.Х.*Измайлов*, Х.И.*Янаев*, Соц. Хезмәт Герое Х.М.Мәҗитова, РФАнең мөхбир әгъзасы Ә.Р.*Тенишев*, мед. фән. д-рлары Р.Х.*Васильев* һәм З.И.*Уразгилдиев*, а.х. фән. д-ры Ф.Х.*Бәхтиев*, техник фән. д-рлары М.Р.*Вяселев* һәм Б.И.*Рәмиев*, икътисад фән. д-ры Ә.М.*Гатауллинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге П.ө. б-н бәйле.

*Әд.:* А к ъ е г е т К. Пенза татарлары: Кыскача тарих, авыллар, халык иҗаты. К., 2001.

**ПЕ́НСИЯ** (лат. pensio — түләү), даими акчалата түләүләр, гражданнарга билгеле бер яшькә җиткәннән соң яисә законда каралган башка очракларда социаль ярдәм формасы. П. эшләүчеләрдән алып калына торган средстволарны кабаттан бүлү юлы белән дәүләт органнары, шулай ук хосусый оешмалар һәм компанияләр тарафыннан түләнә. Төрләре: персональ; тиешле еллар эшләгәне өчен; гариплек буенча; тәрбиячесен югалту очрагында, картлык буенча, хезмәт П.се. Законнар нигезендә дәүләт аның күләмен, билгеләү принципларын, яшьләрен билгели. 2002 елга кадәр РФдә картлык буенча П.гә чыгучылар өчен түләүләр күләме өзлексез гомуми хезмәт стажына һәм билгеле бер вакыт аралыгындагы уртача хезмәт хакына бәйле була. 2002 дән соң башка төрле П. системасына күчелә. Хезмәт стажына һәм уртача хезмәт хакына бәйләнмәгән минималь П.не — база өлешен түләүне дәүләт гарантияли. Иминият өлеше П. алачак затның картлык буенча хезмәт П.сенең иминият өлеше билгеләнгән көннән башлап исәпләнгән пенсия капиталы суммасын түләүләр каралган айлар санына («РФнең хезмәт пенсияләре турында» 2001 ел Федераль законы буенча ул 19 ел, ягъни 228 ай) бүлеп табыла. Туплану өлеше хезмәт П.сенең әлеге өлеше билгеләнгән көнгә кадәр индивидуаль счётның махсус өлешендә исәпләнеп барылган пенсия тупланмалары суммасын алда искә алынган айлар санына бүлеп табыла. РФдә картлык буенча П. хокукы 55 яшькә җиткән хатын-кызларга, 60 ка җиткән ирләргә бирелә. П. күләме — хезмәт хакының 25% ыннан артык түгел, П.нең оптималь күләме — 40–50%.

П. түләүне дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары алып бара, соңгылары дәүләт корпорацияләре, хосусый фирмалар һәм пр-тиеләр тарафыннан аны гамәлгә куючыларның акчалары һәм киләчәктә П. һәм пособие алучыларның взнослары хисабына туплана. 1990 да РФнең Пенсия фонды оештырыла, ул — РФ хөкүмәтенә турыдан-туры буйсына торган мөстәкыйль финанс-кредит учреждениесе. Фондның төп функцияләре: П. һәм пособиеләр түләү өчен акча средстволарын максатчан җыю һәм туплау; халыкны социаль һәм матди яклау буенча федераль һәм төбәк программаларында катнашу; акча средстволарының тупланма өлешен кыйммәтле кәгазьләргә инвестицияләү юллары б-н үстерү, аннан нәтиҗәле файдалану һ.б. Бюджет фонды югары закон чыгару органы тарафыннан раслана. ТРда пенсионерларга РФ пенсия фонды бүлегенең 44 идарәсе хезмәт күрсәтә. Дәүләтнеке булмаган һәм хосусый П. фондлары (НПФ) эшчәнлеге «Дәүләтнеке булмаган пенсия фондлары турында» 1998 ел Федераль законы б-н көйләнә; законда алар коммерциячел булмаган социаль тәэминат оешмасының махсус оештыру-хокукый формасы сыйфатында билгеләнәләр. НПФ килешүләр нигезендә үз әгъзаларын П. б-н тәэмин итәләр; алар б-н «РФдә мәҗбүри пенсия иминиятләштерү турында» 2001 ел Федераль законы нигезендә мәҗбүри пенсия иминиятләштерү турында килешүләр төзиләр.

ТРда 2013 кә 12 Дәүләтнеке булмаган пенсия фонды эшли (5 есе респ-када теркәлгән). ТР буенча РПФБнең 44 идарәсе 10641 мең пенсионерга хезмәт күрсәтә. 2006 дан 8 НПФ эшләп килә (6 сы — респ-када, 2 се Мәскәүдә теркәлгән), Милли НПФның берничә ф-лы (Казанда һәм Әлмәттә) эшли. ТРда НПФда катнашучыларның гомуми саны 360 мең кеше, ягъни барлык икътисади актив халыкның 18% ы һәм респ-ка пр-тиеләрендә хәзер эшләүчеләрнең 22,6% ы. НПФ аша ТРның 2% пенсионеры, ягъни 18324 кеше П. ала.

*Әд.:* Сиевако в Р.Б. Важный инструмент социального менеджмента предприятия // Проблемы совр. экономики. 2007. № 1.

*Р.К.Мәҗитова.*

**ПЕНТАТО́НИКА** (грек. pente — биш һәм tonos — аваз), октава эчендә 5 баскыч авазлар системасы. Аның билгеләмәсенә ике караш яшәп килә: 1) ярымтон һәм тритон бәйләнеше булмаган билгеле бер интервал төзелешенең авазлар рәте; 2) билгеле бер лад һәм интонация мәгънәсе булган муз. телнең үзенчәлекле интонацион-семантик өлкәсе. Ярымтонсыз (ангемитон) пентатоника яисә пентатоник ангемитоника күпләгән Россия халыкларының, ш.и. татарларның да, муз. фольклоры нигезе булып тора. Татар халык җырларының лад төзелешен өйрәнүдә ике юнәлешне аерып карыйлар: 1) пентатониканың барлык биш формасындагы муз. фольклорның ладлы нигезен тану (И.А.*Козлов*, Я.М.*Гиршман*, Л.В.Бражник; к. 1 нче рәсем); 2) татар халык



1 нче рәс.

көйләрендә пентатониканың бөтен әйләнешләре дә файдаланылмавын тану. Немец галиме Г.Шюнеман, Казан татарлары җырларын өйрәнү нигезендә беренче булып, бишавазлы ярымтонсыз ладларның 5 төреннән Казан татарлары җырларында 4 е генә кулланыла дигән нәтиҗәгә килә (пентатоника формаларының берсе, түбәнге баскычтан (3 нче) квинта интервалы төшеп калганы, татар музыка фольклорына хас түгел); М.Н.*Нигъмәтҗанов*, Р.Ә.*Исхакова-Вамба*, З.Н.*Сәйдәшева* да шул карашта торалар. Бу структураларны системалаштыру да ике юнәлешкә бүленә. Беренчесенең тарафдарлары П.ның лад формаларын мажор-минорлы фикерләү ягыннан чыгып тикшерә. Я.М.Гиршман ассызыклаганча, «мажор һәм минорның шундый элементлары бар, аларны ачып җибәрү, пентатоник лад нигезен саклап, көйгә мажор яисә минор төсмерләр бирә»; Гиршман П.ның «үзенең гомум лад үзенчәлекләре» б-н 5 формасын төркемли: аларның берәүләрен мажор (1) һәм минор (5) П. дип, ә башкаларын минор (2 һәм 3) һәм мажор (4) П. дип атый. М.Н.Нигъмәтҗанов ш.у. түбән аваздан терций б-н булган 2 формасын «пентатоник мажор» (1) һәм «пентатоник минор» (5), ә 2 сен (2 һәм 4) — «пентатониканың мажор һәм минор вариантлары» дип атый. Р.Ә.Исхакова-Вамба П.ның 2 формасына «ярымтонсыз мажор» һәм «ярымтонсыз минор» исемнәрен бирә. Хәзерге заман этномузыкологиясендә шундый караш методологик хата булып санала; бу башка төрле тамгаланышлар, аерым алганда, теге яки бу лад формаларына хас булган һәм аларны үзара аерырга мөмкинлек бирә торган интервallы төзелешне кулланучы атамалар әзләүгә китерә. Мондый алым Казан татарларының җыр фольклорын тикшерүдә беренче тапкыр З.Н.Сәйдәшева тарафыннан файдаланыла. Ул чынбарлыкта кулланыла торган 4 П.дан 2 форманың билгеләнешендә терциянең башлангыч интервалыннан чыга, бу формаларны «зур терцияле» (1) һәм «кече терцияле» (5), дип атый, башка икесен күләменә карап тәкъдим итә, аларны «секста» (4) һәм «септима» (2) дип атый. Соңрак бу ладларның төрле төрләрен билгеләүдә музыка белгече Л.В.Бражник шушы ук юлдан бара, ул П.ның амбитус һәм башлангыч «трихорд» кебек структур үзенчәлекләреннән чыга, П.ның барлык 5 төрен «терция секста» (1), «секунда септима» (2), «секста септима» (3) «квартсекста» (4), «терция септима»га (5) бүлә. Чуаш фольклорын өйрәнүче М.Г.Кондратьев авазлар шкаласында кече октаваның — **ре**сеннән алып 1 нче октаваның — **ля**сенә кадәрге, аның үзәк өлешендә кулланыла торган ноталарны тикшерә. Кирәкле авазлар тезмәсен сайлаганда, гадәттә, шкала астында урнашкан хәрефле әйтелештә төп тонга таянуны тәкъдим итә. Ләкин шактый татар көйләре (бигрәк тә китапча интонация б-н җырлау) түбән тон б-н генә түгел, бу аваз тезмәләренең башка тоннары б-н дә тәмамлана. Нәтиҗәдә «интервallы» һәм «хәрефле» тамгаланыш системасы халыкның муз. фикерләвен, хис, мәгънә эчтәлеген тулысынча ачып бетерми. Татарларның муз. фольклоры иҗатын актив өйрәнү, 20 йөзнең 2 нче яртысында күп санлы аудиоязмалар һәм басмалар барлыкка килү, Идел-Кама буе татарларының лад системаларын диатониканың мажор яки минор төрләнешенә яисә интервallар төзелешенә түгел, ә этник, терр., конфессиональ жанр билгеләренә карап аерырга мөмкинлек бирә. Мәс., үзәгендә кече терция булган икенче лад структурасын «керәшенчә» дип атыйлар (к. *Керәшен татарлар*). Төрле җирлектәге керәшен татарлар аны үзләренчә файдалана (к. 2 нче рәсем). Казан керәшен татар-



2 нче рәс.

лары көйләрендә кварта (I) һәм квинта (II) эчендә аска юнәлгән типтагы трихордлы интонацион көйләр төп роль уйный. Бакалы (Башкортстан) керәшеннәренә, чынында аларның «визит карточкасы» булган төрле вариантлылык хас. Мөселманнарның (Казан татарлары һәм мишәрләре) традицион муз. фольклоры көйләренең ладлары нигезендә төрле юнәлештәге аваз яңгырашларының (аскы юнәлеше һәм өске юнәлеше б-н) терция һәм кварта эчендә трихорд тибындагы интонацион ячейкалар булган 1 нче һәм 3 нче форма (сирәк кенә 2 нче) өстенлек итә.

*Әд.:* Козлов И.А. Пятизвучные гаммы в татарской и башкирской музыке и их музыкально-теоретический анализ // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1928. Т. 34, вып. 1; Гиршман Я.М. Пентатоника и её развитие в татарской музыке. М., 1960; Нигмедзянов М.Н. Народная музыка // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Исхакова-Вамба Р.А. Татарские народные песни. М., 1981; Бражник Л.В. Ангемитоника в модальных и тональных системах: На примере тюркских и финно-угорских народов Поволжья и Приуралья. К., 2002; Сайдашева З.Н. Татарская музыкальная этнография. К., 2007.

*З.Н.Сәйдәшева.*

**ПЕНЬКО́В** Иван Николаевич (11.1.1923, Пенза губ., Саранск өязе Соколовка а.), геолог-минералог, геол.-минерал. фән. д-ры (1971), проф. (1974), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Казан ун-тын тәмамлагач (1952), шунда ук эшли, файдалы казылмалар каф. мөдире (1974–87). Хезмәтләре минералогиягә һәм рудалар геологиясенә, минералларны тикшерүнең физик һәм химик алымнарына карый. П. минералларның физик-химик үзлекләрен тикшерүдә квадруполь төш резонансын куллануның нәтиҗәлелеген күрсәтә. Руда минералларын баетуда нигезле алым тәкъдим итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 1 нче (ике тапкыр) һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Аномальная хемосорбция примесей на минералах // Докл. АН СССР. 1977. Т. 184, № 2; Некоторые вопросы химической активности минералов: генетический и технологический аспекты // Зап. Всерос. минерал. об-ва. 2000. № 1.

*Әд.:* Фронтовики-учёные Казанского университета. К., 2000.

**ПЕПЕРО́МИЯ** (Peperomis), борыччалар семьялыгыннан күпьеллык мәңге яшел үләнчел яки ярымкуакчыл үсемлекләр ыругы. Берничә йөз төре билгеле. Чыгышы — ике ярымшарның да тропик пояслары. Яфраклары яшел, еш кына итләч, формасы, зурлыгы, төсе һәм төзелеше төрле-төрле, кыска сапларда. Чәчәкләре вак, куе ак яки яшькелт башак яисә чәкән чәчәк төркемендә, күсе койрыгын хәтерләтә. Куаксыман, туры, ампель (асылма) формалары бар. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Магнолия яфраклы (P. magnoliaefolia) — аз гына иенке сабаклы һәм каты яфраклы зур үсемлек. Чуар яфраклы формалары да бар. Көмешсыман П.нең (P. argyrea) калкансыман яфраклары көмеш төсендәге буй сызыклы, алар тамыр яны таралгысына җыйналган. Берничә сортының яфраклары караңгырак төстә. Җыерчалы П. (caperata) — куе яшел вак яфракчыклы (1,5–2 *см*) кечкенә үсемлек. Яфрак саплары кызыл төстә, нечкә. Башак рәвешле чәчәк төркеме ак, аз гына бөгелгән. Күпчелек П. яфрак һәм ботактан җиңел үрчи; талымсыз; чуар яфраклы формаларына яктылык кирәк, яшелләре күләгәгә чыдам. Уртача дымлылыкны ярата.

**ПЕ́РВИН** Григорий Михайлович (Мееровлич) (1.9.1946, Ульянов ш.), театр эшлеклесе, ТР һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1991, 1998). 1971 елда Казан пед. ин-тының музыка-пед. ф-тын тәмамлый. 1972–84 тә Татар филармониясендә (концертмейстер, баш администратор, концерт бүлеге башлы-

гы) эшли. 1985 тән — Казан Зур драма театрында (директор урынбасары, 1988–2007 дә директор). Театр эшләре буенча тәҗрибәле һәм проф. оештыручы буларак, П. театрның матди-техник җирлеген ныгытуга (сәхнәнең техник җиһазланышы яңартыла, сәхнә арты биналары төзекләндерелә, театр бинасына генераль реконструкция уздырыла башлый), коллективның сәнгать эшчәнлеге дәрәҗәсен күтәрү, аның тамашачы б-н үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә зур игътибар юнәлтә; бу елларда коллективның гастрольләр б-н йөрүе активлаша, театр беренче тапкыр чит илләргә гастрольләр б-н чыга, спектакльләрне сәхнәгә кую өчен чит ил режиссёрларын чакыра башлый. 1988–2007 дә Респ-ка театрлары директорлары советы б-н җитәкчелек итә.

*Әд.:* И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

**ПЕ́РВИН** Михаил Григорьевич (25.10.1918, Румыния, Кагул ш. — 27.2.1976, Казан), мәдәният эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1968). Одесса театр студиясен тәмамлый (1941), укыган вакытта ук Одесса филармониясендә муз. эксцентрик булып эшли. 1942–47 елларда Мәскәү циркы артисты, 1947–49 да Кемерово, Новокузнецк шәһәрләре циркында баш администратор, директор вазифаларын башкаручы. 1949–52 дә — Казанда М.Горький исем. клуб, 1952–65 тә — Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ), 1965–73 тә Татар филармониясе директоры. П., талантлы оештыручы буларак, Казан һәм респ-ка мәдәни төзелешенә зур өлеш кертә. Үзе җитәкчелек иткән коллективларның иҗади үсешен кайгыртта, тәҗрибәле һәм сәләтле җитәкчеләрне хезмәттәшлеккә чакыра. Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) труппасының сәнгать җитәкчелегенә — Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС) тәмамлаган М.Х.Сәлимҗановны, ТРның 1966 да оешкан Дәүләт симф. оркестрының сәнгать җитәкчелегенә Н.Г.Рахлинны чакырып ала. Татар филармониясе коллективлары һәм аерым артистлар чит илләргә гастрольләр б-н чыга башлыйлар. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПЕРВУ́ХИН** Михаил Борисович (1813, Вятка губ. — 1871, Әстерхан ш.), педагог, тел белгече. 1834 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан гимназиясендә гарәп теле укыта. 1841 дән Оренбург чик буе комиссиясендә тәрҗемәче, 1844 тән Эчке Урда ханы канцеляриясе җитәкчесе, 1849 дан канцеляриядә Сырдәрья кыргызлары бүлеге мөдире вазифасын башкара. 1863–66 елларда *Әстерхандагы Беренче ир балалар гимназиясендә* татар теле укыта. П. төзегән «Төрекчә-татарча-русча сүзлек» һәм «Гарәп теле грамматикасы һәм синтаксисы» исемле кульъязма хезмәтләрне тел белеме галимнәре 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында да кулланалар.

**ПЕРВУ́ШИН** Вадим Евгеньевич (2.1.1959, хәзер Украина ССРның Луганск өлкәсе Александровский р-ны Белореченко пос.), машиналар төзүче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Кама автомеханика техникумын (1979), Казан техник ун-тын (2004) тәмамлый. 1978–86 елларда «КамАЗ» ЖБ Ремонт-инструментлар з-дының ярдәмче инструментлар цехында мастер, өлкән мастер. 1986–2008 дә «Алабуга автомобиль заводы» җитештерү берләшмәсе» АҖнең Станок-инструментлар з-дында: цех башлыгы урынбасары, инструментлар-җитештерү башлыгы урынбасары, башлыгы, директор урынбасары (1998 дән), баш инженер (2002 дән). Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын үзләштерү һәм ремонтлауга кирәкле 50 һәм 80 *т* йөк күтәрешле югары технологияле күтәрү агрегатларын эшләп чыгарганы өчен бирелә.

**ПЕРВУ́ШИН** Всеволод Прокопьевич (Прокофьевич) (24.11.1869, Пермь ш. — 21.12.1954, шунда ук), невропатолог, медицина д-ры (1918). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1894), шунда ук, нерв авырулары клиникасында, бер үк вакытта Казан аеклар җәмгыятенең эчкечеләрне савыктыру дәваханәсендә эшли, фельдшер-акушерлар мәктәбендә укыта (1908–19), Кызыл Хач җәмгыятенең Казан шәфкать туташлары оешмасында дәресләр алып бара (П. катнашы б-н анда физиотерапия кабинеты һәм су б-н савыктыру дәваханәсе ачыла). Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Казан ун-ты каршындагы Табибләр җәмгыяте тарафыннан качакларга ярдәм итүче Табибләр ком-ты составына сайлана; Кызыл Хач җәмгыятенең шәһәр госпитальләрендә невропатолог-консультант. Казан ГИДУВын оештыруда катнаша, проф. (1920), шунда нерв авырулары каф. һәм клиникасы җитәкчесе (1920–22). 1922 елдан Пермь ун-тының нерв авырулары клиникасы директоры. П. анда физиокабинетлар, су б-н савыктыру дәваханәләре оештыра. Казан невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте (1918–22), Казандагы Туберкулёзга каршы көрәш лигасы һәм Балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыяте (1905–15) рәисе. Хезмәтләре нейротравматологиягә, физиотерапиягә карый. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Случай поражения позвоночника на почве брюшно-тифозной инфекции «Spondylosis tifosa» // Журн. невропатологии и психиатрии. 1905. Кн. 2; Массовый алкоголизм и борьба с ним. К., 1916; Нервная система и её заболевания. Молотов, 1942; Звуковые особенности, связанные с вызыванием сухожильных рефлексов при их угасании // Советская медицина. 1943. № 4.

*Әд.:* В и з е н Э.М. Памяти В.П.Первушина // Журн. невропатологии и психиатрии. 1955. Т. 55, вып. 4.

**ПЕРЕВЕДЕ́НЦЕВ** Юрий Петрович (23.2.1941, Биектау р-ны Пановка а.), метеоролог, климатолог, геогр. фән. д-ры (1986), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1992), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2005), Казан ун-тының атказ. профессоры (2006). Казан ун-тының геогр. (1963) һәм механика-матем. (1972) ф-тларын тәмамлый. 1971 елдан Казан ун-тында, метеорология, климатология һәм атм. экологиясе каф. мөдире (1978 дән), геогр. һәм геоэкология ф-ты деканы (1983–2006). Хезмәтләре атм. процессларының динамикасын һәм энергетикасын, ТРның климатын өйрәнүгә карый. П. — атм. циркуляциясе һәм климат үзгәрешләре буенча фәнни юнәлешләргә нигез салучыларның берсе. Беренче тапкыр урта атмосфераның циркуляцион-энергетик моделен эшли. Аның җитәкчелегендә космик-геофизик факторлар тәэсирендә атм. циркуляциясе һәм климатның глобаль һәм җирле үзгәрешләренең закончалыклары ачыклана, комплекслы физик-стат. модель төзелә. Казан ун-тында туфрак-үсемлек системалары һәм атмосфера фәнни-тикшеренү лаб-ясен ачу, үзе җитәкләгән каф. каршында климат мониторингы буенча фәнни төркем туплау эшен башлап җибәрүче һәм оештыручылардан берсе. РФдә беренче «Климат теориясе» («Теория климата», 2004) уку ярдәмлеге авторы, «Казан климаты һәм хәзерге чорда аның үзгәрешләре» («Климат Казани и его изменения в современный период», 2006) монографиясе һәм «Атмосфера экологиясе нигезләре» («Основы экологии атмосферы», ч. 1–4, 2000–06) уку ярдәмлегенең автордашы. Россиянең мактаулы гидрометеорология хезмәте хезмәткәре (2001).

Х е з м.: Циркуляционные и энергетические процессы в средней атмосфере. К., 1984; Современные глобальные и региональные изменения окружающей среды и климата. К., 1999 (автордаш); Метеорология в Казанском университете: Становление, развитие, основные достижения. К., 2001.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПЕРЕВЕ́РЗЕВ** Андрей Егорович (29.11.1900 — 1971), химик-технолог, техник фән. д-ры (1949), проф. (1945), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1944, 1957). 1934 елда Ленинград технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, директор урынбасары, 1939 дан 41 нче каф. мөдире (бүленеп: 1942–44 тә Казанда, берләштерелгән Ленинград һәм Казан химия-технол. ин-тлары директоры). Хезмәтләре нитропарафиннар синтезына һәм аларны куллануга, энергия сыйдырышлы каты матдәләр химиясенә һәм технологиясенә карый. П. махсус кулланыштагы эшләнмәләр технологиясенең теоретик нигезләрен эшли. «Капитан Белоусов» бозваткычында Арктикага ике экспедициядә катнаша, диңгез, елга, күлләрнең боз катламы җимерелү шартларын тикшерә, Арктика бозларын шартлатып ваттыру юлын тәкъдим итә. 200 дән артык фәнни хезмәт авторы, уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ПЕРЕВОЛО́ЦКИЙ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1935 елда оештырыла. Мәйданы — 2,7 мең *км²*. Үзәге — Переволоцкий посёлогы (Оренбург шәһәреннән 73 *км* көнбатыштарак). Халкы — 27889 кеше (2012), 4660 татар (2010). Татарлар, башлыча, Иске Зубачи (920 кеше; 1775 тә нигезләнә), Яңа Зубачи (770 кеше; 1801), Чесноковка (1782) авылларында яшиләр. 1917 елга П.р. терр-ясендә 5 мәчет, 2 мәдрәсә була. Бүгенге көндә Иске Зубачи (1996 дан), Яңа Зубачи (1993 тән), Чесно-

ковка (1994 тән) авылларында мәчетләр эшли. Иске Зубачи урта мәктәбендә татар теле фән буларак, Яңа Зубачи һәм Чесноковка мәктәпләрендә факультатив дәрес буларак укытыла. П.р.нда Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры М.Ә.Зидбаев, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Дан ордены кавалеры А.Н.Зәбиров, техник фән. д-ры З.Г.Салихов туган.

**ПЕРЕЛЫ́ГИН** Олег Андреевич (30.9.1940, Сталинград өлкәсенең Михайловка пос., хәзер Волгоград өлкәсендәге шәһәр — 8.1.2004, Казан), химик аппаратлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (1998), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2001). 1962 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Мәскәү һәм Казан оборона пр-тиеләрендә эшли. 1965–2004 тә Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре күп фазалы системаларда гидродинамикага һәм масса алмашуга, химик аппаратларның эш процесслары диагностикасына карый. П. тәкъдим иткән полисилоксаннар синтезлау алымнары технол. цикл вакытын кыскарта һәм су б-н юганда соңгы продукт югалтуларын киметергә мөмкинлек бирә (С.М.Киров исем. Казан ясалма каучук з-дында гамәлгә кертелә). П. тикшеренүләре нигезендә хлор ионнары артык күп булган эмульсияләр өчен роторы титан эретмәләреннән ясалган сепаратор төзелә. Формасында локаль дефектлар булган сүрү конструкцияләренең ныклык сәләтен исәпләү һәм бәяләү алымнарын эшли. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Критериальный анализ уравнений гидродинамики процессов тонкослойного сепарирования // Теорет. основы хим. технологии. 1993. Т. 27, № 3 (автордаш); Исследования течений в пограничных слоях в процессах тонкослойного сепарирования // Теорет. основы хим. технологии. 1995. Т. 29, № 3 (автордаш); Об условии прочности оболочки при возникновении пластических деформаций // Вестн. Казан. технол. ун-та. 2000. № 3 (автордаш).

**ПЕРЕТЯ́ТКОВИЧ** Георгий Иванович (26.11.1840, Бессарабия өлкәсенең Оргеевский өязе — 7.8.1908, Кишинёв ш.), тарихчы, рус тарихы д-ры (1882), хакыйкый статский советник (1894). Дворяннар нәселеннән. Ришелье лицеен (Одесса ш., 1860), Мәскәү ин-тын (1865) тәмамлый. 1865 елдан Мәскәүнең Беренче ир балалар гимназиясе укытучысы. 1877 дән Новороссийск ун-тының (Одесса) рус тарихы кафедрасында: приват-доцент (1877–82), экстраординар проф. (1882–86), ординар проф. (1886–1903), 1903 тән атказ. проф. Түбән һәм Урта Идел буе тарихы буенча хезмәтләре урта гасырларда Идел буе халыкларының үзара йогынтысы һәм багланышлары, аларны 15–18 йөзләрдә христианлаштыру мәсьәләләренә карый. П. Идел буе төбәген колонияләштерү юлларын тасвирлый, торак пунктларның нигезләнүе турында мәгълүматлар китерә, күп кенә авылларның барлыкка килүе кешеләрнең, хакимиятләргә белдерми генә, җир өчен түләүдән качып, үз белдекләре б-н күченүенә бәйлелегенә беренче булып игътибар итә.

Х е з м.: Поволжье в XV и XVI веках: Очерки по истории края и его колонизации. М., 1877; Поволжье в XVII и начале XVIII в.: Очерки из истории колонизации края. Од., 1882; Малороссияне в Оренбургском крае при начале его заселения: По рукописным документам архива М-ва юстиции. Од., 1888.

*Әд.:* Г.И.Перетяткович: Некролог // Ист. вестн. 1908. Т. 114; Л и н н и ч е н к о И.А. Г.И.Перетяткович. Од., 1916.


*Е.Б.Долгов.*

**ПЕРЛОВИ́ЦАЛАР** (Unio), Unionidae семьялыгыннан төче суларда яшәүче ике кабырчыклы моллюсклар ыругы. Россиядә — 6 төре, Татарстан терр-ясендә 4 төре билгеле. Аеруча гадәти төрләр — гади П. (U. pictorum), кабарынкы П. (U. tumidus) һәм юан П. (U. crassus) гадәти төрләр. Кабырчыгы нык, бикләгеч мускуллары яхшы үскән. Гади П. — иң зурлары; озынлыклары 14,5 *см*, башка П.ның 11 *см* га кадәр. Кабырчыкның төсе саргылт-яшел яки яшькелт-көрән, эче сәдәф капламлы. Елга һәм күлләрдә яши, су төбендәге йомшак грунтта буразналар калдырып акрын гына (1–1,5 *м/сәг*) хәрәкәтләнә. Судагы детрит б-н туена, моның өчен ул шактый күләмдә су фильтрлый. Аталануы апрельдән июньгә кадәр, личинкалары (глохидийлар) П.ның саңакларында үсә, май ахырыннан августка кадәр суга тарала. Суда балыкларга берегәләр һәм беркадәр вакыт аларда паразитлык итәләр. П. 15 елга кадәр яшиләр. Суның пычрануына һәм кислород җитмәүгә бик сизгерләр, шунлыктан аларның саны кими бара. П.ны азык буларак кулланалар, йорт хайваннары рационына кушалар, кабырчыкларын сәдәф ясауда файдаланалар. Яшь П. кыргый хайваннар, кошлар һәм балыклар өчен азык булып тора. Сулыкларның үзеннән-үзе чистаруында мөһим роль уйныйлар.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Р а й к о в Б.Е., Р и м с к и й - К о р с а к о в М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

*В.А.Яковлев.*

**ПЕ́РМЬ ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́**, дини архит-ра истәлеге. Пермьдәге мөселман мәхәлләсе үзенең дини ихтыяҗларын 1860 еллардан 20 йөз башына кадәр манарасыз агач бинада башкара. 1897 елда уздырылган халык санын алу буенча, шәһәрдә 650 мөселман, ш.и. 300 дән артык ир-ат яши. П.җ.м. 1901–03 тә арх. А.И.Ожегов проекты буенча татар сәүдәгәрләре Агафуровлар, Тишкиннар, Ибәйтуллиннар акчасына төзелә. Ике канатлы, ике як тәрәзәле, өч ярuслы манарасы төньяк өлеше почмагында салынган мәчет. Намаз залы мәчетнең куб рәвешендәге канатында, дүрт кыеклы түбәне кисеп кергән, тәбәнәк цилиндр нигезгә беркетелгән гөмбәз б-н ябылган. Манараның сигез кырлы ике ярусы астында уелган ишек аның беренче катында урнашкан. Мәәзәнә кечерәк диаметрлы өченче яруста. Аны икенче катның нык, җәенке кәрнизе кочып тора. Манараның вертикаль композициясен биек, тамчысыман гөмбәз төгәлли. Манара урта ярусның түбәнге өлешендә дүрт яктан үсеп чыккан төз, сигез кырлы барабанга утыртылган 4 гөмбәзле булуы б-н аерылып тора. Мәчет шәрекъ-мөселман архит-расы үрнәкләрен кулланып, романтик юнәлештәге эклектик стильдә бизәлгән: дивар колонналарындагы киң архивольтлы, биек аркалы тәрәзәләр, уеп бизәлгән розеткалар б-н каймаланган түгәрәк тәрәзәләр, төп күләмдәге һәм манара ярусларындагы фигуралы тәрәкләр, зур фризлар, нык, җәенке кәрнизләр, фасадларның рустланган өслеге, яшел-зәңгәр-ак төсләр б-н чиратлаштырып буялган дивар әллә каян күренеп тора.



Пермь җамигъ мәчете. Арх. А.И.Ожегов. 2007 елгы фоторәсем.

1937 дә мәчет ябыла, 1939 да бинада партия архивы урнаша, 1986 да күргәзмә залы һәм китапханәсе булган туган якны өйрәнү музее ф-лы ачыла, 1991 дә бина мөселманнар җәмгыятенә кайтарып бирелә. П.җ.м. терр-ясендә совет чорында торак бинаЛар итеп файдаланылган һәм соңрак җәмгыятькә кайтарылган әүвәлге мәдрәсә бинасы һәм мәәзин йорты бар. 2003 тә комплекста яңарту, үзгәртеп кору эшләре башлана. Эш барышында урам ягыннан мәчет б-н бердәй стильдә бизәлгән бер катлы сәүдә-хезмәт күрсәтү юнәлешендәге янкорма төзелә.

*Әд.:* История соборной мечети Перми // Идель. 1991. № 4.

*Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.*

**ПЕРМЬ КРАЕ́**, РФдә. 2005 елда оештырыла. Төньяк һәм Урта Урал, Урал алды р-ннарының көнбатыш сөзәклегендә урнашкан. Мәйданы — 160,6 мең *км*². Үзәге — Пермь шәһәре. Халкы — 2634461 кеше (2012). Татарлар саны: 1970 елда — 169,4 мең, 1979 да — 157,7 мең, 1989 да — 150,5 мең, 2002 дә — 136,6, 2010 да — 115,5 мең кеше. Алар П.к.на элек-электән килеп урнаша. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөздә Урта Идел буеннан күченүчеләр исәбенә татарлар шактый күбәя. Гадәти шөгыльдән (игенчелек, терлекчелек, аучылык, урман умартачылыгы) тыш, алар металл эзләү һәм чыгару б-н шөгыльләнә. Татар мәгъдән эзләүчеләре дәүләт экспедицияләренә һәм рус эшмәкәрләренә мәгъдәнле урыннар табуда булыша, кайберләре бу эштә үзләре сәнәгатьче булып китә (19 йөздә Пермь губернасының төньяк волостьларында яшәүче 360 ка якын татар һәм башкорт сәнәгатьчесе исәпләнә). Татар төбәге-

неӊ икътисади һәм мәдәни үзәге булып Пермь шәһәре тора. 1911 елгы мәгълүматларга караганда, шәһәрнеӊ 65 сәүдә һәм сәнәгать пр-тиесенә татарлар б-н башкортлар хуҗа була (байлыгы буенча «Борадәр Агафуровлар» сәүдә йорты аерылып тора). 1908 дә Пермь шәһәре һәм Пермь өязе мөселманнарыныӊ «Җәмгыяте хәйрия» икътисади-мәдәни һәм хәйрия җәмгыяте, *Мөселман мәгърифәт һәм хәйрия җәмгыяте*, мөселман китапханәсе ачыла. 1901–03 тә татар сәүдәгәрләре иганәсенә шәһәрдә мәчет төзелә (1917 дән соӊ дин тотучылардан тартып алына, 1990 да кире кайтарыла) (к. *Пермь җамигъ мәчете*). 1917 дә Пермьдә дистәдән артык мәдрәсә исәпләнә. 1918 дә шәһәрдә *Мөселманнар хәрби һәйәте* эшли. Совет чорында крайда «*Кызыл таӊ*», «*Ленин юлыннан*» (Пермь), «*Очкын*» (Көнгер ш.), «*Очкын*» (Лысьва ш.), «*Ударник*» (Чусовой ш.), «*Урал кочегаркасы*» (Кизел ш.) татар г-талары нәшер ителә. 1932–55 елларда Пермь р-ныныӊ Куян авылында *Пермь татар педагогия училищесе* эшли. Хәзерге көндә татарлар Пермь, Березники, Гремячинск, Кизел, Губаха, Чайковский шәһәрләрендә яши. Барда, Берёзовка, Куеда, Көнгер, Октябрь, Урда, Оса, Пермь, Суксун, Уя, Чайковский, Чернушка һәм Чусовой р-ннарында 150 дән артык татар торак пункты урнашкан. П.к. татар һәм башкортларыныӊ төбәк милли-мәдәни автономиясе, Пермь татарларыныӊ милли-мәдәни автономиясе, «Пермь шәһәре татар мәдәният-мәгърифәт үзәге» иҗтимагый оешмасы эшли. 80 гә якын мәктәптә татар теле укытыла, 50 гә якын мәктәпкәчә тәрбия учреждениесендә балалар татарча тәрбияләнә. Оса шәһәре пед. уч-щесендә 1960 еллардан татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче төркем эшли. П.к.нда 54 татар-башкорт җыр һәм бию коллективы (иӊ атаклылары — «Мәхәббәт» һәм «Хыял») исәпләнә. «Халык чишмәсе» (Пермь, 1991 дән), «Халык авазы», «Таӊ» (Барда р-ны, 1931 дән), «Балкыш» г-талары нәшер ителә. Татарлар өчен «Кардәшләр» өлкә радио һәм телевидение (1991 дән), Барда р-ны телестудиясе тапшырулары даими чыга. Крайда 25 мәчет бар (1994). Барда (Барда р-ны), Уя (Уя р-ны) авылларында халык музейлары, Бардада халык театры эшли. Ел саен *Сабан туе* уздырыла. П.к. б-н ТР арасында элек-электән тарихи, икътисади һәм мәдәни бәйләнешләр яши. 1708–75 тә бу терр-яләр Казан губернасына керә (1719–75 тә — Пермь провинциясе буларак). 18–19 йөзләрдә Казан губернасындагы Мамадыш, Чистай һәм Спас өязләренеӊ күп кенә авыллары Урал казна тау з-дларына беркетелә. 1864–1917 дә Пермь губернасы *Казан хәрби округына*, 1870–1917 дә Казан мәхкәмә округына керә. Совет чорында П.к.нда зур сәнәгать объектлары төзелешендә һәм эшендә күп кенә татарлар һәм Татарстанлылар (к. М.Ф.*Ардуанов*, М.М.*Мәүлиев* һ.б.) катнаша. Край терр-ясендә Казан селекция станциясендә чыгарылган а.х. культуралары («*Казан 64/95*» люцерна, «*Казан 430*» тары сортлары) районлаштырылган. ТР б-н П.к. арасында икътисад, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешү төзелгән. Мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүне тормышка ашырып, Барда районы мәктәп укучылары ел саен Казанда ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган татар теле һәм әдәбияты буенча төбәкара олимпиадаларда катнашалар. Ш.у.к. *Пермь татарлары*.

*Әд.:* Закиров Д.Г. Известные татары Прикамья. Пермь, 2005; Чагин Г.Н. Народы и культуры Урала XIX–XX вв.: Ист.-этногр. атлас. Екатеринбург, 2003.

*Д.Г.Закиров.*

**ПЕРМЬ РАЙОНЫ́**, *Пермь краенда*, Пермь шәһәр яны зонасында урнашкан. 1939 елда Югары Мулла р-ны буларак оештырыла. 1963 тән бүгенге исемен йөртә. Мәйданы — 3750 $км^2$. Район үзәге Пермь шәһәрендә. Халкы — 104504 кеше (2013), татарлар — 4436 кеше (2010). Татарлар, башлыча, Башкултай (2008 дә — 608 кеше; 1592 дән мәгълүм) һәм Куян (1171 кеше: 17 йөз башыннан мәгълүм) авылларында яшиләр. П.р. терр-ясенә алар Казан ханлыгы таркалгач күченә, күбесе асабалар катлавына керә. 1720 елларда атаклы руда чыгару сәнәгатьчесе Исмәгыйль Тасимов Куян авылы янында 15 бакыр шахтасын нигезли, чыгарылган руда Егошиха һәм Юг з-дларына җибәрелә. Тасимов С.-Петербург тау уч-щесен (соӊрак — ин-тын) оештыручыларныӊ берсе була һәм аӊа матди ярдәм күрсәтә. Куян һәм Башкултайда 1803 тә — 1145, 1816 да — 1437, 1858 дә — 2276, 1904 тә — 3606 кеше яши. 1929 га кадәр Куян авылында 2 җамигъ мәчет (1750 һәм 1897 дә төзелә), мәдрәсә эшли, 1925–30 да Башкултайда мөселман җәмгыяте була. 1948 дә Куянда икенче җамигъ мәчет тергезелеп эшли башлый, ул 1991 гә кадәр Пермь өлкәсендә бердәнбер мөселман гыйбадәтханәсе булып кала. Хәзерге көндә Башкултай һәм Куян мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Куян мәдәният йорты каршында хор һәм бию («Ләйсән») коллективлары эшли. Пед. фән. д-ры Ә.С.*Тайсин* һәм мед. фән. д-ры Р.З.Кузяевныӊ тормышы П.р. б-н бәйле. 2008 дә Куян авылында И.Тасимов истәлегенә мемориаль такта ачыла.

*Әд.:* Мурсалимов Г.С. Кояново // Материалы по Пермской области к Уральской исторической энциклопедии. Пермь. 1994. Вып. 1; шул ук. Село Кояново в истории Пермской губернии // Пермский край: Прошлое и настоящее (к 200-летию образования Пермской губернии). Пермь, 1997.

**ПЕРМЬ СИСТЕ́МАСЫ (ЧОРЫ́)**, пермь (элекке Пермь губ. атамасы буенча), Җирнеӊ геол. тарихындагы палеозой эратемасыныӊ (эрасыныӊ) соӊгы (алтынчы) системасы (чоры). 299±0,8 млн. ел элек башлана, 48±0,4 млн. ел дәвам итә. 3 бүлеккә һәм 9 яруска бүленә. 1841 елда инглиз геологы Р.*Мурчисон* тарафыннан билгеләнә.

П.с.(ч.) интенсив тектоник хәрәкәтләр б-н характерлана. Материклар күчеше дәвам итә, Европа төньякка күчә һәм Азия б-н тоташа, алар кушылган урында Урал таулары формалаша башлый. Татарстан терр-ясе төньякка күчә һәм хәзерге торышыннан көнбатышкарак борыла. Җылы һәм коры климат шартларында диӊгез, лагуна һәм континенталь утыр-



Татарстанныӊ Пермь утырмаларындагы кварц кристаллары.

малар: доломитлар, известьташ, гипс, балчык, кызгылт комсу-балчыксыл токымнар хасил була. П.с.(ч.)ныӊ органик дөньясы җир өсте үсемлек һәм хайваннарыныӊ роле арту б-н характерлана; палеозой хайван һәм үсемлекләре үлеп бетә һәм яӊа төркемнәре барлыкка килә. Мүкләр, диӊгезләрдә яшел су үсемнәр зур роль уйный башлый. Хайваннар дөньясы бай һәм төрле булуы б-н аерылып тора: диӊгезләрдә — бер күзәнәкле хайваннар (фораминифералар), мәрҗәннәр, моллюсклар, акуласыманнар һәм тәӊкәле балыклар, төче сулыкларда ишкәгаяклы кысласыманнар яши. Бөҗәкләрнеӊ (элпәканатлылар), үрмәкүчсыманнарныӊ, җир-су хайваннарыныӊ (панцирь башлылар, бака-кәлтәләр) яӊа отрядлары барлыкка килә, җәнлексыман сөйрәлүчеләр зурая. Татарстан терр-ясендә имезүчеләрнеӊ беренче җылы канлы бабалары — хәнҗәрсыман казык тешле парейазаврларныӊ (3 *м* га кадәр озынлыкта) калдыклары табыла. П.с.(ч.)ныӊ гомуми калынлыгы 600 *м* дан артык. Системаны өйрәнүгә Казан геологлары Н.А.*Головкинский*, А.А.*Штукенберг*, А.В.*Нечаев*, М.Э.*Ноинский*, Е.И.*Тихвинская*, И.Н.*Тихвинский*, В.И.*Игнатьев*, Ю.В.*Сементовский* һ.б. зур өлеш кертәләр. Алар тарафыннан *Уфа ярусы* һәм *Казан ярусы* (Нечаев), *Көнгер ярусы* (Штукенберг) аерым нигезләнә; стратотиплар ачыла (эталон киселешләр, мәс., *Печище геологик киселеше*); Пермь утырмаларында файдалы казылмаларныӊ урнашу закончалыклары билгеләнә. ТР терр-ясендә П.с.(ч.) утырмаларына известьташ, доломит, гипс, битум, нефть, минераль су һ.б. чыганаклар (17–19 йөзләрдә бакыр рудалары чыгарыла) туры килә. Ш.у. к. *Палеоботаника, Палеонтология, Стратиграфия*.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Стратиграфический кодекс России. СПб., 2006.

*Н.Б.Вәлитов, Э.Х.Рәхмәтуллин.*

**ПЕРМЬ ТАТА́Р ПЕДАГО́ГИЯ УЧИ́ЛИЩЕСЕ**, 1929 елда Пермь татар-башкорт пед. техникумы — Свердловск пед. техникумы ф-лы буларак оештырыла; 1937 дән Пермь татар пед. техникумы, 1941 дән пед. уч-ще. Башта Пермь шәһәрендә, 1941 дән Югары Мулла (хәзер Пермь) р-ныныӊ Куян авылында урнаша. 1955 тә ябыла. Пермь өлкәсенеӊ татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерли, ел саен якынча 25 кеше тәмамлый. Тәмамлаучылар арасында — язучы Ә.М.*Маликов*.

**ПЕ́РМЬ ТАТАРЛАРЫ́** (Көнгер татарлары), *Казан татарларының* этнографик төркеме. 20 йөз башында 52,7 мең кеше исәпләнә, Пермь губернасының Пермь, Оса, Красноуфимск һәм Көнгер өязләрендә тупланып яшиләр. 17–18 йөзләрдә П.т. «Көнгер татарлары» (өяз үзәге — Көнгер ш. исеменнән) буларак та билгеле. 21 йөз башында П.т., асылда, Пермь һәм Свердловск өлкәләрендә яшиләр. П.т.ның язуы Казан татарларыныкы шикелле үк — рус алфавиты нигезендә. Дин тотучы П.т. — мөселман-сөнниләр.

П.т. формалашуда Сылва археол. культурасы б-н бәйле угор (ихтимал, төрки-угор) халыклары төркеме әһәмиятле роль уйный. 15 йөз — 17 йөз башы рус чыганакларында әлеге төркем «остяклар» (татарча — иштәк сүзеннән) дип искә алына. Остяклар нугай бәкләренә буйсынган аерым этносәяси берләшмә (Остяклар, яисә Костяклар, җире) рәвешендә Казан ханлыгы йогынтысында булалар. П.т.ның тагын бер мөһим этник компоненты булып Пермь төбәге халкының нугай-кыпчак төркеме санала, моны шәҗәрә язулары, тарихи риваятьләр һ.б. тарихи-этнографик материаллар да раслый. П.т. оешуда 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөз башында Урта Идел буеннан Пермь төбәгенә күчеп килгән Казан татарлары (өлешчә *мишәрләр* дә) сизелерлек роль уйный. Казан татарлары П.т.ның этносәяси һәм этномәдәни үсешенә зур йогынты ясыйлар. Мәдәни-көнкүреш үзенчәлекләре буенча П.т. Мулла, Көнгер, Танып һәм Красноуфимск дип аталган 4 төркемчәгә бүленә. П.т.на кардәш кайбер татар телендә сөйләшүче төркемнәр (мәс., Пермь өлкәсенең Барда р-нында яшәүчеләр) рәсми яктан башкортлар булып исәпләнә. П.т.н татарларга һәм башкортларга аеру юк, бары элеккеге географик һәм нәсел-ыру бүленешенә карап, Гәйнә һәм Көнгер төбәкләренә аерып карау яшәп килә, шунлыктан бу аеру бик тә шартлы булып тора.

*Әд.:* Пермские татары. К., 1983; Историческая этнография татарского народа. К., 1990; Татары. М., 2001.

*Д.М.Исхаков.*

**ПЕРМЯ́К** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 9 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Киндерле елгасы буенда. 2010 елда 133 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб, китапханә. 1565–67 еллардан Тәүгелде атамасы б-н билгеле. Авыл б-н төрле кешеләр идарә итә, 1593–1764 тә авылның бер өлеше Казан Троица-Сергий монастыре карамагында була. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт (элек — экономик, 1764 кә кадәр — монастырь) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, 1860 тан, күн эшкәртүдә кулланылучы бәкам агачын уып, порошок ясау б-н шөгыльләнә. 1719 дан П.та Казан-Богородица чиркәве, 1889–1914 тә хатын-кызлар земство мәктәбе эшли. 20 йөз башында 4 тимерчелек, җил тегермәне, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2244,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 70, 1782 дә — 352 ир-ат; 1859 да — 707, 1897 дә — 922, 1920 дә — 975, 1926 да — 1206 (Мелиновка авылын да кертеп), 1938 дә — 998, 1949 да — 786, 1958 дә — 629, 1970 тә — 324, 1989 да — 176, 2002 дә — 163 кеше.

*Әд.:* Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

**ПЕРО́В И.С. ТАШБАСМАХАНӘСЕ́**, Казанда. 1871 елда Казан цехчысы Иван Семёнович Перов тарафыннан ачыла. Аның вафатыннан соңгы хуҗасы — М.А.Семёнов (1911 дән). Ташбасмаханә 1916 га кадәр эшли. Тора-бара шәһәрдәге иң эре полиграфия пр-тиеләренең берсенә әверелә. 1870 елларда анда 10, 1888 дә — 17, 1899 да — 40, 1915 тә — 50 кеше эшли. 1885 тән — басмаханә һәм ташбасмаханә. Иң беренче продукциясен рус наширләре заказлары буенча басылган эстамплар тәшкил итә. 1879 дан татар телендә ташбасма эшләнмәләр — нигездә, мөселманнарның изге урыннары күренешләре төшерелгән язулы эстамплар, дивар календарьлары, геогр. карталар нәшер ителә. 1883 тә К.Насыйри календаре, 1901 дә — Ш.Таһировның татарча әлифбасы бастырыла. 1879–1910 да 890 мең тираж б-н 67 исемдә татар басмасы дөнья күрә. 20 йөз башыннан төп продукцияне газета һәм китаплар тәшкил итә. Казан ун-ты проф.-табибларының фәнни хезмәтләре, иҗтимагый оешмалар һәм үзидарә органнарының отчётлары, православиегә караган дини әдәбият нәшер ителә. 1901–16 да 352 исемдәге китап басылып чыга. 1905 тән соң Казан карагруһчыларының газеталары һәм листовкалары басыла (И.С.Перов уң оешмаларның гаять актив эшлеклесе була). 1910 нан соң «Камско-Волжская речь» либераль г-тасы басыла башлый.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Г а б д е л ь г а н е е в а Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

*Г.Г.Габделганиева.*

**ПЕРСИ́ДСКИЙ** Константин Петрович (23.10.1903, Сембер губ., Сызрань өязе Лобановка а. — 22.6.1970, Алма-Ата), математик, физика-матем. фән. д-ры (1946), Казакъстан ССР ФАнең акад. (1951), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1944). Н.Н.*Парфентьев* шәкерте. Казан ун-тын тәмамлый (1927), шунда ук матем. кафедрасында эшли, проф. (1934), дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире һәм физика-матем. ф-ты деканы (1938–40), бер үк вакытта Казан авиац. ин-тының югары матем. каф. профессоры (1933–39). 1940 тан Казакъстан ун-тының матем. анализ (1940–44) һәм дифференциаль тигезләмәләр (1946–68) кафедралары мөдире, бер үк вакытта Пед. ин-тының геом. каф. мөдире (Алма-Ата, 1940–44); 1946 дан Казакъстан ССР ФАсендә: матем. һәм механика секторы мөдире (1946–51), Физика-матем. фәннәре бүлегенең акад.-секретаре (рәисе) (1951–54); Матем. һәм механика ин-ты директоры (1966–69) һәм функциональ фәзаларда дифференциаль тигезләмәләр лаб-ясе мөдире (1966–70). 1944–46 да Томск политехник ин-тының матем. каф. мөдире һәм Томск ун-ты укытучысы. Хезмәтләре ихтималлылык теориясенә, дифференциаль һәм интеграль тигезләмәләргә, функцияләр теориясенә һәм функциональ анализга, дифференциаль тигезләмәләр чишелешенең тотрыклылыгы теориясенә карый. П. Ляпуновның икенче алымын үстерә, чишелешләрнең беренче якынчалык буенча тотрыклылыгы мәсьәләләрен өйрәнә, тотрыксызлыкның гомуми теоремасын исбатлый. Гади дифференциаль тигезләмәләр системалары, аерым чыгарылмалы һәм Банах фәзаларындагы тигезләмәләр тотрыклылыгының кайбер мәсьәләләрен өйрәнә. Казакъстанда файдалы казылмалар запасын бәяләү өчен ихтималлык теориясе алымнарын куллана. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль, Казакъстан ССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Избр. труды: В 2 т. А.-А., 1976.

*Әд.:* Константин Петрович Персидский. А.-А., 1984.

**ПЕРФИ́ЛОВ** Николай Петрович (21.11.1924, Арча кантоны Кадыш а., хәзер Казанның Авиатөзелеш р-ны — 19.9.2002, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1955). 1939–84 елларда Казан авиация ҖБдә: токарь, өлкән инженер, инженер-конструктор, клёпкалау-җыю эшләре бүлегенең КБ башлыгы. Дәүләт бүләге универсаль җайланмалар һәм стапель конструкцияләре җыюда яңа технол. процессларны кулланып самолётлар җитештерү алымын эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

**ПЕРЦО́В** Эраст Петрович (29.11.1804, Воронеж ш. — 11.7.1873, С.-Петербург), шагыйрь, драматург, публицист. «Ришвәт алу сәнгате. Мәрхүм титуляр советник Тяжалкин кәгазьләре арасында табылган кулъязма» («Искусство брать взятки. Рукопись, найденная в бумагах Тяжалкина, умершего титулярного советника», 1830) сатирасы, «Андрей Бичев, яки Мин кешеләрдән көләм» («Андрей Бичев, или Смешны мне люди», 1833) комедиясе, «Механиканың гомумхалык курсы» («Общенародный курс механики», 1847) белешмәлеге, крепостной хокукны тәнкыйтьләгән шигырьләр, сәяси вазгыятькә, министрлыклар эшчәнлегенә, крәстияннәр чуалышларына багышланган очерк цикллары авторы. 1811 елдан гаиләсе б-н Казанда, 1824 тән С.-Петербургта яши. 1830 елларда озаклап Казанда яшәп ала. Е.А.Боратынский б-н таныш була. 1833 тә Пушкин Казанга килгәндә П. б-н очраша, аның янында берничә тапкыр М.С.Щепкин туктала. Шагыйрьнең биографы Н.Я.Агафонов сүзләренә караганда, Казанда П. җәмгыятьнең үзәгендә торып, «җәмәгать тормышын җанландыручы» булып санала, А.А.Фуксның әдәби түгәрәгенә йөри. 1861 дә С.-Петербургта «Колокол» ж-лы б-н хезмәттәшлек иткән өчен кулга алына. Тентү вакытында, Казан губернасының Бизнә авылында булган крәстиян чуалышла-

ры тасвирланган, П. исеменә юлланган хат алына. П. Түбән Новгородка сөрелә (сәламәтлеге начар булу сәбәпле азат ителә). Үз-үзенә кул сала.

*Әд.:* Бобров Е.А. А.А.Фукс и Казанские литераторы 30–40-х гг. // Русская старина. 1904. Т. 119, № 7.

*М.М.Сидорова.*

**ПЕРЦО́ВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 4 *км* көнбатыштарак, Бөгелде елгасы буенда. 2010 елда 225 кеше (руслар, татарлар) яши. 1922 дә нигез салына. Оештырылган көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1926 да — 55, 1938 дә — 87, 1949 да — 87, 1958 дә — 96, 1970 тә — 44, 1979 да — 43, 1989 да — 13, 2002 дә — 69 кеше.

**ПЕРШАКО́В** Александр Александрович (24.8.1875, С.-Петербург — февраль 1943, Мари АССРның Мушмари пос.), зоолог, эколог. Казан сәнәгать химия технологиясе уч-щесен тәмамлаганнан соң (1901), шунда ук эшли; бер үк вакытта Казан а.х. һәм урманчылык ин-тында, урман химия технологиясе каф. мөдире (1922–24). 1931–32 елларда Казан ун-тында. 1933 тән Идел буе урман техникасы ин-тында (Йошкар-Ола ш.) проф. (1933), биол. фән. каф. мөдире. Хезмәтләре орнитологиягә, табигатьне саклауга, Татарстан, Чуаш, Удмурт, Мари АССРлар фаунасын өйрәнүгә карый. П. Казан ун-тында Э.А.Эверсман тарафыннан башланган тетраподология (җир өсте хайваннарын өйрәнү) буенча тикшеренүләрне дәвам итә, иҗади коллектив туплый, аның составына И.С.Башкиров, Е.П.Кнорре, В.А.Попов һ.б. галимнәр керә. Вак имезүчеләрне исәпкә алу ысулын эшли. Казан зообbooтаника бакчасын, Идел-Кама саклаулылыгының Раифа участогын (1926), Идел-Кама төбәге промысел-биол. станциясен (1929) оештыручыларның берсе. Гражданнар сугышы елларында Казан губернасында скипидар-сумала табу эшен тергезүдә катнаша. Төбәктә беренче булып Раифа урманында нарат киртләү буенча тәҗрибәләр үткәрә башлый.

Хезм.: Лесные позвоночные как хозяйственные факторы // Изв. Казан. ин-та сел. хоз-ва и лесоводства. 1929. № 1; О местностях, пригодных для выселения бобров в Казанском крае // Пушное дело. 1931. № 11–12; Методика учёта позвоночных в лесном хозяйстве // Изв. Поволжского лесотехнического ин-та. 1935. Вып. 2.

*Әд.:* Гаранин В.И. В.А.Попов и Волжско-Камский заповедник // Тр. Волжско-Камского гос. природного заповедника. 2005. Вып. 6.

*В.И.Гаранин.*

**ПЕСӘ́Й** авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чөмән елгасы буенда. 2010 елда 388 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре, асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.дә мәчет, мәктәп (1840 та ачыла) эшли. 1920 гә кадәр авыл халкының бер өлеше (элекке дәүләт крәстияннәре) — Күрәк, икенче өлеше (элеккеге асабалар һәм типтәрләр) Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1887 дә — 162, 1905 тә — 236, 1920 дә — 662, 1926 да — 1007, 1938 дә — 988, 1949 да — 707, 1958 дә — 477, 1970 тә — 407, 1979 да — 307, 1989 да — 332, 2002 дә — 424 кеше.

**ПЕСИ́ ТӘПИЧӘСЕ́**, песи тәпие (Antennaria), оешма чәчәклеләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр, сирәгрәк — ярымкуакчыклар ыругы. 100 дән артык төре билгеле. ТР терр-ясендә бер төре — ике өйле П.т. (A. dioica) киң таралган. Нарат урманнарында, коры болыннарда һәм тау битләрендә үсә. 8–20 *см* биеклектәге, куе төкчәле күпьеллык ике өйле үсемлек, агачсыман горизонталь тамырчалы һәм тамырланучы түшәлмә бәбәкләре бар. Яфраклары чиратлашкан, бөтен, өсте яшел, аскы ягы киезсыман ак. Тамыр яны яфраклары киң, калаксыман, таралгыда, сабактагылары — кыяк-ланцетсыман. Чәчәкләре вак кәрзиннәрдә, сабак очындагы тыгыз калкан чәчәк төркеменә җыйналган. Ике җенеслеләр — ак, ана чәчәкләр алсу төстә. Җимеше — бүрекчәле озын орлыкча. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Чәчәк кәрзиннәрендә дуплау матдәләре, чәер, сапониннар, органик к-талар бар. Халык медицинасында җир өсте өлешләре үт кудыру, бөрештергеч, кан туктату чарасы буларак кулланыла. Тире авырулары вакытында киң файдаланыла. Декоратив үсемлек. Үлмәс чәчәкләр төренә карый.

**ПЕ́СКЕ** Александр Иванович (1810, Могилёв ш. — ?), архитектор, архит-ра академигы (1841). СА тәмамлаганнан соң (1836), Петергоф сарае идарәсендә эшли. 1843–59 елларда Казан төзелеш комиссиясе архитекторы. 1859–71 дә Волынь һәм Бессарабия губерналарында губерна архитекторы. Соңгы классицизм стилендә эшли. Казанда П. проектлары буенча *Казан руханилар академиясе* бинасы комплексы (1844–48), И.И.Аппаков, Д.И.Майков, З.Б.Госманов, Ф.А.Дугин йортлары төзелә. П. *Губернатор сарае* төзелеше б-н җитәкчелек итә. 1842 елгы янгыннан соң Казанны яңадан торгызуда катнаша: *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты* бинасын, постау мануфактурасы казармаларын реконструкцияли.

*Әд.:* Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**ПЕСНӘ́К КОШЛА́Р** (Paridae), чыпчыксыманнар отрядындагы кошлар семьялыгы. 53 төре билгеле, Көньяк Америка, Мадагаскар һәм Австралиядән тыш киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә песнәк (Parus) һәм яр песнәге (Remiz) ыругыннан 9 төре бар. Кара башлы песнәк (Parus palustris), көрән башлы песнәк (P. montanus), бүрекле песнәк (P. cristatus), зур песнәк (P. major), кара песнәк (московка) (P. ater), зәңгәр песнәк (P. caeruleus) барлык районнарда да очрый. Оя коручы, кышлаучы төрләр. Соры башлы песнәк (P. cinctus) — очып керүче сирәк төр. П.к. катнаш урманнарда, бакча һәм паркларда яши. Гәүдә озынлыгы 10–18 *см*, авырлыгы 7–25 *г*. Томшыгы конуссыман. Тәпиләре көчле бармаклы һәм нык бөгелгән очлы тырнаклы, горизонталь һәм вертикаль ботаклар буенча хәрәкәтләнергә яраклашкан. Койрыгы уртача зурлыкта, тигез яки зур булмаган уемтылы. Каурый капламы куе һәм йомшак. Зур песнәк — песнәкләр арасында иң эресе. Бүрекле песнәкнең башында озын бүрек. Көрән башлы песнәк көрән төстәге «бүрекле». Ояларын агач куышларында коралар. Җәен — бөҗәкләр (филчекләр, ефәк күбәләкләре, яфрагашарлар, яфрак төргечләр һ.б.) һәм үрмәкүчләр, кышын орлыклар б-н тукланалар. Ак төстәге 4–11 йомырка салалар. Гади яр песнәге (Remis pendulinus) һәм ак песнәк (Parus cynan) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ПЕСНӘ́К-ОЗЫНКОЙРЫ́К** (Aegithalos caudatus), шул ук исемдәге семьялыктан бердәнбер кош төре. Евразиянең урман зонасында таралган. Татарстан терр-ясендә барлык районнарда очрый. Куе куаклыклы яфраклы һәм катнаш дымлы урманнарда яши. Утрак яки күчмә кош. Кечкенә (озынлыгы 6–7 *см*) тыгыз тәне һәм тигезсез киртләч озын койрыгы (8–10 *см*) кошны озын саплы кашыкка охшата. Аркасы, канатлары һәм койрыгы кара, аркасында алсу буй, башы, түше, койрыгының ян-ягындагы полосалар ак



төстә. Канатлары кыска, киң. Тәпиләре көчсез. Март ахыры – апрель башында төркем парларга бүленә, шушы вакыттан П.-о. үзен тыныч һәм яшертен тота. Оясын еш кына каен яки зирек ботакларында эллиптик формада кора. Шәмәхә-алсу бизәкле 10–12 ак йомырка сала. Нигездә, бөҗәкләр б-н туклана.

**ПЕСО́ШИН** Алексей Валерьевич (9.12.1963, Казан), дәүләт эшлеклесе, физика-матем. фән. канд. (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1986), 1986–95 елларда шунда ук Чеботарёв исем. Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1995–2000 дә «Жилбытсервис» АҖнең Казан шәһәре Совет р-нындагы 79 нчы торак-файдалану идарәсе-

нең баш инженеры урынбасары, башлыгы. 2000–02 дә «Казан газ аппаратлары заводы — Веста» АҖнең ген. директоры урынбасары, баш инженеры, 2002–07 дә ген. директоры. 2007–10 да Казанның Совет р-ны хакимияте башлыгы. 2010–14 тә «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма ком-ты җитәкчесе. 2014 тән ТР Премьер-министрының 1 нче урынбасары. Хезмәтләре механика өлкәсенә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПЕСО́ШИН** Андрей Петрович (25.8.1918, хәзерге Рязань өлкәсенең Старожиловка р-ны Смыгаловка а. — 25.7.1977, Казан), икътисадчы. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1957). 1938–52 һәм 1957 елларда Казан авиация з-дында техник-технолог, өлкән технолог, куркынычсызлык техникасы бүлеге башлыгы булып эшли. 1952–54 тә партком секретаре урынбасары. 1954–56 да бүлек башлыгы, 1956–57 дә шул ук заводта завод ком-ты рәисе. 1957 дән Татарстан ХХСның Җитештерү-техник идарәсе башлыгы урынбасары. 1963 тән Казан мед. инструментлары з-дында, директор (1963–77). П. пр-тие үсешенә зур өлеш кертә. Заводта реконструкция уздырыла, продукция төрләре яңартыла, җитештерү күләме арта. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, ике «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

**ПЕСО́ШИН** Валерий Андреевич (10.9.1939, Мәскәү), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1987), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998). 1963 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1970 тән Казан техник ун-тында, 1978 дән ЭВМ каф. (хәзер компьютер системалары һәм информацион куркынычсызлык каф.) мөдире, проф. (1989), техник кибернетика һәм информатика ф-ты деканы (1993–97). Хезмәтләре статистик модельләштерү өчен хисаплау техникасы җайланмаларына карый. П. җитәкчелегендә эшләнгән аппарат-программа чаралары ил пр-тиеләрендә сериялап җитештерүгә кертелә, болар: ЕС 6903 очраклы саннарны ЭВМга кертү җайланмасы, РС XT/AT тибындагы ТЭВМ ЕС 1007 һәм ПЭВМ өчен очраклы саннар генераторлары, тигез ихтималлы очраклы эзлеклелекнең зур интеграль схема-генераторы, челтәрләрдәге («Кристалл», «Гранит», «Гранит-Х») ПЭВМнар мәгълүматын криптографик саклаучы аппарат-программа комплексы. Уйлап табуга 36 авторлык таныклыгы һәм 13 патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К проблеме формирования некоррелированных псевдослучайных чисел на основе М-последовательностей // Автоматика и вычисл. техника. 1984. № 4; Сопроцессорные средства формирования случайных чисел и защиты информации // Вопр. радиоэлектроники. 1991. Вып. 6; Цифровые генераторы случайных сигналов для защиты информационных телекоммуникаций // Вопр. радиоэлектроники. 1993. Вып. 4 (автордаш); Моделирование. Вероятностные дискретные модели. К., 1998 (автордаш).

**ПЕСТИЦИДЛА́Р** (лат. pestis — агу һәм caedo- үтерәм) (агулы химикатлар), үсемлекләрне корткычлардан, авырулардан, чүп үләннәрдән саклауда, азык продуктлары корткычлары б-н, туфракның ярлылануы б-н көрәштә кулланыла торган химик һәм биол. матдәләр. П.лар төп кулланылышына, чүп үләннәргә һ.б. корткычларга тәэсир итү характеры, корткычлар организмнарына үтеп керү сәләте, химик табигатенә карап классификацияләнә. Юкка чыгаручы П.: бөҗәкләрне — инсектицидлар, талпаннарны — акарицидлар, түгәрәк кортларны — нематицидлар; югары төзелешле үсемлекләрдә паразитлык итүче гөмбәләрне — фунгицидлар, бактерияләрне — бактерицидлар, вирусларны — вирусоцидлар; умырткалы корткычларны — зооцидлар (кимерүчеләрне — родентицидлар, кошларны — ретицидлар), моллюскларны — моллюскоцидлар), чүп үләннәрне — *гербицидлар*, киръякмәгән агач һәм куак үсемлекләрне — арборицидлар, суүсемнәрне — альгицидлар; механикалаштырылган урып-җыю алдыннан яфракларны койдыра торган — дефолиантлар; үсемлекләрне тамырыннан киптерә торган — десикантлар; хайваннардан һәм кешеләрдән корткыч-бөҗәкләрне куркытып куа торган — репеллентлар, тукланучы үсемлекләрдән — антифидантлар; бөҗәкләрне җәлеп итүче (аларны юкка чыгару яисә санын исәпкә алу өчен) — аттрактантлар; бөҗәкләрнең үрчү сәләтен бетерүче — хемостерилянтлар. П.ны корткычларның үсеш фазасына карап төркемнәргә берләштерәләр (мәс., овицидлар — бөҗәкләр һәм талпаннарның күкәйләрен; ларвицидлар — личинкаларны үтерүчеләр һ.б.). П.ның препарат формалары: чыланучан порошоклар, эмульсия концентратлары, пасталар, гранулятлар, дустлар, аэрозольләр, сыеклыклар, эрүчән порошоклар, тәэсир итүче матдәдән тыш ярдәмче компонентлары, кушылмалары булган куертылган суспензияләр һ.б. бар.

П.ны куллану ысуллары — сиптерү, бөркү, фумигацияләү, агулау, алдавыч җим куюу һ.б. П.ны техник, хуҗалык һәм икътисади нәтиҗәлелеге ягыннан аералар. Иң яхшы нәтиҗәгә П.ны үсемлекләрне саклауның интеграцияләнгән системаларында куллану юлы б-н ирешелә, һәм ул а.х. культураларын үстерүдә интенсив (алдынгы) технологияләрнең әһәмиятле өлеше булып тора.

Корткычларның П.га индивидуаль, популяцияләп, яшәү чорларында һ.б. табигый тотрыклылыгын, ш.у. аларны озак вакытлар һәм системасыз кертү аркасында килеп чыга торган резистентлыкны булдырмау өчен, үсемлекләрне биологик саклау юлларын кулланалар, П.ны чиратлаштыралар, төрлечә тәэсир ясау механизмнары б-н аралаштыралар.

П.ны дөрес кулланмау флора, фауна, а.х. терлекләренә һәм кешеләргә зыян китерергә мөмкин. А.х.нда кулланырга рөхсәт ителгәннәрнең исемлегенә якынча 1,5 мең П. атамасы кертелгән. Һәрбер П. өчен куллану кагыйдәләре һәм сроклары, эшләү зонасындагы һавада рөхсәт ителгән концентрация, терлек азыгында һәм азык-төлектә максималь рөхсәт ителгән дәрәҗә куелган. П.ны куллану Татарстанда 1920–30 елларда колхоз, совхозлар оештыру б-н бергә башлана, башлыча, а.х. культураларының орлыклык материалын кисәү авыруларына, арыш анасына каршы агулау күпләп кертелә. Аларны күбрәк куллану 1960 елларда гамәлгә ашырыла (борчак чәчүлекләрендә гөмбәләрне бетерү, кукуруз чәчүлекләрен химик юл б-н чүп үләннәрдән чистарту һ.б.). 1970 еллар ахырыннан П.ны (инсектицидларны) бәрәңге чәчүлекләрендә *колорадо коңгызына* каршы куллану ихтыяҗы туа. Хәзерге вакытта П. а.х. культураларының күпчелек өлеше б-н эшләгәндә кулланыла (170 ләп атама). Ш.у.к. *Үсемлекләрне саклау*.

*Әд.:* Пестициды: Справ. для агрономов и врачей. Киш., 1970; Руднев Д.Ф., Коновалова Н.Э. Природа и ядохимикаты. М., 1971; Справочник по пестицидам: Гигиена применения и токсикология. Киев, 1974; Пестициды растительного происхождения и фитогормоны. Таш., 1979; Пестициды: Справ. М., 1992; Фитосанитарный прогноз основных вредителей и болезней сельскохозяйственных культур на 2006 год и система мероприятий по борьбе с ними в Республике Татарстан. К., 2006.

*И.Н.Афанасьев.*


Н.Ф.Пестонов.

**ПЕСТО́НОВ** Николай Фёдорович (19.5.1899, Казан губ., Спас өязе Аппак а. — 7.12.1974, Куйбышев ш.), Дан орденының тулы кавалеры (20.5.1944, 7.9.1944, 15.5.1946), гв. өлкән сержанты. Навигация эшләре куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча техниклар мәктәбен тәмамлый (Самара ш., 1929). Куйбышевта техник-топограф булып эшли. Гражданнар сугышында катнаша, 1942 елның апреленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 174 нче гв. укчы полкында сапёрлар взводы командиры ярдәмчесе (8 нче гв. армиянең 57 нче гв. укчы дивизиясе). 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Изюм-Барвенково (1943), Никополь-Кривой Рог (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 11–13 маенда Шерпены (Молдавия ССР Новоанненск р-ны) торак пункты янында Днестр елгасын кичкәндә (подразделениеләргә сугыш кирәк-яракларын һәм азык-төлекне елганың икенче ярына алып чыгуны оста оештыра, дошманның контрһөҗүмен кире кайтаруда катнаша); 1944 нең июлендә Магнушев (Польша) шәһәре янында Висла елгасының сулъяк ярын инженерлык күзәтүе вакытында (бик күп миналарны зарарсызлый һәм полкның елга аша чыгуын тәэмин итә); 1945 нең 17–30 апрелендә Альт-Тухебанд (Зелов шәһәреннән 8 *км* көнчыгыштарак, Германия) торак пункты өчен (сапёрлар төркеме соста-



Н.Н.Петелина.



В.М.Петляков.

вында танкка каршы 200 дән артык минаны зарарсызлый, Берлин урамнарын һәм баррикадаларны миналардан арындыра, Тельт каналы аша салынган күперне тикшерә һәм танкка каршы 8 минаны зарарсызлый) сугышларда батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Куйбышев шәһәрендә заводта тәэминат төркеме җитәкчесе һәм мастер булып эшли. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Л о б о д а В.Ф. Солдатская слава. М., 1963. Кн. 1; Ш е в ч е н к о Н.Я. Звёзды славы. К., 1969; Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЕТЕ́ЛИНА** Наталия Николаевна (20.8.1920, Рязань өлкәсе Рязань р-ны Мурмино а. — 6.9.2007, Казан), агроном-селекционер, а.х. фән. канд. (1952), РФ Дәүләт бүләге лауреаты (1994). (1952), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1980). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлый (1942). 1946–56 елларда Александровский тәҗрибә станциясендә (Рязань өлкәсе) агроном, ярма культуралары селекциясе төркеме мөдире. 1956–60 та Калуга пед. ин-тында, 1960–67 дә Бөтенсоюз бөртекле-кузаклы һәм ярма культуралары фәнни-тикшеренү ин-тында (Орёл ш.). 1968–83 тә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының ярма культуралары селекциясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре карабодай селекциясенә, карабодай уңышын формалаштыруга, методологик факторларның тәэсирен өйрәнүгә карый. Эре бөртекле 11 карабодай сорты («Краснострелецкая», «Майская», «Прикамская», «Сокуровская», «Казанская крупнозёрная», «Идел» һ.б.) авторы. Дәүләт бүләге селекциянең теоретик нигезләрен эшләгәне, карабодайның югары уңышлы һәм тиз өлгерешле сортларын чыгарганы һәм җитештерүгә керткәне өчен бирелә. СССР МС бүләге лауреаты (1986). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының өч алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Крупяное поле Татарии. К., 1979 (автордаш).

**ПЕТЕРБУ́РГ МӨСЕЛМАННАРЫ́ АРАСЫНДА́ МӘГЪРИФӘ́Т ТАРАТУ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, хәйрия җәмгыяте. 1908 елның маенда оештырыла. Оештыручылары — У.С.Шәехгали, М.А.Максутов, Б.Ибраһимова-Шамил, З.М.Шамил. Төп максатлары — мөселман уку йортлары үсешенә булышлык итү, мөселманнар арасында мәгърифәт тарату, фәкыйрьләргә матди ярдәм күрсәтү. С.-Петербургта һәм аның тирәсендә эш итә. 1917 дән соң эшчәнлеге туктатыла.

*Ж.С.Миңнуллин.*

**ПЕТЕРБУ́РГ ХАЛЫ́КАРА КОММЕ́РЦИЯ БА́НКЫНЫҢ КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́**. 1869 елның маенда финанс ресурсларын бергә туплау, сәнәгатькә һәм сәүдәгә, ш.у. дәүләт учреждениеләренә һәм аерым затларга кредит бирү өчен оештырыла. Казан бүлегенең капитал әйләнеше 340 мең сум чамасы тәшкил итә (1916). 1917 нең декабрендә национализацияләнә.

*Әд.:* Л е б е д е в С.К. Санкт-Петербургский Международный коммерческий банк во второй половине XIX века: Европейские и русские связи. М., 2003.

**ПЕТЕРБУ́РГТА ТАТА́Р БИСТӘСЕ́**, татарларның 18 йөзнең 1 нче чирегендә барлыкка килгән тупланып яшәү урыны. Петропавел кальгасы тирәсендә урнашкан. Казаннан, Түбән Новгород, Касыйм, Пензадан һ.б. җирләрдән С.-Петербург төзелешенә китерелгән кешеләр тарафыннан нигезләнгән. 18 йөз тарихи әдәбиятында (Х.Вебер, А.И.Богданов) П.т.б.ндә «...татарлар, төрекләр, калмыклар һәм башка милләтләр һәркайсы үз тормышы белән яши...», «...кальга төзелгәндә шул ук хезмәттәге татарлар кәс түшәделәр, соңыннан артиллериядә төрле эшләр башкардылар» диелә. П.т.б.ннән ерак түгел татар базары булган. Төзелеш эшләре тәмамланганнан соң, татарларның бер өлеше, «...өйләренә кайту өчен ерак юлга...» чыгарга теләмичә, шәһәрдә төпләнеп калган, «моның өчен аларга теләсә кайсы җирдә урнашырга рөхсәт бирелгән». Бистә турындагы истәлек «Татар тыкрыгы» атамасында сакланган. 2006 елда элеккеге П.т.б. тирәлегендә, Кронкверский проспекты һәм Зверинский урамы почмагындагы скверда, Г.Тукайга һәйкәл куела.

*Әд.:* А м и н о в Д.А. Татары в Санкт-Петербурге: Истор. очерк. СПб., 1994; Т е л я ш о в Р.Х. Татарская община Санкт-Петербурга: К 300-летию города. СПб., 2003.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ПЕТЛЯКО́В** Владимир Михайлович (15.6.1891, Ростов өлкәсенең Самбек а., хәзер Новошахтинск ш. — 12.1.1942, Горький өлкәсенең Мамешево а., Казанда җирләнә), авиаконструктор. Таганрог техник уч-щесен (1910), Мәскәү югары техник уч-щесен (1922) тәмамлый. 1910–17 елларда Таганрог, Брянск, Мәскәү пр-тиеләрендә эшли. 1922–37 дә Үзәк аэрогидродинамика ин-тында (Мәскәү): канат төркеме җитәкчесе (1925 тән), баш конструктор урынбасары (1935 тән), тәҗрибә з-дының баш конструкторы (1936 дан). 1937 дә репрессияләнә, НКВДның Үзәк 29 нчы КБнда эшли (1937–40). 1941 дән 22 нче Мәскәү авиация з-дының Тәҗрибә КБ башлыгы (1941 нең көзендә завод Казанга эвакуацияләнә). Авиация һәлакәтендә һәлак була.

П. ныклыкны исәпләү алымнарын эшли (В.Н.Беляев б-н бергә) һәм күп ланжеронлы металл канатлар конструкцияләү теориясен үстерә (1925–35). Аның җитәкчелегендә илнең беренче авыр бомбардировщиклары ТБ-1, ТБ-3 камилләштерелә һәм серияләп җитештерүгә кертелә (1930–35), биектә оча торган бомбардировщик ТБ-7 (Пе-8) (1935–37), югары тизлекле, пике ясарга сәләтле бомбардировщик Пе-2 (1939–40, СССР Дәүләт бүләге, 1941) төзелә, аларга модернизация үткәрелә, күп кенә яңа модификацияләре булдырыла, серияләп җитештерү технологияләре үзләштерелә (1941). П. тарафыннан конструкцияләнгән самолётлар Бөек Ватан сугышында мөһим роль уйный: Пе-2 СССР Хәрби Һава көчләренең төп бомбардировщигы була; Пе-8 дә әһәмиятле стратегик бомбага тотулар, ш.и. 1941 нең августында Берлинга авиаһөҗүмнәр ясала. Барлыгы 11427 Пе-2 (ш.и. Казанда 10 меңнән артык) һәм 93 Пе-8 эшләп чыгарыла. Ике Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* П о н о м а р ё в А.Н. Советские авиационные конструкторы. М., 1977; С у л т а н б е к о в Б.Ф., М а л ы ш е в а С.Ю. Трагические судьбы. К., 1996; Завод стратегического назначения. К., 2002.

**ПЕТО́НДИ** Фома Иванович (1794, Орёл ш. — 13.7.1874, Казан), архитектор. Әтисендә, Орёл шәһәрендә эшләүче итальян архитекторында укый. 1811 елдан Мәскәү Кремле төзелеше экспедициясендә архитектор ярдәмчесе, 1814 тән Орёл төзелеш комиссиясе архитекторы. 1834 тән Казан губернасы архитекторы, бер үк вакытта, 1837 дән, *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты* бинасы архитекторы. 1844 тә, законсыз гамәлләрдә гаепләнеп, вазифасыннан читләштерелә, 1856 да аклана. 1844–60 та Казан төзелеш һәм юл комиссиясе архитекторы. Классицизм стилендә эшли. П. проектлары буенча 100 дән артык бина төзелә, шуларның күпчелеге, ш.и. Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты комплексы (1838–41), *Дротоевский йорты*, Иоанн-Предтеча монастыренең руханилар корпусы (1835); Унжениннар (1835), Мамаевлар, Жарков, Колокольников (барысы да 1836), А.И.Геркен (1839), А.С.Пискунов (1841), А.И.Щербаков (1842), Добрыниннның (1843) торак йортлары; Казан мосафирханәләре (1843, соңрак «Казан» кунакханәсе), Чистайдагы А.Г.Поляков йорты (1840), Зөя өязенең Морат авылындагы Казан Богородица чиркәве (1857) — архит-ра истәлекләре. П. проекты б-н һәм аның җитәкчелегендә *Благовещение кафедраль соборы* реконструкцияләнә (1841–46).



Ф.И.П е т о н д и. Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты. Казан. 1838-41.

*Әд.:* М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

*Е.В.Липаков, Л.М.Мортазина.*

**ПЁТР** (?–1552, Казан), Рус православие чиркәвенең газап чигүчесе. Казан татарларыннан, исеме билгесез. 1551 елда *Шаһгали хан* кабат тәхеткә утырганнан соң, П. гаиләсеннән китә, патша сарае даирәсендә яши. 1552 дә чукына дип фаразлана. Казанлыларның Шаһгалигә каршы баш күтәрүләре вакытында гаиләсенә көчләп кайтарыла. Туганнары аны исламга кайтырга үгетләп карый, әмма П. баш тарта. Шуннан соң аны туганнары, мөртәт буларак, баш күтәрүчеләргә тотып бирә. Җәзалап үтерелә. 1592 дә Казан һәм Әстерхан митрополиты Гермоген тәкъдиме б-н канунлаштырыла. Иске стиль б-н 24 мартта (хәзерге стильдә 6 апрель) Рус православие чиркәве тарафыннан искә алына.

*Әд.:* А р с е н и й (Брянцев). Жития святых и богоносных святителей и страстотерпцев земли Казанской. К., 1900; Жития святых мучеников Казанских Иоанна, Петра и Стефана. К., 2001.

**ПЁТР I** (30.5.1672, Мәскәү — 28.1.1725, С.-Петербург), рус патшасы (1682 дән), Россия императоры (1721 дән). 18 йөзнең 1 нче чирегендә Россиядә аның җитәкчелегендә илнең дөнья күләмендәге бөек державага әверелүен тәэмин иткән сәяси һәм социаль-икътисади үзгәртеп корулар үткәрелә. П.I фәрманнары нигезендә *Казан губернасы* (1708), *Казан постау мануфактурасы* (1714), *Казан адмиралтействосы* (1718), Казан помпа каеш-күннәре з-ды (1719) төзелә; төбәкнең халык исәбен алу тормышка ашырыла. Ул идарә иткән вакытта илдә рус булмаган халыкларны христианлаштыруның яңа дулкыны башлана. Россиядә дәүләт хезмәтен башкаручы мөселман динендәге йомышлы татарларны чукындыруны күздә тоткан 1713–15 еллардагы фәрманнар үтәлмәгән очракта, татар феодалларының утар һәм биләмәләре дәүләт файдасына тартып алына; православие динендәге 4 меңгә якын крепостной крәстиян патша сарае крәстияннәре катлавына күчерелә; 1718 дә йомышлы татарлар Казан адмиралтействосына беркетелә; 1722 дән 10–12 яшьлек татар малайлары хәрби хезмәткә (армиягә — денщик, флотка — юнга итеп) алына башлый һ.б. *Пётр I нең Иранга явы (1722–23)* вакытында, узып барышлый, 1722 нең 27 мае — 8 июнендә П.I Казанда туктала. Сәүдәгәр И.А.Михляев йортында урнаша. Благовещение кафедраль соборын, чиркәү һәм монастырьларны, Татар бистәләрен карап чыга; губерна канцеляриясенә, постау мануфактурасына, помпа каеш-күннәре з-дына, адмиралтействога ревизия үткәрә. Судларны яңа үрнәк буенча төзергә һәм җиһазларга әмер бирә; И.А.Михляевка Казан постау мануфактурасын тапшыра (1724). 1722 нең июнендә Иделнең түбәнге агымына юл тотканда, П.I Болгар шәһәрлегендә туктала; ул Болгар дәүләте башкаласы хәрабәләрен карап чыга, Зур манараны төзекләндерергә, болгар кабер ташларындагы язуларны күчереп алырга әмер бирә.



Пётр I.

1723–26 да П.I нең Казанга килүе хөрмәтенә *Петропавел соборы* төзелә.

*Әд.:* П и н е г и н М.Н. Казань в её прошлом и настоящем: Очерки по истории, достопримечательностям и современному положению города. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

*Е.Б.Долгов.*

**ПЁТР I НЕҢ ИРАНГА́ ЯВЫ́** (1722–23), рус гаскәрләре һәм флотының Пётр I җитәкчелегендә Иранның Каспий буе биләмәләренә явы. Русларның Каспий диңгезендә сәүдә мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм Кавказ артында төрекләр экспансиясен чикләү максатлары б-н оештырыла. 1722 елның 27 мае — 8 июнендә Пётр I Казанда туктала, губерна канцеляриясен тикшереп чыга, постау мануфактурасы, помпа з-ды, адмиралтейство һ.б. б-н таныша. Яуда 30 мең татар (ш.и. тылмач Й.*Ижбулатов*) катнаша. Казан адмиралтействосында П.I И.я. өчен суднолар төзелә. Сугыш хәрәкәтләре 1722 нең июлендә башлана. Сугыш барган җирләрдә яшәүчеләрне яуның сәбәпләре б-н таныштыру өчен, Әстерхан шәһәрендә татар телендә Пётр I манифесты басыла (әлеге басмадан Россиядә татар басма китабы тарихы башлана дип исәпләнә; к. *Пётр I нең поход (йөзмә) басмаханәсе*). Августта рус гаскәрләре Дербент шәһәрен ала. Көзен, гарнизонын Дербентта калдырып һәм Изге Хач кальгасын нигезләп, Пётр I төп көчләре б-н Әстерханга кайта. 1722 нең декабрендә Регит шәһәре, 1723 нең июлендә Баку шәһәре алына. 1723 нең сентябрендә Петербург солыхы төзелә, аның буенча Баку, Дербент шәһәрләре, Ширван, Гилян, Мазендеран, Астрабад провинцияләре Россиягә күчә.

*Әд.:* Л ы с ц о в В.П. Персидский поход Петра I. 1722–1723. М., 1951.

**ПЁТР I НЕҢ ПОХО́Д (ЙӨЗМӘ́) БАСМАХАНӘСЕ́**, император Пётр I нең китап эшендә агарту реформалары: гражданлык шрифты кертү, яңа басмаханәләр ачу, дөньяви басмаларны арттыру, Россиядә беренче газета — «Ведомости» чыга башлау б-н бәйле рәвештә оештырыла. Россиядә татар телендәге беренче басма документ — «Манифест» басылып чыга.

Синод басмаханәсеннән кирәк-яраклары б-н басмаханә станы тапшырыла, анда пунсон мастеры, җыючы, 5 мастеровой эшли башлый. Басмаханә флотилиянең 1722–23 елларда *Пётр I нең Иранга явында* катнашкан корабльләренең берсенә урнаштырыла. Нәшрият эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гарәп, латин һәм грек шрифтлары кулланыла. Басмаханәне оештыруда һәм аның эшендә молдаван галим-энциклопедисты, Пётр I нең шәркый мәсьәләләр буенча киңәшчесе кенәз Дмитрий Кантемир (1673 — 1723) мөһим урын тота. Иранга каршы яуда Кантемир яу канцеляриясенә һәм аның каршындагы басмаханәгә җитәкчелек итә. Аның рәсемнәре буенча гарәп шрифты коела. «Манифест» текстын да ул төзи, аны тәрҗемә итүдә һәм җыюда төп рольне уйный. «Манифест» төрек, фарсы (бу телләрне Кантемир 1688–1710 да Төркиядә тотык чагында өйрәнә), немец һәм татар телләрендә басыла.

«Манифест»ның татарча тексты югары стильдә күпсанлы гарәп һәм фарсы сүзләрен кулланып язылган. Әлеге текстны төзүдә Кантемирга Яшерен Совет тәрҗемәчесе, татар К.М.Тәфкилев булышкан дип фаразлана. Текст брошюра рәвешендә дүрт биттә, тышлыксыз, титул битеннән һәм исемнән башка гына басыла; мәгълүматлар текстның ахырында бирелә. Тиражы 1 мең данә («Манифест» нөсхәсе РФАнең Азия һәм Африка халыклары ин-тының Петербург бүлегендә саклана).

Флотилиянең 1722 нең 15 июлендә Әстерхан шәһәренә килүенә «Манифест» басыла, аннары гаскәрләр арасында да (106 мең сугышчының 30 меңе татар була), соңыннан, «белмибез дип әйтмәсеннәр өчен», Әстерхан, Баку, Дербент, Шемаха шәһәрләренең җирле халкы арасында да танышу өчен таратыла. «Манифест»та яуның максатлары аңлатыла: фарсылар шаһына (аның б-н Пётр I дустанә дипломатик мөнәсәбәтләрдә була) фетнәчеләр б-н көрәштә ярдәм итү, Россия сәүдәгәрләрен талаганнары өчен фетнәчеләрдән акча түләү (4 млн. сум) һәм үтергәннәре өчен җәзага тарту. Каспий диңгезенең көньяк-көнбатыш яры буендагы шәһәрләр халкына һәм чит ил сәүдәгәрләренә берниндидзыян килмәячәге, әмма алар фетнәчеләргә кушылсалар, аларга дошманнарга караган кебек караячаклары белдерелә.

Поход басмаханәсендә ш.у. «Хәрби җинаятьләр буенча законнар җыелмасыннан армия яулап алган урыннарда яшәүчеләргә дә нисбәтле маддәләр өземтәсе» татар телендә гарәп графикасы б-н, параллель рәвештә татар һәм рус телләрендә, басыла (сакланмаган).

Басмаханәдә эшләгән осталар 1723 тә Мәскәүгә формалы басу станы, матрицалы пунсоннар, гарәп шрифтын алып кайталар. Шрифт Синод басмаханәсенә тапшырыла, алга таба кулланылмый.

*Әд.:* К а р и м у л л и н А.Г. У истоков татарской книги. К., 1992.

*И.А.Новицкая.*

**ПЁТР I ФӘРМАНЫ́** (1713 ел, 3 ноябрь. «О крещении в Казанской и Азовской губерниях магометан, у которых в поместьях и вотчинах находятся крестьяне православной веры»), Казан һәм Азов губерналарының православие динендәге крепостной крәстияннә-

ре һәм хезмәтчеләре булган ислам динен тотучы йомышлы кешеләренә, җир биләмәләрен һәм вотчиналарын дәүләт файдасына тартып алу куркынычы астында, ярты ел эчендә чукынырга боерык бирә. Фәрманның үтәлешен тикшерү Сенатка йөкләнә. П.І.Ф. татар алпавытларын православие диненә күчәргә мәҗбүр итүче куәтле чара була.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 5. № 2734.

**ПЁТР I ФӘРМАНЫ́** (1715 ел, 12 июль. «Об описи и взятии в казну крестьян православной веры у помещиков магометанского закона, за невосприятие оными христианской веры»), йомышлы татарларга һәм башка халык вәкилләренә, алар карамагындагы православие динен тотучы крепостной крәстияннәрне җирләре һәм милекләре б-н дәүләт файдасына тартып алу куркынычы астында, чукынырга боерык бирә. Морзаларның утарлары, тегермәннәре һәм җир биләмәләре сакланып кала. Тартып алынган милекнең саны турындагы исемлек Сенатка тапшырыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 5. № 2920.

**ПЁТР I ФӘРМАНЫ́** (1718 ел, 31 гыйнвар. «О сохранении дубовых лесов, и о жестоком наказании тех, которые станут рубить, а также и тех, которые рубить прикажут; о выборе лесных надзирателей, и о даче особых клейм с гербом для заклеймения деревьев»), корабльләр төзергә яраклы агач кисү, юну һәм күчерү өчен түләүле эшләргә морзаларны, йомышлы татарлар, мордва, чуашларны җәлеп итәргә, түләүле эшләргә Казан, Түбән Новгород һәм Воронеж губерналары шәһәрләре, сарай карамагындагы һәм ясаклы рус авыллары балта осталарын, мичкә ясаучыларын, тимерчеләрен тартырга боера. П.І.Ф. лашманлык йөкләмәсенә башлангыч бирә (к. *Лашманнар*).

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 5. № 3149.


*Е.Б.Долгов.*

**ПЁТР АЛЕКСЕ́ЕВИЧ һӘМ ИОА́НН АЛЕКСЕ́ЕВИЧ ПАТШАЛА́Р ФӘРМАНЫ́** (1685 ел, 17 ноябрь «Об освобождении Казанских татар от земских податей и повинностей»), сәүдә һәм һөнәрчелек б-н шөгыльләнүче Казан йомышлы татарларын җир салымы һәм йөкләмәләреннән азат итә һәм аларга сәүдә биналары һәм кәсепләре өчен «элеккеге фәрман һәм яңа уставтагы сәүдә маддәләре буенча» гадәти салымнар түләүне йөкли. 1698 һәм 1763 ел Фәрманнары б-н раслана. 1821 дә гамәлдән чыгарыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 2. № 1143.

*Е.Б.Долгов.*

**ПЁТР ӘВЕРНӘСЕ́**, Пётр хачы (Lathraea), сыраҗчалар семьялыгыннан хлорофиллсыз күпьеллык үсемлекләр ыругы. 5–7 төре билгеле, күбесенчә Евразиянең уртача поясында таралганнар. Россиядә бер төре — тәңкәле П.ә. (L. squamaria) бар. Шулай ук Татарстан терр-ясендә — Кама алдында очрый. Киң яфраклы урманнарда, куак арасында үсә. Чикләвек куагы, юкә, зирек, усак, шомырт һәм кайбер башка агач-куак тамырларында паразит булып яши, бу исә аларның коруына китерә. 8–25 *см* биеклектәге үсемлек, тамырчасы юан, итчел, аксыл төстә, тармаклы, тәңкәсыман яфраклар б-н тыгыз капланган. Гадәттә, П.ә. беренче 10–15 елда җир астында гына үсә. Бу вакыт эчендә аның тамырчасы ныгый, кайвакыт хачсыман тармаклар (икенче исеме шуннан) барлыкка китерә, алардан исә хуҗа үсемлекләрнең тамырына керүче яңа гаусторияләр чыга. Бик зур үскәннән соң, П.ә.дә җир өсте чәчәк бәбәкләре формалаша. Иртә язда алар юан, саргылт яки алсу-ак сабак рәвешендә җир астыннан чыга. Чәчәкләре дөрес булмаган кыңгыраусыман формада, шактый эре, шәмәхә-алсу төстә, башаксыман чукта. Җимеше — бик күп вак кара орлыклы тартмачык. Җимеш бирүче бер бәбәк елга 50 меңгә якын орлык бирә ала. Җимеш биргәннән соң, җир өсте өлешләре шиңә һәм корый. Язгы баллы үсемлекләр.



Тәңкәле Пётр әвернәсе.

**«ПИАНОФО́РУМ»**, Казанда фортепиано музыкасы буенча ел саен уздырыла торган халыкара фестиваль. Беренче тапкыр 1988 елда Казан консерваториясенең махсус фортепиано каф. тырышлыгы б-н уздырыла; консерватория, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Казан шәһәре хакимияте тарафыннан оештырыла. «П.» кысаларында пианистларның соло концертлары, Россия һәм чит ил консерваторияләрендәге әйдәп баручы профессорларның мастер-класслары, яшь пианистларның конкурс-смотрлары, лекцияләр, пед. укулар уздырыла. Аерым «П.»нар күренекле музыкант-композиторлар А.Н.Скрябин (2002), С.В.Рахманинов (2003) юбилейларына багышлана. Төрле елларда «П.»да Россия пианистлары В.В.Горностаева, Л.Н.Наумов, В.К.Мержанов, М.С.Воскресенский, А.Г.Севидов, Н.А.Петров, музыка белгече Л.Е.Гаккель, чит ил башкаручылары Т.Йометс (Эстония), М.Местре Ребул (Испания), чыгышы б-н Татарстаннан Р.Сайткулов (Франция) һәм Р.А.Хәйретдинов (Бөекбритания) катнашалар.

*В.М.Спиридонова.*

**ПЕТРЕ́НКО** Аида Григорьевна (16.9.1933, Приморье крае Никольск-Уссурийский ш., хәзер Уссурийск ш. — 27.1.2010, Казан), археозоолог, биол. фән. д-ры (1985), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1956). 1966 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән Тарих ин-тында (1986 дан — әйдәп баручы, 2004 тән баш фәнни хезмәткәр). Халыкара археозоологлар берлеге әгъзасы (1990). Хезмәтләре палеозоологиягә, Урта Идел буе һәм Урал алдының борынгы, урта гасырлар халкы тарихын һәм рухи мәдәниятен өйрәнүгә карый.

Хезм.: Древнее и средневековое животноводство Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1984; Следы ритуальных животных в могильниках древнего и средневекового населения Среднего Поволжья и Приуралья. К., 2000.

*Әд.:* Бурханов А.А. Человек редкой профессии // Культурные традиции Евразии. К., 2004.

**ПЕТРО́В** Александр Васильевич (24.5.1837, Пенза ш. — 20.5.1885, Казан), патологоанатом, медицина докторы (1865), җәмәгать эшлеклесе. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1859), шунда ук, анатомия кафедрасында, 1863 елдан патологик анатомия кафедрасында эшли, проф. (1868). Россиядә санитария-профилактика эшен, җәмәгать һәм земство медицинасын оештыруга ярдәм итә. Хезмәтләре корсак тифы, уремия, туберкулёз авыруларының патологик анатомиясенә, санитариягә карый. 1870–74, 1879–84 тә Казан ун-ты каршындагы Табибләр җәмгыяте б-н җитәкчелек итә.

Хезм.: К учению об уремии // Уч. зап. Казан. ун-та. 1862. Вып. 2; Очерки исследований, произведённых в патолого-анатомическом кабинете Казанского университета в 1866–67 акад. году // Уч. зап. Казан. ун-та. 1867. Т. 3, вып. 516; Об отравлении мышьяком с патолого-анатомической стороны // Протоколы Об-ва врачей г. Казани. 1871. № 3.

*Әд.:* Фирсов Н.Н. Пионер социальной медицины в Казани // Социальная гигиена. 1928. № 4.

**ПЕТРО́В** Александр Михайлович (23.6.1957, Казан), инженер-механик, ТАССРның атказ. машина төзүчесе (1985), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлагач (1979), «Казан компрессор машиналары төзү заводы» АҖдә эшли: инженер-сынаучы, өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, җитештерү-диспетчерлык бүлеге башлыгы, үзәктән куулы компрессорлар з-ды директоры (1996 елдан), җитештерү һәм коммерция буенча директор (2005 тән), җитештерүдә идарәче директор урынбасары (2012 дән). Дәүләт бүләге газ кудыру агрегатларындагы көч җайланмаларының югары нәтиҗәле алмаш частьларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

**ПЕТРО́В** (Георгиевский) Алексей Зиновьевич (28.10.1910, Самара губ. Кошки а. — 9.5.1972, Киев), математик, геометр, физик-теоретик, физика-матем. фән. д-ры (1957), проф. (1958), Украина ФА академигы (1969). 1937 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Мари һәм Казан пед. ин-тларында укыта. 1939–45 тә Казан авиация ин-тында. 1946 дан Казан ун-тында, геом. каф. профессоры (1956 дан). 1960 та Казан ун-тының физика ф-тында СССРда беренче чагыштырмалылык һәм гравитация кафедрасын оештыра һәм аны җитәкли. 1970 тән Украина ФА Теоретик физика ин-тында чагыштырмалылык һәм гравитация бүлеге мөдире. Хезмәтләре матем. физикага, гомуми чагыштырмалылык теориясенә, тартылу теориясенә, физиканың фәлсәфи мәсьәләләренә карый. Лоренц сигнатуралы дүрт үлчәнешле фәзаларда өч Эйнштейн фәзасы булуы турындагы теореманы исбатлый. Тартылу кырларының дөнья әдәбиятында «Петров типла-

ры» дип йөртелүче классификациясен тәкъдим итә. Ленин бүләге (1972) «Гравитация теориясендә инвариант-төркемле методлар» дигән хезмәтләр циклы өчен бирелә. «Эйнштейн фәзалары» монографиясе («Пространство Эйнштейна». М., 1961), «Гомуми чагыштырмалылык теориясендә яңа алымнар» («Новые методы в общей теории относительности». М., 1966) хезмәте немец һәм инглиз телләренә тәрҗемә ителгән. «Гравитация һәм чагыштырмалылык теориясе» («Гравитация и теория относительности») җыентыгын нәшер итүне башлап җибәрә һәм фәнни мөхәррире була (1965–70). 1960 тан СССР Югары һәм махсус урта белем бирү министрлыгы фәнни-техник советында «Гравитация» секциясе рәисе, Гравитация һәм чагыштырмалылык теориясе буенча Халыкара ком-тта совет комиссиясе рәисе. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пространство — время и материя (Элементарный очерк современной теории относительности). К., 1961.

*Әд.:* А м и н о в а А.В. Алексей Зиновьевич Петров. 1910–1972. К., 2002; Механико-математический факультет Казанского университета: Очерки истории. К., 2003.

**ПЕТРО́В** Алексей Иванович (14.4.1933, Мамадыш р-ны Урманчы а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). 1956 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре энергия сыйдырышлы композицияләр синтезлауга, модификацияләү, аларның компонентларын тикшерү, целлюлоза эфирларын синтезлау һәм модификацияләүгә карый. П. азот катнашкан полимерлар һәм пластификаторларны табу ысулларын, аларның үзлекләрен һәм куллану өлкәләрен тикшерә. Үзлекләре тулаем яхшыртылган целлюлоза нитратларын һәм ацетатларын табу алымнарын эшли. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре С.М.Киров исем. ФҖБдә (Пермь ш.), Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында, «Тасма-Холдинг» АҖдә (Казан) һ.б.да гамәлгә кертелә. 225 тән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 75 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ПЕТРО́В** Анатолий Петрович (26.6.1905, Казан губ., Чабаксар өязе Тренькасы а. — 24.8.1982, Казан), ботаник, биол. фән. д-ры (1944), проф. (1944). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1930), шунда ук эшли. 1934–54 һәм 1964–77 елларда Казан вет. ин-тында, ботаника һәм терлек азыгы җитештерү каф. мөдире (1964–77). 1954–56 да СССР ФА Казан ф-лының Биол. ин-тында, 1956–64 тә Казан пед. ин-тында (ботаника каф. мөдире, 1959–61 дә проректор). Бер үк вакытта, 1961–66 да, Республика а.х. тәҗрибә станциясе директоры һәм ТАССР а.х. министры урынбасары. Хезмәтләре ботаникага, үсемлекләр физиологиясенә, болынчылыкка карый. П. *үсемлекләрнең су режимының* коллоидлы-физик моделе нигезсез булуын исбатлый. Су алмашының организм эшчәнлегендә яраклашкан процесслар системасының органик ингредиенты булуын теоретик яктан һәм тәҗрибәләр ярдәмендә күрсәтә. Функциональ адаптациядә реактивлык ролен раслый. Чуаш АССРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы биологии и агротехники кукурузы. К., 1956; Процессы водного обмена и реактивности растений. К., 1972; Биоэнергетические аспекты водного обмена и засухоустойчивости растений. К., 1974.

**ПЕТРО́В** Василий Петрович (18.1.1934, Чуаш АССРның Канаш р-ны Пожарбоси а. — 8.12.2002, Казан), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1964), проф. (1991), ТРның атказ. икътисадчысы (1993). 1957 елда Ленинград финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1957–61 дә Украина ССРның Винница һәм Херсон өлкәләре техникумнарында, 1961–65 тә Украина а.х. академиясендә (Киев) укыта. 1965–98 дә Казан а.х. ин-тында, бухгалтерлык исәбе каф. мөдире (1969–85), икътисад ф-ты деканы (1989–92). 1997 дән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан) бухгалтерлык исәбе һәм аудит каф. мөдире. Хезмәтләре бухгалтерлык исәбен камилләштерү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Практикум по бухгалтерскому учёту. К., 1996; Тайны экономики (новая экономическая теория). К., 2000; Управленческий (производственный) учёт в сельском хозяйстве: Учеб. пособие. К., 2001 (автордаш); Новое в бухгалтерском учёте Российской Федерации: В 3 вып. К., 2001 (автордаш).

*Әд.:* Краткая Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001.

**ПЕТРО́В** Владимир Александрович (15.1.1913, Казан — 13.9.1983, Ставрополь ш.), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), лейтенант. В.И.Ленин исем. Ленинград электротехника ин-тын (1940), Ленинград фронтының элемтәче кече лейтенантлар курсларын (1942) тәмамлый. 1942 елның октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 954 нче аерым элемтә батальонында телеграф-кабель ротасының взвод командиры (59 нчы армиянең 115 нче укчы корпусы). Ленинград һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Ленинград сугышында (1941–44), Сандомир-Силезия һәм Прага һөҗүм операцияләрендә (1945) катнаша. Ферендорф һәм Фост Линже-Фюльштейн (Германия) авыллары тирәсендә Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1945 нең 30 гыйнварында дивизия командиры б-н корпус командиры арасында өзлексез элемтә тотып, дошман уты астында пехота б-н бергә елганың икенче ярына йөзеп чыга; 2 февральдә дошманның контрһөҗүме вакытында ярдәмче элемтә узелында элемтәчеләр б-н җитәкчелек итә. 1946 дан запаста. Ставропольдә радиоузел башлыгы булып эшли. 1955–72 дә Ставрополь элемтә электротехникумы директоры (хәзер П. исемендә). Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



А.З.Петров.



В.А.Петров.

**ПЕТРО́В** Владимир Ефремович (28.4.1936, Владимир ш. — 2.5.1991, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1982), проф. (1982). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), Казакъстан ССРның Актүбә өлкәсендә агроном булып эшли. 1963–76, 1981–91 елларда Казан ун-тында, 1981 дән үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире. 1976–81 дә СССР ФА Казан ф-лының Биол. ин-тында фотоэнергетика лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре үсемлек күзәнәгендә энергия алмашу, үсемлекләрнең тотрыклылык механизмнарын һәм стресслар тәэсиренә җайлашу юлларын өйрәнүгә карый. П. фотомикрокалориметр төзи, шуның ярдәмендә үсемлекнең энергия туплау тизлеген үлчи һәм аның газометрик алымнар б-н билгеләнүче зурлыктан югары булуын исбатлый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Энергетика ассимилирующей клетки и фотосинтез. К., 1975; Энергетические аспекты устойчивости растений. К., 1985.

*Н.Л.Лосева.*

**ПЕТРО́В** Владислав Васильевич (2.9.1929, Мәскәү өлкәсенең Павловский Посад ш. — 18.4.1995, Мәскәү), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1971), проф. (1972), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Мәскәү юридик ин-тын тәмамлый (1952). 1952–58 елларда Павловский Посад шәһәрендә: Эчке эшләр министрлыгының район бүлегендә тикшерүче (1954 кә кадәр), 1954–55 тә «Ленинская искра» г-тасының бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары, 1955 тән ВЛКСМ шәһәр ком-ты 1 нче секретаре. 1960–72 дә Казан ун-тының гражданлык хокукы кафедрасында, бер үк вакытта, 1968 дән, юридик ф-т деканы. 1972 дән Мәскәү ун-ты профессоры, 1984 тән җир һәм колхоз хокукы каф., 1989 дан экол. хокук каф. мөдире. 1981 дән «Вестник Московского университета. Серия 11. Право» ж-лы баш мөхәррире. Россиядә хуҗалык эшчәнлеген экол.-хокукый көйләү б-н бәйле фәнни юнәлешне нигезләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре колхоз, җир хокукына, экол. хокукка багышлана. П. колхозларда законлылык мәсьәләләрен тикшерә, әйләнә-тирә табигый мохит сыйфаты б-н идарә итүнең юридик механизмнарын, экол. зыянны кайтару формаларын, экол.-хокукый һәм экол.-икътисади җаваплылык төшенчәләрен һәм билгеләрен эшли.

Х е з м.: Закон колхозной жизни. К., 1970; Примерный устав и проблемы социалистической законности в колхозах. К., 1971; Экология и право. М., 1981; Экологическое право России. М., 1995.



Л.С.Петров.



М.П.Петров.

*Әд.:* Голиченков А.К., Петрова Т.В. Профессор Московского университета Владислав Васильевич Петров (к 70-летию со дня рождения) // Государство и право. 1999. № 12.

*Е.Б.Долгов.*

**ПЕТРО́В** Герман Николаевич (8.12.1906, Мәскәү — 15.7.1983, Казан), гидролог, геогр. фән. д-ры (1977), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1982). Казан югары типтагы индустрия техникумын инженер-гидротехник белгечлеге буенча тәмамлый (1929), Архангельск, Владикавказ, Казан шәһәрләрендә тикшеренүләр һәм мелиорация, гидротехника проекты оешмаларында эшли. 1946–63 елларда СССР ФА Казан ф-лының энергетика бүлегендә, 1963 тән Төньяк гидротехника һәм мелиорация фәнни-тикшеренү ин-тының Казан гидрология һәм су ресурслары бүлегендә, мөдир (1976 га кадәр). Хезмәтләре Урта Идел буеның кече елгалары гидрогеологиясенә һәм су ресурсларына карый. П. кече елгаларның җирле агымын өйрәнү һәм картага төшерү методикасын эшли, алар нигезендә сугарулы культуралы көтүлекләр һәм печәнлекләр үсешен нигезли, Урта Идел буе елгалары суларының уртача һәм иң аз чыгымнары картасын төзи. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Меженный сток и его изучение. К., 1956; Проблемы изучения и картирования местных водных ресурсов на примере рек Среднего Поволжья. Пермь, 1975; Озёра Среднего Поволжья. Л., 1976 (автордаш).

**ПЕТРО́В** Константин Константинович (1.4.1924, Буа кантоны Чуаш Бимorзасы а. — 2.11.2007, Чабаксар ш.), язучы, журналист, филол. фән. канд. (1968). 1941 елда Ульянов чуаш пед. уч-щесен, 1958 дә КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү) тәмамлый. 1946–63 тә «Хёрле ялав» г-тасында (Казан), 1963–68 дә «Коммунист Татарии» ж-лында эшли, бер үк вакытта, 1963–84 тә, Казан ун-тында, 1984–90, 1995–99 да Чуаш ун-тында укыта. «Яратсаң» («Юратсан», Чабаксар, 1969) хикәяләр җыентыгы, «Мәхәббәт һәм агу» («Юратупа наркамаш», Чабаксар, 1972), космонавт А.Николаев турында «Зәңгәр йолдыз» («Сенкер салтар», Чабаксар, 1991; рус теленә тәрҗемәсе «Голубая звезда», 1999), «Гаепләләр» («Айаплисем», Чабаксар, 1995), шагыйрь М.Сеспель турында «Яшәү һәм үлем» («Пурнаҫпа вилем», 1999) романнары; «Тылсымлы сүз» («Асамла самах», Чабаксар, 1990) исемле балалар өчен әкиятләр җыентыгы; чуаш журналистикасы тарихы буенча хезмәтләр авторы.

*Әд.:* Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ПЕТРО́В** Леонтий Степанович (7.9.1909, Казан губ., Чистай өязе Яңа Мокшино а. — 10.7.1986, Түбән Кама ш.), агроном, Соц. Хезмәт Герое (1966), РСФСР һәм ТАССРның атказ. агрономы (1966). Чистай а.х. техникумын тәмамлый (1930). 1930–41 елларда — Октябрь р-нының Нурлат МТСында, Аксубай р-нының «МЮД» с-зында агроном. 1945–48 дә Курск өлкәсендә эшли. 1948–66 да Аксубай р-нының Иске Тимәш МТСында, «Большевик» с-зында, «Победа» к-зында агроном. П. инициативасы б-н «Победа» к-зы, республикада беренчеләрдән булып, уҗым культураларын тулысынча пар җирләренә чәчүгә күчә. Алдынгы технологияләр куллану нәтиҗәсендә 1961–65 тә хуҗалык бөртекләләр уңышын 1 *га* дан 12 *ц* дан 18 *ц* га кадәр күтәрүгә ирешә. Герой исеме бөртекле ашлык һәм терлек азыгы культураларын җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешкән уңышлары һәм техниканы югары җитештерүчән файдаланганы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПЕТРО́В** Михаил Петрович (17.11.1904, хәзер БАССРның Бакалы р-ны Иске Шәрәшле а. — 5.8.1967, Украина ССРның Винница ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), полковник. Милләте буенча татар. «Выстрел» курсларын (Мәскәү өлкәсе Солнечногорск ш., 1944), Ленинград югары бронетанк мәктәбен (1949) тәмамлый. Бакалы волосте ком-тында йомышчы, БАССРның Байсар телеграф бүлегендә монтёр булып эшли. 1926 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 364 нче укчы полк командиры (50 нче армиянең 139 нчы укчы дивизиясе). Көнбатыш, Үзәк һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү тирәсендәге сугышта (1941–42), Ржев-Вязьма, Брянск (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) операцияләрендә катнаша. Могилёв шәһәреннән (Белоруссия ССР) көньяктарак Проня, Басы, Реста һәм Днепр елгаларын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1944 нең 24–28 июнендә совет гаскәрләренең июнь һөҗүме барышында дошман оборонасын өзә, полкы б-н 215 торак пунктны азат итүдә катнаша. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам итә. 1954 тән запаста. Винница шәһәрендә яши һәм эшли. Ике Ленин ордены, өч Кызыл Байрак, Александр Невский, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

**ПЕТРО́В** Николай Васильевич (1.5.1859, Уфа губ. Минзәлә ш. — 1.4.1916, Петроград), патологоанатом, медицина д-ры (1885). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1883), Эчке эшләр министрлыгының мед. департаментында эшли. 1886 елдан Казан ун-тының патологик анатомия кафедрасында. 1890 нан Обухов хастаханәсендә, бер үк вакытта, Петербург хәрби мед. академиясендә приват-доцент; 1892 дән бөек княгиня Елена Петровнаның Клиник ин-тында патологик анатомия профессоры, 1916 да патологик анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре буыннарның кискен ялкынсынуы патологик анатомиясенә карый.

Х е з м.: О лёгочной сибирской язве // Рус. архив патологии клинической медицины и бактериологии. 1857. № 6; Одновременное развитие у одного лица 3-х различных злокачественных новообразований: рака желудка, аденокарциномы предстательной железы и злокачественной миомы брыжейки // Русский врач. 1908. № 49; Случай тропической спленомегалии // Русский врач. 1912. № 26.

*Әд.:* Колосов Г. Памяти проф. Н.В.Петрова // Русский врач. 1916. № 15.

**ПЕТРО́В** Николай Васильевич (4.1.1874, Орёл губ., Ливно өязе, Демидово а. — 11.5.1956, Муром ш.), философ, православие теологиясе магистры (1900). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1898), Сембер руханилар семинариясендә укыта. 1900 елдан Казан руханилар академиясенең филос. кафедрасында, 1908–12 дә Иске Гаһеднең Изге Язмалары каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1908 дән, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында рухани, канун өйрәтүче һәм шул ин-ттагы чиркәү башлыгы. 1912–17 дә Казан ун-тының теология каф. профессоры, ун-т чиркәве побы һәм протоиерее (1913 тән). 1918–30 да Варвара чиркәве башлыгы, Казан руханилар академиясе укытучысы (1921 дә ябылганчы). 1921 дә академиянең башка укытучылары б-н бергә шартлы рәвештә 1 елга хөкем ителә. Хезмәтләре Аллаһның барлыгын фәлсәфи исбатлауга карый.

Х е з м.: О святой троице. К., 1912; Об искуплении. К., 1912; Законы мира и Бытие Бога. Номологическое доказательство Бытия Божия. К., 1913; Жизнь после смерти. К., 1915.

*Е.В.Липаков.*

**ПЕТРО́В** Николай Васильевич (4.9.1897, Уфа губ., Минзәлә өязе Кадрәк а. — 1975, Мәскәү), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-тта укый (1919). 1916–17 елларда Россия армиясендә хезмәт итә. 1918 дә Минзәлә өязе башкарма ком-ты секретаре. Өяз Халык комиссарлары советында эшләр идарәсе башлыгы, Минзәлә контрреволюциягә каршы көрәш гадәттән тыш комиссиясе рәисе, 1919–20 дә өяз банк һәм казначылык комиссары; ревком рәисе урынбасары; Минзәлә өязе башкарма ком-ты рәисе урынбасары, рәисе. 1921–29 да ТАССР ҮБК Президиумы секретаре, эчке эшләр халык комиссары, җир эшләре халык комиссары. П. эшләгән чорда ТАССРның 1 нче аграр съезды үткәрелә (1929). Соңрак ул Мәскәүдә партия һәм хуҗалык эшләрендә. «Татарстан республикасының авыл хуҗалыгын үстерү һәм үзгәртеп коруның төп бурычлары» («Основные задачи развития и переустройства сельского хозяйства Татарской республики», 1924) китабы авторы.

*Әд.:* Мухамедов С. Петров Николай Васильевич // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**ПЕТРО́В** Павел Яковлевич (25.6.1814, С.-Петербург — 7.9.1875, Мәскәү), шәркыятьче галим, лингвист-политолог, санскрит әдәбияты д-ры (1864). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1832), Дерпт профессорлар ин-тында тәрбияләнүчеләр составына кертелә, анда Шәрекъ телләре каф. булмау сәбәпле, лекцияләр тыңлау өчен Петербург ун-тында калдырыла (1834–37). Х.Д.Френ, О.И.Сенковский, Ф.Ф.Шармуа, Р.Ленц һ.б. җитәкчелегендә гарәп, фарсы, төрек, кытай һәм санскрит телләрен өйрәнә. Петербург Азия музеендагы санскрит кульъязмаларын һәм Шәрекъ нумизматик тупланмаларын тикшерә. 1837 елда Адхьятмар-маянның «Ситаны урлау» поэмасыннан бер өзекне рус теленә тәрҗемә итә. 1838–40 та Берлин, Лондон, Парижда телләр өйрәнүне камилләштерә. 1841–52 дә П. Казан ун-тының Шәрекъ бүлегендәге санскрит теле кафедрасында: санскрит теле һәм әдәбияты, Кашмир патшалыгы тарихы һәм борынгы һинд ядкәрләре курсларын укый. 1852–75 тә Мәскәү ун-тының көнчыгыш телләр кафедрасында эшли, проф. (1856 дан). Хезмәтләре санскрит әдәбиятының, гарәп һәм фарсы әдәбияты һәм телләренең эпик һәм классик ядкәрләренә карый.

Х е з м.: Программа для преподавания санскритского языка и литературы при Императорском Казанском университете // Уч. зап. Казан. ун-та. 1842. Кн. 2; Санскритская антология. Отд-ние I: Изречения, отрывки эпические, сказки, басни, отрывки описательные и лирические. К., 1846.

*Әд.:* Ш о ф м а н А.С. Русский санскритолог П.Я.Петров // Очерки по истории русского востоковедения. М., 1960. Т. 3.

*Р.М.Вәлиев.*

**ПЕТРО́В** Пётр Иванович (1916, Казан губ., Лаеш өязе Алан-Полян а. — 16.3.1974, Казан), математик, геометр, физика-матем. фән д-ры (1969). 1938 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, 1946 дан Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре риманча фәзаларның дифференциаль инвариантларына карый. П. 3 нче тәртип өч үлчәнешле риманча фәзаларның метрик-скаляр дифференциаль инвариантларының иң гади базисын төзи. Дүрт үлчәнешле риманча фәзаларга карата Суворов алымын (к. Ф.М.*Суворов*) куллана.

Х е з м.: Классификация трёхмерных римановых пространств по их дифференциальным инвариантам // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн. 9; Инварианты и классификация дифференциальных квадратичных форм от четырёх переменных // Изв. АН СССР. Сер. Математика. 1959. Т. 23, № 3; Основная проблема неримановой геометрии в бинарной области // Докл. АН СССР. 1961. Т. 140, № 4.

**ПЕТРО́В** Семён Венедиктович (9.2.1951, Ростов өлкәсенең, Тацинский р-ны Тацинский пос.), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1998). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан шәһәренең 12 нче хастаханәсендә хирург. 1975 елдан Кукмара үзәк хастаханәсе хирургы. 1978 дән Казан мед. ин-тының — госпиталь хирургиясе, 1981 дән патологик анатомия кафедраларында. Бер үк вакытта, 1996 дан, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы Респ-ка онкология клиник үзәгендә шешләргә иммуногистохимик юл б-н диагноз куюлаб-ясе җитәкчесе. Хезмәтләре кеше организмындагы шешләрне иммуногистохимик ысуллар б-н тикшерүгә карый.

Х е з м.: Морфофункциональная характеристика шишковидной железы при раках различной локализации // Вопр. онкологии. 1984. № 9; Ультраструктурная характеристика нейросекреции в эпифизе мыши // Вопр. нейробиологии. 1987. Т. 68; Иммуногистохимическое исследование клеток инвазивного рака влагалищной части шейки матки // Вопр. онкологии. 1990. № 3; Маркеры пролиферации опухолевых клеток в раковых опухолях гортани // Казан. мед. журн. 2001. № 4.

**ПЕТРО́В** Сергей Борисович (4.6.1951, Чуаш АССР, Шумерля ш.), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1990), проф. (1991). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли. 1977 елдан Казан мед. ун-тының патологик анатомия кафедрасында. П. җитәкчелегендә «Морфологик диагностикада заманча технологияләр» («Современные технологии в морфологической диагностике», 2001) респ-ка үзәге оештырыла. Хезмәтләре диагностиканың иммунологик, гистологик, химик ысулларына карый.

Х е з м.: Функциональная морфология инволютивных изменений мужских половых желёз // Архив патологии. 1976. № 10; Лимфоидная инфильтрация раковых опухолей и её прогностическое значение // Казан. мед. журн. 1987. № 3; Медицинский диагноз: Метод. пособие. К., 1996.

**ПЕТРО́ВА** Галина Александровна (26.2.1928, Чуаш АССРның Алатырь ш. — 31.1.2011, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1989), проф. (1990), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли, пед. каф. мөдире (1975–80), бер үк вакытта, 1961–85 елларда, КПССның Казан шәһәр ком-ты каршындагы Казан иҗтимагый укытучылар ун-тында сәнгать белеме ф-ты деканы. Хезмәтләре укучыларга һәм студентларга эстетик тәрбия һәм белем бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: О воспитании художественного вкуса учащихся на уроках литературы в средней школе. К., 1959; Эстетическое восприятие художественных произведений школьниками старших классов. К., 1975; Вопросы эстетической подготовки будущего учителя. К., 1976; Система эстетической подготовки студентов в высших учебных заведениях. К., 1984 (автордаш).

**ПЕТРО́ВА** Любовь Михайловна (20.9.1945, Казан), химик, химия фән. д-ры (1998). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлый, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2002 дән). Хезмәтләре нефть химиясенә карый. П. нефтьне чыганаклардан су тутыру юлы б-н чыгарганда калдык нефтьләрнең составын өйрәнә, нефтькә төрле процессларның (күкертләү, химик һәм биохимик оксидлаштыру, фаза үзгәрешләре һ.б.) җимергеч тәэсирен бәяли, аз үзгәргән калдык нефть һәм көчле әверелешләргә дучар булган калдык нефть дигән яңа төшенчәләр кертә. Калдык нефтьләрнең төп массасы аз үзгәргәннәргә керүен, шунлыктан бу запасларны чыгарып бетерү перспективасы барлыгын күрсәтә. Нефть катламының флюидлар б-н башлангыч туенуы параметрларын билгеләү ысулларын эшли. П. катнашында, нефть б-н хәрәкәтчән һәм хәрәкәтсез туендырылу параметрларын исәпкә алып, чыганактагы нефть запаслары 3 өлешкә бүлеп исәпләнелә: чыганакларның табигый энергиясе ярдәмендә һәм су тутыру юлы б-н алына торганнар, өченчел ысуллар (микробиол., физик-химик, җылылык һ.б.) кулланып чыгарыла торган һәм чыгарып булмый торган нефтьләр. Чыганакны эшкәртүнең соңгы стадиясендә катламның нефть бирүчәнлеген күтәрүнең өченчел технологияләре кулланылганда, калдык нефтьләрнең составын һәм үзлекләрен исәпкә алу зарурлыгын күрсәтә.

Х е з м.: Особенности формирования углеводородного состава остаточных нефтей заводняемых пластов // Нефтехимия. 1998. Т. 38, № 3 (автордаш); Характеристика битумов зоны водонефтяного контакта // Нефтехимия. 2004. Т. 44, № 5 (автордаш); Влияние отложения в пласте твёрдых парафинов на фазовое состояние нефтей в процессе разработки месторождений // Нефтехимия. 2005. Т. 45, № 3 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПЕТРО́ВКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 69 кеше (руслар) яши. 1930 да Ямаш авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән Акташ р-нында. 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны 1938 дә — 151, 1949 да — 124, 1958 дә — 70, 1970 тә — 62, 1979 да — 14, 1989 да — 2, 2002 дә — 18 кеше.

**ПЕТРО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Сула елгасы (Димнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 484 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 56%, татарлар — 26%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 234 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Богоявление волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 355, 1889 да — 176, 1910 да — 225, 1920 дә — 375, 1926 да — 322, 1938 дә — 287, 1949 да — 297, 1958 дә — 219, 1970 тә — 291, 1979 да — 397, 1989 да — 484, 2002 дә — 533 кеше.

**ПЕТРО́ВКА** авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Дим елгасы буенда. 2010 елда 36 кеше (чуашлар) яши. Халкы кырчылык б-н шөгыльләнә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 елның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән Бөгелмә р-нында. Халык саны 1938 дә — 177, 1949 да — 196, 1958 дә — 166, 1970 тә — 179, 1979 да — 124, 1989 да — 72, 2002 дә — 40 кеше.

**ПЕТРО́ВКА** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 20 *км* көнчыгыштарак, Кәү-

җияк елгасы буенда. 2010 елда 80 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 542,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 250, 1897 дә — 583, 1920 дә — 673, 1926 да — 632, 1938 дә — 248, 1949 да — 441, 1958 дә — 362, 1970 тә — 252, 1979 да — 122, 1989 да — 48, 2002 дә — 104 кеше.

**ПЕТРО́ВКА НАРАТЛАРЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Сула елгасы (Дымка елгасының сул кушылдыгы) үзәненең сулъяк текә яры буенда, Бөгелмә р-ны Петровка авылы янында урнашкан. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 53 *га*. 100 яшьлек һәм аннан да картрак аерым үсүче мәһабәт наратлардан торган 3 урман участогын эченә ала. Көньяк тау битендәге агачлар арасында ТРның Кызыл китабына кертелгән дала үсемлекләренең сирәк төрләре: тәбәнәк бадәм, герман буяу куагы, сары мәтрүшкә яфраклы тубылгы куагы, әрмән әреме, рус күкчәчәге, ябалак сөтлегәне, Себер гамбәр үләне, шарсыман суган, биек качим, гади оносма үсә. Участокның



Петровка наратлары.

көньяк чикләрендә 19 йөзгә караган корылмалары б-н борынгы парк урнашкан. Паркка ярларында күп кенә чишмәләре булган буа тоташа. Объект эстетик һәм фәнни әһәмияткә ия.


**ПЕТРО́ВО** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 24 *км* төньяктарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) бассейнында. 2010 елда 14 кеше (руслар) яши. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аркатау Пучинкәсе, Түбән Ия исемнәре б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да чиркәү-приход мәктәбе (1901 дә ачыла), икмәк саклау-сату кибете, 2 җил тегермәне, тимерчелек, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 562,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 27 ир-ат; 1859 да — 194, 1897 дә — 353, 1908 дә — 411, 1920 дә — 412, 1926 да — 508, 1949 да — 301, 1958 дә — 248, 1970 тә — 131, 1979 да — 79, 1989 да — 18, 2002 дә — 8 кеше.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** посёлогы, Казан шәһәренең Идел буе р-ны составында, Казан тимер юл станциясеннән 16 *км* көньяктарак урнашкан. Автотранспорт пр-тиесе. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантоны Воскресенский волостенда. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл р-нында, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. 1998 нең 25 ноябреннән Казан шәһәренең Идел буе р-ны адм. карамагында. Халык саны: 1926 да — 25, 1958 дә — 150, 1970 тә — 635, 1979 да — 927, 1989 да — 892 (ш.и. татарлар — 52%, руслар — 45%) кеше.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1925 тә Елаур авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Чулпан волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1926 да — 142, 1938 дә — 137, 1949 да — 133, 1958 дә — 141, 1970 тә — 132, 1979 да — 95, 1989 да — 63, 2002 дә — 91 кеше.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** посёлогы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 29 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1929 да нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантоны Теләче волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1938 дә — 221, 1949 да — 240, 1958 дә — 191, 1970 тә — 165, 1979 да — 143, 1989 да — 66, 2002 дә — 37 кеше.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** Игорь Сергеевич (29.11.1925, Украина ССРның Луганск ш.), режиссёр, ТАССРның, Абхазия АССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1990). 1946–48 елларда Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тында укый, 1948 дә Ленинград театр ин-тына (Л.С.Вивьен курсы) күчә. Институтны тәмамлаганнан соң (1953), Казан Зур драма театрына җибәрелә. 1953–58 дә аның сәхнәсендә 13 спектакль, ш.и. К.К.Крапиваның «Ахырдан кем көлә?» («Кто смеётся последним?»), В.Гюгоның «Мария Тюдор», В.А.Дыховичныйның «Туй сәяхәте» («Свадебное путешествие»), Ч.Диккенсның «Безнең уртак дустыбыз» («Наш общий друг»), А.Н.Афиногеновның «Үз балаларының әнисе» («Мать своих детей»), К.М.Симоновның «Бер мәхәббәт тарихы» («История одной любви»), С.С.Смирновның «Буг өстендәге ныгытма» («Крепость над Бугом»), В.М.Гусевның «Иван Рыбаков», А.М.Володинның «Фабрика кызы» («Фабричная девчонка»), А.Н.Арбузовның «Ерак юл» («Дальняя дорога») әсәрләре буенча спектакльләр куя. Персонажларга хас гамәлләрнең психол. сәбәпләренең җентекле эшкәртелеше, киеренке эчке хәрәкәтнең оста бирелеше П. спектакльләрендә үзенчәлекле, кабатланмас тышкы форма б-н үрелеп бара. Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында (1957) күрсәтелгән «Үз балаларының әнисе» спектакле театр дөньясында киң масштаблы зур вакыйгага була. Кешегә ышаныч, бер үк вакытта үзенә тапшырылган эшкә җаваплы караш темасы актриса Е.Е.Жилина тарафыннан Лагутина образында ышандырырлык итеп ачыла. Комсомол хәрәкәтендә бюрократизм һәм формализм мәсьәләләрен күтәреп чыккан «Фабрика кызы» спектакле көчле бәхәс тудыра һәм зур иҗтимагый яңгыраш ала. П.ның әхлакый камил шәхес өчен көрәш рухы б-н сугарылган спектакльләре Казан Зур драма театрының 1950 еллардагы иҗат мирасында тирән эз калдыра. Аннан соңгы елларда П. Таллин, Волгоград, Львов, Кишинёв, Орёл, Гродно шәһәрләрендәге театрларда эшли. Киев һәм Кишинёв киностудияләрендә берничә фильм төшерә.





Казан Зур драма театрында И.С.Петровский тарафыннан куелган спектакльләрдән күренешләр: 1. «Үз балаларының әнисе» (А.Н.Афиногенов); 2. «Фабрика кызы» (А.М.Володин).

*Әд.:* Строева М. Критическое направление ума // Театр. 1957. № 6; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** Мемнон Петрович (29.1.1833, Түбән Новгород губ. Васильсурск ш. — 13.4.1912, Казан), филолог, славян телләре галиме, славян филологиясе д-ры (1875), Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1895). Дворяннар нәселеннән. Түбән Новгород дво-

ряннар ин-тын (1850), Казан ун-тын (1855) тәмамлый. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә латин теле укыта. 1860 елдан Казан ун-тында (бүленеп, 1861–63 тә чит илдә фәнни командировкада), проф. (1875). Бер үк вакытта, 1870 тә, Казан руханилар академиясендә рус теле һәм славян шивәләре укыта. Славян халыкларының борынгы истәлекләре, тел һәм әдәбиятлары буенча лекцияләр укый. 1899 да Чехия Тел, әдәбият һәм сәнгать ФА әгъзасы булып сайлана. Славян шагыйрьләре һәм прозаикларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итә.

*Әд.:* Из истории русско-славянских литературных связей. М.–Л., 1963; Славянские страны и русская литература. Л., 1973; Горяинов А.Н., Кишкин Л.С. Книжное собрание М.П. и Н.М.Петровских // Советское славяноведение. 1986. № 5.

**ПЕТРО́ВСКИЙ** Нестор Мемнонович (1.3.1875, Казан — 6.2.1921, шунда ук) филолог, тарихчы, библиограф, славян филологиясе д-ры (1907), РФА мөхбир әгъзасы (1917), статский советник (1907). М.П.*Петровскийның* улы. Казан ун-тын тәмамлый (1897), шунда ук эшли: профессорлык стипендианты (1899 елга кадәр). 1901–07 дә приват-доцент, 1907–19 да ординар проф., 1919 дан славян филологиясе каф. профессоры. Бер үк вакытта Югары хатын-кызлар курсларында, Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография ин-тында (Казан) укыта; 1919 да Казан шәһәр музее китапханәчесе, 1921 дә «Казанский библиофил» ж-лында бүлек мөдире, А.С.Пушкин исем. Казан рус әдәбиятын сөючеләр җәмгыятен тергезүдә башлап йөри, 1916–19 да җәмгыятьнең рәисе була. Шәхси китапханәсен Казан ун-тына тапшыра. Славян әдәбияты һәм телләре тарихына караган хезмәтләр, күп кенә библиографик тикшеренүләр, ш.и. «Чиркәү тарихы буенча 1801 дән 1888 гә кадәр чыккан рус китаплары һәм брошюралары белешмәсе» («Указатель русских книг и брошюр по церковной истории, вышедших с 1801 по 1888 г. включительно», М., 1891), «XVIII йөз рус журналлары турында библиографик язмалар» («Библиографические заметки о русских журналах XVIII века», СПб., 1898) һ.б. хезмәтләр авторы. Казан тарихы, җирле театр һәм журналистика буенча очерклар сериясен нәшер итә: «XVI–XVIII йөзләрдә Казан шәһәре читләре (Болак арты, Архангел һәм Ягодный бистәләре)» («Окраины города Казани в XVI–XVIII веках (Забулацкая, Архангельская и Ягодная слободы)», 1905), «Казан вакытлы матбугатының йөз еллыгы уңаеннан» («По поводу столетия Казанской периодической печати», 1911), «Казанда беренче хосусый газета» («Первая частная газета в Казани», 1917) һ.б. Идел буе халыкларының хәле хакындагы мәсьәләгә кагылып, П. славяннарның яңарыш тарихы аларның үзаңы һәм милли мәдәнияте үсеше өчен үрнәк була ала дигән фикерне алга сөрә. Ул чуашларны борынгы болгарларның варислары дип саный. Болгар хронологиясен һәм татар әдәбиятын өйрәнү б-н шөгыльләнә. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең — хакыйкый (1901), Рус библиография җәмгыятенең шәрәфле (1916) әгъзасы.

Хезм.: К истории русского театра. Комедия о графе Фарсоне. СПб., 1900; О старинном латино-русском словаре. К., 1901; Послесловие к «Истории города Казани» Фукса и биографические сведения о К.Ф.Фуксе. К., 1905; О летосчислении древних болгар. К., 1911.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Справочник печатных работ Нестора Мемноновича Петровского (1875–1921). К., 1986.

*Е.Б.Долгов.*

**ПЕТРО́ВСКИЙ ЗАВО́Д** авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 937 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, урманчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән — Починок Басуплы Илга, 18 йөз чыганакларында Бисипова авылы буларак мәгълүм. 1807 дә керәшеннәр бу авылдан Бөгелмә өязенең Абрамовка авылына (хәзер Әлмәт р-нының Васильевка а.) күченәләр, бу җирләргә хосусый милекче рус крәстияннәре килеп урнаша, һәм торак пункт Петровка дип йөртелә башлый. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, 1891 дән «И.Г.Стахеев һәм уллары» сәүдә йорты карамагындагы аракы з-дында эшлиләр. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 229,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1920 дә — 170, 1926 да — 180, 1938 дә — 844, 1949 да — 584, 1958 дә — 892, 1970 тә — 855, 1979 да — 752, 1989 да — 653, 2002 дә — 1081 кеше.

**ПЕТРОГРА́Д МӨСЕЛМАННА́Р АРАСЫНДА́ КОММЕ́РЦИЯ БЕЛЕМНӘРЕ́Н ТАРАТУ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, мәдәни-агарту, хәйрия оешмасы. 1912 елның 12 декабрендә төзелә. Җәмгыятьнең гамәлгә куючысы һәм рәисе — Дәүләт саклык кассалары идарәсе хезмәткәре, Польша татары Я.А.Мухлио. Мөселманнар арасында икътисади белем дәрәҗәсен күтәрү максатыннан, җәмгыять Петроградта югары башлангыч уч-ще программасы нигезендә эшләүче сәүдә мәктәбе ача. Махсус предметлардан тыш, анда ислам дине тәгълиматы һәм татар теле дә укытыла. 1917 дән соң эшчәнлеге туктатыла.

*Җ.С.Миңнуллин.*

**ПЕТРОГРА́ФИЯ**, петрология (грек. petros — таш һәм ...*графия*), тау токымнары турындагы фән, аларның барлыкка килүен, минераль һәм химик составын, структура һәм текстурасын, аларның яту, җир кабыгында һәм җир өслегендә урнашу закончалыкларын өйрәнә. П. *минералогия, геохимия*, вулканология, *тектоника, стратиграфия* һәм файдалы казылмаларны өйрәнү б-н тыгыз бәйләнгән. Магматик, метаморфик һәм утырма токымнар (яки литология) П.сенә бүленә. Петрохимия, петрофизика, техник П. һ.б.ны аерып карыйлар. Татарстанда П. өлкәсендәге эшләр Казан ун-ты ачылганнан соң башлана (К.Ф.*Фукс*, А.М.*Зайцев*, А.Л.Лаврский һ.б.). Тикшеренүләр Казан тирәсендә, Уралда, Себердә алып барыла. Ф.Ф.*Розен* токымнарны өйрәнүдә микроскопик һәм химик алымнар куллана башлый, шомарту остаханәсе булдырыла. 20 йөз башыннан Б.К.*Поленов* һәм Б.П.*Кротов* — тау токымнарын микроскопик тикшеренүләр буенча, 1922 дән Кротов (илдә беренчеләрдән булып) утырма токымнар П.се буенча лекцияләр курсы укыйлар. Л.Н.*Миропольский* Идел буе һәм Урал тау токымнары буенча төпле тикшеренүләрне башлап җибәрә. В.А.*Полянин*, Ф.М.*Ишмаев*, А.И.*Кринари*, А.А.*Трофимук*, В.А.Тимесков һ.б. тау токымнарын һәм аларга бәйле файдалы казылмаларны: Урал, Алтай тимер һәм боксит рудаларын, Идел буе бакыр рудаларын тикшерәләр. 1930–40 та Идел буенда нефть эзләү эшләренең җәелүе б-н нефтьле токымнарны петрографик өйрәнү башлана. 1950 елларда тау токымнарын өйрәнүдә спектроскопия, рентгенография, термография, люминесценция һ.б. алымнар кулланугa (Казан ун-тында В.М.*Винокуров*, А.И.*Бахтин*; ЦНИИгеолнерудта В.В.Власов, В.Ф.*Крутиков*, Т.З.*Лыгина*, В.А.Тимесков, Р.Ә.*Хәйдәров* һ.б.) бәйле яңа этап башлана. Кристалларның эчке төзелеше, өслеккә чыгучы тирәнлектәге токымнарның составы өйрәнелә, аларның урнашу закончалыклары ачыклана, нигез токымнарының карталары эшләнә (А.М.*Дымкин*, Б.С.Ситдыйков, В.А.Полянин, А.Г.Низаметдинов, В.Г.Изотов һ.б.).

*Әд.:* Винокуров В.М., Бахтин А.И. История кафедры минералогии и петрографии Казанского университета. К., 2004.

*В.А.Тимесков.*

**ПЕТРОПА́ВЕЛ БИСТӘСЕ́** авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 10 *км* көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 688 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1730–40 елларда нигез салына. Беренче булып отставкадагы солдатлар килеп урнаша, соңрак халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чүлмәк ясау, киез итек-киез җиштерү һәм май язу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.б.дә Петропавел чиркәве (1885 тә төзелә; архит-ра истәлеге), Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, земство мәктәбе (1866 да ачыла), хастаханә, су тегермәне, 9 ярма яргыч, 7 май язу йорты, тимерчелек, сырahanә, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли; сишәмбе көннәрендә — базар, 9 нчы җомгада һәм 14 нче сентябрьдә ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5003 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 319 ир-ат; 1859 да — 1622, 1897 дә — 1802, 1908 дә — 3550, 1910 да — 3694, 1920 дә — 3722, 1926 да — 3148, 1938 дә — 1892, 1949 да — 1698, 1958 дә — 1810, 1970 тә — 1608, 1979 да — 1103, 1989 да — 743, 2002 дә — 741 кеше.

**ПЕТРОПА́ВЕЛ БИСТӘСЕ́** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 27 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 26 кеше (руслар) яши. 1565–67 елларда Жилецкий Бистәсе буларак мәгълүм. 1720 елларда анда отставкадагы солдатлар килеп урнаша, алар 19 йөзнең 1 нче чирегендә дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 574 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 135, 1908 дә — 373, 1926 да — 196, 1949 да — 150, 1958 дә — 242, 1970 тә — 209, 1979 да — 136, 1989 да — 74, 2002 дә — 44 кеше.

**ПЕТРОПА́ВЕЛ СОБОРЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. 1726 елда Казан сәүдәгәре И.А.*Михляев* акчасына, шул исемдәге приход чиркәве (1565 тә ачыла) урынына, 1722 дә Казанга Пётр I килү хөрмәтенә корыла. Бер үк вакытта соборның төньяк-көнчыгыш ягында алты яруслы чаң манарасы төзелә. Собор терр-ясенең көньяктагы коймасы арх. М.П.Коринфский проекты буенча 19 йөз уртасында корыла, П.с. күп тапкырлар яна (1742, 1749, 1815, 1842), 1774 елда шәһәрне Е.И.Пугачёв гаскәрләре басып алганда талана. 1815 елгы янгыннан соң, 1824–25 тә яңадан торгызыла. Нигезе тигез утырмау сәбәпле, собор туза башлый, янкормалары җимерелә, чаң манарасы авыша. 1888–96 да арх. М.Н.Литвинов проекты һәм җитәкчелеге б-н собор һәм чаң манарасы үзгәртеп корыла. Янкормалар, баскычлар сүтелә, алар һәм ишегалды мәйданчыгы яңадан әүвәлге хәленә кайтарыла, төньяктагы элек юкка чыккан баскыч кабат торгызыла, чаң манарасы астына яңа нигез салына. Шул вакытта чаң манарасына сәгать ясау остасы П.И.Климов эшләгән сәгать урнаштырыла.

П.с.ның гомуми композициясе дүрткырлыктагы сигезкырлык схемасы буенча төзелгән: җылы храм булып саналган аскы биек катка сигезкырлык утыртылган ике тәрәзәле дүрткырлык төзелә, ул ике гөмбәзле ярымтүгәрәк чатыр б-н тәгәлләнә. Храмга көнбатыш яктан ашау-эчү бүлмәсе кушыла. Соборның биеклеге 52 *м*. Көнбатыштан һәм төньяктан галерея аркадасы кушылган, аның ике киң баскычлы түбәсе мәйдан булып хезмәт итә. Төньяк галереяның көнчыгыш ягында, бер-берсе өстендә, 1888–90 елларда үзгәртеп корылган кышкы һәм җәйге чиркәүләрнең янкормалары урнашкан. П.с. фасадлары сыңар һәм парлы калаклар, пилястралар, ярымколонналар, «әтәч кикриге» рәвешендәге кечкенә фронтонлы чуар йөзлекләр, әвәләп ясалган күпертмә үсемлек орнаментлы сырлы һәм кистерелгән кәрнизләр б-н бизәлә. Колонна кәүсәләренә уралган үлән, чәчәк, яфраклар, шәфтәлу, алма, груша, слива ботаклары б-н аралашкан йөзем тәлгәшләре төп бизәлеш үрнәге булып тора. Әвәләп ясалган кабарынкы үсемлек бизәге тәрәзәләрнең ике ягын да тулыландырып, сигезкырлыкның кырларын томалап тора. П.с.ндагы көнчыгыш фасадның бер тәрәзәсе сигезкырлыкка уелган; кайчандыр аның куышында зур икона «Тәхеттәге Мәрьям Ана изгеләр чорналышында» («Богоматерь на троне в окружении святых») торган. Уеп бизәлгән кысалардагы иконаларның 2 рәте ш.у. дүрткырлыкның көньяк һәм төньяк фасадлардагы өске яктылык тәрәзәләре аралыкларында урнаша. Шундый ук «тирән мәгънә б-н язылган» иконалар храм һәм янкорма ишекләре өсләрендәге куыш бизәкләре булып хезмәт иткән. П.с.ның «украин бароккосы» стилендәге купшы бизәлешен шахмат тәртибендә



Петропавел соборы. Казан. 1726.

ябылган түбә һәм гөмбәзләр, фасадлардагы барлык элементлар һәм декор полихромиясе тәгәлли. Интерьерда 1723–26 да оста Гусев җитәкчелегендәге Казан уеп бизәкләүчеләре башкарган рус бароккосы стилендәге җиде яруслы төп иконостас сакланып калган. 1815 тә чыккан янгында зыян күргән иконалар 1824–25 тә Казан рәссамы В.С.Турин тарафыннан яңартыла. 1864–65 тә уеп бизәк төшерүче М.А.Тюфилин иконостасны кабаттан торгыза (1889–91 дә яңартыла). Чаң манарасы баганасыман корылмадан гыйбарәт. Бер-берсе өстенә үлчәмнәре даими кечерәеп бару тәртибендә куелган сигезкырлыкларның очы барабан өстендәге гөмбәзле чатыр б-н тәгәлләнә. Чаң манарасының архит-расы собор б-н чагыштырганда гадирәк. Төп элементлары — чыгынтылы, шәкелле кәрнизләр, сыңар яки калакларга куелган катлаулы ордерлы пилястралар, архивольтлар б-н эшләнгән чаң куышлары, ярымкултыксалар һәм әвәләп ясалган бизәкләр. Бер генә төстәге диварлар фонында фасадлардагы декорның күптөслелеге, салынып торган тимер кәрнизләре П.с. һәм чаң манарасының чуар бизәлеше үзенчәлеген тәшкил итәләр. 1930–89 да П.с.да архив, реставрация остаханәсе, планетарий урнаша. 1989 да үзгәртеп кору эшләре тәмамлаганнан соң, П.с. дindарларга кайтарып бирелә, 1993 тә ачыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998; Сокровища культуры Татарстана: Историческое наследие, культура и искусство. М., 2004.

*Н.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**ПЕТРОПА́ВЛОВКА** авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы буенда. 2010 елда 42 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1850 елларда Сходнево авылыннан күченүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Рус Сугышлысы. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1188 дис. тәшкил итә. 1923 тә чиркәү (1930 елларга кадәр эшли) төзелә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сходнево волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1889 да — 509, 1900 дә — 603, 1910 да — 803, 1920 дә — 803, 1926 да — 624, 1938 дә — 417, 1949 да — 360, 1958 дә — 264, 1970 тә — 208, 1979 да — 154, 1989 да — 75, 2002 дә — 55 кеше.

**ПЕТРУ́ХИН** Григорий Иванович (1878/79, Казан губ., Тәтеш өязе Зур Фролово волосте Степановка а. — ?), Казан губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты. Чиркәү-приход мәктәбен тәмамлый. Игенчелек б-н шөгыльләнә, 12 ел дәвамында җәй айларында Казан, Әстерхан, Баку, Петровск һ.б. шәһәрләргә эш эзләп бара, ташчы булып эшли; кышын киез итек баса. Дәүләт Думасында трудовиклар фракциясе әгъзасы була, И.Е.Лаврентьев б-н элемтәдә тора. 1907 елның 3 июнендә Думаны куып таратканнан соң язмышы билгесез.

*Әд.:* Усманова Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе России. 1906–1917. К., 2006.

**ПЕТРУШЕ́НКО** Юрий Яковлевич (3.1.1950, Алтай краеның Сетовка а. — 20.10.2011, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998). 1973 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый. 1977–81 дә Оренбург политехник ин-тында укыта. 1981 дән Казан авиация ин-тында, Динамика һәм ныклык проблемалары фәнни-техник үзәгендә директор урынбасары (1991–96). 1996 дан Казан энергетика ун-тында: материаллар белеме һәм ныклыгы каф. мөдире, проректор (1997 дән), ректор (2004–11). Хезмәтләре матем. модельләштерүгә, санлы алымнарга, катлаулы структураларның ныклыгын, тотрыклылыгын һәм динамикасын өйрәнүгә карый. П. сыгылмалы системаларның тотрыклылыгын һәм тирбәнешләрен тикшерә.

Х е з м.: Метод конечных сумм, базирующийся на полиномах Лагранжа, в задачах механики оболочек вращения // Изв. вузов. Авиац. техника. 1993. № 4; Проекционный метод исследования механики нестационарного деформирования составных оболочек, предварительно нагруженных статической нагрузкой // Тр. 17 Междунар. конф. по теории оболочек и пластин. К., 1996; Колебания оболочек сложной геометрии, предварительно нагруженных статической нагрузкой. К., 1997.

**ПЕТРУ́ШКА** (Petroselinum), чатырчалар семьялыгыннан бер яисә икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы; яшелчә культурасы. 3 төре билгеле, шулардан культурада бакча П.сы игелә, 2 төрчәсе бар: тамыр П.сы һәм яфрак П.сы (икесе дә ТРда үстерелә). Азык буларак яфраклары һәм тамыразыгы кулланыла. Эфир майлары П.га әчкелтем хуш ис һәм тәм бирә. Беренче елда үсемлекнең озын саплы яфраклардан торган тамыр яны розеткасы, икенче елда чәчәк сабагы һәм орлыклар үсеп чыга. Тамыразыгы озынча-конуссыман, соргылт-ак яисә саргылт-ак төстә, җимеш йомшагы ак (яфрак П.сы тамыразык барлыкка китерми, бары тик калынайган тармаклы тамырлы була). Яфраклары каурыйсыман телмәле, куе яшел, шома яисә саргылт-яшел, вак, чатырга җыелган. Читтән серкәләнә. Җимеше ике орлыклы. Орлыклары вак, чәнечкесез, соргылт-яшел төстә, үзенчәлекле исле. Тишелеше 2–3 елга кадәр саклана. П. салкынга чыдам үсемлек, шытымнары −7 °С ка бирешми. Яфраклары С витаминына һәм каротинга бай, аңарда шулай ук $B_1$, $B_2$, PP, К витаминнары, фолий к-тасы, шикәр, минераль тозлар (калий, кальций, фосфор, тимер һ.б.ның), азотлы матдәләр бар. Тамыразыкларында аксым һәм углеводлар бар, ләкин аларда яфракларына караганда витаминннар азрак. ТРда П.ны бакча участокларында һәм теплица хуҗалыкларында үстерәләр. Респ-када таралган сортлары: тамыр П.сы — «Урожайная» (1965), «Бриз» (1996), «Сахарная» (1996); яфрак П.сы — «Обыкновенная листовая» (1988). П. уңдырышлы, яхшы ашланган, көпшәк балчыклы һәм комсу туфракларны ярата. Орлыкларын иртә язда 30 *см* ара калдырып рәтләргә чәчәләр. Чәчү нормасы 1 $м^2$ га — 0,5 *г*, орлыкларны күмү тирәнлеге — 1,5–2,5 *см*. Халык медицинасында П. азык эшкәртү бозылганда, үт куыгында таш булганда, бәвел куыгы авырулары, простатит, йөрәк авыруыннан шешенгәндә кулланалар.



*Әд.:* Ваш огород: Маленькая энцикл. М., 1995.

**ПЕТУХО́В** Александр Александрович (27.7.1938, Ярославль ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1987), проф. (1990), ТРның атказ. химигы (1996). Ярославль химия-механика техникумын (1956), Бөтенсоюз политехник читтән торып уку ин-тын (1965) тәмамлый. 1956–79 елларда Ясалма каучук өчен мономерлар фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Ярославль ш.). 1979 дан «Түбәнкаманефтехим» АҖдә, үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә пропилен һәм стирол окисе лаб-ясе мөдире, Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә эшләрен башкару һәм гамәлгә кую идарәсе башлыгы урынбасары (1986 дан), башлыгы (1988 дән), фәнни-тикшеренү үзәгенең пропилен окисе лаб-ясе башлыгы (1998 дән); бер үк вакытта Казан технол. ун-тының Түбән Кама химия-технол. ин-ты профессоры (1989–94). Хезмәтләре төп органик синтезга карый. П. югары алкилбензой к-таларын, бензой һәм кырмыска к-таларын ацетофенонны оксидлау юлы б-н (ацетофенонлы җитештерү калдыкларын кулланып) табу, этилбензол гидропероксидын каталитик таркатып фенол табу технологияләрен эшләүдә; тиңдәшле гидропероксидларына кадәр изопентан һәм изобутанны оксидлаштыру стадияләрен, пропилен һәм изоамиленнар эпоксидлау катализаторларын синтезлау һәм регенерацияләү (изопрен табуның гидропероксид ысулы өчен) стадияләрен эшләүдә катнаша. П. катнашында гидропероксид ысулы б-н стирол һәм пропилен оксидын бергә табу технологиясе үзләштерелә һәм камилләштерелә, юлларга җәелә торган битум, формальдегид нигезендә изопрен җитештерү эшләре башлана һәм дәвам иттерелә. П. этилен окисе һәм пропилен нигезендә гликольләр һәм эфирлар җитештерү, олефиннар эпоксидлау һәм этилбензолны аның гидроперекисена кадәр оксидлаштыру өчен катализаторлар табуның энергия саклаулы технологияләрен тикшерүгә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 109 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар, шуларның 21 е «Түбәнкаманефтехим» АҖ з-дларында гамәлгә куела. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тройные комплексы катализатор — олефин — гидроперекись и их роль в реакции эпоксидирования // Кинетика и катализ. 1976. Т. 17, № 4 (автордаш); Исследование озонолиза линейных α-олефинов с целью получения карбоновых кислот // Журн. прикладной химии. 1993. Т. 66, вып. 5 (автордаш); Оксиэтилирование этанола при катализе гликолятом молибденила // Рос. хим. журн. 1998. Т. 42, № 6 (автордаш).

*Әд.:* А ю п о в М.Ю., Ю с у п о в И.В. Изобретательство в Республике Татарстан. К., 2001; С а ф и н а Ф.Ф. Творческая деятельность изобретателей и рационализаторов // Энергосбережение в Республике Татарстан. 2003. № 1.

**ПЕТУХО́В** Владимир Юрьевич (15.8.1950, Төрекмәнстан ССРның Красноводск ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1998), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1972 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1975 тән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы (1999 дан) фәнни хезмәткәр, бер үк вакытта, 1995 тән, Казан ун-тында, проф. (1999), радиацион химия һәм радиобиол. лаб-ясе мөдире (2004 тән). Хезмәтләре ионлы имплантация физикасына һәм ион-нур синтезына (ИНС) карый. П. төрле нәметалл матрицаларда: ярымүткәргечләрдә, диэлектрикларда, полимерларда, югары темп-ралы үтә үткәргечләрдә һ.б. ИНСның төп закончалыкларын, үзенчәлекләрен ачыклый һәм системалаштыра. Беренче булып ИНС алымы б-н нәметалларда югары Кюри темп-ралы юка ферромагнитик элпәләр таба. Күп компонентлы кушылмалар синтезлау өчен төрле химик элемент ионнарын бер үк вакытта имплантацияләүне тәкъдим итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Магнитные свойства кремния, имплантированного ионами железа // Физика твёрдого тела. 1984. Т. 26, вып. 5 (автордаш); Ion synthesis of thin granular ferromagnetic films in polymethylmethacrylate // Solid State Communications. 1996. V.97, № 5 (автордаш); Formation of thin superconducting YBa CuO layers by oxygen implantation // Physica C. 1997. V.282–287 (автордаш).



И.П.Петухов.

**ПЕТУХО́В** Игнатий Павлович (27.12.1914, Казан губ. Лаеш өязе, хәзер Балык Бистәсе р-ны Масловка а. — 7.5.1950, шунда ук), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), подполковник. Рече лейтенантлар курсларын (1938), Командирлар составын камилләштерү курсларын (1939) тәмамлый. Туган авылында авыл советы секретаре булып эшли. 1936 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 20 нче аерым понтон-күпер батальоны командиры (40 нчы армия). Брянск, Воронеж һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Ворошиловград (1942), Воронеж-Касторное (1943) операцияләрендә, Днепр елгасы буендагы сугышта (1943), Украинаның Уңъяк ярын (1943–44) азат итүдә катнаша. Козинцы авылы (Киев өлкәсе Кагарлык р-ны) янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 23 сентябрь — 5 октябрендә елганың уңъяк ярындагы плацдармны яулап алу һәм киңәйтүне тәэмин итеп, армия гаскәрләренең елга аша кичүен оештыра. 1945 тә демобилизацияләнә. Туган авылында яши һәм эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЕТУХО́В** Сергей Фёдорович (25.9.1917, Смоленск өлкәсенең Гагарин р-ны Боровикино а. — ?), механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1952). Фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбен тәмамлаганнан соң (1930), Октябрьск тимер юлында слесарь булып эшли, соңрак САМ з-дында (Мәскәү). 1937–41 елларда 2 нче Мәскәү сәгать з-дында (1941 дә Чистай шәһәренә эвакуацияләнә). 1941 дән Чистай сәгать з-дында. 1946 да СССР Халык комис-тының 5 нче миномётлар б-н коралланy идарәсе карамагына Мәскәүгә күчерелә. Дәүләт бүләге сәгать җитештерүдә



А.З.Петушков.

югары нәтиҗәле инструментлар һәм хезмәт җайланмалары булдырганы өчен бирелә.

**ПЕТУШКО́В** Адам Захарович (22.4.1918, хәзер Белоруссия Респ-касы, Могилёв өлкәсенең Климовичи р-ны Федотова Буда а. — 25.7.1976, Киев), Сов.Союзы Герое (10.1.1944), полковник. Рогачёв пед. уч-щесен, Пушкин танк уч-щесен (1942), Кызыл Армиянең И.В.Сталин исем. бронетанк һәм механикалаштырылган гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1947) тәмамлый. Укытучы булып эшли. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 166 нчы аерым инженерлык-танк полкында танк взводы командиры (3 нче гв. танк армиясе). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Киев һөҗүм һәм саклану (икесе дә — 1943), Житомир-Бердичев (1943–44), Львов-Сандомир (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Киевтан төньяк-көнбатышта барган сугышларда батырлык күрсәтә: 1943 нең 3–6 ноябрендә П. җитәкләгән танк взводы, дошман оборонасын өзеп, мина кырларында танклар үтү өчен юл ясый; алгы отряд составында аның танк взводы беренче булып — Святошино авылына, икенче сугышта Глеваха авылының (Киев өлкәсе Васильков р-ны) төньягына бәреп керә һәм штурм орудиесен сафтан чыгара. Чигенүче дошманны куып барып, аларның күп кенә җанлы көчләрен һәм техникасын тар-мар итә. Сугыштан соң Совет Армиясе сафларында. 1960–69 да Казан танк уч-щесендә укыта. 1969 дан запаста. Гомеренең соңгы елларында Киевта яши. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЕТЦО́ЛЬД** Оскар Эдуардович (14.12.1867, Казан — 1936), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе. 15 корпустан торган «Шәркый Бавария» сыра з-ды (шәһәр янындагы Пләтән авылында атасы тарафыннан 1867 елда ачыла), Аргы Архангельский урамындагы ике катлы агач йорт, ат з-ды, манеж, бакча, оранжерея кергән утар хуҗасы. «Шәркый Бавария» з-дының продукциясе бөтен Россиядә таныла, Флоренциядә 1906 да үткәрелгән Халыкара күргәзмәдә гран-при яулый, Амстердам (Нидерланд), Бордо (Франция), Брюссель (Бельгия), Лондон, Париж күргәзмәләрендә зур алтын медальгә лаек була. П. Казан мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертә: 1906 да арендага алган «Аркадия» бакчасында ике катлы ресторан, ачык һәм каплаулы театрлар төзи; анда хәрби музыка оркестры уйный, бильярд, тир, кегельбан, синематограф була. Бакчаны һәм театрны яктыртырга электростанция корыла, бакча һәм биналар буйлап янгын сүндерү өчен сүүткәргеч челтәре эшләнә. Паркта тәртипне П. үз хисабына тоткан полиция саклый. Күңел ачу өчен Кабан күлендә аның өч пароходы (һәрберсе 300 кешегә исәпләнгән) була. Беренче бөтендөнья сугышы елларында «Нептун» пароходында земство госпиталенә авыр яралыларны ташыйлар. П. 1915 тән «Электра» (хәзерге «Татарстан») кинотеатры хуҗасы була, 1917 дән Кинематографик театр хуҗаларының бөтенроссия берлеге хакыйкый әгъзасы. П. Казан губерна төрмә ком-ты директоры (1906 дан), тоткыннарны төзәтү бүлеге попечителе (1906–10), Казан губернасы балалар ятимханәләре попечительлегенең шәрәфле әгъзасы (1907 дән), Император Россия суда батучыларны коткару җәмгыятенең Казан округ идарәсе рәисе иптәше (урынбасары) була. Казандагы һәм Чистайдагы уку йортларын ремонтлау өчен шактый акча тота. Казанда октябристлар партиясе ком-тын оештыручыларның берсе. Станислав тасмалы «Тырышлык өчен» көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ПЕ́ХТЕЛЕВ** Иван Георгиевич (21.4.1906, Саратов губ. Камышлы ш. — 30.8.1969, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1956), проф. (1957). Саратов ун-тын тәмамлый (1931). 1933–38 елларда Әстерхан пед. ин-тында каф. мөдире. 1939 дан Казан пед. ин-тында (1946 га кадәр әдәбият каф. мөдире), 1962 дән Казан ун-тында (1962–67 елларда журналистика каф. мөдире). Хезмәтләре 20 йөз башы рус-татар әдәбиятлары бәйләнешләренә, рус революцион-демократик тәнкыйть тарихына, В.Г.Белинский, А.И.Герцен, Н.А.Добролюбов, Д.И.Писарев һ.б.ның иҗади мирасына карый. Г.Тукай, С.Хәким, Ә.Ерикәй, Г.Кутуй, Г.Бәширов һ.б. иҗатына багышланган мәкаләләр авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Габдулла Тукай: Жизнь и творчество. К., 1946; Белинский как историк русской литературы. К., 1957; Тукай и русская литература. К., 1966; Герцен — литературный критик. М., 1967.

*Әд.:* Г и н и я т у л л и н а А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ПЕЧӘ́Н БАЗАРЫ́ МӘЧЕТЕ́** (7 нче Җамигъ мәчет, Юнысов мәчете), Казанда архит-ра истәлеге. 1992 елдан «Нурулла» исемен йөртә. 1845–49 да арх. А.К.*Локман* проекты буенча Г.М.Юнысов һәм аның уллары акчасына (к. *Юнысовлар*) Печән базары мәйданының көньяк-көнбатыш почмагында төзелә. Бина ул вакытта мәйданнан бер катлы кибетләр һәм адм. корпуслар б-н бүлеп алынган ишегалдында диагональ буенча корылган; алар кисешкән почмакта мәчет ишеге урнашкан (түбән ярус аша) манара күтәрелгән. П.б.м.нең күләм чишелеше нигезендә мәчетнең 1844 елгы проект үрнәге композициясе ята. Планда төньяктан ишек урнаштырылган өч ярусы манарасы һәм гөмбәзле залы булган сузынкы сигезкырлык формасындагы ике катлы бина. Беренче кат хезмәт һәм хуҗалык эшләре өчен билгеләнгән. Төп катның эчке озынча-түгәрәк фәзасы а́ркалар б-н намаз залларына бүленгән. Биеклеге буенча чыгып торучы үзәк өлешнең симметрик күләме тыштан суганбашсыман гөмбәз б-н очланган. Гөмбәз тәбәнәк цилиндрик барабанга урнаштырылган һәм үзәк залның интерьерын ярымшар итеп ачкан. П.б.м. милли-романтик юнәлештәге эклектика стилендә бизәлгән. Фасадлардагы турыпочмаклы тышкы як тәрәзәләр гадиләштерелгән, очлы сандриклы йөзлекләр б-н каймаландырылган. Гөмбәз күләме үзәгендә розеткага алынган витражлы түгәрәк тәрәзә урнашкан. Көньяк фасадта михраб чыгынтысы юк. Манараның өскә таба тарая барган цилиндрик кәүсәсе турыпочмаклы кечкенә уемлы тәбәнәк ярус һәм конуссыман чатыр б-н төгәлләнгән. Кәүсә эчендәге бормалы баскыч металл терәк б-н беркетелгән һәм чүкеп ясалган челтәрле киртә б-н тотылган түгәрәк мәәзәнә-балконга алып менә. Мәчет манарасының формасы урта гасырлар болгар һәм Якын көнчыгыш архит-ралары б-н тәңгәл килә.



Печән базары мәчете. Арх. А.К.Ломан. 1845–49. Хәзерге күренеше.

1929 да П.б.м. ябыла, манарасы сүтелә; бина дәүләт учреждениеләренә бирелә һәм торак итеп файдаланыла. 1992 дә мәчет диндарларга кайтарып бирелә, 1990–95 тә яңадан торгызыла, манарасы арх. Р.В.*Билалов* проекты буенча элекке хәленә кайтарыла. Зал интерьеры фирәзә төсендәге ярымтүгәрәк гөмбәз һәм витражлы түгәрәк тәрәзәләр б-н бизәлә. Яңартып төзегәндә беренче катта мәрмәр б-н тышланган һәм үзәгенә уеп ясалган касә куелган декоратив фонтанлы тәһарәт бүлмәсе корыла.

*Әд.:* Х а л и т о в Н.Х. Архитектура мечетей Казани. К., 1991; Мечети Татарстана / Сост. Х.Н.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

*Н.Г.Надыйрова.*

**ПЕЧӘНАШАРЛА́Р** (Psocoptera, яки Copeognatha), бөҗәкләр отряды. Өченчел чордан билгеле. Гәүдә озынлыгы 1–5 *мм*. Авыз аппараты ортоптероид һәм гемиптероид бөҗәк билгеләренә ия, ягъни кимерү һәм чәнчеп суыру функцияләрен үти. Ана затларда гади кукәйсалгыч булу — ортоптероид бөҗәкләр б-н охшашлыкка тагын бер дәлил. 1 меңгә якын төре билгеле, нигездә, тропик

һәм субтропикларда яши. БДБдә 60 ка якын төре бар. Татарстан терр-ясендә төрле агач токымнарында яшәүче Amphigerontia ыругыннан канатлы П. билгеле. Башлыча, тере һәм черегән үсемлек тукымалары (исеме шуннан) б-н туена. Шулай ук синантроп төр — китап П. яки китап «бете» (Liposcelis divinatorius) очрый, бөҗәк коллекцияләрендә, гербарийларда, кош ояларында яши.

*Р.М.Зелеев.*


**ПЕЧИ́ЩЕ** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 2 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында. 2010 елда 757 кеше (руслар) яши. Икмәк комб-ты. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Төбәк тарихы һәм Янка Купала музейлары. Зөя Троица-Сергий монастыре җирләрендә 1592 еллар тирәсендә нигез салына. 1764 тә җирле халык — экономик, соңыннан дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, ак таш чыгару, известь һәм алебастр яндыру б-н шөгыльләнә; бурлаклыкта йөри (19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр), сәүдәгәр И.П.Оконишниковның төбәктәге иң зур пар тегермәнендә (1895 тә ачыла; ел саен 1280 мең потка кадәр бодай эшкәртә) эшли. 20 йөз башында П.да земство мәктәбе (1889 да ачыла), сульфат з-ды, 1 су һәм 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1482 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 203, 1782 дә — 248 ир-ат; 1859 да — 575, 1897 дә — 847, 1908 дә — 996, 1920 дә — 1130, 1926 да — 1115, 1938 дә — 1708, 1949 да — 1841, 1958 дә — 2207, 1970 тә — 1850, 1979 да — 1745, 1989 да — 1071, 2002 дә — 909 кеше.

*Әд.:* Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

**ПЕЧИ́ЩЕ ГЕОЛО́ГИК КИСЕЛЕШЕ́**, Пермь системасының *Казан ярусы* стратотибы; табигать истәлеге (1972). Югары Ослан р-ны терр-ясендә Печище авылы янында урнашкан. 1960 елда, аеруча зурлыгы б-н аерылып торучы өске Казан асъярусы катламнарының бер төре буларак, бөтендөнья стратиграфик эталоннар системасына кертелгән. Түбәнге Казан асъярусы һәм Татар ярусы арасындагы чикне колачлый. Беренче мәртәбә М.Э.*Ноинский* тарафыннан тасвирлана (1899). Доломит, известьташ, мергель, балчык, алевролит, комташ, вак чуерташтан тора. Целестин, гипс, кальцит, кварц, халцедон, сууүсемнәр, умырткасыз хайваннар, моллюск калдыклары, балык тәңкәләре һәм тешләре һ.б. очрый. П.г.к.дә Mn, Cr, Zr, Ti, Ni, Cu, Sr һ.б.ның югары концентрацияле горизонтлары аерылып тора. П.г.к.нең гомуми калынлыгы 44–53 *м*.

*Әд.:* Верхнепермские стратотипы Поволжья: Путеводитель геол. экскурсий. К., 1998.

*Б.В.Буров.*



Печище геологик киселеше.

**ПЕЧМӘНТА́У** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 161 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 га кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Сәрдәбаш буларак билгеле. 1920 еллардан хәзерге исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу, бүрек тегү һәм олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 770,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 480, 1897 дә — 516, 1908 дә — 594, 1920 дә — 504, 1926 да — 545, 1938 дә — 429, 1949 да — 303, 1958 дә — 254, 1970 тә — 265, 1979 да — 226, 1989 да — 171, 2002 дә — 165 кеше.

**ПЕ́ЧНИКОВ** (Печник) Яков (Янгель) Давидович (14.4.1887, Саратов ш. — 21.2.1968, Казан), дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1953), проф. (1955), ТАССРның атказ. табибе (1945). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1911), шунда ук, университет клиникасында эшли. 1914 елдан Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында. 1918 дән Кызыл Армиядә: Черкассы, Казан хәрби госпитальләрендә табиб. 1921 дән Казан ГИДУВында, 1932 дән дерматовенерология каф. мөдире. Хезмәтләре дерматовенерология өлкәсенә караган авыруларның бер-берсенә өстәлүе динамикасын өйрәнүгә карый. П. аллергия авырулары булганда гонорея барышы үзенчәлекләрен тасвирлый, тире авыруларын дәвалау ысулларын эшли. Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методология диагноза и терапии гонореи // Казан. мед. журн. 1935. № 3/4; Простейшие методы и средства лечения кожных болезней. К., 1945; О роли неврогенных моментов в патогенезе и лечении чешуйчатого лишая // Казан. мед. журн. 1962. № 4.

*Әд.:* Памяти Я.Д.Печникова // Вестн. дерматовенерологии. 1968. № 11.

**ПЕ́ШКОВА** Анна Михайловна (8.9.1919, Царицын ш. — 30.8.1988, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1987). Сталинград эшче яшьләр театры каршындагы студияне тәмамлый (1937), бер үк вакытта шул ук театрның актрисасы була. Аннан соң Сталинград, Ростов-Дон шәһәрләрендәге Яшь тамашачылар театрларында эшли. 1942 елда немец оккупантлары тарафыннан Германиягә җибәрелә, аннан кача; 1943 тә Казанга кайтып, шунда эвакуацияләнгән Сталинград яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) труппасына кабат урнаша. Башта, нигездә, малайлар, яшүсмерләр рольләрен уйный: Вознесенский («Полк улы», В.П.Катаев), Җиһан («Р.В.С.», А.П.Гайдар), Гаврош («Хокуксызлар», В.Гюго романы буенча), Васька («Революция исеме белән», М.Ф.Шатров), Володя Дубинин (В.А.Гольдфельдның шул исем. әсәре буенча), Алёша («Алёша Пешков», И.А.Груздев, О.Д.Форш), Витя Малеев («Ике дус», Н.Н.Носов), Тишка («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский). Бу образлар аша актриса кырыс тормыш мәктәбен узган, тоткан кыйблаңнан тайпылмаска кирәклегенә чын күңелдән ышанган яшүсмер психологиясен ышандырырлык итеп ача. П. геройлары тамашачыны үз-үзләрен тотышлары, эчкерсез, ачык, көчле рухлы булулары б-н җәлеп итәләр. П. ш.у. яшь героиня рольләрен дә башкара. Алар арасында аеруча игътибар үзәгендә булганнары — Таня («Әкият», М.А.Светлов), Полина («Мещаннар», М.Горький), Дуняша, Маша («Чия бакчасы», «Өч сеңел», А.П.Чехов), Одарка («Раштуа алдындагы төн», Н.В.Гоголь повесте буенча), Адриана («Хаталар комедиясе», У.Шекспир), Лула («Өч сандугач, 17 нче йорт», Д.Добричанин), Нюра («Шәһәрдә таң ата», А.Н.Арбузов). Алга таба характерлы өлкәннәр рольләрендә дә уйный: Простакова («Житлекмәгән егет», Д.И.Фонвизин), Фёкла Ивановна («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Үги ана («Золушка», Е.Л.Шварц), фрекен Розенблюм («Пеппи-Озыноек», А.Линдгрен), Евдокия Фёдо-





А.М.П е ш к о в а 1. Одарка («Раштуа алдындагы төн», Н.В.Гоголь повесте буенча); 2. Алёша («Алёша Пешков», И.А.Груздев, О.Д.Форш) рольләрендә.

ровна («Малаховны туктатыгыз!», А.В.Аграновский). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Благов Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

*Ю.А.Благов.*

**ПИГА́ЛОВ** Александр Петрович (30.8.1936, Горький өлкәсенең Салган а.), педиатр, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991), РФнең атказ. табибе (1995). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), ТАССРның Куйбышев р-нында баш педиатр, 1964 елдан районның баш табибе урынбасары. 1968 дән Түбән Кама шәһәре баш педиатры, Түбән Кама үзәк р-н хастаханәсенең баш табибе урынбасары. 1986 дан Казан мед. ин-тының педиатрия ф-ты деканы, 1996 дан Казан мед. ун-тының поликлиника педиатриясе каф. мөдире. Хезмәтләре неонатологиягә, аллергологиягә, хатын-кызларның йөклелеген күзәтүгә, ятим балаларга мед.-социаль ярдәм күрсәтүне оештыру мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Оценка состояния здоровья детей. К., 1999; Организация медико-социальной помощи детям-сиротам и детям, оставшимся без попечения родителей, в домах ребёнка. К., 2001; Оценка здоровья детей и подростков. К., 2006; Профилактическая противоэпидемическая работа на педиатрическом участке. К., 2006.

**ПИ́ГОЛИ** авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 37 *км* көньяктарак, Архиерей күленнән 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 39 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1550 елларда Казан *Архиерей йорты* рус крәстияннәре килеп урнаша, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту, шлея (камыт каешы) үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да чиркәү-приход мәктәбе (1892 дә ачыла), 5 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1511,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Казан авыл районында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да — 432, 1897 дә — 546, 1908 дә — 613, 1920 дә — 667, 1949 да — 438, 1958 дә — 448, 1970 тә — 343, 1979 да — 216, 1989 да — 117, 2002 дә 69 кеше.

**ПИКУ́ЗА** Ольга Ивановна (7.4.1941, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1987), проф. (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), Казандагы 2 нче поликлиникалар берләшмәсендә участок педиатры булып эшли. 1967 елдан Казан мед. ин-тында (1994 тән Казан мед. ун-ты), 1985 тән балалар авырулары пропедевтикасы, 1987 дән 1 нче балалар авырулары кафедралары мөдире, 1989–2001 дә педиатрия ф-ты деканы. Хезмәтләре яңа туган балалардагы пневмониягә (үпкә ялкынсынуы), көчле респиратор авырулар патогенезында иммунитет бозылуга һәм микроциркуляр тайпылышларга карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1999).

Хезм.: Клинические аспекты фагоцитоза. К., 1993 (автордаш); Особенности гуморального, антибактериального иммунитета у детей раннего возраста с заболеванием органов дыхания // Журн. микробиологии, эпидемиологии, иммунобиологии. 1999. № 2 (автордаш); Скрининг резервов здоровья ребёнка по показателям местного иммунитета // Казан. мед. журн. 2001. № 2 (автордаш).

**ПИ́КУЛЕВ** Николай Александрович (29.8.1923, Мәскәү — 11.6.2005, Казан), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1978). 1954 елда Мәскәү электротехник элемтә ин-тын тәмамлый. 1948 дән Үзәк төзелеш конструкцияләре фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Мәскәү). 1959–67 дә Урал «Промстройпроект» фәнни-тикшеренү ин-тында, биналар һәм корылмаларны вибрациягә сынау һәм аннан саклауның яңа алымнары лаб-ясе мөдире. 1967–2005 тә Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, металл конструкцияләр һәм корылмаларны сынау каф. мөдире (1967–88). Хезмәтләре корылмаларны вибрациядән саклауга карый. П. биек биналарны һәм вентилятор градирняларын вибрациядән саклау, оптик, лазер һ.б. прецизион җиһазлар өчен фундаментларны вибрациядән изоляцияләү системаларын эшли. Аның җитәкчелегендә конструкцияләр һәм корылмаларны сынау өчен приборлар төзелә (металлургия, химия, төзелеш һәм сәнәгатьнең башка тармаклары пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән). Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Оптимальные параметры группы виброгасителей при нестабильной частоте гармоничного воздействия // Строит. механика и расчёт сооружений. 1975. № 1; Контроль натяжения арматуры предварительно напряжённых конструкций. М., 1976.

**ПИЛНӘ́ РАЙОНЫ́**, *Түбән Новгород өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1313 *км*². 1963 елда оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Пилнә посёлогы (Түбән Новгородтан 268 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 20980 кеше (2012), татарлар — 4025 (2010) кеше. Татарлар, башлыча, Петрякс, Сафаҗай (Красная Горка) (1940 ка кадәр — Собачий Остров), Яңа Мөчәләй һәм Иске Мөчәләй авылларында яшиләр. 1945–55 тә Петрякс авылында — «Сталин байрагы», 1955–57 дә «Коммунизм байрагы» г-талары нәшер ителә. Хәзерге вакытта П.р.нда 9 мәчет бар. Петрякс авылы мәчете каршында гарәп телен һәм Коръән нигезләрен өйрәтүче якшәмбе мәктәбе эшли. Сафаҗай авылында Х.Фәезханов исем. төбәкне өйрәнү музее эшли (2004 тән); урта мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. 2004 тән районда «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары күрсәтелә. П.р.да тарихчы, филолог һәм педагог Х.*Фәезханов*, партия эшлеклесе Ш.Н.*Ибраһимов*, профсоюз эшлеклесе Н.Н.*Алимов*, генерал-полковник М.С.*Хәкимов*, мед. фән. д-ры Р.А.Сөләйманов, Сов. Союзы Герое Г.Г.*Аббасов* туган. ТАССРның халык артисты Р.В.*Ваһаповның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге П.р. б-н бәйле.

*Х.Ә.Габделкаюмов, С.В.Сабиров.*

**ПИЛЬНО́В** Михаил Семёнович (24.9.1874, Оренбург ш. — 1.12.1930, Казан), дерматовенеролог, медицина д-ры (1901). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1897), Тире-венерология клиникасында (Казан), проф. А.Г.Ге карамагында эшли. 1904–09 елларда Оренбург земство хастаханәсенең терапия бүлеге мөдире. 1911 дә Германиядә фәнни командировкада (тире гистологиясен өйрәнә). 1917 дән Казан ун-тында, 1927 дән дерматовенерология каф. мөдире. 1919–21 дә Кызыл Армиядә. 1923–27 дә Казан ГИДУВында дерматовенерогия каф. профессоры һәм мөдире; 1930 да Тире-венерология клиникасы директоры. Хезмәтләре проф. дерматозларга, тире туберкулёзына (волчанка), псориазга диагноз кую һәм авыруларны дәвалауга карый. П. тарафыннан псориазның көчәю стадиясе билгеләре тасвирлана, алар соңрак «Пильнов синдромы» дип атала башлый.

Хезм.: К вопросу о лечении волчанки (Lupus vulgaris) концентрированным светом по способу N.R.Finsen'a. К., 1904; К вопросу о заболеваниях кожи в связи с профессиональной работой // Казан. мед. журн. 1925. № 4.

*Әд.:* Батунин М. М.С.Пильнов: Некролог // Каз. мед. журн. 1930. № 12.

**ПИМӘ́Р** авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.дә мәчет, мәдрәсә, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 650 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Сәләнгеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 40 ир-ат; 1859 да — 294, 1897 дә — 516, 1908 дә — 555, 1920 дә — 309, 1926 да — 575, 1949 да — 495, 1958 дә — 501, 1970 тә — 521, 1979 да — 448, 1989 да — 402, 2002 дә — 295 кеше.

**ПИ́МЕНОВ** Геннадий Георгиевич (30.10.1936, Лаеш р-ны Лаеш а.), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), физика-матем. фән. канд. (1968). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, молекуляр физика кафедрасында эшли. Хезмәтләре полимерларда һәм катлаулы молекуляр системаларда төш-магнит резонансын (ТМР) куллануга карый. Дәүләт бүләге катлаулы молекуляр системаларның структурасын һәм динамикасын тикшерүдә градиентлы ТМРны үстерү буенча хезмәтләр циклы өчен бирелә.

Хезм.: Влияние крутильных колебаний на второй момент линии ЯМР полиариатов // Высокомолекулярные соединения. 1970. Т. 12, № 7 (автор-

даш); Фазовая неоднородность ацетоновых растворов нитроцеллюлозы // Высокомолекулярные соединения. 1987. Т. 29А, № 12 (автордаш).

**ПИНЕ́ГИН** Михаил Николаевич (7.9.1863, Вятка губ. Глазов ш. — 10.7.1935, Киров краеның Малмыж ш.), тарихчы, этнограф, төбәкне өйрәнүче, педагог, җәмәгать эшлеклесе, статский советник (1904). 1886–92 елларда Казан татар укытучылар мәктәбе күзәтчесе, 1892–1900 дә — укытучысы, 1900–07 дә — инспекторы. 1907–11 дә Казан губернасы халык уч-щеләре директоры. Бер үк вакытта, 1892–1902 дә, цензор ярдәмчесе, 1902–06 да Казан аерым цензоры, 1906–17 дә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы ком-ты рәисе. Казан реаль уч-щесендә (1896–98), Казан укытучылар ин-тында (1898–1900) укыта. 1920 елларда Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте эшләрендә катнаша; 1928 дән җәмгыять каршындагы археография комиссиясе әгъзасы. Мәктәп реформасы уздыруны яклап чыга. Реформаның максаты Россиянең барлык халыклары өчен дә бердәм дәүләт мәктәпләре төзү була. Аның киң комплекслы тарихи материалларга нигезләнеп язылган «Казан — үткәне һәм бүгенгесе: шәһәрнең тарихы, истәлекле урыннары һәм хәзерге торышы буенча очерклар, кыскача адрес мәгълүматлары бирелгән кушымта белән» («Казань в её прошлом и настоящем: Очерки по истории, достопримечательностям и современному положению города с приложением кратких адресных сведений», СПб., 1890) хезмәте — популяр юл күрсәткечләрнең берсе. П. Казан төбәге тарихына караган мәкаләләр, ш.у. Казан татарларының туй йолаларына багышланган этнографик хезмәтләр авторы. «Казан губернасының 1900 елгы адреслар китабы»н («Адресная книжка Казанской губернии на 1900 год», 1900) төзүче. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы (1891). Сугышка алынганнарның гаиләләренә ярдәм оештыру Казан ком-тын нигезләүчеләрнең берсе (1914–17), Казан госпитале попечителе, Качакларга ярдәм күрсәтү ком-тының Казан рус бүлеге рәисе (1914–17).

Х е з м.: Свадебные обычаи Казанских татар. К., 1891.

*Әд.:* Казанский университет (1904–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ПИНЧУ́К** Эдуард Иванович (21.1.1938, Ростов-Дон ш.), генерал-майор (1988). Оренбург зенит артиллериясе уч-щесен (1958) тәмамлый. 1963 елдан СССР Кораллы Көчләрендә, 1963–75 тә батарея командиры, ракета бригадасы командиры урынбасары (Краснодар ш.), 1975–80 дә Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә ракета бригадасы командиры. 1989–93 тә ракета гаскәрләренең М.Н.Чистяков исем. Казан югары хәрби инженер-командирлар уч-щесе начальнигы. 1993 тән запаста. 1993–94 тә ТР ЮСның 1 нче категорияле белгече. 1994–2000 дә «Казан Кремле» музей-саклаулыгы директоры урынбасары, 2003 тән гражданнар оборонасы штабы башлыгы. 2000–03 тә ТР Сәүдә һәм тышкы икътисади хезмәттәшлек министрлыгының кадрлар бүлеге башлыгы. Кызыл Йолдыз, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПИО́Н** (Paeonia), пиончалар семьялыгыннан куак яисә ярымкуак рәвешендәге күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 50 агаччыл һәм үләнчел төре билгеле; 15 ләп кыргый төре Россиядә үсә. 1,5 мең елдан артык Кытайда үстерелә. ТРда үстерелә торган үләнчел П.ның бакча сортлары нигездә 2 төрдән — гади, яисә дару П.ыннан (P. officinalis) һәм аксыл-чәчәкле П.нан (P. lactiflora) барлыкка килә. Биеклеге 60 *см* дан 120 *см* га кадәр. Яфраклары чиратлашкан, икешәр яисә өчәр катлаулы. Чәчәкләре эре (6–20 *см* диаметрлы), ярым катмарлы яки катмарлы, ак, алсу, кызыл, куе кызыл (сирәгрәк сары) төстә. П. май ахыры — июнь башында, сортына карап июль уртасына кадәр чәчәк ата. Җимеше 1–5 яфрактан һәм тыгыз кабыклы тышчадан тора. Орлыклары 6–18 *мм* озынлыкта, 3–15 *мм* калынлыкта. Ш.у. авышкак П., яисә гади кызыл чәчәкле «Марья тамыры» (P. anomala), үстерелә. П. башлыча куакларны аеру юлы б-н үрчетелә. 15 августтан 15 сентябрьгә кадәр аерып утырталар. «Марья тамыры» халык медицинасында кан китүдән һәм ашказаны җәрәхәте булганда кулланыла. П.ның авырулары — соры черек, фитофтороз, күгәрек, ончыл чык, сабаклары шиңү һ.б.

*Әд.:* С а в к о в С.Г. Оранжерейные и комнатные растения и уход за ними. М., 1971; Зелёные оазисы дома и на работе. Минск, 1985; 1000 ответов и идей для вашего сада. М., 2007.

**ПИОНЕ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Өтнә елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (татарлар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Кызыл Юл р-нында. 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1938 дә — 220, 1949 да — 232, 1958 дә — 195, 1970 тә — 114, 1979 да — 87, 1989 да — 14, 2002 дә — 2 кеше.

**ПИОНЕ́Р** посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 28 *км* көньяктарак, Зирекле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 159 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 71%, чуашлар — 23%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1930 елларда «МЮД» с-зы бүлекчәсе буларак нигез салына. Оештырылган көненнән Тельман р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 219, 1949 да — 370, 1958 дә — 380, 1970 тә — 470, 1979 да — 342, 1989 да — 238, 2002 дә — 209 кеше.

**«ПИОНЕ́Р»**, журнал, к. «*Ялкын*».

**«ПИОНЕ́Р КАЛӘМЕ́»**, к. «*Ялкын*».

**ПИОНЕРЛА́Р ОЕШМАСЫ́** (В.И.Ленин исем. Бөтенсоюз пионерлар оешмасы), СССРдагы коммунистик юнәлешле массачыл һәвәскәр балалар оешмасы. Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә төзелә. 1921 ел ахырында РКСМ ҮК каршында балалар коммунистик оешмасының программасын, уставын һәм законнарын эшләү өчен махсус комиссия оештырыла. 1922 нең 13 февралендә Мәскәүнең 16 нчы басмаханәсенең комсомол ячейкасы каршында пионерларның 1 нче отряды барлыкка килә. РКСМның 5 нче съездында (1922 нең октябре) пионерлар отрядлары бердәм балалар коммунистик оешмасы итеп тәгаенләнә, аның уставы, законнары, яшь пионерларның тантаналы вәгъдәсе, П.о.ның төп атрибутлары — кызыл галстук һәм күкрәк билгесе раслана. 1924 тә Спартак исем. «Яшь пионерлар» оешмасы В.И.Ленин исем. П.о. итеп үзгәртелә. Партия ҮКның «Пионерлар хәрәкәте турында» (1924 нең 4 августы), «Пионерлар хәрәкәтенең торышы һәм якындагы бурычлары турында» (1928 нең 25 июне), «Пионерлар слётының нәтиҗәләре турында» (1929 ның 2 сентябре), «Пионер оешмасының эше турында» (1932 нең 21 апреле) карарларында, КПСС Программасында П.о.ның төп бурычлары, аның коммунистик тәрбия системасындагы урыны билгеләнә. П.о.ның эшчәнлеге б-н гомуми кысаларда комсомол җитәкчелек итә.

ТАССРда яшь пионерлар оешмасы төзү турындагы карар 3 нче Халыкара балалар атналыгына (1923 нең 10–17 августы) әзерләнү уңаеннан РКСМның Татарстан өлкә ком-тының 1923 нең 19 июнендә уздырылган утырышында кабул ителә. 1923 нең 5 июлендә комсомоллар И.Малкин һәм Ш.Шаммазов җитәкчелегендә Казанның Югары шәһәр р-нында Үзәк коммунистик клуб җирлегендә 5 звенодан торган Спартак исем. пионерлар отряды оештырыла. 1923 нең 10 августында, 3 нче Халыкара балалар атналыгы көннәрендә, Казанда 70 кешелек 1 нче Казан пионерлары отрядының тантаналы сборы була, 12 августта Ирек мәйданында пионерларның беренче парады үткәрелә, 1923 нең 18 декабрендә Казан пионерларының 1 нче конференциясе булып уза. РКСМның 7 нче өлкә конференциясендә (1924 нең июне) пионерлар хәрәкәтен респ-каның барлык кантоннарында җәелдерү хакында карар кабул ителә. Конференциядән соң респ-када пионерлар хәрәкәте күпкә активлаша: 1924 нең язында — 14 отряд (700 бала), 1924 нең көзендә — 100 отряд (5 мең бала), ш.и. 30 татар пионерлары отряды (1500 бала), Казанда — 60, кантоннарда 40 отряд эшли. 1924 тә пионерлар өчен беренче респ-ка газеталары — рус телендә «За Ильичом», татар телендә «Яшь ленинчы» чыга башлый. Татар балалары арасында пионерлар хәрәкәте үсешенә «Кечкенә иптәшләр» балалар ж-лы зур йогынты ясый, М.Җәлил аның мөхәррире була. 1925 тә шагыйрь Һ.Такташ татар телендә беренче пионерлар җырын — «Пионерлар маршы»н иҗат итә (комп. М.Мозаффаров). 1920–30 елларда респ-ка пионерлары актив рәвештә дингә каршы пропаганда алып баралар (күпләре «Сугышчан алласызлар берлеге» әгъзалары була), наданлыкка, сукбайлыкка каршы көрәштә катнашалар, яңа совет көнкүрешен пропагандалыйлар. 1929 ның июлендә 1 нче Бөтентатарстан пионерлар



«Кызыл кустарь» клубы каршындагы пионерлар отряды. Үзәктә – пионервожатый Х.Т.Абдуллин. 1920 еллар. Казан.

слёты уздырыла, аңа 600 дән артык делегат килә. 1 нче Бөтенсоюз пионерлар слётына (1929 ның 18–25 августы, Мәскәү) 70 кешелек делегация сайлана (аны яшь пионерларның өлкә бюросы рәисе М.Родионов җитәкли). Слётта П.о.ның төп бурычлары билгеләнә: үз оешмаларының төп хуҗалары булу; яшь пионерлар законнарын тугры үтәү; П.о. сафларын ике тапкыр арттыру; яллы балалар хезмәтен бетерү, ялланып эшләүче балаларны яклауга күтәрелү. 1930 ның 6–9 сентябрендә 2 нче Бөтентатарстан пионерлар слёты уздырыла, анда оешманың 1 нче Бөтенсоюз слётларыннан соңгы эшенә йомгак ясала, пионерлар оешмалары эшен алга таба яхшырту юллары, интернациональ тәрбия бурычлары билгеләнә. 1931 дә ВКП(б) карары б-н П.о.ның эшчәнлеге тулысынча мәктәпләргә юнәлдерелә. ВЛКСМ ҮКның 2 нче Пленумында (1936) пионерлар отрядларын һәр сыйныфта оештыру турында карар кабул ителә, пионерга алганда социаль чикләүләр бетерелә. 3 нче Бөтентатарстан слётында (1933 нең 26–28 августы) респ-када П.о.ның 10 еллык үсешенә нәтиҗә ясала. 1930 елларда пионерлар арасында физкультура-оборона эшчәнлеге популярлык казана: ату буенча ярышлар уздырыла, «Яшь Ворошилов укчысы» нормативлары тапшырыла, чаңгы походлары оештырыла. Пионерларны физик яктан әзерләүдә җәйге лагерьлар зур роль уйный башлый (1937 дә ТАССРда 189 шундый лагерь исәпләнә).

Бөек Ватан сугышы елларында респ-ка пионерлары актив рәвештә фронтка һәм тылга булышалар. Тимурчылык хәрәкәте киң колач җәя, пионерлар фронтовиклар гаиләләрен шефлыкка алалар. Алар ш.у. «Татарстан пионеры» самолётын, «Татарстан колхозчысы» танк колоннасын, «Социалистик Татарстан» авиация полкын төзү өчен акча, кирәк-ярак җыюда катнашалар. 1943 тә респ-ка комсомоллары һәм пионерлары башлангычында фашистлардан зыян күргән балаларга ярдәм фонды оештырыла (300 мең сум акча һәм 12 мең данә төрле әйберләр җыела), аның хисабына Әгерҗе р-нында фронтовиклар балалары өчен 100 урынга исәпләнгән шифаханә төзелә. 1944 нең 15 декабренә фашистлардан азат ителгән балаларга ярдәм йөзеннән 931876 сум акча, 1054 пар киез итек, 1525 пар күн аяк киеме, 2835 пар бияләй һәм оекбаш һ.б. туплана. Сугыштан соңгы елларда белемнәр, өлгереш һәм дисциплина өчен көрәш П.о.ның үзәктә торган бурычына әверелә: ВЛКСМның 11 нче съездында (1949 ның марты — апреле) П.о.ның эшчәнлеге мәктәпнең укыту-тәрбия бурычларын хәл итүгә буйсындырылырга тиеш, дип ассызыклана. Төрле түгәрәкләр, П.о. тарафыннан яшь натуралистлар, техниклар, туристлар, эзтабарлар слётлары уздыру һ.б. гамәли белемнәр һәм күнекмәләр үзләштерүгә ярдәм итә. 1950 дә респ-када 210 яшь техниклар түгәрәге, 1954 тә 1085 яшь натуралистлар түгәрәге исәпләнә. Пионерлар арасында спорт-масса эше планлы рәвешкә керә, җәйге һәм кышкы спартакиадалар уздырыла (1957/58 уку елында кышкы спартакиадада 50 меңнән артык пионер катнаша). ВЛКСМ ҮКның 8 нче Пленумы (1957 нең ноябре) карарлары нигезендә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты каршында П.о.ның респ-ка советы, районнарда район советлары оештырыла. Респ-ка пионерлары эзтабарлык эше алып баралар, Окт. рев-циясендә катнашучылар, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары геройлары турында мәгълүматлар, документлар һ.б.ны җыялар, мәктәпләрдә тематик музейлар һәм кызыл почмаклар оештыралар. 1957 дә ВЛКСМ өлкә ком-ты башлангычында респ-ка пионервожатыйларын әзерләү сыйфатын күтәрү өчен Татарстан укытучылар белемен камилләштерү ин-ты каршында пионервожатыйлар ун-ты ачыла. П.о.ның «Хезмәт һәм дуслык өчен» лозунгы астында узган 5 нче респ-ка слётында (1958) респ-ка пионер оешмаларының соц. ярышына нәтиҗәләр ясала. Иң яхшы пионер отрядларына комсомолның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР Мәгариф министрлыгының күчмә Кызыл байрагы, иң яхшы тимурчыларга Казан гарнизонының күчмә Кызыл байрагы тапшырыла. Алдагы респ-ка слётлары В.И.Ленинның туган көненә, ТАССР төзелүгә, Окт. рев-циясенә, П.о.на нисбәтле юбилей елларында булып уза. «Балалык елларыннан ук хезмәттә үскән кеше генә илгә файдалы» девизы астында узган 6 нчы респ-ка слёты (1960) — респ-ка П.о.ның хезмәт эшчәнлеге эстафетасына, 7 нче слёт (1962) — яшь натуралистлар, техниклар, эзтабарлар һ.б.ның эшләренә, 8 нче слёт (1965) — «Ленин йолдызлары, балкыгыз» лозунгы астында узган Бөтенсоюз Ленин пионерлар дружиналары смотрына, 9 нчы слёт (1967) Бөтенсоюз смотрында 3 ел дәвамында катнашуга йомгак ясый һ.б. Сугыштан соңгы елларда ТАССРда пионерлар саны пионер яшендәге мәктәп балалары саны б-н тәңгәл килә.

1990 ның җәендә П.о.ның чираттагы респ-ка слётында балаларның яңа җәмәгать оешмасын — «Пионерлар — Татарстан варислары» берлеген төзү турында карар кабул ителә, соңрак атамадан «пионер» сүзе төшереп калдырыла. Берлек, эшчәнлегендә бернинди дә идеологик эчтәлеккә юл куймыйча, П.о.ның иң яхшы традицияләрен дәвам итәргә тиеш була. П.о.ның атрибутлары өлешчә саклана: оешма әгъзалары өч төстәге (ТР флагы төсләре) галстуклар бәйлиләр һәм күкрәк билгесе тагалар. Татарстан варислары берлегеннән тыш, ТРда Татарстан укучылары ассоциациясе, ТР балалар һәм үсмерләр федерациясе, Башлангыч журналистлар лигасы, «Бергәлек» («Содружество»), «Татарстан скаутлары» («Скауты Татарстана») һ.б. бар. Респ-ка П.о.ның вакытлы матбугат органнары: «Яшь ленинчы» г-тасы, «Ялкын» ж-лы.

*Әд.:* Соколова Э.С., Тоборко В.А. Всесоюзная пионерская организация имени В.И.Ленина. М., 1963; Носов С.С. Мы — юные ленинцы. К., 1968; Малкин И.И., Носов С.С., Яруллин Ш.Н. Марш пионерии Татарстана. К., 1973; Малкин И.И. Первые галстуки. К., 1984.

*Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова.*

**ПИОНТКО́ВСКИЙ** Андрей Антонович (3.7.1862, Херсон губ. Тирасполь өязе — 25.12.1915, Казан), хокук белгече, җинаять эшләре хокукы д-ры (1900), статский советник (1901). Нәселдән күчмә мактаулы гражданнар катлавыннан. Новороссия ун-тын тәмамлый (Одесса ш., 1885); шунда ук җинаять эшләре хокукы кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 1885–87 елларда, Одесса округы мәхкәмәсенең антлы ышанычлысы ярдәмчесе, 1887–89 да Седлецк округы мәхкәмәсе прокуроры сәркәтибе. 1895–99 да Демидов юридик лицееның (Ярославль ш.) җинаять эшләре хокукы һәм мәхкәмә эшләрен алып бару каф. экстраординар профессоры. 1899 дан Казан ун-тында: җинаять эшләре хокукы һәм мәхкәмә эшләрен алып бару каф. экстраординар (1901 гә кадәр), ординар (1901 дән) профессоры; бер үк вакытта, 1910–11 дә һәм 1913 тән, юридик ф-т деканы. 1908 дән «Учёные записки Императорского Казанского университета» ж-лы мөхәррире. «Юридик позитивизм» тарафдары. П. — Россиядә җинаять эшләре социологиясенә нигез салучыларның берсе. Җинаять срогы турында» («Об уголовной давности», Од., 1891), «Шартлы хөкем итү яки сынау системасы турында: «Җинаяти-сәяси нисбәттәге тикшеренү» («Об условном осуждении или сис-

теме испытания: Уголовно-политическое исследование», Од., 1894) хезмәтләре реаль нигезгә корылган проф. һәм очраклы җинаятьләргә каршы җинаятьчеләр тудырган чын куркынычтан чыгып көрәшү чараларын эшләүгә багышлана. «Европада үлем җәзасы» («Смертная казнь в Европе», 1908) хезмәтендә Европаның аеруча алга киткән илләрендә әлеге җәза чарасын бетерүне яклап чыга. «Җинаять эшләре хокукы фәне: аның предметы, бурычлары, эчтәлеге һәм әһәмияте» («Наука уголовного права: её предмет, задачи, содержание и значение», Ярославль, 1895), «Җинаять эшләре хокукы: Лекцияләргә ярдәмлек. Гомуми бүлек», (чыг. 1–2) («Уголовное право: Пособие к лекциям. Часть общая», вып. 1–2, 1913–16) хезмәтләрендә П. җинаять һәм җәза мәсьәләсен хәл итүнең төрле ысулларына карый.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2; Миролюбов Н.И. Памяти Андрея Антоновича Пионтковского, профессора Казанского университета. К., 1916; Емельянова И.А. Юридический факультет Казанского государственного университета. 1805–1917 годы: Очерки. К., 1998.

*Е.Б.Долгов.*

**ПИОНТКО́ВСКИЙ** Сергей Андреевич (8.10.1891, Одесса ш. — 8.3.1937, Мәскәү), тарихчы, Коммунистик иҗтимагый фәннәр академиясе (1928), Белоруссия ССР ФА мөхбир әгъзасы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1914), профессорлык дәрәҗәсенә әзерләү өчен, рус тарихы кафедрасында калдырыла. 1912 елда студентлар җыенын оештыручыларның берсе, 1913 тә сул партияләр вәкилләрен берләштергән әдәби түгәрәк рәисе. 1917 нең мартыннан РСДРП (меньшевик-интернационалист) әгъзасы. 1917 нең ахырында Казан губернасы Эшче һәм солдат депутатлары советы башкарма ком-ты әгъзасы, губерна хезмәт комис-ты рәисе урынбасары. «Казанская рабочая газета и известия Совета солдатских и рабочих депутатов», «Знамя революции» г-талары редколлегиясе әгъзасы; ш.у. «Рабочее дело» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә. 1918 дә Уфа губернасына дәваланырга китә, аннары елга якын Томск һәм Владивосток шәһәрләрендә яши. Казанга кайткач, РКП(б) әгъзасы була. 1919 ел ахыры — 1920 ел башында РКП(б)ның Казан губерна ком-тында агитация-пропаганда бүлеге мөдире, губпрофсовет президиумы әгъзасы. Бер үк вакытта Халык мәгарифе югары ин-тында, Казан ун-тының эшчеләр ф-тында укыта. Профсоюзларның өченче Бөтенроссия съезды делегаты (1920 нең апреле). 1920 дән Партия һәм Окт. рев-циясе тарихы ин-тында (Истпарт); 1921 дән — Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-ты, 1922 дән — 2 нче Мәскәү ун-ты, 1930 дан Кызыл профессура ин-ты һәм Мәскәү философия, әдәбият һәм тарих ин-ты профессоры; СССР ФА фәнни хезмәткәре. 1921 нең апрелендә Казанга килә, Истпартның җирле бүлеген ачуда ярдәм күрсәтә, соңрак «Казан өчен көрәш» («Борьба за Казань», 1924) җыентыгын чыгаруда катнаша. Хезмәтләре эшчеләр сыйныфы, революцион хәрәкәт һәм Гражданнар сугышы тарихына, историографиягә карый. «Октябрь революциясе тарихы буенча хрестоматия» («Хрестоматия по истории Октябрьской революции», М., 1923; 3 басма, М.–Л., 1926), «Россиядә Гражданнар сугышы (1918–1921 еллар)» («Гражданская война в России (1918–1921 гг.)», М., 1925) хрестоматиясен төзи. Коммунистик академиянең Тарих ин-ты каршындагы пролетариат тарихын өйрәнү секциясе әгъзасы (1929 дан). 1936 ның 7 октябрендә кулга алына, контрреволюцион террорчылык оешмасы эшчәнлегендә катнашуда гаепләнә, атып үтерелә; үлгәннән соң аклана (1956).

Хезм.: Год в царстве Колчака: Материалы по истории рабочего движения в Сибири с июля 1918 до июля 1919. К., 1920; Краткий очерк истории рабочего движения в России (с 1870 г. по 1917 г.). Л., 1925; Октябрь 1917 г. М.–Л., 1927; Буржуазная историческая наука в России. М., 1931; Очерки истории СССР XIX и XX вв. М.–Л., 1935.

*Әд.:* Дубровин В.Ю. С.А.Пионтковский: Исследование жизни и творчества: Дис. ... К., 2002.

**ПИОТРО́ВСКИЙ** Михаил Борисович (9.12.1944, Ереван), шәркыятьче галим, сәнгать белгече, мәдәният эшлеклесе, тарих фән. д-ры (1985), СА академигы (2006; 1996 елдан мөхбир әгъза), РФАнең мөхбир әгъзасы (1997), ТР ФА Тарих ин-тының шәрәфле д-ры (2005). Ленинград ун-тын тәмамлый. 1967–90 да СССР ФА Шәрекъ ин-тының Ленинград ф-лында эшли. 1983–90 да Йәмәндә совет археол. экспедициясенең җитәкчесе. 1990 нан Дәүләт Эрмитажында, 1992 дән директор. П. җитәкчелегендәге Эрмитаж сәнгати һәм фәнни потенциалын саклап кына калмый, Россия мәдәният мәйданында да ролен киңәйтә, дөньякүләм зур музейлар б-н иҗади элемтәләр урнаштыра. 1997 дән Эрмитаж Казанда музей эшләрен үстерүдә зур булышлык күрсәтә. Иң элек Эрмитаж һәм Мәскәүнең төп музейлары экспонатларыннан «Кубрат хан хәзинәләре» (1997), «Алтын Урда хәзинәләре» (2000) күргәзмәләре оештырыла. 2005 тә «Эрмитаж-Казан» үзәге ачыла, анда музейлар практикасында беренче тапкыр Эрмитаж тупланмаларыннан даими эшләүче күргәзмәләр оештырыла. Хезмәтләре Якын Көнчыгыш илләренең борынгы һәм урта гасырлар тарихы проблемаларына, сәнгать тарихына карый. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен», Почёт орденнары, Италия, Нидерланд, Польша, Франция, Швеция, Украина һ.б. илләрнең орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Южная Аравия в раннее средневековье. М., 1985; Йемен до ислама и в первые века хиджры. Бейрут, 1987; Коранические сказания. М., 1991; Земное Искусство — Небесная красота: Искусство ислама. СПб., 2000; О мусульманском искусстве. СПб., 2001.

**«ПИРАМИ́ДА»**, Казандагы мәдәни-күңел ачу комплексы. 2002 елда архитекторлар Г.Ш.Токарева һәм В.С.Токарев проекты буенча (атамасы күләмле планлаштыру чишелешенә туры килә) төзелә. Бинаның биеклеге 30 *м*, комплексның гомуми мәйданы 16000 *м*², 2500 кеше сыйдырышлы. Төп күләм 1200 урынга исәпләнгән үзгәртеп корыла торган тамаша залын, ресторанны үз эченә ала. «П.»ның традицион залы һәм фойесы фәзаи берләшкән. Фойе алты бар-ложага бүленгән, шунда ук сәхнәне тамаша кылырга була. Партерның идәннәре һәм залның беренче ярусы берничә тигезлектә. Стилобатта урнашкан биналарның аерым ишекләре бер. Фасадлар махсус плитәләр һәм тонықландырылган пыяла б-н ябылган. «П.» автоном яшәү шартлары тудыру, климат-тикшерү системалары б-н җиһазланган.

**ПИРГУЛИ́** (Pirguli) Мөхәммәд (1538 — 1573), төрек шагыйре, татарлар арасында киң таралган «Пиргули васыяте» дини-дидактик әсәре авторы. Анда популяр формада *шәригать* кануннары, мөселман дини йолаларын башкару тәртипләре турында язылган. Китап татар теленә тәрҗемә ителгән (авторы билгесез). 1802 елда Казанда басыла, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку ярдәмлеге рәвешендә кулланыла.

**ПИ́РОВ РАЙОНЫ́**, *Красноярск краеның* көнбатышында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 6241 *км*². Үзәге — Пировский авылы (Красноярскидан 265 *км* көнбатыштарак). Халкы — 7244 (2012) кеше, татарлар — 1994 (2010). Районда 18 татар торак пункты исәпләнә. Татарлар, башлыча, Пировский, Икшермә (326 кеше), Ковригa (168), Яңа Тимершек (146), Яңа Троица (76), Солоуха, Кумырык, Шомбаш, Петропавловка, Яңа Ислам, Сатыш, Шәһрислам һ.б. авылларда яшиләр. Аларның П.р. терр-ясенә күченүләре Столыпинның аграр реформасы үткәрелү (1906–11) б-н бәйле. 1930 елларда Петропавловка авылында татар башлангыч мәктәбе эшли, Комаровка, Шомбаш, Солоуха, Яңа Ислам авылларында җидееллык татар мәктәпләре ачыла (1950 ләрдән укыту рус телендә бара). Хәзерге көндә татар теле факультатив дәрес буларак Пировский һәм Икшермә авыллары урта мәктәпләрендә (1990 еллардан) укытыла. П.р. терр-ясендә 3 мәчет (Солоуха, Икшермә, Долгово а.) эшли.

**ПИРОЖЕ́НКО** Александр Фёдорович (18.11.1935, Чиләбе өлкәсенең Копейск ш. — 20.4.1990, Казан), радиоинженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1960 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Матем. машиналар з-дында (Казан) эшли. 1963 тән Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында, әйдәп баручы инженер, сектор (1968–72), бүлек (1972–82), бүлекчә (1982 дән) башлыгы. Дәүләт бүләге радиолокация өлкәсендәге хезмәтләре өчен бирелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә. «СССРның мактаулы радисты» билгесенә ия.

**ПИРОТЕ́ХНИКА** (грек. pýr — ут һәм téchnē — сәнгать, осталык), пиротехник составларның (ПС) үзлекләрен, аларның эшләнмәләрен, җитештерү һәм кору технологияләрен өйрәнә торган фән һәм техника тармагы. ПС — мөстәкыйль януга сәләтле, яктылык, җылылык, төтен, тавыш һәм реактив эффектлар бирә торган гетероген катнашмалар, хәрби техникада, фәндә һәм халык хуҗалыгында кулланылалар. Күпчелек ПС һәм ягулыкларның нигезен ачыткыч (оксидлаштыргыч) һәм янучан матдә катнашмасы тәш-

кил итә. Күп составларда янучан матдә оксидлаштыргыч кислород хисабына өлешчә генә яна, тулы яну һава яки су кислороды хисабына бара. Югары темп-ралы ПСларда янучан матдә сыйфатында — магний, алюминий (сирәгрәк титан һәм цирконий), аларның эретмәләре, аэрозоль ясаучы ПСларда, башлыча, органик матдәләр файдаланыла. Оксидлаштыргыч булып күбесенчә кайбер кислородлы к-таларның тозлары (нитрат, хлорат, перхлоратлар), металл оксидлары ($Fe_2O_3$, $Fe_3O_4$, $Pb_2O_3$) һәм диоксидлары ($BaO_2$, $MnO_2$) хезмәт итә. Янучан матдә һәм оксидлаштыргычтан тыш, ПСка махсус матдәләр (буяулар — төсле төтен алу өчен, пестицидлар — үсемлек корткычлары һәм авырулары б-н көрәш өчен, реагентлар — артык суынган болытларга, томанга тәэсир итү өчен һ.б.) һәм өстәмәләр (бәйләүче, тотрыкландыручы, акрынайтучы һ.б.) кертелә. Пиротехник эффект катнашмаларның табигатенә һәм асылына, кисәкчәләрнең үлчәменә, катнашу сыйфатына, тыгызлау дәрәҗәсенә генә түгел, пироэлементларның формасы һәм үлчәмнәренә, эшләнмәнең конструкциясенә һ.б.га да бәйле. Кабызып җибәрү төтенле дары, ут үткәрү (бикфорд) шнуры яки махсус кабызу составлары ярдәмендә башкарыла. Хәрби максатларда яктырту, сигнал бирү, яктыртып очу, кабызу, җылылык тудыру, аэрозоль ясау, газ генерацияләү, инфракызыл нурланыш бирү ПСлары, фотокатнашмалар, пироавтоматика чаралары һәм пиротехник ток чыганаклары өчен составлар, ш.у. реактив-һава, туры төбәлүле һәм гидрореактив ракета двигательләре өчен ягулык составлары кулланыла. ПС кино төшерү, торбалар, рельслар, электр үткәргечләрне эретеп ябыштыру, лазерларны тутыру, түбән темп-ралы плазма тудыру, ябык урыннарда янгын сүндерү, нефть һәм газ конденсатлы скважиналарны тернәкләндерү, тавыш һәм яктылык сигналлары җибәрү, атмосфераның югары катлауларын тикшерү, шырпылар, фейерверклар ясау, а.х. культуралары корткычлары һәм авырулары б-н көрәшү, яшелчә саклау урыннарын, теплицаларны, терлек һәм кош комплексларын дезинфекцияләү, боз сугуларны булдырмый калу эшләрендә һ.б. кулланылыш таба.

Әле бик борынгы заманнарда ук утны җылылык һәм яктылык чыганагы итеп кенә түгел, сугышлар вакытында сигнал чарасы буларак та кулланганнар. Кара дары Россиядә 15 йөздә җитештерелә башлый. П. хәрби максатларда да, күңел ачу максатларында да кулланыла.

20 йөзнең 1 нче яртысыннан хәрби техниканың үсеше дары, шартлаучан матдәләр һәм ПС җитештерүнең фәнни нигезләре формалашуга, аларның мөстәкыйль тармакка әверелүенә ярдәм итә. Оборона максатлары өчен ПС һәм чаралар уйлап табу һәм җитештерүгә аеруча игътибар бирелә, фәнни-тикшеренү ин-тлары, заводларда махсус конструкторлык-технол. бюролары, белгечләр әзерләү өчен кафедралар һәм факультетлар ачыла. Бөек Ватан сугышы алдыннан зур күләмдә югары нәтиҗәле пиротехник составлар һәм чаралар эшләнгән була. Совет гаскәрләренең җиңү салютында яктырту һәм сигнал составлары, ш.у. соңрак эшләнгән фейерверк составлары һәм эшләнмәләре кулланыла. Тора-бара П.ның даирәсе киңәя: янган вакытта яктылык, төс, җылылык, тавыш, төтен эффектларын бирә, ш.у. газсыман яисә куертылган продуктлар хасил итә торган максатчан составлар булдырыла. Хәрби максатлар өчен югары нәтиҗәле яктырту, фотояктырту, эз калдыру, төнге һәм көндезге сигналлар бирү, имитация-өйрәтү, төбәү ноктасын күрсәтү, ш.и. маскировка төтеннәре, пироавтоматика составлары эшләнә. Фейерверк, сигнал, термитлы, аэрозоль ясый торган, ш.у. халык хуҗалыгы өчен башка составлар һәм эшләнмәләр булдыруда мөһим уңышларга ирешелә (1990 елларда Россия сәнәгате 500 гә якын исемдәге эшләнмә чыгара).

1786–88 дә Казанда төтенле дары чыгару пр-тиесе төзелә (к. *Казан дары заводы*), 1892 дә Бондюг химия з-дында төтенсез дарының беренче партиясе эшләп чыгарыла (к. *Менделеев* Д.И.). Татарстанда П.ның фән буларак үсеш алуы 1952 дә Казан химия-технол. ин-тында гетероген системалар химиясе һәм технологиясе каф. ачылу б-н бәйле; төп фәнни юнәлешләре: ПСны кабызып җибәрү, яндыру, аэрозоль хасил иттерү һәм ялкын нурландырту; ПС һәм каты пиротехник ягулык компонентларын модификацияләү; төрле кулланылыштагы яңа ПС уйлап табу, аларны әзерләү һәм эшкәртү технологияләре. Периодик нурланыш бирә торган ПС һәм ягулыкларның януы өйрәнелә, фейерверк эшләнмәләрендә кулланыла торган (1967 дән) җемелдәү эффекты бирүче төсле ут составлары булдырыла. Эластомерлар пресслау алымы б-н озын үлчәнешле, югары физик-химик тотрыклылыкка һәм махсус эффектка ия эшләнмәләр ясала. Пластизоль нигезендәге (порошоксыман югары молекуляр матдә һәм парга әйләнми торган диярлек пластификатор) ПС һәм ягулыклар да шушы алым б-н табыла; аларга төсле утлар составлары, пироксилин һәм баллистит дарылар (пиродары составлары) җитештерү технологиясенә яраклаштырылган, целлюлоза нитратлары нигезендә очкынлы-ялкынлы һәм аэрозоль хасил итүче ПС керә. Төсле утларның ПСлары — аз төтенләүләре һәм матур манзара тудырулары, ә аэрозоль хасил итүче ПСлар — югары нәтиҗәлелек б-н аерылып тора. Мәскәүдә Олимпия уеннарында (1980) күрсәтелгән җиде төсле «Ромашка» эшләнмәсе «Олимпиада-80» оештыру ком-тының 8 дипломы б-н бүләкләнә. Үтильләштерелгән дарылар һәм баллистит типтагы ягулыклар, вакланган һәм вак бөртекле пироксилин дарылар нигезендә пиродары составлары, ш.у. алдан бирелгән нурланыш ясаучы, пульсацияле һәм аз газлы составлар эшләнә. П. фәненә М.М.*Арш*, Ф.П.*Мадякин* зур өлеш кертә. Кафедра галимнәренең хезмәтләре уйлап табуга 300 авторлык таныклыгы һәм 11 патент б-н яклана, илнең төрле заводларында гамәлгә кертелә, СССРның Дәүләт бүләге (1975, 1989), Ленин комсомолы бүләге (1983) б-н билгеләп үтелә.

*Әд.:* Варёных Н.М. К 60-летию создания НИИ прикладной химии: современное состояние, основные проблемы и перспективы развития пиротехники в России // Изв. Рос. академии ракетных и артиллерийских наук. 2005. Вып. 3.

*Ф.П.Мадякин.*

**ПИРХ** Альберт (Альфер) Карлович (1791, С.-Петербург — 1853 елдан соң), барон, генерал-майор (1823). Беренче кадетлар корпусын тәмамлый (С.-Петербург, 1807). 1807 елдан хәрби хезмәттә. 1812 елгы Ватан сугышында, рус гаскәрләренең чит илләргә 1813–14 тәге яуларында катнаша. 1830–31 дә Казан гражданнар губернаторы. Отставкага чыкканнан соң, Казан губернасының Спас өязендәге Кызыл Бистә авылындагы утарында яши, анда ул үрнәк хуҗалык төзи. П. эшчәнлеге 1843 тә немец икътисадчысы А.Гакстгаузен тарафыннан югары бәяләнә. Казан икътисадчылар җәмгыятенең 1 нче бүлеге рәисе була (1853 тән).

*Әд.:* Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ПИ́САРЕВ** Владимир Иванович (5.9.1890, Тамбов губ., Усман өязе Излегощи а. — 1960 еллар уртасы, Пенза ш.), тарихчы, тарих фән. канд. (1938), проф. (1946). 1915 елда рус Варшава ун-тын (соңрак Дон, Төньяк Кавказ ун-тлары) тәмамлый һәм югары уку йорты б-н бергә Ростов-Дон шәһәренә күчерелә. 1930 дан Ростов пед. ин-тында. 1933–48 дә Куйбышев пед. ин-тында, СССР тарихы каф. мөдире, тарих ф-ты деканы. 1948–58 дә Казан ун-тында СССР тарихы каф. мөдире. Аннан соң Пенза пед. ин-тында эшли. Хезмәтләре крепостной хокук, Идел буендагы Окт. рев-циясе вакыйгалары тарихларына карый.

Хезм.: Ликвидация крепостного права в Приазовье 1857–1863 гг. Ростов н/Д.-М., 1924; Церковь и крепостное право в России. М., 1931; Борьба за Советскую власть в Самарской губернии. Куйбышев, 1957 (автордаш).

*Әд.:* Профессора исторического факультета Казанского уиверситета (1939–1999). К., 1999.

**ПИ́САРЕВ** Леонид Иванович (4.6.1865, Түбән Новгород губ., Түбән Новгород өязе Высокое а. — ?), христиан теологы, җәмәгать эшлеклесе, теология магистры (1894), чиркәү тарихы д-ры (1915), проф. (1899). 1890 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, шунда кала, патрология кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 1904–06 да «Православный собеседник» ж-лы мөхәррире була. 1905–07 дә, Казан руханилар академиясенең либераль рухлы профессорлар төркеме б-н бергә, «Церковно-общественная жизнь» атналык ж-лын чыгара, мөхәррирләренең берсе була. Журналда дәүләттәге һәм Рус православие чиркәвендәге уртачыл карашлы либераль-демократик реформаларны сәяси пропагандалану сәбәпле эзәрлекләүләргә дучар ителә. 1917–18 дә Рус православие чиркәвенең Поместный соборы делегаты. 1907–17 дә Казан шәһәр думасы гласные. 1918 нең сентябрендә Ак армия гаскәрләре б-н бергә Казаннан китә; аннан соңгы язмышы билгесез. Хезмәтләре патрология (теологиянең Хрис-

тиан чиркәве Аталарының хезмәтләрен өйрәнүче бүлек) өлкәсенә карый.

Х е з м.: Учение Блаженного Августина, Епископа Иппонского о человеке и его отношения к Богу. К., 1895; Очерки из истории христианского вероучения патристического периода. Т. 1. Век мужей апостольских (I и начало II века). К., 1915.

*Әд.:* Х а б и б у л л и н М.З. Михаил Александрович Машанов — профессор Казанской духовной академии, миссионер и исламовед. К., 2006.

*Е.В.Липаков.*

**ПИ́САРЕВА** Стелла Владимировна (28.2.1925, Киев), музей эшлеклесе, ТАССРның атказ.мәдәният хезмәткәре (1975). 1946 елда Казан ун-тын тәмамлагач, Казанда А.М.Горький Әдәби-мемориаль музеенда эшли, 1950 дән директор урынбасары. 1964–78 дә ТАССР Дәүләт музеенда әдәби бүлек мөдире, директор урынбасары. 1978 дән Казан ун-ты тарихы музее директоры. Бөгелмә шәһәрендә Я.Гашек (1966), Козловка шәһәрендә Н.И.Лобачевский (Чуаш Респ-касы, 1994), Казан ун-ты тарихы (1979) музейларын оештыручы һәм экспозицияләр авторы. «Лев Толстой һәм Казан» («Лев Толстой и Казань», 2001), «Н.И.Лобачевский» (2003), «В.М.Бехтеревның туума 150 ел» («В.М.Бехтерев. К 150-летию со дня рождения», 2007) һ.б. буклетларның төзүче-авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пьесы Горького на сцене Казанского драмтеатра в период революционного подъёма и первой русской революции // Горький в Татарии. К., 1961; Векслин Носон-Бер Залманович // Возвращённые имена. К., 1990.

*Әд.:* К о р о л ё в В. Центр притяжения // Казань. 2000. № 1.

**ПИСКАРЁВ** Владимир Иванович (24.12.1949, Смоленск өлкәсенең Гжатск ш.), педагог, тарихчы, тарих фән. канд. (1983), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987), РФнең мактаулы гомуми белем бирү хезмәткәре (2007). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Коммунист Татарии» ж-лы редакциясендә, 1979 елдан партия тормышы бүлеге мөдире, 1985 тән баш мөхәррир урынбасары. 1995 тән ТР Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан әзерләү ин-тында (2005 тән ТР Мәгарифне үстерү ин-ты): 1995–97 дә социаль-икътисад фән. каф. мөдире, 2002 дән тарих һәм иҗтимагый фән. кафедрасында, 2008 тән тарих һәм иҗтимагый фән. каф. мөдире. 2011 дән Мәгариф өлкәсендә перспективалы хезмәтләр үзәге директоры. Фән һәм инновация эшчәнлеге буенча проректор. Мәктәп укучылары өчен Татарстан тарихы буенча уку ярдәмлекләре, укытучылар өчен «Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре: Россия халыкларының дини мәдәнияте нигезләре» («Основы духовно-нравственной культуры народов России: основы религиозных культур народов России», М., 2012) дәреслеге, «Гасырлар авазы = Эхо веков» ж-лы редколлегиясе әгъзасы (ТР Дәүләт бүләге лауреаты, 2011). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПИСКО́РСКИЙ** Владимир Константинович (29.7.1867, Одесса ш. — 3.8.1910, Казан), тарихчы, тарих д-ры (1902). Россиядә Испанияне өйрәнүне нигезләүчеләрдән. Киев ун-тын тәмамлый (1890), шул ук ун-тның приват-доценты. 1896 елда Испания, Франция, Англия, Германиягә ике елга фәнни командировкага җибәрелә. Анда ул магистрлык һәм докторлык диссертациясе өчен шактый мәгълүмат туплый. 1899–1905 тә Нежин тарих-филол. ин-тында экстраординар, ординар проф. 1905 тә конституцион строй һәм акад. бәйсезлек урнаштыруны яклап чыккан Югары уку йортлары эшлеклеләре акад. берлеге эшчәнлегендә катнаша. П. Нежинда Берлекнең бердәнбер әгъзасы һәм аның Икенче бөтенроссия съезды делегаты. 1905 елгы вакыйгалардан соң Нежиннан китәргә мәҗбүр була. 1906 дан Казан ун-тының гомуми тарих каф. ординар профессоры. Казанда Югары хатын-кызлар курсларын оештыруда катнаша. Испания Король сәнгать академиясе мөхбир әгъзасы (1901, Барселона ш.). Төп хезмәтләре Испаниянең урта гасырлар тарихына карый.

Х е з м.: Кастильские кортесы в переходную эпоху от средних веков к новому времени (1188–1520 гг.). Киев, 1897; Крепостное право в Каталонии в средние века. Киев, 1901; История Испании и Португалии. СПб., 1902.

*Әд.:* Х а н и н а А.З. В.К.Пискорский (к столетию со дня рождения) // Вопр. историографии всеобщей истории. К., 1968. Вып. 3; М и л ь с к а я Л.Т., П и ч у г и н а И.С. Русский историк-испанист — В.К.Пискорский (1867–1910 гг.) // Проблемы испанской истории. М., 1975.

**ПИСКУНО́В** Василий Григорьевич (28.2.1919, Вятка губ., Алабуга өязе Тихие Горы а. — 16.11.1994, Әстерхан ш.), Сов. Союзы Герое (13.4.1944), капитан. Очучыларның Энгельс хәрби авиация мәктәбен (1941), Югары офицерлар авиация мәктәбен (1946) тәмамлый. Колхозда, Дзержинск шәһәрендә заводта (Түбән Новгород өлкәсе) эшли. Воронеж шәһәрендә хәрби һава частенда инструктор булып хезмәт итә. 1940 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең мартыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 232 нче штурм авиациясе полкында эскадрилья командиры урынбасары (8 нче һава армиясенең 289 нчы штурм авиация дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Көньяк һәм 4 нче Украина фронтлары составында Полтава, Купянск һәм Валуйки-Россошь юнәлешләрендәге оборона сугышларында (1942), Сталинград сугышында (1942–43), Донбасс, Мелитополь (икесе дә — 1943), Кырым һәм Львов-Сандомир (икесе дә — 1944) операцияләрендә катнаша. Дошманның авиация көчләренә каршы һава сугышында батырлык күрсәтә. 1943 нең ноябренә П. 96 сугышчан очыш ясый. 1945 нең гыйнварында авыр яраланганнан соң, сугышчан юлын тәгәлли. 1946 дан запаста. Сугыштан соң гражданнар авиациясенә күчә һәм Баку-Мәскәү трассасында оча башлый. Түбән Идел совнархозының Әстерхан судноләр төзү з-дында эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*



В.Г.Пискунов.

**ПИСМӘ́Н** елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы, 9,7 *км*, бассейнының мәйданы 46,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Бөгелмә р-ны Солдат Писмәнкәсе (Паны) авылы чигендә, тамагы Лениногорск р-ны Иске Писмән авылында. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 159 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. П.нең 1 һәм 4,1 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,32 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елга җәйге чорда еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 81 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,03 *м³/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан артык. П. бассейнында суның күләме 4 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ПИСЦО́ВЫЙ КЕНӘГӘЛӘ́Р** (Халык санын исәпкә алу кенәгәләре), 1) 15–17 йөзләрдә Россиядә системалы рәвештә уздырылган гомуми җир үлчәү, межалау эшләрен һәм халыкның түләү мөмкинлекләрен исәпкә алуны әзерләү, оештыру һәм гамәлгә ашыру чорында төзелә торган канцелярия эшләрен алып баруга кагылышлы «писцовый» документларның зур комплексы. «П.к.» термины б-н кыр кенәгәләре («тасвирламалар һәм үлчәүләр»), аерым кенәгәләр (йомышлы кешеләрне күчереп утырту язмалары), дозор кенәгәләре («тасвирламалар һәм дозорлар»), исәпкә алу-межалау кенәгәләре («тасвирламалар һәм межалаулар»), махсус межа кенәгәләре, элгәрерәк төзелгән исәпкә алу, дозор һәм аерым кенәгәләр буенча «өстәмә исемлекләр», затларның, биләмәләрнең исемлекләре һәм теркәү язмалары, кайчак утарларны исәпкә алу һәм теркәү язулары һ.б.ш. билгеләнә; 2) шәһәрләр һәм өязләрнең хуҗалык тасвирламаларын исәпкә алу буенча җыелма материаллар. Кагыйдә буларак, алар башында дворяннар арасыннан сайланган җитәкче торган, штатында подъячийлар, кайчак дьяк булган Утарлар приказы билгеләгән затлар тарафыннан уздырыла. П.к. нотариаль асылда була, вотчина хуҗалары һәм алпавытларның җир һәм крәстияннәр биләвенә хокукларын исәпкә алалар, җир биләүдәге үзгәреш-

ләрне теркиләр һәм халык түләргә тиешле дәүләт салымнарының нигезен тәшкил итәләр. Язмалар хуҗалар яки торак пунктлар буенча, яисә ике принципны да истә тотып алып барыла; феодаль җирбиләүчеләрнең вотчина һәм утарларга хокукын тикшерүгә, җирне үлчәүгә, вотчина һәм утар хуҗаларының үз күрсәтмәләренә, халыктан сораштыруга нигезләнә. Тасвирламаны төзү рәвеше теркәүчеләргә куелган күрсәтмәдә чагылыш тапкан кадастр максатыннан чыгып билгеләнә, биләмәнең состав өлешләренә, теркәлә торган мәгълүматларның күләменә, ныгып урнашкан традицияләргә карап, аңа төзәтмәләр кертелә. П.к. төзү берничә этаптан тора: башта «кыр тасвирламалары» языла, алар нигезендә каралама П.к., аннары П.к.нең чиста язмалары барлыкка килә, язулар төгәлләнгәч, тасвирлама бербөтен хәлгә китерелә. П.к. күп максатларда файдаланыла, тасвирлана торган терр-ясенең социаль-икътисади торышын чагылдыра, географик, демографик, генеалогик, ономастик лингвистик һ.б. өлкәләргә караган мәгълүматларны үз эченә ала. Казан төбәгенә теркәүчеләр фәкать *Казан сарай идарәханәсе* тарафыннан җибәрелә. 16 йөзнең 2 нче яртысы — 17 йөзләр Казан төбәге буенча безнең көннәргә кадәр килеп җиткән исәпкә алу материалларының саны 15 берәмлектән артмый, күп өлеше 18 йөз күчермәләре рәвешендә сакланып калган. Җир турындагы бәхәсләрне хәл иткәндә (Генераль межалауга кадәр) түбәндәге кеңгәләрдәге теркәү-исәпкә алу язмалары иң абруйлы булып саналган: өязләре б-н Казан һәм Зөя шәһәрләре (теркәүчеләр — окольничий Н.В.Борисов-Бороздин һәм «иптәшләре белән» Д.А.Кикин (1565–68)), Казан өязе (теркәүчеләр — И.Болтин (1602/03 һәм «иптәшләре белән» С.Волынский (1647–56), Зөя өязе (теркәүчеләр — Ф.Аристов (1602/03) һәм «иптәшләре белән» И.М.Аничков (1646–52)).

Чыг.: Писцовая книга Казанского уезда 1602–1603 годов. К., 1978; Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов. М., 2001; Перечневая книга Свияжского уезда: По материалам писцового описания 1646–1652 годов. К., 2004; Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565–1568 годов. К., 2006.

*Әд.:* Веселовский С.Б. Сошное письмо: Исследование по истории кадастра и посошного обложения Московского государства: В 2 т. М., 1915–16; Мерзон А.Ц. Писцовые и переписные книги XV–XVII вв. М., 1956; Павлов-Сильванский В.Б. Писцовые книги России XVI в.: Проблемы источниковедения и реконструкции текстов. М., 1991.

*Д.Г.Мостафина.*

**ПИТИА́Л** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Илләт елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 52,1 *км*, ТР чикләрендә якынча 30 *км*. Бассейнының мәйданы 361,6 *км*$^2$. Вятка Увалының көньяк чигеннән ага. Елга башы урман массивында, Биектау р-ны Чуаш Иле авылыннан 2,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, елганың урта агымы — Яшел Үзән р-нында, тамагы — Мари Респ-касында, «Мари Чодра» милли паркы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 69 *м*. П.ның су җыелу мәйданында рельефның карст формалары киң таралган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. П.ның 0,7 дән 11,6 *км* га кадәр озынлыктагы 30 кушылдыгы бар (нигездә, уң кушылдыклар). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,56 *км/км*$^2$. Туенуы катнаш, кар сулары б-н туену модуле П. бассейнының төрле өлешләрендә 1 дән 10 *л/с·км*$^2$ га кадәр. П. үзәнендә басымлы җир асты су чыгышлары бар. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәйге чорда, яңгырлар озак яумый торганда, елганың аерым участоклары кибә һәм елга юлы плёслы күләр чылбырына таркала. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. П. бассейнында суның гомуми күләме 3,25 млн. *м*$^3$ булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. П. үзәне сөзәкләрендә ТРның табигать истәлекләре: «Кишәнгер», «Никольский» һәм «Фәхри Яры» ерым-сыза системалары урнашкан.

**ПИТРӘ́Ч** авылы, Питрәч р-ны үзәге. ТРның төньяк-көнбатыш өлешендә, Казан тимер юл станциясеннән 45 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда урнашкан. 2010 елда 8102 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54%, татарлар — 42%) яши. Сөт з-ды, икмәк комб-ты, «Питрәч керамикасы» ҖЧҖ, «Питрәч биофабрикасы» фәнни-производство берләшмәсе, «Питрәч төзелеш сервисы» АҖ, 2 урта мәктәп, коррекция мәктәп-бакчасы, сәнгать мәктәбе, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе. Мәдәният йорты, балалар иҗат йорты, төбәк тарихы музее, район үзәк һәм балалар китапханәсе, хастаханә, «Батыр» мәдәни-спорт комплексы. Мәчет, чиркәү. 1565–67 дән патша сараена караган Зур Питрәч авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский буларак та мәгълүм. 1590 елларда Казан Троица-Сергий монастыре карамагына бирелә. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлек үрчетү, умартачылык, он тарту, кирпеч сугу, тире иләү, тимерчелек, агач эшләре, май язу, паркет ясау һ.б. эшләр б-н шөгыльләнә. 19 йөздә — 20 йөз башында җирле чүлмәкчеләрнең эшләнмәләре (нәфис бизәкле савыт-саба, тышлау өчен плиткалар, панель, балчык торбалар, түбә чирәбе һ.б.) киң танылу ала. Питрәч керәче Казан, Мәскәү, С.-Петербург, Әстерхан һ.б. шәһәр ярминкәләрендә сатыла. 20 йөз башында П.тә Никольский чиркәве (1811 дә төзелә), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), фельдшерлык пункты, вак кредит учреждениесе, паркет ф-касы, су тегермәне, тимерчелек, 1 казна шәраб һәм 15 вак-төякләр кибете, 2 сыраханә була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 4135,5 дис. тәшкил итә. 1911 дә *Питрәч һөнәр-сәнгать остаханәсе* ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында (1924 тән Питрәч волосте үзәге). 1930 ның 10 августыннан — Питрәч р-нының адм. үзәге. Халык саны: 1782 дә — 381 ир-ат; 1859 да — 1660, 1897 дә — 2188, 1908 дә — 2276, 1920 дә — 2410, 1926 да — 2007, 1949 да — 2455, 1958 дә — 2431, 1970 тә — 3341, 1979 да — 4588, 1989 да — 6086, 2002 дә — 7297 кеше.

**ПИТРӘ́Ч РАЙОНЫ́**, ТРның төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Казан икътисади р-нына керә. Мәйданы — 1361 *км*$^2$. 21 авыл җирлеген, 73 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — Питрәч авылы. Халкы — 29,2 мең кеше (2010). 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,2%, руслар — 40,5%. Халыкның урнашу тыгызлыгы — 1 *км*$^2$ га 21,5 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан һәм Лаеш өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Арча һәм Лаеш кантоннарында, 1927 дән ТАССРның *Балык Бистәсе р-нында* һәм Арча кантонында.







Питрәч авылы. 1. Район хакимияте бинасы. 2. Бала тудыру йорты. 3. Мәдәният йорты.




Оештырылган көннән П.р.на 60 авыл советы, 119 торак пункт керә, аларда 57467 кеше (руслар — 40123, татарлар — 17344 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше бернигә тапкыр үзгәрә. 1935 тә терр-ясенең бер өлеше яңа оештырылган Биектау һәм Теләче р-ннарына бирелә. 1940 та мәйданы — 1038 *км²*, халкы — 35 мең кеше; 30 авыл советы, 87 торак пункт була. 1959 ның 12 октябрендә районга таркатылган Теләче р-нының бер өлеше кушыла. 1960 та П.р. 1265,4 *км²* җир били, аңа 12 авыл советы, 107 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССР-да адм. берәмлекләр эреләндерелү сәбәпле, П. р-нына Лаеш р-ны, Биектау һәм Балык Бистәсе р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 5147 *км²*, халкы — 103,3 мең кеше; 58 авыл советы, 326 торак пункт исәпләнә. Лаеш, Биектау, Балык Бистәсе р-ннары кабат торгызылгач (12.1.1965), П.р. терр-ясе 1352 *км²* га кадәр кими, халкы — 37,9 мең; 14 авыл советы, 105 торак пункт кала.

П.р. рельефы — елга үзәннәре һәм чокырлары б-н ергаланган бераз калкулыклы тигезлек (уртача биеклеге — 150 *м*). Мишә елгасы һәм кушылдыклары Сула, Норма, Нырсы сулары ага. Җирләре аксыл-соры, кәсле-көлсу һәм соры урман туфраклы. Терр-ясенең 11% ы — урманлык. Известьташ, доломит, балчык, гипс, вак таш, ком, торф ятмалары бар. Саклаулы табигать терр-яләре: Мишә, Әшнәк елгалары; *Ленино-Кокушкино табигый-тарихи тыюлыгы*, *«Иске тегермән»* табигать тыюлыгы. Район терр-ясендә 50 гә якын археол. истәлек (бронза гасырдан Казан ханлыгы чорына кадәр) табыла; Тау Иле һәм Янсуар авыллары янында 14–16 йөзләр эпиграфик истәлекләре сакланган. П.р.да а.х. тармагы алга киткән. А.х. җирләре 93,4 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр 78 мең *га* тәшкил итә (2010). Сабан бодае, арыш, арпа, солы игелә; бәрәңге үстерелә. Мөгезле эре терлек, ат асрала, җәнлек, кош-корт үрчетелә. 2012 дә районда 26 а.х. пр-тиесе, ш.и. «Ак Барс-Питрәч», «Үшнә» балык хуҗалыгы агрофирмалары исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре: «Пресс» ҖЧҖ, «Питрәчстрой» АҖ, «Тәмле» ҖЧҖ, «Питрәч керамикасы» ҖЧҖ, «Таттрансгаз» ҖЧҖ. Вак таш, известьташ чыгарыла. П.р. терр-ясеннән Казан-Уфа, Казан-Теләче автомобиль юллары уза. Районда 23 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 2 башлангыч, 4 тулы булмаган урта, 17 урта мәктәп эшли; сәнгать, коррекция интернат-мәктәбе, һөнәр лицее, 13 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 13 клуб, 30 китапханә, 4 амбулатория һәм 1 хастаханә бар. Питрәч һәм Керәшен Сәрдәсе авылларында төбәк тарихы музее, Ленино-Кокушкинода Ленин В.И. музей-йорты, Шәледә музей эшли. Татар һәм рус телендә «Алга» («Вперёд») р-н г-тасы нәшер ителә.

**ПИТРӘ́Ч ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́**, Питрәч авылында, ТР Милли музее ф-лы. 1988 елда ачыла. 1914 тә төзелгән элекке земство мәктәбе бинасында урнашкан. Экспозиция мәйданы — 386 *м²*, музей каршындагы парк зонасы — 0,5 *га*. Коллекция 12 меңнән артык саклау берәмлегеннән тора. Экспозиция өч залда урнашкан. «Төбәк халыкларының мәдәнияте һәм көнкүреше» дигән беренче залда 19 йөздәге татар, рус өйләре интерьеры фрагментлары; дворян һәм сәүдәгәрләр көнкүреше әйберләре, 19 йөз — 21 йөз башы төбәк тарихы фоторәсемнәре һәм документлары күргәзмәгә куела. «Хәтер» дигән экспозициянең икенче залында 20 йөздә төбәк тарихы, күмәкләштерү чорындагы а.х. әйберләре, төбәктә туып үскән 1 нче бөтендөнья, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнашучыларның документлары һәм фоторәсемнәре урнашкан. Экспозиция фрагментларының берсе Брест крепосте каһарманы П.М.*Гавриловка* багышлана. Шулай ук күргәзмәгә Әфганстан һәм Чечен сугышларында катнашучылар турындагы материаллар да куела. «Халык һөнәрләре» дигән өченче экспозиция залы Питрәчтә керәч җитештерү тарихы, шәхси чүлмәкчеләр һәм *Питрәч һөнәр-сәнгать остаханәләре* турында сөйли. Шулай ук агачтан кисеп ясалган вак һөнәрчелек әйберләре, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы җирле тимерчелек кәсебе әйберләре тәкъдим ителгән. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — Питрәч керәче коллекцияләре, самавырлар, нумизматик коллекцияләр, совет дәүләте һәм Россия орденнары бар.

Ел саен Халыкара музейлар (18 май), Ачык ишекләр (1 сент.) көннәре үткәрелә.

Директоры — Е.Ф.Корябина.

**ПИТРӘ́Ч ҺӨНӘ́Р-СӘНГА́ТЬ ОСТАХАНӘСЕ́**, чүлмәк ясау һөнәрчелегенә әзерләүче уку йорты, Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгының сәнгать учреждениеләре турында 1902 елның 12 июнь Нигезләмәсенә туры китереп, 1912 нең 16 гыйнварында ачыла. Казан губернасының земство идарәсе тарафыннан оештырылган химаячеләр ком-ты карамагында була (рәисе — А.Н.*Боратынский*, әгъзалары — Н.С.Теренин, А.А.Мельников, крәстиян В.А.Перухин). Казан губернасының чүлмәк ясау вак һөнәрчелек кәсепчелегенең борынгы үзәгендә оештырыла. Остаханәнең эшчәнлеге җирле чүлмәк ясаучыларның сәнгать белеме дәрәҗәсен күтәрүгә, керәч өлкәсендә техник осталыкларын яңарту һәм камилләштерүгә булышлык итүдән гыйбарәт була. 20 йөз башында Питрәчтә савыт-саба һәм чирәп әйберләр җитештерүче зур булмаган 80 гә якын з-д эшли. Остаханәнең төзелүенә земство вәкиле үтенече буенча Петербургтагы барон Штиглицның техник рәсемгә төшерү уч-щесендә, проф. К.И.Келлер җитәкчелегендәге керәч бүлегенең техник лаб-ясендә җирле үзле балчыкның сыйфатын тикшерү сәбәп була. Остаханәнең мөдире әлеге уч-щене тәмамлаган рәссам А.И.Ильинский була, ул рәсем, сызым, технологиядән укыта. Бирedә ш.у. Е.В.Ильинская (акварель, композиция, әвәләп ясау, декор), Т.Бирх (гипсны формага салу һәм токарьлык эше) укыта. Өчьеллык уку курсларына гомуми сәнгать белемен һәм чүлмәк ясау һөнәре техникасын үзләштерү керә. Уч-щега 12 яшьтән алып 20 яшькә кадәрге үсмерләр кабул ителә. Остаханәне тәмамлаучы укучыларга — оста ярдәмчесе (өйрәнчек), 3 елдан соң, мөстәкыйль эше турында хисап биргән очракта, оста дәрәҗәсе бирелә.

Остаханә үзләштергән әйберләр ассортименты гаять тә күптөрле: вазалар, кувшиннар, тәлинкәләр, тәмәке көллекләре, юыну әсбаплары, каминнар, бизәкле паннолар, кәрниз һәм дивар тышлау плитәләре. Уку йортын







1. Питрәч төбәк тарихы музее; 2. Экспозиция фрагменты: татар өе интерьеры; 3. Чүлмәк ясау һөнәрчелеге экспозициясе.

тәмамлаганнарның эшләреннән, соңыннан сату шарты б-н, Казанда күргәзмәләр оештырыла, мәс., 1916–17 елларда үткәрелгән күргәзмәдә 3284 әйбер куела. 2 нче Бөтенроссия вак һөнәрчелек-сәнәгать күргәзмәсендә (Петербург, 1913–14) остаханә бронза медаль б-н бүләкләнә. Беренче бөтендөнья сугышы башлану б-н, остаханәнең укыту эшчәнлеге туктатыла, Гражданнар сугышыннан соң, П.һ.-с.о. ябыла. 1924 тә остаханә җиһазлары Казанга күчерелә, 1926 да Б.Урманче, сәнгать-театр техникумының уку-укыту бүлеге мөдире буларак, шулар нигезендә керәч остаханәсе оештыра (к. *Керәч сәнгате*).


Остаханә әйберләре Казан губерна земствосының вак сәнәгать һәм һөнәри белем үзәк музее тупланмасында була; хәзерге вакытта ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Питрәчтәге төбәк тарихы музеенда саклананалар. Ш.у.к. *Питрәч чүлмәк ясау кәсепчелеге*.

*Әд.:* Ключевская Е.П. Искусство народное и профессиональное: К проблеме взаимодействия в художественной культуре Поволжья XIX–XX вв. // Из истории татарского народного искусства: Сб. статей. К., 1995; Урманче Б. Татарские художники и Казанская школа искусств // Татарстан. 1996. № 4.

*Е.П.Ключевская.*

**ПИТРӘ́Ч ЧҮЛМӘ́К ЯСА́У КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́**, керәч әйберләр җитештерүче халык нәфис кәсепчелеге. 16 йөз ахырында Ярославль, Суздаль, Новгород җирләреннән күчеп килгән руслар төпләнгән Питрәч авылында оеша. Кәсепчелек барлыкка килү авыл янында тимер һәм титан оксидлары катнашмалары булган югары сыйфатлы үзле балчык табылу б-н бәйле (майлылыгы, ачык кызыл төсе б-н аерылып тора). Вакытлар узу б-н чүлмәк җитештерү үсә һәм массакүләм төс ала. Хәтта Питрәч б-н янәшә урнашкан Олан, Зур Дүртөйле авылларында да керәч савыт-сабалар җитештерә башлыйлар. Үзле балчык Питрәчтән китерелләнектән, аларда да П.ч.я.к.нә хас технологияләр кулланыла һәм шундый ук савыт-саба формалары эшләнә (бу авылларда үсеш алган һөнәрчелек чүлмәк ясау кәсепчелегенең локаль чыганагы санала). Балчык алына торган урыннарда җиргә казып кереп эшләнгән остаханәләрдә мичләр чыгарыла, чүлмәк ясау түгәрәкләре (гадәттә, аяк б-н басып әйләндерелә торган) куела, әйберләрне китерү өчен киштәләр урнаштырыла. 19 йөз башында Питрәчтәге 356 хуҗалыкта 66 чүлмәк ясау йорты һәм берничә кечерәк з-д эшли. Алар гадәти савыт-саба ясаучы вак җитештерүчеләр була (19 йөз уртасына аларның саны 70 кә җитә). Төтен юллыклары торбалары һәм гөл чүлмәкләре җитештерүче ике чүлмәк ясау йорты гына җиһазланышы буенча сәнәгать пр-тиеләренә якын тора (аларда, хуҗалардан башка, 2-3 ялланган эшче була).

П.ч.я.к.нең төп продукциясе тар муенлы чүлмәк, җамаяк, зур чүлмәк, тимер учак, гөл чүлмәге, уенчыклар, чирәп, кирпечтән гыйбарәт була. Көнкүреш савыт-сабаларының формалары аларның кулланылышына карап аерыла. Әйберләр күзгә ташланып тормаган сызыклы орнамент б-н бизәлә, өстенә ялтыравык йөгертелә яки шомартыла. 19 йөз уртасыннан савыт-саба бизәлешендә Казан татарларының үсемлек орнаменты элементлары кулланыла башлый: яфраклар б-н аралаштырылган тукранбаш, лалә, төнбоек үрнәкләре һ.б. Татарлар яратып файдаланган алым — бер-берсе эченә урнаштырылган бер типтагы фигуралар ясау алымы кулланыла. Ялтыравык йөгертелгән әйберләрне бизәү 19 йөз ахырыннан модерн стиле сәнгате йогынтысында үзенең ачыклыгы һәм капма-каршы төсләр кулланылу б-н аерылып тора. Савыт-саба җитештерүдә, гадәттә, аерым



Чүлмәк. Керәч чүлмәкчелек сәнгате. 20 йөз башы. Питрәч авылының Төбәк тарихы музее.

гаиләләр яки берничә кешедән торган ширкәтләр катнаша. Чүлмәк ясаучы гаиләләр — Сучковлар, Гурьяновлар, Ишимовлар, Мишухиннар династияләре барлыкка килә. Питрәч керәче Пермьдә, Самарада, Әстерханда һ.б. шәһәрләрдә, күпчелеге Казан губернасында сатыла.

1890 елда фәнни-сәнәгать күргәзмәсенә әзерләнү уңаеннан, П.ч.я.к. б-н Казан өяз земствосы кызыксына һәм мичләрне төзекләндерү һәм җиһазлар сатып алу өчен акча бүлеп бирә. 1910 да Казан губернасының земство җыены чүлмәк ясау һөнәрчелегенә әзерләүче *Питрәч һөнәр-сәнгать остаханәсе*н ачу турында карар кабул итә. Укучыларның беренче хезмәтләре 1912 дә Бөтенроссия сәнәгать күргәзмәсендә югары бәяләнә. Гражданнар сугышыннан соң керәч җитештерү кими, П.ч.я.к. әкренләп сүнә. 1950–60 елларда аны яңадан торгызу омтылышы уңышсызлыкка очрый. Аерым осталар 20 йөз ахырына кадәр эшли (Олан авылыннан Ф.Сучков эшләгән тар муенлы чүлмәкләр, кувшиннар, гөл чүлмәкләре 1983 елда Казанда, Респ-ка гамәли-бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә куела). П.ч.я.к. әйберләре ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Питрәчтәге туган якны өйрәнү музеенда саклананалар. Ш.у.к. илл. *Керәч сәнгате* (№ 10).

*Әд.:* Бусыгин Е.П., Воробьёв Н.И. Художественные мысли Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Бусыгин Е.П. Русское сельское население Среднего Поволжья. К., 1966; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

*А.Ю.Махинин.*

**ПИУНО́ВА-ШМИ́ДГОФ** Екатерина Борисовна (17.11.1843, Түбән-Новгород ш. — 27.11.1909, Казан), драма актрисасы. Кенәз Н.Г.Шаховский карамагындагы крепостной актёрлар гаиләсендә туа, кечкенәдән сәхнә тормышы б-н яши. 1851–53 елларда Мәскәүдә театр мәктәбендә укый, аннан соң Кострома, Пенза, Түбән Новгород шәһәрләре театрларында хезмәт куя. 1858 дә Түбән Новгородта М.С.Щепкин б-н бергә уйный. Актриса башкарган рольләрнең уңышлы килеп чыгуында аның өлеше зур була. 1858 нең 16 сентябрендә директор Н.И.Мирцев чакыруы буенча Казан театр сәхнәсендә беренче тапкыр чыгыш ясый, анда 1860 ка кадәр һәм 1869–89 да эшли. Гризельда (Ф.Гальмның шул исем. әсәре буенча), Амалия («Утыз ел яки Комарбазның хәяте», В.Дюканж), Марианна («Испан морзасы», Ф.Дюмануар, А.Деннери), Офелия, Катарина («Гамлет», «Тискәрегә авызлык», У.Шекспир), леди Мильфорд, Мария («Мәкер вә мәхәббәт», «Мария Стюарт», Ф.Шиллер), Адриенна Лекуврёр (Э.Скрибның шул исем. әсәре буенча), Анна Андреевна, Агафья Тихоновна («Ревизор», «Өйләнү», Н.В.Гоголь), Катерина, Варвара, Кабаниха («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Василиса («Василиса Мелентьева», А.Н.Островский, С.А.Гедеонов), Марфа Борецкая («Марфа-посадница», Н.П.Жандр) рольләрен башкара. Замандашлары фикеренә караганда, П.-Ш.ның уйнавы табигый һәм ышандырырлык булуы, үз геройларының катлаулы эчке дөньяларын ачарга һәм тамашачы игътибарына җиткерергә, шул рәвешчә аңарда аларга карата кызгану хисе уятырга омтылуы б-н аерылып тора. Характерлы рольләрдә актриса, тормыш дөреслегеннән читләшмичә генә, сатира алымнарына да мөрәҗәгать итә. 1889 да сәхнәдән китә. 1879–81 һәм 1895–96 да Казан театрында П.-Ш.ның улы А.М.Шмидгоф та уйный.

*Әд.:* Юшков Н.Ф. К истории русской сцены: Е.Б.Пиунова-Шмидгоф в своих и чужих воспоминаниях. К., 1893; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958.

*Ю.А.Благов.*

**ПИЦЕ́Н** (пичен, бичен, җен, ен, урман иясе), Көнбатыш Себер татарлары мифологиясендә рух, урман хуҗасы. П. турындагы күзаллауларда төрле мифологик персонажларның (җен, *пәри, урман иясе* һ.б.) үзенчәлекләре чагылу «П.» сүзен синонимнарга баета. Кешеләргә ул кулына озын таяк тоткан, җилкәсенә биштәр аскан күркәм карт, чәчләре тузгыган, күкрәкләре салынып төшкән килбәтсез хатын-кыз, төрле җәнлек (мәс., маймыл) кыяфәтендә күренә; хатын-кыз һәм ир-ат тавышлары чыгара, хайван кебек үкерә. П. урманда, ташландык аучы йортларында яши. Урманга кешеләрне алдап алып керә, көрәшкә чакыра. П. курку уята. Аны очраткан яисә аның б-н көрәшкән кеше сөйләшә алмый башлый (догалар уку — рухка каршы торуның бердәнбер чарасы). Аланда йөргән атларны тотып, аларга утырып чабарга, уйнарга ярата. П. *убыр, Шүрәле* (кеше үлгәнче аны кытыкларга мөмкин), рус мифологиясендәге урман иясе (леший; урман б-н бәйләнеш, кешегә дошмани мөнәсәбәт) б-н охшаш.

*Әд.:* Баязитова Ф.С. Пичен // Себер татарлары. Рухи мирас: Гаилә–көнкүреш, йола терми-

нологиясе һәм фольклор. К., 2001; Б а с и м о в В. Пицен // Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2.

*Ф.И.Урманчеев.*

**ПИЦИГА́НОЛАР ПОРТОЛАНЫ́**, геогр. карта. 1367 елда Венеция картографлары бертуган Пьерино Весконте һәм Франческо Пицицанолар тарафыннан төзелә. Башка илләр б-н беррәттән, Алтын Урда терр-ясе шактый тулы сурәтләнә. Анда Кара диңгез яры буе, Идел буе, Урал алды һәм Себернең 40 ка якын шәһәре һәм өлкәсе, ш.и. Сакетим (Жүкәтау), Боргар (Болгар), Берциман (Билҗәмин), Сарай-әл-Мәхруса һ.б. шәһәрләр билгеләнә. К.ш.у. *Портолан*.

*Әд.:* М а г и д о в и ч И.П., М а г и д о в и ч В.И. Очерки по истории географических открытий. М., 1982. Т. 1; Е г о р о в В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985; П о с т н и к о в А.В. Развитие картографии и вопросы использования старых карт. М., 1985.

*И.Л.Измайлов.*



Пициганолар портоланы. Картаның бер өлеше. 1367.

**ПИЧКА́С МӘРМӘ́Р О́НИКСЫ ЧЫГАНАГЫ́**, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 55 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Вожи авылына каршы Актай елгасының уңъяк ярында. 1994–98 елларда ЦНИИгеолнеруд хезмәткәрләре тарафыннан ачыла һәм тикшерелә. 1998 дә чыганакны эшкәртүгә «Оникс» АҖ лицензия ала. Файдалы казылма вак таш һәм известь мелиорантлары алу өчен карбонат токымнарын чыгару буенча ташландык карьерны тикшерү барышында табыла. Ятмалар өч морфогенетик типта бирелә: тамырсыман, ярыкланган, саркымлы кабык (мәгарә). П.м.о.ч. запаслары $C_2$ категориясендә дүрт тамырсыман һәм бер саркымлы кабык ятмалары буенча исәпләнә. Тамырларның озынлыгы 9–21 *м*, калынлыгы берничә дистә *см* дан 2,2 *м* га кадәр, тирәнлеге 12 *м* га кадәр өйрәнелгән. Ачылма токымнары юк. Чыганакны эшкәртү шартлары уңай. Запас — 824 *т*, ш.и. суланмаганнары — 494 *т* (2003). Югары сыйфатлы чималның чыгышы 80%. П.м.о.ч. — Россиядә иң зур һәм аның Европа өлешендә бердәнбер чыганак, запасы буенча бергә алынган барлык чыганаклардан өстен.

*Әд.:* Поделочные и коллекционные камни Республики Татарстан // Георесурсы. 2003. № 3.

*А.В.Шишкин.*

**ПИЧУ́ГИН** Валентин Михайлович (21.4.1898, Казан — 13.3.1992, шунда ук), зоогигиенист, вет. фән. д-ры (1940), проф. (1946). 1921 елда Казан вет. ин-тын тәмамлагач, шунда эшкә калдырыла, гомуми зоотехния каф. мөдире (1927–31). 1932–34 тә Бөтенсоюз эксперименталь вет. ин-тының (Мәскәү) зоогигиена бүлеге мөдире, 1935–36 да Казан а.х. ин-тының зоогигиена һәм сөт технологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта зоотехния ф-ты деканы. 1936–64 тә Казан вет. ин-тының зоогигиена каф. мөдире. Хайваннар бүлеп чыгарган җылылык үлчәмен, кешеләр һәм хайваннар сулап чыгарган һаваның дымлылыгын билгеләү мәсьәләләре б-н шөгыльләнә; махсус калориметр, конденсация гигрометры һ.б. уйлап таба. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Переваримость сена верблюдом // Тр. Ин-та эксперим. ветеринарии. 1926. Т. 4, вып. 1; Содержание и уход за телятами // Проблемы животноводства. 1934. № 2; К вопросу определения кислотности молока // Ветеринарно-техн. вестн. 1939. Вып. 5–6.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*В.Г.Софронов.*

**ПИЧУ́ГИН** Павел Иванович (27.6.1876, Казан губ., Царёвококшайск өязе Морки а. — 31.3.1954, Молотов ш.), педиатр, медицина д-ры (1913). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1902), шунда ук, Балалар авырулары клиникасында эшли. 1904, 1906 елларда Мәскәү бактериол. ин-тында стажировка уза. 1907 дә Швейцариядә фәнни командировкада. Рус-япон (1904–05 тә Маньчжуриядә 20 нче Харбин берләштерелгән госпиталендә) һәм Беренче бөтендөнья сугышларында катнаша. 1911 дән Казан ун-ты каршындагы Акушерлык ин-тында укыта, 1915 тән ун-тның балалар авырулары кафедрасында. Балалар үлеменә каршы көрәш җәмгыятен гамәлгә куючыларның берсе һәм казначысы (1909). 1920 дән Пермь ун-тының үзе оештырган балалар авырулары каф. профессоры; ш.у. ун-т каршында балалар клиникасына нигез сала («Пичугин клиникасы»). П. җитәкчелегендә Уралда балалар санаторийлары төзелә. Хезмәтләре балалар авыруларын өйрәнүгә, бизгәк (малярия), туберкулёз, имчәк балалары авыруларын (ш.и. кызылча) диагнозлау һәм дәвалауга, балаларны тукландыру, ана һәм бала сәламәтлеген кайгырту, балалар үлеменә каршы көрәш мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Скарлатина и меры борьбы с ней. К., 1909; Опыты с культивированием plasmodium vivax по методу Bass'а // Казан. мед. журн. 1913. № 3/4; Лечение малярии детей метиленовой синькой // Казан. мед. журн. 1914. № 3/6; Питание и уход за грудным ребёнком. Молотов, 1940.

*Әд.:* И л ь и н с к и й П.И. 35-летие научно-преподавательской и врачебно-общественной деятельности проф. П.И.Пичугина // Педиатрия. 1938. № 3.

**ПИЧУ́ЕВ** Геннадий Михайлович (26.8.1931, Бурят-Монголия АССРның Верхнеудинск ш., хәзер Улан-Удэ ш. — 4.6.1993, Казан), архитектор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), 1 нче Казан проектлаштыру ин-тында, 1957 елдан «Гипроавиапром» ин-тында, 1962–87 дә «Татаргражданпроект» ин-тында (1965 тән — баш архитектор) эшли. 1987 дән РСФСР Архитекторлар берлеге Татарстан бүлегенең «Архпроект» иҗади архит-ра-проектлаштыру остаханәсен җитәкли. Бер үк вакытта, 1966–93 тә Казан төзүче инженерлар ин-тының архит-ра-проектлаштыру кафедрасында укыта. П. проекты буенча Казанда М.С.Урицкий исем. мәдәният сарае (1961), Химиклар мәдәният сарае (1969), Төзүчеләр мәдәният сарае (1972), Үзәк универсаль кибет (1978),



Г.М. П и ч у е в. М.С.Урицкий исем. мәдәният сарае. Казан. 1961.

ТАССР Рәссамнар берлегенең Күргәзмәләр залы (1981), КПССның Татарстан өлкә ком-ты бинасы (1983), «*Совет власте өчен көрәштә һәлак булганнар һәйкәле*» (1967, автордаш), *Казан циркы* (1967, автордашлыкта), ТАССР МС бинасына янкорма (1979–81, автордаш) һ.б. төзелә. СССР МС бүләге лауреаты (1972).

**ПИЧУ́ШКИН** Юрий Иванович (14.6.1948, Казан), инженер–җылылык энергетикасы белгече, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый (1976). Хезмәт эшчәнлеген 1965 елда Казан авиация з-дында слесарь булып башлый. 1973–87 һәм 1992–2008 дә «Татэнерго» АҖ ф-лында — Казанның 3 нче ТЭЦында (2006 дан «Генерирующая компания» АҖ ф-лы) эшли: электрослесарь, котельный бүлеге машинисты ярдәмчесе, турбиналар б-н идарә итүче үзәк җылылык щиты машинисты, смена башлыгы, казан-турбина цехы башлыгы, җитештерү-техника бүлеге инженер-конструкторы, сәнәгый агымы суларны термик эшкәртү цехы башлыгы. 1987–2008 дә (бүленеп) «Урта Идел» зона органы Казанның 3 нче ТЭЦы буенча өлкән инженер-инспекторы, цех башлыгы. 1991–92 дә Казандагы «Кама» фәнни-җитештерү пр-тиесендә производство башлыгы урынбасары. Дәүләт бүләге югары басымлы казаннар өчен термик су әзерләүнең югары нәтиҗәле һәм экологик камил технологиясен эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Энергосбережения и водоподготовка // Энергетик. 2003. № 1 (автордаш).

**ПИЩЕМА́Р** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Кылна елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 5 кеше (мордвалар) яши. 1929 да нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Тәтеш волостенда. 1930 елның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 79, 1949 да — 125, 1958 дә — 121, 1970 тә — 50, 1979 да — 49, 1989 да — 11, 2002 — дә 7 кеше.

**ПЛАВТ** (Naucoris (Ilyocoris) cimicoides), плавтлылар семьялыгыннан су кандаласы. Барлык җирдә дә таралган. Татарстан терр-ясе өчен гадәти бөҗәк, агымсыз, үсемлекләр күпләп үскән сулыкларда яшиләр. Гәүдәсе яссы, озынча түгәрәк, озынлыгы 1,5 *см*, яшькелт-сары төстә. Куе төкчәләр б-н капланган арткы пар аяклары ярдәмендә яхшы йөзә; су үсемлекләре буйлап үрмәли ала. Атмосфера һавасын сулый. Үсемлек тукымаларына май–июньдә күкәй сала. Коры җирдә җитлеккән халәттә кышлый. Вак тереклек ияләре б-н туклана, бөҗәк личинкаларына, моллюск, чукмарбаш һәм вак балыкларга һөҗүм итә. Очында тырнаклары булган алгы пар аяклары эләктерү органы булып хезмәт итә. П. корбанына очлы хортумчыгын кадый, шул рәвешчә кан һәм сыеклык суыра. Балык хуҗалыгына зарар китерергә мөмкин.

*Әд.:* Жизнь животных. М., 1969. Т. 3; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Р а й к о в Б.Е., Р и м с к и й - К о р с а к о в М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994. *В.А.Яковлев.*

**ПЛАКА́Т** (франц. placard — белдерү, игълан), графика сәнгате төре, агитация максатында иҗат ителгән кыска текстлы сынлы сәнгать әсәре; полиграфик ысул б-н күчереп басыла. П. җәмәгать урыннарында халыкка йогынты ясау өчен әзерләнә, сәяси П. (социаль, патриотик) һәм реклама П.ы (сәүдә рекламасы, кинореклама) төрләренә бүленә.


Казанда беренче сәяси П.лар 1917 елда Февр. рев-циясе вакытында барлыкка килә. Аларны иҗат итүдә К.К.Чеботарёв һәм *Казан сәнгать мәктәбенең* башка вәкилләре катнаша. Плакат сәнгатенең күтәрелеш чоры Гражданнар сугышы вакытына туры килә. П.лар Запас армия штабында һәм сәяси бүлегендә, Идел буе хәрби округының сәяси идарәсендә басыла. Һәрвакыт диярлек аноним, еш кына талантлы һәм уңышлы техник алымнар б-н башкарылган төсле П.лар Антантага каршы көрәшкә чакыралар, дезертирларны фаш итәләр (Казан рәссамнары — П. чыгару б-н җитәкчелек иткән һәм аларның эскизларын әзерләгән И.А.Никитин, В.В.Кудряшов һ.б.). 1919 ел башында Казанга П. остасы В.Н.Дени (Денисов) килә; 1920 нең ахырында Мәскәүгә киткәнгә кадәр, ул Идел буе хәрби комис-тының Агитмәгариф бүлегендә сәнгать секциясен җитәкли; героик һәм сатирик П. жанрын үстерүгә зур өлеш кертә («Антанта», 1919; «Селян Мәрьям-Анасы», 1919). Соңрак, Казанда басылган күп кенә П.лар В.Н.Дени, Д.С.Моор (Орлов) һәм башка совет графикларының оригинал хезмәтләрен кабатлыйлар, трафарет буенча «Окна РОСТА» чыгарыла. 1919 һәм 1920 да Казан губернасының матбугат бүлеге (соңрак — Госиздат) төсле буяулар б-н эшләнгән берничә литографик П. бастыра, бүлек б-н В.В.Кудряшов («Бөлгенлек богауларын көчле хезмәт белән өзик» һ.б.) һәм И.В.Симаков («Китап — безнең чор тормышы» һ.б.) актив хезмәттәшлек итә. Казанда П. кыска вакыт арасында артык катлауландырылган, уйлап чыгарылган аллегорик темалардан динамик, ачык һәм ышандырырлык образларга кадәр юл үтә; аларның үзенчәлекләре җирле тематика һәм Казан рәссамнарының иҗаты йогынтысында формалаша. Шулай ук Казанда басылучы П.ның күпчелек өлеше аноним һәм еш кына түбән сыйфатлы була. Беренче имин еллар П.лары 1921–22 дә Главполитпросвет тарафыннан, күбесенчә кара төс б-н генә басыла һәм Идел буендагы ачлык, наданлык, хәерчелеккә каршы көрәшкә, мәдәният-мәгърифәт һәм профсоюзлар эшчәнлегенә багышлана. Шулай ук дәүләт идарәсе тармаклары — Сәламәтлек саклау, Халык мәгарифе халык комис-тларының, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең П.лары да басылып тора. Алар арасында Ачлыктан интегүчеләргә ярдәм итү ком-тының турыдан-туры хисләргә мөрәҗәгать итү («Ачлык-патша» һәм «Ачлыкның сөякчел куллары», 1920, рәссамы билгесез), фаҗигага тирәнлеген ачу («Ярдәм ит!», Д.С.Моор, 1921) яки агитация максатында башкарылган («Ун тук кеше бер ач кешене туендырсын», «Барлык илләрнең эшчеләре пролетариат революциясе авангардын ачлыктан коткарыр», 1922) П.лары эчтәлекнең тәэсирле чагылышы б-н аерылып торалар.

1920 еллардан башлап, рәссамнар В.Э.*Вильковиская*, Н.С.*Шикалов*, И.Н.*Плещинский*, М.В.*Барашов*, Н.М.*Сокольский* һ.б. эшләгән, Ф.П.Гаврилов җитәкләгән Казан сәнгать-архит-ра остаханәләре П.лар иҗаты үзәгенә әйләнә. П.лар, гадәттә, төсле литография, сирәк кенә линолеумдагы гравюра техникасында языла һәм остаханәләрдә басыла. П.ларның стильләре (реализмнан экспрессионизмга кадәр) һәм темалары (дөнья рев-циясеннән җирле вакыйгаларга кадәр) төрле: «1 Майда бөтендөнья хезмәт ияләре капиталга каршы бердәм фронт яулый» (рәссам Н.Сокольский) һәм «Ирекле булу өчен көчле булыгыз!» (рәссам М.Барашов, Казандагы 2 нче Идел буе спорт олимпиадасына багышлана, 1923).

Казанда ясалган П. гарәп графикасындагы татарча язмалар, татар персонажлары, татар көнкүреше, архит-расы, сәнгате элементларын куллану («Шәрекъ музеена. «Шәрекъ көндәлек тормышына, тарихына һәм сәнгатенә кагылышлы барлык әйберләрне музейга илтегез», рәссам В.П.Соколов, «Өмид» типолитографиясе, вакыты билгесез), сюжет-жанр композицияләре төзү («Чәчү кырларын киңәйтү — бөлгенлектән һәм ачлыктан котылу юлы», рәссам Г.А.Медведев, Госиздат, 1921), еш кына татар авылы тормышы күренешләрен сурәтләү («Тынычлык, хезмәт, икмәк» — татар телендә, авторы һәм вакыты күрсәтелмәгән, «Өмид» типолитографиясендә басылган) б-н аерылып тора.

П. жанрына беренче булып мөрәҗәгать иткән татар рәссамнарының берсе — Ф.Ш.*Таһиров*. «Яңалиф» җәмгыяте аның эскизы буенча латин алфавитын кулланышка кертүне пропагандалаучы «Яңа төрки алфавит турында» П. чыгара. 1920 еллар азагында күп кенә татар рәссамнары Татгосиздат һәм «Гажур» нәшрияты б-н хезмәттәшлек итәләр: мәс., рәсем, фотопроекция һәм стильләшкән шрифт кулланып эшләүче («Татгосиздаттан китап сатып ал», 1929; «Сөтне чиста керәч савытта саклагыз», 1930), П.лары контурлы рәсем һәм колорит, татар халык сәнгатенә хас локаль төсләр куллану осталыгы б-н аерылып торган Ш.Н.*Мөхәммәтҗанов*; Б.Йосыпов («Татиздатта китаплар һәм журналлар», 1929) һ.б. 1929 да Казанда «Казан плакаты» дип исемләнгән беренче П. күргәзмәсе була.

1930 елларда әлеге өлкәдә Б.М.*Әлминов* һәм М.М.Габдуллин кебек осталар эшләвенә карамастан, П. сәнгате торгынлык кичерә. П. яңа көч б-н Бөек Ватан сугышы елларында яңара. Ул Гражданнар сугышы чорының иң яхшы традицияләрен дәвам итсә дә, шул еллар П.ларыннан нык аерыла. Дошманның чын йөзен сатирик юл б-н фаш итү — П.та әйдәп баручы юнәлеш булып тора (Б.М.Әлминовның «Фашизмның канлы сатраплары»; Р.Ф.Сәйфуллинның «Яңа тәртип» һәм «Капитализмның бәйдәге этләре» һ.б.), ш.у. шәһәрләрнең героик оборонасына һәм азат ите-







**Плакат**. 1. В.П.Соколов. «Шәрекъ музеена!» («Шәрекъ көндәлек тормышына, тарихына һәм сәнгатенә кагылышлы барлык әйберләрне музейга илтегез»). Кәгазь, тушь. Датасы күрсәтелмәгән; 2. И.К.Әхмәдиев. «Совет Армиясенә — 60». Плакат эскизы. Кәгазь, гуашь. 1978; 3. И.К.Колмогорцева. «Рәхим итегез!». Плакат эскизы. Кәгазь, гуашь. Датасы күрсәтелмәгән.

лүенә (И.Е.Бобровицкийның «Кавказ дошманны үткәрмәс»; Н.М.Сокольскийның «Канга — кан, үлемгә — үлем»; Э.Б.Гельмсның «Немецларны Днепрда кыйныйбыз»; А.А.Прытковның «Ленинград бирелмәс» һ.б.), тыл хезмәтчәннәренә (Б.М.Әлминовның «Фронтка икмәк»; Р.Сәйфуллинның «Һәр бөртек — дошман башына» һ.б.) багышланган П.лар да басыла. Басма П. Татгосиздат тарафыннан да, бер үк вакытта, 1941–45 елларда И.Е.Бобровицкий, Н.М.Сокольский һәм шагыйрь Б.И.Зернит башлангычы б-н оештырылган «Окна сатиры»да да чыгарыла. Шәһәр витриналары, Казандагы эре пр-тиеләр һәм учреждениеләрнең стендлары «Окна сатиры» П.лары б-н тулы була һәм алар вакытында чыгарылулары б-н аерылып торалар; шигырь текстларын Казандагы шагыйрьләр иҗат итә. П.лар «Татхудожник» остаханәләрендә аз тираж б-н, трафарет ярдәмендә кулдан әзерләнә (барлыгы 170 сан дөнья күрә). Авторлары — И.Е.*Бобровицкий*, Э.Б.*Гельмс*, Н.М.Сокольский, А.А.Прытков, Г.П.Катков, А.Н.*Кашаев*, И.Н.Овчинниковлар.

Кайбер П.лар бер-бер артлы тезелгән картиналарның мавыктыргыч сюжеты б-н җәлеп итсә («Хәерчелектән хәйлә коткарыр», 1942, рәссам И.Бобровицкий), күчле гротескка, сатирик гомумиләштерүгә ия булулары б-н тартып тора («Явыз козгыннар җыелды», А.Прытков, 1943, №78; «Кирәкләрен алдылар», Э.Гельмс, 1944, №117). «Окна сатиры» сәхифәләрендә Кукрыниксклар, Б.Е.Ефимов, И.М.Тоидзе һ.б. күренекле совет П.чыларының эшләре күчерелеп басыла. 1941 дә танылган Мәскәү рәссамы В.Б.Корецкий тарафыннан Казанда тагын бер П. остаханәсе оештырыла. Аның эшенә ул Казан рәссамы Б.М.Әлминов һәм Д.С.Моорның талантлы шәкерте Р.Ф.Сәйфуллинны җәлеп итә.

Бөек Ватан сугышыннан соң, П. үсеше сүлпәнәя. 1940 еллар ахырында — 1950 елларда иҗат ителгән әсәрләр (Б.М.Әлминов, Н.М.Сокольский һәм Х.Г.Якупов хезмәтләреннән кала) чишелешләрнең калыпка салынуы, сатирик кискенлекнең югалуы б-н аерылып тора. 1961 дә Казанда, Л.Я.*Елькович* башлангычында, Татарстанның графика сәнгате тарихында яңа сәхифәләр ачкан, Идел буенда бердәнбер «Агитплакат» остаханәсе оеша. Ефәк җеп ярдәмендә рәсем төшерү техникасында эшләнгән П.лар фикерләренең үзенчәлекле, идеяләренең үткен, формаларының җете ачык һәм тасвирлы булулары б-н аерылып тора. Басмаларның тиражы 1 мең данәгә кадәр җитә. «Агитплакат» эше б-н редколлегия: Л.Я.Елькович (редактор), И.К.*Колмогорцева*, Е.В.*Киселёва* һ.б. җитәкчелек итә. Авторлары — әйдәп баручы графиклар, ш.и. «Чаян» ж-лы рәссамнары була; С.М.Бубеннов, П.Н.Григорьев, Е.В.Киселёва, И.К.Колмогорцева, Э.Г.*Ситдыйков*, И.С.*Хантимеров*, И.Л.*Язынин* актив һәм мавыгып эшли. Казан рәссамнары П.лары «Зур Идел», «Советская Россия», күргәзмәләрендә һәм халыкара күргәзмәләрдә даими катнашып килә. 1960 елларда П.ка яңа, талантлы буын: Л.Х.Насыйров, В.К.Фёдоров, Р.Ә.Төхфәтуллин, Л.М.Кальюранд мөрәҗәгать итә. И.К.Әхмәдиевнең («Иделдә очрашырбыз!» «Идел» халыкара лагеренда совет һәм япон яшьләре фестиваленә, 1967), Р.Ә.Килдебәковның («Татарстан, Беренче май бәйрәме ничек килешә сиңа!», 1968), А.К.Закировның театраль П.лары сәнгать формаларының бизәлеше, милли образлылыгы б-н аерылып торалар.

1970 елларда КамАЗ төзелеше үзәк темаларның берсенә әйләнә. Бөтенсоюз төзелеше романтикасы Е.В.Киселёва («КамАЗ — минем хыялым», 1972), И.Г.Закиров һәм Н.Х.Сәлахиев («Рәхим ит, КамАЗ!», 1974), В.К.Фёдоров («КамАЗ төзүчеләр! Беренче автомобильне бирик»; 1974) әсәрләрендә гәүдәләнә. П. ш.у. яшьләр тәрбиясе, табигатьне һәм мәдәният ядкәрләрен саклау темалары яктыртыла; байтак П. нефтьчеләргә һәм авыл хезмәтчәннәренә багышлана.

1970–80 еллар — «Агитплакат»ның күтәрелеш чоры: аның коллективына Р.С.Сафиуллин, Г.Л.Эйдинов, А.Е.Простов-Покровский, Е.П.Мишаков кебек талантлы яшь рәссамнар килеп кушыла. 1990 елларда «Агитплакат»ка язылу һәм аны финанслау туктала (соңгы чыгарылыш — 1993 ел), социаль, сатирик, патриотик П. юкка чыга. Хәзерге вакытта ксерокүчермә, фоторәсем, компьютер технологияләре ярдәмендә башкарылган реклама П.ы үсештә.

*Әд.:* Е л ь к о в и ч Л.Я. Сатирическая графика художников Татарии. М., 1963; Ф а й н б е р г А.Б. Политический плакат Казанских художников. 1941–1945. К., 1965; Ч е р в о н н а я С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; К о л м о г о р ц е в а И.К. В гуще событий: Из истории Казанского агитплаката // Казань. 2006. № 8/9.

*М.Е.Ильина.*

**ПЛАКСИ́ХА** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 44 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Вятка елгасы буенда. 2010 елда 21 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 18 йөздә татар авылы буларак нигез салына. Беренче исеме — Кубанчур (Кубангур), 19 йөздә руслар килеп урнаша. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 830,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 385, 1897 дә — 694, 1908 дә — 650, 1920 дә — 637, 1926 да — 548, 1949 да — 320, 1970 тә — 173, 1979 да — 96, 1989 да — 64, 2002 дә — 43 кеше.

**ПЛАНА́РИЯЛӘР**, ө ч т а р м а к л ы л а р (Tricladida), төкле суалчаннар классыннан умырткасызлар асотряды. Бөтен җирдә таралганнар. Төче суларда, сирәк кенә диңгезләрдә һәм туфракта яшиләр. Гадәттә, гәүдә озынлыгы берничә *мм* яки *см* дан 60 *см* га кадәр. Эчәк төп 3 тармак (икенче исеме шуннан) хасил итә. Татарстан сулыкларында, аеруча кара күпкүз (Polycelis tenuis), — гадәти төр. Озынлыгы 10–12 *мм*, төсе кара көрәннән карага кадәр. Авыз куышлыгы корсак ягында урнашкан, йоткылыгы җыерчыклы типта. Җенес системасының төзелеше катлаулы, ул исә еш очраучы һәм тышкы кыяфәте б-н аерылмаучы икенче бер P.nigra төрен аеру өчен билге булып тора. Зәңгәр күлдә ак П. (Dendrocelum pacteum) табыла. Саны 23,5 экз./$м^2$ (2002). Сирәк төрләре Аргы Кабан, Раифа күлләрендә күренә. Гәүдә озынлыгы 15–30 *мм*, киңлеге 5–6 *мм*, ак яки алсу төстә, алгы очында ике күз урнашкан. Вак кыслачыклар, бөҗәк личинкалары, башка умырткасыз хайван калдыклары б-н туена. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

*О.Д.Любарская.*

**ПЛАНЕТА́РИЙ**, Казанда, Җир турында фәннәр, астрономия һәм космонавтика буенча белемнәрне пропагандалау үзәге; 1963–90 елларда ТАССР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) бүлекчәсе. 1960 тан эшли, астрономнар А.А.Нефедьев, Ю.В.Евдокимов, М.И.Лавров тырышлыгы б-н рәсми рәвештә 1963 нең 17 маенда *Петропавел соборы* бинасында ачыла. П.да махсус гөмбәздә йолдызлы күкне барлык хронологик һәм геогр. вариантларда, табигать күренешләрен (төньяк балкышы, метеоритлар, кометалар төшү) һәм очкыч аппаратлар очышын тасвирлап, югары дәрәҗәдә төгәл сурәтләргә мөмкинлек бирә торган уникаль оптик җиһазлар («Карл Цейс Йена» фирмасы эшләнмәсе, Бөек Ватан сугышыннан соң Германиядән түләттерелгән контрибуция исәбенә Казанга кайтартыла) урнаштырылган була. Панорама проекты авторы — рәссам А.А.Крылов. П. штатында 6–7 лектор һәм фәнни хезмәткәр исәпләнә, алар Казан һәм Татарстан халкын фәнни агартуда мөһим роль уйныйлар. Биредә лекцияләр укыла (сурәтләү өлеше Казан ун-тының астрономия каф. һәм В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе галимнәре тарафыннан әзерләнә), күргәзмәләр оештырыла, мәктәп укучылары өчен астрономиядән дәресләр, астрономия буенча фәнни конференцияләр үткәрелә. Ел саен Казанда П.га 50 меңгә якын кеше йөри. Казан П.е СССРдагы иң яхшы 40 П. исәбенә керә. 1990 елда Петропавел соборын дин тотучылар җәмгыятенә бирү сәбәпле, П. җиһазлары сүтелә. 2013 тә Казан ун-тының В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе терр-ясендә яңа П. ачыла. Директоры — физика-матем. фән. д-ры Ю.А.Нефедьев.

**ПЛА́НО КАРПИ́НИ**, к. *Карпини.*

**ПЛАСКУ́Й КҮЛӘ́**, Көнчыгыш Кама алдында. Кама елгасының уңъяк тугаенда урнашкан, Алабуга р-ны Танай авылыннан 5,3 *км* көньяк-көнбатыштарак, Криуша ермагы янында. Су өслегенең мәйданы 12,88 *га*. Озынлыгы 1130 *м*, иң зур киңлеге 170 *м*. Формасы озынча, азрак борылмалы. Урыны-урыны б-н яр буе зонасы сазлыкланган.

**ПЛАСТ** шәһәре, *Чиләбе өлкәсендә* урнашкан. Халкы — 17,2 мең (2012), татарлар — 2,5 мең кеше. Татарлар П.та 1860 елларда, җирле алтын приисклары эшли башлагач күренә башлый. 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында күмәкләштерү чорында татарларның саны шактый арта. 1917 гә кадәр П.та татар китапханәсе, 1930 еллар башына кадәр — мәчет, 1950 ләргә кадәр 2 татар мәктәбе эшли. Хәзерге көндә шәһәрдә мәчет (1991 дән), шәһәр мәдәният идарәсе каршында татар-башкорт кунакханәсе эшли (1990 нардан).

**ПЛАСТМА́ССАЛАР**, пластик массалар, пластиклар, төп компонентын югары молекуляр кушылма (синтетик яки табигый полимер) тәшкил иткән композицион полимер материаллар. Полимердан тыш, П. составына түбәндәгеләр керергә мөмкин: тутыргычлар — механик үзлекләрен яхшырту, утырту күләмен киметү, агрессив тирәлекләр тәэсиренә чыдамлыгын арттыру һәм бәясен төшерү өчен; пластификаторлар — ватылучанлыкны киметү һәм салкынга чыдамлыгын арттыру өчен; стабилизаторлар — үзлекләрен озак саклау өчен (антиоксидантлар, фотостабилизаторлар, антирадлар); буяу матдәләре һәм пигментлар; яну ингибиторлары — антипиреннар; күбекләндергеч матдәләр — пенопластлар алу өчен; майлау матдәләре — эшкәртү процессларын җиңеләйтү һәм полимер материалның эшкәртүче җиһаз стеналарына ябышуын булдырмау өчен. Эластомерлар б-н чагыштырганда, П. башлангыч эластиклык модуле кыйммәтләренең югары ($9{\cdot}10^2$-$10^3$ *МПа*) һәм өлешчә кайтма булмаган чагыштырма озынаюның (10–100%) югары чиге кечкенә булу б-н аерылалар. Бер фазадагы (гомоген) П.да төп компонент — полимер, калган ингредиентлар аңарда эрегән була. Гетероген П.да полимер һәркайсы үз фазасында булган һәм бу полимерда дисперслашкан компонентларга карата дисперсия тирәлеге (бәйләгеч) ролен үти. П.дагы бу фазаларның нисбәте шактый киң аралыкларда (полимер массасына карата 45–50% ка кадәр) үзгәрергә мөмкин. Тыгыз тутырылган П.да мондый фазалар полимерның үзеннән өч һәм аннан да артыграк тапкыр күбрәк була. Җылытканда ничек үзгәрүенә карап, П.ны термопластикларга (термопластлар) һәм термореактивларга (реактопластлар) бүләләр. Җылытканда термопластлар йомшыйлар һәм агучан үзле халәткә күчәләр, суытканда — каталар. Бу процесс кайтма була, полимер химик үзгәрешләр кичерми. Реактопластлар, җылытканда (яки суытканда) каты, эремәүчән продуктларга әверелеп, структурлашалар һәм кабаттан формага салыну сәләтен югалталар. Синтезлау алымына карап, П.ларны полимерлаштыру, поликонденсация реакцияләре нәтиҗәсендә алынган полимерлар нигезендә һәм химик модификацияләнгән табигый полимерлар нигезендә табыла торган П.ларга бүлеп йөртәләр.

П.ны гамәли куллану әле полимерлаштыру, поликонденсация һәм полимер халәте теориясе барлыкка килгәннән элегрәк башлана. 1867 дә беренче тапкыр, целлюлоза нитратын камфора б-н тутыру юлын кулланып, целлулоид дип аталган материал алына. Аннан ясалган плёнка эшләнмәләре кинофотоматериалларның төп нигезен тәшкил итә һәм кинематография тууга сәбәп була (19 йөз ахыры). Полимерлар җитештерү һәм эшкәртү, ш.у. күп тонналы чимал базасын булдыру өлкәсендәге теоретик хезмәтләр 20 йөз ахырында дөньяда полимер материаллар җитештерүне шул дәрәҗәгә җиткерә, аны күләме һәм массасы буенча төсле металлар җитештерү б-н чагыштырырга мөмкин була; һәр унъеллык саен полимер материаллар, ш.и. П. җитештерү ике тапкыр арта бара. Алар техниканың төрле тармакларында, төзелештә, а.х.нда, медицинада, җиңел һәм азык-төлек сәнәгатьләрендә һ.б. кулланыла.

Татарстан — Россиядә полимер продукциясе җитештерү буенча иң зур төбәкләрнең берсе. Республика пр-тиеләрендә Россиядә җитештерлә торган полиэтиленның яртысына якыны, поликарбонат, винилацетат б-н этилен сополимеры, полиэтиленгликоль («Казаноргсинтез» АҖ); полипропилен, полистирол пластиклар, этилен б-н пропилен сополимеры («Түбәнкаманефтехим» АҖ) эшләп чыгарыла. Бу җитештерүләрнең башланып китүе һәм үсеше Е.В.*Кузнецов*, В.А.*Воскресенский*, П.А.*Кирпичников* җитәкчелегендәге фәнни хезмәтләр б-н бәйләнгән. ТРда үсешкә ирешкән фәнни юнәлешләр: олефиннар полимерлаштыруның каталитик системаларын модификацияләү (В.И.*Гусев*, Г.С.Бикушев), полиолефиннарның структурасын һәм үзлекләрен модификацияләү һәм алар нигезендә салкынга чыдамлык һәм адгезия үзлекләренә ия булган композицион материаллар булдыру (В.Г.Павлий, А.М.*Кочнев*, А.Е.*Заикин*, А.Н.Садова); полимер материаллар һәм эшләнмәләрнең үзлекләрен тотрыклы итү һәм хезмәт срокларын озайту (Н.А.Мукменёва, Д.Г.*Победимский*, Е.Н.*Черезова*); полиуретаннар синтезлау һәм алардан материаллар җитештерү (М.И.Бахитов, Л.А.Зенитова), акрил к-талары һәм акриламид нигезендә суда эрүчән полимерлар (В.Е.Ложкин, В.А.Мягченков, В.Ф.Куренков), поливинилхлорид нигезендә композицион материаллар һәм эпоксид сумалалар (В.Г.*Хозин*, Е.М.Готлиб, Л.А.*Абдрахманова*, Р.Я.*Дебердеев*, Р.М.Гарипов) синтезлау. Тикшеренүләр Казан технол. һәм Казан архит-ра-төзелеш ун-тларында алып барыла.

*Әд.:* Энциклопедия полимеров: В 3 т. М., 1972–77; Архиреев В.П., Галибеев С.С. Альбом технологических схем производства пластических масс. К., 2002. *В.П.Архиреев.*

**ПЛАТО́Н** (Любарский Пётр) (Чернигов губ., ? — 20.10.1811, Екатеринослав ш.), дин эшлеклесе, тарихчы. Харьков коллегиумын, Киев руханилар академиясен тәмамлый. Ярославль руханилар семинариясендә укыта, 1762 елдан Вятка руханилар семинариясе префекты. 1771 дән монахлыкта. 1772–87 дә Казан руханилар семинариясе ректоры һәм Казан Спас-Преображение монастыре настоятеле. 1787 дән — Мәскәү янындагы Яңа Иерусалим монастыре, 1796 дан Мәскәүдәге Донской монастыре башлыгы. 1794 тән Әстерхан һәм Ставрополь епископы, 1796 дан — архиепископы, 1805 тән Екатеринослав һәм Херсон архиепископы. П. җитәкчелегендә Казан руханилар семинариясендә укыту күзгә күренеп яхшыра. Аның тарафыннан 1782 елда төзелгән «Казан епархиясенең борынгы ядкәрләре һәм үткәндәге хәлләре» («Сборник древностей Казанской епархии и других присно-памятных обстоятельств») хезмәте (1868 дә дөнья күрә) Казан һәм Казан епархиясе тарихы буенча кыйммәтле чыганак булып тора. Н.М.Бантыш-Каменскийга юллаган хатында П. 1774 нең июнендә Е.И.Пугачёв гаскәрләренең Казанга һөҗүмен тәфсилләп сурәтли.

Хезм.: Иерархии Вятская и Астраханская. М., 1848.

*Әд.:* Можаровский А.Ф. Платон Любарский. К., 1870; Липаков Е.В. История Казанской духовной семинарии. К., 2007.

*Е.В.Липаков.*

**ПЛАТО́НОВ** Василий Романович (18.8.1923, Зөя кантоны, хәзер Кайбыч р-ны Кичке а. — 26.2.1967, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (17.4.1944, 14.8.1944, 24.3.1945), гв. кече сержанты. Туган ягында колхозда эшли. 1942 елның маеннан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында 266 нчы гв. укчы полкы разведчигы (8 нче армиянең 88 нче гв. укчы дивизиясе). 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында, Изюм-Барвенково (1943), Никополь-Кривой Рог (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 6 апрелендә ящерен операцияләр вакытында Баланино авылы (Одесса өлкәсе) янында (разведчиклар төркеме составында дошман тылына үтеп керә һәм «тел» ала; разведчиклар чигенешен каплап, дошманның берничә солдатын юк итә); 1944 нең 21 июлендә Влодава (Польша) шәһәреннән көньяктарак Көнбатыш Буг елгасын кичкәндә (П. җитәкләгән разведчиклар төркеме елганың сулъяк ярында дошман траншеясына беренчеләрдән булып бәреп керә һәм пулемёт расчётын юкка чыгара, солдатларның елганы кичүен тәэмин итә); 1945 нең 14 гыйнварында Геленувек (Варшавадан көньяк-көнбатыштарак, Польша) торак пункты янында Висла плацдармында оборонаны өзү сугышында (дошман траншеясына беренче булып бәреп керә, берничә солдатны, дзот һәм 2 пулемёт ноктасын юк итә, 4 кешене әсирлеккә ала) батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Туган ягында колхозда эшли. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



В.Р. Платонов.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЛАТО́НОВ** Сергей Фёдорович (16.6.1860, Чернигов ш. — 10.1.1933, Самара ш.), тарихчы, рус тарихы д-ры (1899), СССР ФА академигы (1920–31; 1909 елдан Петербург ФА мөхбир әгъзасы), яшерен советник (1911). Дворяннар нәселеннән. Петербург ун-тын тәмамлый (1882), 1888 дән шунда ук эшли: приват-доцент (1890 га кадәр), 1890–99 елларда экстраординар проф., 1899–1912 дә ординар проф., 1912–18 дә атказ. проф., 1918 дән рус тарихы каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1905–16 да, Петербург хатын-кызлар пед. ин-ты директоры, 1918–29 да Археография комиссиясе рәисе, 1925–29 да — СССР ФАнең Пушкин Йорты (Рус әдәбияты ин-ты), 1925–28 дә СССР ФА Китапханәсе директоры. 1930 да ОГПУ органнары уйлап чыгарган «академик эш» буенча кулга алына, 1931 дә Самарага сөрелә, шунда үлә. П. — ватан историографиясендәге рәсми юнәлеш вәкиле. Аның хезмәтләре классик позитивизм методологиясе юнәлешендә языла. «Тарихи чыганак буларак, XVII йөзнең болгавыр чоры турында борынгы рус риваятьләре һәм хикәятләре» («Древнерусские сказания и повести о Смутном времени XVII в. как исторический источник», СПб., 1888), «XVI–XVII йөзләрдә Мәскәү дәүләтендәге чуалышлар тарихы буенча очерклар» («Очерки по истории смуты в Московском государстве XVI–XVII вв.», СПб., 1899) дип аталган фәнни хезмәтләре 16 йөзнең 2 яртысы — 17 йөз башындагы Россиянең социаль-сәяси тарихына багышлана. Земство соборлары тарихына, Рус Төньягын колонияләштерүгә караган хезмәтләр, ш.у. Иван Грозный, Борис Годунов, Пётр I турында биографик очерклар авторы. «Рус тарихы буенча лекцияләр» («Лекции по русской истории», СПб., 1899; 10 басма. П., 1917) хезмәтендә П. монголларның рус җирләренә яуларын, Алтын Урданың феодаль таркаулык чорындагы Руська йогынтысын анализлый; Мәскәү кенәзләре һәм патшаларының Шәрекътәге сәясәтенә бәяләмә бирә. Ул, татарлар бөек Мәскәү кенәзе хакимиятен ныгыталар һәм чын рус бердәмлеге үзеген төзиләр, дип саный. Аның фикеренчә, Мәскәү дәүләте Алтын Урдадан абс. монархия, акча хисабы һәм транспорт оештыру идеясен ала.

Х е з м.: Учебник по русской истории для средней школы: В 2 ч. СПб., 1909–10; Статьи по русской истории (1883–1912). СПб., 1912; Борис Годунов. П., 1921; Иван Грозный. П., 1923; Пётр Великий: Личность и деятельность. Л., 1926.

*Әд.:* Сборник статей по русской истории, посвящённых С.Ф.Платонову. П., 1922; Б р а ч е в В.С. С.Ф.Платонов: О жизни и деятельности историка // Отеч. история. 1933. № 1.

*Е.Б.Долгов.*

**ПЛАТО́НОВКА** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1820 дә Венета авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (элек алпавыт П.П.Есипов крепостнойлары) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да икмәк саклау-сату кибете, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 499,25 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 177, 1897 дә — 299, 1908 дә — 335, 1920 дә — 326, 1926 да — 363, 1938 дә — 318, 1949 да — 220, 1958 дә — 188, 1970 тә — 118, 1979 да — 64, 1989 да — 27, 2002 дә — 7 кеше.

**ПЛАТУНО́ВА** Александра Георгиевна (29.3.1896, Вятка губ. Уржум өязе Мари-Төрек а. — 12.7.1966, Мәскәү), график, нәкышьче. Икона язучылар гаиләсеннән. Рәссам К.К.*Чеботарёв* хатыны. Казан сәнгать мәктәбенең нәкышь бүлеген (1916), Казан архит-ра-техника ин-тын (1922; к. *Казан сәнгать уч-щесе*) тәмамлый, шунда ук укыта (1921–26). Н.М.*Сапожникова* студиясендә рәсем ясау кичәләрендә катнаша (1910–1920 еллар башы). «*Подсолнечник*» берләшмәсе (1918), «*Всадник*» графика коллективы (1921–24), *ТатЛЕФ* (1923–26), Рәссамнар берлеге (1942) әгъзасы. 1926 дан Мәскәү өлкәсенең Ново-Гиреево авылында яши.



А.Г. П л а т у н о в а. «Кояш баешыннан алынган тәэсир № 1». Картон, майлы буяу. 1916. И.И. Галиевнең шәхси тупланмасы.

1950–58 дә Полиграфия машиналары фәнни-тикшеренү ин-тының яңа шрифтлар бүлегендә (Мәскәү) эшли.

П. — киң кырлы талант иясе, нәкышь картиналары, станлы, китап һәм журнал графикасы, экслибрислар, юкә тактадан ясалган клише б-н басылган рәсемнәр (портретлар, пейзажлар, тематик, еш кына әкиятләр һәм үз фантазиясе буенча абстракт бизәкле һәм символик-аллегорик композицияләр авторы. П.ның төрле алымнар б-н эшләнгән (кәгазьдә майлы буяу, монотипия, линогравюра, рәсем) әсәрләренә югары сәнгатьлелек, башкару культурасы, якты, ачык образлылык, декоративлык, шигърият, ягымлылык хас. Нәкышь әсәрләре арасында «Төш», «Су кызы», «К.К.Чеботарёв портреты», «К.И.Сотонин портреты», «Автопортрет», «Сирень», «Алмалар», «Көз» (барысы да — 1920 елларның 1 нче яртысы); «Графика» (линогравюралар, 1921), «Виньеткалар. Автогравюралар» (линогравюралар, 1921), «Әкиятләр» (төсле линогравюралар, 1922), «Өчәү. А.Платунова.




А.Г. П л а т у н о в а. «Байрак». «Хәрефләр» сериясеннән. Линогравюра. 1926. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

К.Чеботарёв. Д.Мощевитин» (1922) гравюралары; «Книжные знаки. Выпуск 1» (1922), «Казанские книжные знаки» (1923) җыентыкларындагы (1923) экслибрислары киң танылa. «Казанский музейный вестник» ж-лына һәм Гыйффәт туташның «Зөһрә һәм Йолдыз» китабына тышлыклар ясый (1922). 1929 да гаммәви урам рәсемнәренең бөтенсоюз ябык конкурсында катнаша, «Китап сатып йөрүче мари авылында» эскизы өчен бүләккә лаек була (Госиздат, АХРР, ИзоГИЗ нәшрияты бастырып чыгара). 1930 елларда «Красная Нива», «Красная панорама» ж-ллары, Госиздат, АХРР нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә. 1930–40 елларда А.Пушкин, М.Горький, В.Каменский, Н.Некрасов әсәрләренә иллюстрацияләр сериясе, «Алтын йөгертелгән маңгайлар» рус халык әкиятенә театр эскизы рәвешендәге иллюстрацияләр (гуашь, 1935), «Сугыш елларында» (1941), «Балыклар» (1962–63) монотипияләр серияләре авторы. Белорус, үзбәк, таҗик, казакъ, төрекмән, молдован, карел халыкларының типографик бизәкләре эскизларын ясый (1950–58).

Казан сәнгать мәктәбендәге 5 нче һәм 6 нчы даими күргәзмәләрендә (1914, 1916), «Подсолнечник» берләшмәсенең 1 нче картиналар күргәзмәсендә (Казан, 1918), 1 нче дәүләт сәнгать һәм фән күргәзмәсендә (Казан, 1920), 1 нче Козьмодемьянск картиналар, этюдлар, рәсемнәр күргәзмәсендә (Козьмодемьянск ш., 1920), 2 нче дәүләт нәкышь, скульптура һәм архит-ра күргәзмәсендә (Казан, 1921), Дәүләт сәнгать ин-тының конкурслар (Казан, 1922), «Рус китабы билгеләре» (Казан, 1923) күргәзмәләрендә, «Казан, алга!» сынлы сәнгать күргәзмәсендә (1924), ЛЕФның лаборатор-җитештерү эшләре буенча 2 нче сынлы сәнгать күргәзмәсендә (Казан, 1925), «Гравюрадагы рус китабы билгеләре» (Ленинград, 1925), «Нәфис экслибрис. 1917–1927» (Ленинград, 1928) күргәзмәләрендә катнаша. П.ның әсәрләре ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Омск сәнгать музеенда, А.С.Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Н.А.Некрасовның Ярославль өлкәсе Карабиха авылындагы «Карабиха» әдәби-мемориаль музей-тыюлыгында, РФАнең рус әдәбияты ин-тында (Пушкин Йорты, С.-Петербург); шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Сотонин К.И. Творчество А.Г.Платуновой. К., 1922; Дульский П.М. Современные Казанские графики // Гравюра и книга. 1925. № 1/2; Александра Георгиевна Платунова, Константин Константинович Чеботарёв: Каталог выставки. К., 1964; Ключевская Е.П. В поисках синтеза красок и звуков // Татарстан. 1995. № 1/2.

*Е.П.Ключевская.*

**ПЛАУ́Н** (Lycopodium), плаунчалар семьялыгыннан мәңге яшел күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 10 га якын төре билгеле. Төньяк ярымшарның урман зонасында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар: сөйрәлмә «мүк» (L. annotinum) һәм чукмарсыман П. (L. clavatum). Кама алдында очрыйлар. Күләгәле катнаш һәм ылыслы урманнарда, сазлыклы болыннарда үсәләр. Сабаклары шуышма, озынлыгы 30–150 *см*, тармакланган бәбәкләре бар. Яфраклары вак, куе, кыяк-ланцетсыман. Үсемлекнең үзенә генә хас исе һәм әче тәме бар. Спораларданн, үрчү бөреләреннән, бәбәк өлешләреннән үрчи. Майлы порошокны хәтерләтүче споралары ачык сары төстә, июнь–августта өлгерәләр. Сөйрәлмә «мүк»нең споралы башакчыклары ботакчыклар очында утыра. Чукмарсыман П.ның спораларында 50% ка кадәр май, органик к-талар, алкалоид, аксым бар; халык медицинасында бәвел һәм үт кудыру, ялкынсынуга каршы, адсорбент буларак кулланыла. Күпләп җыелганнан соң, П. фәкать 20–30 елдан соң гына гадәти продуктлылыгын яңарта ала. Декоратив, агулы үсемлекләр. 2 төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Чукмарсыман плаун.

**ПЛА́ХОВ** Анатолий Максимович (5.4.1917, Орёл ш. — 13.7.1998, Мәскәү), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971). Орёл индустриаль техникумын (1936), Мәскәү автомеханика ин-тын (1956) тәмамлый. 1946–70 елларда Мәскәү автомобиль з-дында: мастер, өлкән инженер, башлык урынбасары, цех башлыгы, технол. бүлеге башлыгы, транспорт-склад эшләрен механикалаштыру буенча баш конструктор. 1970–71 дә СССР Автомобиль сәнәгате министрлыгының Баш технолог идарәсе башлыгы. 1971–98 дә «КамАЗ» АҖдә: баш инженер, ген. директорның 1 нче урынбасары, КамАЗ дирекциясенең Мәскәү вәкиллегендә (1980 нән). П. пр-тие үсешенә өлеш кертә. Двигательләр з-дын проектлаштыруда турыдан-туры катнаша. Дәүләт бүләге җитештерүнең төп һәм ярдәмче процессларын комплекслы механикалаштыру системасын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: От АМО до КамАЗа // Подвиг на Каме. М., 1978.

*Әд.:* Родыгин А.А. Становление: Из опыта работы партийной организации КамАЗа. К., 1977.

*А.Б.Канеев.*

**ПЛЕМЕНКО́В** Виталий Владимирович (31.10.1939, Приморье краеның Киров р-ны Киров пос.), химик, химия фән. д-ры (1985), проф. (1985). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1983 тән Казан мед. ин-тында, биоорганик һәм биофизик химия каф. мөдире (1998 гә кадәр). Хезмәтләре стереохимиягә, табигый кушылмалар химиясенә карый. П. синтетик һәм табигый молекулаларның электрон һәм фәзаи төзелешен тикшерә. Циклик молекулаларда функциональ төркемнәрнең «бәйләнеш» һәм «фәза» аша үзара тәэсир итешүләрен микъдари сурәтли; ароматик кушылмалар рәтендәге төркемнәрнең электрон йогынтысын билгеләү өчен «парлылык-параллельлек» теоремасын чыгара һәм формалаштыра. Циклы кушу реакцияләренең механизмнарын һәм синтетик мөмкинлекләрен билгели. Тиазин рәте гетероциклларын һәм төрле карбоциклларны синтезлау өчен киеренке циклоолефиннар катнашында Дильс-Альдер реакциясен куллана. Оешмачәчәклеләр семьялыгы үсемлекләренең фотохимиясе, монотерпен һәм сесквитерпеннарны химик модификацияләү, изопреноидның күкертле биол. актив кушылмаларын синтезлау буенча хезмәтләр авторы.

Хезм.: Синтез караноидов с двумя сульфидными функциями из α- и β-тиоокисей 3-карена // Химия природных соединений. 1993. № 5 (автордаш); Электронное и пространственное строение монофункциональных циклопропанов // Журн. органической химии. 1997. Т. 33, вып. 6; Введение в химию природных соединений. К., 2001.

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПЛЕТЕНИ́** авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 23 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәрле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 91 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1927 дә Зур Подберезье авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән Кайбыч р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 264, 1949 да — 251, 1958 дә — 172, 1970 тә — 176, 1979 да — 174, 1989 да — 139, 2002 дә — 114 кеше.

**ПЛЕУ́ХОВ** Алексей Николаевич (15.12.1943, Казан — 14.2.2000, шунда ук), радиофизик, физика-матем. фән. канд. (1974). 1967 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Проблемалы радиоастрономия лаб-ясендә һәм радиоастрономия кафедрасында эшли, 1998 дән радиофизика каф. мөдире. Хезмәтләре метеорларны һәм метеор күренешләрен өйрәнүгә, аларны радиоэлемтәдә һәм метрологиядә гамәли куллануга карый. П. вакыт шкалаларын синхронлаштыруда радиометеорлар алымын куллануның потенциаль мөмкинлекләрен тикшерә һәм 1970 еллар өчен рекордлы синхронлаштыру төгәллегенә ирешә. Атмосферада электроннар концентрациясен билгеләү алымын, кыска дулкыннар диапазонында спектраль һәм почмак үлчәү тикшерүләре өчен үлчәү стендын эшли. Ионосфераның Е катламы беришсезлекләре барлыкка китергән стохастик радиоканал характеристикаларының 2 мең *км* дан кыскарак трассалар өчен кыска дулкынлы радиоэлемтәне тәүлек буе алып барырга һәм 2 мең *км* дан озынрак трассалар өчен радиоэлемтә вакытын, эшче ешлыкны алыштырмыйча,

3–4 тапкыр арттырырга мөмкинлек бирүен исәпләп таба.

Х е з м.: Невзаимность радиоволн в метеорном радиоканале // Изв. вузов. Радиофизика. 1988. Т. 31, № 5; КВ канал радиосвязи на частотах выше максимально применимой частоты. К., 2000; Спектральная обработка сигналов наклонного зондирования ионосферы с помощью параметрических методов // Изв. вузов. Радиофизика. 2000. Т. 43, № 7 (автордаш).

**ПЛЕЩЕ́ЕВ** Михаил Львович (? — 4.10.1683, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, стольник (1645), бояр (1682). 1654–55 елларда полякларга каршы яу б-н барган Зур полк есаулы. 1656 да, икмәк төялгән олауларны хәрәкәттәге армиягә җибәргәндә саксызлык күрсәткәне өчен, дәрәҗәләреннән мәхрүм ителүгә, утарлары тартып алынуга һәм Себергә сөрелүгә хөкем ителә, әмма ярлыкана. 1670–71 дә Саранск шәһәрендә воевода. 1672 дә кырым татарларына каршы яуда 2 нче воевода. 1677–79 да Казанда 1 нче воевода. Патша Фёдор Алексеевич реформалары нигезендә билгеләнгән идарә принципларын җиренә җиткереп үти; ришвәт һәм бүләкләр алмый, шул рәвешчә ул моңа кадәр күзәтелеп килгән эш башкару тәртипләренә каршы килә. П. идарә иткән вакытта Казан өязендә хуҗалык санын алу уздырыла һәм һәр хуҗалыкка салым түләү йөкләтелә. 1682–83 тә Зур казна приказының баш судьясы.

*Әд.:* Русский биографический словарь. СПб., 1905.

*Е.В.Липаков.*

**ПЛЕЩИ́НСКИЙ** Илларион Николаевич (17.11.1949, Казан — 2.7.2012, шунда ук), физиолог, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2003). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Удмурт АССРның Селычка посёлогында махсуслаштырылган балалар санаториенда балалар табибе булып эшли. 1978 елдан Казан ун-тында, кеше һәм хайваннар физиологиясе каф. мөдире (1996 дан). Хезмәтләре гадәти һәм патологик хәрәкәт б-н идарә итү өлкәсенә карый. П. арка мие травмасы вакытында рефлекция реакцияләрен яңадан кайтару динамикасын эшли. Кул-аяклар хәрәкәте бозылган шартларда арка нейроннарының ярсынучанлык үзгәрешен билгели, нәтиҗәдә нерв-мускул аппараты халәтенә йогынты ясый. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2009).


Х е з м.: Центральная нервная система и основы управления движением. К., 2006 (автордаш); Тормозные системы спинного мозга в контроле взаимодействий функционального сопряжения мышц // Физиология человека. 2007. Т. 33, № 1 (автордаш); Функциональное состояние нервных центров спинного мозга в условиях его травматического повреждения. К., 2008 (автордаш).

**ПЛЕЩИ́НСКИЙ** Илларион Николаевич (28.4.1892, Минск губ. Борисов өязе Докшицы ш. — 6.2.1961, Украина ССР, Киев ш.), график, педагог, проф. (1948). Сынлы сәнгатьтәге беренче күнекмәләрен Минскида рәссам Я.М.Кругердан ала. СА каршындагы Сәнгать әсәрләренә кызыксындыру җәмгыяте мәктәбенең И.Я.Билибин, А.А.Рылов, Н.И.Рерих остаханәләрендә шөгыльләнә. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, әсирлектә (Германия) офорт һәм литография техникасын үзләштерә, немец экспрессионизмы сәнгате б-н мавыга. 1918 елда Минскига кайта, гимназиядә укыта. 1919 дан Казанда яши, 1921 дә Казан дәүләт ирекле сәнгать остаханәләрен тәмамлый (к. *Казан сәнгать уч-щесе*), 1920 дән — литография остаханәсе, 1921 дән графикага өйрәтү остаханәсе б-н җитәкчелек итә. Н.С.Шикалов б-н берлектә «*Всадник*» графика коллективын оештыра. 1924 тә Киевка күчә. Киев сәнгать ин-тында (1924–34, 1944–61), Киев архит-ра ин-тында укыта (1934–41). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1948).

П.ның Казан чоры иҗаты — 1920 еллар башы графика сәнгатендәге иң якты һәм мөһим күренеш. Рәссамның мирасы төр (эстамп, плакат, китап графикасы, экслибрис) һәм жанр (шәһәр һәм табигать пейзажы, портрет, натюрморт, ялангач модель, жанрлы күренешләр, символик-аллегорик композицияләр) төрлелеге, төрле график техникаларда (классик офорт, коры энә, йомшак лак, ксилография, литография, линогравюра, акварель, карандаш, тушь) югары дәрәҗәдәге һөнәри осталыгы б-н аерылып тора. П.ның иҗаты «сул» агымнар һәм революцион темалар йогынтысыннан азат (соңгысы аның замангa ияреп язылган плакатларында чагыла).

П.ның Казан чоры графикасына тышкы тәэсирнең чынлыгына ирешү, экспрессив рәсемгә тартылу б-н бергә, минимализм эстетикасыннан баш тарту, фактуралы уйлап табуга, караңгылык һәм яктылык, таплар һәм сызыклар композицияләренә һәм контрастларына омтылу хас. 1924 тән аның чагылдыру чараларының график гадилеген һәм лирик хисләренең үтә ачыклыгын характерлаучы әсәрләре барлыкка килә. Алар арасында — «Бәрелеш» (линогравюра, 1920), «Урам» (литография, 1920), «Пианинода уйнаучы В.С.Плещинская» (йомшак лак, 1923), «Көлтә бәйләүче уракчы хатыннар» (офорт, коры энә, 1923), «Иделдә» (офорт, 1923), «Доктор Петлицкий портреты» (офорт, 1924), «Лампалы натюрморт» (офорт, коры энә, 1923), «Георгиевский урамы. Казан» (коры энә, 1923–24), «Паркта» (акварель, 1924), «Иртәнге аш. В.С.Плещинская» (офорт, коры энә, 1925), «Кер юу» (офорт, аквапинта, 1925) әсәрләре бар.

П. — Казан рәссам-графикларының «Всадник» коллективының иҗат һәм нәшрият эшчәнлегендә актив катнашучыларның берсе, аның нәшрият маркасы (1920), «Всадник» альманахының 1 нче чыгарылыш тышлыгы һәм шул исемдәге 1 нче күргәзмә каталогының авторы (1920), шул исемдәге ике альманахта катнаша (1920, 1921). Өч гравюра альбомнары: «Литографияләр», «Офортлар» (икесе дә — 1920), «Автолитографияләр» (1921), Г.Тукайның П.Радимов тәрҗемәсендә «Шүрәле», «Кәҗә белән Сарык» әкиятләренең тышлыклары һәм иллюстрацияләре, П.М.Дульскийның «Казан архитектурасында классицизм» (1920), З.Славянованың «Эшче-крестьян театры» китапларының тышлыклары (1921), Казан шагыйрьләренең «Сүзләр тараны» һәм В.Клюеваның «Верхарн. Тәрҗемәләр» җыентыклары тышлыкларының (икесе дә — 1921) авторы. Үзе җитәкләгән ташбасмаханә остаханәсендә басылган «Профсоюзлар — житештерү этәргече», «Производство союзлары, производствоны үзләштерергә әзерләнегез», «Коммунизм өчен капитализм белән соңгы хәлиткеч сугышка күтәрелик» (барысы да — 1921) плакатлары да аның куллары б-н ясалган.



И.Н. П л е щ и н с к и й. «Георгиевский урамы. Казан». Кәгазь, коры энә. 1923–24. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

П.ның Киев чоры иҗатына 1920 еллар сәнгате стиленнән баш тарту һәм натурадан алган тәэсирләрне турыдан-туры рәсемгә, офортка, башлыча, камера-лирик пейзажлы жанрларга тапшыру хас. «Всадник» график коллективының 1 нче күргәзмәсендә (Казан, 1920), Советск музейлар һәм борынгы һәйкәлләрне саклау бүлекчәсенең 2 нче һәм 3 нче күргәзмәләрендә (Вятка губ., Советск ш., 1920, 1921), «Казан, алга!» сынлы сәнгать күргәзмәсендә (Казан, 1924), 14 нче Халыкара сәнгать күргәзмәсендә (Венеция ш., Италия, 1924), Бөтенсоюз полиграфия күргәзмәсендә (Мәскәү, 1927; 2 нче бүләк), «Казан плакаты» (Казан, 1929), «Рус сәнгате» (Винтертур ш., Швейцария, 1929), 2 нче Халыкара гравюралар күргәзмәсендә (Филадельфия, АКШ, 1931) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1922, 1924 (Казан), 1939 (Киев) елларда уздырыла.

П.ның әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Луганск сән-



И.Н. П л е щ и н с к и й. «Урак өсте». Кәгазь, акварель. 1924. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.



Б.Н.Плотников.

гать музеенда (Украина), шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Выставка гравюр и рисунков И.Н.Плещинского: Каталог. К., 1924; Д у л ь с к и й П.М. Современные Казанские графики // Гравюра и книга. 1925. № 1/2; К л ю ч е в с к а я Е.П. Гравёрное отделение Казанской художественной школы. 1896–1929 // Вопр. худож. образования. 1984. Вып. 34; Сулф, ЛЕФ, ТатАХРР: Каталог выставки произведений художников Татарии 20–30 годов. К., 1990; Архумас: Казанский авангард 20-х: Каталог выставки. М., 2005.

*Е.П.Ключевская.*

**ПЛЕЩИ́НСКИЙ** Николай Борисович (24.2.1955, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1997), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли, гамәли матем. каф. мөдире (2007 дән), бер үк вакытта Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының гамәли матем. физика каф. мөдире (2000 нән). Хезмәтләре матем. физикага, матем. модельләштерүгә һәм хисаплау математикасына карый. П. операторлы тигезләмәләрне якынча алымнар б-н чишүнең гомуми теориясен төзи; логарифмик, дәрәҗәле һәм катлаулы төшле интеграль тигезләмәләр чишү теориясен һәм алымнарын тәкъдим итә; дулкыннарның таралуы һәм дифракциясе теориясенең туры һәм кире мәсьәләләрен чишү алымнарын күрсәтә.


Х е з м.: Приложения теории интегральных уравнений с логарифмическими и степенными ядрами. К., 1987; О некоторых классах интегральных уравнений, разрешимых в замкнутой форме // Дифференциальные уравнения. 1989. Т. 25, № 3; Zur Optimierung einer klasse von Integral functionalen im Raum der stetigen Funktionen // Math. Nachr. 1988. V. 136.

**ПЛЕЩИ́ЦЕР** Ария (Арон) Яковлевич (1889, Могилёв ш. — ?), профпатолог, мед. фән. д-ры (1940). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1923), Казан ГИДУВының терапия клиникасында эшли, 1932 елдан һөнәри-техник авырулар кафедрасында, бер үк вакытта, 1932–33 тә, директор вазифаларын башкаручы. 1944 тән Социаль гигиена фәнни-тикшеренү ин-тында (Свердловск ш.). Һөнәри авыруларны тикшерүче.

Х е з м.: Алкоголизм и общественная борьба с ним // Казан. мед. журн. 1929. № 11 (Кушымта); Биологическая роль магния. М., 1955.


**ПЛЁНКИН** Александр Павлович (2.11.1946, Халтурин ш., хәзер Киров өлкәсенең Орлов ш. — 25.3.2010, Казан), геолог-икътисадчы, геогр. фән. канд. (1978), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), ЦНИИгеолнерудта (1989 дан сектор мөдире). 2007 елдан РФ Табигать ресурслары министрлыгының ТР буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану идарәсенең геол. бүлеге башлыгы урынбасары. Хезмәтләре руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе һәм икътисадына карый. П. РФ регионнарында минераль төзелеш чималы, агроруда, минераль сорбентларның тераәк базаларын булдыру һәм үзләштерүдә, Чернобыль авариясе нәтиҗәсендәге зыянны бетерүдә катнаша. Дәүләт бүләге ТР төзелеш материалларын геол.-икътисади яктан тикшерүләре өчен бирелә. Батырлык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПЛО́МБА-ГЕРЛӘ́Р** (археол.), үзәге тишекле, диаметры 3 *см* лы түгәрәк рәвешендәге, урта гасырларда кулланылган сәдәф сыман кургаш, сирәгрәк бронза эшләнмә. Өске ягы еш кына орнамент б-н бизәлгән. П.-г.гә охшаш әйберләр Таҗикстанда Төрки каганлыгы чоры культура катламында, *Танкеевка каберлегендәге* мәҗүсиләр каберләрендә (35 П.-г.),



Бронза һәм кургаш пломба-герләр. Танкеевка каберлеге. 9–10 йөзләр (әлгәреге болгарлар).

*Биләр шәһәрлегендә* (80 нән артык П.-г.) табыла. Бу эшләнмәләрнең нинди максатта файдаланылуы әлегә төгәл генә ачыкланмаган. Күп кенә тикшеренүчеләр фаразлаганча, П.-г. Идел буе Болгар дәүләте терр-ясендә акчасыз чорда (11–12 йөзләр) түләү чарасы сыйфатында кулланылган. Алар болгарларга 9 йөзнең 2 нче яртысында Урта Азиядән кергән.



Бронза һәм кургаш пломба-герләр. Идел буе Болгар дәүләте.

Бизәкле өске ягыннан һәм аскы ягының кырылган булуыннан чыгып фикер йөрткәндә, П.-г.нең ш.у. ниндидер өстәл уенында шашка яки орчык башы буларак кулланылуы да ихтимал.

*Әд.:* Культура Биляра. М., 1985; К а з а к о в Е.П. Культура ранней Волжской Болгарии. М., 1992.

*Е.П.Казаков.*

**ПЛО́ТНИКОВ** Борис Николаевич (21.7.1915, хәзер Волгоград өлкәсе Камышин ш. — 28.4.1969, Казан), Дан орденының тулы кавалеры (26.9.1944, 4.2.1945, 5.5.1945; 7.6.1968 дә кабат бүләкләнә), старшина. Туган ягында тракторчы булып эшли. 1937 елның маеннан Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 65 нче аерым танк полкы танкисты (48 нче һәм 8 нче гв. армияләре). Брянск, Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Елец һәм Малоархангельск юнәлешләрендәге (1943), Курск дугасында (1943), Чернигов-Припять (1943), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 5 сентябрендә Папюрке-Бутне (Белосток өлкәсе, хәзер Польша) торак пункты янындагы сугышта (танк экипажы б-н бергә дошманның 10 нан артык солдатын юк итә, танкны, танкка каршы тупны сафтан чыгара); 1945 нең 18 гыйнварында Лодзь (Польша) шәһәреннән төньяк-көнчыгыштарак торак пункт янындагы сугышта (танкның яраланган механик-йөртүчесен алыштыра, 10 нан артык автоматчыны юк итә, берничә автомашинаны яндыра, 4 тупны һәм 2 миномётны сафтан чыгара); 1945 нең 10 апрелендә Ратшток (Германия) торак пункты янында дошман оборонасын өзгәндә (дошманның 20 дән артык солдат һәм офицерын юк итә, штурм тубын, танкка каршы 4 тупны сафтан чыгара) батырлык күрсәтә. 1965 тә запаска җибәрелә. Горький тимер юлының Казан станциясендә эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПЛО́ТНИКОВА** Ирина Николаевна (9.11.1960, Әлмәт ш.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2007). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), «Татнефть» ҖБнең «Татнефтегазразведка» трестында тематик партия геологы булып эшли. 1985 елдан Украина ФАнең Геол. фән. ин-тында, 1994 тән «Татнефть» АҖнең Татарстан геол. разведка идарәсендә (1996 дан партия башлыгы), 2000 нән ТРның Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының геол. бүлеге башлыгы, 2006–08 дә РФнең Табигый ресурслар министрлыгы Җир асты байлыкларыннан файдалану федераль агентлыгының ТР буенча җир асты байлыкларыннан файдалану идарәсе башлыгы. Бер үк вакытта, 2005 тән, Казан ун-тында, нефть һәм газ геологиясе һәм геохимиясе каф. мөдире. Хезмәтләре нигез кристаллик токымнарының нефть-газлылыгына карый. П. Татарстанның кристаллик нигезен геохимик, битуминологик, гидрохимик тикшерү мәгълүматларын системалаштыру һәм гомумиләштерү (1970 еллардан) б-н шөгыльләнә.

Х е з м.: Нефтегазоносность кристаллических пород фундамента осадочных бассейнов Евразии. Киев. 1987; Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоносности. К., 1996 (автордаш); Геологогеофизические и геохимические предпосылки перспектив нефтегазонос-

ности кристаллического фундамента Татарстана. СПб., 2004.

**ПЛУ́ГИНА** Татьяна Александровна (2.2.1947, Белоруссия ССРның Минск өлкәсе Минск р-ны Югары Уручье а.), гидрогеолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), геол.-минерал. фән. канд. (1979). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1972). «Гидрогеология һәм геоэкология компаниясе» АЖдә (Мәскәү, 1991 дән) эшли. Дәүләт бүләге Татарстан терр-ясендә җир асты төче суларын эзләү һәм запасларын бәяләү алымын эшләүдә һәм кулланышка кертүдә катнашканы өчен бирелә.

**ПЛЮ́ШКИН** Александр Васильевич (20.5.1948, Казан), спортчы (академик ишү), Россиянең атказ. спорт остасы (2005), РФнең атказ. физик культура хезмәткәре (1993). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1974). Спорт б-н 1965 елда «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә шөгыльләнә башлый, 1966 дан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Казан, тренеры В.Т.*Глухих*). РСФСР (1967, 1971), СССР (1975) халыклары спартакиадаларында, СССР (1971–76), Европа (1973) чемпионатларында җиңүче. Дөнья чемпионатларында (1974–75) көмеш медаль ала, Олимпия уеннарында катнаша (1976). 1977–79 да СССР физик культура һәм спорт ком-тының ТАССР буенча тренеры, 1980 нән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советы рәисе урынбасары, 2000–03 тә «КамАЗ-Автоагрегат» АЖ ген. директоры урынбасары, вәкиллек директоры, 2004 тән Казанда «КамАЗ» АЖ вәкиллеге директорының 1 нче урынбасары. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, «ТРның мактаулы динамочысы» билгесе б-н бүләкләнә.

**ПОБЕ́ДА** посёлогы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 26 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 786 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1930 да нигез салына. Беренче исеме — Сокольский, 1931 дән — Вахитов исем. совхоз посёлогы, 1962 нең 28 маеннан хәзерге исемдә. Оештырылган көннән Тымытык р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 300, 1958 дә — 527, 1970 тә — 823, 1979 да — 888, 1989 да — 773, 2002 дә — 844 кеше.

**ПОБЕ́ДА** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Карабаш сусаклагычыннан 2,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда — 453 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 58%, татарлар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. 1960 ның 16 февралендә торак пункт буларак теркәлә. Оештырылган көннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1970 тә — 455, 1979 да — 380, 1989 да — 300, 2002 дә — 490 кеше.

**ПОБЕ́ДА** (Лобашки) посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 13 *км* көнбатыштарак, Бәрле елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 19 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920–30 еллар чигендә нигез салына. Оештырылган көннән Кайбыч р-нында. 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1938 дә — 137, 1949 да — 88, 1958 дә — 95, 1970 тә — 93, 1979 да — 67, 1989 да — 35, 2002 дә — 24 кеше.

**ПОБЕ́ДА** посёлогы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тормы елгасы бассейнында. 2010 елда 13 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920–30 елларда Олы Шәмәк авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оештырылган көннән ТАССРның Буа кантоны Олы Шәмәк волостенда. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1938 дә — 135, 1949 да — 118, 1958 дә — 146, 1970 тә — 116, 1979 да — 44, 1989 да — 23, 2002 дә — 15 кеше.

**«ПОБЕ́ДА ТРУДА́» ХИ́МИЯ ЛАБОРАТО́РИЯСЕ ПРИБОРЛАРЫ́ ҺӘМ САВЫ́Т-САБА́ ЗАВОДЫ́**, к. *Васильево пыяла заводы.*

**ПОБЕДИ́МСКИЙ** Дмитрий Глебович (10.6.1941, Ташкент ш.), химик, химия фән. д-ры (1978), проф. (1980), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1990), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). 1964 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, сәнәгый биотехнол. кафедрасын оештыручы һәм аның җитәкчесе, биоинженерия ф-ты деканы (1982 дән). 1992 дән Мәскәү нечкә химия технологияләре академиясендә, бер үк вакытта, 1993 тән, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Респ-ка фәнни-консультатив тикшеренү-экспертиза үзәгенең баш фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар деструкцияләү һәм стабильләштерү химиясенә һәм химик физикасына, биотехнологияләргә карый. П. ферментлар деструкциясе һәм стабилизациясенең физик-химик нигезләрен эшли. Полимерларда, углеводородларда һәм тере системаларда химик оксидлашу процессларын антиоксидантлар б-н көйләүнең төп нигезләрен гомумиләштерә; күзәнәк метаболитлары биосинтезы көйләгечләре буларак, экзоген антиоксидантлар тәэсиренең синергизм күренешен ача; микроблы аксым продуктларын, аминок-талар һәм органик к-талар синтезлауның сәнәгый процессларын көчәйтү буенча күп кенә гамәли нәтиҗәләр ала. Гомоген реагентлар, дисперс фазалар һәм иммобильләшкән күзәнәкләр нигезендә сәнәгый пычрак суларны биочистартуны яхшыртуның физик-химик ысулларын тәкъдим итә; биологик актив матдәләр биосинтезы процессларын көчәйткеч тәэсирле химик һәм биологик өстәмәләр нигезендә камилләштерүгә ирешә. Фәнни хезмәтләренең нәтиҗәләре «Түбәнкаманефтехим», «Казаноргсинтез» АЖләрендә, «Башбиофарм» ЖБдә (Башкортстан АССР), Фрунзе антибиотиклар з-дында (Кыргызстан ССР) һ.б.да гамәлгә кертелгән. Югары уку йортлары өчен «Ясалма каучуклар өчен мономерлар химиясе һәм технологиясе» («Химия и технология мономеров для синтетических каучуков», Л., 1981), «Микробиологик җитештерүләр технологиясенең теоретик нигезләре» («Теоретические основы технологии микробиологических производств», М., 1990) дәреслекләре авторларының берсе. Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы бар. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1974). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Регуляция химических процессов антиоксидантами: Методологические подходы и их реализация // Журн. физ. химии. 1991. Т. 65, № 7; Phosphororganic stabilizers for polimers; efficency and mechanisms of action // Developmentes in Polimer Stabilization. 1980. V.2, № 4; Metal complexes with ligands-organic phosphits aspolyolefin antioxdants // J. Polymer Sci. 1980. V. 18.

*Әд.:* Российская академия естественных наук: Энцикл. СПб., 1998; Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ПОВАРИ́СОВ** Суфиян Шәмсетдин улы (29.8.1924, Бөре кантоны, хәзер БРның Илеш р-ны Тыпый а.), тел галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1992), БРның һәм ТРның атказ. фән эшлеклесе (1992, 2005). РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1997). БРның халык язучысы (2012). Татар һәм башкорт телләрендә яза. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955), Актаныш р-нының Бурсык мәктәбе директоры булып эшли. 1958–60 елларда «Кызыл таң» (Уфа) г-тасында әдәби хезмәткәр. 1960 тан Башкорт ун-тында. Хезмәтләре татар теленең стилистика, лексика, морфологиясенә, әдәби сүз сәнгатенә карый. Урта мәктәп һәм югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы. «Яратам сине, тормыш» (Уфа, 1963), «Сөмбел» (Уфа, 1973), «Ышанам һиңә» (Уфа, 1984), «Йәшлек йылдары» (Уфа, 1992) һ.б. повестьларында әхлакый мәсьәләләр күтәрә, «Биш партизан» (Уфа, 1987), «Үлемһеҙҙәр юлы» (Уфа, 1996) повестьларында, «Яҙмыш корбандары» (Уфа, 1996) һәм «Ут эсендәге мөхәббәт» (Уфа, 2005) автобиографик романнары Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышы вакыйгаларына багышлана. Татар әдәбияты классигы Г.*Ибраһимовның* фаҗигале язмышы «Пәйгамбәр таңы» (1999), «Күкнең җиденче катында» (1999), «Оҗмахка бер адым» (2000) китапларыннан торган трилогиядә чагылыш таба. П. — «Һөйҙергән дә тел, биҙҙергән дә тел» (Уфа, 1969), «Кәрлә йондоҙ» (Уфа, 1974), «Ауылымдың алһыу таңдары» (Уфа, 1986) һ.б. пьесалар авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, 3 нче дәрәҗә Дан ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Тел — күңелнең көзгесе. К., 1982; Татар телендә чагыштырулар. Уфа, 1996; Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. Уфа, 1997; Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1999–2000; Язык и стиль прозы. Уфа, 1979; Легенды о счастье. Уфа, 1985.

*Әд.:* Суфиян Шамсутдинович Поварисов: Биобиблиогр. указ. Уфа, 2005.

*С.Г.Сафуанов.*

**ПО́ВЕСТЬ**, *хикәя* һәм *роман* арасында торган урта күләмле чәчмә жанр. Урта гасырлар төрки-татар әдәбиятында аңа дини, үгет-нәсихәт бирү характерындагы *хикәят* һәм *кыйсса*лар якын тора. Татар әдәбиятында П. 19 йөзнең 2 нче яртысында формалаша. Жанр мәгърифәтчелек әдәбияты кысаларында гамәлгә куела (татар җәмгыятенең сүз көченә таянып, Европа үрнәгендә үсү мөмкинлеге турындагы идея). Иҗтимагый проблемалар күтәрүе, тормышка тирән иҗтимагый-фәлсәфи бәя бирергә омтылуы б-н П.: социаль-көнкүреш (Р.Фәхретдин «Сәлимә, яки Гыйффәт», «Әсма, яки Гамәл вә җәза»; Г.Гафуров «Тутам»; Г.Исхакый «Кәләпүшче кыз», «Бай угълы»), романтик (Ф.Кәрими «Морза кызы Фатыйма»), иҗтимагый-тәнкыйди (З.Һади «Яңа әсхабе кәһәф» («Яңа тау тишеге»), «Җиһанша хәзрәт»), сатирик (Ш.Мөхәммәдов «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай», «Яфрак асты, яхуд Мәкәрҗә ярминкәсе») һ.б.) төрләргә бүленә. 20 йөз башында мәгърифәтчелек карашлары заманга карата тәнкыйди мөнәсәбәт б-н алмашына, чынбарлыкның шартлы моделен булдыру омтылышы барлыкка килә. Аның нигезен фантастик эчтәлекле пародия (Ф.Әмирхан «Фәтхулла хәзрәт»), автобиографик мотивлар (Г.Исхакый «Зиндан»; Г.Тукай «Исемдә калганнар», Ф.Әмирхан «Тәрҗемәи хәлем») тәшкил итә. Башлыча, психол. (Г.Исхакый «Тормышмы бу?»; Ф.Әмирхан «Хәят»; М.Гафури. «Хәмитнең хаяты», «Мәхәббәт хатлары»), иҗтимагый (Ш.Камал «Акчарлаклар») һәм романтик-психол. (С.Җәләл «Дим буенда»; Г.Исхакый «Очрашу, яки Гөлгыйзар», «Остазбикә») мәсьәләләр күтәрелә.

1920–30 елларда татар әдәбияты сәяси һәм идеологик басым кичерә. Күптөрле эстетик омтылышлар янәшә яшәгән чор шартларында соц. идея б-н бәйле яңа әдәби система формалаша. Әйдәп баручы урынны Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы вакыйгаларына (Г.Ибраһимов «Кызыл чәчәкләр»; Г.Бәширов «Сиваш»), күмәкләштерү чорына багышланган (К.Нәҗми «Кояшлы яңгыр», «Якты сукмак»; М.Әмир «Агыйдел») героик-романтик һәм героик-трагик П. ала. Соц. үзгәрешләрне ирония б-н шәрехләү омтылышы Ф.Әмирханның «Шәфигулла агай» сатирик шаржында, татар П.еның милләт язмышына игътибар бирүе ягыннан рев-циягә кадәрге традицияләрне үстерү Гали Рәхимнең символларга бай романтик рухлы «Идел» әсәрендә күзәтелә. Ләкин бу омтылышлар, башкача фикер йөртүчеләргә каршы кампания башлангач, кире кагыла. Башлыча, көнкүреш П.е төзелеп ятучы яңа тормыштагы кискен соц. конфликтларны чагылдыру мөмкинлеген тудыра. Әйтик, А.Шамовның «Рәүфә» П.е дини хорафатларга, искергән карашларга каршы чыгып, тормышта үз урынын тапкан авыл хатыны язмышына багышлана. Г.Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» П.ендагы Галия образы мисалында мәхәббәткә, гаиләгә, хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урыны һәм роленә кагылышлы булган искелек б-н яңалык конфликты күрсәтелә. Соц. җәмгыять төзү процессы, эшче яшьләрнең көндәлек тормышы И.Газинең «Көмеш сулы Нурминкә», «Бригадир кыз» П.енда чагылыш таба. Соц. идеяне раслап, язучылар үткәннәргә мөрәҗәгать итәләр, бүгенге көнне тарихи ретроспективада карыйлар (Г.Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми»; М.Гафури «Кара йөзләр», «Шагыйрьнең алтын приискасында»), фантастик-романтик формалар кулланалар (Ш.Усманов «Памирдан радио»). 1921 елгы ачлыкны тасвирлау натуралистик һәм публицистик тенденцияләрне көчәйтә (Г.Ибраһимов «Адәмнәр»). Производство һәм колхоз төзү, Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышы турында язучы проза авторлары әдәби тормышның алдынгы сафына чыга.

1940–50 дә П. жанры сүлпәнәя төшә. Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын героик-романтик төстә күрсәтү Ф.Кәримнең «Разведчик язмалары», «Язгы төндә» П.ларында чагылыш таба. Сугыш көндәлеген тасвирлаганда, автор фәлсәфи гомумиләштерүгә омтыла (конкрет вакыйгалар ике дөньяның бил алышуы төсен ала), фашизмның кешелек өчен фаҗига булуын ассызыклый. Сугыш еллары прозасында лирик тәүбә традицияләре үсеш ала. Ф.Хөснинең мәхәббәт, тугрылык, дуслык һәм хыянәт турындагы «Йөзек кашы» П.нда лирик-психол. башлангыч көчле: сугыш кешенең әхлакый пакьлеген һәм намусын сынау аша уздыручы факторга әверелә. Г.Кутуйның «Рөстәм маҗаралары» П.енда мавыктыргыч маҗаралы форма җиңүгә какшамас ышаныч б-н үрелеп бара.

Сугыш темасы әдәбиятта сугыштан соң да әйдәп баручы булып кала бирә. Н.Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» социаль-психол. П.ларында немец лагерьлары, сугыш елларының фаҗигале мизгелләре тасвирлана. 1960 нчы елларда Ш.Рәкыйпов татар әдәбиятында беренче булып документаль П. жанрында яза башлый. Аның «Чәчәкләр сөйли белә», «Кайдан син, Жан?», «Кызлар-йолдызлар», «Кипарислар җыры» һ.б. әсәрләрендә чын язмышлар һәм конкрет кешеләр каһарманлыгы күрсәтелә. Фронтовикларның тыныч тормышка кайтулары Ф.Хөснинең «Җәй башы» П.енда тасвирлана. 1950 еллар П.е татар авылы тормышын яңа яктан ача.

И.Газинең «Алмагачлар чәчәк ата», Ә.Еникинең «Рәхмәт, иптәшләр» П.ларында тормышка искечә һәм заманча караш конфликты совет чынбарлыгында яшәп килгән күп кенә проблемаларны фаш итә. Колхозлар төзү эшенең киеренкелеген, кискенлеген, җитәкчеләрнең тар фикерле, каты бәгырьлелеген, шәхси байлык тупларга омтылуларын ачып бирү б-н бергә, авторлар бер үк вакытта кешенең тормышны үзгәртә алуына ышанып, фидакарь герой-активист образлары тудыралар (Ә.Еники «Саз чәчәге», «Рәшә»; Ф.Хөсни «Авыл өстендә йолдызлар»).

Татар әдәбиятында П. жанрының чәчәк ату чоры 1960–80 елларга карый. Автобиографик П. активлаша. Балачак темасына мөрәҗәгать итеп, әдипләр милли тарих (бигрәк тә 20 йөз башын) һәм тоталитаризм чорының ачы чынбарлыгын тасвирлау мөмкинлекләрен эзли. И.Газинең «Малай чак», Р.Төхвәтуллинның «Җиләкле аланнар», М.Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», «Хатирәләр урманы», Ф.Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Ә.Еникинең «Соңгы китап», Г.Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», Г.Минскийның «Яшенле яңгыр», Ш.Маннурның «Агымсуларга карап», Г.Ахуновның «Йолдызлар калка» кебек автобиографик материалга нигезләнеп язылган П.ларында күп кенә милли, иҗтимагый, фәлсәфи мәсьәләләр күтәрелә.

«Авыл» повесте, тормышны әхлакый-фәлсәфи караш аша тасвирлавы, халыкның гореф-гадәтләренә мәхәббәте, зирәклеге б-н соцреализм схемачыллыгыннан арыну юлын күрсәтә. Р.Төхвәтуллинның «Авылдашым Нәби», «Йолдызым», А.Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», Ә.Баянның «Яшьлегемне эзлим» П.ларының геройлары — буыннарның күпгасырлык тәҗрибәсен саклаучылар, халыкның әхлакый васыятен үтәүчеләр. Алар тормышка, табигатькә, кешеләргә карата рухсыз, үз ихтыяҗларын гына канәгатьләндерүгә корылган мөнәсәбәткә каршы куела. Лирик пафосның тыгызлыгы, символларга мөрәҗәгать итү, тормышны фәлсәфи танып-белү һәм кешенең әхлакый принциплары арасындагы элемтәләрне эзләү П.ның үзенчәлекләрен тәшкил итә. Татар авылының бүгенгесенә эпик караш аша авторларның күбесе 20 йөз тарихын тулаем күрсәтә, күмәкләштерү, шәхес культы чорларын, көчле кешенең сындырылуын бәяләргә омтыла, укучы игътибарын татар халкы өлешенә төшкән сынауларга юнәлтә (Н.Фәттах «Кырык дүртнең май аенда»; А.Гыйләҗев «Өч аршын җир», «Җомга көн, кич белән»; Г.Ахунов «Чикләвек төше»). Геройларын трагик вакыйгалар аша уздырып, прозаиклар кешегә, язмышка каршы торырга ярдәм иткән көч һәм кыйммәтләрне барлый (Хәсән Сарьян «Бер ананың биш улы»; М.Мәһдиев «Кеше китә — җыры кала»; А.Гыйләҗев «Яра»). 1970–80 еллар татар авылын игътибар үзәгенә куеп, авторлар матди муллыкка омтылу, рухи кыйбланы югалту б-н бәйле яңа конфликтлар таба (А.Гыйләҗев «Әтәч менгән читәнгә»). Татар авылының үткәнен бүгенге көн күзлегеннән чыгып яктырту һәм бәяләү аша, П. 20 йөз тарихына гомуми караш формалаштыра. ГУЛАГ темасы беренче тапкыр нәкъ менә П. жанрында чагылдырыла (И.Салахов «Колыма хикәяләре»). Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын яңадан бәяләү өчен ш.у. П. жанрына мөрәҗәгать ителә (М.Юныс «Биектә калу»). Сәнәгать темасына багышланган П.та экологик (М.Әмир «Балыкчы ялганнары»; Г.Ахунов «Артышлы тау буенда»; Р.Төхвәтуллин «Агымсу») һәм иҗтимагый (А.Расих «Ике буйдак», «Сынау») мәсьәләләр заманча көн тәртибенә куела.

20 йөз ахырында П.ның төрле стиль агымнарына, үсеш юнәлешләренә бүленүе аның үсеш үзенчәлегенә дә тәэсир ясый. Өлкән буын прозаиклар тормышның иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә (Г.Бә-

широв «Күзгә ачы җилләрдә», «Сарут»; Г.Ахунов «Этләр патшасы»; Р.Батулла «Юл буенда зәңгәр чәчәк» һ.б.) Җәмгыятьтә дә, кеше күңелендә дә канәгатьсезлек тойгылары көчәя (Ә.Баян «Урланган ай»; М.Галиев «Ерак урман авазы»). Ф.Бәйрәмованың «Болын», «Битлек», «Кем?» экзистенциаль-психол. П.лары һ.б. татар П.еның жанр чикләрен киңәйтеп җибәрә. П.лар психологизм алымнарын, символлар һәм метафорик образлар куллануның өр-яңа мөмкинлекләрен ача. Дини һәм мифологик символиканың иҗтимагый төгәллеккә омтылу б-н кушылуы Ф.Бәйрәмова карашларының фәлсәфи тирәнлеген тәэмин итә («Канатсыз акчарлаклар», «Кыңгырау»). Милли дөнья картинасын сурәтләү омтылышы, милли характерны, милләт образын тергезү 20–21 йөзләр чиге прозасында үзенчәлекле күренеш була (А.Хәлим «Өч аяклы ат», «Татар вакыты»; В.Имамов «Япон татары»). Н.Гыйматдинова әсәрләрендә шартлылыкның мифологик төре магик, мистик сыйфатлар б-н кушылып, ике төрле тормыш моделе тудыра: «Сихерче», «Ут күбәләге», «Кыргый», «Ак торна каргышы» һ.б. Гыйбрәтле хикәянең корылыш тәртибенә нигезләнеп, прозаиклар кеше психикасының аң һәм аң төпкеле өлкәләрен тасвирлау объектына әйләндерә (Ф.Бәйрәмова «Алыплар илендә»; З.Хәким «Курку»; Ф.Садриев «Рәхмәт, әтием!..»; Разил Вәлиев «Эт кояшы» һ.б.) Советлардан соңгы җәмгыятьтә кешенең рухи таркалуга йөз тотуы З.Хәкимнең «Кишер басуы», М.Кәбировның «Сары йортлар сере», Факил Сафинның «Соңгы көз»ендә ассызыклана. Гасырлар чигендә П.та романтик караш (М.Галиев, М.Кәбиров, Мансур Вәлиев, Ә.Салах) һәм сентиментальлек активлаша (Ф.Яруллин, Ф.Садриев). Бүгенге татар П.еның аерылып торган сыйфаты — фәлсәфи һәм психологик тирәнлеккә омтылу.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. К., 1989–2001; З а һ и д у л л и н а Д.Ф. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). К., 2006.

*Д.Ф.Заһидуллина.*

**ПОГО́ДИН** Сергей Николаевич (22.3.1956, Хабаровск ш.), генерал-майор (2001). М.В.Фрунзе исем. Киев югары гомумгаскәри командирлар уч-щесен (1977), М.В.Фрунзе исем. хәрби академия (Мәскәү, 1987), РФ Кораллы Көчләре Генштабының хәрби академиясен (Мәскәү, 1999) тәмамлый. 1977–82 елларда Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә мотоукчы взвод командиры, рота командиры. 1982–84 тә Киев хәрби округында, 1982–83 тә 1 нче гв. гомумгаскәри армиянең 136 нчы гв. мотоукчы дивизиясендә мотоукчы батальон командиры урынбасары — штаб башлыгы, 1983–84 тә 46 нчы мотоукчы дивизиядә 1215 нче мотоукчы полкның мотоукчы батальоны командиры урынбасары — штаб башлыгы. 1987–97 дә Байкал аръягы хәрби округында, 122 нче мотоукчы дивизиядә 382 нче мотоукчы полкның мотоукчы батальоны командиры, 1987–88 дә 36 нчы гомумгаскәри армиядәге 18 нче ныгытылган р-нның танк уты нокталары 578 нче аерым батальоны командиры, 1988–93 тә 36 нчы гомумгаскәри армиядәге 38 нче гв. мотоукчы дивизиянең 408 нче гв. мотоукчы полкы командиры урынбасары — штаб башлыгы, 1993–95 тә 131 нче гв. пулемёт-артиллерия дивизиясендә 408 нче гв. мотоукчы полк командиры, 1995–97 дә 55 нче армия корпусының 168 нче аерым мотоукчы бригадасы командиры. 1999–2002 дә Кавказ аръягы Россия гаскәрләре төркемендә 62 нче хәрби база командиры. 2002–06 да Төньяк Кавказ Хәрби округында 58 нче армия командующие урынбасары. 2006 елдан ТРның хәрби комиссары. «Хәрби казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПОДБЕРЁЗЬЕ РАЙОНЫ́**, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә *Кайбыч районының* бер өлешеннән оештырыла. Үзәге — Олы Подберезье авылы. 1948 дә П.р.ның мәйданы 524 *км*$^2$ була, анда 16 авыл советы, 37 торак пункт исәпләнә. 1956 ның 14 маенда район, терр-ясе Кайбыч р-нына бирелү сәбәпле, таркатыла.

**ПОДБО́РНЫЙ КҮЛЕ́**, Кончыгыш Кама аръягында. Элекке су юлында сакланып калган күл. Кама елгасының уңъяк тугаенда урнашкан, Түбән Кама ГЭСы плотинасыннан түбәндәрәк, Алабуга р-ны Луговой бистәсеннән көньяк-көнчыгыштарак, Түбән Кама милли паркының көньяк чигендә. Су өслегенең мәйданы 41 *га*. Су күләме якынча



Подборный күле.

600 мең *м*$^3$. Озынлыгы 3690 *м*, иң зур киңлеге 170 *м*, уртача тирәнлеге 1,5 *м*, иң зур тирәнлеге 2 *м* тирәсе. Формасы озынча. Төньяк яры текәрәк һәм күтәренке, нарат өстенлек иткән катнаш урман б-н капланган, көньяк яры урыны-урыны б-н сазлыклы. Күл ял итү максатларында файдаланыла.

**ПОДВЫСО́ЦКИЙ** Валериан Осипович (1822, Чернигов губ. — 28.6.1892, Казан), фармацевт, медицина д-ры (1878). 1872–77 дә Дерпт ун-тының мед. ф-тында укый. 1877–79 елларда Фармакология ин-тында (Германия, Драгендорф ш.) эшли. 1879–85 тә фармацевтик химия каф. приват-доценты, фармакол., диетика һәм мед. тарихы профессоры. 1885 тән Казан ун-ты фармакогнозия һәм фармация каф. профессоры. П., беренчеләрдән булып, ун-т студентлары өчен фармакологияне күрсәтмә нигездә укыту һәм практик дәресләр кертә. Хезмәтләре фармацевтик химиягә, үсемлек матдәләренең фармакогнозиясенә, токсикологиягә карый. «Anatomische Untersuchungen über die Zungendrusen des Menschen und der Saugetiere» (1878) хезмәте алтын медальгә лаек була.

Х е з м.: Фармакология железа (Критическое обозрение современных учений о железе и новый взгляд на врачебное его значение) // Врач. 1885. № 18–19; 21; Справочная книга практического врача. К., 1889.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

**ПОДГО́РНОВА** Анна Алексеевна (1.12.1927, Саратов губ. Петровский өязе, хәзер Пенза өлкәсенең Лопатин р-ны Китунькино а.), хокук белгече, Казан юридик ин-тын тәмамлый (1951). 1951–61 елларда Киров р-ны мәхкәмәсенең халык судьясы (Новосибирск ш.). 1961–62 дә ТАССР МС каршындагы Дәүләт арбитражы дәүләт арбитры, 1962–68 дә баш дәүләт арбитры. 1969–83 тә ТАССР адвокатлар коллегиясе адвокаты.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОДГО́РНЫЙ** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Бөгелмә — Азнакай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 941 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 66%, татарлар — 22%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1960 ның 16 февралендә торак пункт буларак теркәлә. Халык саны: 1970 тә — 351, 1979 да — 332, 1989 да — 1011, 2002 дә — 890 кеше.

**ПОДГО́РНЫЙ** посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 10 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 417 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Вахитов исем. с-зның 4 нче бүлекчәсе посёлогы (1937 дән «Ютазы» с-зы), 1962 нең 28 маеннан — хәзерге исемдә. Оештырылган көннән Тымытык р-нында. 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1949 да — 259, 1958 дә — 151, 1970 тә — 575, 1979 да — 471, 1989 да — 413, 2002 дә — 469 кеше.

**ПОДКО́ЛОК** авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 4 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 8 кеше (руслар) яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.та җил тегермәне була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 318,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 173, 1897 дә — 276, 1908 дә — 288, 1920 дә — 343, 1926 да — 228, 1938 дә — 280,

1949 да — 180, 1958 дә — 230, 1970 тә — 137, 1979 да — 85, 1989 да — 28, 2002 дә — 6 кеше.

**ПОДЛЕ́СНЫЙ** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 3 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 703 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 52%, руслар — 43%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1960 ның 16 февралендә торак пункт буларак теркәлә. Оештырылган көннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1970 тә — 132, 1979 да — 124, 1989 да — 158, 2002 дә — 304 кеше.


**ПОДЛЕ́СНЫЙ** (Урманасты) посёлогы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 2 *км* көнчыгыштарак, Лениногорск-Бөгелмә автомобиль юлы буенда. 2010 елда 740 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 46%, татарлар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1954 тә нигез салына. Оештырылган көннән Яңа Писмән р-нында. 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1970 тә — 455, 1979 да — 492, 1989 да — 552, 2002 дә — 566 кеше.

**«ПОДСО́ЛНЕЧНИК»**, 1) 1918 елда гамәлдә булган рәссамнар берләшмәсе; 2) шул ук исемдәге күргәзмә. «П.»ка Казан сәнгать мәктәбе студентлары һәм аның базасында оештырылган Казан иректе сәнгать остаханәләре рәссамнары: К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, Д.С.Мощевитин, Ф.П.Гаврилов (башлап җибәрүче төркем), И.Алпатов, Н.Баранов, В.Попов (псевд. — «Вас. Вера»), Н.Михайлов (псевд. «Диомиди»), П.Зотов, И.Никитин, В.Соловьёв-Озёров, Д.Фёдоров, Г.Потапов керә. Башлап җибәрүче төркем тарафыннан Казан мәгариф комис-тына тапшырылган устав расланмый. «Фәнни-тәҗрибә җәмгыяте»нең идея-иҗат программасы булмый. 1918 елның 23 апрель — 19 май көннәрендә узган «П.» әгъзалары күргәзмәсе иҗат яшьләренең сәнгатьтәге эзләнүләренең неоакадемизм һәм модерннан предметсыз сәнгать һәм кубофутуризмга кадәрге киң спектрын чагылдыра. «П.» күргәзмәсе авангард рәссамнарының Казан сәнгатендәге беренче рәсми чыгышы була, һәм ул 1920 елларның 1 нче яртысында «*Всадник*», «*ТатЛЕФ*» берләшмәләре әгъзаларының иҗатында алга таба киң үсеш ала. Күргәзмәгә 300 гә якын әсәр куела. «Казанское слово» г-тасының 1918 елның 12 май санында басылган рецензиядә «П.» турында: «Кыюлык, чын мәгънәсендәге сәләт, ихлас эзләнү чаткылары бар, әмма шуның б-н бергә аңа еш кына очраклылык, күзгә бәрелеп тору, бернигә карамастан үзенчәлекле булырга омтылу хас», дип языла.

*Әд.:* Ключевская Е.П. Из истории Казанского ЛЕФа // Советское искусство 20–30-х годов: Сб. докл. науч.-практ. конф. К., 1992.

*Е.П.Ключевская.*

**ПОДУРУ́ЕВА ЙОРТЫ́** Казанда, архит-ра истәлеге. 1906 елда арх. Ф.Р.Амлонг проекты буенча Алабуганың 1 нче гильдия сәүдәгәре И.Г.Стахеев төзетә, мирас буенча кызы М.И.Подуруевага күчә. Модерн элементларын катнаштырып, романтик юнәлештәге эклектик формаларда төзелгән ике катлы, антресольле шәһәр йорты. Төп катларның тәрәзә рәтләре, урталыктагы кәрниз һәм ниргә б-н берләштерелгән төрле зурлыктагы ике күләмнән тора. Ишегалдына каршы фасадка купшы антаблемент б-н бизәлгән колонналарга корылган ике катлы түбә астында зур терраса тоташкан. Ике яклы төп баскыч террасадан бакчага алып чыга. Ишегалдындагы ян фасадта урнашкан ишек парлы колонналардагы купшы фронтонлы саравычка аерым төс биреп тора. Вестибюльдәге киң баскыч икенче каттагы тәрәзәләре урамга караган тантана залына һәм бүлмәләргә алып менә. Торак бүлмәләр йортның икенче һәм антресольле катларының (бер басмалы агач баскыч илтә) ишегалды ягында урнашкан. Йокы бүлмәсеннән террасага чыгарга була. Беренче катның ишегалды өлешендә һәм терраса астында аш-су, хуҗалык бүлмәләре һәм хезмәтчеләрнең торак бүлмәләре урнашкан.



М.И.Подуруева йорты. Арх. Ф.Р.Амлонг. Казан. 1906. Хәзерге күренеше.

Үзәк фасадтагы тантана залы кисек пирамида формасындагы биек түбәле, почмак ясап торучы ризалит б-н аерылып тора. Аның нигезенә композит ордерлы парлы колонналар күтәреп торучы купшы антаблементлы, катлаулы барокко формасындагы зур аттиклы фронтон күтәрелгән. Залның зур а́ркалы тәрәзәсен түр бүлмәләрдәге шуңа охшаш, кечерәк үлчәмле 3 тәрәзә кабатлый. П.й. фасадларының купшы бизәлешенә: штукатурланган диварларның рустланган өслеге, беренче каттагы зур бикләгеч ташлы, йөзлекләре кистерелгән тәрәзәләр, икенче каттагы тәрәзә каймаларының киң пилястраларындагы архивольтлары, фронтоннардагы һәм тәрәзә араларындагы тимпаннарга үсемлек рәвешендәге сылап ясалган күпертмә бизәкләр, такта сыман һәм рәте б-н ярымкултыксалы тәрәзә төбе куышлары, түбә периметры буенча сузылган култыксалы аттик диварлар һәм гөл чүлмәкләре куелган квадрат баганачыклар керә. Фасадлар диварларның пастель төсе һәм ак детальләр б-н аралаштырып бизәлгән. 1918–20 дә П.й. Көнчыгыш фронтның Гадәттән тыш комиссиясе карамагында була, анда ябып кую камералары урнаштырыла. Совет хакимияте чорында террасасын, саравычын, бүлмә интерьерларын югалта. 1984 тә бина Композиторлар берлегенә бирелә, 1986 да үзгәртеп корыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

*Х.Г.Надыйрова.*

**ПОДУ́СТ** (түбәнавыз) (Chondrostoma), карплар семьялыгыннан балыклар ыругы. 18 төре билгеле, Евразия елгаларында яшиләр. Татарстан терр-ясендә бер төре Идел П.ы (C. variabile) яши. Иделнең һәм Каманың барлык зур кушылдыкларында, агымлы участокларда очрый. Озынлыгы 20–30 *см*, авырлыгы 300–400 *г*. Гәүдәсе озынча, берникадәр ян-яктан кысылган. Тәңкәсе тыгыз, эре. Сырты яшькелт-кара төстә, ян-яклары һәм корсагы көмешсыман. Койрык йөзгече нык уемтылы, канатлары очлы. Авызы аркылы яки дугасыманрак ярык рәвешендә. Аскы казналыгы мөгезчел тышлык б-н капланган. Җенси яктан 3–5 яшьтә җитлегә. Уылдыгын апрель–майда, суның темп-расы 6 °С булганда, төбе вак ташлы һәм агым көчле булган участокларда чәчә. Үрчемлеге — 5,3 меңнән 16 меңгә кадәр уылдык бөртеге. Уылдык чәчү вакытында ата балыклар ачык төскә керә. Вак умырткасызлар, үсемлекләр б-н туклана. Балык уылдыкларын ашый. Балык тоту спорты объекты. 5 елдан артык яшәми. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

**ПОДЫ́МОВ** Владимир Николаевич (16.5.1932, Самара ш.), физик, техник фән. д-ры (1987), проф. (1990). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Татарстан нефть фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (Бөгелмә ш.). 1958 дән Казан ун-тында, молекуляр физика каф. профессоры (1988–96). Хезмәтләре газ янгандагы автотирбәнешләргә карый. П. газ янганда релаксацион автотирбәнешләр күренешен ача һәм тикшерә. Импульслы камералар — газ катышмасы шартлавы б-н идарә ителә торган кысылу дулкыннарын генерацияләүче җайланмалар проектлауның фәнни нигезләрен эшли. Беренче булып ягу җайланмаларының югары темп-ралы зонасында һәм тузанланган газ агымнары кулланыла торган технологияләрдә җылыну өслеген кысылу дулкыннары б-н чистарту өчен импульслы камералар куллануны тәкъдим итә.

Уйлап табулары СССР, Һиндстан, Болгариянең кара, төсле металлургия пр-тиеләрендә, энергетикада, цемент җитештерүдә гамәлгә кертелә. ТР Куллланучылар хокукларын яклау берлеге советы рәисе (1989 дан). Хезмәтләре фән казанышларын популярлаштыруга һәм кулланучылар хокукларына карый. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пособие по освоению систем релаксационного вибрационного горения. К., 1971 (автордаш); О механизмах импульсной очистки. К., 1979 (автордаш); Теория автоматического управления. К., 2008 (автордаш).

**ПОЗДЕ́ЕВ** Оскар Кимович (31.10.1958, Казан), микробиолог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), РФА КФҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1994 елдан Казан. мед. академиясенең һәм бер үк вакытта, 1999 дан, Казан мед. ун-тының микробиол. кафедралары мөдире. Хезмәтләре вируска каршы торучан иммун реакцияләр механизмнарын, химик кушылмаларның вируска каршы активлыгын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Вирусные иммунодефициты. Механизмы постинфекционной иммунопатологии // Ка-

зан. мед. журн. 1989. № 5 (автордаш); Медицинская микробиология. М., 2001.

**ПОЗДНЯ́К** Александр Олегович (6.4.1961, Казан), эндокринолог, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук, 2 нче терапия кафедрасында эшли. 1989 елдан Казан мед. академиясенең эндокринология кафедрасында. Хезмәтләре калкансыман биз функцияләрен, тиреоидинның күзәнәк иммунитетына һәм гуморал иммунитетка тәэсирен өйрәнүгә, калкансыман биз авыруларына ультратавыш ярдәмендә диагноз куюга карый.

Х е з м.: Внутриклеточные механизмы антицидотического действия димефосфона // Совершенствование профилактики, диагностики, лечения и реабилитации в медицине и практическом здравоохранении. К., 1990; Влияние кордарона на функциональное состояние щитовидной железы // Казан. мед. журн. 1992. № 3 (автордаш).

**ПОЗДНЯКО́В** Каюм Хөсәен улы (1897, Тамбов губ., Темников өязе Караево а. — 7.4.1960, Казан), кинорежиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). Беренче татар кинематографистларыннан берсе. Мәскәү кинематография техникумында укый. «Булат батыр» (1927, реж. Ю.В.Тарич), «Татарстан — дүрт елга иле» (1930, реж. А.И.Дубровский) фильмнарын төшергәндә режиссёр ассистенты була. «Мари Кужер» (1928), «Комета» (1929) фильмнарын төшерүдә катнаша. 1930 елдан «Востоккино» системасында кыска метражлы документаль фильмнар төшерә, соңрак «Союзкинохроника»ның татар бүлеге студиясендә эшли, «Совет Татарстаны» («Советский Татарстан») киножурналын чыгаруда катнаша. П.ның турыдан-туры катнашы белән «Казан университетына 150 ел» («Казанскому университету 150 лет»), «Казандагы М.Горький музее» («Казанский музей М.Горького») һ.б. фильмнар төшерелә. 1954 тән Свердловск фәнни-популяр фильмнар киностудиясендә документаль һәм нәфис фильмнарга дубляж ясау режиссёры; «Тугрылыкны сынау» («Испытание верности»), «Кигәвен» («Овод»), «Ломоносов», «Солдат Иван Бровкин», «Минем кадерле кешем» («Дорогой мой человек»), «Кырык беренче» («Сорок первый»), «Солдат турында баллада» («Баллада о солдате») һ.б. фильмнарга татар һәм башкорт телләрендә дубляж ясый.

*Әд.:* А л е к с е е в И. Рубежи кинодокументалистов Татарии. К., 1974; Б а й к и е в Р. Кинорежиссёр, преданный забвению // Татарские края. 2000. № 41.

*Е.П.Алексеева.*

**ПОЗДНЯКО́В** Эльгиз (Илгиз) Абдулла улы (7.6.1929, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1978), проф. (1992). 2 нче Ленинград артиллерия уч-щесен тәмамлый; 1957 елга кадәр хәрби хезмәттә. Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), РФАнең Дөнья икътисады һәм халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында баш фәнни хезмәткәр (1993 тән). Хезмәтләре СССР һәм РФнең халыкара мөнәсәбәтләре, эчке һәм тышкы сәясәте тарихына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нация, национализм, национальные интересы. М., 1994; Философия государства и права. М., 1996; Философия культуры. М., 1999; Философия преступления. М., 2001.

*Әд.:* Кто есть кто в татарской общине Москвы. М., 2001.

**«ПО́ЗДНЯЯ РО́ЗОВАЯ»**, чия сорты. 1939 елда А.М.Тверитинов тарафыннан Тәмте җиләк-җимеш станциясендә чыгарыла. «Местная красная» сортыннан ирекле серкәләнгән чәчкен. Талымсыз, югары уңышлы, кышка чыдам. Коккомикоз авыруына бирешми. 2–2,5 *м* биеклектәге куак. Яшь ботаклары юан, кызгылт-көрән төстә, уртача озынлыкта. Яфраклары вак, озынча сузылган, очлы борынлы, куе яшел төстә, калын кабыклы, тыгыз, ялтыравыклы һәм яхшы күренеп торган җепселле. Сабагы кыска, юан. Чәчәкләре эре, вак кына ак чәчәк төркеменә җыелганнар. Җимешләре 3,5 *г* га кадәр авырлыкта, озынча-түгәрәк, кызыл төстә, җимеш сабагына нык береккәннәр, июль ахыры – август башында берьюлы өлгерәләр. Җимеш йомшагы тыгыз, аксыл-алсу төстә, тәме әчкелтем-баллы, бераз авызны бөрештерә. Орлыгы уртача зурлыкта. 3–4 нче елда җимеш бирә башлый. Үсентеләр һәм бөре ялгау юлы б-н үрчетелә. Бу сорт Татарстанда 1956 да районлаштырыла.

**ПО́ЗИС**, к. *Серго исемендәге завод.*

**ПОЗНЯ́К** Игорь Павлович (14.9.1930, Казан), спортчы, тренер (баскетбол), РСФСРның атказ. тренеры (1968), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1991). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1954). «Спартак» командасы составында (Казан) РСФСР кубогы (1950), РСФСР беренчелекләрендә көмеш медаль иясе (1949–55). 1950–53 елларда Казан вет. ин-тында, 1953–57, 1971–76 да — Казан химия-технол. ин-тында, 1957–71 дә — Казан ун-тында, 1976–95 тә — Казан пед. ин-тында укыта. 1957–70 тә «Университет» (к. *«УНИКС»*) командасының баш тренеры. 1965–67 дә РСФСР җыелма командасы тренеры. П.ның шәкертләре арасында РСФСР, СССР җыелма командалары әгъзалары, РСФСР беренчелекләрендә медаль алучылар — З.З.Алимов, Ю.Г.Бабьялов, Н.В.Бахарев, В.А.Груша, И.Д.Красновский, В.В.Левченко, В.В.Мясников, В.О.Никитин, Р.Г.Уразманов. Бөтенсоюз студентлар беренчелегендә җиңүче (1965), 1995 тән «УНИКС-Юниор» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренер-консультант.

**ПО́ЙКИНО** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2010 елда 235 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Лыя Пойкина буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1890 да ачыла), ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 936,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 87 ир-ат; 1859 да — 266, 1897 дә — 398, 1908 дә — 470, 1920 дә — 463, 1926 да — 498, 1970 тә — 427, 1979 да — 354, 1989 да — 268, 2002 дә — 291 кеше.

**ПОКРО́В ИСКЕ́ ДИН ТАРАФДАРЛАРЫ́ ЧИРКӘВЕ́**, Казандагы архит-ра истәлеге. Классик архит-ра элементлары б-н борынгы рус формаларындагы эклектика стилендә һәм кирпеч салуның бизәлеш алымы б-н төзелгән. Төзелеш император Николай II нең 1905 елның 17 апрелендә иске дин тарафдарларына храмнар төзергә рөхсәт биргән, дин тоту ирегe турындагы Фәрманы басылганнан соң башлана. Булачак храм өчен урынны Белокриницкий иерархиясенең иске дин тарафдарлары 1880 елларда алалар, 1905 тә ул рәсми рәвештә сәүдәгәр Е.И.Новикова җире булып санала. Булачак храмның бер өлешен 1880 елларда кирпечтән төзелгән склад бинасы тәшкил итә. 1909 ның сентябрендә чиркәү Белокриницкий иерархиясе җитәкчесе, Мәскәү һәм Бөтен Рус архиепископы Иоанн (Картушин) б-н Казан һәм Вятка епископы Иосаф (Зеленкин) тарафыннан изгеләндерелә. 1930 елларга кадәр П.и.д.т.ч. Рус православие иске дин тарафдарлары чиркәвенең *Казан-Вятка епархиясе* кафедраль соборы булып санала. 1931 дә ябыла, ТАССР Дәүләт архивы документлары саклагычы итеп файдаланыла. 1999 да җәмгыятькә кайтарып бирелә; хәзерге вакытта яңарту эшләре бара.

Биш гөмбәзле, дүрт баганалы, өч нефлы, чаң манарасы ишек өстендә урнашкан чиркәү, планда төньяк һәм көньяк фасадлардагы барлык күләм чикләреннән чыгып торучы ике катлы урта квадрат өлеше чиркәүнең төп күләме булып саналган турыпочмаклы корылма. Көнчыгыш фасадта икенче каттагы апсидалы өскорма б-н ян-якларда кыек түбә б-н тоташкан квадрат янкормалар урнашкан. Бер катлы янкормалар һәм турыпочмаклы апсида күләме көнчыгыш фасадтагы биек а́ркалы биш тәрәзә (ян фасадларда берәр тәрәзә), икенче каттагы апсидалар — Көнчыгыш яктагы ике турыпочмаклы тәрәзә, Төньяк һәм Көньяктан берәр тәрәзә б-н яктыртылалар. Вальмалы түбә йомык барабанга утыртылган гөмбәз б-н очланган. Апсиданың уң почмагы биеклеге буенча дүрт яруслы төтен юлы морҗасы сузылган. Чиркәүнең эчке баскычлары һәм ян-яктагы янкормалар кергән сузынкы турыпочмаклы күләмнең көнбатыш фасадында, үзәктә яктылык тәрәзәле барабанга зур гөмбәз куелган ике яруслы, квадрат чаң манарасы калкып тора. Чиркәү болдыры ян-ягы а́ркалы зур цилиндрик баганалар өстендәге цилиндрик гөмбәзле түбәдән гыйбарәт. Чаң манарасының өченче ярусы ике вертикаль киртә б-н өч өлешкә бүлгәләнгән киң, ярымтүгәрәк уем б-н яктыртыла. Беренче каттагы төп күләмнең төньяк һәм көньяк фасадлары — биек а́ркалы дүрт тәрәзә, икенче, антресольле катта турыпочмаклы дүрт тәрә-

зә б-н яктыртыла. Әлеге фасадлардагы ян ишекләрнең болдырлары көнбатыш фасадтагы төп ишектәге кебек төзелгәннәр. Бу фасадлар үзәк буенча очлаеп төгәлләнгән өч җәя сыман торык б-н бизәлгәннәр. Төп күләм дүрт кыеклы түбә б-н ябылган һәм 5 гөмбәз б-н төгәлләнгән. Йомык барабаннардагы 4 почмак гөмбәзчекләре калку аркатура һәм каймаланган а́ркалы дүрт уем б-н бизәлгән. Фасад диварлары киң калаклар б-н бүлгәләнгән. Катларга су агызу өчен кәрнизләр куеп калдырылган. Бинаның җир асты каты бар.

*Әд.:* Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998.

*Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.*

**ПОКРО́В СОБОРЫ́**, к. *Василий Блаженный храмы.*

**ПОКРО́В ЧИРКӘВЕ́**, Казандагы архит-ра истәлеге, Кремль калкулыгының көнбатыш итәгенә урнашкан. *Никола-Низский чиркәве* б-н бергә Никола кафедраль соборы комплексын тәшкил итәләр. 17 йөз уртасында яки ахырында Никола-Низский чиркәве б-н бер вакытта (16 йөз уртасында) агачтан эшләнгән Никола Боровский чиркәве урынында төзелә. Өч апсидалы, дүрт баганалы бер гөмбәзле чиркәүләр төренә керә. 1720–30 елларда П.ч.нең төньяк-көнбатыш почмагында биш ярусլы чаң манарасы төзелә. Дүрткырлы түбәнге яруска бер-берсе өстенә югарыга даими кечерәеп баручы 4 сигезкырлык урнаштырылган. Ике урта яруска биек, а́ркалы чаң уемнары уелган, биек киртәле кәрнизләр б-н төгәлләнгән. Дүрткырлык һәм аскы сигезкырлыкның почмаклары пилястралар, башка сигезкырлыклар пьедесталлардагы ярымколонналар б-н бизәлгән. Манараның сигезкырлык гөмбәзе һәм түбәләре яшел төстәге майолика чирәп б-н ябылган. П.ч.нең кыңгырау манарасы фасады тулаем кирпеч бизәге элементлары булган барокко стилендә бизәлгән. 1892 дә П.ч. үзгәртеп корыла. Яктылык барабаннары өстендә бер урынына Владимир-Суздаль архит-расы стилендә бизәлгән шлем формасындагы биш гөмбәз барлыкка килә; ярымгөмбәзсыман чатыр кыек түбә итеп үзгәртелә. Беренчел бизәлеше көнчыгыш фасадтагы бик зур кайма б-н әйләндереп алынган апсидалы тәрәзәләрдә генә сакланып калган. П.ч. һәм чаң манарасының кирпеч диварлары штукатурланган һәм агартылган. Храм гөмбәзләре һәм түбәләре калай б-н ябылган һәм буялган. 1930 да ябыла, 1945 тә дин тотучыларга кайтарып бирелә.




Покров чиркәве. Казан. Хәзерге күренеш.

*Әд.:* Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**ПОКРО́В ЧИРКӘВЕ́**, Алабугадагы архит-ра истәлеге, шәһәр үзәгендә, Тойма елгасының иң биек урынында урнашкан; шәһәр төзелешенең төп билгесе булып тора. 1818–20 елларда (башка чыганаклар буенча, 1808–15 тә) төзелә, 1884 тә чаң манарасы корыла. Күләмнәре сузынкы — үзәк композиция буенча урнашкан храмнар төренә керә. Храмның нигезен түгәрәк гөмбәзле тәбәнәк яктылык барабаны б-н төгәлләнгән сигезкырлы күләм тәшкил итә. Сигезкырлы күләмдәге тәрәзәләрнең ян-якларында ике кыеклы түбә астындагы турыпочмаклы чыгынтылар бар. Көнчыгыш яктагы чыгынты апсида булып тора, көнбатыштагысы храмны ашханә б-н берләштерә. П.ч.нең сузынкы-үзәк композициясен өч ярусլы чаң манарасы һәм



Покров чиркәве. Алабуга ш.

аңа көнбатыштан кушылган ике кыеклы түбә астындагы зур күләмле ябык болдыр һәм ян-якларына кушып салынган тәбәнәк чатырлар төгәлли. Ике рәт тәрәзәле чиркәү биек түгәрәк ротонданың палладиан тәрәзәләре б-н яктыртылган. Шундый ук тәрәзә алтарьны яктырта. Гөмбәз нигезендәге һәр ротонданың тәрәзәсе өстендә барокко стилендәге түгәрәк уемлы люкарна урнашкан. Гөмбәзле ярымчатырны күтәреп торучы эллипссыман куышлы барабан храмга үзенчәлек биреп тора. Ашханәнең ике кыеклы түбә астындагы зур күләме озынлыкка сузылган ягында а́ркалы тәрәзәләр б-н яктыртылган. Тоскан ордерлы сөяләп торган колонналар өстендә дүрт яктан да зур антаблементлар, өчпочмаклы фронтоннар б-н бизәлгән, күләме өскә таба кечерәеп баручы квадрат ярусլар чаң манарасының үзенчәлеге булып тора. Икенче, өченче кат диварларына а́ркалы чаң уемнары уелган. Манара ике ярусլы, сигезкырлы, гөмбәзле биек өскорма б-н төгәлләнә. П.ч. барокко элементлы классицизм архит-расының ачык үрнәге булып тора. 1937 дә ябыла, 1989 да дин тотучылар җәмгыятенә кайтарыла. 1990–96 да үзгәртеп корыла.

*Әд.:* Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков). К., 1998; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999; П о п а д ю к С.С. Елабуга: История планировки и застройки по архивным материалам // Памятники русской архитектуры и монументальность искусства XIII — XIX вв. М., 2000.

*Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.*

**ПОКРО́ВКА** авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 18 йөз уртасында кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Пеньки буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1864–73 елларда төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1840 тан эшләгән авыл приход мәктәбе җирлегендә 1866 да ачыла), җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2858,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 430 ир-ат; 1859 да — 1453, 1897 дә — 1454, 1908 дә — 1476, 1920 дә — 1374, 1926 да — 1034, 1938 дә — 665, 1949 да — 367, 1958 дә — 244, 1970 тә — 176, 1979 да — 89, 1989 да — 59, 2002 дә — 31 кеше.

**ПОКРО́ВКА** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 22 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2002 елдан даими яшәүчеләр юк. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Минзәлә кантоны Мөслим волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 69, 1938 дә — 111, 1949 да — 116, 1958 дә — 121, 1970 тә — 94, 1979 да — 48, 1989 да — 14 кеше.

**ПОКРО́ВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 67 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Үтәк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 33 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1922 дә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Спас кантоны Кузнечиха волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1926 да — 120, 1938 дә — 141, 1949 да — 106, 1958 дә — 91, 1970 тә — 320, 1979 да — 168, 1989 да — 69, 2002 дә — 74 кеше.

**ПОКРО́ВКА** авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Моркваш елгасы бассейнында. 2010 елда 69 кеше (руслар, чуашлар) яши. 1910 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда. 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя,

1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1920 дә — 268, 1926 да — 260, 1938 дә — 156, 1949 да — 119, 1958 дә — 120, 1970 тә — 86, 1979 да — 43, 1989 да — 79, 2002 дә — 54 кеше.

**ПОКРО́ВСКИЙ** (Синтәк, Сөендек) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кама елгасыннан 1 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 162 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Синтәк буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1885–90 елларда сәүдәгәр Н.Д.Стахеев иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, Ф.Ф.Павленков исем. земство китапханәсе (1907 дә ачыла) эшли. 1921 гә кадәр авыл Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 1260, 1887 дә — 1366, 1905 тә — 1725, 1920 дә — 1719, 1926 да — 1903, 1938 дә — 1668, 1949 да — 1063, 1958 дә — 730, 1970 тә — 561, 1979 да — 399, 1989 да — 255, 2002 дә — 209 кеше.

**ПОКРО́ВСКИЙ** посёлогы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 62 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2002 елда 3 кеше яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Спас кантоны Юхмачы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1926 да — 112, 1949 да — 177, 1958 дә — 155, 1970 тә — 37, 1979 да — 19 кеше. 1989 елда даими яшәүчеләр юк.

**ПОКРО́ВСКИЙ** посёлогы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 32 *км* көньяктарак, Ваешур елгасы буенда. 2010 елда 47 кеше (удмуртлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Бөгелмә кантоны Поповка волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 125, 1938 дә — 130, 1949 да — 91, 1958 дә — 71, 1970 тә — 95, 1979 да — 56, 1989 да — 37, 2002 дә — 49 кеше.

**ПОКРО́ВСКИЙ** Вячеслав Александрович (14.8.1893, Оренбург губ., Троицк өязе Коельский станицасы — 1960), сәясәт һәм хуҗалык эшлеклесе. Г.В.Плеханов исем. Халык хуҗалыгы ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1924). Беренче бөтендөнья сугышы елларында Саратов шәһәренә күчерелгән Киев коммерция ин-ты студенты буларак, 1915 елда рев-цион көрәштә катнаша; студентларның марксистлар түгәрәге әгъзасы. Ул ябылганнан соң, П. полициянең яшерен күзәтүе астында була. 1917 нең Февр. рев-циясе алдыннан Оренбург губернасының Чиләбе өязендәге Кинель авылында укытучы булып эшли, аннан соң волость рев-цион ком-ты әгъзасы. 1917 нең ахырыннан — Киевта. 1918 нең гыйнварында Киев эшчеләренең Үзәк радага каршы фетнәсендә катнаша. 1918 нең февраленДә референт, «Вестник Украинской народной республики» г-тасында бүлек мөдире. Украинаны немец гаскәрләре басып алганнан соң, Мәскәүгә китә. 1918 нең маеннан Казанда. РКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты рәисе сыйфатында «Знамя революции» г-тасы редколлегиясе составына кертелә. Г.Ш.Ольвеницкий үлеменнән соң, П. РКП(б)ның Казан шәһәр ком-ты секретаре итеп сайлана. 1919 ның башында РКП(б)ның Оренбург губерна ком-ты секретаре итеп җибәрелә. Соңрак хәрби эшкә мобилизацияләнә: Төркестан армиясенең сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе, Көнчыгыш фронтның Көньяк төркемендәге 1 нче армиянең Рев-цион Хәрби Советы әгъзасы. 1920 дә — Оренбург, Кыргызстанда, 1921–31 дә Мәскәүдә хуҗалык эшендә. 1931 дән Ерак Көнчыгышта, Край куллanучылар кооперациясе берлеге рәисе урынбасары. 1938 дә эшкә Мәскәүгә кайта. Резина сәнәгате пр-тиеләрендә илебездә җитештерелгән чималдан табигый каучук алу технологиясен эшләп чыгаруны оештыруда катнаша. Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армиядә хуҗалык эшендә. 1945–57 дә Дәүләт азык-төлек һәм матди резервлар министрлыгы баш идарәсе башлыгы.

*Әд.:* С а р к и н В. Покровский Вячеслав Александрович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

**ПОКРО́ВСКИЙ** Иван Михайлович (17.1.1865, Тамбов губ., Шацкий өязе Раево а. — 19.4.1941, Казан), тарихчы, чиркәү тарихы д-ры (1907). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1895), шунда ук — рус гражданлык тарихы кафедрасында, проф. (1908), 1897–1921 елларда рус чиркәү тарихы кафедрасында эшли. Бер үк вакытта, 1905–08 дә, «Известия по Казанской епархии» нашире. Академия ябылганнан соң, 1921 нең апрелендә башка профессорлар б-н бергә, «законсыз рәвештә дин дәресләре биргән өчен», шартлы рәвештә 1 елга ирегеннән мәхрүм ителә. 1921–41 дә ТАССРның архив учреждениеләрендә эшли (1930–33 тә репрессияләнә, Казакъстанда сөргендә була). Казан руханилар академиясе архивын, өяз шәһәрләре архивларын саклап калуда мөһим роль уйный. *Бизнә крәстияннәре кузгалышы* тарихына караган документларны җыя һәм ТАССРның Үзәк архивына тапшыра. 1941 дә ТАССРның Үзәк музеена П.дан *шәмаилләр* (70 данә) тупланмасы тапшырыла. Казан төбәгенең социаль-икътисади тарихы мәсьәләләренә, Рус православие чиркәве тарихына, тарихи чыганакларны барлауга караган хезмәтләр авторы. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте советы әгъзасы (1902–17 дә, бүленеп). Собор каршындагы совет әгъзасы һәм Рус православие чиркәвенең Поместный собор депутаты (1917–18).

Х е з м.: Русские епархии в XVI–XVII вв., их территория, состав и пределы: Опыт церковно-исторического, статистического и географического исследования: В 2 т. К., 1897–1913; К 100-летию кафедры татарского языка в духовно-учебных заведениях России // Православный собеседник. 1900. Ч. 2; Казанский архиерейский дом, его средства и штаты, преимущественно до 1764 года. К., 1906; Гермоген, митрополит Казанский и Астраханский, впоследствии патриарх Всероссийский, первый местный духовный писатель-историк, и его заслуги для Казани. К., 1907.

*Е.В.Липаков.*

**ПОКРО́ВСКИЙ** Сергей Петрович (27.3.1880, Тула губ. — ?), хокук белгече, җәмәгать эшлеклесе. Демидовлар хокук лицеен тәмамлаганнан соң (Ярославль ш., 1907), шунда ук эшли (1917 гә кадәр), 1913 елдан гомуми хокук тарихы каф. приват-доценты. 1911 дән Ярославль губерна гыйльми архив комиссиясе әгъзасы. 1917–18 дә Казан ун-тының юридик ф-ты рус хокукы каф. профессоры. Казан губерна гыйльми архив комиссиясен оештыруда катнаша. 1917 дә җирле вакытлы матбугатта шактый гына мәкаләләр бастыра: «Демократик республика» («Демократическая республика»), «Нәрсә ул ирек һәм аны ничек булдырырга?» («Что такое свобода и как её обеспечить?»), «Учредительләр җыены» («Учредительное собрание») һ.б. Казанда Төньяк-Көнчыгыш археология һәм этнография ин-тын оештыручылардан берсе һәм аның беренче директоры (1917–18). 1917 дә П. институт советы утырышында Казанда юкка чыгып барган хөкүмәт учреждениеләре архивларын саклауны һәм аларны институтка тапшыруны оештыру мәсьәләсен күтәреп чыга (рөхсәт 1917 нең 23 декабрендә алына). 1918 нең сентябрендә ин-т советы тарафыннан Самарада узган КОМУЧ Халык мәгарифе идарәсенең югары белем бирү мәсьәләләре буенча җыелган съездга делегат итеп сайлана. 1918 нең октябреннән Иркутск ун-тының рус хокукы тарихы каф. мөдире. 1920 дән Урта Азия ун-тының адм. хокук каф. профессоры (Ташкент). Аннан соңгы язмышы билгесез. Хезмәтләре Россия һәм Франция адм. хокукы, Россия б-н Бохара мөнәсәбәтләре тарихына карый.

Х е з м.: Министерская власть в России. Ярославль, 1906; Северо-Восточная Россия в историко-археологическом отношении. К., 1917; Административный процесс о превышении власти. К., 1920; Международные отношения России и Бухары в дореволюционное время и при советской власти — до национального размежевания среднеазиатских республик. Таш., 1927.

*Әд.:* Б о б к о в В.Н. Учёные Казанского университета и архивы в первые годы Советской власти // Советские архивы. 1989. № 5; Ш а м с у т д и н о в а Р. Архивное строительство в Татарстане 1917–1920 гг. // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 1/2. *Р.Х.Әхмәтҗанов.*

**ПОКРО́ВСКИЙ УРУСТАМА́К** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ваешур елгасы бу-

енда. 2010 елда 759 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Николашкино буларак та билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, мәктәп, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 7638 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Иваново волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 457, 1889 да — 789, 1910 да — 1406, 1920 дә — 916, 1926 да — 991, 1938 дә — 1058, 1949 да — 936, 1958 дә — 928, 1970 тә — 934, 1979 да — 741, 1989 да — 714, 2002 дә — 767 кеше.

**ПОЛЕЖА́ЕВА** Нина Александровна (13.6.1932, Казан — 29.1.2004, шунда ук), химик-органик, химия фән. д-ры (1980), ТАССРның атказ. химигы (1985). 1955 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, Химия фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер А.М.Бутлеров исем. Химия ин-ты), элементорганик кушылмалар лаб-ясе мөдире (1978 дән), директор урынбасары (1988–91). Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. П. Михаэлис-Беккер реакциясенең яңа тибын — диалкоксифосфорилалкеннар хасил итүне ача. Фосфон-төркемнең енольләү сәләтен таба һәм аны β-кетофосфонатлар мисалында исбатлый; бу кушылмаларның кето-еноль таутомериясен өйрәнә. Таутомериянең фосфор катнаш мигрантлы, пентокоординацияле фосфорның 2 кушылмасы тигезләнеш хәлендә булган яңа тибын ача. Триалкилфосфитлар ияреше (O=C-C=O, -N=N-C=O, O=C-C=N, O=C-C=S һ.б.) бәйләнеш системалары кергән карбониль кушылмалар б-н тәэсир итешкәндә [1+4]-циклы кушу мөмкинлеген — Арбузов реакциясенең классик булмаган вариантын беренче булып күрсәтә. Циклларында P, O, N, S-атомнары булган моноциклик фосфораннар таба. Биол. актив кушылмалар синтезлый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Циклические оксафосфораны // Успехи химии. 1974. Т. 43, № 5 (автордаш); Реакционная способность 1,3,2-дигетерофосфациклaнов, содержащих атом пятикоординированного фосфора // Успехи химии. 1985. Т. 54, № 11 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПОЛЕ́НОВ** Борис Константинович (16.8.1859, Петербург өлкәсенең Пулково а. — 29.1.1923, Пермь ш.), геолог-минералог. Петербург ун-тын тәмамлый (1882), шунда ук Геол. кабинеты хезмәткәре булып эшли (1885 тән), проф. (1903). 1904 елдан Казан ун-тында, минерал. һәм геол. каф. мөдире (1904–13, 1915–16) һәм физика-матем. ф-ты деканы (1907 дән). 1916 дан Петроград ун-тының Пермь бүлегендә (хәзер Пермь ун-ты), геол. тарихы һәм палеонтология каф. мөдире, бер үк вакытта проректор (1920 дән) һәм минерал. каф. мөдире (1921 дән). П. Россиянең Европа өлешендә, Урал, Алтай, Якутиядә геол. туфрак тикшеренүләре үткәрә. Казан ун-ты Геол. кабинеты каршында махсус китапханә оештыра, Геол. музееның минераллар коллекциясен шактый тулыландыра. Ф.А.Брокгауз һәм И.А.Ефронның Энциклопедия сүзлегендә 200 дән артык мәкалә авторы. Казан табигыятьчеләр җәмгыяте президенты (1905–14). Екатеринбург шәһәрендә Урал ун-тын оештыруда катнаша (1920). 4 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены б-н бүләкләнә. Пермь ун-тының Палеонтология һәм геол. тарихы музеена П. исеме бирелә.

Х е з м.: Причины вулканических явлений // Русское богатство. 1887. № 1.

**ПОЛЕТА́ЕВ** Герман Иванович (17.11.1931, Мари автономияле өлкәсенең Таулы Мари кантоны Юрино а. — 9.10.2007, Казан), физиолог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1979), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Проф. А.В.Кибяков шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), шунда ук эшли (бүленеп: 1958–60 елларда Калинин мед. ин-тында), Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1961–62), биол. каф. мөдире (1977 дән), проректор (1983–95). Хезмәтләре мускул җепселләренең мембраналы потенциалын нейротрофик күзәтүләргә карый. «Нерв-мускул элемтәләре физиологиясе» («Физиология нервно-мышечной передачи») хезмәте өчен ТРның Дәүләт бүләге бирелә (1995). «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О механизме действия серотонина на функцию мионевральных синапсов у лягушек // Физиол. журн. СССР им. Сеченова. 1969. Т. 55, № 5; Исследование механизма блокирования передачи возбуждения с нерва на скелетную мышцу при непрямом, редком раздражении // Нейрофизиология. 1977. № 1; Особенности функционального состояния электрогенной мембраны мышечного волокна портняжной мышцы лягушки в условиях нарушения аксоплазматического транспорта // Биол. науки. 1978. № 2.

*Әд.:* Профессор Герман Иванович Полетаев // Казан. мед. журн. 1992. № 1.

**ПОЛИГА́УСС ПРОЦЕССЛАРЫ́**, һәрберсе берничә очраклы Гаусс процессының ихтималый катнашмасы булган очраклы процессларның гаять зур төркеме. Нәтиҗә полигаусс процессның мөмкин саналган реализацияләренең гомуми массивы Гаусс процесслары реализацияләренең хаотик кушылган массивларыннан тора, ә аңа туры килүче П.п.ның ихтималлык бүленеше — ихтималлыкның гауссча бүленешләре суммасы була. Гамәлдә конкрет П.п. реализацияләре, ихтималлык бүленешенә туры килеп, генераль бергәлекләр сайланмасы буларак барлыкка киләләр. Мәс., җитештерүдә П.п.ның киң таралган аерым очрагы — полигаусс очраклы зурлык, аны берничә технол. линиядә һәм бирелгән параметрның төрле системалы һәм очраклы кыйммәтләрендә әзерләнгән продукциянең бердәм партиягә берләшүе нәтиҗәсендә цехның соңгы тикшерү бүлегендә һәр линиянең чагыштырма җитештерүчәнлекләре б-н дәлилләнгән нормаль (гаусс) бүленешләре суммасы буларак табалар. Бериш җирләрне параллель эшләүче агрегатлар б-н сөргәндә сөрү тирәнлеге ихтималлыгының полигаусс бүленеше дә шулай ук табыла. Радио тапшыргычлар асинхрон эшләгәндә, П.п. радиосистема алгычларында күзәтелә. Алар кешеләрнең икътисади, демографик, техник-технологик һәм башка эшчәнлекләрендә чагыла. Аерым алганда, үз трендлары һәм уртача тайпылышлары булган оптимистик, гадәти һәм пессимистик фаразлар, ягъни тригаусс процесс формалары киң кулланыла. Ихтималлык теориясендә П.п. очраклы гаусс процессларның чикле, санаулы яки саналмый торган (континуаль) күплекләренең ихтималый катнашмаларын тәшкил иткән, бердәнбер билгеләнә торган нәгаусс очраклы процесслар классы.

Ихтималый катнашмаларны өйрәнүнең киләчәген француз математигы М.Лоэв билгеләп үтә. Гамәли статистикада очраклы зурлыклар катнашмаларын куллану алымнары безнең ил галимнәре С.А.Айвазян, В.М.Бухштабер, И.С.Енюков, Л.Д.Мешалкин һ.б. хезмәтләрендә системалаштырыла, фильтрлаштыру мәсьәләләрендә «шартлы гаусс процесслары» А.Н.Ширяев куллана. 20 йөзнең 2 яртысында ихтималый үлчәмнәрне гаусс үлчәмнәре катнашмалары б-н апроксимацияләүне Казан ун-тында А.В.*Сульдин*, А.А.Дороднов, Н.И.Мальцева һ.б.; аларны статистик бәяләүне А.Н.*Шерстнёв* өйрәнә. «П.п.» төшенчәсенә билгеләмә (1972), аларны комплексны өйрәнү, төрләрен классификацияләү һәм статистик радиотехниканың посткорреляцион бүлекләрендә полигаусс алымнарны үстерү эше Казан техник ун-тында һәм Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында Ш.М.*Чабдаров*, А.Т.Трофимов, А.Ю.Феоктистов, Н.З.Сафиуллин, А.Ф.Надеев, Р.Р.Фәйзуллин, С.В.Козлов һ.б. тарафыннан алып барыла. П.п. үзләренә ихтималый катнашмаларның һәм гаусс процессларының үзлекләрен берьюлы алалар һәм шунлыктан соңгыларының күп кенә үзлекләре нәгаусс процессларга да күчә. Аерым алганда, П.п. реализацияләрнең детерминант кына түгел, очраклы сызыкча рәвешүзгәрүләренә дә инвариант; П.п. кушылучылар бәйле яки бәйсез булганда да чикле кала. Очраклы гаусс процессы бер үзгәрешле функциясен ике үзгәрешле функциясе б-н парлаштырып, билгеле бер чикләмәләр б-н бирелә; ә П.п. шундый функция парлары күплегендә ихтималлыклар бүленеше («ихтималлыкның гаусс спектрлары») бирелгәндә билгеләнә. Практикада полигаусс модельләр һәм алымнарның әһәмияте шунда, алар төрле нәгаусс мәсьәләләрне бер үк рәвешле итеп формалаштыру, аларны корреляция дәрәҗәсендәге мәсьәләләрнең махсус чишелешләре күплекләренә кайтарып калдыру мөмкинлеген бирә. Очраклы реаль процесс ихтималлык буенча гаусс компонентлары чикләнгән сандагы конкрет полигаусс процесска якынайтылып бирелә, ә аның ихтималлык тыгызлыгы гаусс тыгызлыкларының сызыкча комбинациясенә якынайтыла. Бу исә зур күләмдәге теоретик һәм инженер-техник арсеналны, заманча мәгълүмати һәм матди технологияләр мөмкинлекләреннән чыгып, яңа, катлаулырак


шартларда киңрәк куллану юлларын ача. Мәс., статистик радиофизикада һәм радиотехникада: радиолинияләрдә ирекле нәгаусс аддитив-мултипликатив бозулар һәм ярсыткыч тәэсирләр булганда очраклы процессларның тулы ихтималый сурәтләмәләрен алу; бу тәэсирләрнең типлаштырылган радиотехник төйләнешләр аша узуын анализлау алымнарын һәм төгәллеге шартларын эшләү; сигналлар һәм бозылуларның нәгаусс флуктуациясе булганда, радио кабул итүдәге корреляцион алгоритмнарның комачауларга тотрыклылыгын билгеләү; бердәнбер чикләү — сигналлар һәм бозылулар флуктуациясенең физик реализациясе булганда, комачауларга потенциаль тотрыклылыкка аналитик һәм статистик бәяләмәләр бирү; радио кабул итүнең оптималь алгоритмнарын, шулай ук ихтималлыклар бүленеше идарә ителүе, ш.и. алдан бирелгән ихтималый үлчәнешле П.п.ны генерацияләү алгоритмнарын синтезлау мөмкинлеген бирә.

*Әд.:* Л о э в М. Теория вероятностей. М., 1962; Прикладная статистика. М., 1989; Ч а б д а р о в Ш.М. Полигауссовы представления случайных явлений в радиотехнике // Юбилейный сборник избранных трудов членов Академии наук республики Татарстан. К., 2002; Казанская научная школа полигауссовых явлений посткорреляционной статистической радиотехники // Физика волновых процессов и радиотехнические системы. 2004. Т. 7, № 1.

*Ш.М.Чабдаров.*

**ПОЛИГРАФИ́Я КОМБИНАТЫ́**, к. *Полиграфия-нәшрият комбинаты.*

**ПОЛИГРАФИ́Я МӘКТӘБЕ́**, А. В. Л у н а ч а р с к и й  и с е м е н д ә г е, Казанда. 1921 елда Беренче дәүләт басмаханәсе (элекке университет басмаханәсе) каршында оеша, 1922 елда ачыла. Рус һәм татар бүлекләре эшләп килә; уку курсы — 4 ел. П.м. хәреф җыючылар, китап басучылар, китап төпләүчеләр әзерли. Махсус предмет укытучылары Я.Г.Мейтин (полиграфия һәм җитештерүне оештыру), М.Ф.Михайлов (җитештерү технологиясе), М.М.Кривин (китап басу тарихы), П.М.*Дульский* (графика һәм полиграфия), практика җитәкчеләре — В.Г.Әбдрәшитов, А.М.Феофилактов (хәреф җыю бүлеге), Ф.С.Саттаров (китап басу бүлеге). Мәктәп рус һәм татар хәрефләре төшерелгән кургаш шрифтлар җыелмасы, 9 китап басу машинасы һәм китап төпләү инструментлары (кисү, төпләү, кәгазь пресслау машиналары) б-н җиһазландырыла. Татар сыйныфларында графика эшләрен милли орнамент үрнәкләре кулланып эшлиләр. 1924 тән ТАССР Үзәк музее (хәзерге ТР Милли музее) һәм ТАССР Мәгариф халык комис-тының музей бүлеге басмаларының барысы да диярлек — күргәзмә каталоглары, китаплар, программалар, «*Записки Тетюшского музея*» («Тәтеш музее язмалары»), «ТССР һәйкәлләрен саклау, төзекләндерү һәм торгызу буенча материаллар» ж-ллары һ.б. П.м. басмаханәсендә басыла. Күп кенә басмалар П.М.Дульский күзәтчелегендә нәшер ителә; 1935 тә, «академик бирем тәртибендә», мәктәп укучылары көче б-н һәм укучылар эшләре б-н бизәлеп, аның «Актуаль графика» китабы чыгарыла. Мәктәптә ш.у. «Молодой печатник» («Яшь печатник») г-тасы басыла. Продукция полиграфик эшләнешенең югары дәрәҗәдә булуы һәм матур бизәлеше б-н аерылып тора. 1927 дә мәктәп Ленинградта Сәнгать академиясе тарафыннан оештырылган «1917–1927 еллар графика сәнгате күргәзмәсе»нең «басмаларның сәнгати-типографик бизәлеше өчен» дипломына һәм Мәскәүдә уздырылган Бөтенсоюз полиграфия күргәзмәсенең мактаулы бәясенә лаек була. П.м. Татарстан полиграфиясе өчен квалификацияле кадрлар әзерләүдә зур роль уйный, китап культурасы дәрәҗәсен һәм китап басуның сәнгати сыйфатын күтәрүгә булышлык итә;



«Чәчәкләр тавышы» китабы тышлыгы. Укучы Х.Измайлова эше.

1940 та 2 еллык һөнәри уч-ще итеп үзгәртелә (хәзерге 4 нче полиграфия лицее). Төрле еллардагы җитәкчеләре: В.Н.Литвинов, Н.В.Журавлёв, А.Г.Ефимов, П.М.Шерстнёв, П.Е.Архипов, М.И.Измайлов.

*Әд.:* Полиграфическая школа ФЗУ имени А.В.Луначарского Т.С.С.Р. К., 1929.

*Е.П.Ключевская.*

**ПОЛИГРАФИ́Я-НӘШРИЯ́Т КОМБИНАТЫ́**, Казанда, полиграфия сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 158 кеше (2006). Составында — басуга кадәрге процесслар, офсет-басу, төпләү цехлары; ярдәмче подразделениеләр: ремонт-механика цехы, транспорт участогы. Төрле басма продукция — китаплар, брошюра, буклет, бланклар, этикеткалар, ш.у. сәнәгый каплар һәм төрү материаллары, альбомнар, дәфтәр, папкалар һ.б. чыгара. 1919 елда национализацияләнгән пр-тиеләрне — *Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф коюю ширкәтен*, «*Мәгариф*» басмаханәсен берләштерү юлы б-н 6 нчы басмаханә буларак оештырыла. 1922 дә 6 нчы басмаханәгә Камил Якуб исеме бирелә. 1923 тән ТАССР Нәшрият һәм матбугат комб-ты составында. 1926 дан Татиздат карамагында. 1927 дә К.Якуб исем. китап ф-касы итеп үзгәртелә. Татар һәм рус телләрендә сәяси, фәнни, матур әдәбияттан тыш, СССРның башка төбәкләрендә яшәүчеләр өчен татар телендә басма продукция чыгарыла. 1926–28 елларда басу һәм җыю цехлары, коюстереотип бүлеге яңартып җиһазландырыла һәм механикалаштырыла. Яңалиф гамәлгә кертелгәннән соң (1927) татар телендәге текстлар — латин графикасында, 1939 дан кириллицада басыла, моның өчен җыю билгеләре (хәрефләр) эретеп яңадан коела, җыю машиналарының калыплары алыштырыла. 1928 дә — беренче ротация машинасы, 1930 да линотип эшли башлый, басу машиналары паркы яңартыла. 1927–32 дә продукция чыгару үсә (млн. данә): табак-оттискалар 3,2 дән 4 кә, тираж 0,6 дан 7,6 га кадәр арта.

1930 еллар башында К.Якуб исем. китап ф-касы ТАССРның иң эре полиграфия пр-тиесе була; ул ТАССР районнарында, республикадан читтә, ш.у. илнең татарлар тупланып яшәгән төбәкләрендә басмаханәләр оештыруда гамәли ярдәм күрсәтә. Фабриканың басма паркының айлык җитештерү куәте 4 млн. табак-оттиск, төпләү цехыныкы 250 мең данә тәшкил итә. 1935 тә фабрика *Матбугат йортыны*ң яңа бинасына күченә. Бөек Ватан сугышы елларында пр-тие армия уставлары һәм карарларын, төрле күрсәтмәләр, кызылармияче кенәгәләрен, китаплар, брошюра, конверт, дәфтәрләр бастыра, хәрби йөкләр өчен каплар, әрҗәләр җитештерә.

1958 дә К.Якуб исем. китап ф-касы, Н.Александров исем. газета-журналлар басмаханәсе, «Татполиграф» басмаханәсенең төсле басу һәм фотоцинкография цехы җирлегендә К.Якуб исем. Матбугат йорты оештырыла. Анда республика көндәлек басмалары, ш.и. «*Красная Татария*», «*Кызыл Татарстан*» г-талары басыла, башка басма продукция чыгарыла. 1960 елларда комбинатта яңа полиграфия машиналары һәм җиһазлары урнаштырыла, төпләү эшләре, китап һәм газета продукциясен җыю механикалаштырыла; офсет кулланып басу үзләштерелә. Офсет-басу цехында җитештерү күрсәткече елга 55 млн. прогон тәшкил иткән ике төс һәм бер төс б-н эшләүче машиналар файдаланыла. Формаларны цинк урынына алюминийдан эшләү, китапны бер пресс б-н бастыру үзләштерелә; фотопроцесслар камилләштерелә. Текст диапозитивлары җыелган текстларны фотога төшерү юлы б-н әзерләнә. Фотомеханик корректура кулланыла, оригиналлар сыйфатында төсле диапозитивлар файдаланыла. Цех 4 төстәге журналлар («*Чаян*» һ.б.), 6 төстәге журнал тышлары, күп төстәге ябыштырма битләр, тышлыклар, этикеткалар, балалар әдәбияты чыгара. Җыю цехы күчмә гранка — реаллар һ.б. җайланмалар б-н җиһазландырыла, бер үк вакытта агымлы җитештерү, прогрессив басу технологияләре гамәлгә кертелә; текст юлларын коючы, эре кегльле машиналар, биткә салу-корректура станоклары һ.б. кулланыла. Текстны күпсанлы шрифт, аерып күрсәтүләр һәм гади формулалар б-н җыйганда машинадан файдалану үзләштерелә; брошюралау-төпләү цехы битләр алу, форзацларны ябыштыру, ябыштырма битләрне тегү машиналары б-н җиһазландырыла; синтетик җилемнәр һәм материаллар кулланыла; китапларны пресслау өчен асылма конвейер эшкә кушыла; күчерү-транспортлау операцияләре механикалаштырыла, продукцияне агымлы җитештерү җайга салына. Комб-тта база лаб-ясе эш-

ли, ул республиканың башка басмаханәләренә яңа полиграфик материаллар һәм технологияләр үзләштерүдә ярдәм итә. Басу паркы яссы басма, тигель, ротация машиналарыннан тора.

К.Якуб исем. нәшрият комб-ты ел саен 3–4 мең басма табак күләмендә 6 млн.данәдән артыграк тираж б-н (1966–67 дә — 10 млн. данә) китаплар һәм брошюралар, 300 млн. данә газеталар, 20 млн. *см*² клише, төрле бизәлгән продукция чыгара. Анда респ-када чыгучы барлык китап, журнал һәм газеталар басыла; продукция РСФСР шәһәрләрендәге китап кибетләренә, ш.у. Алма-Ата, Ашхабад, Баку, Ташкент, Фрунзе һ.б. җирләргә җибәрелә.

1960 еллар башында СССРның үзәк газеталарын 1 млн. данәдән арткан көнлек тираж б-н басу өчен җитештерү базасы модернизацияләнә һәм киңәйтелә. 1964 тән шундый 5 газета калып кулланып басыла. 1968–73 тә комб-т басмаханәләрендә яңа машиналар һәм җиһазлар (127 берәмлек) урнаштырыла, эш урыннарына ярымфабрикатлар илтү өчен транспортёрлар (354 *м*) куела. Нәтиҗәдә цехларда күп хезмәт кергән процессларны механикалаштыру дәрәҗәсе арта. Комб-т төрле нәшриятларның заказларын үти. 1970 елларда комб-т Мәскәүдән, ш.у. Дагстан, Каракалпак АССР, Төркмәнстан, Казакъстаннан килгән заказларны башкара.

1973 тә К.Якуб исем. нәшрият комб-ты К.Якуб исем. полиграф. комб-ты итеп үзгәртелә, аның составына Казан авиация технологияләре фәнни-тикшеренү ин-тындагы, Казанның «Элекон», вакуумлы машиналар төзү, резина-техник эшләнмәләр з-дларындагы ф-лары б-н «Татполиграф» басмаханәсе (1927 дә нигезләнә) кертелә (киләчәктә: 1993 тән — «Татполиграф», 1995 тән ф-лары мөстәкыйль пр-тиеләр). Үзгәртеп кору барышында җитештерү реконструкцияләнә, өстәмә биналар төзелә, цехларда һәм участокларда капиталь ремонт уздырыла, прогрессив технологияләр үзләштерелә.

КПССның Татарстан өлкә ком-ты газета-журналлар нәшрияты (1971; хәзер «Татмедиа» ААҖ ф-лы *«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы»*) файдалануга тапшырылу сәбәпле, комб-т эшчәнлеге өлкәсендә китаплар басу (елга каты тышлыкта — 4 млн.нан артык данә, йомшак тышлыкта 6,1 млн. данә) һ.б. төрле басма продукция (18 млн. табак оттиск) калдырыла. 1986–93 тә фотоҗыю, цинк формалар урынына коры фотополимер формалар (ротация машиналары өчен), төсле басмалар өчен төсләргә бүлү җайланмасы, төрле төпләү материаллары гамәлгә кертелә. Ләкин комб-т басмаханәсендә һаман искергән «кайнар җыю» һәм фотоцинкография кулланыла, шул сәбәпле көндәшлеккә сәләтле басма продукция җитештерү мөмкинлекләре чикләнә. 1995–97 дә Англиядән һәм Италиядән кайтартылган заманча полиграфия җиһазлары б-н комб-т техник яктан яңартып коралландырыла. Ассортимент 100 ләп исемдәге продукцияне үз эченә ала. 1997 дә комб-т составында структур подразделение — «Матбугат йорты» нәшрияты оештырыла (1998 дән мөстәкыйль оешма). Шул ук елда пр-тиенең исеме «Полиграфия-нәшрият комбинаты» ДУП дип үзгәртелә; 2008 дән «Казан полиграфия комбинаты» ҖЧҖ. 2011 дә эшчәнлеге туктала.

Заказчылары — ТР Үзәк сайлау комиссиясе, *Татарстан китап нәшрияты, «Мәгариф»*, «Лиана», «Цитадель» нәшриятлары, ТР ФАнең *Татар энциклопедиясе институты, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты* һ.б.

Бөтенсоюз китап күргәзмәсендә сәнгать бизәлеше һәм полиграфия эшләнеше өчен комб-т диплом б-н бүләкләнә («Букварь», 1966); пр-тиегә РСФСР МСның һәм мәдәният хезмәткәрләре профсоюзы ҮКның күчмә Кызыл байрагы тапшырыла (1966, 1967); Бөтенроссия «Китап сәнгате» конкурсында диплом бирелә (1976). Парижда уздырылган халыкара «Прогресс хакына партнёрлык» конкурсында П.-н.к. «Гран-при» (1998), «Алтын Меркурий» (1998), «Бәллүр Ника» (2000) призларын яулый.

Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була: 1 кешегә — РСФСРның атказ. китап басучысы, 1 кешегә — ТРның атказ. икътисадчысы, 2 кешегә ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 1 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — «Почёт билгесе» ордены, 7 кеше — медальләр, 1 кеше ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — П.М.Луговкин (1919–23), Л.Ш.Вахитов (1923–26), А.Р.Төхвәтуллин (1934–37), К.Ә.Әхмәдуллин (1938–42), Н.К.Демидов (1963–72), В.З.Гафуров (1973–78), В.С.Сергеев (1978–83), Р.А.Вафин (1983–86), В.И.Морева (1986–94), Ә.Б.Мадьяров (1994–2007).

*Әд.:* Олевич В. Комбинат им. К.Якуба // Полиграфия. 1967. № 8; Фёдоров В.П. Производственная база печати Татарии // Полиграфия. 1967. № 11/12; Гафуров В.З., Мифтахов З.З. Развитие полиграфии и печати в Татарии. К., 1977.

*М.Ж.Гаитов.*

**ПОЛИКА́РПОВ** Александр Егорович (18.5.1917, Казан губ., Чистай өязе Новотроицкий а. — 20.10.2003, Казан), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Хезмәт эшчәнлеген 1929 елда Яңа Чишмә р-нының «Красная горка» («Кызыл Тау») к-зында башлый, аннан соң Яңа Чишмә МТСында эшли: тракторчы, трактор бригадасы бригадиры, 1948–51 елларда директор урынбасары. 1951–53 тә «Красный Октябрь» к-зы, 1953–63 тә Молотов исем. к-з, 1964–80 дә 22 нче партсъезд исем. к-з рәисе. П. җитәкчелегендә 1966–70 тә хуҗалыкта бөртекле культураларның уңышы, алдагы бишьеллык б-н чагыштырганда, 1 *га* дан 5,6 *ц* га арта һәм уртача — 17,5 *ц*, 1970 тә 20 *ц* тәшкил итә; ашлык сату планы 129,3% ка, сөт — 108%, ит — 140%, йон 131% ка үтәлә; хезмәт җитештерүчәнлеге 30% ка, акчалата керем 41% ка арта. Хуҗалык СССР ВДНХсының 2 нче дәрәҗә дипломы, КПСС ҮК, ЮС Президиумы, СССР МС һәм ВЦСПСның Ленин грамотасы б-н бүләкләнә (1970). Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

*И.Н.Афанасьев.*

**ПОЛИКЛИ́НИКА** (грек. pólis — шәһәр һәм klinikḗ — дәвалау), аяк өстендәге авыруларга үзләрендә яки авыруларның өйләренә барып мед. ярдәме күрсәтү, ш.у. профилактика чаралары үткәрү һәм халыкны диспансеризацияләү б-н шөгыльләнүче күппрофильле махсус дәвалау-профилактика учреждениесе. П. беренче мед.-сан. ярдәмен оештыруда әһәмиятле буынны тәшкил итә, аларда төп дәвалау белгечлекләре: терапия, кардиология, невропатология, хирургия, акушерлык, гинекология, оториноларингология, офтальмология, педиатрия буенча ярдәм күрсәтелә. П. составына рентген һәм физиотерапия бүлекләре, дәвалау-диагностика лаб-ясе, аптека һ.б. керә. П. эпидемияләргә каршы чаралар күрә, хезмәткә яраклылыкны ачыклау буенча экспертиза уздыра, авыруларны клиникаларга һәм мед.-социаль эксперт комиссиясенә юллый. П.ның эшчәнлеге терр. һәм хезмәт урыны (идарәчелек) принцибына карап оештырыла. П.ның төрләре күп, мәс., балалар һәм өлкәннәр өчен шәһәр, район П.лары, үзәк П.; ш.у. махсуслаштырылган П.лар һәм үзәкләр: стоматология, физиотерапия, консультация бирү П.лары (респ-ка һәм өлкә хастаханәләре каршында); су һәм тимер юл транспортында эшләүчеләргә, студентларга, гарнизоннарда — хәрби хезмәттәгеләргә мед. ярдәме күрсәтү пунктлары (здравпункт); хатын-кызлар консультацияләре; консультация-диагностика П.лары; мед.-сан. частьлары һ.б.

Россиядә П. хезмәте принциплары земство медицинасы чорларында формалаша. 19 йөз башында П.лар эре шәһәрләрдә генә була; 1913 елда 1230 лап шәһәр амбулатор-поликлиника учреждениесе исәпләнә (башлыча, түләүле), аларның һәркайсында, кагыйдә буларак, нибары бер гомуми практика табибе эшли. Земство медицинасы тәртипләре буенча, төбәктә П. башкарырга тиешле гамәлләрне табиблек участоклары (1870 ләрдә төзелә) составындагы фельдшерлык-акушерлык пунктлары үти. Казан губернасында 7 табиблек участогы, ш.и. Казанда амбулатория була. Өязләрдә акрынлап участок тәртибенә күчелә.

1924 тә сәламәтлек саклау бүлекләренең 5 нче Бөтенроссия съезды уздырыла. Анда, бушлай квалификацияле дәвалау-профилактика принципларын саклаган хәлдә, халыкка амбулатор-поликлиника ярдәме күрсәтүне үстерү юллары билгеләнә; 1935 тә РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында П.лар советы төзелә; 1947–49 да П.лар б-н хастаханәләрне бердәм дәвалау-профилактика учреждениеләре итеп кушу буенча реформа уздырыла, бу авыруларны тикшереп диагноз кую һәм дәвалау арасында өзеклек булдырмауны тәэмин итү өчен эшләнә (к. *Сәламәтлек саклау*). П. эшчәнлегенең иң мөһим тармакларының берсе — халыкны диспансерлаштыру (к. *Диспансерлар*).

1954 тән Татарстанда П.лар, бүлекләр сыйфатында, хастаханәләр составына кертелә. Хатын-кызлар консультацияләре, стомато-

логия, физиотерапия һәм курорт П.лары гына мөстәкыйль эшчәнлек алып бара. Район үзәкләрендә П. үзәк район хастаханәсенең состав өлеше булып тора, авыл җирләрендә авыруларга фельдшерлык-акушерлык пунктларында һәм амбулаторияләрдә ярдәм күрсәтелә. 1970–80 елларда аерым белгечлекләр буенча махсус мед. ярдәме челтәре үсеш ала.

2000 нән, стационар дәвалану төрен пациентларның яшәү урынына якынайту максатыннан, П.ларда көндезге стационарлар оештырыла башлый.

2011 дә ТРда 226 амбулатория-поликлиника учреждениесе исәпләнә; П.ларның 120 се башка амбулатор-поликлиника учреждениеләре составында эшли. 100 П.да көндезге стационар бар, аларда ел саен 50 меңнән артык кеше дәвалана.

*Әд.:* Популярная медицинская энциклопедия. М., 1987; Зыятдинов К.Ш., Павлухин Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана (до 1917 г.). К., 2005.

*В.Г.Шерпутовский, Ф.Ф.Нуриева.*

**ПОЛИМЕРЛА́Р ҺӘМ МАХСУ́С КАУЧУКЛА́Р ИНСТИТУТЫ́** Казан технология университеты каршындагы фәнни-тикшеренү институты («Спецкаучук»), Казанның С.М.Киров исем. синтетик каучук з-ды каршында Бөтенсоюз синтетик каучук фәнни-тикшеренү институты (ВНИИСК, Ленинград) тарафыннан 1966 елда оештырылган полисульфид каучуклар тармак лаб-ясе базасында, 1968 дә, С.В.Лебедев исемендәге әлеге ин-тның Казан ф-лы буларак төзелә.1988–97 дә «С.М.Киров исем. Казан синтетик каучук заводы» ФҖБ составында, 1992 дә Махсус каучуклар фәнни-тикшеренү институты (1997 гә кадәр химия буенча РФ Дәүләт к-тына карый), 1997 дән хәзерге исемдә. Институт составына полисульфид олигомерлар һәм композицион материаллар лаб-яләре керә. Аның фәнни-тикшеренү юнәлешләре — беренчел чималны синтезлау, түбә ябу һәм судан изоляцияләү материалларын, тиокол һәм уретан герметиклар, кайнар һәм салкын килеш ката торган полиуретанлы композицияләр, төрле резин-техник эшләнмәләрне җитештерү технологияләрен булдыру. Төп эшкәртмәләре Казан синтетик каучук з-дында гамәлгә кертелә. Җитештерү күләме артык зур булмаганлыктан, з-дның җиһазлары яңа технологияләр һәм продуктларны эшләп карау өчен тәҗрибә базасы буларак файдаланыла. 1988 гә кадәр фәнни-тикшеренү эшләре ВНИИСК лаб-яләре б-н бергә алып барыла. 1969–97 дә полиуретан, полисилоксан (җылытуга чыдам), полисульфид эластомерлар лаб-яләре, резинаны кабаттан эшкәртү һәм аның үзлекләрен өйрәнү, физик-химик тикшеренү алымнары лаб-яләре оештырыла. Казан ф-лының төп фәнни эшчәнлеге — уретан, силоксан, полисульфид эластомерлар химиясе, аларны җитештерү һәм эшкәртү технологияләре, куллану даирәсе. Җылылыкка чыдам эластомерлар лаб-ясендә силоксан элостомерлар өлкәсендә тикшеренүләр алып барыла. Структур силоксан (Si-O-Si), силозан (Si-NH-Si), силтиан (Si-S-Si) буыннары кергән кушылмалар синтезлана, аларның үзлекләре, реакциягә керү сәләте, куллану өлкәләре өйрәнелә. Бу тикшеренүләрнең нәтиҗәләре силоксан җитештерү өчен күп кенә продукт һәм ярымпродуктлар алу технологияләренең, органик, нәорганик һәм элементорганик кушылмалар алу алымнарының төп нигезен тәшкил итә. Махсус үзлекле силоксан каучукларның яңа төрләре, алар нигезендәге резиналар, композицион составлар, термототрыклагычлар һ.б. продуктлар эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. Силоксан чылбырын структур металлсилоксан буыннар һәм дифенилсилоксан буыннар б-н үзгәртү хисабына термототрыклылыгы югарырак булган яңа төр каучуклар алу технологияләре; гидросилирлану реакциясе буенча вулканлашуга сәләтле, салкынга чыдамлыгы югары булган винилланган сыек каучуклар эшләү технологияләре; үзлелеге нормага китерелә торган салкынга чыдам каты каучуклар табу технологияләре эшләнә. Саф һәм аеруча саф сыек силоксан каучуклар технологиясенә нигезләнеп, салкын килеш ката торган композицион составлар: пар казаннарын герметиклаштыру өчен җылыга чыдам мастика, махсус техникага салу өчен компаундлар, икмәк пешерү формаларына көнбагыш мае урынына сылана торган составлар җитештерү гамәлгә кертелә. Бакыр-, хромгетеросилоксаннар нигезендә термототрыклагычлар, силоксан резиналар өчен структура үзгәртә торган агентлар эшләнә. Әлеге ярымпродуктларны кулланып, бер стадиядә вулканлаша торган һәм эшләтү ресурсы 2 тапкыр артыграк булган кабельле силоксан резин җитештерү, ш.у. трекингэрозия чыдамлылыгы югары булган силоксан резин җитештерү оештырыла. Силоксан каучук һәм резин җитештерү калдыкларын кабаттан эшкәртү һәм утилләштерү технологиясе гамәлгә кертелә. Икенчел эшкәртү продуктларыннан тәҗрибә-сәнәгать масштабында яңа композицион материаллар алына (төзелеш өчен фасад буяулары, герметиклар һәм компаундлар, гидрофоблаштыручы составлар). Силоксан резиннарның һәм алар нигезендәге резин-техник эшләнмәләрнең яңа маркалары, ш.и. микродулкынлы мичләр җыю өчен эшләнмәләр комплекты,үзәктән куулы кою өчен эластик формалар эшләнә һәм җитештерүгә кертелә. Полиуретан эластомерлар лаб-ясендә «Катур» тибындагы термоэластопласт (аның техникада конструкцион материал буларак кулланылу өлкәләре өйрәнелә), валлар әзерләү өчен коелма уретаннар алу, аяк киеме сәнәгате өчен уретан җилем табу (ш.и. сәнәгать калдыкларын кулланып) технологияләре эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Полисульфид эластомерлар лаб-ясендә тиокол, ТПМ-полимер һәм алар нигезендәге композицион материаллар алуның калдыксыз технологияләре булдырыла. Композицион материаллар лаб-ясендә торак йортлар төзелешендә панельләр арасындагы җөйләрне герметиклаштыру өчен ике компонентлы герметикның 4 төре (Казан синтетик каучук з-дында кулланыла), ш.у. төзелеш ихтыяҗларында түбә ябу өчен рулонлы резин материаллар эшләнә. Институт Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-ты, В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесе, «Капролактам» АҖ (Дзержинск ш.) һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. Төрле елларда ин-т директорлары — Р.К.Вәлетдинов (1968–87), Е.П.Лебедев (1987–97), Л.Ю.Гобәйдуллин (1997–2002), Ю.Н.Хәкимуллин (2002–03), Ф.М.Палютин (2003 тән).

*В.Г.Абзалова.*

**«ПОЛИМЕРФО́ТО»**, химия сәнгате пр-тиесе. 1935–41 елларда Казан фотожелатин з-ды (1939 дан; 1943–63 тә — 9 нчы з-д) буларак сафка баса. 1981–86 да Казан «П.» з-ды буларак «Тасма» ҖБ составында, 1987 дән арендa пр-тиесе, 1996 дан «П.» АҖ. Бөлгенлеккә төшкәннән соң, яшәүдән туктый (1998). Эшләүчеләр саны: 1990 да — 1498 кеше, 1996 да — 893 кеше.

1970 еллар уртасына кадәр илдә кинофото-, аэрофото-, фототехник тасмалар һәм рентген плёнкалары җитештерү өчен желатин (мөгезле эре терлек сөякләреннән), кондитер сәнәгате өчен азык-төлек желатины эшләп чыгаручы бердәнбер пр-тие була. Бөек Ватан сугышы чорында фронт өчен өзлексез кинофотоматериаллар җибәрүне тәэмин итә; сугыштан соңгы беренче елларда проектта каралган куәттә эшли башлый. Алдагы елларда, пр-тиене киңәйтү һәм реконструкцияләү, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру (1970–80 еллар) нәтиҗәсендә желатин чыгару 4 тапкырдан күбрәккә, ассортимент 20 төргә кадәр арта. Аксым гидролизаты һәм сөяк мае (юу чаралары җитештерү өчен), кер сабыны, техник ябыштыргыч тасмалар, синтетик полимерлар нигезендә товарлар эшләп чыгару үзләштерелә; а.х. ихтыяҗлары өчен җитештерү калдыкларыннан ашламалар (преципитат), фосфорга бай сөяк һәм шлам оны эшләнә. 1973 тә завод МК-60 магнитофон кассеталары чыгаруга керешә (магнитлы тасма В.В.Куйбышев исем. Казан химия з-дыннан китерелә). 1982 дә Көнбатыш Германиянең «Антон Олерт» фирмасының автоматлаштырылган җиһазлары урнаштырылганнан соң, СССРда кассеталар җитештерүдә иң югары күрсәткечләргә ирешелә: 1983 тә — 12,3 млн., 1990 да — 27 млн. данә (илдә җитештерелгән әлеге продукциянең яртысыннан күбрәк өлеше). 1990 елларда, икътисади элементләрнең, җитештерү күләмнәренең кискен кимүе нәтиҗәсендә «П.»ның төп продукциясенә ихтыяҗ азаю сәбәпле, азык-төлек желатины һәм техник желатин, пластмасса әйберләр эшләп чыгару арттырыла. 1997 дә, продукцияне сату кыенлашкач, төп эшчәнлек туктала, кассеталар җитештерү 2000 гә кадәр эшләп килгән «Порф Рекордс» АҖгә тапшырыла.

9 нчы бишьеллык планны үтәүдә уңышлары өчен завод — РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1976), механикалаштыру һәм автоматлаштыру өлкәсендәге казанышлары өчен ВЦСПСның 1 нче премиясе һәм дипломы б-н бүләкләнә (1978). Пр-тиенең 298 хезмәткәре орден һәм медальләргә лаек була; Ф.Ш.Нигъмәтҗановага СССРның Дәүләт бүләге бирелә (1980).

Төрле елларда пр-тие җитәкчеләре: В.В.Кузнецов (1935–41), Варнаков (1941–?), А.А.*Кириллович* (1965–82), В.Ф.Бобров, Н.В.Ушаков, Г.И.Трусенёв, В.В.Филиппов, С.Н.Колесников (1989–96), Р.Т.Галимов (1996–98).

**«ПОЛИМИ́З»**, полимер савытлар һәм төргәкләү материаллары җитештерү заводы, химия сәнәгате пр-тиесе. Казанда урнашкан. Басым астында кою, экструзия һ.б. ысуллар кулланып термопластик массалардан эшләнмәләр ясау б-н шөгыльләнә. Пр-тие составында: 2 җитештерү цехы — полимер савытлар, беренчел формалар (преформалар) һәм капкачлар цехлары; 2 участок — пластик массаларны эшкәртү (җитештерүнең технол. калдыкларын ваклау һәм бөртекләндерү) һәм энергомеханика цехы. Эшләүчеләр — 100 кеше (2008). Файдалануга 1971 елда тапшырыла. 2,1 мең *м*² мәйданда 9 җитештерү участогы һәм 5 ярдәмче участок урнаша. Эшләү елларында пр-тие реконструкцияләнә һәм шактый киңәйтелә, пешерелгән казылык һәм казылыксыман ысланган сыр өчен целлюлоза плёнкадан (целлофаннан) тышчалар җитештерү цехы, рельслар яны склады б-н тимер юл тупигы, гараж, складлар төзелә. Даими файдаланулы полиэтилен савытлар һәм плёнка калдыкларын эшкәртү өчен бөртекләндерү куәте елга 1 мең *т* га исәпләнгән герметик линия, полиэтилентерефталаттан (ПЭТ) елга 74 млн. данә преформа җитештерергә сәләтле куәтле Швейцария линиясе, елга 60 млн. данә полиэтилен бөке эшләп чыгаруга исәпләнгән Италия линиясе урнаштырыла. Төп продукциясе — полимер савытлар (төрле туклану продуктларын саклау һәм күчереп йөртү өчен полимер әрҗәләр) һәм төргәкләү материаллары. Шулай ук үрентеләр өчен әрҗәләр, капкачлы баклар, хуҗалыкта кулланыла торган тазлар, ПЭТ шешәләр һәм аларның үзлектән тыгызланучы капкачларын өреп ясау өчен 42 *г* авырлыктагы преформалар, азык-төлекне һ.б. продуктларны төрү, шешәләргә салынган әчемлекләрне термик ысул б-н төркемләп төргәкләү өчен плёнка, полиэтилен капчыклар, пакетлар эшләп чыгарыла. Чимал «Казаноргсинтез», «Чаллы картон-кәгазь комбинаты» халык предприятиесе» АҖләреннән, «Машцентр» ҖЧҖдән (Мәскәү) һ.б.дан китерелә. Товарлыклы продукция җитештерү күләме 102,4 млн. сумга җитә. Эшләнмәләр Татарстанда сатыла, РФ төбәкләренә, ш.у. Казакъстанга чыгарыла. 1980–90 да продукция Кыргызстанга җибәрелә. Бөтенроссия «Савытлар һәм төргәкләү» күргәзмәләрендә җитештерүдәге казанышлары өчен заводка 5 ел рәттән 1, 2 нче дәрәҗә дипломнар бирелә. 1 кеше — «Почёт билгесе» ордены, 2 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: Ф.Г.Шәйдуллин (1968–76), Э.Г.Ганиев (1976–80), Я.М.Дәүләтшин (1980–99), С.В.Князев (1999–2001), Х.Н.Камалов (2001–04), Р.З.Шәйхетдинов (2006–07), Н.Г.Гарифуллин (2007–2012).

*М.Җ.Гаитов.*

**ПОЛИСЕМИ́Я** (лингв.) (грек. polýsēmos), күпмәгънәлелек, бер сүзнең берьюлы берничә (ике яки аннан күбрәк) мәгънә белдерүе. Татар теленә, нигездә, лексик П. хас: бер үк сүз төрле предмет һәм күренешләрне белдерә; мәс., кыр (исем) сүзе түбәндәге лексик мәгънәләргә ия: 1) урмансыз мәйдан (кырда чәчәк җыю); 2) чәчү өчен эшкәртелә торган җир (иген кыры); 3) нәрсә өчен дә булса махсус җиһазландырылган тигез мәйданчык (футбол кыры); 4) чикләрендә нинди дә булса махсус көчләрнең тәэсире чагылыш таба торган киңлек (магнит кыры); 5) китап, дәфтәр кырыендагы чиста буй (дәфтәр кыры); 6) эшләпә кырые (киң кырлы эшләпә). Сүзнең теге яки бу мәгънәсен контекст яки сөйләмнең гомуми тематикасы бирә. Күпмәгънәле сүзнең мәгънәләре арасында билгеле бер семантик бәйләнеш була, шуңа күрә, омоним сүзләрнең мәгънәләреннән аермалы буларак, бу мәгънәләрнең бер үк сүзнеке булуы шик тудырмый.

*Әд.:* Хаков В.Х. Татар әдәби теле. К., 1999; Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. К., 2001; Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

**ПОЛИ́ЦИЯ**, җәмәгать куркынычсызлыгын һәм җәмәгать тәртибен саклау, җинаятьчелеккә каршы көрәш һәм халыкның иркенлектә яшәвенә булышлык итү буенча дәүләт органнары системасы. Россиядә мөстәкыйль учреждение буларак оештырыла. Казанда һәм Казан губернасында П. император Анна Иоанновнаның 1733 ел 23 апрель Фәрманы нигезендә төзелә, 1782 ел 8 апрель Җәмәгать тәртибе Уставына (к. *Җәмәгать тәртибе идарәсе*), аннары император Павел I нең 1797 ел 19 декабрь һәм 1798 ел 28 апрель, император Александр I нең 1825 ел 25 октябрь Фәрманнарына, 1837 ел 3 июнь Нигезләмәсенә һ.б.га яраклаштырып үзгәртелә. 1863 тә П. органнары 1862 нең 25 декабрендәге «Губерна шәһәрләрендә һәм өязләрендә полиция төзелеше турында вакытлы кагыйдәләр»не керткәндә *полиция идарәләренә* әверелә. Гомуми П. губернада губернатор һәм губерна идарәсе карамагында була, өяз шәһәрләрендә һәм өязләрдә — исправниклар һәм өяз П. идарәләре, авылларда — становой приставлар, өяз П. сакчылары (урядниклар, стражниклар) һәм авыл П.се (авыл җыеннарында сайланган десятскийлардан тора, волость старшиналарына буйсына), губерна шәһәрендә — полицмейстер һәм шәһәр П. идарәсе (аның системасына аерым приставлар һәм квартал надзирательләре кул астындагы П. частьлары һәм кварталлары; полиция бүлекләре (околоточлар) һәм түбәнге звено — городовой постлары керә. Гомуми П.дән тыш, сәяси П. (к. *Казан губернасы жандармнар идарәсе, Казан саклау бүлеге*) һәм махсус хезмәт П.се (эзләү, мәхкәмә, елга һәм порт, фабрика-завод һ.б.) аерылып чыга. Барлык П. структуралары Россия Эчке эшләр министрлыгына (1810–19 да Полиция министрлыгына) буйсына. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 нең 10 март һәм 17 апрель карарлары б-н гамәлдән чыгарыла, функцияләре *милициягә* тапшырыла. 2011 дә милиция бетерелә, аның нигезендә П. кабат торгызыла.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 9. № 6378; Т. 21. № 15379; Т. 24. № 18285; Т. 25. № 18506; Т. 40. № 30552; Собр. 2. СПб., 1838, Т. 11, отд. 1. № 10305; 1865. Т. 37, отд. 2. № 39087.

*Әд.:* Сизиков М.И. История полиции России (1718–1917): В 2 вып. М., 1992; История полиции России: Краткий исторический очерк и основные документы. М., 1998.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОЛИ́ЦИЯ ИДАРӘЛӘРЕ́**, җирле адм.-полиция органнары. Казан губернасы терр-ясендә 1862 елның 25 декабрендәге «Губерна шәһәрләре һәм өязләрендә полициянең гомуми тәртибе хакында вакытлы кагыйдәләр»гә яраклы рәвештә шәһәр (Казанда) һәм 12 өяз П.и. барлыкка килә. Алар карамагында башкару, тикшерү, мәхкәмә, хуҗалык-оештыру эшләре була. П.и. становой приставлар һәм аларга буйсынган затларның эшчәнлеген контрольдә тоталар, законнарның үтәлешен күзәтәләр, җәмәгать куркынычсызлыгын саклыйлар, җәмгыятьне төзекләндерү б-н шөгыльләнәләр, полклар һәм төрле хәрби командаларның шәһәрләрдә һәм өязләрдә тору тәртибенә күзәтчелек итәләр, армия һәм флотның запастагы түбән чиндагыларын исәпкә алуны һәм хакыйкый хезмәткә чакыруны гамәлгә ашыралар һ.б. 1864 елгы Мәхкәмә реформасы уздырылганнан соң, мәхкәмә-полиция тикшерүе *Казан округ мәхкәмәсенә* һәм *җәмәгать мәхкәмәсенә* (мировой суд) тапшырыла. П.и.нең җинаять эшләре буенча сорау алу үткәрүдә һәм тикшерү алып баруда чикле күләмдә катнашуы, тиешле затларны тикшерүгә һәм мәхкәмәгә чакыру, җәмәгать судьялары күрсәтмәсе буенча акчалата штрафларны юллап алу вазифалары саклана. 1864 тә земстволар кертелү нәтиҗәсендә П.и. кайбер җирле салымнар җыюдан азат ителә; салым җыемнары — туры-дан-туры салымнар (1903 кә кадәр), подрядлар буенча залоглар җыю, салым һәм пенсия кәгазьләрен җибәрү, бурычларын түләргә хәле җитмәгән кешеләр эшен тикшерү аларга йөкләнеп кала. П.и.нең икенче дәрәҗәдәге вәкаләтләрен кыскарту җәза бирү вәкаләтләренең көчәюенә китерә. Казан шәһәр П.и.нә полицмейстер — шәһәр полициясе башлыгы (вазифасында губернатор тәкъдиме б-н эчке эшләр министры тарафыннан раслана), аның ярдәмчесе һәм гомуми кабулханә керә, аңа шәһәр приставлары, аларның ярдәмчеләре һәм полиция надзирательләре буйсына. Өяз П.и.нә өяз исправнигы (җирле дворяннардан губернатор тарафыннан билгеләнә), аның ярдәмчесе, дворяннар утырышчысы (өяз *Дворяннар җыены* тарафыннан сайлана), 2 авыл утырышчысы, шәһәр магистратыннан ратман (сайланган әгъза) керә. Өяз идарәсе гомуми, җинаять һәм гражданлык эшләре, становой приставлар өстәлләреннән гыйбарәт. Өстәлләр өстәл башлыгы, секретарь һәм хезмәткәрләрне (теркәүчеләр, сотскийлар, десятскийлар, полиция сакчылары) берләштерә. П.и. губернаторга, губерна идарәсенә һәм Россия Эчке эшләр министрлыгына буйсыналар. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 10 март карары нигезендә бетереләләр.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1865. Т. 37, отд. 2. № 39087.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 4.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОЛИЭЛЕКТРОЛИТЛА́Р** (полимер электролитлар), поляр эреткечтә корылган полиион хасил итеп диссоциацияләнә торган полимер кушылмалар классы. П. табигый (аксымнар, нуклеин к-талары, полипептидлар, полишикәрләр, үсемлек сумалалары) һәм синтетик (полиакрилатлар, поливинилсульфонатлар, поливинилфосфатлар, полиакриламид, поливинилпиридин, чиксез к-талар һәм нигезләрнең сополимерлары һ.б.) төрләргә бүленә. Корылма тамгасына карап, анион, катион һәм амфолит П.ны аерып йөртәләр.

П. өлкәсендәге беренче хезмәтләр Германиядә Г.Штаудингер һәм В.Керн тарафыннан язылa (1935). «Полиэлектролит» атамасын 1940 елларда Р.Фоус кертә. СССРда П. Мәскәүдә (В.А.Каргин, В.А.Кабанов), Ленинградта (С.Я.Френкель, О.Б.Птицын), Саратовта (С.А.Гликман), Ташкентта (К.С.Әхмәтов), Алма-Атада (Е.А.Бектуров) өйрәнелә. Татарстанда П. буенча фәнни юнәлеш 1950 елларда Казан химия-технол. ин-тында башлангыч ала (С.М.Кочергин, Е.В.Кузнецов, В.П.Барабанов). Тикшеренүләр полимерлау — бергә полимерлау синтезы һәм кинетикасы (Е.В.Кузнецов, В.П.Архиреев, В.А.Мягченков, В.Ф.Куренков), эремәләр теориясе (В.П.Барабанов, В.М.Центовский, М.Л.Бренерман), күчерү процессы һәм электродлардагы электрохимик процесслар (В.П.Барабанов, Г.Я.Вяселева, А.А.Коноплёва, Д.М.Торсуев), П.ның актив өслекле матдәләр б-н тәэсир итешүе (А.Я.Третьякова, А.И.Курмаева), структуралар хасил булу (Е.В.Кузнецов, С.В.Крупин), полиэлектролит комплекслар (С.В.Крупин, В.А.Мягченков, Т.Г.Победимская, Н.В.Бикчәнтәева) буенча үткәрелә. П.ны сусыз тирәлекләрдә өйрәнүгә аеруча игътибар ителә. П. өлкәсендәге тикшеренү нәтиҗәләре ТР, РФ һәм чит илләр халык хуҗалыгының төрле тармакларында кулланыла: коррозиягә каршы һәм декоратив капламнар — приборлар һәм машиналар төзелешендә, югары тәэсирле флокулянтлар һәм стабилизаторлар — пычрак суларны чистартуда, туфрак структурасын хасил итүчеләр — авыл хуҗалыгында, тампонлау системалары һәм комплексоннар нефть чыгаруда файдаланыла.

*Әд.:* Маравец Г. Макромолекулы в растворе. М., 1967; Барабанов В.П. Растворы полиэлектролитов. М., 2003; Rice S., Nagasawa M. Polyelectrolyte Solytion: Teoretical introduction. L.–N.Y., 1961.

*В.П.Барабанов.*

**ПОЛО́ВНИКОВА** Наталия Александровна (11.12.1916, Вятка губ. Нолинск ш. — 13.3.2000, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1977), проф. (1978), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1991). 1939 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан мәктәпләрендә эшли. 1950–89 да Казан пед. ин-тының пед. кафедрасында, 1962–70 тә каф. мөдире. Хезмәтләре мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укыту процессын интенсивлаштыру мәсьәләләренә карый.

Хезм.: О теоретических основах познавательной самостоятельности. К., 1968; Система воспитания познавательных сил школьников. К., 1985.

**ПОЛОВНЯ́К** Валентин Константинович (22.11.1936, Украина ССРның Донецк өлкәсе Красноармейск ш.), химик, химия фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1966 дан Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре координацион кушылмалар химиясенә карый. П. комплекслы платиналы металл кушылмаларын синтезлау ысулларын эшли һәм интермедиат формаларын тикшерә, соңгылары органик синтез реакцияләре катализаторы сыйфатында гамәли кулланыш таба («Казаноргсинтез» АҖдә гамәлгә кертелә). Оксиалкиллы амин тозлары нигезендә корычның күкертле водород коррозиясе ингибиторларын таба («Татнефть» АҖдә нефть чыгару җиһазларын саклау өчен файдаланыла). Гальваник процессларның пычрак суларын а.х. калдыклары ярдәмендә чистарту ысулларын тәкъдим итә, шуның б-н төсле металларны (бакыр, никель, хром һ.б.лар) үтилләштерү һәм җитештерүдә кабат файдалану мөмкинлеге туа. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. «Атом альянсы» («Атомный альянс», 1997), «Ягымлы сүз белән» («Незлым тихим словом», 1999), «Мәһабәтлек» («Благолепие», 2006), «Күңелем адымнары» «(Шаги моей души», 2007), «Галлей кометасы билгесе астында» («Под знаком кометы Галлея», 2007) шигырь җыентыклары авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Интермедиатные формы комплексных соединений платиновых и благородных металлов. Интермедиаты палладия (1) и палладия (0) // Вестн. Казан. технол. ун-та. 1998. № 1 (автордаш); Формирование адсорбционных плёнок ингибиторов сероводородной коррозии на основе солей оксиалкилированных аминов // Защита металлов. 2003. Т. 29, № 3 (автордаш); Комплексы 4d-платиновых металлов с фосфор(III)- и мышьяк(III)-органическими лигандами. М., 2006 (автордаш); Coordination compounds in silver halide photography // J. Coord. Chem. 1992. V. 27 (автордаш).

*Әд.:* Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

**ПОЛТОРА́ЦКИЙ** Пётр Алексеевич (24.1.1842, Тверь ш. — 2.7.1909, С.-Петербург), дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1891). Дворяннар нәселеннән. Пажлар корпусын тәмамлый (С.-Петербург, 1860). 1860–67 елларда — Хәрби министрлыкта, 1867–72 дә Эчке эшләр министрлыгында хезмәт итә (С.-Петербург). 1872–82 дә — Новгород вице-губернаторы, 1882–83 тә — Архангельск, 1883–89 да — Уфа, 1889–1904 тә Казан губернаторы. 1891–92, 1898–99 еллардагы ачлык, 1892–94 тәге ваба эпидемиясе вакытында Казан губернасы халкына ярдәм күрсәтү б-н җитәкчелек итә. Губернада ятимханәләр, Россия Кызыл Хач, Россия музыка җәмгыятьләренең Казан бүлекләре (1902 дән), Казан кулланучылар җәмгыяте (1894 тән) эшчәнлекләренә ярдәм күрсәтә. «Казанские вести» (1890–92), «Казанский телеграф» (1893 тән), «Камско-Волжский край» (1895–98) г-таларын бастырып чыгаруга булышлык итә. 1897 дә, Бөтенроссия күләмендә беренче тапкыр гомуми халык санын алу уздырылган вакытта, П. Казан губернасының исәпкә алу комиссиясе рәисе була. П. вакытында Мәскәү–Казан тимер юлы төзелеше башлана (1891 дән), Казанда шәһәрне Гривка бистәсе б-н тоташтыручы дамба торгызыла (1892), электр үткәрелә (1897), трамвайлар йөри башлый (1899), Крупениковлар исем. шәһәр картлар йорты (1891), Хезмәт сөючеләр йорты (1893), шәһәр музее (1895), сәнгать мәктәбе (1895), сәнәгать уч-щесе (1897), «Алафузов театры» (1900), кыз балалар гимназиясе (1901) һ.б. ачыла. 1904 тән Россия Дәүләт Советы әгъзасы. Казан ярлыларга ярдәм күрсәтү ком-ты попечителе (1891–1904).



П.А.Полторацкий.

*Әд.:* Альманах современных русских государственных деятелей. СПб., 1897; Афанасьев Н.И. Современники: Альбом биографий: В 2 т. СПб., 1909–10; Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «вручённой на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОЛУМОРДВИ́НОВ** Александр Аполлонович (30.8.1874, Вятка губ. Слободской ш. — 1942, Киров ш.), инженер-электрик, дөньяда беренче булып төсле сурәтне еракка тапшыру ысулын уйлап табучыларның берсе (1899). Казанның Өченче ир балалар гимназиясен (1892), Харьков технол. ин-тын (1898) тәмамлый. 1898–1900 елларда Казан сәнәгать уч-щесендә механика, геом., сызым укыта. 1903 тә Петербург электротехника ин-тын тәмамлый, 1904 тән шунда ук, телефон элемтәсе кафедрасында эшли (1903–04 тә Баш почта һәм телеграфлар идарәсенең телефон бүлеге башлыгы ярдәмчесе). 1914–17 дә Вятка шәһәрендә шәһәр архитекторы ярдәмчесе, шәһәр телефон станциясе хезмәткәре. 1918–32 дә Вятка Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советында һәм Вятка губ-насы Халык хуҗалыгы советында: электрлаштыру һәм җирле телефон челтәрен үстерү б-н шөгыльләнә. П. «*Телефот*» аппаратының (1899), тавыш һәм сурәтне бер үк вакытта тапшыру аппаратының (1903), оптик тавыш яздыру җайланмасының (фотофонограф) схемаларын һәм конструкцияләрен төзи, телефон элемтәсе системасы өчен күп кенә камилләштерүләр тәкъдим итә. 1 нче Бөтенроссия электротехниклар съезды (С.-Петербург, 1899) һәм 1 нче Бөтендөнья электротехниклар конгрессы (Париж, 1900) эшендә катнаша.



П.А. Полушкин.

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Лейтес Л.С. К 100-летию изобретения А.А.Полумордвиновым первой системы цветного телевидения // Техника кино и телевидения. 2000. № 4.

**ПОЛУМОРДВИ́НОВ** Дмитрий Владимирович (25.10.1867, Саратов губ. Хвалынск ш. — 25.1.1919, Казан), физиолог, медицина д-ры (1896). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1890), шунда ук эшли: проректор ярдәмчесе, проректор (1896 дан), 1899 елдан — физиология кафедрасында приват-доцент. 1903 тә П.П.Павловның Эксперименталь мед. ин-тында һәм Петербург ун-тында Н.Е.Введенский лаб-яләрендә стажировка уза. 1907 дә 7 нче Халыкара физиологлар конгрессы эшендә катнаша (Германия, Гейдельберг ш.). 1909 дан Казан ун-тының нормаль анатомия каф. мөдире, проф. (1915). Бер үк вакытта, 1904–11 дә, Казан вет. ин-тында зоофизиол. һәм физиол. химия курсларын алып бара. Тиф авыруыннан үлә. Хезмәтләре кан физиологиясе һәм кан әйләнешенә, эчке әгъзалар иннервациясенә, шома мускуллар морфофизиологиясенә карый.

Хезм.: О чувствительных нервных окончаниях в мышцах произвольного движения. К., 1902; Гладкие мышцы и кровообращение. К., 1908; О двигательных нервах сердца. К., 1909.

*Әд.:* Лебедев К.В., Волкова И.Н., Зефиров Л.Н. Из истории Казанской физиологической школы. К., 1978.

**ПОЛУ́ШКИН** Пётр Алексеевич (14.7.1924, Урал өлкәсенең Яңа Баранча пос. — 19.9.2009, Казан), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. сержанты. Яңа Баранчадагы 658 нче номерлы з-дта инструментлар ясаучы булып эшли. 1942 елның сентябреннән Кызыл Армия сафларында. Пулемётчылар мәктәбен тәмамлый (Тобольск ш., 1943). 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 26 нчы гв. туп-артиллерия бригадасында туп төзәүче (8 нче туп-артиллерия дивизиясе). Калинин, 1 нче һәм 3 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Шяуляй һәм Рига һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1944) катнаша. 1944 нең 18 августында Ауце шәһәре (Латвия ССР) янындагы сугышта батырлык күрсәтә: шәхсән үзе 4 танкны сафтан чыгара, солдатлар утырган машинаны һәм берничә пулемёт ноктасын юк итә. Сугышның кискен мизгелендә, батареяның барлык орудиесе сафтан чыкканнан соң, күрше батареядан үз өстенә ут ачтыра һәм укчы подразделение килгәнче яулап алынган урынны саклап кала. Сугыштан соң артиллерия гаскәрләрендә хезмәт итә (Латвия ССР). 1947 дә демобилизацияләнә. 1948–50 дә Яңа Баранчада 13 нче номерлы һөнәр уч-щесендә, 1950–54 тә 658 нче номерлы з-дта мастер булып эшли. 1954–94 тә Казан тәҗрибә механика з-дында инструментлар ясаучы слесарь. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә; Казан шәһәренең мактаулы гражданы (2007).

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПО́ЛЬСКИЙ** Юрий Ехилевич ( 11.6.1931, Запорожье ш.), радиофизик, физика-матем. фән. д-ры (1972), проф. (1974), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1986, 1997), Казан техник ун-тының атказ. проф. (1998). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан техник ун-тында эшли, квант электроникасы каф. мөдире (1974–98). Хезмәтләре радиофизикага, квант электроникасына, оптик-электрон приборлар төзелешенә карый. П. СССРда беренче электрон-төш-төш резонанслы спектрометр эшли (1971). Нәстационар резонаторлы лазерлар, «Юпитер» тибындагы югары егәрлекле технол. лазерлар, экологик мониторинг өчен приборлар комплексы уйлап таба һәм эшли. «Татарстан-Болгария» халыклар дуслыгы җәмгыятен оештыручы һәм аның рәисе (1993 тән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Тройной электронно-ядерный резонанс // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1971. Т. 61, № 4 (автордаш); Оптические резонаторы мощных газовых лазеров. М., 1980; Динамический диапазон и точность радиотехнических и оптоэлектронных измерительных систем. М., 1989 (автордаш).

**ПО́ЛЬША, ЛИТВА́, БЕЛОРУ́ССИЯҺӘМ УКРАИ́НА ТАТАРЛАРЫНЫ́Ң ҮЗӘ́К КОМИТЕТЫ́**, Польшада яшәүче татарлар тарафыннан төзелгән оешма (1919–25). Ком-тны оештыруда Петроградтагы элеккеге Речь Посполитаның барлык татарларын берләштерү максатын куйган «Польша, Литва, Белоруссия һәм Украина татарлары ком-ты» (1917) әгъзалары башлап йөри. Рәисе А.М.Ахматович. Бәйсез Польша Республикасы барлыкка килгәннән соң (1918), ком-т татар халкы мәнфәгатьләрен яклап чыга, Вильно шәһәрендә поляк хакимиятләренә булышлык күрсәтә. Оешма төп көчләрен поляк армиясендә аерым татар кавалерия часте төзүгә юнәлтә, аны тормышка ашыруда Польша дәүләте башлыгы Ю.Пилсудский ярдәменә таяна. Ком-т мөселманнарга атап өндәмә бастыра, анда татарларның Речь Посполитаның барлык хәрби гамәлләрендә катнашулары һәм аларның илдә нинди зур ихтирам казанулары турында әйтелә; төзелеп килүче татар полкына язылырга чакыру яңгырый, ул 1920 елгы совет-поляк сугышында катнаша (к. *Татар уланнары полкы*).

*Әд.:* Гришин Я.Я. Польско-литовские татары (Наследники Золотой Орды). К., 1995.

*Я.Я.Гришин.*

**«ПО́ЛЬША ТАТАРЛАРЫ́ ГЕРБО́ВНИГЫ»** («Herbarz rodzin tatarskich w Polsce»), Речь Посполитадагы татар нәселләре турында поляк телендә язылган хезмәт. Авторы — Станислав *Дзядулевич*. 1929 елда Вильно (Вильнюс) шәһәрендә нәшер ителә, 1986 да Варшавада кабат бастырыла. Күләме — 500 гә якын бит. Ике бүлектән тора: беренчесе ислам динендәге нәселләргә багышланган, икенчесендә заманында бабалары христианлыкка күчкән татарлардан чыккан поляк шляхталары нәселләре турында бәян ителә (ике бүлектә дә славян һәм төрки тамырлы фамилияләр очрый). «П.т.г.» барлыгы 700 дән артык нәселне колачлый. Иң ишле һәм атаклы нәселләр С.Дзядулевич тарафыннан берничә тармакка бүленгән (мәс., Ассангуковичлар нәселе — Сәет, Абдулла, Коджел, Ырыс, Толыч һ.б. тармаклары, Крычыньскийлар Самуэль, Мостафа, Богдан тармаклары буенча күрсәтелә). Китапта татар нәселләренең гербларлары урнаштырылган: «Араз» — Аразевичлар, «Арслан» — Арслановичлар, «Мешерин» — Мешериновлар, «Урда» — Гиреевскийлар, «Туган» — Барановскийлар яки Туган-Барановскийлар, «Янадар» — Бартошевичлар һ.б. «П.т.г.»нда ш.у. Я.Шенкевич тарафыннан язылган 300 дән артык төрки-татар,гарәп, фарсы сүзләренең һәм гыйбарәләренең аңлатма һәм тәрҗемәләре китерелә (мәс., Кинский фамилиясе иркен, киң, юмарт, ярдәмчел мәгънәләренә ия татарча «киң» сүзеннән, Тальковский фамилиясе — «ирекле» мәгънәсен биргән гарәпчә «тальк» сүзеннән, дип күрсәтелә һ.б.). Хезмәтнең ахырында татар нәсел-ыру тамырлары исемлеге һәм әлеге нәселләрнең алфавит тәртибендәге исемлеге урнаштырылган. Кушымтага иң күренекле 12 нәселнең (Крычыньскийлар, Сулькевичлар һ.б.) генеалогик таблицалары кертелгән.

*Ф.Р.Фәизов.*

**ПО́ЛЬША-ЛИТВА́ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ГМИ́НАСЫ** (дини берлеге, мәхәлләсе). Мәхәлләнең дини, адм.-хуҗалык, мәдәни-агарту мәсьәләләрен башкара. Гминада югары хакимият гомуми җыен кулында була, ул елга бер тапкыр чакырыла. Анда идарә сайлап куела (составына рухани һәм дөньяви затлар керә, 1936 елдан — бары рухани-имамнар). П.-Л.м.г. турыдан-туры Польша-Литва татарлары мөфтиятенә буйсына. 1936 да мөфтият карары б-н идарәләр бетерелә, аларның вәкаләтләре имамнар кулына күчә. Һәрбер гминаның үз фонды була, ул мәчетләр, мәхәллә йортлары, мәктәпләр төзү һәм төзекләндерүгә, зиратларны карап тотуга, мәхәллә фәкыйрьләренә ярдәм итүгә тотыла. 1939 га кадәр 19 П.-Л.м.г. яшәп килә, аларның 9 ы Новогрудский, 2 се — Белостокский воеводалыкларында, берсе Варшавада була.

*Я.Я.Гришин.*

**ПО́ЛЬША-ЛИТВА́ ТАТА́Р СТУДЕНТЛАРЫ́ ТҮГӘРӘГЕ́** (1907–11), яшерен, чыгышлары б-н Польша, Литва, Белоруссиядән булган яшьләр тарафыннан С.-Петербургта оештырыла. Җитәкчеләре — бертуган Л. һәм О.Крычыньскийлар. Түгәрәк әгъзалары татар халкы тарихын, динен, мәдәниятен өйрәнәләр, үз китапханәләрен булдыралар.

*Я.Я.Гришин.*

**ПО́ЛЬША-ЛИТВА́ ТАТАРЛАРЫ́**, татарларның мөстәкыйль этно-терр. бергәлеге. 1993 ел мәгълүматлары буенча, аларның гомуми саны 26 меңнән артык, ш.и. 10 меңнән артык кеше — Белоруссиядә, 4 мең чамасы — Литвада, 5 меңнән күбрәк кеше Польшада яши. Яшәгән терр-яләренә бәйле рәвештә белорус, литва һәм поляк телләрендә сөйләшәләр. Язулары кириллица һәм латин графикасы нигезендә. Дин тотучы П.-Л.т., асылда, мөселман сөнниләр.

П.-Л.т. берлеге 14 йөз ахырында Бөек Литва кенәзлеге терр-ясендә, башлыча, чыгышлары Алтын Урдадан булган кешеләр, соңрак Олы Урдадан һәм Нугай Урдасыннан, Кырым ханлыгыннан чыгучылар хисабына оеша башлый; 15 йөзнең 1 нче яртысында алар Литвага карата вассал *Джаголдай* кенәзлеге оештыралар. Литва терр-ясенә татарлар беренче тапкыр 13–14 йөзләр чигендә килеп утырган дип фаразлана. Татарларның күпләп күчеп килүе бөек Литва кенәзе Витовт (1392–1430) идарә иткән чорга туры килә. Ул вакытта *Җәләлетдин хан* җитәкчелегендәге татар гаскәре Тевтон орденына каршы сугышта катнаша (к. *Грюнвальд сугышы*). 17 йөздә, сугышлар барган чорда, Литвадагы күп кенә татарлар Польшага, Төркиягә күчеп китә. Литва һәм Польша терр-ясенә күчеп килгән татарларга җир бирелә, аның өчен алар бөек Литва кенәзенә яки Польша короленә хезмәт итәргә йөкләмә алалар. 17 йөзгә кадәр П.-Л.т., нигездә, поляк-литва армиясе подразделениеләре — хоругвьларда хезмәт итәләр. 18 йөздә поляк армиясендә татар полклары була. Аларның берсен генерал Ю.*Беляк* җитәкли. Т.Костюшко җитәкчелегендәге поляклар күтәрелешендә полковник Я.Азулевич катнаша (1794). 18 йөзнең 60–70 елларында Польшаны бүлгәләү барышында П.-Л.т.ның күпчелеге рус патшасы хакимиятенә буйсынуда кала, бу аларның Төркиягә яңа миграциясен китереп чыгара. 19 йөздә Наполеон сугышлары вакытында П.-Л.т.ның бер өлеше Польшаны Россия хакимиятеннән азат итү өчен көрәшүче татар эскадронына керә. П.-Л.т. 1830–31, 1863–64 еллардагы поляклар күтәрелешендә актив катнашалар. Беренче бөтендөнья сугышы алдыннан Россия армиясендә П.-Л.т.ннан 20 гә якын генерал хезмәт итә (Х.Базаревский, Т.Беляк, К.Бицутко, С.Вильчыньский, Я.Давидович, С.Б.*Крычыньский*, А.Мильковский, Абу Талиб Мөхлә, Ю.Полтожыцкий, А.*Романович*, С.Соболевский, М.*Сулькевич*, И.*Тальковский*, А.Туган-Барановский, Я.*Юзефович*, Ю.Якубовский, Х.Янушевский һ.б.). П.-Л.т.ның 70% тан артыгын крәстияннәр — яшелчәче, һөнәрчеләр (бигрәк тә күнчеләр) тәшкил итә. Алпавытлар күп булмый, ул катлауга Ахматовичлар, Базаревскийлар, Крычыньскийлар, Мурза-Мурзичлар, Туган-Барановскийлар һәм Сулькевичлар нәселләре керә. Әлеге даирәдән, башлыча, татар интеллигенциясе вәкилләре (укытучылар, врачлар, юристлар, галимнәр, хәрбиләр) чыга. Галимнәр арасында П.-Л.т.ннан икътисадчы М.И.Туган-Барановский (к. *Туган-Барановскийлар*), С.Я.Чаиньский, арх. С.Крычыньский исемнәре билгеле.

1918 дә Польшаның Россиядән бәйсезлеге торгызыла. П.-Л.т., нигездә, аның төньяк-көнчыгыш воеводалыкларында: Белосток, Вильно һәм Новгородскоеда (5 меңнән артык кеше) яшиләр. П.-Л.т.ның зур булмаган җәмгыятьләре Варшавада, Полесское һәм Волын воеводалыкларында була. Рига солых килешүеннән соң (1921), П.-Л.т.ның шактый өлеше Советлар Союзы терр-ясендә кала (Минскида һәм аның тирәсендә 2 меңгә якын кеше). 1 меңнән артык татар ш.у. Литвада да яши. П.-Л.т.ның мәдәнияте һәм телендә үзенчәлекле сыйфатлар формалашуда Бөек Литва кенәзлеге һәм Речь Посполитада татарлар яшәгән аерым сәяси һәм социаль-икътисади шартлар төп рольне уйный. 16–17 йөзләр чигендә П.-Л.т. этник телләрен югалталар, поляк яки рус теленә күчәләр. Шулай да үзләренең традицион диннәрен — ислам динен саклап калалар, моңа Польша корольләренең дин ирекен тану сәясәте дә булышлык итә. П.-Л.т.ның дини һәм иҗтимагый-мәдәни



Грюнвальд янындагы сугышта (1410) катнашкан татарларга Гданьск шәһәрендә куелган һәйкәл.

үзәкләре Вильно (Вильнюс), Варшава шәһәрләрендә эшләп килә, анда «Рочник татарски» бюллетене, «*Жиче татарске*», «Пшеглонд исламски» («Исламча күзәтү») фәнни-популяр ж-ллары басылып чыга. Речь Посполита мөселман дини берлеге, Речь Посполита татарларының мәдәни-агарту берлеге, П.-Л.т. мөфтияте эшли. Икенче бөтендөнья сугышыннан соң, П.-Л.т.ның иҗтимагый-мәдәни тормышын тулысынча тергезү мөмкин булмый, 1947 дә фәкать *Мөселман дини берлеге* генә тергезелә. 21 йөз башына Польшада 6 мөселман җәмгыяте — Варшавада, Белосток, Бохоники, Гданьск, Гожув Велькопольски, Крушыняны (к. *Гмина*) шәһәрләрендә яшәп килә.

*Әд.:* D r i a d u l e w i c z S. Herbarz rodzin tatarskich w Polsce. Wilno, 1929; S o b c z a k J. Poloxenie prawne ludnoseri tuturskiej w Wielkizn Ksisstwie Zitowskini. Warsz.-Poznan, 1984; B o r a w s k i P. Tayarzy w dawnei Rrzeczry pospolitej. Warsz., 1986; M i s k i e w i c r A. Tatarzy polscy. 1918–1939. Warsz., 1990; ш у л у к. Tatarzy polscy w tatach. 1945–1985: Zarys historyczny. Studia podlaskie. Bialystok. 1991. T. 3; Tyszkiewicz. J. Z historii tatarowpolskich. 1794–1944. Pultusk, 2002.

*Я.Я.Гришин.*



Г.Г. Полющенков.

**ПОЛЮ́ЩЕНКОВ** Григорий Григорьевич (3.10.1912, Андреевское а., хәзер Смоленск өлкәсенең Ельнинск р-ны Леонидовский җирлеге Драгинино а. составында — 10.11.1996, Чистай ш.), Соц. Хезмәт Герое (1966). Мәскәү политехникумын (1936), КПСС ҮК каршындагы ВКП(б) Югары партия мәктәбен (1941, 1958) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1930 елда «Бетонит» з-дында (Мәскәү) эшче булып башлый. 1936–37 дә Чаллы шәһәре һәм Тәмте р-ны пр-тиеләрендә техник җитәкче. 1937 дән комсомол һәм партия эшендә: КПССның Лаеш райкомы 1 нче секретаре (1947 дән), Чистай бүлеге мөдире (1952), Татарстан өлкә ком-тында инструктор (1953 тән), Чистай райкомының 1 нче секретаре (1954 тән), Чистай шәһәр ком-ты 1 нче секретаре (1956–62, 1965–83). 1962–65 тә ТАССРның Чистай колхоз-совхоз җитештерү идарәсендә партком секретаре. Герой исеме бөртекле ашлык җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1963–67 дә РСФСР ЮС, 1951–63, 1967–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПОЛЯКО́В** Михаил Александрович (23.2.1932, БАССРның Уфа р-ны Шипово а.), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (1989). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957, Уфа), «Әлмәтнефть» фәнни-җитештерү идарәсенең мед.-санитария частенда эшли, 1957 елдан цех табибе, 1958 дән хирург, Әлмәт шәһәренең баш онкологы. 1964 тән Казан ГИДУВының хирургия кафедрасында, бер үк вакытта, 1966 дан, Казан шәһәре онкология диспансерында клиника бүлеге хирургы. 1971–73 тә Респ-ка онкология диспансерында торакаль клиника бүлеге мөдире. 1973 тән Казан мед. ин-тының — онкология, 1980 нән — хирургия, 1984–2001 дә — гомуми хирургия кафедрасында. 1982–84 тә СССР МФАнең Бөтенсоюз онкология үзәгендә стажировка уза. Хезмәтләре ашказаны рагын хирургик юл б-н дәвалауга карый. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы бар. СССР ВДНХсының көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О комбинированных гастроэктомиях с формированием искусственного желудка по новой методике // Вестн. хирургии. 1984. № 3; Способ еюногастропластики при проксимальной резекции желудка // Клиническая хирургия. 1984. № 5; Арефмоксная еюностомия // Вестн. хирургии. 1985. № 7; Два способа еюногастропластики при гастроэктомии // Хирургия. 1985. № 10.

**ПОЛЯКО́В** Пётр Александрович (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), татар әкиятләрен өйрәнүче. Татар әкиятләрен рус теленә тәрҗемә итә. К.Насыйри б-н бергәләп «Казан татарлары әкиятләре һәм аларны башка халыклар әкиятләре белән чагыштыру» («Сказки Казанских татар и сопоставление их со сказками других народов», 1900) исемле китап бастырып чыгаралар.

**ПОЛЯКО́В** Рувим Львович (11.12.1889, Казан — 12.12.1970, шунда ук), виолончелист, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939). Петроград консерваториясен тәмамлаганнан соң, 1916–45 елларда Казан музыка уч-щесендә укыта, 1919–22 һәм 1941–45 тә шунда ук директор. Бер үк вакытта, 1932 дән, беренче балалар музыка мәктәпләрен оештыручы һәм директоры. 1946–70 тә Казанда 1 нче балалар музыка мәктәбе директоры. П. Казанда башлангыч муз. белем бирүне оештыруга зур өлеш кертә, Татарстанның күп кенә музыка эшлеклеләренең иҗади үсешенә булышлык күрсәтә. Шәкертләре арасында Р.М.Яхин, С.Ә.Гобәйдуллина, А.З.Монасыйпов, Ф.З.Яруллин бар.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ПОЛЯКО́ВА** Ирина Васильевна (9.3.1961, Казан), спортчы (чаңгы спорты), Россиянең атказ. спорт остасы (2005). Мәскәү физик культура академиясен тәмамлый (Малаховка ш., 2000). Спорт б-н 1996 елда ТРның инвалидлар физкультура-спорт җәмгыятендә (тренеры Ф.И.Сафиуллина) шөгыльләнә башлый. Параолимпия уеннарында катнаша (1998); инвалидлар арасында биатлон һәм чаңгыда узышу буенча дөнья чемпионатларында (2003, эстафетада узышу; 2005, биатлон, эстафетада узышу), Параолимпия уеннарында (2006), Дөнья кубогына ярышларда (2007, биатлон) җиңүче. Европа (1997, биатлон; 2001, биатлон, чаңгыда узышу, 2,5 *км* лы дистанция), дөнья (2003, чаңгыда узышу, 2,5 һәм 5 *км* лы дистанцияләр) чемпионатларында, Параолимпия уеннарында (2002, эстафетада узышу) көмеш медальләр ала. Европа чемпионатларында (1997, чаңгыда узышу, 2,5 һәм 5 *км* лы дистанцияләр; 2001, чаңгыда узышу, 5 һәм 10 *км* лы дистанцияләр) бронза медальләр ала. 1981–89 елларда Казанның 47 нче ательесында эшли, 1996 дан ТРның инвалидлар физкультура-спорт җәмгыятендә инструктор. ТР Президенты каршындагы Иҗтимагый палата әгъзасы (2006–07). Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПОЛЯ́НИН** Владимир Алексеевич (15.7.1906, Казан — 26.6.1990, шунда ук), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1955), проф. (1958), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1977). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), Алапаевск геол. партиясендә (Урал) эшли. 1931–86 елларда Казан ун-тында, файдалы казылмалар каф. мөдире (1952–77), проф. (1977–86). Хезмәтләре файдалы казылмалар геологиясенә карый. П. Татарстан, Киров өлкәсенең бакыр рудаларын бәяли, Уралның тимер рудалары һәм бокситларын, Алтайның полиметалл чыганакларын тикшерә, ТАССРның минераль чимал ресурсларына бәя бирә, Идел һәм Кама елгаларының аллювиаль утырмаларының литологик үзенчәлекләрен һәм алар б-н бәйле файдалы казылмаларны ачыклый. Геол. тикшеренүләрдә матем. һәм спектраль анализ алымнарын кертә. 1988 дә Казанда П.ның шәхси картиналар күргәзмәсе уза. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфоритовые формации Вятско-Камского бассейна. К., 1973 (автордаш); Минеральное сырьё ТАССР. К., 1980 (автордаш).

**ПОЛЯ́НКА** авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 53 *км* көнбатыштарак, Баграж елгасы (Чишмәнең уң кушылдыгы) буенда, 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Баграж Аланы, Баграж Бистәсе буларак та билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элеккеге отставкадагы солдатлар) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 1840 елларда П. халкының бер өлеше Оренбург чик буена күчерелә. 20 йөз башында чиркәү, башлангыч мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1124 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның — Бөгелмә, 1924 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1834 тә — 390, 1859 да — 205, 1889 да — 485, 1897 дә — 542, 1910 да — 694, 1920 дә — 813, 1926 да — 561, 1938 дә — 454, 1949 да — 386, 1958 дә — 321, 1970 тә — 158, 1979 да — 33, 1989 да — 4, 2002 дә 14 кеше.

**ПОЛЯ́НКА** авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 2 *км* көнбатыштарак, Бәтке елгасы тамагында урнашкан. 2010 елда 792 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 63%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1617 дән мәгълүм. Халкы — сарай, 1797 дән 1860 елларга кадәр удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балык үрчетү, челтәр бәйләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), су тегермәне, икмәк пристане, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 852,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Анатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 119 ир-ат; 1859 да — 519, 1897 дә — 636, 1908 дә — 592, 1920 дә — 618, 1926 да — 623, 1949 да — 410, 1958 дә — 229, 1970 тә — 160, 1989 да — 668, 2002 дә — 738 кеше.

**ПОЛЯ́НКА** авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 22 *км* көнчыгыштарак, Казан — Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 18 йөз башында М.Н.*Кудрявцев* нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, челтәр бәйләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1722 дә төзелә; архит-ра истәлеге), башлангыч мәктәп (1898 дә ачыла), җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 295,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 244, 1897 дә — 325, 1908 дә — 420, 1920 дә — 417, 1926 да — 445, 1938 дә — 386, 1949 да — 324, 1958 дә — 176, 1970 тә — 70, 1979 да — 45, 1989 да — 23, 2002 дә — 23 кеше.

**ПОЛЯ́НКИ** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы буенда. 2010 елда 597 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Никольский-Полянки буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сарык тиресе эшкәртү, тәгәрмәч ясау, тимерчелек, тегү һәм йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1778 дә Л.И.Лихачёв иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1876 да ачыла), 11 җил тегермәне, 6 кирпеч з-ды, 3 тимерчелек, 2 сарык тиресе эшкәртү һәм 2 йон-тукыма ману бинасы, йон тетү йорты, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1515 дис. тәшкил итә. 1913 тә икенче земство мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Трёхозёрский волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 269 ир-ат; 1859 да — 1209, 1897 дә — 1925, 1908 дә — 2222, 1920 дә — 2357, 1926 да — 2091, 1938 дә — 1446, 1949 да — 931, 1958 дә — 1100, 1970 тә — 754, 1979 да — 669, 1989 да — 733, 2002 дә — 627 кеше. Археолог, нумизмат, коллекционер А.Ф.*Лихачёв* һәм вице-адмирал И.Ф.*Лихачёвның* тормышы П. б-н бәйле.

*Әд.:* Спасские сказания. К., 2003.

**ПОЛЯ́НСКИЙ** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 35 *км* төньяктарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* читтә урнашкан. 2010 елда 31 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Оешты-

рылган көннән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1926 да — 108, 1938 дә — 204, 1949 да — 154, 1958 дә — 131, 1970 тә — 128, 1979 да — 128, 1989 да — 61, 2002 дә — 43 кеше.

**ПОЛЯ́НСКИЙ** Анатолий Антонович (1.5.1912, Самара губ., Богырыслан өязе Похвистнево станциясе — 29.11.1961, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Куйбышев план-икътисад ин-тын тәмамлый (1935). 1935 елдан ТАССР ХКС (1946 дан — МС) каршындагы Дәүләт план комиссиясендә: икътисадчы (1940 ка кадәр), 1940–41 дә сәнәгать секторы башлыгы, 1941–44 тә рәис урынбасары, 1944–60 та рәис. 1947 дән ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОЛЯ́НСКИЙ** Василий Ипатович (23.11.1742, Казан — 28.7.1802, шунда ук), СА сәркәтибе (1772–78), надворный советник (1782). Дворяннар нәселеннән. 1771 елда П. Франциядә була, майда француз философы Вольтер янына, аның Париждагы утарына бара. Вольтер император Екатерина II гә: «Минем җиремдә хәзер чыгышы б-н Казаннан булган Сезнең подданныегыз В.Полянский, мин аңа бик сокланам», — дип яза. Соңрак та Вольтер аның язмышы б-н кызыксына. 1773 нең 3 гыйнварында язган хатына җавап рәвешендә, Екатерина II П.ның СА секретаре булуын хәбәр итә. Законнар төзү комиссиясе әгъзасы буларак, П. «Губерналар турында нигезләмәләр» документын эшли. 1770 еллар ахырында граф З.Г.Чернышёв П.ны Могилёв шәһәренә наместниклык идарәсе советнигы вазифасын башкарырга чакыра. 1781–82 дә П. — Казан наместниклык идарәсе советнигы. 1782 дән — отставкада, Казандагы утарында яши. Бай китапханә туплый, 1798 дә берничә ел дәвамында җыйган төрле телдәге китапларны, ш.у. философ үзе бүләк иткән Вольтер портретын Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә васыять итеп калдыра (к. *Полянский В.И.нең шәхси китапханәсе*); үз исемендәге стипендия булдыра.

*Әд.:* Переписка российской императрицы Екатерины II и господина Вольтера, продолжавшаяся с 1763 по 1778 год. М., 1803; Справочный листок города Казани. 1867. № 92; Записки Добрынина // Русская старина. 1871. Т. 4.

*А.В.Гарзавина.*

**ПОЛЯ́НСКИЙ В.И.НЫҢ ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́**. Петербург САнең элекке сәркәтибе В.И.*Полянский* китапханәсе. Нигездә, Полянскийның 1771–72 елларда Швейцария һәм Италиягә сәяхәтләре вакытында, ш.у. аның Казанда яшәү чорында туплана. 1780 дә отставкага чыккач, В.И.Полянский Казандагы утарында яши, китапханәсе дә шунда урнаша. Китапларының бер өлешен ул (693 томда 298 исемдәге китап) Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә бүләк итә (бүләк язуы 1798 нең 26 ноябрендә теркәлгән). Казан ун-ты ачылганнан соң, 11 китап гимназиядә кала, 287 се университет китапханәсенә тапшырыла. Әлеге китаплар, кенәз Г.А.Потёмкин китапханәсе б-н берлектә, башта — гимназия, соңрак университет китапханәсенең нигезен тәшкил итә. Алар арасында чит телләрдәге (башлыча, французча) 270 хезмәт, ш.и. фәлсәфә, тарих, филологиягә караган 18 йөз басмалары: Вергилий, Плутарх, И.Г.Гмелин, Россиядә тоткынлыкта булган швед офицеры Ф.-И.Страленберг, француз мәгърифәтчесе Ш.Монтескьё, инглиз шагыйре Дж.Мильтон әсәрләре, Б.Фонтенельның «Галәмнәрнең чиксезлеге турында сөйләшүләр» («Разговоры о множестве миров...», французча, фарсыча һәм русчага тәрҗемәдә) һ.б; 18 йөзгә караган рус телендәге 17 китап («Россия аша Бёль сәяхәтләре» («Бёлевы путешествия чрез Россию...»), Ф.Лангансның «Хокук сүзлеге» («Словарь юридический...») һ.б. бар. Полянский китапханәсенең төп өлешенең язмышы билгесез.

*Әд.:* З а г о с к и н Н.П. История императорского Казанского университета. К., 1903. Т. 3; А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. Всё началось с путеводителя. Поиски литературные и исторические. К., 1975; ш у л у к. История Научной библиотеки им. Н.И.Лобачёвского (1804–1850). К., 1985.

**ПОЛЯРЛАШКА́Н КАЙТАВА́З**, к. Электроакустик кайтаваз.

**ПОМИДО́Р**, к. *Томат.*

**ПО́МИНОВ** Иван Сергеевич (19.2.1920, Самара губ., Бозаулык өязе Тупиковка а. — 17.7.1999, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1970), проф. (1971), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). 1948 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, оптика һәм спектроскопия каф. мөдире (1960–91), бер үк вакытта физика ф-ты деканы (1971–86), 1991 дән шул ук кафедраның профессоры. Хезмәтләре ионлы эремәләрдә молекулаара тәэсирләрне зур темп-ра аралыкларында спектроскопик тикшерүләргә карый. П. эремәләрдә ионлы-молекуляр үзара тәэсирләрнең водород бәйләнеше тибында баруын ачыклый. Алынган нәтиҗәләре максатчан рәвештә бирелгән үзлекле матдәләр синтезлауда гамәли кулланыш таба. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр; «СССРның уйлап табучысы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние температуры на спектры поглощения иодида кобальта (II) в органических растворителях // Журн. неорганической химии. 1972. Т. 17, № 11 (автордаш); The spectra and structures of sulphur-containing compounds. Part. 3. The vibrational spectra and conformations of acyclic sulfoxides // Journal of Molecular Structure. 1982. V.96 (автордаш).

**ПО́МПА КАЕ́Ш-КҮННӘРӘ́ ЗАВОДЫ́**, суднолардан су суырту өчен насослар эшләп чыгару күн предприятиесе. Казанда 1719 елда нигезләнә. Җитештерүне оештыру өчен инглиз мастеры чакыртыла, ул рус өйрәнчекләрен күнчелек эшенә өйрәтергә тиеш була. Завод помпа күне җитештерә, аннан помпалар — суднолардан су суырту насослары эшләп чыгаралар. Башта Постаучылар бистәсе терр-ясендә урнашкан була. П.к.-к.з.нда ел саен 300 дән алып 400 гә кадәр тире эшкәртелә. 1720–1814 елларда 31,5 мең помпа күне җитештерелә. Табан күне һәм юфть эшләнә. П.к.-к.з. күннәре *Казан адмиралтействосына*, С.-Петербург, Әстерхан, Архангельск шәһәрләренә җибәрелә. 19 йөз башына П.к.-к.з., М.Н.Пинегин сүзләренә караганда, «җимерелә башлый», аның тирә-ягында корылмалар тыгыз урнашкан булу сәбәпле, янгын куркынычы арта. 1812 дә ул Адмиралтейство бистәсенә, Казансу ярына, Елантау монастыре б-н адмиралтейство арасына күчерелә. Завод өчен 10 агач бина төзелә, урнашу рәвеше б-н алар дүртпочмаклы ишегалды барлыкка китерәләр; юфть эшкәртү өчен аерым биналар корыла. Казан адмиралтействосы ябылгач (1829), П.к.-к.з. шәхси затларга сатыла. Н.П.Загоскин әйтүенчә, 1870 елларда «... аның ярым җимерек агач корылмаларын Елантау һәм язгы пристаньнар арасында күрергә мөмкин була».

*Әд.:* П и н е г и н М. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ПОНИКА́РОВ** Иван Ильич (28.1.1928, Кайбыч р-ны Ульянково а.), химия машиналары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1979, 1988). 1956 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, фәнни-тикшеренү секторы башлыгы (1963–69), химик җитештерү машиналары һәм аппаратлары каф. мөдире (1973–98). Хезмәтләре ике фазалы системаларда гидродинамика һәм масса тапшыру нигезләренә карый. П. җитәкчелегендә аз металл керешле югары интенсив масса алмашу җиһазлары: газдан һәм тузаннан чистарту процесслары өчен күләмле сугару факелы булган өермәле аппаратлар, ректификация һәм абсорбция процесслары өчен газлы-сыеклыклы агымнары бергә бәрә торган аппаратлар, пычрак сулар һәм майларны чистарту өчен агымга каршы үзәктән куулы экстракторлар эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 75 авторлык таныклыгы бар. 2003–04 тә «Машиностроение» энциклопедиясендә (М., 2004, т.12) «Җылылык процесслары һәм аппаратлары» бүлегенең мөхәррире була. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, «СССРның уйлап табучысы», «Мактаулы химик» билгеләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О кинетических закономерностях осаждения капель в центробежном поле // Теорет. основы хим. технологии. 1979. № 1 (автордаш); К расчёту осаждения капель в среде в условиях существования столбов Тейлора // Теорет. основы хим. технологии. 1983. № 4 (автордаш); Машины и аппараты химических производств. М., 1989 (автордаш); Машины и аппараты химических производств и нефтегазопереработки. М., 2006 (автордаш).

**ПОНИКА́РОВ** Сергей Иванович (21.11.1956, Казан), химия машиналары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1979 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер

Казан технол. ун-ты), 1984 тә Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый. Казан технол. ун-тында эшли, химик җитештерү машиналары һәм аппаратлары каф. мөдире (1998 дән), бер үк вакытта хәвеф-хәтәрле җитештерү объектлары җитәкчеләрен һәм белгечләрен әзерләү оешмаларын аккредитацияләү үзәге җитәкчесе (2004 тән). Хезмәтләре гидродинамика, масса алмашу һәм сәнәгать куркынычсызлыгы өлкәсенә карый. П. ике фазалы күп компонентлы тирәлекләрдә компонентларны экстракцияләү һәм ректификацияләү процессларын тикшерә. Почмакча әйләнү тизлеге үзгәрешле булган дифференциаль-контактлы типтагы үзәктән куулы экстракторлар һ.б. сәнәгать аппаратларын эшли (РФнең химия сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Аның тырышлыгы б-н ун-тта «нефть һәм газ эшкәртү җиһазлары» дигән яңа белгечлек ачыла. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Влияние двухслойности жидкости на развитие течения вблизи вращающейся плоскости при разгоне // Изв. РАН. Механика жидкости и газа. 1997. № 3 (автордаш); Расчёт и конструирование оборудования пищевых и химических производств. К., 2002 (автордаш); Пластинчатые и спиральные теплообменники // Машиностроение: Энцикл. М., 2004. Т. 12 (автордаш).

**ПОНИКА́РОВА** Анна Сергеевна (20.3.1982, Казан), икътисадчы-менеджер, икътисад фән. д-ры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2013). Казан технол. ун-тын тәмамлый (2004), шунда ук менеджмент һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге кафедрасында эшли. Хезмәтләре инновацион үсеш шартларында җитештерү-хуҗалык системаларының ышанычлылыгы мәсьәләләренә карый. Дәүләт бүләге ТР нефть химиясе комплексының җитештерү потенциалын модернизацияләү процессында пр-тиеләрдә сәнәгый хәвефлелек ихтималын киметү һәм аларның чыдамлылыгын арттыру механизмын эшләү һәм гамәлгә куюда катнашуы өчен бирелә.

Х е з м.: Антикризисное управление предприятиями в системе устойчивого развития региона. К., 2011 (автордаш); Управление промышленными рисками инновационной деятельности (на примере регионального НХК). Saarbrucken, 2012; Инновационно-инвестиционные проекты, инициирующие структурный сдвиг // Российское предпринимательство. — 2012. — № 205 (автордаш).

**ПОНОМАРЁВ** Алексей Петрович (23.5.1886, Казан — 15.10.1939, шунда ук), ботаник. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1910), хосусый гимназиядә һәм земство укытучылар мәктәбендә табигать белеме укытучысы булып эшли. 1916 елдан Казан ун-тында, проф. (1918), ботаника лаб-ясе мөдире (1921–32); бер үк вакытта пед., политехник һәм вет. ин-тларында микробиол. курсыннан лекцияләр укый. 1932 дән Казан а.х. ин-тында, үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1937 гә кадәр). Хезмәтләре Казан тирәсендәге түбән төзелешле үсемлекләрне, сулыклар флорасын һәм микрофлорасын, күкертле сулар һәм чыганакларның микробиологиясен, үсемлекләрнең пигмент системаларын өйрәнүгә карый. Үсемлекләрнең су б-н төрле шартларда тәэмин ителешендә хлоропластларның коллоид үзлекләрен һәм суланууын өйрәнеп, П. тулы бер күзәнәктә су гомеостазы механизмын тасвирлый.

Х е з м.: К познанию коллоидных свойств хлоропластов // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1918. Т., 48, вып. 1; О пигментной системе зелёных бактерий // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1930. Т. 52, вып. 2; Серные источники и грязи ТАССР // Курортология и физиотерапия. 1935. № 6.

*Әд.:* М а р к о в М.В. Ботаника в Казанском университете за 175 лет. К., 1980; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПОНОМАРЁВ** Павел Петрович (1873, Пермь губ. — ?), христиан теологы, теология д-ры (1909). 1897 елда Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң, шунда ук дини канунннар теологиясе кафедрасында эшли (1921 гә кадәр), проф. (1909). 1919–25 елларда Казан политехник ин-ты һәм Казан пехота курслары рабфакларында рус теле укыта. 1921 дә законсыз дини эшчәнлек алып барганы өчен академиянең башка укытучылары б-н бергә шартлы рәвештә бер елга хөкем ителә. Хезмәтләре патрология (христиан теологиясендә чиркәү аталарының биографияләрен һәм хезмәтләрен өйрәнүче бүлек) өлкәсенә карый.

Х е з м.: Догматические основы христианского аскетизма по творениям восточных писателей-аскетов IV века. К., 1899; Священное Предание как источник христианского ведения. Учение о Священном Предании в древней, преимущественно восточной, Церкви. К., 1908.

*Е.В.Липаков.*

**ПОНОМАРЁВ** Пётр Алексеевич (24.11.1847, Казан — 14.3.1919, шунда ук), археолог, педагог. Чыгышы б-н әнисе ягыннан татар сәүдәгәрләре Алкиннар нәселеннән. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенең 6 сыйныфын тәмамлый; укытучылыкка имтихан тапшырып, пед. эшчәнлек б-н шөгыльләнә башлый. 1860 елларда Казанның Адмиралтейство бистәсендә хосусый мәктәп ача. 1868–1906 да Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында тарих һәм геогр. укытучысы, бер үк вакытта, 1882–1907 дә, Казан хәрби уч-щесендә укыта. 1907–11 дә Казанда хатыны б-н бергәләп үзе ачкан хосусый хатын-кызлар мәктәбендә эшли; 1919 да Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография ин-тының археол. кафедрасында. 1878 дән, ел саен, Казан, Вятка һәм Саратов губерналарында археол. казу эшләре алып бара. П. аеруча Үкәк (1878), Биләр, Болгар, Җүкәтау, Кашан шәһәрлекләрендәге тикшеренүләре б-н таныла (1915–16). Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятен оештыручыларның (1878) берсе һәм аның шәрәфле әгъзасы. П. җәмгыятьнең фәнни эшчәнлегендә актив катнаша, аның каршында археол. музее оештыра. Бөтенроссия 4 нче (Казан, 1878) һәм 7 нче (Ярославль ш., 1887) археол. съездларында катнаша. Ананьино (1881) һәм Маклашеевка (1897) каберлекләрендә бронза һәм тимер гасыр ядкәрләрен, ш.у. Кама алдындагы Ананьино культурасы торулыкларын (1895), Балымер курганнарын (1878), Камай авылы тирәсендәге борынгы татар ядкәрләрен (1904) тикшерә. П. беренчеләрдән булып Ананьино бергәлеге халкының җирләү йолаларының 3 тибын (мәетне җирләү, яндыру, өлешчә җирләү) терки, Ананьино культурасы ядкәрләренең синхронлыгын һәм бер үк мәдәни асылын исбатлый. Үзенең казу эшләре нигезендә беренче тапкыр Болгар культурасын борынгырак булган бронза һәм тимер гасыр культураларыннан аерырга тәкъдим итә. Хезмәтләре бронза һәм элгәрге тимер гасырлар археологиясенә, Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы тарихына карый. Казан төбәге тарихы буенча «Волжско-Камская газета»да, «Волжско-Камская речь», «Казанский телеграф» г-таларында һ.б. басылган мәкаләләр авторы.

Х е з м.: На развалинах города Увека близь Саратова // Древняя и Новая Россия. СПб., 1879; Ошель и его следы // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 3; Материалы для характеристики бронзовой эпохи Камско-Волжского края. Ананьинский могильник // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1892. Т. 10, вып. 4; Булгарский город Кашан // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1893. Т. 11, вып. 2; Тубулга-тау и неопределённые города Волжской Булгарии // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1893. Т. 11, вып. 4.

*Әд.:* Х у д я к о в М.Г. Пётр Алексеевич Пономарёв // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1920. Т. 30, вып. 3.

*С.Ю.Измайлова.*

**ПОНОМАРЁВ** Сергей Николаевич (30.9.1960, Казан), генетика белгече, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), а.х. фән. канд. (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли: 2002 елдан директор урынбасары, селекция үзәге җитәкчесе. 2007 дән тритикале селекциясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре үсемлекләр генетикасы, а.х. культуралары селекциясе һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. П. — РФнең 11 өлкәсендә һәм респ-касында районлаштырылган 5 көзге арыш сорты («Татарская 1», «Эстафета Татарстана», «Радонь», «Огонёк», «Тантана») авторларының берсе. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 4 патенты бар. РФ селекционерлар берлегенең координация советы әгъзасы. Дәүләт бүләге орлыкчылыкның фәнни дәлилләнгән системасы нигезендә көзге арышның югары уңышлы сортларын чыгарганы һәм җитештерүгә тиз кертүгә өчен бирелә.

Х е з м.: Развитие селекции озимой ржи в Северном Поволжье // Интродукция с.-х. растений и её значение для сельского хоз-ва Северо-Востока России. Киров, 1999 (автордаш); Методические основы селекции озимой ржи на повышение питательной ценности зерна // Принципы и методы оптимизации селекционного процесса с.-х. растений: Материалы междунар. науч.-практ. конф. 14–15 июля 2005. Жодино–Минск, 2005.

**ПОНОМАРЁВ РАЙОНЫ́**, *Оренбург өлкәсенең* төньяк-көнбатышында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 2,1 мең *км²*. Үзәге — Пономарёвка авылы (Оренбургтан 220 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 14985 кеше (2013), татарлар саны: 1989 да — 3033, 2002 дә — 3184,

2010 да — 2729 кеше. П.р. терр-ясен татарлар 1740 елларда Яңа Мәскәү юлы төзелешенә нисбәтле рәвештә үзләштерә башлый. Бу чорда Нәүрүз (2007 дә — 1972 кеше) һәм Дүсмәт авыллары нигезләнә, аларда почта станциясе була, һәм халык ямчы хезмәтен үти. Хәзерге көндә Нәүрүз авылында татар теле фән буларак өйрәнелә. Җирле китапханәдә милли әдәбият бүлеге (1 меңнән артык татар китабы бар); М.*Җәлилгә* багышланган китап күргәзмәсе, татар халкының көнкүреш кирәк-яраклары музее эшли; китапханә татар вакытлы матбугатын («Яңа вакыт» г-тасы, «Казан утлары», «Сөембикә», «Сабыйга» ж-ллары һ.б.) алдыра. Нәүрүз авылы мәдәният йорты каршында — «Сандугач» һәм «Сердәш» вокаль төркеме, Дүсмәттә «Ләйсән» татар фольклор балалар коллективы эшли. П.р.ның татар торак пунктларында Сабан туе, Нәүрүз, Карга боткасы бәйрәмнәре үткәрелә; 2007 дән кабельле телевидениедән «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары трансляцияләнә.

*Әд.:* Садыкова З. Говоры Оренбургских татар. К., 1985; Алтухов Н.Г. История Пономарёвского района. Оренбург, 2003.

*З.Ф.Өметбаева.*

**ПОНОМАРЁВА** Мира Леонидовна (13.2.1959, Яшел Үзән ш.), генетика белгече, биол. фән. д-ры (2001), проф. (2005), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында көзге арыш селекциясе лаб-ясе мөдире, көзге арыш һәм тритикале селекциясе бүлеге мөдире (2002 дән). Хезмәтләре үсемлекләр генетикасына, а.х. культуралары селекциясе һәм орлыкчылыгы мәсьәләләренә карый. П. тарафыннан көзге арышның икмәк пешерү һәм туклыклылык сыйфатларын яхшырту, сөрлегүгә һәм гөмбә авыруларына чыдамлыгын күтәрү буенча методик хезмәтләр эшләнә. Районлаштырылган арышның «Татарская 1», «Эстафета Татарстана», «Радонь», «Огонёк», «Тантана» сортлары авторларының берсе. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы, 4 патенты бар. ТР Дәүләт бүләге көзге арышның югары уңышлы сортларын чыгарганы һәм тиз арада җитештерүгә керткәне өчен бирелә (2000). Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Селекционная ценность источников устойчивости озимой ржи к группе грибных болезней // Вестн. защиты растений. 2000. № 3 (автордаш); Селекция адаптивных сортов озимой ржи в Республике Татарстан // Зерновое хоз-во. 2002. № 1 (автордаш).

**ПОНОМАРЁВКА** авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 30 *км* көньяктарак, Зирекле елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 5 кеше (чуашлар, руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 98, 1938 дә — 150, 1949 да — 168, 1958 дә — 139, 1970 тә — 97, 1979 да — 35, 1989 да — 19, 2002 дә 12 кеше.

**ПО́ПЕЛЬ** Андрей Алексеевич (25.10.1919, РСФСРның Гомель губ., хәзер Белоруссия Респ-касы Могилёв өлкәсенең Кричевск р-ны Сокольничи а. — 18.1.1977, Казан), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1969), проф. (1970). 1941 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан оптика-механика з-дында эшли. 1945 тән Казан ун-тында, нәорганик химия каф. мөдире (1965 тән). Хезмәтләре аналитик һәм нәорганик химиядә төрле физик-химик алымнар куллануга карый. П. пара- һәм диамагнит ион эремәләрендә эретkeч (яки лиганд) атомы төшләренең магнит релаксациясе тизлеген үлчәүгә нигезләнеп нәорганик кушылмаларны магнитлы-релаксацион анализлау һәм тикшерү ысулын эшли. Бу ысулның төрле вариантларын, ш.и. магнитлы-релаксацион титрлау юлын тәкъдим итә, соңгысын төрле лигандлы, гомо- һәм гетероүзәкле, протонланган координацион кушылмаларның составын, тотрыклылыгын һәм динамик тотышын өйрәнү, ш.у. электролитларда ионара тәэсир итешүләрне тикшерү өчен куллана.

Хезм.: Ускоренные методы анализа электролитов гальванических ванн. К., 1962; Магнитно-релаксационный метод анализа неорганических соединений. М., 1978; Практическое руководство по химии комплексных соединений. К., 1979 (автордаш).

*А.В.Захаров.*

**ПОПЕЛЯ́НСКИЙ** Яков Юрьевич (25.12.1917, Подольск губ., Винница өязе Самгородок а. — 12.1.2003, АКШ), невропатолог, мед. фән. д-ры (1963), проф. (1963), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Академиклар Н.В.Коновалов, А.Р.Лурия, проф. Н.А.Бернштейн шәкерте. Яңа клиник фән — вертеброневрологиягә нигез салучыларның берсе. 1 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1940), Орёл өлкәсенең Хвастовичи авылында, район хастаханәсендә эшли. 1940–45 елларда армия табибе. 1946–49 да СССР МФАнең Неврология ин-тында. 1950 дән — Кишинёв, 1954 тән Оренбург мед. ин-тларының психиатрия кафедраларында. 1955 тән Мәскәү поликлиникаларында табиб-невропатолог. 1957 дән Новокузнецк ГИДУВында, 1961 дән — нерв авырулары каф, 1967 дән Казан мед. ин-тының шул исемдәге каф. мөдире. Неврология кафедрасында Л.О.*Даркшевич* музеен оештыра. 1989–2001 дә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан мед. ин-ты каршындагы Бөтенроссия вертеброневрология үзәге җитәкчесе. 2001 дән АКШта. Хезмәтләре нерв системасының вертеброген патологиясенә, мед. тарихына карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Шейный остеохондроз. М., 1966; Вертеброгенные заболевания нервной системы: В 3 т. К., 1974–83; Т. 1; Ботулизм: Неврологический аспект. Уфа, 1994.

*Әд.:* Ахмеров Н.У., Подольский М.А. Феномен Якова Попелянского // Вертеброневрология. 1992. № 2.

**ПОПО́В** Александр Васильевич (1808, Саратов губ. Царицын ш. — 10.6.1865, Казан), шәркыятьче галим. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1828), Иркутск шәһәренә һәм Байкал аръягы краена командировкага җибәрелә. Күчмә монголлар һәм бурятлар арасында яши, монгол һәм тибет телләрен өйрәнә. 1833–53 елларда Казан ун-тында: адъюнкт, экстраординар (1835 тән) һәм ординар (1846 дан) проф. Бер үк вакытта Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә монгол теле (1833 тән), Казан руханилар академиясендә монгол һәм калмык телләре (1844 тән) укыта. 1855 тән Петербург ун-ты профессоры. 1860 тан Көнбатыш Себер уч-щеләренең баш инспекторы. Хезмәтләре монгол һәм калмык тел белеменә карый. «Монгол телен өйрәнә башлаучылар өчен монгол хрестоматиясе» («Монгольская хрестоматия для начинающих обучаться монгольскому языку», 1–2 кис., 1836–37) өчен 4 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены б-н бүләкләнә, «Калмык теле грамматикасы» («Грамматика калмыцкого языка», 1848) өчен Демидов бүләгенә лаек була.

Хезм.: Арифметика на монгольском языке. К., 1837; Краткие замечания о приволжских калмыках // Журн. М-ва народного просвещения. 1839. Ч. 22, отд. 2.

*Әд.:* Назарьев В. Жизнь и люди былого времени // Ист. вестн. 1890. № 12.

**ПОПО́В** Александр Никифорович (1840, Витебск губ. — 6.8.1881, Варшава), химик, химия д-ры (1872), проф. (1872). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1865), шунда ук, А.М.Бутлеров җитәкчелегендә эшли. 1869 дан Варшава ун-ты профессоры. Хезмәтләре структур органик химиягә карый. «Углерод атомының охшашлыгы турында» («По поводу сродства углеродного атома», 1865) дигән хезмәтендә П. тәҗрибәләр юлы б-н, немец химигы Г.Кольбе раславына каршы килеп, углеродның барлык дүрт валентлылыгының да бердәй булуын исбатлый, һәм бу А.М.Бутлеровның химик охшашлык теориясен куәтли. Кетоннар оксидлашу кагыйдәсен формалаштыра (к. *Попов кагыйдәсе*), бензол гомологлары оксидлашуының бензол боҗрасы б-н турыдан-туры бәйләнгән углерод атомыннан башлануы турындагы закончалыкны ача (немец химигы Э.К.Т.Цинке б-н бергә). Үсә баручы тотрыклылыгы буенча радикаллар рәтен төзи һәм тотрыклы радикалның карбониль төркем б-н бергә аерылуы турындагы кагыйдәне формалаштыра. Рус-төрек сугышы елларында (1877–78) В.В.Марковников б-н бергә Балканда хәрәкәт итүче рус армиясенең санитар отрядында дезинфекция эшләренә җитәкчелек итә. 4 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены, медаль б-н бүләкләнә.


*Әд.:* Волков В.А., Вонский Е.В., Кузнецова Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

*В.Г.Абзалова.*

**ПОПО́В** Александр Фёдорович (17.11.1815, Вятка ш. — 31.12.1878, Казан), математик һәм механик, матем. д-ры (1845), Петерб. ФАнең мөхбир әгъзасы (1866). 1835 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә укыта. 1846 дан Казан ун-тының саф матем. каф.



Виктор А.Попов.



Владимир А.Попов.

мөдире (элегрәк аны укытучысы Н.И.Лобачевский җитәкли), проф. (1849 дан). Хезмәтләре гидростатикага, гидродинамикага, матем. физикага, сыгылмалылык теориясенә, тавыш теориясенә, саф математикага, матем. тарихына карый.

Х е з м.: О значении некоторых интегралов и сумм // Уч. зап. Казан. ун-та. 1851. Т. 4; О траекториях частичек при перемещении жидкой массы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1867. Т. 11, кн. 2; Общие уравнения равновесия электричества на данной поверхности проводника. К., 1871; Очерк развития арифметики. К., 1873.

**ПОПО́В** Анатолий Андреевич (6.6.1942, Украина ССРның Луганск өлкәсе, Лисичанский р-ны Боровский пос. — 25.4.2009, Казан), зоолог, биол. фән. канд. (1977), проф. (1996). 1971 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли, зоол. каф. мөдире (1984 тән). Хезмәтләре Урта Идел буеның гидрофаунасын өйрәнүгә карый. П. тарафыннан балыкларның башлангыч онтогенезы мәсьәләләре карала, уылдык чәчү характерына бәйле рәвештә маймычларның морфо-экологик үзенчәлекләре ачыклана. «Эволюция теориясе нигезләре» («Основы теории эволюции», 1995), «Табигатьтәге умырткалы хайваннарны өйрәнү» («Изучение позвоночных животных в природе», 2001), «Экология һәм табигатьне саклау нигезләре» («Основы экологии и охраны природы», 2004) уку ярдәмлекләре авторы һәм автордашы. СССР Югары мәктәбе отличнигы (1989), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2003), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2007).

Х е з м.: Характеристика нереста леща и морфологические особенности его молоди на разных этапах развития // Биологические науки. 1974. № 12; Сравнительная анатомия и эволюция животных. К., 2007 (автордаш).

**ПОПО́В** Виктор Алексеевич (15.3.1910, Казан — 20.9.1980, шунда ук), зоолог, эколог, биол. фән. д-ры (1964), проф. (1967), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1974). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1932). 1932–46 елларда Идел-Кама зона сунарчылык промыселы биол. станциясендә. Бер үк вакытта, 1939–46 да, Казан ун-тында укыта, зоол. музее директоры (1942 дән). 1946 дан СССР ФА Казан ф-лының Биология ин-тында, зоол. лаб-ясе мөдире (1955–73). 1969 да Казан ун-тында СССРда беренче табигатьне саклау кафедрасын оештыра һәм аны 1980 гә кадәр җитәкли. Идел-Кама саклаулыгын оештыруны башлап йөрүче. Хезмәтләре аучылыкка, умырткалылар зоологиясенә, экологиягә карый. П. җитәкчелегендә Америка чәшкесен климатка яраклаштыру, имезүчеләр (бөҗәк ашаучылар, кулканатлылар, кимерүчеләр), кошлар экологиясе буенча тикшеренүләр үткәрелә; тикшеренүләр барлык төп биотопларда үткәрелә. Табигатьне саклау идеяләрен пропагандалауга күп көч куя, Татарстан телевидениесендә «Кеше һәм табигать» тапшыруын алып бара. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, СССР ВДНХсының көмеш һәм алтын медальләре, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Материалы по экологии норки (Mustela vison) и результаты акклиматизации её в Татарской АССР // Тр. КФАН СССР. Сер. биологических и с.-х. наук. 1949. Вып. 2; Редкие и исчезающие виды животных Татарии (Позвоночные). К., 1978; Биосфера и проблемы её охраны. К., 1981.

*Әд.:* Г а р а н и н В.И. В.А.Попов и Волжско-Камский заповедник // Тр. Волжско-Камского гос. природного заповедника. 2005. Вып. 6.

*В.И.Гаранин.*

**ПОПО́В** Владимир Александрович (24.6.1924, Украина ССР, Донецк өлкәсенең Мариуполь ш.), график, каллиграф, нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1975), ТАССРның халык рәссамы (1986), Россиянең атказ. рәссамы (2003). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң, Татарстан сәнгать фондында эшли (1951–83). Рәссамнар берлеге (1961), ЮНЕСКО каршындагы халыкара Сынлы сәнгать ассоциациясе (1997) әгъзасы. Табигатькә һәм кешенең аны үзләштерүенә багышланган пейзажлар сериясен иҗат итә: «Алтай. Күтәрелгән чирәм җир», «Далада кич» (икесе дә — 1955), «Мәскәү киңлекләре» (1957), «Нурек катлары», «Кама киңлекләре» (икесе дә — 1982). 1950 еллар ахырыннан станлы графика өлкәсендә линогравюра, офорт, агачтагы гравюра, ксилография, акварель, күмер, тушь б-н ясау техникаларында эшли; табигать күренешләре, индустриаль пейзаж жанрларындагы әсәрләр иҗат итә: «Шәһәрләр үсә» (1959–61), «Асфальт юллар» (1961), «Татарстан нефте» (1964), «Уренгой–Ужгород» (1965), «КамАЗ» (1972), «Нуленче километрдан Чарга кадәр сузылган БАМ» (1986), «Христиан һәм мөселманнарның изге урыннары» («Каргополь», «Соловки», «Псков», 1980–92), «Батырлар симфониясе» (1962, вариантлары — 1967, 1974), «Иске Казан», «Яңа Казан» (икесе дә — 1971), «Чаллы төзелә» (1972), «Җир катламнарына үтүчеләр» (1984), «Чаллы туфрагы» (1989). Казан «Агитплакат» остаханәсендә чыккан плакатлар, интерьер проектлары авторы.


П.ның әсәрләре композицион бөтенлеге, монументаль образлылыгы, хисләргә байлыгы б-н аерылып тора. 1990 еллар башыннан П.ның иҗади потенциалы һәм рухи-эстетик эзләнүләре каллиграфия һәм шәмаилләр сәнгатенең яңа якларын ача. П. — шәмаилне Европа сынлы сәнгате традицияләрен ислам сәнгате кануннары б-н кушып, заманча иҗат төре булярак үстергән проф. рәссамнарның берсе. П. композицияләрендә мәчетләр, ислам архит-расы һәм аның изге символлары кергән реалистик пейзажлар гарәп графикасының орнаментлы, бормалы язулары б-н тулы бергәлек тудыра. Соңрак П., тушь, акварель, гуашь, күмер, сангина кулланып, кече форматлы график шәмаилләр иҗат итә. 600 гә якын каллиграфик әсәр — «Кара таш» (1990, вариант — 1997), «Бөтенесен бүләк итүче», «Аллаһы Тәгалә», «Пәйгамбәр эзе», «Болгар», «Ханнар Казаны», «Бердәм башлангычтан», «Сәмәрканд» (барысы да — 1997); гарәп графикасындагы дини тугралар («Аллаһның 25 рәсүле», «Аллаһ», «Мөхәммәд пәйгамбәр», «Шаһадә», 1995–2008) сериясе, ватаныбыздагы сәясәт һәм җәмәгать эшлеклеләренең (Россия, Татарстан Президентлары һ.б.), корольләрнең, мөселман дөньясындагы рухани затларның исемнәре язылган дистәләгән тугралар (исемле мөһерләр, экслибрислар) авторы.



В.А.Попов. Ренат Акчурин туграсы. Кәгазь, тушь. 2000.

Респ-ка (1952 дән); зона — «Зур Идел» (1964 тән); бөтенроссия (1955 тән), бөтенсоюз эстамп күргәзмәләре (Мәскәү, 1962–63); халыкара — «Совет графикасы һәм скульптурасы» (Пхеньян, Корея Халык Демократик





В.А. П о п о в.
1. «Батырлар симфониясе». Линогравюра. 1962. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
2. «Казан мәчетләре» шәмаиле. Киндер, темпера. 1997. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Респ-касы, 1963), «Совет сәнгате» (Улан-Батор, Монголия; Берлин, ГДР; Прага, Чехословакия; Варшава, Польша, 1971–72), «Совет сынлы сәнгате» (Бәйрут, Ливан, 1974), «Татар милли сәнгате» (Пиза ш., Италия, 2003) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1961–62, 1974, 1984, 1995–2000 (Казан), 2000, 2001, 2002 (Мәскәү), 2000 (Таһран, Иран), 2006 елларда (Бәйрут, Ливан; Димәшкъ, Сүрия; Каһирә, Александрия, Мисыр; Яшел Үзән ш.) үткәрелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Әсәрләре Шәрекъ Дәүләт музеенда (Мәскәү), А.В.Щусев исем. Архит-ра музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгендә, Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Әлмәт, Лениногорск картиналар галереяларында, Мәскәүдә Иран, Мисыр илчелекләрендә, РФнең Каһирә һәм Александриядәге вәкиллекләрендә, Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

*Әд.:* Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; В.А.Попов: Буклет к персональной выставке в Тегеране. М., 2000; Владимир Попов: Альбом. К., 2003; Владимир Попов: Буклет к персональной выставке в Египте. Каир, 2006; Хазиева А. Полумистический мир слова // Элита Татарстана. 2006. Август.

*Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

**ПОПО́В** Вячеслав Андреевич (12.11.1877, С.-Петербург — 26.3.1923, Казан), анатом, медицина д-ры, надворный советник (1914). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1902), шунда ук табиб булып эшли, 1906 елдан — анатомия кафедрасында прозектор ярдәмчесе, 1913–14 тә — прозектор, проф. (1921). Хезмәтләре кешенең югары очлыклары артерияләре морфологиясен өйрәнүгә карый. Рус-япон сугышында (1904–05) катнаша. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Случай прибавочной печени // Казан. мед. журн. 1911. Т. 11, № 3; К морфологии артерий верхней конечности человека. О некоторых артериях области плеча, локтевого сгиба и предплечья. К., 1914.

**ПОПО́В** Георгий Иванович (15.4.1911, Волгоград өлкәсенең Елань р-ны Берёзовка а. — 10.8.2005, С.-Петербург), агроном-селекция белгече, а.х. фән. д-ры (1954), проф. (1971). Саратов а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1932), Казан селекция станциясендә эшли: тары селекциясе төркеме мөдире, директор урынбасары (1937–46). 1946–52 елларда Бөтенсоюз үсемлекчелек ин-тында (Ленинград). 1952–57 дә Ленинград селекция станциясендә (Суйда пос.) директор. 1957–98 дә Төньяк-Көнбатыш а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында (Ленинград өлкәсенең Белогорка пос.): баш фәнни хезмәткәр (1988 дән), фәнни консультант (1992 дән). Хезмәтләре көзге арыш селекциясе мәсьәләләренә карый. Көзге арышның «Гибрид 173», «Ярославна», «Волхова», «Былина», «Эра»; тарының «Казан 176», «Казан 430», «Казан 2» сортлары авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Селекция и семеноводство озимой ржи. Л., 1979 (автордаш).

**ПОПО́В** Евгений Александрович (23.8.1959, Хабаровск крае, Верхнебурея р-ны Чегдомын пос.), физик, физика-матем. фән д-ры (2004). 1982 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. 2000 нән Казан энергетика ун-тында, проф. (2004 тән). Хезмәтләре гамма-нурланышның төш резонанслы чәчелешендә квант интерференциясе эффектын тикшерүгә карый. П. бериш булмаган магнитик тирәлектәге алга һәм кечкенә почмаклы чәчелү каналларында синхротрон нурланыш таралганда гамма-кайтаваз сигналлар килеп чыгу мөмкинлеген ачыклый. Икеле Мёссбауэр-ТМР резонанслы һәм резонанслы гамма-оптик тирәлектә синхрон нурланыш нигезендә иң якын магнит тәртибен анализлау алымын тәкъдим итә.

Х е з м.: Влияние флуктуаций магнитных моментов микрочастиц на временные зависимости мёссбауэровского рассеяния // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 54, № 2; Эффекты квантовой интерференции γ-излучения при кроссинге-антикроссинге ядерных уровней в радиочастотном поле // Изв. РАН. Сер. физ. 2007. Т. 71, № 9 (автордаш); Gamma-echo in forward nuclear scattering of synchrotron radiation in an inhomogeneous medium // Journal Physics: Condensed Matter. 1999. V. 11 (автордаш).

**ПОПО́В** Иван Павлович (1857, Казан — 1927, шунда ук), терлекләрне үрчетү белгече, вет. фән. магистры (1887). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1880), вет. табибе булып эшли. 1887 елда Новоалександрия а.х. һәм урманчылык ин-тын тәмамлый. 1888–1927 дә Казан вет. ин-тының терлекчелек каф. мөдире, проф. (1897), бер үк вакытта, 1921–27 дә, Казан а.х. ин-тының а.х. һәм терлекчелек каф. мөдире. Хезмәтләре җир эшкәртү, терлекчелек, зоотехния, вет. мәсьәләләренә карый. П. төрле а.х. терлекләренең продуктлылыгын һәм токым сыйфатларын билгеләү б-н шөгыльләнә. Авыл хуҗалыгына багышланган популяр брошюралар нәшер итүгә аеруча зур игътибар бирә (гомуми тиражы 1 млн. га якын данә тәшкил итә). П.ның хезмәтләре татар, чуаш, мари, удмурт һәм кыргыз телләренә тәрҗемә ителә.

Х е з м.: Овцеводство в крестьянском хозяйстве Казанской губернии // Уч. зап. Казан вет. ин-та. 1891. Т. 8, вып. 3; О молочном деле в крестьянском хозяйстве. М., 1913; Скотоводство (разведение, кормление, зоогигиена). СПб., 1913; Рабочая лошадь: Популярная беседа о выборе лошади, кормлении и уходе за нею. К., 1926.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ПОПО́В** Леонид Михайлович (8.6.1943, Свердловск өлкәсенең Кировград р-ны Карпушиха пос.), психолог, психол. фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2003). 1960 елдан Свердловск шәһәренең «Уралмаш» з-дында эшли. 1970 тә Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, югары уку йорты эшләре лаб-ясендә, 1974 тән пед. һәм психол. кафедрасында, 1994 тән яңа оештырылган психол. каф. (2003 тән шәхес психологиясе каф.) мөдире, бер үк вакытта, 2003–11 дә, психол. ф-ты деканы. Хезмәтләре шәхес һәм төркемнең үзлегеннән үсеше, иҗат психологиясе проблемаларына, студентның шәхси үсеше һәм гомуми тикшеренү алымнары мәсьәләләренә карый. РФнең Мәгариф өлкәсендәге дәүләт бүләге лауреаты (2012).

Х е з м.: Инициатива и общение в творчестве. К., 1983; Психология самодеятельного творчества студентов. К., 1990; Добро и зло в этической психологии личности. М., 2007.

**ПОПО́В** Михаил Иванович (1828 — 12.11.1882, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче. Буяу-җилем іше әйберләр һәм чәй б-н сәүдә итә. 1865 елдан Казан җәмәгать банкы җитәкчесе урынбасарлыгына кандидат, 1871 дән Казан руханилар семинариясе каршында шәрәфле ригаяче (күзәтеп торучы), 1875 тән Казан сәүдәгәрләр банкының идарә әгъзасы, рәисе. Адмиралтейство хастаханәсен яңадан төзүгә һәм аның өчен йорт сатып алуга 16 мең сум, сукыр балалар өчен яңа уч-ще бинасын төзүгә 5 мең сум, Җир эшкәртү колонияләре һәм һөнәр приютлары җәмгыяте кассасына 10 мең сум, *Николай исемендәге балалар ятимханәсе* каршында 10 урынлы төн куну бүлеге ачуга 16 мең сум акча мирас итеп калдыра (бүлеккә П. исеме бирелә).

*Л.М.Свердлова.*

**ПОПО́В** Николай Михайлович (30.7.1854, Вятка ш. — 31.5.1939, София), психиатр, медицина д-ры (1885). Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлаганнан соң (1878), хәрби мед. хезмәтендә; 1880 елдан Петербург полиция идарәсе каршындагы һәм император Мария Фёдоровна карамагындагы учреждениеләр идарәсе табибе. 1885–88 дә Петербург шәһәр җәмәгатьчелеге идарәсе табибе. 1888 дән Варшава ун-тының — экстраординар, 1889 дан ординар профессоры. 1894 тән Казан ун-тының психиатрия каф. ординар профессоры. 1903 тән Новороссийск (Одесса ш.), 1922 дән София ун-тларында. Хезмәтләре анатомиягә, үзәк нерв системасының нормаль һәм патологик физиологиясенә карый.

Х е з м.: Случай медленного закупоривания верхней серповидной пазухи // Врач. 1884. № 25; К лечению дипсомании // Врач. 1886. № 10; К вопросу об изменении зрительных нервов при спинной сухотке. К., 1893; Патолого-анатомические изменения центральной нервной системы при азиатской холере. Варшава, 1893.

**ПОПО́В** Николай Петрович (1888 — 1961, Казан), ветеринар-гельминтолог, вет. фән. д-ры (1940), проф. (1935). Варшава вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1912), ин-тның патологик анатомия кафедрасында штаттан тыш ассистент итеп калдырыла, 1913–14 елларда квалификация күтәрү максатыннан Германия, Франция, Англиягә командировкага җибәрелә. 1914 тән Россиянең төрле вет. югары уку йортларында укыта. 1937–59 да Казан вет. ин-тының паразитология каф. мөдире. Төп хезмәтләре ат һәм сарык гельминтларын өйрәнүгә карый (гельминтларның 30 дан артык төрен ача). СССРның төрле тө-

бәкләренә оештырылган 22 экспедициядә катнаша, кайберләренә үзе җитәкчелек итә.

Х е з м.: Роль дегельминтизации в экономике овцеводческих хозяйств // Уч. зап. Казан. зоотехническо-вет. ин-та. 1937. Т. 48, вып. 2; Гельминтозы сельскохозяйственных животных, пушных зверей и птиц Татарии и смежных с нею республик Среднего Поволжья // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1960. Т. 75.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ПОПО́В** Нил Александрович (28.3.1833, Тверь губ. Бежецк ш. — 22.12.1891, Мәскәү), тарихчы, славян филол. белгече, архивчы, рус тарихы д-ры (1869), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1883), хакыйкый статский советник (1879). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1854). 1855–57 елларда Мәскәүдә 4 нче ир балалар гимназиясендә укыта. 1857–59 да Казан ун-тының рус тарихы каф. адъюнкты, 1860–69 да приват-доцент, 1869–71 дә экстраординар, 1871–82 дә ординар проф.; 1882 дән Мәскәү ун-тының рус тарихы кафедрасының атказ. профессоры. Бер үк вакытта, 1885–88 дә Юстиция министрлыгының Мәскәү архивы җитәкчесе, 1888 дән — идарәчесе. 1860 та Мәскәү славяннар ком-ты секретаре. Славянофиллар тәгълиматын эшләүчеләрнең берсе. 15–17 йөзләр рус тарихы чыганакларын (алар арасында — «Юстиция министрлыгының Мәскәү архивында сакланган документ һәм кәгазьләрнең тасвирламасы» («Описание документов и бумаг, хранящихся в Московском архиве Министерства юстиции», Т. 5–8, М., 1888–91), «Мәскәү дәүләте актлары» («Акты Московского государства», Т. 1–2, СПб., 1890–91), Казан ун-тының фәнни китапханәсендәге кульъязмалардан файдаланып, Казан крае тарихына багышланган мәкаләләр һәм документлар җыентыклары нәшер итә. «Бөек Пётр чорында 1717–1720 еллар диңгез эшләре тарихы буенча материаллар. Казан адмиралтействосы эшләре күчермәләреннән» («Материалы для истории морского дела при Петре Великом в 1717–1720 годах. Из копий с дел Казанского адмиралтейства», М., 1859) китабында флот кораблары төзү өчен агач әзерләүдә, суднолар төзү һәм аларны җиһазлауда, лашманнар хезмәтен оештыруда, постау мануфактурасының һәм помпа каеш-күннәре з-дының эшчәнлеген көйләүдә губерна хакимияте уздырган чаралар турында вице-губернатор Н.А.Кудрявцев һ.б. чиновникларның Пётр I гә җиткергән хәбәрләрен тасвирлый. «1805 елдан 1834 кә кадәр Казандагы туган телне һәм әдәбиятны сөючеләр җәмгыяте» («Общество любителей отечественной словесности и литературы в Казани с 1805 по 1834 год»; «Русский вестник» ж-лы, 1859, 17 нче кит.) хезмәте Казанда вакытлы матбугат тарихына багышлана. 1858–59 елгы «Московские ведомости» г-тасында урын алган «Казан хатлары»нда («Казанские письма») 1861 елгы Крәстияннәр реформасы алдыннан Казандагы иҗтимагый тормыш турында сөйли. «Татищев һәм ул яшәгән заман. Узган гасырның беренче яртысында Россиядәге дәүләт, иҗтимагый һәм шәхси тормыш тарихыннан» («Татищев и его время. Эпизод из истории государственной, общественной и частной жизни в России первой половины прошедшего столетия», М., 1861) хезмәтендә В.Н.Татищевның Казанга килүе, файдалы казылмалар эзләве, Казан губернасында заводлар төзүе һәм тарихи документлар җыюы турында фактлар китерә. Көньяк һәм төньяк славяннар тарихына, славяннар яшәгән җирләрдә христиан дине таралу мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Очерки религиозной и национальной благотворительности на Востоке и среди славян. СПб., 1871.

*Әд.:* Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; А х у н д з а д е З.С. Нил Александрович Попов (1833–1891): Страницы жизни // Из истории университетского славяноведения в СССР. М., 1983.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОПО́В** Порфирий Иванович (28.2.1892, Тула губ., Новосиль өязе Подтолстое а. — 17.3.1956, Казан), ветеринар-фармаколог, вет. фән. д-ры (1942). ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1951). Казан вет. ин-тын тәмамлагач (1919), шунда эшкә калдырыла, 1923–30, 1935–56 елларда Казан вет. ин-тында фармакология каф. мөдире, проф. (1925), 1930–35 тә Воронеж вет. ин-тының фармакология кафедрасын җитәкли. Хезмәтләре фармакологиягә карый. П. терлекләрдә протозойларга бәйле авыруларны кисәтү өчен химиотерапевтик препаратлар кертү ысулларын эшли, пироплазмоз, атларда нутталиоз очракларында куллану өчен нәтиҗәле препаратлар — гемоспоридин һәм новоплазмин уйлап таба. Вет. фармакологларының Казан мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О действии новоплазмина в больших дозах // Фармакология и токсикология. 1945. № 5; Ветеринарная фармакология. М., 1955 (автордаш).

*Әд.:* Н а б и е в Ф.Г. Профессор Порфирий Иванович Попов. К., 2001; Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*Ф.Г.Нәбиев.*

**ПОПО́В КАГЫЙДӘСЕ́**, кетоннар оксидлашуының карбонил төркемендәге теләсә нинди углерод-углерод бәйләнешенең өзеклек б-н баруы турындагы закончалык. Карбонил төркеменең ике ягында метилен төркемнәре булган кетоннарда дүрт карбон к-тасы катнашмасы хасил була:

Кетоннарны көчле оксидлаштыргычлар (ачы тирәлектә перманганат яки бихромат) б-н җылытканда табылган кислоталарда атомнар саны П.к.дә күрсәтелгәннән кимрәк була (моны кетон төзелешен аның оксидлашу продуктлары буенча билгеләгәндә исәпкә алырга кирәк). П.к.н 1868 елда А.Н.Попов бәян итә.

*Әд.:* Краткая химическая энциклопедия. М., 1965; Химия: Большой энцикл. словарь. М., 2000.

**ПОПО́ВА** Лилия Георгиевна (4.5.1928, Кырым АССР, Евпатория р-ны Акмәчет а.), педиатр, биохимик, мед. фән. д-ры (1983). Харьков мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук, хирургия аппаратлары һәм инструментларын эксперименталь сынау буенча фәнни-тикшеренү лаб-ясендә эшли. 1953 елдан СССР МФАнең Патологик физиол. ин-тында (Мәскәү). 1956 дан Львов өлкәсе Стрый шәһәре балалар хастаханәсендә табиб-педиатр. 1960 тан Мурманск өлкәсенең Кола р-ны Кица станциясе участок хастаханәсе табиб-терапевты. 1964–97 дә Казан мед. ин-тының үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә биохимия төркеме мөдире. Хезмәтләре кан оешуны көйләү мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Специфические и неспецифические методы лечения при экспериментальной терапии туберкулёза // Патофизиология и экспериментальная терапия. 1957. № 2; Изменение контактной фазы свёртывания крови при перитонитах // Казан. мед. журн. 1973. № 3 (автордаш); Прямое воздействие ферментов контактной фазы свертывания с иммобилизованным норадреналином // Казан. мед. журн. 1975. № 6.

**ПОПО́ВКА** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Кандыз елгасы буенда. 2010 елда 827 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 60%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1830 еллар тирәсендә Курск губернасыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да волость идарәсе урнаша; земство станциясе; чиркәү, чиркәү-приход һәм земство мәктәпләре, 2 су тегермәне була; табиб, фельдшер, акушер эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2275 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Самара губернасының Бөгелмә өязе Иваново волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 609, 1889 да — 1029, 1910 да — 1544, 1920 дә — 1456, 1938 дә — 1474, 1949 да — 441, 1958 дә — 411, 1970 тә — 1026, 1979 да — 955, 1989 да — 896, 2002 дә — 902 кеше.

**ПОПО́ВКА** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Баграж елгасының (Дала Зәе бассейны) уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 93 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 1906–11 дә нигез салына. Беренче исемнәре — Яңа Авыл, Зур Поповка. 1920 еллар башында чиркәү төзелә. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 595 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1913 тә — 238, 1920 дә — 330, 1938 дә — 398, 1949 да — 325, 1958 дә — 376, 1970 тә — 431, 1979 да — 273, 1989 да — 143, 2002 дә — 102 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.

**ПОПО́ВКА** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгы-

ле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уратма-Поповка буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында монда Сретение чиркәве (1866 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), 2 су тегермәне, аракы з-ды, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 404,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1782 дә — 64 ир-ат; 1859 да — 834, 1897 дә — 691, 1908 дә — 719, 1920 дә — 870, 1926 да — 898, 1949 да — 587, 1958 дә — 413, 1970 тә — 422, 1979 да — 322, 1989 да — 183, 2002 дә — 144 кеше.

**ПОПО́ВКИН** Василий Иванович (9.12.1924 — 23.11.2000), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1965), проф. (1967), РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992). 1949 елда Ленинград авиация приборлары төзү ин-тын тәмамлый. 1952 дән Казан авиация ин-тында укыта. П. радио б-н идарә итү кафедрасын оештыра һәм җитәкли (1952–71), радиотехника ф-ты деканы (1952–61). 1971 дән Рязань радиотехника ин-тында: ректор (1971–88), радиотехник системалар каф. мөдире (1971–95). Хезмәтләре антенналар синтезына карый. П. антенналар синтезы өчен матем. физиканың төгәл куелмаган мәсьәләләрен чишү алымнарын эшли. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1976).

Х е з м.: Определение диаграмм направленности отдельных излучателей по заданной диаграмме направленности линейной антенной системы // Радиотехника и электроника. 1969. № 2 (автордаш); Оптимальные решения задач теории синтеза антенн // Радиотехника и электроника. 1969. № 7 (автордаш).

**ПОР-КУТЕ́Ш** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 15 *км* төньяктарак, Кошкәт елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 137 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Беренче исеме — Пустошь на речке Кутеше. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1896 да миссионерлык мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 56, 1763 тә — 72, 1795 тә — 11, 1811 дә — 120 ир-ат; 1850 дә — 251, 1884 тә — 350, 1897 дә — 401, 1905 тә — 440, 1920 дә — 541, 1938 дә — 405, 1949 да — 296, 1958 дә — 199, 1970 тә — 193, 1979 да — 171, 1989 да — 124, 2002 дә — 130 кеше.

**ПОРА́Й-КО́ШИЦ** Александр Евгеньевич (26.9.1877, Казан — 17.4.1949, Ленинград), химик-органик, СССР ФА академигы (1935; 1931 елдан мөхбир әгъза). 1903 тә Петербург технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Германия з-длары лаб-яләрендә стажировка үтә. 1905 тән Ленинград технол. ин-тында, проф. (1918), бер үк вакытта Ленинград ун-тында (1926–28). Бөек Ватан сугышы елларында Казан химия-технол. ин-тында (1941–44) һәм бер үк вакытта СССР ФАнең Мәскәүдән Казанга эвакуацияләнгән Органик химия ин-тында арадаш продуктлар һәм буяулар лаб-ясе мөдире (1941–47). Хезмәтләре синтетик буяулар химиясенә һәм технологиясенә карый. П.-К. органик буягычларның төсле булуы сәбәпләре турында фаразлар әйтә. Ароматик һәм гетероциклик рәтләр таутомерларының метилен һәм метил төркемендә — водород атомнарының, альдегидлар, кетоннар һәм нитрозо-кушылмаларда углерод яки азот б-н икеле бәйләнеш ясап кушылган кислород атомнарының хәрәкәтчәнлеген тикшерә. Мамык өчен күп кенә буяулар синтезлый. Буяуларның хиноид классификациясен һәм «буяу» терминын, ш.у. буяуларны спектрофотометр ярдәмендә төгәл идентификацияләүне тәкъдим итә. Буягычлар һәм аксым чыганаклы сүсләр арасында химик тәэсир итешүләр булуын исбатлый. Бер аппаратта азотсызландыру һәм азотны кушу реакцияләрен бергә алып барып, азотлы буяулар алу, ш.у. көнбагыш кабыгыннан сәнәгый юл б-н фурфурол табу ысулларын эшли. Төсле фотография процессының химиясен тикшерә. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1943). Ленин ордены һ.б. орденнар, медальләр б-н бүләкләнә.


Х е з м.: Работы в области органической химии, химии красящих веществ и теории крашения. М.–Л., 1949.

*Әд.:* А.Е.Порай-Кошиц // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. хим. наук. М.–Л., 1948. Вып. 8.

**ПОРЕ́ЦКИЙ** Платон Сергеевич (3.10.1846, Елизаветград ш., хәзер Кировоград ш. — 9.8.1907, хәзер Украина Респ-касының Чернигов өлкәсе Жоведь а.), математик, астроном, логик. Харьков ун-тын тәмамлый (1870). 1876–89 елларда Казан ун-тында: астроном-күзәтүче, приват-доцент (1886 дан). Хезмәтләре логика алгебрасы мәсьәләләренә карый (ул аларны «логик тигезлекләрне исәпләү» дип атый). П.ның бу өлкәдәге комбинатор-логик нәтиҗәләре матем. логиканың аннан соңгы үсешенә йогынты ясый (мәс., 20 йөз Америка логигы А.Блейк хезмәтләре). П. — Россиядә матем. логика һәм аның ихтималлык теориясендә кулланылышы турында лекцияләр укыган беренче галим.

Х е з м.: О способах решения логических равенств и об обратном способе математической логики // Собр. протоколов заседаний секции физ.-матем. наук Об-ва естествоиспытателей при Казан. Имп. ун-те. 1884. Т. 2; Решение общей задачи теории вероятностей при помощи математической логики // Собр. протоколов заседаний секции физ.-матем. наук Об-ва естествоиспытателей при Казан. Имп. ун-те. 1887. Т. 5.

**ПОРТНО́В** Григорий Андреевич (27.2.1923, Арча кантоны Самосырово а. — 23.12.1985, Казан), Дан орденының тулы кавалеры (29.1.1944, 9.8.1944, 27.6.1945), сержант. Казанда кирпеч з-дында газ б-н эретеп ябыштыручы булып эшли. 1943 елдан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 379 нчы укчы дивизиянең 1257 нче укчы полкы укчы отделение командиры (6 нчы гв. һәм 3 нче удар армияләр), 245 нче укчы дивизиянең 901 нче укчы полкы разведчигы (59 нчы армия). 2 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Невель (1943) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 19 гыйнварында мөһим биеклек (Невель р-ны) өчен барган сугышта (дошман уты астында вестовой сыйфатында пехота б-н батальон командиры арасында даими элемтә тота; сугышның хәлиткеч мизгелендә, пулемёты б-н алга ыргылып, дошманның 5 солдатын юк итә); 1944 нең 15 июлендә Янчево (Псков өлкәсе Себеж р-ны) авылы янындагы сугышта (автоматтан дистәләгән солдат һәм офицерны атып үтерә, мотоциклистны әсир төшереп, пулемётын ала); 1945 нең 5 мартында Козель шәһәреннән (Польша) көньяктарак разведка операциясендә (эзләү төркеме составында дошман ягына үтеп, 5 солдатны юк итә, берсен әсир ала) батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә. Казанда икмәк з-дында газ б-н эретеп ябыштыручы булып эшли. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



А.Е. Порай-Кошиц.



Г.А. Портнов.

*Әд.:* Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПОРТОЛА́Н** (портулан), навигацион компаслар картасы (13–16 йөзләр). Урта диңгез буенда 13 йөзнең 2 нче яртысында («Пиза картасы»), кайбер мәгълүматлар буенча, тагын да элегрәк барлыкка килә; мифологик сыйфатларга ия монастырь карталарыннан аермалы буларак, картография үсешендә яңа этап булып тора. П.да сызыклы масштаблар һәм компаслар челтәре бирелә. «П.» атамасы фәнгә 19 йөз уртасында, компаслар картасын 16–17 йөзләргә караган соңгырак карталардан аеру өчен кертелә. П.да яр буе терр-ясе, сирәк кенә материк өлеше җентекләп сурәтләнә. П.ның төгәллеге якынча була, чөнки авторлар җирнең шар рәвешендә булуын исәпкә алмыйлар һәм картографик проекциядән файдаланмыйлар. П.га кертелә торган мәгълүматлар, аеруча материк җирләренә кагылышлылары, еш кына геогр. традицияләргә нигезләнә. Алтын Урда һәм татар ханлык-

лары тарихы өчен П.Весконте (1311, 1318), Әбел-Фида (14 йөзнең 30 нчы еллары) портоланнары, бертуган *Пициганолар портоланы* (1367), Абрахам Крескның Каталан атласы (1375), П.Пасквалини (1408), *Фра-Мауро* (1460) портоланнары һ.б. кызыксыну уята. П.да Алтын Урда шәһәрләренең исемнәре сакланып калган, аларны билгеләү өчен Җүчиләр тамгасы кулланылган. П.нар картография үсешендә әһәмиятле роль уйный.

*Әд.:* Магидович И.П., Магидович В.И. Очерки по истории географических открытий. М., 1982. Т. 1; Постников А.В. Развитие картографии и вопросы использования старых карт. М., 1985; Фоменко И.К. Образ мира на старинных портоланах: Причерноморье. Конец XIII–XVII в. М., 2007.

*И.Л.Измайлов.*

**ПОРТРЕ́Т**, сынлы сәнгатьтә, башлыча, билгеле кешенең сурәтен тасвирлауга багышланган нәкышь, графика, скульптура жанрларының берсе, ш.у. асылда әлеге жанрда башкарылган әсәр. П. сәнгате Борынгы заманда ук сәнгать камиллегенә ирешә (Мисыр, Греция, Рим); 17 йөздән башлап әлеге жанр Европа сәнгатендә, ш.и. Россиядә актив үсештә була. 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең башында Казанда эшләгән портретчы рәссамнар — Ф.И.Чекиев (Казан гимназиясендә рәсем дәресе укыта, портрет классы буенча СА тәмамлый) һәм Г.Никитин (Казанга император Екатерина II килүе хөрмәтенә аның портреты б-н берничә «үтә күренмәле картина» иҗат итә) турында мәгълүмат сакланган. П. жанры өлкәсендә Казан җәмгыятенең барлык танылган вәкилләренең диярлек галереясын төзегән Л.Д.*Крюков* эшчәнлеге аеруча уңышлы була. 19 йөзнең 2 нче яртысында П. сәнгате нәкышьчеләр И.И.Журавлёв, Ф.П.Травкин, Л.О.Сиклер иҗатында «сәйяр күргәзмәләр» реализмы юнәлешендә үсә.

П. сәнгате үсешендә 1895 тә ачылган Казан сәнгать мәктәбе эшчәнлеге алга этәрүче көч булып әверелә. Анда портрет сәнгате күнекмәләрен үзләштерү укыту программасының аерылгысыз өлеше була. П. жанрында мәктәпнең күп кенә укытучылары — нәкышьче Г.А.Медведев, сынчы В.С.Богатырёв, график Ю.И.Тиссен уңышлы эшли; аларның иҗаты тирән эзләнүләр һәм импрессионистик алымнар б-н баетылган сәйяр күргәзмәләр кысаларына сыеп бетә. 20 йөз башында П. жанрының иң югары казанышлары, Казан б-н бергә Россия сәнгатендә дә, Н.И.Фешин исеме б-н бәйле. П.П.Беньков П.ларының композиция төзелешенә иҗат дөньясына хас табигый ирек, образның психологик эшләнешенә игътибар итү хас. Н.М.Сапожникова иҗаты рәсемнәрендәге нәкышь культурасы һәм нечкә хисле психологик образлары б-н истә кала. 1920 еллар сәнгатендәге символизм һәм экспрессионизмнан кубофутуризмга кадәрге стилистик юнәлешләрнең бөтен спектры «*Подсолнечник*» һәм «*Всадник*» берләшмәләре әгъзалары, нәкышьчеләр һәм графиклар К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова, Н.И.Михайлов (Н.Диомиди), И.Н.Плещинский, В.Э.Вильковиская, М.В.Барашова һ.б.ның портрет иҗатында чагылыш таба. Классик композиторларның үзенчәлекле тарихи П.лары сериясен Б.М.Столбов графикада иҗат итә. 1920 елларда Б.И.Урманче әсәрләренең көчле нәкышь дәрте б-н сугарылуы билгеләп үтелә, аның иҗаты соңрак нәкышь, графика, скульптур П. үсешендә тулы бер чор тәшкил итә.

1930–50 еллар — П. сәнгатендә соц. реализм стиле урнашу чоры — П. образларының шәхси сыйфат-холык аерымлыкларын шомартуда һәм типологик сыйфатларны көчәйтүдә күренә, Ю.А.Ананьев, Д.П.Архипов, Д.Г.Булат, Г.В.Житков, Э.Г.Липкинд, Г.Д.Мелентьев, И.Н.Овчинников, А.А.Прытков, Е.А.Симбирин, В.К.Тимофеев, скульпторлар Н.Я.Васильев, И.А.Новосёлов иҗатларында чагылыш таба. П. жанрына тугрылыклы рәссамнарның берсе — үз иҗатында рус реалистик П.ының иң яхшы традицияләрен үстерүче С.А.Ротницкий була. Бөек Ватан сугышында катнашучыларның портретлар галереясын үзләренең фронт рәсемнәрендә Д.Г.Булат, Х.Г.Якупов, А.М.Родионов гәүдәләндерә.

20 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, П. сәнгате совет югары уку йортларында һөнәри белем алган рәссамнарның әсәрләренә хас булган яңа күренешләр б-н байый (А.Ә.Абызгилдин, З.Ф.Гыймаев, И.К.Зарипов, Р.Ф.Имашев, Б.И.Майоров, И.В.Рәфыйков, В.Н.Скобеев, В.К.Фёдоров һ.б.; графиклар Э.Я.Зарипов, С.М.Кульбака, И.К.Колмогорцева, В.В.Карамышев, Ю.Б.Лысогорский, Э.Г.Ситдыйков; скульпторлар Н.И.Гаделев, Ә.К.Бәширов, Г.А.Зяблицев, Р.Х.Нигъмәтуллина, В.И.Рогожин һ.б.). Алар иҗатында П. сәнгатенең тематик, социаль, яшь диапазоннары киңәя, әлеге жанрдагы әсәрләрнең саны күләм ягыннан арта. Замандашларның: фән, мәдәният, сәнгать эшлеклеләренең; җитештерү алдынгылары һәм төрле һөнәр ияләре: төзүчеләр, нефтьчеләр, колхозчыларның киң П. галереясы барлыкка килә. П.ның төр диапазоны киңәя: төрле халәттәге һәм эшчәнлек тørендәге — уку, язу вакытында һ.б. лирик натура этюдлары; пейзаж-жанр үрнәкләре элементлары булган героик-романтик композицияләр, эре форматлы күп фигуралы картиналар; графикада күренекле мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә, тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләрнең тематик цикллары үсеш ала. Әлеге чор П.ларын «кырыс стиль» дип аталган стилистикага хас гомуми сыйфатлар берләштерә, ул да булса, образның кискенлеген һәм эчке динамикасын, колоритлы киеренкелеген эзләү. Рәссамнарның П. жанрындагы традицион чикләрне киңәйтергә омтылулары катнаш жанр — көнкүреш П.ы һәм натюрморт элементлары булган пейзаж П.ы кушылган картиналар иҗат итүгә китерә. 20 йөзнең 2 нче яртысы П. сәнгатендә татар мәдәнияте һәм сәнгатенең танылган эшлеклеләре портретларының күләмле галереясын төзегән Бакый Урманче иҗаты аерым урын алып тора.

20–21 йөзләр чигендә социаль әһәмиятле П.лардан чигенү, ягъни портретка алынучының гомумкешелек сыйфатларын матурайтып күрсәтүдән һәм сәнгатьле сурәтләү чараларын тамырдан үзгәртүдән гыйбарәт тенденция өстенлек итә. П.тагы образ поставангард алымнары (шартлылык, декоративлык, стильләштерү, нәфис гипербола һ.б.) б-н гәүдәләндерелгән, вакыт чикләрен белмәүче, тарихи, фәлсәфи-әхлакый, этномилли картиналарның тагын да киңрәк контекстын тәшкил итүче образлы эчтәлек өлешләренең берсе булып тора.

*Әд.:* Червонная С.М. Искусство Советской Татарии: Живопись, скульптура, графика. М., 1978; шул ук. Искусство Татарии: История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 г. М., 1987; Файнберг А.Б. Художники Татарии. Л., 1983.

*Е.П.Ключевская.*


**ПОРУДОМИ́НСКИЙ** (Майримович) Илья Миронович (11.6.1890, Вильно ш., хәзер Вильнюс — 24.3.1968, Мәскәү), уролог, дерматовенеролог, мед. фән. д-ры (1936), проф. (1939). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1916), Новосибирск тире-венерология хастаханәсе табибе. 1922 елдан Үзәк тире-венерология ин-тында (Мәскәү), 1940–66 да урология бүлеге мөдире. Бер үк вакытта Үзәк табибләр белемен күтәрү ин-тында (Мәскәү). СССРда тире-венерология диспансерларына нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре ир-атлардагы җенси тайпылышларны, ир-атлар үрчемсезлеген тикшерүгә, гонорея авырулары һәм гонореяга бәйле авырулар этиологиясе һәм патогенезына карый.




Хезм.: Патологическая анатомия мужской гонореи // Советский вестн. венерологии и дерматологии. 1935. № 4 (автордаш); Гонорея. М., 1948; Гистологические изменения в семявыводящем протоке клинически здоровой стороны при одностороннем туберкулёзе органов мошонки // Урология. 1960. № 1.


*Әд.:* Памяти И.М.Порудоминского // Урология и нефрология. 1968. № 4.

**ПОРУ́ЧИК** авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 6 *км* көньяктарак, Сәрәпәле елгасы буенда. 2010 елда 448 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 53%, руслар — 42%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 1840–60 та П. янында Александр бакыр коюз-ды эшли. 20 йөз башында Богородский чиркәве (1833 тә төзелә), земство мәктәбе була. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 692 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1858 дә — 277, 1913 тә — 393, 1920 дә — 593, 1926 да — 653, 1938 дә — 621, 1949 да — 455, 1958 дә — 431, 1970 тә — 320, 1979 да — 180, 1989 да — 281, 2002 дә — 409 кеше.

*Әд.:* Заинская энциклопедия. К., 1994.



















**Портрет.** 1. Л.Д. К р ю к о в. «В.П.Молоствов портреты». Акварель. 1820. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. К.Ф. Г у н. «В.А. Лобачевская портреты». 1864. ТР Милли музее; 3. М.Л. Д и м л о н г. «Н.И. Лобачевский портреты». 1896. Казан университеты тарихы музее; 4. Н.И. Ф е ш и н. «Наталья Николаевна Кротова портреты». 1923. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 5. А.Г. П л а т у н о в а. «К.К. Чеботарёв портреты». Кәгазь. Күмер. 1927 елга кадәр. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. И.Н. П л е щ и н с к и й. «Рәссам Семён Козлов портреты». Акварель. 1920 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 7. Б.И. У р м а н ч е. «Сары күлмәкле кыз». 1929. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. Б.И. У р м а н ч е. «Язучы Г.Ибраһимов». Бронза, бетон. 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 9. Х.Г. Я к у п о в. «Советлар Союзы герое М.П. Девятаев портреты». 1971. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Р.Ф. И м а ш е в. «Маляр Р.Рәфыйкова портреты». 1973. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 11. Е.А.С и м б и р и н. С.Сәйдәшев портреты. 1978. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. И.В. Р ә ф ы й к о в. «Журнал укучы ана портреты». 1984; 13. В.К. Ф ё д о р о в. «Д.Х.Бакыева портреты». 1990 еллар; 14. И.К. З а р и п о в. «Улын тоткан Сөембикә». 1990. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 15. И.В. Р о г о ж и н а. «Фёдор Шаляпин». Һәйкәл эскизы. Гипс. 1997; 16. И.А. Х ә с ә н о в. «Кыз һәм шәһәр». 2004.

**ПОРФИ́РОВКА** авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 18 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да Рождество чиркәве, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 4 җил тегермәне, 2 тимерчелек, май язу һәм йон тетү йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 256 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Өчкүл волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас (1935 нең 1 апреленнән 1991 нең 4 октябренә кадәр — Куйбышев) р-нында. 2001 нең 27 июнендә торак пунктлар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1859 да — 568, 1897 дә — 801, 1908 дә — 885, 1920 дә — 1125, 1926 да — 983, 1938 дә — 521, 1949 да — 350, 1958 дә — 297, 1970 тә — 253, 1979 да — 106, 1989 да — 1 кеше.

**ПОРФИ́РЬЕВ** Вассиан Сергеевич (10.12.1907, Мәскәү — 22.2.1990, Казан), геоботаник, биол. фән. д-ры (1970), проф. (1974). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), ТАССР болыннарын инвентаризацияләү, Алабуга урманчылыгында геоботаник һәм типологик тикшеренүләр, Урал өлкәсенең кыр-чүп үсемлекләре, урман һәм терлек азыгы үстерелгән районнар буенча экспедицияләрдә катнаша. 1933 елдан ТАССР Җир эшләре халык комис-тының җир төзү һәм мелиорация бүлегендә геоботаника отряды башлыгы. 1935 тән Казан пед. ин-тында, 1970 тән Казан ун-тының табигатьне саклау каф. профессоры. Хезмәтләре Урта Идел буенең, Идел-Кама саклаулыгының ылыслы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарындагы үсемлек бергәлекләре төзелешенә карый. П. урман типологиясенең топоценотик берәмлекләре системасын эшли, респ-ка болыннарының картасын төзүдә, Куйбышев сусаклагычы төзелешенә бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнаша. Идел-Кама саклаулыгын оештыруны башлап йөрүче. Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан районнарында үсемлекләрне оборона чималы буларак тикшерү б-н шөгыльләнә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Елово-широколиственные леса Раифы // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1961. Т. 64; Ботанические, лесоводственные и зоологические исследования на территории Волжско-Камского государственного заповедника // Тр. Волжско-Камского гос. заповедника. К., 1968. Вып. 1 (автордаш); Темнохвойно-широколиственные леса Волжско-Камского края. Л., 1970.

**ПОРФИ́РЬЕВ** Иван Яковлевич (23.9.1823, Вятка губ., Уржум өязе Атар а. — 26.10.1890, Казан), филолог, христиан теологы, теология д-ры (1873). Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1873), хакыйкый статский советник (1880). Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1848), шунда ук эшли: укытучы, 1859 елдан әдәбият каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1855–58 дә, Соловки монастыре тарафыннан академиягә тапшырылган китапханәдә, 1858–62 дә академия китапханәсендә эшли; 1870–82 дә ректор ярдәмчесе; 1862–72 дә Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында әдәбият укытучысы. Казанда *Дүртенче археология съездында* катнаша (1877). П. Соловки монастыре китапханәсендәге күпчелеге үзе тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелгән кульъязмаларны тикшерә һәм сурәтли («Православный собеседник» ж-лында бастыра). Рухани һәм дөньяви уку йортларында дәреслек сыйфатында файдаланылган «Рус әдәбияты тарихы» («История русской словесности», 1 кис., 1870; 2 кис. өч бүлектә, 1880–91) хезмәте авторы.

Х е з м.: Апокрифические сказания о ветхозаветных лицах и событиях. К., 1873; Апокрифические сказания о новозаветных лицах и событиях по рукописям Соловецкой библиотеки. СПб., 1890.

*Әд.:* Иван Яковлевич Порфирьев: Биогр. очерк. К., 1891; Воспоминания И.Я.Порфирьева, профессора русской словесности Казанской духовной академии // Православный собеседник. 2005. № 2.

**ПОРФИ́РЬЕВ АКЧЫРШЫЛЫГЫ́**, ландшафтлы табигать истәлеге. Мамадыш р-ны терр-ясендә Түбән Арбаш авылыннан төньяк-көнчыгыштарак Баш-Арбаш елгасы (Шыя елгасының сул кушылдыгы) үзәненең сульяк сөзәклегендә һәм субүләр платода урнашкан көньяк-тайга тибындагы урман массивы (Саба урманчылыгы Мишәбаш участок урманчылыгының 371 нче кварталы). 1972 елда билгеләнә. Мәйданы 138 *га*. Рельефы



Порфирьев акчыршылыгы.

нык ергаланган, өслеге Пермь чоры карбонат токымнарыннан тора. Калкулыклы участокларда мөстәкыйль бергәлекләр (тайга урманы өчен сирәк күренеш) барлыкка китерүче Себер ак чыршысы зур урын алган. Берән-сәрән генә чыршы, усак очрый. Ярлы туфраклы ерым битләрендә, нигездә, урман массивының төньяк өлешендә наратлыклар, көнчыгышта гумуслы туфракта чыршы һәм ак чыршы катнаш юкәлекләр таралган. Барлык тип урманнарның үлән капламында көньяк-тайга төрләре: тамырчалы күрән, гади кымызлык үсә.

**ПОРФИ́РЬЕВА** (Әхмәтова) Резидә Тимерхан кызы (13.12.1961, Бондюг штп, хәзер Менделеев ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2006). 1979–83 елларда — Л.Я.Карпов исем. химия з-дында (Менделеев ш.), Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), «Минераль ашламалар» ЖБдә (Мәскәү өлкәсенең Воскресенск ш.) эшли. 1988 дән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, 2004 тән Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре органофосфат кушылмаларга һәм аларга нигезләнгән материаллар технологиясенә карый. П. композицион төзелеш материаллары, авиация төзелеше өчен кызуга чыдам капламнар һ.б.ны җитештергәндә элементларның периодик системасындагы 1 нче һәм 2 нче төркем металларының глицерофосфатларын куллану юлларын тәкъдим итә һәм технологияләрен эшли. Нефть-газ комплексы күкертен полисульфидлар һәм алар нигезендә композицион материаллар алу өчен кабат эшкәртүнең калдыксыз диярлек экологик чиста технологияләрен фәнни яктан нигезли. Күкерт катнашкан системаларда компонентларның үзара тәэсир итешү механизмын ачыклау, ш.у. күкертле чималны эшкәртү технологияләрендә газлар хасил булуны минимальләштерү юлларын билгеләү өчен квант химиясе алымнарын эшли. Терлек азыгын силослау өчен баеткыч консервантлар таба һәм тикшерә. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре юллар төзелешендә һәм а.х.нда гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар.

Х е з м.: Химическая технология неорганических веществ: В 2 кн. М., 2002 (автордаш); Малоотходные технологии переработки серы в сульфиды и полисульфиды. К., 2007 (автордаш).

**ПОРШУ́Р** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 262 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1710–11 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире иләү һәм тегүчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 662,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дә — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 99 ир-ат; 1859 да — 279, 1897 дә — 439, 1908 дә — 471, 1920 дә — 503, 1926 да — 528, 1938 дә — 428, 1949 да — 332, 1958 дә — 266, 1970 тә — 234, 1979 да — 208, 1989 да — 227, 2002 дә — 271 кеше.

**ПОСЕССИО́Н КРӘСТИЯННӘ́Р**, 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында посессион мануфактураларга — дәүләт тарафыннан шәхси затларга шартлы биләмә рәвешендә бирелгән предприятиеләргә беркетелгән крепостнойлар. П.к. аларга эшлиләр һәм үз хуҗаларына хезмәт күрсәтәләр. П.к. пр-тиедән аерым гына сатыла алмый, аларны аннан аерып булмый. Беренче булып кешеләрне сәнәгать ихтыяҗлары өчен сатып алу дворян булмаган катлау вәкилләре тарафыннан 1721 елда рөхсәт ителә. 1736 ел 7 гыйнвар Фәрманы б-н һөнәргә өйрәтелгән барлык хезмәт куючылар халык исәбен алган вакытта эшләгән пр-тиесенә гомерлеккә беркетелә. П.к. юридик яктан алпавыт крепостнойларыннан беркадәр аерылалар: аларны авыл хуҗалыгы эшләренә күчерү, крепостнойлар урынына рекрутлыкка бирү тыела, алар Берг- һәм Мануфактур-коллегияләргә гозернамәләр бирә алганнар, шул коллегияләр хөкемендә булганнар. Казан губернасында П.к.нең төп өлеше *Казан постау мануфактурасына* туры

килә: 1725 тә — 587 кеше, 1797 дә — 1247. 1849 да азат ителәләр (мещаннар булып язылалар). Ш.у.к. *Казан постаучылары чуалышлары*.

*Әд.:* Удинцов В. Посессионное право. Киев, 1896; Панкратова А.М. Формирование пролетариата в России. М., 1963.

*Р.Р.Хәйретдинов.*

**ПОСО́ХИН** Владимир Николаевич (7.1.1940, Сталинград ш., хәзер Волгоград ш.), җылылык технигы, техник фән. д-ры (1985), проф. (1988), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), Казан архит.-төзелеш ун-тының атказ. профессоры (2005). 1960 елда Сталинград шәһәр хуҗалыгы инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Иркутск политехник ин-тында эшли. 1963–66 да Санитария техникасы фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1966 дан Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, газ-җылылык тәэминаты һәм вентиляция каф. мөдире (1967–77 һәм 1987 дән). Хезмәтләре җылыту-вентиляция системалары гидромеханикасы мәсьәләләренә карый. П. җылылык һәм газ җиһазларыннан вентиляцион суыртуларны исәпләү теориясен тәкъдим итә (тикшеренү нәтиҗәләре вентиляцион суырту җайланмаларын конструкцияләү һәм исәпләү гамәленә кертелгән). Изотермик булмаган агымнар теориясен үстерүгә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы һәм патентлары бар. Югары уку йортлары арасындагы «Җылылык-вентиляция җайланмалары гидромеханикасы» («Гидромеханика отопительно-вентиляционных устройств») фәнни хезмәтләр җыентыгының җаваплы мөхәррире (1982–95).

Хезм.: Расчёт местных отсосов от тепло- и газовыделяющего оборудования. М., 1984; Местные отсосы // Вентиляция и кондиционирование воздуха: Справ. проектировщика. М., 1998. Кн. 1 (автордаш); Проектирование аппаратов газоочистки. М., 1998 (автордаш).

**ПОСПЕ́ЛОВ** Георгий Александрович (26.11.1926, Пятигорск ш. — 27.9.1993, Казан), компрессорлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1973), проф. (1974). 1948 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Урал химия машиналары з-дында эшли (Свердловск ш.). 1951 дән Казан компрессорлар з-дында. 1956–62 дә Казан авиация ин-тында укыта. 1962–93 тә Казан технол. ун-тында, компрессор машиналары һәм җайланмалары кафедрасын оештыра һәм җитәкли (1963–82). Хезмәтләре машиналар динамикасына, газ, сыеклык, каты һәм эластик җисемнәрнең гомуми һәм махсус механикасына карый. П. компрессор машиналарда гидрогазодинамик процессларны тикшерә. Турбокомпрессорларда роторларның бөгелеп тирбәнүләренең критик ешлыкларын һәм хәрәкәт тотрыклылыгын исәпләү алымнарын, үзәктән куулы компрессорларда күчәр көчләрен билгеләү методикасын эшли. Техникада, аерым алганда, космик техникада киң куллану тапкан («Восток» һәм «Восход» серияләрендә) газ б-н майлаулы подшипниклар конструкциясен тәкъдим итә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Динамика и прочность турбокомпрессорных машин: В 2 ч. М., 1977–79 (автордаш); Руководство по курсовому и дипломному проектированию по холодильным и компрессорным машинам. М., 1986 (автордаш); Объёмные компрессоры: Атлас конструкций. М., 1994 (автордаш).

**ПОСПЕ́ЛОВО** авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 576 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 52%, татарлар — 41%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1652 дән мәгълүм. Беренче исеме — Заборный. Халкы игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятский волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1905 тә — 941, 1920 дә — 566, 1926 да — 621, 1938 дә — 589, 1949 да — 257, 1958 дә — 232, 1970 тә — 210, 1979 да — 463, 1989 да — 516, 2002 дә — 552 кеше.

**ПОСТА́У**, к. *Тула*.

**ПОСТА́У ТУКУ́ СӘНӘГАТЕ́**, Казан губернасында. 1881 елга кадәр Казан постау мануфактурасы (1714 тә нигезләнә) яшәп килә. 20 йөз башында Казан өязенең Колсәет авылында С.С.Гобәйдуллинның (326 эшче) һәм Казанда И.В.Чернышёвның постау ф-калары эшли. Төп эшләнмәләре — тукымалар. Ш.у.к. *Иске Тимошкино постау мануфактурасы*.

*Әд.:* Фабрично-заводские предприятия Российской империи. СПб., 1909.

**ПОСТАУЧЫЛА́Р БИСТӘСЕ́**, 18 йөзнең 1 нче яртысында Казанның көньяк-көнчыгыш өлешендә *Казан постау мануфактурасы* тирәсендә барлыкка килгән торулык. 1796 елда бистәдә 628, 1831 дә 413 постаучы йорты исәпләнә. 1897 дә халык саны 7361 кеше тәшкил итә. П.б.ндә Күпер урамы, Тар урам, Лаврентьев, Соколов урамнары һ.б. була. П.б. тасвирламаларының берсе В.Невельскийның «Казанның аулак урыннары һәм ярлы кварталлары» («Казанские захолустья и трущобы», 1867) китабында сакланган, анда «туры булмаган, түшәлмәгән, чүп-чар б-н тулган урамнар», «коймалы тыкрыклар», «бик кечкенә йортлар», «утынлы ишегаллары» турында бәян ителә. 19 йөз ахырында тарихчы М.Н.Пинегин Казанның кайбер бистәләре, ш.и. П.б. «...бөтенләй шәһәр белән кушылдылар» дип билгеләп уза. 1736 да бистәдә яшәгән постаучылар пр-тиегә беркетеләләр һәм аның хакимиятенә буйсыналар. Хокуксызлык һәм һөнәри мәнфәгатьләрнең чикләнүе (озын эш көне, түбән хезмәт хакы һ.б.) 18 йөздә — 19 йөзнең беренче яртысында постаучылар чыгышларына китерә (к. *Казан постаучылары чуалышлары*). Н.П.Загоскин сүзләренә караганда, постаучылар «искиткеч ирек сөючәнлек» б-н аерылып торалар. Кискен көрәштән соң алар 1849 да ирек алалар, постаучыларның зур өлеше — мещан, башкалары дәүләт крәстияннәре катлауларына күчәләр. П.б. тарихы б-н кайбер күренекле кешеләрнең, ш.и. Ф.И.*Шаляпин* тормышы бәйле. 1833 тә бистәдә Е.И.Пугачёв кузгалышы тарихы буенча китап язу өчен материал җыярга килгән А.С.Пушкин булып китә. Хәзер П.б. — Петербург, Спартак, Луковский, Павлюхин урамнары р-ны.

*Әд.:* Бессонова Т.В. Казанская Суконная слобода в XVII - первой половине XIX вв. Наб.Челны, 2000; Бикбулатов Р., Мустафин Р. Казань и её слободы. К., 2001.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ПОСТМОДЕРНИ́ЗМ** (лат. post — соңыннан һәм франц. modenus — өр-яңа, заманча), 20 йөзнең 2 нче яртысы — 21 йөз башында *модернизмга* алмашка килгән сәнгать стиле. 1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында абстракт экспрессионизм һәм поп-арт контекстында формалаша башлый. П.ның аерылып торган төп сыйфаты — прогресс идеясеннән баш тарту; аңа диалогизм, эклектизм, фрагментарлык хас. П. агымнарына — концептуальлек, минимальлек, трансавангардлык, гиперреализм, лэнд-арт һ.б.; сурәтләү чаралары категорияләренә — метафора, парадокс, ирония, уен; аеруча еш кулланылучы алымнарга — икеле кодлаштыру, дискрет коллаж, өземтәлек, пастиш, палимпсест керә. П. стилендәге әсәрләрнең төп үзенчәлеген чиге булмаган сәнгати һәм мәдәни контекст б-н бәйләнешне ассызыклап күрсәтүче һәм классик сәнгатьтә сәнгати образ урынын алып



Е.Г.Голубцов. «Алдалык». Агач, майлы буяу. 1994. «Mia Joosten» галереясы. Амстердам, Нидерланд.

торучы «симулякр» — чынбарлыкта булмаган образ тәшкил итә. 1950 еллар ахырында — 1960 еллар башында П. сәнгатендә перформанс һәм хеппенинг кебек формалар барлыкка килә, аларда визуаль башлангыч процессуальлек б-н алышына, образ ишарә ярдәмендә гәүдәләндерелә һәм вакыйга статусын ала. Яңа технологияләр үсеше, техник чаралар мөмкинлеге 1970 еллар башында видеоартны китереп чыгара. П.га интерактивлык категориясе (1980–90 елларда виртуаль чынбарлык йогынтысында үсеш ала), ягъни тамашачы һәм әсәр бәйләнешенең классик булмаган тибы хас. Интерактив әсәрләр барлыкка килүгә нәфис мәгълүмат тапшыруның төрле ысуллары үсеше: телевидение, гиперәдәбият, компьютер уеннары һ.б. ярдәм итә. Татарстан сәнгатендә П. стилистикасының ачыктан-ачык билгеләре 1990 еллар башында Казан нәкышьчеләре Е.Голубцов, А.Дорофеев, В.Нестеренко, А.Артамонов, И.Хә-





1. А.А.А р т а м о н о в. «Язны чакыручы балалар». 1996. «Vorm-en-Beeld» галереясы. Нидерланд, Зутфен ш.; 2. И.И.Х ә с ә н о в. «Балачак метафизикасы». Велосипед, манекен (папье-маше), манометр. 2005.

сәнов, И.Гыймранов, О.Иванов, В.Харисов, Н.Бенинг, Ә.*Ильясова*, В.Тимофеев, А.Бусыгин, Р.Салихов һ.б. иҗатында күренә башлый. Башкортстанда яшәүче татар рәссамнары, аеруча «Чыңгызхан» берләшмәсенең Уфа вәкилләре (Н.*Лотфуллин*, Н.*Байбурин*, Р.*Харисов*, В.*Ханнанов* һ.б.) П. үсешенә көчле агым булып керә. П.ның коллаж һәм күчермә бирү кебек алымнары һәм чаралары — Е.Г.Голубцов, симулякр образ — А.Артамонов, ирония — Р.Харисов, борынгы кулъязмалар техникасын хәтерләтүче палимпсест А.*Терегулов* иҗатында чагыла.

Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә видеоарт барлыкка килү («Фортепианода уйнаучы Телевизор» видеоинсталляциясе, 1975; «Электрон рәссам», 1976; «Юеш чүпрәк өстендә электрон малай», 1991 һ.б.) *«Прометей»* эксперименталь эстетика фәнни-тикшеренү ин-ты эшчәнлеге (җитәкчесе Б.М.Галиев) б-н бәйле. Рәссамнар ш.у. П.ның 1990 елларның 1 нче яртысында барлыкка килгән өр-яңа формаларына — объектка һәм инсталляциягә мөрәҗәгать итәләр («Прометей»ның «Әзер бул — һәрвакыт әзер!», 1993; «Якты күңелле кешеләрнең якты акыллары», 1994 һ.б. хезмәтләре). 1990 еллар ахыры — 2000 еллар башында объект, П. юнәлеше буларак, И.Хәсәнов (Казан); Ш.Фәрхетдинов (Кама Аланы штп); Р.Гаитов, В.Ханнанов, Р.Миңнебаев (Уфа) иҗатларында дадаизм, поп-арт һәм концептуализм традицияләренә таяна.

«Чыңгызхан» рәссамнар берләшмәсенең театральләшкән этник перформанслары П.ның процессуаль сәнгать дип аталучы төбәк юнәлеше үсешенә йогынты ясыйлар. Рәссамнар, интерактивлык алымын кулланып һәм тамашачыны эш процессына җәлеп итеп, Алтын Урданың рухи-фәзаи образын тудыралар («Алтын Пайцза», 2002; «Нурлы арба», 2005 перформанслары һ.б.), төрки-татар тарихының йола һәм символларын яңадан җанландырып җибәрәләр. П.ның этник төбәк феномены рәссамнарның татар халкына һәм мөселман сәнгатенә хас архаик борынгылык теленә, фольклор традицияләренә, героик тарих темасына, әдәби тел һәм символик образлылыкка тугрылык саклауга нигезләнгән.

Татарстан рәссамнарының П. әсәрләре «Яктылык һәм тавыш» (1987, Казан) Бөтенроссия күргәзмәсендә, «Скрябин көннәре» фестивале кысаларында «Мульти-медиа» (1990, Казан консерваториясе), «Яңа сәнгать: кичә, бүген, иртәгә» (1993, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее) күргәзмәләрендә катнаша; аларның күпчелеге ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» Милли мәдәният үзәгендә, Аппелдорн шәһәрендәге (Нидерланд) сынлы сәнгать музеенда, «Mia Joosten» (Амстердам, Нидерланд), «Vorm-en-Beeld» (Зутфен ш., Нидерланд), «Studio 21» (Галифакс ш., Канада), «Dar» (Цюрих, Швейцария); Россия һәм чит илләрдәге шәхси коллекцияләрдә саклана.

*Әд.:* Г а л е е в Б.М. Искусство космического века: Избр. статьи. К., 2002; Ф а й з р а х м а н о в а Г.Р. Постмодернизм в изобразительном искусстве Башкортостана и Татарстана // Изв. Уральского ун-та. Сер. 2. Гуманитарные науки. 2006. № 47, вып. 12; А н д р е е в а Е. Постмодернизм: Искусство второй половины XX — начала XXI века. СПб., 2007.

*Г.Р.Фәйзрахманова.*

**ПО́СТНИК** Иван Яковлевич (16 йөз), рус архитекторы. Мәскәүдәге Василий Блаженный храмын төзүче (1555–61, Барма б-н берлектә). Иван Ширяй б-н бергә Казан Кремле диварларын һәм манараларын (1556–62), *Благовещение кафедраль соборын* (1562), Зөя шәһәрендәге Успение ирләр монастырендa Успение соборын (1560) төзи. Барма б-н П. бер үк кеше дигән фараз да бар.

**ПО́СТНИКОВ ПҮЧИНКӘСЕ́** посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Консар елгасы буенда. 2010 елда 14 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1875 тә Кукмара авылыннан күченүчеләр нигез сала. Игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 144,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1897 дә — 141, 1908 дә — 137, 1920 дә — 91, 1926 да — 98, 1949 да — 207, 1958 дә — 122, 1970 тә — 34, 1979 да — 25, 1989 да — 8, 2002 дә — 23 кеше.

**ПО́СТНИКОВ** Фёдор Егорович (1806 — 27.6.1881, Казан), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, нәселдән күчмә мактаулы граждан, хәйрияче. Сәүдә йортында ситсы сату б-н шөгыльләнә. П.ның капиталы 400 мең сумга җитә. Болак буендагы таш йорт хуҗасы, аның сәүдә рәтләре Проломный урамы ягына карый. Сәүдә йортының чатыр манаралы чиркәвен торгызуга 80 мең сум (3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә), шәһәр гариплләр йорты өчен 64 мең сум һәм ике катлы таш йорт иганә кыла. П. васыяте буенча гарипләр йорты каршында 75 мең сумга гыйбадәтханә төзелә, 25 мең сум акча шуның ихтыяҗларына тапшырыла.

*Л.М.Свердлова.*

**ПОСТПЕТРОГРО́М КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Идел-Урал алды төбәгендә (якынча 10 йөз ахыры — 13 йөзнең беренче утызъеллыгы). Атамасы 10 йөз ахырында Урта Уралдан Урал-Идел буйларының урман-дала җирләренә күченгән кабиләләргә нисбәтле Петрогром культурасыннан алынган. П.к. ядкәрләре беренче тапкыр 1970 еллар ахырында Е.П.Казаков тарафыннан тасвирлана. П.к.ның мәдәни-тарихи комплексы охшашлык ягыннан Урта Урал археол. культураларына якын. Постпетрогром кабиләләре Урал угорларына карый. Монгол яулары алдыннан (1230 еллар) венгр сәяхәтчесе *Юлиан* постпетрогром угорларын Биләр шәһәреннән «ике көнлек юлда», ихтимал, Зәй елгасының түбән агымы буенда очрата. Шул вакытка аларның венгр теленә якын телләре саклана. Өйләрдә яшиләр, әмма җир эшкәртмиләр, терлекчелек б-н шөгыльләнәләр (мөгезле эре терлек һәм атлар өстенлек итә). Гадәттә, П.к. кабиләләре терлек көтү, балык тоту өчен уңайлы елга үзәннәрендә урнашканнар. Күпчелек очракта П.к.на сай чокырлы, өсләренә курган өелгән каберләр хас. Мәетләр күбесенчә баш б-н төньякка каратып җирләнгән, каберләргә сугыш кораллары һәм ат дирбияләре куелган. Керамика — йомры төпле, биек цилиндрик муенлы, тараксыман-шнур орнаменты б-н бизәлгән, әвәләп ясалган балчык савытлар. Балчык эшләнмәләрнең измәсенә төелгән кабырчык кушылган. Шундый савыт-саба Идел болгарларының барлык археол. истәлекләрендә диярлек табыла. Ш.у. болгар-постпетрогром керамикасының гибрид үрнәкләре дә очрый.



Постпетрогром культурасына караган керамика.

П.к. элементлары Чулман буе болгарларының 10–13 йөзләрдәге барлык торулыкларына хас. Татарстан терр-ясендә П.к. ядкәрләре Актаныш р-нының Татар Ямалы авылы, Мөслим р-нының Мәлләтамак авылы янында һ.б. урыннарда табыла.

*Әд.:* К а з а к о в Е.П. О происхождении и этнокультурной принадлежности памятников с гребенчато-шнуровой керамикой // Проблемы средневековой археологии Урала и Поволжья. Уфа, 1987; ш у л у к. Древняя страна «паскатир» // Татарстан. 1993. № 9.

*Е.П.Казаков.*

**ПОТА́НИН** Владимир Петрович (9.6.1946, Казан), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1999), ТРның атказ. табибе (1996). М.З.*Сигал* шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Апас үзәк р-н хастаханәсендә баш хирург булып эшли. 1972 елдан Тәтеш р-ны Олы Тархан участок хастаханәсе хирургы. 1975 тән Казан ГИДУВының хирургия һәм онкология кафедрасында. 1977 дән Респ-ка онкология диспансерында (2000 нән — Респ-ка онкология клиник диспансеры), 1981 дән торакаль бүлек, 1989 дан — үпкә һәм күкрәк куышлыгы хирургиясе бүлеге мөдире. ТР Онкологлар җәмгыяте (1990), Россия эндохирурглары җәмгыяте (1994) әгъзасы. Хезмәтләре үпкә, үңәч һәм ашказаны эндохирургиясенә, күкрәк куышлыгы һәм плеврадагы шешләргә; онкологик авыруларны озон б-н дәвалауга карый. П. тарафыннан плевра эчендәге кан китүләрне диагнозлау өчен торакопорт; урында таралган үзәк үпкә рагын диагнозлау өчен пневмомедиастинум ысулы; үпкә метастазаларын хирургик юл б-н дәвалау ысуллары тәкъдим ителә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хирургия рака желудка и пищевода. К., 1994; Опухоли гормонально-зависимых и гормонопродуцирующих органов. М., 2004.

**ПОТА́НИХА** авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 36 *км* төньяктарак, Ашыт елгасы буенда. 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ивановка, Үтәнеш исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, агач эше, күн эшкәртү, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Иоанн-Предтеча чиркәве (1738 дә сәүдәгәр И.А.*Михляев* акчасына төзелә), земство мәктәбе (1884 тә ачыла), вак кредит ширкәте, су тегермәне, аракы з-ды, сыра складлы, 1 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1454,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 556, 1897 дә — 654, 1908 дә — 875, 1920 дә — 756, 1926 да — 777, 1938 дә — 519, 1949 да — 472, 1958 дә — 303, 1970 тә — 208, 1989 да — 71, 2002 дә — 38 кеше.

**ПОТА́ПОВ** Василий Фёдорович (4.3.1955, Питрәч р-ны Шемёлка а.), спортчы (академик ишү), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1975). СССР Эчке эшләр министрлыгының С.М.Киров исем. Югары хәрби командирлар уч-щесен тәмамлый (Орджоникидзе ш., 1981). Спорт б-н 1972 елда «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советында шөгыльләнә башлый (тренеры В.И.Шабельникова, 1973 тән — В.Т.*Глухих*). СССР (1975–78) чемпионы, СССР халыклары спартакиадалары (1975) чемпионы; дөнья (1975, 1977 — көмеш), СССР (1974, бронза) чемпионатларында медальләр ала; 1976 да Олимпия уеннарында (7 нче урын, А-8 РсР) катнаша; СССР кубогы иясе (1974, А-4 РсР), СССР чемпионатында көмеш медаль ала (1981, А-2 РсР). 1973 тән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советында (1974–76 да ТАССР МС каршында Физик культура һәм спорт комитеты) физик культура буенча инструктор.

**ПОТА́ПОВ** Владимир Яковлевич (22.1.1947, Кайбыч р-ны Лесхоз пос.), генерал-полковник (1999). Казан танк уч-щесен (1967), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү, 1975), СССР Кораллы Көчләре Генштабының Хәрби академиясен (Мәскәү, 1988) тәмамлый. 1967 елдан Германиядә совет гаскәрләре төркемендә, 1967–70 тә взвод командиры, 1970–72 дә рота командиры. 1975–78 дә Сахалин утравында полк штабы башлыгы, 1978–80 дә мотоукчы дивизиядә полк командиры. 1980–81 дә Хабаровск краенда мотоукчы өйрәнү дивизиясе командиры урынбасары. Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә командир урынбасары (1980–84), дивизия командиры (1984–86). 1988–93 тә Ерак Көнчыгыш хәрби округының Уссурийск шәһәрендә урнашкан 5 нче гомумгаскәри армиясендә: 1988–91 дә штаб башлыгы, 1991–93 тә Төньяк Кавказ хәрби округы гаскәрләре командующие, 1997–98 дә РФ Президентының Дәүләт хәрби инспекциясе каршындагы Хәрби инспекторлар идарәсе башлыгы урынбасары, 1998–2003 тә РФ Куркынычсызлык Советы секретаре урынбасары, 2004–05 тә Каспий торба үткәргечләр консорциумы ген. директоры урынбасары. 2005 тән директорның 1 нче урынбасары, 2008 дән «Безопасность» тышкы сәүдә оешмасы Федераль ДУП директоры (Мәскәү). РФнең оборона сәләтен үстерү һәм ныгытуга өлеш керткәне өчен Г.К.Жуков исем. (2001), Бөек Пётр исем. бүләкләргә лаек була. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен», 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

**ПОТА́ПОВ** Геннадий Петрович (22.5.1937, Ижевск ш.), очкыч аппаратлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1986), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), химия автоматикасы КБнда эшли (Воронеж ш.), әйдәп баручы инженер (1963 елдан). 1965 тән Казан техник ун-тында, термодинамик һәм термофизик тикшеренүләр тармак лаб-ясе мөдире (1965–70), фәнни-тикшеренү секторы башлыгы (1970–75), сәнәгать экологиясе каф. мөдире (1988–99), пр-тие икътисады каф. профессоры (1999- 2005). 2005 тән Казан техник ун-тының Түбән Кама ф-лында. 1960 елларда П. «стенка-газ» системасының ионлаштыру үзлекләрен тикшерү буенча фәнни юнәлешне җитәкли; очкыч аппаратларның хәрәкәтләндерүче электрлашуы теориясен эшли. Кешенең тормыш иминлеген һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә энергия җайланмаларының эш режимына диагностика ясау алымнарын, һава атмосферасын, су һәм туфракны саклаудагы сорбцион системалар эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү юлларын тәкъдим итә; социаль-икътисади системалар үсеше динамикасын фаразлауның синергетик алымнарын эшли; икътисад объектларын динамик үстерү, продукция һәм хезмәт күрсәтүләрнең сыйфаты б-н идарә итү параметрларын оптимальләштерә торган модель уйлап таба. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы бар.



В.Я.Потапов.

Х е з м.: Качество воздуха в непроизводственных помещениях. К., 1993; Двигательная электризация летательных аппаратов. К., 1995; Экологические основы техносферы. К., 2000; Безопасность жизнедеятельности с учётом аспектов экономики. К., 2003; Синергетические аспекты затратного менеджмента // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2005. № 3; Факторная модель прогноза финансового состояния предприятия // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 1.

**ПОТА́ПОВО-ТОМБАРЛЫ́** авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Томбарлы елгасы буенда. 2010 елда 744 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 71%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, П.-Т.да 3 су тегермәне, 20 йөз башында Архистратиг Михаил чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1957 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Баулы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 579, 1889 да — 801, 1910 да — 1315, 1920 дә — 1273, 1926 да — 1357, 1938 дә — 1482, 1949 да — 1221, 1958 дә — 1379, 1970 тә — 872,

1979 да — 727, 1989 да — 549, 2002 дә — 758 кеше.

**ПОТА́Ш АЛАНЫ́** посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 7 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык; «Ямашнефть» АҖ санаторие. 1930 елларда нигез салына; торак пункт буларак 1963 нең 23 июлендә теркәлә. Оештырылган көннән Әлмәт р-нында. Халык саны 1938 дә — 38, 1949 да — 67, 1958 дә — 70, 1970 тә — 35, 1979 да — 38, 1989 да — 18, 2002 дә — 25 кеше.

**ПОТАШЁВ** Андрей Валерьевич (13.4.1954, Мейнинген ш., ГДР), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1976), Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1996–2011 елларда Казан югары артиллерия командирлары уч-щесенең югары матем. каф. профессоры. 2011 дән Казан кооперация ин-тында. Хезмәтләре аэрогидродинамиканың кайтма кырый мәсьәләләренә (АККМ) карый. П. шартлау матдәләре катламлы һәм анизотроп тирәлекләрдә тарала торган импульслы-гидродинамик шартлау модельләрен булдыра. АККМне аналитик чишү алымнарын эшли, файдаланудагы модельләрне һәм агым топологияләрен катлауландыру хисабына аларның кулланылыш өлкәсен киңәйтә; чишелеш алгоритмнарын эшли һәм санлы кыйммәтләрен таба; канат профильләрен проектлау һәм характеристикаларын яхшырту өчен АККМ чишелешләреннән файдалану мөмкинлеген күрсәтә һәм методикасын эшли. ТР ФАнең Х.М.Мөштәри исем. бүләге лауреаты (1999).

Х е з м.: Краевые задачи теории взрыва. К., 1986 (автордаш); Обратные краевые задачи аэрогидродинамики: Теория и методы проектирования и оптимизации формы крыловых профилей. М., 1994 (автордаш); Mathematical Methods of Airfoil Design. Inverse Boundary — Value Problems of Aerohydrodinamics. B., 1997 (автордаш).

**ПОТЕ́ХИН** Давид Евсеевич (22.12.1901, Таврия губ. Геническ ш. — 4.11.1978, Казан), терапевт, мед. фән. канд. (1956), ТАССРның атказ. табибе (1940). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1927), Лаеш р-нында табиб һәм берләштерелгән диспансер мөдире булып эшли. 1929 елдан Цивильск ш. (Чуаш АССР) туберкулёз диспансеры табибе һәм мөдире. 1931–51 елларда Казан ГИДУВында: 1938 дән директор урынбасары, 1939–42 дә, 1944–51 дә ректор. Бер үк вакытта, 1942–44 тә, Казан шәһәр сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1951 дән Казан мед. ин-тының госпиталь терапиясе кафедрасында, 1970 тән эчке авырулар каф. доценты. Хезмәтләре ашказаны-эчәк тракты авыруларын, Банг авыруын, гиперацид гастритлар һәм ашказаны ялкынсынуын; балалар үлеме сәбәпләрен өйрәнүгә карый. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из деятельности Цивильского туберкулёзного диспансера // Вопр. туберкулёза. 1930. № 5/6; Рентгенотерапия хронического гриппа // Казан. мед. журн. 1937. № 3 (автордаш).

*Әд.:* П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

**ПОТЁМКИН Г.А.ның ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́.** Россиянең дәүләт һәм хәрби эшлеклесе, кенәз Григорий Александрович Потёмкинның (1739–91) китаплар тупланмасында зур мәдәни-тарихи мирас тәшкил иткән 2 меңнән артык әсәр исәпләнә. Китапларның бер өлеше таралып бетә, икенче өлеше (146 исемдә) Эрмитаж китапханәсенә эләгә, тагын бер өлеше Г.А.Потёмкинның сәркәтибе В.С.Поповка кала. Китапханәнең зур өлеше Екатеринославта (хәзерге Днепропетровск) ачылачак университетка тапшырылырга тиеш була, тик бу ният тормышка ашмый. Башка мәгълүматлар буенча, ул Екатеринослав уч-щесенә бүләк ителә һәм Җәмәгать кайгыртуы приказы карамагындагы казна китапханәсе буларак исәптә тора. 1798 елның маенда император Павел I Казанга килгәч, аның кушуы буенча Г.А.Потёмкинның китаплары һәм башка коллекцияләре Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә тапшырыла. 1799 ның мартында китапханә (барлыгы — 1319, ш.и. 1065 чит телләрдәге, 106 рус телендәге китап, 34 кульязма, 114 карта һәм планнар) Казанга китерелә, ә университет ачылганнан соң, В.И.Полянский китапларының тупланмасы б-н бергә, аның китапханәсенең нигезен тәшкил итә.

Китапханәдә 15–18 йөзгә караган чит ил басмалары — инкунабуллар (беренче басма китаплар), эльзевирлар (16 йөз ахыры — 18 йөз башына караган голланд басмалары), альдиналар (15 йөз ахыры — 16 йөз башына караган Венеция басмалары), грек телендә Г.А.Потёмкин һәм Екатерина II гә багышланган мәдхияләр (тоташ гравюра ысулы б-н эшләнгән басмалар) саклана.

Рус телендәге китаплар арасында М.В.Ломоносовның «Бөек Пётрның адмиралтейство б-н идарә итү һәм верфь турындагы регламентлары» («Регламенты Петра Великого об управлении адмиралтейством и верфи», 1753), «Россиянең кыскача елъязмасы» («Краткий российский летописец», 1760), автор төзәтмәләре б-н В.К.Тредиаковскийның «Әсәрләр һәм тәрҗемәләр»е («Сочинения и переводы...», 1752), Екатерина II гә бүләк ителгән «Анисим Князевның нәсел гербләры җыелмасы» («Собрание фамильных гербов Анисима Князева», 1912 елгы басма), «Стольник Петр Толстойның Европа буйлап сәяхәте... 1697 ел» («Путешествие стольника Петра Толстого по Европе... 1697 года», 1888 дә басыла), ш.у. 18 йөзнең 1 нче яртысында дин юлында сәфәр кылган авторның үз рәсемнәре б-н «Василий Григорович-Барскийның... сәяхәте» («Путешествие... Василия Григоровича-Барского»), «Иван Грозныйның дәрәҗәләр китабы», («Степенная книга Ивана Грозного», 17 йөз күчермәсе), Г.А.Потёмкинның эш кәгазьләре, шәхси мөһере б-н «Көзге заводының акча керемнәре һәм чыгымнары китабы» («Книга приходу и расходу денег по зеркальному заводу») һ.б. була. Китапханәдә ш.у. сирәк язмалардан 50 төргәктән торган иврит телендә бозау тиресенә язылган «Моисейның биш китабы» («Моисеево пятикнижие», якынча 9–10 йөзләр), 18 йөз гравюралары альбомнары җыелмасы, ш.и. «20 махсус картадан торган Россия атласы» («Атлас российский, состоящий из 20 специальных карт», 1745), «Мәскәү һәм аның 30 чакрым әйләнә-тирәсе планы» («План Москвы и окружностей на 30 верст»), «Россиянең төрле шәһәрләре күренеше» («Виды разных российских городов») һ.б. булуы билгеле.

*Әд.:* Полное собрание законов Российской империи. 1798–1799. СПб., 1830. Т. 25; М а р т ы н о в И.Ф. Частные библиотеки в России XVIII в. // Памятники культуры. Новые открытия: Ежегодник. 1975. М., 1976; А р и с т о в В.В., Е р м о л а е в а Н.В. История Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского. К., 1985.

*И.А.Новицкая.*

**ПОТЁМКИНА** Аделаида Матиновна (4.7.1933, Бөгелмә ш.), педиатр, аллерголог, мед. фән. д-ры (1985), проф. (1988), ТАССРның атказ. табибе (1989). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), Казан шәһәрендәге 7 нче хастаханәнең балалар дәвалау-профилактика бүлегендә участок педиатры булып эшли. 1964 елдан — Казан ГИДУВының педиатрия; 1966 дан 1 нче Мәскәү мед. ин-тының педиатрия кафедраларында. 1970 тән Казан ГИДУВының балалар авырулары кафедрасында. СССРда беренче аллергология кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1989), Казанда балалар аллергологиясе хезмәтен булдыручы (1972). Казан шәһәр сәламәтлек саклау идарәсендә балалар аллергологиясе буенча баш белгеч (1973 тән). Хезмәтләре балалык яшендәгеләр аллергологиясенә карый. СССР ВДНХсының көмеш медале; «Сәламәтлек саклау отличнигы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Диагностика и лечение аллергических заболеваний у детей. К., 1990; Лекарственные средства в лечении аллергических заболеваний у детей. К., 1991; Рецепты блюд для больных с пищевой аллергией. К., 1994.

**ПОЦЕЛУ́ЕВА** Людмила Александровна (7.1.1947, Карел-Фин ССР, Сортавала ш.), фармацевт, фармакология фән. д-ры (1992), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). 1 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), 3 нче фармацевтика уч-щесендә (Казан) эшли. 1973 елдан «Татхимфармпрепаратлар» пр-тиесендә. Бер үк вакытта, 1972 дән, Казан мед. ин-тының Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә, 1977 дән — дарулар технологиясе каф. мөдире. Хезмәтләре микроблардан барлыкка килә торган фермент препаратлары булдыруга карый. Уйлап табуга 11 патенты бар. Генетик инженерия, биотехнологияләр һәм мед. максатларында микроб нуклеадлары препаратлары һәм шуларга кардәш ферментлар уйлап тапканы өчен СССР МС бүләге бирелә (1987).

Х е з м.: Противогриппозное действие бактериальной РНКазы в эксперименте и фармакокинетическое обоснование способа введения её в организм // Антибиотики и химиотерапия. 1990. № 3; Биофармацевтическое изучение и оценка безвредности мази биназы // Фармацевт. журн. 1993. № 2; Место нуклеазной активности в противовирусной защите // Казан. мед. журн. 1995. № 3.

*Әд.:* Деканы Казанского медицинского университета: Биогр. словарь. К., 1997.

**ПОЧИ́НКИ-НОВОЛЬЯ́ШЕВО**, к. *Яңа Льяш Пучинкәсе.*

**ПО́ЧТА** (поляк. poczta), почта элемтәсе, элемтәнең язма хат-хәбәрләр җибәрү, посылкалар җибәрү һәм кабул итү, акча күчерү, вакытлы матбугат илтү-тапшыру б-н шөгыльләнүче бер тармагы; көнкүрештә ш.у. элемтә пр-тиеләрен (почтамтлар, элемтә узеллары һәм бүлекчәләре), алар аша җибәрелгән корреспонденция, күчермәләрне П. дип атыйлар. Язу барлыкка килгәч тә мәгълүмат алмашу язма рәвештә башкарыла башлый, бу курьерлык эшенә башлангыч бирә, соңрак даими П. элемтәсе оешуга китерә. Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда идарәчеләре дипломатик язышулар алып баралар, бай кешеләр үзара хатлар алышалар, нәтиҗәдә үзенә бертөрле ям хезмәте барлыкка килә. Русьта беренче почта хезмәтләре 10 йөздән мәгълүм; халык «повоз» йөкләмәсе үти, ягъни кенәз чапкыннары өчен җигелгән атлар бирергә тиеш була. 13 йөздә аерым араларда алмашулы атлар б-н дәүләтнең язма хәбәрләрен тиешле урыннарга җиткерү өчен махсус хезмәт (ям чаптыру) оештырыла, ул 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр яшәп килә. Бу максатта халыкка ям йортларында ямчылар, билгеле күләмдә атлар тоту йөкләнә. 16–18 йөзләрдә ям йортлары саны үсә бара. 16 йөздә ям чаптыру б-н җитәкчелек итү өчен дәүләт учреждениесе — Ям приказы булдырыла (18 йөз башына кадәр саклана). Дәүләт фәрманнарын шәһәрләргә илтү, гаскәрләргә җиткерү б-н махсус чапкыннар шөгыльләнә. 17 йөзнең 2 нче яртысында дәүләт П. учреждениеләре оештырыла башлый, алар дәүләт һәм аерым затларның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш булалар. 1782 елда П. эше б-н идарә итү өчен Почта департаменты төзелә, ям йортлары П. станцияләре дип атала башлый. 1781 дә — П. аша акча җибәрү һәм корреспонденцияләрне хат ташучылар аша илттерү, 1783 тә — корреспонденцияләрнең авырлыгына һәм ара ераклыгына карап аларны җибәрү өчен бердәм тарифлар, 1843 тә — ераклыкка бәйсез рәвештә корреспонденцияләр җибәрүгә бердәм П. тарифы гамәлгә кертелә. 1848 дә — штемпельле конвертлар, 1858 дә П. маркалары чыгарыла. Болар барысы да П. элемтәсе хезмәтеннән файдалануны шактый җиңеләйтә һәм П. алмашу үсешенә ярдәм итә. Тимер юллар барлыкка килгәнче махсус юл грамоталары бирелгән пассажирларны ташу да П. ведомствосы вазифаларына кергән. 1884 тә П. һәм 19 йөз уртасында барлыкка килгән телеграф (к. *Телеграф*) хезмәтләре берләштерелә, Эчке эшләр министрлыгы составында Почта һәм телеграфлар баш идарәсе төзелә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында Казан аша Мәскәүдән Пермьгә, Оренбург, Урал һәм Себергә юнәлгән П. юллары уза. 18 йөзнең 1 нче чирегендә Казанда П. конторасы ачыла. 1830 да шәһәр яңа оештырылган П. округы үзәгенә әверелә. 1866 да Казан губерна П. конторасы каршында *Казан шәһәр почтасы* булдырыла. 1869 да Казан губернасында 48 П. станциясе, аларда 1179 ат исәпләнә. П. атнага 2 тапкыр Казан–Царёвококшайск (хәзер Йошкар-Ола), Казан–Малмыж, Казан–Чистай, Казан–Чабаксар трактлары буйлап китерелә. Авыл халкына дәүләт П.сы тарафыннан хезмәт күрсәтелми. 1865 тән авыл җирендә П. эше б-н земстволар һәм земство П.сы шөгыльләнә, алар үз кагыйдәләре, бәяләре, маркалары б-н эш итәләр. 20 йөз башына Казан губернасы илдәге земство П.сы барлык өязләрне колачлаган 9 губернаның берсе була.

Мәскәүдән Казанга П. җигүле транспорт, тимер юллар төзелгәч, поездлар б-н китерелә. 1868 дән Идел һәм Кама елгалары ярында урнашкан шәһәрләргә «*Самолёт*», «*Кавказ вә Меркурий*» җәмгыятьләре пароходларында П. хезмәте күрсәтелә башлый. Ләкин П. илтүнең оештырылуы озак вакытлар примитив булып кала: элеккечә үк төп чара буларак җигүле транспорт файдаланыла. 1913 тә Казан губернасында уртача алганда җан башына 4 тән дә кимрәк хат-хәбәр туры килә. 1917 дә Казанда — 77, Чистайда — 9, Мамадышта — 4, Царёвококшайскида — 2, Чабаксарда — 5, Арчада 1 П. әрҗәсе була. П.ны эшкәртү, аны төяү һәм бушату буенча барлык операцияләр дә кул көче б-н башкарыла.

Гражданнар сугышы елларында илдәге хуҗалык җимерекләре нәтиҗәсендә П. эше таркала. Элемтә учреждениеләренең саны кими. 1917–21 дә кабул ителгән декретлар б-н почта элемтәсе вазифалары киңәйтелә, 1924 тән хәл уңайлана башлый. П. хезмәте «божра» маршрутына куела, ул респ-каның 3519 торак пунктын (89%) колачлый, яңа почта трактлары (Казан-Минзәлә, Казан-Тәтеш) эшли башлый. Җигүле транспорт б-н бергә автотранспорт та файдаланыла; 1933 тә респ-када П. ташу өчен самолёт җибәрелү мөһим вакыйга була. Казан тимер юл П. бүлекчәсе хезмәткәрләренең саны 6 дан (1917) 40 кешегә җитә (1928). 1925 тә беренче тапкыр авылларда хат ташучы вазифасы кертелә (аларның саны арта: мәс., 1928 дә — 338, 1932 дә 2788 хат ташучы була). Шул ук елда П. корреспонденциясе 16,4 млн. данә (1924 елга карата 200%), җибәрелгән корреспонденция 7,6 млн. данә (195%) тәшкил итә. 1928 дә — 193, 1932 дә 1170 П. агентлыгы һәм пр-тиесе исәпләнә. 1932 дә матбугат тарату хезмәтенең эшен яхшырту максатында Үзәк матбугат тарату идарәсе — *Союзпечать* һәм Татарстан респ-ка элемтә идарәсе каршында матбугат тарату бүлеге оештырыла. Күрелгән чараларга карамастан, респ-када П. элемтәнең артта калган тармагы була. Үзәк газеталар Казанга 3 нче, респ-каның күпчелек районнарына 5–6 нчы көннәрдә килеп җитә. Пенсия һәм пособиеләр 1934 тә П. аша күчереп түләнә башлый.

Бөек Ватан сугышы башлангач, П. эшенең шартлары кискен үзгәрә. П. алмашу шактый арта, ләкин П. хәрәкәте сизелерлек начарая. Фронттагы сугышчыларга җибәрелә торган посылкалардан тыш, аерым затлардан посылкалар кабул итү туктатыла. Почта транспортын хәрби ихтыяҗда яки хуҗалык ихтыяҗларында файдалану тыела; П. вагоннарын гаскәри эшелоннарга тагу рөхсәт ителә. Сугыш елларында респ-када 28 атлы П. станциясе, 2 катер, 47 автомобиль, 48 велосипед була. Сугыштан соңгы елларда П. элемтәсен яхшырту буенча чаралар күрелә; 1947 дән халыктан посылкалар яңадан һәр җирдә дә кабул ителә башлый. 1956 да ТАССР Элемтә идарәсе каршында хуҗалык исәбендә эшләүче автотранспорт конторасы оештырыла, ул П. ташуларның зур өлешен үз өстенә ала; транспортның барлык төрләре — тимер юл, авиация, автомобиль транспорты файдаланыла башлый. Шәһәрләрдә элемтәнең илтү бүлекләре булдырыла, Казанда район элемтә узеллары оештырыла, алар шәһәрнең барлык П. бүлекчәләре эшчәнлеген координацияли. Почтамтта, П. ташу бүлекчәләрендә механикалаштыру чаралары: капларны бәйләүче машиналар, күтәргечләр, автотөягечләр, транспортёрлар, штемпель басучы аппаратлар, нумераторлар, сургыч басучы электр җайланмалары, алты урынлы индекс нигезендә хатларны адреслар буенча аеручы машиналар гамәлгә кертелә; конверт, открытка һәм газеталар сатучы ярымавтоматлар урнаштырыла. 1964 тә клиентлар б-н исәп-хисапларны теркәү һәм эшкәртүне үзәкләштерү өчен почтамт каршында машина-исәпләү бюросы оештырыла (бу тәҗрибә илнең башка элемтә пр-тиеләрендә дә тарала). 1970 тән П.ны контейнерлар б-н ташу үсеш ала. Терәк П. пунктлары, күпкатлы йортларның беренче катларындагы абонент П. әрҗәләре һәм авыллардагы төркемле абонент шкафлары, ш.у. төрләр һәм адреслар буенча бүлүне камилләштерү корреспонденцияләрне илтүне тизләтә. Район үзәкләрендә һәм авыллар-



Почта-пассажир дилижансы.



Казандагы Башпочтамт. Клиентларга хезмәт күрсәтү залы.

да заманча типтагы элемтә пр-тиеләре төзелә. 1980–85 тә 11 район элемтә узелы бинасы, аэропортларда һәм тимер юл станцияләрендә 9 П. алмашу пункты файдаланугa тапшырыла. Матбугат тарату хезмәте дә үсеш кичерә. 1972 дән Казанга үзәк газеталар тизлекле фототелеграф алымы б-н тапшырыла башлый, нәтиҗәдә алар укучыларга чыккан көндә үк барып ирешә. 1980 елларда Казан Россиядә вакытлы матбугатка заказлар кабул итү һәм рәсмиләштерү ЭВМ ЕС 1030, ЭВМ ЕС 1045 тә башкарылган бердәнбер шәһәр була.

1990 еллар башында, базар икътисадына күчү шартларында, куллану ихтыяҗы кимү аркасында П. элемтәсенең традицион хезмәтләр күрсәтү күләме азая башлый (20 йөз ахырында респ-када яшәгән һәр кешегә елга 20 ләп, 21 йөз башында 5 ләп хат туры килә). Моңа бәйле рәвештә, корреспонденцияләрне һәм күчерелгән акчаларны эшкәртү, җибәрү һәм тапшыру б-н бергә, хәзерге вакытта П. 70 тән артык төрдә үз профиленә карамаган хезмәтләр күрсәтә. Заманча технология һәм техника гамәлгә кертелә. П. элемтәсе хезмәт күрсәтүләре буенча автоматлаштырылган эш урыннары оештырыла. Район узеллары һәм почтамт эчке П.ны — «Россия экспресс-почтасы», халыкара П.ны «EMS Гарантпост-Татарстан» системалары буенча тиз арада илтүче-тапшыручы оешмалар челтәренә кертелгән. Җибәрелгән корреспонденцияләрне электрон П. ярдәмендә кабул итү, тапшыру һәм илтеп бирү автоматлаштырылган мәгълүмат системаларына нигезләнгән тизләтелгән күчерүләр башкарыла; басмаларга интернет-язылу, электрон кибетләр һ.б. үзләштерелә. 1997 дә 2 районара почтамт, 9 районара узел, 23 район участогы, 10 район П. элемтәсе узелы, 44 элемтә пункты, 1058 элемтә бүлекчәсе (аларның 844 е авыл җирендә), Респ-ка почта ташу үзәге һәм Респ-ка реклама үзәге составында «Татарстан почтасы» почта элемтәсе идарәсе» ДУП төзелә. Эшләүчеләр саны — 9 меңнән артык кеше, шуларның 3,7 меңе — хат ташучылар. П. маршрутларының озынлыгы 25 мең *км* дан артык. П. хезмәтләре респ-каның барлык торак пунктларын колачлый. 2011 дә ТРга 30,6 млн. данә хат, 69,7 млн. данә газета һәм журнал, 0,3 млн. данә посылка китерелә, 11,4 млн. данә акча күчерүләр һәм пенсия түләүләре башкарыла.

*Әд.:* Орлова А.Ф. Время и связь. К., 1988; Людей связующая нить. К., 2003.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**ПО́ЧТА-ТЕЛЕГРА́Ф О́КРУГЫ** (Казан округы), Россиянең почта-телеграф идарәсе системасындагы адм.-терр. берәмлек. Россия Дәүләт советының император Александр III тарафыннан расланган 1885 ел 28 май карары нигезендә оештырыла, 1885 нең 1 октябрендә ачыла. Округ идарәсе карамагында почта, телеграф бүлекләре һәм 1890 нан җирле телеграф челтәре була. Казан П.-т.о.на Казан (1885–1918), Вятка (1885–1901), Сембер (1901–18), Түбән Новгород (1901–05) губерналары керә. Башта — 87, 20 йөз башында 143 почта-телеграф учреждениесен үз эченә ала. П.-т.о. идарәсенең составы: башлык, аның ярдәмчеләре, эш башкаручы, бухгалтер һәм аларның ярдәмчеләре, канцелярия хезмәткәрләре һәм 1898 нең декабреннән — махсус йөкләмәләр башкаручы чиновниклар һәм хисапчылар, баш, өлкән, кече механиклар, архивариус (барысы — 11 кеше); адм.-идарә, техник, бухгалтерлык, оештыру-инструкторлык, тикшерү, файдалану, махсус йөкләмәләр башкаручы чиновниклар бүлекчәләре була (1915). Округ идарәсе Россия Эчке эшләр министрлыгының Почталар һәм телеграфлар баш идарәсенә, 1917 нең ноябреннән Почталар һәм телеграфлар халык комис-тына буйсына. Почталар һәм телеграфлар халык комис-тының 1918 ел 4 июнь карары б-н бетерелә.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 3. СПб., 1887. Т. 5. № 2989.

*Әд.:* Государственность России: Государственные и церковные учреждения, сословные органы и органы местного самоуправления, единицы административно-территориального, церковного и ведомственного деления (конец XV века — февраль 1917 года): Словарь-справ. М., 2001. Кн. 3.

*Е.Б.Долгов.*

**ПОШАЛЫ́М** елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Казансу елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 11,5 *км*, бассейнының мәйданы 38,5 $км^2$. Арча р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Алмалы авылыннан көнчыгыштарак, тамагы Дүртөйле посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 112 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәйге чорда югары агымда елга кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 145 *мм*, ташу агымы катламы 120 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,045 $м^3/с$. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Елгада су күләме 0,3 млн. $м^3$ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**ПОШИ́** (Alces alces), партоякдылар отрядындагы боланнар семьялыгыннан имезүче хайван. Евразия һәм Төньяк Америка урманнарында киң таралган. 1929 елда Татарстанда 83 поши була, 1950 дә — 1318, 2003 тә — 4430. Куаклыкларда һәм биек үләнле урыннарда яшиләр. Гәүдә озынлыгы 3 *м* га, сырт биеклеге 2,3 *м* га кадәр, авырлыгы 500–570 *кг*. Гәүдәсе кыска, башы зур, кәкре танаулы. Өске ирене кабарынкы һәм аскысы өстеннән салынып төшә. Ата П.ның муен астында тире үсентесе («алка») асылынып тора. Колаклары озын, киң, хәрәкәтчел. Мөгез ата П.да гына, ул кыска кәүсәдән һәм киң яссыланган «көрәктән» тора, аңардан исә берничә үсенте китә. Озын аяклары һәм киң тояклары чытырманлык һәм сазлыкларда җиңел йөрергә мөмкинлек бирә. Йон капламы куе көрән яки кара диярлек төстә, аяклары астан өскә таба аксыл соры яки ак. Берәрләп яки төркемләшеп (3–5 зат) яшиләр. Җенси яктан 3 яшьтә җитлегә. Парлашу чоры — сентябрь–октябрьдә, аннары ата П. мөгезләрен сала. Яңалары апрель–майда гына үсә башлый, көзгә сөякләнеп бетә. П. май–июньдә 1–2 бала китерә. Җәен, нигездә, үләнчел үсемлекләр, ш.у. агач-куак яфраклары һәм яшь ботаклар, көзен коелган яфраклар, кышын ботаклар б-н туклана. 20–25 ел яши, әмма күбесе иртә һәлак була. Төп дошманнары — аю, бүре, селәүсен, комагай. Нарат, имәннәрне зарарлый (яшь үсентеләрнең очларын ашый). Сунарчылык объекты (лицензияләр буенча).



Поши.

**ПОЭ́МА** (грек. póiēma — ясыйм, иҗат итәм), зур күләмле лиро-эпик жанр атамасы. Эпостан хикәяләү, сюжетлылык, персонажлар системасын, матди дөньяны кабул итә, лирикадан — субъектив кичерешләрне гәүдәләндерү, лирик геройның булуы, чагыштырмача уртача күләмгә һәм шигъри телгә тартылуны ала; П.ның чыганаклары еш кына фольклорга барып тоташа. Төрки-татар әдәбиятында беренче П. — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре. Гасырлар дәверендә П.да идеологик синкретизм чагылыш таба: этик-дидактик мотивлар фәлсәфи фикерләр б-н, реалистик элементлар — дини-фантастик һәм мифологик элементлар б-н үрелеп бара. Эчтәлек үзенчәлеге һәм сәнгати структурасы буенча, нигездә, П.ның 3 типологик төрен аерып карыйлар (19 йөзгә кадәр төрле күчемле формалар яшәп килә). Беренче тип — героик П. — халык героик-эпик риваятьләренә барып тоташа. Алтын Урда чорында исламны пропагандалауга багышланган дини-мифологик П.лар языла («Кыйссаи Авык», «Кыйссаи Сәкям», «Кыйссаи Әхтәм»). Икенче тип — эпик-дидактик — халык авыз иҗатының нәсыйхәт жанрларыннан килә (вәгазь, нәсыйхәт). Бу төр әсәрләрнең идея-тематик үзенчәлеген этик-тематик мотивларының фәлсәфә б-н үрелеп баруы тәшкил итә: кеше яшәеше, кешенең җирдәге роле һәм максаты, мәхәббәт кичерешләре, яшәү һәм үлем турындагы уйланулар (Харәзми. «Мәхәббәтнамә»; Хисам Кәтиб. «Җөмҗөмә Солтан»). П.ның өченче тибына мәхәббәт-романтик һәм авантюра-новеллистик П.лар керә. Аларда илаһи һәм дөньяви мәхәббәт неч-

кә, хисчән һәм тирән чагылыш таба (Котб. «Хөсрәү вә Ширин»; Сәйф Сараи. «Сөһәйл вә Гөлдерсен»; Сәйяди. «Дастане Бабахан»).

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъярның «Төхфәи Мәрдан» һәм «Нуры содур» П.лары гуманизм идеяләре һәм дини мотивлар б-н сугарылган. 18 йөздә П. Г.Утыз Имәни иҗатында үстерелә, камилләштерелә («Гавариф әз-заман» («Заман укымышлылары»), «Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих әл-әхъ яр», («Фикерләрне пакьләндерә торган игелекле үгетләр»). П.да дини хорафатларга каршы һәм урта гасырларга хас мәгърифәтчел фикерләр өстенлек ала; традицион романтик күзаллау кысаларында халык мәнфәгатьләреннән ерак торган, үз-үзләреннән канәгать булган руханиларга карата гаепләү мотивлары барлыкка килә. 19 йөздән башлап урта гасырлар П.сыннан яңа тип П.га күчеш башлана. Фәлсәфи, дөньяга караш б-н бәйле мотивлар Г.Кандалыйның «Сәхибҗамал» П.сында чагылыш таба. Анда мәгърифәтчел мотивлар, социаль-әхлакый эчтәлек мөселман руханиларының культын тәнкыйтьләү б-н үрелеп бара. Матурлык категориясе илаһи түгел, ә бәлки «җирле» антропологик эчтәлектә алга чыга. Автобиографик билгеләр хас булган лирик герой П.да яңа төсмер ала. Бу, үз чиратында, кешене тасвирлауга яңа караш барлыкка килү хакында сөйли.

20 йөз башы татар поэзиясендә әдипләр мәдәни аспектта яңа баскычка күтәрелә. П. эчтәлек, идея-эстетик һәм сәнгати планда сыйфат ягыннан югары дәрәҗәгә ирешә. Дөньяга кадими карашны һәм мәдәният парадигмасын кире кагу зарурияттеннән чыгу жанрларның үзгәрүенә китерә; модернистлар иҗатында яңа жанр модификациясе — антижанр-антипоэма барлыкка килә. Анда бүтән яңгыраш алган классик шәрекъ әдәбиятының традицион үзенчәлекләре сизелә. Бу хәл жанрның трансформациясе хакында сөйли: дини-дидактик эчтәлекле сюжет дөньяви фикерләрне җиткерүгә буйсындырыла (Ш.Бабич. «Кандала», «Газазил»; Г.Сөнгати. «Хозыр»; М.Гафури. «Адәм вә Иблис» һ.б.). Ш.Бабичның «Газазил»ендә әдәби пародия алымы файдаланыла, сюжет үзәгендәге Ходай Тәгаләгә буйсынмаган өчен оҗмахтан куылу турындагы дини легенда үзгәртелә. П.да табигый рәвештә С.Рәмиевнең гыйсъянчылык романтизмы (кара: *Гыйсъянчылык*) б-н сатира-юмор, реалистик П. алымнары (Г.Тукай. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш») кушылып китә.

20 йөздә П.ның ике: эпик һәм лирик төрләре күзәтелә. Беренче төр П.да күбесенчә тарихи, конкрет көнкүреш вакыйгалары тасвирлана (Г.Тукай. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»; Һ.Такташ. «Мәхәббәт тәүбәсе»; М.Җәлил. «Хат ташучы»; Ф.Кәрим. «Гөлсем»; С.Хәким. «Дала җыры», «Шагыйрьнең бала чагы»; С.Баттал. «Олы юл буйлап»). Лирик П.да лирик башлам, субъектив кичерешләр өстенлек ала (Ф.Кәрим. «Кыңгыраулы яшел гармун»; И.Юзеев. «Өчәү чыктык ерак юлга...»; Ә.Баян. «Сәяхәтнамә»; Р.Харис. «Рәссам»; М.Әгъләм. «Тукай хатлары» һ.б.).

1920–30 елларда П. яңа сыйфатлар, үзенчәлекле: лирик-публицистик (Һ.Такташ. «Киләчәккә хатлар»), лирик-психол. (Ә.Фәйзи. «Флейталар»), лирик-фәлсәфи (Х.Туфан. «Ант») һ.б. жанр формалары б-н баетыла. Беренче планга җәмгыять үсешенең социаль моделенә йөз тоткан, концептуаль әзләнүләр чыга, геройлар, социаль төзелеш барышы, үрнәк булырдай шәхесләр б-н кызыксыну арта. Әйдәп баручы принцип буларак, кешене җәмгыять тормышында һәм эш-гамәлләрдә сурәтләү үзенчәлеге билгеләнә. Бу чор П.сы романтикадан, милли колориттан ераклашып, яңа идея-эстетик үзенчәлекләргә йөз тота. Гыйсъянчылар героик П. формаларына мөрәҗәгать итәләр. Һ.Такташ көрәшне романтик-символик образларда сурәтләргә омтыла. Аның «Җир уллары трагедиясе»ндә дини-мифологик образлар яңадан тергезелә. Конфликтның нигезен трагик мәхәббәт каршылыгыннан бигрәк, шәхес һәм җәмгыять каршылыгы тәшкил итә. Х.Туфан П.ларында, чорга аваздаш төстә, эпик башлам, искелекне кабул итмәү һәм яңалыкка өстенлек бирү, социализм төзелешенә тугрылык кебек сыйфатлар өстенлек итә; стиль төрлелеге, лириклыкның, шигъри тәҗрибәнең җитенкерәмәве, лирик геройның эчке дөньясын сурәтләүнең арткы планга калдырылуы күзәтелә. М.Җәлил шигъриятендә лирик-эмоциональ стиль тора-бара сәнгати тасвирлауның лиро-эпик формалары б-н алыштырыла. Реалистик һәм романтик башламнарның нисбәте беренчесе ягына таба үзгәрә, «романтик реализм» өстенлек итә башлый. М.Җәлил «Хат ташучы» П.сында реализм б-н романтизм синтезының яңа дәрәҗәсенә ирешә. Бу хәл аның бер әсәр кысаларында жанр структураларының төрле төрләрен яраштыра алуы б-н бәйле. М.Җәлилнең «Алтынчәч», Х.Туфанның «Ант» П.лары яңарышка йөз тотулары б-н аерылып торалар. М.Җәлил халыкның милли азатлык хәрәкәте темасына мөрәҗәгать итә, шартлы алымнар, символик образларга мөрәҗәгать итә. Х.Туфан П.сында кеше кичерешләренең төрлелеген ачу, автор шәхесе, тарих һәм чорның катлаулы проблемалары б-н бәйле рәвештә жанр үсешенең яңа тенденцияләре чагылыш таба; авторның гражданлык позициясе ачык чагыла, илдәге иҗтимагый-сәяси ситуациягә бәя бирелә. Болар барысы да шагыйрьнең эстетик карашларында тирән үзгәрешләр башлануы хакында сөйли. С.Хәкимнең «Пар ат» П.сында автор Г.Тукайның тормышы һәм иҗатына яңача бәя бирергә, аның образын хәрәкәттә сурәтләргә омтыла, композиция һәм поэтика өлкәсендә яңалыкларга йөз тота. Гәрчә бер төркем әсәрләрдә С.Хәким Г.Тукай шәхесен абсолют, идеаль югарылыкка күтәргән булса, «Пар ат»та исә лирик герой б-н шагыйрь образының тәңгәлләшүе күренә.

Бөек Ватан сугышы елларында татар әдәбиятында П. жанрының үсеше Ф.Кәрим иҗаты б-н бәйле («Үлем уены», «Партизан хатыны», «Гөлсем», «Пионерка Гөлчәчәккә хат»). Аның «Кыңгыраулы яшел гармун» П.сында метафора һәм символларның тирәнлеге һәм көче зур роль уйный. Романтик символика лирик геройның шәхси кичерешләрен чагылдыруда сәнгати чара булып тора, рухының җиңелмәслеген раслый.

20 йөзнең 2 нче яртысында да П.ның традицион жанр формалары сакланып килә, эчтәлеккә килгәндә, алар романтик-публицистик пафос, фәлсәфи уйланулар б-н баетылалар. П.да универсаль гомумиләштерүләр барлыкка килә: шагыйрьләрнең Галәмгә карата мөнәсәбәте ачыла, реалистик, романтик, мифологик традицияләр дини-фәлсәфи мотивлар б-н үрелеп китә. И.Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү», «Таш диварлар авазы», «Мәңгелек белән очрашу» романтик поэмаларында образ-символлар күпләп кулланыла, фәлсәфи концепцияләр әдәби материалда тәкъдим ителә һәм яшәешкә мөнәсәбәтле фикерләрне, кануннарны, кешенең Галәмдә яшәвенең мәгънәсен билгеләүгә, социаль-психол. аспектка йөз тота. Кеше акылы, кеше рухы космосның салкын тынлыгына һәм җирдә кылына торган фаҗигаләргә каршы куела. Бу тенденция И.Юзеев поэмаларының нигезен тәшкил итә. Үзенең «Күмәч пешерүчеләр җыры», «Гадиләргә гимн», «Көрәшчеләр» П.ларына Р.Фәйзуллин балачак самимилеген, туган як җылысын, ватанга, халыкка мәхәббәтен гәүдәләндергән конкрет туган ил образларын кертеп җибәрә. П. төрле сәнгати, поэтик чаралар б-н баетыла. Бер әсәр кысаларында реалистик, романтик, мифологик, модернистик алымнар кушылып китә, авторлар төрле бәяләрне берләштерергә омтылалар. Боларга шартлы уен, интертекстуальлек, дини һәм мифологик символларга мөрәҗәгать итү, романтик пафосның реалистик детальләр б-н баетылуы кебек сәнгати чаралар аркылы ирешелә.

*Әд.:* Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Валитова А. Типология восточной поэмы (Проблемы развития жанра в процессе взаимосвязей тюркоязычных литератур) // Советская тюркология. 1973. № 4; Миннегулов Х. Татарская литература и Восточная классика. К., 1993; Шарипов А. Зарождение системы стихотворных жанров. К., 2001.

*Н.М.Йосыпова.*

**ПОЯ́РКОВ** Владимир Сергеевич (25.5.1916, хәзер Воронеж өлкәсенең Сагуны р-ны Сагуны а. — 1.12.1996, Яшел Үзән р-ны Бело-Безводный а.), зоолог, зоогеограф. Воронеж ун-тын тәмамлый (1939). 1946 елдан Россия саклаулыклары (Воронеж, Печора-Илыч, Сихотэ-Алинь) системасында. 1970 тән Идел-Кама саклаулыгында, директор урынбасары (1983 кә кадәр). Хезмәтләре саклаулыклар эшенә, кондызлар биологиясенә, Куйбышев сусаклагычының Идел-Кама саклаулыгы экосистемасына тәэсирен бәяләү мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Основы ведения бобрового хозяйства // Тр. Воронеж. гос. заповедника. 1953. Вып. 4; Лоси Волжско-Камского заповедника // Охотничье хозяйство и заповедное дело. М., 1977; Влияние антропогенных факторов на природный комплекс Волжско-Камского заповедника // Ведение заповедного хозяйства в лесостепной и степной зонах СССР. Воронеж, 1979.

*В.И.Гаранин.*

**ПӨШӘҢГӘ́Р** авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 41 *км* төньяктарак, Сәрдә елгасы буенда. 2010 елда 399 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1664 тән Пустошь Сосмак Бигиня буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Салман, Сасмак, Сасмак-Пөшәңгәр исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чыпта сугу, йон тетү, киез итек басу, балта эше һәм олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерчелек, су тегермәне, 4 чыпта сугу бинасы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1295,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1859 да — 528, 1897 дә — 814, 1908 дә — 1003, 1920 дә — 807, 1926 да — 710, 1938 дә — 773, 1949 да — 520, 1958 дә — 420, 1970 тә — 593, 1979 да — 463, 1989 да — 480, 2002 дә — 394 кеше.

**ПРАВДЮ́К** Анатолий Николаевич (27.8.1950, Ютазы р-ны Ютазы а.), инженер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1976), Уфа нефть-техник ун-тын (2001) тәмамлый. 1968–69, 1977–88 елларда «Татнефть» ҖБнең «Иркеннефть» НГДУнда: слесарь, геолог, цех башлыгы, технол. бүлеге башлыгы. 1969–73 тә Лениногорск промысел-геофиз. конторасында радиоактив каротаж буенча техник, 1973–75 тә Оренбург геол. экспедициясендә геофизик, 1975–77 дә Лениногорск промысел-геофизика конторасында инженер-оператор. 1988–2011 дә Лениногорск катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау идарәсендә технол. бүлеге башлыгы, баш инженер. 2012 дән «Сәнәгать технологияләре»ндә проектлар җитәкчесе. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге эксплуатацияләү колоннасын саклау һәм яңадан торгызу өчен технологияләр һәм техник чаралар комплексын эшләгәне һәм сәнәгатьтә киң кулланышка керткәне өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

**ПРАВОСЛА́ВИЕ**, *христианлыкта* төп юнәлешләрнең берсе. П.нең төп нигезләмәләре 325 (Никея ш.) һәм 381 (Константинополь ш.) елларда чиркәү карамагындагы Вселенский соборларда кабул ителгән Никея-Константинополь «Инану символы» кануни китабында тупланган. Православие динендәгеләр өч сыйфатта: Иләһ-Ата, Иләһ-Ул, Иләһ-Изге Рух ролендә чыгыш ясаучы бер Аллага табыналар. Дөньяны яратучы — Иләһ-Ата. Иләһ-Ул — иләһи һәм адәми сыйфатларга ия булган, дөнья яратылганчы Иләһ-Ата тарафыннан тудырылган, әмма җир йөзендәге гомерен Изге Мәрьям Ана биргән Иисус Христос (Гайса Мәсих). Ул кешелекне коткарып калу хакына хачта газаплы үлем кичерә, ләкин гомернең бакыйлыгына ишарәләп, яңадан терелә. Иләһ-Изге Рух, православие тәгълиматлары буенча — кеше гомеренең рухи нигезе; Иләһ-Атадан башлана (*католицизмның* П.дән аермасы — Изге Рухның Иләһ-Улдан да башлануын тануында); могҗизалар тудыру өчен пәйгамбәрләрне, әүлияләрне, апостолларны иләһи көч б-н бүләкли; ул көч диндарларга дини йолалар башкарганда иңә. Дини тәгълиматлар чыганагын *Библия* һәм христианлык көнчыгыш һәм көнбатыш тармакларга бүлгәләнгәнче (соңгысы — 2 нче Никея Вселенский соборы, 787 ел) булган беренче 7 Вселенский соборның, шуннан соңгы җирле соборларның карарлары, ш.у. 2–8 йөзләр Чиркәү Хакимнәренең (христиан дине галимнәре) тәгълиматлары кергән Изге риваятьләр тәшкил итә. П. 7 йоланы таный: чукыну, хуш исле май сөртү, түгәрәк ак күмәч б-н шәраб эчү, тәүбә итү, руханилык, өйләнешү, зәйтүн мае б-н изгеләндерү (тән сырхауларыннан рухи савыгу һәм тәүбә кылынмаган гөнаһлардан арыну өчен үткәрелә). Иисус Христос тормышы б-н бәйле булулары сәбәпле, чукыну һәм түгәрәк ак күмәч б-н шәраб эчү йолаларының аерым мәгънәсе бар. Чукындыру йоласы чукындырылучыны өч тапкыр суга чумдыру юлы б-н башкарыла. Бу вакытта чукынучы үзенә туганда ук язылган гөнаһларыннан арына (Адәм б-н Хаува). Христианнар ак күмәч салынган шәраб эчүне Иисус Христосның Тәненә һәм Канына кушылу дип ышаналар. П.дә Иисусның анасы Изге Мәрьям, Чукындыручы Иоанн Предтеча, төрле изгеләр (апостоллар, борынгы пәйгамбәрләр, христиан динен таратучылар) һәм аларның изге җәсәдләре аеруча хөрмәт ителә. Иләһ һәм изгеләр б-н аралашу *иконалар* алдында башкарыла. П. тәгълиматы фәрештәләргә, кылган яхшылыклар яки гөнаһлар өчен үлгәннән соң җәза (түләү) алуга, җәннәт һәм җәһәннәмгә ышануны күздә тота. П.дә үзәкләштерү юк, эре чиркәү оешмалары автокефаль тәртиптә — мөстәкыйль идарә ителә. Алар барлыгы — 15, шуларның 4 се (Константинополь, Александрия, Антиохия, Иерусалим) Вселенский титулын йөртә; башкалары — Рус, Грузин, Серб, Румын, Болгар, Кипр, Эллада (грек), Албания, Польша, Чехия җирләре һәм Словакия, Америка җирле чиркәү оешмалары. Ш.у. тагын автономияле православие чиркәүләре бар (Япония, Украина һ.б.). Рус православие чиркәве идарәсенең югары органнары булып закон чыгару, башкарма хокукларга һәм хөкем итү вәкаләтләренә ия булган Поместный собор, Архиерей соборы һәм башында патриарх торган Изге Синод санала. Адм.-чиркәү берәмлеге булып епископ, архиепископ яки митрополит җитәкчелегендәге епархия санала.



Казан Мәрьям Ана иконасы табылу көнендә Хач күтәреп йөрү. 21.7.2011.

Идел буенда беренче христианнар 7 нче йөздә күренә башлый. Киев Русенда П. кабул ителгәнннән соң (988), кенәз Владимир I 990 да Идел буе Болгар дәүләтенә Марк Македонянин җитәкчелегендә миссионерлар җибәрә, ләкин П. динен гаиләләре б-н 4 болгар кенәзе генә кабул итә. Руслар һәм болгарлар арасында сәяси, сәүдә, мәдәни элемтәләр киңәю нәтиҗәсендә, 1006 да сәүдәгәрләрнең ике дәүләт терр-ясе буенча ирекле хәрәкәт итүләре турында килешү төзелә (к. *Болгар-рус килешүләре*). Бу вакыйга Болгар дәүләте терр-ясендә православие җәмгыятьләре барлыкка килүгә сәбәп була. 12 йөзнең 1 нче яртысында — 13 йөзнең 1 нче чирегендә Идел буена П. дине үтеп керә: Болгар шәһәрендә рус сәүдәгәрләре һәм ирекле һөнәрче-христианнар даими яши. Православие динен тотучылар болгарлар арасында да күренә башлый, җәфа чигүче Авраамий Болгарский (1229 да үлә) Рус православие чиркәвенең иң беренче изгеләреннән санала. Ш.у. Болгарда — христиан динле *Әрмәннәр колониясе*, Казанда *Әрмән бистәсе* булуы билгеле (14–15 йөзләр). Казан төбәгендә П. Казан ханлыгы яуланганнан соң (1552) һәм аның җирләрен православие динендәге халыклар б-н колонизацияләү барышында киң тарала. 1555 тә оешкан *Казан епархиясе* татарларны һәм Идел буенда яшәүче рус булмаган башка халыкларны христианлаштыру буенча актив эш башлый (к. *Православие миссионерлыгы, Яңа чукындырылганнар конторасы*). Изгеләндерүчеләр *Гурий*, *Герман* һәм *Варсонофий*, патриарх *Гермогенның* эшчәнлеге Казан епархиясе б-н бәйле, Казан Мәрьям Ана иконасы Казанда табыла (1579). Төбәктә П. дине таралуда ачылуга ук эре дини тәгълимат һәм фәнни шәркыять үзәгенә әйләнгән Казан руханилар академиясе мөһим роль уйный (1842–1921). 1917 дә епархиядә 794 чиркәү, 27 монастырь эшли. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң, «Чиркәүнең дәүләттән һәм мәктәптән аерылуы турында»гы декретка яраклаштырып (1918), монастырьларны, храмнарны, рухани уку йортларын ябу компаниясе башлана. Изге урыннарны җимерүгә каршылык күрсәткән православие руханилары 1918–38 дә репрессияләргә дучар

ителә: 1918 дә Елантау монастыре (к. *Елантау монастыреның шәһит киткән изгеләре*), 1930 да Раифа пустыне (к. *Раифа шәһидләре*, *«Раифа монастыре» эше*) монахлары атып үтерелә. Бөек Ватан сугышы елларында дәүләт хакимияте һәм дини оешмалар арасында беркадәр уңай үзгәрешләр күзәтелә. 1941–44 елларда митрополит Сергийның (Страгородский; 1943 тән Мәскәү һәм бөтен Русь патриархы) ватан өчен көрәшкә берләшүгә чакырып, 30 мөрәҗәгате басылып чыга. Дини җәмгыятьләр армия ихтыяҗына әйберләр җыя. Ләкин сугыш тәмамлануга ук, диндарларга һәм руханиларга адм. басым яңара, халык арасында атеистик пропаганда көчәя. Татарстанда динне әзәрлекләү шартларында архиепископлар *Сергий* (Королёв), *Михаил* (Воскресенский) гамәлдәге гыйбадәт йортларын ябылудан саклап калырга тырышалар. Русьне чукындыруның 1000 еллыгын бәйрәм итү дәүләт һәм православие оешмалары арасындагы мөнәсәбәтләрнең нормальләшүен башлап җибәрә (1988). Бу вакытта Татарстанда 15 православие җәмгыяте исәпләнә, шуларның 3 се Казанда эшли (шәһәрдә — 3, респ-када 9 храм ачыла). 1988 дән Казан епархиясен (2012 дә митрополия итеп үзгәртелә) епископ Анастасий (Меткин) (1996 дан — архиепископ, 2012 дән — митрополит) җитәкли. 2007 дә православие җәмгыятьләре саны 270 кә, гамәлдәге храмнар 198 гә, яңадан ачылган *монастырьлар* 10 га җитә. 1995 тә Казан изгеләндерүчесе Ефрем б-н, изгеләр Иона һәм Нектарийның җәсәдләре табылу (Казан Кремле терр-ясендә алып барылган казу эшләре вакытында) Казан епархиясе тормышында зур вакыйгага әверелә. Казан епархиясе эшчәнлегенә патриарх Алексий II зур игътибар бирә; ул Татарстанга ике тапкыр килә: 1997 дә килүендә Казан руханилар уч-щесе (1998 дән — семинария) Зөядәге Успение монастыре диндарларына тапшырыла; 2005 тә — Казан епархиясе оештырылуына 450 ел тулу уңаеннан — респ-каның православие динен тотучыларына могҗизалы Казан Мәрьям Ана иконасының күчермәсе тапшырыла, Казан Кремлендә Благовещение соборы, Казан Богородица монастыреның Крестовоздвижение соборы ачыла. ТР православие оешмалары респ-каның күп конфессияле яшәеше шартларында төрле дин тарафдарлары арасында ышаныч һәм үзара хөрмәт атмосферасын сакларга омтылалар; аларның халыкны тәрбияләү һәм хәйрия эшчәнлеге мәсьәләләренә игътибары арта бара. Татарстанда, Рус православие чиркәвенең җәмгыятьләреннән башка, 5 иске дин тарафдарлары җәмгыяте (Белокриницкий килешүе һәм Иске помор юнәлешендәге) бар. Ш.у. к. *Иске дин тарафдарлыгы, Казан изгеләре, Керәшен татарлар, Православие бәйрәмнәре, Православие чиркәүләре.*

*Әд.:* Платон (Любарский). Сборник древностей Казанской епархии и других приснопамятных обстоятельств. К., 1868; Богословский Г.К. Краткий очерк Казанской епархии с приложением биографических сведений о Казанских архипастырях. К., 1892; Макарий (Булгаков Михаил Петрович). История Русской церкви: В 7 кн. М., 1994–96; Поспеловский Д.В. Русская православная церковь в XX веке. М., 1995; Журавский А. Жизнеописания новых мучеников Казанских. Год 1918-й. М., 1996; Карташёв А.В. Очерки по истории русской церкви. В 2 т. М., 1997; Тальберг Н. История Русской церкви. М., 1997; Елдашев А.М. Монастыри Казанского края: Очерки истории. К., 2004; Липаков Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

*А.В.Климин.*

**ПРАВОСЛА́ВИЕ БӘЙРӘМНӘРЕ́**, *православие* динендә аерым шәхесләр, вакыйгалар хөрмәтенә яки алар истәлегенә билгеләнгән һәм махсус дини гамәлләр б-н нygытылган тантана көннәре. П.б. әһәмиятләре буенча олы, урта һәм кече төркемнәргә бүленәләр. Бәйрәм көннәре — Юлиан календаре (иске стиль дип йөртелә), пасха көннәре ай календаре буенча билгеләнә. Иң олы П.б. — Иисус Христосның Яңадан терелүе (Светлое Христово Воскресение), Пасха. Уникеле (двунадесятый) дип йөртелә торган бәйрәмнәр (славянча «двунадесять» — 12) — ш.у. олы бәйрәмнәр, аларның өчесе — күчмә, алар Пасханы бәйрәм итү көненә бәйле: Иисус Христосның Иерусалимга керүе (Вход Господень в Иерусалим) яки Кызыл таллы якшәмбе (Вербное воскресенье), Пасхага бер атна кала бәйрәм ителә; Иисус Христосның күккә ашуы (Вознесение Господне), Пасхадан соң 40 нчы көндә; Изге рухның апостолларга иңүе (Сошествие Святого Духа на апостолов) яки Изге Троица көне (День Святой Троицы, башка исеме — Пятидесятница), Пасхадан соң 50 нче көндә. Күчми торганнары: Иисус Христосның тууы яки Раштуа (Рождество Христово), иске стиль б-н 25 декабрьдә яңача 7 гыйнварда бәйрәм ителә; Иисус Христосның Чукынуы (Богоявление яки Крещение Господне), 6–19 гыйнварда; Күрешү көне (Сретение Господне), 2–15 февральдә; Изге Мәрьям Анага Изге хәбәр килү (Благовещение Пресвятой Богородицы), 25 март — 7 апрельдә; Иисус Христосның үзгәрүе (Преображение Господне), 6–19 августта; Изге Мәрьям ананың вафаты (Успение Пресвятой Богородицы), 15–28 августта; Изге Мәрьям Ананың тууы (Рождество Пресвятой Богородицы), 8–21 сентябрьдә; Иисус Христосның тәресен күтәрү (Воздвижение Честного и Животворящего Креста Господня), 14–27 сентябрьдә; Изге Мәрьям Ананы храмга кертү (Введение во храм Пресвятой Богородицы), 21 ноябрь — 4 декабрьдә; Уникеле булмаган олы П.б.: Иисус Христосның сөннәтләнүе (Обрезание господне), 1–14 гыйнварда; Иоанн Предтечаның тууы (Рождество Иоанна Предтечи), 24 июнь — 7 июльдә; Изге апостоллар Пётр һәм Павел көне (День Святых первоверховных апостолов Петра и Павла), 29 июнь — 12 июльдә, ТРда әлеге бәйрәмне керәшен татарлар аеруча тантаналы төстә уздыра; Башы чабылган Иоанн Предтечаны искә алу көне (Усекновение главы Пророка, Предтечи и Крестителя господня Иоанна), 29 август — 11 сентябрьдә; Изге Мәрьям Ана Япмасы бәйрәме (Покров Пресвятой Богородицы), 1–14 октябрьдә. Болардан кала, Могҗиза күрсәтүче Николай (Святитель Николай) көннәре аеруча ихтирам ителә (9–22 май һәм 6–19 декабрь). Урта һәм кече П.б.нә җирле хөрмәтләнүче изгеләр, иконалар, чиркәү тарихыннан җирле әһәмияткә ия вакыйгалар хөрмәтенә үткәрелә торган бәйрәмнәр керә. ТРда гомум кабул ителгәннәр б-н бергә җирле ихтирам ителүче могҗизалы иконалар: Казан Мәрьям Ана иконасының күренүе (8/21 июль), 1612 елда Мәскәүне поляк интервентларыннан азат итү хөрмәтенә *Казан Мәрьям Ана иконасы* (22 октябрь/4 ноябрь), Седмиозёрный Мәрьям Ана иконасы (26/9 июль, 13/26 октябрь), Грузия Мәрьям Ана иконасы (22 август/4 сентябрь) көннәре һәм җирле хөрмәтләнүче изгеләр бәйрәмнәре (к. *Казан изгеләре*) үткәрелә. Ш.у. к. *Икона*.

*Әд.:* Месяцеслов Казанских святых. [Б. м.], 2001; Филарет (Златоустов). Праздники Русской Православной Церкви. К., 2004.

*А.В.Климин.*

**ПРАВОСЛА́ВИЕ МИССИОНЕРЛЫГЫ́** (лат. missio — җибәрү, тапшыру), Рус православие чиркәве эшчәнлегенең максатлары православие динен таратудан, аңа башка диндәгеләрне өндәү һәм чиркәү йогынтысыннан читләшүчеләрне кабат шул мохиткә кайтарудан гыйбарәт юнәлеше. Миссионерлык эшчәнлеген башлау һәм Идел буендагы рус булмаган халыкларны *христианлаштыру* Казан ханлыгы яулангannan соң (1552), Рус православие чиркәвенең татар, чуаш, мари, удмурт халыкларын *ислам* дине йогынтысыннан һәм мәҗүси карашлардан аеру, аларны православие динен кабул итәргә мәҗбүр итү б-н бәйле була. 1555 елда шул максат б-н *Казан епархиясе* төзелә. Казан һәм Зөя архиепископы итеп *Гурий* билгеләнә, Казанга җибәрү алдыннан патша Иван IV аңа төбәк халыкларын христианлаштыру буенча шәхси таләпләрен җиткерә (к. *Иван IV нең Казан архиепискобы Гурийга җибәргән күрсәтмәсе*). Казан Кремленең Спас-Преображение монастыре һәм Зөя Успение монастыре миссионерлык эшчәнлегенең үзәгенә әйләнә. Монастырь башлыклары Варсонофий һәм Герман миссионерлык эшчәнлекләрен адм. һәм соц.-икътисади чаралар (ш.и. православие динен кабул итүчеләргә өстенлекләр бирү) ярдәмендә алып баралар. 1560 еллар ахырына меңнәрчә татар, чуаш, мари һәм удмуртлар чукындыруга дучар ителә. Көчләп чукындыру нәтиҗәсендә яңа чукындырылганнарның православие диненнән чыгу һәм кабат ислам юлына кайту хәрәкәте башлана (төбәкләрдә, ш.и. Казанда яңа мәчетләр төзелә башлый). Бу көчләп христианлаштыруның яңа дулкынын китереп чыгара (к. Патша Фёдор Иванович Фәрманы, 1593 ел, 18 июль, яңа чукындырылган татарлар, алар өчен аерым сөрү җирләре бүлеп бирү һәм мәчетләрне җимерү турында). 1590 еллар ахырында, «Болгавыр заман» чорында П.м. эшчәнлеге яңа чукындырылганнарны православие динендә тотып калуга кайтып кала. Митрополит *Гермогена* миссионерлык эшчәнлеген православие дине нигезләрен үзләштермәгән яңа чукындырылганнар арасында алып барырга туры килә. П.м. турында 17 йөзгә караган мәгълүмат юк диярлек. 18 йөз башында миссионерлык эшчәнлеге митрополит *Тихон* башлангычы б-н көчле үгетләүләр рәвешендә яңадан

башланып китә. 1701–14 тә — протоиерей Ф.Фёдоров, 1714 тән аның улы иеромонах *Алексий* Раифский мари авылларына сәфәр чыгып йөри. Патша Пётр I нең 1713 һәм 1715 елгы Фәрманнары нигезендә йомышлы морзаларның хосусый милкендәге рус крәстияннәре тартып алына, алар эшкәрткән җирләр конфискацияләнә. Тихон тәкъдиме б-н «Яңа чукындырылганнарга барлык җыемнардан 3 еллык ташламалар турында» кабул ителгән *Сенат фәрманы* (1720 ел, 1 сент.) нигезендә Казан епархиясендәге христиан динен кабул итүчеләр җан башына төшкән салымнан һәм рекрутлыктан азат ителә, *лашманнар* катлавыннан чыгарыла (1725 елда Петр I вафатыннан соң ташламалар бетерелә). 1731 дә *Яңа чукындырылганнар комиссиясе* (1734 тән — *Яңа чукындырылганнар конторасы*) төзелә, 1738 дә Казан кафедрасына епископ *Лука* (Конашевич) билгеләнә, «Архимандритны, берничә рухани б-н бергә, яңа чукындырылганнарны христиан кануннарына өйрәтү өчен төрле губерналарга җибәрү һәм христиан динен яңа кабул итүчеләргә бүләк ителгән өстенлекләр турында» *Император Анна Иоанновна Фәрманы (1740 ел, 11 сент.)* чыга, шулардан соң миссионерлык эшчәнлеге кискен активлаша. Казна хисабына чиркәүләр төзелә, яңа чукындырылганнарга акча һәм кием-салым бирелә. Салымнар буенча ташламалар яңадан кайтарыла, алар ислам динендә яки мәҗүсилектә калганнарга салынган өстәмә җыемнар хисабына компенсацияләнә. Милли рухани кадрлар әзерләү өчен яңа чукындырылганнар мәктәпләре ачыла, анда укучылар рекрутлар җыю хисабына, мәҗбүр итү юлы б-н туплана. Бу исә халык арасында каршылык хәрәкәте тудыра (к. *Татарларның 1748 елгы кузгалышы*). Өстәмә басым ясау чарасы буларак, халыкның бер өлеше православие дине кабул иткән авыллардан чукынырга теләмәүчеләрне күпләп куу башлана. Епископ Лука тәкъдиме б-н кабул ителгән «Казан губернасында мәчетләр төзүгә юл куймау, губернаторлар һәм воеводаларның Мөхәммәд канунына кайтучы яңа чукындырылган кешеләрне тикшереп торуы турында» *Сенат фәрманы (1742 ел, 19 ноябрь)* нигезендә «тыючы указлардан», ягъни 1593 тән соң төзелгән барлык мәчетләрне сүтәргә боерык бирелә. Нәтиҗәдә, Казан төбәгендә генә дә 536 мәчетнең 418 е юкка чыгарыла. 1749 да Лука Казанның Татар бистәсендә яшәүчеләрне шәһәр читенә куарга тырышып карый. 1741–54 тә мари, удмурт, чуашларның күпчелеге, мордвалар тулысынча һәм беркадәр татарлар (халыкның 10% ы тирәсе) православие диненә көчәргә мәҗбүр ителә. Әлеге унъеллыкларда дистәләгән мең татар, чуаш, мари, чукындырудан һәм күтәрә алмаслык салымнардан куркып, Кама аръягына һәм башкорт җиренә күчеп китә (к. *Татарлар һиҗрәте*). 1755 тән, *Батырша хәрәкәте* башланганнан соң, Яңа чукындырылганнар конторасының миссионерлык эшчәнлеге күзгә күренеп сүлпәнәя, мәҗбүри көчерүләр туктатыла, 1756 дан яңадан мәчетләр төзергә рөхсәт бирелә. Моннан соң П.м. өчен мөселманнарны православие диненә күчәргә мәҗбүр итүгә караганда, православие динен кабул иткән әҗнәбиләрне христианлыкта тотып калу мөһимрәк була. Император Екатерина II патшалык итә башлагач, дин иреген тану сәясәтенә күчү башлана: 1764 тә Яңа чукындырылганнар конторасы бетерелә, «Барлык диннәргә юл кую һәм архиерейларны башка дин тотучыларга кагылышлы булган төрле эшләргә һәм гыйбадәт йортларының алар кануны буенча төзелүенә тыкшынудан тыю, мондый эшләрне гражданнар хакимиятенә калдыру турында» *Синод фәрманы (1773 ел, 17 июнь)* басылып чыга. Казан һәм Зөя митрополиты Вениамин Казандагы яңа керәшен мәктәбендә белем алуның сыйфатын күтәрүгә ирешә, үз башлангычы б-н авылларга миссионерлык сәфәрләре оештыра, Изге Китапны мари, удмурт, чуаш телләренә тәрҗемә иттерә (тәрҗемәләрнең текстлары сакланмаган). 1780 еллардан башлап 19 йөзнең уртасына кадәр максатчан миссионерлык эшчәнлеге алып барылмый. Керәшен татарларның ислам диненә кайту турында күпләп үтенеч язулары (к. *Чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайту хәрәкәте*), керәшен марилар һәм удмуртларның күпсанлы халык катнашында корбан чалып мәҗүсилек йолаларын үтәүләре б-н бәйле аерым акцияләр була (1826–28, 1836, 1851, 1856). 1818–24 елларда Идел буенда, бөтен Россиядәге кебек, Библия җәмгыяте тарафыннан хакимиятләр химаясендә Изге Китапны Идел һәм Урал буе халыклары телләренә тәрҗемә итү һәм тарату буенча кампания үткәрелә (чуаш һәм мари телләренә тәрҗемәләр Казанда әзерләнә). 1829 да Казан һәм Зөя архиепископы *Филарет* (Амфитеатров) рус булмаган авылларга сәфәр чыгу өчен штатта торучы миссионерлар билгеләү, руханилар семинарияләрендә интенсив рәвештә Идел буе халыклары телләренә өйрәтү, милли рухани кадрлар әзерләү, Изге китапның һәм рухани әдәбиятның тәрҗемәләрен оештыру, ана телендә гыйбадәт кылу, православие динен милли телләр аша сеңдерү максатында киң мәктәпләр челтәре төзүне эченә алган актив миссионерлык эшчәнлеге концепциясен тәкъдим итә. Филаретның тәкъдимнәре рәсми хуплау таба, ләкин тормышка ашмый. Руханилар семинарияләрендә татар һәм чуаш телләрендә укыту киңәя, әмма бу телләрне, асылда, әҗнәбиләр яши торган авыллардан килеп укучылар гына үзләштерә; миссионерлык вазифасын, башлыча, керәшен татарлар, чуаш-марилар яшәгән авылларга бик сирәк сәфәр чыгучы монастырь башлыклары башкара. 1852 дә Казан руханилар академиясендә мөселманлыкка, буддачылыкка, расколчылыкка һәм мәҗүсилеккә (чуаш-чирмешләр) каршы юнәлтелгән аерым бүлекчәләрдән торган миссионерлык бүлеге ачыла (соңгысы 1854 тә ябыла). 1870 тә бүлек бетерелә, ләкин аңа тиңдәш каф. 1918 гә кадәр эшли. Академия профессорларының (Н.И.*Ивановский*, Н.Ф.*Катанов*, А.Е.*Малов*, М.А.*Машанов*, М.М.*Миротворцев* һ.б.) ислам, будда, расколчылыкны, ш.у. Россия халыкларының телләрен һәм мәдәниятен өйрәнү буенча алып барган эшчәнлеге зур фәнни әһәмияткә ия, ләкин моның чын миссионерлык эшенә йогынтысы аз була. Эзлекле миссионерлык эшчәнлеге 1860 еллар уртасыннан, 1864 тә *Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе* ачылгач һәм анда Н.И.Ильминский системасы базасында (к. *Ильминский системасы*) белем бирү процессы үсеш алгач, яңадан башлана. Кириллица нигезендә татар, чуаш, мари, удмурт, мордва һ.б.ның алфавитлары төзелә, туган телләрдә белем бирүче миссионерлык мәктәпләренең киң челтәре оештырыла, милли укытучы кадрлар һәм руханилар әзерләнә, Изге Китапның тәрҗемәләре эшләнә, Идел буе һәм Себер халыклары телләрендә гыйбадәт кылу һәм чиркәү җырлары башкару кертелә. Н.И.Ильминский һәм аның фикердәшләре эшчәнлегенең уңышына бу системаның дәүләт һәм чиркәү структуралары аша түгел, бәлки, башлыча, җәмгать оешмалары аша таралуы булышлык итә (Казан губернасында — 1867 дә оештырылган *Изге Гурий борадәрлеге*, башка губерналарда 1871 дә ачылган *Православие миссионерлык җәмгыятенең* җирле бүлекләре). 1880 еллар башыннан Синодның обер-прокуроры К.П.Победоносцев башлангычы б-н миссионерлык эшчәнлеге яңадан торгызыла: Идел һәм Урал буендагы барлык губерналарда 2 шәр: «Мөхәммәт диненә һәм мәҗүсилеккә каршы» һәм «расколчылыкка һәм сектантлыкка каршы» епархиаль миссионер вазифасы булдырыла. Башлыча, әҗнәбиләрнең телләрен белгән руханилар арасыннан билгеләнеп куелган өяз һәм участок миссионерларының эшчәнлеге өчен түләү билгеләнә. 1889 да *Казан миссионерлык курслары* ачыла. Император Николай II нең Сенатка тапшырган «Дин иреген тану башлангычларын ныгыту турында»гы Фәрманы (1905 ел, 17 апр.) нигезендә адм. ысуллар б-н православие диненә көчләп тоту бетерелгәннән соң, миссионерлар кыен шартларда кала. Шуңа карамастан, чиркәү һәм дәүләт христианлаштыру курсыннан баш тартмый. 1910 да Казанда узган Миссионерлар съезды христианлаштыруны алга таба да таратуда Ильминский системасы иң отышлы ысул дигән нәтиҗә чыгара; шул ук елда дәүләт идарәсе оешмалары тарафыннан рус булмаган милләтләр яшәгән төбәкләрдә ислам дине йогынтысына каршы тору чаралары эшләнә (к. «*Идел буе төбәгендә мөселман татарлар йогынтысына каршы чаралар күрү өчен җыелган махсус киңәшмә*»). 1917 дән соң миссионерлык эшчәнлеге туктатыла. 1990 елларда епархияләрдә миссионерлык бүлекләре яңадан торгызыла, ләкин Рус православие чиркәве Уставы буенча аларның эшчәнлеге башка конфессияләргә каршы түгел, бәлки чиркәү йогынтысыннан читләшкәннәрне үзенә тартуга һәм сектантлыкка каршы торуга юнәлтелә.

*Әд.:* Малов Е.А. О Новокрещенской конторе. К., 1878; Можаровский А.Ф. Изложение хода миссионерского дела по просвещению Казанских инородцев с 1552 по 1867 годы. М., 1880; Харлампович К.В. Казанские новокрещенские школы (К истории христианизации инородцев Казанской епархии в XVIII в.). К., 1905; Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии. С поло-

вины XVI в. до февр. 1917 // Материалы по изучению Татарии. К., 1948. Вып. 1; Ислаев Ф.Г. Православные миссионеры в Поволжье. К., 1999; шул ук. Ислам и православие в России: От конфронтации к веротерпимости, век XVIII. М., 2005; Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в Российском законодательстве второй половины XVI–XVII вв. К., 2002.

*А.В.Климин.*

**ПРАВОСЛА́ВИЕ РУХАНИЛАРЫ́**, православие чиркәве хезмәтенә бирелгән руханилар. Хәзерге П.р.ның сан һәм дәрәҗәләр системасы 4–6 йөзләрдә Вселенский соборлар карарлары буенча формалаша. Кара (монахлык итүче) һәм ак (гаиләле) дәрәҗәләргә (саннарга) бүленә. Руханиларның түбәнге катламын санга ия булмаган затлар тәшкил итә: ак руханиларда — пономарьлар, дьяконнар, 19 йөз уртасыннан — псаломчылар, караларда — иноклар (монахлар). П.р.ның түбәнге дәрәҗәләре дьяконнардан (ак) һәм иеродьяконнардан (кара) тора. Икенче дәрәҗә — священниклар — иерейлар (ак, иң югары дәрәҗәсе — протоиерей, 19 йөзгә кадәр — протопоп) һәм иеромонахлар (кара, иң югары дәрәҗәсе — игумен һәм архимандрит). Дәрәҗәгә багышлау архиерей тарафыннан башкарыла. Руханиларның изге йолаларны (чукындыру һ.б.) үтәү хокукы бар. Өченче, иң югары дәрәҗә — архиерейлар, кара руханилар арасыннан билгеләнә. Архиерей, куйган хезмәтенә һәм токтан урынына карап, епископ, архиепископ, митрополит дәрәҗәсен йөртергә мөмкин. Епархия башлыгын — епархия архиереен Изге Синод сайлый. Кирәк чагында аңа епископ ярдәмчесе беркетелә. Ярдәмче епископның вазифаларын архиепископ билгели. Епархия идарәсенең югары органы — епархия җыены. Башкарма органы — епархия идарәсе. П.р. Россиядә катлау буларак 10 йөздән башлап, башлангыч чорында барлыкка килә. 18 йөзгә кадәр барлык катлаулардан чыгучылар б-н тулылана: кара — монахлардан, ак — священникларны һәм дьяконнарны сайлау системасы нәтиҗәсендә, приход кешеләреннән. Акрынлап, нәселдәнлек системасы урнаша. П.р.на кагылышлы тәртипләр 18 йөзнең 1 нче чирегендә үзгәрә: 1719–27 елларда җан башыннан алына торган салым кертелү һәм беренче ревизия үткәрелү б-н салым түләргә тиешле катлаулардан да, дворяннардан да руханилыкка күчү катгый тыела. Аларның саны штатлар б-н чикләнә, монастырьларга, чынлыкта, П.р. вәкилләре генә кабул ителә. Нәселдәнлек бурычы итеп куелган руханилык хезмәте барлык священникларның балаларын дини уку йортларында мәҗбүри укытуны хуплый. Беренче ревизия мәгълүматлары буенча, Россиядә П.р.на караган барлыгы 97413 ир заты була. Әлеге вазгыять 19 йөзнең уртасына кадәр саклана. Икенче яктан, руханилар катлавы вәкилләренең башка катлауларга күчү процессы гамәлдә була: руханилар семинарияләрендә белем алганнар дөньяви югары уку йортларына һәм дәүләт хезмәтенә бик теләп алына, шул юл б-н дворяннар һәм чиновниклар сафлары тулыландырыла. Катлаулар арасындагы катгый кысаларны җимерү 18 йөзнең 2 нче яртысында «бөек реформалар» чорында башлана. Император Александр II нең 1869 елның 26 май Фәрманы нигезендә руханилар катлавы бетерелә. Моннан соң П.р. балаларына «шәхси дворяннар» һәм «мактаулы гражданнар» хокуклары бирелә, хәрби бурыч һ.б. гражданлык бурычларын үтәү йөкләтелә, алар эшчәнлек төрен сайларга, теләсә кайсы уку йортында белем алырга хокук ала. Шул ук вакытта башка катлаулардан чыккannарга да руханилык дәрәҗәсе бирелә башлый. Руханиларның йомыклылык тәртибе, юридик яктан юкка чыгарылуга карамастан, 1917 гә кадәр дәвам итә: моңа чиркәү әһелләре һәм рухани балалары казна хисабына белем ала торган дини уку йортлары системасы да булышлык итә. 20 йөз башында Россиядә 19900 укучысы булган 4 руханилар академиясе (ш.и. *Казан руханилар академиясе*), 58 семинария (ш.и. *Казан руханилар семинариясе*) эшли. 18 йөздә Казан епархиясендә дөньяви һәм рухани хакимиятләр, миссионерлык максатларын күздә тотып, Идел буенда яшәүче төп халыклардан рухани кадрлар әзерләү теләге б-н руханилар катлавының йомыклылык принцибын бозалар. П.р.ның милли кадрлар әзерләү программасы 1860 елларның 2 нче яртысында Н.И.*Ильминский* тырышлыгы б-н кабат торгызыла. 1867 дә ул Казан үзәк керәшен татар мәктәбенә нигез салучы В.Т.*Тимофеевны* священник дәрәҗәсенә күтәрүгә ирешә. Шушы вакыйгадан соң әҗнәбиләр приходына руханиларны һәм дьяконнарны шул ук милләт вәкилләре арасыннан билгеләү гомуми рәвештә гамәлгә кертелә. Алар Ильминский системасындагы уку йортларын (Казан укытучылар семинариясе, Сембер чуаш укытучылар мәктәбе һ.б.) тәмамлаучылар була. Аларга руханилык дәрәҗәсе күпьеллык укытучылык хезмәтеннән соң яки, 1893 тән башлап, турыдан-туры 5 нче курска кабул ителү тәртибе кертелгән уку йортларын (мәс., *Казан миссионерлар курсларын*) һәм руханилар семинарияләрен тәмамлаганнан соң бирелә. 1909 га Казан губернасында гына да керәшен татарлардан 31 священник хезмәт итә; Уфа, Вятка, Оренбург епархияләрен кертеп, барлыгы 50 дән артып китә. 1905 тә Россия империясендә ак руханилар саны (түбән дәрәҗәдәгеләрне дә кертеп) — 103 мең, каралар 20 мең кешедән артык китә. Окт. рев-циясе П.р.ның социаль катлау төркеме булып яшәвенә нокта куя. 1920–30 да чыгышларының руханилардан булуы һәм дини дәрәҗәләре еш кына сәяси гаепләүләргә һәм репрессияләргә нигез итеп карала. Совет чорында П.р. саны, алар берничә уку йортында гына әзерләнгәнлектән, кисәк кими. 1998 нең азагында Рус Православие чиркәвендә 19000 нән артык приход (Украинада — 8168, Белоруссиядә — 1080), 17500 священник, 2275 дьякон, ягъни 19775 рухани теркәлгән. 2000 еллар башына Изге Патриарх, 25 епископ ярдәмчесе, 11 хезмәттән киткән архиерей б-н бергә 164 архиерей (ш.и. 128 хезмәттәге епископ) исәпләнә. Республикада П.р. кадрларын Казан руханилар семинариясе әзерли.

*Әд.:* Знаменский П.В. Приходское духовенство в России со времени реформы Петра I. К., 1873; Липаков Е.В. Православное духовенство в Казанской епархии второй половины XIX — начала XX века... // Материалы Казан. юбилейной историко-богословской конф. «История и человек в богословии и церковной науке». К., 1996; Павлов П.П. Материалы из истории кряшенских приходов Русской православной церкви // Материалы науч.-практической конф. на тему «Этнические и конфессиональные традиции кряшен: история и современность». К., 2001; Православная энциклопедия. Русская Православная церковь. М., 2000.

*Е.В.Липаков.*

**ПРАВОСЛА́ВИЕ ЧИРКӘВЕ́**, *христианлыктагы* юнәлешләрнең берсе — *православие* тарафдарлыгындагы дини оешма; 2) гыйбадәт кылу, дини йолалар башкару бинасы (храм).

Казан җирендә беренче Православие чиркәүләре барлыкка килү вакыты билгеле түгел; биредә православие Казан ханлыгын Рус дәүләте яулап алганнан (1552) һәм Казан епархиясе төзелгәннән соң (1555) киң тарала башлый һәм шуннан соңгы елларда җирле төп халыклар (татар, мари, чуаш һ.б.) җирләренең православие динендәгеләр тарафыннан колонияләштерелүе барышында дәвам итә.

Үзенең чиркәве, руханилары һәм халкы булган иң түбән чиркәү берәмлеге — чиркәү приходы — рус православие чиркәвенең башлангыч звеносы. Приходлар, гадәттә, ир-ат җенесеннән чиркәүгә йөрерлек 500–700 кеше булганда ачыла, гомуми җыелыш хуҗалык эшләрен алып бару өчен приход попечительлеге әгъзаларын һәм чиркәү старостасын сайлый. Чиркәү приходлары округларга, ә алар епархияләргә берләшәләр. Епархияне патриархка буйсынган архиерейлар (епископлар, архиепископлар һәм митрополитлар) җитәкли. Шәһәрнең төп храмы собор дип атала; дини йола-хезмәтләре архиерей тарафыннан үтәлә торган храм кафедраль собор дип йөртелә. Уку йортларында, клиникалар, картлар һәм ятимнәр йортларында, хастаханәләрдә һ.б. йорт чиркәүләре була (1917 дән соң бетерелә; 1990 еллардан соң тергезелә). Пётр I хакимлек иткән чорга кадәр (18 йөз башы) руханиларга мәгариф эшчәнлеге йөкләнә, монастырьлар һәм соборлар карамагында мәктәпләр барлыкка килә; соңрак, чиркәүләрдә имана салымы түләүче катлам балалары өчен башлангыч уку йортлары — *чиркәү-приход мәктәпләре* ачыла. Храмнар һәм чиркәү руханилары диндарлар биргән ирекле хәерләр, христиан дине йолаларын башкару керемнәре, ш.у. шәмнәр, һ.б. дини кирәк-ярак сатудан кергән акчалар хисабына тотыла.

Чиркәү биналары хач, тормыш һәм кояш яктылыгы символлары б-н очланганнар; интерьерлар дини темаларга багышланган дивар бизәкләре б-н бизәлгәннәр (к. *Нәкышь сәнгате, Фреска*). Православие храмы өч өлешкә бүленә: алгы өлеш — ишек алды (притвор); урта өлеш — гадәттә, баганалар б-н чикләнгән озынча бүлмә (неф); алтарь (дога уку урыны); алтарь чиркәүнең көнчыгыш өлешендә урнаша. Болардан тыш, чаң каланчасы, аш-су (трапеза) бүлмәсе, гыйбадәт киемнәре һәм чиркәү кирәк-яраклары саклана торган бүлмә (ризница) һ.б. бар. Чиркәүнең алгы өлешендә — ишек алды каршында

христиан дине кабул итәргә әзерләнүчеләр һәм тәүбә итүчеләр өчен билгеләнгән ачык мәйданчык (паперть) бар. Чиркәүнең ян-ягында янкормалар — өстәмә алтарьлар булырга мөмкин. Алтарь — храмдагы үзәк, калку, хәер бирә торган изге урын. Анда йола үткәрү өчен биек өстәл (престол) куела. Алтарь бүлмәнең башка өлешеннән *иконостас* б-н бүлеп алына. Бүлмә тактасына өч ишек уела; уртадагы, ике якка ачылмалысы, «патша капкасы», биек өстәлгә илтә. Иконостас алтарьның нефтагы дәвамы булып саналган калку урынга — күперчеккә куела. Күперчекнең урта өлешендәге чыгынтыга — амвонга басып Инҗил укыла һәм вәгазь сөйләнә. Чиркәүнең төньяк һәм көньяк диварлары буендагы күперчекләргә гыйбадәт вакытында дини җырлар башкаручы хор өчен мәйданчык — клирос эшләнә. Дини йолалар православие дине кануннары нигезендә башкарыла.

Христиан динендә төп табыну әйберләренең берсе — *икона* — махсус традицион кагыйдәләр нигезендә, дини сюжетларны символик сурәтләүче образ, нәкышь сәнгате әсәре. Казанда беренче иконалар Иван IV тарафыннан җибәрелә (Окт. рев-циясенә кадәр Благовещение соборында саклаңалар). 1579 да табылган *Казан Мәрьям Ана иконасы* Бөтенроссия изге иконасы булып әверелә. 16 йөзнең 2 нче яртысында Казанда *икона язу* сәнгате үсеш ала. Казан епархиясенә беренче икона язучылар Иван Грозныйның хатыны патшабикә Анастасия боерыгы буенча килә (16 йөз).

Казан епархиясе соборларында һәм чиркәүләрендә гыйбадәт кылу өчен гамәли-бизәлеш сәнгатенең күпсанлы сәнгать әсәрләре туплана: шәрекъ парчасына эре энҗеләр, кыйммәтле асылташлар һәм фирүзә б-н чигелгән ризалар, ефәк, көмеш һәм алтын җепләр б-н чигелгән япмалар, алмаз, зөбәрҗәт, якут б-н бизәлгән инҗилләр, алтыннан һәм көмештән җепкыр, чүкү һәм корлау ысулы б-н бизәлгән чиркәү җиһазлары — барысы да «Казан көмешчеләре» хезмәтләре. Казан чиркәүләре интерьерларында агачка уеп ясалган бизәкләр кулланыла. Җирле осталар тарафыннан барокко стилендә башкарылган *Петропавел соборы* (1726 да төзелгән) иконостасы купшылыгы б-н аерылып тора. Чиркәүләрнең архитектур корылышында ташны кисеп бизәк төшерү алымы башкару осталыгының иң камил дәрәҗәсенә үсеп җитә (Раифа Богородица ирләр монастыреның Троица соборы, Елантау монастыреның Успение чиркәве һ.б.).

Элек П.ч. берьюлы дини һәм иҗтимагый үзәк булып санала. Әйтик, Казан Богородица монастыреның Крестовоздвижение чиркәвендә нәкышь һәм чигү остаханәләре, хастаханә, ятимнәр йорты, китапханә була. Казандагы иң ярлы чиркәүләрнең берсе саналган Евдокия чиркәвендә зур гына китапханә эшли. 20 йөз башында Покров чиркәве китапханәсендә 2000 нән артык китап исәпләнә. Чиркәү китапханәләрендә дин гыйлеме китаплары б-н бергә Азбуковниклар, *Гурий әлифбасы*, ш.у. уку китаплары (мәс., Козьма Индикопловның «Христиан топографиясе»нең тәрҗемәсе) алына. Чиркәүләрдә мәрхүмнәрне искә алу китаплары — Синодиклар язып барыла. Безнең көннәргәчә берничә Синодик сакланып калган; Зөя каласының 16 йөзгә караган Успение соборындагы зур тарихи әһәмияткә ия Синодик христиан дине изгеләре *Гурий* һәм *Герман* исемнәре б-н башланып китә, анда патша Иван Грозный тарафыннан һәлак булганнар турында да бар. Благовещение соборындагы 17 йөз Синодигында гыйбадәт вакытында искә алу өчен шулай ук «Казан патшалары»: Симеон — *Ядегәр Мөхәммәт* хан, Пётр Ибрагимович — ханзадә *Ходайкол*, Александр — *Утәмешгәрәй* исемнәре дә күрсәтелгән. Синодиклар вафат булучыларның исемнәре б-н һәрвакыт тулыландырылып торылган. Чиркәү китапханәләрендә 16–17 йөзләр кулъязма китаплары һәм иң беренче дөнья күргән байтак басмалар саклана.

Төбәктәге чиркәү архит-расы рус дини корылмалары традицияләрендә үсеш ала. Беренче П.ч. башлап Зөя (Успение монастыре, 1551) һәм Казанда (1552) төзелә. 16 йөзгә караган агач корылмаларның күләм-планлаштыру структурасы бүрәнә конструкциясе һәм аның табигый параметрлары б-н билгеләнә. Агач корылмаларда архит-раның төп үлчәме итеп бүрәнә яки уртача озынлыктагы борыс алына. Контур буенча турыпочмаклык ясаган һәм очларындагы уентык ярдәмендә тоташкан дүрт бүрәнә горизонталь урнашкан ниргә барлыкка китерә. Ниргәләр бер-берсе өстенә өелеп, бура барлык килә. Зур биналар төзегәндә теге яки бу тәртиптә берничә бура ялгана. Квадрат бура — дүрткырлык, сигез бүрәнәдән буралган сигез почмаклы бура сигезкырлык дип йөртелә. Бурап салынган корылмаларның мондый системасы келәт дип аталган бер катлы агач храмнарның нигезен тәшкил итә. Татарстан терр-ясендә 16 йөзгә караган агач дини архит-расы үрнәге Зөядә сакланып калган (к. *Троица чиркәве*). Борынгы рус чатыр храмнары архит-расына төрлечә ярашып урнашкан дүрткырлыклар һәм сигезкырлыклар һәм ш.у. югарыга таба кечерәйтеп өелгән ниргәләрдән гөмбәз ясаучы пирамидаль чатырлар хас. Казандагы таштан салынган Благовещение соборы (16 йөз) ТРда иң борынгы әвернә гөмбәзле храм санала. 17 йөздә агач чиркәүләрнең күбесе урынына таш чиркәүләр торгызыла. Элек биек сигезкырлык һәм чатыр б-н төгәлләнгән квадрат корылмадан гыйбарәт булган Никола-Гостинодворский чиркәвенең күләме зурайтыла, әмма 16 йөзгә хас архит-ра сыйфатлары сакланып калына. 17 йөз архит-расы узган чор алымнары б-н үсүен дәвам итә, ләкин биналарның тышкы кыяфәтендәге декоратив формаларның артуы, детальләр һәм төсләрнең еш кулланылуы б-н аерылып тора. 17 йөз архитекторлары чиркәүләрне кисеп-уеп эшләнгән тәрәзә йөзлекләре, кечкенә колонналар, а́ркалар һ.б. б-н бизиләр. 17 йөз корылмалары фасадларының купшы һәм төрле образлардагы бизәлешен, гадәттә, «бизәкле стиль» дип атыйлар (мәс., Казандагы Покров чиркәвенең чаң каланчасы). 17 йөз азагы — 18 йөз башында чиркәүләр барокко стиленнән барлыкка килгән декоратив төсмерләр б-н баетыла; әйтик, 17 йөз Богоявление чиркәве (Казан) 18 йөз уртасында рус *бароккосы* формаларында үзгәртеп корыла. Каймар авылындагы Кирилл-Белозерский чиркәве, Олы Кабан авылындагы Спас-Преображение чиркәве, Державин авылындагы Никола чиркәве шулай ук барокко стиле үрнәкләре булып тора.

18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөзнең 1 нче яртысында чиркәүләр архит-расында ордер формаларын куллануга корылган классицизм стиле таралыш ала. Алабуга шәһәрендәге Никола чиркәве, Чистайдагы Никола соборы төбәктә *классицизм* стилендәге иң яхшы дини архит-ра үрнәкләре булып саналалар. Царицын авылындагы Казан Богородица чиркәве *ампир* стилендә (классицизмның бер төре) төзелгән. 19 йөз — 20 йөз башларындагы дини храмнарның күпчелеге *эклектика* стилендә корылган.

1917 елда Казан епархиясендә 794, Казанда 100 гә якын чиркәү исәпләнә. Совет власте елларында чиркәү төзелеше алып барылмый, П.ч.ләренең күпчелеге сүтелә (1989 да Татарстанда барлыгы 11 чиркәү эшли). 20 йөз азагы — 21 йөз башында чиркәүләр кабат төзелә башлый, сакланып калган храмнар тергезелә, 2012 дә респ-ка терр-ясендә 300 гә якын чиркәү эшли (к. *Казан епархиясе*).

*Әд.:* Заринский П.Е. Очерки Древней Казани, преимущественно XVI в. К., 1877; Казанский сборник статей архиепископа Никанора (Каменского). К., 1909; Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982; Бартенев И.А., Батажкова В.Н. Очерки истории архитектурных стилей. М., 1983; Республика Татарстан: Православные памятники. К., 1998; Православная Казань. К., 2011; Черенков А.В. Православные храмы — памятники Татарстана: Фотоальбом. К., 2012.

*А.В.Гарзавина.*

**«ПРАВОСЛА́ВНЫЙ СОБЕСЕ́ДНИК»** («Православиеле әңгәмәдәш»), вакытлы матбугат басмасы; 1855 елның маеннан Казан һәм Зөя архиепископы *Григорий* (Постников) тырышлыгы б-н *Казан руханилар академиясе* журналы буларак оеша. Башта елга 4 әр, 1858–1915 тә 12 шәр саны чыга (чыгарылышлар 3 өлешкә берләшә, һәркайсы уртак сан б-н билгеләнә). 1916–17 дә икеайлык басма рәвешендә алтышар сан чыга. 1917 дә 4 саны (соңгы 2 се басмаханәдә юк ителә), 1918 нең апрелендә — берданбер саны дөнья күрә. 1859–1914 тә укучыларга журнал б-н бергә җибәрелә торган кушымталар басыла (гадәттә, елына 2–3 әр китап). 1912–16 да, «П.с.» ж-лына кушымта буларак, «*Инородческое обозрение*» ж-лы нәшер ителә. 1855–70 тә редколлегия б-н Казан руханилар академиясе ректоры җитәкчелек итә, 1870 тә ректор баш мөхәррир була, оригиналларны — бер, тәрҗемәләрне икенче мөхәррир карый. Оригиналдагы әсәрләрнең мөхәррирләре: И.П.Гвоздев (1870 тән), П.В.*Знаменский* (1873 тән), тәрҗемә әсәрләренеке: Н.П.*Соколов* (1870 тән), А.А.*Некрасов* (1873 тән). 1879 дан журнал б-н бер генә мөхәррир җитәкчелек итә — *Антоний* (Вадковский),

1883 тән — А.А.*Красносельцев*, 1886 дан журнал б-н редколлегия (П.В.Знаменский, Н.Я.*Беляев*, И.С.*Бердников*) идарә итә. 1896–1918 дә кабат бер генә мөхәррир: 1896 дан П.В.Знаменский, 1897 дән С.А.*Терновский*, 1904 тән Л.И.*Писарев*, 1907 дән С.А.Терновский, 1913 тән В.А.*Никольский*.

1858–59 да Казан руханилар академиясе ректоры Иоанн (Соколов) җитәкчелегендә «П.с.» Россиядәге киң билгеле журналларның берсенә әверелә, анда крепостной хокукны тәнкыйтьләп чыккан мәкаләләр, хакимият органнары, җәмгыятьләр һәм чиркәүләрне реформалаштыру буенча тәкъдимнәр басыла (авторлар арасында — Иоанн үзе, А.П.Щапов һ.б.); Россиянең атаклы журналларында «П.с.» язмаларына карата рецензияләр һәм фикерләр дөнья күрә. Журналның юнәлеше консерваторларда тискәре реакция тудыра, Иоаннга шелтә белдерелә һәм Синод язмалар өстеннән күзәтү кертә; 1860 тан «П.с.»нең тиражы кискен кими. Алга таба журналның тиражы һәм эчтәлегенең сыйфаты, нигездә, финанслауга бәйле була. Акча аз бүлеп бирелгән чорларда гонорарлар кими, яисә бөтенләй




«Православный собеседник» журналы.

түләнми (1861–67, 1878–86, 1911 дән соң), анда күбрәк диссертацияләр һәм студентларның иң яхшы әсәрләре басыла. Аеруча уңышлы чорда академия һ.б. уку йортлары укытучыларының, руханиларның журнал өчен язылган мәкаләләре басыла. Журнал 1906–07 дә, Казан руханилар академиясенең либераль рухтагы профессоры Л.И.Писарев мөхәррирлек иткән чорда, кабат абруй казана, анда чиркәү реформалары турындагы тәкъдимнәр, мөһим сәяси проблемалар тикшерелә. 1911 дә, рухани академияләргә консерватив Уставлар кертелү сәбәпле, акад. журналларның эчтәлеге һәм структурасы Синодның ныклы күзәтүе астына куела. «П.с.» да Казан руханилар академиясе профессорларыннан күпчелегенең төп фәнни хезмәтләре (ш.и. бер үк вакытта яки соңрак аерым китап булып чыкканнары да) басыла. Алар арасында — тарихчы П.В.Знаменский, философлар В.А.Снегирёв, В.И.Несмелов, чиркәү белгече И.С.Бердников, әдәбият белгече И.Я.Порфирьев һ.б.ның дини тәгълимат, гомуми һәм Россия чиркәү тарихы, патрология, агиография, педагогика, тел белеменең төп бүлекләре буенча хезмәтләре. Журналда исламны (Н.И.Ильминский, Н.П.Остроумов, М.Я.Машанов), православие иске динен (И.М.Добротворский, Н.И.Ивановский, М.Н.Васильевский), будда динен (В.В.Миротворцев, Гурий (Степанов) өйрәнү мәсьәләләренә зур игътибар бирелә. Мәкаләләрнең күбесе татарлар һ.б. Идел буе халыкларының этнографиясенә, дини инануларына һәм тарихына багышлана. Журналда, башлыча, Соловки монастыре китапханәсе кульъязмаларына нигезләнеп, чиркәү тарихына багышланган әсәрләр һәм документлар, Вселенский собор Китапларының русчага тәрҗемәләре, ш.у. Рус православие чиркәвенең Стоглавый һ.б. Поместный соборлар Китаплары басыла. 2000 дә «П.с.» *Казан руханилар семинариясе* альманахы буларак кабат чыга башлый. Дини тәгълимат, фәлсәфә, Казан төбәге, рус теле тарихына багышланган язмалар, Казан епархиясендә булып узган фәнни конференция материаллары басыла.

*Әд.:* Л ю с т р и ц к и й В.Ф. Указатель к «Православному собеседнику» за двадцать лет его издания (с 1855–1875 г.). К., 1876; К р а с н о с е л ь ц е в Н.Ф. К истории «Православного собеседника»: По поводу 30-летия журнала // Православный собеседник. 1884. № 12; Указатель статей «Православного собеседника». 1877–1891 гг. К., 1892; Указатель к «Православному собеседнику» за 1892–1909 годы. К., 1910; Ж у р а в с к и й А.В. К истории «Православного собеседника» // Православный собеседник. 2000. Вып. 1.


*Е.В.Липаков.*

**ПРА́КСИН** Иван Александрович (28.7.1855, Сембер губ. Буа ш. — 30.4.1913, Казан), хирург, медицина д-ры (1890). 1874 тә Казан ун-тына укырга керә, 1877 елда Петербург мед.-хирургия академиясенең 3 нче курсына күчә. Академияне тәмамлаганнан соң (1880), проф. Е.И.Богдановскийның госпиталь хирургиясе клиникасында эшли (1880–84). 1885 тә 30 нчы резерв батальонында кече табиб. 1886 дан мохтаҗлар өчен Мария хастаханәсенең (С.-Петербург) хирургия бүлегендә; 1889 дан — мөдир. 1895 тән Тифлис хәрби госпиталенең хирургия бүлегендә консультант. 1897 дән Казан ун-тының госпиталь хирургиясе кафедрасында, проф. (1904). Хезмәтләре ларинготомиягә, корсак куышлыгындагы үтәли яраларны, перитонитны дәвалауга, мед. тарихына карый.

Х е з м.: О клиническом изучении хирургии // Врач. 1897. № 36; Пересадка кожного лоскута шеи в полость рта при рубцовом сведении челюстей в области межчелюстной складки // Тр. 2 съезда рос. хирургов. М., 1901; К симптоматологии и оперативному лечению обширных межуточных и осумковывающих кишечник соединительно-тканных образований при хроническом перитоните // шунда ук. С. 104–108.

*Әд.:* Е п и ф а н о в Н.С. Иван Александрович Праксин // Казан. мед. журн. 1982. № 2.

**ПРАЧЕ́НКО** Владимир Васильевич (21.1.1937, хәзер Белград өлкәсенең Алексеевка р-ны Алексеевка ш. — 29.8.2013, Казан), быргычы, ТАССРның халык артисты (1985). 1964 елда Казан консерваториясен (А.П.Колпинский классы) тәмамлый. 1960–64 һәм 1965–66 да Татар опера һәм балет театрында, 1964–65 тә — Чиләбе опера һәм балет театрында, 1966 дан Татар филармониясе Дәүләт симф. оркестрларында, 1990–2005 тә ТР Телевидение һәм радиотапшырулар Дәүләт ком-ты оркестрында, 2005 тән Татар филармониясе Дәүләт эстрада-симф. оркестрында. Бер үк вакытта, 1965 тән, Казан консерваториясе каршындагы Махсус урта музыка мәктәбендә, 1992 дән Казан консерваториясендә укыта. Оркестрлар составында Голландия, Бельгия, Франция, Төркия һ.б. илләрдә гастрольләрдә була. Классик һәм хәзерге музыка әсәрләреннән төзелгән репертуар б-н концерт эшчәнлеге алып бара. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.



В.В.Праченко.

Ә с ә р.: Переложения для трубы и фортепиано. К., 2005.

*Әд.:* К а н т о р Г.М. Казань музыкальная: Статьи, очерки, рецензии. К.–Йошкар-Ола, 1995.

**ПРЕКО́С ТОКЫМЛЫ́ САРЫКЛА́Р**, ит, йон өчен үрчетелә торган нәзек йонлы сарык токымы. 19 йөз ахырында Франциядә чыгарыла. Яңа шартларга җиңел җайлашу, конституциональ чыдамлык б-н аерылып тора. П.т.с. Украина, Белоруссия, Әзәрбайҗан, Грузиядә, Россиянең Кара туфраклы үзәк һәм Кара туфраклы булмаган зоналарында, Себер, Көньяк Африка, Көньяк Америкада, Европаның күп кенә илләрендә үрчетелә. Бу токым сарыкларына, югары продуктлылык б-н бергә, үрчемлелек, тиз җитлегү һәм азыкка талымсызлык хас. Азык сыйфаты һәм асралу шартлары тиешенчә булганда П.т.с.дан алынган чиста йон авырлыгы буенча башка нечкә йонлы токымнардан калышмый, җитлегү вакыты һәм ит сыйфаты ягыннан алардан уңышлырак санала. СССРда әлеге токым яңа 20 токым китереп чыгаруда файдаланыла һәм башка 24 токым аркылы яңа токымнар китереп чыгару процессында катнаша.

Татарстанга П.т.с. 1921 елда Германиядән кертелә, 1967–2000 дә күмәк һәм фермер хуҗалыкларындагы сарыкларның 76% ын шушы токым тәшкил итә. П.т.с. респ-каның 26 р-нында, ш.и. Азнакай р-ның Вахитов исем. нәселле терлек з-дында һ.б. р-ннардагы 10 нәселле терлек фермасында үрчетелә. 1980 елларда Чистай р-нының 20 нче партсъезд исем., Арча р-нының «Известия»,




Прекос токымлы сарык.

8 нче Март исем., Кукмара р-нының «Россия», Алабуга р-нының Гассар исем. к-зларында 100 сарыктан 120–165 бәрән алына. Азнакай р-нының «Урманай» нәсел с-зында, Буа р-нының «Россия» к-зында бер сарыктан 4,2–5,1 *кг* йон алына. Өстәмә тукландыру шартларында Вахитов исем. нәселле терлек з-дында 15,5 айлык сарыклардан уртача 6,3 *кг* йон кыркыла. Бу хуҗалыкта сарык асрауның рентабельлеге 84,7% ка җитә.

Тукландыру тиешенчә булганда яшь терлекләр тәүлеккә 200–250 *г* артым бирә, 6 айлык бәрәннәрнең авырлыгы 40 *кг* га җитә. Тәкәләрнең тереләй авырлыгы — 110–130, сарыкларныкы — 55–67 *кг.* Тәкәләрдән 7–9, сарыклардан 3,6–4,4 *кг* йон алына. Йонының озынлыгы 8,5–10 *см* (тәкәләр) һәм 8–9 *см* (сарыклар). Чиста йонның чыгышы — 45–50%. 1980 дә Татарстанда П.т.с.ның баш саны 389 мең тәшкил итә; 2010 ел башына — 6 мең.

*Әд.:* Мубаракшин П.М., Соколов В.В., Фазульзянов А.Х. Прекосы заслуживают большего внимания // Овцеводство. 1984. № 2; Мороз В.А. Овцеводство и козоводство. Ставрополь, 2002; Ульянов А.Н. Овцеводство. Краснодар, 2004. *Ә.Х.Фазылҗанов.*

**ПРЕОБРАЖЕ́НСКАЯ** Мария Николаевна (8.12.1878, С.-Петербург — 12.3.1953, Казан), драма актрисасы, ТАССРның халык, РСФСРның атказ. артисты (1939, 1942). Зур театрның Казанга гастрольләр б-н еш килгән һәм 1898–1900 елларда Казанда җыр класслары б-н җитәкчелек иткән танылган солисты Н.А.Преображенский кызы. С.-Петербургта опера-драма курсларын тәмамлый (1895), М.М.Читау һәм М.И.Писаревта белем ала. 1903 тә драма актрисасы буларак беренче тапкыр сәхнәгә чыга. 1907 дә Тула театры актрисасы, аннан соң Архангельск, Воронеж, Саратов, Вятка, Түбән Новгород, Волгоград шәһәрләре театрларында эшли. 1936 дан Казан Зур драма театрында. Рус реалистик актёрлар мәктәбе вәкиле, образга керү остасы буларак, П. Казан театры сәхнәсендә шәһәрнең театр тормышында сизелерлек эз калдырган шактый гына зур образлар иҗат итә. Актрисаның Гурмыжская, Барабошева, Манефа («Урман», «Дөреслек әйбәт, ә бәхет яхшырак», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Хлёстова («Акыллылык бәласе», А.С.Грибоедов), Марфа Тимофеевна («Дворяннар оясы», И.С.Тургенев романы буенча), Бережкова («Текә яр», И.А.Гончаров романы буенча), Василиса Волохова («Фёдор патша», А.К.Толстой), Ефросинья Старицкая («Иван Грозный», А.Н.Толстой), Васса Железнова (М.Горькийның шул исем. әсәре буенча) кебек рольләре тормыштагы күзәтүләр байлыгы, үзенчәлекле детальләр сайлап алудагы төгәллеге, иҗат ителгән образга социаль күренеш масштабын бирә белүе ягыннан аерылып тора. Рус халкы холкына хас сыйфат үзенчәлекләрен П. Аксинья («Фельдмаршал Кутузов», В.А.Соловьёв), Марфа Петровна («Рус кешеләре», К.М.Симонов), няня («Ябырылу», Л.М.Леонов), Зорина («Яшәү чыганагыбыз булган икмәк», Н.Е.Вирта), Мария Львовна («Профессор Полежаев», Л.Н.Рахманов) образларында ачып күрсәтә. Аның героиняларына хас булган рухи юмартлык, ачыклык, эчке нәзакәтлелек, ярдәмчеллек, кеше хәленә керә белү, рухи байлык кебек сыйфатлар тамашачы аңында рус хатын-кызы образын формалаштыра. Актрисаның иҗат палитрасына ш.у. комик һәм сатирик буяулар да хас (мадам Ксидиас — «Интервенция», Л.И.Славин; Роза Еремеевна — «Ял көне», В.П.Катаев). Яралылар өчен 325 концерт куя; ятим балаларга ярдәм күрсәтә (балалар йортларына үз керемennән өлеш чыгара). Медальләр б-н бүләкләнә.


М.Н.Преображенская.

*Әд.:* Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4. *Ю.А.Благов.*



М.Н.Преображенская: 1. Васса Железнова (М.Горькийның шул исем. әсәре буенча); 2. Барабошева («Дөреслек әйбәт, ә бәхет яхшырак», А.Н.Островский) рольләрендә.

**ПРЕСНЯКО́В** Владимир Васильевич (12.12.1951, Бөгелмә ш.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), ТРның атказ. нефть химиясе белгече (2006). Казан химия-технол. ин-тын (1976), Мәскәү авиация ин-тын (2004) тәмамлый. 1976–77 елларда Түбән Кама шин з-дында өлкән мастер булып эшли. 1977–87, 1997–2003 тә «Түбәнкаманефтехим» АҖдә: өлкән мастер, цех механигы, берләшмәнең капиталь төзелеш идарәсе башлыгы урынбасары, АҖнең ген. директоры ярдәмчесе, урынбасары (1998 дән). 1987–90 да «Петрокам» уртак пр-тиесендә баш инженер, 1991–2003 тә «Полифом» пр-тиесенең ген. директоры урынбасары (Түбән Кама ш.). 2003 тән «ТАИФ» АҖ ген. директоры урынбасары. Уйлап табуга патенты бар. Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләгәнгә һәм гамәлгә керткәнгә өчен бирелә.

**ПРИБАВЛЕ́НИЕ К «КАЗА́НСКОМУ ВЕ́СТНИКУ»**, газета, к. «*Казанский вестник*».

**ПРИБО́Й** посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Әрә елгасы буенда. 2010 елда 54 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1920 ләрдә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Норлат волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1938 дә — 181, 1949 да — 138, 1958 дә — 111, 1970 тә — 131, 1979 да — 82, 1989 да — 57, 2002 дә 59 кеше.

**ПРИБЫ́ТКОВЛАР**, Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре. **Александр Андреевич** (? – ?) — сәүдәгәрләр нәселенә нигез салучы, 3 нче гильдия сәүдәгәр. Аның улы **Павел Александрович** (1810, Вологда — 21.9.1883, Казан), 2 нче гильдия сәүдәгәр, дәрәҗәле граждан. Адмиралтейство бистәсендә тире эшкәртү з-ды хуҗасы. 1863–65 елларда Казан шәһәре башлыгы. Күп еллар дәвамында Боголюбов чиркәве старостасы. «Изге Гурий борадәрлеге»н оештыручыларның берсе. Хатыны **Екатерина Сергеевна** (к. *Павловлар*) (1823, Казан — 23.3.1897, шунда ук), 1 нче гильдия сәүдәгәр, хәйрияче. Эшләрен иреннән аерым алып бара. Атасы С.Е.Павловтан Адмиралтейство бистәсендәге күн з-дын мирас итеп ала. 1870 еллар уртасында завод 100 мең сумлык, 1881 дә 260 мең сумлык әйбер җитештерә. Проломный урамында кибетләре була, Гостиный дворда, Түбән Новгород, Сембер, Минзәлә, Мамадыш һәм Эрбет ярминкәләрендә сәүдә биналарын файдалануга алып тора. 1870 тә Боголюбов чиркәве каршында Сергей б-н Евдокия Павловлар һәм аларның кызлары Екатерина Прибыткова исем., 43 мең сум капиталы булган картлар йорты ачтыра. Аның акчасына ике катлы таш йорт салына (флигель һәм хуҗалык бүлмәләре ире акчасына төзелә). Картлар йорты 1917 елга кадәр П. химаясендә була. **Александр Павлович** (? – ?) 1 нче гильдия сәүдәгәр, нәселдән килгән мактаулы граждан. Мәскәү сәүдә фәннәре гамәли академиясен тәмамлый. Берничә тапкыр Казан шәһәр думасы гласные итеп сайлана. Хәйриячелек б-н шөгыльләнә. Адмиралтейство хастаханәсе попечителе, аның бинасын яңартуга һәм төзекләндерүгә 55 мең сум акча бүлеп бирә. *Л.М.Свердлова.*

**ПРИВА́ЛОВ** Дмитрий Карпович (1908, Казан губ. Чистай өязе — 1.11.1943, Украина ССРның Полтава өлкәсе Пирятин ш.), Сов. Союзы Герое (23.10.1943), старшина. Туган авылында колхоз рәисе булып эшли. 1941 елның августыннан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында 957 нче укчы полкта җәяүле разведка взводының отделение командиры (40 нчы армиянең 309 нчы укчы дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш һәм Воронеж фронтлары гаскәрләре составында Десна һәм Тим елгалары (1941) оборона сугышларында, Воронеж-Ворошиловград (1942) һәм Острогожск-Россошь (1943) операцияләрендә катнаша. Балыко-Щучинка авылы (Киев өлкәсе Кагарлык р-ны) тирәсендә Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 24 сентябрендә сугышчылар төркеме башында беренчеләрдән булып елганы йөзеп чыга, уңъяк ярда плацдарм яулап алуда һәм сугыш барышында дошман контрһөҗүмнәрен кире кайтаруда катнаша, ике тапкыр яралана. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Чистай шәһәрендәге бер урамга П. исеме бирелгән, шәһәр паркында стела куелган.



Д.К.Привалов.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПРИВО́ЛЖСКИЙ** посёлогы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 4 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 465 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Куйбышев сусаклагычы астында калган Яңа Мордва авылыннан күченүчеләр 1955 тә нигез сала. Оештырылган көннән Куйбышев р-нында. 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1970 тә — 493, 1979 да — 459, 1989 да — 476, 2002 дә — 469 кеше.

**«ПРИВО́ЛЖСКИЙ КРАЙ»** («Идел буе төбәге»), атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1909 елның 6 октябреннән 1910 нның 19 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. 1909 ның 4 октябрендә чыгудан туктаган «*Волжский листок*» г-тасының дәвамчысы. «Зур прогрессив-демократик газета» дигән өстәмә баш б-н чыга. Мөхәррире — И.П.Кочергин; сов. историографиясе буенча, рәсми мөхәррире РСДРПның Казан ком-ты җитәкчесе Н.Н.Лотов. Газетага с. -д.ның көчле йогынтысы зур була. Мәкаләләрнең күбесендә авторлары күрсәтелми, әдәби әсәрләр генә, гадәттә, авторы күрсәтелеп бирелә (А.С.Бухов, В.Бланк, П.Л.Драверт, Н.С.Охотин — псевд. Изгнанник һ.б.). Реакция чорындагы көчле цензура шартларында редакция, нигездә, кыска мәгълүмати материаллар һәм илдәге, дөньядагы (бигрәк тә Ерак Көнчыгыштагы) иҗтимагый-сәяси вакыйгалар хроникасын, шәһәр думасы һәм шәһәр советы киңәшмәләре турындагы хәбәрләр бирә. Баш күтәрүләр, профсоюзларны эзәрлекләү, алдынгы газета мөхәррирләрен кулга алулар хакындагы кыска хәбәрләр читләтеп с. -д. әйтергә теләгәнне чагылдыралар. Җирле темалар арасында төп игътибар Казан шәһәр думасы эшчәнлегенә, социаль-икътисади вазгыятькә юнәлдерелә. Газета сәүдәгәрләр һәм йорт хуҗаларыннан торган шәһәр думасы начар хезмәт шартларына, нигезсез эштән чыгаруларга, эшчеләрнең хезмәт хакларын киметүгә һ.б. игътибар итми дип белдерә. Профсоюзлар һәм кооперативлар хәрәкәте мәсьәләләре буенча проблемалы төп мәкаләләр «Хезмәт тормышы» рубрикасы б-н бирелә, рубрика еш кына аерым биткә урнаштырыла. Профсоюзлар хәрәкәтендәге төшенкелекнең төп сәбәпләре итеп газета гамәлдәге законнарны, хөкүмәт сәясәтен, сәнагатьтәге торгынлык һәм җимереклекне күрсәтә. Газета профсоюзларны эшчеләрнең берләшергә омтылуларына активрак ярдәм итәргә чакыра; хөкүмәтнең авырулардан иминиятләштерү турындагы закон проектына, кеше хокукларын кысучы чара буларак, каршы чыга. «Хезмәт ияләренең икътисади хәрәкәте төрләре» мәкаләсендә, читләтеп, пролетариатның сәяси хәрәкәтләре зарурлыгы турында әйтелә. Газета либераль һәм монархиячел оешмалар турындагы тискәре фикердә тора; кадетларның «Камско-Волжская речь» г-тасын тәнкыйтьли; «Казан» патриотлары» мәкаләсендә карагруһчылар В.Ф.Залесскийның һәм Ю.Ю.Кудиновның 1909 да Мәскәүдә булган монархистлар съездындагы үз-үзләрен тотышларын, аерым алганда, милли мәсьәлә буенча ясаган чыгышларын фаш итә. Казан кулланучылар җәмгыятенең «Хезмәт союзы» эшчәнлегенә зур игътибар бирелә. Крәстияннәрне яклап, газета хөкүмәтне салымның түләнми калган өлешен түләттерүне туктатырга, авыл җирлегендә вак һөнәрчелек һәм промыселларны үстерергә, авыл товар җитештерүчеләренә ташламалар ясарга, һөнәри мәктәпләр ачарга чакыра.

*Әд.:* Н а ф и г о в Р.И. Казанская социал-демократическая организация в 1907–1914 годах (Краткий очерк). К., 1961; Е н и к е е в Э.А. Деятельность Казанских большевиков по революционному воспитанию студенческой молодёжи (1905 — февраль 1917). К., 1973.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ПРИКА́ЗЧИКЛАР ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́**, Казандагы җәмәгать хәйрия оешмасы (1866–1917). Төп максаты — бер-берсен үзара якынайту аша мөмкинлеккә карап җәмгыять әгъзаларының көнкүреш хәлен яхшырту, файдалы мәгълүмат тарату, мохтаҗларга матди ярдәм күрсәтү. Тол хатыннарга, ятимнәргә пособиеләр һәм пенсияләр билгели, укучылар һәм студентларның укуы өчен түли, үз әгъзаларына эшкә урнашырга ярдәм итә. Устав буенча еллык кертемнәрен түләп барган 55 яшькә кадәрге сәүдә хезмәткәре җәмгыятьнең хакыйкый әгъзасы була алган. Җитәкче орган — 7 кешедән торган идарә, гомуми җыелыш тарафыннан сайланган. Җәмгыятьнең беренче рәисе В.Н.Емельянов була. П.х.җ.нең капиталы турыдан-туры сәүдәгәрләр һәм эшмәкәрләр — бертуган Крестовниковлар, П.В.Щетинкин, Д.А.Черкасов, Н.Н.Чарушин һ.б. кертемнәре хисабына туплана. 1885 елда җәмгыятьтә 500 дән артык хакыйкый әгъза һәм 54 ярышучы әгъза (хакыйкый әгъзалыкка кандидат) исәпләнә, аның капиталы 46 мең сум тәшкил итә. Җәмгыять каршында саклык кассасы, үзара ярдәм кассасы, китапханә (3000 нән артык китап), кибет эшли. 25 ел эчендә җәмгыять 30 мең сумлык пособие бирә. Җәмгыять әгъзалары өчен түләүсез мед. ярдәме оештырыла. Җәмгыять агарту эшчәнлеге б-н шөгыльләнә: әдәби-музыкаль һәм гаилә кичәләре уздыра; бухгалтерия, математика, чит телләр буенча курслар оештыра. 20 йөз башында җәмгыять акчасына бина сатып алына һәм клуб ачыла, ул 1905–17 дә җирле социаль-демократик һәм конституцион-демократик партияләрнең яшерен эшчәнлеген легальләштерү чарасы буларак файдаланыла. Окт. рев-циясеннән соң яшәүдән туктый.

*Әд.:* П и н е г и н М. Казань в её прошлом и настоящем. СПб., 1890; З а г о с к и н Н.П. Спутник по Казани. К., 1895; С в е р д л о в а Л.М. На перекрёстке торговых путей. К., 1991.

*М.Ю.Гребёнкин.*

**«ПРИКАМНЕ́ФТЬ»**, «Татнефть» АҖнең нефть чыганакларын эшкәртү, нефть һәм газ чыгару, әзерләү һәм ташу, нефть һәм газ сәнәгате объектларын проектлау, төзү һәм файдалану б-н шөгыльләнүче нефть-газ чыгару идарәсе (НГДУ). Алабуга шәһәрендә урнашкан. Эшләүчеләр саны — 828 кеше (2012). 1961 елда Бондюг чыганагының берничә разведка скважинасыннан 1958 дән башлап нефть чыгарган Бондюг эреләндерелгән промыселы җирлегендә «П.» нефть промыселы идарәсе буларак оештырыла. 1970 тән — «П.» НГДУы. НГДУ составында: нефть чыгаручы 3 цех, нефтьне әзерләү һәм кудыручы 2 цех, катламнарның басымын нормада тоту, скважиналарны җир астында ремонтлау, җитештерүне автоматлаштыру цехлары. Респ-каның төньяк-көнчыгышында урнашкан 9 адм. район терр-ясендәге 22 чыганакны эшкәртә. Чыганакларның күпчелеге катлам басымын саклау алымы б-н кудыргыч скважиналарга су кудырып эшкәртелә. Түбән Кама сусаклагычы сулары астында калу зонасында урнашкан кайбер чыганаклар (Бондюг, Беренче Май чыганаклары) басымнан дамбалар б-н саклана, скважиналардан файдалану эшләре дамба алдындагы мәйданчыклардан, махсус корылган нигезләрдән торып алып барыла. Гидротехник корылмаларда 150 дән артык скважина эшли. Нефтьнең 20% тан артык өлеше нефть бирүчәнлекне арттыру хисабына чыгарыла, моның өчен катламга физик-химик, геол.-физик басым ясау алымнары комплекслы автоматлаштырыла. 1975 тә нефть чыгаруның макс. еллык күләменә ирешелә (5 млн. 845 мең *т*). 2013 ел башына барлыгы 160,0 млн. *т*, елына уртача 2 млн. *т* дан артык нефть чыгарыла. Чыгарылган продукциянең сулылыгы 86%, скважиналардан файдалануның төп ысулы — насос куллану. 2012 ел башына 2350 дән артык скважина бораулана, файдалану фондын 1040 чыгаручы һәм 430 басым тудыручы скважиналар тәшкил итә. Нефть җыюда герметик система кулланыла. Нефтьне комплекслы

әзерләү 4 җайланмада башкарыла. Табигатьне саклауга (бигрәк тә Түбән Кама милли паркы зонасында эшләгәндә) зур игътибар бирелә.

НГДУ — шәһәр коручы пр-тие, Алабугада тораклар, халык мәгарифе, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәни объектлар, мәктәпкәчә, спорт учреждениеләре һ.б. төзелеше заказчысы. «П.»нең санаторий-профилакторие, балаларны сәламәтләндерү лагере, ат спорты мәктәбе һ.б. бар. Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 11 кешегә — РСФСР, РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре, 18 кешегә — ТРның атказ. нефтьчесе, 2 кешегә — РСФСРның атказ. геологы, 1 кешегә — РФнең атказ. энергетигы, 4 кешегә ТАССР, РСФСРның атказ. төзүчесе, 2 кешегә ТРның атказанган икътисадчысы дигән мактаулы исемнәр бирелә; 3 кеше — Ленин ордены, 7 кеше — Октябрь Революциясе, 22 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 20 кеше — «Почёт билгесе», 19 кеше — 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 1 кеше — Дуслык ордены медале б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: В.М.Шестернин (1958–61), Б.Л.Сапгир (1961–73), Ә.К.Мөхәммәтҗанов (1973–79), М.Ш.Җәләтов (1979–85), Н.К.Җамалетдинов (1985–2007), Г.Н.Шариков (2007 дән).

*Әд.:* Абзянов М., Мухаметзянов А., Фархутдинов А. Вышки над Камой. К., 1978; Золото Прикамья. Елабуга, 1998.

*Г.Я.Мәүлетова.*

**«ПРИКА́МСКАЯ»**, эре бөртекле карабодай сорты. 1974 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында селекция белгечләре Ф.З.Кадыйрова һәм Н.Н.Петелина тарафыннан «Майская» сортыннан салкынга чыдам формаларын сайлап алу юлы б-н чыгарыла. Уртача өлгерешле, 85–90 көндә, районлаштырылган зоналарда башка сортларга караганда 4–6 көнгә иртәрәк өлгерә. Бердәм чәчәк атуы һәм берьюлы өлгерүе б-н аерылып тора. Уртача уңышы 1 *га* дан 1,4–1,8 *т*. Уңышы «Краснострелецкая» (1 *га* дан 0,3 *т* га), «Калининская» (1 *га* дан 0,6 *т* га) сортларыннан югары. Салкынга чыдамлыгы югары, корылыкка чыдамлыгы уртача, бөртегенең технол. күрсәткечләре югары. Кыйммәтле сортлар исемлегенә кертелгән. 1000 бөртекнең авырлыгы 30–32 *г*, элпәлелеге — 23–24%, тигезлеге — 97%, ярма чыгышы 71–73%, ярмадагы аксым 16% тәшкил итә. «П.» сорты СССР ВДНХсының көмеш медаленә лаек була (1981). Марий Эл Респ-касында районлаштырыла.

*Ф.З.Кадыйрова.*

**ПРИОЗЁРНАЯ** авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 55 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 103 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чирмешән, Крутояр буларак та билгеле; 1967 нең 11 августына кадәр Абалдуевка исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында анда Троица чиркәве (1883–86 елларда төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, 1 су һәм 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1284 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Мораса волостенда, 1920 дән ТАССРның — Спас, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 71 ир-ат; 1859 да — 446, 1897 дә — 871, 1908 дә — 852, 1920 дә — 820, 1926 да — 804, 1938 дә — 593, 1949 да — 367, 1958 дә — 318, 1970 тә — 265, 1979 да — 125, 1989 да — 113, 2002 дә — 116 кеше.

**ПРИХОЖА́Н** Пётр Борисович (11.2.1940, Кырым АССРның Евпатория ш.), шагыйрь. Харьков төзүче-инженерлар ин-тын тәмамлый (1964). Братск урман сәнәгате комплексын, КамАЗ, «Атоммаш» (Ростов өлкәсенең Волгодонск ш.) з-дын төзүдә катнаша. 1971 елдан Чаллыда яши. Беренче шигырьләре матбугатта 1962 дә басыла башлый. Иҗатында мәхәббәт һәм гражданлык лирикасы өстенлек итә. «Гулливерлар» («Гулливеры», 1970), «Танышу» («Знакомство», 1986), «Күрәзә өчен түләү» («Плата за гадание», 1990) шигъри җыентыклары авторы. «Шәһри Китеж турында уйлану» («Дума о граде Китеже», 1970), «Төзелеш» («Стройка», 1989), «Алексей һәм Афросинья» («Алексей и Афросинья», 2000) поэмаларында Россиянең тарихи вакыйгалары автор фикерләвендә бирелә. «Критерийлар» («Критерии», 1998) поэмасы поэзиянең кеше шәхесе үсешенә тәэсир итүенә багышлана. Рус теленә Г.Тукай, Г.Кашапов, И.Юзеев, Н.Мадьяров, Р.Миңнуллин һ.б.ның шигырьләрен тәрҗемә итә.

*Әд.:* Хуснуллин Х. Идущий за четвёртым ветром // Светлый путь. 1992. 24 окт.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**«ПРИЧА́Л»** журнал; к. «*Коммунист Татарии*».

**ПРИЮ́Т-ШУРА́Н** авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* төньяктарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 70 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мажын буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чана һәм арба ясау б-н шөгыльләнә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Богодаровка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 193, 1920 дә — 379, 1926 да — 312, 1938 дә — 523, 1949 да — 438, 1958 дә — 349, 1970 тә — 235, 1979 да — 184, 1989 да — 100, 2002 дә — 76 кеше.

**ПРОБЛЕ́МАЛЫ УКЫТУ́**, укучыларның эзләнү эшчәнлекләренең психол. закончалыкларын исәпкә алу һәм танып белү операцияләрен эзлекле рәвештә гамәлгә ашыру нигезендә төзелгән укыту алымнары һәм чаралары системасы. П.у.ның нигезендә проблемалы ситуация тудыру һәм бу проблеманың чишелешен эзләп табу б-н идарә итү хисабына реаль иҗади процессны модельләштерү ята. Хәзерге пед. һәм психол. фәннәрендә П.у. идеяләре һәм принциплары 1960 еллар башыннан эшләнә (А.М.Данилов, Т.В.Кудрявцев, А.М.Матюшкин, И.Я.Лернер, М.Н.Скаткин, Ю.К.Бабанский, Ж.В.*Вилькиев* һ.б.). П.у. башта укыту процессын оптимальләштерү алымнарының берсе буларак карала. П.у. теориясен формалаштыруда һәм гамәлгә кертүдә әйдәп баручы рольне М.И.*Мәхмутов* башкара, ул П.у. теориясен булдыра, методология базасын, алымнар номенклатурасын, проблемалы дәреснең тулы теориясен үз эченә алган системалы оригиналь концепциясен эшли. Аның нигезендә 1970 еллар уртасыннан П.у. теориясе һәм практикасы проблемаларын өйрәнү СССРда, аннан соң РФдә пед. үсешенең әһәмиятле юнәлешләреннән берсенә әйләнә. ТРда П.у.ның үзәге булып *Педагогика һәм психология һөнәри белем бирү институты* һәм *Татар гуманитар-педагогика университеты* (хәзер Казан (Идел буе) федераль ун-ты) тора.

*Әд.:* Махмутов М.И. Теория и практика проблемного обучения. К., 1972; шул ук. Проблемное обучение: Основные вопросы теории. М., 1975; шул ук. Организация проблемного обучения в школе. М., 1977; Ковалевская Е.В. Проблемное обучение: подход, метод, тип, система (на материале обучения иностранным языкам). М., 2000; Сафиуллина И.А. Теория проблемного обучения М.И.Махмутова. К., 2002.

**ПРОБУЖДЕ́НИЕ**, к. *Алан*, Сарман р-ны.

**ПРОБУЖДЕ́НИЕ** посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 11 *км* төньяктарак, Кама елгасы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 1920 ләрдә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Чаллы кантоны Афанас волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 38, 1949 да — 49, 1958 дә — 54, 1970 тә — 71, 1979 да — 67, 1989 да — 28, 2002 дә — 10 кеше.

**ПРОВИ́НЦИЯЛӘР**, 1719–75 елларда Россиядә губерналар составындагы адм.-терр. берәмлекләр. Өязләргә бүленәләр. Воеводалар тарафыннан идарә ителәләр. Казан губернасы башта Казан, Зөя, Пенза, Уфа П.еннән тора. П.нең саны, кайсы губерна карамагындалыгы үзгәрешләр кичерә: 1720 еллар ахырында губерна составына Вятка һәм Соль-Камский П.е кертелә, Уфа провинциясе чыгарыла (1731–34 тә яңадан Казан губернасына буйсынулы) һ.б.ш. 1775 кә Казан губернасында Казан, Вятка, Пермь, Зөя, Пенза, Сембер П.ләре исәпләнә.

*Әд.:* Готье Ю.В. История областного управления в России от Петра I до Екатерины II: В 2 т. М.–Л., 1913–41.

**ПРОВОТО́РОВ** Николай Сергеевич (31.7.1918, Самара губ., Бөгелмә өязе Пальная а. — 16.2.1975, Краснодар ш.), драма актёры, режиссёр, ТАССРның атказ., РСФСРның халык артисты (1954, 1971). 1939–41 елларда Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында укый. Бер үк вакытта,

1940–41 дә, Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) спектакльләрендә катнаша, анда ул Вивиани («Бөек еретик», И.Персонов, Г.Добржинский) һәм Лазаревский («Качу», Д.А.Щеглов) рольләрен башкара. 1941 дә ин-т Омск шәһәренә күчерелә, П., укуын дәвам иткән хәлдә, Омск драма театрында куелган спектакльләрдә зур булмаган рольләр уйный. Сәхнәгә беренче тапкыр 1944 тә Ульянов драма театрында чыга, 1950 дә Ю.А.Завадский тарафыннан Моссовет исем. Мәскәү театрына чакырып алына. 1952–63 тә Казан Зур драма театры актёры. Беренче роле — Володя Ульянов («Гаилә», И.Ф.Попов) П.ны Казан труппасының әйдәп баручы актёрлары рәтенә чыгара. Һәр гамәлнең психол. дәлилләнеше, даими рәвештә сәхнә тормышы б-н яшәү аның сәләтенең бик тә мөһим, үзенчәлекле якларын билгели һәм шактый гына зур рольләр иҗат итәргә мөмкинлек тудыра: Николай Селихов («Хәтәр юлдаш», А.Д.Салынский, 1953), прапорщик Звонарёв («Порт-Артур», А.Н.Степанов, И.Ф.Попов, 1953), Стогов («Эшлекле», И.Городецкий, 1954), Ведерников («Ил гизү еллары», А.Н.Арбузов, 1954), Сергей Чагин («Үз балаларының әнисе», А.Н.Афиногенов, 1955), Муса Җәлил («Үлмәс җыр», Р.Ф.Ишморат, 1956), Габдулла Тукай («Тукай Петербургта» телевизион спектакле, 1962). Н.Ф.Погодинның «Баһадирлар» (1958) һәм «Кремль курантлары» (1962) пьесалары буенча куелган спектакльләрдә П. иҗат иткән Ленин образы актёрның иҗади казанышы булып тора. Классик репертуарда да шактый гына рольләр башкара: дон Карлос (Ф.Шиллерның шул исем. әсәре буенча), Моска («Вольпоне», Б.Джонсон), Фигаро («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), Бастрюков («Иделдә йокы», А.Н.Островский), Трофимов («Чия бакчасы», А.П.Чехов). Актёр тарафыннан иҗат ителгән замандашлары образлары социаль характеристиканың төгәллеге б-н үзенчәлекле: Иван Рыбаков (В.М.Гусевның шул исем. әсәре буенча), Большаков («Югары көчәнеш», И.П.Куприянов), Платонов («Океан», А.П.Штейн), Иван Ручейков («Бүген һәм һәрвакыт», Г.М.Мазин). Үзен режиссёр буларак та таныта, Казан Зур драма театры сәхнәсендә «Аерылышудан соң» («После разлуки», бертуган Турлар) һәм «Разведчик хатын-кызлар» («Разведчицы», И.М.Соболев) спектакльләрен куя. Бернича ел дәвамында Казан ун-тында студентлар театры б-н җитәкчелек итә. Анда ул «Чоңгыл» («Пучина», А.Н.Островский) һәм «Мещаннар» («Мещане», М.Горький) спектакльләрен сәхнәләштерә. Аннан соңгы елларда Кишинёв, Ростов-Дон, Краснодар шәһәрләрендәге театрларда эшли. Матбугатта театр сәнгатенең заманча проблемаларын яктырткан мәкаләләре дөнья күрә, җәмәгать эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты, ТАССРның Г.Тукай исем. (1959), РСФСРның К.С.Станиславский исем. Дәүләт бүләкләре лауреаты (1971).



Н.С. Провоторов.

Х е з м.: К заветной цели // Мы из Советской Татарии. К., 1962; Вперёд, к Станиславскому! // Театральная жизнь. 1969. № 14; Призвание актёра // Театральная жизнь. 1971. № 5.

*Әд.:* Ф р и д Ю. Человек, художник, гражданин // Театральная жизнь. 1960. № 22; Т о л ч ё н о в а Н. О Ленине // Огонёк. 1970. № 9; М а к а р е н к о Ю. Народный артист // Кубань. 1973. № 10; И н г в а р И. Казанская театральная лениниана. К., 1989; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ПРОГРЕ́СС** посёлогы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 5 *км* төньяктарак урнашкан. 2010 елда 644 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 48%, татарлар — 40%) яши. «Птицевод» дәүләт нәселле кош үрчетү з-ды. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Торак пункт буларак 1960 ның 16 февралендә теркәлә. Оештырылган көннән Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1970 тә — 413, 1979 да — 520, 1989 да — 676, 2002 дә — 764 кеше.

**ПРОДНАЛО́Г**, а з ы к - т ө л е к  с а л ы м ы, крәстиян хуҗалыкларыннан натуралата түләнә торган билгеле бер төгәл күләмдәге салым; *яңа икътисади сәясәтнең* (нэп) беренче гамәле. Бөтенроссия ҮБКның 1921 ел 21 март Декреты б-н *продразвёрстка* урынына кертелә. П. күләме язгы чәчүгә кадәр, а.х. продукциясенең һәр төре буенча (продразвёрсткадан шактый түбән күләмдә), җирле шартларны һәм крәстиян хуҗалыкларының хәленә карап билгеләнә. Совет дәүләтенең 1921 ел март–апрель Декретлары б-н икмәккә, бәрәңгегә, майга, орлыкларга, йомыркага, сөт продуктларына, йонга, тире чималына һ.б.га натуралата салым күләме куела. Шул ук елда, Татарстанда икмәк уңышы түбән булу сәбәпле, П. бетерелә; 1922–23 тә П. буенча 6 млн.нан артык пот икмәк (яки икмәкнең тулай җыемының 11,5% ы) җыеп алына. П. кертү сәүдәне, авылдагы хуҗалык мөнәсәбәтләрен җанландырып җибәрә. 1923 нең ахырында ул акчалата салым б-н алыштырыла.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ПРОДРАЗВЁРСТКА**, а з ы к - т ө л е к н е  м ә җ б ү р и  с а т т ы р у, а.х. продуктларын әзерләү системасы; Совет дәүләтенең «*хәрби коммунизм*» чоры сәясәтенең мөһим өлеше. Крәстияннәр шәхси һәм хуҗалык хаҗәтләренә билгеләнгән нормадан арткан икмәк һәм башка а.х. продуктларын алдан билгеләнгән бәягә дәүләткә тапшырырга мәҗбүр ителә. Россиядә П. кертү тәҗрибәсе Беренче бөтендөнья сугышы елларында кулланыла; патша хөкүмәте 1916 елда Россиянең Европа өлешендәге 31 губернасында (ш.и. Казан губернасында да) икмәккә ныклы бәя куярга, 1917 нең 1 гыйнварыннан Россия армиясен тәэмин итәргә тиешле икмәкне ш.у. ныклы бәядән кабул итәргә омтылыш ясый. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Вакытлы хөкүмәт тә П.ны бөтен ил күләмендә җәелдерергә һәм икмәккә ныклы бәя куярга омтылып карый. Гражданнар сугышы башыннан, 1918 нең 2 нче яртысында Сов. Россиясендә РСФСР Азык-төлек халык комис-тының губерналардагы органнарына үзләреннән арткан икмәкне яшереп тотучы һәм икмәк б-н «астан» (спекулянтлар һәм «капчыклы» крәстияннәр аша) сату итүче крәстияннәргә карата гадәттән тыш чаралар күрү вәкаләте биргән азык-төлек диктатурасы урнаштырыла. П. ул чорда бар төбәкләргә дә кагылмый. 1919 ның 11 гыйнварыннан, ХКС декреты нигезендә, П. бөтен ил терр-ясендә, соңрак Украина, Белоруссия, Төркестан һәм Себердә кертелә. РСФСР Азык-төлек халык комис-тының азык-төлекне мәҗбүри саттыру тәртипләре турындагы 1919 ел 13 гыйнвар карары нигезендә дәүләт план-йөкләмәләре губерналар буенча чәчүлек мәйданнары, алынган уңыш һәм алдагы еллардан калган запаслар күлә-







Н.С. П р о в о т о р о в 1. В.И.Ленин («Баһадирлар», Н.Ф. Погодин); 2. Муса Җәлил («Үлмәс җыр», Р.Ф. Ишморат); 3. Прапорщик Звонарёв («Порт-Артур», А.Н. Степанов, И.Ф. Попов, уңда – И.В.Загорский) рольләрендә.

меннән чыгып билгеләнә. П. җирле хакимият структуралары һәм *ярлылар комитеты* ярдәмендә Азык-төлек халык комис-ты органнары һәм азык-төлек отрядлары тарафыннан тормышка ашырыла. Баштарак П. икмәк һәм бөртеклеләр фуражына гына кагылса, 1919–20 еллар кампаниясендә бәрәңге һәм итне, ә 1920 ел ахырыннан барлык төр а.х. продукциясен дә үз эченә ала. 1919–20, 1920–21 еллар азык-төлек әзерләү кампанияләре чорында Казан губернасында 20 млн. пот икмәк, берничә млн. пот башка төр а.х. продукциясе җыела. Җыелганның күпчелеге губернадан читкә чыгарыла. П. кертелү сов. җитәкчелегенә Кызыл Армияне, шәһәр халкын азык-төлек, сәнәгатьне — чимал б-н тәэмин итәргә күпмедер күләмдә мөмкинлек бирә. П. кампанияләре вакытында гадәттән тыш чаралар куллану товар-акча һәм базар мөнәсәбәтләренең тараюына (икмәк, ашлык һ.б. б-н ирекле сәүдә тыела), шәһәр һәм авыл арасында турыдан-туры товар алмашы урнашуга, чәчүлек мәйданнар, терлекләрнең баш саны кимүгә һәм крәстияннәрнең үз хуҗалыгы хаҗәтләре өчен генә җитештерә башлауга күчүенә китерә. П. сәясәте крәстияннәрдә ризасызлык тудыра (к. *Арча крәстияннәре кузгалышы, «Сәнәкчеләр» фетнәсе*). 1921 нең мартыннан *яңа икътисади сәясәткә* күчкәч, П. *продналог* б-н алыштырыла.

*Әд.:* Т а г и р о в И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

*Р.В.Шәйдуллин.*

**ПРОЕ́КТЛАУ ИНСТИТУТЛАРЫ́**, төрле объектлар төзелешләре өчен проект-смета документларын эшләүче оешмалар. Казанда беренче П.и. 1930–40 елларда үзәк проектлау һәм төзү оешмалары ф-ллары рәвешендә барлыкка киләләр. Хәзерге вакытта ТР терр-ясендә дистәләгән проектлау ин-тлары, иҗат бюролары һәм остаханәләре бар. *«Татинвестгражданпроект»* дәүләт баш терр. проектлау-тикшеренүче фәнни-җитештерү фирмасы — респ-када Чаллы («Татинвестгражданпроект» ҖЧҖ ҖФ) һәм Яшел Үзән шәһәрләрендә ф-ллары булган иң эре проектлау ин-ты. Казан шәһәренең ген. планын, шәһәр районнарын, инфраструктура объектларын детальләп планлаштыру проектларын эшләү б-н аренда пр-тиесе — *«Казгражданпроект»* ин-ты шөгыльләнә. Авыл җирлегендә капиталь төзелеш өчен проектлау-тикшеренү эшләре Түбән Кама һәм Лениногорск шәһәрләрендә бүлендек фирмалары булган *«Татагропромпроект»* АҖ тарафыннан башкарыла. *«Казан промстройпроект»* АҖ сәнәгать объектларын комплексы проектлаштыра, сәнәгать зоналарының, зур авылларның һ.б.ның ген. планнарын төзи. Респ-када авиация сәнәгать пр-тиеләрен һәм социаль-мәдәни-көнкүреш объектларын проектлаштыру б-н *«Казан гипрониавиапром»* АҖ шөгыльләнә. Болардан башка, П.и. ТРның зур шәһәрләрендә — Әлмәттәге «Горпроект» ҖЧҖтә, Чаллыдагы «Чаллыпроект» ҖЧҖтә эшли. Заманча зур биналарны һәм корылмаларны проектлаштыручы иҗат остаханәләре арасында «Архитектор Токаревларның иҗат остаханәсе», «Архитектор Нургалиевның иҗат остаханәсе», «Велп» аерылып тора.

**ПРОКОПЕ́НКО** (кыз фамилиясе Сәлимова) Равилә Нәҗип кызы (1941), спортчы (баскетбол), СССРның атказ. спорт остасы (1962). «Мехнат» (Ташкент) ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә. Европа (1962, 1964, 1966, 1968), дөнья (1967) чемпионы.

**ПРОКО́ПОВА** Валентина Васильевна (7.8.1951, Новосибирск ш.), балет артисткасы, педагог, ТРның халык артисты (2011). 1969 елда Новосибирск хореография уч-щесен (С.Юнысова классы), 2005 тә Казан консерваториясен балет педагогикасы белгече буенча тәмамлый. 1969–71 дә Кыргыз акад. опера һәм балет театры артисты. 1971 дән балет солисты, бер үк вакытта, 1978–90 да, Татар опера һәм балет театры педагог-репетиторы, 1974–90 да Казан музыка уч-щесенең хореография бүлеге укытучысы. 1990 нан Прага камера балетының педагог-репетиторы (Чехия), 1996 дан Казанда нәфис гимнастика буенча Олимпия резервы спорт мәктәбендә педагог-хореограф, «Казан» хореография ансамбленең сәнгать җитәкчесе. 2002 дән Татар опера һәм балет театры педагог-репетиторы. Төп хореографик партияләре: Мирта, Гөлнара һәм Медора («Жизель», «Корсар», А.Адан), Фанни («Зур вальс», И.Штраус), Анитра («Пер Гюнт», Э.Григ), Одетта-Одиллия, Аврора («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», П.Чайковский), Китри, Гамзатти («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Леди Капулетти («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Леди Макбет («Макбет», К.Молчанов), Утлы җен пәриләр («Шүрәле», Ф.Яруллин), Тылсымлы торна («Сихерләнгән малай», З.Хәбибуллин) һ.б. Шәкертләре арасында РФ һәм ТРның халык, атказ. артистлары, халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары, балет солистлары, Россия һәм чит ил опера һәм балет театры, балет коллективларының әйдәп баручы педагоглары (ш.и. Чехиядә, Словакиядә, АКШта эшлиләр): И.Жуков, Л.Мөхәммәтгалиева, Н.Шильников, А.Давыдов, А.Низамова, Д.Котермин һ.б. бар.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ПРОКО́ПЬЕВ** Андрей Лаврентьевич (13.2.1922, Казан — 27.8.1993, шунда ук), нәкышьче, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1980). Казан сәнгать уч-щесен тәмамлый (1943). 1944 елдан Казанның мәдәни-агарту учреждениеләре рәссамы, 1951 дән — Татарстан сәнгать фондында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1964). Лирик пейзажлар остасы. Үзенең иҗатында П. Казан сәнгать мәктәбе нигез салган реалистик нәкышь традицияләрен дәвам иттерә һәм үстерә. 1950–70 еллар дәвамында пейзаж жанрында эшли. Идел буеның елга ландшафтларын чагылдырган әсәрләр иҗат итә. П. пейзажларының кабатланмас рухын гомуми камера яңгырашы, биек горизонтлы композиция ракурсы, кечкенә формат барлыкка китерә («Яр буенда», 1955; «Мста елгасы», 1957; «Идел яңгырдан соң», 1966; «Язгы җирдә», 1969). П. Идел һәм Каманың куәтен, бөеклеген, матурлыгын гаҗәеп итеп сурәтли: «Моркваш» (1956), «Идел Казан янында», «Кама» (икесе дә — 1961), «Иделдә балыкчы кызлар» (1965), «Каспийда» (1966 һәм 1968), «Камада» (1971); Татарстан табигатенең һәм борынгы рус шәһәрләренең тыйнак гүзәллеген ачып бирә: «Баулыда яз», «Урман елгасы» (икесе дә — 1957), «Буа» (1961), «Переславль-Залесский» (1963), «Торжок. Кояшлы көн» (1967), «Селигердагы Осташков шәһәре» (1967), «Васильсурск» (1969). П. иҗатында Казан аерым урынны алып тора: «Кышкы парк» (1955); «Казан опера театры» (1962); «Шәһәр читендә кыш» (1972). Рәссам ш.у. тематик картиналар жанрында эшли: «Кокушкино почтасы» (1967, М.И.Семёнов б-н берлектә), «Эштән кайтканда (Яз)» (1978, Б.И.Майоров б-н берлектә), картиналарның сәнгатьчә матурлыгын көчәйтү өчен еш кына пейзажлы (фон) образлар иҗат итә.





А.Л. П р о к о п ь е в. 1. «Шәһәр пейзажы». 1961; 2. «Көмеш көн». 1980. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Респ-ка (1952 елдан); ТАССРның Мәскәүдә (1957, 1968, 1980–81), Алма-Атада (1962), Ташкентта (1965), Ленинградта (1972), Уфада (1975), Нукуста узган сынлы сәнгать күргәзмәләрендә (1980); зона — «Зур Идел» (1964 тән 1991 гә кадәр); бөтенсоюз: РСФСР рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1957) һәм РСФСРның автономияле респ-калары рәссамнары (Мәскәү, 1971) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда 1962, 1966 (Л.А.Потягунин б-н берлектә), 1972, вафатыннан соң 1994 һәм 2002 дә (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда) үткәрелә. Әсәрләре

ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт Картиналар галереясында, Чуаш сәнгать музеенда (Чабаксар ш.), Түбән өлкә картиналар галереясында, Мурманск өлкә туган якны өйрәнү музеенда саклана.

*Әд.:* Выставка работ художника Андрея Лаврентьевича Прокопьева: Каталог. К., 1962; Выставка произведений Казанского художника А.Л.Прокопьева в связи с 50-летием со дня рождения: Каталог. К., 1974.

*М.Е.Ильина.*

**ПРОКУРАТУ́РА**, ведомстволар, учреждение, оешмалар, вазифаи һәм шәхси затлар тарафыннан законнарның төгәл үтәлешен күзәтүне гамәлгә ашыручы дәүләт органы. Россиядә 1722 елда оештырыла. Император Пётр I нең 1722 ел 12 гыйнвар Фәрманы б-н *Казан надворный мәхкәмәсе* каршында прокурор вазифасы булдырыла (1727 нең 24 февралендә бетерелә), 1730 ел 2 октябрь Манифесты, Сенатның 1731 ел 2 апрель, император Анна Иоанновнаның 1733 ел 3 сентябрь һәм император Екатерина II нең 1763 ел 15 декабрь Фәрманнары б-н Казан губернасы һәм провинцияләре прокурорлары вазифалары гамәлгә кертелә (1775 тә Губерна реформасы үткәрү барышында бетерелә). П. дәүләт органнарының гамәлләрен һәм күрсәтмәләрен контрольдә тота, ә мәхкәмә, гаепләү һәм дәгъва эшчәнлеге адм. күзәтчелек функцияләренә аерым өстәмәләрнең берсе булып тора. Казан губерна П.сы 1775 елгы «Губерналар турында Нигезләмә» нигезендә барлыкка килә һәм губерна прокуроры, җинаять һәм казна эшләре буенча ике стряпчий, өяз һәм шәһәр стряпчийлары һәм 1796 га кадәр — югары земство мәхкәмәсе, губерна магистраты һәм югары хөкем прокурорлары составында 1781 нең 23 декабрендә ачыла. Прокурорлар Сенат тарафыннан билгеләнә. Җирле П.га, гомуми күзәтчелектән тыш, дәүләт адвокатурасы һәм тикшерүне контрольдә тоту хокукы йөкләнә. Ул Сенат генерал- һәм оберпрокурорларына һәм 1802 дән — Юстиция министрлыгына буйсына (к. *Казан губерна прокуроры канцеляриясе*). «Мәхкәмә тәртипләрен булдыру турында» 1864 ел 20 ноябрь Нигезләмәсе һәм Сенатның 1869 ел 28 апрель фәрманы нигезендә Казан губерна П.сы бетерелә, 1870 нең 8 ноябрендә *Казан мәхкәмә палатасы* каршында (прокурор, аның 5 иптәше (урынбасары), канцелярия хезмәткәрләре, курьерлар, каравылчы составында; барысы 20 ләп кеше, 1913) һәм *Казан округ мәхкәмәсе* каршында (прокурор, аның 5 иптәше, секретарь, теркәүчеләр, курьерлар, каравылчылар составында; барлыгы 15 тән артык кеше, 1893) прокурор күзәтчелеге органнары булдырыла. Прокурорлар мәхкәмәләрдә исәпләнәләр, әмма алар контролендә булмыйлар. Алар юстиция министрына буйсыналар һәм аның тәкъдиме б-н император тарафыннан билгеләнәләр. Төп вазифалары — законны саклау (гражданлык эшләрен караганда) һәм гаепләү (җинаять эшен кузгатудан алып мәхкәмәдә гаепләүне раслауга кадәр) эшчәнлеге. Ул полиция тикшерүе б-н җитәкчелек итә, алдан алып барылган тикшерү эшләрен, мәхкәмәләрнең эшләрне оештыру һәм алып бару кагыйдәләрен үтәвен күзәтә, мәхкәмә чиновникларының дисциплинар эшләрен карауда катнаша, мәхкәмә карарларына протестлар белдерә, хөкем карарларының үтәлешенә, ябылу урыннарында законлылык саклануына күзәтчелек итә. ХКСның «Судлар турында» 1 нче санлы 1917 нең 22 ноябрь Декреты б-н прокурор күзәтчелеге органнары юкка чыгарыла. Татарстан терр-ясендә аларның функцияләрен: 1917–18 дә Казан губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының юстиция бүлеге, 1918–20 дә Казан губернасы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы башкарма ком-тының Казан губерна юстиция комис-ты, юстиция бүлеге, 1920–22 дә — ТАССР ҮБК, ТАССР ХКС, ТАССР Юстиция халык комис-ты, ТАССР Эшче-крәстиян инспекциясе халык комис-ты, җирле советлар үти. Бөтенроссия ҮБКның 1922 ел 28 май карары буенча 1922 нең августында ТАССР Юстиция халык комис-ты составында П. бүлеге оеша, ТАССР Юстиция наркомы (1932 дән — нарком урынбасары) бер үк вакытта ТАССР прокуроры да булып тора. СССР ҮБК һәм ХКСның 1933 ел 20 июнь һәм 1936 ел 20 июль карарлары нигезендә ТАССР П.сы (1990 нан — ТССР, 1992 дән — ТР) мөстәкыйль учреждение булып аерылып чыга. Законнарның үтәлешенә күзәтчелекне, авыр җинаятьләрне тикшерүне дә кертеп, җинаятьләрне хөкемгә тапшыру, җинаятьчелеккә каршы көрәш буенча тәртип саклау органнарының эшчәнлеген координацияләүне, мәхкәмәләрнең эшләрне каравында катнашуны гамәлгә ашыра. ТР (1990 га кадәр — ТАССР, 1990–92 дә — ТССР) прокуроры җитәкчелек итә, вазифага РФ ген. прокуроры (1992 гә кадәр — СССР ген. прокуроры) тарафыннан билгеләнә. Республика П.сы составында: 1922–36 да гомуми һәм мәхкәмә күзәтчелеге, тикшерү буенча күзәтчелек, хезмәтне һәм җитештерүне саклау буенча, ябылу урыннары һәм ГПУ буенча күзәтчелек төркемнәре; 1930 еллар уртасы — 1950 елларда — бүлекләр: үтәлешне контрольдә тоту буенча прокурор ярдәмчесе, гомуми күзәтчелек, тикшерү, махсус эшләр, милициягә күзәтчелек итү, җинаять-мәхкәмә, ябылу урыннарына күзәтчелек итү, гражданлык-мәхкәмә кадрлары, адм.-хуҗалык, аерым сектор, балигъ булмаганнар эшләре буенча төркем, канцелярия, хуҗалык эшләре; 1960–1980 елларда — тикшерү идарәсе, бүлекләр: үтәлешне контрольдә тоту буенча прокурор ярдәмчесе, гомуми күзәтчелек, мәхкәмәләрдә җинаять эшләрен карауга күзәтчелек итү, мәхкәмәләрдә гражданлык эшләрен карауга күзәтчелек итү, балигъ булмаганнар эшләре буенча, кадрлар, хуҗалык-финанс; 1990 елларда — идарәләр: тикшерү, җинаять эшләре буенча мәхкәмә карарларының законлылыгына күзәтчелек итү; бүлекләр: гомуми күзәтчелек, гражданлык эшләре буенча мәхкәмә карарларының законлылыгына күзәтчелек итү, балигъ булмаганнар турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, җинаять җәзаларын башкарганда законнар үтәлешенә күзәтчелек итү, милләтара мөнәсәбәтләр турындагы законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, икътисад һәм табигатьне саклау өлкәсендә законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү, социаль өлкәдә законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү; статистика; планлаштыру, хезмәт, финанслау, бухгалтер исәпләве һәм хисап бирү; массакүләм мәгълүмат чаралары б-н бәйләнешләр буенча; кадрлар; хатларны карау һәм гражданнарны кабул итү буенча; 21 йөз башында — прокурор ярдәмчеләре; җинаять эшләрен мәхкәмәләрдә карауда прокурорлар катнашуын тәэмин итү идарәсе (бүлекләр: дәүләт гаепләүчеләре, кассация, күзәтчелек); бүлекләр: федераль законнарның саклануына күзәтчелек итү; салым, таможня һәм финанс законнары үтәлешенә күзәтчелек итү; арбитраж һәм гражданлык процессларында прокурорлар катнашуын тәэмин итү; балигъ булмаганнар һәм яшьләр турында законнар үтәлешенә күзәтчелек итү; 1 нче һәм 2 нче номерлы җинаятьләрне тикшерүгә күзәтчелек итү; аеруча әһәмиятле эшләрне тикшерүгә күзәтчелек итү; эчке эшләр, таможня, юстиция һәм наркологик контроль органнарының процессуаль эшчәнлегенә күзәтчелек итү; гомуми һәм аерым эшләр; планлаштыру, хезмәт, финанслау, бухгалтер исәбе һәм хисап бирү; кадрлар, материаль тәэминат, биналарны һәм транспортны эксплуатацияләү. П.га 1920 елларда — 11 кантон П.сы, 1930–1950 елларда — 80, 1960–1980 елларда — 40, 1990–2000 елларда — 58 шәһәр, район һәм махсуслашкан П.лары. РФ Ген. П.сына (1992 гә кадәр — СССР Ген. П.сы) буйсына.



ТР Прокуратурасы бинасы.

Казан губерна прокурорлары: Я.А.Маслов (1731–1732), С.П.Плохов (1734–39), В.Неёлов (1739–1740), А.А.Бахметев (1740–1741), И.Родионов (1753–1758), Н.Юшков (1758–1761), Г.Воронцов (1761–1764), И.Соболев (1764–1765), П.Есипов (1765–?), И.Г.Лукошников (1781–82), В.Кривский (1782–?), В.И.Чемесов (1789–97), М.Д.Княжевич (1797–1801), А.Н.Овцын (1801–05), П.И.Ананьевский (1805–10), К.М.Спе-

ранский (1810–12), В.Н.Овцын (1812–16), Е.А.Кисловский (1816 – февраль 1820), Ф.П.Печёрин (октябрь 1820 – 22), А.М.Херувимов (1822–24), Г.И.Солнцев (1824–44), К.М.Колумбов (1844–48), В.А.Жуков (1848–52), А.С.Оголин (1852–56), Т.Ф.Унтилов (1856–62), А.К.Жизневский (1862–63), Ф.Ф.Ольдекоп (1863–68), А.С.Ольшевский (1868–70).

Казан мәхкәмә палатасы прокурорлары: А.А.Червинский (1870–75), С.М.Гулькевич (1875–77), С.С.Гончаров (1877–80), И.П.Закревский (1881–82), Н.И.Похвиснев (1882–83), В.Н.Варварин (1883–94), А.А.Чернявский (1894–97), В.А.Соколов (1897–99), В.Р.Завадский (1899–1901), А.Е.Кичин (1901–03), А.А.Чебышев (1903–07), А.В.Степанов (1907–09), В.А.Бальц (1909–15), Г.П.Ненарокомов (1915–17), Н.И.Миролюбов (1917–18).

Казан округ мәхкәмәсе прокурорлары: А.Ф.Кони (1870–71), Т.П.Сольский (1871 – 73), П.О.Вархаловский (1873–74), В.Н.Варварин (1874–76), Д.П.Тыртов (1876–80), В.П.Родзянко (1880–81), М.М.Котляревский (1881–84), В.А.Соколов (1884–89), А.А.Зеланд (1889–92), Н.З.Шульгин (1892–97), В.Н.Залеский (1897–99), Д.П.Солодовников (1899–1902), Н.Н.Казин (1902–07), А.П.Чиркин (1907–16), Ф.А.Карасёв (1916–17).

ТАССР, ТР прокурорлары: Г.Б.Баһаветдинов (1922–26), Х.Р.Палютин (1926–28), Ш.Х.Башкиров (1928–29), В.Н.Филиппов (1929–32), В.В.Лесовов (1932–34), Е.М.Лейбович (1935–37), С.Н.Егоров (1937–38), В.С.Перов (1938–41), Д.Н.Исупов (1941–42), И.Д.Ардерихин (1942–44), И.А.Садовников (1944–46), И.С.Надеев (1946–50), С.В.Бекедов (1950–54), П.А.Лоскутов (1954–58), Н.В.Жогин (1958–61), И.Х.Хәмидуллин (1961–81), В.С.Үзбәков (1981–85), О.М.Антонов (1985–92), С.Х.Нәфиев (1992–2000), К.Ф.Әмиров (2000–13), И.С.Нәфыйков (2013 тән).

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 1. СПб., 1830. Т. 6. № 3880, 3981; Т. 8. № 5625, 5736; Т. 9. № 6475; Т. 16. № 11991; Т. 17. № 12537; Т. 20. № 14392; Т. 24. № 17702; Т. 26. № 20004; Собр. 2. СПб., 1874. Т. 45, отд. 1. № 48517; отд. 2. № 48853, 48926; Инструкция чинам прокурорского надзора округа Казанской судебной палаты. К., 1894; Правящая Россия: Полный сборник сведений о правах и обязанностях административных учреждений и должностных лиц Российской империи. СПб., 1906. Ч. 3.

*Әд.:* Нафиев С.Х. Прокуратура Татарстана: История и современность. К., 1997; Прокуратура Татарстана на службе Отечеству и Закону: События, факты, люди. К., 2001.

*Е.Б.Долгов.*

**ПРО́КУШЕВ** Владимир Ионович (1.6.1902, Томск ш. – декабрь, 1956, Ленинград), ТАССРның сәламәтлек саклау эшлеклесе (1942). Томск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1926), Якутия АССРның Витим авылында амбулатория мөдире, 1930 елдан район сәламәтлек саклау бүлеге мөдире (Киренск ш.). 1932 дән Көнчыгыш Себердә чик буе заставасы инспекторы, 1933 тән – Көнчыгыш Себер крае сәламәтлек саклау бүлегенең махсус, 1935 тән дәвалау бүлеге башлыгы. 1936 дан Иркутск шәһәрендә: курортлар тресты башлыгы, 1941 дән өлкә сәламәтлек саклау бүлеге мөдире урынбасары, бер үк вакытта эвакогоспиталь бүлеге башлыгы. 1942 дән ТАССР сәламәтлек саклау халык комиссары, 1946 дан – сәламәтлек саклау министры. 1949 дан Ленинград өлкә сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

**ПРОЛЕ́Й-КА́ША** авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 288 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1611 дән мәгълүм. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балыкчылык б-н шөгыльләнә, бурлаклыкта йөри, шәһәр һәм авылларда ялланып эшли. 20 йөз башында П.-К.да волость идарәсе урнаша; Рождество Христово чиркәве (1906 да төзелә), земство мәктәбе (1890 да ачыла), тимерчелек, 9 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2896,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Пролей-Каша волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның – Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан – Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан – Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә – 80 ир-ат; 1859 да – 914, 1897 дә – 1653, 1908 дә – 2128, 1920 дә – 2074, 1926 да – 1779, 1938 дә – 1565, 1949 да – 1122, 1958 дә – 1084, 1970 тә – 833, 1979 да – 603, 1989 да – 406, 2002 дә – 359 кеше.

**«ПРОЛЕТА́Р»**, газета; к. *«Донбасс эшчесе»*.

**«ПРОЛЕТА́Р ӘДӘБИЯТЫ́»**, газета. Татар пролетар язучылар ассоциациясе органы. 1931 елдан *«Атака»* ж-лының кушымтасы буларак Казанда татар телендә нәшер ителә.

**«ПРОЛЕТАРИА́Т СӘНГАТЕ́»**, рәсемле мәдәни журнал. ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1931 елда Казанда татар телендә 1 саны нәшер ителә. Мәдәният хезмәткәрләрен пролетар мәдәният булдыру эшендә активлык күрсәтергә чакыра. Үзешчән сәнгать, театр һәм драма түгәрәкләре эшен оештыручы идеологик остаз буларак чыгыш ясый. Авторлары арасында – С.Галиуллин, З.Мөхсинов, И.Усманов. ВКП(б)ның театрлар һ.б. мәдәни оешмалар эшчәнлегенә кагылышлы күрсәтмәләре басыла, ТАССР мәдәният хезмәткәрләренең 10 нчы съезды эше яктыртыла. Татарлар яши торган авыллар һәм ерактагы районнардагы драма түгәрәкләре эше турындагы мәкаләләргә аерым урын бирелә; Әстерхан татар театры турындагы мәкаләләр, Ә.Камал шигырьләре басыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ПРОЛЕТА́РИЙ ТАТАРСТА́НА»** («Татарстан пролетарие»), Профсоюзлар Татарстан өлкә советының айлык журналы. 1925 елның февраленнән 1926 ның маена кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 16 саны чыга. Мөхәррире – Татпрофсовет сәркәтибе Н.Рагс. Журналның максаты – ТАССР профсоюзлары эшчәнлеген, сәнәгатьтәге, сәүдә һәм кооперациядәге вазгыятьне, ш.у. профсоюз әгъзаларының көндәлек тормышын һәм эшләрен яктырту. «П.Т.» партия һәм профсоюзларның җитәкче органнары материалларын, ш.и. РКП(б) ҮКның «Профсоюзлар эше турында», ВЦСПСның «Татреспубликада проф. эшләрнең халәте турында», Татпрофсоветның «Пролетарий Татарстана» ж-лы эшчәнлеге турында» пленум резолюцияләрен бастыра. ТАССР проф. оешмалары съездлары һәм кабаттан сайлаулар турындагы язмаларга зур урын бирелә. «Фабрика һәм заводлар буйлап», «Хезмәтне саклау», «Эшчеләр көнкүреше» бүлекләрендә респ-каның «Кызыл шәрекъ», «Спартак», «Хезмәт җиңүе», М.Вахитов исем., «Кызыл тукучы» һ.б. пр-тиеләрендәге хәлләр турында тәфсилле мәкаләләр басыла. Редакция ш.у. икътисад үсеше юнәлешләре турындагы аналитик һәм бәхәсле мәкаләләр дә бастыра («1924–25 елларга ТРда трестлаштырылган сәнәгать һәм аның перспективалары», «Эшче көчләр б-н тәэмин итү турында» һ.б.). Авылдагы эшләргә: профсоюзларны ныгыту, алар эшчәнлегенең үзенчәлекле шартлары, эш башкаруда татар телен гамәлгә кертү, батраклар мәнфәгатен яклау мәсьәләләренә дә игътибар бирелә. Күп кенә язмалар хезмәт биржасына һәм эшсезләр өчен җәмәгать эшләрен оештыруга, производство киңәшмәләре эшен җанландыруга, хезмәтне фәнни оештыруга, хатын-кызларның производствода тоткан урынына, мәдәният эшенең куелышына багышлана. «Безнең союзларыбызның үткәненнән» рубрикасында Татпрофсоветның профсоюзлар хәрәкәтен өйрәнү комиссиясе материаллары, Алафузов һәм Крестовниковлар з-длары эшчеләренең баш күтәрүләре, Казан профсоюзларының яшерен үзәк бюросы, Металлчылар берлеге эшчәнлеге, Казан эшчеләренең беренче маёвкалары турындагы мәкаләләр басыла; профсоюз лидерлары А.И.Догадов, М.Е.Ендаков, К.А.Ратёхин һ.б. хакында очерклар бирелә. 1925 елгы 11 нче сан 1905–07 еллардагы рев-циянең 20 еллыгына багышланып чыга. Әдәби бүлектә фельетоннар, сатирик язмалар, хикәяләр дөнья күрә.

*Әд.:* Абдрашитова И.М. «Пролетарий Татарстана» (1925–1926) // Из истории Татарии. К., 1973. Сб. 5.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ПРОМЕТЕ́Й»**, эксперименталь эстетика фәнни-тикшеренү институты. 1962 елда Казан авиация ин-тының (хәзер Казан техник ун-ты) студентлар КБ буларак оеша, 1963 тән махсус КБ, 1993 тән ТР ФА һәм Казан техник ун-тының уртак фәнни үзәге, 1995 тән фәнни-тикшеренү ин-ты. Баштарак төп эшчәнлеге төсле музыка уен коралларын: «Прометей-1» (1962), «Прометей-2» (1963), «Кристалл» (1966), «Прометей-3» (1987); автоматик төсле музыка җайланмаларын: «Идел» (1968–71), «Ялкын» (1976), «Диско» (1985), калейдофон (1986) эшләү була; фәзаи аваз җайланмасы (1970), «Электрон рәссам»

(1980) телевизион кушу җиһазы конструкцияләнә.

«П.» махсус КБ киң экранлы төсле музыка фильмнары: А.Скрябин музыкасына «Прометей» (1966), Э.Варезның «Электрон поэма» музыкасына «Мәңгелек хәрәкәт» («Вечное движение», 1969), Г.Свиридов музыкасына «Кечкенә триптих» («Маленький триптих», 1975), А.Немтин, С.Крейчиның «Космик соната» («Космическая соната», 1981, видеоверсия 1986); 9 видеофильм: «Храм» һәм «Берндт өчен баллада»; икесе дә Комед музыкасына («Храм», «Баллада для Берндта», 1989) һ.б.ны чыгара. Яктылык архит-ра өлкәсендә Казан Кремленең Спас манарасындагы нәфис кыңгырау тавышы (1966), Казан циркының динамик яктыртылышы (1968), Казан авиация ин-ты музееның үзгәрүчән төсле витражы (1970) һәм Җиңү монументында яктылык динамикасы (Казан, 1996) буенча эшләр алып барыла. 1979–91 дә Казанның Яшьләр үзәгендә төсле музыка студиясе һәм музее эшли.

1960–80 дә, фәнни-техник рев-ция чорының яңа сәнгати формалары үсеше стратегиясен аңлау өчен, актуаль фәнни тикшеренүләр омтылышы туа. Конструкторлык бюросы фәнни-тикшеренү ин-ты итеп үзгәртелгәннән соң, планлы фәнни эшчәнлек башлана. *Синестезия*, *төсле музыка, төсле архитектура* сәнгатьләре синтезы мәсьәләләренә караган эшләр (Б.М.Галиев һ.б.), А.Н.Скрябин мирасын (И.Л.Ванечкина), татар мәдәнияте үрнәгендә «музыка-орнамент» охшашлыгын (Е.В.Синцов) тикшерү, сәнгатьнең үз чаралары б-н аның яңа төрләрен фаразлау (С.В.Синцова), Татарстанда кино тарихы (Е.П.Алексеева), компьютер музыкасы тарихы (М.С.Заливадный) киң таныл ала. Тикшеренү нәтиҗәләре пед. практикасында (Казан, Мәскәү, Петербург консерваторияләрендә) файдаланыла, музыка графикасының оригиналь методикасы ТР мәктәпләрендә актив кертелә (И.А.Трофимова). Техник тәҗрибәләрне лазер, видеоаппаратура, компьютерлар б-н (Р.Ф.Сәйфуллин, В.П.Букатин) шәһәр дизайнында, концерт залларында, музейларда куллану дәвам итә. «П.» — Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге лауреаты (1980), ин-тның техник эшкәртмәләре СССР ВДНХсының 65 медаленә лаек була. Җитәкчесе — Б.М.*Галиев* (1966–2009).

Басмалар: Искусство светящихся звуков. К., 1973; Галеев Б.М., Зорин С.М., Сайфуллин Р.Ф. Светомузыкальные инструменты. М., 1987. Галеев М. Светомузыка в системе искусств. К., 1991; Синцов Е.В. Природа невыразимого в искусстве и культуре. К., 2003; Светомузыка, синестезия, «цветной слух»: Аннотированный библиогр. указ. (1742–2002). К., 2006; Алексеева Е.П. Развитие и становление кинематографа в Казани и Казанской губернии (1897–1917 гг.). К., 2007. Ш.у.к. *Төсле музыка* мәкаләсенә әдәбият.



«Прометей (Скрябин+Кандинский)» концерт куелышыннан күренеш. Казан, 1996.

*Әд.:* Ванслов В.В. Изобразительное искусство и музыка. Л., 1977; Колейчук В.Ф. Кинетизм. М., 1994; Нигматуллина Ю. Системно-комплексное исследование художественного творчества. К., 2004; Pioneers of electronic art. Linz, 1992.

*Б.М.Галиев.*

**ПРО́НИН** Борис Григорьевич (30.1.1931, Түбән Новгород крае, Первомайский р-ны Пруды а.), ветеринар-акушер, биол. фән. д-ры (1991), проф. (1994), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли: акушерлык, гинекология һәм терлекләрне ясалма орлыкландыру кафедрасында, үрчү патологиясе һәм физиологиясе лаб-се мөдире (1962–84), проф. (1992 дән). Фәнни эзләнүләренең төп юнәлешләре: көтүне интенсив яңарту, кысырлыкны кисәтү һәм дәвалау, терлекләрнең үрчү биотехникасы (яралгы эмбрионнары трансплантациясе, югары генетик потенциалга ия үрчем алу һ.б.); ясалма орлыкландыру ысулларын эшләү һәм камилләштерү. СССР МС премиясе иясе (1981). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К вопросу профилактики бесплодия при искусственном осеменении крупного рогатого скота в колхозах и совхозах ТАССР // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1964. Т. 91; Научные достижения в воспроизводстве и искусственном осеменении крупного рогатого скота // Тр. 1 съезда ветеринарных врачей Республики Татарстан. К., 1995.

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

**ПРО́НСКИЙ** (Рыбин-Пронский) Михаил Петрович (? — 11.9.1654, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, бояр (1647). 1626 елдан дәүләт хезмәтендә. Терки (1634–35), Псков (1639–41), Әстерхан (1650–52) шәһәрләрендә воевода. 1636–38 дә Олы приход, Унынчы өлеш җыемы приказларында. 1943–47 дә Казанда 1 нче (баш) воевода. 1645 нең сентябрендә калмыкларның һәм нугайларның Казан өязендә һөҗүмен кире кайтара. 1647 дән Тупчылар приказында, 1654 тә Мәскәүдә Акчалар җыемы приказы б-н җитәкчелек итә.

*Әд.:* Ермолаев И.П. Казанский край во второй половине XVI–XVII вв.: Хронол. перечень док. К., 1980.

*Е.Б.Долгов.*

**«ПРОПАГАНДИ́СТ ҺӘМ АГИТА́ТОР БЛОКНОТЫ́»**, журнал; к. «*Офык*».

**«ПРОПАГАНДИСТКА́ ЯРДӘМГӘ́»**, айлык иҗтимагый-сәяси брошюралар сериясе. ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-ты пропаганда һәм агитация бүлеге органы. 1946–54 елларда Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 29 саны чыга. 1946–49 да «*Пропагандистка һәм агитаторга ярдәмгә*» исеме б-н чыга. Актив авторлары арасында — А.Азизян, М.Баскин, П.Белов, А.Вишняков, В.Григорьян, М.Давыдов, Ф.Константинов, В.Лебедев, Э.Локшин, П.Поспелов, Ф.Хрустов, Д.Чесноков. «Правда», «Труд», «Коммунист», «Большевик», «Партийная жизнь», «Советская Башкирия», «Молодой большевик» г-талары мәкаләләре күчереп бастырыла. К.Маркс, В.И.Ленин, И.В.Сталин тәгълиматы аңлатыла һәм анализлана. Эчке һәм тышкы сәясәт, илдәге иҗтимагый-икътисади вазгыять мәсьәләләре яктыртыла.

*А.Ә.Хәсәвнех.*

**«ПРОПАГАНДИСТКА́ ҺӘМ АГИТА́ТОРГА ЯРДӘМГӘ́»**, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты пропаганда һәм агитация бүлегенең айлык иҗтимагый-сәяси журналы. 1944 елның октябреннән 1958 елга кадәр Казанда татар телендә нәшер ителә. ВКП(б) ҮКның «*Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында*» 1944 ел 9 август карары кабул ителгәннән соң оеша. Идеологик эшнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре буенча материаллар һәм мәкаләләр басыла. Мөхәррирләре — Г.Шәфыйков, И.Үзбәков, Ф.Мәхиянов һ.б.

**ПРОПО́ЛИС**, к. *Тома балавыз*.

**«ПРОСВЕЩЕ́НИЕ И ЖИЗНЬ»**, журнал; к. «*За культурную революцию*».



М.А.Просвирнин.

**ПРОСВИ́РНИН** Михаил Андреевич (1912, Казан губ. Мамадыш өязе, хәзер Мамадыш р-ны Соколка а. — 5.9.1973, шунда ук), Сов. Союзы Герое (3.6.1944), кече лейтенант. Интендантлар уч-щесенең тизләтелгән курсын

тәмамлый (1945). Колхозда эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 7 нче гв. механикалаштырылган бригаданың сапёрлар отделениесе командиры (47 нче армиянең 3 нче гв. механикалаштырылган корпусы). Кавказ, Кырым, Воронеж, 1 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Керчь ярымутравында һөҗүм һәм оборона сугышларында (1941–42), Кавказ өчен сугышта (1942–43), Белгород-Харьков (1943), Люблин-Брест (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Селище авылы (Украина ССРның Черкассы өлкәсе Канев р-ны) янында Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: 1943 нең 28 сентябрендә, беренчеләрдән булып, елганы йөзеп чыга, дошман контрһөҗүмнәрен кире кайтаруда һәм яулап алынган плацдармга миналар куюда катнаша. П. куйган миналарда дошманның 5 танкы шартлый. 1946 дан запаста. Туган авылында сал агызуда эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Мамадыш шәһәрендә П.га бюст куелган.

*Әд.:* Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

*М.З.Хәбибуллин.*

**ПРО́СТИ** авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Кама елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 523 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан Простяк (Прость) буларак билгеле. Башта Алабуга Троица ирләр монастыре карамагында була. 1764 тә җирле халык — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон-тукымаману, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ильинский чиркәве (1836–49 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1876 да ачыла), май з-ды, 2 су һәм 2 җил тегермәне эшли. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 1228, 1897 дә — 1608, 1920 дә — 1879, 1926 да — 1926, 1938 дә — 1685, 1949 да — 1122, 1958 дә — 870, 1970 тә — 938, 1979 да — 762, 1989 да — 480, 2002 дә — 466 кеше. П.да Сов. Союзы Герое Н.Ф.*Кайманов* туган. Авылда аның исем. музей-йорты бар.

**ПРО́СТОВ** (чын фамилиясе Покровский) Евгений Александрович (18.12.1900, Калуга губ. Малоярославец ш. — 1.3.1969, Казан), режиссёр, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1947, 1950). Дворяннар нәселеннән. Калуга реаль уч-щесен (1916), Петровск а.х. академиясенең ике курсын, Мәскәүдә режиссёрлык курсларын (1932) тәмамлый. Сәхнә эшчәнлеген 1921 елда Калуга театры актёры буларак башлый, 1922–31 дә Тула, Ставрополь, Таганрог шәһәрләрендәге театрларда режиссёр ярдәмчесе булып эшли. 1932–43 тә Чиләбе, Ташкент, Калуга, Омск, Архангельск шәһәрләрендәге





Казан Зур драма театрында Е.А. Простов тарафыннан куелган спектакльләрдән күренешләр:
1. «Иван Грозный» (А.Н. Толстой); 2. «Анна Каренина» (Л.Н. Толстой).

театрларда режиссёр һәм баш режиссёр. 1943 тән Казан Зур драма театрында режиссёр, 1946–53, 1959–63 елларда баш режиссёр. 1954–59 да Куйбышев һәм Минск драма театрларында баш режиссёр. Казанда эшләгән елларында барлыгы 39 спектакльне сәхнәгә куя. Аларның һәркайсы шәһәрнең театр тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Актёрлар б-н даими рәвештә әзерлек эшләре алып бару, һәр роль өстендә җентекле эшләү, тышкы күренешнең камиллеге П. спектакльләрен тирән мәгънәле һәм масштаблы итә. «Күптәнге хәлләр» («Давным-давно», А.К.Гладков, 1943), «Иван Грозный», «Михнәтле заман» («Хождение по мукам», (А.Н.Толстой, 1945, 1947), «Мулланур Вахитов» (Н.Исәнбәт, 1950), «Лейпциг, 1933» (Л.В.Компанейц, Л.И.Кронфельд, 1951), «Үле җаннар» («Мёртвые души», Н.В.Гоголь, 1952), «Иделдә йокы» («Сон на Волге», А.Н.Островский, 1953) спектакльләре композицион төзелешнең төрле чараларга бай матурлыгы һәм кеше язмышларының тирән драматизмы б-н тамашачыда көчле тәэсир калдыра. «Дөреслек әйбәт, ә бәхет яхшырак» («Правда — хорошо, а счастье лучше», 1944), «Талантлар һәм аларга баш иючеләр» («Таланты и поклонники», 1945), «Яшенле яңгыр» («Гроза», 1963, барысы да — А.Н.Островский), «Анна Каренина» (Л.Н.Толстой, 1948), «Тормыш төбендә» («На дне», М.Горький, 1949), «Чия бакчасы» («Вишнёвый сад», А.П.Чехов, 1960) спектакльләрендә гәүдәләнеш тапкан чорның тарихи чынбарлыкка туры килүе, персонажларның үзара мөнәсәбәтләре үсешен яктыртканда төгәл алымнар б-н эш итү драматурглар тарафыннан күтәрелгән проблемаларның актуальлеген, әһәмиятен җиткерергә ярдәм итә. П.ның заманча вакыйгаларны яктырткан спектакльләре конфликтның кискенлеге, рухи киеренкелек, гражданлык пафосы б-н аерылып тора: «Рус мәсьәләсе» («Русский вопрос», К.М.Симонов, 1947), «Намус законы» («Закон чести», А.П.Штейн, 1948), «Америка авазы» («Голос Америки», Б.А.Лавренёв, 1950), «Фамилияләрне атамыйча гына» («Не называя фамилий», В.П.Минко, 1953), «Иркутск вакыйгасы» («Иркутская история», А.Н.Арбузов, 1960), «Океан» (А.П.Штейн, 1961). Берничә тапкыр Ленинга багышланган темага да мөрәҗәгать итә, Казан Зур драма театры сәхнәсендә И.Ф.Поповның «Гаилә» («Семья», 1952), Н.Ф.Погодинның «Кремль курантлары» («Кремлёвские куранты», 1962), Р.Ф.Ишморатның «Давылга табан» (1963) әсәрләре буенча спектакльләр куя. П. тарафыннан куелган спектакльләр Мәскәүдә дә даими рәвештә күрсәтелә һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан югары бәяләнә. 1963 тән Казан театр уч-щесендә пед. эшчәнлек алып бара.

*Әд.:* Ингвар И., Иляпова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

**ПРОТА́СОВ** Сергей Юрьевич (7.5.1954, Тәтеш ш.), спортчы, тренер (стендтан ату), СССРның спорт остасы (1972), РСФСРның атказ. тренеры (1987), ТРның атказ. физик культура хезмәткәре (2004). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1976). «Урожай» ирекле спорт җәмгыятенең үзәк советы (1972), Европа (1971) беренчелекләрендә җиңүче, Европа кубогы иясе (1973, яшьләр арасында), РСФСР беренчелегендә (1976) җиңүче. СССР (яшьләр арасында, 1970, 1973, көмеш), ВЦСПС (1971, бронза; 1974, көмеш), РСФСР (1975, бронза) берен-





Казан Зур драма театрында Е.А. Простов тарафыннан куелган спектакльләрдән күренешләр:
1. «Мулланур Вахитов» (Н. Исәнбәт); 2. «Лейпциг, 1933» (Л.В. Компанейц, Л.И. Кронфельд).

челекләрендә медальләр ала. 1976–84 елларда Тәтеш р-нының Нармонка авылында физкультура укытучысы, 1984 елдан стендтан ату буенча Олимпия резервындагы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр мәктәбендә (Тәтеш ш.) тренер-укытучы, 1992 дән директор. 1976 дан ТАССР, ТР җыелма командалары тренеры. Шәкертләре арасында — Н.Данилов, С.А.*Дёмина*, М.Королёва, А.С.Протасова. Медаль б-н бүләкләнә.

**ПРОТЕРОЗО́Й**, протерозой төркеме (эон), (грек. próteros — иртәрәк һәм zōḗ — яшәү), 2 млрд. елдан артык дәвердәге кембрийгача чорның югары бүлекчәсе; *архейдан* соң *палеозой эратемасы* (*эрасы*) алдыннан килә. Яше 542±1–2500±100 млн. ел. П. түбән (иртә) һәм югары (соңгы, *рифей, венд*) өлешләргә бүленә. Татарстан терр-ясендә түбән П. утырмалары 1500 *м* дан тирәндәрәк урнашкан, метаморфик сланецлардан, кварцит, *кристаллик нигезнең* өскә чыккан токымнарыннан гыйбарәт; югары П. комсу-балчыксыл, карбонатлы токымнардан тора, утырма тышлыкның түбәнге өлешен формалаштыра. П. утырмалары вулканик токымнар: гранит, гранодиорит, диорит, сиенит, порфирит, габбро-диабазлар б-н кискәләнгән. Утырма ятмалар коры һәм дымлы җылы климатның континенталь, сай сулы диңгез һәм диңгез шартларында хасил була. П.да тереклек бактерияләр, бер күзәнәкле примитив хайваннар (фораминифера), зәңгәрсу-яшел суүсемнәр, хәзерге диңгез каурыйлары һәм медузаларга якын организмнар рәвешендә фәкать диңгезләрдә генә бара. Соңгы П.да бөҗралы суалчаннар һәм буынтыгаяклылар барлыкка килә. ТР терр-ясендә П. утырмаларының югары өлешендә нефть, газ, битум чыганаклары ачыла. Ш.у.к. *Баулы сериясе*.

*Әд.:* Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. К., 2003; Стратиграфический кодекс России. СПб., 2006.

**ПРОТИСТЛА́Р**, иң түбән төзелешлеләр (Protista) (грек. prṓtistos — иң беренче), бер күзәнәкле һәм күп күзәнәкле организмнар патшалыгы; эволюцион планда, прокариот организмнар б-н күп күзәнәкле һәм лицелийлы башка эукариотлар арасындагы күчеш төркемә. «П.» терминын 1866 елда немец галиме Э.Геккель кертә, ул беренче тапкыр тере организмнарның 3 патшалыгын — күп күзәнәкле хайваннар, күп күзәнәкле үсемлекләр һәм П.ны билгели, соңгысына бактерияләрне, иң гади төзелешлеләрне, бер күзәнәкле суүсемнәр һәм түбән төзелешле гөмбәләрне кертә. 19 йөз ахырында «П. патшалыгы» таксонынан баш тарталар, алар хайваннар һәм үсемлекләр патшалыгы арасында билгеләнә. Иң гади төзелешлеләрдә күзәнәк төзелешенең төрлелеген һәм аларның суүсемнәр төркеме рәте б-н филогенетик якынлыгын күрсәтүче яңа ультраструктуралы һәм молекуляр-генетик тикшеренүләргә бәйле рәвештә, 1956 да Х.Коупланд П. идеясен хәзерге мәгънәсендә яңадан тергезә (эукариотлар өчен бу патшалыкны дүртнең берсе буларак яңадан кертә; 3 нче патшалык — гөмбәләр), Р. Уиттекер (1969) һәм Дж. Корлис (1984) бу идеяне үстерәләр (П.га иң түбән төзелешлеләрне, суүсемнәрне һәм зооспоралы үсемлекләрне кертәләр). П. — күбесенчә бер күзәнәкле, микроскопик (1 *мкм* дан — споровиклар), ш.у. синцитиаль, ценобиаль һәм күп күзәнәкле зур формалары да (10 *м* га кадәр, мәс., көрән суүсемнәр) бар; камчылылар, керфекчекләр, псевдоподийлар (ялган аяклар), күзәнәкнең өске структуралары ярдәмендә хәрәкәтләнәләр; тукланулары — автотроф, гетеротроф, миксотроф. Прокариотлар б-н башка эукариотлар арасындагы күчеш төркеме буларак, П. турындагы күзаллаулар үсеше, П. эчендә туклану төре генә түгел, ә бәлки бөтен күзәнәк системаларының формалашуын аңлата. Геном дәрәҗәсендә ди-, поли- һәм амфиплоидлылык, күп төшлелек һәм гетероморфизм, генетик материалның барлык урнашу төрләре, эукариот аксым синтезлаучы системалар барлыкка килә. Күзәнәк дәрәҗәсендә күзәнәк капламнарының, органеллар һәм цитосклет структураларының барлык төрләре, симбиогенез юлы б-н митохондрия һәм пластидлар формалаша. П.да организм дәрәҗәсендә күзәнәк яшәешенең мөмкин булган барлык цикллары һәм рәвешләре, генетик материал редукциясенең барлык формалары (гаметалы, споралы, зиготалы), җенси процессның ике формасы да (бер һәм ике баскычлы мейоз), күзәнәк хәрәкәте һәм туклануының барлык төрләре, күп күзәнәклелекнең төрле вариантлары очрый.

Төрле авторларның мәгълүматлары буенча, П.ның типлар саны төрлечә, иң күбен (45) Дж. Корлис ачыклый. Гамәлдә П.ның берничә миллион төре билгеле, әмма аларның чагыштырмача аз өлеше генә өйрәнелгән; кремнийлы суүсемнәрнең генә дә 10 млн. га кадәр төре исәпләнә, 12 меңе өйрәнелгән. П. яшәү мөмкин булган барлык тирәлекләрдә — океан һәм диңгезләрдә, төче һәм тозлы суларда, туфракта таралган.

Татарстан терр-ясендә якынча 20 типтагы П. вәкилләре очрый: евгленозалар (евглена), тамыраяклар (*амёбалар*), фораминифералар, опалиналар, кинетопластидлар (трипаносомалар), *инфузорияләр*, кояшсыманнар, динофитлар һәм *суүсемнәрнең* башка типлары. П.ның төр составы бик аз өйрәнелгән. Алар арасында паразитлар күп. Органик матдәләр продукциясендә һәм деструкциясендә, хайваннарның туклану чылбырында, әйләнә-тирәнең органик пычрану дәрәҗәсен индикацияләүдә, агым суларны биологик чистартуда һәм сулыкларның үз-үзләрен чистартуында П.ның гамәли әһәмияте гаять зур. Кайберләре кешедә күп кенә авырулар (амёбиаз, лямблиоз, трихомониаз, бизгәк һ.б.) тудыручы булып торалар. П.ны протистология фәне өйрәнә; еш кына «П.» термины протозоология (иң гади төзелешлеләр турындагы фән) синонимы буларак кулланыла. Ш.у.к. *Умырткасызлар, Камчылылар*.

*Әд.:* Кусакин О.Г., Дроздов А.Л. Филема органического мира. Ч. 2. Прокариоты и низшие Евкариоты. СПб, 1998; Протисты: Рук. по зоологии. СПб., 2000. Ч. 1; Copeland H.F. The classification of lower organisms. Palo Alto, 1956; Whittaker R.H. New concept of Kingdoms of organisms // Science. 1969. V. 163; Corliss J.O. The Kingdom Protista and its 45 phyla // Bio Systems. 1984. V. 17; Brusca R.C., Brusca G.J. Invertebrates. Mass., 2002.

*Р.М.Сабиров.*

**ПРОТОПО́ПОВ** Дмитрий Иванович (1806, Казан — 21.2.1857, шунда ук), терапевт, фармаколог, медицина д-ры (1832). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1825), шунда ук, проф. Л.Л.*Фогель* карамагында фармакология репетиторы. 1828 елдан — инспектор ярдәмчесе. 1829–33 тә Петербург мед.-хирургия академиясендә. 1833 тән — Казан ун-тында фармация укытучысы, 1837 дән — гомуми терапия, фармакология һәм рецептура профессоры, 1845–53 тә — мед. ф-ты деканы. 1831 дә С.-Петербургта ваба эпидемиясен бетерүдә катнаша. Хезмәтләре шифалы суларны өйрәнүгә, дару матдәләре химиясенә карый.


Хезм.: Очерки фармакохимии для руководства в преподавании. К., 1838.

**ПРОТОПО́ПОВКА** авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 9 *км* көньяктарак, Сәкел елгасы буенда. 2010 елда 544 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 78%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1565–67 елларда — Пустошь Кеземет, 17 йөздә Куземетева атамасы б-н мәгълүм. Башта Зөя Успение Богородица монастыре карамагында була. 1764 тә халкы — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, 4 тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 234 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 464, 1897 дә — 497, 1908 дә — 460, 1920 дә — 475, 1926 да — 545, 1938 дә — 582, 1949 да — 490, 1958 дә — 419, 1970 тә — 222, 1979 да — 447, 1989 да — 510, 2002 дә — 576 кеше.

**ПРОТОПО́ПОВО** авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 100 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 60%, руслар — 36%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп. 1650 елларда дворяннар Игнатий һәм Василий Протопоповлар нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кувшиновка, Кушниково, Богородский, Павлиновка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1817 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 900,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Рунга волостенда. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 535, 1897 дә — 781, 1913 тә — 960, 1920 дә — 1002,

1926 да — 1290, 1938 дә — 468, 1949 да — 394, 1958 дә — 247, 1970 тә — 209, 1979 да — 159, 1989 да — 115, 2002 дә — 122 кеше.

**ПРОФСОЮЗЛА́Р**, җитештерүнең төрле тармакларында һәм җитештерүгә карамаган өлкәләрдә эшләүчеләрнең социаль-икътисади мәнфәгатьләрен яклау максатыннан һөнәрдәш хезмәт ияләрен ирекле рәвештә берләштергән оешмалар. Казанда беренче һөнәри җәмгыятьләр — сәүдә-сәнәгать хезмәткәрләре, китап басучы эшчеләр һәм табибләр оешмалары 19–20 йөз чикләрендә барлыкка килә. 1905 елның 17 октябрь манифесты яңадан-яңа һөнәри берләшмәләргә ачыктан-ачык теркәлү мөмкинлеге бирә. 1905 нең октябрендә, беренче булып, китап басучы эшчеләр профсоюзы оеша (1906 ның 19 февралендә «Китап басу эше хезмәткәрләре берлеге» — «Союз работников печатного дела» исеме ала); 1905 нең 13 ноябрендә Идел суднолары хезмәткәрләре профсоюзы, 1905 нең 25 ноябрендә — «Сәүдә-сәнәгать предприятиеләре приказчиклары һәм хезмәткәрләре берлеге» («Союз приказчиков и служащих торгово-промышленных предприятий») оеша. А.И.*Догадов* башлангычында 1906 ның 15 июнендә металл б-н эшләүчеләр профсоюзы барлыкка килә. 1906 да Казанда 3 мең кешене берләштергән 10 һөнәри берлек эшли. 1906 ның 4 мартында профсоюзлар эшчәнлеген билгеле бер тәртипкә салу максатыннан «Сәүдә һәм сәнәгать предприятиеләрендә эшләүче затлар яки шул предприятие хуҗалары мәнфәгатендә оештырылган һөнәри җәмгыятьләр турында вакытлыча кабул ителгән кагыйдәләр» («Временные правила о профессиональных обществах, учреждаемых для лиц, занятых в торговых и промышленных предприятиях или для владельцев этих предприятий») басылып чыга. Һәр һөнәри берлек үз уставын нотариуста раслатып, карап тикшерү өчен Җәмгыятьләр һәм берлекләр кабулханәсенә тапшырырга тиеш була. «... вакытлыча кабул ителгән кагыйдәләр» күп кенә П.га үз эшчәнлекләрен ачыктан-ачык алып барырга комачаулык тудыра. 1907 ел башында Казанда П.ның яшерен Үзәк бюросы оеша, аның уставында әлегә таркау П.ны берләштерү һәм Казанда профсоюз хәрәкәтен җәелдерү төп максатлар итеп күрсәтелә. 1905–17 дә Казан губернасында П. саны акрын арта, аларның лидерлары арасында җитди каршылыклар була, хәрәкәт активистлары полиция тарафыннан эзәрлекләнә. Профсоюз хәрәкәте 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң кискен көчәя, июль аена губернадагы профсоюз әгъзалары саны 20 меңгә җитә. 1917 нең апрель урталарында Казан сәнәгать р-ны П. Советы оеша. Әлеге Совет башлангыч профсоюз оешмалары эшенә нигез салу, булганнарының эшчәнлеген үзгәртеп кору юнәлешендә зур хезмәт куя. 1918 нең 22 гыйнварында Казан губернасы П. Советы Уставы кабул ителә. Совет үз алдына түбәндәге бурычларны куя: профсоюз хәрәкәтен җәелдерүгә, эшче сыйныфның икътисади һәм сәяси көрәшенә булышлык итү; тарифлар булдыру, килешүләр төзү һ.б. мәсьәләләрдә аерым берлекләрнең эшчәнлеген көйләү; берлекләрнең сәяси хокукларын яклау; эшчеләргә кагылышлы законнар эшләнешенә йогынты ясау; медицина ярдәме һәм юридик ярдәм күрсәтүне җайга салу, китапханә һәм уку өйләре булдыру, лекцияләр һәм курслар оештыру, хезмәт биржалары һ.б. социаль-сәяси учреждениеләр булдыруда катнашу; эшчеләр хәрәкәтенең башка формадагы оешмалары б-н элемтәгә керү, җыелышлар һәм съездлар уздыру. Совет тарафыннан башында рәис торган Башкарма комиссия төзелә. 1918 ел башына Совет үз эченә Казанның 25 профсоюзын һәм Чистай, Чабаксар, Маринский Посад эшчеләренең Берләштерелгән һөнәри берлекләрен (барлыгы 47700 әгъза) ала. П. һөнәри принциптан чыгып төзелә. Окт. рев-циясеннән соң татар эшчеләре берлекләре эшчәнлеге б-н Үзәк мөселман бюросы җитәкчелек итә. Бюроның 2 вәкиле киңәшү хокукы б-н П. Советына керә. Күп кенә П.да мөселман бюросы була. 1918 дә милли бюроларның берлекләргә кушылу процессы башлана. П.ның 1 нче Бөтенроссия съездында (1918, 7–14 гыйн.) һөнәри берлекләрне җитештерү тармагына карап үзгәртеп кору (эшче һәм хезмәткәрләрне җитештерүнең аеруча әһәмиятле тармаклары яки икътисади эшчәнлек участоклары буенча илкүләм эре берлекләргә оештыру) турында карар кабул ителә. Һөнәри берлекләрнең иң югары органы — елга 2 тапкыр чакырыла торган губерна съезды булачак, съездда П.ның губерна советы сайланачак дип раслана. Казан губернасы Советы җитештерүне контрольдә тотучы фабрика һәм завод ком-тлары (ФЗК) эшчәнлеген үзгәртеп коруга аеруча зур әһәмият бирә. П.дан аермалы буларак, ком-тлар эшчәнлеге барлык эшчеләргә дә кагыла. Профсоюзлар һәм фабрика-завод ком-тларының Казан шәһәр конференциясендә (1918, 17 апр.) ФЗКның үз тармагындагы П.ның башкарма органы булырга тиешлеге турында карар кабул ителә. Татарстан профсоюзларының 1 нче съездында (1920, 22–24 сент.) берлекнең исеме раслана — П.ның Татарстан өлкә советы (өзеклекләр б-н эшли, 1937 дә бетерелә; 1945 тә ВЦСПСның ТАССР буенча Вәкаләтле вәкиле идарәсе оештырыла, 1948 дә бетерелә). Съездда 96 мең кешене берләштергән 17 губерна бүлегеннән һәм 40818 кешене берләштергән 9 өяз һөнәри бюросыннан юлланган 52 делегат катнаша. Берлекләрнең губерна бүлекләре — өлкә ком-тлары, өяз бүлекчәләре — кантон ком-тлары дип үзгәртелә. Президиум, ревизия комиссиясе сайлана. 1920 ел ахырына 22 өлкә ком-ты, 167 кантон бүлекчәсе (164296 әгъза) эшли. ВЦСПСның 4 нче Пленумы карарлары нигезендә 1934 тә респ-када П. күләм ягыннан кечерәйтелә: 37 урынына 78 оешма барлыкка килә. П. Советлар эшчәнлегендә, эшче контрольне тормышка ашыруда, хуҗалык һәм дәүләт органнарын формалаштыруда актив катнаша. 1936 елгы СССР Конституциясендә хезмәт ияләренең П.га берләшү хокукы беркетелә. 1930 елларда респ-ка П.ы хезмәт ияләренең иң массачыл оешмаларының берсенә әверелә (208995 әгъза). Соц. ярышлар, өмәләр, стахановчылык һәм рационализаторлык хәрәкәтләрен оештыруда П. төп көч була. Ватан сугышы елларында П. халык хуҗалыгын сугыш мәнфәгатьләренә көйләүдә, эвакуацияләнгән сәнәгать пр-тиеләрен урнаштыруда, дәүләт йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүдә актив эшчәнлек күрсәтә. ТАССР П.ының 1 нче берлекара конференциясендә (1948, 13 нояб.) П.ның Татарстан өлкә советы торгызыла. П. тарафыннан хезмәт ияләренең культура дәрәҗәсен күтәрүгә зур әһәмият бирелә: 1954 тә респ-ка П.ы карамагында 128 клуб, мәдәният йорты, мәдәният сарае, 90 китапханә, 1100 кызыл почмак, 70 кино күрсәтү җайланмасы була. 1964 тә колхозларда П. оештырыла. ВЦСПС Президиумы (1957, 17 авг.) тарафыннан П. өлкә советларының хокук һәм эшчәнлек даирәсен сизелерлек киңәйткән документ — «Профсоюзларның республика, край һәм өлкә советы турында нигезләмә» («Положение о республиканском, краевом и областном совете профсоюзов») раслана. 1958 нең 15 июлендә СССР Югары Советы «Һөнәри берлекнең фабрика, завод, җирле комитеты хокуклары турында»гы («О правах фабричного, заводского, местного комитета профессионального союза») нигезләмәне раслый. Әлеге документ профкомнарның җитештерү процессы б-н идарә итүдәге хокукларын киңәйтә. 1958 нең башыннан идарә итүдә эшлекле хезмәт киңәшмәләренә игътибар көчәя, алар тиздән даими рәвештә уздырыла башлый: 1970 тә респ-када 1049 иҗтимагый һәм 743 цех даими эшлекле киңәшмәсе исәптә тора.


ПРОФЕССИОНАЛЬНЫЙ СОЮЗ

(ПРОФСОЮЗ СЕЛЬХОЗЛЕСРАБОЧИХ)

Отдел

Отделение

Членский билет №

Фамилия

Имя, отчество

Год рождения

Грамотность

Профессия

Выполн. работа

Общий профстаж

Выдан 192

Подпись владельца билета

Председатель

Секретарь

Авыл һәм урман хуҗалыгы эшчеләре профсоюзының әгъзалык билеты. 1920 еллар.

1990 нан һөнәри берлекләр эшчәнлегенә П.ның Татарстан респ-ка советы җитәкчелек итә. 1995 тән әлеге даирә Татарстан Республикасы П.ы федерациясе (ТР ПФ) карамагында. ТР П.ының иң югары органы — конференция, профсоюз конференцияләре арасында эшли торган башкарма орган — ТР ПФ. Ул 19 тармак профсоюзларын берләштерә. Һөнәри берлекләр эшчәнлегенең хокукый нигезен ТР Конституциясе һәм башка за-

коннар («Һөнәри берлекләр турында» — «О профессиональных союзах», «Коллектив договорлар һәм килешүләр турында» — «О коллективных договорах и соглашениях», «Халыкның хезмәт белән тәэмин ителеше турында» — «О занятости населения» һ.б.) тәшкил итә. 1980 еллар ахыры — 1990 еллар башындагы күчеш чорында Татарстанның һөнәри берлекләре тарафыннан базар икътисады шартларында респ-ка профсоюзларының тотрыклы эшчәнлеген тәэмин итәрлек хокукый нигез булдыру чаралары күрелә. Хезмәт урыннары б-н тәэмин итү, хезмәтне оештыру, хезмәткә түләү, хезмәт шартлары булдыру, гражданнарның хезмәт б-н тапкан керемнәрен инфляциядән саклау, торакка, белем алуга, медицина ярдәменә булган хокукларын тормышка ашыру өлкәләрендә ике якның да мәнфәгатьләрен көйләүгә юнәлдерелгән социаль партнёрлык системасы барлыкка китерелә. ТР ПФ башлангычы б-н 1992 дән социаль һәм хезмәт мөнәсәбәтләрен көйләүгә корылган өч яклы Татарстан комиссиясе үз эшен башлый. Башлангыч профсоюз оешмасы булган пр-тиеләрнең 85% ында 45 — район, тарифлар буенча 30 тармак килешүе төзелә. ТР ПФ Россия Федерациясендә иң эре профсоюз берләшмәләреннән санала (1995 тә — 1,5 млн. чамасы, 2007 дә 1,3 млн.нан артык әгъза исәпләнә). Басма органы — «*Новое слово*» г-сы (1989 дан).

П.ның Татарстан (өлкә, респ-ка) советы рәисләре: А.И.Догадов (1920–21), М.Е.*Ендаков* (1921–23), К.А.Ратёхин (1923–26), Я.И.*Боярский-Шимшелевич* (1926–28), Я.И.*Фин* (1928–29), В.П.Куликов (1929–30), П.В.*Аксёнов* (1930–35), А.Г.*Долотказин* (1945–53), У.Х.Аипов (1953–57), Г.Б.*Бәдыйгов* (1967–65), Ә.Ә.*Милмөхәммәтов* (1965–72), С.Г.*Сафин* (1972–84), Ш.Ә.*Мостаев* (1984–86), Г.С.Баштанюк (1986–89), Р.Ш.Шәмгунов (1989–90), Ф.И.*Гайнуллина* (1990–2000), Т.П.Водопьянова (2000 нән).

*Әд.:* Из жизни профсоюзов Татарстана: Итоги и перспективы работы. К., 1925; Борисов М.И. Профсоюзы Татарской республики за 1925–1926 гг. К., 1927; Саттарова Ф.Ф. Школа коммунизма. К., 1983; Сафин С.Г., Пашковский А.Б. Влиятельная сила. К., 1984; Мирсияпов Т.А., Фомин А.А. Профсоюзы Республики Татарстан: История, опыт, проблемы (1905–1995 гг.). К., 1995.

*Р.Х.Әхмәтҗанов.*


**ПРОФСОЮЗЛАРНЫ́Ң ФИЗКУЛЬТУ́РА-СПОРТ ЖӘМГЫЯТЕ́ ТАТАРСТА́Н РЕСПУ́БЛИКА СОВЕТЫ́**, 1987 елда Казанда «Буревестник», «Зенит», «Спартак», «Труд», «Локомотив», «Урожай» ирекле спорт җәмгыятьләрен (1989 га кадәр Профсоюзларның Бөтенсоюз ирекле физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы) берләштерү юлы б-н оештырыла. 2 меңнән артык физкультура коллективларын берләштерә, аларда шөгыльләнүчеләр саны 400 меңнән артык, физкультура хезмәткәрләренең саны 2 меңнән артык; 3 Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенә күзәтчелек итә; якынча 50 спорт төрен җәелдерә. Матди-техник базасы 21 стадионны, якынча 300 спорт залын, 12 ябык йөзү бассейнын, 3 җиңел атлетика манежын, 2 спорт сараен үз эченә ала. 2005 тә бетерелә. Атаклы спортчылар — А.М.*Абдульманов* (Габделмәнов), Н.К.Афанасьев, А.М.*Галләмова*, З.Р.*Гарипова*, Ф.Ә.*Гатин*, Д.В.*Капустин*, Л.Ф.*Нуретдинова*, Ф.Р.*Солтанова-Жданова*, Н.К.*Хаматов*, Ә.Ш.*Шәйхетдинов*; тренерлар — Л.Ф.*Арсланов*, З.Б.Гафиятуллин, С.К.*Дёмин*, В.А.*Елфимов*, Ю.Ф.Золотов, Ю.М.*Красильников*, В.В.*Краснов*, Ф.Ш.Нуретдинов, В.И.*Осипов*, С.М.Ромадановский, Н.И.*Сентябрёв*, Е.Ә.*Тимержанов*, М.Н.*Чинкин*, И.Р.Шәймәрданов, С.С.*Яруллин*. Совет рәисләре: И.И.Насыйров (1987–89), К.С.Хөснетдинов (1989–2005).



Д.Ф.Прохоренко.



В.Н.Прохоров.



В.К.Проценко.

**«ПРОФСОЮ́ЗНЫЙ ВЕ́СТНИК»**, газета, к. «*Новое слово*».

**ПРОХОРЕ́НКО** Василий Галактионович (17.1.1928, хәзер Белоруссия Респ-касының Гомель өлкәсе Добруш р-ны Крупец а. — 15.8.2004, Яшел Үзән ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). Ленинград хәрби-механика ин-тын тәмамлый (1955). «Серго исем. завод» ҖБдә эшли: конструктор, баш технолог бүлегендә бюро башлыгы, баш технолог урынбасары, баш технолог, баш инженер (1969 елдан), директор (1975 тән), ген. директор (1975–80). 1980–89 да «Прибор» ФҖБдә баш конструктор урынбасары (Мәскәү). П. заводның үсешенә зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә пр-тие үзгәртеп корыла (СССРда көнкүреш суыткычларын җитештерүче иң зур предприятиеләрнең берсенә әверелә). Уйлап табуга 13 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге махсус билгеләнгән эшләнмәләрне камилләштергәне һәм аларны җитештерүдә алдынгы технологияләр булдырганы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ПРОХОРЕ́НКО** Дмитрий Фёдорович (3.11.1906, хәзер Украина Респ-касының Черкасск өлкәсе Золотоноша ш. — 11.1.1977, Чаллы ш.), инженер-төзүче, Соц. Хезмәт Герое (1958). Киев инженерлык-мелиорация ин-тын тәмамлый (1934). 1934–59 елларда «Мәскәү–Идел» каналы, Владивосток шәһәре объектлары, Таллин диңгез порты, «Куйбышевгидрострой» төзелешләрендә прораб, участок башлыгы булып эшли. 1959–71 дә Чаллы шәһәре оешмалары төзелешендә: 3 нче төзелеш-монтаж идарәсе башлыгы (1965 кә кадәр), «Камгэсэнергострой» төзелеш идарәсендә баш технолог. Герой исеме Идел ГЭС корылышында ирешкән уңышлары, электростанциянең монтаж җиһазлары һәм гидрокорылмалары төзелешендә алдынгы яңа алымнар эшләгәне һәм аларны гамәлгә ашырганы өчен бирелә. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПРО́ХОРОВ** Александр Октябринович (6.1.1948, Казан), психолог, психол. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лында, 1986 дан Казан пед. ин-тында, 2001 дән Казан ун-тында, гомуми психол. каф. мөдире (2003 тән). Хезмәтләре кеше халәтләре, аң психологиясенә, психик халәтләрне көйләү мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Психические состояния и их проявления в учебном процессе. К., 1991; Психические состояния и их функции. К., 1994; Психология неравновесных состояний. М., 1998; Саморегуляция психических состояний: феноменология, механизмы, закономерности. М., 2005.

**ПРО́ХОРОВ** Василий Никитович (4.2.1924, Спас кантоны, хәзер Әлки р-ны Хлебодаровка а. — 27.5.1992, шунда ук), Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1940 елда ОСОАВИАХИМның Әлки р-ны бүлегендә инструктор булып башлый. 1953–58 дә Хлебодаровка авыл советы секретаре. 1958–84 тә Әлки р-ның «Салман» с-зында: бүлек идарәчесе, трактор-кырчылык бригадасы бригадиры. Герой исеме бөртекле ашлык һәм терлек азыгы культураларын җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешкән уңышлары һәм техниканы югары җитештерүчән кулланганы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены , 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПРОЦЕ́НКО** Виктор Кузьмич (16.6.1939, Куйбышев өлкәсенең Чапаевск ш.), «Хезмәт Даны» орденының тулы кавалеры (1976, 1981, 1986), ТАССРның атказ. көнкүреш хезмәткәре (1980). Ростов-Дон шәһәрендә техник уч-ще тәмамлый (1960). 1960–94 елларда «Таттелерадиобыттехника» ҖБдә радиомеханик, мастер булып эшли (Казан, Арча, Югары Ослан, Биектау, Лаеш р-ннары). Төсле телевизорларны ремонтлауны беренчеләрдән булып үзләштерә. Каналларның югары ешлыктагы селекторларын ремонтлауның П. керткән ысулы телевизорларны төзә-

тү срокларын сизелерлек кыскарту мөмкинлеген бирә. Медаль, «СССРның мактаулы радисты» билгесе б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

**ПРО́ШЕЧКИН** Александр Иванович (28.4.1946, БАССРның Дәүләкән ш.), инженер-технолог, «Әлмәт насослар заводы» («Әлнас») АҖнең ген. директоры (1982–2001), ТРның, РФнең атказ. машина төзүчесе (1993, 1996). 1968 елда Урал политехник ин-тын тәмамлый (Свердловск ш.). 1969–72 дә Ангарск химия комб-тында эшли. 1972–73 тә Уфа приборлар төзү з-ды мастеры. 1973–82 дә Татарстан «Радиоприбор» ҖБнең Лениногорск ф-лында: цех башлыгы урынбасары, җитештерү-диспетчерлык бүлеге башлыгы, директор урынбасары. 2001–07 дә «Әлмәт насослар заводы» («Әлнас») АҖнең директорлар советы рәисе. П. завод үсешенә зур өлеш кертә. Аның җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла, электр насосларын, комплектлы төяү җайланмаларын (СССРда беренче тапкыр) эшләп чыгару күпкә арта, аларны серияләп җитештерү җайга салына, «ALNAS» — Әлмәт насослары сәүдә маркасы теркәлә. 2 нче дәрәҗә Бөек Пётр ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

*Әд.:* Альметьевский насосный завод: 20 лет пути (1978–1998). Альметьевск, 1998.

**ПРО́ШИН** Юрий Николаевич (19.12.1956, Казакъстан ССРның Семипалатинск ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1996), проф. (1999). 1979 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли (бүленеп), теоретик физика каф. профессоры (1998 дән), шул ук каф. мөдире (2005 тән). 1984–89 да Казан химия-технол. ин-тының химик кибернетика кафедрасында. Хезмәтләре гадәти һәм үтә үткәрүчән металларда, ферромагнетикларда магнит күренешләре теориясенә карый. П. металларда үтәли магнит тишекләре теориясен төзи. Бериш булмаган диссипацияле юка ферромагнитик элпәләрдә спинлы автодулкыннар килеп чыгу мөмкинлеген фаразлый. Катламлы ферромагнитик металл — үтә үткәргеч структуралар өчен якынлык эффекты теориясен төзи һәм мондый системаларда күп кенә күренешләрне (кайтма үтә үткәрүчәнлек) алдан әйтә.


Х е з м.: Магнитный пробой в металлах: спиновая динамика электронов проводимости // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1987. Т. 93, № 4; Магнитный пробой с переворотом спина // Успехи физ. наук. 1995. Т. 165, № 1; Конкуренция сверхпроводимости и магнетизма в гетероструктурах ферромагнетик/сверхпроводник // Успехи физ. наук. 2002. Т. 172, № 2 (автордаш).

**ПРУСС** Нэлла Матвеевна (1.1.1941, Свердловск ш.), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. канд. (1978), проф. (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1997). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Казан химия-технол. ин-тының чит телләр кафедрасында укыта. 1993 тә П. башлангычында һәм аның җитәкчелегендә Казанда, беренчеләрдән булып, дәүләтнеке булмаган югары уку йорты оештырыла (хәзер «ТИСБИ» идарә ун-ты), ул зур уку-укыту, методик һәм фәнни эшчәнлек үзәгенә әверелә. Университет оешканнан бирле аның ректоры. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формирование институтов социальной ответственности предпринимательского сообщества в российских регионах. К., 2009 (автордаш); Модель профессиональной подготовки студентов с нарушениями слуха в условиях негосударственного вуза. К., 2001 (автордаш).

**ПРЫТКО́В** Геннадий Николаевич (25.1.1948, Алексеев р-ны Левашёво а. ), драма актёры, режиссёр, педагог, ТАССР, РФнең халык артисты (1989, 2007). 1968 елда Казан театр уч-щесен тәмамлый һәм Казан Зур драма театры труппасына кабул ителә. Студент елларында ук П. үзендә үзенчәлекле актёрлык сәләте барлыгын тоя һәм В.Н.Войновичның «Ике иптәш» повесте буенча куелган спектакльдә (реж.-педагог Е.А.Каменецкий) Валерка ролен кыю һәм дәртле итеп башкара. Аның Казан Зур драма театры сәхнәсендә уйнаган Гекльберри Финн («Том Сойер маҗаралары», М.Твен романы буенча), Малай («Медея», Ж.Ануй), Пера («Министр ханым», Б.Нушич) кебек беренче рольләрендә үк образның тышкы күренешендә характерның эчке драматизмын чагылдыра алу осталыгы ачыла. П. тарафыннан иҗат ителгән яшь герой образлары тормышта тынгысыз, кешеләргә карата булган таләпләрендә еш кына бик катгый: Давыт («Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Вася («Искиткеч бүләк», Е.И.Габрилович, С.Г.Розен), Узелков («Явызлык», П.Ф.Нилин повесте буенча), Пашка («Иң бәхетле», Э.Я.Володарский). Актёрның Глумов («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский, 1977), Сотников («Урам чаты», В.В.Быков әсәрләре буенча, 1977), Базаров («Аталар һәм балалар», И.С.Тургенев романы буенча, 1979) кебек рольләре эчке дөньяларының күпмәгънәлелеге, яңача чишелешле һәм истә калырлык булулары б-н аерылып тора. Кинг («Карагыз, кем килгән!», В.К.Арро, 1983), Воланд («Мастер һәм Маргарита», М.А.Булгаков романы буенча, 1989), Менахем («Мәрхүмне искә алу догасы», Г.И.Горин, 1992), Кочкарёв, Городничий («Өйләнү», 1992; «Ревизор», 1997, Н.В.Гоголь), Смит («Өч тиенлек опера», Б.Брехт, 2000), генерал Колошин («Америка фахишәсе», И.Квирикадзе, 2002), Босс Манган («Йөрәкләрне яралый торган йорт», Б.Шоу, 2004), Гаев («Чия бакчасы», А.П.Чехов, 2004), Крутицкий («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский, 2007) рольләре П.ның зур тәҗрибә туплаган оста булып өлгерүен, кеше характеры асылына төшенүдә психол. тирәнлеккә, чишелештә масштаблылыкка ирешүен ассызыклый. Актёр иҗатына сәхнәдәге табигый яшәешнең гротесклы форма б-н парадоксаль үрелеп баруы хас. Бу аның Зорро («Тавык күзе», Н.В.Коляда, 1998), Сен-Жермен («Пики дамасы», А.С.Пушкин повесте буенча, 1999), Угаров («Булмас димә — дөнья бу», А.В.Вампилов, 1999) рольләрендә ачык күренә.





Г.Н.П р ы т к о в: 1. Менахем («Мәрхүмне искә алу догасы», Г.И. Горин; сулда — Голда ролендә Г.С. Ишкова); 2. Генерал Колошин («Америка фахишәсе», И. Квирикадзе) рольләрендә.



Г.Н. П р ы т к о в Воланд ролендә («Мастер һәм Маргарита», М.А. Булгаков романы буенча).

1982 дә П. Казан Зур драма театры сәхнәсендә Л.А.Жуховицкийның «Мәхәббәт һәм сагыш хакында» («О любви и печали») пьесасы буенча беренче спектакльне куя. Анда аның режиссёр буларак сәнгатьчә чаралардан оста файдалана белүе, теге яки бу спектакльне сәхнәгә куючы коллективны, уртак бурычны хәл иткәндә, бергә туплый алу сәләте ачык күренә. Алга таба ул Казан Зур драма театры һәм Казан яшь тамашачылар театрында (ТЮЗ) шактый гына спектакльләр куя. Алар арасында «Блез» (К.Манье), «Замокка чакырылганнар» («Приглашённые в замок», Ж.Ануй пьесасы буенча), «Барысы да бетте» («Всё кончено», Э.Олби; Ю.А.Благов б-н берлектә), «Пыяла читлек» («Стеклянная клетка», Д.Б.Пристли) спектакльләре аеруча игътибарга лаек. 1992 дә П. «Театр-99» антрепренёрлык театры оештыра, анда ул «Фрёкен Юлия» (А.Стриндберг), «Бал тәме» («Вкус мёда», Ш.Дилени), «Лолита» (Э.Олби, В.В.Набоков романы буенча), «Sorry» («Гафу», А.М.Галин), «Ахмак» («Дура», М.Ашар) спектакльләрен куя. Алар истә калырлык үзенчәлекле формага ия булу-

лары, ш.у. драматургия материалының, актёрлар эшенең ышандырырлык булуы б-н игътибарны җәлеп итә һәм кызыксыну уята. 1978 дән Казан театр уч-щесендә пед. эшчәнлек алып бара, 2001 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2012).

*Әд.:* Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

*Ю.А.Благов.*

**ПРЯ́ХИН** Владимир Юрьевич (18.9.1963, Үзбәкстан ССРның Сәмәрканд ш.), драма актёры, реж., ТРның халык артисты (2010). 1997–2000 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укый. Сәхнә эшчәнлеген 1980 дә Сәмәрканд шәһәрендәге рус театрында башлап җибәрә. 1996 дан Бөгелмә рус драма театрында, 2010 нан баш режиссёр. Матур тышкы кыяфәте, сәхнәдә үзен иркен тотуы, табигыйлеге, теге яки бу образны тудырганда төрледән-төрле сәнгатьчә чаралар һәм алымнардан оста файдалануы аның һәр чыгышын истә калырлык итә. П. күп кенә зур



В.Ю.Пряхин Стэнли Поуни ролендә («Җәтмәгә эләккән эти», Р.Куни).

образларны уйный: Котэ («Ханума», А.Цагарели), Әскәр («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Подхалюзин («Банкрот», А.Н.Островский), Сергей («Мценск өязендәге леди Макбет», Н.С.Лесков очеркы буенча) һ.б. Режиссёр буларак, «Тәкъдим» («Предложение»), «Юбилей» (А.П.Чехов комедияләре буенча), «Бик гади вакыйга» («Очень простая история», М.Ладо), «Туфраксыз бакча» («Сад без земли», Л.Н.Разумовская), «Соңгы герой» («Последний герой», А.Мардань) спектакльләрен куя.

**ПСЕВДОНИ́М** (грек. pséudos — уйдырма, ялган һәм ónyma — исем, тәхәллүс), чын исем-фамилияне алыштыра алган шартлы исем. П.ның барлыкка килү сәбәпләре: чын фамилиянең начар яңгырашы, бер үк фамилияле берничә кеше булу, цензурага бәйле сәбәпләр, иҗатта үз көченә ышанмау, исемне белдерергә теләмәү һ.б. Барлык әдәбиятларда да, бигрәк тә Шәрекъ әдәбиятында очрый. Татарларда исем (яки кыскартылган исем) һәм кыскартылган фамилиядән барлыкка килгән П.нар киң таралган: **Габдулла Тукай** (Габдулла Тукаев), **Фатих Әмирхан** (Фатих Әмирханов), **Галиәсгар Камал** (Галиәсгар Камалетдинов), **Кави Нәҗми** (Габделкави Нәҗметдинов), **Гадел Кутуй** (Гаделша Кутуев), **Муса Җәлил** (Муса Җәлилов) һ.б. Кайбер П.лар киң таралмый калган очракта, кеше кире үз фамилиясенә кайта (**Разин** — Г.Бәширов, **Бичура** — А.Таһиров); кайвакыт П., фамилияне кысрыклап чыгарып, әдәби исем булып кала (**Кандалый** — Габделҗаббар Габделмәҗит угылы, **Акмулла** — Мифтахетдин Камалетдин угылы, **Дәрдемәнд** — Мөхәммәдзакир Рәмиев, Г.**Минский** — Г.Аллаһбирдиев, Х.**Туфан** — Хизбулла Гөлзизин, Н.**Исәнбәт** — Н.Закиров, С.**Урайский** — М.Мәүлетов). Кайбер очракларда исем П. булып китә (**Сирин** — Сирин Батыршин, Г.**Газиз** — Газиз Гобәйдуллин), аерым очракларда язучы исемен (**Демьян Фәтхи** — Касыйм Фәтхетдинов) яки фамилиясен үзгәртә (Г.**Карам** — Г.Рәхмәтуллин). П. кешенең туган урынын (Сәйф **Сараи**, Габдеррәфыйк **Минзәләви**, Мәхмүд **Кашгари**, Габденасыйр Ибраһим улы **Курсави**, Нәҗип **Думави**), этник группага (**Мишәр**, **Кәбәй** — Ф.Бурнашев), иҗади жанрга мөнәсәбәтле булуын (**Татарин театраль** — Г.Коләхмәтов), социаль чыгышын (**Дамелла** — Ф.Әмирхан), характер үзенчәлеген (**Утмалай** — Г.Кутуй, **Әүлия** — Г.Камал) чагылдырырга мөмкин. Кайбер вакыт автор кыскартылган фамилиясенә сүз өсти (Ф.Сәйфи-**Казанлы**). Аерым язучыларның берничә дистәгә якын П.ы җыела (мәс., Г.Тукайда — 60 тан артык). Бу күренеш бигрәк тә 20 йөз башына хас, чөнки язучылар газета-журналларда да актив язышa. Аерым очракларда, мәс., бер санда язучының берничә мәкаләсе басылганда, автор төрле П. куллана. Кайвакыт автор, мәкаләнең эчтәлегеннән чыгып, төрле типтагы П. ала; мәс., Ф.Әмирхан сатирик әсәрләрен **Ташмөхәммәд** (яки кыскартып **Т-д**), әдәби-тәнкыйди мәкаләләрен **Дамелла**, ә 1917 елдан соң язылганнарын **Марксист** П.ы б-н бастыра. Г.Тукай җитди әсәрләрен тулы исеме б-н, ә сатирик әсәрләрен **Шүрәле**, **Тиктормас**, **Бик усал**, **Мин язмадым**, **Кырмыска** һ.б. П. б-н бастыра. Ш.у.к. *Атрибуция.*


*Әд.:* Һади М. Псевдонимнар хакында берничә сүз // Казан утлары. 1969. № 1; Мәһдиев М. XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар // Казан утлары. 1973. № 12; Рәмиев З. Тукай һәм замандаш әдипләр. К., 2004.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ПСИХИАТРИ́Я** (грек. psychē̃ — җан, iatréia — дәвалау), психик авыруларның этиологиясе, патогенезы турындагы фән, аларны кисәтү, дәвалау, авыруларга ярдәм итүгә караган клиник мед. өлкәсе. Психозлар һәм киеренке халәт чикләре, ш.и. соматик авырулар вакытындагы психик үзгәрешләр һәм шәхес патологиясе П.нең өйрәнү объектын тәшкил итә. Фәнни дисциплина буларак, П. 19 йөздә формалаша башлый, Казан ун-тында 1837 елдан укытыла (курсны Н.А.Скандовский, 1862 дән А.У.Фрезе алып бара)); 1866 да, Россиядә иканче булып, П. каф. оештырыла. А.У.Фрезеның фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе буларак, «Мәхкәмә психологиясенә караган язмалар», («Очерки судебной психологии», 1871) хезмәте, «Психиатрия буенча кыскача курс» («Краткий курс психиатрии», 1881) — Россиядә язылган беренче дәреслек дөнья күрә; Казан округ П. дәваханәсендә А.У.Фрезе, Россиядә беренче булып,



Г.Н.Прытков.



В.Ю.Пряхин.

бәйдән арындыру системасын (норестрент) куллана: авыруларны механик юл б-н нинди дә булса урынга беркетү ысулыннан тулысынча баш тарта. Аның «Акылдан язганнар өчен йортлар төзү» («Об устройстве домов умалишённых», 1862) монографиясе Россиянең башка губерналарында хастаханәләр салуда һәм аларны кулланышка кертүдә үрнәк итеп файдаланыла. Казан ун-ты, С.-Петербургтан кала, П.гә караган мед. учреждениеләре өчен кадрлар әзерләүче иканче үзәк була. А.У.Фрезедан соң ун-тның П. кафедрасына җитәкчелек иткән В.М.Бехтерев (1885–93) психоневрология — кеше турындагы гыйлемнәр комплексы, ә психик чагылышлар нигезендә баш мие эшчәнлегенең анатомик-физиол. үзенчәлекләре ята, дип саный. В.М.Бехтерев тарафыннан психофизиол. лаб-ясе (Көнбатыш Европада иканче) ачыла, невротик тайпылышларны дәвалауның яңа методикасы тәкъдим ителә, тынычландыргыч микстура (соңрак аның исемен ала) уйлап табыла, алкоголизмнан дәвалауда психотерапия ысулы кулланыла. 1883 тә галим «Неврологический вестник» ж-лын гамәлгә куя. В.М.Бехтеревның Казан чоры фәнни эзләнүләре психопатияләргә, йөдәткеч уй-халәткә карата гипнотерапия куллануга, эпилепсияне дәвалауга багышлана. Аның алмашчысы Н.М.Попов (1894–1903) Россиядәге беренче уку ярдәмлеге булган «Психик авыруларның патологик анатомиясенә караган материаллар» («Материалы к патологической анатомии душевных заболеваний», 1896) хезмәтен һәм «Гомуми һәм аерым психопатология буенча лекцияләр курсы»н («Курс лекций по общей и частной психопатологии», 1898) бастырып чыгара. В.П.Осиповның (1906–15) фәнни эшчәнлеге клиник-нозологик юнәлешкә басым ясый. Ул психик авыруларга диагноз куйганда клиник яктан карауны иң мөһиме дип саный, ботулизм һәм имгәнү очракларындагы психик тайпылышларны өйрәнә, фотографик кычкырып уку симптомын кататоник тайпылыш чагылышы буларак тасвирлый (1908), психик тайпылышларны кисәтүгә игътибар бирә, аларның барлыкка килүендә нәселдәнлек б-н бергә социаль факторларның да зур роль уйнавын күрсәтә (йөклелек патологиясе, халык арасында эчкечелек таралу, эпидемияләр, йогышлы авырулар). 1914 тә В.П.Осипов башлангычында мөстәкыйль П. клиникасы — Казан ун-ты студентлары өчен уку-укыту базасы ачыла. Психик авырулар этиологиясендә нәселдәнлек фак-

торын өйрәнгән галим Т.И.Юдин Россия фәне үсешенә зур өлеш кертә. Ул психологияне гомуми медицинаның бер өлеше итеп карый, психик авыруларны фәкать пациентның соматик статусына фәкать дөрес бәя бирү аркылы гына аңларга мөмкин дип саный («Евгеника», 1925; «Психопатик конституцияләр» — «Психопатические конституции», 1926). Аерым психик тайпылышларда нәселдән килгән факторларның роле турында Т.И.Юдин башлаган тикшеренүләрне М.П.Андреев һ.б. дәвам итә. 1930 елларда фәнни эзләнүләрдә клиник-профилактик юнәлеш өстенлек ала. М.П.Андреев психик авыруларның патогенетик классификациясен тәкъдим итә (1966), психик авыруларның сөйләмен магнитофон язмасы һәм осциллограф ярдәмендә тикшеренүнең объектив ысулларын эшли. Галимнәр тарафыннан симптоматик шизофрения билгеләре б-н баручы соматик авырулар вакытындагы психозлар (Е.Н.Мигаловская, С.А.Эсселевич, А.П.Соловцова), сугыш чоры шизофрениясе тасвирлана (Е.С.Станкевич). С.В.Курашов, П. практикасында тире астына кислород өрдерүнең нәтиҗәлелеген өйрәнү өчен, фәнни тикшеренүләр уздыра (1938). 1967 дән психопатологик синдромнар: онейроид (А.К.Сәйфуллина), астеник (В.И.Сердинский) һәм вербаль (Д.М.Менделевич) галлюцинозларның патофизиол. церебраль нигезләрен өйрәнү фәнни эзләнүләрнең төп юнәлешләрен тәшкил итә. Тикшеренү нәтиҗәләре «Психик авыруларның церебраль механизмнары» («Церебральные механизмы психических заболеваний», 1971), «Психик авыру очракларында үзәк нерв системасын өйрәнүнең төп принциплары һәм алымнары» («Основные принципы и методы изучения центральной нервной системы при психических заболеваниях», 1979), «Вербаль галлюциноз» («Вербальный галлюциноз», 1980) тематик җыентыкларында басылып чыга. 1980 еллардан шизофрениядә нәселдәнлекнең роле, баш миенең системалы эшчәнлеге бозылу мәсьәләләре И.Х.Галимов, М.А.Шмакова һ.б.ның фәнни эзләнү даирәсен тәшкил итә. Ачыкланган тайпылышлар үзәк нерв системасының нәселдән килгән факторлар һәм перинаталь чор патологиясенең кушылма тәэсире б-н бәйле дизонтогенезы чагылышы буларак карала. Фармакологлар б-н берлектә клиникада яңа психоактив матдәләргә сынау уздырыла (Н.Н.Идрисов, Т.Г.Медведкова, А.М.Карпов һ.б.). 1980–2000 елларда психик тайпылыш чигендәге киеренке халәтне өйрәнү дәвам итә: соматик һәм органик халәт чикләре Т.Н.Новошинова, С.А.Әкбәрова, М.О.Киселёв, З.Р.Зөлкарнәева, Л.К.Галиуллина; гинекологик патология очракларындагы киеренке халәт чикләре В.Д.Менделевич, Е.А.Сахаров һ.б. тарафыннан өйрәнелә. К.К.Яхинның «Җитештерү өлкәсендәге физик факторлар тәэсире шартларында эшләүчеләрдә психик тайпылыш чиге халәте» («Пограничные психические расстройства у лиц, работающих в условиях воздействия физических факторов производства», 1993), В.Д.Менделевичның «Радикаль онкогинекологик операцияләрдән соң психик тайпылыш чиге халәте» («Пограничные психические расстройства после радикальных онкогинекологических операций», 1994), Л.К.Шайдукованың «Хатын-кызларда алкоголизмның барлыкка килүе һәм барышы» («Особенности формирования и течения алкоголизма у женщин», 2001) хезмәтләре нәшер ителә. 1996 да Казан мед. ун-тында мөстәкыйль мед. психологиясе һәм гомуми психол. каф., П. һәм наркология каф. оештырыла. Фәнни тикшеренүләрнең төп юнәлешләрен психик сәламәтлек халәтенә һөнәри факторлар тәэсирен (Казан мед. ун-тының хезмәт гигиенасы һәм һөнәри авырулар каф. б-н берлектә); эчке нерв авырулары һәм йогышлы авырулар клиникасында соматопсихик һәм психосоматик тәэсир итешүләрне өйрәнү тәшкил итә; мәхкәмә П.се өлкәсендәге эзләнүләр дәвам итә.

Казан ГИДУВында П., наркология һәм психотерапия каф. 1937–57 дә (1953 тән — психоневрология каф.) эшли, 1973 тә эшчәнлеге торгызыла (1986 дан — П. һәм наркология каф.). Д.Г.Еникиев, А.М.Карпов җитәкчелегендә галимнәр тарафыннан кеше шәхесенең төп параметрлары иерархик структурасы барлыкка китергән гомуми биопсихосоциаль модель турындагы гипотезаның аерым аспектлары, ш.у. алкоголь куллану сәбәпле килеп чыккан тайпылышларны дәвалау юллары һәм авырулар патоморфозы өйрәнелә. 1892 дән бирле Казанда В.М.Бехтерев тарафыннан оештырылган Невропатологлар һәм психиатрлар җәмгыяте эшли (к. *Казанда фәнни медицина җәмгыятьләре*). 1974 тә Казанда невропатологлар һәм психиатрларның 3 нче Бөтенроссия съезды уздырыла.

2011 елга ТРда психик тайпылышлар һәм үз-үзләрен тоту тайпылышлары б-н 46303 авыру исәптә тора (100 мең кешегә — уртача 1232,3 авыру); хастаханә учреждениеләрендә 480 психиатр һәм нарколог эшли. Казанда 2 П. каф. (Казан дәүләт мед. ун-ты, Казан дәүләт мед. академиясе; 9 мед. фән. д-ры), *Республика психиатрия хастаханәсе*, 5 психоневрология диспансеры (700 ятак-урын) бар.

*Әд.:* Юдин Т.И. Очерки отечественной психиатрии. М., 1951; Дьяконова И.Н., Попелянский Я.Ю., Чудновский В.С. История развития научной невропатологии и психиатрии в Казани. К., 1974; Менделевич Д.М., Яхин К.К., Менделевич В.Д. Кафедра психиатрии // Казанский медицинский институт, 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

*Д.М.Менделевич.*

**ПСИХИАТРИ́Я КЛИ́НИКАСЫ БИНАСЫ́**, Казандагы архит-ра истәлеге, 1915 елда Казан ун-тының психиатрия клиникасы өчен рациональ юнәлештәге модерн стилендә (кирпеч стиле) И.И.Брюно проекты буенча төзелә. Һәрвакыт башлангыч максатларында файдаланыла. Хәзерге вакытта стационарлы шәһәр психиатрия диспансеры.

Перпендикуляр урнашкан ян-як канатлары б-н үзәк фасад каршында ишегалды-каре (турыпочмаклы эчке ишегалды булган квадрат формасындагы бина) барлыкка китергән ике катлы сузынкы бина. Коридор-кабинет планында төзелгән. Бүлмәләрне юка металл рамалы биек тәрәзәләр яктырта. Фасад дивары кызыл кирпеч һәм штукатурланган яссылык б-н аралашкан. Модерн үрнәкләре тәрәзә йөзлекләрендә һәм фасад детальләренең үзенчәлекле чишелешендә чагыла.

*Әд.:* Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

**«ПТИЦЕВО́Д»**, Бөгелмә р-нындагы дәүләт нәселле кошчылык з-ды. Кошчылык ф-касы 1929 елда төзелә башлый, 1934 тә төзелеп бетә. 1936 да аның составына Бөгелмә орлыкчылык с-зының 1 нче бүлеге, 1957 дә Матросов исем. һәм «Красное Знамя» к-злары керә. 1934 тән «Бөгелмә» кошчылык с-зы, 1960 тан «Бөгелмә» дәүләт нәселле кошчылык з-ды, 1971 дән «Птицевод» дәүләт нәселле кошчылык з-ды. 2006 га, үзгәртеп корулардан соң, пр-тиегә 1 торак пункт карый (Прогресс пос., эшләүчеләр саны 280 кеше); 1435 *га* а.х. файдалану җирләре (ш.и. 1287 *га* сөрүлек җирләр), 183 мең баш кош бар. Төп юнәлеше — нәселле тавыклар йомыркасы һәм кош ите җитештерү. 2006 да 25,1 млн данә йомырка, 296 *т* ит, ш.у. 6668 *т* бөртекле ашлык җитештерелә. 1 тавыктан 264 йомырка алына. 1936 дан — «Род-айланд», 1955 тән — «Русская белая», 1967 дән — «Кристалл-5», 1982 дән — «Беларусь-9», 1987 дән — Бөтенсоюз кошчылык фәнни-тикшеренү технол. ин-ты селекциясе кроссы «П-46», 1998 дән Голландия кроссы «Бованс белый» токымнары үрчетелә. Голландия кроссы «Бованс белый» һәм Россия кроссы «П-46» селекциясеннән Бөгелмә кроссы чыгарыла. 2003 тә Германиядән «Ломанн-LSL» һәм «Ломанн-Браун» кроссының ата-ана формалары кайтарыла.

Хуҗалыкка СССР ВДНХсының 1 нче дәрәҗә дипломнары (1972, 1973, 1983), РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы (1975, 1981, 1983), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Мактау грамотасы (1986) бирелә. «П.» СССР ВДНХсының 4 алтын, 1 көмеш медале б-н бүләкләнә. Эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 3 кешегә — РФнең атказ. а.х. хезмәткәре, 8 кешегә ТРның атказ. а.х. хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелә; 2 кеше — Ленин ордены, 8 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — Халыклар дуслыгы, 5 кеше «Почёт билгесе», 3 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары, 9 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Хуҗалык җитәкчеләре — А.С.Ефремов (1946–50), Ю.Н.*Ягъфәров* (1963–94), Д.Г.Ситдыйков (1996–2003), Ф.С.Якупов (2003–06), Р.А.Рахманов (2006 дан) һ.б. (барлыгы 17 кеше). 2011 дән бөлгенлек процедурасыннан соң «Репродукт» ҖЧҖ.

*И.Н.Афанасьев.*

**ПУАНСЕ́ТТИЯ** (Poinsettia), сөтлегәнчәләр семьялыгыннан күпьеллык куакчыл үсемлекләр ыругы. Биеклеге 1,5 *м* га кадәр. Культурада бер генә төре бар. Чыгышы — Мексика һәм Үзәк Америка. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Яфраклары озын сапларда, бөтен, өскеләре очлы, кырыйлары аерчалы. Чәчәкләре вак, күрексез, ботак очындагы катлаулы чатыр чәчәк төркеменә җый-

налган; күп санлы ачык кызыл яфраклар б-н әйләндереп алынган, алар исә үзенә бертөрле йолдыз хасил итә, шунлыктан П.не еш кына «Яңа ел йолдызы» (декабрь–гыйнварда чәчәк ата) дип тә атыйлар. Ботаклардан үрчетелә, башта, сөтчел сыекчасы агып бетсен өчен, 30 минут җылы суда тотыла. Сентябрь ахырыннан, көннең 2 нче яртысында, чәчәк атуны тизләтү өчен, салкынча караңгы урынга куялар.

**ПУГАЧЁВ** Емельян Иванович (1742 тирәсе, Зимовейская на Дону станицасы — 10.1.1775, Мәскәү), Дон буе казагы, 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышы* җитәкчесе. Җидееллык (1756–63) сугышта катнаша. 1768–74 тәге рус-төрек сугышы вакытында хәрәкәттәге армиягә җибәрелә, хорунжий-казак офицеры дәрәҗәсен ала (1770); авыру сәбәпле өенә кайта. 1771 ахырында Терек казаклары янына кача. 1772 дә Чернигов, Гомель тирәсендә, Иргиз елгасы буенда иске дин тарафдарлары арасында яши. Берничә тапкыр кулга алына, ш.и. 1772 нең декабрендә Җаек казакларын Кубаньга күчәргә өндәгәне өчен, 1773 нең гыйнвар аенда Казан төрмәсендә утыра. Екатерина II указы б-н аны камчыларга һәм Пелым шәһәренә «дәүләт хезмәтенә» җибәрергә тиеш булганнар. 1773 нең май аенда Казаннан Җаек казаклары янына кача. 1773 нең сентябрендә үзен император Пётр III дип белдереп, казаклар фетнәсен күтәрә. П. манифест һәм фәрманнарында халыкка ирек, салымнардан азат булу, дин иреге һ.б. игълан ителә. («Сезгә җир һәм суларыгызны, ипи һәм тозыгызны... дин һәм намусыгызны, байлык һәм хәзинәгезне мәңгегә бүләк итәм»). Идел буе һәм Урал алды рус булмаган халыкларын, ш.и. татарларны (Уфа провинциясендә 34 мең, Казан губернасында 50 меңнән артык кеше) баш күтәрүчеләр хәрәкәтенә тарта. П. көрәштәшләре арасында Б.*Канкаев*, К.*Усаев*; аның Хәрби коллегиясе әгъзасы С.*Сәетов* була. Баш күтәрүчеләр 1773 нең октябреннән 1774 нең мартына кадәр Оренбург шәһәрен камалышта тоталар. Хөкүмәт гаскәрләре 1774 нең март–апрелендә Татищев кальгасе б-н Сакмар шәһәрчеге тирәләрендә П. отрядларын җиңүгә ирешә. П. гаскәре 1774 нең 12 июлендә Казанны штурмлап ала (к. *Казан өчен сугыш*), 15 июльдә җиңелә. П. шуннан соң, Идел аша кичеп, көньякка юнәлә. Август ахырында Кара Яр буенда тулысынча тар-мар ителә; 1774 нең сентябрендә көрәштәшләре тарафыннан хөкүмәткә тотып бирелә. 1774 нең декабрь ахырында Мәскәүдә П. үлем җәзасына хөкем ителә, җәзалап үтерелә.

*Әд.:* Крестьянская война в России в 1773–1775 годах: Восстание Пугачёва: В 3 т. Л., 1961–70; Лимонов Ю.А., Мавродин В.В., Панеях В.М. Пугачёв и пугачёвцы. Л., 1974.

*И.Р.Вәлиуллин.*

**ПУДОВИ́К** Аркадий Николаевич (15.3.1916, Казан губ. Цивильск ш. — 23.2.2006, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1951), РФА мөхбир әгъзасы (1991; 1964 елдан СССР ФА мөхбир әгъзасы), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1991), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1966), Казан шәһәренең мактаулы гражданы (1988). 1938 дә Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, С.М.Киров исем. Казан ясалма каучук з-дында, 1941–45 тә оборона пр-тиесендә эшли. 1945 тән Казан ун-тында, полимерлар химиясе каф. мөдире (1948–88), химия ф-ты деканы (1950–59), проф. (1951). Бер үк вакытта, 1946 дан, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, үзе оештырган элементорганик синтез лаб-ясе мөдире (1964–89), директор (1971–89), дирекция киңәшчесе (1989 дан). Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә карый. П. өч валентлы фосфор һәм аның тиоаналоглары к-таларының тулы булмаган эфирларын гомо- һәм гетероатомлы кабат бәйләнешле туенмаган реагентларга кушу реакциясен (*Пудовик реакциясе*) ача, бу реакциянең синтетик мөмкинлекләре төрлелеген күрсәтә, Р-С бәйләнешенә кислород яки азот кертү б-н бәйле яңа тип кабат төркемләнешләрне (фосфонат-фосфат, аминофосфонат-аминофосфат) таба; дитиофосфатларның структурасы һәм реакциягә сәләте арасындагы үзара бәйләнешнең төп закончалыкларын билгели. Өч валентлы фосфор кушылмаларының (фосфитлар һәм аларның аналоглары, тиофосфитлар, амидофосфитлар, ацилфосфитлар һ.б.) электрофиль реагентлар б-н реакцияләрен (Арбузов нәклассик реакциясе) өйрәнүгә зур өлеш кертә, аларның узу механизмы турында мәгълүмат таба, фосфорорганик кушылмаларның яңа төркемләнешләрен, аларның төрле класс һәм типларын синтезлауның зур мөмкинлекләрен ачыклый. П. β-функциональләшкән алкилфосфонатларны синтезлау (фосфонэтиллау реакциясе) ысулын тәкъдим итә һәм аны күпсанлы α- һәм β-алмашкан алкенил-, кето-, имино- һәм эпоксифосфонатларда куллана. Алканоламин, алкилендиамин, орто-функциональ алмашкан ароматик аминнарны фосфориллау юлы б-н өч, дүрт, биш һәм алты валентлы фосфорның туенган һәм чиксез гетероциклик кушылмаларын синтезлау алымнарын эшли. П. җитәкчелегендә диаза-кушылмалар катнашында диполяр циклльы кушу реакцияләре, фосфонатларның альдегидлар һәм кетоннар б-н үзара тәэсир итешүе (РО-олефинлау реакциясе) өйрәнелә, фосфорорганик кушылмаларның фәзаи һәм электрон структурасы, аларның комплекслар хасил итү үзлекләре тикшерелә. Авыл хуҗалыгы терлекләрен дәвалау өчен мефопран чарасын, этилсидифон дезодорантын, гадәти һәм махсус каучукларны вулканлаштыруны тизләтә торган ускофос һәм тридифос препаратларын эшләүдә катнаша. П. синтезлаган кушылмалар арасында югары радиопротектор, вирусларга каршы, пестицид активлыгына ия булган матдәләр барлыгы ачыкланган. Ленин бүләге (1978), Халыкара Арбузов бүләге (1997) лауреаты. Д.И.Менделеев исем. Бөтенсоюз химия җәмгыятенең Татарстан респ-ка бүлеге рәисе (1964–69). Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Е.И. Пугачёв.



А.Н. Пудовик.

Хезм.: Реакции присоединения фосфорсодержащих соединений с подвижным атомом водорода // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1968. Кн. 19 (автордаш); Реакции производных кислот трёхвалентного фосфора с электрофильными реагентами // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1973. Кн. 23 (автордаш); Тиопроизводные кислот трёхвалентного фосфора. М., 1990 (автордаш); The addition of incomlete esters of phosphorus acids to multiply bonds. The phosphonate-phosphate rearrangment // Chimie organiane du phosphore. 1970. V. 182.

*Әд.:* Коновалова И.В. Аркадий Николаевич Пудовик. К., 2002; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.


**ПУДОВИ́К** Михаил Аркадьевич (11.3.1940, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1984), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе, РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995, 2006). А.Н.*Пудовикның* улы. 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, элементорганик синтез лаб-ясе мөдире (1989 дан). Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. П. җитәкчелегендә күп функцияле фосфорорганик кушылмаларны (ФОК) молекула эчендә трансформацияләп эндоциклик фосфор-углерод бәйләнешле полигетерофосфацикланнар формалаштыру алымы эшләнә. Моно-, поли- һәм спирофосфациклик кушылмаларның яңа тип һәм классларын орто-функциональ алмашкан ароматик аминнар, алканоламиннар, диаминнар һ.б. нигезендә синтезлау мөмкинлеге күрсәтелә. Меркаптокарбонил кушылмаларны фосфориллау һәм силиллау буенча тикшеренүләр үткәрелә, фосфор, күкерт, кремний б-н туенган чиксез циклик һәм сызыкча чыгарылмаларның яңа типлары синтезлана, алар рәтендә моңарчы билгеле булмаган төркемләнешләр табыла. Кайбер энантиосаф ФОК классы вәкилләре синтезлана. Табылган кушылмалар арасында вирусларга һәм бактерияләргә каршы югары активлыкка ия булган, эффектив лантанид экстрагентлары; фосфорорганика гамәлендә кулланыла торган (гидрофосфориль функция кертү, силоксиллау, аминосилиллау, ациламидлау һ.б.) кремний, азот һәм күкерт катнашкан синтон матдәләре ачыкланган. ФОКны стереоселектив синтезлау, кремний-фосфорорганик кушылмалар химиясе, супрамолекуляр химия буенча эшләр җитәкчесе. Уйлап табуга 38 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: 1,3,2-Бензоксазафосфолины. Синтез и свойства // Журн. общей химии. 1993. Т. 73, № 12;

Реакции α-аминофосфонатов с изо(тио)цианатофосфатами(фосфонатами, фосфинатами). Синтез 1,3,4-тиазафосфолинов // Журн. общей химии. 2003. Т. 73, № 8 (автордаш); 1,3,4-Thia(selen)azaphospholines and phospholidines // Heteroatom. chem. 1994. V. 5. № 5–6 (автордаш).

*Әд.:* Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

**ПУДОВИ́К РЕА́КЦИЯСЕ**, алкил(арил)-фосфонит һәм фосфит к-талары тулы булмаган эфирларының, селтеле металлар алкоголятлары катнашында, активлашкан кабатлы бәйләнешле чиксез кушылмаларга кушылулары:



R=Alk; R'=Alk, Ar, OAlk; R"=COAlk, COAr, COOAlk, $CONH_2$, COOH, CHO һ.б.


Диалкил(диарил)фосфитлар һәм фосфор тиокислоталарының тулы булмаган эфирлары да шундый ук реакциягә керә. Чиксез кушылмалар сыйфатында ацетиленлы кушылмалар, полиолефиннар, алкенилфосфонат к-талары эфирлары кулланылырга мөмкин. Ацетиленлы һәм этиленлы углеводородлар, галогенолефиннар, чиксез спиртлар, винил һәм аллил эфирлары нигез катализы шартларында реакциягә кермиләр; алар перекисьлы кушылмалар булганда яки ультрамиләүшә нурланыш астында фосфор к-таларының тулы булмаган эфирлары б-н реакциягә керә. Кирәксез реакцияләр: башлангыч олефиннарның изомерлашуы һәм полимерлашуы, теломеризация (радикаль процесс шартларында), карбонил төркем буенча кушылу реакцияләре. 1947 елда Казан ун-тында А.Н.Пудовик тарафыннан ачыла.

*Әд.:* Вацуро К.В., Мищенко Г.Л. Именные реакции в органической химии: Справ. М., 1976.

**ПУДО́ВКИН** Михаил Александрович (8.11.1914, Казан губ., Зөя өязе Паново а. — 19.12.1984, Казан), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1966), проф. (1966). 1938 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, мәктәптә математика укыта (Куйбышев ш.), Куйбышев индустриаль ин-тының югары матем. һәм теоретик механика кафедрасында эшли. 1940 тан Казан ун-тында матем. анализ, гомуми математика (1950 дән), хисаплау математикасы (1961 дән) кафедраларында; механика-матем. ф-ты деканы (1968). Хезмәтләре чын (реаль) үзгәрешленең функцияләре теориясенә, матем. физика тигезләмәләренә, сыгылмалылык теориясенә, җир асты гидромеханикасына карый. П. — нефть катламнарының эчке контурына су тутыру вакытында җылылык һәм масса күчеше процесслары буенча фәнни юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Беренче булып, катламнарга зур су массалары кергәндә, аларның суынуы проблемасын күтәрә. Җир асты җылылык казаннары теориясенә, скважиналарны бораулау һәм эксплуатацияләү вакытында термогидродинамик процессларны тикшерүгә зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Задачи теплообмена в приложениях к теории бурения скважин. К., 1977 (автордаш); Температурные процессы в действующих скважинах. К., 1977 (автордаш); Краевые задачи математической теории теплопроводности в приложении к расчётам температурных полей в нефтяных пластах при заводнении. К., 1978 (автордаш).

**ПУЛ** (лат. follis (акча капчыгы) сүзеннән), бакыр акча. 13–15 йөзләрдә Алтын Урдада сугыла. Тәңкәнең бер ягында сугылу елы һәм урыны күрсәтелгән, икенче ягында төрле хайваннар, кошлар, чәчәкләр, әйберләр (балта, чүлмәк) яки геом. фигуралар сурәтләнгән. П.ның авырлыгы 1–2 *г* булган. Үзбәк хан акчаларында «уналты пул — дәник» дигән язу бар. 32 П. бер *дирһәмгә* туры килгән. 14–16 йөзләрдә Җүчи П.лары үрнәгендә «пула» сүзе төшерелгән бакыр акчалар Мәскәүдә, Тверь, Углич, Ярославльдә һ.б. кайбер рус шәһәрләрендә сугыла. Урта Азиядә 18 йөз



Бакыр акча. Алтын Урда. 13–15 йөзләр.

ахырыннан (мәс., Бохарада 1774 еллар тирәсендә) 20 йөзгә кадәр сугылган акчалар — П., 4,5 *г* авырлыктагы акчалар карапул дип аталган.

*Әд.:* Мухамадиев А.Г. Древние монеты Поволжья. К., 1990.

*Ә.Г.Мөхәммәдиев.*

**ПУЛА́Т ХАН**, к. *Булат солтан хан.*

**ПУНКТУА́ЦИЯ** (соңгы чор лат. punctuatio, лат. punctum сүзеннән — нокта), 1) *графика* һәм *орфография* б-н берлектә язма телнең төп чараларын барлыкка китерүче алфавиттан тыш график билгеләр системасы (тыныш билгеләре); 2) тыныш билгеләрен кую (П. кагыйдәләре); 3) тел белеменең П. системасы закончалыкларын һәм тыныш билгеләренең кулланылыш нормаларын өйрәнүче бер тармагы. П.нең формалашуы язма рәвештә аралашу таләпләре б-н бәйле була. Төрки рун ядкәрләрендә үк (7–9 йөзләр) П. элементлары кулланылыш таба: сүзләр, сирәк кенә сүзтезмәләр арасында вертикаль урнашкан ике нокта күрергә була. Уйгыр графикалы төрки ядкәрләрдә (10–14 йөзләр) берсе өстенә икенчесе урнашкан ноктала (вертикаль язуда) бер җөмләне икенчесеннән, иярчен җөмләне баш җөмләдән, туры сөйләмне автор сөйләменнән аеру өчен хезмәт иткән; зуррак сегментны аерып күрсәтү өчен, дүрт нокта тибындагы билге дә кулланылган. Иске гарәп язуында тыныш билгеләре кулланылмаган, шуңа күрә төрки телле текстлар бу графикада, гадәттә, аеру билгеләрсез генә язылган. 19 йөз ахырында татар галимнәре һәм телчеләре (К.Насыйри, М.Акъегетзадә һ.б.) гарәп графикасына нигезләнгән татар язуында П. кагыйдәләрен булдыру мөһимлеге турындагы мәсьәләне күтәреп чыгалар. 20 йөз башында Г.Ибраһимов, Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, М.Корбангалиев һ.б.ның татар теле дәреслекләрендә тыныш билгеләре системасы китерелә, рус грамматикасы үрнәгендә татар П.се кагыйдәләре эшләнә. Хәзерге татар П.сендә рус П.сендәге кебек үк 10 билге кулланыла: нокта, сорау билгесе, өндәү билгесе, өтер, нокталы өтер, ике нокта, күп нокталар, сызык, җәяләр, куштырнаклар. Алдагы 8 е, язма телдәге функцияләреннән чыгып, ялгызак билгеләр дип атала. Алар бер-берсенә тыгыз бәйләнмәгән синтаксик берәмлекләрне (җөмләләрне, аларның аерым өлешләрен) аеру өчен хезмәт итә; соңгы 2 се, ш.у. парлы өтерләр һәм сызыклар парлы билгеләр дип атала. Алар текстның төрле өлешләрен интонацион-мәгънәви яктан аерып күрсәтү яки чит сөйләмне оештыру өчен кулланыла. Рус П.се кебек үк татар П.се дә синтаксик (төзелеш), семантик (мәгънәви) һәм интонацион принципларга нигезләнә. Күп кенә тыныш билгеләренең куелуы җөмлә төзелешенә бәйле; нокта җөмләнең тәмамлануын белдерә; өтер, сызык, ике нокта җөмләдәге тиңдәш кисәкләрне, кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен һ.б. очракларда куела. П.нең семантик принцибы лексик һәм синтаксик чаралар б-н белдерелә алмаган теге яки бу мәгънәви бәйләнешләрне һәм төсмерләрне тыныш билгеләре ярдәмендә белдерүдә чагылыш таба: синтаксик омонимнарның аерымлануы (өтер б-н яки өтерсез), кайбер төр синтетик иярчен җөмләләрнең өтерләр б-н аерып күрсәтелмәве һ.б. П.нең синтаксик һәм семантик принциплары үзара тыгыз бәйләнештә, чөнки күпчелек очракта сөйләмне грамматик һәм мәгънәви кисәкләргә бүлү бергә туры килә. П. интонацион үзенчәлекләрне дә чагылдыра: тавыш күбрәк төшкән урында һәм озын пауза булганда нокта куелу, сорау һәм өндәү билгеләре, интонацион сызык һ.б. Шулай да интонацион принцип беренчел әһәмияткә ия түгел һәм синтаксик принцип файдасына бозылырга да мөмкин, мәс., пауза ясалмаган урында тыныш билгесе куелу яки, киресенчә, тыныш билгесе куелмаган урында пауза ясалу очрагы — шундыйлардан.

*Әд.:* Сабиров К.С. Татар телендә тыныш билгеләре. К., 1956; Сафиуллина Ф.С., Ибраһимов С.М., Вафина Э.М. Татар телендә тыныш билгеләре: Белешмә. К., 1995; Хәкимҗан Ф.С., Шәкүрова М.М. Хәзерге татар теле. Пунктуация. К., 2003; Зәкиев М.З. Татар синтаксисы: Югары уку йортлары өчен дәреслек. К., 2008.

*Р.Ә.Закиров, Р.Х.Мөхиярова.*

**ПУРЯ́ЕВ** Айдар Солтангали улы (13.6.1971, Апас р-ны Урта Балтай а.), машиналар төзүче, икътисад фән. д-ры (2010). 1994 елда Кама политехник ин-тын (хәзер Казан ун-тының Чаллы ф-лы) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, җитештерү икътисады, оештыру һәм идарә каф. профессоры. Хезмәтләре машиналар төзелешендә инвестицияләр эшчәнлеге һәм технол. процессларның нәтиҗәлелеге өлкәсенә, икътисади тикшеренүләрнең фәнни нигезләренә карый. Инвестиция проектларының файдасын бәяләү методологиясен, чуен эретү һәм коюда технол. процессларны сайлап алу методикасын эшли.

Х е з м.: Математический аппарат компромиссной оценки эффективности инвестиционных проектов // Вестн. ИНЖЭКОНа. Сер. Экономика. 2009. № 6; Несовершенство оценки синергетической эффективности и эффекта // Казан. наука. 2010. № 7 (автордаш); Компромиссная оценка эффективности инвестиционных проектов глобального значения // Вестн. Ижев. гос. техн. ун-та. 2012. № 2.

**ПУСТЫ́Е МОРКВА́ШИ** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 24 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 104 кеше (руслар, татарлар) яши. «Газовик» ял базасы (элеккеге «Пустые Моркваши» ял йорты). Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Югары Ослан р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1949 да — 92, 1958 дә — 529, 1970 тә — 181, 1979 да — 165, 1989 да — 132, 2002 дә — 122 кеше.


**ПУТА́К** елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының (Олы Чирмешән бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 15,4 *км*, ТР чикләрендә якынча 6 *км*. Бассейнының мәйданы 106,2 *км²*. Идел аръягы калкулыгыннан ага. Елга башы һәм урта агымның төп өлеше — Ульянов өлкәсе терр-ясендә, тамагы Әлки р-ны Апак авылыннан 2,6 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. П.ның 3,3 һәм 5,2 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км²*. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә туена. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км²*. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 83 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,029 *м³/с*. Коры елларда елганың аерым участоклары кибә. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. П. бассейнында су күләме 0,24 млн. *м³* булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

**«ПУТИ́ РЕВОЛЮ́ЦИИ»** («Революция юллары»), тарихи журнал. *Испартның* Татарстан бюросы, РКП(б) өлкә ком-ты органы. 1922–23 елларда Казанда рус телендә (барысы 3 сан) нәшер ителә. Беренче саны 1922 нең мартында чыга. Басманың максаты — Испартның эшен яктырту, рев-ция һәм РКП(б) тарихы б-н кызыксынучыларны хезмәттәшлеккә җәлеп итү. Редакция «Революцион көрәштә катнашучылар һәм аның шаһитлары! Көрәшнең бөек көннәре турындагы хатирәләрегез б-н уртаклашыгыз» дигән мөрәҗәгать бастыра. Журнал матбугатта басылган язмалар, документлар, көндәлекләр, плакатлар, фотосурәтләр, карталар һ.б.ны җыю эшен активлаштырырга тиеш була. 1 нче санда Казан төбәгендәге революцион хәрәкәт б-н бәйле эшлеклеләрнең исемлеге бирелә (Испартка алар турындагы материаллар беренче чиратта кирәк була). Редакция пролетар рев-циянең тәфсилле басма елъязмасын булдырырга планлаштыра. 2 нче һәм 3 нче саннар тематик сан була: 2 нчесе — партиянең яшерен чорына (1880 еллар ахыры — 1905), 3 нчесе 1905–07 елгы рев-циягә багышлана. Журналда С.Е.Лившицның «Казан социал-демократлары тарихыннан очерклар (1888–1916)» («Очерки истории Казанской социал-демократии (1888–1916)», Н.Н.Фирсовның «1917 елгы Крәстиян революциясе (октябрьгә кадәр) һәм Вакытлы хөкүмәт» («Крестьянская революция 1917 (до октября) и Временное правительство») һ.б. мәкаләләр урын ала. А.И.Елизарова-Ульянованың «В.И.Ульянов-Ленинның 1887–89 елларда Казандагы тормышы турында» («О жизни В.И.Ульянова-Ленина в Казани в 1887–89 гг.»), А.Я.Аросевның «Казан тыныч елларда (1906–1909)» («Казань в глухие годы (1906–1909)») һәм «17 ел элек Октябрь көннәре» («Октябрьские дни 17 лет тому назад»), Н.А.Семашконың «1899–1901 елларда Казан социал-демократик төркеме» («Казанская социал-демократическая группа в 1899–1901»), В.Н.Залежскийның «Минем беренче адымнарым» («Мои первые шаги»), А.П.Жаковның «Безнең партия февральдән октябрьгә кадәрге чорда Казанда» («Наша партия в период от февраля до октября в Казани»), И.Н.Волковның «Элекке патша сөргенчесе хатирәләре» («Воспоминания бывшего царского каторжанина») һ.б. истәлекләр басыла. «П.р.» битләрендә күренекле революционерлар М.М.Вахитов, И.Н.Волков, А.П.Комлев, А.С.Кулеш, М.И.Межлаук, Г.Ш.Ольконицкий, Я.М.Свердлов, Е.П.Табейкин, В.А.Тихомиров, Я.С.Шейнкман һ.б. турында истәлек-хатирәләр дөнья күрә. «Материаллар» бүлегендә РСДРПның Казан ком-тлары тарафыннан 1903–05 тә чыгарылган прокламацияләре басыла. Журналда ш.у. Истпарт утырышларының стенограммалары да биреп барыла. Мәскәүдәге «Пролетарская революция» ж-лы редакциясе «П.р.»ны РКП(б) тарихын яктыртучы иң яхшы журналларның берсе дип атый.

*Әд.:* Н е в с к и й В.И. Обзор нашей провинциальной истпартовской литературы // Пролетарская революция. 1923. № 4.

*Р.А.Айнетдинов.*

**ПУТИ́ЛИН** Николай Георгиевич (26.4.1954, Саратов өлкәсенең Татищев р-ны Идолга а.), җырчы (баритон), ТАССРның һәм РФнең халык артисты (1987, 2003). 1980 елда Красноярск сәнгать ин-тын вокал буенча (проф. Е.Иоффель классы) тәмамлый. 1980–84 тә — Коми Респ-касы (Сыктывкар) Музыкаль театры, 1984–91 дә Татар опера һәм балет театры, Мария опера һәм балет театры (С.-Петербург) солисты. Вокал б-н бергәттән зур актёрлык осталыгы, катлаулы образны ачу, көчле театральлек һәм темперамент таләп ителә торган героик, фаҗигале пландагы партияләрне башкара. Җырчыга образларны фәлсәфи яктан ачу, төгәл пластика, форманы сизү хисе, идеаль вокаль техника хас. П. сирәк очрый торган, көчле һәм обертоннарга бай тавышка ия. Репертуары 60 тан артык партияне: Фигаро («Фигароның туе», В.А.Моцарт), Набукко, Риголетто, Жермон, король Филипп, Амонасро, Яго («Набукко», «Риголетто», «Травиата», «Дон Карлос», «Аида», «Отелло», Дж. Верди), Голландец, Клингзор («Оча торган голландец», «Парсифаль», Р.Вагнер), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Эскамильо («Кармен», Ж.Бизе), Барон Скарпиа («Тоска», Дж.Пуччини), Князь Игорь Святославович («Князь Игорь», А.Бородин), Борис Годунов (шул исем. опера, М.Мусоргский), Мизгирь, Григорий Грязной («Кар кызы», «Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Онегин, Мазепа, Елецкий һәм Томский («Евгений Онегин», «Мазепа», «Пики дамасы», П.Чайковский) һ.б.ны үз эченә ала.



Н.Г.Путилин.



Н.Г. П у т и л и н Годунов ролендә (М. Мусоргскийның «Борис Годунов» операсы).


Җырчының концерт репертуарында рус һәм Европа композиторларының вокаль камера музыкасы киң урын алып тора. Күренекле җырчылар һәм дирижёрлар б-н дөньяның иң зур «Метрополитен-Опера» (Нью-Йорк ш.), «Ла Скала» (Милан), «Ковент-Гарден» (Лондон), «Опера Бастий» (Париж), «Гамбург операсы» сәхнәләрендә даими чыгышлар ясый. Соло концерт программалары б-н гастрольләрдә була, Казанда еш чыгыш ясый.

Вокалистларның Халыкара (София, Болгария, 1988), Казанда Ф.И.Шаляпин исем. 1 нче халыкара вокалистлар (1989) конкурслары лауреаты. РФнең Дәүләт бүләге лауреаты (1998).

*Әд.:* Николай Путилин. Шедевры оперного репертуара: Для баритона в сопровождении фортепиано. СПб., 2004.

*Ф.Ш.Салитова.*

**ПУ́ТИН** Владимир Владимирович (7.10.1952, Ленинград), дәүләт эшлеклесе, икътисад фән. канд. (1997), запастагы дәүләт куркынычсызлыгы полковнигы (1999). Ленинград ун-тын (1975), СССР КГБсының 1 нче югары мәктәбен (Мәскәү, 1985) тәмамлый. 1975–84 елларда СССР КГБсының Ленинград идарәсендә, 1985–90 да СССР КГБсы Тышкы разведка идарәсендә, Дрезден шәһәрендә (ГДР) Совет-Германия дуслыгы йорты директоры. 1991–96 да С.-Петербург мэриясенең Тышкы багланышлар ком-ты рәисе. Бер үк вакытта, 1992–94 тә, С.-Петербург хөкүмәте рәисе урынбасары, 1994–96 да — 1 нче урынбасары. 1996–97 дә РФ Президентының эшләр башкаручысы урынбасары. 1997–98 дә РФ Президенты Администрациясе җитәкчесе урынбасары — РФ Президенты Баш контроль идарәсе башлыгы. 1998–99 да РФ Федераль иминлек хезмәте директоры. 1999 ның март–августында РФ Куркынычсызлык советы секретаре. 1999 ның август–декабрендә РФ Хөкүмәте Рәисе. 1999 ның 31 декабреннән РФ Президенты вазифаларын башкаручы. 2000–04 тә, 2004–08 дә РФ Президенты. 2008 нең маеннан РФ Хөкүмәте Рәисе. 2012 нең маеннан РФ Президенты.


В.В. Путин.

П. Президент булган елларда Россия система кризисыннан чыга; илдә конституцион тәртип кертелә, дәүләт институтлары, бердәм хокукый пространство ныгытыла, үзәк, төбәк һәм җирле үзидарәләр вәкаләтләренә чикләүләр билгеләнә; РФнең базар икътисадына күчүе төгәлләнә һәм аның уңышлы эшчәнлегенә шартлар тудырыла, илнең макроикътисади тотрыклылыгы һәм финанс мөстәкыйльлеге тәэмин ителә, чит ил инвестицияләре күләме арта, Россия икътисадын инновацион үсеш юлына күчерү җайга салына; гражданнарның социаль гарантияләре яңартыла; а.х.н, сәламәтлек саклау; торак төзелешен, белем алуны үстерү буенча милли проектлар эшләнә һәм гамәлгә куела; фән, мәдәният, демография өлкәсендә уңай үзгәрешләргә ирешелә, РФнең халыкара позицияләре торгызыла. П. берничә мәртәбә Татарстанда була; аның сүзләре буенча, ТР «төрле мәдәниятләр һәм диннәрнең тыныч һәм туганнарча янәшә яшәвенең» яхшы үрнәге булып тора. Россиядә дөнья цивилизациясе хәзинәсенә зур өлеш керткән фәнни, мәдәни һәм сәнәгый үзәкләрнең берсе буларак, Казанның тарихи ролен исәпкә алып, П. 2000–05 елларда Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек буенча Дәүләт комиссиясен җитәкли, һәм аңа гомумроссия масштабын биреп, 2005 тә бәйрәмнең уңышлы узуына булышлык итә. 2005 нең 26–27 августында Казанда юбилей тантанасы кысаларында П. җитәкчелегендә БДБ илләре башлыклары Советы *саммиты* булып уза; РФнең 81 субъекты башлыклары, федераль министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре катнашында РФ Дәүләт Советы утырышы үткәрелә. 2007 нең 26 июнендә П. ТР Президенты М.Ш.Шәймиев б-н бергә «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары б-н Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамәгә кул куя, аннары ул РФнең Федераль законы сыйфатында раслана. Шартнамә Татарстанның сәяси тормышында яңа этапны билгели, респ-каның яшәп килүче статусын ныгыта, ТР Конституциясен аның дәүләтчелеге нигезе буларак таный.


В.В.Путин Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткәндә БДБ илләре башлыклары белән. Казан Кремле. 26 август, 2005 ел.

П.ның актив булышлыгы б-н 2008 дә Казан 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарын (Универсиада) (2013) уздыру хокукына ия була. 2013 нең мартында РФ Президенты каршындагы физик культура һәм спорт Советы Президиумының 27 нче җәйге Универсиадага әзерлек мәсьәләләренә багышланган утырышын уздыра, утырышта «Казан Россиянең спорт башкаласына әверелә бара», дип билгеләп уза. 2013 нең 6 июлендә Казанда Универсиада ачылу тантанасында катнаша. Хезмәтләре РФнең эчке һәм тышкы сәясәте, Россиянең икътисади үсеше, милли куркынычсызлык мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, чит илләрнең дәүләт бүләкләре, ш.и. Франциянең Почётлы легион ордены Зур хачы б-н бүләкләнә. Казан (2005), С.-Петербург (2006), Әстерхан (2008) һ.б. шәһәрләрнең Мактаулы гражданы.

**«ПУТЬ ИЛЬИЧА́»**, Тәтеш р-нындагы а.х. җитештерү кооперативы. 1990 елда шул ук исем. колхоз җирлегендә оештырыла (1959 да «Путь Ильича» һәм «Ленинский путь» к-зларын берләштерү юлы б-н булдырыла). 1990 да бүлгәләнә, 2004 тә элекке составына кире кайтарыла. Тонширма, Келәш авылларын үз эченә ала; 316 хуҗалыкта 945 кеше яши (шуларның 464 е эшләүчеләр). А.х. файдалану җирләре 5063 *га* (ш.и. 4407 *га* сөрүлекләр), 1557 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 202 сыер), 2087 баш дуңгыз, 61 баш ат исәпләнә. Төп юнәлеше — бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, ит, сөт җитештерү. 2005 тә 6787 *т* бөртекле ашлык, 6383 *т* шикәр чөгендере, 397 *т* ит, 559 *т* сөт җитештерелә. 1 *га* дан бөртекле ашлык уңышы — 30,3 *ц*, шикәр чөгендере — 255 *ц* тәшкил итә. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә, ит — 78,2 *ц*, сөт — 110,2 *ц* җитештерелә. 3 млн. 920 мең сум табыш алына. Хуҗалыкта 3500 баш мөгезле эре терлек симертү комплексы; социаль-мәдәният һәм көнкүреш объектлары бар. Хуҗалык РСФСР МС, ВЦСПСның Күчмә Кызыл Байрагы (1980, 1984, 1985), КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның Мактау грамотасы (1986) б-н бүләкләнә. Эшчеләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 8 кешегә ТАССРның, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелә; 1 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Октябрь Революциясе, 4 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 3 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны ордены», 4 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше Почёт орденнары б-н бүләкләнә. Хуҗалык үсешенә И.В.*Садыйков* (1959–92), Ш.Н.Хөсәенов (1992 дән) зур өлеш кертәләр.

*И.Н.Афанасьев.*

**«ПУТЬ ИЛЬИЧА́»**, журнал; к. «*Коммунист Татарии*».

**ПУХАЧЁВ** Анатолий Павлович (14.3.1940, Алабуга р-ны Мальцево а.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), а.х. фән. канд. (1982), ТАССРның атказ. агрономы (1990). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1965). 1955–59 елларда Братск ГЭСы төзелешендә эшли. 1965–71 дә Казан а.х. ин-тында. 1971–99 да Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының туфрак саклаулы игенчелек лаб-ясе мөдире. 1999 дан ТР экология һәм табигый ресурслар министрлыгының ландшафт профилендәге «Чулпан» дәүләт табигый заказнигы директоры. Дәүләт бүләге агроландшафтлы адаптив игенчелек системасының теоретик нигезләрен эшләгәне һәм җитештерүгә керткәне (Биектау р-нының «Чулпан», Арча р-нының «Игенче» күмәк пр-тиеләре мисалында) өчен бирелә. СССР ВДНХсының бер алтын, ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

**ПУЧКО́ВСКИЙ** Александр Игнатьевич (9.11.1920, Зөя ш. — 19.1.1980, Казан), ветеринар-акушер, вет. фән. д-ры (1968), проф. (1970). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1944), Белоруссия ССРның Лельчицы р-нында вет. табибе булып эшли. 1945–47 елларда «Главзаготскот»ның Казан базасында вет. табибе. 1947 дән Казан вет. ин-тында, 1968–80 дә акушерлык, гинекология һәм ясалма орлыкландыру каф. мөдире. Хезмәтләре терлекләрнең үрчү функциясенә аксымлы азыклар тәэсирен өйрәнүгә, мөгезле эре терлекләрнең кысырлыгын кисәтүгә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рекомендации по профилактике и ликвидации бесплодия крупного рогатого скота в ТАССР. К., 1973 (автордаш); Профилактика бесплодия крупного рогатого скота. К., 1977 (автордаш).

*Әд.:* Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

*М.Г.Зухрабов.*

**ПУЧЫ́** авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 48 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан—Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1409 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; а.х. техникасы һәм а.х. химиясе пр-тиеләре. Урта мәктәп, музыка мәктәбе, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз башында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү һәм күмәч пешерү б-н шөгыльләнә; 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.П.Пугачёв ягында сугыша. 20 йөз башында П.да волость идарәсе урнаша; 3 мәчет (берсе 1911 дә төзелә; архит-ра истәлеге), ир балалар өчен — 3, кызлар өчен 1 мәктәп, 4 тимерчелек, җил тегермәне, печән кабул итү пункты була; сишәмбе базары эшли. Елына ике тапкыр (1–7 июнь, 29 сентябрь — 6 октябрь) ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3020 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин р-ны үзәге. 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 373, 1816 да — 532, 1859 да — 1161, 1870 тә — 1319, 1884 тә — 1567, 1897 дә — 2322, 1906 да — 2420, 1913 тә — 2568, 1920 дә — 2457, 1926 да — 2001, 1938 дә — 1965, 1949 да — 1936, 1958 дә — 2344, 1970 тә — 2490, 1979 да — 2119, 1989 да — 1562, 2002 дә — 1383 кеше. Пучы урта мәктәбен тәмамлаучылар арасында ТРның беренче Президенты М.Ш.*Шәймиев* тә бар.

**ПУ́ШКИН** Александр Сергеевич (26.5.1799, Мәскәү — 29.1.1837, С.-Петербург, Святогорск монастыренда җирләнә, хәзер Псков өлкәсенең Пушкинские Горы пос.), шагыйрь, яңа рус әдәбиятына нигез салучы, рус әдәби телен булдыручы. «Руслан һәм Людмила» («Руслан и Людмила», 1820), «Кавказ тоткыны» («Кавказский пленник», 1822), «Бакчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан», 1824), «Чегәннәр» («Цыганы», 1827), «Полтава» (1829), «Бакыр җайдак» («Медный всадник», 1837) шигъри поэмалары, «Евгений Онегин» (1833) шигъри романы, «Капитан кызы» («Капитанская дочка», 1836), «Белкин повестьлары» («Повести Белкина», 1837), «Дубровский» (1841) романнары, драма әсәрләре, әкиятләр, публицистик мәкаләләр авторы.

Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышы турында тарихи-документаль роман язу нияте б-н, 1833 нең сентябрендә П. Казанда булып китә. Шәһәргә ул 5 сентябрьдән 6 сентябрьгә каршы



«А.С. Пушкин портреты».
Рәссам Г.А. Кипренский. 1827.

төндә килә. Икенче көнне Постаучылар бистәсендә постаучы В.П.Бабин б-н очраша. Ул, шул көннәрнең шаһиты булган әти-әнисе сүзләреннән чыгып, шагыйрьгә 1774 елның июль вакыйгалары турында сөйли. 7 сентябрьдә П. К.Ф.Фукс б-н таныша. Аның турында «Пугачёв тарихы» («История Пугачёва», 1834) романының искәрмәләрендә болай дип яза: «Мин аңа биредә тасвирланган чор һәм шушы як турында күп кенә кызыклы мәгълүматлар ала алганым өчен бик рәхмәтлемен». Әүвәле Пугачёв ставкасы урнашкан урынга — Арча кырындагы Троицкая Нокса авылына (хәзер Казан шәһәренә керә) һәм Кремльгә бара, яшүсмер чагында пугачёвчылар тарафыннан кулга алынган сәүдәгәр Л.Ф.Крупеников б-н очраша. 8 сентябрьдә П. Казаннан китеп бара, юлда үзенең көндәлегенә: «Биредә мин картлар, минем геройның замандашлары б-н кайнаштым, шәһәр читләрен урап уздым, сугыш барган урыннарны карап чыктым, сораштым, язып алдым һәм бу җирләргә килеп чыгуымнан бик канәгать калдым», — дип яза.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан 1899 да Казан ун-ты каршында А.С.Пушкин истәлегенә *Рус телен сөючеләр җәмгыяте* оештырыла. 1956 да М.Җәлил исем. Опера һәм балет театры янында П.га һәйкәл куела (скульп. Н.К.Вентцель).

Ә с ә р.: Собр. соч.: В 10 т. М., 1974–78.

*Әд.:* А р х а н г е л ь с к и й А.С. А.С.Пушкин в Казани (5–8 сентября 1833 года): Несколько заметок о пребывании А.С.Пушкина в Казани с присоединением относящихся к этому литературных материалов. К., 1899; Б о б р о в Е.А. А.С.Пушкин в Казани // Пушкин и его современники: Материалы исследования. СПб., 1905. Вып. 3.

*М.М.Сидорова.*

**ПУ́ЩИН** Павел Петрович (19.6.1768, С.-Петербург — 14.2.1828, шунда ук), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1800), сенатор (1818). Дворяннар нәселеннән. 1781 елдан хәрби хезмәттә. 1788–90 да рус-швед сугышында, 1812 елгы Ватан сугышында катнаша. 1798 нең март–сентябрь айларында Казан коменданты. 1798–1801 дә Казан хәрби губернаторы. Губерна терр-ясендә иң кирәкле ашамлыкларның бәяләрен җайга сала, шуның өчен император Павел I аңа үзенең рәхмәтен белдерә. П. заманында Арча, Спас, Тәтеш өязләре бетерелә (1799), Казан хәрби уч-щесе оештырыла (1801). Хакимияттән законсыз файдаланганы өчен, вазифасыннан азат ителә. 1804 тә аклана, 1805 тән хәрби хезмәтен Эстляндиядә, Варшава герцоглыгында, Бессарабиядә дәвам итә. 1818 дән Сенатның дүртенче департаментында.

*Е.Б.Долгов.*

**ПУКӘ́Л** авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Саба посёлогыннан 15 *км* төньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 189 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1678 дән Букаллы авылы буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Измә исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 947,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 70 ир-ат; 1859 да — 342, 1897 дә — 527, 1908 дә — 713, 1920 дә — 457, 1926 да — 434, 1949 да — 414, 1970 тә — 235, 1979 да — 203, 1989 да — 176, 2002 дә — 195 кеше.

**ПУСКӘ́Н** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 12 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы буенда. 2010 елда 197 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1664 тән Починок Посконь Черме буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Поскань Кутуймас исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 327,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан

Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 17 ир-ат; 1859 да — 180, 1897 дә — 219, 1908 дә — 225, 1920 дә — 253, 1926 да — 264, 1938 дә — 336, 1949 да — 293, 1958 дә — 231, 1970 тә — 239, 1979 да — 231, 1989 да — 198, 2002 дә — 195 кеше.

**ПҮЧИНКӘ́-ЕНА́Й** авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 6 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 88 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1699 га кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.-Е.да мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 808,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинка-Шонгат волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 55 ир-ат; 1859 да — 428, 1897 дә — 841, 1908 дә — 872, 1920 дә — 781, 1926 да — 597, 1938 дә — 482, 1949 да — 255, 1958 дә — 240, 1970 тә — 207, 1979 да — 163, 1989 да — 111, 2002 дә — 100 кеше.

**ПҮЧИНКӘ́-КУЧУ́К** (Мултан) авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 16 *км* көньяктарак, Кенә елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 403 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, марилар — 58%, татарлар — 36%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән рус чыганакларында Починок Кучюковский буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кучюковский, Мултан исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1898 дә ачыла), 2 тимерчелек, тегермән, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 556,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 153, 1897 дә — 246, 1908 дә — 250, 1920 дә — 263, 1926 да — 282, 1938 дә — 333, 1949 да — 287, 1958 дә — 301, 1970 тә — 430, 1979 да — 479, 1989 да — 423, 2002 дә — 485 кеше.

**ПҮЧИНКӘ́-ПОНИ́К** посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кесмәс елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1678 дән Починок по речке Поник буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1888 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 184 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 еллардан Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 8 ир-ат; 1859 да — 101, 1897 дә — 193, 1908 дә — 203, 1920 дә — 227, 1926 да — 94, 1938 дә — 233, 1949 да — 222, 1958 дә — 208, 1970 тә — 229, 1979 да — 143, 1989 да — 77, 2002 дә — 85 кеше.

**ПЧЕЛОВО́Д** (Кортлык) авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 33 *км* көнбатыштарак, Балтач–Кукмара автомобиль юлы буенда. 2010 елда 242 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Арча кантонында, 1928 дән Мамадыш кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 161, 1949 да — 145, 1958 дә — 211, 1970 тә — 259, 1979 да — 239, 1989 да — 224, 2002 дә — 277 кеше.

**«ПЧЕЛОВО́Д»** («Умартачы»), айлык рәсемле журнал. 1910 елның ноябреннән Вятка шәһәрендә, 1913 нең февраленнән С.-Петербургта, 1916 ның октябреннән 1917 нең ахырына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — 1906–16 да «Пчеловодная жизнь» ж-лын чыгарган, умартачылык буенча күп китаплар авторы, «*Журнал Казанского общества пчеловодства*» ж-лы б-н хезмәттәшлек иткән М.А.Дернов. Басмага чыгымнар үсү сәбәпле, Дернов 1916 да «Пчеловодная жизнь» ж-лын Петроградта чыгарудан туктата һәм «П.» редакциясен Казанга күчерә, эчтәлеге һәм бәясе б-н һәркем сатып алырлык журнал чыгаруны максат итеп куя. «П.» «гамәли умартачылык журналы» дигән өстәмә баш б-н чыга («Пчеловодная жизнь» ж-лы «прогрессив умартачылык журналы» дип күрсәтелгән була). Аның һәр саны Дерновның «Умартачылык турында әңгәмәләр»е б-н башлана. «П.» укучыларны умарта кортларын карауның яңа ысуллары, яңа җиһазлар һәм кирәк-яраклар, бал кортларын дәвалауның һәм корткычлар б-н көрәшүнең алдынгы чара һәм ысулларын куллану б-н таныштырып бара. Редакция «Пчела», «Опытная пасека», «Русский пчеловодный лист» һ.б. ж-ллардагы язмаларны күчереп бастыруны гамәлгә кертә. Һәвәскәр умартачыларның сорауларына бирелгән җаваплар зур урын алып тора. «Пчеловодная жизнь» рубрикасында умартачы курслары, түгәрәкләре, артельләре, ширкәтләре, җәмгыятьләре эшчәнлеге, умартачылар съездлары һәм утырышлары эше, Россиянең төрле төбәкләрендә умартачылык торышы һ.б. турындагы мәгълүматлар бастырыла. Умартачылык буенча басмаларга күзәтүгә зур игътибар бирелә.

*Р.А.Айнетдинов.*

**«ПШЕ́ГЛЕНД ИСЛА́МСКИ»** («Przeglad Islamski» — «Ислам күзәтүе»), кварталга бер чыга торган газета. Варшавадагы мөселманнар җәмгыяте органы. 1930–37 елларда Варшавада поляк телендә басыла (1930 да 1–4, 1931 дә 5–6 саннары дөнья күрә, аннары дамими чыкмый). Мөхәррире — В.Джабаги.

**«ПШИ́ШЛОСТЬ»** («Przyszfość» — «Киләчәк»), иҗтимагый-сәяси, әдәби журнал. Поляк демократик эмигрант интеллигенциясе органы. 1918 елда Казанда поляк телендә нәшер ителә. Беренче бөтендөнья сугышы башланганнан соң, Польша, Литва һәм Белоруссиядән күчеп килгән качаклар исәбенә саннары артып тора һәм, башлыча, Казан гарнизоны хәрбиләреннән, ш.у. шәһәр интеллигенциясе, укучылар һәм мещаннардан торган Казан поляк диаспорасы өчен чыга. Беренче саны 1918 нең 31 мартында басыла. Мөхәррире — Я.Ференцевич. Редакция әгъзалары һәм төп авторлары арасында — А.Ванчура, К.Виязовский, М.Каминский, Х.Миансковский, В.Орловский, З.Паздро, К.Сташевский, М.Хубер. Журнал ике бүлектән тора. Беренчесендә Польшаның үткәндәге һәм бүгенге иҗтимагый һәм икътисади тормышының төрле якларын чагылдырган язмалар басыла («Россиядә Польша илчесе», «Уния һәм Федерация», «Галициядә икътисади сәясәт», «Тадеуш Корзон» һ.б. мәкаләләр); икенчесендә Казандагы поляк оешмалары эшчәнлеге яктыртыла («Казанда борынгы поляк ядкәрләрен саклау мәсьәләсе», «Пан Арасимовичның Казан университеты каршындагы рус теле һәм әдәбиятын сөючеләр җәмгыяте җыелышы турындагы хисабы», «Качаклар һәм сугыш корбаннары җәмгыяте җыелышы» мәкаләләре һ.б.). Журналда Казандагы поляк студентлары, Эшчеләр берлегенең Казан бүлеге вәкилләре хатлары да басыла.

*Әд.:* Субаев Н. Из жизни поляков в Казани // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4.

*Т.М.Насыйров.*

**ПЫЖМАРА́** авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 32 *км* төньяктарак, Кубыр елгасы буенда. 2010 елда 402 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында Шубан авылыннан күченүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында П.да 2 мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1172,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Шода волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1859 да — 679, 1884 тә — 960, 1905 тә — 1096, 1920 дә — 1179, 1926 да — 1068, 1938 дә — 845, 1949 да — 561, 1958 дә — 440, 1970 тә — 479, 1979 да — 420, 1989 да — 397, 2002 дә — 415 кеше.

**ПЫЧА́К** авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 156 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, китапханә. 18 йөздә Әсән-Елга авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Исәк Пучинкәсе буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1111,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әсән-Елга волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 557, 1897 дә — 711, 1908 дә — 742, 1920 дә — 674, 1926 да — 566, 1938 дә — 380, 1949 да — 343, 1958 дә — 236, 1970 тә — 200, 1979 да — 174, 1989 да — 155, 2002 дә — 142 кеше.

**ПЫЯЛА́ КОМЫ́**, кварц (90% тан күбрәк) һәм кыр шпатыннан (7% ка кадәр) торучы вак кисәкләргә таркалучан көпшәк утырма токым. Кушылмалары: циркон, рутил, ильменит, гранат, слюда, балчыксыл матдәләр. Татарстанда П.к. ятмалары һәм чыганаклары Идел елгасы һәм аның кушылдыклары (Зөя, Чирмешән, сирәк кенә Кама) утырмаларына туры килә. Республикада П.к. табигый халәтендә, нигездә, яктылык үткәрүчәнлеге түбән булган пыяла эшләнмәләр ясау өчен яраклы. Хәзерге вакытта чыганаклар эшкәртелми.

*Әд.:* Б и р ю л ё в Г.Н., Г о н ю х В.М., К о р н и л о в А.В. Минеральное сырьё. Сырьё стекольное: Справ. М., 1999; Минеральное сырьё. Песок кварцевый: Справ. М., 1999.

*Г.Н.Бирюлёв.*

**ПЫЯЛА́ СӘНӘГАТЕ́**, к. *Васильево пыяла заводы.*

**ПЫЯЛА́Ч КҮБӘЛӘКЛӘ́Р** (Sesiidae, Aegeriidae), күбәләкләр семьялыгы. Канатлары тар, аларның җәеме 15–45 *мм.* Алгы канатларының арткы һәм еш кына шактый өлешендә тәңкәләре юк (исеме шуннан). Аяклары озын, зур типкеле. Гәүдәсе чагыштырмача юан. Гусеницалары агач һәм куак кайрылары астында, сирәк кенә үләнчел үсемлек тамырларында җитлегә. Күп кенә П.к. тышкы билгеләре буенча шөпшәләргә бик охшаш, уклы элпәканатлылар б-н бу охшашлык аларны еш кына дошманнарыннан коткара. 1000 якын төре билгеле, Россиядә — 80 нән артык (8 ыруглан). Татарстан терр-ясендә киң таралганнары: зур тирәк пыялач күбәләге [Sesia (Aegeria) apiformis] — канат җәеме 35–45 *мм*, майдан июльгә кадәр оча, гусеницалары усак, тирәк, сирәк кенә каен, тал, корычагачны зарарлый; карлыган пыялач күбәләге (Aegeria tipulaeformis) — канат җәеме 16–20 *мм*, июнь–июльдә оча, гусеницалары карлыган, крыжовник һ.б. куакларның сабакларын зарарлый; каен пыялач күбәләге (Aegeria scoliaeformis) — бик матур төр, канат җәеме — 30–36 *мм*, июньнән июльгә кадәр оча, каен агачын зарарлый; ш.у. кечкенә тирәк күбәләгендә тимер кара канатлы күбәләк, алмагач пыялач күбәләге, кура җиләге пыялач күбәләге, озынборынсыман пыялач күбәләге, кырмыска пыялач күбәләк һ.б. Ара-тирә шөпшәсыман пыялач күбәләк (Sesia bembeciformis) очрый — канат җәеме — 34–40 *мм*, июнь–июльдә оча, гусеницалары тал агачында һәм кабыгында яшиләр.

*С.Г.Гордиенко.*

**ПЬЯНОБО́Р КУЛЬТУ́РАСЫ** (археол.), Кама алды төбәгендә тимер гасыр (якынча б.э.к. 3 йөз — б.э. 2 йөзе) археол. культурасы. П.к.ның атамасы П.П.Пасынков тарафыннан Пьяный Бор авылы (хәзер Әгерҗе р-ны Красный Бор авылы) терр-ясендә җыелган һәм Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә бүләк ителгән борынгы әйберләр б-н бәйле. П.к. 19 йөзнең соңгы чирегеннән өйрәнелә (П.А.Пономарёв, А.А.Спицын, М.Г.Худяков, В.Ф.Генинг, Б.Б.Агеев һ.б.). 1901 елда А.А.Спицын аны мөстәкыйль культура сыйфатында нигезли. П.к.ның мәдәни-тарихи комплексы охшашлык ягыннан Ананьино, Мазунино, Караабыз һәм Азелино археол. культураларына якын. Фаразланганча, фин-угор кабиләләре тарафыннан калдырылган. П.к. кабиләләре игенчелек, терлекчелек, сунарчылык, балыкчылык б-н шөгыльләнәләр; бигрәк тә терлекчелек үсеш кичерә. Торулыкларның культура катламнарында ат, мөгезле эре терлек, дуңгыз сөякләренең калдыклары табыла. Ш.у. игенчелек тә билгеле бер дәрәҗәдә үсеш ала: Осиново шәһәрлегендә борай, арпа, йомшак бодай, солы бөртекләре очрый. Сунарчылык һәм балыкчылык иkenчел урын тота, мехлы вак җәнлекләр, ихтимал, бик күп ауланган (төп ау коралы — җәя). П.к. кешеләре тимер һәм бакыр металлургиясе б-н таныш була. Чегадино I шәһәрлегендәге казу эшләре вакытында примитив тимер эретү мичләре калдыклары табыла. Бакыр һәм аның эретмәләре бизәмәләр, хатын-кыз һәм ир-ат киемнәренең аерым әйберләрен эшләү өчен кулланыла. Хатын-кыз киемнәренең бизәмәләре һәм детальләре, алар арасында 4,5 *см* га кадәр киңлектәге юка бакыр пластинадан очлары таратып (2,5 *см* га кадәр) эшләнгән кокошниклар, чыбыктан бөҗралар, сигезпочмаклык һәм сорау билгесе рәвешендә ясалган, махсус трубкалы чигә асылмалары, тоташ яки куыш коник трубкалы яфраксыман асылмалар (күп кенә асылмалар Ананьино культурасының шундый ук әйберләре б-н охшаш), кечкенә калкан рәвешендәге, элмәкле һәм өч, сирәгрәк ике кечкенә түгәрәк өстәлгән муен асылмалары гаять үзенчәлекле. Бронза тәңкәләр, фигуралы күкрәк һәм бил (эполетлар рәвешендә) каптырмалары, каеш бизәкләре, күкрәк тәңкәләре, обоймалар, кояш сурәтле аеллар аеруча киң тарала. Шулай ук тимер, бронза, сирәгрәк алтын бизәкләр, көмеш һәм алтын тегелмә бизәкләр очрый. П.к. ядкәрләренең культура катламнарында бронза, тимер һәм сөяк ук, сөңге очлыклары, садак ыргаклары, тимер туры кылычлар, хәнҗәр, гөрзиләр; әвәләп эшләнгән йомры төпле, касәсыман бизәксез балчык савытлар (измәгә төелгән кабырчыклар кушылган) табыла. Каберләр кечерәк сай чокырлар (тирәнлеге 1 *м* дан артмый) рәвешендә казылган. Мәетләр төрле юнәлештә җирләнгән; ялгыз җирләү өстенлек итә, ш.у. парлы һәм күмәк (иң зуры — 11 мәет җирләнгән) каберләр дә очрый. Б.Б.Агеев мәгълүматлары буенча, П.к.на караган 32 каберлек мәгълүм; 2 меңнән артык кабер казып өйрәнелгән. Татарстан терр-ясендә П.к. ядкәрләре Менделеев р-нының Монай һәм Бәзәкә авыллары, Минзәлә р-нының Дәвек һәм Бикбау авыллары, Мөслим р-нының Мәлләтамак һәм Иске Чакмак авыллары янында һ.б. җирләрдә табылган.





1. Бил каешының эполет рәвешендәге бронза каптырмалары; 2. Бронза эшләнмәләр.

*Әд.:* Г е н и н г В.Ф. Археологические памятники Удмуртии. Ижевск, 1958; ш у л  у к. Очерк этнических культур Прикамья в эпоху железа // Тр. КФАН СССР. Сер. гуманитарных наук. 1959. Вып. 2; ш у л  у к. История населения Нижнего Прикамья в пьяноборскую эпоху (чегадинская культура) III в. до н. э. — II в. н. э. // Вопр. археологии Урала. Ижевск, 1970. Вып. 10; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989; А г е е в Б.Б. Пьяноборская культура. Уфа, 1992; С т а р о с т и н П.Н. Пьяноборская культура: Очерк по археологии Татарстана. К., 2001.

*Е.П.Казаков.*

**«ПЯТИДВО́РКА»** посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* читтә урнашкан. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 1920 ләрдә нигез салына. Оештырылган көннән ТАССРның Зөя кантоны Югары Ослан волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Юга-

ры Ослан р-нында. Халык саны: 1938 дә — 51, 1949 да — 43, 1958 дә — 51, 1970 тә — 26, 1979 да — 15, 1989 да — 6, 2002 дә — 2 кеше.

**«ПЯТИЛЕ́ТКА»** совхозы посёлогы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 6 *км* көньяктарак, Вятка елгасы буенда. 2010 елда 455 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 46%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Башлангыч мәктәп-бакча, мәдәният йорты. 1930 елларда нигез салына. Оештырылган көннән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1958 дә — 569, 1970 тә — 558, 1979 да — 419, 1989 да — 483, 2002 дә — 489 кеше.

**ПЯ́ТНИЦКАЯ** Мария Александровна (25.6.1885, Дон гаскәре өлкәсе Новочеркасск ш. — 9.7.1953, Казан), пианистка, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1939), РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1945). 1907 елда Петербург консерваториясен фортепиано классы буенча тәмамлый. 1907–53 тә Казан музыка уч-щесендә, проф. (1921), бер үк вакытта, 1945 тән, Казан консерваториясендә (1947 гә кадәр фортепиано ф-ты деканы) укыта. 20 йөзнең 1 нче яртысында Казанның әйдәп баручы фортепиано педагогы. Шәһәр музыка мәктәпләрен оештыруда актив катнаша. Яшь музыкантларны укытканда классик репертуарга зур игътибар бирә. Казан фортепиано мәктәбен булдыруга зур өлеш кертә. П.ның шәкертләре арасында соңыннан Мәскәү консерваториясе профессорлары булган Б.С.Землянский, С.С.Григорьев, Н.С.Николаева, Саратов консерваториясе профессоры А.А.Бренинг һ.б. бар. Концерт эшчәнлеге алып бара (репертуарында үзәк урынны романтик композиторлар Ф.Шопен, Ф.Лист, Ф.Мендельсон әсәрләре алып тора).

*Әд.:* С п и р и д о н о в а В.М. Дорогие имена // Казань. 1996. № 5/6.

*В.М.Спиридонова.*

**ПЯ́ТНИЦКИЙ** Пётр Григорьевич (1788, С.-Петербург — 1855, Казан губ., Лаеш өязе Шармаш а.), архитектор. 1809 елда СА тәмамлый. 1809–15 тә Эчке эшләр министрлыгының төзелеш бүлеге архитекторы ярдәмчесе, 1815 тән Петербург почтамты архитекторы, 1816 дан 2 нче кадетлар корпусы архитекторы һәм укытучысы. 1820–25 тә Казан ун-тында гражданлык архит-расы архитекторы һәм укытучысы. 1825 тә П. проекты буенча *Казан университетының* төп бинасы төзелә. 1826–34 һәм 1841–46 елларда — Казан шәһәре архитекторы, 1834–41 дә — Казан хәрби кантонистлар батальоннарын биналарга урнаштыру ком-ты архитекторы. Рус классицизмы һәм ампиры вәкиле. П. проектлары буенча ш.у. Казанда юнкерлар пехота уч-щесе бинасы (1830 еллар), *Котелов йорты* (1833), *Алафузов йорты* (1833–34), үзенең шәхси йорты (1835), Алябов йорты (1834–36), хәрби госпитальнең дәвалау корпусы (1840), Манассейн йорты (1843); Казан өязенең Хәтнә авылында Петропавел чиркәве (1830), Чистайдагы *Никола соборы* (1838) һ.б. төзелә.

*Әд.:* Е г е р е в В.В. Архитектор Г.П.Пятницкий: Очерк жизни и творчества. К., 1961; М у р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. словарь. К., 1999.

*Л.М.Мортазина.*

**«ПЯТЬДЕСЯ́Т ЛЕТ ТАТА́РИИ»**, совхоз, 1970 елда Минзәлә р-нының Киров исем. к-зы җирлегендә оештырыла. Совхоз составына Белопахотный посёлогы, Коноваловка, Тупач, Канонерка, Фионовка, Иске Ашпала (үзәк утар) авыллары керә. А.х. җитештерүендә эшләүчеләр саны: 1993 елда — 462, 2002 дә — 216, 2004 тә — 128 кеше. А.х. файдалану җирләренең мәйданы 7,2 мең *га* (ш.и. 6 мең *га* дан артык сөрүлек җирләр). Төп юнәлеш — ит җитештерү. Хуҗалыкта 1980–90 елларда 11 мең баш мөгезле эре терлек үстерү һәм симертү урыны була, Татарстандагы иң зур комплекс эшли. 1981–93 тә 10,4–10,8 мең баш терлек асрала, тәүлеклек артым 1 башка уртача 775–828 *г* тәшкил итә; 100 *га* а.х. файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә, 612–962 *ц* ит җитештерелә. Ит сату (тере үлчәмдә) елына уртача 1981–85 тә 3624 *т*, 1986–90 да 3986 *т*. Совхоз берничә тапкыр СССР, РСФСРның Мактау грамоталары, дипломнар б-н бүләкләнә. Хуҗалык үсешенә С.Н.Хисамиев (1970–78) һәм И.Х.Газизов (1978–89) зур өлеш кертәләр. 1990 елларда җитештерү түбәнәя башлый, 2001 дән хуҗалык табышсыз эшли. 2004 тә ит җитештерү 1986–90 ның уртача дәрәҗәсеннән 35 тапкыр кими. 2005 тә, банкротлыкка чыгу процедураларын узганнан соң, хуҗалык бетерелә, аның терр-ясе «Вамин-Минзәлә» агрофирмасы» ҖЧҖ, «Чулман» агрофирмасы» ҖЧҖ составына керә.

*И.Н.Афанасьев.*

## ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
археол. — археология, археологик
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология, биологик
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль
геогр. — география, географик
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология, гинекологик
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
и.к. — иялек килеш
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
ин-т — институт
ингл. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат
к-та — кислота (исем янында)
К$^{o}$ — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб., лаб-я — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
либр. — либретто
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос. — посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология, психологик
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев. — революцион
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
ст. — станция
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
төрки. — төркичә (төрки телләрдән)
ун-т — университет
ур. — урам
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр

## ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

### Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Дүш./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.—Л. — Мәскәү—Ленинград/Москва—Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

### Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — Meˇxico
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

## БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал (лар)
зап. — записки
кис. — кисәк
кит. — китап
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
т. — том
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләр)
чыг. — чыганак
энцикл. — энциклопедия

## АББРЕВИАТУРАЛАР

ААҖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АҖ — акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Бәйсез Дәүләтләр Берлеге
БР — Башкортстан Республикасы
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибләрнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ДУП — дәүләт унитар предприятиесе
ЖБ — җитештерү берләшмәсе
ЖЧЖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ (КАМАЗ) — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия Мәгариф академиясе
РМФА — Россия Медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — җылылык-электр үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАҖ — ябык акционерлык җәмгыяте

## ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

*А* — ампер
*а.б.* — астрономик берәмлек
*а.к.* — ат көче
*В* — вольт
*Вб* — вебер
*В·А* — вольт-ампер
*Вт* — ватт
*Гн* — генри
*Гц* — герц
*Гпа* — гектопаскаль
*Гс* — гаусс
*г* — грамм
*га* — гектар
*град* — почмакча градус
*Дж* — джоуль
*дБ* — децибел
*дал* — декалитр
*дптр* — диоптрия
*К* — кельвин
*кВт·сәг.* — киловатт-сәгать
*кал* — калория
*кар* — карат
*кг* — килограмм
*Кл* — кулон
*км* — километр
*л* — литр
*лк* — люкс
*лм* — люмен
*м.а.б.* — массаның атом берәмлеге
*м* — метр
*мг* — миллиграмм
*мин.* — минут
*мкм* — микрометр
*мм* — миллиметр
*Н* — ньютон
*окт* — октава
*Па* — паскаль
*рад* — радиан
*с* — секунд
*°С* — градус (Цельсий шкаласы буенча)
*сәг.* — сәгать
*см* — сантиметр
*т* — тонна
*Ф* — фарад
*ц* — центнер
*Э* — эрстед
*эВ* — электронвольт
‰ — промилле

## КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ

(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Тарихи карталар.
Малмыж өязе (35), Мамадыш кантоны (39), Мамадыш өязе (40), Минзәлә кантоны (176), Минзәлә өязе (176), Нугай Урдасы (413).

Районнарның административ карталары.
Мамадыш районы (40), Менделеев районы (135), Минзәлә районы (177), Мөслим районы (268), Нурлат районы (425), Питрәч районы (553).

## КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н — район
с-з — совхоз
ш. — шәһәр
штп. — шәһәр тибындагы посёлок

## ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

**Торак пунктлар**

Татарстан Республикасы башкаласы — Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ЛЕНИНОГОРСК — Шәһәрләр
КУКМАРА — Шәһәр тибындагы посёлоклар
*Тимәш* — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гә кадәр
500 дән 1000 гә кадәр
500 дән кимрәк

**Чик билгеләре**

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
1Р 241 — Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар

Елгалар
Сусаклагычлар

### ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2014 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

### ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

**Чик билгеләре**

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары
Өязләр

**Юл билгеләре**

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

# Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

**Археология.** Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Борһанов, Рафаэль М.Вәлиев, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.

**Архитектура.** С.С.Айдаров (рәис), Г.Н.Айдарова, Х.Г.Надыйрова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.

**Астрономия.** Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.

**Биология.** А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов, Р.Х.Фәйзрахманова.

**География.** Ю.П.Переведенцев (рәис), А.Х.Газизуллин, Ю.А.Горшков, Э.П.Наумов, В.А.Рубцов.

**Геология.** Д.К.Нургалиев (рәис), У.Г.Дистанов, Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Р.Р.Хәсәнов.

**Дәүләт һәм хокук.** В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.

**20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы.** Р.В.Шәйдуллин (рәис), И.Л.Измайлов, И.К.Заһидуллин, Ф.Г.Ислаев, Д.Г.Мостафина.

**20—21 йөзләр Татарстан һәм татар халкы тарихы.** И.Р.Таһиров (рәис), Р.К.Вәлиев, И.А.Гыйләҗев, Р.Р.Салихов, О.В.Синицын.

**20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты.** Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.К.Ганиева, Н.Ш.Хисамов.

**20—21 йөзләр татар әдәбияты.** Д.Ф.Заһидуллина (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.М.Харисов.

**Икътисад.** Ф.Г.Газизуллин (рәис), В.П.Захаров, В.А.Мальгин, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары.** В.З.Гарифуллин (рәис), Е.С.Дорощук, Р.М.Нуруллина, Р.А.Ратникова.

**Математика.** М.М.Арсланов (рәис), А.М.Елизаров, Д.Х.Мөштәри Э.В.Скворцов.

**Медицина. Сәламәтлек саклау.** М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, Р.Г.Исхакова, А.С.Созинов, В.Х.Фазылов.

**Музейлар.** Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, О.Е.Щелковская.

**Музыка.** Р.К.Абдуллин (рәис), В.Р.Дулат-Алиев, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.

**Педагогика, халык мәгарифе.** Җ.Г.Нигъмәтов (рәис), Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Ф.Ә.Шәрифуллин, И.Э.Ярмәкиев.

**Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә.** Ш.М.Вәлитов (рәис), С.А.Нәҗипова, Р.З.Рәхимов, И.Ш.Рахманкулов, К.Ф.Фәсхетдинов.

**Сынлы сәнгать.** Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), З.Ф.Гыймаев, И.К.Зарипов, О.И.Тульская, Х.Г.Якупов.

**Театр сәнгате.** А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, Ю.А.Благов, Д.Ә.Гыймранова, И.И.Илялова.

**Тел белеме.** М.З.Зәкиев (рәис), Л.К.Бәйрәмова, Ф.Ә.Ганиев, Д.Б.Рамазанова.

**Терлекчелек. Ветеринария.** Р.Г.Госманов (рәис), А.М.Алимов, А.В.Иванов, Н.Н.Мөхәммәтгалиев, К.Х.Папуниди, М.Ш.Шәкүров.

**Техника һәм технология.** Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, О.Ш.Даутов, И.М.Закиров, С.О.Мирумянц.

**Торак пунктлар тарихы.** М.И.Әхмәтҗанов (рәис), Д.Г.Мостафина, А.И.Ногманов, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.

**Үсемлекчелек.** Г.Г.Җиһаншин (рәис), Е.И.Захарова, Ф.З.Кадыйрова, М.Л.Пономарёва, И.П.Таланов.

**Фәлсәфә һәм дин.** Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), В.П.Козлов, Н.М.Мөхәррәмов, Р.Ә.Нәбиев, Р.М.Нугаев, Ф.М.Солтанов.

**Физик культура һәм спорт.** Х.Х.Шәйхетдинов (рәис), А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, И.Г.Илдарханов, З.Н.Пантелеева.

**Физика.** К.М.Салихов (рәис), В.А.Голенищев-Кутузов, Ә.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев.

**Фольклор.** Ф.И.Урманчеев (рәис), Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов.

**Хәрби эшлекләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары.** А.А.Иванов (рәис), Н.Х.Булатов, И.Ш.Мостюков, В.Ф.Телишев, С.Н.Погодин, М.В.Черепанов.

**Химия һәм химия технологиясе.** В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин, Ф.П.Мадякин.

**Этнография.** Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, Г.Р.Столярова, С.В.Суслова, Р.К.Уразманова.

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү буенча фәнни мөхәрририят.** М.З.Зәкиев (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Г.Гарипова, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, Р.Ә.Шакирҗанов, А.Г.Яруллина.

## Татар энциклопедиясе институты

Директоры — тарих фән. д-ры Р.М.ВӘЛИЕВ

Директорның беренче урынбасары — тарих фән. д-ры Р.В.ШӘЙДУЛЛИН

Директор урынбасары — Е.С.ЧИЛЯКОВ

Гыйльми секретарь — тарих фән. канд. М.З.ХӘБИБУЛЛИН

*

Татар энциклопедиясенең җаваплы мөхәррире — тарих фән. канд. Г.С.САБИРҖАНОВ

### Бүлекләр

**Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге.** Мөдире — филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: В.Г.Габдрахманова, Л.К.Галиева, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, филол. фән. канд. Г.И.Каюмова, И.Г.Нигъмәтҗанов, Р.И.Хәлиуллина; әдәби мөхәррирләр төркеме: житәкчесе — И.Х.Хәлиуллин; мөхәррирләр: Ф.Р.Бәдретдинова, Р.С.Вафина, Р.И.Раскулова; корректор Ф.Г.Макарова.

**Биология, география һәм геология бүлеге.** Мөдире — а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. канд. В.Г.Бакирова, геол.-минерал. фән. канд. Э.Х.Рәхмәтуллин, О.В.Ерёгин, Л.Р.Камалиева, Р.Э.Рәхмәтуллин.

**Икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге**. Мөдире — Г.Я.Мәүлетова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: икътисад фән. д-ры Ф.С.Зыятдинов, а.х. фән. д-ры Ә.Х.Фазылҗанов, а.х. фән. канд. Р.Ә.Әсретдинова, икътисад фән. канд. М.Җ.Гаитов, И.Н.Афанасьев, С.Г.Белов.

**Иллюстрацияләр һәм картография бүлеге**. Мөдире — Ф.Ә.Ибраһимова, 2014 елдан Г.Р.Дәүләтьянова, өлкән фәнни хезмәткәрләр: геогр. фән. канд. Г.Н.Булатова, Р.Г.Нурмөхәммәтов; фәнни хезмәткәр: сәнгать фән. канд. Л.Н.Донина; фотограф Р.Н.Шакиров.

**Массакүләм мәгълүмат чаралары һәм мәдәният учреждениеләре бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Р.А.Айнетдинов; өлкән фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. З.З.Гыйләҗев.

**Медицина, сәламәтлек саклау һәм спорт бүлеге**. Мөдире — биол. фән. канд. Р.Г.Исхакова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: пед. фән. канд. Н.Д.Бобырев, Л.Ф.Ильина; фәнни хезмәткәр Ф.Ф.Нуриева.

**Рус телендәге текстларны редакцияләү бүлеге**. Мөдире — С.А.Ярмөхәммәтова; мөхәррирләр: Р.Х.Нуриев, Ф.Ш.Әхмәтҗанова, Л.Т.Мөхәммәтшина, Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Табигать һәм техник фәннәр бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. Г.Г.Осокина; өлкән фәнни хезмәткәрләр: физ.-матем. фән. д-ры Р.Г.Усманов, В.Г.Абзалова, Н.Ф.Мироновская, фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

**Тарих һәм иҗтимагый фикер бүлеге.** Мөдире — тарих фән. д-ры Р.В.Шәйдуллин; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. д-рлары Р.М.Вәлиев, Е.П.Казаков, Р.Ә.Нәбиев, тарих фән. канд-тлары Л.М.Айнетдинова, Р.Р.Батыршин, И.Р.Вәлиуллин, Е.Б.Долгов, Ф.Г.Кәлимуллина, Ф.Г.Миңнеханов, М.З.Хәбибуллин; өлкән фәнни хезмәткәр А.В.Климин.

**Тел белеме һәм әдәбият бүлеге**. Мөдире — филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. д-ры Ф.И.Урманчеев; филол. фән. канд. А.М.Ахунов, Л.Р.Әскәрова, Г.М.Габделхакова, Л.Т.Нигъмәтҗанова.

**Торак пунктлар тарихы бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. А.И.Ногманов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд-тлары Р.Р.Ибраһимов, С.А.Фәйзуллин, Х.Ә.Абдулкаюмов; фәнни хезмәткәрләр: Э.В.Әбдрәхимова, Д.М.Васильев.

**Мәгариф һәм мәдәният бүлеге.** Мөдире — тарих фән. канд. Л.М.Айнетдинова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: сәнгать фән. д-ры Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, пед. фән. д-ры Ф.Ш.Салитова, архит. фән. канд. Х.Г.Надыйрова, Ф.Ә.Әхмәтшина, Ю.А.Благов.

**Фәнни мәгълүмат хезмәте һәм библиография бүлеге**. Мөдире — Р.Ф.Шәрәпова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Э.Г.Сәйфетдинова, Г.Р.Садриева, Э.Т.Сибагатуллина; әйдәп баручы библиограф Р.М.Вовченко.

**Фәнни методика һәм контроль бүлеге.** Мөдире — биол. фән. канд. И.Г.Кадошникова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: биол. фән. д-ры Н.Н.Максютова, А.В.Гарзавина, Р.И.Гурьянова, Т.П.Жучкова, Л.М.Сәхапова.

**Фәнни нәшрият бүлеге.** Мөдире — техник фән. канд. Р.Р.Сәләхиев; программист Г.Х.Галимуллина; компьютерда җыючылар: Л.С.Касыймова, Г.К.Кәримова, А.Б.Насыйбуллина, И.И.Насыйбуллина, Л.Р.Хисамиева.

* * *

**Бухгалтерия.** Баш бухгалтер Н.Г.Локманова, бухгалтер-икътисадчы А.Н.Вәлиева.

**Канцелярия мөдире** Г.Р.Вәлиуллина.

**Кадрлар буенча белгеч** Г.Н.Харисова.

**Маркетинг һәм хуҗалык эшләре бүлеге**. Мөдире — Е.С.Чиляков, хуҗалык бүлеге башлыгы Е.Н.Алькова, склад мөдире З.Н.Таҗиева, машина йөртүче Р.Н.Әминов.

## ТЭ 4 нче томының авторлар исемлеге

В.Г.Абзалова, Ш.А.Абилов, М.Ю.Абросимова, Г.Д.Аверьянов, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, И.Е.Алексеев, Е.П.Алексеева, М.С.Алексеева, Х.А.Алиметов, В.В.Амелин, И.И.Андреева, В.А.Анохин, М.М.Арсланов, В.А.Архипов, И.Н.Афанасьев, Е.В.Афонина, А.М.Ахунов, Л.К.Әминов, Н.Х.Әмиров, Л.Р.Әскәрова, А.Г.Әхмәдуллин, М.И.Әхмәтҗанов, Р.Х.Әхмәтҗанов, Э.И.Байбаков, В.Г.Бакирова, В.П.Барабанов, Р.Р.Батыршин, С.Г.Белов, А.Н.Бикташева, Ф.Ш.Бикчурина, Г.Н.Бирюлёв, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, Э.И.Богданов, В.Ф.Богоявленский, Ф.Г.Борһанов, Р.Г.Бохараев, Б.В.Буров, Л.Е.Бушканец, Р.В.Вәлетдинов, Р.К.Вәлиев, Р.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Н.Б.Вәлитов, И.Н.Вәлиуллин, И.Р.Вәлиуллин, Н.Н.Ведерников, О.Г.Вербина, М.А.Верещагин, А.А.Виноградов, В.М.Винокуров, Р.С.Габәшев, Г.Г.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Г.М.Габделхакова, Э.В.Габдрәхимова, И.Р.Габдуллин, А.Х.Газизуллин, М.Җ.Гаитов, И.С.Гайнетдинов, М.В.Гайнетдинов, Б.М.Галиев, М.Ш.Галимова, Т.Н.Галиуллин, Р.Х.Галиуллина, Р.Ш.Ганиев, Р.К.Ганиева, В.И.Гаранин, А.В.Гарзавина, А.А.Гатин, С.Г.Гордиенко, Л.Х.Гордон, В.Н.Горшков, Ю.А.Горшков, М.Г.Госманов, Д.М.Госманова, Г.Б.Гөбәйдуллина, М.Ю.Гребёнкин, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, М.М.Гыйбатдинов, И.Г.Гыйззәтуллин, З.З.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗев, М.Ю.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗетдинов, Д.Ә.Гыймранова, В.И.Данилов, А.П.Дедков, И.Н.Дияров, Е.Б.Долгов, Л.Н.Донина, В.Н.Доронин, В.Р.Дулат-Алиев, И.В.Дьячков, А.М.Елизаров, С.С.Елизарова, А.К.Жеребцов, Ә.Х.Җаббаров, Л.Ш.Җамалетдинов, А.А.Җиһаншин, Ә.М.Закирҗанов, З.Г.Закиров, Р.Ә.Закиров, А.В.Захаров, С.А.Захарова, И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, М.З.Зәкиев, Р.М.Зелеев, С.О.Зорина, М.Г.Зухрабов, Ф.С.Зыятдинов, Ә.И.Ибраһимова, Ф.И.Ибраһимова, И.Л.Измайлов, С.Ю.Измайлова, М.Е.Ильина, О.Н.Ильинская, Н.Б.Ильинский, М.М.Ильясов, И.И.Илялова, С.И.Ионенко, Э.Ф.Ионов, Н.Ф.Исмәгыйлов, Д.М.Исхаков, Н.С.Исхакова, Р.Г.Исхакова, Э.Ә.Ишмаева, Ю.Й.Йосыпов, Н.М.Йосыпова, С.И.Кадошников, И.Г.Кадошникова, Ф.З.Кадыйрова, Е.П.Казаков, Л.Р.Камалиева, Б.А.Канеев, В.Д.Капитов, Ф.Г.Кәлимуллина, А.В.Климин, В.В.Клоков, Е.П.Ключевская, М.Я.Коварская, А.Н.Корнишин, М.Е.Королёв, Т.Е.Костина, О.В.Краснов, В.А.Кузнецов, М.В.Кузнецова, А.А.Куприянова, В.Н.Куршев, Г.Н.Лапшина, Я.А.Левин, Е.В.Липаков, И.Ф.Лобашева, Г.П.Логинов, Н.Л.Лосева, О.Д.Любарская, Е.Л.Любарский, А.Д.Ляшко, Ф.П.Мадякин, Л.И.Майоров, Ф.Г.Макарова, М.А.Малахальцев, М.М.Мәүләтшин, Г.Я.Мәүлетова, Х.Ш.Мәхмүтов, И.В.Мезрина, В.Д.Менделевич, Д.М.Менделевич, М.М.Минһаҗев, Н.М.Минһаҗева, М.М.Миңлебаев, Х.Й.Миңнегулов, Җ.С.Миңнуллин, К.М.Мирзоев, М.Г.Миролюбов, Р.И.Михайлова, Ш.Х.Монасыйпов, Г.А.Морозов, Л.М.Мортазина, М.Ә.Мостафин, М.Р.Мостафин, Р.Ә.Мостафин, Д.Г.Мостафина, И.М.Мөлеков, Р.Х.Мөслимов, Ә.Г.Мөхәммәдиев, Р.М.Мөхәммәтшин, Р.Х.Мөхиярова, Д.Х.Мөштәри, Р.Р.Муллахмәтова, Р.Р.Мусабәкова, Г.П.Мягков, И.Н.Надыйров, Х.Г.Надыйрова, Т.М.Насыйров, В.А.Наумов, Э.П.Наумов, Ф.Г.Нәбиев, К.А.Нәҗипова, Т.К.Нәҗметдинов, Л.Ф.Недашковский, Л.В.Нестеров, З.Н.Нигъмәтҗанов, Р.М.Низамов, И.Н.Никитин, Г.А.Николаев, К.В.Николаева, И.А.Новицкая, А.И.Новицкий, А.И.Ногманов, Д.К.Нургалиев, Г.Г.Нуретдинова, Д.Р.Нуретдинова, Ф.Ф.Нуриева, Ф.Ш.Нуриева, И.В.Овчинников, Г.Е.Осипов, З.Ф.Өметбаева, Ю.П.Переведенцев, С.И.Поляков, Л.Д.Полякова, Е.В.Порфирьева, Н.Б.Прохоренко, С.И.Раимова, Д.Б.Рамазанова, З.З.Рәмиев, Р.Э.Рәхмәтуллин, Э.Х.Рәхмәтуллин, Г.В.Романова, Г.С.Сабирҗанов, Р.М.Сабиров, С.В.Сабиров, А.Ф.Садыйков, Ф.Ш.Салитова, Р.Р.Салихов, Л.И.Саттарова, Р.И.Сафин, Ф.Н.Сафиуллин, С.Г.Сафуанов, М.А.Сәгыйров, З.Н.Сәйдәшева, М.А.Сәйдәшева, Р.С.Сәйфуллин, Г.Р.Сәйфуллина, Р.Р.Сәлахиев, Х.Х.Сәлимов, М.Ф.Сәфәров, Л.М.Свердлова, Л.А.Севастьянова, Л.Н.Севастьянова, Г.И.Середа, Е.А.Серова, М.М.Сидорова, В.В.Силантьев, Р.И.Ситдыйков, А.П.Ситников, А.Э.Скворцов, З.В.Скворцова, А.В.Скоробогатов, В.М.Смелков, Е.О.Смышлявкина, А.С.Созинов, В.Г.Софронов, В.М.Спиридонова, П.Н.Старостин, Р.И.Сулимов, И.Р.Таһиров, В.Ф.Телишев, В.А.Тимесков, В.В.Трепавлов, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усманов, Б.В.Успенский, И.Д.Фадеева, Ә.Х.Фазылҗанов, М.П.Файзуллаева, Ф.Р.Фәизов, Г.Р.Фәйзрахманова, М.Х.Фәйзуллин, К.Ф.Фәсхетдинов, Р.Ә.Фәттахов, Л.А.Федотова, В.Г.Федулов, С.А.Фролова, В.Х.Хаков, Р.Ф.Халитов, Ю.М.Ханжин, Н.Г.Ханзафаров, Р.Ф.Харрасова, Р.Я.Хәбибҗанов, М.З.Хәбибуллин, А.И.Хәбибуллина, Р.Ә.Хәйретдинов, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Р.Хәйретдинов, Д.Р.Хәйретдинова, Ф.К.Хәлиуллин, Л.Х.Хәмидуллин, А.Ә.Хәсәвнех, Р.Ш.Хәсәнов, А.Х.Хәсәншина, Ф.Ш.Хуҗин, Р.А.Циунчук, Д.Э.Цыплаков, М.П.Чензор, А.А.Чижевский, В.А.Шагалов, Л.К.Шайдукова, О.Л.Шайтанов, И.М.Шакиров, Б.Н.Шапуков, Д.Ә.Шаһавиев, Р.В.Шәйдуллин, М.Ш.Шәкүров, Н.Ш.Шәмсетдинов, Ә.М.Шәрипов, Р.Ф.Шәрифуллин, Ф.Л.Шәрифуллина, С.М.Шәфигуллина, А.Н.Шерстнёв, В.Г.Шерпутовский, А.А.Шинкарёв, А.В.Шишкин, Н.В.Шулаев, Е.С.Шуликов, В.В.Шурыгин, Р.З.Юлдашев, В.А.Юрчёнков, В.А.Яковлев.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек», «Ветеринария» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, Е.Г.Бычков, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакиров тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, А.Г.Гаянов, Ф.С.Гобәев, В.А.Голенищев-Кутузов, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, О.Г.Столова, А.Л.Яскович, И.В.Яценко архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры (Р.И.Такташ), Г.Камал исем. Татар академия театры (Л.Г.Шакирҗанова), В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры (Ю.А.Благов) музейлары, Казан (Идел буе) федераль университеты Геология музее (В.В.Силантьев), В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе фотоархивы (Н.Г.Ризванов) фондларыннан алынган фоторәсемнәр һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре А.И.Дубин, Г.В.Фролов коллекцияләреннән алынды.

Томның материалларын туплауда ТР Милли архивы (директоры Л.В.Горохова), ТР Тарихи-сәяси документларны саклау үзәк дәүләт архивы (директоры В.Г.Хәмидуллина), ТР Аудио-визуаль документлар үзәк дәүләт архивы (директоры С.И.Горохов). Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе (директоры Е.Н.Струков), ТР Милли китапханәсе (директоры Н.А.Камбеев), ТР Милли музее (директоры Г.Р.Нәҗипова), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее (директоры Р.М.Нургалиева) хезмәткәрләре катнашты.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР ФА аппаратына, ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына (рәисе В.П.Кандилов), ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенә (Д.И.Ибраһимов), ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (Р.А.Шәйхетдинов), Икътисад (М.Р.Шаһиәхмәтов), Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (М.Г.Әхмәтов), Мәгариф һәм фән (Э.Н.Фәттахов), Мәдәният (А.М.Сибагатуллин), Сәламәтлек саклау (Г.Ю.Вафин) министрлыкларына, Казан (Идел буе) федераль университеты (ректоры И.Р.Гафуров), Казан дәүләт консерваториясе (ректоры Р.К.Абдуллин), Казан дәүләт медицина академиясе (ректоры К.Ш.Зыятдинов), Казан дәүләт медицина университеты (ректоры А.С.Созинов), Казан дәүләт техник университеты (ректоры А.Х.Гыйльметдинов), Казан дәүләт технология университеты (ректоры Г.С.Дьяконов), Казан дәүләт аграр университеты (ректоры Җ.И.Фәйзрахманов); ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (директоры К.М.Миңнуллин), Тарих институты (директоры Р.С.Хәкимов), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (директоры Е.М.Аксёнов), Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (директоры М.Ш.Таһиров) галимнәренә һәм белгечләренә зур рәхмәтен белдерә.

Төрле вакытта Татар энциклопедиясенең 4 нче томын әзерләүдә Ф.Г.Гарипова, Д.Ә.Гыймранова, А.Х.Мәхмүтова, Р.Ф.Халитов, Р.Ә.Шакирҗанов катнашты.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

**Татар энциклопедиясе:** 6 томда / Баш мөхәррир Ә.М.Мазһаров, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабирҗанов. — Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты, 2014. — **4 т.**: М–П. — 632 бит, илл., карталар.

ISBN 978-5-902375-10-1

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан беренче фәнни универсаль басма. Китапта 2966 мәкалә (1513 биографик), 930 иллюстрация (530 төсле) урын алды.

**Tatar ensiklopediəse:** 6 tomda / Baş məxərrir Ə.M.Mazharov, cavaplı məxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: TR FAneñ Tatar ensiklopediəse institutı, 2014. — **4 t.**: M–P. — 632 b., ill., kartalar.

Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannıñ borıngı zamannardan alıp bezneñ kənnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal' basma. Tomda 2966 məqalə (1513 şəxeslərgə qarıy), 930 illustratsiə (530 təsle).

**Татар энциклопедиясе**

4 нче том

Басарга кул куелды 5.7.2014. Махсус кәгазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 66,36. Нәшер-хисап табагы 118,65.
Заказ

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе институты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

Әзер оригинал-макеттан «Алгоритм+» ЯАҖ басмаханәсендә бастырылды.
420044, Казан шәһәре, Ямашев проспекты, 36.
Тел.: (843) 521-49-67. E-mail: npovti_ot@mail.ru.